*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*җитәкчелеге, бу сүзлекне бастырып чыгаруда*
*матди ярдәм күрсәткәннәре өчен,*
***Камил Алим улы Әбләзов, Равил Рифат улы Әбдрәшитов,***
***Илдар Камил улы Тугушев, Рөстәм Рафаил улы***
***Гыйльметдинов** һәм **Локман Камил улы Әбләзовларга***
*рәхмәтен белдерә*

АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА им. Г. ИБРАГИМОВА

**Р. Г. АХМЕТЬЯНОВ**

# ЭТИМОЛОГИЧЕСКИЙ СЛОВАРЬ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

В ДВУХ ТОМАХ

I том

**А–Л**

КАЗАНЬ • ИЗДАТЕЛЬСТВО «МАГАРИФ—ВАКЫТ» • 2015

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исем. ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ һәм СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

Р. Г. ӘХМӘТЬЯНОВ

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ЭТИМОЛОГИК СҮЗЛЕГЕ

ИКЕ ТОМДА

I том

А–Л

КАЗАН • «МӘГАРИФ — ВАКЫТ» НӘШРИЯТЫ • 2015

УДК 494.3
ББК 81.632.3
Ә 87

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Гыйльми советы
карары нигезендә басыла*

Россия Федерациясенең «Авторлык хокуклары һәм арадаш хокуклар турында»гы Законы белән саклана.
Китапка кергән материалларны тулысы белән яки өлешчә башка басмалар өчен файдалану, төрле,
шул исәптән электрон мәгълүмат чыганакларына күчереп яки төшереп алу
авторлык хокукына ия булган затның язма рөхсәтеннән башка катгый тыела

**Редколлегия:**

К.М. МИҢНУЛЛИН, А.Ә. ТИМЕРХАНОВ (җаваплы редактор), М.Х. ВӘЛИЕВ

**Фәнни редактор**

Р.Т. СӘФӘРОВ

**Бәяләүчеләр:**

Д.Б. РАМАЗАНОВА, филол. ф. док., проф., ТФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ;
Ф.М. ХИСАМОВА, филол. ф. док., проф., Казан (Идел буе) федераль университеты

**Әхмәтьянов, Р.Г.**

**Ә 87** Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда. I том (А—Л). — Казан: Мәгариф — Вакыт, 2015. — 543 б.
ISBN

Хәзерге татар лексикографиясендә этимологик сүзлек мондый киң күләмдә һәм чагыштырмача тулы шәкелдә беренче тапкыр нәшер ителә. Сүзлек авторның озак еллар дәвамында алып барган фәнни тикшеренү-эзләнү нәтиҗәләрен, аның бу өлкәдәге табышларын-казанышларын чагылдыра. Сүзлектә барлыгы 10300 чамасы сүзнең килеп чыгышы аңлатылган. Теркәлгән сүзләрнең зур күпчелеге төрки тамырлы берәмлекләр һәм татар теленең диалекталь лексикасы тәшкил итә. Нигездә фонетик яктан үзләштерелгән рус, шулай ук гарәп-фарсы алынмалары да чикләнгән күләмдә кертелгән.

Этимологик сүзлек – филологиянең барча тармакларына иң кирәкле ярдәмлек. Тарихчылар, этнографлар, сәнгатьчеләр һ. б. лар өчен дә ул файдалы белешмә чыганагы була ала. Киң катлам укучылар да монда татар сүзләренең тарихы хакында кызыклы мәгълүмат таба алачак.

Сүзлек, анда тупланган тел материалын мәктәпләрдә, югары уку йортларында уку-укыту программалары кысаларында файдалану өчен шулай ук зур мөмкинлекләр бирә.

ISBN

© Әхмәтьянов Р.Г., 2015
© ТФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ, 2015

## СҮЗ БАШЫ

Татар теленең этимологик сүзлеге – бу юнәлештә башкарылган фундаменталь характердагы беренче хезмәт. Аның эшләнеп нәшер ителүе – татар фән дөньясында һәм киң җәмәгатьчелек тормышында игътибарга лаек зур вакыйга.

Сүзлекне төзүче – танылган тел галиме, профессор, хәзерге вакытта Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фәнни хезмәткәре Р.Г. Әхмәтьянов. Ошбу хезмәт авторның күп еллар дәвамында алып барган фәнни тикшеренү, эзләнү нәтиҗәләрен, аның бу өлкәдәге уңышларын чагылдыра.

Татар теленең төп лексик фондын тәшкил иткән сүзләрнең килеп чыгышын тикшерү, тарихын ачыклау, аларның мәгънәләрен, кулланылыш үзенчәлекләрен билгеләү, лексиканың аерым катламнарына, тематик төркемнәренә караган берәмлекләрне төрлечә якын килеп, аеруча чагыштырма-тарихи планда өйрәнү, нигездә, күпсанлы мәкаләләрдә чагылыш таба килде. Татар этимологиясенә караган махсус хезмәтләрдән исә, иң элек, шул ук авторның берничә монографиясен һәм сүзлекләрен атарга кирәк. 1981 һәм 1989 елларда Мәскәүдә Р.Г. Әхмәтьяновның ике китабы – «Общая лексика духовной культуры народов Среднего Поволжья» һәм «Общая лексика материальной культуры народов Среднего Поволжья» исемле хезмәтләре нәшер ителә. Беренче хезмәттә игътибар үзәгендә мифология, фольклор, календарь һәм гаилә йолаларына караган лексиканы, шулай ук татар, башкорт, чуваш, мари, удмуртлар өчен уртак булган кеше исемнәрен семантик һәм этимологик яклап тикшерү торса, икенчесендә «Табигать, кеше, җәмгыять» кебек зур тематик төркемгә караган 300 дән артык берәмлеккә анализ ясала. Автор билгеләп үткәнчә, йөзләгән сүзләрнең этимологик һәм семантик күрсәткечләре Идел–Кама төбәгендә гасырлар буена янәшә тыгыз аралашып яшәгән төрле этник төркемнәрнең – фин-угор, төрки, рус һ.б.ның бер-берсенә булган көчле йогынтысы турында сөйли.

2003 елда Р.Г. Әхмәтьяновның «Татар терминологиясенең тарихи чыганаклары» дигән монографиясе дөнья күрә. Китапта терминнарның килеп чыгышы, аларның ясалу ысуллары хакында күпсанлы мисаллар белән дәлилләнгән кызыклы мәгълүмат китерелә, нәтиҗәләр ясала. Фәнни даирәләрдә һәм киң катлау укучылар арасында китапка ихтыяҗ зур булганлыктан, ул тиз арада сатылып та бетә.

Авторның этимология өлкәсендәге күпьеллык эшчәнлеге аның лексикографик хезмәтләрендә дә чагылыш таба. 2001 елда укучыга тәкъдим ителгән «Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге» телебезнең төп лексик фондын этимология фәне югарылыгында яктыртуның беренче җитди тәҗрибәсе булып тора. Шуның дәвамы буларак, 2005 елда Р.Г. Әхмәтьяновның бертомлык этимологик сүзлеге дөнья күрә (Бөре, 2005, 233 б.). Ул А–Й хәрефләрен эченә ала һәм, нигездә, автор редакциясендә гамәлгә куела. Төрле сәбәпләр аркасында сүзлекнең башка кисәкләре басылмый кала. Шулай да автор үз эшен туктатмый, эзләнүләрен дәвам итә.

Ниһаять, бүген укучы хөкеменә лексикографик хезмәтнең иң тулы версиясен тәкъдим итү мөмкинлеге туды. Сүзлек – төрки-татар этимологиясе мәсьәләләрен җентекле һәм әтрафлы тикшерү-өйрәнүгә ярты гасырдан артыграк гомерен багышлаган авторның иң зур казанышы.

Ул хәзерге лексикографиядә кабул ителгән принципларга таянып, аеруча этимологик сүзлекләргә куела торган таләпләрне исәпкә алып эшләнде. Ике томнан торган сүзлеккә, вариантларыннан тыш, 10300 чамасы сүз теркәлеп, аларга аңлатмалар бирелде. Аның лөгатьлеген, иң элек, төрки тамырлы сүзләр, шулай ук күпсанлы диалекталь берәмлекләр тәшкил итә. Татар теле тарафыннан күптәннән үзләштерелгән рус сүзләре, чикләнгән

күләмдә гарәп-фарсы алынмалары да бу сүзлек кысаларында тикшерү-тасвирлау объекты булып тора.

Вокабула итеп теркәлгән сүзләр арасында автор үзе реконструкцияләгән, ягъни тел закончалыкларына таянып, телдә сакланып калган дериватлар нигезендә тергезгән сүзләр дә бар. Текстта алар йолдыз тамгасы белән бирелә.

Баш сүз итеп алынган берәмлекләр алфавит тәртибендә урнаштырыла. Төп сүз янында, еш кына, аның диалекталь вариантлары һәм аларны теркәгән чыганаклар күрсәтелә. Төрки тамырлы яки күптәннән үзләштерелгән сүзләргә кардәш һәм кардәш булмаган теллpoints параллельләр, ясалыш модельләре китерелеп, аваз күчешләре, семантик үзгәрешләр һ.б. теркәлә. Алынма сүзләрнең исә, кагыйдә буларак, чыганак теле генә күрсәтелә.

Сүзлек гамәлдәге орфография нигезендә эшләнде. Шулай да, аерым сүзләрнең язылышында авторның үз позициясе дә чагылыш таба. Андый очраклар вокабула сыйфатында норма буларак кабул ителгән сүздән соң аның язылыш вариантын күрсәтү юлы белән билгеләнә. Язылышы белән укылышы арасында аерма булган баш сүзләрнең транскрипциясе дә бирелә.

Текстта автор, хәзерге әдәби тел нормалары югарылыгыннан караганда, искергән яки үтә диалекталь дип кабул ителгән үзенчәлекле берәмлекләрне еш куллана, аерым урыннарда яңарак терминнар да тәкъдим итә. Мисал өчен, *җефетләшү* – кушылгалану (смешение), *күперчекләр* – (этимологик фаразны раслау өчен билгеләнә торган) арадаш яңгырашлар, нигезләр һәм мәгънәләр, *тәкълит* – охшату (подражание), *тәкълиди сүз* – охшату сүзе (подражательное слово), *тәнәйтү* – реконструкцияләү*, чигенте* – кагыйдәдән чыгарма (исключение) һ.б. Андый сүзләр вокабула итеп алынган очракларда гына текстта шул шәкелдә калдырылды.

Сүзлекнең төп өлешеннән тыш, тел гыйлеменең зур бер тармагы буларак, этимология фәне турында күләмле теоретик мәгълүмат та китерелә. Анда этимологиянең максат-бурычлары, тикшерү методикасы һәм ысуллары, этимологик анализның асылы, үзенчәлекле яклары һ.б. күпсанлы мисаллар нигезендә тәфсилләп бәян ителә. Автор хәзерге төрки-татар этимологиясендә булган аерым бәхәсле карашларга да үзенең мөнәсәбәтен белдереп уза. Ахырдан гомумэтимологиягә нисбәтле хезмәтләрнең, кулланылган һәртөрле чыганакларның зур исемлеге китерелә. Кыскасы, сүзлеккә кушып бирелгән бу бай теоретик һәм фактик материал төрки-татар этимологиясе өлкәсендә үзе бер мөстәкыйль уку-укыту әсбабы һәм библиографик чыганак була ала.

Гомумән, эзлекле фәнни принципларга таянып, җентекләп тикшерелгән, өйрәнелгән һәм сүзлеккә теркәлгән ифрат дәрәҗәдәге бай тел материалы төрле тарихи чорларда башка телләрнең татар теленә булган тәэсирен, аның масштабын күзалларга мөмкинлек бирә, димәк, татар халкының үткәнен яхшырак аңларга, аның асылына төшенергә ярдәм итә.

Әлеге хезмәтнең фәнни даирәләр һәм киң җәмәгатьчелек өчен зур әһәмияте аңлаучы затлар – Институт җитәкчелеге һәм хомаячеләр ярдәме белән аның гамәлгә куелганлыгын да ассызыклап үтәргә кирәк. Химаячеләр арасында халкыбызның булдыклы улы тарих фәннәре кандидаты Камил Алим улы Әбләзов һәм аның якыннарына аерым рәхмәтебезне белдерәбез. Сарытау җирендә яшәүче милләтпәрвәр егетләребезнең ярдәме бу файдалы хезмәтнең дөнья күрүен тизләтте.

Сүзлекне басмага әзерләү эшләре Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге мөдире ф. ф. д. А.Ә. Тимерханов җитәкчелегендә оештырылды һәм нәшрият бүлеге хезмәткәрләренең уртак тырышлыгы белән башкарылды. Эш барышында аның эчтәлегенә һәм, гомумән, техник эшләнешенә зур игътибар бирелде: фәнни принципларына тегәллек кертелде, материалны теркәү һәм тасвирлау эзлекле системага салынды, техник эшләнеше камилләштерелде.

Фәнни редакцияләүне, автор белән берлектә, лексикография бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре ф. ф. к. Р.Т. Сәфәров башкарды. «Этимология», «Сүзлеккә кереш» өлешләрен А.Ә. Тимерханов редакцияләде. «Библиография» яңадан эшләнде.

Сүзлектә «Сүз башы» өлешен А.Ә. Тимерханов, «Шартлы кыскартмалар»ны Р.Т. Сәфәров, «Сүзлек мәкаләсенең структурасы»н А.Ә. Тимерханов белән Р.Т. Сәфәров әзерләделәр.

Текстны компьютерда җыю, корректура, биткә салу һ.б.ш. эшләрне Н.Т. Абдуллина белән Е.Ф. Лукьянченко башкарды.

Басманы төзүче автор һәм редколлегия әгъзалары сүзлекнең эчтәлегенә карата әйтеләчәк фикер һәм искәрмәләр өчен аларның авторларына алдан ук рәхмәтләрен белдерәләр. Бәяләмәләрне түбәндәге адреска җибәрергә мөмкин: 420111, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, лексикография бүлеге, Казан шәһ., Лобачевский ур., 2/31, 48 бүлмә. Электрон почта адресы: iyali.anrt@mail.ru

## СҮЗЛЕК МӘКАЛӘСЕНЕҢ ТӨЗЕЛЕШЕ

Ярымкалын баш хәрефләр белән бирелгән һәм алфавит тәртибендә урнаштырылган баш сүз

Баш сүзнең русча аңлатмасы

**АБЫСТАЙ** «жена муллы; учёная женщина», диал. (Рамазанова 1991: 42–51; ТТДС I: 18–19 һ.б.) «старшая сестра» < *абыз тутай* id.; диалектологлар күрсәткәнчә, кайбер төбәкләрдә *абыз* сүзе үзе генә дә «апа» мәгъ. килә һәм шул нигездә *абыз апа, абыз бикә, абыстути* һ.б.ш. кебек шул ук «апа» мәгъ. сүзләр, сүзтезмәләр ясала.

**ҖЕМИЕМ** «полуулыбка; усмешка»; чаг. диал. (Гиганов) *ъмыямень* «усмехаюсь», үзб. *җимий-*, к.-калп., кырг. *жымый-* «авызны ачмыйча елмаю», к.-калп. *жымың* «җемием» <…>.

Автор тарафыннан реконструкцияләнгән нигез сүз формасы

***КАРЫМ** «бастард; метис – человек, родившийся от смешанного брака татарина (татарки) или русского и аборигена Сибири» ~ рус. диал. (Аникин: 270) *карим, харим,* бур. *харим* id. (монг. сүзе диелә), к. каз. (ҚТДС: 196) *қарым* «чыгыш, нәсел» (метислар тур.?) <…>.

Ул тәкъдирдә тат. **карымчак** әлеге **карым** «бастард» сүзенә баглы микән, дигән сорау туа.

***МАЙ-У, майы-у** «загнуться назад; отказаться от решения, передумать; отступить перед трудностями» <…>.

***ӨЛ-Ү** «распределять; разделить» – бу сүз тат. диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) *өлү* ~ як. һ.б. *үлүү* «участок, өлкә» сүзендә чагыла. К. **Өлә-ү.**

Баш сүз аерым кулланылмаган яки аның мәгънәсен контексттан тыш ачып булмаган очрак

Баш сүзгә китерелгән сүзтезмә компонентларының лексик вариантлары

**КӘЗ: кәз-кәз басу (йөрү, атлау)** «размеренно и быстро шагать»; чаг. каз. *каз-каз басу* id. **Каз** сүзеннәнме?

.

Мәгънә уртаклыгы нигезендә төп сүзнең этимологиясен ачарга ярдәм иткән берәмлекләр

**БӘЙНӘ-БӘЙНӘ** «подробно, связно, ясно (о сообщении)» < фар. *бәйнә-бәйнә* id., гар. *бәйн* «ара, урта; арадашлык» сүзеннән. К. **Бәйнәлмиләл.**

**БӘЙНӘЛМИЛӘЛ** «интернациональный» < гар. *бәйн әл-миләл* «милләтләр арасы»; к. **Бәйнә-бәйнә, Милләт.**

Баш сүзнең диалекталь вариантлары

Баш сүзнең диалекталь вариантларын теркәгән чыганаклар

**АБЫШКА,** диал. **абычка, амыцка, амышка** (ТТДС I: 19; Тумашева 1992: 24; Рамазанова 1991: 100) <…>.

**КҮЗӘНӘК,** (БТДһ: 156–160) **күзгәнәк, күзгәнәс** «ячейка в сотах; клетка (тела); почки в картофелине; маленький колодец» <...>.

Омонимнарның бирелеше

**КАМИЛ I** «совершенный, совершеннолетний» (более правильное написание – **кямил**) < гар. *кāмил* id. Тат. сөйләшләрендә (к. ЗДС: 271) *кямил* «бөтенләй, тәмам», Батырша хатында (XVIII г. уртасы) *кямилләү* «башкару» (*чирү кешеләре пахутка барып, каравыл тормак эшене кямилләйләр*).

**КАМИЛ II** диал. (Г. Әпсәләмов) «камвольный» – рус яки ним. теленнән: рус. *камволь* < ним. *Kammwoll* «тарап алынган кәҗә мамыгы» (*Kamm* «тарак», *Woll* «мамык, йон»).

Язылышы белән укылышы арасында аерма булган баш сүзләрнең транскрипциясе

**АВАН [a$^{o}$wан]** (ДС III: 14, ТТДС 1969: 19) «хороший; открытый, простодушный», «невежественный, нецивилизованный» <…>.

**КӘВЕШ [кәwĕш]** «кожаные туфли, башмачки» <…>.

Алынма сүзгә китерелгән чыганак тел

**КӘБИСӘ (кәбисә ел)** «високосный (год)» < гар. *кäбӣсä* id. Тимергалин: 235.

Төрки тамырлы яки күптәннән үзләштерелгән сүзләргә кардәш һәм кардәш булмаган телләрдән китерелгән параллельләр, аваз күчешләре, семантик үзгәрешләр һ.б.

**КӘГАЗЬ [кәғәз]** «бумага; официальный документ; бумажный» > мар., удм. *кагаз* id.; тат. диал. *қыйағаз* > чув. диал. *киакас*; тат. диал. *җәғаз, йәғаз* > удм. диал. *ягаз* id. < ...>.

**ЧӘРЕК** «диагональная доска, брус и т. п., поддерживающий деревянные рамочные конструкции в устойчивости, распорка» <…>.

М. Федотов (II: 390) чув. *чар-* сүзен тат. *тый-* < бор. төрки *tıδ-* сүзе белән чагыштыра; чыннан да монда тиешле аваз күчешләрен күрергә мөмкин (чув. телендә *т-* > *ч-, а > ы, б ~ р*), ләкин алт. һ.б. *чэр-* (< яз. монг. *čeger-* «туктату, тыю»?) сүзеннән дип уйлау табигыйрак. <…>.

Баш сүзнең кулланылыш активлыгын чагылдырган дериватлар һәм/яки тотрыклы сүзтезмәләр.

**ӘМӘЛ II** себ., **әмил** (әстр.) (ЗДС: 81–82) «весенний праздник» < гар. *хдмдл* «хәмәл (март-апрель) ае» (к. **Хәмәл**).

Бу бәйрәм бигрәк тә Әстерхан якларында популяр булган, һәм **әмил** сүзе белән бертөркем фразеологизмнар ясалган: **әмил атау, әмил ашы (буткасы), әмил туе, әмил чүләсе** һ.б.; **әмәл куразы** (ЗДС: 428) «әтәч сурәтендәге күмәч».

**ДУЕН II [дуйын]** (ТТДС II: 86) диал. «апогей торжества (свадьбы и т. п.)» < бур. *дуил*, бор. монг. *tuil* «азак, чик; апогей». К. фразеологизм: *ун көн туен, ун көн дуен (үткәрәләр).*

**КӘЕФ**, диал. (ДС I: 88) **киф** «настроение» < гар. *кәйф* id. ← *кйф* «формалаштыру, җайлау» тамырыннан. К. ш. ук иске әд. *кәйфия, кәйфият* «форма» (к. ТГРС: 222) <…> Дерив.: **кәефле, кәефсез; кәефлән-ү** һ.б.

Баш сүзне җентекле тикшергән авторлар яки аерым хезмәтләр

**ЧАЯ [ча$^{о}$йа]**, диал. (Ф. Сәйфи-Казанлы, «Өч нарат») **чайан** «бойкий; дерзкий» ~ себ. (ДС I: 212, 215; Тумашева 1992: 232, 236) <…>.

Антонов 1971: 127–130; Vasilevitc W.M. The Acquisition of shamanistic Ability among the Evenki // Popular Beliefs: 336–349; Ахметьянов 1981: 24–25; МНМ I: 197–199, 375; II: 247; 623 һ.б. <…>.

**ЭНЕ,** себ. (Радлов I: 733) *äнi* «младший брат» < гом. кыпч., гом. угыз., уйг. үзб. як. *ини*, төр. диал. *enі*, сары уйг. *ыны,* чыгт. *инäчä*, алт. *иин*, бор. тк (ДТС: 210) *ini* id., төркм. диал. *ини* «җиян» ~ тунг.-маньч. *ина, инан* «җиян» һ.б. Покровская: 36–38; Räsänen 1969: 172; ЭСТЯ I: 362–363; Рамазанова 1991: 55, 114, 166; Кормушин 1997: 81.

# ЭТИМОЛОГИЯ ТУРЫНДА

**1. Этимология** дип «сүзләрнең килеп чыгышы» турындагы фән тармагын атыйлар. Бу сүз тагын аерым сүзнең тарихына да карый: «фәлән сүзнең этимологиясе» дип сөйлиләр һәм язалар. Термин үзе грекча: **этимо(н)** «асыл (төп) мәгънә» һәм **-логия** «сүз алып бару» (фән атамалары ясагыч кушымча). **Этимон** сүзе үзе генә хәзерге фәндә «сүзнең билгеле булган иң борынгы формасы» мәгънәсендә кулланыла. Бу терминнарны борынгы Рим философлары – стоиклар керткән. Алар үзләреннән дә борынгы фәлсәфи текстларны дөрес аңлау өчен алардагы сүзләрнең борынгы форма вә эчтәлекләрен тикшерергә кирәклеген алга сөргәннәр. Соңрак **этимология** сүзен «гайре регуляр сүзьясалышы» мәгънәсендә кулланганнар.

**Этимология** белән шөгыльләнүчеләрне (бүтән фәннәргә ияреп) **этимолог** дип атыйлар. Кайбер галимнәр **этимологист** терминын тәкъдим итәләр.

Хәзерге тел гыйлемендә **этимология** – ясалышы бүгенге (синхроник) сүз ясалу кагыйдәләре белән аңлатылмый торган сүз нигезләренең һәм фразеологизмнарның тарихын тикшерә торган фән дип билгеләнә. Ләкин гамәлдә этимология объекты итеп барча гади (хәзерге караш буенча бүленми торган) морфемаларны да алалар. Шулай итеп, этимология фәне һәм этимологик тикшеренү объектларына:

а) гади морфемалар;

б) ике яки күбрәк морфемадан торган, ләкин ул морфемалар тезмәсе хәзерге караштa аңлашылмый торган нигезләр;

в) составындагы сүзләрдән мәгънәләре чыгарылмый торган сүзтезмәләр – идиомалар керә. Әмма, аларга кайбер идиоматик сүзтезмәләр, мәсәлән, парафрастик фигыль төрләре керми.

Этимологик тикшеренү нәтиҗәләре, гадәттә, этимологик сүзлекләрдә бәян ителә. Аерым сүзләр яисә сүз төркемнәре турында мәкаләләр языла. Кайбер сүзләрнең тарихы, мәгънәләре, кулланылышлары шулкадәр бай була ки, аларның һәрберсе турында саллы гына китап язылырга мөмкин. Әмма гамәлдә тик аерым этноним яисә топонимнар турында гына шулай итәләр. Мәсәлән, Казакстанда **казак** сүзенең этимологиясе турында калын бер том китап чыгарганнар. **Байкал** сүзенә генә багышланган китап барлыгы да билгеле һ.б.

**2.** Аерым тел лексикасына караган этимологик сүзлекләр чиктән тыш киңәеп китмәсен өчен, төрле чикләүләр куела. Шуларның иң мөһиме – алынма сүзләр турында сүзне кыскарак тоту. Алынма нигез, гомумән, конкрет бер тел югарылыгыннан караганда, тамыр сүз ул. Мәсәлән, татарча **пароходчылык** сүзенең тамыры **пароход** дип карала. Ә бу тамырның рус телендә ничек ясалганлыгы мәсьәләсенә тирән керергә татар теле белгече бурычлы түгел.

**3.** Этимология – тел гыйлеменең иң катлаулы, һәрхәлдә, һәртөрле өлкәләрдән киң белем таләп итә торган өлеше. Этимология лингвистиканың барча тармакларына, аннары этнография һәм бигрәк тә тарих фәннәренә чиктәш.

Шуны әйтергә кирәк: асылда, этимология белән һәркем шөгыльләнә. Бу ягы белән этимология медицина һәм педагогикага охшаш: бу гыйлем тармаклары белән дә һәркем шөгыльләнергә мәҗбүр. Яшәү, тормыш шуны таләп итә. Һәм бу телгә алынган өлкәләрдә һәр кешенең үз карашы була. Һәртөрле фикерләр, карашлар, расламалар диңгезендә югалып калмас өчен, бу өлкәләрдә фәннилек принципларына таянып эш итү мөһим.

**Фәннилек,** иң беренче чиратта, дөреслеккә, хакыйкатькә ирешү ысулларын куллану дигән сүз. Фәнни методиканың иң мөһим моментлары булып мәсьәләне дөрес куя белү, кирәкле мәгълүматлар җыю һәм ул мәгълүматларны моңарчы билгеле булган закончалык формулаларына куеп карау санала. Билгеле, һәр фән тармагының үзенчәлекле методикасы да була, ләкин әйтелгәннәр һәр фәнгә дә кагыла. Түбәндәрәк без этимологик тикшеренүнең махсус принципларына аерым тукталырбыз, ә хәзер гомумфәнни методиканың этимологиядә кулланылышына күз салыйк.

Мәсьәләнең куелышы дигәндә, этимология белән кызыксынучының максатлары мөһим: ул

этимология ярдәмендә алдан алынган берәр тезисны, фикерне, карашны исбатларга телиме яисә объектив хакыйкатьне табарга телиме? Этимология – социологик фән, ул кешеләрнең иҗтимагый һәм шәхси мәнфәгатьләренә турыдан-туры кагыла. Шунлыктан монда субъективизм бик көчле: һәр кеше үзенең хаклыгын якларга омтыла. Ләкин субъективизм еш кына телгәннең киресенә китерә. Моның мисалларын без көн саен, сәгать саен диярлек күрәбез. «Җәһәннәм юлы изге теләкләр белән түшәлгән» дигән мәкаль тирән мәгънәгә ия. Этимологиядә дә шулай. Объектив дөреслекне таный белү этимологик тикшеренүләрдә дә әһәмиятле. Икенче яктан, әлбәттә, субъектив файда булмаганда тикшеренүнең кызыгы да югала. Билгеле, бернинди мәнфәгатькә дә хезмәт итмәгән хакыйкать ул – тип-тигез коры дала уртасына салынган күпер кебек. Этимологиядә мәсьәләне дөрес кую – актуаль позицияне сайлый белү ул. Бу исә тирәнтен рухи культуралы булуны таләп итә. Этимологиядә алдан уйланган тезисны исбат итмәкче булу – мәдәни позиция түгел, әлбәттә. Субъектив файда мәсьәләне һәр яктан карарга ярдәм итә, ләкин ул нәтиҗәләрдә чагылырга тиеш түгел.

**4. Этимология** – төгәл фән, аның нәтиҗәләре принципта хакыйкать хокукына ия, ләкин кайбер бүтән төгәл фәннәрдән, әйтик, математикадан үзгә буларак, этимология белән шөгыльләнүчеләр арасында фәннән читтә торган ихтыяҗлар, субъективизм бик көчле булучан.

Гамәли этимологиядә, чыннан да, бик еш кына объектив хакыйкать дәрәҗәсендә торган расламалар очрый. Шуның белән бергә, этимологик тикшеренү нәтиҗәләре, гомумән алганда, ихтималлык белән үлчәнә. «Йөз процентлы» ихтималлык белән билгеләнгән этимологик нәтиҗәләр этимологик сүзлекләрдә бирелгән мәкаләләрдә чама белән 60–70% тәшкил итә. Калганнарын **ихтималлыгы зур, бик ихтимал** һәм **ихтимал** дип бәяләп билгеләп үтәләр (бу сүзләр әйтелмәскә дә, ә ихтималлык дәрәҗәсе исә аңлатма тексттан аңлашылып торырга мөмкин).

Йөз процент ихтимал булмаган этимологияләрне нигә язып торырга соң дигән сорау туарга мөмкин. Язып тору кирәк, чөнки азмы-күпме ихтимал фәнни фаразлар, беренчедән, тикшеренүләргә дөрес юнәлеш бирәләр, икенчедән, төптән ялгыш һәртөрле фаразлардан (андыйлар, гадәттә, күп була) кисәтәләр.

Этимологиянең ихтималлыгы тикшеренүченең тырышлыгы вә сәләтенә, методикасының дөреслегенә генә бәйле түгел. Күбрәк очракта тулаем ихтимал этимологик нәтиҗә ясау өчен материал-фактлар һәм методик эшләнмәләр җитенкерәми. Бераз киресенчәрәк тә булгалый: теге яки бу сүзнең тарихын тикшерү өчен, материал бик күп булганда һәм ихтималлыклары тиң берничә нәтиҗә ясалганда, ул нәтиҗәләрнең гомуми бәяләмәсе, әлбәттә, түбәнәя.

Этимологиянең әһәмияте гаять зур. Атаклы этимолог-иранист В.И. Абаев моны болай аңлата: «Тел – инсанның рухи эшчәнлеге һәрьяктан белендерелә торган шәй. Халыкның теле – аның сүз-сурәт, сүз-төшенчәләрдә вә грамматик категорияләрдә гомумиләштерелгән тарихи тәҗрибәсе ул. Кеше яшәешенең аның сөйләмендә чагылдырылмаган бер генә ягы да, бер генә яшерен култыгы да юк. Һәм һәрбер сүз, аның тарихи эчтәлеген дөрес ачкан тәкъдирдә, иң борынгы матди ядкәрләр белән ярышырлык документ булып тора» (Абаев В.И., 1949: 9). «Этимологик тикшеренүләр мөһим тарихи вә этногенетик мәсьәләләрне хәл итүдә беренче дәрәҗәдәге әһәмияткә ия булучан» (Абаев В.И., 1956: 5). Заманында татар теле һәм этнографиясе өлкәсендә зур хезмәтләр язып калдырган В.А. Богородицкий да шуны әйткән: «Һәр халыкның теле аның мәдәни вә социаль тарихының елъязмасы шикелле» (Богородицкий В.А., 1933: 3). Тагын шуны да өстәп әйтергә кирәк: халык тарихының көзгесе буларак, тел материалы чын, объектив була (язма тарихи документлар турында моны әйтеп булмый әле).

*Тарих дәреслеген һәр хөкемдар*
*Үзе теләгәнчә төзеткән.*
*Тик сатылмас бер тарихчы – тел бар,*
*Һәм ул төгәллекне үз иткән.*

(Г. Рәхмәтҗан)

Тарихы һәрдаим бозылып, мәдәнияте түбәнсетелеп килгән татар халкы өчен объектив тарих коралы булган этимологиянең әһәмияте аеруча зур.

Телгән максатларга – тарихи объективлыкка хезмәт итсен өчен, этимология ышандырырлык булырга тиеш. Ышандырырлык этимология генә ышанычлы.

Орфография һәм орфоэпия мәсьәләләрен хәл итүдә, дөрес һәм мантыйклы грамматик кагыйдәләр төзүдә һ.б. өлкәләрдә дә этимологиянең әһәмияте зур. Ә лексикология һәм лексикография өлкәсендә этимологиясез азмы-күпме фәнни эш башкару мөмкин дә түгел.

## Этимологиянең методикасы

Этимологиянең методикасында гомумфәнни принциплар һәм махсус (лингвистик) принциплар аерымлана.

Гомумфәнни принциплар – 1) төгәллек, 2) тикшереп һәм кабатлап булучанлык, 3) тикшеренүдә логик төзеклек. Тикшеренү үзе материал (мәгълүмат) җыю һәм җыелган материалны табылган закончалык формулаларына куеп нәтиҗә чыгарудан тора.

Этимологиянең өстәмә фәнни принцибы – тарихилык. Бу принцип этимологиядә генә түгел, бар иҗтимагый (инсаният җәмгыятенә караган) фәннәрдә дә зур әһәмияткә ия. Тарихилык, ягъни нәрсәләрне, күренешләрне аларның үсешендә карау, этимологиягә нисбәтле сүзләрнең фаразланган үсеш-үзгәреш моделе билгеле тарихи факт вә закончалыкларга ярашлы булырга тиеш дигән сүз.

Махсус (хосусый) принциплар – сүзнең чыгышын һәм тарихын билгеләгәндә, 1) фонетик, 2) морфологик, 3) синтаксик һәм 4) семантик үзгәреш закончалыкларын исәпкә алу дигән сүз. Бу закончалыкларны бик яхшы (мөмкин кадәр яхшырак) белми торып, ышандырырлык этимология ясап булмый, әлбәттә.

Төгәллек принцибы буенча этимологиядә сүзләр мөмкин кадәр төгәл транскрипциядә бирелә һәм аларның мәгънәләре дә төгәл ачылырга тиеш. Этимологлар башлыча сүзлекләр белән эш итәләр, һәм алар һәр әдәби һ.б. телдәге язылышларны яхшы белергә тиеш. Этимологик нәтиҗәләр, гадәттә, күпсанлы диалектлардан, шивәләрдән, телләрдән алынган сүзләрне чагыштыру (чагыштырма-тарихи метод) нигезендә ясала. Шулардан иң мөһимнәре – кардәш телләргә караган сүзләр. Һәр этимолог кардәш телләрне мөмкин кадәр яхшырак белергә тиеш.

Этимологиянең авторы үзенең таянган материалы каян алынганлыгын ачык белдерергә һәм нинди закончалыкларга таянганлыгын ачык әйтергә тиеш. Сүз чыганаклары – сүзлек-китапның сәхифәсе күрсәтелеп бару, бу хезмәтне тикшерүче яки авторның дәвамчысы авторның эшен кабатлап карап чыга алсын дип һәм, гомумән, ышандырырлык булсын дип эшләнә.

Ышандырырлык булсын өчен, этимологик аңлатма ачык вә кыска, тавтология яки эмоциональ кабатлаулардан азат булырга тиеш. Аңлатмада тикшеренү процессы чагылып барса да начар түгел, әмма ул сәнгатьле риторик сөйләмгә әверелмәсен.

Гадиләштереп әйткәндә, этимология түбәндәгечә эшләнә. Иң элек тарихы тикшереләсе сүз турында барлык мәгълүматлар туплана. Ягъни, сүзнең барлык төрле телләрдә, төрле заманнарда, төрле китапларда һ.б. язмаларда теркәлгән вариантлары җыела. Дилетант этимологларның төп хаталарының берсе шул: алар материал тупланып бетмәстән элек «этимологиягә» керешәләр, сүзләрне үзләренчә аңлата башлыйлар. Хәтта туган тел материалы нигезендә генә этимологик нәтиҗәләр ясаучылар булгалый.

Җыелган материал, әлбәттә, белгеч күзе аша карала. Иң беренче чиратта туган телнең, аннары кардәш телләрнең һәм аларның язма ядкәрләрендә теркәлгән лексик материалы игътибар үзәгендә була. Шуның белән бергә, кардәш булмаган күрше телләрдә дә сүзләрнең этимологиясе өчен әһәмиятле, хәтта хәлиткеч кыйммәткә ия булган яңгыраш вә формалары сакланырга мөмкин. Һәм «сүз турында материал» җөмләсенә, әлбәттә, туган (тикшерелә торган) телдән бүтән телләргә алынган сүзләр дә керә. Күрше фин-угор телләрендә татар этимологиясе өчен гаять зур лексик материал – аерым сүзләр, татар теленнән калькалар һәм ярым калькалар, борынгы яңгырашлар бар. Аларның кайберләре бердәнбер, хәтта төрки телләрнең үзләрендә дә сакланмаган булырга мөмкин. Мәсәлән, **бура** (торак корылмасы) сүзенең борынгы **бугра** варианты удмурт телендә генә сакланган. Шундый кыйммәтле табыш сүзләр рус телендә, аның төрле сөйләшләрендә, шулай ук фарсы-таҗик, төрле Кавказ телләрендә һ.б. бик күп. Ә инде кардәш дип исәпләнгән монгол һәм тунгус-маньчжур телләре татар этимологиясе өчен төрки телләр белән бер дәрәҗәдә диярлек әһәмиятле.

Тагын шуны да әйтеп китик: этимологиядә ашыгыч нәтиҗәләрдән саклану мөһим. Шундый «этимологик» сентенция бар: *случайные совпадения – худший враг истины* (очраклы охшашлыклар – хакыйкатьнең иң яман дошманы). Һәм төрки телләрдә үзара охшаш, әмма кардәш-тамырдаш булмаган сүзләр еш кына очрый.

## Этимологик тикшеренү ысуллары

Этимологиянең махсус процедур ысулларына **эчке реконструкция, аналогия** (индукция), **күперчекләр табу*** һәм **изоглоссалар** табу керә.

* Безнең бу очеркта татар тел гыйлемендә моңарчы кулланылмаган кайбер терминнар тәкъдим ителә.

**Эчке реконструкция** дип, асылда, нигезнең үзенә игътибар белән карауга әйтәләр: бүленмәс нигез чыннан да бүленмиме? Бу сүз гади конверсия яисә лексикалашу гына түгелме? Аның мәгънәсе инклюзив үзгәреш кичермәгәнме? Сүзнең яңгырашы ялгыш аңлау яисә ялгыш язылу нәтиҗәсе генә түгелме? Эчке реконструкция процедурасында шул сорауларга җавап бирелә һәм туган телнең үзендә генә яки үзендә дә булган, була алган фонетик, морфологик, лексикологик һ.б. үзгәрешләрне күз алдында тотып эш ителә. Мәсәлән, татар теле өчен *а* > *ә* күчеше аеруча хас: *аз* > *әз*, *ачы* > *әче*, *акрын* > *әкрен*, *байла-у* > *бәйлә-ү*, *байрам* > *бәйрәм*, *җай* > *җәй* (шулай ук *җай-у* > *җәй-ү*) кебек палатализация очраклары татар телен яхшы белгән һәркемгә мәгълүм булса кирәк. Шуннан чыгып, *җәнлек* < *җанлык*, *йәрәшү* < *йарашу*, *йүри* < *йурый* (чаг. диалекталь *йурамал* < *йурамалы* «юри, юрап, сынап»), *тәртә* < *тарта* (борынгырак формасы *тартна*) дип ышанып әйтеп була. Бу сүзләрнең палаталь пардашлары татар теленең үзендә килеп чыкканнар. Татар телендә сузыклар редукциясе еш очрый һәм, шуны истә тотып, *чорма* < *очырма*, *терлек* < *терелек, шүрлек* < *шүрелек* дип аңлатулар (әлбәттә, һәртөрле бүтән принципларны да онытмыйча) бик тә ышандырырлык. Татар теленә кушма сүзләр кыскартылу күренеше дә ят түгел. Мисал өчен, *чабагач* < *чәп агачы* (*чәп* үзе «чабагач» ~ рус һ.б. *цеп*), *читек* < *эч итек* татар телендә пәйда булган гаплологик тамыр ясалыш очраклары булса кирәк. Татар теленең үзендә килеп чыккан тарихи мәгънә үзгәреш очраклары да юк түгел. Мәсәлән, *атлама* «түбә кыегының терәк өчпочмагы» сүзенең этимологиясен әллә кайлардан эзлисе юк: бу сүз иң башта А формасындагы җир үлчәгечне (*таяк* дип тә атала) белдергән, аны *атлатып,* җир озынлыгын үлчиләр. Шуннан нәкъ шул формадагы терәкне дә (*стропила*) *атлама* дип атый башлаганнар. Андый җайланманы кайбер якларда *бәбкә* дип тә атыйлар. Монысы русча *бабка* «әбекәй» сүзеннән килә: шулай дип, иң элек конуссыман көлтә өемен (ул итәген киңәйтеп, кринолин күлмәк кигән әбигә охшатылган) һәм аның өчпочмаклы агач каркасын атаганнар. *Кыек* (исем сүз) *кыек* сыйфатыннан килә, чөнки безнең яңгырлы якларда корылма түбәсе кыек, кыеш, авыш куела. *Түшәм* сүзе төптә *түшәлгән* нәрсә, *түшәү* нәтиҗәсе дигән сүз. Бу мәгънә үзгәрешләре татар тормышында гына килеп чыга алган.

Эчке реконструкциядә морфологик закончалыкларны куллану аеруча нәтиҗәле. Бу бүлектә иң беренчел билгеле аффикслар ярдәмендә билгесез тамырлардан ясалган сүзләрне искә алырга кирәк. Андый тамырларны аерым алып карау уңай нәтиҗәләргә китерә. Мәсәлән, *шикелле* «кебек» һәм диалекталь *шикелсез* «кыяфәтсез» сүзләреннән чыгып, элекке телебездә *шикел* сүзе булган дип ышанып әйтеп була. Арытабан бу элекке татар әдәби телендәге *шәкел* «схема» (һөнәрчелек лексикасында «металл кою формасы») сүзе белән чагыштырыла; бу нигезнең исә гарәпчә *шакл* сүзеннән икәнлеге мәгълүм. Бу очракта иң кызыклысы шул: *а* > *э* күчеше гомумкыпчак телендә булган. Шул *э* исә татар телендә *и*-гә күчә: димәк, *шәкел* сүзе гарәп теленнән бик иртә, VII – VIII гасырларда кыпчак телләренә кереп, татар теленә дә бик иртә кергән. Шулай итеп, бу сүзләрдә чагылган *а* > *э* > *и* күчешләре тел үсешенең нисби хронологиясен билгеләү өчен дә әһәмиятле (гомумән, бу аерым мәсьәлә). Эчке реконструкциянең борынгы нигез вә тамырларны билгеләү өчен хезмәт итүгә тагын бер ише кызыклы мисаллар фигыльләрдә очрый. Мәсәлән, *юан-у* һәм *юат-у* фигыльләреннән чыгып, без борынгы телдә *юа-у* фигыле булган дип ышанып әйтә алабыз; *йуан* – шул фигыльнең кайтым юнәлеше. Ә *йуат* – йөкләтү юнәлеше булып чыга. Шулай ук *уян-* һәм *уят-* фигыльләре төп **уя-у* фигыленнән икәнлеге ачык. Хәер, *уяу* сыйфаты – сыйфатлашкан исем фигыль хәзер дә гамәлдә.

Эчке реконструкция борынгы яки искергән кушымчалар нигезендә дә башкарыла. Мәсәлән, *бугай* сүзенең *булгай* сүзеннән икәнлеге элекке язма телдә шактый киң кулланылган *-кай* аффиксының мәгънәләреннән чыгып дәлилләнә. Борынгы төрки телләрдә (һәм хәзерге чуваш телендә дә) *-н* аффиксы белән ясала торган инструменталь килеш актив кулланылган. Ул хәзерге телебездә *ялгыз → ялгызын*, *кич → кичен*, *иртә → иртән* кебек очракларда чагыла. Шуны белеп, без *кырын* ← *кыр*, *саен* (*сайын*) ← *сайы* («сан» мәгънәсендә), *тиген* ← *тик* һ.б. ны әйтә алабыз. Әлбәттә, бу фаразлар диалекталь материал һәм бүтән төрки телләр материалы белән чагыштыргач кына расланалар. Мәсәлән, *сайы* «саен» сүзе төньяк Башкортстан татар сөйләшләрендә кулланыла. Тик һәрбер *=(ы)н* // *(е)н*-гә беткән рәвеш яки сыйфат инструменталь килештән килә дип әйтеп булмый.

Эчке реконструкция этимологиянең башлангыч һәм мөһим этабы, ләкин аның белән артык мавыгырга да ярамый. Әлбәттә, туган тел сүзләренең этимологиясен туган телдән эзләү эзләнлек принцибына бик тәңгәл вә ярашлы. Ләкин бәхәсле

очракларда патриотизмнан чыгып «үз ягыңны каеру» – фәнни төгәллеккә хилаф нәрсә. Хәлбуки, кайбер этимологлар, мәсәлән, рус теленең ике томлык этимологик сүзлеген нәшерләгән П.Я. Черных, күптән кабул ителгән кайбер этимологияләрне – башлыча рус телендәге төрки алынмаларны кире кагып, саф русча яңа этимологияләр тәкъдим итә. Мисал өчен, ул русча *бурка* < төрки *бурка* «бөркәү», *бурлак* < татарча *бурлак*, *гоголь* < төрки *гоголь* «кыр үрдәге төре, күгәл» дип аңлатуларга каршы чыга. *Бурка* сүзен ул «бурый» сүзеннән ди, ләкин *бурка*ның *бурый* «көрән» төстә булуы бөтенләй шарт түгел. Һәм *бурка*лар «гадәттә көрән төстә булалар» дип тә әйтеп булмый. Чынлыкта, *бурка* күп төрки чыганакларда теркәлгән *бурҝаг* «ябынча» сүзеннән килә. *Бурлак* сүзен П.Я. Черных русча *бурлить* «тавышлану» сүзеннән ди. Тагын килеп, бурлаклар өчен тавыш куптару бигрәк тә хас дип әйтеп буламы икән? *Бурлак* ул – элекке заманда Идел яры буйлап агымга каршы каек тартып баручы. Иделнең үрге агымнарына җиткәч, бурлаклар эш хакы алганнар һәм, шул ук каекка утырып, кабат Әстерханга кадәр төшкәннәр. Бу коточкыч авыр һәм үзенчәлекле эшкә, гадәттә, йортсыз-җирсез ир-ат алынган. Һәм татар телендә *бурлак* гомумән «ялланмыш кеше, сезонлы эшче» (мәсәлән, Н. Думави телендә бу сүз шул мәгънәдә). Безнеңчә, *бурлак* иске татарча (С. Хәлфин) *буралгы*, казакъча *буралкы*, башкортча *боралкы* «бер югалып, бер табылып йөри торган терлек яисә кеше, сукбай» сүзеннән булса кирәк. Шулай дип алу бурлак тормышын тасвирлауга шактый туры килә. *Буралкы* сүзенең *буралак* варианты булу бик тә ихтимал. *Гоголь* сүзен рус этимологлары *гоготать* «каңгылдау» сүзен дәлил итеп, төп рус-славян сүзе иң элек «каз» мәгънәсендә булып, соңрак үрдәккә күчкән диләр. Хәлбуки төрек сөйләшләрендә *gögel* «күгәл» сүзе < *kök* «күк, яшькелт» сүзеннән бик билгеле сүз модельләре буенча ясалган (Yerif Ali Bozkaplan. Türkiye türkçesi agızlarında kuş isimleri // Türk dili araştırmaları yıllıgı, 1992. b. 2). Русча *гоголь* – болгарча *гогаль* сүзеннән, ә болгар сүзе төрек сөйләшләреннән икәнлеге җитәрлек дәрәҗәдә ачык вә аңлаешлы. Каз атамасының үрдәккә күчүенә килгәндә исә, аның мисалы, аналогиясе дөньяда юк шикелле.

**Аналогия ысулы** – этимологик тикшеренүләрдә иң нәтиҗәле, әһәмиятле ысул.

Һәрбер кеше үзенең белгән сүз байлыгын (хәтердә тоту җиңел булсын өчен) аналогик төркемнәр буенча тәртипкә китерергә омтыла. Бу, бигрәк тә, балалар телендә сизелә. Һәм этимолог инсан уй-фикеренең шушы хасиятен исәпкә ала.

Этимологиянең төп принципларына туры китереп караганда, аналогиянең түбәндәге төркемнәрен аерырга була: 1) изофонетик аналогияләр, 2) изоморфик аналогияләр, 3) изосемантик аналогияләр.

Боларның һәрберсендә телнең үзендә, телләрнең аерым төркемендә, аннары дөньядагы барча телләргә хас булган изо- (типик, фреквенталь) күренешләр аерымлана. Гомумән, аналогик төркемнәр чиксез күп, ләкин һәр аерым телдә аларның ешрак очраганнарын төрен-төргә аерып чыгарга мөмкин. Шундый эшне эшләгәндә (хәер, ул әлегәчә бер тел өчен дә эшләнмәгән), этимологияне компьютерда да башкарып булыр иде. Ә хәзергә һәртөрле аналогик теземнәр тикшеренүченең хәтерендә – башында булырга тиеш.

Аналогияләр моңа кадәр таныш булмаган сүз үсешенең гипотетик моделен реконструкцияләү өчен кирәк. Мәсәлән, *тыкырык* сүзен алыйк. Иң элек татар телендә фигыльләрдән *-к* кушымчасы ярдәмендә ясалган сүзләр рәте барлыгын хәтерлибез: *боз-* → *боз-ык, көй-* → *көек, яз-* (*юлдан яз-*) → *язык* («гөнаһ») һ.б. Шушы сүзьясалыш моделеннән чыгып, *тыкыр-ык* сүзе *тыкыр-* сүзеннән дип фаразлыйбыз. Андый фигыль гомумхалык татар телендә юк. Диалекталь сүзлекләрдән эзлибез – юк. Шуннан соң кардәш һәм күрше телләр сүзлекләренә мөрәҗәгать итәбез – юк. Инде татар телендә еш кына интервокаль (ике сузык арасындагы) *-к-* борынгы ике *к* (*кк*) авазыннан килеп чыгуын хәтерлибез һәм *тыкырык* ул *тыккыр-ык* булырга мөмкин дип уйлыйбыз. Кыпчак телләрендә *тыккыр-* «тыгылу, тупикка терәлү» фигыле барлыгын табабыз. Димәк, *тыккыр-ык* «тупикка терәлгән» дигән сыйфат булган, ул сыйфат семантик үзгәреш кичереп, исемгә әверелгән (чагыштыр: *ватык, кисек* – сыйфат та, исем дә булып киләләр).

Аналогия ысулының төрле – фонетик, морфологик һәм семантик аспектлары бар. Фонетик аспект бу очракта этимологик аңлатманың фонетик үзгәреш законнарына хилаф булмавы гына түгел, монда бөтен бер аваз комплексларының, бер тип сүзләрнең охшаш үзгәрүе, гаплология модельләре күз алдында тотыла. Мәсәлән, *борынла-у* > *борна-у, кешенлә-у* > *кешнә-у, сарынла-у* («ритуаль җыр җырлау») > *сарна-у;* шулардан чыгып, *тырна-у* ның элекке формасы *тырынла-у* булган, ә *чорна-у* фигыле *чорынла-у* формасыннан килеп чыккан дип уйлый алабыз һәм шул юнәлештә раслагыч

фактлар эзлибез. Әлбәттә, мондый аналогик фаразларда этимологик мәсьәләнең бүтәнчә чишелешләре булу ихтималын да истән чыгарырга ярамый. Мәсәлән, *белдек, калдык, урындык* һ.б. исемнәрдән, аларда *-дык//-тык* аффиксы барлыгыннан чыгып, *сандык* сүзен дә ниндидер *сан-* нигезеннән ясалган дип фаразларга мөмкин. Ләкин *сандык* сүзенең барлык параллельләрен карап чыксак, бу сүзнең Көнбатыш һәм Көньяк Азиядә электән киң таралганлыгы (гарәп, фарсы һ.б. телләрдә бар) һәм һинд телләрендәге *самдана* «сандык» сүзенә кайтып калуы мәгълүм була. Борынгы һинд телендә *samdhana – sam* «барчасы, бөтенесе», *dhana* «савыт, сыйдыргыч; эченә салына торган нәрсә», *dhe-* «кую, салу» фигыленнән ясалган исем; борынгы фарсы телендә бу сүзгә кечерәйтү кушымчасы *-к* ялганып, ул *санданак* формасын алган, шуннан *сандаңк, сандук, сундук* һ.б. вариантлар пәйда булган. Бу мәгълүматлар булмаса, татарча *сондык* варианты «сона торган нәрсә» дип фаразларга мөмкинлек бирер иде. Чынлыкта бу вариант халык этимологиясе буенча гына килеп чыккан.

Морфологик аналогия сүзьясалыш модельләре нигезендә ясала. Этимологиядә, әлбәттә, бүгенге сүзьясалыш ысулларын, кушымчаларын һ.б.ны гына түгел, борынгыларын да белергә кирәк. Мәсәлән, борынгы төрки телләрдә (хәзерге инглиз телендәге шикелле) исем (һәм сыйфат) нигезләр бик җиңел рәвештә фигыль булып китә алганнар. Татар телендә бүгенгәчә сакланган *куш* (сыйфат) ~ *куш-* (фигыль), *туң* (исем һәм сыйфат) ~ *туң-* (фигыль), *тын* (сыйфат) ~ *тын-* (фигыль), *уң* (сыйфат) ~ *уң-* (фигыль), *шеш* (исем) ~ *шеш-* (фигыль) шул халәтнең калдыкларыдыр. Моны белү күп кенә бүтән сүзләрнең чыгышын ачыкларга ярдәм итә.

Борынгы телебездә (татар теле үсешенең уртарак бер этабында) *-к* һәм *-лык* < *л-ык* интенсивлык фигыль аффиксы киң кулланылган: хәзерге телдә моның калдыклары: *йот-у → йотлык-у, кыз-у → кызык-у, өз-у → өзлек-у, яз-у → язлык-у* һ.б. Моны белү безгә *атлык-у ← ат-у, ашык-у ← аш-у* («менү, менеп җитү»), *курык-у ← куры-* (төрекчә *koru-* «һөҗүмнән саклану»), *тотлык-у ← тот-у* дип ышаныч белән расларга мөмкинлек бирә. Алай гына да түгел, бу морфологик закончалыкны истә тотып, татар телендә онытылган фигыльләрне **тәнәйтергә***, ягъни реконструкцияләргә дә мөмкин.

Мәсәлән, *күзек-ү* фигыле *күз-ү* фигыленнән дип фаразлап була. Һәм чыннан да, кайбер төрки телләрдә *көз-* (*гөз-*) «текәлеп карау, ачык күрү» фигыле билгеле (ЭСТЯ, 3: 60–63). Бу сүз исә *күз* < *көз* исем сүзенең фигыль коррелянты.

Семантик аналогия бигрәк тә катлаулы тармаклы. Шуны әйтергә кирәк: һәвәскәр этимологлар һәм кайбер филологлар да мәгънә күчеш закончалыкларын белмиләр, аларга тиешенчә игътибар итмиләр. Мәсәлән, элекке текстларда очрый торган *үчер-ү* «янган утны сүндерү» фигылен *очыр-у* дип укыйлар. Хәлбуки «очыру > сүндерү» күчеше беркайда да теркәлмәгән. Һәм *үчер-ү* < гомумкыпчакча *өчир-,* кыргызча, уйгурча *өчүр-* «сызып ташлау, исемлектән сызу; сүндерү» *өч-* «юкка чыгу; сүнү» сүзеннән килә (к. себер татар сөйләшләрендә *үцер-ү* «сүндерү», *үц-ү, үч-ү* «сүнү», Д.Г. Тумашева 1992: 231). Шулай итеп, фонетик яктан да *үчерү* һәм *очыру* арасында тирәнтен аерма бар, алар «чагышмыйлар».

**Күперчекләр ысулы** ул – этимологик фаразны раслау өчен, арадаш яңгырашлар, нигезләр һәм мәгънәләр эзләү дигән сүз. Мәсәлән, югарыда китерелгән *булгай* > *бугай* фаразын раслау өчен иске бер җырда:

*Тәрәзәләр ачып яулык болгай –*
*Без сөясе ярлар шул булгай,*

дип әйтелә. Монда *булгай* сүзе «бугай» мәгънәсендә ич. Яки *торыш-у* > *тырыш-у* икәнлегенә *бай байга булышыр, ярлы ярлы өчен тырышыр* мәкалендәге *торыш-у* сүзе инандыргыч мисал *(о* > *ы* татар телендә ясалышы, морфемик составы томанланган сүзләрдә очраштыргалый).

Күперчекләр, шулай итеп, татар теленең үзендә мәкаль, әйтемнәрдә, иске җырларда, әкият-риваятьләрдә, шулай ук язучылар-шагыйрьләр телендә табыла. Ләкин күперчекләрнең төп чыганагы – татар теленең диалекталь лексикасы, барча бүтән төрки телләр һәм аларның шивәләре, фольклоры, әдәбияты һ.б. Шуны әйтергә кирәк: этимологик күперчекләрне табу өчен сүзлекләр, фольклор һәм язма әдәбият белән эш итү генә җитми, җанлы телләрне дә белергә кирәк. Еш кына күперчекләр пардаш телләрдә түгел, күрше телләрдә – татар теленнән алынмаларда табыла. Мәсәлән, *маташ-у* татар телендә «белмичә, юкка, уңышсыз рәвештә тырышу» дигән мәгънәдә генә кулланыла. Формаль

* *Тәнәйтү, танайту* диалекталь сөйләмдә «көчен кайтару» [атны ял иттереп *тәнәйтү,* җирне *тәнәйтүгә* иген чәчмичә калдыру һ.б.]; без бу сүзне «реконструкцияләү» мәгънәсендә кулланабыз. *Тәнәй-, тәнә-* «көченә, элекке әйбәт хәленә кайту» фигыле борынгы төрки сүз, ул борынгы монголча *tenij* «бөялгәч язылу, тураю» сүзләре белән тамырдаш).

яктан *маташ-* нигезе *мата-у* дигән фигыльнең уртаклык юнәлеше. Татар сөйләшләрендә *мата-у* фигыле чыннан да бар, ләкин «тоткарлау, комачаулау» мәгънәсендә; *маташ*-уны шул *матау*-дан дип әйтергә мәгълүмат кына җитми. Кирәкле мәгълүмат – күперчек бүтән төрки телләрдә юк, ул удмурт телендә табыла: *маташ (мата-шыны)* «көрәшкәндә аяк чалу (чалышу), шундый (көрәштә тыелган) ысул белән җиңмәкче булу» – «бер-береңне матау».

**Изоглоссалар алымы.** Изоглосса дигәндә, аерым сүзнең, шулай ук аның яңгыраш яисә мәгънә төсмерләренең, төрләнеш вә кулланыш үзенчәлекләренең таралыш чикләрен һәм шул чик сызыклары эчендә калган таралыш ареалын күз алдында тоталар. Изоглосса этимологиясе эзләнелгән сүзнең мөһим характеристикаларының берсе була. Гомумән, билгеләнгән изоглоссалар күптөрле лингвистик, тарихи-этнографик һ.б. мәгълүмат чыганагы була алалар.

Изоглоссаларны белүнең этимология өчен әһәмиятен түбәндәге бер мисалдан күрергә мөмкин: күрше фин-угор телләрендә, күрше рус сөйләшләрендә, шулай ук кыпчак шиваләрендә *зепъ, зеп, җәп* «киң кесә» сүзе теркәлгән (бу мәдәни интернациональ сүз хакында рус этимологы И. Добродомовның махсус һәм күләмле мәкаләсе бар). Ләкин татар телендә бу сүз теркәлмәгән кебек иде. Нишләп инде алай, һәр дүрт тарафта бу сүз бар, татар теле ареалы *зәп* сүзенең изоглоссасы эчендә кала, ә татар телендә ул теркәлмәгән? Булырга тиеш ул сүз бездә! Һәм, чыннан да, бар икән: «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә аны *җеп* мәкаләсендә биргәннәр: *җеп кесә* – түш уртасына урнаштырылган киң кесә. Мондагы *җеп* – дөрес *җип* – һичшиксез, әлеге *җәп, зәп* (*э>и* күчеше татар теленә аеруча хас).

Икенче яктан, теге яки бу сүзнең изоглоссасы аерым бер телдән тышкары чыкмаса, бу аның этимологиясен шул телнең үзеннән эзләргә кирәклеген искәртә. Мәсәлән, татар телендә шулкадәр киң кулланышлы *гел (гелән)* сүзенең бүтән төрки телләрдә (башкорт телен исәпкә алмаганда) юклыгын белгәч, әлбәттә, аның чыгышын да татар сөйләшләреннән генә эзләргә кирәк, һәм татар этимологиясендә *гел (гелән)* сүзен иренсезләштерүчән сөйләшләрдә *гөлле, гөллән* сүзләреннән килеп чыккан дип билгеләнүе (Җ. Вәлиди, Л. Җәләй) бик дөрес.

*Тырыш-у* һәм *тырыш* сүзләре дә бүтән төрки телләрдә сирәк. Тик иске төрки татарча «Кисекбаш» телендә *дурушалым* «тырышыйк» сүзе бар һ.б. Гомумән, *тырыш-у* диалекталь *торыш-у* сүзеннән килә. *Тырыш* сүзе, үз чиратында, *торыш* сүзеннән (бу сүз исә *тырышу* < *торышу* фигыленнән алынган яисә русча *стойкий* сүзеннән калька булса кирәк). Бу очракларда да татар (бигрәк тә мишәр) сөйләшләренә хас булган иренсезләштерү (делабилизация) күзәтелә.

### Тарихилык принцибы

Фәндә тарихилык принцибы күп аспектлы нәрсә. Гомумән, тарихилык үсеш теориясенә нигезләнә. Теоретик тарихилыкның берничә конкрет таләбе (регулятивы) аерымлана: 1) ретроспективлык (үтелгән юлга карау), 2) сәбәпле бәйләнешләрдә аңлау һәм аңлату (ни өчен шулай булган), 3) диалектиклык, 4) стадия (фаза, этап, период) буыннарына бүлү һәм исәпкә алу, 5) бер стадиядән икенче стадиягә күчеш законнарын белү һәм игътибарга алу һ.б. (П.В. Алексеев, А.В. Панин. Философия. М., 2000. 392–402 бб.).

Этимология өчен шулардан ретроспективлык регулятивы әһәмиятле. Үткән юлга карау өчен, аны белергә кирәк! Конкретрак әйткәндә, этимолог туган тел тарихын иң борынгылыктан башлап өйрәнергә һәм яхшы күзалларга тиеш (ә бу исә гомуми тарихны өйрәнү вә белүдән башка мөмкин түгел). Мәсәлән, безнең татар теле үзенең төп аергыч хосусиятләре (борынгы руник тел консонантизмының һәм лексикасының нигездә саклануы, ләкин вокализмының аффинлы, ягъни үзара бәйләнышлы үзгәрүе) белән кайчан һәм нинди конкрет тарихи шартларда барлыкка килгән? Татар этимологының (тел тарихчысының) күңелендә бу сорауга конкрет җавап яту тиешле. Шундый җавап (күзәфәләү, «күзаллау») этимология белән шөгыльләнгән һәр кешенең (ул теләсә дә, теләмәсә дә) эшендә чагылмыйча калмый.

Этимологик ретроспективлык таләбенең бик тә мөһим бер ягы – эздән кайту, эздәнлек кирәклеге. **Эздәнлек принцибы** буенча чыгышы тикшереләсе сүзнең иң элек туган телдәге (аның сөйләм вә әдәби формаларындагы, диалект вә сөйләшләрендәге) яңгыраш һәм мәгънәләре җентекләп өйрәнелә. Еш кына сүзнең этимологиясенә ачкыч шушы этапта ук табыла. Мәсәлән, *тома* (сукыр, надан), *шома* сүзләре гап-гади (диалекталь) *ту-ма* «тумыштан» һәм *шу-ма* «шуу өчен җайлы» сүзләреннән икәнлеге мәгълүм була. Әйтергә кирәк, сүзнең этимологиясе туган тел материалында аңлашылуы – кардәш, күрше һәм борынгы телләр лексикасын

өйрәнү кирәклеген һич кенә дә кыйммәтсезләндерми. Шул ук *тома* һәм *шома* сүзләренең татар теленең үзендә ясалуы безнең фараз белән түгел, ул сүзләрнең бүтән чыганакларда – кардәш вә иске телләрдә юклыгы белән раслана! Ә бу факт (сүзнең бүтән төрки телләрдә юклыгы) исә әлеге телләр лексикасын карап чыккач кына мәгълүм була.

Эздәнлекнең тарихи һәм географик аспектлары бар. Тарихи аспектка карап туган телнең элекке, элгәреге («иске», «борынгы») лексикасы өйрәнелә: язма ядкәрләр, сүзлекләр һ.б. карап чыгыла. Шуннан соң иң якын кардәш телләр (татар теле өчен – башкорт һәм нугай, караим һәм кумык телләре), аннары көнчыгыш кыпчак (кыргыз, казах, каракалпак), аннары уйгур теле материалы һ.б. карала.

Географик аспектта, иң беренче эш итеп, татарларга күрше (иң беренче чиратта – кардәш, төрки) халыкларның телләре лексикасы карала, аннары ераграк халыклар телләренә мөрәҗәгать ителә. Игътибарны географик аспектка юнәлтү бигрәк тә матди мәдәният атамаларын этимологик аңлатуда әһәмиятле. Күршеләр татарлар белән бердәй матди тормыш шартларында яшәгәннәр ич.

Әйтергә кирәк, төрки дөньяда тарихи һәм географик аспектлар еш кына тәңгәлләшми. Тарихи аспектта чуваш теле – татар теленнән иң ерак төрки тел. Ләкин географик аспектта татарлар белән иң көчле аралашкан, мең ел буенча бер үк дәүләтләр составында яшәгән. Кайбер телчеләр (мәсәлән, Н. Поппе) чуваш теле лексикасының 80 % татар теленнән алынган дип раслыйлар. Бу чынлыкка якын. Шулай булгач, татар теленең тарихи лексикологиясен чуваш теле материалын исәпкә алмыйча өйрәнү – абсурд. Чөнки чуваш телендә татар теленең үзендә онытылган сүзләр, сүз формалары, сүз мәгънәләре дә сакланган (бу хәл бик табигый), һәм андый очраклар аз түгел. Мари теле турында да шуны әйтергә мөмкин. Мари лексикологлары (Ф.М. Гордеев, Н.И. Исанбаев һ.б.) бу телдә күп меңнәрчә татар алынмаларын күрсәтәләр. Удмурт телендә дә борынгы төрки сүзләр күп кенә һ.б.ш.

Эздәнлек принцибына игътибарсызлык бигрәк тә спекулятив (эффектка исәпләнгән) этимологиядә еш очрый. Мәсәлән, башкорт телчеләре еш кына башкорт сүзләрен һәр яктан ерак инглиз, һинд, шумер һ.б. телләрнең сүзләре белән чагыштыралар, шул ук вакытта бүтән төрки телләрне (хәтта татар телен) игътибарга алмыйлар. Татар сүзеннән берни белән дә аерылмаган сүзләрне «башкорт сүзе» дип атау да алардагы фәнни әдәбиятта еш очрый торган күренеш. Мәсәлән, *тәңкә* сүзе татарча да, башкортча да нәкъ бер төрле яңгырый һәм бердәй мәгънәдә. Башкорт лексикологы аны, бернигә дә карамыйча, «төп башкорт һүҙе» дип атый. Ә татар теле кая киткән? Этимологиядә иң элек шуңа игътибар итү фарыз. Һәм бу сүзне, фәнни төгәллек өчен, **татар-башкорт** (яисә, бик теләсәгез, **башкорт-татар**) дип аңлатырга кирәк. Башкорт филологы, гадәттә, **татар** сүзен телгә дә алмастан, борынгы һәм ерак (мәсәлән, фарсы) телләрдән параллель күрсәтә башлый. *Тәҙрә*, һичшиксез, башкорт сүзе (андый яңгыраш татар сөйләшләрендә юк ахырысы), *тәрәзә* – татарныкы, ләкин башкорт сүзенә иң якын яңгыраш барыбер татар теле сөйләшләрендә: *тәрзә.* Һәм башкортча *тәҙрә* сүзенә этимологик аңлатма биргәндә, татар диалекталь вариантын китерү фарыз (чөнки *тәҙрә* < *тәрзә*).

Тарихилык принцибының тагын бер мөһим һәм гаять зур белемнәр таләп иткән аспекты халык кичереп үткән тормыш шартларын һәм рухи халәтләрне белеп эш итүдән гыйбарәт. Мәсәлән, нәрсә ул *тупса,* гомумкыпчак эталонынча *топса* (гомумтөрки *о*)? Хәзерге мәгънәләре «бусага; шарнир, питла». Беренче карашка (синхроник планда), бу – табышмак сүз. Ләкин шуны искә төшерик: элек ачылмалы тәрәзә һәм ишекләр (тимер кыйммәт булган заманнарда) төп агачка, күчәркәгә беркетелеп, күчәркәнең аскы һәм өске түгәрәк уемнарына куелып ясалган. Шул *туп* кереп утыра торган уемлы агач *тупса* дип аталган да инде! *Туп-са,* димәк ки, туп урыны, туп савыты; чагыштыр: *беләк-сә* «манжет, беләккә киелә торган нәрсә», *җиңсә* «җиңгә киелә торган нәрсә», үзбәк, төрекмән телләрендә *дупсә* < *туп-сә* «топсә, чүлмәк утыртыла торган түгәрәк төпле җайланма» (*туп* «төп»). *Туп* сүзе дә, *-са*//*-сә* кушымчасы да татар телендә яхшы билгеле, тик тарихи чынбарлыкны белеп бетермәү нәтиҗәсендә генә *тупса* сүзе табышмак булып кала. *Тупса* сүзенең «бусага» мәгънәсе – икенчел (метонимия буенча мәгънә күчеше), «шарнир» мәгънәсе шулай ук икенчел (функция буенча мәгънә күчеше). Беренчел мәгънәнең денотаты үзе юкка чыккач, икенчел мәгънәләр генә торып калган (алар белдергән нәрсәләр хәзер дә бар һәм еш очрый).

Чынбарлыкның онытылуы әйберләр үзгәрүдән генә түгел, халыклар күченү процессында табигый шартлар үзгәрүдән дә булгалый. Андый очраклар үтә кызыклы, алар халыкның ата-бабалары нинди табигый шартларда яшәгәнлеген күрсәтәләр. Моңа ачык мисалны якут филологлары китерә: якут календарендә март «су ташу ае» дип атала. Хәлбуки Якутиядә мартта каты суыклар, су

ташуының исе-косы да юк. Димәк, якутлар көньяктан килгәннәр! Татар телендә дә татарлар составына кергән кайбер этник төркемнәрнең көньяктан килгәнлегенә дәлилләр табыла. Мәсәлән, *койма кою* тәгъбирен алыйк. Койманы татарлар такталар кадаклап ясыйлар, ул ни өчен «кою»? Хикмәт шунда: көньяк ярымчүлләр зонасында (Уйгурстанда, Урта Азиядә һ. б.) койманы ике кыса арасына сыек балчык *коеп* ясыйлар! Ә менә *кәбен кою* борынгы гадәттән килә: никах туе вакытында кәләшнең башына *кәбен* – вак көмеш тәңкәләр койганнар. *Кәбен* сүзе ирани телләрдән килә, димәк, безнең ерак бабалар ирани халыклар белән тыгыз аралашып яшәгәннәр.

Этимологиядә халыкның тарихын күз алдында тәфсилле ачыклык белән күрә белү мөһим дидек. Этимолог шуңа омтыларак, тарихи, археологик һәм этнографик әдәбиятны җентекләп өйрәнергә тиеш. Һәм татар телчесенең аңында, әйткәнебезчә, татар тарихының төгәл концепциясе булырга тиеш. Бу бүлектә без үзебез, мәсәлән, шундый нигез фикерләрдә торабыз:

1. Татар халкы үзенең төп тел үзенчәлекләре белән Урта Идел регионында формалашкан.

2. Татар теленең аергыч үзенчәлекләре (борынгы руник һәм борынгы кыпчак консонантизмының саклануы, ә вокализмның кискен, әмма аффинлы системаны бозмыйча үзгәрүе) VI–VIII гасырларда, җирле фин-угор кабиләләрен ассимиляцияләү процессында барлыкка килгән.

3. Азов буе болгарларының теле бик үзенчәлекле булган, әмма ул болгарлар Урта Иделгә килгәч (VIII–IX гасырлар, төгәл генә билгеле түгел), аларның теле борынгы татар субстраты (ул әле «татар» дип аталмаган) тәэсирендә үзгәргән. Болгарлар, нигездә, үз консанантизмнарын саклаганнар (консонантизм, гомумән, сакланучан), әмма борынгы татар вокализмына күчкәннәр.

4. Монгол яулары татар теленә бик аз үзгәреш керткәннәр. Татар вокализмы Алтын Урда чорында яки хәтта соңрак та формалашкан дип бару – тарихи, этнологик һәм лингвистик закончалыкларга каршы килә. Алтын Урда чорында татарларга татар исеме тагылган, урта уйгур теленең тәэсире көчле булган, монгол теленнән берничә дистә сүз алынган. Гомумән, төрки телләрдә монгол алынмалары күп кенә, ләкин алар Чыңгыз хан яуларына кадәр алынганнар! Шул гына.

5. Татар теле һәрвакыт диярлек язулы һәм Урта Идел вә Көньяк Урал регионында халыкара аралашу чарасы булган. Ул барча күрше халыклар телләренә көчле тәэсир ясаган. Күрше телләрдә татар теленең үзендә онытылган сүзләр һәм тәгъбирләр сакланып килә. Иң тәүге дәвердән соң күрше телләрнең татар теленә тәэсире исә көчле булмаган (фин-угор телләреннән алынган сүзләрнең азлыгы шуны күрсәтә).

Тарихи мәгълүматлар этимологик эзләнүләргә башлангыч юнәлеш бирсәләр, этимологик тикшеренүләр тарихи мәгълүматларга төгәллек кертәләр һәм тарихи фаразларны расларлык дәлилләр бирәләр. «Этимология – язма тарихның, тарихчының күрәге» дигән афоризм шуңа ишарә итә. Конкрет алганда, мәсәлән, Алтын Урда дәүләтендә кәнсәләр-контора эшен уйгурлар башкарган, идарә аппаратын шулар тәшкил иткән дип фараз ителә иде (чөнки уйгурлар, бигрәк тә аларның манихей – себер сөйләшләрендәге *маныхай* – динендәгеләре баштан ук Чыңгыз хан яклы булганнар һәм Чыңгыз хан аларны идарә эшләренә җәлеп иткән). Ләкин бу күренешнең масштабы, чикләре һ.б. бик үк билгеле түгел иде. Татар теле буенча тарихи-этимологик тикшеренүләр борынгы уйгур тәэсиренең күләмен чамаларга мөмкинлек бирә. Менә, мәсәлән, *тәпән* «кечерәк бал мичкәсе» сүзе элекке уйгурча *тәги пәнт* «төбе яссы» сүзеннән, арытабан, шул ук *тәги пәнт* татарча диалекталь *тәбән,* шуннан *тәбән-әк* сүзләренә этимологик нигез булуы билгеле. Бу факт исә уйгурларның татар халкы составына да кергәнлеген күрсәтә, чөнки *тәпән, тәбән* һәм *тәбәнәк* кебек көнкүрешкә караган сүзләр турыдан-туры сөйләшеп аралашу нигезендә таралалар.

### Тамыр ясалышы

Тамырлар һәм кушымчалар мәсьәләсе этимологиянең төп тикшерү предметларының (шәйләренең) берсе.

Этимологиядә, синхрон тел гыйлеменнән үзгә буларак, тамыр ясалышы турында да сүз алып барырга туры килә. Синхрон сүз ясалышында тамыр аерым өлешләргә бүленми торган лексик морфема, этимологиядә исә тамыр да еш кына аерым өлешләргә таркатыла.

Татар теленең тамырлар составы түбәндәгечә классификацияләнә:

1) борынгы төркилектән калган һәм инде (хәзергечә) чыннан да таркатылмый торган сүзләр,

2) алынма тамыр сүзләр,

3) тел тарихы дәвамында ясалган тамырлар.

Тамыр ясалу юллары түбәндәгеләр: *гаплология, конверсия* һәм *лексикалашу,* чит телдән *үзләштеру, дублетлашу* һәм *кабат таркалу.*

**Гаплология** дип сүзнең, сүзтезмәнең бик нык кыскарып, состав өлешләре танымаслык булып үзгәрүен атыйлар*. Гаплология, димәк, ике төрле: а) элекке кушымчалы сүз кыскару очраклары, мәсәлән, *бугай* < *булгай* «булырга тиеш» (*бул-* фигыль тамырына теләк фигыль кушымчасы *-гай* ялганып ясалган сүз, борыңгы текстларда, мәсәлән, «төшлек китапларында» – юраунамәләрдә еш очрый), *кумәч* < *куммәч* (*-мач* // *-мәч* ашамлык атамалары ясагыч кушымча), *күтәрү* < *күлтәрү* (элекке *күл-* «йөкләү» фигылен йөкләтү юнәлеше), *ылыгу* < *ыклыгу* (диалекталь *ыгу* «су уңаена агу» сүзенең интенсивлык формасы) һ.б.; б) сүзтезмәләр берегеп кыскару очраклары, мәсәлән: *кузгалак* < *кузыйкалак* < *кузый колак, ябалак* < *йабаколак* < *йабай колак (йабай* – кыргый ат төре), *нитү* < *ни итү; сиксән* < *сэксән* < *сэккиз он; туксан* << *токкуз он; сарут* < *сары ут, ярут* < *яр уты* һ.б.ш.

Татар этимологиясендә гаплологиягә һәрвакыт игътибар ителде, хәтта артыграк та. Мәсәлән, татар телчеләре әйткән *алачык* < *алы (алды) ачык, беләзек* < *беләк йөзек, котыру* < *кот ору* кебек гипотетик гаплология очраклары акланмый (гомумән, дөрес фаразларга өстәмә дәлилләр табыла тора, дөрес булмаганнарына табылып бармый).

***Конверсия*** – сүзләрнең нигез (кушымчасыз) формасында бер сүз төркеменнән икенче сүз төркеменә күчүе – төрки телләрдә элек-электән киң таралган булган. Борынгы төрки телләрдә күп кенә тамыр сүзләр исем дә, фигыль дә булып кулланыла алганнар. Моның сакланган үрнәкләре хәзер дә очрый: *җил* (исем) – *җил-ү* (фигыль), *кат* (исем) – *кат-у* («кушу» – фигыль), *куш* (исем һәм сыйфат) – *куш-у* (фигыль) һ.б. (кара:10 б.). Исемнең сыйфатка һәм киресенчә күчүе хәзерге телдә шактый еш, ә сыйфатның рәвешкә күчүе инде, гомумән, кагыйдә булып киткән диярлек. Шунысы да кызыклы ки, кайбер очракларда бер үк тамыр сүз фигыль дә, исем дә, сыйфат та булып кулланыла ала: *туң-у, көзге туң, туң җир* һ.б. Этимологик тикшеренүләрдә, конверсиянең борынгылыгын искә алып, мәсәлән, хәзерге фигыль тамырының элек исем буларак та кулланылу ихтималын хәтердә тоту мөһим. Фараз буларак, *кыр-у* фигыленең тамыры *кыр* «кырылган җир» булуы ихтимал һәм моның *кыр* «басу» сүзе белән бердәй булу ихтималы юк түгел. Шуның шикелле үк, тюркологлар *яр-у* һәм *яр* («крутой берег») сүзләрен чагыштыралар икән, без бу чагыштыруны баштан ук юкка чыгарырга тиеш түгелбез. Татар сөйләшләрендә киң таралган *чый-у* «очлы нәрсә белән язу, сызу» сүзенең исем коррелянты да бар: себер сөйләшләрендә *цый* «очлы нәрсә белән сызылган сызык». Без бу сүзне кытайча *цзый* «иероглиф» сүзеннән дип карыйбыз, һәм бу фаразның дөреслегенә өстәмә дәлилләр дә табыла: *чый* сүзенең *чыймай* варианты да бар – ул «икмәк, кабартма һ.б.ш. өстенә төшерелгән бизәк» һәм «шундый бизәк төшергеч корал» дигән сүз. Казах сөйләшләрендә *шимай* < *чимай* «аркылы-торкылы сызыклар» – иероглифның үзе инде. Өстәвенә, кытайча да *цзый-ма* «иероглиф сызымы» сүзе бар! Бу этимологик процедурада иң мөһим момент – кытайча исем төркемчәсенә кергән сүзнең фигыль булып китә алуы. Беренче карашка, бу гайре табигый кебек, әмма борынгы дәверләрдә гадәти күренеш булган икән!

Конверсиягә *эллиптик тамыр* ясалышы якын. Лексик эллипсис дип, кушымчалы сүздән кушымча, сүзтезмәдән бер сүз төшерелеп калдырылуны атыйлар. Шундый редукция нәтиҗәсендә сүзнең грамматик һәм лексик мәгънәсе кискен генә үзгәрергә мөмкин. Мәсәлән, татарча *кәләш* сүзе шулай килеп чыккан. Кардәш кыпчак телләреннән һәм чувашчадан да күренгәнчә, *кәләш* «сөйләшү, сөйләм» *(кәлә-* «сөйләү» фигыленең уртаклык юнәлеше) дигән сүз. «Сөйләшү» мәгънәсендәге сүзнең «кыз ярәшү» мәгънәсен алуы – типологик күренеш («кыз сөйләштек» дип хәзер дә әйткәлиләр). Менә шуннан инде элгәре *кәләшле* «сөйләшенгән, ярәшелгән (кыз)» дигән сүз ясалган булган. Бу сүздән азактагы *кыз* сүзе һәм *-ле* кушымчасы да кыскарып, *кәләш* сүзе килеп чыккан. Эллиптик яңа тамыр ясалышы өчен, шулай итеп, транзитив-арадаш ясалмалар булуы шарт. Мондый шартлар исә бик үк еш булмый. Югарыда телгә алынган очракта *кәләш-ү* «сөйләшү» сүзенең онытыла баруы зур роль уйнаган. Нәтиҗәдә, *кәләш* «сөйләш» һәм *кәләш* («невеста») сүзләренең берсе бөтенләй «телдән төшеп калган».

Татар телендә эллиптик тамыр ясалышы, гомумән, еш кына *-лы//-ле* кушымчасы төшеп калу юлы белән бара. Мәсәлән, гарәп сүзләренең чыганактагы мәгънәсе үзгәреп, асылда яңа сүз – яңа тамыр килеп чыгу очраклары шундыйрак: гарәпчә *тәwәккәл* «риск», шуннан татарча *тәwәккәлле* сүзе ясалган, бу сүзнең *-ле* өлеше кыскарып, *тәwәккәл* «ни булса, шул булыр дип, ахыргача уйлап бетермәстән гамәлгә керешүчән» сүзе килеп чыккан. Шулай ук *сабыр* (гарәпчә бу сүз – исем) → *сабыр-*

[1] Рус тел гыйлемендә **гаплология** терминына таррак мәгънә бирелә.

*лы* → *сабыр* (сыйфат), *хәтәр* (исем) → *хәтәрле* → *хәтәр* (сыйфат) һ.б.

***Лексикалашу*** – төрләнеш формасындагы сүзнең төп формадагы сүз булып аңлашылуы (һәм еш кына фонетик яктан да үзгәрүе) – алай ук еш күренеш түгел. Лексикалашуга хәзерге телебездә кайбер бәйлек һ.б. ярдәмлек сүзләрнең, исемнәрнең юнәлеш килеш (мәсәлән, *башка, үзгә),* фигыльләрнең хәзерге заман өченче зат (мәсәлән, *аша* ← *ашу*, *үтә* ← *үтү*) формаларыннан килеп чыгулары мисал. Кайбер вакыт рәвешләре дә шушы рәттә тора, мәсәлән, *иртәгә, кичкә* һ.б.ш. Татар телендә борынгы (*-н* кушымчалы) инструменталь килеш формаларының рәвешкә әверелү очраклары күп кенә: *җәй* → *җәен, күз* → *күзен, кыр* → *кырын, өст* → *өстен, ялгыз* → *ялгызын, кич* → *кичен, иртә* → *иртән* һ.б. (конверсия һәм лексикалашу очраклары синхроник планда Ф.Ә. Ганиевнең «Конверсия в татарском языке» дигән китабында яктыртылган).

***Чит телдән үзләштерү*** дигәннән, алынмалар алу түгел, ә алынма сүзләрнең фонетик яктан гына түгел, мәгънә ягыннан да нык үзгәрү очраклары күз алдында тотыла, мәсәлән, татарча *дәрт* «күңел кузгуы, ярсынучанлык» < фарсыча *дәрт* «авыру, чир, хасталык», татарча *мут* «елгыр һәм хәйләкәр» < русча *мот* «мал-мөлкәтен (бигрәк тә акчасын) әрәм-шәрәм итүче» һ.б.

***Этимологик дублетлашу*** нәтиҗәсендә пәйда булган сүзләрнең оригиналга иң якыннан калганнары – яңа тамыр, мәсәлән, *газап* һәм *азап* парының беренче сыңары – алынма сүз, икенчесе – татар телендә пәйда булган яңа тамыр сүз. Шулай ук *карта* сүзе – рус теленнән алынма, *кәрт* – татар телендә килеп чыккан яңа тамыр һ.б. (мондый тамырлар күп). Төп төрки *бөек* һәм *биек, олуг* һәм *олы, ыруг* һәм *ыру* һ.б.ш. парларның һәр сыңары – аерым тамыр (болардан *бөек, олуг, ыруг* – бүтән төрки телләрдән алынма).

***Кабаттаркалыш күренеше*** тамыр ясалу ысулы буларак артык киң кулланылмый. Бу ысулга мисал – парлы *исе-косы* (*юк*) < борынгы *иесе-конысы*: монда *исе* – борынгы *ийе (< ыйыз, ыйыд)* «ис, аңкыш» сүзенең өченче зат тартым формасыннан: *ие-се*. Тора-бара *ийе* тамыр сүзе үзе онытылгач, *ие-се* сүзе *иес-е* дип «кабат таркатылган» һәм шуңарчы булмаган *ис* («запах») сүзе пәйда булган (шуннан элекке *ис* < *эс* «хәтер» сүзенә омоним килеп чыккан). Нәкъ шуның шикелле, *куңу-сы* > *коңысы* > *кос-ы* (кебек аңлашылган). *Төс* сүзе борынгы *тү-сү* «тө-се» (*тү* «атның һ.б. терлекләрнең йон-ябагасы») сүзеннән. *Микән* кисәкчәсе *-мы икән* компонентларыннан кабаттаркалыш юлы белән ясалган һ.б.

## Кушымчалар ясалышы

Кушымча морфемаларның ясалыш юллары түбәндәгеләр:

1) кушымча тулы лексик мәгънәле сүздән, мәсәлән, *-чы* исем ясагыч кушымчасы (*башчы, итекче, эшче*) борынгы *чын* «кеше, кемсә» сүзеннән; *балтырган, бөрлегән, карлыган, кылган, шалкан* үсемлек исемнәрендәге *-ган* || *-кан* кушымчасы монгол телләрендә сакланган *гана* || *кана* «үсемлек, җимешле үлән» сүзеннән (татар сөйләшләрендә *кана-у* «үсеп чыгу, курпылау») һ.б.;

2) кушымча борынгы ике-өч кушымча яисә лексик мәгънәле сүз һәм кушымча берегүдән килеп чыга, мәсәлән, *-кыч* кушымчасы элекке *-кучы* < *-ку+чы* кушма кушымчасыннан; *-ла* һәм *-лы* < *-лыг* кушымчаларының *-л* өлеше борынгы *ул* «җыен, масса, туплам, күплек» сүзеннән (*-ла* < *-ул-а, -лыг* < *-ул-ыг*); *-ты* үткән заман фигыль кушымчасы борынгы *-т* + *ы* кушмасыннан (*-т* фигыльдән исем ясагыч, *-ы*//*-е* тартым кушымчасы); *-ныкы*//*-неке* кушымчасы *-ның*//*-нең+ке* кушымчаларыннан тора һ.б.;

3) кушымча чит телдән үзләштерелә, мәсәлән, фарсы теленнән *имәнсәр, каенсар* кебек сүзләрдәге *-сар*//*-сәр; акылдар, илдар, колдар* кебек сүзләрдәге *-дар* кушымчасы алынган; *Дума-ви* (*Дума* авылыннан), *Утыз Имәни* (*Утыз имән* авылыннан) кебек фамилияләрдәге, шулай ук *әкият-и, дәүләт-и* кебек сүзләрдәге *-и, -ви* – гарәп теленнән һ.б.;

4) яңа кушымча борынгы кушымча дублетлашу мәгънәсендә пәйда була, мәсәлән, *-лы* || *-ле* һәм *-лык*//*-лек* борынгы *-лыг* кушымчасыннан килә һ.б.

## Фонетик принцип

Этимологиядә фонетик принципның ике аспекты бар: 1) методологик аспект һәм 2) этимологиянең ышандыргыч булуы аспекты.

Әйткәнебезчә, җитди этимология тикшерелгән сүз турында барча мәгълүматларны, иң беренче чиратта, аның таралыш ареалын, нинди телләрдә нинди яңгырашларда, нинди язылышларда һәм ниндиерәк мәгънәләрдә очравын теркәүдән башлана. Бу эшне башкару өчен исә бер үк тарихи лексик берәмлекне теләсә нинди фонетик һәм орфографик киемдә таный белергә кирәк.

Моның өчен исә, беренче чиратта, телләр арасындагы фонетик тәңгәллек закончалыкларын өйрәнергә кирәк. Ә фонетик тәңгәллекләр бик катлаулы,

аларны бер утыруда гына нык үзләштереп булмый. Фонетик закончалыклар шундый ки, беренче караштa охшаш сүзләр бөтенләй ят-чит, ә бөтенләй охшаш булмаган сүзләр, чынлыкта, бер үк сүзнең төрле локаль яңгырашлары булырга мөмкин.

Мәсәлән, кыргызча *болот* дип язылган. Кыргыз теленең фонетик закончалыкларын белмәгән татар моны *болыт* («туча») дип уйлап куюын көт тә тор. Хәлбуки, кыргызча *болот* – татарча *булат* (аеруча сыйфатлы корыч).

Чувашча *хур* – татарча *каз.* Бер генә аваз да туры килми. Әмма болар – бер үк тарихи сүзнең төрлечә чагылышлары гына. Һәм безнең шулай дип раславыбыз барча фонетик закончалыкларга нигезләнә, шулардан килеп чыга.

Фонетик закончалыклар барча телләр һәм барча чорлар өчен бердәй түгел. Бер өлкәдә бер чорда булып үткән фонетик үзгәреш бүтән өлкәдә бүтән чорда кабатланмаска мөмкин, гәрчә бер үк телнең тарихында булса да.

Фонетик үзгәрешләр тарих дәвамында берсе өстенә берсе җиңел катламланалар һәм моны да исәпкә алырга кирәк. Мәсәлән, татарча *кыз* – чувашча *хĕр: з* урынында *р* – борынгылык галәмәте (ягъни *р* борынгырак). Ләкин әле бу сүзнең иң борынгы яңгырашы чувашча дигән сүз түгел, чуваш телендәге *х*, татарча *ķ*-га караганда, яңарак, ә палательләшү (*ы* > *ĕ*) аннан да яңарак. Димәк, татарча *кыз*ның *кы* өлеше, ә чувашча *хер*нең *-р* өлеше борынгырак. Безгә билгеле булган иң борыңгы варианты – *ķыр* «алтын, кыйммәт нәрсә» (кызларны шулай атаганнар).

Этимологиянең ышандыргыч булуы ягыннан каралган фонетик принцип – сүзнең тарихы телнең тарихи фонетикасына хилафлык китерү рәвешендә аңлатылмаска тиешлеге ул.

Татар теленең фонетик тарихы мәгълүм (тик ул дәреслекләрдә начар яктыртыла, монысы – икенче мәсьәлә). Һәм, әйтеп үтик, татар фонетикасы тарихи яктан күрше төрки телләр – чуваш, башкорт, казах фонетикаларына караганда гадирәк тә. Базис нәрсә – руник ядкәрләрдә чагылыш тапкан тел. Борынгы кыпчаклар, бу телне кабул иткәндә, элекке телләрендә булган *w* авазын төрки интервокаль *-ғ-* һәм *-г-* урынына кулланганнар, интервокаль *ķ* һәм *к* урынына исә алар *-ғ-* һәм *-г-* авазларын куллана башлаганнар. Гомумән, бу процесс «тел ялкаулыгы» закончалыкларына туры килә: сөйләшүчеләр, аңлаешлылыкны саклаган хәлдә, җиңелрәк әйтергә тырышалар. Төрки *ғ, г* тартыклары, *ķ, к* тартыкларына караганда, ә *w*, *v* тартыклары, *ғ, г* тартыкларына караганда, җиңелрәк әйтелә. Шул рәвештә аффинлы (үзара багланышлы) дип билгеләнә торган күчешләр пәйда булган:

*ķ* > *ғ* || *ғ* > *w*, *v*
*к* > *г* || *г* > *w, v.*

Татар теле борынгы кыпчак теленнән үсеп чыккан. Борынгы кыпчакларның бер өлешендә тагын түбәндәге аффинлы күчеш пәйда булган:

*э* > *и* || *и* > *ĕ* (татарча кыска *е*).

Менә шул телдә сөйләшүче кыпчак кавеме Урта Идел регионына килеп утырып, җирле финугорларны төркиләштергән. Бу кыпчаклар, үз чиратларында, җирле телләрдә булган *ŏ* һәм *х* авазларын үзләштереп, гомумтөрки *у* һәм *ү* урынына куллана башлаганнар. Шул процесста алар гомумтөрки *о* һәм *ö* авазларын оныткаңнар, аларны *у* һәм *ү* авазлары белән алмаштырганнар. Шулай итеп, түбәндәге аффинлы күчешләр пәйда булган:

*о* > *у* || *у* > *ŏ;*
*х* > *ү* || *ү* > *ө;*

Татар тарихи фонетикасы шул этаплар белән билгеле. Әлбәттә, монда катлауландыргыч моментлар да бар. Андыйлар турында (алар зур роль уйнамаганлыктан) без биредә сөйләп тормыйбыз. Тик түбәндәгеләрне өстәү мөһим.

Аваз күчешләре гомумән ике төрле: *тоталь күчешләр* һәм *позицион күчешләр*. Тоталь күчештә телдәге бер аваз тулысынча, барча сүзләрдә дә икенче бер авазга «күчеп», әверелеп бетә. Позицион күчештә аваз позициясенә карап үзгәрә: мәгълүм бер позициядә үзгәрә, калганнарында үзгәрми. Тоталь күчешләр нинди дә булса бер кавем, халык **чагыштырмача тиз арада** икенче халык теленә **борынгы заман шартларында** күчкәндә килеп чыкканнар. Ул заманнарда җиңелгән халыкта да, җиңгән халыкта да тел нормаларын саклау булмаган диярлек: яңа телгә күчү дә һәм субстрат тел тәэсире дә җиңел кичерелгән. Позицион күчешләр исә башлыча телнең камилләшү, үсү процессында пәйда булалар. Ләкин бу процесста да субстрат яисә күрше телләрнең тәэсире шактый зур роль уйный.

Шушы уңайдан телләр кушылгалану турында да бер-ике сүз әйтергә кирәк. Заманында бездә В.Я. Марр фәнни мәктәбе телләр кушылуга зур әһәмият биргән. И.В. Сталин телләр кушылу теориясен юкка чыгарган, ике халык берләшкәндә, бер генә тел җиңеп чыга дигән. Хакыйкать уртада булса кирәк: әлбәттә, телләр кушылу очрагында, грамматика ягыннан бер генә тел грамматикасы

кулланыла башлый, әмма фонетика һәм лексикада, шулай ук сүз ясалышында аерым үзенчәлекләр, элементлар һәр ике телдән дә алынырга мөмкин һәм алынган да. Бу закончалык казакъ телендә ачык күренә. Бу тел борынгы кыргыз һәм борынгы нугай телләренең кушылуыннан килеп чыккан: кыргыз теленнән көчле ассимиляция-диссимиляция күренешләре, нугай теленнән аффинлы *ч* > *ш* || *ш* > *с* күчешләре алынган.

Шуны әйтергә кирәк: хәзерге заман шартларында телләрнең борынгыча берләшүе, һәрхәлдә Евразиядә, мөмкин түгел диярлек. Үзара бик якын булган телләр генә уртак әдәби тел кабул итеп, ул әдәби телнең нормалары төрле телләрдән сайлап алынган булырга мөмкин. Мәсәлән, немец әдәби теле «Саксония кәнсәләрендә төзелгән» дип язалар. Хәзерге немец әдәби теле күп кенә диалектларны берләштерә.

Ясалма әдәби телләрнең берсе – хәзерге чуваш әдәби теле. Аның кайбер фонетик нормалары (*а* > *о* > *у* күчеше) анатри диалектыннан, икенчеләре (басымны беренче иҗеккә төшерү һ.б.) вирьял диалектыннан алынган. Нәтиҗәдә, чуваш әдәби теле татар теленнән махсус ераклаштырылган. Татар әдәби телендә дә мишәр һәм урта диалектларының үзенчәлекләре берләштерелгән (шуны әйтергә кирәк: халык теленә якынрак яңа татар әдәби теле мәсьәләсен нәкъ менә мишәрләр – бертуган Фәезхановлар һ.б. күтәреп чыкканнар). Заманында С. Кукляшев (шулай ук мишәр) яңа татар (Казан) телен барлык кыпчак халыкларының – татар-башкорт, нугай, казакъ, кыргыз, кумык һәм карачай-балкарларның – уртак әдәби теле итеп үстерергә тәкъдим иткән (һәм бу юнәлештәге омтылышлар XX гасырның егерменче елларына кадәр дәвам иткән), ләкин Рәсәй идарәчеләре (алар нинди генә – царистмы, коммунистмы булмасын) һәрвакыт мондый омтылышларга каршы чаралар күргәннәр.

Башкорт әдәби теле дә (бәлки, бигрәк тә) ясалма. Аның лексик, фонетик һәм морфологик нормалары төрле сөйләш үзенчәлекләрен чагылдыра. Мәсәлән, башкортча *әсә* «ана» (*әсәй* «әни») сүзләре башкортларның дүрттән бер өлешендә генә кулланыла (шуны әйтеп узыйк: диалектолог Д.Б. Рамазанова күрсәткәнчә, *әчә* «ана» сүзе татар теленең төрле сөйләшләрендә дә киң таралган сүз икән). Башкортларның күпчелеге *инә, инәй* дип сөйләшә (бу вариант татарлар арасында да, бигрәк тә Көньяк Урал ягында, еш очрый һәм хакас телендә норматив вариант). *Әсә* сүзен нормативлаштыру, күренеп тора, ничек тә булса татар теленнән аерылу өчен кирәк булган. Шул ук хәл фонетик нормаларда: башкорт әдәби орфографиясендә, мәсәлән, гомумтөрки һәм гомуммөселманча сүзләрдәге *д* һәм *з* авазларын һәрдаим (электән үк булса да, булмаса да) интерденталь *ҙ* авазы (хәрефе) белән алмаштыралар: *әҙәбият* «әдәбият», *мәҙәни* «мәдәни», *үҙем* «үзем» һ.б. (әмма рус теленнән һәм рус теле аша кергән сүзләргә кагылынмый: *директор* «директор», *закон* «закон» һ.б.). Этимологик тикшеренүләрдә менә бу хәлләрне дә белергә һәм исәпкә алырга кирәк, чөнки сүзлекләрдәге кайбер сүзләр яңа ясалмалар булырга мөмкин яисә аларның яңгырашы, әйтелеше һ.б. ясалма әдәби-норматив тел калыпларында бирелеп, этимолог өчен «бозылган товар» булуы ихтимал.

Этимологиядә фонетик үзгәреш законнарын исәпкә алу – иң әһәмиятле принципларның берсе, һәм менә шуның өчен дә әдәби-язма телләрнең орфографиясе реаль яңгырашларны ничек чагылдыруын бик яхшы белү кирәк.

Фонетик законнар кырыс, алар (күп тапкырлар тикшерелгән) һичкайчан да тикмәгә бозылмыйлар. Әгәр тәкъдим ителгән этимология фонетик законнар белән килешми икән, тәкъдим кире кагыла. Мәсәлән, *җилпуч сүзе җилпәвеч, җилпевүч* сүзеннән дип тәкъдим ителә. Ләкин, беренчедән, төп татар телендә *и* – *у* сингармоник чылбыры юк, икенчедән, бу сүздә беренче иҗектә алгы рәт (нечкә) сузык, икенче иҗектә арткы рәт (калын) сузык. Мондый хәлләр кушма сүзләрдә генә булырга мөмкин. Димәк, *җилпуч* кушма сүз. Безнеңчә, ул *җил* + *пуст: җил* «җил, җилләтү», *пуст* (фарсычадан) «тире»; баштан ук *җилпуч* агачтан түгел, каткан тиредән ясалган! Бүтәнчә икенче иҗектәге *у* авазын аңлатып булмый.

Нәкъ шундый ук хәл (татар сингармоник чылбырларына хас булмаганча, -*и*- авазыннан соң -*у*- килү) *бичура, мичура, пичура* сүзләрендә дә күзәтелә һәм ул бу сүзләрнең төбендә кушма сүз булырга тиеш дигән фикергә китерә (безнеңчә, борынгы *мич чура* сүзеннән: *мич* < *мәч, мәчин* «маймыл, ямьсез пәри», *мичен, би-чен* дә диелә һәм *чура* «уйнаштан туган бала, кол, хезмәтче»).

*Матур* сүзе ничек кенә төп татар сүзе кебек тоелса да, фонетик йөзе буенча – алынма (себер төрки телләреннән килеп кергән: алтай сөйләшләрендә *матур* < *магатур* «батыр, баһадир; матур егет» – асылда шул ук *баһадир ~ баһадур ~ батыр).*

### Тел лексикасының этимологик класслары

Татар телендәге таркатылмас нигезләр тарихи яктан түбәндәгечә классификацияләнәләр:

1) гомумтөрки нигезләр;

2) татар теленең үзендә генә булган нигезләр;

3) төрки булмаган телләрдән алынма нигезләр.

Бу классификация аңлатуга мохтаҗ. Гомумтөрки нигезләр дигәннән: а) барлык яисә күпчелек төрки телләрдә теркәлгән нигез сүзләр, б) борынгы баба төрки (пратюркский) бер телдә булган дип фараз ителгән нигез сүзләр керә. Ягъни, гомумтөрки дип аңлату өчен, сүзнең барлык төрки телләрдә дә билгеле булуы шарт түгел. Чөнки сүзләр онытылучан һәм, өстәвенә, телдә булып та, әле һаман теркәлмичә калырга мөмкин. Икенче яктан, гомумтөрки сүзләр арасында һинд-ирани, кытай, монгол һ.б. телләрдән алынмалар да аз түгел.

Татар теленең үзендә генә булган нигезләр мәсьәләсе дә гади түгел. Бу төр нигезләр арасында: а) гомумтөрки тамырлардан ясалганнары, б) алынмалардан ясалганнары, б) фонетик дублетлашу юлы белән ясалганнары, в) чыгышы билгесез сүзләр бар. Өстәвенә, кайбер нигезләр бүтән төрки телләрдә татар теленә бәйсез рәвештә үзләрендә нәкъ татарча кебек ясалырга һәм теркәлми калырга мөмкин. Андый параллель ясалышлы нигезләр, гадәттә, татарча варианттан фонетик яктан аерылалар, ләкин аерылмаска да мөмкин.

Алынма дигәннән, гомумтөрки алынмаларны татар телендәге алынмалар рәтенә кертү-кертмәү мәсьәләсе четерекле. Бу төркемдә тагын түбәндәге асклассլар бар:

а) төрки телләрдән алынмалар;

б) калькалар һәм лексикологик субституцияләр;

в) чыгышы билгесез халыкара, «мәдәни» сүзләр;

г) бер борынгы сүздән таралып, татар телендә төрле чыганаклардан һәм төрлечә килеп кергән полиплет алынмалар.

Икенче бер яктан, таркатылмас нигезләр сүз төркемнәре буенча бүленәләр. Этимология өчен сүз төркемнәренең (схемада күрсәтелгән) дихотомик бүленеше уңайлы һәм нәтиҗәле. Сүз төркемнәренең һәркайсының этимологиясе үзенчәлекле була һәм ул үзенчәлекләрне белеп эш итү тиешле.

**Сүз төркемнәренең этимологик үзенчәлекләре буенча классификациясе**




**Ымлыклар** (беренчел, төп ымлыклар) барча телләрдә бер ишлерәк; *аһ, эһ, ифу, һи-һи, ыы* һ.б. Алар рефлектор авазларның белдерелешләре.

**Тәкълиди** (русча «*подражательные*») **сүзләр** ике төрле: **имитативлар** (татарча **ияртемнәр** дә диеләә, ләкин бу уңышсыз термин, чөнки **ияртем** ул, сүз ясалу мантыйгы буенча, «ияртелгән нәрсә» – русча «нагрузка к товару; придача», шулай ук «ведомый, завлекаемый»), мәсәлән, **барк-барк** (үрдәкләр кычкырыгына тәкълит, ягъни шуңа охшатып кычкыру), **кар-кар, чи-чи; ыж-ж, ыс-с** һ.б., һәм **ономопоэтик (ономатопоэтик)** сүзләр, мәсәлән, **елт, ялт, җилт, кылт, тумп** (**тумпа** сүзенең тамыры), **челт** һ.б. (ягъни, авазы-өне булмаган күренешләрне гүяки авазлы итеп белдерүләр). Беренче төр тәкълиди сүзләр барча телләрдә охшаш, икенчеләре алай түгел.

Төрки телләрдә тәкълиди сүзләрнең үз морфологиясе һәм сүзьясалыш модельләре бар.

**Билге сүзләрдә** яңгыраш-авазлар составы һәм иҗек төзелеше белән белдерелгән нәрсә арасында берниндн уртаклык та юк, ләкин еш кына билге сүзләр тәкълиди сүзләрдән ясалалар.

**Ярдәмлекләр** тел үсеше тарихында төшенчәлек билге сүзләрдән килеп чыгалар. Хәзерге төрки телләрдә бик күп ярдәмлекләр – алынма сүзләр.

**Алмашлыклар** һәм **төп саннар** һәр телдә чикләнгән санда була. **Алмашлыкларда** һәр телдә регуляр булмаган төрләнеш (супплетивизм) һәм лексикализация еш очрый. Алар һәр төрки телдә үзенчә.

Саннар, алмашлыклар һәм фигыльләр составында алынма сүзләр бик сирәк була. Исемнәрдә һәм сыйфатларда алынмаларга чик куелмый.

Этимологиягә караган нигезләр тагын типологик яктан да тикшерелә. Андый каралышта түбәндәге класслар аерыла:

1) төрки телләрдән элеккерәк (гомумтөрки телгә төзү материалы биргән) телләрдән калган билге тамыр сүзләр;

2) ясалганлыгы билгеле билге тамырлар;

3) алынмалыгы билгеле билге тамырлар;

4) ымлык тамырлар;

5) тәкълиди тамырлар һәм нигезләр;

6) чыгышы билгесез тамырлар һәм нигезләр.

Ясалма тамыр һәм нигезләрнең аерым четерекле ягы бар: аларның ясалыш мотивациясе. Аерым алганда, бу мәсьәләдә субституция һәм калька дигән мотивацияне белү мөһим.

## Субституцияләр һәм калькалар

**Субституция** – чит телдәге тел элементларын үз тел элементлары белән алмаштыру дигән сүз.

Фонетик субституция чит телдәге авазларны (һ.б. фонетик элементларны) үз фонетик элементлар белән алмаштыру (мәсәлән, *ведро* > *бидрә, грузди* > *гөрежди, печь* > *мич* һ.б.) сүзләрдә була. Фонетик субституция (һәр ике тел арасындагы фонетик тәңгәллекләр) аерым закончалыкларга буйсына һәм этимологиядә аларны бик яхшы белергә кирәк. Алар шактый катлаулы булырга мөмкин (мәсәлән, рус-татар, татар-чуваш, татар-башкорт телләре арасында фонетик тәңгәллекләр һ.б.ш.).

Лексик субституция дигәннән, бүтән бер телдән «тәрҗемә ителеп», бүтән тел сүзе (шул ук сүзтезмәсе) урынында ясалган сүзләр (һәм сүзтезмәләр) күз алдында тотыла (мәсәлән, *тракторчы* «тракторист», *эшчеләр сыйныфы* «рабочий класс»). Сүз уңаеннан шуны да әйтеп узыйк: хәзерге татар әдәби телендәге һәртөрле административ терминнар бик еш кына рус телендәге тәгъбирләрдән лексик субституцияләр: *дәүләт комитеты, профильле мәктәп, яшьләр үзәге* һ.б. Мондый сүзтезмәләрнең конкрет мәгънәсе еш кына аларның русча тәңгәллекләрен белгәндә генә ачык аңлашыла. Ләкин аларны алынма дияргә ярамый!

**Калька** дип, чит телдәге сүзнең (сүзтезмәнең) ясалыш яисә мәгънә структурасын туган телдәге тәрҗемә сүзгә тулысынча күчерүне атыйлар. Калькалаштырганда, чит телдәге сүзнең күчерелмә мәгънәсе күчерелә.

Икетеллек шартларында (ә татар халкының шактый өлеше һәрвакыт, һәр заманда ике телле булган) калькалар сүз ясалышына һәм мәгънәви үзгәрешләргә гаять зур йогынты ясаганнар. Кальканың калька икәнлеген белү өчен, экстралингвистик детальләрне белү мәҗбүри.

Субституция һәм калькалар ясалышы этимология өчен гаять зур әһәмияткә ия, әмма ул иң аз өйрәнелгән өлкә. Хикмәт шунда: сүзлекләрдә сүзләрнең төп мәгънәләре һәм кайбер күчерелмә мәгънәләре, кайбер (киң кулланылучан) сүзтезмәләр составында килүләре генә күрсәтелә. Өстәвенә, күчерелмә мәгънәләр һәм сүзтезмәләрнең күбесе тарих дәвамында агым су кебек тотрыксыз: бүген актуаль күчерелмә мәгънә яисә сүзтезмә иртәгә бөтенләй онытылырга мөмкин.

Калькалар өлкәсендә тагын шундый мәсьәлә килеп туа: еш кына бер-берсеннән ерак торган телләрдә дә бердәй сүзләр вә сүзтезмәләрнең мәгънә структуралары бердәй булырга мөмкин. Мифологиядә, әкиятләрдә, йолаларда охшаш элементлар барча телләрдә дә табылган шикелле, сүз структураларында да телләр тәэсирләшүдән тыш килеп чыккан охшашлыклар булгалый. Мәсәлән, русча *бабье лето* ~ татарча *әбиләр чуагы* ~ немецча *Altweibersommer* – көзге җылы көннәрнең фигураль атамасын игътибарлап карасак, рус һәм немец тәгъбирләре үзара тәэсирләшү нәтиҗәсе булуы бик ихтимал булса да, *әбиләр чуагы* тәгъбиренең нәкъ рус яисә немец сүзе тәэсирендә килеп чыгуы шикле.

Шулай ук, русча *игрушка* һәм татарча *уенчык* сүзләренең мәгънәви структурасында аеруча охшашлык бар: һәр ике очракта сүзнең формаль мәгънәсе «кечкенә уен», реаль (күчерелмә) мәгънәсе «уйнау предметы». Калькалаштырумы икән бу? Хәтта монда да әйтүе читен. Өстәвенә, һәр ике очрак өченче бер телдән калька булу ихтималы юк түгел.

Бертөркем тел семьялыкларында – төркиләрдә, монголларда, фин-угорларда, кытайларда һәм

дравидларда (Көньяк Һиндстан) модификатор (актионсарт) фигыльләр кулланыла һәм аларның мәгънәләре бертөсле. Мәсәлән, *киту* мәгънәсендәге фигыльләр модификатор буларак «кинәт башлануны» (*балкып киту, ярсып киту*), *чыгу* мәгънәсендәге фигыльләр «тәмамлау, һәммәне эченә алуны» (*укып чыгу, карап чыгу*) белдерә һ.б. Бу очракта да модификатор фигыльләрнең функцияләре – мәгънә структуралары охшашлыгы борынгы тәэсирләшү нәтиҗәсе дип әйтеп булмый әле. Өстәмә дәлилләр кирәк.

XX гасырның 10–20 нче елларында татар әдәби телендә бик күп калькалар (башлыча рус сүзләреннән күчереп) ясалганнар. Иң элек алар иҗтимагый-сәяси терминнар: *алым ~ приём* («ысул» мәгънәсендә), (*социаль*) *чыгыш ~* (*социальное*) *происхождение* (*исходить* «чыгу»), *суллык ~ левизна* («артыкча революционлык, кискенлек» мәгънәсендә). Соңрак матди мәдәниятка мөнәсәбәтле сүзләр калькалаштырыла: *азыктамыр ~ корнеплод, субүләр ~ водораздел, водораздельный, суүсем ~ водоросль; очлыклар ~ конечности* (аяк-куллар, бу сүз, үз чиратында, французча *extremitat* сүзеннән калька) һ.б. Этимолог бу очракларны да белергә тиеш. Әйтергә кирәк, бу өлкәдә дә кайбер сүзләр, сүзтезмәләр чынлыкта калька түгел, күп дигәндә, субституция генә. Мәсәлән, *ташландык ~ бросовый, утчәчәк ~ горицвет, еллык балдаклар ~ годичные кольца* кебек номинацияләр рус телен бөтенләй белмәгән кешеләр телендә килеп чыга яки ясала алыр иде.

### Омонимнар

Татар телендә омоним нигезләр һәм тамырлар шактый күп. Ләкин абсолют омонимнар – бер үк сүз төркеменә караганнары артык күп түгел. Омоним тамырларның күпчелек өлешендә сүзләрнең берсе – сыйфат, рәвеш яисә исем, икенчесе – фигыль. Мәсәлән, *аз – аз, күп – күп, кыл – кыл, тел – тел, чык – чык, ят – ят* һ.б.ш. Тел, гадәттә, омонимнардан котылырга омтыла. Бу сыйфат (исем)-фигыль омонимнарның телдә сакланып калуы шуның белән аңлатыла: исемнәрнең һәм фигыльләрнең төрләнеш парадигмалары үзгә, аермалы. Ә бит һәрбер сүз инсан миендә тамыры-нигезе белән генә түгел, бөтен төрләнеш формалары белән берлектә яши. Шунлыктан әлеге омонимнар телдә буталышмыйлар. Өстәвенә, кайбер фигыль тамырлар «саф» – киемсез килеш гамәлдә бөтенләй диярлек кулланылмый. Мәсәлән, *ак* «белый», «светлый» кулланыла, ә *елга, ак*! дип әмер бирү (хәзерге заман берлектәге икенче зат формасы) сирәктән сирәк кенә телгә килергә мөмкин. Элеккерәк заманнарда фигыль тамырлар вә нигезләр «ялангач» шәкелдә бөтенләй кулланылмаган. Боерык фигыльнең икенче зат берлек формасы *-гыл//-гел, -кыл//-кел* кушымчасы ярдәмендә белдерелгән: *әйткел, баргыл, килгел* һ.б. (шундый формалардан *диген* < *дигел* хәзер дә кулланыла). Гомумән, бердәй сүз төркеменә караган омонимнарның яшәве дә аларның пардаш кайберләре аз валентлы булулары, аерым сүзләр белән генә килүе яисә мәкальәйтемнәрдә генә очравы белән аңлатыла. Мәсәлән, сүзлекләрдә биш *төш* сүзе күрсәтелә. Тик аларның берсе фигыль тамыры, аның парадигмасы үзгә. Исем *төш*ләрдән тулы парадигмасында тик русча «сон» мәгънәсендәге сүз генә кулланыла. «Көн уртасы» һәм «урын, нокта» мәгънәсендәге *төш*ләр бөтенләй үзгә сүзләр белән кулланылалар: *төшкә кадәр, төштән соң* тәгъбирләрен *шул төштә* тәгъбире белән беркем дә бутамый ич. Бишенче *төш* исә, гадәттә, «чикләвек» сүзе белән генә килә (аны русча физикадагы «ядро» мәгънәсендә куллану ясалма рәвештә – русчадан тупас калькалаштырудан килеп чыга, монда бүтән сүз табып булыр иде).

Этимологиягә мөнәсәбәттә карап, чыгышлары буенча омонимнарны түбәндәге төркемнәргә аерырга мөмкин: 1) фонетик үсеш-үзгәрешләр нәтиҗәсендә пәйда булганнары, 2) омоним тамырлардан яисә омоним кушымчалар ярдәмендә бердәй тамырлардан ясалганнары, 3) төрле мәгънә үзгәрешләре нәтиҗәсендә бер үк сүзләрнең ике мәгънәдә һәм төрле валентлыкта кулланыла башлау очраклары – радиация, 4) лексик һәм фразеологик эллипсис нәтиҗәләре, 5) чит теллләрдән сүзләр алу яисә калькалаштыру нәтиҗәләре.

**Фонетик үзгәрешләр,** югарыдарак әйткәнебезчә, башлыча ике төрле: позицион һәм тоталь характерда була. Позицион үзгәрешләр тагы ике төрле: аваз кыскарулар (редукция һ.б.ш.) һәм позицион аваз күчешләре (ассимиляция, диссимиляция һ.б.ш.). Махсус тарихи фонетика курсларында фонетик үзгәрешләрнең бүтән (сирәк) төрләре дә күрсәтелә, без аларга тукталып тормыйбыз.

Барча телләрдә сүзләрнең кыскара баруы – фонетик үсешнең генераль линиясе ул. Бигрәк тә сүз нигезе азаклары кыскара: редукцияләнә. Ләкин һәрбер тел механизмы үзендәге кыскару процессына үзенчә җайлаша, үзрегуляция һәр телдә үзгәчәрәк бара. Төрки телләрдә бер-берсенә ялганып килә торган төрләндергеч кушымчалар кыскарты-

луга бирешмиләр, чөнки аларның һәрберсе үз урыннарында алыштыргысыз: һәр төрләндергеч үз мәгънәсендә (һәм үз сингармоник рәтендә) бер генә һәм ул бер генә грамматик мәгънәгә ия. Ә менә тамырлар һәм нигезләр кыскаручан. Нәкъ менә шундый кыскарулар нәтиҗәсе буларак, *ат* (< *ахта*) һәм *ат* (< *айыт*) «исем», *кул* (<*кол*) һәм *кул* (<*коол*) «тирән үзән», *сай* һәм *сай* (< *сагай*) «рәт, тезем» һ.б. омоним тамырлар пәйда булган.

Кайбер төрки телләрдә омонимнар тоталь фонетик үзгәрешләр нәтиҗәсендә пәйда булалар. Мәсәлән, казакъ телендә *бас* «бас!» (*бас-у* фигыленең боерык формасы) һәм *бас* «баш» сүзләренең омонимлыгы казакъ телендә тоталь *ч* > *ш*//*ш* > *с* үзара бәйләнешле күчешләре нәтиҗәсендә килеп чыккан.

Чуваш телендә велярлашу (*ә* > *а*, *ү* > *у* һ.б.ш.) нәтиҗәсендә *анра-* «аңгырау» – *анра-* «иңрәү», *антăх-* «ант итү» – *антăх* «интегү», *ас-* «азу» – *ас* «ис», *ват-* «вату» – *ват* «ут», *какăр* «кәкер, кәкре таяк» – *какăр* «каһәр» кебек омонимнар пәйда булган. Башкорт телендә *з* > *ҙ* һәм *д* > *з,* күчешләре (тоталь диярлек *ҙ*-ләштеру) нәтиҗәсендә омонимнар пәйда була: *биҙәр* «бидәр» һәм *биҙәр* «бизәр».

Татар теле тарихында (һәрхәлдә, Күктөрек каганаты заманнарыннан соң) тартыклар өлкәсендә (позицион-тоталь *-ķ, -к* > *-г, -г*//*-г, г* > *w, v* күчешен исәпкә алмаганда) тоталь аваз күчешләре булмаган диярлек. Шунлыктан, аваз күчешләре нәтиҗәсендә пәйда булган омонимнар юк. Сүз уңаеннан шуны әйтергә кирәк: аваз күчешләре нәтиҗәсендә омонимнар пәйда булу шул аваз күчешләренең нисби хронологиясен билгеләү өчен ышанычлы чыганак булып тора.

**Омоним кушымчалар** бер үк тамырларга вә нигезләргә ялганып яңа омоним нигезләр ясалуга ачык мисал – татар телендә *килеш-* (фигыль нигезе *кил-ү* сүзенең уртаклык юнәлеше) һәм *килеш* (исем, шул ук *кил-* тамырына исем ясагыч *-еш* кушымчасы ялганып ясалган) шикелле пардашлар сериясе: *йөреш-ү* һәм *йөреш, караш-у* һәм *караш* һ.б. **Омоним тамырлардан** омоним нигезләр дә ясала ала, әлбәттә: *атлы* ← *ат* (хайван) һәм *атлы* ← *ат* (исем); *парлы* ← *пар* (бу) һәм *парлы* ← *пар* (икелек). Ләкин андый сүзләр күп түгел, тел омонимнардан кача.

**Лексик радиациягә** бердәйлекләре нык үзгәргән һәм хәзер инде танылмый торган сүзләр карый (гади конверсия һәм исем-фигыль синкретизмы боларга керми). Мәсәлән, борынгы *балык* «кала, шәһәр» һәм *балык* (рыба) сүзләрен тюркологлар борынгы *балыг, балуг* < *баллуг* «балчыклы, сазламык» сүзенә кайтарып калдыралар. Хикмәт шунда: киез торакларда яшәргә күнеккән төркиләр өчен чи кирпечтән эшләнгән кала корылмалары «балчык» булган. Шул ук вакытта, сазлыкларда яшәгән сазан, табан кебек балыклар да «балчык, саз җанвары» буларак күзалланган. *Ут* һәм *ут* «үлән» сүзләре учакка коры үлән ягып яшәгән заманнардан калган булса кирәк (чагыштырыгыз: шул ук *учак* < *утчак* һәм *утын*). *Ял* «хезмәтченең эш хакы» һәм *ял* «тәнәфес» сүзләре дә төбендә бер үк сүздән булырга тиеш һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, радиацияне билгеләү өчен, борынгы замандагы яшәү шартларын һәм борынгыларның фикерләү рәвешен яхшы белергә кирәк. *Кер* «пычрак» һәм *кер* «юылган тукыма, кием», *уба* «ясалма» һәм *уба* «чокыр», *чүпләү* «чүпле итү» һәм *чүпләү* «чүпләрне җыю» кебек (шәп түгел) очраклар төрле этник төркемнәрдә төрлечә уйлау нәтиҗәләре.

Радиациянең икенче бер төре бер үк телгә төрле диалект, шивә һәм телләрдән сүзләр керүдән килеп чыга. Мәсәлән, *керешү* «бер-берсенә керү» һәм *керешү* «башлау, тотыну» омонимнары шундый юл белән лингвистик ситуация үзенчәлекләре нәтиҗәсендә пәйда булганнар.

**Эллипсис** нәтиҗәсендә радиация килеп чыгуга мисал: *килеш* «килү күренеше» һәм *килеш* (рәвеш) – *килешли* сүзеннән (*килеш* – грамматик термин беренче сүздән күч. мәгъ.); *тибеш* «тибү күренеше» һәм *тибеш* (сыйфат – «көчле, импульсив») – *тибешле* сүзеннән; *тиеш «*тию күренеше» һәм *тиеш* (хәбәрлек) – *тиешле* сүзеннән.

**Чит телләрдән сүзләр алу** (яисә керү) нәтиҗәсендә татар телендә барлыкка килгән омонимнарга мисаллар: *бур* < русча «вор» – *бур* «известьташ», *бит* < «ведь» (кисәкчә) – *бит* «йөз», *көшел* «ындырда ашлык өеме» (русча *кошель* сүзеннән булса кирәк, аның шундый мәгънәсе дә бар) – *көшел* «су күсесе», *кул* «тән әгъзасы» (борынгы төрки *кол* сүзеннән) – *кул* «кечкенә инешле яки инешсез үзәнчек» (борынгы монголча *коол* сүзеннән), *сабак* (*сап* сүзеннән) – *сабак* «үзләштерәсе уку материалы» (гарәпчәдән), *сала* «зур авыл (село)» – *сала* «тезем (биш бармак бергә, яссыга тармакланган ботаклар)», *чут* < «счеты (хисаплау)» – *чут* «махсус аркылы балта» (шуннан *өй бурасын чутлау* – тигезләү) һ.б. очраклар.

Шулай ук омоним парларның икесе ике телдән алынма булу очраклары да сирәк түгел, мәсәлән: татарча *пот* < рус. *пуд* – *пот* < һинди *Будда* (һәйкәле).

Кайбер очракларда омонимнар икесе дә бер үк телдән алынма була, мәсәлән, *җәһәт* «тиз генә, эшлекле рәвештә» – *җәһәт* «як, тараф» икесе дә гарәпчәдән (гарәпчәдә алар икесе ике сүз). *Ну* (ымлыгы) < русча *ну – ну* (теркәгече) < русча *но*; *тут* (агач) – *тут* «тигез төшкән буяу, төс» (шуннан *кер тутлату*) икесе дә фарсыдан, *хур* (*хур булу* сүзендәге) – *хур* (*кызы*) икесе дә гарәпчәдән; *хәл* «гомуми торыш» – *хәл* «чишелеш (хәл итү)» икесе дә гарәпчәдән (чыганак телләрдә бу сүзләр төрлечә язылалар).

Шулай итеп, омоним яисә радиатив пардашы булу сүзнең алынмалык билгеләренең берсе дип расларга мөмкин. Икенче төрле әйткәндә, әгәр телдәге таркатылмас нигезләрдә бер үк сүз төркеменә кергән омоним сүзләр бар икән, шуларның кимендә берсе алынма дип фараз итү һәм тикшереп карау тиеш. Чөнки тел, гомумән, омонимнардан котылырга тырыша һәм үз эчендә генә кайнаган телдә, принципта, тора-бара бер омоним да калмас иде.

Калькалаштыру нәтиҗәсендә радиация килеп чыгу күренеше дә бар. Татар телендә ул башлыча Октябрь революциясеннән соңгы чорларга карый. Бу чорда русча сүзләрнең эквивалентларын табу максатында калькалаштыру киң колач ала һәм яңа омонимнар барлыкка килә. Калькалар арасында бик үк уңышлы булмаганнар очрый: бер өлкәдә *чыгарма* «вывод», икенче бер өлкәдә «исключение»; *социаль чыгыш* (~ русча *происхождение*) һәм *кереш-чыгыш* яисә *чәйнең чыгышы* һ.б. шундыйлар.

Шулай итеп, этимолог омонимнар һәм радиатив сүзләр ясалу ысулларын сүз вә тамыр ясалыш ысулларын белгән кебек үк яхшы белергә тиеш.

### Контаминация һәм халык этимологиясе. «Мәдәни» сүзләр

Этимологиядә берәр сүзнең ике аерым сүздән килеп чыгу (яисә чыга алу) очрагы **контаминация** дип атала. Мәсәлән, *түти* < *түтәй* сүзе *тутай* сүзенең палатальләшүеннән дә, русча *тётя* сүзеннән дә килеп чыга ала; шулай ук *түтәй* сүзенең барлыкка килүе һәм кулланышка кереп китүенә һәр ике чыганак тәэсир иткән булуы мөмкин. Һәм без *түтәй* сүзен *тутай* һәм *тётя* сүзләренең контаминациясе дибез.

Диалекталь сүзлекләрдә очрый торган *телазар* сүзе татарча *теле азар* тәгъбиренең фарсыча *дилазаре* «күңел рәнҗеткеч» сүзе белән аваздашлыгы нәтиҗәсендә барлыкка килгән һәм кулланышка кереп киткән булса кирәк, монысы да контаминация мисалы.

Телчеләр *кылык* сүзен **кыл-у** фигыленнән дә, *холык* сүзеннән дә чыгаралар. Монда да контаминация ихтималы юк түгел.

**Халык этимологиясе** табигате белән контаминациягә якын. Халык этимологиясе дип, гадәттә, алынма сүзләрне туган тел сүзьясалышы модельләреннән чыгып аңлау вә таркатуны атыйлар. Мәсәлән, сөйләшләрдә (әдәби телгә дә кереп була) *канцелярия* сүзен *кәнсәләр* дип әйтәләр һәм бу сүз *кәнсә* сүзенең күплек формасы дип аңлыйлар. Шулай итеп *кәнсә* сүзе килеп чыга. Шуның шикелле үк, *абзай* < *абызагай* сүзеннән элек булмаган *абза* нигезе (*аның абзасы* диләр) пәйда булган һ.б.

**Мәдәни сүзләр** дип, Евразиядәге күп телләрдә очрый һәм чыгышлары, төп чыганаклары тәгаен билгеле булмаган сүзләрне атыйлар. Шундыйлардан татар телендә, мәсәлән, *бәрән* (чаг. русча *баран,* фарсыча *бәррә* һ.б.), *кәҗә, мал* сүзләре керә.

### Этимологиянең фәнчә ышандыргыч булуы

Югарыда сөйләнелгәнчә, этимология барча фәнни принципларга тайпылышсыз җавап бирергә тиеш. Аннары, тәкъдим ителгән этимология гади мантыйкка каршы килмәскә тиеш. Бу таләп бигрәк тә идентификация мәсьәләсендә, ягъни этимологизацияләргә алынган сүзләрнең барысы да чыннан да шул ук сүзме дигән сорауга җавап биргәндә чагыла. Әйтик, татарча *баш*, казахча *бас,* хакасча *пас*, чувашча *поҫ, пуҫ* бер үк сүзнең чагылышларымы соң дип сорау куйыйк. Әлбәттә, диярбез. Ләкин ни өчен? Чөнки бу телләрдә күп меңнәрчә сүзләр һәм, гомумән, морфемалар гаять зур систематик охшашлыклар хасил итәләр һәм әлеге сүз бу телләрдәге аваз тәңгәллекләре кысасыннан чыкмый. Тарихи яктан бу телләрдә сөйләшүче халыкларның күптөрле багланышлар кичергәнлеге билгеле һ.б. Шунлыктан, без йөз процентлы ышаныч белән шуны әйтә алабыз: татарча *баш* һәм хакасча *пас* (һ.б.) – бер үк сүздән киләләр.

Кардәш булмаган телләрдәге сүзләрне чагыштыруда мәсьәлә катлаулана. Мәгънәләре дә, яңгырашлары да бик охшаш, мәгънәләре «туры килгән» сүзләр дә кардәш булмаска мөмкин. Мәсәлән, латин телендә татар сүзләренә охшаш сүзләр очрый: *cardo* «чик сызыгы (киртә?)», *carpo* «эләктереп алу (балык *карпыту* – ?)», *delirium* «тилерү», *macto* «мактау (?)», *maturus* «өлгергән (матур ?)», *salus* « саулык (?)», *tuber* «тубырчык (?)». Ләкин бу сүзләр-

не татар сүзләре белән кардәш дип әйтеп булмый: тикшереп караганда, латин һәм татар сүзләрнең мәгънәви, фонетик һәм морфематик үсешләре бөтенләй үзгә булуы беленә. Аннары, латиннар белән төркиләрнең сүзләр алышырлык тыгыз багланышта булганлыгын тарих белми. Шулай ук немецча *schelten* һәм тат. *шелтә*, *saugen* «имү, саву» һәм тат. *сау-у* мәгънәдәш вә аваздаш булсалар да, тамырдаш-нигездәш түгелләр һ.б. Сүзләр бит һавадан очып килеп кунмыйлар, кешеләр аралашуында таралалар.

Тарихи аз билгеле телләрдәге сүзләр белән татар (туган тел) сүзләрен чагыштырганда, шуңа да игътибар итү мөһим: ике-өч аваздан торган сүзләрнең охшашлыгы бернигә дә ишарә итми, чөнки дөньяда ике фонематик аваз тезмәләренең саны чикле, шулар арасында охшашрак мәгънәлеләре очрау бер дә гаҗәп түгел. Ике-өч авазлы татар тамыр сүзләренә мәгънә ягыннан да охшаш ике-өч авазлы сүзләрне дөньядагы һәрбер телдән табып була. Дүрт-биш авазлы тамыр сүзләр (мәсәлән, югарыда телгә алынган латин сүзләре) дә, бүтән сәбәпләр булмаса, үзләре генә этимологлар игътибарын җәлеп итмиләр. Тик биш авазлы тамырлар гына (ә андыйлар гомумән аз) уйландырырга мөмкин. Бигрәк тә мәдәни мәгънәле, киң таралучан эчтәлекле сүзләр булса. Мәсәлән, мари телендәге *вулно, волно* ~ шумер телендәге *ална* «кургаш», (М. Гордеев уйлавынча) шундыйлар. Әмма андый очраклар да тулысынча ышандырырлык түгел. Бердәй мәгънәдәге фраземалар, җөмләләр эчендә килгән сүзләр рәте бердәйлеге генә тулысы белән ышандыргыч булырга мөмкин.

Һәм, әлбәттә, бу очракта да фонетик закончалыклар гамәлдән чыкмый. Мәсәлән, русча *маленький гражданин* татарча *бәләкәй граждан* тезмәләреннән чыгып, *маленький* һәм *бәләкәй* сүзләре бердәй дип әйтә алабызмы? Юк, чөнки бу сүзләрдәге фонетик аермалыклар аерым-аерым да, берләштергәндә дә дә закончалыклы түгел, аналоглары юк. Русча сүз *мал-* тамырыннан килә, русча *м-* авазы татарчада *б-* авазына әверелү мисалы юк (киресенчәсе – *б-* > *м-* очрый: борынгы русча *бъчка* > татарча *мичкә*); *-ньк-* тезмәсенең татарча субституциясендә *-н-* төшеп калуга мисал кайда?

Гомумән, этимологик фаразлар, «кырык иләк» аша үткәрелгәч кенә, тулысынча ышандырырлык булалар һәм шул чагында гына алар тарих өчен табыш вә материал булалар.

Шуны әйтеп узыйк: күп кенә лингвистлар мавыгып китә торган «ностратик», «бореалистик», «төрки-индиан», «сино-кавказ» һ.б.ш. уртак сүзләргә без бик шикләнеп карыйбыз, алар фәнни этимология таләпләренә канәгатьләнерлек җавап бирмиләр. Мәсәлән, Т. Гарипов һ.б. төрки *айақ* < *аҙақ* һәм русча *пеший* «җәяүле» сүзләрен бер тамырдан дип бара һәм фикерен менә болай нигезли: борынгы төркичә *аҙақ* < *адақ,* борынгы *падақ* сүзеннән килә (кайбер төрки-тунгус-монгол сүзләрендә бор. *п* > *ф* > *һ* > ноль аваз икәнлеге исбат ителгән), димәк, тамыр монда *пад*, рус. *пеший* исә *пех* < *педх* нигезеннән, һинд-европалы *педh* «аяк» тамырыннан. Алтаистик *пад* һәм һинд-европалы *пед//под* бер-берсенә охшашлыгын кем инкяр итә ала? Шулаен шулай да, монда ышандырырлык исбаты булмаган моментлар күбрәк шул: *айақ* < *адақ* сүзенең *падак,* сүзеннән килеп чыккан дигән фараз бары тик корейча *патак* «аяк» сүзенә генә нигезләнә. Төрки-корей уртаклыклары, гомумән, аерым тамыр сүзләргә генә карый һәм шунлыктан шик уяталар. «Аяк» чувашча *ура* < *ора* һәм бу сүз борынгы төрки *арақ* вариантыннан булса кирәк (монысы күп кенә гомуми закончалыклар белән исбатлана). Аннары *аяк* < *адақ* ~ *арақ* һ.б. төрки сүзьясалыш модельләрендә фигыльдән ясалган сүзгә охшаш (*ар-ақ* яисә *ара-қ*), ә *пед//под* тамырының фигыль мәгънәсе билгеле түгел.

Ностратистлар *болан, бозау* һәм *поши* сүзләрен уртак тамыр сүздән дип баралар һәм, моңа ышандыру өчен, тагын егермеләп төрле телдән (бөтен Евразия буйлап) эзләп, шуларга охшаш сүзләр китерәләр. Һәр телдә сүзләр бик күп һәм мөгезле эре терлек-хайван да күп кенә төрдә була. Билгеле, монда чагыштырырга киң мөмкинлекләр ачыла. Һәм мондый этимологик уенның «нәтиҗәләре» дә кыйммәтсезрәк булып чыга.

Ностратистлар *бәр-ү* сүзенә, бөтен иске дөнья телләрен айкап чыгып, «сугу, яру, җимерү, тибү, таптау һ.б.» мәгънәләрдәге иллеләп параллель сүз табалар, һәм аларның яңгырашлары да, охшаш булса да, бик төрле: *пил, пир, спир, ир, мол, мур, бор, бур, муаф, боо* һ.б. Хәлбүки, *бәр-ү* сүзенең этимологиясе (инде күптән Л. Җәләй күрсәткәнчә) бик гади: ул борынгы төрки *бәр-* «бирү» сүзеннән (чагыштыру өчен: русча *дать* «бирү, бәрү, сугу»; мондый мәгънә күчешләрен бүтән төрки телләрдән дә табып була), к. себ. татар сөйләшләрендә *бәрү* «бирү».

Ностратик теорияләренең иң зәгыйфь төше шунда: алар этимологияне конкрет тарихтан аерып карыйлар, тел фактларын фикри схемаларга куып кертәләр.

## Татар телендә төп сүзләр һәм алынмалар

1. Һәрбер телнең сүзлек составында *үз сүзләр* һәм *алынмалар* барлыгын һәрбер балигъ кеше белә. Урта мәктәпне тәмамлаган һәркем татар телендә кайбер гарәп-фарсы һәм рус сүзләрен күрсәтә ала. Тик менә төп төрки-татар сүзләрен сорагандa гына икеләнеп калалар. Татар сүзләре турында сөйләгәндә төрки сүз дип әйтсәң, гаҗәпләнеп калучылар да очрый: «соң, татарның үз сүзе юкмы әллә?» дигәнне ишетергә туры килә. Бу төрки телләр һәм халыклар тарихы урта мәктәптә тиешенчә яктыртылмаудан килә. Татар кешесе үз халкының кайсы агачның яфрагы икәнлеген белми. Элек-электән татарча халыкара әхвәлебез-кыйблабыз турында сөйләгәндә, иң элек «без – мөселманбыз» дип өйрәткәннәр. Шуннан «без гарәпләр белән кардәш икән» дигән фикер туган. Аннары, Совет власте урнашкач, «без – СССР кешесе» дигән раслама беренче урынга куелган. Атаклы әдип Мостай Кәрим: «Башкортостан – Россия дигән агачның бер яфрагы» исемле шигыре белән дан казанды. Әдип хаклы, ләкин монда башкортларның иң элек төрки агачның бер яфрагы булуы турында бәян итү урынлырак булыр иде.

Гомумән, үз сүзләр һәм алынмалар мәсьәләсе, әйтелгәнчә, махсус катлауландырмасаң да катлаулы. Аны төрле караштан, төрлечә яктыртырга мөмкин. Без биредә болай дип алыйк: татар лексикасында (сүз нигезләре, нигез сүзләр составында) өч катлам аерыла: 1) төрки мирас, 2) төрле тарихи алынмалар, 3) татар теленең үзендә килеп чыккан яки пәйда булган сүзләр.

**Алынмалар таблицасы**

| Чыганаклар / Лексик төркемнәр | кытай-тибет | һинд-иран, сугди | фарсы-таҗик | гарәп-семит | монгол | рус-славян | фин-угор | бүтән билгеле һәм билгесез телләрдән |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| гомумтөрки | + | + | + | – | + | – | – | – |
| көнбатыш төрки | + | + | + | + | + | + | – | – |
| гомумкыпчак | + | + | + | + | + | + | – | – |
| татар телендә генә очрый | + | + | + | + | + | + | + | + |

*Төрки мирас* төшенчәсе дә гади генә түгел. Төп төрки лексикасына а) гомумтөрки сүзләр, б) көнбатыш төрки (мөселман төркиләре телендә пәйда булып, христиан вә яһүди төркиләргә дә йоккан) сүзләр, тәгъбирләр, в) гомумкыпчак сүзләре аерымлана. Без инде рус тюркологиясендә кулланыла торган төркиара (межтюркский) төшенчәсеннән баш тартабыз (чөнки арырак китәбез).

Алынмалар да шул ук рубрикаларга һәм, өстәвенә, чыганакларына карап бүленә (таблицада булганнары – плюс, юклары – минус).

Бу билгеләүләр дә, әлбәттә, абсолют хакыйкатькә дәгъва итми. Һәм кайбер искәрмәләргә дә мохтаҗ. Һинд-иран һәм сугди алынмалардан фарсы-таҗик алынмалары яңа (IX–X гасырларда формалашкан) фарсы теленнән булулары белән генә аерыла. Югыйсә фарсы-таҗик теле үзе дә ирани тел бит! Монгол алынмаларының бер өлеше бәхәсле. Аннары, монгол алынмалары рәтенә тунгус-маньчжур телләреннән килгәннәре дә кертелә (чөнки алар төрки телләргә монгол телләре аша кергән булырга тиеш). «Бүтән телләр» дигәндә, иң беренче чиратта, борынгы Балтыйк телләре, аннары Кавказ телләре, әрмән теле һәм, ихтимал, тохар теле күз алдында тотыла. Безнеңчә, татар телендә борынгы герман (остгот) сүзләре дә бар.

Күрсәтелгәннәрдән тыш, татар әдәби һәм гомумхалык телендә *кардәш төрки телләрдән алынмалар* катламы да бар (к. түбәндәрәк). Һәм алар арасында тагын төрки булмаган (алынма) сүзләр дә очрый.

Шулай итеп, *алынма* төшенчәсе үзе дә катлаулы. Безнең сүзлекләрдә, гадәттә, турыдан-туры алынма чыганагы, ягъни татар теленә турыдан-туры кайсы телдән кергәнлеге күрсәтелә. Ул телдә әлеге сүз үзе икенче бер телдән, икенче телдәге сүз өченче телдә һ.б. алынма булырга мөмкин. Мәсәлән, татарча *пижама* русчадан алынган, русчага бу сүз француз теленнән, француз теленә – инглиз теленнән, инглиз теленә – Һиндстан телләреннән, Һиндстан телләренә – фарсыча *пайҗама* «аяккием», ягъни «аякларны каплап торган озын итәкле өс киеме» сүзеннән. Кайбер очракларда (аерым махсус хезмәтләрдә) билгеле булган иң беренче (иң борынгы) чыганак кына күрсәтелә. Ләкин бу ысул популяр түгел. Һәм, мәсәлән, *пижама* сүзен фарсы алынмасы дип әйтү дөрес булмас иде. Алынма сүз турында җитди сөйләгәндә, әлбәттә, сүзнең бөтен үткән юлын яктыртырга кирәк.

2. Сүзләрнең алынмалыгын билгеләү чагыштырма лексикологик хезмәтләрдә башкарыла. Кызганыч, татар лексикологиясендә алынмаларны билгеләүгә шактый җиңелчә караш яшәп килә: мә-

сәлән, әгәр берәр сүз татар телендә дә, рус телендә дә булса, ул сүз, әлбәттә, рус теленнән дип аңлатыла, филологик хәзерлек үтмәгән кешеләр генә түгел, филологлар да алагаемлык күрсәтәләр. Моңа мисалларны төрле сүзлекләрдә күпләп табып була. *Кәрап, каравыл, ясавыл* кебек сүзләрне рус алынмасы дип күрсәтүләрне күп китапларда очратасың. Югары уку йортында татар телен укытучы бер ханым хәтта *авыл* сүзен дә рус теленнән дип күрсәтә иде!

Алынмаларның *фонетик, морфологик* һәм *мәгънәви-семантик* билгеләре була.

### Фонетик билгеләр

Татар әдәби теленең шундый үзенчәлеге бар: анда алынмалар ике зур төркемгә бүленә. Беренчесе – фонетик яктан үзләштерелгән алынмалар, икенчесе – үзләштерелеп бетмәгәннәре. Менә бу үзенчәлек соңгы гасырларда, башлыча, китап теле аша кергән һәм чыганак телләрнең таныткыч билгеләрен саклаган хәлдә, татар гомумхалык теленең фонетик үзенчәлекләренә каршы килгән күпсанлы алынмаларны танып алырга мөмкинлек бирә.

Татар теленең гомумтөрки үзенчәлекләр нигезендә һәм борынгы субстрат тәэсирендә кимендә мең ел дәвамында формалашкан үз, төп фонетик законнарын безнең максатлар өчен а) авазлар составы, б) аларның кулланылыш кагыйдәләре, в) иҗек һәм сүз басымы үзенчәлекләре ягыннан аңлату уңайлы.

Иске, кадим кыпчак-татар телендә авазлар составы хәзергедән ярлырак: анда тугыз сузык (*а, ә, у, ү, о, ө, е, ы* һәм *и*), унтугыз тартык (җиде сонор – *л, м, н, ң, р, w, й* һәм унике парлы – *б/п, г/к, д/м, з/с, җ/ч* һәм *ж/ш*) булган. Каты һәм йомшак тартыклар (шул исәптән, *қ* һәм *к*, *ғ* һәм *г*) аерым фонема булмаганнар. Күрсәтелгәннәрдән *ж* авазы ымлык, тәкълиди тамырларда һәм шулардан ясалган сүзләрдә генә очраган (мәс., *ажгыру* ‘котырынып исү; нык давыллау’, *ыжылдау* ‘туктаусыз ыж-ыж кебек тавыш чыгару’, *жуылдау* ‘жу иткән тавыш чыгару’).

*Ф, ж* һәм *һ* авазлары да тик ымлык һәм тәкълиди сүзләрдә генә очраганнар һәм асылда фонематик аваз булмаганнар. Каты *ғ* һәм *қ,* шулай ук *ф, х, һ* авазларын аерым аваз итеп тану һәм фонемалаштыру борынгы ирани (сугди, фарсы) телләрдән күпсанлы сүзләр алу процессында пәйда булган.

**Авазларны куллану**, беренчедән, сингармонизмның биш законы нигезендә башкарылган.

***1 закон.*** Бер сүз эчендә я гел нечкә (алгы рәт), я гел калын (арткы рәт) сузыклар гына кулланыла (*әбиләремдә, бабаларыма* һ.б.).

***2 закон.*** Нечкә сузыклар белән йомшак тартыклар, калын сузыклар белән каты тартыклар яраша.

***3 закон.*** Сузык авазларның беренче, икенче һәм өченче (һәм аннан соң килгән) иҗекләрдә кулланылышы төрлечә: аларның урыны без компакт рәвештә гадиләштеребрәк түбәндәгечә сурәтләгән шәкелләрдә билгеләнә ала:

| арткы рәт (калын сузыклы) сүзләрдә | алгы рәт (нечкә сузыклы) сүзләрдә |
|---|---|
|   |   |

Ягъни беренче иҗектә барча сузыклар кулланылса, икенче иҗектә шуларның өч пары гына кала (е, ә, ө; ы, а, о), ә өченче һәм аннан соң килгән иҗекләрдә *е, ә* һәм *ы, а* авазлары гына кулланыла. Шуңа күрә дә татар теле кушымчаларында тик *е, ә* һәм *ы, а* авазлары гына кулланыла. Дөрес язуда исем фигыль кушымчасы *-у//-ү* һәм хәзерге заман хикәя фигыль кушымчасы *-и* рәвешендә языла. Ләкин асылда искечә бу кушымчалар *-ыw//-еw* һәм *-ей.* Бу хәл әлеге кушымчаларга тартым кушымчалары ялганганда ачык күренә: *баруы* дип языла, *бары-wы* дип әйтелә, шулай ук *киле-wе*, *эшле-йә-чәк* һ.б. Русча гына укыган балаларга татарча диктант яздырганда *әней, әтей* дип язулары юкка түгел: алар ничек ишетелсә, шулай язалар. Шулай ук *обы* «абый», *орта* «арта» дип язу да очрый. Чөнки русча *О* авазы $a^o$ авазына тартымлы.

***4 закон.*** Беренче иҗектәге *о* һәм *ө* авазларыннан соң килгән этимологик *ы* һәм *е* иренләшә, мәсәлән, *бозлык* [бōзлōк], *коллык* [қōллōқ], *тормыш* [тōрмōш], *көнем* [*көнөм*], *төзек* [төзөк] һ.б. (ләкин беренче иҗек тартыкка бетеп, икенче иҗек тә тартыкка башланса һәм ул тартыкларның берсе дә сонар булмаса, 4 закон гадәттә сакланмый, мәсәлән, *постыр-у* дигәндә *-ы-*, *өстер-ү* дигәндә *-е-* гадәттә иренләшми).

Беренче иҗектәге *у-* һәм *ү-* авазларыннан соң килгән сузыклар да бераз иренләшә булса кирәк (һәрхәлдә *урман,* мәсәлән *урма*$^o$*н* кебегрәк әйтелә һ.б.).

Беренче иҗектәге *а-* авазы ачык иренләштереп, шуннан соң килгән *-а-* да бераз иренләштереп әйтелә (Г. Алпаров законы).

Сузыкларның кулланылышындагы бу чикләүләр борынгыдан килә. Моны борынгы һәм хәзерге сузык аваз кубларыннан күрергә мөмкин.

Борынгы төрки сузыклар кубы




Хәзерге татар сузыклары кубы




Бу кублардан күренгәнчә, татар теле тарихында түбәндәгечә сузык аваз күчешләре булып үткән:

о > у // у > ŏ ; ӧ > ү // ү > ө;

э > и // и > ĕ һәм, аерым очракларда (беренче иҗектә) э > ә.

***5 закон.*** Кушымчаларда а һәм ә, ы һәм е сузыклары гына кулланыла (бу кагыйдә 3 нче законнан да чыга). Һәм кушымчаларның алгы яисә арткы (нечкә яисә калын) вариантлары нигезләрнең соңгы авазына карап ялгана (бу закон, гомумән, 2 нче законнан чыга, ләкин аның аерым үзенчәлекләре дә бар).

Төп төрки телләрдәге иң мөһим **консонат (тартык авазлардагы)** тәңгәллекләрне һәм ул авазларның кулланылу үзенчәлекләрен түбәндәге таблицадан күрергә мөмкин.

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Бор. *ǯ – č* парының үсешләре яки саклануы (*jan* «ян» һәм *čaq* «чак» сүзләре мисалында) | Кыпчак телләре: иҗек азагында борынгы *-г, -g* урынына *w, j, q, k* килә: *jaг* урынына *jaw*, *saг* урынына *saw* һәм *saq* һ.б. | | Ауслаутта бор. *-г, -g* саклана: *baгla-, beg, taг* | |
| | Сүз башында төп төрки сүзләрдәге тартыклар саңгырау, ләкин мәгънә аеру өчен яңгырауларда кулланыла: *ti-* һәм *di-, tәw* һәм *dәw* һ.б. (бу күренешләр соңрак килеп чыккан). | | | Гомумтөрки сүз башында *k-, q-, t-* урынында *g-, г-, d-* |
| | Ассимиляция-диссимиляция процесслары көчле үсеш алган | Ассимиляция-диссимиляция процесслары зәгыйфь | | |
| *ǯ – č: jan* «бок» – *čaq* «пора» | кыргыз | Казан диалекты (урта диалект), үзбәк теленең кыпчак диалекты | | |
| *ǯ* вә *j* (сүздән сүзне аеруда) – *ч* [мәсәлән, *ǯan*, *jan* һәм *čaq*] | | Гомумхалык татар теле; кумык теле | Төрке тел, уйгур, үзбәк әдәби телләре | Угыз төрки телләре |
| *j – č* *jan – čak* | | Көньяк мишәр сөйләшләре | | |
| *j – ч; j – с (ц)* *jan – čak* | | Төньяк мишәр сөйләшләре | | |
| *jan – čaq* | | Себер татар һәм караим диалектлары | | |
| *ǯ – с [ц]* | Кыргыз сөйләшләре | Карачай-балкар һәм караим сөйләшләре | | |
| *j – s [//s>h]* *jan – saq* | Башкорт | Көньяк башкорт диалекты | | |
| *j – š [//š > s]* *jan – šaq* | | Нугай | | |
| *ž – š [//š > s]* *ǧan – šaq* | Казакъ | Каракалпак | | |
| *č (ч) – š* *čan – šaq* | Тува | | | |

Чуваш, якут вә кайбер бүтән телләрдә тартык авазлар составы һәм кулланылышы бик катлаулы үзгәрешләр кичергән. Чуваш теле гомумтөрки *-з (> с)* урынында күп кенә (йөзгә якын) нигез сүзләрдә һәм кушымчаларда борынгы *-р* авазы, аннары тагы утыздан артык очракта гомумтөрки *-ш* урынында *-л* кулланылу белән дә характерлана.

Төп төрки сузыклар кулланылышында булган кебек, тартыклар кулланылышында төрле чикләүләр булган һәм бар. Һәм сүзләрнең алынмалар булуы алардагы тартыклар тезмәсеннән дә күренеп тора, мәсәлән, *пөхтә* сүзендәге ике сузык уртасындагы *-хт-* – алынмалык билгесе (кара: түбәндәрәк).

Татар консонантизмы законнарын белү дә этимологиядә мәҗбүри шарт. Тартыкларның борынгыдан килгән кыпчакча кулланылышындагы закончалыклар башлыча түбәндәгеләр:

1) сүз башында ике тартык бергә килми;

2) сүз башында *л* һәм *р* авазлары кулланылмый;

3) иҗек азагында *б, ғ, г, ж, җ* һәм *д* авазлары килми;

4) саңгырау авазлардан соң яңгырау тартыклар (кайбер сонорлардан үзгә) килми;

Тартыкларның үзара бәйләнеп килүендә дә аерым закончалыклар булган һәм бар. Төркичә-татарча тартык аваз бергәлекләрен (тезмәләрен) түбәндәгечә күрсәтергә була:

йw, йй, йл, йм, йн, йр, йб, йғ, йг, йк, йк, йд, йт, йч, йт, йз, йс

лw, лл, лм, лн, лб, лп, лз, лғ, лк, лк, лд, лт, лж, лч, лш, лс

рл, рм, рн, рб, рп, рғ, рг, рк, рк, рд, рт, рж, рч, рш, рс

мл, мм, мн, мр, мб, мп, мг, мч, мк, мк, мд, мт, мч, мш, мс

ww, wл, wм, wн, wр, wз, wғ, wк, wк, wд, wг, wш, wс

пл, пм, пн, пр, пк, пк, пт, пч, пш, пс

кл, км, кн, кр, кт, кч, кш, кс (к дә шулай да)

тл, тм, тн, тр, тк, тк, тч, тш, тс

чл, чм, чн, чр, чк, чк, чч, чс

шл, шм, шн, шр, шм, шк, шч, шс

зл, зм, зн, зр, зз, зғ, зд, зч, зс

сл, см, сн, ср, ск, ск, ст, сч, сс

ңл, ңм, ңм, ңг, нг, нк, ңд, ңт, нч, ңш, ңс

җл, җм, җн, җр, җғ, җг, җд, җч

хл, хм, хн, хр, хт

фл, фм, фн, фр, фч

Болардан тыш, яңарак (сүзләр кыскару процессында) килеп чыккан *бр, пр, гр, др, тр* аваз тезмәләре һ.б. очрый. *Б, г, д* авазлары бүтән тартыклар белән чатлашмаучан.

Таблицадан күренгәнчә (татар телендә тартык аваз тезмәләренең җентекләп өйрәнелмәгәнлеген дә әйтеп үтик), мөмкин булган тезмәләрнең бер өлеше ($18^2$=324 тән 200 е) генә реализацияләнә. Сонор тартыклардан *й, л, м, р* барча бүтән тартыклар белән килә ала: *б* һәм *п* авазлары парлы тартыклардан соң килми; парлы тартыкларның берберсенә иярү мөмкинлеге, гомумән, чикләнгән.

**Иҗек төзелеше**: Төп татар сүзләрендә, билгеле ки, иҗек калыплары җиде (Т – тартык, С – сузык аваз): *С, СТ, СТТ, ТС, ТСТ, ТСТТ* һәм тәкълиди сүзләрдә генә *ТТСТ* (мәсәлән, *прых, трах*). Шуларның да *СТТ* һәм *ТСТТ* калыплары иҗек азагында *т* яисә, сирәгрәк, *п* авазы килгәндә генә очрый: *-йт (әйт, кайт), -лт (гөлт, кылт, чалт), -нт (ант, кәнт), -рт (арт, карт, урт), ст (аст, өст), жт (выжт), -шт (кышт, пышт), -мп (гөмп, чумп).*

**Сүз басымы** төп татар сүзләрендә – исем, сыйфат, сан, рәвешләрдә һәрвакыт соңгы иҗеккә төшә. Фигыльләрнең күпчелек формаларында да шул ук хәл. Әмма соңгы иҗеккә төшми һәм төгәл кагыйдәләр буенча бүтән иҗекләргә төшә торган басымнар да бар. Алар нигездә түбәндәгеләр: 1) сорау һәм күрсәтү алмашлыкларында, боерык фигыльнең икенче затында басым беренче иҗектә; 2) басым юклык (инкяр) кушымчасы, сорау кушымчасы һәм хәбәрлек кушымчалары алдыннан килә (бүтән очракларга биредә тукталып тормыйбыз).

Төрки телләрдә сүз башында элек-электән *л-* һәм *р-* авазлары кулланылмый. Элек *н-* авазы да кулланылмаган, әмма соңрак *й->н-* көчеше килеп чыккан һәм шул нигездә күп кенә төп төрки сүзләр *н*-га башлана: *ни* (сорау алмашлыгы), *нигез, ниргә* һ.б. Иҗек азагында сонорлар еш очраса да, яңгырау тартыклар очрамый. Моннан *-з* авазы чигенте (исключение) булып тора (ул элекке *-р* авазыннан килеп чыккан).

Регуляр кушымчаларда татар телендә *л, м, н, ң, р, з, г, ң, к, т, д, с, ч, ш* авазлары кулланыла. *Б, ж, җ, ф, х, һ* авазлары кушымчаларда очрамый. *П* авазы борынгы фигыль кушымчасы составында очрый (мәсәлән, *җилпе-, салпы, талпы-н-* һ.б.ш.). *З* авазы кушымчаларда тик иҗек азагында гына очрый.

**Алынмаларны фонетик билгеләр буенча тану** өчен, барча югарыда телгә алынган татарчалык үзенчәлекләрен истә тоту кирәк. Әгәр нинди дә булса сүз нигезе шул әйтелмеш кагыйдәләргә буйсынмый икән, димәк, ул, мөгаен, алынма сүз

була. Гадәттә, алынма сүздә берничә алынмалык билгесе була. Моны мисалларда аңлату нәтиҗәле.

**Абзар** – мөгаен, алынма, чөнки төп төрки-татарча сүзләрдә *-бз-* аваз тезмәсе һәм иҗек азагында *-б* булмый.

**Катгый** – алынма, чөнки төп татарчада *-тг-* тезмәсе юк.

**Алебастр** – алынма, чөнки 1) сингармоник чылбырлар законы сакланмый (татар телендә *а – е – а* чылбыры юк); 2) сүз азагында өч тартык бергә килгән (дөрес, татарча *әлибастыр* дип әйтү бар, ләкин бу очракта да сингармоник чылбыр татарча түгел).

Сүзлекләрдән карап, кайсы телдән алынганлыгын эзлибез: русча *алебастр*, немецча *Alabaster* < латинча *alabastros*, грекча *alabastros* < борынгы Мисыр телендә *ala baste* «Эбастә дигән алиһә мае» – алдан җәрәхәтләргә ябыла торган шифалы балчыкны белдергән (Фасмер II: 71, Kluge: 27).

**Арзан** – алынма, чөнки төрки татар сүзләрендә *-рз-* тезмәсе булмый. Сүзлекләрдән карыйбыз: фарсыча *арзан* «арзан», *арзидан* «бәясенә лаек булу, бәясенә тору» сүзеннән.

**Әтраф** – алынма, чөнки татарчада *ә-а* чылбыры юк. Гарәпчәдән *әтраф* «тарафлар».

**Игълан** – алынма, чөнки төп татарчада, беренчедән, *и-а* чылбыры юк, икенчедән, иҗек азагында *г* була алмый.

**Ризык** – алынма, чөнки 1) *и – ы* чылбыры татарча түгел, 2) төрки-татар сүзләре *р* авазына башланмый. Сүзлекләрдә – гарәпчәдә *ризķ* «көндәлек азык» (борынгы ирани *рузик* «көндәлек аш» сүзеннән алынма) һ.б.

Алынма сүзләрнең, гомумән, алынмалыгын гына түгел, конкрет кайсы телдән иксәнлеген дә яңгырашыннан белеп була. Хәер, бу раслама башлыча чагыштырмача яңарак (соңгы меңьеллыктагы) алынмаларга карый. Борынгырак алынмалар фонетик яктан күптән үзләштерелгән була. Монгол алынмалары, монгол телләрендәге фонетик закончалыклар төрки телләрдәгеләргә охшаш булганлыктан, аерылып тормый.

Татар телендә фонетик яктан аеруча **рус теленнән** алынган сүзләр аерылып тора. Аларның төп билгеләре түбәндәгеләр.

1. Басым сүз нигезләрендә соңгы иҗекчә түгел: *áрмия, архитéктор, бухгáлтер, галáктика, трáктор* һ.б.

2. Авазлар составында төп татар телендә булмаган **о:** *орган, район*; **э** (ачык э – иреннәр киңрәк ерыла): *эра, этап, нетто*; урта *г, к* (төп татарчада я бик йомшак *г, к*, я *г, ķ* гына була): *газ, магазин*; *кила* < *кило, тактика*; **ц:** *центнер, милиция.*

3. Сингармонизм законнары сакланмый: бер үк сүздә алгы рәт сузыклары белән бергә арткы рәт сузыклар да очрый; каты тартыклар янында нечкә сузыклар һәм киресенчә була ала; сингармоник чылбырлар, әлбәттә, бөтенләй татарча түгел (чөнки төп татар сузыкларыннан рус телендә *а, и, у* авазлары гына охшаш).

4. Сүз (һәм иҗек) башында һәм азагында да теләсә нинди составтагы ике һәм өч тартык бергә килә ала (мәсәлән, *скрипка, трест, фронт, курс, оркестр*).

5. Тартыкларның төп татар телендә булмаган тезмәләре очрый (мәсәлән, *лз*: *гильза*, *рз*: *бурзай* < *борзая* һ.б.); сүз башында *р-* килә ала (мәсәлән, *рам, рәт, руда* һ.б.).

Рус алынмалары составында, билгеле ки, чит ил телләреннән кергән сүзләр күп кенә. Аларның да аерым фонетик билгеләре бар. Мәсәлән, русча һәм, русчага ияреп, татарчада *джоуль* (физик берәмлек), *джин* (аракы төре), *бридж* (кәрт уены төре) кебек язылган сүзләр еш кына инглиз теленнән килә. Французчадан рус теле аша килгән сүзләрдә *ж* авазы еш очрый (*дож, ложа, паж* һ.б.) һ.б. Йомшаклык билгесе (*ь*) кыска *й* кебек укылган бертөркем сүзләрдә (*батальон, каньон, лосьон* һ.б.) французчадан. Бу телдән кергән сүзләрнең кызыклы бер төркеме татар әдәби телендә бердәнбер үзенчәлекле очрак: каты *л* һәм йомшак *л'* авазлары фонема булып, үзара кардәш сүзләрне (исем һәм сыйфатны) аерып тора: *вокал – вокаль, генерал – генераль, дифференциал – дифференциаль, интеграл – интеграль, капитал – капиталь, маргинал – маргиналь, магистрал – магистраль, оригинал – оригиналь, радикал – радикаль, театрал – театраль* һ.б. Йомшак *л'*гә беткән исем парсыз сүзләр тагын да күбрәк: *аномаль, бактериаль, вербаль, визуаль, виртуаль, гениаль, горизонталь, диаметраль, диагональ, зональ, иррациональ, колаииаль, континенталь, клерикаль, меридиональ, номиналь, нормаль, радиаль, сентиментaль, социаль, термаль, территориаль, уникаль, формаль, федераль* һ.б. Бу сүзләр русча сыйфатлардагы *-ный* аффиксын алып ташлаудан килеп чыгалар, ләкин алар Европа телләрендәге ярымйомшак *л'*не чагылдыралар.

Сан ягыннан икенче (гомумхалык лексикасында – беренче) урында торган алынмалар – **гарәп алынмалары** түбәндәге билгеләре буенча таныла ала.

1. Басым соңгы иҗектә түгел: *әлбәттә, гомумән, ләкин* һ.б. (башлыча ярдәмлек сүзләрдә).

2. Сингармонизм законнары сакланмый: *исраф* (*и – а* чылбыры); *мәкаль* [*мәкәл*] (каты *ӄ* нечкә сузыклар тирәлегендә килгән), *икътисад* (*и – и – а* чылбыры; нечкә *и* авазыннан соң килгән каты *ӄ*) һ.б.

3. Тартыкларның төп татар телендә булмаган тезмәләре очрый, мәсәлән: *-гз-: әгъза, -гн-: мәгънә, -гҗ-: могҗиза, сх: мәсхәрә,* ике *р* бергә килү: *кәррә.*

4. Төп татар телендә булмаган (соңрак кайбер сүзләрдә генә килеп чыккан) *ф, х, һ, һәмзә* авазлары: *фетнә, халык, һөҗүм, тәэсир* һ.б. Сүз башында *р-: рәсем, рәис* һ.б.

**Фарсы алынмаларының** фонетик билгеләре:

1. Сингармонизм законнары игътибарга алынмый: *әждаһа, дивана, кәрван* һ.б.

2. Сүзләрдә *ф, х, һ* (*әфарин, тәхет, һәр, һич*) һәм урта *г, к* авазлары очрый: *гүаһ, сәркятип* [сәркатип]. Сүз башында *р-: рас, раушан, рәвеш.*

3. Тартыкларның төп татарча булмаган тезмәләре: *-др-: бәдрәф, гөлбадран* һ.б.; ике *р* бергә килү: *дәррәү* һ.б.

Әгәр бер үк сүздә *п* һәм *һ*, *г* һәм *һ* яисә *ч* һәм *һ* очраса, ул сүз тәгаен фарсы сүзе, мәсәлән: *дәргяһ, пәһлеван, гәүһәр, һич, чәһрә,* һ.б.

Фонетик билгеләрнең күпчелеге гомуми *ориентир* булып кына хезмәт итә. Сүзнең яңгырашына карап, кайсы телдән алынганлыгын төгәл билгеләп булган очраклар кайбер рус һәм әлеге фарсы сүзләре генә. Һәм һәрвакыт күз уңында торган чыганакларны сүзлекләр буенча тикшереп чыгу кирәк.

Тагы бер мөһим искәрмә: чыгышларын тикшерүгә татар сүзләренең озынрак вариантларын алырга кирәк. Чөнки сүзләрнең кыскалыкка омтылуы гомуми закон һәм еш кына татар телендә, бигрәк тә поэтик телдә, авазларның позицион үзгәрешләре нәтиҗәсендә моңарчы булмаган тезмәләре килеп чыгу ихтимал.

### Алынмаларның морфологик билгеләре

Татар телендәге гарәп һәм рус алынмаларының бик ачык *морфологик билгеләре* дә бар. Фарсы һәм монгол алынмаларында бу билгеләр күзгә ташланып тормый.

Рус алынмалары дигәннән, рус теле аша Европа телләреннән кергән сүзләр дә күз алдында тотыла.

**Рус теленнән кергән** сүзләрдә сүз ясагыч кушымча һәм «окончание»ләр башлыча исемнәрдә саклана: *-ка* (линейка, клиника, юбка), *-ник* (мошенник, начальник, парник), *-щик* (натурщик). Ләкин бу типтагы сүзләрнең саны күп түгел. Ә менә Европа телләреннән кергән сүзләрдәге *-изм, -ист, -ия, -ция, -ика* кушымчаларының һәркайсына йөзләрчә алынма мисалы китерергә мөмкин: *алогизм, анимизм, коммунизм, силлогизм*; *артист, дантист, марксист*; *авария, авиация, модификация, модуляция*; *техника, физика* һ.б.; *-ер, -нер, -ор, -тор* кушымчалы актив шәхес (орган, деталь) мәгънәсен белдергән сүзләр дә шактый: *актёр, легионер, милиционер, планер, револьвер, механизатор* һ.б. Югарыда, фонетик билгеләр турында сөйләгәндә, без *-аль* аффиксына башлана торган «интернациональ» сыйфатларны искә алган идек инде.

**Гарәп алынмаларына** иң беренче чиратта *тә-, мә-, ма-, мо-* префикслары [*тәгълим* (чаг. *гыйлем*); *тәэсир* (чаг. *әсәр*); *мәктәп* (чаг. *китап, көтепханә*); *мәрхәмәт* (чаг. *рәхмәт*); *мөгъҗиза* (чаг. *гаҗиз*)], *-ия, -ият, -ат/әт* постфикслары [*гадлия* «юстиция» (чаг. *гадел*), *әдәбият* (чаг. *әдәп*); *хөррият* (чаг. *хөр*); *хайванат* (чаг. *хайван*)], сыйфат ясагыч *-и//-ый* кушымчасы: *гамәли* (чаг. *гамәл*); *гомуми* (чаг. *гомум*); *фәнни* (чаг. *фән*) характерлы.

Гарәп сүзләренә шулай ук бер үк сүзнең мөзәккәр (мужской род) һәм мөәннәс (женский род) формалары булу (*гали – галия, галим – галимә, гашикъ – гашика* һ.б.ш.), *-ан/-ән* рәвеш ясагыч кушымчасы (*шәхсән,* чаг. *шәхес, шәхси*; *горуран*, чаг. *горур*) характерлы. Редупликатив нигезләрнең *-а/ә* кушымчасы белән ясалуы да гарәп теле үзенчәлеге (мәсәлән, *вәсвәсә, зилзилә, силсилә* һ.б.).

Монгол алынмаларының морфологик билгеләре булып сыйфат ясагыч *-гай//-гәй, -агай//-әгәй* (*болагай* ‘шапшак’*, комагай* ‘нәфесле, комсыз’*, карагай* ‘нарат’), *-дар//-дәр, -тар//-тәр* (*каудар* ‘кипкән үлән’*, сөлтәр* ‘скелет, шәүлә’), исем ясагыч *-сын//-сен* (*кавырсын* ‘эре каурый’*, селәүсен* ‘урман мәчесе, рус. *рысь*’) аффикслары хезмәт итә. Монгол алынмаларының күпчелеге махсус тарихи-лингвистик тикшеренү нәтиҗәсендә генә беленә.

Фарсы теленнән кергән сүзләрнең морфологик билгеләре катлаулы. Шуны әйтергә кирәк: кайбер фарсы кушымчалары үзләре шул көенчә татар теленә кергән. Мәсәлән, *-анә//-әнә* (*мәгърурәнә* ‘горурланып’*, галибәнә* ‘җиңеп, җиңү белән’), *-зар//-зәр* > *-сар//-сәр* (*гөлзар* ‘гөлләр бакчасы’, ‘*имәнсәр* ’, ‘*каенсар*’ һ.б.ш.), *-ханә* (*тәһарәтханә, чәйханә*), *-намә* (*васыятьнамә* – рус. *завещание, рөхсәтнамә* – рус. *лицензия*) һ.б.ш. Мишәр сөйләшләрендә очрый торган чагыштыру-зурайту кушымчасы *-тарай//-тәрәй* дә фарсы теленнән килә (шуның ярдәмендә

гомумбилгеле *куптарай* «мактанчык» < *хубитарай* «купшырак», *титарай* < *тилетарай* «артык тиле» сүзләре ясалган).

Тикшеренүчеләр күптәннән билгеләп үткәнчә, төрки әдәби-язма телләрдә гарәп теленең үзендә булмаган, ләкин гарәп модельләре буенча (еш кына төрки, хәтта русча тамырлардан) ясалган сүзләр килеп чыга, мәсәлән, татарча *әмҗәк (мужиклар).*

**Алынмаларның тарихы, мәгънәви-семантик билгеләре.**

Мәгънәви-семантик билгеләр дигәннән, башлыча, сүзләрнең тематик рубрикаларга каравы күз алдына тотыла.

Борынгы төркиләр, иң беренче чиратта, ике мәдәни даирә – көньяк-көнчыгышта Кытай, көнбатышта Ирани халыклар арасында яшәгәннәр. Көнчыгыш Азия белән Урта Азия һәм Иран арасында сәүдә эше (бөек «ефәк юлы») булган; яңа эра башларында бу сәүдәгә төркиләр кушылып, сугдиләр белән аралашып, катнашып киткәннәр һәм V гасырга ул сугдиләр үзләре төркиләшә башлаганнар. Шул чорда төрки телләргә ирани телләрдән бик күп сүзләр кергән һәм калькалар ясалган. Шушы фактлан чыгып, төрки телләрдә сәүдә өлкәсенә (борынгы транспорт, товар атамалары, үлчәү-бәяәү терминнары һ.б.) караган күп кенә сүзләр сугди теленнән дип фаразлана. Сугди теленең үзендә борынгы (исламны кабул иткәнче формалашкан) фарсы һәм һинд телләреннән алынмалар бик күп булган. Алар да билгеле төрки телләргә күчкәннәр. Шушы мәгълүматлар яктылыгында, мәсәлән, гомумтөрки *ат* сүзенең борынгы фарсы *ахта* «алаша» сүзеннән булуы бик тә ышандырырлык.

Ефәк юлындагы сәүдә әйберләренең төп җитештерүчесе – борынгы Кытай теленнән дә күп сүзләр алынуы табигый. Иң беренче чиратта товар, әйбер атамалары кытайчадан булырга тиеш. Аннары кытайлар төркиләргә үзләренең мәдәни казанышларын йоктырырга тырышканнар. Музыкага караган кайбер сүзләрнең (*көй, кубыз, чәң* һ.б.) кытай теленнән булуы шуның белән аңлатыла. Идарә һәм суд эшләре терминологиясендә дә кытай теле тәэсире сизелә. Ләкин бу өлкәләрдә төркиләргә бигрәк тә ирани халыклар үрнәк булган.

Монголлар белән төркиләр озак гасырлар буенча бик тыгыз бәйләнешләрдә, бер килешеп, бер сугышып, күп тапкырлар бер үк дәүләтләр составына бергә кереп яшәгәннәр. Өстәвенә аларның тормыш рәвешләре дә бердәй булган (хәер, монголлар сәүдә белән азрак шөгыльләнгәннәр). Нәтиҗәдә, монгол һәм төрки телләре арасында сүзләр алмашу бик күптәннән килгән. Күп кенә сүзләрнең кайсы телдән кайсына кергәнлеге хәзергәчә ачык түгел. Тик шуны аерып әйтергә кирәк: **монгол телләреннән татар теленә алынган сүзләрнең зур күпчелеге Чыңгыз хан яуларына кадәр кергән!** Ягъни монгол яулары төрки телләргә монгол сүзләрен таратуда әллә ни зур роль уйнамаган. Ул яулар тик монгол хәрби терминологиясенең киң таралуына гына китергән.

Гарәп теленнән, билгеле, иң беренче чиратта, дини терминология киң таралган. Ислам диненә (аның теориясенә, ритуалларына, агиографиясенә һ.б.) караган сүзләрнең уннан тугыз өлеше гарәп теленнән алынган. Шулар белән бергә турыдан-туры дингә карамаган күп кенә сүзләр гарәп теленнән килә. Аларны төрлечә төрен-төргә аерырга мөмкин. Мәсәлән: 1) гомуммәдәни терминнар, 2) шигырь теориясе, әдәбият терминнары, 3) мораль, әхлак төшенчәләренең атамалары, 4) хокук, дәүләтчелек терминологиясе, 5) матди мәдәният (хуҗалык-икътисад) терминнары һ.б.

Боларның саны меңнәрчә. VIII–XI гасырларда гарәп телендәге фән һәм сәнгать әдәбияты гаять киң таралыш ала. Европа галимнәре гарәп әдәбиятын укыйлар, тәрҗемә итәләр һ.б. Шул нигездә һәм гарәпләрнең хәрби-дәүләт куәте тәэсирендә, шулай ук соңрак төрек теле аша да күп кенә гарәп сүзләре Европа (иң беренче чиратта, испан һәм итальян) телләренә үтеп керә. Хәзерге гомуевропа лексикасындагы *агат, адмирал, алгебра, алгоритм, алкоголь, альманах, алюминий, амальгама, анемона, анилин, арабеска, арсенал, атлас* (тукыма), *алзур* (*лазурь*), *балдахин, бальзам, гитара, фанфара* (гарәпчә *фарфара*), *гамаши, газ* (тукыма исеме), *жираф, карат, коттон* (тукыма исеме), *магазин, маскарад* (шуннан – *маска*, киресенчә түгел!), *мохер* (кәҗә мамыгы), *мокко* (кофе төре), *муссон, оранжерия, ракета* (челтәрле чәпәмә), *сандалия, сатин, сода, софа, талисман, тамбур, тун* (русча *тунец* [балык төре]), *цифра* (*цифр*) һ.б. Бу рәткә әле экзотизмнар (гарәп-шәрык дөньясына хас нәрсәләрнең атамалары, мәс., *минарет* «манара», *султан* «солтан», *халиф* «хәлифә») кермәде.

Шуны әйтергә кирәк ки, гарәп сүзләренең шактый өлеше төп семит тамырларыннан түгел, алынма. Гарәпләр үзләре борынгы Мисыр халкы – кыйбтыйлар (рус. *копты*) белән кардәш булсалар да, безнең эра башларында әле кыргый халык булалар. Алар озак заманнар бабиллеләргә, фарсыларга, грекларга, римлеләргә, төрекләргә буйсынып

яшәгәннәр һәм шул халыклар телләреннән күп кенә сүзләр алганнар. Һәм шул алынма сүзләр, гарәпчәләштерелгән формада, татар теленә дә килеп ирешкән. Шундыйларга, мәсәлән, *ризык* (борынгы фарсы теленнән), *фәлсәфә* (грек теленнән), *кыйсса, сират* 'күпер' (латин теленнән), *бөреҗ* 'бастион, кирмән'(герман телләреннән) сүзләре карый. VII–XII гасырларга гарәп теленә «яшь» Европа телләреннән дә сүзләр үтеп керә башлый. Һәм болар барсы да диярлек мәдәни лексикага карый. X гасырдан алып, гарәп теленә төрки сүзләр дә керә башлый.

Фарсы алынмаларының аерып күрсәтерлек семантик-тарихи билгеләре юк: алар һәртөрле темаларга карыйлар. Моның хикмәте шунда: ирани халыклар белән төркиләр кимендә ике мең ел тыгыз аралашып яшиләр. Безнең эраның беренче меңьеллыгында төркиләр күчмә скиф-сармат кабиләләрен (ә алар ирани телләрдә сөйләшкәннәр) төркиләштерәләр. Икенче яктан, бик күп төркиләр үзләре фарсылаша һәм еш кына кабаттан төркиләшә. Шул ук вакытта фарсы рухы вә матди мәдәнияте төркиләр өчен үрнәк булып торган. Бу контактлар нәтиҗәсендә, төрки-фарсы телләр союзы барлыкка килгән дип әйтеп була: төрки һәм яңа ирани телләр арасында лексик кына түгел, морфологик охшашлыклар һәм өлешчә уртак лексика пәйда булган. Фарсы-ирани алынмаларның характеры татарлар составына фарсы телле халык кергән дигән фикергә китерә. Мәсәлән, көнбатыш (мөселман) төрки телләргә хас күренеш: сыйфатларның артыклык дәрәҗәсе үзенчәлекле аллитератив кисәкчәләр ярдәмендә ясала. Мисал өчен, *кап-кара, кып-кызыл, кұм-күк, ямь-яшел, япь-яшь* һ.б. Мондый «парлы» сүзләрнең беренче өлеше фарсы теле моделе буенча һәм фарсы бәйлеге *ба* ярдәмендә ясалган. Фарсыча *сиаһ-ба-сиаһ* ~ *кара-ба-кара* булган бу редупликатив сүзнең беренче өлеше кыскарып, *караб-кара* > *карб-кара* > *кап-кара* стадияләрен үткән. Шуның кебек, *туры-ба-туры* > *турып-туры* > *туп-туры, түгәрәк-бә-түгәрәк* >> *түп-түгәрәк* һ.б. *Сүзмә-сүз, эзмә-эз* кебек кабатлама сүзләрдәге *-мә* дә шул *-ба* дан килә. Фарсы теленнән мондый күчермә ике (фарсы-төрки) телле халыкта гына килеп чыга ала. Татар телендәге кайбер хайван һәм үсемлек атамаларының фарсычадан булуы да шул фикергә китерә. Мәсәлән, *маймыч* (диалекталь *маймуч*) ~ *мармыш* «җимбалык» фарсыча *маримуск* «сөлек» (хәрефмә-хәреф әйткәндә «елан-имгеч») сүзеннән булса кирәк, ш. ук *анар, гөл, карбыз, кишер* һ.б.

Алынмаларның чагыштырма диалектологик билгеләре дә бар. Мәсәлән, кайбер телләрдән алынмалар татар теленең аерым сөйләшләрендә ешрак кулланыла: фин-угор телләреннән алынмалар Татарстанның төньяк районнарында, рус теленнән алынмалар – мишәр сөйләшләрендә, Урта Азия телләреннән алынмалар – себер сөйләшләрендә һ.б.ш.

Сүзнең фонетик вариантлары күплеге, гадәттә, аның алынма булуына ишарә итә. Моның ачык мисаллары итеп *аҗаган* (вариантлары: *айҗаган, аҗҗаган, аҗагай, нажагай, җалагай, ялагай* һ.б.), *әрекмән* (*арыкман, арахман, рахман, чирахман, әремкән* һ.б.), *мунча* (*муйылца, момаца, мунича* һ.б.), *тәрәзә* (*тәрзә, тәрәз, тирәзә, тәзрә* һ.б.) сүзләрен китерергә мөмкин.

Ниһаять, омоним парлар арасында алынмалар еш булуын әйтергә кирәк (бу хакта к. *Омонимнар* бүлекчәсен).

Лексик системада алынма – өстәмә чимал. Озак заманнар аерым бер социаль катламга аралашу чарасы буларак хезмәт иткән телдә һәр сүзнең үзенең стилистик төсмере, валентлыгы ныклап урнашкан була. Шул фонда алынманы телгә ямау булуыннан да сиземләргә мөмкин.

## СҮЗЛЕККӘ КЕРЕШ

Ошбу этимологик сүзлек авторның күп еллар буенча җыелган материалын, табышларын-казанышларын чагылдыра. Ләкин теге яки бу сүзнең этимологиясен аңлатканда, әлеге хезмәттә чагылган карашлар һичкенә дә «иң дөрес, иң соңгы сүзгә» дәгъва итми. Шуны да әйтеп үтик: без татар сүзләренең барча төрки параллельләрен теркәп күрсәтүне өстебезгә алмадык, гәрчә, принципта, ул таләп ителсә дә. Без характерлы мисал-параллель сүзләрне генә китердек. Калганнары күңелдә калды. Югыйсә безнең этимологик сүзлек өч-дүрт тапкыр зуррак булыр иде. Гомумән алганда, без тик сүзләрнең этимологиясен тикшергәндә эзләнү юнәлешен генә күрсәтәбез, дип әйтәсебез килә. Этимологиянең чиге юк. Бәхәсләр һәрвакыт кала һәм шулай булырга тиеш тә.

Сүзлеккә хәзерге татар теленең таркатылмас сүз нигезләре фонды алынды дисәк, бу раслама ике яктан нык чикләнә. Беренчедән, рус алынмаларының башлыча фонетик яктан үзләштерелгәннәре генә (шуларга *совет – сәвит, часть – чәст, фонарь – фанар* кебекләрен дә кертеп) алынды; икенчедән, гарәп-фарсы алынмалары да бик чикләнгән күләмдә генә сүзлеккә кертелде.

Әмма иске татар (**төрке**) теленең төрки тамырлы сүзләренә (мәсәлән, *анчак* ‘ул вакытта, ул чакта; ләкин’*, дәхи* ‘тагы’, *нитәккем* – рус. *так как, поскольку*), шулай ук үзенчәлекле, әдәби телдә бер сүз белән генә белдерелми торган мәгънәләргә ия булган диалекталь сүзләргә чик куелмады. Шуны истә тотыйк: хәзерге әдәби телнең төп лексик фонды шактый очраклы рәвештә (кайчакта тупас ялгышларга юл куелып) формалашкан. Бу тел формалашкан чорларда татар сөйләм һәм диалекталь лексикасы бик аз күләмдә генә билгеле булган, гаять зур байлык читтә калган.

Сүзлекләрдә бер генә тапкыр очраган «томанлы» сүзләр сүзлекккә алынмады.

Бу китапны язганда, әлбәттә, түбәндә күрсәтелмәгән бик күп китаплар һәм мәкаләләр файдаланылды. Аларның кайберләре, аерым сүзләргә багышланганнары, шул сүзләр мәкаләсендә күрсәтелә. Андый язмаларның авторлары исә сүзлекнең азагында бирелә.

Һәм, ниһаять, без бер бәхәсле мәсьәләгә тукталып китик: ул чуваш телендә татар алынмалары мәсьәләсе. Чуваш телчеләре (В.Е. Егоров һ.б.) чуваш телендә иң күп дигәндә ике йөз татар сүзе бар дип баралар. Ләкин чит ил тюркологлары бөтенләй башка фикердә. Н. Поппе (N. Poppe. Die türkische Lehnworter im Tschuwassischen // Ungarische Jahrbücher. Berlin, 1927. Bd. VII. H. 1–4), А. Науто һәм Г. Дёрфер (G. Doerfer. Tschuwaschisch -m < urtürkisch *-m > gemeintürkisch ün // Ural-Altaische Jahrbucher. 45. Wiesbaden. 1973: 175) чуваш лексикасының (таркатылмас нигезләренең) 80% ы татар теленнән алынган диләр. Рус галимнәре бик сак кына, «чуваш телендә гомумтөрки (болгари булмаган) алынмалар күп» дип әйтү белән чикләнәләр. Яисә ачыктан-ачык «татар алынмасы» дип әйтәсе урында «кыпчак алынмасы» дип гомумиләштерәләр. Хәлбуки Урта Идел регионында яшәп, чувашлар белән гасырларча тыгыз аралашкан барча кыпчакларның токымнары татарлар гына, бередә бүтән төрки халык юк. Һәм без чуваш телендәге татар алынмаларын икеләнүсез күрсәтә бардык.

Тагын бер бәхәсле мәсьәлә: татар телендәге болгари алынмалар. Аларны инкяр итеп тә, бүтәнчә атап та булмый. Хәлбуки кайберәүләр «болгар теле шул ук татар теле» һ.б. нигезсез сүзләр сөйләп (һәм язып та) чыгалар. Икенче яктан, без болгари телне «борынгы чуваш теле» дип атауга да каршы. Чуваш телендә болгари элементлар күп, ләкин чуваш теленең үзенчәлекләрен алар гына билгеләми.

### Язылышлар һәм хәрефләр

Татар һәм башкорт сүзләре гадәти кириллик язылышта. Аларның укылышы гомуми кагыйдәләргә туры килә. Тик кайбер (әмма күп кенә) очракларда сүзләрнең транскрипциясе дә бирелде. Транскрипциядә түбәндәге хәрефләр кулланыла.

Татарча **қ** һәм **ғ** «койрыклар» белән төгәллләп белдерелде. Татар, башкорт, чуваш, шулай ук күрше мари, удмурт һәм кардәш казак вә хакас

телләренә хас булган «кыска» **ĕ** һәрдаим шул **ĕ** билгесе белән белдерелде. Шуны әйтергә кирәк: татар һәм башкорт телләреннән тыш бу авазны төрлечә белдерәләр, мәсәлән, чувашлар **ĕ** белән, марилар **ӹ** белән, казакълар, хакаслар һәм удмуртлар **і** белән. Без бу төрлелекне унификацияләр идек. Этимология өчен шулай кирәк.

Татар һәм башкорт орфографиясендәге **ө** бик үзенчәлекле авазны белдерә (шуңа якын авазлар чуваш һәм мари телләрендә дә бар). Бүтән төрки кириллик орфографияләрдә кулланылган **ө** хәрефе бөтенләй башка авазны – **ö** не белдерә. Һәм без төрки-монгол кириллик орфографиядә язылган сүзлекләрдә очрый торган **ө** (карачай-балкар, кумык орфографияләрендәге **ё**) хәрефен һәрдаим **ö** гә күчереп яздык. Татарча **ŏ** да гомумтөрки **о** дан үзгә, тик без аны транскрипциядә генә аерым рәвештә яздык. Бүтән төрки телләрнең кириллик орфографиясендәге **е** хәрефе һич кенә дә татар-башкорт язма **е** сенә тәңгәл түгел, ул русча **э** гә охшаш (иреннәрне киң ерып әйтелә торган) авазны белдерә. Без бу авазны *гом. кыпчак, гом. тк.* искәрмәләре белән килгәндә **э** хәрефе белән белдердек, конкрет телләрдән китерелгән мисалларда **е** килеш калдырдык (чөнки ул аваз «латинча» транскрипциядә дә шулай бирелеп килә).

**Ү** авазы шулай ук һәрдаим **ү** белән белдерелде (кайбер төрки кириллик орфографияләрдә ул **ӯ** яисә **ьу**, яисә **ю** хәрефләре белән белдерелә һәм без аларны **ү** хәрефенә алмаштыра бардык).

### Сылтамалар һәм «фәнни аппарат» турында

Без теге яки бу сүз турында барча фикерләрне җыеп күрсәтүне максат итеп куймадык. Сылтамалар, ишарәләр билгеле кыйммәте булган китап вә мәкаләләргә, пассажларга вә фикерләргә генә юнәлтелде.

Гомумән алганда, сүзләрнең (һәм аерым сүзнең) этимологиясенә мөнәсәбәтле барча фикерләрне җыеп бетерү мөмкин дә түгел. Хәзерге көндә төрки телләр буенча елына йөзләрчә газета-журналлар чыга, меңнәрчә кешеләр эшли һәм һәрбер төрки сүз турында диярлек кимендә бер аерым мәкалә яисә пассаж (публикациядән зур гына өзек) табып була. Алар арасында дилетантларча язылганнары яисә ачыктан-ачык субъектив, тенденциоз характердагы язмалар да очрый. Аларны кабатлауның нигә кирәге бар?

Мәскәүдә чыгып килә торган ЭСТЯ (төрки телләрнең этимологик сүзлеге) томнарында барлык мөһим фикерләрне, фаразларны теркәү күзәтелә шикелле. Ләкин бу беренче карашка гына шулай: аларда башлыча рус һәм Европа телләрендәге публикацияләргә игътибар ителә, төрки телле язмалар игътибардан читтәрәк тотыла (мәсәлән, безнең К. Насыйри, Җ. Вәлиди, Л. Җәләй хезмәтләре, китап-мәкаләләре искә алынмый).

Без татар телчеләренең азмы-күпме кыйммәтле фикерләрен аеруча искә ала бардык. Ләкин нәкъ менә кыйммәтлеләрен генә. Теге яки бу сүзгә махсус багышланып та искә алырлык эчтәлеге (реаль яңалыгы) булмаган язмалар еш кына очрый (безнең, шәхсән үзебезнең, шундый берничә мәкаләбез бар һәм без аларны хезмәтләребезнең исемлегенә дә кертмибез).

Икенче яктан, этимологиягә махсус багышланмаган публикацияләрдә дә аерым сүзнең этимологиясенә бәйле тапкыр, кыйммәтле фикер очрарга мөмкин. Мәсәлән, Зәки Вәлиди хезмәтләре шундый.

Гомумән, һәртөрле фараз-фикерләрне барлау, күрсәтү ул – этимология тарихына караган материал. Безнең хезмәт исә этимология тарихына багышланмый.

# БИБЛИОГРАФИЯ

## Этимологиянең методологиясе

Белецкий А.А. Принципы этимологических исследований. – Киев, 1950.

Ефремов Л.П. Сущность лексических заимствований и основные признаки освоения заимствованных слов. – Алма-Ата, 1959.

Звегинцев В.А. Семасиология. – М., 1957.

Пауль Г. Принципы истории языка. – М., 1960.

Пизани В. Этимология. – М., 1956.

Покровский М.М. Избранные работы по общему языкознанию. – М., 1959.

Поливанов Е.Ф. Статьи по общему языкознанию. – М., 1985.

Потебня А.А. Мысль и язык. – Харьков, 1913.

Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология. – Казан, 1999.

Сафиуллина Ф.С. Тел гыйлеменә кереш. – Казан, 2001.

Серебренников Б.А. Вероятностные обоснования в компаративистике. – М., 1974.

Теория и практика этимологических исследований. – М., 1985.

Топоров В.Н. О некоторых теоретических основаниях этимологического анализа // Вопросы языкознания. 1960. – № 3.

Шараф Г. Сонорная длительность татарских гласных // Вестник по татароведению. – Казань, 1927. – № 8.

Языкознание (энциклопедия). – М., 2000.

Seebold E. Etymologie. Eine Einfuhrung am Beispiel der deutschen Sprache. – München, 1981.

## Төп әдәбият

Абаев В.И. Доистория индоиранцев в свете арио-уральских языковых контактов // Этнические проблемы истории Центральной Азии в древности. – М., 1981.

Абаев В.И. Историко-этимологический словарь осетинского языка. Тт. I–IV. – М., 1958–1978.

Абаев В.И. Скифо-европейские изоглассы. – М., 1980.

Абаев Н., Жамбалдагаев Н. Тибетская медицина: как быть здоровым // Азия и Африка сегодня. – М., 1989. – № 8.

Абдуллаев Ф.А. Фонетика хорезмских говоров. – Ташкент, 1967.

Абдуллин И.А. Лексикада кайбер үзгәрешләр тарихыннан // Татар теле һәм әдәбияты. – Казан, 1963.

Абдуллин И.А. Социально-политическая терминология языка армяно-кыпчакских памятников // Историко-лингвистический анализ старописьменных памятников. – Казань, 1983.

Аблязов К.А. Историческая судьба татар. Тт. I–II. – Саратов, 2012.

Абусеитова М.Х. Джувейни об отрарской катастрофе // Вопросы истории. – Алма-Ата, 1975.

Авижанская А.А., Бикбулатов Н.В., Кузеев Р.Г. Декоративное искусство у башкир. – Уфа, 1964.

АДДЛ – Азәрбаjҹан дилинин диалектологик лүғәти. – Бакы, 1964.

Алатырев В.И. Из пермской этимологии // Вопросы финно-угорского языкознания. Вып. IV. – Ижевск, 1967.

Алатырев В.И. Именные деривационные аффиксы и этимология некоторых слов // Вопросы удмуртского языкознания. Вып. IV. – Ижевск, 1976.

Алатырев В.И. Татарские заимствования в удмуртском языке // Всесоюзная конференция по финно-угроведению. Тезисы докладов. – Сыктывкар, 1965.

Алатырев В.И. Этимология некоторых диалектальных слов // Вопросы удмурской диалектологии. – Ижевск, 1977.

Алексеев Н.А. Ранние формы религии тюркоязычных народов Сибири. – Новосибирск, 1980.

Алияров С.С. К этнической биографии Алп-Эрена // СТ. – 1987. – № 6.

Алпаров Г. Сайланма хезмәтләр. – Казан, 1945.

Алтай кеп-куучындар. – Горно-Алтайск, 1994.

Алтайские этимологии. – Л., 1984.

Аманжолов С. Вопросы диалектологии и истории казахского языка. Ч. II. – Алма-Ата, 1959.

Аникин А.Е. Этимологический словарь русских диалектов Сибири. – Новосибирск, 2000.

Анисимов А.Ф. Общее и особенное в развитии общества и религий народов Сибири. – Л., 1969.

Анисимов А.Ф. Религия эвенков. – М.–Л., 1958.

Антонов Н.К. Материалы по исторической лексике якутского языка. – Якутск, 1971.

Арабско-русский словарь / Х.К. Баранов. Изд. 2-ое, стер. – М., 1958.

Аракин В.Д. Тюркские лексические элементы в русских повестях и сказаниях // СТ. – 1973. – № 3.

Арсланов Л.Ш. Язык алабугатских татар Каспийского района Калмыцкой АССР. – Казань, 1988.

Арсланов Л.Ш. Язык карагашей, ногайцев Астраханской области. – Казань, 1992.

Арсланов Л.Ш. Язык юртовских татар // Материалы по татарской диалектологии. – Казань, 1976.

Атаманов М.Г. Географические апеллятивы удмуртского языка, связанные с лесом // Пермистика: вопросы диалектологии и истории пермских языков. – Ижевск, 1987.

Атласи Һ. Себер тарихы. – Казан, 1993.

Ахатов Г.Х. Диалект западносибирских татар. – Уфа, 1963.

Ахатов Г.Х. Мишарский диалект татарского языка. – Уфа, 1980.

Ахатов Г.Х. Татарская диалектология. Средний диалект. – Уфа, 1979.

Ахмаров Г.Н. О языке и народности мишарей // ИОАИЭ. Т. XIX. – Казань, 1903.

Ахмаров Г. Свадебные обряды Казанских татар // ИОАИЭ, Т. XXIII, Вып. 1. – Казань, 1907.

Ахмаров Г. Спор о литературном языке татар // Казанский телеграф, 13 дек. – Казань, 1905.

Ахмаров Г.Н. Тептяри и их происхождение. – Казань, 1907.

Ахметжанов К.С. Жараған темір кигендер. (Батырлардың қару-жарағы, әскери өнері, салт-дәстүрлері). – Алматы, 1996.

Ахметьянов Р.Г. «Лес», «дерево» и «барс» у тюрков (этимологические этюды) // СТ. – 1980. – № 5.

Ахметьянов Р.Г. Из области лексических взаимосвязей языков Поволжья // Проблемы составления этимологического словаря отдельного языка. – Чебоксары, 1986.

Ахметьянов Р.Г. Некоторые варианты диалектальных слов и фразеологизмов в сергачевском говоре // Нормативность и вариативность в татарском языке. – Казань, 1987.

Ахметьянов Р.Г. Некоторые названия лошадей в татарском языке // СТ. – 1975. – № 2.

Ахметьянов Р.Г. Некоторые термины обрядов и мифологии булгаро-чувашского происхождения у народов Урало-Поволжья // СФУ. – 1977. – № 2.

Ахметьянов Р.Г. Некоторые чувашско-татарские лексические параллели и их этимологии // Диалекты и топонимия Поволжья. – Чебоксары, 1978.

Ахметьянов Р.Г. Об изменениях сингармонических цепочек в системе татарско-башкирского вокализма // Тезисы докладов конференции молодых учёных. – Казань, 1967.

Ахметьянов Р.Г. Об историзме в этимологии // Теория и практика этимологических исследований. – М., 1985.

Ахметьянов Р.Г. Общая лексика духовной культуры народов Среднего Поволжья. – М., 1981.

Ахметьянов Р.Г. Общая лексика материальной культуры народов Среднего Поволжья. – М., 1989.

Ахметьянов Р.Г. Опыт историко-семантической интерпретации некоторых глаголов-модификаторов в алтайских языках // Вопросы семантики. – М., 1974.

Ахметьянов Р.Г. Служебные слова в татарской прозе XVIII века // Анализы текстов по истории татарского литературного языка. – Казань, 1987.

Ахметьянов Р.Г. Слова *кузы* < *qoγu* и термины игры в альчики // МТД. – Казань, 1988.

Ахметьянов Р.Г. Случаи гаплологии и эллипсиса в чувашском языке и соответствующие им татарские словосочетания // Материалы научной сессии «Проблемы словосочетания в тюркских языках». – Чебоксары, 1975.

Ахметьянов Р.Г. Сравнительное исследование татарского и чувашского языков. – М., 1978.

Ахметьянов Р.Г. Этимология некоторых служебных слов, распространенных в языках Среднего Поволжья // Историко-лингвистический анализ старописьменных памятников. – Казань, 1983.

Ахунзянов Э.М. Русские заимствования в татарском языке. – Казань, 1968.

Ашмарин Н.И. Опыт исследования чувашского синтаксиса II. – Симбирск, 1923.

Ашмарин Н.И. Подражания в языках Среднего Поволжья // Известия Аз. ГУ. Общественные науки. Вып. II–III, IV–V. – Баку, 1925.

Ашмарин Н.И. Материалы к изучению чувашского языка. – Казань, 1898.

Ашмарин Н.И. О морфологических категориях подражаний в чувашском языке. – Казань, 1928.

Ашмарин Н.И. Отголоски золотоордынской страны в народных верованиях чуваш. – Казан, 1921.

Ашмарин Н.И. Словарь чувашского языка. – Казань–Чебоксары, 1928–1950. – Вып. 1–17.

Әбдирахманов А. Топонимика және этимология. – Алма-Аты, 1975.

Әдәби сүзлек. – Казан, 2001.

Әт-төхфәт – Изысканный дар тюркскому языку (Китаб ӓт-тухфа ӓз-зӓкийа фи-л-луга ат-туркийа), памятник XIV века. – Ташкент, 1978.

Әхмәтҗанов М.И. Нугай урдасы: татар халкының тарихи мирасы. – Казан, 2002.

Әхмәтҗанов М. Нугай урдасы: татар халкының тарихи мирасы. – Казан, 2009.

Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. – Казан, 2001.

Әхмәтьянов Р.Г. Татар терминологиясенең тарихи чыганаклары. – Казан, 2003.

Бабур З.М. Трактат об арузе. – М., 1972.

Бабур З.М. Трактат об арузе. – М., 1977.

Бакиров М.Х. Татар фольклоры: Югары уку йортлары өчен дәреслек. – Казан, 2008.

Банзаров Д. Собрание сочинений. – М., 1955.

Барбаро и Контарини о России. – М., 1971.

Бартикян Р.М. О протоболгарских надписях ханов Крума (803–814) и Омуртага (814–831) и некоторые вопросы организации раннеболгарского государства // Вестник общественных наук. – Ереван, 1981. – № 4.

Бартольд В.В. Сочинения. Тт. I–IX. – М., 1960–1975.

Баскаков Н.А. Диалект кумандинцев. – М., 1972.

Баскаков Н.А. Диалект черневых татар. – М., 1966.

Баскаков Н.А. Душа в древних верованиях тюрков Алтая (термины, их значение и этимология) // СЭ. – 1973. – № 5.

Баскаков Н.А. Каракалпакский язык. Т. II. – М., 1952.

Баскаков Н.А. К проблеме китайских заимствований в тюркских языках // СТ. –1987. – № 5.

Баскаков Н.А. Русские фамилии тюркского происхождения. – М., 1971.

Баскаков Н.А. Северные диалекты алтайского (ойротского) языка. Диалект черневых татар (туба кижи). Тексты и переводы. – М, 1965.

Баскаков Н.А. Тюркская лексика в «Слове о полку Игореве». – М., 1985.

Баттал Г. Казан төрекләре. – Казан, 1996.

Башкирская диалектология.– Уфа, 1965.

Башкирская этнонимия. – Уфа, 1969.

Башҡорт диалектологияһы. – Өфө, 1963.

Башҡорт халыҡ ижады. – Өфө, 1982, 1997.

Башкортостан. Краткая энциклопедия. – Уфа, 1996.

Башҡортса-русса һүҙлек. – Мәскәү, 1996.

Баязитова Ф.С. Говоры татар-кряшен в сравнительном освещении. – М., 1986.

Баязитова Ф.С. Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары. – Казан, 1995.

Баязитова Ф.С. Себер татарлары. – Казан, 2001.

Баязитова Ф.С. Урта Урал (Свердловск өлкәсе) татарлары. – Казан, 2002.

Баязитова Ф.С. Нократ сөйләше. – Казан, 2006.

Бәетләр. – Казан, 1960.

Березин И.Н. Очерк внутреннего устройства Улуса Джагатайского // Журнал министерства народного просвещения. Вып. XVIII. – СПб., 1850.

Беркутов В.М. Татар халык календаре. – Казан, 1966.

Бертагаев Т.А. К вопросу о внутренних законах развития языка // Известия АН СССР. – М., 1951.

Бертагаев Т.А. К исследованию лексики монгольских языков. – Улан-Удэ, 1961.

Бимбаев Р. Монгольско-русский словарь. – Иркутск, 1914.

Биржанова Е.Э., Войнова Л.А., Кутник Л.Л. Очерки по исторической лексикологии русского языка. – Л., 1973.

Бируни А.-Р. Сочинения. Т. 5. Фармокогнозия. – Ташкент. 1974.

Бируни А. Индия. – М., 1995.

Бичурин Н.Я. Записки о Монголии. – СПб., 1828.

Биялиев А. Киргизские народные термины промысловой охоты: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Фрунзе, 1972.

Благова Г.Ф. Топонимическое использование слов «сарай» и «орду»/«орда» // Диалекты и топонимия Поволжья (Материалы и сообщения). Вып. 1. – Чебоксары, 1972.

Богородицкий В.А. Введение в татарское языкознание в связи с другими тюркскими языками. – Казань, 1934.

Богородицкий В.А. Этюды по татарскому и тюркскому языкознанию. – Казань, 1933.

Большой академический монгольско-русский словарь. Тт. I –III. – М., 2001.

Большой турецко-русский словарь. – М., 2008.

Борһанова Н.Б. Татар телендә авыл төзелешенә караган лексик-семантик төркемнәр // Исследования по диалектологии и истории татарского языка. – Казань, 1982.

Борһанова Н.Б. Татар телендә үсемлек атамалары // Вопросы лексикологии и лексикографии татарского языка. – Казань, 1976.

Борһанова Н.Б. Татар телендә үсемлек атамалары. ТТДС I гә (к.) өстәмә.

Боровков А.К. Бадā'и' ал-лугат. Словарь Тāли Имāни Гератского к сочинениям А. Навои. – М., 1961.

Боровков А.К. Лексика среднеазиатского тафсира XII–XIII веков. – М., 1963.

Борынгы татар әдәбияты. – Казан, 1961.

БРС – Башкирско-русский словарь. – М., 1996.

Брук С. Народы мира. – М., 1982.

БРЭ – Большая российская энциклопедия. – М., Т. 2. – 2005; Т. 4. – 2006; Т. 8. – 2007.

БТДҺ – Башҡорт теленең диалектологик һүҙлеге. – Өфө, 2002.

Будагов Л. Сравнительный словарь турецко-татарских наречий. Тт. I–II. – СПб., 1869–1871.

Буддизм. – М., 1992.

Булатов А.Дж. К происхождению слова *јэк* у тюрок // Исследования по грамматике и лексике тюркских языков. – М., 1965.

Булаховский Л.А. Семасиологические этюды. Славянские названия птиц // Уч. зап. Львовского университета. Т. VII. – Львов, 1948.

Бурганова Н.Б. К вопросу о формировании земледельческой лексики в татарском языке // Лексика и стилистика татарского языка. – Казань, 1982.

Буронов М. Ўзбэк тилининг касб-ҳунар лексикасидан. – Нукус, 1978.

Бутанаев В.Я. Хакасы. – М., 1988.

Бутанаев В.Я. Этническая история хакасов XVII–XIX веков. – М., 1990.

БҺҺ I, II – Башҡорт һөйләштәре һүҙлеге. Тт. I–II. – Өфө, 1969–1970.

Вагапова М.З. Синтаксические функции причастия *диген* в современном киргизском языке и некоторые карачаево-балкарские параллели к ним // Тюркологический сборник. – Черкесск, 1967.

Вайнштейн С.И. История народного искусства Тувы. – М. 1961.

Вайнштейн С.И. Тувинцы-тоджинцы. –М., 1961.

Валеев Ф.Т. Обереги как пережиток доисламских верований у сибирских татар // Из истории Сибири. – Томск, 1976.

Валеев Ф.Т. Сибирские татары: культура и быт. – Казань, 1993.

Валиханов Ч.Ч. Собрание сочинений. Т. 1. – Алма-Ата, 1984.

Валькова Д.П. Чулан в театре // Русская речь. – 1971. – № 1.

Василевич Г.М. Эвенки. Историко-этнографические очерки. (XVIII–начало XX века). – Л., 1969.

Вашари И. Ещё раз о термине tartanaq // СТ. 1987. – № 4.

Вәлиди Җ. Җырларыбыз хакында // Шура. – 1911. – № 19.

Вәлиди Җ. Татар теленең тулы аңлатмалы сүзлеге. Тт. I – II. – Казан, 1928–1929.

Вәлиуллин А.В., Самуилов Ф.Д. Җиләк-җимеш бакчасы утырту. – Казан, 1957.

Вельяминов-Зернов В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. Тт. I–IV. – СПб., 1863–1887.

Вербицкий В.И. Словарь алтайского и аладагского наречий тюркского языка. – Казань, 1884.

Вершинин В.И. Словарь марийских говоров Татарстана и Удмуртии. – Йошкар-Ола, 2011.

Вестник научного общества татароведения. – Казань, 1925. – № 1–2.

Владимирцов Б.Я. Сравнительная грамматика монгольского письменного языка и хакасского наречия. Введение и фонетика. – Л., 1929.

Волков А.Г. Язык как система знаков. – М., 1966.

Вопросы истории тюркских языков. – Алма-Ата, 1986.

Вопросы удмуртской диалектологии. – Ижевск, 1977.

Воробьев Н.И. Материальная культура казанских татар. – Казань, 1930.

ВЯ – Вопросы языкознания.

Габэн, фон.-А. Культура письма и печатания у древних тюрков // Зарубежная тюркология. – М., 1986.

Гаврилов М.Ф. Остатки ясы и юсуна у узбеков. – Ташкент, 1929.

Гаврилов Б.Г. Поверья, обряды и обычаи вотяков Мамадышского уезда // Материалы IV археологического съезда в России. Т. II. – Казань, 1891.

Гаврилов Б.Г. Поверья, обряды и обычаи вотяков мамадышского уезда. – Казань, 1876.

Галайская Р.Б. Варган у народов Советского Союза // Проблемы музыкального фольклора народов СССР. – М., 1973.

Галданова Г.Р. Структура традиционной бурятской свадьбы // Традиционная культура народов Центральной Азии. Материалы и исследования. – Новосибирск, 1986.

Гали Х. Адашкан лөгатьләр // Шура. – 1911. – № 26.

Галибик Г. Җәмигъ әт-тәварих. – СПб., 1830.

Галкин И.С. Кто и почему так назвал. – Йошкар-Ола, 1991.

Гамкрелидзе Т.В., Иванов Вяч. Вс. Индоевропейский язык и индоевропейцы. Тт. I–II. – Тбилиси, 1984.

Ганиев Ф.А. Конверсия в татарском языке. – Казань, 1985.

Гараджаев Ч. Военная лексика в туркменском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Ашхабад, 1978.

Гарипова Ф.Г. Авыллар һәм калалар тарихыннан. – Казан, 2001.

Гарипова Ф.Г. Татарская гидронимия. – Казань, 1998.

Гарипов Т.М. Старописьменные памятники Башкирии // СТ. – 1972. – № 4.

Гариф Н.Г. Казан ханлыгы. – Казан, 2006.

Гаффарова Ф.Ф. Алтайский пласт лексики земледелия: названия зерна и некоторых зерновых // ПЛЛТЯ. – Казань, 2006. – № 7.

Гаффарова Ф.Ф. Игенчелек терминологиясе мисалларында үсемлек анатомиясе атамаларына чагыштырма-тарихи анализ // ПЛЛТЯ. – Казань, 1999. – № 5.

Гаффарова... – Гаффарова Ф.Ф., Насипов И.С., Рамазанова Д.Б. Сравнительно-исторические исследования системы лексико-тематических групп татарского языка. – Уфа, 2007.

Георгиев В.И. Исследования по сравнительно-историческому языкознанию. – М., 1958.

Гераклитов А.А. Алатырская мордва. – Саранск, 1938.

Гераклитов А.А. Саратовская мордва (К истории мордовской колонизации в Саратовском крае). – Саратов, 1926.

Гиганов И. Словарь российско-татарский. – СПб., 1804.

Гиршман Р. Иран и миграция индоарийцев // Этнические проблемы истории Центральной Азии в древности. – М., 1981.

Гордеев Ф.И. Историческое развитие лексики марийского языка. – Йошкар-Ола, 1985.

Гордеев Ф.И. К истории этнонима черемись // Вопросы диалектологии и истории марийского языка. – Йошкар-Ола, 1964.

Гордеев Ф.И. О происхождении тюркских этнонимов // Вопросы марийского языкознания. – Йошкар-Ола, 1968.

Гордеев Ф.И. О татарских лексических заимствованиях марийского языка // Вопросы марийского языкознания. Вып. 3. – Йошкар-Ола, 1973.

Гордеев Ф.И. Этимологический словарь марийского языка. Тт. I–II. – Йошкар-Ола, 1979–1983.

Гордеев Ф.М. Подражательные слова и этимология // Вопросы марийской диалектологии. – Йошкар-Ола, 1981.

Гордлевский В.А. Государство сельджукидов в Малой Азии. – М.–Л., 1941.

Гордлевский В.А. Избранные сочинения Тт. I–II. – М., 1960, 1961.

Гордлевский В.А. Элементы культуры у касимовских татар. – Рязань, 1927.

Горелик М.В. Халха-калкан: монгольский щит и его дериваты. // Восток-Запад: диалог культур Евразии. Вып. 4. – Казань, 2004.

Грач А.Д. Древнетюркские изваяния Тувы. – М., 1961.

Гребнев Л.В. Тувинский героический эпос: опыт историко-этнографического анализа. – М., 1960.

Греков Б.Д., Якубовский А.Ю. Золотая Орда и её падение. – М., 1950.

Громов Г.Г. Сельскохозяйственная техника и этнические традиции // СЭ. – 1981. – № 3.

ГТРС – Гарәпчә-татарча-русча сүзлек / төз.: К.З. Хәмзин, М.И.Мәхмүтов, Г.Ш.Сәйфуллин. – Казан, 1965.

Губайдуллин Г. К вопросы о происхождении татар // Вестник татароведения. – 1928. – № 1.

Гукасян В.Л. Закавказские источники к изучению истории азербайджанского языка // СТ. – 1978. – № 2.

Гукасян В.Л. Об одной древнетюркской письменности // СТ. – 1981. – № 5.

Гумилёв Л.Н. Хунну. – М., 1960.

Гумилёв Л.Н. Древние тюрки. – М., 1967.

Гумилёв Л.Н. Поиски вымышленного царства. – М., 1994.

Гумилёв Л.Н. Тысячелетие вокруг Каспия. – М., 2002.

Гусейнзаде А. Параллели огузских этнонимов в современной топонимике Азербайджанской ССР // СТ. – 1977. – № 4.

Гыйльманов Г. Татар мифлары. – Казан, 1996.

Давлетшин Г.М. Очерки по истории духовной культуры предков татарского народа. Казань, 2004.

Давлетшин Г.М. Традиционные верования населения Волжской Булгарии как система // Языки, духовная культура и история тюрков. Труды международной конференции, Т. 3. – Казань – М., 1992.

Дагестанские народные сказки. – М., 1991.

Даль В.И. Толковый словарь живого великорусского языка. Тт. 1–4. – М., 1955.

Дамдинов Д.Г. О земледельческих терминах в монгольских языках // Исследования по восточной филологии. – М., 1974.

ДАУ – Диалектологический атлас удмуртского языка. Вып. I–III. – Ижевск, 2003, 2007, 2013.

Даулей Р. Святки у крещёных татар // ИОАИЭ, Т. XIX. – Казань, 1903.

Денисов П.В. Религиозные верования чуваш. – Чебоксары, 1959.

Денисов П.В. Этнокультурные параллели дунайских болгар и чуваей. – Чебоксары, 1969.

Диалекты хакасского языка. Очерки и материалы. – Абакан, 1973.

Диваев А.Л., Андерсон В.Н. Киргизская легенда о ветхозаветном великане адже (оге) // ИОАИЭ, Т. XXIV. – Казань, 1908.

Диваев А. Месяца по киргизскому стилю с обозначением народных примет // ИОАИЭ. Т. XIII. – Казань, 1895.

Димитриев В.Д. История Чувашии XVIII века. – Чебоксары, 1959.

Димитриев В.Д. Мера веса *батман* в Среднем Поволжье и Приуралье в XVI–XIX веках // Актуальные проблемы археологии и этнографии Чувашской АССР. – Чебоксары, 1982.

Димитриев В.Д. Чуваши в эпоху феодализма. – Чебоксары, 1986.

Дмитриева Л.В. Из этимологии названия растений в тюркских и монгольских языках // Исследования в области этимологии алтайских языков. – М., 1979.

Дмитриева Л.В. О некоторых заимствованиях в тюркских языках // Языки народов Сибири. – М.,1980.

Дмитриева Л.В. Язык барабинских татар. – Л., 1981.

Дмитриев Н.К. Строй тюркских языков. – М., 1962.

Добродомов И.Г. К этимологии русского слова колчан // Этимологические исследования по русскому языку. IX. – М., 1981.

Добродомов И.Г. Проблемы изучения булгарских лексических элементов в славянских языках: автореф. дис. … д-ра филол. наук. – М., 1974.

Добродомов И.Г. Вопросы хронологии тюркских заимствований в славянских языках // СТ. – 1976. – № 6.

Добродомов И.Г. К названию обско-угорского названия шёлка // СФУ. – 1978. – № 1.

Добродомов И.Г. Ландшафтная терминология в пратюркском // Природное окружение и материальная культура пратюркских народов / отв. ред. А.В. Дыбо; Ин-т языкознания РАН. – М., 2008.

Добродомов И.Г. Типы поселений ранних тюрок. Историческая эволюция // Природное окружение и материальная культура пратюркских народов / отв. ред. А.В. Дыбо; Ин-т языкознания РАН. – М., 2008.

Добродомов И.Г. Тюркские заимствования в названиях птиц // СТ. – 1980. – № 2.

Добродомов И.Г., Кучкин В.А. Этимология и старые географические объекты // Топонимика на службе географии. – М., 1979.

Дондуков У.-Ж.Ш. Аффиксальное словообразование частей речи в бурятском языке. – Улан-Удэ, 1964.

ДС – Диалектологик сүзлек. I чыг. – Казан, 1948. II чыг. – Казан, 1953. III чыг. – Казан, 1958.

ДСЯЯ – Диалектологический словарь якутского языка. – М., 1976.

ДТС – Древнетюркский словарь. – Л., 1969.

Дульзон А.П. Система счета времени у чулымских татар // Краткие сообщения ин-та этнографии. X. – М., 1950.

Дыбо Л.В. К истории ангропометрических терминов // СТ. – 1989. – № 1.

Дьякова В.П. Некоторые этнокультурные параллели в шаманстве тюркоязычных народов Саяна-Алтая // Этнокультурные контакты народов Сибири. – Л., 1984.

Евсевьев М.Е. Мордовская свадьба. – М., 1931.

Егоров В.А. О времени возникновения Казани // Советская археология. – 1975. – № 4.

Егоров В.Г. Русско-чувашский словарь. – Чебоксары, 1960.

Егоров В.Г. Этимологический словарь чувашского языка. – Чебоксары, 1964.

Еремеев Д.Е. Ислам: образ жизни и стиль мышления. – М., 1990.

Ершов Н.Н., Широкова З.А. Альбом одежды таджиков. – Душанбе, 1969.

Жаримбетов А. Тюркские лексические элементы в русской номенклатуре растений. – Нукус, 1980.

Жубанов Е., Ибатов А. Анализ этимона *тәңрі* «всевышний (опыт ретроспективного подхода) // Проблемы этимологии тюркских языков. – Алма-Ата, 1990.

Жуковская Н.Л. Народные веровения монголов и буддизм // Арехология и этнография Монголии. – Новосибирск, 1978.

Җантурин С. Лөгать (татар әдәби телендә гарәп, фарсы һәм иске төрки сүзләр). – Уфа, 1911.

Жаҳонгиров Г. Ўзбек болалар фольклори. – Ташкент. 1975.

Җәләй Л. Татар диалектологиясе. – Казан, 1947.

Җәләй Л. Татар теленең орфоэпик нигезләре. – Казан, 1953.

Җәләй Л. Татар теленең тарихи морфологиясе. – Казан, 2000.

Җәләй Л. Татар теленең тарихи фонетикасы буенча материаллар. – Казан, 1954.

Заимствования русского языка в историко-функциональном аспекте. Сб. – Казань, 1991.

Закиев М.З. Об этнониме *мишар* // СТ. – 1976. – № 2.

Закиров Ф.Д. Агулы үсемлекләр. – Казан, 2010.

Заходер Б.Н. Каспийский свод сведений о Восточной Европе. – М., 1967.

Зварич В.В. Нумизматический словарь. – Львов, 1978.

Зверева Л.Е. О четырех терминах в удмуртской микротопонимике // Вопросы удмуртской диалектологии и ономастики. – Ижевск, 1982.

ЗДС – Татар теленең зур диалектологик сүзлеге. – Казан, 2009.

Зифельд-Симумяги А.Р. Uralo-Altaica. – Баку, 1928.

Золотницкий Н.И. Корневой чувашский словарь. – Казань, 1876.

Золотарёв А.М. Родовой строй и первобытная мифология. – М., 1964.

Зуев Ю.Н. К этнической истории усуней // Новые материалы по древней и средневековой истории Казахстана. – Алма-Ата, 1960.

Иванова Р.Г. Дикорастущие съедобные растения Татарии. – Казань, 1987, 1990.

Иванов И.Г., Тужаров Г.М. Словарь северо-западного наречия марийского языка. – Йошкар-Ола, 1971.

Иванов С.А. Центральная группа говоров якутского языка. – М., 1993.

Иванов С.В. Скульптура алтайцев, хакасов и сибирских татар. – М., 1979.

Из глубины столетий (выписка из главных источников по истории тюрок и татар). – Казань, 2004.

Износков И.А. Материалы для истории христианского просвещения инородцев Казанского края. – М., 1895.

ИМ – Ибне Мүһәнна. Китаби тäрҗүмāни фарси вä түрки вä моголи.

Инан А. Шаманизм тарихта һәм бөгөн. – Өфө, 1998.

Индонезийско-русский словарь. – М., 1961.

Иоанн де Плано Карпини. История монголов. Вильгельм де Рубрук. Путешествие в восточные страны в лето благости 1253 / введение, перевод и прим. А.И. Малеина. – СПб., 1911.

Исанбаев Н.И. Лексико-семантическая классификация татарских заимствований в марийском языке // Вопросы марийского языка. – Йошкар-Ола, 1978.

Исанбаев Н.И. Неопубликованные рукописи Г.Ф. Миллера по марийскому языку // Вопросы марийского языкознания. III. – Йошкар-Ола, 1973.

Исәнбәт Н.С. Татар теленең фразеологик сүзлеге. Тт. I–II. – Казан, 1989, 1990.

Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. Т. I. – Казан, 1959. Т. II. – Казан, 1963. Т. III. – Казан, 1967.

Исенгалиева В.А. Служебные имена и послелоги в казахском языке. – Алма-Ата, 1957.

Ислам в татарском мире. – Казань, 1997.

Историко-лингвистический анализ старописьменных памятников. – Казань, 1983.

История Татарии в материалах и документах. – М., 1937.

История татар с древнейших времён. Т 1, Т. 2, Т 3. – Казань, 2002, 2006, 2009.

Исхаков А.И. О подражательных словах в казахском языке // Тюркологический сборник. – М., 1951.

Исхаков Д.М. К вопросу об этносоциальной структуре татарских ханств (на примере Казанского и Касимовского ханств XV – сер. XVI в.) // Панорама форум. – Казань, 2007. – № 3.

Исхаков Д.М. К этнической истории татар восточных районов Татарской АССР // К вопросу этнической истории татарского народа. – Казань, 1985.

Исхаков Д.М., Измайлов И.Л. Этнополитическая история татар. – Казань, 2007.

Исхаков Ф.Г. Наблюдения по лексике в области прилагательных в тюркских языках // Историческое развитие лексики тюркских языков. – М., 1961.

Исхаков Ф.Г. Некоторые предположения о происхождении конечных **-т** и **-д** в словах *аст, үст, алд, арт* // Академику Гордлевскому к его семидесятилетию. – М., 1953.

Исхакова В.И. Исследования этнонима *татар* в зарубежной тюркологии // Вопросы взаимодействия татарского и русского языков на современном этапе. – Казань, 1992.

Кажибеков Е.З. Глагольно-именная корреляция гамогенных корней в тюркских языках. – Алма-Ата, 1986.

Қазақ тілінің түсіндірү сөздігі. Тт. I–II. – Алматы, 1959–1961.

Қазақтар. Т. IV. – Алматы. 1994.

Камалов А.А. Топонимика Республики Башкортстана. – Уфа, 2002.

Камалов А.А., Камалова Ф.У. Атайсал. – Уфа, 2001.

Караимско-русско-польский словарь. – М., 1974.

Каракалпакский язык. Т. II. – М., 1952.

Каракалпакско-русский словарь. – М., 1958.

Каримуллин А.Г. Татары: этнос и этноним. – Казань, 1988.

Кармышева Б.Г. Архаическая символика в погребальнопоминальной обрядности узбеков Ферганы // Древние обряды верований и культур народов Средней Азии. – М., 1986.

Кароматов Ф., Нурджанов Н. Музыкальное искусство Памира. – М., 1978.

Карпини П. История монголов. – СПб., 1911.

Каррыев Б.А. Богатырская свадьба Гёр-оглы // Известия АН Туркменистана. – Ашхабад. – 1977. – № 3.

Катанов Н.Ф. Алфавитный указатель собственных имен, встречающихся во втором томе «Образцов народной литеротуры тюркских племен», собранных В.В. Радловым. – СПб., 1888.

Катанов Н.Ф. Краткий татарско-русский словарь. – Казань, 1912.

Катанов Н.Ф. Сказания иностранцев о России // ИОАИЭ, XIX. Вып. 5–6. – Казань, 1903.

Катаринский В. Башкирско-русский словарь. – Оренбург, 1899.

Катаринский В. Киргизско (казахско)-русский словарь. – Оренбург, 1903.

Кашафутдинов Р.Г. Праздники и обычаи татар, связанные с хозяйственной деятельностью // Вопросы истории, филологии и педагогики. – Казань, 1965.

Кәримуллин Ә.Г. Язмыш, язмыш...: мәкаләләр. – Казан, 1996.

КБ – Кутадгу билиг.

Кельмаков В.К. Краткая характеристика кырыкмасских говоров южноудмуртского наречия // Вопросы удмуртской диалектологии. – Ижевск, 1977.

Кельмаков В.К. Удмуртско-татарские языковые контакты и некоторые фонетические особенности южного наречия удмуртского языка // СТ. – 1974. – № 3.

Кенесбаев І. Қазақ тілінің фразеологиялық сөздігі. – Алматы, 1977.

Керимов И.А. Очерки кумыкской диалектологии. – Махачкала, 1967.

Киекбаев Ж.Г. Хәҙерге башҡорт теленең лексикаһы һәм фразеологияһы. – Өфө, 1966.

Киргизско-русский словарь / К.К. Юдахин. – М., 1965.

Киселёв С.В. Каменная черепаха, «бежавшая» из Каракорума // Монгольский археологический сборник. – М., 1962.

Клавихо Р.-Г. Дневник путешествия ко двору Тимура. – М., 1990.

Климов Г.А. Этимологический словарь картвельских языков. – М., 1964.

Кляшторный С.Г. Девятая надпись с Уйбита // СТ. – 1987. – № 1.

Кляшторный С.Г. Древнетюркские рунические памятники. – М., 1965.

Кляшторный С.Г., Лившиц В.А. Согдийская надпись из Бугута // Страны и народы Востока. Вып. X. – М., 1971.

Книга Марко Поло. – М., 1995.

Коблов Я.Д. Мифология казанских татар // ИОАИЭ, XXVI вып. – Казань, 1912.

Коблов Я.Д. Религиозные обряды и обычаи татар-магометан // ИОАИЭ, XXIV вып. – Казань, 1910.

Колесникова В.Д. Названия частей тела человека в алтайских языках. // Очерки сравнительной лексикологии алтайских языков. – Л., 1972.

Коломиец В.Т. Происхождение общеславянских названий рыб. – Киев, 1983.

Кондратьева Т.Н. Собственные имена в русском эпосе. – Казань, 1967.

Константинова О.А. К характеристике лексического комплекса «очаг – жилище – народ» в алтайских языках // Проблемы общности алтайских языков. – Л., 1969.

Кормушин И.В. Тюркские енисейские эпитафии. – М., 1997.

Корнилов Г.Е. Чувашское диалектологические названия для зайца и проблема русско-чувашских сатэм ~ кентумных параллелей // Материалы по чувашской диалектологии. IV. – Чебоксары, 1971.

Корнилов Г.Е. Этимологии некоторых чувашских зоонимов // Учёные записки ЧНИИ. – Вып. 46. – Чебоксары, 1970.

Котвич В.Л. Исследование по алтайским языкам. – М., 1962.

Кочин Г.Е. Термины для терминологического словаря древней Руси. – М.–Л., 1937.

Краснов Ю.А. Проблемы происхождения чувашского народа в свете археологических данных // Советская археология. – 1974. – № 4.

Крачковский Н.А. Избранные сочинения. Т. 1. – М., 1956.

Крюкова Ф.А. Коллекция П.С. Палласа по народам Поволжья // Сборник музея антропологии и этнографии АН СССР. Т. XII. – М., 1949.

КУ – Казан утлары.

Кузеев Р.Г. О характере присоединения народов Волго-Уральского района к русскому государству // Этнолингвистические исследования в Башкортостане. – Уфа, 1994.

Кузнецов П.И. Глагол *тур- (тăр-)* и понудительный залог // СТ. – 1985. – № 6.

Куклин А.Н. Фонетическая адаптация тюркизмов в марийской фитомонике // Вопросы марийской аномастики. – Йошкар-Ола, 1980.

Кумыкско-русский словарь. – М., 1969.

Курдско-русский словарь / К.К. Курдоев. – М., 1960.

Курышжанов А.К. Исследования по лексике старо-кыпчакского письменного памятника XIII века (тюркско-арабского словаря). – Алма-Ата, 1970.

Къарачай-малкъар-орус сёзлюк. – М., 1989.

Кызласов И.Л. Земледельческое жертвоприношение древнехакасской общины // СТ. – 1987. – № 1.

Кызласов Л.Р. О значении термина «балбал» древнетюркских надписей // Тюркологический сборник. К шестидесятилетию А.Н. Кононова. – М., 1966.

КЭСК – Лыткин В.И., Гуляев Е.И. Краткий этимологический словарь коми языка. – М., 1970.

ҚТАС – Қазақ тілінің аймактық сөздігі. – Алматы, 2005.

ҚТДС – Қазақ тілінің диалектологиялық сөздігі. – Алматы, 1969.

ҚТҚЭС – Қазақ тілінің қысқаша этимологиялық сөздігі. – Алматы, 1960.

Ларин Б.А. Русско-английский словарь-дневник Ричарда Джемса. – Л., 1959.

Латинско-русский словарь / И.Х. Дворецкий. – М., 1976.

Лебедева А.А., Сафьянов А.В. Промысел кедрового ореха в Сибири // СЭ. – 1979. – № 4.

Левитская Л.С. Заметки о чувашско-татарских связях // Уч. зап. Чув. НИИЯЛИ. Вып. 26. – Чебоксары, 1963.

Левитская Л.С. Историческая морфология чувашского языка. – М., 1976.

Левитская Л.С. *Правый* и *левый* в тюркских языках // Уч. зап. Чув. НИИЯЛИ, 46. – Чебоксары, 1970.

Лигети Л. Табгачский язык – диалект сяньбийского // Народы Азии и Африки. – М., 1969.

Линдберг Г.У., Герд А.С. Словарь названий пресноводных рыб СССР. – Л., 1972.

Лобанова Н.П. К истории календарных обрядов у земледельцев Средней Азии // Древние верования, обычаи и культы народов Средней Азии. – М., 1986.

Лойфман И.Я., Попов С.И. Топонимические названия Оренбургской области. – Оренбург, 1960.

Ломоносов М.В. Древняя Российская история от начала российского народа до кончины великого князя Ярослава первого или до 1054 г. – СПб., 1766.

ЛС – Татар теленең аңлатмалы сүзлеген төзүгә сүзләр җыю өчен лексикологик сораулык. – Казан, 1958.

ЛТ – Насыйри К. Ләһҗәи татари. Т. I. – Казан, 1895. Т II. – Казан, 1896.

Лыткин В.И. К этимологии слова *туес* // Русское и славянское языкознание. – М., 1972.

Львова Э.А. Материалы к изучению этнической истории чулымских тюрков по данным шаманистского культа // Происхождение аборегенов Сибири и их языки. – Томск, 1973.

Маадай-Кара. Алтайский героический эпос. М., 1973.

Магницкий И.К. Материалы к объяснению старой чувашской веры. – Казань, 1881.

Максуди Ә.-Һ. Төрки сарфы. – Казан, 1910.

Максютова Н.Х. Восточный диалект башкирского языка. – М., 1976.

Малов С.Е Памятники древнетюркской письменности Монголии и Киргизии. – М.–Л., 1959.

Малов С.Е. Остатки шаманства у желтых уйгуров. – СПб., 1912.

Малов С.Е. Памятники древнетюркской письменности. – М.–Л., 1951.

Малов С.Е. Уйгурский язык. Хамийское наречие. – М.–Л., 1954.

Малов С.Е. Язык жёлтых уйгуров. Тексты и переводы. – М., 1967.

Марийский фольклор. Мифы, легенды предания. – Йошкар-Ола, 1991.

Матвеев А.К. Географические названия Урала. – Свердловск, 1980.

Матвеев А.К. О происхождении названия Урал // Вопросы истории Урала. Вып. 39, ч. I. – Свердловск, 1961.

Матвеев С.М. О крещёных инородцах Уфимской епархии. – Уфа, 1910.

Матвеев С.М. Свадебные обычаи и обряды крещёных татар Уфимской Губернии // ИОАИЖ, XIII. – Казань, 1895.

Матвеева А.К. О финно-угорских заимствованиях в русских говорах // Вопросы финно-угорского языкознания. – М., 1962.

Материалы по истории Башкирии. Т. I. – М.–Л., 1936.

Материалы по истории России. Т. 1. – Оренбург, 1800 (А.И. Тевкелев һәм И.К. Кирилловларның сораугa җавап итеп язган белешмәләре китерелә).

Материалы по истории сюнну. Вып. 1. – М., 1968.

Махмутова Л.Т. Опыт исследования тюркских диалектов. Мишарский диалект татарского языка. – М., 1978.

Мәрҗани Ш. Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан, 1989.

Мәхмүтов Х.Ш. Ел тәүлеге – 12 ай: халык календаре битләреннән. – Казан, 1991.

Мелиоранский П.М. Араб-филолог о турецком языке. – СПб., 1900.

Менгес К.Г. Восточные элементы в «Слове о полку Игореве». – М., 1979.

Меликишвили Г.А. О некоторых названиях металлов в древневосточных и кавказких языках // Вестник древней истории. – М., 1968. – № 4.

Миржанова С.Ф. Южный диалект башкирского языка. – М., 1979.

Михайлов С.М. Труды. – Чебоксары, 1979.

МК – Мәхмүд Кашгари.

МНМ – Мифы народов мира. Тт. I–II. – М., 2000.

Мокшанско-русский словарь. – М., 1949.

Мольнар Э. Проблемы этногенеза и древней истории венгерского народа. – Будапешт, 1955.

Мордва-каратаи: язык и фольклор. – Казань 1991.

Мөдәррис Ш. Яшел тасма. – Казан, 1957.

Мөхәммәтҗанов Р. Эзләсәң – табыла. – КУ. – 1977. – № 9.

МТД – Материалы по татарской диалектологии. Вып. 1–4. – Казань, 1958–1979.

Мурзаев Э.М. Два топонимических сюжета // СТ. – 1977. – № 2.

Мурзаев Э.М. Словарь народных географических терминов. – М., 1984.

Мусаев К.М. Лексика тюркских языков в сравнительном освещении. – М., 1976.

Мусаев К.М. Лексикология тюркских языков. – М., 1984.

Мусина Н.Г. Тюркизмы в русских названиях верхней одежды: дипломная работа в КГУ. – 1978.

Мухамедова З.Б. Исследования по истории туркменского языка XI–XIV веков. – Ашхабад, 1973.

Мухамедова З.Б. Огузско-туркменские этнонимы // СТ. – 1971. – № 1.

Мухамедова Р.Г. Татары-мишари. – М., 1972.

Мухаметшин Ю.Г. Татары-кряшены. – М., 1977.

Нагаева Л.И. Танцы восточных башкир. – М., 1981.

Нагайбаки (комплексное исследование группы крещёных татар-казаков). – Казань, 1995.

Наделяев В.М. Древнетюркские надписи горного Алтая // Известия сибирского отделения АН СССР. – Новосибирск, 1981. – № 11.

Наджип Э.Н. Исследования по истории тюркских языков XI–XIV вв. – М., 1989.

Наджип Э.Н. Тюркский язык дегийского султана // СТ. – 1988. – № 2.

Названия народов СССР. – Л., 1973.

Народное творчество башкир. – Уфа, 1976.

Насибуллин Р.Ш. Наблюдения над языком красноуфимских удмуртов // О диалектах и говорах южноудмуртского наречия. – Ижевск, 1978.

Насилов В.М. Язык тюркских памятников уйгурского письма XI–XV веков. – М., 1974.

Насипов И.С. Лексико-семантические группы финно-угорских заимствований в татарском языке // Сравнительно-исторические исследования системы лексико-тематических групп татарского языка. – Уфа, 2007.

Насипов И.С. Об изучении русских заимствований в татарском языке в контексте лингвокультурологии // Язык и литература в поликультурном пространстве. – Бирск, 2005.

На стыке континентов и цивилизаций. – М., 1996.

Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Тт. I–II. – Казан, 1974–1975.

Нахмедов А.П. Основные пути развития тюркских народных театров // СТ. – 1989. – № 4.

Нестеров В.А. О семантическом спектре термина *ор//ур* в топонимии Чувашии // Проблемы исторической лексикологии чувашского языка. – Чебоксары, 1980.

Никольский Н.В. Курс этнографии чуваш. – Чебоксары, 1928.

Никольский Н.В. Народности Поволжья по историческим документам. – Казань, 1920.

Новикова К.А. Названия животных в тунгусо-маньчжурских языках // Алтайские этимологии. – Л., 1984.

Новиков А.И. Некоторые аналогии к мамонту из области алтайской этнографии // Сборник музея антропологии и этнографии. XI. – М., 1999.

Новосельцев А.Н. Хазарское государство и его роль в истории восточной Европы. – М., 1990.

Ногайцы – Калмыков И.Х., Керейтов Р.Х., Сикалиев А.И. Ногайцы. – Черкесск, 1988.

Ногман М. XVII–XVIII йөзләрдәге русча-татарча кульязма сүзлекләр. – Казан, 1969.

Ноғайша-орысша соьзлик. – М., 1963.

Ноғай халқ йырлары. – М., 1969.

Номинханов Ц.-Д. Материалы к изучению истории калмыцкого языка. – М., 1975.

Номинханов Ц.-Д. Термины родства в тюрко-монгольских языках // Вопросы истории и диалектологии казахского языка. I. – Алма-Ата, 1958.

Нұрмағамбетов А. Жергілікті тіл еректеліктерінің төркіні. – Алматы, 1985.

Нуртдинов Р.Ф. Язык priтаныпских татар. – Казань, 1998.

НФ – Нәһҗел-фәрадис.

Ожегов С.П., Шведова Н.Ю. Толковый словарь русского языка. – М., 1997.

Ойротско-русский словарь. – М., 1947.

Окладников А.П. Конь и знамя на ленских писаницах // Тюркологический сборник. Вып. 1. – М.–Л., 1951.

Олеарий А. Подробное описание путешествия голштинского посольства в Московию и Персию в 1633, 1636 и 1639 годах / пер. с нем. П. Барсова. – М., 1870.

Оранский И.М. Иранские языки в историческом освещении. – М., 1979.

Оранский И.М. Исследования восточных языков и проблемы истории культуры народов Востока // Народы Азии и Африки. – 1972. – № 4.

Остроумов Н. Первый опыт словаря народно-татарского языка. – Казань, 1876.

Остроумов Н. Татарско-русский словарь по крещенскому выговору. – Казань, 1892.

Отаров Т. Жайық, Орал, Теке топонимдарының сырлары // Қазақстан мұғалімі. – 1972. – № 24.

Отаров И.М. Очерки карачаево-балкарской топонимии. – Нальчик, 1987.

Отаров И.М. Профессиональная лексика карачаево-балкарского языка. – Нальчик, 1978.

Очерки истории культуры средневекового Ирана. Письменность и литература / Отв. ред. О.Ф. Акимушкин. – М., 1984.

Пекарский Э.К. Словарь якутского языка. Тт. I–III. – М., 1959 (фототипия издания 1907–1930 гг.).

Персидско-русский словарь. – М., 1960.

Петрушевский И.П. Ислам в Иране в VII–XV веках. – М., 1966.

Плетнёва С.А. Половецкие каменные изваяния. – М., 1974.

ПЛЛТЯ – Проблемы лексикологии и лексикографии татарского языка. – Казань, 1999, 2005, 2006, 2007.

Позднеев А.М. Монголия и монголы. Т. I. – СПб., 1896.

Покровская Л.А. Термины родства в тюркских языках // Историческое развитие лексики тюркских языков. – М., 1961.

Полякова Е.Н. Лексика местных деловых памятников XVII – начале XVIII веков и принципы её изучения. – Пермь, 1979.

Попов А.И. Из истории лексики языков Восточной Европы, – Л., 1957.

Поппе Н.Н. Золотоордынская рукопись на бересте // Советское Востоковедение. – Л., 1941. – № 2.

Поппе Н.Н. Монгольский словарь Мукаддимат ал-адаб. Ч. I–II. – М.–Л., 1938–1939.

Порохова А.Г. Лексика сибирских летописей. – М., 1969.

Потанин Г.Н. Казак-киргизские и алтайские предания, легенды и сказки // Живая старина. – СПб., 1917. – Вып. II–III.

Потанин Г.Н. – Казахский фольклор в собрании Г.Н. Потанина. – М., 1972.

Потапов Л.П. Лук и стрела в шаманстве у алтайцев // СЭ. – 1934. – № 3.

Потапов Л.П. Очерки из истории алтайцев. – М., 1953.

Потапов Л.П. Очерки народного быта тувинцев. – М., 1969.

Преображенский А.Г. Этимологический словарь русского языка. – Харбин, 1959 (фототипия издания 1913 г.).

Природное окружение и материальная культура пратюркских народов / отв. ред. А.В. Дыбо; Ин-т языкознания РАН. – М., 2008.

Проблемы функционирования, диалектологии и истории языка (сборник). – Казань, 1998.

Проблемы этимологии тюркских языков. – Алма-Ата, 1990.

Продолжение древней российской вивлиофики VIII. – СПб., 1793.

Прокопьев И.П. Брак у чуваш. // ИОАИЭ. – Т. XIX. Вып. 1. – Казань, 1903.

Проценко Б.М. Название белки в русском языке и в некоторых других славянских языках // Этимологические исследования по русскому языку. Вып. IX. – М., 1981.

Прыткова Н.Ф. Одежда хантов // Сборник музея антропологии и этнографии. – М.–Л., 1953.

Путешествие Адама Олеария в Москву и Персию. – М., 1870.

Радлов В.В. Образцы народной литературы тюркских племен. Ч. IV. – СПб., 1872. Ч. IX. – СПб., 1907.

Радлов В.В. Опыт словаря тюрксих наречий. Тт. I–IV. – СПб., 1893–1911.

Радлов В.В. Ярлыки Тохтамыша и Темир-Кутлуга // Записки восточного отделения Русского археологического общества. Т. III. Вып. I. – СПб., 1908.

Райс Т.Т. Сельджуки. – М., 2004.

Рамазанова Д.Б. Вопросы татарской диалектологии. – Казань, 2008.

Рамазанова Д.Б. Татар теленең Урта Кама тирәсендә таралган сөйләшләре (кандидатлык диссертациясе кулъязмасы). – Казан, 1968.

Рамазанова Д.Б. Термины родства и свойства в татарском языке (в 2-х книгах). – Казань, 1991.

Рамазанова Д.Б. Себер деалектларыннан материаллар. – Казан, 2001.

Рамазанова Д.Б. Татар телендә кешегә бәйләнешле лексика. – Казан, 2013.

Рамстедт Г.И. Введение в алтайское языкознание. – М., 1957.

Рапопорт Ю.В. Космогонический сюжет на хорезмийских сосудах // Средняя Азия в древности средневековье. – М., 1977.

Рассадин В.И. Комплекс охотничье-рыболовческой лексики в саянских тюркских языках таежного ареала // Природное окружение… – М., 2008.

Рассадин В.И. О культе медведя у тофаларов // Изв. АН СССР. СО. Серия общественных наук.– Новосибирск, 1973. – Вып. 3. – № 11.

Рәхимова Р.К. Татар теленең һөнәрчелек лексикасы. – Казан, 1983.

Редеи К., Рона-Таш А. Об одном агрокультурном термина в языках Среднего Поволжья // Turkologıca к семидесятилетию акад. А.Н. Кононова. – Л., 1976.

Ретегов А.М. Материалы по этнографии народов Поволжья в Санкт-Петербургском филиале архива РАН // Этнолингвистические исследования в Башкортостане. – Уфа, 1994.

Ригведа. Т.1. – М., 1989.

Розова Л.И. Инструкция по передаче на карте географических названий Татарской АССР. – М., 1969.

Романов Н.Р. Очерки по истории бурлачества // Записки ЧНИИ. Вып. 2. – Чебоксары, 1949.

Романов Н.Р. Чувашские пословицы, поговорки и загадки. – Чебоксары, 1960.

Романов Н.Р. Чувашский народный календарь // Уч. зап. Чув. НИИЯЛИ. – Чебоксары, 1966.

Романова Г.Я. Наименования мер длины в русском языке. – М., 1975.

Романова... – Романова А.В., Мырьева А.Н. Барашков П.П. Взаимовлияние эвенкийского и якутского языков. – Л., 1975.

Ромбандеева Е.И. Названия разновидностей гор в мансийском языке // СФУ. – 1987. – № 4.

Рона-Таш А. Об одном заимствованном среднемонгольском слове в марийском языке // Исследования по восточной филологии. – М., 1974.

Русско-кумыкский словарь. – М., 1960.

Русско-тувинский словарь. – М., 1980.

Русско-турецкий словарь. – М., 1972.

Русско-якутский словарь. – М., 1968.

Руденко С.К. Башкиры. – М.-Л., 1955.

Рыбаков Б.А. Язычество Древней Руси. – М., 1988.

Рыбаков С.М. Музыка и песни уральских мусульман с очерками их быта. – СПб., 1897.

Рыбаков С.М. Очерк быта и современного состояния инородцев Урала // Наблюдатель. – 1895. – № 7–8.

Рычков П.И. Топография Оренбургской губернии. – Уфа, 1999.

Рясянен М. Материалы по исторической фонетике тюркских языков. – М.–Л., 1955.

Саваткова А.А. Словарь горного наречия марийского языка. – Йошкар-Ола, 1981.

Сагалаев А.М. Мифология и верования алтайцев. Центральноазиатские влияния. – Новосибирск, 1984.

Садыкова З.Р. Говоры оренбургских татар. – Казань, 1985.

Садыкова З.Р. Названия хозяйственных построек и инвентаря в татарском языке. – Казань, 2003.

Сат Ш.Ч. Прически и традиционные украшения тувинских женщин. – Кызыл, 1984.

Сат Ш.Ч. Табу и эвфемизме в тувинском языке // СТ. – 1981. – № 5.

Сатлаев Ф.А. Старинный обряд испрашивания плодородия у кумандинцев // Религиозные представления и обряды Сибири. – Л., 1971.

Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. – Саранск, 1960.

Сафаров Р.Т. Военная лексика татарского языка. – Казань, 2015.

Сафина Ф.Ш. Ткачество татар Поволжья и Приуралья. – Л., 1990.

Сафина Э.И. Названия птиц в татарском языке и их лексикографирование. – Казань, 2006.

Сбоев В. Чуваши в бытовом, историческом и религиозном отношениях. – М., 1865.

Сборник материалов, относящихся к Золотой Орде. – Л., 1941.

Севортян Э.В. Аффиксы глаголообразования азербайджанского языка. – М., 1962.

Сепеев Г.А. Восточные марийцы. Историко-этнографическое исследование материальной культуры (середина XIX – начало XX в.). – Йошкар-Ола, 1975.

Сергеев В.И. О так называемых странствующих словах // Проблемы исторической лексикологии чувашского языка. – Чебоксары, 1890.

Сергеев И.Т. Об одном забытом чувашском названии старинной единицы земельной меры // Уч. зап. Чув. НИИЯЛИ, 49. – Чебоксары, 1970.

Сергеев И.Т. Русские областные слова в лексике чувашского языка и его диалектов // Проблемы исторической лексикологии чувашского языка. – Чебоксары, 1980.

Сергеев Л.П. Диалектологический словарь чувашского языка. – Чебоксары, 1968.

Сергеев Л.П. Изогласные явления русских лексических проникновений в чувашский язык // Уч. зап. ЧНИИЯЛИ. – Чебоксары, 1966.

Сергеев Л.П. Консонантизм верхового диалекта // Чувашский язык, литература и фольклор. Вып. 2. Чебоксары, 1978.

Сергеев Л.П. О памятниках чувашский письменности // Уч. зап. Чув. НИИ. – Чебоксары, 1970.

Сергеев Л.П. Словарь чувашских народных говоров. Фонетические диалектизмы // Материалы по чувашской диалектологии. Вып. 4. – Чебоксары, 1971.

Сердобов Н.А. История формирования тувинской нации. – Кызыл, 1971.

Сетаров Д.С. Тюркизмы в названиях животного мира // СТ. – 1980. – № 1.

Сидихменов В.Я. Китай: страницы прошлого. – Смоленк, 2000.

Система и уровни языка (сборник). – М., 1969.

Сказки народов Памира. – М., 1976.

Скворцов М.И. Из истории древней чувашской социальной лексики // Вопросы чувашской фонетики и лексикологии. – Чебоксары, 1976.

Скворцов М.И. Отражение старого общественно-юридического быта в чувашской лексике // Чувашский язык, литература и фольклор. Сб. статей. Вып. 1. – Чебоксары, 1972.

Словарь-справочник «Слово о полку Игореве». Вып. 4. – М., 1973.

Смирнов И.Н. Вотяки. Историко-этнографический очерк. – Казань, 1890.

Смирнов И.Н. Мордва. Историко-этнографический очерк. – Казань, 1895.

Смирнов И.Н. Черемисы: Историко-этнографический очерк. – Казань, 1889.

Смит Г. Драгоценные камни. – М., 1984.

СНО – Словарь русских народных говоров Новосибирской области. – М., 1979.

Советская историческая энциклопедия. Т. 29. – М., 1978.

Соколова В.С. Очерки по фонетике иранских языков. – М., 1953.

Соколов С.В. О некоторых русских названиях птиц и животных в удмуртском языке // Материалы всесоюзной конференции по финно-угроведению. – Йошкар-Ола, 1969.

Соколов С.В. Этимология некоторых названий птиц в удмуртском языке // Вопросы финно-угорского языкознания. Вып. IV. – Ижевск, 1967.

Сороколетов Ф.П. История военной лексики в русском языке. – Л., 1970.

Софийский И.М. О кереметях крещёных татар // Труды четвёртого археологического съезда России. – СПб., 1891.

Срезневский И.И. Материалы для словаря древнерусского языка. Т. I–IV. – М., 1958.

СРНГ – Словарь русских народных говоров. Вып. 1–20. – М., 1971–1985.

СРЯ – Словарь современного русского литературного языка. Т. XV. – М.–Л., 1963.

ССРЯ – Словарь современного русского языка. Т. 5. – М., 1959.

ССТМЯ – Сравнительный словарь тунгусо-маньчжурских языков. Тт. I–II. – Л., 1975–1977.

СТ – Советская тюркология. Баку.

Старчевский А.В. Сибирский переводчик. – СПб., 1893.

Субракова О.В. Этимология некоторых архаичных слов хакасского языка. – Абакан, 1987.

Султанов Т.И. Опыт анализа тридиционных списков 92 племен «Илатиа» // Средняя Азия в древности и средневековье. – М., 1977.

Сухарева О.А. Празднества цветов у равнинных таджиков (конец XIX – начало XX в.) // Древние обряды, верования и культы народов Средней Азии. – М., 1986.

СФУ – Советское финноугроведение. Таллин.

СЭ – Советская этнография. М.

СЯ – Советское языкознание. М.

Таджикско-русский словарь. – М., 1954.

ТАЁТ – XIII–XIV асрлар туркий адабий ёдгорликлар тили. – Ташкент, 1986.

Тараканов И.В. Тюркизмы в удмуртских диалектах по письменным памятникам XVIII века // Вопросы удмуртской диалектологии. – Ижевск, 1977.

Тараканов И.В. Удмуртско-тюркские языковые контакты: автореф. дис. ... докт. филол. наук. – Устинов, 1985.

Тарихи һәм лирик җырлар. – Казан, 1988.

Таскин В.С. – Материалы по истории сюнну (по китайским источникам). Вып. 1 / Предисловие, перевод и примечания В.С. Таскина. – М., 1968.

Татар халык җырлары. – Казан, 1965.

Татары среднего Поволжья и Приуралья. – М., 1967.

Татарстан. Краткая энциклопедия. – Казань, 1999.

ТДГДС – Търкмен дилиниң гыскача диалектологик сөзлүги. – Ашгабат, 1977.

ТДМ – Татар диалектологиясе буенча материаллар. – Казан, 1978.

Тел ярышы. – Оренбург, 1910.

Тенишев Э.Р. Строй саларского языка. – М., 1976.

Тенишев Э.Р. Язык саларов. – М., 1963.

Тепляшина Н.И. Язык бесермян. – М., 1970.

Тимергалин А.К. Миллият сүзлеге. – Казан, 2007.

Тихонов Д.М. Зависимое инджу // Новые материалы по древней и средневековой истории Казахстана. Т. 8. – Алма-Ата, 1960.

Тихонов Д.М. Хозяйственный и общественный строй Уйгурского государства. – М., 1966.

Толстова Л.С. Исторические предания Южного Приаралья. – М., 1984.

Томилов Н.А. Этнография тюркоязычного населения Томского Приобья. – Томск, 1980.

Топонимая Поволжья. – Ульяновск, 1969.

Тощакова Е.М. Традиционные черты народной культуры алтайцев. – Новосибирск, 1978.

Төхфэт – Аттухфатуз закияту филлугатит туркия. – Тошкент, 1968.

Троянский А. Татарско-русский словарь. Т. I. – СПб., 1833. Т. II. – СПб., 1835.

Традиционное мировоззрение тюрков Южной Сибири. – М., 1989.

ТРС – Татарско-русский словарь. – Казань, 1931; М., 1966; Казань, 2007.

Трубачев О.Н. История славянских терминов родства. – М., 1959.

ТТАС – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Тт. I–III. – Казан, 1977–1981.

ТТАС – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан, 2005.

ТТДС – Татар теленең диалектологик сүзлеге. Тт. I–II. – Казан, 1969–1993.

Тувинско-русский словарь. – М., 1968.

Тумашева Д.Г. Көнбатыш Себер татарлары теле: Грамматик очерк һәм сүзлек.– Казан, 1961.

Тумашева Д.Г. Словарь диалектов сибирских татар. – Казань, 1992.

Тумашева Д.Г. Этнические связи западно-сибирских татар: По материалам топонимии и антропонимии // СТ.– 1987. – № 2.

Тучков М.С. – Военный словарь. Тт. I–II. – СПб., 1918.

Түркмен дилиниң сөзлүги. – Ашгабат, 1962.

ТХИ – Татар халык иҗаты (13 томлык фольклор җыентыгы). – Казан, 1976–1993.

Тыбыкова А.Т. Составные глаголы в алтайском языке // Система и уровни языка. – М., 1969.

Тыва улустық чогаалы. – Кызыл, 1979.

ТЭ – Татарская энциклопедия. Тт 1–5. – Казань, 2002–2010.

ТЭС – Татарский энциклопедический словарь. – Казань, 1999.

Убрятова Е.И. Служебное слово *киэнэ* в якутском языке // Академику В.А. Гордлевскому к его 75-летию. – М., 1953.

Удмуртско-русский словарь. – М., 1983.

Узбекско-русский словарь. – М., 1959.

Уйгурско-русский словарь. – М., 1968.

Унгвицкая М.А., Майньгашева В.Е. Хакасское народно-поэтическое творчество. – Абакан, 1972.

Упымарий (В.М. Васильев). Марий мутэр. – Моско, 1929.

Уразманова Р.К. Современные обряды татарского народа: историко-этнографические исследования. – Казань, 1984.

Урманче Ф.И. Татар мифологиясе: энциклопедик сүзлек. Тт. 1–3. – Казан, 2008, 2009, 2011.

Урманчеев Ф.И. Татарская мифология. – Казань, 1984.

ЎХШЛ – Ўзбек халқ шевалари луғати. – Тошкент, 1971.

Фасеев Ф.С. К расшифровке хуннских фрагментов // Источниковедение и история тюркских языков. – Казань, 1978.

Фасеев Ф.С. Старотатарская деловая письменность XVIII века. – Казань, 1982.

Фасмер М. Этимологический словарь русского языка. Т. I. – М., 1986. Т. II. – М., 1986. Т. III. – М., 1987. Т. IV. – М., 1987.

Фахретдинов Р.Г. Об имени и титула правителя Волжской Булгарии // СТ. – 1979. – № 2.

Фәхреддинев Р. Болгар вә Казан төрекләре. – Казан, 1993.

Фәхретдинов Р. Татар теле һәм Татарстан тарихы. – Казан, 1996.

Федоров-Давыдов Г.А. Кочевники Восточной Европы под властью золоордынских ханов. – М., 1966.

Федотов М.Р. Об арабских и персидских заимствованиях в чувашском языке // Уч. зап. Чув. НИИЯЛИ. – Вып. XXVI. – Чебоксары, 1963.

Федотов М.Р. Чувашско-марийский языковые связи. – Саранск, 1990.

Федотов М.Р. Этимологический словарь чувашского языка. Тт. I–II. – Чебоксары, 1996.

Фокин П.П. Молодежные объединения в дореволюционной чувашской деревне // История и культура Чувашской АССР. Вып. 4. – Чебоксары, 1979.

Фрейман А.А. Хорезмский язык. – М., 1951.

Хабичев М.А. К структуре первичных корней в тюркских языках // СТ. – 1980. – № 5.

Хазуев Н.А. Лексико-семантическая характеристика тибетских заимствований в бурятском языке // Исследования по бурятской филологии. – Улан-Удэ, 1978.

Хайдаков С.М. Сравнительно-сопоставительный словарь дагестанских языков. – М., 1973.

Хайрутдинова Т.Х. Бытовая лексика татарского языка. – Казань, 2000.

Хайрутдинова Т.Х. Говор златоустовских татар. – Казань, 1985.

Хайрутдинова Т.Х. Названия пищи в татарском языке. – Казань, 1993.

Хакасско-русский словарь. – М., 1953.

Хакасско-русский словарь. – Новосибирск, 2006.

Хакимзянов Ф.С. Язык эпитафий волжских булгар. – М., 1978.

Хаков В.Х. Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше. – Казан, 1972.

Халиков А.Х. Культура Среднего Поволжья в X–XIII вв. // Вопросы истории. – 1976. – № 4.

Халиков А.Х. Татар этнонимы // Мирас. – 1992. – № 5.

Халиков Н.А. Земледелие татар Среднего Поволжья и Приуралья XIX – начала XX века. – М., 1981.

Халиков Н.А. Хозяйство татар Поволжья и Урала. – Казань, 1995.

Хангалов М.Н. Собрание сочинений. Т. II. – Улан-Удэ, 1959.

Хара-Даван Д.Р.Э. Чингис-хан как полководец и его наследие // На стыке континентов и цивилизаций. – Казань, 1996.

Хинц З. Государство Элам. – М., 1977.

Хисамова Ф.М. XVIII йөздәге татарча эш кәгазьләренең тел үзенчәлекләре. – Казан, 1981.

Хисамова Ф.М. Функционирование и развитие старотатарской деловой письменности (XVI–XVII вв.). – Казань, 1990.

Хөснуллин К. Мөнәҗәтләр һәм бәетләр. – Казан, 2001.

Худайкулиев М. Подражательные слова в туркменском языке. – Ашхабад, 1962.

Цинциус В.И. Вопросы сравнительной лексикологии алтайских языков // Проблемы общности алтайских языков. – Л., 1971.

Цинциус В.И. О некоторых лексических моделях алтайских языков // Языковые универсалии и лингвистическая типология. – М., 1969.

Цинциус В.И. Этимологии алтайских лексем с анлаутными придыхательными смычными губно-губным *п” и заднеязычным *к” // Алтайские этимологии. – Л., 1984.

Цинциус В.И., Бугаева Т.Г. Этимологические исследования названий металлов и их сплавов в языках алтайской общности // Теоретические проблемы восточного языкознания. – М., 1977.

Чăвашла-вырасла словарь. – Мускав, 1982.

Черкасский М.А. Тюркский вокализм и сингармонизм. – М., 1965.

Чернецов В.Н. О проникновении восточного серебра в Приобье // Труды института этнографии. Новоая серия. I. – М., 1947.

Черных П.Я. Этимологический словарь русского языка. Тт. I–II. – М., 1999.

Черных С.Я. Марийские антропонимы, связанные с этнонимами // Вопросы марийской ономастики. – Йошкар-Ола, 1980.

Чернышёв Е.И. – Селения Казанского ханства // Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья. – Казань, 1971.

Четкарёв К.А. Племенное название марийцев // Ученые записки Мар. НИИ, 5. – Йошкар-Ола, 1953.

Чирiм тамырлары [хакасские народные легенды]. – Абакан, 1982.

Чичуров И.С. Византийские исторические сочинения. – М., 1980.

Чуваши Приуралья. – Чебоксары, 1989.

Чувашско-русский словарь. – М., 1961.

Шайхулов А.Г. Историческая и диалектная лексика тюркоязычных народов Волго-Камского-Уральского региона. – Уфа, 1988.

Шайхулов А.Г. Лексические взаимосязи кыпчакских языков Урало-Поволжья в свете их историко-культурной общности. – Уфа, 1999.

Шайхулов А.Г. Словарный массив алтайского языкового сообщества // Вопросы алтайской филологии. – М., 2008.

Шакуров Р.З. Нагайбак: топоним и этноним // Башкирская этнонимия. – Уфа, 1987.

Шамсутов Р.И. Слово и образ в татарском шамаиле. – Казань, 2003.

Шанский Н.М., Иванов В.В., Шанская Т.В. Краткий этимологический словарь русского языка. – М., 1975.

Шапшал С.М. К вопросу о тарханных ярлыках // Акад. В.В. Гордлевскому к его семидесятилетию. – М., 1953.

Шараф Г. Сонорная длительность татарских гласных // Вестник татароведенья. – Казань, 1928. – № 8.

Шарифуллина Ф.Л. Касимовские татары. – Казань, 1991.

Шипова Е.Н. Словарь тюркизмов в русском языке. – Алма-Ата, 1976.

Шитова С.Н. Обычаи и культурно-бытовые традиции башкир. – Уфа, 1980.

Шпилевский С.М. Древние города и другие булгарско-татарские памятники в Казанской губернии. – Казань, 1877.

Штейниц В.К. Финно-угорско-тюркско-русские этимологии // Язык и человек. – М., 1970.

Щербак А.М. Названия домашних и диких животных // Историческое развитие лексики тюркских языков. – М., 1961.

Щербак А.М. Очерки по сравнительной морфологии тюркских языков (наречия, служебные части речи). – Л., 1987.

Щербак А.М. Сравнительная фонетика тюркских языков. – М., 1970.

Эргис Г.У. Очерки по якутскому фольклору. – М., 1974.

Эрдниев У.Э. Калмыки. – Элиста, 1970.

ЭСИЯ – Расторгуева В.С, Эдельман Д.И. Этимологический словарь иранских языков. Тт. I–III. – М., 2000–2007; Эдельман Д.И. Этимологический словарь иранских языков. т. IV. – М., 2011.

ЭСТЯ – Этимологический словарь тюркских языков. Тт. I–IV. – М., 1974–1980 (Э.В. Севортян өлеше). Тт. V–VI. – М., 1989–2005.

Эфендиева А.Д. К истории слова *аманат*, в русском языке. – Учён. зап. Азерб. пед. ин-та языков. Сер. 12 (Язык и лит-ра). – 1972. – № 4.

Юналеева Р.А. Из истории слов тюркского происхождения // Исследования по диалектологии. – Казань, 1982.

Юналеева Р.А. Опыт исследования заимствований. – Казань, 1992.

Юнусалиев Б.М. Киргизская диалектология. – Фрунзе, 1971.

Юсупов Г.В. Болгаро-татарская эпиграфика и топонимика как источник исследования этногенеза казанских татар // Археология и этнография Татарии. Вып. I. Вопросы этногенеза тюркоязычных народов древнего Поволжья /АН СССР. Казан. фил. – Казань, 1971.

Юсупов Ф.Ю. Көньяк Урал һәм Урал арты сөйләшләре. – Казан, 1979.

Юсупов Ф.Ю. Неличные формы глагола в диалектах татарского языка. – Казань, 1985.

Якутско-русский словарь. – М., 1972.

Яншина Э.М. Формирование и развитие древнекитайской мифологии. – М., 1984.

Ястребов Е.В. Название уральских гор в XV–XVIII вв. // Топонимика на службе географии. – М., 1979.

ЯТ – Андреев М.С., Пещерева Е.М. Ягнобские тексты. – М.–Л., 1957.

Яшин Д.А. Об одном удмуртском сказочном персонаже *алангасаре* // Проблемы изучения финно-угорского фольклора. – Саранск, 1972.

* * *

Açıkgöz H. Türkçede halı ve halıcılık terimleri // Türk dünyası araştırmaları, 32. – Ankara, 1984.

Akb – Ayuv kulak batır. – Bukuresti, 1986 (Румыниядәге татар теле үрнәкләре).

Altheim F. Geschichte der Hunnen. T. I. – Berlin, 1959.

AMES – A Magyar nyelv torteneti-etimologiai szotara. Tt. I–II. – Budapest, 1970.

Arpad Berta. Die russische Lehnworter in der Mundart der getauften Tataren // Tatarische etymologishe Studien I. – Szeged, 1983.

A Survey of Persian Art: From Prehistoric Times to the Present. V. 1–6 – L. and N.Y., 1938–1939.

Avьl xuçalьꝏь həm urmancьlьq atamalarь. – Qazan, 1931.

Balint G. Kazany-tatar nyelvtanulmanyok. – Budapest, 1875; 1988.

Bang W. Gewagte türkische Wörterklarungen // MSFOu. LXVII – 1948.

Bazin L. Formules propitiatoires et genres oraux traditionnels: etude d'une Familie de mots turco-mongole // Turcica, I. – Paris, 1969.

Berta A. Zwei Wolgabolgarısche Lehnwörter in der Mundart de getunften Tataren // Studies in Chuvash etymology I. – Szeged, 1982.

Bonnerja B. Popular belifs en folklore tradition in Sibiria. – Budapest, 1968 (немесчәгә тәрҗемәсе – 1971).

Bonnerja B. Relationship between Eskimo-Aleut and Ural-Altaic // Acta Linguistica, XXI, – Budapest, 1971.

Božilov J., Dmitrov H. About the Historical Geography of the Northern Black Sea Coast // Bulgarian historical rewiew. – Sofia, 1985. – № 4.

Bozqaplan T. Türkiye rürkçesi agızlarında kuş isimleri // Türk dili araştırmaları yıllığı. – Ankara, 1992.

Caferoglu A. Eski uygur türkçesi sözlüğü. – Ankara, 1993.

CAJ – Central Asiatic Journal. The Hague; Wiesbaden.

CC – Codex Cumanicus – Das türkische Sprachmaterial des Codex Cumanicus von W. Radloff. – СПб., 1887.

Christos Nzitzilies. Griechische Lehnwörter in Türkischen. – Wien, 1989.

Clauson G. An etymological Dictionary of Pre-Thirteenth century Turkish. – Oxford, 1972.

Csaki E. Mıddle Mongolian Loan Words in Volga Kıpchak Languages. – Wiesbaden, 2006.

Czegledy K. Çoγay-Quzı, Qara Qum, Kök öng // Acta Orientalia (Budapest), XV, 1–3, 1962.

Çagatay S. Einige Ellipsen in türk dialekten // UAJ. – XXIX, f. 3–4. – 1957.

Çagatay S. Die Bezeichnungen fuc Frau im Türkischer // UAJ. – XXXIX, f. 1–2. – 1962.

Çagatay S. Die Frau im Türkischen // UAJ. XXXIII, 1–2. – 1961.

Çay A.M. Türk Ergenekon Bayramı Nevrûz, Türk Kültürünü Araştırma Enstitüsü Yayınları No: 88. – Ankara, 1988.

Çay A.M. Türk Ergenekon Bayramı Nevrûz. – Ankara, 1993.

Die chinesiche Nachrichten zur Geschichte der Ost-Türken. I. – Wießbaden, 1958.

Dioszegi V. Libation songs of the Altaic turks // Acta ethnografica. – XIX, f. 1–2. – Budapest, 1970.

DLT – Divani lugat et-türk tercümesi. Tt. I–III.– İstanbul, 1939–1941.

Dobr. – Dobruca kırımtatar sözlüğü. Tt I–III. – Kostence [Румыния], 2011.

Doerfer G. Türkische und mongolische Elemente im Neupersischen… Bd. 1. Mongolische Elemente im Neupersischen. – Wiesbaden, 1963; Bd. II–IV. Türkische Elemente im Neupersischen. – Wiesbaden, 1965–1975.

Doerfer G. Die Entsprechungen der türkischen Langvokalen tungusischen // UAJ. 40. H.1–2. – 1968.

Donner K. Ethnological notes about the Jenisey ostyaks (in the Turukhansk region) // MSFOu, LXVI. – 1933.

Donuk A. İdari-askeri titul ve terimler. – İstanbul, 1988.

DS – Derleme sözlügü. Tt. I–XIII. – Ankara, 1966–1986.

EI – The Encyclopaedia of Islam. V. 1–5. – Leiden – London, 1960–1986.

Epstein H. The origin of the domestic animals of Africa. T.II. – Leipzig, 1971.

Eren H. Türk dilinin etimolojik sözlüğü. – Ankara, 1999.

Eyuboğlu Z. Türk dilinin etimoloji sözlüğü. – İstanbul, 1988.

Feher G. Bulgarisch-ungarischen Beziehungen in der V–IX Jahrhunderts // Keleti Szemle. – XIX. – 1912. – № 1–2.

Fischer J. Sibirische Geschichte. – СПб., 1767.

Fraenkel E. Litauisches etymologisches Wörterbuch. – Heidelberg, 1955.

FUF – Finnisch-ugrische Forschungen. Helsinki.

Gabain, A. von, Alttürkische Grammatik. 3. Aufl. – Wiesbaden, 1974, Berlin, 1950.
Gabain, A. von, Das Leben in uigurischen Königreich von Qočo. – Wiesbaden 1973.
Golden P. Khazar Studies. – Budapest, 1980.
Gombocs Z. Die bulgarisch-türkishen Lehnörter in der ungarischen Sprache // MSFOu. – XXX. – Helsinki, 1912.
Grundriß der germanischen Philologie. – Strasburg, 1901.
Hajdu P. Finnougrische Urheimatforschung // UAJ. – XLI, f. 1–4. – 1969.
Hämäläinen A. Das kultische Wachsfeuer der Mordwinen und Tscheremissen // JSFOu. – XLVIII. 1936–37.
Holmberg U. Die Wassergottheiten der finnisch-ugrischen Völker // MSFOu. – 1913.
Hombüs L. Historie des Mongols avant Jengiskhan // CAJ. – 1970. – № 1–3.
Horn. Etymologisches Wörterbuch der Urdu und Paschto. – 1893.
İA – İslam Ansiklopedisi. – İstanbul, 1940–1987.
İnan A. Makaleler ve incelemeler. I cilt. – Ankara, 1998.
Itkonen E. Bemerkungen über den Vokalismus der ersten Silbe von tschuwaschischen Lehnwörter in einigen finnisch-ougrischen Sprachen // FUF. Bd. XXXVIII, Hf. 1–3. – Helsinki, 1970.
Jarring G. Wörterverzeichnis zu ujgurishe. Täjißila Zöhra. – Lund, 1967.
Joki A.J. Uralier und Indogermanen // Memoires de la Societe Finno-Ougrienne. – T. 151. – Helsinki, 1973.
Joki A.J. Zur Herkunft ugrischer worter // FUF. – XL, f. 1–3. – 1979.
Joki A.J. Wörterverzeichniss des Sajan-samojediscen // Memoires de la Societe Finno-Ougrienne. – T. 103. – Helsinki, 1952.
JSFOu – Jornal de la Societe Finno-ougrienne. Helsinki.
Kalkan M. Orta Asya türk devletlerinde ordu ve savaş stratejileri. – İzmir, 1995.
Kannisto A. Die tatarische Lehnwörter im Vogulischen // FUF. XVII. – 1925.
Kannisto A. Materialen zur Mythologie der Vogulen. – Helsinki, 1958.
Kara G. Les mots Mongols dans une liste de marchandıses chez Gmelin (1918) // Acta Orientalia. – XI, f.1–3. – Budapest, 1960.
Kecskemeti J., Paasonen H. Tatarisches Dialekwörterverzeichniss // JSROu. 66. – Helsinki, 1965.
Kırzaoğlu F. Kıpçaklar. – Ankara, 1992.
Kluge. Etymologisches Wörterbuch der deutschen Sprache. 24 Auflage. – Berlin / New York, 2002.
Kurat A.N. Peçenek tarihi. – İstanbul, 1937.
Liu Mau-tsai, Die Chinesischen Nachrichten zur Geschichte der Ost-Türken I. – Wiesbaden, 1958.
Lorincz L. Sonnenmythos, Sonnen (Solar) heros und Kulturheros in der mongolischen Mythologie // Acta Orientalia. – t. XXXI, f. 3. – Budapest, 1977.
Lovıs Hambis. Historie des mongols avant Jengiskhan // CAJ. – 1970. – № 1–3.
Mandoky-Kongur J. Die Etimologie eines ungarischen Pflanzennamens kumanischen Ursprungs // Hungaro-Turcica. – Budapest, 1976.
Marquatr J. Über das Volkstum der Komanen. – Berlin, 1914.
MES – A magyar nyelv történeti etymologial szótára. t. III. – Budapest, 1971.
Menges K.H. Altaische kultur Wörter im slavischen // UAJ. – XXXVII, f.2. – 1961.
Menges K. Einige Bemerkungen zu türk. *saydaq, qur* und *kes* // UAJ. XVIII. – 1974. – № 1.
Menges K.H. Zu einigen slavisch-türkischen Lehnbezichungen // Tatarica. –Wammala, 1987.
Menges K.H. Zur Etimologie Armeno-Qypčaqischen // Der Islam. – Bd. 48. – Berlin, 1972.
Morgenstierne G. An etymologycal vocabulary of Pashto. – Oslo, 1927.
MSFOu – Memoires de la Societe Finno-ougrienne.
Nemeth I. Eine Benennung für scheckige Tiere bei Türken und Ungarn // Acta Linguistica. – XV, f. 1–2. – Budapest, 1965.
Nevruz. – Ankara, 1995.
Ögel B. Türk mitolojisi. T. I. – Ankara, 1993.
Özön M. Osmanlıca-türkçe sözlik. – Ankara, 1997.
Paasonen H. Mordwinische Lautlehre. // MSFOu XXII. – Helsinki, 1903.
Paasonen H. Ost-tscheremissisches Wörterbuch. LSFU XI. – Helsinki, 1948.
Paasonen H. Tatarisches Dialektwörterverzeichniss. – Helsinki, 1949.
Paasonen H. Tscheremissische Texte – Helsinki, 1939.
Paasonen H. Über die ursprunglichen Seeleforstellungen beiden finnisch-ugrischen Sprachen // JSFOU. – XXVI. – 1909.
Paasonen H. Volksbrauche und Volksdichtung der Tschuwassen // MSFOu. – XCIV. – Helsinki, 1949.
Paul H. Grundriβ der neupersischen Etymologie. – Straβburg, 1893.
Platts A.J. A dictionary of Urdu, classical Hindi and English. – M., 1949.

Pokorny J. Indogermanisches etymologisches Wörterbuch. – Berlin und München, 1951–1959.

Poppe N. Die türkischen Lehnwörter im Tscheremıssısсhen // UAJ. –VI. – 1927.

Poppe N. Introduction to Altaic linguistics. – Wiesbaden, 1955.

Poppe N. Introduction to Mongolion comparative studies // MSFOU. – 1955.

Poppe N. Vergleichende Grammatik der altaischen Sprachen. T.1. – Wiesbaden, 1960.

Poppe N. Die mongolischen Lehnwörter im komanischen // Nemeth armaganı. – Ankara, 1962.

Poppe N. A new symposium on the altaic theory // CAJ. – 1972. – № 1.

Poppe N. On some Mongolian loan words in evenki // CAJ. – 1972. – № 2.

Poucha P. Die Geheime Geschichte der Mongolen als Geschichtsquelle und Literaturdenkmal. – Prague, 1956.

Pritsak O. Bolgarische Etymologien // UAJ. – XXIV, f. 3–4. – 1957.

Pritsak O. Die bulgarische Fürstenliste und die Sprache der Protobulgaren. – Wiesbaden. 1955.

Rahmeti Arat R. *Balık, Batman* // İA II. 14–15. – Ankara, 1943.

Ramstedt G.J. Alte türkische und mongolische Titel. JSFOu. – 55.– 1951.

Ramstedt G. Kalmuckisches Worterbuch // JSFOu, III, – Helsinki, 1976.

Ramstedt G.J. Studies in Korean Etymology. – MSFOu. XCV. – Helsinki, 1949.

Räsänen M. Die tatarischen Lehnwörter im Tscheremissischen // MSFOu. – L, 1923.

Räsänen M. Die tschuwassischen Lehnwörter im Tscheremissischen.– MSFOu. – XLVIII. – 1920.

Räsänen M. Versuch eines etymologisches Wörterbuchs der türksprachen. – LSFU. – XVII. 1. – Helsinki, 1969.

Redhouse J.W. A turkish and English lexicon. – Ankara, 1993.

Rona-Tas A. Dariganda dialect of Mongolia // Acta Orientalia, IX. – Budapest, 1960.

Rona-Tas. Notes on the Kazak yurt of West Mongolia // Acta Orientalia. – XII.– Budapest, 1964.

Rona-Tas A. Dream, magic power and divination in the Altaic World // Acta Orientalia. – XXV. – Budapest, 1972.

Röhrborn K. Uigurisches Wörterbuch. – Wiesbaden, 1986.

Salonen A. Agricultura mesopotamica nach šumerisch-akkadische Quellen. – Helsinki, 1968.

Solonen A. Agricultura Mesopotamica nach sumerisch-akkadischtn quellen. – Helsinki, 1968

Salonen A. Ein akkadisches Lehnwört in türkischen // Tatarica. – Helsinki, 1987.

Scherner B. Arabische und neupersische Lehnwörter im tschuwaschissen. Versuch einer chronologie ihrer Lautveranderungen. – Wiesbaden, 1977.

Schott W. Versuch über die Tatarischen Sprachen. – Berlin, 1736.

Sertkaya O.F. Mongolian words and forms in chagatay türkish (eastern turki) and Turkey türkish (western turki) // Türk dili araştırmaları yıllığı. – Ankara, 1992.

Steinitz W. Tatarische lehnwörter in Osttjakischen and Wogulischen // Acta Linguistica.– XV, f. 1–2. – Budapest, 1965.

Steuerwald K. Türkisch-Deutsches Wörterbuch. – Istanbul, 1998.

Stralenberg F.J. Historie der Reisen in Russland, Siberien und der grossen Tartarey. – Leipzig,1730.

Sumer F. Oguzlar. – İstanbul, 1992.

Sumer F. Türklerde atçılık ve biniçilik. – Ankara, 1983.

TA – Türk Ansiklopedisi. – Ankara, 1964–1970.

Tabiɤət həm biologiə terminnarь. – Qazan, 1935.

Tarama sözlüğü. I–IV. – Ankara, 1963–1969.

Tatarica. – Wammala, 1987.

Tatarische etymologische studien. – Szeged, 1988.

Taube E. Tuwinische Volksmärchen. – Berlin, 1978.

Tezcan C., Zieme P. Uigurısches Brieffragmente // Stidıa turcica. – Budapest, 1971.

Toivonen Y.H. Zur Geschichte der finnougrishen inlaut affrikaten // FUF. – XIX, H. 1–2. – Helsinki, 1928.

Tryjarski E.F. Dictionnaire armeno-kiptchak, t. I, f. 1. A–h. – Warszawa, 1968.

Tryjarski E.F. On dialectal differentiation of armena-kipchak // TAJ. – 1987.

TS – Türk dilinin temel sözlüğü. 10-ncu baskısı. – Ankara. 2009.

Türkler. – Tt. I–15. – Ankara, 2002.

UAJ – Ural-Altaische Jahrbucher. Wiesbaden.

Uray-Köholmi K. Qurluq und sadaq. AO XI. 1960

Velidi-Togan Z. Umumi türk tarihine giriş. – İstanbul, 1981.

Walde A. Vergleichendes Wörterbuch der indogermanischen Sprachen. 3 Bde. Herausgegeben und bearbeitet von J. Pokorny. de Gruyter – Berlin, 1927–1932.

Wichmann Y. Tschuwassischen Lehnwörter in den permischen Sprachen // MSFOu, 21. – 1903.

Wichmann Y. Über eine Reformbewegung der heidnischen Tscheremissen // JSFOu, XIV. –1932.

YTS – Yeni türkçe sözlük.

Zajączkowski A. Najstarsza wersja turecka Husrov u Širin Qutba, Cz. III: Slownik. – Warszawa, 1961.

Zenker J.T. Dictionnaire turc-arabo persan. – T. I–II. – Wiesbaden-Leipzig, 1866–1876.

Zieme P. Neue Fundung zur Geschichte der Türken in der Mongolei // Das Altectum. – Bd. 18, Heft 4. – Berlin, 1972.

ألاختري كبير = Әхтәри кәбир (гарәпчә-төрекчә зур сүзлек). – Истанбул, ١٣٥٩ (1891).

**Төп текстта күрсәтелгән публикацияләрнең авторлары исемлеге**

Боларның кайберләре керештәге библиографиядә дә бар (мәс., Алатырев, Ашмарин, Вәлиди Җ., Рамстедт, Menges һ.б.ш.). Биредә исә аларның бүтән публикацияләре, гадәттә, аерым сүзләргә генә багышланганнары күрсәтелә. Фамилия һәм инициаллардан соң ул автор һәм аның мәкаләсе һ.б. махсус багышланган сүз яки сүзләр языла. Без һәр очраган авторны яки публикацияне түгел, безнең караштан билгеле бер кыйммәте яки гыйбрәте булганнарны гына искә алдык. Билгеле бер кыйммәт дигәннән, телгә алынган авторның фикере генә түгел, кызыклы мәгълүматы да күз уңында тотыла. Ләкин әдәби әсәр (гомумән, билгеләре) авторлары, текстта искә алынса да, биредә китерелмәде. Шулай ук исемлеккә җыентыклар, коллектив хезмәтләр дә кертелде.

Исемлекнең беренче өлешендә кириллицада басылган хезмәтләр, икенче өлешендә – латинда, өченчесендә – катнаш шрифтлы, авторлары күрсәтелмәгән чыганаклар, ягъни легендалар, коллектив төзелгән сүзлекләр һ. б. китерелде. Соңгыларының атамалары тулысынча сүзлекнең төп текстында бирелә.

Абаев В.И. – **Сәмрәү**
Абаев Н. – **Миң**
Абаева Л.Л. – **Уба**
Абдирахманов А. – **Казак**
Абдуллин И. – **Беләң, Давыл**
Абрамзон С.А. – **Умай**
Абусеитова М.Х. – **Бирун**
Авижанская А.В. и др. – **Адаргы**
Акцорин В.А. – **Апата**
Алатырев В.И. – **Кузгалак**
Алекперов А.К. – **Адым**
Алексеев Н.А. – **Җаду**
Алияров С.С. – **Алпар, Идел**
Алпаров Г. – **Кузгалак, Кучкар**
Аль-Куфи Я. **– Хәреҗ**
Анисимов А.Ф. – **Абага, Ау**
Аракин В.Д. – **Куч, Ялау**
Арсланов Л.Ш. – **Печә**
Артамонов М.И. – **Хазар**
Атаманов М.Г. – **Куак**
Ахатов Г. – **Күтәр-ү, Шәүлегән**
Ахмаров Г.Н. – **Мишәр, Типтәр**
Ахметьянов Р.Г. – **Җабылса**
Ашмарин Н.И. – **Наркөмеш, Типтәр, Чукын-у**
Ашнин Ф.Д. – **Шөйлә**
Әсфәндияров А.З. – **Типтәр**
Әхмәтҗанов М. – **Нократ, Типсә-ү**
Әхтәри кәбир – **Нократ**
Бабич Щ. – **Канун**
Бакиров М. – **Сак-Сок**
Байрамов Ф.Р. – **Бул-у**
Барашков П.П. – **Талта**
Барбаро Й. – **Акча, Идел, Казан**
Баскаков Н.А – **Жулик, Ку, Таң, Сана//сәнә**
Березин И.Н. – **Типтәр**
Беркутов В.М. – **Кырлач**
Бертагаев Т.А. – **Иркә, Улус**
Бимбаев Р. – **Монгол**
Бирҗанова Е.Э. – **Магаҗи**
Бируни А. – **Андыз, Гәрәбә, Җофар, Туз**
Бичурин И. – **Гөбер**
Благова Г.Ф. – **Сарай, Урда, Чыгтай**
Богородицкий В.В. – **Камыт**
Борһанова Н. – **Кәрешкә**
Брук С – **Татар**
Будегечиева Т.Б. – **Кай**
Булатов А.В – **Болгар, Җик**
Булатова А.К. – **Йөз**
Булаховскии Л.А. – **Балабан**
Бурангулов М. – **Калкан, Кушамат**
Бурнаш Ф. – **Аткый-маткый, Чичән**
Буранов М. – **Казак**
Бутанаев В.Я. – **Өлкәр**
Бушаков В.А. – **Сала**
Вагапова М.З. – **Дии-ү**
Вайнштейн С.И. – **Балбан, Җидегән, Оча**
Валькова Д.П. – **Чолан**
Василевич Г.М. – **Абага**
Васильев М.А. – **Санай**
Вассоевич А.Л. – **Нефть**

Вафин Т. – **Мәкрә**
Вашари И. – **Тартанак**
Вәисев Б. **– Абузин**
Вәлиди З. – **Күкшен, Кыпчак**
Вәлиди Җ. – **Әйрән**
Виноградов Г. – **Аткый-маткый**
Владыкин В.Е. – **Кирәмәт**
Воинова Л.А. – **Магаҗи**
Воробьев Н. – **Эреш**
Габэн А. – **Кәгазь**
Гаврилов М.Ф. – **Юсын, Ясак**
Газиз Г. – **Идел**
Гайнетдинов М. – **Кәнсә**
Галайская Р. – **Кубыз**
Галданова Г.Р. – **Төкләче**
Гали Х. – **Азамат, Әртил, Кала**
Галибик К. – **Җабылка**
Галкин И.С. – **Бәрәңге**
Гараджиев Ч. – **Туксаба**
Гарипов Т.М. – **Бөрҗән**
Гафуров Г. – **Типтәр**
Георгиев В. – **Кәнтәй**
Гераклитов А.А. – **Бүләк II, Җөп, Янкылыч**
Гиршман – **Кондыз**
Гмыря Л.Б**. – Хазар**
Полякова Е.Н. – **Дары**
Гонсалес де Клавихо – **Татар**
Гордеев Ф.М. – **Кыргыз, Кышт, Сыра, Чирмеш**
Гордлевский В.А. – **Җандар, Салаш**
Граков Б.Н. – **Бабай**
Грач А.Д. – **Балбан, Күшә**
Гребнев Л.В. – **Патпалчын**
Греков Б.Д. – **Кабак**
Громов Г**. – Сука**
Губайдуллин Г. – **Татар**
Гукасян В.П. – **Агачире, Сәүче, Утыз, Чиш-ү, Ювари**
Гуломов А. – **Куырмач, Күтәр-ү**
Гумилев Л.Н. – **Кол, Маңкорт, Татар, Тиңгенәй, Үсергән, Хазар, Хунну**
Гусейнзаде А. – **Бәҗәнәк**
Даулей Р. – **Чипичья**
Демидов С.М. – **Ишан**
Демьяненко З.П. – **Билтер**
Джидалаев Н.С. – **Ләкшә**
Диваев А. – **Әләңгәсәр, Этәлә, Кантар**
Димитриев В.Д. – **Батман, Урда**
Дмитриев В.Р. – **Тархан**
Дмитриев Н.К. – **Ай, Әртил, Мәктәп**
Дмитриева Л.В. – **Саксавыл, Суган**
Добродомов И.Г. – **Балаган, Боздыган, Дүдәк, Жулик, Имнек, Казан, Калчан, Керән, Кыр, Магаҗи, Порак, Рабат, Сайдак, Тиркеш, Үркән, Чабата, Ярмак**
Донидзе Г.И. – **Кайчан**
Дубровин Н. – **Өлеңге**
Дульзон А.П. – **Кырлач**
Дыбо А.В. – **Каре**
Дьякова В.П. – **Армай**
Егоров В.Л. – **Казан**
Елкина Н.М. – **Тавар**
Еремеев Д.Е. – **Ир, Төрки**
Ернштедт П.В. – **Кәйтән**
Ершов Н.И. – **Путмар**
Жамбагалдаев Н. – **Миң**
Жахонгиров Г. – **Байчәчәк**
Жәләй Л**. – Акын, Бәр-ү, Шай I**
Жубанов Е. – **Тәңре**
Жукова Л. – **Сандал**
Жуковская Н.Л. – **Миң, Үтәгән**
Зайцев А.Н., Кузнецов – **Тибет**
Заусенко А. – **Каралык**
Захарова И.В. – **Мәмәл**
Заходер Б.Н. – **Болгар**
Зәкиев М.З. – **Бәҗәнәк**
Зверева Л.Е. – **Калым, Магаҗи**
Зворич – **Талир**
Зеленин Д.К. – **Оңкыт**
Зуев – **Кыргыз**
Ибатов А. – **Тәңре**
Иванов М. **– Тубал**
Износков И.А. – **Казак**
Инальчик Х. – **Калгай**
Исанбаев Н.И. – **Чәтертән**
Исәнбәт Н. – **Наз, Сәңки**
Ислаев Ф. – **Морза**
Исхак Ә. – **Черчет**
Исхаков А.И. – **Ялпы, Ялт**
Исхаков Д.Г. – **Иштәк, Тархан**
Исхаков Ф.Г. – **Алын, Байгыш, Оҗмах**
Исхакова В.И. – **Татар**
Кара Д. – **Телмәр**
Карагӧзли – **Тугызлык**
Кармышева Б.Г. – **Май II**
Кароматов Ф. – **Канун**
Карпини П. – **Бичермән, Кам**
Каррыев Б.А. – **Юха**
Каганов Н.Ф. – **Какул**
Качалкин А.Н. – **Маяк, Мәйдан**
Кәримуллин Ә. **– Татар**
Керимов И.К. – **Шәмәхә**

Кириллов И.К. – **Типтәр**
Киселев СВ. – **Ташбака**
Клавихо Р.Г. – **Татар**
Клепикова Г.П. – **Шалаш**
Климов Г.А. – **Албасты**
Кляшторный С.Г. – **Тархан, Татар, Тон, Төрек**
Коблов Я.Д. – **Савым**
Ковалев Г.Ф. – **Типтәр**
Ковтун Л.С. – **Яргы**
Колесников Н.П. – **Карандаш**
Колесникова В.Д. – **Күкрәк**
Коломиец В.Т. – **Кәрәкә**
Кондратьева Т.Н. – **Чур**
Кононов А.Н. – **Йорт, Түгел**
Константинова О.А. – **Аран I, Кул**
Корбангалиев Р. – **Татар**
Корнилов Г.Е. – **Бурсык, Игәр, Куян, Чабак, Чаллы, Эт**
Короглы Ш. – **Коркыт**
Корш Ф. – **Балдак, Беләзек**
Котби (Котып) – **Тарту**
Кочин Г.Е. – **Казак**
Краснов Ю.А. – **Чуваш**
Крылова И.Л. – **Гәзнич, Тупызлык**
Крюакова Т.А. – **Путмар**
Кузеев Р. **– Ара II, Типтәр, Ыру**
Кузнецов И.Д. – **Куштан**
Кузьмина Е.Е. – **Баш-аяк**
Кутина Л.Л. – **Магаҗи**
Куфтин Б.А. – **Мастан**
Куфтин М.С. – **Маяк**
Кучкин В.А. – **Казан**
Кызласов И.Л. – **Балбан, Кыргыз, Өзәңге, Татар**
Лафарг П. – **Намус**
Левитская Л.С. – **Иске, Уж, Шомырт**
Либединский Л.Н. – **Кай**
Лившиц В.В. – **Тархан**
Лигети Л. – **Телмәр**
Лобанова Н.П. – **Андыз**
Лойфман И.Я. – **Җаек**
Лыткин А.Е. – **Туез**
Львова – **Җик**
Магницкий И.К. – **Җар**
Майногашева О.Е. – **Зөһрә, Кай**
Максуди Һ. – **Ләбаса**
Максутова Г. – **Тархан**
Малов С.Е. **– Авыз, Кам, Ялгыз**
Марко Поло – **Идел**
Марлинский А.А. – **Дарай**
Матвеев А.К. – **Бака, Лапас, Урал, Уфа, Юша**
Матвеев СМ. – **Би, Келәп**
Мәҗитов Н. – **Кимәк**
Мельников Г.П. – **Түгел**
Меркулова В.А. – **Быргы, Кузый, Мармыш**
Минорский В.Ф. – **Тапкыр**
Минский Г. – **Токандыр-у**
Михайлов С.М. – **Урда**
Моллова М. **– Толык, Толым**
Мөхәммәди Ә. – **Киңәш**
Мөхәммәтҗанов Р. – **Җар, Самак**
Мукминов Р.Г. – **Эчкен**
Муратов С.Н. – **Төрән**
Мурзаев Э.М. – **Ыек**
Мусина И.Г. – **Казак, Сарафан**
Мухамедова З.Б. – **Бәҗәнәк**
Мухаметшин Ю. – **Керәшен, Куңгыра**
Мырьева А.Н. – **Талта**
Нагаева – **Әйшәлә-ү**
Нагайбаки – **Тәберсен**
Наделяев В.М. – **Ир, Ир-ат**
Наджип Э.Н. – **Зәлә, Уйгур**
Напольских В.В. – **Тиресаяк**
Нарты 1994 – **Җилбегән**
Насилов В.М. **– Мындыр**
Нахмедов А.П. – **Нәүрүз**
Нәваи Г. – **Тупчак**
Немет Т.Ю. – **Карандаш**
Новикова А. – **Куй, Мал**
Новосельцов А.П. – **Акча, Булыш**
Ногманова А. – **Морза**
Нурджанов И. – **Канун**
Нуретдинов Ф. – **Бигер**
Нюргун боотур – **Кол, Үтәгән**
Окладников Е.А. – **Уба**
Окладников О.П. – **Сөлтәр**
Олеарий А. – **Какул**
Оранский И.М. – **Нан, Тат**
Остин Е.С. – **Дий-ү**
Отаров Л.М. – **Кузгалак**
Отаров Т. – **Җаек, Сыяу**
Отин Е.С. – **Харчи, Хәрәҗәт**
Палло М. – **Сазаган**
Пачулиа В.П. – **Байчәчәк, Какул**
Петрухин В.Я. – **Сират**
Плетнева С.А. – **Балбан**
Позднеев А. – **Шыйлык**
Поливанов Е.Д, – **Өй**
Полякова Е.Н. – **Кирәм**
Попов А.И. – **Ант, Бүләк**
Поппе Н. – **Кәлшә, Көрчек, Куш**
Порохова А.Г. – **Катаргы**

Потанин Г.Н. – **Гурк, Сәрдә**
Потапов Л.П. – **Йола, Комага, Онык, Умай**
Прицак О. – **Мишәр, Савыт, Ювари**
Прокопьев И.А. – **Уртак**
Прыжов И.Т. – **Кабак**
Рамазанова Д.Б. – **Башкорт, Бабүл, Мишәр, Типтәр, Уя**
Рамузио – **Идел**
Рапопорт Ю.А. – **Комай, Сәмрәү**
Рассадин Б.И. – **Абага**
Рәхим Г. – **Самак, Шәүлегән**
Рәхимова Р. – **Савыр-у**
Рәшидетдин – **Какул, Карачы, Күрән**
Редеи К. – **Кушамат**
Решетов А.М. – **Типтәр**
Ригведа I – **Айзар-Байзар**
Розова Л:И. – **Калым**
Романов Н.Р. **– Бурлак, Кырлач**
Романова Г.Я. – **Сажин**
Ромбандеева Е.И. – **Урал, Урман**
Рона-Таш А. – **Бөлдеркә, Кушман, Чавыш, Чаңгарак**
Рубрук В. – **Кам**
Руденко С.К. – **Сакал, Чәрмә, Ыслак**
Рыбаков С.М. – **Типтәр**
Сат Л.Ш. – **Кемәй, Күшә**
Сатлаев Ф.А. – **Кучкар**
Саттаров Г.Ф. – **Казан, Чаллы**
Сафаргалиев М.Г. – **Бүләк II, Татар**
Сафина Ф. – **Чыгыр**
Сафьянов А.В. – **Толым**
Сбоев В. – **Кырлач**
Сергеев И.Т. – **Пажма, Ярымбиш**
Сергеев Л.П. – **Бәрәңге, Камыт**
Сердобоев Н.И. – **Татар**
Серебренников Б.А. – **Казан**
Сетаров Д.С. – **Тарбаган**
Симашко М. – **Бага**
Симонов И. – **Шәүлегән**
Скворцов М.И. – **Куштан, Тархан**
Смирнов В.Д. – **Чәләби**
Смирнов И.Н. – **Чарача**
Соболева О.А. – **Гәзнич, Тупызлык**
Соколов С.В. – **Бурсык, Сыерчык**
Соколова В.С. – **Шешә**
Софийский И.М. – **Кирәмәт**
Спасский Н.А. – **Чабаксар**
Субракова О.А. – **Саравыч, Яргак**
Султанов Т.И. – **Татар**
Сухарева О.А. – **Байчәчәк**
Сыздыкова Г.А. – **Алама**
Талипов Т.Г. – **Ылак**
Тевкелев А.И. – **Типтәр**
Тенишев А.Р. – **Кула**
Тепляшина Т.Н. – **Кугыл**
Тихонов Д.М. – **Инче**
Токарев С.А. – **Чичән**
Толстова Л.С. – **Мөлтәл**
Толымбай А.Т. – **Чыжым**
Томилов Н.А. – **Чиләк**
Торма Й. – **Кучкар, Күчәр, Пайпак**
Трофимов Г.Ф. – **Сак-Сок**
Трубачев О.Н. – **Балык, Онык**
Тумашева Д.Т. – **Туксаба**
Түләк китабы – **Типтәр**
Тыбыкова А.Т. – **Бул-у, Кылык**
Убрятова Е. – **Айгыр, Кәнт**
Уйфальви К. – **Башкорт, Мишәр, Типтәр**
Унгвицкая М.Н. – **Зөһрә, Кай**
Уразманова Р.Х. – **Зана, Сабантуй**
Утыз-Имәни Г. – **Шыйлык**
Фалина А.И. – **Акча**
Фасеев Ф.Ф. – **Киңәш, Отыры**
Фәезхан Х. – **Ювари**
Фәхретдинов Равил – **Илтибәр, Кимәк**
Фәхретдинов Риза – **Бәлтуар**
Фәхретдинов Ф. – **Татар**
Федотов-Давыдов Г.А. – **Инче**
Федотов М.Р. – **Идел, Типтәр**
Филимонов Е.С. – **Типтәр**
Фозилов Э. – **Көрәш**
Фокин П.П. – **Тап**
Фрейман А.А. – **Шәй** II
Хабичев М.А. – **Отыры**
Хайрутдинов Р. – **Морза**
Хайям О. – **Нәүрүз**
Халиков А.Х. – **Татар, Тиен**
Хәлфин С. – **Биркә**
Хиллари Э. – **Шүрәле**
Хоренлы М. – **Барлас, Болгар**
Цельникер С.С. – **Бурсык**
Цинциус В.И. – **Абага, Керә, Үләксә, Яз**
Черкасский М.А. – **Балчык, Былчыра-у**
Чернецов В.Н. – **Тора**
Чернов Б.П. – **Кай**
Четкарев А. – **Чирмеш**
Чичуров И.С. – **Себер**
Шакуров Р.З. – **Нагайбәк**
Шамсутов Р. – **Шамаил**
Шараф Г. – **Чәм**
Шәрифуллина **– Тиркеш**
Шастина Н.П. – **Чәм**

Шафиков Г. – **Тархан**

Шернер Б. – **Рәшә**

Широкова З.А. – **Путал**

Шитова С.Н. – **Чарык**

Щербак А.М. – **Байтал, Бия**

Эдельман Д.И. – **Албасты**

Эрдниев У.Э. – **Чураш**

Юдахин К.К. – **Акын**

Юлдашев А. – **Типтәр**

Юсупов Г.В. – **Миран, Нокыр**

Юсупов Ф.Ю. – **Таразай**

Якупов Р.И. – **Типтәр**

Ялчыгул Т. – **Май II, Һомай**

Яншина Э.М. – **Пампалчын, Тап**

Ястребов Е.В. – **Урал**

Яхонтов С.Е. – **Ләү**

* * *

Abrahamowicz Z. – **Кәшәнә**

Acıkgöz H. – **Келәм, Палас, Тет-ү**

Altheim K. – **Болгар**

Arat R.R. – **Батман**

Balazc J. – **Пангы**

Bang B. – **Бие-ү, Төче**

Bažin L. – **Йомак, Коркыт, Өлкәр**

Berta A. – **Шырт**

Bombaci A. – **Кот**

Bonnerja R. – **Кил-ү**

Caferoglu A. – **Кунка**

Çagatay S. – **Биби, Өйлә, Өчен, Тугай**

Czegledy K. – **Каракош, Үтәгән**

Das Papagaienbuch – **Сак-Сок**

Doerfer G. – **Монгол**

Durduyeva A. – **Нәүрүз**

Eren H. – **Бөтен**

Ediskin H. – **Үрнәк**

Emin S. – **Үрнәк**

Epstein H. – **Тарпан**

Eren H. – **Ашы, Дилбегә, Дөм**

Fischer J. – **Иштәк**

Gabain-fon, A. – **Казак**

Golden P. – **Хазар**

Gyoffry G. – **Боерык**

Ibrahim H. – **Җитәк**

Itkonen E. – **Чүк**

Jarring G. – **Батман**

Joki A. – **Бурсык**

Jyrkankallio – **Талмач**

Kara G. – **Хәтфә**

Kannisto A. – **Иштәк**

Karamanoglu A.F. – **Күлек**

Korkmaz Z. – **Өчен**

Ligeti L. – **Арча, Телмәр**

Lipman **– Шикәр**

Lorincz C. – **Җидегән**

Lovis H. – **Татар**

Mandoky L. – **Чулпан**

Markuart J. – **Кыпчак**

Masing U. – **Максима**

Menges K. – **Арба, Багрый, Плин, Сайдак, Сакма, Тәләкә**

Molnar A. – **Толык**

Munkacsi B. – **Урал**

Nemeth J. – **Мишәр**

Paasonen H. – **Казан, Үз**

Podhorodecki J. – **Татар**

Pokora T. – **Кәгазь**

Poppe N. – **Арчи, Корык, Нуян, Өлтерә-ү**

Poucha K. – **Иҗек, Камис**

Pritsak O. – **Мишәр, Савыт, Тукай**

Rahmati-Arat R. – **Балык, Бараба, Батман**

Ramstedt G.J. – **Батыр, Бат-у, Бау, Бәхши, Күнтәй, Үрдәк**

Röhrborn – **Аяу**

Rona-Tas A. – **Бөлдеркә, Төш, Чаңгырак**

Salonen A. – **Зәнбил, Сөмбәлә**

Scherner B. – **Рәшә**

Shott W. – **Илче**

Shiraiwa K. – **Инче**

Steinitz W. – **Чытырман**

Tezcan S. – **Аргыш**

Tryjarski E. – **Типтәр**

Uray-Koholmi K. – **Сайдак**

Vasäri J. – **Сусын**

Vasilerits W.M. **– Чая**

Wichman Y. – **Боерчы, Чалык**

Zieme P. – **Аргыш, Ташбака**

* * *

Алтай кеп-куучындар 1994 – **Ыек**

Астраханские татары 1992 – **Куна**

Әдәби мирас 4 – **Букча, Типсәү**

Башҡорт халыҡ ижады 1994 – **Мөлтәл**

Бәетләр 1960 – **Буран, Саз**

Български язик (журнал) – **Күмәртә**

Вестник научного общества татароведения 1925 – **Төтен**

Дагестанские народные сказки 1991 – **Нәзнәй**

Диване хикмәт – **Буйсын-у, Каен**

Идегәй – татар халык эпосы (берничә тапкыр нәшер ителгән) – **Ак, Тулыксы-у, Чүң**

Индийский эпос – Ригведа I – **Айзар-Байзар**

История татар – **Урта**
Казахский фольклор 1972 – **Җаек**
Материалы по истории Башкирии I – **Диван, Туснак**
Материалы по диалектологии 1978 – **Печән**
Материалы по истории России – **Типтәр**
Нарты 1994 – **Җилбегәй**
Нюргун Боотур 1975 – **Кол**
Риваятьлә һәм легендалар 1987 **– Әзгәрәй**
Сказки народов Памира 1976 – **Азык**
Тарихи һәм лирик җырлар – **Май**
Традиционное мировеззрение ... 1989 – **Ичәчән**
Труды Вятской ученой архивной комиссии 1905 – **Иштәк**
Улап Халлаписем 1993 – **Бөрҗән**
Уч. зап. Рязанского ГПИ – **Гөлбәч**
Хаятел-Хайван **– Сак-Сок, Шүрәле, Ярымтын**
Язык земли сибирской – **Себер**
Atamalar Syzlege – **Мәкәй, Ябалдаш**
Encyclopaedia of Islam – **Азәрбайҗан, Камис**
Tabiƣət həm biologiə terminnarь 1931 – **Мармыш**
Türk ansiklopedisi, XII – **Чыңгыз**

## ШАРТЛЫ КЫСКАРТМАЛАР

id. – ibidem, ягъни «шул ук мәгънәдә»
op. cit. – opus citatum – (югарыдарак) күрсәтелгән хезмәт
әд. – әдәби тел
бор. – борынгы
г., гг. – гасыр, гасырлар
гом. – гомум, гомуми
дерив. – деривация
диал. – диалекталь
ирон. – ирониялe
иск. – искергән, иске
йөкл. – йөкләтү (юнәлеше)
к. – карагыз
кайт. – кайтым (юнәлеше)
кит. – китаби сүз
көнб. – көнбатыш
көнч. – көнчыгыш
күп. – күплек сан
күч. – күчерелмә мәгънәдә
мәгъ. –мәгънәсендә, мәгънә һ.б.ш.
мәс. – мәсәлән
миф. – мифологиягә караган сүз
неол. – неологизм
сөйл. – сөйләм теле
тар. – тарихи сүз
төш. – төшем (юнәлеше)
тур. – турында
урт. – уртаклык (юнәлеше)
фольк. – фольклор әсәрләрендә кулланыла торган бирәмлек
фонем. – фонематик
хәз. – хәзерге
һ.б.; һ.б.ш. – һәм башка шундый
чаг. – чагыштырыгыз
ш. ук – шулай ук
шигъ. – шигъри сүз
ы. – ымлык
эвф. – эвфемизм
юг. – югары стиль
юн. – юнәлеш
← тамырыннан, тамыр сүздән
> үзгәрү юнәлеше яки телдән телгә күчү-алыну юнәлеше
>> арадаш формалар яисә телләр аша үзгәреп килгән
* реконструкцияләнгән яңгыраш
~ тәңгәл формалар (яңгырашлар) арасында куела
? «шулай микән» мәгънәсендә куела

### Телләр һәм сөйләшләр

абаз. – абазин теле
авар – авар теле
авест. – «Авеста» теле
адыгей – адыгей теле
аз. – азәрбайҗан теле
айну – айну теле
алабугат – татар теленең алабугат сөйләше
алб. – албан теле
алеут – алеут теле
алт. – алтай теле
ассур – ассур теле
әрм. – әрмән теле
әстр. – татар теленең әстерхан сөйләше
әфг. – әфган теле
башк. – башкорт теле
бәҗ. – бәҗәнәк теле
белорус – белорус теле
болг. – Идел буе болгар теле
болг. Д. яки Д. болг. – Дунай буе болгар теле
босн. – босния теле
бөре – татар теленең бөре сөйләше
брб. – татар теленең бараба диалекты
бур. – бурят теле
венг. – венгер (венгр) теле
вьет. – вьетнам теле
гаг. – гагауз теле
гар. – гарәп теле
гәй. – татар теленең гәйнә сөйләше

герм. – герман телләре
голл. – голланд теле
госм. – госманлы теле
груз. – грузин теле
даргин – даргин теле
дат – дат теле
дравид – дравид телләре
дөб. – татар теленең дөбъяз сөйләше
инг. – инглиз теле
ингуш – ингуш теле
индонез. – индонез теле
ир. – иран телләре
исланд – исланд теле
исп. – испан теле
ит. – итальян теле
к.-балк. – карачай-балкар теле
к.-калп. – каракалпак теле
кабарда – кабарда теле
каз. ар. – татар теленең казан арты сөйләшләре
каз. – казак теле
калм. – калмык теле
камас – камас теле
кар. – караим (карай) теле
карагас – карагас теле
карагаш – татар теленең карагаш сөйләше
карел – карел теле
кас. – татар теленең касыйм сөйләше
кет – кет теле
кмшл. – татар теленең камышлы сөйләше
койбал – койбал теле
ком. – комык теле
коми – коми теле
кор. – корей теле
котт – котт теле
көрд – көрд теле
кргл. – татар теленең каргалы сөйләше
кр.-тат. – кырымтатар теле
крш. – татар теленең керәшен сөйләшләре
кузн. – татар теленең кузнецк сөйләше
куман – куман теле
кумд. – куманды теле
кыпч. – кыпчак теле
кырг. – кыргыз теле
кыт. – кытай теле
лат. – латин теле
латыш – латыш теле
леб. – лебедин теле
лезг. – лезгин теле
лив – лив теле
литв. – литва теле
лобнор – уйгур теленең лобнор диалекты
м.-кар. – модва-каратай теле
макед. – македон теле
манси – манси теле
маньч. – маньчжур теле
мар. – мари теле (мар. Т. – мари теленең тау сөйләшләре, мар. Б. – мари теленең болын сөйләшләре, мар. кч. – мари теленең көнчыгыш сөйләшләре, мар. т.-кб. – мари теленең төньяк-көнбатыш сөйләшләре
минз. – татар теленең минзәлә сөйләше
миш. – татар теленең көнбатыш (мишәр) диалекты
молдав. – молдаван теле
монг. – монгол теле
морд. – мордва теле (морд. М. – мукшы, морд. Э. – эрзя)
нан. – нанай теле
негид. – негидал теле
нен. – ненец теле
нидерланд – нидерланд теле
ним. – нимес теле
нокр. – татар теленең нократ сөйләше
нуг. – нугай теле
орок – орок теле
ороч – ороч теле
осет. – осетин теле
пәһл. – пәһләви теле
перм. – пермь теле
пол. – поляк теле
прм. – татар теленең пермь сөйләше
прус – прус теле
пушт. – пуштун теле
рум. – румын теле
рус – рус теле
саам – саам теле
сагай – хакас теленең сагай диалекты
самод. – самодий телләре
санск. – санскрит
сарт – сарт теле
сары уйг. – сары уйгур теле
себ. тат. яки себ. – татар теленең көнчыгыш (себер) диалекты һәм сөйләшләре
селькуп – селькуп теле
сем. – семит телләре
серб – серб теле
серг. – татар теленең сергач сөйләше
слав. –славян телләре
слов. – словен теле
салар – салар теле
сол. – солон теле
сугд – сугд теле

т. я. – татар теленең тау ягы сөйләшләре
тадҗ. – таҗик теле
талыш – талыш теле
тамил – тамил теле
таранчы – уйгур теленең таранчы диалекты
тат. – татар теле
тел. – телеут теле
телегу – телегу теле
тибет – тибет теле
тоф. – тофалар теле
тохар – тохар теле
төм. – татар теленең түбән сөйләше
төр. – төрек теле
төрки – төрки тел(ләр)
төркм. – төрекмән теле
тпк. – татар теленең тепекәй сөйләше
трбс. – татар теленең турбаслы сөйләше
туб. – татар теленең тубыл сөйләше
туба. – тубалар теле
тув. – тува (тыва) теле
тунг. – тунгус теле
тунг.-маньч. – тунгус-маньчжур телләре
угыз – угыз телләре
уд. – удэй теле
удм. – удмурт теле
уйг. – уйгур теле
укр. – украин теле
ульч – ульч теле
урал – урал телләре
урду – урду теле
урум – урум теле
үзб. – үзбәк теле
фар.– фарсы теле
фин – фин теле
фин-угор. – фин-угор телләре
фр. – француз теле
хак. – хакас теле
халаҗ – халаҗ теле
халха – монгол теленең халха диалекты
хант. – ханты теле
харәзем – Харәзем дәүләте теле
хатт – хатт теле
хетт – хетт теле
хива – Хива ханлыгында кулланылган тел
хорв. – хорват теле
һинд. – һинд теле
һинд-евр. – һинд-европа телләре
һинд-ир. – һинд-иран телләре
чех – чех теле
чеч. – чечен теле
чжуан – чжуан теле
чирк. – чиркәс теле
чув. – чуваш теле
чулым – чулым теле
чыгт. – чыгтай теле
шор – шор теле
шрл. – татар теленең шарлык сөйләше
шумер – шумер теле
эвен – эвен теле
эвенк – эвенк теле
элам – элам теле
эстон – эстон теле
эстр. – татар теленең эстәрлетамак сөйләше
эчк. – татар теленең эчкен сөйләше
ягн. – ягноб теле
яз. монг. – язма монгол теле
як. – якут теле
яп. – япон теле
яушт. – татар теленең яүштә-чат сөйләше
яһ. – яһүд теле

Кайбер телләрнең атамалары текстта кыскартылмыйча язылды (мәс., авар., рус., урду. һ.б.), ләкин тел турында сүз барганлыгын белдерү өчен нокта куелды.

## ТАТАР АЛФАВИТЫ

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **Аа** | **Дд** | **Зз** | **Мм** | **Пп** | **Үү** | **Чч** | **Ьь** |
| **Әә** | **Ее** | **Ии** | **Нн** | **Рр** | **Фф** | **Шш** | **Ээ** |
| **Бб** | **Ёё** | **Йй** | **Ңң** | **Сс** | **Хх** | **Щщ** | **Юю** |
| **Вв** | **Жж** | **Кк** | **Оо** | **Тт** | **Һһ** | **Ъъ** | **Яя** |
| **Гг** | **Җҗ** | **Лл** | **Өө** | **Уу** | **Цц** | **Ыы** | |

# А

**А** авазы төрки-тат. һәм үзләштерелгән сүзләрдә беренче иҗектә иренләштерелгән (а=а°). Бу күренеш гомумтөрки *о*ның тат. телендә югалуы, *у*га күчүе белән баглы. Беренче иҗектә *а* > *о* күчеше үзб., таҗ. телләренә дә хас.

**АБА** (ЗДС: 13–144) «старший брат», (Тумашева 1992: 15) «старшая сестра» ~ *аба* «ана», к.-балк. *аба* «әти, әни» (һәркайсына карата кулланыла), кырг. *аба* «иң өлкән абый» һ.б. төрле төрки телләрдә очрый: алт., хак. *аба, ава* «ата», бор. төрки (ДТС: 1) *aba* «ана» ~ монг., тунг.-маньч. (ЭСТЯ 1: 54–58) *аба, абаға* һ.б. «ата; дәвәти; дәвәни һ.б.ш.» ~ кор. *abağa, abi* «ата, әти». *Аба, абба, абу* (гар. *äбӯ* > тат. *әбү*) «ата» семит телләрендә дә киң таралган, ләкин бу мисаллар ностратик уртаклык тур. сөйләми, чөнки ностратик булмаган индонезия телендә дә *ав, ава, ави* «ата, әти». Гомумән, *аба//апа, ага//ака, ана, ата, баба, гага//кака, мама, нана, тата* дөньядагы барча телләрдә табыла торган һәм «бәбиләр теленнән» килгән тамырлар. Аларның фонетик вә мәгънәви модификацияләре һәм деривацияләре дә күптөрле вә киң булучан. Тат. телендәгеләр тур. к. **Абага, Абый, Апа, Ага, Ана, Ата, Әбә, Баба, Дәдә, Нәнә.**

Төрки *аба* тур. күп язылган: Покровская: 29–32; Räsänen 1969: 1; Мухамедова 1973: 51–52; Рамазанова 1991. Рус. *аба* «апа; ата» (< төрки) тур. Аникин: 71.

**АБАБА(У),** диал. **әбәбәү** «междометие омерзения, содрагания» < *аба-абау* булса кирәк. К. **Абау.**

**АБАГА** «папоротник; орляк; щитовник» > мар. диал., удм. *абага* id., ш. ук. «тубылгы» (Гордеев I: 30), чув. *опаха* > *упаха* id., *упакка кӗҫи* «абага көпшәсе», *упа [уба] лапи* «аю табаны – абага»: *опа* > *упа* «аю». **Абага** сүзен бор. чувашчадан дип уйларга нигез юк, чөнки *аба, абага* «аю» сүзләре тат. телендә дә булган, к. диал. (ТТДС I: 11, 16; ЗДС: 13) **абага** «ялбыр; ябалак (язгы аю кебек)», **абакай** «әрекмән (аю үләне)», **абагай** «кызу канлы (аю кебек?)» һ.б.; үсемлек атамаларында «аю» мәгъ. сүз кулланылу еш очрый, к. тат. (ТТДС I: 28, 588) *айукамыр* «гөлҗимеш», *айу көпшәсе, айу табаны* – төрле үсемлек атамалары, *айу табаны* «абага» һ.б. Удм. *абалгы* «абага» хак. *абалыг* «аюлы; ияле» сүзе белән чагыштырыла ала.

Бор. тат. *аба, абага* < бор. төрки (ДТС: 1) *aba* «аю» сүзе шул ук яңгыраштагы «баба, бабай» мәгъ. сүздән, **аба** (к.) тамырыннан; аюны *җәт* («нәсел башы, борынгы баба») дип атау төрки, монг., тунг.-маньч. телләрендә еш күзәтелә: куман., чыгт., алт., як. *абаға,* чыгт. *äбäгä,* уйг. *обуға* ~ монг., калм. (Номинханов 1958: 46) *абаға, абуға, абга, авга* «әтинең энесе яисә абыйсы» > *авга* «аю», як. *абаға* «ыруда, гаиләдә иң өлкән ирзат; ага», *абаха* «аю агачы – зирек», тув., хак. *аба, абахы* «җәт», «аю», башк. диал. *бабай* «аю». Алт. *аба,* тат. диал. **апшыйак** > рус. диал. *апшак* «бабай > аю» тур. к. Аникин: 71–73. К. ш. ук Рассадин 1973: 122–175; Анисимов 1958: 106–127 (эвен. *амака* «бабай» – «ана аю», *энэкэ* «инәкәй, әби» – «инәк аю» тур.). К. ш. ук Joki 1955: 55–56; МНМ II: 128–130; Федотов II: 281–282 («бабай → аю» мәгъ. күчешенә мисаллар китерелә); Тимергалин: 9.

Дерив.: **абагалы, абагалык; абага чәчәге** (аның тылсымлы хасиятләре тур. әкияти мотив күп күрше халыкларда очрый). Ахметьянов 1981: 11.

**АБАЙ** «внимание; внимательность, предостережение» – гом. кыпч., үзб., уйг., төркм. *абай* id.; бу сүзнең үзеннән бигрәк дериваты – гом. кыпч. *абайла-у* «сизү» сүзе ешрак очрый; гомумән, бу сүз фраземалар составында килүчән: тат. **абай бул-у,** кырг. *абай кыл-* «игътибар кылу (итү)»; үзб. (ЎХШЛ: 12) *абай эт!, абай булл!* – кычкырып янау, җикерү сүзе; кар. *абайлы* «кадерле, хөрмәтле», *абайла* «хөрмәтләү» ← бор. төрки, бор. монг. *abaj, abaγaj* «асылзат, түрә һ.б.ш.». Шулай итеп, *абайла-у* «олы кеше алдында әдәп саклау» дигәннән дә була ала. Чаг. ш. ук алт. *аай* «билге; игътибар»; монг. *убайлах* «абайлау», *авайлах* «кызгану, җәлләү; ярату». Будагов I: 3; Dobr. I: 4–5 (киң деривация).

**АБАЛА-У** «набрасываться с лаем» ~ каз., кырг., монг., маньч. *абала-*, алт., хак. *абла-* id., бор.

төрки *аба* «барча ирзат бергәлектә ауга чыгу (рус.: облавная охота)», *абала-* «шундый ауга катнашу» сүзеннән (к. Хара-Даван 1996: 157–158). Каз. (ҚТАС: 15) *абылау* «камалау». К. **Абалан-у.**

**АБАЛАН-У** (Остроумов 1872: 45) «торопливо возиться» ~ чув. *апалан-, аппалан-* id., як. *абалан-* «ачуланып борчылу»; к. ш. ук. башк. *абалан-, әбәлән-* «чәбәләнү». *Абала-у* фигыле нигезендә барлыкка килгән.

**АБАУ [а°баw], аба,** ш. ук. тат.-башк. **әбәү** «ой-ой-ой» – гом. төрки сүз, ләкин сүзлекләргә кертелмәскә дә мөмкин. Кемнең дә булса кылынышына, сүзенә гаҗәпләнеп үпкәләүне, шелтәләүне, мыскыллауны һ.б. (к. ДТС: 1) яисә куркынуны белдерә. К. чув. *апав, апап,* үзб. *абба, оббо, оббо-эй,* уйг. *аба* (к. Радлов I: 620), бур. *апаа* id. Мар. *äбäу, абау* < тат. (к. Гордеев 1: 31). К. **Абабау.**

**АБЕЛХӘЯТ [а°бĕлхәйат]** к. **Әбелхәят.**

**АБЗА,** диал. (Рамазанова 1992: 57–58) **әбзә** «старший родственник (говорящего)» – тат. телендә кабаттаркалыш юлы белән килеп чыккан сүз: *абзый* < *абзай* (< *абыз агай*) сүзе гүяки *абза* нигезеннән дип аңлашылган. К. **Абзый.**

**АБЗАР,** диал. (ЗДС: 14, 22) **азбар** «хлев, скотный двор; двор вообще» > мар. *абзар, азбар,* удм. *абзар* id., рус диал. *асбаръ* (Даль) «чирмеш авылы», тат. диал. (БТДҺ: 11, минз.) *азбар* «авыл тирәли киртә» ~ нуг., кр.-тат., кар., каз. *азбар*, к.-балк., башк. диал. *арбаз* «йорт, абзар», ком. *азбар, абзар* «йорт», «биләмә», «ачык урын».

Бу тарихыбыз өчен әһәмиятле сүзнең этимологиясе тур. күп фикерләр әйтелгән. К. Насыйри (ЛТ I: 5) буенча, *абзар* < фар. *x̱ʷābzār* «төнләү, йокы урыны». Ләкин бу фараз дәлилләргә мохтаҗ (югыйсә терлекләр гомумән аз йоклыйлар). Ф.А. Гордеев (I: 34) буенча, **абзар** < рус. *овчарня.* Бу фараз да фонетик һәм тарихи нигезләмәләр сорый. Аннары, *азбар* кыпч. телләрендә XIII г. бирле билгеле (Курышжанов 1970: 78) – ул вакытларда рус телендә *овчарня* сүзе үзе булды микән?

Сүзнең мәгънә эчтәлеге (һәм яңгырашы да) борынгы фар. телендәге (атаклы Бисутун кыясы язмаларында) *абичариш* «алпавыт утары; мал ашату урыны» сүзенә бик тә бап килә. Ләкин гаять зур вакыт һәм җирлек аралыгы монда катгый раслауларга мөмкинлек бирми.

Безнеңчә, сүзнең тарихи нигезе кырг., төркм., үзб. диал. (ЎХШЛ: 12) *абзал, аабзел* < фар. *äбзар, äфзар* «инструмент; сабан-сука һ.б. һәм шуларны саклый торган урын» белән дә бәйле булырга мөмкин.

Тагын бер фараз – төп вариант башк. (БТДҺ: 24) *арбаз,* к.-балк. *арбаз* булса, ул гар. *арбаз* «каралты, утар» (← *рбз* «саклап яту») сүзеннән.

Кыскасы – төрле фаразлар күп кенә булса да, *абзар ~ азбар* сүзенең чыгышы-тарихы бераз томанлы хәлдә кала. Аваз тезмәләре (*-зб-* яисә *-бз-*) буенча хөкем йөрткәндә, бу сүз төрки түгел, алынма нигездән. Мәгънәсенә күрә ул утрак халыкка хас сүз.

**Азбар ~ абзар** продуктив нигез түгел (бу хәл дә аның алынма булуын дәлилли): **азбарлы, азбарлык** кебек регуляр ясалмалардан тыш, бернинди дә тотрыклы дериваты юк. **Азбар иясе** (мифик зат) тәгъбире *өй иясе* кебек тәгъбирләргә аналогик рәвештә бик җиңел тәшкилләнә алган. Räsänen 1969: 33; Ахметьянов 1989: 127–128; Тимергалин: 10; Садыкова 2003: 91 (сәер **ызбар** вариантын китерә, тик ул *ызба* тәэсирендә ясалган).

**АБЗЫЙ** «слово уважительного называния старшего мужчины и обращения к нему: мистер, пан, герр (но не господин или сударь – стилистически не то)» – *абызый* яисә *абызагай* формаларыннан. Тамыры абыз (к. **Абыз**). Шулай итеп, тышкы охшашлыкка карамастан, **абзый** сүзенең **абый** сүзе белән бәйләнешы юк. **Абзый**ның «иң олы абый» мәгънәсе шуның белән аңлатыла: күп ир балалы гаиләдә гадәттә иң өлкән угыл мәдрәсәгә җибәрелгән. **Абый – аба** белән аналогиягә кертелеп, **абзый** сүзе нигезендә **абза** сүзе килеп чыккан (к. Тукайда: *Бу егет абзаң булыр бу, бик белеп тор син, энем*). **Абзый** сүзенең фонетик һәм морфологик вариантлары күп һәм алар барысы да тат. теленең үзендә ясалганнар. К. Рамазанова I: 57–58.

**Абзый** сүзеннән **абзыкай < абзыйкай** сүзе пәйда булган. Диал. сөйләмдә **абдый, әбзи, әбзекәй** кебек вариантлар да очрый. Чаг. ш. ук мар. (Исанбаев 1978: 9) *авызый, азий, äзий* «абый».

**АБРАУ [а°браw]** «бережёный, благовоспитанный» (*абрау кыз* «кызлыклы кыз») – **абра-у** фигыленең исем формасыннан. Бор. заманнарда *абрау җир* вакытлы тыюлык (ау ауланмый торган җир) булган.

**АБРА-У** (ДС II: 24; ДС III: 60; ТТДС I: 17) «беречь; регулировать потребление и употребление»

~ чув. *опра-* > *упра-* < гом. кыпч. *абра*, куман., як. *абыра-* «саклау, химая итү; коткару», кр.-тат. (Dobr. I: 9) *abra-* «җир сөрү (?)», төр. *abra-* «идарә итү; юнәтү, рәтләү», алт. *амыра-*, тув. *авура-, авыра-* «коткару; амнистияләү» < бор. монг. *abura-* «яклау» бор. төрки, бор. монг. *abu, ab* «изге дога; сихер кайтару» сүзеннән булса кирәк, к. төр. диал. *абырла-* «абрау», як. *абыла-* «сихерләү», *абы* «сихер». К. **Арба-у.**

**Абра-у** фигыленең кызыклы дериватлары – чув. *упраҫӑ* < *опраҫӑ* ~ як. *абраачы, абыраачы* «коткаручы, химаяче, яклаучы фәрештә». ЭСТЯ I: 59–60; Федотов II: 282–283.

**АБРУЙ** «авторитет; честное имя» < фар. *ābи рӯй* «йөз суы» сүзеннән (тат. *йөз суы* тәгъбире «абруй» мәгъ. кулланыла). Будагов I: 2.

Дерив.: **абруйлы, абруйсыз.**

**АБСӘ** себ. (Будагов I: 5; Тумашева 1991: 25) «обжора», **апса, апсы** «жадный, прожорливый, в еде неумеренный» (шуннан *апсай-у, апсалан-у*). Чаг. як. *абаасы, абааһы* «явыз рух; убыр» << яз. монг. *abuγči* «җан алгыч», бор. төрки *abačı* «өрәк» >> рус. *абас* «җен, шайтан» (к. Аникин: 72).

**АБСЫН, апсын, абысын, абызын** (Тумашева 1992: 15; Рамазанова 1991: 166) «сношенница, слово обращения жён братьев друг к другу»< гом. кыпч., уйг., үзб. (ЎХШЛ: 323) *абысын, авсын, абсын, авсун, овсын,* хак. *абызын,* башк. (БТДҺ: 11) *апсын, апһын* һ.б. < монг. *абусун* (*-сун* җыйма күп. кушымчасы) id. ← *аба, ава* «апа, җиңгә, килен».

**Абсын** сүзен **абыз** сүзеннән чыгару дөрес түгел.

**АБУЗИН** иск. (Б. Вәисев шигырьләрендә очрый) «чудовище; обезьяна» < фар. *абузинә* «маймыл». Рус. *обезьяна* сүзенең каян килеп керүе ачык түгел – төр. яисә фар. теленнән дип исәпләнә (Фасмер I: 98). Тат. < фар. (һәрхәлдә русчадан түгел).

Фар. *абузинә* (бу сүз хәзерге сүзлекләрдә очрамый) сүзенең чыгышы безгә намәгълүм. Ахметьянов 1981: 12.

**АБЫЗ** диал., тар. (Будагов I: 4; ТТДС: 18) «грамотей; учитель; мулла», «старший родственник» > чув. *апӑс* «белемче (карт, карчык)» ~ нуг., каз. *абыз* «мулла» тат.-нуг. даирәсендәге тарихи ядкәрләрдә бик еш очрый һәм бор. кыпч. сөйләшләрендә фонетик үзгәреш кичергән гар. *хāфиẓ* «укымышлы; яттан сөйләүче» (к. **Хафиз**) сүзеннән килә. Бүтән аңлатмалар (алар тур. Рамазанова 1991: 50–51) ышындырырлык түгелләр.

Элекке чорларда (Казан ханлыгы, Русия империясе) *абыз* – административ термин («писер, чиновник») булган. Себер төркиләрендә *абыз, апыс* дип рус руханиларын да атаганнар. Федотов I: 52–53; Аникин: 73.

**Абыз** продуктив тамыръясагыч нигез: к. **Абза, Абзый, Абыстай, Әбез.** *Абыз* сүзе кушма *абызәби* > *абзәби, абызәни* > *абзәни, абызбабай* һ.б.ш. сүзләр ясалуда киң кулланыла (бу сүзләрнең фонетик вариантлары, кыскартмалары да күп), к. ТТДС I: 18–19, 539; БТДҺ: 11, 423; Тимергалин: 10–12 (бик тәфсилле). Рус диал. *абыз* тур. Аникин: 73.

**АБЫЙ** «старший брат; братан» < (диал., к. ТТДС I: 16) *абай* id. ← *аба* «өлкән иртуган» ~ алт., хак., кырг. һәм гом. монг., тунг.-маньч. (ССТМЯ I: 8; ЭСТЯ I: 54–58) *аба* «өлкән туган» (ш. ук кайбер очракларда «ата, ана») сүзеннән. Нәкъ *абый* яңгырашында бу сүз тагы хак. телендә генә очрый (һәм бу хәл очраклы түгелдер). Нуг., ком., төр., кр.-тат. *абий* «абый; әти» < *аға бий* (һәм *абый* белән бердәй түгел).

Татарларда традиция буенча укытучыга, мөдәрриskә *абый* дип эндәшү һәм атау бар (чаг. ш. ук *апа* – укытучыга эндәшү сүзе). Рамазанова 1991: 57.

**АБЫН-У** «споткнуться» ~ нуг., к.-балк. *абын-*, кар. *абун-* id., төр. *aban-*, төркм. *аабан-* «авышу; тезләнү» сүзе белән бердәй булса кирәк. Чув. (Сергеев 1971: 132) *упӗн-* «абыну», *упален-, уппелен-, опальан-* «мүкәйләү» сүзләре белән *абун-у* арасындагы мөнәсәбәтләр ачык түгел. Гомумән, *абынниндидер* **аб-у* яисә **абы-, *аба-* фигыленең кайт. юн. булырга тиеш. Чаг. ш. ук диал. *абалан-кабалан* «бик ашыгып, егыла-түнә».

**Абын-у** тат. телендә генә булса, **авын-у**дан килеп чыга алыр иде кебек, ләкин угыз телләре материалы бу фаразга юл куймый.

**АБЫСТАЙ** «жена муллы; учёная женщина», диал. (Рамазанова 1991: 42–51; ТТДС I: 18–19 һ.б.) «старшая сестра» < *абыз тутай* id.; диалектологлар күрсәткәнчә, кайбер төбәкләрдә *абыз* сүзе үзе генә дә «апа» мәгъ. килә һәм шул нигездә *абыз апа, абыз бикә, абыстути* һ.б.ш. кебек шул ук «апа» мәгъ. сүзләр, сүзтезмәләр ясала.

**АБЫШКА,** диал. **абычка, амыцка, амышка** (ТТДС I: 19; Тумашева 1992: 24; Рамазанова 1991:

100) «муж; второй муж; вдовец» > чув. *авăшка, опăшка > упăшка,* мар. *овышка, овашка* id., гом. көнб. төрки *абышка,* уйг. *абушка* һ.б. (к. ЭСТЯ I: 60–61, тат. мисаллары китерелми) < бор. төрки (ДТС: 2–3, 70) *abučqa, avïnčγa* «карт ир; карт» – бик хикмәтле сүз. Бу сүзгә алт., хак. *апшыйак, апшыйах* «карый; карт» тоташа бугай (*-ак, -йак* – иркәләү кушымчасы), ул чагында себ. **абыш** «агай» һәм урта диал. **апыч** «абый» сүзләре дә *абышка* сүзе белән бәйле түгелме дигән фикер туа (чөнки *апыч* сүзен **абый** сүзеннән дию фонетик кыенлыкларга дучар). Э.В. Севортян (ЭСТЯ) *абышка* сүзенең *аба* «өлкән туган; ата-ана» тамыры белән баглы булуына шикләнми, ләкин ул бор. *avınčγa* (ш. ук *авунча,* Боровков 1963: 36) сүзләрен игътибарга алмый. Хәлбуки бор. *avınča < abınčqa* «абышка» бор. төрки *avınč, abınč* «җенси рәхәтлек, күңел ачу» ← *avın-, abın-* «(җенси) рәхәтлеккә бирелү» сүзеннән дә килеп чыга ала ич! Чаг. төр. *avınč* «юаныч», *avın-* «юану», *avıt-* «юату, әветү».

Башк. сөйләшләрендә *абышҡа* сүзе «икенче ир; карт ир» мәгъ. очрый. Ягъни башкортлардагы левират йоласы буенча, хатын кешенең ире үлгәч, аны үлгән иренең кардәше (агасы яки энесе) алган. Бу йолага баглы кызыклы җырлар да бар:

*Без бәләкәй чакларда*
*Сикреп мендек атларга;*
*Агай үлеп, җиңгәй калса*
*Җибәрмәдек ятларга;*
*Акылың булса, карт җиңгәңне*
*Ала күрмә, уңмаган* һ.б.

**Абышка** сүзе, ихтимал, шундый левират йоласы буенча агасының хатынын алган энесен белдергәндер (башкортларда *абышҡа* сүзе кыз ала алмаган иргә карата мыскыллап та әйтелгән). Чаг. ш. ук эвенк., эвен. (ССТМЯ I: 11) *авус, абусни* һ.б. «кияү; җизни; ыруыбыздан хатын алган һәр ир кеше». Рус. *апшах* < себ. төрки **абшыйах** тур. к. Аникин: 73.

**АВАЗ [a$^{o}$waз]** «звук; возглас» – башлыча китап телендә күп телләргә таралган сүз; фар. *āwāz* < бор. фар. *avač* id. һинд-евр. **vak* тамырыннан (шуннан ук *вокаль, вокатив*). К. ш. ук төр. *avaze* «көй авазы».

**АВАН [a$^{o}$waн]** (ДС III: 14; ТТДС 1969: 19) «хороший; открытый, простодушный», «невежественный, нецивилизованный» ~ нуг., чув. *аван* «игелекле, эчкерсез», төркм. диал. (ТДГДС: 11) *аван* «саран», гаг. *аван* «тупас, явыз», кар. *аван* «гөнаһлы» < яһ. *ғawan* «гөнаһ» (гөнаһлы кеше > гади кеше). Бу сүз Хәзәр ханлыгы заманнарыннан калган булса кирәк.

М.Р. Федотовның (I: 25) чув. *аван* сүзен *аман* сүзеннән дип раславы дөрес түгел. Тимергалин: 12 (бор. *аван кул* тәгъбирен «сугыш эшенә өйрәтелгән кул (гаскәри бүлек)» дип аңлата. Безнеңчә, киресенчә – өйрәтелмәгән кул).

**А́ВГУСТ [август], агуст, аугыс** «август» < рус. < лат.

**АВЫЗ [a$^{o}$wы̆з],** диал. (Тумашева 1992: 16) **ағыс, әwүс** «рот» < гом. кыпч. *awыз, awуз* < гом. төрки, бор. төрки *ағыз//aγız* ~ чув. *çăвар* < ***җаwар** < *җағар//җағыр* «авыз», «чәйнәгеч» (хатыннар теленнән!), бор. төрки *jaγ, ǯaγ* «яңак сөяге» сүзенең күп. (яисә икелек) формасыннан (С.Е. Малов этимологиясе). Бүтән этимологияләр: 1) бор. монг., бор. төрки *аң* «ярык, тишек, авыз» сүзеннән, имеш (ЭСТЯ I:81–82); 2) кор. *aguri* «авыз» белән тамырдаш (?) (Рамстедт). Хак., шор. *аас*, алт. *уус* кебек вариантлар кыпч. телләреннән, икенчел. Räsänen 1969: 8; Федотов II: 90.

**Авыз** күпмәгънәле продуктив нигез: **авызлан-у, авызлык** һ.б.

**АВЫК I [a$^{o}$wы̆к]** «промежуток, интервал времени» < гар. *äwķ* «вакыт» (шуннан ук **вакыт**) > мар. *аук* id., чув. *авăк* «авык» ш. ук «кабынучан, ярсып китүчән; мавыгучан». К. ш. ук каз. *ауық,* к.-балк. *аўукъ* «вакыт, чак». К. **Әүкать.** Ахметьянов 1989: 14–15.

М.Р. Федотовның (I: 25) бу сүзне бор. төрки *evik* «ашыгучан» сүзе белән бәйләве нигезсез.

**АВЫК II [a$^{o}$wы̆к]** «укромное место; место на отшибе» (шуннан **ауҡан, ауҡын** «аулак җирдә», к. ТТДС I: 35; БТДҺ: 30) – **ау** сүзе белән баглы булса кирәк. Чаг. ш. ук себ. (Тумашева 1991: 32) *ауҡ* «куян».

**Аwыҡ** ← *ау* [*aw*] булса, бу сүз бор. төрки (?), эвенк. (ССТМЯ I: 13) *аук, ауык* «тайга; аулак дала; ау, киек һ.б.ш.» белән тамырдаш.

**АВЫЛ [a$^{o}$wы̆л],** себ. тат. **әул, әwел** (к. Тумашева 1991: 39) «деревня» ~ гом. кыпч. *awıl, awul* «авыл» < төр., төркм. *ағыл* «кәртә-кура; абзар; утар» (> фар., таҗ. *ағил, оғил* id.), төр. диал. *ағ, ағы* «абзар, кәртә, кәртә-кура; тур (җәнлек, кош-корт аулау өчен челтәр), ау» сүзеннән ясалган, ягъни *ау* сүзе белән тамырдаш булып чыга. Асылда *ауыл* <

*агыл* киекләрне куып кертү өчен корылма булган, к. каз. (ҚТДС: 13) *агыл* < бор. төрки (МК) *aγıl* «куй курасы», төркм. (Мухамедова 1973: 55) *аагыл* «кура; түгәрәк». Себ. тат. **айыл, әйел** «авыл» һәм **әүле** «йорт, кәртә» сүзләре төптә **авыл** белән тамырдаш түгел. К. **Аел II, Әүле.** Радлов I: 163, 171, 198, 639; ЭСТЯ I (Севортян): 65–66; Федотов II: 497–498 (*авыл* һәм *ял* бердәй дип карый, ләкин *ял* «җәмәгать, авыл халкы» сүзен аерым карый). Рус. *аил* һәм *аул* тур. Аникин: 77 (ш. ук бу сүзләрне бердәй дип, ләкин *аил* монголчадан, *аул* төрки телләрдән дип карый).

*Агыл, аул* сүзе төрки телләрдән барча күрше телләргә кергән. Тат. телендә ул шактый продуктив нигез: **авылдаш, авыллы,** себ. **авылла-у, авыллаш-у** (авылдан авылга кунакка йөрү, йөрешү), **авылцы** (кунакка йөрергә яратучы) һ.б. Ахметьянов 1989: 127; Тимергалин: 12–19.

**АВЫР [a$^{o}$wы̆р]** «тяжёлый; тяжело», «беременность» < гом. кыпч. *аwыр* (кырг. *оор,* алт. *уур, аар,* хак., тув. *аар*), як. *ыар* < бор. төрки (ДТС: 18–19) *aγïr* < чыгт., угыз. һ.б. *аагыр* > *агыр* id. Иске тат. әд. телендә дә һәрдаим *агыр* дип языла. Э.В. Севортян бу сүзне *ааг-, ааң-* «бер якка явып төшү (йөк тур.)» тамырына нисбәт итә (ЭСТЯ I: 85–86) һәм *авыр-у* сүзеннән бөтенләй аера. Шул ук вакытта ул угыз (аз., төр., тув., як.) телләрендәге *агыр ~ аар ~ ыар* «кыйммәтле, кыйбатлы» сүзен *агыр* мәкаләсендә бергә карый (хәер, ул телләрнең сүзлекләрендә дә шулай). Х. Әрән (Eren 1999: 4) сүзнең тамыры *аг-* «авыр килү» дип кенә чикләнә.

Бу очракларда этимологик төгәллекне бор. төрки телләрдә *аг (ааг), аң (ааң)* диелгән омоним тамырлар күплеге кыенлаштыра. Бәлки монда өч аерым тамыр булгандыр. Ләкин ул тамырларның дериватлары күптән бер-берсе белән контаминацияләнгән һәм уртак формага китерелгән.

Безнеңчә, *авыр* һәм *авыр-ы-у* сүзләрен аерырга ярамас, ә *агыр* «кыйммәтле» бор. төрки (ДТС: 17) *aγï* «кыйммәтле тавар, ефәк; кыйммәт» сүзе белән баглы. ДТСта *aγïr I* «авыр», *aγïr II* «кыйммәтле» аерым бирелүе бик дөрес. Бор. төрки *aγrï* > куман., төр. *avrı* «акча» мисалы да (Мухамедова 1973: 53) моны раслый.

*Авыр < агыр* сүзенең ясалышы да Э.В. Севортянча (*аг-ыр*: *-р* фигыльдән исемьясагыч) булмаска мөмкин. Үзб. сөйләшләрендә *аггыр, оггир* «авыр», димәк сүз *аг-гыр* «авучан; аугыр; ава торган» формасыннан килә. *Агыр* «кыйммәтле» сүзе исә, мәс., *агы эрир* тәгъбиреннән ясала ала, к. ш. ук Räsänen 1969: 8; Федотов I: 178–179 (чув. *йăвăр, йывăр* «авыр» сүзенә параллельләр генә китерелә, фонетик һәм морфологик аңлатмалар бирелми).

**Авыр** продуктив нигез: **авырлы** («йөкле, көмәнле» мәгъ.), **авырлык; авырай-у (авырлат-у, авырлаш-у), авырсы-у, авырсын-у,** диал. (Тумашева 1992: 32) **аурыкай** «чирләшкә, авыручан» һ.б. К. **Авыр-у, Авырыксын-у.**

**АВЫРТ-У [a$^{o}$wы̆рт-]** «болеть (о частях тела), чувствоваться – о боли» (**авырту** «боль») – **авыр-у** сүзенең йөкл. юнәлешеннән (*авыр-ыт-* формасы да бар), чаг. чув. *ырат-,* як. *ыарыт-* «авыру». Федотов II: 474 (аңлатма бирми).

**АВЫР-У [a$^{o}$wы̆р-]** «болеть (болезнью)» – гом. кыпч. *аwыр-* < чыгт., төркм. һ.б. *агыр-,* бор. төрки (ДТС: 19–22) *aγïrï-, aγrï-, aγru-* «авыр булып китү»; тат. диал. (БТДҺ: 30, гәй.) **аура-** формасы да бар, уйг. диал. (ЭСТЯ I: 86–87) *aγra-* id. һ.б. Э.В. Севортян бу сүзне *авыр < агыр* сүзеннән аерып, бор. **аγ-, aγï-* (төр. *ağ,* үзб. диал. *ыг* һ.б.) «авыру, чир» исем фигыль тамырыннан димәкче. Безнеңчә, бу фараз өстәмә дәлилләүгә мохтаҗ.

**АВЫРЫКСЫН-У [a$^{o}$wы̆ры̆қсы̆н-]** «счесть себя приболевшим, счесть для себя непосильным» ~ к.-балк. *авруқсун-,* кырг. *ооруқсун-* id. < бор. кыпч. **аwырық < аwыр-ық* «авырган» сүзеннән.

**АВЫСКАЛ [a$^{o}$wы̆сқал]** (ЗДС: 18; БТДҺ: 31) «тупица; забывчивый» < гом. кыпч., к. нуг., каз., к.-калп. *ауысқыл,* кырг. *оошқал* «авышучан», башк. *ауысқал* «миңгерәү; такылдык; аумакай».

**АВЫШ [a$^{o}$wы̆ш]** «наклонный», «склон», диал. «иной, другой» (к. ТТДС: 20) < гом. кыпч. *аwыш* id. ← *аw-* (к. **Ау-у**); тәүдә «аву хәле» мәгъ. булган, ләкин соңрак төрле мәгъ. алган, к. нуг. *авыс* «алмашлык», «һушы китүчән», к.-калп. диал. (ҚТДС: 31) *ауыш* «акылы киткән», *ауыс* «начар», к.-балк. *аўуш* «үткел, таулар арасындагы тар юл». К. **Авыш-у.**

Дерив.: **авышаю** «авыш булу», ш. ук диал. «һушың китү, зиһенең таралу», **авышлы, авышлык.**

**АВЫШ-У [a$^{o}$wы̆ш-]** «наклоняться; перевалить, переходить черту» (к. җырда: *Мәшрикъ тарафыннан чыккан болыт Мәгъриб тарафына авышкай*), диал. (ТТДС: 20) *аwышу* «меняться, изменяться; проходить (о болезни, хвори)» < гом. кыпч. *аwыш-*

(нуг., каз., к.-калп. *ауыс-*, кырг. *оош-*) «авышу; алмашыну; үзгәрү» формасынча *ау-у* фигыленең урт. юн. («берьюлы бергә аву»), ләкин соңрак «ава төшү, авуын дәвам итү» мәгъ. алган. К. **Ау-у.**

**Авыш-** тат. сөйләшләрендә дә күпмәгънәле һәм продуктив нигез: **авышыл-у, авышын-у, авыштыру** «алмашу, алмаштыру» мәгъ., диал. **авышкан** «акылы киткән» һ.б. К. **Авышчан.**

**АВЫШЧАН [aᵒwы̆шчан]** «сговорчивый; не упрямый в своём мнении» – моның ише сүзләрнең **авыш** исем сүзеннәнме, яисә **авыш-** фигыленнәнме ясалганлыгын аныклау кыен.

**АГА** «дядя; старший брат; уважаемый мужчина», вокатив формасында **агай** ш. ук «крестьянин» – гом. төрки, гом. монг. *аға, ағай*, кр.-тат., чыгт., эвенк. һ.б. *ака, akāj* id., бор. төрки *aqı* «батыр; зур», тув. *акы, акый* «агай». Алт. телләрендә иң киң таралган һәм күптармаклы нәсел-нәсәп термины; төрки телләрдән күп күрше телләргә дә үтеп кергән: к. Кавказ телләрендә, көрд., фар., гар. һ.б. *аға* «мистер; өлкән башлык; нәчәлник, полиция офицеры һ.б.» (< башлыча төр.), мар., удм. *агай* «агай» (< тат., к. Гордеев I: 44). Будагов I: 60–61; Зифельд-Симумяги: 125; Номинханов 1958: 43–45; Покровская: 33–36; ССТМЯ I: 24; ЭСТЯ I: 70–71; Тимергалин: 13. Рус. *ага* тур. Аникин: 74.

Тат. бу тамыр сүзнең **ака, акы** вариантлары да бар: диал. (ЗДС; Рамазанова 1991: 36–37, 136–137, 164–166) (миш., эчк., м.-кар. һ.б.) **акый** «олы кеше, абыстай», **аккай** «абый, абыстай» (< *акыкай*), **ака** > мар. *äкä*, *ака*, удм. *ака, акы,* морд. М. *ака, акай* «апа, түти». Күренгәнчә, *-к*лы вариантлар тат. телендә дә хатын-кызны белдерә. К. **Акай, Әкә.**

Характерлы дериват: **агала-у** «хөрмәт итү».

**АГАРТ-У** «белить; просвещать» (*агар-* сүзенең төш. юн.) – соңгы мәгъ. русчадан калька булуы ихтимал (ләкин, к. Тукайда *Укы, балам, мәктәптә – Кара күңлең агарсын!*).

Дерив.: **агартучылык** «мәгърифәтчелек».

**АГАЧ,** диал. **агац,** себ. тат. **йыгаш,** иске әд. **җигач, җыгач** «дерево; древесина; деревянный». Төрки телләрдә бик тә күп вариантта очрый: гом. төрки *ағач,* бор. төрки, уйг. *jïɣač,* үзб. диал. *йағғач,* чув. *йывăç,* башк. *ағас,* алт., тув. диал. (Баскаков 1966) *ағыч, аач, ааш, нааш, найш, ңāш* > як. *мас* «агач, урман» (себ. тат. *ағац* «урман»), тув. *ыяш* «урман». Кайбер төрки телләрдә (кр.-тат., аз.) *ағач* 6–8 километрлык ара. Чув. (Сергеев: 23) *йӳç* «тал төре; болын, сазлык».

Бу сүзне Севортян (ЭСТЯ I: 71–72) бор. *ы, ый* «үсенте, урман, куаклык» сүзеннән, Л.В. Дмитриева **jaɣ* тамырыннан чыгара; һәрхәлдә *-гач* (кечерәйтү) кушымчасы бар дип карала. К. себ. (Гиганов) *аңган* (бәлки хата басылгандыр: *аңгац?*) «зур урман», алт. *аңгац*, *аңаш* «урман; агач», эвенк. *агин, ағый* «тайга, тигезлектәге урман». Будагов I: 61; Федотов I: 179; Ахметьянов 1989: 27–28; Тимергалин: 13.

**Агачире** – янәсе «урман кешеләре» мәгъ. борынгы кабилә исеме – күп кенә чыганакларда *aɣačeri* (хәз. көндә Иранда һәм Төркиядә бер кабилә атамасы) шулай аңлатыла.

**Агач** продуктив нигез: **агачлы; агачлык; агачлан-у** һ.б. Ахметьянов 1989: 27–28.

**АГЛА-У** иск. «плакать» ~ бор. төрки (ДТС: 21) *aɣïla-* id.; *aɣï* – елау тавышы, к. **Ыгы-зыгы.** К. **Ела-у.**

**АГУ [aғы̆w]** «яд» < чыгт., угыз., бор. төрки (ДТС: 24) *aɣu* < **ааг-гу: *ааг//ааң* «ачы, агулы; ачы булу (итү), агулы булу (итү)» синкретик тамырыннан (к. ЭСТЯ I: 67), к. төр. *ağı* «агу», монг. *аг* «агы нәрсә; агу» һ.б. Шулай итеп, тат., башк. *ағу, ағыу* бүтән төрки телләрдән алынма сүз. Төп кыпч. яңгырашы **awғы* булган, шуннан тат., башк. *awы, ыwы* > *ыw* (к. **У, Уа**). К. ш. ук төркм. *ааwы* (ихтимал, бор. кыпч. телләреннәндер), к. Мухамедова 1973: 53.

**Ағу** ~ **ағғы,* ихтимал, бор. төрки (ДТС: 16–17) *aɣ-, aaɣ-* «агарыну, йөз төсе үзгәрү» тамырынандыр: *ағу* < *ағғу.* Бор. төрки *aɣïq-* «агулану» < *aɣ-ïq-* «нык агарыну» (*-ïq-* фигыльләрдә көчәйткеч кушымча, чаг. *аш-* > *ашық-, қыз* > *қызық-, пеш-* > *пешек-* һ.б.ш.).

**Агу** продуктив нигез: **агулы; агула-у, агулан-у** (бу сүзләр күрше фин-угор телләренә дә кергән).

**АГУЫН,** диал. (Тумашева 1992: 15) **агун** «куропатка» ~ монг. *агуна* id. К. тув. *аганак* «ак көртлек». Тат. ау терминнарының кайберләре монг. килә.

**АГЫЕК [aᵒғы̆йы̆қ], ағыйақ** (Тумашева 1992: 15) «недорогое украшение, бусы» < бор. төрки (ДТС: 17; Боровков 1963: 39) *aɣï, aɣu* «кыйммәтле әйбер, кыйммәтле бүләк» сүзенең кечерәйтү формасыннан булса кирәк: *ағычақ* > *ағыжқақ* > *ағыйак* (интервокаль *ч* > *ж* һәм *жç* > *й* себ. төрки теллә-

рендә очрый). Монда ике күчеш бергә килгән (андый очраклар булгалый).

Бор. төрки *ayı* шул ук мәгъ. *ayır* һәм (ДТС: 48, 71) *aqï, axï* «юмарт» сүзләре белән бер тамырдан булса кирәк. Бу сүзләрнең дәвамы да, тамыры да хәз. төрки телләрдә күренми (яисә без танымыйбызмы?).

**АГЫТ-У** диал. (Тумашева 1992: 16) «бросать, выбрасывать; пускать (на ветер), отпускать на волю (скот)» – бу сирәк, әмма этимологик планда әһәмиятле сүз бор. **ағы-* ~ уйг., госм. *ағ-*, *аң-* >> чув. *ох-, ух-* «күтәрелү, үсү; ары китү» фигыленең йөкл. юн., чаг. тат. диал. *аткар-у* «эшләп ташлау, өстеңнән төшерү» < *агыткар-у* (?). К. **Актык, Ат-у.**

**АДАЛАН-У** диал. (Вәлиди I: 49; ЗДС: 20), *адан-у* (ТРС 1931: 4) «увлекаться». Чаг. төр. *adatak* «кыз ярәшү». Чаг. **Әтәлән-ү.**

**АДАНАШ** диал. (Арсланов 1988:70) «родной брат; родные братья» ~ нуг. *аданас, аданаш* «бертуган», к.-калп. *аталас*, башк. *аталаш* «кавемдәш, атадаш» (?). Әрмән исеме *Атанас* бу сүзнең этимологиясе гади генә түгеллегенә дәлил. **Атанаш** сүзе иске тат. фольклорында очрый: *Һәрбер бәлаказадан Йолып алыр атанаш; Атанашың булмаса, Ни эшләрсең – ялгыз баш?*

Диал. (ЗДС: 20) *адамач* id. яңгырашы тат. телендә килеп чыккан.

**АДАРГЫ,** диал. **адырга** – примитивный ткацкий станок, который ставится прямо на пол ~ башк., каз., кырг., үзб. *адарға*, *адарғы*, кырг. *адырғы* «көре ролен үти торган такта» бор. төрки *адыр-* «аеру» сүзеннән булса кирәк (к. Авижанская А.А. һ.б.: 35).

**АДАРЫН-У** «вести себя импульсивно: клясться, давать обеты, умолять, громко роптать и т.п.» ~ себ. (Тумашева 1992: 30) *атарын-* «пыр тузу, тузыну», башк. *аҙарын-* «адарыну», кырг. *адараңда-* «шәрә батырлык күрсәтү», тув. *атыырга-* «мактану; көязләнү». Ихтимал, тат. диал. *адан-у, адалан-у* «мавыгу» белән тамырдаштыр. К. ш. ук төр. *adak* «нәзер, изге максат», *ada-mak* «атау, билгеләү; вәгъдә итү».

**АДАШ** «тёзка» – гом. төрки *адаш* (*атдаш, атташ* «исемдәш») id., ш. ук «дус». Мар., удм., морд. *адаш,* чув. *аташ* (*адаш* дип укыла) < тат. (к. Федотов I: 68). Хак. *адас* «борынгы җәтләр (ата-баба)» мәгънәсе игътибарга лаек (к. Бутанаев 1990: 132). КБдә *адаш* < *атташ* дибрәк тәгърифләнә. Будагов I: 132.

**АДАШ-У** «заблудиться, блуждать» ~ чув. *аташ-*, кр.-тат., куман. *азаш-* вариантлары бу фигыльне гом. төрки *аз-* «юлдан язу, азу»га (к. **Аз-у**) нисбәт итәргә мөмкинлек бирә (к. ЭСТЯ I: 94–95). Ләкин ни өчен *адаш-* варианты килеп чыккан – аңлашылмый. Төр. *adaş-* «вәгъдәләшү, ант итешү» *ad* «исем, ат» сүзеннән булса кирәк. Федотов I: 68.

**АДӘМ** «человек; Адам» тәүдә фар. *адәми зат* «Адәм галәйһиссәлам токымы (заты)» дигән тәгъбирдән кыскарган (бу тәгъбир хәзер дә кулланыла). *Адәм* – иң беренче кеше – исеме һәм образы Библиядә килә һәм бор. яһүди диненнән алынган (яһ. *adamah* «кеше, тиреле зат»).

Тат. сөйләм телендә **адәм, әдәм** «бер кеше; юньле кеше» > чув. *этем*, мар., удм *ăдăм; адəми* формасы да фин-угор телләренә кергән: мар. *айдеме,* удм. *адями, ăзăми,* хант. *ăтăме* «кеше, адәм» һ.б.

Тат. һәм бүтән төрки телләрдә *адәм, әдәм* сүзеннән күп кенә дериватлар һәм фразеологизмнар ясалган: **адәмгәр** «кешелекле», **адәмчелек, адәм хуры** һ.б. К. Федотов II: 482; Тимергалин: 14–15.

**Адәм** сүзенең этимологиясе бик күп сүзлекләрдә бирелә.

**АДЫМ** «шаг» – гом. төрки *адым,* чув. *утă, утăс, утăм* id. Чув. мисаллары һәм гом. төрки *-ым* сүзнең тамыры *ада-* фигыле икәнлеген күрсәтә, һәм чыннан да төр. диал. *admak* «атлау», төркм. *әдим әдә* «атлау, адымлау», *әдим әдип әтләди* «адым атып атлады» кебек фразалар, **адым** сүзе **ат-у** белән гомоген түгелме икән, дигән фикергә китерәләр. ЭСТЯ I: 88–89; Алекперов А.К. Фонетическая система современного азербайджанского языка. Баку, 1971: 60. К. **Атла-у.**

Дерив.: **адымлы, адымсыз; адымлык; адымла-у.**

**АЕК [а°йы̆к]** «трезвый», диал. (Тумашева 1992: 19) «ясный» > мар., удм. *айык* id. < гом. кыпч., чыгт. (Радлов I: 3, 218), угыз. *айыķ* < бор. төрки (ДТС: 14) *адïу* id. ~ чув. *орă > урă* id., бор. гом. төрки *ай- < ад- ~ ai* «ачык, сәламәт булу» тамырыннан (*ай-ык*). К. Räsänen 1969: 5; Федотов II: 285.

Дерив.: **аеклык.** К. түбәндәгене.

**АЕК-У (аекты, аегу)** диал. «трезветь; выздоравливать» < гом. кыпч., угыз. *айық-* id. *ай-* «сау, сәламәт, зиһене ачык булып китү» фигыленең интенсивлык формасы (*ай-ық-*). К. ш. ук **Айны-у.** К. ЭСТЯ I: 113–114.

**АЕЛ I [а$^{o}$йы̆л]** «пряжка; подпруга» > мар. (Саваткова: 7) *айыл*, чув., мар. *ойыл* > *уйыл* id. *ай-* «аеру-җыю» тамырыннан, к. ЭСТЯ I: 114–115; Федотов II: 270.

Бу сүз төрки телләрдән күрше телләргә киң таралган, к. манси. *oil* һ.б. (Räsänen 1969: 11–12).

Дерив.: **аеллы; аелла-у.**

**АЕЛ II [а$^{o}$йы̆л]** диал. (Тумашева 1992: 20) «деревня» ~ кырг., алт. *айыл* «торлак; авыл» < монг. *айил* «торлак, гаилә, группа; авыл» > эвенк. *айил* «күрше; авыл» (к. ССТМЯ I: 21): бор. монг. *ajil, ajal* сүзеннән тув., хак. *аал* һәм чув., мар. *йал* < болг. **йаал* «авыл» сүзләре дә килә. Гадәттә бу *айыл ~ йал ~ аал* ны *авыл* сүзе белән бердәй дип карыйлар (к. Федотов II: 479; Аникин: 77, шунда ук шул фикердәге бүтән авторлар да күрсәтелә). Безнеңчә, *айыл* сүзе бор. монг. *ай-* «җыю, җыелу» фигыленнән (к. **Аймак**) һәм аның *авыл* сүзенә катнашы юк.

Шунысы кызык: *айыл* сүзе булган һәр телдә *айылчы* (*айилчи* һ.б.) «биләмче, авылдан авылга йөрүчән» сүзе дә очрый.

**АЕЛ-У [а$^{o}$йы̆л-]** диал. (Тумашева 1992: 20) «выздороветь» < чыгт. (Ясәви) *айыл-* «айну» < бор. төрки (ДТС: 15) *adïl-* ~ чув. *орӑл- ~ урӑл-* id. Бор. *ай-* «зиһен ачык булу» фигыленең төш. юн. К. **Аек.**

**АЕМ [а$^{o}$йы̆м]: аембикә** «благородная женщина, госпожа; титул матери царствующего хана» (к. Будагов I: 208), **аемкыз** «принцесса» ~ нуг. *айым* «хөрмәтле ханым», каз. *айым* «кәләш», уйг., госм. *айим* «хаҗи хатыны, аембикә», *айи* «өлкән хөрмәтле хатын», фар. *айим* «чибәр» < грек. *αγιος* «изге» сүзеннән, бор. Бактрия грек теленнән таралган. К. рус һ.б. *агиография* «изгеләр тур. әдәбият».

Идиома: **айым әби** «аулакта контрольлек итүче әби» (кызбикә дип тә аталган).

**АЕР [а$^{o}$йы̆р]** диал. (ДС I: 10; ТТДС I: 29) «развилина, разветвление», (Тумашева 1992: 20) «речной рукав» ~ каз., к.-калп., алт. *айыр* id. < бор. төрки (ДТС: 11–15) *adïr* > тув. *адыр* id. Бор. *ай- ~ ад-* «аерым булу» фигыльленнән мөстәкыйль рәвештә (ягъни **аер-у** фигыленә бинисбәтән) ясалган.

Дерив.: **аерлы; аерча.**

**АЕРТКЫ [а$^{o}$йы̆ртқы̆]** (Дүртөйле, Тәтеш) «обезжиренное молоко; сыворотка» – «(сөт) аерту» фигыленнән, махсус мәгъ. карарлашкан. Чаг. **Әйрәтке.**

**АЕР-У [а$^{o}$йы̆р-]** «разделять, различать; отделять; разнимать» > мар. *айыр-* > *ойыр-*, чув. *ойыр-* > *уйыр-* id. < гом. кыпч., чыгт., гом. угыз. *айыр-,* үзб. *айир-* < бор. төрки (ДТС: 11–15) *adïr-, adïr-* id. К. ш. ук хак. *азыр-*, як. *атыр-* id. Чаг. уйг. *айра-*, үзб., уйг. диал. *аҗира-, аҗра-*, кырг. *аҗыр-*, *аҗира-,* каз. *ажыра-* «аеру» ~ бор. монг. (Поппе 1938: 66) *aǯı-* «аерылу», *aǯıra-* «ычкыну, азат булу». Күпсанлы дериватлары да охшаш булгач, *айыр-* һәм *аҗыра-* сүзләрен тамырдаш дип карарга кирәк, аларның уртак тамыры *ай ~ *ад ~*ар* булып күзаллана. Шунлыктан *айыр-* фигылен бор. *аң-//ай-* тамырына нисбәт итү (ЭСТЯ I: 115) ышандырмый. К. ш. ук Федотов II: 270–271.

**Аер-** төрки телләрдә иң продуктив нигезләрнең берсе: **аерыл-у, аерыш-у, аерт-у; аерма, аерым, аеруча** ~ диал. **аерыкча,** диал. **айра, аерата.** К. ш. ук **Айравык, Айры, Әйрән.**

**АЕРЫК I [а$^{o}$йы̆ры̆қ]** диал. к. **Айравык.**

**АЕРЫК II [а$^{o}$йы̆ры̆қ], айырық, айрық** диал. «отделенный, отлучённый; иной» ~ гом. төрки (к. Будагов I: 190) *айрық, айруқ* «нык аерылган» < бор. төрки (ДТС: 5, 30) *adruq, ajruq* «бүтән» ← *adır-, adır-, ajır-* «аеру; читләтү», к. **Аер-у.** Бу **аерык** сүзеннән рус. *ерик* «төп елгадан аерылып киткән тармак» килә бугай. К. түбәндәгене.

**АЕРЫШ [а$^{o}$йы̆ры̆ш]** диал. вообще «отделение от себя», но в частном топонимическом значении «развилка дорог; место развилки; меньшее ответвление дороги» < бор. төрки (ДТС: 5, 30) *adrïš, ajrïš* id.

**АЕРЫШЧЫ [а$^{o}$йы̆ры̆шчы̆], аерчы [а$^{o}$йы̆рчы̆],** к. Будагов II: 236 (**мөслих** сүзенең тәрҗемәсе) «член третейского суда» диелгән. Элекке Казан сөйләшеннән булса кирәк. Гомумән, **аерчы** «килештерүче» булган, аеручы түгел.

**АЕШ I [а$^{o}$йы̆ш]** «суть, признак; понятие». Бор. *ай-* «аеру» тамырыннан булса кирәк, к. тат. диал.

(крш.) **айа** «игътибарлы» (> мар. *айала-* «аеру, аешын белү, аешына төшенү»), алт. *ай* «төшенчә», к. Räsänen 1920: 18. К. ш. ук бор. төрки (ДТС:14) *ād* «яхшы фал, яхшыга юралган билге» һ.б., шуның фигыль коррелянты *аδ-* булырга тиеш.

**Аеш** сүзе әд. телдә сирәк кулланыла, ләкин Агыйдел-Урал регионындагы сөйләшләрдә еш очрый.

Себ. **айыш** «әйтү, әйтеш» ← *ай-* «әйтү», к. **Әйт-ү.**

Дерив.: **аешлы** «аңлаешлы, аңлап була торган», **аешсыз** «аңлашылмый торган».

**АЕШ II [а°йыш]** диал. «рассказ; словесная игра – хитроумные вопросы и ответы». К. **Әет.** Әлбәттә, **ай-у** «әйтү» сүзеннән.

**АЖГЫР-У** «реветь, стремясь вселить ужас» > мар. *ажгыр-,* чув. *ашкăр-* id.; *аж* тәкълиди сүзеннән (*-гыр* кушымчасы тур. к. **Акыр-у**).

**АЖДАҺА,** диал. **әждаһа, әчтәр** (к. Тумашева 1992: 39–40), **аждак, аждагы, аздагы, аздягы, әздяхы** «дракон» > чув. *аçтаха,* мар., удм. (Гордеев I: 53); *äждäгä*, *ажьдага, азьдага, азьтага* < фар. *аждаһа, аждарһа* «аждаһа; койрык байрак; хәрби ат; исемле кылыч» (Будагов I: 38) борынгы ир. (Авеста) телендә *ажидаһак* «чагучы елан»: (*аж, ажи* «елан; ләү», *daһak* «чага, тешли торган»), ш. ук фар. *ajgar* «буар елан». Аждаһа образы Шәрык әдәбиятында Фирдәүсинең атаклы «Шаһнамә» эпосы аша популярлаштырылган: *Зәххак* исемле шайтан патшага ашман (пешекче) булып эшкә кергән һәм патша аның эшеннән бик канәгать калган. Шуннан Зәххак аңардан: «Сиңа нинди бүләк бирим?» – дип сораган. Шайтан: «Теләгем шул – сезнең ике кулбашыгыздан үбим әле», – дигән. Зәххак рөхсәт биргән. Шайтан үпкән төшләрдән ике елан үсеп чыккан һәм алар көн саен бер кеше мие таләп итә башлаганнар. Зәххактан халыкны Кова дигән тимерче коткарган.

Фирдәүсинең Зәххак дигәне – борынгы **даһака** «җимергеч» сүзеннән, әлбәттә.

Фар. теленнән төрки телләргә дә күчкән **аждар, аждарһа, ecdar** һ.б. яңгырашы *аҗгар* һәм *аждаһа* сүзләренең контаминациясеннән гыйбарәт (к. ш. ук «Заятүләк» дастанының М. Гафури версиясендә **Җаждар** «су асты патшасы»).

Тат. сөйләшләрендәге **аждамыр** варианты фар. *әҗдар мар* «аждаһа елан» (*мар* «елан») сүзеннән. Тат. әкиятләрендә дә **аждаһа елан** тәгъбире кулланыла (шуннан удм. *азъдага кый: кый* «елан»). Федотов I: 66; Ахметьянов 1981: 14; МНМ I: 50 (күптөрле вариантлары күрсәтелә); Тимергалин: 15–16.

**АҖАГАН** «сполохи; зарница» – тат. телендә бу сүзнең вариантлары хәтсез: **нажагай, назыгыш, нәҗәгай, нажакай, аждаган, аҗыган, әҗәгән, әжегән, әҗҗаһы, әҗәга, әҗәгы, җайнагай, җайнаган, җалагай, ялагай, ялтагай.** ТТДС 1969: 60, 318–320, 550–551 һ.б.

Бу сүзләр халык аңында бергә охшатылса да, аларда берничә аерым сүз шәйләнә: **нажагай** бор. төрки-монг. (Марко Поло) *надигай* «яшен һәм җир тәңресе» сүзеннән килә; бу сүз, ихтимал, тат. диал. *нәйзә, найза* ~ нуг., каз., к.-калп., кырг., үзб. *найза* «кечкенә сөңге» (к. **Нәйзә**) тәэсирендә дә формалашкандыр.

**Җайнагай** варианты нуг.-каз. даирәсеннән килә: нуг. *яйнаган* «ялтырак, ялтырау», каз., к.-калп., кырг. *җайна-, җайна-* «нурлану, нур чәчү, (нурлар чәчелү)», *җайнаган* «ялтырап торган нәрсә; аҗаган».

**Җайнагай ~ ялагай ← яла-у:** имеш, аҗаган «ялагач» арыш өлгерә (аҗаганнар бигрәк тә июнь-июль айларында күзәтелә). **Аҗаган** үзе **нажагай** һәм **аждаһа** сүзләренең контаминациясеннән гыйбарәт. Чаг. кырг. *аҗаган* «явыз».

Борынгыдан килгән карашлар буенча, аҗаган ул аждаһа, ләү уены: ул, имеш, шулай койрыгын болгый. Ахметьянов 1981: 14–15. Чаг. **Сазаган.**

**АҖАР** «блеск; свежая фактура (кожи у кожевников)» ~ башк., каз., к.-калп. *ажар* «матур төс, сәрен йөз», кырг. *аҗар*, төр. *acar, a'car* «оста, булдыклы; кыю; сәрен» < гар. *ä'җар* id. (Redhouse: 6). Будагов (I: 11) чыганак итеп фар. *аҗар* «сәренлек, тазәлек» сүзен күрсәтә.

**АҖАУ [аҗаw],** диал. **аҗу** «голавль; яз; сом» ~ башк. *ажау*, мар. диал. *азау;* чыгышы билгесез.

**АҖИ КӘРӘМ, Ужи Кәрәм, Ауни Кәрәм, Аслы Кәрәм** (ДС I: 11; ТТДС I: 459) – любовная песня, которая поётся на свадьбе с припевом, названным именем героя огузско-среднеазиатского любовного эпоса – *Кәрәм вә Аслы, Аслы вә Кәрәм* ике гашыйк-мәгъшука турында дастан, атаклы «Күр углы» дастаннар циклының бер өлеше (исемнәр аның төрле вариантларыннан килә: **Азый Кәрәм** дигәндә Азый – гази, дин өчен көрәшүче; **Василкәрәм, Хаҗикәрәм** вариантлары кеше исеме буларак та популяр).

Күрәсең, бу эпос татарлар арасында да таралган булган. Бер Кавказ вариантын М.Ю. Лермонтов *Ашик Керип* дип русча бәян иткән, шуңа охшаш *Кашикарип* – башкорт экияте герое бар, к. Башкорт экиятләре. Уфа, 1996.

**АҖУН, ажун** «мир, свет» – уйг., чыгт. һ.б. әдәби төрки телләрдә еш очрый торган бу сүз (бездә – Утыз-Имәни, Кандалый һ.б. әсәрләрендә) бор. төрки әдәбияттан килә һәм сугд. теленнән (*"žwn* «дөнья, галәм») алынган булган. К. ДТС: 73.

**АЗ I, ас** – название ногайских племён в сочетаниях *дӧрт уллу ас* «ас с четырьмя сыновьями», *ак ас* «белый ас», *кара ас* «чёрный ас», *шӧмүшли ас* «ас с тамгой в виле половника» и т.п. (к. Ногайцы 1988: 12–19) – считается названием одного из булгарских племён ~ бор. төрки (ДТС: 72) *az* «аз халкы», хәз. алт. диал. *аз, ас* – бер ыру атамасы; Ф. Кырзаоглу *аз, ас* компонентын *кенгерес (< кеңгер ас), әнказ (< әник аз)* дигән бор. этнонимнарда таба (Kırzaoglu: 83–92). Хәз. *хакас < хягаз* этнонимында да *аз* компонетын күрергә мөмкин. Кайбер тикшеренүчеләр *аз* халкы кыпчакларның нигезен тәшкил иткән диләр. Һәм хәтта татарларның бор. бабалары *аз* кабиләсеннән булган, марича *суазь* «татар» сүзе ул *су асы* дигән тәгъбирдән килә, дигән фикер дә бар. Ләкин болар барысы да дәлилсез, юраулы.

**АЗ II, әз** «мало, малый» ~ бор. төрки, гом. төрки *аз*, төркм. *ааз,* як. *аччыгай < азчыгай* «азрак» (төрки *azçıgaz* азрак, күп түгел) ~ чув. диал. *ар* > мар. *ор, ар* id. (Räsänen 1969: 32), монг. *арай, аран,* эвенк. *ара, арай* «аз», маньч. *арқан* «көчкә, аз кала» сүзе белән чагыштырыла (ЭСТЯ I: 94).

Аз сүзен фар. *āz* «комсызлык, саранлык» сүзе белән чагыштыралар. Ул чагында *аз* сүзе белән *аз-*фигыле арасында «күпер салына» (к. Gabain: 40). К. **Аз-у,** к. ш. ук Кажибеков: 128.

**Аз** продуктив тамыр: **азай-у; азсын-у; азлык** һ.б. **Азчылык** рус. «меньшинство» сүзеннән калька. **Аз гына** тәгъбире – тат. диал., кр.-тат. *азгана* аерым сүз булып киткән.

**АЗА, аза кубу** «землетрясение» (букв. «подъём духа земли Аза»), **аза куу** «изгнание бесов в новогодние праздники»; себ. тат. (к. ТТДС 1969: 22; Радлов I: 557) *аза* «явыз рух». Тат. диал. (трбс.) *азат сындырган* күкрәге яньчелгән яисә бөкре бала тур. ~ башк. диал. (БҺҺ II: 18) *азат һынтырыу,* чув. (Ашмарин II: 92) *асат хуçнă* (азат сындырган), *асат çапнă* (азат суккан) «спондилитлы (бала)» кебек тәгъбирләрдә; **азат** – монг. «азалар». К. алт., хак., тув., монг. *аза*, монг. *азар,* калм., бур., бор. төрки *ада* – явыз рух, җир асты, кабер, үлем рухы, ул яңа туган балаларга һөҗүм итә; бор. язмаларда (Clauson 1979: 40) *beš türlüg ada bar* диелә. *Ада, азат* сүзен бор. һинд. *asat* «үлекләр дөньясы» сүзе белән чагыштыралар, ләкин монда фонетик кыенлыклар бар. К. ш. ук Катанов 1888: 1. Чаг. **Азар-бизәр, Әри.**

Кырг., каз. *аза* «траур, тәгъзия» сүзенең *аза*га катнашы юк: ул гарәпләрдән булса кирәк. Ахметьянов 1981: 12.

**АЗАК** диал. «потом; затем; конец, исход» – гом. төрки *аҙағ, азақ, адақ* «соңыннан; соң; елга тамагы» (шуннан *Азак диңгезе, Азау диңгезе* (*азак < азағ < азау*) «Азов диңгезе», ягъни Дон елгасының тамагында урнашкан бор. порт атамасыннан). Мар. *азак, адак* «азак; тагын» < тат. К. Räsänen 1969: 5; ЭСТЯ I: 104–105. К. **Аяк.**

Дерив.: **азаккы; азактан, азагы.**

**АЗАМАТ** «кадровый военный, добрый мо́лодец» – башк. *аҙамат* «хөрмәтле ирзат», *азаматлы* «көчле, гайрәтле», каз. *азамат* «гражданин; ил әркяны» < гар. *'аҙамăт* (عَظَمَة) «олылык, бөеклекләр, чиксез зурлыклар; хәрби һәм сәяси куәт» сүзеннән үзгәргән: *газәмәтле → газәмәт* (*әгъзамат* булса, *әгъзам* «иң куәтле» сүзеннән күп. формасы).

Тат. әд. телендә **газәмәт** «бөекләр, олуглар» варианты да очрый; *газыйм* (*валлаһи-газыйм* – ант сүзе) «чиксез көчле» шуңа тамырдаш. **Газәмәт** – «кемсә» мәгънәсендә тат. ядкәрләрендә тәүләп «Җәмигъ эт-тәварих»та кулланыла. Телче Г. Хәсән сүзләренә караганда (к. Шура № 7, 1910, «Югалган лөгатьләр» мәкаләсе) **азамат** сүзе бор. кыпчакларда, шулай ук XV–XIX гасырлардагы кыргыз, казакларда билгеле бер корны – яшь аралыгын, атап әйткәндә, 24–36 (яки соңрак 20–30) яшьләр арасындагы чорны һәм шул яшьтәге ир-егетләрне белдергән. Бу кордагы кешеләр илнең төп сугышчыларын тәшкил иткәннәр. Хәз. тат. телендә *азамат* «шәп егет, батыр сугышчы», *азамат күру «*сугыш кыенлыкларын һәм, гомумән, ир-егет башына төшә торган кыенлыкларны күреп үткәрү» дигәнне аңлата. *Берәү йөри азаматта, берәү йөри быраматта* дигән макальдән *азамат* сүзенең «ил файдасына хезмәт, хәрби хезмәт» мәгънәсе аңлашыла. *Азамат ирнең билгесе – аз сөйләр дә күп тыңлар*

дигән мәкаль (Н. Исәнбәт, III: 741) хәрби дисциплинага ишарә итә. Диал. *азамат тике* «зур гәүдәле, кыяфәте батырларныкы кебек булган» сүзе күз алдында хәрби гвардияне тота. Мари телендә *асамат* «университет, хәрби өйрәнүләр, сугыш, шау-шу» дигән сүз (Ўпымарий 1929: 35), чув. *асамат* «тантана», *асамат кĕпрĕ* «салават күпере». Бу мәгълүматлардан сүзнең мәгънә үсешен болай дип аныклап була: *газамат* «сугышчылар буыны», шуннан – «хәрби хезмәт, сугыш һөнәренә өйрәнүләр», шуннан «сугыш һөнәренә оста кеше, югары офицер, сәргаскәр, ил хезмәтенә тайяр булган ир-егет». Алтын Урдада һәм XV–XVI гг. татар дәүләтләрендә хәрби һәм әһли (цивиль) чиннар бирберсеннән ачык кына аерылмаган.

**АЗАН** «призыв к молитве» – барлык мөселманнарда *азан, адан* «азан», гар. «колаклар» сүзеннән (гар. *уʒун* «колак» сүзенең күп. формасы), ягъни «ишетегез, тыңлагыз!» дигән сүз.

**АЗАП** «мучение, страдание, муки» **газап** (к.) сүзенең лексик дублеты. Чув. *асап*, мар., удм. *азап* id. Федотов I: 62.

Дерив.: **азаплан-у, азапла-у,** тат. теленең үзендә ясалган сүзләр.

**АЗАР** «жестокое порицание; выговор» – барлык мөселман төрки телләрдә **азар** (> мар. *азар*) «рәнҗетү; рәнҗү», кайбер телләрдә «газап; авыру» < фар. *азар* id., ш. ук «террор» < сугд. *āzār, āzārun* «рәнҗетү», к. ДТС: 72; Räsänen 1969: 32. Кайбер авторлар бу сүзне гар. *азарр* «бик зарарлы» сүзеннән диләр, к. Özön: 56.

Дерив.: **азарла-у** (ДС I: 11) «каты сүгү, сүгелү» > мар. *азарла-* «көнләшеп газаплану» ~ гом. кыпч. *азарла-* «каты шелтә бирү».

**АЗАР-БИЗӘР** «нечистая сила; ссора» ~ чув. *асар-писер* id., аз. (Caferzade 1990: 144) *azar-bezar* «саташу, авыру рухы» << һинд-ир. *Асура-Миʒра* – берсе төнлә, берсе көндез дөньяда тәртип саклаучы рухлар исеменнән. К. тув. *азарлар* «фәрештәләр». Бу сүзнең тат., чув., аз. телләрендә тискәре мәгънә алуы мәҗүсилекне яратмаудан килә. Безнең тат. *Азары булса бизәре булыр* дигән мәкаль ишеткәнебез бар. К. **Айзар-Байзар.**

**АЗАТ I** «свободный» – гом. мөселман төрки **азат** id. < фар. *āзāд* «ирекле, ireккә җибәрелгән (кол)», бик бор. сүз.

**АЗАТ II** «злой дух, нападающий на младенцев» к. **Аза.**

**АЗАУ I [аᵒзаw]** «клык; коренной зуб» – дөресрәге диал. (ТРС I: 58) *азу, азый* < бор. төрки, хак., уйг. *азыг,* төр. *azı, azıw* һ.б. ~ бор. монг. *arïya* < хәз. монг. *араа* «азау». R-варианты мари телендә дә сакланган: *ора пуй* «азау теш». Чув. *асав*, удм. *азау*, мар. *азу, азау* < тат. (Гордеев I: 57). Семантик структурасы, чыгышы ачык түгел. ССТМЯ авторлары (I: 50) маньч. *арган* «чөй, азау, пычкы теше», *аргали* «бертөрле тайга боланы» (> рус. *аргали*), *аргату* «болан иркәге» һ.б.ш. сүзләр белән чагыштыралар (тамыры **arγa* «иркәк хайван, иркәк болан яисә кабан» булып чыга). К. **Арган.** ЭСТЯ I: 97, 218.

**АЗАУ II [аᵒзаw]** (ЗДС: 22) «уже подросший жеребёнок», «племенной жеребец», «подросток, который играет среди младших» к. **Азаулы, Асау.**

**АЗАУЛЫ [аᵒзаwлы̆], азулы** «клыкастый»; это слово издревле употреблялось в значении «мощный, храбрый; грозный в бою», кр.-тат. *azuwlı,* төр. *azığlı* «азау тешле; гайрәтле» < бор. төрки (ДТС: 72) *azïγlï* «азау тешле; батыр, гайрәтле», *azïγla-* «азау теш белән бәрү, тешләү» һ.б. (параллельләре күп телләрдә бар). КБтә (тәрҗемәләр безнеке. – *Р.Ә.*):

*Ничә мең азаулы ирән-иркәкләр*
*Хатын-кызга була җан биргән тәккә.*

**АЗӘРБАЙҖАН** «Азербайджан; азербайджанец» < бор. фар. *ātar pates, atur patakan* «ут белән якланмыш» сүзеннән: Азәрбайҗанда җир астыннан чыккан газ «мәңге янып» торган бер гыйбадәтханә булган. К. EI I: 188–191.

**АЗГЫН** «сбившийся с пути, развратный, ленивый, блудный» > чув. *аскӑн,* мар., удм. *азгын* < гом. кыпч. *азгын* «азгын; арык, ябык», каз., к.-калп. «гибрид; метис», тат. диал., гаг. һ.б. «артык көчәйгән (авыру, чир тур.)» ← *аз-* (к. **Аз-у**).

Морд. *азгун* «азгын эшлексез» тат. теленнән түгел, бүтән бор. төрки телләрдән булса кирәк, к. бор. чыгт. *азгун* «азгын». Чаг. **Азман I.**

**Азгын** продуктив нигез: **азгынчы, азгынчылык; азгынлан-у.**

**АЗМАН I** «что-, кто-либо неординарное; выродок; метис» > мар. *азман* «озак төзәлми торган

яра», удм. *азман,* тув. *азымил* «күкәйләренең берсе яки икесе дә күкәй янчыгында түгел, ә корсак куышлыгында я касык каналында урнашкан айгыр (рус. нутрец)» < гом. кыпч. *азман* (нуг., каз., к.-калп., кырг. *азбан*) «соң печтерелгән; зәгыйфь, көчсез», «бишенче-алтынчы яшьтә генә печтерелгән (айгыр, үгез)» (к. Радлов I: 581–582), кр.-тат., төр., гаг., аз. *азман* «чиктән тыш зур», төркм. *азман* «дүрт яшьлек тәкә, кучкар» < бор. төрки (ДТС: 73) *aztan* «печтерелгән тәкә» ~ иске монг. *asatan* «алаша» (к. Räsänen 1969: 33). Сүзнең тамыры *аз-* (к. **Аз-у**) булса кирәк, ләкин ясалышы ачык түгел. Ахметьянов 1989: 93–94.

**Азман** сүзенең дерив. юк диярлек. К. **Азман II.**

**АЗМАН II** (ДС I: 11) «шершень» ~ кр.-тат., госм. (Радлов I: 82) *азман* «әрә, сорыкорт». **Азман I** сүзенең аерым мәгъ. булса кирәк.

**АЗРАИЛ** «дух смерти» ~ чув. *эсрел, есрел,* мар. *азырин* id. **Газраил** (к.) сүзеннән. Ахметьянов 1981: 14.

**АЗ-У** «выходить за рамки, совращаться, сбиваться с пути; выродиться; запуститься (о болезни); беситься; что-либо делать чрезмерно; расшалиться» > мар., удм. *аз-,* мар. *аж-,* чув. *ас-* «азу, азыну» < гом. төрки *аз-, āз-* < **арг-* id. Räsänen 1969: 33; ЭСТЯ I: 94–95. Кайбер сүзлекләрдә *аз-* «зәгыйфьләнү» һәм *аз-* «хәттин ашу» ике сүз итеп бирелә. К. ш. ук бор. төрки (ДТС: 71) *az* «комсызлык, ачкүзлелек». Чув. *ур-* < *ор-* «котыру» ~ гом. төрки *аз-* id. тур. к. Федотов II: 283 (без, гомумән, бу очракта М. Федотов яклы). Räsänen 1969: 33; ЭСТЯ I: 94–95.

Тюркологлар *āз-* тамыран *яз-у* (*юлдан язу*) һәм *адаш-у* фигыльләре белән чагыштыралар. Безнеңчә, бу чагыштырулар юраулы – хәлиткеч дәлилләр юк. Чаг. ш. ук **Ары-у.** Ахметьянов 1989: 93–94.

**Аз-** продуктив нигез: **азыл-у, азын-у, азыш-у, аздыр-у,** диал. **азымтык** «ялкау». К. **Азгын, Азман.**

**АЗЫК** «пища, корм, провизия, запас пищи, припас» – гом. кыпч., алт. *азық,* уйг., чыгт. *азуқ,* төр. диал. *аззуқ, азық, азак* (ЭСТЯ I: 98). Геминатлы вариант тамырда ассимиляцияләнгән икенче бер тартык аваз булганлыгын күрсәтә, безнеңчә, борынгырак вариант Памир телләрендә сакланган: *арзуқ* «майле кәтермәч» – юл азыгы (к. Сказки народов Памира. М., 1976: 519) сүзеннән.

Элегрәк төрки *азуқ* сүзен фар. *азуқа* < *ab-zuqqa* «азык», сүзмә-сүз «су-ипи» (Platts I: 37) сүзеннән дип уйлыйлар иде, ләкин алт. *азык-* «ризык әзерләү» сүзе бор. *азы-* < *арзы-* «юллык азык әзерләү» сүзенә ишарә итә. Фар. сүзе үзе төрки телләрдән алынган. Чаг. *асра-.*

Рус. диал. *азык* «тегелмәгән тукыма» тат. диал. (Җ. Вәлиди) *азық* «запас тукыма» сүзеннән (Дмитриев 1962: 490). Гомумән, **азык** күп кенә күрше телләргә алынган, к. мар. диал. *азык* «провизия», *азыклан-* «азыклану», *азыклык* «азыклык» (Гордеев I: 57), Кавказ телләрендә *азык, азук* һ.б. Рус. *азу* ашамлык (төре) < тат. диал. (кас.) **азу’** (-*қ* әйтелми) id. сүзеннән булуы ихтимал.

**АЙ I** «луна; месяц (календарный)» < гом. төрки *ай* < *аай,* як. *ый,* чув. *уйӑх* < *ойӑх* < болг. **айх* id. Болг. сүздән чыгып фикер йөрткәндә, *ай-* «ай калку» сүзе булган һәм чыннан да төр. диал. (DS I: 409) *ау ау-* «ай яктырту» тәгъбире бар. Сүзнең *ань, аань* яңгырашлары да билгеле (ЭСТЯ I: 98–99).

Гомумән, *ай* сүзенең чыгышы бер дә гади түгел. К. ш. ук Кажибеков: 129–130. Федотов II: 271.

Дерив.: **айла-у,** диал. (Тумашева 1992: 18) **айлы, айлу** «көмәнле» (чаг. *ае-көне җитү* ~ хак. *айыкүнӗ чит-* «бәбиләргә якынлашу»); **айлык** (эш хакы) һ.б. К. **Айдын, Аяз.**

Ай исемнәре татар телендә бик төрле (төрле урынчылыкларда һәм чыганакларда төрлечә) һәм алар тиешенчә тикшерелмәгән дә. Мисал өчен, Бараба татарларындагы ай исемнәрен китерик (Радлов I: 7): *бирнен ай* (беренче ай) «апрель», *тармақ* (үсемлек үсеше) *ай* «май», *кижу ызы* (эссе) *ай* «июнь», *улу ызы* (агац) *ай* «июль», *оргац* (уңыш) *ай* «август», *саргка* (сарык) *ай* «сентябрь», *йалан агац ай* «октябрь», *кижу суук ай* «ноябрь», *улу суук ай* «декабрь», *йил* (җил) *ай* «январь», *кужугөн* (бөркет) *ай* «февраль», *қаарга* (карга) *ай* «март». К. ш. ук Будагов I: 171–172; Тимергалин: 17; Dobr I: 197–198.

**АЙ II** ы. «ай, ой» ~ *һай* id. < гом. төрки *ай, айә* – барча телләрдә диярлек очрый. Еш кына редупликатив һәм парлы сүзләрдә: *ай-ай, айяй, айһай* һ.б. К. **Әйдә-ү.**

**АЙБАЛТА** «секира» – «айсыман йөзле балта» мәгъ. гом. төрки характердагы сүз. Шуның кебек *айказан, айпычак, айқолак* («саңак» мәгъ.), *айчәчәк* кебек кушма сүзләр дә бар (к. Тумашева 1992: 18 һ.б.).

**АЙГАК** диал. (к. Арсланов 1992: 13) «подложный свидетель, человек, который говорит то, что ему подсказывают» < гом. кыпч. *айғақ* «әләкче шаһит, айгак; провокатор», үзб. *айғоқчи*, үзб. диал., төркм. *айғағ* «ялачы, әләкче», ләкин чыгт., каз., к.-балк. *айғақ* «шаһит; дәлил», аз. (АДДЛ: 25) *айғағ* «шомакай; юламан, гид» ← *ай* (к. **Ай-у**) «әйтү» фигыленнән. К. Будагов I: 198.

Дерив.: тат. диал. **айгакла-у** (ш. ук *айыкла-у*) «әләкләү, бөһтан итү» ~ аз. *айғақла-* «фаш итү».

**АЙГЫР** «жеребец» ~ гом. төрки *айғыр, айғур,* бор. төрки *азғыр, аҙғыр,* чув. *ăйăр*, як. *атыыр, азарга* ниндидер табышмаклы **аджи* тамырына ишарә иткән шикелле. Радлов бор. төрки *adγır* «айгыр»ны *ат* белән чагыштыра (Радлов I: 15). Е. Убрятованың махсус мәкаләсендә (Вопросы тюркологии, Ташкент, 1965: 11–16) *айгыр* бор. төрки *ай-* «булдыру; идарә итү, күрсәтмә бирү» сүзеннән диелә. Безнеңчә, *айгыр* бор. **azγırγaq* (шуннан монг. *ağirγa* һ.б.ш.) «аздыручы», ягъни «женси теләккә китерүче» кебегрәк мәгънәдә булган, к. кыргь. *азғыр-* «җенси аздыру», тув. *асқым* «азгын; чыгымчы», *асқыр* «айгыр». Аникин (: 100, 419) рус диал. *озоргой* һәм *аскыр* «аеруча матур айгыр» һәм шор. *aiğyr аз* «(тиресе елкылдап торган) ата кеш» сүзләреннән чыгып, *айгыр* сүзе эвфемизм күренеше, бу сүз асылда кешне, асны (ас < аз < арс) белдергәндер дигән фикер әйтә. Гомумән, сүзнең этимологиясе юраулы булып кала. Щербак 1961: 88–89; Räsänen 1969: 6; ЭСТЯ I: 107; Федотов I: 81–82; Dobr I: 207.

**Айгыр, айгур** сүзе бүтәнтелләргә алынган: рус. (Аникин: 78), мар., удм. (ДАУ III: 181–182) *айгыр,* морд. *айгор,* груз. *аҗилга* < *аҗырга* «айгыр, сабан төрәне (күч. мәгъ.), укр. *óгер*, пол. *ogier* «айгыр» һ.б. К. түбәндәгене.

**АЙГЫРАК** (ЗДС: 27) «молодой жеребец» ~ тув. *аскырак* id. < **азғырғақ*. К. **Айгыр.**

**АЙДАР** диал. (Арсланов 1988: 70) «чуб на голове мальчиков» ~ башк. *айҙар*, нуг., каз., к.-калп., кырг. *айдар* id., рус. *айдар, ардар* «круглая казачья стрижка» (Даль). **Айдар** ир-егетлек билгесе саналган. Ихтимал, бу сүз гом. монг. *алдар* «дан» сүзе белән бердәйдер. Бу сүзне исә А. Йоки (1973: 248) скиф телендәге *ардароç* «дус, яудаш» < бор. ир. *armdār* «кул бирүче» сүзеннән дип аңлата.

Ихтимал, **Айдар** исеме дә ошбу сүздәндер. Тимергалин: 17.

**АЙДУР** диал., (ТТДС I: 27) **адюр** «телега для возки брёвен и т.п. тяжёлых предметов» ~ башк. *айдур,* чув. (Сергеев 1968: 9, 74) *айтур, уйдур,* мар. *айдор, айдыр, айдар* «роспуск; волокуша; дроги» < рус. диал. *одёр* id. (Ашмарин I: 39). Бу сүз Дальдә әйбәт аңлатылган.

Дерив.: **айдур аты** «гадәттә мәетләрне зиратка алып бара торган ат», күч. «авылларда вакыт-вакыт зур көч таләп итә торган авыр эшләргә чакырыла торган олы гәүдәле, ләкин ялкау һәм иренчәк кеше».

**АЙДЫН** «лунный, освещённый лунным светом», «ясный» – гом. төрки *айдын, айдың, айдуң* id. бор. сүз (як. *ыйдаңы* id.). *Ай* сүзеннән, ләкин ясалышы аңлашылып бетми (*ай* һәм *тын ~ тың* дип аңлату бигрәк беркатлы булыр иде).

**АЙЗАР: айзар-байзар** – припев веселой песни, а также название пляски с песней (*Айзар, гизаем, байзар, гизаем* да диелә) ~ ш. ук *азар-бизәр, әсәр-мәсәр, исәр-мисәр* (Г. Ахунов; ТТДС: 547) «тәртипсез активлык (рухы)».

Хәз. көндә конкрет мәгънәсен, нинди дә булса төшенчәне белдерүчәнлеген югалткан бу сүзләр, безнеңчә, тарих төпкеленнән – безнең бабаларыбыз ирани культлар һәм диннәр тәэсирендә яшәгән чорлардан калган. Чуваш теле тарихчысы В.Г. Егоров фикеренчә (Егоров 1964: 34), бу *азар-бизәр* сүзе бор. Иран тәңреләре *Асура* һәм *Миҙра* исемнәреннән килә. Бу фикер яңа фактлар белән ныгытыла бара.

Идел-Урал телләрендә тат. *азар-бизәр, әсәр-мисәр,* чув. *асар-писәр,* удм. *эзэр-бэзэр* «явыз рух; тәртипсезлек, вәсвәсәләшү» тагылмалы сүзе бүтән төрки телләрдә дә очрый: кырг. *азар-бэзэр* «тынычсыз, вәсвәсәле», аз. *азар-бәзәр* «төрле чир-чор», ком. *эсэр-мэсэр* «таркау, зиһенсез» һ.б. Башк. сөйләшләрендә *азарыныу-бизәренеү* «ант итү» (*Азар* һәм *Бизәр* исемнәре белән). Ләкин алт., тув. *Азар-Базар* әкияттә «атасыз-анасыз калган баланы саклаучы ике эт».

*Азар (айзар) – Асура* сүзенә башк. *Һур* < *Сур йолдызы* «Чулпан, Венера» сүзе дә кайтып кала шикелле.

*Бизәр (байзар) < Мизра, Мизһра* (*зһ* – башкортча *ҙ* кебек әйтелә) сүзе Евразия телләрендә бигрәк тә күп тармаклар-курпылар биргән. Безнең эрага кадәр үк ул антик дөньяга үтеп кергән һәм анда *Митра* дип аталмыш Кояш тәңресе сыйфатында хөрмәт ителгән. Үзенең Ватанында – Иранда һәм

Урта Азиядә бу атама *Миһра* һәм *Миһр, Миһер* яңгырашын алган һәм көзге кояшны белдергән (шуннан ук фар. *Миһриган* «көзге игътидал, көзге сәвия» – 22–23 сентябрь көннәре). *Миһербан* «кояш кебек җылы караш, шәфкать» сүзе шуңа тоташа. Татар халкының традицион исемнәре арасында без *Миһри* һәм *Миһран* дигәннәрен табабыз – болар да шуннан килә.

Бор. (ислам динен кабул иткәнгәчә чорлардагы) Иран халыкларында (ә алар Урта диңгез буеннан Кытай чикләренә кадәр киң аралыкта яшәгәннәр) *Асура* – төн илаһы, дөньяны, кешеләрне явыз рухлардан төнлә саклый торган илаһ, ә *Мизра (Мидра)* – көн, яктылык, килешү рухы, кешеләрне көндез химая кыла торган илаһ булган. Бор. ирани халыкларның мәдәнияте һәм теле бор. төркиләргә гаять көчле тәэсир ясаган. Һәм, әлбәттә, бор. төркиләр *Асура* һәм *Мизраны* бик яхшы белгәннәр.

Югарыда китерелгән җыр мисрагының «*Айзара гидаем, Байзара гидаем»* дигән варианты да бар. *Гизай, гидай* бор. ирани *хветай* «тәңре» (шуннан ук фар. *худа, худай* «хода, ходай») сүзеннән булса кирәк. Ягъни китерелгән мисраг «*Асура ходаем, Мизра ходаем»* дигән эндәшүдән – бор. догадан гыйбарәт. Ә бу юлларның бию көенә башкарылуы аның бор. бәйрәмнәрдә әйтелүе белән баглы.

Мордваларда *Азорь пазь* «төн илаһы», *Позяра пазь* «яз һәм көн илаһы» (*пазь* «илаһ, тәңре»). *Позяра* ш. ук уен көе атамасы да. Бу сүзләр турыдан-туры скифлардан түгел, төркиләрдән, анығрак әйткәндә, бор. мишәрләрдән алынган булса кирәк: *азарь, азора* < *айзара, позяра* < *базйара* < *байзара* (*эй* > *йэ* күренеше миш. шивәсенә хас: *әтйәм* < *әйтәм, әд'йә* < *әйдә, карйак* < *кайрак* кебек күренешләрне хәтерләтә).

Һинд-ир. һәм бераз соңрак ирани илаһлар пантеоны төрки халыкларга башлыча скифлар һәм сугдлар аша кергән. Борынгыдан килгән сөйләкләрдә *Ай хан, Көн хан, Тау хан, Диңгез хан* турында әйтелә. Иранистлар скифларда *Колаксай* «көн (кояш) шаһы», *Липоксай* «таулар шаһы», *Арпоксай* «тирәнлекләр (диңгезләр шаһы)» булганлыгын сөйлиләр. Һичшиксез, *Асура* һәм *Мизра* скифларда да ригая ителгән. Шулай булса *айзар-байзар* безгә үз җиребездә кергән. К. ш. ук **Миһер, Мир.**

Бор. һиндләрдә *асура* бер ялгыз зат түгел, ә илаһларга каршы көрәшкән бөтен бер рухлар классы (гомумән, *асура* «хөкемдар» дигән сүз). Алар икенче бер төрле явыз рухлар – *гаруда*лар белән бергә төнлә очып йөриләр һәм шунлыктан бор. төрки язмаларда (ДТС: 61) *асури-гаруди* рәвешендә искә алыналар. *Гаруда*лар *Хан Кирәдә* яңгырашында Алтай мифологиясендә хәзер дә сөйләнелә.

Ирани мифологиядә дә *асура-аһура* башта «фәрештә» мәгънәсендәге күмәклек исеме була. Ул *аһура*ларның иң яхшы вә көчлесе *Аһура Мазда, Аһура Маһазда* «зур акыллы аһура» булган. Бу тәгъбир соңрак гаплология (берләшү) процессын кичереп, безнең эра башларында *Һурмузда, Һармузд, Ормузд* яңгырашын алган. Төрки һәм монгол телләренә бу сүз төрле вакытларда һәм төрле яңгырашларда (монг. *Хормусды, Кормуста, Хан-хурмус, Хюрмус, Тюрмус,* тув. *Курбусту, Корбустан,* алт. *Кёрмес, Кёрбес,* себ. тат. *Курмәц, Курмац*) «иҗатчы, тылсымчы тәңре» мәгънәсендә кабул ителгән (*Асура* һәм *Митра* һ.б. тур. к. Ригведа I: 497–506; МНМ II: 154–158).

Тат.-башк. һәм каз.-кырг. фольклорының атаклы каһарманы *Кузый-Күрпәч* исеменең икенче өлеше дә шул тәңре исеменнән килә булса кирәк. Бу исемнең мәгънәсе «Кузый (сарык бәрәне) рәвешендәге (юаш) иҗатчы тәңре» булып чыга.

Безнең бу фикер түбәндәреләргә нигезләнә: Үзәк Азия һәм Тибет эпосының кайбер баш геройлары, мәс., атаклы *Гәсәр (Гисәр), Һармузднең* кубылгылары (үзгәреп гәүдәләнүе) булып чыгалар. Һармузның шундый гадәте бар: ул берәр бала, колын, хәтта кузый (бәрән) булып туа.

*Кузый Күрпәч* эпосында (һәрхәлдә аның кайбер вариантларында) колагы кителгән бәрән – кузый зур роль уйный – ул Баян сылуга үзенең баегы (бәби чакта ук ярәшелгән егете) килгәнлеген хәбәр итә (еш кына ул моны телгә килеп сөйли). Кузый Күрпәч, гомумән, бик тә тәвәккәл һәм көчле, катгый һәм хәтта рәхимсез батыр. Аны берничек тә, кайберәүләр аңлатканча, *кузы көрпә* «йомшак бәти» дип характерлап булмый. Юк, аның атамасы характерыннан түгел, ә кайчакта кузый булып әверелүеннән килеп чыккан. Чиксез кодрәтле тәңре кайчагында чиксез зәгыйфь һәм ярдәмсез җан иясе булып әверелә һәм кешеләрне сыный.

«Кузый Күрпәч белән Баян сылу» дастаны, гомумән, бик бор. детальләр һәм мотивлар белән тулы. Бу дастанның беренче рәвеше бик нык бозылганлыгы, аның тәүге нигез мифы онытылганлыгы күренеп тора. Ахметьянов 1981: 13–14.

**АЙКА-У** «потрясать в воздухе чем-либо; взбалтывать, мешать; переворашивая, искать что-либо» – бу сүз төп формада тат.-башк. даирәсеннән тыш очрамый, тик төрле юн. формаларында гына очрый: кырг. *айкал-* «бер-берсенә кочаклашып ябы-

шу»; *айкаш-* > нуг., каз., к.-калп. *айкас-* «чатлашу; эләгешү, ябышу; тыгыз аралашу»; чув. (< тат.) *айкат-* «актарып эзләү». К. ш. ук себ. (ДС I: 11) *айгалыш-* «тарткалашу; аралашу».

В.В. Радлов фикеренчә (I: 10), *айка-* фигыле *һай-һай* дип (кул селтәп) кычкырыуннудан килеп чыккан. Чаг. ш. ук маньч. (ССТМЯ I: 21–22) *aja* «пыр-пыр килү; тырпылдау», *ajxa-* «тыр-тыр чабу».

**АЙКЫНЛЫ** диал., башк. **айканлы** «по ясному поводу, по причине, по случаю» ← башк. диал., тат. диал. (әстр.) *айкын, айкан* «хөкемдә дәлил, шиксез сәбәп» ~ каз., к.-калп., кырг. *айкын* «ачык, конкрет, бәхәссез» < *айық-ын,* ягъни *айык* сүзенең инструменталь килеш формасыннан, к. **Аек.** Чаг. ш. ук **Айгак.**

**Айкан** варианты фар. *айыкан* «аек килеш; ачык рәвештә» формасыннан да була ала.

**АЙЛАК** диал. «очень» (Арсланов 1982: 70) ~ нуг. *айлақ* «бигрәк тә; соң дәрәҗәдә» ~ каз. (ҚТДС: 15) *айлак* «бухта, кимәләрнең килеп тукталу урыны», төркм. *айлаг* «салдау, пристань», госм. *aylak* «елга бөгелеше», «юкка ары-бире килеп йөрүче», төркм. *айлав* (< кыпч. *айлаw)* «ат чаптыру ярышлары өчен махсус мәйдан, ипподром», үзб. (ЎХШЛ: 15) *айлав* «ярыштагы атның бер әйләнеп килүе; ипподромдагы юл бөҗрасы», каз. *айлам* «ярыш юлы» ← *айла-* «әйләнеп чыгу» фигыленнән. Мәгънә үсеше: «финиш > максат > соң дәрәҗә > бигрәк тә».

**АЙЛЫ,** себ. **айлу** «беременная» < гом. кыпч. (характерда), к. кырг. *айлы* id. ← *ай.* К. **Ай I.** *Аекөне җиткән* дип бәбиләүгә якынлашкан хатын тур. әйтелә.

**АЙМАК,** диал. (ТТДС I: 27, 55) **аумак,** (ЗДС: 78) **әймәк** «аймак» в тат. письменных памятниках и говорах имеет множество значений: «круг родственников, род», «(большая) группа, масса, множество», «территория (величиной с район), район», «часть деревни, околица, улица, группа дворов, стоящая поодаль» (ДС I: 12; ДС II: 28; ДС III: 16) ~ башк. *аймақ* «нәсел-ыру; урман кешеләре; алан; күмәклек; күпчелек» > мар. кч. *аймак* «авылның бер очы; зур группа, масса», удм. (Насибуллин: 105) *аймакын «*бергәләп, аймакланып» < гом. кыпч., гом. төрки (Радлов I: 64) *аймак* «халык, ыру; гаилә; чит ыру; күп куйлы күчмәче һ.б.» (икенчел мәгъ. күп) < бор. монг. *ajımag* «җыен, җыелыш» (ЭСТЯ I: 110–111). Бу сүзнең ясагыч нигезе тат., башк. сөйләшләрендә дә бар: **айма-у** «учлап, уратып әләктерү, уратып тоту» (Тумашева 1992: 19; БТДҺ: 15) ← **ай-* «тотып алу» (бу фигыльнең интенсивлык дәрәҗәсе). **Аймак** – элекке татар дәүләтләрендә административ берәмлек булган һәм шул мәгъ. тув., бур., монг., як. һ.б. Себер телләрендә бүгенгәчә кулланыла. Будагов I: 208; Антонов: 103–104, 172–173; ССТМЯ I: 22; Аникин: 78.

Дерив. (барысы да сөйләшләрдә): **аймак-аймак** («төркемләп»), **аймаклап, аймаклашып, аймаклашу, аймаклы.**

**АЙМАН** диал. (Арсланов 1988: 70) «большая посуда; большой котёл» ~ төркм. *айман* «әйберләр бергә куела торган урын», каз. *айман* «зур җиз казан» (*аймандай* «ялтырап торган») һ.б. **Аймак** сүзе белән тамырдаш булуы мөмкин, к. маньч. *айман* «аймак». Тат. *ай күрдем айман белән*... дигән мәҗүси догада **айман** сүзенең мәгънәсе аңлашылып бетми.

**АЙМУТ** «омёт (тупас салынган кибән)» < рус. *омёт* (*метать* «ыргыту, ташлау» фигыленнән).

**АЙМЫЛ: аймыл бул-у** «разминуться, не встретиться в предполагаемой точке» ~ чув. *аймӑл, уймӑл,* мар. *аймыл,* удм. *аймыл, аймыш* id.; тат. диал. *аймы-л-у*, удм. *аймыланы* «очрашалмау». Удм. материалы күрсәткәнчә, *аймыл-у, айма-, аймы-* дигән төп фигыльнең төш. юн., аның *аймын-у, аймы-ш-у, аймы-т-у* дигән юн. формалары да булган; чыннан да андый фигыль табыла: тув. *айма-* «мәрәйгә тимәү, сибелү», хак. *аймас-* «урыныннан кубу, юлдан чыгу», *аймах* «төрле». Тат. **аймылыш** «очрашалмау күренеше» **аймыл-у** фигыленнән.

Идел-Урал регионыннан тыш бу сүзләр сирәк очрый. К. Федотов I: 271.

**АЙНӘ, айнәк, әйнәк** «очки» (Тумашева 1961: 91, 231) ~ үзб., чыгт. һ.б. *айна* «көзге» < гар. *ʻайнä* id. (*ʻайн* «үзе һәм күзе» сүзеннән).

**АЙНЫ-У** «протрезветь; выдохнуться, выветриться» – гом. кыпч. *айны-* < тат. диал., уйг., төр. һ.б. *айын-* id. Иске тат. *айыл-* < бор. төрки *адıl-* id. К. **Ай-у II, Аек.**

**АЙРАВЫК [а°йраwык]** «вейник (растение); пырей» ~ башк. *айрауық,* нуг. *айравық*, мар. *айраук, айрак, аряк* «сарут» (к. Гордеев I: 64, 156) ~

бор. төрки *ajrıq* id. *Айра, аир* дигән үлән төре грек (һинд-евр.) сүзе хисапланыла. Ләкин сүз ясалу моделе буенча *айравык* сүзенең тамыры *айра-* дигән фигыль, чаг. **Аер-у.**

**АЙРАТ** «автономия» *айру* < *айыр-у* сүзеннән булса кирәк. Бу 1920 нче еллардагы ясалма сүз кеше исеме буларак киң кулланыла. К. башк. *айрата,* төркм. *айратын* «бигрәк тә, аеруча». ← бор. төрки (ДТС: 13) *adra* «аерма». К. ш. ук Тимергалин: 18.

**АЙРЫ, айрык, айра** диал. (ЗДС: 228–229) «отдельный; отдельно», «часть, другой, иной» < гом. кыпч. *айры*, бор. төрки *adırıγ* id. һ.б. К. **Аер-у, Әйре**.

**Айры** үзе генә дә продуктив нигез һәм компонент, к. тат., башк. (ТТДС I: 29; ТТДС II: 22; БТДҺ: 16) **айрыбаш, айрыкай** ~ **айырыкай, айрыкойрык, айрыча** ~ **айырыса** – төрле үсемлек, бөҗәк һ.б.ш. төрләре. Диал., башк. **айрата** «бигрәк тә» ← **айырат-у** «аерым күрсәтү» һ.б.

**АЙРЫК** диал. – название растения. **Айравык** белән бердәй түгелдер. Сүзлекләрдә төр. (Будагов I: 190) **айрык уты = Мәккә айрыгы, Мәккә саманы** русча «ёжа, палечная трава» ~ бор. төрки (ДТС: 5, 30; МК) *adrïq, ajrïk* «айравык (сарут)» сүзе очрый. Бу шул ук айравык микән – кистереп кенә әйтеп булмый.

**АЙ-У I** (Тумашева 1992:19) «сказать» < бор. төрки *ай-* ~ як. *ый-* id. К. **Әй-ү.**

**АЙ-У II** (айы-у?) «быть в добром здравии, быть нормальным». Бу фигыль шул көенчә төрки телләрдә табылмады, тик тунг. телләрендә генә (ССТМЯ I: 17–18) *ай-* «ярдәм; ярдәм итү, коткару» фигыле бар.

**Ай-** фигыле *айык* (к. **Аек**), *айыл-* (к. **Аел**) һәм *аен-* (к. **Айны-у**) сүзләренең тамыры буларак билгеле. Ихтимал, *айыш* «ачыкланыш, мәсьәләнең төбе – асыл мәгънәсе» сүзе дә шул тамырга карыйдыр.

**Ай-** фигыле *ай-* «ачык, якты, нурлы; ай» сүзе белән бердәй булуы ихтимал (тик моны исбатлау читен). Һәрхәлдә бик күп телләрдә *ай* «яхшы, якты, изге» мәгънәсендә йөри.

**АЙ-ҺАЙ** модальное слово «ой-ли; вряд ли; неужели», в фольклоре «до чего же» (*ай-һай матур кыз*) ~ чув. *ай-хай,* мар. *айхай,* удм. *айкай* id. – Идел-Урал региональ сүзе. К. ш. ук **Һай**.

К. ш. ук тат. *айхаемда да юк* «исем дә китми» ~ мар. *айхай,* удм. *айкай* «сизенү, күңел тоюо», чаг. кыт. *āй, һāй* «борчылу, хәстәр, кайгы».

**АК I** «белый» < гом. төрки *аķ* < *ааķ* id. Бу сүз кайбер төрки телләрдә юк («ак» – чув. *шурă,* як. *үрүң*), шунлыктан ул чагыштырмача яңа сүз булса кирәк. Аны бор. кыт. **pak* «ак» сүзеннән диләр.

**Ак** бик продуктив нигез: **аклы, аклык; акла-у** (төрле мәгъ.), **агар-у** (< **ак-ар-**), **аксыл.** К. **Агуын, Акай II, Акай-, Акбарыс, Акбүз, Аккош, Аксакал, Аксым, Акча, Акчарлак, Акшар, Аппак** һ.б.

**Ак өй** «кунаклар өчен бүлмә яки өй» – күчмәчелек чорында махсус **ак киездән** корылган тирмәне белдергән. Шуңа охшаш *ак келәт* – «туй вакытында кәләш белән кияү куна торган келәт» тә тәүдә ак тирмә булган: төркиләр таш, балчык яисә агач (буралы) өйләрдә яши башлагач та туй мәрасиме өчен ак тирмәләр ясатканнар. К. Veledi: 280.

Нәсел-нәсәп терминологиясендә **ак** (**агаби, акбабай, актүти** һ.б.) «яше буенча иң өлкәннән кала икенче» дигәнне белдерә. ЭСТЯ I: 116–117; Тимергалин: 18–19; ЗДС: 31.

**АК II** диал. (ТТДС I: 29; ТТДС II: 22–23; ЗДС: 31–32 бай мәгълүмат) «цена невесты», «взаимный подарок жениха и невесты» < мар. *ак, āк* «бәя», к. **Аклаш-у.**

**АКАЙ I** диал. «дядя; тётя» ~ төркм. *акай* «укытучы (абый)», сирәк «укытучы апа». .

**АКАЙ II: акай күзле** «пучеглазый» > мар. *акай* id. – **акай-у** фигыленнән «экстракт» булса кирәк. К. ш. ук нуг., каз. *аķай* «акай күзле».

**АКАЙ-У** «выпучить глаза, смотреть с гневом или с вожделением» – *аķ* сүзеннән (к. Радлов I: 97), чаг. чув. *шурă куçпа пăх-* «ак күз белән карау» – «акаю». К. нуг., каз. диал. *аķай-у* «акаеп карау». *Акай-* нигезендә *-ķ-* саклану аңлашылып бетми (ихтимал, < **аķ-ķа-й-*).

Дерив.: **акаеш-у, акайт-у.**

**АКБАРЫС** «барс (снежный)» собственно «белый барс»; бу сүз кеше исеме буларак киң билгеле (мар. *акпарс* < тат.). *Акбарыс* – Алтын Урда гербларының берсендәге һәм Татарстан гербындагы рәсем. Тимергалин: 18. Безнеңчә, **ак барыс** дип аерып язу – принципсызлык. Бергә язу хәерле.

**АККОШ** «лебедь» – собственно «белая птица» < чыгт., уйг. *аққуш*; бу сүз гом. кыпч., алт. *аққу* «аккош» сүзенең икенче компоненты (алт. *ку, куу, күгу* «аккош») онытылгач, халык этимологиясенчә ясалган. К. **Кош.**

**АККУ** «лебедь» (Дәрдемәнд һ.б. иске язучыларда) ~ нуг., каз., кырг., алт. һ.б. *аққу, аққув.* К. **Аккош.**

**АККҮБӘК** – имя авантюрного одноимённого героя у татар. Безнең тапкан мәгълүматларга караганда, Аккүбәк куман-кыпчак федерациясендә бер кабилә башлыгының углы булган һәм *Кидән* (*Күдән,* рус. *Котян*) хан белән низаглашып, үз кабиләсен еракка – Алтай тарафларына алып киткән. Шунда ул Чыңгыз хан әүляды белән дуслашкан һәм монгол гаскәрләре составында Көн. Европаны яулап алуда катнашкан. Монголлар аны башкортларга башлык итеп куйганнар бугай. Ул себер татар эпосында юлбашчы, кабилә башлыгы итеп сурәтләнсә, башкорт эпосының сакланып калган өзекләрендә мәзәк егет: ул ярәшелгән кәләше белән йокламаган – арага кылыч куеп: «Мин кызыл (алтын) караватта гына кызлыгыңны алачакмын», дигән. Икенче көнне аны яуга чакырганнар һәм ул сугыштан караватъ ясарлык алтын алып кайткан. Ләкин аның кәләше ул югында «карама төбендәге кара җирдә» бер көтүче белән йоклаган булган, ди. Себер төркиләрендә Аккүбәкнең бүтән маҗаралары тур. фольклор әсәрләре бар. Гомумән, бу герой күп чыганакларда искә алына.

**Аккүбәк** исемен кайберәүләр **ак күбек** дип аңлаганнар (кайбер эпик текстларда Аккүбәкне «син күбек кенә ич» дип хурлыйлар), ләкин к. кырг. *ак күбө* «ак көбә» (эчтән нygытылган калын сырма). Гарәп тарихи чыганакларында аның исеме **Ак кäбäк, Ак кубäл** «ак көбәле» (булса кирәк). Кайбер текстларда ул **ак күбәкле** «ак кендекле» дип тә сыйфатлана. Мәрҗани: 157; Урманчеев 1984: 130–143; Ögel: 321–322.

**АКЛАН** «поляна в лесу» (бу сүзне **алан** белән бутыйлар, хәлбуки чыгышлары буенча да, мәгънәләре буенча алар бердәй түгел) ~ эвен., эвенк. *аглан, авлан* id. ~ монг. *aylay, аглаг* «ерак һәм аулак урын»; мар., удм. *аклан* id. < тат. К. **Аулак.** Чаг. шумер. *ag [аг]* «кырый, чик, чүл». Ахметьянов 1989: 28–29.

**АКЛА-У** «снять обвинение; оправдать» ~ нуг., к.-калп. һ.б. *ақ-ла-у*, каз., кырг. *ақта-* «ак итү; аклау» сүзеннән. Ләкин к. диал. *ак* «хак, хаклылык». Монда мәгънә контаминациясе бар бугай. К. **Аклашу.**

**АКЛАШ-У** «договариваться о бракосочетании (о родителях и близких жениха и невесты)» – гом. кыпч. *ақ* «хак, бәя; бүләк» сүзеннән, к. кырг. *ақ* < *хақ* «гаилә корырга ярарлык», тат. диал. *ақ* «вәгъдә бүләге» (ТТДС I: 29), *хак, как* «хак», *хаклаш-* «кәләш хакы турында килешү» (Катанов 1912: 119), үзб. *хақлық* «кодаларга бүләк», ком., төркм. *ақлық* «никах, кәбен».

**АКМА** «гноеточивая болезнь (гла́за, у́ха)» ~ гом. төрки *ақма* id., ш. ук «ага торган».

**АКМАН (акман-токман)** «пора метелей в феврале-марте» – алыкман (к.) сүзеннән булса кирәк. Диал. **әкмән-төкмән, әпмән-төпмән** икенчел.

**АКРҮЛӘ** диал. «послеобеденный отдых» < диал. (миш.) *ахыр үлә* «ахыр өйлә, икенче өйлә».

**АКСАК** «хромой; хромец» ~ чув. *уксах, уксак* < *оксак* ~ мар. *оксак* < *аксак* (< тат., к. Федотов II: 273) < гом. кыпч., уйг., чыгт., алт. һ.б. *ақсақ, ахсақ* < id. ← **акса-,** к. **Акса-у.**

**АКСАКАЛ** «аксакал, уважаемый старец» < гом. кыпч., уйг. һ.б. *ақсақал* id. ~ фар. *муй сафед* «аксакал, хөрмәтле карт» (*муй* «төк, сакал-мыек», *сафед* «ак»).

**АКСА-У** «хромать» < гом. кыпч., уйг., чыгт., угыз. *ақса-,* төркм. *агса-* id. ~ як. (Пекарский I: 205) *ахсаа-* «зәгыйфьләнү, буын кату», бур. *агса-* «атта йөреп аяк ою». Гомумән, ачык түгел. ЭСТЯ I: 76; Федотов II: 273.

**АКСЫМ** «белок» ~ алт., тув. *аксым, аксымаар* «аксыл», үзб. *оксил* «аксым» (ә *оксим* – «ящур»). Сүзнең терминологик мәгънәсе – рус теленнән калька («йомырка аксымы» → «аксым»); *-сым* < *-сы-м* (ш. ук *-сыл* < *-сы-л*).

**АКСЫРГАК** «чемерица белая (ядовитое растение)», диал. (Дмитриева 1979: 74–75) *аксырдак* «чемерица» > мар. (Гордеев I: 69) *акзыргак, аксыргак* ~ башк. *ақһырғақ,* нуг., каз. *ақсырқақ.* Л.В. Дмитриева *ак сырга* тезмәсеннән ди.

Аксыргак кеше агулау өчен кулланылган һәм, ихтимал, бу сүздәге *аҡ* < *агу. Сыргак* чыннан да аңлашылмый: аксыргакның *сыра* торган үзлеге юк.

**АКТАР-У** «переворачивать; разбросать» ~ чув. *ухтар-*, *охтар-* < гом. кыпч., уйг., чыгт., угыз. *аҡтар-* id. < бор. *ағдар-*. Федотов II: 297.

**АКТИКӘН** «крыжовник» < *ак тикән* (*тикән* «чәнечке»). К. **Тигәнәк, Тикән.**

**АКТЫК** «последний», (ДС II: 30) «самый младший из детей», «наихудший, выброшенный» (*адәм актыгы* «наихудший из людей») > чув. *актăк,* мар., удм. *аҡтыҡ* < гом. кыпч. характерда: нуг., к.-калп., кр.-тат., кар. *аҡтыҡ* «актык, онык; онанык (оныкның баласы)», каз. *аҡтыҡ* «иярчен, дәвамчы», төркм., төр., аз. *аагдык, аагтык* «актык, артык», безнеңчә, тат. диал. (бор. кыпч.) *ағыт-ыҡ* «ташландык; көтүчесез далага куылган (терлек)» ← *ағыт-* «ташлау, куып җибәрү» (к. **Агыт-у**). К. ш. ук чув. *ытти* «калганнары, артыгы» сүзе дә *артыгы* сүзеннән түгел, *актыгы* сүзеннән: Э.В. Севортян (ЭСТЯ I: 78–79) бу сүзне бор. төрки *atı* «онык» сүзе белән чагыштыра (хәер, ул карарчан әйтми).

Тув. *аактыг* «капризлы (бала)», як. *ахтаах* «исләнгән, бозылган (май)» сүзләренең *актык* сүзенә катнашы юк. Ләкин тув. *актыг* «хәтем, мәетне искә алу (мәҗлесе)», ихтимал, *актык* белән баглыдыр.

**АК-У (акты, агу)** «течь, протекать» < гом. кыпч., гом. төрки *аҡ-,* угыз, хак. *ах-, аг-,* тув. *аъҡ-* ~ себ. тат. (Тумашева 1992: 253), үзб. диал. *ыҡ-,* чув. *йух-, йох-* id. < бор. (болг.) **айыҡ-, *ыйыҡ-* сүзеннән булса кирәк (к. ш. ук мар. *йоҡ-* «агу», *йогын* «агын, агым» һ.б.).

Шунысы игътибарга лаек ки, моңа охшаш һинд.-евр. сүзләре бар: гот. *ahwa* «елга, агым», *аһа* «агым», хотан-сак телендә *хāһа* «чишмә», лат. *aqva* «су, агым» ~ (ЯТ: 360), тохар. *yok-* «эчү». Төрки сүзнең тохар теленнән алынган булуы ихтимал (*агым су* «эчәрлек су»!). Чаг. ш. ук **Алкын.** ЭСТЯ I: 118–119; Федотов I: 495–496; Ахметьянов 1989: 28.

**Ак-** продуктив нигез: **агыл-у, агыз-у** (дөрес булмаган йөкл. юн. формасы); **агым, агын; акма** (шеш тур.).

**АКУЛЧА,** ш. ук (ДС II: 29–30, 249, 255) **акулча, әкүлсә, үкәлчә** «околица» > мар. *окулча* > чув. *укăлча* > мар. диал. *угылза* id. – рус теленнән. Федотов II: 272–273.

**АКЧА** «деньга, деньги», тар. «единица счёта денег» ~ чув. *укҫа* < *окҫа,* мар. *окса*, удм. *уксё* ~ гом. төрки *акча* id., төп мәгънәсендә «ак нәрсә», ягъни «көмеш тәңкә», к. чыгт. *аҡча* «ак кына», морд. М. *акша* (< нуг.) «ак, аклык, акмык».

**Акча** сүзе төрки телләрдән бик күп күрше телләргә кергән.

**Акча**ның **ак** сүзеннән икәнлеге турында XIII г. итальян сәяхәтчесе Й. Барбаро (к. Барбаро и Контарини о России, М. 1971: 154) яза: күп кенә телләрдә, – ди ул, – «акча» мәгънәсендәге сүз «ак» сүзеннән ясала, мәс. мингрел. (грузин) *tetari,* грек. *аспр*, исп. *bianche,* төр. *акча* – барысы да «ак» һәм «акча». Хәзәр акчасы *шэлэг* (> бор. рус. *щеляга*) да яһ. «ак» дигән сүздән (к. Новосельцев 1990: 117, 120).

**Акча** сүзе тур. әдәбият бик ишле, мәс., ЭСТЯ I: 120–121; Фалина 1974: 193–204; Федотов II: 273; Тимергалин: 20.

Русча *белка* «тиен» тат.-төркичә **акча** сүзеннән калька (*ак ~ бел, -ча ~ -ка*): Ибне Фазлан әйткәнчә, тиен тиресе акча ролен үтәгән (к. **Тин I**). Чаг. мәкаль: *Ике тиен – бер акча* (димәк, **акча** акча берәмлеге мәгънәсендә дә йөргән).

Дерив.: **акчалы; акчалан-у.**

**АКЧАРЛАК** «белая чайка» < **ак чарлак** (кушма сүз): к. себ. тат. *царлак*, ком., алт. диал., төркм. *чарлак*, чув. *чарлан, чарлак* «акчарлак; челән», башк. *сарҙак,* кырг. *чардак*, каз. диал. *шардаҡ* id. *Чарла-, чарылда-* тәкълиди сүзеннән; хак. *сарлах, сарыглак* «ас, суыр» икенче тамырдан.

**АКШАР** «побелка; известь» < *ак шар* (кушма сүз): себ. тат. *шāр, шағыр* «ак буяу» (> бор. рус. *шаръ* «буяу», *шаръчии* «рәссам, живописец», к. Срезневский III: 1983.

Себ. (Тумашева 1992: 248–249) **шагыр** «буяу» монг. *чагар* «ак буяу, аклык» сүзеннән булса кирәк, к. **Чагыр.**

**АКЪЯЛ батыр** – сказочный персонаж, «богатырь с белой гривой». Акъял батыр сюжеты күп төрки, монг. әкиятләрендә очрый. Салар халкында (Тенишев 1964: 102–106) **Акъял** батыр **Масембу** дип атала, бу сүз Кытай-Тибет телләрендә «ат углы» мәгъ. Салар әкиятендә **Масембу** биядән туа. Төрки-монг. әкиятләрендә «биядән туу» мотивы юк. Акъял ~ Масембу образы Тибеттан килсә кирәк.

**АКЫЛ** «ум» < гар. *ʻакл* id. > **гакыл** «танып белгәнне гомумиләштерә алу сәләте», гар. *ʻкл* «ярашлы булу» тамырыннан, шуннан ук к. **Мәгъкуль.**

Дерив.: **акыллы, акылдар** («хикмәт иясе»), **акылсыз, акыллан-у, акыллаш-у, акылчы.**

**АКЫН** «акын» < каз., кырг. *акын* < фар. *ахōнд, ахунд* «укымышлы» > тат. **ахун** «өлкән мулла». К. Җәләй 1953: 324–329.

**АКЫР-У** «орать» > чув. *ахăр-*, мар. *акыр-* id. < гом. кыпч. *акыр-* < *айкыр-*, үзб. *һайкир-, һайкыр* id. – *һай!* дип кычкыру.

Бу сүздә күренгән *-кы̌р//-кěр, -гы̌р//-гěр* форманты тәкълиди сүзләрдән бик күп фигыльләр ясалуда катнашкан: к. **ажгыр-у, бакыр-у** (*бак-кыр-?*), **выжгыр-у, җикер-ү, йөткер-ү, какыр-у, кикер-ү, кыйгыр-у, кычкыр-у, өшкер-ү, пошкыр-у, пыжгырт-у, сеңгер-ү, сызгыр-у, төкер-ү, төчкер-ү, үкер-ү, чажгыр-у, чакыр-у, ыжгыр-у** һ.б. Кайбер очракларда *-к//-г, -к//-г* редукцияләнгән, к. *өфер-ү* > *өр-ү* (< *өфгер-ү*), *усыр-у* < *усгыр-*, *уфыр-у* < *уфгыр-* һ.б., *-гыр* аффиксы гомумән аерым сүздән булса кирәк. К. Федотов I: 72.

**Акыр-** продуктив нигез: **акырык; акырыл-у, акырын-у, акырыш-у, акырт-у.**

**АКЫРЫН** «медленно; медленный» ~ сөйл. **әкерен, әкрен** (бераз стилистик аерма белән) id., **акыртын, әкертен** – рәвеш мәгъ.; диал. (ЗДС: 35) **акыр, акырт, әкерт,** башк. (БТДС: 424) *әкерес* формасы да бар.

Бу гом. төрки сүз бор. **акур-* «әкрен башкару» сүзеннән (ЭСТЯ I: 123–124); ул фигыльнең борынгырак яңгырашы *аккур-* булса кирәк, моңа, беренчедән, ике сузык арасында *-к-* авазының саклануы, икенчедән, алт. *аккырын* формасы шәһадәт итә. Әгәр төп форма *аккур-*, *аккыр-* икән, **акырын** сүзен гом. төрки *агыр* «авыр; әкрен» сүзе белән чагыштыру җирлеген югалта. Бор. төрки *аккур-*, ихтимал, монг. *alγur* «әкренлек», *alγu* «әкрен» сүзләреннәндер (*алкур-* > *аккур-*). Бор. төрки, тат. диал. **акру** «әкрен» бор. хәл фигыль формасыннан, ә **акырын** үзе **акыр, аккыр** нигезенең инструменталь килеш формасы булса кирәк.

**Әкерен, әкрен, әкертен** яңгырашлары тат. телендә килеп чыккан.

**АЛ I** «алый», «благородный» – соңгы («асыл») мәгънә язма ядкәрләрдә һәм фольклорда очрый: *ал кара кеш тун, ал бишек, ал тәхет* («Идегәй» дастанында), *ал балдак, ал көзге* («Заятүләк белән Сусылу» дастанында) һ.б. ~ гом. төрки *ал* «ал», нуг., ком., калм. *ал* «ал», «асыл». Һинд-евр. телләрендә *al, ol, el* «кызыл буяу бирүчән үсемлек» (ЭСТЯ I: 125–126). Ләкин, безнеңчә, төрки телләрдән күрше телләргә дә киң таралган *ал* сүзе бор. *лал* «ләгыль, кызыл рубин» сүзеннән, к. бор. төрки (Clauson: 120) *āl* «кызыл, асыл тукыма». Сүз башындагы *л*-ның төшеп калуы төрки телләрдә сүз башында *л-* авазы киләлмәү белән аңлатыла.

**Ал** «ал тукыма» (*Атласым бар, алым юк, Ал алырга хәлем юк…* Җыр) сүзе бор. ядкәрләрдә үк очрый: бу сүз белән байраклар һәм парад атларның чапрагы өчен кулланылган махсус ал тукыма аталган (МК). Будагов I: 76; ДТС: 25, 32, 167.

**АЛ II** диал. (Арсланов 1988: 71; ЗДС: 35) «хороший, хорошо; ладно». **Ал I** белән баглы булмаса кирәк – кулланышы шиккә төшерә. Чаг. як. *аал уот* «изге ут; өй учагы», *аал луук мас* «изге имән, байтирәк», *аал уххан* «изге учак». МНМ I: 61.

**АЛ III,** иск., кит. **алд** «перед, передняя часть; передний» < гом. төрки *алд, алт* «ал, ас» бор. гом. төрки «аяк асты» тамырыннан (*ал* > *аст* мәгъ. күчеше барган тарафың, юлың аяк астында калуы белән аңлатыла: *ал* тамыры фин-угор **ul* «ас» тамыры белән чагыштырыла. Гомумән, бу сүзләрнең этимологиясе бик юраулы. *Алд, аст, өст, арт* сүзләрнең уртак элементы *-д/-т* да бит төрлечә карала (к. ЭСТЯ I: 140–141).

Элекке (гарәп шрифтындагы) язылышта гадәттә *алт* сүзенең *-т* өлеше төшерелеп калдырылмаган һәм бу дөрес тә кебек (*алд як* һ.б. дип язылган), һәрхәлдә гомуми системага муафикъ.

**Ал** продуктив нигез: **алгы, алдын** һ.б. К. **Алын.**

**АЛА I** «пёстрый» > мар., удм. диал. *ала*, чув. *ола* > *ула* id. < гом. төрки *ала, аала*, гом. тунг. *ала,* монг. *алаг* «ала» һ.б. (ЭСТЯ I: 129–130).

Бу сүзне монг. *ола* < *огула* «карлы таулар (алар ала-кола күренә)» сүзеннән дип аңлату бар, к. бор. төрки (ДТС: 32) *ala* > башк. диал. *ала* «таз», *алай* «ала» (чаг. кырг., уйг. *Алатау, Алайтау, Алай* – Урта Азиядәге зур тау сырты). Räsänen 1969: 15; Федотов II: 274–275.

Күп кенә төрки кушма сүзләрдә *ал, ала* «начар» мәгънәсендә килә, к. **Алагаем, Алафарман.**

**АЛА II** диал., (ЗДС: 35–37) **алата, алаты, алатык, алатыгы** «начиная с» ~ мар. диал. *алата* id.

Тат. телендә килеп чыккан сүз булса кирәк. **Ал-у** фигыленнән бугай, *т* элементы аңлашылмый.

**АЛАБУГА,** диал. (ЗДС: 35–36) **аламага, аламуга** «окунь» ~ хак., тув. *алабуга, алапуга* «алабуга», ләкин уйг., үзб., кырг. *алабуга* «форель, алабалык». Һичшиксез *ала* сүзеннән (к. ш. ук чув. *уланкă*, мар. *оланга, аланга* ~ бур. *алгана, алагана* «алабуга»), ләкин **-буга**сы аңлашылып бетми (**буга** «үгез» мәгънәсе монда урынсыз кебек).

**АЛАБУТА**, диал. (ЗДС: 35, 451, 456, 559) **алабата, алабота, лабута, ләбәтә, либәдә** «лебеда», ш. ук «амарант» ~ гом. кыпч. *алабота, алабута,* уйг. *алапута*, кырг. *алабата* (мар. *алабута,* удм. *алабута* < тат., к. Гордеев I: 78). Әгәр бу сүз рус. *лобода* «лебеда» сүзеннән булса, каз., кырг., уйг., үзб. *алабута,* төркм. *алабота* һ.б. – тат. теленнән таралган.

Ләкин икенче бер фараз да яшәргә хаклы: башк. *алабүтә* «алабута» сүзендәге **бүтә** < гом. төрки, монг. *бута, буть* «куак, курай» (Номинханов 1975: 289). Ләкин башк. (БТДҺ: 424) *әлбиҙ* < *әлбидә* «ак алабута» рус. *лебеда* белән гомоген, әлбәттә. Себ. (Тумашева 1992: 21) **алабатан,** *ала бытын* «алабута» (?) < *ала бадан* булуы ихтимал, к. **Бадан.** Тимергалин: 21.

**АЛАГАЕМ [а°лағайы̆м]** «чрезмерно; грубо; не вникая, чёрствый» ~ үзб. диал., каз., кырг. *алағайым* id. < *ала кайым: ала* «начар», *кайым* «торыш, караш» (гар. булса кирәк). Тат. диал. (ТТДС I: 31) *алагайып* халык этимологиясе нигезендә ясалган. Чаг. ш. ук тат. диал. **алакай** «тыйнаксыз», **алайукка** «бушка; кирәксезгә», башк. *алаққаҙау* «дуамал», каз. *алақыйғы, алақыйғаш* «юкка ямьсез кычкыру» һ.б. сүзләрдә **ала** «начар, ямьсез». К. **Алакан II.**

**АЛАЙ I** «полк; парад; процессия» < чыгт., төр. *алай, алайы, алайыш* id. Төрек сүзлекләрендә грекчадан диелә. Икенче бер аңлату буенча, гар. *галәи* «бөтен гаскәр» сүзеннән. К. ш. ук Räsänen 1969: 15.

**АЛАЙ II** «так» (> чув., мар., удм. *алай* id.), тат. диал. **әләй** < *аллай* < *анлай,* к. к.-балк. *аллай* «алай». К. **Ан II.**

**АЛАЙСА(К)** «в таком случае» < *алай исә(ң).* К. **Алай II.**

**АЛАКАН I** диал. (ЗДС: 35) «ладонь» ~ каз., кырг., алт. *алақан* id. («баһадир учы»: к. *Ялан кебек алақанын җәя төшеп исәнләште»*, Маадай-Кара: 158 һ.б.) ~ монг. *alaγan* ~маньч. *falaŋgu.* Räsänen 1969: 15.

**АЛАКАН II** диал. (ЗДС: 35–36) «паника»: *алақанна-* «күз-баш әйләнү» ~ каз. *алақан* «паника» ~ бор. төрки (ДТС: 33) *alaŋad-, alaŋu-, alaŋur-* «хәлсезләнү». Чаг. **Алагаем.**

**АЛАМА,** диал. (трбс. һ.б.) **аламак** «плохой, дрянной; дрянь», тат. диал. (Остроумов 1892: 42) *әләмә* «арык; начар», тат. диал. (удм., мар.) *аламасалама, әләмә-сәләмә, алам-салам, әләм-сәләм* «һәртөрле начар», чув. *элем-селем* «рәтсез; чуар киемле», каз., чыгт. *алама* «чүпрәк-чапрак, иске-москы». Рясянен каз. *аламай*, алт. диал., кырг. *аламық* «ала тышлы, чуар, төрле» сүзләреннән чыгып, *аламаны ала* сүзеннән дип бара. Пекарский (I: 240–241) як. *äлäмä* (хәз/ сүзлекләрдә *элээмэ*) «чүпрәк-чапрак» сүзен тат. *алама* белән бәйли, ләкин як. сүзе *äлäi-* «искерү, тузу» ~ монг. *äлä-* «(кием) тузу» фигыленнән һәм аның *ала* сүзенә багланышы шикле.

*Алама* < *аламак* < *аламык* булса, **ала-мык:** *-мык* ашамлык атамаларын, шулай ук авыруларны белдерүчән кушымча (чаг. *боламык, карамык, кызамык*). **Ал** «начар әшәке» тамыры тур. к. Сыздыкова Р.Г. Роль семантической реконструкции словоформ // Проблемы этимологии… 1990: 139–145.

Чаг. ш. ук гом. төрки *ал, алу* < *алығ* «хәйлә; начар, әшәке; кыргый; буталчык», к. **Ала, Алагаем.**

**АЛАМАН** «шайка всадников» ~ башк. *аламан* «таланган улҗа, талаучылар төркеме; талпа», *аламансы* «талаучы»; каз., кырг., төркм. *аламан чап-* «талау сәфәре оештыру», *аламан* «атлы юлбасарлар төркеме; чуар төркем» < фар., чыгт. *ғулāмāн* «яллы гаскәрләр» > тат. диал. (ТТДС 1969: 140) *әләмән* «төрле төстәге, аралаш». К. **Әләм-әтрәк.**

**АЛАН** «площадка, поляна», диал. «крытая площадка» > мар. *алан* «болынлык өчен махсус чистартылган урман кисентесе», удм. *алан* «аклан, урман эчендәге болын», рус. *алан* «урмандагы туры кисенте» ~ нуг., каз. *алаң, алан* «алан, болын», төр. *al* «түбәнлек»; бор. төрки *alan* «мәйдан, чистартылган мәйданчык». Бу сүзне эстон. *alan*, фин. *alanko* «түбәнлек, язы» белән чагыштыралар (Мурзаев 1984: 44–45) һәм *ялан* сүзеннән дә

аермыйлар (Севортян I: 130–136). Өстәвенә, табигый рәвештә, **аклан** сүзе дә *алан* белән бердәй дип карала. Бик ихтимал ки, монда очраклы охшашлык та юк түгелдер. Һәрхәлдә без *alan, aklan* һәм *ялан* сүзләрен аерым нигезләр дип карыйбыз. К. ш. ук **Алачык.** Насипов 2007: 59; Тимергалин: 21.

**АЛАН-ЙОЛАН (карану)** «с разбегающимися глазами (смотреть); разбегающиеся (о глазах)», **алаңла-у** «беспокойно озираться» ~ башк. *алан-йолан, әлән-борхан, алан-елән (булу),* кыпч., уйг. *алаңла-,* каз., кырг. *алаңда-* «куркынып карау, борчылып карану», кырг., алт., уйг., монг. *алаң* «гаҗәпләнү хәле», төр. диал. *алан-талан* «асты өскә килү» һ.б. Сирәк кулланылгач, бу сүзнең дериватлары аз һәм чыгышын билгеләү дә кыен. Räsänen 1969: 16.

Дерив.: диал. **алаңла-у** «артыкча куркыну», чаг. ш. ук (ЗДС: 36) **алаңгыр** «куркыныч зур (бер субъект, зат итеп күзаллана)».

**АЛАП** (Троянский I: 60, ЛТ I: 29) «большой короб (из лыка, бересты)» > мар., удм. *алап* id. (к. Гордеев I: 81) – Идел-Урал регионы сүзе булса кирәк; каз. *алап* «әрҗә; зур улак» (ихтимал, татарчадан яки башкортчадан), каз. диал. *алап* «ян-як, бордюр, рам» (Аманжолов: 355). Чаг. башк. (БТДҺ: 250) *алап* «балчык белән сыланган кәрзин».

**АЛАПА I** «грубый голос; грубый, громкий разговор», диал. «большой и нескладный» (о человеке) – ачык түгел. Чаг. һинд. *ālāp, ālānpa* «алапа, тупас кычкырулар». Бәлки **алып** сүзе тәэсирендәдер.

**АЛАПА II** «трофей», «премия за храбрость в бою; компенсация за рану» к. **Әләфә.** Velidi: 291; ҚТАС: 51 (*алапа* «кызлык өчен бүләк»).

**АЛАР** «они» < **анлар,** к. **Ан.**

**АЛАТУБА** «горлица; вяхирь» ~ чув. *улатăпа, олаппа* id. < **ала туба** «ала томшык», тат. диал. **туба** «шешмән томшык», чаг. башк. *тубар* «җилекле сөякнең шешмән башы».

**АЛАТЫР** – название этнографической группы татар в Башкортостане, а также нескольких деревень (одна из них – русская). Ихтимал Чувашстандагы *Алатырь* (кала һәм елга исеме) якларыннан килгәннәрдер. Рус халык риваятьләрендә хикмәтле бер *алатырь-камень* тур. сөйләнелә, ләкин ул «ташның» кайдалыгы, чыгышы тур. мәгълүмат юк, к. Фасмер I: 69. Бор. рус. *Алатырское море* «Балтыйк диңгезе» белән чагыштыру да (МНМ I: 57) тайгак.

**АЛАФАРМАН** «сломя голову, во всю прыть» ~ башк. *алабарман* id. < *ала фәрман* «начар фәрман; афәт хәбәре». К. **Ала I.**

**АЛАХАН** диал. «конский щавель» (ДС II: 32) < монг., к. бур. *алагхан* «чуаркай, чуар башаклы» Чаг. **Алакан I.**

**АЛАЧ** – общий уран (клич, девиз) кыпчакских народов (шуннан **Алач Урда** «борынгы кыпчак дәүләте» ~ кырг. *алач*, каз. *алаш* id.) себ., нуг., кырг., үзб. *алас* ут аша сикереп «арулану», ант итү, яшь кәләшләрне, атларны һ.б. учак аша чыгарып, явыз рухлар кәсәфәтеннән коткару йоласы һәм шул вакытта әйтелгән ымлык һәм такмаза: тат. диал. (Тумашева 1992: 21) *алас, алас, һәр бәладән халас!* Кырг. *алас, алас, балакеттен калас!* Үзб. *алас, алас, күлли балодан халас!* [Бу сүзләрдә *калас* < *халас* < гар. *ẖalāṣ* «саф, ару, чир-чордан азат»]. Алт. диал. *алас* – төтәсләү өчен яндырыла торган үлән исеме.

Казан арты татарларындагы *әләшә* – яшьләрнең язгы бәйрәме – су буена чыгып учак, калау ягуын белдергән сүз дә (ТТДС I: 543) *алас, алач*тан булса кирәк.

Утка табыну, ут-учак ярдәмендә «чистарыну» иң беренче чиратта бор. ирани халыкларга – зәрдүшт диненә хас. Һәм ир. телләрдә *āл* «ут рухы», *мадари-āл* «ут анасы» – корбан таләп итүче рух. *Āл* сүзе бор. ир. *aδr* «ут рухы» сүзеннән (ЯТ: 298).

**Алас** сүзе вә йоласы Көньяк Себер төркиләрендә – алт., хак., тув. – бар, як. телендә дә аның эзләре саклана: *аал уот* «өй уты, ут рәвешендәге өй иясе, изге ут» (к. Пекарский: 67–71, 88). Бу фактлар *алач ~ алас* сүзенең ир. телләрдән (бәлки, сугдлардан) төркиләргә X г. кадәр үк кергәнлеген раслый.

**АЛАЧА** «пестрядина; дерюга; полосатая ткань» (ЛТ I: 28; ДС I: 13) > мар., удм. *алача* id., төр. *alaca* «клетчатая ткань» (Насибуллин: 105), чув. *улача* id. ~ башк. *аласа*, каз., к.-калп. *алаша*, бүтән төрки телләрдә *алача* (Радлов I: 361–363) – *ала-ча,* ягъни *ала* сүзеннән (к. мар. диал. *ала* «алача», Саваткова: 8). Тәүдә бу сүз (һәм тукыма) Урта Азиядә килеп чыккан дигән фикер бар.

**АЛАЧЫК** «примитивное жильё со стенами из плетня; летняя кухня» – татар этимологиясендә **алды ачык** дип тә тәгърифләнгән бу сүз барлык төрки вә аларга күрше телләрдә очрый (мәс., бор. рус. *алачюга* – Срезневский I: 1379 ~ хәз. рус. *лачуга*): кырг., төр., ком., кар. һ.б. *алачық,* куман., чыгт. *алачуқ* «алачык», тат. диал. (ДС I: 13), алт. *алачык* «ихата, кәртә», алт. *аланчык* «кабык тирмә; кәртәлек», чаг. тат. (әд. телдән) *алан* «тәрәзәле лапас, казарма».

Мәзкүр сүзләрдән чыгып, *алачык* < *алан-чык* «кечкенә алан» дип уйларга мөмкин, ләкин бу сүзнең бу мәгълүматлар кәртәсенә сыймаган вариантлары бар: чув. *лаҫ, лаҫӑ* << тув. *алажы, алаҗы* < бор. төрки (МК, Clauson: 129) *alaču* «алачык»; як. *аласа* «ышык җир, утар, ихата»; башк. *ылаш* «корыт киптерелә торган таскак» һ.б. ЭСТЯ I: 130–132. Ахметьянов 1989: 128; Аникин: 81–82; Федотов I: 331.

**АЛАША I** «мерин», диал. (миш.) **алаш, алаша** «лошадь» > мар. *алаша*, удм. *олоша, улошо* ~ гом. кыпч. *алаша* id. > аз. *алаша* id.; төр. *алаша* «менге ат; парад аты» (шуннан булса кирәк ком. *алаша* «тулпар» > кырг. *алаша* «матур, сылу»), төркм., каз. диал. *алаша* «токымлы ат (яисә дөя) белән токымсыз ат (яисә дөя) кушылгагы», төркм. *алаша* «айгыр».

Бу сүзне Рясянен һәм Севортян гом. кыпч. *алаша* «тәбәнәк» сүзе белән бәйлиләр (ЭСТЯ I: 136–137), ләкин, безнеңчә, слав. телләрендәге материал моны расламый; рус. *лошадь* «ат», *лошак* «мул, качыр», укр. *лоша* «колын», пол. *losza* «бия» ~ чув., үзб. диал. *лаша* «ат», «алаша» бор. чыганакта бу сүз башында *л-* булганлыгын күрсәтә һәм аны бор. монг. *loša* «качыр, алаша» (Зәмәхшәри, к. Поппе 1938: 103, 232), тунг.-маньч. *лӧс, лосо* «мул, качыр» (ССТМЯ I: 505) сүзләре белән чагыштырырга мөмкинлек бирә. Дёрфер фикеренчә (Doerfer IV: 262–263), *алаша* төрки телләргә монг. теленнән таралган, бор. монг. *alasas* «Хуай провинциясеннән килгән ат токымы» < кыт. *лоӊзы* «качыр, ат урынына файдаланылган хайван» (*ло* «ат»); А. фон-Габэн кыт. *lotsŭ* «ат кушылгагы», *malotsŭ* «мул», *lülotsŭ* «качыр» сүзләре булганлыгын күрсәтә (Gabain 1973: 42).

Безнеңчә, **алаша** < *ат-лоша* дигән парлы сүздән (*«Ат» ~ «алаша»* мәгънә күчеше тур. к. **Ат**), ә рус. *лошадь* < *лоша-ат*. Ахметьянов 1989: 75; Федотов I: 332 (рус. *лошадь* тур. безнең версияне кабатлый). К. ш. ук Тимергалин: 23 (төрле фаразлар китерелә).

**АЛАША II** диал. (ЗДС: 37) «низкий» ~ гом. кыпч. *алаша*, нуг., каз., к.-калп. *аласа*, тат. диал. (ЗДС: 37) *алача* (казакчаның «кайтавазы») id. *алашак* «түбән-тәбәнәк» сүзеннән булса кирәк, к. бор. төрки *al* «түбәнге як», *ašaq* «тау итәге, тау асты». К. **Ашагы.**

Безнеңчә, **Алаша I** гә катнашы юк (чөнки *алаша*лар аеруча тәбәнәк булмый).

**АЛӘТ** «орудие, оружие, инструмент» < гар. *ālāt* id. (к. Будагов I: 81).

**АЛБАЙ** (Г. Исхакый) «полковник» ~ добр. (Dobr. I: 65) *albay* id. < *alay beyi* «алай бәе» дип аңлатыла. Бу сүз тат. телендә XVI г. бирле билгеле.

**АЛБАН** – вид подати. К. **Алман II. Албан** яңгырашында Көньяк Себер төркиләрендә, элекке себ. татарларында, төрле рус документларында билгеле, к. Аникин: 82.

**АЛБАСТЫ** «злой домовой; ночной кошмар» > мар., удм. *албаста,* рус. диал. *албасты, албастый* id. ~ гом. кыпч. *албасты,* нуг., ком. *албаслы,* уйг., үзб. *албасти,* төркм. *албассы,* таҗ. *алмасты* id. Төньяк Кавказ телләрендә *алмосту, албасты* «хатын кыяфәтендәге явыз рух» һ.б. Г.А. Климов һәм Д.И. Эдельман бу сүзне бор. Месопотамиядә билгеле булган *labasty* дигән мифик зат белән бәйлиләр (СТ № 3, 1979: 57–63). Ләкин, безнеңчә, монда очраклы охшашлык кына, чөнки уртак тарихи җирлек ачык түгел. **Албасты** сүзен алт., тув. *абыс, алмыс, аламыс*, монг. *алмас, аламас* >> чув. *алпас,* шор. *ылбыс* «албасты; мифик кар кешесе; утлы өрәк» (к. Радлов I: 434–438, 1380) сүзеннән аерырга ярамас кебек; бу *алмас, албас* сүзенең кырг. *албың* ~ монг. *албын* «шайтан кызы» вариантлары да бар. Безнеңчә, бу сүзләрнең тамыры яисә бер компоненты бор. төрки < ир. *āл* «хатын-кызны интектерүче явыз ут рухы» (к. **Алгазы**), *басты* исә *барыс* сүзеннән, к. себ. *албарты* < кырг. *албарсты* «албасты» (ул бала табучы хатыннарга зыян сала), чаг. ш. ук як. (Пекарский I: 69–71, 88) *илбис* «шайтан, сугыш рухы; убырлы карчык», *албас* «хәйлә, сихер», *албастах* «сихерләүче рух» һ.б. Алт. диал. *алты кӧстү ала барс (парс, марс)* «алты күзле ала барыс» – явыз рух. К. ш. ук кырг. *қарабасты* – явыз рух төре, төр. *ал карысы* «убырлы карчык».

**Албасты** тур. әдәбият күп кенә: һәр халыкта ул үзенчәлекле образ (биредә без аларның барысын да тасвирлап бетерә алмыйбыз). Федотов I: 35–36

(чув. *алпастӑ* һ.б. татарчадан, ди); Ахметьянов 1981: 16–17; Инан: 177–179; Тимергалин: 22–23.

**АЛБЫР** диал. «клубы дыма, тумана; облако; в клочьях, клубах; рваный (об одежде)» гом. кыпч. характерда: нуг. *албыр (албыр-ялбыр)*, кырг. *албыр* «албыр, тетелгән (кием)», шуннан, башк. (БҺҺ II: 25) *албыра-, ылбыра-* «тетелү, ялбырлану; өлешләргә бүленеп таркалу», *албырла-у* «хәлдән тайдыру».

Бу сүзләр белән иске тат. (Будагов I: 80) **албырга-у** «эш юктан гына шөгыльләнү» ~ башк. *албырғат-у* «юату, әветү», *албарға-у* «юану», тат. диал. (ЗДС: 38) **албыра** «аптырап тору», каз. *албыра-* «хәлдән таю» сүзләре дә тамырдаш булса кирәк.

Себ. **албыр-у** «алсулану» (Тумашева 1992: 22) фигыленең мәзкүр тат. сүзләренә катнашы ачык түгел.

**АЛГАЗЫ** (ДС II: 32; ТТДС I: 34; Зимасов: 10) «чрезмерно бойкий (преимущественно о девочках); дух-обжора» << төркм., төр. *алгызы, ал кызы* «ал (дигән утлы җен) кызы; усал рух; албасты», чаг. ш. ук як. *илбис кыыһа* «илбис (албасты) кызы, сугыш алиһәсе, үтереш рухы». Ф. Гордеев (I: 83) мар. *алгазе* «шаян бичура» сүзен тат. *алкачы* «алка урлаучы наян» дип аңлата.

**АЛГАРЫ(ГА)** «вперёд; далее» тат. теленә аеруча хас сүз, хәз. һәм бор. телләрдән күбесендә күренми. Чаг. ш. ук тат. диал. **арткары, аскары, өскәре, соңгары, сулгары, табары, төпкәре, тышкары, читкәре, эчкәре, яңгары** һ.б.ш. Болардагы *-гары//-қары, -гәре//-кәре* кушымчасы монг. *-гар* «кул» сүзе белән чагыштырыла (чаг. тат. *уңкулга, сулкулга* һ.б. китү). Минемчә, бу кушымча төрки *-қа* + фар. (ир.) *руй* «йөз» (*алга руй* «алга йөз»).

Дерив.: **алгару; алгарыш** («прогресс» мәгъ. әд. телдә), **алгарту** («алдан сизү, белү»); **алгарсын** һ.б. Боларны аерым әдипләр ясаган дип гөман итәм.

**АЛГАСА-У, алгыса-у, алгас-у** (ТТДС I: 34; БТДҺ: 20) «шалить, озорничать; увлекаться, обольщаться, возбуждаться; тревожиться (от призрачной причины)» > башк. *алғаһа-, алғыһа-* «ярсыну, сагышлану», чув. *алхас-* «артыкча шаяру, алгасу» ~ кар., к.-балк., төркм., як. *алғаса-,* госм. *алңаса-* ~ бур. *алгаса* «үзеңә контроль югалту, таркаулану; алгасу» ← монг. *алга-* «язлыгу; мәрәйгә тимәү» нигезеннән (бу нигездән монг. телләрендә бик күп сүзләр ясалган), ләкин, безнеңчә, *алгаса-* < *алгас-а,* к. як. *алгаҫ* «ялгышлык», *алғаһаа-* «ялгышу». Э.В. Севортян **алгас** сүзен гом. төрки *алық* «тилемсә» нигезе белән бәйли, ләкин аның чагыштыруларында диффузлык сизелә (к. ЭСТЯ I: 145–146). К. **Алгаш-у.** Чаг. **Алан-йолан.**

Дерив.: **алгасак** «җиңел ярсынучан, җилкенүчән», **алгысат-у** «мавыктыру». Моның кебек сүзләр (*алга* нигезләнгән) монг. телләрендә бик күп.

**АЛГАШ-У** иск. (Будагов I: 84) «пленяться, увлекаться», шуннан *алгаштыр-* > мар. *алгаштар-* «үзеңә гашыйк итү; сихерләү». **Алгаса-у** һ.б. белән баглы, әлбәттә. Чаг. добр. (Dobr. I: 72) *algaš-* «алга китү».

**АЛГЫР** «бойкий, удачливый» < гом. кыпч. *алгыр,* чыгт. *алғур* һ.б. «киек кошларны еш ала торган (лачын һ.б.ш.)». К. **Ал-у.**

**АЛДАЛА-У** «обманывать» > чув. *олтала-* > мар. *ондала-* id. **алда-у** фигыленең Идел-Урал регионында таралган ешайту формасы (бүтән төрки телләрдә юк шикелле).

**АЛДАР, Алдар күсә, Алдар таз, Кырыгалдар** «легендарный каллап-расказчик, хитрец и плут у кыпчакских народов» > мар., удм. *алдар, алдар-таз* (к. Гордеев I: 84) «хәйләкәр, мут, алдакчы», гадәттә *алда-у* фигыленә нисбәт ителә, ләкин чаг. монг., бур. *алдар* «дан, чап, атак» – тунг.-маньч. *алду* «дан, хәбәр, яңалык». к. ССТМЯ I: 31.

**АЛДА-У** «обмануть; врать» ~ чув. *улта-* < *олта-*, удм. *алдайа-* < гом. төрки *алда-,* венг. *alta-ni* id. ~ монг., бур., эвенк. һ.б. (ССТМЯ 1: 31) > фар. һ.б. *āл (аал)* «хәрби хәйлә, мәкер» сүзеннән дип исәпләнә. к. (Räsänen 1969: 14; ЭСТЯ I: 126–127), Федотов II: 278.

Шул ук *аал* тамырыннан бор. төрки (МК) *alčı* >> каз. *алжы* «алдакчы» сүзе ясала. **Алда-у** фигыленнән этимологик тикшерүгә мохтаҗ кайбер нигезләр ясалган, мәс., тат. диал. **алдаwыр** > удм. *алдаур* «алдаткыч» (Алатырев 1976: 144–145). К. ш. ук бор. төрки *алда-* «язлыгу, хаталану; югалту». К. Räsänen 1969: 17.

Дерив.: **алдан-у, алдаш-у, алдат-у; алдак** (бу сүзләр күрше фин-угор телләренә дә кергән).

**АЛДЫР** «разливательная чашка» ~ мар. *алдыр, алтыр, алдэр* «зур чүмеч; уҗау», чув. *алтӑр*

«зур чүмеч», «бәләкәйрәк ялгаш, улак»; башк. *кытайалдыр* «чынаяк», *ташалдыр* «керамик кясә», *алдыраяк* «кечерәк чынаяк», удм. *алдур* «сыра бүлү чүмече», тат. диал. **ташалдырык** «таш ялгаш» (к. ДС III: 152).

В.Г. Егоров (1964: 25), чув. *алтăр* сүзен *алт*- «чоку, ую» сүзеннән ди. Ф. Гордеев (I: 85–86) *алдыр, алдур*ны удм. *дуры* «чүмеч» сүзеннән чыгып аңлату яклы (*дуры* ~ коми. *дари* id. исә һинд-ир. *darvih* «агач кашык» сүзеннән дип уйланыла). Тат. *алдырык* варианты бу фаразларның берсенә дә туры килми.

Л. Будагов (I: 83) тат. *алдыз* «соскы, сиптергеч, су сипкеч» сүзен китерә, ләкин бу вариант бүтән чыганакларда күренми, шунлыктан аны хата язылыш дип уйларга мөмкин (гарәпчә ر өстенә ялгыш нокта кунган). М.Р. Федотов (I: 37) тат. **алдыр, алдырык** сүзләрен белми.

**АЛДЫР-У** «быстро двигаться; успешно работать» – бу сүзне гадәти сүзлекләрдә **ал-у** сүзенә (аның йөкл. юн. дип) нисбәтлиләр, ләкин эзлекле мәгънәви бәйләныш ачык түгел. Чаг. уйг. *алдыра*- «ашыктыру, ашыгу», төр. *aldırış* «игътибар». Тат. диал. (ЗДС: 39) **алдыргыш** «тапкыр», (ТРС: 2007) **алдырык** «размах». Чаг. **Әлдермеш.**

Норматив **алдыр-у** («алырга әмер яисә мөмкинлек бирү») сүзенең мәгъ. киң булгач, **алдыру** «булдыру» гади сөйләмдә дә телдән төшеп бара.

**АЛҖЫ-У,** диал. (ДС I: 15) **алҗа-у,** себ. **алцы-у** «выбиться из сил; впасть в детство от старости» < гом. кыпч. *алҗы*-, ком., к.-балк., төр. һ.б. *алҗа*-, кырг. *алчы*-, кар. *алаҗай-,* башк. *алйы-, алйа*- һ.б. id. ~ бор. монг. *alǯija-,* монг., бур. *алҗаа*- > эвенк. һ.б. тунг.-маньч. (ССТМЯ I: 32) *алза*- «алҗу, хәлдән таю, акылдан язу». К. ш. ук себ. (Тумашева 1992: 32) **алцык** «алҗыган», тат. диал. **алҗыра-,** чув. *алчăра*- «аптыраштa калу, шашу» ← **алҗыр,* шор. *ылчыр* «хәлсез». ЭСТЯ I: 145–146.

Чаг. ш. ук бур. *аалишаг* «тыныч, юаш», *аалин* «тып-тын», тунг.-маньч. (ССТМЯ I: 32) *ал-, ала*- «тыныч-юаш булу».

**АЛҖУСЫККА** диал. (трбс.) «понапрасну; формально, ради проформы» ~ башк. *алъюҫыкка* id. – *ал юсыкка* тезмәсеннән, к. **Юсык.** Башк. сөйләшләрендә *ал-, алый*- «начар, кирәкмәгән» мәгънәсендәге префикс: *алйөрем* «юкка йөрү», *алйырлау* «сәбәпсез җырлау» һ.б.

**АЛИҺӘ** «богиня» < гар. *āлиһā* id.

**АЛЙОТ** «идиот» < башк. *алйыт* «алҗыт, алҗыган кеше» сүзеннән (*-т* бор. фигыльләрдән исем ясагыч кушымча); **ал-йот** дип аңлау – халык этимологиясе. К. **Алҗы-у.**

**АЛКА** «серьга; кольцо, шайба; круг (вокруг луны)», диал. «крендель» < гар. *хăлҗа* id. *хлҗ* «ышкылау, кыру» фигыленнән (*хăлҗа*ның беренчел мәгънәсе – «әйләнә булып юнылган йомычка»). *Алка* сүзе барча Идел-Урал телләрендә билгеле, к. Федотов I: 34.

**АЛКА-У,** (Тумашева 1992: 22) **алга-у** «благословлять» ~ тув., як. *алга*- > тунг.-маньч. (ССТЯ I: 30) *алга*-, бор. төрки (ДТС: 38) *alga*- «фатиха бирү; шаман догасын уку». К. **Алкыш.**

Бу сүзне тат., төркм. *әл,* тунг. *һалахан ~ фалаҗан,* кор. *pal* «уч, кул, табан» нигезләре белән чагыштыралар. ССТМЯ I: 312.

**АЛКЫМ, ылкым, ылҗын** диал. «горло, горловина; самое узкое место обуви (сапог, чулок)» ~ уйг., үзб. *илҗим* һ.б. id. < гар. *хăлҗӯм* «бугаз».

**АЛКЫН, алкым** «стрежень; бурное течение, бурный (о протоке)» ~ башк. *алкын* «күп сулы» > *алкын-ган «*тулып ашкан», бор. **алҗы-, алыҗ*- «су күтәрелү, шәбәю» сүзеннән, к. чув. *улăх*- < *алыҗ*- «күтәрелү» (Ашмарин III: 340), тат. диал. **алыкмас** – үлән төре («казаяк» диелә, к. Тумашева 1992: 23, ләкин төптә җиргә ятып үскән үлән булса кирәк), тат. сөйл. **алкын-** «ярсып агу» (*Агыйделләр алкынадыр, Алкынмас инде хәзер, Сүнде якты йолдызларым – Балкымас инде хәзер.* Җыр) ~ кырг. *алҗын*- «ярсып ыргылу», *алҗылда*- id., мар. *алкынаш* «ярсыну» һ.б.; гар. *алҗ-, алиҗ*- «тулып, ялтырап яту» төрки телләрдән. Шулар белән бергә, гаҗәп рәвештә бор. төрки *alq-, alqın*- нәкъ кире мәгънәләрдә: «төшү; шиңү, басылу» һ.б.ш. да бар. (к. ДТС: 35–39).

**АЛКЫШ** «овация, аплодисменты» < гом. төрки *алкыш* «хәер-дога, фатиха», иске *алкаш* (ЛТ I: 30) id., бор. төрки, монг. *алҗы*-, *алҗа*- «фатиха бирү; кул белән дога кылу» < **alqaya*-, к. монг. *алга* «кул чугы, уч» ~ алт. диал. *алыкан*, алт., башк., к.-калп. диал. *алаҗан* «уч»; к. бор. төрки (МК) *alkıš alkaldı* «дога кылынды», бур. *альган*- «уч; яңаклау». **Алкыш** фольклор жанры буларак та билгеле (бу сүз тур. әдәбият зур). К. **Алка-у.** ЭСТЯ I: 137–138.

**АЛЛА, Аллаһ** «Бог, Аллах» < гар. *Аллаһу* id. Гар. телендә *илаһ* сүзенең *әл-* билгелелек артикле белән килүеннән ясалган. *Алланың кашка тәкәсе, Алла бозавы* тәгъбирләрендә бор. семит кабиләләренең мәҗүси гадәтләре чагыла: корбанга кашка тәкә чалганнар, алтын бозау сынына табынганнар (к. рус. *Поклонение золотому тельцу*).

**АЛЛАГУАТ** – название большой деревни на месте современного г. Салават (Башкортостан). 1552 елда Казанны яклауда актив катнашкан нугай мирзасы Аллаһхауват исеменнән булса кирәк. К. Продолжение... VIII. СПб., 1793. С. 241, 312,

**АЛМА** «яблоко» < гом. кыпч., уйг., угыз. һ.б. *алма//elma* > мар. *алма, олма,* чув. *алма, улма, улми,* удм. *улмо* ~ коми. *үлме,* венг. *alma* id. ~ бор. төрки *almïla* > монг. *альмына* > *альман* id. Бор. төрки яңгыраш бор. һинд-евр. (яки лат. гына) *abella* «алмагач; алма» сүзеннән килә (Pokorny I: 3), шуннан да фин. *omena* «алма». Федотов II: 278, ССТМЯ I: 33.

Алманың мәдәни төрләрен һинд-европалылар үстерә башлаган булса кирәк.

Дерив.: **алмалы, алмасыз; алмалык, алмалаш-у** «алма кебек булу».

**АЛМАЗ,** иск. **алмас** «алмаз» < гар. *äлмāс* < грек. *adamas* «уалмас» сүзеннән дип исәпләнә. Рус. *алмаз* төрки телләрдән дигән фикер бар (< *уалмаз* сүзеннән!), азактагы *-з* шуның белән аңлатыла. К. ш. ук алт., хак. *алмас болот, армас болот* әкияти «тупармас кылыч».

**АЛМАН I** «немец, германец» < төр., гар. *āлмāн.* Бу сүзне төрки *алма* сүзеннән дип уйлыйлар, ләкин бор. герман кабиләсе *alleman* сүзеннән дә булырга мөмкин.

**АЛМАН II: алман би** «наместник хана – сборщик налогов» < монг., маньч. *албан, албань* «салым, хәрәҗ», бор. төрки (ДТС: 34, 37) *alban, alpan* «мәҗбүри эшләр». Velidi: 288. К. **Албан, Армай.**

**АЛМАШ** «смена», **алмаш-** «меняться» (> мар., удм. *алмаш* һәм *алмаш-,* чув. *улмаш* һәм *улмаш-*) < гом. кыпч., уйг., үзб. *алмаш* (үзб. *олмош*) һәм *алмаш-* (*олмош-*) id. бор. **алма-* < *алыма-* дигән фигыльдән (*-ма* интенсивлаштыру кушымчасы). **Ал-у** сүзеннән.

**АЛПАВЫТ [а$^{о}$лпаwыт]** «помещик» > мар. диал., удм. диал., рус. диал. *алпаут* id. ~ тат. диал. (ТТДС I: 33, 36) *албут, алпут* id. Тат. телендә тарих дәвамында төрле мәгънәләр алган сүз: Казан дәүләтендә (рус яз. ядкәрләре нигезендә) *олбуд* «ханның киңәшчесе», Касыйм ханлыгында *алпагут, алпавут* «генерал; комиссар» (*алпаwуттылмач* Уразмәт хан заманында Борис Годунов патшаның хәрби комиссары). Гомумән, *алпаwут* ~ *алпагут* сүзе бор. кыпч. берлеге заманнарында ук монг. телләреннән (?) алынып кулланылган; бор. һәм урта төрки телләрендә (ДТС: 36) *alp-alpaγut* «герой» ← *alpaγu* id. Räsänen 1969: 18; ЭСТЯ I: 139; Ахметьянов 1989: 162. К. **Алып.**

**АЛПАР I** фольк. «рыцарь, воин в доспехах» (известно и как имя собственное) < бор. төрки *алп эр, Алп эрэн* «алып ир» – эпик баһадир исеме, к. Алияров С.С. К этнической биографии Алп-Эрэна // СТ № 6, 1987: 19–28. К. **Алып.** Ахметьянов 1989: 18 (тәфсиллерәк).

**АЛПАР II** «оста көрәшче» *алпа-у* фигыленнән дә ясала ала. Ләкин бу икенче сүз була.

**АЛПА-У** (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «провести прием в борьбе; проявить геройство» ← **алп-а-,** к. **Алып.**

**АЛСЫН,** диал. (ЗДС: 39, 41, 42) **алзын, алыс, алысын** «отава, трава под снегом или из-под снега; некошеная (хорошая) трава осенью»; иск. (Будагов I: 84) *алсун* «отпрыск, отрасль», башк. *алһын* «иген астындагы үлән», гом. кыпч., аз. һ.б. *алысын* «алсын», «яшеренеп, капланып», к. **Алыс.** Бу сүз бик бор. булса кирәк, к. бор. монг. *alirsun* >> бур. *алирһан,* маньч. *алисун* «нарат җиләге; алсын», к. ССТМЯ I: 32. Чаг. ш. ук хәз. монг. *алиус, алис* «алсын; кәлшә». К. ш. ук Umre Gyarmati. Über den Ursprung von kirg. *alisin* Grummet, sprout // UAJ (Budapest), 1984. t. XXXVIII, 3: 357–365. Чаг. **Ас.**

**АЛТМЫШ** «шестьдесят» < бор. *алтымыш* < *алтым-ынч* «алтынчы (ун)» сүзеннән. Чув. *утмал, отмал* < *алтымыл* < *алтымын* булса кирәк. К. **Алты.** ЭСТЯ I: 140; Федотов II: 295.

**АЛТЫ** «шесть» < гом. төрки *алты* id. **Алты** һәм **җиде** (< *jetti*) сүзләре икесе бер модельдә һәм үзара нисбәтән ясалганнар.

Саннарның этимологиясе һәрвакыт аеруча кызыксыну уята, шунлыктан тюркологиядә дә бу бабта публикацияләр исәпсез күп; татар тел гыйлемендә Л. Җәләй (2000) һәм Ф. Фәсиев (1983) хезмәтләре билгеле. Без биредә бу саннар этимологиясендәге фараз вә бәхәсләргә кермибез. К. Федотов II: 279–280 (шунда әдәбият һәм бәхәсләр күрсәтелә).

**АЛТЫН** «золото» ~ чув. *ылтын, ылттăн* < гом. төрки *алтын, алтун* ~ монг., тунг., як. *алтан* «алтын», тунг. ш. ук «калай»; монг. *алт* «алтын (исем)» һәм *алтын* «алтын (сыйфат)» аерыла. Төрки телләрдән *алтын* сүзе барлык күрше телләргә кергән. Бор. төрки *altun* < *āl ton: ton* < кыт. *ton', tun* «металл; бакыр» (Цинциус – Бугаева 1977: 86–89; бу этимологияне барлык тикшеренүчеләр таный).

Икенче бер версия буенча, *алтын, алтан, *алтаӊ* үзе «алсу» мәгъ. генә булган һәм, димәк, тат. *алтын-көмеш* парлы сүз түгел, ә бор. «алсу көмеш» – алтын дигәннән, чаг. як. *кыһыл күмүс* «кызыл көмеш» – «алтын». Угыз диалектларында алтынны *кызыл, гызыл* дип кенә атыйлар (әмма шунысы бар: *кыз* < **кырг* үзе «алтын» мәгъ. булган).

**Алтын** сүзе күп күрше телләрдә төрлечәрәк мәгъ. очрый, мәс. рус. *алтын* «алтын» һәм бор. рус. (XVIII г. кадәр) *алтын* «алты тиенлек, өч тиенлек вак акча» (бу сүзне *алты тиен* сүзеннән дип тә аңлаталар, к. Фасмер I: 72), ләкин Аникин (: 84) һәм бүтән кайбер авторлар бу аңлатмага каршы, алар «вак акча» мәгъ. төр. *altıncak, altıncık* «вак алтын тәңкә» сүзеннән килә дип уйлыйлар. Гомумән, алтын сүзенең акча берәмлеге мәгъ. йөрүе еш очрый, к. Будагов I: 81–82. Иске тат. телендә дә алтын акча һәм кечкенә авырлык берәмлеге булып та йөргән булса кирәк. Räsänen 1969: 14–15; ЭСТЯ I: 142; Федотов II: 471 (арытабангы әдәбият күрсәтелә); Тимергалин: 25–26.

Дерив.: **алтынлы** «алтыны бар», ш. ук «алтынга буялган», **алтынсыз, алтынлык; алтынла-у, алтынлан-у, алтынлат-у; алтынчы** (оста); аерым идиомалар: **алтын багана** (кадерле зат), **алтын казык** «тимерказык йолдызы, поляр йолдыз» һ.б.

**Алтын Урда** сүзе Урхун буйларындагы бор. уйгур дәүләтендә (IX–X гг.) үк хан сараен белдергән (ихтимал, ул кызыл төстә булгандыр). Бату ханның тирмәсе алтынга буялган булса кирәк.

**АЛ-У** «брать, взять; уметь, суметь» ~ гом. төрки *ал-, аал-,* чув. *ил-*, як. *ыл-* id. тат. телендә гадәттән тыш күп мәгънәле фигыль. Эвенк. *ал-* «кабуллау, кабул итү» сүзе белән чагыштырыла (ССТМЯ I: 27). Безнеңчә, *ал*-ны монг. *абал-, абул-* «алу» белән чагыштырып тикшерү перспектив (монг. *аб-* «тоту, алу»). Räsänen 1969: 14–15; Федотов I: 164.

Дерив.: **алын-у, алыш-у, алдыр-у;** диал. **ала** «бирле), **алгыч, алым** (рус. *прием* сүзеннән калька булса кирәк). К. **Алгыр.**

**АЛЧА** «алыча, вишня» < иске *алуча, алу* < фар. *алү* «алча». **Алча** яңгырашы тат. телендә түгел, Урта Азиядә килеп чыккан (к. үзб. *алча*, төркм., төр. *алча* id.). К. **Әлү.**

**АЛЧАЙ-У, алцай-у** диал. «вставать на дыбы; стоять с расставленными ногами», **алчаӊ** «с расставленными ногами» ~ як., гом. кыпч., алт., башк., бур. *алсай-,* монг. *алца-* id.; **алчы** сүзеннән булса кирәк, ягъни ашыкның тигез якы өстә калып, ул басып калган шәкелдә кебек. Чаг. себ. (Тумашева 1922: 23) **алцаңна-** «тик басып тору яисә тиктөскә тик тору», каз., к.-калп. *алшак* «тырпа», *алшай-* «алчаю» һ.б.

**АЛЧАК,** диал. **алцак** – это слово, характеризующее человека (изредка – коня), имеет как в татарском языке, так и в других тюркских языках очень разнообразные, иногда противоположные значения; в тат. «злой, нахальный; порывистый; (ТТАС I: 54) «приветливый, открытый»; күпчелек очракта *алчак* «илгәзәк; ачык; тәкәллефсез, юаш; тыңлаучан, йомшак холыклы» ~ нуг., каз. *алшақ,* алт., бор. уйг., бор. чыгт. (ДТС: 34; Боровков 1963: 50; Баскаков 1972: 201) *алчак, алчах, алчык,* госм. *алчақ* «гади әдәплелек, тыйнак» һ.б., ләкин үзб. *олчоқ* «хәйләкәр һәм явыз», кар. *алчақ* «түбән холыклы» ← төр. диал. *alca-*, *alça-* «комсызлану». Рясянен һәм Севортян (ЭСТЯ I: 173) бу сүзне бор. төрки *al* «түбән, тәбәнәк» сүзеннән чыгаралар, к. (Dobr. I: 87) кр.-тат. *alçaq,* нуг. *alşaq* «гомумән түбән, тәбәнәк; кыска буйлы; юаш; гади (кеше тур.)», ш. ук «характерсыз, наданнарча, беркатлы саран, комсыз». К. ш. ук бор. төрки (ДТС: 35) *alïγ* «начар», *alïq-* «түбәнәю; начарлану; пычрану». Рамазанова 2013: 189. Чаг. венг. (Räsänen 1969: 16) *olcsó* «арзан».

**АЛЧЫ** «выигрышная сторона альчика» – ашыкның тигез ягы: ул өстә ятса, отыш исәпләнә < гом. төрки, гом. монг. *алчы, алча* > *алца* id. К. ЭСТЯ I: 144–145.

Бор. заманнарда төрки-монгол халыкларында ашык уены балаларга мәктәп ролен үтәгән һәм ашык сөягенең һәр ягы, һәр кырые, һәр ноктасы аерым исәпләнгән. К. **Ашык, Әлче I.**

**АЛЫКМАН** диал. «чистый урожай; нетто» < **алқыман* id. к. бор. төрки (к.-балк.) *алыҡ* «алына торган нәрсә», алт. *алкы* «мөлкәт, мал-туар» (*алкыла* «гадел мал табу», Будагов I: 725), алт. диал. *алык* «зур, киң» (урман, мөмкинлекләр, к. Баскаков 1972: 201), бор. төрки *alquγın* «бөтенесе бергә, җөмләсе» (ДТС: 39). Тат. диал. (ТТДС I: 327) **олокман** «зур кисәк, толыкман» – **олы** сүзе тәэсирендә ясалган сүз. К. ш. ук **Алыш-у.**

**Алыкман** сүзеннән **Акман-токман** парлы сүзенең беренче өлеше килеп чыккан.

**АЛЫКМАС: алыкмас үлән** (Тумашева 1992: 23) «гусиная лапка» – ***алык-** «югары күтәрелү», к. чув. *улых-* < *олых-* < **алык-* «күтәрелү» (Федотов II: 277). К. **Алкын.**

**АЛЫН** «постать, прогон», диал. «перед; ранее» ~ тув., төр., төркм. *алын* «маңгай, ал як», як. *алын* «нигез, ас», хак. *алнын* < *алынын* «алда, алдан» бор. төрки *alın* «мангай, йөз; кашлак» һ.б. *Алыны* > (тат. диал.) *алны* < *алды* формасыннан тат. һәм гом. төрки *алд* «алгы як», «аст» (угыз телләрендә) сүзе килеп чыккан, ягъни нәкъ **алын** борынгырак сүз (**алд** түгел), к. Исхаков 1953: 124–137.

**Алын** үзе бор. төрки *ал* «түбән, ас як» сүзенең инструменталь килеш формасы булса кирәк (**ал-ын,** к. **Алан**). Ни өчен «түбән, аскы» һәм «йөз, маңгай, алгы» мәгънәләре тәңгәлләшкән – моны ачыклыйсы бар, әмма бу хәл – факт.

**АЛЫП** «великан (в сказках)» > мар. (Исанбаев 1978: 48) *алып, алым*, чув. *олӑп* > *улӑп* id. < бор. төрки *алп*. Иң бор. беренчел иҗтимагый оешма ыру һәм кабилә булган. Һәм һәрбер шундый оешмада баштан ук ике үзәк пәйда булган – идеолог, рухи башчы һәм административ, идарәче. Соңгысы башта хуҗалык күрсәтмәләр бирүчене, хәрби башлыкны һәм хәтта казыйны да берләштергән.

Тат. телендә һәм барча бүтән төрки телләрдә билгеле булган **алып** сүзе, күрәсең, тәүдә шундый башлыкны белдергән. Бу сүз шулкадәр бор. ки, аның гадирәк мәгънәле тамыры да онытылган.

Тат. телендә **алып** башлыча әкиятләрдә очрый һәм гаять зур гәүдәле вә физик көчле затны белдерә. Башкортча *алып* һәм *айлып* физик көче белән генә түгел, мәргәнлеге белән дә билгеле. Чувашларның *алӑп (улӑп)* батыры – бик күпьяклы персонаж. 1993 елда Чабаксарда басылып чыккан «Улӑп халлапӗсем» («Алып әфсанәләре») дигән китапта аның турында 227 сөйләк, мәзәк, әкият һәм хәтта дастаннар бәян ителгән. Бүтән төрки, монг. һәм тунг.-маньч. телләрендә *алп* – «әзмәвер, герой, батыр сугышчы», караим телендә – «старшина». Төньяк Кавказдагы абазин телендә *алып* – «тулпар» (күрәсең, бу сүз төрки телләрдәге *алып аты* сүзеннән). Енисей буенда сакланган кет халкы телендә *алп* «баш рухани, җенле кеше, җен». Бор. герман телләрендә дә *алб, алп* – «явыз рух», ләкин бу сүз төрки *алп*ка баглымы икән, монысын кистереп әйтеп булмый. Һәрхәлдә бор. германнарның бу сүзне һуннардан үзләштергән булуы мөмкин.

*Алып, алп* тамырыннан бик күп сүзләр ясалган. Бор. төрки язмаларда *Алп Тегин, Алп Ару, Алп илтибәр, Алп хан, Алп шалчы, Алп тархан* кебек титуллар һәм ялгызлык исемнәр (еш кына бор. кәлимәнең титулмы, исемме икәнен аеру кыен) теркәлгән (к. ДТС: 36–37).

Тат. телендә бу тамырдан ясалган **алпамак, алпар, алпамыш, алпавыт, алпак** сүзләре билгеле.

**Алпамак** фигыле бездә моңарчы беркайда да теркәлмәгән. Мин аны Тау ягы кешесеннән ишеттем. «Безнең якларда сабан туенда көрәшкән берәр төрле алым ясауны **алпау** дип атыйлар, – диде ул. – Көрәшчеләргә тамашачылар гайрәт биреп, **алпа, алпа,** дип кычкырып торалар». *Алпа-мак* фигыле шул мәгънәдә уйг. телендә дә билгеле.

**Алпар** «батыр сугышчы, рыцарь» (шуннан **Алпар** исеме һәм **Алпаров** фамилиясе килә) сүзе тәүләп Мәхмүд Кашгариның «Дивану лүгатеттүрк» дигән энциклопедик-лексикографик сүзлегендә (1070 ел) теркәлгән. Анда төркиләрнең борынгы легендар каһарманы *Туңга алп эр* була һәм аны иранлылар *Афрасиаб* дип атаганнар, диелә. Урта Азиядә вә Уйгурстанда мөселманлык кертеп төрки халыкларны ислам мәдәниятенә җәлеп итүдә зур эш башкарган Караханиләр дәүләтендә *Алпар хан* дигән титул булган. Аннары русларның (дөресрәге, көнч. славяннарның) «Изге Олег турында җыр» дигән атаклы эпосында *ольбер*лар – төркиләрдән торган яллы сугышчылар – искә алына. Менә шуның кебек мәгълүматлар *алпар* сүзенең *алып әр* сүзеннән чыкканлыгына шик калдырмый.

Тат. халык фольклорында **алпамша, алпамыш** – типик әкияти батыр. Бүтән төрки халыкларда Алпамыш исемендә озын-озын эпик поэмалар бар; бу сүз үзе бор. кыпчак батыры *Алып Маңаш* сүзеннән

кыскарган. *Алып Маңаш* исә кыргызның Манас батыры – дөньяда иң күләмле дастан каһарманы. *Маңаш* «аксыл томансу, карасу ак» дигән мәгънәне аңлата. Бор. сүз (батырлар исемен) ясау моделе буенча *Алып Маңаш* «карасу ак атта йөрүче алып» дигән төшенчәгә ия. Алт. халык дастаны каһарманы *Маадай (Маңадай) кара* яки *Кара Манаш* та шул мәгънәдә.

Бор. алыплар махсус саклангыч кием, мундир – *алпагы* (*алп агы* дигәннән, «агы» бор. төркичә «кыйммәтле кием») киеп йөргәннәр. Бу сүз иске тат. телендә **алпак** һәм **алпау** рәвешендә чагыла. Башк. фольклорында шундый юллар очратырга мөмкин:

*Атай, атай, алпар килә,*
*Алпак кигән берәү килә,*
*Ултырдыйһә уй һелкетә,*
*Йөрөниһә йер һелкенә,*
*Миңә булыр кияү килә!*

«Башкортостан Кызы»,
1967 ел, № 7, 21 бит.

Монголлар *алпак, алпагы* сүзен «алпарның үзе» мәгъ. аңлаганнар. Шуннан монг. телендә *алпагут* «алпарлар, рыцарьлар табәкасе (сословие)» сүзе ясалган. Монг. теленнән төрки халыкларга бу сүз *алпагыт, алпавыт* (тат. сөйләшләрендә *алпут* > чув. *улпут*) рәвешендә кайткан. Безнең Идел-Урал җирлегендә *алпагут* башта «генерал» мәгъ. булган. Казан дәүләтендә (Блез де Вигенер материалларына караганда һәм «Җәмигъ әт-тәварих» буенча) *олбуд* «ханның киңәшчесе», *олбудулу* «дворян» *олбагут* «рус патшасының (Борис Годуновның) Касыйм ханы янындагы комиссары» мәгъ. йөргән. Караимнарда *алпаут* – «дворян, мирза». Караим материалы *алпавыт* сүзенең кыпчакларда Алтын Урдадан да элек булуына дәлилдер. Räsänen 1969: 18; ЭСТЯ I: 139; Федотов II: 276; Давлетшин: 99–100.

**АЛЫС** «далёкий (на горизонте); горизонт» ~ башк. *алыҫ,* нуг., ком., кырг., каз., к.-калп. *алыс, алыйс,* уйг. *алис,* үзб. *олис,* чыгт. (Будагов I: 84), *алус, алүз,* «ерак, ераклыгы», алт. *алыс* «ышыкланган урын», тув. *алыс* «чыганак, тамыр; ерак; күренешнең асылы» < монг. *алс, алус* «ерак, алыс» > як., эвенк. *алыс, алус* «бик тә, үтә».

Этимологлар бу сүзне *алсын* «кар астында калган, яшеренгән» (к. **Алсын**), аннары бор. монг. *ali* ~ кор. *al* «яшергән ашлык» һ.б.ш. сүзләр белән бәглыйлар. Иванов 1993: 34–35.

**Алыс** сүзе, шулай итеп, монг. *ali-sun* (*-sun* массаны белдергән кушымча) кабаттаркалышыннан килеп чыккан; *алыс* яки *алисун*нан тат. һ.б. *алсын* (диал. *алыс*) «кар астында калган үлән – тибендәге мал ризыгы», ш. ук «ерак токым (дүртенче буыннан соңгылар)» сүзе ясалган. К. ш. ук **Асый.** Чаг. **Ал III, Ас I.**

**АЛЫШ** (ЗДС: 42), **алышкы** «друг, дружище» (шутливое обращение парней друг другу), ~ алт., тув. *алышкы* «профессиональ көрәшче», «герой», төр. *alışkı* «гадәт; өйрәтелгәнлек», *alışkan, alışkın* «көрәшкә өйрәтелгән, гадәтләнгән» – *alış-* «гадәтләнү; күнегү». К. түбәндәгене.

**АЛЫШ-У,** диал. (ЗДС: 38) **алгыш-у** «схватиться (в борьбе)»; диал. «меняться (чем)» ~ чув. *олăш-* > *улăш-* «начар якка үзгәрү, алмашу, алмашыну; ялгышу» ~ кырг. *алыш-,* нуг., каз., к.-калп., хак. *алыс-* «алышу». Бу сүзне **ал-у** фигыленең урт. юн. дип кенә тәгърифләү җитенкерәми: хак. *алыг,* тув. *алых* «көрәшче, батыр». Сүзнең тарихи нигезе **алык-у** «алыгу» – **ал-** фигыленең интенсивлык формасы кебек. Чаг. бур. *алалда-ха* «алышу», *ала-ха* «тотып алу; чәнчү, сую». К. **Алыш.** Федотов II: 277–278.

**АМАКАЙ, әмәкәй** диал. «беззубый; беззубый рот», к. диал. **ама-у** «тешсез авыз белән кабу», **амак** «(кырыйлары бетәшкән) агач тишеге» (к. ДС II: 34). Гиганов сүзлегендә рус. *атакую* – **амаймен** диелгән. Чаг. як. *амай-* «авызны киң ачу» һ.б. К. тат. диал., каз., к.-калп., кырг., үзб. һ.б. *ам, әм* «тешсез авыз; vulva», *амавыз* «шелтәләү, сүгү сүзе» (бу сүзлекләргә кертелми), тат. диал. *ам иту, әм иту* «кабып алу» (рус телендә дә *ам!* «кабып алу» имитатив сүз), бор. монг., бур. *ама*, монг. *ам*, тунг. *алңа* «авыз, тишек, ярык» һ.б. ш. (ССТМЯ I: 38–39).

**АМАН** к. **Әманәт.**

**АМБАЛ, әмбәл** (тат. язучылары теленнән) «крутой начальник» < кырг., уйг. *амбал* id. < кыт. *амбань* < *анбань* «округ башлыгы». Бу сүз Көнч. Азиядә киң таралган, анда *амбан* «юлбарыс» мәгъ. дә ия. ССТМЯ I: 36–37; Аникин; 85–86; ҚТАС: 60.

К.-балк. *амбал* «йөкче, хәммаль» < гар. *хаммāл* id., ягъни икенче сүз.

**АМБАР** «амбар, склад» < фар. *амбар* id. < бор. ир. *һam-bar* «бергә җыелган; җыен, җыелмыш» сүзеннән (Platt I: 55); бор. рус., гар., бор. монг., чыгт. *анбар* яңгырашы икенчел. Гомумән, бу сүз Евразиядә киң таралган. Федотов I: 41.

**АМИТКӘ** диал. (трбс.), **амутька** диал. (шар.) «дружок недалёкий; голова садовая» < чув. *амутке* id. *ами* «дускай» сүзеннән, к. Федотов I: 41–42. Тат. сөйләшләрендә **ами, әми** «дускай (ироник яңгыраштa)» сүзе дә кулланыла (к. ш. ук *пәрәми* «дускай» < *бәгырь әми*, к. ТТДС I: 352). К. түбәндәгене.

**АМРАК** (ТТДС I: 58), **амырый** диал. (ТТДС I: 30–32) «друг, дружище» < бор. төрки (ДТС: 41–42) *amïr* «рәхәт, тыныч яшәү хәле», *amra-* «ярату, дус күрү», *amraq* «сөйгән яр», чаг. тунг., монг. *amur* «тыныч яшәү, тыныч агым» (шуннан **Амур**) ~ монг. *амраг* «мәхәббәт», *амраах* «тынычландыру» һ.б. ← **ам* «тынычлык». Тат. теленә бу сүзләр уйгурчадан кергән булса кирәк. К. Räsänen 1969: 19.

**АН I** «момент» (**һәр ан** «һәрвакыт») < гар. *ān*. Төр. сүзлекләрендә бу сүз «хатыннар телендә» дип тәгърифләнә. Тимергалин: 30 (тәфсилле).

**АН II** диал. (себ., к. Тумашева 1992: 24) «да, именно; имея в виду», **анан, ананни** «конечно, а как же, помним, что...; известное дело; знамо» ~ төр. (угыз) *ан-* «искә алу, хәтерләү». Чаг. **әнәчә.**

**АН III** «он, тот» (супплетивная основа местоимения *ул* «тот», без аффиксов не употребляется) – чрезвычайно продуктивная словообразовательная морфема, отсюда: *алар* < *аллар* < *анлар* «они», *аның* < *анның* «его», *аны* < *анны* «его», *аңа, аңар* < *анга, ангары* «ему; тому», *аннан* < *андан* «от него; оттого; потом, далее», *анда* «там, туда» (но *аңарда* < *аңнарыда* «у него»), *андый* < *андай* < бор. *antaγ* «такой»; *анлык* «для того, для этого», *ансыз* «без того, без этого», *аңача* < *ангача* «до этого» һ.б.

Бор. яз. төрки телләрдән килгән *анча* «шул чаклы», *анчак* «ул очракта; ләкин» сүзләре тат. сөйләшләрендә еш кына очраса да, әдәби телдә сирәк кулланыла.

**Ан** бор. руник яз. телдә киң кулланылган (к. ДТС: 43–45); төрки телләр ике төркемгә бүленә: 1) супплетив **ан** кулланылганнары – бор. төрки (руник), бор. уйг., тат., чув., кар., ком., хак., шор., 2) **ан** спорадик рәвештә генә очраганнары – калганнары (шул хисаптан башк. теле дә). **Ан**лы телләр бор. мәҗүси **язма тел** традициясен дәвам иттерәләр.

**Ан** сүзе төрки телләргә ир. (сугд.) телләрдән кергән булса кирәк. Фар. һ.б. *ан* «ул» (рус. *он* белән тамырдаш). К. ш. ук **Ана I, Анчак.**

**А́НА I, э́нә** (варианты различаются стилистически) «вот, вон» < гом. кыпч., уйг., хак., тув. *ана*, уйг. *әнә, энә* һ.б. (ЭСТЯ I: 147–149) id. *ан-а* парлы сүзеннән (**а** үзе генә дә *әнә* мәгъ. булган, шуннан чув. *ак* «әнә!» һ.б.). К. **Ан, Анау.**

Бу сүз гомумән типологик характерга ия: сузык аваз *+н* «ана; әнә, анау, теге» бик күп телләрдә очрый (чаг. рус. *вон, вона* һ.б.). Һинд.-евр. *eno* (ним. *jene* ~ һинд. *ana* «шул») тур. Kluge: 452.

**АНА II** «мать» < гом. төрки, бор. төрки (ДТС: 43) *ana* ~ чув. *ама* һ.б. id. Дөньядагы барча телләрдә диярлек охшаш сүзләр бар. Мәс., удм., коми. *ань* «хытын-кыз», һинд-евр. (Pokorny: 36) *ati*, элам. *амма*, алеут. *ana* «ана, әни», тамил. *annai*, яп. *ane* «апа, түти», бор. герм. һәм пушт. телләрендә *ana* «дәвәни» һ.б. (Зифельд-Симумяги: 120–121). Шунлыктан *ана* сүзен *ан-а* дип таркатуда бик зур мәгънә күренми: бу типологик «балалар сүзе». Покровская: 22–25. ЭСТЯ I: 278–280. Рамазанова 1991: 11–15.

Тат. телендә **ана** сүзенең бик күп фономорфологик вариантлары билгеле: *анай* (*ана* сүзеннән вокатив, күрше удм. һәм морд. телләренә дә кергән, к. ДАУ III: 204–217), *анакай, анакач, анач, әнәй* һ.б. К. **Әни, Әннә, Инә.**

**АНАР** «гранат» < фар. *ānāр* id.

**АНАУ [a$^{o}$haw]** «вон тот; тот-видимый» ~ башк., каз. һ.б. кыпч. *анау* < *ана ул*, *ана ол*. Бу сүзнең **анавы** варианты да киң кулланыла. *Анавы, анавы, анавының танавы*, диләр.

**АНГУР** (ЗДС: 44) «вид пухового платка» ← рус. *ангор, ангорский* «кәҗә мамыгы; мамыклы кәҗә токымы»; к. ш. ук *кот ангорский* «йонлач песи токымы». Бу сүзләр Төркиядәге *Әнкяра* (дөрес язылышы шулай) – бор. *Ангор* < *Ангира* дигән хетт (б.э.к. икенче мең ел электән билгеле) шәһәре исеменнән. «Мамык кәҗәләре» токымы шуннан таралган. Ул якларда андый кәҗәләрне хәзер дә күпләп асрыйлар.

**АНДА** «там», **андый** «такой» һ.б. к. **Ан.**

**АНДЫЗ** «девясил» > чув. диал. *антăс,* мар., удм. *андыз* < гом. кыпч., уйг., үзб. *андыз*, уйг. *андуз* id., кырг. *андыс* – хуш исле үләннәрнең гомуми атамасы, төр. *андуз* «атларны дәвалауда кулланыла торган үлән» (Будагов I: 101), «исе дәва булган

үлән» (ТДГДС), бор. төрки (ДТС: 47) *anduz* «андыз». Безнеңчә, *аңды-у* «аңкыту» сүзеннән: бор. заманнардан бирле, М. Бируни язып калдырганча, *андуз* төтәсләү өчен кулланылган – андыз исе әрвахларны туендыра дип исәпләгәннәр (шундый исле үсемлекләрдән тагын арча, әрем һ.б. әйтелә), к. Лобанова: 25. ЭСТЯ I: 150–151 (Севортян *андыз* сүзенә охшаш сүзләрдән дәва-дару итеп кулланыла торган тагын берничә үсемлек атамасын китерә).

**АНИКА́** (ЗДС:44) «мамаша» – русчалашкан *әникәй* микән? Ләкин к. (Малов 1967: 105) уйг. *аника* «карчык».

**АНСАТ** «легко, нетрудно» – вариантлары **асан, асат** < фар. *āсāнд* «җиңел, тыныч кына» (*āсӯдāн* «тынычлану» фигыленнән). Төрки телләргә бу сүз *ансат* яңгырашында күптән кергән, к. нуг., каз., к.-калп., төркм., аз. *аңсат, ансат* id.; чув., мар., удм. *ансат, асат* < тат. Федотов I: 48.

**АНТ** «клятва, присяга» – гом. төрки **ант** id. тунг.-маньч. *анда* «чит кабилә-кавемнән булган дус» сүзе белән чагыштырыла, к. Räsänen 1969: 28, ЭСТЯ I: 151.

Рус тарихчысы А.И. Попов **ант** дигән бор. слав. кабиләсенең атамасы төркиләр белән *антлашу*дан килеп чыккан дип исәпли, к. аның Названия народов СССР. Л., 1973: 34–37.

**Ант эчү, ант кисү** тәгъбирләре бер-берсенең (аз гына киселгән ярадан) канын суыру-ялау сүзеннән: шундый юл белән кардәшлек беркетелгән. **Ант** сүзе бор. төрки ***аныт** «истәлек» сүзеннән дә булырга мөмкин. К. **Ан II.** Иске терминологиядә *антлы утырышчы* – присяжный заседатель.

**АНЧАК, анцяк** диал. «только, лишь; однако» > морд. *аньцек, ансяк,* чув. *анчах* id. < гом. кыпч., алт. *анчак,* угыз., бор. төрки (ДТС: 43) *ančaγ* < *an čaγ* «ул чак(та)» тәгъбиреннән. Федотов I: 49–50.

**АНЫК** «определённый, точный; готовый», «запас, припас» (к. ДС I: 16; ДС II: 36) > мар. *анык* «запас», морд. *анок* «әзер» < гом. кыпч. *аныкъ,* кр.-тат., кар., госм. *анукъ* < бор. төрки (ДТС: 46) *aniq* «анык, әзер», уйг. (Радлов I: 231–234) *аныкъ, анук* «һичшиксез, әлбәттә», хәз. уйг. *еникъ, аникъ,* үзб. *аникъ* «анык» ← бор. төрки *ani-, anu-* «әзерләү» > төр. *an-*, як. *анаа-*, хак. *аны-* «казану, табу; алу». Чаг. ш. ук як. (Пекарский I: 106–107) *аны, аныгы* «хәзерге, хәзер; киләчәк». Räsänen 1969: 20; ЭСТЯ I: 151–152.

**Анык** продуктив нигез: **аныклы, аныклык; аныклагыч; аныкла-у, аныклан-у, аныклат-у** һ.б. Бу сүз төрки телләрдән күрше телләргә дә кергән, к. гар. *äникъ* (< төр.).

**АҢ I** «сознание; сознательность; просвещение» > чув. *ан, ăн* < гом. кыпч., уйг. *аң*, төркм. *ааң,* иске төр. *анк* «аң», алт. *аң* «шаман законы», яз. монг. *ang* «гадәт; әхлак», бор. төрки (ДТС: 46–47) *aŋa-, aŋla-* «аңлау» сүзләренә караганда *aŋ* бор. төрки телләрдә дә булган. Ләкин гомумән бу абстракт мәгънәле сүзне бор. төркиләр күрше мәдәни телләрдән алган дип уйлыйлар (чаг. санск. *anuh* «күзәтү, караш; зирәклек; мәгънә; аң»).

**Аң** сүзенең фигыль коррелянты төркм., төр. диал., кар., кр.-тат. *аң-* «искә төшерү, хәтерләү; күрсәтеп, аңлатып бирү һ.б.» иске тат. телендә дә булган – шуннан *аңдыру* «аңлату, үктерү» һәм *аңышу* «бергә аңлап алу» фигыльләре килә. К. Максудидә: *Кәндү әхвәлен аңып, калды таңа* [таңга].

**Аң** сыйфат ~ рәвеш буларак та кулланыла: *аң бул!* «аңлы, сак бул» – кисәтү сүзе һ.б. Räsänen 1969: 362; ЭСТЯ I: 153–154; Федотов I: 84.

**Аң** продуктив нигез: **аңлы, аңсыз; аңла-у** (шуннан **аңлаеш, аңлан-у, аңлаш-у, аңлат-у**). К. ш. ук **Аңгар-у, Аңгыра, Анды-у, Әнәчә.**

**АҢ II** (Тумашева 1992: 24–25) «лось, олень; дичь; охота» < гом. кыпч., алт., хак., тув. *аң* ~ иске монг. *aŋ* id., бор. төрки (ДТС: 46) *aŋ* «җәве-мае дәва булган бер кош», к. ш. ук уйг. *әң* «ау; киек». **Аң** сүзе *ау ~ аг* «киек аулау өчен кәртә, түгәрәк мәйдан» сүзе белән чагыштырыла (к. ЭСТЯ I: 152–153).

Дерив.: **аңчы** < бор. төрки *aŋčï* «киекче, аучы».

**АҢГАР-У** диал. (ТТДС I: 61) «понять, узнать» < **аңыг-ар-* булса кирәк (димәк, **аңыг* «аңлаган; аңлаулы» сүзе булган). Икенче яктан, бу фигыль *аң* сүзеннән *аткар-у, җилгәр-ү* һ.б. моделендә дә ясала алган.

ЭСТЯ I: 156–157 (бөтенләй икенче *аңгар-* «аңгырау, аңгыралану» бирелә, тат.-башк. *аңгар-* телгә алынмый).

**АҢГЫ-МИҢГЕ, аңкы-миңке** «беспамятный» << монг. *аңгуй-мәңгүй* «аңсыз-хәтерсез». Чув. *анкă-минкĕ* «идиот» < тат., к. Федотов I: 47. Рамазанова 2013: 240–241.

**АҢГЫРА** «глупый, тупой», «выдохшийся (о спиртных напитках)» ~ чыгт. (Радлов I: 185) *аңара* «аңгыра», чыгт., кырг. *аңыр-* «аптырау», каз., к.-калп., кырг. *аңрай-* «ачылып тору, шар ачык булу; авыз ачып калу» ~ тат., башк. *аңгырай-у* «аңгыралану, хәтерсезләнү», к.-балк. *аңгырау-у* «аптырап, гаҗәпләнеп калу», чув. (тат. сөйләшләреннән) *аңра, анкăра* «аңгыра», *анра-, анкăра-* «аңгырау, аптырап калу, һушсызлану һ.б.» ~ яз. монг. *aŋgra-, angara-* «зур ярык, ачыклык булып тору» (шуннан **Ангара** елгасының атамасы – тәүдә Байкал күленнән агып чыккан төшендә зур, тирән тарлавык ясавыннан) ← бор. монг., гом. тунг. (к. ССТМЯ I: 45) *аң, аңга* «ярык», *аңга-* «ярылып, ачыклык булып тору» > тат. һ.б. *аңкау* «сусап авыз ачу» һ.б., к. **Аңкай-у.** ЭСТЯ I: 154–156; Федотов I: 48 (сүзнең тамырын төркм. *аңк бол* тәгъбирендә күрә, ләкин к. тат. *аң бул*!)

**Аңгыра** сүзен бор. ир. *Ангро-Майнью* «явыз рух, Аһриман» сүзеннән дип карау (Урманче II, 1999: 187) нигезсез: явыз рухлар, бигрәк тә Аһриман кебек иблисләр, кызганычка каршы, һичшиксез дә аңгыра булмыйлар. Һәм, гомумән, *аңгыра* дигән рух юк бугай, аны «бармактан суырып» чыгарганнар.

**Аңгыра** сүзе *аң* (рус. «сознание») сүзе белән дә тамырдаш түгел. Чаг. **Миңгерә-ү, саңгырау.**

Дерив.: **аңгыралык, аңгыралан-у, аңгыралат-у.**

**АҢДЫ-У, аңда-у** диал. «подстерегать (добычу)» > чув. *анта-*, мар. (Гордеев I: 122) *ангда-* < гом. төрки *аңта-, аңда-, аңды-, анта-, анды* id. **аң** «киек» сүзеннән (ЭСТЯ I: 157–158).

**АҢКАЙ-У** (Радлов I: 186) «стоять с разинутым ртом» ~ гом. кыпч. *аңкай-*, алт., тув., як. *аңгай-* id. ← *аңга* «ачылган авыз; ачылган авызлы» (к. **Аңгыра**). Бу сүз тат. телендә дә булган күрәсең. ЭСТЯ I: 154–155.

**АҢКАУ I [aᵒңкaw]** «нёбо, зев» – **аңка-у** фигыленнән исемләшкән; беренчел мәгънәсе – «киң ачылган, аңкавы күренеп торган (авыз тур.)». Чаг. чув. *анка-,* мар. *аңга-* << кырг. һ.б. *аңка-* «ач булу; авыз ачып тору». Федотов I: 46; Рамазанова 2013: 239.

**АҢКАУ II [aᵒңкaw]** «простоватый, наивный; бестолковый» ~ нуг., каз., к.-калп., уйг. *аңкау,* кырг. *анкоо* id. – асылда «ачыгавыз». К. **Аңкау I.**

**АҢКА-У** «раскрыть рот в изнемождении, от жажды (о птицах и пр.) > чув. *анка-*, мар. *ангка-* «чуть не околеть от голода и жажды» (Гордеев I: 121–122), бор. төрки *аңык-а* яки *аңк-а* id. **аң** «ачылган авыз, зур ярык, зур тишек» тамырыннан, к. эвенк., негид. *аң, аңа* ~ бор. монг. *anq, angxa* «ярык, ачылган авыз һ.б.ш.» (ССТМЯ I: 45). К. **Аңкай-у, Анка-у.**

**АҢКЫ-У** «сильно пахнуть, сильно чувствоваться (о запахе)» ~ каз., кырг. *аңкы-* id. (һәм «бик шәп чыбу»), төркм. *аңка-,* як. *анкылый-*, монг. *аңкыл-*, бур. *унгил-* «аңку», *унхи* «көчле ис», эвенк. һ.б. *унку-* «агызу» (ССТМЯ II: 279).

**АП-, әп-** исконный префикс в татарском языке: русчага тәрҗемә иткәндә түбәндәге мәгъ. бирә: **апбар-у** «завести, довести», **апбир-ү** «подать, купить кому что-либо», **апкайт-у** «привести, принести (издалека), **апкал-у** «оставить у себя», **апкил-ү** «принести», **апкит-ү** «унести», **апкуй-у** «ставить». Чаг. уйг., тув. һ.б. *акел-, экел-,* як. *агал-* «алып килү». *Ап-* < *алып* икәнлеге ачык. ЭСТЯ I: 128; Иванов 1993: 73–76.

Без бу *ап*ны активлаштыру ягында.

**АПА,** диал. (ЗДС: 47) **апак, апака, аппа, аппай, аппак** (урта диал.) «старшая сестра; женщина, которая старше говорящего, но младше его (её) матери; учительница (в устах учеников)» > чув. *аппа, апай*, мар. *апа* id. < гом. кыпч. *апа* «бертуган апа» һәм «ана». Тат. теленең кырый сөйләшләрендә (Себердә, к. ЗДС: 13, добр. татарларында, к. Dobr. I: 1) *аба* ~ *ава* «апа» (шул ук вакытта *апа* дип әйтү дә билгеле). Икенче яктан, тат. теленең әстр. сөйләшләрендә (ЗДС: 46), Добруҗада, нуг., каз., к.-калп., кырг., уйг., үзб. диал. һ.б.да *апа* «ана», «хатын кеше» (тик бертуган апа түгел). Аларда үз апаны **апай** дип аерып әйткәлиләр. К. **Апай I.**

**Апа** нигезе типологик *аba* тамырыннан (к. **Абый, Әбә** һ.б.), мәс., һинд.-ир. *apa* «апа». Ике сузык арасында геминат *-пп-* авазы я алынмалык билгесе, я элекке ике тартык урынында килеп чыга. Федотов I: 5; ЭСТЯ I: 159–160; Рамазанова 2002 һ.б. (бу сүз Д.Б. Рамазанованың күпсанлы публикацияләрендә яктыртыла). Рус. диал. *аба* «апа» тур. Аникин: 71.

**АПАЙ I** күп сөйләшләрдә гади сөйләмдә (ЗДС: 46) «замужняя женщина», «старшая сестра» һ.б.

Аеруча башк. телендә еш кулланыла. Күрше (рус, фин-угор) телләргә дә кергән.

**Апа** сүзенең вокатив формасы.

**АПАЙ II** диал. (ЗДС: 46–47) «обращение к младшим: братец, братишка, сестрёнка, сестричка», ш. ук *апак* id. Ешрак *апаем* формасында кулланыла һәм, ихтимал, *алп-ак* «кечкенә алыбым (батырым)» сүзеннәндер (к. **Алып**). К. диал. (Зимасов), башк. диал. (чынлыкта тат.) *алпа* «энекәш, олан», «сөйкемле». Һәрхәлдә бу *апай* **Апай I** (к. югарыда) сүзеннән түгел (андый мәгънә үзгәрешләре булмый)! Чөнки, беренчедән, бу **апай** үзеңнән кечкенәләргә карата, икенчедән, күбесенчә малайларга эндәшеп әйтелә (кызларга түгел), к. шаян җырда:

*Яңгыр ява кар эри.*
*Ике егет кар көри.*
*Берсе көри, берсе сорый*
*– Әйт,* ***апаем,*** *кәнфит бирәм,*
***Апаң*** *кем белән йөри?*

**АПАКАЙ** – формально форма ласкательности, но в диал. имеет обособленное значение от *апакаем* «моя милая старшая сестра», к. (ЗДС: 47) *апака* «иң зур апа» ~ тув., монг. *апакай, абахай* «кенәз хатыны». Нуг., кр.-тат., добр. сөйләшләрендә (Dobr. I: 113–114) *apakay* «ханым, хөрмәтле хатын, ир хатыны» турыдан-туры тат. һ.б. *апа* сүзенең иркәләүле формасы түгел, әлеге монг. *апакай* > каз. *апағай* «бикә, асылзат хатыны» сүзеннән булса кирәк. К. төркм. диал. *апақай* < *апа ақай* «укытучы апа».

**АПАРА,** диал. **апра, апыра** «пойло для скота, болтушка, жидкое тесто» ~ мар., удм., чув. *апыра, апра* id. < рус. «опара – пареная смесь соломы с мукой, солью для скота». Ләкин төр. *apara* ~ фар. *обра* «апара, боламык» сүзеннән дә була ала.

**АПАТА, апыта, атапа** диал. «леший, чёрт» > мар. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) *апатай* «ямьсез (кеше)», тат. диал. (ТТДС: 546) *әпәтә, әптә* «сакау» id., башк. диал. (БҺҺ III: 13) *абада, апата* «акрын, мыштырдык», (ТХИ: Дастаннар 1984: 57–58) *әбетә, әбәдә* «хәрабәләр иясе», «йөз җен анасы» – барысы да бор. төрки *abita* < санск. (ДТС: 2) *amitabha* «табигать буддасы; табигать тәңресе» сүзеннән; к. ш. ук тат. диал. *аптунай, әптүнәй* «урман рухы», чув. *упăте* (< *абыдә*), *опита,* удм. *обида*, мар. *обда, овда, овыта, овыча* «шүрәле» (бу тур. к. Акцорин В.А. Этногенез марийского народа по данным фольклора // Происхождение марийского народа. Йошкар-Ола, 1967: 159–164), уйг. *амита*, монг. *abuda*, алт. *амыт, амытан,* яп. *Амида* «будда Амитаба» һ.б. (бик күп телләрдә очрый). К. ш. ук Марийский фольклор: 224–240.

**АППАК** «беленький» – бу сүз **ап-ак**тан килеп чыкмаган, ә борынгы **ак-ба-ак** «акка ак» тәгъбиреннән; гомумән, сыйфатлардагы артыклык дәрәҗәсе формалары бор. *-бе-, -ба-* (иран телләреннән булса кирәк) кисәкчәсе ярдәмендә ясалганнары: *кап-кара < кара-ба-кара, сап-сары < сары-ба-сары* һ.б.

**АПРЕЛЬ, април** «апрель» < рус. < лат., төбендә грек мәхәббәт алиһәсе Афродита исеме, к. Kluge: 55.

**АПТАЛ** диал. (ЗДС: 85) «блаженный, человек, делающий добро себе во вред», «сказочный персонаж, делающий обрезание тем мальчикам, о которых не позаботились родители» < гар. *Абдăл* легендар бер кеше исеме, *абдал-мăкан* «җирле, төбәктәге аптал»; «Мең дә бер кичә» әкиятләрендә – төрле кыяфәттә йөри торган герой, изге сихерче, Хызыр кебек персонаж, җирле Хуҗа Насретдин. Кр.-тат., добр. (Dobr. I: 5, гомумән Кавказ, Кара диңгез тирәләрендә киң кулланыла) *abdal, aptal* «дивана, мәҗнүн; диванага сабышучы», «күчмән», «бер тарикать һәм шул тарикатьтәге дәрвиш» бай деривациягә ия: **апталчы; апталдай; абдаллаш-у; абдаллык** һ.б.

**АПТЫРА-У,** диал. **абдыра-у** (к. ТТДС I: 16–17) «растеряться; быть в недоумении; заторопиться» > чув. *аптăра*, мар., удм. *абдура-* id. < гом. төрки *абдыра-* id. *абдыр* (к. Dobr. I: 6–7) «ашыгыч» нигезеннән, бор. төрки, бор. монг. *ап, аб* (> тат. диал. *әп*) «сихер; ырым; тылсым» сүзеннән (Räsänen 1969: 22; ЭСТЯ I: 58–59). Морд. *апторга-* «аптырау» борынгырак төрки яңгыращны чагылдыра бугай, чаг. *аңгыра- < аңгырга-*, *өлтерә- < өлтергә-*, *тинтерә- < тинтергә*. К. ш. ук **Абра-, Арба-, Әп.**

**Аптыра-** фигыленең нигезе ***аптыр, абдыр** ничек ясалганлыгы билгесез. Чаг. ш. ук к.-балк. *абызыра-* «аптырау» < *абызы-ра-* (*-ра* киңәйткече).

Дерив.: **аптыран-у, аптыраш-у, аптырат-у; аптыраш.**

**АР** «удмурт» – бор. төрки *ar, ār* «җирән (чәчле)» сүзеннән булса кирәк: удмуртларда җирән чәчлеләр еш очрый. Удмуртлар үзләрен **ар** дип

атамыйлар. XIV г. әл-Гарнати Болгардан төньяктарак *arw*/*ару* халкы яшәгәнлеген язып калдырган. **Ар** сүзен чув. *ар* < *әр* «ир» сүзеннән дию (Федотов I: 55) бик шикле.

**АРА I** «промежуток, расстояние; между» < гом. төрки **ара** id. бик ихтимал, бор. төрки *ar-* «аеру» тамырыннандыр (чаг. *яр – яра, әйлән – әйләнә*), к. ДТС: 50–52. Чаг. ш. ук бор. төрки, үзб., каз. һ.б. *арал* «утрау». ЭСТЯ I: 162–167.

**Ара** исеме белән тат. диал., төр. *ара-у* «(арала-у) эзләү» бердәй булса кирәк (исем-фигыль бердәйлеге). Чаг. ш. ук **Ара II**.

**АРА II** диал. (кас.) «низшее сословие» ~ башк. *ара* «күрше-күлән, җыен», «община» (БҺҺ II: 28; Кузеев Р. Очерки исторической этнографии башкир. Уфа, 1957 һ.б.) сүзендә дә чагылыш таба. Бу сүз тат. *күрше-ара, ара-тирә* кушма сүзләрендә сакланган булса кирәк. Бүтән төрки телләрдән мисаллар – тув. *ара (ара-албаты)* «табигъләр», каз. *аран* «хөкем, власть» (ҚТДС: 29), кырг. *араан* «отряд, полк» – күрсәткәнчә, бу сүз монг. телләрендәге *ара, араган* (күп. формасы *арат* < *арагад*) «гади халык, гаскәри бүләк» сүзе белән бердәй.

**Ара I** белән тамырдаш булса кирәк. Чаг. ш. ук мар. *аран*, *äрäн* «ыру, токым» (Гордеев I: 132).

**АРАКЫ,** иск., тар. **ғарақый** «водка; вино, спиртное» – барлык төрки һәм күрше телләргә киң таралган бу сүз гар. теленнән дип уйланыла, ләкин төгәл генә беленми, к. гар. *ʻрқ* «тирләү», *рах* «шәраб». Чаг. ш. ук санск. *gar-ah* «эчемлек». Тимергалин: 31–32 (сүзнең таралуы һ.б. бәян ителә).

Чув. телендәге палаталь вариант *ĕрех* «аракы» кызыклы (к. ш. ук мар. *äрäкä* > *арака* id.). Федотов II: 479. Рус. *арак, арака* тур. Аникин: 91 (бай әдәбият күрсәтелә).

Дерив.: **аракычы** «аракы эчүче» ~ монг. *аракчин* id. Бу сүз белән гар.-фар., төр. телләре даирәсеннән алып Себергә кадәр таралган һәм рус телендә кат-кат теркәлгән (к. Аникин: 91) *аракчин, аракчын* «баш түбәсен генә каплый торган түбәтәй» сүзе баглы. Будагов буенча (I: 762), *арақчин, ғарақчин,* фар. *гаракчир* «эчкеченең тирен сөртү өчен» киелгән икән. **Аракычы** яисә **аракчин** сүзеннән рус. *Аракчеев* (дворяннар фамилиясе) килә.

**АРАН I** (Будагов I: 23; Тумашева 1992: 26; ЗДС: 48; Добр. I: 122) «лёгкие не срубные сени; карда; срубное, утеплённое помещение для скота, особенно – для лошадей; стойло» > мар. *аран, äрäн* id., ш. ук «көтү», рус. *аран, оран, еран* «кәртә-кура», гом. төрки *аран*, куман. *airan* id. тунг. *һаран* «учак урыны» гом. төрки, монг. *аран* «халык» сүзе белән чагыштырыла (к. Константинова, 166–173). Ахметьянов 1989: 128–129; ССТМЯ II: 317; Аникин: 92.

**АРАН II, әрән, әрәндә** (Арсланов 1988: 73) диал. «едва, еле-еле, насилу» ~ каз. *әрең,* чув. *аран,* ком. *гьаран,* уйг., үзб. *аранг,* аз. диал. *аран-саран* < монг. *аран, арай,* як. *арый* id. **Аз** сүзе белән тамырдаш дип исәпләнә (ЭСТЯ I: 167–168; ССТМЯ I: 48). К. ш. ук Федотов I: 55; ҚТАС: 67 (күп параллельләр китерелә).

**АРАТА, әрәтә** «перекладина; ступенька лестницы; поперечина, рама» ~ мар. *арата*, чув. *арата* > *урата* id. Чаг. бор. төрки (ДТС: 50–51) *arata* «вакыт аралыгы», *ара* сүзеннән, ләкин ясалышы ачык түгел (монг. *аратай* «аралы»?). **Ара**ның үзен дә **арата** дип атау бар (*бу аратада* «бу арада»). Федотов II: 284.

**АРА-У** (Ш. Бабич) «выискивать, разыскивать» < төр. *aramak* id.

Дерив.: **араштырмак ~ араштыру** ш. ук төрекчәдән.

**АРАЧА** к. **Әрәчә.**

**АРАЧАН** диал. «молочная водка» < калм. *арачан*; к. себ. (Тумашева 1992: 26) *арацан-корацан* төрле эчемлекләр, чаг. калм., ойрот (көнб. монгол) *арза* «өч тапкыр куылган аракы», *харза* «дүрт тапкыр куылган аракы». Э.В. Севортян буенча (ЭСТЯ I: 168), кырг. *арашан* > каз. *арасан* ~ алт., тув. *аржан* «шифалы су» < санск. *rasayana* id. К. ш. ук **Арчан.** Тимергалин: 31.

**АРБА** «арба, телега» > мар., удм. *арба, араба* < гом. кыпч. *арба*, уйг. *һарба*, тат. диал. (ТТДС I: 41), угыз. *араба* > чув. *урапа, орапа*, *орава,* иске тат. әд., госм. *гарәбә* (мәс., Акъегетзадәдә) < гар. *ʻарабăн*, *аʻрабăн* «күчмәчелек» id. К. **Гарәп.**

Татарлар да Урта Азиядәге зур ике тәгәрмәчле арбаларны *араба* дип атыйлар. Ягъни *араба* һәм *арба* – ике сүз. К. ш. ук Menges 1972: 310–312; Федотов II: 284; Аникин: 93; Тимергалин: 32.

**АРБАТ** «станция для переночёвки, место остановки караванов» – название ряда населенных

пунктов от Марокко до Сибири; к. Мәскәүдәге **Арбат** бистәсе. К. **Рапат.**

**АРБА-У** «обольстить; внушать какое-либо настроение, замыслы; уговорить» гом. кыпч., алт., бор. төрки *арба-* id. *Абрау* (к.) сүзеннән метатеза. Радлов I: 335–337; Räsänen 1969: 24; ЭСТЯ I: 168–170; Тимергалин: 32.

**АРГАМАК** «аргамак, породистая лошадь» < гом. кыпч., төркм. *аргамақ, аргымақ,* уйг. *аргымақ,* үзб. диал. *аргумақ* ~ монг. *аргамаг* id. Э.В. Севортян буенча (ЭСТЯ I: 171), кырг., тув. *аргы-,* ком. *аргу-* «эре адым белән чабу, ыргу» сүзеннән. Ләкин бу фигыльнең икенче мәгъ. дә бар. к. **Аргыш.**

**Аргамак** сүзе мәҗүсилек объекты: мар. *аргамак*, чув. *архамак* > *урхамах* «корбанга чалына торган ат» (бор. кыпч. – татарлардан булса кирәк). Федотов I: 289; Ахметьянов 1989: 18.

**АРГАН** (Радлов I: 269) «лосось» ~ монг. *арган* «азау; пычкы теше» (арган балыгы тешләч була). Чаг. рус. *аргаш* «алабалык төре». Чаг. **Ыргай II.**

**АРГУЫН, арғун, арбуын** (Будагов I: 24; Тумашева 1992: 26–27) «оса; шершень». Бу сүз иске тат. *аргуан, әргуан* «җете кызыллы-сарылы чәчәкле куак» сүзеннән булса кирәк, к. фар. (Будагов I: 29) *äрғawāн* ~ гар. *äрҗäwāн* үсемлеге. Бу фитоним ахыр чиктә грек. *archegoniun* ~ лат. *archegoniun* «җете кызыл» сүзеннән. *Әргуан* сүзеннән фар. *әргуани* (< төр. *ergutani*) «кызыл шәраб» сүзе дә килә.

Бөҗәк атамасы буларак *арҗуан* «сарылы-кызыллы» яисә «кызыл чәчәкләр яратучан» мәгънәләреннән килә ала. Бәлки, төптә *аргуан* бездә бериш чәчәкле үлән булгандыр. Монда **ары** «бал корты» сүзенең контаминацион тәэсире бар.

**АРГЫШ** «аргиш, санный караван; свадебный поезд». Евразия очсыз-кырыйсыз, ә төгәлрәк әйткәндә, ун меңнәрчә чакрымга сузылган дала-чүлләрендә гомер кичергән төрки халыклар юл үтү, олау, почта хәлләрен заманында дөньяга барча халыклардан яхшырак белгәннәр. Бор. заманнарда ук дөньяның алдагы дәүләтләре аралашуның һәм йөк күчерүнең эстафеталы ысулын кулланганнар. Ун-унбиш чакрым йөгергән йөгерешчене, атлы-арбалыны билгеле бер төштә алмашчы көтеп торган. Алмашчы үз арасын йөгереп яисә чабып узгач, әйтәсе сүзне, тапшырасы хатны яисә йөкне икенче алмашчыга тапшырган... Шул ысул белән бор. хәбәр вә әйберне, бик ашыгыч булса, тәүлегенә бишәр йөз чакрым тизлек белән «җиренә җиткерә» алганнар.

Бор. төрки телдә шундый эстафетаның бер чират өлеше **аркыш** (к. ДТС: 54) дип аталган. Бу сүз тува телендә сакланган *арқы-мак, арғы-мак* – «барып кайту, арлы-бирле йөрү-чабу» фигыленнән ясалган. Башта бу фигыль, күрәсең, «тау сыртын ашу» мәгънәсендә булган (чапкыннарның алмашыну пунктлары тау сыртларында – алмашчы килгәнен күреп торырлык урыннарда куелган). Тат. *аркыл-мак* «билгеле бер бусагадан, киртәдән ашып үтү» фигыле дә шул бор. *аркы-мак*тан килә. Сүз уңаенда әйтергә кирәк, *аргымақ, аргамақ* – «бик шәп гамәли чабыш аты» сүзе дә шуннан (ихтимал, ул тәүдә ашыгыч почта атын белдергәндер). Чаг. көрд., төр. диал. *аргуш* «куян».

*Аркыш* «эстафета» һәм «эстафетачы» мәгънәле сүз тиз арада күптөрле яңа мәгънәләр йөкләп алган. К.-балк. *аргыш* «олау». Алт., як. телләрендә *аргыш, аргыс* – «иптәш, юлдаш». Башк. сөйләшләрендә (БТДҺ: 24) *аргыш* – «киртәнең бер торыгы» («юлның бер өлеше» мәгънәсеннән), чув. (XVIII г. сүзлекләрендә) *аргаç-мак* – «киләп сармак» (чаг. **Аркау**). Татарның төрле группаларында *аргыш, аргош* «парлы кунак», «кәләшне кияү өенә озатучы», «иярчен бала» һ.б. (ЗДС: 50) мәгънәләрендә очрый. XIX г. татар (крш.) этнографы Б.Г. Гаврилов удм. телендәге *аргыш* – «яңгыр буткасын оештыручы әби» сүзен теркәп калдырган. Гаг. телендә *аркуш* – «кылкубыз (скрипка) сызгысы» (аның аргыш кебек арлы-бирле йөрүеннән) һ.б.

Төрле бор. төрки дәүләтләрдә *аргыш, аркыш* «хәбәрче», «почта», «илче» һәм хәтта «хат» мәгънәсендә йөргән. Тайга һәм тундра зонасында як., эвенк., нен., рус һәм башка телләрдә *аргыш, аркиш* – «чаналы кәрван», «боланнар яисә этләр җигелгән чаналар төркеме» – үткән гасырларда бик актив кулланылган һәм хәзер дә очрый. Себер татарларында бу сүзнең «йөк күчерү урыны» мәгънәсе дә билгеле. **Аргыш** дигән авыл атамалары (мәс., Башкортстанның Дүртөйле районында) шул мәгънәдә.

Шунысы гаҗәп ки, шундый колоритлы тарихи сүз, күп кенә сөйләшләрдә (бигрәк тә Урал вә Себер якларында) еш кына очраса да, тат. яз. әд. теленә үтеп кермәгән. Ә бит аны «конвой», «почта», «курьер» яки «поезд» мәгънәләрендә кулланып булыр иде.

Гаврилов 1891: 96; Tezcan S., Zieme P.: 456; Donuk: 66; Аникин: 95 (шунда арытабангы әдәбият);

Тимергалин: 32 (**аргыш** һәм **аркыш** сүзләрен аерып яза).

**АРДАК,** диал. **арда** «нега, балование; ухоженность; почёт, почести, уважение» > мар. **ардак* (*ардаксыз* «тәрбиясез, әдәпсез», к. Гордеев I: 140, мар. Т. *одокла-* < *ардакла-* «азындыру; узындыру», к. Саваткова: 105) ~ чув. *артак*, башк. *арҙаҡ*, гом. кыпч., алт., уйг. *ардаҡ*, бур. *ардаг* «тәҗрибәсез, кыргый; шук; әбәләк», монг. *арда, ардаг* «асау (ат); иркә, тарханда үскән; тәҗрибәсез». ЭСТЯ I: 173; Рамазанова 2013: 188–189.

Рясянян һәм Севортян бу сүзне монг. теленнән диләр. Безнеңчә, бу фараз гына. Чув. *иртех-* «азыну; иркәләнү», *иртен-* «масаю» ← **ирте-* < бор. тат. **ирдә-* < **эрдә-* < *арда-* «иркәләнеп, иркендә үсү» төрки телләрдә була торган фонетик үзгәрешләр фонын хәтерләтә. Бор. **арда-*, шикләнмәскә мөмкин, бор. төрки (ДТС: 56) *arta-* «бозылу, рухан таркалу» (*artaq* «бозык, яман, юньсез») сүзеннән килә (*-t-* > *-d-* угыз телләрендә очрый, мәс., төркм. *арты* > *арды* һ.б.ш.). Диал. (ТТДС I: 43–45) **ардаклау** «чистарту, арындыру» сүзе себ. (Тумашева 1992: 28) **артыкла-у** < **арытакла-у** «чистарту» (← **арыт-ык** «арытылган») сүзенә охшаш.

**АРЗАН, арзанлы,** диал. **әрзән** (< уйг. *әрзән*) «недорогой» < фар. *арзидан* «бәясенә тору» → иске тат. әд., үзб. һ.б. *арзы-мак* id. К. түбәндәгене.

Дерив.: **арзанлык; арзанчылык; арзанай-у** (һәм аның дериватлары); **арзанлан-у, арзанла-у** (*син мине бик арзанлама,* диләр). К. түбәндәгене.

**АРЗУ** иск., кит. «страстное, дорогое желание; мечта», диал. (Тумашева 1992: 37) **әрзү** (< *әрзүле*) «гордый; высокомерный» ~ төр. һ.б. *arzu* id. Иске әд. телдә күпмәгънәле һәм киң деривацияле бу сүз (Будагов I: 27) фар. *āрзӯ* ← *арз* бор. ир. *arg* «бәя» сүзеннән, к. **Арзан.**

Иске тат. һ.б. **арзуман** «кадерле дус» < фар. *āрзӯмäнд* id. Бу сүзләр тур. ЭСИЯ I: 218–220.

**Арзу** сүзе элек кызларга, ә **Арзуман** егетләргә кушыла торган исем булган. **Арзамас** шәһәренең атамасы да кеше исеменнән килсә кирәк. (*Арзунмазза* «татлы теләк»). К. түбәндәгене.

**АРЗЫУ [а°рзы̆w]** кит. «стоить чего, оправдывать заплаченное» – иске төрки телләрдә фар. *арз* «бәя, кыйммәт» тамырыннан ясалган (**арз-ы-**) фигыль.

**АРКА** «спина» < гом. төрки *арҡа* – бор. *ар,* **ару* тамырына -*ка* кушымчасы ялганып ясалган (чаг. *җилкә, умыртка, үпкә* һ.б.), чаг. эвенк. һ.б. *аркан* «арка, җилкә», бор. монг. *ару* «арт, арка як; төньяк, күләгә» (ССТМЯ I: 51) – һичшиксез *арт* сүзе белән тамырдаш, ләкин *арка* < *артка* фаразлау дөрес булмас. К. **Аркада, Аркадаш, Аркалык, Аркылы.** ЭСТЯ I: 174–175; ССТМЯ I: 51.

**Арка** «тау сырты» тур. к. Мурзаев 1984: 55.

**АРКАДА** (**арка** сүзенең барча зат-тартым-сан формаларында) «благодаря, из-за (*него, тебя, меня* и т.п. во всех формах притяжательности – буквально «из-за тени»): *арка* бу очракта бор. төрки, бор. монг. *arqa* «төньяк; күләгә; эз, нәтиҗә» мәгъ. килә. Чаг. иске тат. *сайәсендә* «аркасында» ← фар. *сайә* «күләгә»; к. ш. ук гом. тунг., монг. *арга* «мөмкинлек, чара; әмәл». **Аркада, аркасында** (һ.б.) барча кыпч., үзб. (*орқасида*), уйг. (*арқисида*) очрый. Удм. *аркаын* «аркасында» татарчадан ярымкалька. Севортян (ЭСТЯ I: 170–171, 174–175) *арга* «чара, сәбәп» һәм *арка* «сырт» сүзләрен аерым карый. Асылда **аркада** һ.б.ш. сүзләргә монг. һәм төрки сүзләрнең контаминациясе күзәтелә. Чаг. себ. (ЗДС: 50) **аргалы** «тырыш; чаралы», **аргасыз** «ялкау; чарасыз».

**АРКАДАШ** «сотоварищ» – *арка* < бор. төрки *arqa* «арка, терәк, таяныч; тыл» сүзеннән. **Аркадаш** сүзе күп иске һәм яңа төрки телләрдә «иптәш» мәгъ. килә. Чаг. **Аркасында.** Диал. **аркалан-у** «кемнең дә булса көченә, ярдәменә таяну» һ.б.

**АРКАЛЫК** «чересседельник» > мар. *аргалык, аркалык* (Гордеев I: 145), чув. *орхалăх*, *урхалăх,* рус. диал. *аркалы́к* id. (Фасмер I: 86; Аникин: 86) ~ гом. кыпч. *арҡалыҡ* id.

Рус. *архалук, архалуг* «арка җылыткан чапан» төр. яисә аз. телләреннән алынма (к. Юналеева 1982: 29–31).

Себ. тат. сөйләшләрендә **арғалық, арқалық** (к. Тумашева 1992: 27) «матча; өрлек», ш. ук «изге теләк (теләп калу)», **арқалы, арғалы** «тырыш» < уйг. *арқалығ* (хәз. әд. уйг. *арқилиғ*) «ярдәмчел». Федотов II: 288.

**АРКАН I,** диал. **аркатан** «спиной (стоять), на спине (плавать)» – **арка** сүзенең бор. инструменталь килеш формасы. **Аркатан** варианты монг. *архатай//архатань* «аркалы» формасыннан булса кирәк. К. ш. ук гом. тунг. *аркан* «арка» (ССТМЯ I: 51).

**АРКАН II** «аркан, толстая верёвка, канат» > мар., удм., рус. *аркан* < гом. төрки *арқан*, кар. *äркäн*, госм. *урған* (Радлов I: 288, 779, 1665) «йон бау» ~ хак., тув., алт., монг. *аргамчы, аргамжы* id., к. алт. (Баскаков 1972: 202–203) *арбаңчы, арғымча, армаңдьы, армакчы* «бау; йөгән». «Лассо» «корык» мәгънәсе Кавказ телләрендә генә.

Э.В. Севортян (ЭСТЯ I: 170) бу сүзне **аркау** (к.) сүзе белән бәйли, к. абаз. *арган* «чыпта палас, чапрак». Ләкин барыбер *аркан ~ аргамчы* сүзләренең ясалышы аңлашылып бетми. Чаг. **арт-у** «арбага һ.б. йөкләү», башк. *арҡатау* «батман бавы».

Ихтимал, монда төрле сүзләр кушылгандыр: башк. диал. *әркән* ~ тат. диал. *үркән, үргән* «кавын, карбыз, кыярларның озын сабагы» < бор. *öркäн* (*ү < ö > үә > ә*); бор. *оғурқан, арқан* «корык» (к. **Корык**) һәм монг. *аргамчы*.

**АРКАСЫНДА, аркада** «из-за; благодаря» – **арка** сүзеннән түгел; чөнки диал. **арткысында** id. ← **арткы** «нәтиҗә», к. ш. ук бор. төрки (ДТС: 54) *arda* ~ монг. *арга* (бик продуктив нигез) «сәбәп; нәтиҗә; ярдәм», тунг., манчь. (ССТЯ I: 49–50) *арга* «чара; хәйлә; исәп». К. **Аркадаш, Аркылы.**

**АРКАУ [a$^{o}$рқаw]** «уток ткани» < гом. кыпч. *арқау,* кырг. *арқоо,* үзб., уйг., бор. төрки (ДТС: 54) *arqaγ* > себ. тат. (ЗДС: 51–52), кырг. *арқақ* «аркау, аркаулык» ~ угыз. *аргач* id. Бор. *арка-** «аркау ату; кат-кат урау» фигыленнән – бор. *арға-*, *аргы-* «бер юлдан килеп-китеп йөрү, киләп сару» фигыле белән бердәй булса кирәк, к. мар. *äргä-, äркä-* «аркау ату, пәрәвез кору» ~ тув. *арғыг* «бәйләм; үрмәк, тукыма» ← *аргы* «бәйләү, үрү, туку». К. **Аргыш, Аркылы.**

**Аркау** сүзенең **арку** варианты да бар. К. тув. *арғыг* «бәйләү; тегү, туку», *арғы-* «әрле-бирле йөрү», *арық* «кәрзин». *Арка-, аркы, арга-, аргы-* фигыле борынгы *ар-* «үрү, туку» сүзеннән булып чыга. Чаг. ш. ук төр. *ardaç* «аркау, аркаулык».

**АРКЫЛАШ** диал. «ригель, поперечная линия (брус, бревно и т.п.), поперечина, поперечный» < *аркылы агач* булса кирәк, ләкин бор. **аркы* (~ хак. *архы,* як. *аргы*) «арата, аркылаш» сүзеннән дә ясала ала; < *аркылы агач* файдасына чув. *орлаç > урлаç* «арата» сүзе сөйли: ул *орлă йываç* «аркылы агач» сүзеннән килә.

**АРКЫЛ-У** «перевалить» тат. телендә генә, ихтимал, **аркылы** (к.) сүзе нигезендә халык этимологиясенчә ясалгандыр; ш. ук уйг. *арқур-* «аша чыгу» сүзеннән килеп чыга ала (*-р > -л*). К. **Аркылаш, Аркылы.**

**АРКЫЛЫ,** диал. (ЗДС: 53, 62 һ.б.) **арткылый, арткырлы, арткыры, арткырылы, аткыры** һ.б. «через; поперёк, благодаря (чему)», диал. «непослушный, несогласный» ~ башк., каз., к.-калп. *арҡалы*, кырг. *арқалуу,* уйг. *арқилиқ* (< *арқалық*) «аркасында, йөкләп алу нәтиҗәсендә» ← *арка*; к. ш. ук башк., госм. һ.б. *арқыры* < уйг. *арқыру, арқыра,* бор. төрки (ДТС: 55) *arquru* «аркылы үтеп» (*арқыр-* < *арқур-* фигыленнән, к. **Аркыл-у**); ш. ук иске тат. (Троянский I: 22) **арткылы** «аркылы»; чув. *урлă* < *орлă* ← болг. **аркыл-у?* Гомумән, **аркылы** сүзе төрле тамырдаш сүзләрнең контаминациясе булса кирәк. Федотов II: 286 (*аркылы* сүзен *аркыл-у*дан чыгара).

**Аркылы** продуктив нигез: **аркылылык, аркылылан-у.** К. **Аркасында; Аркылаш.**

**АРЛАУ [a$^{o}$рлаw]** «приспособление для снятия мездры – лезвие, прикреплённое к развилине палки»; (ТТАС 2005: 174, **изгеч** мәкаләсендә) «мешалка» < *арыла-у, арула-у* «арчу, әрчү, чистарту», к. **Ару.**

**АРМАГАН** «посвящение»; «свадебный подарок», (Будагов I: 32) «прекрасный» ~ төр. *armagan, armugan* ~ фар. *äрмаган* «котлау бүләге». Гомумән, ачык түгел. Чаг. **Арма-у, Арна-у.**

**АРМАЙ** «надсмотрщик, бурмистр; староста», башк. «наказание розгами» (*армай һуғыу* «бить палками в наказание») > мар., удм. *армай,* чув. *ормай > урмай* «армай», ш. ук «туйда тәртип саклаучы», «суд карары буенча таяк яки камчы белән кыйнаучы; палач», рус. (Даль) *армай* «юлбасар; бүтәннәрне кыйнарга яратучы» – Идел-Урал регионы сүзе. Бик ихтимал, бу сүз мәҗүси мифологиядән киләдер. К. алт. *алмай* «явыз рухларны йорттан куучы рух» (к. Дьякова: 34–35). *Албаң* – әкият батырларының хезмәтчесе (Катанов 1888: 8), бор. монг. *alban* «дәүләт хезмәте; салым» ← *alba-* «мәҗбүр итү» (ихтимал, *алып* сүзе белән баглыдар). Никольский 1920: 118; Гордеев I: 147; Номинханов 1975: 94. К. **Алман.**

Н. Исәнбәт *армай* сүзен *арымай,* ягъни «туктаусыз хәрәкәттә булган кеше» дип аңлата. Халык этимологиясе. Монг. *арбан* (хәз. монг. *арвн*) «ун; ун башы» сүзе белән баглау да шикле.

**АРМАН** диал. (Арсланов 1988: 71), себ. (Тумашева 1992: 38) **әрман** «заветное (неисполненное) желание» ~ уйг., чыгт. *әрман, арман*, каз., кырг. һ.б. *арман*, к.-балк. *арман* «үпкә» ~ фар. *арман, äрман* id., ш. ук «тәүбә» фар. сүзе дип уйланыла (Будагов I: 32), ләкин к. көрд. *artmanc* id. төрки сүзгә охшый. К. ш. ук себ. **әрмәч** «борчылу, кайгы һ.б.» < **әрманыч* id. Тат. әд. (ТТАС I: 69) *арманда* «арман» сүзе *арманда калу* тәгъбиреннән эллипсис булса кирәк. Төрки телләрдә *арман* сүзе бигрәк тә *арманда калу* «үтәлмәгән теләктә калу» һәм *арманым калмады* «барча теләкләрем үтәлде» тәгъбирләрендә очрый.

**АРМУТ,** диал. **армыт** «груша» < фар. *амрӯд* id. сүзеннән төрки телләрдә метатезаланган.

**АРНА-У** (ДС I: 18; башк.) «посвящать, посвятить» ~ каз., кырг., уйг. *арна-* «багышлау, билгеләү», каз. (Будагов I: 33), к.-калп. *арна-* «махсус чакыру, чакырулы караш ташлау», алт. *арына-* «максат итү», бор. уйг. *arnag, arinag* «махсус ысул, әмәл» ← *arın-* «уку, остару, күнекмә һәм тәҗрибә хасил итү» (к. Röhrborn: 197).

Дерив.: **арнау** (исем); **арнал-у, арнат-у.**

**АРПА** «ячмень»; иск. озынлык үлчәү берәмлеге ≈ «3 миллиметра» ~ чув. *орпа* > *урпа* гом. кыпч. *арпа*, кырг., уйг., аз. һ.б. (Радлов I: 333–334) *арпа, арфа, арба* ~ бор. монг. *arbai* ~ чыгт. *arpa* id. (к. Поппе 1938: 104), хәз. монг. *арбай, арвай* (к. Номинханов 1975: 288) – электән бирле һинд-евр. *albhi* > ир. *arbhi* «арпа» сүзеннән дип хисаплана (Pokorny I: 29; ЭСТЯ I: 176–177). Төрки телләргә сугд теленнән кергән булса кирәк.

**Арпа** сүзенең «күз тирәсенә чыккан сызлавык» мәгъ. күп телләрдә очрый, к. рус. *ячмень,* ним. *gerste,* лат. *hordeobus,* бор. грек. *krithe* id. һ.б., к. Kluge: 349.

**Арпа** Көнб. Азия телләрендә *һарпа* элек-электән ат азыгы итеп кулланылган. **Арпа** бор. заманнардан бирле озынлык үлчәме буларак та билгеле: гарәп-төрек даирәсендә 3 **арпа** – 1 **бармак,** 24 бармак – 1 **зираг** (аршын), 3500 зираг – 1 **мил,** 3 мил – 1 **фәрсәх,** 3 фәрсәх – 1 **бәрид,** 3 бәрид – 1 **буруд** булган. Авырлык берәмлеге буларак 3 **арпа** – 1 грамм.

Төркиядә һәм элекке Госманлылар империясе илләрендә *арпа* «пенсия», **арпалык, арпачай** «хәрбиләргә пенсия урынына бирелгән җир, бакча». **Арпачы –** «иген сәүдәгәре», «арпа бөртекләре белән юраучы күрәзә», «пенсионер», «игенне басудан урлаучы карак» (чаг. тат. **ындырчы** id.) һ.б. мәгъ. кулланылган. Будагов I: 24; Тимергалин: 23; Гаффарова 2006: 76–79; 2007: 81–86.

**Арпа** продуктив нигез: **арпалы, арпалык,** парлы исем **арпа-көрпә.** К. **Арпаган.**

**АРПАГАН** (Вәлиди I: 55) «ячмень дикий» < бор. төрки (ДТС: 53) *arpaγan* «арпага охшаш үсемлек», к. ш. ук кырг. *арпакан* «солыча, кара солы».

**АРТ** «задняя сторона, тыл» < гом. кыпч., чыгт., алт., угыз. *арт*, *аарт*, төр. *ard* ~ калм. *ard* id. ~ монг. *ару*, бур., тув. *ара* «арт; көнбатыш» (бор. тирмәләрнең ишеге көнчыгышка караган) – бор. *ар* «арт як» (к. **Арка**) сүзе белән тамырдаш (к. ЭСТЯ I: 179–180). К. **Арт-у II.**

**Арт** продуктив нигез: **арткары; артлы** (*берсе артлы берсе, аллы-артлы*); **артлык; артынча; артталык** һ.б. (икенчел сүзләр бик күп), диал. (Тумашева 1992: 27) **артлац** (< **артлач**) «аймылыш», (ТТДС I: 46) **артла-у, артча.**

**АРТАК** диал. «драчливый; артачливый (о лошади)» (к. җыр: *Биек тауны менгән чакта атың артак булмасын; Аең-көнең уртак булсын – ярың уртак булмасын*) < бор. уйг. *artak, artaq* «артак, бозылган; явыз, артык усал» ← *arta-* «начар холыклы булу (ат тур.), бозылу, черү» фигыленнән (Röhrborn I: 205–207). Бор. төрки сүзлектә (ДТС: 51–56) *ardaq* һәм *artaq* сүзләре тиңләштерелә, к. **Ардак.** Чаг. ш. ук як. *атаах* «артак (ат)», башк. (БТДҺ I: 26) *арта-у* «артык әчү, бозылу», *артаҡ* «җинаятьче». КБдә *аты артаҡ* «яман атлы» (кеше), *арта-* «бозу, аздыру»:

*Йүрәксез кишиләр чәриг артатыр,*
*Чәриг артаса, эр эриг артатыр*

ягъни «йөрәксез кешеләр чирүне – шеренганы боза, шеренга бозылса ирне ир (ягъни сугышчыны сугышчы) аздыра».

Бу тексттагы мәгънәдән чыгып, *арта-* фигыле *аз-* «азу» белән тамырдаш түгелме икән, дигән фикер туа.

Тат. **артак** сүзенә рус. *артачиться* «чыгымлау (ат тур.)» сүзе тоташа. Ахметьянов 1989: 76–77.

**АРТМАК** «сумка через плечо» ~ башк. (БҺҺ II: 30) «притужина» > мар. *артмак, ортмак* ~ чув. *ортмах, уртмах* < гом. кыпч. *артмаҡ* «курҗын»

← **арт-у II** (йөкләү) сүзеннән. Алт. *арчымак* < *артимак* id. (монг. телләре аша үткән яңгыраш).

Рус. *аржмак, арчмак* тур. к. Аникин: 100.

**АРТ-У I** «увеличиваться; переходить меру, быть слишком по размерам; превышать» > мар. (Гордеев I: 151) *арташ,* удм. диал. (Насибуллин: 106) *ӓртънъ* «арту, зураю» < гом. кыпч., гом. төрки, бор. төрки (ДТС: 55–56) *art-* id. (бу сүз танырлык шәкелдә чув. һәм як. телләрендә генә юк). К. ш. ук Будагов I: 25–26.

Э.В. Севортян фикеренчә (ЭСТЯ I: 181–182), *арт-* фигыле бор. **ар-* «артык булу» фигыленең йөкл. юн.; ул бу сүзне **арт II** «йөкләү» сүзе белән берләштерүгә каршы. Ләкин без бу фикергә кушылмыйбыз. К. **Артык.**

Дерив.: **артыр-у, артым, артыш.**

**АРТ-У II** (Тумашева 1992: 27–28) «нагружать, навьючивать» ~ чув. *урт-* < *орт-* «баш-башын асылындырып элү» (Федотов II: 287) < гом. кыпч., алт., уйг., чыгт., хак., тув. *арт-,* угыз. *аарт-, арт-, ард-* «арту, хайван аркасына салу, асылындырып элү» (ЭСТЯ I: 180–181); В.В. Радлов (I: 306) **арт I** һәм **арт II** не бер сүзнең төрле мәгъ. итеп карый. Э.В. Севортян аларны аера һәм *арт* «арт як» белән *арт-* фигылен гомоген дип карый; ләкин угыз *аарт-* яңгырашы бу бор. **аар-* фигыленең йөкл. юн. түгелме икән фикергә этәрә. Гомумән, монда ачыклыйсы нәрсәләр шактый.

**Арт-** продуктив нигез: диал. (ТТДС I: 46) **артыл-у** «ташып чыгу», (Тумашева 1992: 28) «(тау, киртә) аша чыгу», **арту** «киртә» (чаг. кырг., тув. *арт* «тау үткеле»). К. **Артмак, Артык.**

**АРТЫК** «лишний; более (значительный); излишне; больше (не)» > удм., мар. *артык* id. < гом. кыпч. *артыҡ,* уйг. *артуҡ,* хак. *артых*, куман. *artuch, artuk* < бор. төрки (ДТС: 57) *artuq, artïq* id. Бу сүз **арт-у I** сүзеннән дә, **арт-у II** сүзеннән ясала ала, к. тув. *аартык* «артык йөк» ~ бор. төрки (ДТС: 57) *artïγ* «куржынлы йөкнең бер тарафы, тәе». Шулай итеп, бу сүз ике мәзкүр фигыльне баглап тора. Төп мәгънә *арт-* «йөкләү, куржынлау, асылындыру» → *артык* «артылган, асылынып торган (йөк өлеше)» → *арт-у* «артык булу» (кире сүзьясалыш) була ала. Хәер, монда тикшеренәсе бар.

Дерив.: **артыклык, артыкча.**

**АРТЫШ** «можжевельник» > мар., рус. *артыш*, чув. *ортӑш* > *уртӑш, урттӑш, орӑш* ~ алт., тув. *артыш* < уйг. *ардыч*, уйг., чыгт. *артуч, ардуч,* угыз. *ардыч, ардыҗ* < бор. төрки (ДТС: 57) *artuč, artïz* id. ← *art-* «чистарту, арыту» (ЭСТЯ I: 173–174). Асылда бу сүз **арча** (к.) белән уртак этимоннан булырга мөмкин. Räsänen 1969: 28; Федотов II: 288; Аникин: 98.

**Артыш** күп күрше телләргә кергән. Аның «популярлыгы» элекке заманнарда артыш агачы ярдәмендә төрле дәва чаралары – ырымнар һ.б. үткәрелүгә бәйле. Күп кенә якларда *артыш* (арча) бердәнбер ылыслы агач. Ылысларны төнәтү юлы белән елның теләгән бер фасылында витаминлы-шифалы эчемлек алып була. Артышны яндырып төтәсләү – котлау йоласы башкарганнар һ.б. (к. мәкаль: *Артыш исеннән шайтан кача.* Исәнбәт I: 525).

Дерив.: **артышлы, артышлык; артышла-у; артышсыман (артышсыманнар)** – ботаник термин. Себердәге *Иртеш* ~ *Әртеш* елга атамасы да бу сүзгә бәйле: к. фар. (Будагов I: 25–26) *ārдӣҗ, ārдиҗ* «артыш». Бор. кимәк-кыпчаклар Иртеш суын изге, шифалы дип исәпләгәннәр. К. **Идел.**

**АРУ I [aºры̆w]** «чистый; здоровый», «здорово, очень», «совсем»; «целебный» (к. мәкаль: *Бал – ару, җитмеш җиде чиргә дару*), диал. (крш.) «святой» (*арулар белән изгеләр* «святые и священные»), «хороший» > мар., удм. *ару* «әйбәт, исән-сау» < гом. кыпч.: кар., каз., к.-калп *ару, аруw,* кырг., алт. *аруу* «матур, затлы, ару», нуг., тат. диал. (әстр., Арсланов 1988: 73) **әрү, әреw,** к.-балк., ком. *ариw* «матур, саф» (к. **Ары-у I**). К. ш. ук төрки (угыз.) *arı* «чиста, ару», як. *ыраас* «ару», *ырыт-* «арыту, чистарту», монг. *ариг* «пөхтә».

**Ару** сүзенең Төньяк Кавказ телләрендәге гайре сингармоник варианты уйг. *ариғ* «ару» сүзеннән килсә кирәк – аның мәгънәсе дә «югары» – «гүзәл, затлы, асылзат». Чув. *ырӑ* «ару, изге» сүзе дә палаталь варианттан булуы ихтимал, к. мар. диал. (Иванов, Тужаров: 54, Саваткова: 35–36) *ире, эре* «чиста, сәрен».

Гомумән, тат. *ару* һәм чув. *ырӑ* сүзләре мәгънәви җәһәттән дә, морфологик җәһәттән үзара «корреспонденция» мөнәсәбәтендә: тат. **арусыз** (> удм. *арсыз*) ~ чув. **ырӑсар* (~ мар. *ирсыр*) «шапшак, пычрак» ~ бор. төрки (ДТС: 52) *arïγsïz* «пычрак, тәүфикъсыз, мәкруһ»; тат. **арулан-** ~ чув. *ырӑлан-* «яхшыру»; тат. диал. **аруын** ~ чув. *ыррӑн* «ягымлы»; тат. диал. (Тумашева 1992: 28) **арула-** «мактау, тәбрикләү» ~ чув. *ырлав* id. һ.б. Мар. телендә болг. һәм тат. вариантлар параллель (ләкин төрлерәк мәгъ.) кулланыла: *ару* ~ *ире; ару-*

*лан- ~ ирĕлӓн; арулы- ~ ирĕлӓ-*; *арулык ~ ирĕлĕк* һ.б. Бу параллелизмнар (чув. сүзләрен дә кертеп) кыпчак (тат.) – болг. телләренең тәэсирләшүе мари бердәмлеге заманнарыннан килгәнлегенә дәлил.

Төрле материаллардан күренгәчә, *ару* < *арығ* сүзе күп гасырлар элек үк «изге, рухи асылзат һ.б.ш.» мәгънәләрен белдергән һәм, күрәсең, билгеле бер иҗтимагый катлам билгесе булган. ЭСТЯ I: 184–186; Федотов II: 474–475; Ахметьянов 1989: 94–95.

**Ару** тат. теленең үзендә генә дә продуктив нигез: **аруга** > *ару* «бөтенләй; һәрвакыт; һич» (к. ТТДС I: 47–48), **арулат-у** «печтерү», **арумы** «исәнмесез», һ.б. к. **Ардак, Арлау.**

**АРУ II** (ТТДС I: 73) «хорошо, что», «хорошо, ладно» – бу мәгънә добр. (Dobr. I: 139–140) *arüw* сүзендә дә бар.

**АРУЧА** диал. «холостой, холостая» – **ару** сүзенең «җенси җәһәттән чиста, гыйффәтле» мәгънәсеннән, к. тат. диал. (ТТДС I: 47–48) **ару** «аталанмаган (йомырка)», **арула-у** «печтерү»; **аруча** бор. сүз, шуннан чув. *уҫа (усча), урсча, орсча* «тол яки өйләнмәгән» ~ як. *усса, уйса, урса* «баласыз яки аз бала тапкан». Тат. диал. (ТТДС I: 48) **арчала-у** «иреннән аертып алу» < *аручала-у.*

**АРЧА** «вид можжевельника; сосна» < чыгт., уйг., кырг. *арча* (> каз., к.-калп. *арша*) ~ монг. > эвенк. һ.б. *арча* id. Бер версия буенча, бор. монг. *artiča* «чиста» сүзеннән, икенче версия буенча (к. Ligeti L. Un vocabulaire sino-ouigour // Acta orientalia Budapest, T. XIX. 1966:130) бор. монг. *aүarča* сүзеннән. Һәрхәлдә монг. телләреннән кергән һәм *арыт-* «чистару» фигыленә тоташа. К. ш. ук уйг., як. *арчы*, алт. диал. *арчый* «арча; төтәсләгеч агач, төтәсләү» → *арчыла-у* «арча ярдәмендә төтәсләү (чистарту ырым-йоласы)»: ЭСТЯ I: 182–183; ССТМЯ I: 52. Рус. *арца, арса*, *арча* тур. Аникин: 98–99 (шунда ук арытабангы әдәбият). К. **Артыш, Арчан.**

Дерив.: **арчалык.** Татарстандагы **Арча** шәһәренең исеме шуннан бугай.

**АРЧАН** «вереск» < **арчаган* «арчасыман (үсемлек)» булса кирәк. Монг. телләрендә *аршан, арчан* «хикмәтле, шифалы су; үлемсезлек суы; мәңге яшәтер су чыганагы» тур. күп риваятьләр йөри (к. МНМ I: 198; МНМ II: 271, 372 һ.б.). Андый риваятьләр төрки халыкларда да очрый һәм **нарзан** суы атамасы да *арҗан* < **арчан** вариантыннан килә. **Арчан** суы чыннан да бик шифалы, мәс., цинга, рахит кебек элекке чир-чурлардан бик тиз терелткән. Шуннан аның бу сыйфаты гиперболизацияләнгән. К. **Артыш, Арча.**

**АРЧАЛА-У, әрцәлә-ү, әрчәлә-ү** (ТТДС: 49; ЗДС: 88) «разнимать дерущихся; защищать от опасности»; «отнимать жену у другого» ~ башк. *әрсәлә-ү* id. < **арачла-у ~ арачыла-у.** К. ш. ук бор. монг., чыгт. (Поппе 1938: 105) *arčila-* «аралау, арчалау» (чаг. **Арчи**). К. түбәндәгене.

**АРЧИ, арчый** (ЗДС: 56) «поезжанин на свадьбе; сопровождающий невесту» > мар. *ӓрчи* «аргыш», башк. *арсый* «кучты, тәнсакчы; арчи» < бор. монг. *arçi* «яклаучы» сүзеннән; к. ш. ук тат. диал. (ТТДС I: 48; Тумашева 1992: 38) **арчала-, әрцәлә-** ~ башк. *әрсәлә-* < бор. монг. *arçila-* id. > куман. *arsila-* «яклау (кәләшне туй уенында)». К. ш. ук **Әрәчә.**

**Арчи** сүзендә тат. теленә хас булмаганча (*а*дан соң) икенче иҗектә *и* килү бу сүзнең монг. теленнән чагыштырмача соң (Алтын Урда чорында) алынганлыгын күрсәтә.

**Арчи** урынына **артчы** дип әйтү (ЗДС: 53) – халык этимологиясеннән.

**АРЧУ** «полотенце» – исемләшкән **арчы-у.** **Арчу** «сөлге» сүзе куман телендә дә булган. К. ш. ук тат. диал. (ЗДС: 56) *арчуыл, арцуул* < монг. *арчуур* «сөлге».

**АРЧЫ-У, әрче-ү** «чистить, очищать» ~ башк. *арсы-, әрсе-*, кырг. *аарчы-*, нуг., каз., к.-калп. *аршы-* < бор. төрки, чыгт. *арчи-* id. монг. телләреннән бор. алынма (Räsänen 1969: 24): бор. монг. *arti-* id. Тамыры, әлбәттә, **Ары-у** (к.).

**АРШЫН** «аршин» < фар. *аршин* < бор. фар. *arašniš, arašni* «терсәк» (озынлык үлчәмнәре еш кына кул, аяк һәм аларның өлешләре белән атала) < һинд-евр. *el* «бөгелеш; терсәк» (бу сүзнең рефлекслары барлык һинд-евр. телләрендә бар, к. Pokorny: 307; Абаев I: 129).

**Аршин** сүзе Евразиядә дә киң таралган. Федотов I: 60; Тимергалин: 33.

**АРЫ** «далее, по ту сторону» < гом. кыпч. *ары*, хак. *аары,* төркм. *аңыры* id. < бор. төрки **aŋaru* «аңа» (*-ru* бор. юн. килеш кушымчасы, ул *-ғары*//

*-гәре, -қары//-кәре* кушымчасында да күренә), к. **Ан.** Чаг. үзб., уйг. *нәри* < *нары* «ары» < _*анры._

Дерив.: **аргы; ары-бире.**

**АРЫ-У I** диал., сирәк «очиститься» < бор. төрки *arı-,* шор., хак. *ары-* «арыну, чиста булып китү». Бу бор. сүзнең хәзер юн. формалары гына актив кулланыла: *арын-у* һәм *арыт-у* > *арт-у***.** К. **Ару.** ЭСТЯ I: 184–186.

**Ары-** фигыле формасы буенча бор. _*ар_ (*аар*) «чиста, таза, саф (нәрсә)» сүзеннән (**ар-ы-**). Бу сүзне һинд-ир. *ariya* «чиста (кавем)» белән чагыштырырга мөмкин. Шунысы да бар: бор. *арығ* «ару» сүзе физик чисталыкны гына түгел, рухи чисталыкны, изгелекне һ.б.ш. белдерә.

**Ар** тамырын **арий**лар белән чагыштыру тагын шуның белән куәтләнә: тат. *тас* «һәлак булган; хөрти, начар» < бор. һинд. *dāca, дасью* «арийлар тарафыннан коллыкка төшерелгән халык, шул халыктан булган кол-хезмәтче», чаг. ш. ук бор. төрки *jaj-* ~ һинд-ир. *уау-* «корбанга чалу», бор. төрки, уйг. ~ һинд-ир. *ǯia* «җәя» һ.б. К. **Әри, Җәя, Зая, Тас II.**

**АРЫ-У II** «уставать; измучиться», этимологик җәһәттән дөресрәге диал. **ар-** (*ул тиз ара*), к. тув., төр. диал. *ар-*, як. *ыр-*, чув. *ыр- (ыйр-)*, үзб., уйг., чыгт. *һар-*, төркм. *аар-* ~ төркм. диал. *ааз-* > ком. *аз-* «арыклану; хәлдән таю» (к. ЭСТЯ I: 160–162). Пеллио законы буенча, *һар* вариантыннан чыгып, *ар* фин-угор. *pār-* «ару, йончу» фигыле белән чагыштырыла (М. Рясянен һ.б.). Этимологлар *āр-* ~ *āз-* «ару, арыклану» фигылен *āз-* «азу, чиктән ашу» сүзе белән тиңләштерергә ашыкмыйлар.

**Ар-** фигыленнән гом. төрки **арық** «ябыккан, йончу» сүзе ясалган. К. ш. ук төр. диал. *arık-, arqı-* «нык ябыгу». **Арыл-у, арыт-у** юн. формалары да киң таралган.

**АРЫК** «арык, оросительная канава» – гом. төрки *арық, арқ* «арык, канал, канау, елга тармагы; елга утравы; аерым урман», тат. диал. *арык* «тегермән буасыннын язгы суларны китәрү өчен канал (рус. вешняк)» > мар., удм. *арық* id. К. ш. ук чув. *аркӑ* < бор. төрки *arqu, arγı*, бор. монг. *aruγu* «арык, сугару каналы», үзб. диал. *әриғ* id. Электән үк кырг. *айрық* «агымсу тармагы» сүзе белән чагыштырыла һәм *аер-у* фигыленнән дип карала (Радлов I: 25–27, 269), к. ш. ук тат. диал., хак. *айры*, себ. тат. *әйре* «елга, инеш». Ләкин бу аңлатмада фонетик кыенлыклар бар (*айрык* > *арык* типик авыз күчешенә муафикъ түгел). Бу мәдәни терминга зур әдәбият багышланган (к. ЭСТЯ I: 187–189). Ихтимал, **арык** «айрык»тан түгел, *аер-* < *аҙыр-* фигыленең бор. тамыры _*ar-_ (шуннан *аҙ-* > *аз-*) сүзеннән турыдан-туры ясалгандыр, чаг. чув. *орах, урӑх* «аерым, бүтән, икенче».

Рус. *ерик* тур. к. Аникин: 202.

**АРЫК-У (арыгу)** «сильно похудеть» – *ары-у* фигыленең интенсивлык формасы.

**АРЫСЛАН** «лев» > чув., мар. һ.б. *арӑслан, услан* < гом. төрки *арыслан, арслан,* монг. *арсалаң* id. < *арсыл лаң* «җирән киек» булса кирәк: бор. уйг. *арсыл,* бор. төрки (ДТС: 55) *arsal* «кызгылт җирән» (*ар* «җирән», *-сыл, -sal* кушымча, *-лаң* кытайча «киек, кыргый хайван» яки бор. төркичә _*ли аң_: *ли* кыт. «арыслан», *аң* «җәнлек-җанвар»). Турыдан-туры *арсыл (арсал)аң* булырга да бик мөмкин, чаг. алт. *арсыл (арсыл аjу)* «арыслан» (Радлов I: 327).

Бор. төркиләр арысланнарның үзләрен күрмәгәннәр, белмәгәннәр. Кытай сурәтләрендә арыслан кызгылт җирән төстә булган. Һәм кытайча сурәттә ул аюга да охшаган.

Рус. *Еруслан* > *Руслан* «арыслан» дип әйтү бик үк дөрес түгел: *Еруслан* бор. тат. мифик *Уразлаң* «бәхет хайваны» сүзеннән. К. **Ураз.** Ул «бәхет киеге» ничек гәүдәләндерелгәндер – әйтүе кыен.

**Арыслан** сүзенең бүтән этимологияләре ышандырырлык түгел. Федотов I: 56; Тимергалин: 33–34.

**АРЫШ I** диал. (киң таралган, к. ЗДС: 57) «оглобля» ~ ком., к.-балк. *арыш,* үзб. *ариш,* төр. *arış* һ.б (> нуг., каз., к.-калп. *арыс*) id., кырг. *арыш* «адым; бер ян», монг. *arš* ~ *арш* «тәртә». К. **Әреш II.**

**АРЫШ II** «рожь» ~ чув. *ыраш*, мар. *уржа, ружа, рыжа* (Иванов-Тужаров: 249), морд. *розь*, коми. *рудзёг, ǯizeg*, удм. *зег (җёг)* < бор. перм. _*ruǯə ~ roǯə_ (КЭСК: 245).

Бүтән төрки телләрдәге *арыш* «арыш» тат. теленнән (чөнки татарлар элек-электән арыш иккән иң ишле төрки халык): каз., алт. *арыш* > хак. *арыс* һ.б. шундыйлар.

Мәзкүр мисаллар, мордвачаны исәпкә алмаганда, берсе дә турыдан-туры рус теленнән алынмаган – алар ниндидер бүтән һинд-евр. теленнән килә. Һәм аларның чыганагы уртак: барлык Идел-Урал телләрендә дә *арыш анасы* (чув. *ыраш амӑшӗ*, мар. *уржа ава, уржава*, удм. *җеганай*), *арыш атасы*

мифологик образлары һәм *арыш урагы* төшенчәсе бар (чув. *ыраш çурли* ~ мар. *уржа счарла* id.). Һинд-евр. дигәннән, балт-слав. телләреннән тыш, бу тарихи сүз герм. телләрендә генә (ним. *Roggen* һ.б.) бар.

Рус теленнән булса, тат. *рожь* > *эрүш* булыр иде. Шуның өчен һ.б. сәбәпләргә күрә дә кайбер галимнәр тат. *арыш* сүзенең нәкъ рус теленнән алынганлыгына шикләнеп карыйлар. Рус. диал. *аржаной* «арыш (оны, икмәге тур.)» ← **аржа* ~ мар. *уржа* ш. ук *рожь* белән турыдан-туры баглы түгел. Räsänen 1969: 26; Федотов I: 474; Ахметьянов 1989: 48–49; Гаффарова 2007: 89–95 (тәфсилле); Тимергалин: 34.

**АС I,** иск., кит. **аст** «низ» < гом. төрки *аст* (татарлар гарәп хәрефләре белән язган чорларда һәрвакыт *аст* дип язылган; угыз телләрендә сирәк кулланыла – аларда бу мәгънәдә *алт*) < бор. ***асны ← асын** (чаг. **Алын**). Борынгы **ас** «төшерү; төшелгән җир» исем-фигыль синкретик тамырыннан. К. **Ал III, Астыртын, Ас-у.**

Дерив.: **аскы; аслык** һ.б.

**АС II** «горностай» (лат. Mustela erminea), дөресрәге **ак ас** < гом. төрки *ас, āс*, бор. төрки *az, as, aš* ← *арс,* к. кырг. *арыс чычкан* «ас»; чув. *йус* < *йос* < *йас* «ас» < **айс* < *арс* id. (чаг. чув. *йал* < *айл* «авыл», *йуман* < *йоман* < *айман* < *әймән* «имән» һ.б.). **Арс** нигезе уйг. *арыс* «кыргый, усал» сүзе белән бердәй булса кирәк. К. **Асау.**

Бор. сүзлекләрдә (Ибне Мүһәнна) *ас, аш* гар. *әл-ʻарс, әл-ʻирс* «ак ас» сүзеннән дип аңлатыла (**ак ас** тиресе бик кыйммәтле саналган – шуннан монархлар һәм кәләшләр туны тегелгән), ләкин Севортян (I: 191–192) моны кире кага. Чаг. әмма, гар. *ʻарус, ʻаруси* «ас» һәм «кәләш», ә төр. *gelincik* «кәләш, киленчәк» һәм «ас, ләтчә» мәгъ. йөри. *Ас* кышын «туй» вакытында ап-ак булып йөри һәм матур кылана – уенчак була, русча да матур кәләшләрне *горностаюшка* дип атаганнар (әйтмәкче, рус. *горностай* сүзенең ачык-аян этимологиясе юк, ул төр. *kurnaz* «шаян, уйнак, елгыр-елдам» сүзенә тамырдаш түгелме икән әле?). Кыскасы, без **ас** < *арс* гар.-фар. *ʻарус* ~ *ʻаруси* «кәләш» сүзеннән булуы ихтимал дигән фикердә калабыз.

**АСА, гаса** кит. «палка, планка, употребляемая при тканье, вязании сетей, а также узоры, которые ткут при помощи этой планки» ~ башк. (БТДҺ: 32) *аша* id., к. **Әса.**

**АСАБА, гасаба** тар. «вотчинник, хозяин наследственных земель; круг наследников, человек, которому должен оставаться (или уже принадлежит) отцовский удел; наследство» > мар. (Исанбаев 1978: 15) *асаба* «хәлле кеше» < гар. *ʻаçабӓ* «төп хуҗа, варисларның иң беренчесе (гарәпләрдә – өлкәне)» – *ʻçб* «үзәк, үңәч, нервы» (чаг. тат. әд. *гасаби* «нервлы, үртәнгән») тамырыннан, к. Будагов I: 162–163 (энциклопедик аңлатма).

Удм. *асаба* «гаилә башлыгы» < тат.; нуг., каз., кар. *асаба* «варис», к.-калп. диал. *асаба* «туйда төп персонажларның берсе» (ҠТДС I: 30), кырг. *асаба* «флаг, гаилә байрагы» һ.б. бу сүзнең күптән таралганлыгын күрсәтә.

**АСАУ [аºсаw],** себ. (ЗДС: 52) **арсар** «одичавший, неприрученный (о лошади)», «переросток» < гом. кыпч. *асау* < *арсау* (Радлов I: 536), к. башк. диал. *арса-* «өстенә мендермәү, җиктермәү (ат турында)»; бу фигыль исә уйг. *арыс* (к. **Ас**) «усал, кыргый» сүзеннән. Диал. (ЗДС: 22) *азау* «чәчелмичә үскән иген» **азау** сүзе тәэсирендә барлыкка килгән. К. **Азау II.**

**АСИЯ [аºсийа]** иск. «Азия» бор. сем. *асу* «көнчыгыш» сүзеннән. Тимергалин: 16, 34.

**АСЛАМ** «торговля наездом», **аслам, асытлама** «барыш, процент» > мар. *аслам, ослам, ашлам, ашлӓм,* чув. *ослам* > *услам*, удм. *услом,* манси. *ослым* < гом. кыпч. *аслам, астлам* < *асылам, асылама* «сәүдә табышы; вак сәүдә» (к. Радлов I: 547; Räsänen 1920: 171); бу сүзнең бор. кыпч. *astelan* (CC), *astılan* формасы тат. диал. *ашыт, асыт* «файда» сүзеннән ясалган (бу сүз исә *асы, асу* «сәүдә табышы» нигезенең бор. күп. формасы булса кирәк). К. **Асу.**

*Аслам* ~ *ашлам* сүзе бигрәк тә мари телендә күп мәгънәле «файда, табыш; түләүсез ярдәм; өмә; процентлар» (Упымарий: 28, 30, Саваткова: 12). **Аслам** сүзен *асыл мал* (Ж. Вәлиди) яисә *асылмалы* (асламчыларның кәрзин «асып» йөрүеннән) дип аңлатучылар бу сүзнең бор. һәм кардәш вә күрше телләрдәге мәгънәләрен исәпкә алмыйлар.

**Аслам** сүзе Алтын Урда чорында актуальләшкән булса кирәк. Будагов I: 55; Räsänen 1969: 29; Ахметьянов 1989: 103; Федотов II: 291.

Дерив.: **асламчы, асламчылык.**

**А́СЛАН, а́сла** диал. (ТТДС I: 50) «совершенно; нисколько» < гар. *аçлāн* id. ← *асыл* (к.).

**АСМАН** «небо, небеса» < фар. *āсмāн* id. бор. һинд-евр. *akmen* «таш» (шуннан ук рус. *камень*) сүзеннән; тамыры һинд-евр. *ак, ок* «үткен» (Pokorny: 17–19); күкне таш дип күзаллау бор. психологиягә хас булган.

**АСРАУ [а°сраw]** «прислуга; сирота (девочка), взятая в дом в качестве прислуги» ← **асра-у** (к.).

Дерив.: **асраулы, асраулык.**

**АСРА-У, асыра-у** «воспитывать, содержать; кормить, питать; разводить (скот); рожать» < гом. кыпч., чыгт. *асра-, асыра-*; себ. (брб.), алт., хак., тув. *азыра-* «асрау», к.-балк. *асыра-* id., ш. ук «җирләү, күмү», ә маньч. *асара-* «асрау, саклау; мәетне өйдә саклау» (к. ССТМЯ I: 54) – бу мисаллар сүзнең төп мәгъ. «(үзеңдә) саклау, яшерү» булганлыгын күрсәтә (к. ш. ук Ясәвидә: *Илаһи, шәрри шәйтандан сән асра*). Гомумән, *асра-* тюркологиядә иң бәхәсле сүзләрнең берсе. Ул, шиксез, монг. *асара, асра-* «асрау, яклау» сүзе белән гомоген. Бор. төрки телләрдә *асра-* теркәлмәгән, шуннан чыгып булса кирәк, Рясянен (Räsänen 1969: 29) *асра-, асыра-* сүзен монголчадан алынган ди. Э.В. Севортян (ЭСТЯ I: 193–194) монг. сүзе үзе төрки телләрдән дип бара, аныңча, *асра-* < *асыра-* бор. *асыгра-* «файда китерү» сүзеннән (к. **Асу**). М.Р. Федотов (II: 292) чув. *усра-* < *осра-* < *асра-* сүзен гом. төрки *аш, ас* «аш» сүзеннән дип бара һ.б.

Безнеңчә, бу сүзнең таралуына монг. телләре күп өлеш керткән, ләкин ул төп төрки сүз, к. уйг. (Радлов I: 896) *äзiргä-* «саклау, яклау» < **азырга-*, бор. **азы-* (шуннан *азыг* > *азык*) «запас ясау, запас җыю» сүзенең дәвамлы интенсивлык формасы, чаг. *ачы-у* → *ачырга-у, кат-у* →*катырга-у, сөй-ү* → *сөяркә-ү* һ.б.ш.

Дерив.: **асрал-у, асран-у** «ничек тә яшәп тору», диал. «бала табу», **асрат-у; асрама** (*асрамага бирү,* мәс., баланы); **асранты** (*асранты бала*).

**АСТАНӘ** «могила святых» < фар. *āстāнä* id. – «табыну урыны; мавзолей»; каз. *астана* «административ үзәк, башкала» бу сүзнең күчмәчеләр өчен очрашу һәм идарә урыны изге каберләр булуыннан килә.

**АСТАР** «подкладка, подстилка» < фар. *āстäр* id. ~ санск. *āstara* id. һинд-евр. **star-, ster-* «җәю» тамырыннан (шуннан ук рус. *стелить, стол* һ.б.). Будагов I: 40.

Мар. *астар* «кыек шикмәсенә китә торган сыйфатсыз такта» татарчада да шундый мәгънә булганлыгын күрсәтә. Гомумән, **астар** күп төрки телләрдә очрый.

Дерив.: **астарлы, астарлык; астарла-у** (һәм аның юн. формалары) һ.б.

**АСТАРЛАБ** иск. «астролябия» < гар. < грек., гар. теленә VII г. ук алынган.

**АСТЫГАН** «малина», **аслаган, аслыган, әстәган** «ежевика» (к. Тумашева 1992: 29, 38) – сүзнең кушымчасына (*-ган*) караганда, монголчадан.

**АСТЫН** диал. (ДС I: 20) «низом, по низу» – *аст* сүзенең инструменталь килешеннән (**өстен** сүзенә антоним буларак ясалган).

**АСТЫРТЫН** «исподтишка; скрытно» ← диал. (ДС II: 40) *астыр* «түбән җир» сүзеннән; бу сүзне исә *аст ур* «түбәнге ур» дип тә тәгърифлиләр. Чаг. ш. ук себ. (Тумашева 1992: 29) **астыргак** «тел асты» < **аст урғақ?**

**АСУ** иск., кит. «полезность; выигрыш, профит» > мар., морд. *асу,* чув. *ус, уссă, усă* < гом. кыпч. *асу* < бор. төрки (ДТС: 60 һ.б.) *асыг* id. ~ монг. *ашиг, асик* id.; күп төрки телләрдә очрый һәм күрше телләргә дә кергән (бор. төрки ядкәрләрдә *асыг* «файдалы булу» **асы-** тамырыннан), төр. *assı* «асу, процент», ~ маньч. *аjси, аjши* «файда, табыш, сәмәрә, тырышлык нәтиҗәсе һ.б.» < кыт. *ай си, ай ши* «табыш, процентлар» – төп мәгънәсендә «йок, касмак, утырган тузан, борак оны» – сәүдәгәрләр телендә табышны кечерәйтеп әйтүдән. Кыт. *ай-сигу, ай-ши-гу* – «беркадәр, бер данә табыш».

Бор. *аси* тамыры төрки телләрдә бик тармакланган һәм күп дерив. биргән (бу хәл бор. төркиләрнең сәүдәгәрлеге белән аңлатыла). К. **Аслам, Ашы.** Радлов I: 541; Будагов I: 48; Боровков: 61 (арытабангы әдәбият күрсәтелә); Федотов II: 290–291; Тимергалин: 35–36.

**АС-У** «повесить, свесить; кипятить, варить» (*казан асу*) < гом. төрки *ас-* > чув. *ос-* > *ус-* id. (кайбер телләрдә «кайнату» мәгънәсе өстенлек итә) ~ бор. монг. *as-* id. К. Räsänen 1969: 28; ДТС: 59; Федотов II: 289.

Дерив.: **асыл-у** (→ **асылдыр-у, асылын-у**); **астыр-у; аскы** (нәрсәнедер асу җайланмасы); **асмалы, асылмалы** һ.б.

**АСЫЙ** (ДС I: 20; Тумашева 1992: 30) «несвежий, прежний; просроченный», Й. Гиганов сүзлегендә «годовалый» ~ кырг. *асый* «печелмичә калган айгыр», алт., хак. *азый* «асый, искергән, элекке» < бор. *алсый* < *алсиғ* < *алыс-ығ* «кар астында калган» сүзеннән, к. **Асау, Алсын, Алыс.**

**АСЫЛ** «коренной; благородный; качественный» < гар. *аҫил* «борынгы, затлы, нәселле» һәм *аҫл* «тамыр, башлангыч» сүзләренең тат. телендә килеп чыккан контаминациясе (гомумән, *асил* һәм *асыл* сүзләрен аерырга кирәк иде). *Аҫл* сүзеннән иске тат. *áслан* < гар. *аслан* «бөтенләй, тамырдан» сүзе ясалган. Будагов I: 34.

**АСЫТ** «прибыль (в торговле), барыш» к. **Аслам**.

**АТ I** «лошадь» < гом. төрки *ат, аат,* тув. *аът* «ат, алаша» < бор. төрки, монг. *ағта*, *ахта* (к. иске тат. *ахтачы* «конюх») < фар. *ахта* «алаша» сүзеннән дип исәпләнә, ләкин бу фикер шик астына алына (к. ЭСТЯ I: 197–198). Бор. төрки, фарсы һәм сугдлар эшкә-менгегә башлыча печтерелгән айгырлардан файдаланганнар (чаг. ш. ук *алаша → лошадь* «гомумән ат»). К. **Атан, Аткый, Атла-у, Атлыкса**. Чув. *ат* > *ут* тур. Федотов II: 293; Тимергалин: 36–37.

**АТ II** «имя (персоны); слава» < гом. төрки *ат, аат* id., бор. төрки (ДТС: 64–65) *ad, at, āt* «исем, титул; дан» бор. *айыт, айыды* «исемләнү, исемләнүе» ← *ай-* (к. **Әй-ү**) «сөйләү, әйтү» сүзеннән булса кирәк (к. Радлов I: 440): чув. *йат* «ат, исем» < *айт* < *айыт*. Тат. диал. (ДС III: 24) *атыма* «үземә» – «сораганыма» дигәннән. Кайбер телләрдә (мәс., «Сиражел-Қолүб»тә, к. Наджип 1989: 172) *ад* «исем» һәм *ат* «ат, елкы» сүзләре аермалы языла, ләкин Э.В. Севортян фикеренчә (ЭСТЯ I: 198–199), бу аерымлану этимологик характерда түгел, соңрак килеп чыккан күренеш. К. ш. ук Федотов II: 505.

**Ат II** – продуктив нигез: к. сөйл. **атлы** «исемле» (*ни атлы?*), к. **Адарын-у, Атаклы, Атал-у, Ата-у**.

**АТА** «отец» < гом. төрки *ата,* куман. *атта* (> тат. *әттә*) «ата», кайбер телләрдә «дәвәти, бабай» типологик *ата//аса* тамырыннан (Зифельд-Симумяги: 122–124; Покровская: 25–29; Номинханов 1958: 42–44; ЭСТЯ I: 200–201; Рамазанова 1991: 161–166). Тат. телендә **ата** нигезе бик күп фономорфологик дериватлар биргән, *атай* (вокатив), *атакай, атакаем* (ымлык), *атач* > *әтәч* (к. **Әти**), *атыш* < *атайыш* «фамилия» (ДС II: 22), к. ш. ук **Әти.** *Atta* «ата» һинд.-евр. телләрендә киң таралган, к. Kluge: 69. Тарихи дериватлар тур. Будагов I: 8–9. К. **Аталык.**

**Ата** һәм аның фономорфологик дериватлары күрше фин-угор телләренә дә кергән, к. ДАУ III: 235–258.

**АТАКЛЫ** «знаменитый, именитый», диал. **атаҡ** «яманат» ~ нуг., каз., кырг. *атаҡ* «дан, шөһрәт» ← *ата-* «атау, исемләү» ← *ат* «исем» сүзеннән (*ата-ҡ*). Чаг. *атаулы* «атаклы» (ДС I: 21). *Атак* «героик исем» булган булса кирәк: бор. төркиләрдә сугышта үзен күрсәткән ир-егетләргә икенче – каһарманнар исеме бирелгән.

**АТАЛАН-У** «оплодотворяться» тат. теленең үзендә махсус ясалган булса кирәк (әд. телдә); диал. *аталан-* «бик зураю, үсеп китү» – бөтенләй бүтән мәгънәдә. **Атаданлык** «отчество» – шулай ук ясалма сүз.

**АТАЛГЫ** «скобель; поперечный топор» – тәгәрмәчнең күчәр тишеген тишә торган зур махсус бораy; аркылы балта, бәлҗә > мар. *аталык*, нуг., каз. *аталғы* «китмән» < монг. *аталга* «аркылы балта, китмән» < *ата-лга* id. *ата-, ада-* «кисү, тишү» фигыленнән (Рамстедт).

**АТАЛ-У** «называться» ← *атау* дип карала, ләкин бор. төрки телләрдә үк *ат ал-(у)* «ат, исем алу» – сүз икенче, «героик исем» тур. бара. К. **Атаклы.**

**АТАЛЫК** «аталык, человек, принявший на воспитание в своей семье мальчика другого – обычно близкого человека по тюркскому обычаю (была и **аналык** – принявшая на воспитание девочку); воспитатель сына знатного лица» – гом. кыпч., чыгт. һ.б. **ата-лык** id. Будагов I: 8–9; Doerfer II: 69–71; Аникин: 101; Тимергалин: 38.

**АТАМАН** «атаман; коновод, предводитель (в игре)» – халык этимологиясендә **ата** сүзе белән якынлаштырыла һәм *атай, атайман* дип тә әйтелә. Ләкин тикшеренүчеләр (А.Г. Преображенский; Җ. Вәлиди I: 33) бу сүзне кр.-тат. *отаман,* нуг. *одаман* «көтүчеләр башлыгы» («куыш башлыгы»)

сүзеннән чыгаралар. К. **Атау.** Чаг. **Узаман.** Чув. *утаман* < *отаман* тур. Федотов II: 204.

**АТАН** «верблюд-самец (холощёный)» < бор. төрки (ДТС: 66) *atan* id., хәз. нуг., каз., к.-калп., кырг., уйг., ш. ук монг. телләрендә *атаң, атан* «(көчле) атан; чемпион, батыр; шедевр». **Ат** сүзе белән тамырдаш, к. монг. *агтан* «ат; атан». Тат. диал., башк. (БТДҺ: 28) **атан** «чикерткәнең бер төре» (рус. кобылка); күп мәгъ. ЭСТЯ I: 202–203.

**АТАУ [aᵒtaw]** «остров (в дельте реки); островок травянистой или лесистой местности в скудной степи» (к. ДС III: 23; ТТДС I: 52; Тумашева 1992: 31) > мар. *атау* «чоңгыл, тоба», *ата, ото* > чув. *отӑ, утӑ* «атау, утрау», удм. *атау* «елга утравы» < нуг., каз. һ.б. *атау* < бор. кыпч. (куман) *atov* < бор. төрки, бор. монг. (ДТС: 8) *aday* > *adaq* «елга тамагы; **аяк**», к. ш. ук кар., ком., төркм. *ада*, аз., төр., кр.-тат. *ада* «утрау». Рус. *отава* «аерым әйбәт көтүлек» < кыпч. *ataw* id. Рус. этимологик сүзлекләрендә бу факт кире кагыла, ләкин алмашка юньлерәк аңлатма тәкъдим ителми (к. Фасмер III: 86). Räsänen 1969: 31; ЭСТЯ I: 87–88; Ахметьянов 1989: 29–30. К. **Азак, Аяк.**

**АТА-У** «называть; нарекать именем» < гом. кыпч. *ата-,* угыз. *ада-* «атау, вәгъдә итү» ← *ат,* угыз. *ад* «ат, исем». К. **Адарыну.**

**АТӘШ, аташ** «священный огонь; огонь в груди» (*атәшле* «пламенный») < бор. төрки (ДТС: 66) *ataš* id. (*atašluγ* «атәшле») фар. теленнән бик бор. алынма, Кушан дәүләтендә (б.э. I–II гасырларда) *Атшо* «ут тәңресе»; башк. *аташла-у* «ут аша атлау (рухан чистарыну, ш. ук ант итү билгесе)» (к. БТДҺ: 39) шул заманнардан калган.

**Атәш, аташ** иске әд. телдә актив кулланылган (ГТДС I: 19; Будагов I: 9), шуннан *атәшпәрәст* «утка табынучы», *аташханә* «утка табыну гыйбадәтханәсе», *аташин* «ялкынлы (публицист һ.б.)» барысы да фарсы теленнән.

**АТКАР-У** «исполнить; доделать да конца (и с плеч долой)» ~ каз., к.-калп. *аткар-*, үзб. *отгар-* id. К. бор. төрки *atqa-* «абстрактны конкретка баглау» (к. ДТС: 68); бор. төрки *атгар-* «атка атландыру – гаскәр җыю» (Боровков 1963: 63), кырг. *аткар-* «атка атландырыю җибәрү; кыз озату», төркм. *атгар-* «аткару» (ТДГДС: 27), чаг. *җил → җилгәр-ү, су → сугар-у, ту → тугар-у.* К. **Ат.**

Төрки халыкларда кызны атка атландырып – «аткарып» озату гадәте булган.

**АТКЫ** «бита, биток (в играх); стрела, которую метают резким взмахом, насадив на конец палки» ← **Ат-у** (к.).

**АТКЫЙ** «конский щавель» < *ат қыйы: қый* «чүп үлән», к. **Кый.**

**АТКЫЙ-МАТКЫЙ, әйтке-мәйтке** «привет-ответ» игра в рифмованных вопросах-ответах < *айыткы* «вопрошание» – *майыткы* «ответ, отповедь» (букв. «загибание назад), к. ***Майтар-у, Мает-у.**

Бу сүз башлыча миш. сөйләшләрендә теркәлгән (**аткы-маткы** «мишәрләрдә бер уен», Вәлиди I: 35; Ф. Бурнашта: *Матур кызлар бу кичне мактыймактый, Диделәр бер-беренә аткый-маткый;* Ульян өлкәсе Лабис авылында *атки-матки* дип сүз башлаучыга *Шәһәдәт кый* дип җаваплыйлар һәм көрдәшү такмагы әйтәләр); мишәрләрдән бу сүз рус теленә дә кергән: *атки-патки, аты-баты* һ.б.ш. (к. Виноградов 1930: 161–163).

**АТЛАМА** «стропило (с ригелем); скоба, саженник (устройство для измерения земли)» < *атла-ма́* «атлый торган нәрсә» кебегрәк. К. **Кереш** өлешен. Җир үлчәгәндә А хәрефенә охшаш *атламаны* «атлаталар» иде. Хәзер җирүлчәгеч оптик аппаратура кулланыла.

**АТЛАН: атлан май** «масло коровье» к. **Аты.**

**АТЛАН-У** «сесть верхом», диал. «отправиться» < гом. кыпч. *атлан-* «атка ия булу» кебегрәк (бу сүзнең мәгънә үсешләре тур. к. Севортян 1962: 121). К. ш. ук каз. *атлан* – «ашыгу».

Дерив.: **атланыш-у, атландыр-у;** диал. **атланган көн** «атнакич» – элекке заманда ир-ат атларга менеп хәрби өйрәнүләргә чыга торган көн (чаг. чув. *утлари кун* id. «атлардагы көн»).

**АТЛАС** «атлас (вид ткани); атласовый, атласный» – бу сүз төрки телләрдә электән билгеле (русчадан түгел) һәм гар. *ӓṭлӓс* «шома тукыма» дигәннән килә. Сүзнең тамыры *ṭалӓсӓ* «юу, жую» грек. *θάλασσα* «диңгез дулкыны, диңгез» сүзеннән дип уйлыйлар.

Шуннан (гарәпчәдән) үк **атлас** «карталар, рәсемнәр альбомы». Рус теленә Европа телләре аша кергән.

**АТЛА-У** «шагать», диал. (Akb: 56) **atla-** «перешагнуть» < гом. кыпч. *атла-* (каз., кырг. *атта-*) id., ш. ук «ашыгу, кабалану» бор. төрки **ат-* (госм. *ад-*, чув. *от-* > *ут-*, төркм. *əəт-*) «атлау» тамырыннан, бу тамыр сүз исә **агылт-* яңгырашыннан булса кирәк, к. тат. диал. (Арсланов 1988: 70) *awыт* «адым», *awытла-* «атлау» һәм к. монг. *алд* «адым (озынлыгы)»; бор. **агылт* > **awылт* > **алт* «адым» – «атлау» (исем-фигыль синкретизмы) сүзеннән бер яктан *алтым* > *адым*, икенче яктан *алтла-* > *атла-* сүзе килеп чыккан. Чаг. ш. ук төркм. *әдим әд-* «адым атлау», *әтле-* «атлау».

Әмма бу фараз гына. **Адым** һәм **атла-у** сүзләренең тамырдашлыгы шиксез булса да, алар арасындагы мөнәсәбәтләрне ачыклыйсы бар. Чув. *ут-* < *от-* < болг. **ат-* тур. Федотов I: 293.

Дерив.: **атлат-у; атлам.** К. **Атлама.**

**АТЛЫКСА** «конюшня; помещение, где содержится сбруя и т.п.» ← **атлык** (бу сүз үзе сирәк очрый).

**АТЛЫК-У (атлыгу, атлыкты)** «рваться (в дело, в бой и т.п.) < *атыл-ык-,* ягъни *ат-у* сүзенең интенсивлык формасыннан, чаг. *өзү – өзлегү, тыю – тыйлыгу, чөю – чөйлегү, язу – язлыгу* һ.б.; *-лык//-лек* фигыль аффиксы гомумән *-ыл-ык//-ĕл-ĕк* итеп таркатыла, ягъни төш. юн. кушымчасы *-ыл//-ĕл* һәм интенсивлык форманты *-ык//-ĕк*тән гыйбарәт.

**АТНА,** диал. (ТТДС I: 548) **әтнә** «неделя; пятница» < уйг. *одина, адинә*, үзб. диал. (ЎХШЛ: 14), аз. *адына* < бор. төрки (ДТС: 11) *adïna* «җомга» < фар. *адинä* < бор. фар. (Харәзем) *fadena* «бишенче көн» (*fade* «биш») сүзеннән дип исәпләнә. Бор. Харәзем атнасы биш көнлек булган һәм моның эзләре тат. (гом. көнб. кыпч.) мәҗүси атна көннәре атамаларында (*баш көн, буш көн, кан көн, атланган көн, атна көн*) чагыла; яңа – җиде көнлек атна белән иске атна арасындагы аерма – шимбә – *атнарас (атна арасы) көн* дип, ә якшәмбе *урыс атнасы* дип аталу, шулай ук *җомга* көнне «*кече атна*» дип атаулар (к. ТТДС I: 53–54, 456) элекке бишкөнлек атна соңгы заманнарга кадәр гамәлдә булганлыгын күрсәтә.

*Атна* < *одна* < *адына* сүзе төрле телләрдә күп фонетик вариантлы һәм бу вариантлар күрше вә кардәш телләрдә дә күренә: башк. *аҙна,* «Сиражел-Қолуб» телендә (Наджиб 1989: 173) *аҙинā*, Әбү Хәйян сүзлегендә *айна* (Мухамедова 1973: 57), төркм. *анна*; чув. *ерне* < болг. **әрнә, *арнә* > мар., удм. *арня, äрнä* «җомга; якшәмбе; ял көне; атна» ~ көрд. *arna* «атна». Болг.-чув. һәм көрд вариантлары аеруча кызыксыну уята: әгәр алар үзара баглы булсалар, каян таралганнар?

Хәз. төрки телләрдә *атна* сүзе киң таралмаган. Тат., башк., нуг. сөйләшләрендә «атна» мәгънәсендә *йома, җӧма, җума* «җомга», иске яз. тат. телендә (шулай ук үзб. һ.б. Урта Азия телләрендә) *һәфтә* (фар. *һäфтä*) «атна, җидекөнлек» сүзе кулланыла. Кайбер Төньяк Кавказ кыпчак сөйләшләрендә хәтта *бәрәскә* < грек. παρασκευή сүзе дә «атна» һәм «җомга көн» мәгъ. очрый (*Бәрәскә* дигән татар авыллары да бар!).

Җиде көнлек атна бор. заманнардан бирле билгеле җиде планетага тәкълидидән килеп чыккан. К. Бируни 1995: 207–213; Тимергалин: 38–40 (атна көннәре тур.)

**АТСЫЗ: атсыз бармак** «мизинец; безымянный палец» ← *ат* «исем, атама». Гомумән, *атсыз* сүзе элек-электән төрле мәгънәләрдә киң кулланылып килгән, к. себ. (МНМ I: 124) *атсыс* «шайтан» ~ удм. *атсыз* (< тат.) «шүрәле», миш. (ТТДС I: 54) *атсыз* «кандала», «кызу чире» һ.б. Күрәсең, *атсыз* сүзе табу йоласы буенча исемен әйтергә ярамаган нәрсәләрне (атап әйтсәң – үзе килә) атау өчен кулланылган.

**АТУ I** диал. «а то, иначе» ~ башк. *атыу*, чув. *атту,* удм., мар. *ато* id. < рус. *Атуса* варианты *ату исә* тезмәсеннән. Чаг. *юкса* < *юк исә.*

**АТУ II** (Тумашева 1992: 30) «ичиги, мягкие сапоги» ~ әстр. сөйләшләрендә *ату, атыw* һ.б. болг. **атыw*< **ăтеw* сүзеннән. Турыдан-туры чув. *атă [ады]* «итек» сүзеннән дип фаразлау (Федотов I: 69) фонетик җәһәттән акланмый. Каз. (ҚТДС: 34) *ату* «итек» тат. сөйләшләреннән булса кирәк. Гомумән, *ату* сүзе төрле сораулар уята: ихтимал, велярлашу күренеше (*ä* > *а* һ.б.ш.) болг. теленең үзендә үк (чув. һәм мар. телләрендә генә түгел) килеп чыкмадымы икән?

**АТ-У** «бросать, кидать; стрелять, пропустить челнок через ряд основ» < гом. төрки *ат-*, *аат-*, як. *ыт-* id., бор. төрки (ДТС: 65) *at-, āt-* «ату; куып җибәрү; качыру» < бор. төрки (ДТС: 20–21) *aγït-* id. *aγ-* (ДТС: 16) «күтәрелү; очып китү» сүзенең йөкл. юн. Бу күчешләр һәм сүзьясалышлар бор. һәм хәз. төрки телләр материалында бик ачык шәйләнәләр. К. ш. ук чув. *ут-* < *от-* «ату» (< тат.) һәм *ывăт-*

<< **агыт-* (< болг.). К. **Агыт-у, Атын-у.** Räsänen 1969: 31; ЭСТЯ (Севортян) I: 199–200; Федотов II: 469–470.

**АТЯКШ, атякыш** (ЗДС: 61, миш.) «клоун в новогодних играх» < морд. *атякш* id., төп. мәгъ. «әтәч».

**АТЫ** диал. «мутовка; посуда для сбивания масла» ~ чыгт. *ати, атиғ* id. (Радлов I: 462) ~ як. *ытык* id. ниндидер фигыльдән ясалган сүз (чаг. *ат-у*).

**Аты** сүзенең үзеннән бигрәк аның дериватлары билгеле: 1) сөйл. *(май) атла-у < атыла-у > атала-у* «май чыгару өчен каймакны болгату» шуннан *атлан (< атылаган)* яисә *аталама май* «сөт мае», *атлавык, атлавыч (< атылавык, атылавыч*) «гөбе пешкәге» (ДС II: 41); 2) диал. (себ. һ.б.) *атала, әтәлә* «боламык» < *аталау* < **атылагу* һ.б. *Атавыч, аталавыч* (ТТДС I: 52) «аты». К. **Әтәлә.**

**АТЫЗ** «пашня, поле среди болот» к. **Әтез.**

**АТЫ-ЮЛЫ: аты-юлы белән хурлау, сүгү** «сильно поносить, ругать во всю». Бор. мажара эзләүче батырлар очрашканда бер-берсенең хөрмәтле исемен – атын һәм юлын – максатын сораганнар, аннары каршыдашның атын һәм юлын хурлап, аны үртәгәннәр, ярсытканнар; шуннан соң сугыша башлаганнар (бу гадәт һуннардан Европага да кергән). *Атың-юлың кем* дигән сорау формуласы себер төркиләре эпосында күп тапкырлар кабатлана.

**АУ [a°w]** «охота (на животных)»; «большие сети (для ловли зверей и рыб)» > мар., удм. *ау* id. < гом. кыпч. *ау [aw],* гом. төрки *āб, āв, āғ, аң, ың* «ау, ау шәе (объекты) һәм ау коралы» (һәр телдә үзенчәлекле комбинация һәм мәгънәләрдә), өстәвенә *аң//ан* «болан, киек», кушымча буларак хайван атамаларын ясый: *көзән, куян, чаян* һ.б. (ләкин *болан, колан, әрлән* һ.б.ш. сүзләрдә *ан//ән* түгел, *-лаң//-ләң* кушымчасы бар дип карала). Чаг. ш. ук монг. *аба* «ау, аулау», к. **Абала-у.**

**Ау** төрки-монгол халыклары тормышында гаять зур роль уйнаган һәм ул бик тә оешкан төстә башкарылган: зур мәйданнар (*абрау җирләр*) киекләр үрчесенгә калдырылган – аларның чикләре сакланган һәм ау бөтен хөкүмәт тарафыннан билгеләнгән вакытта гына вә бергәләп башкарылган. Ау кагыйдәләрен бозучылар җәзага тартылган (гадәттә аларны буралы көпкәгә япканнар һәм аналары карамагына калдырганнар). К. Анисимов. 1969: 15–20. Будагов I: 60, 105; ЭСТЯ I: 62–65, 152.

Дерив.: **аула-у** (шуннан **аулан-у, аулаш-у, аулат-у**); **аучы, аучылык.**

**АУК [a°wқ], аwык [a°wы̆к]** (Тумашева 1992: 32) «заяц». К. Насыйри (ЛТ I: 33) **аwыҡ** «ауланган хайван» сүзе бар ди. Әмма бу шикле: тат. *авыҡ* дип *ивуҡ*ны – кечкенә дала боланын (аның баласын) да атыйлар (к. атаклы «Ивук кыйссасы»). К. **Аулак.**

**АУЛАК [a°wлаҡ]** «укромное место, посиделки» > мар. *аулак, олак* > чув. *олак, улах*, удм. *аулак* < гом. кыпч. *аулак* < гом. төрки *ағлаҡ* id. тәүдә «киек үрчесен өчен буш куелган, кешесез калдырылган җирләр» мәгъ. булган (к. **Ау**). Бу мәгънә тат. әд. телендә дә бар: *Патшаның аулагы булган бу урманга ни эшләп килдең* («Кәлилә вә Димнә»). Соңыннан *аулак* «ерак җир» мәгънәсен алган, к. кырг. *оолак* «ерак», *оола-* «ерагаю, олагу», Катанов сүзлегендәге тат. диал. *аулан-* «(ерагаеп) ялгыз калу» һәм *аулат-* «ялгыз калдыру» сүзләре икенчел; монг., тунг. *агы* «ерак, буш» (шуннан *аглах, аглага, аглан* «ерак җир, кола ялан, ачык дала» >> тат. *аклан*) шул ук *аг* «ау» тамырыннан булырга тиеш (әлбәттә, монда контаминация күренешләре дә бардыр).

К. Räsänen 1969: 8; ЭСТЯ I: 62–63, 152–153; Федотов II: 275.

**АУМАКАЙ [a°wмаҡай]** «быстро поддающийся уговорам; беспринципный, безвольный» < гом. кыпч. *аумакай, аума* «аву (күренеше)» сүзеннән. Ихтимал, *-кай, -га* кушымчасының катнашы бардыр.

**АУНА-У [a°wна-]** «валяться; переворачиваться» < гом. кыпч. *ауна-* id. < бор. төрки *ағна-, ағына-* id. *ағ-* «аву» сүзеннән (*авын-* < *ағын-* «үзеннән-үзе аву» нигезеннән булса кирәк). Тат. диал. **аунатма, аунаткы** «үзбушаткыч, самосвал» сүзләре игътибарга лаек.

**АУСАН-У [a°wсан-]** (ЗДС: 65, себ.) «припомнить (в разговоре); говорить что-либо о прошлом» < бор. төрки (ДТС: 21, 24) *ayïzan-* «әйтү», *ayzan-* «әйтү; кычкырып уку» ← *ayïz* «явыз». Күрәсең, кайчандыр *ағза-* < *ағыза-* «авыз ачып сөйләү» сүзе булган. Чаг. уйг., чыгт. *ағзәки* «телдән әйтелгән», *ағузлан-* > себ. (Будагов I: 63) **аwыслан-** «телгә алу» һ.б. К. **Авыз.**

**АУ-У [а$^{o}$w-]** «валиться в сторону, свалиться» < гом. кыпч. *ау-* < гом. төрки *āг-, аг-,* төр. диал. *ыг-*, чув. *йăв-ан- (< аwын-)* id. шуннан *агдар-* > *аудар-у* һәм > *актар-у* (татарчада ике сүз) килеп чыккан. К. **Актар-, Аумакай, Ауна-.** Чаг. **Авыр.** Будагов I: 158–159.

**АФӘТ** «бедствие» < гар. *āфäт* id.

**АХ** ы. «ах!»; **ах итү** «сопереживать, принять близко к сердцу» – тат. теленең үзендә ясалган. **Ах** русчадан булса кирәк, чаг. **Ah.**

**АХАК, ахык** «сердолик; агат» > мар. *ахах* id. иске яз. тат. *ақыйқ, ғақыйқ* > башк. *ақық,* тув. *акак, ахах,* мар. *акук*, удм. *какыт* < гар. *ʻақӣқ* id. Рус. *агат* < ним. *Agat* < лат. *achates* – грекчадан, шуннан ук гарәпчәсе. Федотов I: 71.

**АХИРӘТ I** «загробная жизнь; загробный мир» > чув. (Федотов I: 72–73) *ахрет* id. < гар. *āхирäт* id. к. **Ахыр.**

**АХИРӘТ II** «подруга» – «ахирәттә (к. **Ахирәт I**) бергә калкыйк дип сөйләшкән кешең, ахирәт дустың» сүзеннән, шул ук мәгънәдәге (мөзәккәр) *ахири* сүзе дә бар. Бу төшенчәләр гар. телендә үк формалашкан, к. Тимергалин: 41.

**АХИРИ, ахир** «друг – мужчина». К. **Ахирәт II.**

**АХМАК** «глупец; дурак» > чув. *ухмак* < *охмах* ~ мар. *окмак* < *акмак* < гом. кыпч. *ахмақ, ақмақ* < гар. *äхмäқ* id. (*хмқ* «ахмак булу») сүзеннән исәпләнә. Ләкин чаг. бор. төрки *иңатиq* «ахмак» (ДТС: 612), хак. *аңмах* «ачыгавыз, ахмак» ← *аңмай-* «авыз ачу, ачыгавыз булу» ~ (тат. диал. *әңмәй* «ачыгавыз, аңгыра» (к. ДС I: 253), тув., алт. *аамай* «ачыгавыз» һ.б. тунг.-маньч. *аңма* «ачыгавыз»; *аңма-* «авыз ачу» һ.б. (к. **Аңгыра)**. Гар. сүзләре үзләре төрки телләрдән булырга мөмкин. Федотов II: 297.

**АХУН** «ахун, старший мулла (духовный чин)» < иске яз. тат. *ахунд* фар. *āхōнд* «укытучы; укымышлы» < *āt xanden* «укыту эшендәге» сүзеннән (Paul 1893: 30), фар. *хандäн* «уку, ятлау, өйрәтү» ~ санск. *svan-* id. (Platts I: 495). К. ш. ук Тимергалин: 41 (безнекеннән үзгә аңлатма китерелә).

**АХШАМ** «сумерки; намаз, совершаемый сразу после захода солнца» > удм. *акшан* «эңгер-меңгер вакыты» < бор. аз. *ах шам* «ак төн»: фар. *шāм* ~ санск. *šama* «кич, төн, караңгылык»; к. үзб. *шом* «ахшам намазы». Тимергалин: 41.

**АХЫР** «конец, в конце концов», в форме притяжательности **ахры, ахыры, ахрысы** «видимо, вероятно; должно быть» > чув. *ахăр,* мар. *акр, акыре, ахре,* удм. *акыр* id. < гом. кыпч. *ахыр, ахыры, акыры* < id. чыганыгы гар. *āхр* «ахыр; соңгы, соң». К. **Ахирәт, Ахири.** Федотов I: 71–72.

**АХЫРЗАМАН** «время, эпоха, ближе концу света» < гар. *āхир äл-зäмāн* «заман ахыры»; чув. *ахăр саман,* удм. *акырзаман, ахырзаман* < тат. булса кирәк. Тимергалин: 42 (энциклопедик аңлатма).

**АҺӘҢ** «тон» < фар. *āһäнг, āһäң* id. Будагов I: 171.

**АЧ** «голодный» < гом. төрки *аач* (башк. *ас*, нуг., каз., к.-калп., тув. *аш*) «ач; арык» һәм сирәгрәк, *аач-* «ачыгу» (тат. **ачык-у** «ачыгу» үзе *ач-* фигыленең интенсивлык формасы); к. чув. *выç, выçă* «ач» һәм *выç-* «ачыгу», мар. *вусы* «ач (башак)», *вусын-* (*вуснаш-*) «ачыну, ач булу, ач тору»: чув. һәм мар. яңгырашлары бор. **аwыч* < **агыч* (исем) һәм **аwыч-* < **агчы-* (фигыль) нигезләрен тәнәйтергә мөмкинлек бирә (к. ш. ук карагас. *аiш* «ач», Радлов I: 58); боларның тамыры монг. телендә сакланган *аг//эг* «ачы, тозлы» (шуннан ук к. **Ачу, Әгерже ~ Игәрче)** тамырыннан (бу тамырны һинд-евр. **ек// ак//ок* «үткен кырлы» тамыры белән чагыштырып карарга була).

*Аг//агч* нигезеннән *ачы- (агчы- ?)* фигыле ясалган, к. **Ач-у II, Ачы-у.**

Дерив.: **ачлык** (к. Тимергалин: 42–44, энциклопедик аңлатма); **ачарбак < ачәрвах** – мифологик рух, догасыз үлгән кеше рухы. К. **Ачкернә.**

**АЧА** диал. «развилка, развилина» ~ кырг., уйг. *ача* id. һәм «бот арасы», үзб. (ЎХШЛ: 22) *ача* «ике мөгез арасы; маңгай, ми» , башк., бур. *аса*, каз., к.-калп. *аша* «аеры; ача; бүленеш» ~ бор. монг. *ačar* < **alčar* (к. нан. *алчар* «ике ботак арасы», к. ССТМЯ I: 53–54). *Ача* сүзен Э.В. Севортян (ЭСТЯ I: 209–210) *ач-у* белән бәйли. Чыннан да, тат. диал. (Тумашева 1992: 33) *ацак* «билге, (чатлы) сызык» < *ач-а қ* < **алч-ак* булса, бу дөрес тә. К. түбәндәгене.

**АЧАМАЙ, ацамай, әчәмәй** (ЗДС: 65–66, 91) «крестовина; ветер, который веет наискось» ~ башк.

*асамай,* мар., удм., кырг. һ.б. *ачамай* (> каз., к.-калп. *ашамай*) «кыек атламасы, кайчы; аеры, чат; ыңгырчак канатлары; чатлаш» < монг. *ацмай, ацымай* «дөя ыңгырчагы». К. түбәндәгене.

**АЧАТАЙ** «двуног; ножницы (в фигуральном значении)» ~ башк. *асатай* < *ачатай* < *ачлатай* id. ← *ачаан* «артмак, куржын (ике яклы куш капчык һ.б.)», ш. ук «ыңгырчак төре». *Ача* тамыры бар. **ач-, *ачы-* «йөкче терлек аркасына төяү, кушлап салу» сүзеннән килсә кирәк. К. рус. диал. (Аникин: 103) *ачан* < монг. *ачаан* «атка артылган тулы комплект йөк» һ.б. Монг. *ацан* «айры (ике япьле) сәнәк», *ацантай* «икелекле» һ.б. (шуларга иш күп сүзләр бар).

**АЧКЕРНӘ** «живоглот; голь перекатная» < *ач кернә: кернә* < фар. *гирнэ* «киң ачылган авыз».

**АЧУ [а$^{o}$чы̆w]** «гнев, озлобление» < гом. кыпч. *ачыw, ачуw* (кырг. *ачуу,* нуг., каз., к.-калп. *ашыў,* башк. *асыу*) id. < чыгт. *ачығ, ачык* (> госм. *ачы, ажҫы* һ.б.) id. (к. Будагов I: 13) < бор. төрки (ДТС: 4–5) *ačïγ* «ачы; ачу китергеч, авыр, хәсрәтле; ачулы». Шулай итеп, *ачу* һәм *ачы* сүзләре бер үк нигездән, ләкин бик иртә (X г. иртәрәк) аерымлана башлаганнар. К. **Ачы-у.**

**Ачу** продуктив нигез: **ачулан-у; ачулы, ачусыз һ.б.**

**АЧ-У I,** диал. **ац-, әч-** «открывать; открыть» < гом. кыпч. *ач* (нуг., каз., к.-калп., шор. *аш-,* башк. *ас-*) id., чув. *оç-* > *уç-,* як. *ас-* id., бор. төрки (ДТС: 3–4) *ač-* «ачу, сибү, тарату, чишү, юл салу, яулап алу; аеру».

**Ач-** продуктив нигез: **ачкыч, ачыш,** к. **Ача, Ачык-у.** Räsänen 1969: 3; Федотов II: 292–293 (шунда бор. фин-угор тамырлары белән чагыштыру да китерелә); ЭСТЯ I: 209–210.

**АЧ-У II,** диал. **ац-у** «проголодаться» (к. диал. *корсак ачты*), иске тат. («Сиражел-Колүб») *ач-* (Наджип 1989: 172) < гом. кыпч. *ач-* (сирәк кулланыла) < бор. төрки (ДТС: 4) *ač-, aač-* id. **aγ//eg* «агу; ачы» сүзеннән булса кирәк. К. **Ачык-у, Ачын-у.**

Дерив.: **ачкак** «ач рух; һәрвакыт ач кеше» – диал., сөйләмдә очрый.

**АЧУТАШ**, диал. **ачылташ** ~ чув. *ачăлташ,* удм. *ачылташ,* мар. *анзылташ* «квасцы» < бор. **ачығ таш, *ачыглы таш: ачығ* монда «тозлак» (к. **Әче**) сүзеннән. **Ачуташ** тире иеләү измәсен ясау өчен кулланылган. Гомумән, *ачуташ* (фонетик йөзеннән үк күренгәнчә) тат. теленә уйг. группасы телләреннән кергән (чыгт. *ачуташ*), ләкин бу телләрдә хәзер фиксацияләнми диярлек. Бу сүз атаклы Болгар күнчелеген башлап җибәрүчеләр Урта Азия әһелләре булганлыгына дәлил. К. Федотов I: 74–75.

**АЧЧЫ,** себ. (ЗДС: 66–67) **аццы, аццығ,** миш. **ацы, ачы** «слишком; беда, проблема» ~ добр. *ассı, асı [аҗы]* «авыру, сызлау; актуаль проблема һ.б.ш.»; төр. телендә *acı, acık, acıcık* «проблема» мәгънәсендә бик активлаштырылган һәм шуннан яңа сүзләр ясалган: *acısında* «турында, мәсьәләсендә» һ.б.

Бу **аччы – ачы** сүзенең борынгырак яңгырашы, ихтимал, ***аччы-** «ачулы булып китү» сүзеннәндер. К. түбәндәгеләрне.

**АЧЫ** «горький; горько», себ. (Тумашева 1992: 33) **ацы, ацығ** «кислый» < гом. кыпч. *ачы, аччы* (< каз., к.-калп., нуг. *ашы,* башк. *асы*) < бор. төрки *аччығ* id. ЭСТЯ I: 89–93. К. **Ачы-у, Әче.**

Сөйл. телендә без бу сүзнең **айчы** вариантын ишеткәнебез бар. Бәлки төп вариант ***ағчы**дыр, к. бор. төрки **аɣ* (к. **Агу**).

**АЧЫК** «открытый, ясный; ясно» ~ башк. *асыҡ* id. ← **ач-** (к. **Ач-у**).

**АЧЫК-У (ачыкты, ачыга)** «проголодаться» – **ач-у II** фигыленең интенсивлык формасы.

**АЧЫКЫЙ, әчеки** «щавель кислый» (ТТДС I: 590) < *ачы қый: қый* «чүп үлән; кыргый үлән», к. **Кый, Кыяк.** Чаг. **Аткый.**

**АЧЫРГАЛАН-У,** (ЗДС: 91) **әчергәлән-ү** «сильно раздражаться» – кар. *ацырған-у,* каз. *ашырған-у* id. куман. *ačirga-mach* «ачынмак, ачыну» һ.б. *-рга* суффиксы ярдәмендә *ачы-* фигыленнән ясалганнар, чаг. ш. ук. **көчергән-ү.**

**АЧЫ-У** «киснуть, закисать» < гом. төрки *āчы-* (башк. *асы-*, нуг., каз., к.-калп. *ашы-, ашчы-*), төркм. *āҗҫы-* < бор. төрки **ағчы* «ачу; әрнү» бор. *ағ* «ачы, агу» (к. **Ачу**) сүзенә фигыль ясагыч *-чы//-че* кушымчасы ялганып ясалган (чаг. *күп – күпче-, кыр – кырчы-, үр – үрче-* һ.б.).

Бор. *ачы-* фигыленең исемләшкән фигыль формасы **ачу** (кинә), к. ш. ук тат. < чыгт. *ачуташ* > чув. *ачăлташ* id. (Федотов I: 74).

**Ачы-** нигезенең **агчы-* яңгырашыннан килеп чыкканлыгын *ачы* «яндыра торган тәм тур.» < гом. төрки *ачы, ачыг* < үзб., уйг., тат. диал. *аччы, ачгыг* (себ. *аццыг*) id. сүзенең тат. диал. *айчы* варианты да дәлилләп тора (димәк, *-чы* алдыннан бер аваз булган). К. ш. ук чув. *йӳҫĕ* «әче» һәм *йӳҫ-* «әче-ү». Бу сүзләр тат. палаталь вариантлар *әче-* һәм *әче* (~ башк. *әче-* һәм *әсе*) ~ госм., чыгт., куман. *äкши-* < **äкчи-, äкши* < **äкчи* сүзләре линиясе белән бәйле булса кирәк (*-чы//-че* фигыль ясагыч аффиксның *-шы//-ше* вариантына күчүе төрки телләрдә еш күзәтелә, к. кр.-тат. *кыршы-* < *кырчы, тыкшын-* < *тыкчын-* һ.б.).

Дерив.: **ачыт-у; ачыткы, ачыткыч;** к. **Ачын-у.**

**АШ I** «суп; пища; пир (в религиозных и семейных праздниках)» < гом. төрки *аш* (хак., нуг., каз., к.-калп *ас*) id., ш. ук тат. диал. (брб.) *аш* «арпа; бөртекле иген» (шул мәгънәдән **ашлык**) фар. *āш* < санск. *aça* «аш, бутка; сый; ритуаль сый» сүзеннән исәпләнә (Радлов I: 583; Севортян I: 211–212; Pokorny: 28). Шул ук вакытта төрки *аш* сүзен кор. *al* «бөртекле ашлык» сүзе белән чагыштыралар (Рамстедт: 178). К. **Ашлык.**

Аш төрләре тур. ЗДС: 67–71 (бик тәфсилле).

**АШ II** «добавление; польза, прок» к. **Асу, Ашы.**

**АША** «через; чрезмерно» < гом. кыпч., уйг. *аша,* төркм. *аша* id., ш. ук кайбер төрки телләрдә *ашыра* id. *аш-у* фигыленең хәл фигыль формасы (*аша* «ашып» мәгъ.). Щербак 1987: 82.

**АШАГЫ, ашага, ашак** диал. «низкий; низменное место, низовья», «чужой, чужбина» ~ диал. **әшәк** id. ~ чув. *ушах* «саз» ~ гом. төрки *āшак, āшагы* id., төр., бор. төрки *ašaγï* «түбән, түбәнгә», бор. төрки *ašaq* «тау итәге» ~ бор. төрки *al, alaŋ* «түбәнлек, түбән җир» (к. ДТС: 32, 62). К. **Алан, Алаша II.**

Себ. (Тумашева 1992: 34) **ашага, ашагы** «ят җир, ят як» асылда «Обь елгасының түбәнге агымы яклары» булса кирәк.

**АШИНА** название древнего правящего рода у тюрков древности, упоминается среди касимовских татар XV–XVII веков. Чаг. **Әшинә** диал. (әстр.) «якын дус; яклаучы дус» ~ үзб. *ошина, ашина* «дус егет яки кыз». Безнеңчә, бу сүзләр төрки халыклар тарихында атаклы *ашина ~ ачина ~ асина* ыруын хәтерләтә. Төрле (кытайларда язма рәвештә сакланган) риваятьләр буенча, Ашина – дошманнары тарафыннан кырылган түрк кавеменнән торып калган бердәнбер угыл белән ана бүредән туган балаларның берсе. Ул (яисә аның углы *Әнәс* яки *Әсән*) үрчеп киткән төркиләрне **Иргәнәкун** тарлавыгыннан алып чыгучы була. Ашина токымнары һәрдаим төрки кавемнәрнең идарәчеләре булып килгәннәр. Хәзәрләрнең башлыклары – **ашиналар,** Чыңгыз хан (ярым төрки) **ашина** нәселеннән, хәтта Касыйм татарлары арасында да иң белемлеләре ашиналардан, имеш. **Ашина** сүзе, күренеп тора ки, төркичә түгел (сингармонизм сакланмый). Һәм ашина токымы сары чәчле, зәңгәр күзле, әмма йөз чалымнары монголоид булган. Ашина сүзен, шул мәгълүматлардан чыгып, фар. *ахсинаг* «зәңгәр күк; күгәрчен» сүзеннән килә диләр (С. Кляшторный фикере, к. История татар I: 220). Икенче бер киң таралган фикергә күрә, **ашина** – монголча *чина* «бүре, ана бүре» сүзеннән имеш (чаг. төркиләрнең башлыгы булган **күк бүре** һәм **күктүрк** кабиләсе, к. **Күк I** сүзен). Velidi: 57–58, 68; Гумилёв 1964 (күп урында); Давлетшин 2004: 30–31; 100–101; ТЭ I: 256; БРЭ II: 593 (кытай сүзе *А-ши-на*дан дигән караш алга сөрелә; ул сүз ниндидер төрки сүзнең тәрҗемәсе була). Чаг. ш. ук **Әшнә.**

Ашина образы татар матур әдәбиятында да кулланыла. Мәс., «Мирас» (2014, № 4) журналында Р. Зәйдулланың «Түркләр» дигән шигыре шундый юллар белән башлана:

> *Түркләр без! –*
> *Кысан бу дөньяга*
> *Тудырган да безне Ашина,*
> *Җилдергәнбез җитез тулпарларда*
> *Җилләр, зилзиләләр каршына.*

**АШКӘРӘ** «предзнамение» к. **Әшкәрә.**

**АШКЫН** диал. «чрезмерно ретивый; чрезмерный; чересчур» **аш-у** фигыленнән (*аш-кын*); к. кырг., госм. һ.б. *ашқын* «ашкын, артык».

**АШКЫН-У** «рваться (в бой, на работу и т.п.); беситься», диал. «остервенеть, разъяриться» > мар., удм. *ашкын-, ажгын-* id. чув. *ашкăн-* «артык шаяру», нуг., каз., к.-калп. *асқын-* «чыгырдан чыгу; хәттин ашу» һ.б. *ашық-ын-у* «үзеннән үзе ашыгу», ягъни *ашык-у (ашыгу)* сүзенең кайт. юн. булса кирәк. К. ш. ук Федотов I: 78.

**АШЛАМА** «удобрение» > мар. (Исанбаев 1978: 37) *ашлама* id. ~ төр. *aşılama* һ.б. – иске

*ашла-у* < *ашыла-у* «файдалы өстәмә бирү, ялгау, өстән беркетү» сүзеннән. К. **Ашы.**

**АШЛАУ [а°шлаw]** «дощатое корыто» ~ к.-балк., үзб. диал. (ЎХШЛ: 22) *ашлаw*, төркм. диал. (ТДГДС: 28) *ашлоw*, кырг. *аштоо*, нуг., к.-калп. *аслаw*, каз. (ҚТДС: 28) *астау* id. кыпч. телләреннән таралган **ашы-ла-у** «тире ашлау өчен савыт» ← *ашы* к. **Ашы.** К. бор. төрки (ДТС: 62–63) *ašla-* «калай беркеткеч белән ватылган савытны җыеп беркетү» ← *aš* «калай беркеткеч».

**АШЛА-У** «удобрять; крахмалить полотно» < *ашы-ла-у*, к. **Ашы.**

Дерив.: **ашлан-у;** к. **Ашлама.**

**АШЛЫК** «зерновые и бобовые» ~ уйг. *ашлиқ* < бор. төрки (ДТС: 63) *ašlïk* «чистартылган бодай» ← *aš* «аш»; нуг. *аслық*, каз. *астық*, кырг. *аштық* «ашлык» уйг. яки тат. теленнән.

**АШУ** диал. «сверх; более» ~ башк. *ашу, ашыу* id., к. бор. төрки *ašnu, ašru* id. (ДТС: 64). К. **Аш-у.**

**АШ-У** «перевалить; подняться, парить» күч. «преступать, претвориться; осуществляться» < гом. төрки *аш-* id. ~ тунг.-маньч. *āl-* «тау аша үтү» (Räsänen 1969: 30; Севортян I: 212–214; ССТМЯ I: 27–28).

Бу тамырдан күп кенә аерым нигезләр ясалган: шулардан тат. телендәге **аша, ашу, ашкын, ашкын-у, ашык-у, ашыр-у** аерым аңлатмага мохтаҗ.

**АШЫ,** диал. **аш** «полезная добавка; полезный (добавленный компонент); что-либо добавленное, прибавленное, прикреплённое сверху; прививка; состав для обработки шкур и кожи; побелка (раствор)», иск. «бобровая струя» (Троянский I: 13; Радлов I: 587–602) ~ аз. *ашы*, төр. *aşı* id., аз. *аш* «дуплау измәсе» ~ чыгт. *ашый* «файдалы компонент, өстәмә», безнеңчә, *асу* < *ай-си-гу* «файда, табыш» сүзе белән бердәй, аның бор. *ай-ши-у* вариантыннан, к. **Асу** һ.б. ЭСТЯ I: 216, Eren: 26.

**Ашы** сүзеннән (тат. һ.б.) *ашыла-у* «өстәмә (компонент) кертү, өстәп ягу» фигыле. **Ашыла-у** – шул (тулы) яңгырашында – «үсемлелкәрне ялгамлау » мәгънәсендә дә кулланыла; к. ш. ук иске *яфрак ашысы* «ялгам, ялганма» (К. Насыйри).

Кайбер очракларда *ашы* сүзе *аш* белән контаминациягә кергән, мәс., бу тире иеләү сеңәлен *аш* дип атауда күренә: сеңәл «ашка» – боламыкка охшаш, ләкин чынлыкта *ашы* «(тирегә бирелә торган) файдалы компонент» сүзеннән килә, чаг. таҗ. *āш (ош) дадан* «тирегә ашы бирү, аны сеңәл салынган чанда тоту». Чаг. ш. ук тат. *аш булсын* (~ мар. *аш лийже*) «файдасы тисен» һәм *аш бу сиңа* «бу сиңа файдалы (җәза, бәлә-каза тур.)» сүзләрендәге **аш** «файда» ~ төр. диал. *aş, eş*, үзб. диал., як. *ас* «файдалы нәтиҗә» (як. телендә ш. ук «касмак, ялтырау, сайкал, маял»). Монг. *аш* «уңайлылык». К. **Ашлама.**

**Киндераш** «киндер үсемлеге» сүзендә шул ук *ашы* сүзе бар булса кирәк.

**АШЫК** «козонок; игра в козонки, альчики», «лодыжка» > чув. *ашăк,* удм. *ашык* id. < гом. төрки *ашык*, чыгт., бор. төрки *ašuq* (ДТС: 64) «тубык сөяге һәм сөяк уены» – бор. төрки *aş-* «беркетелү» (чаг. бор. төрки *aš* «беркеткеч, ватылган савытны беркетү детале», ДТС: 62) фигыленнән; кайбер вариантлардагы *ашшыкъ* (Севортян I: 216) *-ш-* алдыннан бер тартык булганлыгын сөйли һәм чыннан да яз. монг. *alčи* (> тат. *алчы,* кр.-тат., аз. һ.б. *алчу*) «ашыкның яссы ягы; ашык» моны раслый (к. Федотов I: 77); гаг. *аршык* «ашык» < *алчык* булса кирәк. К. ш. ук тат. диал. (ДС I: 13) *акшак* «тез асты» ~ башк. *ашҡаҡ* «сыйрак», каз. *асқақ, ақша*, бор. төрки *ашғақ* «ашык сөяге; үкчә; беләзек сөяге» (Радлов I: 547–548); чаг. мар. *уш-* «ялгау, ашылау», *ушык* «беркетелү урыны, буын; союз», *ушкын* (> тат. диал. *ушкын,* чув. *ушкăн*) «төркем, группа, команда».

**Ашык** уены озак гасырлар буенча балаларга мәктәп ролен үтәгән (санарга да, хәреф танырга *ашык*лар ярдәмендә өйрәткәннәр). Ашык уены терминологиясе тур. к. Будагов I: 50–51; Катаринский 1915 (*Бабка* маддәсе); Федотов I: 77–78; Тимергалин: 45.

Китерелгән әдәбияттан күренгәнчә, рус ашык уены терминологиясе төркиләрдән (татарлардан) алынган.

**Шайтан ашыгы** – ашык сөяге: аны тәңре терлекләрне балчыктан әвәләгәндә, кешеләр комарлы ашык уйнап азсыннар дип, яшерен генә килеп, шайтан кыстырган ди. К. **Сигез, Тугыз.**

**АШЫК: ашык-пошык** «второпях; торопливо, суетливо» – *ашыҡ-у* һәм *пошыҡ-у* фигыльләреннән чыгып ясалган сүз (тәүдә *ашыгык-пошыгык* булган булса кирәк).

**АШЫК-У (ашыгу, ашыкты)** «торопиться, спешить» < гом. төрки *ашыҡ-* (нуг., каз., к.-калп.

*асыķ-*), бор. төрки *ašuq-* id. *аш-у* фигыленең интенсивлык формасы, чаг. чув. *ашăх-* «нык үсеп китү, хәттин ашу» (Ашмарин II: 90–91).

Дерив.: **ашыгыл-у, ашыктыр-у; ашыгыч.**

Чув. *васка-* «ашыгу», *вашак* «ашыгучан» сүзләренең тат. һ.б. *ашыгу*га катнашы юк – ул сүз бор. болг. **wəскə-* < уйг., бор. төрки *ускə-* «ашыгу» сүзеннән.

**АШЫР-У** «претворять (в жизнь)» – *аш-у* фигыленең йөкл. юн. формасы (*ашыр- < ашшыр- < аштыр-*).

**АШЫТ** название реки в Татарстане, к. диал. (ЗДС: 74) **ашыт** «мостик» < *аш-,* к. **Аш-у.**

**АЮ [а$^{o}$йы̆w]** «медведь» < гом. кыпч. *айу* (кырг., алт. *айуу, айық*) төр. *ауı* < бор. төрки (ДТС: 14) *adïγ, adïγ, aduγ, ajïγ* id. < бор. гом. төрки **arıγ,* ихтимал, *азау* сүзе белән тамырдаштыр.

Бор. төркиләрдә аю тотем дип исәпләнгән һәм аңа баглы бик күп йолалар, ырымнар, мифлар булган. Бу хакта бай әдәбият бар, к. Kannisto: 233–283. К. **Абага.**

**АЯ [а$^{o}$йа]** «ладонь, кисть руки; приспособление для очистки кудели – широкий гребень, укрепленный на прочной основе» < гом. кыпч., төркм. *айа* (ешрак «кул чугы» мәгъ. очрый), к.-балк. *айаз* id.; к. ш. ук бор. төрки (ДТС: 25; Боровков: 45) *aja* < *аба, ada* < *ara (?)* «рәшәткә». Саян төрки (Рассадин 2008: 188) *айа* «капкын төре (рус. самострел)». Ихтимал, **Аяк I** белән тамырдаштыр.

Дерив.: **аяла-у** «көнҗәләне һ.б.ш. ая белән чистарту».

**АЯГУРӘ [а$^{o}$йағы̆wрә]** «стоя на ногах» < иске тат. *айак үзрә* «аяк өстендә».

**АЯЗ [а$^{o}$йаз]** «ясный; ведренный» < гом. кыпч. *айаз,* кӧнч. төрки *айас* «аяз; салкын; суык» ш. ук (кырг., кр.-тат., куман., госм.) «ай яктысы» (к. Радлов I: 214–216) ~ мар. *айар* > *ойар* ~ чув. *ойар* > *уйар* id. К. **Аяз-у.** Ахметьянов 1989: 4.

**АЯЗ-У [а$^{o}$йаз-]** «проясняться (о погоде), стать ведренным» ~ к.-балк. *айаз-* ~ мар. *айар-* id. (бүтән телләрдә *айар-, айаз-, айас-* сүзенең фигыль мәгънәсе теркәлмәгән). *Айаз* < *айар* тәңгәллеге (*-з* < *-р*) һәм бу нигезнең исем ~ сыйфат ~ фигыль мәгънәләре булу аның борынгылыгын күрсәтә. *Айаз* сүзенең ай белән багланышы халык этимологиясеннән килергә мөмкин. Һинд-европачылар төрки *айаз* сүзен морд. *айра, айыра*, хант. *айтра*, алт. диал. *айтра, айтрак*, каз. *адра* (*адра асман* сүзендә, Инан: 155) «аяз» < грек. *αἰθήρ* «ачык, аяз, сөзген һава; эфир» (шуннан *эфир* сүзе үзе, рус. *вёдро* «аяз көн» белән тамырдаш) сүзләре белән баглыйлар. Pokorny: 11; Абаев I: 548; Räsänen 1969: 11; ЭСТЯ I: 102–103; Федотов II: 298.

Дерив.: **аязыт-у** (**аяздыр-у** булырга тиеш иде).

**АЯК I [а$^{o}$йаķ]** диал. «чашка; горшок» < гом. төрки (Радлов I: 20) *ajaķ* ~ як. *ajax, аньах* «авыз, ачыклык; бәке, чокыр» (Пекарский I: 55), бор. монг. *ajaġa* «кясә, фарфор чынаяк», нан. *айака$^{н}$* «фляга»ны Рамстедт (1957: 188) кор. телендәге *pai ~ fai* «кабырчак, көймә» сүзе белән, Рясянен (Räsänen 1953: 81) исә фин-угор. *аŋ, ап, апәх* «тишек, чокыр, ярык» сүзе белән чагыштыра. Рамстедт фаразы ышандыра төшә: зур диңгез кабырчаклары савытаяк буларак элек киң кулланылган һәм сәүдә шәе булган. ЭСТЯ I: 105; Хайрутдинова 2000: 50–54 (*ашаяк, балаяк, җамаяк, кырмаяк, саплаяк, соскаяк, сараяк, тазаяк, ташаяк, тусаяк, чанлаяк* сүзләре бар ди).

Дерив.: **аякчы** ~ монг. *аягачин* «көрәгәче».

**АЯК II [а$^{o}$йаķ]** «нога» < гом. төрки *айаķ* < бор. төрки *адаq* id. Төрки телләрдә бу сүзнең вариантлары һәм икенчел мәгънәләре күп: алт., хак. *азак* «аяк» < бор. *azaγ* > бор. кыпч. *азау* «аяк; елганың түбәндәге агымы» > *Азов*, к. ш. ук иске тат. *Азак диңгезе* «Азов диңгезе»; тат. *азак,* башк. *аҙаķ* «соңыннан, ахырда, ахыр» кӧнч. төрки диалектлардан (бор. хак. компонентыннан соңрак кергән); як. һ.б. *атах* «аяк, түбәнге; ахыргы; елганың түбәнге агымы» < **атаг* > кыпч., тат. *атау* «елга утравы, дельта; аерым көтүлек» һ.б. Чаг. ш. ук чув. *ура* < *ора* < **араķ* «аяк»; бор. төрки *adaq* «бәбиләрне атларга өйрәтер өчен ясалган җайланма» (ЭСТЯ I: 45).

**Аяк** сүзе нindидер **ad-* яисә **ar-* фигыленнән булса кирәк (ихтимал, *адым* белән тамырдаштыр), ләкин моны исбат итү кыен. К. **Азак, Атау.** ЭСТЯ I: 103–104.

Дерив.: **аяклы, аяксыз; аяклан-у** һ.б. (күп сүзләр сөйләшләрдә очрый, к. ЗДС: 25–26).

**АЯКЧУ [а$^{o}$йаķчы̆w]** «обувь; портянка» (к. Будагов I: 174), диал. (ДС I: 25; ДС II: 46; ДС III: 25) **аякчу, аяк чуы, аякцу, аякчөw** «чолгау», *аяк*

һәм *чу* бор. төрки *čоγ* «төргәк; кап, футляр» (МК) сүзләреннән гыйбарәт, чаг. ш. ук диал. *аяккап, аяк кабы, аяк савыты,* әд. *аяк киеме.* Ошбу мәгънәдә иң тыматы һәм, димәк, иң яхшысы *аякчу*.

**АЯН [а$^{o}$йан]** иск. «известно, явственно» (*кырмысканың кая басканы да Тәңрегә аян* «Богу известно даже то, куда ступает муравей») < гар. *ʻийāн* id. (ГТРС: 90 – *ғаян*). Гом. кыпч. *аян* id.

**АЯНЫЧ [а$^{o}$йаныч]** «сожаление» < гом. кыпч. *айаныч* (нуг., каз., к.-калп. *аяныш,* башк. *аяныс*) id. *Ая-у* фигыленең кайт. юн. формасыннан, ясалышы җәһәтеннән чаг. *имәнеч, куаныч, кызганыч, сөенеч* һ.б. *-ныч//-нĕч* < *-ыныч//-ĕнĕч* аффиксы, шулай итеп, эчке кичерешләрне белдерә торган исем сыйфатлар ясый.

Дерив.: **аянычлы, аянычсыз.**

**АЯҢ [а$^{o}$йаң]** «ровный ход; ритм» < гом. кыпч. *айаң* (кырг. *айал,* башк. *айан*) «ат адымы (йөреше)» ~ тув. *айан* «гармония, ритм», чаг. ш. ук чыгт. *айалгы* «аккорд; оркестр», бор. монг. *ajan* «атта барганда озын юл» (к. ССТМЯ I: 20). Будагов I: 175; ЭСТЯ I: 106–107.

**АЯТЬ [а$^{o}$йәт]** «отдельный стих Корана» < бор. гар. *āйāт* «җыр назымы, шигырь; изге билге» *айй* «көйләү» тамырыннан.

**АЯУ [а$^{o}$йаw]** «пощада; соблюдение правил; языческий праздник – время родов природы-матери во время созревания ржи (22 июня – 5 июля)» (к. ш. ук **Нардуган, Челлә**) – *ая-у* сүзенең исемләшкән исем фигыль формасы. Тимергалин: 45–46.

Мәҗүси татарларның *айаw* бәйрәме мар. *айа* > *айо* һәм чувашларның *ойав* > *уйав* «җәйге нардуган; гомумән бәйрәм» сүзендә чагыла (тат. *-w* > чув. *-в*). К. **Ая-у.**

**АЯ-У [а$^{o}$йа-]** «щадить» > чув. *ойа-* > *уйа-* < гом. кыпч. *айа-* «абрау, кадерләү; аяу; үкенү» (к. **Аяныч**) < бор. төрки (ДТС: 25–27) *аја-* «абрау, тәртип саклау, хөрмәт итү» (дериватлары күплеге белән аерылып тора) бор. төрки, монг., тунг. *aj, aja* «яхшы, изге; изгелек, шәфкать; тәртип» сүзеннән ясалган (к. ССТМЯ I: 17–20). К. ш. ук Räsänen 1969: 11, ЭСТЯ I: 101–102; Röhrborn: 291–292; Федотов II: 298.

Тат.-башк. сөйләшләрендә бу фигыльнең юн. формалары *айал-, айан-, айат-* очрый (к. БҺҺ II: 20; ТТДС I: 26).

# Ә

**Ә I** татар теленең үз авазы; бер очракларда (мәс., икенче иҗектә) гом. төрки *э* дән (*берәү, күрән, тәкә*), икенче очракларда чит телләрдәге *ä* дән (*бәндә, мәгәр, хаҗәт*), өченче очракларда чит телләрдәге кайбер сузыкларның субституциясе буларак (*бүрәнә, гәүдә, шәм*) һәм, ниһаять, элекке *а* авазыннан палатальләшеп барлыкка килгән (*балакай* > *бәләкәй, чандыр* > *чәлтер, ярашу* > *ярәшү*).

**Ә II** ы. «а!». Күп телләрдә очрый торган халыкара сүз, к. **А III.**

**Ә III** «а (*союз и вопросительная частица*)» – рус теленнән булса кирәк; ләкин *ә, а* кисәкчәсе бик күп телләрдә очрый; бор. һәм кайбер хәз. төрки телләрдә *а, ә* «ич, бит, мәгәр» мәгънәләрендә килә.

**ӘБАБИЛ** – название мифической птицы, стаи которого погубили войска йеменцев в год рождения пророка Мухаммеда. Төр. *ebabil* «яр карлыгачы; әбабил» < гар. *äбāбӣл* ← *иббāлä* «талпа; көтү (кошлар тур.)». Штойервальд буенча – «давыл кошы». Бу сүз Коръәннең «Фил» сүрәсендә кулланылган, шуннан татарча тәфсирләргә һәм дини китапларга алынып таралган.

**ӘБӘ I** диал. (Тумашева: 35; ЗДС: 74) «бабушка (необязательно родная); женщина, обслуживающая невесту на свадьбе, женщин – во время родов»; төрле мәгънәви үзенчәлекләре белән себ. **эпә, эппә,** төрле сөйләшләрдә **әбәгә, әбетә, әбтә** (бу сүзләрнең кайберләрендә бүтән сүзләрнең тәэсире сизелә) ~ кр.-тат., төр. *ebe* id. К. уйг., үзб. диал. *әбә,* гом. төрки *эбә* ~ *ebä* «әби; яшь ана; өлкән апа» ~ тат. диал. (ЗДС: 13) **аба** id.

Дерив.: **әбәкә, әбәкәй; әбәлек; әбә күмәче** «урман үләне төре» ~ каз. (Будагов I: 6) *әбә песеге* «песи үләне»; нуг. *ebeköteşi,* төр. *ebegüteçi,* кр.-тат. *ebem-köteş* «әт борчагы» (лат. *Malva neglecta,* кызыл чәчәкле үсемлек); ихтимал, монда *әбә* «урман әбисе» мәгъ.дер, к. *әбә кучтәнәче* «куян кучтәнәче». К. ш. ук себ. **эпи** «табыну курчагы».

Бу мәҗүси сүз бор. татарларда киң кулланылган булса кирәк, чөнки мар., удм., морд. *ава*, мар. Т. *äвä* «ана; урман-кыр, җил, ут һ.б. анасы» төрки телләрдән алынган (Joki). К. **Әби.** Рамазанова 1991: 29–30, 36, 167.

**Әбә** сүзе гом. алт. *абä//äпä* «өлкән кардәш, абый, апа; дәвәни, дәвәти», сирәгрәк «кече кардәш» (к. **Абый**) тамырыннан. Монда төрле фонетик вә мәгънәви вариантлар тапкырланып, *-ка//-кай, -га//-гай, -кә//-кәй, -гә//-гәй, -ча//-чай, -чә//-чәй* һ.б.ш. кушымчалар да (еш кына өсте-өстенә) ялганып, исәпсез күп нәсел-нәсәп терминнары ясала. Һәм һәр гаиләнең үз терминологиясе булучан.

**ӘБӘ II** диал. (ЗДС: 74) «глуповатый, бестолковый». Сүзлекләрдә аңлатмасы **эпә** сүзенә җибәреләә, ләкин **әбә** сүзенең мәгънә үзенчәлеге, мәгънәлеге бар; **әбә** ул бөтенләй үк **эпә** түгел. К. диал. **әбәлән-ү** «каушапмы, ашыгуданмы тәртипсез кылану». К. **Әбәләк.**

**ӘБӘГӘР,** диал. (ЗДС: 74) **әбегәр** «хилый; изможденный» (**әбәгәрлән-ү, әбегәрлән-ү** «остановиться в изможденни») ~ үзб. диал. (ЎХШЛ: 23) *әбгәр* «ыгы-зыгы», кырг. *абыгер* «азап» һ.б.ш. – төр. *ephеr,* гар. *äбһäр*, «аорта; кан тамыры; йөрәк тибү» сүзеннән булса кирәк. Себ. тат. (Будагов I: 6) **абугар** «ярым үлек» каз. сөйләшләреннән (тәүдә *әбәгәрсез* < *әбһәрсез* булган). Будагов (II: 391) **эбегәр** сүзен гар. *äфкар* «уйга калу»дан ди.

**ӘБӘД:** юг. **та әбәд** «навечно» < фар., ләкин үзе генә сирәк кулланылышлы *әбәд* «мәңге» < *äбäдä* «үзгәрмәс табигать булу» (кешеләрнең үзгәрүчән тормышына каршы куела). Тимергалин: 47; Dobr. II: 2.

Дерив.: **әбәди** «мәңгелек», **әбәдән, әбәдиян, әбәдият** сүзләре гарәпчәдән, **әбәдилек** тат. үзендә ясалган.

**ӘБӘДӘ, әбедә** (әкиятләрдә) «дух природы», буддистларда «күк потларының иң шәрәфлесе» (ДТС: 2; МНМ I: 69). К. **Апата, Әптәнә.** Миш. (ЗДС: 676) **убыйда** «җен, өрәк» чув. *упăте* (< *абыда*) id. сүзеннән.

**ӘБӘК** игра вдогонки́: догнавший ударяет догоняемого ладонью, говорит *әбәк!* и убегает, теперь должен догонять ударенный; каз.-тат. *äбi* «айва,

квит» (к. Радлов I: 991) ~ чув. *епек*, мар. *äбьiк,* удм. *абак* «әбәк»; Идел-Урал регионыннан тыш, төр. *ebe* «әбәк (уены)». Ф. Гордеев бу сүзне уйг. *әвүк*, бор. төрки (ДТС: 189) *eväk* «ашыгыч!» сүзе белән чагыштыра (димәк, *әбәк* «эстафета»). Ләкин чув. *эпекле-* «әбәкләү» – «иркәләү» мәгъ. кулланыла (к. ш. ук чув. *евĕк* «иркәләү»).

Тат. диал. **әбәлке** «әбәк» < **әбәкле** булса кирәк.

Чаг. ш. ук як. *äппäi* ~ уйг. *äп-* «йөгерү, качу» (к. Пекарский I: 272), тунг.-маньч. (ССТМЯ I: 434–435) *эви-, эби-* «уйнау, шаяру, ярышу».

**ӘБӘЛӘК** «суетливый», «обидчивый, недотрога» ~ каз., к.-калп. *ебәләк* id., каз. диал., нуг. *эбелек, ебелек* – «көзен дала буйлап тәгәри торган үлән – камгакның җиңел төре; комбайн һ.б.ш.ның такта канатлы әйләнмәле саламыргыткычы», чаг. чув. *епелек* «кыяклы үлән төре». Сүзнең хәз. тат.-башк. мәгънәсе – икенчел, күчерелмә (мар. *äбäлäк* id. < тат., к. Гордеев I: 31); башк. диал. (БҺҺ II: 320) *әбәлә-ү, әбәлән-ү* «чәбәләнү» – сүзнең тамыры *әбә* икәнлеген күрсәтә; фигыль булса кирәк, чаг. ш. ук уйг. *әп-* «йөгерү, качу, ашыгу», каз. диал. *елбеле-* «әйләнеп очкалау». Гомумән, бу сүзнең этимологиясе аз тикшерелгән.

**ӘБӘТ** «обед» ~ чув. *апат, епет*, венг. *ebed* id. Татарчада бу сүз рус теленнән диләр, ләкин чув. *апат* «әбәт; икмәк» < болг. **әбәт* < бор. төрки *ebäk* «балалар телендә ипи, икмәк» (ДТС: 162) булырга мөмкин. Рус. *обед* татарча *әбит* диелә, *әбәт* түгел. Федотов I: 51–52.

Рус. *обед, обедня* «төшке гыйбадәт», «христианның иманын сынау мәрасиме (литургия дә диелә)».

**ӘБӘҮ** к. **Абау.**

**ӘБДӘН, әптән, әптәм, абдан** диал. (ТТДС I: 516, 539; БҺҺ II: 224) «бөтенләй; һич тә, бер дә, башала», каз. *әбден,* чыгт. *әбдан* id. < фар. *āбāдāн* «яхшы, шәп; әфарин!» ди Будагов (I: 108). К. ш. ук иске тат. **әбәдән** «мәңгегә» < гар. *äбäдäн* id. ← *äбäд* «мәңгелек». Монда контаминация күзәтелә. Dobr. I: 3; ҚТАС: 13.

**ӘБЕЗ** (ЗДС: 74–76) миш. «старая женщина» с множеством частных значений: **әбзәңкәш, әбзәни, әбзәңки** «дәвәни; кайнана», кайбер сүзләрнең мәгънәләре төп *абыз < хафиз* мәгънәсеннән читкә китә: **әбестәтәй** «каенсеңел», **әбестәтә** «каенана», **әбестүти** «иреңнең апасы»; **әбезчичи** «әнинең хатын-кыз туганы, кардәше». Шул ук вакытта кайбер сөйләшләрдә **әбзәй, әбзә, әбзи** «абзый; абый».

**Абыз** ~ **әбез** нигезенең болай тармаклануы – тат. теленә генә аеруча хас кызыклы күренеш. Палатальләшү процессы *әбә ~ әби* сүзе тәэсирендә барлыкка килгән (ул сүз исә бөтенләй икенче тамырдан).

**ӘБЕЛХӘЯТ [әбĕлхәйат], абелхәят** «живая вода» башлыча шигърияттә күч. мәгъ. кулланыла – фар. *āб* «су» һәм гар. *хäйāт* «яшәү» сүзләреннән гыйбарәт; чаг. үзб. *оби хаёт*, уйг. *аби һайат* id. Тимергалин: 9.

**ӘБЕРЧЕН** «горлица; витютень» ~ башк. *әгерсен* id. (БҺҺ I: 30). Монголчадан булса кирәк.

**ӘБҖӘТ, әбҗәд** «способ исчисления по цифровым значениям букв арабского алфавита» < гар. *äбҗäд* id. (Будагов I: 3). «Әбҗәт арифметикасы» Г. Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» әсәрендә тасвирлана. Иске русчада да *абевегеде* «әбҗәт». Гомумән, лат. теленнән таралган булса кирәк. Тимергалин: 48–49.

**ӘБИ [әбĕй]** «бабушка; повивальная бабка; тёща»; «кендекче карчык» мәгъ. *әбилек,* **әбия** дә диләр. Тат. телендә ясалган: *әбә-й* (к. **Әбә**) > *әбей*; тат. теленнән (бигрәк тә «кендекче хатын» мәгъ.) күп күрше телләргә кергән: башк. *әбей,* чув. *эпи, апи,* мар. *ави, äви, äбий* (к. Гордеев I: 33), удм. *аби* һ.б. Гомумән, шуңа охшаш сүзләр барлык Урал-Алтай телләрендә очрый: ком. *абай, әбәй* «әби», кар., төр. *әбә, әбә, эб, эбанай* «кендекче әби», иске монг. *ebei* «әни», як., эвенк. *эбэкэ* «әби» һ.б. К. **Апа.**

Дерив.: **әбиле, әбисез; әбиләрчә;** себ. (Баязитова 2001: 141, 145) **әбилек** «кендекче». Еш кына **әби** сүзен «дәвәни, нәнәй» мәгъ. куллану очрый. Безнеңчә, бу – рус теле тәэсиреннән.

**Әбиләр чуагы** тәгъбире тур. Тимергалин: 49–50. Төрле **әби**ләр (рухлар) тур. ЗДС: 75–76 (мул материал бирелә).

**ӘБРӘКӘЙ** «отхожее место» – башк., мар., удм. *äбрäкäй* < фар. *āбраһа* «шакшы су юлы». **Әбрәс//әбрәсханә** «бәдрәф» исә < фар. *абриз (хāнä)* «тәһарәт бүлмәсе» сүзеннән (шуннан ук куман. *аурыз* id.).

**ӘБУНӘ** «абонемент» < төр. *abone* id. Асылда фр. теленнән, к. Kluge: 8.

**ӘБҮҖӘҺЕЛ** «невежественный, но крутой начальник, тиран» < гар. *äбӯ җäһл «*җаһиллек атасы, надан» – Мөхәммәт пәйгамбәрнең явыз дошманы Гамр бин Һишамның мөселманнар биргән кушаматы. Гамр Мәккәдә бик абруйлы зат, ләкин рәсми җитәкче-фәлән булмаган.

**ӘБҮРКӘ** диал. «оборки (платья)» < рус. *обо́рка.*
Дерив.: **әбүркәле, әбүркәсез; әбүркәлә-ү.**

**ӘБҺӘР** иск. «пульс, пульсация» > **әбегәр** (ЗДС: 74) «булашу, мәш килү» < гар. *äбһäр* id.

Дерив.: **әбһәрлән-ү** «нык тәэсирләнү, киеренке хәлгә төшү», **әбегәрлән-ү** «тегендә-монда йөгеренү», «йөгерә-йөгерә хәлдән таю».

**ӘВӘЛӘ-Ү [әwәлә-]** «валять, обвалять; скатывать» – башк. (БТДҺ: 421) *әүелә-ү*дән үзгә төрки телләрдә без ышандырырлык параллельләрен тапмадык, тик диал. (ЗДС: 90, 147) *әүкәлә-ү, әүмәлә-ү,* ш. ук *әүшәлә-ү,* үзб. *ӯкала- ~ öwkala-* «уалау» сүзләре генә **әwәлә-ү**гә якын шикелле.

Дерив.: **әвәлән-ү, әвәләш-ү, әвәләт-ү.**

**ӘВӘРӘ [әwәрә],** диал. **әүвәрә, авара** «занят, увлечен (чем-либо малополезным); возня» < фар. *awwape, awapэ* «сукбай, сукбайлык; тик йөрү».

**ӘВӘС [әwәс]** «охотник до чего; пристрастился к чему» < диал. *әвәсле < һәвәсле* id. К. **Һәвәс.** Бу сүз добр. (Dobr I: 185) бик кулланышлы: *aves, aveslenmek, avesli* һ.б.

**ӘВЕН [әwĕн]** «овин» ~ чув. *авăн*, морд. М. *авонь,* морд. Э. *авн, ауня,* удм. *обинь* id. – бу сүзне рус теленнән дип кистереп әйтеп булмый, чөнки рус. *овин* сүзенең чыгышы үзе бәхәсле һәм төрки телләрдә бу сүзнең параллельләре күп табыла, к. рус. диал. *овин* «охотничья засада» ~ тат. диал., башк. диал. *әwен* «аучы шалашы, ау базы», урта төрки (Котбидә) *әвүн* «кош аулау челтәре – тур» бугай: *Әбүнсүз курса болмаз кушка һәч аг,* ягъни «кошка әвенсез ау корып булмый», диелә. Икенче яктан төр. диал., бор. төрки (ДТС: 189) *evin* «бөртекле ашлык». Бигрәк тә мар. теле материалы кызыклы: *ан, äн, аун, авун, äвӱн, агун, äгун < äвгун* «әвен». Ф. Гордеев (I: 48) бу сүзне болг. телендә гом. төрки (угыз линиясе) *äв* «өй» сүзеннән ясалган дип карый. М.Р. Федотов (I: 26), чув. *авăн* сүзен рус теленнән дип таныган хәлдә, бор. төрки *ev* «өй» сүзеннән дә килеп чыга ала ди. Ахметьянов 1989: 49.

**ӘВЕНБӘКЪ [әwĕнбәк]** диал. («Тел ярышы») «гусь гуменный» – к. рус. диал. (Аникин: 274) *каумбак, каумбаха* «үрдәк төре», башк. (БТДҺ: 31, 194) *ауымбак* «тузганак; алачуар үрдәк», *ҡауымбаҡ* «гагара» < фар. *хаwубе мäрг* «кош мамыгы» (үрдәксыманнар семьялыгындагы кошлардан кош мамыгы алалар): *хаwуб* «мамыкча», *мäрг* «кош». **Әвенбәк** «кош мамыгы» элек кыйммәтле мал булган. Сүзнең таралышы шуның белән аңлатыла.

**Әвенбак [әwенбак]** яңгырашы элекке атаманы **әвен** сүзенә нисбәтләүдән килеп чыккан булса кирәк. Хәлбуки чынлыкта ул алай түгел.

**ӘВЕРНӘ [әwĕрнә]** «крестовина-моталка» – *әвер-* «әйләндерү, чорнау» сүзеннән. Идел-Урал регионында гына очрый, к. мар. *агуртньо, авуртньо*, удм. *ауртн'о* «әвернә» (к. Гордеев I: 48; Насибуллин: 106); *-нә* исемьясагыч кушымчасы тагын *бирнә, энә < игнә* һ.б. сүзләрдә бар. Чаг. ш. ук чув. *авăр* «әйләнмә, уйравык, чоңгыл», к. Федотов I: 37.

**ӘВЕР-Ү [әwĕр-]** «превращать» (более употребителен страдательный залог *әверел-ү* «превращаться») ~ тат. диал., башк. диал. *әүер-* «әйләндерү» – гом. төрки (к. ЭСТЯ I: 227–231; ДТС: 189–190; Радлов I: 931, 933, 1811) *эбир-, эбүр-, эвүр-, эгүр-,* төр. *evir-,* чув. *авăр-*, мар. (< төрки) *авыр-, авур-, агур-* ~ хак. *ибĕр-* «әверү; әйләндерү; әйләнү, чорнау; тегермән тарттыру» – бор. бер фигыльнең (**әү-* < ** эг-*) йөкл. юн. формасы булса кирәк. К. **Әвернә, Әвеш-түвеш.** Федотов I: 26–27. Чаг. **Әүрә-ү.**

**ӘВЕС [әwĕс], әвеслек** «навес для сушки сена, снопов, для хранения телег, саней и т.п.» – бүтән төрки телләрдә юк, чыгышы ачык түгел. Чаг. **Әүсәк.** Ихтимал, төркм. *öвүс-,* бор. төрки *evüs-* > чув. *авăс-* «ашлык җилгерү» белән бәйледер.

**ӘВЕТ-Ү [әwĕт-],** диал. (Тумашева 1992: 32) **ауыт-у** «утешать, отвлекать (внимание)», башк. (БТДҺ: 429) *әүерт-ү* «баланы юату; игътибарны читкә җибәрү» < уйг. *аwут-* id. ← *аwу-* «юану» (уйг. *аwын* «юану»); к. бор. төрки (ДТС: 3, 69–70) *abin-, avïn-* «күңел ачу, юану», *avït-* «юату». Котби телендә **әфтү** «әветеп, юатып». К. **Абышка, Әүрә-ү.** Чаг. **Әви.**

**ӘВЕШ-ТҮВЕШ [әwĕш-түwĕш],** диал. **әвеш-төвеш, әвеш-тәвеш** «(разный) обмен, размен; мелкая торговля» – монда ике синоним исем фигыль бар, к. бор. төрки *ewür-tewür-* «алмашу, әйләндерү,

сату итү» (МК II: 81; ДТС: 191). Бор. төрки һәм тат. сүзләрен чагыштыру бор. *әү-* һәм *тәү-* «әйләндерү, әйләнешкә кертү» сүзләре булганлыгын дәлилли кебек. *Әү-* < *әг-* (к. **Әвер**-), *тәү-* < *тәг-* (к. **Тәүлек** һ.б.).

**ӘВИ [әwи], әве** (әстр., ЗДС: 16) «песня с описанием событий, с слухово-зрительными образами (чего у татар почти нет)» – «сюжетлы җыр, такмак» ~ каз. *ән,* (ҚТДС: 46) *әуен* «җыр-әкият», (Катаринский) *әң* «(матур) тавыш, көй». Чаг. себ. *өй-ү, эй-ү* «хикәяләү». Бу бик кыска сүзнең тамыр бәйләнышларын билгеләү читен. Әмма татар-башкортта сюжетлы-тасвирлы җырлар сирәк булгач, бу терминны активлаштырасы иде. К. **Әветү.** Чаг. **Әй-ү.**

**ӘГӘР** «если», сөйл. **әгәреңки,** эд. **әгәр дә** id. ~ гом. төрки *әгәр* id. ~ фар. *äгäр, гäр* «әгәр», бор. ир. *äkara* «соңгы чиктә» мәгъ. сүздән. К. **Гәрчә.**

**Әгәр** сүзе тат. теленнән чув. һәм фин-угор телләренә дә кергән: чув. *эхер, экер*, мар. *äгäр, агар*, удм. диал. *агар* id. Ләкин бу сүз төрки телләр даирәсендә бик борынгыдан билгеле, к. венг. *akar* «әгәр», себ. тат. *гәр* (!) «була бирсен!» Федотов II: 347.

**ӘГЕРҖЕ** «сдобное тесто» к. **Игәрче.**

**ӘГЪВА [әғwа]** «обольщение; вымогательство» < гар. *äʻwā* id. *ʻawaй* «адашу; юлдан язу» тамырыннан.

Дерив.: **әгъвалы; әгъвала-у, әгъвалан-у.**

**ӘГЪЗА** «член» < гар. *äʻẓа* id., иске тат. *гозу* < гар. *ʻyẓw* «тән әгъзасы, мөчә; оешма әгъзасы» сүзенең күп. формасы (ягъни *äгза* – гозулар).

**ӘДӘП** «благопристойность» < гар. *äдäб* id., шуннан **әдәби, әдәбият** (ягъни «әдәпкә өйрәтә торган язмалар»), **әдип** «әдәпкә өйрәтүче; әдәбиятчы».

Дерив.: **әдәпле, әдәпсез; әдәплән-ү < әдәплен-ү, әдә́пчә.**

**ӘДЕП,** диал. **әдүп** (Троянский: 3, 98), **әлеп,** башк. *әҙеп,* уйг. *әдип* «подшивка по краям одежды», «эчлек; кием кырыеның эчке ягын беркетеп тегелгән шал, тасма» < фар. *һäмдӯх̣т*, фар. диал. *һäмдӯфт* «кушып тегелгән нәрсә» сүзеннән. К. ш. ук иске тат. *атып* «атның корсак каешы» (Будагов I: 9).

Дерив.: **әдепле; әдеплә-ү.**

**ӘДЕРНӘ** тар. «огромный лук, тетиву которого натягивают несколько человек или при помощи лошадей», к. башк. *әзәрнә ян, әҙернә йәйә* «лук особо крепкого изготовления», тат. (Тумашева 1992: 38) *әтәрнә,* (Дмитриева 1981: 132) *әтирнә* «җәя бавы, кереш» (чаг. каз. *әдірне* «лира, вертикаль кыллы музыка уен коралы») ~ нуг. *äдирине* «әдернә» (*Алты ат тарткан аьдирине...* к. Ноғай халқ йырлары: 85) ~ калм. *адароно* «укның керешкә куелган очы», бурят эпосы «Гэсэр»дә **Эрдени́** «тылсымлы ук»: табышмаклы сүз. Л. Будагов (I: 20) башк. *әдринә, әдеринә* «кереше тартылган җәя» сүзен «Кавказ төркиләрендә дә очрый» ди. Бу сүзне төрек шәһәре *Әдернә* (Адрианополь) белән бәйләргә да нигезләр күренми: Әдернәдә аеруча сыйфатлы укҗәяләр ясалганы билгеле түгел.

Ихтимал, *әдиринә ~ адарона* сүзе бор. һинд *Айндра-Дрона* «Дрона дигән батырның тылсымлы ук-җәясе» (аңа бу коралны сугыш тәңресе Индра биргән) сүзенең чагылышыдыр. Куманнарның сигез кеше киереп тарта торган җәяләре булганлыгы тур. рус елъязмаларында (к. Карамзин һ.б.) язылa. Күрәсең, ул җәя вертикаль хәлдә тотылган – шуннан каз. «лира» мәгъ. килә. Чаг. ш. ук. осет. *äндурä, äрдунä* «җәя» ~ фар. *дäрӯнә* «салават; җәя» һ.б. (бик күп параллельләр, к. ЭСИЯ II: 362). İnan II: 292–294.

**ӘДРӘС,** сөйл. **әдерәс** «пёстрая ткань на шёлковой основе» ~ башк. *әҙерәс* id. < фар. *адрас, äдрас* < һинд. *adharsa* «ярым ефәк» (*adh* «ярты, ярым», *arsa* «ефәк», к. Platt I: 33–34); *әдрәс* сүзе киң таралган: чув. *этрес*, мар., удм. (Гордеев I: 51) *äдрäс, адрас* «бохари ярым ефәк тукыма» татарчадан булса кирәк, к. тат. *әдрәс гөл* > удм. *адрас гыль* «бегония» һ.б.

Дерив.: **әдрәслән-ү** (Ф. Хөсни) «җете чуар булу».

**ӘЕТ [әйёт]** диал. (кас.), **әеш [әйёш]** себ. «сказка; байка» – **әй-ү** (к.) сүзеннән ясалган.

**ӘҖӘЛ,** себ. тат. **әцәл** «смерть, преставление» ~ чув. *ичел,* мар. *äзäл, äзьäл, äжьäл,* удм. *эзель* «смерть; судьба», гом. мөселман төрки *әҗәл* < гар. *äҗäл* «әҗәл, бүлҗәл, мөтдәт; ара».

**ӘҖӘМ,** диал. **әзәм** «азям, вид кафтана; чапан» ~ чув. *аҫам,* мар. *азям, айзам,* рус. *азем, азян, озям, озян, езям, езян, узян, узяк* (Юналеева 1982: 18–22) id. – тат. **әҗәми** «иранча, фарсыча, Иранныкы» сүзеннән. *Әҗәм, Гаҗәм* үзе гар. «варвар»;

«Иран» (тат. әд. телендә дә кулланылган). К. ш. ук тат. диал. *әҗем* «ят кеше; бигәнәй» (ТТДС I: 551); *әҗәме* «кечкенә буйлы, карсак; курач» – бу сүз татарларның үзләрендә ясалмаган – шул көенчә бүтән төркиләрдән алынган, к. төр. *aceti* «беренче курс курсанты; рекрут; яшь яничәри». *Әҗәми огланнар «*солтан сарае сакчысы» булганнар.

Шунысы кызык, *әҗәм* дип фарсылар гарәпләрнең үзләрен атыйлар. Федотов I: 66; Аникин: 66–67 (шунда ук әдәбият).

**ӘҖӘТ,** диал. (ЗДС: 91) **әцәт** «долг» <**хаҗәт** (к.). Элек-электән **әҗәт** ~ кр.-тат., төр. һ.б. *acet* «табигый хаҗәт» мәгъ. кулланылган, шуннан **әҗәтханә,** (ЗДС: 77) **әҗәтлек** «бәдрәф» һәм бигрәк тә **әҗәткана** вариантында – сүгенү сүзе.

**ӘҖЕКӘЙ,** себ. (Тумашева 1992: 33, 39) **әцегәй, әчегәй, ацыгай,** диал. (Будагов I: 15) **ачыкай** «творожник; красный творог» ~ башк. (БҺҺ II: 225) *әзекәй, изекәй* «эремчек». Бу сүз беренче карашка *ачы//әче* сүзеннән тат. теленең үзендә ясалган кебек булса да, бик күптәннән килә, к. эвенк. *эӡэмуг* «эремчек (эҗәмек)», маньч. *эӡихэ* «каймак», бор. монг. *eӡegei, egeӡegei* > як. *иэҗэгэй, иэҗигэй* «эремчек» (ССТМЯ II: 439). Тамыры бор. монг. *ege [эгэ]* «әче» булса кирәк.

Тат. *ачыкай* яңадан ясалган сүз; чаг. ш. ук **Ачыкый.**

**ӘҖЕМ: Әҗем мәчете** – знаменитая мечеть в Казани, иганәче – XIX г. сәүдәгәре Әҗимов исеменнән (рус. *М.М. Азимов* дип языла). **Әҗим** исеменең этимологиясе безгә ачык түгел.

**ӘҖЕМЛЕК** диал. «вуаль невесты на свадьбе». К. **Әчемлек. Әҗемлек** варианты кайбер себ. сөйләшләрендә – интервокаль *-ч-* яңгыраулаштырыла торган төбәкләрдә кулланыла.

**ӘҖЕР** «воздаяние; вознаграждение; возмещение расходов» ~ гар. *äҗр(ун)* id. К. ш. ук иске тат. *әҗрәт* «түләү; аренда хакы». **Иҗарә** (к.) белән тамырдаш. Будагов I: 12.

**ӘҖИ** (ТТДС I: 395) «старший брат; жена старшего брата», ш. ук вакытта м.-кар. *әдьи, әҗи* «нәнәй, әни». Монда төрле чыганакларда килгән сүзләр – контаминация күзәтелә. Охшаш сүзләр мордва телләрендә дә һәм себер телләрендә дә бар, к. як. *эдьий* «апа» («әни» ~ «апа» мәгъ. күчешләре төрки телләрдә еш очрый, чөнки күп балалы гаиләдә апалар энеләрен-сеңелләрен әниләредәй тәрбияләгәннәр). Чаг. **Әзи, Әчә.**

К. ш. ук бер яктан бор. төрки *eči* «абзый; ир туган», хак. *ача* «абый, абзый», *ачы* «әтинең энесе; абыйның баласы», үзб. диал. *аҗи* «абый», төр. *ece* «карт» һ.б., икенче яктан иске үзб., төркм. *әҗә, эҗә* «әни» һ.б. Мухамедова: 41–42.

**ӘҖИТАРХАН** ~ **Хаҗитархан** ~ **Әчтәрхан** – хәзер русчага ияреп **Астрахань** дип кулланылышка кергән шәһәр исеменең элекке сөйл. һәм яз. тат. телендәге варианты. Тат. сөйләкләре буенча, Әҗитарханны бер хаҗи (хаҗга, Мәккәгә барып кайткан) тархан нигезләгән. Бу хәл Каспий диңгезенең ташуы беткәч булган (X–XIV гг.). БРЭ IV: 113 (шәһәрнең төрле русча атамалары әйтелә). Төрекләр бу шәһәрне *Аҗдархан* «аждаһа» дип тә атыйлар. Әмма без бу сүзнең **Әчтерхан** дип язылышы яклы, чөнки халык әдәбияты үрнәкләрендә дә шулай. К. **Әстерхан.**

**ӘҖНӘБИ** «чужеземец; чужестранный» < гар. *äҗнäбӣ* id. Госманлы Төркиядә әҗнәбиләр (*ecnebi*) аерым хокук һәм бурычларга ия булганнар.

**ӘЗ** «малый; мало», к. **Аз. Аз** һәм **әз** сүзләренең стилистик аермасы бар: беренчесе кит. телгә тартым.

**Әз** сүзенең дерив. **аз** сүзеннән аерылмый диярлек. Шулай да бу сүзләрне аерым мәгънәдәрәк куллану мәгъкуль. Мәс., кит. **азчылык** бар, **әзчелек** юк бугай (аны кулланасы түгел).

**ӘЗӘЛ,** (ЗДС: 77) **әзил: әзәлдән бирле; та әзәлдән** «извечно» ~ гар. *äзäл* «мәңгелек».

**ӘЗГӘРӘЙ, әзгәри** (ТТДС I: 540) «древний»; древняя монета с арабскими цифрами «пять» и «десять» ~ башк. диал. *әзгәрәй, әзгерәй* (БҺҺ II: 313, 320) «борынгы биш тиенлек көмеш акча».

Кадыйр Галибикнең «Җәмигъ әт-тәварих»ына ничектер адашып килеп кергән бер язмада берничә татар авылы кешеләре җыелып шунда батрак булып йөргән берәүне Хаҗигәрәй хан итеп күтәрүләре турында сөйләнелә. Ул авылларның исемнәре Казан тирәсендәге авыл исемнәренә охшаш. Ләкин Казан тирәсе авылларыннан хан сайланып куелуы турында бүтән бер мәгълүмат та юк.

«Татар халык иҗаты» циклының 1987 елда чыккан «Риваятьләр һәм легендалар» томында

шундый вакыйга сөйләнелә: XVI г. башларында булса кирәк, Казан тирәсе авылларыннан бер төркем кешеләр Чулманның сул тарафына, Урта Азиядән килгән олы юл өстенә күченеп утыралар. Анда күп кенә яңа авыллар барлыкка килеп, аларның исемнәре иске авылларныкын кабатлый (мондый күренеш һәр җирдә һәм еш күзәтелә). Яңа авыллар Казан сәүдәсенә комачаулый башлаганнармы яки башка сәбәп беләнме, Казан ханнары казаклар (солдатлар) белән килеп, аларны кире иске урыннарына кайтырга мәҗбүр итәләр.

Бөтен китерелмеш мәгълүматларны җыйганда, шул билгеле була: Казан дәүләте кешеләре, XV г. афәтләреннән соң, буш калган Чулман артын яңадан аякка бастырырга омтылып шунда яңа дәүләт төзегәннәр һәм хан сайлаганнар, ул хан исеменнән акчалар – тәңкәләр суга башлаганнар. Бу акчалар шул яклардагы сирәк утырган татар-башкортлар арасында киң кулланыш тапкан.

**ӘЗЕ** (Остроумов 1892: 5) «святой». Керәшеннәрдә **җиде изге** келәү корбаны бирү турында әйтелә. ТТДС (II: 39) бу **әзе** сүзенә дә «изге» дип кенә аңлатма бирелсә дә, **әзе** – фонетик җәһәттән *изге* сүзеннән дип раслап булмый. Монда синонимнар гына.

Кем икән ул *җиде изге?* Тарихи риваятьләрдә, Казан соңгы тапкыр камалган вакытта, җиде (икенче бер вариантта унике) гөнаһсыз кызның шәһәр дивары тышына чыгып дошманнарны каргап торулары искә алына. Ләкин нишләп аларны нәкъ менә керәшеннәр (мөселманнар түгел) изге дип хөрмәт итәләр соң? Монда ниндидер өзеклек, очы очка ялганмау күренеше бар.

**ӘЗЕР** «готовый; готов» – **хәзе́р** (к.) сүзенең кыпч. үзләштерелгән вариантыннан.

Дерив.: **әзерлек; әзерлә-ү** (һ.б. юн. формалары).

**ӘЗИ** (ТТДС I: 540) «дядя, старший брат; дядя (как название знакомого мужчины старше себя)» < *әwзи* < *әбзи* < *абзый* булса кирәк. *Әзи бергенәсе* «кадерле, ардаклы кемсә» сүзе агаларның кыз кардәшенең кызы турында аеруча кайгырту йоласыннан (әгәр ул кыз бер генә булса, аның кадерлерәк булуы да аңлашыла). К. **Абзый.**

**ӘЗМӘВЕР [әзмәwĕр],** (Зимасов: 14) **әзмәүир** «великан; рослый дурак», в сказках «страшный охотник» ~ төр. *aznavur* «батыр сугышчы; юлбасарлар атаманы». Һичшиксез, нуг., к.-балк., кр.-тат. һ.б. кыпч. телләрендәге *азнавур, азнаур* «зур гәүдәле тупасрак кыланышлы кемсә» сүзе белән бер. Груз., әрм. һәм фар. телләрендә *азнаур, азнавар* «дворян, патша тирәсендә торучылар» дигән сүз. Аның ясалышы турында ике версия бар: беренчесе – *азнавур* әрм. *азнив* «асылзат; милләт вәкиле» сүзенә фар. *авар* – «йөртүче, алып баручы, әйдәүче» кушымчасы кушылып ясалган (к. Будагов I: 37–38); аны груз. теленнән дә чыгаралар (Steuerwald); икенчесе – *азнавар* сүзе саф фар. *аз нәвард* яки *аз нәвар* «шаһ тирәлегендәге асылзатлардан» (*нәвард* – «асыл, хөрмәткә лаеклы») яисә «шаһның кургавылларыннан» (*невар* «шаһ чатырын әйләндереп төзелгән хәрби төзем») дигәннән килә. Безнеңчә, соңгысы дөресрәк. Тат. телендә, *ул әзмәвердәй, ул әзмәвер кебек*, дип сөйләү бар. Шул ук мәгънәдә, *гуардин (гвардин) кебек,* дип тә сөйлиләр. Димәк, *әзмәвер* тат. дәүләтләрендә *гвардин* – хөкемдарны (бәлтаварны, ханны, бине һ.б.) саклаучы зур гәүдәле, көчле егетләрнең берсе. Әрм.-кыпч. документларындагы *азнаур-албрим* «азнавур-алпар» парлы сүзе дә шуңа ишарә итә, ягъни *азнаур* «алпар» мәгънәсендә булган.

Тат. сөйләшләрендә бик дәү вә көчле кешене *аждамыр* да диләр. Ләкин бу фар. *аждаһар* сүзеннән (бәлки, *әзмәвер* тәэсирендә) үзгәреп килеп чыккан. Ахметьянов 1981: 19–20.

**ӘЙ I** «эй; ай; ой» – күп телләрдә таралган ымлык; кайбер мәгънәләрендә рус теле тәэсирендә карарлашкан булса кирәк. Федотов II: 476. Иске төрки әд. телләрдәге **әйә, әйа** «әй, и» сүзе тур. Тимергалин: 54.

**ӘЙ II –** река Ай (в горной части Башкортостана). Күрәсең, *әй, әйле* кабиләсе исеменнән, *әйле* «әй кабиләсе кешесе». Әй кабиләсенең тарихы томанлы. **Каратаулы, сарт әйле, төрекмән** дигәныру атамаларына караганда, әйлеләрнең җәтләре Сыр-Дәрья буйларында яшәгән булганнар. К. Башкортостан. Краткая энциклопедия: 108.

Хәз. Әй буйларында татар авыллары да бар.

**ӘЙБӘТ** «хороший, замечательный; хорошо, замечательно» *һәйбәт* (к.) сүзеннән; удм. *айбат,* мар. *äйбат,* чув. диал. *эйпет* id. < тат. К. ш. ук нуг. *äйбäт* «әйбәт», ләкин ком., каз., к.-калп., кырг. *айбат* id.

**ӘЙБЕР,** диал. **әрбер, әребер, әрби, әрбир** «вещь, предмет» > удм. *арбери,* мар. *арвер, арбер, äрьвел* (к. Гордеев I: 136) id. Тат. *әрбир* варианты

бердәм сүзгә хас булмаган сингармоник чылбыры (*ә – и*) белән үк үзенең ике сүздән гыйбарәт икәнен күрсәтә – *әр-бир*: *әр* (болг. сүзе) ~ бор. төрки *еδ* (хак. *ис*, себ. тат. *ит, әт*) «күн» (к. ш. ук уйг. *әт* ~ тув. *эт* ~ *эдэ* «әйбер» > бор. монг. *et* > бур. *эд* «товар», эвенк. *эт* «товар, төрле әйбер») һәм тат. диал. (нокр.) *бир* ~ чув. *пир* «комач, тукыма» ~ гом. төрки *бэз* > тат. *бәз* id.). Шулай итеп *әйбер* < *әрбир* болг. *әр-бир* «күн һәм тукыма товарлар, шәйләр» дигән сүз. Чаг. тув. *эт-мал, эт-сеп* «төрле мөлкәт». К. **Итлек** һәм **Бир.**

**Әйбер** сүзенең (безнең фараздан тыш) бүтән тамырлары да булуы ихтимал: тохар телендәге *ārwar, ārwer* «әйбер, әзер нәрсә» сүзен Клуге (Kluge: 330) герм. *arwa, garwa* «әзер нәрсә; исләнгән тире», ним. *gerben* «тире иеләү» сүзе белән чагыштыра. Тик тохар сүзе төрки телләрдән алынган булуы мөмкин.

**Әйбер < әрбер** сүзен «**һәрбер**»дән чыгару (киң таралган версия) семантик закончалыкларга бик үк туры килми. Ахметьянов 1989: 131; ССТМЯ II: 469.

**ӘЙДӘ-Ү** «гнать, погонять; вести под конвоем» – гом. төрки *һайда-, һәйдә-* «һәй! дип куу» сүзеннән (к. Радлов I: 49), к. үзб. *һайда-* «җир сөрү (сөрүче хайваннарны куалау)», чаг. тадж. *һай кардан* «һай итү – куу, сөрү», чув. *айта-* [*айда-*] «чакыру, рухландырып кычкыру; ат куалау».

**Әйдә-ү** фигыленең боерык формасы *әйдә!* «(атны) куала» тат. теленнән рус., мар., удм. телләренә ымлык һәм «киттек!» мәгънәсен алып, күп телләрдә киң таралыш тапкан: рус. *айда*, чув. *айта,* мар. *äйдä, айда*, удм. *ойдо* һ.б.

**ӘЙДҮК** «пожалуйста, милости просим» < *әйдә үк;* диал. **әйдүклә-ү** «кыстап керергә чакыру». **Әйдүк** дигән исем бүтән чыганактан: *Әйдулла < Гайдулла* «Алланың бүләге (бәйрәме)» кыскартылмасы (шуннан ук **Әйди** фамилиясе).

**ӘЙЕ,** сөйл. **ийе, йе,** диал. **әйге** «да» < гом. төрки *äгӱ*, *äigi, äji* «яхшы, иге» сүзеннән (к. **Иге**), к. Радлов I: 658–659, 853; тамыры бор. төрки *еδ [эȥ]* «әйбер, байлык, яхшылык, яхшы әхвәл» (к. ДТС: 163–167).

*Әйе, ие, е* сүзе үз мәгънәсендә тат. теленнән чув., мар., удм. телләренә, бүтән төрки телләрдән гар., фар. һ.б. телләргә дә кергән. Тат. сөйл. *әйем, әййем* «юк, теләмим» *әйемим* < *әйе димим* сүзеннән булса кирәк.

**Әйге** бор. төрки (Боровков: 71; ДТС: 162–167) *edgü, еδü, ejgü* «яхшы, әйбәт; яхшылык, игелек» < *ed-* «яхшылык итү; яхшылау», ш. ук «йомшарту; тире иеләү», исем коррелянты **ed* «яхшылык: әйбәт сыйфат» сүзеннән. К. диал. (Тумашева 1992: 53) *ий* «яхшы сыйфат; тиешле сыйфат дәрәҗәсе (йомшаклык – тире турында)», шуннан *ийче* ~ *ийце* «тире иеләүче». Шул ук сүздән **ийләү, ийеләү** (к.) һәм, бор. *э* > *ә* сакланып, **әйлә-ү** (к.) килә. Бу сүзнең мәгънәсе абстрактлашып, «эшкәртү > булдыру > итү»ләргә барып җиткән. Монда, әлбәттә, төрле морфологик вариантлар булган. К. **Изге.**

Гомуми закончалык буенча, *ezed* ~ *еδ* ~ *ei* рәтенең **er-* һәм *et-* эгъзалары – вариантлары да булгандыр һәм, эзләгәндә, бәлки табылыр да.

**ӘЙКӘЛ, әйкәр, әйкүн** (ЗДС: 78–79) «пелерина; высокий тесный воротник; широкое (бетонное и.т.п.) кольцо для укрепления стен колодца и т.п. сооружений» ~ каз. (ҚТДС: 41) *әйкел* id. Чаг. **Хәйкә.**

**ӘЙЛӘНӘ,** себ. (ЗДС: 27) **айлана** «круг» < гом. кыпч., алт. (үзб. уйг.) *айлана*, кырг., каз. диал. һ.б. *айлала* id. беренче карашка әйлән-ү фигыленнән кебек, ләкин ясалышы гайре табигый булгач, бу сүз турыдан-туры *әйлә-* ~ *айла-* нигезеннән ясалмадымы икән дигән фикер туа. Мәс. **әйләнәк** сүзе бар бугай, шуны активлаштырасы иде.

**ӘЙЛӘН-БӘЙЛӘН:** «хоровод (первоначально вокруг родового дерева)». К. фольк. **әйләнмәле карама:** кызлар такмаклап *Әйләнмәле карама, бәйләнмәле карама* дип карама тирәсендә яки янында **әйләнмә-бәйлән** уйнаганнар, шуннан әйтелгән. Әйләнмәле карама, бер матур кызны күргәч, артыннан ияреп борылып, шул хәлендә катып калган, ди (карама кәүсәсенең каерылып-борылып үсә торган булуыннан). Шуңа охшаш сөйләкне к. «Шали камыш». Карама, гомумән, явыз рухлар куна торган шомлы агач дип исәпләнгән. Кызлар, билгесез язмышны көтеп, явыз рухны үртәгәннәр булса кирәк. К. шундый усал туй җыры бар:

*Караманың каерын*
*Каерып ук алырбыз.*
*Матур кызны анасыннан*
*Аерып ук алырбыз.*

**ӘЙЛӘН-Ү,** себ. (ЗДС: 27) **айлан-у** «крутиться, вертеться; обходить, сделать обход» < гом. кыпч., уйг., үзб., алт., аз. диал. *айлан-* ~ *айнал-* id., ш. ук «озак сөйләшү; хөрмәт күрсәтү, булашу» (к. Радлов I: 18) ← гом. кыпч., уйг. һ.б. *айла-* «әйләндерү,

уратып алу» фигыленең кайт. юн. Бу *айла-* нигезе тур. төрле фикерләр бар: *ай* сүзеннән (Дмитриев 1962: 586), кырг. *айант* ~ тув. *айаң* «ялан, аклан» нигезеннән (ЭСТЯ I: 109–110). Безнеңчә, сүзнең нигезе (алт.) *айа, айы* «түгәрәк кура, кәртә» булуы ихтималрак, к. башк. (БТДҺ: 321) *әйлә-ү* «курага кертү». Чаг. ш. ук чыгт., госм. (Радлов I: 9) *ai-* «күтәрелү; әйләнү; кыялау». Бу сүзләрнең палаталь вариантлары тат.-башк. даирәсендә генә түгел: хак. диал. *äйлä-* «әйләндерү», кар. *эйлян-* «әйләнү» һ.б.

Дерив.: **әйләнел-ү, әйләнеш-ү, әйләндер-ү;** диал. **әйләнек** «ураулы (юл һ.б.)»; **әйләнмә; әйләнеч ~ әйләнгеч** һ.б. К. ш. ук **Әйләнә, Әйләнчек.**

**ӘЙЛӘНЧЕК** «юла; вертун; вертячка» < гом. кыпч., алт. *айланчыӄ, айланчуӄ* id. ***айлан** исем сүзеннән шикелле.

**ӘЙЛӘ-Ү** «сделать каким-либо; творить» – Э.В. Севортян буенча (ЭСТЯ I: 248–249), бор. *edle-* «яхшы итү» сүзеннән. К. ш. ук бор. төрки (ДТС: 167) *ejlä-* «эшкәртү», куман. *äi* «таман», уйг., госм. *aјы* «яхшы, ачык, һәйбәт һ.б.» (Радлов I: 628, 218); чаг. уйг. *әйлә-* «тире иеләү; эш итү, хәрәкәт итү». К. **Иелә-ү.**

**ӘЙЛЕ-ШӘЙЛЕ** «неопределённый; неопределённо; в сомнении, нерешительно» – тат. телендә (башк. теленнән гайре телләрдә параллельләре юк) *әй, әйе* һәм *шәй ~ шай* сүзләре нигезендә ясалган: к. **Әйе** һәм **Шай.**

**ӘЙНӘК, айнәк** (Тумашева 1992: 18, 36) «зеркало; очки; окошко» < каз. *айнаӄ, айнәк* < фар. *āйнäк* «көзге» ← гар. *ʻайн* «үзе, үзгенәсе; чагылышы».

**ӘЙРӘН,** себ. **айран** «айран, напиток из кислого молока» > чув. *уйран, урян, орян, орен* > мар. *орен, öран,* рус. диал. *ýрень, урéнь* (к. Федотов I: 272), мар. (Гордеев I: 64) *айряк, айрян, айран*, удм., рус. диал. (Аникин: 100) *арьян* id. < гом. төрки, бор. төрки (як. телендә генә юк бугай) *айран* > рус. *айран* «әйрән; май язу калдыгы – сыекча». Мар. *айряк* формасы рус. (Аникин: 78) *айрак, айрик* < бор. монг. *ajraγ, ajriγ* «катык төре» рәтендә булса кирәк. Гадәттә бу сүз «сөт (каймак) аеру» тәгъбиренә нисбәт ителә, ләкин к. тат. диал. (нокр., к. Velidi. Noqrat həm Glazof tatarlarь arasьnda // Tatarstan, 1926: № 5–6) *ərgin* «әйрән» < **әгрән?* К. ш. ук маньч. *ajapa, ари* «кымыз» һ.б. (ССТМЯ I: 20). Чаг. ш. ук **Арачан.** ЭСТЯ I: 111; Федотов II: 271–272. К. **Әйрәтке.**

**ӘЙРӘТКЕ** диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «кумысная закваска» ← *әйрә-* < **әгрә-* «әчеп чыгу» сүзеннән булса кирәк. К. **Әгерҗе.**

**ӘЙРЕ, әйерек** (Тумашева 1992: 36) «речка, рукав реки, проток» < **айры, айырык** «ответвление», чаг. башк. (БТДҺ: 16) *айыра, айырса* < *айыртын* «әйре». Рус. *ерик* < тат. **әйерек.** Рус сүзе тур. Аникин: 202 (тат. сүзләрен белми).

**ӘЙТӘВЕР [әйтәwĕр]** диал. (ТТДС I: 541, Садыкова 1985: 100) «и не говори (и так ясно)» ~ башк. *әйтәгүр,* каз. *әйтәүер* id. Себ. тат. (Тумашева 1992: 38) *әтәүер, әтәwер* «хөрмәтле; шәп» ~ төркм. (ТДГДС: 224; Мухамедова 1973: 58) *әйтөvүр, айдыбер* «әйтмә дә инде; әйтә күр» («в ритуале приветствия двух сверстников» диелә).

**ӘЙТӘМ: әйтәм җирле** «то-то оно; вот оно что; вот почему» – *әйтәм* һәм *җирле* сүзләренең ярым ирекле тезмәсе: *җирле* монда «урынлы» мәгъ., к. төр. *yerli* «урынлы, хокуклы, хаклы» – бор. *jer, jär* (к. **Җир**) «урын, биләмә, хан утырышында кайдалыгы төгәл билгеләнгән утыру урыны» (мәс., «ханнан санап уңдагы өченче урында» – министр дәрәҗәсендә) сүзеннән килә. Чаг. ш. ук тат. *җирле җирендә ~* төр. *yerli yerinde* «һәркайсы, һәрнәрсә үз урынында (мәкальләр: *җирле җирендә – үрдәк күлендә; җирле җирендә – шәйтан тәмугында* һ.б.ш.).

**ӘЙТЕШ** – поэтическое состязание, состоящее из мудрёных вопросов и ответов в стихотворной форме, выраженных пением под аккомпонемент струнных инструментов, особенно во время свадеб – *әйт-* сүзенең «шигъри фольклор текстларын башкару» мәгънәсеннән, к. ш. ук кырг. *айтыш*, төр. *aytış,* нуг., каз., к.-калп. *айтыс* id. К. **Әйтеш-ү.**

**ӘЙТЕШ-Ү** обычно «переругиваться», но в специальном значении «состязаться в поэтических способностях – импровизацией куплетов (особенно во время свадьбы)» – гом. кыпч. характерда: кырг. *айтыш-*, нуг., каз., к.-калп. *айтыс-* id. К. **Әйтеш.**

**ӘЙТИК,** диал. **әйтәйек** «положим; допустим; например; скажем так» < гом. кыпч. *айтайыӄ* id.

Мәгънәви җәһәттән чаг. к.-балк. *сёзден* «сүздән; мәсәлән» ~ чув. *сăмахран* «сүздән, мәсәлән». Тат. телендә дә *сүздән* шул мәгънәдә кулланылган. К. **Әйт-ү.**

**ӘЙТМӘКЧЕ** «кстати; между прочим» – *шуны да әйтмәкче булам* тәгъбиреннән эллипсис, к. ш. ук башк. *әйтмәксе,* каз., к.-калп. *айтпакшы* id.

**ӘЙТТЕР-Ү: кыз әйттер-ү** «свататься к девушке», далее **әйттер-ү-типтер-ү** и (просто) **әйттер-ү** «наяривать, шумно веселиться» – төп мәгъ. «кызның кулын-ризалыгын сорау һәм җавап алу», «кыз риза булса, шатлыктан уйнау-бию» – *әйтү* сүзенең элекке «сөйләтү, җавап бирдерү» мәгънәсеннән килә, к. гом. кыпч. *айттыр-* < *айыттыр-* id. (еш кына кыз белән егетнең сорашып-җаваплашып җырлау формасында да булган). К. **Аткыйматкый, Әйтеш.**

**ӘЙТ-Ү** «сказать», «исполнять стихотворное фольклорное произведение» < гом. кыпч. (ш. ук себ. тат.) *айт-, айыт-*, алт., хак., гом. угыз. *айт-* «әйтү» ~ чув. *айт-*, як. *ыйыт-* «сорау, сорашу». Сүзнең палаталь варианты тат.-башк. даирәсеннән тыш кар., үзб. диал., уйг. шивәләрендә очрый. Бор. *айыт-* ~ *айат-* варианты мар. *йад-*, *йат-* «сорау, сорашу» сүзендә чагыла (һәм бу вариантны чув. теленә нисбәтләү бик бәхәсле). Чув. диал. (Сергеев 1980: 93) *эт-* «әйтү, әләкләү» < миш. *әт-* id.

*Әйт-* < *айт-* < *айыт-* гом. төрки *ай-* «сөйләү» фигыленең (к. **Әй-ү**) йөкл. юн., ягъни асылда «сөйләтү» дигәннән. Тумашева 1992: 19; Будагов I: 78; ЭСТЯ I: 98–99 (әдәбият күрсәтелә); ДТС: 29–30; Мухамедова 1973: 58; Федотов II: 47.

**Әйт-ү** бик продуктив сүзьясагыч нигез: **әйтел-ү, әйтен-ү** («сүгенү» мәгъ.), **әйтеш-ү** («җаваплашып җырлашу», «тиргәшеп алу» мәгъ.), **әйттер-ү** (к. аерым сүз). Бу нигезләрдән икенчел дериватлар ясала: **әйтелеш, әйтелмә, әйтештер-ү** һ.б.ш. Төп фигыльнең аерым төрләнеш формалары лексикалашуга йөз тоткан: **әйтәле, әет, әйткәндәй, әйтмешли, әйтмә (дә инде), әйтерең (бармы), әйтүле** «чакырулы»; **әйтәм (аны), әйтерсең** «гүяки». К. **Әйтәвер, Әйтәм, Әйтем, Әйтеш, Әйтик, Әйтмәкче.** К. түбәндәгене.

**ӘЙ-Ү, эй-ү** диал. «сказать, заявить; петь речитативом; рассказывать сказки» – себ. диалектларында сакланган бу сүз (*иртәк әй-ү* «әкият сөйләү») тат. диал. (Тумашева 1992: 19) *ай-* < уйг., бор. төрки (ДТС: 25) *aj-* «әйтү, сөйләү, җырлау» сүзеннән (ЭСТЯ I: 111–112). Шуны әйтергә кирәк, *әй-, эй-* (палаталь) варианты тат. телендә генә түгел, борынгыдан килә – ул угыз телләрендә дә очрый: «Кыйссаи Юсуф» дастанындагы *Йусуф әйде* «Йосыф әйтте» ул *әйтте* дигәннән кыскару-садәләшү түгел, ә турыдан-туры *әй-* сүзеннән. К. **Әет, Әйт-ү.**

**ӘЙШӘ-БАТМАН: минем кулым (сүзем) түгел, әйшә-батман кулы (сүзе)** «не моя рука (не мои причеты-слова), а рука (слово) Айши и Фатимы (т.е. любимой жены и любимой дочери пророка Мухаммеда)» Мөхәммәт пәйгамбәрнең сөекле хатыны Гаишә һәм кызы Фатыйма исемнәреннән кыпчакча «бозылган» сүзләрдән: ошбу (тарихи) затлар изгеләр булып исәпләнәләр һәм ырымчы дәвалауның нәтиҗәсе өчен җаваплылыкны әлеге затларга япсара. Чаг. ш. ук **Әйшәлә-ү.** Чув. **Ашапатман** культы тур. к. Федотов I: 76.

**ӘЙШӘЛӘ-Ү, әйсәлә-ү** «петь и плясать на свадьбе» (к. Нагаева: 20) – тат. диал. һ.б. **Әйшә, Айша** «хәзрәте Гаишә – Мөхәммәт пәйгамбәрнең хатыны» исеменнән: ул иргә бик яшьли чыккан һәм ирле хатын булса да курчаклар белән уйнап күңел ачкан. Хәзрәте Гаишә булып уйнау шигыйларда (Иранда, Төркиядә һ.б.) төрле мистерияләрдә күзәтелгән, яшь килен Гаишәгә тиңләштерелгән һ.б.

**ӘКАЛЬ, әккаль**, диал. (ДС I: 249; Тумашева 1992: 36) **әкәлле, әкәллә, әхаль** «хотя бы; по крайней мере» ~ чув. *ахаль* «тиген, бушлай; болай гына; тәккә, юкка» < уйг. *әкәлли,* кар. *акәллән* «ким дигәндә, минимум», төр. *ekal, ekalli* «иң кимендә, югында» < гар. *äққал'* id. ← *қлл* «аз булу» тамырыннан (шуннан ук иске тат. *калил* «аз, күп түгел»). Тат. диал. (ЛТ I: 13) **ахаль, әхәл** «бушлай, азга; мәшәкатьсез» – болг. теленнән (*қ* < *х*).

М.Р. Федотовның (I: 71) чув. *ахаль* сүзен монг. *эгэл* (бор. монг. *egel*) «гади» сүзеннән дию дөрес түгел, әлбәттә. Иске әд. телдә **экаллият** «азчылык».

**ӘКӘ, әккә** диал., **әкәй, әкәү** – звательные формы (Тумашева 1961: 99, 231; ТТДС I: 541) «старший брат; уважаемый мужчина; старшина; шапка старшины» – «абый» мәгъ. бу сүз себер татарларында һәм башкортларга үзбәк һәм казаклардан кергән (к. үзб., уйг., аз. *әкә* «абый; абзый»); башкорт старшиналарын да *әкә* дип атаганнар.

Тат. сөйләшләрендә икенче бер **әкәй** «әби, дәвани» дә бар; бу сүз болг. теленнән килсә кирәк,

к. чув. *акай, аккай* «апа». *Игә* сүзе белән бәйле, к. **Игәч, Ага.**

**ӘКӘДИ** «чудной; чудеса» (к. ЗДС: 79) < гар. *äккäдӣ* «аккад (Гыйрактагы бор. җирле халык атамасы), аккадлы», күч. мәгъ. «гаҗәп».

**ӘКӘЙ** (ЗДС: 79) «головной убор молодухи, украшенный монетами» ~ мар. (Гордеев I: 68) *äкäй* id., шуннан тат. диал. *әкәй* «мари хатын-кызы». Тат. баш киеме мәгъ. *әкәй* марилардан ерак җирдә теркәлгән. Бу сүз **хәйкә** (к.) белән бердәй булса кирәк.

**ӘКӘЛӘ, әкәле, әкәли** «жёлудь; тестикула» ~ чув., мар. *акала, еккел* id. фар. *һакалэк* «чикләвек» сүзеннән булса кирәк. Төрки телләрдә бик сирәк очрый.

**ӘКӘМӘТ,** диал. **икәмәт** «потеха, диво; странности; приключение» ~ тат. диал. (ЗДС: 80) *әкәмәй* (> мар. *äкäмäй*) «болагай, шалапай», мар. *екемет, йэгэмэт* «борынгы, борынгылык», мар., удм. *äкäмäт, акамат* «әкәмәт; кызыклы очрак», чув. *екемет* «яшерелгән, серле, кул җитмәс нәрсә» < иске тат. (к. Насыйри II: 45) *әкәмәт* «әкияти рух, күзгә күренмәс җан иясе» < гар. *хäкäмäт* «тоткарлагыч нәрсә» (*хäкäмä* «нукта, тезген»), ш. ук. *хикäмäт* «хикмәтләр» (*хикмәт* сүзенең күп. формасы ди Катанов 1912: 120). Сүзнең тамыры *хкм* «тоту, тоткарлау, игътибарны җәлеп итү», шуннан ук *хаким, хәким, хөкем, хөкүмәт, мәхкәмә, мәхкүм* һ.б.

**ӘКӘМ-ТӨКӘМ** «слизняк, улитка», чаг. тат. диал. *акы-токы, тәкә-бөкә,* башк. *үкән-түкән,* мар. *акан-тукан,* удм. *акась-тукась* id. Идел-Урал регионы сүзе, чаг. ш. ук. венг. *csigabiga* id. **Төкәм** < **төкән** < мар. *түкäн* «мөгезле».

**ӘКӘРТСӘ, әкәтсә, әкәт** (ЗДС: 80) «акация; жёлтая акация» – русчадан алынып, халык этимологиясенчә үзгәртелгән булса кирәк.

Рус. **акация** < лат. *acacia* < грек. *akakia* үзе төр. *ak akıya, ak akıyk* «ак акация» сүзеннән. *Akıyk* исә гар. *ʻақӣқа* «бәби чәче», күч. мәгъ. «акация» сүзеннән килә: акация-әкәтсәнең кузаклары чәчсыман үсентеләр арасыннан чыгалар. К. Kluge: 29. К. **Гакыйка.**

Әкәтсә **кузак агачы** дип тә атала.

**ӘКЕР, әкерт, акыр** (ЗДС: 35, 80) «медленно, не торопясь». Бу нигезнең үзенең параллельләре бүтән телләрдән табылмады, әмма тат., башк. **акырын ~ әкерен, акыртын ~ әкертен** күрше мар., удм. телләрендә очрый һәм каз., чыгт. (Будагов I: 69) *ақрын, ақрун* (гар. язуында) сүзе киң билгеле. Бор. төрки (ДТС: 49) *aqru, aquru, aqrun* «акрын» һәм аны *aqır ~ ayır* «авыр, кыйммәтле» сүзе белән нигездәш дип уйларга мөмкин, ләкин бу фаразны дәлилләргә материал җитенкерәми.

**ӘКЕРТЕН, әкерт, әкертенләп** «медленный; медленно» к. **Акырын.**

**ӘКИЯТ [әкийәт]** «сказка; небылица» ~ удм. *әкият* id., мар. *äкият* «мәзәк, юк-бар сүз», чув. диал. *әкият* «такмак» ~ әрм.-кыпч. *hakiat* «әкият» бу сүзнең бор. кыпчаклык заманнарында ук таралганлыгын дәлилли. Сүзнең чыганыгы – гар. *хикāйäт,* к. **Хикәя.** Хәз. кыпч. телләрендә «әкият» мәгъ. бүтән сүзләр кулланыла. Ахметьянов 1981: 103.

**ӘКРӘБӘ, әкърәбә** диал. «родня, круг родственников» < гар. *äқрабä* «якыннар» *қрб* «якын булу» тамырыннан. К. **Карип.**

**ӘКСӘР, әксәре, әксәрият** иск. «бóльший; наибольший» < гар. *äкçäр* id.; ш. ук «(җыелышларда) күпчелек» мәгъ. **әксәрият** < гар. *äкçäриййäт* id.

**ӘКЧӘК** иск. «вена; пульс» < бор. төрки (ДТС: 167, КБ) *ekček* «кара кан тамыры» ← **ekče-*, к. диал. **әкчә-ү,** (ЗДС: 80) **әкцә-ү** «кан тамырында кан бәрү, сулкылдау; ярсыну; ярсыту» ~ каз. (ҚТДС: 97) *ekcim* «ачу, ачулану, ярсыну». Чаг. **Иксә-ү.**

**ӘЛ** иск. «рука» < угыз. *äл* id. > чув. *ал, алă* id. ~ гом. төрки, бор. төрки (ДТС: 169) *el* id. К. ш. ук Котби телендә һ.б. *әлик* «кул» ЭСТЯ I: 260–261; Федотов I: 33–34.

**ӘЛӘК,** диал. **әлик, йәләк** «ябеда; донос; клевета» ~ чув. *елек, элек* «әләк; афәт, каза» (к. Сергеев 1968: 93), мар. *алак, аляк* «гайбәт; әләк, яла», удм. *аляк* «җанга тигеч», *аляк-инмар* «әләкче фәрештә», *эрекчан* «ялган, алдак», *эрекчи* «ялганчы, алдакчы», себ. тат. *äлäк* «корбан, корбанлык» (к. Дмитриева 1981: 131) ~ нуг. *элек* «һәлакәт; бозым» һ.б. бу сүзне *һәлак* (к.) сүзеннән дип уйларга мөмкинлек бирә, к. ш. ук себ. *әләк* «бик, бик күп, һәлак күп» (Тумашева 1992: 36). Ләкин к. чыгт., бор. төрки *елўк, äлик, elik* (ДТС: 111) ~ алт., як., монг. *äлäк, элэг, элэк* «мыскыл; әләк», к.-калп. *еле-* «кү-

реп алу», *елең* «дикъкать». Күрәсең, *әләк* һәм *әлик* икесе ике чынагактан килә, ләкин үзара контаминациягә кергәннәр. Räsänen 1969: 40; Федотов II: 477; Ахметьянов 1981: 20.

Дерив.: **әләклә-** һәм **әләкче** (Идел-Урал регионында шулай ук киң таралганнар).

**ӘЛӘМ** «знамя, флаг» – тат.-башк. **әләм** турыдан-туры фар. *äläм* «әләм, флаг, зур булмаган байрак» сүзеннән алынган һәм гар. *ʻaläм* «әләм, билге» сүзенә кайтып кала (иске тат. текстларында һәм сүзлекләрендә, мәс., А. Троянский сүзлегендә ул *галәм* дип язылa да). Чаг. төр. *alem* «әләм».

Мар. *äläм,* һәм чув. *элем* «әләм» сүзләренә караганда, бу кәлимә Казан дәүләте чорында киң кулланылган. Төр. *aләм* һәм кар. *алам* «байрак, әләм» сүзләре турыдан-туры гарәпчәдән кергән булуы ихтимал.

Төрки телләрдә *әләм* сүзе бик үк киң кулланылмый, чөнки шул мәгънәдә *байрак, ялау, санҗак, кутаз, туг, өлеңге* һ.б. сүзләр бар. Гомумән, һәртөрле байрак вә әләмнәр төрки халыкларда хәтсез заманнардан бирле билгеле. Федотов II: 47; Тимергалин 56–57.

Иске төрки әд. телләрдә икенче бер *әләм* «интегү, җәфа чигү» дигән гар. сүзе дә очрый. Ул икенче бер тамырдан булса кирәк.

**ӘЛӘМ-ӘТРӘК, әтрәк-әләм, әтрәгәләм** «голь перекатная, отребье (бедные и невоспитанные люди)» < гар. *äғläмү-л-äтрäк* «төрки балалары»: *äғläмү-л-ғулāм* «малай, яшь кенә егет» (*ғлм* «яшь һәм шук булу» тамырыннан) сүзенең күп. формасы. *Ғулāм* – «хуҗасына тугры солдат, (тәнсакчы) егет» Шәрыктә бик билгеле персонаж (иске тат. *әгъләм* һәм *голәма* «галимнәр» сүзләре белән бутамаска – аларның тамырлары үзгә). Чаг. ш. ук тат. (дини) *гыйльман* «оҗмахтагы хезмәтче егет» – *ғулāм* сүзенең «гомуми күплек» формасы. К. **Аламан.**

**Әтрәк** өлеше – гар. *äтрäк* «төркиләр» дигәннән. Урта гасырларда Шәрык илләрендә төрки балалары күпләп коллыкка сатылган. Төрки малайлар сугыш эшенә өйрәтелгән, алардан хуҗалары талау отрядлары да оештырганнар. Үскәч алар үзләре *әләм-әтрәк* булып та киткәләгәннәр. К. ш. ук **Төрек**.

**ӘЛӘҢГӘСӘР** миф. «исполин, заставлявший платить себе дань». Урта Иделдә хакимлек иткән беренче зур дәүләт, безгә билгеле мәгълүматларга караганда, атаклы Хәзәр дәүләте ул (VI–XI гг.). Бу дәүләт заманыннан безгә кадәр бишкөнлек көн исемнәре (*баш көн, буш көн, атланган көн, кан көн, атна көн*), *аван* «якты, гади (кеше)» сүзе һәм *әләңгәсәр* сүзе торып калган.

Тат. *әләңгәсәр*, башк. *әләңгәҫәр*, тат. сөйләшләрендә *алганкасар* «игътибарсыз, тәртипсез» (Казан арты сөйләшендәге *алмасар* шуның бер варианты булса кирәк), нуг. *алаңгсар* «игътибарсыз», кырг. *алаңгазар* «ахмак», каз., к.-калп. *алаңгасыр* «башсыз, юньсез» – көтелмәгән рәвештә «героик» этимологиягә ия: ул борынгы *алан-хәзәр* хәрби союзы исеменнән. Н. Исәнбәт җыйган мәкальләрдә (III том, 247 б.), *алаңгасар алман би, алымсаклы яман би* тәгъбире китерелә. Мариларда һәм удмуртларда (Смирнов: 219–220) *алангасар* – ниндидер бор. килмешәк халык; «бик буйчан, баһадир, әмма җенлерәк кеше», удмурт фольклорчысы Д.А. Яшин (Яшин: 97–100) буенча, ул – «әкияти дию». Атаклы татар-казакъ этнографы А.А. Диваев мәгълүматларына караганда (к. Диваев, Андерсон: 431–433), тат. *алангасар алиф* (*алангасар алып* булса кирәк) «борынгы бер баһадир», кар. *алангасар* «әзмәвер», *аланкасар* «сәүдә юлларын саклауда батырлыклар күрсәткән бер атаклы каһарман» һ.б. бу сүзнең *алан-хәзәр* дигәннән булуын дәлиллиләр кебек. Мәгълүм ки, аланнар белән хәзәрләр союздаш булганнар һәм беразга Урта Идел регионын яулап алганнар (Болгар иле дә Хәзәрстан карамагында булган). Күрәсең, алан-хәзәрләр, **хәраҗ** (к.) җыйганда, ашык-пошык һәм тупас эш иткәннәр. Шуннан алар кабалану, игътибарсызлык символы булып калганнар. Караимнар өчен хәзәрләр – баһадир бабалар, шуңа күрә кар. авыз иҗатында *алангасар* – герой, каһарман. Ахметьянов 1981: 15.

**ӘЛӘФӘ** «льгота», иск. **ӑлапа** «постой (кормление солдат населением)» > чув. *ӑлапа* id. – бор. термин. Тат. дәүләтчелегендә яуда батырлык, дәүләт өчен тырышу һ.б. башка фазыйләтләр өчен бүләк, өстенчелек, ташлама һ.б. бирү дә булган. Шуларның бер формасы *әләфә* «бүләк, пенсия, стипендия һ.б.» дип аталган һәм рус теленә *лафа* яңгырашында кергән.

*Әләфә* сүзе гомумән гар. *äʻläфä* яисә *ʻалӯфäт* «печән, үлән» сүзеннән килә: башта ул дәүләт хезмәтендәге кешеләргә генә хәзерләп бирелгән печәнне, терлек азыгын белдергән. Ләкин дәүләтчелек эше катлауланган саен әлеге сүзнең мәгънәсе дә киңәя барган.

Тат. *Алапасы олы, кабыргасы коры* мәкалендәге *алапа* (Исәнбәт I: 301), шулай ук кар. *алэфа,* ком.

*алапа,* кырг. *улапа* «сугышчыга бирелгән эш хакы, гомумән, эш хакы, бүләк» мәгънәләрендә килә. Каз. *алапа* – ришвәт. Кайбер төрки телләрдә *алапа, алафа, алйафа* «вакытча бирелә торган эш хакы (оклад)» мәгънәсендә кулланыла. К. ш. ук **Алапа.**

Тат. телендә бу сүзне рустан кергән *льгота* урынына кулланырга була.

**ӘЛӘЦ** (Тумашева 1992: 36) «удочка» ~ тув. *элегес,* монг. *элэгэц* id.

**ӘЛӘШӘ** (ТТДС I: 543) «весенний праздник молодёжи» ~ мар. *алаша* id. – **Алач** (к.) сүзе белән бердәй булса кирәк.

**ӘЛБӘ,** диал. (ЗДС: 37–38) **алба, алwа** «райское кушанье», «кушанье, которое дают роженицам – обычно овсяные блины и каши, сваренные в молоке» > мар. *äлба, алба,* удм. *альба,* чув. диал. *элпе* id. *Хәлвә* сүзеннән булса кирәк, к. кырг. *алба* «хәлвә». *Әлвән* (к.) сүзе белән уртаклыгы юк. Тимергалин: 57.

**ӘЛБӘТТӘ,** диал., башк. *әлбиттә* «конечно» < чыгт., уйг. һ.б. *әлбәттә,* төр. *elbette* id. *әлбәт тә* тезмәсеннән булса кирәк, к. иске тат. *әлбәт* «әлбәттә» < гар. *äл-бāд < äл-äбäд* «мәңге дә (бозылмас), һич тә (киресе түгел)» тезмәсеннән (ЛТ I: 37).

**ӘЛВӘН, әлүан, әлүн: әлван (әлүн) кагы** (ТТДС I: 542–543) «пастила (алычёвая)» – **әлү** (к.) һәм *әлван нигъмәтләр* тәгъбирләренең контаминациясе, **әлван** гар. *äлwāн* «төрле-төрле» сүзеннән, к. чыгт., уйг. *әлwан, әлwан-әлwан, әлwан-түрлүк* «күптөрле».

**ӘЛВИДАГ** «прощание; прощальная песня (не плач) девушки-невесты в доме родителей» < гар. *äл-wидā‘* «хушлашу, саубуллашу» сүзеннән. Чаг. **Әлфирак.**

**ӘЛДЕРМЕШ** диал. «торопыга; горячий (человек)» ~ уйг. *алдырмиш* id. ← *алдири-* «ашыгу, еш-еш, кабаланып буталу». Чаг. тат. сөйл. *әлтерәү-бәлтерәү* «ашыгып, нишләргә белмәү», (ЗДС: 81) *әлтән,* төр. *aldır* «хәстәрләү».

**ӘЛҖЕ-МӨЛҖЕ** «подслеповатый; мельтешение перед глазами», чаг. ш. ук *әлҗерә-* ~ чув. *алчăра-, алчăрка-* «сукыраю». Чаг. **әмәл-җөмәл.**

**ӘЛЕ** «теперь; пока; ещё; таким образом, вот так; *-ка* (частица просьбы)» ~ мар. *але, äль, äльы, äле,* удм. *али, але,* нуг., каз., кырг., уйг. *али, äли,* үзб., ком., төр., төркм. һ.б. *һali, halä,* ком., кар. *ғали, гäли,* һ.б. < гар. *хāлä, хāлäн* > тат. кит. *халән* «хәзерге, шушы хәлдә»; к. **Халь.** Чув. телендә бу сүз *халь, ха* формаларында кулланыла (шуннан удм. *каль* «әле»).

Гар. сүзенең төрки сөйләм телләренә болай тирән үтеп керүе гаҗәбрәк тә.

**Әле** нигезендә берничә яңа сүз ясалган: тат. сөйл. **ә́лдә** «ярый әле, шөкер» (> мар. *äлдä* id.); **әлегәчтән** (> удм. *алигес*) «хәзердән үк; хәзер генә» – бу сүзнең ясалышы тикшерелмәгән; **әледән-әле** «еш кына кабатланып (кабатлап)» һ.б. **Әлеге** «искә алынган» сүзе гомумтөрки характерга ия. **Әлеге** сүзен «ошбу» мәгъ. куллану дөрес түгел.

**ӘЛИФ, әлеп, әлип** «первая буква арабского алфавита; алфавит»; гар. *äлиф* < грек. *άλφα* «әлиф, *а* (*ä*) хәрефе» борынгы семит телләрендә «үгез» мәгънәсендә булган һәм үгез башына охшаш хәрефне (∀) белдергән. Бу хәреф әйләндерелеп, хәзерге баш *А* сурәтен алган.

**Әлифба** «алфавит» *әлиф* һәм *ба* (*б* хәрефенең атамасы) сүзләреннән гыйбарәт, *ба* хәрефе исә сем. *бäйт* «өй» сүзе белән бәйле (тәүдә ⊴ рәвешендә булган).

**ӘЛКЫЙССА** «сло́вом; итак; короче говоря» – «хикәябезгә кайтыйк» мәгъ кулланылган, **кыйсса** (к.) сүзе белән бәйле.

**ӘЛЛӘ** «то ли; может быть» ~ чув. *эле, элле,* мар. *äлä, ала,* удм. *ало, алла* < гом. кыпч., үзб., төркм., гаг. *алла, элле,* каз., кырг. *элде, әлдә* id. Бу сүзнең этимологиясе бәхәсле: Радловча (I: 809), *әллә* төрки сүз – *ә* ымлыгы нигезендә ясалган; Рясянен (Räsänen 1969: 40) *әллә*не бор. монг. *ele* «әйе, әлбәттә» сүзе белән чагыштыра; безнеңчә – гар. *äллā, äлā* «түгел мени, түгелме икән» сүзеннән. Федотов II: 476–477.

**Әллә** тат. телендә иң кулланышлы сүзләрнең берсе: сорау кисәкләре белән аерым компонент буларак күп кенә сүзләр ясый һәм русчага тәрҗемә иткәндә түбәндәге мәгъ. бирә: **әллә кем** «(ни) бог весть кто; якобы важная персона» **әллә ни** (к. җырда: *Күңелләрем тели әллә ни, Кызарып ла пешкән әлбәни*) «(ни) бог весть что», **әллә кайда** «бог весть где», **әллә кайчан** «давным-давно», **әллә ничек** «каким-то образом» һ.б. Гади сөйл. *әлләләп*

*торма инде* диләр. Бу тәгъбирләр күрше чув., мар., удм. телләрендә калькалаштырылалар һәм беренче сүз итеп *элле ~ ала ~ ало* алына.

**ӘЛЛӘЗИ, әлләҗи** «человек, добывающий на пропитание только словом; угодливый бродяга; человек, неспособный ни к какому делу» – фонетик үзенчәлекләре буенча монг. *эллэзин < элләжчин < эллэчин* «калдык табыш эзләүче» сүзеннән, к. нуг. *әлләүчин, әллевшин* «хәерче, теләнче», ком. *әлле-* «калдык эзләп йөрү», кырг. *җәллә, җалла* «калдык-постык әйберләр; иске-москы». Бу сүз Алтын Урда чорында таралган булса кирәк.

**ӘЛЛӘҮ, әллә-лә** һ.б. «ой, ой-ой» (междометие, выражающее боль). К. **Алла.**

**ӘЛЛИ-БӘЛЛИ, әллү-бәллү** «баюшки-баю!» (слова убаюкивания) ~ удм. *алли-балли* id., уйг. *аллу-валлу* (ихтимал, татарчадан). Бу сүз киң таралган ымлыктан, к. ним. *lallen-* «баланы бәветү» һ.б. Шуннан үк **бәллү** «бишек», **әллүки, әллүкәй, әллүкәй-бәллүкәй** «бишек җыры».

**ӘЛСЕРӘ-Ү** «выбиться из сил (от жары, жажды)» ~ мар. *äлсӹрäй-*, удм. *альсыра-,* чув. *халсăрлан-, халсăра-* «әлсерәү, хәлсезләнү». В.В. Радловча (I: 828–830), *әл-сез-рә-* сүзеннән; тат. диал. (Остроумов) *әл* ~ каз. *әл* «хәл, көч», *әлсире-* «әлсерәү»; кырг. *ал* «көч, хәл», *алсыра-* «әлсерәү»; *әл ~ ал* < гар. *хäл,* к. **Хәл.** К. ш. ук тат. диал. **хәлсерә-** «хәлсезләнү, хәлсерәтү, әлсерәтү» (к. ТТДС I: 464).

Л. Җәләй бу сүзнең тамыры *әл < хәл* икәнлеген таныган хәлдә, монда *-сер//-сыр* (~ гом. төрки *-сез//-сыз*) болг. кушымчасы бар дип раслый (Җәләй 1951: 61). Безнеңчә, *әлсерә- < хәлсерә- < хәл-серә*; чаг. **Кансыра-у.**

**ӘЛҮ, әлүн** «слива» < фар. *āлӯ* id. К. **Алча.**

**ӘЛФИРАК** иск., диал. «разлука, разлучение; прощальная песня девушки с родной деревней» < гар. *äл-фирāķ* «аерылу, аерылышу».

**ӘЛХАСЫЙЛЬ** «в итоге; короче говоря» (Ш. Камал, Ә. Еники һ.б. куллана), **хасил** id. (Г. Ибраһимов) < гар. *äл-хāçил* «уңыш, нәтиҗә».

**ӘЛХӘМ** «татарское название первой суры Корана» < гар. *äлхäмду лиллäһи* дип башланып киткән «Фатиха» сүрәсенең беренче *äл-хäмд* «мактау» сүзеннән кыскарган.

**ӘЛЧЕ I** «боковое положение альчика в игре в альчики (бабки)» – выигрыш второй степени < **әлчек* id. Рус. *альчик* «ашык» *әлчек* сүзеннән булса кирәк. К. **Алчы, Ашык.**

**ӘЛЧЕ II, әлчи, әлце** диал. (ЗДС: 81) «нарядный, гордый» < (безнеңчә) болг. (эпитафияләрдә сакланган) *әлчи* < куман. *әлти, алти* «изге бикә, изге хатын», төркм. *элти* «ишан хатыны». Чаг. ш. ук төр. *elci* «илче».

Идиома: **әлче салу** «баш киемен кырый салу».

**ӘМАНӘТ** «препоручение; вклад (в сберкассу); доверенное имущество (ценность)», тар. «заложник, аманат» (к. Эфендиева: 50–55) < гар. *äмāнäт* id. формаль төгәллектә – «аманлык, әманлыклар», к. диал. **әман, аман** ~ гом. мөселман төрки *аман* «исән-сау; сак бул; ая, кызган!» Бу сүзгә *имин, иман, мөэмин, тәэмин* сүзләре дә тамырдаш. Будагов I: 91. Рус. *аманат, иманат* тур. Аникин: 85.

**ӘМӘЙЛЕК** (ЗДС: 81) «ошейник с монетами» ~ башк. *әмәйҙек* > чув. диал. *мизьих,* нуг., каз. диал. *амайыллык < әмайеллек* id., *амайыл* < иске тат. *хәмайел* ~ гар. *хäмā'ил* «путемарлар; амулетлар» сүзеннән төркиләштереп үзгәртелгән, к. рус. (< фр.) *амулет* << гар. *хäмā'улāт* «һәртөрле хәмаелләр, ягъни асыла торган фетишлар».

**ӘМӘЛ I** «средство, способ действия; выход из положения; ухищрения» < гар. *'амäл* id., татарчадан чув. *эмел* «әмәл; дәва», мар. *äмäл, амал* «сәбәп; ысул», удм. *амал* «метод, ястау (юл)». Төрки телләрдә (мәҗүси халыкларда да) бу сүз гаять киң таралып, бик күп төрле мәгънәләр биргән, к.-балк., хак. *амал* «кылмыш; хәйлә, җай», ком. *амал* «кыен хәл» (чаг. тат. *әмәлгә калу* «авыр хәлгә калу») һ.б.

Дериватлары тат. **әмәлче** ~ чув. *эмелчĕ* > мар. *амалзе* «ырымчы; хәйләкәр, тапкыр» ~ үзб., төркм. һ.б. *амалчы* id. киң таралган, к. ш. ук. тат. **әмәлләү** «ничек тә рәтләү, җайлау» һ.б. Räsänen 1969: 18; Федотов II: 478.

**ӘМӘЛ II** себ., **әмил** (әстр.) (ЗДС: 81–82) «весенний праздник» < гар. *хäмäл* «хәмәл (март-апрель) ае» (к. **Хәмәл**).

Бу бәйрәм бигрәк тә Әстерхан якларында популяр булган һәм **әмил** сүзе белән бертөркем

фразеологизмнар ясалган: **әмил атау, әмил ашы (буткасы), әмил туе, әмил чүләсе** һ.б.; **әмәл куразы** (ЗДС: 428) «әтәч сурәтендәге күмәч».

**ӘМӘЛ-ҖӨМӘЛ** диал. «кое-как» ~ алт. *емил-дьемил* «байтирәкне (мифик ыру агачын) саклаучы ике бөркет» (мәгънәсе **әмәл I** сүзе тәэсирендә бозылган).

**ӘМӘН** диал. «как бы; будто, подобно, похоже; наверно» (ТТДС I: 543; Тумашева 1961: 231–232; Махмутова: 249–250), себ. (Гиганов 1804) *амянь,* уйг. *әмән*, тат. диал., нуг., каз. *аман, амал* id. (к. **Дуамал**). К. ш. ук чув. *эмен* «кебек, гүя», мар. *ӓмӓн* «һаман»; *аман* «һәрчак; хәзер; күрәсең; ләкин, даимән», удм. *аман* «һәрвакыт, даимән; шулай да» – бу мәгънәләр фар. *һāмāн* «бер үк вакытта, бер үк төсле» (*һәм* «бергә, бер үк», *ан* «вакыт, мизгел; хәл» – иске тат. әд. телендә дә очрый: *Тәүрат*, *Зәбур, Инҗил, Коръән – Искә алыңлар һәр ан*) сүзеннән. К. «Кыйссаи Йосыфта» *һаман кем* «гүяки».

**ӘМЕР** «приказ, приказание» < гар. *äмр* id. Шуңа тамырдаш **әмир** «әмер бирүче; принц, әмир». Будагов I: 92, 95.

**ӘММА** «однако, но» < гар. *äммā* id. Төрки әд. телләрдә киң таралган сүз.

**Ә́НӘ** «вот недалёко, вона (диал.)» ~ уйг., каз. диал. *әнә,* нуг., каз., к.-калп. һ.б. *ана,* уйг. диал. *инә* id. К. **Ана, Анау.**

**ӘНӘЧ** «цыпленок – будущая курица» < диал. *анач* «анасына охшаш», бор. төрки (ДТС: 43, МК) *апаč* «анасы кебек акыллы кыз». **Ана** сүзеннән, әлбәттә. Чаг. **Әтәч.**

**ӘНӘЧӘ, әнәсә, әнәшә** «фигурка, изображение животного из теста, в особенности из семян конопли в мёде» < тат. диал. **әнәүчә** (ЛТ I: 168; ДС I: 250; ТТДС I: 545) id., *әнәчә* «түпрә [киндераш орлыгын сыкканнан соңгы түбе» (Катанов: 54)] < бор. төрки *апаwča* «сурәт», к. бор. төрки *апаүи, аŋаүи* «сурәт, тасвир, күренеш, кыяфәт» (уйг. «Угызнамә»дә генә) > тат. диал. *әнәү, әләү (әләүтаныk)* «кыяфәт», башк. (БТДҺ: 425) *әнәсә, әнчи, әнчә* «чәнти бармак».

*Әнәчә* < *анауча* элек-электән киндераш орлыгыннан ясалып, Нәүрүз һәм Сөмбелә бәйрәмнәрендә яшь (11–14 яшьлек) саф кызларны җиңелчә исертеп, теләсә ни сөйләндереп, аларның бәйләнешсез сүзләрен юрау өчен кулланылган. *Анача* сүзенең каз. варианты *анаша, наша* > үзб. *нәшә* «киндераш орлыгыннан ясалган наркотик» – рус теле аша киң таралган сүз.

Бор. *анагу* «сурәт» сүзе *ан-* «искә алу, хәтерләү» тамырыннан булса кирәк (Р. Рәхмәти). Чаг. ш. ук һинд. *Агни* «ялкын, ут тәңресе» – әнәшә ашатып исертелгән кызый шул Агни тәңресе сүзләрен сөйли, имеш. *Агни* > *Агна* > *Анаг* булырга да мөмкин.

Дерив.: (ЗДС: 83) **әнәчәләү, әнәшәләү** «киндераш оныннан ясалган камырны боткасыман өлешләргә бүлү».

**ӘНГӘРӘК, әнгерәк** диал. «злостный лентяй» < төр. *engerek* «агулы елан төре». Тат. *әнгерәк уты* ~ төр. *engerek otu* «елан чагуыннан дәва үләне».

**ӘНДӘК, әнтәк** диал. «крот» (ЗДС: 83, 84) – иске тат., гар. *хәндәқ* «окоп, җир асты юлы» сүзеннән булса кирәк (*хәндәқ сычканы* дигәннән эллипсис).

**ӘНДЕРИ: әндери әбәте** «полдник в поле, паужок», **әндери чиләге** «ведро для еды в полдник»; **әндери казнасы** «бездонная казна», к. ш. ук **әндери вакыты** «иртәнге 8–10 сәгать» (соң уянган кешеләр вакыты) ~ мар. *андри, ӓндри* «азгын егет», *ӓндри обеде* «әндери әбәте», чув. *ентĕри апатье* id. К. ш. ук чув. *сеппер апачĕ* «сәфәр әбәте – әндери әбәте» (татарларны үртәү өченме?).

Күренгәнчә, **әндери** һәртөрле чиктән чыккан нәрсәләрне белдерә. Ихтимал, бу сүз русларның Идел-Урал регионында да таралган Андриан сектасы атамасыннан чыккандыр: ул секта вәкилләре һәртөрле эпатаж белән атаклы булган. Ахметьянов 1989: 15 (тәфсиллерәк аңлатыла); Тимергалин: 61 (бездә булмаган мәгълүматлар китерелә).

**ӘНИ,** диал. **әнәй, әнәү** (бу вариант бик төрле җирләрдә – керәшеннәрдә, Себердә һ.б. очрый) «мама; свекровь», *әни [әней]* < *әнәй* алт., уйг. һ.б. *әнә* «ана» сүзенең вокатив формасыннан. Бор. палаталь *әнә, эней* (чаг. тунг. *энэ* «әни») тат.-башк. телләрендә закончалыклы рәвештә *инә*, *инәй* яңгырашларын биргән, к. **Әннә, Инә, Инәкә.**

**Әнкәй** < *әнәкәй* < *әникәй*. **Әни, әнкәй** белән параллель рәвештә һәм стилистик үзенчәлекле мәгъ. *анай, анакай* сүзләре дә кулланылып килә. К. **Әннә, Инә.**

**ӘНИС,** диал. **энеч** «анис» < рус. (түбәндә грек сүзе). Үсемлек атамасы *әнис* гар. *äнис* «дус» сүзеннән түгел.

**ӘНКӘЙ, әнкә, әнки** «мама, маменька, мамочка». Әлбәттә, **әникәй** > **әнекәй** > **әнеки,** ш. ук **әнекәч** кебек вариантлардан аеруча активлашкан формалар.

**ӘННӘ** «мама (в младенческой речи)». **Әннә** яңгырашы, ихтимал, угыз телләреннән киләдер, к. төр., аз., чув. *анне* «әни». Ләкин чув. *анней, аннев, áни* формаларын (к. Сергеев 1971: 50) тат. теленнән түгел дип әйтүе кыен. М.Р. Федотов (I: 47–48) тат. *әннә* сүзен искә алмый, хәлбуки чув. *анна* татарчадан аерылгысыз. Мар. *äннä* «әннә» дә татарчадан.

**ӘНТӘРИ** тар. «длинная (ниже колен) мужская рубаха» < төр. *entari* id. фар. сүзе.

**ӘНЧЕК** «собачка; щенок; зверёк» ~ төр. *enik, enicik* id., к. ш. ук чув. *анчăк,* алт. *аҥчаҡ,* тат. диал. (к. Будагов I: 74) *аңчыҡ* «кечкенә ерткыч» бор. гом. төрки – *аң* «хайван, ау шәе» сүзеннән. Чаг. ш. ук аз. (АДДЛ: 219) *әних*, бор. төрки (ДТС: 174) *enük* «көчек, ерткыч баласы». Федотов I: 50–51 (шунда ук төрле фаразлар һәм әдәбият күрсәтелә).

**ӘҢГӘМӘ** «беседа», диал. «порицание» (ЗДС: 84) < фар. *һäңгäмä* id. Фар. сүзе үзе төрки телләрдән булса кирәк: к. каз. *äңгі* «кычкырык» < фар. *һäнг, һäңгі,* ләкин каз. *äнгілä-* «тавышлану» төрки сүз була. Ихтимал, **әңгә-* < **һәңгә-* дигән фигыль булгандыр, шуннан *әңгә-мә*. К. төр. (Özön: 315) *hengame* «гауга; гөрелте».

**ӘҢКӘМӘ, әңмәй, әңгез, әңкес, әңке-төнке** «глуховатый, непонятливый, глуповатый». Чаг. бор. төрки (ДТС: 174) *eŋ-* «гаҗәпләнү; каушап калу», ш. ук (ДТС: 28–31, 45) *ajïγ, aŋïγ, aǰïγ* «явыз ахмак, бозгын; бозым» ← **aj ~ aǰ* (ань) «бозымлау». Төр. *eŋgebe, eŋgeme* «тигезсезлек, чокыр-чакыр» һ.б.? Мондый өзек-өзек мәгълүматлар буенча сүзнең тамырын-үсешен билгеләү кыен.

**ӘП** диал. «возможность» (к. *Әбе килсә ябе килми,* мәкаль) ~ гом. төрки *еп (эп)* id. > *ип* (к. **Ип**).

Бу сүз гом. төрки, монг. *аб, ап* «сихер, им-том» белән бәйләнешле микән – әйтүе кыен. Һәрхәлдә себ. тат. **әплә-ү** «кот кою» (к. Тумашева 1992: 37) һәм тат. диал. *әпче, әпчи* «сихерче, им-томчы (карчык)» сүзләрендә *әп* < *ап* тамыры «сихер һ.б.» мәгъ. дип уйларга мөмкин. Ләкин кайбер төрки телләрдә *әпчи, эпчи* «хуҗабикә (өйче)». **Әпче** сүзен шулай ук *әбиче* (кендекче) яки *әбичә* сүзеннән кыскарган дип тә уйларга мөмкин. ЭСТЯ I: 286–288.

**ӘП-** усилительная префиксальная частица к прилагательным и наречиям, начинающимся на *ә-* (*әп-әз, әп-әкерен, әп-әче*); билгеле модель буенча ясала: *әз-бә-әз* > *әп-әз, әкерен-бә-әкерен* > *әп-әкерен, әче-бә-әче* > *әп-әче.*

**ӘПӘ, әбә, пәпә, әпәпә** «немой, косноязычный» ~ башк. *әпә,* мар. (Гордеев I: 123; Саваткова: 10) *апа, äпä, апай*, башк. диал. (БҺҺ II: 322) *әпе, әпеүә* id. Ономопоэтик сүз булса кирәк (чаг. **Пүпәлә-ү**), чаг. санск. *apatra* «әпә» (Platts I: 7). *Әпә, әбә* бор. төрки кавем *апар ~ авар* сүзеннән булуы да ихтимал: бер төрки телдә сөйләшүчеләр икенчеләр өчен «сакау, телсез» була: чаг. рус. *немец* – халык исеме, диал. *мимеч* «телсез», гар. *ä‘җäм* «Иран (кешесе); телсез, сакау» (к. **Әҗәм**). Чаг. ш. ук **Апата.**

**ӘПӘЙ** «хлеб» ~ угыз. (аз.) *eppei* «ашамлык». К. **Ипи.**

**ӘПЕН** диал. «человек с неосторожными движениями; увалень»; шуннан ук тат. диал. **апын-топын,** (ЗДС: 85) **әпен-талау, әпен-чөпөн, әпен-төпен,** чув. *аппăн-тĕппĕн*, кырг. *апан-тапан, апылтапыл* «игътибарсыз (хәрәкәт итү)», тат. диал. **әбен-төбенү** «бәрелеп-сугылып йөрү» (Вәлиди I: 29). Чаг. **Алпан-тилпән.**

**ӘПСЕ** «рожа (болезнь)», «дух смерти» (*әпсе ашау, әпсе тибү* «үлер алдыннан тән күгәрү»), к. ТТАС III: 683. Юраулы. Чаг. фар. *āбе сӯ̄* «хәвефле су, үле суы».

**ӘПТӘНӘЙ, әттәнә** диал. (Баязитова 2001: 261, 264; Рамазанова 2001: 7) «главарь идолов, которым поклонялись» – буддистларның табынганы *амита* сүзеннән; чаг. диал. (трбс.) *аптунай* «ниндидер урман рухы». К. **Апата, Әбедә.** Бу сүзләр бор. татарларда да буддизм галәмәтләре булганлыгына дәлил.

**ӘПЧЕ** «колдунья» к. **Әп.**

**ӘР** диал. «ругань, поношение», «обидчивость; обида» – шуннан киңрәк кулланылучан **әрлә-ү, әрсез,** диал. **әрле** (*әрле килен ач торганда, әрсез*

*килен ашап бетерә*, мәкаль), **әрлән-ү** «гарьләнү», **әрләндерү** «гарьләндерү», **әрчән** «әрләүчән» (ЛТ I: 41) ~ чув. *эрлен-* «гарьләнү», *эрлĕк* «гарьлек», *эрленчĕк* «гарьләнүчән, үпкәләүчән» (барысы да татарчадан), мар. *ар, äр* «әр; гарь», *äрлäш* «әрләү», *äрлäн-, гäрлäн-* «гарьләнү», удм. *арсыр* < мар. *äрсыр* «гарьсез» – болгарчадан. Шулай итеп *әр – гарь* параллельлеге бик күп дериватларда чагыла. *Әр* < *гарь*, күрәсең, Болгар заманнарында ук киң таралыш алган.

**ӘРӘ I** «трутень» ~ тат. диал., башк. *әри, әрей* < гом. төрки *āры* (ЭСТЯ I: 186–187) id. К. ш. ук башк. (БТДҺ: 23) *ара* «төклетура», алт., хак., тув., каз., к.-калп. *ара,* үзб. *арра*, тат. диал. *арры* «бал корты», *арғуан, арбуын* «шөпшә» (Тумашева 1992: 26). Бу сүз гар. һәм фар. телләрендә дә очрый һәм һинд. *alih* «бал корты» белән чагыштырыла.

**ӘРӘ II, әрәйе** диал. (миш.) «разве». Бу сүзне рус теленнән дип кистереп әйтеп булмый, чөнки чув. *ара, вара* «инде, әле; шулай; шулаймы» ~ кар. *вэрэ (вәрә)* «һәрвакыт, һәрдаим» сүзе бар (миш., кар. һәм чув. телләреннең уртак сүзе булгач, аны хәзәр теленнән дип гөман итеп була).

**ӘРӘМ** «бесполезная трата; накладно» ~ чув. *эрем,* удм. *арам,* удм. диал. *äрäм* (Насибуллин: 106), мар. *äрäм* (Гордеев I: 131–132) ~ төр. *arem* < гар. *хäрам* (к. **Харам**). К. **Әрәмзә.** Ахметьянов 1981: 114–115.

**Әрәм булу, әрәм итү, әрәмтамак** лексемалары чув., мар. һәм удм. телләрендә ярымкалька рәвешендә кулланыла. Кырг., төр., себ. *арам* «пычрак».

**ӘРӘМӘ** «урема, урёма, пойменный лес» – удм., мар. *арама, äрäмä*, морд. Э. *урама* id. < болг. **әрәмән* < *wәрәмән* < **өрэмэн* id. *Әрем, имән* һәм, ихтимал, *урман* сүзләре белән бердәй тарихи нигездән, чаг. каз. *ермене* «әрем, әремлек», башк. диал. *иремән* «курайлы үсемлек» ~ калм. *eremen* «акация, чилек». Рус. диал. (Аникин: 96, 201, 589) *арема, ерема, урема* «әрәмә» тат. сөйләшләреннән һ.б. К. Ахметьянов 1980. К. ш. ук **Әрем, Имән.**

Башк. *Ирәмәл тавы* атамасы да шуннан (< *ирәмәле*) булса кирәк, к. аз. (АДДЛ: 236) *ирәмә* «калкулык», *ирәмәли* «тау-чагыллы».

**ӘРӘМЗӘ, әрәмзәлек** «незаконорожденный; аморальный» ~ мар. *арамса* id. < иске әд. *хәрамзадә* id. К. **Әрәм, Харам, Хәрәм.**

**ӘРӘПӘ** (ЗДС: 86–87 ТТДС II: 400; БТДҺ: 427), **рәпә** (ТТДС I: 355) «канун, преддверие (праздника, обычно – сабантуя), приготовления к празднику», (ТТДС II: 400) «поминки в Пасху и в летние дни у крещёных татар», «пир, созывание гостей перед свадьбой (без приглашения другой стороны, в кругу своих, но сваты могут присутствовать)» << *гарәфә* (к.) < гар. *ʻарафä* «бәйрәм алды» > уйг. *әрәпә* (гомумән тат.-башк. сүзе уйгурлардан булса кирәк). Чаг. **Гарәфә.**

Идиомалар: **әрәпәгә чыгу** «сабантуй репетициясе ясау; репетиция (бигрәк тә җыр репетициясе)», **әрәпә җыйыны** «труйчынга ике-өч көн калгач кунакка йөрешү-чакырышу».

**ӘРӘЧӘ** диал. (Вәлиди I: 272) «суть, сущность» ~ башк. *әрәсә* id. ТТАС (2005) «ярдәмлек, кулланмалык; адвокат» мәгъ. бирә. Андый мәгънә реаль булса, *әрәчә* төр. *araç* «чара, васита» сүзе белән гомоген (асылда фар. сүзе).

Дерив.: тат. диал. **әрәчәлә-ү** ~ башк. *әрәсәлә-ү* «туйда кәләшкә ярдәм итү». Бик үк ачык түгел. Чаг. **Арчала-у.**

**ӘРБӘ, әре, әреш, иреш** «мякина; отруби; охвостье, обмолоченные колосья» ~ чув. *ерпе, арпа, авра* «әрбә, солы кибәге», мар. *äрвä, арва* «әрбә» ~ нуг. *эрпек* «коелдык; әтәмби, ябае». К. ш. ук башк. диал. *әүрә, әүре, әүрәү* «әрбә» (БҺҺ II: 325).

Бары тик (яисә башлыча?) Идел-Урал регионында гына очрый торган бу сүзләр бор. болг. теленнән булса кирәк: *әреш, иреш* < болг. **эреше* < **эре-се* (*эре* сүзенең тартым формасыннан, болг. телендә *-сы//-се* һәр очракта *-шы//-ше* булып әверелгән). *Әре, эре* сүзе герм. сүзе *āhre* «башак»ны, ә *әрбә* < *әрбәк* герм. (ним.) *achel, agel, ahil* < кадим. *ahir, ahre* «әре, буш башак», соңрак *Ahre* «башак», *āhrebāck* «башак арты – кибәк, мәкинә» сүзен хәтерләтә (чаг. ш. ук инг. *harvest* «уңыш; башаклар»). К. Kluge: 12, 14, 23.

Бор. болгарлар Азов диңгезе ярларында – алардан бер-ике гасыр элегрәк остготлар яшәгән җирләрдә дәүләт корганнар. Аларның остгот теленнән сүзләр – бигрәк тә авыл хуҗалыгы терминнары алуы бик ихтимал вә табигый.

Хәер, *әре, әрбә* сүзләренең һинд-евр. чыганагы аннан да борынгырак булырга мөмкин, к. грек. *аера* «әрбә, әре, бакра», лат. *ager, agri* «басу, игенлек» (шуннан *агро-*) һ.б.

Räsänen 1969: 47; Федотов I: 59; Ахметьянов 1989: 50–51.

**ӘРВАХ** «духи умерших» < гар. *äрwāх* id. – *рух* сүзенең күп. формасы. Сөйл. (ЗДС: 50, 66) *арбак, ачарбак* (> удм. *арвак*) «догасыз үлгәннәрнең явыз өрәге». Башк. *арбакты* < *әрвахлы* «җенле». К. **Өрәк.**

**ӘРГАН** «лосось» (Будагов I: 49). Ачык түгел. К. **Арган.**

**ӘРГӘН** «шарманка; гармоника, гармонь» ~ удм. *арган* id. < рус. *орган*.

**ӘРДӘНӘ, әрдинә,** (ЗДС: 83, 87) **әндәрә, әртәнә** «поленница; запасы дров» > мар. *артана*, удм. *ардана*, удм. диал. *äртäмäd* < куман. *äрдäң,* угыз. *erden «*тиелмәгән запас; кызлыклы кыз», чыгт. *äрдäнä*, каз. *ардана* «яхшы дөя», төркм. *ардана* «бозауламыйча саудыра торган сыер», уйг., монг. (Радлов I: 794–795) *äрдäн* «асылташ», алт. *эрдьине,* тув. *эртине* «кыйммәтле нәрсә, хәзинә» < бор. төрки (ДТС: 176, 182) *erdini, erdäni* «хәзинә; эре энҗе» < санск. *ratna* «хәзинә», кыйммәтлек». Тат. мәгънәсе төр. «тиелмәгән урман-кыр» сүзенекенә якын. Гомумән, бу сүз күп телләрдә очрый һәм топонимикада (бигрәк тә Себердә, Монголиядә) еш кына чагыла.

Дерив.: **әрдәнәле, әрдәнәлә-ү** һ.б.ш.

**ӘРЕКМӘН** «лопух, репейник» ~ мар. *äрыкмäн,* удм. *арыкман* id. (< тат.). Тат.-башк. сөйләшләрендә бу сүзнең исәпсез күп вариантлары очрый: *әрәмкән* (Троянский I: 28), *әпертмән*, *әпрәмән, әпрән, әрехмән, әрәтмән, әфрәмән* (ТТДС I: 609–610), *әберәкмән*, *әперәкмән, әберәм* (БҺҺ II: 319), миш. сөйләшләрендә *рахман, абдрахман, чирахман* һ.б.; берничә вариантта *-с-* авазы бар: башк. диал. *әрәсмән,* уйг., кырг. *абдрасман* «бәбиләрне төтәсләү өчен кулланыла торган үлән төре», чаг. бор. ир. *barəstan* «гыйбадәт урынына җәелә торган салам, изге салам»; чаг. ш. ук фар.-таҗ. *испанд* «төтәсләү, арулау ырымнарында кулланыла торган хуш исле үлән» һәм хак. *ирбең* «шуышма чабыр үләне», «әрем» (к. **Әрем**). Әрекмән яраларга ябу өчен кулланыла һәм аның атама вариантлары күплеге бу сүзнең парлы сүздән килеп чыкканлыгына дәлил (ихтимал, **ирмән-испәннән*). Өстәвенә монда *рахман* сүзенең тәэсире дә беленә.

Кызыклы рәвештә әрекмән сүзенең барча без китергән вариантлары удм. телендә дә очрый, к. ДАУ III: 42–43.

**ӘРЕМ** «полынь» ~ чув. *эрĕм, армути, арăм ути*, мар., удм. *арым, äрыӹм* ~ венг. *üröт* id. Бүтән төрки шивә вә телләрдә сүзнең *-н*га беткән вариантлы өстенлек итә: себ. *ирмән* ~ хак. *ирбең, эрбäн,* уйг. *әрмән*, кырг. *ермäн* (Радлов I: 800–802), каз., к.-калп. *эрмене* «әрем; көчле исле үлән төре», к. ш. ук каз. *жермен, жермене*, монг. *эрэм, эрэмин*, як. *эрбэһин* < *эрбэсүн* << бур. *үрмэдэсэн* «әрем». К. **Имән, Әрәмә.**

*-Н*сыз вариант монг. телләрендә килеп чыккан (анда азаккы *-н* факультатив), к. бур. *эрмэ*[н]*,* калм. *эрм* «әрем», *-н*лы вариант тат. диал. *әбәнде, әрбәнде* «вак-төяк куаклык» (ТТДС I: 539) сүзендә саклана. К. ш. ук башк. *әрмәнде* «әремлек бакасы (бака төре)», *Ирәмәл, Ирәмән* – мәшһүр тау (< **ирәмәнле*). Räsänen 1969: 48; Федотов II: 480 (боларда этимология сай бирелә).

**ӘРЕП** «ссора; неприятие» гар. > иске тат. *хәрб* «җәң, сугыш» сүзеннән (Радлов I: 773). К. **Хәрби.**

Дерив.: **әрепләш-ү** (киң таралган).

**ӘРЕШ I** «охвостье» к. **Әрбә.**

**ӘРЕШ II,** диал. (ЗДС: 215) **ireш,** «основа тканья» ~ башк. *ireш,* кырг., төркм. *эриш* (төркм. *ireш-арқаг* «буйлык-аркау»), гом. кыпч. *арыш* id., төр. (Будагов I: 28; Steuerwald) *arš, ariš* «әреш; тәртә, өзәңге», каз., хак. *арыс* «тәртә; параллель ике арата; арба, чана; дуаль мөнәсәбәттә торган ике кабилә»; тат. диал. **арыш таягы** «аюбаш таягы (туку урдынында (тукылган тукыманы урап бару өчен ясалган валны фиксацияли торган таяк)», Воробьёв Н.И. Примитивный тип татарского ткацкого стана // Материалы центрального музея ТАССР. Казань, 1927) < бор. төрки (ДТС: 53, 58) *arïš, arïs-arqaγ, aruš,* «буйлык».

Бу сүзләр тур. күп язылган. Күпчелек тикшеренүчеләр алар **аршын** сүзенә тамырдаш һәм Һиндстан телләреннән таралган диләр.

**ӘРҖӘ** диал., «ящик, сундучок; корзина, кадка из бересты, лыка и т.п.», > мар. *äржä, äрзьä, öрзä,* чув. (Сергеев 1971: 158) *ырча, арча, öрçе* id. ~ башк. *әрйә* «кумта; кисмәк», башк. диал. «көбә кием; запас умарта; корт тубалы», каз., үзб. (Аманжолов 356, 439; ҚТДС: 30; ЎХШЛ: 20) *аржа, әрже, әржі* «стружка (< орнамент); махсус орнаментлы тар сандык», к.-калп. *арша* «традицион калай бизәкле сандык, бирнә сандыгы» < фар. *äржäңи* «бизәкле кумта; һәртөрле хикмәтле рәсем-

бизәкләр» ← *äржäң, äрзäңи* (к. Будагов II: 201) «манихей динендәгеләрнең бизәкле китабы һәм китап савыты», төр. *erjeng, ertenk* «Мáнинең көллияте (барча әсәрләре), шуның өчен махсус әрҗә». **Әрдәнә** белән гомоген булса кирәк, к. алт. *эрдьине, эрджине* «хәзинә». Манихей диненең төркиләр арасында билгеле булуы себ. **Ванихай** (к.) сүзендә дә сизелә. Удм. *арҗа* «тукыма шакмагы» < «әрҗә шакмагы» булса кирәк.

**Әрҗә** сүзен алт. һ.б. *хааржақ* «тартма, табут» яисә алт., тув. *арчымак* «кәрзин» сүзләре белән (Joki 1955: 15), ш. ук як. *аржа* «эре ярыклы мурда» сүзе белән (Пекарский I: 148–149) чагыштырулар бар.

**ӘРИ, ары, арын** (мордва-каратайларда без теркәдек. – *Р.Ә.*) «злой дух» ~ чув. *ар,* маньч. *ари,* эвенк. *ар, аринка, аринки* һ.б. (к. ССТМЯ I: 151) < санск. *ari* «явыз рух».

**ӘРКӘҮ [әркәw]** (ЗДС: 87) «деревянная чаша для мёда у пчеловодов» ~ башк. *арҡау, арҡатау* id. Ачык түгел. *Ар-* ~ *әр-* тәңгәллегенә караганда тат. *ары* ~ *әре* «ата бал корты; гомумән бал корты» сүзе баглы булырга мөмкин.

Чаг. ш. ук бор. төрки (ДТС: 54) *arqu-* «эзләү».

**ӘРЛӘН,** диал. **ирлән** «хомяк; крот» ~ башк. *ирлән* id. > чув. *эрлен,* мар., удм. *арлан, äрлäн,* морд. *арлян* id. ~ алт. *эрлен,* хак. *ирлен, ирлең* «күсе; ас» < бор. төрки (КБтә) *ärlän* «күсе; ниндидер җирказыр хайванчык» *-лаң//-ләң* кушымчасы ярдәмендә ясалган хайван атамаларының берсе булса кирәк. Чаг. ш. ук бур. *эрлен хан* «җир асты патшасы, әрлик» (к. **Әрлик**).

Башк. һ.б. (күп кенә телләрдәге) *арлан* «ата эт; этләрнең бер токымы» сүзен *әрлән* сүзенә нисбәтләргә фонетик һәм семантик төгәлсезлекләр комачаулый (*арлан* ул «әрлән аулый торган эт» дип беркайда да әйтелми).

**Әрлән** сүзенең **йерлән** (ЗДС: 216, 218) варианты сүзнең тамыры *йер* «җир» булуын күрсәтә шикелле.

**ӘРЛЕ-БИРЛЕ** «туда и сюда» < **арылы-биреле.**

**ӘРЛИК** тар. (Котбның «Хөсрәү вә Ширин»ендә) «Эрлик, злой дух, хозяин подземного мира» – алт., хак., тув. һ.б. *Эрлиг, Эрлик, Ирлик* id. < бор. төрки (ДТС: 180; КБ) *Эрклиг* «ирекле, кодрәтле» – җир асты, тәмуг патшасы. Аның турында күптөрле, еш кына капма-каршы бәяләмәдәге мифлар бар. Эрлик образы (һәм сүзе) төркиләрдән монгол халыкларына да кергән һәм буддизм дине изгеләренең берсе булып киткән. Әрлик турындагы мифология һиндиләрдәге Яма тәңресе хакындагы мифологиядән алынган, диләр (МНМ II: 657–658).

**ӘРЛҮС, әрлүч** диал. «качели; перекладина» болг. **арлыwыч* < **аркылы йыwач* «аркылы агач» сүзеннән, к. чув. *урлаççи* «аркылы агачы». К. ш. ук мар. *арлу* «тәрәзә, ишек яңагы» – татарчаданмы?

**ӘРМӘК** «армяк» < болг. **wәрмәк* < гом. төрки *örmek* (*ö* > *wә* күчеше һәрхәлдә Урта Идел болг. теленә хас булган), к. каз. *örтöк,* чыгт. *örmäk* «әрмәк; юан йон җептән «үрелгән» тукыма» > тат. диал. (ДС III: 256) *үрмәк* < «тупас келәм; палас» , чаг. башк. *әрмәк* «аркавы чүпрәктән эшләнгән палас» (к. БҺҺ II: 393). Гом. төрки *öр-* «үрү» сүзе белән аңлатыла.

Кайбер телчеләр бор. төрки *örmek* бор. монг. *örmege, örmüge* «өске кием, әрмәк» сүзеннән дип карыйлар. Шунысы кызыклы, бор. монг. *örmüge* сүзенә (Поппе 1938: 443) мар. *öрмäкá* «хатын-кыз күлмәгенең кулбаш бизәге» сүзе бик чагыша.

Рус. *армяк* тур. к. Юналеева 1982: 23–29, Аникин: 102.

**ӘРМӘН** «армянин» – русча *армян* сүзеннән: *армян* > *әрмән* сүзе исә арами телендәге *һар миңә* «югары ил (тау башы)» сүзеннән килә һәм ассур телендәге *Урарту, Уруарту* «югары (таулы) җир» сүзенең калькасы буларак барлыкка килгән. *Армян, армин, әрмән* сүзе дөньяга фар. теле аша таралган.

X г. бирле Урта Идел регионында яшәгән әрмәннәрне татарлар *хәчтерүш* дип атаганнар. К. **Хәчтерүш.**

**ӘРНЕ-Ү,** иске тат. **әбрән-ү, әбрә-ү** «ныть; щемить, сильно горевать»; бу сүзгә һичшиксез чагыша торган (башк. *эрне-*, мар. *äрнä*-ләрне исәпкә алмаганда) бер генә сүз табылды: бор. монг. *örni-* «әрнү, сызлау», шуннан, болг. **wәрне* формасы аша, *әрне-* килеп чыга ала. Тагын бер сүз – алт. *аарны-* «әрнү; ачулану» – бор. *aγı, aγu* «ачы» тамырына илтә. К. **Ачы.**

**ӘРНИ** диал. «пожалуйста» (Тумашева 1961: 232), «вроде как» (Арсланов 1988) ~ чув. *эрнĕ, эрне* > удм. *арна* «әлбәттә, шулайрак», монг. *арня* «әлбәттә» (к. Алатырев 1976: 145).

**ӘРРӘ, әргә** диал. «цепная пила» ~ башк. *ара быскы* «ножовка», үзб., уйг. *арра, ара, әрә* id. Чыгышы ачык түгел (фар. телендә дә бар).

**ӘРСЕЗ** «беззастенчивый; невзыскательный» > мар., удм. *арсыз, äрсыз* id. Шунысы игътибарга лаек, мар., удм. телләрендә бу сүзнең *арсыр, äрсыр* (болг. варианты) да сакланган (чув. телендә ул юк). К. **Әр.**

**ӘРХӘРӘЙ** «архиерей», диал. (Остроумов 1892: 50) **әркәнәй** id. < рус. *архиерей.*

**ӘРТИЛ** «артель, группа» < рус. *артель.* Рус этимологиясендә бу сүз бәхәсле: берәүләр аны төрки телләрдән яисә монг. теленнән, икенчеләр ит. *artieri* «һөнәрчеләр группасы» сүзеннән уйлыйлар. Һәр ике очракта семантик кыенлыклар бар. Бүгенге тат. (шулай ук башк., мар., удм.) *әртил*, күренеп тора ки, рус теленнән (икенче иҗектә *и* авазы алынма сүз булу галәмәте). Әмма рус. *артель* үзе тат. теленнән дип уйланыла (бу турыда заманында татар телчесе Хәсән Гали, аннары бик билгеле рус тюркологы Н.К. Дмитриев язганнар). Тик менә аның тат. телендәге төп варианты, дөресен генә әйткәндә, табылганы юк. Башк. сөйләшләрендә *әртел* «өер» (*бүре әртеле*) бар барын, ләкин ул, мөгаен, *артил* сүзен халыклаштырудан гына килеп чыккан вариант. Хәсән Гали *әртилне* «арт ил» сүзеннән ди, борынгырак яңгыраштa бу тәгъбир *арт эл* булырга тиеш: бор. төрки язмаларда *арт (арт-басут)* «ярдәм, ярдәмче», *эл (ил)* сүзенең исә «отряд, хәрби төркем» мәгънәсе дә бар. Шулай итеп, *арт эл, арт ил* «ярдәмче отряд» сүзе була ала.

Эзләгән этимон тирәсендә йөри торган сүзләр тагын күп: фар. *ардәл* – «офицерның хезмәтче солдаты (денщик)», «кургавыл» (төрки телләрдән булса кирәк); төр. *ардыл* «варис токым, өстәмә, ярдәмче, ярдәмлек»; монг. *ардчил* «халыкчы», *арчи* – «ярдәмче отряд» (шуннан тат. һәм бүтән Идел-Чулман телләрендәге *арчи* «кәләшне озата баручылар төркеме» сүзе дә килә) һ.б. тирәсендә йөриләр, ә менә алмасына тимиләр...

**Әртил** сүзенең этимологиясе һаман исбатсыз кала бирә.

Ярдәмче хәрби частьләрне безнең бабаларыбыз тагын **күмәк, талпа, хәшәр** сүзләре белән дә атаганнар.

**ӘРЧЕ-Ү** «очистить (от кожуры)» к. **Арчы-у.**

**ӘСА** тар. «жезл» < гар. *ʻaçā* «таяк, хакимлек билгесе булган таяк» сүзеннән, к. иске тат. әд. *гаса* «култаяк». К. **Аса.**

Бу сүзне башк., каз., к.-калп., бур. *аса* < *ача* «чатлы таяк, атлама» сүзе белән баглау ярамас.

**ӘСАС** «основа, основание» < гар. *äcāc* id. *äcca* «нигез; әзерлек» сүзеннән. Шуннан ук иске тат. *мөәссәсә* «учреждение».

**ӘСӘР** «произведение; впечатление; признак, след» < гар. *äçäр* id. *äçäрä* «махсус эз калдыру» тамырыннан. Шуннан ук *тәэсир. Әсәрлән-ү* тат. телендә ясалган. Чаг. ш. ук тат. диал. **әсәртә** «йок; зәгыйфь калдык».

Дерив.: **әсәрле, әсәрсез; әсәрлән-ү.**

**ӘСӘТ** зодиакальный месяц – «23 июля – 23 августа» < гар. *äcäд* «арыслан» («арыслан йолдызлыгы») сүзеннән.

**ӘСБАП** «принадлежность какой-либо деятельности, занятия» < гар. *äсбāб* id. ← *сбб* «сәбәп булу; гаепле булу». К. түбәндәгене.

**ӘСБӘТ, әспәт, әспәк** (к. ЗДС: 88) «хороший вид одежды; чистота и аккуратность» < гар. *äсбāб* «кирәкле әйберләр», ш. ук «яхшы кием» ← *сбб* «сәбәп булу» тамырыннан. Тат. **әсбәт** һ.б. турыдантуры гар. теленнән түгел, төрекчәдән, к. төр. *esbap, esvap* «яхшы кием», *esbapçı* «гардеробчы».

Дерив.: **әсбәтле, әспәтлә-ү** һ.б. **Әспәк** варианты, ихтимал ки, фар. *äсбаби пакь* сүзеннәндер.

К. югарыдагыны.

**ӘСИР** «пленный» < гар. *äcūр* id. Ләкин гар. сүзе үзе бор. төрки *йасир* < *йағы сир* «яуланган сир (кабилә атамасы)» сүзеннән, к. көрд. *yexsîr [йәхсыр]* «әсир; кол», *yextirme, yexme [йäгмä]* < бор. төрки *jaγma* (*jaγ* «яулау») «талау сәфәре». Рус. *ясырь, ясир* турыдан-туры төрки телләрдән. «Әсир» мәгънәсендәге сүзләрдә еш кына этнонимнар – (күрше, дошман, яуланган) кабилә, кавем атамалары саклана.

**ӘСПӘРӘК, әспе (әспе чыбыгы)** «спаржа, спарва» (гөл буларак та, агу-дару буларак та, буяу чыганагы буларак та билгеле үлән үсемлек) < фар. *эспäрäк* id. < бор. ир. *fraspar*ə*γa* «үсенте» > лат. *asparagus* > ит. *sparagio* >> рус. *спаржа.* Фасмер III: 732; Kluge: 860.

**Әспе** белән кызамыкны дәвалаганнар. Шуннан *әспә* «кызамык», рус. *оспа* белән очраклы охшашлык.

**ӘСТӘ I** (ТТДС I: 547; БТДҺ: 427) «железная вилка для лучины (в старину)» < фар. *äстä* «тимер деталь».

**ӘСТӘ II** (Тумашева 1992: 38) «потихоньку, медленно» < уйг. *әстә, аста* < фар. *āһистä* id. к. **Ируаста.**

**ӘСТӘГЪФИРУЛЛА** > сөйл. **әстәкъ, әстәгым** «прости меня, господи!» (междометие) < гар. *äстäғфир-уллаһ* «Аллаһ мине гафу итсен».

**ӘТӘЙ** «папа» к. **Әти.**

**ӘТӘЛӘ, атала** диал. «жидкая мучная болтушка (на сметане)», **әтәләм** (Хайрутдинова 1993: 89–90) «вид масла» < уйг., кырг., каз. диал. (ҚТДС: 33) *атала,* үзб. диал. *әтәлә* id., чаг. ком. *атала-* «болгату». К. башк. (Нагаева: 56) *әүмәлә* «әтәлә» (ихтимал, хәреф хатасыдыр, дөресе *әүтәлә* булса кирәк). Чаг. **атла-у II** < *атыла-у.*

**ӘТӘЛӘН-Ү, әтелән-ү** (ЗДС: 88) «сильно волноваться, забегаться по недостойному (по мнению говорящего) поводу» ~ мар. *ӓтӓлӓн-* id. Шактый киң таралган (әд. әсәрләрдә дә очрый) бу сүз *атылан-у* май язганда «**аты** (к.) белән болгатылу»дан палатальләшкән булса кирәк, к. диал. (ЗДС: 88) **әтәлән май** «атлан (атыланган) май». Кайбер тарафларда **әтеләнү** мәгъ. **өтеләнү** дип сөйлиләр, анысы **өт-ү** сүзенә нисбәтләнә.

**ӘТӘЛГЕ** «крупный вид коршунов; кречет» ~ себ. (Тумашева 1992: 61) **итәлгү** «мышелов (птица)» ~ бор. төрки (Поппе 1938: 568) *itelgü*, чыгт. (Радлов III: 1086) *тälгү* «әтәлге» ~ каз. *ителгi,* кырг. *ителги*, үзб. *итолғи* id., аз. (АДДЛ: 466) *үтәлки* «козгын» һ.б. (һәм төрле җирдә төрле ерткыч кош атамасы)» ~ калм. (Номинханов I: 111) *итлг* «ана балабан». Л. Будагов (I: 111) буенча, бу сүз бор. төрки *öt-* «сайрау» сүзеннән: к. төр. *ötelgü, ötlegü* «әтәлге; сайрагыч» – әтәлге табыш эзләгәндә моңлы бер аваз салып оча икән; бу версияне төрек филологы Б. Өгәл (Ögel: 367) дә куәтли (әтәлге кайбер төрки кабиләләрнең ыру кошы).

**ӘТӘМБИ, әтәмбәй** «опавшие семена, падалица; злаки, выросшие из осыпавшихся зёрен; отродье», (ТТДС I: 548–549) **әтәмбай** «болезненный, хилый (ребёнок, детёныш)» ~ башк. (БТДҺ: 428) *әтәлбай, әтәмбай, әтәрбай* «әтәмби; типтәр, җибәрелмеш (припущенник)» > мар., удм. *ӓтӓмбӓй, ӓтӓмбей* (вариантлары күп) «әтәмби; чураш (никахсыз туган яисә иярчен бала)» һ.б. Идел-Урал регионы сүзе; һичшиксез, кушма сүздән (*-бай* «пай, өлеш» мәгъ. булса кирәк), арытабан ачык түгел, чаг. тат. *әтәм-сәтәм, әтрәм-сәтрәм* (> мар. *ӓтӹрям-сӓтырам*) «ниҗитте, һәртөрле кирәксез (нәрсәләр)».

**ӘТӘЧ** «петух» > мар. *атась, ӓтӓчь,* удм. *атась, атазь* (Тараканов 1977: 95; Гордеев I: 162) id. ~ тат. үз сүзе, к. диал. (ДС I: 251; ДС II: 252; ДС III: 212) *әтәч* < *атач* «әтәч буласы чебеш» (*әнәч* < *анач* «тавык буласы чебеш»), башк. (БТДҺ: 428) *әтәкәс, әтәс* «атасына охшаган бала» < бор. төрки (ДТС: 43, 66) *atač* «атасына охшаш», *anač* «анасына охшаш (бала)». Ошбу аңлатма К. Насыйри хезмәтләрендә бирелә. Кайбер филологик хезмәтләрдә (Будагов һ.б.) *әтәч* сүзен бор. төрки *öt-* «җырлау» сүзеннән дип аңлату дөрес түгел. Ахметьянов 1989: 66.

**Әтәч** продуктив нигез: **әтәчле, әтәчлек** «кукраючанлык», **әтәчлән-ү** «кукраю, сугышчанланып кылану» һ.б.

**Әтәч чакыра** дигән тәгъбирдә (шуңа охшаш фраземалар күп телләрдә бар икән, к. Kluge: 384) «әтәч таң кызын, көнне уята яки чакыра» дигән мифологема ята. Әтәч *кычкыра* да белә, ләкин бу бөтенләй икенче аваз. *Әтәч җырлый* дип русчага ияреп кенә (*петух поёт* дигәннән калькалаштырып) кына әйтәләр бугай, әмма *тавыклар җырлыйлар* дию – үзебезнеке.

**Әтәче кычкыра (кытный)** дип *шәһвәте килә* мәгъ. сөйлиләр.

**ӘТЕЗ, әтиз** диал. «пашня, поле посреди болот (в Сибири)» < бор. төрки *atïz* «ике арык арасындагы чәчүлек» (ДТС: 13, 67) сүзеннән; бу сүз Болгар заманнарында актив кулланылган, к. коми. (КЭСК: 30) *адас* «җир кишәрлеге», удм. *удыс* < бор. төрки *адыз* «эшчәнлек өлкәсе». Удм. сүзе чув. *утас* «атлыйсы» сүзе белән чагыштырыла, ләкин бу дөрес түгел – мәгънәсе һәм формасы чагышмый. К. ш. ук алт. диал., төр. *адыс*, каз. диал. *итыз*, каз., үзб. диал. (ҚТДС: 34, 142; ЎХШЛ: 21) *атыз* «сугарулы җир мәйданы», уйг. *етиз* «чәчүлек җир» ~ нуг., кырг., хак., тув. *адыр* «калкулык, тигезсез җир мәйданы; ике хәвез аркасындагы калкулык» >> мар.

*атыл, отыл* «басу» һ.б. кор. *pat, pathari* «басу» сүзе белән дә чагыштырыла (Räsänen 1969: 31). Ахметьянов 1989: 49–50.

**ӘТИ [әтей]** < диал. **этей** (Уралда), **әтәү** «папа; свёкор» < диал. һәм гом. кыпч. *атай* (вокатив от *ата* «отец») – тат. теленең үзендә килеп чыккан (*а* < *ә*) сүз; мар., удм. *äти, атя, äтя, аття,* чув. (Сергеев 1971: 52) *атте, этти, атей, атти, етте* һ.б., әлбәттә, татарчадан. М.Р. Федотов (I: 70) шул чув. сүзләре тур. язганда тат. вариантларын искә дә алмый. Венг. *atya* «әти» сүзе, ихтимал, Идел-Урал регионыннан алып кителгәндер. К. **Ата.**

**Әти < этәй** сүзе һәртөрле фономорфологик вариантларга бай (к. Рамазанова 1972: 23–27): **эткәй < этекәй, эттә** һ.б. (кушма сүзләр составында). Шунысы кызыклы ки, *atti, atte* һ.б.ш. «әти, дәвәти» һинд.-евр. телләрендә дә еш кына очрый, к. Kluge: 69.

**ӘТМӘ** (ТТДС I: 548; БТДҺ: 428) «перепонка между пальцами плавучих птиц; намет, сеть; силок; задвижка» ~ мар. *äтма, атма,* чув. *атма* «әтмә, челтәр, ятьмә һ.б.ш.», морд. *алтма* id. чув. *ат-* < *әт-* < **әлт-* «үрү, типчү, чапраз ясау», к. уйг. *әт-* «төймәләү; ишергеч белән бикләү». К. **Ятьмә.**

**Әтмә** продуктив нигез: **әтмәлә-ү** «аннан-моннан гына эләктереп эшләү; сыйфатсыз гына ясау» (> мар. *атмала-* «үрү, чормаштыру»); **әтмәчә** «аннан-моннан эшләнгән нәрсә» һ.б.

**ӘТМӘЛЛӘ-Ү, экмәллә-ү** диал. (шрл.) «сделать кое-как». Бу сүз **әтмә** нигезеннән ясалган кебек. Ләкин к. диал. (ЗДС: 701) **хәтмәлләй** «тиз генә, тиз арада» ← гар. *хäдди мä‘қӯлä* «бик кирәгенчә генә, кабул ителерлек чикләрдә» (иске мәдрәсә жаргонында булган сүз).

**ӘТНЕК** «лук угластый» – юа суганы, болын юасы ~ башк. *әтнәк, әтлек* «кыңгырау чәчәк», *әтмәкәй* «әтнек» (БҺҺ II: 324–325). Ясалышы һәм чыгышы ачык түгел.

**ӘТРӘК-ӘЛӘМ, әтрәгәләм,** диал. (Ф. Хөсни «Утызынчы ел») **әләм-әтрәк,** (ТТДС I: 543) **әле’-мәтре’** «голь перекатная» – гар. *äтрäк ғулāм* «төркиләрдән торган яллы гаскәр» сүзеннән: *әтрәк* «төркиләр», *ғулāм, ғулäман* «(фар.-гар.) яллы гаскәри» (к. **Аламан, Әләм-әтрәк**).

**Әтрәк** «төрки чиру» мәгънәсендә К. Галибикнең «Җәмигъ әт-тәварих» китабында еш очрый (к. Библиотека восточных историков, т. II, Казань 1854: 4–26). Тимергалин: 65.

**ӘТТӘ, эттә-тә** «возглас восхищения, восторга, удивления» – бу сүз бөтен дөньяга таралган бугай, к. Кавказ телләрендә, ним. *атта*, тунг. (ССТМЯ II: 471) *этэ-тэ* id. һ.б.

**ӘТТӘГЕНӘСЕ,** диал. (ДС I: 253) **әттәң, әттәңәй** ы. «вот так штука!» ~ каз. *әттәң* id.. тат., башк. *әттәгенә* җырда асемантик кушымча (*әттәгенә генәме? әттәгенә генәдер* һ.б.) < уйг. *әттигинәй* «кызганыч, ай-яй», *әттән* «минә сиңа кирәк булса» < *әртәгиң* «әкиятең, минә әкият!» – *әртәк, әртәги* «әкият, күптәнге вакыйга, үткәннәр» сүзеннән (к. **Иртәк**).

*Әттәгенә* < *әртәгиң, ә* сүзе Алтын Урда чорында Идел буе шәһәрләрендә яшәгән уйгурлар теленнән таралган.

**ӘТТӘХИЯТ** «формальная и торжественная часть общественного мероприятия» < гар. *äт-тäхиййäт* «сәламләү, бүләкләр бирү; намазда тезләнеп утырып укый торган дога» сүзеннән; шуннан **әттәхиятсез** «формаль булмаган рәвештә».

**ӘТҮЛЕ, ат'улы** (ЗДС: 61, 63, 90) «знаменитый, известный всем (о людях)» – **әйтүле** һәм **атаулы** сүзләреннән контаминация.

**ӘТҮТӘН** (Т. Гыйззәт һ.б. авторларда) «сопровождающее лицо важной персоны; клеврет; якшающийся с начальством» ~ башк. *әтәүтән* id. < рус. (< фр.) *адъютант* id.

**ӘҮ** «модально-экспрессивная частица»; диал. *әү, ау* «әйе бит» ~ нуг., каз., к.-калп. *ау* id. Башкорт фольклорында да очрый.

**ӘҮВӘЛ [әwwәл]** «первый; прежде» (*-дан әүвәл* «прежде чем»), «прежний», хәз. әд. һәм иске әд. *әүвәлен, әүвәлән, әүвәлтен* «тәүләп, беренчеләй» һ.б. гар. *äwwäл-үн* «баш, тәүге, борынгы, әүвәлге» сүзеннән. Чув. *авал, авалхи, аваллăк* «әүвәл, әүвәлге, әүвәллек», удм. *валлё, валля, валлян* «әүвәлен, әүвәлән» < тат.

**Әүвәл** һәм аның дериватлары төрки телләрдә киң таралган. К. Räsänen 1969: 32; Федотов I: 24.

**ӘҮКАТЬ [әwқәт]** диал. «трапеза; богатый стол» < гар. *äwқāт* «вакытлар; иң вакыты» сүзеннән

(*вакыт* сүзенең күп. формасы). Күп кенә төрки телләрдә (нуг., каз., к.-калп., үзб. һ.б.) *авкат, әукать* «ашамлыклар, аш-су» мәгъ. кулланыла, к. ш. ук кырг. *ооқат* «азык-төлек; хуҗалык», башк. (БТДҺ: 429) *әуқат* «көч, хәл; дәүләт». Урта тат. әд. телендә *әукатьле* «вакытлы (хан, әмир, би), вазифа башкаручы» (титул), ягъни рус. «исполняющий обязанности»; диал. (ЗДС: 90) **әүхатле** «күрекле, хәлле, булдыклы». К. ш. ук **әүкатьле,** диал. (ЗДС: 64) **аукатлы** «мул тормышлы»; **әүкатьлән-ү** «вакытында ашау, ашауга тукталу».

**ӘҮКӘН** (Дмитриева 1981: 132; Тумашева 1992: 39), **әүгән** «большой; многочисленный (о группе, семье)», (ТТДС I: 55) **әуқан,** башк. (БТДҺ: 30, 429) *аукам, аукан* «уңайлы, ышык, аулак» ~ каз. *ауқан* «зур (төркем)», к.-калп. *аукам* «кабиләләр союзы; яшерен союз» < гар. *äқwāм* «кавемнәр». К. **Кавем.**

**ӘҮЛЕ, әүлә** диал. «сарай; чулан» (Тумашева 1961: 232), «ограда могилы» (ДС I: 253), «двор» (Арсланов 1988: 73), **awла** (ЗДС: 17) id. ~ каз. диал. *әүлә, аула,* үзб. *һавли,* төрки *avli, avlu,* грек. *αβλυ* «кәртә-кура, йорт». Бу сүз грек теленнән Бактрия (б.э.к. Урта Азиядә һәм Төньяк Әфганстанда хөкем сөргән грек дәүләте) заманнарыннан ук таралган.

Шул ук грек сүзе рус теленә *ул-* (***у**лица, пере**у**лок*) рәвешендә кергән.

**ӘҮЛИЯ [әwлийа]** «святой (человек)» < гар. *äwлийā* id. ← *wäлӣ* «вәли» сүзенең күп. формасы.

**ӘҮМӘКЛӘШ-Ү [әwмәкләш-]** «играть в кучамала» ← диал. **әүмәк.* К. **Әүмәл-ү.**

**ӘҮМӘЛ-Ү [әwмәл-]** «валиться». *Ау-у* сүзеннән булса кирәк (*ау-ма-л-* > *әүмәл-* һ.б.ш.); к. ш. ук башк. (БТДҺ: 429) *әүмәлә-ү* «әвәләү» һ.б.

**ӘҮРӘ-Ү [әwрә-], әүрәт-ү** «завлекать (дитя, больного)» > мар. *äÿргäш* id. (Гордеев I: 168–169); башк. (БТДҺ: 429, 430) *аура-у, әүрә-ү* «мавыгып китү» (диелә), *әүер-еү, әүрәлә-ү* «кызыксындыру, мавыктыру», к. ш. ук тат. диал. *әwи, әwе* (к. Арсланов 1992: 116) «балалар фольклорында капмакаршы җыр», к. ш. ук чув. *авăрт-* «җырлау», үзб. *овун-моқ* «юану», каз. < *ән,* диал. *әуен* «җыр», (Аманжолов: 438) «бишек җыры» ← **әб-* < бор. төрки **ab-* (бу фигыльнең кайт. һәм йөкл. юн. бар), к. **Әвет-ү.** К. **Абышка.**

**ӘҮСӘК [әwсәк],** диал. (ТТДС I: 550) **әсәк, әчәк** «плита; очаг» ~ башк. (БТДҺ: 227, 230) *әсәк, әшәк* «кечкенә мич, учак», чув. *ыс, ăвăс, евĕс* «түгәрәк капкач», *ăвсак* «плита», кырг. *өсөк* «тимер өчаяк» (Будагов I: 136) нининдидер *өс* тамырыннан.

**ӘФАРИН** «молодец; браво; отлично (как школьная отметка)» < фар. *äфāрин* id. (*афридан* «иҗат итү» фигыленнән); *äфāриннāмä* «мактау кәгазе».

**ӘФӘНДЕ** «господин; сударь» – төр. *efendi* «әфәнде» сүзеннән күп телләргә (башлыча мөселман халыкларга) таралган.

Төр. теленә бу сүз грек теленнән кергән: Рум грек. *afendi* < бор. грек. *αὐζεντίης* «үзе хуҗа; гаилә башлыгы» сүзеннән дип уйланыла (Zenker: 75; EI II: 687), ягъни *аутентик* сүзе белән бердәй; икенче бер версия буенча, румча *afendi* «Афинада укыган», «Афина философы» дигән сүз. Чаг. үзб., таҗ. *афанди* «мәҗнүн, хыялый; Хуҗа Насретдин». Тимергалин: 66.

**ӘФГЫЙ: әфгый елан** «сказочная змея, мудрая и хитрая» фар., гар. *äф'ӣ,* рус. *эфа* id.

**ӘФЛИСУН** «апельсин» – рус теленнән булса кирәк; рус сүзе исә голл. *appelsien* «Кытай алмасы» дигәннән.

**ӘФСАНӘ** «вымысел; миф; волшебная сказка» < фар. *äфсāнä* id. < бор. ир. *ali spāna* «сихер, сихерче»; шул ук чыганактан **әфсен** < фар. *äфсӯн* «сихер догасы».

Бу фар. сүзләре гар. үзләштерелеп, فسن «сүз белән сихерләү» дигән фигыльне, шуннан *фусӯн* «сихер догалары» сүзен китереп чыгарган (иске тат. телендә дә кулланылган).

**ӘФТӘР, эптәр** (ЗДС: 85, 90) «несобранный; сделанный кое-как» < гар. *äбтäр* id., түбәндә «ир баласы булмаган кеше».

Дерив.: **әфтәрлә-ү** «әштер-өштер генә эшләү, ясау».

**ӘФТИЯК [әфтийәк]** «одна седьмая (наиболее употребительные суры) Корана»; күч. «брошюра, книжка инструкций» < фар. *һäфт-ү-йäк* «җидедән бер (өлеш)» дигәннән.

**ӘФЬЮН [әфйун]** «опиум» < гар. < грек. *οπιον* «сут, үсемлек сөте» *οπο-ς* «сут» сүзенең кечерәй-

телгән формасы; грекча *опион*ны римлеләр *опиум* дип аңлаганнар. Шулай итеп, *әфьюн* бор. грек чыганагына якынрак, «дөресрәк». Грек. *оп-* нигезе ахыр чиктә рус. (> тат.) *сок* «сут» сүзе белән гомоген икән, к. Kluge: 668.

**ӘХВӘЛ [әхwәл]** «положение, ситуация; обстоятельства» < гар. *äхwäл* «хәлләр» сүзеннән, к. **Хәл.**

**ӘХЛАК [әхләк]** «нравы; нравственность» < гар. *äхлāķ* «холыклар» сүзеннән, к. **Холык.**

**ӘХТӘРИ** диал. «карты игральные; игра в карты» – яз. әд. *әхтәри* «сүзлек» < гар. *äхтäр, äхтäрӣ* «ачкыч; белешмәлек» сүзеннән. Элек рәсемнәр тик сүзлекләрдә генә булган. Мәгънә үсеше: *ачкыч > белешмәлек > рәсемле сүзлек > рәсем > кәрт.* К. «Әхтәри кәбир» элекке популяр зур гарәпчә-төркичә сүзлек.

**ӘҺАЛИ** кит. «население» < гар. *äһāлӣ* id. **Әһел** (к.) сүзенең күп. формасы.

**ӘҺЕЛ** «представитель (группы, коллектива)», **әһли** «гражданский», **әһлия** «полноправный член, домочадец; иждивенец», **әһлият** «дееспособность; вменяемость» < гар. *äһл* «нәселдәшләрнең берсе» сүзе һәм аның дериватлары. Фарсычарак *әһле* «иясе, классы, әһелләре» префиксонды ярдәмендә бик күп тезмә тәгъбирләр төзелгән, мәс., *әһле гыйлем* «гыйлем ияләре», *әһле китап* «китап әһелләре», ягъни христианнар яки яһүдиләр, *әһле сафа* «типтерүчеләр, сафа сөрүчеләр». К. Будагов I: 171; Özön: 192; Тимергалин: 171.

**ӘЧӘ, ичә, әчәй, әчи** диал. «бабушка со стороны матери», «золовка» ~ башк. *әсә, әсәй,* тат. диал. *әҗә, әҗәй* «ана, әни» (Арсланов 1988: 73), *әҗә, әҗи, аджа, аджыкай* «анакай» (м.-кар., к. Рамазанова 1991: 134–135) ~ үзб. *ача, әчә* «ана; дәвәни; кайнана» (ЎХШЛ: 328), кырг., ком. *әчив* «әтинең апасы», төркм. *әҗе, әзе//әзә* ~ бор. монг. *eǯei* «анакай», маньч. *aǯa* id. (ССТМЯ I: 16); кайбер телләрдә иkенчерәк мәгънәдә, к. бор. төрки (ДТС: 4, 16) *аčа* «өлкән кардәш», *еčа* «өлкән апа», *еčі* «өлкән абый», төр. диал. *есе [әҗә]* «абый яки апа; ханбикә; өлкән кеше» (Redhouse: 324), кырг. диал. *әче, әчи* «әби, дәвәни», хак. *іче* «ана» ~ тунг.-маньч. *эдӣ, эҗи* «гаилә башлыгы» һ.б. (ССТМЯ II: 437–438). Чаг. ш. ук **Әҗи.**

Түбәндәге линия игътибарга лаек: үзб. *әчә* «кыз», «уйнаштан бала табып, ата-анасы өендә яшәгән кыз» (ЎХШЛ: 361) ~ кыт. *ацао* «җиңги» > маньч. *аша, аца*, тунг. *асӣ* «хатын; җиңги; ире үлгән җиңги (аңа иренең кече туганнары өйләнгән)». Бор. төрки (ДТС: 16) *есі-ара* «җәтләр, элгәрләр, борынгы бабалар».

**ӘЧЕ I** «кислый», **әче-ү** «киснуть, закисать»: **ачы** һәм **ачы-у** сүзләренең палаталь вариантлары уйг. теленнән килсә кирәк: уйг. *эчи-* «әчү, ачу» (һәм аның күпсанлы дериватлары) фонетик закончалыклар белән аңлатыла, чув. телендә дә *йӳҫ* «әче», *йӳҫ-* «әчү». Федотов I: 207.

**ӘЧЕ II, әчел** «солончак» ~ башк. *әсе,* уйг. *эчи* id. ~ тат. диал. *ачы* id.; чув. *йӳҫ* «сазлык; тозлак; әче», *йӳҫ-* «әчү». К. **Ачы.** *Әче < ачы* (I–II) сүзләренең төрле мәгънәләре аларның төрле юллар белән килеп чыкканлыгына ишарә итә шикелле, к. каз. *әжі* < фар. *әҗә* «известь» (ҚТДС: 40; Будагов II: 121) < монг. **эҗи* id. К. түбәндәгене.

**ӘЧЕЛ** «кислота» – 1920 нче елларда тат. әд. телендә кулланылган, шуннан соң *кислота* сүзе белән алмаштырылган. К. түбәндәгене.

**ӘЧЕЛЕК** «сени; уборная, туалет (обычно в медресе)» ← диал. **әчел, әчлек, әчәлтек, әчелтек** «солончак; известковая земля» – **әче II** сүзеннән. Мәдрәсә һәм бәдрәф ишегалдына известь һәм ком җәю гадәтеннән. К. «Шура» 1910: 160–161 (еллык комплект пагинациясе). Тимергалин: 68 (*әчелек* «чистасыз» булган ди; бу сүз дөрес түгел).

**ӘЧЕМЛЕК, әцемлек** (Тумашева 1992: 38) «покрывало невесты на свадьбе» ← *ачымлык* «ачыла торган шәй» булса кирәк. К. **ачу > әчү** күп тат. сөйләшләрендә кулланыла торган вариантлар. Туйда **әчемлек** – «тантаналы рәвештә әзерләнеп, киленнең кунакларга йөзен күрсәтүе».

**ӘЧМУХА** «осьмуха, осьмушка – восьмая часть фунта» < рус. Төрки телләргә күптән кергән, к. кырг. *ашмушке* < рус. *осьмушка.*

**ӘЧТЕРХАН, Әстерхан** «Астрахань» – тат. яз. әд. телендә электән *Хаҗи тархан* дип язылган һәм аңлатылган, ләкин к. төр. *Astrakan, Astragan* һәм *Ejderhan* [*Әҗдәрхан*] – гүяки «аждаһалар шәһәре».

Бу топонимның бүтән аңлатмалары да юк түгел. К. **Әҗитархан.**

Идиоматика: **Әчтерхан бүреге** – колакчынсыз бүрек төре, «кубанка». **Әчтерхан чикләвеге.**

**ӘЧ-ТҮЧ** – слова приветствия (*Әч-түч, Бибкәй кыз* җырында) ~ бор. төрки (ДТС: 184) *eš-tuš* «дус-иш».

**ӘШӘ** – река Аша (в Челябинской области, откуда и название города Аша). К. себ. тат. *әшә* «шүре; камыш». Ихтимал, тәүдә **әшәле** «камышлы» булгандыр. Хәер бу топонимга бүтән этимоннар да бар.

**ӘШӘК < ашак** (ТТДС I: 58, 555) «низкий» < бор. төрки (ДТС: 62) *ašaq* «тау итәге». Тат. диал. *әшәк* тә шул мәгънәдәрәк кулланыла.

**ӘШӘКЕ** «отвратительный; мерзкий» > чув. (Сергеев 1968: 93) *эшеккĕ*, мар. *äшäкä, ашака*, удм. *ашак, ашаки* id. < фар. *x̣āшāкӣ* «әшәке, пычрак» ← *x̣āшāк* «чүп; йомычкалар».

**ӘШӘЛЧӘ** (ЛТ I: 44), **әшәлче,** (Н. Фәттах) **әчәлче** «зубровник, зверобой; ятрышник» ~ башк. *әшәлсә* «төнге миләүшә», *озон әшәлсә* «төертамыр, күке яше, сәхләб» (һ.б. үлән исемнәре составында килә), *әсәнче* (БҺҺ III: 227) «кияү үләне, чабыр үләне)» ~ удм. *ашальчи* «әшәлчә». Ачык түгел. *Әче әлче* сүзеннәнме?

**ӘШИНӘ** к. **Ашина.**

**ӘШКӘР** диал. «множество, толпа; войско» (Тумашева 1961: 233), «солдат; толковый» (Арсланов) ~ чув. *эшкер, эшкерĕ* «толпа, войско» – чаг. тат. диал. *әскәр* < *гаскәр* (*с* > *ш* күчеше монда нуг.-каз. *ш* > *с* авазын «кайтарып» *ш*ылаштыру нигезендә килеп чыккан булса кирәк).

**ӘШКӘР-Ү** «подсказывать» к. **Әшкәрт-ү.**

**ӘШКӘРӘ (әшкярә): әшкәрә булу** «стать становиться явным, явственным; выявляться» < фар. *āшик'āрā* «ачык, анык, күренеп» (күп кенә төрки телләрдә бар) < бор. фар. *avis kara* «ачык итү»: *avis* «ачыклык, өн» ~ рус. *явь* белән бердәй; *kara* «кылу, итү» > тат. **кяр** (к.). Тимергалин: 69.

**ӘШКӘРТ-Ү** «известить, оповещать, надоумить» < *әшкәрә ит-ү* тезмәсеннән булса кирәк; бу сүз уйг. телендә килеп чыккан, к. уйг. *әшкәрт-,* кырг. *ашкарт-* «әшкәрә итү». Тат. *әшкәр-ү* (халык этимологиясе нигезендә) *әшкәрт-ү*дән.

**ӘШНӘ** «приятель; дружок (нехороший)» < фар. *āшнā, āшинā* «дус, ирзатның хатын-кыз дусты» (җенси мөнәсәбәтләргә бинисбәтән). Күп төрки әд. телләрдә кулланыла.

**ӘШЬЯ [әшйа]** «изделие; вещь» < гар. *äшйā* «әйберләр» – **шәй** (к.) сүзенең күп. формасы.

# Б

**Б** тат. телендә бор. төрки *б* авазыннан килә; кайбер очракларда бор. *м* авазын алмаштыра (*барамыз* > *барабыз* һәм тат. теле бу җәһәттән чув. теле белән бер группада).

**БА** – междометие удивления – типологик характерда: рус., фар. һ.б. *ба, аба* id. К. **Абау.**

**БАБ** «глава, раздел книги; тема разговора; порода глагола в арабской грамматике» < гар. *bāb* id., төп. мәгъ. «капка, юл, юнәлеш» (ЛТ I: 79). К. **Бап.**

**БАБА,** себ. (Тумашева 1992: 166) **паба** «предок; дед; мужчина (любой) старше отца» (вообще это слово в татарском языке в разных пластах лексики и в разных говорах имеет очень разнообразные значения, к. Рамазанова 1991: 29–35) < гом. кыпч., уйг., алт. диал. *баба* id. (ком. телендә юк – бу хәл субстрат тәэсиреннән булса кирәк), угыз. *баба* < бор. төрки (ДТС: 76) *baba* «ата» һ.б. – көнб. төрки телләргә хас. Чув. һәм тув. теркәлмәгән, як. *баабый* «көчле» *бабай* сүзеннән булырга мөмкин ~ барча тел семьялыкларында очрый торган «бәбиләр теле» сүзләреннән, чаг. гар. *баба* «әти» (ихтимал, төрекчәдәндер); һинд-евр. *baba* «ата; баба» ~ груз. (Климов: 47, 152) *вавиа, ваба* «ата» һ.б. Будагов I: 217; ЎХШЛ: 334; ЭСТЯ II: 10–12; Фасмер II: 200 (рус. *папа* тур.).

Дерив.: **бабалы, бабалык.** К. **Бабай, Бабакай, Бабакош.**

**БАБАЙ** «дед» («мужчина старше отца», значение «родной дед» навеяно влиянием русского языка), исконное значение «отец жены, тесть» – *баба* сүзенең вокативя формасы > мар., удм. *бабай,* мар. *павай,* чув. *папай* «бабай, бабакай» (ләкин удм. *бубы* «ата», *буба* «дәвәти, бабай» татарчадан түгел, төп фин-угор сүзе) id., рус. *бабай* «татар карты; куркылык» (к. Аникин: 104–105) < гом. кыпч. *бабай* ~ бур. *баабай* «бабай; әти; әтинең абыйсы». Бурятларда һәм кайбер бүтән монг. халыкларында **бабай** (*Буха нойон бабай* «буга – үгезбозау нуян бабай», чаг. тат. әкиятләрендә **Бозаубаш батыр**) – мифологемалар герое. Дөньяның кайбер бүтән телләрендә дә *вавай, бабай* һ.б. төрле дини һәм әкиятизатларны белдерә. Шуңа күрә **бабай** сүзен **баба** нигезенең вокативы дип кенә аңлату кяфи түгел. Чаг. бор. скиф. (Граков Б.Н. Скифы. М., 1971: 81–82) *папай* «күк һәм күгерт (күкрәү) тәңресе». Тимергалин: 70.

**БАБАКАЙ** «(дорогой) тесть», «дедуля» – *баба* сүзеннән дә, *бабай* сүзеннән дә ясала торган сүз.

**БАБАКОШ** «пеликан» < төр. *babakuş* id. ← *baba* «зур, дәү» сүзеннән, чаг. чув. *папакайӑк* (*кайӑк* «кош») «дүдәк».

**БАБАЛАШ** (ТТДС I: 62; БТДҺ: 33) «сыч» < *бабырбаш* «каплан башлы», к. кырг. *бабырган* «бабалаш», хак. *пабырган* «очкалак тиен».

**БАБАСЫР** «геморрой; глиста, острица» > мар. *бабасыр, павасыр* id., удм. *бабасыр* «явыз рух; бабасыр» ~ ком. *бабасур,* төркм. *бабасыл,* үзб. *бобосил* һ.б. < гар. *bäwāсӣр* (*bāсӯр* «күтән чыгу; шеш; оры» сүзенең күп. формасы). «Бүсер рухын» бик ямьсез талпансыман хайван итеп күзаллаганнар. К. **Бүсер.**

Дерив.: **бабасырла-у; бабасыр уты** – үлән.

**БАБҮЛ** «бобыль, безземельный крестьянин-поденщик; беглец из центральных губерний в Приуралье (с XVI века)» < гар. *bābӯл, bābӣл* «Бабил (Вавилон); гөнаһ, азгынлык», фар. *bābōлӣ* «Бабилле; фахиш, азгын (ир)», аз. (Будагов I: 218) *бабүл* «гөнаһ», «сутенёр», *бабүллик* «сутенёрлык», *бабүлханә* «фәхешханә» ~ төр. (Redhouse: 115) *babulhâne* id. Гарәпләр Бабилне азгынлык шәһәре дип белгәннәр.

Русчага *бобыль* сүзе, бу сүзнең таралыш ареалына караганда, татарчадан кергән булса кирәк. Башк. (БТДҺ: 33) *бабүр йеңгә* «яшь кияү белән кызны женси тормышка өйрәтүче җиңгә» < *бабүл җиңгә* (ул җиңгә тол хатын булган һәм төрки халыкларда еш кына үзе башлап кияү егет белән кушылып күрсәткән). Рус. *бобыль* тур. Даль сүзлегендә күп материал бар. К. ш. ук Рамазанова Д.Б. Некоторые материалы о бобылях Башкирии // Исследования по историографии Татарстана. Казань, 1978: 140–148; Рамазанова Д.Б. К вопросу о бобылях Башкирии // Вопросы татарской диалектологии. Казань, 2008: 130–138.

**БАБҮНӘ** «вид ромашки» (ЛТ: 79) ~ үзб. *бобуна, бабун* «бабунә, туфли» гар. телендә фар. алынмасы *бабуш* < *папуш* «туфли, чирбек» сүзе (шуңа охшаш чәчәк) нигезендә килеп чыккан.

**БАВЫР [ба$^{о}$wы̆р]** «печень; сердце; живот, грудь» < гом. кыпч. *бawыр* (кырг. *боор*, алт. диал. *буур*) < бор. төрки (ДТС: 78) *bayïr* «бавыр, корсак; канкардәш», чув. *пӗвер, пӑвыр,* тув. *баар* > хак. *паар,* як. *быар* «бавыр; матча, урталык һ.б.» (Пекарский I: 600); бор. *bayïr* «бавыр; бакыр» мәгънәләреннән чыгып, «бавыр» мәгънәсе «бакыр, бакыр төсендәге орган» сүзеннән дип уйлыйлар (Н.А. Баскаков), к. **Бакыр, Бәгырь.**

*Бавыр* сүзенең кайбер дериватлары этимологик аңлатмага мохтаҗ: *бавыр агачы* – бу агач деталь тукучының бавыр турысында торуыннан булса кирәк; *бавырга керү «*йөрәккә, үзәккә, күңелгә керү»; *бавырлы* «шәфкатьле» – *бавыр*ның «йөрәк» мәгънәсеннән. К. **Бавыргалык, Бавырсак, Бавырчы.** ЭСТЯ II: 17–20 (*бөер* < *бөгүр* белән дә чагыштырыла). Чув. *пӗвер* тур. к. Федотов I: 417–418.

**БАВЫРГАЛЫК [ба$^{о}$wы̆рғалы̆қ]** «подбрюшник; подпруга; чересседельник» > мар., удм. *баургалык* id. *бавыр* сүзенең «күкрәк асты, корсак» мәгънәсеннән: *бавыр-га-лык.* Тат. телендә ясалган булса кирәк.

**БАВЫРСАК [ба$^{о}$wы̆рсақ]** «баурсак, кусочки теста, жаренные в масле» < каз., к.-калп. *бawырсақ,* кырг. *боорсақ,* уйг. *бағырсақ,* үзб. *боғурсақ, буғурсақ* id., шул ук вакытта ком., кар. *бawурсақ* < төр., аз. *бағырсақ* < төр. «эчәк, үпкә-бавыр», бор. төрки *bayarsuq, bayïrsuq* id. < *бағыр-сақ* парлы сүзеннән (*бағыр* «бавыр», *сақ* «эчәкләр», к. тат. *бук-сак*), чаг. чув. *пырша* «эчәкләр» < **бawырса* << **бағырсак* (Егоров: 173). *Бавырсак* << *багырсак* сүзен *багырса-қ* «бавырга охшаш» дип тә аңлаталар. ЭСТЯ II: 22–24; Федотов I: 466.

**БАВЫРЧЫ [ба$^{о}$wы̆рчы̆]** тар. «повар, дегустатор»; иске әд. әсәрләрдә очрый торган бу сүз *бавыр* сүзеннән русча *повар* тәэсирендә ясалмадымы икән, дигән сорау туа, чөнки *бавырчы* тәүләп кыпч. сүзлекләрендә искә алына. К. рус. *повар* (бу сүз *вар* «кайнаган нәрсә» сүзеннән дип карала, ләкин ясалышы табышмаклы) > тат. *пýвар* «ашчы». К. ш. ук үзб. (ЎХШЛ: 215) *повурхона* «ашханә». Чаг. ш. ук тат. диал. (ЗДС: 515) *пawар* «учак, калау», сугд. *puwar* «ут» ~ ним. *Feuer* id. Тимергалин: 72.

**БАГ I** «сад (фруктовый; для развлечений); парк» < чыгт. < фар. *бāғ* id. Бор. төрки (ДТС: 77) *bay* «бакча» сугд теленнән дип күрсәтелә. Баг сүзе тат. поэтик телдә кулланыла: *баг алмасы* → *багалма* «чибәр кыз» һ.б.ш. К. **Багбан, Бакча.** Будагов I: 233 (тәфсилле); Dobr. I: 238.

**БАГ II** иск. «узы, оковы, путы» (1905 нче елгы революциядән соң тат. газеталары *бағлар өзелде* дип язганнар) < бор. төрки (ДТС: 76, 77) *bay, bāy* «баг; битлек; бәйләвеч» ← *bā-, ba-* «баглау; бәйләү, каплау». *Баг* сүзе үзе дә, аның фонетик модификацияләре **бау, бай > бәй** дә күп кенә дериватлар биргәннәр. **Баґ** үзгәрешсез диярлек уйг., чыгт., угыз., тув. һәм иске монг. телләрендә, **паґ** иске себ. тат., алт. диал., хак. кулланыла. *Баг* һ.б. күрше телләргә, ш. ук рус сөйләшләренә дә (к. Аникин: 105–106) үтеп кергән. К. **Багдаш, Багла-у, Баглы, Бәй.** Будагов I: 231–232; ЭСТЯ II: 13–17; Тимергалин: 72.

**БАГА** древний термин государственности (ДТС: 77) → тат. *илче бага* «посол, парламентёр». Төрки телләрдә бор. заманнардан бирле илнең, кавемнең, кабиләнең, дәүләтнең баш идеологы, рухание *бага, баган* дип аталган; *алып* «оештыручы» булса, *бага* «рухландыручы» булган. Хәзер бу сүз сүзлекләргә дә сирәк кертелә һәм тик фольклор әсәрләренең иске язмаларында гына очрый (хәер, кайбер белдеклерәк шагыйрьләр аны кулланалар инде). *Бага* сүзенең пассивлашуы ислам идеологларының мәҗүсиләрне кысрыклавы белән баглы.

Бор. төрки (руник) язмаларда *бага-таркан, бага-тәңрикән* титулы еш очрый. *Бага*лар еш кына халыкара мөнәсәбәтләр, илчелек, килештерү белән шөгыльләнгәннәр (татар-башкортта билгеле булган *Илче-бага* көе һәм риваятьләре дошманга ышанып башын салган *бага*ның фаҗигале язмышын сурәтли). Бор. аварларда һәм Азак (Азов) болгарларында *баган* күбрәк дөньяви оештыру эшләре белән шөгыльләнгән һәм шул *баган* сүзенең истәлеге булып Балкан славяннарында һәм мадьяр телендәге *бан* «кенәз» сүзе калган (Donuk: 4). Пол., укр. *пан* «әфәнде» сүзе дә шуннан булса кирәк. IX г. Дунай болгарларында *bayain* «генерал».

Фарсы тарихчылары Гәрдизи (XI г.) һәм Мәрвәзи (XII г.) сүзләренә караганда, төркиләрдә рухани *фагинун* (гарәп авторлары, үз телләрендә *п* авазы булмагач, аны *ф* белән алмаштырганнар, димәк, асылда *пагынын*) дип аталган; ул фагинуннарга наркотик ашатканнар һәм аларга исерек хәллә-

рендә төрле сораулар биргәннәр. Аларның үзләрен белештермәстән әйткән сүзләре тәңредән килә дип уйланылган. Соңрак ул *пагын*нарны нәүрузбикә алмаштырган.

Төрки коллар һәм алар яшәгән авыл бор. фар. *паг* һәм *паган* дип аталган. Бор. фар. теленнән бу сүзләр лат. теленә «мәҗүси» мәгънәсендә кергән һәм шуннан рус. *поганый* «мәҗүси» сүзе килә (к. Симашко М. Маздак. М., 1984: 28).

*Бага* сүзен сугд яз. телендә *бг* (сузыклары билгеле түгел) һәм бор. фар. сүзлекләрендәге *фаг* «матурлап бизәлгән пот, санәм; гүзәл кыз, нәүрузбикә» сүзе белән (к. **Баган**) чагыштыралар. Борынгы ир. (фарсыдан элекке) телләрдәге *бага* – Аһура-мәзда, һинди тәңре (шуннан русча *бог*) сүзе дә хәтергә алына. Икенче яктан *бага, баган* гом. төрки *батыр* < *багатур, бакмак (багу)* һәм *багана* сүзләре вә хәтта *бака* (ташбака – күктөркиләрдә «мәңгелек» символы) белән чагыштырыла. Чын дөресен инде – валлаһе әгъләм! К. ш. ук **Баган.**

**БАГАВЫЛ [баᵒғаwы̆л]** «опекун» ← *бақ-* (к. **Бак-у**), к. үзб. *бақовул* «сарайда тәртип саклаучы; багавыл», (ЎХШЛ: 41) *бақавул* «ашчы (дегустатор)». Рус. *бегеул* «пристав» < чыгт. *бäгäул* id. сүзе (Фасмер I: 142) бүтән сүз – ул *бәк-* «көтү, карап тору» тамырыннан.

**БАГАН I,** себ. (Тумашева 1992: 166) **паған,** диал., башк. «столб для влезания во сремя сабантуя; столб – центральная опора примитивного дома (с плоской крышей и т.п.)» ~ каз. *баған*, алт. диал. *баккан, паккан,* як. (ДСЯЯ: 57) *бағах* «ат бәйләү баганасы» (якут сабантуенда – *ысыахта*), тув. *маган* «түшәмнең урта баганасы» ~ эвен. (ССТМЯ I: 68) *бақса* id. Рус сөйләшләрендә: *баган* «рух – терлекләр химаячесе» (Даль), «ат һәм сыерларның хәрәкәтен чикләү өчен аякларына бәйләнгән такта яисә чош, кәртәлек» (к. СРНГ II: 32, Аникин: 106) һ.б. – төрки телләрдән. К. ш. ук үзб. уйг. (ЎХШЛ: 42) *бакан* «багана, терәк».

Булган материалдан, ш. ук түбәндәге *багана* сүзе мәгънәләреннән күренгәнчә, *баган* «урта багана»ны белдергән һәм, ихтимал, (ат рухына) табыну объекты булган (аңа корбанлык тиреләр асылган, к. Пекарский 326, 329). Сүзнең тамыры **баг, бақ,* к. бор. фар. (Очерки истории культуры Средневекового Ирана: 221–222) *фаг* «агачтан юнылган санәм» → *фаган* «потханә» (һәр ике сүз Фирганә өлкәсендә кулланыла диелгән), к. ш. ук **Бага.** Чаг. бор. төрки (КБ) *пагана, багна* «арата».

Э.В. Севортян (ЭСТЯ I: 42–43) бу сүзләрнең этимологиясе ачык түгеллеген таный. Ахметьянов 1989: 103–104.

**БАГАН II, бақан** «надкопытный сустав», иск. **бағанчак** id. (к. Ногман 1969: 90), диал. *бағанчак* «койка, дерелдек» > чув. *пакалчак* id., *пакалчамас* «киң тояклы (ат)» һ.б. ~ гом. төрки сүз. К. **Бакай, Бәкәл.**

**БАГАНА** «столб; кол», гом. төрки, гом. монг. *бағана*, алт. *бакана*, *пағана*, як. *мағана* id. Бор. төрки (ДТС: 78) *baγna,* уйг. *пағана*, үзб. *поғона* «арата» *багана* сүзенә баглы бугай. Чаг. алт. диал. *паххан* «багана кагу», *пагана* «шаман төңгерендә агач сурәте». Күп күрше телләргә кергән, к. **Баган I.**

Дерив.: **баганалы, баганасыз; баганала-у** һ.б. *Баганалы юл* рус. *столбовая дорога* (тракт) сүзеннән калька. Махсус әдәбиятта (биологиядә) **баганачык** – рус. *столбик* сүзеннән калька. **Баганалык** «баганага ярарлык».

**БАГАНАЙ** «дылда, оглобля (долговязый человек)» – **багана** сүзеннән, әлбәттә. Ихтимал, рус. диал. *багань́* «борчак киптерү өчен араталы багана» сүзеннән кире алынмадыр. Элегрәк **Кәтүк белән Баганай** – ике эстрада артисты парлашып чыгыш ясыйлар иде.

**БАГБАН** иск., шигъ. «садовник; меценат; заботливый критик» (*мәдәният багбаннары* диелгән) < фар. *бāғбāн* id., сүзмә-сүз «баг (бакча) караучы». К. **Баг I.**

**БАГБОСТАН** «сад с цветами» < фар. *бāғ-у-бустāн* «баг һәм чәчәклек». К. ш. ук **багстан** «бакчалык» < фар. *бāғстāн* id.

**БАГДАТ –** неофициальное название отдалённых населенных пунктов в Башкортостане, тар. геогр. **Багдат** «Багдад» (*Алла биек, Багдат ерак* мәкалендә очрый). **Багдад** топонимын фар. *бāғи Дад* «Дад дигән кешенең багы, бакчасы» дип аңлаталар.

Дерив.: **багдади** «затлы», **бағдидин** «бик зиннәтле (өй, бүлмә, мебель тур.)», шуннан рус. < Европа телләрендә **балдахин** «караватөстенә куела торган бик зиннәтле чаршау». К. Kluge: 84.

**БАГДАШ,** себ. (Тумашева 1992: 166) **пағдаш** – способ сидения с перекрещенными ногами, добр.

(Dobr. II: 439) *mandaş* (< *maŋdaş*): *mandaş qurtaq* id. ← төр. *bagda-,* бор. төрки (ДТС: 77) *baγda-, badγa* «аяк чалу (төп һәм күч. мәгъ.), аяк чатмаштыру». **Багдаш** (исем) белән беррәттән кр.-тат., төр. *bağdaş-* «катнашу, кушылу» фигыле дә актив кулланыла. Сәер сүзләр. К. ЭСТЯ VII: 22–25 (бик күп параллельләр күрсәтелә). Бәлки бор. алынма нигездәндер («Будда кебек утыру»мы?). Морфологик җәһәттән **багыт* «бәйләм» (*багыт-а-ш*) булырга мөмкин.

**БАГЛА-У** «связать (надежды и т.п.)» < чыгт. *багла-* id. бор. төрки *baγ* «бәйләм; бау» сүзеннән, к. **Бау, Бәй, Бәйлә-ү.**

Дерив.: **баглан-у, багланыш** (аларны *бәйләнү, бәйләнеш* сүзләре белән алмаштыру – мәдәниятсезлек!), **баглат-у, баглаш-у** һ.б.

**БАГЛЫ** «связано (с чем)», иск. «несвободный; угнетённый; подавленный» (*баглы күңел* «подавленная переживаниями душа») – электән үк гом. төрки *баглы, баглыг* шул (к. ДТС: 79) абстракт мәгъ. кулланылган. К. **Баг II.**

Дериватларыннан **баглылык** актив кулланыла.

**БАГРЫ** «вид форели» к. **Пәкрә.**

**БАГРЫЙ** (Н. Исәнбәт; ТХИ: Табышмаклар 1997: 135) «медный, цвета меди» < иске фар. *багрый* id. (*багыр* «бакыр» сүзеннән) >> иске рус. *багръ* «порфира; бакыр төс, бакыр төстәге буяу» (K. Menges. Schwierige slavisch-orientalische Lehnbeziehung: *багрь* «порфира» < төрки *bagïr* // UAJ H. 1–2. 1957), шуннан рус. *багряный, багровый.* К. авар. (Дагстан) *баһар* «багрый; туры (ат төсе)». К. **Бакра, Бакыр.**

**БАГУ** «гадание; ворожба» к. **Бак-у.**

**БАГЫ** «рычаг, противовес» > мар. диал. *багы* id. < рус. *ва́га* < ним. *Wagge.*

**БАГЫН-У** «преклоняться, смотреть с любовью», диал. «озираться» – *бак-* сүзенең кайт. юн.

**БАГЫШ** иск. «преподношение» ~ кар., каз. *багыш* id. < фар. *бӑх̮ш* «бүләк бирү» < авест. *baxš* «өлеш кертү» *baγa* «өлеш» тамырыннан (к. **Бага**). Бу тамырдан < госм., чыгт. *багышла-у* «кемгәдер атау», *багышлы* «бүләк бирүче; өлешле» сүзләре ясалган; к. ягн. *baxš, baxšak* «бүләк итү; ярлыкау, кичерү» (ягъни «мәрхәмәт бүләк итү») (ЯТ: 230). К. ш. ук диал. (ТТДС I: 63) *багышла-у* «охшату; дип карар итү», *багышлы* «охшаш». К. **Бәхшеш.**

**БАДАН** «бадан, растение с крупным корнеплодом» ~ рус. *баданъ* (Будагов I: 222). Фар.-таҗ. даирәсеннән булса кирәк.

**БАДӘМ** «миндаль» < фар. *бāдäм* id.

**БАДРАК, бәдрәк** (Әхмәтҗанов М. 2009: 83–94), **бәзрәк** (< башк. *бәҙрәк*) – название ряда сёл в Татарстане, Башкортостане и сопредельных областях – Казан ханлыгында да актив роль уйнаган нугай кабиләсе исеменнән. Ул кабилә атаклы канлы (к.) халкының бер (төп) өлеше булган, имеш. Сүзнең этимологиясе томанлы. каз. *бидрақ* «акайкүз» очраклы охшашлык булса кирәк. К. **Батрак.**

**БАДРАН** «декоративное растение с крупными желтовато-белыми цветами» < фар. (< гар.) *бадыран* «тулган айлар (кебек)»; гар. *бäдр* «тулган ай» (тат. исемнәрендә *бәдер-, бәдри*), *бадир* «тулган ай кебек (кызлар һәм хөкемдарларга комплемент); цитрус». Чаг. рус. *бадрян, бадрянка* (Даль) «эре лимон». К. ш. ук **Гөлбадран, Бадымҗан.**

**БАДЫМҖАН, бадылҗан** «баклажан» < фар. *бадриңҗан* < *бадриңи җан* «зур кыяр» (*бадриң, бадрäң* «кыяр; цитруслар» – «ай сыман җимешләр»). Чаг. ш. ук к.-балк. *бадражан* «помидор», чаг. **Бадран.**

**БАДЫЯ [баᵒдыйа]** «бадья, деревянное ведро (колодца)», диал. (ЗДС: 108) **бәйдән** id., (ДС III: 43) **бадыян//мадиян** «агач тустаган» > мар. *пайдан, падиа* «агач тустаган; бадыя», удм. *бадьян* «агач табак, шава; әнис үләне; песи үләне», чув. *патьен* «бадыя» – барысы да кызгылт төстәге бер агач һәм бер үлән – *бадыян* (фар.) исеменнән; к. ш. ук **бадиян** «аш тәмләткеч хуш исле состав – бәлки, әнис үләненнән ясаладыр», төркм. *бадыйа* «табак», *бадыян* «чиләк». Рус. *бадья* һәм *бадьян* (үлән) икесе дә < тат. (Фасмер I: 104, Аникин: 107–108).

Шунысы кызык ки, якут сөйләшләрендә дә *бадыйан* «усакка охшашлы бер агач» (ДСЯЯ: 57) – анда да тат. теленнән түгелме икән? Бадиян агачы һәм бадыян үләне элек татарларда бик популяр булган – изге саналган, алар турында халык җырларында искә алына.

**БАЕК [баºйык]** «определённый, определённо; верный, наверняка» ~ уйг., тәр., бор. төрки (ИМ, МК, ДТС: 79) *bajiq* «баек; дөрес»; төркм. *баайың* (Мухамедова 1973: 64) «билгеле, ышанычлы, дөрес, туры», аз. *payıg* «билгеләнгән» – бор. гом. төрки *бай//пай* «өлеш» сүзеннән (к. Вәлиди II: 394), чаг. чув. *пайӑр* «үз өлешең; баек, анык, билгеле» < тат. **байыр*, к. нуг. *байыр* «үз өлешең», каз., к.-калп., кырг. *байыр* «асаба җир, гадәтләнгән яшәү урыны, үз илең» һ.б. Чаг. аз. *pay* «түләк; өлеш».

**Баек** дип бик яшьли (кайчакта бишектән үк) ярәшелгән егет яисә кәләшне дә атаганнар: «Баек» башкорт халык бию көе шуннан булса кирәк. Ләкин башк. *байык*, топоним һәм этноним буларак, «билгеләнгән җир өлеше, биләмә» булырга тиеш, к. тат., башк. *байыкла-у* «билгеләү, тәгаенләү». К. **Байка-у.**

**БАЕК-У (баекты, баегу)** «разбогатеть; обогатиться» – *байы-у* фигыленең интенсивлык формасы.

**БАЕЛТЫ [баºйылты]** иск. «эйфория, увеселение для поднятия духа»; «позиция перед боем» < монг. < уйг. **байыл-ты* «тукталыш урыны», **байыл-* «килеп тукталу, позиция алу», к. кр.-тат., тәр. *bayıl-* «төрле сәбәптән (ачлыктан да, шатлыктан да) гамьсезләнү; һуштан язу», үзб. *пайт* «кирәкле, билгеле вакыт < **баелты*», *пойламоқ* < *байыллама*қ «сагалау, көтеп тору, саклау». К. **Бай II.**

**БАЕРАК [баºйырак], байрак** (ЗДС: 96) «буерак, холмисто-овражистая местность» ~ рус. *баерак, буерак* (бик күп вариантлар) id. төрки теләрдән, к. кр.-тат., тәр. *bayır* «калкулык». Аникин: 138; Dobr. I: 283 (тәфсилле).

**БАЕРКА [баºйырка]** «прядь, пук, клок шерсти» ~ чув. *пайӑрка*, мар. *пайыр*, *пайырка*, *парга*, үзб. диал. *байырқа* id. Räsänen 1969: 378; Федотов I: 378.

Тат. һ.б. **байырка** рус. *поярок* «язгы йон» сүзеннән дигән фараз бар. Безнеңчә, бу фараз өстәмә дәлил сорый.

**БАҖ** «пошлина, акциз» < фар. *бāҗ*; күп төрки әд. телләрдә очрый.

**БАҖА,** диал. **баҗай, баз'а, баца, бази, пача, паца** (ДС I: 27; ТТДС II: 64; Тумашева 1992: 170) «свояк» > мар. (Гордеев I: 185) *базьа, байза, вайзя,* удм. *базя,* морд. М. *базя, базяй (< баҗай) <* гом. төрки *баҗа* (башк., нуг., каз., к.-калп. *бажа*) id. ~ монг. *баджа, база* id. Бу сүзнең угыз вариантлары – чув. *пуҫчана* < *посчана* < мар. *посана* < *пасана* < болг. **баҗана* > удм. *бусено* << аз., госм., чыгт. *баҗанақ, баҗынақ,* бор. төрки *пачынак* > көрд. *баджаных* id. Баҗа сүзе тәүдә ирләргә түгел, хатын-кызларга караган (ягъни *абсын* мәгъ. булган), к. шор. *пäҗä,* як. *бадьа* «баҗа; җиян (туганнан туганның) хатыны», госм., кр.-тат., аз. *баҗы* < бур. *абаҗы* «күпхатынлы ирнең өлкән хатыны» һ.б. < бор. төрки *ара-аča* «олы һәм кече хатыннар» (кушма сүз), к. **Апа, Әчә.** *Баҗанак* вариантына килгәндә, ул безнең этимологияне раслый: *-нак, -анак* кушымчасы төрки телләрдә «күп беришле нәрсәләрнең бер данәсе» мәгънәсен бирә, ягъни «баҗаның (туплам мәгъ.) *берсе*» дигән сүз, чаг. тат. диал. *печәнәк* < *печәннәк* «печәндәге бер үлән», *күзәнәк* «кәрәздәге «күзләрнең» берсе» һ.б. К. **Бәҗәнәк.**

Ихтимал, **баҗа** сүзенең формалашуына һинд. *bhaiya* «карендәш, кастадаш, баҗа» сүзенең дә (Platts I: 181, 198) тәэсире булгандыр (к. чыгт. *paja* «кияү», Радлов IV: 1138).

К. Покровская: 66–67; Räsänen 1969: 54; ЭСТЯ I: 24–25; Рамазанова 1991: 122–141 (безнең этимология берсендә дә юк); Федотов I: 453 (гади чагыштыру белән чикләнә).

**БАҖАНАК** «печенег» к. **Баҗа, Бәҗәнәк.**

**БАЗ I** «искусственная яма; подполье; шахта» – гом. кыпч. характерындагы сүз: нуг., кар. *баз* id. > рус. (Кавказ алды һәм Җаек казакларында) *баз, базок, базкá* «абзар, кура», калм. *баз, бас* «көпкә (зимләнке)», к.-балк. *базама* id. ~ чув. *пос, посӑ, пусӑ* «мөгрәп; кое».

Бу сүзнең фигыль коррелянты *баз-* «казу» **басу** (к.) сүзендә чагыла, к. ш. ук бор. төрки (ДТС: 81) *bazγan* «ерынты, чокыр». Räsänen 1969: 55; Федотов I: 451; Аникин: 108 (бу әсәрләрдә мәгълүматлар тулы түгел).

Дерив.: **базлавык; базлы, базлык.**

**БАЗ II** «богатырский спор, похвальба, вызов на поединок». Тат. телендә һәм күп кенә шивәләрендә халыкара мөнәсәбәтләр этикасын чагылдыра торган бер гаҗәеп сүз бар – **баз** «үз кабиләсе-иле исеменнән бергә-бер көрәшкә чыккан батырлар бәхәсе». *Ялгыз сөйләп баз булмас; Атасы баз сөйләгәнгә углы кан кояр; Бәхел (үчле) уңмас, баз уңар* кебек мәкальләр, к.-балк., нуг., ком. һәм башка Төньяк Кавказ (абаз., чирк.) телләрендәге

*баз* «бәхәс, пари, ядәч», кар., кр.-тат. *баз* «ярашукилешү», *баз бәрмәк* – «баз бирмәк», «сәлам бирмәк», бор. яз. ядкәрләрдәге *баз* «буйсынган дошман», *баз кылмак* «дошманны тынычлык сакларга мәҗбүр итмәк», *ят-баз* «чит ил кешесе» һ.б. бу сүзнең бик бор. булуын сөйлиләр (к. ДТС: 89).

**Баз** сүзенең фигыль мәгънәсе тат.-башк., к.-балк. һ.б. телләрдәге *базмак, базынмак* «җөрьәт итмәк» сүзендә чагыла. Шул ук нигездән гом. кыпч. *базык* «баһадир гәүдәле, киң, ныкча, төптән юан» сүзе, тат.-башк. телләрендәге *базнат* «батырчылык, кыюлык» кәлимәсе дә ясалган булса кирәк.

Кар. *базла-мак* «тәбрикләмәк», башк. *базлау* «ерактан кычкырып килү; кыяфәте белән ялтырау», кырг. *баз (бас) килү* «тиң килү», алт. *базыш-, пазыш-* «кызышу – батырлар көрәш алдыннан мактанышу һ.б.» да бу тамырга карыйлар. К. ш. ук нуг., тат. (Арсланов 1992: 117) *базлас-у* < *базлаш-у* «отышка бәхәсләшү» >> рус. *базанить, базланить, базлать* (Даль) «кычкырып, сүгенеп бәхәсләшү».

**Баз** сүзенең мәгънәләре, аннан ясалган сүзләр, мәкаль-әйтемнәр дошман белән сөйләшкәндә әйтер сүзеңне бик уйлап әйтүне, аның белән кыю, әмма гадел булуны таләп итәләр. Räsänen 1969: 66 (тулы мәгълүматы юк).

**БАЗАР** «базар, рынок» < фар. *bāzār* < бор. фар. *abāzar* «ашамлык күп урын» (Platts I: 121); икенче версия – *bahzar* «яшелчә сату урыны» сүзеннән. Бу сүз бөтен дөньяга таралган. *-зар* «урын, ни дә булса җыелган җир» мәгъ. кушымча тат. теленә *-сар*// *-сәр* яңгырашында кергән. Тимергалин: 73.

Дерив.: **базарчы, базарчылык; базарлан-у.**

**БАЗАРКЯН, бәзәргән** «ханский купец, водитель караванов» < фар. *bāzārг'āн* < *bāzārг'āһāн* id. Төрки-тат. фольклорында еш очрый торган сүз. Төр. *bezirgân* «яһүди сәүдәгәр».

**БАЗНА,** (Тумашева 1992: 46) **басна,** сөйл., **базнат** «осмеление; дерзость» ~ нуг., каз., к.-калп. *базна,* башк. *баҙнат* «нахаллык» *базын-у* (к. **Баз-у**) сүзеннән ясалган булса кирәк, тик ясалышы ачык түгел.

Дерив.: **базналык** «әрсез, битсез» (Ногман), «ышаныч» (ДС II: 48).

**БАЗУ I** «нахальный, дерзкий» – **баз-у** фигыленнән сыйфатлашкан булса кирәк. Ләкин бор. **базыг* формасыннан да килә ала.

**БАЗУ II** (ЛТ I: 80) «предплечье» – кулның беләзектән югары өлеше < иске фар. *bāzu* «көчле кул(лы), киң җилкә(ле) << авест. *bāzuһ* «зур, зурлык» сүзеннән булса кирәк. Ләкин к. **Базык.**

**БАЗ-У** «осмелиться; дерзать» ~ к.-балк., ком. *баз-* id., алт. *паз-* «(бай алдында) шапырыну». К. **Баз II**. Ахметьянов 1989: 105.

Дерив.: **базымчылык; базын-у.**

**БАЗЫК** «крепкий, толстый, мощный (о столбах, стволах деревьев); широкоплечий, коренастый, богатырского сложения» < гом. көнб. төрки *базыķ* id. (ш. ук «хәлле, бай») > чув. *посӑк, пусӑх, пысӗӑх* «базык, зур; бөек» ← **баз-у** (к.) булса кирәк.

Федотов (I: 466) чув. *пысӑх* һ.б. сүзенең чыгышын перспективасыз юнәлештә эзли, чөнки тат. һ.б. *базык* сүзен белми.

**БАЙ I** «богатый; богач» < гом. төрки *бай* (себ., уйг., алт., хак., тув.) *пай* «бай; хуҗа; ир», як. *баай* «байлык; бай» һ.б. (ЭСТЯ II: 27–30). Һәрдаим бор. төрки, бор. монг. (ДТС: 120; Поппе 1938: 126, 144) *bujan* (*buyan*) «игелек; байлык; бай» > гом. монг., гом. тунг.-маньч. (ССТМЯ I: 65) *байан* > болг. **байан* > мар. *пайан* > *пойан* чув. *пойан* > *пуйан* «бай» сүзләре белән чагыштырыла. Әлеге *bujan* вариантын исә санск. *punja, punӡa* «бәхет, байлык, иминлек» сүзеннән килсә кирәк. Ахметьянов 1989: 184.

*Байан* > *бай* кыскаруы төрлечә аңлатылырга мөмкин; һәрхәлдә монда **бай II** тәэсире юк түгел.

*Бай, баян* сүзләре күп күрше телләргә кергән: чирк., абаз. *байа* «бай» аеруча игътибарга лаек. Рус. *бай* тур. Аникин: 109 (арытабангы әдәбият күрсәтелә). К. ш. ук Федотов I: 440–441 (чув. *пуйан* «бай» сүзен *пуй-* «баю» сүзеннән чув. теленең үзендә ясалган димәкче һәм асылда әлеге санск. сүзе белән чагыштыруны кире кагып, *бай* нигезен ир. телләрдән дигән караштa тора).

**Бай** продуктив нигез: **байлы, байлык; байы-у; байларча** һ.б.

**БАЙ II** (ДС II: 48; ДС III: 27), **байә** (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «доля; компенсация; участок земли при дележе; родовой участок», **пай** (ЛТ I: 111) «мирастагы өлеш» ~ госм., кр.-тат., кар. *пай* > рус. *пай* «өлеш, пай». Гом. кыпч. һәм гом. төрки *бай* варианты тат. теленнән тыш күч. мәгъ. һәм аерым дериватлардан гына билгеле, к. себ. (Тумашева 1992: 166) *пайым* «ирем (өлешем)», тат. диал., нуг. (Арсланов 1988: 73; Арсланов 1992: 117), төркм. *бай*

«хатын ире». Арытабан к. алт., хак. һ.б. *бай, пай* «өлеш; туган җир; ырудан килгән, изге» һәм *бай-* «тукталу» (к. **Байы-у II**). К. **Баек, Баелты, Байрак, Байтирәк, Байчәчәк, Баяу.** Федотов I: 377–378. К. **Пай.**

**Бай II** сүзенең һәм аның дериватларының (*байлы* «кагылгысыз; хөрмәтле», *байла-* «кагылгысыз хөрмәтле дип игълан итү») **Бай I** сүзеннән аерымлы булуы алтай сөйләкләрендә һәм ырым догаларында бик ачык күренә, к. Алтай кеп-куучындар: 300–320.

**БАЙБАК** «байбак, сурок» (Marmota Bobak), диал. (Тумашева 1992: 40) «тире оек» ~ кар. *байбак* «эшәке кеше; ялкау» ~ *байдбах, байдаҡ* «бәдбәхет». Рус сүзе кар. теленнән дип исәпләнә (Фасмер I: 107), ләкин к. рус. диал. (Аникин: 109) *байбака* «пайпак (киез кунычлы итек)». Ихтимал, байбак тиресен тулаем салдырып, итек ясаганнардыр. Ул чагында кар. *байбак* сүзенең җәнлеккә катнашы юк. К. **Пайпак.** К. түбәндәгене.

**БАЙБАКТЫ, бәйбакты, бибакты** – рус. *Бибахтино* – название двух населенных пунктов, а также башкирского рода в Башкортостане ~ кр.-тат., себ., тат., нуг., кырг., каз. *байбакты* ыру-кабилә атамасы, ш. ук кеше исеме. Бу сүз *бай бакты-карады* да, *байбак-лы* да түгел, ә нуг., каз. һ.б. *байбак, байпак* «чигүле киез итек» (к. **Пайпак**) нигезеннән. *Байпакты* «пайпаклы» дип чигүле ак пайпак киеп йөргән асылзат егетләрне атаганнар. Башкортстандагы әлеге авыл атамалары XVI г. русларга каршы көрәшкән **Байбакты** дигән нугай мирзасы исменнән булса кирәк.

**БАЙГЫШ** «сыч; бедолага, бедняк» > чув. *пайкуш* «гаиләсез кеше» < гом. кыпч., уйг., чыгт., угыз. *байқуш, байғуш,* башк. *байғош* «байгыш; өендә генә утыручан» (к.-балк.), каз., к.-калп. *байқус* «төн күгәрчене», *байғус* «байгыш», бор. чыгт. (Поппе 1938: 218) *bai quš* id. һ.б. Болар белән беррәттән иске тат. *байғызы,* каз. *байғыз,* чыгт., уйг. диал., госм. *байқыс,* үзб. *бойуғли,* төркм. (ТДГДС: 31) *бā̄йоғлы, бā̄йғотон, бā̄йғутон, бā̄йхатын* «байгыш, ябалак», к. ш. ук үзб. (ЎХШЛ: 48–49) *бойэқуш, бомқуш* «байгыш, өке». Бай баласының тәкәбберләнеп, ә ярлының мескенләнеп сүзсез утыруыннан, дип уйланыла: байгышлар көндез оялары янында тик кенә утыралар; ихтимал, бу – халык этимологияседер, тәүдә *бай куш* «бәхет (өлеш) кошы, ыру кошы» мәгъ. булуы да мөмкин. Исхаков Ф.Г. Наблюдения по лексике // Историческое развитие тюркских языков. М., 1961: 197–198; ЭСТЯ I: 32–33. Рус. *байгуш* «сукбай, ярлы» тур. Фасмер I: 107.

Дерив.: **байгышлы, байгышлан-у.**

**БАЙДАК** (Будагов I: 240) «идән тактасы, калын такта» < фар. *пāй так* «такта идән (аяк асты)»; чаг. рус. *байдак* «елга каегы, баржа, палубалы кимә» (Фасмер I: 107), ш. ук «идән тактасы» (Даль).

**БАЙКА-У,** диал. (Тумашева 1992: 166) **пайга-у** «замечать, подмечать; почуять (неладное); проверять истинность; прикинуть в уме, сообразить» < гом. кыпч., чулым. (Радлов I: 1421), төркм. (ТДГДС: 31) *байқа-*, үзб., уйг. *пайқа-*, үзб. (ЎХШЛ: 211) *пәйхәслә-* id., уйг. *пайла-,* үзб. *пойла-* «карау, каравыллау, эзәрләү» сүзе белән тамырдаш булса кирәк, чаг. ш. ук як. *барка-, барагы-, бараһыай-* «байкау; күрәзәләү» ~ монг. *барға*, маньч. *барька-* «байкау» (ССТМЯ I: 73). Гомумән, ачык түгел. Ихтимал, **баек** (к.) сүзеннәндер.

**БАЙКЫ** – Байки – название реки и сёл (**Бәйке** в Татарстане, **Байкыбаш** в Башкортостане). Бор. *Байкы би ~ Майкы би* исеменә нисбәт итела: риваятьләрдә, шәҗәрәләрдә ул Ука елгасы буеннан Көньяк Урал регионына кадәрге төрле урыннарда яшәгән итеп күрсәтелә. Башкортстанда табылган шәҗәрәләргә күрә, ул Чыңгыз хан дәргяһына барып сөйләшүләр нәтиҗәсендә үзенә кабилә башлыгы дәрәҗәсен һәм оран, тамга, ыру агачы вә ыру кошы атамаларын алып кайткан, ди. *Майкы ~ Байкы* тур. сөйләкләр, язмалар казак, каракалпак һәм кыргыз халыкларында бар һәм Рәшидетдиннең Чыңгыз тарихы китабында (XIII г. азагында) искә алына. Ул уйсүн кабиләсенең бие булган, имеш. Уйсүннәрнең төп җире исә Балхаш күленең көньягындагы далалар. Күрәсең, аларның бер өлеше Көньяк Урал – Урта Идел төбәгенә күченеп (яки күчерелеп) килгәндер. Кайбер язмаларда Майка би *табын, барын, тиләү, күбә* ыруларының бабасы булган диелә. К. ш. ук **Сөн.**

Безнеңчә, *байкы ~ майкы* (бу яңгырашларның бердәйлеге шиксез) төптә кеше исеме түгел, ә титул. Угыз төркиләрендә *байгу* сүзе ау кошын (лачын төрен) дә, бер феодаль дәрәҗәне дә белдергән (к. Райс: 12, 19). Потанин 1917: 49–54; Валиханов: 106–107. Әхмәтҗанов: 153–165 (бу автор фикеренчә, *Байкы бине* «нәкъ менә башкорт булган» дияргә дә нигезләр юк); Әхмәтҗанов 2009: 11, 296.

**БАЙМАК** (ТТДС I: 65) «одинокий (как перст)» ~ башк. *баймаҡ* «бармак», кырг. *баймак* «ат аягының түбәнге өлеше». Ачык түгел.

Башкортстандагы **Баймак** каласы атамасының да (ул мөгаен төрки сүздән) атамасы томанлы (анда шул исемдәге кавем, елга, тау-фәлән дә юк бугай). Бик зур территорияле Баймак районында татар авыллары да бар.

**БАЙРАК** «знамя» < гом. кыпч., уйг., чыгт., угыз. *байраҡ* id., ш. ук «хәрби бүлек, бәйге бүлеге» (к. ЭСТЯ II: 33–34) < бор. төрки (ДТС: 77, 79) *bajraq, batraq, badruq,* төркм., үзб. диал. *байдаҡ,* алт. диал. *байтраҡ* id. *Байраҡ* яңгырашында бу сүз күп күрше телләргә (Шәрык, Кавказ, Балкан илләренә) кергән һәм аның тур. әдәбият ишле (рус телендә А.П. Окладников, Г.А. Федотов-Давыдов һ.б. язган).

Бу сүз тур. фаразлар күп. Безнеңчә, төп мәгънә «тукталыш урынын белдергән билге байрак» һәм бу сүз *бай тураҡ//бай туруҡ* «тукталышта тору» тезмәсеннән килә, к. **Бай-у.** ЭСТЯ II: 33–34.

Дерив.: **байраклы; байракдар; байракчы.**

**БАЙСАК** диал., тар. «личный охранник владетеля» (к. Иҙеүкәй менән Мораҙым. Өфө, 1994: 272); «полицейский, вышибала» < монг. *байсаг, байысагал* «суд тикшерүчесе», к. ш. ук диал. (кас.) *байсактай* «зур гәүдәле, әзмәвер» (к. ТТДС I: 65), чаг. тув. *байыса* – «җинаять тикшерүдә сорау алу, шаһитләрдән сорашу», *байсаакчы* «тикшерүче». Бу сүз монгол хакимияте, Алтын Урда заманнарыннан калган булса кирәк.

**БА́ЙТАК** «изрядно; довольно много, немало», диал. (Тумашева 1992: 40) «обширный, широко раскинутый» > чув. *пайтах*, мар. *пайтак*, удм. *майтак*, морд. М. *байтяк* < гом. кыпч., алт., аз. диал. *байтак*, шор. *пейдаҡ* «байтак; киң, зур» < фар. *пāйтăхт* «пайтәхет», «тәхет асты, империя» сүзеннән, к. «Идегәй» дастанында *байтаҡ* «бөтен дәүләт; Алтын Урда империясе». Ихтимал, *бай* сүзенең контаминацион тәэсире бардыр. Räsänen 1969: 576; ЭСТЯ II: 36; Федотов I: 379 (Э.В. Севортян кебек үк, бу сүзнең этимонын *бай* сүзеннән эзли).

**БАЙТАЛ** «еще неожеребившаяся и переставшая рожать кобыла», диал. «кобыла (вообще)» > чув. *пайттал* < гом. кыпч., уйг., үзб. *байтал* id. < монг. *байтал, байдал* «тукталыш, торгынлык», *байтас* «байтал», к. як. (Пекарский: 340) *багтасын* «ту бия» < монг. *байтасан, байтасун* id. һ.б. *бай-* «тукталу» тамырыннан, к. **Бай-у, Бая, Баяу.** К. Щербак 1961: 89; ЭСТЯ II: 36–37 (Э.В. Севортянда кирәксез шикләнүләр бар).

**БАЙТАР** «коновал, ветеринар» ~ төр. *baytar* id. < гар. *байṭāр* id.

**БАЙТИРӘК,** диал. **байтәрәк** «родовое дерево, дерево рода; большое дерево с ветвистой кроной» – каз., кырг., алт. *байтерек [байтэрэк]* «тупыл; ыруның үзенә хас изге агачы» – күп кенә китапларда тупас рәвештә *бай тирәк,* ягъни, янәсе, «ботакка бай тирәк» дип аңлатыла. Чынлыкта монда *бай* «бәхет өлеше, изге, борынгы бабалардан калган» дигән сүз (к. **Бай II**). Бу *бай* сүзе төрки телләрдә махсус мәгънәле кушма сүзләрдә киң кулланыла, к. ком. диал. (Каримов: 39) *байагач* «бүк» ~ алт. *байағач, байагаш* «изге агач», алт. *байказың* «байкаен, изге каен» (к. Маадай-Кара: 461–463), шор. *пайкузук* «кедр» ~ як. *аар кудук мас* «кедр – ару козык агач = изге козык*»* (димәк *пай, бай* «ару, изге»). Агач исемнәрендә *бай-* һичшиксез ыру-кабилә агачын белдергән (төрки-монголларда һәрбер кабиләнең агачы, кошы, тамгасы һәм ораны билгеләнгән). Соңрак ыругчылык үз әһәмиятен югалткач, ыру агачы гади агач исеменә әверелә башлаган. К. ш. ук **Байчәчәк. Байтирәк** – «ыру (дөнья) агачы» тур. әдәбият зур (махсус китаплар бар). Ахметьянов 1981: 94–96; к. ш. ук СТ № 5, 1980 (*бай* «өлеш» сүзенең *бай* «зур милек иясе» сүзеннән аерымлы булуы тур. мәкаләләр). Хакасларда (Бутанаев 1990: 132) *пай агас* – ыру агачы баш кам (шаман) кәртәсендә булган һәм шуңа – байтирәккә ыру тамгасы киртелгән булган. Кыргызларның «Манас» дастанында *байтерек* бик тәмләп тасвирлана. К. Религиозные традиции мира. Т. I. М., 1996: 188–190. «Мөхәммәдия»дә – ислам мифологиясендә тасвирланган *туба агачы* типологик җәһәттән шул ук *байтирәк*.


Себер халыкларында такталарга ясалган, тукымаларга чигелгән (төрле чыганаклардан алып, бергәрәк күрсәтелә) байтирәк рәсемнәре

**БАЙТКӘ,** диал. **бачкә** – слово фамильярного обращения друг к другу ~ башк. (БТДҺ: 342) *мәткә* id. < рус. *батька, батенька.* К. **Пачышка.**

**БАЙЧӘЧӘК,** себ. **пайчәчәк** «первоцвет (цветок, который первым увидел в этом году: если красный – к радости, желтый – к горю и т.п.); языческий праздник цветов весной» – кырг. *байчечекей* id., үзб. *бойчечак* «умырзая; беренче чәчәк белән котлау бәйрәме» (к. Җаһонгиров: 70–72; Сухарева: 31–46) < *бай* «өлеш, бәхет» (к. **Бай II**) һәм *чәчәк.* Чаг. чув. *çеçпĕл* < мар. *цäшпыль* «байчәчәк, бәхет чәчәге» < *цäш* (рус. *счастье*) «бәхет» һәм *пыль* «чәчәк»; *беренче чәчәк* бәйрәме Кавказ халыкларында да булган (к. Пачулиа В.П. Падение Анаконды. М., 1986: 69).

**Байчәчәк** бәйрәме тагын **җимчәчәк** һәм **эргәзембай** дип тә аталган (шул матдәләрне к.). К. **Байтирәк.**

**БАЙЫ-У I (баю, байый),** диал. **бай-у (баю, бая)** «закатиться (о небесных телах)» ~ кр.-тат., каз., госм. һ.б. *байы-* «(гомер) үтеп китү; югалу, төкәнү, кояш һ.б. баю», кырг. *байы-* «басылу, бетү (ташкын, давыл һ.б.)», төр. *bayıl-* «аңын югалту, бөтенләй тып-тыныч калу», төркм. *байа-* «бетү», бор. монг. *baji-* < **bagi* «тукталу, бер урынга килеп урнашу» (к. Ramstedt 1935: 40) һ.б. Г. Рамстедт фикеренчә, бу сүз кыт. *ба, бай* «урын, барып җитәсе җир» сүзеннән һәм, әгәр шулай икән, бу сүз *бай* «өлеш» сүзе белән тамырдаш. (*Кояш һ.б. баю*, димәк, «барып җитәсе җиренә җитү» дигән сүз була). К. **Байтал, Бая, Баяу.**

**БАЙЫ-У II** «разбогатеть» ~ чув. *пуй-* < *пой-* id. *бай* сүзенә *-ы* кушымчасы ялганып ясалган булса кирәк, к. уйг. *пайы-, байы-* «баю». **Байык-у (баегу)** варианты *байы-у* сүзенең интенсивлык формасы гына. Räsänen 1969: 56; Федотов I: 441.

**БАКА** «лягушка, жаба; черепаха; моллюск» > мар. диал., удм. диал. *бака* < гом. төрки, монг. *бака* (себ., уйг. *пака,* хак., тув. *паға,* шор. *паған*) id. ~ венг. *beka* «бака», төр. *baga* «ташбака». Бор. төрки яз. телдә *бака* (*ташбака*) – сынташ, стелла беркетү өчен ташбака сурәтендә ясалган пьедесталны белдергән, шул нигездә **бака**ның «уртасы тишекле, уемлы деталь» мәгънәсе килеп чыккан, к. тат. *бака* «тегермән ташының күчәре һәм күчәр кигезелә торган тимер деталь; аскы таш» мәгънәсе, шулай ук «уртасы квадрат тишекле тактачык». Сүзнең бор. яңгырашы *бакка* – бакылдаудан.

**Бака** сүзенең «оры, шеш» мәгъ. дә бар (*агач бакасы, күкрәк бакасы, теш бакасы, тамак бакасы*) һәм бу юнәлештә *бака, бакка, паккула* «агач орысы» рус һәм фин-угор телләрендә киң таралган (к. Матвеев А.К. Заимствования из пермских языков в русских говорах // Acta Linguistica, Budapest, XIV, 1964). ЭСТЯ II: 40–42.

**БАКАЙ,** диал. **пагайак** «голень (животного)» < гом. кыпч. *бақай* «тояк өсте». К. **Баган II, Бәкәл.**

**БАКАЛТАЙ, бакай** (С. Хальфин) «пристань; гавань» – шуннан *бишбалта(й)* < *биш бакалтай* (Казанның Идел буе бистәсе) – Көнч. Европада таралган сүз: чув. *пайккал,* рус. *бакай,* башк. *бақай* «елганың аерылып киткән тармагы», укр. *бакаль* «чукрак күл», морд. *бакалда* «чишмә, чукрак күл», рус. диал. *бакалда* «язгы су тулган чокыр-чакыр» (Даль). Чаг. бур. *бакалтай* «бакалы күл» (!).

К. Фасмер I: 109; Мурзаев 1984: 66–67; Гордеев I: 188 (берсе дә монг. телләреннән дими); Федотов I: 378.

**БАКЛАЖАН** < рус. Рус теленә исә төрки телләрдән, к. **Бадымҗан.**

**БАКЛАН** «баклан, вид морской утки» < төр. *baklankaz* «баклан каз», бор. монг. (Поппе 1938: 111) *baqlan* «симез» < *balxayan* «түгәрәк – симез, юан – тулы» (к. Ramstedt 1935: 28), *balx* «тулы-түгәрәк» образлы сүзеннән. Чаг. **Балкы-у.** К. ш. ук каз., кырг., уйг. *бағлан* «кечкенә симез бәрән». Рус. *баклан* тур. к. Аникин: 110.

**БАКРА** «куколь» – иске тат. (Троянский I: 219) *бакыра*, диал. (ТТДС I: 290) *бакыр тәтәй* id. ~ чув. *покра* > *пукра, похра* > *пухра,* мар. *покро, похро, пакыра, пахыра* (Саваткова: 115) морд. М. *пакор,* удм. *бокро* id. – иске тат., болг. (?) **бақырақ* «бакыр төстәге чәчәк» сүзеннән, к. тат. диал. **багрый** (к.) «бакыр төсендәге» (чаг. рус. *багровый, багряный*). Чаг. рус. *бакра, бахра* «ике тиенлек бакыр – вак тәңкә» (рус сүзе үзе төрки телләрдән, ихтимал, болг. теленнәндер). Федотов I: 441 (этимологиясе бирелми); Ахметьянов 1989: 52.

**БАКРАВЫК [ба°кра**w**ы̆к]** «громко и часто блеющий (о козах, козлятах, овцах, ягнятах)» диал.

**бакра-у** сүзеннән. Мондый модельдә тагы **мөгрә-ү, чыңра-у** һ.б. К. **Бакыр-у.**

**БАКРАЧ,** (Троянский I: 220) **бакырач** «черпак, половник», себ. (ЗДС: 515) **паған,** (Старчевский) **баграц** «(медный) котелок», «чугунок», «медный тазик» ~ каз., к.-калп. *бақыраш* «уҗау» һ.б. < (тат. диал.) **бақырғач,** башк. *бақырса* «бакыр чәйгүн», к.-калп. *бақыраш* «таба» һ.б. кырг., каз., үзб., төркм. «бакыр савыт»; *-гач//-қач* – кечерәйтү кушымчасы, төп нигез **бақыр** «бакыр чиләк, казан», к. **Бакыр.** Шул ук нигездән бүтән кечерәйтү формалары тат. **бакырча, багырча,** башк. *бакырса* «бакыр чәйгүн» ~ төр. *bakırcak* «бакыр тәлинкә»; себ. тат. (ЗДС: 515) **пағрац** «өч аяклы чуен чүлмәк» < бор. **бакыраг.* Рус. диал. (Аникин: 111–112) *бакирка, бакарка, бакерка* «чәйгүн», *бакыр, бакырка* «бидрә, металл чиләк», *бакиро́к* «кечкенә чиләк» төрки аналоглар буенча ясалганнар. Каз., кырг., үзб., төркм. һ.б. *бақыр, пақыр* «бакыр чиләк», үзб. диал. (ЎХШЛ: 211) *пәқър* «чиләк, бидрә, бакыр савыт». Күрсәтелгән сүзләрнең бүтән фонетик вариантлары да бардыр. Әлбәттә, **бакыр** (металл) нигезеннән («металл > савыт» мәгъ. күчеше, к. **Чуен**).

Озак заманнар дәвамында (бигрәк тә төрки халыкларда) бакыр, точ савытлар популяр булганнар: аларны коемлау җиңел, алар үзләре матур, үзләре ватылучан түгел. К. **Бакыргач.**

Китерелгән төрки сүзләр күп күрше телләргә кергән: мар. *бакрач, бакырча*дан алып гар. (к. Гордлевский II: 148) *бақраж* «кофе чәйнеге»нә кадәр күп мисаллар табыла.

**БАК-У (багу, бакты)** «посмотреть, смотреть; погадать; зависеть» ~ чув. *пăх-* гом. төрки *бақ-,* себ., хак., уйг. *пақ-* < бор. төрки (ДТС: 77, 81–82) *baq-* «игътибар белән карау», *bay-* «тилмереп карау, багыну» һ.б. Räsänen 1969: 58; Федотов: 407; ЭСТЯ II: 38–40; Ахметьянов 1989: 103–104.

Дерив.: **багучы; багыл-у, багыш-у, бактыр-у.** К. **Багын-у.**

**БАКЧА** «сад; огород» > башк. *бақса,* чув. *пахҫа* id. < фар. *бағча, вағиче* «кечкенә баг». Бу сүз күп телләргә кергән, к. кр.-тат., төр. *bahçe,* нуг., каз. *бақша,* Кавказ телләрендә *бакча, бағча* һ.б. Мар. *пакча, бакча,* удм. *бакча,* морд. М. *пакся* «артбакча, яшелчә (бәрәңге) бакчасы» < тат. Ахметьянов 1989: 52; Федотов I: 392. Рус. *бакча, бахча* һ.б. тур. Аникин: 112 (бай әдәбият күрсәтелә).

Дерив.: **бакчалы, бакчалык** һ.б.

**БАКЧАР** (Будагов I: 233) «скворец; вид скворца; дрозд», **багчаргэ** (там же) «сыч» ~ башк. *бақсар* id. ← себ. *қарабақчарға,* ягъни *кара бакчарга* id. **Бақчарға,** *бақцарға, бикцәргә, пәкчергәй* һ.б. үзе (күп вариантлар, к. Тумашева 1992: 42–43, 167 һ.б.) исә бөтенләй үзгә кош – «чырайсыз ябалак»ны белдерә. К. ш. ук як. *мэкчиргэ* ~ бур. *бэгсэргэ* «байгыш». Һәрхәлдә *-чар* һәм *-гай* кош атамаларында очрый торган аффикслар. Чаг. **Карабакчар.**

**БАКЫЙ** «вечный», диал. «пережиток» < гар. *bāqī* id. (төп мәгъ. «үзгәрешсез кала торган»). Чаг. иске тат. *бәқа* «мәңгелек». К. **Бакыя.**

**БАКЫР,** диал. (ДС II: 47) **бағыр,** себ. **пағыр** «медь; медный тазик» < гом. төрки *бақыр, бағыр* (вариантлары күп) фар. *баҳыр, бағир* «бакыр» сүзеннән исәпләнә (Räsänen 1969: 58; Joki 1955: 80). Фар. сүзенең этимологиясе ачык түгел: сүзнең беренчел итеп Кавказ телләрендәге *barkil* «кызыл металл» (к. ЭСТЯ III: 45–47) яки иске гар. *magra* «кызыл җир» күрсәтелә (Егоров 1964: 151). К. **Багрый, Бавыр, Бакра, Бакрач, Бакырт, Барнау, Бәгырь.** Чув. *пăхăр* тур. Федотов I: 408.

Дерив. киң: **бакырла-у; бакырчы, бакырчылык, бакырташ** «малахит»; хайван һәм үсемлек атамаларында бакыр төсендәге мәгъ. килә: *бакыр елан; бакыр тәтәй, бакыр чәчәк* һ.б.

**БАКЫРГАЧ** диал. (ЗДС: 97) «ракушка, раковина» – төп мәгъ. «казан, чүлмәк, бакыр савыт» булса кирәк. **Бакыргач** – түгәрәк бакакый төре була. К. **Бакрач.**

**БАКЫРТ, бакырут** «рожок», «манок» < *бақыр уд,* к. төр. *bakır ut* «бакырт»: *ut, ud* < гар. *ʻуд* «курай, сыбызгы» ← *ʻада* «кычкыту». Сүзлекләрдә кайчакта **бакырт** сүзен *бакыру*га нисбәтлиләр.

**БАКЫР-У,** диал. **абакыр-у** «громко, грубо и возбуждённо кричать, орать; громко блеять (об овцах и козах)», < *ба-кыр* (*-кыр-* морфемасы тур. к. **Акыр-**). Гом. төрки *бақыр-, бағыр-, пағыр-* < бор. төрки (ДТС: 82) *baqïr-* id.

Дерив.: **бакырын-у, бакырыш-у; бакырыш. Бакырт-у,** төп мәгъдән тыш, «музыкаль аләтне бас тавышта уйнату». Dobr. I: 245.

**Бакыр-у** сүзеннән **бакравык** сүзе ясала.

**БАКЫЯ [ба°қыйә]** «пережиток; далёкий потомок» < гар. *бāқийā* id. К. **Бакый.**

**БАЛ** «мёд» < гом. төрки, монг., бор. төрки *bal* id. ~ кар. *bat, bad* id. (к. **Батман**) < санск. *madhu* «бал» сүзеннән дип уйлыйлар (Рясянен һ.б.); бу сүз турыдан-туры санскриттан алынмаган, ә *-d* ~ *-l* күчешләре булган ниндидер бор. телдән (сугд., тохар. һ.б.ш.) кергән. Санск. *madhu* – бор. һинд-евр. сүзе (шуннан ук рус. *мёд*, к. Фасмер II: 588–589). Räsänen 1969: 59; Федотов I: 463–464. К. **Мәй.**

**БАЛА** «дитя; малый (о вещах, которые имеют и большой вариант)» < бор. һинд. *bāla* «кечкенә; яшь; бала» сүзеннән (сугд теле аша, к. ЭСТЯ II: 47–48), к. ш. ук ягн. *pulla* «бала, бәби, малай», телугу (дравид.) *pilla* id. *Бала* кайбер төрки телләрдә (чув., тув. һ.б.) сирәк кулланыла яисә бөтенләй юк. Удм. диал., мар. диал. *бала* < тат. **Бала-чага** дигәндәге **чага** тур. к. **Чага.** Диал. (ЗДС: 98) **бала-бута** дигәндәге **бута** тур. к. **Бута.**

**Бала** сүзенең «кече» мәгънәсе *балитәк* < *бала итәк, балакир* < *бала кир* (к. **Балакир**) һәм бигрәк тә башкорт кабилә-ыру атамаларында еш очрый: *олы катай – бала катай* һ.б.ш.

Дерив. тат. телендә ишле: **балалы, баласыз; балалык; балакай** (бик актив); **балала-у, балалат-у;** һ.б.

**БАЛАБАН** «охотничий ястреб», диал. «сильный, крепкий, мощный» ~ кр.-тат., төр. *balaban* «зур гәүдәле, көрәшче», кар., к.-балк. *балабан* «бик зур, дәү», рус. *балобан* «лачын төре», төр., калм., бор. төрки *balaban,* төр. *balban* «лачын», башк. *балапан* «лачын яисә бөркетнең иң көчле баласы; таза, бәдәнле», нуг., каз. *балапан*, каз., ком. *балпан* «кош баласы; чеби, бәпкә», уйг., ком., аз. *балабан* «сыбызгы, курай» ~ кр.-тат. *балабан* «барабан», к.-балк. *палапан* «зур гәүдәле, көрәшче», авар. *палупан* «арканда биюче эквилибрист» һ.б. (сүзләр күп); бу берберсенә «керешкән» сүзләрне Севортян (II: 49–51) «гетероген» (төрле) тамырлардан дип карый; Редхауз сүзлегендә төр. *balaban* сүзенең «барабан», «биергә өйрәтелгән аю» мәгънәләре дә күрсәтелә (Redhouse: 126) һәм барысы да бергә бирелә. Һәм инглиз лексикографы хаклы – бу мәгънәләр, Җ. Вәлиди дә язганча, бер үк **пәһлеван** (к.) сүзенә кайтып калалар: аның «батыр» һәм «сабантуйда, сәелдә (язгы бәйрәмдә) көрәштә катнашучы» мәгънәсеннән «биергә өйрәтелгән аю», гомумән «аю биетү» аннары аю биеткәндә (биетмәгәндә дә) «сыбызгыда уйнау, барабан кагу», аннары «барабан» мәгънәсе чыга һ.б. К. **Балбан, Барабан.** Räsänen 1969: 59. Кр.-тат. *балабан* сүзенең төрле мәгъ. тур. Dobr. I: 250.

Рус. *балабон* «кош төре» < төрки *балабан* тур. к. Булаховский: 83; Аникин: 111. *Балабан* «самый большой сокол» тур. СРНГ: 41.

**БАЛАВЫЗ [ба$^{о}$лаwы̆з]** «воск» < гом. кыпч. *balauz, balavuz* > калм. *балуус*, кар. *балагуз* < *бал ағуз* «бал угызы» сүзеннән (Räsänen 1969: 60), к. тат. диал. (миш.) *уыз, ывыз* «угыз», болг. (Ибне Фазлан, МК) *авус* «балавыз». Балавыз угызга төсе буенча охшатылган. К.-балк. *балкаўуз* варианты халык этимологиясе буенча пәйда булган (*каўуз* «сулык», к. **Кавыз**).

**БАЛАГАН** диал. «балаган, саманный дом» < рус. *балаган* «вакытлы корылма, цирк; балчык өй», рус теленнән күп телләргә күчкән, беренче чыганыгы фар. *balaxanä* «мансарда, ишек өстендәге бүлмә» (Фасмер I: 112); И.Г. Добродомов (1982: 83–90) бу сүзне ахыр чиктә бор. төрки (ДТС: 80–81) *balïq, baluq* «шәһәр, балык диварлары, кальга» сүзенә тоташа дипраслый. А.Е. Аникин (: 113–114) шул ук фикердәрәк. Без иске этимология яклы, чөнки *балаган* рус телендә «вакытлы театр корылмасы», аның сәхнәсе биектә, балаханә сыман була, як. *балаған* сүзе дә шундыйрак корылманы белдерә (як. телендә фар. алынмалары юк түгел). К. ш. ук каз., к.-калп. *балаған, балағаш* (ҚТДС: 52) «(киез) куыш».

**БАЛАК** «штанина» > мар. (Гордеев II: 192) < гом. кыпч. *балақ* id., төркм. *балақ* «чалбар», госм., үзб. диал. (Радлов IV: 1449) «балакның түбәнге өлеше» < кырг. *бағалақ* < *бақалақ* «балакның иң түбәнге – аякчуга ышкыла торган урынындагы өстәмә тегелмә» (к. **Бәкәл**). **Балак** сүзенең «аяк табанының куышланып торган өлеше» (к.-балк.), «касык, бот арасы» (шуннан рус. *балаки* «атта күп йөрүченең чалбар балаклары арасына тегелгән өстәмә тукыма», к. Аникин: 114) мәгънәләре икенчел булса кирәк. К. Räsänen 1969: 59; ЭСТЯ II: 51. Безнеңчә, *балак* < *бағлақ*, бағлақлақ* (чаг. рус. *пагаленок*) тәүдә балакның инчек турысына *бағланган*-бәйләнгән өлешен генә белдергән. Чаг. **Балдак, Балтыр.**

Дерив.: **балаклы** (балаксыман өстәмәсе булган), **балаксыз.**

**БАЛАКА** (Вәлиди I: 385; ДС II: 49) «рукоятка сохи» < *балақақ* «кечкенә балак» булса кирәк (балакалар икәү була); чаг. ш. ук к.-балк. *балақа* «(мәдрәсәдә) күрсәткеч таяк» һ.б.

**БАЛАКИР** «сөт чүлмәге» < *бала кир*: *бала* «кечкенә» мәгъ., *кир* «балчык савыт». Рус. *балакир* (> чув. *палаккӑр* «сапсыз күкшен», к. Сергеев 1968: 46) < тат. Чаг. сөйл. *балаказан* «кечкенә казан». К. **Киршән.**

**БАЛАМУТ** «баламут, взбалмошный» < рус *баламут,* чаг. ш. ук рус. *балагур*. К. төр. *palamut* «уенда хәрәмләшү», бор. монг. *balamad, balamud* «авантюрист, мут», маньч. *бала* «юньсез, дуамал» (к. ССТМЯ I: 68) ~ кыт. *бáла* «җитәр, туктат, чыгырдан чыкма!». Шанский: 33.

**Баламут** сүзе русчага бәлки тат. теленнән кергәндер, к. Ш. Галиев шигырендә:

*Әти, бәлки, мактангандыр*
*«Минем балам – ут», – диеп.*
*Бүтәннәр кул селти иде:*
*– Beләм, баламут, – диеп.*

Ләкин тат. **баламыт** булырга тиеш иде.

Рус этимологик сүзлекләрендә **баламут** сүзендә **бала-* нигезен күрәләр һәм Корш тәкъдим иткән монг. чыгышын кире кагып, слав. телләренә йөз тотып аңлаталар. Гомумән, аңлатмалары ышанычлы түгел. К. Фасмер I: 113.

Тат. телендә генә булса, бу сүзне *бала мут* яисә *бәла мут* дип тә аңлатып булыр иде...

**БАЛАН,** диал. **палан, малан** > удм., мар. *полан* «калина» ~ алт. *палан, балан*, чув., ком. *палам* id. Егоров (1964: 142) грек. *βαλανος* «әкәлә» сүзеннән димәкче – ышандырмый. Чаг. алт. *пеле, беле* «балан».

**БАЛАТА** «состав для дубления» ~ к.-балк., төр., аз. *балата*, хак. *палаты* id., аз. *балата, балаты* «ачыткы» < бор. угыз. **баналты, *балылты* «буяу яки эремә ясаганда эремичә калган өлеш» сүзеннән, чаг. каз. *малта, малты* id. К. **Мандаша, Ман-у.**

**БАЛБАН, балпан** тар. «балбал, каменная статуя», диал. «толстый, здоровенный; самый сильный из семьи» ~ кырг. *балбан* «көрәшче, батыр», төр. *балбан* «ау карчыгасы» < фар. «пәһлеван» (к. **Пәһлеван**) сүзеннән, к. **Балабан.**

**Балбан** сүзеннән бор. төрки *балбал* «кабер өстенә куелган сынташ» сүзе дә килсә кирәк. Бу сүз тур. зур әдәбият бар, к. Грач 1961; Плетнёва 1974; Кызласов Л.Р. О значении термина *балбал...* // Тюркологический сборник. М., 1966: 206–208. Вайнштейн 1974; Фасмер I: 186–187 (**Болван** сүзе тур.); Аникин: 114.

**БАЛГА** «поперечный топор; боевой топор; кувалда» ~ башк. *балға* «агач ую өчен аркылы балта», каз. *балға,* кырг., уйг. *балқа*, уйг. диал. *балоқа* «зур чүкеч» << аккад. *pelakku* «сугыш балтасы, айбалта», чув. *пулле* «аркылы балта» турыдан-туры тат. *балга*га баглы түгел. Гомумән, бу сүз бөтен Евразиягә таралган (бу хәлгә аның бизәлгәнлеге ярдәм иткән), к. тунг.-маньч. *палуга*, яз. монг. *һaluxa* (к. ССТМЯ II: 313) һәм икенче тарафта грек. *pelekys* «ике яклы балта» һ.б. К. **Палач.**

**БАЛДАК** «кольцо; перстень», диал. (ЗДС:99) «пагаленок», себ. (ЗДС: 518) **палтақ** «костыль, палка» ~ к.-калп., кырг., үзб. диал. һ.б. *балдақ* «култаяк», нуг., кр.-тат., төр. *балдақ* «хәнҗәр, кылыч сабы яисә аркылачы, эфес», уйг. *балдақ* «кәүсә кисеме» < чыгт. *бағалдақ* «балдак, билдәмә, көбә эченнән киелә торган киң билбау, биләүсә», төр. *bayıldak* «элекке такта бишеккә салынган бәбине баглап-бәйләп кую өчен каеш, бау» һ.б. *бағ* «бау» сүзеннән дериватлар. Тат. әд. **балдак** сүзенең мәгънәсе төп мәгънәдән ерак киткән. К. ш. ук бор. төрки, үзб. *бақал, бағал* «бәкәл; аяк балдагы». К. **Балак, Балака, Балтыр, Бәкәл.** Корш Ф.Е. Слово *балдак* и долгота гласных в турецких языках // Живая старина, 70–71, вып. II–III, 1909; ЭСТЯ II: 52–53. Рус. *набалдашник* «култаяк очын беркеткән балдак, сакма» сүзендә элекке тат. *балдак* «балдаклы таяк» сүзе чагылыш тапкан.

Дерив.: **балдаклы, балдаксыз; балдакла-у, балдаклан-у** һ.б.

**БАЛДЫ** (сөйл. **бал-**) слово-детерминант к младшему из ряда родственников одинакового положения относительно говорящего: *бaләби ~ бәлдәби* «младшая из бабушек», *балдабый* «младший из старших братьев» и т.п. ~ хәз. җанлы телдә бу сүзнең төп мәгънәсе *бал* сүзе тәэсирендә шактый җуелган. Диал. *балдыкай* «килендәшләрнең берберсенә эндәшү сүзе» һич кенә дә *балдыз*дан кыскармаган, ә мөстәкыйль сүз; к. як. (ДСЯЯ: 59) *балты эне, балтыкай* «сеңел», төркм. (ТДГДС: 32) *баллы < балды* энеләрнең яисә сеңелләрнең иң кечесе; к. ш. ук төр. *balnine* «дәвәни», *balnene* «дәүдәвәни» (DS II: 495) һ.б.

**Балды** сүзе, безнеңчә, эвенк. (һ.б. тунг.) *балди-* «туу, тудыру; үсү, үстерү; япь-яшь булу» (бик күп дериватлар, к. ССТМЯ I: 69–70) белән тамырдаш. К. **Балдыз, Балтырган.** Ахметьянов 1981: 78–79.

**БАЛДЫЗ** «свояченица», диал. «шурин» – тәүдә (диал.) **кыз балдыз** һәм **ир балдыз** аерымланган (к. ДС III: 93–61), башк. диал. *балдыҙ* «кайнеш» (БҺҺ II: 39), тат. диал. **балдызак** id. ← гом. төрки *бāлдыз* < **baltırg* > бор. төрки *baltïr* (ДТС: 80–81) «кече кызкардәш» > чув. *полтыр* > *пултăр* «хатынның энесе яисә сеңлесе», *пултыр кин* «кече килен» (Ашмарин IX: 283), удм. *бултыр* «кече (икенче) хатын», бор. төрки (МК) *baldïr ogul* «үги угыл», калм. > тат. диал. (Арсланов 1988: 74) *балдыр* «метис, төрле милләт кушылгагы».

**Балдыз ~ балдыр** сүзенең семантикасында «чит кавемнән» дигән төсмер бар – шул ук төсмер тунг. *балди-* (к. **Балды**) сүзенең бер дериватында бар: *балдиху* «килен алыша торган күрше кабилә кешесе».

**Балдыр** сүзе бор. төрки *baldır* > уйг. *балдур* «тәүге, беренче (бала)» (Clauson: 334) белән бердәй булса кирәк. К. ш. ук **Балтырган.** Räsänen 1969: 60$ Федотов I: 443–444.

**БАЛИГЪ** «совершеннолетний» < гар. *бāлиғ* id. К. ш. ук **бәләгать** «балигълык» < гар. *бāлāғат* id.

**БАЛИТӘК** «оборки» < **бала итәк** «кечкенә итәк». К. **Бала.**

**БАЛКА** диал. «балка, болотистая долина» ~ монг. диал. *балга* id. Тат. теленең диал. сүзлекләрдә бу сүз күренми, ләкин кайбер рус сүзлекчеләре (Даль һ.б.) аны тат. сүзе дип күрсәтәләр. *Балка* < *балқа* «бик киңәйгән елга үзәне; ярым далалардагы коры үзән» дип характерлана. Ләкин Төньяк Кавказ төркиләрендәге *балқа, малқа* «тау елгасы» (конкрет елга атамалары: *Олы Балка, Кече Балка*) сүзенең төп мәгънәсе киңрәк булганлыгын күрсәтә. Гомумән, *балка* бор. төрки *балык* «сазламаклы үзән; балчыклык» (ш. ук «чи кирпеч, кирпечтән корылган бина һ.б., кирпеч диварлы кала») сүзе белән бердәй булса кирәк. *Балқа,* мәс., **балыкъаг** (чаг. **баткак**) формасыннан килеп чыга ала. Чаг. рус. диал. *балка ~ балкан ~ балчук* «балка». Һәрхәлдә балка сүзенең төрки **балкаш** (к. **Балкаш**), **балчык** кебек сүзләр белән тамырдаш булуы бик мөмкин.

**БАЛКАН** – название ряда возвышенностей в Башкортостане. Бу топоним төркиләр яшәгән күп урыннарда очрый, мәс., Төрекмәнстанда **Балкан** таулары, Европада **Балкан** ярымутравы (русча *Балканы,* төрекчә *Балканлар* «сөзәк таулар» дигәннән тәрҗемә). **Бархан** сүзе белән асылда бердәй. Гомумән, «йомры, өркәчсыман тау» мәгъ. булган булса кирәк, к. Dobr. I: 253. Чаг. кырг. *балкай-* «симереп йомрылану».

**БАЛКАР** «балкар, балкарец (народность на Кавказе), самоназвание *балқар ~ малқар,* а также *тавлу*) – революциягәчә аларны *татар* дип тә атаганнар һәм чыннан да аларның теле тат. теленә, бигрәк тә мишәр диалектына бик охшаш (цылаштыру бар һ.б.). **Балкар** сүзе алар яшәгән төбәктәге *Балқа ~Малқа* елгасы атамасына баглы булса кирәк, бу сүз исә тат. диал. **балка** (к. югарыда) «елга» сүзе белән чагыша. Элек балкарларда биш каста булуы һәм аларның атамалары кызыклы: 1) *таубий, тау бие* «иң зур феодалларның берсе», 2) *үздән* «дворян», 3) *қарақас* «ирекле җирбагар», 4) *чағар* «чура кол (крепостной)», 5) *қазах* «кол», к. EI I: 1000–1002.

Гадәттә *балкар* сүзен *болгар* белән чагыштыралар, ләкин бу чагыштыру нигезсез.

**БАЛКОН** «балкон» < рус.; рус теленә иске тат. (< фар.) *балаханә* «өске ханә (бүлмә)» сүзеннән. Бу фикерне кире кагучылар да бар, к. Фасмер II: 115 (төрки сүз түгел димәкче).

**БАЛКЫ-У** «сиять, засиять» – чаг. *балк итү* id. имитатив фигыль. Гом. кыпч., чыгт., угыз. *балқ-, балкы-* сүзенең кайбер телләрдә (каз., к.-калп.) «(металл) эрү, эреп балку», «мөлдерәмә булу» мәгънәләре бар (к. ЭСТЯ II: 56–57).

Дерив.: **балкыт-у, балкыда-у.**

**БАЛТА** «топор» < гом. кыпч. (> венг.) һ.б. *балта* «балта», монг., бур. *балта* «чүкеч», тув. *балту,* бор. төрки *baldu* «балта». Параллель рәвештә чув. *пурта* < *порта* «балта», эвенк. *парта, пурта* «пычак» < бор. ир. *parаđи* «балта» > коми., удм. *пурт* «пычак» һ.б. (бик күп телләргә таралган сүз) < һинд-евр. *bhrendhā* «балта; сакал» (> рус. *брада ~ борода*) сүзеннән (Pokorny: 40), шуннан ук бор. фар. *tabar* > рус. *топор* һ.б. К. Абаев I: 451; Сафаров: 32; ССТМЯ I: 71; Федотов I: 447–450; ЭСТЯ VII: 101–102.

**БАЛТЫР** «икра ног» < гом. төрки *балтыр, балдыр* «балтыр, аяк; кыяклы үсемлек сабагы, балдак; билдәмә» < **бағал-тур, бағал-тыр* (*-тур, -тыр* морфемасының чыгышы ачык түгел) «билдәмәле сабак» сүзеннән, *бағал* (к. **Бәкәл**) нигезеннән,

к. тат. диал. (ЗДС: 94) **бағылтырық** «завязка, перевязка», чыгт. *балдур* «беләзек; сум акча» (Радлов IV: 1505), *baldırın* «балтыр» (Поппе 1938: 202). Бор. төрки *baldır* «чыгынты тау, кашлак» сүзеннән *балтыр*га мәгънәви мөнәсәбәте ачык түгел: ихтимал, монда контаминацион тәэсирләр бардыр, к. як. *балчарган* ~ бур. *балсагар (< балчагар)* «кабарынкы мускул». К. **Балдак.** ЭСТЯ II: 54–55.

**Балтыр** сүзеннән: тат. диал. **балтырак** ~ төр. *baldırak* «балак» һәм тат. диал. **балтыра-у** «чалбар балагы итек өстеннән йөрү» (гадәттә балак итек эчендә була).

**БАЛТЫРГАН,** диал. **балдырған** «борщевик; дягиль» < гом. кыпч. *балтырған* (күп кенә телләрдә сирәк кулланыла), алт., хак. *палдырған,* башк. диал. *балдырған* < монг. *балдыргана, балчиргана* id. (*-гана//-гэнэ* үсемлек атамалары ясагыч кушымча, чаг. себ. тат. **каңа-у** «күпләп үсү»); бу сүзнең монголчадан таралганлыгына бер дәлил: Н. Барбаро «татарлар (монголлар) дала буйлап ерак сәфәргә юнәлгәндә **балтракан** дигән үлән үскән вакытны көтеп торалар – шуның белән терекләнәләр» дип яза (Барбаро и Контарини: 170). Ләкин ул **балтракан**ның нинди үлән икәнлеген кистереп әйтеп булмый, чөнки ул төрле үләннәрне белдерә, мәс., төр. *балдырган* «түндербаш», *балдыран* «шома көпшә», Будагов «шомалак (гладыш)» ди (I: 236), төр. *baldırıkara ~ karabaldır* «кара йонлач үсемлек», *baldus* «озын һәм киң яфраклы үсемлек» (Steuerwald: 86–87). Бу сүзнең тәүге, төп мәгънәсе «бәбәк, үсемлекнең нәфис яшь өлеше» (к. каз. диал. *балдыр* «су төбендә үсә торган йомшак үлән; һәр яшь, йомшак, нәфис җан иясе», *балдырған* «яшь үлән; курпы; буыны катмаган бала», к. Аманжолов I: 88) – асылда *балдыз ~ балдыр* белән бер һәм бор. *балды-* «үсү, яшь кенә булу» тамырыннан килә, к. **Балды, Балдыз, Балтыр.** К. ЭСТЯ II: 55–56.

**Балдырган** сүзе барлык күрше телләргә кергән: чув. *патран, палтран, пăлтаран, пултăран* (Сергеев 1971: 99–100), мар. *палдыран, полдран,* рус. диал. *балдырьян* (Даль) «балтырган», венг. *bojtorgan* «тигәнәк», кабарда. *батырган* «балтырган» һ.б. Räsänen 1969: 61; Федотов I: 444. Ним. *baldrian* ~ яз. (соңгы) лат. *valeriana* «песи үләне» сүзенең *балтырган* сүзенә мөнәсәбәте, тиешле фараз булса да, ачык түгел, к. Kluge: 84–85.

**БАЛЧЫК,** диал. **бәлчек** (к. мәкаль: *Акча – кылчык, бал – бәлчек*) «ил, тина, слякоть; глина» < гом. төрки *балчык* > гом. монг. *балчиг* id., *балчы-// былчы-* (бор. төрки *а ~ ы* чиратлашуы) «сыеклану, ләм хәленә килү» борынгырак *бал-//был-* «сыеклану, сыек булу; сыеклык, су» исем-фигыль синкретик тамырыннан (бу тамыр *бал* белән дә, *бала* белән дә бәйле түгел, аерым сүз булган булырга тиеш); *балчы*-ның фонетик параллеле *былчы-*, шуннан тат. диал. **былчык** «күз эрене» (*-чы//-че* кушымчасы күп кенә фигыльләрдән яңа фигыль ясый: *кыр → кырчы-, тип → типче-, тин → тинче-, чокы → чокчы-* һ.б.), к. ш. ук. чув. *пулчăк < полчăк* һәм *пылчак* «балчык, ләм»; сүзнең уйг. *балчук, балчуғ,* госм. *балчақ,* тат. диал., уйг. *палчық ~* хак. *палчах, малчах* вариантлары да бар. Бор. төрки *balčiq* «яңгыр».

«Балчык» мәгъ. кайбер телләрдә (бор. төрки, уйг.) *балық < баллығ* сүзе дә кулланыла (Мухамедова 1973: 66). Бу очракта сүзнең тамыры **бал* икәнлеге шәйләнә.

Шул ук *бал ~ был* тамырыннан тув. *балгаш,* хак. *палгас*, алт. *балкач > балкыш* «сазламык, батлаклык» сүзеннән **Балхаш** күле исеме килә.

Рус. *балчуг* дигән топонимнар (мәс., Мәскәүдә *Балчуг, Балчужная* урамнары) һәм *балка* < төрки *балка* «сазламыклы тау арасы» сүзе дә шуңа тамырдаш. К. **Балка, Балык, Былчырак, Пычрак, Пычыргы.** Räsänen 1969: 60; Федотов I: 464–465; ЭСТЯ VII: 102–105.

**Балчык** продуктив нигез: **балчыклы, балчыксыз, балчыклык; балчыкла-у, балчыклан-у; балчыксыл** (туфрак), **балчыкчыл** (хайван, үсемлек).

**БАЛЫК,** диал. **палык** «рыба» < гом. төрки *балық* id. (к. ЭСТЯ II: 59–60), сүзнең төгәллекле этимологиясе юк, зур ихтималлык белән **бал-лыг* «суныкы, сучан, сазныкы, сазчан» сүзеннән дип уйларга ярый, к. як. *баллыгы* «яшь шамбы», *баллыгынай* «шамбы уылдыгы; бака балалары», *баллымах* «балык тоту өчен уелган киң бәке». Һәрхәлдә төрки *балық* (бор. төрки *balaq, balïq*, к. ДТС: 80) чагыштырмача соң ясалган сүз һәм аның ясалышында очраклы моментлар роль уйнаган булса кирәк (мәс., табу йоласы яисә бу сүз балыкның бер төрен генә белдергәндер һ.б.).

**Балык** бор. төрки *balıq* (*balčıq-balıq* парлы сүз) «яра, былчырак» һәм *balıq-* «яралану» (ДТС: 80), ш. ук. *balčiq, balčiuq* «балчык» сүзләре белән кардәшлеге дә бик ихтимал, к. чув. *полă > пулă* «балык», хак. *палығ* «чиләнеп – «сазланып» торган яра», к. ш. ук **пычыргы.** Барча бу сүзләрнең уртак тамыры **bal//bıl* дип уйланыла һәм ул һиндевр. **bal* (шуннан, хосусан, рус. *болото* «саз» сүзе

килә дип тә уйлыйлар) «саз; ак (?)» сүзе белән тамырдаш дигән ностратик фараз бар.

**Балык** «су хайваны» һәм бор. төрки *balıq, baluq* «кала, шәһәр» (ДТС: 80–81) сүзләренең бердәйлеге-түгеллеге бәхәсле шәй (к. Трубачев: 10–12). Кайбер телчеләр бу сүзләрнең бердәйлеген «сазламык > балчык > балчык дивар > кальга, кирмән» күчешләре ихтималлыгы белән раслыйлар. Чыннан да бор. төрки кальга-кирмәннәр ике кыса арасына сыек балчык коеп (к. **Койма**) ясалган диварлар белән характерлы булганнар (коры һәм эссе климатта бу диварлар тиз кибеп, җитәрлек дәрәҗәдә ныклы киртә хасил иткәннәр). Чаг. монг. диал. *балга, балаг,* «җир балчык».

**Балык** продуктив нигез: **балыкчы, балыкчылык; балыклы.** Бу сүз төркиләр белән күрше халыклар телләренә дә үтеп кергән (чаг. рус. *балык* «каклаган балык» – кырым төркиләре шундый балык белән сату иткәннән дип уйлыйлар). К. **Балыклау.**

Räsänen 1969: 61; ЭСТЯ II: 59–60; Федотов I: 443.

**БАЛЫКЛАУ** диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «место, где ловят рыбу» – «балык тотыла торган урын», чаг. себ. (Тумашева 1992: 168) *палыхлау* «балык тоту». Бу сүзләр бүтән телләрдә дә очрый һәм Кырымдагы *Балаклава* шәһәре атамасы да шуннан килә.

**БАНАРАС** (Вәлиди II: 390) «вид белой хлопчатобумажной ткани» < Һиндстандагы *Бәнарәс* шәһәре исеменнән.

**БАНДИТ** «бандит, член банды» < рус. Тат. телендә актив сүзьясагыч нигез: **бандитлану, бандитла́рча, бандитлык.**

**БАНИ** «строитель; основатель какого-либо общества; попечитель учебного заведения» < гар. *bānī* id. **Бина** сүзе белән тамырдаш.

**БА́НКА [банкы̆]** «банка (стеклянная и т.п.)» < рус. Тат. сөйләм телендә *банк* та *банкы* дип әйтелә. Хәлбуки *банк* Көнб. Европа телләреннән алынган (ит. теленнән таралган) сүз, *банка* исә рус теленең үзендә барлыкка килгән сүз (к. Фасмер I: 120–121).

**БАҢ** иск. (Батырша һ.б. телендә) «гвалт, шум» < фар. *баң* id. Бор. төрки (ДТС: 81, 94) *beŋ, baŋ* «кычкырык; елау, зар».

**БАП** диал., тар. «весьма подходит, уместно, к месту» < фар. *bāп* id. (гар. *bāб* сүзеннән булса кирәк). Бу сүз Урта Азия төрки телләрендә киң таралган һәм шуннан яңа сүзләр дә ясалган (уйг. *бапла-*, кырг. *бапта-* «нәрсәне дә булса бик шәп эшләү, булдыру»). К. ш. ук **Бәплә-ү.**

**БАПИШ** (әстр.) «утка; баклан» ~ ком., к.-балк., аз. *бабуш, бапуш* id. Төньяк Кавказда киң таралган.

**БАР** «есть, имеется» < гом. төрки *бāр* (уйг., көнч. төрки *пар,* чув. *пор* > *пур*) id.; ихтимал, бор. **бу-, *буа-* «булыну, булу» ~ бор. монг. *bui* (хәз. монг. *бий*) «бар», тунг.-маньч. *би-* (к. ССТМЯ I: 79–80) «бар булу» фигыле белән тамырдаштыр. Чаг. ш. ук һинд-евр. *bheu, bhnu, bhū* «үсү, таралу, булу» (Pokorny: 146). К. **Бул-у.** ЭСТЯ II: 61–63; Федотов I: 444–445.

**БАРАБАН** «барабан» < кр.-тат., төр. *балабан* «солдатларны өйрәткәндә, аю биеткәндә кулланыла торган барабан» сүзеннән. К. ш. ук ком., аз., уйг. *балабан* «арканда биюче чыгыш ясаганда уйнатыла торган быргы; арканда биюче үзе» < *пәһлеван,* к. **Балабан, Балпан:** кайбер бүтән очраклардагы кебек (к. *кикелек* > *кикерек, челем* > *черем* һ.б.ш.), монда да *л* > *р*; к. добр. татарлары әкиятендә: *Anası man baraban [зур] sandıknı aşkanlar* (Akb: 17) «анасы белән барабан сандыкны ачканнар». Хак. *палабан кам* «пәһлеван кам» – барабанчы (к. Чирім тамырлары: 17). Рус. **барабан** тур. к. Аникин: 116.

**БАРАГАЙ, бараган** в выражении **башкорт барагай (бараган)** «толстый башкир» ~ кырг. *бараан* «(калын) гәүдәле», *баранду* «күренекле (конкрет мәгънәдә), зур», тув. *бараан* «дәү кыяфәт, силуэт», як. *баараҕай* «дәү, гәүдәле, базык» һ.б. монг. телләреннән килсә кирәк.

**БАРАК I, карабарак** (БТДһ: 71) «порода собак с лохматой чёрной шерстью», бор. төрки (ДТС: 83; Redhouse: 139) *barag* id. Бу атама тур. төрле мәгълүматлар Өгәл (Ögel 1993: 185–193, 394–397) китабында китерелә: *бараклар* кәркәс дигән кошның йомыркасыннан туалар, ди. *Эт барак, кыл барак* дигән кабиләләр, *Карабарак* дигән бер патша булган һ.б. *Барак* ыруы башкорт, нугай, казакларда хәзер дә бар. Бу ыру венгерлардан килә дип уйлыйлар: анда *Bárag* ыруы бар. Тикшерергә кызыклы тематика.

**БАРАК II** «барак, одно- или двухэтажное здание со многими квартирами» тат. теленә русчадан кергән, ләкин рус теленә бор. тат. теленнән килгән дип карасак (рус телчеләре дә каршы түгел) хата

булмастыр, к. бор. тат. (Ибне Баттута буенча, Алтын Урдада, Үзбәк хан сараенда, к. Из глубины... : 198–199) *барака* «дүрт багана өстенә корылган зур чатыр» ~ алт. (Баскаков 1965: 65–66) *барақ,* төр. *baraka* «яңгырдан, кардан саклану өчен зур корылма». Бор. төрки (ДТС: 84) *barq, ev-barq* «бина, корылма», *barïq* «еракта күренгән ачык-аян булмаган силуэт» (чаг. тат. *каралты* «корылма; силуэт»). Күрсәтелгән сүзләрнең гомогенлыгы исбатлы түгел. Европа телләрендә дә (Kluge: 90) *Baracke* «лапас, корылма» сүзенең чыгышы бәхәсле дип исәпләнә. Фар. *багряһ* «юлакай кереп чыга торган урын; юлдагы (очраклы яисә махсус) корылма», *барäк* ← *bār* «йөкләр саклана, калдырыла торган корылма» фонетик җәһәттән **барак** сүзенә охшамыйлар.

**БАРАНЖАР** к. **Бәрәнҗәр.**

**БАРДАК** *русча урта* [*-к*] «бардак, бордель» – тат. телендә рус теленнән, әмма рус телендә себ. (Старчевский), госм., кр.-тат., куман. *бардақ* «күкшен, сидек савыты» сүзеннән булса кирәк (Дмитриев 1962: 493). К. ш. ук ЭСТЯ II: 65–66; Dobr. I: 260.

**БАРК: барқ-барқ** – подражание громким крикам уток. Бу вариант әдәбиятта ешрак кулланылган **бак-бак** вариантыннан дөресрәк – үрдәк авазына якынрак. К. түбәндәгене.

**БАРКЫЛДАК, баркылдык** «утка» (аффективное название), кр.-тат. (Dobr. I: 261) *barqıldaq* «кыр үрдәге» ~ бор. төрки (ДТС: 78) *bayïrlaq* «чүрәгәй үрдәк». Бу сүз барча төрки телләрдә бар бугай, к. кырг., каз. *барқылдақ* «көчле тавыш белән күп сөйләүче кеше» – әлбәттә үрдәк атамасыннан күч. мәгъ. **Барқылдақ, барқылдавық, барқылдық** ← **баркылда-у** «барқ-барқ итү», к. югарыдагыны.

Сәеррәк рәвештә **баркылдак** сүзе белән башк. (БТДҺ: 262) *парпылдақ* ~ хак. *парлах, парчых* «сыерчык; чуартүш» һ.б. сүзләр буталыша. Ягъни **баркылдак ~ парпылдак** дип сыерчыкны да атыйлар. Хәлбуки үрдәк тавышы белән сыерчык тавышы охшаш түгел.

**БАРЛАК I** «залежь (необрабатываемая земля)» ~ чув. *парлак* id. < рус. *перелог* булса кирәк. Чаг. ш. ук түбәндәгене.

**БАРЛАК II, барлык** «временное жилище (во время полевых работ); убежище» (к. ТТДС I: 70), диал. ш. ук **бурлақ, бурлак** < бор. төрки *borluq* «виноград (бакчасы), виноградлык» сүзеннән булса кирәк (Урта Иделдә виноград үсмәгәч, бу сүз төрле үзгәрешләр кичергән), тамыры бор. төрки *bor* «шәраб; виноград». К. ш. ук тат. диал., ком., к.-балк. *барлақ* «чирәм җир, калдау»; каз. диал. *барлақ* «бастырма, шикмә» виноградлыктагы шәйшеләрне хәтерләп әйтелгән сүз булса кирәк.

**БАРЛАС** «крылатый барс на гербе Татарстана (и Золотой Орды)», издавна используется и как имя собственное. Татарстан гербындагы ак барыс, асылда, барлас – канатлы барыс. Кояш нурлары фонында чабып барган канатлы барыс (гепард) Алтын Урда акчаларында бик еш очрый, шундый ук барыс бор. Енисей кыргызлары (хакаслар) байрагында да булган. Як. *барылас* «бөркет, барыс-кош» кангалас ыруының символы, монг. *барулас, барула* «бөркет, оча торган барыс» – бор. бер ыруның атамасы, чыгт. *барлас, бәрләс* «бөркет, сәргаскәр, батыр сугышчы» һ.б. сүзнең *бар* «барыс» һәм *лаус* «ләү, утлы бөркет» сүзләреннән ясалганлыгын күрсәтәләр.

Күп кенә сүзлекләрдә *барлас* монг. телләреннән таралган дип күрсәтелә. «Үзбәк Совет энциклопедиясе» моны катгый рәвештә кире кага һәм бу сүзне бор. төрки сүз дип раслый (үзбәкләрдә *барлас* дигән кабилә һәм ырулар бар, шуларның берсеннән Аксак Тимер чыккан). Ләкин сүз азагында *-с* кушымчасы (мондый очракта), чыннан да, монг. телләренә хас. Шуңа күрә *барласның* монг. сүзе булуы бик ихтимал. Чаг. **Барсула.**

Гомумән, *барыс, барс* > *бар* сүзе этноним буларак очсыз-кырыйсыз төрки дөньяның төрле почмакларында калкып чыга: *ак барыс, ала барыс* һәм *барсган, барсил* кабиләләре шулардан иң билгелеләре. Будагов I: 253–254; Räsänen 1969: 63.

**БАРМАК,** себ. (Тумашева 1992: 168, 148) **пармақ, мармақ,** урта диал. (ТТДС I: 70), башк. диал. (БһҺ III: 32) **барнақ** «палец».

Бу сүзнең ике варианты ике чыганактан килә: 1) **бармак** < гом. кыпч., уйг., гом. угыз һ.б. *бармақ,* 2) иске тат. **барнак,** төр. *parnak,* алт. диал. *парбақ* һ.б. < бор. төрки **barıŋaq, *barınyaq* «тоткыч, капшагыч» (← *barı-* «тоту, капшау» к. ЭСТЯ I: 66–68) тат. диал., төр. диал. *barnaq* >> чув. *порна* > *пурна*. Димәк, бор. төрки диалектларның күпчелегендә бу сүздә бор. *ң* > *м*, кайберләрендә *ң* > *н* күчеше йөз биргән. Иң кызыклысы шул ки, мар. *парняш, парняшка* < *пäрнäскä* ~ чув. *пурнеске* «уймак» сүзләре, һичшиксез, тат. диал. (ТТДС I: 70)

**барнасқа** < *барнақса* (метатеза) «уймак, барнак савыты» сүзеннән киләләр (бүтән чыганак теркәлмәгән). Димәк, Урта Идел регионында иң бор. төрки тел – татар теле, аның *барнақ* дип сөйләгән борынгырак катламы булып чыга! Чув. *порна* < болг. **ба°рнаһ, *ба°рнах* < бор. тат. *барнақ,* димәк бу сүзне болгарлар бор. татарлардан алганнар.

*Барнак ~ бармак* бу мәгънәдә иң бор. сүз түгел, моны як. бармак – *эргэх* (бор. уйг. *äрäңäк*), ә тув. *салаа* (к. **Сала II**) булуы дәлилли. Бүтән төрки телләрдән туваларның бабаларыннан да элегрәк аерылган болгарларда да бармак бүтән сүз белән белдерелгәндер дип уйларга бөтен нигезләр бар.

**Бармак** сүзенең тамыры *бари-* < *бары-* «тоткалау» монг. телләрендә сакланган. Монда тән әгъзаларын белдергән ностратик тамырлар эзләүнең (Рамазанова 2013: 122) кирәклеге күренми.

**Бармак** продуктив нигез: **бармаклы, бармаклык, бармаксыз, бармакса, бармакча; бармаклан-у** һ.б. Бармак төрләре (*баш бармак, имән бармак* һ.б.) тур. ЗДС: 100–101; Тимергалин: 78; Рамазанова 2013: 112–117 (күп вариантлар һәм утызлап төрле аерым бармак атамалары күрсәтелә: аерым бармак атамалары тур. иң тәфсилле пассаж); Dobr. III: 29–30 (добр. *пармақ* сүзенең төрле мәгъ., ш. ук аерым бармак атамалары күрсәтелә).

**БАРНАСКА** «напёрстка» < диал. **барнакса** id. ← **барнак** диал. «бармак» сүзеннән регуляр ясалма (*-са* аффиксы киелә торган нәрсә атамаларын ясый). Монда метатеза бик күптәннән булган, к. мар. *парнят, парнятка, пäрнäска,* чув. *пӳрнеске* id. К. югарыдагыны.

**БАРНАУ [ба°рнаw], барнавыл, барнагыл** «трёхкопеечная медная монета» (Вәлиди II: 358) – себ. тат. *багыр нагыл* > *бавыр навыл* «бакыр тәңкә» сүзеннән; *бақыр* > *бағыр* > *баwыр* «бакыр», *нағыл* > *наwыл* «кырые калку зур тәнкә» < гар. *нä'л* «үкчәлек, аяк киеме үкчәсе; дага; тәлинкә» сүзләреннән гыйбарәт. К. **Нал, Нәлбәк.**

**Барнаул** исеме ул шәһәрдә Екатерина II заманнарында шундый тәңкәләр сугылудан (Даль) килә.

**БАРСУЛА** – одно из племён древней Булгарии.

Мәгълүм ки, бор. Болгардагы кабиләләрнең берсе *бәрсула//барсула* дип, аларның иле *Барсулия* дип аталган. Бу сүзне күп чыганаклардан билгеле *барсил* төрки этнонимы белән чагыштыралар.

*Барсил* этнонимына килгәндә, ул – Көнч. Европада пәйда булган иң тәүге төрки кавемнәрнең атамасы. Бор. әрм. чыганакларында 194–216 елларда *барсилк* һәм *хазирк* дигән ике кавемнең Дербент аша Кура бассейнына чыгуы хәбәр ителә. Аннары V г. әрм. тарихчысы М. Хоренлы барсилләрнең Идел дельтасында (аның җитмеш тармакка аерылып диңгезгә койган җирендә) яшәүләрен һәм *хазир*ләр вә *булг*лар белән дус, бергә булуларын хәбәр итә. Барсилләр хәзәрләр белән кыз алышып, кыз бирешеп торганнар. VIII г. хәзәрләрне һәм хәзәрләрнең союздашларын гарәп сәргаскәре Мәрвән ибне Мөхәммәд тар-мар иткәч, барсилләр (аларны *көмеш болгар* дип атаганнар бугай) Болгарга күченгәннәр. Болгар тарихында билгеле **бәрәнҗәрләр** дә аларга ияреп килгән шикелле. К. **Бәрәнҗәр.** Шунысы кызык, *барсил* «барыс» сүзеннән булса, *хәзәр//кәзәр* иске монгол һәм алтай төркиләре телендә «ау эте» дигән сүз. Барсилләр белән хәзәрләр үзара «ярышып», гепард белән бурзай кебек, шундый атама алмадылар микән? История татар I: 278, чаг. **берсуат.**

**БАР-У** «целенаправленно двигаться (от говорящего); ехать, идти, ходить куда (для чего)» < гом. төрки *бар-* < *баар-* (чув. *пыр-*) id. Чаг. гом. ир. *bar-, bār-* «ат өстендә йөрү» (Абаев I: 232) < һинд-евр. *bher-, bhur-* «йөрү, хәрәкәт итү». Räsänen 1969: 62; Федотов I: 465.

**БАРУТ** «порох» < төр. *barut*, фар., көрд. *bārut* id. Төрки сүз булса кирәк (Жантурин: 59). Чаг. **Порак.**

**БАРХАН** «бархан, барханы» – волнообразные горы в пустынях – **балкан** (к.) сүзеннән булса кирәк.

**БА́РЧА** «всё (что есть)» < *барыча, барычан*, к. хак. *парчан, парчаң* id.

**БА́РЫБЕР,** диал. **бәребер** «всё равно, в любом случае» < бары (да) бер; к. диал. *бардабер* «барыбер».

**БАРЫМТА** «баранта, угон скота у других» < монг. *баримта* «тоту; гаепләү» ← *бари-* «тоту, кармау» фигыленнән. К. **Бармак.** Рус. *баранта, барантач (< барантачы)* тур. Аникин: 117.

**БАРЫС** «барс» < гом. төрки *барыс, барс,* монг. *бар,* як. *баарын* «барыс; юлбарыс», Алтын Урдада *барыс* «гепард» < фар. *барыс, бабрыс* id. Ихтимал, һинд. *бабыр, бабур* «юлбарыс» һәм төрки *ус* (ДТС:

616) «зур бөркет» сүзләреннән торадыр (чаг. **Барлас**): **бабыр** да, **ус** та ау хайваны булган. Фар. һ.б. *барс, бабыр, бабрас* < хатт. *ha-prašš,* хетт. *paršana* сүзеннән таралган, к. Иванов В.В. Разыскания в области языкознания // Этимология 1976. М., 1978; МНМ II: 48–49.

Гомумән, *гепард, леопард* һәм *пардус,* лат. *pardalis* һ.б. кайбер ерткыч хайван атамаларындагы *пард* өлеше дә *барс* ~ *барыс* сүзе белән тамырдаш булырга тиеш. Рус. *пантера* ~ ним. *Panther, Pantel* «каплан, леопард» та әлеге сүзләр рәтендә тора шикелле, к. Kluge: 627. Чаг. рус. *барбос* «зур эт».

Тат. **прес, перес** ~ рус. *брысь* дигән песиләрне куу ымлыгы да мәзкүр сүзләргә тамырдаш бугай.

Уникеллык хайваннар календаре исәбендә **барыс елы** мөчәл башыннан өченче ел – әйбәт ел дип исәпләнә.

**БАСА I,** диал. **паса** (Тумашева 1992: 148), **маса** «посконь, мужские особи конопли», «бесплодный цвет; холостяк (не женившийся ни разу)» ~ башк. (БТДҺ: 39) *баҫау,* чув. *поса* > *пуса,* морд. Э. *пазе,* морд. М. *пазяй* id., башк. *баса* «яхшы җитен». Чаг. маньч. *масэ* «киндераш» < кыт. *мацзы* «киндераш» (ССТМЯ I: 532). Чаг. ш. ук рус. *посконь* < Балтыйк телләрендә *pas kanna, paskañas* «баса, саңгырау киндер» (Фасмер III: 339). Гомумән, ачык түгел. Федотов I: 451; Насипов 2007: 213.

**БАСА II,** диал. **пәсә, бәсә, мәсә, мыса** – модальная частица противительно-утвердительного значения ~ чув. *паса, пасса* (< тат. булса кирәк), алт. *база,* хак. *паза* id. Чаг. бор. төрки *basa* «соңыннан; һәм, тагы, соң?» (ДТС: 85). К. **Ләбаса.**

«Соң» мәгънәсе беренчел булса, бу сүз **бас-у** фигыленнән.

**БАСКАК** «наместник хана Золотой Орды, баскак» < гом. кыпч. *басқақ* id., төп мәгънә «басучан, изүчән».

**Баскак** «Алтын Урда дәүләтенләге югары чин, губернатор» сүзен гадәттә «басып алучы, налог җыючы» дип күз алдына китерәләр. Бу сүз, чынлап та, *бас-мак* «басу, бастыру, басып тору» фигыленнән ясалса да, аның тарихы катлаулырак. Ул монг. телендәге **даругачы** сүзенең кыпчакча калькасы. Монг. *дару-* «басмак, таптамак»; *даруга* «басып алынган өлкә, биләмә, губерния»; *даругачы* «биләмә башлыгы». *Даруга* сүзе Алтын Урдада аерым биләмә үзәкләрен тоташтырган *ямыл юлын* да белдергән һәм шуннан рус. *дорога* сүзе торып калган. Әмма *баскак* сүзе андый мәгънәне алмаган.

**Баскак** сүзе турында Аникин: 131 (бай әдәбият күрсәтелә).

**БАСКЫЧ,** сөйл. **бачкыч** «лестница» ← **бас-у.** Баскыч сүзенең мәгънәсе морфемик составына тәңгәл түгеллеге күзгә ташлана: **баскыч** асылда «басма, басып менә торган киртләч». Бүтән төрки телләрдә – бүтән сүзләр. К. **Шикмә.**

**БАСМА** – в словарях тюркских языков даётся ряд омонимов **басма,** и все они образованы от *бас-* (к. **Бас-у**), но от различных его значений; тат.: «мостки, ступенька», «издание (книг и т.п.)», «краска для печати», «единица измерения ниток и холста» (ТТАС: 128–129) – бу сүзләрнең кайберләре (мәс., «буяу төре») Урта Азия төрки телләреннән килә. Үз чиратында, тат. теленнән бу сүзләр күрше фин-угор һәм рус телләренә дә кергән, к. Юналеева 1982: 89; Аникин: 131.

**БАСМЫР** «гнетущий, давящий» ~ башк. *баҫмыр* id. ← **бас-у** (к.). Чаг. **Үсмер.**

**БАСТАҢГЫР** диал. (ТТДС I: 71) «вечеринка молодёжи на свежем воздухе» ~ ком., каз. *бастангыр* id. < кыпч. *бағстан кӧр//бағстан кур* «ерак басудагы җыен-кор» (к. **Кор**) сүзеннән. Башк. *баштанкҹыу,* нуг. *бастанув,* әстр. (Арсланов 1976: 64) *башлангыр* id. беренчел яңгырашның төрле бозылышлары.

**БАСТАР** диал. (Башкортстан, Дөмәй авылында) «кольцевое крепление (например, косы к рукоятке – к косовищу)» ~ чув. *пастар*, мар. *пашкар* «бик, келә; кыллы музыка уен коралларында боргыч» < фар. *бäстк'āр* id. (*бäст* «бәйләвеч, тоташтыргыч», *бäстäн* «бәйләү, тоташтыру, ныгыту»).

**БАСТЫРЫК** «гнёт, прижим» > рус., мар. диал., удм. диал. *бастрык* < гом. кыпч., тув. *бастрық, бастырық,* үзб. *босриқ* id. Бу сүзнең (каз. *бастырық,* үзб. *босриқ,* төркм. *басрық*) «атябуы, чапрак» мәгънәләре дә бар.

Ясалышы буенча **бастырык** – «бастырылган (нәрсә)»; дөресрәге – *бастыргыч*. Рус. *бастрык* тур. Фасмер I: 132; Аникин: 121.

**БАСУ [баᵒсы̆w],** себ. **пасу** «пахотное поле», (ДС II: 44, 51) «ещё незасеянное поле», диал. (Рад-

лов IV: 1528) *басау* (?) id. ~ чув. *пос* > *пус*, *посӑ* > *пусӑ, посу* > *пусу*, мар. *пасу, пашу, пасо,* удм. *бусы* «басу» – Идел-Урал дистинктив сүзе һәм ул тат. теленнән таралган; удм. варианты тат. теленең Идел-Урал регионында бор.ы заманда – XIII г. кадәр үк таралганлыгын күрсәтә, чөнки пермь телләрендә *а* > *у* шактый бор. күренеш (чув. *а* > *о* > *у* күчешләренең моңа катнашы юк).

**Басу** сүзе исемләшкән фигыльгә охшаган, ләкин мәгънәдәш фигыле беркайда да теркәлмәгән. Тәүдә *басу* исем түгел, сыйфат булган булса кирәк (*басу җир* тезмәсе булган) һәм ул иске кыпч. *баз-* «казу фигыле белән баглы. К. Котби телендә:

*Чәтүк, ким өз баласын тогзун асрир,*
*Суңы һәм өзи бир гөр-түрпә базар,*

ягъни «тугыз бала үстергән кыргый мәче соңында үзенең гүрен-төрбәсен үзе казый» (чүл кыргый мәчеләренең авырган чакларында комга өн казып ятулары тур.); тат. диал. (ТТДС I: 71) *бас-у* «казу» ~ як. *бас-* «җирне көрәп алу» бор. *баз-* яңгырашыннан булырга тиеш (тат. телендә бу сүз *басу-* «бастыру; изү» сүзе белән контаминацияләнгән). *Баз-* «казу» фигыле омоним сүзләр *бас-у* һәм *баз-у* «җөрьәт итү» тарафыннан читләтелгән булса кирәк. Күренгәнчә, *басу* тәүдә сөрелгән җирне түгел, казылган җирне аңлаткан.

**Басу** сүзенең **баз** сүзе белән бәйләнешы шиксез дип әйтергә мөмкин. Әгәр төп нигез *баз-* яисә *баз* (исем) булса, *басу* < *базсу* (чаг. *уйсу*) булырга тиеш.

**Басу** сүзенең этимологиясе мөһим этногенетик әһәмияткә ия – ул бор. татарларның болгарлардан элек үк утрак тормышка күчкәнлеген дәлилли.

Räsänen 1969: 64; Федотов I: 450–451 (чув. *пус, пусӑ* < «басу» һәм *пус, пусӑ* «баз» сүзләрен аерым бирә һәм үзара багламый); Ахметьянов 1989: 52.

Басу продуктив нигез: **басулы, басулык** h.б.

**БАС-У,** себ. **пас-у** «наступать; стоять стоймя» (со многими вторичными значениями) < гом. төрки *бас-, баас-* (чув. *пус-* < *пос-,* мар. *пыс-*) id. Иң бор. төп төрки сүзләрнең берсе. Räsänen 1969: 64; ЭСТЯ I: 74–78; Федотов I: 448–449.

**Бас-** иң продуктив тамырларның берсе: **басыл-у, басын-у** (*басынып утыру* «боегып утыру»), **басыш-у, бастыр-у** (болардан тагын сүзләр ясала: **басылдыр-у, басынкы, бастырык** h.б.); **баскын, баскыч, басмач.** К. **Баскак, Басма, Басым** h.б. (бу сүзләр фин-угор телләрендә дә очрый). Будагов I: 229–231.

**БАСЫМ** «(твёрдый) шаг; ударение (в фонетике); давление», разовое действие (от всех значений слова **бас-**). Грамматик-фонетик мәгънәсе XX г. карарлашкан.

**БАСЫМЧАК** «кроткий; униженный», иск. «ступенька крыльца» ~ башк. *базымсаҡ* id., төркм., аз. *басғанчаҡ, басғынчаҡ* «басма; ишек алды басмасының бер тактасы». Хәз. тат. мәгънәсе *басымчак итү* тәгъбиреннән килә, төп мәгънәсен аңлаганда, бу фразеологизм «кимсетү» генә түгел, «кеше башына басып күтәрүлү, кешене үзенә басма тактасы итү» булып чыга. *Басымчакка бака баш* мәкалендә яр буе басмасы *басмачык* күз алдында тотылган. Тамыры, әлбәттә, **бас-у.**

**БАСЫНКЫ** «сдержанный, спокойный» башк. *басынҡы* id. ← **басын-у** «үз-үзеңне басу, тыелу», чаг. ш. ук диал. **бастырынкы** «басынкы» ← *бастырын-у,* чув. *пусӑрӑнкӑ* «басынкы» тат. теле материалы тәэсирендә ясалган. Чаг. ш. ук башк. *базылҡы* ~ удм. *басыл* «басынкы». К. **Бас-у.**

**БАСЫРГАН** «домовой, душащий во время сна» – бу сүзне *бастырылу* белән баглау бик табигый кебек. Ләкин к. венг (МНМ I: 984) *bо́соркань* «убыр».

**БАТА,** себ. (Тумашева 1992: 166) **пада, падика** ~ каз., кырг. *бата,* төркм. *пата* «молитва; благословение» < гар. *fātихā* id.

**БАТАГА** диал. (Арсланов 1992: 118) «балыкчылар торагы» ~ каз., ком. *батаға* < монг. *байтагай* «тукталу урыны» (*бай-* «тукталу»). Рус. *ватага* «төркем; балыкчылар әртиле», бор. рус. «куыш, шалаш» ~ морд. М. *ватага* «елга буенча балыкчылар тукталган урын». Бу сүзне чув. теленнән чыгару дөрес түгел.

**БАТИНКА [к], батинкә, бәтинкә** «ботинок» < рус. *ботинки* (тамыры *бот-* Көнб. Европа телләреннән).

**БАТКАК** «грязь, слякоть» ← **бат-у;** бу мәгънәдә сөйләшләрдә сүзләр күп: *баткын, баткалак, батлак, батмак* h.б. ~ кырг., каз., чыгт. *батҡаҡ,* угыз. *батғаҡ, батаҡ*, ком., к.-балк., төркм. *батмаҡ,* нуг., каз., к.-калп. *батпаҡ*. Рус. *баткак* тур. Фасмер I: 134; Аникин: 122.

Дерив.: **баткаклы, баткаксыз; баткаклык** h.б. Ш. ук мәгъ. якын **баткалак** сүзе бар.

**БАТКЫЧ,** себ. (Тумашева 1992: 169) **паткыц** «крыльцо» ~ ком. *баткыч* «баскыч, трап». Бу гом. кыпчаклык заманнарында яисә Алтын Урдада еш кулланылган сүзнең ясалыш нигезе шул чорларда ачыграк булган. К. ш. ук тат. диал. **батмаш, бацман** (ТТДС I: 72–73) «болдыр, ишек алды басмасы». Боларның нигезе тат. диал. *баст, паст* «болдыр» (к. **Паст**) булуы ихтимал (*баст* > *бат, бац*).

**БАТМАН** «мера веса (≈10 фунтов мёда или 4 пуда ржи, приравненного по цене); мера земли (1/4 десятины); кадка; сосуд из полого ствола дерева (для мёда)» > чув., мар. *патман*, удм., морд. *батман* < гом. кыпч. *батман* (кырг., каз., к.-калп. *батпан*) ~ барча төрки-монг. телләрендә билгеле сүз. Аның үлчәү берәмлек мәгънәсе (үзб. *батман,* уйг. *патман* һ.б.) орлык авырлыгыннан – бер батман чәчәрлек җирне белдерә (к. Jarring: 43); уйг. *патман*ы, мәс., 573,44 кг арпа чәчәрлек җир мәйданы булган (к. ш. ук. Arat. 1943: 342–344). Авырлык үлчәме буларак *батман* гаять төрле конкрет мәгъ.: рус телендә генә дә 26 поттан башлап ике кадакка чаклы (к. Даль), төр. телендә дә шулай ук 1–4 кг (к. Redhouse), *батман* сүзенең бүтән икенчел мәгъ. дә күп, мәс., ком. «балчык чүлмәк; йон үлчәү берәмлеге» һ.б. К. Будагов I: 231, 589.

**Батман** сүзе тур. әдәбият чиксез. М. Рясянен (1969: 65) *батман* < *бәзмән* < фар. *вазнӓн* «авырлыкча» (*вӓзн*) дигән күптәнлеге (XIX г. бирле килгән) фикерне кабатлый. А. Габән (1973: 63) бор. уйг. *batman* < сугд. *ptm'n* «үлчәм» ди. Э.В. Севортян (ЭСТЯ I: 81–82) төрле фаразларны китерү белән чикләнә. Рус теле буенча этимологик хезмәтләрдә *батман* һәм *бизмән//бәзмән* сүзләренең тарихи бердәйлегенә шик белдерелә һәм *батман* сүзе *бат-у* сүзенә (үлчәүнең бер тәлинкәсе «бата», имеш) нисбәт ителә (к. Фасмер I: 134). А. Аникин (: 122) бу фикерне хаклы рәвештә кире кага. К. ш. ук Тимергалин: 79.

Безнеңчә, *батман* ~ уйг. *бадман*, монг. *бадман* «кытай кадагы (фунты)» бор. төрки *баҙ* «бал» сүзеннән, к. кар. *бат*, рус. арго (к. Вопросы социальной лингвистики. М. 1969: 413) *баз* «бал» (< бор. кыпч.); Үзәк Азиядә *бат* > *пат* «бал»; *-ман* исә ир. *мэнн* (к. Будагов II: 254), *мани* «авырлык үлчәү берәмлеге» ~ чыгт. *ман* id. *Батман* сүзенең *бал* белән баглы булуы тур. чуваш тарихчысы В.Д. Димитриев та яза (Димитриев 1982: 95–103); чув. *пасман* «батман» һәм *батман* сүзләренең бердәйлеге тур. к. Федотов I: 389, 390. К. ш. ук к.-балк. *батман* «умарта».

Батман сүзенең киң таралуы бор. заманнарда балның акча функциясендә йөргәнлегеннән килә: *бал* бу функциягә бик ярашлы – ул тиз бозылмый (чаг. мәкаль: *бал бозылмый, кыз картаймый*). Фонетик җәһәттән *батман* < *бадман* < *баҙман* > *базман* > *бәзмән* ~ *бизмән* бик ихтимал, хәтта законлалыклы; мондый күчешләр Үзәк Азиядә – уйгур мәдәнияте даирәсендә була алган. Шуннан төрле юллардан ике вариант *батман* һәм *бәзмән* Урта Идел регионына килеп ирешкән. Ахметьянов 1989: 155–157. К. **Бизмән.**

**Батман** продуктив нигез: **батманлы, батманлык, батманла-у** (чаг. бор. чыгт., монг. *batmanla-* «авырлыгын үлчәү», к. Поппе 1938: 113–143); фольклор телендә *батман* зур, авыр нәрсә мисалы (к. мәкальләр: *Идел суы илле батман; Акылы бер батман; Батманбаш* – әкият герое).

**БАТРАК** «батрак» < рус. (шуннан ук чув. *патрак*, мар., удм. *батрак*). Рус теленең үзендә бу сүзнең этимологиясе бәхәсле һәм төрлечә аңлатыла. Гадәттә, аны төрки телләрдән дип исәплиләр һәм чыннан да шулай уйларга нигезләр бар (әмма ышандырырлык арадаш дәлилчекләр генә җитми); ихтималлыклары түбәндәгечә:

**батрак** < иске тат. *батырак* «батырның урынбасары» (**батыр** «бурлакларның башлыгы»);

**батрак** < нуг. *бадрак, бадырак* нугай кабиләсе; бадраклар Казанда да яшәгәннәр (к. Продолжение древней российской вивлиофики: 146);

**батрак** < монг. *батрагчин* «фуражир, терлекче, мал караучы» (*батра-* «терлек ашату»);

**батрак** < монг. *бартагчин, бэртэгчин* «кара халык вәкиле» < сугд. *prtkčn* < санск. *prtagjina* id. (Владимирцов: 135);

**батрак** < бор. уйг. *batraq, batraγ* «тизрәк! җәһәт! ятьрәк!»;

**батрак** < калм. *бадараг* (~ мар. *падра*) «тәбәнәк базык кеше», шуннан нуг., каз. *бадырай-* «дәүлеге белән аерылып тору», «(күзе) акаю», *бадырак* «батрак; акайкүз»;

**батрак** < тат. *бәтрәк* «түбән катлам кешесе», к. **Бәтрәк;**

**батрак** < себ. *патрак* «сәләмә, эш киеме» (к. Тумашева 1992: 161) (< *балтырак* «итексез»?), *патрат-у* (< *балтырат-у*) «киемне җыйнаксыз кию». Бу ихтималлыкларның берәвен сайлау өчен материал – төгәлләргә мөмкинлек биргән текстлар, сүз кулланышлары һ.б. юк.

**Батрак** (бигрәк рус телендә) продуктив нигез: **батраклы, батраксыз, батрачком** (русчадан бул-

са кирәк) – 1920 нче елларда авылларда батраклар комитеты. *Батрак, батрак̡* элекке СССРдагы барча төрки телләрдә очрый, ләкин һичбер очракта рус теленнән түгел дип әйтеп булмый. Ахметьянов 1989: 163.

**БАТ-У,** диал. **пат-у** «погрузиться; тонуть» (со многими вторичными значениями) < гом. кыпч. *бат-*, гом. төрки *бат-*, хак. *пат-*, чув. *пот-* > *пут-* id. (гомумән, күп кенә күч. мәгъ. кулланыла). Ошбу сүз чув. телендә татарчадан булса кирәк, чөнки *пот-* > *пут-* белән беррәттән *пыт-* (*пытар-* «яшерү; батыру») варианты – болг. сүзе дә шәйләнә.

*Бат-* тамыры монг. *багта-*, тунг.-маньч. *бакта-, бат-* «сыю, сыеп бетү, бату» (ССТМЯ I: 76–77) сүзе белән бердәй булса кирәк, к. себ. тат. (ДС I: 30) *бат-* «сыю, сыешу». Ихтимал, бу сүз **багы-* фигыленең йөкл. юнәлешедер, к. кор. *па-* «бату, ташу» (Ramstedt 1952: 148); ЭСТЯ II: 78–80; Федотов I: 455.

**Бат-** продуктив нигез: **батыл-у** («батырга туры килү» мәгъ.), **батын-у** (диал. «фикерен, мәелен яшерү»), **батыр-у (< баттыр-), баткыл, батма** («бата-калка торган», мәс., «батма насус»); **батык, батым, батынкы, батыш** һ.б. (бу сүзләрдән икенчел дериватлар тармаклана). К. **Баткак.**

**БАТЫР** «храбрец, герой; богатырь; чемпион в борьбе» < гом. төрки *батыр, матыр, баатыр, баатур* һ.б. < бор. төрки *baγatur, baγatır* id., ш. ук титул; себ. *багадыр* «баһадир, каһарман» икенчел (фарсычадан яисә русчадан) булса кирәк; монг. *батор, баатур* «батыр» һ.б. (бик киң таралган сүз, к. Doerfer II: 366–377).

Бу сүз төрлечә аңлатыла: 1) һинд-ир. *bahadur* < бор. *maha, bhaha* «зур, бөек» һәм *turas* «көчле, тизгер» сүзләреннән гыйбарәт дип; 2) тибет. *dbaa* < *dbaha* «герой» һәм монг. аффиксы *tur-* сүзләреннән дип; 3) борынгы һунн патшасы – кытайча *Маодунь* исеменнән дип (к. Материалы по истории сюнну: 38–40) һ.б. К. **Баһадир, Матур.**

Рус. *богатырь* куман теленнән булса кирәк. ЭСТЯ II: 82–85; Федотов I: 391; ССТМЯ I: 61–62; Иванов 1993: 35.

**БАУ [ба$^{о}$w]** «верёвка» < гом. кыпч. *baw* (*бау, бав*, кырг. *боо*) < гом. төрки *бāғ* «бау; төргәк, бәйләм» (ЭСТЯ II: 13–17) бор. *bā-* «бәйлә-ү» сүзеннән ясалган (*ba-γ*), к. бор. *bal-* «бәйләнелү» һәм *ban-* «билгә буу»; гом. төрки *бай* «бәй» сүзе турыдан-туры *бāғ*дан түгел, ә аерым *бā-й-* фигыль нигезеннән булса кирәк (чаг. тат. диал. *бәйгеч* «бәйләгеч»). К. **Багла-, Баглы, Бәй.**

*Ба-* фигыле монг. вә тунг.-маньч. телләрендә дә бар һәм кор. *pa, paŋ* «бау, киндерә» белән чагыштырыла (Ramstedt 1952: 179). К. ш. ук Мухамедова 1973: 63; ЭСТЯ II: 13–17.

Тат. диал. *бау-шу* < бор. төрки (ДТС: 77) *baγ čoγ* «төйнәлгән төргәкле таварлар» сүзеннән.

**БАХБАЙ** «лошадка (в детском языке); конь» – ат чакыру ымлыгы *баһ-баһ* сүзеннән (*баһ-бай*) > мар., чув. *пах, паххи* id.. Бу ымлык исә бор. сармат (? к. Гордеев I: 206) *бах* «ат» сүзеннән, к. рус. диал. *бах* «җәләхә, арык ат», бор. рус. *бахмат* «ат» («татарская лошадь» диелгән, к. Срезневский), осет., ингуш. (Абаев I: 256) *бәх* «ат», груз. *бахи* «начар гына ат» һ.б., к. ш. ук башк. диал. (БҺҺ II: 41, 64) *бахмис* «чабышкы ат», *бәхмис* «дәү ат». Ахметьянов 1989: 72.

Уйг. *пихпай* «йонлач» сүзе мәгъ. җәһәтеннән **бахбай**га бигүк ошамый, бәлки Үзәк Азиядәге йонлы кыргый атлар тур. сүз барадыр.

**БАХЫР,** диал. (ДС III: 123) **факыр, пакыр**, (ДС I: 27; Тумашева 1992: 166) **багыр, пагыр** «бедняга, бедолага», ш. ук «мәрхүм» > чув. *паххăр* «мескен, бахыр», мар. *пакыр, покыр* «юньсез» (Упымарий: 159) ~ каз. *бақыр, пақыр,* кырг. *бақыр,* төркм. *пақыр* «бахыр» < гар. *фāк̣ӣр* «фәкыйрь» сүзеннән. К. **Фәкыйрь.**

**БАҺА, бәһа** «цена» > чув. *паха,* мар. *пага* id. К. **Бәя.** Федотов I: 392.

**БАҺАДИР** кит. «богатырь; богатырский» < фар. *бāһāдир* id. К. **Батыр, Матур.**

Дерив.: **баһадирлык, баһадирларча; баһадиранә** < фар.

**БАЧӘК** «босяк (как социальная прослойка)» < рус. Асылда «яланаяк» мәгъ.

**БАШ,** себ. **паш** «голова; головной» < гом. кыпч., уйг., угыз. *баш,* алт. диал. *паш*, нуг., каз., к.-калп., як. *бас*, хак. *пас* һ.б. ~ чув. *поç* > *пуç,* тув. *бāш,* бор. төрки (ДТС: 81–82) *baš* id. Чув. варианты болг. *баж* < **балч* вариантыннан закончалыклы рәвештә килә (әйтергә кирәк, бу вариантны реконструкцияләүдә Э.В. Севортянның хезмәте зур); ул вариантның төбендә «үсү, баш калкыту»

(фигыль мәгъ.), «үсемлек сабагының югары өлеше, башка, бәрчә» (исем мәгъ.) һәм *башаҡ* < *баш-аҡ* сүзе фигыль мәгънәсеннән ясалган дигән фикер дә бар. Бор. *балч* тамырына нан. һ.б. *балǯа, балǯир* «йөз, баш; түбә» һәм *балди-* «туу, туып үсү» сүзләре тоташа (к. ССТМЯ I: 69–70). Шуннан чыгып, *баш* сүзе *балды* «канкардәш» сүзе белән тамырдаш дип карала (к. **Балды, Балдыз, Балтырган**).

*Баш* < *балч* < **балти* тамырының таралуы бор. төркиләр белән бор. тунгус-маньчжурлар арасында дуаль (киленнәр алмашулы) мөнәсәбәтләр заманыннан калган булса кирәк. *Баш* сүзенең төрле төрки телләрдә «калым; ыру» мәгънәләре булуы да шуңа дәлил. Räsänen 1969: 452; ЭСТЯ II: 85–88; Федотов I: 452–453. *Балч* > *баҗ* тармагы тур. к. **Бәҗәр-ү.**

**Баш** бик продуктив нигез: **башлы, башсыз; башлык** (бик төрле мәгъ. очрый); **башла-у; башлаш; башмак; башка, башкар-у** (һәр ике омонимик сүздә); сирәгрәк очрый торган сүзләрдән – **башкы, башча, башчы.** К. ш. ук **Башай, Башантай, Башак.**

**Баш йорт** (кодаларны кабул итү йорты), **башка чыгу** тәгъбирләре тур. Ахметьянов 1981: 79–80. Рамазанова 2013: 13–20.

Рус. *баш* һәм аның күпсанлы дериватлары тур. к. Заимствования…: 100–114.

**БАШАЙ, башантай** «носки; колос» ~ башк. *башай, башантай, башалтай, бәшәлтәй, бәшәй* < монг. *башалтай* «ук башагы; тулка, калпак, башка, нәрсәнең дә булса башына кидерелгән нәрсә» сүзеннән. *Башай* варианты *башалтай*дан килеп чыккан булса кирәк (чаг. диал. *дәwәй* < *дәwәни*). Чаг. ш. ук бор. төрки (ДТС: 87) *bašaq* «башмак». Әлбәттә, *баш* сүзеннән, к. чув. *пуҫах* < *поҫах,* хак. *пазах* һ.б. «оекбаш».

**БАШАК** «колос; наконечник стрелы» < гом. төрки *башаҡ* (*басаҡ, пашаҡ, машаҡ*) < бор. төрки *bašaq* id. К. **Баш.** Федотов I: 453; Гаффарова: 1999: 36–37.

**БАШАЛА, башалук (< башала ук)** «совершенно, категорически; сразу (об отказе и т.п.)» ~ чув. *пуҫ иле* id. Ат ярышларында «баш алу» – беренче минутлардан ук алгарак чыгып, уңайлы позиция алу, к. Будагов I: 3 (өстәмәләрдә) ~ фар. *сäр-ра гирифтан* id. Төркиләрдә киң таралган тәгъбир.

**БАШ-АЯК** «голова и ноги (как мясо)» → *бәладән баш-аяк* «пожертвование чем-либо, чтобы отвязаться от кого-либо»; бор. заманнарда бөтен ат урынына, аның башын һәм аякларын гына корбанлык урынына, кабергә һ.б. кую гадәтеннән (к. Кузьмина Е.Е. Распространие коневодства и культ коня... // Средняя Азия в древности и Средневековье. М., 1977: 28–52).

**БАШБАТА** диал. (ДС II: 52) «эпитафия» < *баш бата* (к. **Бата**).

**БАШ-БАШ I** «в виде рядом расположенных голов» – **баш** сүзеннән гадәти ясалма сүз.

**БАШ-БАШ II, бәс-бәс, бәцкәй-бәцкәй, бәчи-бәчи** (ЗДС: 105, 112) междометие подзывания овец, к. рус. *бяш-бяш* id. Ары таба к. тат. (ЗДС: 112) *бәшәкә* «кияүгә китәсе кыз үзе багып үстерә торган бәти» ~ рус. *бяша* «сарык» һ.б. Халыкара сүз булса кирәк. К. **Пәшә.**

**БАШБАШТАК** «самовольный, произвольный; самовольно, произвольно; шалун» ~ тат. диал. *баштаҡ*, алт., кырг. *баштааҡ, башаанаҡ* ~ чув. *пуҫтах*, тув. *паштаҡ,* хак. *пастах,* як. *бас-баттах* id. төптә «баш кына исән калсын» мәгъ. булуы ихтимал. Федотов I: 454; Рамазанова 2013: 216 (**баштак** тур.). Чаг. фар. *сәрсәри, сәритак* «башбаштак» (*сәр* «баш», *так* «так, ялгыз»).

**БАШКА** «другой, иной; отдельный; без; кроме, помимо» > удм. *башка* < гом. төрки *башҡа* ~ мар. *пасна, посна* > чув. *поҫне, пуҫне* id. К. ш. ук тат., башк. *башка-башка* ~ мар. *пасна-пасна, посна-посна*. Әлбәттә, *баш* сүзеннән, тик ясалышы аңлашылып бетми.

Дерив.: **башкалык, башкача; башкалан-у.**

**БАШКАР-У I** «совершить, выполнить; управлять; регулировать» ~ чыгт., кырг., уйг., тув. һ.б. *башҡар-*, нуг., каз., к.-калп. *басҡар-,* төр., аз. *башар-*, чув. *пуҫар-, пуҫхар-, пушкар-* (соңгы вариант һичшиксез татарчадан), уйг. *башҡур-* id. ДТСта юк, ләкин бик бор. сүз, к. *бәҗәр-ү* ~ *баҗар-у.* Бу ике вариантның уртак нигезе *л* > *ш* көчешеннән элек үк булган.

*башкар-*
**балчҡар* <
*балчар-* > *баҗар-* > *бәҗәр-*

Дерив.: **башкарыл-у, башкарын-у** «үз-үзеңә хезмәт күрсәтү»; **башкарма́** (киң кулланышлы административ термин), **башкаручан** һ.б.

**БАШКАР-У II** «стать другим, совсем измениться» ← *башка.* Чаг. **үзгәр-ү ← үзгә.**

**БАШКОДА** «сватающий невесту (за сына другого человека)» – **баш** сүзенең «беренче, тәүге, башлык» мәгънәсеннән түгел, ә бор. төрки *башын* «кияү белән кәләш өчен махсус өй, тирмә» сүзеннән булса кирәк; татарда **башын** ролен **ак келәт,** ә ул да булмаса күрше өе үтәгән; һәм **башын кодасы** – «өен биреп торучы күрше» булып чыга; тора-бара **башын** сүзе **баш** сүзе белән контаминацияләнгән, к. башк. *баш* «туй йорты» – тат. *баш, баш йорт* ~ чув. *пускил,* удм. *бушкель* (*кил* «тәгәрмәчле арба өстендәге тирмә», к. **Киләк**), мар. *пашкуды* «күрше; баш өй хуҗасы» (*куды* «өй»).

**Башкода**ның хатыны **башлык** дип аталган: хатын җәмәгатенең туйга әзерләнүе белән ул җитәкчелек иткән. К. **Башня.**

**БАШКОРТ,** диал. **башкырт** «башкир», иске рус. *башкирятин, башкурт* (төрле чыганаклардагы язылышлар тур. к. Башкирская этнонимия), иске тат. («Җәмигъ әт-тәварих»та) **бачкыр.** Бу сүз тур. күп язылган. Сүз үзе башкортча түгел, *а–о* сузыклар чылбыры, башкорт телчесе Ә. Биишев әйткәнчә, бу телгә хас түгел һәм ошбу этнонимның кушма сүздән килеп чыкканлыгын дәлилли. Иң тәүләп теркәлгән вариант **бажгирд** – хәзәрләргә хезмәт иткән бер кеше исеме (ихтимал, чин яки һөнәр атамасы). Рус. *башкир* варианты *-д*сыз бор. бер чыганактан килә. XVIII г. рус документларында *башкурут* дип тә языла. Безнеңчә, бу вариант монг. телендә пәйда булган: *башкир-ут* (*-ут* монг. күп. кушымчасы) кире ассимиляция буенча *башкурут*ка әверелгән. Бор. варианттагы йомшак *-д'* белән бергә тәүдә йомшак *-г-* булганлыгын бу сүзнең бор. гар. *башҗәрд* яки *башҗирд* рәвешендә язылуы да раслый (гар. телендә Мөхәммәт пәйгамбәр заманнарыннан бирле йомшак *г* һәрчак *җ* авазына күчә). Димәк, тәүге, нигез вариант әлеге *бажгирд.* Бу сүз фарсыча кушма *бажгир* «баҗ алучы» яки *бахшгир* «салым җыючы» сүзләренә охшаш. Урта Азиядәге *башкирд, башгирд* сыртлары баҗ алу линияләре – чикләре булган бугай. Һәм күрсәтелгән *бажгирд* хәзәрләрнең салым җыючысы – кондатьер гына булган, ахыры.

Башкорт теленең төп үзенчәлекләре төрки телләр фонында түбәндәге тоталь күчешләре белән билгеләнә:

1) *ч > с // с > һ* (ягъни барча *ч* авазлары *с* авазына күчкәч, барча элекке, гом. төрки *с* авазлары *һ* авазына әверелә);

2) ассимиляция һәм диссимиляция күренешләренең көчле үсешкәнлеге (мәс., *кызлар > кыҙҙар* һәм *атлар > аттар* дигәндә ассимиляция, *юллар > юлдар, илләр > илдәр* дигәндә диссимиляция).

3) нигездә татарча вокализм.

Әйтелгәннәрдән тыш, башк. теле асылда кайбер сөйләшләрдә генә еш кулланыла торган *ҙ* һәм *ç* авазлары булуы белән дә характерлана. Шулардан *ҙ* авазы тат. сөйләшләрендә дә очрый (мәс., башкортлардан ерак торган дөб. сөйләшендә).

Беренче төр («һ» авазы белән характерланган) фонетик үзенчәлек башкорт халык составына кергән монгол-бурят компонентыннан килә. Икенче төр (ассимиляция-диссимиляция) үзенчәлеге барча (себер татарларыннан тыш) себер төркиләренә һәм дә кыргыз вә казак телләренә хас. Башк. *ҙ* һәм *ç* авазлары *сәлҗигут* (угыз-төркм.) компоненты белән баглы (бу компонент татар халкында да бар, к. **Сәлҗук** сүзен).

Башк. һәм тат. (ш. ук. чув.) телләренең вокализм (сузык авазларның составы һәм кулланылыш закончалыклары) уртак бер чыганактан, безнеңчә, бор. тат. теленнән таралган.

Гомумән, башкорт халкы баштан ук төрле төрки, угор, монгол кавем-кабилә кыйпылчыкларының конгломераты булган. Төрле төркемнәр дошманнардан качып яки мәҗбүрән күчерелеп бу аулак, таулы-урманлы Урал регионына килгәннәр. Аларны берзаман *башгирдлар* берләштерсәләр дә, бирегә бердәм хуҗалык һәм көчле, тотрыклы дәүләт корылмаган. Көньяк Урал төбәгенең кырыс табигате, юлсызлык гетероген халаекка күпләп үрчергә дә, ныклап берләшергә дә мөмкинлек бирмәгән. Өстәвенә һәр яктан яулар килеп торган. Мәс., монгол яулары килер алдыннан *бажгирдлар ~ бачкырлар* бик көчәеп, монголларга каршы уңышлы гына көрәшкәннәр, әмма монгол дипломатиясе коткылары аркасында монголларга кушылып, аларның ерак йөреш-һөҗүмнәрендә катнашканнар. Нәтиҗәдә башкортларның төп конструктив көчләре таркалган, идарә башы булып килмешәк биләр, мәс., монгол агенты Аккүбәк калган, ул исә мөстәкыйль дәүләт төзү-фәлән тур., безнеңчә, уйламаган. «Заятүләк» эпосы азагында элекке дәүләт «булмаган кебек бетте» сүзләре шул заман хәлләрен чагылдыра бугай.

XVI–XVII гг. башкортларга мөстәкыйль дәүләт оештырырга тагын мөмкинчелек туган, ләкин башкортлар шуннан файдалана белмәгәннәр (монда сугышчан калмыклар да кире роль уйнаганнар бугай). XVII г. бирле *башкорт* дип Башкортстандагы

татарларны һ.б. атау күзәтелә. XVIII г. вакыйгаларны үз күзе белән күргән танылган администратор һәм тарихчы В.Н.Татищев сүзләренә караганда, башкортларның дүрттән өч өлеше кырып бетерелгән. К. «Мирас», № 7, 2007 (безнең мәкалә. – *Р.Ә.*).

**БАШКӨЛЛӘЙ** диал. «совсем, всецело» < *баш* һәм *көлли* «барысы» (к. **Гел**) сүзләреннән тора. К. шул ук мәгъ. башук < *баш ук?*

**БАШЛЫК I** «башлык, капюшон; шапка» һәм **башлык** «начальник» икесе ике даирәдә формалашкан сүзләр (икесе дә рус теленә дә кергәннәр). Аникин: 127.

**БАШЛЫК II** диал. «жена». К. **Пашлык.**

**БАШМАК I** «башмаки; туфля; головка обуви» < гом. кыпч. *башмақ* (*баспақ, пашмақ*) id. ~ як. *басымыкы//баһымыкы* «сыер аягы тиресеннән тегелгән итек, аякчу»; күп кенә күрше телләргә кергән сүз: ышандырырлык этимологиясе юк; чаг. кор. *палмак* «күн аякчу»; кырг. *башмақ* «аякчуның башы» < гом. төрки *баш* һәм фар. *пак* «кием, каплавыч» (чаг. **Калпак, Күлмәк, Паймак**) дип аңлатып була. К. ш. ук **Башай, Башмак II.** Ахметьянов 1989: 67; Аникин: 124–125 (төрле фаразлар китерелә).

Дерив.: **башмакчы** (һөнәрче, ш. ук «мәчеттә башмаклар саклаучы»); **башмаклык** «кәләшнең анасына бүләк төре».

**БАШМАК II** «тёлка» < гом. кыпч. *башмақ (пашмақ, баспақ)* id. сүзен *баш мақ* «киленгә бирелгән бүләк» дип аңлатырга мөмкин (килен төшергәндә аңар башмак бүләк иткәннәр, к. **Таянчык**), чаг. башк. *баш ат* ~ нуг., каз. *бас ат* «калым белән бирелгән ат (ул кәләшнең атасына бирелгән)», к. башкорт-татар җырында *Атасы бар – ат сорый, Инәсе бар – тун сорый; Кыелдырык җиңгәсе бар – Бер салмалык он сорый; Атына да күнәмен, тунына күнәмен, Кыелдырык җиңгәсенә егыламын, үләмен.*

Икенче бер версия буенча, *башмак* «тана» бер яшьлек бозауның каты тоягы – «башмагы» пәйда булудан (к. Будагов I: 229). Алайса, **башмак II** – *башмаклы бозау* тәгъбиреннән эллипсис. Кызганычка каршы, андый фразеологизм теркәлмәгән. Бор. төрки телләрдә (МК) **Башмак I** генә теркәлгән.

Һәрхәлдә **Башмак I** һәм **Башмак II** үзара бәйләнгән булырга тиеш. ЭСТЯ II: 93–94 (Э.В. Севортян да бу сүзләрнең этимологиясе томанлы булуын билгеләп үтә); Аникин: 125.

**БА́ШНЯ** «башня» < рус. Рус телендә бу сүзне бор. рус. *башта* ~ чех., пол. *baštu, baszta* «бастион» сүзеннән дип уйлыйлар (Фасмер: 139). Б.Я. Владимирцов (: 291) рус. *башня* «Себердәге өй төре, фанза, сарай, каралты» сүзен бор. монг. *bayišing* ~ тув. *пазың*, алт. *башың*, алт. диал. *пайжын* «кытайча өй; зиндан; ак келәт» < фар. *пиш айван* «веранда» сүзеннән (?) ди. Һәрхәлдә **башня**ны **баш** сүзе белән бәйләмиләр.

**БАЯ [баᵒйа],** себ. (Тумашева 1992: 170) **пәйә** «не так давно, недавно, давеча (обязательно сегодня)» > мар., удм. *байа,* чув. *паян, паякӑн* id. Тат. кулланышлырак формасы **баягынак** > (ТТДС I: 65) **баянақ** – этимологиясе бик катлаулы сүз. Тат., башк., кырг., уйг., төркм., алт. диал. *байа*, алт., хак. *пайа* < бор. төрки (ДТС: 79) *baja* id. белән беррәттән кырг., каз. һ.б. *байыры, байырқы* «бая» сүзе дә бар. Э.В. Севортян *баға, бағана* формасын да таба (ЭСТЯ II: 30–32), гомумән, канәгатьләндерерлек аңлатма бирми (анынча сүзнең тамырын *баға* юнәлешендә дию, безнеңчә, ялгыш).

Безнеңчә, гом. кыпч. (к. **Баягы**), уйг. *байа*, төр. диал. *bayı* «бая» *бай-, байы-* «тукталу» сүзенең хәл фигыль формасыннан; шул ук фигыльнең *бай-ыр*-паронимыннан (*бай* «тукталыш» исем коррелянты нигезендә) **байыру* (бор. уйг.) хәл фигыль формасыннан (фонетик үзгәрешләр кичереп) *байыры* формасы килеп чыккан; ниһаять, *бай-* фигыленең **байчы-* интенсивлык формасыннан **байчыру* «туктала төшеп, баярак» сүзе ясалган (ш. ук хәл фигыль), шуннан **бәйҗер* > тат. *бәзер, пәзер* «бу арада, күптән түгел» (к. **Бәзер**) яңгырашы, шуннан чув. *пaçӑр* «бая» килә. *Баййа* > *бәйә* > *пәйә,* хак. диал. *пийә* кебек палатальләшү күренешләре интервокаль *-й-* тәэсирендә пәйда булганнар. Төр. *bayakıt* «баягынак».

*Байчы-* фигыль нигезе эвенк. (ССТМЯ I: 66) *bajǯe-* < бор. монг. *bajǯa-* «туктале; баярак» сүзендә чагыла.

Як. *баагын ~ маагын, баайын ~ маайын* «бая» тур. Иванов С.А.: 189–190. Төркм. *байақ, байаһ* тур. Мухамедова: 64.

Чыгт., угыз. *байақ* «бая» сүзе кушма сүздән гаплология юлы белән килеп чыккан (мәс., *байа оқ* > тат. **баюк** «бая ук» ) булса кирәк.

Чув. *паян* «бүген» < бор. тат. *баягы-н* булса кирәк. К. Федотов I: 392–393. Гомумән, *байа* барча төрки телләрдә чагылышы булган сүзләрнең берсе.

**БАЯГЫ [баºйағы̆]** «давешний; упомянутый» < гом. кыпч. *байағы*, каз. *банағы*, *манағы*, уйг. *байақы,* алт. *байаға*, *пийеги*, добр. (Akb: 34) *banagı* id. *байа* сүзенә *-ғы//-қы* кушымчасы ялганып ясалган; кайбер шивәләрдә *байағы* «бая» мәгъ. кулланылуы – семантик үзгәрешләр нәтиҗәсе; каз. *байырғы*, кырг. *байырқы* «бая» *баягы* моделендә *байыр* < *байағыр* нигезеннән ясалган. К. сары уйг. (Малов: 53) *піāғыр* «баягы».

Гомумән, *байа, байағы* сүзләренең фономорфологик вариантлары төрки телләрдә (бигрәк тә як. телендә) гадәптән тыш күп, ләкин аларның барысын да без биредә тәкъдим иткән схемадан (*бай-, байыр-, байчыр-* фигыльләреннән) чыгып аңлатып була шикелле. К. **Бая.**

**БАЯЛЫЧ [баºйалы̆ч], баялыш** «боярышник» < рус.; рус телендә бу сүз *бояр* «алпавыт» сүзеннән: элекке боярлар һәм баярлар утарларын баялыш куаклары белән кәртәләгәннәр. К. башк. диал. *байар йемеше* «баялыш, дүләнә» (БҺҺ II: 37); каз., кырг. *баялыш* id. татарчадан булса кирәк.

**БАЯН СЫЛУ** «легендарная девушка, верная своему наречённому Кузый-Курпячу (Кузыю из рода Курпяч)» ~ тат. диал., каз. диал. *Маян сылу,* башк. *Маян Һылыу* id. Дастанның эчтәлегенә караганда, *баян* < *баяган* «бик яшьли (тугач ук) баекланган» дигән сүз (к. **Баек**). Алт. *Пајан кыс, Биян-Сулы* «баһадир кыз» (дастан каһарманы), каз., кырг. *баян//маян* «мифик хайван; ана дөя – гайрәтле хатын-кыз символы» («ана арыслан» кебегрәк), чыгт. (Будагов I: 240) *байан* «акылдар», алт. *пийан* «игелек» һ.б., чаг. түбәндәгене, к. **Җилмая.**

**БАЯНДЫ [баºйанды̆]** диал.(ЗДС:17) «обещанный подарок» ~ алт. диал. *пийанду* «юмарт».

**БАЯНДЫЗ [баºйанды̆з]** (Ф. Баязитова) «коврик; то, что кладётся под ноги невесте при схождении со свадебной кареты *мәгәлдәк*» < фар. *пāй äндāз* «аяк астына ташланган (әйбер)»; *пāй* «аяк», *äндāз* «ташланган». К. кырг. *баяндос* «кыйммәтле күпчек, зиннәтле чапрак һ.б.ш.».

**БАЯР [баºйар]** тар. «помещик (русский)» – бу мәгънәдә шулай язылырга тиешле, югыйсә татар басмаларында күп еллардан бирле «рус алпавыты» мәгъ. сүзне дә, «рус феодалы – үзенә гаскәр тоткан бай»ны да бер **бояр** (русча укыла: **бōяр**) язылышында бирәләр.

Тат. әд. телендәге *баяр* (башк., удм., мар. телләрендә, шулай ук нуг., каз., аз. һ.б. *байар*) – «рус алпавыты» сүзе бор. рус. *боярове дети* сүзеннән. Шулай дип боярларның гаскәри башлыкларын атаганнар. Аларга яулап алынган территорияләрдә зур-зур кишәрләр бирелә торган булган. «Алпавыт» мәгъ. шуннан.

Бор. Русь һәм бор. (славян) Болгария дәүләтләрендә **бояр, боляр** дип үзенә гаскәр тотарга хокуклы булган эре феодалны атаганнар. Бу сүз VIII г. Дунай буйларын яулап алган һәм шундагы Болгарияне оештырган төрки болгардан калган һәм асылда *бойла эр* дигән бор. төрки титулдан кыскарган. Бу титулда *эр* «ир, батыр» булса, *бойла, багийлә* – VII–IX г. Дунай буйларыннан Кореягә кадәр барча төркиләрдә билгеле булган идарәче титулы. *Бойлә,* гадәттә, үзе генә кулланылмаган, ул *бойля таркан, бойля бага, ичиргү бойлә, бойлә эр, бойля эр капаган* кебек тезмәләр составында еш очрый.

*Бойлә* сүзенең беренчел мәгънәсе «халык вәкиле, хәким, судья» булган дип уйлыйлар. Ул бор. *бой, бод* «халык төркеме, кавем, кабилә» сүзеннән ясалган һәм кабиләнең үзәк хөкүмәт каршындагы вәкилен белдергән.

*Бой* сүзе (рус. *бой* кебек укыла) төрке һәм морд. телләрендә (төрки телләрдән кереп) сакланган. Тат. телендә, Н. Исәнбәт китергән *Үтмәс ярлык – буйга хурлык* мәкален исәпкә алмаганда, бу сүз сакланмаган. Ләкин, бик ихтимал, *буй* «кабилә, дәүләт башында торган дүрт кабиләнең берсе», асылда *буй* «бәдән, бөтен тән, озынлык» белән бердәйдер.

**Баяр** сүзен төрки *бай эр* «бай ир» дип аңлатулар – абсурд, чөнки *баяр* сүзе тик русларга (шуларга ияргән нимесләргә һ.б.) карый, татарлар үз алпавытларын **баяр** дип атамаганнар. Тимергалин: 101. К. **Бояр.**

**БАЯУ [баºйаw],** диал. (Арсланов 1988: 75; Арсланов 1992: 117; Тумашева 1992: 167) **пайаw** «спокойно; покой; нельзя, спокойно!» (вежливое предупреждение) – **байа-у* фигыленең исемләшкән формасы, ул фигыль исә **бай-у** (к.) фигыленнән ясалган, к. монг., бур. *бай-* «бер урында яшәп тору», *байл-* «килеп урнашу, тукталу», абазин. (< кыпч.) *байаура-* «килеп тукталу», кырг. *байы-* «савылуны туктату (сыер тур.)» һ.б. Төр. *baygın* «һушсыз; тып-тыныч», *bayıl-* «һуштан язу; тынычлану» сүзләренең нигезе *bay-* «бөтенләй тынычлану» булса кирәк. К. ш. ук башк. (БҺҺ II: 37) *байан* «чәчәк аткан дала (җәйләү урыны)» ~ каз. *байан* «тыныч; тукталыш» һ.б. Чаг. **Бая.**

**БӘБӘК,** диал. **бәбәнәк** «зрачок», «зеница», күч. «глазное яблоко, зенко» – **бәбәнәк** аңа караган кеше үзе «бәби» рәвештә (бик кечкенә булып) чагылудан килеп чыккан мәгънә. К. С. Сараида *күз бәбәге* ~ төр. *göz bebeği* «бәбәк». Бу кызыклы мәгъ. күчеше тур. Д.Б. Рамазанова (1993: 36–37) бик тәфсилләп һәм төрле тикшеренүчеләрнең фикерләрен дә китереп яза: **күз бәбәге** белән беррәттән **күз бәбәе, күз нәние** тәгъбирләре бар; күз карасына җентекләп караган ирләр «күз кызын» ягъни үз йөзләренең чагылышын күрәләр; ләкин борынгылар, элеккеләр кеше күзендә «кечкенә кеше» бар дип уйлаганнар. К. **Бәби.** ЭСТЯ II: 95–96.

**БӘБЕР** «бабка мелких копытных животных» – ачык түгел.

**БӘБЕШ I,** диал. (Г. Ахмаров) **бәбеч, бәбец, папыч** «меховые тапочки; (ТТДС I: 101) мягкие сапоги» < фар. *nāпӯш* id., хәрефкә-хәреф «аяк каплагыч». Бу сүз төрки телләрдә киң таралган: нуг. *бапиш, бәпиш, бәбеш,* ком. *папич* «ыштыр», төр. *paриç* «башмак; бәбеш» һ.б. Рус. *бабуши* (< тат.) «бәбеш» тур. Аникин: 105. К. ш. ук Будагов I: 307; Фасмер III: 186.

**БӘБЕШ II,** диал. (ТТДС I: 101) **бәбиш** «гусёнок или утёнок», *папи* (Будагов I: 307) «утка» ~ к.-балк. *бабуш, баппуш,* ком. *бабиш* «үрдәк» ~ төр. диал. *pabis* id. һ.б. Асылда башк. *бәпес* «бәби» белән бердәй.

**БӘБИ,** диал. **бәбә, бәбәй,** (ДС I: 34) **бибә, бәббә** (башлыча колын тур.), **бәбеч, бәпеч** (шуннан *тал бәбчеге* < *бәпеччеге* «песие») «младенец» ~ башк. *бәпәй, бәпес,* ком. *бебей* «бәби, күз бәбәге», кар. *бебей, бәбәй,* аз. диал. (АДДЛ: 66) *бәби* «курчак», болг. Д. *бебе* «бәби; курчак» < төр. *bebe, bebek* «бәби» һ.б. киң таралган ономопоэтик сүз, к. эвенк., эвен. *бэбэ* «бәби; бишек», маньч. *бәбу* «бишек», як. *биэбэ, биэбэкэ* «нарасый, балакай, бәпкәм», бур. *бүүбэй* «бәби; бишек», һинд. *babuwa* «бала, малай; уенчык, ташкурчак», инг. *baby* «бәби», алб. *bebë* һ.б. (Pokorny: 91–98). Kluge: 80, 678.

Добр. тат. (Dobr. I: 288) *bebiy,* кулланылыш тирәлегенә караганда (*menĭm anam kelĭnnĭ bebiydiy süyer*) шундагы безнең мөһаҗир татарлар теленнән килә.

Бу ише сүзләрнең бер тармагы кошларга нисбәт ителә: тат., башк. *бәпкә, бипкә, биби* «каз яки үрдәк баласы», госм. *bāba* «бәбкә; күркә»; күз әгъзаларын һәм бөрене белдерү дә күзәтелә: тат., башк. *бәбәк, бәбәнәк, бәбәгә* ~ чув. *папак, папакка* «тал бәбәге, бала», аз. *бәбәнәк* «балтырган һ.б. бәбәге», бор. төрки, төр. *bebek,* төркм. *бәәбенек* «күз алмасы» (Мухамедова 1973: 69) һ.б. к. **Бишек.**

**Бәби** нигезенең тамырлары, гомумән, **бабанықына** охшаш булса да, *бәбәй* < *бабай* дип раслауның кирәге юк шикелле. Ләкин *оныk* ~ *дәвәти* мәгънә багланышы изосемантик характерга ия, к. ш. ук *нәнәй* ~ *нәни.*

**БӘВЕЛ [бәwĕл]** кит. «урина» < гар. *бäwл* id.

**БӘВЕТ-Ү [бәwĕт-], бәwелт-ү** «качать колыбель», *бәwел-ү* «колебаться» (ЗДС: 107–108) ← **бәwе-*, к. **Бәү.**

**БӘГЫРЬ [бәғер]** «сердечко; душенька» < уйг. *бәғир* < *бағыйр* «бавыр; йөрәк» сүзеннән. К. **Бавыр.**

**БӘГЪЗЕ [бәғзĕ]** «некоторый, отдельный» < гар. *бä'ḍ* id.; шунысы кызык ки, бу сүз диалекталь лексикага да кергән: себ. (Тумашева 1992: 71) **пәс** «кайбер, бәгъзе», **пәстә** «кайчакта» . К. ш. ук иске әд. *бәгъзән* «кайчакта» < гар. *бä'ḍан* id.

**БӘДӘВИ [бәдәwи]** «кочевой; бедуин (арабкочевник)» < гар. *бäдäwӣ* id. *бāдийä* «дала, чүл» сүзенән. К. **Бидәү.**

**БӘДӘН** «тело; естество; плоть» < гар. *бäдäн* id., ш. ук «кальга диварындагы тешләр арасындагы аралык». Төп гар. сүзе түгел, ниндидер бор. телдән.

**БӘДБӘХЕТ** «проклятый; злосчастный» < фар. *бäдбäхт* «начар язмышлы», «әшәке бәхетле»; *бäд* «начар, әшәке» сүзе бик күп кушма сүзләр составында очрый; шулардан тат. телендә: *бәддога* «явыз теләк белән укылган дога», к. **Бәдрәф, Бәтрәк, Битәр.**

**БӘДРӘФ** «туалет, отхожее место» < фар. *бäдрафт* «начар агым».

**БӘЕТ [бәйĕт]** «лиро-эпический фольклорный жанр – стихотворный рассказ о достопримечательном случае, происшедшем в течение года – между двумя праздниками **навруз»** – асылда «нәүрүз бәйтләре» тәгъбиреннән: *бәйт* гар. «кушык, строфа», төп мәгъ. «өй». Нәүрүз көнендә ел тәүле-

гендә булып үткән гыйбрәтле вакыйгалар турында шигырь язу фар.-төрки дөньясында күп гасырлардан бирле килгән. Шуңа күрә дә бәетләр «фәлән карьяда, фәлән сәнәдә, фәлән вакыйгалар заһир булды» дип башланалар. Бәет чыгару һәм нәүрүз бәйрәмендә шигырь уку – татар халкының югары рухи мәдәниятен күрсәткән факт.

Хәз. әд. телдә *бәйт* «ике юллык шигырь кушыгы» сүзе дә кулланыла. Тимергалин: 84. К. **Бәйт.**

**БӘҖ** «паз (в срубе)» – ошбу яңгыраштта (*бәҗ алу* фраземасында һ.б.) төньяк-көнб. Башкортстанда, *пас-йек* «бәҗ-җек» парлы сүзендә Себердә (ЗДС: 520) кулланыла. Рус. *паз* сүзеннән килә дияргә монда *бәҗ*нең фонетик йөзе һәм рус сүзенең үзенең канәгатьләндерерлек этимологиясе юклыгы комачаулый. К. ш. ук башк. *бажым, бажыу* «бәҗ», *базау* «ырмау; ырмаулау», төркм. диал. (ТДГДС: 30) *бажҫov* «иң кечкенә арык, сугару канавы», алт. диал. (Баскаков 1972: 240) *пас ал* – «бәҗ алу» (ихтимал, татарчадандыр). Арытабан ачык түгел (чаг. фар. *бäст* «бәй, эләктергеч» һ.б.).

Рус. *паз* үзе болг. теленнән булса кирәк (бор. рус кенәзлекләрендә болгар осталары эшләгәнлеге билгеле).

**БӘҖӘНӘК** «печенег» ~ бор. төрки *bečänäk* (МК), бор. рус. *печенъг,* венг. *besenyö*, бор. төрки гарәпчә язылышы باجناق, باجاناق, бор. грек. (Византия) *πατζιναχος, πατζιναχίτης,* лат. *pasinaci, pacinakitae,* бор. әрм. *pacinak* «бәҗәнәк, баҗанак халкы». Кайбер чыганакларда беренче иҗектә *-i-* авазы күренә: венгер. *picenati*, бор. пол. *pincenakiti* id. Бор. төрки тарихи әсәрләрдә *bečene* «күк ханның өченче углы», «изгелектә тырыш», «тырыш, эшчән», имеш (к. Мухамедова 1977: 47–51 һ.б.). Гомумән, этимологияләрнең иң ышандырырлыгы – *бәҗәнәк, баҗанак* гом. төрки **баҗанак** «баҗаларның берсе» дигән иске караш, к. **Баҗа.**

Бәҗәнәкләр бер кешенең (ихтимал, Коркытның, к. **Коркыт ата**) баҗалары булып, VIII г. Идел-Җаек аралыгында оешканнар. Аларның кабилә һәм кеше исемнәре безгә аңлашылмый. X г. башларында аларны кыпчак-куманнар тар-мар итә. Шуннан бәҗәнәкләр хәз. Көньяк Украинага күченгәннәр. Русча *Кто к нам с мечом придет, от меча и погибнет* дигән сүз бәҗәнәк мәкаленнән тәрҗемә икән: бәҗәнәкләр шулай дип рус кенәзе Святославны тар-мар иткәч әйткәннәр. Бу хакта иске рус елъязмаларына таянып М.В. Ломоносов үзенең «Древняя Российская история...» китабында яза. Ләкин кыпчак-куманнар бәҗәнәкләрне тагын килеп җиңгәннәр, теге мәкаль дөрескә чыкмаган. Порфирородный К. О северных скифах // Из глубины столетий (сборник древних текстов). Казань, 2004: 88–97 (*Пачинакитлар* тур. иң кыйммәтле чыганак); Ломоносов М.В. Древняя Российская история от начала российского народа до кончины великого князя Ярослава первого. СПб., 1766 (соңыннан берничә тапкыр нәшер ителгән). Гомумән, бәҗәнәкләр тур. төр., рус, венг. телләрендә зур әдәбият бар.

**БӘҖӘР-Ү** (әстр., добр.), **баҗар-у** (м.-кар.) диал. «обслуживать» ~ чув. *пуҫар-* < *поҫар-* «инициатива күрсәтү», к.-балк., үзб., төркм. һ.б. *баҗар-*, уйг., гаг. *бәҗәр-*, төр. *becer-*, кар. *бэшэр-* «башкарып чыгу, булдыру» < бор. төрки **балчар* < *балчкар-* id. К. **Баш, Башкар-у.**

**БӘЗ** «белая ткань» – үзб., төр. һ.б. *бәз* < гар. *бäзз(ун)* id. Рус. *бязь* татарчадан (к. Фасмер I: 261, бу автор да шәрык сүзләре тур. сөйләгәндә татар арадашлыгын исәпкә алмый). Чаг. **Бүз II.**

**БӘЗӘНКЕ** (М. Гали) «вязаная шапочка» < рус. *вязанка* id.

**БӘЗЕР,** себ. (Тумашева 1992: 171) **пәзер** «тотчас, вмиг, сразу» (*әзергә бәзер* «к готовому вмиг готов») < болг. **бәҗер* < **баҗыр* ~ чув. *паҫӑр* «әле генә, бая гына», к. **Бая.**

**БӘЙ I** «привязь», «моток ниток для вязания» (ДС II: 66) < гом. төрки (тат. диал. к. ДС II: 48, ТТДС I: 65) *бай* id. сүзеннән бор. тат. телендә (*а* > *ә*) килеп чыккан, бор. төрки *ба-* тамырыннан (к. **Бау**). Палаталь вариант – тат. теле билгесе булганлыктан, башк. *бәй* дә татарчадан алынган дип уйларга кирәк. *Бәй* сүзенең бор. тат. *бәй-* фигыль коррелянты булган, к. диал. *бәйгеч* «бәйләвеч», чув. *пайав, пайӑв* < бор. тат. **бәю* «бәйләү» (исем фигыль).

**Бәй, бәй-** сүзеннән бик күп сүзләр ясалган: **бәйлә-ү, бәйләм, бәйләмә, бәйләвеч, бәйлән-ү** (бу сүзнең мәгънә структурасы рус теленең «привязаться» сүзеннән калька булса кирәк). К. аерым каралган **Бәйлән-ү, Бәйлә-ү, Бәйле, Бәйлек.** К. **Баг II.**

**БӘЙ II** тар. «месье, сэр, господин» < госм., кр.-тат. һ.б. *бей, бәй* id. < бор. төрки *beg,* к. **Би.** Төрле **бәй, бәк, бий, бик**ләр тур. Будагов I: 263–265.

**БӘЙ III** междометие удивления – башк. *бәй,* чув. һ.б. *пай,* рус. диал., үзб. *бай, бай-бай,* тат., рус. һ.б. *ба!* – ономопоэтик интернациональ сүз.

**БӘЙГАТЬ [бәйғәт]** тар. «присяга (на верность)» < фар., гар. *бӓй‘ат* id. ш. ук «кыйммәтле нәрсә сатып алганда кул кысышу яки кул сугышу» – гар. *бӣ‘* «кул бирешү, сатып алу» фигыленнән (Redhouse: 165). Төп мәгъ. тат. **бәйгать бирү** тәгъбирендә дә чагыла.

**БӘЙГЕ** «спортивное соревнование, скачки; байга», «приз на соревнованиях», «площадь для соревнований» (ТТДС I: 108), «кусок красной материи (за который борются соревнующиеся на свадьбе)» (БТДҺ: 69), иске башк. (Катаринский) *пай, пайга* «пир, торжество» ~ каз., к.-калп. *бәйгӗ* (татарчадан түгелме икән? Чөнки хәз. сүзлекләрдә теркәлми һәм, күрәсең, бу телләрдә сирәк кулланыла), шор., лобнор (уйг. диал.) *пайга,* сагай. (хак. диал.) *пайға*, үзб. диал. *пайғӓ* «ярышулы бәйрәмнәр» монг. *бай* «мишень; мәрәй; приз; финиш; чик; ара» сүзе белән чагыштырыла, ләкин Э.В. Севортян (ЭСТЯ II: 32) бу чагыштыруны кире кага.

Гомумән, бу сүзнең чыгышы моңарчы ачылмаган. Без түбәндәгеләргә игътибар итәбез: 1) бу сүз гом. кыпч. характерында түгел (күпчелек кыпч., ш. ук угыз телләрендә теркәлмәгән); 2) кайбер телләрдә (хак., шор.) *пай* һәм *пайға*, *бай* һәм *байға* икесе бер мәгъ. йөри (к. Радлов IV: 1119–1120); 3) кырг. *байге,* үзб. *пайге* «бәйге, финиш» сингармонизм законнарына буйсынмый – димәк ул алынма, яңарак сүз һәм чыннан да монг. *бай* белән турыдан-туры баглы түгел. Безнеңчә, сүзнең этимоны – фар. *пāйг'āһ* «бүләкләү урыны; ярыш урыны; финиш, ямыл, почта станциясе»: *бай* (к. **Бай II**) < *пай* (төрки < ир.) «өлеш; бүләк; бүләк өчен ярышу» һәм *г'āһ* «урын». Кырг., үзб. вариантларындагы икенче иҗектәге *-ге, -гә* чыганактагы урта *-г-* авазы тәэсиреннән килгән палатальләшү.

Рус. *байга* тур. Аникин: 109.

**БӘЙЛӘН-Ү** «привязаться», күч. «придираться; приставать» > удм., мар. (Исанбаев 1978: 10) *бӓйлӓн-, вӓйлӓн-* id. (бигрәк тә күч. мәгъ.) < гом. кыпч. *байлан-* < гом. төрки, бор. төрки (ДТС: 78) *baylan-* (> әд. тат. *баглан-*) «бәйләнү» – **бәйлә-ү** (к.) сүзенең бик аерымланып киткән кайт. юн. Гом. кыпч. **байлан-** нигезенең мәгънә спектры таррак.

Дерив.: **бәйләнеш** (бу нигездә икенче этапта тагын күп кенә нигезләр ясала: **бәйләнешле, бәйләнешсез**); **бәйләнмәле; бәйләнчек** һ.б. Юн. формалары **бәйләндер-ү, бәйләнел-ү, бәйләнеш-ү** сирәгрәк кулланыла. К. ш. ук түбәндәгене.

**БӘЙЛӘ-Ү** «привязать; вязать» < гом. кыпч. *байла-* < бор. төрки *bayla-* id. ← «бәйләп кую һәм шуның чарасы – бау» ← *ba-* «бәйләү, бау урап беркетү» (иң бор. төшенчәләрнең берсе), к. ДТС: 76, 78. **Бәйлә-ү** гом. уртак үзенчәлеген тәшкил итә. К. схеманы:

бор. төрки *bayla-* → кыпч. *байла-* → тат. *бәйлә-*; кр.-тат. *bayla-*
бор. төрки *bayla-* → чыгт., уйг. *багла-* → тат. әд. *багла-*
бор. төрки *bayla-* → алт., кыпч. *баула-* → тат. *баула-*

Бу нигезләр, әлбәттә, мәгънә җәһәтеннән дә бераз аерылалар. Мәс., кр.-тат. *байла-* (*bayla-*) нигезенең тат. телендә булмаган кайбер мәгънәләре бар. К. **Баг II, Бау, Бәй.**

**БӘЙЛЕ** «на привязи, привязанный» – **бәй** (к.) нигезеннән ясалып, яңа мәгъ. алган сүз. К. мәкаль: *Уллы өйнең капкасында утыз ат бәйле тора, кызлы өйнең капкасында кырык ат бәйле тора.* Ләкин *-га//-гә, -ка//-кә* бәйле кебек кулланышларда бу сүз (русчадан күчерелепме) «зависит» мәгъ. кулланыла. Чаг. **Баглы** һәм **баулы** (к. **Бау**).

**БӘЙЛЕК** «завязка», как грамматический термин «послелог» – сирәк кулланыла торган *бәй* «киндерә очы» сүзеннән, к. **Бәй.**

Грамматик термин буларак бу сүзнең төрки параллельләре (төрек галимәсе Әминә Наскали буенча) кызыклы: к.-балк. *байлав,* ком. *байлавуч,* кырг. *байламча,* үзб. *боғловчи,* уйг. *бағлиғучи,* хак. *палганты* < *пагланты* «багланты», кр.-тат. *бағлайычы,* аз. *бағлайыҹы,* төркм. *бааглайыҗы;* төр. *bağlaç,* шуннан булса кирәк үрнәк алып, шор грамматикасында *паглаш.* Бүтән төрки телләрдә «бәйлек» мәгъ. сүзләр үзгәчә ясала. К. Dobr. I: 240. Иске әд. телебездә бәйлек һәм шуңа охшаш сүзчекләр гарәпчә *әдат* (төп мәгънәсе «инструмент») дип аталган. **Әдат** тур. Тимергалин: 52.

**БӘЙНӘ-БӘЙНӘ** «подробно, связно, ясно (о сообщении)» < фар. *бӓйнә-бӓйнә* id., гар. *бӓйн* «ара, урта; арадашлык» сүзеннән. К. **Бәйнәлмиләл.**

**БӘЙНӘЛМИЛӘЛ** «интернациональ» < гар. *бӓйн ӓл-милӓл* «милләтләр арасы»; к. **Бәйнә-бәйнә, Милләт.**

**БӘЙРӘМ** «праздник», тат. диал., башк. һәм гом. кыпч. *байрам* << бор. һинд-ир. *verethragna* «Рагнаны – явызлык һәм кыш рухын җиңүче, Индра (иң зур тәңреләрнең берсе)» сүзеннән. Бу сүз ир. тел һәм диалектларында төрле үзгәрешләр кичергән һәм төрки-монголлар бу сүзне төрле чыганаклардан алганнар. *Бәйрәм < байрам,* К. Насыйри күрсәткәнчә (ЛТ I: 107), турыдан-туры фар. *Бäһрам < бäһар ангам* «яз тәңресе», *бäһар* (иске тат. *бәһар*) «яз» сүзләреннән (шуннан ук Афанасий Никитин телендә *баграмъ, багримъ ← бäһар* «язгы бәйрәм» һәм *улубагръ* «олы бәһар» – «яз бәйрәме»). Монг. *байар, бейыр* «язгы бәйрәм» сүзе дә шул *беһар, *бәһыр* сүзеннән булса кирәк. Бор. төрки *baδram, baδrem* варианты *verethragna* сүзенең икенче бер (сугд.) чагылышыннан (борынгы *h < th = ç < ʒ*). К. фар. *бәдрам* «бәйрәм, туй, сый». Чаг. төр. диал. (Steuerwald: 102) *bayra-* «бәйрәм итү».

Чув. *пейрем* «бәйрәм» < тат., мар. *байрам, агабайрам* «яз бәйрәме (Гордеев II: 187) < болг. (*ага* «олы» болг. сүзе), удм. *байрам, бäйрäм* < тат.; чув. *вирĕм* «пасха, олы көн (христианнарда язгы дини бәйрәм)» бор. бер ир. чыганактан булса кирәк. К. бор. төрки (КБ) *байрым* «җомга көне». ЭСТЯ II: 35–36.

Дерив.: **бәйрәмлә-ү, бәйрәмче.**

**БӘЙТ** «двустишие; строфа» < гар. *бäйт* «өй, йорт; дүртпочмак». К. **Бәет.**

**БӘЙТЕЛМАЛ** тар. «коммунальный склад; место, где складывались трофеи до распределения» < гар. *бäйт äл-мāл* «табыш-мал йорты, казна». К. EI I: 1141–1149.

**БӘК** тар. «человек рыцарских доблестей; бек, феодал» < бор. төрки *бәк < бәг* id. (бәкнең ирдәм, фазыйләтле кеше булырга тиешлеге турында «Кутадгу билик»тә бик тәфсилләп һәм күп тапкырлар сөйләнелә). Тат. телендә бор. *beg* сүзеннән дүрт сүз тармакланып килеп чыккан: **бәй II, бәк, би II, бик III.**

**БӘКӘЙ, бәкәч** (< **бәкәйчә*), башк. *бәкәс* «ягнёнок» һ.б., к. ЗДС:109 (төрле вариантлар һәм дериватлар күрсәтелә), *бә-ә* тәкълитеннән ясала, чаг. рус. *бяка* «бәрән» һ.б.ш.

**БӘКӘЛ,** диал. **бәкәй** «путовая кость; узкое место между копытом и берцом», «головка лаптей» (к. Сәйфи-Казанлы Ф. Өч нарат. Казан, 1929: 163), башк. *бәкәл, бәкәлсәй (< бәкәлчәй, бәкәлчәк)* > мар. *бакал* id. < бор. төрки *baqal < baqañ < baqaj* id., к. тат. диал., ком. *бакай* «сыер яки ат ашыгы» ~ башк., нуг., каз., к.-калп., кырг. *бакай,* себ. (Тумашева 1992: 166) *пагайақ* «сыйрак», хак. *пагаях,* алт. диал. *пāкāйāк*, бор. төрки (ДТС: 82) *baqajaq, baqapaq*, *baqajiq, baqapiq* «партояк ачыклыгы; тактояк уртасындагы сызык (партояклыларның бор. бабаларыннан калган сызык)» һ.б.; төр. *baqapaq* «бәкәл; сәкәл», *bagal* «бәкәл, бәкәл артындагы кабарынкылык», үзб., каз. (ЎХШЛ: 42; ҚТДС: 50) *бақалақ* «мөшкә» (каз. телендә *бақалақ* дигән җидесигез омоним бар – бу хәл атчылыкның гадәттән тыш актуальлеге белән аңлатыла) һ.б. К. ш. ук чув. (< тат. диал.) *пақăлчақ* нуг., каз., к.-калп. *бақалшақ,* уйг. диал. *пақалчақ,* кырг. *бағалчақ,* кар., ком. *бағынчақ* «бәкәл сөяге; сарык ашыгы» һ.б. *Бакал ~ бакань ~ бакай* сүзенең чыгышы тур. к. ЭСТЯ II: 43–45 (асылда юраулы). Төп мәгънә ат аягына караган һәм бәкәл билдәвен белдергән булса кирәк, шуннан к. **Балак, Балака, Балдак, Балтыр.** К. ш. ук Федотов I: 379–380 (бик аз мәгълүмат бирелә).

**БӘКЕ,** диал. **мәке** «прорубь» – мар. *вäк, вäкы* сүзеннән (бу яңгырашны Казан арты сөйләше вәкилләре әд. телгә керткәннәр); мар. *вäкы* (> чув. *вакă*) < болг. **wәкә* < бор. төрки *öкӥ ~* төр. *ögü* «бәке»; бор. төрки варианттан турыдан-туры миш. (срг.) **өкө,** (кас.) **үке** «бәке» вариантлары килә; к. ш. ук чыгт. *öкү, öгү*, к.-калп. *үки* id., венг. *vek* id. болг. теленнән. К. Räsänen 1969: 370.

Чаг. һинд-евр. **oqu* «күз» (шуннан рус. *óко, очкó, окнó*).

**БӘЛА [бәлә]** «беда» > чув. *пеле,* мар., удм. *бäлä, бала* «бедствие» – фар. *балā, балō* «бала тудыручы хатыннарга зыян китерүче рух; бәла; елгыр» ~ иске фар. *балāх*, ком., к.-балк. һ.б. *балагъ* «бәла» (күп телләрдә бар); гар. сүзе түгел, ләкин фарсыча дип тә раслап булмый.

**БӘЛӘБӘЙ** – название речки и города на ней в Башкортостане. Риваятьләр буенча, шул исемдәге бер чуваш салган өй ~ авыл атамасыннан, имеш.

**БӘЛӘК,** диал. **вәләк** (ДС I: 45) «валёк, валик» (для обкатки мытья)» ~ чув. *валек,* мар. *валяк,* удм. *бальак* id. < рус. *валёк*; мар. *бäлäклä-* < тат. *бәләклә-ү.*

**БӘЛӘКӘЙ** «малый, маленький» > чув. диал. *пеleккей* (Сергеев 1968: 49), мар. *бäлäкäй* «бәләкәй»,

кырг. *белекей* «тәбәнәк» < тат. диал. (миш.) *балакай* «кечкенә, бала», чаг. аз. *балаҗа, балага* «бәләкәй, кечкенә», к. **Бала.** Себ. (Тумашева 1992: 171) *пәликәйле* «бәләкәй» аерым аңлатма сорый.

**БӘЛӘСӘ** «балясы; баллюстрада» < рус. *балясы* << ит. *balanstro* id.

**БӘЛЕШ,** диал. **бәләш, пәләш,** (ЗДС: 123, 523) **билеш, мәләц, пәлиц,** себ. (Тумашева 1992: 150) **мәлец** < **мәлеч** «большой круглый пирог; беляш» > чув. *пелĕш,* мар. *палыш, пӓлыш*, удм. *бальыш,* рус. *беляш* id. Татар этимологиясендә традицион аңлатма: *баһалы аш* сүзеннән (ДС II: 33). Ләкин бу халык этимологиясенә тартым. Ышандырырлыграк этимология дә юк. Кайберәүләр бор. төрки, монг. *балиш* «бик зур акча берәмлеге» сүзе белән чагыштыралар, к. Тимергалин: 86.

К. ш. ук фар. *палез, пализ* «янбакча, ишек алды бакчасы; пәрәмәч төре, бәлеш» < бор. фар. *pairi daeza* «киртәләнгән бакча» (шуннан к. **Фирдәвес**). Фар. телендә ашамлык атамалары гөлчәчәкләр һ.б.ш.дан килүчән (к. **Гөбәдия, Гөлләч** һ.б.). Чаг. каз. (ҚТДС: 64) *бәләш* > *белес* «артбакча, яшелчә бакчасы».

**БӘЛҖӘ** (Троянский I: 231) «поперечный топор; тесло; пазник» < фар. *белчә, белҗә* «көрәкчек», *бел [бәл]* «көрәк». Рус. *белеза* «тимер көрәкчек» татарчадан булса кирәк. К. ш. ук. башк. *бәлйә,* чув. *пулле* «бәлҗә». Абаев I: 260; Фасмер I: 147 (каян икәнен белми).

**БӘЛЗӘМ** «бальзам» < рус. *бальзам* < гар. *бӓлсӓм, бӓлсӓн, бӓлӓсāн* > диал. (ЗДС:110) *бәлсән* << яһ. *бāсьāм* id. Төрле телләрдә очрый. Тимергалин: 86.

**БӘ́ЛКИ** «может, вероятно; может быть» < фар. *бӓлки* id. гар. *бӓл* һәм фар. *ки* сүзләреннән гыйбарәт; фар. *бәлки*нең төрки ярымкалькасы *бәлкем* халык телендә ешрак кулланыла. К. Будагов I: 267.

**БӘЛ** «выделения из половых органов женщин вне обычных месячных» (*бәл килә* диләр) ~ төр., кр.-тат. (Dobr. I: 293) *bel* «җенси органнардан килгән юешлек» < гар. *бӓлл, бӓллӓт* id. (гомумән «юешлек»).

**Бәл** гадәттә начар чир галәмәте дип исәпләнми.

**БӘЛЛҮ I [бәллĕw],** диал. **бәлли** «люлька, колыбель» > мар. диал. *балу*, удм. *бали, балли* id. ~ к.-балк. *белляу* «бәллү; бишек җыры», үзб. *балла-, бӓллӓ-*, як. *билкā-* «бала тирбәтү» һ.б. Ләкин төп материал тат. теленең үзендә, к. тат. сөйл. *бәвеллә-ү, бәүлә-ү* «бәби тирбәтү», *бәвелдерек* «маятник» (Вәлиди II: 471), *бәвелт-ү, бәвет-ү* «көйләп тирбәтеп йоклату яки тынычландыру» һ.б. *бәү* ымлыгыннан ясалган сүзләр. К. **Әлли-бәлли, Бишек.**

**БӘЛЛҮ II** (Мөхәммәдьяр, Максуди кебек әдипләр телендә) «известно, конкретно; известный, славный»; чув. *паллă* > мар. *палы* id. иске тат. теленнән кереп калган булса кирәк. Төр. *belli* < бор. төрки (ДТС: 94, 100) *bellük, bellüg* «билгеле, данлы». К. ш. ук кр.-тат. (Dobr. I: 293–294) *bel, belge, belgĭ* «ишарәт, галәмәт; документ».

Бу сүз *билге* белән тамырдаш булса кирәк. К. **Билге.**

**БӘЛТЕРӘ-Ү** «маяться, мучиться (в бессилии); раскиснуть (от старости)» ~ башк. *бәлтерәннә-ү*, мар. *бӓлдыра-* «эшкә комачаулап йөрү» (Гордеев I: 194), кырг. *балдырақ* «бытылдап сөйләүчән». Имитатив тамырдан булса кирәк (*бәлтер-бәлтер, пылтыр-пылтыр*).

**БӘЛТӘКӘ** (ДС I: 41; БҺҺ III: 47; ТТДС I: 104; ТТДС II: 67) «необработанная шкура; шкурка, лоскут шкуры», **бәлтәкәр** «мездра». Чаг. фар. *бӓндӓкӓ* «сеңер, бәйләвеч» яки *пӓртикяр* «эш ташландыклары». Тире эшкәртү терминологиясе тат. телендә башлыча фар. теленнән килә.

**БӘЛТӘРАФ** (ТТДС II: 62) «растрата» < фар. *бӓрт̣араф* «төрле якка, як-якка (тарафка)»

**БӘЛТУАР** «титул правителя Булгарии» – бу бик бәхәсле термин: Ибне Фазан язмаларында (аларның күчермәсендә) ачык язылмаган сүзне *белгуар* (Н. Исәнбәт), *илтәбәр* (күпчелек), *йылтуар* (И.Г. Добродомов), *бәлтуар, белтуар* дип (Р. Фәхретдинов) укыйлар. Һәм, безнеңчә, Р. Фәхретдинов хаклы, чөнки чув. телендә *патвар* «батыр, герой» сүзе бор. *бәлтуар*дан гына килеп чыга ала. *Бәлтуар* исә фар. *пӓртаван* «сәргаскәр», «парфян» сүзеннән булуы бик мөмкин. К. Фәхретдинов: 63, 69.

**БӘЛҮДӘ** диал. (М. Гафури һ.б. телендә) «мелкая тарелка, блюдечко» < рус. *блюдо* id.

**БӘНДӘ** «человек, жалкий человек; раб (божий)» < фар. *бӓндӓ,* авест. *banda*, санск. *bandһa*

«кол, хезмәтче», сугд. *bandak*, *bantak* «кол» – төп мәгъ. «бәйле, бәйләнгән» (һинд-евр. тамырыннан, шуннан *банда, бинт, бунт* һ.б. сүзләр килә).

Дерив.: **бәндәчелек.**

**БӘПКӘ I,** диал. **бәбекә** «птенец; гусёнок или утёнок» к. **Бәби.**

**БӘПКӘ II** «стропило» ~ тат. диал., мар., удм. *бабка* id. < рус. *бабка* id. «әби, бәпкә» сүзеннән; к. ш. ук диал. **бәбкә** «көлтә өеменең бер төре» – киң итәкле рус карчыгына охшатылган. Көлтә өемен колгалардан корылган куыш каркасына өеп ясаганнар, шуннан каркасның үзе дә *бабка* > *бәпкә* дип аталган. Ахметьянов 1989: 53.

**БӘПЛӘ-Ү** диал. «успокаивать (дитя); обучать (лошадь)» < диал. (себ., БТДҺ: 38) *бапла-у* «доводить до кондиции», к.-калп. *бапла-*, кырг. *бапта-* «бәпләү, күнектерү; нәрсәне булса җиренә җиткерү», уйг. *бапла-*, үзб. *бопла-* «шәп итү; алдау» асылда «бабларга бүлү, системалы итеп эшләү» ← башк., кырг., к.-калп. *бап*, үзб. *боб* «осталык, атны яисә ау кошын өйрәтү» < гар. *bāб* «капка; өйрәнү чоры» һ.б. (к. **Баб**) сүзеннән.

**БӘРАБӘР** «равен, равно; одинаковым образом» < фар. *бäрāбäр* < *бäр-бā-бäр* «бәрабәр» – төп мәгъ. «күкрәккә күкрәк» (*бäр* < авест. *vara* «күкрәк»), чув. *пакапар* «тиң» – татарчадан бозылып кергән.

**БӘРӘҖӘ, бәрәзә** «женский цветастый халат» < фар., төр. *фәраҗә* «хатын-кыз халаты; ирләрнең (мәүләви суфиларының) бик озын күлмәге»; к. ш. ук. кырг., каз. *бераҗа* «үзбәк халаты», *беренҗи, беренжи* «пеньюар». К. Будагов I: 251; Räsänen 1969: 70. К. **Пирәсә.**

**БӘРӘКАЛЛА, бәрәк** «благочестивое восклицание при удивлении»; гади сөйләмдә *бәрәч, бәрәк* < гар. *бäрäк Аллаһу* «Алланың изгелеге (бу)». К. **Бәрәкәт.**

**БӘРӘКӘТ** «экономичность; бережливость; прибыль; спорость; благодать» > удм. *берекет*, мар., чув. *перекет, переккет* «бәрәкәт; акча саклыгы» (чув. *перекет касси = бәрәкәт кассасы* «саклык кассасы») < гар. *бäрäкäт* «иркенлек, киңлек; уңышлылык», *брк* тамырыннан; к. ш. ук *бәрәкәт догасы* уңыш теләү догасы. К. **Тәбрик.**

Дерив.: **бәрәкәтле; бәрәкәтсез.**

**БӘРӘН** «ягнёнок; козлёнок (реже)», диал. (ЗДС: 110–111) **бәрәх, бәрәч, бәрәк, бәрәкәч** id. ~ чув. диал. *пудрам, порам, перам, пäран*, мар. *паран, пäрäн* id. ~ үзб., таҗ. *барра* «бәрән; илтер (каракүл) бәрәне», рус., гом. слав. *баран* «кучкар, сарык тәкәсе» һ.б. (дөньядагы күп телләрдә охшаш сүзләр бар) – сарыклар чыгарган авазларга тәкълиттән, к. тат. *бәр-бәр, бәрә-бәрә, бәрәшбәрәш* ~ рус. *баря-баря* сарыкларны чакыру ымлыгы. Тат. диал. *бәрәч* ~ рус. *барашка* – очраклы охшашлык түгел. Ләкин тат. сүзләре рус теленнән алынмаган. Чаг. ш. ук бор. һинд-ир. *brana* «алтын мөгезле тәкә». Бор. ир. халыкларда сарык тәкәсе *фарн*ның, ягъни яшәү, тереклек ялкынының чагылышы булган, к. МНМ II: 557–558. Преображенский I: 16; Федотов I: 399. К. **Бәкәй, Кучкар.**

Дерив.: **бәрәнле, бәрәнсез; бәрәнлә-ү.**

**БӘРӘНҖӘР, бәләнҗәр, баранҗар, баланҗар** «баранджары» – одно из племён Волжской Булгарии – тәүдә Хәзәр империясендә яшәгәннәр, IX г. Болгар иленә күченгәннәр. Тарихчылар **бәрәнҗәр** сүзеннән соңрак искә алынган **бараҗ** этнонимы (кавем атамасы) килеп чыккан диләр. Безнеңчә, **бәрәнҗәр** – тарихи язмаларда гарәпчәләштерелгән **бәрәңгәр* сүзеннән: *ғар//-гәр, -қар//-кәр* бор. һуннболгар кавемнәре атамаларына хас кушымча. ТЭ II: 301.

**БӘРӘҢГЕ,** (ЗДС: 110) **бәрәй** «картофель, картошка» – Идел-Урал телләрендә таралган сүз, тат. телендә килеп чыккан булса кирәк – тат. диал. *бәрәнке,* мар., чув. *паранкӑ, пәрәңге*, *бäрангы* (ләкин болар норматив вариант түгел). Башк. диал. *бүрәңке, бүреңке,* мар. диал. *бöрäнгы, бÿрäнгы,* ш. ук венг. *burgonya* «бәрәңге» вариантлары бу сүзне бур. *бөөрэнхы* < бор. монг. *bögürekei* «йомарлак, тубалак, йомры нәрсә» (>> рус. *баранка* «тоташ тәгәрмәч») сүзе белән бәйләргә мөмкинлек бирә (*бөрәңкәй* > *бүәрәңкә* > *бүрәнке* һәм *бәрәнке*: мондый *ә* < *ö* > *у* болг. сүзләренә хас, к. **Аркан, Әрмәк**). Тикшеренүләр *бәрәңге*нең күпләр уйлаганча безгә Европадан түгел, көнчыгыштан – Себердән таралганлыгын күрсәтәләр. Бу *bögürekei* – *бөре* сүзенең ише, к. **Бөре.** К. ш. ук чув. *пуранхӑ* «бәрәңге алмасы; бөре».

Удм. *баранги,* үзб. *бәрәң* һ.б.ш. «бәрәңге» < тат. Чув. вариантлар тур. к. Сергеев Л.П. Чувашские диалектные названия картофеля и их география // Диалекты и топонимия Поволжья. Чебоксары, 1972: 53–62. **Бәрәңге** сүзе Мари-Элдагы татар авылы

*Бәрәңге*дән таралган (тәүләп шунда иккәннәр) дигән фикер игътибарга лаеклы; бу авыл исеме шундагы зур гына *Параньга* елгасы исеменнән (к. Галкин: 150).

**Бәрәңге** сүзенең бүтән аңлатмалары: гар. > иске тат. *фәрәңги* «Европаныкы, франкларның» сүзеннән (К. Насыйри), *Беринг* (Ерак Көнч. диңгезләрен тикшергән сәяхәтче) исеменнән (Н.К. Дмитриев), рус. диал. *мериканка* < *американка* «бәрәңге» сүзеннән (В.Г. Егоров), рус. сөйл. *паренька* «пешерелеп (парландырып) ашала торган тамыразык (шалкан, бәрәңге)» сүзеннән (Рясянен) – *бүрәнке* вариантын аңлата алмыйлар). Ахметьянов 1989: 53–54 (тәфсиллерәк аңлатыла); Тимергалин: 87–88.

**БӘРӘЧ** к. **Бәрәкалла.**

**БӘРБӘР** иске әд. (Тукай һ.б.) «парикмахер, брадобрей» < төр. *berber,* фар. *бäрбäр* id. **Бәрбәрханә** «парикмахерская».

Бу сүз беркадәр бәхәсле: фар. *бäрбäр* < *бäрдбар, бäрдбур* «сакал кисүче» сүзе бар, ләкин төр. *berber* id., лат. *barberins* (~ фр., ним. һ.б. *Barbier,* инг. *barber*) сүзләреннән дип аңлатыла. Шуннан ук рус. *борода* ~ *брада* «сакал», *брадобрей* «бәрбәр».

**БӘРДЕ,** диал. **бәрдем, пәрде, фәрде** «хариус, пескарь» ~ мар. диал. *бäрда* ~ башк. *бәрле* (*бәрлесәк*) «бәрде маймычы», к. БҺҺ II: 63. К. **Бәртәч.**

**БӘРКӘ** диал., иске тат. «крепость; стойкость; усилие» к. **Биркә.**

**БӘРМӘЧЕК,** диал. **бәрмәнчек, бәрмәчлекей** (Остроумов 1892: 55), **бәрмәчтеки** (ЗДС:111), **бәрмәчлек** (Ашмарин 1902: 112) «вербное воскресенье», «Лазарева суббота» (христианский праздник) *бәр-ү* һәм рус. *верба* сүзләренең контаминациясеннән гыйбарәт: язгы бер көнне кешеләрне урамга куу – өйдәгеләрне талчыбык белән «бәргәләү»; к. удм. диал. (Насибуллин) *ъштъp бэрмак* < тат. *ыштыр бәрмәк* «бәрмәчек» (бу бәйрәмне ыштырларны ыргыту-бәрү көне дип аңлаудан), чув. *вервӓ* (Магницкий: 126–127), *варпӓнни* id. Христиан бәйрәме мәҗүси бәйрәм-сөрән йолалары белән кушылган. Рус. *вербное воскресенье* сүзе лат. *palmarii* «пальма көне» сүзеннән калька; пасха бәйрәмендә христианнар Гайса пәйгамбәр табутына пальманың яшь ботак-яфракларын китереп тезәләр. Россиядә пальмаларны яфраклары (формасы белән) охшаш булган талчыбыкка алмаштырганнар. К. Фасмер III: 193.

**БӘРТӘЧ,** диал. **бертәс, бәртәс, бәрдәс** (Вәлиди II: 464) «голавль; язь» ~ мар. *пäрдäш* > *пардаш* ~ фин. *partti* id. Күрәсең, *бәрде* һәм *бәртәч* – фин-угор (мари) телләреннән килә. Насипов 2007: 228.

**БӘР-Ү** «ударить», диал. «бросать, кидать» > чув. *пер-*, мар. *пер-*, *пäр-* id. < гом. кыпч. *бәр-* «бирү» сүзеннән (*ә* < *э* > *и*), (чаг. рус *дать* «бирү; бәрү, сугу»). М. Рясянен һәм М.Р. Федотов (I: 413–414) бу сүзнең этимологиясен ялгыш юнәлештә эзлиләр һәм яз. монг. *berege* «таяк» сүзен китерәләр. **Бәрү** һәм **бирү** сүзләренең этимологик бердәйлегенә Л. Җәләй игътибар иткән. К. себ. **бәр-ү** «бирү».

**Бәр-ү** продуктив нигез: **бәрел-ү, бәрен-ү, бәреш-ү, бәрдер-ү; бәргеч, бәрмә** (музыка кораллары тур.).

**БӘРХӘДӘР** кит. «прок, польза (от деяния)» ~ чув. *пархатар, перхетер,* иске тат. *барходар, бәрхурдар* < фар. *бäрхордар* «гамәленнән файда күрүче» (*бäрхор-дар*): *бäрхор* «уңышлы эш, бәхетле очрак». Федотов I: 387–388.

**БӘРХЕТ** «бархат» > мар., удм. *бархат, бäрхäт, баркът* < рус. *бархат* < ним. *barchât, barchent* < төр., гар. *барракан* «йомшак йон тукыма», к. Фасмер I: 123, 129; Kluge: 91. Чаг. **Бирән I.**

**БӘРЧӘ,** диал. (ЗДС: 110–142) **бәлчә, бәтчә** «кисть (например, проса), серёжка растений» ~ чув. *перче,* мар. *пäрчӓ, пäрцӓ, парча, пäртня* «бәрчә; вак яфраклы сабак очы» < фар. *бäртче* id., төп мәгъ. «сакалчык» (*бäр, бäрт* «сакал» ~ рус. *борода* id.). Федотов I: 414–415 (тат. сүзен белми); Ахметьянов 1989: 55.

**БӘРЧЕН** «дорогая шёлковая ткань» ~ башк. *бәрсен* «ефәк чук», чув. *пурҫӑн, порҫӑн*, мар. *порсын, парсын*, удм. *бурчин* ~ үзб., бор. төрки *barčӱn* «бәрчен; келәм һ.б.» (күп телләрдә бар) фар. теленнән булса кирәк. Чаг. фар. *абрешим* «ефәк төре»? К. Wickman 1903: 49.

Төрки дастаннарда *Бәрчен сылу, Айбәрчен, Бәрчен-Салыр* (*салыр* < *салаур* кабиләсенең **Бәрчене**) – атаклы бор. гүзәл, «бәрчен киемле матур». Федотов I: 447. Рус. *брачина* «бәрчен» тур. Фасмер

I: 308–309 (тат. һәм бүтән кыпч. параллельләрен китерми). Рус. диал. *бурс, бурса* «ефәк төре» сүзен дә Аникин (: 145) *abrešim, abrişom* «ефәк» сүзе белән чагыштыруны кабатлый. Мәгънә җәһәтеннән кыенлык булмаса да, фонетик җәһәттән монда сораулар туа.

**БӘС I** «иней; изморозь; пороша» ~ чув. *пас,* мар. *пäс, пас, бäс* id. ~ к.-калп. *баз* «күгәрек», себ. тат. (ДС I: 154) *пәс* «(ява торган) боз», чаг. госм., чыгт. *пас* «кунык, юшкын, тут». Чыгышы бик үк ачык түгел.

**БӘС II** «хватит; достаточно (сказанное); значит» < фар. *бäс, бас* id. < бор. фар. *vaš,* авест. *vašanh,* санск. *vašaš* «җитәрлек; яхшы, күп, мул» (Platts I: 154). К. **Бәслә-ү.**

**Бәс,** төр. *bes, pes* «җитәр, бетерәсе, туктыйсы» сүзеннән рус. *пас* «көрәштән (гадәттә кәрт уеныннан) тукталмалы», «җитәр!» сүзе килә. К. ш. ук кр.-тат. (Dobr. I: 300, 304) *besi* < төр., аз. < фар. *бäси* «канәгать, тук; артык күп».

**БӘС III** «фиолетовый» ~ башк. *бәҫ* id. Ачык түгел. Ихтимал, «бәз тукыма» сүзеннәндер (кайбер бәзләр миләүшә, шәмәхә төсендә дә булган).

**БӘСЛӘ-Ү** диал. «обслуживать; воспитывать; удовлетворять»; «кинуть жребий» (к. Будагов I: 258) – бу сүз әле XIX г. азагында миш. диалектларында актив кулланылган ~ кар. *бэслэ-*, төр., аз. *бәслә-,* id.; гаг. *бәс [бэс]* «симертү», *бэсим* «туклык», *бесиле-* «симертү» һ.б. К. ш. ук башк. *бәҫтә-ү* «хөрмәтләү», *бәҫле* «хөрмәтле» һ.б. **Бәс II** сүзеннән булса кирәк.

**БӘТИ,** диал. **бәди, беди, бәки, бәкәй** (ДС: 31, ДС II: 65–66) «козлёнок» ~ чув. *пытек, пытьак, путек, питек* (Сергеев 1971: 100), мар. *батя, пача, пäтьä* id. сүзен Гордеев (I: 205) кырг. *бойдак,* таранчы. (уйг.) *бойтаҡ* «яшь сарык тәкәсе» сүзеннән чыгара. Безнеңчә, монда андый чагыштыруларга урын юк: *бәти < бәки, бәкәй < бә-кәй,* ягъни «бәэлдәүче» сүзеннән – һәр сөйләштә мөстәкыйль рәвештә килеп чыга ала. Чаг. ш. ук рус. *бяка, баля* һ.б. «бәти, бәрән».

**БӘТРӘК** «драчун; несдержанный» ~ каз. *бедрäк, бäдрäк* «юньсез кеше», *бедрäі-* «әтәчләнү» (Радлов IV: 1624); чаг. фар. *бäдраһ* «бозык, азгын», «начар юлдагы» (кеше); *бäд рäфт* «тәрбиясез», «начар тәрбияле», *бäдрäг* «явыз; түбән катламнан» (*бäд* «әшәке, начар»).

**БӘТЧӘ,** диал. (ЗДС: 527) **пәце** «чадо, отпрыск» < үзб., таҗ. *бача, бачча* «малай; яшь терлек; бозау» – һинд-ир. телләрендә киң таралган сүз (Platts I: 117, 136–137). Төрки телләрдә (Урта Азия, Кавказ) бу сүзнең «фахиш малай» мәгъ. билгеле.

**БӘҮ, бәү-бәү** «баюшки-баю» – киң таралган ымлык. К. **Бәллү.**

**БӘХӘС** «спор» < гар. *бäхäҫ* «тикшерү; бәхәсләшү»; к. ш. ук фар. *баҳс* id. Мар., удм. *бäхäс, бäкäс* < тат. (Гордеев I: 188).

Дерив.: **бәхәсле, бәхәссез; бәхәсләш-ү.**

**БӘХЕЛ** «скупой; мелочный» < гар. *бäх̣ӣл,* к. **Бәхил II.**

**БӘХЕР** «стопа (в стихотворени)» < гар. *бäхрүн* id., төбендә «дулкын» ← *бхр* «диңгезгә охшау» тамырыннан (шуннан «дулкынлану» > «ритм»).

**БӘХЕТ** «счастье» > чув. *пехĕт,* мар. *бäкет, пакыт* id. < фар. *бäх̣т, бах̣т* < авест. *bakhta* ~ санск. *bhakta* «өлеш, бәхет». Күп телләргә таралган сүз.

**БӘХЕШ** ист., кит. «бахшиш; подарок с определённой целью» (ЛТ I: 143) < фар. *бахш* «бүлек, бүләк, өлеш». К. **Багыш.** Федотов I: 415.

**БӘХИЛ I** «прощаю; доволен (кем)»; бу сүзнең дериватлары киң кулланыла: **бәхилләү** «гафу итү, кичерү; канәгатьләнү», **бәхилләт-ү** «риза итү, канәгатьләндерү», **бәхилләш-ү** «бөтенләйгә, күрешмәскә аерылу», **бәхиллек** «ризалык» һ.б. **Бәхил** сүзе татарчадан күрше телләргә дә күчкән: чув. *пехил,* мар. *пакел.* удм. *бакель* id. (дериватлары һәм фразеологизмнары да бердәй яки охшаш).

**Бәхил** сүзе мәзкүр мәгънәдә гарәпчә сүзләрдә сирәк очрый, шуңа күрә аны фар. *бә хәл, би хәл* «хәл эчендә» фразеологизмыннан чыгып аңлаталар (Будагов I: 246). **Хәл эчендә** «үлергә якын» мәгъ. идиома.

**БӘХИЛ II,** диал. (себ., ЗДС: 97) **бақыл** «скряга, скупой» ~ каз. *бақыл* < гар. *бäх̣ӣл* «бәхел, саран»; *бихәл* (بحل)дән үзгә буларак, икенче төр – каты *х̣* (خ) белән языла ягъни бүтән тамырдан. Федотов I: 415. Тимергалин: 89–90.

**БӘХШИ** «языческий мудрец; учитель бардов – народных профессиональных мастеров слова» < уйг. *бәхши, бахши*, кырг. *бақшы*, каз. *бақсы* һ.б. «укымышлы, сихерче, врач, мастер һ.б.» ~ тув. *башқы* «укытучы, мөдәррис» сүзен фин галимнәре (Рамстедт, Рясянен) кыт. теленнән чыгаралар: бор. кыт. *pah si* «укытучы», яки хәз. кыт. *боши* < **bag ši* «тәрбияче, остаз» (ДТС: 82) яки **pak ǯči* «ханның йолдызбагары, астрологы» (Ramstedt 1951: 59–82) һәм бу версия дөрескә охшый, к. як. *кытай баксы* «сихерче-тимерче». Рус тикшеренүчеләре *бакшы* сүзен санск. теленнән диләр. Будагов I: 245–246 (бик тәфсилле); Аникин: 112–113 (бай әдәбият).

**БӘҺА** кит. «цена», гади «до́рого» (*бәһа төште* «обошлось дорого») к. **Бәя.**

**БӘҺАР** иск. «весна; весеннее торжество» < фар. *бäһāр* id. К. **Бәйрәм.**

**БӘЯ [бәйә]** «цена, стоимость» < кит. *бәһа* < фар. *бäһā* id. *Бәйә* варианты тат. телендә килеп чыккан булса кирәк, бүтән төрки телләрдә актив кулланылмый (аларда *баа, бага, паха* һ.б.ш.).

**БӘЯЗ [бәйаз]** тар. «беловик, чистовик» < гар. *бäйāḑ* id. (Будагов I: 298).

**БӘЯН [бәйан]** «изложение» < гар. *бäййāн* id.

**БЕЖГӘК** «брюзга» (**бежгәклә-ү** «брюзжать, ворчать», к. Остроумов 1892: 39) онопоэтик сүз булса кирәк; ихтимал, рус. диал. *брюзжак* сүзеннән ярымкалькадыр.

**БЕЗ I** «мы» < гом. төрки *биз* < **бирг,* к. чув. *эпир [ĕбир]* < **бир – *би* «мин» сүзенең күп. (икелек?) формасы. К. **Мин.**

**БЕЗ II** «шило», **мез** (Тумашева 1992: 151) «лезвие ножа» < гом. төрки *биз* < *бигиз*, к. каз. *біғиз,* үзб. *бегиз*, чыгт. *бигиз* «без; пычак һ.б. үткен ягы» < **бәгирг,* к. чув. *атпăри* «итек безе» (?), калм. *бирм* < бор. монг. *birim* >> ним. (һунн теленнән) *Pfriem* id. Бор. гом. төрки **би* «үткенлек, оч, кискен кырый» сүзе белән чагыштырыла, к. **Белә-ү.**

**БЕЗГЕЛДӘК, бизгелдәк,** себ. (Рамазанова 2001: 97) **пискәнәк** «стрепет» ~ башк. *биҙгәләк, безгелдек,* үзб. *безгалдак,* каз., к.-калп. *безгелдек* id. ~ тат. диал. (ТТДС I: 84) **бизгелдә-** «ваксу, капризлану», башк. *бизгелдә-* «елаклау; самаклау, калтыранып такмаклап елау», к.-калп. *безеңле-* «тызбыз йөрү», үзб. *безангла-* «сискәнү, калтырану» һ.б. бор. төрки (ДТС: 91) *bez-* «калтырау, тетрәү» сүзеннән, к. **Безлә-ү, Биз II, Бизгәк.** К. ш. ук диал. (ЗДС: 112, 533) **безбелдек** «сагызак, шөпшәнең бер төре», **писелтәк** «каушаучан», нуг. *безгелек* «боҗыр», *безелен-* «күкәй салырга урын эзләү».

**БЕЗЛӘ-Ү** «дрожать (о животном), вертеть хвостом» – **бизлә-ү** «калтырау» белән бердәй булса кирәк. Чаг. ш. ук **бузла-у.**

**БЕЗРӘК, безәрәк, бездәрәк** (ЗДС: 112) «немножко» ~ башк. диал. *безрик*, тув. *безерек [бэзэрэк]* id. < монг. *бэзэрэг, бэсрэг* «дефектлы, җитенкерәми; түбән сортлы; кушылгак (чиста кан түгел)», к. ССТМЯ I: 127. К. ш. ук мар. *пы̆чы̆рик* «безрәк».

**БЕЛӘЗЕК** «браслет; запястье» < гом. кыпч., төр. *билезик* сүзен Ф. Корш XIX г. ук *биләк йүзүк* «беләк йөзек» дип аңлаткан һәм бу аңлатма шуннан соң күп тапкырлар кабатланды. Ләкин бу дөрес түгел (к. Gombocz: 46–47), к. себ. *пеләлек, пеләрек*, кырг. *билерезик*, аз. *биләрзик*, бор. монг. *bilečüg*, калм. *bilürüg* «беләзек», хәз. монг. *билэчэг,* бур. *бэһэлиг* < *бэсэлиг* < *бэлэчүг* һ.б. (вариантлар бик күп). Нигезе – бор. **биләр* «анатомик беләзек» чыннан да *беләк* белән тамырдаш, ләкин монда *биләк* элементы юк! К. **Беләк.**

Мар., удм. *бы̆лазы̆к* «беләзек, манжет, күчәр тулкасы» < тат. К. Пекарский I: 467; Тумашева 1992: 172. Рус. *бел(ь)чук* «кул беләзеге, йөзек» ~ тат. *беләзек* тур. к. Фасмер I: 150, шунда ук әдәбият күрсәтелә. Гомумән, бу сүз күп күрше (гар., венг., слав.) телләренә алынган.

**БЕЛӘК,** себ. тат. **пеләк** «рука (от кисти до плеча)» < гом. төрки *билек, биläк* «запястье; редко нижняя часть рукава» ~ эвенк., эвен. һ.б.ш. *билан, билэн* id. Күренеп торганча, *-к* яисә *-әк* кушымчасы ярдәмендә ясалган. Ләкин сүз нигезе бик үк ачык-аян түгел. Чаг. **Бил.** ЭСТЯ II: 145. Бор. алт. теленнән килә дигән фикер бар, к. Рамазанова 2013: 104 (сүзнең күп күч. мәгъ. күрсәтелә).

Дерив.: **беләкле** «көчле» мәгъ.; **беләксә** «урак урганда беләккә киелә торган кием».

**БЕЛӘН** «с, вместе с» – гом. төрки *билэн* < *бирлэн* id. *бир* «бер» сүзеннән: бор. *-лэ, -лэн* рәвеш ясагыч аффикс булган.

Бу бәйлек төрки телләрдә генә түгел, тат. теле сөйләшләрендә дә күп вариантлы: **белә** (урта диалект), **билән, блә, бя, бә, былан, балан, бән, бан, ман, мән, пан, пән, мынан, менән** һ.б. Иң сәере – тат. диал. *булан*ның ком. телендә параллеле бар. Кайбер телләрдә (кар., чув., кр.-тат.) *-ба, -бә* (кушымчага әверелгән). К. Абдуллин 1963; Арсланов 1976: 3–71; Садыкова 1985: 95; Щербак 1987: 80–81 (арытабангы әдәбият күрсәтелә). К. **Берлә.**

**БЕЛӘНДЕК** (Башкортстан) «тахта для совершения намаза» < үзб., уйг. *бәләндлик* id. – *бәләнд* (фар.) «югары» сүзеннән.

**БЕЛӘ-Ү** «точить» < гом. төрки *билә-, булә-* (як. *бүүлэ-, мүүлэ-*) «беләү, кайрау», як. *билэ-* «кисү», *би, бү* «үткен оч, үткен кырый; кискен, кисү» сүзеннән (*би-лэ-, бү-лэ-*), бу яңгырашларның уртак чыганагы **bägi* булырга тиеш. К. **Без, Пычак.**

**БЕЛӘҮ [bĕləw]** «оселок, брусок» ~ чув. *пĕлев,* мар. *пюлау, пӹлау* (Исанбаев 1978: 38) удм. *билёү* бор. төрки *bilägü* id. сүзеннән килә һәм барлык төрки телләрдә диярлек рефлекслы (ЭСТЯ II: 142–143). Федотов I: 419–420. Тат. сөйл. *беләү* «ипинең көя төшкән катысы», *беләү җара* «озак төзәлми торган яра» – икенчел мәгънәләр.

**БЕЛГЕ** «специально сделанный признак, марка для опознания»; «знание необходимых правил, сведений» – бу ике мәгънә ике тарафтан килеп бирелгән. К. добр. (Dobr. I: 317) *bĭlgi* (нәк татарча әйтелә) «белергә тырышу; белем, гыйлем, культура; белергә, белемгә омтылыш» < гом. кыпч. *билги* id.

Дерив.: **белгесез** «әдәп-хәя кагыйдәләрен белми торган (кеше)», нишләптер **белге, белгесез** сүзләре сүзлекләргә кертелмәгән, бәлки **билге** сүзе җитәр дип уйланыладыр. Ләкин **белге** белән **билге** бераз аерымлана: **белге** махсус ясала, **билге** исә махсус ясалмаска да мөмкин. **Белге бирү** «инструкция бирү».

**БЕЛЕК** «знание законов, правил» – гом. төрки *билиг, билик* id. «язма закон» мәгъ. дә йөргән. ДТС: 99–100; Из глубины столетий: 113–118.

Тарихта төрки *билиг ~ билик ~ билүк* күптөрле мәгъ. кулланылган: «аерым билге, (Будагов I: 268) кыяметтә гөнаһлыларның муенына асылган язу», «хөкүмәт киңәшендә белдерелгән фикер, белгеч киңәше», к. ш. ук бор. рус. *белег ~* ним. *Beleg* «мөһим мәгълүмат» төрки телләрдән. К. **Бәлгә, Белге, Бел-ү.** Тимергалин: 90.

Дерив.: **белекле, белексез.** К. түбәндәгеләрне.

**БЕЛЕКЧЕ, белемче** «знаток обрядов, народной медицины и т.п.», гом. төрки *билигчи ~ билгүчи* «гомумән белгеч», к. ДТС: 99–100. Бу сүзләр бор. заманнарда ук Европа телләренә дә кергән. К. бор. рус. *блехчий* «тимерче» < болг. **биләхчи* id. Фасмер I: 174.

**БЕЛЕМ** «знание; образование» < гом. төрки *билим* id. Бу сүз *билик*тән соңра пәйда булган.

**БЕЛЕН** «блин» – тат. диал. *белем,* чув. *пĕлĕм,* мар. *бӹлӹн, пылын,* удм. *мильым* id. < рус. *блин* < *млин*, төп мәгъ. (*мелень*) «тегермәндә тарттырылган он» (к. Фасмер I: 175), ягъни шуннан пешерелгән затлы аш. Федотов I: 420.

**БЕЛ-Ү** «знать; узнать; суметь» < гом. төрки *бил-* (себ. тат., чув. *пĕл-*, себ. төрки *пил-*) id. як. ш. ук «идарә итү»; бу бик тә киң кулланышлы фигыльнең этимологиясе өчен чув. *пал, палă, палкă* «билге», *палла-* «белү, тану», *паллă* «билгеле, атаклы» сүзләре (Ашмарин IX: 82–85) әһәмиятле – алар *бәл-* < *бэл-* вариантыннан килә: болг. *bäljük* «һәйкәл, кабер ташы» > мар. *пӓлы, пӓлык* «билге, тамга», венг. *belyeg* «билге» (Gombocz 1912: 43), төр. *bellek* «истәлек», *belle-* «истәлек итү, ядкәр итү; сагышлау, сагыну», *bel* «билге, тамга», *belli* ~ гаг. *белли*, үзб. диал. *белли* «тамга, билге» (ЎХШЛ: 50) – мәзкүр телләрдә шул ук вакытта *бил-* сүзе һәм аның дериватлары да бар. Һәм тат. телендә дә *бел-* белән рәттән *билге, билдә!* Хәлбуки монда төптән үк ике сүз булырга тиеш түгел. Димәк, тат. *бел-* һәм *бил-*, гом. төрки *бил-* һәм *бэл (бәл)* вариантлары өченче бер – төп варианттан – **бәйл-*дән килеп чыкканнар (*бил* < *бәйл* > *бәл-*).

Бу сүз исә борынгыча исемне дә фигыльне дә белдергән: «биләмә чиге; билгеләү» һәм «биләмә чиге билгесе». **Бәйл*не кытайча *бэй* «стела, кабер башы» белән чагыштырып була. К. **Белге, Билге, Биләү, Бүләк.** Будагов I: 267–269; Räsänen 1969: 75; ЭСТЯ I: 138; Федотов I: 49. Рус. *белмес* «белмим» тур. Аникин: 126.

Дерив.: **белен-ү, белеш-ү, белдер-ү; белгеч; белек; белеш; белдек** (*үз белдеге*).

**БЕНЗИН** «бензин» < рус. < фр. *le benzoin* < төр. *lüban cavi* «Ява җәве (җавы)» сүзеннән: *lü* иҗеген

французлар үзләренең *lü* артикле дип уйлаганнар. Шулай итеп, *бензин* сүзе тәркибендә төрки *җәү* сүзе бар. К. Kluge: 109.

Фәнни-техник терминологиядә *бензо* нигезеннән күп сүзләр ясалган. Мәс., *бензол* сүзен нимес химигы Либих иҗат иткән.

Суматра һәм Ява утраулары берара Госманлы империясе составында булганнар (үз теләкләре белән хәлифәгә буйсынганнар). Шул чорда Төркиягә Индонезиядән табигый бензин китерелгән.

**БЕР** «один» < гом. төрки *бир* id.; тамыр бәйләнешләре ачык түгел, Г. Рамстедт тунг. *бури* «барча, һәммәсе» сүзе белән чагыштыра, ләкин бу фараз гына; *бармак* белән чагыштыру (Л. Җәләй, Н. Борһанова) бөтенләй чәрексез (к. **Бармак**). Рус. һ.б. *первый* ~ тохар. *pärwat* «тәүге, элекке; иң өлкән» белән чагыштыру да бик юраулы.

**Бер** сүзеннән тат. телендә генә дә йөзләрчә кушма сүз ясалган һәм аның гайре регуляр дериватлары да аз түгел:

**берәү** < бор. төрки *бирәгү; -әгү* өлеше (ш. ук *икәгү* «икәү» һ.б.) кыт. *гэ, гү* «данә» сүзеннән дигән фараз бар; чаг. ш. ук **Берәгәй;**

**берең** «коллективтан, төркемнән бер кеше», **бер-берең** «үзара якын мөнәсәбәттә булган кешеләр»;

**бергенәм** «кадерле кешем» һ.б.

**бер-** юклыкны белдерә торган компонент буларак тәүге *һич* төшерелү – эллипсис нәтиҗәсендә килеп чыккан: *беркайчан* < *һичберкайчан, беркем* < *һичберкем* һ.б. Räsänen 1969: 92; Федотов I: 421–422.

Гади дерив.: **бер-бер** «нинди дә булса кәтелмәгән», **бергә-бер, бердәнбер, беренче, берләш-ү, берле, берлек** һ.б.

**БЕРАВЫК [бĕраwы̆к]** «некоторое короткое время, в течение такого времени». К. шаян җырда *Гел үземә булыр әле Ятлар сөйсен беравык.* Монда **awык** < гар. *äwķ* «вакыт аралыгы; кичектерү».

Нәкъ ш. ук мәгъ. **берқawым** (ЗДС: 116) сүзендә *қawым* < гар. *ķawm* «аягүрә; шундук». К. **Кыям** һ.б.

**БЕРАДӘР, бәрадәр, борадәр** кит. «брат; браток (при обращении к незнакомому мужчине)» < фар. *bärādär, бирāдäр* id. < һинд-евр. **bhrater* (рус. *брат*). Иске әд. *бәрадәран, берадәран* «бертуган ирзатлар (компаниясе)» < фар. *bärādärān, бирāдäрāн* «бертуган ирзатлар».

**БЕРАЗ** «немного, толику; некоторое количество» < иске әд., төр. *biraz* id. Чаг. ш. ук мәгъ. **беркадәр,** диал. **берсәк** < *берчәк,* **берталай** һ.б. (к. ЗДС: 114–115). К. түбәндәгене.

**БЕРАНЧА, беранчак** (ЗДС: 115) «некоторое количество, несколько, немного» < *бер анча* һәм *бер анча ук* тәгъбирләреннән. **Анча** «шулкадәр, шактый, җитәрлек» < үзб., уйг. һ.б. *анча,* бор. төрки (ДТС: 43) *apča* «шулай; шактый», *apčay* «шулкадәр». **Анчак** белән турыдан-туры баглы түгел. К. **Ан.**

**БЕРӘГӘЙ** «ядрёный, стоящий», тулы формасы *берәгәйле* > мар. *берäгäй, бäрäгäй* «саллы, авыр» (к. Гордеев I: 198, 214) ~ каз., к.-калп. *бирәгәй, берәгәй,* id., ихтимал, кыт. *гү, гэ, гэгэ* «данә» сүзе ялганып, *бир* «бер» сүзеннән ясалгандыр (к. Pritsak: 55): **берәгәй** белән **берәй** «бер тапкыр, бер данә» бердәй тарихи нигездән булса кирәк: *берәгәй* < *бирәгәй* < *бирәгәә* > *бирәй* > *берәй.* К. хак. *пирээ* «берәй, нинди дә булса бер».

Дерив.: **берәгәйләп, берәгәйле.**

**БЕРӘЙ, берәйе** (ЗДС: 114) «какой-нибудь» ~ төр. *birey* id. һ.б. (гом. төрки сүз булса кирәк, ләкин теркәлми), ихтимал, бор. төрки (ДТС: 101) *birägü* «берәү, берәр» сүзеннәндер (шуннан ук – **берәү**). Икенче яктан **берәгәй** (к.) сүзеннән дә килеп чыга ала.

Мантыйк буенча, «нинди дә булса бер» мәгъ. тат. әд. теле ошбу шактый киң таралган **берәй** сүзен кулланырга тиеш иде, ләкин нишләптер **берәр** «берәмләп» сүзенә омоним **берәр** сүзе активлаштырылган: *берәй кеше* диясенә *берәр кеше* диләр. Казан тирәсендә һәм мишәрләрдә **берәй** сүзе юктыр, күрәсең.

**БЕРӘМ** диал. «единица; единый, одиночный» – бор. болг. тәртип саны кушымчасы *-әм* ялганып ясалган сүз (ул кушымча чув. телендә *-ам* яңгырашында актив кулланыла; тат. сөйл. **берәм**нән соң *икәм, өчәм, дүртәм, бишәм* дип бишташ уенында ташларны саныйлар).

**Берәм** бик продуктив сүз ясагыч нигез, к. тат., башк. **берәм-берәм, берәмек (→ берәмеклә-ү), берәмлек, берәмле; берәмлә-ү; берәмтек, берәмтеклә-ү** һ.б.

**БЕРГӘ** «вместе, совместно» *бир* «бер» сүзеннән бор. яз. телләрдә үк ясалган булса кирәк, к. бор. төрки (ДТС: 102) *birgärü* «бергә», *birgär-*

«берләшү», *birgärt-* «берләштерү». Хәз. төрки телләрдә к. уйг. *биргә,* үзб. *бирга* һ.б. Бай деривация.

**БЕ́РДӘЙ** «тождественный; как один и тот же» < *бер+дәй.* Бу сүз XX г. терминлаштырылган. Шуннан **бердәйлек** математика термины ясалган һ.б.

**БЕРДӘМ** «дружно, вместе» – бор. төрки *birdäm* «бөтенләй» (? к. ДТС: 102) *бер (< бир)* һәм фар. *däm* «сулыш, тын; момент» сүзләреннән гыйбарәт. **Бердәм** мәгъ. *бердән < бирдән* сүзе дә кулланыла.

**БЕРЕК-Ү (берегү)** «объединиться; прикрепиться, крепко пристать» < гом. төрки *бирик-* id. (ЭСТЯ II: 148); формаль җәһәттән *бере-* дигән фигыльдән, аның интенсивлык формасы булырга тиеш, ләкин андый фигыль теркәлмәгән. *Берек-* фигыленең ясалуына гом. төрки *бәрк* «ныклы, каты» сүзе тәэсир иткән. К. **Беркет-ү.**

XX г. **берек-** нигезеннән (аңача булганлыгы шикле) **берек** исем сүзе ясап, аңа «союз» мәгънәсен биреп маташканнар: *Советлар берегe* диелгән.

**БЕРКЕТ-Ү** «прикрепить» – этимологик җәһәттән дөресе *биркет-ү* – гом. төрки *бәрки-* «ныгу» (к. **Бигән-ү, Бик II**) фигыленнән йөкл. юн. формасы; **беркет-ү** сүзенең яңгырашына **берек-ү** фигыле тәэсир иткән (хәлбуки *берегү* һәм *беркетү* тамырдаш түгел).

Бу сүз XX г. активлаштырылып, **беркетел-ү, беркеткеч, беркетмә** сүзләренә яңа мәгъ. бирелгән.

**БЕРЛӘ, берлән** «вместе с ..., совместно». Иске әд. телебездә киң кулланылган бу сүз чыгт. теле аша бор. төрки (ДТС: 102) *birlä, birlän* id. нигезеннән килә. **Бер** сүзеннән, ясалышы-төзелеше ачык түгел. *Берлән ~ бирлән* сүзеннән **белән** һ.б. килеп чыккан.

**БЕРЛӘЧ** «единственный; одиночка (о детёнышах животных, иногда о детях)» *-лач//-ләч* кушымчасы ярдәмендә тат. теленең үзендә ясалган (чаг. **итләч, сөтләч** һ.б.ш.). Төбендә «бер генә бала тудыра торган» мәгъ. булган.

**БЕРСӘК, берцәк, берчәк** диал. (ЗДС: 116–117) «немножко; некоторое время; толику» < *бер чәк < бер чак* булса кирәк: *чәк ~ цәк* (*чәк кенә*) < *чак,* к. **Чак II.**

Кайбер сөйләшләрдә таралган **берчә** «кайчак, бертөрле һ.б.» (күпмәгънәле, к. ЗДС: 117) сүзе дә **берчәк** сүзеннән булуы ихтимал.

**БЕРСЕКӨН, бересекөн, берсекөнә** «позавчера», диал. «послезавтра» < гом. төрки *бирси (бириси) кун (күни, гүни, күнә, гүнә)*, төр. *öbürüsü gün* id. «бер элекке» сүзеннән: *öbürüsü* «тегесе», *күни* монда фар. *күһнә* «элекке, иске» сүзеннән; ш. ук диал. *икесе көнә* «ике көн ташлап; аннары», к. **Көнәген.**

**БЕРТЫНА, бертымал** (ЗДС: 117), **бертона** дип тә әйтелә, *бер тына(рак)* сүзеннән шикелле, к. **Тын-у.** Ләкин сөйләүчеләр кайчакта үзләре белгән бүтән сүзләрне күз алдында тотып **бертын** дип әйтәләр. Сүзнең *ике тона* дигән, *өч тона* кебек әйтелештәге гап-гади *тона* дигән варианты да бар: бу очракларда сүзнең тамыры *тон-у* фигыле булып чыга. К. ш. ук ЗДС: 639.

**БЕРҮК** «пожалуйста; непременно» < *бер ук: бер* монда «бер тапкыр гына» мәгъ. булса кирәк, *бер ук* «бер уйла» (к. **Үкенү**) сүзеннән дә була ала.

Диалектологик сүзлекләрдә *берук* «ләкин» сүзе китерелә: бусы Урта Азия телләрендәге *бироқ* «ләкин, әмма» < *бир оқ* «бер тыңла (әле)» сүзеннән (бор. төрки *оқ-, уқ-* «тыңла»).

**БЕТ,** диал. (миш., без теркәдек. – *Р.Ә.*) **пёт, пыйт** «вошь» ~ чув. *пыйт, пыйтӑ* (к. Ашмарин IX: 177) < гом. кыпч., чыгт., үзб., угыз. *бит*, үзб. диал., алт. диал. (Баскаков 1972: 205) *бийит*; тув. *быт, пыт,* як. *бит, быт* «бет; талпан; кандала» (як. *сир быты* «җир бете» – «кырмыска»); уйг. *пишт* (< *бижит* < *бийит*) «бет» һ.б. Бор. монг. *böwesün* «бет» белән чагыштырыла (к. ЭСТЯ II: 151–152), чаг. ш. ук мар. *пуди, пыйк* «талпан» (тат. *урман бете* «талпан»).

Дерив.: **бетле, бетлә-ү.** К. **Бетчә.**

**БЕТЕК** тар. «записка; письменный документ, расписка һ.б.» < чыгт. һ.б. (Будагов I: 242) *битик, битүк,* уйг. *бидик, бидүк* һ.б. id. ~ алт. *бичик, пичик* < бор. төрки (ДТС: 103) *bitig* «язу; китап» ← *biti-* «язу», к. **Бөти, Пичәт.**

Дерив.: **бетекче** – элекке тат. һәм төрки дәүләтләрдә канцлер, хәрби инспектор (писер генә түгел). Иске тат. **бетке** «кечкенә язу, хат», **беteклә-ү, беткелә-ү** «язу» һ.б. К. Velidi: 290.

**БЕТҮ** диал. к. **Бөти.**

**БЕТ-Ү I,** себ. **пөйт-** «закончиться, кончаться» ~ мар., чув. *пĕт-* id. < гом. кыпч., гом. угыз. *бит-* (к.-калп. *пит-*), уйг., тув., як., алт. *бүт-*, хак. *пүт-* (> башк. *бөт-*), сары уйг. *пут-, путе-* ~ монг. *бүтэ-* «бетү, тәмамлану», уйг., кырг., алт. һ.б. кайбер шивәләрдә «бетерү, тәмамлау» (к. ЭСТЯ II: 152–154) < (тат. диал.) *бүйт-, пүйт-* id. ниндидер бор. фигыльнең (**бүй-*) йөкл. юн. Räsänen 1969: 93; Федотов II: 426 (барча мәзкүр авторлар тат. диал. *пөйт-* яңгырашын белмиләр).

**Бет-** продуктив нигез: **бетеш-ү, бетер-ү (< беттер-ү), бетем, беткен** (диал. «бетүгә барган»), **беткесез** һ.б. (икенчел дериватлар да шактый).

**БЕТ-Ү II** диал. «расти, разрастать, сплошь покрыть собой (о растениях)» – к. *телгә беткән: йөзенә гөл беткән* һ.б. тәгъбирләрдә һ.б. < гом. кыпч., угыз. *бит-* id. К. **Бөт-ү.**

**БЕТЧӘ** «прыщ, угри, веснушка (на лице)» ~ башк. *бетсә* id. ← *бет* (булса кирәк); чаг. ш. ук диал. *пат, пата* «бетчә» < **пәт.*

Дерив.: **бетчәле, бетчәсез; бетчәлә-ү.**

**БЕЧӘ** (Х. Мөслими, «Тәварихы Болгария»дә) «Вятка, Нократ» < мар. *Бичä, Виче, Пицэ* «Нократ; гомумән зур елга, идел» (*Ош Виче* «Ак Идел, Агыйдел»). К. Гордеев II: 117–118. Шул ук «Тәварихы Болгария»дә искә алынган «мәшһүр елга» – *Чуашпсә = Чуаш писа* «Чуаш иделе» – *Чипча* булса кирәк (Чипча буйларында бер төркем чуваш халкы яшәгәнлеге мәгълүм).

**БЕШТЕРӘ, биштерә** (ТТДС I: 83) «отверстие для продевания шнура, прошнуровки» ~ чув. *пуштер, пуштĕр* id., ш. ук «кием өстенә тегелгән һәм бау өчен тишеге булган (төймә яки чапраз өчен тишекләрне ныгытуга куелган) кештәк» < фар. *пӯши тара* «ярык каплавычы».

**БИ I** название второй буквы ب в персидском алфавите (в арабском *ба*) – употреблялось как предмет сравнения: *Кашың-күзең ни кебек – әлифтәге би кебек* (җырдан).

**БИ II** «бей, тюркский феодал, военачальник второго ранга» – в тат. языке имело и имеет весьма разнообразные конкретные значения в зависимости от места и времени, вообще прибавлялось к имени собственному любого влиятельного, знатного лица, владетеля и т.п. (Будагов I: 263–264; ЭСТЯ I: 97–101), «ближайший родственник мужа, свёкор» (Матвеев 1895: 352; Рамазанова 1991: 167, 169) ~ гом. кыпч. *бий,* башк. *бĕй* «би, феодал, түрә; түбәнге судья», тув. диал. *пии* «кияү» («зять», к. Радлов IV: 1324) ~ як. *бии* «абый» (*биим* «абыем») < бор. төрки *bēg* < *bägü* «би», *begi, beki* «ир; герой» (Малов 1951: 370; ДТС: 91–92) – төбендә «ыру яисә кабилә башлыгы» > *бәк, бик* «феодал», төр. *бәй* «әфәнде». Бор. *beg, bäg* < *bägü* тамыр сүзен бор. кыт. *piāk* «башлык» сүзе белән дә, сугд. *by* (< бор. ир. *bagha*) «би, әфәнде, өлкән» сүзе белән чагыштыралар. Һәм, әлбәттә, бу сүзнең күрше телләрдән алынмаган булуы да ихтимал, к. эвенк., эвен. һ.б. *бәгин, бәгән* «башлык, хуҗа, биата» (ССТМЯ I: 119). К. **Бәй II, Бәк, Бием, Бик, Бикә, Бикәч, Билә-ү, Бичә.** Räsänen 1969: 411–412; Федотов I: 411–412. «Кутадгу билик»тән күренгәнчә, *бәг* сүзенең «рыцарь, югары әхлаклы асылзат» мәгъ. дә булган.

**БИ-** приставка со значением «не-, без-»: **бивафа** «вафасыз», **бимаза** «мазасыз, кәефсез», **бинамаз** «намаз укымаучы» һ.б. К. **Бигайбә, Бигаять, Бигәнәй, Бикәр, Бинисбәтән, Битараф, Бичара** һ.б. фарсы теленнән. Бу префикс үзе генә активлашып китмәгән – төрки нигезләргә ялганмый. Будагов I: 298.

**БИБЕК** «чибис», **пибек** «пигалица» ономопоэтик-тәкълиди сүзләр: кош-кортның *би//пи* авазына нигезләнеп ясалганнар; шундый сүзләр бүтән телләрдә дә еш кына очрый: төр. *ibik*, *ibibik* «һөдһед» [лат. *Upupa epops*], венг. *bibic, bibis* «бибек, тәкәрлек», бор. монг. *bübük* – чыгт. *bübiš* «һөдһед» (Поппе 1938: 127), рус. *пичуга* «һәртөрле вак кош» һ.б.

**БИБИ** «госпожа» < гом. мөселман төрки *биби* (ЭСТЯ II: 127–128) < фар. *bihbih,* к. S. Çagatay (UAJ, XXXIII, 1–2, 1961).

**БИГА́ЙБӘ** «простите, извините, но (иначе не могу, нельзя)» – нәрсәнедер кире кагуны, кабул итмәүне хәбәр иткәндә әйтелә < фар. *бӣʻайбӓ* «гаепсезмен; гаепләмәгез».

**БИГАЯТЬ [биғайәт]** «очень даже; беспредельно» < фар. *бӣʻāйāт* «чиксез», к. **Гаять.**

**БИГӘН-Ү** диал. «крепиться душой; надеяться, стремиться» > чув. *пикен- (пигэн-)* id. (нишләптер

тат. әд. теленә кермәгән бу киң таралган сүз чув. телендә киң кулланыла), к. тат. диал. (ТТДС I: 85; БТДҺ: 47; Тумашева 1992: 43, 151) *бийән-ү, пийән-ү* «өметләнү, булырына ышану» ~ кар. *биян-* «(хәлләр әйбәтләгенә) шатлану», *бигән-* «бигәнү», ком. *бегин-* «ныгу», каз., к.-калп., кырг. *беки-, бекин-,* к.-балк. *бегин-* «ныгу; карарлану, карарлашу» һ.б. (ЭСТЯ II: 101) < уйг. *бәркин-, бекин-* «ныгу, ныгыну», *бәрки-, беки-* «ныгыту», нуг. *берки-* id. һ.б. гом. төрки *берк [бәрк], бәрк* «нык, бик» сүзеннән, к. ш. ук төркм. *бекемек* «көчлеләндермәк», *беркемек* «каты булмак», төр. *beğen-* «ярату, соклану, канәгать булу, өметләнеп шатлану», венг. *beke* «рухи тынычлык» ~ төр. диал. *bikik* id., к.-балк. *бегим* «карар» һ.б. К. **Бик I, Бик II, Биркә.** Dobr. I: 290–291 (сүзнең киң дерив. һәм төрле мәгъ. күрсәтелә).

**БИГӘНӘЙ,** диал. **бигәнәк** «безродный; чужой, чужак; посторонний» (Троянский I: 226) ~ уйг. *биганә,* үзб. *бегана,* кырг. диал. *бегәнә* < фар. *bīgānä* «ят, таныш түгел», *bīgānäk* «ят булган» (*bī-gānä* «нәселсез, ырусыз; бер ыругка да карамаган)».

**БИГЕР, бигәр** «удмуртское название татар». Болгар этнонимы IX г. башларында Урта Идел регионына килеп дәүләт корган кавемнең үзатамасы булган. Ләкин бу җирләрдә аларга кадәр үк азмыкүпме төркиләр булган булса кирәк. X г. башларында, мәшһүр сәяхәтче Ибне Фазлан хәбәр иткәнчә, Болгарстанда болгарларның үзләреннән тыш, *бәрәнҗәр, берсула, эскел* һәм *сувар* дигән этник төркемнәр дә булган һәм алар болгарлар белән бергә килгәннәр дип раслап булмый. Әмма ул төркемнәр дә тора-бара болгар этнонимын кабул иткәннәр.

Шунысы кызык ки, болгар этнонимы безнең күрше халыклардан удмуртларда *бигер, бүгөр, вугор* «татар» вариантларында чагылыш таба.

*Бүгор, вугор* сүзләре удм. теленең көньяк-көнб. диалектында *бувгәр, бувгар* сүзеннән килә: мәзкүр диалектта иҗек азагындагы *л* авазы *в(w)* авазы белән алмаштырыла. *Бүгор*ның *Бигәр*гә әверелүе шуның белән аңлатыла: удм. теленең күпчелек сөйләшләрендә *ү* авазы юк, ул *и* авазына күчә (*ү* > *и*). Шулай итеп *булгар* > *бүлгәр* > *бүвгәр* ~ *бигәр* килеп чыккан.

Күрәсең, болгар белән фин-угор халыкларыннан беренче буларак бор. удмуртлар багланышка кергәннәр.

Шушы фактлар яктылыгында кайберәүләрнең бор. скандинав язма ядкәрләрендә очраган *Биарм* дигән ил атамасын удмуртча *бигер* «татар» сүзе белән баглавының нигезсезлеге дә күзгә ташлана. Гомумән алганда, бу турыда сөйләп тору да артык сүз, әмма әлеге гипотеза вакыт-вакыт матбугатта үзенең кәсафәтен күрсәтә. Мәс., «Республика Татарстан» газетының 17 август (2000 ел) санында Фәрит Нуретдинов дигән кеше «Викинги в городе Дракона» исемле мәкалә бастырып, анда күп кенә татар топонимнарын викинглар – герман кабиләсе теленнән чыгып аңлатыла. Үзенең фантастик фаразларында ул М. Зәкиевка таяна.

Шунысы кызык ки, кайбер һәвәскәр тарихчылар төрки-татарларны ничек тә «атаклы» объектларга – һәртөрле грекларга, юнаннарга, этрускларга, һич булмаса викингларга тоташтырырга тырышалыр. Балалар авыруы! Әйтерсең без кешедән ким.

**БИДАЕК [бидайы̆к]** в эпосе «Идегәй» «самый дорогой вид ловчей птицы», «орёл в гербе», диал. (ЗДС:136) **буйтайак** «один из видов ястреба; тат. мәкальдә *эт түрәсе комайык, кош түрәсе богдайык,* кырг. *буудайык,* чыгт., үзб., төр. (Ögel: 219) *buydayık* «мифик бөркетләр патшасы», «угыз кабиләсе чавулдурның гербы», чыгт. (Будагов I: 285) *бугдайнак* «Һомай кошы». Ихтимал, монг. *богдо, богды* «император; Кытай императоры, богдыхан» сүзеннәндер. К. **Пудаек.**

**БИДӘ, бида** диал., разг. (ЗДС: 120) – слово восхищения удалью ребёнка. Көньяк Уралда киң таралган сүз, к. башк. *биҙа* id. Рус. сөйл. *беда* id., (төп мәгъ. «бәла») сүзеннәндер.

**БИДӘР** диал. (ЛТ I: 218, ТТДС I: 84) «рельефное украшение; рельефная вышивка; узоры, орнамент» ~ башк. *биҙәр*, каз., кырг. *бедер* «чуар каурый; орнамент, (бизәкле) кылыч» < бор. монг. *beder, bedir* «буй-буй бизәк», бур. *будэр, бэдир* id., як. *бэдэр* «селәүсен, мәчесыман хайван».

Эвенк. (ССТМЯ I: 120) *бэдэр* id. ~ бор. төрки (ДТС: 90–91) *bediz, beδiz* «бидәр; зиннәтле бина; рәсем», *bediz-* «бизәү», *beδäz* «икона» ← *bed-, bedi-* «бизәү, орнамент һ.б. ясау». Гомуми закончалык буенча *бидәр* ~ *бэдэр* борынгырак булырга тиеш, ләкин ул төрки сүз, монг. сүзе түгел. Ихтимал, кр.-тат. (Dobr. I: 289–290) *beder, büdĭr* ~ төр. *pütür* «кытыршы (өслек тур.)» *бидәр* сүзенә тамырдаштыр. Кр.-тат. *beder-beder* ~ төр. *pütür-pütür* «рельефлы (өслек тур.)» сүзе *бөдрә* сүзен хәтерләтә башлый. К. **Бизәк.**

Дерив.: **бидәрлә-ү** «рельефлы бизәк ясау», **бидәрле,** к. иске җырда:

*Ал бидәрле, гөл бидәрле*
*Кайсы байның чанасы...*

**БИДӘҮ [бидәw]** «бесплодная, неродящая», диал. (Арсланов 1988: 74), **бедеw,** башк. *биҙәү* (*карабиҙәү* «һичбер бала тапмаган», *акбиҙәү* «бер генә бала тапкан», *кызылбиҙәү* «бер бала тапкач ырусыз калган хатын», к. БҺҺ II: 22, 134, 152) ~ нуг., кар. *бедев* id. чыгт., каз. *бидәу* «колынламый торган бия; бәдәви (гарәп) аты». Гарәп бияләре безнең якларда колынламаганлыктан, бу сүз «ырусыз, балатапмас» мәгънәсен алган; югыйсә нуг., ком. *бедев,* кырг. *безөө*, аз. *бәдәв, бәдәй* «бәдәви (гарәп) токымлы ярыш аты» < гар. *bädävī* «күчмәче, күчмән» (*бәду* «дала») сүзеннән.

Чаг. чув. *пĕтев* «зур гәүдә, бәдән», тат. диал. *мөтәк* «атның бәкәл сөяге (ашыгы)» ~ рус. *битюг* «зур гәүдәле ат».

**БИДРӘ, бидерә,** себ. **пәтрә** һ.б.ш. «(металлическое, жестяное) ведро» ~ башк. *биҙрә*, мар. *бидрä,* чув. *питре, витре*, удм. *ведра* id. < рус. *ведро* (русистлар фикеренчә, «су чиләге» мәгъ. *вод- ~ вед-* «су» тамырыннан).

**БИЕК,** диал. (ЗДС: 121; 538, 545) **бийен, бийерек;** себ. **пөйек, пүйүк** «высокий» ← диал. *бөй-*, (Дмитриева 1981: 176–177) *пөй-* «биегәю». Гом. кыпч., к. кар. *бийик* «биек, зур» ← *бийи-* «югарылану», бор. төрки *bedük* «биек» ← *bedü-* «үсү» һ.б. Тат. диал. (м.-кар.) **безек** «биек» аерым юлдан килгән бор. төрки сүз.

Дерив.: **биегәй-ү, биегәйт-ү, биеклән-ү, биеклә т-ү; биеклек.** К. **Бөек.**

**БИЕМ** «свекровь» ~ кар. *бийим*, Котби телендә *бигим,* уйг. *бәгүм* > фар. *бегүм* «аембикә, кәникә (принцесса); патшабикә» – *бәг* «би, бәк» сүзеннән: монда *-ем* – тартым кушымчасы түгел, ә бор. мөәннәс сүзьясагыч кушымча (к. ш. ук **Ханым**). К. Dobr. I: 290.

Һиндстанда *begum* (ялгыш рәвештә) «принц, шаһзадә» мәгъ. һәм ир-атка хөрмәтләп эндәшү сүзе буларак киңчә кулланыла.

**БИЕ-Ү [бĕйĕ-],** диал. (м.-кар.) **беҗе-ү** «плясать» ~ каз., к.-калп., кырг., ком. *бэйэ-, бäйä-* «бию (фигыль)», *би, бий* «бию (исем)», нуг. диал. *бити-*, каз. диал. *бүйи-*, бор. төрки (ДТС: 131) *büdi, büđi, büti* «бию» ~ алт. *бидье,* як. *бити* «бию (исем)» ~ монг. *бэйэлэ-,* бор. монг. *böğі-* «бию» (Поппе 1938: 123); тикшеренүчеләр бу сүзләргә чув. диал. *пач-* ~ тат. *пәч-* «уңышка ирешү (шуннан – бию)» сүзен дә өстиләр, ләкин бу бик шикле. Гомумән, бор. төрки *бөд* «бию» һәм шуннан *бөди-* «бию (фигыль)» ясалганлыгы шәйләнә. ЭСТЯ II: 131–133.

*Бөд-* «бию» бор. төрки *böd* «тәхет» сүзе белән бердәй булса кирәк: кыт. чыганакларында сюнну ханын сайлаганда, претендентны хәрби бию биетеп караулары турында әйтелә: кем биегрәк сикереп биесә, шул сайланган. Булачак хөкемдарның сәламәтлеген сынау барча бор. халыкларда булган гадәт (Дж.Дж. Фрэйзер). Bang: 38–40.

Дерив.: **бию; биел-ү, биеш-ү; биет-ү** һ.б.

**БИЗ I** «железа», диал. «адамово яблоко» > удм. *без* < гом. төрки *бэз, бәз* (*пэз, мэз*), төркм. *бәәз, мәәз*, чув. *пар* (< **бәр*) «биз» ~ бор. монг. *ber-segü* «биз-сөял» – «каты шеш», як. *бэр, бэрг* «тәндәге катылык», хак. *мир* «каты шеш, биз», шор. *мäрс, мäрслäк* «җилен, биз» һ.б.; гомумән, *биз* < *бэ̄з* < *бэ̄рҗ* < *бэ̄рг,* к. себ. *бирец* (ДС I: 35), ком. *берч* [*бэрҗ*], тунг. *бэ̄ргэ* «каты симез» – бор. **бэр* тамырыннан, к. **Бирт, Бирчә-.**

Фин галимнәре (Рясянен: 26) **бэргэ* тамырын фин-угор телләрендә дә табалар: венг. *mirigy* «биз» ~ фин. *märkä* «эрен» һ.б. Мухамедова 1973: 83; Федотов I: 384; ЭСТЯ VII: 60–61.

**БИЗ II** диал. (ЗДС: 120–121) «холодок, стужа» < бор. төрки **bez* < **berg* id. К. **Бизгәк, Биз-ү II.**

Дерив.: **бизлә-ү, бизләт-ү.**

**БИЗАР,** себ. (ЗДС: 533) **писар, писәр** «состояние отвращения (к чему)» < фар. *bīзāр* id. Төрки телләрдә *бизар булу, бизар кылу* кебек тәгъбирләрдә кулланылучан.

**БИЗӘ-Ү** «украшать» (*бизәү* «украшение» < чув. *писе, писев* id.) < гом. кыпч. *безä-*, уйг. *бәзә-* һ.б. < бор. төрки (ДТС: 97) *bezä-* id. бор. төрки (ДТС: 90–91) *beđiz, bediz* «бизәк» сүзеннән ясалган фигыль булса кирәк (*beđiz-e* > *bejze-* > *бизә-*). К. **Бидәр.**

**Бизә-** продуктив нигез: **бизәк, бизәнчек; бизәл-ү, бизән-ү, бизәш-ү, бизәт-ү** һ.б. Räsänen 1969: 72; ЭСТЯ II: 105–106; Федотов I: 435.

**БИЗГӘК** «лихорадка» < гом. кыпч., чыгт., уйг. һ.б. *бәзгәк* < бор. төрки (МК, ДТС: 97) *bezgäk* id., тат. диал. **биз-ү** (к.), гом. төрки *бәз-* < бор. төрки

*bez-* «калтырау, дерелдәү» фигыленнән. Бу тамырдан төрки телләрдә күп кенә сүзләр ясалган, к. кар. *безгәк [бәзгәк]* «күбәләк», башк. *бизгелдә-ү* «калтыранып елау», үзб. *безангламак* «тетрәнеп кую» һ.б. К. **Биз II, Безгәлдәк.** ЭСТЯ II: 104–105.

**БИЗМӘН** «безмен (рычажные весы; мера веса в 2,5 фунта)» ~ себ. *бәзмән, бәсмән* «авырлык үлчәме» (*бай інді бір бäсмäн маі алды, ōн курäнкä ун алды,* к. Радлов, Образцы ... IV: 323) > чув. *писмен,* мар. *пезмен* «бизмән; авырлык, тәй», *пысман, песмäн* «ызан, җир чиге» ~ удм. *бисмянь, бесмен* id. (бу мәгънә бор. *бизмәнбаш* «җир үлчәү өчен башына гер тагылган аркан» сүзеннән, чаг. удм. *безменйыр* «бизмәнбаш – зур башлы, бау аяклы явыз җен» ~ каз. *батпанбас* id.) ~ чув. *пасман, пасмана* «батман, дүрт пот» < болг. **бәзмән, бәзмәнәг* >> абаз. *базман* «бизмән» һ.б. бор. **бәз, *баз* «бал» һәм *ман* «авырлык үлчәме» сүзеннән, к. **Батман.**

Көньяк һәм көнч. төрки телләрдә *бизмән* сүзенең чагылышлары сирәк очрый (безгә тик хак. *пізібан* «бизмән» билгеле), чөнки ул тарафларда умартачылык та үсешмәгән, аның каруы Европада *bisman, bismari,* дат. *bismer*, бор. ним. *beseman, bezemer,* чех. *prezmen*, пол. *bezmian* һ.б. «бизмән». Танылган инглиз кәшеф итүчесе **Бессемер** фамилиясе (шуннан **бессемер** «чуен эретү миче») «бизмәнче» дигән сүз икән, к. Kluge: 114.

Шунысы игътибарга лаек, санск. *pariman, parman* «үлчәү, шкала, авырлык, күләм», *pariman dand* «авырлык үлчәү таягы» – «бизмән» (Platts II: 253).

М.Р. Федотов (I: 435) чув. *писмен* сүзенең тат. *бизмән* сүзеннән икәнлеген әйтми һәм бик гомуми мәгълүмат бирә. Тик аның шәрәфенә әйтергә кирәк – ул М. Рясяненнең *бизмән* < чув. *виҫмен* (*виҫ-* «үлчәү») дигән фаразын кабул итми.

**БИЗ-Ү I (-дан//-дән, -тан//-тән биз),** диал. **бизрә-ү** (ТТДС I: 84) «отвращаться, чувствовать отвращение» > чув. *пис-*, удм. *без-* «бизү», морд. М. *безярдемс* «санга сукмау», мар. *пезнаш* «бизенү», *пездар-* (< болг. **бэздер-*) «биздерү» < нуг., каз., к.-калп., кырг. һ.б. *без-,* госм., уйг., кар. *бәз-* (> Д. болг., серб., алб., грек. *без-*) < бор. **бәрг-,* к. эвен. *бәр-* «үзгәрү, таркалу, сүтелү, чишелү» (ССТМЯ I: 126). Чаг. башк. *бизел* «аерылып чыккан авыл». ЭСТЯ II: 103–104; Федотов I: 434.

**БИЗ-Ү II** диал. «похолодать», **биз** «холод» ~ диал. (ТТДС II: 84) **бизлә-ү** «салкынайту», башк. *бизләүек* «болытлы салкын, өшеткеч» ~ уйг., бор. төрки *бәз-* «(суыктан) калтырау», шуннан *бизгәк.* **Биз-ү I** белән бәйле булса кирәк (Räsänen 1969: 73). К. ш. ук монг. *бээрэ-* «өшеп калтырау».

**БИК I,** диал. **бәк, пик** «очень» > мар. *пäк,* морд. *пяк*, чув. *пите* (< *бикте*) < гом. кыпч. *бәк,* госм., кр.-тат. *пәк* < бор. төрки *bek* id. < *berk* «нык, ныклы, көчле». К. **Бик II.**

**БИК II,** диал. **пик** «запор, замок (внутренний)» > чув., мар. *пит,* мар., удм. *бик* < гом. кыпч., алт. *бек,* чыгт., уйг. диал. *бәк*, уйг., кр.-тат., хак., шор. *пәк* «ныклы; ныгытма > бик» < бор. төрки *bek* < *berk* id., к. ш. ук кар. *бәрк* «ныгытма, кальга», каз., к.-калп., үзб., чыгт. *берк,* куман. *berch*, аз. *бәрк* һ.б. «нык; ныклык»; бу сүзнең фигыль мәгънәсе дә булган: тат. диал. ЗДС: 119, 122) **бигет-ү** «бикләү», **биге-ү** «ныгу» һ.б., *биккеч* «бөке». К. **Беркет-ү, Бигән-ү, Биклә-ү, Биркә.** ЭСТЯ II: 116–118.

**БИК III** «феодал; заместитель хана». Гом. төрки сүз, к. **Бәк, Би.**

**БИКАСАП** «полушёлковая ткань» < фар., аз. *бәкасап* «алтын төстәге җепләр кушып тукылган тукыма». Асылда гар. *би ӄаҫаб* «касаплы, алтын җепле». К. **Касап.**

**БИКӘ** «госпожа»; в роли второго компонента ряда сложных слов означает лицо женского пола: *арыслан* «лев» → *арысланбикә* «львица», *хуҗа* «хозяин» → *хуҗабикә* «хозяйка» > чув. *пике, пики, пие, пи* (соңгы ике сүзне без теркәдек. – *Р.Ә.*), мар. (Гордеев I: 218) *бикä* id. – кар., к.-балк., ком., кырг., каз., к.-калп. *бийкә* «җиткән кыз, кәләш»; кр.-тат. диал. (Тумашева 1992: 173) *пигә* «иреңнең апасы» кебек конкретлаштырылган мәгънәләре дә бар. К. **Би.** Будагов I: 303; Федотов I: 430–431; ЭСТЯ II: 134–135; Рамазанова 1991: 167–169.

**Бикә** сүзе кыпч. телләрендә соңрак формалашкан. Бор. телләрдә ул очрамый бугай.

**БИКӘР, бикәргә** «зря, напрасно; безрезультатно; без дела», себ. (Тумашева 1992: 173) **бикар** «ялган; буш сүз», башк. (БТДҺ: 48) *бикәр* «сәбәпсезгә» < фар. *бӣ к'āр* «эшсез; нәтиҗәсез, кәрсез». **Бикяр** сүзе мөселман төрки телләрендә еш очрый.

**БИКӘЧ** «молодуха, молодайка», диал. **бигәч** «невеста» ~ к. тат. диал. *бикәч* «инәк бозау» (Balint 1988: 160) яисә «бия колын»; үзб. (ЎХШЛ: 327)

*бийкәч*, каз., к.-калп. *бийкеш* «кайнигәч, би игәч», кырг., уйг. *бийкәч* «туташ» < бор. төрки *begeč* «принцесса» (Clauson: 325), *bekäč* «принц» (ДТС: 92) < *beg-käč*. Räsänen 1969: 67.

Дерив.: **бикәчлә-ү** (элекке бер гадәт буенча, яшь хатын ата-анасында яшәгәндә, кияү аның янына килеп йөрү).

**БИКЛӘ-Ү** «запереть», иск. «вытвердить наизусть» (*Коръән бикләү* «Коръән ятлау») – **Бик II** сүзеннән: «ныгыту». «Ятлау» мәгънәсендә бор. *бәрк* «ныклы» сүзенең тәэсире сизелә, чаг. чув. *пикле-* «ятлау».

Төр., аз., кр.-тат. (Будагов I: 263) *bekle-* «караыллау; сакта тору, көтү».

Дерив.: төрле мәгъ. **биклән-ү, бикләт-ү, бикләш-ү, бикләштер-ү** һ.б. Элек **Бикләмеш** дигән хас исем таралган булган, бу сүзнең конкрет мәгънәсе безгә ачык түгел (ихтимал «сакчы»дыр).

**БИКТАШ, биктәш, биктәши** «мусульманская секта бекташей, имевшая приверженцев и среди татар» – бикташиләр мәзһәбе 1210–1271 елларда Урта Азиядә һәм Төркиядә яшәгән Бәкташ Вәли исеменнән. Ул хәрбиләрнең һәм яничәриләрнең химаячесе булып исәпләнгән. Бикташиләр тәгълиматына күрә, намаз уку һәм ураза тоту саваплы, ләкин ихтыяри гамәлләр (мотлак фарыз түгел).

Татарларда **Бикташ** дигән хас исем һәм Урта Идел регионында **Бикташ** дигән авыллар бар. К. EI I. – L., 1960: 1161–1163 («бикташиләр тарихта зур роль уйнаган» диелә); Dobr. I: 293.

**БИЛ I,** диал. **пил** «поясница; талия, пояс» < гом. төрки *бел, бәйил* id. ~ бор. монг. *bel* «бот», к. ш. ук башк. *бил* < кырг., тув. һ.б. *бел* «тау итәге, сукай», як. *биил* «билнең һ.б. иң нәзек төше», хак. *пил* «тау теземе» → башк. *билән* id.

Бу тамыр сүздән күп кенә этимологиягә мохтаҗ сүзләр хасил булган: *билдәмә* «өрлек» ← *билдә-ү* < *билләү* (?) «бил ясап тарайту»; тат. **билгәү** ~ башк. *билгау* «билбау» ~ бор. монг. *belkegü* «бил, билләнеп торган җир»; *билдәк* (Вәлиди II: 489) «билле урын» һ.б. К. **Билдәү, Билтер.** Räsänen 1969: 69; Федотов II: 432.

**БИЛ II,** диал. (себ.) **пил** «таймень (рыба)» ~ як. *бил*, хак. *пил*, алт., тув. *бел* id. Будагов I: 265; Линдберг-Герд: 96.

**БИЛАЛА** «обученная охоте птица (сокол и т.п.)»: к. себ. (ЗДС: 122): *Аwаларга оцкан билаланың Канат оцкайларын йил ала* (җыр). «Идегәй»дә: *Бер дигәндә бил алган Ак лачыным бар минем.* Бик үк ачык түгел; көрәшкәндә *бил алу* тәгъбире бар бугай.

**БИЛӘМ** «прогулка; развлечение на миру, хождение по соседям» > мар. диал. *белäм, билäм* (Гордеев I: 212, 218), к. башк. диал. (БҺҺ II: 48) *биләм* «авыл агалары җыелышы; балкорт күче; урман кисү кишәре; авыл утырышы» һ.б. *Билә-ү*, *биләмә* белән чагыштыру семантик җәһәттән аксый; ихтимал *билләм* «билгеләр куеп йөрү»дер (бу эш җиңелгә исәпләнгән), к. төркм., төр., к.-калп., к.-балк. *белле-* ~ чув. *палла-* «билгеләр кую, истә калдыру» һ.б. (ЭСТЯ II: 109–110), к. удм. *беленчи* «күзәтче бал корты» (шуңа карап тиздән күч аерылачагын беләләр). Чаг. тат. *биләмне* «күңелле»; мар. диал. *пäлмезы* (Иванов, Тужаров: 152) «кыю, өлгер, хәрәкәтчән» ~ тат. *биләмче* (?).

**БИЛӘМӘ** «владение» ← **билә-ү II.**

**БИЛӘН,** себ. (Тумашева 1992: 173) **пилән** «всегда готовый» (к. табышмак: *билле-билле билән ат, биле нечкә көрән ат* – кырмыска тур.) ~ кырг., алт., тув. *белен [бэлэн]* «җиңел, уңай, ансат; әзер», як. *бэлэн*, *бэлэм* «әзер; хәзер», алт. *белен, бäлäн* «кеше карамагында булу хәле» ~ монг. *бэлэн* < бор. монг. *beleken* «әзер; күренеп тора, кул астында», эвенк., эвен. һ.б. (ССТМЯ I: 125) *бэлэн* «әзер, хәзер; запас әйберләр» ← бор. төрки **бэ-лэ-* (?) «әзерләү», к. алт. *беле-, бäлä-* «әзерләү».

**БИЛӘНӘ** (Гали Рәхим) «удельное владение; большое наследство». **Билә-ү II** (к.) белән баглы булса кирәк, к. башк. *билән* «җир үлчәме (чирек дисәтинә)».

**БИЛӘҢКЕ** «радикулит; больной радикулитом» – диал. *билеңке* id. – безнеңчә, *бил* белән баглы түгел, ә **билең** (к.) сүзеннән – биләңкеле кешенең кинәт билеңләп, кычкырып җибәрүеннән. Чаг. башк. (БТДҺ: 49) *биләңке* «өзлегү; сыкра, боелыгын тотмау авыруы», себ. (Тумашева 1992: 174) *пидиң-ү, пилеңлә-ү* «куркып саташу», *пилиндзе* «куркып саташучан». Тәүдә *билеңке* нервы авыруын белдергән, соңыннан, халык этимологиясенчә, *бил* сүзенә нисбәт ителгән. Шул ук хәл үзб. *белäңги, белаңги* «биле авыртучан» сүзендә дә күзәтелә.

**БИЛӘР** «город Билярск»; название этнографической группы татар. Бу сүзнең тат. **Бүләр**

~ чув. *Пулер* вариантлары бар һәм ул татарларда да, чувашларда да «изге җир» атамасы булган: анда танылган рухани Мәлем хуҗа торган. Шулар нигезендә без бу топоним гап-гади *би-ләр* (яшәгән кала) дигән фикергә килдек, чөнки тат. *би* ~ чув. *пү* (к. **Би, бий**). XII г. Болгар иленең иң зур шәһәре булып киткән Биләр XII г. монголлар тарафыннан, соңрак Алтын Урда ханнары һәм руслар тарафыннан кат-кат туздырыла. Биләр халкы бердәм рәвештә көнчыгышка кача һәм этнографик төркем булып оеша. XVII г. рус администрациясе «һичкайчан башкортча сөйләшмәгән» (С.И. Руденко) **биләр**ләрне башкорт кабиләләре җөмләсенә кертә. Шул нигездә хәзер кайбер башкорт тарихчылары **Биләр** шәһәрен башкортлар нигезләгән (!) дип раслый башладылар. Гомумән, *Биләр* ~ *Бүләр* сүзе тур. бәхәсләр дәвам итә. Безнең караш тур. к. безнең мәкалә: *Биләр*/*Бүләр* топонимы һәм татар халкының оешуы турында // «Мирас» 1992, № 7.

Бор. монг. чыганакларында **булар** диелгән аерым халык **бүләр** булса кирәк. Гомумән, *болгар* һәм *бүләр* сүзләрен буташтыру XX г. башларында да күзәтелгән.

**БИЛӘ-Ү I** «владеть, занимать (место)» ~ нуг., каз., к.-калп., кырг., ком., уйг., үзб. диал., алт. *бийле-* «биләү, хакимлек итү». *Би* сүзеннән булса кирәк, әмма бор. **бәйл-лә-* «чик билгесе кую» сүзеннән булуы да ихтимал. К. **Билге.**

**БИЛӘ-Ү II** «пеленать» (**биләү** «свивальник») диал. **биелә-ү, бөйелә-ү** id. *бийә-, бөйә-ү* «уратып бәйләү» фигыленең интенсивлык дәрәҗәсеннән (чаг. *куу → куалау, сибү → сибәләү* һ.б.ш.), к. ш. ук себ. (Будагов I: 304) *бийе* «кап, төргәк», чув. *пийе, пийев* «биләү (исем)», *пийел* «биләүсә», *пиелĕх* «биләүсәлек», *пийеле-* «бала биләү», *пелче* «биләүсә» < *пиелче* һ.б.; чув. теле материалы элек тат. *пийел* < *биял* ~ *бөял* «биләүсә, бәйләвеч» сүзе булганлыгын күрсәтә һәм *билә-ү* < *биял-лә-ү* дә була ала, чаг. үзб. диал. (ЎХШЛ: 51) *бийәлләмәк* «тәрбияләү» ~ к.-балк. *белляў* «биләүсә». Чаг. ш. ук нуг., каз., к.-калп. *бөле-*, кырг., уйг. *бөли-*, төр. *беле-* «бала биләү» (ЭСТЯ II: 111–112), ләкин безнең чув.-тат. лексик материалы байрак. К. ш. ук Федотов I: 413; Фасмер III: 228–229 (төрки *belänä* «биләү» сүзе искә алына).

Рус этимологиясендә *пелена, пелька* «биләүсә» лат. *pellis, *pellnis* «тире» сүзенә тоташтырыла; ләкин (бигрәк тә *пелька*) ← **пель* чув. *пийĕл* ~ тат. **биел* сүзенә якын.

Барлык китерелгән сүзләрнең тамыры бор. төрки *böj* «хәрәкәтсезләндерү; хәрәкәтсезлек, паралич хәле» (шуннан ук тат. *күз бөйлә-ү*, ялгыш әйтелеше *күз бәйләү* «гипнозлау»). К. **Биләүсә, Бөя, Бөят**.

**БИЛӘҮСӘ [биләwсә]** «свивальник» ← **биләү** (исем) сүзеннән; *-сә* кушымчасы һәртөрле сыешлыкларны белдергәнлектән, *биләүсә* элек бәби конвертын, махсус капчыкны белдергән дип фаразларга мөмкин. **Биләү** исеме бор. төрки *beleg* > төр. *belek* id. һ.б.ш. сүзеннән. Чаг. **Бүләк II.**

**БИЛБАУ [билбаw]** «пояс» – кар., нуг., ком. һ.б. кыпч. *бельбав, белибав, бэльбагъы* id.; бу сүздә *бау* < *баг* төп «бәйләгеч» мәгъ. кулланыла; чув. *писчиххи* < *пил çыххи* татарчадан калька (*çăхă* «бау; бәйләгеч»).

Диал. (БТДҺ: 48) **билгәү,** себ. (Тумашева 1992: 174) **пилгәү** «билбау» ~ үзб. *билгов* id., димәк, *гәү* < *гаw* (**бау** түгел). Гипотетик *гау* безгә таныш түгел.

**БИЛГА́КЕС** иск. «наоборот» < гар. *би-л-ʻакс* «көзгедә чагылган кебек, киресенчә» (*ʻакс* «кире як, чагылыш»).

**БИЛГЕ** «знак, признак», тар. «пограничный знак; знак принадлежности земли кому-либо» (к. *билге тек-* «ставить такой знак») < гом. төрки, төр. *belgi,* бор. төрки *belgü* id.; бу сүз дөньяда иң таралган төрки сүздер, мөгаен, к. гом. монг. *бэлгэ,* бор. слав. *белегь,* венг. *belyeg*, ним. *Beleg*, гар. *бәлҗә, билҗә* «билге, белешмә», фар. *бӓлге* «(судта) дәлил» һ.б. (Gombocz: 43; ЭСТЯ II: 108–111); төрки чыганакларда бу сүзнең *бэлги, бэлгэ, бэлгү, пүлгү* вариантлары билгеле.

Әгәр бу сүз гом. төрки *бил-* «белү» тамырыннан булса, гом. төрки *билги, билгү* > тат. *белге* булыр иде. Ләкин **билге** очрагында тамыр *бәл* һәм шул тамырдан мар. *пӓл-* > *пал-* «белү, билгеләү», *пӓлы* > *палы* «билге», чув. *палла* «белү, искәрү», *паллă* (< *бәлле*) «билгеле, билге» ~ чаг. төркм., үзб. диал., к.-калп., к.-балк. *белли (бэлли)*, бор. төрки (ДТС: 100) *billüg* «билгеле» сүзе дә килә; гомумән, *бәл* сүзе фигыль дә, исем дә була алган.

*Бәл* һәм *бил-* сүзләре бердәй булса, алар бор. *bäil* «тамга; чик билгесе» тамырына кайтып кала (*bil-* < *bäil-* > *bäl, bel*). Бу *bäil* сүзен кыт. *бэй* «стела, кабер ташы» сүзе белән чагыштыралар (ССТМЯ I: 120); шуны әйтергә кирәк, бу әле **бәйл* кыт. теленнән дигән сүз түгел: кытайлар үзләре бу

сүзне төркиләрдән алган булуы ихтимал. Чөнки буш, киң дала-көтүлекләрдә «билге тегү»ләр күчмәннәр өчен әһәмиятлерәк. К. **Билдә.** Фасмер I: 147; Федотов I: 382–383.

**БИЛДӘ** диал., башк. «знак» < бор. монг. *beltei* «тамгалы, билгеле» сүзеннән, *бэл* «билге» тамырыннан.

**БИЛДӘМӘ, билдәү** «широкий пояс; верхняя часть юбки; поясная часть туши» ~ **бил-лә-ү** фигыленнән, чаг. нуг. *белдеме*, кырг. *белдемчи* «юбка», каз., к.-калп. *белдеу* «тирмәне кысып, җыеп торган киң тасма», ком. *белдев* «панель», уйг. *бәлдәш* «берәр нәрсәнең уртасын билле итү, билләү», *бәлдәмчи* «бандаж», төр. *belleme* «ат ябуы; камзул» >> мар. *пеллама* «эшлия каешы» һ.б.

**БИЛЕК I** «княжество, бейлик» < бор. төрки (ДТС: 92) *beglik* «билек; би биләмәсе; би хөкемдарлыгы» (*beglig* «бинеке») ~ барча төрки телләргә таралган сүз (к. төр. *beylik* һ.б.). К. **Би, Билә-ү.**

**БИЛЕК II: билек ай (айы)** (ТТДС I: 23) «пятый месяц года по древнему календарю» < болг. **билек* ~ чув. *пилĕк, пиллĕк* «биш», к. болгар эпитафияләренлдә *биал* (بيال) «биш». **Билек** түбәндә «бишлек» мәгъ. булган булса кирәк.

**Билек** сүзе тат. теленең чувашлар беләр аралашып яшәгән илат телендә генә теркәлгән һәм, ихтимал, чув. теленнән соңрак кергәндер. Ләкин шунысы бар: аның вокализмы татарча (э > *и*, төп чув. исә э > *ă* > *а*). Шулай итеп, тат. *билек* ~ чув. *пилĕк* бор. тат. теленең болг. теленә көчле тәэсире тур. сөйли.

**БИЛЕҢ,** диал. **пилең** «болезненная пугливость; непроизвольная дрожь (от страха, переживаний)» ~ башк. *билен*, нуг. *белең [бәлэң]*, төркм. *белин,* госм. *бәлиң*, алт. *пäлиң* «куркудан чирләү, кычкырып җибәрүчән булу», бор. төрки (ДТС: 94) *beliŋ* «курку, паника» һ.б., к. ш. ук эвенк. *бэлиң* «истерика», *бэлиин-* «куркудан дертләү, калтырау» – **бэл-* тамырыннан, чаг. нан. *бэлчи* «тилемсә, тәтәш» (төрки телләрдән), маньч. *бэли, бэлэр* «тиләскәү» (чаг. тат. *тиле-миле* < *тиле-биле*).

*Билең* < *бэлиң* сүзенең дериватлары: тат. **билеңләү** (> диал. сөйл. *билемләү*) «куркып саташу», башк. *билеңдә-* < алт. *белиңдэ*, төр. *belinle-* «куркып калтырау»; тат. **билтәк** < бор. төрки *beliŋtäg* «коты очкан, куркудан сакау яки телсез калган» һ.б. (бүтән телләрдә дә бар). Рус. *взбелениться* «ярсудан тотлыгу» – төрки нигездән. К. **Биләнке, Билтәк.**

**БИЛЛҮР, бәллүр** «хрусталь» ~ башк. *бәлләүер* id. < гар. *бәллӯр*, *билләwр* < фар. *бүллүр* (> бор. монг. *böler, bolur*) < пракрит. (гади сөйләм һинди) *veluriya* < санск. *vaidurya* id. >> грек. *βηρυλλος* «берилл, хрусталь» (Владимирцов: 129).

**БИЛТӘ** тар. «пушка; щетка для очистки ствола пушки», хәз. «кусок войлока, шерсть, конопля, хлопок и т.п. для очистки чего-либо» ~ ком. *бэлтэ* id. *Филтә* сүзеннән булса кирәк, к. монг. *билта* «пушка, (филтәле) мылтык». К. **Мылтык.**

**БИЛТӘК** «заика» ~ госм. (Радлов IV: 1246) *пäлтäк* id., бор. уйг. (Малов 1951: 370) *bäliŋdäk* «куркудан өнсез калу». К. **Билең.** Чаг. ш. ук тат. (Радлов IV: 1758, 1770) *биртäк* «билтәк».

**БИЛТЕР** «подъём ноги; обуви», «суженное место чего-либо», диал. **билтер, пилтер** «проток между двумя озёрами» – гом. төрки *белтир* < *беллир* > *билир* id. Киң таралган сүз, к. Räsänen 1969: 69; Демьяненко З.П. Долганское *билир* в ряду однокоренных слов // Лексика и морфология тюркских языков. Новосибирск, 1982: 59–67. һ.б. бор. төрки (ДТС: 94) *beltir* «юл чаты; елгалар кушылган урын» – *bel* «бил» сүзеннән булырга тиеш.

**БИЛЧӘН** «осот; бодяк» ~ мар. *писан, пелчан* id., чув. *писчен* «шайтан таягы» – этимологиясе юраулы; чаг. як. *бэлчирэҥ* «утлау, көтүлек» ← монг. *бэлчи-, билчи-* «утлап йөрү». К. ш. ук (ТТДС II: 67) **бәлчән** «бәрчә; тәлгәш» **бәрт-чән* «тәлгәшле, тармаклы» > *бәлчән* > *билчән* id.?

**БИНА** «здание» < гар. *бинā* «бина, корылма» *бн* «төзү» тамырыннан; шуннан иске әд. *бани* «архитектор; оешманы һ.б. нигезләүче; спонсор».

**БИНИ́СБӘТӘН** «безотносительно» < фар. *бинисбетэн* К. **Би-** һәм **Нисбәтән.**

**БИҢЗӘ-Ү** кит. «походить, быть похожим» < бор. төрки *bäŋzä-* < *bänizä-* id. *bäniz* «йөз; образ; икона» сүзеннән, тамыры *бэң//мэң* «миң», к. **Минәз, Миң.** К. Räsänen 1969: 70, 337; Мухамедова 1973: 72–73.

Бу сүзнең дериватларыннан иске тат., диал. (ЗДС: 123) **биңзәш** «охшаш; матур» ~ төркм. *мең-*

*зеш,* к.-калп. *мегзес,* каз. (ҚТДС: 239) *меңдес* һ.б. «охшаш» киң таралган. Каз. сүзне **меңдәш* дип тә аңларга мөмкин.

**БИР, пир, пире** диал. «вид чертей» ~ башк. *бир* «бес» (*бирле* «җенләнгән»), чув. *пир, пирлĕ* «илаһ», нуг. *берли* «җенләнгән, җене булган». Бу сүзне *пәри*дән үзгәргән дип кенә котылып булмый. Чаг. монг. *бирд* «ачлык рухы» < санск. *preta* «ач әрвах» (к. ССТМЯ I: 85).

**БИРӘН I** «обжора» ~ башк. диал. *биран, миран*, мар., удм. (Гордеев I: 218) *бирӓн, бирен* < болг. *быйран, бӧйран* id. **быйр, бӧйр* < *бӧһар* «бугаз» сүзеннән, чаг. тат. диал. **боғарлан-** «күп ашау» (Ш. Маннур). Чаг. чув. *пыр (пыйр), пур* «бугаз; азык». Тат. *бирәнең тыгылдымы* дигәндә **бирән** «ачлык рухы». Чаг. **Бир** (шуның контаминацион тәэсире).

**БИРӘН II** диал. (ТТДС I: 88) «милая» ~ нуг. *берен (бэрэн)* «чибәр, гүзәл», чыгт., каз. *бэрэн, бӓрӓн* < фар. *бӓрӓнд, пӓрӓнд* «иң матур ефәк тукыма» >> тат. диал. **ферән** (эстр.) id., к. ш. ук кырг. *берән* «иң яхшы булат». «Кыз ~ ефәк» мәгънә алмашынуы төрки телләрдән килә (бор. төрки телләрдә һәр икесе «кыйммәт нәрсә» мәгъ. йөргән). Монг. *бэр, бэргэн* «кәләш; җиңги» белән чагыштыру да мәгъкуль.

**БИРГЕ** (ТТДС I: 86) «дар; подать, задаток» ← **бир-ү.** К. бор. төрки (ДТС: 85) *bergü* «бүләк».

**БИРЕ,** себ. **пире** «сюда; ближе; с тех пор как» < нуг., төр., үзб. һ.б. *бери,* чыгт. *бэрү,* төркм. *бээри* id. (к. Мухамедова 1973: 82). Бәхәсле сүз: Г. Рамстедт (1952: 44) буенча, бор. *бэнгэрү* «миңа таба» сүзеннән, икенчеләр *бу йер* сүзеннән диләр, чөнки хак. *пээр*, тув. *бээр* «бире».

**БИРЕШ-Ү** «поддаваться; подкачать; не стерпеть» – тат. һәм башк. телләрендә генә булса кирәк. Әлбәттә, *бир-ү* фигыленнән (чаг. *калыш-у* ← *кал-у, килеш-ү* ← *кил-ү* һ.б. урт. юн. аерым мәгънә очраклары).

**БИРКӘ** диал. «причина, основание» (к. ДС I: 86), «основательный; расторопный» («бурычын биргән – биркә килен» диелә, к. ТХИ: Мәкальләр һәм әйтемнәр 1987: 375), «крепкий» (И. Хәлфин сүзлегендә *биркәләнмәк* «ныгынмак») < чыгт. *бэркэ* «нык; ныклык» ~ як., эвенк., эвен. һ.б. тунг. *бэркэ* «нык, көчле; бик тә; өлгер, елгыр, көчле, батыр», бор. монг. *berke* «ныклык, көч» > гом. төрки *берк, бәрк* id. к. **Бик II.**

К. ш. ук иске уйг. *бәркә,* тув. *берге* «кыенлык; ныклык таләп иткән эш». Иске телебездә бу сүз актив кулланылган; чув. *пирке* < тат. *биркә* «сәбәп», чув. *парка* (> мар. *парга*) «ныклы, көчле, шәп, өлгер, булдыклы» < тат. *бәркә* (к. *Бәркә Фәкыйһ* бор. шагыйрь исеме) id. > мар. *перке* «уңышлылык, ырам».

М.Р. Федотов (I: 433–434) чув. *пирке* сүзен *пир-ке* дип тарката һәм *пир* тамыры тур. сүз йөртә: аны мар. *вир* «сәбәп, сылтау» сүзе белән чагыштыра. Әмма монда очраклы охшашлык кына: мар. сүзенең *биркә* ~ *пирге* сүзенә катнашы юк. Чув. *пирке* сүзе, тат. теле материаллары һ.б. яктылыгында чув. (Федотов I: 386) *парка* «ныклы, саглам, сәламәт» сүзенең үзгенәсе, тик беренче вариант тат. (миш.) сөйләшләреннән алынма булса кирәк.

Диал. һәм китаби *биркәсе(ндә)* «аркасында, ярдәмендә» сүзе бар.

**БИРНӘ** «приданое», диал. (ТТДС I: 86–87) «бүләк; пай һ.б.ш.» > мар. диал. *бирнӓ* < кар., к.-балк. *бэрнэ,* бор. кыпч. **бэрнэ* > чув. *парне, парня* > мар. *парня* «бүләк, бирнә». К. ш. ук нуг. *берне* «ритуаль бүләк – корал төре», бор. төрки (Ибне Мүһәнна) *berne* id. һ.б. бор. төрки *ber-* «бирү» фигыленнән (*-нә* кушымчасы *әвернә, энә* һ.б. сүзләрдә дә күренә). Федотов I: 387.

**БИРТ** «щербина; ушиб; сухая рана», **бирт-,** диал. **пирет-** «ушибить; вывихнуть, ранить» ~ үзб. *берт* һәм *берт-моқ,* бор. төрки *bert* һәм бор. монг. *bert-* id., нуг., каз., к.-калп. *мерт-* «биртү», чаг. ш. ук төр. *bärt* «кырчын» ~ безнеңчә, барысы да *биз* сүзе белән тамырдаш. Севортян (ЭСТЯ II: 70–72) *бәр-ү* сүзе белән чагыштыра.

Дериватларыннан тат. *биртек* ~ нуг., к.-калп. *мертик* «эчке яра, буын таю»; күч. «инвалид; авыл карамагында булган ятим» сүзе кызыклы. К. **Бирчә.**

**БИРУН (кеше)** «представитель военного сословия в Казанском ханстве» (слово встречается в переписи 1602 г.). Бу сүзне *бер ун кеше* дип язу (мәс., Гариф Н. Казан ханлыгы. Казан, 2006: 134) очрый, ләкин ядкәрләрдә *бирун* аерым бер кешегә карата әйтелә, ун кешегә карата түгел). Безнеңчә, бу сүз төр. *birun*, фар. *беруни* «чик саклаучы гаскәри; тышкы гаскәри» (Redhouse: 194) белән бердәй (бөек Шәрык галиме *Бируни* тәхәллүсе дә

шуннан). *Бируни гаскәргә даруни гаскәр* «эчке гаскәр» антоним. К. **Эчкен.**

**БИР-Ү** «давать» < гом. кыпч. *бәр-* ~ чув. *пар* < **бәр-* id. К. **Бәр-ү.** Федотов I: 984. Ностратистлар бу сүзне һинд.-евр. *bher-* «китерү, бирү» тамыры белән чагыштыралар.

Дерив.: **бирел-ү, биреш-ү, бирдер-ү; бирге, бирем** һ.б.

**БИРЧӘ, биреч, пирец** «мозоль; рубец раны» ~ чув. *пирче, пирчев* «каты шеш», к.-балк., ком. *берч* «тәндә каты төш, сөяк», каз. *беріш* «ак шеш» һ.б. **бирт** (к.) сүзе белән тамырдаш (**биртчә?**). К. ш. ук себ. (Будагов I: 251) *бирич* «тиз генә сынмый торган (сабак)».

Дерив.: **бирчәй-ү, бирчә-ү** «сөялләнү, кату (мәс., яра кырыйлары яисә эштә күп ышкылу-кысылуга дучар кул өлешләре тур.)»; **бирчәле** «төерле, тигезсез (җеп яисә тукыма өслеге тур.)»; **биреч-ү** фигыле дә булган, к. каз. (ҚТДС: 69) *берішмек* «эрене эчендә каткан шеш».

(Бу матдәдәге сүзләрнең кайберләрен мин үзем язып алдым. – *Р.Ә.*).

**БИСМИЛЛА, бисмилләһи** «о боже; именем Аллаха», күч. «с богом (доброе начало дела)». Сүзнең чыганагы – Коръәннең тугызынчы «Тәүбә» сүрәсеннән тыш, һәр сүрә башында килгән *бисмилләһир-рахманир-рахим* җөмләсе, «рәхимле, шәфкатьле Алланың исеме белән (башлыйк)» мәгъ. Бу сүзләр күрше телләргә дә кергән: мар. (Исанбаев 1978: 47) *высмыла, смелла* «бисмилла» һ.б., чув. *пĕсмĕл, пĕсмĕлле* id. тат. теленә кайтып кергән, к. диал. (ТРС II: 140) **песмел** «торжественное введение, речь к открытию собрания» (ешрак ирония төсмере белән әйтелә) һ.б.

Дерив.: **песмеллә-ү** «әфсенләү, укыну», **песмелсез** «әдәпсез, ихтирамсыз; тәкәллефсез» һ.б.

**БИСТАРКА** (ЗДС: 125) «такта кызаулы арба» < рус. *безтарка* (*без тары,* ягъни махсус капчыксыз, тартмасыз гына ашлык ташый торган арба). **Бистарка**лар колхозларда популяр иде.

**БИСТӘ** «слобода; место остановки купцов» ~ мар. *пэстэ* «киртәләнеп алынган урын; утырыш, пажма» < төр., фар. *бäст, бäсте* «сәүдәгәрләр өчен экстерриториаль кагылгысыз урын; гомумән, сугышлар вакытында да беркем дә керми торган утар» (к. Будагов I: 258). Бу сүзне рус. *посад* яисә *место* («шәһәрчек» мәгъ.) сүзләреннән дип аңлатулар (к. журнал «Деятель», № 6–7, 1903: 298; Вәлиди II: 483) дөрес түгел. К. ш. ук Räsänen 1923: 52; Тимергалин: 97.

**Бистә** сүзе тат. телендә «сәүдәгәр» мәгънәсен дә алган. Шуннан *тел бистәсе, җыр бистәсе* тәгъбирләре килә.

Фар. *бәстә,* бор. фар. *upasta* сүзеннән килә, рус. төгәл эквиваленты *постой* «вакытлы тору урыны» (*upa* = по, *sta* = стой). Ахметьянов 1989: 129.

**БИСТӘР** диал. (Остроумов 1892: 43; ТТДС I: 88) «вид свадебного полотенца» ~ үзб. (ЎХШЛ: 52) *бистар* «килен-кияү өчен махсус ефәк юрган» < фар. *бистар* ~ урду. һ.б. *bistara* «палас, келәм; урын-ятак; хирка». Чаг. **Биштәр.** К. ш. ук Материалы по татарской диалектологии, 1978: 28.

**БИТ I** «лицо, щека; склон (горы); страница» (төрле мәгъ. тур. Рамазанова 2013: 26–29) < гом. төрки *бәт* id. Тув. *бэът* (һәмзә белән) әйтешенә караганда, ниндидер ике иҗекле сүздән килә; бу сүзнең «ян» мәгънәсе дә бар (≈чув. *пат*), ул тат. сөйләшләрендә төрле төбәкләрдә очрый (*аның битенә килдем*), к.; ТТДС I: 88, Материалы по татарской диалектологии 1976: 68 һ.б. Һәм бу мәгънәне Рясянен шул ук *бит* ~ *бәт* сүзеннән, Радлов (IV: 1247) исә гарәпчәдән (*бä'д* «соң, арт» сүзеннән) чыгара. Безнеңчә, монда фар. *руй* «йөз; каршы» (*ба руй* «каршына, янына») сүзеннән калька күзәтелә.

**Бит < бәт** сүзенең параллеләре – монг. телләрендә *bütü, bötö*, тунг. *maty* «кебек, шикелле», хант. *mitte* «кебек» (ЭСТЯ II: 121–122) бездә аеруча ышаныч уятмыйлар. Чув. *пит* «йөз, бит» татарчадан, *пат* < **бәт* «яны, якыны» «төп чуваш» теленнән. К. Федотов I: 389, 436 (этимологик аңлатмалары фантастикага бай).

Дерив.: **битле, битсез** «оятсыз»; **битлек, битлә-ү** (мәс., китапны).

**БИТ II,** диал. **вет** «ведь» < рус. К. ш. ук чув. *веет, вэт*, удм. *ведь* id. Рус. *ведь* «белеп тор!» ← *ведать* «белү, белеп тору».

**БИТАМАН** диал. «сброд, голь; недотёпа» ~ диал. *мат'аман* id., к. балк. *байтамал,* каз. *майталман* «кызгыныч ки; шайтан алгыры» (ымлык). Чаг. гар. *бäйт-ул-мāл* «җәмәгать амбары; ябулы базар; ыгы-зыгы». **Битаман** дип җәмәгать исәбенә асрала торган акылы зәгыйфь, гарип-гораба һ.б.ларны атаганнар. Бу мәгънә *битаманга калу* «җәмәгать

исәбенә яшәүгә калу» тәгъбиреннән эллипсис. К. ш. ук Тимергалин: 85.

**БИТАРАФ** «равнодушный; нейтральный» < фар. *бӣṭараф* «тарафсыз», к. **Би-.**

**БИТӘР** «хуже, ещё хуже; ещё более», иске тат. *биттәр,* кар. *бэтэр, бэтар*, нуг., каз., к.-калп., гаг. *бетер (бэтэр)*, уйг. *бәттәр* < фар. *бäдтар: бäд* «начар, әшәке», *-тар* (> тат. диал. *тарак, тарай*) сыйфатларда көчәйтү, арттыру кушымчасы. *Бäд* сүзе күп кенә тат. кушма сүзләрендә очрый: *бәддога, бәдбәхет* һ.б. Чаг. ш. ук. тат. диал. **битләү** «битәрләү, яманлау» < *бäдлä-* id.

**БИТЕР** «узоры на продольном срезе дерева» (Будагов I: 299) «складки на неправильно сушеной шкуре» < рус. *вéтер* id. (булса кирәк).

Дерив.: **битерле** «бөрмәләнеп каткан (тире)».

**БИТЛӘ-Ү** «порицать, хулить» < гом. кыпч. *бетле-* [*бэтлэ-*] id. ← фар. *бäд* «әшәке». К. **Бәдбәхет, Битәр.**

**БИТЬЯУЛЫК [битйаwлык]** диал. «полотенце» – фар. *рӯймāл, рӯмāл* «яулык» (*рӯ, рӯй* «йөз», *мāл* «сөртү») сүзеннән калька.

**БИЧ,** миш. **вич** «весь, все» < рус., к. ш. ук башк. *бис, вис,* чув. *вез*, мар. *вич, веч* id.

**БИЧАРА** «бедняжка» < фар. *бӣчāрä* «чарасыз».

**БИЧӘ,** диал. **пицә** «жена, замужняя женщина» < гом. кыпч. *бичэ,* башк. *бисә,* алт. диал. *пичä*, хак. *пижэ*, нуг., каз., к.-калп. *бишэ* id. *би* сүзеннән (*бичә*). К. **Би II.** Башкортстанда *бичәкәй* формасында да кулланыла.

**БИЧЕН,** диал. (Тумашева 1992: 44, 175) **пицен** «обезьяна» (*бичен елы* «год обезьяны»), «леший, ведьма». **Бичен** һәм **мечит йолдызлыгы** тур. МНМ II: 160, 316. К. **Бичура.**

**БИЧЕРМАН** «бесермянин, представитель этнографической группы обудмуртившихся тюрков в бассейне реки Чипца» ~ бор. зур бер төрки халык – мөселман кыпчаклар (Плано де Карпини: 24) – ихтимал, татарларның монгол яуларына кадәрге атамасыдыр. К. рус. *бесерменин, басурман, бусурман,* төр. диал. *мүсүрман* «мөселман» (Фасмер I: 160). **Бичермән ~ бесермян** этнонимы тур. Н.И. Тепляшина хезмәтләрендә («Язык бесермян», М., 1970 һ.б.) күп языла. Венгерларның бер группасы да *böszörmen* дип атала һәм бу сүз тур. венгер филологиясендә дә әдәбият зур. Бичермәннәр Алтын Урда чорында салым җыючылар булганнар.

**БИЧУРА,** диал. **пичура, мичура, бисура, мисура** «домовой» > удм. *бичыра* id. < *бичура, биченчура* «җен баласы» яисә «җен хезмәтчесе» сүзеннән, к. тат. диал. *бичен, пицен* «маймыл; шүрәле; убырлы карчык» < бор. төрки *bičin* «маймыл» < *mačin* санск. *bhaga*//*Magha Čina* «бөек Кытай» (реаль Көньяк Кытай) сүзеннән. Маймыллар шуннан китерелгән. К. **Бичен, Мәчкәй. Пичура, мичура** вариантлары бичуралар мич тирәсендә булыналар дигән мифның чагылышы (к. табышмак: *Мич артында мичура билен буып утыра* – себерке тур.). МНМ I: 173.

**БИШ** «пять» < госм., төрки *бэш* ~ чув. *пилĕк, пиллĕк* ~ болг. **биэл* id. (к. тат. **Билек**). Төрки *бэш* сүзе тохар. *piç* «биш» белән чагыштыру очрый – безнеңчә, бу очраклы охшашлык. *Биш* < *бэш* < **бэл* «бил, беләк» сүзе белән бәйләү мантыйкка ярашлы (к. Баскаков Н.А. Тюркские языки 1960: 32), ләкин бу да – фараз гына. Räsänen 1969: 71; Федотов II: 434.

**БИШӘМ** «суслон, копна из пяти снопов» бор. «бишенче» мәгъ. сүздән, к. төркм. *бәшим* «бишенче угыл».

**БИШБИТӘР** «ещё более; более чем» < төр. *besbeter* < фар. *бэси бäдтäр* «җитәренчә начар». **Биш** – монда халык этимологиясе буенча әйтелгән.

**БИШЕК** «колыбель» < гом. кыпч., гом. угыз. *бэшик* (нуг., каз., к.-калп. *бэсик,* каз. *бесĕк*), төркм. *бишек (бишэк)*, *бишик*, уйг. *бишик* һ.б. төрки id. (ЭСТЯ I: 122–123), уйг. диал. *бөшүк* < бор. гом. төрки **бөлчүг.* К. чыгт. *биши-* «тирбәтү» < **бөлчи-* id. → венг. *bölcsö, belchew, böcsü* «бишек» (к. Gombocz: 54–55). Сары уйг. *пелек* «бишек». Сүзнең «бәби; токым; дус» мәгънәләре дә бар. Чаг. **Бәвелт-ү.**

Дерив.: **бишекле, бишеклек** (рус. *колыбель* сүзеннән калькалаштырылган мәгънәләрдә) һ.б.

**БИШМӘТ** «стёганое пальто, бешмет», диал. (ТТДС I: 89; БҺһ II: 49) «камзол; пиджак» > удм.,

рус. *бешмет*, чув. диал. *пишмет* «бишмәт», мар. (Упымарий: 181) *пэшмэт* «хатын-кызның туй костюмы» < фар. *пэши бәнд* «алдан бәйләүле, алдан каптырмалы (кием)» сүзеннән (*пэш* «салынып торган нәрсә», *бәнд* «бәйләвеч, каптырма һ.б.ш.»), к. каз. диал. (Аманжолов: 399) *пеш пент*, к.-калп. *бешпент,* кырг. *бешмант*, уйг. *пәшмәт* «бишмәт; хатын-кыз җиләне, озын камзул». Чаг. үзб. (ЎХШЛ: 218) *пешонабанд* > *пэшнәвәт* «кашбау» < фар. *пешана бәнд* «маңгай бәйләвече». Рус. *бешмет* тур. Юналеева 1982: 35–38.

**БИШНИ** «вишнёвый» < рус. (*вишня* «чия» сүзеннән; чаг. тат. *чия* «куе кызыл» мәгъ.)

**БИШТӘР,** диал. (Остроумов 1892: 43; ДС II: 58, 59, 154) **бистәр, бичтәр, пичтәр, пиштәр** «приспособления для ношения грузов на спине» < рус. *пестерь, пешер, бестерь, пистер* һ.б. (к. Аникин: 446) «аркада йөртелә торган юкә кумта, сумка, челтәр капчык һ.б.ш.» – фин-угор телләреннән дип исәпләнә. Ләкин к. фар. *bistar*, урду. *bistara* (Platts) «юл ятагы, келәме, хирка; арка йөге»; ш. ук таҗ. *пуштора, пуштара* «арка йөге» ~ мар. *пуштыр, пӧштыр* «арка йөге». Монда берничә охшаш, әмма тамырлары үзгә булган сүзләрнең контаминациясе бар булса кирәк.

Дерив.: **биштәрле** «биштәрләнгән», **биштәрлә-ү.**

**БИЮ** «плясать» к. **Бие-ү.**

**БИЯ [бийә],** себ. **пийә** «кобыла, кабылица» < гом. кыпч., чыгт., уйг., төр. диал. *бийә, бийә*, башк. *бѐйә,* шор. *пәй,* кырг. *бээ* ~ алт., тув. *бээ, пää* > хак. *пии* id. Бу сүзнең башлыча колынлаган яисә колынлы бияне белдерүеннән чыгып, А.М. Щербак (1961: 89) **бигә* ~ бор. төрки **begä* «бикә, бикәч» сүзе белән бәйли. Ләкин гомумән бу сүзнең этимологиясе авыр. Тат. диал. (ТТДС I: 107) *бөйә* «бия» ~ уйг., үзб. *бүви, бүwи* «ана» тәңгәлләштерүе дөрес булса, кырг. *бээ* яңгырашы да аңлашыла (алт., тув. *бээ* бор. кырг. теленнән була ала). Төркиләрдә атларны кешеләр белән тиңәштерү киң таралган. Ләкин А.М. Щербак фаразына раслагыч фактлар (арадаш форма вә мәгънәләр) җитенкерәми, к. ЭСТЯ II: 133–134.

Бор. төрки (ДТС: 97) *bi* «бия» һәртөрле үзгә фаразларга да юл ача: сүзнең тамыры *бий* дип карарга мөмкин, ләкин ул чагында азаккы *-йә/-ә* нәрсәне белдерә? Бор. чыгт. (Төхфәт) *бийи-* «бия булып үсү» сүзеннән **бийиг, *бийәг* «бия» сүзе ясала ала, ләкин андый сүз беркайда да теркәлмәгән.

**БИЯЛӘЙ [бийәләй],** диал. (ЗДС: 109) **бәләй, били, бийәлей,** себ. (Тумашева 1992: 149) **мәгәләй, мийәли** < гом. кыпч. *биэлэй, биалай,* алт., уйг. *пәләй,* кырг. *мээлэй,* алт. *мäлäй* ~ калм., монг. *beelee, begelei* id. һ.б. < чыгт. (Радлов IV: 1243, 1583) *бäһлä* «лачынчының күн бияләе» < фар., урду. *bihla, bahla* «лачынчыларның озын күн бияләе һәм күн иңсәсе (ерткыч кошларның үткен тырнагыннан саклану өчен махсус кием)». Каз. (ҚТДС: 66) *биялай* «кулкап, бияләй», ш. ук үзб. (ЎХШЛ: 53) *бъйәлей, биялей* «пирчәтке, бияләй» татарчадан булса кирәк. Гомумән, бу сүз төрки телләргә күптән кергән, к. як. (Пекарский: 428) *бäлäнјiк* «манжет», *баланчи* «бияләй һәм аучылар киемендәге махсус күн өлешләр». К. ш. ук **Малахай, Мәләкәй, Мәләнчек.** Platts: 191; Номинханов 1975: 126; Нұрмағамбетов: 23 (бу хезмәтләрдә мәгълүматлар аз).

*Бияләй < бәһләи* сүзнең төрки телләрдәге филиацияләре күп булса да, дериватлары күп түгел: **бияләйле, бияләйлек, бияләйчән, бияләйчек** (дип әйтергә мөмкин).

**БОГАРДАК,** диал. **бурдак** (ДС II: 62, ТТДС I: 94) «петля на шее (животных)», (ЗДС: 127) **боғорлоқ** «укрюк» ~ башк. *боғарҙаҡ, боғарлаҡ* «трахея» (БҺҺ II: 50) ~ мар. *погырдак* «псалия» (к. Упымарий: 158) < болг. **бӧғар* «бугаз» сүзеннән (*r* > *z*), к. ш. ук. тат. диал. *боғарлану* «күп ашау» (*Тукранбашлар бал гына, Әйдә, богарлан гына*, Ш. Маннур). Чаг. чыгт. (Будагов I: 285) *буғудаҡ* «юан муен», тат. **боғазлау,** башк. *боғаслау* «трахея, бугаз» (ТТДС I: 90; БҺҺ II: 50). К. **Бугаз.**

**БОГАУ [бŏғаw]** «путы, кандалы, оковы» > удм. *бугоу,* чув. *пăхав* < гом. кыпч. *буғаw, биқаw* < *buqayu, boqayu* (күп чыганакларда) > венг. *békó* id. (бор. төрки телләрдән булса кирәк), к. бор. төрки *boqarsuq* «богау, камыт», *buyalyk* «корык» һ.б. бор. *буғ-* «буу, элмәк ярдәмендә кысу, диаметрны тарайту» сүзеннән (*буқағу* яңгырашындагы *-қ-* диссимилятив күренеш). Малов 1951: 379; Räsänen 1969: 87; ЭСТЯ I: 248–250; Федотов I: 407.

Дерив.: **богаулы, богаусыз; богаула-у** (→ **богалан-у, богаулаш-у, богаулат-у**).

**БОГЫЛ [бŏғŏл],** диал. (ЗДС: 480, 485) **могыл, мугул** «стожок, копна» ~ алт. *бугул*, алт. диал., хак.

*пугул, пуул*, монг. *богол, бугул, букул, бохол* > як. *бугул* (Пекарский: 534) һ.б. id. Күп телләрдән билгеле *бугул//мугул* (к. **Могыл, Мүкләк**) «кабарынкы-тумпа нәрсә, йомры чыгынты» сүзеннән, к. манси. *мукал,* удм. *быгыл* «быгыл» (ихтимал, татарчадан), коми. *бугыль* «күз алмасы», венг. *boglya* «кибән», рус. *бугор* һ.б. Бу сүзләрнең үзенчәлекле тамыры *буғ* (к. **Букча**), чаг. тат. диал. (ДС I: 37) *бȯйȯт* < *бȯғȯт* «калкып торган нәрсә», эвен. *боңко* «зуркорсак» һ.б.ш. (мисаллар чиксез күп). К. Аникин: 131, 137 («Яшел печән; махсус, сугарылган җир кишәре» сүзен *богыл*га бәйли. Рус *могила* «кабер» сүзе төрки телләрдән – һунн теленнән – дигән фаразны Аникин кире кага).

Дерив.: **(бер) богыллык** (печән); **богылла-у** «богыл итеп өю».

**БОГЫРЫСЛАН [бȯғȯры̆слан]** тар. – название животного, видимо «тур» – к. нуг. *бугы* «иркәк болан» һәм *арыслан* сүзләреннән гыйбарәт. **Бугуруслан** шәһәре атамасы шул җирләрдә богырысланнар күплектәндер. Богырысланнар бик агрессив булганнар һәм русчада *буй тур* дип аталганнар (чаг. рус. *буйный, буян*).

**БОДАЙ** «пшеница» < гом. төрки *буғдай* (> иске тат. *бȯғдай* «оҗмахтагы агач»), башк. *бȯйҙай* id. < монг. *бугудай* (ЭСТЯ II: 232–234). Этимологиясе бәхәсләргә бай: кайберәүләре *борай* сүзеннән чыгаралар, ләкин *бугурай* дигән вариант юк. А. Йоки буенча (Joki 1952: 108), *боғдай* бор. кыт. *twok dai* «бодай – бодай төре» (парлы сүз) дигәннән. Ләкин бу юраулы, конкрет тарихи фактлар белән ныгытылмый. Чаг. төр. *bug* «ашлык бөртеге; бөртекле ашлык».

Деривациясе регуляр.

**БОЕК [бȯйȯк]** «печальный, притихший от печали», диал. «изнурённый, утомлённый» – тат., башк. телләрендә генә бугай – иске кыпч. **буй-уķ* «күшенгән, суыктан бөршәйгән» ← **буй* – «күшегү, өшү, туңу». К. **Боек-у.**

**БОЕК-У (боекты, боегу)** «запечалиться, молча переживать», (Троянский I: 250) «быть изнемождённым», себ. (Тумашева 1992: 178) **пуйуķ-у** (*пуйуғу*) «өшү, туңу» < гом. кыпч. *буйуķ-* (каз. *бȯйыķ-*, к.-калп. *буйыķ-*) «туңу, күшегү, бөршәю» ~ төр. диал., аз. *буйух-* «туңу, өшү», тув. *бууķ-* «өшү» ← бор. төрки (угыз.) *буй-* < бор. төрки (ДТС: 120) *bиδ-* «туңып калу» фигыленең интенсивлык (*-ķ* кушымчасы, к. *аш-у* → *ашык-у* һ.б.ш.) формасы; **боеķ** < *буйуķ* (к. **Боек**) сүзе исә икенче *-ķ* – фигыльләрдән сыйфат ясагыч ярдәмендә ясалган. К. ш. ук үзб. (ЎХШЛ: 56) *буйу, буйуķ* «каты суыклар». ЭСТЯ II: 242–243.

Бор. төрки *bиδ-* = *буҙ-* тамыры *боз* сүзе белән бердәй булса кирәк.

**Боек-** продуктив нигез: **боегыл-у, боегыш-у, боектыр-у.**

**БОЕЛЫК [бȯйȯлы̆ķ]** «естественная потребность» (күч. «нужда») ~ башк. *бȯйлȯķ* id., тат. диал. (Ф. Баязитова) *буйлык* «ярарлык нәрсә», бор. *буй-, буй-* «кирәк булу, әмер бирү» сүзеннән (к. **Боерык**), шул фигыль төш. юнәлешеннән булса кирәк. Башлыча *боелыгын тоту* «нормаль (вакытын-урынын белеп) сию» тәгъбирендә кулланыла.

**БОЕНДЫРЫК [бȯйȯнды̆ры̆ķ],** себ. (Будагов II: 414) **муйдруķ** «ярмо, иго» ~ угыз. *бойундуруķ,* алт., тув., хак., як. *мойндурух, мойдырыķ* һ.б. (күп вариантлар, к. ЭСТЯ II: 182–183) «үгез камыты; махсус яки төре» һичшиксез *муйун* < *бойун* сүзеннән (к. **Муен**): *-дырыķ* < *-дуруķ* – төрле кидерелә торган нәрсәләр атамасын ясагыч гом. төрки аффикс. Ошбу сүзнең тат. лексик дублеты – диал. (ЗДС: 481) **мойундырык** «киң күкрәкчә төре».

**БОЕРГА-У [бȯйȯрға-]** диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «настоятельно приказывать» – **бȯй-у* «кирәк дип күрсәтү» фигыленә *-рга* аффиксы ялганып ясалган (*боер-* нигезеннән түгел!). К. түбәндәгене.

**БОЕР-У [бȯйȯр-],** себ. (Тумашева 1992: 180) **пүр-, пүүр-** «приказывать, повелевать» < гом. кыпч., гом. угыз., үзб. *буйур-* (> нуг., к.-калп. *буйыр-,* каз. *бȯйыр-*), уйг. диал. *буйура-* «боеру; җибәрү, күндерү; рәхим итеп, килү» (ләкин соңгы мәгъ. икенчел булса кирәк) ← бор. **буй-, *буйу-* «боеру, эш кушу» (к. ЭСТЯ II: 245–247): Э.В. Севортян лобнор төрки телендә һәм уйг. диал. *буй(у)-*, *bиjи-* «боеру» мисалларын китерә, ләкин бүтән дәлилләр дә бар: тат. диал. **бөйөм,** башк. *бȯйȯм* «боерык; йомыш» ~ нуг. *буйым* «әмер; кирәклек, хаҗәт» (к. ш. ук **Боелык**) ← *бȯй-* < *буй-* «кирәк булу; абсолют хаҗәт булу». Шулай итеп, *бȯйȯр-* < *буйур-* < **буйғур-* асылда «кирәклекне аңлату» мәгъ. булган.

Себ. тат. (Радлов IV: 1397) *пүүр-* > *пүр-* «боеру» ~ чув. *пүр* «язмышны билгеләү (Алла боеру)» игътибарны җәлеп итә: бу очраклы тәңгәллекме,

яисә бор. багланышларны чагылдырамы? Ошбу палаталь вариант мар. телендә дә күзәтелә: *пүр-* «язмыш кушу», *пүрен* «шулай язган», *пүремыш* «бoермыш, язмыш» һ.б. (к. Иванов-Тужаров: 181) һәм рус. *бирчий* (к. **Боерчы**) сүзендә дә чагыла. Димәк, палаталь вариантлар бор. йогынтылы мәдәни чыганактан, ихтимал ки, болгар теленнән килә.

**Боер-** продуктив нигез: **боерыл-у, боерыш-у; боермыш** һ.б. К. **Боерга-у, Боерык.**

**БОЕРЧЫ [бөйөрчы̆]** тар. «высший судебный чин в татарских государствах (Казань, Тобольск)» – гомумән, бу сүз язмада сакланмаган (безгә мәгълүм түгел) – ул мар. (Paasonen 1939: 67–69, 187–188) *пуйыршо – йумын удырже* «пуйыршо – Юманың [тәңренең кызы]» һәм *эрхэ пуйыршо* «угыл пуйыршо» сүзләреннән һәм манси мифологиясендәге *пойрёхш, пайрыхсы,* хант. *пайрахта* (к. Kannisto 1958: 145) «тәңренең урынбасары» сүзләреннән чыгып тәнәйтелә, к. ш. ук мар. (Иванов-Тужаров: 181) *пурыкшо* «язмыш тәңресе», (Wichman 1932: 28) *бүршо* «Уган, дөньяны бар иткән тәңре»; мар. сүзләренең төркичә яңгырашы *буйырчы* яки *буйрыкчы* булуына шик юк: төрки дәүләтләрендә *буйрук* яисә *буйрукчы* титулы яз. мәгълүматлардан яхшы билгеле (к. **Боерык**). Мари һәм ханты-манси мифологиясендә төрки дәүләтләрнең сарай иерархиясе чагылыш табуы да билгеле. Фин-угор мәгълүматларына слав. мәгълүматлары өстәлә: бор. рус. (1229 елдан, ягъни монгол яулары килүдән элек) *биричь, бирюч, бирчий* «суд хөкемен игълан итүче, пристав», укр. *бiрич,* слов. *birič* «суд хөкемен җиренә җиткерүче», лужица телендә *bĕrč, bĕrıč, berıč* «полиция шымчысы». Бу сүзләрнең изоглоссаларына карап хөкем йөрткәндә, алар тик авар теленнән генә була ала (Идел болгарларыннан дисәң, нишләп алар Германиянең төньягында яшәгән «лужичин»нарга кадәр барып җитә алсын?), к. Фасмер I: 167. Икенче яктан, ханты-мансилар мәзкүр сүзләрне аварлардан откан дип тә раслап булмый. Димәк, *боерчы* < *буйуругчы* сүзе (һәм эше) бор. Күктүрек дәүләтендә үк булган.

Китерелгән (һәм бүтән кайбер) мәгълүматлардан ук күренгәнчә, бор. төрки *буйурчы, буйуругчы* суд карарын игълан итүче булган: җаваплы очракларда авыр карарны ханның кызы әйтеп биргән (ул, мөгаен, гөнаһсыз кызчык булгандыр): бу хәл карарның объективлыгын ассысызыклау өчен эшләнгән, к. ш. ук Скворцов 1972: 392–406 (*бирчий* сүзен чув. *пүрүч* сүзеннән ди, ләкин чув. сүзлекләрендә андый сүз юк!).

**БОЕРЫК [бөйөры̆к]** «повеление, приказ» < гом. кыпч. *буйруқ* (нуг., каз., к.-калп. *буйрық*), куман., госм. һ.б. (Радлов IV: 1811) *буjуруқ* id. ~ бор. төрки (ДТС: 121, 125) *bujuruq, bujruq* мәсьүл кешенең титулы («эч бойрык», «тыш бойрык» һ.б. булган) һ.б. Тат. *боерык* ← *боер-* сүзнең төп мәгъ. кулланыла, әмма бор. һәм кайбер иске телләрдә бу сүз затны, шәхесне һәм эшнең үзен дә белдергән, к. Бартольд V: 502; Györffy G. Die Rolle des Buyruq in der alttürkischen Gesellschaft // Acta orientalia (Budapest). XI. 1966: 174–180.

**Боерык** сүзеннән бор. заманнарда ук **боерыкчы** сүзе ясалган һәм ул идарәви термин булган: **боеручы** исә ирекле мәгънәдәге сүз; әмма **боерчы** (бор. төрки телләрдә *-чы//-че* кушымчасы турыдантуры фигыль нигезенә ялганган) ш. ук термин булган (к. **Боерчы**). **Боерык** сүзенең nomina agentis мәгъ. бор. Дунай болгарлары ядкәрләрендә *wyrg* рәвешендә, венг. телендә *ur* «әфәнде, начальник» сүзендә чагыла (Donuk: 11–13).

**БОЖАН, боҗан** «жук – жужелица», диал. **буҗан, бужан** «коңгыз» (ТТДС I: 94) – *буҗ* тәкълиди сүзеннән: *бужан бужлау* (Остроумов 1892: 48), *боҗан буҗлау* (Г. Мөхәммәтшин, к. КУ, № 6, 1965: 4), чаг. рус. *жук жужжит.* Чаг. ш. ук *бузан, бусан* «сагызак, шөпшә», *бусан-* «пыр тузу, тиргәнү», *бежгәк, беҗгәк* «тиргәнүчән, сукранучан», *беҗләү* «тиргәнү» һ.б.ш.

**БОҖРА,** диал. (Башкортстан, Тәтешле районы Аксәет авылында) **бөҗөрә** «кольцо (звено цепи)», «серьги, которые ввинчиваются в мочки ушей» (Вәлиди II: 431) ~ чув. *пăчăрă, пăлчăра* «чылбырчык» < чув. диал. *вăлчăра* (Егоров 1964: 51), *пăчра, пăлчăрка* id. (Сергеев 1971: 57). Каз. (ҚТДС: 72) *бужыра* «тезгенне дугага бәйләү, элү өчен кулланыла торган алка, дүңгәләк». Чаг. калм. *buldžr, buldzrxa* «муен бизе» (Ramstedt 1935), башк. диал. *бŏзŏра* «лампа челтәре; цынга» (БҺҺ II: 50). Федотов (I: 114–15) бүтән чагыштырулар да китерә, ләкин тат. сүзен белми.

**БОҖЫР [бŏҗŏр]** «куропатка; рябчик» ~ башк. (БТДҺ: 52) *бŏжŏр, бŏзŏр,* чув. *пăчăр* [*пŏҗŏр*] id., каз. *бŏжыр,* тув. *бозур* каз., як. *бужур*, монг. *боҗур, буҗигир* «бөдрә, шадра», башк. *бөзөр, быжыр* «су өстендә дулкынчыклар», каз. (Будагов I: 244) *бужур,* кырг. *бүчүр* «шадра» сүзе белән чагыштырыла һәм *пăч* < *бŏҗ* «тап, тимгел» тамырыннан дип карала (Егоров 1964: 151). Семантик

параллельләр итеп рус. *рябь* ~ *рябчик* күз алдында тотыла. Ләкин эвенк. *бучугарас, бөчүгүрäс, бөчүгүнүөр* «бoжыр» бөтенләй бүтән юнәлештә – як. *бочигира* – «чыркылдау, көртләү» сүзеннән дип аңлатыла, к. ССТМЯ I: 117. Федотов I: 409.

**БОЗ** «лёд; град», себ. (Тумашева 1992: 153) **мŏс,** башк. диал. (БТДҺ: 233) *мŏз, муз* (кайбер башкорт филологлары бу сүзне әд. нормага кертмәкче) ~ нуг., к.-балк., ком., угыз. *буз* < бор. төрки (ДТС: 130) *buz* < бор. гом. төрки **бууз* (к. төркм. *бууз,* як. *буус, муус*) < **пуург* ~ чув. *пăр [пŏр]* id. Сүзнең *м-* варианты каз., к.-калп., уйг., үзб. телләрдә очрый һәм ул икенчел булса кирәк; *моз* < *муз* иске тат. әд. телдә дә кулланылган. К. ш. ук алт., хак. *пус,* алт. диал. *бус* h.б. «боз».

*Бŏз* < *бууз* бор. *бу* (фигыль һәм исем) сүзеннән, к. гом. кыпч. *буй-* < *буҙ-*, бор. төрки (ДТС: 120) *вид* – «туңу, кату, өшү» (к. **Боек**) h.б. К. ЭСТЯ II: 238–239. Бор. **бург* тамыры тат. диал., башк. (БТДҺ: 53) *бŏрғақ, борғанак* «вак йомры кар» сүзендә дә саклана. Төрки телләрдән тыш *буз* сүзе эвенк. *буксэ* h.б. (к. ССТМЯ I: 105) сүзе белән чагыштырыла, к. ш. ук эвенк. (ССТМЯ I: 113) *бурка* «вак каты кар», эвен. *бурқу*, *бурқун* «кар йомгагы» h.б. Räsänen 1969: 91; Федотов I: 398. Рус. *бузлук, базлук, базлык* «боз өстендә йөрү өчен дагалы аякчу» тур. Аникин: 108 (арытабангы әдәбият күрсәтелә).

**Боз** продуктив нигез: **бозлы, бозсыз, бозлык; бозлак, бозлавык; бозлан-у, бозла-у.** Сүзнең фигыль мәгъ. диал. (ЗДС: 127) **бозғақ** «бозлак» сүзендә чагыла.

**БОЗАРА [бŏзара]** (ДС II: 78) «хорёк, вид хорька» ~ удм. *бызара* «йомран; бозара», мар. *пушара*, чув. *пăсара* «көзән, бозара» < *пăсар-* < иске тат. **бŏзар-* «сасы ис чыгару» (?) < **боз-гыр ? ← боз-з, *быз-з* тәкълиди сүзеннән (к. рус. *бздить* id.). Федотов (I: 404) чув. сүзен чыгт., уйг. диал. *осар-* h.б. «усыру» сүзеннән димәкче, ләкин, безнеңчә, ул сүзнең *бозар-* сүзенә турыдан-туры кагылышы юк (Федотов тат. вариантны күрсәтмәгән дә).

**БОЗАУ [бŏзаw],** себ. (Тумашева 1992: 176) **посау** «телёнок» ~башк. *бŏҙау, быҙау* < гом. кыпч. *бузаw* > угыз. *бузоw, бозоw* < бор. төрки (ДТС: 130) *buzaγ, buzaγu* ~ бор. монг. *biraγu* (хәз. монг. *буруу*), уйг. диал. (Zenker) *burγu* ~ чув. *пăру* (< болг. **бŏру*) id.; тат. **бозағы** «тире-күн сорты, бозау күн» < чыгт. *бузағу,* госм. *бузағы* h.б. (Радлов IV: 1867–1868), к. ш. ук кырг.,төркм. диал. *музоо,* уйг. диал. *музай, мозай* id. (гомумән, бу сүзнең фонетик вариантлары бик күп, к. Joki 1925: 111; ЭСТЯ II: 239–242), як. *бурғунас* «тана» h.б.

*Бозаw* бор. төрки **буза-* фигыленнән булса кирәк, ул чагында аның тамыры *буз* < **бург* һәм бу сүз яшь сыерны белдергән: *бузагы* < *бурағы* «яшь сыер буласы» мәгъ. ясалган, к. иске монг. *buru* < *buraγu* ~ чыгт. *torbaq* «өч яшьлек бозау» (Поппе 1938: 282).

Географик җәһәттән *-r-* варианты киң таралган: венг. *borju* «бозау» ~ эвенк. *бээру* «кәҗә тәкәсе», мар. *прӗзы, пӗрезь, пырэзӗ* «башмак, бозау» < болг. **бŏрусы* «бозавы; башмагы». Рус. *бурун* «башмак» < бур. *буруун* id. тур. Аникин: 145.

Сүзнең тамыры тур. күп фикерләр әйтелгән. Э.В. Севортян төр. диал. *buza-* «бозаулау» сүзеннән **buz* «бозау» тамырын аерып күрсәтә. Шуны әйтергә кирәк иң бор. тамыр **буз* түгел, чөнки төрки *-з* < *-р*. Аннары тамыр – төрки сүз, монг. *biraγu*, эвенк. *беру* h.б. төрки телләрдән алынган. Димәк, төрки телләрдән тыш чагыштыру объекты *бур* ~ *бир* генә була ала: к. грек. *poris,* талыш. *purna* «бозау»; икенче яктан шумер. *buru* «бозау», *bir* «мөгезле эре терлек» h.б. Ләкин болар барысы да юраулы. К. ш. ук Räsänen 1969: 74–75; Федотов I: 402–403.

**Бозау** продуктив нигез: **бозаулы, бозаулык** (бозауларны утлату өчен киртәләп алынган урын); **бозаула-у, бозаулат-у, бозаучы.** К. **Бозаубаш.**

**БОЗАУБАШ [бŏзаwбаш]** (Арсланов 1988: 75) «медведка (насекомое)» – «башы бозауныкына охшаш» мәгъ. ясалган ~ каз. (ҚТДС: 72) *бŏзаубас* нииндидер хайван.

**БОЗДЫГАН [бŏздŏған]** «клевец; воеводский жезл, у которого яблоко набито гвоздями» ~ төр. *bozdoğan* «махсус гөрзи» ~ асылда тат. диал. (Тумашева 1992: 177) *пос туйгун* «чуар лачын» сүзеннән: *боздыган*ның башы тәүдә ерткыч кош башы рәвешендә ясалган булган (бу хакта махсус рәсемнәргә таянабыз). К. **Бүзтойгын, Бүзтургай.**

**Боздыган** сүзе күптәннән инде слав. телләренә кергән (иске рус. *буздыхан*), к. Добродомов 1974: 29–31. Бу автор да, М. Рясянен да бу сүзне *буз-* «бозу» белән аңлаталар, чөнки алар төр. *bozdoğan*-ның үзен күрмәгәннәр!

**БОЗ-У [бŏз-]** «портить», диал. (ТТДС I: 90) «разбить на части», «разделывать, разделить тушу (не соблюдая этикета)» < гом. кыпч., уйг., чыгт. *буз-*, төркм. *поз-* алт., хак. *пус-*, госм. *боз-* < бор.

төрки (ДТС: 130) *boz-, buz-* «бозу, яралау, тар-мар итү», «түшкәне тәртипсез бүлгәләү» (хәлбуки мәҗлесләрдә пешерелгән түшкәне бозуның катгый төгәл кагыйдәләре булган; чаг. тат. *коймак бозу* «кәләш гыйффәтсез булып чыкса, сый коймагын кияү пәкесе белән ерткалап чыгып китү»). *Боз-* < *буз-* фигыле электән үк *борчы-* < *бурчы-* «борчу» фигыле белән чагыштырыла (*бурчы-* үзе бор. **бур-* «бозу» фигыленең ешайтулы формасы: «еш кына бозу») һәм моңа семантик нигезләр шиксез (к. Будагов I: 280), к. алт. *буру* «гаеп; тәртип бозу» ~ бор. монг. (Поппе 1938: 126) *buruyu, burayu* «ялгышлык, бозылу» > эвенк., як. (ССТМЯ I: 114) *буруу, буруй* «бозу; гаепле булу» һ.б.

Тат. теленнән бу сүз күрше телләргә таралган: чув. *пăс-*, мар. *пуз-, пуж-* «бозу, вату, комачаулау» (к. ш. ук. мар. *пужык, пузык* «бозык», *пузукчо* «бозымчы, сихерче» һ.б.). ЭСТЯ VII: 113–115.

**Боз-** продуктив нигез: **бозгын, бозыл-у, боздыр-у; бозык, бозым** «сихер».

**БОЙТЛА-У, бойотла-у, ботла-у** диал. (ТТДС II: 56, 58) «потакать дурным склонностям, прощать неблаговидные поступки», чаг. башк. (БТДҺ: 60) *буйт* «рәт, мәгънә» *буйтһыҙ* «мәгънәсез», *буйтлы* «сайланмыш». Чаг. себ. (Тумашева 1992: 46) **буйтауцыл** «үзсүзле, үзбелдекле». Ачык түгел. Чаг. **Боер-у.**

ТТДС II авторлары бу сүзнең нигезен русчадан дип белдерәләр, ләкин конкрет бер сүз күрсәтмиләр.

**БОКАЙ, букай** «страшилище (при разговоре с детьми)» ~ рус. *буки.* Чаг. **Бөкәй.**

**БОЛА** «мятеж» < бор. угыз. (Мухамедова: 80) *булгаг* «бола»; бор. монг., бор. төрки (ДТС: 122) *bulɣar, bulɣaq* > башк. диал. *болғаҡ* «кузгалыш, фетнә», «сугыш, җәң». Бу сүз рус, осет. һ.б. телләргә дә үтеп кергән, к. Фасмер I: 238, Абаев I: 270. Чаг. ш. ук кырг. *булаан* «болгавырлык» < монг. *булаган,* уйг. *булаң* «талау». К. **Болагай, Болгавыр, Болга-у, Булак.** Рус. *булгачить* «бола чыгару» тур. Аникин: 140 (шунда ук *болғак* сүзе тур. бай әдәбият күрсәтелә).

**БОЛАГАЙ, былагай** «смутьян; болтун» ~ чув. *пăлахай, плахай* id. ~ кырг. *булаан* «ыгы-зыгы, болгавырлык; талаучылык» < монг. *булагай* «болагай» (> як. *булағай* «явызлык; явыз рух», *былағай* «бола, фетнә») ← төрки *була-, булга-* «болгату» (к. **Бола, Болаңгыр** һ.б.) сүзеннән ясалган; тат. телендә *-гай* кушымчасы кире характеристика атамаларында очрый: к. **камагай, кырагай, ялагай** һ.б.ш.

**БОЛАЙ** «этак, так» < *бу-лай*, к. **Бу.** Кыпч. телләренә хас сүз.

**БОЛАК** диал., ш. ук Дәрдемәнд һ.б. телендә «(бурный, большой) источник». К. **Булак.**

**БОЛАМЫК** «месиво; мучная каша» > мар. *быламык, пуламык* (Гордеев I: 252; Упымарий 166), чув. диал. *пăламăк* < гом. кыпч. *буламық, буламуқ*, чыгт. *буламақ, буламач*, бор. чыгт. *bulamaq*, монг. *bulamay* id. ← гом. төрки, монг. *була-* < *булға-* «болгау, болгату» сүзеннән (к. Радлов IV: 1841–1842), к. ш. ук иске тат. (ЛТ I: 103), гаг., төр. *буламач,* аз. *буламаҗ* «боламык» һ.б. Чаг. ш. ук тат. диал. (ЗДС: 128) **болама, болгама** «боламык; тәртипсезлек» һ.б.

**БОЛАН** «олень», диал. «лось» > чув. *пăлан, пăлам*, мар., удм. *булан, былан* < гом. кыпч. (кайбер телләрдә хәзер теркәлми), уйг. *булан,* алт. диал., хак. *пулан* һ.б. < бор. төрки (МК, ДТС: 121) *bulan* –ниндидер хайван; бу сүз составында, безнеңчә, *-лан* элементы шиксез дип әйтерлек. Гомумән, бу сүз тур. күп язылган, к. Räsänen 1969: 87–88; Корнилов 1970: 224; ЭСТЯ II: 260; Федотов I: 395.

**Болан** < *булан* сүзе күп күрше телләргә кергән: кабарда. *бланэ* «пошый», чеч. *булан* «зубр» ~ венг. *bölény* «бизон»; рус. *буланый* «болан төсендәге (ат)», к. Фасмер I: 238 һ.б.

**БОЛАҢГЫР** «мутный (о воздухе, о небесах)» ~ башк. *бŏлангырт, болаңкыр, бөләңгерт*, мар. (к. СФУ № 3, 1987: 209) *пуламыр, пыламурь* «бола» << бур. *булангир* >> эвенк. (ССТМЯ I: 91) *болаҥир* ~ яз. монг. *bulangir* ~ чыгт. *bulɣančaq* «болганчык» (к. Поппе 1938: 125) һ.б. Бу төркем сүзләр тур. к. Poppe 1972: 52. Аларның тамыры монг., төрки *була* «сазламык» дип исәпләнә (к. Ramstedt 1935: 60). Чаг. **Болгавыр.**

**Болаңгыр** сүзе Идел-Урал даирәсеннән тыш кыпч. телләрендә теркәлмәгән.

**БОЛГАВЫР [бŏлғаwы̆р],** диал. (Тумашева 1992: 184) **полауыр, пылаур** «смута; смутный; неразбериха, беспорядок; переполох, суматоха» ~ нуг., ком. *булгавур* id. ← *булга-* «болгатылу», чаг. **Бола.**

Дерив.: **болгавырлы, болгавырлык; болгавырлан-у.**

**БОЛГАР [бŏлғар]** «булгар, булгарин (один из булгар); Булгария (Волжская Болгария)» – один из древних этнонимов, который татары, по-видимому, издавна произносят по-своему (с *ŏ* в первом слоге)» ~ чув. *пăлхар* id. (ләкин чувашларда бу сүз китаби телдән XIX г. ясалма рәвештә таралган булса кирәк). Тат. яз. ядкәрләрендә бу сүз ким дигәндә XVI г. бирле (Мөхәммәдьяр) билгеле. Ә гомумән *булгар* атамасы тәүләп 482 елда Византия чыганакларында искә алына (к. Менгес: 47–52). Аннары, бор. Сурия чыганакларында хәбәр ителгәнчә, VI г., **Булгариос** дигән авар шаһзадәсе, үзенең 10000 кешесе белән килеп, Византия императоры Маврикийгә хезмәткә кергән. Нимес тарихчысы Карл Альтһайм бу сүзне төркичә *бүрегәр* «бүре кабиләсе, бүре токымы» дип аңлаткан (K. Altheim: 226), чөнки кайбер (әрм. һ.б.) чыганакларда болгарларны *бургар* дип атау күзәтелә.

**Болгар** < *булгар* сүзенең гар. язылышларын һәвәскәр тарихчы Ә.В. Булатов (к. аныкы: К этимологии слова *Болгар* // Уч. зап. ЧНИИ. XXIX. 1966: 259–260) һәм Б.Н. Заходер (1967: 23–45) китерәләр. Ул язылышлар бик төрлечә: *блғар, брғар, бунғар, блқар, блхар, блкар* (йомшак *к* белән!) һ.б. Ә. Булатов фикеренчә, бу сүз *болғар* «бөек (зур, мул) гар халкы» дигәннән. Шуны әйтергә кирәк, ك белән язу Болгарстан ядкәрләрендә (чүлмәкләрдә, тәңкәләрдә һ.б.) да күзәтелә. З. Вәлиди (Velidi: 169) *болгар* сүзенең бор. варианты *балугар* димәкче, тик бу раслама да тикшерүгә мохтаҗ. Ш. ук *болгар* һәм *балкар* этнонимнарын тәңгәлләштерү дә төрле яктан тәнкыйтьләнә.

Безнеңчә, *болгар* < *булгар* сүзен *-ғар//-гәр*, *-қар//-кәр*, *-ғыр//-қыр* элементына беткән күпсанлы һунн һәм дә эвенк-тунгус этнонимнары рәтендә карап тикшерергә кирәк.

**Болгар** сүзен (бик теләп) рус. *волгарь* «Волга (Идел) кешесе» дип аңлатулар еш очрый. Ләкин М. Фасмер (I: 187, 337) моны кире кага, чөнки тарихи чыганакларда *болгар* сүзе *волгарь* сүзеннән күп гасырлар элек һәм *Волга*дан ерак җирдә теркәлгән. Тик М. Фасмерның үзенең яклаган этимологиясе – төрки *булга-* «болгау, бутау» сүзеннән (янәсе, болгарлар кушылгак халык, «болганган» кавем) диюе дә ышандырмый. Гомумән, бу бик бор. этнонимның чыгышын төгәл билгеләү гамәлдә мөмкин түгел. К. **Бигәр; Болгари.** К. ш. ук Feher 1921; Федотов 1990: 32–34 (Фасмер фикере яклы); Тимергалин: 99–100.

**БОЛГАРИ** «булгарский; сорт высококачественной кожи» – бу ясалышы буенча гарәпчә сүз һәр ике мәгънәдә гарәпчә һ.б. язылышларда хәтсез күп төрки, монг., фар. һ.б. чыганакларда һәм вариантларда (*булгайры, булгайыр, былгāр* һ.б.) XII г. бирле очрый. Монг. (ССТМЯ I: 91) *булигаар* «яхшы күн» *болгар* < *булгар* сүзеннән борынгырак бер вариантын чагылдыруы да ихтимал.

Рус. *булгар* «кара күн» тур. Аникин: 139–140 (шунда ук бай әдәбият күрсәтелә).

Тарихта **Болгари** күп кенә мәшһүр кешеләрнең (аларның кайберләре гарәп илләрендә, Иранда, Төркиядә яшәгән) тәхәллүсе булган. Хәз. көндә дә татарлар арасында **Болгари** фамилиясен алучылар очрый.

**БОЛГА-У** «перемешивать, мутить (палкой); вилять, махать» < гом. кыпч., монг. *булға* < бор. *булуғ-а-* id. **булу-* **бул-* тамырыннан (к. ЭСТЯ II: 253–257); шуннан бик күп сүзләр ясалып килә, к. **Бола, Боламык, Болагай, Болаңгыр, Болгавыр, Болыт, Булак, Булашу.** К. ш. ук Иванов 1993: 47–49; Федотов I: 397.

**Болга-** фигыленең турыдан-туры үзеннән **болгавыч, болгама (болгатма), болгаткыч, болган-у, болганчык, болганыш,** диал. **болгаксы-у** сүзләре ясалган.

**БОЛДЫР [бŏлдŏр]** «сени, крыльцо» > чув. *пăлтăр,* мар. *пулдыр, пылдыр, пы̆лды̆р,* иске мар. *пулдыр* (к. СФУ № 3, 1987: 209–210), иске чув. *плдарь* (к. Сергеев 1970: 231) «болдыр; бәләсә» < фар. *пули дāр* «ишек (ишегалды) күпере» (*пул* «күпер», *дар* «ишек»), к. ш. ук фар. *бāлā дāр* «ишек өстендәге тәрәзә яки так (куыш)». Рус. *булдырь* «авылдан читтә торган өй» сүзен чувашчадан дип, ә чуваш сүзе чув. *пăл* «такта (агач) морҗа» сүзеннән дип раслау (Федотов I: 396) дөрес түгел. «Морҗа» мәгъ. «болдыр» мәгънәсеннән (яки киресенчә) килеп чыкмастыр кебек.

Даль сүзлегендә һәм бүтән рус диалекталь сүзлекләреннән күренгәнчә, *болдарь, болдырь, булды́р* «түмгәк, өем, үзендә куе чүп үлән үскән кечкенә калкулык» һ.б.ш. мәгъ. кулланыла. К. Аникин: 132, 140 (моның ише сүзләр, ихтимал, монг. телләреннән, димәкче һәм тат. болдырны искә алмый); Ахметьянов 1989: 129–130.

**БОЛЫН [бŏлŏн]** «луг» > чув. *пăлăм,* мар. *былым* id. < алт., як. *булуң*, хак. *тулуң,* бор. төрки, монг. *булуң* «почмак, болын, таба; елга бөгелеше, елга алкасы белән уратылып алынган җир» сүзеннән (семантик үсеш ягыннан чаг. **Тугай**), чаг. ш. ук монг., бур. *булаң* «кәкрелек, дугай», эвенк. *болан*

«почмак» һ.б., бор. төрки *buluŋ* «түтәрәм (дүрттән бер өлеш)». К. Räsänen 1969: 88–89; ЭСТЯ II: 261–262; Мурзаев: 101; Федотов I: 346. Рус. *булунчик* «кечкенә култык» тур. Аникин: 141.

Бор. *булуң* сүзен М. Рясянен бор. *буңул* «почмак» сүзеннән метатеза дип карый, бу сүз исә бор. төрки, гом. төрки *буң, муң* «почмак, тупик» тамырыннан, к. **Мөеш.**

**БОЛЫТ [bŏlŏt]** «облако, туча» < гом. төрки *булут* «болыт; томан, болаңгыр» < бор. монг. *buluŋut* < *bulaŋgit* «болганчык, болаңгыр» бор. төрки, монг. **бул-* тамырыннан (к. **Болга-у**), к. як. *былыть* «томан», чув. *пĕлĕт,* мар. *бĕлĕт, пĕлĕт* «күк; болыт» – икенчел сүзләр. К. ЭСТЯ II: 262–264.

**БОРАЙ** «полба» ~ чув. *пури* id. > тат. диал. (ЗДС: 543) **пури** «сарут». Бу хәз. бүтән төрки телләрдә очрамый торган сүз бик бәхәсле булып чыкты (ЭСТЯ II: 234): берәүләр аны болг. телендә *бугдай, будай* сүзеннән килеп чыккан дип исәплиләр, икенчеләр литв. *purai* «көзге бодай, борай», латыш. *puri* id., бор. рус. *пыро* «бодай» (ш. ук *пырей* «сарут») ~ санск. *pūras* «көлчә; борай (?)», грек. *πυρος* «бодай, бөртек» һ.б.ш. сүзләргә нигезләнеп, һинд-евр. телләреннән Урта Идел телләренә кергән диләр. Г. Рамстедт (1957: 206) *борай* сүзен кор. *pori* «арпа» сүзе белән чагыштыра. Чаг. ш. ук. гар. *бурр* «бодай». Федотов I: 400–401.

**БОРАК I** «мучная пыль, осевшая на стенах мельницы изнутри» к. **Порак.**

**БОРАК II,** ш. ук **порак, пырак** «мифическая лошадь, на которой пророк Мухаммед летел к Богу», «райская лошадь» < гар. *бурāķ* id., *п*га башланган вариант фар. яки төр. телләреннән килә.

Гар. *әл-бурāķ* төбендә «яшен» дигән сүздән, к. МНМ I: 195; ГТРС: 36.

**БОРАМ, борым, брам, брен, брун** диал. «паром» (ТТДС I: 91–93, ЗДС: 134) ~ ком. *бурам* id., тат. диал. сүзлекләрдә русчадан диелә, ләкин рус сүзенең үзенең дә канәгатьләндерерлек этимологиясе юк һәм *бŏрам* бу яңгырашларда һ.б. «паром» << бор. ним. *farm* id. (Фасмер III: 331) яки ним. диал. *Prahm* (күплек санда *Präme*) > төр. (һ.б. Балкан телләрендә) *pram, pereme* «баржа, паром» сүзеннән. К. Kluge: 717.

Бу сүз, ихтимал, күп заманнар (VII–XIII гг.) дәвамында зур елгалар аша кичерү белән көн күргән герман кабиләсе «брамчылар» (русча *бродники*) теленнән таркалгандыр. Аларның XIII г. монголларга хезмәт итүе билгеле.

**БОРАУ [bŏraw]** «бурав» ~ нуг., каз., к.-калп. *бурай (бурав, буров)*, кырг. *бурро* id. иске *бора-* «бору, бораулау» фигыленнән, к. үзб. *бура-* id. (к. **Бор-у**). Чув. *пăра* «бораү, без» һәм рус. *бурав* < тат. булса кирәк. К. ш. ук **Бормач.** Федотов I: 398–399; Аникин: 142–143.

Дерив.: **борау-ла-у** (бу фигыль күрше фин-угор телләренә дә кергән, к. мар. *проулаш* id.).

**БОРГАТА** – название деревни в Западном Башкортостане (она находится у большого озера), себ. (ЗДС: 537) **поргатага китү** «пропасть, исчезнуть». Чаг. төр. (Steuerwald: 136) *burgata* «яндырып тишү коралы; тоташ бер агач кәүсәсеннән каек ясаганда каек янтавының калынлыгын белү (артыкча юнмау) өчен ясала торган тишек һәм шуны ясый торган корал (бораү)», *burgatalık* (шундый тишек тур.) «шундый калынлыкта». Әлеге *Поргатага* ~ *Боргатага китү* тәгъбире, күрәсең, «кимә тишегеннән төшеп китү – суга төшеп югалу»дыр.

Бу киң (Себердән Төркиягә хәтле) таралган сүзнең чыгыш-ясалышы безгә ачык түгел.

**БОРГЫ** «притужальник (в ткацком станке), закрутка» ← **бор-** (к. **Бор-у**). **Боргы** < *бургу* сүзе киң таралган, хәтта Европа телләрендә, гар. телендә һ.б. очрый.

**БОРЛЫК-У (борлыкты, борлыгу)** «чувствовать себя скверно (от чего)» – **борыл-* сүзеннән интенсивлык дәрәҗәсе, к. төр. диал. *бурул-* «үрсәләнү» ← төр. диал. *бур-* id., *буру* «газаплану (исем)», чаг. ш. ук кырг. *бурук-,* хак. *пурук-* «ачулы булу» (ЭСТЯ II: 269). К. **Борсалан-у.**

**БОРМАЧ** диал. (трбс.) «спираль (рогов козы)» ~ башк. *бормас* id. **Бор-у** фигыленнән (чаг. **Бөрмәч, Төрмәч**).

Дерив.: **бормачлы; бормачла-у** «борып сыгу».

**БОРНАЙ, бырнай** (ЗДС: 128, 146) «привередливый; кичливый» мәдрәсә шәкертләре телендә *борын* нигезеннән гар.-фар. сүзе моделендә ясалган, к. төр. *burnai, buruni* «борнай, борын чөерүче». Гар. яки фар. телләрендә дә ясала ала, чөнки *бурун* сүзе аларга да кергән. К. **Борын I.** Рамазанова 2013: 53–54.

**Борнай** сүзенең китерелгән этимологиясе шиксез-шелтәсез түгел – аның ясалышы томанлы. *Борнай* < *бурнай* сүзенең фар. *бур-у-най* «һәртөрле сыбызгы-сызгырткы», күч. мәгъ. «нигезсез мактану, һавалану» сүзеннән дә килүе ихтимал.

Деривациясе дә бар: **борнайлык; борнайлан-у.**

**БОРНА-У** «вылупиться; выходить из яйца» < *борын-на-у* < *борынла-у* «борынын чыгару». К. **Борын I.**

**БОРСАЛАН-У, порсалан-у** (ЗДС: 129, 531) «сильно беспокоиться; переворачиваться в бессоннице с боку на бок». Чаг. диал. **борсала-у** ~ себ. (ЗДС: 543) **пуса-у** «борчу» һәм **пошалан-у** (к.) ~ себ. **пусалан-у** «борсалану». Монда синонимик аттракция – тамырлары төрле, ләкин мәгънәләре вә яңгырашлары охшаш булган сүзләрнең үзара якынаюы күзәтелә. Чаг. ш. ук **борлык-у, боргы-у.**

**БОРТАК: бортак авыз** «похабный, выражающийся матом (преимущественно о женщине)», диал. (ТТДС I: 92) «экономный (?)», себ. (Тумашева 1992: 47, 176) **буртаҡ, портаҡ** «неопрятный; расточительный», **порсым-портаҡ** «неряшливый» ~ нуг., ком., кырг. *буртаҡ* «тупас сүзле, әшәке телле» ~ калм. *burtag* «пычрак, әшәке», алт. *пыртак* «пычрак; явыз рух» (*пырча хан* «әшәкелек рухы»), хак. *пуртах, пыртах* «болганчылык, былчырак, пычрак», тув. *быртак* «лайла; чүплек» ~ монг., бур. *буртах*, яз. монг. (Поппе 1938: 125) *burtak* – чыгт. *arıqsız* «арусыз», иске монг. (Владимирцов: 125) *bortun, börtün* «түгенте, пычрак су» һ.б. ~ эвенк. (ССТМЯ I: 114) *буртак* «менструаль кан», орок. *боротчи-* «пычрату», көнч. төрки (Zenker: 215) *burtaq* «пычранты; каткан; каткан пычрак», чаг. ш. ук чыгт. (Радлов IV: 1830–1831) *буртаҡ* «бик тигезсез җир, керентеле-чыгынтылы рельеф», төр. *burtak* «бик ташлы (җир)», уйг. *пордаҡ* «чунтай, күкәй капчыгы», үзб. *муртаҡ* «яралгы» – ясалышына караганда *бурт-аҡ,* ягъни *бурт* тамырыннан, чаг. чыгт., госм. (Радлов, Op. cit.) *бурт-* «җыерчыклану», (Zenker, Op. cit.) *burt* «җыерчык, җыерчыкка җыелган кер», чаг. нуг. *буртай-* «чыраен сыту», себ. (Тумашева 1992: 179) *пурт-* «искерү (бөршәю?)».

Китерелгән мисаллардан күренгәнчә, тат. сүзлекләрендә (ТТАС I: 179; ТТДС I: 92) *бортак* «хәстәрле, сак тота белүче» дию бөтенләй дөрес түгел – ул очраклы чыганактан алынган, контекстны дөрес аңламаудан килеп чыккан.

Мар. (Упымарий: 168) *пуртак* «артель» (?), (Саваткова: 127) *пурлак* «бурлак; пычрак битле» сүзләренең *бортаҡ* сүзенә багланышы ачык түгел.

**БОРТАС** «буртас (название древнего племени в Серднем Поволжье, буртасами с XVII века называли и татар-мишарей, “посопных татар”)». *Бортас кебек* «бик таза, бәдәнле» кеше; *борыны бортас, карыны картас* дигән табышмак та бар. Бортаслар тур. күп язылган, иң этрафлы мәкалә: Попов А.И. Буртасы // Названия народов СССР. Л., 1973: 111–121. Этимологиясе ачык түгел. Гомумән, бортаслар мордваларга якын булган дип уйлыйлар.

**Бортас** дигән елга (Иделнең кушылдыгы) да булган (к. История татар I: 475); Шәрыктә иң яхшы төлке тиресе *буртаси* дип аталган. Болгар белән бортас бертуганнар дигән легенда да бар. К. Давлетшин 2004: 98. Шуннан чыгып, Түбән Идел буе мишәрләре бортас токымыннан дигән фикер әйтелгәли.

**БОР-У,** себ. **пор-у** «повёртывать, повернуть; выжимать; отклонять; крутить» ~ ком., к.-балк. *бур-* id. Бүтән кыпч., ш. ук уйг. телләрендә боларга тәңгәл ике сүз бар: *бур-* «бору, әйләндерү» һәм *бура-* «борып кертү (чыгару)»; **бора-у** фигыле тат. сөйләшләрендә дә бар (һәм шуннан к. **Бора**у), ләкин әд. телнең (бу очракта тискәре) тәэсире нәтиҗәсендә әлеге мәгънә дифференциациясе юкка чыгарылган.

**Бор-** < *бур-* (алт. *пур-*, чув. *пӑр-*) сүзе гом. төрки, гом. монг., гом. тунг.-маньч. характерда; төрки, монг. даирәсеннән тыш, бүтән тел төркемнәрендә дә очрый (к. рус. *бур*).

**Бора-** < *бура-* нигезе бор. **бур* «борыла, бөтерелә торган нәрсә» (исем) сүзеннән ясалган, чаг. уйг. *буру-* ~ *буры-* «бору, бөтерү» һ.б., к. ЭСТЯ II: 264–267; Федотов I: 398.

**Бор-** бик продуктив нигез: **боргыч, борык** «борып ясалган, борылган» (*дүрт торык, ике борык* – тәкә яки кучкар тур. табышмак); **борым** (Остроумов 1892: 60) «җеп бавы, киләп»; **борыл-у, борыш-у, бордыр-у.** К. **Борам, Борау, Боргы, Борыт, Бөр-ү, Бурлак.**

**БОРХАН, борған** (Н. Исәнбәт) «языческий идол, икона» ~ алт., хак. *буркан, пурҡан* «Будда хан» (кыт. **bur* < *but* < санск. *Buddha*); икенче төрлесе – бор. төрки (ДТС: 127, төрле чыганаклардан) *burxan* «пәйгамбәр; будда; икона» < бор. кыт. *bvyr* «будда, Будда» сүзеннән дип аңлатыла, к. ш. ук

тув. *бурган* ~ монг. *бурхан* > эвенк. (ССТМЯ I: 113) *буркаан* «тәңре; борхан» һ.б. (к. Аникин: 146, шунда бай әдәбият күрсәтелә).

**Борхан** сүзен гар. теленнән кергән *Борһан* исеме белән бутарга ярамый.

**БОРХЫЛ-У, порхыл-у** «валить густо, клубами (о пыли и т.п.)» ← *борхы-*; к. **Борхыт-у.**

Дерив.: **борхылдык** – гөмбә төре.

**БОРХЫТ-У [бŏрхŏт-], порхыт-у** «вздымать (пыль и т.п.)» диал. **борхы-у, порхы-у,** башк. *борҡо-у* «бөркелеп тузан, төтен һ.б.ш. күтәрелү, чыгу» сүзенең йөкл. юн.; *борҡы-* фигыле гом. алт. сүзе: каз., к.-калп. *бурҡы-,* үзб. *бурқи-,* як. *бурғай-* ~ бор. монг. *burgi-* «борхылу» ~ эвенк. һ.б. *бурқи бурқу* «куе тузан, ишелеп яуган кар һ.б.ш.» (к. ССТМЯ I: 113); к. ш. ук нуг. *бурҡыра-*, кырг. *бурҡура-*, тув. *бургура-* «борхылу».

Тат. телендә бу сүздәге *-х-* авазы (*пырхылды-у* сүзендәге кебек үк) *порых, борых* – бөркелеп тузан, төтен чыгуга тәкълит сүзеннән килә (тәкълиди сүзләрдә гадәти булмаган авазлар да очрый). Сүзнең төп тамыры *бур, бур-бур,* тат. (ЗДС: 139, 537) *бурым, пор* – бөркелеп чыгуга тәкълит – монг. телләрендә ачык сакланган (ССТМЯ I: 111–112). Чаг. **Порак.**

**БОРЧА, бөрчә,** себ. (Тумашева 1992: 180) **пүрцә** «блоха» ~ башк. *бөрсә,* чув. *пăрҫа* id. ~ к.-балк., ком. *бюрче,* нуг. *бүрше, бүршә,* кар. *бурача,* төр. *pïre, pire,* бор. кыпч. (әл-Идрак) *bürä, bürcä* id. Ш. ук вакытта каз., к.-калп., чыгт. *бүргэ,* кырг. *бүргө*, уйг. *бүргә,* үзб. *бурга* ~ монг. *бүргэ* < бор. төрки (ДТС: 118, 133) *bürgä, bürkä* id. К. ш. ук каз. (ҚТДС: 74) *бŏрша* «борча».

Сүзнең тамыры *бүр* яисә *бүр-* (фигыле), веляр вариантлар икенчел (тат. *бŏрча,* ихтимал, болг. яисә чув. сөйләшләреннәндер, бу вариант әд. телгә очраклы рәвештә кергән: күпчелек сөйләшләрдә – *бөрчә*); *-чә//-ча* һәм *-кә, -гә* (монголча) кечерәйтү кушымчалары.

Шул да игътибарга лаек: гар. *бурғаҫа* «кандала», фар. шивәләрендә *бруса,* бор. фар. *brušā*, бор. һинди. *prusi,* грек. *bhlusa,* литв. *blusa* ~ рус. *блоха* «борча». ЭСТЯ II: 298–299; Федотов I: 402. Һинд.-евр. сүзләр тур. Фасмер I: 176–177; Kluge: 303.

Дерив.: **бөрчәле//борчалы; бөрчәлә-ү//борчала-у. Бөрчә** ~ *бүргә* варианты мәкальләрдә саклана: *бурыч бөрчә булып кергә, богра булып чыга* (*богра* «ата дөя»).

**БОРЧАК** «горох» < гом. кыпч. (ком., к.-балк., куман. һ.б.) *бурчаҡ* > нуг., каз., к.-калп. *буршаҡ,* төр. *burçak,* бор. төрки *burčaq* «борчак», уйг. *пурчаҡ* «борганак, рашкы; фасоль, борчак» ~ чув. *пăрҫа*, мар. *пурса, пурсак, пырса* «борчак», ш. ук. «кукуруз; бөре» < бор. төрки **боғурчағ* «түгәрәкчек» сүзеннән ~ гом. төрки, фин-угор., слав. һ.б. *богур* «йомры-түгәрәк нәрсә» тамырыннан, шуннан бик күп сүзләр килә, к. тат. диал. *боғыр, буғур,* удм. *бугор,* чув. *пăхăр* «йомгак», чаг. ш. ук **Бөкер, Бөре.**

Калм. *бурцык* «борчак» < кыпч., венг. *bórso* «борчак» < болг. Федотов I: 401; Гаффарова 2006: 80–82 (әдәбият китерелә).

**БОРЧА-У,** себ. **борца-у, перца-у** «бөреләнү» – «прорастать» (ди Тумашева 1992: 176) ~ төр. *burča-* «бөрелмәләнү; үрентеләнү». **Борчак** белән турыдан-туры багланышы юктыр.

**БОРЧЫ-У [бŏрчŏ-]** «беспокоить; огорчать», диал. «портить, измять, помять, сминать (одежду); шелушить (кедровые орехи)» ~ кырг. *бурчи-* «борчу», монг. *бурчи-* «тәпәрләү» һ.б. бор. төрки *бор-* < *бур-* ~ монг. *бури-* «бөрештерү, җыерчыклау; бозу, деформацияләү» фигыленең интенсивлык формасы (*бор-чы-*, чаг. *ар-чы-, күп-че, кыр-чы-* һ.б.ш.). К. **Бозу.**

Дерив.: **борчыл-у, борчыт-у.**

**БОРЫН I [бŏрŏн]** «нос; мыс» ~ башк. *мŏрŏн* < гом. төрки *бурун, мурун* < бор. **бургун* id. бор. төрки **бур- *буры-, бура-* «искәү (иснәү)» сүзеннән, к. монг. *бур-* «искәү», нан. *бури*, кор. *пури* «борын» (Рамстедт), кырг. *бура-*, уйг. диал. *пура-* «искәү; бурсу, исләнү» һ.б. *Бор//бур* тамырының исем һәм сыйфат мәгънәләре дә булган, к. монг. *бур, бор* «ис», шуннан тат. *бурсы-у* «исләнү, чери башлау».

**Борын <** *бурун* сүзе күп мәгънәләр алган һәм күп телләргә кергән, мәс., к. рус. *бурун* «суның кыяга бәрелгән төшендәге өермә» (к. Мурзаев 1984: 103–104). Рамазанова 2013: 51–55.

Дерив.: **борынлы, борынсыз; борынла-у > борна-у;** к. **Борындык.** Ихтимал, к. **Борнай.**

**БОРЫН II [бŏрŏн],** себ. (ЗДС: 57) **порон** «прежде (чем); прежний, сказочный (о временах)» – гом. кыпч. *бурун* (кайбер төрки телләрдә *мурун* «борын I», ә *бурун* «элек»). Гадәттә **борын I** сүзеннән дип аңлатыла (к. ЭСТЯ II: 271–274), к. диал. *борында* «элек» («борын > алгы як > элек» мәгънә

күчеше). Ләкин бор. китаби (уйг.) телдә *puran* < бор. төрки (ДТС: 398) *purani* < санск. *purana* «борынгы хәлләр; легенда; борынгы заманнар тур. хикәят, әкият» сүзеннән булырга мөмкин. Тат. телендә әкиятләрне *борын* (*борын-борын*) сүзеннән башлау шуңа ишарә итә. К. ш. ук себ. *порнаңкы,* (Рамазанова 2001: 7, 58) *борнагы* «борынгы» < **пурананғы?*

Дерив.: **борынгы; борында** һ.б. Диал. **борнач** «беренче бала», к. **Борна-у.**

**БОРЫНДЫК I [бŏрŏндык̆],** тат диал., башк. **морондок** «намордник; палочка, продеваемая через носовые перегородки быка, верблюда, к которой прикрепляется поводок» > чув. *пăрăнтăк* id. – **борын** сүзеннән (кайбер телчеләр *бор-у,* ягъни «борып йөртү» сүзеннән диләр, тик бу кирәксез фантазия). К. гом. кыпч. *бурындық, бурундуқ* (каз., кырг. *мурундуқ*), бор. төрки (ДТС: 126) *burunduq,* төр. *buruntuk,* төркм. (ТДГДС: 42) *бурунтуруқ,* аз. *бурунтулуғ,* төркм. *бурунтаг* ~ монг., бур. *бурунтаг* «борындык». Туй терминологиясендә (ТТДС II: 54; БТДҺ: 54) *борондык анай* (~ *инәй, җиңги,* сирәгрәк – *атай*), башк. *морондок инәй* (~ *әсәй, агай*) «кәләш менгән атның, дөянең һ.б. борындыгын-йөгәнен тотып баручы» булган, к. Будагов I: 278. Бор. төрки телләрдә (КБ, МК) *burunduq vezir* термины булган. Рус. *бурундук* «көймә тарттыру җайланмасы» тур. Аникин: 145–146. Чаг. ш. ук себ. (Баязитова 2001: 26–27, 98) *борнаучы* ~ *порнауцы* «туйда хәбәрче, арадашчы». ЭСТЯ III: 271–273 (тулы түгел). К. түбәндәгене.

**БОРЫНДЫК II [бŏрŏндык̆]** «бурундук (зверёк с пятью продольными полосами на спине)» > чув. *пăрăнтăк*, рус. *бурундук* id., ш. ук «люцерна (үсемлек)», к. Фасмер I: 248; Аникин: 146). Моңарчы бу сүзнең килеп чыгышы аңлатылмаган. Безнеңчә, буй-буй тасмалы бу сөйкемле кимерүче җәнлек *борындык апага (анага)* охшатылган: *борындык анай (инәй)* «печә тун», ягъни «буй-буй кишәрле тун» (андый тун явыз рухлардан саклый дип уйланылган) киеп йөргән, к. **Печә.**

Мар. *урымдо, урымтыш* «борындык(җәнлек)» сүзенең *борындык* сүзенә этимологик багланышы юк – ул мар. *ур-* «күмеп кую» фигыленнән килә (борындык кышкылык чикләвек запасларын җиргә күмеп куя).

**БОРЫС [бŏрŏс]** «брус» ~ чув. *пăрăс* һ.б. < рус. Федотов I: 400.

**БОРЫТ [бŏрŏт], борык** (*дүрт торык, ике борык* – кәҗә тур. табышмак) «жгут, притужальник» – **бор-у** фигыленнән; чаг. чув. *пăртуççи, пӳртӳççи* «борыт» < «борыт агачы». Чаг. кр.-тат. һ.б. *buruq* «бормалы». Федотов I: 402 (бөтенләй ялгыш).

**БОРЫЧ [бŏрŏч],** диал. **порыц** «перец» > чув. *пурăç*, мар. *бурысь, пурыс, бурыч,* удм. *пурус, пуръс* (Гордеев I: 246, Насибуллин: 134) < куман. *burč*, гом. кыпч. *бурч, буруч,* төр. *biruc*, уйг. *мурч* һ.б. (күп төрки телләрдә) – ахыр чиктә санск. *mariča* «борыч» сүзеннән (Абаев I: 282; Räsänen 1969: 345). Төрки сүзләр рус. *перец* сүзеннән түгел, сугд. теленнән алынганнар, к. сугд. *mrč* «борыч». Федотов I: 400.

**БОТ,** диал. **пот** «бедро»; диал. «нога» < гом. төрки *бут*, төркм., як. *бӯт* id. ~ тунг. *бōди* «бот; аяк». Чув. *пĕçĕ* «бот». Э.В. Севортян буенча, **бŏтсы* < **бŏтысы* сүзеннән, ә М. Рясянен (Räsänen 1969: 425) аны бөтенләй бүтән, фин-угор тамырыннан ди, к. удм. *пыд* «аяк», *пыдес* «тез». Чаг. ш. ук ягн. *pusa* «бот» (ЯТ: 57, 310). Федотов I: 424.

**БОТАК** «ветвь, сук» < гом. төрки *бутақ*, себ. тат., хак. һ.б.ш. *путақ, пудағ* < бор. төрки, чыгт. (Будагов I: 284) *буғдақ,* бор. төрки (ДТС: 129) *butïq* id. ← тат. диал. *бота-,* гом. кыпч. *бута-,* себ. тат. *пода-,* хак., алт. диал. һ.б. *пуда-* < **буғта-* «ботакларны кискәләп, кәүсәне арындыру», чаг. ш. ук бор. монг. (Поппе 1938: 126) *buta-* «ботак ботау», бур. *бута* «челпәрәмә», *бутала-* «ваклау, ботарлау». Тамыры бор. *богут* «буынтык, буын, буыннар» дип фаразларга мөмкин, ягъни *ботак* < *бутак* < *бугутак* ← *бугут-а* «буынлау, буынтыклар ясау һ.б.ш.». **Бутак** дип кайбер үсемлекләргә хас рәвештә (мәс., кыяклыларда) кәүсәнең бөҗраланып калынайган урыннан берничә тармак берьюлы чыккак төшне атаганнар булса кирәк: алтай шаманнарының дәрәҗәләре ботаклар буенча аталган, мин дүртенче *пудак* шаманы, ә ул җиденче *пудак* шаманы (димәк «югарырак тора») дигәннәр. Мухамедова 1973: 79.

**БОТАРЛА-У** «бүлгәләү, өзгәләү» *бота-* фигыленең интенсивлык формасы (чаг. *бөгү – бөгәрләү, йому – йомарлау*); чаг. бор. монг. *butara-* id., эвен. *бут-* «сындыру, яру», уд. *букта-* «яру, чатнату» һ.б. (күп сүзләр, к. ССТМЯ I: 116).

Шуларга охшаш сүзләрнең күп телләрдә очравы игътибарга лаек: гар. *бăтăра* «аергалау, ботарлау»,

лат. *putare* «агач ботау» (шуннан *ампутир-лау,* бор. ним. *poten* «ботау» һ.б.).

**БОТА-У** «обрубать ветви». К. **Ботак.**

**БОХАР** «бухарский», **бохари** «учившийся в Бухаре». **Бохар** сүзе тат. күп тезмәләрдә очрый: *бохар кынасы*, *бохар мәчесе, бохар миләше, бохар чапаны, бохар яулыгы* һ.б. Бохара шәһәре күп гасырлардан бирле мәдәни үзәк булган.

**БОЯР** < рус. *бояр* (берлек санда *боярин*) < бор. рус. *боляр (болярин)* Дунай болгарлары телендәге *бойла*, *bovληα* ~ бор. руник *bojla*, кыт. чыганакларында *пейло* ~ маньч. *bejle*, чжурчжень (черчет) яз. телендә *bogiljä* «би, кенәз» (чаг. ш. ук бор. рус. *быля* «дәрәҗәле түрә») һәм бор. төрки *er, ār* «ир, батыр» сүзләреннән гыйбарәт (*бойла, боййа* күп чыганакларда искә алына).

Безнеңчә, *бойла* бор. төрки *бой* < *бодги* < *борги* «кабилә» сүзеннән һәм «үзәк хөкүмәт (каган) каршында кабилә вәкиле» мәгънәсендә булган.

**Бояр** сүзе тур. әдәбият зур, к. Фасмер I: 203, 259; Менгес: 83–86; Бартикян: 67–77; Donuk: 9–10. К. **Баяр.**

**БӨГӘВЕЛ [бөгәwӗл]** тар. «агент; шпион» < чыгт. (Радлов IV: 158) «сарайдагы бер чин», көнч. төрки (уйг. диал., к. Zenker: 204) *bakawul*, *bukawul* «хөкемдарның ашын (агуламадылармы дип) татып карауучы» ~ үзб. *букавул,* кырг. диал. (Юнусалиев: 1971) *бөкөвүл* «туйда ашамлык-эчемлек бүлүче» >> рус. (Срезневский I: 47) *бегеол, бегеул* «агент», бор. төрки (ДТС: 131–132) *bük* «яшертен (сак), сер», *bük-* «иелеп, чүгәләп утыру» ~ яз. монг. *büggü-,* эвен. *буғун-* «посу, поскында утыру» (к. ССТМЯ I: 102) сүзеннән; чаг. ш. ук алт. диал. *бӧг-* «яшеренү», тув. *bük* «тар үзән, кул; ышык җир», бор. төрки (ДТС: 117) *bök* < бор. кыт. *pieg* «дивар; койма; Бөек Кытай дивары». Фасмер I: 142.

**БӨГӘҖӘ,** диал. (ТТДС I: 106) **бөгәрҗә, бөдәҗә, бөгелчә** «дужка; облучок, вязовая обойма косовища; деревянное кольцо для различных целей» ~ башк. (БТДҺ: 55) *бөгәзе, бөгәжә, бөгәзә, бөгәзәк, бөгәлйә,* кырг. *бөгөжү, мөгөжү* «агач богау, тышау», монг. *бөгж*, бор. монг. *bögeǯi* «дуга» – бор. *бүгәр//бүгәл* «бөгел, бөгелгән нәрсә» сүзеннән, әлбәттә, чаг. чув. *пĕкече* «бөгәҗә», *пĕке* ~ мар. *пӱгӧ* «дуга». К. **Бөгел, Бөк-ү.** «Бөгәҗә» мәгъ. диал. (ЗДС: 127) **бого** һәм **богача** сүзләре дә бар. Болар икенче тамырдан.

**БӨГӘЛЧӘН,** диал. (ДС I: 42) **бөгәчә, бөгәләк, бөгелчән** «самка овода; овод лошадиный» ~ башк. (БТДҺ: 55–56) *бөбәләк, бөгөлсөн, бөгәлә, бөгәләк,* каз. *бүгөлүк, бүңөлүк, бүгөзөк,* кырг. *бөгөнөк*, алт. *пӧкӧнӧк*, госм. *бүкелик, бүйәлик, бүвалик*, үзб. *бүкалаг* id., як. *бүгүлэх* «шөпшә»; *бүгүҗэх, бүгүйэх* «кигәвен» ~ монг. *бүкүнэ, бөкүгүнэ* «черки»; к. ш. ук нуг., к.-балк. *бүклесин* «кигәвен; солитёр (< кигәвен корты)». Башк. *бөгөлсөн* һәм нуг., к.-балк. мисаллары бу сүзнең монг. телләреннән кергәнлеген күрсәтә: монг. *бүкүнэсүн* «һәртөрле кигәвен-шөпшәләр», сүзнең тамыры **бүңкә-* «кадау», чаг. бор. төрки (ДТС: 116–117) *bögdä, böktä* «хәнҗәр», чув. *пăван* «кигәвен» (чаг. *бөгән*) венг. *bögöly* «бөгәлчән, кигәвен». Gombocz: 38 (тагын мисаллар китерелә). Räsänen 1969: 91; ЭСТЯ II: 212–213 (Э.В. Севортян бор. төрки *bög* «чаян, бөя» сүзе белән чагыштыра); Федотов I: 394. Бу сүзләрдә *бүк-* «бөгү» һәм *бүк-* «кадау, тешләү» контаминацияләнә.

**БӨГӘН, бөргән, бөйөргән** «жерушник, жеруха (растение с крючками)», (ТТДС I: 42) «шиповник» ~ башк. (БТДҺ: 57) *бөрәк, бөргәнәк, бөрәнәк* «әрекмән» һ.б. Ихтимал, **бөгәлчән** < **бөгәлсен* белән тамырдаштыр. Гомумән, ачык түгел.

**БӨГӘРЛӘ-Ү** «сгибать, согнуть, мять, смять, перекручивать» – *бөк-ү (бөгү)* сүзенең интенсивлык формасы (чаг. *ботау – ботарлау, йому – йомарлау*); чаг. чув. *пĕкĕрĕл-* «бөгәрләү», мар. *пĕкĕрт- ~ пӱкырт-* «бөгү».

**БӨГӘТ, бүгәт** (ЗДС: 141) «пруд» ~ бор. чыгт., төркм. (Мухамедова: 78) *бөгет, бөвет* «бөя, арыкны, сулыкның күтәрелеп өелгән кырые (басу арыктан түбән булганда шулай итәләр)», төр. *büget* «бөяләп торган су», чыгт. (Будагов I: 286) *букäт, букäт* «бөя, буа» һ.б. чыгт. *бүкә-,* төр. *büge-* һ.б. «бөяү, буу». Чаг. **Бөя, Бөят, Бөя-ү.**

Бөгәтләр сугарулы җирләрдә генә актуаль булган.

**БӨГЕЛ [бөгөл]** «загиб, загогулина» – *бөк-ү (бөгү)* сүзеннән, чаг. башк. *бөгәл* «елга борылмасы», тув. *боол* id.

**БӨДӘ-Ү** «давать соразмерно чему-либо, давать порциями» < бор. чыгт. *булдэ-ү* id., ш. ук «сәмән билгеләү», к. **Бүлҗәл.**

**БӨДРӘ** «кудрявый» (*бөдеркә* «завив волос») ~ чув. *пĕтре,* удм. *бӯдрäй* (Насибуллин: 108–121) ~ венг. *bodras*, эвен. *бодурука* «бөдрә», к. ш. ук як. *буҗур*, монг. *божур* «бөдрә» < бор. монг. *buǯigir, *budigir* «бөдрә; бөтеркәле», төркм., нуг., к.-калп. *бөйрә,* каз. *буйра* «бөдрә» монг. **буҗрә* вариантыннан булса кирәк. К. **Божыр.**

Тат. диал. *көдрә* ~ хак. *кудур* «бөдрә; ялбыр» варианты бүтән тамырдан, әмма *бөдрә* ~ *бүдрәгә* охшатылып формалашкан булса кирәк. Рус. *кудря, кудерь* «бөдрә; бөдеркә» *кудель* «көнҗәлә» сүзе белән чагыштырыла (Фасмер II: 400).

**БӨЕ [бөйө]** «(земляной) паук; тарантул» ~ башк. *бөйө,* госм. *бүйә, бөг,* кырг. *бөйү, бөй, бөө,* төркм. (Мухамедова 1973: 73) *мөөй, бөй,* каз. (Будагов I: 306) *бийе,* хива. *мәү,* ком. *мия*, бор. төрки (ДТС: 116) *böj, bi, bög* id.

**БӨЕК [бөйөк]** «великий» < госм. *бүйүк* id. сүзеннән, гом. кыпч. *бийик,* тув. *бедик*, хак. *pözik* һ.б. бор. *bedük*, чыгт. *бәдук* «үскән» *bed-, beδ-* «үсү, зураю; биегәю» > угыз. *бүйү-* id. сүзеннән. ЭСТЯ VII: 107. К. **Биек.**

**БӨЕР [бөйөр]** «почки; таз» < гом. кыпч., госм. *бүйүр, бөйүр* ~ тат. диал. (миш.) *бĕвĕр, бүвĕр* ~ чув. *пĕвĕр,* угыз. *бөвүр* id., һәр ике линия бор. төрки (ДТС: 111) *бөгүр (bögür)* сүзенә тоташа, к. ш. ук бор. монг. *bögere* id.

Бу нигездән ясалган тат. *бөйрәк//бүрәк* ~ төр. *böyürek*, *bübrek, bövrek*, каз., төркм. һ.б. *бөрәк,* к.-балк. *бүрек*, шор. *пүгрүк*, хак. *пүгүряк* «бөер, хайван бөере» бөернең үзеннән киңрәк таралган. Бор. *бүйүрәг* вариантына рус *пирог* сүзе тап килә (бор. болг. яисә бәҗ. теленнән) – асылда ул «бөерәккә охшаган камырдан (һәм берәр эчлектән) ясалган ашамлык» була, к. к.-балк. *бөрек* «бөер, бөйрәк; бөккән», калм. *бөөрг* «вак пәрәмәч».

**Бөйөр** < *bögür* йомры-түгәрәк нәрсәләрне белдерә торган ономопоэтик *bogur//bugor* нигезеннән, *bög//boγ* тамырыннан (шуның палаталь вариантыннан), к. **Бөкер, Бөре I, Бүксә** һ.б. (бик күп сүзләр) килә. ЭСТЯ II: 205–208, 219; Аникин: 135.

**БӨЕ-Ү [бөйө-],** себ. **пөйө-ү, пөйөлә-ү** «колдовать, заколдовать, гипнотизировать» ~ кр.-тат., төр. *büyü, büyücü* «сихер; сихерче» (к. Dobr. I: 378–379). Венг. *bü* «сихер» сүзен Гомбоц (Gombocz: 43) шаман биюе – «бөюе» белән чагыштыра. Ш. ук **Бөя, Бөе** (к.) сүзен дә «корбанын гипнозлаучы» дигәннән дип уйлыйлар. Монда тикшеренүләргә урын киң.

**БӨҖӘК** «насекомое; козявка», иск. «пресмыкающееся» (к. Троянский I: 178), тат. диал. **мөҗәк** «бөҗәк; бүре; явыз рух» (к. Радлов IV: 2134) ~ кр.-тат. *бӧжек, бӧджек,* төркм. *мөр-мөҗек, мөҗеҗик* «бөҗәк», нуг. *бӧжек* «коңгыз», кырг. *бӧжӧк* «куян баласы», як. *бүгүҗәк* «бөкер; бөҗәк, бөгәләк» (к. Пекарский I: 579), каз. *бүгежек (бүгәҗәк)* «бөкчәйгән, бөкре», төр. *böcek* «кәлтә; таракан, бет һ.б. паразитлар; кысла», үзб. диал. *бӧдҗәк, бүҗәк* «кәлтәнең бер төре» (ЎХШЛ: 55), чыгт. *мӧчек* «бүре» һ.б. < бор. төрки (МК III: 206) *büǯgäk* «бөҗәк». Бор. төрки формадан чыгып, ниндидер *büǯ-* фигыленнән дип уйларга мөмкин, чаг. удм. *бӧчы* «коңгыз» ~ төр. *böcü* «корт, бөҗәк», ләкин *büǯgäk* < *bügcäk* булырга да мөмкин, ул чакта сүзнең тамыры *bög* «бөе» (к. **Бөе**). Чаг. ш. ук **Бөгәлчән.** ЭСТЯ VII: 76.

**БӨЙРӘК,** диал. (ЗДС: 131) **бөйөрәк** «почка животных» ~ кр.-тат. *büyrek, büyürek* id., каз. *бүйрек* «сугымнан бирелгән хәер – гадәттә бөйрәк» һ.б. (гом. кыпч. сүзе бугай) < бор. төрки *bögüräk* ← (ДТС: 116) *bögür* «бөер; янтык».

Бу сүзнең күп вариантлары булуы күзгә ташлана, к. төр. *böbrek, bövrek, bövürek,* тат. диал. (ЗДС: 131, 538) **бөйән, бөйәнә, пөйдер** «бөйрәк» (бу сүзләр бүтән төрки телләрдә күренмәде). Күрәсең, сүзнең тамыры **бөй < *бүг < bög?* К. **Бөер, Пәрәмәч, Пирук.**

**БӨК, бөге** «выпуклая сторона альчика» – гом. кыпч. *бук, бӧк, бӱгӧ* id. ш. ук «калкулык» > удм. *пог, пуг,* рус. *бук* ~ к.-калп. *пүкке*, тув. *бүге,* калм. *бук, бӧкӧ* «бөк», үзб. *бук, бүк* «бөкер, бөкре», кырг. *бүк* «бөгелеш урыны» ~ эвенк. һ.б. *буку, бэкэ, боко, мүкэ* «бөкер» (ССТМЯ I: 104), бор. пермь *püg* «түгәрәк, йомры нәрсә; бөк» (КЭСК: 232), осет. *buk* «бөкре» (Абаев I: 269), чаг. ш. ук инг. *buckle* «бөгелеш», индонез. *bokong* «шеш», *boktja* «букчай», *buku* «агач орысы», *bukit* «бәләкәй тау» һ.б. халыкара тәкълиди тамырдан.

К. ш. ук алт. *пүк*, хак. *пүг,* як. *бүк* «елга бөгелеше, бөгелеш»; тат. *бөклә-ү* < гом. кыпч. *бүклә-* фигыленең тамыры да шул ук мәгънәдә. **Бөк** исем тамырының үзеннән тат. телендә тагын *бөкәч, бөктәр, бөкчәй-, бөкәй-ү* ~ *мүкәй-ү, бүксә* сүзләре ясалган. *Бөк-ер* ~ *бөгер* нигезе бигрәк продуктив, к. **Бөер, Бөкәч, Бөкрән, Бөкре, Бөре, Бөрлегән, Бәрәңге** һ.б.ш.

**Бөк** исем тамырыннан бүтән төрки телләрдә тагын бик күп сүзләр ясала. **Бөк** исеменең фигыль коррелянты **бөк-ү (бөгү)** булса кирәк.

**БӨКӘ, бөгә,** себ. (ЗДС: 538) **пөгә** «мудрый герой, сила которого скорее в уме, чем в физических возможностях» < бор. төрки (ДТС: 116–117) *bögä, bögü, bökä* «мәҗүси акылдар; герой, баһадир» > ком. *бүгү,* уйг. *пөгү,* монг. *büge* һ.б. «шаман». Чаг. бор. төрки *bögün-* «тирән аңлау», *bögüš* «аңлам» ← **bög-* «уйлау»?

**БӨКӘЙ, бөки, бүкәй, бүки** (ТТДС I: 91, 108; ТТДС II: 72; БТДҺ: 56) «бука, страшилище; старик с лохматой седой головой» ~ рус. (Фасмер I: 235–236) *бука* «староста, начальник; бөкәй» (төрки телләрдәнме? Фасмер этимологиясен ачык калдыра). Төр. *böke* «көрәшче» **бөкә**дәнме икән, **бөкәй**дәнме икән? Гомумән, болар ише сүзләр күп күрше телләрдә очрый, мәс., төркм. *бөкәчи* «сикерүче», *бөк-* [*bök-*] «сикерү, ыргу». Атаклы инглиз язучысы Д. Дефоның «Гулливер сәяхәтләре» турындагы популяр фантастик хикәятендә лилипутлар дәүләтендә баш министр итеп кем биегрәк сикерә, шуны сайлыйлар. Д. Дефо бу мотивны Үзәк Азиядәге **бөкәләр** тур. хәбәрләр нигезендә әсәренә керткән бугай. Чаг: ш. ук *bü, госм. büйі* «сихер», уйг. *pögü,* ком. *бүгү,* монг. *büge* «шаман». Gombocz: 43. К. **Бүкәй.**

Дерив.: **бөкәйбаш** «тузганак».

**БӨКӘЧ** «плотного сложения (о лошади)» ~ к. диал. (ЗДС: 132) **бөкөс, бөкөч** «тәбәнәк юан», башк. (БҺҺ II: 54) *бөкәс* «бөкре» < *бөк-кәч.* Чаг. ш. ук *бөгөс* «юантык ныклы» һ.б.ш. *бөк//бүк* тамырыннан. К. **Бөкчәй-ү.**

**БӨКЕ [бөкө]** «пробка» ~ чув. *пăкă,* алт. *пӧк, бӧк,* хак. *пӧк* «бөке, төрмә (!)», як. *бүӧ,* чыгт. *бӧгүт,* монг. *бӧг* «бөке, тыгынчык» ~ госм. *букү, бүккү* «чөмәк, бүрәнкә, конус, очлы кәгазь бүрек» (к. Радлов IV: 1298, 1876–1877) һ.б. бор. тат. *бӧк-, бүк-* «каплау, тыгынлау» сүзеннән: **бөк-ке** < *бүк-кү.* К. **Бөят.** Федотов I: 395.

**БӨКЕР [бөкөр]** «горб (у человека)», **бөкре,** диал. **бөкрәч** «горбатый; сутулый» ~ мар. *пӱкыр, мугыр, пӱгыр,* чув. диал. *пĕкĕр,* удм. *вогыр* < гом. кыпч. *букир, букүр* «бөкер, бөкре» (бу мәгънәләр тат. телендә дә бутала) ~ як. *букүр* id. *бөк-, бүк-* тамырыннан, к. **Бөк.**

**БӨККӘН, бөккен, бөкке, бөге, бөгеш, бөкмәч, бөкрәч, бөкери, бүккәл** (ЗДС: 131–132, 141) һ.б. (егермеләп фономорфологик вариант) «пирог, виды пирога; вареники; клёцки – все завернутые виды с содержимым» ← *бөк-* (к. **Бөк-ү**). Бүтән төрки сүзлекләрдә сирәк бирелә торган сүзләр. К. Хайрутдинова 1993 (бу авторның аш-су бабында язылган күпсанлы хезмәтләрендә яктыртыла).

**БӨКЛӘ-Ү** «сгибать, сложить» ← **бөк** (к.)

**БӨКРЕ [бөкрө]** «горбатый» к. **Бөкре.**

**БӨКТӘР** «узел; заплечный мешок» ~ каз., к.-калп. *бөктер,* үзб., кырг. диал. *бүктәр, буктар,* кырг. *бӧктӧр* «хәнҗәр; ияргә арттан беркетелгән йөк» < монг. *бӧктүр, бӧктәр* id. *бөк- ~ бүк-* «түгәрәк өем һ.б.ш.» тамырыннан (*-тәр//-дәр* монг. кушымчасы); каз., к.-калп. *бӧктер-*, хак. *пүктер-* «бөктәрләү» фигыле дә бар. К. **Бөк, Бөктә-ү.**

Монг. *бӧктүр* сүзенең «бөктәрле, бөктәр» мәгънәсендәге *бӧгтүргэ* дериваты да төрки телләргә киң таралган: каз., к.-калп. *бӧктерги*, төркм. *бӧкдерги*, кырг. *бӧктӧргӧ*, як. *бӧгтүргӓ* «бөктәрле; бөкерле; мүктәрге», к. **Мүктәрге.**

**БӨКТӘ-Ү,** (Тумашева 1992: 177) **пөктә-ү** «собирать в кучу, в узелок» ~ каз. *бүктә-*, алт. *пүкте-, бүкте-*, *бӧктӧ-* id. К. «Маадай-Кара» эпосында (авазлары татарчалаштырылды) *Алын итәк бу җәелгән, Атның башын бу бөктәгән, Киен итәк бу чөелгән, Ат саурысын бу бөктәгән.* Каз. (ҚТДС: 76) *бүктеме* «акча янчыгы, җәнчек». К. югарыдагыны.

**БӨК-Ү I (бөгү, бөкте)** «гнуть, наклонять» ~ чув. *пĕк- [пөк], пүк-* < гом. кыпч., уйг., чыгт. *бүк-*, алт., хак., тув. диал. *пүк-* id. тат. *бөк* < гом. кыпч. *бүк* «ашыкның калку ягы; кабарынкылык, түмгәк һ.б.ш.» сүзенең фигыль коррелянты, ономопоэтик тамырдан, чаг. рус. *бугор*, ним. *bücken* «бөгү», индонез. *buku* «оры, кабарынкылык» һ.б.

**Бөк < бүк** тамырыннан төрки телләрдә бик күп сүзләр ясалган, к. **бөгел-ү, бөген-ү, бөгеш-ү, бөктер-ү** – гади юн. формалары (алар үзләре дә продуктив нигезләр), аннары **бөгәҗә, бөгәк, бөгәл, бөгәләк, бөгәлчән, бөгәр** «тез», **бөгәрлә-ү, бөгел, бөгел-бөгел, бөгелмә, бөгелчә, бөгелчән, бөгелеш, бөгем, бөгеш** (күп мәгъ. сүз), **бөгештер-ү, бөкем ~ бөгем, бөккел, бөккен, бөккеч, бөкмә, бөкмәрлә-ү, бөкмәч, бөктә-ү, бөктәл, бөктәр**

һ.б. Бүтән төрки телләрдә дә шул ук продуктивлык бардыр, әмма сүзлекләрдә тулысынча чагылдырылмый.

Югарыда һәм түбәндәрәк мәзкүр сүзләрнең кайберләренә аерым тукталдык.

**БӨК-Ү II (бөгеп салу)** «есть много, наедаться», чаг. бор. төрки (ДТС: 417, 432) *bük-, bök-* «ләззәтләнү, ләззәт алу».

**БӨКЧӘЙ-Ү, бөкшәй-ү** «сутулиться; согнуться; нагибаться» ~ башк. *бөксәй-ү* < *бөкчә* «бөкре, бөкреле; бөк сыман» (к. башк. – БТДһ: 56 – *бөксә* «бөкре») сүзеннән, кырг. *бөкчөй-, бокчүй-*, к.-калп. *бүкший-,* як. *бөкчөй-* ~ яз. монг. *bögtüi-*, бур. *бөхтэй-*, эвен. *бөкчир-* һ.б. (охшаш сүзләр бик күп, к. ССТМЯ I: 104). *Бөкчә* сүзе, ихтимал, бор. **бүкчәг* сүзенәндер, к. алт. *бөкчөк,* (Баскаков 1972: 243) *пүкчүк, пүкчик* «бөкре» һ.б. Сүзнең тамыры – *bök//бүк*, к. **Бөк, Мүкәй.** Пекарский: 579.

**БӨЛГЕН [бөлгөн]** «разорённый; разорение, разгром» ← *бөл-* (к. **Бөл-ү**). Бүтән төрки телләрдә бу сүзнең бүтәнчәрәк мәгъ. бар: каз. *бүлгён,* к.-калп. *бүлгин*, кырг. *бүлгүн* «бунт; бола; ызгыш-талаш». Бу хәл *бөлгөн* < *бүлгүн* сүзен бор. төрки (ДТС: 123) *bulım* > башк. (Катаринский) *бүлүн* «әсир, плен» ~ эвен. *булун* «дошман», эвенк. *булэән* «дошман, сугыш; ызгыш» (к. ССТМЯ I: 109–110) сүзләре белән чагыштырырга нигез бирә.

**БӨЛДЕРКӘ [бөлдөркә]** «дрёма (петля для удержания кнутовища в руке), темляк» ~ башк. *мүлдергә* id. ~ чув. (Сергеев 1971: 97) *пĕтĕре* «күн янчык», *пĕтре* «чыбыркы футляры; бөлдеркә», мар. *пĕлдĕрӓ*, *пылдыра* «бөлдеркә», (< болг. **бөлдөрһә*) < гом. кыпч. *бүлдиргә, бүлдүргө*, чыгт., каз. (Будагов I: 289) *бөлдүркэ* (һ.б., гарәп хәрефләре белән язылышта بولدورگه) < монг. диал. *бэгүлдүрүгэ* «билбау, җыеп бәйләгеч шнур, бәйләвеч» (*дүрүгэ* = төрки *дерек//дырык* – һәртөрле тагылма атамаларын ясагыч аффикс). Чаг. **Бөгел.**

Тат. диал. (С. Кудаш), башк. *бөлдермә* > чув. *пĕлтĕрме* «бөлдеркә» халык этимологиясенчә ясалган булса кирәк. Räsänen 1969: 92 (материалы бик аз).

**БӨЛДЕРЧЕН [бөлдөрчӗн],** себ. (ЗДС: 142) **бүлдүрцүн** «вид перепёлки» ~ гом. төрки (ЭСТЯ II: 305–306) *былдырчин, билдирчин* һ.б. id. монг. телләреннән алынган (*-чин* аффиксы!). Чаг. себ. тат. (Будагов I: 266) *бүлтерәмәк, бултырамак* «лыгырдау, күп сөйләү». Рус. диал. (Аникин: 140) *булдюрюк, билдирюк,* каз., кырг. *булдурук* һ.б. «божыр төре».

**БӨЛ-Ү** «разоряться; попасть в беду» ~ чув. *пĕл-* id. < гом. кыпч. *бүл-* id. – бүтән төрки телләрдә теркәлмәгән, тик бор. төрки (ДТС: 132) *bül* «бозылган, җимерелгән, тузгылган» сүзе *бүл-* фигыленең исем коррелянты дияргә ярый. Räsänen 1969: 92; Федотов I: 419 (мәгълүматлары бик аз).

Кыпч. телләрендә *бүл-* продуктив нигез, к. тат. **бөлен-ү; бөлдер-ү;** диал. (БТДһ: 57; ЗДС: 132) **бөлөк** «хәвефле; йончыган» ~ каз. *бүлĕк* «бунт; каза», каз., к.-калп. *бүлин-*, кырг. *бүлүүн-* «бозылу; һәлак булу» һ.б. К. **Бөлген.**

**БӨРЕ I [бөрө],** диал. (Тумашева 1992: 177) **пөр, пөре, пөрчәк** «почка растений» ~ башк. [БТДһ: 57] *бөр, бөрө* < гом. кыпч. *бүр*, алт., хак. *бүр, пүр* < бор. төрки (ДТС: 132) *bür* «бөре». Шулай итеп, тат., башк. **бөрө** гом. төрки фонда үзгәлекле яңгыраш: ул я *бөр-е* (тартым формасы) дигәннән, я бор. **бүрү-г* дигәннән, к. чыгт., госм. (Радлов IV: 1887–1889) *бүрү-* «бөре җибәрү», шуннан кр.-тат. *бүрүм*, *бүрүмчәк* «бөре»; каз. *бүрик, бүрийк* «бөре, җиләк», тув. *бүрү, буру* (?) «бөре, яшь яфрак». К. ш. ук алт. *бөрөк, бөрчөк* «бөре; бөер». Гомумән, *бөр* < *бүр* < **бөгүр* булса кирәк, к. **Бөйрәк, Бөк, Бөрлегән.** Федотов I: 461.

**БӨРЕ II [бөрө],** диал. (ДС I: 42; Тумашева 1992: 45, 177) **пөр, пөре** «молодое дерево, лоза; ветка (для плетения плетня, морды и т.п. изделий)». **Бөре I** белән баглы булса кирәк.

**БӨРЕҖ [бөрөж]** «созвездие и знак зодиака» ~ төр. *bürç, burç* id., ш. ук «бастион, кальга, кирмән» < гар. *бурҗ* (күп. форм. *бурӯҗ*, к. Будагов I: 251) id. < бор. герм. *burg* «кальга, кирмән» (гар. телендә *г* > *җ*).

Кальгаларны герман халыклары унике бастионлы (почмак башнялы) итеп сала торган булганнар, Россиядә дә нимес инженерлары, мәс., Оренбург кальгасын унике почмаклы итеп салганнар. Герман кабиләләре III–IV гг. Урта диңгез ярларында күп кенә ныгытмалар ясаганнар.

**БӨРЕШ [бөрөш]** «пешня (инструмент для пробивания льда)», «инструмент для очистки улья» ~ башк. *бөрөç, бөрөҙ,* чув. *пүрүш*, удм. *причь, пырич,* коми. *пырижҗ* «бөреш, кыргыч» ← *пир* «кылыч, сөңге» (КЭСК: 236). Гомумән, фин-угор сүзе

булса кирәк. Әлбәттә, *бөреш* «бөрү эше» сүзенә катнашы юк.

**БӨРЕШ-Ү [бөрөш-]** «съёживаться, морщиться» ~ гом. кыпч. *бүрүш-* id. *бөр-* < *бүр-* «бөрү» сүзеннән (урт. юн. формасыннан икенчел мәгъ.).

Дерив.: **бөрештер-ү** (бу сүзне *бөр-ү* фигыленең «саксызрак, ара-тирә эш итү» мәгънәсендәге *бөр-ештер-ү* формасыннан дип тә аңлап була), диал. **бөрешкәк** (*бөрешкәк гөмбә*).

**БӨРҖӘН** «бурзян (бурзяне)» – название башкирского племени < бор. монг. *börǯigin* < *börǯigün* кабилә атамасы (шуннан Чыңгыз хан чыккан), к. Гарипов: 39; Исхаков, Измайлов: 79. Монг. *börǯigün* сүзе исә бор. монг. *börte ǯiguna* «бүртә бүре, күк бүре» – хәз. монг. *Бөртe чино* – төрле әфсанәләр герое (к. МНМ I: 180). Башкорт фольклорында әйтелгәнчә, бөрҗәннәр аерым бер халык булган һәм соңрак кына башкортлар белән *бер йән* (бер җан) булып киткәннәр, имеш.

*Бөржән* сүзенең тат. яңгырашыннан рус. *бурзян* һәм башк. *бөрйән* яңгырашлары килә (тарихтагы барча чыганакларда бу сүз *-жҫ-, -дж-* белән языла). Бу хәл бөрҗәннәрнең татарларга элек-электән таныш булуы тур. сөйли. Алай гына да түгел, чув. фольклорындагы *Пурçăхан улăп* (*Пурҗыһан алып*) һәм *Пурçăхан иле* сүзләре (к. Улăп халлапĕсем. Чебоксары, 1993) сүзләре бөрҗәннәрнең Урта Идел регионында – Чувашстан тирәләрендә яшәгәнлеген күрсәтә (к. безнең мәкалә: «Бөрҗән һәм угызлар» // Татарстан, № 11–12, 1995: 80–82). Чуваш дастанында *пурҗыһан*нар Амму (Аму-Дәрья) буйларында яшиләр, дөя асрыйлар... Бу билгеләр дә бөрҗәннәргә туры килә: аларның берзаман Урта Азиядә яшәгәнлеге ачык билгеле. Чув. *пурҗыһан* << монг. *боржигун* күчеше фонетик закончалыкларга бик бап килә. К. ш. ук чыгт. (Әбүлгази) *бурчыгыйн* «бөрҗән». Бөрҗәннәрне тагы мәшһүр *бурчә угыллары* куман кабиләсе (рус. *бурчевич*лар) һәм болгарларга багланышта телгә алына торган *бурҗан* кабиләсе белән чагыштыралар. Ләкин монда тарихи һәм лингвистик (фонетик) кыенлыклар туа. З. Вәлиди (Velidi: 67) буенча, монг. *borčegin* асылда төрки *Bori tegin* «бүре принц» дигән кеше исеменнән, бу кеше кыят (кайлар) кабиләсеннән.

**БӨРКӘ-Ү,** себ. (Тумашева 1992: 45, 48, 177) **бүргә-ү, пүркә-ү** «закрывать со всех сторон, завёртывать; пеленать» ~ чув. *пĕрке-, пүрке-* < гом. кыпч., уйг. *бүркә-, бүркә-*, кырг. *бүркө-*, хак., алт. *пүрке-, пүркä-*, тув. *бүрге-,* як. *бүрүй-* ~ яз. монг. (Поппе 1938: 127) *bürke-, bürkü-* «бөркәү, өртү» ← бор. төрки (госм., чыгт., к. Радлов IV: 1887–1888) *бүрү-* «бөркәү» (*бүрүк* «каплаулы» → *бүрүк-э* «каплау» булса кирәк), к. ш. ук бур. *бүри-* «өртеп каплау, тышлау» ~ тунг., маньч. *бури-* id. (к. ССТМЯ I: 113–114), бор. төрки (ДТС: 133) *bürün-* «бөркәнү» һ.б.

**Бөркә-** бик продуктив нигез һәм дериватлары гом. төрки, гом. кыпч. характерга ия: тат. **бөркәү** «каплама, вуаль, бөркәнчек» > чув. *пĕркев* «фата, бөркәнчек» ~ кырг. *бүркөө* «ябынча» < бор. төрки **бүркәг* > тув. *бүргег,* к.-калп. *бүркек* «бөркәүле, бөркү» ~ чыгт. *бүркä*, хак., алт. *пүркä* (к. Радлов IV: 1389, 1890) «вуаль, бөркәнчек» > рус. *бурка* (рус этимологлары хәзер бу аңлатманы кире кагалар, ләкин аларның рәдделәре ышандырмый); рус сүзе бүтән сүздән дә киләлә, к. **Бурка.**

Тат. **бөркә-ү,** шуннан **бөркәнчек** ~ нуг., каз. *бүркеншик,* ком. *бюркенчик,* уйг. *бүркәнчүк* id., «нашмак, яшмак, зур шәл» ~ төр. *bürüncük, bürümcük*, бор. төрки (ДТС: 133) *bürüncük* «хатын-кыз бүреге; бөркәнчек», бор. чыгт. (Поппе 1938: 536) *bürünčеk* «фата»; к. ш. ук чув. *пĕркенчĕк* > мар. *пүртенчык, бүргенчык* (мар. телендә вариантлары күп) < тат. *бөркәнчек* һ.б. К. ш. ук **Бөркет, Бөркү, Бүрек.** Räsänen 1969: 92; ЭСТЯ II: 296–298 (Э.В. Севортян **бүр-** «каплау» нигезе бар дип раслый, ләкин, безнеңчә, андый нигез ачык күренми); Федотов I: 422–423 (чув. *пүркенчĕк* > мар. *пĕркензык* сүзен күрсәтә, ләкин чув. сүзенең тат. теленнән икәнлеген әйтми); Гордеев II: 196.

Дерив. (югарыда әйтелгәннәрдән тыш): **бөркәвеч; бөркәл-ү; бөркәүле.**

**БӨРКЕТ [бөркөт],** диал. **пүркүт** «орёл-беркут» > мар. кч. *пӱркыт,* удм. *быркыт*, чув. *пĕркĕт* < гом. кыпч. *бүркүт, бүркит,* тув. *бүргүт,* алт. *мöркүт,* монг. *бүргэд* id. М. Рясянен һәм Э.В. Севортян (ЭСТЯ II: 300) бу сүзне *бүр-* «тырнаклау» сүзеннән дип аңлаталар. Безнеңчә, бу фараз җитәрлек дәлилләнмәгән һәм **бөркет** < *бүркүт* чыгт. (Радлов IV: 1891) *бүркүт* «бөркәү, бөркәвеч» сүзе белән бердәй һәм «бөркәвечле, буркалы кош» мәгънәсеннән килә (кошның кыяфәте чыннан да ябынча-бурка киеп утырган затныкы шикелле).

Урта Азия халыклары **бүркүт баба,** төркм. (Мухамедова: 196) *бöркүт* «яңгыр химаячесе, яңгыр хәбәрчесе» (кайбер ерткыч кошлар яңгыр килгәндә активлашалар, к. рус. *буревестник* id.). К. ш. ук чыгт. (Будагов II: 74) *бöркүт* «бөркү, томанлы һава», уйг. *бүркүт* id. Сүз ясалышы буенча монг.

сүзенә тартым, к. алт. *мӱркӱт* ~ монг. *мүркүт* «козгын».

**БӨРКЕ-Ү [бөркө-], бөрек-ү [бөрөк-]** (катнаш төрләнештә: **бөрке-де** һәм **бөрек-те** параллель рәвештә кулланылалар) «обрызгивать, опрыскивать» < гом. кыпч. *бүрк-* бор. төрки *bürk-* id., ләкин кайбер төрки телләрдә иҗек азагында *-рк* тезмәсе була алмый, шунлыктан бор. төрки сүз бер очракта (госм., чыгт.) *бүрүк-* > тат. *бөрек-* ~ чув. *пĕрĕх-* булып, икенче очракта *бүркү-* > *бөрке-* булып әверелә. Мар. *пүргäлäш, пүргäш* «бөркү» тат. теленнән дә, чув. теленнән дә килә ала. Федотов I: 422 (М. Рясянен һәм Э.В. Севортян бу сүзгә тукталмыйлар).

**БӨРКҮ,** диал. **пөркү** «душно; душный, пасмурный», башк. *бөркөү* < гом. кыпч. *бүркәw*, аз. *бүркү*, алт., шор. *пӱркӱ, пүркäү*, тув. *бүргег* ~ монг. *bürüŋkei, bürüngüi* id. Чаг. ш. ук. кырг. *бүркөк*, чыгт. *бүркүт* «томанлы». **Бөркә-ү** сүзе белән бәглы (к. ЭСТЯ II: 298).

**БӨРЛЕГӘН [бөрлөгән]** «костяника; ежевика; брусника» ~ чув. *пĕрлĕхен* id., ком. *бюрюлген,* каз., кырг. *бүлдүркөн* id. һ.б., бор. монг. *bürlügen* «балан», *bürülgene* «бөрлегән» – үсемлек атамалары ясый торган *-кана//-кәнә, -гана//-гәнә* кушымчасы ярдәмендә *bürü* «бөре, җиләк» сүзеннән ясалган. К. Räsänen 1969: 93; Федотов I: 423.

Чаг. ш. ук төр. *bögürtlen,* чыгт. (Поппе 1938: 128) *bürlügeč* ~ каз. *бүрлүгөз* «балан; бөрлегән».

**БӨРТЕК [бөртөк]** «зерно; зёрнышко; крошка» > удм. *быртык, бӥртӥк* «орлык, бөртек» < гом. кыпч. *бүртүк* id. Севортян (ЭСТЯ II: 300–301) бу сүзне **бөрчек** белән бергә карый һәм *бүрт-* «кубып төшү, кишмекләнү» фигыленнән ди. Рясянен исә **бөртек** һәм **бөрчек** сүзләрен аерым карый. К. **Бөрчек.** Гаффарова 2007: 63–68 (бик тәфсилле).

Чув. *пĕрчĕ, пĕрчĕк, пĕрчеш* «бөртек, бөрчек» тур. Федотов I: 423–424.

**БӨРТИК** диал. «малорослый да удалой» < *бөре тик,* к. **Бөре.**

**БӨР-Ү** «собирать в складки и стягивать; затягивать» ~ чув. *пĕр- [пөр-]* < гом. кыпч., уйг. диал., як. *бүр-* «бөрү; чәңгәлләре белән тотып, эләктереп алу (ерткыч кошлар тур.)», алт. диал. *пүр-* «бәби биләү, төрү», угыз. *бүри-, бүрә-* > ком. *бүре-* «бөреп тегү» ~ аз. *бүз-*, төр. *büz-* «бөрү». М. Рясянен (Räsänen 1969: 92) һәм Э.В. Севортян (ЭСТЯ II: 296–298) бу сүзне госм., кр.-тат. *бүри-* «каплау» ~ монг. *бүри-* «каплау, бөркәү» һәм *бөркә-ү* < *бүркә-* сүзләре белән бергә карыйлар, әмма без монда төптәнге аерма күрәбез: «бөркәү» һәм «бөрү» бер-берсенә охшашмаган хәрәкәтләр. Чаг. ш. ук як. (Пекарский 582–590) *бүй-* «бөре», кырг. *бүйүр-* «бөрештерү, бөрү» (*бөр-* < *бүр-* < *бүйүр-* ?). К. ш. ук Федотов I: 421.

**Бөр- < бүр-** продуктив нигез: **бөрел-ү, бөреш-ү** (бу юн. формасы үзе аеруча продуктив нигез) һәм **бөрем, бөреш** «күлмәк бөрмәсе»; **бөрмә** < гом. кыпч. *бүрмә* (шунысы кызык ки, аз. *бүзмәк* «бөрү», ләкин *бүрмә* «бөрмә»: сүз нигезе эчендә элекке, беренчел аваз саклануның ачык мисалы), шуннан тагы бер төркем сүзләр ясалган: **бөрмәкәй** (к. ЗДС: 133), **бөрмәлә-ү, бөрмәле, бөрмәч, бөрмәшкә** һ.б.).

**БӨРЧЕК [бөрчөк]** «крапинка, горошинка (на ткани); зёрнышко, крошка, частица» ~ чув. *пĕрчĕ, пĕрчĕк, пĕрчĕш*, мар. *пырче, пĕрцĕ, пĕрцĕк, пырцык* ~ каз., к.-калп. *бүршик,* хак. *пүртүк* id. тат., башк. диал. (ТТДС I: 108, БҺҺ II: 54) *бөрчĕ-, бөрчө-, бөрсө-* ~ төр. *bürçü-* «бөртекләп җыю, тирү» сүзеннән шикелле. К. ш. ук үзб. диал. (ЎХШЛ: 58) *бүрчүк* «йөзек кашы; алкага һ.б. беркетелгән вак асылташ». Ләкин *бөрче-* фигыле кире ясалышы буенча пәйда була ала (*бөрчек → бөрче-*) һәм, тат. *бөрче-* фигылен белмәгән хәлдә М. Рясянен, Э.В. Севортян һ.б. тюркологлар *бөрчек* һәм *бөртек* сүзләренең бердәй чыгышына шикләнмиләр (гомумән *-т-* > *-ч-* күчеше очраштыргалый), к. **Бөртек.**

М.Р. Федотов (I: 423–424) чув. *пĕрчĕк* сүзе *пĕр* «бер» нигезеннән ди. Ләкин сүзнең тамыры һәр җирдә *бөр* < *бүр*, ягъни иренләшкән аваз белән килә.

Гомумән, *бөрчек* чыннан да *бөрче-* < *бүрчү-* фигыленән, *бөр* < *бүр* «вак җиләк» (к. **Бөре, Бөрлегән**) сүзеннән булып чыга, чаг. тат. *чемче-ү* «валчыклап ашау» ← *чем* «яфрак сабы». **Бөртек** сүзе **бөрчек** сүзенә контаминацион тәэсир ясаган.

Дерив.: **бөрчекле, бөрчеклә-ү** «бөрчекле итү».

**БӨРЧЕ-Ү [бөрчө-]** «собирать по крупинкам» к. **Бөрчек.**

**БӨС-БӨТЕН, бөсбөтен** (Ш. Әхмәдиев һ.б. авторларда) «целиком; совершенно целый» < кр.-тат., аз., төр. һ.б. *büsbütün* id. Чаг. як. (Пекарский: 588–589) *бүрү бүтүн* id. (*бүрү, бүрэ* «барысы да»

~ бур. *бүри* id.). Димәк, *бүрү-бүтүн* > *бүзбүтүн* > тат. *бөсбөтен.*

**Бөс-бөтен** сүзеннән халык этимологиясенчә *весь бөтен* дип аңлатып булыр иде. Ләкин, күрәсең, алай түгел.

**БӨТ** диал. (*бөт үк* тәгъбирендә, к. ТТДС I: 109) «все, весь», (*өрете-бөте* тәгъбирендә) «новое поколение; все одногодки» < (кырг., үзб. диал.) *бүт* «бөтен, бөтенлек» < бор. төрки **бүгүт, *бүкүт* ← бор. **бүкү* «исәпкә алу; исәпкә алу өчен җыелган халык һәм мал» – М. Рясянен фикеренчә (Räsänen 1969: 92–93), бор. монг. *bü-, büi-*, бор. төрки **бү-* «яшәү, булу», безнеңчә, «үсү, үрчү, үсеп җитү, өлгерү» сүзеннән. К. ш. ук башк. (БТДҺ: 58, 64) *бөтләү* «балык ятуы (яткысы)», *бүтләнү* «яңа җиргә (авылга һ.б.) ияләшү», хак. *пӧк-* «сынау, исәпләү», *пӧгĕн* «халык санын алу»; тув. *бүгү,* кырг. *бүкүлү,* алт. *бүкүлү, пүкүлү,* хак. *пүкүлә* < яз. монг. *bükü* (> хәз. монг. *бүх, бүхэ*), *бүкүли, бүкэли* > эвенк. һ.б. (ССТМЯ I: 105) *букули* «бөтенесе, җыены», бор. монг. (Поппе 1938: 127) *bugude, büküde* < калм. *bugde* «бөтен, барчасы; җәмгысы, җыены». Бу сүз себ. (Тумашева 1992: 117) **пөктә-ү** «җыю, камап алу (исәпкә алу өчен)» < *пүкүт-ә-* фигылендә дә сакланып килә. Кыт. чыганакларында бәян ителгәнчә, бор. төрки билекләр һәм административ берәмлекләр елына ике тапкыр барчасы бергә җыелганнар: җәен – аерым урыннарда гыйбадәт кылу өчен, көзен – кешеләрне һәм мал-туарны исәпкә алу өчен. Шул җыен *бү-кү* һәм *бү-к-үт* дип аталган, күрәсең. К. **Бөтә, Бөтә-ү, Бөтен I, II.**

**БӨТӘ** (ТТДС I: 109, башк. әд.), **пөтә** (Тумашева 1992: 117) «бөтенесе, ба́рча» ← ***бөт-** «тәмамлау, бөтен итү һ.б.» < **бүгүт-* id. ← *бү-* «үсү» (к. **Бөт**), к. алт., тув. *бүт-*, хак. *пүт-* «бар итү, тәмам итү; нормаль хәлгә килү; үстерү». *Бөтә,* гомумән, бор. монг. *bügüde* «бөтенесе» сүзеннән дә килеп чыга ала, ләкин бу версиянең ихтималлыгы азрак. К. **Бөт, Бөтәй-ү, Бөтә-ү, Бөтен.**

Фразема: **бөтә итү, пөтә итү** (Тумашева 1992: 117) «бөтәйтү».

**БӨТӘЙ-Ү** «избавиться от материальной необеспеченности; добиться достатка» – бүтән кыпч. телләрендә теркәлмәгән тат.-башк. сүзе – *бөт* яисә сыйфатлашкан *бөтә* тамырыннан (к. **Бөт, Бөтә**). Мар. *бүтäй-* «бөтәю» < тат. (Гордеев I: 250).

Дерив.: **бөтәеш-ү, бөтәйт-ү** (мәс., *кием бөтәйт-ү* «яхшы кием-салым алу» һ.б.). Як. *бүтэй* «тоташ, тулы» сүзенә *бөтәй-ү* сүзенә катнашы юк.

**БӨТӘРЛӘ-Ү** «окрутить, свернуть в комок» – тат., башк. телләрендә генә теркәлгән – **бөтер-ү** фигыленең интенсивлык формасыннан (*ботау → ботарла-у, бөгү → бөгәрлә-ү, йому → йомарла-у* һ.б. моделендә). К. **Бөтер-ү.**

**БӨТӘҮ [бөтәw]: бөтәү яра** «закрытый перелом, закрытая рана» ~ башк. (БТДҺ: 38) *бөтәү* «кямил; бөтәйгән, бөтәймеш» ~ к.-балк. *бютеў* «бө́тен; бөте́н», кырг. *бүтөө* «һәр яктан ябылган, көпләнгән», үзб. (ЎХШЛ: 58) *бүтәв* «бүленмәслек» – **бөтә-ү** фигыленнән. К. ш. ук тат. диал. (ДС I: 42–43) **бөтәү** «бөтенләй».

**БӨТӘ-Ү** (БТДҺ: 58) «обеспечить, снабдить (одеждой и т.п.)» ~ кырг. *бүтө-* «бөтәйтү, бөтен итү; көпләү, (тишекне, ярыкны) каплау» ~ бор. монг. *büte-* «тәмамлану, төгәлләнү, булдырылу» (Räsänen 1969: 93) һ.б. ← *бөт* < *бүт* (к. **Бөт**).

Дерив.: **бөтәш-ү** (диал. **бетәш-ү**) «яраның һ.б. өсте көпләнү».

**БӨ́ТЕН I [бөтөн]** «все (без исключения)» – **бөте́н** сүзеннән эмфатик басым алып ясалган.

**БӨТЕ́Н II [бөтөн],** себ. **пөтөн** «целый, в целости; целое» > мар., удм. *бүтĕн* id. < гом. кыпч. *бүтүн* (нуг., каз., к.-калп. *бүтин*) ~ гом. төрки (Радлов IV: 1896–1898) *бүтүн* «бөтен; барча, бө́тен» ~ монг. *bütün*/*бүтүн* > эвенк. (ССТМЯ I: 116) *бутун* «барчасы, бөтенесе» һ.б. < бор. төрки (ДТС: 134) *bütün* id. ← *büt-* II «үсү, өлгерү, уңышлы булу», ш. ук, күрәсең, **büt* «үсем, уңыш, өлгереш, яңа буын» (к. **Бөт**) сүзеннән. **Бөтен < бүтүн** бу үзара коррелянт тамырлардан өч төрле юл белән ясала ала: 1) *бүт* исем сүзенең инструменталь килеш формасыннан, 2) *бүт-* фигыленнән сыйфат фигыль формасы (бу карашны Э.В. Севортян һ.б. яклый, к. ЭСТЯ II: 303), 3) *бүт-күн* дигән парлы сүздән (бор. төрки *күн* «халык, җәмгыять», к. **Көн II**); соңгы фаразны як. *буттуун* формасы куәтли. К. **Бөткел.** Чаг. ш. ук **Бөтә.**

**Бөтен** продуктив нигез: **бөтенәй-ү, бөтенләнү; бөтенләй** һ.б. **Бөтен** сүзенең бор. төрки (ДТС: 108, 120) *bodun, budun* «халык» сүзенә катнашы юк бугай.

**БӨТЕРГЕЧ [бөтөргĕч]** «свивалка; веретено с набалдашником; юла» ~ мар. *путĕреч, пытирец*

(Саваткова: 135–136) «сөт язу пешкәге» ← *бөтер-* < **бүтүр-* id., к. **Бөтер-ү.**

**БӨТЕРЕП [бөтөрёп], бөтеребе** (> **бетереп, бетеребе,** к. ДС III: 35), себ. (Тумашева 1992: 176) **пөтөрә** «весь; совсем; точно как; совершенно (как)» ~ карагас. *бүтүрү,* төр. диал. *bitürü* id. асылда *бөтер-* «тәмамлау» ← *бөт-, бүт-* «барлыгы бергә җыелу» булса кирәк (к. ЭСТЯ II: 303). Гомумән, ясалышы ачык түгел.

**БӨТЕРКӘ [бөтөркә], бөтеркәч** «свив; локон, завиток; с завитками (о шерсти, волосах)» ~ чув. *пĕтĕрке,* мар. *пĕтĕрка* id., удм. *путырка* «бөдрә, бөтеркә» ← **бөтер-ү** (к.) сүзеннән тат. телендә ясалган.

Дерив.: **бөтеркәле (бөтеркәчле); бөтеркәлән-ү, бөтеркәләндер-ү** һ.б.

**БӨТЕР-Ү [бөтөр-]** «навивать, скручивать, свёртывать (в верёвку)» ~ чув. *пĕтĕр-,* мар. *пүтĕр-, пĕтĕр-* id. – Идел-Урал даирәсендә генә таркәлгән, бор. **бөлтĕр-* яңгырашыннан булса кирәк, к. тув. *белдир-* «(җеп) кату, төйнәү, бөтерү» (*бөөлдә-* «боргалау» ?); к.-балк., ком. *бюлдюргю, бюлдюрюнкю* «сикәлтәле; сакау (сүз тур.)»: ихтимал, бор. **бүлтүр-* сүзенең күч. мәгънәләредер. Чаг. ш. ук. **Бөдрә.** Федотов I: 427–428 (бик аз әйтелә).

**Бөтер-** продуктив нигез: **бөтерел-ү, бөтерен-ү** (мәс., биегәндә), **бөтереш-ү, бөтерт-ү; бөтермә(ле); бөтеренке** һ.б. К. **Бөтергеч, Бөтеркә, Бөтеркәч, Бөтерчек.**

**БӨТЕРЧЕК [бөтөрчĕк]** «юла, волчок» – *кыланчык, уенчык* һ.б. моделендә **бөтер-ү** (к.) сүзеннән тат. телендә ясалган.

**БӨТИ,** диал. **бөтү, бетү, петү, бетег** (ДС III: 35–36) «амулет» < бор. уйг. *bitig, bitik, pütük* «язма, язылган дога; китап, пичәт» (к. **Пичәт**), *bit-, biti-, pütü-* «язу (фигыль)». Бу тамыр сүзне алынма булырга тиеш диләр һәм күпчелек лингвистлар кыт. *пи* < *пйет* «пумала, пумалачык» сүзеннән дип карыйлар (мәгъ. күчешләре җәһәтеннән к. **Чый-**). Тохар яки грек теленнән дип уйланучылар да бар (ЭСТЯ II: 155–158).

Бор. *biti, pütü* баштан ук «изге язу, кяләм» мәгъ. булган; аның фигыль коррелянты *biti*дән бик күп сүзләр ясалган (к. ДТС: 104). К. **Бетекче.** Федотов I: 428–429.

Дерив.: **бөтиле, бөтилек.**

**БӨТКЕЛ, бөткелле, бөткөлге** (ДС I: 34; ДС II: 69; БТДҺ: 58 һ.б.) «все; все вместе» ~ кырг. *бүткүл* «тулаем», хак. *пүткүл* «тулы, тулысынча», тув. *бүткүр* id. < *бүт-күн* «терлек җыены – халык җыены» сүзеннән булуы ихтимал. К. **Бөт.**

**БӨТЛЕК, бөтлөк** (ТТДС I: 109; БТДҺ: 58) «все» < бор. төрки *bütlük* id., к. **Бөт.**

**БӨТНЕК [бөтнөк],** диал. (ДС III: 35–36; ТТДС I: 591, 600) **бетнек, бытьнык,** (Рамазанова 1987: 73) **мөртлек** «мята» ~ мар. *пүртнык,* удм. *бутник* id. < рус. *мятник*; рус. (слав.) *мята* лат. *mentha* сүзеннән бор. заманда (к. Фасмер III: 30) алынган, шуннан рус сөйләшләреннән *мятник* сүзе ясалган. К. ш. ук **Мәтлек.** Федотов I: 428.

**БӨТ-Ү, бет-ү** (*бөтеп ышану* тәгъбирендә) «верить, доверять» < бор. төрки (ДТС: 133) *büt-* id.

**БӨЯ [бөйә],** диал. (ТТДС I: 109) **бүwә, бүгә** «плотина пруда» ~ чув. *пĕве* id. < бор. *бүwәг ~ бүгәг* id. (к. **Бөя-ү**). Тат. телендәге *бөйә* саф кыпч. линиясе (*г > й*), *бүwә* ~ чув. *пĕве* [> *пĕwe*] миш.-угыз линиясе, мар. *пүйа* тат. теленең урта диалектыннан, мар. Т. *пөвә, пүä* id. миш. (угыз, чув.) диалектыннан килә. М.Р. Федотов (I: 416–417) бу линияләрне аермыйча, мар. вариантларының барысы да чув. теленнән дип раслый, ә тат. вариантларын бөтенләй белми. К. **Бөят.** К. ш. ук Räsänen 1969: 83 (материалы бай түгел).

**БӨЯЛ-Ү [бөйәл-]** «скопиться перед проходом, запруживаться» ← **бөя-ү** (к.)

**БӨЯТ [бөйәт], бөйөт** (?, к. Троянский I: 247), себ. (Тумашева 1992: 154–173) **мөйәт, пеүәт** «бөят; җигемлек (сбруя)», *мөйәт-шай* «бөят-җигемлек», диал. (ТТДС I: 109) **бүwә, бүwәт, бүгә** «подхомутник» (длинный футляр, набитый мягким материалом, употребляемый для того, чтобы хомут не натёр шею лошади, отсюда, по подобию, башк. – БТДҺ: 56 – *бөйәт* «домашняя колбаса»), башк. *мөйәт* «бөят» > мар. *пүйат* ~ чув. (Ашмарин X: 73) *пĕвет* id. ~ нуг. *мүйет* id. Бүтән телләрдә бу сүз бөтенләй икенче нәрсәне белдерә: башк. (БТДҺ I: 62) *бүгәт*, каз., к.-калп. *бөгет,* кырг. *бөгөт*, үзб. диал. (ЎХШЛ: 55) *бөгәт,* чыгт. (Радлов IV: 1694) *бөкäт*, төр. *büğet*, төркм. *бөвет* «бөя; буа». Шул ук мәгъ. чыгт. (Радлов IV: 1994–1699) *бөкäн* «бөя; буа», ләкин *бөкүт* «төймә,

тыгынчык». Өченче бер вариант – башк. (БТДҺ: 62) *бүгәк* «бөят».

Себ. тат., башк. *мөйәт* ~ нуг. *мүйет,* кырг. диал. *мөөт* «бөят» кырг.-нуг. фонетик изолиниясенә карыйлар; чаг. ш. ук башк. *бөйәнә, бөйәнәк* ~ кырг. *мөөн* «унике илле эчәк», чув. *пĕвен* «бөят» (-*н* вариантлар). Шулай итеп берничә төрле консонантив вариантта берничә бердәй мәгънә алмашынып кабатлана. Бу сүзләр дүрт вариант фигыльдән ясалган.

**БӨЯ-Ү [бөйә-],** диал. (ТТДС I: 107–111) **бийә-ү,** миш. **bewә-** (чув. *пĕве-*) «запрудить» – һәр ике вариант (-*й*- һәм -*w*-) тат. диал. (ТТДС I: 109) *бүгә-ү* < (каз.) *бөге-*, кырг. *бөгө-*, төр. *büğe-* һ.б. «бөяү» ← бор. төрки (ДТС: 117, 132) *bök, bük* «Бөек Кытай дивары», шуннан ук *bök-, bük-* «бөяү» (> тат. диал. *бү-ү*) сүзләреннән.

Шулай итеп, *бөяү* һәм *(буа) буу, бөя* һәм *буа* сүзләре бөтенләй синонимнар түгел; һәм асылда тат. телендә *бөя* «су юлын буып ясалган корылма», ә *буа* «бөялүдән җыелган сулык».

Дерив.: **бөял-ү, бөянте** (к. ЗДС: 131) К. **Бөя, Бөят.**

**БРИГАТ** «бригада (в колхозе)», диал. «конюшня (колхоза)» < рус. (асылда фр. теленнән таралган). «Атлыкса» мәгъ. тат. телендә килеп чыккан – *бригат атлары* дигән тәгъбир транзитив момент ролен үтәгән.

**БУ I,** себ. **пу** «это, этот» [в парадигме склонения имеет фонетические порой сильно изменённые варианты: **бŏ** (*бŏлар* «эти»), **мŏ** (*мŏны* «этого, эту», *мŏның* «у этого»), **мŏн** (*мŏнда* «в этом месте, здесь») и др.], «данный, указанный» < гом. төрки *бу, пу* id. (һәрбер төрки телдә төрләнеш формаларында фонетик вариантлары һәм супплетив нигезләре күп очрый); чув. *ку* «бу» **бу** сүзенең фонетик варианты түгел – аның тамырлары үзгә, ләкин кулланышта һәм төрләнештә чув. сүзе тат. *бу*сына охшашкан.

Иске тат. әд. телендә **бу** сүзе регуляр төрләнеш формаларына кертелгән: **булар, буның, бундан,** ш. ук **булай,** хәтта **буғача** «моңача» һ.б. Ул «регулярлыктан» халык телендә **бусы** сүзе генә торып калган (ул да урта диалекттан таралган). Гомумән, хәз. тат. **бу** һәм аның төрле вариантлары вә формалары бор. төрки яз. телләрнекенә охшаш.

**Бу** сүзен бор. гом. төрки **пуу* вариантыннан дип уйлыйлар. К. ЭСТЯ II: 225–228. Ләкин гомумән мәсьәлә чишелмәгән.

Башк. *был* < *бол* тат. теленең бер сөйләшендә дә теркәлмәгән шикелле; *бŏл ~ бул ~ бол* вариантлары каз., к.-калп., кырг. телләренә хас һәм кайбер угыз сөйләшләрендә очрый. К. ш. ук **Менә, Мона.**

**Бу** сүзенең үзгәрешле төрләнеш формаларының кайберләре ошбу сүзлектә аерым карала.

**БУ II** «пар, утренний туман», башк. *быу* id. ~ чув. *пăв, пу* id. < гом. кыпч. *бу, буw*, алт., кырг. *буу* id., ш. ук «металл эретмә» < бор. төрки, бор. монг. (Поппе 1938: 434) *buγ* id. ~ төр. *buğu*, төр. диал. *buγu, buһu* id., чаг. фар.-һинди (Platts: 138) *bukһur* «бу, пар». ЭСТЯ I: 229–230.

**БУА,** диал. (ЗДС: 134) **буwам, буwау** «пруд» – тат. телендә халык этимологиясе буенча диал. *бүә* «буа» сүзеннән (гәй., минз. *бүwә,* каз. ар. *бүгә* «буа», к. ТТДС I: 109), к. ш. ук диал. (ТТДС I: 107) *бөйә* id., *бүү-* «буа буу» (ТТДС I: 111) > чув. *пĕве, пүве, пүйе*, мар. *пүä, пүйә, пүйä* id. Гомуми законченлык буенча, *бүә, бүwә* варианты миш. диалектыннан булырга тиеш һәм һәр ике вариантның уртак чыганагы *бүгә* < бор. чыгт. **бөгäк,* к. чыгт. *бөгäн, бөгäт*, *бүгäт* «буа» ← *бөгä-*, *бөгү-* «буа буу» ← *бөг* «буылган, бүлтәйгән урын» һ.б.

Халык аңында *буа* елганың «буылган» урыны булган; ләкин гом. төрки планда андый күзаллау күзәтелми, буа бөтенләй башкача атала.

Дерив.: **буалы.**

**БУАЗ** «стельная, беременная (о животных)» < гом. кыпч. *буаз, буwаз* < гом. төрки *боғаз, боғуз* < бор. төрки (ДТС: 109, 579) *boγaz* id. *boγ* «төер, төен» тамырыннан (шуннан бик күп сүзләр ясалган: к. **Буак II, Бугаз, Буын, Букча, Бу-у, Буа** һ.б. ЭСТЯ I: 169–170 (шунда ук арытабангы әдәбият).

**БУАК I [бы̆wак]** (ДС I: 39, ДС II: 61), себ. (Тумашева 1992: 178, 181) **пуақ, пыуақ** «утренний белый туман», «обильный иней на деревьях» ← *бу, быw*, к. **Бу II.**

**БУАК II [бы̆wақ]** «зоб; второй подбородок (у жирного человека)», себ. (Тумашева 1992: 45) **богақ, боғағы** «зоб» ~ башк. *бŏғақ* < гом. кыпч. *боғақ* (ком. *боғақ*), алт., кырг. *боғоқ* < бор. төрки (ДТС: 109, 125) *boγuq, buγuq, buqaq* «буак; кошларның томшык асты бизе» ← *боғ* «буылып, калынаеп торган төш». Чаг. **Бугаз, Букча.**

**БУАТ [бы̆wат]** «шестидесятилетний животный цикл (состоящий из пяти двенадцатилетних циклов); век» < бор. монг. *boγut* «буыннар» – *boγun* «буын» сүзенең күп. формасы булса кирәк. К. ш. ук к.-калп. *буўат* «төргәк, бәйләм».

Хәз. башк. телендә *быуат* «гасыр, йөзъеллык» мәгънәсен алган. Алтмыш еллык берәмлек – Юпитер планетасының күктәге торышы үзгәрү циклы, к. Бируни 1995: 207–213. Чаг. **Бүлҗәл.**

**БУГА, бога, бугай** «бык (не облегчённый)», «телёнок-бычок», себ. (Тумашева 1992: 175) **пŏға** «бык», ~ гом. кыпч. *буға, бугай* < бор. төрки (ДТС: 120, 125) *boqa*, *buqa* id., к. ш. ук башк. *буға* «тана; үгез бозау», уйг., монг., тунг. *буқа*, *буқу*, монг. *бух, буха* id., каз. *буғы,* кырг., чыгт. *бугу* «ата болан, болан үгезе», төркм. *буғы* «пошый» < бор. төрки (ДТС: 120) *buγu* «болан», маньч. *буқа* «кучкар, тәкә», *буха* «җанвар» һ.б. Рус. *бугай* төрки телләрдән, ләкин к. литв. *bukas* «күлбога», латыш. *buga* «мүкләк сыер» һ.б. һинд-евр. *bek-* «шешенкеләнү» тамырыннан дигән фикер бар. Шуннан ук рус. *бык* «үгез» сүзен дә чыгаралар. **Буга** сүзе кыт. теленнән дигән фараз дә бар. Pokorny: 98; Joki 1952: 106; Фасмер I: 228; ЭСТЯ II: 230–232; ССТМЯ I: 103–104.

**Буга** сүзенең дерив. юк диярлек, сирәк кулланыла. Себ. (Тумашева, Ор. cit) **поғылта-у** «үкерү (үгез тур.)» икенчел ясалма булса кирәк (ягъни, халык этимологиясе буенча кирегә сүз ясалышыннан).

**БУГАЗ,** диал. **бŏгаз** (Радлов IV: 1807), **буғуз,** себ. (Тумашева 1992: 178) **пу'аз** «горло (в анатомическом значении); пролив» < чыгт., госм., төркм. (һ.б. угыз) *боғаз*, уйг., бор. төрки (ДТС: 109–110) *buγaz, buγuz* «бугаз, тамак; ашау хаҗәте» һ.б. (барча иске чыганакларда очрый). Кыпч. телләрендә *бугаз, боғаз* (кырг. *боғоӡ*) «буак, бүксә; үзәннәр чатлашкан төш» һ.б. икенчел мәгънәләрдә очрый.

**Бугаз** < *боғаз* (һ.б.) сүзе төрки телләрдә *-r* (*-р*) вариантында да саклану белән игътибарны җәлеп итә: тат. сөйл. (Ш. Маннур) **богарлан-у** «туйганнан артык, егылганчы ашау»; тат. **бугазла-у** «сую, бугазын кисү», чыгт. *boγuzla-* ~ яз. монг. *boγarla-* «бугазлау; буу» (к. Поппе 1938: 120, 398); чув. *пыр* «бугаз; ашаучанлык» < бор. төрки **боғург* (к. **Бирән**). К. ш. ук **Бугырдак, Буна-у, Буын.**

**Бугаз,** һичшиксез, **буаз** (к.) сүзе белән уртак тарихи нигездән, **боғ* тамырыннан килә, к. чыгт., аз. *боғаз* «буаз» ~ яз. монг. (Поппе Ор. sit.: 120) *boγar, buγar* «буаз, көмәнле» һ.б. Будагов I: 283–284; Räsänen 1969: 78; ЭСТЯ II: 167–170; Clauson: 322; Мухамедова 1973: 79; Федотов I: 465.

Дерив.: **бугазлы, бугазлык; бугазла-у, бугазлан-у, бугазлаш-у** «бер-берсенең бугазына ябышу», **бугазлат-у;** тат. сөйл. (Balint: 161) *boγozlau* «бугаз, тамак» – сирәк очрый торган сүз.

**БУГАЙ** «видимо, вероятно; кажется» > чув. *пукай,* мар. *пукай, пугай*, удм. *бугай* id. ~ ком. *буғай*, нуг. *боғай* id. < бор. чыгт., яз. төрки (Төхфәт... 1978: 284), тув. *болгай* «бугай, булырга тиеш» – *бол-* «булу» фигыленең теләк формасыннан. Чаг. ш. ук тат. җырында: *Тәрәзәләр ачып яулык болгай – Без сөясе ярлар шул булгай.*

Бу модаль сүзнең икенче вариантында *-г-* редукцияләнгән: *булгай* > тат. диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) **булай** > **булый** > чув. *пулĕ* «булырга тиеш, бугай» < бор. кыпч. (Төхфәт... 1978: 284) *болгай, болай, булай* «ихтимал, күрәсең, булса кирәк».

**БУГЫРДАК, буғардак** (ТТДС I: 94) «верёвка с ошейником», себ. (Тумашева 1992: 178) *пуғыртақ* «кадык, сгиб обуви» ~ башк. (БТДҺ: 51) *боғарӡақ ороһо* «кадык», к.-балк. *богурдақ* «трахея». Гом. төрки сүз булса кирәк, ләкин сүзлекләргә сирәк кертелә. К. **Бугаз.**

**БУЕНЧА [буйы̆нча]** «по, согласно; сообразно; соответственно» > мар. (Гордеев I: 237) *буйынча, вуйынча, вонча* id. – Алтын Урда яз. теленнән булса кирәк, к. нуг., каз., к.-калп. *бойынша,* кырг., төркм. *боюнча,* төр. *boyunca*, үзб., уйг. *бойинча* id. ← *бой* «буй; зурлык; үлчәм». Абстракт мәгъ. бу сүз тәүдә «күләменчә, үлчәменчә» кебегрәк аңлашылудан. **Буенча** белән беррәттән тат. сөйләшләрендә **буйына, буйлата, буйында** сүзләре дә кулланыла, к. Махмутова: 225–226.

Ихтимал ки, төрки *буйынча* < *бойунча* фар. *дäр бäраи* «авырлыгында-күләмендә, турында, буенча» сүзеннән калькадыр.

**БУЗ** иск., диал. (Тумашева 1992: 177) **пос** «серый, светло-серый» (вообще это слово обозначает разные неяркие светлые тона), башк. *буӡ* < бор. төрки (ДТС: 115) *boz* id. Күп телләрдә очрый (к. ЭСТЯ II: 171–173) һәм алт., төр. һ.б. *bor* «чал; бурыл» сүзе белән чагыштырыла. К. **Бузар-у, Бурлы.**

**БУЗА,** диал. (Тумашева 1992: 176) **поза** «буза, молочная водка», күч. «пьяная ссора», диал. (Ту-

машева 1992: 4) **буса, пуса** «квас, пиво, брага; закваска, закисшая пшеничная каша для дубления; барда» < гом. кыпч. *боза* id., к. себ. *поза*, каз. *боза* «арпа яки тарыдан ясалган буза» һ.б. гаҗәеп рәвештә бу сүз нәкъ менә тат. яңгырашында (*о* > *у*) бөтен дөньяга таралган, к. рус. *буза,* фар. *буза,* гар., суахили һәм хауса телләрендә *бузә, буза*. Хәлбуки бу сүзнең фонетик вариантлары күп: хак. *пожҫа, пожҫе*, тув. *божҫа*, алт. *бодо, пойа*, монг. *божҫу, бозо* > *боз,* эвенк. *боӟ* һ.б. (к. ЭСТЯ II: 173–175, ССТМЯ I: 89; Фасмер I: 232), к. ш. ук башк. (БТДҺ: 59) *будагый* «буза». К. **Буча.** Фонетик вариантларның күплеге бу сүзнең алынма булуына ишарәли. Гадәттә *буза* < *боза* сүзен бор. төрки *bor* «шәраб» сүзе белән чагыштыралар, әмма монда *r* ~ *z* күчеше юк: *боза* < *божҫа* < **борчар* < **бор-чагыр* булырга мөмкин (кушма сүз яисә **бор чагыр* «шәраб түпрәсе»). К. **Чагыр.** Рус *баджа, боза, буз* «көмешкә түпрәсе; соус төре; катыктан ясалган эчемлек һ.б.» тур. Аникин: 107, 131–136, 138–139 (арытабан әдәбият).

Характерлы идиома: **буза куптару** = рус. *бузить, бузотёр*. К. **Буз-у.**

**БУЗАР-У** «посереть; побледнеть» < гом. кыпч. *бозар-*, алт., кырг. *бозор-* id. ← *буз* < гом. төрки *боз* (к. **Буз**). Бу сүз тамырыннан ешрак кулланыла һәм киңрәк билгеле.

**БУЗЛА-У,** (Бәетләр 1960: 282) **бузда-у** «громко рыдать; реветь» ~ башк. *буҙла-* id. < гом. кыпч., уйг., чыгт. һ.б. *бозла-* id. Әстерхан татарларында *бузлау*, нуг. *бозла*, угыз төркиләрендә *bozlag* «матәм җыры», ш. ук «бутасы үлгән дөя бакырыгы» (Ясәвидә киресенчә *бута бузлый: Азып калган буталар тик бузласам мин...* 119 хикмәт) һ.б. К. бу хакта Akbaba E. Nogay türklerinde ölüm ile ilgili inaneler ve ağıtlar // Milli folklor. № 78, 2008: 77–84 (бузлау жанры үрнәкләре бирелә). ЭСТЯ II: 175–176 (*бозау* сүзе белән бәйледер дигән фараз күрсәтелә). Чаг. **Базла-у** (к. **Баз II**).

**БУЗ-У** «прокиснуть, превратиться в бузу» к. **Буза**.

**БУЙ I,** себ. **пуй** «длина; глубина; рост, стан», «пролёт; единица длины – 1,5 м; кусок материи, изготовленный как часть одежды», «уже взрослый (но ещё не обзавёлся семьёй)» > мар., морд., удм. *буй* (к. Гордеев I: 235–236) < гом. кыпч. *бой* < бор. төрки (ДТС: 106–110) *boj, boδ, bod* < *бор* (?); к. ш. ук уйг., угыз. *бой*, хак. диал. *пос* < *боз*, тув. *бот* > уйг. *пот* id.; чув. *пү, пӗв* «буй» – миш., угыз линиясеннән, *пуршӑй* < *борсы* «буй җиткән; буйсы» – болг. **Буй** – төрки телләрдә иң төп сүзләрнең берсе – монг. *бодо* «буй, үзе: эре терлек» һәм тунг.-маньч. *бэйэ* «кеше, ир; тән; үзе» сүзләре белән чагыштырыла (к. ЭСТЯ II: 176–178), ләкин, безнеңчә, бу чагыштырулар фонетик җәһәттән җентекләп нигезләүгә мохтаҗ.

**Буй < бой** сүзенең фигыль коррелянты бор. *бой-* «буяу» дигән фараз бар, әмма *бой* һ.б. ничек кенә күпмәгънәле булмасын (к. Радлов IV: 1262, 1282, 1287, 1640 һ.б.; Будагов I: 294–295), аның «буяу, төс» мәгънәсен дә алуы шикле. К. ш. ук Räsänen 1969: 77; Федотов I: 416.

**Буй** продуктив нигез: **буй-буй, буйлы, буйлык, буйсыз, буйчан; буйла-у** «нәрсәнең дә булса буе, озынлыгы буенча йөрү», «тирәнлекне үз буең белән, чумып үлчәү», «буйсынмыйча качып чабып китү – терлек тур.»; сүзнең кайбер грамматик формалары лексикалашкан: **буе//буйлыгы** «озынлык үлчәме», **буйдан-буйга** һ.б. К. **Буенча, Буйсын-у.** **Буй** сүзенең мәгънәләрен һәм деривациясен бик тәфсилләп Д.Б. Рамазанова (1913: 86–94) бәян итә.

**Буй < бой** һәм аның төрле дериватлары күп күрше (ир., Кавказ, Балкан һ.б.) телләренә кергән.

**БУЙ II** тар. «большая семья; род» (к. мәкаль: *Үтмәс ярлык – буйга хурлык,* Исәнбәт III: 322) < угыз. *бой* (> морд. *бой*), төр. *boy* «кабилә; примитив күчмә кабилә» < бор. төрки (ДТС: 107–110) *bod, boδ, boj* «төркем; группа: кабилә, ыру һ.б.ш.». Тәүдә «союздаш» мәгъ. булган, к. тат. (ЛТ I: 105) **буйлы-туйлы** «барча нәсел-ыруы, союздашлары белән бергә» (**туй** сүзенең «тантаналы җыен» мәгъ. булган). Себ. (Тумашева 1992: 178) **пуйын** «хезмәтче», «буйсынган хәлдә(ге)» **пуй < буй** сүзенең инструменталь килеше шикелле – ул чагында *буй* < *бой* «уртак үзәккә буйсынган кабиләләрнең берсе» мәгъ. булган, к. бор. төрки (ДТС: 108–110) *bodun, boδun, bojun* «халык; рәгыять, буйсынган халык», *bodu-, boδu-* «беркетү, баглау».

Бор. төрки *bojla* – шан-шәрәфле титул (*bojla baγa tarqan* – Туңъйокукның атамасы) сүзендә дә *boj* сүзе ятса кирәк: мәзкүр титул «буйның-кабиләнең рухи юлбашчысы – тархан» мәгъ. булып чыга. К. **Бояр** < **бойла эр.*

**БУЙГАТ,** диал. **буйкат,** (Тумашева 1992: 178) **пуйгат** «беременная (женщина)» < *буйы кат(лы)* «буй җимешле» сүзеннән булса кирәк (*ҡат* «җимеш, җиләк»).

**БУЙДАК** «холостяк», диал. «бродяга; пешеход» (ДС III: 40) ~ башк. диал. *буйҙак* «баласыз» (БҺҺ II: 35), нуг., каз., кырг., ком. *бойдаҡ* «буйдак», кар., чыгт., төркм. *бōйдаҡ,* алт. *пойдоҥ* «яшь яки печтерелгән кучкар; буйдак», калм. *бойдаг* «ике яшьлек тәкә» (>> чув. *путек* «бәрән»). Л. Җәләй (1997: 94) буенча, тат. диал. *буе так* (ялгыз) < гом. төрки *бойу так* сүзеннән (к. **Так I**), аның киресе (себ.) *буе кат* «көмәнле; өйләнгән». Мантыйк җәһәтеннән кызыклы булса да, бу фараз өстәмә дәлилләргә мохтаҗ. Чаг. **Буйла-у.** Насипов 2007: 161.

**БУЙЛА-У** «не даваться в руки, убегать (о скотине)» ~ алт. *буйла-*, башк. *буйта-у, буйда-у, буйҙа-у* id. < калм. *була-*, *булйа-*, *булиа-* «талап алу; алып качу, талаучы булу, хөкемгә буйсынмау» (Ramstedt 1935: 59). Ихтимал, *буй < бой < боги* «аерым кабилә; кабиләчелек, трайбализм, сепаратизм» сүзеннәндер (к. **Буй I**). Чаг. төр. *boy* «башбаштак». Чаг. ш. ук рус. *буй* «холыксыз батыр» һ.б.ш. (Фасмер I: 234).

**БУЙРА** (ТРС 1931) «вид высокого камыша; циновка» ~ уйг., үзб. *буйра*, каз., төркм. *бойра* id. Чаг. рус. *бурьян* < миш. тат. **бур'ан < *буйран* ?

Чаг. бор. монг., чыгт. (Поппе 1938: 126) *buriyai* «камыш». К. **Быргы.**

**БУЙСЫН-У** «подчиниться» > мар. *буйсын-* < гом. кыпч. *бойсын-,* уйг. *бойсун- < бойун сун-* «муен сону», ягъни «киссәң кис дип муеныңны сузу», к. Ә. Ясәвидә «*Җилкәң ачып, дога әйләп, буйун сунгыл*» (Диване хикмәт, Казан, 1912: 183), чыгт. *boyin suntayan* «буйсынмаган» (Поппе 1938: 157); моны **буй-ын сон-у** дип тә аңларга мөмкин, ләкин Ясәвидә ачык әйтелгән **буйуң** түгел, **буйун.** Чаг. ш. ук тат. *баш сону, баш салу* «буйсыну» ~ фар. *гäрдäндаде* «муен биреп – буйсынып».

**БУК,** диал. **пуҡ** «дерьмо, говно» ~ чув. *пăх* < гом. төрки *боҡ, боғ* ~ монг. *боғ* id. Бу сүзнең мифологик мәгънәсе дә бар: монг. диал. *пуг* ~ тув. *буҡ*, к.-балк. *пуҡ, фуҡ* «явыз рух, әшәкелек, пычраклык рухы».

Абаев (I: 417) бу сүзне осет. *fagus* «тирес» сүзе белән чагыштыра. Федотов I: 407.

**БУКЧА,** диал. **бухча, бүкчә, мукча** (к. Әдәби мирас, 4. Казан, 1997: 52) «сумка, ранец» ~ чув. *пухча* «чепчик, лампа челтәре» ~ ком. *боҡча,* нуг., каз. *боҡша,* кырг. *боҡчо*, үзб. *бухча*, аз. *боғча* «сумка; чемодан», төр. *bohca* «төен», төркм. *бууҡҗа* < *буғукча* «авызы бөрмәле (будырмалы) янчык, капчык» сүзеннән. «Чепчик» мәгънәсе дә «бөрмәле баш киеме» дигәннән. Тамыры тур. к. **Бу-у.**

**БУЛА,** диал. **бōла, была** «из-за (чего), по причине; увлекаясь кем-чем (и забывая другое, нужное)» > чув., мар. *пула* «благодаря» (Ашмарин IX: 26) < к.-калп., уйг. *бола* id., бу телләрнең грамматикаларында *болгай* «булырга тиеш» (к. **Бугай**) сүзеннән дип аңлатыла, әмма бу аңлатма семантик җәһәттән акланмый. Безнеңчә, бу сүз иске тат., диал. *була-* «мәш килү, маташу» < *булга-* ~ монг. *болга-* id. сүзеннән, к. диал. *булап* «була» (Рамазанова 1984: 10). К. **Булаш-у.**

**БУЛАК,** (Дәрдемәнд) **бōлак,** себ. (Тумашева 1992: 180) **пүлöк** «источник, ключ; полноводная река» > мар. (топонимнар составында) *булаҡ* (к. Гордеев I: 238–239), мар. кч. *пулак* «булак, кул, сыза» < гом. кыпч., уйг., угыз. *булаҡ* < бор. төрки (ДТС: 121–122) *bulaq* «чишмә; канал, арык», *bulyaq* «су дулкынлану; бола» ~ гом. монг. *булаг,* эвенк. (ЭСТМЯ I: 91) *болаҡ* id. һ.б. < *бул-ғаҡ* яисә *булғ-аҡ,* чаг. себ. (Будагов I: 290) *булғылтамаҡ* «селкенеп тору – саз тур.», каз. *булҡылдаҡ* «сазлы елга»; сүзнең тамыры тәкъдиди *булҡ//былк//бүлк* – кайнап, болганып торган су авазын белдерә, к. ш. ук **Бола, Боламык, Болга-у.**

Э.В. Севортян үзенең күпсүзле аңлатмасында (ЭСТЯ I: 257–258) *булаҡ* сүзенең тамырын һәм ясалышын күрсәтми, төрле фикерләрне генә китерә. Рус. *булак* тур. Аникин: 139 (шунда ук арытабангы әдәбият). К. ш. ук Мухамедова 1973: 80.

**Булак** сүзе төрки телләрдән бик күп күрше телләргә (бигрәк тә «шәһәрнең канализация каналы» мәгъ.) кергән һәм бик күп топонимнарда чагыла.

**БУЛАН-У I** (ТТАС I: 188) «испускать пары, париться» ← **Бу II.**

**БУЛАН-У II** диал. «испачкаться грязью» ~ төр. һ.б. *bulan-* id. ← *була- < булла-* (?) «сыек балчык белән пычрату». Чаг. **Булаш-у.**

**БУЛАТ,** диал. **пулат** «булат, восточная сталь; оружие из такой стали» < гом. кыпч. *болат* (кырг. *болот, молот*, хак. *молат*) < фар. *пӯлāд, фӯлāд* < пәһл. *pulavat* id. бор. бер өлкә (хәз. Иран Азәрбайҗанында) исеменнән (к. Меликишвили 1968).

**Булат** сүзе шул (татарчарак!) яңгырашында бөтен дөньяга билгеле: рус. *булат* (к. Фасмер I: 238),

гар. *фӯлāʒ*, *бӯлāд,* яз. монг. *bold, bolot, bolud,* сугд. *pld*, әрм. *potovat, potpat* (к. Абаев I: 265), эвенк. *болот* (к. ССТМЯ I: 93) һ.б.

**БУЛАТА, мулата, муллата** (к. ТТДС I: 309) «болото, болотистое место» – рус. теленнән шикелле, ләкин монда икенче бер сүзнең тәэсире булмадымы икән? Мәс., монг. *булагтай* «болаклы, чишмәле (җир)».

Рус. һәм гом. слав. *болото* ~ *блато* «сазлык» сүзен ахыр чиктә *бел* «ак» сүзе белән баглап аңлаталар.

**БУЛАФКЫ,** диал. **пылафкы** «булавка» < рус. Әмма *булавка* сүзенең тамыры *булава* «гетман таягы (томары)» үзе бор. кыпч. **булаwа* < бор. монг. *bulaγu* > хәз. монг. *булва* «махсус күсәк, томар» сүзеннән (к. Поппе 1938: 125). Сүзнең тамыры төр. *bula, bule* «шарчык, туп» ~ бур. *була* «сөякнең йомры башы» булса кирәк.

Рус. *булава* мәгънәсе буенча бор. монг. *bulaγu* > кыпч. **булаwа* сүзенә тулысынча тәңгәлләшүенә һәм тарихи мәгълүматлар да хилафлык кылмавына карамастан, рус этимологик сүзлекләрендә мәзкүр сүзнең төрки-монг. телләреннән килүе инкяр ителә һәм этимология славян телләрендәге *bula* «күбек, шар һ.б.ш.» сүзеннән эзләнелә (к. Фасмер I: 237).

**БУЛАШ-У,** диал. **болашу, былашу** «возиться; увлекаться; общаться с кем-либо зря», *була-* фигыленең (к. **Була**) урт. юн. < кр.-тат., госм., гаг. *булаш-* < *булгаш-* (бу яңгыраш тат. сөйл. телендә дә очрый: *юк белән булгашма!*) id. Төп юнәлештәге фигыль *була-* < *булга-* «аралаштыру», асылда *болга-у* белән бердәй, к. төр. *bulaşmak* «булашу», *bulamak* «болгатмак, аралаштырмак», *bulanık, bulaşık* «болганчык; аралаш», үзб. диал. *булә-* «катыштыру, аралаштыру» һ.б. К. **Болагай, Булан-у** һ.б. Тат. сөйләшләрендә **булаштыр-у** «булашу» ~ мар. *пулаштыр-* «болгату» һ.б.

Тат. сөйл. телендә һәм хәтта яз. әд. телдә дә *булаш-* урынына *булыш-* сүзен куллану еш очрый. Хәлбуки **булаш-у** һәм **булыш-у** төптән-тамырдан икесе ике сүз; һәм омонимнардан качу принцибыннан чыгып та аларны бутарга, «унификацияләргә» ярамый.

**БУЛДЫК: булдыклы** «сноровистый, дельный, толковый», **булдыксыз** «бестолковый, неумелый» – *бул-* «табу» фигыленнән булса кирәк, к. **Бул-у II.** К. төркм. *буул-* «табу», *булдык* «табыш», *булдыклы* «табышлы».

**БУЛДЫР-У,** диал. **болдыр-у, былдыр-у** «создавать, производить, приобретать, осуществлять; успешно действовать, мочь» ~ чув. *полтар-*, *пултар-* id. Бу сүз **бул-у** сүзенең йөкл. юн. кебек, ләкин монда диал. **бол-у,** угыз. *бул-* «табу» сүзенең тәэсире бар бугай. Чаг. **Булыш-у.**

**БУЛКИ, бүлке** «булка» < рус.; ләкин рус., укр. *булка*, пол. *bula* үзе төрки *булаwа* (к. **Булафкы**) сүзеннән була ала.

**БУЛМАЧЫ, булмацы, пулмацы** (ТТДС I: 96; Тумашева 1992: 179) «бездельник, негодник» >> мар. (Упымарий: 159; Иванов, Тужаров: 152) *полмэзэ, палмезы* «зәһәр, телгә беткән булдыксыз».

**БУЛ-У I,** себ. **пул-у** «быть» < гом. кыпч., уйг., чыгт. һ.б. *бол-*, чув. *пул-,* алт. *бул-, бол-, пул-, пол-*, угыз. **вол-* > *ол-* ~ монг. *бол-*, бор. төрки (ДТС: 111) *bol-* «булу (аның төрле мәгънәләрендә)» < бор. төрки **боол-* (к. як. *буол-*), **поол* id. (к. ЭСТЯ I: 285–288). Бу фигыльнең исем коррелянты да булырга тиеш, ләкин ул ышандыргыч рәвештә табылмаган әле. Монг. телләрендә бу сүзнең «җитү, өлгерү» мәгънәсе активрак (к. **Бүлҗәл**). Шуннан чыгып, *бул-* < *бōл-* фигыленең гипотетик исем коррелянын тунг. телләрендәге *боло* «көз» сүзе белән бәйлиләр (ССТМЯ I: 93).

*Бул-* < *бōл-* сүзен нindидер **бо-, боw-* фигыленең төш. юн. дип караганда, аны санск. *bhu-* «булу» сүзеннән дип гөманларга да мөмкин. Ләкин мәгънәсеннән чыгып караганда исә, *бул-у* фигыленең **бар** предикативы белән баглы булуы ихтимал.

**Бул-у** ярдәмлек фигыль булырак гаять киң вә төрлечә кулланыла һәм аның бу функциясе тур. әдәбият зур. К. Система и уровни языка. М., 1969 (Ф.Р. Байрамов һәм. А.Т. Тыбыкова мәкаләләре); Räsänen 1969: 79; Федотов I: 442–443.

**Бул-у** продуктив нигез: **булын-у, булдыр-у; булмыш.**

**БУЛ-У II** «найти, достать, сделать» < бор. төрки, угыз. *бул-* id. Бу фигыль тат. телендә *бул-* < гом. төрки *бол-* сүзе белән буталган (буталуына бигрәк тә надан орфографлар ярдәм иткән), югыйсә «табу» мәгъ. сүз *бŏл-* дип язылырга тиеш иде (сөйләмдә еш кына шулай әйтелә дә). Тат. **булган** (< **булаган*), **булмаган** (< **буламаган*), **булдыклы, булдыр-у** һ.б. кайбер сүзләр угыз. һәм бор. төрки *бул-* тамырыннан ясалган (сөйл., диал. *бŏлган* > *былган, бŏлдыклы* >

*былдыклы, бөлдыру* > *былдыру, бөлды* > *былды* «эш унды» вариантлары тарихи яктан дөресрәк). **Булмаса** «юк икән» сүзенең кайсы *булдан* ясалганлыгын әйтү кыен. К. ш. ук **Булыш-у.** ЭСТЯ II: 252–253 (тат. теле материалы искә алынмый).

**БУЛУҢ: дүрт булуң** тар. «четыре стороны света» < чыгт., уйг. *төрт булуң* «дүрт почмак» сүзеннән. К. **Болын.**

**БУЛЫЙ** диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «должно быть» < болг. **булый* < *булай* id., к. **Бугай.** Чаг. чув. *пулĕ* id.

**БУЛЫК-У (булыгу, булыкты), болык-у, былык-у** «захлебнуться» – **бу-у** (к.) сүзенең интенсивлык формасы (чаг. *йоту* → *йотлыгу, өзү* → *өзлегү* һ.б.ш.). К. кр.-тат. *булқ-* ~ төр. *bılk-* > *bık-* «(хисләрдән) буылу, тын бетү».

**БУЛЫН-У** «находиться, пребывать» < төр. *bulun-* id. ← *bul-* «табу». К. **Бул-у II. Булын-у** сүзен кайбер язучылар кулланып карасалар да, әд. телгә кереп китмәгән. Хәлбуки кирәкле сүз!

**БУЛЫШ** «помощь» > чув. *пулăш*, мар. *полыш* < бор. төрки (ДТС: 112) *boluş,* алт., хак. *полуш* id. Кыпч. телләрендә бу сүзнең оригиналь мәгъ. бар: к.-балк. *болуш,* каз. (ҚТДС: 69) *болыс* «кәләш белән яшь ирнең туй мәлендә яши торган өе – гадәттә күрше яисә егетнең дустының өе» > тат. диал. **булышлы** id.; **булышлый бару** (ТТДС I: 96) «туйга үз аш-суың белән бару».

**Булыш** сүзенең **булыш-у** сүзенә катнашы ачык булса да, ясалышы ачык түгел (**бул-* < **бол-* «ярдәм итү» фигыленнән, әмма андый фигыль конкрет теркәлмәгән).

**Булыш-** продуктив нигез: **булышлык** (> мар. диал. *полыщлык*, удм. *булышлыķ*) < гом. кыпч. *болушлуқ* (кайбер телләрдә юк) id., **булышчы, булышцы** (~ хәзәрләрдә *булшцы* – бер титул, к. Новосельцев: 144) < гом. кыпч. *болушчы* һ.б.; диал. **булышлый (бару)** «туйга үз азыгыңны күтәреп бару» (к. ТТДС I: 96). К. **Булыш-у.**

**БУЛЫШ-У** «помогать, содействовать» > удм. *булыш-,* чув. *пулăш-*, мар. *полшаш, палшаш* һ.б. < гом. кыпч., уйг., алт., тув. *болуш-, болыш-,* нуг., каз. *болыс-,* хак. *полыс-* һ.б. < бор. төрки (ДТС: 112) *boluş-* id. ← *bol-* «булу, әзер булу, үсү» (к. **Бул-у I**) сүзенең урт. юн.

**Булыш-** продуктив нигез: **булышыл-у; булышкала-у** һ.б., диал. **булышык** «ярдәм» (> мар. *полшык, палшык, палыкш*, к. Саваткова: 112) ~ хак. *полызыг* id.

**БУМАЗИ, бумаҗи** «бумази, бумазея (вид ткани)» < рус., рус телендә исә *бумага* «мамык» сүзеннән, к. **Мамык.**

**БУМАЛЫ** «эпилептик» ← *бума* «эпилепсия» ← **бу-у** (к.).

**БУН** диал. (трбс., без теркәдек. – *Р.Ә.*) «буханка хлеба; кусок колбасы и т.п.» – бор. (ДТС: 109) *boɣun* «буын, буынтык» сүзеннән булса кирәк. К. **Буна-у.**

**БУНА-У** (ТТДС I: 96) «разрезать, распилить на части; окольцевать (ствол дерева)» ~ каз. *буна-*, ком. *бувна-* id. ← *бувун* «буын».

Дерив.: диал. **бунак** (**бунак-бунак** «сегментлы» сүзендә, к. ТТДС I: 96) «сегмент, аерым өлешләрдән торган нәрсәнең бер өлеше».

**БУР I** «известняк, мел» < гом. кыпч. *бōр* id. киң таралган сүз; тат. диал. (себ.), чув., мар. *пор* > *пур*, удм. *бур* id. кыпч. телләреннән. Як. *буор*, төркм. *боор*, морд. *пувор* бу сүзнең төбендә ике иҗекле булганлыгын күрсәтәләр. Монг., тунг. *бор* «бур» төрки телләрдән булса кирәк. Чаг. ш. ук **Бүртә.**

Кайбер тикшеренүчеләр **бур** < *бор* сүзен фар. *бōр, бӯр,* монг. *бора, боро* һ.б. «көрән; буз, бүз» сүзе белән чагыштыралар. ЭСТЯ II: 192–194; Федотов I: 444.

**БУР II** «вор» < рус. Мар. *бор, бур*, ихтимал, татарчадан. Рус. *вор*ны чув. *ворă* < *угры* сүзеннән диючеләр бар (Федотов I: 109), ләкин бу ышандырмый, чөнки рус. *вор* сүзенең бор. мәгъ. «алдакчы, хыянәтче» (чаг. рус. *врать* «алдаштыру»).

**БУРА I,** себ. **пура,** тат. диал. (ДС II: 62) **бурай** «сруб; городки (построение из палочек в одноимённой игре)» > мар. *пура* «бура», каз. (ҚТДС: 69, 273) *бора, пура* «ашлык саклау ханәсе» > кырг. *боро* id. Чаг. ш. ук себ. (ДС I: 62; Тумашева 1992: 179) *пурау* «талчыбык бәйләме» < бор. төрки **buɣra*_(> удм. *бугра, бугро* «бура»), к. (ДТС: 120) *buɣra-* «кискәләү, яргалау», *buɣruš-* «юнып тигезләү». К. **Бура-у.** Федотов I: 445; ДАУ II: 281–285.

Дерив.: **буралы** (к. ш. ук себ. **пуралы** «шакмаклы»), **буралык.**

**БУРА II: бура кебек** «очень большой (о корове или лошади)» – гом. төрки *бугра*, монг. *бугура* ~ үзб. *бувра* «ата дөя» сүзеннән булса кирәк. К. алт. *бура* «шаман менгән (хыялдагы) хайван; пырак». Ихтимал, татар мәҗүсилегендә дә **бура** реаль хайваннан бигрәк мифик гигант хайванны белдергәндер.

Рус. диал. *бура* «ата яки ана дөя» тур. Аникин: 142 (бай әдәбият).

**БУРАЗНА** «борозда» < бор. рус. *боразна* сүзеннән, к. ш. ук морд. М. *борозна,* кар. *паразна,* чув. *пăрусна* id. Рус. *борозда//борозна//бразда* үзе тәүдә «төрән» мәгъ. булган һәм *борона* «тырма» сүзе белән тамырдаш.

**БУРАН** «буран, метель» < тат. диал. *бураган,* ягъни «бурый-бурый ява торган кар» (ЛТ I: 96) – *качаган, тибәгән* моделендә **бура-у** (к. **Бура-у I)** «кар җилләп һәм мул яву» фигыленнән; бу фигыльнең исем коррелянты **бура** «гомумән җилләп яуган явым» (ДС III: 41) билгеле. Шуннан **бура** сыйфат мәгъ. *бура яңгыр* тәгъбире бар. К. ш. ук диал. *буракла-у* «бераз буранлау» (Бәетләр 1960: 141).

Бу сүзләрнең параллельләре барча төрки телләрдә табыла, мәс., алт., кырг. *борогон* ~ монг. *бороон* «буран; көчле яңгыр», к. ш. ук тув. *бораң* «томса көн», төр. диал. *боруҡ* «томан». Чаг. фар.-таҗ. *боридан* «яңгыр яву», *боран* «яңгыр».

Дерив.: **буранлы; буранла-у.**

**Буран** сүзе тат. вариантында күп күрше телләрдә очрый: рус., мар., морд. *буран* һ.б. Абаев I: 273; Фасмер I: 244, 250; Аникин: 143.

Дерив.: **буранлы, буpансыз; буранла-у. Буран** төрләре тур. к. БТДҺ: 60. К. түбәндәгене.

**БУРА-У I** «падать волнами, шквалами (о дожде, снеге)» < гом. кыпч. *бора-*, гом. төрки *бора-*, *пора-* id., ш. ук «ачулы булу» (Радлов IV: 1662; ЭСТЯ II: 189–191). Чаг. тат. диал. (ДС III: 141) **бура** «буран»; гомумән *бура-* < *бора-* ← бор. **бор, *боор* «һава бөтерелү һ.б.ш.» – халыкара сүздән, к. эвенк. һ.б. (ССТМЯ I: 111, 113) *бурга-* ~ як., бур. *бурға* «буран», *бурки-* «борхылдау» һ.б.; һинд. *bhur-* «борхылдау, һава бөтерелү; чабу», лат. *furo* «тузыну хәле», фин. *pyry* «буран» һ.б.

**БУРА-У II** «срубить сруб» ~ чув. *пура, пăвра* < болг. (?) **буwра-* < бор. төрки *boүra-* id. К. **Бура I.** Ахметьянов 1989: 130; Федотов I: 445.

**БУРГАН: бурган би** «князь-буддист» (*Түрә бидә туган юк, бурган бидә иман юк*, Исәнбәт III: 334) < бор. төрки, монг. *burqan, burxan* «Будда, тәңре» һ.б. К. ССТМЯ I: 113; Аникин: 116 (шунда ук бу сүз тур. бай әдәбият күрсәтелә). К. **Борхан.**

**БУРДА** «корм, пойло для откармливания», **будра** (ЗДС: 135) «осадок пищи, браги» ~ монг. *бордоо* «фураж; ашлама», як. *бурдук* «симерткеч он, арпа» < бур. *бурдууг* «терлекләргә апара», рус. *бурдук*, *бурудук, бирдух* «апара; симертелгән (мал)», *бордаг* «симертү абзары» ← яз. монг. *borda-//bordu-* «җир ашлау» → *borduγa* «ашлама һ.б.»; чыгт. (Радлов IV: 1831–1832) *бурдаҡ* «симертелгән, йомры, симез». Төр. *burtlak* «чучка (дуңгыз баласы)», уйг. *бурдак* «сугымлык», тат. (Будагов I: 275) *бурдаған* «йомыркасын ватучан (тавык)» сүзләре дә мәзкүр нигезләргә кардәш булса кирәк. Гомумән алганда бу сүзләр монг. телләреннән таралган шикелле. К. Гаффарова 2006: 66 (һич нигезсез **бөртек** белән чагыштыра, әмма материалы күп). К. түбәндәгене.

**БУРДА-У** (Будагов I: 275) «разжиреть» < чыгт. *бурда-* id. ~ монг. *борда-, борду-* «җир ашлау; симертү»; к. ш. ук (ТТДС I: 94) *будра* < *бурда* «симерткеч болгамач» < **бурда-ҡ* > тат. диал. (кас.) *бурда'* > рус. *бурда* id. К. югарыдагыны. (Фасмер I: 244). Аникин: 144.

Чаг. диал. (ТТДС II: 60) *бур* «симез» ~ монг. *бор-* «симерү».

**БУРДЫК, бурдак** «кожаная бутылка; бурдюк» ~ башк. (БРҺ 1996: 111) *буртаҡ,* аз. *бурдуҡ, бүрдүк* (> рус. *бурдюк*) id. ← *бурт-*, себ. (Тумашева 1992: 178) *пурт-* «(тире, ипи) катып китү», шуның исем коррелянты башк. *бурт* «ыслап-эретеп катырылган тире»; чаг. ш. ук кырг. *бортҡо* ~ калм. *bortxo* «бурдык».

**БУРЗАЙ** «борзая (собака)» ~ чув. *пурсай*, мар. *бурзай*, морд. М. *борзой* < рус. (тамыры *борз* «чапкыр, тизгер»).

**БУРКА** «бурка» < рус., ләкин рус сүзе төрки телләрдән, к. иске фар. *бурҡағ* «бурка» < бор. төр., чаг. бор. төрки (ДТС: 126) *burquγ* «бөрелгән, бөрмәле нәрсә»; иске тат. яз. ядкәрләрендә дә очрый: Котбидә *буркыйғ* «бурка», Максудидә *йөзе бурҡағлы* «бөркәүле» һ.б. Сүзнең нигезе **бурыҡ-* фигыле, к. кр.-тат. *бурмаҡ* «уратып каплау» һ.б.

Рус сүзлекләрендә *бурка* сүзен төрлечә (һәм уңышсыз) аңлаталар, тик төрки телләр материалына игътибар итмиләр, к. Özön: 105.

**БУРКЫН** (Вәлиди II: 417) «богородская трава» ← *бур-* < *бор-* «ис бөркү», к. **Бурсык.**

**БУРЛАК I** «бурлак; поденщик» ~ иск. (С. Хәлфин) *буралгы, буралкы* «сукбай» ~ башк. (БТДҺ: 53) *боралкы*, каз. (Будагов I: 276), к.-калп. *буралкы* «сукбай, иясез эт; читтән килгән кеше, килмешәк; бер югалып, бер табылып йөрүчән (терлек)», башк. диал. *бораклы* < *боралкы* «ирдән кайткан хатын баласы» һ.б. ← (каз., к.-калп.) *бурал-* «килеп-китеп йөрү» сүзеннән (ихтимал, *бурлак* < **буралак,* к. ш. ук тув. *боралгак* «уйравык»). Чаг. **Брамат, Бырамат.**

Мар., удм. *бурлак*, чув., мар. *пурлак* < рус., укр. *бурлак* «бурлак, көнлекче; сукбай» < тат. *бурлак* id. Дмитриев 1962: 557 (тат. **бургалак* сүзеннән ди); Фасмер I: 246 (ним. *burlach* «җәмәгать» сүзенә нисбәт итә); Романов: 55–109 (*бурлак* сүзе чув. теленнән димәкче). Ахметьянов 1989: 163; Тимергалин: 104.

**БУРЛАК II** диал. «залежь» ~ башк. *бурлак* id. (БҺҺ II: 56) ~ тат. диал., ком. *барлак,* чув. *парлак* id. Бор. төрки, госм. һ.б. *бор* «сөрелми торган, уңдырышсыз җир, бурлак» сүзеннән булса кирәк. *Барлак* варианты себ. тат. *партәк* ~ каз. диал. *партак, бартак* «ташландык җир» < фар. *партафт* «ташландык» сүзе тәэсирендә килеп чыккан.

**БУРЛАТ** «кумач, ярко-красная ткань» > удм. *бурлат,* мар. *порлат* << төркм. *бо̄рлат* id. Ачык түгел.

**БУРЛЫ, бурыл,** себ. **пурыл** «чалый, сивый» > удм. *бырлы, бӧрлы, бурлы*, мар. *пурло* id. ~ чув. *пурлӑ, пӑвӑрлӑ* id. **Бурлы** варианты соңрак, *бур* сүзе тәэсирендә килеп чыккан, нигез вариант – *бурыл* < *бургыл* булырга тиеш (төс атамалары ясагыч *-гыл* аффиксы!), к. нуг., каз. *бурыл,* төркм. *буврыл* < *бугрыл* < *бургыл,* як. *булур, бурул* id. һ.б. Монг. *бугурул* «бурыл» (< *бугрул* < *бургул*) нигезендә кабаттаркалыш юлы белән *бугур* «бурыл» сүзе килеп чыккан (шуннан чув. *пӑвӑр*). Һәрхәлдә *бурыл* сүзен күп телләрдә (төрки, ир.) таралган *бор, боро, боор* «төлке төсендәге (ат)» (Joki 1952: 97) сүзеннән аерып булмый. К. ш. ук **Бүртә.** Шанский: 64 (рус. *бурый* төрки телләрдән ди); Федотов I: 394; Ахметьянов 1989: 77–78.

**БУРСЫ** «стеклярус, поддельный жемчуг» (Р. Рәхимова материаллары) < гар. *бусра* id. булса кирәк, шуннан ук рус. *бисер* id. К. Фасмер I: 168, 252 (рус. *бусыр* «иске-москы, чүп-чар» тур. О. Трубачев искәрмәсе).

**БУРСЫК** «барсук» > удм. диал. *бурсък* (Насибуллин: 108), мар. *бурсык, пурсык, порсык* < кар. *борсык*, төр. *борсук*, төр., алт., хак. *порсук, морсык,* чыгт., бор. төрки *bursuq*, бор. төрки (ДТС: 113) *borsmaq*, *borsmuq* монг. *борсуг, bursumaq* (!) «бурсык» – *бурсы-* < *борсу-* «ислән ү» сүзеннән (к. Цельникер С.С. Некоторые дополнения к этимологии слова барсук // Этимология. М., 1963: 120–122). А. Йоки (Joki 1952: 98) *бурсык* сүзе бор. монг. *bor* «симерү» сүзеннән ди (к. монг., кырг. *борсогой* «симереп түгәрәкләнгән, йомрыкай»), М. Рясянен (Räsänen 1969: 81) буенча, сүзнең тамыры бор. төрки *borz* «бурсык» барча мәзкүр фаразларны шик астына куя. К. ш. ук Соколов 1969: 210–211; Корнилов 1970: 220–222; Федотов I: 446–447; Eren: 337; ЭСТЯ VII: 117–118.

**БУРСЫ-У** «протухать; пропахнуть нездоровым духом» > мар. *пурса-, порса-* < гом. кыпч. *борсы-,* төркм., аз. *порси-, порсу-* id. *бор, бур* «сасы ис; исләнү» (МК) тамырыннан (чаг. *сасы* < *сассы-, ярсы-* һ.б.ш. *-сы* аффиксы). К. **Бурсык.** Чаг. **мурт,** себ. (Тумашева 1992: 179) **пурт-у** «искерү, бурсу». ЭСТЯ VII: 115–116.

**БУРЫЧ** «долг» ~ башк. *бурыс* < гом. кыпч. *борч* (нуг., каз., к.-калп. *борыш*) < гом. төрки *борч, борыҗ* «бурыч» ~ бор. монг. (Поппе 1938: 278) *borč* ~ фар. *борҗ* «ия; бурыч бирүче», чыгт. *борч, борҗ* «иҗтимагый бурыч (йөкләмә)» сугд. *porč* id. сүзеннән (ЭСТЯ II: 196–197). Сугд. сүзе исә грек. *φορος* «кертем, салым, иганә» сүзеннән (Бактрия грекларыннан алынган) дип фараз ителә.

Икенче бер версия буенча, *бурыч* < *борч* гом. монг. *buru*, кырг. *буроо*, як. *буруй* «гаеп, бурыч, җәза» сүзе белән бәйле һәм төптә *буручы* «гаепче» сүзеннән (Joki 1952: 93–94); чаг. мар. *порыс* «бурычлы кеше». Безнеңчә, бу версия фонетик җәһәттән аксый.

**БУСАГА** «порог двери» > чув. *пусаха* «бусага; өзәңге; баскыч; утлык рәшәткәсе» < гом. кыпч., чыгт. *босага* «бусага; ишек рамы», кр.-тат., каз. «өйнең ишек ягы (түрнең киресе)» ~ бор. чыгт. *bosoqa* – монг. *bosoγa* (Поппе 1938: 141) «өске тупса» > хәз. монг. *босго*, бур. *боһого* «бусага» ~ бор.

төрки *bosuүa* > шор. *позаға*, алт. *позого*, як. *можҫого* «бусага, тупса»; төркм. (ТДГДС: 41) *босаға* «тияк» ~ эвенк. (һ.б. тунг.) *bosoүo* «тау битләве; төньяк яисә көнбатыш битләү». К. ш. ук тув. *посуӄ* «бусага». Н. Поппе бу сүзне яз. монг. *basurүa* «бусага» ← *bas-* «басу, таптау» сүзеннән ди (Poppe 1960: 65); ЭСТЯ II: 197–198.

Дерив.: **бусагалы, бусагалык.**

**БУСАН-У** (Остроумов 1876: 51) «раздражаться; бурно сердиться» ~ венг. (Gombocz: 32) *boszant, boszu* «гарьчел» ~ чыгт. *бухса-, буғса-* «пыр тузу; үкереп елау» ← (хак. диал.) *буғ, бух* «ачу, ярсу»; к. бур. *бугла-*, монг. *бугса*, калм. *buksaүa* «ярсып китәргә әзер булу» (Ramstedt 1935: 59) ~ эвенк. (ССТМЯ I: 101) *буғаğа-* id.; тат. диал. (ТТДС I: 97) **бусан** «шөпшә» сүзенең әлеге сүзгә мөнәсәбәте ачык түгел (**бусанчык** сүзеннән эллипсис булырга мөмкин). Чаг. бор. төрки (КБ) **бушы** «ярсынучан, ачучан».

**БУТА,** әстр. (ЗДС: 130) **бота, бŏта,** себ. (Тумашева 1992: 176) **пода түө** «верблюжонок» < гом. кыпч. *бота*, кырг. *бото*, үзб. *бўта,* бор. төрки (ДТС: 115) *bota*, *botu, botuq* id. Гомумән, бу сүз күпвариантлы, к. ЭСТЯ II: 198–201. Асылда санск. *pota, potı* «яшь терлек» сүзеннән булса кирәк.

К. ш. ук әстр. *ботакан* ~ тув. *бодаган* «буталы дөя», бор. монг. (Поппе 1938: 122) *botaүan* «бутакай».

**БУТА-У,** диал. **бота-у** «мешать, перемешать; путать; смешать» ~ хак. *путха-*, *пуда-*, як. *бутуй-* id. Бу фигыль күп төрки телләрдә юк. Чаг. рус. *путать, ботать* (*бот* «озын таяк» сүзеннән). Чаг. **Бутка, Буя-у.**

**БУТКА, ботка** «каша» ~ чув. *пăта, пăтă*, хак. *потхы,* гом. кыпч. *ботӄа* (ләкин күп телләрдә сирәк кулланыла), алт. *ботко* «кымыз белән талкан катнашмасы», тув. *быдаа* «ярма; бутка», монг. *будаан* «ярма; бутка» һ.б. К. Räsänen 1969: 82; ЭСТЯ II: 201–202. **Бутка** сүзенең **Бута-у** белән бәйләнеше халык этимологиясе тәңгәлендә. Федотов I: 405–406.

**БУТЫЙ** «боты» < рус.

**БУТЫШ** «водяной дух» (Остроумов 1876: 61) ~ чув. *вутăш, вотăш,* мар. *водыш, вадаш, бодош* «табигый объектның иясе – шунда үлгән берәр кеше рухы» дип аңлатыла, чаг. алт. *Баташа хан, Ботош хан* Әрликнең (җир асты һәм үлгәннәр патшасының) бер углы. Мар., чув. *вӳд ашшы* «су атасы» дип аңлату (Holmberg 1913: 126–129) дә бар. Ахметьянов 1981: 21; Федотов I: 133–134 (*вот* > *вут* «ут» сүзендә); Насипов 2007: 246–247.

**БУ-У** «душить; перетягивать, туго перевязать; прудить реку» ~ башк. *быу-,* чув. *пăв-* < гом. кыпч. *бу-*, *быw-* < гом. төрки *буғ-, боғ-*, тув., хак. *поғ-* һ.б. «буу; төен, бүлтәймә хасил итү» (һәм күп кенә икенчел мәгъ.) – төрки телләрдә иң продуктив тамырларның берсе; аның исем коррелянты гом. төрки (ЭСТЯ II: 165–166) *боғ* «озынча нәрсәнең бүлтәйгән, юанайган төше». Төрки телләрдән тыш: монг. *богу, боо-* «буу; уратып бәйләү», эвенк. һ.б. *бооӄ-* «тоткарлау, бәйләү» (ССТМЯ I: 80).

Тат. дерив.: **буыл-у, буыш-у, будыр-у,** диал. **буыр-у, буырт-у** һ.б.; **бугалак ~ буwанаӄ** (ЗДС: 134–135) «элмәк төре», **бугыч** (диал. **буғаӄ**), **будыргыч, будырма** (диал. **бумак**) һ.б. К. **Бирән, Буа, Буаз, Буак II, Бугаз, Букча, Бума, Бун, Буна-у, Буын, Буырдак** (һәм шуларның дублет-вариантлары). Чаг. ш. ук **Богау.**

**БУЧА,** диал. (Тумашева 1992: 47) **буса, буца** «барда для обработки кожи» ~ хак. *пожа*, тув. *божа* id. Чаг. рус. *буча* «тире иеләү чаны», *бучить* «тирене шундый чанда тоту». *Буча* дип руслар тегермән куласасы урнашкан рамны һәм су агып төшеп кайнап торган урынны да атаганнар. Шуннан, арытабан, *буча* «тормыш кайнап торган төш». К. **Буза.**

**БУШ** «пустой; ненагруженный; свободный (от забот)» > чув. *пуш, пушă, пошă*, удм. диал. *буш* < гом. төрки *бош, боош* (ног., каз., к.-калп. *бос,* хак. *пос,* алт. диал. *пош*) «буш; бәйсез» id. < бор. төрки **болч*, к. венг. (Gombocz: 26) *bolschu* < төрки *бошлай* «бушлай»; фар. *пуч*, һинди. *роč* «буш; файдасыз; вак, бушак» очраклы охшашлык булса кирәк. Рус. (слав.) *пуст* сүзе белән бәйләнешләре тәэсирләшү дәрәҗәсендә генә.

**Буш** тамырыннан күп кенә сүзләр ясалган: **бушка; бушлык, буша-** «буш калу; бәйсез калу» (чаг. *эштән бушат-у*), **бушан-у** «тәрәт итү». Бор. төрки (ДТС: 113–115) *boš* тамыры аеруча дериватлы. К. ш. ук **Бушак, Бүшән.** Räsänen 1969: 82; ЭСТЯ II: 203–205; Федотов I: 457.

**БУШАГАН** (ДС II: 63; ЗДС: 140) «большое шило; кочедык», **пышатан** (ЗДС: 181) «шило, которым работают в накалённом виде» ~ чув. *пăшатан, пушатан* id., ш. ук «чөшле». Фин-угор телләреннән булса кирәк.

**БУШАК,** диал. **бушаң** (ДС I: 39), **бушанкы** «ненапряжённый, ослабленный» (о чём-либо, что должно быть крепко стянутым); ***буша-** фигыленнән.

**БУЫН,** себ. **пуын** «сустав; узел, утолщение в стебле растений; поколение» ~ башк. *быуын* > мар. (Гордеев I: 240) *буын* id., ш. ук «бура уены» < гом. кыпч. *буун, бушун, буын* (асылда бердәй яңгыраштa), алт., кырг. *муун, мун,* алт., хак. *пуун* id. < бор. төрки (ДТС: 109) *boүun* id. Әлбәттә, *боғ* исем фигыль тамырыннан. Бүтән фаразлар (к. ЭСТЯ II: 170–171) кирәксез. К. **Бун, Бу-у.**

Дерив.: **буынлы, буынсыз; буынлык, буынтык** (чаг. **куентык**); **буынлан-у, буынлаш-у** (махсус терминологиядә), **буын-буын, буыннан-буынга** һ.б.

**БУЫРДАК, бугыртак,** себ. (Тумашева 1992: 178) **пугыртак** «кадык; сгиб обуви между подъёмом и голенищем», к. **Богардак.**

**БУЯК [буйак]** «краска для крашения кожи и кожных изделий», (ТТДС I: 94) «краска (любая)» < гом. кыпч., чыгт., уйг. *бойақ*. К. **Буяу.**

**БУЯУ [буйаw]** «краска» < гом. кыпч. *бойаw* < бор. төрки (ДТС: 108–109) *boduү, водиү* id. К. **Буя-у.**

**БУЯ-У [буйа-]** «красить; марать» < гом. төрки *бойа-* < *боду-* id. (ЭСТЯ II: 178–180) ~ уйг. *подуқ-*, як. *бутуй-*, бур. *будаг-*, алт. *будуу-* «буяу», бор. монг. *buduq* ~ чыгт. *boyaq* «буяу (матдә)» (Поппе 1938: 124, 176) монг. бур. *буда-*, эвенк. *буду-* «буяу» (к. ССТМЯ I: 102) > як. *бутуй-* id. һ.б. бор. төрки *boj* < *bod* «буяу» сүзеннән. Чув. *пĕве-, пӳйе-* «буяу» тур. Федотов I: 417.

Дерив.: **буял-у, буян-у, бuяш-у, буят-у,** к. **Буяк, Буяу.**

**БҮГЕН,** диал. **пүген, бөгөн, беген** «сегодня» ~ гом. төрки *бүгүн* (> башк. *бөгөн*) < *бу күн;* барлык төрки телләрдә – шактый бор. заманнарда ук ясалган (хәтта як. телендә дә *бүгүн*) < бор. төрки (ДТС: 131–132) *bügün, bükün* «бүген»; к. ш. ук хак., шор., алт. диал. *пүүм* id. Чув. *пайан* «бүген» тышкы яктан гына бүгенгә охшаш, чынлыкта ул **бая** сүзе белән бердәй (шуннан килеп чыккан), к. Федотов I: 392–393.

**БҮДӘНӘ I** «перепел, перепёлка» > чув. *пӳтене,* удм. *бӧҗӧно, бӧдено*, мар. *бӱдӓнӓ, потяна* < чыгт. *бүдӓнӓ,* алт. *бӧдӧнӧ* (> себ. **пӧдӧнӧ,** к. Тумашева 1992: 177), бур. *бүдэнэ*, тув. *бӧдене,* бор. монг. *bödüne*, икенче бер линия иренләшүсез: үзб., төркм., ком. *бедене [бэдэнэ]* id.; к. ш. ук фар.-таҗ. *bedona* id. Тува һәм монгол әкиятләрендә *бӧдэнэ* ите һәр чирдән терелтә торган мифик кош һәм, безнеңчә, бу сүз ниндидер мәдәни телдән алынма; күп телләрдә очрый торган *былдырчын, белдерчин* «бүдәнә, бытбылдык» сүзе белән бәйләнеше халык этимологиясе кимәлендә генә. ЭСТЯ II: 305–306; Федотов I: 455–456.

**БҮДӘНӘ II** «вид сдобного изделия» < рус. (< инг.) *пудинг*; халык этимологиясе буенча «татарчалаштырылган». К. Воробьев: 142.

**БҮЗ I** «беловато-серый; бледный; бледно-зелёный», «степь весной», «зелёный – молодой» (**бүз егет** «молодой человек от двенадцати до двадцати четырёх лет») < диал. *буз* < гом. төрки *боз* (себ. *пōс*) id., к. ш. ук каз. *бӧз* «кавыл», к. **Бузар-у.**

*Бүз ~ буз* сүзе күп төрки телләргә таралган бертакым кушма сүзләрдә «изге, сихерле» мәгъ. очрый, к. *Акбүзат//Акбузат* < бор. төрки *aq bozat* ~ монг. *čaүan bora morin* «(җиңүче атланып йөри торган) ак ат», к. Поппе 1938: 130 (гомумән, бу тәгъбир VIII г. бирле билгеле, к. Clauson 1972: 388–389); *boz qoj* «аксыл соры йонлы куй токымы»; төр. *bozkır* «дала» һ.б. Төр. *боздыган* ~ себ. тат. (Тумашева 1992: 177) *пōс туйгун* «ау карчыгасы». **Бүз тойгын** төркиләрдә хәрби көч символы була, бүз тойгын томшыгы рәвешендәрәк ясалган сакмалы таяк яу башы билгесе булган, шуннан рус. *буздыхан* «старшинская булава» сүзе килә (бу сүз күп телләрдә очрый, к. И.Г. Добродомов 1974: 29–31). К. ш. ук **Бүздәк, Бүзтойгын, Бүзтургай.**

**БҮЗ II** «грубая белая хлопчатобумажная ткань (на толстых нитках), миткаль, коленкор» > чув. *пус* < гом. төрки *бӧз* > тув. *пӧс*, мар. *пӧс*, удм. *бӧз, боз* id. Еш кына *бәз* сүзе белән бутала. **Бәз, бүз** һәм тат. диал. **бир** ~ чув. *пир* өчесе өч төрле тукыма һәм аларның бердәйлегенә ышандыргыч дәлилләр юк (к. ЭСТЯ II: 1978: 102–103).

**Бүз** сүзен грек. *βυςςος* яки кыт. *пу* кебек тукыма атамалары белән чагыштырып карарга мөмкин.

**БҮЗДӘК** «степной жаворонок» – **бүз I** (яшькелт дала) сүзеннән: *-дак//-дәк* кош атамаларында очрый торган кушымча (к. **Бизгелдәк, Кашкалдак, Үрдәк**).

**БҮЗТОЙГЫН [бүзтŏйзŏн]** (Идегәй 1988: 13–17), себ. **постуйгун** «пустельга, мелкая разновидность ястребов». Рус. *пустельга* үзе себ. тат. сөйләшләреннән булса кирәк. Шуннан ук рус. *буздыхан* «бор. хәрби корал».

Бүзтойгын рәсеме элекке гербларда, әләмнәрдә, коралларда сурәтләнгән.

К. **Бүз** һәм **Тойгын.** К. **Боздыган.**

**БҮЗТУРГАЙ** диал. «синица» < гом. төрки *бозторғай* «төрле кошларны белдерә» (шул хисаптан әкияти, мифик һәм ерткыч кошларны да). К. манси. (< себ. тат.) *pestorqai* «әкияти сәмрәү кош».

К. **Бүз һәм Тургай.** Аникин: 263.

**БҮКӘЙ, мөкәй, мукай, бүки, букай, бөкәй, бука** диал. «страшилище» (ДС I: 42 һ.б.) ~ каз. *мөкей* < бор. төрки (ДТС: 132) *bükä* ~ як. *бөгө*, кырг., монг. *бөкө* id. К. ш. ук як. *моохуй,* шор. *мокай* «аю; бүкәй» (Пекарский I: 1598), Гом. монг. *могай, могой* «аждаһа елан» (к. МНМ I: 28–29). Рус. *бука* төрки телләрдән булса кирәк. Чаг. **Микәлә-ү, Мүкәлә-ү.** К. **Бөкәй, Бокай.**

**БҮКӘН** «чурбан; табурет; стойка бревенчатого дома» < мар. *пӧкэн, пукен* < удм. *пукэм, пукон* «урындык», чаг. удм. *пукыны* «утырырга». Насипов 2007: 182–183 (тәфсилле).

**БҮКСӘ,** диал. (ТТДС I: 111) **бүсә** «округлая часть тела (женская грудь; ягодица)», диал. «зоб» ~ чув. *пүске* < *пүксе* «мяч, колобок» (чаг. ш. ук. тат. диал. **бүскә,** кырг. *бөскө, бөксө*) < каз., к.-калп. *бөксэ* ~ иске монг. *бөгсэ* > як. *бүгсэ* «арт сан (күт)» > эвенк. һ.б. *буксу* id., бур. *бүхэ*, калм. *бөг* «арт як (күт)» ~ як. *бөх* «чүп өеме» ономопоэтик *бүк//бөк* тамырыннан. Тат. диал. (ТТДС I: 111) **бүскә** «пыяла шар; уен тубы» (~ чув. *пүске* id.) ~ кырг. *бөксө* «түгәрәк тау». Асылда *бүксә* «(күн) имилек», «(күн) күтлек» булган булса кирәк: *бүк-сә* ← *бүк* < *бөк* «күкрәк яисә күт кабарынкылыгы». К. ш. ук бор. төрки (ДТС: 117) *böksäk, böksik* «бүксә», *bök-* «бөялү, буылып кабару».

**БҮЛӘ** (Башкортстанда башлыча колыннар тур. – атчылыкта), диал. (Арсланов 1988: 76) **бөлә** «дети двух сестёр в отношении друг к другу» < нуг., каз., к.-калп. *бөле,* кырг., бор. монг. *бөлө* > алт. *пөлө*; хәз. монг. *бул, бүлэ* > эвенк. *бүлэ* id., шуннан монг. *бөлэчэр* > нуг. *бөлэшэр* «апа-сеңелнең кызларының берсе (үзара мөнәсәбәттә)» Чаг. ш. ук төр. диал. *böle* «бертуган кызкардәш».

Башкорт телендә *бүлә*, *бүләсәр* «нук, нука» дип тәгърифләнә. К. Покровская 61: 53–54; Номинханов 1958: 42–47; ССТМЯ I: 109. К. **Бүлтерек.**

**БҮЛӘК I,** диал. (Тумашева 1992: 173) **пиләк** «подарок» > чув., мар. *пүлэк*, удм. *бүлэк* < бор. төрки *böläk* id. Ләкин гом. төрки планда «Себер варианты» – кырг., тув. *бэлэк*, алт., тув. *пäлäк* (Радлов IV: 1243), як. *бäлäх* «бүләк; корбанлык» (Пекарский: 428–429) < бор. төрки *belek, belgük*, бор. монг. *beleg* (ССТМЯ I: 124–125) һ.б. киңрәк таралган: сүзнең төп мәгъ. «билге, дуслык билгесе», ләкин бор. заманнарда ук моны *бүл-* сүзенә нисбәт итүчеләр булган. К. **Билге.** ЭСТЯ II: 112–113.

Дерив.: **бүләклек; бүләклә-ү.**

**БҮЛӘК II** тар., диал. (ЗДС: 113, 142, 539, 545) **беләк, пәлик, пүлөк** «определённая часть земельных и охотничьих угодий; административная единица во времена Золотой Орды и Казанского государства», (Тумашева 1992: 177, 182) **пөйләк, пүләк** «определённая часть леса» ~ миш., морд. *беляк, белёк* иск. «хәз. район зурлыгындагы административ берәмлек», удм. *боляк* «күрше-тирә берлеге», рус административ документларында *буляк, боляк* «бортный ухожай» – «бер чолыкчы карамагында булган урман өлеше» һ.б. Татарлар яшәгән төбәкләрдә *бүләк, бәләк, беләк* дигән топонимнар (урман-кыр, авыл исемнәре) очрый (к. ЗДС: 113, 142). Бүтән телләрдә: кар. *бөляк* «көтүлек җирләр», ком. *белек* «аерым бер урман», «Бабурнамә»дә *бөлүк* «өяз»; бор. угыз., бор. монг. (Радлов IV: 1701) *бөлүк* «рота», к.-балк. *белёк*, кырг. *бөлөк,* үзб. *булак*, уйг. *бүләк* «аерымланган ике якның берсе; «өлеш», бор. төрки (ДТС: 118) *bölük* «өлеш; бүлек; көтү; группа; көтү, көтүлек өлеше». Бу бик бор. хәрби-административ термин; кыт. чыганакларында ук *фу-ло* «һуннарда хәрби отряд». Хәз. Евразия (шул хисаптан герм., слав., угор, гар.-фар.) телләрендә *бүләк* ~ *бәлүк* сүзенең чагылышлары хисапсыз күп (мәс., ним. *Volk* «халык, хәрби берәмлек» > рус. *полк* сүзен дә кайбер этимологлар әлеге һунн сүзенә кайтарып калдыралар). Гераклитов 1926: 108; Сафаргалиев: 72; ЭСТЯ II: 216; Попов А.И. О термине *беляк* // Вопросы мордовского языкознания. Труды морд. НИИЯЛИ. Вып. 42. Саранск, 1972. К. **Бүлкә.**

**БҮЛБЕ** «клубень», себ. (Тумашева 1992: 180) **пүлбө** «картофель» < рус. диал., белорус., укр., пол.

*бульба* ~ лат. *бульбум* «бүлбе; бәрәңге» сүзеннән (*бүл-ү* фигыленең контаминацион тәэсире булуы ихтимал), к. Фасмер I: 240; ДАУ I: 119–120 (удм. *булгы* «бүлбе» тур.).

**БҮЛҖӘЛ** (Будагов I: 289) «условленный срок; отпуск; двенадцатилетний животный цикл» > чув. *пăлчал, пăнчал, мăчал* «туй көнен билгеләү, билгеләнгән көн» > мар. *пунчал* id. башк. (БҺҺ II: 56) *булйал* < гом. кыпч., үзб., уйг. *болҗал*, кырг. *болжол* «мөддәт; чама, исәп (еш кына туй планына карата)» < монг. *bolzaar* < *bolǯagari* id. (к. Ramstedt 1935: 50–51) ← яз. монг. *bolǯa-* «билгеләү», к. **Бүлҗәр, Бүлҗә-ү.** Ахметьянов 1981: 81. К. **Мөрчәл. Бүлҗәл** ~ **мөчәл** тур. бай әдәбият бар. Чаг. **Мөҗәл.**

*Бүлҗәл* һәм *мөчәл* сүзләренең бердәй мәгънәләре дә, охшаш яңгырашлары да бар (чаг. ш. ук **мөчә:** *унике мөчә* «унике ай»). Безнеңчә, монг. *bolǯa-* < бор. төрки **borǯa-* «бөрежгә тукталу» сүзеннән килеп чыга ала (к. **Бөреж**). **Бөреж** исә бор. лат. (< герм.?) *burg* «кальганың почмак башыны (башнясы)» сүзеннән. Һәм шундый схема күз алдыбызга килә:




Безнең бу фаразлар бор. (язусыз-сәвәтсез) монголларның «унике бүлҗәл йолдызлыклары» төшенчәсенә җитәрлек гыйлемгә ия була алуларына шикләнүебездән килә.

**БҮЛҖӘР** (уйг., чыгт. к. Будагов I: 289) «место встречи воинских частей» – «гаскәрләрнең очрашу урыны һәм вакыты; дисциплина» (бу сүзне *болҗар, булҗар* дип тә укыйлар, ләкин тат., һәрхәлдә, *бүлҗәр* булырга тиеш, к. **Бүлҗәл**). Бу сүзнең *м*га башланган варианты киң таралган: тат. диал. (ЗДС: 488) *мүлчәр* «чама, үлчәм: пропорция», каз. *мөлшөр* «пропорция; субординация; чама, үлчәм», кырг. *мөлчөр,* уйг. *мөлчәр* «билгеләнгән урын яисә чик, мөддәт», к.-калп. *мөлшер* «чамаланган күләм» һ.б., Алтын Урда (Сборник материалов 1941: 159, 175) *мурчил* «гаскәрләрнең хәрәкәт итү һәм урнашу тәртибе» << яз. монг. *bolǯagari* id. дип исәпләнә. Ләкин **бүлҗәл** һәм **бүлҗәр** аерым-аерым да уртак *bolǯa-* нигезеннән ясала алалар. К. **Бүлҗә-ү.** ЭСТЯ II: 188. Рус. *больджор* «җыен, җыелыш» тур. Аникин: 133.

**БҮЛҖӘ-Ү** диал. «планировать; проектировать», себ. (Тумашева 1992: 45, 47, 179) **болца-у, булча-у, пулца-у** «вакытын билгеләү; чара күрүне оештыру» ~ башк. *булйа-у,* каз., к.-калп. *болжа-*, уйг. *болҗа-*, тув. *болча-*, хак. *молҗа-* «алдан чамалау, юрау, алдан сөйләшеп-килешеп кую» һ.б.ш. < бор. монг. *bolǯa-* «билгеләү, билгеләп кую» фигыленнән, *бол-* «булу; өлгертү, өлгерү» тамырыннан дип исәпләнә. К. ш. ук тат. диал. *бүлҗәү* (исем), *булҗау, болҗау* > чув. *пăлчав* ~ үзб. (ЎХШЛ: 54) *болҗай*, тув. *полҗаг* «сөйләшеп килешү, конкрет үлчәп билгеләү күренеше», кырг. *болжо-* «билгеләү», алт. диал. *молжо-* «корбанын сагалау (ерткыч хайваннар тур.)». Räsänen 1969: 79–80; ЭСТЯ II: 158–159; Федотов I: 397 (тат. мисалларын белми диярлек).

Дерив.: иске тат. **бүлҗәк,** себ. (Будагов I: 280) **булҗагла-у** «билгеләү». **Бүлҗәк** дип гаскәр бүлкәләре очрашасы урынны атаганнар.

**БҮЛТӘ** «округло-выпуклый» ~ каз. *бұлтақ,* алт. *болчоқ* «бүлтә», бур. *болдог, болтог* «түмгәк, бүлтә», госм. *булдақ* «түмгәкле; кытыршы» ~ ономопоэтик *бол//мол* тамырыннан, к. эвенк. *болдо, бултэ* «эре (җиләк, борчак һ.б. тур.)», негид. *бултэ* «акай (күз)» (ССТМЯ I: 92, 109), башк. *бүлт* «бүлтәеп чыгу» (тәкълиди-образлы сүз), *бүлтәк* «бүлтәйгән».

Бу нигездән ясалган *бүлтәй-* фигыле бигрәк тә киң таралган, к. каз., к.-калп., кырг. *бөлтәй-, бөлтөй-, бултай-,* алт. *бултый-,* бур. *бултай-*, бор. монг. *bültei-, bultai-* «бүлтәю». К. **Бүтәгә, Мөлдерә-ү.**

**БҮЛТӘК** («Идегәй») «ягодица» к. югарыдагыны.

**БҮЛТЕРЕК** «ягнёнок осеннего (вторичного окота)», күч. «недоросший, малорослый» > удм. *быльтрык*, мар. *пöлдырык* id. – каз., кырг. *бөлтүрүк* «яшь бүре, инде энеләре-сеңелләре булган, ләкин анасы янында калган бүре» (рус. *переярок*), бор. монг. *belterig,* бур. *бэлтэргэ* id. (ССТМЯ I: 124) гом. монг. *бөл* «гаилә; өер» сүзеннән (*бөлтүрүг* «гаиләгә өстәмә»: *-түрүг//-туруг* «өстәмә, каплама, кидерелгән нәрсә» мәгънәсен бирә торган төрки-монг. кушымча). К. ш. ук тат. диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) **бөлү** «инде энесе-сеңлесе булган колын». К. **Бүлә.** Ахметьянов 1989: 67.

**БҮЛ-Ү** «разделить; делить» ~ чув. *пӳл-* [*пүл-*], мар. *пӧл-* id. < гом. төрки *бөл-*, *пөл-* id.; шунысы кызык ки, чув. *пүл-* «аерылу; бүленү», ягъни төш. юнәлешендәге фигыль, бу факт исә *бөл-* тамырын *бө-л-* дип таркатып карарга мөмкинлек бирә. Ягъни бор. *бө-* дигән тамыр сүз булган.

Дерив.: **бүлен-ү** (икенчел дериватлары бик ишле: **бүлендер-ү, бүленел-ү, бүленеш-ү; бүлендек** һәм **бүлентек, бүленеш → бүленешле** һ.б.), **бүлеш-ү** (→ **бүлештер-ү** һ.б.), **бүлдер-ү;** математик һ.б. фәнни-техник терминологиядә **бүлгеч, бүленешле, бүленмәс** (сан); көнкүрештә **бүлгәлә-ү** һәм **бүлгелә-ү; бүлеш; бүлемтә** һәм **бүлемтек** һ.б.

*Бөл-* фигыленнән элек-электән гом. төрки *бөләк* (к. **Бүләк II**), *бөлык ~ бөлүк* «бүлек», *бөлүм* «бүлем», *бөлмә* «бүлмә» ясалып килә. Шулардан тат. диал., башк. *бүлкә* ~ төр. *bölge* «бүлмә, ыруның бер өлеше», тат. сөйл., диал. **бүлтә** һ.б. сирәк кулланыла. Räsänen 1969: 84; ЭСТЯ II: 214–217; Федотов I: 459.

**БҮРӘК, бөрәк** диал. (Арсланов 1988: 75) «пельмень; пирог» ~ каз., к.-калп. *бөрек* < *бүйрек* id., төр *börek* «паштет» **бөйрәк** (к.) сүзе белән бердәй булса кирәк, икенче төрле карашлар тур. ЭСТЯ II: 219. К. ш. ук **Пәрәмәч, Шешбәрә.**

**БҮРӘН, пүрән** (ЗДС: 142) «старица, речной рукав; стоячая вода, озерцо» ~ рус. (Аникин: 144, татарчадан дип күрсәтелә) *бурень* «җәен елгадан өзелә торган сулык». Ихтимал ки, бу сүз фар. *бурийāн* «камышлар, камышлык» сүзеннәндер (шуннан ук рус. *бурьян*). Нәкъ менә бүрәннәрдә төрле камышлар шәп үсә. Себ. тат. сөйләшләрендә фар. сүзләре аеруча еш очрый.

**БҮРӘНӘ** «бревно; бревенчатый» – бор. рус. *беревна, бервьно* id. (Срезневский IV: 13) сүзеннән, чаг. мар. *преня, пыреня* «бүрәнә» (Саваткова: 125).

Дерив.: **бүрәнәле, бүрәнәлек.**

**БҮРӘНКЕ** «воронка (как кухонная утварь)» < рус. (гом. слав. сүзе, к. Фасмер I: 354).

**БҮРЕ,** себ. (ЗДС: 539) **пөрө, пөрү** «волк», гом. төрки *бөри, бөрү, бүрү*, алт. диал. (Баскаков 1972: 233) *мөөрө, мөөри,* бор. төрки (ДТС: 118) *böri* һ.б. (күп кенә вариантлар) id. Угыз төрки телләрендә сирәк очрый. Чув. әд. телендә дә кулланылмый. Шунлыктан бу сүзне төрки телләргә соңрак кергән дип уйлыйлар. Гадәттә бор. ир. *vəһrka,* санск. *vrka* ~ бор. слав. *vliki* (>> рус. *волк*) һ.б. һинд-евр. сүзләре белән чагыштырыла. Бу чагыштыруга мар. *пире* «бүре», *пириге, пирӓгү* «бүре баласы» (> рус. *бирюк* «урманда ялгыз яшәүче») дәлил. Чаг. ш. ук морд. М. *верьгиз*, морд. Э. *виргас* (~ литв. *vilkas*) «бүре» һ.б. Ним. *Wolf* һәм шуңа охшаш сүзләр тур. Kluge: 995.

Угыз төркиләрендә *боз бөри (бөрү)* «соры бүре» рәсеме (башы) байракларга тегелгән. Угызхан тур. дастаннарда бор. төрки гаскәрләргә юл күрсәтеп алдан баручы шул булган дип сөйләнелә. Бор. рус. *босой волк* образы төркиләрдән алынган (соңрак ул *серый волк* дип тәрҗемәләнгән). Төр. телендә **бүре** сүзенә һәм образына багышланган публикацияләр күп кенә. Будагов I: 278; Аникин: 128–129 (күп кенә әдәбият күрсәтелә).

Бүре – төрки халыкларның тотемы булган һәм бу хакта төрле риваятьләр очрый. Шуларга бәйле рәвештә **бүре** сүзенең үзгә этимологияләре дә бар. К. ЭСТЯ II: 219–221. К. **Күкбүре.**

**БҮРЕК**, диал. **бүрке** (ДС I: 43) < гом. төрки *бөрик, бөрүк*, бор. төрки, бор. монг. *börk* «бүрек» ~ монг. *бурх* «эшләпә», *бүрхэ-* «каплау, бөркәү», бор. монг. *börkür* > «калпак; конус, мичкә», алт. *бөрүк* «бүрек, эшләпә», бор. чыгт. *pörük* ~ алт. *пүрүк* «бүрек; ябу, капкач» һ.б. К. **Бөркә-ү.**

**Бүрек** сүзен **бүре** сүзеннән дип тә уйлыйлар: бор. төрки хәрбиләр бүре башы сыман бүрекләр кигәннәр, имеш. ЭСТЯ II: 222. Рус. диал. *бурк* тур. Аникин: 144.

**БҮРТӘ,** диал. (себ.) **пөртү, бөртү, мөртү** «мухортый, бурый» ~ кырг. *бөртө* id., чаг. чыгт. (Радлов IV: 1665) *борта* «болан; йөк аты», төр. *bortük* «сары таплы». Чаг. рус. *мухортый* «бүртә» (бу сүзнең бәхәссез этимологиясе юк).

**БҮРТ-Ү**, диал. (Balint: 104) *бөрөт-* «набухать, увеличиваться в размере, впитывая влагу» < гом. төрки *бөрт-, бөрүт-* id. (ЭСТЯ II: 224–225); шуның белән беррәттән: тат. диал., башк. *бүртәй-*, нуг. *буртай-*, каз. *буртый-*, кырг. *буртуй-* «бүртү» – *бүрт* < *бүрт//бүлт* < *булт* «бүлтәеп торган нәрсә» тамырыннан булырга тиеш. К. **Бүлтә.**

**БҮСЕР** «пупочная грыжа у детей; геморрой; грыжа; катар желудка» > чув. *пӳсер*, мар. *бөсыр, пөшыр, пусыр* id., удм. *бөсыр* «гарип; бүсер», *бусир* «шәмәхә» (бу мәгънә шуннан чыккан: бәбиләр

бүсерен шәмәхә кара белән тәлинкәгә төшерелгән «бүсер рухы» рәсемен чайкап эчереп дәвалыйлар), каз. *бөсүр* «катар, бүсер» < гар. *bāsūr* (> төр. *basur*) «геморрой», *бср* «вакытсыз булу; борчу, борчылу» тамырыннан. К. ш. ук **Бабасыр.**

**БҮС-Ү** «поесть через край; лопнуть (от внутреннего напряжения); разрывать» (Вәлиди II: 420) < бор. төрки *бөс-* id. (к. Радлов IV: 1705); тат. телендә төш. юн. формасы *бүсел-* < бор. төрки *бөсүл-* активрак кулланыла; бу сүз исә бор. төрки (ДТС: 117, 132) *böksil-, boksül-, büksül-* «бүселү» сүзеннән килә, димәк *бүс-* < **бүкс-* < **böküs-* < **boküz-* < *bökür-* id. **бөк* тамырыннан (чаг. **Бөк, Бөктәр**). Шуннан ук **бүксә** < *böksäk*, к. **Бүксә.**

**БҮТӘГӘ** «желудок у птиц; зоб», тат. диал., башк. **бүтәкә, пүтәгә** «низкорослый, трава, растущая по низу других трав» (ДС III 45; БҺҺ II: 59) ~ чув. *путеке* «бүксә; бөер», нуг., каз. *бөтеке, бөтеге*, кырг. *бөтөкө, бөтөкөн* «бүксә; бөер; бүтәгә», чыгт. *бөтäкä, пөтөгä*, як. *бөтөгө* «бүтәгә» < бор. монг. *bŏldegen* «күкәй (testicula); чунтай (күкәй капчыгы)» > бур. *бүлдэгэн* id. (*бүтәгэ* «бармак башы; колак йомшагы»), тамыры **бүлтә** > монг. *бүлдэ* id. К. **Бүлтә.** ЭСТЯ VII: 108.

Монг. *бэтэгэ, бэтэг* «бүтәгә», ш. ук «vulva» (тат. телендә дә шул кулланыла) икенче бер сүздер (монда паронимик аттракция булган).

Чув. *пĕсехе* «бүтәгә»нең чыгышы фонетик җәһәттән аңлашылып бетми. Федотов I: 424.

**БҮТӘН** «иной, другой» ~ нуг., каз., үзб. диал. *бөтен* «чит, ят; бүтән, үзгә» < фар. *бедун [бэдун]* ~ гар. *бидун* «бүтән; тиңсез, ишсез, сынар» (чаг. тат. диал. *бүтәнчә* «бигрәк тә», ДС II: 70), һинд-фар. *dūn, dūna* «игез, тигез, охшаш, дубликат» сүзеннән булса кирәк (Platts I: 535).

**БҮТТӘ беттә, бетә** диал. «будто, якобы» ~ мар. *буйто, пуйто, вуйто*, удм. *будто ке,* чув. *пуття* < рус. теленнән (Махмутова: 249–250).

**БҮ-Ү** «околдовать» – бу сүз надан халык телендә *бу-у* белән буталган: «күз буу» диләр. Хәлбуки к. төр., гаг. *бү-ү* «сихерләү, арбау», *бүү* «сихер, арбау», төр. *bütek* «бүмәк», *büyü* «бүү» һ.б. < бор. **bö-* id.; к. **Бөе-ү.**

**БҮШӘН** «рыхлый (телом)» – *бушан* сүзеннән, к. **Буш.**

**БЫҖБЫҖЫК** «куча мала (игра)» ~ чаг. һинд-фар. *бежбажа* «кайнашу, уйнау, тавышлану, шаугәр килү» (Platts I: 134).

**БЫЗ: быз-быз** – имитатив жужжанию некоторых насекомых, а также звукам дудки, варгана.

Дерив.: тат. диал. > удм. **бызгы → быз** «курай, кубыз».

**БЫЛ** диал. «цикорий». Ачык түгел (к. Иванова: 174). Чаг. рус. *былка, былинка* «үлән чеме».

**БЫЛБЫЛ** «соловей; бульбуль; соловушка» < гар. *бүлбүл* id.

**БЫЛКЫЛДА-У** «колыхаться (о жирных телесах)» – *былк* (*былк итү*), *былкы* тәкълиди сүзеннән; к. диал. **былкын** «көпшәк тәнле», башк. диал. *былҡым* «йомшак тәнле, көчсез» һ.б. Чаг. монг. *балбагай* «былкым».

**БЫЛТЫР** «в прошлом году» ~ чув. *пĕлтĕр*, гом. төрки *былтыр, былдыр* һ.б., гомуми фикер буенча, бор. *бир йыл турур* «(узганына) бер ел торыр» сүзеннән. Räsänen 1969: 74; Федотов I: 420–421.

**БЫЛЧЫРАК** «грязь, жижа» к. **Былчыра-у.**

**БЫЛЧЫРА-У** «хлюпать (о грязи); загрязниться» ~ диал. *балчыра-*, кырг. *былчыра-,* каз. *булжыра-, булшыра-* id., шуннан гом. кыпч. *былчырак*, тат. диал. (Остроумов 1892: 56) *балчырак* һ.б.ш. «былчырак» – тат. диал. **былчы-у** «юешләнү» фигыленнән, к. диал. **былчык** «эренле (яра, күз)»; тамыры *былч//балч* «балчык чәпелдәү тавышы» (*былч-ы-*), гом. төрки, монг. һ.б. *бал// бул//был* «юешлек, сусыллык, сазламык» тамырыннан, к. **Балчык, Балык, Пычрак, Пычыргы** һ.б. (**бал* тамыры тур. Черкасский: 94). Тат. әд. телендә **пычрак** һәм **былчырак** аерым мәгънәле сүзләр.

**БЫРАК-У (бырагу, быракты)** «бросить» – иске әд. телдә (XIX г. – XX г. башлары) кулланылмыш бу сүз госм. теленнән кергән (төр. *bırak-* id.), әмма ул миш. сөйләшләрендә электән булган, чаг. башк. *бырақтыр-у* «ташлату», чув. *пăрах-* «ташлау», кр.-тат. *бырақ-*, *бурақ-*, *брақ-* ~ як. *бырах-* id. К. **Бырык-у.** Федотов I: 399–400; ЭСТЯ II: 307–308. Чаг. **Пыр.**

**БЫРАМАТ, борамат, брамат** «вольный казак – человек толковый, но без постоянного места жительства; бродяга-интеллектуал начала XX века», диал. **быраматчы** id. > мар. *брамат, бурамат* (Гордеев I: 243) «сукбай» ~ башк. *барамат* (БҺҺ II: 40) «азман, азгын кеше», тат. диал. (ТТДС I: 91) *браматлау* «берәр телдә начар сөйләшү», чаг. ш. ук диал. *борамаклау* «әрәм итү» – ихтимал, *борал-* «кайтып-китеп йөрү» сүзеннәндер, к. **Бурлак.** Чаг. ш. ук фар. *бäрамäд* «килеп китте; килеп чыгу», *бäрамäди* «килеп-китеп йөргән кеше; эмигрант». Ахметьянов 1989: 163.

**БЫРГЫ,** диал. **боргы** «горн, дуда, рог» > удм. *бургы* «медная труба» < үзб., бор. чыгт. *бургу*, *бурқу*, уйг. *борғу*, бор. төрки *borγuj* (ДТС: 113) < тамил. (Һиндстандагы дравид телләренең берсе) *boriγaj, puriγaj* «тынлы музыка уен коралы» сүзеннән киң таралган, к. төр. *boru* «труба», тув. *мургу*, хак. *пыргы*, бор. монг. *bürijen, bürijel* (> рус. *бирюлька*) «курай, музыкаль һ.б. труба» > нан., маньч. *бурэ, бурэн* «гармун»; тув. *авыра, авырга* «маралларны алдатып чакыру быргысы» (< *аңбыргы*, к. *аң* «ау»), гар. *бурийүн* «мөгез быргы» һ.б. К. Меркулова В.А. Мелкие заметки по истории и этимологии слов // Этимология 1971, М., 1973: 185–190 (бик тәфсилле!). Рус. *борга* «аучылар быргысы» тур. Аникин 134–135 (бай әдәбият).

**БЫРЫК-У (бырыкты, бырыгу)** диал. «бросать; отказываться» ~ иске әд. *бырак-у*, чув. *пăрах-*, төр. *bırak-*, *brak-*, як. *бырах-, барах-* id. күрәсең бик бор. сүз. К. ЭСТЯ II: 306–308. К. **Бырак-у, Пыргыт-у.**

**БЫТБЫЛДЫК,** диал. **пытпылдык** «перепел» ~ чув. *пĕтпĕлдĕк* id., чаг. ш. ук төр. *bıtbıldık*, гаг. *пытпылдак* id. ← *бытбылда-у* фигыленнән; шуның параллеле тат. **бытылдык** «такылдык, лыгырдык» ← *бытылды-у* «быт-быт итү» һ.б. Күренеп тора ки – тәкълиди тамырдан. К. **Быт: быт-быт.**

**БЫТ: быт-быт** – подражание косноязычной речи ~ чув. *пăт-пăт* < гом. кыпч. *быт-быт* id. Шул ук тамырдан к. **Бытбылдык,** башк. диал. *бытый* «сакау» (БТДҺ: 67) һ.б. К. **Бытыр.**

**БЫТЫР: бытыр-бытыр,** сирәк **бытыл-бытыл** – подражание быстрой и малопонятной речи, к. ш. ук башк. *бытыр, бытырҙаҡ,* тат. *бытырдык* «бигүк ачык булмаганча һәм тиз-тиз сөйләшүче».

# В

**В** хәрефе төп тат. сүзләрендә иҗек башында килгәндә хәз. орфографиядә [**w**] авазын белдерә (түбәндәге язылышларда шуны истә тоту кирәк).

Русчага тартым **в** авазы төп тат. телендә фонематик аваз буларак кулланылмаган, ул тик **б** фонемасының аллофоны булып килгән (мәс., игътибарсыз әйтелештә *булды* урынына *вулды*).

**ВАБА [wa$^{о}$ба]** «чума» < гар. *wāбā* id., төп мәгъ. «кычкырып авыру».

**ВАБАЛ [wa$^{о}$бал], убал** иск. «авыр нәтиҗә, зарар; җаваплылык» («гөнаһыңның wабалы бу» диләр) < гар. *wăбāл'* id. Төрки телләрдә киң таралган сүз. Räsänen: 356.

**ВАДИ [wa$^{о}$ди]** «вади, сухое русло (в пустынях)», «широкая и длинная долина, ложе реки» < гар. *wāдū* «чүлләрдә бик зур, озын һәм күбесенчә ел буенча коры үзән». Төр. телендә *vadi* сүзенең «кирәксез озын сүз, актуаль булмаган тема» мәгъ. дә бар.

**ВАЕМ [wa$^{о}$йы̆м]** «забота» – *вай* сүзеннән (ди Будагов II: 302). К. **Вай.**

Дерив.: **ваемлы, ваемсыз; ваемла-у.**

**ВАҖИБ [wa$^{о}$җип]** «необходимость; необходимо» < гар. *wāҗ̧иб* id.; иске әд. **ваҗиплек, ваҗиплык** (Будагов II: 300) «должность» дип бирелгән.

**ВАЗ: ваз кич-ү [wa$^{о}$з кич-]** «отрекаться, отказываться (от намерения, мнения)» – фар. *waз гаштан, waз кашидан, waз гузоштан* тәгъбирләреннән ярымкалька: *waз* < *ваз* < авест. *apaš* < *apa апč* «алып, ачып ташлау», *кашидан, гашитан, гузоштан* «кичү, кичерү». Будагов I: 301. Сирәкләп *ваз* сүзе үзе генә дә кулланыла.

**ВАЗГЫЯТЬ [ва$^{о}$зғийәт]** «общее положение (дел), ситуация» < гар. *wăḍʻиййăт* id.

**ВАЗИФА [wa$^{о}$зифа]** (**вазыйфа** дип тә языла) «обязанность; должность» < гар. *wăẓифă* id. Будагов II: 305.

Дерив.: **вазифалы, вазифасыз; вазифаландыр-у.**

**ВАЙ** «увы!», «рачение, беспокойство» < фар. *waй* id., к. ш. ук каз., к.-калп. *уwай, уwайым*, кырг. *убай, убайым* «ваем, хәстәр» һ.б. Фар. сүзе авест. *avoi, yavoi* «вай», төбендә бер тәңре атамасы – җир асты патшасы дигән фикер бар, чаг. рус., укр. *Вий* «үлекләр патшасы»; рус. *увы* сүзе дә шуннан дип исәпләнә. Һәрхәлдә *вай* һәм *увы* тамырдаш сүзләр (Фасмер IV: 144).

**ВАК [wa$^{о}$ķ]** «мелкий; мелочь» > чув., удм., мар. *вак* id. < тат. диал. (Тумашева 1992: 224, һ.б. чыганаклар) **уаķ** id., ягъни «уалган»; тик бу сүз тат. телендә генә ясалмаган, бор. яз. ядкәрләрдә үк *уwак, увак, уфаķ* > гом. кыпч. *уwаķ,* иске тат., кр.-тат., төр. *уфаķ* id. ← *уw-, уг-*, к. ш. ук кырг., алт., шор., хак. *ооķ* «вак» һ.б. К. **Ошак, У-у** һ.б. Будагов I: 106; ЭСТЯ I: 560–561; Федотов I: 97 (чув. *вак* сүзенең татарчадан икәнлеген әйтми).

Дерив.: **ваклы, ваксыз; ваклык, вакла-у; ваклан-у, ваклаш-у** (күч. мәгънәләре бик үзенчәлекле); **ваклат-у; ваксы-у,** неол. **вакланма, ваклаучы** һ.б.

**ВАК-ТӨЯК [wa$^{о}$ķ-төйәк],** диал. **wаķ-түәк** «мелочь» ~ бор. төрки *ufak-tüfek* һ.б. id.; **төяк** – дөресе **төек ← төю** (к. **Төй-ү**): **вак-төяк,** димәк, «уылган һәм төелгән (нәрсә)».

**ВАКЧЫЛ [wa$^{о}$ķчы̆л], ваксыл [wa$^{о}$ķсы̆л]** «мелочный», ш. ук диал. **wаķсы-у** «мелочиться; проявлять недовольство по пустякам» – тат. теленең үзендә ясалган сүзләр. К. **Вак.**

**ВАКЫЙГА [wa$^{о}$ķиға]** «событие» < гар. *wāķиʻа* id. ← *wķʻ* «очрау, тап булу; абыну»; шуннан ук иске әд. **ва́кыйган** «чыннан да», **вакыйг булу** «килеп чыгу, пәйда булу» һ.б. Будагов II: 32.

Дерив.: **вакыйгалы, вакыйгасыз.**

**ВАКЫТ [wa$^{о}$ķы̆т],** диал., сөйл. **вахыт** «время, пора; эпоха» > мар. (Исанбаев 1978: 18) *вакыт, вӓгыт*, удм. (Насибуллин: 109) *вагът* < гар. *waķт* id. ← *wķт* «мөlдәт билгеләү», шуннан ук к. **Әүкать.**

Крш. (ТТДС I: 66) **бакыт, багыт, пагыт** > мар. *пагыт* бор. кыпч. сөйләшләреннән килә; чув. *вă-*

*хӑт* шулай ук татарчадан түгел, үзгә чыганактан. Гомумән, бор. төрки телләрдә «вакыт» мәгъ. үз сүз булмагач, гар. сүзе бик иртә үзләштерелгән һәм фонетик тармакланышка дучар булган. Будагов II: 306; Федотов I: 114.

Дерив.: **вакытлы, вакытсыз** (үзенчәлекле мәгъ.); **вакыт-вакыт, вакытча, вакытчан** «үз вакытында».

**ВАКЫФ [waºқыф]** «җәмгыятьтә дини оешмаларга, кәсәбәләргә һ.б. тапшырыла торган материаль кыйммәтлекләр, ш. ук капитал». *Wқф* «тукталып тору» тамырыннан (**вакыф** дип дини текстларны укыганда бераз тукталуны да атыйлар). Ислам илләрендә вакыфтан салым алынмый, ләкин вакыфтан килгән керемнәр мотлак дин юлына китәргә тиеш. Вакыфка охшаш күренешләр (тик дингә түгел, фәнгә карата) Россиядә дә бар. Будагов I: 306–307; Тимергалин: 110.

**ВАЛИ [waºли]** «осуществляющий; управляющий; исполнитель; наместник» < гар. *wālū* id. К. **Вилаять.** Будагов II: 308.

Дерив.: **валилек; вәли нигъмәт** «нигъмәт иясе, ашатучы».

**ВАЛЧЫК [waºлчы̆қ]** «крошка» > чув. *ванчăк* < *уалчық* ← *уал-у* ← **у-у** (к.). Чаг. **Ват-у.**

**ВАНИХАЙ [waºнихай]** (Тумашева 1992: 224) «путаница» < бор. төрки *tanihaj* «манихей (бор. төркиләрдә шактый киң таралган манихейлык динен тотучы кеше)». К. **Маный.**

**ВАРИС [waºрис]** «наследник; унаследователь» < гар. *wāриç* id. ← *wrç* «варис булу»; шуннан ук иске әд. **варәсә** «варислар җөмләсе», **варәсәт** «варислык».

**ВАСИТА [waºсита]** «средство; посредство» < гар. *wāсиṭа* «васита, чара; арадаш; ара; урта» сүзеннән; иске әд. **бил-васит** «ярдәмендә», **би-ля-васита** «турыдан-туры». Тимергалин: 108.

**ВАСЫЯТЬ [waºсы̆йәт]** «завещание» < гар. *wāçийӓт* id. ← *wçй* тамырыннан; шуннан ук **тәүсыя** «киңәш, васыять».

**ВАТАН [waºтан]** «Родина» < гар. *wӓṭан*, *wṭн* «яшәп тору» фигыленнән. Кайбер кыпч. телләрендә бу сүз бик үзгәртелә: каз. *отан*, кырг. *оотан*.

Дерив.: **ватанлы, ватансыз; ватандар, ватандаш, ватанпәрвәр, ватанчы.**

**ВАТ-У** «разрушать; размельчать» > чув. *ват-* id. < *уат-у* ← **у-у** (к.); к. ш. ук гом. кыпч. *ywat-*, уйг. диал. *уват-*, төр. *ufat-* ~ алт., хак. һ.б. *оот-* id.

Федотов I: 102 (чув. сүзенең татарчаданлыгын әйтми һәм хәтта татар параллелен дә китерми).

Дерив.: **ватыл-у, ватыш-у, ваттыр-у; ваткыч; ватык**.

**ВАФА [waºфа]** «верность» < гар. *wӓфā* id., к. иске әд. **вафи** «тугрылыклы, хыянәтсез».

Дерив.: **вафалы, вафасыз.**

**ВАФАТ [waфат]** «преставление, смерть; преставился (умер)» < гар. *wӓфāт* id. ← *wфт* «барып җитү (теге дөньяга)» тамырыннан.

**ВАФЫР [waºфы̆р]** диал. (Тумашева 1992: 224) «паром» < иске тат. (XIX г.) *wафур, wапур* < төр. *vapur* «пароход» < фр.

**ВӘ [wә]** «и, ещё» < фар. *wӓ, у, у* < бор. фар. *ufa* < *uva* (Platts II: 1176) ~ авест., санск. *va* «яисә; я». Бу сүз гар. дә кергән һәм Коръән телендә кулланыла һәм, ихтимал, төрки телләргә гарәпчәдән кергәндер.

**ВӘГАЗЬ [wәғәз]** «проповедь» < гар. *wӓʻӓẓ* id. К. иске тат. **вагыйзь** «вәгазь сөйләүче, вәгазьче».

**ВӘГЪДӘ [wәғдә],** себ. (ЗДС: 148) **wәтә** «обещание», «наречение» < гар. *wӓʻдӓ-т* id.; тат. сөйл. **вәгадә**, башк. *вәғәҙә* (*wәғәҙә*), чув. диал. *вахате* «вәгъдә» < *wәғәдә* «вәгъдәләр».

Дерив.: **вәгъдәле; вәгадәле (яр); вәгъдәсез** (сүзендә тормаучан); **вәгъдәләш-ү;** себ. **вәтәлә-ү** «ялган вәгъдәләр бирү».

**ВӘЗАРӘТ [wәзарәт]** «министерство». Шәрык илләрендә кулланылган бу сүз гар. телендә *wзр* тамырыннан, асылда *wӓзūр* сүзе нигезендә ясалган. Чаг. **Нәзарәт.**

**ВӘЗЕН [wәзӗн]** «стихотворный размер» < гар. *wӓзн* id. *wзн* «үлчәү» тамырыннан. К. **Вәсвәсә.**

**ВӘЗЕРКӘ [вәзӗркә]** (ЗДС: 148) диал. «женщина сухопарая, с тонкими членами тела». Рус. диал. *назерка* id. Телара аттракциянең кызыклы мисалы.

**ВӘЗИР [wәзир]** «везир, премьер-министр» < гар. *wäзӣр* id., төп мәгънәсе «авырлык күтәрүче» *wзр* «авырлык күтәрү» тамырыннан; ләкин бу тамыр үзе икенчел – **вәзир**дән «алынган», *вәзир* исә фар. *вәзенгир* «авырлыкны алучы» дигәннән, әмма *вәзен* «авырлык; үлчәү» – гарәпчәдән. Шулай итеп монда сүзләр гарәпчәдән фарсычага кат-кат күчкән. К. **Вәзарәт, Вәзен.** Будагов II: 304; Тимергалин: 109.

**ВӘЙРАН [wәйран]** «развалины; в развалинах» < фар. *wӣрāн, wäйрāн* id.

Дерив.: **вәйранлык; вәйранлан-у.**

**ВӘКАРЬ [wәқәр]** «степенность, серьёзность» < гар. *wäқāр* id.

Дерив.: **вәкарьле, вәкарьлек.**

**ВӘКИЛ [wәкил]** «представитель» < гар. *wäкӣл* id., «чыгыш ясаучы; алга чыгучы» ← *wкл* «алга чыгу», шуннан ук **вәкаләт** (дөресрәге **вәкяләт**) < гар. *wäкалäт* «вәкиллек хокукы» (**вәкяләтле** «вәкяләте булган, хокуклы»); к. ш. ук **Тәвәккәл.**

Дерив.: **вәкилле, вәкилсез; вәкиллек.**

**ВӘЛ [вәл, wәл]** «пуховый платок; шаль-паутинка» < рус. *вуаль* (к. ТТДС I: 114).

**ВӘЛӘКИН [wәлә́кин]** «однако» < гар. *wә* + *ләкин*, к. **Вә** һәм **Ләкин.**

**ВӘЛИГӘ,** (ТТДС I: 112) **варига** «варежки» < рус. сөйл. *варега* id., Фасмер (I: 274) фикеренчә, «варяг бияләе».

**ВӘЛҮК** «валёк (поперечника при запряжке лошадей попарно)» < рус. *валёк* id., к. ш. ук **Бәләк.**

**ВӘРНӘ-Ү** (миш., ТТДС I: 112) «плакать, стонать (о животных)» ~ чув. *йĕр-* id., *йĕр* «елау (күренеше)». Табышмаклы сүз.

**ВӘСВӘСӘ [wәсwәсә]** «искушение; соблазн» < гар. *wäсwäсä* < *wäзwäзä* id., төп. мәгъ. – «үлчәүнең тигезләнмичә торуы», к. **Вәзен.**

Дерив.: **вәсвәсәле, вәсвәсәсез; вәсвәсәче; вәсвәсәлән-ү.**

**ВӘССӘЛАМ [wәссәләм]** «и привет! вот и всё» > мар. (Гордеев I: 57) *вäссäлäм* id. < гар. *wä äссäлāм* «һәм сәлам – бүтән сүзгә урын юк».

**ВӘТ [вәт]** «вот», (Махмутова: 236–237) **вата, ваты, вытa** диал. «вот это» < рус., әлбәттә.

**ВӘХШИ [wәхши]** «дикий; дикарь» < гар. *wäхшӣ* id. ← *wäхш* «кыргый җирләр»; шуннан ук әд. **вәхшәт** «кыргыйлык, вандализм».

Дерив.: **вәхшилек; вәхшилән-ү.**

**ВИЛАЯТЬ [wилайәт]** «провинция; губерния» (к. Будагов II: 307–308) < гар. *wилāйäт* id. ← *wлй* «тәэмин итү», шуннан ук к. **Вали.**

**ВИСА [виса],** (ТТДС I: 113) **вис** диал. «весы полевые» ~ чув. *виçе, визä*, удм. *вес*, мар. *виса, вися, вичя* < рус. диал. *висо* id. (Гордеев II: 111). Әгәр **весы** сүзеннән булса, тат. *висый* булыр иде.

Бу сүзне чув. *виç-* (< *öлч-*) «үлчәү» сүзеннән диючеләр бар. Räsänen 1969: 371; Федотов I: 126.

**ВӨҖДАН [wөҗдан]** «совесть» < гар. *wуҗдāн* «тыныч күңел; актив тынычлык; шатлыклы иминлек» ← *wҗд* «тырышып эзләү һәм табу». Будагов I: 303. К. **Вөҗүд.**

Дерив.: **вөҗданлы, вөҗдансыз.**

**ВӨҖҮД [wөҗүт]** «сущее, сущность; бытие; существо, существование» < гар. *wуҗӯд* id. ← *wҗд* «тырышып табу (табылу), бар булу (ителү)», шуннан ук иске әд. **мәүҗүд** «…дән тора; бар, булган».

Дерив.: **вөҗүдлек**.

# Г

**Г** хәрефе кириллица нигезендә татар алфавитында өч авазны – *ғ, г* һәм *г'* авазларын белдерә. Болардан урта *г* башлыча рус теленнән һәм рус теле аша кергән сүзләрдә очрый (сирәгрәк фар. сүзләрендә дә булгалый, мәс. *гөнаһ, гүаһ, гяһ*).

Каты *ғ* авазына тат. телендә башлыча гар. теленнән кергән сүзләр башлана. Ул гар. сүзләренең бер өлеше оригиналда ноктлы *ғ* хәрефенә, бер өлеше ноктасыз ʽга башлана һәм соңгылары гарәпчәдә вә Урта Азия, Төркия телләрендә гомумән әйтелми дә. Татарлар гарәп сүзләрен күбесенчә китаптан, язылыштан үзләштергәннәр һәм ике *ғ* (*ʽайн, ғайн*) ны яңгыратып әйтәләр. Тик кайбер сөйләшләрдә, бигрәк тә мишәр сөйләшләрендә ул авазлар гомумән төшерелеп калдырыла, мәс., *аеп* < *ғаеп, айшык* < *ғыйшыk, арьләнү* < *ғарьләнү* һ.б. Һәм монда билгеле бер кагыйдә юк. Йомшак *г* авазына гар. сүзләре гомумән башланмый, әмма фарсы сүзләре башлана һәм еш кына.

Русчадан алынган сүзләрдә каты – (гарәпчә) *ғ* – принципта юк дип әйтергә мөмкин. Тик кайбер, халык үзенчәрәк аңлаган рус сүзләре генә каты *ғ* белән әйтелә.

**ГАВАМ [ғаᵒwам]** «масса; чернь» < гар. *ғawāм*, ГТРС: 63; Тимергалин: 113.

**ГАДӘЛӘТ, гадаләт** кит. «справедливость, равноправие» < гар. *ʽадāлāт* id. К. **Гадел**.

**ГАДӘТ** «обычай, адат» > мар. диал., удм. диал. *гадат, гäдäт* < гар. *ʽадāт* id., к. ГТРС: 65.

**Гадәт** продуктив нигез: **гадәтлән-ү, гадәтле, гадәтсез, гадәтчел; гадәтән** «гадәте буенча» гарәпчәдән булса, **гадәти** тат. телендә ясалган булса кирәк.

**ГАДЕЛ** «справедливый; честный», иск. диал. «справедливость» > удм. *гадель,* мар. *гäдел, äдыл*, чув. диал. *хатĕл* id. < гар. *ʽадл* id. (ГТРС: 64). Тат. *гадел* сыйфаты *гаделле* сүзеннән эллипсис яисә иске тат. < гар. *ʽāдил* «гадел» (сыйфат). К. **Гадлия.**

Дерив.: **гаделлек.**

**ГАДИ** «обычный, обыкновенный, простой» < гар. *ʽāдū* id. (к. ГТРС: 64). К. ш. ук уйг. *гаддий, аддий*, үзб. *оддий* (*addij*) һ.б.

**Гади** продуктив нигез: **гадилән-ү, гадиләш-ү, гадилек, гадичә** һ.б.

**ГАДЛИЯ [ғәдлийә]** «юстиция» < гар. *ʽадлийä* id. (к. ГТРС: 64). К. **Гадел.**

**ГАДЕН** «Эдем; Аден – портовый город в Йемене»; **гаднән** (Һ. Такташ) «җәннәттәй (табигать тур.)» < гар. *ʽаднāн* «оҗмахтагыча». К. ГТРС: 64.

**ГАЕП [ғәйеп]** «ви́на» > мар. *гаеп* < гар. *ʽайб* id., *ʽабä* «шелтәләү» тамырыннан.

**ГАЕП-ГАРӘТ** «злое, чрезмерное осуждение». **Гарәт** «дошманча, талаучыл мөнәсәбәт», гарәпчәдән, к. ш. ук **Күзәрәт.**

**ГАЕТ [ғәйёт]** «праздник (религиозный), празднество» < гар. *ʽайд-ун*, фар., төр. *ид* дип кенә әйтелә. К. Будагов I: 769 (тәфсилле матдә).

Гар. *ʽūд* тамырын лат. *id-us* < *vid-us* «ай уртасы (бәйрәме)» белән чагыштыралар.

**ГАҖӘЕП [ғәҗәйёп]** «чудный» < гар. *ʽаҗāʼиб* id. *ʽаҗūбә* «гаҗәпләндергеч» сүзенең күп. формасы.

**ГАҖӘП [ғәҗәп],** уст. **гаҗип** «удивительный» < гар. *ʽаҗāб* id. *ʽҗб* «гаҗәпләнү, аптырау» тамырыннан. К. ш. ук иске тат**. гаҗәбә!** «бу ни хәл?»←

Дерив.: **гаҗәплек; гаҗәплән-ү, гаҗәпсен-ү.**

**ГАҖИЗ [ғәҗиз]** «беспомощный; в безысходности; в тупике; в удивлении» < гар. *ʽāҗиз* «ярдәмсез». К. **Могҗиза.** Будагов I: 756.

Дерив.: **гаҗизлек; гаҗизлән-ү.**

**ГАЗАВАТ** «(справедливая) война» < гар. *ғазäwāт, ғазwä* «хәрби сәфәр» сүзенең күп. формасы ← *ғзw* «(дин өчен) сугышу», шуннан ук иске тат., гом. мөселман. *ғāзи* «сугышта катнашучы». Тимергалин: 115.

**ГАЗАП [ғаᵒзап]** «страдание, страдания, гнев от страданий» < гар. *ʽаẓāб* id. К. **Азап.**

Дерив.: **газаплы, газапсыз; газаплан-у.**

**ГАЗӘЛ [ғәзәл]** «газель, любовное стихотворение определённой формы (4–15 строф на одну рифму)» < гар. *ʻазӓл* id.; **газәл** «газель, горная антилопа как символ стройности тела, красоты движения и глаз» < гар. *ʻазӓл* – икесе дә *ʻзл* «мәхәббәт җыры, озын серенада җырлау < җеп эрләү» тамырыннан. К. Redhouse: 389.

**ГАЗИЗ** «дорогой; почитаемый» (мөәннәсе **газизә**) < гар. *ʻазӣз, ʻазӣзӓ* id. *ʻзз* «көчле вә хөрмәтле булу» тамырыннан, шуннан ук к. **Гыйззәт.**

**ГАЗРАИЛ** «ангел смерти» < гар. (к. МНМ I: 488) *ʻазрā'ил* id. Газраил образы Идел-Урал халыкларында (к. чув. *эсрел,* мар. *азырен*) трансформация кичергән.

**ГАИД** иск. «относящийся к» < гар. *ʻā'ид* id. Төрки яз. әд. телләрдә *аид* id. *Бу мәсьәләгә гаид фикерләр...* диелә.

**ГАИЛӘ** «семья» < гар. *ʻā'илӓ* «гаилә; туйдырылмыш, тәрбияләнмешләр» *ʻалӓ* «туйдыру, асрау, тәрбияләү» тамырыннан, шуннан ук тат. диал. **айал, айәл** < *ʻайӓл* «хатын, бичә». Тимергалин: 116.

Дерив.: **гаиләле, гаиләсез;** сирәк **гаиләви.**

**ГАИП** «неизвестно где; исчез» < гар. *ғā'иб* «юкка чыккан, күз алдында юк» ← *ғиб* «юк булу». Бу сүз **гаеп**кә тамырдаш түгел.

**ГАЙБӘТ [ғәйбәт]** «сплетни, хула» < гар. *ғайбӓт* id., *ғйб* «булмау, күренмәү» тамырыннан. **Гаеп** сүзе миш. диалектында (бүтән төрки телләрдәге кебек үк) *ғ* сыз кулланыла: **айып** > мар. *аип, аеп,* чув. *айӑп* «гаеп, гаепләү».

**ГАЙРӘТ** «энергия; энергичность; предприимчивость» < гар. *ғайрат* id. *ғӣр* «төрле җирдә (читтә) йөрү, йөреп тору» тамырыннан, шуннан ук к. **Гайре, Гайяр.**

Дерив.: **гайрәтле, гайрәтсез; гайрәтлән-ү.**

**ГАЙРЕ, гайри** «кроме, без-, не-» < гар. *ғайри* «читтә йөрүче» ← *ғӣр* «читтә йөрү» (к. **Гайрәт, Гайяр**). Тимергалин: 117.

**ГАЙЯР,** диал. **аяр, әйәр** (к. ЗДС: 78) «энергичный; предприимчивый, хитрый» < гар. *ғаййāр* id. **Гайрәт** сүзе белән тамырдаш. Элекке ислам дәүләтләрендә **гайяр** дип хөкүмәтнең махсус агентларын атаганнар (шуннан иске тат., диал. **аяр** «усал, явыз; гангстер»).

**ГАКРӘП [ғәкрәп]** «скорпион; созвездие и месяц скорпиона (23 октября – 22 ноября)» < гар. *ʻақраб* id., ш. ук «сәгать нәйзәсе, угы, пушка тәгәрмәче», күч. «вакыт үтүе, картаю».

**ГАЛАНКЫ** «печь, обитая жестью» < рус. *голанка, голландка* (голландская печь). К. Фасмер I: 427.

**ГАЛӘМ [ғәләм]** «вселенная; галактика» < гар. *ʻалӓм* id., ш. ук «бөтен халык, масса», *ʻлм* «белге, белгеләнү» тамырыннан, шуннан бик күп сүзләр ясалган һәм алар тат. теленә дә кергәннәр, к. **Әләм, Галәмәт, Галим, Гыйлем, Голәма, Мәгълүм, Мөгаллим, Тәгълим.** К. Будагов I: 765–766.

**ГАЛӘМӘТ [ғәләмәт]** «знак, признак; большое событие; нечто удивительное, достопамятное» < гар. *ʻалāмӓт* id. К. югарыдагыны.

**ГАЛИ** «великий, высокий (о деяниях, помыслах, чувствах)» < гар. *ʻāлӣ* id., кеше исеме буларак **Гали (Галия)** < гар. *ʻалӣ*. К. **Галия.**

**ГАЛИЯ** тар. «высшее учебное заведение» – тат. әд. телендә гар. *ʻāлийӓ* «биек» сүзеннән килеп чыккан (тәүдә **мәдрәсәи галия** дигән фарсыча-гарәпчә тәгъбир була, шуннан беренче өлеше кыскартыла).

**ГАЛИМ** «учёный» < гар. *ʻāлим* id. К. **Галәм.**

Дерив.: **галимлек; галимнәрчә.**

**ГАЛЯКА [ғаᵒл'ақа]** кит. (элекке телдә, мәс., Тукайда киң кулланылган) «связь, отношение» < гар. *ʻалāқа* id. ← *ʻлқ* «асылган булу; бәйле булу». Бу тамырдан бик күп сүзләр ясалган һәм аларның кайберләре тат. әд. теленә дә үтеп кергән: *тәгъликъ* «гарәп хәрефләрен бер-берсенә тоташтырып язу ысулы»; *мөгалләкъ* «үзара баглы (әсәрләр); бер әсәргә шәрех китабы» (кайбер *мөгалләкъ*лар нигез әсәрнең үзеннән зуррак була; мәс., «Мөхәммәдия» китабына шәрехләр китабы үзеннән өч тапкыр зуррак).

Дерив.: **галякалы, галякасыз.**

**ГАМӘЛ [ғәмәл]** «деяние; (религиозная) практика» < гар. *ʻамӓл* id. (шуннан ук к. **Әмәл**) *ʻмл*

«эш, эшләү» тамырыннан, шуннан ук к. **Гамил.** Иске әд. **истигъмал** «кулланылыш, куллану».

Дерив. киң: **гамәлә, гамәлән, гамәли** – гар. телендә ясалганнар; **гамәлдә, гамәлле, гамәлсез, бигамәл** һ.б.

**ГАМБӘР [ғәмбәр],** диал. **ҫәмбәр** – имя собственное и название душистого цветочного растения (*гамбәр гөле*); «амбра» – бу халыкара таралган сүз гарәпчә «кашалот төре һәм шуннан алына торган ислемай» мәгъ. Ләкин гар. сүзе үзе каяндыр алынма. Steuerwald: 39; Тимергалин: 120.

**Гамбәр ана** – төркиләрдә, бигрәк тә татарларда киң билгеле әүлия, изге хатын, кошчылык химаячесе. Риваять буенча, Бакыргани [Бакыркяни] әүлияның хатыны, Хызыр белән Ильяска тиңләштерелгән изге егет Хөбби хуҗаның анасы, к. Кол Шәриф. Казан, 1997. Бакыргани, Гамбәр ана һәм Хөбби хуҗа XII г., Сыр-Дәрья буйларында яшәгән төрки затлар.

**ГАМИЛ** кит. «деятельный», «рабочий» < гар. *ʻāмил* id. Кирәкле сүз. К. **Гамәл.**

**ГАМЬ [ғәм]** «забота; озабоченность» < гар. *ʻамм* id. Тат. телендә продуктив нигез: **гамьле, гамьсез** һ.б.

**ГАНВӘ [ғаºнwә]** «обида; гнев» ~ диал. (Остроумов 1892: 58; ТТДС I: 117; ТТДС II: 77) **гиниwа, ғыйнаwа, гынабя** id.; мәзкүр чыганаклар бу сүзне рус. *гнев* сүзеннән дип күрсәтәләр; ләкин *ғ* авазы ук уйландыра: рус. йомшак *г* кайчан каты тамак авазы *ғ* га әверелгәне бар? Чынлыкта бу сүз гар. *ʻанwä* «рәнҗетү, җәбер» сүзеннән килә.

Дерив.: **ганвәле; ганвәлән-ү.**

**ГАНИМӘТ [ғәнимәт]** «достояние; достаток; трофей» < гар. *ғанӣмäт* id. Тимергалин: 120–121.

**ГАНКА [ғаºңка]** «баснословная птица, анка» в мусульманской мифологии, образ которой не очень определён < гар. *ʻанқā* id. Тат. диал. (ЗДС: 272) **канка** «күркә», ихтимал, **ганка** сүзеннәндер. Татарлар күркәнең сәер кыяфәтен күргәч шулай атаганнар.

**ГАРӘФӘ [ғәрәфә]** «канун» < гар. *ʻарафäт* id., *ʻрф* «белеп тору, алдан белү» тамырыннан, шуннан ук к. **Әрәпә, Гореф, Мәгариф, Мәгърифәт, Тәгъриф.**

**ГАРЕП [ғәреп]** «Запад (группа стран)» < гар. *ғарб* id. Шуннан ук тарихи мәгъ. **гарби** «көнбатышныкы». К. **Гарип, Мәгърип.**

**ГАРЕШ [ғәреш]** «престол божий; эмпиреи» < гар. *ʻарш* id. – түбәндә «кош оясы»; тат. телендә фразеологизмнарда еш очрый: *гарешкә киту* рус. «витать в облаках», *күзен гарешкә төбәп* рус. «возведя очи горе», *дәүләт гареше* рус. «цитадель власти» һ.б.

**ГАРИЗА** «заявление (официальная бумага)» < гар. *ʻарӣḍа* id. К. **Гаруз, Гарыз.**

**ГАРИП [ғәрип]** «калека» < гар. *ғарӣб* «читтән килгән яисә читтә йөрүче кеше, килмешәк; мескен; кызганыч, гыйбрәтле хәлдәге бәндә» *ғрб* «читтә йөрү; олагу; кояш баю», шуннан ук **гарби** «көнбатышныкы; Европаныкы». К. **Гареп, Горбәт, Мәгърип.**

Гар. **гариб** сүзенең күп. формасы **гараиб** «гаҗәпләнерлек» мәгъ. кулланыла (*гаҗаиб вә гараиб хәлләр*).

**ГАРУЗ** «аруз-просодия стиха» < гар. *ʻарӯḍ* «гаруз; дүртьюллык шигырьнең икенче юлы» – төп мәгъ. «катнашлык, катнашлыгы булу». К. **Гарыз.**

**ГАРЫЗ** «прошение, обращение; географическая широта» < гар. *ʻарḍ* id. ← *ʻрḍ* «катнашу, тию» тамырыннан, к. ш. ук **Гариза, Гаруз.** К. иск. *гарзы халь* «авыр хәлдә булу; үтенеч».

**ГАРЬ [ғәр]** «бесчестие, стыд» < гар. *ʻāрр* id. **Гарь** сүзе тат. телендә актив кулланылышта булып килгән, к. дериватлары **гарьлек, гарьлән-ү, гарьчел** (бу сүзләр күрше телләргә дә кергән). К. ш. ук **Әр.**

**ГАСАБИ** «нервный; озлобленный» < гар. *ʻаṣабӣ* id. ← *ʻаṣаб* «нервы, үзәк». К. **Асаба.**

**ГАСКӘР [ғәскәр]** «армия» < фар.-гар. *ʻаскäр* id.; ш. ук «бер солдат». К. **Ләшкәр.** К. ш. ук **гаскәри** «гаскәргә бәйләнешле; хәрби кеше».

**Гаскәр** сүзен бор. фар. *kasekār* «сугыш кешесе» сүзеннән дип уйлыйлар: *kase* «кеше, шәхес», *kār* «сугыш, җәң». Ләкин бу сүз гар. теленә кереп, гарәп формаларын алган. Көньяк-көнб. Азиядә **гаскәр** сүзе *аскäр, аскер* яңгырашында киң таралган. Рус. *аскер* «төрек солдаты» – экзотизм.

**ГАТЫРША** «вид духов; герань» < фар. *ʻатри шāһ* «хушисләрнең шаһы» сүзеннән: гар. *ʻатр* «хушбуй» (шуннан иске әд. **гаттар** «парфюмер»), фар. *шаһ* «шаһ».

**ГАУ [ғаᵒw]** «шум ссоры; шумная ссора» < фар. *ғаw* id. < авест. *gau* «хахылдап көлү; дер селкетү» (Morgenstierne: 29).

**ГАУГА [ғаᵒwға]** «шум-гам с бранью; дрязги» ~ гом. кыпч., уйг., төркм. һ.б. *ғауға*, кырг. *қооға* id., ш. ук. «шомлы хәбәр», кр.-тат., кар., к.-балк., ком. *қауға* «сугыш» гар., фар. *ғаwғā'* сүзеннән дип аңлатыла, бу фикернең нигезе фар. *ғау* сүзе (к. **Гау**). Ләкин *ғауға, қауға* башлыча төрки телләрдә очрый, безнеңчә **гауга** төптә монг. *қау гал* «үрт, язын кау (каугал) яндыру» сүзеннән (*гал* «ут»; күчмәннәр язга чыккан яшь үлән тизрәк һәм әйбәтрәк үссен өчен зур мәйданнарны арындырып, каудан яндырганнар), фар. *ғау* белән охшашлык – очраклы, чаг. Максудида **ғалға** «гауга»: *әйләде галга мәлаик ул заман* «мәләкләр шунда шау-шу күтәрделәр». К. чув. *хавха* «очыну, каударлану; рухлану; шау-шу; көпшәк, тыгызсыз», *халхав, хавхал* «шомлы хәбәр; янгын», башк. *қауқа* «үрт; каудан; хәтәр». К. **Кауга, Каугал, Каудан.**

**Гауга** бик кулланылышлы һәм дериватлы сүз: **гаугалы, гаугасыз, гаугачыл; гаугала-у, гаугалан-у** һ.б. икенчел сүзләр. Алар күрше фин-угор телләренә дә кергән.

**ГАУРӘТ [ғәwрәт]** «срамные части тела» < гар. *ʻаwрат* «гаурәт; зәгыйфьлек; женси органнар; хатын-кыз» *ʻwр* «һәлак итү» тамырыннан.

**ГАФИЛ** «беспечный, нерадивый, небрежный; беспечно» < гар. *ғāфил* id. *ғфл* «саксыз, моңсыз булу» тамырыннан; шуннан ук иске әд. **ғафләт** «гамьсезлек, хәстәрсезлек».

Дерив.: **гафиллек; гафиллән-ү.**

**ГАФУ** «извинение; извините!» < гар. *ʻафw-ун* id. ← *ʻфw* «гафу итү».

**ГАҺЕТ [гәhет]** «присяга; договор» > тат. диал., башк. диал. (БТДҺ: 218) *қәһәт, қәһет* «(недобрая) клятва» < гар. *ʻаһд* «ант; йөкләмә», ш. ук «Библия, изге китап» (чаг. рус. *завет*, лат. *testamentum*).

**ГАШЫЙК** «влюблённый» < гар. *ʻāшиқ* id. *ʻшқ* «ярату, сөю» тамырыннан, шуннан ук **гыйшык, мәгъшук, мәгъшука.** Сөйләшләрдә *айшик* «гашыйк; гыйшык» сүзе киң таралган.

**ГАЯТЬ [ғайәт]** «чрезвычайно, особенно» < гар. *ғāйāт* «чик, соң дәрәҗә» *ғйй* «күтәрү» тамыреннан, шуннан ук әд. **гайә** < *гайә* «идея; иҗтимагый хәрәкәт юнәлеше, омтылышы, агымы».

**ГАЗЕТ,** сөйл. **гәзит, гәзитә, гәҗит** «газета» < рус. < ит., ит. телендә *gazetta* «саесканчык»: саескан хәбәр таратучан дип исәпләнә. К. Преображенский I: 115.

**ГӘЗ** иск. «аршин» к. **Киз.**

**ГӘЗНИЧ, казнич, казлич, казлиц,** (ТТДС I: 592; ЗДС: 152, 267) **казгылдич, казгылдый** «пастернак» < рус. *козелец* id. (тат. *кәҗә сакалы* дип тә атала), ләкин кайбер вариантлар аеруча аңлатуга мохтаҗ. к. Соболева Л.С., Крылова И.Л. Зеленая аптека Татарии. Казань, 1990: 145.

**ГӘП,** диал. **кәп** (ДС I: 112) «слово, речь, пустой разговор; беседа» < фар. *гäп, гäб* id. *гуфтäн* «әйтү, сөйләү» фигыле белән тамырдаш. **Гәп** сүзе күп төрки телләрдә очрый, хәтта як. *кэпсээ* «сөйләү; гәпләшү». К. Гаджиева Н.З., Коклянова А.А. Глаголы речи // Историческое развитие лексики тюрк. языков. М., 1961: 365–367.

Дерив.: **гәпер-ү, кәпер-ү; кәпкер, кәпчел** «сүзчән», к. ЗДС: 290.

**ГӘРӘБӘ** «янтарь» < фар. *кäһрубā* «салам тарткыч» сүзеннән (гәрәбәнең корылып вак салам сыныкларын үзенә тартуыннан) дип исәпләнелә (ЛТ II: 66). Ләкин бу этимология (ул Фирдәүсидә дә китерелә) ясалма: гәрәбәнең төп хасияте «салам тарту» түгел ич! Гәрәбәне Иран һәм Урта Азиягә элек-электән Идел Болгарыннан китергәннәр (бу турыда к. Бируни 1974: 776–778), Болгар дәүләтенә исә ул викинглар тарафыннан Балтыйк буеннан, Көнб. Двина тамагыннан китерелгән, Двина тамагы җирле халык телендә **Грива** дип аталган, шуннан гәрәбәне дә **грива** дип атаганнар. Бу **грива**дан славяннар муенсалар ясаганнар (рус. *грива* «муенса; ат ялы» шуннан) һәм ул муенсаларны акча итеп тә кулланганнар – шуннан бор. рус., хәз. укр. *гривна, гривенка* – акча һәм авырлык үлчәү берәмлеге килә; бу сүзләр Шәрык илләрендә дә таралган: *герәбәнкә, гөрәнкә* «бер кадак» (430 грамм чамасы) ~ фар. *гирванкā* id. һ.б. Кыскасы, *грива* >

*гәрәбә* һәм бу болгар сүзен фарсылар халык этимологиясе буенча үзгәрткәннәр. Чаг. ш. ук удм. *гуривесь* «гәрәбә».

Барча этимологик, тарихи һ.б. сүзлекләрдә (к. төр. İA VI: 537; EI IV: 445) төр. *kehruba,* фар. *kahruba* сүзен әлеге «салам тарткыч» мәгъ. сүздән дип аңлаталар һәм гәрәбәнең Идел Болгарыннан килгәнлеген таныйлар. Ләкин тат. **гәрәбә** яңгырашы (*г* авазына башланган вариант) искә дә алынмый. Хәлбуки нәкъ безнең гәрәбәдән Шәрык вариантлары килә, киресенчә түгел! Рус этимологик сүзлекләрендә *гривна* һәм *грива* сүзләренең бердәйлеге, *гривна* сүзенең бор. мәгънәсе «гәрәбә муенча» булганлыгы хакында әйтелгәли, ләкин Шәрык илләрендәге *каһруба* сүзенә бәйләнешы хакында ләм-мим сүз юк. Кыскасы, без монда үзебезнең оригиналь этимологиябезне бирәбез.

**ГӘРӘНКЕ,** диал. **гәрәңкә, кәрәңке, әрәңги** (к. Радлов I: 757) «брюква» > мар. *караңкы* id. < рус. *галанка* < *голландка* «голланд шалканы» к. ш. ук **Галанкы, Кәлигә.** Руслар **гәрәнке**не «немка» дип тә атаганнар (Даль). Тат. **гәрәнке** яңгырашы, ихтимал, **бәрәңке, бәрәңге** сүзенә охшатыларак килеп чыккандыр.

**ГӘРЕЧ: Гәреч юлы** одна из «дорог» (главных областей) Казанского государства – рус. *Галич* сүзеннән; *Галич* Суздаль кенәзлегенең төп шәһәрләреннән берсе (хәз. Кострома). **Гәреч юлы** – X г. бирле Скандинавия илләре белән сәүдә итү юлы булган. *Галич* > *Гәреч* күчеше монголларга кадәрге заманнарда ук пәйда булган булса кирәк, чөнки XIII г. инде Галич зур сәүдә үзәге булмаган.

**ГӘРНИЧ, гәрес** диал. «гарнец» – борак оны (к. **Порак**) < рус. Рус. *гарнец* – тәүдә нисби авырлык үлчәме < пол. *garniec* «зур чүлмәк» сүзеннән (Фасмер I: 394).

**ГӘРЧӘ** «хотя и…» < *әгәрчә* < фар. *ägärčänd* (ЛТ I: 45): *ägär čänd* «әгәр кайсы, әгәр ничә». К. **Әгәр.**

**ГӘҮДӘ [гәwдә]** «туловище, тело» > мар. *gäydä* «тело, стан» (Гордеев II: 228) ~ чув. *хевте* «мощь; силы природы; туловище», төр. *gövde*, каз., к.-калп. *геўде,* башк. диал. *кәүҙә,* нуг. *кевде* «тән» ~ төркм. *гевре* id. бу сүз фар. сүзе дип исәпләнә, ләкин хәз. фар. телендә кулланылмый; тик таҗ. гына *говдо* «гәүдә» < *говдор* «тән иясе» ← *гов* «тән» (?).

Гомумән, бу сүзнең этимологиясе катлаулы. Ул төбендә төрки сүз булырга да мөмкин. Чаг. **Кәвәрә.**

Дерив.: **гәүдәле, гәүдәсез; гәүдәлән-ү (→ гәүдәләндерү).**

**ГӘҮҺӘР [гәwһәр]** «жемчужина; перл; бриллиант» < фар. *gäwhär* id. К. **Җәүһәр.** К. чув. *кавер чул* «гәүһәрташ».

**ГЕДЕ** диал. «надменный негодяй» ~ башк. (БҺҺ III: 77) *кеҙе* id. ~ к.-балк. *гёдю* ~ төр. *gidi* «мут; кабахәт». Фар. сүзе булса кирәк.

**ГЕЛ,** диал. **гелән, келән** «всегда; постоянно; почти как» > мар. *гыль, гел,* удм. *гыль* «гел», чув. *кӗл* «очень» < угыз. (бор. төркм.) *гүл, гүлән* < гар. *күлл* «һәммә, барысы, һәрчак; бөтен», *күллäн* «барысы бергә» һ.б. К. **Гөлле.**

**ГЕНӘ** – ограничительная частица, к. **Кенә.**

**ГЕР** «гиря» < рус.; рус теленә исә фар. *геран, гиран* «авырлык; әһәмият», *герансäң* «гер ташы» сүзеннән. Себ. тат. **кийрә, қыйрә** «гер» фар. теленнән турыдан-туры килсә кирәк. Миш. (ЗДС: 250) *йирлек* < *гирлек* «герлек, гер» дә рус сүзеннән түгел сыман (чаг. **авырлык**).

Чув. *кӗр*, мар. *гырь, гер, кир, кыр,* удм. *гир, гира* «гер» русчадан да, татарчадан да таралган сүзләр. Татарларның элек-электән сәүдә белән шөгыльләнгәнен искә алу зарур.

**ГЕРӘБӘНКӘ,** диал. **герәмәнкә, гәрәңкә, гөрәңкә** «фунт»; «кадак; унтиенлек көмеш» < рус. *гривенка* сүзеннән урта гасырларда ук таралган сүз, к. фар. *гирванкä*, әрм. *грванка,* осет. (Абаев I: 519) *грибанка* id., к. ш. ук мар. *кырвэнгä, крэмка*, удм. *гирвонка* «фунт» һ.б. К. **Гәрәбә.** Шанский: 114 (*Гривенник* матдәсендә).

**ГЕРӘН** (ТТДС I: 117) «грань» (иск. «граница земельных наделов») < рус. Чаг. тат. сөйл. *гыраните*а < рус. *граница* ← *грань*.

**ГЕРДӘ: кырык гердә,** диал. (Хайрутдинова 1991: 28) **гөрнә** «маленькие слоёные пирожки, сорок штук которых ставится за дверьми в ночь перед праздником навруз, для *сорока невидимых святых*» ~ кар. *гирда*, уйг. *гирдә*, төр. *girde* < фар. *гирда* «түгәрәк», к. Остроумов 1892; Çау: 53 (тәфсилле аңлатма). К. ш. ук төркм. *гирде, гирденә* «кәрлә».

**ГЕРЕС** (ТТДС I: 117) «кровоизлияние; приступ болезни» < фар. *гūрūст, гūрūфт* «тулгак», к. **Гереш.**

**ГЕРЕШ** «достаточная вымочка льна» < фар. *гūрūш* id. *гūрдāн* «тоту, эләктерү» сүзеннән. К. **Герес.**

**ГИДАЙ** «бедняк (презренный)» < фар. *гäдāū* «ярлы; ярлылык» ← *гäдā* «ярлы; мескен».

Дерив.: **гидайлык.**

**ГИЗ** кит. «раз» бор. *гэз* «бер тапкыр урап чыгу» сүзеннән (семантик җәһәттән к. *юлы* «тапкыр»). К. **Гиз-ү, Киз-ү, Һәргиз.**

**ГИЗЛЕ** тар., диал. «скрытый, потаённый» < госм. *гизли* id., к. **Кизлә-ү.** ЭСТЯ III: 43.

**ГИЗ-Ү,** диал. **киз-ү** «бродить; делать экскурсию (получая удовольствие от лицезрения); странствовать» < төр. *gez-* id. (төр. телендә бу сүзнең мәгънәләре күбрәк) < гом. төрки, бор. төрки *kez-* ~ бор. монг. *kerü, keri*, кор. *ketta* (< **kerta*) id., к. Ramstedt 1949: 109. К. ш. ук чув. *кас-* «гизү, урап килү», тув. *кез-* «капкыннарны карап, урап килү», *кези-* «гизү», як. *кэри-* «капкыннарны карап чыгу» (< монг.) һ.б. К. ЭСТЯ III: 11. Хәз. монг. *хэсэх* «гизү» сүзе дә бар. К. **Кизген, Киздер-ү.**

**ГИСЕР: гисер чүлмәге** (М. Гайнетдинов) миш. «огромный кувшин (для хранения муки, зерна)» < монг., бур. *Гэсэр* – монг. халыкларының иң атаклы эпик герое. **Гисер ~ Гәсәр** тур. әкиятләр татарларда да булган.

**ГОЗЕР [ғөзөр]** «извинительная просьба; мольба» < гар. *ʿуẓр* id. *ʿẓр* «кичерү, аклау; ялыну» тамырыннан. Шуннан ук иске тат. **мәгъзур** «нәрсәдер сорап, үтенеп йөрүче».

Дерив.: **гозерле, гозерсез; гозерлән-ү.**

**ГОЛӘМА [ғөләма]** «(религиозная) интеллигенция; улемы» < гар. *ʿулäмā* «галимнәр» ← *ʿāлим* «галим»нең күп. формасы. К. **Галим.**

**ГОЛТ** – подражание бульканию жидкости в горле: **голт-голт (итеп)** «громко булькая горлом (о глотании, питье)»; к. ш. ук **голдыр-голдыр** күркәләрнең характерлы тамак авазлары тур.; **голдырда-у** – характерлы авазлар чыгару. Чаг. кырг. *қылт,* үзб. *қулт,* фар. *қӯлт* id., рус. (Аникин: 242) *колтать* «гол-голт йоту».

**ГОМЕР [ғөмөр],** диал. **өмөр, үмер** «век; жизнь» > чув. *ĕмĕр* «гасыр», удм. *гумър*, мар. *гүмыр, гумир, үмүр* < гар. *ʿумр* id. *ʿмр* «яшәү, яшәп тору» тамырыннан, шуннан ук к. **Гыймарәт,** иске әд. **мигъмар** «төзүче, архитектор» һ.б. күп сүзләр. Ахметьянов 1989: 15.

Дерив.: **гомерле, гомерсез, гомерлек, гомер-гомергә** һ.б., диал. **гомерлән-ү** «озак бергә яшәү». Элек (мәс., Дәрдемәнд телендә) **гомер** «гасыр» мәгъ. (рус. *век* «гомер; гасыр» сүзеннән калька) булган.

**ГОМУМ** «обще- (в сложных словах)» < гар. *ʿумӯм* «гомумилек, универсальлек» сүзеннән, *ʿмм* «уртак булу» тамырыннан, шуннан ук әд. **гаммә** «масса», **гавам** «гади халык» аеруча киң кулланышлы **гомумән.** К. түбәндәгене.

**ГОМУМИ** «общий» < гар. *ʿумӯмū* id. К. **Гомум.**

Дерив.: **гомумилек; гомумиләш-ү** (→ **гомумиләштер-ү** һ.б.). Тат. әд. телендә **гомуми** сүзенең мәгънәсе русча *общий* сүзенә тәңгәлләштерелеп, артык киңәйтелгән. **Гомумән** кереш сүзе гар. теленнән.

**ГОНВАН [ғонwан]** «титул» < гар. *ʿунwāн* id.

**ГОРБӘТ [ғөрбәт]** «чужбина» (**горбәттә** «на чужбине, вдали от Родины») < гар. *ғурбäт* id. К. **Гарип.**

**ГОРЕФ [ғөрөф]** «народный обычай» < гар. *ʿурф* id. *ʿрф* «белү, тану» тамырыннан, шуннан ук к. **Гарәфә, Мәгариф, Мәгърифәт** һ.б. бик күп сүзләр.

Дерив.: **горефле, горефсез.**

**ГОРРӘ [ғөррә]** «гороскоп; гадание по новолунию» < гар. *ғурра-т* id. *ғрр* «яктылыгы белән сукырайту, күз камаштыру» тамырыннан, к. **Горур.**

Дерив.: **горрәлек, горрәнамә** «гороскоп, юрау календаре».

**ГОРУР** «гордый» ← *горурлы* сүзеннән эллипсис, к. гар. *ғурӯр* «горурлык» ← *ғрр* тамырыннан, к. **Горрә.**

Дерив.: **горурлык; горурлан-у.** К. ш. ук **Мәгърур.**

**ГОСЕЛ [ғөсөл]** «ритуальное омовение и умащивание» < гар. *ғусл* id. *ғсл* «баллану» тамырыннан. Шуннан ук иске тат. **гасәл** «бал».

**ГОШЕР [ғөшөр]** «десятая часть урожая, отдаваемая на благотворительность» < гар. *ʻушр* id. *ʻшр* «унынчы булу» тамырыннан, шуннан ук **гашүрә** – дини бәйрәм – мөхәррәм аеның унынчы кичәсе.

**ГӨБӘДИЯ,** (ЗДС: 156) **гөлбәдийә** «пирог со сложной начинкой» < фар. *гүлибӓдиӓ* id. < *гүли бӓдиһӓ* «розаның бер төре».

Розага охшатып камыр ашлары пешерү фарсы кухнясы традициясеннән. К. **Гөлбәнәк, Гөрәбия.**

**ГӨБЕ [гөбө],** диал. (ТТДС I: 120–121, 273) **гөбән, гөбөн** (*гөбән кебек – гөбе кебек шешенү*), **көбә, көбө, гәбе** (*гәбе атлау, гәбе язу*, ДС II: 74) «маслобойка – высокий цилиндрический сосуд, пахталка из цельного ствола дерева», диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) **көбе** «длинный цилиндр, надеваемый на столб, на который наматывается канат для поворота рабочей части ветряной мельницы» < гом. кыпч. **күби*, к. нуг. *күби,* каз. *күбби*, кырг. (Юнусалиев 1971) *гүвү,* үзб. (ЎХШЛ: 151) *куви, күпи, күби, гүппи*, алт. *күп* «гөбе», аз. (АДДЛ: 275) *күпи* «шүре, камыш көпшә», төркм. (ТДГДС: 69) *күпи, гүпи, күфи* «көбәк; гөбе» ~ венг. *köpü* «гөбе». К. удм. *гумы,* коми. *гум, гуми* ~ фин. *kääti* «көпшә, көбәк; цилиндр» һ.б. бор. **күбү* «үзәге алынган кәүсә» сүзеннән; шундый кәүсәдән элекке хуҗалыкта һәртөрле савытлар, торбалар һ.б. ясаган. Бу тамырга тоташкан сүзләр төрле фин-угор, монг., ир. һ.б. телләрдә дә очрый. К. **Көбәк, Көпчәк, Көпшә.** Рус. диал. *куп* «гөбе» тур. Аникин: 324 (уйг., төр. *küp* ~ фар. *күп* «чүлмәк» сүзләрен дә китерә. Безнеңчә, болар икенче тамырдан, к. **Купы**). КЭСК: 82.

**Гөбе** азмы-күпме ышандырырлык ностратик сүзләрнең берсе. Безнеңчә, ул мәдәни сүз генә – Евразиягә сәүдә юллары буйлап таралган. Шунысы игътибарга лаек – чув. телендә бу сүзнең чагылышы һәм хәтта берсүзле эквиваленты да юк.

**ГӨБЕР [гөбөр],** диал. **гөбәр** «ворс», диал. (себ. һ.б.) **көбир, күбүр** «мүк» (ДС I: 47; Тумашева 1992: 100; Дмитриева 1981: 160 һ.б.); шуннан **гөберкә** «мүкләч тап», **гөберле бака**. **Гөбер** сүзенең бүтән телләрдәге багланышлары табышмаклы: бер яктан, к. осет. *гӧбӧр* «таз, чиләнеп торган яра», төр. *gübre*, каз. *кӧбүр* «тирес, черек»; икенче яктан к.-балк. *күбүр* «тартма, күн сандык» < бор. *көпүр* «елгалар кичү өчен кулланылган тире капчык» (к. **Күпер**) > кырг. *күбүр* «өсте боз кисәкләре белән чуарланган сулык», өченче яктан монг. *губерь* «ламаларның йон пончосы» (к. Бичурин: 194).

**ГӨБЛӘ, гөбелә, көбелә** «мелкий кузнечик», «тля» – **күбәләк** белән бердәй булса кирәк. К. **Күбәләк.**

**ГӨЖ –** подражание шуму пчёл, мух, а также множества людей и т.п. Шуннан: **гөжлә-ү, гөжелдә-ү, гөж килү** һ.б. Параллельләре мар., удм. телләрендә очрый.

**ГӨЛ,** диал. **гел,** (Тумашева 1992: 101, 107) **көл, күл** «декоративный цвет (растение)» > чув. *кӗл*, мар. *гыль, гел*, удм. *гыль* < фар. *гүл* < бор. фар. *varedha* (Platts II: 911). Будагов II: 132.

*Гөл* < *гүл* сүзе нигезендә фар. телендә бик күп (йөзгә якын) кушма сүзләр ясалган, шуларның дистәләбе тат. теленә дә кергән, к. түбәндәгеләр.

**ГӨЛӘНДӘМ** «букет (роз)» < фар. *гүл ӓндāм* «гөл бәйләме».

**ГӨЛӘП** «роза; шиповник» < фар. *гүли āб* «роза суы, суландыру розасы» – роза суы белән авыруларга дару биргәннәр; гөлҗимеш суы үзе дә бик шифалы. Рус. *гуляб* тур. Будагов I: 139.

**ГӨЛБАДРАН** «пижма» < фар. *гүли бӓдран* «айсыман гөл (чәчәк)»; ихтимал, бу сүз-исем икенче бер үсемлеккә бирелгән булгандыр.

**ГӨЛБАКЧА** «цветник, сад цветов» – тат. телендә ясалган: **гөл + бакча.**

**ГӨЛБӘНӘК** «печенье в виде розы» < фар. *гүл бӓндак* «гөл бәйләме» яки *гүли бәнәк* «миңле гөл». Фар. телендә ашамлык атамаларында еш кына *гүл* «гөл» сүзе очрый.

**ГӨЛБӘЧ,** диал. **гөлбәс, гөлбеч, гөлбәчте** (ДС II: 74), **гүлбич, гүлбис** (БҺҺ II: 65) «голбец; подполье» < рус. Бу сүз тәүдә мөгрәп өслеген белдергән: аның ишек өстенә *голубь* «күгәрчен» сурәтен ясап куйганнар: *голбец*ның рус. диал. вариантлары *голубец, голубица,* к. Уч. зап. Рязанского ГПИ, № 10, 1955: 121–123.

Удм. *гулбеч,* мар. *гӧлвеч* «гөлбәч» рус теленең үзеннән булса кирәк.

**ГӨЛБОСТАН** «цветник; цветущая страна» < фар. *гули бустāн* «гөл басуы».

**ГӨЛГЕН [гөлгөн]** тар. «лошадь одной ровной масти с ног до головы (на такой лошади ездили принцы и принцессы)» < фар. *гулгун, гулли гун* id.: *гулли* «гөлле, бертөрле» (к. **Гөлле**), *гун* «ат төсмере». «Хөсрәү вә Ширин» романында **Гөлгөн** – Шириннең аты. Ихтимал, *көлөн* (к. **Көлкәй**) «яшь колын» сүзе дә *гөлген* нигезеннәндер. Колыннар яңа туган мәлләрендә тигез бер төстә булалар. Будагов II: 132; Özön: 266 (*гулгун* «гөл төсендә» ди).

**ГӨЛДӘСТӘ** «маленький букетик; букет роз», тар. «сборник стихов» ~ төр. *güldeste* «антология». Фар. теленнән, к. **Гөл** һәм **Дәстә.**

**ГӨЛЕСТАН I** «цветущая страна» < фар. *гулистāн* id.

**ГӨЛЕСТАН II** «гусли» (к. ТХИ: Дастаннар 1984: 131–133) < фар. *гусадан, кöсалдан* id., төп мәгъ. «кыллар кысасы (савыты)». Тат. дөресе – **гөселдан.**

**ГӨЛҖИМЕШ** «шиповник» – тат. теленең үзендә ясалган: **гөл + җимеш.**

**ГӨЛЗАР** «питомник лечебных трав (цветов)» < фар. *гулзāр* id.

**ГӨЛЛӘЧ** диал. «гуляш, суп с клёцками (в виде розы)» < төр. *gülleç, güllaç* id. Бу сүз төр. теленнән венг. теленә, венгерчадан русчага *гуляш* рәвешендә кергән. Özön: 266.

**ГӨЛЛЕ [гөллө],** диал. **көлле** «все вместе» < фар. *кулли* ← гар. *куллāн* id. Бу сүз күрше мар., удм. телләренә (< тат., әлбәттә) кергән. К. **Гел.**

**ГӨМАН** «предположение» < фар. *гумāн* < авест. *vi-тапаnh* «икеле уй; фараз» сүзеннән. К. **Көмән.**

**ГӨМБӘ** «гриб» ~ башк. (БТДҺ: 151) *көмбә,* чув. *кăмпа,* удм. *губи,* коми. *гоб* «ашарлык гөмбә» ~ рус. *губа* «гөмбә; буа болыты (*губка*)» – киң таралган сүз: венг. *gömb* «шар», литв. *gumbas* «оры, шеш», пушт. *xomba,* талыш. *гобалай* «гөмбә» һ.б. (бу сүз тур. әдәбият шактый). Morgenstierne: 96; КЭСК: 76–77; Федотов I: 253; Аникин: 169–170 (бу әсәрләрдә *гөмбә* һ.б. тур. төрле бәхәсләр яктыртыла).

Дерив.: **гөмбәле; гөмбәлек; гөмбәчек; гөмбәлә-ү.**

**ГӨМБӘЗ** «купол» < фар. *гунбä, гунбäд* «гөмбәз; пирамида; кирмән башнясы». Асылда бор. Мисыр теленнән таралган, к. ш. ук төр. *kümbelti, kümbet* «гөмбәз, түгәрәк калкулык» һ.б. (күп төрки телләрдә очрый). Özön: 267.

Дерив.: **гөмбәзле; гөмбәзлә-ү.**

**ГӨНАҺ,** сөйл. **гөнаһа, гөнаһы,** диал. (крш.) **гонага** «грех, грехопадение» > мар. (Гордеев II:) *гунах, гунаге, хöнах* < фар. *гунāһ* < бор. фар. *vanāh* id. ← авест. *nāš* «урлашу». Будагов II: 138–139; Platts: 916.

Дерив.: **гөнаһлы, гөнаһсыз; гөнаһлан-у; гөнаһкяр.**

**ГӨНӘФШӘ** «вид фиалки» < фар. *гун äфшан* «нурчәчәр», «гөнәфшә», *гул äфшан* «гөлчәчәр».

**ГӨП** подражание глухому удару или падению тяжёлого предмета > мар. (Гордеев II: 239) *гöп* һ.б. Шуннан **гөп-гөп, гөпелдә-ү.** Чаг. рус. *гоп* id. (ш. ук сикереп төшүне белдерү ымлыгы).

**ГӨПӘШ, гөбәш** (ТТАС I: 286) «толстяк с коротким туловищем» ~ төр. *gebaš* id. Чаг. гар. *kebaš* «тукмак».

**ГӨР, гөр-ү –** подражание раскатистому шуму, грохоту, грому ~ чув. *кĕр* id.; шуннан: **гөр-гөр, гөрел-гөрел, гөрелдә-ү** һ.б. К. **Гөрелте, Гөрләвек, Гөрлә-ү I.** Бу сүзләр күрше телләргә дә таралган, к. Гордеев II: 248, 250.

**Гр, гүр** һ.б.ш. авазлар барлык телләрдә охшаш күренешләрне белдерә, к. рус. *гром, грохот, греметь,* ним. *grell, groll* һ.б.

**ГӨРӘБИЯ** «вид слоёного печенья» < фар. *гули рабиййа* «гөрәбия; розаның дүрт лепелдәкле төрчәсе». *Рабиййа* «дүртлекле» < гар. Чаг. **Гөлбәнәк.**

**ГӨРӘНКЕ, гөрәнкә** «фунт; совок для муки (объёмом в один фунт)» ~ чув. *кĕренке* id. К. **Герәбәнкә.**

**ГӨРЕҖДӘ [гөрөждә]** «груздь» < рус.; тат. телендә бу сүзнең фонетик вариантлары күп (ТТДС I: 122; БТДҺ: 74).

**ГӨРЕЛТЕ [гөрөлтĕ]** «многоголосый шум; звуки далёкого грома» – **гөрелдә-ү** сүзеннән оригиналь ясалыш; морфологик җәһәттән караганда – «үтеп киткән күкрәүнең калдыгы, соңгысы» ← **гөр-ү* «гөрләү» фигыленнән. Чаг. төр. *gürültü* «гөрелте, шау-шу», *gürül* «гөрелдәү авазы», *gür* «гөр».

**ГӨРЛӘВЕК [гөрләwĕк]** букв. «журчалка» – «ручеёк» > чув. *кĕрлевĕк, кĕрленкĕ*, мар. *гĕрлӓук, гĕрлек* (Гордеев II: 250) һ.б. **гөрлә-ү** сүзеннән, әлбәттә.

**ГӨРЛӘ-Ү I** «шуметь; журчать, ворковать; весело гулять» – *в отличие от* **Гөрелдә-ү** *обозначает менее спонтанные звуки* ~ чув. *кĕрле-*, мар. *гĕрлӓ-*, удм. *гурла-* id. тат., башк. *гөр,* мар. *гĕр,* чув. *кĕр* тәкълиди сүзеннән (*-гр-* гомумән гөрләү, гөрелдәү тавышын белдерә, к. рус. *греметь, гром, гроза, грохотать*, удм. *гур* «көй; елау», эвенк. *кўрэлэндэй* «гөжелдәү»).

**Гөрләү**нең актив кулланышлы дериваты – **гөрләш-ү.** К. ш. ук **Гөрләвек.**

**ГӨРЛӘ-Ү II** «водить в игре в прятки» ~ башк. (БТДҺ: 74, 154) *гөрҙә-ү, көргөлдә-ү,* мар. *кургулӓ-* id. Чаг. ш. ук *гөр-гөр уйнау* ~ морд. Э. *гурь-гурь бабаса-* «уенда гөрләү (качышлы уенда күз йомып тору – гөрләүче тур.)». Чаг. як. *кöрдöö-* «эзләү». Чаг. **Көрдәш-ү.**

Дерив.: башк. *гөрләмеш, гөрҙәмеш* «гөрләүче», *көргөлдәк* «гөрләү уены».

**ГӨРНӘЧӘ, гүрничә** (ЗДС: 157–160) «горница; закрытое крыльцо» < рус., әлбәттә. **Гүренкә** яңгырашы рус. диал. *горёнка* id. дигәннән. Миш. (Balint: 72) *gürnäčä* «кунак бүлмәсе» рус. төп мәгънәгә якынрак, *gürbäč, gurmäč* «кече зал» сүзендә **гөлбәч** (к.) сүзенең тәэсире (контаминация) бар.

Рус. *горница, горёнка* һ.б. «югары өй, югары бүлмә, күтәрелгән идәнле» мәгъ. *гор-а* «тау» тамырыннан дип исәпләнә. Элекке заманнарда русларда зимләнкесыман тәбәнәк өйләр өстенлек иткән. Идәне җир кимәленнән югарырак торган өй инде *гора* «тау» булган. Даль сүзлеген карагыз.

**ГӨР-Ү, гөргө-ү** «шуровать; поддувать (в самоварную трубу)» ~ башк. (БТДҺ: 74, 154) *гөрҙөр-* «сөйрәтү, алга-артка тарттыру», *көргө-, көргә-* «гөргү», **көргө** «мич пумаласы; дөмбе» һ.б.

Дерив.: **гөргеч** «торбаларны һ.б.ш. эчтән чистарту җайланмасы, пумала» (шуннан **гөргечлә-ү**).

**ГӨСЛӘ** «гусли» ~ чув. *кĕсле*, мар. *кусле* id. русчадан булса кирәк, рус сүзен исә бор. **гудьсьли* сүзеннән дип уйлыйлар (*гуд* «гөрләү», шуннан **гудок**), к. Фасмер II: 477. Ләкин фар. теле даирәсендә *косӓл* «кыллы музыкаль инструмент, музыкаль кыл» сүзе бар. К. **Гөлестан II.**

**ГРИФТАР** «обречён, подвержен чему» < фар. *гирифтар* «эләккән, тотылган» ← *гирифтан* «тоту, эләктерү» сүзеннән (гом. һинд.-евр. тамыры, к. ним. *griffen, greifen* «тоту; эләктерү»).

**ГУБЕРНА, губирна** «губерния» (1789 елда фиксацияләнә, к. Абдуллин 1990: 368) < рус. *губерния* < лат. *gubernius* «идарәче» (чаг. рус. *гувернант* «тәрбияче»).

**ГУҖ** «обжора» > удм. диал. *гуж* < гар. *ʻӮҗ бин ʻӮнқ* мифологик персонаж, күп ашаучан була ~ рус. Библиядә (< яһ.) *Ог* id., ш. ук *ʻӮк* id., к. Будагов I: 768.

**ГУҢГЫЙК** «навозный жук» < фар. *гаwӓки гоһ* «гуңгыйк», сүзмә-сүз «тирес үгезчеге» сүзеннән. Гуңгыйкның иркәкләре зур гына мөгезле була.

**ГУРК** – древнее название татар, сохранившееся у удмуртов. XIII г. теркәлгән. «Угызнамә»ләрнең берсендә Угыз ханның төньяк өлкәләрдәге *Гурк вә Башгурд* илен яулап алуы турында әйтелә, к. Kırzaoğlu 1992: 4–5.

Хәз. Әфганстанда ир. телдә сөйләшүче *гур* кабиләсе, З. Вәлиди (Velidi: 45, 109, 148, 452) буенча, «иң борынгы төркиләрдән» имеш. Бор. һунн кабиләләре атамалары исемнәренең *гурк, гур* фонетик яисә морфемик азагы күп тапкырлар очрый һәм ул **гурк** белән бердәй булса да гаҗәп түгел.

**ГҮАҺ [гүwаһ]** «свидетель, свидетельство», иск. «разоблачён» < фар. *гуāһ, гӓwāһ* id.

Дерив.: **гүаһлы, гүаһландыру** һ.б.; **гүаһ булу** тәгъбире еш очрый.

**ГҮЗӘЛ** «прекрасный; красавица» < гом. кыпч., угыз. *гӧзәл* (> нуг. *көзэл*) Э.В. Севортян (ЭСТЯ III: 63–64) фикеренчә, *көз* «күз» сүзеннән; безнеңчә, бор. *көз* «күрү» фигыленнән (кушымчасы *-ал//-әл* аеруча монгол телләренә хас) булала. Икенче яктан, к. добр. татарларында (Akb: 85) *gülzel, gülsel* «гүзәл» ← *gül* «гөл» сүзеннән. Чаг. ш. ук фар. *гӧзин* «сайланып алынган (кыз)».

**ГҮР** «могила» < фар. *гӯр* «кабер; кабер өсте корылмасы» (татар телендә палатальләшкән).

Дерив.: **гүрстан.**

**ГҮЯ [гүйә], гүяки** «будто; точно как» < фар. *гӯйā, гӯйā кә* «әйтеп; әйтерсең» (*гуфтāн* «әйтү, сөйләү» фигыленең хәл фигыль формасы). Тат. **әйтерсең** – фар. *гӯйā* сүзеннән калька.

**ГЫЖ –** подражание тяжёлому дыханию с хрипом; шуннан: **гыжла-у, гыжылда-у** һ.б.

**ГЫЙБАДӘТ [ғибадәт]** «поклонение, моление» < гар. *ʻибāдāт* «хезмәт итү» сүзеннән, *ʻбд* «кол булу» тамырыннан (шуннан күп сүзләр ясалган).

**ГЫЙБАРӘ [ғибарә]** «выражение, фразема» < гар. *ʻибāра(т)* «хезмәт итү» сүзеннән (бу мәгънәләр фар. телендә аерымланган төскә кергән), *ʻбр* тамырыннан. К. **Тәгъбир.**

**ГЫЙБАРӘТ** «состоит из.., является», к. **Гыйбарә.**

**ГЫЙБРӘТ** «случай, наводящий на размышление; отрицательный пример» < гар. *ʻибрат* id. *ʻбр* тамырыннан, к. **Тәгъбир.**

Дерив.: **гыйбрәтле; гыйбрәтлән-ү.**

**ГЫЙҖЕК [ғиҗĕк]** «вид скрипки; вид гуслей», диал. (Дмитриева 1981: 157) *кыцак, кызак* «скрипка, сыбызгы, түтек» ~ каз. *қыжақ* (ҚТДС: 217), кырг. *кыҗак, кыйак,* төркм. *гыҗак* «кыллы музыкаль инструмент», уйг. *ғыйҗәк*, чыгт., фар. *гаҗәк* «гитара төре», чыгт. *ғыйрчәк* «скрипка төре», кар. *гыйржак* «гөслә». Будагов I: 772. Тәкълиди тамырдан булса кирәк.

**ГЫЙЗЗӘТ** «высокое уважение» < гар. *ʻиззāт* «газизлек», к. **Газиз.**

Дерив.: **гыйззәтле.**

**ГЫЙЛАВӘ [ғилаwә]** «приложение; addenda et corrigenda» < гар. *ʻилāwā* id.

**ГЫЙЛЕМ [ғилĕм]** «знание» < гар. *ʻилм* id. К. **Галәмәт, Галим, Голәма, Тәгълим.**

Дерив.: **гыйлемле, гыйлемсез; гыйлемдар** «күпбелемле (кеше)»; иск. **гыйлемкяр.**

**ГЫЙЛЛӘ [ғиллә], гыйлләт** «внутренний дефект; подоплёка, первопричина; оказия» < гар. *ʻиллāт* id. Чаг. бор. тәгъбир: **ғалāл-ғиллā** «сәбәпләрнең сәбәбе – Аллаһ».

**ГЫЙМАРӘТ** иск. «строения, здания; постройки», диал. (Тумашева 1992: 55) **имарат** «усадьба» < гар. *ʻмāрат* id. ← *ʻмр* «яшәү», шуннан ук **гомер** һ.б. К. **Мәгъмүр.**

**ГЫЙФРИТ [ғифрит]** «ифрит, могучий злой дух (в арабской мифологии)» < гар. *ʻифрӣт* id. Әкиятләрдә еш очрый. Коръәндә дә искә алына.

Дерив.: **гыйфритлек; гыйфритлән-ү.**

**ГЫЙФФӘТ [ғиффәт]** «целомудрие» < гар. *ʻиффāт* id. *ʻфф* «тыйнак булу» тамырыннан; шуннан ук **Гафифә** (> **Әпипә**) «тыйнак, кызлыклы кыз».

Дерив.: **гыйффәтле, гыйффәтсез.**

**ГЫНА//генә, кына//кенә,** диал. **гынак//генәк** (**кынак//кенәк** сирәк очрый) – *частица ограничительно-ласкательная:* только; лишь; раз; всего; всего-навсего; же; исключительно; *употребляется и в значении уменьшительного аффикса* > чув. *кăна,* мар. диал. *гäнä, гäнäк,* (Иванов, Тужаров: 42, Саваткова: 29) *гана, гына, гĕнä, кына, кĕнä, гынай* һ.б., удм. *гына, гинэ* id., (к. ш. ук тат. *гына түгел* ~ чув. *кăна мар*, мар. *гына огыл*, удм. *гинэ öвöл* id.) < гом. кыпч., уйг., үзб. *гана//гэнэ, кана//кэнэ, кына//кинэ* < бор. төрки *qına, kıye, qıja, qıĵa* id. – монг. *хан//хэн, хон//хөн* id. як. *ӄунья, ӄуйа* «кечкенә» сүзе белән чагыштырыла (Räsänen 1969: 264), ләкин сүзнең чыгышы барыбер ачыкланмый, бигрәк тә тат. **гынак//генәк** һ.б. (азактагы *-к*) үзенчәлекле һәм бүтән төрки телләрдә юк шикелле. К. ш. ук хак. *на//нэ* «гына» (< *гына//гĕнä*).

**ГЫР** – подражание хрипу, хрипению; шуннан: **гыр-гыр, гырла-у, гырылда-у** һ.б. Барча төрки телләрдә охшаш сүзләр бар, ләкин сүзлекләргә кертелми кала. Чаг. **хыр.**

Дерив.: **гырылдык.**

# Д

**Д** – сүз башында төрки телләрдә **т** урынында чагыштырмача соңрак кулланыла башлаган. *Дылаштыру* (*т-* > *д-*) бигрәк тә төрекмән теленә хас, әмма тат. телендә дә *т-* > *д-* очраклары күп кенә, к. түбәндәгеләрне.

**ДА I** частица «и, да» к. **Та.**

**ДА II** диал. предикатив *да* ~ нуг. *дä* id. русча сүздән булса кирәк. Рус. *да* «әйе» төрлечә аңлатыла, күпчелек телчеләр аны *дать* «бирү» фигыленнән чыгаралар, к. Преображенский I: 172; Фасмер I: 480 һ.б.

Рус. *да* төрки телләрдән алынган булу ихтималы да юк түгел, к. алт. *дьа*, *дьэ* «я; әйе» (к. тат. *яме? я!*).

**ДАВЫЛ [да$^{o}$wы̆л],** диал. **тawыл** «буря, ураган» > мар., удм. *даул*, мар. *таул* id., удм. *дабыл, дабыль, дабыр, дабур* «шау-шу» ~ чув. *тавăл*, морд. *тавал* < гом. төрки, к. нуг. *давыл*, үзб. *довул,* уйг. *давул*, кырг. *дабул, доол*, к.-балк. *тавул*, алт. *туул*, як. *тыал* «давыл», СС *daaul*, к.-балк. *даур, даўур*, ком. *давлу* «ызгыш-талаш, паника» ~ нуг., каз. *дабыл* «сигнал, быргы тавышы, җар, чакыру» < каз. диал. *дабыл* «ау барабаны; яңа хәбәр», уйг. *давул*, чыгт. *даул*, госм. *davul* «зур сигнал барабаны», добр. тат. *davul, davıl* «барабан» < гар., фар. *табл* диелә. *Даул* «буря» һәм *давул* «барабан» сүзләренең бердәйлегенә Будагов та (I: 732) игътибар иткән. Гар. *табл* үзе бор. шумер. *taballu* «гаять зур хәрби барабан» сүзеннән (чаг. каз. диал. *дабыл үй* «кечерәк тирмә»). Бор. хәрби барабаннар дошманга дәһшәт салу өчен кулланылган һәм «барабан тавышы > давыл» мәгънә күчеше бик ихтимал, к. кар. *давул, тавул* «зур барабан; җил-давыл»; к. ш. ук кр.-тат., үзб. диал. һ.б. *тавл* «зур барабан». Фар. (A Survey III: 2785) *табыр, тапра* «барабан» < ассур. *tabbalu* id. диелә. К. ш. ук **Тибрә-ү, Тыйбел.**

Бу шумер сүзен таратуда гарәпләр катнашкан булса да, төркиләрдә дә ул гарәп экспанциясеннән күп элек тарала башлаган булырга тиеш, к. бор. төрки (Clauson: 439) *tawil* «зур барабан». Шул мәдәни тамырга **Тавыш** (к.), **Тип** (к.) сүзләре дә тоташа. К. **Давылбаз.** Räsänen 1969: 476; Федотов II: 185–186; Ахметьянов 1989: 5; ЭСТЯ III: 112–113 (материалы аз).

**Давыл чәчәге** > удм. *даулсәскә,* башк. *даулсискә* сүзе бөтен дөньяга таралган мифологик мотив: бөек сихерченең чәчәккә әверелгән кызы (яисә бүтән изге кыз – аңар кул тидерсәң давыл чыга) белән баглы тәгъбир. К. Гастон Леру. Дама в черном // Призрак оперы (җыентык). СПб., 1993: 544–545 (әсәрдә давыл чәчәге – кыз мотивы файдаланылган).

Дерив.: **давыллы, давылсыз; давыллан-у.**

**ДАВЫЛБАЗ [да$^{o}$wы̆лбаз]** «парадный или оркестровый барабан; барабанщик» < фар. *даул-баз,* госм. *давылбаз* id. (*даул//давул* «барабан», *-баз* «уен, уенчы, уйнаучы») сүзеннән. Төрки телләрдә киң таралган: кар. *давулбаз,* каз. *даулпаз*, кырг. *добулбас, доолбарс*, ком. *давлубаз*, к.-балк. *даўурбаз* «барабан».

**ДАГА,** диал. (Тумашева 1992: 199) **тага** «подкова» > удм. *дага* ~ чув. *такан,* мар. *таган* id. < гом. төрки, алт., хак. *тақа, таққа*, каз., як. *таға,* монг. *тақа*, чыгт. *тақан,* кырг. *таған,* маньч. *тахан* id. **Дaға** варианты, тат. теленнән тыш, тув. һәм төркм. телләрендә очрый – угыз линиясе; төр. *takav* «дага» – кыпч. телләреннән булса кирәк, к. к.-балк. *тақа, тағай* «тауга менү өчен тырнак».

Бу сүзнең гадәттә **так-у** (*тагу*) сүзенә нисбәт итәләр (**таққаг* «таккак, тагыла торган нәрсә»?), ләкин хәлиткеч дәлилләр юк. Пекарский (III: 2517) төр. диал. *танка* «чүлмәк аяклары» белән чагыштыра, ләкин бу сүзнең дә чыгышы билгеле түгел. К. **Таган, Таңган.** Räsänen 1969: 456; Федотов I: 164–165. Рус. *така, таха* «аякчу дагасы» тур. Аникин: 526.

Дерив.: **дагалы, дагасыз; дагала-у** (барча юн. бар).

**ДАГЛА-У** диал. «жарить», иск. «ставить клеймо, тавро, прижигая кожу» бор. фар. *даг* «ялкын, яну» сүзеннән, к. **Тамга, Тат II.**

Иске әд. телдәге *калебне (күңелне) даглау* тәгъбире тат. халык теленә *йөрәкне яндыру* рәв. тәрҗемәләнгән. Шуннан *йөрәк яну* тәгъбире килеп чыккан. Будагов I: 548 (тәфсилле).

**ДАГЫЙ** тар. «молящийся за кого-нибудь Богу»; күч. «адвокат» ← гар. *dā‘ū* id., *d‘w-* «таләп итү; үтенү». Шуннан ук **дау < дәгъва, дога** (к. **Дога**). *Үлсәң дә дагыйларың калсын,* диләр. Тимергалин: 159.

**ДАДАН** диал. (трбс. һ.б.) «улей, состоящий из обрезанного полого ствола дерева», «борть», **задан** (ЗДС: 167) «верхние рамы в улье». Бу сүз тат. сүзлекләрендә һәрдаим < рус. диал. *задан, задание* «крыша улья (сделанного из полого ствола дерева)», дип исәпләнә. Ләкин к. чыгт. (Будагов I: 554) *дадаң* «зур кавем; күпсанлы өер» («халык > умарта» мәгъ. күчеше билгеле). Аннары күрсәтелгән рус сүзенең үзенең ясалышы-чыгышы да ачык түгел.

**ДАИМ** иск., хәз. **һәрдаим** (к.) «постоянно» < гар. *dā'им* «һәрвакыт булып торган; дәвамлы»; ш. ук гар. *dā'имā* «даимән». **Даими** һәм **даимән** сүзләре гар. телендә ясалганнар. К. **Дәвам.**

Дерив.: **даимилек; даимләш-ү** һ.б. (фән телендә кулланылалар).

**ДАИР** «относящийся к ...» < гар. *dā'up* id. асылда «әйләнгән, әйләнештәге; түгәрәгендә», к. **Даирә.**

**ДАИРӘ** «круг (в социальном смысле)» < гар. *dā'upa* id. *dwp* «әйләнү, әйләндерү» тамырыннан», шуннан ук к. **Даир, Дәвер, Идарә, Мөдир.**

**Даирә** сүзе тат. әд. телендә чагыштырмача киң кулланыла һәм хәтта **даирәви, даирәдәге, даирәле, даирәлек, даирәчә** кебек терминологик характердагы сүзләр дә ясала килә.

**ДАЙЧА́** диал., сөйл. «дача (загородный участок горожан)». Бу сүз элекке (XVIII г. бирле билгеле) «чиновникларга хезмәтләре өчен бирелгән кишәр, участок» – рус. *дача* сүзеннән (сүзнең бозылышы шул заманнан килә), дать «бирү» фигыленнән.

**ДАК: дак-дак** (саңгыраурак **так-так** авазына тәкълит) звукоподражание: о звуках ударов по толстой доске и т.п. Ш. ук **дак-док** дип тә әйтелә, чаг. **так-ток.**

**ДАЛА,** диал. **тала** «степь» < нуг., каз., к.-калп. *дала,* уйг., кырг., төркм. *дала, талā* «дала; урам, йорт», ком., к.-балк. *тала* «алан», бор. монг., бор. төрки *tala*, як. *таала* «дала; болын; алан»; чаг. алт. *тала* «як, тараф» ~ санск. *tala* «тигезлек; уч табаны». К. Räsänen 1969: 458; Мурзаев 1984: 169–170. Рус. *та́ла* «балчыксыл тау» < як. *тāла* id. тур. Аникин: 528. Чаг. Т**алай.**

**ДА́МКА,** себ. **тамка** «да́мка, фигура в игре в шашки, вышедшая на последнюю горизонталь противоположной стороны и обретшая способность проходить любое количество клеток доски по диагоналям», «игра в шашки». Бу сүз беренче карашка уйлаганча *дама, дамочка* «асылзатбикә» түгел икән, ә иске рус. *дам* < Европа телләрендә *dam, tamm* «шашка уены; дамка» < гар. *тамм* «тулы көчендә» (> тат. к. **тамм**) сүзеннән икән. К. Kluge: 178.

Ихтимал ки, рус. *дамка* сүзендә фар. *таммгяћ* «дамкагы чыгу, дамкага чыккан» сүзе чагыладыр (ягъни *-ка* монда кечерәйтү кушымчасы түгелдер).

Бу сүз мисалында кайчакта чыгышы ачык-аян кебек булган сүзләрдә дә әллә нинди тарихи хикмәтләр була алуы күренә.

**ДАН,** диал. (С. Рәмиев) **данык** «слава», диал., иск. **даңлы** «славный» > мар., удм. *дан, дäн* < нуг. каз., к.-калп., кырг., ком., уйг. *даң, данқ* id. ~ көрд. *däŋ* «дан; аваз, тавыш, шау-шу; дан» – тамыр бәйләнышлары юраулы. Чаг. бор. төрки *taŋuq* «бүләккә бирелә торган ефәк; байрак тукымасы». Еш кына фар. теленә нисбәт ителә, к. ЭСТЯ III: 145, тик бу шикле (Ахметьянов 1989: 106). Чаг. **Таң II.**

Дерив.: **данлы, дансыз; данла-у;** диал. **данлык** (!).

**ДАНА** «мудрый» < фар. *dānā* id. *dāнидан* «белү» сүзеннән (шуннан ук, ихтимал, **таны-у**).

**ДАНӘ** «штука, единица» < фар. *dānä* «данә, бөртек, тош, җиләк» < авест. *dāna* ~ санск. *dћāna* id. (Platts I: 504).

**ДАҢ** – имитатив звону больших колоколов.

Дерив.: **даң-доң; даңгыл-доңгыл; даңгалда-у.** Чаг. **Дан.**

**ДАҢГЫЛ, дәңгел** (ЗДС: 163, 166) «широкий, просторный» ~ каз., кырг. *даңгыл* ш. ук «саф һава, иркенлек, сәхрә» < монг. *даңгуул* «бушлык, киңлек; ерак горизонтлы җир». К. ш. ук каз. (Будагов I: 550, *даң* матдәсе эчендә, 568) *даңгыл* «киң күңелле садә (кеше)», *даңгыл йол* «киң далада туры юл», *дәңгел* «зур мәҗлес; утырыш». Бу сүзләрне әд. телгә кертәсе иде.

**ДАР** «виселица» < фар. *dāp* «дар; бүрәнә; өрлек, багана» < бор. фар. *dāru* «агач» һинд-евр. тамырларыннан (чаг. рус. *дер-ево*). К. **Дару.**

**ДАРАЙ** (ЗДС: 163) «дорогая восточная ткань» > чув., мар. *тарай,* удм. *дарали* ~ ком., кырг., чыгт., уйг. *дарай*, рус. (Аникин: 189) *дорог, дароги, дораи, дараги* һ.б. «калын ефәк тукыма, комач» < фар. *дарāӣ* id. ~ төр. (Özön: 152) *darayi* «патшалар киеме; патшалык» ← Дара «Дарий патша». Гомумән, бу сүз киң таралган, к. Фасмер I: 484. К. **Дәрия.**

**ДАРДАР** «ясень» (көньяк карамасы) < гар. *dāp-dāp* id.

**ДАРЕЛ-, дарәл-** «урыны» мәгъ. гар. *dāp* «урын, йорт» сүзеннән алынган, күп кенә иске мәдәни сүзләрнең беренче компоненты; *дарелфөнүн* «фәннәр академиясе», *дарелхөкем* «суд, суд бинасы», *дарелшифа* «хастаханә» һ.б.

**ДАРКАС, дархас** (ДС III: 50) диал. «ради бога» ~ чув. *тăрхас* id. < фар. *дāр касд* яки *дāр хаст* «бик кирәккә». Федотов II: 179.

Дерив.: **даркасла-у** «кыстау, үтенү», **дархасла-у** диал. «зурлау» (ЗДС: 163, 164).

**ДАРМАНА** (трбс.) «противоглистное средство», диал. «дурман». К. ш. ук диал (ДТС: 164, 166) **дармана//дәрмәнә үләне** «гөлбадран» ~ башк. *зармана* һ.б. «гөлбадран, албидрә» диелә. К. **Дәрман.**

**ДАРУ,** диал. (Тумашева 1992: 204, 207) **тары, тәрӗ** «лекарство, зелье» > мар., удм. *дару,* чув. диал. *тару* < фар. *дāрӯ* id. бор. фар. *dāru* «агач; кайры». К. **Дары, Дәрман.** Ахметьянов 1989: 95–96.

Дерив.: **дарулы, дарусыз; дарулык; дарула-у** (барча юн. белән); **даруханә.**

**ДАРУГА** тар. «губернатор (монгольский)» < монг. *даруга* id. Будагов II: 547; Räsänen: 133; Фасмер I: 484 һ.б. (әдәбият ишле).

Бу сүз бор. монг. *daruγa* (← *daru-* «кысу, бастыру») «бастырык» сүзеннән заманалар узу белән төрле мәгънәләр алып, бөтен Евразиягә таралган, мәс., иске рус. *даруга, дорога, дорага* «татар чиновнигы», тув. *тарга* «башлык» һ.б. EI. II: 162–163; Аникин: 177–178.

Дерив.: иске тат. **даругачы** «губернатор».

Монг. **даруга** сүзеннән рус. *дорога* «юл (берәр губернага юл)» сүзе дә килеп чыккан дигән иске фаразны рус телчеләре кире кагалар.

**ДАРЧИН** «корица», «коричневый» > удм. *дарысин* id. < фар. *дāрчӣн, дāрсӣн* < *дāри-чӣн* «Кытай кайрысы».

**ДАРЫ,** диал. **тары, тәре** «порох» > мар., чув. *тар*, удм. *дары* id. < фар. *дāрӯ* «дару» сүзеннән, к. иске фар., таҗ. *дару-и-милтиқ* «мылтык даруы, дары». «*Дару > дары*» мәгънә күчеше киң таралган, к. к.-балк. *шкок от(у)* «мылтык уты (үләне > даруы)»; рус телендә «дары» мәгъ. озак вакытлар *ружейное зелье, зелье* («дару, дару үләне») сүзе кулланылган (к. Полякова 1979: 69–70), чаг. ш. ук удм. *дари* «купорос (дару буларак)», себ. (Тумашева 1992: 204) *тары* «дару; дары». Кыт. *хо яо* «утлы дару» – «дары». **Дару** һәм **дары** сүзләренең бәйләнышы тур. Räsänen: 132–133.

*Дару > дары* сүзе төрки телләрдә күптән – дары үзе билгеле булгач ук килеп чыккан һәм хәзер күп телләрдә очрый, ш. ук монг. *дарь* «дары» һ.б. Федотов II: 175–176 (тиешле әдәбият бар); Ахметьянов 1989: 95–96; Тимергалин: 140.

**ДАСТАН** «эпос, былина», (ЗДС: 164) «мунаджат, духовные стихи» < фар. *дāстāн, дāситāн* «хикәя, дастан, көйләп сөйләнелгән текст». Дастан, төр. *destan* сүзе төрки халыкларда киң таралган һәм үзенчәлекле мәгъ. дә алган, к. кр.-тат. *dästan* «мәсәл». К. түбәндәгене.

Дерив.: **дастанчы; дастанчылык.**

**ДАСТУЕН, дастыйн** (ЗДС: 164 һ.б. сүзлекләрдә) «рослый и мощный телом» һәрчак рус. *достойный* сүзеннән дип аңлатыла, ләкин к. иске әд. *даситани* «дастан батыры (кебек)». Рус. *достоин, достойный* сүзләренең «баһадир» мәгъ. дә юк бугай әле. К. ш. ук **Дистан.**

**ДАУ [даᵒw],** диал. **тау** «ссоры; претензия» > мар., чув. *тав* < нуг., каз., к.-калп., төр., к.-балк. *даў*, төркм. *даав, дава,* кырг. *доо* id., ком. *дав* «сугыш, җәдәл» < бор. кыпч. *dawa* < гар. *дā‘wā* (к. **Дәгъва**) сүзеннән, к. көрд., осет., абаз., кабарда. *дауэ, дауа* «дау», мар. диал. *тäва* «претензия». Бу сүзнең таралуына шәригать хөкеме ярдәм иткән. Ахметьянов 1989: 106–107.

Дерив.: **даулы, даусыз; даула-у,** диал. **даучы; даучыл, даучан.**

**ДАҺИ** «гений; гениальный» < гар. *dāhū* id. төбендә «авышып китүчән», ягъни «иҗади экстазга грифтар».

Дерив.: **даһилык; даһиларча.**

**ДАЯ [даºйә]** «няня, кормилица ребёнка; жердь для качания колыбели (во дворе, в поле)» (ДС II: 76) < фар. *dāйä* < пәһл. *dāyak* id. бор. ир. *day* «имү» сүзеннән (к. Абаев I: 351).

**ДӘВА [дәwa]** «нечто исцеляющее, целебное, лекарство» < гар. *däwā* id. *dwa* «авыру» тамырыннан килә.

Дерив.: **дәвалы, дәвасыз; дәваханә; дәвала-у.**

**ДӘВАМ [дәwам]** «продолжение» < гар. *däwām* id. К. **Даими.**

Дерив.: **дәвамлы, дәвамсыз; дәвамла-у; дәвамчан;** иск. **дәвамән** «өзлексез» гар. үзеннән.

**ДӘВӘТ I [дәwәт], тәwәт** диал. «чернильница; косо надеваемое нагрудное украшение» – бу беренче карашка бер-берсеннән ерак торган мәгънәләрнең бер чыганактан килгәнлеге шуның белән аңлатыла: бор. бетекчеләр-писерләр үзләренең кара савытларын иңгә кыеклап бәйләнгән киң тасмага беркетеп асып йөрткәннәр (к. TS, 2: 275) ~ фар. *däwāt*, төр. *divit, devat*, бор. чыгт., монг. *dewit* (Поппе 1938: 141) id. *Дәвәт* иңгә кыеклап куелган киң тасма мәгъ. күрше телләргә дә кергән: чув. *тевет, тевӗт*, мар. *däyät* id. «Кара савыты» мәгъ. *дәwәт* күп төрки телләрдә (мәс., нуг., каз., к.-калп.) очрый. Тимергалин: 140.

Фар. *däwāt,* Пляттс буенча (Platts I: 536), гар. *däwāt* «дару болгаткыч таяк» (*дәва* «дару») сүзеннән; монда «дару > язу карасы», «болгаткыч таякчык > каләм» мәгънә күчешләре булган, имеш. Тат. **дәвәтдар** < фар. *däwätdāр* «секретарь» сүзе дә булган. Бу сүз тур. EI V: 173.

**ДӘВӘТ II [дәwәт]** иск., диал. «доведь, дамка, игра в шашки» (Будагов I: 568) < рус. Шашка уенының бу бор. рус. атамасы Себердә күп кенә телләрдә очрый (к. ССТМЯ I: 211). Аникин: 187–188.

**ДӘВЕР [дәwĕр]** «период; эпоха» < гар. *däwp* «әйләнеш» сүзеннән, к. **Даирә.** *Дәвер* сүзенең элекке дини ритуалларда төрле үзенчәлекле мәгънәләре булган; тагын бер мәгънәсе – «тост».

**ДӘВЕШ [дәwĕш], дәвешләмә** диал. (ЗДС: 165) «вид круглого пирога с тонкой оболочкой» ~ угыз., уйг., кр.-тат. *дәгиш,* төр. *değiş, değişleme* id. ← *değ* «алмаш, үзгәреш; алмаш кием» < бор. төрки **teŋiš* «суррогат; маскировка» сүзеннән була ала. Бу нигез тур. ЭСТЯ III: 181–182. Чаг. тат. (*әвеш-тәвеш* дигәндә һ.б.) **тәwеш** «алмашу». К. **Дәүширмә.**

**Дәвеш** угыз-төркм. яңгырашындагы сүз. Безнең якларга ничек эләккәндер инде.

**ДӘГЕЛ** «дягиль (растение)» < рус. булса кирәк (к. Фасмер I: 561). Удм. *дагыль* id. ш. ук < рус. Ахметьянов 1989: 16.

**ДӘГЪВА [дәғwa]** кит. «претензия; жалоба в суд», иск. «приглашение» < гар. *däɣwā* id. Шуннан ук **дәгъвәт, дәгъвәтнамә** «кунакка һ.б. чакыру» һәм дәүләти игълан төрләре. Будагов I: 560–561; ДТС: 159; EI II: 168–172. К. ш. ук **Дау, Дагый, Дога.**

Дерив.: **дәгъвалы, дәгъвасыз; дәгъвала-у; дәгъвачы** («дәгъва кылучы», ш. ук «претендент» мәгъ. дә кулланыла), **дәгъвачыл.**

**ДӘДӘ, дәдәй** «дядя». Бу сүз диал. сүзлекләрдә (ЗДС: 165; Рамазанова 1991: 61–65) «абый», «әтиәнинең бертуган ир кардәше» һ.б.ш. мәгъ. күрсәтелә һәм хаклы рәвештә рус сүзе диелми. Будагов (I: 545–546) рус. *дядя* сүзенең үзе тат. теленнән, ди. Тат. бор. телдә һәм башлыча миш. сөйләшләрендә, аннары Кырым татарларында, аз., төр. сөйләшләрендә, үзб., Кавказ төрки шивәләрендә, Иранда төрле кардәш-кавемлек терминологиясендә очрый. Румыниядә (Dobr. I: 512) *dede* «дәвәти; җәт». Якын Шәрыктә (төркм., таҗ. һ.б.) *дада, дадә, дәдә* «изге карт, дәрвишләрнең башлыгы», төр. *dadı* «бала караучы», иске төр. (Özön: 147) «бала караучы негр хатын-кызы». К. ш. ук төрле Кавказ һәм Иран телләрендә *дадаш* «көчле һәм абруйлы карт; баба, ишле гаилә башлыгы» (< *дадача* формасы микән?). Гомумән, бу сүз тур. бик күп язып була. Чаг. **Дадан.** ЭСТЯ III: 212–213; EI II: 199–200.

**ДӘҖҖАЛ,** диал. (ДС II: 79) **дәтьял** «антихрист; изверг» < гар. *Däǯǯāl* – ахырзаманда Гайсаның икенче тапкыр җир йөзенә килүеннән алда кешеләрне диннән яздыручы зат. Асылда лат. *Decial* «(христианнарны эзәрлекләгән) император Деций токымы» дигән сүз. Ул Деций христианнарга карата аяусыз, «дециаль» чаралар күргән. Тат. сөйл. (ЗДС: 166) **Дәтйал** варианты, ихтимал, гарәпчәдән түгел, бүтән чыганактан киләдер: лат. *Дециал* «унынчы бала» исеме *Дектиан* дип тә әйтелгән, тарихта берничә *Дециал* билгеле. К. **Дәкыянус.**

Ул *Дәтйал, Дәтйан* (ш. ук *Дәййан*) океандагы бер кыяга зынҗырлап куелган, һәм ул анда көнетөне ярсынып йолкына, ди. Һәм ул бауларын өзсә, Кыямәт булачак, имеш, к. ЗДС: 166.

**ДӘКЫЙКА** кит. «миг; мгновенье; секунда» < гар. *дӓқӣқа* id. к. **Дикъкать.** Тимергалин: 141.

**ДӘКЫЯНУС** «некий великий повелитель древности» по арабским легендам, по Будагову (I: 561) тот же Деций. Ләкин бу *Дәкыянус* < лат. *Dacianos* Дакияне (хәз. Румынияне) яулап алган Траян (б.э. 53–117 еллар) булса кирәк; аның заманына Рим дәүләте иң зур кодрәтенә ирешкән һәм ул акыллы, гадел хөкемдар буларак та билгеле. **Дәкыянус** дип иң сыйфатлы тәңкә акчаларны атаганнар. Дәкыянус турында, аны уңай сыйфатлап сөйләнгән әкият-легендалар күп булган.

**ДӘЛ: дәл булу** «встретиться на пути», чаг. чув. *тĕл пул* – id. Ихтимал, чыганакта (ТХИ: Дастаннар 1984: 66) дөрес язылмагандыр.

**ДӘЛИЛ** «доказательство; довод» < гар. *дӓлӣл* id., *длл* «күрсәтү» тамырыннан, шуннан ук иске әд. **дәллал** «маклер» (**дәлләтче** дә диелгән).

**ДӘЛИР,** себ. (Будагов I: 565) **тәлир,** ш. ук (ЗДС: 165) **дәллә, дәлил** «смелый» < фар. *дӓлӣр* id.

**ДӘЛИЯ** «георгина» < лат. *dahlia* швед биологы А. Даль исеменнән; татар галимнәре бу атаманы гарәп сүзенә охшатканнар.

**ДӘЛҮ** «водолей (зодиакальное созвездие, знак и месяц)» < гар. *дӓлӯ* id., түбәндә «чиләк, бидрә». Тимергалин: 142.

**ДӘМ,** диал. **тәм, тим** «дыхание, короткий отдых; короткий период времени, момент» < фар. *дāм* id. (к. ЛТ I: 168). Бу сүз хәз. әд. телдә һәм диал. лексикада төрле кушма сүзләрдә һәм фразеологизмнарда очрый: **һәрдәм** «һәрвакыт», **бердәм** «бер моментта» (монда контаминация дә бар); себ. (Тумашева 1992: 206, 210) **тәм кысу** «тын кысылу», **тим алу** «тын алу, бераз ял итү».

**ДӘМӘН** (ЗДС: 166) «верблюд; верблюдица». **Дөя** сүзенең бу варианты аеруча Үзәк Аиядә, Монголиядә билгеле.

**Дәмән әнә (инә)** дип Әстерхан якларында калын әйберләрне тегә торган зур энәне атыйлар. Чаг. ш. ук **Тибән энә.**

**ДӘМЛӘ-Ү** «искусно заваривать чай» ~ уйг. *дәмлә-* (*дәмләмәк*) id. ← фар., төр. *dӓm, dem* «эчемлек». **Тәм** белән бердәй түгел, ә югарыда күрсәтелгән **дәм** «сулыш; хуш ис» сүзеннән, к. Özön: 159.

Дерив.: **дәмлән-ү.**

**ДӘМУЛЛА, дамулла** «мулла, преподающий в медресе; помощник муллы в медресе» < төр. *дайы мулла* «мулла абый» (*дай* «абый»; к. **Тай II**). Будагов I: 550.

**ДӘҢ, дәңк** иск. «правильный вес; правильное время по часам; точно» (к. Räsänen 1969: 135) ~ госм. *дӓң* id. Чаг. тунг.-маньч. *тэң* «дөрес; төгәл» (ССТМЯ II: 236). **Тиң** сүзе белән гомоген булса кирәк.

**ДӘҢГЕ** тар. (Мөхәммәдьяр телендә) «деньга, деньги» ~ рус. *деньга, денга* «бор. заманда көмеш яки бакыр тәңкә». Монг. *tenge*, фар. *tanka* «тәңкә» ~ санск. *tanka* «алтын» һ.б., к. **Тәңкә.** Яңгыраулаштыру, минемчә, монг. телендә XVII г. йөз биргән. Аникин: 181 (автор **тиен** белән чагыштыруны шикле дип таба; бай әдәбият китерә, тат. сүзен белми).

**ДӘҢГЕЗ** (ЗДС: 166–167, **дәңгезлә-ү** «бер аякта сикеренү» дигәннең нигезе) «прыжок, прыжки (на одной ноге, как игра детей)», ***деңгез, диңгез** (**деңгезлек** «сикәлтә, салулык» сүзенең нигезе) «перепады на дороге», себ. (Гиганов; Тумашева: 206, 211; ЗДС: 618, 672) **тәңзәл-ү, тиңзәл-ү, тиңсәл-ү, тыңсал-у** «чайкалу, тирбәлү, дулкынлану», **тәңзәлт-ү** «тирбәлтү, тирбәтү», **тән-ү, тәң-ү** «селкенү, дулкынлану» сүзләренең бүтән төрки телләрдә ачык-аян параллельләре юк шикелле, ләкин к. тат. (дөб.) **тенәлү** «сискәнү, сикереп тору» ~ тув. *тең-, дең-, дәң-* «сикереп тору; сикеренү», бор. төрки (ДТС: 551–552) *teŋ-, teŋi-, teŋil* «күтәрелү; очып китү». Чаг. ш. ук **Диңгез I.**

**ДӘРӘ, зәрә** (ТТДС I: 137, 141; Уразманова: 53) «общественная каша для детей во время сабантуя». Рус. *заря* белән чагыштыру бары тик фонетик охшашлыкка гына корылган. Чаг. төр. *dere* < фар. *dӓre* «ялан, тугай», шуннан каз. (ҚТДС: 88–89) *дере* «ачык кырда су эчерү өчен улак; яландагы ашханә, алачык; арыкка корылган бөя, буа». К. түбәндәгене.

**ДӘРӘБӘЙ** (Г. Исхакый) «богатый помещик, боярин», иск. «человек, помогающий бедным шакирдам из гуманных соображений». Төр., аз. *дәрә* «ямьле басу, кыр; үзәнлек» сүзе киң кулланыла. Шуннан билгеле социаль терминнар – *derebey* «феодал», соңрак *дәрәбәй, dere beyi* «бай алпавыт» сүзе ясалган. Дәрәбәйләр бәйрәм көннәрендә фәкыйрь балаларны сыйлау мәрасимен оештырганнар.

**Дәрә,** *dere* (фар.) *дәрья* сүзеннәнме яисә **тәрә** «тирә»дәнме икән – бигүк ачык түгел.

**ДӘРӘҖӘ** «степень; уровень» < гар. *дäраҗӑ-т* id. *дрҗ* «әкренләп күтәрелү» тамырыннан.

**ДӘРВАЗӘ [дәрwазә]** тар. «городские ворота» < фар. *дäрвāзэ* id.

**ДӘРВИШ** «дервиш; человек не от мира сего» < фар. *дарвеш* id. < авест. *driwis* id. (Platts I: 514). Төрле дәрвишләр тур. Будагов (I: 57; бик тәфсилләп язган). Казан янындагы **Дербышки** бистәсе атамасы **дәрвиш** сүзеннән килә, диләр.

**ДӘРГЯҺ** «прихожая, приёмная; порог» < фар. *дäрг'āһ* «ишек урыны, бусага» (*дäр* «ишек», *г'āһ* «урын»), к. ш. ук ГТРС: 116.

**ДӘРЕС** «урок» < гар. *дäрс-ун* «дәрес; күнегү, өйрәнү» – түбендә «суктырырга җәелгән көлтәләрнең бер түшәмәсе», «бер түшәмә көлтәне суктырулык вакыт аралыгы» ← *дрс* «иген суктыру; күнегү»; шул ук тамырдан к. **Мәдрәсә, Мөдәррис.**

**ДӘРИЯ** «вид ткани» к. **Дөррия.**

**ДӘРМАН,** сөйл. **дарман,** (ЗДС: 603) **тарман** һ.б. «способ, средство, возможность для достижения чего-либо» ~ чув. *термен* id. < фар. *дäрмāн* «дару, дәва». **Дару** сүзе белән тамырдаш. Фар. теләндә шул ук нигездән *dermane* «исерткеч дару» > тат. **дәрмана, дармана** «эч кортларын чыгаргыч» һәм *durman* (< *деруман*) «дурман». Тамыры *дāр* «агач, агач кайрысы (дару һәм буяу чыганагы буларак)», икенче версия буенча бор. фар. *dhar-* «тоту, тернәкләү» сүзеннән (Horn: 123). Федотов II: 208–209.

**ДӘРМӘН,** диал. **дарман, дарманча** (ТТДС I: 124) «без повода; без особой причины» < фар. *дäр мāнд* «искә алу белән; исенә төшү белән», «искә төшкәндә».

**ДӘРРӘҮ** «сразу (вместе)» < фар. *дäррав* id. хәрефмә-хәреф «йөрештә ук, юлда ук» (чаг. рус. *на ходу, на лету*).

**ДӘРТ,** диал. **тәрт** «страсть», диал. «болезнь; горе, печаль» (ДС III: 79; ТТДС I: 132) > чув. (Федотов II: 209) *терт* «авыру, хаста», мар. *дäрт,* удм. *дарт* «дәрт» < фар. *дäрд* < авест. *drita* «газаплану; йөрәксенү»; к. ш. ук бор. тат. (XVI г.) *дирт*, нуг., к.-балк. *дэрт* «үч; судка бирү», иске нуг. (Российская вивлиофика, VII: 250, 310, 330–331) дирт һәм ширт – судта серләрне фаш итү формуласы (~ иске рус. *слово и дело*).

Дерив.: **дәртле, дәртсез; дәртлән-ү.**

**ДӘРТЧӘЧӘК** «страстоцвет» – русчадан калька.

**ДӘРЬЯ [дәрйа]** «очень широкий водоём, большая река, море» < фар. *дäрйā* < бор. фар. *daraya, zaraya* < авест. *zrayanh* id. *zri* «яшелле-зәңгәрле» сүзеннән дип уйланыла (Platts I: 514).

**ДӘСТӘ** «пучок; набор» < фар. *дäстэ* id. бор. фар. *dast* «кул, үлчәм» сүзеннән (к. ЯТ: 244–245).

**ДӘСТӘРХАН,** диал. (Тумашева 1992: 208) **тәстерған** «скатерть» < фар. *дäстāр хон* «зур тастар, зур эскәтер» сүзеннән. К. **Тастар.** Eren 1999: 109.

**ДӘСТҮР** тар. «свод правил, законов; министр (охранитель законов); образец, модель; разрешение на аудиенцию» < фар. *дäстӯр* id. < бор. фар. *dästwār* «җитәкче; җитәкчелек». К. башк. диал. *тәстүрләү* «җиренә җиткерү» (БҺҺ II: 273).

Дерив.: **дәстүрлә-ү** «эш күрү, оештыру, планлаштыру», **дәстүрханә** «кабулханә, утырышлар залы».

**ДӘҮ [дәw]** «большой, огромный; старший» – һичшиксез (дияргә туры килә, чөнки үзгә фикерләр дә очрый) фар. *дэw* «дию», «гаять зур гәүдәле рух» < һинд-евр. **deivos* «тәңре, илаһ» сүзеннән (бу сүзләр чагылышлары һинд-евр. телләрендә исәпсез күп һәм төрле, мәс., рус. *диво* «гаҗәеп нәрсә»), к. башк. диал. *дәү фарыҫы* «дию пәрие», нуг. *дав* «әзмәвер, баһадир» (чаг. удм. *дау пэри* «дию пәрие»), каз., к.-калп. *тәв, дәү* «дию; җиңелмәс кеше» (к. Радлов III: 1658, 1692). Кырг. *дөө* «дию; дәү», аз. *дәв* «зур һәм килбәтсез», төр. *dev* «дию; дәү» һ.б., себ. тат. *дәү* «дию» (к. ТХИ: Дастаннар 1988: 79–80). К. **Дию.**

Дерив.: **дәүлек, дәүлеге.**

**ДӘҮКӘДИ [дәwкәди]** «мужеподобная женщина» < фар. *дәwкäдū* «дию бичәсе» (*дәw* «дию», *кäдū* «хуҗабикә»).

**ДӘҮЛӘТ [дәwләт]** «государство; богатство» < гар. *däwlät* id. *dwl* «үтү, узу» тамырыннан (дини караш буенча, дәүләт – уза, бетә торган нәмәрсә); *дәүләт* сүзе күптәнге алынма, моның дәлиле чув. *тивлет* < тат. **дивләт* «уңыш, җиңү», кар. *девлять* «көч, куәт» һ.б.

Дерив.: **дәүләтле, дәүләтсез; дәүләтчелек** һ.б.

**ДӘҮРӘН [дәwрән]** иск., фольк. «богатырь-единоборец», имя богатыря в сказках. Бу сүзне *дәү ирән* дип аңларга да мөмкин, ләкин к. каз. *дәурен,* үзб. *даврон* «бәхетле дәверләр, чаклар» < фар. *däwrān, däwirān* «дәверләр»; төр. (киресенчә) *deveran, devran* «үзгәрешләр; ышанычсыз язмыш». Монда ике гар. нигездәге сүз – *däwp* һәм *däwūp,* һәр икесе *dwp* «әйләнү, әверелү, үзгәрү» тамырыннан – чагыла. К. **Дәвер.**

Дерив.: **дәүрән сөрү,** диал. **дәүсеру** «шәп яшәү; маҗара эзләп йөрү (әкият батырлары тур.)».

**ДӘҮШИРМӘ [дәwширмә]** тар. «организация кадровых военных из воспитанников специальных училищ; кадетский корпус» ← төр. *devşirme* «яничәриләр оешмасы» ← *devşir-* «җыю, туплау» ← *deviş-* «төрү» ← бор. төрки *tev-, teg-* «әйләндереп төрү», к. **Тәвеш.** Будагов I: 571–572.

Төркиядә дәүширмә озак заманнар дәвам иткән. Россиядә дәүширмәгә охшаш оешма – *почётные полки* Петр I заманында гына искә алына. Татарлар **дәүширмә** дип Оренбург хәрби училищесын атаганнар – аңа татар-башкорт балаларын 10–12 яшьтән ата-аналарыннан аерып алып укытканнар. Россиядә *Суворовское училище, Нахимовское училище* кебек хәрби мәктәпләр дәүширмәгә охшашлар. Ләкин алардагы курсантлар ятим түгел. К. ЕI II: 210–213.

**ДӘФЕН** кит. «погребение, похороны» < гар. *дäфн* id. (к. Будагов I: 561).

Дерив.: **дәфенлә-ү.**

**ДӘФНӘ** «олеандр, лавр» < фар. < гар. *дäфнä* id. Ахыр чиктә грек. *Дафна* – Аполлоннан качып дәфнәгә әверелгән кыз исеменнән булса кирәк.

**ДӘФТӘР** «тетрадь», иск. «конторская книга» < фар. < гар. *дäфтäр* id. < бор. грек. *diftera* (*δίφθερα*) «тире, пергамент» > «документ» сүзеннән. Фар. сүзе бор. заманнарда ук төрки-монгол телләрендә киң таралыш тапкан, к. монг. *дэвтэр* «дәфтәр», бор. монг. *köke debter* «салымнар дәфтәре» һ.б. К. **Типтәр.** Тимергалин: 145. Тарихтагы төрле **дәфтәрләр** тур. ЕI II: 77–83.

**ДӘХЕЛ** «причастность; касательство» < фар. < гар. *дäх̣л* (к. Җантурин: 148–149), к. иске тат. *дахил* «эчке, эчтәге» < гар. *дāх̣ил* id., ш. ук «мөнәсәбәтле». Сөйл. телендә *дәхелең булмасын* дигән тәгъбир дә очрый.

**ДӘХИ** иск. «ещё; ещё более» бор. угыз. әд. теленнән, асылда **тагы** сүзе белән бердәй (*т* > *д, г* > *х*), к. ш. ук кырг. *деги, теги* id. К. **Тагы.**

**ДӘҺШӘТ** «ужас; ошеломлённость» < гар. *дäһшäт* id. *дһш* «аптырау» тамырыннан; шуннан ук иске әд. **мөдһиш** «дәһшәтле».

**ДЕБЕТ,** диал. **дөбөт, дөбет,** иск. (ЛТ I: 124) **тебет** «козий пух; пуховая нить для вышивания; пуховый» < угыз. **дүбүт* < бор. төрки (Радлов III: 1598) *Түпүт* «Тибет» сүзеннән: *дебет* тәүдә як мамыгын белдергән, ул мамык исә Тибеттан китерелгән.

**Түбүт** «Тибет» сүзе тат. телендә **төбет** «зур гәүдәле көтүче эте» һәм диал. **дебет** «чукрак (чит ил кешесе, тибетлы кебек)» сүзендә дә чагыла (к. ДС III: 16, 76).

К. ш. ук уйг. *тивит,* каз. *түбіт* «дебет», кырг. *тыбыт* «йон төбе мамыгы», төр., аз. *тифтик* «махсус кәҗә токымы һәм аның мамыгы» һ.б.

**ДЕГӘЧ** диал. (ДС II: 16) «гусиное крыло, употребляемое в домашнем хозяйстве» к. **Дегәшкәй.**

**ДЕГӘШКӘЙ, дегәчи** «гусёнок», **деге-деге** «междометие для подзывания гусей», диал. **дигәшкәй, дашкай** ~ чув. *тики-тики, тикĕ-тикĕ*, мар., удм. *дига-дига,* коми. *тига-тига*, рус. диал. *теги-теги, тига-тига* id. (к. Гордеев II: 263), удм. *диго, дигонь* «ана каз; дегәшкәй», рус. *дигонька,* морд. Э. *дига, дьига,* карел. *дьига*, селькуп. *тека, тöка* «каз». Таралыш даирәсенә караганда, бор. фин-угор сүзе.

**ДЕГЕТ** «дёготь» рус теленнән (рус теленә исә Балтыйк телләреннән кергән булса кирәк, к. лит. *degutas* «деГет», *degti-* «яну») ~ чув. *тикĕт*, мар. *тигыт, тегыт* һ.б.; бу сүз бор. заманнарда ук кыпчак телләренә кергән, к. бор. Мисыр кыпч. *tägät, täkät* «дегет» Федотов II: 228–229.

**ДЕКАБРЬ, дикәбер** «декабрь» < рус. < лат. *december* id. (төбендә – ел башы март булганда – «унынчы ай» дигән сүз). Бу сүзнең **дикап** яңгырашы (ЗДС: 168) русчадан түгел, гарәпчәдән килә: лат. ай исемнәре гарәпләргә бор. заманнарда ук таралган, чаг. ш. ук **синтәп.**

**ДЕН** «совесть; убеждение» – *дин* (к. **Дин**) сүзеннән булса кирәк.

**ДЕРӘН, дөрен** диал. (ТТДС I: 125, 134) «группа, очередь» (*дерән-дерән, дөрен-дөрен* «группами; очередно, очередями») < уйг. *дöрән, дöрәм* id.

Бу сүз тат. телендә бигүк сирәк түгел, к. такмаза: *Дерен-дерен, дерендә, ике көннең берендә ...*

**ДИБӘ** диал. (ТТДС I: 125) «очень» < рус. диал. *дúво* id.

**ДИВАН [диwан]** «диван; ханский совет в Казанском государстве; сборник стихов одного поэта» – барлык бу мәгънәләр бор. Шәрык мәдәни-идари тәртипләрдән килә. Бор. тат. халык телендә хан киңәше *дуам, дуан* дип аталган булса кирәк, к. чув. *тăвам*, мар. *туам* «тәңреләр киңәше (миф.)», бурлаклар әртилләрендә эш хакын бүлешү киңәше *дуван* диелгән; хан киңәше үзе дә, әгъзалары да *дуван* дип аталган (Материалы по истории Башкирии: 11). К. ш. ук ком. *дуван* «суд».

*Диван* сүзе төбендә гар. *dūwān* «язулар; шигырьләр» сүзеннән, *däwwänä* «язу» фигыленнән; мәгънә үсеше: «язулар» > «ни дә булса языла торган урын; секретарьләр бүлмәсе» һәм > «шигырьләр > шагыйрьләр җыелып шигырь укый-тыңлый торган урын > диван, зур урындык». Соңгы мәгънәдә диван бөтен дөньяга билгеле. Аникин: 190; Kluge 2002: 207; Тимергалин: 146.

**ДИВАНА [диwана]** «помешанный, сумасшедший» > мар. *дувана* id. < фар. *dīwānä, девона* id. «диюсыман» (*дew-ана*, чаг. *дуст-анә, шагыйр-анә* һ.б.ш.); чаг. к.-балк. *дуўана* «шайтан», кырг. *дувана, дубана* «җенле» һ.б. К. **Дию.**

**ДИВАР [диwар]** «стена (толстая, крепостная)» < фар. *dūwār* id. Бор. фар. *däv* «катлам» сүзеннән (Platts I: 559). К. ш. ук **Дувал.**

**ДИЙ-Ү [дию],** диал. **тий-ү** «говорить, сказать» < гом. төрки, бор. төрки *te-, tä-* id. Төрки телләрдә иң киң кулланышлы сүзләрнең берсе. Алмашлыклар шикелле, бу фигыльнең аерым формалары лексикалашып, асылда аерым берәмлекләргә әверелгәннәр. **Ди** «сөйли, әйтә» < *ди-и, дийә,* диал. **дир** < *дийер* id.; экиятләрдә ул «дип сөйлиләр» мәгъ. кулланыла; **диган** бәйлек һәм теркәгеч мәгъ.; **дигәндә, дигәндәй** – модаль сүзләр; **дип** – бәйлек; **дигәч, дисәңче, дисәң** кисәкчәләр мәгъ.; *димәк, димәк ки* модаль сүз; **диген** – бор. боерык килеш формасы *дигел* дән, модаль мәгъ., диал. **диң** < *диең* «диеп әйт» һ.б. Бу формалар кыпч. һәм уйг. телләрендә киң кулланыла. К. Вагапова: 140–161. Тат., башк. *ди-, дей-* яңгырашы угыз телләреннән килсә кирәк.

Кайбер филологик хезмәтләрдә рус. *де, дей, дескать* «янәсе» сүзе кыпч.-тат. *ди, дей* сүзенә кайтарып калдырыла (һәм бу дөрес булса кирәк), әмма Е.С. Остин ул *де-* турында язган хезмәтендә (к. аныкы. К этимологии одного славянского глагола речи // Этимологические исследования по русскому языку. Вып. IX. М., 1981: 144–166) бу хакта берни дә әйтми (рус. *де-* сен *деять* фигыленә нисбәт итә). Будагов I: 580–581; ЭСТЯ III: 221–226; Федотов II: 205 (әдәбият күрсәтелә); Тимергалин: 148.

**ДИКЪКАТЬ [диққәт]** «внимание; сосредоточенность» < гар. *диққäт* id. *дққ* «төю, тукылдату, бер ноктага бәрү» тамырыннан; шуннан ук иске әд. **дәкыйка** «секунд; момент».

**ДИЛӘНКЕ** «делянка, участок леса, подлежащий вырубке» < рус.; к. ш. ук чув. *тиленкĕ*, мар. *делäнкä, еланка, еланкы* id. Рус сүзе үзе *делить* «бүлү» фигыленнән бугай (СРНГ 7: 348–349).

**ДИЛБЕГӘ** «вожжи» > чув. *тилхепĕ* ~ куман. *тäлбуга* (Радлов III: 1091), нуг. *телбиге* һ.б. бор. монг. *delbegen, delbeke, delbeg* id. ← *delbe-* «ат йөретү» сүзеннән. К. ш. ук каз. *дилбе*, каз. диал. (ҚТДС: 87) *делбегей*, ком. *телбав* «дилбегә». Чаг. як. *дэлбиргэ* «ак ат ялы кылыннан үрелгән ритуаль бау», монг. *дэл* «ял». Räsänen 1969: 471; ССТМЯ II: 232; Федотов II: 230.

Дерив.: **дилбегәле, дилбегәсез.**

**ДИМ I** «уговоры» – Троянский (I: 536) бу сүзне **дием – ди-ү** сүзеннән дип аңлата, ләкин күпсанлы төрки һ.б. параллельләр моны расламый: удм. *дэм* «киңәш; мир җыены» (*дэмчи* «димче») ~ чув. *тим* «теләк, омтылыш, тырышлык», нуг., каз., к.-калп., кырг., тув. *дем [дэм]* «ярдәм; бергәлек; көч», хак. *тим* «әзерлек», *тимнэ-, тĕмнэ* «әзерләү», алт. *тэм* «уртак эш; иганә», *теме-* «иярү, охшату», ~ монг.

*дәм* «ястау, тапкырлык; бергә атлау; авышкан килеш борыла белү (ат турында)», *дәмчи, дәмци* «өяз башлыгы; министрның казначысы». Бу сүзләр массасына фар. алынмасы *дәм* (к. **Дәм**) дә кушылып китә. Räsänen 1969: 135; Федотов II: 231; Ахметьянов 1981: 81–82.

Дерив.: **димле, димсез; димлә-ү; димче** (бу сүз, күренгәнчә, бер дә гади генә түгел, бай тарихи эчтәлеккә ия).

**ДИМ II** «Дёма» (название реки, популярное в тат. фольклоре) – рус. атамасы һичшиксез борынгырак бер вариантны чагылдыра һәм ул XIII г. ук теркәлгән (к. Матвеев А.К. Географические названия Урала. Свердловск, 1980: 81); ул вариант башк. *дөйөм* «уртак, гомуми; зур җыен» сүзенә иш (к. **Дөем**): Дим елгасы тамагы тирәләрендә башкорт кабиләләренең зур җыены үткәрелгән һәм шул тирәдәге бер тау да < *Дөйөм тавы* (> шуннан *Юматово)* дип аталган. *Дөйөм* > *Дейем* > *Дим* миш. сөйләшләрендә була торган үзгәрешләрдән.

Рус баяры *Юматов* фамилиясе дә шул ук сүздән булса кирәк (рус баярларына фамилиясен биләгән җиренә карап куйгалаганнар).

**ДИМ III: дим кыяры** «кабачки» – Дим елгасы исеменнән түгел, рус. *демьянка* сүзеннән.

**ДИН** «религия» ~ чув. *тĕн*, мар. *тын, тен,* удм. *ден, дин, дын* id. < гар. *дӣн* < фар. *дӣн, дэн* ~ сугд., бор. ир. *dĕn* «дин, тәгълимат, өйрәтү» сүзеннән.

Дериватлары: **диянәт** гар. телендә ясалган, **диндар** саф фар. сүзе, **динче** – тат. сүзе. Тат. телендә **дин** сүзеннән **ден** тамыры барлыкка килгән һәм **дин – ден** лексик дублеты пәйда булган. К. **Ден.**

**ДИҢГЕЗ I,** диал. **тиңгез** «море» гом. кыпч. *тәңгиз* ~ гом. төрки *дәңгиз, дэңгиз, дәңиз* id. (к. ЭСТЯ III: 194–195) < бор. гом. төрки *teŋgir* id., к. венг. *tenger* «диңгез»; к. ш. ук чув. *тĕнĕс*, мар. *теҥыз, теныж, тангыж* id. (болар татарчадан түгел!). Бу сүзнең кырг. варианты кызыклы: *деңиз, теңиз* «диңгез», *теңиз Манас* «бөек Манас», *теңизим* «кадерлем», *деңиз баш* «куптарай, үз-үзенә артык ышанган кеше» – болар *теңиз* сүзенең ниндидер затны (геройны, тәңрене һ.б.ш.) белдергән булганлыгына ишарәли. Шул нигездә *диңгез* < *тәңгиз* сүзен шумер. *diŋir* «тәңреләрнең берсе» сүзе белән чагыштыру бар (ВЯ, 1954, № 5, б. 50), моңа осет. *dyngyr* «дәү, зур» сүзен дә өстиләр (Абаев I: 383), шулай итеп *диңгез* < *teŋgir* ~ *тәңре* (ихтимал, шумер. *diŋir* «сулык, диңгез тәңресе» булгандыр) тәңгәлләштерелүе килеп чыга. Ләкин эвен. *тонгэр,* эвенк. *тунгэр*, нан. *тэнки* «күл, күлләвек» сүзе әлеге гипотезага шик төшерә. *Диңгез* сүзе гапгади *дәңгез – диңгез* «дулкын, ташкын» сүзе белән бердәй булса кирәк. К. **Дәңгезлә-ү.**

К. ш. ук Федотов II: 232.

**ДИҢГЕЗ II** диал. (ЗДС: 168) «фундамент, основание; род, семейство» ← *диң* ~ (ЗДС: 672) **тың** «ныклы» булса кирәк. К. уйг. *тиң* «точ, тыгыз». Чаг. бор. төрки (ДТС: 551–552) *teŋ-* «күтәрелү». Чаг. ш. ук төр. *denk* «тиң, тәңгәллек» һ.б. (бик күп дериватлар). Һәрхәлдә **Диңгез II** не **Диңгез I** гә ялгау мөшкил. Болар төптән икесе ике сүз булган.

**ДИҢКҮ, диңке-ү** (ДС II: 77) «чувствовать отвращение» – «бизү, ялыгу», **диңкет-ү** «ялыктыру». Чаг. чыгт., төр., фар. *дәң* «аптыраштa; ялыккан; бизгән».

**ДИРБИЯ [дирбийә]** «комплект; сервиз; сбруя; корм; состав», чаг. иске тат. **тәрбийә** id. (Будагов I: 348), төр. *terbiye* «дилбегә; җигемлек» ~ як. *тэриэбэ* «дирбия» сүзләренә караганда, гом. төрки *тәр-* «җыю» сүзеннән шикелле; тик **дирбия** сүзенең формалашуына гар. **тәрбия** сүзе һәм, ихтимал, рус. диал. *збруя* «җигемлек» контаминацион тәэсир ясагандыр. Ахметьянов 1981: 82. Хәсән Әрән (1999: 404) бу сүзне ахыр чиктә монг. *tillbige* «дилбегә» сүзе белән бердәй дип аңлата.

**ДИСӘТИНӘ,** диал. **дисәтин** «десятина (1,09 гектара земли)» ~ чув. *теҫеттин,* удм. *десетин*, мар. *десачин, сетина* < рус. (к. Гордеев II: 261), рус. *десятина* асылда «гошер», «җирнең чиркәүгә садакага дип игелгән уннан бер өлеше» – *десять* «ун» сүзеннән, к. ш. ук тат. диал. **дисәтник** < рус. *десятник* «унбашы».

**ДИСБЕ,** диал. **тисбе, диспе** «чётки» ~ нуг. *дәспе,* каз. диал. *дисбәк* id. *тәсбих* сүзеннән, к. **Тәсбих.**

**ДИСТӘ** «десяток» < рус. *десть* «ике дюжина (тәүдә кәгазь битләрен санау берәмлеге була)», соңрак «дистә» сүзеннән; ләкин рус сүзе үзе фар. *дӓстэ* «дәстә, учлам, группа», таҗ. ш. ук «дистә, унлык» сүзеннән (к. Фасмер I: 507). Тат. **дистә** турыдан-туры фар. теленнән булырга да мөмкин, к. башк. *тәстә, тистә* (БҺҺ II: 273) «дистә». К. **Дәстә.**

**ДИСТЕР** диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «товарищ; одногодок», башк. *тистер* id. < фар. *дäстгир* id., хәрефмә-хәреф «кул тот» – «кул бирүче» (*дäст* «кул», *гир-* «ал, тот»).

**ДИХАЙ,** (БҺҺ II: 250) **тихай,** (ДС III: 51; БҺҺ II: 69; ТТДС II: 85) **дихи, дихай, дихәй** диал. «однообразный (о жизни), спонтанный; дикий, нецивилизованный; совсем чужой», башк. *тикәй* «простецкий, грубоватый; крестьянский» < фар. *диһи, дәһи, диhһаи, дәhһаи* «авылча, авыллардагыча» (*дәһ* «авыл, утар», *дәһһа* «авыллар») сүзеннән.

Бу сүзне рус. *тихий* сүзеннән дип карауга анлаут *д-* комачаулый: рус алынмаларында *т-* > *д-* күзәтелми.

**ДИҺКАН** «крестьянин; дехкан (крестьянин в Сердней Азии и Иране)» < фар. *диһқāн, деһқāн* id. ← *дәһ* «авыл».

**ДИЮ [дийү]** «див, чудовище безбразного вида и огромного роста, страшный, но глуповатый» < фар. *див, диw* «дию; әзмәвер» < бор. фар. *дәв* < авест. *daeva* «дию» – санск. *dĕva* «тәңре». Ирани халыкларда *дәв, дайва* һ.б. сүзләрнең «гаять көчле, әмма ахмак рух» мәгъ. белән бергә һәрвакыт «зур гәүдәле (кеше)» мәгъ. дә булган. Бу сүзнең гомумән кире мәгънә алуы бор. ирани халыкларның үзләренә якын кардәш халык – бор. һиндләр белән дошманлашуыннан килә; югыйсә, сүзнең төп мәгънәсе санск. *dĕva, dev, deo, deu* «тәңре, илаһ» һәм бу сүз һинд-евр. **deuos* «баш илаһ» (шуннан – *Зевс*) сүзе белән тамырдаш, к. ш. ук лат. *deus* «илаһ» (боларның чагылышлары барча һинд-евр. телләрендә бар). К. МНМ I: 417–418.

*Дию ~ дәү* сүзләре төрки телләргә б.э. беренче гасырларында ук кергән булса кирәк, чаг. **Тиле.** К. **Дәү, Дәүкәди, Дивана.**

**ДОГА** «молитва» > удм. *дуа* «бәхиллек, фатиха», чув. *тука* «сихер» < гар. *ду'ā'* «дога, җар, Аллага мөрәҗәгать» – **дәгъва** сүзе белән тамырдаш. К. **Дагый.**

Дерив.: **догалы, догасыз; догалык, догачы.**

**ДОРФА,** диал. **торпа, төрпә** «грубый в обращении с людьми» < бор. угыз. (төркм.) *дурфа* < фар. *турфә* «гаҗәп! гаҗәп нәрсә» сүзеннән, бу сүз исә гар. *турфӓ-т* «күзгә ташланган нәрсә» (*трф* «күзгә ташлану») дигәннән (к. **Тариф**). Ләкин бу сүзнең «дорфа» мәгънәсе яһ. теленнән килә.

Мәзкүр сүзнең икенче бер паронимы – себ. *торбайы, торпайы, торпы* (Старчевский; ДС I: 187) < фар. *турфаги* «гаҗәепле».

**ДОХА [дŏха]** «доха (шуба шерстью наружу)» – рус теленнән булса кирәк, ләкин киресенчә булу ихтималы юк түгел, к. **Ябага.** Рус. *даха, доха* < бур. яки калм. *даха* тур. Аникин: 179 (гомумән бу сүз монг. телләреннән).

**ДОШМАН** «враг» > чув., мар. *тушман,* чув. *тăшман*, удм. *тушмон* id., морд. Э. *душмон* «явыз», морд. М. *душман* «сихерче, җадучы» < гом. төрки < фар. *душмāн* «дошман» < авест. *duz manah* «начар уйлы»: *duz* «начар», *mana-* «уйлау» (к. Абаев I: 386). Федотов II: 205.

Дерив.: **дошманлы, дошмансыз; дошманлык** һ.б.

**ДӨБРӘН, дебрән** (ЗДС: 167, 169) «глухой, глухонемой, плохо понимающий слово» – төп мәгъ. «бастард; бүтән милләт токымы» бугай, к. каз. *дүбәре* «артык иртә туган бала; төрле токым кушылгагы; кушылма, кушылгак», каз. диал. (ҚТАС: 202–203) *дүбәрә, дүбәрән, дүбірән, дүбәрәндік, дүбірәнә* «артык иртә туган бозау, бәти, колын һ.б.» < фар. *дӯбāрә* «ике тапкыр», *дӯбäррә* «икеләч, бер елда ике тапкыр кузылаган сарык бәрәне һ.б.»

**Дебрән** атасы яки анасы урыс һ.б. бүтән милләттән булган балаларның еш кына тат. телен яхшылап белмәүләреннән булса кирәк.

**ДӨГЕ [дөгө]** «рис» > чув. *тĕкĕ*, удм. *дугы* < гом. кыпч., аз. *дүгү* < угыз., төркм., төр. *дүгү, дүги* (TS: 74; ТДГДС: 81), төркм., иске уйг., бор. төрки *түги* id., бу сүз гомумән чистартылган ашлыкны белдергән, к. уйг. *түги, түки* «борчак (ашлык)», күп төрки телләрдә *төй* «төелгән тары», к. Räsänen 1969: 503. К. **Тү.**

**ДӨЕМ [дөйөм]** диал., башк. «общий», тар. «общее собрание родов и племён башкир» ~ кырг. *дүйүм, түркүн-дүйүм* «төрле, һәртөрле, һәрнинди (халык)», каз., к.-калп. *дүйым* «төрле; гомуми; тулаем», *дүйым жұрт* «бөтен халык»; чаг. төр. *düyün*, *dügün* «туй» < **toj-kün* (Räsänen 1969: 142): *toj* «туй; тантаналы җыен»; *kün* «халык, ил-көн». К. ш. ук тув. *дөгүм,* хак. *төгем* «өмә». Башкортларның **дөйө**мнәре Дим тамагы тирәсендә (Берсуан елгасы буенда) булган, к. **Дим II.**

**ДӨЛДЕЛ [дөлдөл]** «сказочная летающая лошадь», диал. «лошадь с пышной гривой и хвостом; мохнатый» ~ башк. диал. *дөлдөл* «кешегә тырышып эшләгән кеше» < гар. *дулдул* – Мөхәммәт пәйгамбәрнең ак качыры, ул аны хәзрәте Галигә бүләк иткән булган һәм бу менге хайван күп сугышларда катнашкан. Ислам дөньясында бик билгеле кыйсса һәм сүз.

**ДӨЛМӘН** «большая папаха (генералов)» к. **Дүлмән.**

**ДӨМ** эмфатическая частица – «совершенно», диал. **дөммә-дөм** «кап-караңгы» > морд. Э. *дюм,* мар. *түм* < угыз-төркм. *дүм* «бөтен; бөтенләй» ~ төр. *tüm* id., чаг. төркм. *түм,* як. *түң* «кап-караңгы» (к. Dil yazıları. Ankara 1974: 211–217). Махсус мәкалә: Eren H. Tümmü yoksa bütünmü // Türk dili, 1994: 403–409. К. **Төм.**

**ДӨМБЕ [дөмбө], дөмбәс** «ботало» ~ мар. *томба* id., морд. *томбамс* «дөмбәсләү», чув. *тăмпă* «дөмбәсләү авазы», чаг. рус. *дубасить* – тәкълиди **домп** < **дүмп** сүзеннән ясалалар.

**ДӨМЕК-Ү (дөмекте, дөмегү)** «пропасть; околеть, издыхать» – тат. һәм башк. телләрендә генә булса кирәк – ***дөм-ү** фигыленең интенсивлык формасы. К. **Дүн-ү, Түң-ү (дөмек-ү << түңек-ү).**

Дерив.: **дөмектер-ү; дөмеккән** «чукынган» (каргану сүзе).

**ДӨНГЕШ [дөңгөш], дөгәҗ** (ДС II: 76; БҺҺ II: 70) «вид шмеля» чаг. **Иңкеш.**

**ДӨНЬЯ [дөнйа],** диал. **донйа, донҗа** «мир, свет» < гар. *дунйā* «якын, башлангыч, тәүге (яшәү дәвере)» – **ахирәт**кә каршы куеларак әйтелгән; бу ислам дине тәгълиматы белән киң таралган; удм. *дунне, дунза, динза*, чув. *тĕнче*, мар. *төня, дуньҗä, дүнчä* (к. ш. ук мар. *түня умбал* ~ тат. *дөнья йөзе* ~ чув. *тĕнче çĕри*).

**Дөнья** сүзенең дериватларыннан **дөньялык** ~ нуг. *дуньялык,* кар. *дуньялых*, гаг. *дүннäлык*, кырг. *дүйнөлүк* һ.б. еш очрый.

**Дөнья** сүзенең гарәпчәсе шактый ясалма семантикага («якын → дөнья») ия, шуңа күрә бу сүзне бор. фар. *du niyo < du nizaya* «икенче тапкыр туу» (беренчесе Алланың язмышлар китабында булганы) сүзеннән дип аңлату бар. Гарәпләр бу сүзне үз сүз ясау калыпларына керткәннәр (мондый хәл бүтән сүзләрдә дә күзәтелә, к. **Кәгазь**). Ахметьянов 1989: 5–6.

**ДӨРЕС [дөрөс],** иск., кит. **дөрест** «правильно; правильный, верно и то» > чув. *тĕрĕс*, мар. *тӹрыс, дӹрыс*, удм. *дъръсь, дурись* < фар. *дуруст, дүрүст* «дөрес, каты, көчле, сәламәт» < бор. ир. **duruva ast* «агач кебек» сүзеннән (к. Pokorny: 214–216). Федотов II: 221.

Дерив.: **дөреслек; дөреслә-ү; дөрестән дә** һ.б.

**ДӨРИЯ [дөрийә]** «муар, переливающаяся цветами ткань; тафта, атлас» ~ кырг. диал. *дүрүйә* < фар. *дӯ рӯйэ* «ике йөзле, ике яклы (ике ягы ике төрле)» сүзеннән.

**ДӨРРӘ, төррә, терря** «возглас, которым гонят овец» ~ чув. *тĕр-р* һ.б. Ниндидер бор. телдә «сарык» мәгъ. сүз булырга тиешле.

**ДӨРРИЯ [дөррийә]** кит. «перл, жемчужина» < гар. *дүррийä-т* id.; к. иске тат. **дөрре** < гар. *дүррүн* «энҗе бөртеге; шедевр»; **дөрре ятим** «бердәнбер нәрсә, әсәр, кыйммәт» (мәс., Мөхәммәт пәйгамбәр).

**ДӨЯ [дөйә],** диал. **дәвә, тәвә** «верблюд» ~ чув. *тĕвĕ*, мар. *тӱе*, удм. *дүйэ* id. ~ гом. төрки *дүйэ, түйэ*, угыз линиясендә *дэвэ, тэвэ* < бор. **түгэ, түгэне, тэвэгэн,* (ДТС: 557) *tevi.* К. ш. ук фин. *tewapa* ~ монг. *тэмэ, тэмэгэн ~ *тэбэгэн* «дөя» – бор. мәдәни сүз. Корнилов 1970: 225; Räsänen 1969: 114; Федотов II: 211.

Кайбер төрки телләрдә, мәс., каз. телендә дөянең (яше-җенесе атамаларыннан тыш) егермеләп төрен аералар. З. Мухамедова (1973: 86) буенча, төркм. *деве, девей* «дөя» тәүдә дөянең инәген белдергән, чаг. төркм. диал. *дүйу, дүве, түве* «бозау, сыер» (к. тат. **Түгәнәй**). К. **Дәмән, Тәвә.**

**ДРАНЧА, дыранча** (к. фольк. *Өй түбәсе дыранча, Дыранчасын җил ача*) «щепка для покрытия крыши» < рус. *драница* id. К. ш. ук чув. *транча,* мар. *дыранча, транза,* удм. *дранча* < тат.

**ДУ: ду килү** «разбушеваться, расшуметься» ~ башк. *дыу* «шау-шулы», кырг. *дуу* «шау-шу», ком. *дув* «котырынкы», монг. *дуу, дуун* «тавыш; җыр», эвен. *дэву* «өермә; җил-буран» һ.б. Бу сүз саф тәкълиди характерда түгелдер, ләкин **дуылда-** тәкълиди характердагы ясалма. К. ш. ук **Дула-у.**

**ДУАДАК,** диал. (ЗДС: 171, 175) **дуwадак, дуғадақ, дуғазақ, дывадақ** «одинокий; холостой; скотина без хозяина» ~ нуг., каз., к.-калп. *дуwадақ,* үзб. *туwдақ, туwалақ,* кырг. *тоодақ,* монг. *тоодог* < *тоғадаг* ~ венг. *tuzok* «дуадак каз; дүдәк», бор. төрки (ДТС: 570) *toδ, toj* «дүдәк», чыгт., госм. *toy* id. Бу сүзнең формалашуына бор. төрки *tuysaq* «тол хатын» (> тат. фольк. *Тугызак карчык* – кабиләдән бер оныгы белән ялгыз торып калган карчык) сүзе тәэсир иткән. К. **Дүдәк.** Чаг. ш. ук башк. *туғазақ, тыуғазақ* «ту-казак» (парлы сүз) «дуадак, дүдәк» (к. **ту** һәм **казак**). Каз. (ҚТАС: 202) *дуалақ* «дүдәк» икенчел.

**Дуадак ~ дүдәк** мәгъ. күчеше дүдәкләрнең берсе балалары белән яшеренебрәк йөргәндә икенчесенең ялгызы гына тирә-юньне карап торуы белән баглы.

**ДУАМАЛ** «взбалмошный; необдуманно, безрассудно» > мар., удм. диал. *дуамал*, чув. диал. *тăвамал* < нуг. *давамал* «дию кебек, җен кебек» (нуг. *дав* «дию; дәү», *амал* «кебек» ~ тат. диал. **әмәл, әмән** «кебек, шикелле, гүяки» < фар. *һāмāн* «шул ук») яисә *давамал* «дию гамәлле, диюләрчә кыланышлы» (*амал* «гамәл, кыланыш, эш итү рәвеше») сүзеннән, к. башк. *дәүмәл* < **дәүәмәл* «зурлык; зур, көчле, дию кебек» ~ иске тат. (Радлов III: 1608) *даумал* «кискен, тупас». Бу сүзне **дәгъвамал*дан дип аңлату да бар (*-мал* монгол кушымчасы).

**ДУВАН [дуwан]** иск. «плотина», «грубая корзина из хвороста (которая первоначально употреблялась для возведения плотины)» (к. ДС II: 78) < бор. тат. **дуған* id., к. иске тат. (XIX г.) *дуғамы* «буа; тоба» (к. Будагов I: 572) ~ тат. диал. (ДС II: 78) **дуваны** – «зур шешә урнаштыру өчен кәрзин» ← «буа буар өчен кәрзинсыман үрелмә» ~ уйг. *туған* «дамба», үзб. *туғоң*, кырг. *тогон, тогоон* «бөя, дамба» ← чыгт., уйг., үзб. *туғ* «бөя, дамба», бор. төрки *tuγ* «киртә; сиңгәр; юшькә» ~ фар. *тӯғ* «кыршау, чәмбәр; камыт, муенса; будыргыч». К. ш. ук **Тугым, Тугынак.**

Башкортстанда **Дуван** каласы, районы, елгасы һәм хәтта кабиләсе дә бар. Дуван каласын **дуган** (к.) белән чагыштыручылар да очрый.

**ДУГА** «дуга» рус теленнән диючеләр бар, әмма каты *-г-* моны расламый. Чаг. **Дугай.**

**ДУГАЙ** «старица (длинное кривое озеро на месте старого русла реки)»; «полукруг» ~ башк. (БТДҺ: 82) *дуғай* «елганың киңәйгән урыны», тув. *дугай* «дугай, бөгелеш; терсәк», *дугуй* «тәгәрмәч», як. *доғуй* «тез бөгү» (Пекарский: 729) һ.б. **Тугай** белән бердәй.

Дерив.: **дугайлан-у** «дуга шикелле бөгелү».

**ДУГАН** – компонент в составе ойконимов: **Дуган, Карадуган.** Чаг. монг. *дуган* «буддистлар гыйбадәтханәсе».

**ДУГЫЗ** диал. «рама на потолке вокруг печной трубы» ~ ком. *догаз, тогас* «аркылагач, әрлүс», аз. диал. (АДДЛ: 195, 203) *доғғоз, дуғғазчә* «тишекле аркылагач», таҗ. *дугаза* «агач аслык»; *дугыз* < *дугаз* нигезе халык этимологиясе буенча *донгыз, дуңгыз* дип әйтелә (ДС II: 53, 57). Чынлыкта бу сүз *туғ* «йомык дүртпочмактан гыйбарәт деталь, бөҗра» тамырыннан булса кирәк, к. **Дуван, Тугым.**

**ДУДАК** кит. «губа, уста» ~ чув. *тута [туда]* ~ төркм. *тодақ,* госм. *дудақ,* төр. *dodak* id. ЭСТЯ III: 251; Федотов II: 256.

**ДУЕН I [дуйы̆н]** (ТТДС II: 86; БТДҺ: 82) «наносной ил; накипь» ~ үзб. (ЎХШЛ: 92) *дуйин* «кара балчык», каз. (ҚТДС: 333) *тойын*, төркм. *тоюн* «саз балчыгы» ← уйг., шор., каз. *той*, як. *туой* «чүлмәк ясарлык балчык, мәте», бор. төрки *tōj* «балчык, мәте». Чаг. кыт. *дуй* «өю, салу». Räsänen 1969: 488.

**ДУЕН II [дуйы̆н]** (ТТДС II: 86) диал. «апогей торжества (свадьбы и т.п.)» < бур. *дуил*, бор. монг. *tuil* «азак, чик; апогей». К. фразеологизм: *ун көн туен, ун көн дуен (үткәрәләр).*

**ДУКИЛ, дукиле** (ЗДС: 172) «беспредельно, до конца; всё время; все» < иске тат. («Мәҗмугъ әл-хикәят» һ.б.) *ду күлли* «бөтенесе, һәммәсе» фар. теленнән булса кирәк: *ду* «ике; ике як», *күлли* «барчасы». Рус. *докель* сүзеннән дип аңлату (ТТДС I: 128) да бар.

**ДУЛАП, тулап** иск. «круглый вертящийся шкаф» < төр. *dolap* id. һәм бүтән күп мәгъ. («карусель», «чар» һ.б.) ~ гар. *дӯлāб* «түгәрәк кимә (елга кичү өчен генә)», күп. *дäwāлӣб*. Ләкин бу сүз гарәпләргә төркиләрдән кергән булса кирәк. Будагов I: 573; Steuerwald: 237–238; Özön: 175.

**ДУЛА-У,** диал. **тула-у** «понести (о лошади); бурно протестовать, буйствовать» ~ башк. *тула-*, мар. *дула-*, *тула-*, чув. *тăвла-, тăвăлла-,* удм. *дуа-, дула-* id., гом кыпч., нуг., ком. *дувла-* «дулау», каз. *тула-,*

кырг. *туула-,* алт. диал. *туйла-,* тув. *дывыла-* «үрә басу (ат тур.)». Күрәсең, монда **ду** (к. **Ду килү**) тамыры белән бүтән бер тамыр да контаминацияләнгән. К. монг. һәм тунг.-маньч. *дуула-*, *давла-* < *дагула-* «шаулатып җырлау», **дагу** «җыр», к. ССТМЯ I: 186.

Дерив.: **дулат-у, дулаш-у.**

**ДУЛКЫН,** диал. **тулкын** «волна» < гом. кыпч. *толқын*, үзб., уйг. *толқин*, ком., кырг. *толқун* ~ як. *долгун*, монг. *долгиин, долгион* «дулкын» ← тат. диал., башк. (БТДҺ: 335) *тулкы-,* каз. *толқы-,* кырг. *толқу-*, як. *долгуо-*, монг. *долги-* һ.б. «дулкынлану; дулкын бәрү; дулкында хәрәкәтләнү» (к. Räsänen 1969: 487), асылда *дулкын* < **дулкыгын,* к. тат. диал., башк. *тулкын-у* «дулкынлану, дулкын кебек хәрәкәтләнү» ← бор. төрки *tōl-* «төртү, бәрү; бәрелү» < **toγul-*, бор. гом. төрки *toq-* «туку, тукылдату» тамырыннан булса кирәк. Чаг. шор. *токыл* «дулкын» < *ток-ыл* (монда метатеза гына түгелдер); к. ш. ук башк. (БТДҺ: 335) *тулкыт-* «борчу» ~ як. *толгут-* «дулкынландыру».

Дерив.: **дулкынлы, дулкынсыз, дулкынлан-у, дулкынчык.**

**ДУМБЫРА, думбра** «домра, домбра» > удм. *домбро,* мар. *томра*, чув. *тӑмра* «балалайка» ~ кр.-тат., төр. *тамбура, дамбура* < гар. *ṭамбӯр* (> рус. *тамбурин*) «думбыра; цилиндр» << иске фар. *dumi barra* «озын муенлы кабак төре», асылда «яшь куй койрыгы» сүзеннән (Platts I: 331): *dum* «койрык», *barra* «яшь куй, бәрән». Рус. *домра* – татарчадан (Фасмер I: 528). Федотов II: 192.

**ДУҢГЫЗ** «свинья, боров» > мар. кч. *тоңгыз* «дуңгыз», чув. *тункăс* «ахмак», удм. *дуңгыз* «ялкау» < гом. төрки *доңгуз, тоңгуз* (барча телләрдә һәм диалектларда очрый); бу сүз тур. күп язылган (к. Räsänen 1969: 488; ЭСТЯ III: 267–268 һ.б.), күпчелек телчеләр кор.-кыт. *ton, toŋ* «дуңгыз» сүзе белән чагыштыра, чөнки дуңгызчылык Корея һәм Кытай халыкларына аеруча хас. Ләкин дуңгызчылык терминологиясе төрки халыкларда да бигүк ярлы түгел, к. **Турай, Чучка.** Ахметьянов 1989: 68 (тәфсиллерәк аңлатма).

Гади сөйл. **дуңгыз** – берәүне сүгү сүзе; бөтен дөньяда таралган мотивация, чөнки дуңгызлар әрсезлеге, тирестә, былчыракта чокчынулары белән характерлана. **Дуңгыз** сүзенең шул күч. мәгънәсе нигезендә – **дуңгызлык, дуңгызлан-у.** Начар дуңгыз фермаларын *дуңгызчылык түгел бу, дуңгызлык,* дип сүгәләр...

Әд. телдә **дуңгыз** сүзен *чучка* сүзеннән аерырга кирәк: беренчесе җитлеккән терлекне, икенчесе аның баласын белдерә. Хәлбуки сөйл. телендә бу сүзләрне аермау, буташтыру күзәтелә. К. ш. ук **Дугыз.**

**ДУПЛЫ** «дублёный» – рус теленнән үзенчәлекле үзгәрештә алынган: рус сүзе исә *дуб* < бор. *дубль* ~ *дубръ* «имән (кайрысы)» сүзеннән: тирене имән кайрысында тоту аны иеләүнең мөһим бер стадиясе.

**ДУС,** иск., кит. **дуст** «друг» > чув., мар. *тус*, удм. *дус* < фар. *дӯст* < бор. фар. *дōст* < бор. ир. *dauštar* «(үзеңә) охшаган кеше»: *dauš-* «ошау; теләү». **Дустанә** «дусларча» – фарсычаның үзеннән.

Дерив.: **дуслык; дусларча; дуслаш-у** һ.б.

**ДУЧ: дуч булу** «встретить неожиданно; попасться» к. **Туш.**

**ДУЧАР** «подвержен; постигнут; обречён» < фар. *дӯчāр* «бергә-бер очрау хәле, дучар» сүзеннән.

**ДУЧМАК,** диал. (Остроумов 1892: 628; ДС I: 49) **дурчмак** «четырёхугольная ватрушка» < *дүрт почмак.* К. **Дүртмәк.**

**ДҮДӘК** «дрофа» – ком., нуг., каз. *дувадақ, дуадық,* к.-балк. *дудақ,* кырг., калм. *тоодақ,* уйг. *доғдақ*, тув. *тогдуқ,* чыгт. *тоғадақ,* иске монг. *тогодог* һ.б. id. Рус диал. *дудак* id. кыпч. телләреннән. Бу сүзнең вариантлары бик күп (һәм бу дүдәкнең элек йорт кошы булуы белән аңлатыла): иске монг. (Поппе 1938: 161) *toγdak, toγdai*, төркм. *тоғдары, тоғдуғуш*, *тоқлытай,* каз. *дуалақ, дувалақ,* бор. төрки (Räsänen 1969: 483) *doγdur*, венг. *túzok* id. Сүзнең тамыры бор. төрки (ДТС: 570) *тоб, toj* «дүдәк», к. ш. ук **Дуадак.**

Рус. *дрофа* < *дрохва* сүзен дә болг.-чув. **дырах* < **тоғрақ* < *тоғдақ* дип аңлаталар. Бу гипотетик вариантларга ним. *Trappe* «дүдәк» сүзе дә кушыла (к. Добродомов И.Г. Тюркские заимствования в названиях птиц: дудак // СТ № 2, 1970). Сафина 2006: 32–33.

**ДҮДӘРДӘК** (ДС I: 89), **дүдәрлек** (ЗДС: 174) «вид диких уток» ~ к.-балк. *дудақ* «кыр казы». К. ш. ук удм. *дӧдек, дыдык*, коми. *дыды* «күгәрчен», чех. *dudek* «һөдһед». Соколов 1967: 195. Бу сүзләрдә берничә кош атамасы контаминацияләнгән. Чаг. ш. ук төр. һ.б. Шәрык телләрендә *dudu* – «күп сөйләүчән» кош төре, гомумән – «сүзчән чибәр». Рус жаргонында *мадам дуду* id.

**ДҮКӘЛЕ** (ЗДС: 174) «временно; временная жена» – рус. *доколе, доколи* «кайчангача» сүзеннән булса кирәк. Мәзәк мәкаль бар: *Дүкәле дип алган [хатын] – үзеннән соң калган.*

**ДҮЛӘ** диал. (Халиков Н.А.: 125) «груша» < рус. диал. *ду́ля* id. (к. Фасмер I: 552).

**ДҮЛӘНӘ,** диал. (ДС III: 235, Тумашева 1992: 217) **дулана, тулана** «боярышник» ~ алт. *толоно,* тув. *тологона,* як. *дологоно, долокуна, долукуна, дөлүөсүөн* «дүләнә; гөлҗимеш» < бор. ***толукана*** (безнеңчә) «тугылы кана»: (як.) *тоо* < **тогу* «вак җиләк; муенса», *тоолу* < *тогулу, кана//куна* «куак, курпы», к. **Куна-у.**

**Дүләнә** киң таралган сүз, к. ЭСТЯ III: 269–270; ССТМЯ I: 214. Фар.-таҗ. телендәге *дулана* «дүләнә; тилебәрән» *ду лана* «ике оя» (орлыгы ике оялы) дип тә аңлатыла, ләкин бу – халык этимологиясе. Рус. *дологон, толоно* «дүләнә» тур. Аникин: 530.

**ДҮЛМӘН, дөлмән** (Ш. Камал) «папаха; копна волос» < госм. *дүлбәнд, түлбәнд* «чалма; тюльпан» < фар. *дӯлбәнд* id.: *дӯл* «цилиндр; чиләк» (к. **Тубал**), *бәнд* «урама». Госманлы төрекләренең хәрби баш киеме катыргы цилиндрга уралган биек ак яисә кызыл чалмадан гыйбарәт булган. Шуннан ук рус. *тюрбан* һәм *тюльпан* сүзләре дә килә.

Иске рус. *доломан* «махсус гаскәри баш киеме» дә төр. диал. *дулыман* < *дүлбәнд* сүзеннән; чув. *тăламан* «дүлмән (бүрек)» рус теленнән булса кирәк.

**ДҮНӘН** «четырёхлетняя лошадь» < монг. *дөнэн* < *дөрнэн* id., *дүрт* сүзе белән тамырдаш. ЭСТЯ III: 278–279. Рус. дунан «дүртенче яштәге терлек» тур. Аникин: 191 (бай әдәбият күрсәтелә).

**ДҮН-Ү** «отрекаться; отступить (от намерения)» < госм. *дөн-* < гом. төрки *төн-* > тат. *түн-* id. К. **Түн-ү.** Будагов I: 576; ЭСТЯ III: 276–278.

Дерив.: **дүнел-ү, дүндер-ү.**

**ДҮҢГӘЛӘК,** диал. **дүңгәнәк, түңгәләк** «деревянное (вязовое) кольцо или зажим (для различных целей)» < гом. төрки *дөңгәләк, төңгәләк,* бор. монг. (Поппе 1938: 211) *tüngelik* «алка, бөҗра» һ.б. (к. ЭСТЯ III: 281–283) бор. төрки *töŋäl* ~ тунг. **toŋal* ~ кор. *тоңгыл* «түгәрәк, дүңгәләк» сүзеннән (к. ССТМЯ I: 198). **Түгәрәк** сүзенә турыдан-туры бәйләнешы юк.

**ДҮҢКӘЛ** «мушмула (дерево)» < төр. *döngel* id.

**ДҮРТ** «четыре» < гом. төрки *төрт* (> угыз. *дөрт*) ~ монг. *дүрбэн, дөрбэн,* эвенк. һ.б. *дыгин, дигин* id., эвенк. *дигирэгдэ* «дүртәү, дүртәүләп» (ССТМЯ I: 204). ЭСТЯ III: 284–286. Бу – барча алтай телләренә уртак булган бердәнбер сан. К. **Түтәрәм.**

Дерив.: саннар өчен регуляр; к. түбәндәгене.

**ДҮРТКЕЛ** «четырёхугольный» < *дүрт кел: кел* < гом. кыпч. *кил, кэл,* төр. *гэл* «почмак». Чаг. *бишкел, өчкел.*

**ДҮРТМӘК,** диал. (ЗДС: 174) **дүречмак, дурочмак, дүртмеш** «род лепёшки», видимо «четырёхугольник» ← *дүрт* + *-мәк* «ашамлык төре». К. ш. ук алт. сөйләшләрендә (Баскаков 1966: 154) *тäртмäк, тäрпäк, тäртмäк* «(түгәрәк) көлчә, күмәччек» > рус. (Аникин: 546) *терпёк* «көлчә төре». Чаг. **Өчмәк** < **Өчпочмак.**

**ДҮСМӘТ** (ЗДС: 174, дөб.) «здоровенный» ~ үзб., таҗ. һ.б. *дусмат, дустмәд, дустмәт* id. < *дустимөхәммәд* «Мөхәммәт пәйгамбәрнең дустларыннан берсе». Шулай дип, бик көчле кешеләр булган дип күзалланган сахабәләр тур. әйткәннәр. **Дусмәт** хас исеме *дусти-мәрд* «батыр дус» сүзеннән дә килеп чыга ала (бу исем төрки халыкларда еш очрый).

**ДҮСТЕР** (ТТДС I: 134) «очертания» ~ чаг. кар. *тюрсюнь* «сурәт, кыяфәт», үзб. *дурсун, дүрсүн* < монг. *dürsün, dürüsün* id. *dürü* «йөз, бит» сүзеннән. **Дүстер** бәлки бор. монг. *dürsüt* «йөзләр, битләр» сүзеннән метатезадыр.

**ДЫМ** «влага; сырость» ~ удм., мар., нуг., каз. *дым,* үзб. *дим* ~ чув. *лăм,* кырг. *ным* id. Чаг. уйг. *нәм,* үзб. *нам* id. Мар. *лүм,* удм. *лымы,* фин. *lumi* «кар» белән чагыштыру (Егоров: 126) дөрес түгелдер. Э.В. Севортян (ЭСТЯ III: 294) бу сүзне тат. (Будагов I: 566) *дум* ~ төр. *dum* «сыеклык, сыекча» сүзе белән бергә карый. Безнеңчә, *дым* һәм *дум* – икесе ике тамырдан.

Дерив.: **дымлы, дымсыз; дымлан-у;** диал. (ЗДС: 175) **дымай-у, дымайт-у, дымык-у.**

**ДЫҢГЫЧ** «уплотнитель; притужальник» ~ башк. *тынкыс* id. гом. төрки *тыңк, дыңк* «киеренке, нык» тәкълиди сүзеннән (аның фигыль мәгънәсеннән, к. диал. **дыңкы-у** «үзенекен итү; көчләп тотыру, ныку» һ.б.).

Дерив.: **дыңгычла-у.**

**-ДЫР//-ДЕР** кушымчасы, к. **-тыр//-тер.**

# Е

**Е** – бу хәреф ижек һәм сүз башында килгәндә **йӗ** һәм **йы̆** аваз тезмәләрен белдерә.

**ЕГӘР [йӗгәр],** диал. **җегәр** «мощь, сила; энергия», «мощный, энергичный» > чув. *йӗкер,* мар. *йыгар, йегар, җыгар*, удм. *зигар* id. фар. *җигäр, җегäр* «бавыр; йөрәк; үпкә; кыюлык» сүзеннән, бор. һинд-евр. **yeg*[u]*r, yek*[u]*r* «бөер, бавыр» тамырыннан, к. лат. *jecur*, лит. *jeknos* «бөер».

Бу сүз төрки телләргә бор. заманнарда ук кергән һәм төрле мәгъ. алган, к. иске тат. *җөкәр* «йөрәк» (*Балам, бәпкәм, җөкәр-бәгърем,* дип башланган җыр бар), нуг. *йигер* «ихтыяр, үҗәтлек, кыюлык», кр.-тат., к.-балк., ком. *җигер* «гайрәт, тырышлык», төркм. *җигер* «йөрәк, йөрәклелек», госм., гаг. *җийәр* «бөер, йөрәк», як. *сэгэр* «бәгърем» һ.б. Төрки телләрдән бик күп күрше телләргә дә кергән. Ул, ихтимал, фар. теленнән генә түгел, бүтән ир. телләрдән дә таралгандыр. Будагов I: 438.

Дерив.: **егәрле, егәрсез; егәрлек, егәрлән-ү.**

**ЕГЕРМЕ [йӗгӗрмӗ],** диал. **җегерме,** иске тат. **йӗкӗрмӗ,** себ. (Тумашева 1992: 72) **йәгирмә** «двадцать» < бор. төрки (ДТС: 253, 200) *jegirmi, jigirmä,* үзб., уйг. *йигирмә, җигирмә,* чыгт. *йигирми* id. Бүтән төрки телләрдә бу сүз нык үзгәргән: төр. *yirmi,* нуг. *йырма,* ком. *йыгырма*, каз., к.-калп. *жигирма, җигӗрбä,* кырг., к.-балк. *жыгырма, жыйырма,* алт. сөйләшләрендә *чигирбэ, дьиирбе, йäгäрбä,* тув., хак. *чээрби*, як. *сүүрбэ* id.; чув. *çирӗм*, *çӗрӗм* < болг. **җирӗм* < бор. тат. (хәз. тат. диал.) **җигӗрӗм* id. (*җигеремберр* дип әйтелә) һ.б. бу сүзне гом. төрки, монг. *эгиз ~ игир ~* чув. *йӗкӗр* «игез» сүзе белән чагыштыруга этәрәләр. Ләкин кайбер кыпч. телләрендә сингармонизмга буйсынмаучан (димәк, кушма сүз) һәм веляр вариантлар күп кенә сораулар куя. Каз., к.-калп. *жигирма < җигир + ма* сүзеннән булса кирәк. Бу *-ма* каян килгән? – бу хакта күп бәхәсләр, фаразлар бар (к. Федотов I: 121–123). Без дә үзебезнең фаразны тәкъдим итик: *-ма* кыт. *ма* «ат» сүзеннәндер. Хикмәт шунда: казакларда туй бүләге – калым *җійрма* дип аталган һәм *егерме ат*ка яисә шуңа тиңләштерелгән мал-туар санына тигез булган (к. Будагов I: 360). Кәләшнең әтисенә *ике ат* бүләк йоласы башкортларда XX г. кадәр сакланган. К. ш. ук. Räsänen 1969: 204; ЭСТЯ IV: 201–202.

Дерив.: **егерменче, егермәләп (егермеләгән); егермеле, егермесез** «егермегә, егерменчегә җитмичә»; **егермелек** һ.б.

**ЕГЕТ [йӗгӗт],** диал. **җегет, җигет** «джигит, молодой человек (кавалер), парень» > чув. *йӗкӗт,* мар. *йыгыт*, удм. *зигыт, зэгыт* < гом. төрки *йигит* (кыпч. *җигит* > шор. *чиңäт*) һ.б. (вариантлары бик күп); бу сүздә бор. төрки-монг. күп. кушымчасы *-т* бар, к. хак. *чиит* ~ иске монг. *jigede* «яшьләр». Гадәттә бу сүзне бор. төрки *tegit* «шаһзадәләр төркеме» ← *tegin* «шаһзадә» сүзләре белән бәйлиләр, М. Рясянен (Räsänen 1969: 203) моңа кушылмый. Әмма к. добр. тат. телендә *җегент* «егет» (Akb: 146). Гомумән, мәзкүр сүзләр тур. әдәбият бик ишле, к. Малов I: 430; Clauson: 483; Федотов I: 192; Donuk: 48–49; ЭСТЯ IV: 198–199.

Дерив.: **егетле, егетсез** (кыз); **егетлек; егетләрчә; егетлән-ү.**

**ЕК-У (йыкты, йыгу),** диал. **җык-у (җыгу)** «валить, свалить» < гом. кыпч. *йык-, җык-* «егу; кулдан төшерү», бор. төрки, бор. чыгт. һ.б. (к. ДТС: 268, Боровков 1963: 155–157) *jiq-, jiŋ-* id.; ЭСТЯ IV: 273–274.

Дерив.: **егыл-у, егыт-у** (регуляр булмаган форма), **ектыр-у.** Чаг. **Җиң-ү.**

**ЕЛ [йы̆л],** диал. **җыл** «год» < гом. төрки *йыл* (> кырг., к.-балк. *җыл,* каз. *жыл*), бор. төрки (ДТС: 266) *jïl,* чув. *çул, çол* < **җал* ~ болг. *җал* «ел», монг. *җил*, бур. *жэл*; бу сүздә бор. *а ~ ы* чиратлашуы чагыла. К. ш. ук тув. *чыл,* як. *сыл* «ел».

Типологик закон буенча, «ел» мәгъ. сүз берәр ел фасылы һәм табигать күренеше атамасы белән тәңгәл була (чаг. тув. *хар* «кар; ел, яшь», мар. *ий* «боз; ел, яшь», морд. *киза* «җәй; ел», бор. кидань телендә *по* «яз; ел, вакыт» һ.б.); ошбу законга таянып *йы̆л* сүзен бор. **йāл* «яшь» (*л ~ ш*) сүзе белән бердәй диләр. *Елын еллаган, яшен яшәгән* әйтеме дә шуңа ишарә. Räsänen 1969: 192; Федотов II: 130–131; ЭСТЯ IV: 275.

**Ел** продуктив нигез: **еллы, елсыз** («бер ел үтмичә»); **еллык** (төрле мәгъ.); **елла-у** (шуннан **еллат-у, еллаган**); **елдан-елга; елын-елга;** конкретлаштыргыч сүзләр белән: **елгы, еллап.** *Ел* сүзе

белән ясалган күп кенә фраземаларны Будагов (II: 389–390) китерә.

**ЕЛА** (вид дерева) к. **Җыла.**

**ЕЛАН [йы̆лан],** диал. **җылан** «змея» ~ чув. *çĕлен* < гом. кыпч.: каз., к.-калп., к.-балк., кырг. *җылан*, кырг. *җылаан*, нуг., уйг., угыз. *йылан,* алт. *дьылан*, тув., хак. *чылан* ~ бор. төрки (ДТС: 266) *jılan* id. – этимологларның бердәм диярлек фикеренчә *йыл-* (к. **Ел-у**) «җирдән шуышып бару» сүзеннән, к. Ашмарин XIII: 58–63; Räsänen 1969: 200; ЭСТЯ IV: 40–41; Федотов II: 106–107. Рус. диал. *джиланка, чилан* «елан» тур. Аникин: 184, 661.

Сүзнең ясалышы тур. төрле фикерләр була: **йыл-аң* (*-аң* «хайван, җәнлек»), **йыл-лаң* (*-лаң* ш. ук хайван атамалары ясагыч кушымча), *йыл-ан* угыз телләрендә «елучан» һ.б. Ш. ук бүтән фикерләр бар: тат. *йүлан* (?, к. Будагов II: 362) ~ монг. *nilaii* «шома» (к. Рамстедт 1957: 143).

**Елан** – миф. һәм фольк. төп персонажларның берсе, күбесенчә тискәре, явыз зат образы, еш кына – су хуҗасы, төрки календарда **елан елы, елан атнасы, елан сәгате** һ.б. булган.

Дерив.: **еланлы, еланлык** «хәйләкәр явызлык» мәгъ.

**ЕЛА-У [йы̆ла-у],** диал. **җыла-у** «плакать» < гом. кыпч.: башк. *ила-у,* нуг., кар., ком. *йыла-*, кырг., алт. *ыйла-*, к.-балк., кырг. *җыла-*, каз., к.-калп. *жыла-* < уйг., чыгт. *йиғла-, йығла-* ~ угыз. *ағла-* id. Бор. язмаларда (ДТС: 18, 21, 218, 266) *ayla-, ayïla-, jïyla-, ïyla-* id. ← бор. төрки *aγı ~ ıγı* «елау күренеше, үлгәннәрне искә алу» ← **ā-//ī-* «елау, елашу» (к. **Ыгы-зыгы**). К. ЭСТЯ I: 79–81.

Тат. әд. телендә угыз һәм уйг. телләреннән кергән *ағла-у* һәм *йығла-у* вариантлары да (татарча төрләнештә килеп) еш кулланылган һәм хәзер дә очрый: әд. телдә төп норма *ела-у* исәпләнсә дә, кайбер язучылар *җыла-у* вариантын кулланалар.

**Ела-** продуктив нигез: **елаш-у, елат-у; елавык; елак;** диал. **еламык** «елау, күз яше агу чире» һ.б.

**ЕЛГА [йы̆лға],** диал. **җылга** «река», диал. (Будагов I: 439; ДС III: 67) «суходол» > чув. *йăлка* «төп үзән», мар. (Исанбаев 1978: 26) *йылга* «елга» < гом. кыпч.: нуг. *йылга*, кырг. *җылга*, каз., к.-калп. *жылга,* уйг. *йылға,* уйг. диал., үзб. *җилға* ~ яз. монг. *ǯilγa*, бур. *жалга* «елгасы булган сай үзән; ерынты», кар. (хәтта) *илға, йылға* «дала, киң үзән», төр. *ulga* «тауларда кәҗә сукмагы». Бу сүзнең *-у-, -ү-* вариантлы бездә дә бар: башк. (БҺҺ II: 73) *йүлгә* «сай үзән» ~ үзб. *җулға* «үзән», каз. *жулга* «елгачык» һ.б. һәм бу вариант сүзне хак. *жул, җул*, чув. *çăл*, алт. диал. *йул* < бор. төрки (ДТС: 277–278), *jul, jūl* «чишмә; кое; тау елгасы» сүзе белән бәйләргә хокук бирә. Ләкин фонетик җәһәттән кайбер сораулар җавапсыз кала. Морфологик җәһәттән *йылга* << *йулгай* (*гай* < *кай* «урын, төш») булса кирәк, к. рус. диал. *жалгай, ялгай* «коры яки бик кечкенә сулы үзәнчек» < төрки **йолгай* (к. Аникин: 205, 727). Räsänen 1969: 200; ЭСТЯ IV: 36–37; Мурзаев 1984: 180, 199, 232; Гарипова 1998: 91–94.

Дерив.: **елгалы, елгасыз; елгачы; елгачык; елгала-у** (*елгалап агу*).

**ЕЛГА-У [йы̆лға-]** диал. (к. Тумашева 1992: 90) «катиться (с горы), быстро скользить» ~ алт. диал. *дьылга-* id. (Баскаков 1972: 204) *ел-у* [*йыл-* < *дьыл*] фигыленнән, әлбәттә.

Дерив.: **йылгайак** «махсус чаңгы эзе» (рус. «лыжня»).

**ЕЛГЫР [йы̆лғы̆р],** диал. **җылгыр** «ловкий, шустрый, юркий» ~ себ. (Тумашева 1992: 90) **йылгыр** «тиз, яхшы шуа торган; җитез» ~ алт. *дылгыр,* хак., тув. *чылгыр* id. Чаг. диал. (ДС II: 263) **җылдак** «ашыгучан». К. **Ел-у.**

Дерив.: **елгырлык; елгырлан-у.**

**ЕЛДАМ [йы̆лдам],** диал. **җылдам** «проворный, резвый» > чув. *йăлттам,* каз., к.-калп. *жылдам,* төркм. *йылдам*, як. *сылдам* id.; чаг. диал. (ДС II: 26) **җылдак** «ашыгучан» һ.б. *ел-у* фигыленнән. ЭСТЯ IV: 278–279.

**ЕЛДЫР-У [йы̆лды̆р-]** (Будагов II: 365) диал., башк. «быстро скользить»; күч. «покатить (по льду)» ← **ел-у** (к. **Ел-у**).

**ЕЛДЫРЫМ [йы̆лды̆ры̆м], йылтырым** (ТТДС I: 118), **җылдырым** (ЗДС: 195) «молния; молния – приспособление вместо пуговиц» ~ төр. (һ.б. угыз) *йылдырым* id. ← *йылдыр, йылтыр* ← *йылт*, к. **Елт.** Икенче бер **елдырым** *елдыр-у* сүзеннән ясала ала.

**ЕЛКЫ [йы̆лкы̆],** диал. **җылкы** «лошадь как скот; лошадиные» > мар. диал. *йылкы* < гом. төрки *йылқы* «ат; табын, өер», нуг. *йылқы*, госм. *ылқы* «ирektә йөргән атлар, ат көтүе», алт. *д'ылкы* «асау бия; бия», каз., к.-калп. *жалқы* «йылкы; бердәнбер терлек», чулым. (Радлов I: 181) *jалты* «елкы».

К. ш. ук тув. *чылгы* «ат көтүе», як. *сылгы* «елкы». Мусаев (1976: 109–110) бу сүзне *йыл-* «җыелу» фигыленнән ди, әмма хәлиткеч дәлилләр юк. К.-балк. телендә *йылҗы* гомумән «хайван» мәгъ. кулланыла. Ахметьянов 1989: 81; ЭСТЯ IV: 281–282.

Дерив.: **елкычы; елкылы, елкысыз.**

**ЕЛМАЙ-У [йы̆лмай-],** диал. **җылмай-у** «улыбаться» – Идел-Урал регионында гына актив кулланыла – диал. *йылма* «көләч якты йөзле» сыйфатыннан (чаг. *зур – зураю, кара – караю, туры – тураю* һ.б.ш.), бу сыйфат исә госм. *йылма*, себ. *йылмагай,* каз., к.-калп. *җылмаң* «шат күңелле» монг. *җилмагай* «ялтырап торган, шома» сүзеннән дә булала (к. **Җылы, Җылымса**).

Нуг. *йылмай-у*, каз., к.-калп., үзб. *җылмай-у, җылмаю, җилмой-* «ачудан соң бераз гына йомшару» мәгъ. кулланыла. Чаг. ш. ук чув. *йăл кул-* «елмаю», *йăл* «ялт» (к. Ашмарин V: 54–55), к. ш. ук Ramstedt 1935: 109–110. Э.В. Севортян *йылмай-* нигезен *йылым-ай-* шәклендә карый, ягъни «җылымлану» кебегрәк була, к. ЭСТЯ IV: 279.

**ЕЛТ [йы̆лт],** диал. **җылт, йелт** – подражание мгновенному блеску < гом. төрки *йылт*, чаг. **Ялт, Җилт** һ.б. Моның кебек сүзләрнең дерив. киң: **елт-елт, елтырт, елтыр-елтыр;** диал. (ЗДС: 262) **йылтын, йылтынлы; йылтырак;** фигыльләр: **елтла-у, елтыра-у, елтырт.** К. **Елдырым, Елтыр.**

**ЕЛТЫР [йы̆лты̆р],** диал. **җылтыр** «сверкающий (о глазах)». Бу сүзне сыйфатлашкан тәкълиди сүз дип карарга кирәк. К. югарыдагыны.

Дерив.: **елтырак** «алдавыч», **елтырка** «ялтыравык».

**ЕЛ-У [йы̆л-],** диал. **җыл-у** «скользить (по своей воле), быстро двигаться ползком» < гом. төрки *йыл-* > алт. *д'ыл-*, хак., тув. *чыл-*, як. *сыл-* id. Бу төбендә образлы-имитатив сүздән бик күп нигезләр ясала: к. **Елан, Елга-у, Елгыр, Елдам, Елдыр-у,** ш. ук **Елыш-у.** К. Будагов I: 365; Räsänen 1969: 200; ЭСТЯ IV: 40–41.

**ЕЛЫШ-У [йы̆лы̆ш-]** «исподтишка приближаться», диал. «скользить» ← **йыл-у** (к. **Ел-у**).

Дерив.: **елыштыр-у, елышын-у.**

**ЕРАК [йы̆рақ],** диал. **җырак** «далёкий, далеко; даль» < гом. кыпч., гом. төрки: нуг., кар., уйг., госм., чыгт. *йырақ,* кыргл. диал., к.-балк. диал. *җырақ,* каз., к.-калп. *жырақ,* кыргл. *ыраақ,* як. *ыраах*, хак., тув., алт., чыгт. (Боровков 1963: 129) *ырақ,* төр. *ırak* < бор. төрки (ДТС: 219, 268) *jïraq, ïraq* id. ← себ. (брб.) *ыра-, ра-*, алт., хак., тув. *ыра-,* уйг. *йыра-* «ераклашу», бор. төрки (ДТС: 268) *jïra-* «читләшү» (бу фигыльнең барча юн. кулланылган), бик ихтимал, каз., бор. төрки *jır* «төньяк җирләр» (шуннан *jıraja* «сул яктан, сулга; төньякка», *jırjaqı* «сулдагы; төньяктагы», *jırγaru* «төньякка») сүзеннәндер (*йыр-а-*). Шул вакытта *йыра-* < *йыг-ра-* «ераклашу, качу» (к. төр. диал. *ıra-* «качу») бор. *йы, йыг* «урман» (к. **Агач**) сүзеннән дә була ала. «Мөхәммәдия» телендәге *айырак* (күп тапкыр очрый) «ерак» *аеру*дан түгелме икән, дигән фаразга урын бирә. Räsänen 1969: 201 (фаразлар китерми). ЭСТЯ IV: 286–287.

Дерив.: **ерак-ерак; ерагай-у, еракла-у** (→ **ераклан-у, ераклат-у**), **ераклаш-у; ераклык; ераксын-у;** диал. **ераккы.** К. **Еракай.**

**ЕРАКАЙ [йы̆рақай], ерак, җырак** (Рамазанова 1991: 64–65; 127–128) «(родственник) с материнской стороны». **Ерак** монда «читтәге» дигән мәгънәдә: киленнәр ирләре торган җиргә киләләр, аларның төркеннәре «еракта» – читтә кала.

**ЕРГАК [йы̆рғақ]** «кривой нож для снятия шкуры животного» ~ кар. *йыргақ* «сәнәк». **Ер-у** (к.) сүзеннән, әлбәттә.

**ЕРГАНАК [йы̆рғанақ],** диал. **җырганак** «протока; обрывистая речка» > удм. *җъраганак* id. ~ башк. (БҺҺ II: 96) *йырманақ* морфологиясе буенча хөкем йөрткәндә «күп ерынтыларның берсе», ихтимал, *йырғы-нақ* (*-нақ* «күп беришле нәрсәләрдән берсе» мәгъ. белдерә торган кушымча) яки **йыргым-ак;** мәгънәдәш сүзләр тат. сөйләшләрендә күп кенә: **йырым, йырын, йырымчақ; йырғын, йырғынчақ** һ.б. ← **йыр-у;** к. нуг. *йыранақ* «кул, чокыр». К. **Ермак, Ер-у.**

**ЕРМАК [йы̆рмак],** диал. **җырмақ** «новая протока, новое русло реки; глубокая промоина, прорыв дамбы» > чув. *йăрмак* ~ чыгт. (Будагов II: 355) *йырмақ, йырғамақ,* каз. *жырмақ, җырмақ* «тирән ерганак, ерганак тобасы», чув. *çырма* «кул, сыза; инеш» ~ бор. кыпч., төр. *ırmak, ırmaq*, үзб. *ирмақ* «агым, агынты» һ.б. ← *йыр-* (к. **Ер-у**). Räsänen 1969: 202; ЭСТЯ I: 664–645.

**ЕРМАЧ [йы̆рмач],** диал. **җырмач,** (Тумашева 1992: 91) **йырмац** «разрез, вырез ткани, шкуры не

до конца; ширинка брюк», (ТТДС I: 179) «прореха» ~ башк. (к. БҺҺ III: 96) *йырмас* «төймәләгеч тишекләр урнашкан төш», к.-балк., ком. *җырмач* «ярык, ермач», каз., к.-калп. *жырмаш* «кием ерыгы, ерынтысы», нуг. *йырмаш* «киемнең ян ерыгы (махсус калдырылганы)» һ.б. ← *йыр-* (к. **Ер-у**), әлбәттә.

Дерив.: **ермачлы; ермачла-у.**

**ЕРТКЫЧ [йы̆ртқы̆ч],** диал. **җырткыч** «хищник, хищный» – бор. яз. телләрдән килә, к. чыгт. *yırtquči* «ерткыч» (Поппе 1938: 144), төр. *yırtıcı*, бор. төрки (ДТС: 269) *jırtuč* id. К. **Ер-у.**

Дерив.: **ерткычлык; ерткычлан-у.**

**ЕРТЛАЧ** «хищный (о характере человека)» гом. төрки характердагы сүз булса киркә, к. төр. *yırtlaz (-z!)* «ертлач». **Ерт-у** сүзеннән, әлбәттә.

Дерив.: **ертлачлык; ертлачлан-у.**

**ЕРТ-У [йы̆рт-]** «рвать, разрывать» < гом. кыпч. *йырт-, җырт-* id. < *йырыт-*, к. **Ер-у.**

Дерив.: **ертыл-у, ертыш-у, ерттыру; ертык.** К. **Ерткыч, Ертлач** һәм түбәндәгене.

**ЕРТЫШ [йы̆рты̆ш],** диал. **җырткыч** (ТТДС I: 179, 579) «специальная ткань, занавес, который должен порвать жених, когда заходит к невесте, при этом ему мешают, требуют выкупа» ~ кырг. *җыртыш*, каз., к.-калп. *җыртыс* «кунакларга яки җеназада катнашучыларга бүлеп бирелә торган тукыма»; башкортларда *йыртыш* «кияү кәләш янына кергәндә ерткалап хатын-кызларга, бала-чагага бирә торган тукыма» (к. БҺҺ II: 96). К. **Ерт-у, Ер-у.**

«Кутадгу билик»тән күренгәнчә, **ертыш** йоласы монг. *хадак* йоласына иш-гомоген.

**ЕР-У [йы̆р-],** диал. **җыр-у** «прорывать, рыть (канаву); разрывать, вспарывать» < гом. кыпч., кар., нуг., ком., чыгт. *йыр-*, кырг., к.-балк. *җыр-,* каз., к.-калп. *жыр-* id., уйг., үзб. *йир-, жир-* [каты *-р*], угыз., төр. *yır-*, алт. *йыр-* «сүтү, кечкенә ярык ясау», тув. *чир-* «киту, китек ясау», як. диал. *сыыр-* «еру» һ.б. бор. төрки язмаларда бу сүз юк, ләкин дериватлары (*jırt-, jırtuč* «ерткыч», к. ДТС: 269) бар. К. ш. ук чув. *çыр-* «ярны еру».

*Йыр-* фигыле *йар-* фигыле белән гомоген булса кирәк (бор. төрки *а ~ ы* тәңгәллеге), ләкин бик бор. заманнарда ук аларның мәгъ. аерымлана, дифференциацияләнә башлаган. Хәз. көндә бу фигыльләрнең кайбер мәгъ. тәңгәл (мәс., *юл еру* = *юл яру*), бүтәннәре тәңгәлләшми (мәс., *авыз еру* ↔ *авыз яру*).

*Йыр-* һәм *йар-* фигыльләренең гомогенлыгы аларның кайбер дериватларында да күренә: кырг. *җыра,* к.-калп. *жыра* «ерынты» ~ гом. төрки *җара, йара*; *йырык ~ йарык* һ.б. Räsänen 1969: 201; ЭСТЯ IV: 136–137; Федотов II: 155–158 (буталчык).

**Ер-** продуктив нигез: **ерыл-у, ерыш-у, ердыр-у; ергала-у; ерынты; ергыч, ерык.** К. **Ергак, Ерганак, Ермак, Ермач, Ерт-у.**

Рус. *ерик* «вакытлы су юлы; буа ерыгы, ерынты» тур. Аникин: 202 (бик ишле әдәбият күрсәтелә, ләкин барча русистларның тат., башк. **ерық** сүзен белмәгәнлеге шәйләнә).

**ЕРЬТЕЦ [йӗртӗц]** диал. «старая Родина» – бу сүз безнең тарафтан 1968 елда Сергач мишәрләрендә теркәлде – к. куман. *jertinči,* бор. уйг. *jirtinčü, jirtünčü, jerteñčö* (к. Räsänen 1969: 198), иске монг. *jirtinču,* монг. *ертөнц*, бур. *юртэмсэ* «дөнья» тибет *ǰigrten* «галәм, дөнья» сүзеннән (ССТМЯ I: 355). Чаг. ш. ук диал. (Әсирлектән кайткан әкиятләр. Казан, 2009: 154) *йиертеш* «йорт-җир, ихата».

**ЕФӘК [йӗфәк],** диал. **җифәк, җебәк** «шёлк» ~ каз. *жибек,* к.-калп., к.-балк. *җибәк* «ефәк», алт. *дьибäк*, хак. *чибäк* «ефәк киндерә» ~ уйг., үзб., чыгт., кр.-тат., госм., аз. *ипак, ипәк* «ефәк» гом. төрки *җип ~ йип, ип* «җеп, киндерә» сүзеннән; тат. *йефәк* бор. уйг. теленнән (*б > п > ф*) булса кирәк. Гомумән *йипәк* һ.б. төрки телләрдә сирәк кулланыла. К. **Җеп.** ЭСТЯ IV: 269–270.

**ЕШ [йы̆ш],** диал. **җыш** «частый; часто» < бор. **йыг-ыш* id. бор. **йыг-* «куеру, ешаю» тамырыннан, к. себ. тат. *йынық* (Старчевский сүзлегендә *Бик*), *йыйы* ~ нуг. *йыйы* < бор. төрки (МК, ДТС: 260) *jïyï* > чув. *йыва̌, йу* (Ашмарин V: 294, 312, V: 45) «еш».

**Еш** сүзе күпчелек төрки телләрдә юк. Э.В. Севортян *йыш* сүзен *йеш* «урман» сүзе белән бәйли (ЭСТЯ IV: 44).

**ЕШ-У [йы̆ш-]** «тереть, натирать» ~ алт. *йыш-*, хак. *чыс-* id. (к. Räsänen 1969: 202). Күпчелек төрки телләрдә юк. К. **Ышкы-у.**

**ЕШЫМ [йы̆шы̆м], йыйшым, йешем, ишим, эшем** (ЗДС: 250, 264; Ахатов 1963: 114) «чулок, вид чулков» < бор. төрки (ДТС: 263) *jišim* «ыштыр». Бу сүз рус теленә кат-кат кергән; рус. диал.

(Аникин: 288–289) *ишимы, шимы* «аучылар итеге», бор. рус. *ischimiš* «оекла аякчу, озын кунычлы итек (чалбары белән берләштерелгән аякчу)». К. ш. ук үзб., уйг. *шим, шым,* кырг. *шым* > каз. (ҚТДС: 306) *сым* «постау чалбар». Күрәсең, күптәнге гом. төрки сүз. Чыганагын фар. теле дип күрсәтәләр.

**ЕШЫН-У [йы̆шы̆н-]** диал. (Ф. Кәрим, III: 61; БТДҺ: 131) «сыену, урын алу; карарлашу, тотрыклы хәлгә килү» ~ чув. *йышăн-, йăшăн-* id. *йыш, йăш* «иш» сүзеннән хисапланыла. Тат. телендә бу сүз я чув. теленнән алынган, я болг. теленнән калган. Чув. телендә бик актив кулланыла.

**ЕШЬ [йѐш]** «долина, окружённая лесистыми горами; горы с открытыми долинами» – бу сүз тат. телендә мәкальләрдә генә очрый: *һәр йешнең үз сандугачы бар; иш ише белән, йеш кошы белән* һ.б. – к. себ. (Тумашева 1992: 92) *йыш агац* (дөресрәге *йыш-агац* парлы сүз булса кирәк) «урман», *йыш ийә* «урман иясе» ~ диал. (Урал) *шнә* < *йеш инә* «шүрәле»; бор. төрки *jyš* «ешь», алт. *дьыш,* хак. *чыс* «карурман, тайга», тув. *чыс* «тау башы; бер рәткә тезелгән таулар», бор. төрки (ДТС: 268) *jiš* «яшәргә җайлы үзәнле таулык».

Räsänen 1969: 202; ЭСТЯ IV: 44 (тат. *йеш* искә алынмый).

# Ж

**Ж** авазы тат. телендә тәкълиди сүзләрдә (*жу итү, ажгыр-у, ыжгыр-у* һ.б.) электән булса да, киң кулланылмаган. Тәкълиди булмаган сүзләрдә **ж** тәүдә фар. алынмаларында, аннары рус алынмаларында очрый башлаган.

**ЖАЛУ** (ешрак **жалу итү** фраземасында) «жалоба» < рус. Башк. *йалыӳ* id. тат. теле аша булса кирәк.

**ЖАЛУНҖА** диал. «зарплата, жалование» < рус. *жалованье* вариантыннан.

**ЖӘЛ** «жаль; жалко» ~ мар. (Саваткова: 224) *жел, жäл, ыжäл*, чув. *шел* id. < рус. Тат. *жәллә-ү* сүзе дә рус. *жалеть, пожалеть* сүзе тәэсирендә ясалган булса кирәк.

**ЖИРӘБӘ** «жребий; жеребий (как единица земельного надела)» < рус.; рус сүзе прус. *girbin* «сан», ним. *Kerben* «киртү, кирт» ~ грек. *γραφω* «язам» сүзләре белән чагыштырыла (Фасмер II: 48).

**ЖИРДА** диал., башк. «жердь, жердина» < рус. Рус сүзе иске ним. *gerta, gerte* «кәртә» белән чагыштырыла. Фасмер II: 47.

**ЖУЛАП** «жёлоб» ~ удм. *жолоб* id. < рус. Бу рус сүзенең ышанычлы этимологиясе юк. Ихтимал, төрки яисә фар. теленнәндер, к. иске тат. **дулап** «су гөбесе». К. **Тубал.**

**ЖУЛИК** «жулик» < рус. Рус. сөйләшләрдә бу сүз «кечкенә үткен пәке» мәгъ. дә билгеле һәм рус сүзен И.Г. Добродомов һәм Н.А. Баскаков (СТ 1984: № 4, 10–11) төрки сүздән дип карыйлар; этимон итеп бор. төрки *jülü-* «чәч, сакал кыру», *jüligü* «өстара, пәке» сүзләре карала, к. тат. диал. (ТТДС I: 52) *җөл-* «чәч һ.б. кыру», *йөл-* «җирдәге үләнне кыру; отып алу», *йөлте, йөлтө* «отыш», *йөлтек, йөлтөк* «жулик». К. **Йөле-ү.**

# Җ

**Җ** авазы төп урта диалектта анлаутта гомумтөрки (бор. төрки) *й-* (*j-, у-*) урынында кулланыла һәм бу җәһәттән казантатар теле к.-балк., к.-калп. һәм кырг. телләре белән бер группага кергән. Әмма яз. әд. телләрнең көчле тәэсире нәтиҗәсендә һәм миш. диалекты вәкилләренең тат. әд. теленең формалашуында зур роль уйнавыннан хәз. әд. телдә сүз башында (сүзләрнең чыгышына да бинисбәтән) *й-* авазы да бик еш очрый.

**ҖАБЫЛКА БЕЛӘН ҖАБЫЛСА** «Япония и Корея (?)» – иске тат. телендә көнчыгышта ерак илләр (*Борис Годуновның даны ... Җабылка белән Җабылсага җитте*, диелә Кадыйр Галибикнең «Җәмигъ әт-тәварих»ында) – госм. *Cabılka* «Ерак Көнчыгышта мифик мең капкалы шәһәр; абсолют бәхеткә омтылышта беренче адым», *Cabılsa* «абсолют бәхет иле» (к. Redhouse: 211); бор. төрки (МК) *Җабәрҗа* «ерак көнчыгышта бер ил, Мачиннан аларны зур диңгез аерып тора» < кыт. *жибэньго* (*yi pen kuo*) «кояш чыккан җир» – Япония, шуннан португал телендә *Җапан* «Япония» сүзе формалашкан һәм ахыр чиктә бөтен дөньяга таралган. *Җабылса* исә кыт. *жибэньсо* «кояш чыккан билек» дигәннән. Чаг. хәз. тат. диал. (ЗДС: 177) **җабыл** «билгесез ерак җир», **җабылдан** «ерактан, читтән (килгән)».

**ҖАВАП [җаwап]** «ответ» < гар. *җӓwāб* id. *җwб* «кисү» тамырыннан (*җавап*, димәк, «кистереп әйтү»).

Дерив.: **җаваплы, җавапсыз; җавапла-у; җавапнамә;** сир. **җавапчы.**

**ҖАГАЛБАЙ,** диал., башк. **ягылбай** «кобчик, соколик» > чув. *якӑлпай* ~ кырг., уйг. *җағалмай,* алт. диал. *дьагалбай*, калм. *загалмэ* id. бор. төрки *җағал* «шакал» һәм *май* «лачын, ау кошы» сүзеннән (Ramstedt 1949: 137). К. ш. ук **Чагалак.** ЭСТЯ IV: 10–11.

**ҖАДАГАТ** миш. (ЗДС: 177) «всадник (без седла)» < *җайдак ат.* К. **Җайдак.**

**ҖАДА-У** диал. «бедствовать» к. **Ядау.** Чаг. **Җәяү.**

**ҖАДУ** (көчле сихер; һава хәлен үзгәртерлек көче булган мифик таш яки дога язылган тактачык) – «сильный талисман, алатырь – камень (способный изменить погоду)» ~ себ. **чату** «сихерче; күрәзә», **йада** «тылсымлы таш» (к. Тумашева 1992: 64, 246) ~ уйг., госм., монг. *җаду*, каз., к.-калп. *жады, җады*, кар. *джаду, дзаду*, гаг. *жады*, нуг. *яды* «сихер; тылсымчы», алт. *дьада*, тув. диал. *яда*, як., рус. *сата*, монг. *цзада* «җаду ташы», «сихер» (бу таш тур. тәфсилле Алексеев: 40–59). Фар., төр., гар. телләре даирәсендә *җаду, җады* «сихер көче; явыз сихерче; убыр, вампир» һ.б.ш. белән беррәттән поэзиядә «кызларның сихерләрлек карашы, мәхәббәт тылсымы; сөйдергеч дога» мәгънәләрен дә алган.

*Җаду* сүзе авест. *yātu*, пәһл. *ǯatak* бор. һинди *ǯatak* «мистик поэзия һәм хикәятләр җыентыгы» (төп мәгъ. «кәрзин») сүзенә тоташа. Тәүдә ул хикәятләрдә Будданың «силкенүләре» – үзе теләгән җан иясе формасына кереп яшәүләре өстенлек иткән. Соңрак бу хикәяләргә мифик ташлар тур. төрле хикәятләр өстәлгән. Һәм сүз үзе төрле яңгырашлар алып, аерым телләргә кат-кат кергән. Мәс., тат. сөйләшләрендә *җаду* ~ *йаду* белән беррәттән:

– урта диал. (Арсланов 1988: 63) *җәт* ~ бор. төрки (ДТС: 247) *jat, ǯat* > тув. *чат, чыт* «сихерчелек»;

– себ. тат. (Тумашева 1992: 64–65, 79) *йай, йәй, йөй* ~ кырг. *җөй* «сихер, сихерчелек»; себ. (ЗДС: 226–227, 241) **йадацы, йайцы, йәйце** «сихерче»;

– тат. диал., башк. диал. *йәтә* ~ төр. *yede taşı* «һава хәлен үзгәртерлек кодрәткә ия изге таш». Ул ташны Нух пәйгамбәргә Җәбраил фәрештә биргән һәм, бик үтенсәң, ул таш туфан яңгырын туктатыр, дигән. Нух *йәдә*нең кодрәтен сынарга теләгән, әмма суга төшереп җибәргән, ди (икенче бер версия буенча, *җаду ташын* Нухның углы Яфәс кулыннан ычкындырган). Югыйсә ибне адәмнәр яңгырны үзләре теләгәнчә яудырырлар икән. Урта гасырларда төрки халыкларның һәр төбәктә җиңеп алга барганлыгын күргән Шәрык халыклары төркиләр кулында *йәдә ташы* бар, дип сөйләгәннәр (к. ТХИ: Әкиятләр 1981: 17–18, 21). Башкортстанның Гафури районында шундый **йәдә** ташларын күрсәтәләр: алар янында дога кылсаң, яңгыр явачак, имеш. К. **Җадугәр, Җаудар, Җәрәкәү.**

**Җадугәр** «сихерче» < фар. *җāдӯгāр* «җадучы, җаду кылучы». К. ш. ук тат. **җадучы** (бу сүз иске риваятьләрдә, әкиятләрдә еш очрый). Будагов I: 426; Будагов II: 351–352; Velidi: 108; ЭСТЯ II: 195–196; Аникин: 488; Гумилёв 1963: 84.

**ЖАЕК [җа°йык]** «Яик, река Урал» ~ тат. *Җайык* татарларның бу елганы күптән белгәнлеген күрсәтә, чөнки бу елганы якыннан белгән бүтән халыкларда безнеңчәрәк: каз. *Жайық*, башк., нуг. *Йайық* (нәкъ бу вариант рус теленә алынган). Иң борынгы фиксация – грек галиме Клавдий Птолемей «География» дигән китабында *Даисъ* рәвешендә б.э. II г. теркәлгән һәм шул ук исем белән VI г. икенче бер географ Менандр Протектор хезмәтләрендә искә алына. XIII г. сәяхәтчесе Г. де-Рубрик аны *Йаакъ* һәм *Йагаг* дип атый.

**Җаек** сүзенең этимологиясенә багышланган хезмәтләр бик күп һәм еш кына бу топоним төрки телләр материалында аңлатыла: башк. филологлары **Йайык** < *йай ық* «җай ык, әкрен агым», дип аңлата, каз., к.-калп., кырг. (мәс., к. Отаров 1972) *җайық, жайық,* төр. *yayık*, чыгт. *йайық,* алт. *дьайык,* хак., тув. *чайық* «җәелгән; ташкан агымсу», кайбер хезмәтләрдә, шулай ук бор. төрки (> алт.) *jajïγ, jajïq* (к. ДТС: 226) «ташып чыгучан, шашкын» сүзеннән диелә. Өченче версия буенча, Җайык елгасының кайчандыр изге һәм ориентация ноктасы – тәбе булып исәпләнгәнлеген искә алып, бу гидроним алт. *дьайык* < бор. төрки *йайық* «корбанлык, Үлген тәңренең хезмәтчесе» сүзеннән чыгып аңлатыла (к. Казахский фольклор в собрании Г.Н. Потанина. М., 1972: 293).

И.Я. Лойфман, С.И. Поповларның «Топонимические названия Оренбургской области» (Оренбург 1960: 16) китабында Яик төркичә (нугайча) *йай* «җәй» һәм *ык* «агымсу» сүзләреннән гыйбарәт диелә, әмма ык сүзе фин. *joki*, манси. *юган* «елга» сүзе белән чагыштырыла.

Ниһаять, бор. *Даик* варианты «*дак*лар (*дак* халкы) елгасы» дип аңлату да бар. Гарипова 1998: 242–245.

**ҖАЗИБӘ** «прелесть; прелестница» < гар. *җāзибä* id.

Дерив.: **җазибәле.**

**ҖАИЗ** (техник әдәбиятта кулланыла) «допустимый, дозволенный» < гар. *җā'из* id. К. **Иҗазәт. Җаиз йөкләнеш** рус. «допустимая нагрузка».

**ҖАЙ I,** диал. (ЗДС: 227) **йай** «удобный случай, момент; соответствующее целям и задачам место» ~ башк. *яй,* каз. *жай*, уйг., к.-калп., кырг. *җай*, үзб. *җой*, төркм. *җāй* «урын; урынлылык; урын-җир; торак, бина; тәшкиләт» – кайбер төрки телләрдә (ДТСта да) юк, ләкин киң таралган халыкара сүз, к. фар. *җā, җāй* < бор. фар. *ǯaһ* «урын; урынлылык; урынлы теләк, сүз һ.б.» ~ кыт. *джай, дзай* «торак, квартира» (к. Баскаков 1987: 72). К. **Җай II.** Чаг. **Җәй.** Будагов I: 430 (фар. сүзе ди).

Дерив.: **җайлы, җайсыз; җайла-у** (күп дериватлы).

**ҖАЙ II,** диал. **йай** «неторопливо, медленно», диал. «свобода; достаток» ~ башк., чув. диал. *яй,* куман. *yay,* каз. *жай,* монг. *джай, дзай, дзаб*, хак., тув. *чай* «ара; буш (вакыт)» ~ бор. монг. *ǯabu* id. Бу сүздә **җай I** белән контаминация сизелә. К. ш. ук Räsänen 1969: 179. К. **Җайдак.**

**ҖАЙДАК,** диал. (ЗДС: 177, 183) **җадагат** (< **җайдак ат**), **җәйдәк** «всадник; наездник» әд. тат. телендә тарихи назардан бөтенләй дөрес түгел рәвештә кулланыла, чөнки чынлыкта диал. *җайдак* «иярсез; иярсез ат менгән кеше» дигән сүз, к. башк. *яйҙак* «иярсез (атка менү); кырмысканың бер төре (корсагын югары күтәреп йөгергәндә атлы кешене хәтерләтә)», себ. тат. (Тумашева 1992: 65, 74) **йәйтак** «артсыз чана; сөзәк; иярсез», кырг., к.-балк. *җайдак,* каз., к.-калп. *жайдақ, җайдақ,* чыгт. (алт., уйг. диал.), нуг., ком. *яйдақ* «иярсез; иярсез атлы» – кайбер телләрдә «ябусыз, чахулсыз, артсыз, киемсез, түбәсез» һ.б.ш. мәгънәләрдә дә йөри (к. Будагов II: 346), к. ш. ук як. *дьайдаах* «таз». Бу сүзнең *-б-* варианты да киң таралган, к. алт. *jабыдак,* хак. *чабыдак, чабдак*, тув. *чавыдак* «иярсез». Монг. телләреннән булса кирәк, к. бур. *зайдан, зайдаң* «иярсез; ялангач, шыр; киң» һ.б. бор. *ǯab ~ ǯaj* «буш ара, кола ялан» сүзе белән бәйле. К. **Җай II, Җап.**

**ҖАКЛАН-У,** диал. **йаклан-**у (ТТДС I: 161, 564) «хвастаться; кривляться; жеманничать» ~ чув. *çыхлан-* «бәйләнү»? К. ш. ук **җаклы//яклы** «кыланчык» ~ чув. *çыхлă* «бәйләнүчән»?

**ҖАЛА** «блеск» к. **Җәла.**

**ҖАЛАГАЙ, ялагай** диал. «зарница» к. **Аҗаган.**

**ҖАМ** иск. «стеклянная посуда; бокал» к. **Җамаяк.**

**ЖАМАЯК [жаᵒмайак]** «стеклянная посуда» ~ башк. *йамаяҡ* id. *җам* «пыяла; пыяла савыт» < фар. *җāм* < авест. *yāma* «савыт, купы» (Platts I: 373) һәм *аяк* «савыт» сүзләреннән гыйбарәт.

**Җам** «пыяла савыт» сүзе күп телләргә таралган; фар. *җāмдāр* «пыяла (сыйфат)» сүзенә чув. *йантар* «пыяла», мар. *йамдар* «шешә», *йандар* «сөзек, үтәкүренмәле», венг. *gyantar* «гәрәбә» > рус. *янтарь* сүзләре тоташа (к. Räsänen 1969: 123). Чаг. **Ямьле.**

**ҖАМИГЪ** «соборная мечеть» < гар. *җāми‘* id. ← *җм‘* «җыелу». К. кар. *джами,* төр. *cami* «зур мәчет». К. **Җәмәгать.**

**ҖАН,** диал. **йан, җән, йән** «душа» > мар. *цан, чон,* чув. *чон, чун*, удм. *зан, йан* id. < фар. *җāн* id. (барлык төрки телләрдә диярлек очрый) << пәһл. *gān*, авест. *gayan* ~ санск. *gaya* «тын, сулыш, һава» (Platts I: 372) яки санск. *yanah* «хатын; ыру» сүзеннән. Бу сүз бор. ир. телләрдән гар. теленә кереп, гарәпчәдән фар. теленә кайткан булса кирәк, һәрхәлдә иске әд. *җаннан* «йөрәк, җан» гар. телендә ясалган.

**Җан** сүзе нигезендә күп кенә бүтән сүзләр ясалган: **җаныкач, җаным, җәнкәй < җанкай** һ.б. К. **Җанбаз, Җанвар, Җаный < җанай, Җәнлек.**

**ҖАНАШ** «милый; возлюбленная» – *җан* (*җаным*) сүзеннән, **җанаш < җанғач** дип уйланыла, ләкин к. алт. *дьанашчаак* «иркәләүле», *дьанаш-* «дус булу, ярату» ← *дьан* «ян, якынлык». К. **Ян, Янәшә.**

**ҖАНБАЗ** иск. «вольтижёр; самоотверженный; отчаянный» < фар. *җāнбāз* «җаны белән уйнаучы» – арканда биюче (биеклектә тарттырылган арканда йөрү-бию Шәрык илләрендә борынгыдан килгән аттракцион).

**ҖАНВАР [жаᵒнwар],** диал. **җанывар** «животное; зверь» ~ башк. *йануар, йанур* (БҺҺ II: 85), чув. *янавар* «хайван; юньсез кеше» > мар. *янавар* «сукбай» ~ кар. *джанавар* «җанвар; шәфкатьсез», добр. тат., гаг. һ.б. *җәнавар* «бүре», ком. *җанавар* «икеләнүчән, куркак (йорт хайваны шикелле)», *җанывар* «җан иясе» < фар. *җāнwäр* «җан иясе, җан йөртүче; мәхлук, юньсез, мескен» (*җан* «җан», *wäр* «йөртүче» < авест. *bar* ~ санск. *bhar* id.).

**ҖАНДАР, җандарман** (Г. Тукайда) «жандарм; вооружённая охрана (личности)» < төр. < фар. *җāндāр*, *җāнибдāр* «кучты, шәхси сакчы» (к. Гордлевский 1941: 78). Бу сүзнең рус. (< фр.) *жандарм* сүзе тәэсирендә «җанлануы» күренеп тора.

**ҖАНФАРМАН** «сломя голову; во весь дух» иск. *җәң фәрманы* «сугыш турында фәрман» сүзеннән (к. **Җәң**). Чаг. ш. ук тат. диал., башк. *алафарман, алабарман* «җанфарман» < бор. *галифәрман* «хан фәрманы» (к. **Гали**) ~ фар. *фäрмāне ‘алū* id.

**ҖАНЫЙ** «душенька, милый» < *җанай* id. добр. сүзлегендә *сапау* «җан, ай!» дип аңлатыла. К. Dobr. I: 397.

**ҖАҢЫШАК** «болтун, речистая старуха» к. **Яңшак.**

**ҖАП** диал. (ТТДС I: 566) «долина между горами» ~ **йәп** «уйсу җир» (к. Бәетләр 1960: 79), себ. (Тумашева 1992: 63) **йаб** «калкулык», **йаб асты** «тау итәгендәге тигезлек» ~ каз. диал. *жап* «чик, чигәрә», төркм., бор. төрки (Мухамедова 1973: 99) *йаап* «арык», бор. монг. *ǧab, ǧaba* «ара, аралык», тунг. *ǯапка* «аралык; яр» (к. ССТМЯ I: 251) ~ тат. диал. (к. ТТДС I: 579) *җыпҗы* «инкүлек; ерганак», *җыпты* (< монг. *ǯaptu*) «түбәнге, иңкү». К. **Җаптак, Җәп, Ябык, Ябырыл-у, Япсар-у.**

**ҖАПСАР** (ЗДС: 180) «верх крутизны», «стожок, ворох (при стоговании сена и т.п.)» ~ каз. *жапсар* «бер яссы нәрсәнең кырыена икенче яссы нәрсәнең кырые ябылган төш» < бор. монг. *ǯabsar* (> хәз. монг. *завсар*) «аралык, ябулык, җек һ.б.», тат. мәгънәсе «арадаш өем» булса кирәк. К. ш. ук эвенк. *зафсар*, тув. *чапсар* «ара; тәнәфес». К. **Җап, Яп, Япсар-у.** Владимирцов: 259; Рус. *запцыр* < бур. *завсыр*, *забһар* «бәйрәм алды, аралык; ял итү» тур. Аникин: 209.

Дерив.: **җапсарла-у** «аралыкны, ярык-җекләрне каплау» (каз. телендә бу сүз төрле күч. мәгъ. алган); **җапсарлы.**

**ҖАПТАК** «низ крутизны; отрог (отроги) крутизны, обрамляющий долину: обрамлённая долина», **йаптак** (Тумашева 1992: 69) «разводы саней, сани с разводами» ~ каз. (КТДС: 103) *җабдан* «яссы үзәндәге кыр, басу», бор. төрки (ДТС: 222, 236) *jabïtaq, japïtaq* «иярсез, җайдак». К. монг. *җапту* «аралык, аралар» һ.б. Чаг. **Җап.**

**ҖАР I** «песня-обращение к природе; клич» ~ иске тат. (М. Гафури) *чар* «приказ, әмер», башк.

*йар иту* «хәбәр тарату», иске чув. *чар* «игълан» (к. Магницкий: 16), иске тат. (Радлов III: 100), тат. диал. *йар (йар салу)* «игълан кычкыру» һ.б. мәҗүси төрки дәүләтчелек терминологиясеннән калган һәм төрки-монг. телләрендә аның рефлекслары бик күп: кырг., к.-калп., үзб. диал. *җар*, алт. *дьар*, чыгт., госм., бор. төрки *jar* ~ бор. монг. *ǯar*, калм. *зар* «кычкырып әйтелгән хөкем, игълан», хак., тув. *чар* «җар», *чарат* «хөкем, карар» (*чарат салу* «җар салу, карар иту». Тат. әд. телендә XVI г. бирле *җ*-белән языла, к. Максуди телендә: *Ул мөселман аңа варып кылды җар*. Фигыль коррелянты да бар: тат. диал. *йар-* (*йарып сал-*) «кычкырып, ап-ачык игълан иту», кр.-тат. *йар-*, алт. *дьар-* «халык алдында хөкем иту». К. **Яргы, Ярлык, Ярлыка-у.** Будагов II: 323; Räsänen 1969: 108; Номинханов 1975: 101–102; ЭСТЯ IV: 18–20; Ахметьянов 1981: 103. К. **Ярлык.**

Дерив.: себ. (Тумашева 1992: 70, 25) **йарла-у** «халыкка игълан иту», урта диал. (Мөхәммәтҗанов: 161–162) **җарау** id., иске тат., кырг., төркм. **җарчы,** үзб. *жарчы* ~ монг. *зарц* һ.б. «игъланчы, нидачы»; иске тат., төркм. **җарнамә** «язма игълан».

**ЖАР II: җәшел җар** диал. (ТТДС I: 566) «ярь-медянка; купорос (краситель)» < рус. булса кирәк. Рус. *ярь* < грек. (Фасмер IV: 563).

**ЖАРА** «каштановый (о лошади)» (бер җырда гына сакланган: *Җара атым Җар буенда, Җиз кыңгырау муенында…*) ~ чув. *çырă* id. ~ бор. төрки *jaγïz* «көрән (ат)», к. ДТС: 225. Тат. телендә болг. сүз.

**ЖАРГАК,** диал. (ЗДС: 235) **йарғак** «болтун, хвастун» – *җар-* «кычкырып игълан иту» сүзеннән булса кирәк. К. **Ярлык.** Чаг. **Җырга-у.**

**ЖАУ [җаᵒw]** «җир», к. **Яу II.**

**ЖАУДАР [җаᵒwдар]** «царь подводного мира» («Заятүләк» эпосында) < фар. *җāдӯдāр* «җаду ташына ия зат» (к. **Җаду**), к. ш. ук төркм. *җувдар, җувдарһа* id. (< фар. *җāдӯдāрһā* «җадударлар»).

**ЖАҺИЛ,** тат. диал., башк. **йаһил** «(злой); невежда, неуч» < гар. *җāһил* id.

Дерив.: **җаһиллек; җаһилләң-ү.** Иске тат. **Әбү Җәһел** «җаһиллекнең атасы (явыз кеше тур.)» – Мөхәммәт пәйгамбәрнең хас дошманы Гамер бин Һишам кушаматыннан; **җәһаләт** «явыз наданлык» – барысы да гарәпчәдән.

**ЖӘБӘ: җәбә хәере** «язын күтәрмәгә калган ат» (Исәнбәт, фраз. II: 361; «Идегәй») «обессилевшая к весне от голода лошадь» ~ иске тат. *җәбә, җаба*, каз. *жабы*, нуг., үзб., төркм. *йәбә* «кыргый атның бер төре; токымсыз ат; йөк аты», үзб. диал. *йабы, йаабы, җабы*, себ. (Радлов IV: 58) *цабы*, төркм. *йабы* «начар алаша». Йот елында кыргый (хәзер юк инде – XVIII г. ук кырып бетергәннәр) *җәбәләр* ачлыктан хәлсезләнеп, далада аунап ятканнар, шуларны «җәбәләрнең хәере» дип атаганнар. К. **Ябай, Ябалак.** Ахметҗанов: 32–33.

**ЖӘБӘЛӘЙ** «кисть – украшение на голове парадной (свадебной) лошади» (бу сүзне Башкортстанда Балтач район үзәгендә ишеттем. – *Р.Ә.*) – монг. телләреннән, к. **Җибәләй, Ябәлә.**

Фразеологизм: **җәбәләй кебек кенә** «бик сыек кына (миллек, себерке һ.б.)».

**ЖӘБЕР,** тат. диал., башк. **йәбер** «насилие, угнетение; оскорбление» < гар. *җăбр* id. К. иске тат. **җәбер, әлҗәбер** «алгебра» сүзе да шуннан (әл-Харәзминең «Әл-җәбр вә әл-мукабәлә» дигән математик трактатында тәүләп алгебраик алымнар – саннарны «җәберләү» – хәрефләр белән алмаштыру кулланылган, шуннан алгебра фәненең исеме вә җисеме формалашкан). К. **Мәҗбүр.**

**ЖӘВЕЗ [җәwĕз]** диал. (Арсланов 1988: 102) «мускатный орех» < төр. *ceviz* < гар. *җăwз* id., к. кар. *джэвиз* «әстерхан чикләвеге».

**ЖӘВЕР, йәwер, йаwыр, жаwыр** диал. (к. ТТДС I: 180, 580) «семья, семейство, фамилия, род» ~ башк. диал. *зат-зәүер* (< миш.), чув. *евĕр [йэвĕр]* «кыяфәт, менәз» (< миш.), *çăвăр* «бала; уыл, бала корт; күч; яңа буын», *çури* «токым» ~ төр., гаг. *йавру*, чыгт. *йавры* «бала-чага», бор. төрки (ИМ) *йаwры* «чебеш» (к. тат. диал. **җәwер** «каз бәпкәләре тупламы», **җибер** «өер», к. ТТАС: 786), ком. *җувурҗа* «ерак нәсел» < **җаwырча*; кр.-тат. *йәwру,* чыгт., төр. *jauruk* «бала, токым»; мар. *йавыр* «ыру» һ.б. ***яра-** (*ярал-, ярат-*) фигыле белән тамырдаш булса кирәк, к. кар. *йавры-* «бар иту, тудыру». Räsänen 1969: 178; Исанбаев 1978: 9; ЭСТЯ IV: 53 (буталчык, тат. сүзләре искә алынмый); Федотов II: 140–141 (тат. сүзләрен искә дә алмый).

**ЖӘДӘЛ** «сопротивление», себ. (ЗДС: 243) **йәтәл** «упорно; упорство» < гар. *җăдăл* «бәхәс,

тартышу». төрки телләрдә киң таралган. ГТРС: 776. К. **Җанҗал.**

Дерив.: **җәдәлләш-ү.**

**ҖӘДВӘЛ** «расписание; таблица» < гар. *җäдwäл* «канал; план, карта; таблица, исемлек». К. **Җәзбә.**

**ҖӘДИ** «козерог (знак зодиака)», диал. (ТТДС I: 582) **җәтти,** (Тумашева 1992: 236) **цәдди** «декабрь» < гар. *җäдӣ* «бәти, кәҗә бәрәне» < бор. сем. *гäдӣ* id. > төр. *kedi* «песи баласы». Бу сүз ностратик тамырларның берсе дип исәпләнә, чаг. инг. *kid* «бәти».

**ҖӘДИТ** тар. «сторонник обновления системы образования в конце XIX – начале XX века» < гар. *җäдӣд* «яңа, яңалыкчы» сүзеннән. К. **Җитди.**

Дерив.: **җәдитче, җәдитчелек.**

**ҖӘЕН [җәйён]** «сом», диал. (Остроумов 1892: 65) **җаин** «шамбы» ~ удм. *зейым* «җәен» < чув. *çуйам, çуйӑн, çойӑн* һ.б. (вариантлары күп, к. Сергеев 1971: 116) ~ кырг. *җайын, җайан* «җәен; ләү», үзб., к.-калп. *җайын*, каз. *жайын*, ног. *йайын* «җәен», госм., төркм., төр. *yayın* «бер диңгез балыгы, мәрсин», чыгт. *чаjін* «чуртан». Чыгышыясалышы ачык түгел. ЭСТЯ IV: 80–81 (бик аз; Радловта теркәлгән тат. *jajык* яңгырашы күрсәтелә, әмма бу шикле вариант). Чаг. яз. монг. *ǯaγasun* «балык» (*-sun* җыйма күп. кушымчасы).

Ихтимал ки, *җайан* бор. төрки (күп чыганакларда) *йаган* «фил» сүзеннәндер: җәен дә, фил дә гадәттән тыш зур һәм сәер кыяфәтлеләр – аларга уртак билге шул. К. **Яган.**

**ҖӘЗА** «наказание» < гар. *җäзā'* id. Тат. диал., башк. *җаза, йаза* дип тә әйтелә.

Дерив.: **җәзалы, җәзасыз; җәзала-у → җәзалан-у → җәзаландыр-у; җәзачы.**

**ҖӘЗБӘ,** диал. **йәзбә** «циркуль (для переноса размера)» > башк. *йәзбә* id.; тат. телендә *җәдвәл* (к. **Җәдвәл**) сүзеннән үзгәреп килеп чыккан; к. үзб. (ЎХШЛ: 100) *җәзбәр//җәзвәл* «линейка»

**ҖӘЙ,** диал. **йәй** «лето» ~ башк. *йәй* id. < гом. төрки (регуляр фонетик вариантлары белән) *йай* id. Кайбер төрки телләрдә бу сүз юк, аның урынында *йаз* сүзе кулланыла; чув. *çу* < **çав* «җәй» бор. төрки **йаг* «җәй» булган дип уйларга мөмкинлек бирә. Икенче яктан *җәй* < *җай* бор. монг. *ǯun* «җәй» белән чагыштырыла, к. ш. ук эвен. *дёгни* «җәй». Себ (ЗДС: 227) **йайык-у** «җәй башлану» (*йай-* «җәй булу»). Федотов II: 128; ЭСТЯ IV: 74 (бик кыска).

Дерив.: **җәйле** (*җәйле-кышлы*), **җәйлек, җәйлә-ү.** К. **Җәйләү I.**

**ҖӘЙГОР,** диал., башк. (БТДҺ: 131) **йайғыр, йәйғор, йәйгуры** һ.б. «радуга» < бор. *җәй, җай, йай* «җәя» һәм *қор* < *қур* «билбау» сүзеннән. К. **Янкылыч.**

**ҖӘЙДӘК, җәйдә'** (ЗДС: 183) «верховой без седла», **җәйдәкле** дә диелә; к. **Җайдак.**

**ҖӘЙЛӘҮ I,** диал. **җәйләвек** «летовка, место, где проводят лето» < гом. төрки *йайла-г* id., к. хак., тув. *чайлаг,* чыгт., ком. *яйлак* id. Чаг. **кышлау ~ кышлак** һ.б.ш. Бу сүз күп күрше телләргә дә кергән: рус. *чайлаг, яйлы* «җәйләү». *Яйла* «тау биеклегендәге көтүлек – плато» тур. Аникин: 636–637, 722.

**ҖӘЙЛӘҮ II** диал. «чайное блюдечко» (Остроумов) ~ башк. *йәләү, йәйләү* «икмәк салу табасы» (БҺҺ II: 97). Чаг. **Җәй-ү.**

**ҖӘЙМӘ** «скатерть; раскатанное тесто» ~ тат. диал., башк. *йәймә*, чув. *ейме*, каз. диал. *җәйма* id., ног. *йайма* «камыр җәймәсе» һ.б., *җәй* < *җай* ~ *йай* фигыленнән; к.-балк. *джайма* «хәтем көлчәсе» ~ тат. диал. *җәймеш* id.

**ҖӘЙМӘН, җайман** (Зимасов: 23) «постель» **җәй-ү** яисә **җай** нигезеннән. Чаг. ш. ук фар. *җāймāн* «бер кешелек урын (*җай* «урын»)». Контаминация булса кирәк.

Әд. телгә бу сүзне кертергә кирәк. Чөнки шул мәгънәдә кулланылган *урын-җир* төгәллекле түгел.

**ҖӘЙПӘК,** себ. (Тумашева 1992: 74) **йәйбәк** ~ башк. (БТДҺ: 133) *йәйпәк, йәйпе* «уплощенный; блюдечко (под чашку)» << кырг., к.-калп. һ.б. *җайпак* id., *җайпа-, җайпы-* «бераз җәю, җәелдерү» сүзеннән. Чаг. тат. диал., башк. (ТТДС I: 581; БҺҺ II: 97) **җәйләү, йәйләү** «җәйпәк; таба», чув. (Сергеев 1968: 16) *ейлеке* «сай (савыт)».

**ҖӘЙРӘКӘ** (ЗДС: 183) «крупный, ширококостный» ~ чув. *çарлака* «киң, киңчә». Бу сүзләр тамырдаш булмаска да мөмкин. Ләкин уникаль *-әкә ~ -ака* кушымчасы уртак. К. тат. **җәйрә-** < гом. төрки *җайра-, йайра* «җәйрәү», чув. *сар-, çар-* «җәю; сирү».

**ҖӘЙРӘН,** себ., башк. **йәйрән** «джейран, серна» < бор. төрки, бор. монг. *ǯegeren, ǯägärän* > фар. *җайран* > төр. *ceren, ceran, ceyran, ceylan* id. К. **Җирән.**

Рус. *дзерен, ерень* «җәйрән» тур. Аникин: 186, 201–202.

**ҖӘЙРӘ-Ү,** диал. (Г. Афзал) **җайра-у,** себ. тат., башк. **йәйрә-ү** «широко расстилаться, развернуться» ~ уйг. *йайра- (йайримак)* «җәйрәү; үзеңне иркен хис итү», нуг. *яйра-* «таралып төшү», каз., к.-калп. *җайра-*, *жайра-* «җимерелеп яту», алт. *дьайрат-, йайрат-* «җимерү», кырг. *җайра-* «егылып үлү» һ.б. *җәй-* < *җай-, йай-* «җәю» фигыленнән (чаг. *көй-ү → көй-рә-ү, кый-у → кый-ра-у, уй-у → уй-ра-у*). К. **Җәйрәкә.**

Иске тат. (ЛТ I: 167) **чайра-у** «арка белән яту» ~ себ. (Тумашева 1992: 233) **цайра-у** «таралу» сүзе **җәйрә-ү** белән бердәй, әмма монда хак. компоненты тәэсире сизелә (*җ-* > *ч-*). К. **Җәй-ү.**

**ҖӘЙ-Ү,** тат. диал., башк. **йәй-ү** «расстилать, стелить» < гом. төрки *йай-* (> *җай-*) «җәю, тарату, таркату» – чиктән тыш күп вариантлы сүз: бор. төрки язмаларда аның *jaδ-, jad-, jaz-, jas-, jat-* вариантлары бар һәм *йаз-у* (I һәм II) сүзе **җәй-ү** белән кардәш булса кирәк. К. ДТС: 226–227.

**Йай- > җәй-** фигыле нигезендә гом. кыпч. *җайна-* < *йайна-* «иркенәю», *җәйпә-* < *җайпа-* < *йайпа-* (к. **Җәйпәк**), *җәйрә-* < *җайра-* < *йайра-* фигыльләре һ.б. ясалган. ЭСТЯ IV: 76–77.

Тат. дерив. дә киң: **җәел-ү, җәеш-ү; җәйдер-ү** һ.б.

**ҖӘК, җек** «одинокий; только один (одно, одна)» < фар. *йäк* id. *Җәк (җек) тиен дә (юк)*, дигәндә генә сакланып килә.

**ҖӘЛА,** иске тат. (ЛТ I: 155) **җала** «блеск, полировка; глазурь», тат. диал. «блеск зарницы» < гар. *җäллā, җäлā* id. *җлл* «якты булу» тамырыннан (шуннан **Җәлил** исеме килә). **Җәла** иске һөнәрчелектә киң кулланылган сүз. К. ш. ук **Җила.**

**ҖӘЛАЕР I [җәлайыр]** «река Зилаир» – рус. < тат., чөнки башк. *Йылайыр* диелә. Тарихта атаклы тат.-төрки < монг. *җалайыр* кабиләсе исеменнән. К. Султанов 1977: 168; Velidi: 231–141 (гомумән күп тапкыр сөйләнелә). К. түбәндәгене.

**ҖӘЛАЕР II [җәлайыр]** – название древнего монгольского племени; җәлаер кабиләсе башкортлар составына да, Себер һәм Касыйм татарлары составына да кергән. Атаклы тат. тарихчысы (XVII г.) Кадир Җәлаири шулардан чыккан. Гомумән, җәлаерлар аеруча ышанычлы хәрби каста буларак, барча төрки өлкәләрдә, бигрәк тә Анатолиядә (Төркия), монгол хакимиятен куәтләү хезмәтен башкарганнар. Башкортстанда Җәлаер ныгытмасы булган (рус. Крепостной Зилаир) һәм хәз. топонимнар – ике **Йылайыр** – шулардан калган.

**ҖӘЛӘК** диал. «жилет» – кар. *йэлек, йэлэк,* чув. *елек* ~ төр. *yelek* > фр. *gilet* > рус. *жилет* (хәер, бу этимология шикле). К. ш. ук төркм. (ТДГДС: 101) *йеләх* «бөркәнчек», ЭСТЯ IV: 178–179.

**ҖӘЛӘП,** иск. **җәләби** «проститутка; зазывала на рынке», «нарочно привлекающий внимание» ~ каз. *җәлеп, җәлеби* id. < гар. *җäлäб, җäлаби* id. К. **Җәлеп.** К. **Чәләби, Челби.**

Дерив.: **җәләплән-ү** «кирәксез вакытта күзгә ташлана торган киемнән йөрү».

**ҖӘЛЕП: җәлеп ит-ү** «привлекать (к чему)» < гар. *җäлб-ун* id. *җлб* «тарту, китерү» тамырыннан. К. **Җәләп.**

**ҖӘЛТ** – подражание порывистому быстрому движению: **җәлт кенә** «быстренько», **җәлт-җәлт** подражание порывистым движениям; шуннан: **җәлтерә-ү** «быстро и порывисто двигаться» – **ялт**// **җалт** тәкълиди сүзеннән, к. **Җилтер, Ялт.** Чаг. ш. ук фар. *җäлд* «елгыр, өлгер».

**ҖӘМ** диал. «норов, внутренний лад» (*җәмән* «үз холкы белән эшләүче», **җәмсез** «көтелмәгәнчә кылanучан», к. ТТДС I: 581–582) < болг. **җәм* > мар. *с'äм, с'ам, сем*, удм. *сам*, чув. *çем* «көй; әдәп; охшашлык», *çемĕн* «үз көенчә» һ.б. Федотов I: 100.

**ҖӘМӘГАТЬ [җәмәғәт],** тат. диал., башк. *йәмәғәт* > мар. *йамагат* «собрание общины (обращение к собравшимся)»; «жена, супруга; супруг» < гар. *җäмā'ат* id. К. **Җәмгыять.**

**ҖӘМГЫ** «все вместе» < гар. *җäм'-ун* id.

**ҖӘМГЫЯТЬ [җәмғыйәт]** «общество» < гар. *җäм'иййāт* id. *җм'* «җыю» тамыр сүзеннән, шуннан ук **Җәмәгать, Җамигъ, Җәмгы, Җомга, Иҗтимагый.**

**ҖӘМКӘ** диал. (т.я., без теркәдек. – *Р.Ә.*) «лоб; череп» ~ чув. *çамка*, мар. *с'аңка, саңка* id. ~ алт., кырг. *әмгек* «лепкә», аз. *әмкәк* «баш түбәсе». Федотов II: 83–84. Икенче яктан к. төр. *серһе* «маңгай; фронт» < гар. *җăбһă* id.

**ҖӘМКИ, җәмкый** (ТТДС I: 581) «щипцы (в особенности – для свеч)» ~ башк. *җәмкә, йәмкей* < чув. (Сергеев 1968: 17) *ямкке,* каз. диал. *жәмке* ~ бур. *зиимхэ,* монг. *чимхэх* id. – **чемет-ү** белән тамырдаш булса кирәк, к. Нұрмағамбетов: 43–44.

**ҖӘНАБ** (ш. ук **җәнабе гали**) «уважаемый господин; сударь» < гар. *җăнāб, җăнāб-ул-ʻāлū* id. Будагов I: 442.

**ҖӘНҖАЛ** «скандал» < фар. *җăң-у-җăдāл* «сугыш-талаш»: *җăң* (к. **Җәң**) «зур сугыш» һәм *җăдāл* (> тат. диал. **җәдәл**) «талаш». К. тат. диал. **җәдәлләш-ү** «талашу».

**ҖӘНЛЕК,** диал., башк. **йәнлек** «зверь» > чув. *енлĕк*, мар. *йанлык, йалнык*, удм. *зăнлык* id. < бор. төрки *ǯanlïγ* «җанлы зат», **җан** сүзеннән.

**ҖӘННӘТ** «рай» < гар. *җăннăт* «җәннәт, бакча». Дерив.: **җәннәтле (җәннәтле булу), җәннәтлек.**

**ҖӘҢ** тар. «битва» ~ уйг., чыгт., кар., төр. *ǯăŋ (cenk)* id. фар. теленнән дип исәпләнә, ләкин фар. *җăң* id. үзе төрки телләрдә булырга мөмкин, чаг. *җиң-у*. К. **Җанфәрман, Җәнҗал.**

**ҖӘП,** диал. **зәп** (ТТАС I: 353) «зябь (осенняя вспашка)» < рус. *зябь* id.

**ҖӘПЛӘШКӘ** «развилка» < *җәпләкәч* > *җәпләкәш*. К. **Япь.**

**ҖӘПТӘШ** «охотник помогать людям; хороший сосед» – ихтимал, бор. бер **җәп** «уртак арык» сүзеннәндер (**җәптәш** «арыкташ»!). К. **Җап, Япь.**

**ҖӘР: хәрфе җәр** иск. «послелог, ставящий существительное в родительный падеж», күч. «правильное произношение, дикция» < гар. *җăрр* id.

Дерив.: **җәрле**, **җәрсез.** Гар. хәрефләре гамәлдә чагында бу сүзләр актуаль булган.

**ҖӘРАЯН [җәрайан]** иск., кит. (*вакыйгалар җәраяны*) «цепь событий, явлений, связанных друг с другом; взаимосвязь» < төр. (< гар.) *cereyan* «агым, агынты; үзара бәйле вакыйгалар, күренешләр үсеше», техникада «электр тогы» ← гар. *җăрăн* «тиз агу, тиз үсү; тиз үсешү». Бу тамырдан мөселман илләрендә киң кулланышлы (тат. әд.) **иҗра** «башкару, башкарылу», **җария** «хезмәтче кыз; фрейлина», **мәҗара** ← «маҗара, үзара баглы вакыйгалар төене» һ.б. сүзләр ясалган.

Элекке әд. телебездә **җәраян** сүзе шактый киң (мәс., Г. Исхакый телендә) кулланылган.

**ҖӘРӘКӘҮ, җирәкәү** (к. ТТДС I: 574, 582) «угодливый; угодник» (**җәрәкәүләнү** «ялагайлану») < иске *җәвекәр* < *җадигәр* «сихерче, җадучы» сүзенән метатеза, к. себ. **йәйкәр** < *йадыкәр* «ярамсак күрәзә» (*йәйкәрлән-ү* «ярамсаклану», Тумашева 1992: 76). К. **Җаду.**

**ҖӘРӘХӘТ** «рана» < гар. *җăрāхăт* id. *җрх* «яралау» тамырыннан, к. ш. ук **Мәҗрух.**

**ҖӘРБӘК** «руб, рубище» к. **Ярбәк, Яргак.**

**ҖӘРГӘ, җәркә, йәркә-сүрәт** (Кадыйр Галибик) тар. «боевой строй; ряд; порядок; устав» ~ кар. *йэргя* «рәт, баскыч, дәрәҗә», ком. *жерге* [*җэргэ*] «рәт; түтәлләр теземе; чират», к.-балк. *джерге-джерге* «рәт-рәт», кырг. *җерге* «рәт, тезем; тугандашлар группасы (түгәрәге)», чыгт., фар. *җәргә, чәргә* «түгәрәк; линия, хәрби тезем, рәт; камау; шан-шәрәф», тув. *черге* «дәрәҗә, разряд», як. *сэрэг, сэргэ* «ат бәйләү өчен баганалар теземе; янында (бәйлек мәгъ.)» ~ бур. *зэргэ* < бор. монг. *ǯerge* «рәт; рәтләр, хәрби тезем; дәрәҗә, тиң, титул; рәттә, рәтендә, янында»; бу сүз угыз телләрендә бик сирәк очрый: чаг. ш. ук чув. *çерке* «тезем», *йĕрке, йерке* «тәртип; рәт, тезем; система». Мар. *йэргэ* «рәт», рус. *черга* «чират» (к. Фасмер IV: 336) һәм маньч. *ǯэрги* «рәт; тезем; сорт» (ССТМЯ I: 285) төрки телләрдән. Фар. *җăргă* дә төрки алынма булырга тиеш.

Тамыры – бик бор. Урал-Алтай сүзе булса кирәк. К. **Ниргә, Эргә.** ЭСТЯ IV: 25–26; Федотов I: 200 (тат. сүзен белми).

**ҖӘРИБ,** диал. **гәрип** «десятина; 40 сотых» – вообще «единица измерения земли» – гар. *җăрūб* «күтәрелгән чирәм» сүзеннән, *җрб* «яңа җир сөрү» тамырыннан (шуннан ук **тәҗрибә** сүзе килә).

*Җәриб* сүзе ислам илләрендә еш кына очрый. Аның «≈216 литрлы берәмлек» мәгъ. дә бар.

**ҖӘРИДӘ** тар. «газета или журнал» < гар. *җӓрӣдӓ* id., ш. ук «таблица; белешмәлек һ.б.ш.», бор. гар. «хәбәрче, игъланчы; чапкын», Будагов I: 435.

**ҖӘТ, җәд** «предок» < гар. *җӓдд* id. К. ш. ук *җәддә* «инәкә, дәүдәүәни».

**ҖӘТМӘ** «сетка; перепонка». К. **Ятьмә, Җитемәк.**

**ҖӘҮЗӘ [җәwзә]** «близнецы (знак, созвездие зодиака); название месяца (считая с *нәуруз*а): 23 мая – 21 июня» < гар. *җӓwзā* id. >> себ. (Тумашева 1992: 235) *цауза* id.

Идиома: **җәүзә мае** «иң сыйфатлы ак май».

**ҖӘҮҺӘР [җәwһәр]** «квинтэссенция; самое дорогое в чем-либо» < гар. *җӓwһӓр* (к. **Гәүһәр**).

**ҖӘФА,** диал., башк. **йафа** «страдание; горе, причина горя» < гар. *җӓфā'* id. ← *җфw* «кысрыклау». **Җәфа** дип Алтын Урда чорында салымнарны да атаганнар: **даруга** сүзенең тәрҗемәсе булган.

Дерив.: **җәфалы, җәфасыз** (*дөнья вафасыз: яшәтми җәфасыз*); **җәфалан-у.**

**ҖӘҺӘННӘМ,** диал., башк. **йәһәннәм,** себ. **йәнтәм** (Тумашева 1992: 75) «ад, геенна» < гар. *җӓһӓннӓм* < яһ. *гэй-Һинном* тәүдә Һинном дигән кешенең беләмәсе – вадие (коры үзәне) булган, соңыннан бу вадигә Молох дигән тәңре сынын куеп, аңа килеп кешеләрне корбан иткәннәр һәм аннан сасы ис – черегән ит исе килеп торган. Рус. *геенна*, инг. *gehenna* һ.б. – Библия теленнән.

**ҖӘҺӘТ I** «быстренько, живо» < гар. *җӓһд* «тырышлык» *җһд* «тырышу, көч салу» тамырыннан, шуннан ук к. **иҗтиһат, мөҗаһит, мөҗтәһит.**

**ҖӘҺӘТ II** «сторона; отношения» < гар. *җиһӓт* «як, тараф; ян» *wҗһ* «икегә аерылу, ике якның берсе» тамырыннан. Иске тат. **биҗиһәт** «битараф».

**ҖӘЯ [җәйә]** «лук; шерстобитный смычок» – гом. төрки бу сүзнең дүрт варианты бар: 1) *җәйә, йәйә* ~ ком., к.-балк. *җайа*, себ. *йайа*; 2) башк., нуг., чыгт. *йай*, төр., төркм. *йаай*, каз., к.-калп., кырг. *җай, жай*; 3) алт., куман., бор. төрки *ja*, хак., тув. *ча*, як. *саа*; 4) башк., тат. диал. (Тумашева 1992: 62) *йан* «җәя»; бик оригиналь бишенче вариант – *йаға* (брб., к. Тумашева 1992: 64) бердәнбер булгач, шик уята (хата язылыш һ.б. ихтимал).

Бу сүзне берәүләр эвен. *нāj, наjы* «керәшчә, сөңге» белән, икенчеләр авест. *ǰya* ~ санск. *jya* «кереш, буйлык, җәя» сүзе белән чагыштыралар; санск. сүзе, үз чиратында, лит. *gija*, грек. *βιος* сүзенә тәңгәлләштерелә (к. Преображенский I: 234, рус. *жиһа* сүзенә тәгъриф). Болар барысы да юраулы. ЭСТЯ IV: 45; Федотов II: 126, 274.

**Җәя** сүзенең язу билгесе – рус. «скобка, скобки» – мәгънәсе иске тат., үзб., чыгт. *қаwс, қаwыс* «җәя, язудагы җәя» сүзеннән калькалаштырылган, к. **Кавыс II.**

**ҖӘЯК [җәйәк],** миш. (ЗДС: 182, 240) **йәйәк** «скула; челюсть» ~ чув. *çене* [*счэнэ*], төр. *çепе* [*чәнә*] id., чаг. төр. *çigne-* «чәйнәү». **Яңак** (к.) белән **җәйәк** арасында күп арадаш яңгырашлар булырга тиеш.

**ҖӘЯҮ [җәйәw],** диал. **йәйәү, йейәү,** себ. (Тумашева 1992: 65) **йайау** «пешком» ~ к.-балк., к.-калп., кар. *джайау*, нуг., ком. *яяв,* башк. *йәйәү* һ.б. < бор. төрки *jadaγ, jaбaγ* id.; төр., гаг. *йайан* ~ чув. *çуран* < *çоран* < болг. **җаран* < бор. *jadaγın – jadaγ* сүзенең инструменталь килеш формасы (чув. *-р-* < *-*d-*).

Бор. *jadaq* я бор. монг. *jabudaq* «йөрүчән» сүзеннән (*jabu-* «йөрү», я бор. фар. *пийадаг* «җәяүле» сүзеннән (к. Räsänen 1969: 177) дип карала. Ләкин безнеңчә, бор. *jadaγ, jaбaγ* (к. ДТС: 222–223) «җәяү» белән чыгт. (Будагов II: 322–323) *йадағ* «алҗыган, арыган; җадау» сүзе бер булырга тиеш (к. **Җада-у**). Әйтмәкче, *йадағ* «җадау» мәгъ. ДТСта теркәлмәгән. Бу мәгълүматлар Рясянен гипотезасы тегермәненә су коймый. ЭСТЯ IV: 68–69, 77; Федотов I: 141.

**ҖЕБЕН** «беспомощный, малодушный» – гар. *җӓбӣн* «куркак» сүзеннән булса кирәк. **Җебегән** сүзе – контаминация элементы.

**ҖЕБЕ-Ү,** диал. **йебе-** «промокать, намокнуть» ~ башк. *йебе-,* нуг., кар., ком. *йиби-*, алт. *дьаби*, кырг., к.-балк., к.-калп. *җиби-*, шор. *чиби-*, хак. *чiбi-* id., уйг. диал. *iбi* «йомшару» (к. Радлов I: 1569). К. ш. ук чув. *йĕп, йĕпĕ* (< тат. диал. **йебек**) «юеш», *йĕпĕн-* «җебенү» (тат. диал. **йебен-**), *йĕпре-*, *йăпра-* «җебү, юешләнү». Бор. төрки *jibi-* id., я ниндидер **йип* исем тамырыннан (*jib-i-*), я *ji-* фигыль тамырыннан (*ji-pi-*). ЭСТЯ IV: 196–197; Ахметьянов 1989: 63. Чув. *йĕпĕ, йепе* (<**йибиг*) «юеш» тур. Федотов I: 196–197. К. **Җепшек, Юеш.** Чаг. ш. ук эвенк. *чип-* «җебү» (гом. тунг. параллельләре белән) < *чиг-пи-*, к. **Чи.** Ләкин *ч-* ~ *й-* бор. төрки телләрдә күзәтелми.

Дерив.: **җебен-ү, җебет-ү; җебек, җебегән** һ.б.

**ҖЕК,** диал. **җик,** себ. (Тумашева 1992: 97) **йек, ик** «стык; щель на стыке; шов» > мар. *йык* ~ башк. *йек,* к.-калп., кырг. *җик*, алт. *дьиг,* тув. *тиг,* хак. *чiк*, як. *сиик* id., гаг. *ек [йэк]* «буын, буынтык; тоташма», төр. *yiv* «җек; җөй». Чаг. **Җөй.** ЭСТЯ IV: 197–198 (*җөй* белән *җек*нең бердәйлеген бик ышанып әйтә). Чаг. **Ик.**

**ҖЕКРӘЧ, җекерәч** (к. ТТДС I: 569) «двойня (у скотины)», *йекерәч* варианты да булырга тиеш, к. чув. *йĕкĕреш* id. – болг. теленнән, к. мар. *йыгыр, йĕгĕр, йыгыре*, венг. *iker*, эвенк. *игирэ, икирэ* «игез, җекрәч». Бу сүзләр бор. төрки телнең -*r* тел булганлыгына бер дәлил. К. **Игез.**

**ҖЕМ** диал. «крупинка» к. **Чем.**

**ҖЕМЕЛДӘ-Ү,** диал., башк. **йемелдә-ү** «мерцать; поблескивать», **җем* (*җем-җем*) тәкълиди сүзеннән (*җем-елдә-*).

**ҖЕМИЕМ** «полуулыбка; усмешка»; чаг. диал. (Гиганов) *ъмыямень* «усмехаюсь», үзб. *җимий-*, к.-калп., кырг. *җымый-* «авызны ачмыйча елмаю», к.-калп. *җымың* «җемием», *җымый-* «кысылу, бөрешү», калм. *җими-* id., монг. *җимийх* «ирен тешләү». *Җумайх* «җемием елмаю» ← **җим-*, **җуум-*. К. як. *ньимий-* «ирен кысылу», *ньимит* «ирен тешләү».

**ҖЕМТЕК** (ТТДС I: 570) «корм для птиц». Чаг. **Җим.**

**ҖЕН I,** диал. **йен** «злой дух, бес, джинн» ~ башк. *йен* id. > чув. диал. *йĕн*, мар. диал. *зын,* удм. *зин* id. < гар. *җинн* «җен; яшерен зат» – *җнн* «яшерү» фигыленнән. К. ш. ук тат. диал., фольк. *әҗинә* «хатын җен, җен хатыны». К. **Мәҗнүн.**

Дерив.: **җенле; җенлән-ү.**

**ҖЕН II,** диал. **йен** «пищевод; сухожилие» (ТТДС I: 570; БҺҺ II: 88) ~ чув. *чĕн*, мар. *шүн, шөн, сүн*, коми., удм. *сöн*, фин. *suoni* id. Күрәсең, финугор сүзе.

Төрки телләрдә к.-калп., кырг. *җин* < бор. төрки *jin* «тизәк» сүзе бар, ләкин аның мәгънәсе тат. сүзенә туры килми.

**ҖЕНАЗА** «панихида, отпевание покойника» < фар. *жäнāзä, җинāзä* id. < гар. *жäнāзä* «мәет колашасы; мәет» сүзеннән.

**ҖЕНЕС** «пол; род (в классификации)» < гар. *җинс* id. (*җнс* «бер төрле итү»); бу сүз лат. *genus* «нәсел, чыгыш» сүзеннән килә дигән фараз бар (гар. телендә бор. Рим империясе чорыннан калган сүзләр күп кенә).

**ҖЕНСИ** «половой» < гар. *җинсӣ* id. К. **Җенес.**

**ҖЕНТЕК,** диал., башк. **йентек** «доскональность, дотошность, скрупулёзность» – күрше төрки телләрдә юк. Чаг. үзб. *синчикла-* «җентекләү», төр. *çintik* «вак кирт, вак аралы параллель сызыкларның берсе», *çint* «вак-вак киртү», ихтимал, бор. чыгт. *ǯin* ~ бор. монг. *ǯintü* «(вак) үлчәү берәмлеге, вак берәмлек» (к. Поппе 1938: 206) сүзеннәндер; к. ш. ук бор. төрки (ДТС: 261) *jin-, jind-* «тикшерү, эзләү, җентекләү», алт. *чиҥде-* «җентекләү», тув. *чинзе-* «эзләү», *чин* «порция, үлчәм», хак. *син* «үлчәү, чак, яшь, дәрәҗә» < **чин* > як. *син* «җитәр!». Гипотетик төрки **чин* сүзеннән слав. *чин* сүзе килә дигән фикер бар. Чаг. ш. ук кырг. *жентек* (тат. **җентәк* ~ **җинтәк* булырга тиеш була) «бала туу уңаеннан уздырылган туй-сый», уйг. *җиңдәк* «әз генә» ← *җиң* (кыт.) «цзинь» – 5,6 грамм.

Гомумән, **җентек** сүзенең этимологиясе томанлы: эзлекле үсеш җебе күренми.

Дерив.: **җентекле, җентеклә-ү.**

**ҖЕНЧЕК** «верх стопы ног» к. **Җинчек.**

**ҖЕП,** диал., башк. **йеп, ип** «нить, нитка» < гом. төрки *йип* (к.-балк., кырг., к.-калп. *җип*, хак., тув. *чип* һ.б.); чув. *çип,* төр., аз. *ип*, төркм. *йүп, öп* id. ССта *yp* «җеп», *ypak* «ефәк» язылышы игътибарга лаеклы. Чаг. тунг. *чӣва* «атның муен сеңереннән ясалган җеп» (к. ССТМЯ II: 389), тат. аны *чәчүргеч* диләр; ул ефәккә охшаш була. К. **Ефәк.** Räsänen 1969: 104; ЭСТЯ IV: 268–269; Федотов II: 120.

**ҖЕПКЕР, җепкәр** «скань (вид декоративно-ювелирного искусства)» < фар. *җүфтгир* һәм *җүфткар* id. (асылда «ишеп эшләү»). Чаг. **Чуптар, Чүпләм.** Чаг. уйг. *чөпкәр* «пресс, эскәнҗә (вак эшләр өчен, кечкенә)». Тимергалин: 167 (төрле фаразлар китерә).

**ҖЕПКЕР-Ү** диал. «чувствовать отвращение» (Катанов 1912; ЗДС: 187), к. **җепсен-** (ЛТ I: 153) id., **җепкерт-ү** «биздерү, туйдыру» (ТТДС: 570) һ.б. **җик, җык** «шайтан, явыз рух; кыенлык» сүзе белән бәйле булырга тиеш, к. **Җик, Җиксен-ү.**

**ҖЕПСӘ,** диал. **йепсә** «шпона; иглица (соединительная деталь в конструкциях из одинаковых отдельных частей, планка, стержень и т.п.) ~ чув. *йĕпсе* «бәйләм энәсе, шәл бәйләгәндә кулланыла торган озын энә; җепсә; кизә (гомумән күп буыннарны, буҗраларны һ.б. бергә җыеп тора торган нәрсә)», мар. *йыпш, йыпша, җыпса* id., чув. *йĕп*, мар. *йып* «сөңге; озын энә (шуңа бәйләм элмәкләре тезелә)»; бигүк ачык түгел, чаг. уйг. *җипса* «үзара беркетелгән; кушма», фар. *чефт* «элмәк; җепсә». К. Федотов I: 197.

**ҖЕПШЕК,** диал., башк. **йепшек** «мокрый (о снеге)» > мар. *йыпшык* (Исанбаев 1978: 27, Гордеев 1983: 31) id. < тат. *җебеш-ек//йебеш-ек* «җебегән, җебешкән» **җебе-ү** фигылennән. К. тат. диал. *җепше-ү, җепшет-ү* «юешләнү, юешләтү» (карны, кар тур.). Чув. *йĕпсү, йăпшу, йăпсăк* «карлы яңгыр; төтрә яңгыр» < тат. диал. *йепшү* «юеш карлы», чув. *йĕпхү* «җебегән» < тат. диал. *йебегү ~ җебегү* «җеби төшү». К. ш. ук себ. (ДС I: 55) *йепкәс*, башк. *йĕпшән* «җепшек». К. **Юеш.**

**ҖЕТЕ,** диал., башк. **йете** «резкий, острый; яркий; зоркий», ш. ук себ. **йетек, йетү** «үткер», иске тат. **йөте** ~ к.-балк. *җютю*, әмма күпчелек телләрдә тамырда *и*: кр.-тат., госм. *ити*, куман., уйг., чыгт., кар. *йити*, *йитиг, йитик*, бор. уйг. *йитиг* (к. Боровков 1963: 154), тув. *читиг* > шор. *чыдыг* > як. *сыты* һ.б. (Räsänen 1969: 204). Безнеңчә, борынгырак кыпч. яңгыраш *җигит-и* > *җиwити* булган һәм бу сүз **җиги-т-//йиги-т-* «үткерләү» фигылennән (**җиги-* «үткер булу») ясалган, к. чыгт., аз. *ити-, ит-* «үткер булу» (Будагов I: 180), чув. *çивĕч* «җете» (*çĕçĕ* «пычак») < **җиwĕтĕ// *йиwĕтĕ.* Тамыры бор. **эг* «оч; үткер, үткен» булса кирәк, к. **Ик.**

**ҖЕТЕК: җетек ыру** «выморочный род; последний из рода (и бездетный)»; **җетек юл** «теряющаяся дорога, тропинка (например, в лесу), исчезающий след». К. **Җет-ү.**

***ҖЕТ-Ү,** диал. (Тумашева 1992: 80) **йет-ү** «похудеть; потеряться»; бу фигыльнең төп нигезе урта диалектта сирәк кулланыла, ләкин дериватлары еш кына очрый; *үлем-җетем; җетек* «бетүгә йөз тоткан»; *йетер-ү, җетер-ү* «бетерү, юкка чыгару» (*Әкрен эшен бетерер, җитез үзен җетерер,* мәкаль); *җетмә сукыр* «беткән сукыр, өметсез сукыр» (к. ТТДС I: 570), бүтән телләрдә: чув. *çĕт-* «юкка чыгу; адашу», *çĕтĕр-* «җетерү», *çĕтĕк* «кыршылып беткән, таркалган; җетек; өметсез чирле», чыгт., куман., госм., төркм. *ит-, йит-* «бетүгә бару», үзб. диал. (ЎХШЛ: 133) *йет-, йит-,* кырг., к.-балк. *җит-,* тув. *чит-,* хак. *чiт-,* як. *сүт-* id. һ.б. Будагов I: 180; Räsänen 1969: 204; Федотов I: 113–114 (тат. параллельләрен белми); ЭСТЯ IV: 205–206.

**ҖЕФЕТ,** диал., башк. **йефет** «супруг, супруга», бор. *җефетләшү* «парлашу» сүзеннән кабаттаркалыш юлы белән ясалган, сүзнең нигезе – иске *җефет* «пар» < фар. *җүфт* «пар, парлы; кат, катлы». Бу фар. сүзеннән төрки телләрдә исәпсез күп яңа сүзләр ясалган, к. **Җепкер, Җөп, Җүп, Чуптар, Чыпта, Юкә.** Мухамедова 1973: 189.

**ҖИБӘЛӘЙ, зибәләй** (ЗДС: 200) «подмаренник (растение с султаном)», **җебәрәк** (ТТДС I: 595, 610), **йебәләй** (ЗДС: 245) «ковыль» **ябәлә** «парад аты маңгаена куелган саплы җилфердәк» сүзе белән бәйле. Чаг. ш. ук каз. (ҚТДС: 118) *җебелек* «кызлар чәченә кушып үреләторган дөя кылы». К. **Җәбәләй, Ябәлә.**

**ҖИБӘР-Ү,** диал., башк. **йебәр-** «посылать, послать; отпускать (товар)» < элекке *ийә бәр-* «әтеп бир (бәр)» сүзеннән гаплология, к. себ. (Тумашева 1992: 49, 53) *ейү, ийәбәрү, ийү* «җибәрү, озату, күндерү», к. ш. ук *'пу алтынны үс патышасына йийәбәргән ол пала* (Дмитриева 1981: 49) > гом. кыпч.: нуг., ком. *йибер*, кар., кр.-тат. *йәбәр-* id. – төркм. *ибәр-*, уйг. диал. *ебер-*, *әбәр-* һ.б. (ЭСТЯ IV: 322–324); к. **Ий-ү; Ыек.**

Сөйл. телендәге *җиббәр-, җиффәр-* яңгырашлары очраклы түгел, алар *ийә бәр*нең *йиеп бәр-* вариантыннан (паронимыннан) киләләр.

Дерив.: **җибәрел-ү** (бу сүзнең «корычны яндырып йомшарту» мәгъ. дә бар, чаг. рус. *отпускать* шул мәгъ.); **җибәреш-ү, җибәрт-ү.**

**ҖИБЕР** «род, отродье» к. **Җәвер.**

**ҖИБУТА** (ТТДС I: 570) «сбруя» (но это, видимо, суженное значение) < төр. диал. *җифута*, төр. *civata* «болт, винт»; «(корабельная) снасть», фар. *җәфтә* «ярдәмлек корылма» сүзенең дөрес булмаган күп. формасы. Тат. теленә **җибута** кр.-тат. теленнән кергән булса кирәк.

**ҖИДА,** диал. **йедә** (добр. тат. әкиятендә каһарман кыз *йегнә (энә) тоткан кулым, йедә (сөңге) дә тотар*, дип әйтә), себ. (Тумашева 1992: 89) **йыда,**

**йыта** «пика, меч» ~ ком. *жҫыда*, госм., гаг. *жҫида,* аз. *чида*, уйг., алт., хак. *чыда* ~ бор. монг. *ǯida* (хәз. монг. *жад, зад*), тунг.-маньч. *чида, чит* «җида, чәнчү коралы» < кыт. *цзу, цзя,* бор. кыт. **ки, *кя* «төрле чәнчү коралы». К. ССТМЯ I: 148.

Бу сүзнең беренче иҗектә *а*лы варианты – төр. *yat, yata,* кабарда. һ.б. Кавказ телләрендә *джатә,* бур. *җада, зада* «кылыч төре» киң таралган, к. **Ядыган.** Ramstedt 1935: 108; Räsänen 1969: 192–193; Номинханов 1975: 202.

**ҖИДӘ, җөйдә, җөдә,** әстр. (ЗДС: 185) **җегедә** «тутовник, тутовая ягода» ~ каз. *җидә,* к.-калп., кырг. *җийде,* үзб. *җийда*, *җийдә,* уйг. *җигдә* һ.б. «җиләкле агач». **Җиләк** сүзе белән тамырдаш. Бу агачны һәм аның җимешләрен руслар төрлечә атыйлар: «лох, мох, моховина» һ.б., к. Будагов I: 448.

**ҖИДЕ,** диал. **йӗдӗ,** себ. (Тумашева 1992: 80) **йӗттӗ** «семь» (**йӗтӗ** «неделя») < бор. төрки *jetti*, рефлекслары барча төрки телләрдә бар, к. ЭСТЯ IV: 167–168 (ышандырырлык этимологиясе юк диелә). Деривациясе (саннар өчен) регуляр. К. **Җидегән.**

**Җиде** сүзе белән ясалган тарихи-географик фразеологизмнар күп.

**ҖИДЕГӘН,** диал. **йедегән, йетегән** > мар. диал., удм. диал. *ǯедыган* ~ алт. *йäттäгäн,* башк. *йедегән, йетегән,* бор. төрки (ДТС: 259) *jetigen, jetikän* ~ төр. *yedikent* «җиде кала» (к. **Кәнт**), төр. *yediger* «җиде өй» (к. монг. *ger* «өй, кирмән»), «җидегән». Күп телләрдә *җиде хан* (алт. *jeti каан*) дип тә аңлатыла һәм моның да нигезе бар: фар. *һäфтөрең* «җиде тәхет» – җидегән. Гомумән, «җиде» мәгъ. сүздән соңгы өлеше һәртөрле аңлатуларга дучар. Ком., к.-балк. телләрендә *жедиждэгэн* «җиде җиян» (к. **Җиян**) диелә һәм бу җиде җиян тур. легенда сөйләнелә, уйг., үзб., кырг. «җиде кардәш», «җиде батыр», «җиде күзәтче», «җиде архар (кыргый сарык кучкары)», монг. халыкларында *долоон үбэгэд* «җиде аксакал» һ.б. «җидегән» (к. Вайнштейн 1961: 148; Будагов II: 363; Lorincz: 365–389; Алтай кеп-куучындар: 59–60, МНМ I: 391). К. ш. ук **Масан.**

Себ. татарларыннан язып алынган «Алтаин Сайын Сүмә» дастанында герой **киәң**нең (корольнең) җиде атын ияртеп күккә оча һәм бор. (бер вариантында) шунда торып кала, алар Җидегәнгә әвереләләр, үзе Тимерказык була күрәсең. Бу фикергә *Сүмә* сүзенең санск. *сумйä* «Тимерказык, Котып йолдызы» сүзеннән булуы китерә.

Кайбер публикацияләрдә «олы җидегән» – «кече җидегән» сүзләрен куллану тарихи яктан дөрес түгел: төрки телләрдә бер генә **җидегән** бар. «Кече җидегән» дигәне төрки телләрдә **Акбүзат йолдызлыгы** була, *Олы җидегән – кече җидегән* атамалары рус һәм Европа телләрендәге **«Олы ана аю» – «Кече ана аю»** мәгъ. атамалардан килә (калька). Тат., башк. сөйләшләрендә җидегәнне *чүмеч* яки *соскы* (алт. *суску*) дип атау да бар.

**ҖИЗ,** диал. **йез** «латунь, латунный» > удм. *ǯез,* мар. кч. *йез* ~ башк. *йез,* чув. *йӗс, йӗҫ* id., к. ш. ук *ёз,* мар. *йеж* «чем, метал чыбык» < гом. төрки, бор. төрки *jez, jäz* (> к.-балк., кырг., к.-калп. *жез,* каз. *жез*, алт., як. *д'эс* һ.б. закончалыклы вариантлар), уйг. *йиз,* бор. уйг. *ǯiz* (Поппе 1938: 439) «җиз, бакыр». Аеруча игътибарга чув. *ҫăвăҫ, шăвăҫ, шывăҫ, шоҫ* «җиз калай» (к. Сергеев 1971: 150) лаеклы, шуннан иң бор. яңгыраш **җыwыз* < **җүиз* булуы ачыклана.

**Җиз** < *җэз* сүзе төрки телләрдән бик күп күрше телләргә кергән, монг. *йэс, җэс* > эвенк. *җэ̄с, җэт* (ССТМЯ I: 286), адыг телләрендә *җэз, җäз* «җиз», рус. *жесть,* укр. *жерсть* «калай».

Тунг. *чӣр-ит, чӣриктэ* «бакыр, бронза» *җиз* белән тамырдаш булуы ихтимал (Бугаева – Цинциус 1975: 84–85). Федотов I: 200–201; ЭСТЯ IV: 168 (чув. диалекталь вариантлары искә алынмаган).

**ҖИЗНӘ, җизнәй > җизни,** диал., башк. **йезнә, йезнәй, йезни** «муж старшей сестры» > чув. *йыснa, йысни, исни,* мар. диал. *езнай,* морд. М. *эзна,* рус. диал. *снай* (Räsänen 1969: 199) < гом. төрки, бор. төрки *jezne* < **jeŋiznä* > гаг. *йеңиште*, төр. *enişte* id., чаг. тув. *честе*, алт. *д'есте*, чыгт. *йәздә* һ.б. id. < бор. төрки **йәңирңә*. К. **Җиңгә.**

**ҖИЙ-Ү (җию),** диал. (ДС I: 52, 57) **йӗй-ү** «есть, кушать» ~ башк. *йей-,* чув. *ҫи- (< җи-),* кар., нуг., кр.-тат., төр., уйг., үзб. *йэ-, йә-*, төркм. *ий-*, каз., к.-калп. *җэр, җэ-*, тув. *чи-*, як. *сiä- (сиэ-)* һ.б. «ашау» ~ тунг. (ССТМЯ I: 279–280) *ǯэб* id. һәм кыт. *чи* «ашау, ашамлык» сүзләре белән чагыштырыла. ДТС: 252–256; ЭСТЯ I: 333; Федотов II: 114–115 (тәфсилле).

*Җи-* < *җэ-* иң бор. төрки тамырларның берсе һәм аннан күп кенә яңа сүзләр ясалган, к. **Җим, Җимер-ү, Җимеш.**

*Җи-* һәм *җый-* сүзләренең кардәшлеге ихтимал, к. куман. *jу-* (*йы-*), уйг., бор. төрки *jуγ-*, шор. *чыг-* «ашау», ләкин бу контаминацион күренеш булырга

мөмкин. Шунлыктан *җи-* һәм *җый-* этимологик дублет дип кистереп әйтеп булмый. Шулай ук тат. диал. *җий-ү* «эренләү» ~ як. *сиэ-* id. сүзен дә *җий-* белән гомоген дип әйтү шик уята. К. түбәндәгене.

**ҖИК I: Җик Мәргән** имя эпического богатыря. К. **Җик II.**

**ҖИК II,** диал. **җык,** диал., башк. **йек, йык** «нечто отвратительное, крайне трудное; мерзкий», **җик булу** «омерзеть» ~ к.-калп., кырг. *җек,* к.-балк. *җэк,* алт. *дьек, дьеек* «әшәкелек, әшәке, кабахәт, явыз рух» ~ чув. *йăх* «яман чир; явыз рух», к. алт. диал. *чэк* «җирәнгеч» һ.б., куман., уйг., чыгт. *jäk* «җен, хәтәр, явызлык; усал зәгыйфь» (Радлов III: 316), хак, *чик* < бор. төрки *jäk* «ачлык җене» (Gabain 1950: 42), *jek ičkäk* «явызлык рухлары» (ДТС: 253) урта фар. *jakuha* «явыз җен» сүзе белән чагыштырыла. К. ш. ук төркм. *йек*, алт. *чäк,* хак. *чек* «әшәке, әшәкелек»; чулым. *улуг чäк* «унике башлы шайтан»; *җик//җык күр-ү* тәгъбире (күп телләрдә бар). К. **Җиксен-ү, Җирән-ү.**

Бор. *jäk* «яхшы» мәгъ. дә кулланылган, ләкин бу – шәп, елгыр кешегә сокланып «шайтан» дигән шикелле күч. мәгъ. булырга мөмкин. Котбинең «Хөсрәү вә Ширин»ендә *йәк* «батыр сугышчы, офицер».

**Җик** < *йәк* сүзе тур. әдәбият ишле: Булатов 1965: 34–36; Будагов I: 359; Räsänen 1969: 194–195; Львова: 174–175; ЭСТЯ IV: 170–172. К. **Җык I.** Бор. төрки *jek-ičkek* сүзеннән чыгып хөкем йөрткәндә *jek* «(кешене) ашаучы» ← *je-* «ашау» (ә *ičkek* «кеше канын эчүче»).

**ҖИКӘН,** диал. **зикән,** диал., башк. **йекән,** себ. **йегән** «рогозник; палочник; тростник (вообще камышовое растение)» ~ мар., удм. *йекäн, йэкэн,* чув. *йеккен*, мар. *цäган* «камыш», удм. *сякан* «камыш чыпта» < бор. чыгт. *йäкäн* «чыпта; палас», төркм. *екен [йэкэн],* уйг., бор. төрки (ДТС: 253) *jekän* «камышның бер төре», к.-калп., к.-балк., кырг. *җекен* << бор. кыпч. *җэкэн* >> венг. *gyekeny,* хант., манси *йекäн* id. һ.б. (к. Gombocz: 76–77; Räsänen 1969: 195); бу сүз күп күрше телләргә дә кергән (к. Абаев I: 396); фар. *чäгäн, җäгäн*, рус. *чакан* һ.б. төрки телләрдән; чаг. ш. ук **Чәкән.**

Төрки *җэкэн* < *йэкэн* бор. *йэгэкэн* (*-кэн* – үсемлек атамаларын ясагыч кушымча) формасыннан, к. алт. *дьекан, дьеекен [д'ääкäн]* < *д'эгэ-кэн*, иске монг. *ǯigesün – ǯige* «чыпта» тамырыннан, к. ш. ук негид. *ǯисиктэ,* маньч. *нисиктэ* «чыпта үрү өчен камыш» (ССТМЯ I: 260, 600). ЭСТЯ IV: 172–173.

**ҖИКЕР-Ү,** диал., башк. **йекер-ү** «грозно кричать (на кого)» ~ к.-калп., к.-балк., кырг. *җекир-*, кр.-тат. *чекир-*, нуг., ком., уйг. *йекир-* «җикерү», төрле аваз-кычкырыкларны белдерүчән фигыльләр ясагыч *-кыр//-кир, -гыр//-гир* аффиксы ярдәмендә *һи* ымлыгыннан ясалган: *һи-и-кир-* > *йекир-* > *җикер-*. Чаг. ш. ук алт. *дьеркирэ-* «дьер (шайтан) дип кычкыру, җикерү».

Дерив.: **җикерен-ү, җикереш-ү.**

**ҖИКСЕН-Ү,** диал. **йексен-ү** «отвращаться, почувствовать отвращение (к чему)» – диал. *җиксе-* «җик дип исәпләү» фигыленең кайт. юн. формасы, к. башк. *йекһен-, йекһе-*, алт. *йэксин-, йэкси-*, хак. *чикси-*, хак. диал. *чэскин-*, калм. *җикшии-*, монг. *җигшии-* «җиксенү, җиксү». Тамыры – к. **Җик II,** к. чув. *йĕклен-* «күңел болгану», *йексү* «яман ачы» (Ашмарин V: 119, 120), уйг. *йäклік* «явызлык», чыгт. *jäкläш-* «зәгыйфь көе үчләшү», як. *дьиксин-* «шүрләү, курку, имәнү». Чув. *йĕксĕк* (< тат. диал. *йĕксĕк*) «җирәнгеч» тур. Федотов I: 193 (тат.-башк. һ.б. кыпч. мисалларын искә дә алмый).

**ҖИК-Ү (җигү, җикте),** диал., башк. **йек-ү** «запрягать» ~ кырг., каз., к.-балк. *жэк-*, нуг., кар., ком., алт. диал. *йэк-*, алт. *д'эк-* id. Бу сүзнең исем коррелянты бар: себ. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) *йәклә-* ~ алт. *jäктä* (Радлов III: 317–319) **йәк* исем сүзеннән; себ. (Дмитриева 1981: 145) **йәкү, йигү,** кр.-тат. *йäкү* «үгез камыты, боендырык» вариантлары бу сүзне гот. *juk*, ним. *Joch* ~ рус. *иго* һ.б. «боендырык» сүзе белән чагыштырырга мөмкинлек бирә.

Икенче яктан, *җик-* < *җэк-* сүзен чув. *çак-* < **җäк-* «асу, асып кую; йөк асу» белән чагыштыру юнәлешендә тикшереп карарга да мөмкин. ЭСТЯ IV: 172.

Дерив.: **җигем, җигемлек** «сбруй», **җикке** (ат); **җигел-ү, җиген-ү, җигеш-ү; җиктер-ү.**

**ҖИЛ,** диал., башк. **йĕл** «ветер; невидимый дух» > чув. *çил* ~ к.-калп., к.-балк., кырг. *җел,* чыгт., уйг., кр.-тат., бор. төрки *jel, jäl* «җил; явыз рух». Кайбер төрки телләрдә бу сирәк очрый яисә бөтенләй юк, мәс., «җил» мәгъ. төр. *rüzgâr* (фар.), үзб. *шамол* (гар.) сүзләре кулланыла. К. ш. ук ДТС: 254–255.

Безнеңчә, *җил* < *җэл, җәл* образлы-имитатив *йәл//йал//чал//сал//тал* тамырыннан; бу тамыр кискен, җитез хәрәкәт һәм яктыртылышларны белдерә (*җил-җил атлау, җилт-җилт хәрәкәтләнү, җәлт кенә карап алу* һ.б.), к. **Җил-ү, Җиләс, Җилбәзәк, Җилбегән, Җилгәр-ү, Җилдәк, Җилкән,**

**Җилкен-ү, Җилле, Җилмая, Җилпәзә, Җилпе-ү, Җилсен-ү, Җилтерә-ү, Җилфердә-ү** һ.б.

Дерив.: **җилле, җилсез; җиллә-ү, җиллэт-ү; җиллән-ү** һ.б. Тат. диал., башк. **елтә-ү, елтәкәй, елтән, елтәнләү, елтелдә-ү** «уйламыйча йөрү (йөрүче)» һ.б. Моның ише сүзләр бүтән төрки телләрдә дә күп.

**ҖИЛА** диал. «место сбора душ умерших; рай» (к. Мордва-каратаи: 44) – «место пребывания душ умерших детей до Судного дня» ~ алт. *чула* id., чаг. уйг., бор. төрки (ДТС: 278) *jala, julqa* «факел, чырак; яктылык, нур», к.-балк. *джула* «ярадан эренне чыгару өчен кулланыла торган көпшә», ком. *юла* «мылтык көпшәсе; тампон» ~ монг. *җула*, *зул, зула, зулу* «яктылык, шәм» < кыт. *чжу ла* «балавыз шәм; яктырткыч», к. ССТМЯ I: 272.

Икенче яктан к. һинд-евр. **uel* «мәрхүмнәрнең яшәгән урыны – киң көтүлек», хетт. *uellu* id., тохар. *walu* «мәрхүм җан», бор. герм. *Вальгалла* «җила», бор. грек. *Ἠλύσιον* «Елисей оҗмахы (Елисей болыннары)»; «җила». Татарча вариант хетт вариантына бик якын, ләкин тарихи-хронологик аралар бик ерак! Чаг. ш. ук чув. (Федотов I: 106) *вăлă, выла* «сугышта үлгән кешенең рухы» (?), ләкин *вăлăра вырчан ырасем* «вылыда яткан изгеләр (арулар)» тәгъбирендә *вăлă* – урын атамасы.

**ҖИЛӘГӘЙ** диал. «рубашка без рукавов» к. **Җилбәгәй.**

**ҖИЛӘК,** диал. **йеләк, эләк** «ягода» ~ башк. *йеләк,* к.-калп., к.-балк., кырг. *җелек*, к.-калп. *җидек*, төр. *çilek, çiğlek,* төркм. *чигелек,* аз. *җийәләк*, алт. диал. *йиглэк, йигläк*, алт. *дьестек* > чув. *честек*, шор. *честек* «җиләк, җир җиләге» ~ чув. *çырла* < **җирләк* ~ венг. *szöllö* «виноград». Бу сүзләрнең тамырдашлыгы бик ихтимал булган хәлдә, фонетик һәм морфологик җәһәтләрдән этимоны бик үк ачык түгел; Н. Поппе буенча, бор. форма *jigdlak* (Poppe 1960: 28), чаг. бор. монг. *ǯegde, ǯigde* «җир җиләге» ~ төрки *җигдә* > *җийдә* «тут җиләге», к. **Җидә.** Тунг. телләрендә *ǯиксинэ* «кара җиләк», *ǯиктэ* «җиләк, мүк җиләге» һ.б.ш. (ССТМЯ I: 256). Кайбер тикшеренүчеләр **чия** сүзен дә бу рәттә карыйлар.

Дерив.: **җиләкле, җиләксез; җиләклек, җиләкче, җиләкчелек; җиләклән-ү.**

**ҖИЛӘН I,** диал., башк. **йелән** «летнее пальто, суконная поддёвка; женский халат» > чув. *илан, йĕлен,* мар. *елан*, удм. *йәҥэлан* ~ гом. кыпчак. *җәлэн, жэлэҥ,* нуг. *елеҥ,* каз. *желеҥ* id., себ. тат. **елеҥ** *[йеләҥ]* «җиңелчә киелгән», К. Насыйри буенча (ЛТ I: 140), фар. *йäлäн* «пәрдә» – «башта бер тукыма исеме». Ләкин фар. сүзе үзе төрки телләрдән булса кирәк, к. бор. монг. *degelei* > маньч. *дэхэлэн* һ.б. «җилән» (ССТМЯ I: 231), к. ш. ук кет телендә *елен* «шаман җиләне», алт. диал. *т'элэн* ~ эвенк., як. *сэлэн* «җилән». Татарларда җилән руханилар киеме булып исәпләнгән һәм бу, күрәсең, бор. шаманчылыктан ук килә. К. **Җилбәгәй.** Федотов I: 194; ЭСТЯ IV: 178–179 (кар., госм., төркм. *йелек, йäлäк*, кырг. *җелек*, каз., к.-калп. *желек* «жилет» сүзе белән бергә карала). К. **Тигәләй.**

**ҖИЛӘН II** (**йегет-җилән** дигәндә) «молодёжь» ← фар. *йäлāн* «егетләр» ← *йäл* «егет».

**ҖИЛӘС,** диал. **җиләз,** диал., башк. **йелес** «прохладный; освежающий, слегка ветреный» > мар. *елаз, елäз, желäз* id. ~ госм. *җилäз* id.; *җил* < *йэл* сүзеннән бор. ясалма (гомумән, ясалышы ачык түгел).

Дерив.: **җиләслек; җиләслән-ү.**

**ҖИЛӘҮ [җиләw]** (XVII г. шагыйрьләре теленнән) «уздцы, поводья (у кавалеристов)» ~ чыгт. (Будагов I: 449–450) *җилау,* аз., төр. *cılav,* фар. *желоу* id. бор. төрки (ДТС: 278) *jular* «йөгән, тезген» белән бердәй булса кирәк, к. калм. *dźolā,* монг. *ǯulγγa* һ.б. «йөгән, тезген». Чаг. **Җиле.** Sumer 1983: 98–99; ЭСТЯ IV: 41–42. Рус. *жол* «терлекне казыкка бәйләү өчен бау» < салар., монг. *ǯulγγa* «җиләү» тур. Аникин: 207.

**ҖИЛӘ-Ү** «приедаться *кому что*» ~ башк. *йелә*- id. бор. *йэг-лә-* «нәфрәт алу» (к. **Җик**) сүзеннән булса кирәк; к. *җиксен-ү,* диал. *җилек-ү* < *җиклек-ү* id. Чаг. ш. ук ком. *елик-*, к.-калп. *желик-* «ачуланып ярсу», эвен. (ССТМЯ: II: 990–991) *һил-* < *сила-* «азаплану» ~ як. *сылаа* «ару-талу», *сылай-* «ару; җиләү».

**ҖИЛБӘГӘЙ,** диал. **җилбегәй,** диал., башк. **йелбәгәй** «нараспашку; внакидку» ~ к.-калп. *җелбигей,* каз. *желбегей*, ком. *елбегей*, к.-балк. *җелпегей,* үзб. диал. (ЎХШЛ: 131) *йелвәгәй* id. Шул ук мәгънәдәрәк чув. (< тат.) *елехей* «җилбәгәй», кырг. *желегей* «җилбәгәй; җиңсез күлмәк», к. ш. ук як. (Пекарский: 686) *дäлбäгäi* «җилбәгәй», тув. *делбигер, далбыгар, далбагар*, бур. *дэльбэгэр* «тырпа, тарау, тузгыган», *далбагар, далбагай* «киң, җәенке, тарау, җилбәгәй», к. ш. ук каз. *жалбағай, желбегей* «киң колакчынлы постау башлык» (Аманжолов 376–378), «җәйге баш киеме» (ҚТДС: 119).

Сүзнең тамыры *жэли, жэлбэ* «бәйләвеч» (к. **Җиле**), шуннан монг. *жэлбэ-гүй* «бәйләвечсез (төймәсез)» сүзе ясала, шуннан *җиләгәй, җилбәгәй* килә. Бу сүзгә монг. *далба//дэлбэ* «җилфердәп торган; тузгын» һәм җил сүзләре контаминацион тәэсир ясаган, бу сүз үзе исә *дэл//дэлб* «җил, талпыну һ.б.» тамырыннан, к. **Җил.** ЭСТЯ IV: 177–178 (аңлатма безнекенчә түгел).

**ҖИЛБӘЗӘК,** диал. **җилбезәк** «увлекающийся; легкомысленный; попрыгунья», себ. (ЗДС: 188) **йелбәзәк** «ялтырка, ялтыравыклар» – бу формада тат. (> башк. *йелбәҙәк*) телендә генә; **җилбәзәк,** ихтимал, фар. *җилвәбазӓк* id. сүзеннәндер, ләкин бу (бик мөмкин булган) сүз без караган сүзлекләрдән табылмады, к. фар. > төр. *җилвэбаз (җилвэкар, җилвесаз)* «җилбәзәк, кыланчык гүзәл» < *җилвә* «чибәрләрчә кыланыш, кыланчыклык; үзенә җәлеп итү». К. **Җилбердәк** һәм **Җилвә.** К. ш. ук **Җилпәзә.**

**ҖИЛБЕГӘН,** диал. (Тумашева 1992: 77) **йелбегән** «злой дух, Баба-Яга; людоед» ~ алт. *дьелбеген, йӓлбӓгӓн* > хак. *чилбiгэн*, тув. *чылбыга* «күпбашлы явыз рух», бор. төрки (ДТС: 254) *jel bükü* «аждаһа» сүзеннән килсәләр кирәк. К. **Илбис.** К.-балк. *эмеген* (к. Нарты. М., 1994: 37–38) «убырлы карчык» һ.б. сүзендә монг., алт. *эмеген* «карчык» сүзенең тәэсире сизелә. К. Катанов (Алфавитный указатель): 80–81.

Җилбегәннәр тур. әдәбият бик ишле (к. Алтай кеп-куучындар II, 2: 75–78). Räsänen 1969: 196.

**ҖИЛБЕРДӘК, йилбердәк, йелберцәк** (ЗДС: 188, 246) диал. «блестки; яркие тесьмы», **йелбәрцәк** «гребень у петуха» – элекке бизәнү әйберләре. Әлбәттә, **җилп** тәкълиди тамырыннан ясалмалар. Чаг. кр.-тат. (Dobr. I: 423–425) *celbĭremek, celpĭremek* «җилдә җилфердәү», каз. *желбiр, желбiршек* «бөрмә, әбүркә» һ.б. күп сүзләр.

**ҖИЛВӘ [җилwә]** иск. «обольщение; лесть», (ГТРС: 767) *җӓлвӓ* «ялтырау, ялтырак; көязлек; кыланчыклык; йөз күрсәтү (кәләш тур.)» диелә. Әмма к. бор. төрки *jelvi*, уйг. *йәлви, йилви* «сихерләү, арбау», алт. *jилбү* «кызык», хак. *чэлбэ-* «ырымлау», монг. *җэлбэ* «хәйлә, алдашу, тылсым» (Räsänen 1969: 196) бу сүзнең нәкъ гарәпчә булуына шикләнергә мәҗбүр итәләр.

**ҖИЛГӘР-Ү,** диал., башк. **йелгәр-ү** «веять, провеивать» > каз. диал. (ҚТДС: 120) *желгер-* id. бик урынлы рәвештә тат. диал. *җилгә бәр-ү* сүзеннән дип аңлатыла (Л. Җәләй һ.б.); әмма *су-гару* шикелле *җил-гәрү* дә булырга мөмкин. Һәрхәлдә бу сүз тат. (> башк.) даирәсендә генә актив кулланыла.

**ҖИЛД** «том» < гар. *җилд* «том; тире тышлык; тире» сүзеннән.

**ҖИЛДӘК,** диал., башк. **йелдәк, йелтәк** «анемона, ветреница; вейник», себ. (Будагов I: 363) *iелтеке* «тупса, флюгер», төр., алт. диал. *йӓлтӓк* «җилфердәк» (к. Радлов III: 354). Башкортстан территориясендә *Җилдәк* ~ *Йелдәк* дигән берничә торак (XVIII г. кальга) атамасы билгеле; Рабгузида (Радлов III: 354) *йӓлтӓк* «тынычсыз» ~ хак. *чилдек, силдек* «тиктормас, тырпа». Шул исемдәге кабиләкавем атамалары да очрый; кырг. *җелдек* «ялак (жилет); кечкенә байрак, ялау» бу сүзне **җиле** сүзе белән багларга да урын калдыра. К. **Җилтәгә.**

**ҖИЛЕ** «петля; узел; привязь, кольцо для привязывания двух и более голов скота; верёвка или кольцо, связывающие верхние концы кольев шалаша», себ. (Тумашева 1992: 78), башк. **йеле** «аркан, канат, натянутый через реку (для парома; для того, чтобы держаться при переходе вброд, а также для прицепления лесок ряда удочек)», «нитка перебора при тканье», «ряд петель на одном канате» и т.п. ~ к.-калп. *желе*, кырг. *җеле,* алт. *дьеле,* хак. *чиле*, тув. *челе*, як. *сэлэ* ~ монг. *зэл*, *зэлэ* (аерым мәгъ. үзенчәлекләре белән) «җиле». Мар. *сила* «җиле» < чув. *çилĕ* id. < тат. (Федотов II: 117). К. ш. ук төркм. (ТДГДС: 85) *җелле; җеллә* «ятьмә, тозак (ат кылыннан үрелә)», төр. *çile* «кереш, җиле». Будагов I: 440.

Дериват: **җилесез** «дуамал».

**ҖИЛЕК, җелек,** диал. (Зимасов: 32) **җөлөк,** диал., башк. **йелек** «костный мозг» ~ к.-калп., кырг., к.-балк. *җилик,* каз. *желiк*, уйг., үзб., кар., госм., чыгт. *илик, йилик* «җилек; җилекле сөяк», алт. *дьилик*, тув. *чилиг,* як. *силии* «җилек»; шул ук мәгъ. тат. диал. *йөлөн*, себ. тат., алт. диал, каз., чыгт. *йүлүн,* алт. *дьүлүң* «арка мие»; төркм. *йүлүк*, алт. *дьүлүк* «җилек» ~ бор. монг. *җилуга* id. Сүзнең тамыры **йүй* «эчке май, җилек; җилек чыгару» булса кирәк, к. **Йөле-ү.** ЭСТЯ IV: 265–266.

Дерив.: **җилекле, җилексез.**

**ҖИЛЕМ I,** диал., башк. **йелем** «клей» ~ чув. *çилĕм* > мар. *сильым*, к.-калп., к.-балк., кырг. *җе-*

*лим*, уйг., чыгт., төр., бор. төрки һ.б. *jelim, jelem* «балык тәңкәсеннән ясалган җилем», к. ш. ук як. *силим*, фар. *йäлäм*, *шилим*, монг. *жилий* (төрки телләрдән булса кирәк). Чаг. себ. (Тумашева 1992: 248) *чылым* «балык тәңкәсе», монг. *ǯilsun* «җилем» һ.б. ЭСТЯ IV: 179–180; Тимергалин: 169 (интернациональ сүз түгелме икән, дип карый).

Чаг. ш. ук эвенк. *дэлкин*, бор. монг. *deligin* «талак; җилем» (ССТМЯ I: 233). К. **Җилен.**

**ҖИЛЕМ II** – река Зилим (русча атамасы татарчадан килә). Башк. *Еҙем [йĕҙĕм]* дип атала һәм бу атама фонетик җәһәттән тат. атамасына тәңгәлләшеп бетми: интервокаль *-л-* ~ *-ҙ-* фонетик корреспонденциясе юк бугай.

**Җилем** төрки сүзгә бик охшаш, ләкин (бүтән елга атамалары кебек үк) аңлатуга авыр. Чаг чув. *çилĕм* «җылым» < тат. диал. **җилем* id. Бу башлангыч фаразга гына ярый торган мәгълүмат.

**ҖИЛЕН,** диал. **җилем, йелен** «вымя; набухшая матка» ~ башк. *йелен,* чув. *çилĕ* ~ к.-калп., к.-балк., кырг. *җелин*, каз. *желiн*, нуг., ком., уйг., бор. төрки, үзб., төркм. *йелин*, алт. *дьели*, хак. *чилин*, як. *силин, сирин* ~ бор. монг. *deleng*, бур. *дэлэнг,* маньч. *делен* «җилен»; бор. **йэл, д'эл* тамырыннан, к. алт. *дьелде-* < **йэл-лэ* «җилен башлау», себ. тат. (Тумашева 1992: 236) *цәл* < **җәл* «соңгылык; эчке җилен». ЭСТЯ IV: 180–181 (аңлатма икенче төрлерәк).

Гомумән, *җилен* һәм *җилем* түбәндә тамырдаш һәм **йэл-* «аналык» яки «балык уылдыгы» (*җилем* шуннан да ясалган) сүзеннән булса кирәк.

Дерив.: **җиленле, җиленсез; җиленләү.**

**ҖИЛКӘ,** диал., башк. **йелкә** «затылок, задняя часть шеи; загривок» ~ к.-калп., к.-балк., кырг. *җелке*, нуг. *елке,* чыгт., уйг. *йәлкә* «җилкә», аз. диал. (АДДЛ: 244) *јелкә* «хатын-кыз чәче; ял», чув. *çилке, çилхе, çилĕх* (к. Сергеев 1971: 115) «ял», як. *силгэ* «ял асты сеңере, сеңер», төр. *yele*, гаг. *елä* «ял; атның маңгай чәче»; тув. *чел* «ял, маңгай ялы» > рус. *чёл* (*чёлка*). Шулай итеп *җилкә ~ ял* мәгъ. күчеше төрки телләрдә киң таралган һәм беренче мәгъ. «ат ялы» булса кирәк, (чаг. рус. *грива* «ял, җилкә чәче; муен, муенса, гәрәбә»). К. **Ял I** яки **II.**

Себ. (Тумашева 1992: 78, 81) **йелткә, йилткә, йерткә** «арка, җилкә; буынтык» сүзенең җилкәгә мөнәсәбәте ачык түгел.

**ҖИЛКӘН,** диал. **йелкән** «парус» ~ башк. *йелкән*, каз. *желкен*, нуг., кар., ком., төр., төркм., гаг., аз., уйг. *йэлкэн, йәлкән* id., тәүдә **йэлкәл* булган (*-кал// -кәл* һәртөрле әйбер атамалары ясагыч кушымча), каз. диал. (Аманжолов: 378) *желқом* «җилкән» аңлашылмый. ЭСТЯ IV: 181 (этимология анда бернәкечә түгел). Һәрхәлдә *җил* белән баглы.

**ҖИЛКЕН-Ү,** диал., башк. **йелкен-** «порываться (без оснований)» > мар. *елкын-*, *җелкын-* «котырыну; ахмаклану» ~ кырг. *желкин-* id.; к. ш. ук *күңел* **җилкет-ү** < бор. төрки (ДТС: 316) *köŋöl jelkit-*, *jelküt-*, (КБ) *jelgüt-* «дәртләндерү, ымсындыру», *jelgür-* «канат кагу»; бор. төрки *jelkin* «йөгерүче; сәяхәтче» һ.б. Бу сүзләр, Идел-Урал даирәсеннән тыш, төрки телләрдә сирәк кулланыла. Төп фигыль – **җилке-* сүзлекләрдә теркәлмәгән. Әлбәттә **җил** сүзеннән.

Дерив.: **җилкенчек, йелкенчәк** (> мар. *йелкынчык, йелкынчак*).

**ҖИЛКУАР** «ветрогон», диал. (ЗДС: 246) **йелғывыҡ** «ветреный (человек)» – күп кенә төрки телләрдә бар. Тат. сүзе рус. *ветрогон* сүзеннән калька булырга мөмкин. К. ш. ук төр. *jelkovan* «сәгатьнең минутсекунд угы; җилтәгә; диңгездәге давыл кошы».

**ҖИЛЛӘ-Ү,** диал., башк. **йеллә-** «проветриться; веять (о ветре); сушиться (на ветру)» > мар. *елла-* id. < гом. төрки *йэллэ-* id. Бу фигыльнең кайт. юн. **җиллән-ү** «ахмакларча дәртләнү» **җил** сүзенең «җен; җенлелек» мәгънәсеннән.

**ҖИЛЛЕ,** диал., башк. **йелле** «ветреный; замечательный, молодецкий», диал. «помешаный» > мар. *җиллĕ, еллы* id., гом. төрки характерда, к. аз. диал. (АДДЛ: 244–245) *јелли* «тиз генә; ярсулы; ревматизм»; чаг. чув. *çиллĕ, çилĕллĕ* «ярсулы, ачучан, кызу». Чаг. **Җиллә-ү.**

**ҖИЛМАЯ [җилмайа]** «чудесный конь; конёк-горбунок» ~ башк. *йелмайа,* к.-калп., кырг. *җелмайа*, үзб., нуг., төркм. *елмая [йэлмайа]* «тиз йөрешле, чапкыр дөя; әкияти канатлы дөя», *җил* < *җэл, йэл* һәм үзб., каз., төркм. (Радлов IV: 81, 2012) *майа* «ана дөя; бер өркәчле һәм ике өркәчле дөя кушылгагы». **Җилмайа** сүзенең атка күчерелүе дөясез якларда пәйда булган. *Майа* «токымлы ана дөя» тур. Будагов II: 203.

**ҖИЛПӘВЕЧ [җилпәwĕч]** «веер, опахало» ~ башк. *йелпәүес, йелпеүес*, нуг. *елпивиш*, ком. *елпивич* [*йэлпиwич*], к.-калп. *желпитиш*, бор. уйг. *yelbügič,*

*yelpügüč* id.(Поппе 1938: 390). Тат. телендә фонетик үзгәреш: *ү* > *әү* (мондый үзгәреш еш кына очрый, к. **шүлегән** > **шәүлегән**). К. **Җилпе-ү.**

**ҖИЛПӘЗӘ** «веер» < госм. *йäлпäзä* < чыгт. *йäл-пезä* парлы сүз: төркичә *йэл, йäл* «җил» + фар. *бадзан, базбезäн* «җилпәзә» (*бад* «җил», *зан* «бәргеч» – *задан* «бәрү» фигыленең нигезе). К. Räsänen 1969: 195. Каз. *желбезек* «саңак» икенчел, күч. мәгънә.

**ҖИЛПЕК** диал. «дух, превращающий видимое в невидимое (и уносящий его)» к. бор. төрки *jelpik* «эпидемия рухы» (ДТС: 255). К. ш. ук алт. *дьелбү* «рух».

**ҖИЛПЕ-Ү,** диал., башк. **йелпе-** «веять, повеять (один раз)» ~ к.-калп., к.-балк., кырг. *җелпи-* [*җэлпи-*], нуг., кар. *йэлпи-*, алт. *дьелби-*, тув. *челби-* «җилпү, җилгәрү», бур. *дэлби-* «канат җилпү, талпу» һ.б. *йэл* ~ *дэл* «җил» тамырыннан, аның фигыль мәгънәсеннән. ЭСТЯ IV: 182–183.

**ҖИЛПУЧ** «ночёвка» – бу сүзнең икенче иҗегендә арткы рәт сузыгы -*у*- булу аның төптә кушма сүз булганлыгын күрсәтә, ихтимал, **җилпү уч**? Яки *җил пуст* (диал. *пуст* «каткан тире, тире ашъяулык» < фар. *пуст* «тире»): күчмә тормышта ашлыкны *пуст* өстендә чистартканнар.

**ҖИЛСЕН-Ү** «заболеть от сквозняка», **җилсет-ү** «навеять болезнь (о сквозняке)» – **җилсе-ү* фигыленнән, ләкин бу фигыль теркәлмәгән.

**ҖИЛТӘГӘ, йелтәгә** (Будагов I: 363; Тумашева 1992: 75) «флюгер» < *җилтәгәр* id., к. **Тәгәр.**

**ҖИЛТЕРӘ-Ү,** диал., башк. **йелтерә-ү** «вращаться на ветру (о флюгере)», күч. «легко двигаться, порхать» – төрки сүз моделе буенча *җил*// *җилт*//*җәлт* тамырыннан ясалган (чаг. *калтыра-, мөлдерә-, пылтыра-, челтерә-, шылтыра-* һ.б.).

**ҖИЛ-Ү,** диал., башк. **йел-ү** «мчаться (как ветер)» < гом. төрки, бор. төрки *jel-* (ДТС: 254) id. Шуннан йөкл. юн. формасы *җилдер-ү* < бор. төрки *jeldir-* «атта чабу (> машинада тиз бару)» төп фигыльдән киңрәк кулланыла. К. **Җил.**

**ҖИЛФЕРДӘ-Ү,** диал. **җилпердә-ү, җилбердә-ү,** диал., башк. **йелфердә-, йелпердә-, йелпелдә-** һ.б. «развеваться (на ветру)» – **җилфер (җилбер, җилпер)** тәкълиди сүзеннән, бу сүз исә *жилп* нигезеннән. К. к.-калп., к.-балк., кырг. *җелбире-, җелпилде-*, алт. диал. *jälбирä-* ~ як. *сäлiбiрä-* «җилфердәү» (Пекарский: 2624).

Дерив.: **җилфердәш-ү, җилфердәт-ү; җилфердәк.**

**ҖИМ** «корм; приманка (для животных)» ~ башк. *йем* id. > мар. *ем*, удм. *җем* id. < гом. төрки (барлык телләрдә закончалыклы фонетик вариантларда) < бор. төрки *jem* (к. ДТС: 255), *je-* «җию, ашау» сүзеннән. К. **Җи-ү.**

**ҖИМАЙ,** диал. (ТТДС I: 484) **чима, чимай** «лекало», (Троянский I: 414) «резец; резьба», себ. (Тумашева 1992: 239) **цимәй** «сызылган бизәк» ~ башк. *сымай* id., кар. *цэмэ-* «онаш өстенә бизәк төшерү», каз. *шымай* «аркылы-торкылы сызыклар» < кыт. *цзы ма* «иероглиф шаблоны», к. **Чый-у. Җимай** сүзе, шулай итеп, кытайларның икмәк, күмәч өстенә бәхет теләп иероглифлар язу гадәте төркиләрдә дә булганлыгын күрсәтә.

**ҖИМЕР-Ү,** диал., башк. **йемер-ү** «рушить, разрушить» ~ чув. *çĕмĕр-*, к.-калп., к.-балк., кырг. *җемир-*, нуг., ком. һ.б. *йэмир-*, алт. *дьемир-*, хак. *чемир-* «җимерү, умыру», чыгт. *йүмүр-*, бор. төрки (ДТС: 256) *jemür-* (> мар. *сӱмыр-*) «җимереп төшерү; тамыры белән чыгару», к. төр. диал. *çim-* «суга җимереп төшерү яки төшерелү» (Redhouse: 255); тув. *чемдий* «яньчелү», *чемир-* «яньчү, умырып төшерү»; күренгәнчә, *җимер-* < *йэмир-* < **йэмгир-* «җимерү» **йэм-* фигыленең йөкл. юн. Räsänen 1969: 197; Будагов II: 365; ЭСТЯ IV: 183–184.

Дерив.: **җимерел-ү, җимерен-ү; җимереш-ү, җимерт-ү; җимерек.**

**ҖИМЕШ,** диал., башк. **йемеш** «плоды, ягоды, фрукты» > мар., удм. *емыш, емыж* id. чув. *çимĕç* ~ к.-калп., к.-балк., кырг. *җемиш*, нуг., ком., чыгт., госм., бор. төрки *jemiš* ~ монг. *жэмиш*, тув. *чемиш*, алт. *дьемиш*, хак. *немис, нимiс* һ.б. (Räsänen 1969: 197) «җимеш, ашамлык», бор. **җүймүлч* id. (> венг. *gyümölcs* id.); **җий-ү** белән бәйлылыгы шиксез, әмма ясалышы ачык түгел, *җи-меш* кебегрәк дип аңлату канәгатьләндерми. К. **Җим, Җимшән, Җимшә-ү, Зим.** ЭСТЯ IV: 165; Федотов II: 115.

Дерив.: **җимешле, җимешсез; җимешлек; җимешлән-ү.**

**ҖИМТЕК** «остатки от еды, стола (животных); дополнительный корм, подкормка» ~ кырг. *жемдык* «җимлек» (*җем* «җим»), үзб. *йемтик* «ашамлык» (ЎХШЛ: 131) *җим* сүзе *җи-* < *йә-* фигыленнән турыдан-туры ясалган булса **җи-мте-к* < *йәмти-г* формасыннан килә (ягъни **җим** нигезеннән түгел): монда кушымча *-мте* < *-мти* һәм *-к* < *-г*. Чаг. диал. (ЗДС: 72) **ашамтык** «җимтек».

**ҖИМЧӘЧӘК** «завязь цветов (с плодами); праздник летнего солнцестояния, праздник принесения цветов в жертву воде (вместо девушек в языческие времена)» ~ үзб. диал. *йемчачак* id. Бу бәйрәм **байчәчәк** беренче чәчәк бәйрәменнән соң һәм шуның дәвамы буларак үткәрелгән.

**ҖИМШӘН,** диал., башк. **йемшән** «завязь цветка» – **җимшә-ү//йемшә-ү** «җимешләнү, җимешкә әверелә башлау (чәчәк төбе тур.)» сүзеннән булса кирәк. Бор. төрки *jemšen* «кыпчак далаларында бер үлән» (МК, к. ДТС: 256) > рус. *емшан, евшан* «әрем» (Фасмер II: 7, 19), төркм. (ТДГДС: 101) *йемшан* «кызыл чәчәкле үлән төре» тат. **җимшән** сүзенә мәгънәдәш түгел.

**ҖИМШӘ-Ү,** диал., башк. **йемшә-ү** «завязываться в плод (о цветках); превратиться в движущееся существо (об икринках рыб)» ~ тув. *чемзек* «запас», як. *сэмсэ* «артым» һ.б. Сүзнең нигезе *җимеш* < *йәмиш*. Шуның белән бергә, төрки телләрдә *җимсәү* ~ башк. *йемшәү*, кырг. *җемсөө*, к.-калп. *җемсәк* «кош бүксәсе» сүзе дә бар. Бу сүзнең нигезе *җимсә-* < *йәмсә-* «җимне кабул итү».

**ҖИНАЯТЬ [җинайәт]** «преступление» < гар. *җинāйăт* id. *җнй* «җинаять кылу» тамырыннан.

**ҖИНЧЕК,** диал. (ЗДС: 186) **женчек,** ш. ук **җинтчек** «верхняя часть стопы», себ. (ЗДС: 247) **йинцек, йенцек,** чыгт., тат. (Будагов I: 213) *инчук* һ.б. «щиколотка, щиколоточная кость», башк. *енсек* [*йенсек*] «голень», үзб. диал. (ЎХШЛ: 116) *инҗик* «локтевая кость» ~ кар. *инчик, инцик, инъчык*, төр. *encik, incik* «сыйрак», «балтыр; бот сөяге» – сүзнең борынгырак варианты себ. (Тумашева 1992: 81) **йилиндзик** «балтыр» ~ кырг. *жилинчик* «сыйракның аскы өлеше», к.-калп. *жилиншик, жилик* «сыйрак сөяге», алт. (Баскаков 1972: 213) *дьегинчек* < *йәлгинчäк* «үкчә» һ.б.; *-чик* > *-чек* кечерәйтү аффиксы, нигезе *йәлгин,* тамыры ачык түгел.

Рус. диал. *инчики* «итек кунычын тыгызлагыч каеш» < тув. *инчик* «чалбар каешы» ~ төркм. *инҗик* «балтыр ите», себ. **йинцә,** *инци* «уылдык, балык корсагы» арытабан манси *нись*, фин. *niiska* «уылдык» белән чагыштырыла (*балтыр ~ уылдыклы корсак* мәгънә рус. *икра* сүзендә дә күзәтелә), ләкин бу чагыштыру (Аникин: 222) дөрес түгел. Бор. **йилинчик* сүзен *җилен* белән чагыштыру дөресрәк.

**ҖИҢ,** диал., башк. **йең** «рукав» < гом. төрки (закончалыклы фонетик үзгәрешләр белән), бор. төрки *jeŋ, jäŋ* id. (к. Räsänen 1969: 197) ~ тув. диал. *нең, нәң*, хак. *ниң* һәм чув. *çанă, çавнă* < **җәүне* id.; к. ш. ук алт. диал. *йää*, як. *сиэх* < *йәңәк* «җиң; итәк», аз. *җийин, чийин* «иң, иңсә». Тат. диал. (Радлов III: 512) *jiңнä-* ~ алт. (Баскаков 1965: 86; 1972: 211) *дьеңде-* «җиңү» «бор. гадәт буенча, әсирләрнең җиңнәрен артка бәйләү» сүзе, **җиң** һәм **җиң-ү** сүзләре гомоген түгелме, дигән фикергә этәрә. ЭСТЯ IV: 186–187; Федотов II: 84.

Дерив.: **җиңле, җиңсез; җиңлек;** к. **Җиңсә.**

**ҖИҢГӘ, җиңги < җиңгәй,** диал. (ЗДС: 212, 242, 247–248, 255 һ.б.) **иңкә, йәңә, йеңкә, йеңкәү, йөңөү** һ.б. (гомумән, тат. сөйләшләрендә бу сүзнең егермедән артык фонетик һәм морфологик варианты билгеле, бүтән төрки телләрдә дә аз түгелдер) «жена старшего брата, брата отца и т.п.; любая женщина из другой деревни (старше говорящего); сводница жениха и невесты на свадьбе и т.п.» > мар. *еңга, еңгой, инга,* чув. *йĕнке, инке* < башк. *йеңгә*, к.-калп., к.-балк., кырг. *җенге*, уйг., чыгт., бор. төрки *jeŋge, jäŋgä* (Räsänen 1969: 198; Покровская: 65–66; Рамазанова 1991: 126), к. ш. ук хак. *негä, ниге*, шор. *нäңä*, венг. *angy* «җиңгә, килен», үзб. диал., төркм. *йеңңә* «килен».

**Җиңгә** < *җәңгә, җәңгә,* мөгаен, *жизнә* < *жәңәзнә* (к. **Җизнә**) сүзе белән бер модельдә ясалган сүз: *йәңшә* < ** йәң экә* «чит кавемнән килгән апа» (бор. төрки, тибет. *еке, екä* «апа», к. **Игәч**), *йәңәзнә* < **йәң эрнәк* «чит кавемнән килгән егет» (бор. *эрнәк* «егет», к. **Иргәел**), **йәң* «безнең белән дуаль кардәшлек мөнәсәбәтләрендә торган күрше кабилә һәм аның бер кешесе». К. **Җизнә.**

**Йәң** элементы *җиян* < *йәңинә* «чит кавемдәге эне» сүзендә дә бар булса кирәк, к. **Җиян.**

**Җизнә** һәм **җиңгә** төшенчәләре һәм аерым сүзләре күп телләрдә юк, шунлыктан алар еш кына төрки телләрдән алыналар: төрки телләрдә бу төшенчәлекләр, ихтимал, кыт. теле тәэсирендә барлыкка килгәндер – Кытайда алар бар һәм к. маньч.,

бор. монг. *jen* [*йән*] «бор. Кытай (Инь династиясе)», кыт. «тау арты» (шуннан ук *инь-ян* хатынлыкирлек символы булган түгәрәк фигура).

Ул чагында *йәнгә* «кытайлы (тау арты) апа», *йәзнә* «кытайлы (тау арты) абый». Бор. төркиләр (бигрәк тә югары катлам кешеләре) белән кытайларның килен алышып-кыз бирешеп йөргәнлеге билгеле. Кардәшлек мөнәсәбәтләренә караган терминологиядә югаргы катлам мөнәсәбәтләре үрнәк! Аннары, мәгълүм ки, *җизнә* һәм бигрәк тә *җиңгә* культуртрегерлык функцияләренә ия: алар үзгә кеше туйларында да оештыручы өйрәтүче-церемонимейстер булып йөриләр. Бу да мәдәни күршеләрдән килгән кешеләргә хас. Шунысы кызык, үзендә кайбер чал борынгылыклар сакланган чув. телендә төп оригиналь **җизнә** һәм **җиңгә** сүзләретөшенчәлекләре юк (*йысна* һәм *инке, йенке* < тат.). Димәк бу сүзләр гомумән чагыштырмача яңарак. Чаг. **Җыракай.** ЭСТЯ IV: 189–190; Федотов I: 169.

**ҖИҢЕЛ,** диал., башк. **йеңел** «легкий» ~ к.-калп., к.-балк., кырг. *җеңил*, кар., ком., чыгт., алт., төркм. *йәңил, дьенгил*, уйг. *йиңил*, төр. *yüпül,* бор. чыгт., куман. *йүңүл, jöңүл, jүгүл* (Боровков 1963: 162–164) бор. төрки (ДТС: 256) *jenik* id. *jeni-* «җиңеләю» сүзеннән; этимон *йеникkил* > *йенккил* яңгырашында булган (*-кыл*//*-кил* > *-кел* бор. сыйфат ясагыч кушымча); тат. сөйл. телендә *җиңгел* дип әйтү очраклы түгел.

Бор. төрки, уйг. (Радлов III: 321–330) *jäпi-* «җиңеләю, җиңеләйтү» фигыленең тамыры *jäп* сүзен Рясянен (Räsänen 1969: 198), аз. *йүнкүл,* чыгт. (Будагов II: 386) *йөнгүль* «җиңел» вариантыннан чыгып, гом. төрки *йүн, йүң, йуң* «йон» сүзеннән дип раслый. К. төр. *jegni, jegnik* < *jengik* «җиңел». Чув. *çăмăл* «җиңел» һәм *çăм* «йон» сүзләре дә әлеге фаразга су коя. ЭСТЯ IV: 188–189; Федотов II: 94–95.

Бор. төрки телдә авырлык-җиңеллек төшенчәләре конкрет йөк-әйбер атамасыннан чыгып формалашкан. *Йон (җөн)* товар чагыштырмача җиңел, ә *агы* (ефәк, кыйммәтле таш һ.б.) чагыштырмача авыр булган.

**ҖИҢСӘ** «нарукавник; муфта» – **җиң** сүзеннән: *-са*//*-сә* савыт, тышлык, урын һ.б. атамаларын ясый торган кушымча. **Җиңсә** – диал., башк. *йеңсә,* к.-калп., к.-балк., кырг. *җеңсе* һ.б. гом. төрки сүзләр рәтендә (к. ЭСТЯ IV: 186–187).

**ҖИҢ-Ү,** диал., башк. **йең-ү** «победить», себ. диал. (к. Радлов III: 512) *йиңнә-у* < *йәң-лә-у* ~ алт. диал. (Баскаков 1965: 86; 1972: 211) *дьеңде-* id. сүзнең тамыры исем булганлыгын күрсәтсә кирәк; бор. *йәң* (исем) тамыры белән гом. төрки *йәң* «җиң» (әсирләрнең җиңнәрен бәйләгәннәр) яисә фар. *җәң* (к. **Җәң**) «бәрелеш, зур сугыш» сүзләре чагыштырыла ала. Чаг. ш. ук үзб. диал. (ЎХШЛ: 132) *йең-* «дилбәгә тоту – җигелгән ат белән идарә итү» .

*Йәң* исеме бик иртә фигыльләшкән булса кирәк: кыпч. *җең-*, гом. төрки *йәң-* «җиңү», алт. *дьең-*, чув. *çĕн-, çĕңтер- (<*йәңдә-р-?)* ~ мар. *сең-, сäң-* (< болг. **җәң*) id. Ихтимал, тәүдә *йәңи-* < *йәң-и-* «җиңләү» булгандыр. ЭСТЯ IV: 187–188 (күп кенә фаразлар китерелә).

**ҖИП** «карман в груди» (*түш җип*, к. ТТАС III: 291, *җеп* дип язылган) ~ удм. *зеп*, рус. *зепь, зеп* ~ кар. *джэб, джэп*, хак. *изеп*, як. *сиэп*, аз. *җиб*, төркм. *җүби* һ.б. «кесә», төр. *сер, сеур* «яка ачыклыгы; куен; синус; юл буенда юлаучылар өчен куелган алачык» < гар. *җäйб-үн* «яка ачыклыгы, куен» > иске тат. **җәеб** «яка ачыклыгы, җилән кесәсе; синус» (ГТРС: 772).

Бу сүз Евразиядә киң таралган, к. Добродомов И.Г. Об одном финно-угорском названии кармана // Вопросы советского финно-угроведения. Саранск, 1972: 14–15; Юналеева 1982: 95–96.

**ҖИР I,** диал., башк. **йĕр,** себ. (Тумашева 1992: 58, 75–76) **ир, йәр** «земля; почва; место; участок; постель», «стандартная длина десятины – 80 саженей» ~ к.-калп., к.-балк., кырг. *җер [җэр]*, нуг., ком., чыгт., уйг., үзб., төр., төркм. *йәр, йәр*, бор. төрки *jer*, тув. *чер*, як. *сир* һ.б. «җир», чув. *çĕр* id. бик тә күп мәгънәле сүз һәм бу күпмәгънәлек аның этимологиясен билгеләүне читенләштерә. Себ. (Тумашева 1992: 76) *йәрт-ү* «җиргә җәелү» сүзенә караганда, сүзнең фигыль мәгъ. дә булган.

Рясянен гом. төрки *йәр, йир* «җир» сүзен куман. *jertinči*, бор. монг., уйг. *jirtinčü, jirtünčü* (> бур. *юртэмсэ*) «дөнья, галәм, җир-су» < тибет. *ǯig rten* (ДТС: 263) сүзе белән чагыштыра; бу сүз миш. сөйләшләрендә (срг.) да табылды: *йертец, йертпец* «элекке (ташлап киткән) җир, элекке туган як».

**Җир** < *йәр* сүзен эвенк. *jәркэ, jаркэ, н'эркэ* «җир, галәм, учак, урын» сүзе белән дә чагыштыралар, к. Будагов II: 352–353; Räsänen 1969: 198; ССТМЯ I: 355; ЭСТЯ IV: 191–193; Федотов II: 110 (кирәкмәгән юнәлештә эзләнә).

Дерив.: **җирле, җирсез; җирлек; җирсә-ү** (себ. **йәрзә-ү**) «туган җиреңне сагыну».

**ҖИР II** «отвратительный (*җир бит* «мерзкое лицо»)» ~ алт. *дьер* «оят!», төр., бор. төрки *jer-,* як. *сир-* «чиркану». К. **Җилә-ү, Җирән-ү, Җирек-ү, Чиркан-у.** ЭСТЯ IV: 193 (сүзнең фигыль мәгъ. генә китерелә).

**ҖИРӘН** «рыжий» ~ к.-калп., к.-балк. *җирен,* уйг. диал., кырг. *жейрен*, алт. *дьеерен*, төркм., бор. төрки *jegrän* (ДТС: 253), бор. монг. *ǯegeren* «җирән; җәйрән» күп кенә төрки телләрдә дә (кырг., алт.) бу сүз шул ук вакытта **җәйрән**не дә белдерә (*җәйрән*нәр һәрвакыт **җирән** була), ягъни **җирән** һәм **җәйрән** тат. телендә этимологик дублетлар. **Җирән** < *жэгэрэн* сүзенең нигезе *җэгэр*, к. як. *сиэр*, хак. диал. *чегэр, чигĕр, чэгри, чэгрин,* сары уйг. *җигэр, йигэр, йигыр, җигыр* «болан, җор» (к. Räsänen 1969: 194). Чув. *çӳрен* «җирән» < болг. **җәүрән* < *җэгрэн* id. Хәз. монг. *зээрэн* «җәйрән», *зээрд* «җирән».

Сары уйгур вариантларында сингармонизм бозылу (**җиғыр**) бу сүзнең төптә кушма икәнлеген күрсәтә шикелле. Ахметьянов 1989: 78; ЭСТЯ IV: 167; Федотов II: 149–150.

**Җирән** һәм **җәйрән** сүзләре күп күрше телләргә алынганнар. Рус телендәге *игрений, саврасый* һәм *чегравый* дигән ат төсмерләренең нигезләре төрле төрки диалектларыннан килә (*саврас* – нигезе чув. **çаврасси* «җирәне» дигәннән булса кирәк). К. Аникин: 186, 201–202, 213, 218–219 (күп әдәбият күрсәтелә).

**ҖИРӘН-Ү,** миш., себ., башк. **йерән-ү** «гнушаться, брезговать, относиться с омерзением» > чув. *йĕрĕн-, йĕрен-* < уйг., төр., чыгт. (Поппе 1938: 195, 205; Боровков: 154) *jigren-, igren-,* кр.-тат. *игрэн-,* бор. төрки (ДТС: 261) *jigren-* «җирәнү, куркыну, чәчләр үрә тору; чи иттән качу» һ.б. ← тат. диал. (ЗДС: 250) **йигрә-** «шикләнү», бор. чыгт. (Радлов III: 316–318) *jäkrä-* «дошман күрү», бу сүз исә, үз чиратында, бор. монг. (Поппе 1938: 132, 195, 205) *čegür* «җирәнгән хәлдә», *ǯigir* «җирәнү» кебек нигезләрдән ясалган шикелле. Боларның тамыры *җик ~ йэк* «шайтан», себ. (ЗДС: 246) **йек** «җирәнгеч», *йеклəү* «кыерсыту», бор. төрки *ig, jeg* «авыру» һ.б. була ала. Чаг. **Җик, Җиксен-ү.**

Шуның белән бергә, төрки телләрдә к.-калп. *җеркен-, җерген-*, алт. *дьеркäн-* «нәфрәтләнү», як. *сиргэн-* «җирәнү» сүзләренең тамыры бор. төрки (ДТС: 257), госм., төр. *jär-, jer-,* як. *сир-* «җирәнү, эшәкелеккә түзәлмәү» сүзе бар. К. ш. ук монг. *җийрхэ-* «җирәнү; бик тә яратмау», *җийрэ-* «чиркану». Һәм бор. **jegrä-* вә **jergä-* бер үк сүзме икән, дигән сорау туа. К. **Җир II, Җирек-ү, Чиркан-у.** Räsänen 1969: 198; Федотов I: 199.

**ҖИРГӘН, зиргән** – название большого старинного села на юге Башкортостана, а также название тат.-башк. родов – ихтимал, алт. *дьэргэ, черген*, тув. *чэргэ, чэргэн* (*черген*), хак. *сэргэ* һ.б. «ат бәйләү өчен махсус (бизәкле) баганалар теземе» сүзеннәндер. Фольклорда *җиде өяле җиргән агач* тәгъбире бар. К. **Җәргә** һәм бор. төрки (ДТС: 144) *čergä* «чират», *čergaš-* «рәткә, җәргәгә тезелү». Җиргән авылы элекке татар мәгърифәте үзәге булган, анда күренекле татар иганәчесе шагыйрь Дәрдемәнд (С. Рәмиев) туып үскән.

**ҖИРЕК-Ү (җирегү),** диал., башк. **йерек-ү,** себ. **йәрик-ү** «почувствовать отвращение к чемулибо» ~ к.-калп. *зерик-,* кырг. *җерик-, зерик-* id. – *җир-, җире-* «дошман күрү, өнәмәү» фигыленең интенсивлык дәрәҗәсе, к. бор. төрки (МК), госм. *йэр-, йäр-*, бор. чыгт. *йир-*, як. *сир-* «җирәнеп карау», к.-калп., кырг. *җери-*, алт. *дьери-* «кире кагу, яратмау» һ.б. К. **Җир II.** ЭСТЯ IV: 143.

**ҖИРҖИС** < гар. *Җäрҗис* – один из персонажей исламской священной истории. Лингвистик җәһәттән грек. *Георгиос* «изге Георгий (Егорий, Юрий, фр. Жорж)» исеме белән тамырдаш (шуннан төр. *Gürcistan* > тат. *Гөрҗестан,* рус. *Грузия* < лат. *Georgia* һ.б. топонимнар килә). Төрки телләрдәге **Чурас** < *Журиос* (к. **Чураш**) исеме дә шуннан килә дигән фараз бар.

Христианнарда «изге Георгий» дин өчен көрәшүче һәм аждаһаларны җиңүче (МНМ I: 273–275), ә исламда **Җирҗис** («Мөхәммәдия» буенча) бик каршылыклы образ. Кайбер дини әсәрләрдә *Җирҗис, Җәрҗис* пәйгамбәр итеп күрсәтелә. Ул, Хызыр шикелле, хәзер дә кешеләргә ярдәм күрсәтүче зат, имеш.

**ҖИРКЕНДЕК** «провал; глубокое озеро среди болот» < *җир кендеге* сүзеннән (к. БҺҺ II: 90), к. ш. ук каз. *жер кiндiгi*, алт. *дьер киндиги* «тирән сазлык». Бу сүзниндидер мифологемага баглы, к. алт. *«җир кендекле Кара Бөкә әрлик бинең биясе»* диелә.

**ҖИРЛЕ,** диал. (Тумашева 1992: 123–124), башк. **йерле** «то-то, вот почему» – *җир* сүзенең «хокук; урынлылык; булдыклылык» мәгънәсеннән ясалган; к. ш. ук башк. диал. (БҺҺ II: 90) *йерле* «бөтенләй», нуг., кар., ком., уйг. *йэрли* «урынлы; хокуклы, гадел». Чаг. тат. сөйл. *мактаныр җирең юк.*

*Җир* сүзенең «сәбәп, нигез» мәгънәсен алуы фар. *зир* «ас, аслык», «төп, яшерен сәбәп» тәэсирендә булган бугай. К. **Зира.**

**ҖИР-СУ** «земля и вода» < бор. төрки (ДТС: 257; МНМ I: 599) *jer-suv, jer-sub* «җир-су; җир һәм су тәңресе»; бу тәгъбир һуннарда да булганлыгы безнең эрага кадәр ук кыт. елъязмаларында әйтелә. Бүгенге тәлләрдән к. алт. *дьер-су* «җир һәм су рухлары», чув. *çĕршыв* «ил; туган ил» һ.б.

**ҖИСӘ** диал. (Г. Фәезханов) «голень птицы» ~ чув. *чавса* «терсәк, җиңнең аскы өлеше; озынлык үлчәме» < **җәүсә*. Чаг. **Җиңсә.**

**ҖИСЕМ** «тело (в абстрактном значении), плоть, вещество» < гар. *җисм-үн* id. К. ш. ук иске әд. **җисмән, җисмани** (*рухи* сүзенә каршы куеларак), **тәҗәссем** һ.б. гар. телендә *җсм* «зур булу» тамырыннан.

**ҖИСЕР,** диал. **җистер** (**җәтим-җистер** парлы сүзендә) «вдова, выданная замуж за брата умершего мужа по закону левирата», «завоёванная или выигранная в игре жена» ~ кырг. *җесир,* каз. *жесыр* id. Гарәпчәдән булса кирәк. Чаг. *әсир ~ йасир.*

**ҖИТӘК,** диал., башк. **йетәк** «ведение на поводу»; тар. «ведомая на поводу запасная лошадь», себ. (ЗДС: 250) **йидәк** «тезген», к.-калп., к.-балк., кырг. *җетек* id. һәм «йөгән; өстәмә», нуг. *йетәк, йетек*, чыгт., госм., гаг. *jätäk, jädäk* «җитәк, бау; тире савыт, тире алъяпкыч; җитәкләнгән, ияртелгән нәрсә», хак., тув. *чидек, чедек* «йөгән» һ.б. (*йäдäк* төр., фар., гар. һ.б. Шәрык телләрендә «запас ит, резерв; буксир» мәгъ. таралган) башк. ← (БТДҺ:120) *йет-ү*, бор. төрки (МК: 314) *jet-, jät-*, кр.-тат. (Радлов III: 194) *йäтä,* гаг. *еде-* төркм. *иит-* «ат җитәкләү; тарту; сөйрәү яки итәгендә йөртү». Бор. *jät-* фигыленең чув. варианты *çавăт-* < болг. **җәwĕт-* булса, тамыры **җәү ~ *йәw-,* ләкин андый сүз теркәлмәгән. К. **Итәк.** Räsänen 1969: 199; ЭСТЯ IV: 194; İbrahim H. Yedmek fiili üzerine// Türk dili, №489, 1992: 241–246.

Дерив.: **җитәклә-ү; җитәкче** (бу сүз күп телләрдә очрый), шуннан неол. – **җитәкчелек.**

**ҖИТДИ** «серьёзный» ~ башк. *етди* < гар. *җиддӣ* id. *җдд* «әһәмиятле, нәтиҗәле, мәгънәле булу» тамырыннан, шуннан ук *җәдид* «җәдит; яңа, әһәмиятле нәрсә», *мәҗид* «уңышлы, бәхетле» – түбәндә бор. мисырча *гәдә* «яңа уңыш» сүзе ята дигән фикер бар. Дерив. регуляр.

**ҖИТЕЗ,** диал., башк. **йетез** «ловкий, скорый, расторопный, прыткий» > мар. *етыз, җитез* һ.б. (к. Гордеев 1983: 26), удм. *етиз*, чув. *йĕтĕс* id. ~ кар. *йэтиз* «тырыш, уңган, ушлы»; бүтән хәз. төрки телләрдә юк бугай; бор. төрки (Боровков 1963: 152; ДТС: 259) *jetiz* «киң, зур; мул», чаг. ш. ук бор. чыгт., төрк. *itik, jetik* «җитез». Һичшиксез *җит-* < *jet-* фигыленнән, ләкин ясалышы ачык түгел (бор. төрки *jetinč* «барып җитәрлек» сүзе булган, бәлки шуннандыр).

**ҖИТЕМӘК** диал. «сетка с крупными ячейками» ~ як. *ситимэг* «пәрәвез» – *ситим* «нечкә тегәрҗеп»; тув. *четки* «ятьмә; пәрәвез». Бор. **җэт-* тамырыннан, к. **Ятьмә.**

**ҖИТЕН,** диал., башк. **йетен, җинтун** (? к. ЛТ I: 159) «лён» > чув. *йĕтĕн,* мар. *йĕтĕн, итын*, удм. *етин, зэтин* < бор. төрки (ДТС: 264) *jetim, jitim* «киндер орлыгы», *jitin* (Радлов III: 524) «җитен». Бу сүз бүтән хәз. төрки телләрдә күренми, тик Төньяк Кавказ телләрендә калкып чыга: кабарда.-чирк. *чэтэн* «җитен; тукыма» (ә Кавказ төркиләрендә теркәлмәгән!). В.Г. Егоров (1964: 219) бу сүзне гом. төрки *кэтэн* > *китән* (к. **Китән**) сүзеннән болг. телендә килеп чыккан ди (*к-* > *й-*), ләкин бу шикле. Чаг. бор. төрки *jetän, jetäŋ* «җәя; йон теткеч җәя» (МК, к. ДТС: 259) – *җитен* – «җәядә тетеләнә торган сүс»ме? К. ш. ук Федотов I: 203.

Дерив.: **җитенчелек.**

**ҖИТЕН-Ү, йиден-ү** (ЗДС: 250) «достигать» ~ чыгт. *еде-, еден-* «ия булу» ~ тув. *четтин-* «кулдан тоту», *четтир-* «җитәкләү», хак. *чидін* id. Бу сүз **җит-ү** һәм **җитәк** сүзләрен бәйли.

**ҖИТЛЕК-Ү (җитлекте, җитлегү) – җит-ү** сүзенең интенсивлык формасы (к. *ату – атлыгу, йоту – йотлыгу, өзү – өзлегү* һ.б.). **Җитлек** нигезеннән **җитлекле** «вакыты җитеп туган», **җитлексез** «вакытыннан алда туган» диелгән неологизмнар ясалган: **җитлектер-ү** исә электән бар.

**ҖИТМЕШ,** диал., башк. **йетмеш** «семьдесят» ~ к.-калп., к.-балк., кырг. *җетмиш*, уйг., чыгт., төр. һ.б. *йетмиш* id. Себер төрки телләрендә бу сүз юк, аларда 70 – *йэтэн* < *йэтти он* тезмәсеннән килә. Ләкин чув. *çитмĕл*. Безнеңчә, *җитмеш* < *йэтмиш* < **йэтти-м-инч ~ йэтти-м-илч* > чув. *çитмĕл* «җиденче (ун)». Бүтән фаразлар да бар. К. **Алты.** ЭСТЯ IV: 194–195.

Дерив. регуляр.

**ҖИТ-Ү,** диал., башк. **йет-ү** «доходить, достигать; хватать, быть достаточным» > чув. *çит-,* мар. *с'ит-* (чув. һәм мар. телләрендә **җит-ү** сүзенең бөтен сүзьясалыш парадигмасы да кабатлана)» < к.-калп., к.-балк., кырг. *җет- [җэт-]*, куман., чыгт., уйг., бор. төрки *jet-, jät-*, алт. *дьет-*, тув. *чет-*, хак. *чит-*, як. *сит-* id. маньч. *ǯи-*, кор. *чи-, ти-* «билгеле бер хәлгә килү; булу» фигыленең йөкл. юн. формасы дип карала (Рамстедт 1953: 148). Будагов II: 349–350; ЭСТЯ IV: 193–194; Федотов II: 123–124.

Тат. телендә **җит-** фигыле дериватларының күплеге һәм кулланылыш ешлыгы белән аерылып тора: диал. **җитү (кыз)** – инде тормышка чыгарлык; **җитәр; җитәрлек, җитмәслек, җитек ~ йетек** (ЗДС: 190, 149) «тормышчан», **җител-ү** (мәс., *барып җителде*, диелә); **җитенке; җитенкерә-ү, җитен-ү** «баю», **җитеш-ү** (шуннан терминологик **җитештер-ү, җитештерүчән** һ.б.); **җитеш** (шуннан **җитешле, җитешсез**); **җиткән (кыз)** ~ **җиткен; җиткез-ү ~ җиткер-ү** (мәгъ. аерымлану тенденциясе бар); **җиткел; җиткелек (җиткелекле, җиткелексез); җитмәсә** (модаль сүз) һ.б. К. ш. ук **Җитез; Җитлек-ү.** Бу сүзләр үзләре үк продуктив нигезләр. Өстәвенә *җит-* актив модифактор фигыль (*-п* форманты белән кулланыла: *барып җит-, килеп җит-, уйлап җиткер-* һ.б.ш.).

**ҖИҮ** «ртуть» (к. Җантурин: 119) ~ төр. *civa*, фар. *civ, cev* «терекөмеш», иске тат. *җива бирү* «ялтырату, ялтыратып ышку». Чыгышы ачык түгел.

**ҖИ-Ү** «есть; заедать» дөресрәк язылышы *җий-ү* (к.) дип бирелде, чөнки сузыкка беткән тамыр түгел, тартыкка беткән тамыр: *җии* димиләр, *җия [җийә]* диләр.

**ҖИҺАЗ** «оборудование; мебельный гарнитур» < гар. *җиһāз* id.

Дерив.: **җиһазлы, җиһазсыз; җиһазла-у.**

**ҖИҺАН** «мир, вселенная» < фар. *җäһāн* < бор. фар. *gehān*, авест. *gaetha* «дөнья» (Platts I: 401).

**Җиһан** сүзе төрки телләргә күптән кергән, к. чув. *çанталăк* «һава хәле, һава торышы» < **җәһан тәүлек* «дөнья түгәрәге».

**ҖИЯ [җийә],** диал. (Тумашева 1992: 238) **цийә, йейә** «болотная ягода» [**торнакүз җия, торна җиясе, тырнауц ция** «мүк җиләге», **кызыл җия** «нарат җиләге» (к. Будагов I: 450)] < **Җидә** (к.).

**ҖИЯК I [җийәк]** «оторочка из цветной кожи» < фар. *зеһак* id. ← *зеһ, зиһ* «кереш; буйлык; ука, җияк».

**ҖИЯК II [җийәк], йәйәк, йейәк** диал. (ЗДС: 187, 250) «щека, деталь ткацкого станка, косяк, брус оконно-дверной рамы» ~ кр.-тат., төр. (Dobr. I: 485) *çepe, şepe,* чыгт. *чаңға* «урт һәм яңак сөяге» ~ фар. *чане, чäне* id. Чаг. бор. төрки (ДТС: 174) *ejegü* «ияк, яңак». Бу сүз **ияк** белән дә, **яңак** белән дә тамырдаш булмаска мөмкин. Чаг. **Җияк I.**

**ҖИЯН [җийән],** диал. **жийән** «племянник», диал. (Арсланов 1988: 102) «внук от дочери», үзб. *җиян*, к.-калп. *җиен [җийэн]*, кырг. *җээн*, төр., төркм. *йэгэн*, алт. *дьейен, йääн*, хак., тув. *чээн*, як. *сиэн* id., ш. ук. *сыған* күп телләрдә бар; безнеңчә, бор. **йәң энä* «чит иру эне» сүзеннән (*йәң, йән* «чит ыру; тау арты; Кытай», *энä* «эне»), к. **Җизнә, Җиңгә.**

Бор. халыкларда **җиян** белән *тагай* аеруча мөнәсәбәтләрдә торганнан: **җиян** – сеңелкәшнең яки апаның кызы, **тагай** – әнинең бертуган абыйсы яисә энесе һәм ул үз балаларыннан бигрәк җияннәре өчен кайгыртырга тиеш булган (алтайларда, кыргызларда *«тауны күрсә бүре шатлана, тагаен күрсә җияне шатлана», «җиянем килгәнче җиде бүре килсен»* кебек мәкальләр бар).

Башк. телендә *йейән* гомумән «онык». **Җиян** тур. әдәбият ишле, к. Покровская: 53; Номинханов 1975: 44; Räsänen 1969: 194; ЭСТЯ IV: 166–167 (**җиңгә** сүзе белән багламыйлар).

**ҖИЯНЧӘР,** диал. **җияншәр** «внучка (от дочери)» ~ кырг. *җээнчәр* «кыз җиян», як. *сиэнчэр* «хатын-кыз линиясе буенча токымнар», бур. *зээнсэр* ~ башк. *йейәнсәр* «оныкның кызы» һ.б.; *-чәр//-чар* кушымчасы монг. телләрендә мөәннәсне белдерә. К. югарыдагыны.

**ҖОБАН-У,** диал., башк. **йобан-у** «медлить, замешкаться; утешиться», к. **Йоба-у, Юан-у, Юбал-у.**

**ҖОК** «только чего-либо, хоть немного чего» к. **Йок.**

**ҖОМГА,** диал. **җөма, йома** «пятница», диал. «неделя» ~ башк. *йомға, йома* id. < гар. *җум'а* «җыелыш, җыелу көне» (җыелып намаз уку), *җм'* «җыелу» тамырыннан, к. **Җамигъ, Җәмәга, Җәмәгать, Җәмгыять.** Тимергалин: 171–172 (тәфсилле тарихи аңлатма).

**ҖОР,** диал., башк. **йӧр** «шустрый, юркий» > чув. *йăр, йăрă* id. ~ к.-балк., кырг. *җур*, кар., ком. *йур* – кыр кәҗәләренең бер төре – кыска йонлы һәм зифа, сак һәм елгыр була, ихтимал, сары уйг. *җигыр* «антилопа, җәйрән» сүзеннәндер. Чаг. иске төр. *kulan* «колан; елгыр» (Steuerwald: 563). Бор. *җигур* сүзен бор. фар. *җаһигур* «саванна коланы» сүзе белән чагыштырырга мөмкин.

**Җор** сүзенең палаталь варианты да бар, к. тат. диал. (ДС II: 263) **җөр** «җор», *җөр карап тору* «барысы бергә текәлеп карап тору» ~ чув. *йĕрĕ* «җор, сак, елгыр» (к. Ашмарин V, 88–94, 139). К. ш. ук **Җорнай.**

**ҖОРНАЙ,** диал. (ТТДС I: 417) **җырнай, зырнай** «вьюн (рыба)» – *җор* сүзеннән булса кирәк. Чаг. ш. ук диал. **цырнай** «бик ябык, арык» (к. Тумашева 1992: 245).

**ҖОФАР,** диал., башк. **йофар,** (Тумашева 1992: 91) **йапар, йыпар; йыпар сычкан,** (себ., Радлов җыйган фольклорда) **йыбар, йыпар** «мускус; выхухоль (из желез которой получают мускус)» > чув. *йăпар* «җофар (җәнлек)» < бор. кыпч. *ypar, jypar*, төр. *ipar* к.-калп. *җупар,* кырг. *җыпар*, чыгт., уйг., алт. *йыпар*, иске тат. (Троянский), бор. монг. *ǯiyar* (хәз. монг. *заар*) «мускус» һ.б. Безнеңчә, бор. төрки *jid par, jıγ par* «исле барыс, циветта» сүзеннән (*jıd ~ jıdıγ* «ис»); бор. заманнарда *җофар* – барыска охшаш мәчесыман хайван – читлекләрдә асралган; соңрак бу сүз Идел бассейнында гына яши торган хайван – җофарга күчерелгән. Фар. *ипар* «исле үлән, мәтрүшкә» – күч. мәгъ. ЭСТЯ IV: 184–185; ССТМЯ I: 252.

**ҖӨББӘ** «риза, плащ» < гар. *җуббā* id. Бу сүздән (төрле юллар белән) *чоба* һәм *зыбын, юбка (юба)* сүзләре дә килеп чыккан. К. **Чоба.**

**ҖӨГӘРӘ** «сорго, среднеазиатское просо» < үзб. *җугара*, госм. *çökeri*, кырг. *җүгөрү*, к.-балк. *җүгәри* «җөгәрә, кукуруза», калм. *җүгүр*, бор. төрки *jügür* id. һ.б. киң таралган сүз (к. Räsänen 1969: 117). Кайчандыр бу сүз Идел-Урал регионында гомумән ашлыкны һәм икмәкне белдергән, к. **Чөкер.**

**ҖӨДА** «начисто лишённый; отделённый», диал. **җөдә** «очень, крайне» ~ кырг., үзб. *җуда* «бик тә» < фар. *җудā* «аерылган хәлдәге, аеруча».

**ҖӨЗӘ, җөзьә, җөзү** «часть, том; раздел» (элек киң кулланылган сүз) < гар. *җуз'* id. Казак халкының өч зур кавеме *җөзләр* (*җүз*) дип аталган һәм моны мәзкүр гарәп сүзеннән дип аңлаталар.

**ҖӨЙ,** диал. **йү, йөй** «шов» ~ чув. *çĕвĕ* < **җĕw* ~ төр. *йив*, бор. төрки *ji* (ДТС: 260, бу сүзлектә *ji* «җөй» *jı* «еш» сүзе белән буталган – дөрес түгел) ~ гом. *йиг* (к. **Җек**) сүзе белән бердәй булса кирәк. *Йүй ~ җүй* «җөй» яңгырашы төрки телләрдә сирәк (бары тик к.-калп. *җүй* id.), тик монг. *ǯуй* < *җуй* id. К. **Җик, Юлә-ү.**

Чаг. ш. ук ягн. *ǯiv-, ǯivak-* «җөйләү, типчү» < сугд. *zib, ǯiy-* «җөйләү» (ЯТ: 327).

**ҖӨЛ-Ү** «выщипать волосы» – «сакал-мыекны китәрү» к. **Йөле-ү.** К. **Жулик.**

**ҖӨМ** «отгадка; решение задачи», чаг. диал. (ТТДС I: 145–146) *им-җом, им-ом, им-йом* «имтом» ~ чув. *йум* «күрәзәләү; имләү», төр. *yom, yum* «начар галәмәт; ырым» алт. *чум, чумдепел* «риваять».

**ҖӨМҖӨМӘ** тар. «круглая голова; круглый череп», «маленького роста красавица» < төр. *cümcüme, cimcime* id. һәм «(кечкенә, түгәрәк һәм бик татлы) карбыз сорты» < гар. *җумҗумā-т* «баш сөягеннән ясалган шәраб савыты». Ахыр чиктә бу сүз рус. *Голгофа* «бор. Фәләстыйнда җинаятьчеләрне үтерү (башларын кисү) урыны» сүзе белән уртак нигездән, арамей. *gulgalta* «баш сөяге, чирәп» сүзеннән килә.

**ҖӨМЛӘ I** «предложение» > башк. *йөмлә* < гар. *җумлā* «фраза; нәтиҗә; туплам», к. **Җөмлә II.**

**ҖӨ́МЛӘ II,** кит. **җө́мләтән** (Г. Тукай) «всё вместе взятое» к. **Җөмлә I.**

**ҖӨН, йөн,** диал. **җөң, йөң** «шерсть; шерстинка» (к. мәкальдә: *Аю дисәң – җөне юк, кеше дисәң – җуне юк*) < гом. төрки *йүн, йүң* id. К. **Йон.** Кайбер язучылар теге яки бу вариантны гына кулланалар. К. ш. ук **Җөнтәс.**

**ҖӨНТӘЙ** диал. (распространено, но в словарях не отмечается) «дурачок». Чаг. рус. (Аникин: 215) *зунчук, зунтугло* < бур. *зүнтэч* «картаеп, юньсезлектән» ~ монг. *зонто* id., *зөног* «җүнки». Тат. сүзе борг. монг. телләреннән булса кирәк. К. *Җүләр-Җүнки* дигән парлы сүздә *җүнки* < бор. монг. *җүнгүй* «юньсез».

**ҖӨНТӘС, җөнтәч** «волосатый; мохнатый» ← *Җөн* (к.), ясалышы ачык түгел. **Йонлач**тан түгелдер.

**ҖӨП I,** диал., башк. **йөп, йүп** «чётный» < фар. *җүфт* «пар, тиңдәш, пардаш, җефет, тиңлек, ярашулы, тулы комплект» < авест. *ǯuxt, yaoiti,* санск. *yuuti, *yuvuti* id. Бу фар. сүзе нигезендә төрки телләрдә бик күп яңа сүзләр килеп чыккан яки ясалган, к. **Җепкер, Җефет, Җөп II, Чуптар, Чүпләү II, Чыпта, Юкә, Юрган.**

Элекке (XIX г.) тат. телендә тагын *өфти* «ике авызлы капчык», *йүфтә, йүхтә* «ике яки өч басулы система» сүзләре дә булган (к. Гераклитов 1938; Фасмер IV: 536–537) ~ төр. *çift* «җир сөрү; бер пар үгез» һ.б.

**ҖӨП II,** диал., башк. **җүп, йүп, йөп: җөп күр-ү** «считать хорошим (идею, мысль), согласиться, одобрять»; бу сүзнең **җөплә-ү, җүплә-ү** (ДС II: 264) дериваты актив кулланыла, чаг. ш. ук *җөптәш* «фикердәш» (Бәшири З. Сайл. әсәрләр, 1958: 180), **җүпләмә-ү** «теләмәү» (ТТДС I: 584), **йүпәйтлә-ү** «хуплау» (БҺҺ II: 95), к. чув. *йуп* «җөп, җүп», нуг. *йӧпле-*, к.-калп., кырг. *җӧпле-* «җөпләү» һ.б. **Җөп** «яхшы, ярый» сүзе тат. теленә көнчыгыштан килгән, к. алт. *йӧп, дьӧп,* хак., тув. *чӧп,* як. *сӧп,* бор. монг. *ǯӧв* (хәз. монг. *зөв,* бур. *зүб*) «яхшы, хуш; әйе, ярый», к. ш. ук бор. монг., бор. чыгт. *ǯӧв* «яхшы эш, дөрес, дөреслек» Поппе 1938: 439; Федотов I: 205.

**Җөп II** шул ук фар. *җүфт* (к. **Җөп I**) сүзеннән булса кирәк, тик ул төрки-монг. телләренә элегрәк – исламгача (б.э. I меңьеллыгында) кергән.

**ҖӨРГӘК,** диал. **җөрдәк, йөргәк** (ТТДС I: 184, 582), **йүргә, йүргәк** (ЗДС:260) «короткая рубашка, распашонка младенца; пелёнка» ~ каз. һ.б. кыпч. *җөрчек, йӧрчәк*, бор. төрки (ДТС: 27.) *jörgäk* «юрганчык, ябынгыч» ← тат. диал. *йөрә, йүрә* «урап төрү» < гом. төрки, бор. төрки *jörge-* «урау», *jör-* «төрү» сүзеннән, к. **Җүрмә-ү, Юргәмеш, Юрмә-ү.** Räsänen 1969: 208 (күп сүзле).

**ҖӨЯ [җөйә]** «место в системе; связь, звено» (в рассуждении, чаг. *Җөяле сүз җөясен табар*, мәкаль) ~ каз., к.-калп. *җүйе*, кырг. *җүйө*, үзб. *җуя* id. < фар. *жуйа, җүйе* «яраклы, уңышлы».

**ҖУЕН [җуйын],** диал. **йуйын** «погибший (М. Акчурин телендә) к. **Җуй-у.**

**ҖУЙ** диал. «замысел» (к. мәкаль: *Уе барның җуе бар*), вторая часть парного слова **уй-җуй** «замысел (недобрый); хитросплетение; козни» ~ мар. *йой* «хитрый, лукавый; проворный, деловой» ~ кырг. *җой*, үзб., уйг. *йой* «җуй», алт. *йой, дьой* id., ш. ук «алдакчы», тув., хак. *чой* һ.б. id. Чаг. добр. тат. телендә *соу [җой]* «эзләнелә торган нәрсә (Akb: 141), уйг. *җӧй* «хәйләле мактану», *чуй* (< кыт.) «исәп-хисап, исәпләү». К. **Җуй-у.**

**ҖУЙ-У,** диал. **йуй-у** «потерять (нарочно скрывать); стереть (написанное); отменить; списать (долги)» ~ башк. *йуй-,* к.-калп., кырг., к.-балк. *җой-*, нуг. *йой-* < бор. төрки *jod-, joδ-* id., *joj-* «яшерү», к. ДТС: 266, 270. К. **Җуй, Юк.**

**ҖУША** «охра (глина желтоватого цвета, употребляется в качестве краски)» ~ башк. *йуша* «төсле таш», кырг. *жошо* «сурик», каз., к.-калп. *жоса* «охра» уйг. (< кыт.) *йоңса* «кытай түрәсенең баш киеме түбәсенә беркетелгән махсус төсле таш», к. төр. диал. *yoğşa* «кызгылт туфрак», к. ш. ук алт. *йожо*, як. *соһо* «кызыл буяу» ~ бор. монг. *ǯoša* id. ЭСТЯ IV: 31 (аңлатмасы юк).

**ҖҮЗ** «одно из трёх подразделений казахского народа» < каз. *җүз, жүз* id. Төрлечә аңлатыла. К. **Җөзә.**

**ҖҮЛӘР** «безумный» к. **Юләр.**

**ҖҮР** диал. (ТТДС I: 584; БҺҺ III: 57) «специальный нож для твёрдого материала» – ачык түгел. Чаг. як. *йэт* «агачтан савыт ясау өчен кәкре пычак» < *йүрт?*

**ҖҮРМӘ-Ү,** диал., башк. **йүрмә-ү** «шить через край, намётывать» ~ кырг., к.-балк., кырг. *җӧрме-*, нуг., ком., төр. һ.б. *йӧрме-* id. бор. төрки *jör-* «җайлап сүтү яки урау» сүзеннән. Чаг. **Җөргәк, Юргәмеш.**

**ҖҮТ** диал. «упорно молчаливый; упорно против (чего); против», чаг. кр.-тат. *җүт, җүвүт* «яһүди», төр. *çіһüt* «яһүди; кинәле кемсә».

**ҖҮШӘН** (а также **җөббә-җүшән,** к. ЛТ I: 154, 157) «военное обмундирование» < фар. *жоушан, җоушӓн* id., к. ш. ук бор. рус. *юмша, юмшан, юшан*, төр. *cevşen* «шайман, көбә». Бу сүз төбендә монг. сүзе булса кирәк.

**ҖЫБЫЛДА-У** «быстро-быстро вилять (хвостом); рябить (о волне)» < *җылбырда-у.*

**ЖЫБЫРДА-У** «кишеть (о насекомых), чувствительно двигаться по коже человека (о насекомых и т.п.); чувствоваться (о зуде)» ~ чув. *йăпăрта-*, кырг. *жыбыра-* id. һ.б. гом. төрки *жыбыр-* (*жыбыр-жыбыр*) имитативыннан.

**ЖЫБЫТКЫ** «медлительный» < **жобаткы*, к. **Йоба-у.**

**ЖЫДА** «копье» к. **Жида.**

**ЖЫЕЛ-У [жы̆йы̆л-]** «собираться», «убираться (о сельхозкультурах)» < гом. төрки *jıγıl-* id. һ.б. **жый-у** сүзенең төш. юн.

Бу фигыль үзе генә дә күп сүзләргә нигез булган: **жыелдыр-у; жыелма** (шуннан «өченче тармак» сүз – **жыелмалы**); **жыелдык ~ йыйылдык;** аеруча **жыелыш** «утырыш», иск. «парламент» – **жыел-у** < **жый-у** нигезләреннән ясалып, киң иҗтимагый-сәяси мәгъ. алган сүз. Ихтимал, монда рус. *собрание* сүзенең (сүзьясалышта һәм сүз мәгънәсендә) тәэсире булгандыр. XX г. **милләт жыелышы** – «национальное собрание» төшенчәсе барлыкка килгән.

**ЖЫЕМ [жы̆йы̆м]** «сбор средств», иск. «налог», төп (кагыйдәгә буйсынган) мәгънәсе буенча «жыелган нәрсәләр тупламы», «жыю нәтиҗәсе» ← **жый-у.**

Бүтән төрки телләрдә бу сүз сирәк очрый. Иске телдә бу сүз урынына **жыймак, жыймаклык.**

**ЖЫ́ЕН I [жы̆́йы̆н],** диал., башк. **йыйын** «все разные, весь разный (с пренебрежительным оттенком)» – **жые́н** сүзеннән басым үзгәртеп ясалган (эмфатик басымлы форма лексик мәгънә алган). К. **Жыйна-у, Жый-у I.** Чаг. рус. *сброд ← бродить.*

**ЖЫЕ́Н II [жы̆йы̆н],** диал. **зыын,** (ЗДС: 187, 206) **йыйын, жыйын, йы̆йын** «собрание; община; большой сабантуй», «поминки» күпмәгънәле тарихи сүз. К. иске тат. < бор. төрки **йыйғын* > үзб., уйг. *йиғин* электән килгән иҗтимагый термин, һәртөрле бергәлекләрне – нәселдәшләр төркемен, авылдагы бер тарафны, авыллар төркемен – гадәттә бор. бер авылдан таралганнарын белдерә. Бу **жыен**нар тур. күп язылган, чөнки сүз киң таралган, к. башк. *йыйын*, диал. *зыйын* (> рус. диал. *зиин*) > мар. *зиин*, *дийын, йейын*, чув. *ейăн*, удм. *жиын, зыйын, зин* ~ к.-калп., к.-балк., ком., кырг. *жыйын*, нуг. *йыйын*, уйг., чыгт., төркм., гаг. *йығын* < бор. төрки (ДТС: 265–266) *jïγïn* «жыелыш, жыен; тантаналы жыелыш; сабантуй, нәселдәшләр группасы, хәрби отряд» (к. Татары … 1967: 196–200; Бурганова: 20–67); бу сүз Кавказ телләренә дә кергән. К. ш. ук Будагов II: 357–358 (кызыклы тар. мәгълүмат бирә). Ахметьянов 1989: 147–148; ЭСТЯ IV: 271–272. К. **Жый-у I.**

**ЖЫЕНТЫК [жы̆йы̆нты̆к]** «сборник» – асылда «төрле жыелган нәрсәләр», чаг. **иләнтек, калдык.** К. түбәндәгене.

**ЖЫЕН-У [жы̆йы̆н-]**«собирать свои вещи (исходное значение)» и (возможно под влиянием русского слова) «собираться, намереваться». **Жый-у I** (к.) сүзеннән үзенчәлекле дериват.

Дерив.: **жыендыр-у, жыенып-у, жыеныш-у** һ.б. К. түбәндәгеләрне.

**ЖЫЕР-У [жы̆йы̆р-],** диал., башк. **йыйыр-у** «морщить, делать складки» ~ каз. *жиыр-,* к.-калп., к.-балк., кырг., ком. *жыйыр-, жиыр-*, төркм. *йыгыр-*, (*jıγrıl-* «жыерыл-» төш. юн. формасына караганда) бор. төрки **jıγır-* id. *jıγ-* «жыю» фигыленең йөкл. юн. (**жый-гыр-у*). К. **Жый-у I, Жык.** К. түбәндәгене.

Дерив.: **жыерыл-у → жыерылдыр-у; жыерылучан** һ.б., **жыерык** һ.б.

**ЖЫЕРЧЫК [жы̆йы̆рчы̆к]** «складка, складки на поверхности» ~ башк. *йыйырсык* id., ихтимал, **жыерыкчык** сүзеннән кыскаргандыр.

Дерив.: **жыерчыклан-у** һ.б. Актив кулланылучан сүз.

**ЖЫЕШТЫР-У [жы̆йы̆шты̆р-]** – учащательная форма на *-штыр-* от **жый-** «убирать, приводить в порядок». Тат. әд. телендә шактый активлашып киткән сүз. Аның төп норматив мәгъ. дә онытыла төшкән һәм ул еш кына **жиштыр-у** дип тә әйтелә.

Дерив.: **жыештырыл-у, жыештырын-у, жыештырт-у; жыештыручы** һ.б.

**ЖЫЙГЫЧ** «нечто собирающее». Хәз. техник лексикада активлашып киткән яңа ясалма сүз. Бу сүзне гомумән караганда кушма сүзләрнең икенче компоненты итү кирәктер: *хәреф жыйгыч* түгел, **хәрефжыйгыч.** К. түбәндәгене.

**ЖЫЙМА** (ш. ук **жыелма**) «собирательный; сборный» – хәз. заман (XX–XXI гг.) лексикасын-

да активлашкан сүз. Төрле сөйләшләрдә **жыйма** специфик мәгънәләргә ия (мәс., тукучылыкта).

Дерив.: **жыймалы,** (ш. ук) **жыелмалы** «аерым өлешләрдән жыела торган (мәс., йорт, җиһаз)»; диал. **жыймала-у.**

**ЖЫЙНАК,** диал. **йыйнак** «аккуратный, прибранный» ~ башк. *йыйнаҡ,* к.-калп., к.-балк., ком., кырг. *җыйнаҡ,* төркм. *йыгнак* id., ш. ук «жыелыш; жыентык» башлыча кыпч. телләрендә очрый. К. **Жыен-у, Жыйна-у, Жый-у I.**

**ЖЫЙНА-У** (шуннан **жыйнал-у, жыйналыш-у** «компания төзү») фигыле **жыен** сүзеннән ясалган булса кирәк (турыдан-туры **җый* дигән исемнән дә була ала); **жыйнау** «бергәләшеп» әлбәттә исем фигыльдән.

**ЖЫЙ-У I,** диал., башк. **йый-у** «собирать, собрать»; диал. «прятать; хоронить» ~ к.-калп., к.-балк., кырг. *җый-*, нуг. *йый-*, уйг., үзб., кр.-тат. һ.б. *йығ,* шор. *чыг,* бор. төрки *jïγ* id. Бу сүзнең исем коррелянты – тат. диал. *җык* < бор. *йыг* булса кирәк, к. **Жык II.** ЭСТЯ IV: 271–272.

**Жый-у** сүзенең аерым дериватлары күптән төп мәгънәдән ераклашып, үзенчәлекле мәгънәләр алган; **жыел-у, жыен-у, жыеш-у, жыйдыр-у** (юклык формалары) икенчел һәм өченчел дериватлар биргән. **Жый-** нигезенең үзеннән ясалган **жыйгыч, жыем, жыен** нигезләре дә тармакланган, дериватлары – нигезләр, к. аерым матдәләр. Миш. **йый-** варианты тагын үзенчәлекле вариантлар тудырган. К. **Йый-у.**

**ЖЫЙ-У II (жыю), жийы-у** (ЗДС: 187, 194) «гнить, загневать» – ачык түгел. Гадәттә *эрен җыя* дип әйтәләр. Күрше төрки сүзлекләрдә дә ачыклагыч материал таба алмадык.

**ЖЫК I,** (ЛТ I: 155) диал., башк. **йык** «в растерянности; в изнеможении; нужда; сап (болезнь лошадей)». К. **Жик II.**

**ЖЫК II** диал., башк. **йык** «род; отродье», башк. *йӧҡ* «ыру башы» (БҺҺ II: 91), иске тат. («Нәһҗелфәрадис»тә) *йык-йыwыҡ* «нәсел-нәсәп, нәселе якын» ~ чув. *йӑх* «нәсел-ыру, буын, токым, сорт», *йӑх-* «аталандыру, үрчетү»; мар. *йыксыр* «нәселсез; тамырыннан (корыту)» < болг. **йыксыр* «нәселсез, жыксыз», *йыксырт-* «юк итү».

Тат. сөйләшләрендә **жык** сүзенең *жӧҡ* варианты да бар (ТТДС I: 575) ләкин ул **йок** сүзе (к. **Йок**) тәэсирендә барлыкка килсә кирәк. **Жык** сүзе белән каз. диал., кырг. *җыҡ* «күп; масса, шыгрым» сүзе тамырдаш булуы бик ихтимал; әгәр шулай икән, **жык** < **йык** бор. *йыг-* «җыю» фигыленең исем коррелянты. К. **Жый-у I.**

**ЖЫЛА,** башк. **йыла** «кора молодых деревьев (особенно ольхи и ивы), которая ранней весной сдирается как хороший корм молодняку» < рус. диал. *ёлха, елоха* < бор. слав. *jelьха,* рус. *ольха* «зирек» булса кирәк, гомумән *җыла ~ йылы* үзеннән тире иеләгеч буяу алу өчен суелган зирек һәм имән кайрысын белдергән. Башкортстанда зирек кайрысы шиерып «хөкүмәткә» сату 1920–1940 елларда үзенчәлекле бер кәсеп иде; бу кайрылар Уфадагы «Дубитель» заводында эшкәртелә иде (соңыннан, синтетик буяулар эшләнә башлагач, әлеге кәсеп бетте). Кайнатып суы сыгылган кайрылар көндәлек тормышта терлеккә ашатылган.

**ЖЫЛБЫРДА-У,** диал. **йылбырда-** «волноваться рябью (о лужах); тускло мерцать» ~ башк. *йылбырҙа-, йылбырла-* id. – *җылбыр (җылбыр-җылбыр)* тәкълиди сүзеннән, бу сүз исә *йалп*// *җылп* тамырыннан, к. **Жил, Ялбыр, Ялбырда-у.**

**ЖЫЛМЫЙ** «полуулыбка» к. **Жемием.** Чаг. каз. *җылми-* «елмайган булу».

**ЖЫЛУ,** диал., башк. **йылыу** «полынья» к. **Жылы.**

**ЖЫЛЫ,** диал., башк. **йылы** «тёплый; теплота» ~ к.-калп., к.-балк., кырг. *җылы*, нуг., кар., алт. *йылы*, хак., тув. *чылыг, чылых*, төр. *ılı* (к. Räsänen 1969: 200) < бор. төрки *jılıγ* id., к. ш. ук як. *сылыас* «жылы, жылыкай». Бу сүзнең борынгырак варианты кар. *йылла* ~ добр. тат. (к. Akb: 210) *җыллы* булса кирәк.

Сыйфат **жылы** белән беррәттән тат. диал. *җылы-*, башк. *йылы-* < бор. төрки *jılı-,* төркм. *йыла-* «жылыну, жылы булып китү» фигыле дә бар. Моның исем фигыль формасы *җылу, йылыу* < гом. кыпч. *йылу, йулу*, хак., тув. *чылыг* һ.б. «туш; жылу» – киң таралган сүз.

Сүз тамырының *йӧл//йул//йол* вариантлылыгы игътибарга лаек, к. алт. *йулу, йолу, дьулу, дьолу* «жылы», куман. *йолу* id., як. *д'улха,* эвенк. *йулку*, маньч. *ӡилан, ӡулан* «жылу» (к. ССТМЯ I: 257, 350), чув. *йӑлу, йӑлка* «жылу; юеш жир» (*йӑлу, йӑлга* дип әйтелә) һ.б. Бу хәл сүзне бор. төрки *jul*

«чишмә, кизләү» сүзе белән чагыштырырга мөмкинлек бирә: бу сүзнең фигыль коррелянты *jul-* «кар һ.б. эреп агу» булырга мөмкин. Бор. төркиләрнең таулы җирләрдә яшәгәнлеген искә алсак, төп мәгънә тау карлары эрүгә баглы булырга тиеш. ЭСТЯ IV: 275–277. Чаг. *ел ~ яшь.*

Дерив.: **жылымса, жылымык.** К. **Жылу.**

**ЖЫЛЫМ,** диал. **йылым** «невод, трал», «мрежи» (Троянский I: 408) > удм. *җылым*, мар. *йылым* ~ башк. *йылым,* каз., к.-калп. *җылым*, нуг., ком., төркм. *йылым* id.; бу сүзнең палаталь варианты киң таралган, к. чув. *çилим, çилĕм,* куман. *илим* (> рус. диал. *илым*), як. *илим* һ.б. (Räsänen 1969: 200); бу сүзне гом. төрки *ил-, ыйл-* «элмәкләп үрү» сүзеннән дип уйлыйлар, к. чув. *йăлă* «элмәк» һ.б. Ләкин себ. тат. *йалым* >> венг. *gyalom* «җылым» варианты бу фаразга хилаф, кайбер телчеләр (к. Фасмер II: 127) бор. һинд. *ǯalam* «җылым» сүзе белән чагыштырырга мөмкин дип саныйлар. ЭСТЯ IV: 44, 282; Федотов II: 118.

**ЖЫПКЫ, жыпты** (ТРС 1966) «ровная долина между горами» ~ башк. *йыпҡы, йыпҡыу* id. (к. БТДҺ: 129). К. **Жап.**

**ЖЫР,** диал. **йыр** «песня» ~ чув. *йор, йорă, юрă* < башк., нуг., ком., кырг. диал., төркм. *йыр*, төр. диал. *yır*, каз., к.-калп. *жыр,* к.-балк., кырг. *җыр,* үзб. диал., уйг. *җиръ* < бор. төрки (ДТС: 219, 268) *jïr* ~ як. *ырыа* «җыр». Себ. тат. (к. Радлов. Образцы… IV: 77), чув. *йур* < бор. төрки (ДТС: 282) **jur* (*jurla-* «җырлау») «җыр» варианты бар һәм *йар* варианты да бар бугай, к. эвенк., нан. (ССТМЯ I: 243, 252, 338) *ǯара-* «җырлау, телмәр сөйләү», маньч. *ǯари-* «дини җырлау». Бу язылышлар сүзнең бор. төп варианттан кыскарганлыгын күрсәтәләр, ихтимал **җаwыр* яисә **җыwар* варианты булгандыр. Шунлыктан *җыр* сүзен бор. фар. *ǯar, zar*, бор. һинд. *jar* «җырлау» сүзе белән баглау шикле була. Кырг. *җырға-, ырға-*, монг. *җарга-*, маньч. *җирға-* «күңел ачу, сөенешү» сүзе белән баглау җаиз шикелле (к. **Жырга-у**). Иске тат. *җыру, йыру* «(озын) җыр», тат. диал. **жырау, йырау,** каз. *жырау,* кырг. *җыроо* «җыр, эпос», ш. ук «җырчы, эпос башкаручы» **җыра-у, *җыры-у ~ *йыра-у, *йыры-у* фигыленә ишарәли; к. ш. ук үзб. диал. *иримоқ* «җырлау». Бу сүз *җырга-у* белән бердәй булуы да ихтимал. Ахметьянов 1981: 103–105; ЭСТЯ IV: 285–286; Федотов II: 490. К. түбәндәгене.

Дерив.: (фонетик вариантлары белән) **жырла-у → жырлан-у, жырлат-у, жырлаш-у; жырчы.** Кар. *йырцык* «җырчык, балалар җыры» бездә дә бардыр.

**ЖЫРГА-У, йырга-у** в памятниках письменности с XVII столетия: Касыйм тарихында (Вельяминов-Зернов II: 407) *хан... кичә-көндез гыйш-гашрәткә җыркамыш* «хан... днём и ночью предавался удовольствиям» һ.б.; бу сүзнең дериватлары *йыргал ~* монг. *җиргал, заргал, җаргалаң* «тантаналы мәҗлес», рус. диал. (Аникин: 184) *джирган* «көзен сугымлык терлек суелгач үткәрелгән бәйрәм» << бор. монг., алт. *ǯırγal* > хак. *čyrγal* һ.б. «шатлык, бәхет, бәйрәм, туй». Күп кенә ядкәрләрдә, хәз.каз. *жырға-,* кырг. *җырға-* «рәхәтлек чигү», алт. («Маадай-Кара»: 77) *јырга-* «күңел ачу», *јыргал* «кәеф-сафа»; чыгт. (Будагов I: 505) *чырғамак, чырғаламақ* «очып барган кошларга атып күңел ачу». Еш кына очравына карамастан, *җырга-* сүзенең этимоны ачык түгел. Без **жыр** сүзе белән баглы дип гөман итәбез.

Билгеле ки, **жыр** сүзенең **жар** һәм **жур** ~ *юр* вариантлары да бар. Чагыштыруларны таблицада күрик (*й-* вариантлары «күңелдә калсын»):

| жыр | жар | жур |
|---|---|---|
| **жыргал** | **жаргал** | ***жургал?** |
| **жырау** «җыр, җырлау», к. түбәндәгене | **жарау** «җырлап өшкерү» | себ. тат. **йура-** «җырлау» |

Һәм, ихтимал, этимологиясе ачылмаган рус. *жърец > жрец* «каһин, мәҗүси рухани» сүзе дә борынгы төрки (һунн, болгар) **жырчы** сүзеннән ярымкалькадыр.

**ЖЫРУ, йыру, йырыу** (ЗДС: 197, 263, 264), иске тат. **жырау, йырау** «песня», себ. йырау, йырауцы «җырчы, эпос башкаручы» ~ каз. *жырау* id. һ.б. (к. **жыр, жыргал**) кырг. *җырға-* «рухлану; рәхәтләнү» сүзенә бик охшаш, ләкин монда кайбер сораулар кала. Монда төп мәгънә «рухлану; күңел киңәю, (рухан) зураю» булса кирәк. Будаговта (II: 354–355) чыгт., Казан тат. (?) «*ул кош бер йыргандьı – сарайның ярымыга тулды*» диелә, бу очракта **йырган-у** «кубылу, силкенү, икенче сурәткә керү» мәгъ. Шунда ук *су йырган-* «су ташу», *гареш йырган-* «күк капусы ачылу» тәгъбирләре китерелә (Будагов бу сүзләрне *йыр-* «еру» сүзенә нисбәтли, ләкин бу дөрес түгел).

# З

**З** авазы сүз башында руник язмалар телендә алынмаларда гына кулланыла башлаган. Гарәп сүзләрендәге дүрт төрле (*з, ҙ, ҙ̣, д̣*) аваз субституты.

Кайбер сөйләшләрдә (срг. һ.б.) **з-** < **җ- ~ й-** күзәтелә: *зәдәс* < *җәдәч, зәймә* < *җәймә, зиңги* < *җиңги* һ.б.

**з** авазына төрле сөйләшләрдә рус сүзләре, рус теле аша кергән алынма сүзләр башлана.

**ЗАВОД, завут, заwыт** (Батырша хатыннан башлап билгеле) «завод» < рус. *заводъ* id. (ике төрле аңлатыла)

**ЗАДӘ** как правило в сложных словах «сын, дочь, дитя, -ич//-евич» (*ханзадә* «царевич») < фар. *зāдӓ* id. Чаг. **Зат.**

**ЗАДУР** диал. «задорный, дерзкий» ~ башк. *ҙадур,* удм. *задор,* чув. *сатур*, мар. *задур, садур, сатурло* id. тат. теленнән таралган рус сүзе булса кирәк.

**ЗАЛ** «зал, зала» < рус. < ним. *Салон* «затлы зур бүлмә» сүзе белән тамырдаш. К. Kluge: 778, 782.

**ЗАЛП** «залп (военный, артиллерийский)»; бу сүз, ахыр чиктә, төр. *zalp* < *zarb* id. К. **Зарбә.** Kluge: 779.

**ЗАМАН** «время, эпоха», диал. «быстренько», «самое лучшее время, своё время (*кого*)» < фар., гар. *зӓман* id. (моның фар. сүземе яисә төптән гар. сүземе икәнлеге ачыкланмаган, к. бор. фар. *daman, dӓtan* «вакытлар, моментлар») > чув. *саман*, мар., удм. *саман, заман* id. (бу сүз төрки телләргә исламгача ук кергән); Идел-Урал телләрендә заман сүзенең төрле модификацияләре дә актив кулланылышта: 1) тат.-башк. **замана** ~ чув. *самана*, удм. *замана* «чор, эпоха, гасыр» < фар. *зӓмāне* id. 2) тат. диал. **замат, замант, заманта** (себ.), **заматта** (крш., к. Balint: 145), **зәмәт, сәмәт** (Арсланов) > чув. *самант, семен*, мар., удм. *заман, замант*, мар. *самат* «тиз генә; момент; күз ачып йомганчы» ~ уйг., каз. *замат* «момент, замат». Чаг. ш. ук алт. *саман* «сәгать», хак. *самал* «вакыт, заман, эпоха» һ.б. Будагов II: 606; Ахметьянов 1989: 17–18.

Дерив.: **заманча; заманында; замандаш; заманасында** (тарихи затлар, хәлләр хакында әйтелә).

**ЗАМИР** «то, что взамен; отражение (нежелательное); местоимение» (к. Исәнбәт II: 256) < гар. *д̣амӣр* id. (к. ГТРС: 125). Шуннан ук *замира* «яшерен хыял, теләк». Тимергалин: 176.

**ЗАНА, зына** «гриб для окуривания покойника» (к. Уразманова: 118). Бу сүз бор. һинд. *сома*ны (наркотик эчемлек ясауда кулланыла торган гөмбәне) хәтерләтә. Гаҗәп!

**ЗАҢ** «право, закон; мирские обычаи» < каз., кырг., монг. *заң* id.; бу сүз монг. яки калм. теленнән чагыштырмача соң гына (XVII г. да элек түгел) таралган, чөнки аның бор. монголчасы *җаң* (> эвенк. *ǯат* «ышаныч», к. ССТМЯ I: 247) ~ алт. *дьаң, йаң*, уйг., куман., себ. (брб.), бор. төрки (төрле чыганакларда) *jaŋ* «принцип, гадәт, закон» < кыт. *йан-цзы* «тәртип, модель» (к. Räsänen 1969: 186; Номинханов 1975: 104).

Бу бор. *jaŋ* сүзеннән бор. *jaŋlıγ* «кебек, шикелле» (к. **Яңлы**) сүзе ясалган. К. Clauson 1972: 940; ЭСТЯ IV: 121–122.

**ЗАР** «стенания; сетование» > удм., мар. диал. *зар* id. (ш. ук фразеологизмнарда: удм. *зар бордыны – зар елау*) < фар. *зāр* < авест. *zār, āzār* «зар, мөшкеллек; инәлү; зәгыйфь, нечкә» (к. **Азар**). **Зар** сүзе төрки телләргә күптән кергән һәм фигыльләшеп тә беткән булган: **зәрык-у (зарыгу)** фигыле бор. **зар-* фигыленең интенсивлык формасы. К. ш. ук гом. кыпч. *зарла-у, зарлан-у, зарлы.*

**Зар-зар** һәм **зари (зари-зари)** дериватлары фар. теленең үзендә дә бар. **Зарила-у** (*зарилап елау, сорау*) тат. телендә ясалган.

Гар. *зāрӣ'* «зари» < фар.

**ЗАРАР,** диал. (Balint: 145) **зарал** «вред» < гар. *д̣арар* id. *д̣рр* «мохтаҗлыкка китерү, кирәк булу» тамырыннан, шуннан ук к. **Зарур. Зарар** татарчадан күрше чув., мар., удм. телләренә дә кергән.

Дерив. киң: **зарарлы, зарарсыз; зарарлан-у** һ.б. (бу сүзләр үзләре дә күпмәгънәле һәм актив сүзьясагычлар).

**ЗАРБ** (**зарып** дип тә әйтелгән) иск. «умножение (в математике), деривация (образование ряда

слов из одного корня в грамматике)» < гар. *д̣арб* id. К. түбәндәгене.

**ЗАРБӘ** тар. «удар; залп (военный); умножение (арифметическое)» < гар. *д̣арбä* id. ← *д̣рб* «кат-кат сугу, бергәләшеп бәргәләү, бәрү». Шуннан ук *зарб* һәм иск. *зәрб* «акча сугу; чәкәнләү; залп» (шул ук сүз төр. теленнән рус теленә *залп* рәвешендә кергән). К. **Зарб, Сарып.**

**Зарб, зарбä** сүзләре күп кенә халыкара сүзләр тәшкиленә нигез булганнар. К. иске тат. **зарабә-изрибу** «сүзләрнең төрләнеш парадигмасы»; **зарбүлмәсәл** «мәсәл; уйдырма мисал белән тиз генә аңлату». К. **Зарбәзан.** Тимергалин: 177; Özön: 152–153.

**ЗАРБӘЗАН** тар. «пушка полевая» < фар. *дарбзан, зарбäзан* «зарбә ясагыч, пушка». Бу сүз төрки телләргә кат-кат кергән. К. **Сарбысан.**

Заманында (XV г.) төрек артиллериясе дөньяда иң зур, иң алгарышлы булган, ләкин хәрби терминологиядә гар.-фар. сүзләре өстенлек иткән.

**ЗАРӘФӘ** иск. «изящность; разукрашенность; украшенная часть минарета», «жираф» гар. теленнән аерым-аерым алынганнар. К. түбәндәгене.

**ЗАРИФ** «элегантный, изящный» < гар. *з̧арӣф* id. *з̧рф* «матур булу» тамырыннан. Шуннан ук **зарифә** «элегант хатын-кыз», **зарәфәт** «югары матурлык» һ.б. **Зарәфәт былбылы** дип актрисаларны атаганнар.

**ЗАРИЯ [за°рийә]** (ЗДС: 199) «вид молодёжной игры вкруговую», «припев частушек (повторяется после каждого полустишия)» – төрлечә аңлатылырга мөмкин. Шунлыктан бу мәдәни сүзне сүзлекләргә дә кертмиләр.

**ЗАРУР** «необходмый, обязательно нужный; необходимо, нужно» < гар. *д̣арӯр* id. ← *д̣рр* «кирәк булу». Әд. телдә (бигрәк тә XIX г. – XX г. башында) киң кулланылган. Гар. телендә бу нигездән ясалган **зарурат, зарури, заруріят** тат. әд. телендә дә кулланыла.

Дерив. (тат.): **зарурлык, зарурлан-у.**

**ЗАРЫФ** иск., лингв. «наречие; служебные части речи» ~ кр.-тат., аз., төр. *zarf* id. < гар. *з̧арф* «эченә документлар, хатлар куела торган янчык» – ягъни бу сүз төркеменә бик төрле сүзләр кертелгән. К. Dobr. III: 543.

**ЗАТ** «род; личность, лицо (юридическое, грамматическое)», диал. «вещь, предмет» < фар.-таҗ. *зāд, зāт* < авест. *zāta* (шуннан к. **Задә**) *zan-* «туу, тумыш, нәсел, угыл» тамырыннан, бу тамыр һинд-евр. *ген* тамыры белән бердәй. Сөйләшләрдә *зат* төрле мәгъ. ия, к. ЗДС: 199; Будагов I: 602.

**Затлы** «сыйфатлы» сүзе башта «яхшы нәселле (кеше)» дигән мәгъ. булган. **Затлану, затланыш** үзләре (грамм. терминнар) XX г. ясалган. **Затсыз** сүзе күтелгән (тискәре) мәгънәсеннән тыш «оятсыз, юньсез усал, угры-карак» мәгъ. дә кулланыла. К. түбәндәгене.

**ЗА́ТӘН** кит. «в сущности; собственно; лично» < фар. *зāдäн* id. сүзеннән татарчалаштырылган яисә гар. *з̧атäн* id. дигәннән. Асылда фар. сүзе *зад* гар. *з̧ат* булып әверелгән. Хәер, бор. фар. *зāта* «зат» сүзе дә булган. Тимергалин: 177; Dobr. III: 545.

**ЗАҺИД, заһит** «аскет, монах, отшельник» < гар. *зāһид.* Мөәннәс формасы **Заһидә** дә актив кулланылган.

**ЗАҺИР I** «блестящий, цветущий» < гар. *зāһир* id. ← *зһр* «ялтырап нурлану, чәчәк ату», шуннан ук *зäһр* «чәчәк» (фар. *зäһр* «агу» белән бутамаска), ш. ук «очко́, күз». Соңгы сүздән *äз-зäһрäт* «алты яклы шакмак белән уйнала торган комарлы уен», шуннан исә, испан теле аша таралып, **азарт** (тат. < рус.) сүзе килә, к. Kluge 2002: 394. К. **Зөһрә.**

**ЗАҺИР II** «ясно видимый; ясный» < гар. *з̧āһир* id. ← *з̧һр* «ачык күренү». Шуннан ук иске тат. **зоһур** «күренеш, чыгыш» < гар. *з̧уһӯр* «өслек», тат. **изһар** «ачык мәгълүм итү» < гар. *из̧һāр* id. сүзләре килә. Тат. әд. телендә бигрәк тә *заһир булу* тәгъбире билгеле.

**ЗАЯ I [за°йа]** «напрасно содеян, потерян, потерянный (об усилиях, времени и т.п., но не о деньгах и вещах)» > чув. *сая*, удм. диал. *зайо*, мар. диал. *сайа, зайа* id. < гом. кыпч. *зайа* < иске тат. < гар. *д̣ай'* id., *д̣й'* «һәлак булу» тамырыннан.

**ЗАЯ II: Зая Түләк (Заятүләк)** – имя героя татарско-башкирского эпоса – калм., монг. *зайа, зайан* «шәһитләрнең тынычсыз рухы» сүзеннән (әсәрдә **Түләк** дигән егет дошманнары тарафыннан үтереләә һәм яңадан терелә). К. диал. (Арсланов 1992: 124) *зайала-* «имгәтү, гарип итү», нуг. *зая* «газап; газапланып үтерелгән кеше». «Заятүләк» дас-

танының фабуласы монг. әкиятләрендә (анда герой *Намжҗыл* исемле) һәм тува әкиятләрендә (герой – *Балжҗын хээр*) очрый. К. Монгол ардын үлгэр. Уланбаатыр, 1969: 209–212; Сказки и предания алтайских тувинцев. М., 1994: 330–333. К. **Чая.**

Монг. халыкларында – халха монголларда, бурятларда, калмыкларда *заян, заяган, дзаячи, заячи* > *заяч* бик күп мәгънәле дини-миф. зат – аның хакында исәпсез күп мифлар билгеле: монг. (МНМ II: 500) *дзагаячи* «иң олуг тәңре», ойратларда (Себер калмыкларында, к. МНМ II: 247, 473) *дзаячи* «язмыш, тәкъдир тәңресе», бурятларда (МНМ I: 197, 198, 375, 391) *дзаячи* «бәхет бирүче тәңре»; шуннан төрле *заян*нарның дәрәҗәсе кими бара: *саган заян* «ак заян» – изге рух, *солбон* «Чулпан йолдызы» аның углы; *хара заян* «явыз рух», алар икесе дә дә Хан Хормуска (к. **Күрпәч**) буйсыналар. *Заян* – «үлгән шаман рухы», ул аерым төбәкләрдәге таукалкулык, үзән, елга-күлнең иясе. Җидегән йолдызлыгын «җиде заян» дип сөйләгәннәр. Чыңгыз хан – күктән иңгән һәм кеше булып йөргән *заян.*

**Зая, заян** элекке *җайа, җайан* вариантыннан. Төрки телләрдә бу сүзнең *дыйан ~ йайан ~ ньайан ~ чайан* вариантлары билгеле. Сүзнең тамыры *йай- ~ дьай-* «корбан итү» булса кирәк.

**Заян** сүзе «теге дөнья; өйдән еракта яшәү» һ.б.ш. мәгънәләрдә рус теленә дә үтеп кергән, к. Аникин: 211. К. түбәндәгене.

**ЗАЯЛА-У** (әстр.), ш. ук нуг. *зайала-* «замучить» ← **зая** «корбан ителгән рух». К. югарыдагыны.

Кр.-тат. (Dobr. III: 545) *zaya kişi* «гаиптән хәбәр бирә белүче изге зат» әлеге монг. *зайасы* булса кирәк. **Заялар** – табигый үлем белән үлмәгән кешеләрнең тынычсыз рухлары күпне беләләр һәм кайчакта кешеләргә хәбәр итәләр. Күрсәтелгән сүзлектә *zaya* тат. **зая** < гар. *ḍай‘* сүзеннән аерылмыйча бирелгән. Хәлбуки аның мәгънәсе *зая ~ ḍай‘* сүзенең мәгънәләренә ябышмый, туры килми.

**ЗӘБӘЛ** (ЗДС: 199) «завал, завалинка» – өй тирәли, койма янында һ.б. балчыктан һ.б. өелгән һәм әйбәтләп кысаланган терраса, тәңгәл < рус. *завал* id. ← *валить* «өю».

**ЗӘВЕҖ** «супруг», **зәүҗә** «супруга» кит. < гар. *зäwж, зäwжä* id., id.

**ЗӘВЫК,** диал. **зawык** «эстетический вкус; интересность; весёлость», диал. (ДС III: 56; ТТДС I: 137) «веселый, увеселение, веселье», себ. (Тумашева 1992: 189) **саук, сауык** «һәвәскәр; мастер» ~ удм. *заук* «мелодия, көй», *зауко* «моңлы, музыкаль» (к. Кельмаков 1977: 53) ~ башк. *зауыҡ* «дәрт, теләк», (БҺҺ II: 73–74) *зәүек* «шәп, кызыклы, күңелле», кар., нуг., ком. *завк, завх*, кр.-тат. *zewq,* каз., к.-калп. *зăуық,* кырг. *зооҡ* «рәхәтлек, күңеллелек; күңел ачу» һ.б. гар. *ẕawḳ* «тәм, зәвык; тат, татлылык», *ẕwḳ* «тату, татлы булу» тамырыннан (к. ш. ук ГТРС: 139).

Дерив.: **зәвыклы, зәвыксыз; завыклану** һ.б. (киң кулланылалар).

**ЗӘГЫЙФЬ [зәғиф]** «слабый; слабый мужчина» (**зәгыйфә** «женщина как слабое существо») < гар. *ḍа‘ӣф, ḍа‘ӣфä* id., id.

**ЗӘГЪФЫРАН** «шафран (растение)» ~ кырг. *запран* «үт» (к. Будагов I: 605) < фар. < гар. *зä‘фрāн* (үсемлек). Рус. *шафран* шул ук чыганактан Европа телләре аша кергән (к. Фасмер IV: 414).

**ЗӘЙ** название реки на юго-востоке Татарстана. **Зәй** топонимын гом. төрки характердагы *сай ~ чай* «елга, үзән» белән чагыштыру (Г. Саттаров) конкрет мәгълүматлар белән ныгытылмый. Сүз башында *с > з* күчеше тат. теленең төп сөйләшләре өчен характерлы түгел (кайбер миш. сөйләшләрендә генә очраштыргалый). Безнеңчә, **Зәй** сүзен каз. (ҚТДС: 134–137), уйг. *зай, зәй, зей, зәк* «сазламык, тозлы саз», *зәйкәш* «дренаж канал», төркм. *зей, зейкеш* id., id. < фар. *зäh, зеh* «арык, канау», *зеhкäши* «сугару яисә корыту канаулары казу» сүзләре белән чагыштыру мәслихәт. Зәй буйларында сазламык җирләр бар. Зәй үзәнен X–XII гг. Урта Азия тарафларыннан килгән (өлешчә фарсыча сөйләшкән) халаек үзләштергән булуы ихтимал.

Бу язганнарыбыз, әлбәттә, фараз гына әле. Топонимнарны тикшерү шактый катлаулы әйбер.

**ЗӘЙТҮН** «олива» < гар. *зäйтӯн* «зәйтүн; сатин» Кытай порты *Цзяо-дуң* атамасыннан (гар. сәүдәгәрләре зәйтүн җимешен дә, сатин тукымасын да шуннан китерә торган булганнар). Velidi: 447; к. **Сатин.**

**Зәйтүнә** исеме – «Кытай гүзәле» (Кытай кызлары аеруча матур дип исәпләнгән).

**ЗӘКЪКУМ** «(духовный) яд, отрава; невыносимые жизненные условия» < бор. гар. (Коръәндә китерелә) *зäḳḳӯм* «җәһәннәмдәге зәһәрле агач». Дини риваятьләр аша ислам дөньясында киң таралган сүз. Хәз. гар. *зäḳḳӯм* (Будагов I: 605) «майлы

тәмсез хөрмә»; «кыргый зәйтүн агачы». К. ш. ук добр. *zıqqım* id. **Зәкъкум** сүзе тат. поэзиясендә кулланыла.

**ЗӘКЯТ** «одна сороковая часть доходов за год, отдаваемая в пользу бедных» < гар. *зäкат* «рухи чисталык, намус сафлыгы; зәкят» (бу тур. к. Будагов I: 605–606). К. ш. иске тат. *зәкяват* «һәртөрле хәерләр, җәмгыять файдасына сәмән бирүләр».

**ЗӘЛӘ, зәлкә,** диал. **зәлқә** «дрозд» (к. ТТДС I: 141; ТТДС II: 95; Наджип Э.Н. Пятиязычный словарь Дамаскина // СТ № 2, 1980: 60) < фар. *заги-лäга, заги-лäқа* «карганың азманы». Удм. *залка, зäлкä* «сыерчык» < тат. (ЗДС, киресенчә, удм. теленнән дип күрсәтә).

**ЗӘМ** иск. «порицание, укор» < гар. *ẓäмм* id., асылда «кимчелек, начарлык, хурлык».

Дерив.: иск. **зимми** тар. «ислам дәүләтендә башка диндә булган кеше»; **зәм итү (кылу)** «кимсетеп шелтәләү»; мәкаль: *Әсирне кылма зәм, Чөнки ул әдәм*. **Зәм** мәдрәсә телендә кулланылган.

**ЗӘМӘТ** «сплошной (каменный, глиняный) забор» (к. Тел ярышы. Оренбург, 1910: 169; ТТДС I: 141) < гар. *сäмäд* id. Бу сүз очрагында *с > з* күчеше кызыклы, андый күчеш миш. диал. һәм кар., к.-балк. телләренә генә хас, чаг. миш. *зөңгө* «сөңге», *зебә* «сөбә», *зыр* «сыр», к.-балк. *зурна* «сорнай», *зылды* «селте», *зыраф* «исраф» һ.б., кар. *зэвда* «сәүдә».

**ЗӘМЗӘМ** «святой источник в Мекке» (к. Будагов I: 606), «вода из этого источника», күч. «вино» < гар. *зäмзäм* id. (тәкълиди характердагы сүз).

**ЗӘМИН** кит. «основание; возможности, условия (для деятельности)» < фар. *зäмūн* «җир» (рус. *земля* белән тамырдаш). Тимергалин: 179.

**ЗӘМҺӘРИР** «жгучий мороз, морозы; стужа; студёный ад в религиозной мифологии» < фар. *зäмһäрūр* id. (гар. дә бар, ләкин түбәндә фар. сүзе булса кирәк). Тимергалин: 179.

**ЗӘНБӘРӘК** иск. «арбалет» төр. *zemberek* < фар. *зäмбурäк* id. ← *зäмбур* «шөпшә». Будагов I: 607; Тимергалин: 180.

Каз. сүзлекләрендә *зеңбірек* «пушка» диелә.

**ЗӘНБИЛ, зәмбел, зимба** (ЗДС: 200) «камышовая корзина» < төр., фар. *зäнбил, зäмбил* id. < аккад. *zabbilu* «сумалаланган кәрзиннән гыйбарәт түгәрәк көймә; кәрзин» (*zabalu* «күтәреп ташу») сүзеннән, к. Salonen 1987: 290–292.

**ЗӘҢГӘР** «синий, голубой» ~ башк. *зәңгәр, зәнкәр* «бакыр купоросы, бакыр рудасы» (БҺҺ II: 74), чув. *сенкер* id. < фар. *зäнг'āр* «зәңгәр буяу; бакыр тутыгы төсе» *зäң* «тут, тутык» (< бор. фар. *gang*, авест. *kanha* «карасулык, тут, яра») һәм *ар, ара* «буяу» сүзләреннән оешкан. К. ш. ук иске тат. **зәңгәри** «зәңгәр буяу; яшькелт зәңгәр» > мар. *занари*, удм. *зангари* «җете зәңгәр». Монг. *сенкер, сеңхер*, бур. *сэнхир, сэнхигэр* «зәңгәр; диңгез төсе» сүзенең тамыры үзгә булырга мөмкин (к. **Чагыр**). К. ш. ук **Зәңгелә, Сәң II.** Ахметьянов 1989: 96–97.

Элекке яз. әд. телдә **зәңгәр** «тут, тутык» мәгъ. киң кулланылган, к. Ә. Ясәвидә (XI г.): *Күксемдәге зәңгәрләрем китәр микән* (57 хикмәт); *Арыйытыр дил зәңгәрен һу-һу яды* (68 хикмәт); *Кырык еллык зәңгәр баскан күңлем милкен* (140 хикмәт) һ.б.

**ЗӘҢГӘРТ** диал. (ТТДС II: 96), **зәнгәт** (Татар балалар фольклоры. Казан, 1999: 297) «праща» < фар. *сäңгäрд* id. (сүзмә-сүз «таш әйләндергеч»); *с > з* тур. к. **Зәмәт, Сабан.**

**ЗӘҢГЕЛӘ,** диал., башк. **зәңгәлә, зәңгәле, зәңнә** (к. БҺҺ III: 61; БТДҺ: 95, «зеңгелә; ревматизм» диелә) «цынга» > мар. *зäнгыла*, удм. *занла* «цынга; ревматизм», *занлатурын* «торна борчагы», рус. *чина* весенняя, сочевничек весенний, диелгән» ≈ зәңгелә үләне, *турын* «үлән», шуны ашагач, зәңгелә бик тиз бетә; ш. ук удм. *замлагач* «быел беренче тапкыр ашарга яраклы үсемлекләрне кабып караганда әйтелә торган әфсен сүзе» ≈ татарча бу очракта *Иске авыз, яңа җимеш, Зәңгелә кач – Идел кич*, дип такмаклыйлар, шуннан *зәңгелә кач* > удм. *замлагач*. **Зәңгелә** үзе тат. диал., башк. диал. *зәңгәрә* «тән күгәрү, зәңгәрләнү» < фар. *зäнгара* id. сүзеннән булса кирәк. К. ш. ук башк. *зәңге* «зәңгелә» < фар. *зäңги* «эренле, күгәрекле чир, зәңгелә». Бу сүз тат. теленә дә күптән кергән, к. себ. (Тумашева 1992: 189) **сәң** «күгәрек, тутык; төтен; тизәк», морд. Э. *сэньгев* «яшел зәңгәр; тут», *сэньчикай* «күгәл, яшел башлы үрдәк», *сэнь* «зәңгәрлек, күгәрек» < тат. **зәңгәү, *зәңчикәй, *зәң* id. id. id. Рус. *цынга, цинга* миш. **дзәңгә, *дзәңгәү* id. вариантыннан булырга тиеш. Чаг. ш. ук чув. *сиңкер, сиңкер-сехмет* «эпидемия». К. **Зәңгәр.**

**ЗӘҢГИ** «негр; чернокожий раб» ← фар. *зäнгū* «тутык төсендәге». Бу сүз гарәпчәгә *зäнҗū* яңгы-

рашында кергән (шуннан *Занзибар* утравы атамасы – «коллар яры» мәгъ.). Фольклорда **Зәңги ата** атаклы әүлия, Гамбәр ананың икенче ире. К. Колшәриф. Казан, 1997. Чаг. түбәндәгене.

**ЗӘҢКИ** «сардонический (голос)» < фар. *зäнгӣ* id. (*зäң «*тут, тутык»).

**ЗӘР I,** диал. **эзәр, изәр** «дорогой пояс; пояс с позументом (невесты); вышитый золотом платок, употребляемый как пояс» > мар. *ызäр*, удм. *зар*, чув. *сар* id. < фар. *зард* id.

**ЗӘР II, зир** иск. «золото; золотой цвет» < фар. *зäр* «алтын». Бу сүз бор. телдә юк (к. ДТС: 639) кулланылып, *зäр* > *зәр* > *зир* үзгәрешләрен кичергән. К. мәкальләр: *Зир кадерен зирәк белә; Зиргә дә җирлек кирәк* һ.б. К. нуг., каз. *зер* «позумент, алтын яки көмеш кәнитил» һ.б.

Дерив.: **зәрле, зирле** «алтынлы җеп белән чигелгән», **зәрләү** «алтынлау».

**ЗӘРӘ** диал. «заря» ~ мар. Т. *жера, җäрä* id. төбендә рус теленнән түгелдер. К. гар. *зäһрā* «таң, яктыру, яктылык» (к. җырда: *Таң микән, таңның зәрәләре бар микән?*) Чаг. диал. (ЗДС: 200) **зәрә очу** «кот очу» һәм гар. *зäһрā'* «йөз нуры» һ.б., к. **Зөһрә.** Һәрхәлдә рус сүзенең тәэсире юк түгел, к. ЗДС: 200.

**ЗӘРӘПИ** (ЗДС: 200) «зверобой (растение)» < рус. булса кирәк.

**ЗӘРБӘЗАН** тар. (Максудидә) «пушка»» к. **Зарбәзан, Сарбысан.**

**ЗӘРГӘР** «ювелир» < фар. *зäргäр* id. К. **Зәр.**

**ЗӘРДӘ, зәрҗә** һ.б. диал. (ЗДС:200) к. **Сәрдә.**

**ЗӘРРӘ** «частица; крупинка» < гар. *зäррä* id.

**ЗӘХМӘТ** «хворь (от порчи); эпидемия; инфекция; дух болезни» ~ чув. *сехмет* id. < гар. *зäхмäт* id. *зхм* «бозу, бозылу» тамырыннан. К. **Зыкым.**

Аерым төрки телләрдә (кар., ком., уйг., төркм.) бу сүз «хезмәт, эш» мәгъ. кулланыла. Кайбер филологлар *зәхмәт* сүзе бор. Мисыр *Сөхмет* «кодрәтле алиһә» сүзенә баглана диләр.

**ЗӘҺӘР,** диал. (к. Balint: 145 һ.б.) **зäгäр,** себ. (Тумашева 1992: 188) **сәр** «яд; отрава», күч. «замечательно; очень» > мар. *зäр, зäхäр, сäхäр*, удм. *зäр, загар* «чая; зәһәр, шәп; зерә, бик тә» < фар. *зäһр* «агу; үт; зәһәр» >> чув. *сехĕр* «үт; курку; аффект»; к. ш. ук фар.-таҗ. *зäһрä* «үтлек; кыюлык» > чув. *сехре* «үт; курку» – бу чув. формалары болг. теленең үзеннән алынганнар, к. тат. диал. (ТТДС I: 141) **зәрә** «кот; курку» < *зәһрә*. К. **Зерә.**

**Зәһәр** сүзе гарәпчә дә төрләнә, к. **Заһир,** ләкин аның тамыры төбендә фар. (һәрхәлдә ир.) телдән булса кирәк. Ахметьянов 1989: 96.

Дерив.: **зәһәрле; зәһәрлән-ү** (күч. мәгъ.)

**ЗЕЛПЕ,** диал. **зелеф, зөлеп, җилпе** (к. ДС II: 259) «жимолость; бересклет (Lonicera caprifolium)» > мар. диал. *дьылпе,* удм. *зелпе* id. < фар. (< гар.) *зулф* «бөдрә толым», *зулфӣ* «толымлы». Бу сүзләр Кавказ телләрендә дә еш очрый (к. Абаев I: 312).

**ЗЕР, җер** диал. (ТТДС I: 138) «чёрный-пречёрный; чумазый», чаг. чув. *çĕр* «төн; каралык, караңгылык». Федотов II: 112 (бор. төрки *jır* «төньяк» сүзеннән димәкче).

**ЗЕРӘ I** «очень, чрезвычайно» > удм., мар. *зыра, зырä,* чув. *çĕре* < фар.-таҗ. *зäһрä* «үт; үтле; зәһәрле; кыюлык, кыю», чаг. ш. ук диал. (ДС III: 261) *әзәр* «усал» < фар. (< гар.) *äзһäр* «иң зәһәрле»; к. **Зәһәр.**

**ЗЕРӘ II,** диал. **зерәгә** «зря» ~ мар. *зĕра, ĕзра* id. < рус. *зря* «күрә торып; зерә, юкка».

**ЗИЛАНТ, зиланты** «змей на гербе г. Казани» < рус., скорее всего, придуманное – Татарстандагы Зилант монастыре исеменнән. Ул тирәне татарлар **Җылантау, Җылан (елан) тавы** дип атаганнар, русча топоним **Җылантау** сүзеннән була ала. Ләкин монда **җылан** сүзенең еланны белдерүе шикле. Мари легендаларында (Марийский фольклор: 240–244, 247–250), имеш, Явыз Иванга ярдәмгә килгән мари патшасы *Йыланда* – рус. *Еландей* турында сөйләнелә һәм Зилант монастыре шуңа арналган диелә. *Зиланты* белән *Йыланда,* мөгаен, бер үк сүз, әмма аларның мәгънәләре һәм аңлатмалары бик үк охшашмый.

**Зилант** дип атала торган сурәт (арт аяклары булмаган ләү – аждаһа) Алтын Урда чорыннан калган тәңкәләрдә очрый, ләкин сирәк. Һәм ул фигураның заманында ничек аталганлыгы билгеле түгел. Ул «зилант» Әстерхан дәүләтенә карый булса кирәк – төрекләр **Әстерхан**ны *Әждаһа тархан* сүзеннән дип аңлаталар.

**ЗИЛЗИЛӘ** «землятрясение» < гар. *зилзилä* id.; чаг. **силсилә, тантана** һ.б.ш.

**ЗИМ** диал. «питательность; соки (организма)» > башк. *зим, дим*, чув. *сим* «зим, җим», чаг. ш. ук удм. диал. *җем* «нектар; җим». *Җим* > *зим* күчеше миш. сөйләшләрендә генә булала. **Җим.** (к.) сүзеннән кебек. Ләкин к. яз. монг. *sime* (хәз. монг. *шим*), тунг.-маньч. *симэн* «зим». ССТМЯ II: 87.

**ЗИМАГУР** «рабочий-сезонник; бродяга» ~ мар., удм., рус. диал. *зимагор* – иске тат. *зинахур* < фар. *зинāхōр* «әрәмтамак зиначы» (зина кылу һәм сукбайлык икесе бер тактага куелган, чаг. ш. ук **Бабүл**). **Зимагор** яңгырашы рус телендә килеп чыккан. Этимология бүтәнчә дә булырга мөмкин.

**ЗИН,** диал. (ТРС, 1966) **зим** «шуга (мелкий рыхлый лед на реке)» ~ гом. кыпч. *сеӊ,* чыгт., үзб. диал. (Радлов III: 286; ЎХШЛ: 233) *сәӊ, саӊ,* башк. *ҙим, дим* id. сүзе белән бердәй булса кирәк (*с* >*з* миш. сөйләшләрендә очрый). К. ш. ук чув. *сан* «зин», тунг.-маньч. (ССТМЯ I: 321) *сиӊгу, сиӊга* «кинәт килгән каты суык». Räsänen: 410 (монг., тунг., фин. телләрендә дә параллельләрен таба). ЭСТЯ VII: 238 (тат. сүзе күрсәтелмәгән).

**ЗИНА** «прелюбодеяние, разврат»<гар. *зинā* id.< бор. фар. *zinay, zanay* id. *zan* «хатын, бичә» сүзеннән.

**ЗИНДАН** «темница, тюрьма» < фар. *зиндāн* < авест. *zantu dan* «караӊгы җир, кара җир» сүзеннән. Dobr. III: 558.

**ЗИННӘТ** «дорогие украшения; роскошь» < гар. *зӣннäт* id.

Дерив.: **зиннәтле; зиннәтлә-ү.**

**ЗИНҺАР** «пожалуйста, ради бога» < фар. *зинһāр* «(Алла каһәреннән) саклан!» сүзеннән, чаг. сөйл. *зинһарыгыз* «сакланыгыз». Башта үтенечне түгел, нәрсәнедер эшләми калуны белдереп кулланылган.

**ЗИРА, зираки** кит. «так как; ввиду того, что» < фар. *зирā ки* id. Төрки телләрдә еш очрый. Тимергалин: 183.

**ЗИРАГАТЬ [зирағӓт]** иск. «сельское хозяйство; хлебопашество» ← гар. *зирā‘ат* id. ← *зр‘* «чәчү». Бу сүз тат. теленә кирәкле булган, юкка сөреп чыгарганнар. Тимергалин: 182–183.

Дерив.: **зирагатьче** «авыл хуҗалыгы эшчесе» һ.б.; **зирагатьчелек.**

**ЗИРАТ, зыярат,** (ЗДС: 200) **зәрәт** «кладбище» > мар. диал., удм. диал. *зират* id. < фар. *зийарäт-г'āһ* «зират, барып йөри торган җир; барасы җир» сүзеннән; гар. *зийāрат* «барып күрү, барып йөрү, визит», *г'āһ* «урын, төш». К. кит. *зыярат итү* «барып күрү». **Зират, зыярат** сүзе төрки телләрдә, хәтта мөселман булмаганнарда да киң таралган, к. хак. *сыырат* «зират». К. **Зиярәт.**

Дерив.: **зиратлы, зиратсыз; зиратлык ~ зәрәтлек.**

**ЗИРӘ, җирә** «тмин» (к. Иванова 1990: 110) ~ уйг. *зирә* id. – ачык түгел.

**ЗИРӘК** «смышлёный, сообразительный; догадливый, проницательный» > мар. кч. *зерäк,* удм. *сэрэк* («чая, тере») id. < уйг. *зерәк* < уйг., бор. төрки *сäргäк* (*с* > *з* бу очракта уйгур җирлегендә); к. диал. *зиргәк «зирәк»* ~ бор. монг. (Поппе 1938: 320) *sergek*, хак. *сиргек, сиргäк* «зирәк, сизгер». Каз., к.-калп. *зирәк*, кырг., төркм. *зейрек, зейрәк*, төр. *zeyrek* < фар., көрд. *зирак, зиирак*, ләкин фар. сүзе үзе төрки телләрдән булса кирәк. К. ш. ук эвенк. *сэргэк, һэргэк*, як. *сäрäх* «сак, уяу, зирәк», бур. *сээрэг* «сак; куркак».

*Зирәк* < **сәргәк* нигезе бор. төрки, монг., тунг. *сәр-, сәгәр-* «сизү, уяу булу, зирәк булу» сүзеннән (к. ССТМЯ I: 145, бик тәфсилле). Шуннан ук к. **Сәрин, Сәрмә-ү, Сиз-ү, Сискән-ү.**

**ЗИРЕК,** диал. **җирек, йерек** «ольха (Alnus)» ~ к.-балк. *җерк*, кырг., үзб. *зирк, зирик*, венг. *gyürü, girek* id. фар.-таҗ. *зирк, зирик* (> уйг., үзб., кырг., төркм. *зирк, зириқ, зириқ*) «барбарис» сүзеннән, төптә «үзеннән (кайрысыннан) алтын сары буяу алына торган агач» дигән сүз, к. фар., көрд. *zeriq* «алтын төс», *zerik* «йомырка сарысы», *zeri* «сарылык; алтын төсе» ← *zer, zär* «алтын».

*Зирек* < *зәрик* сүзе төрки телләргә күптән кергән, к. алт. *йурук, дьурук* «кедр» (аныӊ кайрысы да буяуга ярый), як. *сиһик* < *сисик* «зирек, тал (аныӊ кайрысы тире буяу өчен файдаланыла)» < **жизик* < *җирик.*

Дерив.: **зирекле; зиреклек.**

**ЗИРЕК-Ү (зирегү)** «отвращаться, отвратиться от чего» к. **Җирек-ү.**

**ЗИР-ЗӘБӘР** «суматоха; разгром», өлешләре аерым төрләнеп тә кулланыла: *зирен зәбәргә китерү* (к.

ТРС I 2007: 422). Ясәвидә (86 хикмәт): *пәйгамбәр... бер аһ орса галәм булыр зир вә зәбәр.* Фар. *зир-у-зäбäр* «ас вә өс» сүзеннән, ягъни «асты өскә килү».

**ЗИФА,** диал. **зиба** (Троянский I: 555, 558: *зиба, зифа* икесе дә бар) «стройный; красивый (станом)» < уйг., каз. *зипа* < фар. *зиба* «зифа, чибәр» ← *зиб, зәб* «орнамент; грация; чибәрлек».

Дерив.: **зифалык; зифалан-у.**

**ЗИҺЕН,** диал. (1988: 145) **зиген** «внимательность, ум» < гар. *ȥиһн* id., к. ТТРС: 132.

Дерив.: **зиһенле, зиһенсез.**

**ЗИЯДӘ [зийадә]** кит. «все более; весьма, чрезмерно», «добавление (в парных словах)» < фар. id. < гар. *зийāдä* «күбрәк».

**ЗИЯРӘТ [зийарәт]** «посещение святых (или – дорогих лично) мест; посещение могил святых, а также родных; визит» < гар. *зийāрат* id. ← *зwр* «изге җирләргә бару, йөрү», шуннан ук к. **Мазар.** Будагов I: 609 (*Һәм зиярәт, һәм тиҗарәт* мәкале шунда китерелгән). Räsänen 1969: 531–532.

**ЗОБАНИ** «служитель ада», күч. «злой угнетатель, тиран, изверг» < гар. *зүбāнӣ* id.

**ЗӨБӘРҖӘТ** «изумруд; смарагд» < гар. *зүбäрҗäд* < грек. *ҫμαραγδος* id.; рус. *изумруд* һәм *смарагд* икесе бор. бер сүздән киләләр. Шуннан ук *Эсмеральда* исеме дә килә икән. К. Смит: 308.

**ЗӨФАФ** «брачная ночь« < гар. *зүфāф* «кәләшнең кияү өенә килүе».

**ЗӨХАЛЬ** иск. «Сатурн». Якын Шәрык телләреннән, әлбәттә.

**ЗӨҺРӘ** «Венера (планета)» < гар. *зүһра* «чәчәк; нур чәчүче» *зһр* «нурлану, балку, ялтырау» сүзеннән.

*Зөһрә, Айзөһрә* тур. күп кенә легендалар бар. Айның кечкенә ятимәне үзенә алуы тур. легенда Идел-Урал регионында һәм хакасларда да бар (к. Унгвицкая, Майногашева 1972: 27–28). К. **Заһир.**

**ЗӨЯ [зөйә]** – река Свияга – чув. *Сĕве* id. < тат. диал. **Зүә.** Бу топонимны М. Фасмерның (III: 583) рус. *извиваться* «боргалану» сүзеннән чыгып аңлатмакчы булуы игътибарга лаек түгел (кайсы гына елга боргаланмый?).

**Зөя (Свияжск)** кальгасы элекке татар кальгасы урынына салынган. Ихтимал, Зөя тәүдә кальга атамасы булгандыр. Монда урта диалектта **Зөя,** миш. **Зеwә** булуы игътибарга лаек: мондагыча *й* ~ *w* тәңгәллеге *көянтә* ~ *кеwәнтә, сөя* ~ *сеwә, зөя* ~ *зеwә* дә шулар рәтендә торса, бу сүзнең нигезен бор. төрки телдән эзләргә кирәк. Һәм өстәвенә китерелгән фонетик закончалык чув. *Сĕве* варианты мишәрчәдән алынганлыгын сөйли.

Русча *Свияга* дигәнне мари топонимистлары *Севä йога* кебек тезмә сүздән дип аңлаталар. Моның белән килешергә була: төп мари телендә *йога, йуга* «елга» мәгънәсендә. Төньяк-көнч. Европада *-уга* ~ *-га* кушымчасына беткән елга атмалары шактый.

**Зөйә ~ Зүwә** дигәндә нишләп *з-* авазы килеп чыккан, дигән сорау да бер башваткыч. Чөнки бор. төрки телләрдә анлаут *з-* авазы булмаган, ул соңрак, төрле алынма сүзләр тәэсирендә генә килеп чыккан.

Тагын шуны да әйтик, **чуваш** сүзен *Зеwә* > *Сĕве* топонимына баглау, ш. ук **Зөя** сүзен Ерак Көнчыгыштагы **Зея** елга атамасы белән чагыштыру кызыклы түгел.

**ЗУБАНА, зумана** (ЗДС: 202) «зобня (корзина для охвостья)» ~ удм. *зубнё*, чув. *супне* id. < рус. *зобня* id. ← зоб «тамак, корсак, ашамлык токчае» сүзеннән.

**ЗУР** «большой», бу сүзнең тат. мәгънәсе фин, эстон телләрендәге *суур* id. сүзенә охшаш. Гом. көнб. төрки *зор* < фар. *зор, зур* «көч, көчлек; көчәнү, кыен» дигән мәгънәдә, ә менә бор. һинд-ир. *sūra*, бор. грек. *ҫор(α)* «көчле, зур». Димәк, тат. *зур* фар. теленнән алынмаган, бор. бер һинд-евр. теленнән үк килә! Тик себ. **зур** «көчлек» (**зурла-у** «көчләү, җәберләү», к. Тумашева 1992: 52) Урта Азия телләреннән.

Дерив.: **зурлык; зурлан-у, зурай-у** (дериватлары күп).

**ЗУРАТ,** диал. (ДС III: 58) **зурут,** себ. **сарут, сурт** (Тумашева 1992: 188) «стог; сарай для сена» ~ чув. *сурат, сорат, сурак* (Сергеев 1971: 109), удм. *зурод* «длинный стог», мар. *сорат* «стог из стеблей гороха» (Исанбаев 1978: 38), «стожары» (Упымарий: 192) < рус. *зарод, зарад* «киртәләнгән кибән; тигеле кибән» (Фасмер II: 105). Бу сүз рус теленнән Себер телләренә дә кергән, к. тув. *сараат* «кибән». Ахметьянов 1989: 55; Гаффарова 2007: 103–104.

**ЗЫБЫН,** диал. (ЗДС: 198, 562) **зыпын, запун, сапун, сыбын,** (Акъегетзадә телендә) **зәпүн** «зипун, суконная поддевка» ~ башк., удм. *зыбын, зывын* id., чув. *саппун* «алъяпкыч», *сăпăн* «хатын-кыз җиләне», мар. *сывын, сӗвӗн* яшел сукнодан тегелгән хатын-кыз җиләне, купшы кием» < рус. < ит. (Фасмер II: 98), ит. теленә – гар. *җүббүн* «җөббә» сүзеннән диелә. К. ләкин добр. *zıbın* «бәбиләр күлмәге»: бу сүзнең русчадан булуы шикле. К. ш. ук **Чоба, Юбка.** Рус. *зипун* тур. Юналеева 1982: 42–46.

**ЗЫЙ** «годичное кольцо или вообще узоры на срезе дерева; струя древесного волокна» > чув. *сăй*, мар. *шый, ши* ~ фин. *syy* [*сыы*], удм. *си* (Räsänen 1969: 260). Насипов 2007: 224.

**ЗЫЙТ, зит, зид** (написание не устоялось) «против, противо-» < гар. *ḍидд* «дошман як», чаг. *җүт* (?). К. ГТРС: 133.

**ЗЫК: зык кил-ү (кубу)** «шуметь, поднимать шум, галдёж» ~ башк. диал. *зыу* (*зыу сыгар-ыу, зыулау*) id., чув. *сăвă* «җыр, такмак», кырг. *суу* «мәҗүси дога», себ. *сыу-бал* «сыw һәм фал» – күрәзәләү (Тумашева 1992: 198), бор. төрки *сағы//сығы* «кешене дәфенләгәндә аның фазыйләтләрен бәян иткән җыр» > тат. **ыгы-зыгы** сүзенең икенче компоненты. К. **Ыгы-зыгы.**

**ЗЫКЫМ** «косвенное влияние» (Г. Гобәй) ~ фар. *захм* id. (*захми чашм* «күз тию»). Чаг. ш. ук добр. (Dobr. III: 553) *zıqqıt, zıqqın* «агу, зәһәр, бәла», төр. *zıkkım* «күп ашаудан чирләү». Һәр ике сүз < гар. К. **Зәхмәт.**

**ЗЫНҖЫР,** (ЗДС: 196, 263, 719, 772, 792) **җынҗыр, йынҗыр, цынтыр, цынцыр, чындыр, чынҗыр, шынжыр** «вериги; кандалы; цепи колодника, пленного» > чув. *сăнчăр*, мар. *шинчыр*, морд. *цинзер* ~ кырг. *зынҗыр, чынҗыр*, нуг., каз., к.-калп. *сынҗыр*, *шанҗыр*, ком. *шинҗир*, госм. *zincir* һ.б. (күп телләрдә бар) < фар. *зӓнҗӣр, зинҗӣр* id. дип исәпләнә. Dobr. III: 554

**ЗЫҢ** «дребезжание оконных стёкол; звук от пил в некоторых рабочих состояниях их» (чаг. ш. ук **чың**) ~ добр. (Dobr. III: 555) *zıñg* id. (шунда ук бу сүзнең дериватлары *zıngıl, zınyır* > рум. *zăngăni, zdrangani* id. күрсәтелә). Күп төрки телләрдә бар бугай, к. тат., каз., кырг. һ.б. *зың* – имитатив (*зың итү* һ.б.), **зың-зың** дәвамлы *зың,* **зыңыл-зыңыл, зыңгыл-зыңгыл** дәвамлы *зың*ны белдергән авазларга имитатив; **зыңылда-у, зыңгылда-у – зың** нигезендә имитатив фигыльләр. Диал. *зыңгырда-у* да бар. Чаг. рус. *дзинь, дзинь-дзинь* һ.б.ш.

**ЗЫҢКАР** (ЗДС: 203) «хворь; отклонение от нормального здоровья, а также от нормального поведения» < **зыянкәр** (к. **Зыян**) булса кирәк, чөнки дериваты **зынкарлек** дип әйтелә. К. фар. *зийӑнкӓр* «зыянлы, зыян итүче». Фонетик үзгәрешләр аңлашылып бетми.

**ЗЫР I** – подражание быстрому вращению > чув. *сăр* ~ каз., госм. һ.б. *зыр* id. Шуннан **зырыл** *(зырыл-зырыл), зырылда-у* һ.б. Имитатив. Dobr. III; 555–556 (күп дериватлар китерелә).

**ЗЫР II** диал. (ЗДС: 204) «замкнутый круг, замкнутая линия». Ачык түгел. Чаг. кр.-тат. *zır* «тоташ хәрби кием, көбә» < төр. *zırh* < фар. *zirih* Dobr. III: 555.

**ЗЫР III** (ЗДС: 204) «крашеная полоса» (в отличие от *сыр* «рельефная полоса»). Бу сүзне активлаштырасы иде. К. **Сыр.**

**ЗЫЯ [зы̆йа]** кит., иск. «просвещённость, интеллигентность» < гар. *ḍийӓ'* «яктылык» (каты *ḍ*-булганлыктан тат. *-ы-* языла).

Дерив.: **зыялы** «интеллигент» (**зыялылар** «интеллигенция»); **зыялылык** һ.б.

**ЗЫЯН [зы̆йан]** «вред» > удм., морд. *зыйан*, *ызъян, изъян*, мар. *зиян*, *сиян*, чув. *сиен* < фар. *зийӑн* < авест. *zyana* «кыенлык, зыян». Төрки телләрдә киң таралган сүз. Рус. *изъян* Балкан телләре аша төр. теленнән. Räsänen 1969: 531.

Дерив.: **зыянлы, зыянсыз; зыянла-у;** к. **Зыяндаш, Зыңкар.**

**ЗЫЯНДАШ [зы̆йандаш]** «эпилепсия; падучая» ~ чув. *сиенташ, сăянташ* id. уйг. *зийандаш* «корткыч; сихерче» < фар. *зийӑн дӑшт* «зыян иткеч, бозымчы». Зыяндаш, шулай итеп, «ырымчы җибәргән авыру-чир» була.

**ЗЫЯФӘТ [зы̆йафәт]** «торжественный пир, банкет» < гар. *ḍийӑфӓт* id., «туй мәҗлесе». **Изафә** сүзе белән тамырдаш.

# И

**И I** – төп төрки чыгышлы сүзләрнең нигезләрендә гом. төрки *е* ~ *ä*, кушымчаларда *-äj* [*-äу*] авазын белдерә. Бу аваз гом. төрки *э* < *ә* авазыннан Идел-Урал регионындагы бүтән төрки телләрдә дә (башк., чув.) очрый һәм (бер үк сүзләрдә) хак. телендә бар. Хак. *э* > *и* // *и* > *ĕ* тат. *ә* > *и* // *и* > *е* белән гомоген, бер үк чыганактан килә (бу фикергә каршы чыгучылар да юк түгел).

**И II** ы. 1) соответствует рус. *о, ай: и табигать* «о природа», 2) соответствует рус. *э: и, бу ни эш* «э, да что это такое» (Тат.-рус. сүзлекләреннән к.). Бүтән төрки телләрдә бу ымлыкның бердәм тәңгәллеге юк, тик башк., каз. *и* тат. *и*гә якын мәгъ. ия. К. ТРС I 2007: 428.

**И III, ий-** сөйл., диал. «хорошее расположение духа» (только в глагольных словосочетаниях), себ (Тумашева 1992: 52) «мягкость (в обращении)»: *и ~ ий бул-у, игә килү, ийе кил-ү*. Чаг. **Ий-ү.**

**ИБАЗ: ибазга бирү** «наказать», букв. «отдавать Ибазу», балаларны куркыту өчен әйтелә (ЗДС: 204). Бик ихтимал, төр. *ivaza vermek* «яхшырагына алмаштыру» сүзеннәндер. Төр. *ivaz* < гар. *'uwäḍ* «өстәмә биреп, яхшырагына алмаштыру күренеше», «товарга өстәмә».

Шул ук вакытта чаг. төр. *Ayvaza vermek* балаларны куркытып тынычландыру сүзе: *Ayvaz* төр. «курчак театрында – балаларны урлаучы юлбасар». *Ayvaz* дип хирургны, балаларны сөннәтләүчене дә атаганнар.

Ниһаять, бу **ибазга бирү** төбендә «өйбазга бәрү» мәгъ. булу ихтималы да юк түгел. Әмма тат. **бирү** белән **бәрү** асылда бер үк сүз булсалар да, хәзер беркайда да буталмыйлар бугай.

**ИБӘ** (ЗДС: 304) «подарок родственнику жениха» < гар. *һибä* «бүләк».

**ИБӘТӘЙ** диал. «всё в полном порядке, всё в ажуре (к приему гостей)» ~ баш. *ибәтәй* «килешлелек; иплелек», каз. *ебетей* «осталык», *ебдей* «елгыр, әмма ипле». Монг. сүзе булса кирәк (аффикс *-тәй!*). Чаг. **Ип.**

Дерив.: **ибәтәйле** «тактлы, ипле» ≈ рус. *обходительный.*

**ИБЛИС** «дьявол, сатана» > мар. *эвлес* id. (Исанбаев 1978: 48) < гар. *иблис* id. < бор. грек. *διαβολος* (> рус. *дьявол*) сүзеннән. К. ш. ук **Явыл.**

**ИБНЕ –** лексема со значением отчества: «-ич, -ович, -евич» < гар. *ибн* «ул; ир бала»; ш. ук мәгъ. **бин-**, **бәнат-** (хатын-кызга карата). Бу префикс татарларда да кулланылган.

**Ибне Адәм** «Адәм баласы (гөнаһлы бәндә мәгъ.)».

**ИВУК «**косуля, детёныш косули, лани, серны» < чыгт. *ивуқ,* бор. төрки (ДТС: 221) *ïvïq*, кадим сүзлекләрдә (Мухамедова 1973: 57) *айвуғ, айвуқ* id. Әдәбиятта **авык** дип язу очрый.

**ИГАНӘ** «пожертвование, лепта» < гар. *и'āнä(т)* id. Элекке тат. югары уку йортлары иганәләр ярдәмендә яшәгән һәм бу сүз актуаль булган.

**ИГӘМӘН** иск. «владелец» (к. мәкаль: *Ил өстендә игәмән*) – в отличие от **иләмән** – неофициальный. Төр. *egemen* id. сүзеннән (*ege* «ия»).

**ИГӘР, игар** (Троянский I: 160) **икәр** «гончая собака», диал. (ДС III: 21) **әкәр** «пёс; кот» ~ башк. (БҺҺ II: 320) *әгәр* «ата эт», «эт беләнн бүре кушылгагы», чув., удм. *акар* < болг. **әгәр* «ерткыч, усал эт» ~ ком., к.-балк. *эгер*, алт. (Баскаков 1972: 273) *эгер, эгир, инир*, шор., кр.-тат., чыгт. (Радлов I: 695, 711) *äгäр, äңгäр* ~ венг. *agar* «бурзай». Мәдәни сүз булса кирәк, к. осет. *йегар*, слав. *огар* һ.б. (Корнилов 1970: 188–189). Этләрнең аеруча кыйммәтле токымнары сәүдә шәе булган һәм аларның атамалары сәүдә юллары буйлап таралган. К. ш. ук Федотов I: 32.

**ИГӘРЧЕ**, диал. (ДС III: 59; ТТДС I: 142–143) **ийәрче, әгерҗе** «хлебец для поминок, хлебец из остатков теста; закваска, дрожжи», «творог» – Урта Идел регионына уртак сүз: чув. *икерчĕ* «коймак, белен, пәрәмәч», *йӑварчӑ* «әчетке, кур», мар. (Упымарий: 295; Иванов, Тужаров: 45; Саваткова: 228) *эгәрчэ, эгәрцэ* «солы коймагы», «тәбикмәк», «салма», морд. *игырҗа* «игәрче» ~ чыгт. (Радлов I: 1425) *игäрлик* «әче, әчеткеч» – бу сүзнең

параллельләре бүтән кыпч. телләрендә теркәлмәгән, веляр вариантта к. хак., алт. *аарчы,* тув. *ааржҗы* «эремчек, эркет» < бор. монг. *agarča, agarči* (хәз. монг. *аарц*), төр. *ağırtı* id. ← *ау//äg, eg* «ачы, әче» тамырыннан (шуннан ук к. **Агу, Ачы, Кәрче-ү**). Räsänen 1969: 37; ССТМЯ I: 53; Федотов I: 162; рус. *арса, арсун, арца, арчи* «эремчек; игәрче» (монг. телләреннән) тур. Аникин: 98–99.

Мәшһүр **Әгерҗе** шәһәренең исеме иске тат. теленнән.

**ИГӘТ** (ТТДС I: 142; ТТДС II: 97) «приданое в виде скота или надела земли» > мар. (Исанбаев 1978: 46) *игат* «бирнә» < бор. төрки (ДТС: 165) *egät* «яшь кәләшкә зөфаф кичәсендә хезмәт күрсәтергә җибәрелгән хатын-хадимә»; хәз. кыпч. телләрендә бу сүз күч. мәгъ. очрый: башк. *игәт* «(ата өчен) үги бала, иярчен», к.-балк. *эгет* «иярчен, вассал», үзб. *эгат* «буразна (китәсе кызга атап чәчелгән басу өлеше)», уйг. *игәт* «түтәл».

Сүзнең чыгышы безгә ачык түгел. Юдахинның кырг. *агет* «түтәл» сүзен ир. сүз диюе ышандырмый. Чаг. төр. *eğitmek* «тәрбия итмәк». К. **Ик-ү.**

**ИГӘҮ [игәw]** «напильник, подпилок» > чув. (Ашмарин V: 114) *йĕкев,* удм. *эго*, мар. (Исанбаев 1978: 40) *игäу, öгö* (к. ш. ук мар. *йага* < *йäгä* «кыска пычкы, игәү» ~ чув. *йага* «шомартылган, шомарган, шома») < гом. кыпч. *эгев* > үзб. *эгов,* чыгт. (Будагов I: 201) *икäк*, хак. диал. *игек, игег,* тув. *егее, öгöö*, бор. чыгт. (Зәмәхшәри: 17) *иигек* ~ төркм. (к. Мухамедова 1973: 93) *ииге, игэгү* id.; к. ш. ук як. *игии,* кр.-тат., госм. (Радлов I: 720) *äjä* ~ к.-балк. *йейе*, кырг. *эгө* һ.б. id. < бор. төрки *egä-, igä-* «игәү» фигыленнән. К. **Игә-ү.**

Дерив.: **игәүле; игәүлә-ү** (> **игәүлән-ү, игәүләт-ү**) һ.б.

**ИГӘ-Ү** «работать напильником, точить» < гом. кыпч. *эгә-* ~ хак. *иге-,* алт., тув. (Поппе 1938: 152) *eke-*, төр. *eğe-* «игәү, игәүләү» < бор. төрки (ДТС: 204) *ige-* id. һ.б. Бу сүзнең фонетик үсешендә аңлашылмаган моментлар (мәс., палаталь тирәлектәге *-г-*) тур. к. ЭСТЯ I: 326–328 (шунда ук әдәбият, фаразлар күрсәтелә). *Игә-* < *эгä-*, ихтимал, эвенк. *ирэүэ, иүирэ*, эвен. *иргэ* «игәү; игә-ү» сүзе белән тамырдаштыр (ССТМЯ I: 328–329), бу сүз исә бор. монг. *ig* «без, кылчык» сүзеннән; к. ш. ук тунг. (ССТМЯ I: 328–329) *ивэ-* < *һивэ-* < *пивэ-* «игәү» (бор. төрки *bi* – ДТС: 97 – «без, үткен кырый» сүзе белән чагыштырыла). К. ш. ук Räsänen 1969: 38; Федотов I: 190 (чув. телендә «игәү» мәгъ. исем генә бар, фигыле юк).

Дерив.: **игәл-ү, игәт-ү.** К. **Игәү.** Чаг. **Ик-ү II.**

**ИГӘЧ**, диал. (ТТДС I: 157; Рамазанова 1991: 24, 165–166) **иңәч** «ближайшая по возрасту родная сестра», «двойня» (**кайнигәч** «свояченица») ~ хак. *игечĕ,* үзб. (ЎХШЛ: 329) *эгәчи, әкәчи, әкәҗи* «апа, түти; ахирәт, тиңгенәй», чыгт., тат. (Будагов I: 201) *игач, агачи* «апа», *икачә* «җиянчәр, бертуганның кызы», чыгт. *äкäчи,* ком. *эгечи*, к.-балк. *эгеч,* төр. *egeç, egeçi*, *ekeçi* «игәч» < бор. монг. (к. Поппе 1938: 15) *egeçi* «апа» (нәсел-нәсәп терминнарында *-чи* кушымчасы монг. теленнән булу галәмәте) ~ тув. *эгече* «байбикә». Ихтимал, монг. сүзе төрки *эгэчэ* < *экэчэ* < *экэ эчэ* «өлкән апа» сүзеннән (к. **Әкә** һәм **Әчә**) үзгәргәндер. ЭСТЯ I: 222–224; Наджип 1989: 254.

**ИГЕ** (ДС I: 59) «хорошо, замечательно; добрый» ~ к.-калп., үзб. *ийги*, куман. *eygi*, уйг. *аги*, бор. төрки *äjgü,* төр. *iyi, eyü,* тув. *эки* «яхшы». Э.В. Севортян моны **изге** сүзе белән бердәй дип карый (ЭСТЯ I: 245–247), к. бор. төрки *edgü, eδgü* «изге; иге» (ДТС: 163–167). К. ш. ук чыгт. (Радлов I: 1507–1508) *иги* «иге; тәңре, фәрештә». К. **Әйе.**

**ИГЕЗ,** себ. (ЗДС: 76) **эгис** «двойняшки, близнецы; являющиеся двойняшками, близнецами» ~ кр.-тат. (Dobr. II: 7) *egĭz, ekĭz, ikiz,* каз. *егĭз,* чыгт., уйг. *экиз, эгиз,* гом. кыпч. *эгиз,* госм. *äkiz* (к. Радлов I: 682), төр. *ekiz*, бор. төрки *jekiz* ~ чув. *йĕкĕрĕш* (< **йĕкĕрĕсĕ*) «игез», *йĕкĕр* «ике япьле, икелекле», мар. *йыгыр, йегер* «игез» ~ венг. *iker*, монг. *икир, ихэр,* эвенк. *икирэ*, маньч. *икири*, бор. монг. *ikire* > як. *игирэ* «игез», к. ш. ук төр. *ikirçin-* «икеләнү, вәсвәсә». К. **Җекрәч, Ике.** Redhouse: 525; ССТМЯ II: 300; ЭСТЯ I: 252; Федотов I: 191–192.

**ИГЕЗӘК** «один из близнецов» < **игез-әк.** К. **Игез.** Тимергалин: 182 (гадәтенчә, тәфсилле тарихи-экстралинвистик аңлатма бирә).

**ИГЕН I** «хлеба (на корню)» > мар., удм. диал. *игын* id. ~ гом. кыпч. *эгин,* уйг. *экин, экин*, үзб. *экин*, төр. *ekin, ekim,* бор. төрки (ДТС: 168) *ekin* «чәчүле җир; чәчүлек» ← *ek-* «чәчү» >> чув. *ак-* «чәчү, игү», *акăм* «иген» Чаг. шумер. (Salonen 1968: 404) *ака* «иген игү, җир эшкәртү, җир багу». К. **Икмәк, Ик-ү.** Чаг. **Игет-ү.**

Дерив.: **игенле; игенче, игенчелек** һ.б.

**ИГЕН II, игин** (ЗДС: 205, 175) «плечи» < бор. төрки (ДТС: 166) *eŋin, egin, eŋgin, egnin* id. Бу сүз **иң** сүзе белән тамырдаш, күрәсең, ләкин ничек баглангандыр – әйтеп булмый.

**ИГЕРЧЕ, игырча** (ЗДС: 205) Себердә теркәлгән бу сүз рус. (Даль) *игрище, игрища* «җыенлы уеннар» сүзеннән һәм шул мәгънәдә, тик татарларда, сабантуй кебек, берничә авыл бер-берсенә чиратлашып барып бәйрәм итү төсмерен алган.

**ИГЕТ-Ү** диал., иск. «взращивать; воспитывать». Без бу тат., төр. сүзгә КБтә параллель таптык (бераз татарчалаштырылды):

*Огул-кыз түрәсә синең ай тиңен,*
*Эвеңдә игиткел, игетмә үңен,*

ягъни «айга тиң угыл-кыз үссә, өеңдә тәрбиялә, бүтәнчә тәрбияләмә». Хәз. төр. *eğitmek* «тәрбияләү» (шуннан киң кулланылышлы *eğitim* «тәрбия эше; тәгълим-тәрбия»). Чаг. **Ик-ү I.**

**ИГРЕ** диал. *Игре булганга да тугры бул* диелә, иск. [Ясәвидә *Надан кеше... Тугры әйтсәм игре юлга буйнын тулгара,* 13 хикмәт, һ.б. урыннарда еш кына] «криво, кривой; нечестный», «коленный сгиб, подколенник у коня» ~ гом. кыпч., үзб., уйг., төр., аз. һ.б. (Будагов I: 73) *эгри, эңри,* бор. төрки (ДТС: 166) *egri* «кәкре, кыек» < **эгриг,* к. төр. *eğrilmek* «бөгелгәләү» ← **egir-* «бөгү». **Эрлә-ү** < *эгирлә-у* белән тамырдаш (к. **Иер-ү I**).

**ИГЪЛАН** «объявление» < гар. *иʻлāн* id. ← *ʻлн* «белдерү» тамырыннан.

Дерив.: иск. **игъланнамә; игъланлы** һ.б.

**ИГЪТИБАР [ихтибар]** «внимание» < гар. *иʻтибāр* id. К. **Гыйбарә.**

Дерив.: **игътибарлы, игътибарсыз;** иск. **игътибарән** «искә алып, игътибарга алып».

**ИГЪТИДАЛ** «день равноденствия, равноденствие» < гар. *иʻтидāл* id. к. **Гадел.** Тимергалин: 187.

**ИДАРӘ** «управление, правление» < гар. *идāра* id. *dwp* «әйләнү» тамырыннан, шуннан ук *даир, даирә, дәвер, мөдир*, иске тат. **дийар** «өлкә; тирәюнь». К. **Даир.**

**ИДӘН,** диал., себ. (Тумашева 1992: 61) **идин, итан, итән**, крш. **идәм** «пол» > мар. *идем, йидем* id. ~ башк. *иҙән* «идән», чув. *итем* «ындыр табагы» ~ чыгт., үзб. диал. (Радлов I: 850; ЎХШЛ: 21) *әдән* «ишек төбе», нуг. *ыдан* «баз, чокыр, зиндан» (Ноғай халқ йырлары: 86) < *ӑрдаң, ӑрдӧң* «кырып тигезләнгән җир, җир идән, ындыр», к. **Ындыр.** Räsänen 1969: 167 (нуг. сүзен китерми). Федотов I: 201; Ахметьянов 1989: 56.

Дерив.: **идәнле, идәнсез; идәнлек.**

**ИДЕ** вспомогательный глагол «было» < иске тат. *ирде* < бор. төрки, гом. төрки *эрди* «булды, бар иде», к. **Ир-**. *Эди, әди* яңгырашы төрки телләрдә киң таралган.

**ИДЕЗ** (к. ЛС: 28) «мудрый; благостно-мудрый; степенный; тактичный» < чыгт. *эдиз*, куман. *ӓтиз*, уйг. *әдис*, чулым. *атис*, бор. төрки (ДТС: 163–165) *ediz, edüz, eδiz* «олпат, гали, акылдар», «угызларның бер кавеме» (> каз., к.-калп. *әдис, әдес* «хәйлә; әмәл»). Ачык түгел. «Кутадгу билик»тә *эдиз* конкрет мәгъ. «югары, биек; оҗмах». Чаг. уйг. *эдиз* «изге агач, байтирәк» (МНМ II: 537).

**ИДЕЛ,** себ. (Тумашева 1992: 36) **Әдил** «Волга (после слияния с Камой); большая (судоходная) река вообще» ~ гом. кыпч. *Эдил,* бор. төрки *Etil,* (ДТС: 163) *Edil* беренче тапкыр грек географы һәм тарихчысы Менандрда *Atel* яңгырашында 582 елда (VI г.) фиксацияләнгән, шуннан соң IX г. Византия тарихчысы Феофанда *Ατελ* яңгырашы теркәлгән (Федотов I: 69), аннары гарәп тарихчысы Ибн Рустәдә *ʻИтил* яңгырашында 903 елда теркәлгән. Чама белән шул ук чорда төрки язмаларда да очрый башлый. Шундый яңгыраштан чыгып, татар тарихчысы һәм язучы Г. Газиз *Идел* < *Әдил* сүзен гарәпчә *ʻадил* яисә *ӓʻдил* «гадел зат» дип аңлаткан (ул *Гадил буе, Гадил татарлары* дип яза, к. Маариф вә Мәдәният. Бакы, 1925, № 3. «Татарстанда мәдәни хәрәкәт» мәкаләсе), бу аңлатма рус телендәге публикацияләрдә дә очрый, ләкин Менандрның шәһадәте бу версияне юкка чыгара (VI г. гарәп теленең тәэсире бик аз булган). Тат. *Идел* һәм чув. *Атӑл* [*адыл* дип укыла] < **әдӗл* бор. төрки *этил*дән килеп чыкканнар (фонетик җәһәттән бу бик тә характерлы күчешләрне эченә ала). *Этил, Атель* «Идел» дип бор. венгрлар Днепр һәм Буг елгаларын да атаганнар, **Ателькузо** – «ике идел арасы» – венгрларның хәз. ватаннарына килер алдыннан яшәгән җирләре (к. Božilov, Dimitriv 1985: 50–58).

Ни хикмәттер, к.-балк. телендә Идел көтелгәнчә *Эдил* түгел, *Атил, Адил,* кабарда телендә *Андыл,*

адыгейча *Индыл*, ә ком. *Дол!* Уртада тартык аваз ит. вариантларда да күзәтелә: Барбаро һәм аның редакторы Рамузио (559 ел) *Эрдил* һәм *Ледиль* дип язалар (Барбаро и Контарини о России: 115, 135, 137, 152), алардан элегрәк яшәгән Марко Поло телендә Идел – *Һердил* дип атала (Книга Марко Поло: 252). Әгәр бу вариант бор. яңгырашны чагылдырса, *Идел* < *Эрдил* < *Эртил* гидронимы *Иртеш* < *Эртиш* гидронимы белән бердәй булуы ихтимал. Ф.Г. Гарипованың «Татарская гидронимия» (1998: 236–240) китабында Себердә *Итыл, Ателла* дигән елгалар барлыгы әйтелә. Төрки халыклар көнчыгыштан көнбатышка хәрәкәтләнгәндә юлларында очраган (һәм меридиональ юнәлештә аккан) зур елгаларны башта *Эртил* дип, соңрак (*л* > *ш* көчешеннән соң) *Эртиш* дип атаган булуы бик ихтимал (халыклар көченгәндә «яңа» географик объектларга үзләренең элекке урыннардагы атамалар бирү – типологик күренеш).

**Аттила** (һуннар башлыгы) исемен *Идел* белән бәйләүгә без шикләнеп карыйбыз: аны исбат итү мөмкин түгел. *Идел* сүзен төркм. *эдил* «нәкъ (урта)» белән баглау да шикле.

*Идел* күптәннән төрки мифологиягә кергән. «Угызнамә»ләрнең берсендә атаклы батыр *Алп-Эрән* икенче төрле *Этил-Алп* дип атала, к. Алияров: 19–27.

**ИДЕШ: идеш-табак** «посуда (всякая)» ~ үзб., уйг., төркм., чыгт. (Будагов I: 183) *idiş,* хак. *идис,* кырг. *ыдыш* > каз. *ыдыс* id. һ.б. бор. төрки (ДТС: 163, 203) *ediš, idiš, eδiš* «савыт, чүлмәк, бокал» һ.б. Калм. *idš* «ашамлык», як. (< монг.) *idäsi* «ашарлык ит» < бор. монг. *idesi* «ашамлык» ← *ide-* «ашау, туклану» белән чагыштыруны Рясянен (Räsänen) махсус рәвештә кире кага. Аникин: 219 (әдәбият күрсәтелә).

**ИЕЛӘ-Ү [ийѐлә-],** сөйл. **илә-ү** «выделывать кожу» к. **Ие-ү.**

**ИЕР-Ү I [ийѐр-]** (ЗДС: 185–186, 206), ш. ук **игер-ү, йегер-ү** «прясть, сучить; крутить». Бу *ийер-ү* варианты гом. төрки планда киң таралган, к. тат. диал. *игрек* «кәүсәсе боргаланган (агач)», чыгт., аз., төр., һ.б. *игирмәк, иңгәрмәк* «эрләү, бөтерү», (Будагов I: 201, 202) *игри, эгри, әгри,* бор. төрки (ДТС: 165–166) *egdü, egri* «кәкре; борылган» (ш. ук «ялган, алдак»), *egrik* «иерек, җеп эрләгәндә төерләнгән төш», *egril-* «иерелү, бөтерелү; өермәгә әләгү», *egriš-* «бөтерелеп әйләнү».

Рус. (Аникин: 225) *ирчик* «колёсико для сучения пряжи» мөгаен тат. **ийерчек, иерчәк** (мин бу сүзне ишеткәнем бар) һәм арытабан, Аникин әйткәнчә, хак., алт. диал. *иирчек* [*irčäx*] ~ бур. *ээрсэг* «орчык, эрләгеч, бөтерчек» сүзләреннәндер, һәм арытабан яз. монг. *egerčeg* «бот сөягенең оча сөяге уемындагы түгәрәк башы» (> як. *iärčäx* «бот төбе буыны, шарнир». Бу сүзләрнең нигезе бор. төрки (ДТС: 166–167) *egir-* «эрләү, җегерү, әйләндерү», ш. ук «урау; әверү; каеру». К. **Эрлә-ү.**

**ИЕР-Ү II [ийѐр-]**«размягчать шкуру (как первый этап обработки)» > чув. *ир-* id. *ие-ү* фигылennән йөкл. юн. (*ие-р-*, чаг. *ки – киер-, ти – ти-ер, чөй – чөер-*). К. ш. ук тат. диал. **ийерек** «тире йомшарткыч камыр», каз. исә – «эшкәртелә торган тире», к. Будагов I: 188. К. **Ие-ү.**

**ИЕРЧӘК [ийѐрчәк]** диал. «прясло, пряслица, пряслень» (җеп катканда, бөтергәндә орчыкны авырайту өчен кидерелгән таш яки чуен балдак) ← *иер-ү, игер-ү* (к. **Игер-ү**) фигылennән. К. **Иер-ү I.**

**Иерчәк** еш кына *орчыкбаш* дип атала.

**ИЕ-Ү [ию]** «размягчаться (о вымени); облезать и размягчаться (о коже); размягчаться вообще» (себ., к. ДС I: 66); чаще употребляется дериват этого глагола – **иегән** «йоны коелган».

**Иѐ-, ий-ѐ** «йомшару» тат. диал. (к. Тумашева 1992: 52), каз., к.-калп. *ий* «эшкәртелгән, йомшарган тире, күн» < бор. *ej, еδ, ed, er* (к. **Әйбер**) «күн, эшкәртелгән тире» сүзеннән ясалган фигыль. Бор. төркилектә тире эшкәртү иң беренче дәрәҗәдәге әһәмияткә ия булганлыктан (кием-салым һәм савыт-саба башлыча тиредән эшләнгән), бу тамыр бор. заманнарда ук бик күп семантик дублетлар һәм дериватлар биргән, к. төркм. *ей*, кырг., ком. *ий*, тув. *ет* «тире иеләгеч состав», к.-калп. *ий* «иеләнгән» һ.б. К. ЭСТЯ I: 236–237.

**Ие-** фигыленең интенсивлык формасы *ие-лә-ү* һәм турыдан-туры *ий* < *эйдән* ясалган **ий-лә-ү** – паронимнар. К. бер яктан, тув. *идээ* «иеләгеч», *идээлэ-* «иеләү» ~ бор. монг. (Поппе 1938: 151) *edele-* «иеләү», икенче яктан, гом. төрки *ейле-, йилә-* > тат. диал., уйг. *әйлә-*, тат. диал. *илә-* id. К. ш. ук өченче пароним – **Иер-ү.**

*Иѐ-* фигыле дә «иеләү» мәгъ. була ала, к. гом. тунг. *ид-* «тирене йомшарту, челен кыру» (ССТМЯ I: 394). К. ш. ук Räsänen 1969: 35 (күп материал бирә).

Тат. әд. телендә **илә-ү** «иләк белән иләү» һәм **иелә-ү** «тире иеләү» аерылып торса хәерлерәк. К. ш. ук **Әйлә-ү, Ийче.**

**ИҖАБ, иҗап** «принятие предложения, согласие выйти замуж» < гар. *ūҗāб* id., иске терминологиядә *иҗабү-кабул* – парлы сүз (ГТРС: 192, *иҗабе-кабул*, бу язылыш дөрес түгел) – «хатын-кызның кияүгә чыгарга рәсми ризалыгы». К. **Иҗаби.**

**ИҖАБИ** «положительный (о герое)» < гар. *ūҗāбū* id. *wҗб* «кабул итү, килешү» тамырыннан, шуннан ук **важиб** «кирәкле гамәл, гамәлләрнең мотлак өлеше».

**ИҖАЗӘТ** юг. «разрешение; позволение; доверенность» < гар. *иҗāзāт* id., к. **Җаиз.**

Дерив.: **иҗазәт бирү; иҗазәт итү** (*иҗазәт итәм* «ихтимал дип саныйм»); **иҗазәтнамә** «аттестат».

**ИҖАТ** «творчество» < гар. *ūҗāд* id. *wҗд* «төзү, бар итү» тамырыннан; шуннан **иҗади, иҗадият** «иҗатчылык». К. ш. ук **Вөждан** (төптә «конструктив ястау; конструктивлык»), **Вөҗүд**.

Дерив.: **иҗатла-у; иҗатчы, иҗатчылык.**

**ИҖЕК,** иск. **иҗү,** себ. (Тумашева: 62) **ицә** «слог (лингвистический)» – кайбер телчеләр бу сүзне төр. < гар. *ħāҗҗā* «иҗек» сүзеннән «бозылган» диләр (к. Будагов I: 180), ләкин, безнеңчә, бу дөрес түгел, чынлыкта иҗек бор. төрки *üžik, üžük* «иҗек, хәреф» сүзеннән (к. ДТС: 631), к. тув. *үжүк* «хәреф» ~ бор. кыт. *dz'iәg* > хәз. кыт. *цзый* «хәреф, иероглиф» (к. **Чый**), бу тур. к. Poucha: 191.

**ИЗА, ыза** «мучение, страдание» ~ ком., чыгт., уйг., бор. төрки *иза,* үзб. *изо*, нуг., каз., к.-калп., кырг. *ыза* «оят, оятланыш; җәбер, җәберсенү» < гар. *ūʒā'* (Радлов I: 1537).

Дерив.: **изала-у, изалан-у, ызала-у, ызалан-у.**

**ИЗАР** «женская рубашка, повязка на живот; очень широкий пояс» – «хатын-кыз күлмәге; мунчада киела торган күн алъяпкыч; бик киң билбау» < фар. *эзāр* id. К. **Эзәр.**

**ИЗӘ-Ү** «кивать (головой, рукой)» ~ нуг. *ийзе-*, кырг. *ийсе-*, каз. *изә-, изе-* id., ш. ук. (Радлов I: 1537) «тупас пычак белән ышку». Күрсәтелгәннәрдән үзгә параллельләре юк бугай. Каз. *изәк, изек* «изәү хәрәкәте», *изекте-* «кат-кат изәү» сүзе бар. Ышанычлы чагыштыруны Рясянен (Räsänen 1969: 176) да тапмаган. К. **Икчә-ү.**

**ИЗГЕ** «священный», «святой» ~ уйг., бор. уйг., чыгт. *äзгӳ* (к. Боровков 1963: 70), үзб. *эзги, эзгу* «яхшы, изге» < бор. төрки *äδgü* ~ уйг. *этку* «изге, яхшы» < бор. төрки *et* < *ed* < *еδ* < *ez* ~ **er* «эшкәртелгән тире, күн; мал, байлык» сүзеннән килеп чыккан дип исәпләнә, к. **Әйбер, Иге, Ие-ү.** К. Радлов I: 844; Räsänen 1969: 36; ЭСТЯ I: 237–241; Тимергалин: 189–191 (изге урыннар тур. тәфсилле очерк).

Дерив.: **изгелек; изгеләрчә.**

**ИЗЕН** «разрешение, позволение» (к. Будагов I: 21) ~ башк. *иҙен,* нуг., каз. *ызын* id. < гар. *иʒн* id.

**ИЗРӘ-Ү** «разлагаться; развариваться; развалиться в изнеможении (о человеке)» – **из-ү** фигыленнән ясалган (чаг. *җәю – җәйрәү, көю – көйрәү* һ.б.ш.).

**ИЗҮ [изĕw]** «разрез, украшенный вырез на груди платья, рубашки» > чув. *исү*, мар. *изү* < гом. кыпч.: нуг. *эзүв*, к.-балк. *эзүү,* каз. *езу*, к.-калп. *йезу* > үзб. *езув* id. < **эзиг* id. ← *из-, эз-//ыз-* «зигзаг ясап тегү, җөйләү» сүзеннән исем фигыль формасы, к. каз. *iз-* «җөйләү», тат. диал. *ыз-у* «зигзаг ясау, зигзаглап сөрү, сөргәләү» < бор. гом. төрки **йырг-* id., к. чув. *çăр-* < **җыр-* < **йырг-* «ызу», шуннан *çăрăх* «изү» << **җырыг* id. (болг. сүз). К. ш. ук себ. (ДС I: 65) *исү* «авызның ике як чите» ~ каз. *езу* id. Räsänen 1969: 53 (*изү* сүзен бор. төрки *еδ* «күн» сүзенә нисбәтли).

Дерив.: ***измә** > бисермән. (Тепляшина: 46) *изма* «ишелгән киндерә, шнур шикелле чигү җөе» > чув. *исме* «изү бавы», чаг. **Ызма** (асылда бу сүз изү ачыклыгын шнурлап-зигзаг ясап тоташтыруны белдергән), к. ш. ук «Нәһҗел-фәрадис»тә: Мөхәммәт пәйгамбәр кызы Фатыйманы никяһка киендергәндә «*үзмә үзмәк* өчен бакырлы сырча (ялтыравыклы шнур)» әзерлиләр; **изүчә** > мар. (к. Исанбаев 1978: 34) *эзуча* «хатын-кыз киемендә бизәкле ызма, ызманы имитацияләгән бизәкле күкрәкчә». К. **Ызан.**

Дерив.: **изүле, изүсез, изүлек; изүчә** (аеруча бизәкле изү төре).

**ИЗ-Ү** «толочь; мять; месить; раздавливать», күч. «жестоко обращаться, эксплуатировать» < гом. кыпч. *эз-* id. ~ уйг., угыз. *әз-* (к. Радлов I: 887;

ЭСТЯ I: 235–236) id., бор. төрки (ДТС: 192) *еδ-, ez-* «хайванның тиресен сую» һ.б. (бу сүзнең мәгънә диапазоны бик киң); М. Рясянен (Räsänen 1969: 52) аны монг. *erü-* «казу» белән чагыштыра. Чув. *ир-* «изү» сүзен тат. *из-* белән чагыштыру (Федотов I: 170) шикле, чөнки ул чув. сүзе < тат. *иер-* (к. **Иер-ү**) булса кирәк.

Дерив.: **изел-ү** (бор. төрки *ezil-* «изелү, бозылу»), **изеш-ү, издер-ү; изгеч; измә; изүче** («эксплуататор» мәгъ.) һ.б.

**ИЙ-Ү (ию)** (Тумашева 1992: 49, 164; миш., Ставрополь өлкәсендә, без теркәдек. – *Р.Ә.*) «посылать, послать» < гом. кыпч., алт. *ий-* (> тат. диал. (гәй.) *эй-*, к. БҺҺ III: 218) id. < бор. төрки (ДТС: 217, 221) *ıd-, ıδ-, it-, iz-* > алт. диал. *ыз-* > хак. *ыс-*, тув., як., уйг. *ыт-* id. ~ бор. монг. *ıtı-* (к. Рамстедт: 110). ЭСТЯ I: 332–333; Федотов II: 503.

Дерив.: себ. **ийәр-** (>> чув. *яр-* «җибәрү, күндерү», *ер-* «ычкындыру, таркату»), к. **Җибәр-ү.**

**ИЙЧЕ, ийце** (Тумашева 1992: 53) «скорняк» ~ каз. *ише* id. *ий* «иеләнгән тире; иеләр өчен сеңәл – сыекча» сүзеннән, к. **Ие-ү, Иер-ү.**

**ИК** (*иге дә юк, чиге дә юк; иксез-чиксез*) «край, конец» ~ госм. (Радлов I: 674) *äк,* төр. *ek* «кырый, җөй; яра кырые; яка; өстәмә аффикс» ~ монг. (Ramstedt 1949: 76) *eg*, калм. *ēg* «кырый, алдагы, җитәсе чик» ~ кор. *jek* id. К. төркм. диал. *эк, эң* «ераклык, горизонт». Чаг. **Иң II.**

**ИКАЗ** иск., кит. «предупреждение, предостережение». Рус. *указ*га охшаш бу сүз асылда гар. *īқāẓ* «кисәтү, искәртү» (төп мәгъ. «уяту, йокыдан торгызу») сүзеннән килә.

**ИКАМӘТ** иск., кит. «определённые формулы, произносимые перед намазом»; «прописка; проживание в определённом месте» < гар. *иқāмäт* id. ← *қwм* «нык тору, басып тору». Иске әд. телебездә *иқамәт итү* «яшәп яту, дөнья көтү» тәгъбире киң кулланылган. К. **Кыям.** Будагов I: 67. К. ш. ук **Камәт.**

**ИКӘН**, иск. **иркән,** диал. (ТТДС I: 144; Тумашева 1992: 52) **икә, икәй, игән** «оказывается, что; надо бы, желательно» > чув. *иккен,* удм. *эке* (?) id. ~ гом. кыпч. *экән*, уйг. *экән, әкән*, угыз. *икән* < бор. төрки (ДТС: 179) *erkän* id. (гомумән, бу сүзнең мәгъ. диапазоны киң) ← *er- [эр-]* «булу, бар булу» фигыленең «кыпчакча» сыйфат фигыль формасыннан.

**ИКӘҮ [икәw]** «вдвоём; двое» < бор. төрки *ek-kägü* «ике данә (*gä – данә*)» сүзеннән. Бу сүз аеруча тат. телендә актив кулланышта.

**Икәүләп, икәүләшеп** фигыльләре киң кулланыла. Добр. *ekew, ekewleşmek* һ.б. безнең татарчадан бугай. К. **Ике.**

**ИКӘЧ** (Батырша телендә) «если так, то» < бор. төрки **erkäč [эркәч]* «булгач» ← *эр-* «булу», к. **Икән.**

**ИКЕ** «два» > чув. *иккĕ, икĕ* < гом. кыпч. *эки,* кырг. диал., алт. *экки* (Радлов язылышында *äкка*), хак. *ĕккĕ,* уйг. *иги, эги* > тув. *ийи* < бор. төрки (ДТС: 167–168) *eki, iki, ikki* һ.б., к. ЭСТЯ I: 337–338; Федотов I: 162–163 (бу автор чув. яңгырашы татарчадан икәнлеген әйтми). Сүзнең мәзкүр чыганакларда Г. Рамстедтның (1957: 65) бор. төрки **ek-* < **hek-* < **pek-* «иярү, икенче булу» фигыленнән ясалган дигән фикере китерелә. К. ш. ук **Игез.**

Дерив.: **икеле** (төрле мәгъ.), **икесез** (*сәгать икесез*); **икелек; икелә-ү; икеләи-ү, икеләт-ү; икеләч; икенче** («бүтән, бүтәнчә» мәгъ. дә кулланыла), диал. **икәм** «икенче» һ.б. К. **Икенде.**

**ИКЕНДЕ** «время перед заходом солнца» < гом. кыпч. *экинди* (ком. *экинни*), төркм., госм., аз. *икинди* < бор. төрки (ДТС: 168, 206) *ekinti, ikindi* «икенче (намаз), гомумән икенче (*ikindi aj* «икенче ай»); бор. *pegimte* «иң якын вакыт» сүзеннән (Рамстедт), дигән фикер бар. К. **Ике.** Будагов I: 200.

**ИКМӘК**, диал. (ДС II: 89, 225; ТТДС I: 557, 571) **итмәк, үкмәк, үпмәк,** себ. (Тумашева 1992: 61, 228, 231) **итмәк, үптәк, үптөк, үтмөк** «хлеб; хлеба» ~ бор. төрки (ДТС: 175, 188, 393) *ertek, etmak, ötmäk*, чыгт. ~ яз. монг. (Поппе 1938: 67, 279) *etmek, ötmek* > төр., аз. (Будагов I: 200) *этмек, үтмек, өпмек* һ.б. күп вариантлар (к. ЭСТЯ I: 254–257, ләкин анда да барысы да искә алынмаган). Тат. *икмәк* ~ угыз *экмәк* (төр. *ekmek*) варианты *ик-* «игү» фигыле тәэсирендә халык этимологиясе буенча килеп чыккан, төп варианты бор. (МК) *ertek* һәм ул сүз тат., башк. *әпәй, ипей* > *ипи* (к. **Ипи**) сүзе белән тамырдаш дигән фикер бар (Э.В. Севортян).

Дерив.: **икмәкле, икмәксез; икмәкче.**

**ИКСЕЛ-Ү** (только в молитвах и фразеологизмах) «уменьшаться, убывать» ~ чув. *иксĕл-* (а также *иксерт-, иксет-*), гом. төрки *екси-* < *егсу-* «кимү,

бетүгә якынлашу» фигыленең төш. юн. (к. ЭСТЯ I: 257–258), бу фигыль исә бор. төрки, төр. һ.б. *eg, ek* «чик, кырый» сүзеннән булса кирәк, к. **Ик.** ДТС: 168, 382 (*öksü-* варианты күрсәтелә); Räsänen 1969: 39.

**Иксе-ү** фигыленнән тагы тат. (дини һәм диал.) **иксек** «бетә башлаган» сүзе ясалган. Бу сүзнең элегрәк тат. телендә киң кулланышта булуына мар. *экшык* «җитешсезлек; афәт, каза» сүзе шаһитлык итә. Федотов I: 163.

**ИК-Ү I (икте, игү)** «заниматься хлеборобством; посеять и ухаживать за посевами» < гом. төрки *эк-, äк-* (к. Радлов I: 674) > чув. *ак-* «чәчү, утырту; тудыру»; чув. (> мар.) *ака [ага]* < **экәк* «сука, сабан» бу сүзнең «сөрү» мәгъ. дә булганлыгын күрсәтә: чаг. шумер. *ака-* «игенчелек белән шөгыльләнү». ЭСТЯ I: 251–252; Федотов I: 31; Ахметьянов 1989: 51.

Дерив.: **игел-ү, иктер-ү.** К. **Иген.**

**ИК-Ү II (икте, игү)** диал. «тереть, протереть (фрукты, картофель) в массу» (к. ТТДС I: 143) – **игә-ү** сүзе белән тамырдаш булса кирәк.

Дерив.: **иккеч** «тишекле кыргыч».

**ИКЧӘ-Ү,** диал. (Тумашева 1992: 54) **иксә-ү** «качать головой (о лошади)», (БТДҺ: 95) **иксә-ү, икшә-ү** «кайчы белән эшләп тору (туктаусыз ачуkысу)» ~ кырг. *экче-,* алт. *екче-, äксĕ-*, алт. *äкчä-* > каз., к.-калп. *икше-, екше-* «кат-кат беришле хәрәкәтләр ясау (игәү, иләү, кат-кат селкетү һ.б.)», хак. *ике-, иксе-* «икчәү; иләк белән иләү» > «сайлау; сайлап алу». ЭСТЯ I: 258–259. К. **Изә-ү.**

Бу сүз белән, ихтимал, тат. диал., башк. (Тумашева 1992: 54, БТДҺ: 96) **икше-ү** «кыланчыклану», себ. (Радлов I: 686) *äкцä-у* «тетрәнү; ярсыну, ярсыту», башк. диал. *иксе-ү* «шәһвәттән тетрәнү, бик бәдәнле ир күргәч хәлсезләнү (хатын-кыз тур.)» сүзе гомогендыр. Чаг. ш. ук алт. (Räsänen 1969: 38–39) *äкčä-* «кылану», каз. *ekci-* «җилкенү» һ.б.

**ИЛ** «страна», диал., фольк. «деревня, село» (ЛТ I: 77; ДС III: 59–60) «мир, мирно, дружно», (Тумашева 1992: 54) «народ, племя» > мар. *эл* < гом. кыпч., гом. төрки *эл*, аз. *әл*, угыз. *ил, или* «ил; халык» (к. Будагов I: 203–204; Радлов I: 803, 805; ЭСТЯ I: 339–343). К. ш. ук Мухамедова 1973: 94; Гумилёв 1993: 100–102; Ахметьянов 1989: 107.

**Ил** сүзе (нәкъ тат. яңгыраешта) б.э. кадәрге Үзәк Азия һуннары теленнән үк билгеле. Һәм шул чакта ук «төзек дәүләт, тыныч юл» мәгъ. булган. Тат. сөйләшләрендәге *ил* «тынычлык, иминлек» мәгъ. (дөнья хәлләре турында «илме – яумы?» дип сорау һ.б.) Урхун язуларындагы *ил такы (тагы) ил болды* җөмләсендә чагылыш таба. Тат. сөйләшләрендәге *ил-көн* «илдәге барча кешеләр җөмләсе (рус. *население*)», *ил-күз* «илдәге барча эшче көче (салым түләүчеләр)», *ил-су* «дәүләтнең цивиль халкы һәм армиясе» сүзләре дә бор. төрки дәүләтләрдән килә. Болардан тыш, тат. һәм башк. телләрендә *илу* «волость, урта зурлыктагы административ берәмлек», *иләү* «җәмәга, община» һәм монг. теленнән кергән *ил-ат* (дөресе *илят*, *илат* – монг. «илләр») «илдәге барча халык» һ.б. дәүләтчелеккә даир сүзләр бар (к. аерым матдәләр).

*Ил* < *эл* сүзе белән эвенк. *илэ* «кеше; кунак» сүзе чагыштырыла (ССТМЯ I: 311). К. ш. ук монг. *ил* «дус».

Тат. телендә *-дар* фар. кушымчасы ярдәмендә **илдар** «иле булган кеше, ил гражданы» сүзе ясалган. Шундый эчтәлекле сүзне, кызганычка каршы, рәсми кулланышка һаман кертеп җибәрмибез.

Борын-борыннан килгән **илче** сүзе кайбер чорларда «идарәче» мәгъ. дә йөргән. Аның төп мәгъ. «тынычлык яклы, тынычлык урнаштыручы». Бу сүздән *илчелек* һәм *илчеханә* сүзләре ясалган.

Гомумән, сүзьясагыч нигез буларак, *ил, эл* төрки телләрнең барысында да киң кулланыла. Бу сүз үзе төркиләр белән күрше булган бик күп халыкларга (шул хисаптан марилларга да) үтеп кергән, һәм аның турында исәпсез күп мәкаләләр язылган.

*Ил* – борынгы язмаларда *ӣл, э̄л* озын сузык белән килә. Бу хәл ошбу сүзнең әүвәле озынрак бер сүздән кыскарып хасил булганлыгына ишарә итә кебек. Räsänen 1969: 39 (монда ике сүз кушылып киткән ди).

Һиндстанның көньягында яшәгән дравид халыклары телендә *ил* «өй, йорт» дигән сүз. Ләкин бер генә иҗекле булуы сәбәпле, аның төрки *ил* белән бердәйлегенә инануы читен. Төрки халыкларның төп ватаны Инд дәрьясы буендагы Хараппа цивилизациясе (б.э.к. 3–2 меңъеллыклар) булган, шуннан анда һинд-европалылар бәреп кергәч, төркиләр төньякка качкан, дип уйларга мөмкин, әлбәттә. Хараппалылар шумерлар белән кардәш булган. Төрки-шумер сүз уртаклыклары шул юл белән аңлатыла ала.

**ИЛАҺ** «божество, бог» < гар. *илāҺ* id., аккад-шумер яз. теленнән килә. К. **Илаһи.**

**ИЛАҺИ** «божественный; божественность» (к. Будагов I: 85–86) < гар. *илāһū;* бу сүзнең «гимн; шигырь» (тат. әдәбиятында *илаһи бәет* «гадәти Шәрык шигъриятендә каралмаган шигырь» жанры) мәгъ. бар; к. ш. ук **илаһият** «Аллага багышланган, Алла хакындагы әсәр; теология» < гар. *илāһийāт* id.

Дерив.: **илаһилык.**

**ИЛӘ, илән** иск. «вместе с…, посредством чего» < кар., уйг., үзб., төр. һ.б. *ile, ilen, ilän* id. < **ikilen* «икәүләшеп», чаг. **белән** < **берлән**. К. бор. төрки (ДТС: 206) *ikilä* «икесе дә, икесе бергә».

**ИЛӘК** «сито», диал. (Тумашева 1992: 54) **илгәк** > удм. диал., мар. диал. *иляк, илек* < гом. төрки *әләк, äläk*, уйг. *әгләк* < бор. төрки *elgek, elgäk* ~ монг. *элкэг* id. бор. *elge-* «иләү», *elig* «кул» сүзеннән (*илә-ү* «куллану, кул белән селкетү»). Чаг. чув. *ала* «иләк» < **әлә, *әләг, ала-, алла-* «иләү» < болг. **әллә-ү*. К. **Илә-ү.** Тимергалин: 194 (тәфсилле тарихи-этнографик аңлатма бирә).

Дерив.: **иләк иләү** дигәндә **иләк** «иләнәсе нәрсә». Гомуми дериватлары күп.

**ИЛӘМ** «красота, благолепие» ~ чув. *илем* id. (к. Федотов I: 164), ихтимал, гар. *äл-äййāм* «матур көннәр» сүзеннән, к. **Ямь.** Гомумән, табышмаклы сүз.

Дерив.: **иләмле** «ямьле», **иләмсез** «бигрәк, ямьсез, артык (зур һәм ямьсез)».

**ИЛӘМӘН** «общественный деятель» ~ башк. *иләймән, илүмән* «хөкемдар, башлык», к.-балк. *элемен* «иләмән; әкият персонажы – хәзинә каравыллаучы, әзмәвер», үзб. *эламан* «каравылчы» < гар. *äл-äмāн* «әманәтче, иминлекне тәэмин итүче; полиция» сүзеннән бор. алынма. *Ил* сүзенә нисбәт ителгән. Чаг. ш. ук иске фар.-төр. *älätan* «алманнар (нимесләр), швейцарлар» – алар Европада гына түгел, Шәрыктә дә сарай каравылчылыгы вазифасын башкарганнар. Татарлар бу сүзләрне *ил* белән багланышта аңлаганнар. К. **Ил, Илү.**

**ИЛӘН-Ү** «привыкать; повадиться» < **иялән-ү** дип уйларга мөмкин; ләкин диал. (Гиганов) *илән-ү* «аптырату, җиләтү» ~ чув. *илен-*, алт. диал. *алäн-* «иләшү» бу фаразга шик төшерә. **Илән-ү** < *иллән-ү* булырга да мөмкин (тат. диал. *ил* «юаш, яратуга мәелле» сүзеннән, элек *илме-яумы* дип беренче очрашкан батырлар бер-берсеннән сорашканнар; *ил булу* «тынычлану, күнегү»), к. диал. (ТТДС I: 143–144) *ийек-ү* «иләнү, иләшү», *иенке, илем* «кеше яратучан, илгәзәк» һ.б.

Чув. *илен-* сүзен (тат. *илән-* сүздәнлеген искә дә алмыйча) гом. төрки *илин-* «эленү» сүзе белән бәйләү (к. Федотов I: 164) бөтенләй дөрес түгел.

**ИЛӘҢНӘ-Ү** диал. (Тумашева 1992: 54) «колебаться в глазах (о чем-либо очень удалённом)» ~ каз. *елеңде-*, кырг. *эленде-* «алаңлау, алан-йолан карану» ← *элең* «игътибар» – *иләс* сүзе белән баглы булса кирәк.

**ИЛӘПӘН** (ТТДС I: 145) «рыхлотелый, жирный». Чаг. **Илбәк.**

**ИЛӘС** «призрак, привидение, галлюцинация, бред»; күч. «призрачные надежды» (*иләс-миләс* «питающий призрачные надежды») ~ чув. *элес-мелес* «җен төсле; ялбыр чәчле» < *иле-миләс* «ямьсез, шөкәтсез», кырг. *элес* «үләксә; өрәк», *элес алган* «иләсләнгән», каз., к.-калп. *елес*, кырг., алт. *элес, элет* «силуэт; өрәк, күренгән җен», к.-калп. *елесле-*, кырг., алт., тув. *элесте-* «күренеп кую, күзгә күренү (булмаган нәрсәләр тур.)», уйг. *әләс* «кылый күзле (җен кебек)», як. *элес, элэс, äläс* «күз алдыннан җилпелдәп үтү», *Элясь батыр* «абзар иясе – химаяче рух» һ.б. < бор. төрки **әләс* < **әләз* «өрәк» *эле-* «булмаган нәрсә күзгә күренү» фигыленнән, к. каз. *еле-,* кырг. *эле-* «күреп алу», кырг. *элөө, элең* «игътибар; киеренке рәвештә карану», башк. диал. (БҺҺ II: 248) *илеү* «сөкәт, сыер сaудырсын өченге бозау сыман фигура» ~ гом. монг. *elie* «очып йөри торган рух, очкалак» (Poppe 1955: 45), ш. ук «козгын, лачын һ.б. тиз очучан ерткыч кошлар» (төрки-монгол мифологиясендә мифик образларны реаль хайваннар, җәнлекләр белән бутау еш очрый, к. **Төлке, Шәүлегән**). К. **Иләңнә-ү, Илер-ү**. ЭСТЯ IV: 263 (мәгълүматлары тулы түгел); Федотов I: 165.

Дерив.: **иләслән-ү** ~ кр.-тат. *eleslenmek* id.

**ИЛӘСӘ** (ТТДС I: 145) «перчатка, рукавица» < болг. **иләсә*, к. чув. *ал, алă* < **әл, *әлĕ* «кул», *алса* «бияләй» < **әлсә*. К. тат. әд. *ал, әл* «кул», к. «Кисекбаш китабы»нда «*Нә гәүдәсе, нә азакы, нә иле – Бер кисек баштыр – һаман сүзләр теле*». Чаг. иске әд. **әлдуан** < төр. *eldüvan* «пирчәтке». Федотов I: 36–37.

Фонетик җәһәттән караганда *иләсә* бөтенләй дөрес түгел, *илсә* булган булырга тиеш; *илсә ~ әлсә* тат. теленә хас булган *и- ~ ә-* чиратлашуына мисал.

**ИЛӘТ, илат** (ялгыш язылышта **ил-ат**) «население» < чыгт. (> фар.) *элат, элäт,* кырг. *элет* «күчмән кабиләләр», үзб. (ЎХШЛ: 94) *элäт, еләт, елат* «мәхәллә, административ берәмлек» < монг. *илат* «илләр; җәмәгаләр».

**ИЛӘ-Ү** «просеивать» < каз. *але-,* гом. кыпч., гом. төрки (Радлов I: 809–810) *елä-, äлä-* < бор. чыгт., бор. монг. (Поппе 1938: 152) *elge* (> алт. кырг. *элге-, äлгä-,* хак. *илге-*) id., «кул белән селкетү» булса кирәк, к. чув. *алла-* < **әллә-* id. ← *ал* < *әл* «кул» (к. **Әл**). Ләкин к. тув. *еғле-* id. Räsänen 1969: 40; ЭСТЯ I: 261–263; Федотов I: 33.

Дерив.: **иләң-ү, иләт-ү;** диал. **иләнте, иләмтек** (дөресрәге – **иләнтек**). К. **Иләк.**

**ИЛӘШ-Ү** «привыкать, привязаться, повадиться» – бу сүзнең сөйләшләрдә **ияләш-ү** (*ия* «сүзеннән») һәм **илләш-ү** (*ил* «тыныч халык, тынычлык» сүзеннән) вариантлары бар. **Иләш-ү** < *илләш-ү* икәнлеген Будагов (I: 204) та искәреп үтә. К. каз., кырг. *илдеш-* «ияләшү», бор. төрки (ДТС: 171, КБ) *elleš-* «солых төзү, килешү» ← *elle-* «союз төзү». Ләкин гом. кыпч. *эләш-* (к.-балк. *илеш,* нуг., каз., к.-калп. *элес-*) вариантын каз., к.-калп., кырг. *эле-* «игътибар итү» сүзеннән дә китереп чыгаралар. Чаг. ш. ук төр. *elleş-* «кул бирешү, кул кысышу». К. **Илек-ү.**

Дерив.: **иләшел-ү, иләштер-ү.**

**ИЛБАШ** (Тумашева 1992: 54) «двухгодовалый лось» ~ рус. диал. *ельбаш, эльбаш, эльбяш, либаш, липаш, лéбеж, мельпяш* id. (к. Аникин: 198, 221, 383) – русчага татарчадан кергән дип уйланыла. Чаг. башк. (БТДҺ: 96) *илбас* «йөрәк авыруыннан дару».

**ИЛБӘК** диал. (БҺҺ II: 76) «приветливый; хлебосольный» > чув. *илпек* «муллык» ~ куман. *elbek* id., хак. *илбек* «муллык; мул; дәү, зур», алт., тув. *элбәк, элбек* «җитешлек; хатын-кыз күкрәге; илбәк, юмарт», як. *элбәх* «күпсанлы» һ.б. ~ монг. *элбэг* «илбәк» як. *элбӟ-, äлбä-*, бор. монг. *elbe-* «мул булу» фигыленнән, бу сүз исә бор. **ele-* тамырыннан, к. алт., хак. *илэдэ, илäдä* < бор. монг. *elegede* «мул, күп» (к. Räsänen 1969: 39, 40). Чаг. тат. диал. **иләпән** «артык мул гәүдәле». ТТДС I: 15; Федотов I: 165.

**ИЛБИС** (Тумашева 1992: 54) «тигр, ирбис; рысь» < кырг. *илбирс* «барс», бор. төрки *irbiz* «каплан», *irbič* «селәүсен» > яз. монг. *irbis* «юлбарыс, каплан» һ.б. К. ш. ук як. *илбис* «явыз рух, сугыш рухы», *илбис кыһы (кызы)* «ызгыш рухы»., алт. *јелбис* «рух, ия» (*суу јелбис* «су илбисе» һәм *туу јелбис* «тау илбисе»). ДТС: 211; ЭСТЯ I: 346. Рус. *ирбис* тур. Аникин: 221, 223 (күп параллельләр һәм арытабангы әдәбият күрсәтелә). Төрки мифологиягә реаль хайваннар белән җен-шайтаннарны тиңләштерү хас.

**ИЛГӘЗӘК**, диал. **илгәдәк, илгәсәк** (ДС I: 60, 61) «приветливый, общительный» ~ нуг., каз., к.-калп. *елгезек [элгәзәк]* id. ~ калм. (Ramstedt) *elgəsəg* «туганчыл, нәсел-нәсепне яратучан», *elgn* «нәсел-нәсеп» (< *elken* «кешекәй»), бор. монг. *elk* «кеше; ир; туган-тумача» сүзеннән (*el-ken-se-g*), *-seg* ~ тат. *-сак//-сәк* «сүз нигезендә белдерелгән нәрсәне яратучан» мәгъ. кушымча; *-с-* > *-з-*. Чаг. **Алгасак.**

**ИЛГӘР** (Тумашева 1992: 54) «рысистая лошадь», ди. Бу сүзне **җил-ү** белән баглап карарга мөмкин. Ләкин к. уйг. *илғар,* үзб. *илғор,* «алдынгы», төбендә «ат көтүен башлап йөрүче ат» ← брб., алт., тув., як. *ылға-* < монг. *илға-* «сайлану, яхшыракны сайлап йөрү» ← *ила-* «аерылып тору». К. Räsänen 1969: 164.

**ИЛЕК**, диал. (Тумашева 1992: 54) **иләк,** иске тат. **әлек,** себ. (ЗДС: 346) **йелек** «вид ланей, лань, косуля» ~ каз. *елік,* кырг., төркм. (угыз.) *элик*, алт. *әлик, ээлик* id., хак. *илік* «илек», *элік* «илекнең инәге, кәҗәсе» ~ тув. *элик* id.; гом. төрки характерда к. бор. төрки (ДТС: 171) *elik* «тау кәҗәсе (нәкъ кәҗәсе, инәге)» ~ монг. *ил, или* «яшь болан», чаг. эвенк. *илк* «көмәнле, корсаклы» (ССТМЯ I: 311). К. **Илтер.** Räsänen 1969: 40; ЭСТЯ I: 265–266.

**ИЛЕК-Ү (илегү)** «привыкать, уживаться, осваиваться» (к. ТТДС I: 143–144) ~ төркм. диал. *элик-* id., үзб. *элик-* «хатын-кыз артыннан йөрү; илегү»; каз., к.-калп., кырг. *эликле-*, *еликле-* «ияру (рус. «подражать»); үчекләү»; *елик-, элик-* «мавыгу», бор. төрки (ДТС: 171) *eliklä-* «үчекләү» һ.б. Чаг. төр. *elgi* «якын мөнәсәбәт, бәйләныш».

**ИЛЕМ** (ЗДС: 208) «общительный; радушный» **илгәзәк** сүзе белән тамырдаш булса кирәк.

**ИЛЕР-Ү** «дико кричать; беспричинно закричать (во сне, в бреду, о душевно больном); вести себя крайне разнузданно» ~ башк. *илер-* id., *илерек* «лунатик», чув. *илер-, илеш-* «тыелгысыз көлү»,

*илĕр-* «мавыгу» ~ каз. *елір-,* к.-калп. *елир-* «ярсу; мавыгу; саташу» – «*иле* булу», ягъни *иле* < *эли* «күзгә күренмәс рух; ияле, җенле» сүзеннән булса кирәк. **Илегү** һәм **илерү** сүзләре беркадәр тәэсирләшкәннәр. К. ш. ук **Иләс.**

**ИЛҖӘ КӨНЕ, Иллә көне** «ильин день (религиозный праздник у христиан, 2–3 августа)» – **Илья** «Ильяс пәйгамбәр» исеменнән. Татар һәм төрекләрдә «Ильяс камчысы», «Хызыр-Ильяс көне» апрельдә уздырыла. Чаг. к.-балк. *Илийэ* «яшен-күгерт тәңресе» – бор. төрки христианлыктан калган. Чаг. **Элҗен.**

**ИЛ-КӨН** «население» к. **Көн II.**

**ИЛЛА, иллә,** ш. ук **илля мәгәр** «исключительно, особенно; во что бы то ни стало» > мар. *илла мăгăр* id., үзб., чыгт. *илла (илла мӓгӓр),* төр. *illâ de* «илла, шуннан артык, дәхи; башкача, шулай гына булмаса» < гар. *иллā* id. К. ш. ук чув. *елле* «илла (ох и, ну и)». К. Будагов I: 78; Redhouse: 530–531.

**ИЛЛЕ I** «пятьдесят» < гом. төрки *элли, эллик, эллиг,* бор. төрки *eliklik* id. *эл* «кул» сүзеннән, к. ш. ук чув. *ал* «кул», *аллă* «илле» (болг. *әл, әлү*). К. Гордлевский 1961: 123–131; ЭСТЯ I: 266–267; Федотов I: 34; Җәләй 2000: 103–104.

**ИЛЛЕ II,** диал. **иле** «единица длины – 6 арпа ≈ 18 мм» ~ нуг., каз., к.-калп. һ.б. *ели, эли,* уйг., чыгт. *илик, элик,* таҗ. *илĕк* id. *элик* «кул» сүзеннән к. як. *или* «бармак озынлыгы; бармак киңлеге», үзб. диал. *илик, элик* «карыш»; һичшиксез **илле I** сүзе белән бердәй, к. Радлов I: 814–815, 1484; ЭСТЯ I: 266–277. К. **Илле I.**

Алт. (Баскаков 1972: 238) *öly* «илле» икенчел булса кирәк (*илү* > *öлү;* регрессив ассимиляция).

**ИЛ-СҮ** «население, народ» – *ил* һәм бор. төрки *сү* «гаскәр» сүзләреннән гыйбарәт. **Ил-су** язылышы – халык этимологиясе нигезендә.

**ИЛТЕР** «мерлушка, смушка (род обработанных шкур)» > удм. *эльтыр* id. ~ ком. *элтир,* нуг. *элтири,* куман. (Радлов I: 826) *ӓlmipi*, бор. төрки (МК) *eldiri* «илтер; ылак тиресе» (*el* «яшь яисә ана илек», *teri* «тире»), ләкин уйг. *әлтирә* «илтер». К. **Илек.**

**ИЛТИБӘР** «эльтибер, военачальник или премьер-министр у разных тюркских народов древности: у азов *eltäbär* (ДТС: 171), у хазар и булгар *алп-элтэбэр* и т.п.» – безнеңчә, бу сүзнең этимоны *элтэбрэр* «илне сәфәргә күтәрүче – тибрәүче» (к. **Тибрә-ү**), шуның кебек бор. титул *илтиреш* < *eltäriš* «илне җыючы» (к. **Тир-ү**). К. Фахретдинов 1979: 63–71. К. ш. ук **Бәлтуар.**

**ИЛТИФАТ** «внимание (к человеку); почтительное, внимательное, мягкое обращение» < гар. *илтифāт* id., к. ГТРС: 137. К. ш. ук **Латыйф.**

Дерив.: **илтифатлы, илтифатсыз.**

**ИЛТ-Ү**, диал. (ЗДС: 308–309) **илтә-ү** «относить, отвозить, везти», «уносить», **илет-ү** (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «передать; оставить (подальше)», төр., кр.-тат. (Dobr. II: 148) *ilet-* ~ хак. диал. *илт-*, куман., уйг., чыгт. (Радлов I: 824) *ӓлт-* «илтү», к.-балк., ком. *elt-/элт-* «алып бару», сары уйг. *elt-/элт-* «алып китү», төркм. *elt-/әлт-* «читкәрәк җибәрү», як. *ӓлт-, илт-* «күтәрү, күтәреп илтү»; **әлит-, илит-** варианты уйг., үзб. телләрендә дә «илтү», бор. төрки (ДТС: 169–171) *ilet-, elät-, elit-, elt-* «күтәреп алып бару» ~ монг. *elde-* «куу, куып җибәрү» һ.б. Г. Рамстедт (1951: 175) бу сүзне бор. төрки *el* «әл (кул)» сүзеннән ди (чаг. рус. «вручить»). Безнеңчә, бу фигыльнең тамыры *эй-* (к. **Ий-ү**) «җибәрү»; шуннан **эйил-* «җибәрелү», ә монысының йөкл. юн. *эйилт-* > *элит-* ясала ала. К. бор. монг. (Поппе 1938: 439) *ile-* «җибәрү», шуннан *ilet-* «җибәртү»... К. ш. ук Räsänen 1969: 41; ЭСТЯ I: 267–269 (төрле фикерләр китерелә).

Дерив.: **илттер-ү, илтеш-ү,** бик сирәк **илтел-ү.**

**ИЛҮ** «волость; большая община; место, где много чего» (*җиләк илүе* «место, где много ягод; ягодное место», к. ТТДС I: 394); бу сүзнең еш кына очрый торган *иләү* дип язылышының тарихи тамырлары юк, бу – саф тат. фонетик күренеше: *-w* алдыннан килгән *ĕ* > *ә, илеw* > *иләw* генә. *Илү* бор. төрки *elig* (ДТС: 170) «хөкемдар; патша» сүзенең «хөкемдарлык, патшалык (өлкә)» мәгънәсеннән килә ала.

Шулай ук *илү* миш. *ил-ү* «ил-өй» сүзеннән килеп чыкса да гаҗәп түгел, к. **кырмыска илүве** «кырмыска оясы», әмма моны исбатлап булмый.

Тат.-башк. даирәсеннән тыш *илү* сүзе күренми.

**ИЛХАН** «глава подчинённой страны» – Монгол империясе дәверендә ясалган сүз, к. Будагов I: 206. *Ил* монда «буйсынган» мәгъ., к. **Иләш-ү**.

**ИЛҺАМ** «воодушевление; внушение сверху» < гар. *илһāм* id., к. ГТРС: 158.

Дерив.: **илһамлы; илһамлан-у; илһамчы**.

**ИЛЧЕ** «посланник, парламентёр» ~ гом. төрки *элчи*, монг. *элчин* id. (фонетик вариантлары закончалыклы) *ил* < *эл* сүзенең «тыныч, риза» мәгънәсеннән чыгып ясалган бу сүз төрки телләрдән бик күп күрше телләргә (шул хисаптан фар., гар., бор. рус телләренә дә) үтеп кергән һәм бу хакта XVIII г. ук язганнар, к. Schott: 11–12. Шуннан соң бу сүз тур. күп тапкыр язылган. Räsänen 1969: 39.

Дерив.: **илчелек.**

**ИМ** «лечение (знахарскими способами); лекарство, снадобье; процесс лечения, прок от лечения» > мар., удм. *эм, им* (ш. ук *имце* > *эмчы*) < гом. төрки, гом. монг. *эм* (> хак. *им*) id.; фин-угорчылар мар., удм. *эм* сүзен чувашлардан дип күрсәтәләр, ләкин чув. *эм* дә *ам* < *әм* дә юк; чув. *им* исә һичшиксез тат. теленнән; дөрес, чув. телендә болг. (?) **әм* сүзенең дериватлары *аман-* «имгәнү», *амак* «имгәк» бар, ләкин алар күптән деэтимологизация кичергәннәр. К. **Имгәк I, Имгән-ү, Им-том.** Федотов I: 166–167.

**ИМАМ** «имам, предводитель в коллективном намазе» (*имам тор-у* «стоять во главе молящихся») < гар. *имāм* id., к. ГТРС: 158.

Мөселман илләрендә *имам* сүзенең бүтән мәгъ. дә бар, к. Будагов I: 91. Тат. телендә *имам* – руханиларның иң түбән дәрәҗәсе, «гади мулла».

**ИМАМӘТ** «должность имама; государство, во главе которого стоит имам» < гар. *имāмāт* id.

**ИМАН** «вера в Бога» (**имансыз** «безбожный») < гар. *имāн* id. *Имин, мөэмин* сүзләре белән тамырдаш.

Дерив.: **иманлы**, **имансыз** (сүгү сүзе).

**ИМАНА** «надел земли» (первое упоминание – 1792 г.) иске рус. *имяна* > хәз. рус. *имена* «исемнәр, исемлек» сүзеннән, к. Будагов I: 209; Ахмаров 1907: 10; Ахунзянов: 155–156.

**ИМӘГӘН, Әмәкәй** (ЗДС: 81) диал. «злой дух в образе женщины ~ к.-балк. *эмеген* id., ләкин алт., тув. *эмеген* «инәкә; изге әби» ~ монг. *эмегелжин* id. ← *эмэ* «ана, хатын». К. МНМ II: 661.Чаг. **Җилбегән, Илбис.** Räsänen 1969: 42.

**ИМӘН** «дуб», диал. «тополь», себ. (Тумашева 1992: 55) **имэн** «(мелкая) сосна» < уйг. *эмән,* нуг., каз., к.-калп., кырг. *эмен [эмэн]*, чыгт. *äмäн*, уйг., алт. *эрмен, эрмән*, хак. *ирбен от* id.; икенче яктан себ. тат. һ.б. *ирмән* (ЗДС: 216), каз., кырг. *эрмен, эрмән, эрмене*, уйг. диал. *әмән* «әрем», башк. диал. *ирәмән* «курайлы үсемлек». К. ш. ук. кырг. *эмил* «бик ныклы агач төре».

Шулай итеп, **имән** һәм **әрем** сүзләренең этимологик бердәйлеге күренеп тора һәм беренчел мәгъ. – «тау итәгендәге үсемлек» дигән сүз булган, к. **Әрем, Әрәмә.**

**ИМӘН-Ү** «ужасаться; сильно опасаться», диал. (ДС I: 59, 62) «быть в смятении (от стыда и т.п.) > чув. *имен-,* мар. *айман-* «кыенсыну, тартыну» < каз. *имен,* чыгт. *имән-,* уйг. *әймән-* < бор. төрки (ДТС: 167) *ejmen-, ajman-* «нык оялу» бор. **айма-* «куркыну, коелып төшү» фигыленнән, к. монг. *айма-хай* «куркынучан»; бу *айма-* фигыле исә бор. **ай-* «курку, кызгану, имәнү» фигыленнән, чаг. **Ая-у.**

**Имәнеч** сүзе дә бик борыннан килә, к. бор. төрки *ajmanč* id. Будагов I: 211; ЭСТЯ I: 249–251 (бик әйбәт аңлатма); Федотов I: 167.

**ИМӘС** диал. (в говорах, представители которых общаются с казахами, узбеками и пр.) «не является» < нуг., каз., к.-калп. *эмес,* үзб. *эмас*, уйг. *имәс, әмәс,* хак. *нимэс* < чыгт., бор. уйг. *эрмес, эрмäс* < бор. төрки **эрмәз* < *эрмәр* > чув. *мар* (< болг. **эмәр*) «түгел» ← *эр-* «булу», к. **Ир-ү.**

**ИМГӘК I** «беда, лишения; обуза, бесполезный в деле, беспомощный человек» > мар. *эңгек,* чув. *инкек* ~ гом. төрки (ЭСТЯ I: 272–274) *эмгек, эмгэк,* кр.-тат. *emgek* «эш, хезмәт», «авыр эш» ~ монг. *эмгэг* «авыру, сырхау, хаста»; төр. *емек* «авыр эш; пенсия», чув. *амак* «эпилепсия» < болг. **әмәк* id. Кырг. *эмгек* > каз. *еңбек* «хезмәт» (!) – рус. *труд, трудный* дигәннән уңышсыз калька. Бор. төрки (ДТС: 173) *emgäk* «азап».

**Имгәк- *имгә-ү** (< *эмгä*) фигыленнән ясалган исем, к. шул ук фигыльдән **имгән-ү, имгә-т-ү. Имгә-** < (КБ телендә) **эмгә-** исә **эмиг-ә-** «имгә мохтаҗ булу» дигәннән. К. **Им, Имгән-ү.**

Федотов (I: 40–46, 168–169) чув. *амак* (< болг. **әмәк*) «билгесез авыру» сүзен *аман-* «имгәнү» белән бәйләми, чөнки, имеш, **имгәк** сүзе чув. *инкек* булып яңгырый. Ләкин бор. *эмгäк* сүзеннән *әмäк* тә, *имгәк* тә килеп чыга ала; болг. теленең *-г-*

һәм *-г-* авазларын редукцияләве билгеле. К. ш. ук Будагов II: 94; Мухамедова 1973: 197–199.

Дерив.: **имгәкле; имгәклән-ү.**

**ИМГӘК II** «младенец, ещё сосущий грудь матери» – **имгәк I** сүзе тәэсирендә **им-ү** фигыленнән ясалган.

Бу **имгәк II** сүзеннән, мәгънәсе ераклашып, **имгәклә-ү** «(бәби турында) үрмәләп йөрү» фигыле ясалган. К. ЗДС: 209.

Дерив.: **имгәклә-ү** «шуышып йөрү (бәби тур.)». Räsänen 1969: 42 (төрки телләрдән күп кенә параллельләр китерә).

**ИМГӘН-Ү** «получить увечье, раниться, повреждаться» > мар. *эмган-* < гом. төрки *эмгән-* id. Бор. төрки (ДТС: 172) *emgä-* уйг. *әмгә-* «азаплану, газаплану» сүзеннән кайт. юн. (к. Räsänen 1969: 42; ЭСТЯ I: 274–275).

Шул ук *эмгә-, әмгә-* фигыленең йөкл. юн. **имгәт-** < *эмгәт-* сүзе дә киң таралган. К. ш. ук чув. *аман-* «имгән-ү», *амант-* «имгәт-ү»; бор. монг. *emgeni-je* «борчылу» һ.б. К. **Имгәк I.**

**ИМЕЗЛЕК** «соска искусственная» < *имезүлек*; бүтән төрки телләрдә *эмизик*. Чаг. тат. диал. **имезәк** «әле имә торган (бала)»; төр. *emzik* < *emizik* «имезлек». К. **Им-ү.** К. түбәндәгене.

**Имез-ү, имгез-ү** – **им-ү** фигыленең үзенчәлекле йөкл. формасы. «Дөрес» булган **имдер-ү** формасы мәгънәсе җәһәтеннән аерыла: «имергә рөхсәт (мөмкинлек) бирү» була.

**ИМЕЛДӘШ** тар. «молочный брат (царевича), т.е. сын кормилицы сына правителя» ~ нуг. *имилдеш* id. (Будагов I: 211, Продолжение… 1793: 8) – **ими** сүзеннән. Руслар **имелдәш** сүзен *мамич* дип тәрҗемә иткәннәр (шуннан *Мамышев* фамилиясе килә).

Шул ук мәгъ. төрки телләрдә *күкелдәш* сүзе билгеле, ул бор. төрки *күк* < *kök* «ими, күкрәк» сүзеннән ясалган.

**ИМЕШ** «якобы» (ш. ук **имештер, имештерем, имештер ки,** к. Махмутова 1978: 248) < гом. төрки *эмиш* < *эрмиш* id. әдәби-китаби телләрдә таралган; ясалышы буенча угыз төркиләрендә килеп чыккан сүз (**эр-миш**), к. **Ир-ү.** Федотов I: 167.

**ИМЗА** «подпись» ~ гар. *имḍā* «имза; сайлап алу» сүзеннән. к. Zenker: 96; Redhouse: 535.

**ИМИ**, диал. **эми** «материнская грудь» < гом. төрки *эми* < *эмиг* ~ уйг. *әмиг* id. К. **Им-ү, Имчәк.**

Дерив.: **имилек.**

**ИМИН** «спокойно, спокойный; безбоязненный, не внушающий опасений» (**иминлек** «спокойная жизнь»), удм. *эмэн* id. < гар. *имӣн* id. К. **Әман, Иман, Мөэмин, Тәэмин.**

**ИМКЯН, имкән, имкәм** (ЗДС: 219) «широкая возможность, выбор» < гар. *имкāн* id. Чаг. **Мөмкин.**

**ИМЛЯ [имл'а]** «орфография; искусство письма; диктант; прочтение» < гар. *имлā* id.

**ИМНЕК, имнег** диал. (Тумашева 1992: 53) «дикий, неприученный (о лошади)» ~ нуг. *эминик,* хак. *имнiк*, кырг., тув. *эмдик*, алт. *эмтик*, як. *ämнiк* һ.б. ~ бур. *эмниг,* бор. монг. *emneg, elmeg, elemeg* > эвенк. *эмник, эминики* «асау; кыргый болан; аркылы, кире», маньч. *элмин, элмэн* «асау, кыргый; эшсез; бер маньчжур ыруының атамасы» (к. ССТМЯ II: 450) ~ мар. *имни, имнэ, ымньы* «ат».

И.Г. Добродомов (К этимологии марийского названия лошади // Советское финно-угроведение, VI, 1970, № 4: 253–254) бу сүзне төрки *эмилик* > тат. **эмилек** «әле имә торган – яшь колын» сүзеннән дип бара. Безнеңчә, монда катгый нәтиҗәгә килерлек урын юк – кайбер фонетик һәм семантик рәтсезлекләр бар. Анасын вакытыннан соң да имеп йөргән терлек ул – гайре табигый шартларда гына булырга мөмкин түгелме? Маньчжур, тунгус вариантларындагы фонетик үзгәрешләр закончалыклымы? Нишләп «кыргый ат» > «гомумән ат» күчеше килеп чыккан? һ.б.

И.Г. Добродомов китергән сүзләр рәтендә (ул әйтелмәгән) тат. **имтек** «имезлек; имезелә торган яшь терлекне ясалма рәвештә имезү» (к. ТТДС I: 145 һ.б.) сүзе дә тора. Һәм бу мәгънәләр И.Г. Добродомовның семантик үсеш реконструкциясендә урын тапмыйлар. Ихтимал, **имнек** формалашуында үзгә бер сүзнең тәэсире бардыр.

**ИМРА, имыра** «злой дух – воплощение зимних холодов» ~ нуг. *емире* id. Чаг. һинд-евр. **ieто* → кафир. *imra (< yamarājan* «Яма әфәнде), исланд. *имир-* «үлем һәм җирасты рухлары» (МНМ I: 529; МНМ II: 229), ләкин кафирларда (Әфганстанда озак вакытлар мәҗүсилектә «кяфер» булып калган кабилә) **имра-** «баш тәңре, башлыча уңай рух». Та-

тарларда *имраның* тискәре рух булуы мөселманлык карашыннандыр.

**ИМРӘ-Ү** «задремать, отключиться от сознания, поддаваться чарам, гипнотизироваться», **имрәт**- «охмурить» > мар. *эмрат-* «юату», каз. *емрән-, емрен-* «иркәләнү», госм. *äмрäн-, етren-* «хыяллану» (к. Räsänen 1923: 25) һ.б. бор. төрки *amra-* «ярату; иркәләнү» (күп дериватлары белән, к. ДТС: 41–42) сүзеннән килсә кирәк. К. **Амрак.**

**ИМТЕК** «сосунок; подсос» к. **Имнек.**

**ИМТИХАН** «экзамены» < гар. *имтихāн* id. **Михнәт** сүзе белән тамырдаш.

**ИМТИЯЗ [имтийаз]** «льгота; выгодные (для учащихся) условия» < гар. *имтийāз* id.

**ИМ-ТОМ, им-төм** «лечение (народными средствами)» ~ хак. *им-тōм* id. – *им* һәм *том* «дога, ырым һ.б.ш.» Шулай итеп *им* «материаль (дарулар белән һ.б.) дәва», ә *том* «рухи дәвалау». Чаг. ш. ук тув. *эм шагаан* һәм *дом шагаан* – изге тауда үсә торган шифалы үләннәр (к. Taube: 223); Сары уйгур телендә (Малов: 144–145, 150–151) *емчі хан* һәм *томҗы хан* – дәвалаучы тәңреләр; монг. *дом* «магия, дога; имләү». К. **Йомак.**

**ИМ-Ү** «сосать (материнскую грудь)» < гом. төрки *эм-, әм-* id. ~ монг., фин-угор телләрендә дә охшаш сүзләр бар (к. ЭСТЯ I: 270–271). Йөкл. юн. формасы *имез-* < гом. төрки *эмиз* < бор. төрки *emgiz-* id. Räsänen 1969: 41–42 (Урал-Алтай сүзе ди). К. **Имезлек, Имелдәш, Ими, Имнек, Имтек, Имчәк.**

**ИМЧӘК,** миш., себ. **имцәк,** «соска (натуральная, материнская)» ~ башк. *имсәк* id. < **имичәк** < *эмигчäк.* Гом. кыпч. *эмчәк* (нуг., каз., к.-калп. *эмшек*), уйг. *эмчәк,* төр. *emcek, emcik* id. К. **Ими.** Тәүдә бу сүз имезлекне белдергән.

**ИН I** (ТТДС I: 146), диал. (Тумашева 1992: 37) **эн** «полотно; закрой одежды; мера длины (ширины полотна); пахотное поле» < гом. кыпч., чыгт. *эн, ен*, бор. төрки, уйг. *эн* ~ төркм. *иин,* як. *иен* id., к. Радлов I: 726; ЭСТЯ I: 352–353.

Чув. *ан* id. < **эн*; к. мар. *äнä, äңä > ана*, чув., удм. *ана* «җир кишәре, дисәтинә» < болг. **äн-äг, *äң-äг, *äңäк* id. Идел-Урал регионының оригиналь сүзе.

*Ин* һәм *иң* бик охшаш сүзләр, әмма һәркайсының электән килгән оригиналь, дистинктив мәгънәләре бар (к. Будагов I: 211), шуның өчен монда садә фонетик күчеш кенә күзәтелми, бу сүзләр бер-берсеннән ясалган (*э-ин* > *ин* яисә *эниг* > *иң*). Чаг. **Ин II, Инеч, Иң I, II.**

Дерив.: **иннә-ү** < **инлә-ү** «озынлыкны үлчәү».

**ИН II,** диал. **им, иң** «метка (на ухе домашних животных преимущественно в виде разреза)» ~ уйг. *эн,* төр. *en* һ.б. id. ~ эвенк. *им, һим* < **pim* id. (к. ССТМЯ I: 324).

Дерив.: **инә-ү, иңә-ү** (к. ТТДС I: 147, 157) «ин салу» ~ уйг. *энә-* ~ монг., тунг. *имлэ-, имнэ-* id.

**ИНА, инаса, инасы** (Махмутова: 249–250), **инасак** (ЗДС: 210) «тогда, в таком случае» ~ морд. *ина* < рус. диал. *ино, иносъ* id.

**ИНАК** тар., себ. (Тумашева 1992: 253) **ынаķ** «верный друг», (Хисамова 1990: 72, 137) **инаķ, инаķ талиб** «государственный советник», «старшина» ~ чыгт., үзб. (Будагов I: 212) *инаķ* «хәрби киңәшче, провинция башлыгы; союзник», каз., кырг., к.-балк., алт. һ.б. (Радлов I: 1362) *инаķ, ийнаķ* «дуслык; тату, матур», госм. *инаг, инаķ,* төр. *inak* «киңәшче, сердәш, фикердәш», бор. төрки (ДТС: 218–219) *ïnaγ, ïnaq* «дәүләт киңәше әгъзасы»; төркм., уйг., тув. *ынаķ,* хак. *ынаг* «дус, сөекле», к. ш. ук бур. *инаг,* монг. *энэг, анаг* «киңәшче дус» > калм. *инъг* id. һ.б. ← бор. *ина-, ына-* «ышану», к. **Инал, Инан-у.** Будагов I: 212; Ногман: 94; Номинханов 1975: 124–125; Redhouse: 595; ЭСТЯ I: 654–655.

**Инаķ,** күрәсең, татар дәүләтчелегендә бик билгеле термин булган. Һәм аның онытылуы, кулланылмавы гаҗәбрәк.

**ИНАЛ** тар. «дворянин, находящийся в родстве с правящим домом» < бор. төрки (ДТС: 209, 219) *ināl, inal, ïnal* «гади кеше һәм хан затыннан булган хатын углы; гомумән (ярым) асылзат» > иске каз., кырг. (Будагов I: 212, Әбүлгази буенча) *инал* «идарәче» ← **ина-*, к. **Инак.**

**ИНАН-У**, диал. (И. Гази) **инән-ү**, (ДС II: 253) **ёнән-ү, үнән-ү** «искренне верить; убедиться; доверять» ~ мар. *ёнäн-, ынян-*, чув. *ĕнен-, инен-* < бор. төрки (ДТС: 218) *ïnan* id. ← бор. төрки **ına-, *ïna-* > хак., тув. *ина-, ына-* «ышану; серләшү, киңәшү», к. ш. ук куман. (Радлов I: 1363) *ынамлы* «ышанычлы», Чаг. тунг.-маньч. (ССТМЯ I: 315) *иңа* «җиян,

бүтән ыруга бирелгән кызның углы». К. **Инак, Инал.** Räsänen 1969: 165; ЭСТЯ I: 655–656; Donuk: 15–18; Федотов I: 152.

Тат. *инан-* чыгт. теленнән килсә, *инән-, ĕнән-* (палаталь вариант) болг. теленнән булса кирәк.

Дерив.: **инаныч** (гом. төрки характердагы сүз); **инандыр-у, инандыргыч** һ.б.

**ИНӘ** диал. киң таралган, к. (Рамазанова 1991: 13–14) «мать; самка», башк. *инә* id. < уйг. *инә*, алт., хак. *инэ*, кырг. *эне*, каз. (ҚТДС: 98) *ене* «инә; ана; әни», каз., к.-калп. *эне* «кайнана» ~ монг. диал., тунг.-маньч. (ССТМЯ I: 456) *энэ, инэ* «ана» (бик күп дериватлары бар). Ахыр чиктә **ана** сүзе белән тамырдаш. К. **Инәк**, **Инәкә.**

Дерив.: **инәй** (вокатив), чаг. башк. *инәй* «дәвәни; әби»; ком. *эней* «белемче карчык». Бик күп иркәләү-кечерәйтү формалары: **инәкәй, инәки; инәлек** «кендек әбисе». ЭСТЯ I: 278–281.

**ИНӘК,** себ. (Тумашева 1992: 50) **ĕнәк, әнәк** (Арча, без теркәдек. – *Р.Ә.*) «корова; лосиха; самка вообще» ~ чув. *ĕне [ĕнэ]* «сыер» < бор. төрки (ДТС: 211) *iŋäk* «сыер; ташбаканың инәсе» (күрәсең, артык конкретлаштырылган) > уйг., аз. *инәк*, гом. төрки *инэк*, як. *ынах* «сыер; инә, теше» һ.б. Щербак 1961: 97; ЭСТЯ I: 358–360; Федотов I: 151–152 (монг. һ.б. телләрдән дә параллельләр китерә).

**Инәк** сүзе бер төркем охшаш мәгъ. сүзләр рәтендә, к. бор. төрки (ДТС: 211) *iŋän* «ана дөя», бур. *инеэн* «ана пошый», рус. дал. (Аникин: 222) *инян* «бер яшьлек (ана) болан баласы; пошый», бор. төрки (МК) *ingek, iŋek* «ана бака, ана ташбака» (к. Мухамедова 1973: 95). Бу сүзләр кыт. *инь-ян* символикасында *инь* «ана, теше булу билгесе»н хәтерләтә (ул да **таш бака** рәвешендә изафәләнгән).

**ИНӘКӘ** «прабабушка; предок-женщина» (к. мәкаль: *Минем телем түгел, Идел кичкән инәкәләр теле*), «кормилица, не своя, но вырастившая мать», (ДС I: 62) «свекровь» ~ уйг. *әникә,* үзб. (ЎХШЛ: 360) *әнәкә, әнәгә*, кырг., алт. *энеке* «әнкәй» ~ эвенк., алт. *энеке*, *энэкэ, энекә* «дәвәни; ана аю; мифологик әзәлге ана (рус. прародительница)». Тунг.-маньч. материаллары бу сүзнең гади генә **инәкәй**дән түгел, борынгылыктан килгәнлеген күрсәтә. Наджип 1989: 254. К. **Имәгән.**

**ИНӘЛ-Ү,** диал. (миш., ЗДС: 213) **иңәл-ү, икәл-ү** «жалобно умолять» > чув. *инел-* «ялагайлану», мар. *инал-, инäл-* «ялвару» < алт. *äнäл-*, *энел-*, хак. *энел-*, *инäл-*, төр. *inil-*, як. (Пекарский: 263) *änälii-, äŋeälii-* «интегү», «инәлү» < иске монг. *enel-*, бур. *энэл-*, хәз. монг. *энэлэ-* «кайгыру» ← бор. төрки (?) *энэ-, эн-* «хасталану, авыртудан ыңгырашу; әлләлә-лә (авыру ымлыгы)» сүзеннән, к. хак. *инет-* «иңрәтү», *инеч* «ялыныч», гом. тунг. (ССТМЯ II: 455) *энӯ, энэ-* «авыру, хасталану», чыгт. *äнік* «зар елау» < **äніг* (**äн-* фигыленең интенсивлык формасы). Уйг., госм. *ilän-* «инәлү, тетрәнү» **инәл-** сүзеннән метатеза. Радлов I: 1478–1480; Räsänen 1969: 43. Чаг. **Интек-ү, Иңрә-ү.**

**ИНГЕРЕШ, иңкеш** (БҺҺ II: 78) «низина» ~ каз. *ĕнкиш* id. К. **Ин-ү, Иң-ү**.

**ИНГЛИЗ** «англичанин; английский» < төр. *ingliz* id. Төр. < фр. Иске сөйл. **әгелчән** < рус. *англичан.*

**ИНДЕ,** диал. **инди** «уже; уж; -ка» (частица просьбы) < иске әд., чыгт. *имде, имди* < *эмди* > нуг., каз., к.-калп., к.-балк., ком., үзб. *энди,* уйг., кырг. *инди* «инде»; бу сүзнең икенче бер фонетик вариантлы – миш. **эндĕ** (Махмутова 1978: 246) ~ брб. **ĕнди, ĕнти** (Дмитриева 1981: 137, 139) > чув. *ĕнтĕ*, мар. *ында,* удм. *ъндe, индэ* (Насибуллин 1978: 160). Һәр ике линиянең уртак чыганагы себ. сөйләшләрендә сакланган (к. Тумашева 1992: 37) *әмтир* «әмдер» ← **әм** (ТХИ: Дастаннар 1984: 90) «хәзер» – бор. гом. төрки сүз, к. алт. *эм,* уйг. *әм*, хак. тув. *ам* id. (*амди* «инде»). К. ш. ук алт., уйг. диал., куман., аз. *ämdi* «инде», алт., шор. *ämdä* «менә хәзер» (Радлов I: 943, 965 һ.б.). *Амты* «инде» монг. телләренә дә үтеп кергән.

*Ам, әм, эм* «хәзер, хәзер менә, хәзер инде» сүзенең чыгышы ачык түгел, чаг. эвенк. *ама* «тизрәк, тиз бул!» (ССТМЯ I: 34), уйг. *әм* «беррәттән» (Рамстедт: 50) < ир. *hат* «бергә» (?). К. **Индеге.**

**ИНДЕГЕ** диал. «теперешний; предстоящий (в ближайшем будущем)» ~ к.-калп. *ендиги*, к.-балк., үзб., уйг., ком. *эндиги* id. *инде* < *энди* сүзеннән уйг. телендә килеп чыккан.

**ИНДЕЕЦ** «индеец» < рус. «Америка кыйтгасының җирле халкы вәкиле» мәгъ., тат. бу сүз ятышсызрак. Дөресрәге һәм кулайрагы – **индиан**, төр. телендәге вариант.

**ИНДЕР-Ү** «внедрить, внедрять» – әд. телдә неологизм булган бу сүз диалекталь лексикадан алын-

ган һәм **ин-ү** «керү» сүзенең йөкл. юн. гыйбарәт. Әмма *индерү* иске яз.-әд. телдә дә очрый. К. **Ин-ү.**

**ИНДУС** «индус; житель Индии» < рус. < инг.: *hindu-s* «һиндләр, һиндиләр». Хәз. рус телендә *индус* сүзе сирәк кулланыла, чөнки Һиндстандагы аерым милләтләр аерым атала (*хиндустанец, бихарец, бенгалец* һ.б.). К. **Һинд, Һинди.**

**ИНЕЧ, иңәч** «подклад рубашки, платья (на плечах)» *иң эче* сүзеннән (к. Будагов I: 212); башк. диал. (БҺҺ II: 78) *иңсе* id. < *иң эсе.*

**ИНЕШ** «ручеёк (в пологой долине)», миш. «көнбатыш» (к. ТТДС I: 146, Гарипова 1998: 90) ~ чув. *анăç* id., *аниш* «иңкүлек» ← *ан-* «инү, түбәнәю»; тат. диал., башк. диал. *иңкеш* «иңкүлек; сөзәклек» (ТТДС I: 146; БҺҺ II: 78) ~ кар. *эниш, энис,* к.-балк. *эниш*, кр.-тат., куман. *äніш* (Радлов I: 734), хак. *иніс*, төркм. *ииниш*, бор. төрки *eniš*, кырг. *эниш* «төшү юлы, сукай, сөзәклек» һ.б. (күп телләрдә бар). Шулай итеп, тат. сүзе мәгънәсе белән гом. төрки эталоннан аерылып тора. К. ш. ук **Иңкел**. Федотов I: 46, II: 478.

**ИНҖӘР** – река Инзер – русчасы татарчадан килә, башкортчадан түгел, чөнки башк. *Инйәр* диелә. Бу гидроним, гомумән, аңлатуга авыр һәм, ихтимал, төрки сүз түгелдер (интервокаль *-нҗ-!*). *Инзер* дигән елга Мордовиядә дә бар.

**ИНКЫЙЛАБ** «революция» < гар. *инқилāб* id. *қлб* «формасын алмаштыру» тамырыннан, к. **Каллап, Калып.**

Дерив.: **инкыйлаби, инкыйлабчы.**

**ИНКЯР** «отрицание; неприятие, отвержение» < гар. *инк'āр* id. ← *нкр* «кире кагу».

**ИННЕК I**, (ЗДС: 212) **иңелек** «румяна» < уйг., төр., чыгт., бор. төрки (Поппе 1938: 737; МК һ.б.) *änlik, eŋlik* id. уйг. *əн, эн,* төр. *en, eŋ*, як. *ин* «йөз төсе; яңак, бит алмасы» сүзеннән; чаг. ш. ук кырг. *эндик* «арнебия (иннек алына торган үсемлек)», тув. *энгиске* < бор. монг. *engeske* «иннек».

**ИННЕК II,** диал., башк. **индек** «заворы; скотный двор в поле (на выгоне)» > мар. *аньык, аник* (Гордеев I: 119–120) < бор. тат. диал. **әнник, *әнлик* бор. **ән//*ин* «кечкенә капка» – **ин-ү** «керү» сүзенең исем коррелянтыннан, к. тат. диал., удм. диал. *ин* «капка; өн авазы; керү-чыгу урыны» ~ мар. *äң, аң, äн, ан*, чув. *ан* < болг. *әң* id.; Нуг. *эндек*, к.-балк. *индек* «киртә урынына тирән канау, ур» – бүтән сүз, ул гар. *ҳандāқ* «ур, чокыр» сүзеннән килә.

**ИНСАН** «человек, личность» < гар. *инсāн* id. Шуннан ук **инсанияг** «барча кешелек». К. ш. ук **Ниса.**

**ИНСАФ** «совестливость; порядочность» < гар. *инсāф* id. (ТГРС: 163).

Дерив.: **инсафлы, инсафсыз; инсафлан-у** һ.б.

**ИНТЕК-Ү (интегү, интекте)** «страдать» ~ каз., добр. *entĭk-, ентік, интік-, інтік-* < гом. кыпч., үзб. *энтик-,* аз. (АДДЛ: 218) *әндих-* каз. диал. *ындық-* «авыр сулыш алу; буылу; интегү» һ.б. (к. ЭСТЯ I: 283–284). Чув. *антăх-* < **әнтек-* «буылу», безнеңчә, *энти-*, уйг. *ініт-* «бик теләү, ялвару, сагыну» сүзенең интенсивлык формасы; к. уйг. *әндикмәк* «борчылу, авыр сулау; өшү, калтырау, буылу һ.б. уңайсызлыклар сизенү». Чаг. ш. ук тат. диал. (ЗДС: 211) **интек** «тилмерү; юксыну хәле», чаг. ш. ук тув., тунг., монг. *эндә-* «ялгышып һәлак булу, як. *эндэй-* «адашу, ялгышу», яз. монг. *anda-, ende-* «ялгышу», к. ССТМЯ II: 453–454. Сүзнең тамыры **эн-* «авыртудан ыңгырашу, авыр сулау» булырга тиеш (ләкин моны исбат итү кыен). К. **Инәл-ү, Инчек.**

**ИНТИЗАМ** «официальный порядок; устав; узаконение» < гар. *интиẓам* id. *нẓм* тамырыннан, к. **Назым.**

**ИН-Ү** диал. «входить; спуститься» ~ башк. *ин-,* үзб. *эн-*, бор. төрки *en-* ~ чув. *ан-* < **ән-* id. К. ш. ук тат. диал. **ин** «керү урыны, ишек, капка», к. **Иннек**. Ләкин к. бор. төрки (ДТС: 173) *en* «төшү урыны», *en-* «төшү, инү». К. **Иң-ү.** ЭСТЯ I: 285–286; Федотов I: 43.

**Ин-ү** фигыле иске тат. әд. телендә очрый: *Ишекдин инде-керде, Кыйулды кашы-күзе, Ни галим йегет үзе, Бал-шикәр татлы сүзе* (Татар әдәбияты тарихыннан материаллар II. Казан, 1967: 34). Дини югары стильдә **ин-ү** «Алладан килү». К. **Индер-ү.**

**ИНЧЕ,** диал. **инчү, инҗе, индзи, инци** (к. Будагов I: 213; Тумашева 1992: 56; ТТДС I: 146) «собственно-личное имущество замужней женщины (в виде скота или земли, т.е. способное

воспроизводить ценности); часть имущества, предназначенное детям пожизненно», иске әд. *әнче* (к. Троянский I: 73), башк. *инсе* id. ~ гом. кыпч. *энчи,* алт. *äнчи* < бор. төрки (ДТС: 210) *enčü, inčü* «мирас» , алт. *индье* «имана», тув. *өнчү* «инче, мөлкәт», үзб. *энчи*, уйг. *әңчи* «атаның угылга башка чыкканда бүлеп биргән мөлкәте (бигрәк тә ат)», каз. *енши* id. һәм «мирасның (васыятьнамәгә бинисбәтән) мәҗбүри – законлы өлеше», бор. уйг. *инҗү* «чура коллар; алпавыт утары» һ.б. Бу сүзнең төп мәгъ. һәм чыгышы тур. күп язылган һәм бик төрле фикерләр әйтелгән. Э.В. Севортян (ЭСТЯ I: 361–362) бу сүздә *-чү (-чы//-че)* аффиксы бар дип уйлый, К. Шираива (K. Shiraiwa tavarich of Rashid ad-din // Acta Orientalia (Budapest, 1980), T. XLII, f. 2–3, p. 371–376) буенча, *инче* < *инчү* монг. *emčü* «үзеңнеке, үзенеке» сүзеннән; безнеңчә, бәхәстә Г. Дёрфер һәм Д.М. Тихонов (к. аның 1960: 25–31 һәм 1966: 128–135, 162–168) хаклы: *инче, инҗе* бор. кыт. *инь цзы* «кәләш малы, хатын-кыз өлеше» сүзеннән, к. фар. *инжу* «патшабикә бирнәсе», бор. монг. *инҗу*, як. *энньэ* «бирнә». Ирандагы (к. Будагов I: 213) *инжу* «ханзадәгә бирелгән өлкә; патша хужалыгы», сугд. *inč* «хатын» кебек мәгънәләр соңрак килеп чыккан. К. ш. ук Ramstedt 1935: 208; Räsänen 1969: 44; Федоров-Давыдов: 61; Ахметьянов 1981: 82–83; Velidi: 286–287.

**ИНЧЕК I** «кляча; больное животное», диал. (Тумашева 1992: 56) **инцек** «горбун, урод» ~ төр., үзб., уйг. *инҗик, инчик* «капризлы; сызланучан» ← *инҗи-, инчи-* «сызлану, зарлану». Чаг. **Интек-ү.**

**ИНЧЕК II** к. **Җинчек**.

**ИНЧЕК III** «внутренняя сторона ворота рубахи» < **иңчек** (к. **иң**) булса кирәк.

**ИНША** «сочинение; слог, стиль; редакция (стиля)» < гар. *иншā'* id. Иске тат. *иншалык* – «документлар, хатлар язу өчен инструкция һәм үрнәкләр җыентыгы».

**ИҢ I,** себ. **әң, ән** «плечо, загривок; ширина» (гомогенность этих значений мы считаем очевидной) < гом. кыпч., үзб. *эң*, уйг. *әң* id., монг. *эң* «иң, киңлек» ~ чув., удм. *ан* < болг. **әң* > мар. *äң, аң* «иң, киңлек; тукыма, киндер»; к. ш. ук чув. *ана* < болг. **әңәг* > мар. *äңä, äңгä, анга*, удм. диал. *аңа* «җир үлчәме: 2/3 дисәтинә, 16 сутый һ.б. – төрле җирдә төрлечә» (к. Иванов, Тужаров: 22; Саваткова 1981: 13–14; Гордеев I: 43–44; Насибуллин: 105).

*Иң ~ эң ~ әң < эгин* булса кирәк, к. уйг. *әңин, әңил,* алт. *ийин* «иң, җилкә», *ээн* «иң, киңлек», шор., чыгт., сарт. (Радлов I: 698) *äгiн,* тув. *эгин* «иң», яз. төрки *ekin* id. → *ekni* «иңе» (к. Поппе 1938: 177) һ.б. *Эгин < экин* нигезе исә бор. *эк, әк* «кырый, чик» сүзенең инструменталь килеш формасы булырга да мөмкин. К. **Иңсә.** Räsänen 1969: 37; ЭСТЯ I: 225–227; Федотов I: 43.

**ИҢ II** «самый, наи-» > чув. диал. (Сергеев 1968: 19) *ин*, морд. Э. *ине, энъ*, мар. *энг, эң* < гом. төрки *эң, äң* (к. Радлов I: 709), кар. *энъкэ, эң,* тув. *эңне,* хак. *иң, ниң* ~ бор. монг. *eŋ* «киң; иң (бик)» ~ эвенк. *энгэий,* эвен. *энги, энгне* «күчле; иң»; чаг. ш. ук. уйг. *эгин* «иң». Төрлечә аңлатыла. ЭСТЯ I: 365–366.

**ИҢЕЗ** («Кыйссаи-Йосыф») «высь; воздух» ~ уйг. *егиз,* (Радлов I: 702–703) *äгiс, äгүс*, чыгт. *äгiз* «югары; кямил».

**ИҢКӘЙ-Ү** «(слегка) нагибаться» < гом. кыпч., төркм., аз. *эңкей-*, уйг. *энкәй-*, үзб. *энкай-*, алт. *иңкей-* < **эңик-эй-* id. ← **эңик* «түбән» ← *иң-, эң-* «түбәнәю». Чаг. тат. диал. **инек-төшек** «түбәнәйгән» ~ төр. *inik* «иңгән». К. **Иң-ү.**

**ИҢКӘЛ**, диал., башк. (Будагов I: 75; ТТДС I: 156; БҺҺ II: 322; БҺҺ III: 226) **эңкәл**, (ЗДС: 504) **онкал** «тонкий кусок теста, сваренный в бульоне» ~ каз. *ĕнкәл,* нуг. *инькал,* ком. *гъинкъал,* балк. *хинкял,* аз. *хинкъал* > рус. *хинкал* id. Кавказ телләреннән булса кирәк. Нұрмағамбетов: 147–148; Хайрутдинова 1993: 78.

**ИҢКЕЛ**, **иңкү** «пониженный (рельеф); ложбина» ← *иң-ү* (к.); чаг. **баткыл, үткел, чоңгыл** һ.б.ш. *Иңкү < эңкү,* кырг. *эңкүү* – гом. кыпч. сүзе.

Дерив.: **иңкеллек.**

**ИҢКЕШ,** диал., башк. (БҺҺ II: 78) **иңгеш** «дикая пчела; трутень» ~ морд. М. *эңгиш*. Ачык түгел. Чаг. ним. *Imker* «иңкеш», *Imkers* «иңкешләр» (ләкин очраклы охшашлык булса кирәк).

**ИҢРӘ-Ү** «стонать» < гом. кыпч., к. каз. *энрä-*, *ĕнре-*, чыгт. (Радлов I: 716) *äңрä-,* бор. чыгт. – бор. монг. (Поппе 1938: 161) *eңre-, eŋren-*, үзб. *иңра-*, кырг. *эңгире-*, к.-калп. *аңыра-* «иңрәп елау» *эң//иң//*

*ың* ымлыгыннан; к. ш. ук чув. (Ашмарин I: 121) *ӗнӗр-* «иңрәү». К. **Ыңгыраш-у.** Федотов I: 153–154. К. ш. ук кр.-тат., төр. һ.б. (ЭСТЯ I: 266–267) *иңле-* «иңрәү».

Дерив.: **иңрән-ү, иңрәш-ү, иңрәт-ү.**

**ИҢСӘ** «часть спины между плечами; соответствующая часть одежды» ~ чув. *инсе, энсе, ӗнсе* < гом. кыпч. *эңсе, эңсä,* куман., чыгт., госм. (Радлов I: 718–719) *äңсä* һ.б. id. Тәүдә бу сүз кием өлешен белдергән (*-сә* кушымчасы!) – *«иң* капламышы» мәгъ. булган. Räsänen 1969: 45; Федотов I: 154 һ.б.

Дерив.: **иңсәле; иңсәлек** ~ себ. (ДС I: 68) **иңзәлек** «камыш эче, бөят» ← **иңзә** «җилкә»; **иңсәлә-ү** «иңсәгә алып күтәрү» (куман. *äңсäлä-* «иңсәгә сугу»!).

**ИҢ-Ү** «оседать, втягиваться; понижаться, понизиться», тат. диал. **иң** «пониженность» ~ гом. төрки *эң-* (ЭСТЯ I: 353–354), чув. *ан-* < *әң-* id. Һәр төрки телдә диярлек *ин-* < *эн-* һәм *иң-* < *эң-* үзара керешә. Гомумән, *ин* < *эң* < *эңк-* <**эник-* дип, ә *эн-* тамырын *эйин-* < *эгин-,* ягъни «иенү» (к. **Ий-ү**) сүзеннән дип карап була, ләкин бу реконструкциянең реаль тарихи үсешне никадәр чагылдырачагын әйтүе кыен. Ихтимал, *ин-, иң-* (*эн-, эң-*) сүзләренең «төшү» һәм «керү» төшенчәләрен аңлатуы борынгыларның көпкәдә (зимләнкедә) яшәве белән бәйледер (кергәндә төшәргә кирәк булган). К. **Инеш, Иннек, Ин-ү, Иңкәй-, Иңкел.** К. ш. ук Räsänen 1969: 43; Федотов I: 43 (чув. телендә бор. *эн-* һәм *эң-* (**ин-ү** һәм **иң-ү**) сүзләренең рефлекслары берләшәләр һәм. М.Р. Федотов та аларны аермый).

Дерив.: **иңел-ү, иңдер-ү.**

**ИП** «способ; способность; приспособление; порядочность, лад; совместная деятельность», диал. «дар» > чув. *ип* < гом. төрки *эп, äп* (к. Радлов I: 916–917) id. ~ як. *эмп* «ип; им», бор. монг. *eb* «бергәлек, тынычлык, татулык», чаг. шумер. *ib* «чара, әмәл».

К. ш. ук себ. **әп** «им» (ләкин бу *ап* сүзеннән түгелме икән?) ~ уйг. *әп* «ип», тат. диал. **әп** (*Әбе килсә җәбе килми,* к. Исәнбәт, Мәкальләр I: 291) id., *йәбдәш* «иптәш» (ДС III: 203).

**Ип** – бик продуктив нигез: **ипле, ипсез, ипләү, иптәш, ипчел** һ.б. сүзләр гом. кыпч. характерда; к. ш. ук башк. *ибәтәй* «ходатай, юллаучы» – үзе ипле һәм бүтәннәрне ипләүче (< монг.).

**ИПИ [ипӗй]**, диал. **эпи, ипекәй** «хлеб» – бу вариантлар һәммәсе дә (барча татар диалектларында очрый торган) **эпәй** вариантыннан килә, бу вариант исә бор. **эппә, *эбә* «ипи, көлчә, коймак» сүзенең иркәләү формасы, к. иске тат. *әпетмәк, ипетмәк* (Троянский I: 7) «бәбине ашату», чыгт. *ібі-* «ашау» (Радлов I: 1569), хак. *ипек, іпек* < бор. төрки (ДТС: 62) *ebäk* «ипи, икмәк» («балалар телендә», ди М. Кашгари), каз. диал. *әпә* ~ нан. *эпэ,* эвенк. *эвэди,* маньч. *эфэн* «тәбикмәк, көлчә» (ССТМЯ II: 436).

**ИР,** себ. **әр** (к. Тумашева 1992: 37) «муж; взрослый мужчина; настоящий мужчина» < гом. төрки *эр, äр,* алт. *ээр*, чув., мар. *ар, äр* < болг. *әр* ~ гом. монг. *er* «ир; батыр, герой»; тат. әд. *ирән* < гом. төрки, монг., бор. төрки *eren, ärän*, уйг. *әрән, әрәнәк* «чын ир кеше» формасы бу сүзне шумер. *eren* «яугир» сүзе белән чагыштырырга мөмкинлек бирә, ләкин *eren, erän* (ДТС: 176) «яугир» ир. *eran* «ирләр» сүзеннән дә килә ала. Бу форманы һиндир. *arya, aryani* «арийлар» белән дә чагыштыралар, к. Еремеев. 1990: 129–135. К. Радлов I: 751. К. **Ирән.**

**Ир** < **эр** – бик продуктив тамыр: **ирле, ирсез; ирлек; ирләрчә.** К. **Иравыл, Ирәмсе-ү, Иргәел, Иркәк, Иркәч, Ирсәк, Ирсе-ү, Эргәзембай** һ.б.

**ИРАВЫЛ, ирәвел** «авангард; разведка, конный разведчик» ~ чыгт. *ираул,* үзб. *эравул,* каз. һ.б. *эраwул* id. < монг. *эрагул* «бергә-бер сугышучы» (Будагов I: 185–186) – **ир** < *эр* сүзеннән. Чаг. к.-балк. *эрявюл* «эре гәүдәле».

**ИР-АТ** «мужчины, мужская часть общины, коллектива» < бор. төрки (ДТС: 176) *erat* «ирләр, батырлар» – *eren, eran* «ир, батыр» сүзенең бор. күп. формасыннан яисә бор. *är at* «герой исеме, сугышта катнашкач алган шанлы исеме» сүзеннән (к. Наделяев: 65–81).

**ИРӘК** «стан, ставка главнокомандующего – временная столица», диал. «прибежище; вертеп» (ТТДС I: 151 «ерак» дигәне дөрес түгел, әмма китерелгән мисаллар дөрес) ~ нуг. *ийрек* «аран», к.-балк. *эрек* «авылдан читтәге абзар», кр.-тат., төр. *erek* «кальганың эчке өлеше, кремль», ш. ук (Dobr. II: 281) «максат, җитәсе (ерак) җир» < бор. төрки (ДТС: 177) *ergü, erig jer, erig-ornag* «хан урнашкан җир, ставка» < бор. төрки *er-, är-* «барып җитү, барып тукталу» булса кирәк (ДТСдә *er* янгырашында сигез сүз булгач, фаразларга урын киң). Чаг. ш. ук фар. *irgän* < яз. монг. *irgen* > хәз. монг.

*иргэн* > тув. *ирген* «гади утрак халык, кытайлар». Дёрфер (Doerfer I: 125–127) буенча, бу сүз *irk-* «туплау» нигезеннән. ЭСТЯ I: 219, TS 2: 337, 339. К. түбәндәгене.

**ИРӘКТЕ** – название башкирского рода-племени, а также местности в Северном Башкортостане. Асылда «Казан ханнарының ирәге (к. югарыда) һәм шул ирәкнең гарнизоны» мәгъ. сүз булган булса кирәк. **Ирәкте** (башк.) < тат. **ирәкле.** Ләкин каз. *ерек* «аерым», *еректі* «аерымланган, аерылган».

**ИРӘМ (ирәм багы)** «сады Ирама», күч. «земной рай» < гар. *ирăм* id. Асылда Коръәндә искә алынган *гадь* халкының башкаласы булып, ниндидер һәлакәткә очраган зур бер шәһәрнең грекча атамасы *Эвдемон* «бәхетле» сүзеннән килә (*д* ~ *ʒ* ~ *р*). Шуннан ук **Йәмән** сүзе дә килә бугай. Ләкин әлеге шәһәрнең хәрабәләре Йәмәндә түгел, **Гоман**да, 1990 елларда табылган. К. Харун Яхъя. Чудо Корана. М., 2008: 334–337.

Гарәп риваятьләре буенча, *Ирам ʒāт äл-ʻимāд* «күп колонналы Ирәм»не Шәддам патша оҗмахка тиң булсын дип төзеткән. Әмма Аллаһы Тәгалә аны бер сулыш өреп юкка чыгарган. Тик кайчакта чүлдә Ирәм пәйда була, аның капкалары ачыла һәм ул калага гөнаһсыз кеше керә ала, ди. Без бу әкияти мотивны «Илдусның беренче сәяхәте» дигән озын фантастик поэмабызда файдаланган идек. Ул мотив С. Лагерлёфның «Нильсның кыр казлары белән сәяхәте» дигән популяр әкият-кыйссасында да күренә.

**ИРӘМСЕ-Ү** «возгордиться, считать себя героем (о детях, юношах)», башк. *ирәмһе-ү* «распускаться, вольничать», «стать радушным, щедрым», вольничать», себ. (Радлов I: 1458) **ірäмсім-** «гордиться» ← *ірäм* ~ башк. *ирәм* «шат һәм киң күңелле батыр» к. ш. ук алт. (Баскаков 1966: 30) *эрэмжий-* «үзен зурга кую», бур. *эрэмшэ-* «үз-үзенә артык ышану», яз. монг. *eremsi-* «үзеңә ышану». К. ССТМЯ I: 407, ләкин анда бу сүз «өметләнү, ымсыну» мәгънәсендәрәк һәм як., эвенк. *эрэн-*, маньч. *эрэ-* «үзеңә ышану, өметләнү» фигыле белән бәйләнелә. Һәрхәлдә бу сүзне **ир** < **әр** сүзеннән аерып булмый. Чаг. *йокы-мсы-ра-, көл-емсе-рә-*.

**ИРӘН** иск. «важный (учёный, государственный) муж; божий человек» (обычно в форме *ирәннәр* «божьи люди», *гаиб ирәннәр* «сорок святых, которые стали невидимыми и ходят до светопреставления меж людей, творя добрые дела»), тат. диал. (Тумашева 1992: 58) «муж жены» < гом. төрки *эрэн*, кар. *эран*, хак. *ирэн* һ.б. *ир* < *эр* сүзенең күп. формасы дип исәпләнә (ЭСТЯ I: 290–291), к. ш. ук **Ир-ат.** Тат. диал. **әйрән** (Тумашева 1992: 36) вариантлы кызыклы. Радлов I: 757; Будагов I: 185; Тимергалин: 199–200.

**ИРГӘЕЛ [иргәйёл],** диал. **иргәҗел, эргәҗел** «мальчик-с-пальчик; гном» (сказочный персонаж), «первый сын; подснежник» ~ башк. *иргәйел, илгәйер*, кырг. *эргэжҫэл, эргэжҫил, эргэжҫэли,* каз. *эргэжэй, эргэжэйлі,* нуг. *эргэжэйли*, үзб. (ЎХШЛ: 95) *эргәжҫәл* «кәрлә, бармак батыр», к. ш. ук рус. *Ирбеел* яки *Ирбит* Көнб. Себердә елга һәм шул елга буендагы мәшһүр сәүдә үзәге – **Эрбет,** рус. диал. *аргуль, арагулька, иргулька, иргулька, ургуль* (> *ургуй*)*, ургулька, джарахулька, джарахай* «эргәзембай чәчәге», *джарахия, джирахей, джирахулька* «маймыч; үсеп җитмәгән, бәләкәй балык» (Аникин: 91, 183, 589) – барлык бу сүзләрнең нигезе – бор. төрки *erŋek* «бармак», шуннан *erŋäjü* «бармак буйлыгы кеше» (МК, ДТС: 181) – әкият персонажы: имеш, бу бармак чаклы кешеләр җир астында кышлыйлар да, язын уянып чыгалар һәм әйлән-бәйлән уйныйлар; кеше күрүгә алар *эргәзембайга* (< *әргәҗҫелбайга*) әвереләләр һ.б. К. **Эргәзембай.**

*Иргәйел* < *иргәҗел* < *иргәҗҫәйел* < **эргәкчәйлиг* яисә *әргәкчәй-йәл* (*йәл* «пәри») булса кирәк (*-чәй-* «иркәләү, кечерәктү кушымчасы»), к. алт., тув. *эргэк* «баш бармак; батырлык символы» («Маадай-Кара», 1973: 108, 463), *Ӓргäк, Ергäк* – бер эпик батыр исеме (Катанов 1888: 19–20), як. *эрбэх* «баш бармак; баһадир көч», *Эрбэхтэй бэргэн* эпик баһадир («бармактай мәргән»), к. ш. ук алт. диал. *эркэң,* уйг. *әрңәк*, яз. монг. *ereikei, eregei, erekei*, эвенк. *хэрбэк,* маньч. *ferxe* «баш бармак» һ.б. (Poppe 1955: 11), хәз. монг. *эрхий* id., *эрхий-мерген* «иргәел мәргән».

Бу сүзнең монг. күп. формасы *эргэнүт* «шекәләр (гномнар)» сүзеннән *Иркүт* елгасы һәм *Иркутск* – шәһәр атамасы килә; к. хак. *Иргэгит чоңы* «иргәелләр (гномнар)» (*чоң* «халык»), к. Чирім тамырлары: 42.

Бу сүзнең төп мәгъ. «бармак, баш бармак». Аның «кечкенә, әмма бик көчле батыр» мәгъ. шуның белән аңлатыла: бу сүз ук атучының керешне ычкындыру өчен кулланыла торган бармаксасын (киң металл балдагын) да белдергән һәм җәя

белән укның көче «батыр» булып символлаштырылган. К. ССТМЯ II: 354; Ахметьянов 1981: 27; МНМ II: 669.

**ИРГӘНӘК** «перегородка; ширма», диал. «лёгкие ворота» (ДС I: 63; Тумашева 1992: 59) ~ нуг. *эргэнэк* «чалгы, саламҗыйгыч һ.б. канаты», каз., к.-калп., үзб. диал. (ЎХШЛ: 97) *эргенек, йэргэнэк* «иргәнәк; ишек», чыгт. *иргäнä,* бур. *эргэнэг* «савыт-саба шкафы», эвенк. (ССТМЯ: 402) *эргэк,* бор. монг. *ergineg* «иргәнәк, шкаф» – тәүдә «әйләнмәле шкаф, этажерка» булган, к. тунг. *эргэктэ-* << бор. монг. *ergi-, ergin-* «әйләнү». Чаг. **Эргә.**

Рясянен (Räsänen 1969: 47) чув. *аркă* «күлмәк итәге» сүзен дә **иргәнәк** белән тамырдаш ди.

**ИРГӘНӘКҮН, әргәнәкүн** «легендарная прародина тюркских народов» < монг. *эргэгэ кон* id. Төр. *ergenekon* «Нәүрүз бәйрәме» һәм бу сүзгә баглы күп легендалар бар. Татарларда *иргәнәкүн* «Идегәй» дастанында телгә алына: иргәнәкүннән чыгып, мең еллар буе үлмәгән Кара тиен [тәгин] Йосынчы аксак Тимернең кызын урлый, ул кызны Идегәй табып бирә, к. Идегәй 1988: 102–107; Будагов I: 31; МНМ I: 183, II: 171.

Гомумән, *иргәнәкүн* монгол сүзе: *иргәнә* (к. **Иргәнәк**) «капка», *күн* «тау сырты». Угыз төркиләрендә *иргәнә күн* тур. мифологиянең киң таралуы шуның белән баглы – угызлар элекке (төркиләшкән) монголлар алар. *Иргәнәкүн* диагән реаль географик урын Маньчжуриядә бар.

**ИРГӘСӘР** диал. «дурак; похотливый; язычник» ~ каз. *енгезер* «әзмәвер» монг. халыкларындагы эпик герой *Эр-Гэсэр* сүзеннән булса кирәк.

**ИРГӘШ** «брань; ссора». К. **Иргәш-ү**.

**Иргәш** сүзе элекке ядкәрләрдә «үчекләшү күренеше», аннары «иярүче, иярчен, тәкълитче; дәвамчы» мәгъ. очрый. Монда ике тамыр.

**ИРГӘШ-Ү, иргәләш-ү** (к. Будагов I: 185–189; ТТДС I: 148) «яростно спорить» > мар., удм. *аргаш-* < *äргäш-* «тиргәшү, үчләшү» < гом. кыпч. **эргәш-, *эригаш-* к. каз., к.-калп. *ерегис-, ергелес-* «үҗәтләшү», уйг. *әргәш-*, үзб. *эргаш-* «ирешү, кызып-кызып бәхәсләшү» ← **эргә-* кырг. *эрги-*, ком. *эрик-* «ярсыну, рухлану» һ.б. Чаг. **Иреш-ү II.** Чаг. ш. ук к.-балк. *эриш* «комарлы; көнчел; бәхәс».

Дерив.: **иргәштер-ү.**

**ИРДАВАЙ**, диал. **ирдәвәй, ирдавый** (Остроумов 1876: 80; ТТДС I: 148–149) төбендә «ир дию», ләкин халык этимологиясе буенча «хатын дию; ирсәк» («ир давай») булып киткән; **ирдәүкә** варианты «ирсыман хатын» мәгъ. Һәр очракта **дәү** «дию». К. **Дәү.**

**ИРДӘМ** «мужественный», диал. (Будагов I: 184) «мужественность; мужской пол» ~ уйг. *әрдәм, әдрәм,* кырг. *эрдем,* төр. *ertem, erdem* < бор. төрки (ДТС: 176) *erdäm, erδäm* «ирлек, егетлек» *ер* «ир» сүзеннән (*-dem* кушымча, чаг. *үктәм, ярдәм*). **Ирдәм** сүзе бор. төрки телләрдән күрше телләргә киң таралган булган: бор. төрки > монг. > тув. *эртем, эрдем* «фән; егетлек, осталык; дөнья күрү», маньч. *эрдэму* «осталык»; венг. *erdem* һәм мар. *артам* «егетлек, осталык» бор. болг. теленнән. Будагов I: 184; Räsänen 1969: 47; Мухамедова: 198.

Дерив.: **ирдәмле, ирдәмлек; ирдәмсез** һ.б. Хәз. әд. телдә **ирдәм** һәм аның дериватлары сирәк кулланылу гаҗәп тә. Егетләрнең ирдәмлеге юк!

**ИРЕК** «воля, свобода» > чув. *ирĕк*, мар. *эрык*, удм. *эрик, эрък* (к. ш. ук *элъксър* < мар. *элыксыр* «ирексез», к. Насибуллин: 150) < гом. кыпч., алт., чыгт., уйг. *эрик*, башк. диал. *ирк*, уйг., үзб. *эрк, әрк* < бор. төрки (ДТС: 179) *erk* «көч, куәт, мөмкинлек, ирек» ~ бор. монг. *erke* «ирек; хак, хокук», к. Радлов I: 762; ЭСТЯ I: 295–296; Poppe 1955: 87; Федотов I: 170–171.

Гомуми закончалык буенча, монг. *erke* > *эркэ, эрхэ* «ирек» борынгырак һәм ул чагында *ирек* << *эркэ* ← *ир* < *эр* (к. *Ир-* «хәрби демократия заманында тулы хокуклы сугышчы») сүзеннән. Һәм тат. диал., башк. *иркәй* «ир кеше, хатын ире» иң бор. форманы чагылдыруы ихтимал. К. **Иркә, Иркен.**

Дерив.: **ирекле, ирексез; ireклек** һ.б.

**ИРЕК-Ү (иректе, ирегү)** (к. ДС I: 63; ДС III: 61–62), **әргәр-ү, әрек-ү** (ЗДС: 86–87) «тяготиться (своим положением), скучать» < гом. кыпч., чыгт. *эрик-* ~ алт. *äрik* (Радлов I: 763), уйг. *эрик-* id., төркм. һ.б. *ӣрик-* «ирену, ирегү» (к. ЭСТЯ I: 374–376) бор. *э̄р-* «әкренәю, сүлпәнәю, сүрелү» фигыленең интенсивлык формасы. К. **Иру.**

**ИРЕМ** (Урал, себ., к. ЗДС:215) «углубление на дне реки (на месте крутого поворота)», «клок шерсти или хлопка для прядения» – дөресе *ийерем* булса кирәк > рус. (Аникин: 226) *ырым, ярым* «елга бөгелешендәге тоба» ~ кырг., алт. *ирим*

«елганың тирән төше», тоф. *ээрим,* төр. *egrim* «агым өермәсе», чыгт. (Радлов I: 705) *эгрим,* бор. төрки (ДТС: 166) *egrim* «тоба, су җыелган төш» ← *egir-* «әйләндерү, урау, бөтерү, өерү; әрләү»; чаг. ш. ук тат. диал. *җегер-ү, йегер-ү*, *ийер-ү* «әрләү, бөтерү», шуннан *ирем* < *ийерем* (ЗДС: 215) «кабага бер бәйләрлек йон» һ.б. К. **Иер-ү, Әрлә-ү.**

Идел-Урал регионында **Ирим, Ирем** дигән елга, төбәк исемнәре бар.

**ИРЕН,** диал. (ЗДС: 190, 248) **җирен, йерен, йирне** «губа», себ. (Радлов I: 766; Тумашева 1992: 38) *äрiн, әрин* < бор. төрки *erin* id. (ДТС: 178) ~ куман., алт., чыгт., госм. *äрiн* «ирен; аскы ирен; ирнәү» (Радлов I: 766), үзб. *ирин* id.; кайбер телләрдә хәтта «танау, урт» һ.б. Икенче яктан, күп телләрдә «ирен» мәгъ. бүтән сүзләр кулланыла (чув. *тута* < **түтәг* > төр. *dudak*; үзб. *лаб* һ.б.). к. ш. ук бор. монг. *erün* «ияк» (к. Поппе 1938: 165).

*Ирен-* ясалышы буенча *борын, буын, карын, куен, муен* кебек сүзләр моделендә һәм бор. *ǟр* < **эгәр* (*эк* «кырый, чик») «күтәрелеп, калкып торган кырый, тигезлекне чикләгән тау сыртларын» белдергән сүздән, к. тув. *эрик* «яр, кырый», *эрин* «киңлек»; алт. диал. *ээрин*, *эрин* «ирен», ләкин *эрди* «ирене» >> уйг. *ирт* «ирен». К. **Ирнәү.** К. ЭСТЯ I: 292–293.

Дерив.: **иренле, иренсез; иренләш-ү** (неол.).

**ИРЕН-Ү** «лениться», диал. ш. ук **ирек-ү** ~ хак. *ирiн-*, гом. кыпч., үзб. *эрин-*, шор., уйг., чыгт., госм. *äрiн-* «иренү, ирегү, үзен иркен сизү» (Радлов I: 767–768) *ир-ү* < *эр-,* төркм. *иир-* «ару, талу» фигыленең кайт. юн. ЭСТЯ I: 376–377.

Барлык кыпч. телләрендә **иренчәк** < *эринчәк, эринчäк* (куман. *äрицäк*, нуг., каз., к.-калп. *эриншэк,* үзб. *эринчак*) сүзе характерлы. К. **Ирү.**

**ИРЕЧ** (ЗДС: 215) «несчастье, жалкое положение» ~ бор. төрки (ДТС: 178–179) *erinč* «бәхетсез, бәхетсезлек», *erinčig* «кызганыч, кызганычлы», *erinčkä-* «кызгану, җәлләү». Кайбер төрки телләрдә ошбу (?) сүз капма-каршы мәгъ. очрый: төр. *erinč* «рәхәт, хозур; бәхет» < бор. төрки (ДТС: 179) *erinč* «тынычлык, рәхәт», КБтә *ärič* «өмет» һ.б. ← гом. төрки (булган булса кирәк) **äri-* «өметләнү», шуннан (к. Räsänen 1969: 47) уйг., чыгт., госм. *äri-m-* «өметләнеп көтү» ~ монг. *erim* «өмет», *eri-* «сорап тору».

Дерив.: **иречле** «баласыз, бала табалмый торган (хатын)».

**ИРЕШ** диал. «основа ткани» ~ каз. *epic* id. Бу сүз тат. диал. *ирешкарыш* «аркылы-торкылы» сүзендә билгеле: *карыш* «аркаулык»

**ИРЕШ-Ү I** «достигнуть; добиться» ~ куман., кар., кр.-тат., госм. *äрiш-* (Радлов I: 755), үзб. *эриш-* id. – күп төрки телләрдә юк – ш. ук сирәк кар., кр.-тат., госм., төр. *эр-, йäр-* ~ монг. *ир-* «барып җитү; өлгерү; ярашлы булу» сүзенең урт. юн. (ЭСТЯ I: 288–289). К. ш. ук TS: 338–339. К. **Ир-ү.**

**ИРЕШ-Ү II** диал. «спорить азартно; препираться; стоять на своем из-за самолюбия» < гом. кыпч. *эриш-* id., к. кар., куман. *эриш-* «шаяру, капризлану», к.-балк. *эриш-* «ярышу», хак. *iрiс-* «ирештерү, үртәү», *ире-* «ярсу», нуг., каз., к.-калп. *эрис-*, *эристир-* «ирештерү». Севортян (ЭСТЯ I: 293–294) бор. *ир-* < *эр-* «шаяру» сүзеннән ди һәм *ирмәк* сүзен дә шуннан чыгара. Рясянен (Räsänen 1969: 46) каз. *erägäs-//ерегiс-* «бәхәсләшеп ярышу» сүзен монг. *eri-* «таләп итү» белән чагыштыра. Безнеңчә, *иреш-ү* < *иргәш-ү* (бозылган вариант), к. чыгт. (Радлов I: 673) *äрiклä-* «ирештерү, үртәү». К. **Иргәш, Ирше.**

Дерив.: **ирештер-ү** (бу форма төп фигыльдән ешрак кулланыла); диал., башк. (ТТДС II: 102; БТДҺ: 100) **ирешен-ү** «үчекләшү» (асылда тат. сөйләшеннән).

**ИРҖӘНКӘ** диал. «женщина, любящая общаться или работать с мужчинами (не блудница!)» – ачык түгел: *ир җәнкә* дип аңлату мәгънәсенә туры килми. Шул ук мәгъ. **ирмирәй** (ТТДС I: 149) тур. да шуны әйтергә мөмкин. Чаг. ш. ук добр. *ırcanke* «ыржаеп көлүчән», *ırcan-* «тешләрен күрсәтеп көлү». Монда төрле «халык этимологияләре» бар бугай.

**ИРКӘ** «неженка; баловник; любимчик; нежный, ласковый; изнеженный» > мар. *эрка,* удм. *эрке* id. < гом. кыпч., алт. *эркэ*, уйг. *әркә*, хак. *иркэ, иргэ,* тув. *эрге* id. (кайбер төрки телләрдә юк) – бор. төрки > монг. *эркэ*, бор. монг. *erke* «көч-куәт, ихтыяр, ирек, хокук, хак» (эвенк. *эркэ* «шәп егет; ирдәм» һ.б. к. ССТМЯ II: 465) сүзенең төрки телләрдәге чагылышы булса кирәк. Чаг. добр. *erke* (ат) «иректәге, эшләтелмичә йөри торган (ат)», тат. диал. (эчк., ТТДС I: 149) **иркәце** «иркәче, иркә», ягъни үзенә «ирек, хокук бирелгән зат», чаг. ш. ук эвенк. *эркач* «иркә» ~ үзб. *эргаш* «беренче ир бала» >> мар. *эргаш* «угыл, ир бала». К. **Ирек.** К. ш. ук

бур. *эрхэ* (> тув. *эрге*) «хокук; иркә», алт., уйг. диал. *эркэ, äркä* (Радлов I: 776–777) «артык иркәләү»; бур. *эрхэ-* «иркәләү» (фигыль); чув. *иртен-* «шаяру; ирәмсү», *иртех* «иркә булып китү» (Ашмарин III: 142). К. Бертагаев 1951; 579).

**ИРКӘК** «самец животных» < бор. төрки *erkäk* (ДТС: 179) «ир; иркәк» ~ гом. төрки *эркäк, эркэк* id. Бу сүзнең ясалышы бигүк ачык түгел **эрык-эк* булса кирәк, ягъни элек **эрик* «ир» сүзе булган; яисә **эрикэ-к*, к. **Ирек.** К. ш. ук тув. *эргэк,* як. *иргэк* «иркәк». Мухамедова 1973: 199. К. түбәндәгене.

**ИРКӘЧ** «самец-вожак», «козёл» ~ гом. кыпч., чыгт. *эркäч,* төр. *ergeç, erkeç* < *эр-кäч* id.

**ИРКЕН**, себ. **ирген** «свободно, просторно; вольготно; свободный, просторный» > чув. *иркĕн, ирккĕн*, мар., удм. *иркын, эркын* < гом. кыпч., алт., гом. төрки (ЭСТЯ I: 296) *эркин,* уйг. *әркин* «иркен; ирекле», алт. *эркин* «ирек; көч, кодрәт» һ.б. *эрк* «көч, ирек, ихтыяр» сүзенең инструменталь килеш формасыннан (*эрк-ин*). Чув. *ирĕккĕн, ирĕкĕн* «иркен; үз теләге белән» шул ук юл белән кабаттан ясалган.

Дерив.: **иркенлек, иркенәй-ү.**

**ИРМӘК** «потеха, забава; потешный, забавный; свободная беседа, разговор», диал. (ДС III: 62; ТТДС I: 149) «потешник, шутник» ~ башк. (БҺҺ II: 79) **ирнәк** «комик» > удм. (Насибуллин: 150) *эрмак* «комик» < гом. кыпч., алт., чыгт. *ермек [эрмэк],* уйг. *әрмәк,* алт. *ербек* > хак. *ирбек* id., ш. ук «сорау; әйтке-мәйтке», алт. диал. *эрмек, эрбек* «кызыклы хәбәр», төркм. *эрмек* «шөгыль»; үзб. *эрмак* «ирмәк, юаныч; адәм көлкесе» ← *эр-* «(каракаршы) сөйләшү, җаваплашу; киңәшү; эшләү» (к. **Иреш-ү**).

Төрки телләрдә икенче **эрмәк** ~ бор. төрки (ДТС: 180) *ermagü* «ялкау, иренчәк», яз. монг. *eremeg, erneg*, бур. *эрмэг* «бала тапмый торган» сүзе дә бар. Аның **ирмәк** сүзенә катнашы ачык түгел. Будагов I: 191; Räsänen 1969: 49; ЭСТЯ I: 300–301.

**ИРМӘН** себ. (Тумашева 1992: 59; ЗДС: 217) «богородская трава; чабрец; сероцвет; неувяда» (төрле җирдә төрлечә аңлатыла) ~ каз. (ҚТДС: 100) *ермен, ермене,* к.-калп. *эрмене,* кырг. (Радлов I: 800) *ермäн,* уйг. *әрмән* ~ бур. *эрмэн* – әрем төрләре. Чаг. **Әрәмә, Имән.**

Каз. телендә *ермен* «әрем (Artemisia)», ә *ермене* «меңьяфрак (Achillea millefolium)» диелә.

**ИРНӘҮ** «утолщение на краю посуды» ~ ком. *эрнев*, нуг. *эрнек,* каз., к.-калп. *ернек [йэрнэк]*, *ернеу,* төркм. *эрнәк, эрнэк,* чыгт. *эрнäк, эрнэк, эрник* һ.б. ~ (ЭСТЯ I: 301) *эрин-э-* «иренләү» ← *ирен* < *эрин.*

**ИРСӘК** «мужелюбивая, похотливая» ~ башк. *ирҫәк* id. < гом. кыпч. *эрсäк* ~ төр. *ersek* id. < бор. төрки (ДТС: 187) *ersäk* ← тат. диал. *ирсә-* < бор. **эрсә-* «ир теләү, теләккә килү» ← *ир* < *эр*. Монг. *эрсэг* «ирсәк» төрки телләрдән. К. **Ир, Ирсе-ү.** Мухамедова 1973: 199.

**ИРСЕ-Ү** (ТТДС I: 149; Тумашева 1992: 59) «капризничать; хвалиться, возомнить себя» < бор. төрки (к. ДТС: 181) *ersi-* «үзен ир (герой) дип исәпләү». Чаг. **Ирәмсе-ү.**

**ИРТӘ** «утро; рано» < гом. төрки *эртэ,* як. *эрдэ*, монг. *эртэ(н)* id., хак. *ирте,* уйг. *әртә* «иртә, иртәгә», үзб. *эрта* id. һ.б. ← чув. *ир,* мар. *ир, эр*, төркм., үзб. диал. (ЎХШЛ: 96) *ээр*, госм., чыгт. (Будагов I: 184–185) *эр*, *ир* (гарәпчә язылышта бирелгән), *йир* «иртә, иртәнге чак» (к. ЭСТЯ I: 396–371). Чув. сүзе, ихтимал, бор. тат. теленнәндер (*ә* ~ *э* > *и*), тат. телендә бу сүз *ир* «хатынының ире» сүзе белән омоним булганлыктан төшереп калдырылган.

*Иртә* < *эрта* сүзен *ир* ~ *эр* сүзенең урын-вакыт килеше (*эр-тä*) формасы түгеллеге тур. Э.В. Севортян (ЭСТЯ I: 301–304) бик нигезле рәвештә сөйли һәм *эртä* сүзенең ясалышы тур. төрле фаразлар китерә. К. к.-балк. *эртдэ-, эртде* «иртә; элек», «борын-борын заманда».

*Ир* < *эр* сүзенә килгәндә, аны Э.В. Севортян (ЭСТЯ I: 396–371) чув., гом. кыпч., алт., хак. *ирт-*, *эрт-* «үтү, китү, (вакыт) үтү» сүзе белән бәйләмакчы. Ш. ук вакытта ул бор. төрки (ДТС: 175, 211) *er, ir* «тауның кояш төшкән ягы; кояш» сүзе белән дә чагыштыра. К. ш. ук һинд-евр. (Pokorny: 12) *aier* «көн, иртә» (шуннан ним. *eher* «элегрәк, иртәрәк, тәүдәрәк»). К. ш. ук Räsänen 1969: 46; Федотов I: 169–170; Ахметьянов 1989: 18; Жубанов, Ибатов: 327–328 (авторлар *иртән* < *иртаң* < *ир таң* «иртә-таң» парлы сүзеннән димәкчеләр).

Дерив.: **иртәле (иртәле-кичле); иртәлә-ү** (бу сүз МКда ук теркәлгән). К. **Иртәгә, Иртән.**

**ИРТӘГӘ,** диал. (ЗДС: 87) **әртәгән** «завтра» < гом. кыпч., үзб. *эртäгä* (үзб. *эртага* дип тә язылa), *эртенгä,* уйг. *әртигән*, тат. диал. (ТТДС I:

150) **иртәсте** «иртәгә; иртән үк» һ.б. *иртә* < *эрте* сүзеннән (чаг. рус. *завтра* < *за утро*). К. ш. ук каз. *ертең* «иртәгә».

Дерив.: **иртәгәсе, иртәгәсен**; сөйл. **иртәгәләү** («иртәгә, иртәгә» дип соңлау); **иртәгәдән.** Чаг. диал. **көнүтә** ~ **төнүтә** «көн (төн) үткәч; иртәгә».

**ИРТӘК** диал., фольк. «предание; сказка» ~ нуг., каз., к.-калп. *ертек [эртэк],* уйг. *әртәк,* үзб. *эртак* id. < тат. диал. (Арсланов 1988: 59, 60, 62) **эртәңки** «иртән (ягъни күптән) булган (вакыйгалар)» > калм. (Ramstedt 1935: 127) *erteki* ~ нуг. диал., алт. диал. *эртэги* id., к. ш. ук монг. *эрт* «элек», алт. диал. (Баскаков 1972) *эртэк* «момент». К. ш. ук себ. (Тумашева: 37) **әрдәги** «күптәнге».

Э.В. Севортян (ЭСТЯ I: 304–305) бу сүзне гом. төрки (~ себ. тат.) *эрт-, ирт-* > чув. *ирт-* «үтеп китү» фигыленнән ди. Ләкин нуг., к.-балк. һәм добр. тат. телендә әкиятләрнең *эртде-эртде* «борын-борын заманда» дип башлануында *эрт* – исем («күптән үткән замана» мәгъ.). К. **Иртән, Ирт-ү.**

**ИРТӘН** «утром», диал. (М. Гафури) «утро», диал. **иртён** «утро; утром» < гом. кыпч., алт., тув. *эртэн* < *эрттэн* (сирәк очрый), нуг., каз., к.-калп., чыгт. *эртәң, эртәң* сүзен Э.В. Севортян (ЭСТЯ I: 305–306) *эр-таң* кушма сүзеннән дип аңлата да, *эртә* «иртә» сүзенең инструменталь килешеннән дә булырга мөмкин, ди; алт. (Баскаков 1972: 275) *эртин* «иртә» соңгы фаразны куәтли. Чаг. ш. ук яз. монг. *erten* «иртә» (к. **Иртә**). Гомумән, **иртән** сүзенең төрле чакта төрлечә ясалып, бергә консолидацияләнүе дә ихтимал, к. **Иртәнчәк.**

Дерив.: **иртәнге, иртәнгелек.**

**ИРТӘНЧӘК,** диал. **иртәнчек,** (ТТДС I: 149–150) **ирти, иртин, иртестән, иртәстен, иртәстөн, иртәгәч** һ.б. «раненько утром» ~ башк. *иртәнсәк, иртәнсек* id., мар. *эрде́не, ирдӧн* id. һ.б. Һәрберсе аерым аңлатуны сорый: **иртәнчәк, иртәнчек – иртән** сүзенең кечерәйтү-иркәләү формасы (*иртән чак* түгел) шикелле. Чув. *ирӗнпех* ≈ тат. *иртән белән үк*, к. тат. диал. *иртә(н) блә* ~ гом. кыпч. характерда; каз., к.-калп. *иртеншек* id. тат. теленнән булса кирәк (э > *и!*).

**ИРТЕШ,** диал. **Әртиш,** (Будагов I: 186) **Ирдиш** «Иртыш (река в Сибири)», бор. төрки (ДТС: 182) *Ertiš* id.; иске үзб. (Боровков 1961: 40) *Артыш* – Г. Нәваи буенча, «гомумән зур елга; рус, йөмуд (төрекмән) һәм калмык (җунгар?) илләре арасындагы елга». Г. Нәваи, күрәсең, географияне начар белгән – аның заманында руслар Иртештән әле ерак булганнар; яисә аның **Әртиш ~ Артыш* дигәне – Идел (Волга). Һәм *Артыш* язылышы да бик шикле.

Гомумән *Иртеш, Ирдеш* һәм *Идел* < *Ирдел* сүзләренең бердәй нигездән килүе бик ихтимал, к. **Идел.** Гарипова 1998: 214–268.

**ИРТ-Ү** диал. «быть давно прошедшим» ~ чув. *ирт-* «(күптән) үтеп китү» ~ бор. төрки (ДТС: 182) *ert-* «үтеп китү» (күп дериватлары бар), добр. тат. *ert, irt* «күптән үткән заманнар». **Ирт-ү** сүзе, күрәсең, **үт-ү** сүзе белән кысрыкланып чыгарылган. **Ирт-ү, ирт** сүзләренең бүтән берәр нигез белән бәйләнешы ачык түгел. Чаг. **Ир-ү.**

**ИРҮ** диал. (Радлов I: 1464; ДС I: 63, 64) «медленно, не торопясь; лень; привал» (к. ТТДС I: 414) > чув. *ирӳ (ирепен)* ~ каз. *ерү* id. бор. кыпч. **эр-ү* «әкренәю, тукталу; дәвам итүдән баш тарту» сүзеннән, к. ш. ук бор. төрки (ДТС: 175–176) *er-, er-jalq-* «җиләү, тую, ялыгу; кәефсезләнү», ихтимал, *er-* «барып җитү, булу» белән бердәйдер (шуның күч. мәгънәседер). К. **Ирен-ү**, **Ирүаста.**

**ИР-Ү** иск. «быть, являться» < гом. төрки *ер-, эр-* (ЭСТЯ I: 218–220 буенча, *э-р, ә-р-*) «булу»; бу сүз хәз. төрки телләрнең берсендә дә тулы парадигмага ия түгел, әмма парадигмасының кайбер буыннары аерым сүз-ярдәмлек буларак аеруча активлашып киткәннәр; бу хәл бор. төрки (руник) әд. телендә үк күзәтелә, к. бор. төрки *ermiš* > тат. кит. **ирмеш** «булган» > **имеш**; *erkän* > *иркән* > **икән**; *erdi* > *ирде* > **иде**; *ersä* > *ирсә* > **исә** (кисәкчә), *ermäs* > *ирмәс* > тат. диал. **имәс**, иске тат. (XVIII г.) **икәч** < *иркәч*. Бу лексикалашкан сүзшәкелләр бик борынгыдан килгәнлеген чув. *мар* < **мәр* < **әмәр* < **эр-мәр* «түгел» сүзе күрсәтә (димәк, бор. *-р* телдә үк мондый ярдәмлек сүз булган). *Икән, икәч* сүзләрендәге *-к-* (*-г-* түгел!) да борынгылык галәмәте (*икән* < *иркән*).

*Ир-* < *эр-* фигыле гом. төрки характердагы *эр-, әр-* «җитү, җитешү, өлгерү» сүзе белән (к. **Иреш-ү**) бердәй булса кирәк, к. төр. *ermek* (*er-*) «җитә алу (мәс., кул җитү); булдыру, табу; ирешү; балигъ булу һ.б.» (TTS I: 339). Шунлыктан, *ир-* сүзе *ир* (к.) сүзенең фигыль коррелянты дип тә уйлыйлар. К. **Иде, Икән, Имеш, Ит-ү.**

**ИРҮАСТА** (Тумашева 1992: 59) «не торопясь» < *ирү-аста: ирү* (к. югарыда) + *аста* < фар. (Будагов I: 170) *аhистӓ* «әкренләп, тын гына».

**ИРШЕ** диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «некрасивый (о ребёнке)» ~ кр.-тат. (Dobr. II: 32) *erşi* «сәер чиркен», каз. *ерсі* id. << бор. төрки (ДТС: 181, 212) *irši* «явызларча көнләшү», *irši-qarši* «көнчелек һәм каршылык» < санск. *irşya* «көнчелек».

**Ирши** сүзе күп кенә төрки һ.б. телләрдә очрый. Бәлки тат. **иреш-ү** «көнләшеп бәхәсләшү» < **иршеш-ү**дәндер (ягъни **ирши** исем сүзеннән **ирши-** «ямьсез көнләшү» сүзе ясалгандыр).

**ИС I** «сознание, память, чувство» > удм. *эс* (Насибуллин: 150), мар. Т. *ӓш* < гом. төрки *эс, ӓс* id. (к. ЭСТЯ I: 306) ~ чув. *ас* < **әс* id., бор. монг. *es* id. (*eslebe* «хәтерләде, исләде», *estü* «исле, акыллы», к. Поппе 1938: 167). Räsänen 1969: 49.

Бу сүз төрки телләрдә бик күп дериватлар биргән, к. **Исәй-ү, Исән, Исәңгерә-ү, Исәр, Исер-ү, Искәр-ү.** Федотов I: 60–61.

**ИС II,** диал. (ЗДС: 264) **йыс** «запах; угар» ~ башк. *еҫ* (*йеҫ*), кар., к.-калп. *ийис,* каз. *иәс*, кырг. *ис* «ис газы» бор. *ийэ* «ис» сүзеннән – *ийэси* формасыннан, ягъни кабаттаркалу юлыннан килеп чыккан: *йий-си* «исе» дигәнне кыпчаклар *ийис-и* дип аңлый башлаганнар һәм моңарчы булмаган нигез *ийис* пәйда булган, к. аз. *и,* госм. *ий, ик* «ис, хушбуй», *ийилә-* «ис чыгару, ис килү» (Радлов I: 1407, 1413–1415), чаг. тат. сөйл. *исе-косы* < *ийй-си-куңусы* «әз генә (начар) исе» (чаг. **Кос-**). Бу *ийэ*не *ий-* «җибәрү» (к. **Ий-ү**) белән дә чагыштыралар.

Дерив.: **исле, иссез; ислән-ү** (ашамлыклар тур.); иң кызыклылары себ. (ЗДС: 364) **йысла-у** «иснәү», **йыслы** «исле»; **йысы-у, йысык-у** «ислән-ү»; **йыслыҡ** «борын тишеге». Бу сүзләрнең аналоглары юк бугай. Ихтимал, алар фин-угор (себ. татарлары составына кергән халыклар) телендә булган модельләр буенча ясалганнардыр.

Коми *ис*, нен. *йас* «ис, начар ис» төрки телләрдән кергән дип була, әмма мөстәкыйль фин-угор сүзе дә булырга мөмкин. Чув. *йăс* – көйрәүгә тәкълит (*йăс-пăс* «ис-пос») тә *ис* сүзе белән бәйле булса кирәк (чаг. **Пос**).

**ИСӘ** «что касается, а, же» < гом. төрки *эсӓ* < бор. төрки *ersä* > иске тат. *ирсә* «булса, кылса» – *ир-* < *эр-* фигыленең (к. **Ир-ү**) шарт фигыль 3 зат берлек формасы; тат. сөйләшләрендә һәм фольклорда 1 һәм 2 затлары да кулланыла: **исәм, исәң, исәгез,** сирәгрәк **исәк** (мәс., *күрдисәк* < *күрдек исәк*).

**ИСӘЙ-Ү** «взрослеть; поумнеть; вылечиться» ~ башк. *иҫәй-*, нуг., каз., к.-калп., кырг. *эсей-,* каз. *есей-* id. **ис I** сүзеннән, аның сыйфат мәгънәсеннән (ләкин андый мәгънә конкрет теркәлмәгән). К. **Исән.**

**ИСӘКӘЙ** (к. ТТДС I: 152) «ряженый (в виде водяного)» ~ башк. (БҺҺ II: 324) *әсәкәй* id. ~ як. *эсэкэй, эһэккэй* «урман, ут, су ияләрен хөрмәтләп атау сүзе» – төп мәгъ. «бабай, атакай» < яз. монг. *ečige* «бабай, атай» < **этикә* id. Шулай итеп, бу сүз *ата* ~ *әтә* тамырына кайтып кала. К. ССТМЯ II: 469 (эвенк һ.б. *этиркэн* «бабай» тур.).

Тат. *исәкәй* башк. сөйләшләреннән булса кирәк.

**ИСӘН** «здоровый, целый, в целостности (особенно – после пережитой опасности)» > чув. диал. *исен* (без теркәдек. – *Р.Ә.*), мар. *эсен,* удм. *эсӓн*, *исан, исӧн* id. (сүзнең таралуына аның мәзкүр телләрдә дә кулланыла торган дериватлары – **исәнме, исәнлек, исәнләш-ү** сүзләре ярдәм иткән) < гом. кыпч. *эсен*, каз., к.-балк. *есен* [*йэсэн*], хак. *изен*, уйг., чыгт. *әсән, эсән,* төр. *esen*, алт. диал. һ.б. (Радлов I: 883, 889, 1413) *ӓсӓн, ӓзӓн* < бор. төрки (Р. Рәхмәти материалларында) *asan,* як. (Пекарский: 314) *ӓтӓңңӓ* «исән-сау» ~ яз. монг. *esen* id. гадәттә (к. Räsänen 1969: 50; ЭСТЯ I: 308–309) фар. *асан* «җиңел, кулай, авырлыксыз» сүзеннән дип аңлатыла.

Безнеңчә, бу сүз төрки *ис* < *эс* «һуш; үз-үзеңне яхшы белү; хәтер» сүзеннән (к. **Ис I**). К. тат. *исәй-ү* (к. **Исәй-ү**) «үз-үзеңне яхшы сизү, терелү, айну», госм. *ӓсӓн-* «сәламәт, исән-сау булу», кар. *эсэв* «шатлык; шатлану», себ. (Радлов I: 1538; Тумашева 1992: 53) *ізäн-, изә-ү* «аңлау, истә тоту», уйг. диал. *äsängü* «үз-үзеңне сизү». К. ш. ук **Исәңгерә-ү.** Ахметьянов 1989: 97.

Дерив.: **исәнлек; исәнләшү;** к. **Исәнмесез**. Парлы сүз компоненты буларак: **исән-аман, исән-сау.**

**ИСӘНМЕСЕЗ** «здравствуйте» – миш. диалектыннан («казанча» **исәнсезме**). К. **Исән.**

**ИСӘНТӘ** (Тумашева 1992: 60) «киләсе елда» ~ уйг. *әсән* «ярен, киләсе ел». Монг. теленнән булса кирәк.

**ИСӘҢГЕРӘ-Ү** «обалдеть; оторопеть; растеряться» ~ башк. (БТДҺ: 103) *иҫәңкерә-, иҫәңке-* id.,

каз., к.-калп. *есеңкире-*, кырг. *эсенгире-* «зәгыйфьләнү; боегу; коелып төшү», үзб. *эсанкира-* «аптырау, исәңгерәү» ~ уйг. *есәнгири-* (*эсәнгирә-*) күчемле фигыль: «аптырату, исәңгерәтү» – *исән* сүзе белән баглы, ихтимал, монг. **эсэнгүй-рэ-* «исәнсезләнү» формасыннандыр; ш. ук *иссә-* < *эссä-* «исен-һушын югалту» (к. **Исәр**) фигыленнән дә ясала ала.

Дерив.: **исәңгерәш-ү, исәңгерәт-ү.**

**ИСӘП** «намерение, план на будущее; счёт, смета» > чув. (Сергеев 1968: 20) *исеп,* удм. *эсеп, эсэп*, мар. *эсап* id. < *хисап* (к.) сүзеннән; чаг. чув. *хисеп* «исәп; сан, хөрмәт».

Дерив.: **исәпле, исәпсез; исәплән-ү, исәпләш-ү, исәпләт-ү;** неол. **исәплек; исәптән (исәбемнән, исәбеңнән, исәбеннән);** диал., сөйл. **исәптәш.**

**ИСӘР** «дурачок» > мар. *исер, исäр,* чув. диал. *исер* ~ башк. *иҫәр,* себ. (Räsänen 1969: 51) *ežär* (?), *ĕсәр, исәр* > хант. *isär* < гом. кыпч. *эсер* (каз., к.-калп. *есер, есәр*), кырг. диал. *эсәр,* үзб. *эсар* id., (ЎХШЛ: 132) *йесәр* «елгыр; тыңлаусыз, башбаштак, әнисез үскән» – **ис I** сүзе белән баглы булса кирәк (Радлов I: 874), ләкин ясалышы табышмаклы сүз (чөнки этимоннарның вариантлары күп); чаг. башк. (БҺҺ II: 79–80) *иҫәү, иҫәүән* «исәр». Себ. (Тумашева 1992: 27) *арсар* «исәр, кыргый», каз., кырг. *арсар* «гөнаһ; аптыраш; аптырамыш» ← *арсы-у* «ахмаклык эшләү» (к. ш. ук Радлов I: 326–327) сүзе белән тәңгәлләштерү өстәмә дәлилләр сорый.

Дерив.: **исәрлек; исәрлән-ү; исәрләрчә.**

**ИСБАТ** «доказательство» < гар. *иçбāт* «исбат, ныгыту» *çбт* «нык булу» тамырыннан, шуннан ук **сөбат** «рухи ныклык, түземлек». Будагов I: 11.

Дерив.: **исбатлы, исбатсыз; исбатлау; исбатчы** (суд термины).

**ИСЕМ** «имя (человека); название; имя существительное» < гар. *исм* id.

Дерив.: **исемле, исемсез; исемлә-ү (> исемлән-ү, исемләт-ү); исемләш-ү; исемдәш.** Иске грамматик терминологиядә **исем** «мәгънәле сүз», шуннан **исме зат** «исем (сүз төркеме)», **исме сыйфат** «сыйфат», **исме мәгъруф** «ялгызлык исеме» һ.б., к. Будагов I: 46–47.

**ИСЕРГӘ-Ү** тар. «заступиться за кого-либо, защитить, сочувствовать» ~ төр. *esirge-* < бор. төрки (ДТС: 184 һ.б.) *esirkä-* «кызгану, җәлләү» < *es-irkä-* «истә тоту, искә төшерү» фигыленнән (*-irtke//-ırtqa* – бор. фигыль һәм исем кушымчасы, ул *комыртка, йомыртка* һ.б. сүзләрдә бар), бу сүз каз., аз. як. телләрендә һ.б. да очрый, чаг. ш. ук чув. *аçăрха-* «искәрү; күзәтү» < болг. **әсәрһә-* id. Räsänen 1969: 50; ЭСТЯ I: 310.

Иске документларда **исергәп** «яклау грамотасы» Алтын Урданың башлангыч чорыннан калган һәм монголча *эсиргэбэ* «яклады, якладым» сүзеннән килә: хан грамотасы шулай башланган.

**ИСЕР-Ү** «опьянеть, пьянеть» < гом. кыпч. *эсир-*, башк. *иҫер-,* алт. диал. *эзир-*, хак. *исир-*, уйг., куман., бор. төрки (Радлов I: 874, 876) *äсäр-, äсир-* < бор. төрки (ДТС: 184, 391) *esür-, ösür* «исерү; масаю» > чув. *ӳсĕр-* «исерү», безнеңчә, бор. *ög-süg//ögsig* «акылга мохтаҗ» (← *öг* «акыл, һуш») сүзеннән (*эсир-* < **эйсир-* < **öйсир* < **ögsig-ir* > *үсир-*), к. **Үк, Үксе-ү.**

Төрки телләрдә тагын (Будагов I: 136) чыгт. *үсрэ-,* төркм., уйг. *әсрә-*, төр. диал. *esre-* «исерү» паронимы бар, ул **ögsi-re* формасыннан булса кирәк.

Чув. *ӳсĕр*, *ӳссер*, *ĕссĕр* «исерек» бор. болг. *ӳ-сĕр* < **ög-sür* «акылсыз, һушсыз» сүзеннән. Räsänen 1969: 50; ЭСТЯ I: 309–310 (Э.В. Севортянның аңлатмалары безнекеннән үзгәрәк); Федотов II: 302 (этимологик аңлатма бирми, чагыштырулар белән канәгатьләнә).

Дерив.: **исерек; исереш-ү, исерт-ү; исерткеч.**

**ИСКӘР-Ү** «напомнить», диал. «вспомнить; наблюдать, следить» > мар., удм. *эскер-*, чув. *искер-* ~ каз., к.-калп. *ескәр, ескэр* id. хак. *искір-* «хәбәр итү» – *эс-кäр-* (кушымча *кäр-*, чаг. *су-гар, җил-гәр, ту-гар-*). Чаг. диал. *искә-ү* «истә калдыру». Димәк, *ис-* < *эс-* истә тоту фигыле булган.

Дериватлары – **искәрт-ү, искәрмә, искәртмә, искәрткеч** һ.б.

**ИСКӘ-Ү** «нюхать» ~ башк. *еҫкә-*, нуг., каз. *иĕскэ-*, кырг. *иске-* [*искэ-*], үзб. *иска-*, аз. *ыска-, іскä-,* төркм. *ысга-*, хак. *изе-* «искәү, ис сизү; гомумән сизенү» – бу фигыль контаминацион характерда: аның семантикасында **ис I** һәм **ис II** сүзләре тәэсире бердәй сизелә; *-кә//-ка* кушымчасы *<(ы)к// а(к) + ä* соңрак формалашкан.

Тат. әд. телендә «сулап ис сизү» мәгъ. *иснә-ү* кулланыла, ләкин *иснә-ү*нең «йокы килүдән авыз ачылу» мәгънәсе бар. Халык телендә бу мәгънәләргә аерым фигыльләр була торып, омоним фи-

гыльләргә ябышып яту сәвәтле лексикология һәм лексикография принципларына туры килми. *Искә-ү* сүзе тат. телендә җитәрлек дәрәҗәдә киң таралган (күп сөйләшләрдә бар).

Дерив.: **искән-ү, искәт-ү**.

**ИСКЕ I** «старый (только о неодушевленных предметах); древний; устарелый; старьё» < гом. төрки *эски,* бор. төрки (ДТС: 184) *eski* id. К. ш. ук төр., үзб. диал., кр.-тат., кар. *эски-* «искерү» фигыле дә бар, димәк **эсик* сүзе булган, шуннан *эсик-ү* фигыль, *эсик-и-г* (сыйфат) > *иске* килеп чыккан, чаг. монг. *эси* «башлангыч» (бу чагыштыруның авторы Г. Рамстедт) ~ тунг.-маньч. *эси* (*эсикә, эсикән*) «әле генә, менә хәзер; бая» (ССТМЯ II: 468). Чаг. ш. ук шор. *äзä* «элек» ~ монг. *esin* id., к. Räsänen 1969: 49.

*Иске* сүзен уйг. *эрги, эркә*, тув. *эрги,* хак. *иргі*, як. *эргэ* «иске, элекке, иртә» сүзе белән чагыштыруны галимнәр кире кага, к. Л.С. Левитская. Лексикологические заметки. Уч. зап. Чув. НИИЯЛИ, вып. 46. 1970: 265–266.

Дерив.: **искер-ү, искелән-ү; искелек; искеләр** дигәндә – исем; **иске-поскы, иске-москы** «посып» калган нәрсәләр тур. булса кирәк.

**ИСКЕ II** «ткань, полотно и т.п. для завёртывания младенца» беренче карашка **иске I** белән бердәй күренгән бу сүз (бәбине иске киемнәргә, мәс., малай бәбине әтисенең иске күлмәгенә төрү гадәте чынлап та булса да), алай түгел икән, к. добр. *eski* «бүз саргы (саргыч, урагыч); чисталык тукымасы» ← бор. төрки, монг. *es-* «чиста тоту, чистарту», монг. *эскии, esgii* «чистарту өчен киез». Dobr. II: 34–35.

**ИСЛАМ** «ислам, мусульманство» < гар. *ислāм* id. *слм* «сәламәт булу, тыныч яшәү» сүзеннән (русча әдәбиятта бу сүз «буйсыну» дип аңлатыла, ләкин бу дөрес түгел), шуннан ук **Мөселман, Мөслим, Мөслимә, Сәлам, Тәслим.**

**ИСЛЕ** диал. (ТТДС I: 152) «өлкән, балигь булган, хәтерле, ушлы» ~ башк. диал. *иҫлě*, кар. *исли* ~ чув. *аслă* < *əслě* id. *ис* < *эс* сүзеннән булса кирәк. К. ш. ук каз. *естiб* кырг. *эстүү* «акыллы».

**ИСНӘ-Ү** «зевать» ~ куман., төркм., госм. *äснä-,* шор. *äзä-*, тув. *ээз-* төр. диал. *äсäн-* (к. Радлов I: 873, 889), үзб. *эсна-* «иснәү; сузылу; киерелү», бор. төрки (ДТС: 184) *esnä-* «иснәү (зевать); җил исү)». **Иснә-ү** сүзенең «искәү» мәгъ. уйг. *əснə-*дә дә бар.

**Иснә-ү**, күрәсең, (җил) *ис-ү* сүзе белән бәйле, к. тув. *эзин* «һава агымы», ләкин морфологиясе бик буталган. ЭСТЯ I: 310–311.

**ИСПӘРӘК I** «живокость (растение), спаржа» – лат. *asparagus* сүзеннән татарчалаштырылган, лат. сүзе исә грек теленнән; шуннан ук төр. *asfirac* «испәрәк». Гомумән, бу халыкара сүз Шәрыктә дә, гарептә дә төрле вариантларга бай, к. Фасмер III: 732.

**ИСПӘРӘК II** – Аспарух (основатель Дунайской Болгарии, по легенде, один из сыновей хана Кубрата – правителя Приазовской Болгарии) – бор. төрки *išbara, išbaraš* «бер титул» < санск. *išvara* «Саф Брама» – буддизмда бер изге зат. Икенче версия буенча, бор. һинди *svaraj, svaraja* (*свараж, сва ража*) «мөстәкыйль идарәче» сүзеннән, шуннан ук рус. *Сварог* «тәңре, күк илаһы» (к. Фасмер III: 569–570). Өченче версия – һинди *svargas* «күк» (к. Рыбаков: 447) сүзеннән.

Тат. (элекке тарихчыларда) *испәрәк* < *испәрәг* варианты каян алынгандыр, безгә билгеле түгел.

**ИСРАФ** «перерасход; расточительность; растрата» < гар. *исрāф* id. *срф* «сибелдерү, таратып җәю» тамырыннан.

**ИСРАФИЛ** «Серафим; один из четырёх главных ангелов, ангел-глашатай» < аккад. *исраф-ил* «сур (мөгез быргы) кычкыртучы» сүзеннән. Рус. < грек. *Серафим* (шуннан ук рус. *херувим*) < яһ. *серафим* шул ук аккад сүзеннән «бозылган» вариант.

**ИСТӘРМӘ, истәргән** (Ф. Баязитова материалларыннан, ЗДС: 219) «подслушивание в целях гадания» (в новогоднюю ночь). Ачык түгел. Бәлки *искәрү*дәндер. Ләкин к. рус. *стрема* «сакчылардан саклану хәле; тыңлану».

**ИС-Ү** «веять (о ветре)» < гом. төрки *эс-*, уйг., аз. *əс-*, төркм. *өвүс-* id. К. **Иснә-ү.**

**ИТ** «мясо» < гом. төрки *эт,* уйг. *əт*, тув. *эът* «ит; тән; сыер ите», госм. *äд* (Радлов I: 835), чув. *үт* (!) «ит, тән», кайбер телләрдә «җимешнең йомшак өлеше» (к. ЭСТЯ I: 311–312); к. ш. ук як. *эт* «ит, тән; прокатка алынган терлек»; ниндидер ике иҗекле сүздән, чаг. ягн. *йота* ~ бор. харәзем. *yatti*,

бор. ир. *yatta* «ирен, ит» (ЯТ: 366). *Ит* мәгъ. сүзләр элек эвфемистик рәвештә «ирен», «колак» мәгъ. белдергәннәр; *ит*, ихтимал, элекке *эйт* «колак» сүзеннәндер, чаг. фар. *гуш, гушт* «колак, ит» (чаг. *колак итен ашау* – бер нәрсә тур. күп сөйләү»). Федотов II: 302–307.

Дерив.: **итле**, **итсез; итләч.**

**ИТАГАТЬ** «послушание, смиренность» < гар. *иṭā'ат* id. *ṭw'* «буйсыну» тамырыннан; шуннан ук *тагать* «гыйбадәт; дини дисциплина».

Дерив.: **итагатьле, итагатьсез; итагатьлек.**

**ИТӘК** «подол; юбка», диал. «окружность, окрестность» (ДС I: 65), «местность» (ДС II: 89) > мар., удм. *этак* «кайма; итәк» < гом. төрки *этек, etek ~ этәк, этүк* «итәк, кайма, кырый, алъяпкыч; елга тамагы; олтан; асма; соңгылык» (ЭСТЯ I: 313) ~ чув. *арӑк, аркӑ* «итәк; чабу» < **әрӗк* < **әдук*, чаг. алт., шор. *ӓдӓк* (Радлов I: 849) «итәк». Сүзнең тамыры *эт-*, *энт-* (чаг. төркм. диал. *энтәк* «итәк») булса кирәк, аның якынча мәгънәсе «өстәмә булу, өстәү, дәвам итү», чаг. бор. төрки *jet-* «җитәкләү, ияртү һ.б.ш.», к. **Җитәк.**

Г. Рамстедт (1957: 128) уйг. *әтәк* «итәк» сүзен монг. *этә-* «өстерәү, сөйрәү» сүзе белән чагыштыра. К. ш. ук Федотов I: 56.

**ИТЕК,** диал. **әтик** (Тумашева 1992: 38), **ойтӓк** (Дмитриева 1981: 171), **үтүк** (Радлов I: 1865) id. һ.б., **өдүк, өйтөк, үтек** (ЗДС: 509, 511, 69) «сапог» – гом. кыпч. *этик, итик*, госм., тув. *идик* «итек», төркм. *әдик, эдик*, бүтән телләрдә иренләшкән анлаутлы: уйг. *өтүк,* алт., шор. *өдүк* (к. Радлов I: 842, 1279, 1508 һ.б.) «итек; башмак»; алт. диал. *өөтөк.*

Тат. диал. (себ., әстр., к. ДС I: 21; ДС II: 42) *ату* «үкчәсез итек, читек» ~ каз. *ату,* чув. *атӑ* болг. теленнән булса кирәк, к. үзб. диал. *әтүв* «итек». Идел Болгары Евразиядә күн әйберләр җитештерү үзәге булган.

*Итек* сүзен Г. Рамстедт һәм Э.В. Севортян бор. *ӓт-* «киенү» сүзеннән дип баралар, ләкин бу фараз иренләшкән вариантларны аңлатмый. Дөрес, *ӓт- < үәт- < өөт-* булуы да бар, ләкин к. чув. *ат- < *әт-* «без белән тегү; үрү» (к. **Әтмә**). Безнеңчә, *итек < өйтүк*, *өйтәк* «тегелгән аякчу» **өйүт-иг* «тегелгән, чигелгән» (аякчу) дигән сүздән, сүзнең фигыль тамыры **өйүт-* «тегү, чигү» (к. **Оек**) ә *ату* – икенче бер сүз. Räsänen 1969: 52–53; (ЭСТЯ I: 319–321), Федотов I: 69. Гомумән, сүзнең чыгышы томанлы.

**ИТЕНЕШ** диал. (ЗДС: 220) «неординарное поведение» ← **итен-ү** «необычно вести себя». **Ит-ү** сүзеннән булса кирәк. К. добр., төр. *edin-* «гадәтләнү; (гадәткә) ия булу».

**ИТЛЕК** диал. (себ., эчк, к. Тумашева 1992: 116; ТТДС I: 154) «склад, амбар» – *ит* сүзеннән түгел, ә бор. уйг. *эт, әт ~* бор. төрки *әӡ* «әйбер, товар» сүзеннән, к. **Әйбер.** Ахметьянов 1989: 131.

**ИТТИФАК** «согласие, единодушие; коалиция; союз» < гар. *иттифāқ* id., төп мәгъ. «туры килү»; к. ш. ук иске әд. **иттифақан** «бергәләшеп; очраклы рәвештә», **иттифақый** «очраклы». **Тәүфикъ** сүзе белән тамырдаш.

**ИТУ (иту да)** сөйл. «и то» ~ чув. *итту*, мар., удм. *ито* id. < рус.

**ИТ-Ү** «делать, совершать; сделать, совершить; хотеть» (употребляется преимущественно как вспомогательный глагол и при образовании составных глаголов) < гом. төрки *эт-* id. «Грамматика алтайского языка» (Казань 1869: 54) авторларыннан алып бүгенгәчә барлык телчеләр бу сүзне *эрт-,* ягъни *эр-* «булу» (к. **Ир-ү**) фигыленең йөкл. юн. дип карыйлар. Тат. сөйләшләрендә бу фигыльнең кайт. юн. *итен-ү* «үзен сәер тоту, кылану» мәгъ. мөстәкыйль рәвештә дә кулланыла (к. ТТДС I: 153–154). К. **Итенеш, Нит-ү.** Будагов I: 179.

**И-Ү [ийү]**, диал., башк. **ӗй-ү** «гнуть, согнуть (вниз); опустить (голову)» ~ каз., к.-калп., кырг., алт. диал. *и- (ий-),* аз., госм. *еу-*, алт. диал., куман. *ӓң-* id. (к. Радлов I: 658–710) бор. төрки *eg-, äg-* > бор. кыпч. **әw-* > чув. *ав* id., к. ш. ук тув. *эг-*, *ээг-*, як. (Пекарский: 887–900) *iäх-* id. һ.б. Räsänen 1969: 37.

Севортян (ЭСТЯ I: 330–332) бу сүзне төр. *eg, ey* ~ тат. *ик* (*иксез-чиксез*) «кырый, чик; текә тау бите» сүзе белән чагыштыра. К. ш. ук Федотов I: 23.

Дерив.: **идер-ү, иел-ү.**

**ИФРАТ**, сөйл. **ифырат** «очень, чрезвычайно» < гар. *ифрāṭ* id. (төп. мәгъ. «артык»).

**ИХАТА** «ограда; приусадебный участок земли, двор» < гар. *ихāṭа* id. *xwm* «әйләндереп алу, саклау» тамырыннан, шуннан ук к. **Мохит**. К. ГТРС: 185.

Дерив.: **ихаталы, ихатасыз; ихатала-у.**

**ИХЛАС** «искренне; искренность; увлечение» < гар. *ихлас* «ихласлык» (исем мәгъ.). К. ГТРС: 186. *Ихлас* сыйфат мәгъ. *ихласлы* формасыннан морфологик эллипсис. К. ш. ук **Халис.**

**ИХТИМАЛ** «возможность, вероятность; возможно, вероятно» < гар. *ихтимāл* id. (к. ГТРС: 188) – *хмл* «тоту, күтәрү» тамырыннан, шуннан ук иске тат. **хамилә** «көмәнле хатын», **хәмәл** «ай исеме» һ.б.

Дерив.: **ихтималлы, ихтималсыз; ихтималлык; ихтималлаш-у.**

**ИХТИРАМ** «уважение» < гар. (ГТРС: 188) *ихтирāм* id. *хрм* «тыю; изге дип игълан итү» тамырыннан, шуннан ук **харам, хәрәм; хөрмәт; мәхрүм; мөхәррәм** (ай атамасы) һ.б.

Дерив.: **ихтирамлы, ихтирамсыз; ихтирамла-у.**

**ИХТЫЯҖ** «потребность» < гар. *ихтийāҗ* id. *хwҗ* «кирәк булу» тамырыннан, к. **Хаҗәт.**

Дерив.: **ихтыяҗлы, ихтыяҗсыз.**

**ИХТЫЯР** «воля; выбор, предпочтение» < гар. *иҳтийāр* id. *хйр* «сайлау»; яхшырак булу» тамырыннан. К. **Хәер.**

Дерив.: **ихтыярлы, ихтыярсыз; ихтыярлык.**

**ИЧ** «ведь, же» – диал. (ДС I: 66) *ич* «бер дә» сүзеннән чыгып, *һич* сүзеннән дип уйланыла.

Шуның белән бергә бүтән фаразларга да урын бар, к. бор. төрки *erinč* «икән; бит, ич, ихтимал» (ДТС: 178) > *ич* булала; чув. *ĕç, ĕçке* > удм. *эсь, эське* «ич» болг. *ирчĕ, эрчĕ, эрти* «иде» сүзе белән чагыштырыла; мар. *ач* «ич» (<**әч* ?) сүзен Гордеев (I: 172–173) рус. диал. *ач, аци* һәм *еще* сүзләре белән бәйли.

**ИЧӘ** диал. «матушка», *әчә* (к.) сүзенең *и-* варианты ~ хак. *иче,* як. *идьэ* id. һ.б., к. **Чичә.**

**ИЧӘН, иҗән** (Кадыйр Гали, XVII г. тарихчысы, рус патшасын **ичән** дип атый; XVIII г. документларында очрый) «император (китайский, русский)» < уйг. *әҗән, эҗен, эчен, эчән* «Кытай императоры», монг. (МНМ II: 657) *эдзен* «хуҗа, башлык», бур. *эжин,* калм. *эзны* «билгеле бер төбәкнең, районның рухи хуҗасы, химаячесе». Тув. *эжен, эҗин* «әфәнде, галиҗәнаб» ~ монг. *эдзен, эжен,* калм. *эзн* «ия», *эдзен бабай* «җир иясе».

XIV г. монгол ханнары бөтенләй Кытайга күченгәч, барча элекке монгол җирләре Кытай императорыныкы дип игълан ителгән һәм җирле хакимнәрне еш кына Кытай императорының вәкиле дип игълан иткәннәр. Шул нигездә **иҗән** «гомуми император» образы мифик төс алган. Чаг. як. *иччи* «җир хуҗасы», селькуп. *ичкачка, ича* «күктә чабып йөрүче герой-сыбайлы». К. МНМ I: 594; МНМ II: 596, 657 һ.б. (күп урында).

**Ичән** сүзенең кытайча прототипы безгә төгәл билгеле түгел. К. түбәндәгене.

**ИЧӘЧӘН: Бозау Ичәчән –** герой сказок, богатырь с головой телёнка < алт. **Йәр (йәр) чэчэн** Үлгән (Өлгән) тәңренең ярдәмчесе. **Өлгән тәңре** исә баш Тәңренең иҗатчысы, җирне төзүче һәм төзекләндерүче. **Йәр Чәчән**гә кешеләргә гомер-тормыш өләшергә кушылган булган һәм ул шул йомыш белән кызлар җыелган җиргә килеп кергән. Ләкин бозау башлы егетне күреп, кызлар көлә башлаганнар. Йәр Чәчән ачуланып, аларга хатынкыз язмышы биргән, ди (к. Традиционное мировоззрение тюрков Южной Сибири. М., 1989: 138). К. югарыдагыны.

Татар әкиятендә бу мифологемадан исем генә калган. **Ичәчән** образында бор. һинд-иран халыкларындагы сыер культы чагылса кирәк.

**ИЧЕК** диал. «мех; шкура для обработки» к. **Эчек.** К. **Ичке.**

**ИЧКЕ, ицке, ицкә, ишке** (себ., әстр., кузн. һ.б., к. ТТДС I: 105; ЗДС I: 221–222) «коза» ~ гом. кыпч., алт. *ички,* кр.-тат. *әчки*, кырг., үзб., уйг. *эчки, әчки,* алт. *äчк, эчкэ* һ.б. < бор. төрки (ДТС: 162) *ečkі, ečkü* id., к. ш. ук (төп линиядән читләшкән) каз. *ешкі,* уйг. диал. (Малов: 49) *ушко,* монг. *ишиг,* калм. *ишкэ,* бор. монг. *išigen* «кәҗә» > рус. диал. (Аникин: 228) *ишиген* «бәти». Бу сүзне кар. *эчки* ~ *кэчки* «кәҗәкәй» кебек вариантлардан чыгып, **кәҗә** сүзе белән бердәй дип раслау еш очрый. Ләкин А.Е. Аникин хаклы рәвештә диярлек бу фикерне кире кага. К. ш. ук Räsänen 1969: 35 (тагын мисаллар китерә).

*Ичке биргән куй алыр, һич бирмәгән ни алыр?* – дигән мәкаль бар икән, к. Dobr. II: 38–39.

**ИЧМАСА** «хотя бы; и даже» > чув. *ицмасса,* башк. *исмаһа*, удм. *эсьма, эсьмаса*, мар. *эсмаса, эсмäсä* id. – Идел-Урал региональ сүзе, к. К. Насыйри буенча (ЛТ I: 71), *һич имәсә* дигәннән, чаг.

*һич булмаса*; ләкин сүзнең веляр яңгырашы бу фаразга туры килми. Аннары **ичмасам, ичмасак** (ДС II: 90) вариантлары да аңлатуга мохтаҗ. К. Федотов I: 174 (чув. телендә бу сүзнең фонетик вариантлары бик күп).

**ИШ** «один из пары; напарник; спутник», диал. «коллектив; множество (подобных друг другу)» > мар., удм. *эш* < гом. төрки *эш, әш, ээш* (Радлов I: 902; Будагов I: 196; ЭСТЯ I: 313–315; Räsänen 1969: 50) id., төр. *eş* «җефет», чув. *йыш* «коллектив, артель; туган-тумача, гаилә, хуҗа», безнеңчә, тат., башк. *иш-* «аллы-артлы, чиратлы, ритмик хәрәкәтләр ясау» белән (*бау ишү, ишкәк ишү,* диал. **иш-ү** «бер-бер артлы сугу; зур, авыр адымнар ясап озак чабу») < гом. төрки *эш-* id. (Радлов I: 871, 872; ЭСТЯ I: 316) белән тамырдаш, ягъни бу сүзләр – бор. төрки телләргә хас булган исем – фигыль парын тәшкил итәләр (чаг. *кат – кат-у, куш – куш-у*), к. алт. диал. (Радлов I: 904) *эш-, äш-* «иярү» . *Иш* < *эш, әш* тамырын чув. *ал-* < *әл-* «дөмбәсләү» фигыле белән дә чагыштыралар. Ахметьянов 1989: 108; Федотов I: 208.

**Иш** (исем вә фигыль) тат. телендә шактый продуктив тамыр, к. **ишәй-ү** «күбәю, үрчү», **ишле** «күпсанлы». К. **Иш-ү.**

**ИШАН** «ишан, духовный глава мюридов» < фар. *ишāн* «алар» (хөрмәтле затның күз артында атау) сүзеннән.

Ишаннар тур. к. Демидов С.М. Суфизм в Туркменистане. Ашхабад, 1978: 105–120.

**ИШАРӘ, ишарәт** «знак рукой; намёк» < гар. *ишāра, ишāрат* id.

**ИШӘЙ-Ү** «сильно размножаться, увеличиться в числе» (тат.-башк. телләрендә генә очрый) ← *иш* (к.), әлбәттә.

**ИШӘК** «осёл, ишак» < гом. төрки (Радлов I: 906, 912) *эшäк, äшäк, эштäк*, алт. *äштäк* > каз. (ҚТДС: 102) *естек*, урта төрки (Боровков I: 86) *äшкäк,* бор. төрки (МК I: 111, 114) *ešgek, ešyek* id. < **elčеk < elč-ek,* к. тув. *элчиген* < бор. монг. *elčigen, elğigen* «ишәк». Бор. **elç- < *anč- <<* шумер. *ansu* «ишәк» (И. Немет K. Menges'нең «The Turkic Languages and Peoples» китабына рецензиясендә, – к. Acta Linguistica (Budapest), t. XXI. f. 3–4, 1971: 471–474, – шулай ди). К. ш. ук Бернштейн С.В. Несколько слов о ностратической гипотезе // ВЯ, № 3. 1986: 38–41. Ләкин *иш* < **элч* тамырының төрки телләрдә автохтон булуы да ихтимал. Чув. *ашак* «ишәк» тур. Федотов I: 76. Рус. *ишак* тур. Аникин: 228 (шунда ук – әдәбият). Рус теле аша бу сүз күп телләргә таралган.

**ИШЕ** «подобно, вроде (о людях)» ~ чув. *йышши,* мар. *ишы, ишыжо*, удм. *ишы, эшы, эшез* id. *иш* сүзенең 3 зат берлектәге тартым формасыннан лексикалашкан.

**ИШЕК** «дверь» < гом. төрки (Радлов I: 908) *эшик, эшүк, ишик,* бор. төрки (ДТС: 185–186) *ešik* «ишек, тупса», *ešük* «ябу, ябынча» ← *ešü-* «ябу, каплау» (чаг. ш. ук КБтә *Йарук дүнйа йүзкә эшүнсә эшүк*... «Якты дөнья йөзенә ябулык ябынса...»). Нуг., каз., к.-калп. *эсик, исик,* тув. диал. (Радлов I: 726) *äjik* «ишек» – фонетик вариантлар; угыз телләрендә *эшик, эшүк, әшүк* «ишек тупсасы» һ.б. (күп вариантлар). Чув. *алăк* < болг. **әлĕк,* бор. төрки (ДТС: 169, МК, КБ) *el, il* «ишек төбе, бусага», чаг. гом. тунг. (ССТМЯ I: 293) *ӣ-, ӣл-* «керү». Сүзнең бор. тамыры **эл* (шуннан **элчик >> ишек*) дип уйларга мөмкин. Будагов I: 198; Räsänen 1969: 151; ЭСТЯ I: 396–398; Федотов I: 135.

Дерив.: **ишекле, ишексез; ишекче; ишекчек.** Чыгт., төр. һ.б. *эшик агасы* «ишек агасы; сарай хезмәтчесе, церемонимейстер» булган.

**ИШЕЛ** – река Ишим ~ каз. *Исил* < **Ишил* > рус. **Ишим.** Искечә **Ишул** дип язылган. К. Будагов I: 198.

**ИШЕТ-Ү** «слышать, услышать, услыхать» < гом. төрки *эшит-*, нуг. *эсит-*, каз., к.-калп. *есит-* id. тат. диал. (ТТДС I: 156) **иш-** ~ хак. *ис-*, чулым., хак. диал. *эш-*, каз. *ес-*, хак. *эс-*, *ис-* «ишетү, тыңлау» фигыленнән, дөресе **эши* булган булса кирәк (*эши-т-* шуның йөкл. юн.). Э.В. Севортян (ЭСТЯ I: 318–319) бу сүзне авест. *uš,* хетт. *iš* «колак» белән чагыштыра, ләкин *ишет-* сүзеннән чув. *илт-* «ишетү» сүзен аерырга ярамый, димәк, сүзнең тарихи тамыры **элч, *эл* булган. Чаг. тунг. телләрендә *ӣ-* «яңгырау, ишетелү» (ССТМЯ I: 293–294). Räsänen 1969: 51; Федотов I: 266.

Дерив.: **ишетел-ү, ишеттер-ү; ишетем** (неол.). Диал. **ишел-ү** «ишетелү» һич тә редукцияләнгән форма түгел, ә **иш-* «тыңлау» фигыленең төш. юн.

**ИШТӘ** иск. «именно, вот именно» < төр. *işte* id., ш. ук «инде».

**ИШТӘК** «один из башкирских родов; часть башкир», диал. (себ.) «остяк, хант» – калм. (Ramstedt 1935: 211) *istăg* «башкорт; пики (кәрт төре)» *иштг мангт* «башкорт», каз. *истәк, иштәк, истек* «башкорт»; *үштәк, иштәк* «себер татары»; хәз. көндә **Истәк** дигән ике татар авылы бар – берсе Башкортстанның Яңавыл районында, берсе Пермь өлкәсенең Суксун районында. Төрки чыганакларда *иштәк* XVII г. бирле билгеле: Әбүлгазиның «Шәҗәрәи тәрәкимә» («Төрекмәннәр шәҗәрәсе») әсәрендә «дала кыпчаклары монголлардан качып иштәкләргә бардылар, бу көндә иштәкләрнең күпчелеге кыпчакның нәселеннән торыр» диелә. XVIII г. башларында материал туплаган Ф. Страленберг *sari yschtek* (сары иштәк) халкы «татар-болгар телендә сөйләшүче башкортлар» дигән (к. Stralenberg: 424). *Кара, сары* һәм *ак мангытлар* (к. **Мангыт** сүзен) булган шикелле, *кара, сары* һәм *ак иштәкләр* (соңгылары – татарлар) да булган. *Иштәк, эштак* ыругы үзбәкләрдә дә бар.

Төрле чыганакларда *иштәк* сүзе белән рус. *остяк*, тат. *үштәк* этнонимы буталып килә (к. Fischer: 420). **Остяк** исә бөтенләй төрки түгел.

Русча ядкәрләрдә искә алынган *костяк* һәм төрек сәяхәтчесе Ә. Чәләби язмаларындагы *һәшдәк, хәштәк* этнонимнарын да *иштәк*кә нисбәт итәләр. *Һәшдәк* сүзе фар. *һăшт* «сигез» сүзеннән ясалган булса, бу сүз рус чыганакларында башкортларны *осьмиродцы* дип атауга бап килә. Әд.: Фирсов Н. Положение инородцев северо-восточной России в Московском государстве. Казань, 1866: 37; Kannisto A. Zur Etymologie des Volkernamens ostjak // MSFOu LVIII. 1928: 417–420; Исхаков Д.М. К этнической истории татар восточных районов Татарской АССР // К вопросу этнической истории татарского народа. Казань, 1985: 36–65; Kırzaoğlu F. Kıpcaklar. Ankara, 1992: 13; Аникин: 430–432. Бу хезмәтләрдә арытабангы бай әдәбият күрсәтелә.

**ИШ-Ү** «грести; вить; бежать иноходью (вообще попеременно работать то справа, то слева)», «работать лопатой, разрушать» > чув. *иш-* «җимерү; йөзү» < гом. төрки *эш-, ӓш-* < **алч-* > болг. **ӓл-* > чув. *ал-* «казу; сөрү». Бу сүзнең исем коррелянты **иш** (к.). ЭСТЯ I: 315–317; Федотов I: 32, 175.

**Иш-** бик продуктив нигез: **ишел-ү** «күпләп, массасы белән бүселү, тоташ җимерелеп төшү» → **ишелдер-ү** «җимертү»; **ишер-ү > эшер-ү**, **ишкәк; ишмә.** Кр.-тат. *eşin-* «казыну, казынып яшеренү», *eşit-* «ишеп төшерү» (тат. **иштер-ү** диләр).

**ИЮ** к. **И-ү.**

**ИЮЛЬ** «июль» < рус. < лат.

**ИЮНЬ** «июнь» < рус. < лат.

**ИЯ [ийә],** диал. (себ.) **әйә** «хозяин; дух, гений чего-, кого-либо», «подлежащее» > чув. *ыйӑ, ыйа, иййе* ~ чув., нуг., каз., к.-калп. *ие*, кырг. *ээ* < үзб. *эга,* уйг. *әгә*, госм., чыгт. *икә, игә,* бор. төрки (ДТС: 104, 105) *ëgä, igä, ije* id. Шуңа параллель рәвештә хак. *ӓзи,* бор. төрки *edi, ädi*. Тунг. *эди,* иске монг. *эҗэн* «ия; хуҗа» сүзе дә бар. К. урта төрки (Боровков 1963: 70–71, 121–122) *ӓjӓ* «хуҗа», *i, iδi* «хуҗа; тәңре». «Җен, пәри» мәгъ. *ия* сүзе күрше мар., удм. телләрендә дә мәгълүм, к. Марийский фольклор: 67–68, 118–120 һ.б. Гомумән, төрки телләрдә *ия* < *эгӓ* сүзенең мәгъ. күп һәм кулланылышы киң. Аның миф. «төрле объектларның (берсенең) хуҗасы», «бигүк явыз булмаган рух» сүзе киң таралган, к. МНМ II: 659. Минемчә, *ияне* (**эйәгә*) шумер. *эййӓ* «химаяче рух» сүзе белән баглап карау кызыклы. ЭСТЯ I: 237–239.

Дерив.: **ияле** (бу сүзнең «җенле» мәгъ. дә бар), **иясез; иялек** (килеш); **иялән-ү, ияләш-ү** һ.б.

**ИЯК [ийәк],** диал. (ЗДС: 210, 212, 803) **инәк, иңәк, эйек** «подбородок» < башк. *эйәк, нуг. иек,* кр.-тат. *iyek, yiyek,* хак. *иңэк, иңек,* госм., төркм., үзб. *эңәк* «ияк», төр. *enek* «аскы урт сөяге», куман., чыгт. *ӓңӓк* «ияк, ияк очы», чув. *ана* id. ← бор. төрки (язма чыганакларда, к. Räsänen 1969: 45), аз. *ӓн, ӓң* «яңак очы». Бу сүзләрне баштук бор. төрки (Поппе 1938: 201; ДТС: 174) *eyegü* «ияк, яңак» белән чагыштыру ярамас, арадаш формаларны табу мөһим. К. **Йәйәк. Яңак** белән чагыштыру да төрле сораулар уята. Радлов I: 714; Мухамедова 1973: 148; Федотов I: 45.

**ИЯЛӘШ-Ү [ийәләш-],** диал. **илләш-ү** «привыкать, привыкнуть к кому-, чему-либо» ~ башк. *илек- (илегү)* id., чув. *илент-, илентер-* (Ашмарин III: 104) id. як. *илләс-* «татулашу», каз. *еллес-* һ.б. *ил* < *эл* «тынычлык» сүзеннән булса кирәк, ләкин *иялә-ү* сүзенең контаминациясе сизелә.

Сүзнең дөресрәк язылышы **илләш-ү** булырга тиеш.

**ИЯР [ийәр]** «седло» < гом. кыпч. *эйәр, ӓjӓр* (к. Радлов I: 695) ~ чув. *ĕнер, йĕнер* «ияр», *йĕнерчĕк* «ыңгырчак»; бу сүзнең кырг. *ээр,* тув. *эзер,*

шор., чулым. *äзäр* (Радлов I: 892), бор. төрки (ДТС: 164) *eдär, edär* вариантлары белән бергә уйг. диал. *әгәр*, чыгт., кар. *эгәр, игәр,* төр. *eğer* вариантлы да бар. К. **Ыңгырчак.** Федотов I: 195; ЭСТЯ I: 241–242.

Дерив.: **ияреш-ү**, **иярт-ү**; **иярчен** һ.б.

**ИЯР-Ү [ийәр-],** диал. **игәр-ү** (ТТДС I: 142) «следовать за-кем-либо» > чув., удм. *ер- [йэр-]*, мар. *ияр-* < гом. кыпч. *эйäр-,* нуг. *иер-*, каз., к.-калп. *ер-*, кырг. *ээр-* < уйг., чыгт. *эгәр, äгäр-* ~ тув. *едер- [эдэр-]* уйг. *идәр-*, бор. төрки (ДТС: 164) *eдär-* id. бор. *ij-* < *eд-* «артыннан бару» фигыленнән йөкл. юн. булса кирәк. К. ш. ук урта төрки *iд* «эз», *iдärü* «ияреп» (к. Боровков 1963: 122). КБтә *eдär-* «эзәрү, эзәрлекләү; иярү». Димәк, бор. төрки *iд* ~ *iд-* исем-фигыль пары булган. К. **Иярчен, Эз.** Räsänen 1969: 37 (**ияр-ү**не **эрлә-ү** белән багламакчы).

Дерив.: **ияреш-ү, иярт-ү; иярчен** һ.б.

**ИЯРЧЕН [ийәрчён],** диал. **иярчек** «последователь; спутник, сателлит; сопровождающий» – дөресрәге *иярчән* булса кирәк, к. ком. *иерчен,* нуг. *иершен* «иярчен», каз., к.-калп. *ершең* «иярчен (бала)»; кырг. *ээрчи-* «иярә төшү» сүзенең **иярчен** сүзе ясалуына контаминацион тәэсире генә бер бугай. Э.В. Севортян (ЭСТЯ I: 242–245), *иярчән* сүзеннән чыгып, элек *ияр* < *эйәр* дигән исем булган, димәкче. Ләкин *-чән* < *-чәң* кушымчасы элек фигыль нигезләренә дә ялгана алган.

# Й

**Й** хәрефе иҗек башында хәз. татарча кириллик орфографиядә *ŏ* һәм *ө* авазлары алдыннан (шуларны белдерү өчен) кулланыла.

**ЙОБА-У** диал. «замучиться; присмиреть (от неудач)», диал. (себ., эчк.) *йобау* «похудевший, понурый» (ДС I: 69; ТТДС I: 174), *йыбау* «боек», *йуба-у* «газаплану» (Тумашева 1992: 81, 85, 89) ~ кырг. *жобо-* «баш әйләндерү; кайгыру», алт. *дьобо-* «йончу, арыклану», хак. *чоба-*, тув. *чова-* «ару, талчыгу», як. *собоо-* «арыклану, ябыгу» ~ урта монг. *joba-* «азаплау, имгәтү» (Поппе 1938: 207), маньч., нан. *ǯобо-* «күңелсезләнү, кайгыру, газаплану» ~ эвенк. *ǯопо-* «ярлылыкта булу, җик күрү» һ.б. (ССТМЯ I: 260–261).

Бу нигезнең исем мәгъ. дә киң таралган, к. уйг. диал. (таранчы) *joба,* алт. диал. *jобо, дьобо*, хак. *чоба*, тув. *чова* «арыганлык; кайгы; арыган, кайгылы», хак. *чобаг,* тув. *човаг* «арыган, талчыккан (ат)» һ.б. Чаг. кыт. *чибу* «ачлык; ашамау».

*Йоба-* нигезе төрки телләрдә бик тә продуктив. Бик иртә бу сүз «сулыш алу > тынычлану > күңел күтәрелү > шатлану» (!) мәгъ. үзгәрешләре кичергән (шундый антонимлашу *усал* сүзендә дә күзәтелә), к. бор. монг. *joba-* «кичерешү, кеше хәленә керү», куман. *йубан-* «шатлану», к. **Юан-у, Юат-у, Юаш, Юбалг-у.**

**ЙОГЫРТ [йŏғŏрт],** диал. **җыфырт, җыwырт** «подмаренник (растение); йогурт» ~ чув. *ҫăвăрт*, ком. *ювурт,* ног. *ювырт*, к.-балк. *җуўурт* «катык, сөзмә, эремчек», уйг., госм., кр.-тат., урта төрки *joγart, juγurt, jaγurt* (Räsänen 1969: 205) «катык, эремчек, йогырт», кырг. *җуурат,* як. *суорат,* хак. диал. *чоорт* id. себ. тат. (ЗДС: 259, 261) *йуур-*, *йуғур-, йŏғŏр-, йыwыр-,* бор. тат. (Максуди) *йуғра-,* алт. *йуғур-, дьуғур-,* бор. төрки, уйг., госм., чыгт. *йоғур-,* тув., шор. *чуур-, дьуур-*, чув. *ҫăр-* «әчетү; камыр изү» фигыленнән (чаг. **эркет, саркыт**), к. Gombocz: 80–81. К. куман. *йуур-, йаур-* < бор. монг. *ǯiγura-* > алт. *дьура-* «камыр изү» ~ орок. (тунг.) *jурэли-* «болгату» (ССТМЯ I: 351). Гаҗәп ки, камыр һәм сөт әчетү мәгъ. сүзләр төркиләргә монголлардан килә. ЭСТЯ I: 243–244.

**ЙОДРЫК [йŏдрŏқ],** диал. **йоҙрык, җŏдŏрык,** иск. **йŏмдŏрык, йŏмрык** «кулак» < ног., кр.-тат., алт., уйг. *йудруқ,* каз., к.-калп. *жудуруқ,* кырг. *җудуруқ,* к.-балк. *җундуруқ,* тув. *чудуруқ* ~ як. *сутуруқ* id. һ.б. һичшиксез бор. төрки *jumduruq* «йодрык» сүзеннән, *jum-* «йому» фигыленнән. Семантик анализ буенча, ул сүз я *йумдур-* «учта яшерү, йодрык төйнәү» сүзеннән (**йум-дур-уг-а*), я бор. **уйм* «төен; йодрык» сүзеннән, ул чагында *йумдурук* йодрыкка киелә торган хәрби бияләйне белдергән, чаг. алт. *дьудрук* «тукмак» (*-дуруқ//-дырык* аффиксы һәртөрле кидерелә торган нәрсәләрнең атамасын ясый), рус. диал *нюдургун* «җиңсә» (Аникин: 412).

**Йумдурука* > **нумдурука* сүзе монг. һәм тунг. телләренә дә үтеп кергән (һәм шуннан кайбер төрки телләргә кайткан), к. бур. *н'удурга*, монг. *нудурган* ~ хак. *нузурух* «йодрык» һ.б. Монг. *нудра-*, бур. *нюдур-* «йодрыклау, төртү» < бор. төрки, алт. *ньумдур-* ~ *йумдур-* «йомдыру», эвенк. *нидурга* < бор. монг. *niduryа* «йодрык» һ.б. к. ССТМЯ I: 590. К. **Йом-у, Йомыш.** Räsänen 1969: 209.

Дерив.: **йодрыклы, йодрыксыз; йодрыкла-у.**

**ЙОЗАК,** диал. **җозак** «замóк» < урта төрки, кар., уйг. диал. *йузақ, йозақ,* куман. *йузақ, йусхак* ~ чув. *ҫăра [счŏра]* > мар. *с'ура, с'ыра* id. Төрки телләрнең күпчелегендә бу сүз юк, бор. гом. төрки **йургақ* id. ниндидер *йур-* фигыленнән булырга тиеш кебек, ләкин аның мәгънәсе юраулы. Шор. *чодақ, чозақ* (Радлов III: 2028) «ышаныч; йозак» варианты да бу сүзне ачыкламый («ышаныч» мәгъ. икенчел булырга мөмкин). Тунг.-маньч. *jохшу, jосо* һ.б. «йозак» (ССТМЯ I: 348) шулай ук фонетик һ.б. җәһәтләрдән *йузақ* сүзенә ябышмый. Монг. *цуурга* «йозак» тур. да шуны әйтеп була.

**ЙОК,** диал. **җŏк** «припёка, что-либо прилипшее либо остаточное» ~ ног., ком. *йуқ,* к.-балк., к.-калп., кырг. *җуқ,* каз. *жуқ* id., тув. *чуқ* «сумала» – *йоқ-у [йоғу]* фигыленең исем коррелянты. К. ш. ук үзб. (ЎХШЛ: 135), *йооқ* «йок».

Тат. диал. (ТТДС: 575) **җогоро** «әз генә калдык, эз», як. *ньогох* «савытка йоккан калдык, касмак». К. **Йок-у.**

**ЙОКЛА-У** «спать» < *йокы-ла-у,* к. **Йокы.**

**ЙОК-У (йогу),** диал. **җөк-у (җөгу)** «прилипать; заразить (болезнью – о болезни)» ~ куман., ком., нуг. *йуҡ*-, к.-балк., каз., к.-калп., кырг. *җуҡ-,* алт. *дьуҡ,* тув. диал. *чуҡ*-, хак. *чух*- id.

**Йок-** тамырыннан шактый күп төрки сүзләр ясалган, к. тат.-башк. **йөғөн-у** «кагылу», **йөғөнты** «тәэсир, рефлекс», **йөгөш** «зараза», диал. **җөгөш** «ягымлылык» (ТТДС I: 574) ~ каз., к.-калп., кырг. *җугум* «ябышучанлык, зимлек; зирәклек, тиз отып алучанлык» һ.б. К. ш. ук диал. **йогаш, җогаш** «охшаш», **йогачан** «йогышлы» (*йоҡ-* бор. варианты **йуға, *йуҡа* булуы ихтимал). К. **Йок, Йокылык.**

**ЙОКЫ [йөкө],** диал. **җөкө** «сон, дрёма» < гом. кыпч., уйг., чыгт., үзб. һ.б. *йуҡы, уйҡы, уйҡу,* хак., шор., чыгт. *уйғу*, аз. *уйху*, төр. *uyku* һ.б. > чув. *ыйăх, ăйăх, ыйăхă, ăйăхă, ăйхă* id. < бор. төрки *идиq, идиqи* «йокы» ← *иди-, иδı-* «йоклау», *ији-* «йокы процессын кичерү» (ДТС: 606–607) > төр. һ.б. *иуи-(ији-)* > тат. *өйө-у* «әкренләп йоклап китү» (бу сүз *өйө-у* «сизү көчен югалту» сүзе белән бердәй булуы да ихтимал). Бор. төрки (ДТС: 503) *и*, як. *уу* «йокы» я **иδ, иди* сүзеннән кыскарып килеп чыккан, я шуннан әлеге *и-ди- (<и-ғи-)* фигыле ясалган. Дөньядагы күп кенә телләрдә «йокы» *о-, у-* тамырыннан икәнлеген искә алсак, соңгы фараз ышанычлырак кебек (чаг. мар. *ом, омо,* удм. *ум,* морд. *он* «йокы», *удомс* – ихтимал, төрки – «йоклау»). Федотов II: 470. Кыпч. интервокаль *-ҡ//-к* – гадәттә элекке икеләтелгән-тәштитле *ҡҡ//кк* дән килеп чыга; шуны исәпкә алганда *йөкө* < *уйукку* булырга тиеш (ягъни бор. **уйу-ҡ-* фигыле – *уйу*ның интенсивлык формасы булган). ЭСТЯ I: 244.

**Йокы** продуктив нигез: **йокылы, йокыла-у** > **йоклау; йокысыз; йокычан** һ.б.

**ЙОКЫЛЫК [йөкөлык]** «рубашка новорожденного» < *йөҡҡылыҡ* ← *йок-у* (к. **Йок-у**), ягъни «йогып калган нәрсә» сүзеннән, к. башк. (БҺҺ II: 72) *йөкөлөк* «ашказаны асты бизе», к.-балк. *җуҡу* «эч мае оершасы (мәс., эчәкләрдә)» һ.б.

**ЙОЛА,** диал. **җөла** «обычай, обряд», диал. «выражение лица; лицо» (ДС I: 68) ~ чув. *йăла, йăлла,* мар. *йула, йулӓ,* удм. *йылал, йылол*, морд. *ила* id. < бор. кыпч. **йула*, к. каз., к.-калп. *жула*, кырг. *жолой* «йола» ~ алт. *дьула, йула*, хак. *чула* «җан» (к. Потапов 1934; Баскаков 1973: 108–112). Бу сүз күпчелек төркиләрдә юк, һәм шунлыктан аның чыгышын билгеләү кыенлаша, Һ.В. Юсупов һәм С.Е. Маловлар фикеренчә, *йола* бор. төрки *joluγ, juluγ* «мәҗүси корбан» сүзеннән, к. Малов 1951: 390. К. **Йол-у.** Федотов I: 179–180 (монг. *xauli* ~ як. *куолу* «йола, закон» сүзе белән чагыштыра).

*Йола* < *йула* сүзе *йула* ритуаль «шәм» сүзеннән дә (к. **Җила**) килеп чыга ала (мәҗүсилектә «җан шәме» яндыру булган).

**ЙОЛДЫЗ [йөлдөз],** диал. **җөлдөз, җөндөз,** диал., башк. **йөндөз** «звезда» ~ гом. төрки *йулдуз*, төр. *yıldız*, к.-балк. *җулдуз*, каз., к.-калп. *жундыз, жундуз,* кырг. *җылдыз*, шор. *чылтыс*, як. *сулус* ~ чув. *çăлтăр* [*счөлдөр*] id. *-дыз//-дез* аффиксына беткән төрки сүзләр рәтенә керә (чаг. *андыз, балдыз, кондыз, көндез, мондыз* һ.б.), тамыры имитатив *йал//йул* – ялтырау тәкълите булса кирәк, к. Ашмарин 1925: 145. К. ш. ук Räsänen 1969: 210; ЭСТЯ IV: 279–281; Федотов II: 93 (мар. *шудыр* «йолдыз» сүзен дә чувашчадан ди).

Дерив.: **йолдызлы, йолдызсыз; йолдызак** (үлән атамасы). **Йолдызлык** һәм **йолдызчык** сүзләре русчадан калька булса кирәк. К. түбәндәгене.

**ЙОЛДЫЗНАМӘ** «астрология; астрономия; книга по астрологии и астрономии» – татарларда бик билгеле булган әйберләр, алар элек-электән язылып һәм басылып килгәннәр. **Йолдызнамә** сүзе үзе дә тат. телендә ясалган булса кирәк (бүтән яз. төрки телләрдә башкача атала). Кайбер төрки йолдыз атамалары һ.б. тур. к. Будагов II: 363–364.

**ЙОЛКЫН-У [йөлҡөн-], җолкын-у [җөлҡөн-]** «дёргаться, вырываться изо всех сил» – **йолык-у** (к.) фигыленең кайт. юн.

**ЙОЛКЫШ [йөлҡөш], җөлҡөш** «бродяга, бездельник; оборванец» < гом. кыпч. *йулҡуш, җулҡуш*, к.-балк. *җулҡуч* (рус. «рвач» диелгән), хак. *чулгус* id., чув. *çăлкăç* «йолку калдыгы» ← **йолык-у** (к.).

**ЙОЛТЫ [йөлтө]** «трофей; приз» к. **Йөлте, Жулик.**

**ЙОЛ-У,** диал. **җөл-у** «рвать, вырывать; вырвать из беды; выкупить» < гом. төрки *йул-,* төр. *yol*-, к.-балк., кырг. *җул-*, каз., к.-калп. *жул-* id., к. ш. ук алт. *дьул-*, хак., тув. *чул-* «йолу; урлау», чув. *çăл-*, як. *сулуй-, сулла-* «йолу, йолку», бор. төрки *jol-, jul-* id. ~ яз. монг. *ǯulu-, ǯilu-,* бор. монг. *ǯulγu-* «йолку» > эвенк. *ǯулуа-* id. (ССТМЯ I: 272); монг. формасы төрки *жулқу-, йулқу-* (> тат. *җолкы-, йолкы-*) сүзеннән, ә бу сүз исә *йул-уҡ-* нигезеннән, ягъни

*йул-* сүзенең интенсивлык дәрәҗәсеннән килә (тат. сөйл. *йолқ-, жолк-: йолкый* да, *йолка* дип тә әйтелә), шуннан **йолкын-у** (гом. төрки параллельләре белән). Чаг. як. *сул* «сөян, суелган агач», *сул-* «чистарту», *сулуй-* «йолу». Будагов (II: 983) *йүл-, йөл-* сүзен *йүл-, йөл-* «сакал-мыек эскәкләү» (к. **Җөл-ү**) сүзе белән бердәй дип карый. ЭСТЯ IV: 215–217; Федотов I: 92.

Дерив.: **йолын-у; йолыш-у;** тат. **йолым,** бор. төрки *juluγ* «штраф; калым; корбан, әсир өчен түләү» һ.б. К. **Йолкыш.**

**ЙОЛЫК-У (йолыкты, йолку)** «выдёргивать» < гом. кыпч., уйг., чыгт. һ.б. *йулқ-, йулуқ-* бор. төрки (ДТС: 279) *julq-*, к.-балк., кырг. *җулқ-*, каз., к.-калп. *жулық-* һ.б. id. *йол-* < *йул-* фигыленең (к. **Йол-у**) интенсивлык формасы; к. ш. ук яз. монг. *ǯulγu, ǯulγa-* > эвенк. һ.б. тунг. *ǯulγa-* «йолку» (к. ССТМЯ I: 272).

**Йолык-** продуктив нигез: **йолкыш-у, йолкыт-у;** к. **Йолкын-у, Йолкыш.**

**ЙОМАК,** диал. **йумақ, җомак,** (БТДҺ: 122) **йомалақ** «сказка (у сибирских татар и башкир), загадка (у казанских татар)» > чув. *юмах*, мар. *йомак* id., удм. *юмоқ* «көлке; мәзәк, әкәмәт» (Алатырев 1976: 159–160) < гом. кыпч. *йумақ, йомақ* id. (каз. к.-калп. *жумбақ,* кырг. *жомоқ* «әкият; эпос»), хак. *нымах* «эпос», алт. диал. *ньомак* «әкият» ~ монг. *домаг* «легенда» һ.б. ← угыз. *йум, йом* (> чув. *йăм*) «дога; легенда; шаманның авыру кешенең җаны теге дөньяда ниләр кичергәне тур. сөйләгәне» сүзеннән. Räsänen 1969: 206; ЭСТЯ IV: 220–221; Федотов II: 485–486. Махсус мәкалә: Bazin. 1969: 9–24 (Урал-Алтай параллельләрен күрсәтә).

**ЙОМАРЛА-У,** диал. **җомарла-у** «сбивать в ком» ~ нуг. *юмарла-*, кырг. *җумарла-* һ.б. *йом-, йум-* фигыленең тәртипсез интенсивлык формасы (*йумарла-*). Тат. *йомарлак, җомарлак* ~ кырг. *җумарлақ* һ.б. гом. кыпч. сүзе, к. ш. ук төркм. *йумала-*, кырг. *җумала-* (*-р-* редукцияләнгән) «тәгәрәтү, әвәләү». ЭСТЯ IV: 247.

**ЙОМГАК** «круглый моток (ниток), клубок», күч. «заключение, резюме» ~ чув. *çăмка, çăмха* ~ чыгт., алт. *йумғақ,* госм. *йумақ,* хак. *ныңмах* «йомгак» – *йом-* < *йум-* сүзеннән (Räsänen 1969: 210), к. ш. ук каз., к.-калп. *жумақ* «йон йомгагы», чув. *çăмах* «умач». К. ш. ук тат. диал. *йомгалак, җомгалак* ~ кырг. *җумалак*, куман. *йумғалак*, уйг. диал. *йумулак* «йомры; йомгак» (Радлов III: 577–579), бор. төрки (ДТС: 279) *jumbalaq* «йомгак», *jumγaq* «йомры, шарсыман». ЭСТЯ IV: 246–247.

Дерив.: **йомгаклы, йомгаксыз; йомгаклык; йомгакла-у.** К. **Йом-у.**

**ЙОМРАН,** диал. **җǒмран, җǒмǒран** «суслик» > удм., мар. *йумыран*, чув. *йăмран* < чыгт. *йумран,* к.-балк. *җумран, җумыран, җубуран* (> абаз. *җумаран,* кабарда. *җумэрэн*), алт. диал. *йубуран, йыбыран*, як. *дьабара(н)* id. < безнеңчә, бор. монг. *ǯurum-bar-agan* (чаг. бур. *зумбара, зумбарāн*) «соргылт җәнлек»: *ǯurum* «йомран» – бор. мәгъ. «соры», *-bar* монг. кушымча (чаг. *чи-бәр*), *-āп* – күп. кушымчасы яисә *-ан* «җәнлек» дигән сүздән. К. ш. ук рус. диал. *евражка*, к. ш. ук рус. *емуранка, евран, зумурушка* һ.б. < төрки **йубуран* (Аникин: 186–187, 190, 195), салар. *зимбра, ǯимбур,* маньч. *ǯумарган, ǯумархан* «йомран, тычкан, сукыр тычкан» (ССТМЯ I: 275). Räsänen 1969: 210; ЭСТЯ IV: 247–248; Федотов I: 182–183 һ.б. (әдәбият күп).

Бу сүзне **йомры** сүзеннән диючеләр бар. Башкортларда **йомран** ыругы һәм авыллары билгеле.

**ЙОМРЫ [йǒмрǒ],** диал. **йǒмǒры̆, җǒмры̆, җǒмǒрǒк** «круглый в сечении, округлый» < чыгт. *йумры,* госм., кр.-тат. *йумру*, төркм. *йумурук,йумрук* < бор. **йум-ур-уғ* «түгәрәкләнгән» булса кирәк. Чаг. ш. ук **Йомыр.** ЭСТЯ IV: 248–249.

**ЙОМ-У,** диал. **җǒм-у** «сомкнуть» < гом. төрки *йум-* (алт. *дьум*, каз., к.-калп. *жум-*, к.-балк., кырг. *җум-* id.). Рамстедт (1957: 43) бу тамырны *йом-ыш* һәм хәтта *йогыр-* < **йомгыр-* сүзләре белән дә бәйли (тик бу фараз гына булып кала). Безнеңчә, бор. *йум* «җәмгыять, җыен» сүзе дә булган. К. **Йомыт-у.**

**Йом- < йум-** тамырыннан күп гом. төрки нигезләр ясалган, к. **Йодрык, Йомгак, Йомарла-у, Йомык, Йомыр, Йомры, Йомырка, Шомырт.** Räsänen: 210 (*йум-* тамырын монг. *ǯитиji* «бикләнү» белән чагыштыра). ЭСТЯ IV: 245–246.

Дерив.: **йомыл-у, йомдыр-у.**

**ЙОМШАК,** диал. **җомшак, йомышка** «мягкий» < гом. кыпч., бор. төрки *йумушақ, йумшақ,* нуг. *юмсақ,* каз., к.-калп. *жумсақ,* кырг., к.-балк. *җумшақ, җумушақ,* алт. *дьымжақ,* тув. *чымчақ,* хак. *нымысақ,* як. *сымна* ~ чув. *çĕмçе* «йомшак; күмәч, коймак» һ.б. *йомша-* < *йумша-* фигыленнән; чув. *йăмшак* «ак ипи» < тат. диал. *йǒмшак.* К. **Йомша-у.**

**ЙОМША-У** «размягчиться» < гом. төрки, бор. төрки *йумша-,* нуг. *юмса-*, каз., к.-калп. *жумса-*, к.-балк., кырг. *жумша*, алт. *дьымжа-,* хак. *нымса-*, тув. *чымча-* як. *сымнаа-* ~ чув. *çемçе-* id. гадәттә (М. Рясянен һ.б.) гом. төрки *йуң* «йон, кыл, мех, каурый» сүзеннән дип аңлатыла. Ләкин монда аңлашылмаган момент кала: ни өчен чув. *çемçе-* < **җәмҗә-* яки *җәмшә-*? Як. *сымна* «йомшак» ← *сым* «ипи йомшагы» каян килә? Чаг. ш. ук яз. монг. *nitegen* ~ эвенк. *нэмкун, нэјумкун* «нечкә; йомшак; назлы» (ССТМЯ I: 616, 624) һ.б. ЭСТЯ IV: 252–253.

**ЙОМЫК [йŏмŏķ]** «замкнутый» ← **йом-у** сүзеннән (*йом-ык* «йомылган»); гом. төрки *йумуķ* id. Тат. диал. (ЗДС: 252) **йомоклы** «оешкан».

Дерив.: **йомыкый < йомыккай** «замкнутый; застенчивый».

**ЙОМЫЛ-У [йŏмŏл-]** «пускаться в бег во всю мочь» > мар. *йумыл-* «ташлану, һөҗүм итү (кешегә – ат тур.)» ~ үзб. *йумул-* «йомылу» id. Төр. сүзлекләрендә бу мәгънәне *yumul-* «(күз) йомылу, яшерелү һ.б.ш.» белән бергә бирәләр. Безнеңчә, бу *йомыл*ның нигезе *йом-у* «йомыш-юлга чабу (йөгереп китү)» булырга тиеш, к. **Йомыш.** Чаг. ш. ук чув. *йăмăл-* «(йомышка йөреп) ару-талу» – тат. сөйләшләреннән булса кирәк.

**ЙОМЫР [йŏмŏр],** диал. **йомар, җŏмŏр** «круглый; круглая чашка» > мар. *йумыр* «шар» (Упымарий: 312), чув. *чăмăр* «түгәрәк», *çăмăр* «йодрык» һ.б. *йŏм-* сүзеннән әлбәттә, әмма ясалышы бигүк ачык түгел. Һәрхәлдә, **йомры** һәм **йомыр** сүзләрен аерырга кирәк.

*Йомыр* сүзенең «чынаяк, тәгәч» мәгънәсе бу әйбернең формасына карап түгел, ә кырг. *җумур, җумыр* ~ тув. *чумур* «карта; ашказан; картадан ясалган савыт» сүзеннән килә: элекке картаны киптереп һәм ыслап махсус савытлар ясаганнар. Себ. *йумар*ның «бавырсак» мәгъ. дә «карта» мәгънәсеннән килсә кирәк (Тумашева 1992: 82). К. ш. ук **Йомырка.**

**ЙОМЫРА [йŏмŏра]** диал. «ветла» ~ чув. *йăмра* < бор. төрки (ДТС: 279) *jumraq* «бөгелүчән, йомшак, сыек».

**ЙОМЫРКА [йŏмŏрķа],** диал. **җŏмŏрķа, йомыртка, йŏмŏртķы** «яйцо» < гом. төрки *йумуртка* ~ чув. *çăмăрта* << гаг. *йымырта* id., гомумән, «йомры нәрсә», гом. төрки *-ыртка*//*-ерткä*, *-ырткы*//*-ертке* аффиксы ярдәмендә *йŏм-* < *йум-* (к. **Йом-у**) тамырыннан ясалган. К. Räsänen 1969: 211; ЭСТЯ IV: 250–251.

Шул *йомыртка* нигезеннән үзгәреп **Шомырт** сүзе килеп чыккан, к. **Шомырт.**

**ЙОМЫРЧКА [йŏмŏрчķа]** «трилистник, люцерна (культурная кормовая трава)», себ. (Тумашева 1992: 83, 86) **йомрыцка, йомырцка, йомырыцка, йуңырыцка** – төрле кузаклы үсемлекләр ~ үзб. диал. (ЎХШЛ: 135) *йомушак, йоңырчка, йуңгичка* «тукранбаш», урта төрки (Боровков 1963: 162) *йорынчга* id.; вариантлары бик күп: хива. (Будагов I: 450) *жиунишķа, йурунчэ,* кырг. *җунучķа,* чыгт. *йунучķа,* төр. *уопса* һ.б. Тамыры ачык түгел. Чаг. **Йомычка.**

**ЙОМЫТ-У [йŏмŏт-],** себ. (Тумашева 1993: 91) **йымыту** «зажать в кулаке», к. сары уйг. (Малов 1967: 27, 138) *йумут-* «җыю, җыелу» ← **йуму-* ← **йум.* К. **Йом-у.**

**ЙОМЫЧКА [йŏмŏчķа]** «щепка», диал. **йомрычка** (ТТДС I: 174) < гом. кыпч., нуг. *юмыршка*, ком. *ёнгурчка* «йомычка; люцерна» (!).

**Йомычка** нигезен *йунғычķа* ← *йун-, йон-* (к. **Юн-у**) нигезенә нисбәтләү табигый шикелле күренсә дә, кайбер сорауларга җавап юк. Чаг. **Йомырчка.**

**ЙОМЫШ [йŏмŏш],** диал. **җŏмŏш, йымыш** «поручение», иск. «служба» < гом. төрки, бор. төрки *йумуш* id., нуг. *юмыш*, каз., к.-калп. *жумыс,* кырг., к.-балк. *җумуш*, тув. *чымыш*, алт. *дьумыш, ньумуш, дьумуш*, хак. *нымыс* һ.б. < бор. гом. төрки **йумулч* > болг. **җумул* > *җŏмŏл* > чув. *йăмăл* «йомыш», *çăмăл* [*счŏмŏл*] «сәбәп» > мар. Б. *с'омыл* > мар. Т. *с'амыл* «йомыш, хуҗалык эше; ярдәмче, йомышчы» (мар. *сомылка* > *самылка* «йомышлы, йомышчы» формасы да актив кулланыла) ~ як. *соболоң* «юл, йөрү өчен түләү, бүләк».

Төрки телләрдә *йŏмŏш* < *йумуш* тамырыннан тат. диал. (Тумашева 1992: 82) **йŏмша-** ~ уйг. *йушма-*, нуг. *юмса-*, кырг. *җумша-*, каз., к.-калп. *жумса-*, хак. *нымза-* «йомыш кушу, әмер бирү, боеру», башк. диал. *йомоша-* «файдалану» фигыле дә ясалган.

**Йомыш** сүзенең бор. иҗтимагый төземгә катнашы бар; аның тамыры бор. гом төрки *йом* < *йум* – исем һәм фигыль – «берек»; «җәмгыять, җәмә-

гать», «оешма» һәм «иҗтимагый максатларда җыелу-җыю», «бүтәннәрдән аерым, үзара җыену» мәгъ. булганга охшый, к. бор. төрки (Боровков: 163; ДТС: 279) *jumtar-, jumdar* – (> кар. *йомдар-*) «җыю», *jumɣu, jumɣı, jumɣın* «барчасы, бөтенесе бергә», *jumıt* «җыелыш, җыелу». Бор. төрки сүзләр һәм мәгънәләр удм. *юмша-* (< *йумуш-а-*) «җыелышып гыйбадәт кылу һәм күңел ачу», *юмшан* «сабантуй» һәм «гомуми мәҗүси гыйбадәт» һ.б. сүзләрдә сакланган шикелле. Чаг. ш. ук чув. *им-йăм* (тат. *им-йом*) «мәҗүси догалар». К. **Йом-у.** ЭСТЯ IV: 251; Ахметьянов 1989: 108.

**ЙОН,** диал. **җөн, йөн, җон** < гом. кыпч. *йун, йуң*, алт. *дьун, дум,* хак. диал. *дьуг, чуг,* як. *суң, суңк* ~ чув. *ҫăм* «йон». Күпчелек төрки телләрдә палаталь вариант: куман., чыгт. *йүң*, к.-балк., кырг. *жүн*, каз., к.-калп. *жүн*, алт. диал. *ньуң*, тув. *йүм*, бор. төрки *jüŋ, jük* «йон; мамык; каурый» (ДТС: 285–289); вариантларның күплеге монда ике иҗекле сүз булганлыгын сөйли һәм алт. *дьууң* «каурый» да шуны күрсәтә. Räsänen 1969: 211; Федотов I: 93; ЭСТЯ III: 267–268.

Тикшеренүчеләр бу сүзне *төк* < *түк* сүзе белән тамырдашлыгы ихтимал диләр.

Дерив.: **йонлы, йонсыз, йонлач; йонлан-у.** К. **Йөнтәс.**

**ЙОНЧУ,** диал. **йонцу** (ДС I: 69; ЗДС: 253) «худой» турыдан-туры бор. төрки (ДТС: 280) *junčïɣ* «зәгыйфь, арык; яраксыз» сүзеннән. К.-балк. *джунчуу* «аптыраш».

**ЙОНЧЫ-У [йŏнчŏ-],** диал. **җончы-у, җөнче-ү, йөнче-ү, йөнчерә-ү,** себ. (Тумашева 1992: 83) **йонза-у** «изнуриться, сильно уставать, замаяться», диал. (ЗДС: 253), «присмиреть», «беспокоить» ~ башк. *йонсо-,* чув. *йĕнчĕ-* «йончу» ~ к.-балк. *жунчу-* «тартыну; йөдәү» < бор. төрки *junčï-* «зәгыйфьләнү, йончу, арыклану» – гомуми модель калыбында *jun-* фигыленнән, чаг. *арчы-у, борчы-у, кырчы-у* һ.б. Бу сүз, ихтимал, тәүдә «йоны коелу» мәгъ. булгандыр., к. төркм. *йүнҗүмәк* «йоны коелган». ЭСТЯ IV: 254.

Дерив.: **йончыл-у, йончыт-у, йөнчерә-ү.**

**ЙОРТ,** диал. **җорт** «дом; двор, усадьба» > удм. *җурт*, чув. *ҫурт*, мар. *сурт* < гом. төрки, бор. төрки *йурт* > каз., к.-калп. *җурт*, к.-балк., кырг. *журт*, тув., хак. *чурт*, як. *сурт*, төркм. *йуурт, йувырт, йүверт* > башк. диал. *йŏрŏт* id. А.Н. Кононов фикеренчә (к. Родословная туркмен. М., 1958: 79), гом. төрки *йугыры-, йуры-* «йөрү» сүзеннән (*йуры-т*) һәм тәүдә күчмәнче биләмәләрен белдергән, к. иске әд. тат. (Әхмәтҗанов 2009: 30 һ.б) *йорт* «ил, дәүләт», *йорот иту* «яшәп тору».

Тат. **йорт-җир** тәгъбире дә тарихи берәмлек, к. чув. *ҫурт-йĕр* (Ашмарин XII: 273), удм. *җурт-җәр* «ихата». К. ш. ук удм. *йуртла-* (< тат., к. Кельмаков 1977: 54) «яңа торлакка, яңа җиргә күчү» ~ алт. *дьурта-*, тув., хак. *чурта-* «яшәү, яшәп яту». Эпик әдәбият телендә: *ил илләгән, йорт йортлаган хан…*

Рус. (Аникин: 718) *юрт, юрта* «тирмә; ихата» төрле төрки диалектлардан; морд. *юрхта* «йорт» русчадан булса кирәк. Будагов II: 371; Ахметьянов 1989: 132; ЭСТЯ IV: 254–255 (шунда ук арытабангы мул әдәбият күрсәтелә).

Дерив.: **йортлы, йортсыз** һ.б.

**ЙОРЫН [йŏрŏн],** диал. **җŏрŏн** «шёлк, шёлковый (ТТДС I: 175); шёлковая подкладка; лоскут (Тумашева 1992: 82); аппликация (из шёлковой ткани)» ~ башк. *йŏрŏн* «кештәк; почкак» ~ чыгт. (Будагов II: 374) *юрун*, каз. *журын, җурын, җулый* «итәк, яка, кесә, бүрек каймасы, кырпу» – иске затлы киемдә. Ул бик ачык, җете төстә булган (ҠТДС: 120), к. ш. ук к.-балк. *җурун*, алт. диал. (Баскаков 1972: 213) *дьурук* «кештәк», тув. *чурук* «кештәк; бизәү, картина» >> як. *сурук* «язу; рәсем», *суруй-* «язу; рәсемләү» (*сурун-* «язылу») ~ яз. монг. *ǯiru-* «сызу, рәсемләү, чыю», *ǯiruɣ, ǯirum* «сызым, план» > эвенк. *ǯuru-*, маньч. *ниру-* «язу, сызу, рәсемләү» (к. ССТМЯ I: 273, 600). Ихтимал, тат. *цурла-у, чурла-у* «бизәклә-ү» шуннандыр (тат. телендә *й* > *җ* > *ч* очраклары бар). К. **Чур-у.**

**Йорын** сүзенең «ефәк кисәге» мәгъ. борынгыдан килә, к. бор. төрки *jurun* «ефәк тукыма кисәге» (МК, к. ДТС: 282), ләкин бу мәгъ. хәз. тат. телендә генә сакланган, чув. *ҫĕрҫĕн* «ефәк» сүзенең этимологиясе ачык түгел (**җŏр-җŏн*?). ЭСТЯ IV: 255–256.

Дерив.: **йорынлы** (рус. «в шелках» мәгъ.).

**ЙОРЧЫ [йŏрчŏ]** «брат жены», диал. **йŏрцы** «младший брат жены», **йŏрчы** «младшие брат или сестра жены» (Тумашева 1992: 83; Будагов II: 372) ~ башк. *йорсо* «кайниш», алт. диал. *дьурчу*, алт. *йŏрчү* id. << бор. төрки *jorcï, jorɣučï* «аңлатучы, юраучы» (к. ДТС: 274) сүзеннән (Kannisto: 94–95): йорчылар туй барышында кияү белән кәләш арасында (алар кавышканчы) хәбәр ташып йөргәннәр,

к. манси. *iürš* << *jorč* «хатынның энесе» (МК). К. Ахметьянов 1981: 83.

**ЙОТ,** диал. **җот** «бескормица скота от оледенения пастбищ зимой (у кочевников)» < гом. кыпч., бор. төрки *йут*, к.-балк., кырг. *җут,* каз., к.-калп. *жут, җут*, алт. *дьут*, тув., хак. *чут*, як. *сут* id. К. ш. ук тат. **җӧт** «гуҗ, чүп ашаучы (явыз рух мәгъ. дә очрый)» > чув. *ҫăт,* мар. *сут, сыт,* удм. *сюты* id. К. **Йотлык-у, Йот-у, Йөдә-ү.** ЭСТЯ IV: 256–257.

**ЙОТА, йода** (брб., ЗДС: 254) «голень, верхняя часть ноги; икры ног» (ни өчендер *кыр йота* дип тә әйтелә) < уйг. *йота,* бор. төрки (ДТС: 269, 275) *joda, jota* id. Гомумән киң таралган сүз: сары уйг. *jota, juta, jovta, javta* «сарык аягында үзенчәлекле сөяк», алт. сөйләшләрендә *дьодо, йодо, йӧдӧб чота* «балтыр сөяге һ.б.», каз. *жота,* кырг. *җотаа* «итләч тән әгъзасы», як. *сотуруо, сутуруо* «тез капкачы; тез турысына махсус (өшемәсен өчен һ.б.) ямалган ямау; калын чалбар» > рус. диал. (Аникин: 507, 514–515) *сотуры, сутуры* «биек (тездән өскә күтәртелгән) итек» яки «бик калын ыштан» (төрле төрләре күрсәтелгән). Як. сүзе (< бор. **җота орагы* «йота урамасы») барча себ. телләренә алынган. Räsänen 1969: 207.

Чаг. тат. диал. **җуда** «дөя йоны» (дөянең тезләрендә аеруча мул булган йон).

**ЙОТКЫН [йŏткŏн],** диал. **йоткыш** «злой дух, упырь» ~ чув. *ҫăтхăн, ҫуткăн* «комсыз, йот», мар. диал. *йоткан* id. (к. Иванов, Тужаров: 262). *Йот-у* сүзенән булса кирәк.

**ЙОТЛЫК-У [йŏтлŏк-],** диал. **йотык-у, җотлык-у, җотык-у** «сильно проголодаться» – **йот-у** сүзенең интенсивлык формалары (*-ык, -лык* икесе дә интенсивлык кушымчасы, к. *ату – атлыгу, җит-ү – җитлек-ү, сөрү – сөрлегү* һ.б.); чаг. чув. *ҫăтăх* «саранлану».

**ЙОТ-У,** диал. **җот-у** «глотать, проглотить» < гом. төрки, бор. төрки *йут-*, к.-балк., кырг. *җут*, каз., к.-калп. *жут-, җут-* һ.б. id., куман. *jovut-*, төркм. *йувыт-* сүзләренә караганда, бор. *йов-* < **йог-* (?) фигыленнән һәм ул фигыль фин-угор. *juo-* ~ монг. *у-* «эчү» сүзе белән чагыштырыла (Räsänen 1969: 212); икенче яктан бу тамырны монг., тунг. (ССТМЯ I: 209–210) *до-* «эчү, эчкә алу» белән дә чагыштыралар. **Йот-у,** ихтимал, **йот** белән бәйледер, ләкин моны исбатлап булмый. ЭСТЯ IV: 242–243.

Дерив.: **йоткылык; йотым; йотыл-у; йоттыр-у,** к. **Йоткын, Йотлык-у.**

**ЙӨГӘН,** диал. **җөгән, җөгин, җигин, җигем** (халык этимологиясе!), **йүгән** «узда, уздечка; повод» ~ ком. *йуген*, к.-балк. *җүген*, кырг. *җүгөн, җӧӧн, җүөн*, нуг. *йүвен*, каз., к.-калп. *жүwән*, чыгт., уйг. *жүгән, йүгән,* бор. төрки *jügün, čigin* (ДТС: 145, 185), алт. *үйген,* төркм. *үйән*, аз. *йүйән*, алт. диал., тув. *чүген* һ.б. урта төрки *jüjgen*, төркм. *уйан, ойан*, төр. диал. *ögügen* id. Ф. Сумер (Sumer 1983: 94–96) *йүе* «ат башына куела торган каурый, җәбәлә» сүзеннән ди. Бу гипотеза өстәмә дәлилләргә мохтаҗ. Чаг. ш. ук грек. *ζυγον*, лат. *jugum, jungo* «бәй, камыт, йөгән» (лат.-грек сүзләре бор. төрки телләргә Бактриядән – Урта Азия грек дәүләтеннән кергәннәр). Э.В. Севортян (ЭСТЯ I: 177) *уй ~ ой – үг ~ йүг* тамыры тур. сөйли.

Дерив.: **йөгәнле, йөгәнсез; йөгәнлек; йөгәнлә-ү** (һәм аның юнәлешләре).

**ЙӨГЕН-Ү [йөгөн-],** диал. **җөгөн-** «преклонять колени, делать реверанс» ~ чув. *ҫăкăн- [сч̆ӧгӧн-]* ~ куман., ком., нуг., үзб. *йүгүн-*, кырг., к.-балк. *җүгүн-*, каз., к.-калп. *җүгин-*, бор. уйг., бор. төрки (ДТС: 285) *jükün-* id. бор. төрки **jük-* «чүгү, тезләнү» > чув. *ҫӗк-, ҫăк- [счөк-, сч̆ӧк-]* «тезләнү, егылу» > мар. *сук-* id. сүзеннән, чаг. **Чүк-ү (чүгү).** ЭСТЯ IV: 264–265.

Дерив.: **йөгенеш-ү, йөгендер-ү.**

**ЙӨГЕР-Ү [йөгөр-],** диал. **җөгөр-ү, йугыр-у, йыгыр-у** «бежать, бегать» ~ башк. *йөгөр-, йүгер-* < гом. төрки *йүгүр-*, кырг. *жүгүр*, каз., к.-калп. *жүгир-, жуwыр-*, алт. *дьүгир-, дьүүр-, чүгүр-*, хак., тув. *чүгүр-*, як. *сүүр*, үзб. диал., төркм. диал. *йүвүр-* (ЎХШЛ: 136; ТДГДС: 105) һ.б. id. **Йөр-ү** белән гомоген булса кирәк. К. **Юырт-у.**

Дерив.: **йөгерел-ү, йөгерен-ү, йөгереш-ү, йөгерт-ү; йөгерек; йөгереш.**

**ЙӨДӘ-Ү,** диал. **җөдә-ү, гедә-ү** (ТТДС I: 116), **җөзә-ү,** себ. **йөтә-ү, йүдә-ү, йота-у, йута-у** (Тумашева 1992: 83, 85, 88). «изнемогать; маяться, терять рассудок (от горя)» > чув. *йүте-, йүтке-*, удм. *җудэ-* id., мар. *йӱдӓ-* «акылсызлану; аптырау» ~ башк. *йөдә-,* кырг. *җүдө-* id., алт. *дьуда-* «ярлылыкка төшү», *дьүде-* «йөдәү, үләттән үлү» (*дьүдек* «зәгыйфь, пычрак»), хак., тув. *чүдэ-* «авырып, пыч-

рак хәлгә килү (терлек тур.)» ~ як. (Пекарский: 868–869) *җүҗәі, җүдјәі-, дьүдәй-* «ябыгу, пычрану» , эвенк. *ǯудәй-* «арыклану, начарлану» (*ǯудәк* «арык, начар, шапшак» ~ яз. монг. *ǯüdere* «йөдәү, арыклану», *ǯüde-* «артык авыр хәлгә төшү, йөдәү».

К. ш. ук тат. *йөдәү, йөтәү* (ДС I: 69), *җөдәү* (ДС II: 263) «арык, начар, юньсез» ~ удм. *ǯудон* «аптыраш – йөдәш»; тат. *йөдәт-у, җөдәт-у* > чув. *йүтет-*, мар. *йүдӓт-* «йөдәтү, җиләтү, җанга тию», *чүдӧ, цүдӧ* (Упымарий: 248) «ярлы, накыс».

*Йөдә-* нигезен ике төрле аңлатып була: 1) *йот* сүзеннән, к. себ. (Тумашева 1992: 83), башк. диал. *йота-у* «йоттан хәлсезләнү (терлек тур.), кайгыру (кеше тур.)», хак. *чут* «начар һавалар; хәлдән тайган; шапшак» < *чут* «йот», тув. *чуданкы* «йөдәгән», алт. диал. *чуда-,* калм. (Räsänen 1969: 481) *zuta-* «ачлыктан үлү»; 2) бор. *jüde-* > уйг. *җүдә-*, тув. *чүдэ-* «үзенә йөк алу, артык йөкләнү» дигәннән, к. ш. ук эвен. *дёг-дай-* «ярлылану», *дёг-ан* «фәкыйрьлек», эвенк. *дюдей-* «йөдәү» (терлек тур.).

КБтә:

*Аҗун бӧдни барча улуш-кӓнд кодуп,*
*Туруп тағка барса ағыр йүк йүдүп,*

ягъни:

Галәм халкы барча авыл-калаларны куеп,
Торып тауга барса, авыр йөк **йөдөп.**

*Йөдөп* монда *йөкләү, йөкләнү.* Тамырдаш исем һәм фигыль бер фразема ясау төрки тел өчен бик гадәти хәл.

Räsänen 1969: 212; ЭСТЯ IV: 35; Федотов I: 207 (*йөдә-* < *йүдә-* сүзен *йада-у, җада-у* белән чагыштыра).

Дерив.: **йөдәш-ү, йөдәт-ү.**

**ЙӨЗ I,** диал. **җөз** «лицо, лик» < гом. төрки *йүз, йүс* (Радлов III: 614–618), к.-балк., кырг. *җүз,* каз., к.-калп. *жүз,* алт. *дьүзүн, йүзүн* «йөз», як. *дјүсүн* «йөз, кыяфәт», *дјүсүк* «кыяфәт алу», *дјүсүлӓн-* «кылану» һ.б. (Пекарский: 722–723), үзб. *йуза, йүзә* «өслек», урта төрки *yüzigen* ~ монг. *nigüran* «йөзен» (Поппе 1938: 142) һ.б. бор. төрки *jüz, jǖz* «йөз, абруй» (ДТС: 287–288) < **jigüre* > бор. монг. *nigüre* (> эвен. *нгорь*) «йөз, маска» >> тат. диал. *нөр,* к. **Нөр.** Будагов I 375–376; ЭСТЯ IV: 259–260.

Дерив.: **йөзле, йөзсез; йөзлек.**

**ЙӨЗ II,** диал. **җөз** «сто» < гом. төрки, бор. төрки *йүз*, к.-балк., кырг. *җүз*, каз., к.-калп. *жүз*, алт. *дьүс,* тув. *чүс* ~ болг. *җүр* > чув. *ҫӗр [счөр]* id., к. ш. ук камас. *җюр,* нен. *jur* (Joki 1955: 124). Безнеңчә, бу сүз бор. уйг. *jüz*, тув. *чүс*, як. *сүс* һ.б. «буын, бармак буыны» сүзе белән бердәй (ун бармактан соң ун бармак буынын санаганнар). Räsänen 1969: 213; ЭСТЯ IV: 260; Федотов I: 111–112 (төрле карашларны яктырта). К. ш. ук Булатова А.К. Развитие значений слов в тюркских языках // Научный Татарстан. 2013. № 1: 104–107 (**арка, аяк, йөз** сүзләренең гом. төрки планда мәгъ. үзгәрешләре тур. җентекләп язылган).

Дерив.: регуляр сан формалары; **йөзлек; йөзләгән, йөзләрчә.**

**ЙӨЗЕК [йөзөк],** диал. **җөзөк** «кольцо (с камушком), перстень» < гом. төрки, бор. төрки *йүзүк*, госм. *йүзүүк* < *йүзгүк*, урта төрки *jüksük* (Räsänen 1969: 214), тув. *чүстүк, чүскүк, чүксүк*, алт. *йүстүк*, хак. *чүстүк* «йөзек» – диал. (ЗДС: 254) **йөз** < бор. төрки *jüz* >> тув. *чүс* «буын» сүзенәннән булса кирәк, к. тув. *чүстүг* «буынлы, буынлык»; чув. *ҫӗрӗ [счөрө]* < **җөрөг* < *җүр-гүг* бу сүзнең борынгылыгын күрсәтә, к. ш. ук венг. *gyüri* «йөзек».

К.-балк., кырг. *жүзүк*, каз., к.-калп. *жүзүк, җүзүк* һ.б. «йөзек» закончалыклы фонетик вариантлар.

Монг. *дәрү,* як. *дөрө* «балдак» сүзе белән чагыштыру (Егоров 1964: 212) безгә ышандырырлык булып тоелмый. Räsänen 1969: 214; ЭСТЯ IV: 261–262; Федотов I: 112.

Дерив.: **йөзекле, йөзексез; йөзеклек.**

**ЙӨЗЕМ [йөзөм],** диал. **җөзөм, өзөм** «виноград; изюм» – гом. төрки (күп телләрдә юк) *йүзүм,* төр., бор. төрки, чыгт. *үзүм*, к.-балк., кырг. *җүзүм*, каз., к.-калп. *жүзім, җүзім* id. бор. *üzüm* «өзеп алына торган җимеш, тәлгәш» сүзеннән, ди Г. Клоусон (Clauson: 288), к. бор. төрки *jüdüm* «бәйләм, тәлгәш» (Боровков 1963: 16), к. ш. ук Будагов I: 133; ЭСТЯ I: 625; ДТС: 631. Анлаут *й-* килеп чыгу уйг.-үзб. диалектларында очрый: *үз-* > *йүз-* «өзү».

Виноград үзе бор. төрки телләрдә *borlaq* дип аталган. Рус. *изюм* «киптерелгән йөзем» төрки телләрдән, к. Фасмер I: 124.

**ЙӨЗ-Ү,** диал. **җөз-ү** «плавать» < гом. төрки *йүз*, көнч. төрки *йүс-*, госм., аз. *үз-* id. (Радлов III: 614–618; Räsänen 1969: 214), к.-балк., кырг. *җүз-*, каз., к.-калп. *жүз-, җүз-* гади закончалыклы вариантлар, үзб. *суз-, сүз-* «йөзү» контаминацион характерда (к. **Сөз-ү**).

Дерив.: **йөзеш-ү, йөздер-ү; йөзгеч.**

**ЙӨК,** диал. **җөк** «груз; вьюк; воз, поклажа» > удм. диал. *жук,* мар. *йук, йык, йёк* (Исанбаев 1978: 39) ~ чув. *çĕк, çăк* [*счөк, счŏк*] < гом. төрки, бор. төрки *йүк* > к.-балк., кырг. *җүк*, каз., к.-калп. *жүк* id. бор. *jü-* «йөкләнү», шуннан бор. төрки *jüd-* «йөкләү» (ДТС: 283–285; Боровков 1963: 165) > чув. *йĕт, йăт-* id., к. бур. *зөө- < җөө-* «ташу, йөкләү» < бор. монг. *ǯüge-* id. К. ш. ук КБтә *йүҗүр-* «йөкләү, йөк ташыту». ЭСТЯ IV: 262–263.

Рус. *вьюк* төрки телләрдән (Фасмер I: 373, *йүк* сүзенең чыгышы тур. – бөтенләй хата).

Дерив.: **йөкле, йөксез; йөклә-ү; йөкче** (икенчел дериватлары да күп).

**ЙӨЛӘ,** диал. **җөлә** «нижняя часть спинного хребта» ~ башк. (БТДҺ: 121) *йола, йөлә, йөлдә* id. < бор. төрки (ДТС: 278–279) *jöläk* «төп терәк», *jöl-ägü* «ярдәм, ярдәмләшү». КБтә (татарчалаштырып):

> *Тақы ма нәгү ирсә арзу-теләк,*
> *Баят ук була бирсен арка йөләк,*

ягъни «Ничек кенә булса да арзу-теләк,
Алла үзе булсын тик арка-йөләк».

К. **Йөлә-ү, Йөлен.**

**ЙӨЛӘ-Ү,** диал. **җүлә-ү,** себ. (Тумашева 1992: 88) **йӧлӧ-ү, йүлө-ү** «спасать от падения» – «егылудан коткару», **йүлә-ү** «сөяп кую», трбс. һ.б. **йүлә-ү** ~ **җүлә-ү** «озайтып бәйләү (бауны бауга һ.б.)», «терәтү» ~ каз. *җөле-* «сөяп кую», алт. (Будагов I: 383) *йӧлӧ-,* бор. төрки (ДТС: 274) *jölä-* «сөяү, терәтү», кырг. *жөөлө-* (*жөөлө-*) «терәү, терәлү». К. ш. ук диал. (ЗДС: 255) **йөлөн-ү < йөлән-ү** «таяну, сөялү». Югарыдагы **йөлә** сүзе белән баглы булса кирәк.

Морфологиясенә карап фикер йөрткәндә, бу сүзләрнең тамыры **йӧ* «аскы терәк».

**ЙӨЛЕН [йөлөн],** диал. (Тумашева 1992: 84, 88) **җөлөн, йүн** «поясница; спинной мозг» ~ башк. *йөлөн, йола, йӧлӧн,* нуг. *йулын, йурын,* чыгт., алт., үзб. диал. *йүлүн*, кырг. *җүлүн*, каз. *жұлын, җүлүн*, к.-калп. *жулын* id. К. **Йөлә.** ЭСТЯ IV: 266 (аңлатмасы ярлы).

**ЙӨЛЕ-Ү [йөлө-], йөлө-ү, йөл-ү, җилү, җөлү** (ТТДС 1969: 572, 583) диал. «удалить волосы, брить, сбривать» (ДС I: 69), «очищать землю от травы; брить, бриться» (Тумашева 1992: 84) ~ ком., кр.-тат., төр. *jülü-*, алт. *йүл-* (Будагов II: 383), каз. *жүли-, жөли-* < бор. төрки *jüli-* id., шуннан *jüligü* «өстәрә (бритва)» (ДТС: 285–286). И.Г. Добродомов һәм. Н.А. Баскаков рус. *жулик* «пәке; жулик» сүзен дә шул сүздән дип карыйлар (Баскаков 1984: 10–11), к. к.-калп. *җөлик*, кырг. *җүлүк*, к.-балк. *жүлия* «жулик, алдакчы, хәйләкәр» (*жүлийә < jüligü !*).

Чаг. ш. ук себ. тат. **йөлтөк** «ялкау; хәйләкәр ялкау» > *йөлдөк < *йөллик >> жулик?* К. түбәндәгене.

**ЙӨЛТЕ [йөлтө]** (ЗДС: 255), башк. «приз победителю на свадебных соревнованиях», «неожиданная находка или добыча», добр. (Dobr. I: 471) *cülde* «традицион татар көрәшендә җиңүчегә төп бүләккә бәйләп бирелгән бизәк (матур тәлгәш, тасма һ.б.)» ~ каз. *жүлдү,* кырг. *җүлдү, жүлү* «тулай алынган товар; үтергән өчен түләтү» (гадәттә үтерүченең бар малын һәм хатынын да алганнар), *җүлде* «ярышларда приз» ~ фар. *жулду, жӱлдӱ* «батырлык өчен бүләк» һ.б. Чаг. ш. ук чыгт. (Будагов I: 446, 499) *чулду* «трофей», алт., тув. *чулду* «табыш» һ.б. Будагов моны фар. сүзе ди. Чаг. ләкин югарыдагы белән.

**ЙӨНТӘС, йөнтәй, җөнтәс, җөнтәч,** себ. (Тумашева 1992: 82–84) **йөнләшкә,** башк. ш. ук (БТДҺ: 125) *йөнтәмәс, йөннәшкә, йөнтәфкә* «мохнатый, волосатый» – бу **йон ~ йөн** сүзеннән ясалмаларда монг. кушымчасы *-тәс ~ -тәй* барлыгы сизелә.

**ЙӨҢ, йүң, йөн** диал. «дёрн; борозда» (Тумашева 1992: 85–88) ~ алт. *йӧң, дьӧң* «ук каурые; кәз», алт. диал. *joң, дьоң*, туба. *ноң* «сөрелгән буразнадагы сирәк үлән» ~ чув. *çăм [счŏм] > дуом* «чүп үлән» (к. Räsänen 1969: 210–212).

**Йөң** сүзе төрки халыкларның бабалары игенчелекне яхшы белгәнлекләрен дәлилли.

**ЙӨРӘК,** диал. **җөрәк** «сердце; храбрость» < гом. төрки, бор. төрки *йүрәк*, к.-балк., кырг. *җүрөк*, каз., к.-калп. *жүрәк, җүрәк*, чув. *çĕре [счөрә] < *җөрәг* id. ~ яз. монг. *ǯirüke* >> бур. *зүрхэ*, бор. монг. *ǯürüken* «йөрәк». Гадәттә *йөр-ү < йүр-* сүзеннән дип аңлатыла. К. ш. ук аз. *үрәк, үрек*, як. *сүрэк* «йөрәк, күңел». К. Поппе 1938: 211; Räsänen 1969: 213; ССТМЯ I: 278; ЭСТЯ IV: 270–271; Федотов II: 414–415.

Дерив.: **йөрәкле, йөрәксез; йөрәклән-ү.**

**ЙӨРГӘК** «пелёнка» к. **Җөргәк.**

**ЙӨР-Ү,** диал. **җөре-ү, җөр-ү, йөр-ү** «ходить; быть на ходу; ездить» < гом. төрки *йүрү-, йүүр-, йүр-,*

үзб. *йура-, йүрә-* ~ чув. *çүре- [счүрэ-]*, бор. төрки *jür-, jüri-, jürü-, jor-, jorı-* (ДТС: 274, 286–287) ~ яз. монг. *ǯori-* id. К. ш. ук к.-балк., кырг. *җүрү-*, каз., к.-калп. *җүрі-, жүрі-,* тув. *чору-* һ.б. *йөгер-ү, йогыр-у* < *йүгүр-, йугур-* сүзеннән аерылырга тиеш түгел. К. **Йөгер-ү, Юрык, Юрга, Юырт-у.** Будагов II: 373.

Дерив.: **йөрел-ү, йөрен-ү, йөреш-ү, йөрет-ү, йөрдер-ү** (аерым мәгъ.); **йөреш; йөремсәк, йөреткеч** (неол.), диал. (ДС I: 69; ДС II: 263) **йөртәк, йөрелтәк, йөрештәк** «йөреп торучан».

**ЙӨТКЕР-Ү [йөткөр-],** диал. **җөткер-ү** «кашлять, кашлянуть» ~ башк. *йүткер-*, *йүткөр-*, чыгт., алт. *йүткүр-*, каз. *җүткір-, җүткөр-,* к.-балк. *җүwүткүр-* id. **йүwүт, *җүwүт* «ихтыярсыз аваз» нигезеннән (*йүwүт-кĕр-*), к. **Ютәл.** К. к.-балк. *җүw* «сызгырык, чыелдау һ.б.ш.». ЭСТЯ I: 557.

**ЙЫУ-У, йу-у [йуы-у?]** (себ., ЗДС: 259) «собирать, например, сено» – «җыю (мәс., печәнне)» < *йыw-* < *йыгы-?* Чаг. (ЗДС: 261) **йыгрыл-у,** ш. ук *игрыл-у* < *йыгырыл-у* «җыерыл-у»; бу сүз борынгырак яңгырашлы **йыйгыр-у** сүзенең төш. юн. булса кирәк, к. шунда ук **йый-** «җыю», **йыйгыр** «оста җыючы», **йыйым** «урак өсте» – оригиналь диал. (себ.) сүзләр. Күрәсең **йыйг-у, йыйыг-у** «җыя төшү, интенсив рәвештә җыю». К. Ясәвидә дә:

*Дөнья малын сансыз йыйгып алганнарга*
*Үлем килсә, бере вафа кылмас, ирмеш.*

Гом. төрки *йыг-* «җыю» < **йыйыг-** булса кирәк. К. **Җый-у.**

# К

**К** хәрефе кириллица нигезендәге татар алфавитында калын **қ**, урта **к** һәм нечкә **к′** тартык авазларын белдерә.

Сүз башында **қ** һәм **к′** бор. төрки **q-** һәм **k-** авазларыннан килә. Урта **к** мишәр сөйләшләрендә һәм алынма сүзләрдә генә очрый.

Сүз (иҗек) азагындагы **-қ** һәм **-к** бор. төрки **-γ** һәм **-g** авазларыннан килергә мөмкин.

Интервокаль позициядәге **-қ-** һәм **-к-** еш кына бор. икеләтелгән **-ққ-** һәм **-кк-** тезмәләреннән килә (*бака* < *бакка, ике* < *икки, тәкә* < *тәккә* һ.б.). Каты **қ-** авазыннан соң палаталь сузык килү очраклары гадәттә гар.-фар., ш. ук уйг. теленнән алынган сүзләрдә күзәтелә.

**-КА, -КӘ** – древний аффикс, образующий ласкательно-уменьшительные названия живых существ (и растений). Хәз. тат. үзе генә сирәк кулланыла (мәс., *анака* ~ *инәкә, әбекә* һ.б.), гадәттә бу кушымчага *-й* (ш. ук иркәләү кушымчасы) өстәлә һәм **-кай//-кәй** кушымчасы пәйда була (*анакай* ~ *инәкәй, әбекәй* һ.б.) һәм ул киң кулланыла. Кайбер очракларда бу **-кай//-кәй** җансыз әйбер атамаларына ялгана башлый, мәс., актив кулланышлы **җылыкай** һ.б.ш.

Бүтән кушымчалардан үзгә буларак, **-ка//-кә** кушымчасында тартык авазлар интервокаль позициядә дә яңгыраулашмый (мәс., **атакай, кешекәй** диелә, *атагай, кешегәй* түгел, чаг. – юн. килеш кушымчасы яңгыраулаша: *атага, кешегә* һ.б.). Ихтимал, бор. төрки *qa, кә* аерым сүз булгандыр, чаг. кыт. *кә* «әҗәлле (кеше)».

Ошбу сүзлектә **-ка//-кә** ярдәмендә ясалган барча сүзләр дә күрсәтелмәде.

**КАБА I** «пряслице; сошник (деревянная часть плуга, сохи, на которую надевается железный лемех)» > мар. (Исанбаев 1978: 43) *ка́ва*, удм. *кубо* id. Бу бор. агротехник термин ниндидер субстрат телдән алынган булырга мөмкин, к. рус. диал. (Даль) *каба, коба, кова* «тәбәнәк кенә багана, юан казык һ.б.ш.». Икенче яктан к. угыз. төркиләрендә *kaba, qaba* – угызларның бабаларын «тудырган» мифологик агач (к. Ögel: 89).

*Каба* сүзеннән чув. *йопа* > *йупа* «күшә баганасы; кеше кыяфәтендәге (кабер ташы)» сүзе килсә кирәк (гом. төрки *қ-* > чув. *й-* күп кенә сүзләрдә күзәтелә); к. ш. ук мар. (Упымарий: 74) *копа, копка* «уч, кул чугы». Ашмарин IV: 342–347; Федотов II: 488–489 (чув. *юпа* сүзен монг. һ.б. *обо* «уба» (к. **Уба**) сүзе белән бәйли, безнеңчә, бу бик шикле).

Дерив.: **кабалы, кабасыз, кабалык.**

Халык фантазиясе *каба агачын* байтирәк (рус. «мировое дерево») белән тиңләгән, шуннан «тугыз кабаны чайкаган су белән дәвалау» (к. русларда «...водою из девяти веретен») ырымы килеп чыккан.

**КАБА II: каба сакал** «пышная борода» < гом. кыпч., госм. *қаба* «калын, киң сакал», бор. төрки (Räsänen 1969: 215) *qaba* id. > төркм., аз. *ғаба* «юан, симез, зур, тупас; калын (сакал)» ~ кр.-тат., кар., ком. *қаба* «тупас, дорфа һ.б.» (к. Zenker: 689, Steuerwald: 463).

Бу **каба** сүзеннән тыш, чыгт., кыпч. *қаба,* төр. (Будагов II: 35) *қāбā, қабā* «тупас тукымадан өс киеме, чикмән» сүзе дә (иске ядкәрләрдә) очрый. Бу сүз гарәпчәдән килә һәм аның **қаба I** сүзенә кагылышы юк.

**КАБАГА** в отдельных выражениях: **кабагасы калын** «о человеке, не выражающем реакцию на разговоры вокруг», **кабагасына кар яуган** «о человеке, упорно отмалчивающемся» (от обиды или для важности) – букв. «на его веки снег выпал» ~ монг. **қабағай* «күз кабагы; калын кабак».

**КАБАГАН: кабаган (эт)** «кусачий (о собаке, лошади)» ~ нуг., каз., к.-калп., алт. *қабаған*, кырг. *қабааған,* ком. *қабаған,* чув. *хыпакан* id. *қап-* ~ *хып-* фигыльләреннән регуляр ясалмалар (сыйфат фигыль формалары): чаг. бор. төрки *Qapaγan* – атаклы хан һәм соңрак титул (ДТС: 420). Чаг. **Тибәгән.**

**КАБАК I** «веко (глаз)» < гом. кыпч. *қабақ* id., алт. *кабак, қабақ* «кат, кабак», хак. *хахпах* «капкач, күз кабагы», тув. *хабақ* «маңгай, кузыр – козырёк» < бор. төрки (ДТС: 420) *qaраγ* «капкач; күз кабагы; кызлык пәрдәсе» ~ чув. *хопах* > *хупах* «күз кабагы». **Күз кабагы** тәгъбиреннән үк күренә, төп мәгъ. «капкач». Федотов II: 359 (аз материал китерелә).

Төрки телләрдә (тат. диал. (ЗДС: 265), кырг., башк. диал. һ.б) тагы *қабақ* «зур түгел текә ярлау,

текә кашлак» ~ аз., төр. (Будагов II: 36) *қабағ* «кыек, түбә; палуба; тау сырты, тау башы», аз. *ғабағ* «алгы як; элек», алт. диал., чулым., уйг. (Joki 1952: 155–156) *қамақ* «маңгай», тув. *хавак* «кашлак, тау текәсе» (сүзлекләрдә *қабақ* «маңгай» сүзеннән аерылмый) сүзләре дә бар. Бу сүзләр *қабақ* сүзенең күч. мәгънәләреннән булса кирәк, к. Гарипова 1998: 94–95.

**Кабак** нигезе һичшиксез *қап* тамырыннан (*капақ > қабақ*), к. **Кабага, Кабак III, Капкач.**

**КАБАК II** «тыква», диал. (Тумашева 1992: 112–113) **кабақ, каwақ** «трава; лист» > чув., мар. удм. *кабақ,* рус. диал. *кабак* (шуннан *кабачок, кабачки* «вак кабак төре») < гом. кыпч., гом. угыз. *қабақ, қабқа, қаwақ* < бор. төрки (ДТС: 399) *qabaγ, qabaq* id., уйг. *қапақ* «кабак; озын муенлы кабактан эшләнгән декоратив савыт» һ.б. К.-балк. (> абаз.) *қаб* «кабак» сүзеннән чыгып, бу сүзне дә *қап* тамырыннан дип уйларга мөмкин, тик сүзнең кайбер яңгырашлары һәм мәгънәләре читкә алып китә, к. төркм. *қаабақ,* рус. (төрки телләрдән) *кабака, кебека* «кабак», М. Кашгари буенча (МК I: 382), *қабақ* «яшел килеш ашала торган җимеш» (чаг. чув. *хопах > хупах* «әрекмән» ~ мар. *кавақ* id.). Г. Рамстедт (1957: 181) *қабақ* сүзен кор. *һupak* < кыт. **hu pak* «варвар кабагы» сүзе белән чагыштыра һ.б. Будагов II: 36; Doerfer 3: 412; Фасмер II: 148, 220; Мухамедова 1973: 109–110; ЭСТЯ V: 164; Аникин: 229.

Кабакның гаҗәеп үзлеге бар: ул тамырларын тирән җибәреп (әгәр аста сулы катлам булса) сусыз-яңгырсыз чүлләрдә дә үсеп утыра. Җылы якларда үсә торган озын муенлы *ташкабак* төреннән төрле комгансыман савытлар ясыйлар. Көнч. Азия халыкларында *кабак* демиург (дөньяны яратучы зат) дип исәпләнә. Бер үзбәк әкиятендә кабакны кискәләгәндә пычагы кабак эченә төшеп киткән бер кеше шул пычагын алам дип кулын тыгу белән үзе дә төшеп китә һәм бүтән бер дөньяга барып чыга. МНМ II: 175, 231, 488.

**КАБАК III** «кабак, питейное заведение», диал. (ТТДС I: 224; Тумашева 1992: 113) «лавка, магазин», **кабак** (урта *к*) «ворота; усадьба; двор», (Будагов II: 2) «забор на меже», (ЗДС: 371) «родовой праздник нескольких сёл». Алтын Урда тат. телендә *кабак* «шәһәр капкасы» (**кабакчы** «шәһәр капкасы сакчысы», к. Греков, Якубовский: 114) < гом. кыпч.: нуг. *қабақ* «авыл, хутор», кар. *кабах,* әрм.-кыпч. *хавах* «капка; кальга, шәһәр» (*хабахчы* «капкачы»), к.-балк. *қабақ* «торлак; авыл; капка; киртә, кәртә» < куман. *kabак, kabacь* «кальга капкасы» < бор. төрки (ДТС: 420–421) *qaраγ, qариγ* «капка, ишек; кабулханә, кергелек» һ.б. барысы да *қап* «капкач, капкачлы савыт; кап» тамырыннан, әлбәттә. Гомумән, бу сүз төптә **күз кабагы** белән бердәй; элекке кирмән, кальга капкалары вертикаль хәрәкәттә ачылган (югары күтәрелгән); димәк чыгыш мәгънәсе «кирмән капкасы», шуннан «гомумән капка» → «капкалы ихата» һ.б. (к. югарыда). Шәһәр капкасы янында элек-электән сатучылар, кибетләр торган, шуннан «кибет, магазин» һәм, ниһаять, рус телендәге «исерткеч эчемлек сату урыны» мәгъ. килеп чыккан (к. Прыжов И.Т. История кабаков в России. СПб., 1914). Чув. *хопах > хупах,* як. *хабаах* һ.б. «мәйханә» рус теленнән таралган.

Казан дәүләтендә *қабақ* сүзенең төп мәгъ. «магазин, кибет» булуы билгеле. Ахметьянов 1989: 132–133; Федотов II: 359 (бик аз). Фасмер II: 148 (һич кирәкмәгән фаразлар китерә); Тимергалин: 215.

**КАБАК IV** (дөб., ЗДС: 371) «родовой праздник». Чаг. себ. тат., к.-балк. *қабақ* «кечкенә авыл», башк. *қабақ* – бер авыл һәм ыруг атамасы, тат. (ЗДС: 371) *қабақ* «кабык» һ.б. Монда кайсы **қабақ** чагыштырылгандыр, әйтүе кыен.

**КАБАЛӘ** тар. «купчая крепость» < гар. *қабāлӓ* «кабалә, кабул ителгән шартлар язмасы; контракт» сүзеннән (мәзәк рәвештә бу сүзнең «акушерка» мәгъ. дә бар). **Кабалә** сүзе Идел-Урал регионына монголгача ук кергән булса кирәк, к. удм. *куболо* «расписка», тат. диал. *кабала* «шартнамә» (Никольский 1920: 400–403), морд. Э. *габала* ~ коми. *кабала* «кәгазь»! Рус. *кабала* < *кабалә* тур. к. Будагов II: 37; Аникин: 229. К. **Кабул, Хәблә.**

**КАБАЛАН-У** «торопиться, суетиться» – диал. **кабала-у, кабашла-у** «тотынгалау, әле моңа, әле тегеңә тотыну» (ДС II: 93–94) фигыленең кайт. формасы, чаг. чув. *хыпала-* «капшау, тоткалау», *хыпалан-* «кабалану», хак. *хабын-* «тотынгалау» *хап-* «кабу, тоту, эләктерү» фигыленнән, к. ш. ук төркм., к.-калп. *ғабалақ* «ашыгучан». К. **Кап-у.** Федотов II: 380–381.

**Кабалан** рәвеше аерым модель калыбында ясалган. *Каб-*уның бор. «тоту» мәгъ. *тота-каба* дигән парлы сүздән дә беленә.

**КАБАН** (чаще в выраж. **кабан дуңгызы**) «кабан, дикая свинья, вепрь» < гом. төрки *қабан*, тув. *хаван*, алт. *каман* id. < монг. *қабан, хаваң* дип

исәпләнә (Räsänen 1969: 216), ни өчен монголчадан икәнлеге аңлашылмый. Рус. **кабан** төрки телләрдән, к. Аникин: 229 (шунда ук әдәбият).

**Кабан күле** тур. к. Гарипова 1998: 405–407 (тикшеренүчеләрнең күпчелеге бу топонимны зооним белән баглый ди).

**КАБАР-У I** «вздуваться, распухать» < гом. төрки, бор. төрки *қабар-*, уйг. *қапар-,* төркм., аз. *габар-*, тув. *хавар-*, чув. *хăпар-* < болг. **ħабар* > мар. *авар-* id. *кап* «кипрән, сүрү» сүзеннән: **кабар-у** «кап булу», к. **Кап II.** Чаг. ш. ук тув. *хапый-* < *қабай-* «кабару», бор. монг. (Поппе 1938: 285) *qabat-, qabud-* id. һ.б.

**Кабар-** бик продуктив нигез: **кабарыл-у, кабарын-у, кабарыш-у, кабарт-у; кабартма** (> чув. *капартма,* к. Федотов I: 226) «калын тәбикмәк»; **кабарынкы**; к. **Кабарчык.**

**КАБАР-У II, кабарын-у** «недобро завидовать; разгневаться» (*капмаганга кабарма,* диләр) ~ кырг., каз., төр. *kabar-* «ярсыну» **кабар-у I** нең күч. мәгъ. итеп күрсәтелә, тик як. *хабар-,* аз. *габар-* «кирелләнү, үҗәтләнү; ярсыну» сүзләре бар, әмма аларның «кабару, кубү» мәгъ. юк.

Хәер, к. тат. **күбен-ү, күп-ү** «кабару; ярсыну» (ягъни монда типологик мәгъ. күчеше).

**КАБАРЧЫК**, диал. **кабарцык** «волдырь», диал. «пышка» – гом. кыпч. һ.б. *қабарчық* (башк. *қабарсық,* нуг., каз., к.-калп. *қабаршық*), аз. *габарчыг,* яз. төрки *qabarčiq* «кабарчык, күбек» < * *қабар* ~ аз. *габар* «кабарган нәрсә», бу сүз исә *кабар-у* фигыленең исем коррелянты булса кирәк, чаг. **Кабыр**. К. Мухамедова 1973: 111.

Тат. диал. **қабарчы** (ТТДС I: 185) «кабартма, чәлпәк» > болг. **ħабарчы* > мар. *аварцы, оварцы* id. *кабарчык* сүзеннән булса кирәк.

**КАБАРЫК** диал. «вздувшийся» – миш.-угыз линиясенә хас ясалма, к. төр., гаг. *қабарық* id. **Кабарчык**тан үзгә буларак, турыдан-туры **кабар-у** фигыленнән. Чаг. ш. ук як. *хабыры, хампары* «кабарык» (Пекарский: 3217, 3219). К. югарыдагыны.

**КАБАТ** «раз», диал. «рядом, около; сторона», «опять, вторично» (Троянский) > удм. (Насибуллин: 118) *кабат* «яңадан, кабат», мар. *кабат, кäбäт* (ш. ук *кäбäт-кäбäт* «кабат-кабат») > гом. кыпч. *қабат*, үзб. *қават* «катлам, кабат, икенчеләй һ.б.», кайбер телләрдә үзенчәлекле мәгънәләр алган: ком., каз., к.-калп.. кырг. «этаж, ярус», төркм. *ғабат* «янында; әйләнә-тирә», диал. (ТТГДС: 44) «костюм», үзб. *қабат* «икенче кат кием», чыгт. (Будагов II: 35) «икенче катлам» һ.б., шулардан чыгып, **қапқат* формасыннан түгелме икән, дип әйтергә ярый. Чаг. ш. ук алт., тув. *катап* «кабат». Башк. (Будагов II: 35) *қабата* «кабат, кабаттан» вариантлы икенчеләй очрамады. Уйг. *қәвәт* «кабат» фонетик инновация. Рус. һәм гом. слав. *кабат* «җиңсез кием» (к. Фасмер II: 22) төрки телләрдән булса кирәк (чаг., ләкин **капот**). Ул сүзне гар. *қаба* нигезеннән диләр.

Дерив.: **кабатлы, кабатсыз; кабатла-у; кабатлан-у** һ.б. (икенчел дериватлар күп).

**КАБАХӘТ** «дрянной, гадкий, подлый» ← иск. *кабахәтле* id.; гар. *қабāхäт* «әшәкелекләр» сүзеннән, к. иске әд. *қāбих* «әшәке, явыз».

Дерив.: **кабахәтлек; кабахәтлән-ү.**

**КАБЕР** «могила» < гар. *қабр* id. *қбр* «күмү» тамырыннан.

Дерив.: **каберлек, каберче, каберстан.**

**КАБЗА-У** «охватить противника в клещи ». Бу сүз *капса-у* да, *капша-у* да түгел, бөтенләй бүтән тамырдан – гар. (Будагов II: 37) *қабд̣* «тотыну; алым; конфискация» сүзеннән. Без XX г. башында татарча хәрби уставта кулланылган бу сүзне гыйбрәт өчен алдык.

**КАБИЛӘ** «племя, род, клан» < гар. *қабӣлä* «ишләр, охшашлар төркеме; кабилә», *қбл* «охшаш булу» тамырыннан, чаг. иске әд. **кабиленнән** «кебекләрдән».

Дерив.: **кабиләче, кабиләчелек; (күп) кабиләле.**

**КАБУЛ** «принятие, приём» < гар. *қабӯл* id. Урта Идел регионында монголгача кергән сүз, к. чув. *хапăл* «кунакчыллык; бик теләп; көч-куәт», мар. *кавыл*, удм. *кабыл* «дога нияте; фатиха» (чаг. тат. *догабыз кабул булсын*), гар. *қбл* «каршылау» тамырыннан, шуннан ук к. **Кабалә, Мәкъбүл**, иске тат. **қабил** «откыр, сәләтле», **кабилият** «сәләт» һ.б. Федотов II: 310–311.

Дерив.: **кабуллан-у; кабуллык, кабулханә** «кабул итү бүлмәсе».

**КАБЫЗЛЫК** «горец (трава)», диал. (ТТДС I: 180) «сухая травка для разжигания огня» ← **кабыз-у.**

**КАБЫЗ-У** «зажечь огонь, поджечь», собственно (диал.) «дать схватить ртом» < гом. кыпч., к. ком. *қабуз-*, алт. *қабыс-*, тув. *қывыс-* «ут кабызу» (күп сүзлекләрдә теркәлмәгән) < **қапқыз-* < **капқырғ-* ← *қап-* әлбәттә, к. **Кап-у** (*ут кабу*), **Кабын-у.**

Дерив.: **кабызыл-у, кабыздыр-у**, к. **Кабызлык.**

**КАБЫК** «кора, луб; кожура; оболочка; скорлупа, шелуха» < гом. кыпч. *қабық,* чыгт., госм., ком. *кабуқ, кабуғ, кабух*, тув. *хавық* һ.б. < бор. төрки (Поппе 1938: 173) *qapuγ, qapuq* ~ чув. *хуп, хуппăн, хуппа* «кабык» ← *қап-* «каплау» фигыленнән. К. ш. ук төркм. *ғабық,* аз. *ғабығ* «кабык», як. *хаах* > *хах* id. Чаг. **Кабак I, Кап II, Капла-у.** Мухамедова 1973: 111.

Дерив.: **кабыклы, кабыксыз, кабыкла-у; кабыкча**.

**КАБЫН-У** «возгораться, загореться, зажигаться, вспыхивать», «вспылить» < гом. кыпч. *қабын-* (ком. *қабун-*) id. – *ут кабын-у* тезмәсеннән эллипсис. *Ут кабын-у* дигәндә утның, гүяки җанлы нәрсәнең «үз-үзен кабуы» күзаллана, чөнки *кабын-*, гомумән алганда, *қап-* фигыленең кайт. юн.

Дерив.: **кабыныл-у, кабыныш-у, кабындыр-у.**

**КАБЫР** (ЗДС: 265; БҺҺ II: 126) «могила» ~ ком. *қабур* id. – **кабер** сүзеннән түгел, ә бор. *қабур* «табут, әрҗә» сүзеннән, к. **Кабырга, Кабырчык, Кубыр.** Чаг. бур. *хаабари, хаабур* «япкыч, капкач» ← *хаа-* «капкачлау» һ.б.

**КАБЫРГА** «ребро», «бок; склон горы» < гом. кыпч. *қабырға*, үзб., уйг. *қабирға* id., ком. *қабырға* «дивар, өргә», төр. *kabırga, kaburga,* аз. *ғабырға* «кабырга; ян шайманы», төркм. (ТДГДС: 50) *ғапырға* «чигеш үрнәге, бизәк төре» (*ғапырғасыз* «каюсыз»), хак. *хабырга* ~ монг. *хабирга* < бор. монг. *qabirγa* > як. *хобурған* > эвенк. *хобурган* «кабырга; чана карамасы» һ.б. Түбәндә бу сүз тән әгъзасын түгел, тирмә, әрҗә кирәгәсен белдергән һәм, телчеләр фикеренчә, монг. телләрендә **кабыр, кабур** (к.) сүзеннән ясалган. К. башк. (БҺҺ II: 126) *қабыра, қабырый* «ян як, өргә», чув. (Сергеев 1968: 25) *капăрка* «табут». Үзб. (ЎХШЛ: 153) *қабыз* «кабырга, култык асты» (< **қабырғ*) *р* > *з* күчешенең юнәлешен билгеләү өчен әһәмиятле. Räsänen 1969: 216.

Дерив.: **кабыргалы, кабыргасыз; кабыргалык. Кабыргалы-камчылы** дигән уен исемендә **қабырга** «ян шайманы булса кирәк, к. госм. (Будагов II: 3) *қабырға* «бөҗраларсыз көбә».

**КАБЫРЛА-У** (ТТДС I: 225) «сгонять в одно место» ~ чув. *хупăрла-* id., ш. ук «төрле яктан капла-у, камау» < бор. кыпч. **қабырла-* ← *қап-* «каплау» фигыленең интенсивлык формасыннан булса кирәк. **Қабыр** (к.) сүзеннән дә ясалган булуы ихтимал. Чаг. ш. ук бор. төрки (ДТС: 436) *qavïr-* «җыю». Гомумән, *қабырла-у* фигыле тат. теленнән гайре телдә теркәлмәгән шикелле.

**КАБЫРЧЫК, кабырчак** «раковина» < бор. төрки (ДТС: 399) *qabïrčaq* «әрҗә, сандык; табут һ.б.ш.», чыгт. (Радлов II: 654) *қобурчақ* id., чыгт. (Поппе 1938: 285) *qawurčaq* «кабырчак, ташбака калканы» ~ кырг. *кабырчық,* нуг., каз., к.-калп. *қабыршақ, қабыршық* «балык тәңкәсе; шайман, көбә; юка яндау», к.-балк. *қабурчақ, қабырчақ* «каты, ташсыман (ташбака кабырчыгы шикелле)», як. *қуорчах* «агач кәүсәсеннән ясалган табут (аны мәете белән я агачка асып куйганнар, я елгага агызып җибәргәннәр; шундый гадәт бор. болгарларда да булган)» ~ иске монг. *qaγurčaq* «озын әрҗә, табут» ~ алт. (Баскаков 1972: 215–216) *қаарчық, қайырчақ,* алт. диал., тув. *хааржак, хаарчақ* «зур тартма, әрҗә»; к. ш. ук чыгт., госм. (Радлов II: 660) *қапурҗуқ* «кумта» һ.б. Төрки телләрдән бу сүз күрше телләргә дә кергән: венг. *koporso* «табут», рус. *ковчег* «борынгы тупас һәм зур кимә» < бәҗ. **қаучақ* ~ бор. бәҗ. **кавучақ,* күрәсең, ритуаль мәет озату кимәсе яки көймәсе булган, анда үлгән асылзат белән бергә аның малтуары, хәтта коллары-кәнизәкләре дә төялгән (әлбәттә, үтерелеп), ут төртелгән һәм суга агызылган. Шуннан, бәҗәнәк теленнән булса кирәк рус. *ковчег* сүзенең «килбәтсез көймә» һәм «Нух көймәсе» мәгънәсе килә.

**Кабырчак**, татарчасыннан ук күренеп торганча, **кабыр** (к.) «әрҗә» сүзеннән (*қабыр-чақ*), к. ш. ук **Кабырга, Кубыр.** Шуны да искәртик – **кабырчак** ул **кабырчык** белән бердәй түгел, болар төптән-тамырдан аерым сүзләр.

Дерив.: **кабырчыклы, кабырчыксыз; кабырчыклан-у.**

**КАВАЙ [қаºwай]** диал. «белый мох (на коре дерева)» ~ башк. *кауай* «вспыльчивый» < **кау-аг* < **кауағу* < «кабыза торган» сүзеннән. К. **Кау, Каудар.**

**КАВАК [қаºwақ], кавык [қаºwық]** «перхоть на голове; труха» ~ башк. диал. *қабақ, қауақ* «кавак; кибәк», (БҺҺ II: 140; БҺҺ III: 101) *кауҙан* id. (шунда ук) ~ себ. тат. (Дмитриева 1981: 153) **қаутан** «кавак», (Тумашева 1992: 112–113) **қауақ,**

**қаақ** «яфрак; үлән» ~ к.-балк. *қабу* «кавак», төркм. *kawak* һ.б. «куак; вак яфраклы үлән» һ.б. (к. **Куак**) – барысы да ахыр чиктә *қау* < *қагу* ~ *қабу* «корыган үсемлек яфрагы, корыган үлән, ку» тамырыннан; бу тамырдан төрки телләрдә йөзләрчә сүз ясалган.

Сүзнең морфологик структурасы *қау-ақ,* мәгънә үсеше: «вак кына кипкән яфраклар, кибәк» (к. чув. *хывах* «кибәк») > «кибәксыман чүп, кавак». *Қау-ақ* > *қауық*. К. **Кава-у**, **Кау, Каудан, Каулан.**

Бор. төрки *qavïq, qavuq* «кибәк, көрпә» (ДТС: 436, 438) шулай ук **qavaq* формасыннан, ягъни **кабык**тан түгел (һәм **qab** тамырыннан да түгел), к. бор. төрки *qavaγu* «ку». Шулай итеп, **кавык**ны **кабык**ка җибәрергә ярамый!

К. ш. ук Будагов II: 85 (язылышы һәм чагыштыруы дөрес түгел); ЗДС: 373 (**kawak** сүзе белән ясалган күп кенә фраземалар бирелә).

**КАВАЛ [қа°wал]** диал. (Арсланов 1988: 79) «свадебный барабан», (ЗДС: 373) «струнный музыкальный инструмент» ~ нуг., кр.-тат. һ.б. *қабал* «көтүче быргысы» < фар., көрд. һ.б. *qaval*, аз. *ғавал* «барабан төре». Шәрыктә киң таралган сүз. К. Будагов II: 67.

**КАВА-У [қа°wа-]** диал., башк. (к. БТДҺ: 193, *кауап төшөү* «кубалаклау») «облезать; облупляться (о коже человека и животных)» ← **кау** (к.). Мар. (Исанбаев 1978: 24) *каган* «каудан» тат. *қаwаған* сүзеннән булса кирәк.

**КАВЕМ [қа°wĕм]** «народность; этническая группа» < гар. *қаwм* id., тәүдә – «төркем», бор. мисыр *хаум* «өем, ашлык өеме, көшел» сүзеннән (шул сүзнең иероглифыннан – тәүдә үл Λ формасында була – грекча Χ – *икс* хәрефе һәм сүзе килә: *X* > *КҺ* > *КС* үзгәрешләре бор. грек телендә йөз биргән).

**КАВЫЗ I [қа°wӹз],** диал. (ТТДС I: 186, 225; БҺҺ III: 77) **қәwез** «узел мельничного колеса: погонный ларь – канава, желоб, по которому вода подаётся на колёса, а также шлюз мельничного колеса» > чув. *кавăс, кавус*, мар. *ко́выз,* удм. *кауз* id. < урта төрки *хаwыз* (> үзб. *ҳовуз* һ.б.), төр. *havuz* id. < гар. *ḥаwḍ* «ясалма күл, бассейн» (к. ГТРС: 671) сүзеннән, шуннан ук к. **Кауза, Хәвез, Хәүзә**. К. Егоров 1964: 84.

Рус. *кауз, каус, коус, ковуз, хауз* «кавыз» тур. Аникин: 274 (автор моны төрек теленнән ди; безнеңчә, төрле вариантлар төрле чыганаклардан, ш. ук тат. теленнән дә, икенче яктан, кайбер тат. һәм чув. вариантлары рус теленнән кире кайткан булырга мөмкин).

**КАВЫЗ II [қа°wӹз],** диал. (Башкортстан) «чешуя, шелуха; мякина от проса» ~ каз., чыгт. (Будагов II: 29) *қауз,* кр.-тат. *qawuz, qawız,* нуг., каз. *қаўыз,* төр. *kavuz,* гаг. *қооз,* чыгт. (Радлов II: 57) *қобуз* «кавыз, кабык; кибәк». **Қау** тамырыннан булса кирәк, к. **Кауза-у.** Чаг. бор. төрки (ДТС: 436, 438) *qavïq, qavuq* «тары кибәге». Тары кибәгеннән һәртөрле корткычлар, микроблар кача, шунлыктан элек бәбиләрне тары кибәгендә асраганнар, мендәргә тары кибәге тутырганнар. Кавызның бактерецидлыгы озаклы тәҗрибәдән беленгән, күрәсең. К. каз. (ҚТДС: 198) *қауыздай кигiз* «кавызлау киез» – бәби астына салына торган киез. Чаг. **Каулак.**

Дерив.: **кавызлы (мендәр); кавызлау.**

**КАВЫК** «перхоть» к. **Кавак.**

**КАВЫЛ [қа°wӹл]** диал. (Тумашева 1992: 124) «прошлогодняя трава» >> рус. *ковыль*, морд. *кавал* «кылган, әби чәче» < бор. төрки **кағул* id. (> молдав. **кагул** «дала») *каг* ~ *қаw* тамырыннан. К.-калп. *геўил* «кавыл» төркм. диалектларыннан булса кирәк. К. ш. ук хак. *хаал* «кawыл». К. **Кавыз, Кау, Каудан, Каулан.** Рус. *ковыль* тур. Менгес: 105–107 (төрле фаразлар китерә, дөреслеккә якынлаша, әмма тат. **қаwыл** сүзен белми); Ахметьянов 1989: 30–32.

Дерив.: **кавыллы, кавыллык; кавылла-у** «биек үлән үсеп каплау».

**КАВЫН [қа°wӹн]** «дыня», диал. «тыква; огурцы» (к. ДС I: 71) > чув. *кавăн*, удм., мар. *каун* «кабак» < гом. кыпч. *қаwын, қауын, қаун*, госм. *қавын, қавун* > уйг., чыгт., бор. төрки (ДТС: 406) *qaγun*, үзб. диал. (ЎХШЛ: 158) *қа:ғун*, бор. төрки *қауғун* «кавын» ~ яз. монг. *γaun*, калм. *гуун* id. тибет. *ga-gon* «кавын» сүзеннән (Doerfer III: 294) хисаплана. Ләкин төркм. *гаавун* «кавын, бастан (кавын-карбыз бакчасы)» бүтән фаразларга да урын калдыра, к. Мухамедова 1973: 110; ЭСТЯ V: 175.

Рус., укр. *кавун* «кавын» тур. Аникин: 231.

**КАВЫР [қа°wӹр],** диал. (ДС III: 68) **кагыр** «перо птицы» ~ хак. *хоор* id., к. **Кавырсын I, Каурый.**

**КАВЫРСЫН I [қа°wӹрсӹн]** «костяк, стебель пера птицы», күч. «пластмасса; пластмассовый» ~

каз., к.-калп. *қаўырсын*, кырг. *қуурсын,* к.-балк. *қаўурсун,* төркм., госм. *қавурсун,* як. *қуорсун,* СС *kavusin* id. һ.б. монг. телләреннән. К. башк. *қауырһын* бор. бур. сөйләшеннән (*с* > *һ*). К. түбәндәгеләрне.

**КАВЫРСЫН II [қа°wы̆рсы̆н]** диал. (Тумашева: 125) «сухой стебель злаков», Себ. (ДС III: 69) *қағырсын* id. < бор. монг. *qaγurasun, qawurasun* «корыган башаклар, чемнәр, салам» (*-sun* җыелма күплек кушымчасы), хәз. монг. *гауурсун,* бур. *гуурһан* id. ← *гуур, гауур* < **qaγur* «башаклы үсемлек сабы», к. **Кавыз II.** К. ш. ук **Кагурцын, Каурый.** Räsänen 1969: 242.

**КАВЫРЧЫН [қа°wы̆рчы̆н]** диал. «перо птицы (к. **Өке**), прикрепляемое к головному убору (как знак девичества или неженатости у молодых людей)» < монг. (искечә) *қауурчин* id. Бу сүз ясалышы буенча **қавырсын** белән бердәй (*с* > *ч*) түгел, ә тат. **кавырчы** кебегрәк сүз, ягъни төп мәгъ. «ярсызлык билгесе буларак, баш киеменә каурый беркетеп йөрүче яшь кыз яки егет» була.

**КАВЫС I [қа°wы̆с]** зодиакальный месяц «стрелец» < гар. *қawäc* «җәя». **Кавыс ае** хәзерге 22 ноябрь – 21 декабрь аралыгына тәңгәл килә. *Каус* «җәя» сүзе б.э. II меңьеллыктан, атаклы Ашшур (Ассирия) патшасы Тиглат-Паласар ядкәрләреннән үк билгеле. Ассирия – хәз. Гыйрак җирләрендә яңгырлар һәм салават күпере ноябрьдә генә булгалаган. Җирле халык ул салават күперләрен *Кawс äл-Кузах* «Кузах дигән мифик батырның җәясе» дип сөйләгән, татарларның кайберләре бу сүзне «казак җәясе» дип үзләштергәннәр. Будагов II: 80; EI IV: 795–803.

**КАВЫС II [қа°wы̆с]** иск. «скобка (в письме)» ~ чыгт., үзб. *қаwус, қаwсы* id., төр. *kavsı* «ярымтүгәрәк; дугасыман». **Каwыс I** (к.) сүзеннән булса кирәк, хәз. тат. **җәя** (язу билгесе) сүзе шуннан тәрҗемә ителгән. Тимергалин: 217.

**КАВЫШ-У [қа°wы̆ш-]** «соединиться, сойтись (о влюблённых)» < уйг. *қаwыш-*, каз., к.-калп. *қаўыс-*, кырг. *қоош-*, аз., төркм. *говуш-*, төр. *kavuş* «кавышу», нуг. *қавыс-* «кояш баю (көрчегенә җитү)» < алт., тув. *қабыш-*, алт. диал. *кууш-*, *кобыш-*, бор. төрки (ДТС: 399, 337–338) *qabūš-*, *qavïš-* «кавышу» – *кап-у* сүзенең «эләгү, туры килү» мәгънәсеннән (чаг. тат. *балык кабу*; *ә, каптыңмы?*), к. Joki 1952: 175. К. **Кушыр-у.**

**КАГАЙ-У** «задирать голову; окаменеть с задиристым и надменным видом», башк. (БТДҺ: 181), каз. *қақай-у* «башны артка ташлау», «кату». Ләкин тат. (ЗДС: 368, 380) **какай-у, қақай-у** «боегу, ябыгу; күңел төшмәүдән ялкаулану» ~ каз., к.-калп., кырг. *қағау-* «катып калу» ← *қақ* «каты өслек; кипкән күл төбе», к. **Как II.** Монда төрле тамырлар булырга мөмкин.

**КАГАЛ-У** (Будагов II: 18; Тумашева 1992: 18) «задыхаться (от гнева и т.п. чувств); маяться» ~ каз., к.-калп., кырг., уйг. *қақал-, қақа-* «буылу».

**КАГАН** тар. «каган, император (в древнетюркских государствах, а также в Киевской Руси до принятия христианства)» < бор. төрки (ДТС: 405) *qaγan* id.; иске төрки телендә бу сүз *хақан* яңгырашында ешрак очрый. Кытай һәм фарсы чыганакларында бу сүз кимендә IV г. бирле билгеле. К. **Хан.** Будагов II: 1; Менгес: 107–111; Фасмер II: 155; Kalkan: 66–68.

Дерив.: **каганат, каганлык** (беренче вариант халыкара термин, гарәпчә булса кирәк).

**КАГАНАК** (ЗДС: 374) «послед, плацента» ~ каз., кырг. *қағанақ* id., к ш. ук (ҚТДС: 180) «лампа куыгы». Чаг. себ. тат. **qaγan** «кечкенә субасар болын» > рус. диал. *каган* «болында җәен кибә торган (төбендә суүсемнәр булган) күлчек», к. Аникин: 231. К. **Как, Какал.**

**КАГАУ [қа°ғaw]** «вид коршуна» ~ себ. (Тумашева 1992: 113), уйг. *қаға* id.

**КАГУ** к. **Как-у.**

**КАГУРЦЫН, кагырчын** диал. (к. Бәетләр 1960: 79) «стебель колоса, колосьев; стебель пера птицы» ~ каз. *қауыршан* id. Бу сүздә **қагырсын** (к. **Кавырсын**) нигезендәге монг. *-сын* < *-сун* кушымчасы төрки (бөтенләй үзгә) *-чын* ~ *-чан* белән алмаштырылган.

**КАГУЫЛ** диал. «обширный сухостой высоких трав» ← *қағы-, қаға-* «сохнуть (о травах)» ← *қақ,* к. **Как.**

Элекке тормышта **кагуыл** сүзе актив кулланылган, к. каз. *қағуылда-у* < *қағуылла-у* «кагуылда җәнлек, кош аулау» ← *қағуыл* «тауның, калкулыкның кояш кыздыра, киптерә торган ягы».

*Қағуылшы қағуылда* «киек, кош-корт аулаучы курайлыкта (булыр)».

**КАГЫЛ-У** «касаться, прикасаться; задеть» < гом. кыпч. *қағыл-* id. < уйг., угыз., бор. төрки (ДТС: 422) *qaqıl-* id. ← *qaq-* «кагу, тию; сугу, бәрү» сүзеннән, асылда **қақ-у** сүзенең төш. юн. белән бердәй, тик тарих дәвамында аерым мәгънә һәм чыгыш килеш белән башкарылыш алган (*нәрсәгә кагыл-у* һәм *нәрсә кагыл-у*). К. **Как-у.**

Дерив.: **кагылыш-у, кагылдыр-у; кагылгысыз;** диал. **кагылма́** «юлдагы кискен борылышта хасил булган чокырчык» һ.б.

**КАГЫН-У** «отряхиваться, размахивать крыльями» < гом. кыпч. *қағын-* < *қақын-* id. ← **қақ-**, к. **Как-у.**

**КАГЫРАН** (Тумашева: 113) «ясная погода зимой». Чаг. каз. *қағыр* «коры; кибеп, туңып каткан балчык», төр. (Räsänen 1969: 223) *kakırdak,* чыгт. *qaqırdaq* «туңган былчырак; касмак». Чаг. **Как.**

**КАГЫТ** «тонкая пастила» ← бор. **қак-* «киптерү» фигыленнән (**қақ-ыт*) булырга тиеш. Чаг. **Как II.**

**КАДАК I,** диал. (Будагов II: 7) **қаҙақ** «гвоздь» > удм., мар. (Насибуллин: 118; Исанбаев 1978: 40) *кадак* < гом. кыпч. *қадақ,* төркм. *ғадақ,* тув. *қадаг* ~ тат. диал. (Тумашева 1992: 113) **кадау,** куман., чыгт. *қадаw* > чув. *хотав* > *хутав* id. ~ кирг. *қадоо,* алт. *қаду, қадуу* «кадак, кадама; шырпы; дага». Тат. әд. телендә *қадау* «итекчеләрнең кечкенә агач кадагы». Аз. *гадаг* «кыны» (кылыч, пычак һ.б.ш. кадап куела торган нәрсә) кызыклы – төп мәгъ. бор. *қадағу* «беркеткеч, кадаткыч» булса кирәк, к. як. *хатаа*, монг. *хата-сун* «кадак, кадаткыч һ.б.», алт. *қадағы* «беркетмә; карар» һ.б. К. **Када-у**. Федотов II: 373.

Дерив.: **кадаклы, кадаксыз; кадакла-у.** Кайбер сөйләшләрдә **кадак** һәм **казык** контаминацияләнә.

**КАДАК II** «фунт (≈ 400 граммов)» – бизмәннең үлчәү таягына кагылган кечкенә *кадак*ларны күзаллап әйтелгән сүздән; бу сүз мар., удм., ш. ук Урта Азия һәм Уйгурстан телләрендә дә кулланыла, хәлбуки ул телләрдә *қадақ*ның «беркетү әйбере» мәгъ. юк (аның урынына бүтән сүзләр, мәс., *мих* килә). Ошбу факт *кадак* «фунт» сүзенең тат. теленнән таралганлыгын күрсәтә шикелле. К. **Када-у.**

**КАДА-У,** диал. **қаҙа-у** «колоть острием; приколоть» < гом. кыпч., уйг., чыгт., алт., тув. *қада-,* башк., хак. *қаҙа-,* угыз. *ғада-*, як. *хатаа-*, гом. монг. *хада-, хадха-* ~ гом. тунг. *қада-* id. һ.б. Радлов II: 306; Егоров 1964: 311; Räsänen 1969: 217–218; ССТМЯ I: 359–360 (бик тәфсилле).

Дерив.: **кадау; кадал-у, кадаш-у, кадат-у; кадагыч, кадама.** К. **Кадак I.**

**КАДАШ** иск., кит. (Максуди) «брат, дорогой родственник». Иске төрки әд. телләрдә очрый торган (к. ДТС: 399, 402, 404, 405, 420; КБтә бик еш) *qadaš, qaдaš, qaүadaš* id. бор. төрки *qa, qaүa* «аналык, яткылык» сүзеннән. Ягъни **кардәш** (к.) сүзеннән түгел (тамырдаш булуы да шикле). Хәз. телләрдән бу сүз добр. сөйләшләрендә очрый: *qada, qaday* «энекәш». Räsänen 1969: 214 (кор. *ка* «кардәш-кавем» сүзе белән баглый).

**КАДӘР [қәдәр]**, диал. **кадяр, хадяр, хәдәр** «столько, настолько; с, как; до (определённой, указанной) границы, степени» – диалекталь лексикада киң таралган **кадярлы, хадярлы** (Махмутова 1978: 223), **хәдәре, хәдәрем, хәдәрле, хәдәрлек, хәдәрлеге** (Садыкова 1985: 95; Юсупов 1976: 144), башк. диал. *хәҙәре, хәҙәрем, һәҙәрем* (Максютова: 109) формаларыннан морфологик эллипсис; бу сүзләрнең нигезе – гар. *қадӓр* «күләм, зурлык» (бәйлек түгел, исем), *қдр* «са́нча зур булу, масса, күләм» тамырыннан. К. **Кадәри, Микъдар, Тәкъдир.**

**Кадәрле → кадәр** күчеше элекке төрки телендә үк килеп чыккан, к. үзб. *қадарли* «кадәрле, кадәр». Будагов II: 41.

Дерив.: **кадәрге**, иск. **кадәренчә.**

**КАДӘРИ: кадәри халь** «по возможности» < фар. *қадӓри хāл'* id.

**КАДӘХ** иск. «рюмка, бокал» < гар. *қадӓх* id.

**КАДЕР [қәдер]** «почёт; достоинство» > чув. *катӗр*, удм. (Насибуллин: 118) *кадыр*, мар. (Исанбаев 1978: 13) *кадыр, кӓдр* id. < гар. *қадр* id. Будагов II: 41.

Дерив.: **кадерле, кадерсез;** диал. **кадерлек** (**кадерлелек** мәгъ. түгел); **кадерлә-ү; Кадер кичәсе** – гар. *Лӓйлӓт-ул-қадр* тәгъбиреннән калька – Рамазан аеның 27 нче төненә каршы бәйрәм (Коръән иңә башлаган төн).

**КАДИМ [қәдим]** иск. «старый (о времени), старинный» > мар. *кадем* id. < гар. *қāдим* «кадим, тәү-

ге, әүвәлге, беренчел» *қдм* «юлга чыгу, адым салу» тамырыннан, шуннан ук **тәкъдим**, иске әд. **мөкаддимә** «китапка кереш», **мөкаддәм** «элек, элегрәк».

Дерив.: **кадимче, кадимчелек; кадими.**

**КАЕЗ [қа$^{o}$йы̆з]** «обработанная для поделок кора липы, вяза, берёзы и т.п.», диал. (ДС I: 71, ТТДС I: 236) **қайыз, кайыс** «вяз», себ. (Тумашева 1992: 114) **қайас** «берестяная коробка» ~ башк. иск. (Троянский I: 128) *қайыз* «кабык; кайры», миш. (ЗДС: 268) **кайыз** «карама агачы», үзб. (ЎХШЛ: 154) *қайиз* «кайры» < бор. төрки (ДТС: 403–404) *qaδïz, qadïz* ~ чув. *хойыр* > *хуйыр* < болг. **қайыры* (?) ~ чаг. монг. *хайиласун, хайиласан* «карама».

Каез кадимге тормышта бик кулланышлы нәрсә булган, шунлыктан аның дериватлары да күп булырга тиеш, к. тат. диал., башк. диал. (ТТДС I: 188; БТДҺ: 179) **кайжы-у, кайжа-у** «әрчү» ~ үзб. (к. Абдуллаев: 149) *қайза-* «каезлау, кайрысын салдыру», бор. (ДТС: 403) *qadïzlan-* «кайрылану, кайры үсү», тат. диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) **қайызғақ** «кайрысы җиңел аерылучан», **кайызла-у** «кабыктан каез ясау; кыйнау, тукмау» (чаг. рус. *луб, луп* «каез», *лупить* «тукмау»). К. **Кайры.**

**КАЕК [қа$^{o}$йы̆қ]**, диал. (Тумашева 1992: 93) **кәйүк** «большая лодка» (чаг. мәкаль: *каек килсә кимә качар, катаргы килсә каек качар*), (ЗДС: 366) **қайақ** «лодка-долблёнка» < гом. кыпч. *қайық,* угыз. *ғайық* (> аз. *ғайығ*), як. *хайық, хайууқ, хойуқ* һ.б. < бор. төрки (ДТС: 407) *qajγïq, qajγuq* id.; чаг. бур. *хайба* «каек», бор. монг. (Поппе 1938: 437) *haiǯaγa* «кәрап» һ.б.

Күренгәнчә, *қайық* сүзе **қай-* тамырыннан, бу тамырны В.В. Радлов (II: 3–4) алт., төр. *қай-* «шуу» фигыле белән тәңгәлләштерә. Ш. ук к. бор. төрки (МК III: 382) *kadhık* «агачтан уелган нәрсә» ← *qaδ-,* (каз.) *қай-* «чапкалау, ботау». Ихтимал, *қай* тамыры *қайыз* сүзенең тамырына баглыдыр, к. эвенк. (ССТМЯ I: 362) *кајук* «туз кимә». Алт. *қайық* «ишкәк», *кайыкты кеме* «каеклы = ишкәкле кимә!». Будагов II: 33–34; ЭСТЯ V: 212.

Эскимос. *каяк* «каек, кимә» сүзенең төрки телләрдән алынган булуы шикле; монда очраклы охшашлык булса кирәк. Рус. *каюк* «каек» тур. Аникин: 278–279.

Дерив.: **каекчы** «каек белән елга аша кичерүче», **каекчылык.**

**КАЕМ [ка$^{o}$йы̆м]** диал. (ТТДС I: 188) «осуждение» ~ каз., кырг. *қайым* «чиратлашып, берсе артыннан берсе үләң әйтү» < гар. *қа'им* «бер-берсен алмаштырып тору тәртибе, чиратлашып дәвам итү», *қwм* «басып тору» тамырыннан, к. **Кыямәт.** К. ш. ук төркм. *ғайым* «үҗәт».

Дерив.: **кайымнаш-у** (БТДҺ: 180) «телләшү; сүзгә сүз иярү», **кайымцыл** (ЗДС: 367) «гаепләүчән».

**КАЕН I [қа$^{o}$йы̆н]** «берёза» < гом. кыпч. *қайын* (к.-калп., кырг., госм. *кайың*) < бор. төрки (ДТС: 404) *qaδïŋ, qadïn, qajïn, qazïn* ~ болг. **қарың* > чув. *хорӑн* > *хурӑн*, к. ш. ук бор. уйг., тув. *қадың*, шор. *казың* > бор. гар., фар. (Doerfer I: 5) *хадаң*, Ә. Ясәви телендә *хазан* (*Рәңгем мисле бәрқе-хазан яңлығ сулса*, к. Диване хикмәт, 1912: 197), төркм. *ғаайын,* аз. *ғайын*, як. *хатың* «каен». һ.б. Монг. *хус, хусун* «каен; кедр» белән чагыштырулар ышандырырлык түгел, чаг. ләкин калм. *xadıŋ* «туз». Чаг. **Каез.** Räsänen 1969: 218; Федотов II: 366. Бу сүз турында күп язылган.

Дерив.: **каенлы, каенсыз; каенлык;** к. **Каенсар.**

**КАЕН- II [ка$^{o}$йы̆н-, кайн-]** «родственник (-ца) жены или мужа; брачное родство (к. Рамазанова 1991: 101–102) < гом. кыпч., үзб., уйг., төр. *қайын-, қайн-*, аз., төркм. *ғайын-, ғāйн-* уйг., тув. *қадын,* хак., шор. *қазын* < бор. төрки (ДТС: 402, 404, 407, 439) *qājïn, qaδïn, qadïn, qazïn* ~ бор. монг. *qadum* > хәз. монг. *хадум, хадам*, тунг. *кадум* id. Номинханов 1958: 45; Räsänen 1969: 218; Покровская: 68–72; ССТМЯ I: 361; Doerfer II: 45.

Диал. (ЗДС: 379) **қайын** «биата, биага» < *қайын ата, қайын ағa* һ.б., чөнки тат. **қайын** үзе генә андый мәгънәгә ия түгел; миш. *кань* ~ чув. *хонь, хунь* < бор. төрки *кань* сүзе гом. төрки *қайын* сүзеннән булса кирәк (миш. диалектында *кайн* > *кань* гадәти фонетик закон, чаг. миш. *каняу* < *кайнау, катя* < *кайта* һ.б.) һәм чув. *хонь* миш. диалектыннан бор. заманнарда алынган, димәк миш. диалектының нигезе бик борынгы!), к. ш. ук мар. *онь-* «кайн-» (*оньо, оньы* «кайната», *оньыска* «кайнага», *оняка* «кайнигәч») – болг. **һонь* < бор. миш. *кань-* < *кайн-*. Федотов II: 358.

**Кайын** сүзенең этимологиясе катлаулы. Ихтимал, ул бор. төрки *qaŋ* «өлкән ата, патриарх» сүзеннәндер (монг. *qadum* < **qaŋdum* < төрки *qaŋıum?*) һәм миш. *кан'* турыдан-туры шуннандыр.

Удм. телендә *кайн-* мәгънәсендә (һәм тат. кушма сүзләреннән калька рәвешендә) *вар* «хезмәтче» сүзе килә; бәлки *қайн-* сүзе тув. *хаа* < бор. төрки *қа, *қай* > монг. *ха, хай* «хезмәтче» сүзеннән (туй термины буларак) киләдер.

**Кайын-, кайн-** морфемасыннан тат. телендә бик күп яңа сүзләр – нәсел-нәсәп терминнары ясалган: **кайнага, кайнана, кайната, кайнинә** һ.б. (йөзләп сүз, к. ЗДС: 376–379; 404–405). К. ш. ук **Кайны, Кайнә, Кайнигәч, Кайникә, Кайниш**.

**КАЕНСАР [қа$^{о}$йы̆нсар]** «березняк» < иске *кайынзар* id.: *-зар//-зәр* «урын, -лык» мәгънәсендә фар. теленнән алынган кушымча, к. ш. ук **имәнсар, усаксар.** Тат. теленнән тыш уйг. *қейинзар* id.

**КАЕР [қа$^{о}$йы̆р]** (Арсланов 1988: 80) «сырой речной песок», «твёрдая поверхность; кожура; твёрдая корочка» < гом. кыпч. (барча телләрдә), үзб. *қайыр*, чув. *хӑйӑр*, төр. *kayır, kair* «кырчынташ, каты өслекле комлык; төбе ташлы сайлык», як. (Пекарский: 3250) *хайыр* «тоташ ташлык» ~ монг. *хайир, хайр* «кырчынташ, елганың һ.б. вак ташлы, комлы төбе» < бор. монг. *xajir* «кайыр; вак таш», бур. *хайр кулуу* «каерташ»: к. ш. ук тув. *хайыр, хайырлығ* «тозлак, шүр», алт. (Баскаков 1966: 122; Баскаков 1972: 218) *кайыр* «елганың кызу аккан төше (гадәттә төбе ташлы булган сай урын)», башк. (БТДҺ: 181) *қайыр* «каер, көчле; кайнар, кызу холыклы» («кызу аккан елга» мәгънәсенннән метафора булса кирәк), төркм. (ТДТДС: 46) *ғайыр* «ташкыннан кала торган җир; комлык» һ.б. Ш. ук алт. *кайыр* «текә яр(лы)» сүзе дә гом. кыпч. *қайыр* белән гомоген булса кирәк.

**Каер** сүзен бер яктан **кайры** сүзе белән чагыштырырга мөмкин (кайбер кулланышларда *каер* «кайры»). Икенче яктан төр., бор. төрки һ.б. *қай, қайы* «яр, кырый, чит» сүзе белән дә чагыштырырга була. Төрле очракларда, әлбәттә, контаминация дә булырга тиеш. Федотов I: 319.

Дерив.: **каерлы, каерсыз** (мәс., икмәк тур.); **каерла-у** (диал. «каезлау, каерын кыру»), к. **Кайрак I, Кайра-у.**

**КАЕРАК [қа$^{о}$йы̆рақ]** «припека хлеба», «бубон, воспаление лимфатических узлов» – к. **Кайрак II**. Удм. *куярак* id. < тат. булса кирәк.

**КАЕР-У [қа$^{о}$й[қа$^{о}$йы̆р]р-]** «загибать; переворачивать, поддевать снизу» < гом. кыпч. *қайыр-, қайр-*, уйг. *қайир-, қайри-,* угыз. *қайыр-* (> аз. *ғайыр-*) < бор. төрки (ДТС: 404) *qaδïr-* «борып җибәрү, кире кагу» > тув. *қадыр-* шор., алт. диал. *қазыр-*, хак. *хазыр-* «бору, урау; кайшалдыру» һ.б., бор. төрки (ДТС: 406) *qaj-* < **qaδ-* «каеру; артка әйләнү» (> алт. *қай-* «артка әйләнү») сүзенең йөкл. юн., к. ш. ук **кайт-у** (к.), чаг. яз. монг. *qaǯi-ji* «бөгелү». Räsänen 1969: 219. Чув. *хир-, хайӑр-* < тат. булса кирәк, к. Федотов II: 305–306, 349.

Ихтимал, төп тамыр **qar-* дыр. Бор. төрки сүзлектә (ДТС: 403, 404, 407, 433, 438) бор. **qaδ-* нигезеннән ясалган *qadïr-, qaδïr-, qatar-* «бору, борылып китү, янтаю, янтайту, каерылу, артка китү» фигыле китерелә. Ягъни бүтән күп кенә мисалларда күренгәнчә

*qar-//qaδ-//* → *qaz-* / *qaj-* / *qad-* → *qat-* (*r ~ δ ~ d ~ z ~ j*)

тәңгәллекләре шәйләнә. К. ш. ук аз. *qanır-, qaŋır-* «каеру».

Дерив.: **каерыл-у** («әйләнү, борылу», «читләш-ү» мәгъ. дә бар), **каерыш-у, каерту; каергы** (рычаг; боргыч таягы), **каергыч; каерма** (читән төре). Чаг. **Кайкы, Кайт-у.**

**КАЕШ [қа$^{о}$йы̆ш]** «ремень» > чув. *кайӑш*, мар., удм. *кайыш* (күрше телләрдә бу сүз диалекталь сөйләмдә генә очрый) < гом. кыпч., гом. төрки (Радлов II: 44) *қайыш* (> нуг., каз., к.-калп., кар. *қайыс*), төркм. *ғайыш* < бор. төрки (ДТС: 404) *qaδïš, qadïš* > як. *хатыс* id., ш. ук хак. *хайыс, хаас,* тув. *қаас* id. *кай-* < *qaδ-* «каю» фигыленнән (**каеш** «каелган билбау, каюлы кушак»). Күп күрше телләргә кергән, к. лезг. *қайиш* «тукылган каеш».

Дерив.: **каешлы, каешсыз; каешлык; каешлан-у.**

**КАҖАР I, кацар** (себ., к. ЗДС: 401) «скуластый». Ихтимал, *каҗар* дигән төрки кавем атамасыннандыр. К. түбәндәгене.

**КАҖАР II** «каджар, воинственное туркменское племя, представители которой были шахиншахами Ирана в 1779–1925 гг.». Каҗарлар хәзер Төркия һәм Иранда яшиләр. З. Вәлиди (1981: 170–171) **каҗар** сүзе *агачäри, акацир* этнонимының гарәпләр һәм фарсылар үзгәрткән варианты түгелме икән, дигән сорауны куя. Кайбер белешмәлекләрдә **кажар** «качар» дип аңлатыла. Ләкин бу халык этимологиясе бугай. Кабиләнең исеме монгол кенәзе **Каҗар** (XIV г., төп мәгъ. «кыргый үгез төре») сүзеннән дигән фараз ышанычлырак. К. İA VI: 33–35.

**КАЗ,** себ. **кас** «гусь» < гом. кыпч., төр. һ.б. *қаз*, төркм. *ғааз, ғаз* (> үзб. *ғоз*), як. *хаас* һ.б. ~ чув. *хур* < *хор* < **қарғ* < *қаргу* id., к. маньч. *гару*, тунг.

(ССТМЯ I: 142–143) *гāрэ* «аккош», ш. ук «өке, ябалак», *гаса* «аккош, үрдәк һ.б.ш. су кошы», икенче яктан к. бор. монг. *γalaγun* ~ морд. *гала* «каз» (к. **Кәли**); тунг. һәм монг. сүзләре белән чагыштырулар өстәмә дәлилләргә мохтаҗ. Чаг. ш. ук себ. (Тумашева 1992: 113) *қаза-қаза, қаза* (> рус. диал. *каза-каза*) казларны куу яисә чакыру ымлыгы, рус. *казара, казарка* «кыр казы; казлар семьялыгыннан төрле кош атамалары» (төрки телләрдән). Räsänen 1969: 243; ЭСТЯ V: 184; Федотов II: 361; Аникин: 233–234 (арытабангы әдәбият китерелә).

**КАЗА** «убыток, ущерб, возмещение убытка; вред, возмещение вреда» < гар. *қаḍā* «бурыч; язмыш; бер казый карамагындагы участок» (к. Будагов II: 58), гомумән «суд алдында җавап бирү, суд карары нигезендә штраф h.б. түләү» сүзеннән, *қḍй* тамырыннан, шуннан ук к. **Казый.** Төрки телләрдә *каза* сүзе асылда **қазалық** «штрафлык» дигәннән эллипсис (элекке телебездә «каза» мәгъ. *казалык* диелгән дә). Хәз. яз. әд. телдә *каза* сүзен «афәт, авария» мәгъ. куллану күренгәли (стилистик җәһәттән бу дөрес түгел).

Дерив.: **казалы, казасыз; казалан-у. Казага калдыр-у** «вакытында башкармыйча, киләчәккә калдыру».

**КАЗАК [қа°зақ]** «казак (русский); казах», диал. **қазақ** «вдовый; холостой, холостая; одинокий, солдат» (ТТДС I: 186), «вид раскладки снопов» (ТТДС I: 225), **казак ат** «мерин» (ДС I: 71), **казак яту** «бездельничать» ~ добр. *qazaq* «румын», кр.-тат. *qazaq* «христиан», башк. *қазақ қоҙа* «ша́фер» (БҺҺ II: 127), чув. *хосах, хусах* «буйдак; тол», *хосах* «уенда – качучы», *хусах (хосах) лаша* «казак ат – алаша», *хусах йупа* «терәк багана» (к. Ашмарин XVI: 238–239; Федотов II: 369–370 h.б.), ш. ук чув. *касак* варианты да бар: *касак шывĕ* «янгын сүндерү өчен су», *касак яшки* «казак ләкшәсе» – өйрә (Сергеев 1968: 26); мар. *ажак, ожак* «буйдак» < болг. теленнән, *казак* «буйдак» < рус. яисә тат.; рус. *казак, козак* сүзенең мәгънәләре чиксез күп, иң билгелеләре: «украин гаскәрие, украин; татар армиясендә солдат; һәвәскәр солдат (доброволец), рыцарь, атчабар; качкын, сукбай, маҗара эзләүче; казак (украин теле элементлары булган халык); батрак; буйдак; каекларда яллы ишкәкче; хезмәтче, хадим» (Кочин: 138, к. ш. ук Мусина) h.б. Казан губернасы тарихчысы И.А. Износков (к. аныкы: Материалы для истории христианского просвещения инородцев Казанского края. М., 1895: 15) буенча, *казак* дип лашманнарны атаганнар һәм хәзерге **казаклар** дип аталган авылларны лашманнар нигезләгән. К. ш. ук Аникин: 232–233.

Бүтән халыкларда: үзб. *қазақ*, нуг., к.-балк., ком., кр.-тат. *қазақ* «барымтага йөрүче, юлбасар», чыгт. (Будагов II: 54) «сукбай» ~ фар. *қазақ* «хөкүмәткә буйсынмаган кавем» h.б. **Казак** сүзенең этимологиясенә багышланган хезмәтләрнең санына чыгу кыен. Татарлар һәм башкортлар төрки казак халкын *кыр казагы* яки *кыргыз казагы* дип атаганнар (Хисамова 1981: 183), ягъни *казак* – «атлы солдат» сүзеннән чыгарылган. Егоров (1964) һәм аннан күрмәкче Р. Батулла (к. «Мәдәни җомга» 2001, № 28: 9) да *казак*ны *качак* сүзеннән чыгара, ләкин бу фонетик закончалыкларга туры килми.

Казаклар үзләре бу этнонимның этимологиясенә багышланган бөтен бер калын том нәшер иттеләр (Қазақтар, т. IV. 1994). *Қазақ* сүзенең этимологиясе белән күптән шөгыльләнүче А. Абдырахманов *казақ* < *каз оқ* «каз кабиләсе» дип барса, казакларның күпчелек телчеләре үзләрен бор. *сак* халкы атамасы белән бәйлиләр (*каз сак,* имеш), моңа дәлил итеп иске рус. *кайсак* «казах» сүзен китерәләр. Ләкин бу атама калмык теленнән килә (калм. телендә *з* авазы *йс*ка алмаштырыла: *з* > *йс*). Әлеге китап авторларының (алар илле кеше) күбесе әлеге *качак* вариантын кабатлый h.б.

Без исә *казак* сүзенең этимологияләренең иң дөресе нимес тюркологы Аннамари фон Габенныкы дип карыйбыз: *казак* < *казақ* < *казгак* «кышын кар казып үлән ашап йөри торган ат» (к. аныкы Kazakentum, eine soziologisch-philologische Studie // Acta Orientalia, t. XI, f. 1–3, Budapest 1960), моңа өстәмә дәлил итеп төркм. (ТДГДС: 45) *ғазақый* «төрекмән токымлы сарык», үзб. диал. (Буронов: 20) *қазақы* «кыргый ат», себ. **қасғақ** «ерак юлга китүче» (к. Тумашева 1992: 122), ягъни «казаклыкка, кәсепкә китүче», кр.-тат. *қазақташ* «сәфәрдәш» сүзләрен китерергә мөмкин. К. Ахметьянов 1989: 164–166. К. **Казан-у, Кәзәки.**

**КАЗАМАТ**, диал. **кызамат** «тюрьма» ~ удм., мар. *казамат, кызамат* (к. Саваткова: 68) id. < рус. *казамат* < фр. *casemate* «кара өй» (*case* «өй», *mate* «кара») ~ «хәрби төрмә» сүзеннән. Чаг. **Казарма**.

**КАЗАН I [қа°зан]**, себ. (Тумашева 1992: 122) **қасан** «котёл, казан» > мар., удм., рус. *казан* < гом. төрки (Радлов II: 367) *қазан,* аз., төркм. *ғазан* h.б. < бор. төрки (к. Räsänen 1969: 243; Поппе 1938: 444) *qazγan* ~ болг. **қарган* > чув. *хоран* > *хуран*

«казан»; *казган* варианты тат. (ДС I: 32) **казган** *бүрек* «колакчынсыз бүрек» сүзендә, аннары лезг. (к. Хайдаков: 85) *кажған* сүзендә һ.б. сакланып килә; *хархан* варианты гаг. телендә һ.б. саклана. Гомумән, бу сүз төрки телләрдән күп күрше телләргә кергән (рус. *казан* тур. к. Аникин: 234). *Казан* сүзенең бор. мәгънәләре тур. Будагов II: 14.

*Казан* < *казган* < **қаарған* сүзен Г. Рамстедттан (Рамстедт: 135) башлап *каз-у* сүзеннән дип баралар, к. Räsänen 1969: 243; ЭСТЯ V: 187 һ.б.; Федотов (II: 365) Х. Әрәннең төр. диал. *harani* «казан» < фар. *харани* сүзенең *қазан* сүзенә катнашы юк дигән фикерен куәтли; ләкин безнеңчә, фар. сүзе үзе бер төрки телдән булырга мөмкин.

*Казан* сүзенең *каз-у* фигыленнән икәнлеген дәлилләү өчен яз. монг. *qarum* «казан» сүзенең ясалышын аңлатырга кирәк: чаг. ш. ук (ССТМЯ I: 463) яз. монг. *xaranγa* «гонг (казансыман чаң)».

Дерив.: **казанлы, казансыз; казанлык** (топонимик аппеллятив); **казанчык.** Рус. *казённая часть (ружья)* дигәндә *казённый* сүзе *казна* сүзеннән түгел, бор. төрки *казан* «пушка» сүзеннән, к. Будагов II: 14. **Казан асу** гом. төрки тәгъбир, к. Мухамедова 1973: 111.

**КАЗАН II [қаᵒзан]** «город Казань; река Казанка» > чув. *Хосан* > *Хусан [Хозан* > *Хузан]* ~ мар. *Ажаң, Озаң* (*Озаң ола* «Казан каласы»). Барча мөселман төркиләр *Казан* дип әйтәләр, тик Себер төркиләре бу яңгырашны белеп бетермиләр. Татар риваятьләрендә Казансу елгасына бер хатын казанын төшереп җибәргән дә, «казаным», дип кычкырган, шуннан елгага да исем кушылган, ди. Гомумән, И. Барбаро заманнарыннан бирле (XV г., к. Барбаро и Контарини: 158) Казан шәһәре *казан* сүзеннән чыгып аңлатыла. Ләкин бу топонимның кайбер мар. вариантлары бүтәнчә уйланырга мәҗбүр итә, к. Фасмер II: 159.

Чув. *Хосан* > *Хусан* әллә ни проблема тудырмый. Бу вариант һичшиксез тат. *Қаᵒзан* яңгырашыннан: дистәләрчә сүзләрдә гом. төрки *қа-* > тат. *қаᵒ-* > чув. *хо-* > *ху-*, к. *қаᵒла* > *хула* «шәһәр», *қаᵒра* > *хура* «кара төс», *қаᵒт* > *хут* «ян, каршы, хозур» һ.б.ш. Чув. *х-* мар. телендә йомшартылып бөтенләй төшеп калучан: чув. *хола* > мар. *ола* «кала, шәһәр» һ.б. Ләкин мар. *Озаң* «Казан (шәһәре)» дигәндә азактагы *-ң* каян килгән? Шуны күреп һәм XVI–XVII г. рус административ документларында Казан тирәсендәге авылларда башлыча «чувашлар» яшәгәнлеге күрсәтелүдән чыгып, кайбер тикшеренүчеләр Казан топонимы үзе дә чув. телендә пәйда булган дигән фикергә киләләр. Бу фикерне тәүдә мәшһүр фин галиме Һ. Паасонен (FUF 6: 111) әйткән бугай. Чув. һәм кайбер рус галимнәре моны күтәреп алалар. Чув. этимологлары В.Г. Егоров һәм М.Р. Федотов (II: 369) тат. *Казан* < чув. *Хазаң* дип раслыйлар. Бу фаразны бигрәк тә рус тюркологы И. Г. Добродомов каткат бәян итеп факт дәрәҗәсенә күтәрмәкче, к. аның «Типы поселений» (к. Природное окружение... М., 2008: 209–213) мәкаләсен һ.б.

Объектив-тыныч уйлаганда, китерелгән мар. вариантлары тик шуны гына күрсәтә: *Казан* топонимы *казан* «чуен савыт» сүзеннән түгел бугай, һәм беренчел вариантта азакта *-ң* авазы булган. Бу фикер дә әле йөз процетка ышандырырлык түгел: кайбер Себер төркиләрендә гом. төрки *-н* һәрвакыт *-ң* белән алмаштырыла. Әмма ул төркиләр ерак, тарихта зур роль уйнамаган, артык шикләнмичә аларны калдырып торыйк.

XVI г. һәм элегрәк тә Казан тирәсендә гел чувашлар яшәгән һәм шунлыктан *Казан* топонимының чыгышын чув. теленнән эзләргә кирәк дигән фикер ышандырырлык түгел. Бернчедән, Казанны тәгаен татар идарәчеләре – биләре, ханнары нигезләгән, анда хөкем йөрткән чуваш идарәче тур. бернинди хәбәр дә юк. Икенчедән, Казан тирәсендә яшәгән әлеге «чувашлар» этник чуваш булдымы икән әле – аларның исемнәре һәм яшәгән авыллар исемнәре дә гел татарча дияргә мөмкин. **Чуваш** дип (к. **Чуваш** матдәсен) еш кына мариларны һәм татарларны да атаганнар. Аннары, нәрсәне белдергән соң ул гипотетик **хазаң* сүзе? Бу хакта берни дә әйтеп, хәтта гипотеза корып та булмый. Безнеңчә, мар. *Аджаң, Озаң* – беренчесе турыдантуры татарчадан, икенчесе чув. диалекты аркылы – бор. тат. **қазанғы* «сазламык» сүзеннән килә ала: бор. төрки (МК) *qazanγu* «сазлыклы җир» бар; бор. тат. *қазаңғы* «казанган, казанылган, яулап алынган» сүзе булуы ихтимал.

ДТСта (: 438) *jір qazanγu* «җеп чуалган» дип аңлатыла һәм бүтәнчә күрелмәгән *qazanγu* «чуалган» сүзе бар булып чыга. Төрекләр МК сүзлегенең үз тәрҗемәләрендә бу урында *jар qazanγu* «җап – сугару каналы чуалган, казынтылы» дип аңлаталар. Казанның өч Кабан күле сугарулы җирләрдә очрый торган ташландык канал сазламыкларына бик охшаш булган.

Фонетик җәһәттән чув. *х-* авазының тат. *қ-* булып әверелүе гомумән мөмкин булса да, мотлака шулай булырга тиеш дигән сүз түгел. Тат. теленең үзендә дә *х-* күптәннән бирле кулланыла, мәс., *хан,*

*хатын, хуҗа* һ.б. Һәм *х* > *ķ* күренеше берничә сүздә генә, Себердә һ.б. Казаннан ерак төбәкләрдә генә очрый. Татарлар гомумән чув. теленнән сүзләр алмыйлар.

Рус топонимик әдәбиятында Казан сүзен **Хәсән хан** исеменнән дип аңлату да бар (к. Добродомов И.Г., Кучкин В.А. Этимология и старые географические объекты // Топонимика на службе географии. М., 1979: 157–163; Егоров В.Л. О времени возникновения Казани // Советская археология. 1975, № 4: 80–87), ләкин фонетик закончалыклар җәһәтеннән бу гипотеза акланмый: татарлар *Хәсән*не **Хасан** дип әйтмиләр һәм әйтмәгәннәр. Казанны Хәсән хан нигезләве һ.б. хакында тарихи мәгълүматлар юк.

Казан шәһәре һәм мифик Казан батыр, Казан хан тур. Идел-Урал регионында күп кенә легендалар бар. Ләкин алар икенчел булса кирәк. Кавказда, Төркиядә һ.б. татарларны *казан, казанлы* дип атау бар.

*Димә миңа угыз, кайы, госманлы.*
*Түркем – бу ат һәр гонваннан өстендер.*
*Юктыр үзбәк, нугай, кыргыз, казанлы,*
*Түрк милләте бер бүленмәз бөтендер.*
З. Гёкалп.

Рус. *казан* һәм *Казань* тур. Даль; Аникин: 234.

**КАЗАН-У** «приобретать, заслужить, заслуживать» < кр.-тат., госм. *ķазан-,* аз. *газан-* «казану» ~ як. *хасаан-* «үзенә җыю» < як. диал. *ķасаан-* > эвен. *каҗаң-* «азык табу; карны казып, мүк ашау (боланнар тур.), тибендә йөрү» (ССТМЯ I: 385) < бор. төрки *qazγan-* «тырышып эшләү, тырышып табу» (к. ДТС: 439; Поппе 1938: 209) – *казы-у* сүзеннән. К. **Казак, Казан, Казган-у, Казна, Казы-у.**

Дерив.: **казаныш.**

**КАЗАРМÁ** «казарма» < рус. < ит. *cazerma* «хәрби йорт», к. Фасмер II: 159.

**КАЗАХ** «казах» < рус. Татарлар төрки казак халкын *казах* дип атамаганнар. Хәзер аларны рус. *казак* сүзеннән аеру өчен шулай языла.

**КАЗАЯК,** диал. (ТТДС I: 591) **казыяк** «гусиная лапка (растение)» – гадәттә, *каз аяк, каз аягы* сүзеннән дип аңлатыла, ләкин **казыййаķ** варианты бу аңлатмага шик төшерә; **казайак** варианты русча атамасы тәэсирендә ясалган бозылыш түгелме икән? Башк. сөйләшләрендә *ķазғыйаķ* (< *ķаз кыйаķ*) «казаяк, каз үләне».

**КАЗГАН-У** миш., **ķазғану** себ. (ЗДС: 267, 376) «добиваться, стараться», «приобретать; заслужить, добыть» ~ гом. кыпч. (куман телендә үк бар), бор. төрки, уйг. һ.б. *ķазган-, qazγan-* id., күрәсең, бор. **ķазға-* яки **ķазғы-, *ķазығ* нигезеннән, ләкин бу фигыльнең үзе дә, бүтән юнәлешләре дә сакланмаган. Гомумән, әлбәттә, күп дериватлы *qaz-* < **qarγ-* тамырыннан. Әд. **казан-у** (к.) угыз телләреннән (аларда *-г-* төшеп калучан). Будагов II: 14; Räsänen 1969: 243.

**Казган-у** элекке әд. телдә ешрак кулланылган. Бу сүзнең **казан-у**дан беркадәр мәгънәви һәм стилистик аермасы бар.

Дерив.: **казганчык** «тырыш, иҗтиһатлы; максатчан», **казгалан-у** (ЗДС: 376) ← **казга* (сүзеннәнме?).

**КАЗНА,** (ЗДС: 376) **ķазнаķ, ķазнау** «казна; основание; доска, которая прикрывает зияющее отверстие» (*мич казнасы* «бревенчатое основание печи», *сәке казнасы* «доска, прикрывающая поднары»); диал. «ларь» ~ башк. *ķазна* «основание печи», *ķызана* «сруб под печкой» ~ чув. *хысна* «казна; налог» < бор. төрки (ДТС: 439–450) *qaznaq, qïznaq* «казна»; *а ~ ы* тәңгәллеге бу сүзнең бик борынгылыгын дәлилли һәм Doerfer (3: 472–474) фар. *qaznaq* «чолан» сүзен төрки телләрдән дип бик хаклы рәвештә күрсәтә; бу сүз бор. төрки мөлкәт кую (яшерү) өчен казылган һәм бура белән ныгытылган чокырны белдергән. **Казна** сүзен гар. *хәзинә* сүзеннән дип бару (киң таралган версия) дөреслеккә орына гына: гарәп сүзенең контаминацион тәэсире генә булган. К. ш. ук кырг., уйг. *казынак, казанак, казнак* «казна; келәт; ләхет», тув. *казанак* «көпкә (зимләнке), өй кәмәше; эт оясы – куңгыра», төр. *kasnak* «кыса; көрәшченең бик киң бил каешы; чигү тамбуры», төркм. (ТДГДС: 45) *газна* «кимәдә аркылы такта», аз. *газнаг* «баз, казылган чокыр» һ.б.

Удм. *казна* «казна» тат. һәм рус телләреннән, мар. кч. *гäзна, гозна* тат. сөйләшләреннән булса кирәк. Рус *казнá* куман теленнән кергән дип исәпләнә (Аникин: 235, бай әдәбият күрсәтелә). К. **Кәҗүнни, Кәзәнкә.**

Дерив.: **казначы; казналык** (*теш казналыгы*).

**КАЗЫ, казылык**, диал. (Хайрутдинова 1993: 106–107) **каз, ʻазо, ʻазу** «конская колбаса»; диал. (ДС III: 70) «грудинка» > чув. *хас,* мар. *каж,* удм. *каз* «өйдә эшләнгән колбаса» < гом. төрки, бор. төрки *ķазы* «эч мае» (к. ДТС: 439), чаг. бур. *харма*

«казы», бор. монг. *qarbiŋ* ~ *xar-biŋ* «корсак мае» ~ эвенк., маньч. *калбиң, калбин* (ССТМЯ I: 365). К. ш. ук як. *хаса, хасаа* (Пекарский: 3373) «корсак мае» һ.б. К. **Карта, Карын, Касык.**

Рус. *азу* «итле бәрәңге» Касыйм татарлары телендәге *ʻазу* < **казығ* сүзеннән.

**КАЗЫЙ** «судья (в духовном управлении, в медресе)», иск. «кади, судья (вообще)» < гар. *ķāḑī* id., *каза* сүзе белән тамырдаш. Будагов I: 17; Тимергалин: 219.

**Казый** сүзе фольклорда – әкиятләрдә, мәзәкләрдә киң кулланылган. *Казыйә* «хатын казый» сүзе дә бар.

**КАЗЫК** «кол; столбик» ~ гом. кыпч., уйг., госм. (Радлов II: 374 һ.б.) *ķазыķ,* урта төрки *ķазуķ* < уйг., бор. төрки (ДТС: 439) *qazγuq, qazuŋuq* > уйг. диал. *козуķ, кузук* «казык; чөй» ~ алт. *ķастык* id. һичшиксез *казы-у* < **карғ-* сүзеннән, к. чув. *хусăк* «тар көрәк», тув. *казынчы* «җир казучы» ~ монг. диал. *харху*, венг. *karo* «казык». Будагов II: 14; Räsänen 1969: 243.

Рус. диал. *каз, казык, козык* «балыкчылар куллана торган казык» тур. к. Аникин: 235. К. түбәндәгене.

**КАЗЫ-У,** диал. **кас-у** «копать» < гом. төрки, бор. төрки *каз-, казы-*, төркм. *ғазы-*, як. *хасый-, хаһый-, харый-* «казу» < бор. гом. төрки **карғ-*, к. иске монг. *qaru-* «казу» һ.б. Семантик характеры буенча бу сүз бик бор. Төр. *kaz-, kazı-* «ермачлау, чыю» һ.б. тик «казу» түгел. Федотов II: 368 (әдәбият шунда). К. **Казак, Казан, Казан-у, Казна, Казык, Каргын.**

Дерив.: **казыл-у, казын-у** («эзләнү, компромат эзләү» мәгъ. дә кулланыла), **казыш-у, казыт-у; казыгыч, казма** (көрәк төре), **казынты** (бу сүзләр гом. кыпч. характерга ия).

**КАЙ I** (үзе генә кулланылмый диярлек), диал. (Тумашева 1992: 246, **чәлән** матдәсендә) **кәү** < *кәң,* иск. **қайу** «какой, где; что за» – основа вопросительных местоимений к. **кайсы** «который (из)», **кайчан** «когда», **кая < кайга** «куда», **кайда** «где», **каян < кайдан** «откуда» – < гом. кыпч., алт. *ķай* < бор. төрки (ДТС: 408–410, 419) *qaju* «кайсы, нинди» < *qanju* id. **qaŋ* тамырыннан, бу тамыр исә ностратик характерда булса кирәк, к. мар., удм. *ку, кү* «кай», монг. *хаа* < *qaa* «кайда, кая», тунг. *xajja* «нәрсә» (һ.б., к. ССТМЯ I: 4–5, 14–15, 32) ~ бор. ир. *каδ, kai* «кай, кайчан», һинд-ир. *кии* «кайда» ~ һинд-евр. **kwi, kwo* «нәрсә, кем һ.б.» (күп телләрдә охшаш сүзләр табалар). Шул ук вакытта төрки-монг.-тунг. тамырының һинд-евр. һ.б. охшаш тамырлар белән гомоген булмавы да ихтимал. Будагов II: 30–31; Рясянен 1955: 19; Фасмер II: 274, 393 (*когда, кто* сүзләре тур.); Kluge: 989.

**Кай//кан** тамырыннан һәрбер төрки телдә бик күп сүзләр – башлыча алмашлыклар ясалган, к. **Кайре, Калай II, Кандай, Кани, Кач,** к. ш. ук **Кем.**

**Кай** диалекталь лексикада (ТТДС I: 187) кушма сүзләр ясалуда катнаша: **кайкем** «кайбер кешеләр», **кайкөн**, **кайкен** «шушы арада, бу арада», **кайки** «кая (каян, кайда) да булса» һ.б.

**КАЙ II** (ДС I: 72; Тумашева 1992: 114) «первый снег; снег в середине или конце мая; ненастье, первый снег или дождь после смерти кого-либо (видимо, особо отмечалось)» ~ төр., госм. (Будагов II: 30) *ķай* «көчле җил, хәтәр давыл; язмыш», каз. (ҚТДС: 182) *ķай,* төркм. *ғай* «диңгез давылы, җил-давыл, һава бозылу» < бор. төрки (ДТС: 404) *qaδ* «җил-буран, каршы яңгыр» (*qaδ-* «буранда һәлак булу») **кар** сүзе белән бердәй булуы ихтимал. Сүзнең фигыль коррелянты себ. (ЗДС: 318) **кай-** «болытлау». Чаг. ш. ук **Кай IV, Кайгы, Кайна-у, Касарткы.**

**КАЙ III** (к. Радлов I: 327) «особый горловый голос (которым исполняли эпос, в частности «Кузый Күрпәч»), горловое пение, шаманское чревовещание»; у сибирских татар – «отпевание покойника» ~ алт., сары уйг. *ķай* «өшкерү; шаман рухы», хак. *хай* «кай; сызгырулы тавыш» һ.б.; иске тат. сөйләшләреннән бу сүз күрше телләргә дә алынган: чув. *хай* «хикәя, әкият», мар. *хой* > *ой* «сөйләү; хикәя, әкият» (к. Räsänen 1969: 221); башкортларда *ķай* әле XX г. башларында да очраган (к. Либединский Л. Башкирские народные песни и наигрыши. М., 1962: 147–149). Хәз. көндә *кай* (*каккы* да диелә) Тувада билгеле һәм ул биш төргә бүленә: *хөөмей, сыгыт, каргыраа, эзэңгилээр* һәм *баºрбаºңнаар* (к. Унгвицкая, Майногашева: 41–55; Чернов Б.П. Феномен тувинского двухголосия // Природа, № 6, 1978: 48–49; аныкы ук, О физиологии механизма тувинского и хакасского горлового пения // Проблема хакасского фольклора. Абакан, 1982: 87–93; Будегечиева Т.Б. Горловое пение в системе художественной культуры тувинцев // Проблема истории Тувы. Кызыл, 1984: 199–206). *Кай*

һөнәре монгол халыкларында һәм Тибетта да билгеле. Сүзнең чыгышы юраулы.

Дерив.: себ. тат. (Будагов II: 34; Тумашева 1992: 114) **кайла-у** «сүзсез көйләү, мыгырдану» ~ кырг. *кайлоо* «кай белән әкият сөйләү» ~ чув. *хайлав*, мар. *хойло* > *ойло* «әкият» (*ойлымаш* «легенда, сөйләк»); иске башк. (русча «Кузы-Курпяч»та, татарчадан) **қайчы** («саф башкортча» *қайсы* булыр иде) «кайлый белүче» ~ хак. *хайҗы* «акын». Рясянен буенча, «сихер догасы» мәгъ. *кай* рус. диал., коми диал., хантыйларга да кергән. Чаг. **Өз, Өзлә-ү.**

**КАЙ IV** – название страны в фольклоре; **Заятүләк** эпосында – Госманлы империясе. Гомумән, башк. *қай,* төр. *кай, кайы* һ.б. – күп тарихи чыганаклардан билгеле бер угыз кабиләсе. Атама үзе бор. төрки **кау** «аждаһа; яшенле яңгыр» сүзе белән баглы булса кирәк. Башкортларның кайлы ырулары бар, аларның *йылан* кабиләсе әлеге *кайлар* белән кардәш булуы ихтимал. Кайлар тур. З. Вәлиди күп язган. (к. Velidi: 162, 175, 321–324). Аның фаразынча, тувалар һәм якутлар составында булган *урянхай – үрәңкай* этнонимы монг. *үрэнкай* «ак кай» сүзеннән һәм *каракай* кабиләсе дә бар. *Кыят* дигән атаклы төрки кабиләсе дә монг. *кайут* «кайлар» дигәннән.

***КАЙ V** «обратная сторона; возвратиться, идти назад»; «поскользнуться» – күп сүзләрдән беленә: *кайкан, кайкы, кайра, кайму* (к. *каймыгу*), *кайыр-у* (к. *каер-у*), *кайыш-у* (к. *каеш-у*), *кайшал-у, кайпы-у* (к. *кайпыл-у*) һ.б. Тамыр сүз буларак к. алт., уйг. (Радлов II: 4–4) *кай-,* төр. *kay-* «шуу, таудан шуып төшү», төр. *kayıt-* «каймыктыру», алт. *кайкала-* «өслектән шуып бару», кырг. *кайкала-* «артка бөгелү, чалкаю» һ.б. К. ш. ук **Кайпан, Кайт-у, Кайтар-у**.

**КАЙГАНАК, қайғана, кайғынак** (ЗДС: 267, 376**)**, себ. (ЗДС: 285) **кәйгенә,** (к. Хайрутдинова 1993: 112) **хәйгәнә, 'әйнә'** «яичница на сковороде» ~ нуг. *қайқана*, кр.-тат. *qayγapa,* төр. *kaygana* id. ← *kaygan, kaygın* «шома; сыек; шуып йөрүчән, җәелүчән» ← *kay-* «шуу, таю; җәелеп китү». К. **Каймык-у.** Бор. төрки *qaj-* «шуу, шуып бару» күп сүзләр биргән тамыр.

**КАЙГА-У** «удивляться», к. себ. (Тумашева 1992: 114) *қайгандзы* < *қайганчық* «могҗиза», *қайган-у* «гаҗәпләнү», *қайғат-у* «гаҗәпләндерү» ~ кырг., алт. *қайқа-* «гаҗәпләнү», тув. *қайға-*, хак. *хайха-,* монг. *гайха-* «гаҗәпләнеп тору; текәләп карау» ← *хай-* «дикъкать итү» < **қаӡ-*, к. госм. (Радлов II: 277) *қат қалмақ* «хәйран калмак»; к. ш. ук алт. (Радлов II: 6–9) *қаіққы* «гаҗәпләнү». Фонетик һәм морфологик җәһәтләрдән караганда **кайгы** сүзенә бик тәңгәл, әмма мәгънәсе гаҗәбрәк.

**КАЙГЫ** «горе, печаль; забота; проблема» > удм. диал. (Насибуллин: 118) *кайгъ*, мар. кч. *кайгы, койге*, удм. *куйкы* id., ш. ук вакытта, чув. *хуйӑх* < *хойӑх, хуйхы* < *хойхӑ* < болг. **һа$^{о}$йғы* > мар. *ойхо, ойго, ойхы* «кайгы» ~ гом. кыпч., госм., чыгт. *қайғы,* иске тат., тат. диал. (брб., к. Радлов II: 10), уйг. *қайғу, қазғу* < бор. төрки *qadγu, qaδγu* > *qajγu* (к. ДТС: 402–407), иске уйг. (Радлов II: 95) *қатқу* id. һ.б. *қай-* (хак. *хай-*) < *қаӡ-* < *-қар-* «кызгану, карау-багу; хәстәрләү» фигыленнән *-кы* кушымчасы ялганып ясалган. Бу гипотетик фигыльнең рефлексын М. Рясянен (Räsänen 1969: 217) чув. *хор-* > *хур-* «камыр һ.б. изү» фигылендә күрә, чөнки, имеш, фин телендә «(камыр) изү > кайгыру» мәгъ. күчеше бар. Чаг. ш. ук монг. *гай* < *қай* «бәла-каза».

Безнең фаразыбызча, бор. **қар-* < **кайр-*, к. маньч. (ССТМЯ I: 362) *хаjра-* «кызгану» (шуннан *хаjран* ~ монг. *хайран, кайран,* алт., тув. *қайракан, қайран* > себ. **қайран** «кызганыч; гаҗәп; рәхим-шәфкать») ← бор. кыт. **хай, *һай* «кызгану, җәлләү». К. **Кайгырт-у, Кайгыр-у, Кайран.** Будагов II: 33; Федотов II: 352–353.

Дерив.: **кайгылы, кайгысыз.**

**КАЙГЫРТ-У I** «заставить горевать, ввести в горе-печаль» (к. **Кайгы**) ← **кайгыр-у** «горевать». Бу сүзне түбәндәге сүздән аеру тиешле.

**КАЙГЫРТ-У II** «проявлять заботу, печься о чём-либо» (вряд ли от «заставить горевать»). К. себ. тат. (Будагов II: 411) **кыйгарт-у** «тәртипкә китерү» ← **кыйгар-у** «тәртипкә килү». Чаг. себ. (Будагов, шунда ук) **кыйга** «акыллы» < фар. *хуйаяһ* «акылга килү, тәртиплелек һ.б.»

Дерив.: **кайгыртучы; кайгыртучан;** сирәк кенә юн. формалары да кулланыла: **кайгырттыру** һ.б.

**КАЙГЫР-У** «горевать, печалиться о чём» ← *қайгы-р-* булса кирәк (чаг. *иске* → *искер-ү*) < гом. кыпч. *қайғыр-*, чыгт., уйг. һ.б. *қайғур-* id. К. ш. ук бор. төрки *qadγur-, qaδγur-*, бор. уйг. *қаткур-* «кайгыру». К. ш. ук төркм. (ТДГДС: 45) *ғайғыр-мақ* «кызгану, җәлләү» һ.б.

Бу сүз Идел-Урал төбәге телләрендә киң таралган: чув. *хойхăр-* > *хуйхăр-*, мар., удм. *кайгыр-, кайгър-*, мар. (болг. теленнән) *ойхыр-, ойгыр-* id. К. **Кайгы, Кайгырт-у.**

Дерив.: **кайгырыл-у, кайгырын-у, кайгырыш-у, кайгырт-у.**

**КАЙКА, кайкы** (диал., БТДҺ: 179) «откинутый назад», «гордо выпятивший грудь» ~ нуг., каз., к.-калп., кырг. *кайкы* «эчкә бөгелгән; ике тау арасындагы сай иңкүлек» ← ***кай-**, чаг. **каер-у**, **кайшал-у**. К. **Кай V**.

**Кайкы** продуктив нигез: **кайкай-у** «киерелү, аркага каерылу», башк. һ.б. *кайкаң* «көяз кыланучан», *кайкаңла-у* «боргалану, кыланчык хәрәкәтләр ясау».

**КАЙЛӘН-Ү, кайеллән-ү** (ТТДС I: 223) «лениться» < **каһиллән-ү** id. К. **Каллән, Каһил.**

**КАЙМА** «кайма, бордюр» < *кайыма* «каелган шәй» ← *кайы-*, к. **Кайы-у**. Бу сүз рус теле аша күп телләргә таралган. Фасмер II: 162 (төр. теленнән дип күрсәтә, ләкин ни өчен нәкъ менә төрекчәдән? **Кайма** сүзе барча кыпч. телләрендә дә очрый). К. **Каеш, Кайы-у.** Федотов II: 305.

**Кайма** белән беррәттән **кайым** сүзе дә очрый (якынча шул ук мәгъ.).

Дерив.: **каймалы, каймасыз; каймала-у, каймалан-у, каймалат-у.** Рус сөйләшләрендә (Аникин: 237) ~ хант. *кайым, хайым* «тотылган киекләрне асрау һәм симертү өчен киртәләнгән урын» сүзе очрый. Бик ихтимал, бу сүз тат. теленнән (аның бор. мәгънәсеннән) алынгандыр.

**КАЙМАК** «каймак, сметана» < гом. кыпч., алт., уйг., төр., төркм. һ.б. *қаймақ,* аз. *гаймаг* id., як. (Пекарский: 3440) *хоймох* «касмак, кайнаган сөтнең төпкә утырган өлеше» ~ монг. *хайлмаг* «каймак», бор. төрки (ДТС: 406) *qajaq, qaŋaq, qïjaq* id. **кайна-у** сүзе белән гомоген. Чаг. ш. ук тув. *хойтпақ* «катыкның бер төре». Чув. *хăйма* «каймак» болг. теленнән.

**Каймак** сүзе төрки телләрдән күп күрше (фин-угор., фар.-таҗ., Кавказ, Балкан) телләренә кергән һәм кайчакта үзәнчәлекле мәгъ. алган, мәс., морд. Э. *каймак* «пәрәмәч» ~ рус. *каймашка* id. К Аникин: 237; ЭСТЯ V: 200; Федотов II: 319–200.

Дерив.: **каймаклы, каймаксыз; каймаклан-у.**

**КАЙМЫК-У (каймыкты, каймыгу)** «вывихнуться (о суставах)» < гом. кыпч., к. нуг. *қаймық* id., к.-калп. *қаймық-* «тайчану, читкә китү; куркыну», каз. *қаймық-* «яскану, сискәнү, куркыну», уйг. *қаймақ-, қаймуқ-* «баш әйләнү», чаг. як. *хайбай-* «бераз читкәрәк китү, янтая төшү». Формасы буенча **кайым-* фигыленең интенсивлык дәрәҗәсе, к. төр. *kay-* «шуышу; кыегаю». Гомумән ачык түгел. Чаг. **Кайшыл-у, Кай V.**

Дерив.: **каймыктыр-у.**

**КАЙНА-У** «кипеть» < гом. төрки, бор. төрки *қайна-*, уйг., чыгт. *қатқа-* < бор. төрки (ДТС: 403, 408) *qadna-, qajïn-* id. > тув. *хайын-* id. бор. **қай-* < *каδ-* тамырыннан *(*қайын-* шуның кайт. формасы, *қайын* < *қайғын* «кайнаган», шуннан *кайн-а-* булса кирәк). Räsänen 1969: 222. К. **Кай II.**

**КАЙНӘ [қәйнә]** диал. «свекровь» ~ башк. id. < *қайын инә* (*инә* «ана» сүзе таралган якларда); **кайна** варианты исә **кайнана** дигәннән. К. **Каен II**.

**КАЙНИГӘЧ,** диал. **қәйнегәч, кәйнегәц, кәйнегәч** (ЗДС: 404–405) «старшая сестра жены» < *кан игәч* (к. **Игәч**) булса кирәк. ***Кайникәч** (иркәләүле) сүзеннән дә була ала, чөнки *қәйни* «иренең яисә хатынының кыз-хатын кардәшләреннән теләсә кем» сүзе бар. К. **Каен II.**

**КАЙНИКӘ, каймбикә** (ЗДС: 377) «старшая сестра мужа» *кайынбикә* сүзеннән үзгәреп пәйда булган бугай. Гомумән, төрки телләрдә *әкә ~ икә* «өлкән кардәш (ир зат та, хатын зат та була ала)» сүзе бар (к. **Әкә**), шуннан да *қайнәкә ~ қайникә* килеп чыга ала. К. **Каен II.**

**КАЙНИШ, кайнеш** «младший брат жены, шурин» < *кайын энекәш* (?); *кайниш* яңгырашы (икенче иҗектә *-и-)* аңлашылмый. **Кайн иш** түгелме икән? К. **Каен II**.

**КАЙПАН** – этническая группа татар на севере Башкортостана < төр. (угыз) *kayпап* «качып аерылган төркем» сүзеннән булса кирәк. **Кайпан**нар хәз. төньяк Башкортстанга XVI г. ук килгәннәр. К. төр., каз. *кайпан-, кайпын-* «сугудан качу, тайпылу» ← (төр. *kaypa* – «качыну, күздән югалу», төп мәгъ. «шуу» ← *kay*– «шуу; кыегаю»).

Башкорт ономастикасында «башкортларның **кайпан** ыругы» тур. сөйлиләр һәм **кай, кайы** кабиләсе белән баглыйлар. Бу – бик шикле.

**КАЙРА, кайрата** (Тумашева 1992: 112) «обратно» < гом. кыпч., алт., үзб. *қайра* < бор. төрки

(ДТС: 408) *qajra* «кабат, кирегә», төркм. *гайра* «төньякка» ← себ. (Тумашева 1992: 114) **қайр-у** «кайту». Ихтимал, **кайт-у** (к.) белән тамырдаштыр. А.М. Щербак (1987: 83) бу сүзне **кайыр-у** (к. **Каеру**) фигыленнән дип аңлата.

**КАЙРАК I** «брусок (точильный)» < гом. кыпч., чыгт., үзб., төр. һ.б. (Радлов II: 21) *қайрақ, кайраг,* хак. *хайрах* id. ← *қайра-у* id. К. ш. ук себ. (Будагов II: 32) *қайраға̄ч* «кайрак» ~ як. *хайыргас* «кырчынташ»; монг. *хайраг, хаирга* ~ тув. *хайырга* «кайрак», эвенк. (ССТМЯ II: 357–358) *кавира* «бурташ». К. **Кайра-у, Каер.**

**КАЙРАК II** (ДС II: 96, БТДҺ: 179–180) «сырой, плохо печёный; припёка» < *қайыр-ақ,* чаг. **Кайрак III.**

**КАЙРАК III, қайырақ, қыйрақ, қыйырақ** (ЗДС: 377, 438; БТДҺ: 179–180) «твёрдая опухоль, железа (в промежности)», «твёрдая корка, утолщение в корке хлеба» – **кайыр ~ қыйыр** (к. **Кыйыр**) нигезеннән булса кирәк, чаг. үзб. (ЎХШЛ: 154) *қайрақ, қайыр* «сугарылмый торган ташлы җир» ~ бор. төрки (ДТС: 403–404) *qadraq, qadruq* «тау кырасы» (рус. «гребень горы»), *qadïrγaq > qaδïzγaq* «кыйрак, сөял» ← *qadïr, qaδïr > qadïz, qaδïz* «каты; каткан төш», күч. мәгъ. «рәхимсез», ниндидер бор. **qar* тамырыннан (монда төрле фаразларга урын киң). Чаг. **Кыер.**

Бу сүзне әд. телгә **кыерак** яңгырашында алу хәерле, к. диал. сөйләмдә (ЗДС: 438) *кыйракны кайрак белән имнәйләр, көянтәне атлагансың, арбаныңкын арышны (тәртәне) атлагансың (өстеннән атлап чыккансың), тип.* Ягъни гади телдә **кайрак I** белән **кыйрак** бик яхшы аерылган!

Дерив.: **кайраклан-у** (монда **кайрак I** сүзенең контаминацион тәэсире сизелә) ~ **кыйраклан-у; кайраклы ~ кыйраклы, кайраксыз** һ.б.

**КАЙРАН** (ЗДС: 377) «диво; удивительно» ~ алт., тув. и т.п. *қайран, қайрақан* «ни гаҗәп! Аллага шөкер» яки хак. *хайран* «җаным, җанкаем!». Сары уйг. *қайра,* КБ. *қайр* «яхшылык, игелек» һ.б.ш. ымлык мәгъ. сүз < монг. *хаирханъ* «фәрештә, җирле тәңре» һ.б.ш. Будагов II: 32; Räsänen 1969: 223; Аникин: 603 (тәфсилле). Гар. *ҳайр, ҳайран* сүзләреннән түгел!

**КАЙРА-У** «точить на бруске» ~ чув. *хӑйра-* id. < гом. кыпч., чыгт., үзб., госм. һ.б. *қайра-* id. ~ монг. *хавира-* < иске монг. *xabir-, xabira-* «кайра-у», каз., алт. (Радлов II: 20–21) *қайра-, қайыра-* «чыкырдау (таш тур.)» ← *қайыр,* к. **Каер.** Räsänen 1969: 222; Федотов II: 320.

Дерив.: **кайрал-у, кайрат-у;** к. **Кайрак.**

**КАЙРЕ, кайри, каре** миш. «где; откуда; куда» ~ кар. *кайре, кайри, кайра,* к.-балк. *кайры* id. көнб. кыпч. төркеменең характерлы сүзе < *кай йир-э* тезмәсеннән, к. үзб. *кайердан* «кайдан».

**КАЙРЫ I,** диал. **кайыр** «кора (толстая), луб» ~ чув. *хойӑр > хуйӑр* id. бу сүзне бор. төрки **кайырығ* < **қадырығ* «каерып, суеп алынган нәрсә» дип кенә аңлатып була (к. Будагов II: 32), к. тув. *казырык* «йомырка кабыгы», як. *хатирык* «кайры», ләкин *каб* тамыры үзе **кайр* тамырыннан, ә бу тамыр ностратик характерга ия. К. тунг. **хэйр* > *хə̄р* (ССТМЯ I: 482), удм. *кур, кӧр*, коми. *корй*, мар. *күр*, морд. М. *кяр* «кайры» (КЭСК: 133), фин. *kuori, kaarna*, венг. *hars*, рус. *кора*, лит. *karna* һ.б. Федотов II: 352.

*Кайры тун* тәгъбире «агач кайрысы суында дупланган тиредән тегелгән тун» дигән мәгънәдә.

Дерив.: **кайрылан-у.**

***КАЙРЫ II, қайр** (себ., к. Будагов I: 32) «мускусный мешочек кабарги» ~ хак. *кайыр,* тув. *хайр,* бор. төрки (ДТС: 466) *qunduz qajïrï* id. Рус. (XVII г.) *каира* id. тур. Аникин: 236 (шунда бүтән мәгълүматлар да китерелә). Гомумән, бу сүзнең чыгышы-ясалышы ачык түгел.

**КАЙСӘР** «христианский, византийский император» < бор. төрки (ДТС: 408) *qajsar* < гар. *қайҫар* id. < герм. (гот.) теленнән таралган һәм лат. *Caesar* – атаклы Рим императоры (Цезарь) исеменә кайтып кала (Kluge: 460), шуннан ук рус. *царь* сүзе дә килә; *к ~ ц* күчеше лат. диалектларына хас булган. Уйг. телендә *қәйсәр* «гайяр кеше» > каз., к.-калп. *қайсар* id.

**КАЙСЫ** «который из, некоторый» ~ башк. *кайһы, қайныһы* < гом. кыпч. *қайсы*, уйг., үзб. *қайси* < бор. төрки *qajusı* (*кайусы* варианты иске тат. һәм диал. сөйләмдә дә очрый, к. **Кай**).

Башк. *қайныһы < қайнысы* < бор. төрки (ДТС: 419) *qanjusı* формасыннан булса кирәк. Чув. *хӑшӗ* «кайсы» < болг. < кыпч. (бор. тат.) теленнән.

Дерив.: **кайсылай, кайсылый** (диал.) «ничек»; ш. ук кушма сүзләрдә: **кайсы бер > кайсыбер,**

**кайсыкем;** тат. сөйләшләрендә **кас′е-кас′е, кайсы-кайсы** «кайберсе»; әд. телдә **кайсы, кайсы ки, кайсыдыр ки** сүзләрен русча «который» мөнәсәбәтле сүзе мәгъ. һәм ролендә куллану очрый.

**КАЙТ** «самый нужный; узловой» (к. ш. ук *ҡәтмәл* «иң кирәкле мәл», к. ТТДС I: 224) – к. иске әд. *ҡайд иту* «теркәү, беркетү, раслау, билгеләү, чикләү» < гар. *ҡайд* id. (к. ГТРС: 200) төбендә «бәй, төен, төйнәү»; шуннан ук төр. *кайдал* > гар. *ҡайдāни* ← *кайд*ның икелек сан формасы «ике бәй» > рус. *кайдалы, кандалы* (Фасмер II: 178; Аникин: 236, 255). К. Будагов II: 102.

**КАЙТА** (к. мәкаль: *Кайта килгән яу яман, кайтып килгән кыз яман*) «снова, опять», диал. «очень, настоятельно» ~ гом. кыпч., үзб. һ.б. *ҡайта* id. **кайт-у** фигыленең хәл (рәвеш) фигыль формасы.

**КАЙТАВЫЛ [ҡаᵒйтаwы̊л]** диал. «возвращение; отступление; отступающая группа» ~ башк. *ҡайтауыл* id., каз. (ҠТДС: 183) *ҡайтауыл,* төркм. *ғайтаwыл* «контратака» һ.б.ш. хәрби термин модельләре буенча *кайт-у* сүзеннән.

Будагов (II: 102) бу сүзне, Рәшидетдиннән алып, **ҡайтул** дип яза һәм «төп лагерь» дип, икенче бер иске сүзлек буенча «кальга» дип аңлата. Монголча *ҡайтуул* булырга тиеш.

**КАЙТАДАН** «снова, сначала» ~ башк. *ҡайтанан* id. < гом. кыпч. *ҡайта, ҡайтадан* ← **кайт.** К. **Кайт-у.**

Чаг. тат. диал., башк. **кайта-кайта** «кабаткабат».

**КАЙТАР-У** «вернуть; вернуть обратно; отбить нападение (*яу кайтару*)» ~ гом. кыпч. *ҡайтар-* < *кайт-тар-у* (*кайт-у* фигыленең йөкл. юн.) булса кирәк, ләкин бор. **кай-* фигыленнән дә ясала ала.

Дерив.: **кайтарыл-у, кайтарын-у, кайтарыш-у, кайтарт-у; кайтаргыч, кайтарым** (икенчел дериватлар да күп), **кайтарулы** һ.б. Шулардан **кайтарма** гом. кыпч. мәдәни термин – бию атамасы, туй терминологиясендә – бүләк төре һ.б. (к. ЗДС: 378). К. ш. ук тат. **кайтармалы яка.** Диал. сөйләмдә **кайтармыш** «кайтарып бирелгән артык акча».

**КАЙТ-У,** диал. **кайыт-у** «вернуться» < гом. төрки *ҡайт-*, бор. кыпч. *ҡайыт-*, аз. *гайыт-* < бор. төрки *qaδıt-* id. *qaδ-, qaj-* «борып җибәрү, кайтару» (к. **Каер-у**) фигыленнән (к. ДТС: 404, 406–407). Бу фигыль, үз чиратында, монг. *хари-* < бор. монг. *qari-* «кайту» сүзенә караганда **qar-* тамырыннан. Чаг. ш. ук чув. *кай-* «бару», як. *хай-* «әздән бару». К. ш. ук Будагов II: 31–32; Räsänen 1969: 223; Федотов I: 211–212.

Дерив.: **кайтыл-у** (мәс., *озак кайтыл-у*), **кайтыш-у; кайтым;** диал. **кайтма, кайтмалы** (*әйтмәле дә кайтмалы*), **кайтмакай, кайтымсак** һ.б. К. **Кайтадан, Кайтар-у, Кайтыш, Кайтавыл.**

**КАЙТЫШ** «меньше, хуже» > чув. диал. *кайтăш* «ярлы» (Сергеев 1968: 24) **кайт-у** фигыленнән булса кирәк (*кайту* «чигенү» мәгънәсеннән: *кайтыш* «чигенеш > җиңелү, бирешү, начаррак булып чыгу → начаррак»).

**КАЙЧАН**, диал. **качан, кацан,** «когда» < *кай чагын* тәгъбиреннән. Төрки телләрдә *ҡачан,* башк. *касан,* нуг., каз., к.-калп., тув. *кашан* һ.б. вариантлары киң таралган (хәтта бор. төрки *qačan*), к. Донидзе Г.И. О составе и функциях слова *хазан [хаҗан]* в хакасском языке. Уч. записки Хак. НИИЯЛИ. Абакан, 1960: 138–149. Чув. *хăҫан, кăҫан, хăsан* «кайчан» тур. Федотов II: 335 (тәфсилле аңлатма).

Дерив.: **кайчангы; кайчанга, кайчангача, кайчаннан, кайчанлык.**

**КАЙЧЫ**, диал. (ДС II: 96 һ.б.) **канчы, качы** «ножницы; клёст» > удм. *качы,* мар. *каче, кайыц* (Исанбаев 1978: 31), чув. *хачă*, удм. *кайсы* «чукыр (кош)» < гом. кыпч., алт. *ҡайчы,* үзб., уйг. *ҡайчи* (нуг., каз., к.-калп. *ҡайшы*), иске монг. *qajiči, qabčuir* < **qabčaa-γur*, фар. *ҡайинчи, ҡайчи, ҡаучи* (төрки телләрдән), яз. монг. *хайичин*, эвенк. *кајик, кайич,* хак. *хыпты*, як. *кыптый* «кайчы; кыскыч», хак. диал. *капты* id. һ.б. (вариантлары күп) – төп форма **кабыты* булса кирәк. Бу сүзне бор. кыт. *kiap toi* «кыстыргыч пычак» сүзеннән чыгаралар, к. кор. *keptoi* «пәке, катламалы пычак» (< кыт.): кыт. **kiap* > *kep* «кыстыру», **toi* «пычак» (к. Joki 1952: 161). Монг. һәм тунг. вариантлары тур. ССТМЯ I: 362, 397, 457–458; Федотов I: 315.

Дерив.: **кайчылы, кайчысыз; кайчыла-у; кайчылык** «бәпкә, атлама».

Тарихи фразеологизм: **кайчы кода** – бер үк кешегә кызын да биргән, шуннан килен дә алган кеше. Калым һәм бирнә бирмәс өчен шулай эш иткәннәр.

**КАЙШЫЛ-У, кайшал-у** «коробиться; выгибаться, откинуться спиной» > чув., мар. *кайшал-* id. ← тат. (ЗДС: 285, 379) **ҡайыш-у, кәйшә-ү** «бөгәр-

ләнү» (←***кайы-у**) фигыленең төш. юн. К. кырг. *қайшы* «кире, каршы», башк. (к. БТДҺ: 179), нуг., каз., к.-калп. *қайқы* (күп вариантлары белән) «бөгелгән, кайтарылган», тув. *хайа* «артка карап». Чаг. **Кайт-у.** Чаг. бор. монг. *хаǯаі-* «кайшылу». К. ш. ук **калҗай-у, калтай-у.**

**КАЙЫ-У (каеды, каю)** «вышивать по краю; оторочить; строчить» ~ гом. кыпч., алт. *кайы-*, угыз. *гайы-* < бор. төрки **qaбı-* id.; борынгыдан бирле *кайу* исеме дә килә: алт. *кāјы*, каз. *қайу,* кырг. *қайуу, қайуқ* «эре җөй» < бор. төрки (МК) *qaбıγ* id. < **qaб-ı-γ*, чаг. тув. диал., хак. *хай-* «каймалау». Räsänen 1969: 221; Joki 1952: 152; Федотов II: 305 (**Кыю II** сүзе белән чагыштыра). Чаг. **Кый.**

Дерив.: **каел-у, кает-у.** К. **Каеш, Кайма.**

**КАК I** «сухой; засушенный; твёрдый и голый (о поверхности)» > мар., чув. диал. (Сергеев 1968: 24) *как* < гом. төрки *қақ* id., кыпч. телләрендә исем мәгъ. дә кулланыла, к. тат. *какта яту, какка калу* һ.б. **Как** сүзенең фигыль коррелянты да булган, к. чув. *хох-, хух-* «кибеп кечерәю» (чаг. ш. ук тат., башк. **каклык-у** «кипшенү; кайшалу» **какыл-у* кебегрәк нигездән ясалган фигыль). **Как** сүзенең конкретлашкан-тарайтылган мәгънәләре **Как II, Как III** сүзләрендә күренә. Будагов I: 18; ССТМЯ II: 363–364; ЭСТЯ V: 219–220.

Дерив.: **каклык,** диал. **какай-у.** К. **Кагай-у, Какал, Какла-у, Какмач, Каксы-у, Какча, Какчыр, Какша-у, Каушау.**

**КАК II** «пастила» ~ диал. (трбс.) **қақы** id. < гом. кыпч. (гомумән сирәк очрый) *қақ* id. Үсемлек атамасы буларак та кулланыла бугай; ашамлык мәгъ. бу сүз күптәннән билгеле. Бируни (к. аның 1974: 697) «шифалы измә ашамлык *как*ны Харәземгә түркләр иленнән китерәләр» дип яза. Кыпч. телләрендә (үзб. диал., каз., кырг. һ.б.) *қақ* «какланган ит». Күп күрше телләргә кергән.

Сөйләшләрдәге *какы* < *каккы* сүзенә карагандa, төбендә бу сүз **қақ-* «кору, кибү» фигыленнән ясалган булган, чаг. **Как I, Кагыт.**

**КАК III** (Тумашева 1992: 115; Dobr. II: 181) «лужа; бессточное озеро в степи; пруд (небольшой, мелкий)», «накипь, осадок (на месте лужи, высохшего озера, пруда» < гом. төрки (к. Радлов II: 57) *қақ* < бор. төрки (ДТС: 422) *qaq* ~ башк. (БТДҺ: 181), тув. *қақ* «юшкын», хак. *хах* «балыклы урын (кибә торган сайлык)» ~ калм. *xag* «былчырак», монг. *хаг* «юшкын» һ.б. Будагов II: 18; ССТМЯ I: 364 (бор. кыпч. *һак* «кара җир» сүзе белән чагыштырыла), ЭСТЯ V: 219–220. Рус. *как* «далада былчырак урын» (Фасмер IV: 216) төрки телләрдән булса кирәк. Сусыз, корылыклы тарафларда *қақ, каклык* «яңгыр сулары җыелсын өчен махсус уелмалар, чокырлар», к. Мухамедова 1973: 112; Dobr. II: 182.

**Қақ** төрки телләрнең иң характерлы тамыр сүзләреннән берсе һәм аның мәгъ. структурасы бор. төркиләр яшәгән җирләргә (коры дала-чүлләр, чукрак сулыклар, аларның еш кына кибүе һ.б.) бик бап килә. Һәм **Как I** сүзе тур. да шуны әйтергә мөмкин. К. ш. ук **Какал.**

**КАКАЙ-У** (ЗДС: 268, 380) «стоять в недоумении; худеть» ~ каз., кырг. *қақай-* id. К. **Кагай-у.** Будагов I: 19.

**КАКАЛ** (Ш. Маннур) «степное бессточное озеро» ~ себ., алт. диал. **қаған** «субасар болын; ташкыннан калган күлләвек» > рус. диал. *каган* id., *таган* «сазламык» ← **как II.** Аникин: 231, 522 (арытабангы әдәбият та күрсәтелә). Себ. (Тумашева 1992: 113) **қағалақ** «саз үләне» сүзе дә шуннан булса кирәк: *қағал-ақ* «димәк, *қағал* «калдык күлләвектә үскән үсемлек» мәгъ. дә булган). К. **Каганак, Как I.**

**КАКЛА-У** «вялить (мясо)» ← **как I.**

Дерив.: **каклаган, какланган**.

**КАКЛЫК-У** (ТТДС I: 188; БТДҺ: 181) «переутомляться (?) – вероятно, не основное значение», себ. (Тумашева 1992: 116) «удариться» ~ к.-калп. *қақлық-* «бәрелү, каты кагылу» **как-у** фигыленең интенсивлык формасыннан (*кагыл-ык-*); к. ш. ук тат. **каклыкма** «чана кыеш китеп бәрелә торган төш».

**КАКМАЧ** (ТТДС I: 189) «сухощавый», **қақмац** (Тумашева 1992: 116) «сухой, засохший» ~ үзб. диал. (ЎХШЛ: 154) *қақмач* > к.-калп. *какпаш* «кипкән балык» – бу мәгънә төп, чөнки *-мач* ашамлык атамалары ясый торган кушымча. К. **Как I.**

**КАКСЫ-У** «прогоркнуть» < гом. кыпч. *қақсы-, қақса-*, уйг. *қаңсы-*, як. *хахсый-* ~ монг. *хагша-* id. ← бор. төрки *қаг* «коп-коры», к. **Как I.** К. ш. ук монг. *хагша-*, тунг. *қақта-*, маньч. *хақса-* (к. ССТМЯ II: 364) id., ш. ук «көю, көек исе килү» ← **қақ I**.

**Каксы-** фигыленең **каксык** «каксыган, искергән» дериваты гом. төрки характерда, к. як. *хахсыҡ* «каксыган».

**КАК-У (какты, кагу)** «стучать, ударять, колотить, бить, вбивать», күч. «отвергать» < гом. төрки (Радлов II: 59) *ҡаҡ-*, тув. *хак-* > хак. *хах-* id. Гомумән, бу сүз бик күп мәгънәләрдә кулланыла (к. Будагов II: 19).

Дерив.: **кагыл-у** (икенчел дериватлары да күп кенә), **кагын-у, кагыш-у, кактыр-у;** диал. **каккы (каккы-суккы), какма** һ.б.

**КАКУЛ** (ЗДС: 268), миш. **кякюл,** «хохолок у птиц; кисть на шапке», «часть гривы у лошади» (в этом значении встречается в фольклоре: *Ай-һай, астымдагы туры, да, атым – Ял арткырлы салган какулы*). Асыл мәгънәсендә «ир кешенең яшьтән үк баш түбәсендә киселмичә-кырылмыйча калдырыла торган толымчык», чаг. добр. *kâkül, kyakyül* < фар. *каһкүл* id., рус., укр. *хохол*, Кавказ телләрендә *кукул* һ.б. id. Бу сүз Евразиядә күп телләрдә очрый һәм фар. теленнән таралган дип исәпләнә. Какул калдыру гадәте бор. Мисырда да булган һәм Якын Шәрыктә күптән билгеле. Ихтимал, ул бөтен Азиягә шуннан таралгандыр. Татарларда *какул* калдыру әле XIX г. башларында да күзәтелгән (Катанов 1903: 281); XVII г. чирмешләрдә төйнәлгән *какул* – коллык билгесе булган (Олеарий: 409), ә рус казакларында *хохол* ирекле булу билгесе. Гомумән, какул калдыруның мотивациясе һәм аңлатмалары бик үк ачык түгел. Рәшидетдин хәбәренчә, монголлар төрки әсирләрнең какулларын төйнәгәннәр (к. Рашид-ад-дин 1952: 208), ә Урта Азиядә *какул* көтелгән ир бала башында калдырылган; кыргызларда какулны туйга кадәр генә йөрткәннәр. Кавказ халыкларында какул калдыруны, егет сугышта үлсә, аның башын алып йөртергә җайлы булсын өчен, дип аңлатканнар (Пачулиа В.П. Падение Анакопии. М., 1986: 112–113). Безнең төркиләрдә исә риваять яшәгән: имеш, Тәңре һәр бәндәнең баш түбәсеннән үскән күзгә күренмәс бер бөртек чәчен күккә күтәреп тотып ала да, кавышасы кыз белән малайның чәчләрен бергә төйнәп бәйләп куя. Шуннан инде бу парлар кайда гына йөрсәләр дә, бер көн килеп барыбер кавышачаклар, имеш. Менә шуннан инде татарларда *чәче чәчкә бәйләнү* дигән әйтем килә. Какул (ул **айдар чәче** яки **пәрҗәм** дип тә атала) шул язмыш чәченең нигезен белдергән. Татарларда, кыз ярәшелгәч, егетнең какул чәчен, инде кирәкми дип, кисеп ыргыта торган булганнар. Какул турында бик күп мәкаләләр язылган (чөнки *хохол* «украин» мәгънәсе кызыклы).

**Какул** сүзенең ясалышы ачык түгел. Аны *көк оглу* (*күк углы*) яисә *кан (хан) кулу (колы)* тезмәләреннән дип аңлатулар – ирекле уйдырмалар. К. **Кәкел, Кикрик.** Будагов II: 110; Ramstedt 1949: 115.

**КАКЧА**, «сухощавый» ~ башк. *ҡаҡ* id. – **как I** сүзеннән тат. телендә ясалган булса кирәк. К. түбәндәгене.

Дерив.: **какчалык, какчалан-у.**

**КАКЧЫР** (ТТДС I: 189) «засохшая ветка», **какцыр** (Тумашева 1992: 116) «корочка раны; сухой слой коры дерева» ~ башк. (БТДҺ: 182) *ҡаҡчыр* «какча», *ҡаҡсыр* «икегә тармакланган ботак, аю сөңгесе», *ҡаҡшыр* «салдау», кырг. *ҡаҡчың, ҡаҡчыгай* «хәрәкәтчән какча карт», *ҡаҡчый-* «хәрәкәтчән какча карт булу» < *ҡаҡчыгай-* id.

**Какчыр**, күрәсең *ҡаҡчы-* «кагая, каклана төшү» яисә «артык кибү» фигыленнән, ә бу фигыль исә **как-* «кибү, кору» фигыленең кабатланучан интенсивлык формасы. Ләкин **какчыр** «шеш, яра өстендәге кутыр» мәгънәсе **как чыр** (к. **Чыр**) сүзеннән дә була ала.

**КАКША-У** «рассыпаться и стать шатким (о закреплённых деталях), расшататься», диал. (ТТДС I: 227) **какшау** «хәлсезлек», «ябыгу, арыклану; хәлсезләнү» < гом. төрки *ҡаҡша-* > нуг., каз., к.-калп. *ҡаҡса-*, кырг. *ҡаҡшы-*, уйг. *ҡахша-,* тув. *ҡагжа-*, хак. *хахса-* һ.б. (Радлов III: 67) «кибеп, формасын югалту; какшау; зәгыйфьләнү; каушау» ~ яз. монг. *хаўča-* «кибегү, челегү» һ.б., һичшиксез *как* «коры, кипкән» сүзеннән, к. тат. диал. (к. югарыдарак) **каклык-у (каклыгу)** «артык нык кибү; какшау» К. **Кауша-у.** Будагов II: 19; Räsänen 1969: 223.

Дерив.: **какшат-у, какшак** «какшый торган».

**КАКЫ**, диал. **кукы** (ТТДС I: 589, 598) «свербигуз; свергубец» ~ чув. *хухӑ* id. < *ғаҡыйҡ* «ахак, агат» сүзеннән (үсемлекнең киң яфрагында калку ак таплар булуыннан), дип аңлату бар, к. диал. **ахык** «какы». *Какы* < *каккы* «мичкәләрне **кагып** ныгыту өчен кулланыла торган үсемлек» дип аңлату да бар (Радлов II: 61). Безгә бу аңлашылмый. Чаг. диал. *какла-* < *какыла-* «чагу, кымырҗыту» (үсемлекләр тур.). Ш. ук *какы* < *как кый* «какта (сазлыкта) үсә торган кый (кыяклы үлән)» булырга да мөмкин (ә *кукы* икенче сүз булса кирәк). Алт. *ҡаҡы* гомумән «зур үлән». Дерив.: **какылык.**

**КАКЫЛДА-У** «гоготать» к. **Каңгылда-у.**

**КАКЫР-У** «харкать, отхаркнуть» < гом. кыпч. *қақыр-* < *қарқ-қыр-* id. – «карк итү» (*-кыр//-кер, -гыр//-гер* тәкълиди сүзләрдән һәм ымлыклардан фигыль ясагыч кушымча, к. *а-кыр-, ба-кыр-, сызгыр-, төч-кер-* һ.б.); к. як. *хах* «какыру авазы» (Пекарский: 3414, 3417–3418), монг. *гэхрэ-* «какыру», чув. *кахăр-* «кикерү» һ.б.

**КАЛ I** диал. (Тумашева 1992: 116) «глупец, бестолковый» < бор. төрки (ДТС: 410) *qal.*

**КАЛ II, калы** (ЗДС: 381, 384) «родимое пятно» < фар. *хал* id.

**КАЛА I** «город; городок» ~ чув. *хула* < *хола* болг. **һола* > мар. *ола, оло* id. ~ гом. кыпч. *қала*, кырг. *қалаа* id. < гар. *қал'а* «кирмән» > төр., кр.-тат. *kale* id. һәм «манара, башня». Бу сүз төрки телләрдән бик күп күрше телләргә кергән. К. Шура № 3, 1911 (**кала** сүзе тур. Һади Атласов һәм Хәсән Гали мәкаләләре); Мурзаев 1984: 242–244. К. **Каланча, Кальга.**

Дерив.: **кала́ча; калачык;** (археологиядә) **калалык**.

**КАЛА II** бәйлек (-дан//-дән, -тан//-тән **кала**) «после; кроме» – **кал-у** фигыленең хәз. заман өченче зат формасыннан.

**КА́ЛА III** диал. (Арсланов 1992: 126) «а ну-ка, начни, двинь» и т.п., **кала-у** «высказаться, высказать пожелание; выбирать» ~ нуг., каз., кырг. *қала-* < уйг., үзб. *хаһ-ла-* id. фар. *хаһ* «теләк» нигезендә ясалган сүз.

**КАЛАБАЛЫК** «тёмная масса народа» (к. *Калабалык төсле өсне каплап Була шатлыгыңа күләгә.* М. Гафури) < гом. кыпч., гаг., төр. һ.б. *калабалык*, кар. *халабалык*, ком. *қаламалық* id., ш. ук (Dobr. II: 183) *qalabalıq* «мәгънәсез шау-шу; тыгын», төркм. һ.б. *ғалаба* < гар. *ғалăбă* «җыну; шау-шу» сүзеннән. Рус. *калабалык* тур. Фасмер II: 163–164.

**КАЛАВЫЗ [ка°лаwы̆з]**, себ. (Тумашева 2000: 238) **калаус,** (ЗДС: 150, 381, 382) **галаwыс, қалаwыс, қалаус** «котомка», (Рамазанова 2001: 18) **колоwыс** «мешок для подарков невесты», иске тат. **қалағуз** «кожаный мешок для воды; дорожная котомка» ~ рус. (Аникин: 238) *калауз, калауш, калауж, колоучи* id. һ.б. иске төрки **колавыз** сүзеннән булса кирәк, ягъни *кулавыз* (< *колаwыз*) *капчыгы* сүзеннән эллипсис. К. ш. ук Себер телләрендә *қалавус,* як. *халабыс* «юл капчыгы», «ашамлык чынтае». Фар. *калагуз, галавуз* «юлбашчы», *колавыз, калавус* «курҗын» бу сүзнең шактый борынгылыгын күрсәтә. Төрки сүз булса кирәк. Чаг. **Кулавыз.**

**КАЛАЙ I** «кровельное железо; жесть» > чув., мар., удм. *калай* id. < гом. кыпч., төр. һ.б. *қалай* id., ш. ук төр. *kalay* «аккургаш» ~ бор. монг. *qalaj* «тимер белән аккургаш эремәсе» ~ гар. *қал'ӣ* «аккургаш». Абаев (I: 617) буенча, Малайзиянең *Куалаһ* өлкәсе исеменнән – анда элек-электән аккургаш табылган.

**Калай** сүзе төрки телләрдән күп телләргә таралган. Федотов I: 215.

Дерив.: **калайлы; калайлан-у** (күз тур. – хәрәкәтсез калу).

**КА́ЛАЙ II** диал. (ЗДС: 381) «как, каким образом; каков» ~ башк. *қалай* id., к.-балк. һ.б. кыпч. *қаллай* < *қаңғыдай,* к. бор. төрки (ДТС: 419) *qanï, qanju, qanyï* «кайсы, ничек; кайдагы». К. **Кай**.

**КАЛАК** «деревянная лопаточка, мутовка; лопасть; лопатка (кость)», диал. (ДС III: 7) «ложка; стручок» > чув. *калак, калек, кальак,* мар., удм. *калак* id. < гом. кыпч. *қалақ* id. үзб., уйг. *қалақ* «ишкәк» ~ алт., тув. *калбак* «киң, яссы; иң», эвенк. (ССТМЯ I: 365) *калбика,* маньч. *халба, калби, калбин* «калак сөяге; киң, ялпак», монг. *калбага* «кашык, калак, ишкәк», бор. монг. *γalbuγa* «калак, кашык». Поппе 1938: 139, 193; Рамстедт 1957: 187; Федотов I: 215–216. К. **Кашык.**

**КАЛАМА** диал. (ДС II: 96) «телега, тележка» – рус. *каламага, колымага, колимог* сүзеннән булса кирәк (тат. сүзе бер генә төбәктә теркәлгән).

Рус. *колымага, калимашка* «начар арба» сүзенең этимологиясе ачык түгел. Аны төрки телләрдә киң таралган *каң, каңлы, каңга* «тәгәрмәч; ике тәгәрмәчле арба» сүзеннән дип тә уйлыйлар (*каңла-ма* сүзе булгандыр) һәм калм. *қалимаг* «калмык (калмык арбасы)» сүзеннән дә чыгаралар. К. **Каңлы.** Фасмер II: 164, 291.

**КАЛАН** «вид налога, обложения в Казанском ханстве» ~ алт. *қалан* < бор. төрки *qalan*. К. **Кылан.**

**КАЛАНЧА** «каланча, вышка» > чув., мар., удм., рус. *каланча* id. Тат. телендә кайбер төрки

телләрдәге (һәм миш. сөйләшләрендәге шартлаулы *ч (*$^{т}$*ч)* белән әйтелгән *калача* «кечкенә кала, кечкенә кирмән» сүзеннән килеп чыккан: *кала*$^{т}$*ча* > *каланча. Каланча, калача* госманлы телендә дә теркәлгән һәм анда да шул ук сәбәпләр белән параллель рәвештә пәйда булган. Фасмер II: 165.

**КАЛАҢНА-У** (Тумашева 1992: 116) «качаться, колебаться» ~ алт. (Будагов II: 20) *қалаңда-* «качаться как маятник» ← **қалаң* «маятник», к. тув. *халаңна-* «чайкалып тору», *халаң, халаг, халаңгай* «чайкалучан», *қалбаңна-* «чайкалу, тирбәлү; тагылып, асылынып торган нәрсә кебек булу». Төбендә монг. сүзе булса кирәк.

**КАЛАУ [қа°лаw]** «кострище; ритуальный костёр» < гом. кыпч. *қалаw* (> кырг. *қалоо*), аз. *ғалағ* < бор. төрки **қалағу* ← **кала-**, к. **Кала-у.**

**КАЛА-У** диал. «сложить (костёр); сооружать» < гом. кыпч., башк. (БТДҺ: 183), чыгт., алт. һ.б. (к. Будагов II: 20, бик әйбәт мисаллар белән) *қала-,* аз., төркм. *ғала-* id. < бор. төрки (ДТС: 410) *qala-* id., к. як. *хаала-* «өю, таслау; савытка салу» (← *хаа* «савыт, сыешлык»?); к. ш. ук бор. төрки, бор. монг., фар. *qal* (> хәз. монг. *ғал*) «учак, калау, тимерче учагы»; чаг. шумер. *kal* «өй, учак; төрбә».

Заманында Хәсән Гали **кала** сүзен дә гар. *кальга* сүзеннән түгел, **кала-у** фигыленнән дип язган (ләкин бу фикер яклау тапмаган). Чыннан да, кр.-тат. *qala-* «койма кою, кальга ясау» фигыле бар.

**КАЛАЧ,** диал. **калац,** (Тумашева 1992: 116) **қалац** «белый хлеб, булка», (Хайрутдинова 1985: 128) **қалас** «бублик, лепёшка с дырой посередине» ~ мар. (Саваткова: 47) *калач, калац, кӓлӓц* «калач; келиндер төре», чув. *кулас, кулаҫă, колаҫă* «калач» ~ кар., к.-балк., ком. *қалач*, нуг., кр.-тат., каз., к.-калп. *қалаш*, добр. *qalas,* хак. *халас* «калач, көлчә һ.б.ш. икмәк төрләреннән берсе (мәгъ. үзенчәлекләре бик күп булырга мөмкин)» ~ Нәваи телендә (Боровков 1961: 27) *kālāč*, XIV г. кыпч. сүзлекләрендә (әт-Төхфәт) *қалач* «калач, күмәч» һ.б. Рус этимологиясендә (Преображенский I: 332; Фасмер II: 285 һ.б.) рус. *калач, колач* бор. гом. слав. *коло* «түгәрәк» сүзеннән дипраслана һәм гом. кыпч. *қалач* русчадан булып чыга. Ләкин бу фикерне шик астына алырга да нигезләр бар: Себер төркиләрендә (алт., тув. һ.б.) *калач, калаач* «төңгер (бер яклы түгәрәк барабан), гомумән түгәрәк», үзб. *қалач* ~ осет. *qalas* «зур чүмеч; чара, шава (яссы табак төрләре)». Һәрхәлдә тат. **калач** турыдан-туры рус теленнән түгел.

Тат. һәвәскәр этимологиядә **қалач** сүзен *кала́ча (икмәк)*, яки *кала ашы* дип аңлату үзенчә кызыклы.

**КАЛӘМ** «ручка с пером»; диал. «карандаш» > мар. *қӓлӓм* < гар. *қалӓм* < лат. *calamus* «камыш, каләм» < грек. *kalamos* id. рус. *солома* «салам» белән нигездәш, к. Kluge: 386; Будагов II: 63; Тимергалин: 221, 222 (тәфсилле).

Дерив.: **каләмле, каләмсез; каләмдәш.**

**КАЛӘМКЯР** иск. «коленкор, тонкая узорчатая, художественная ткань, миткаль» (к. Даль), ш. ук «гравёр, металл өслеккә бидәр-бизәк төшерүче». Һәр ике мәгънәдә фар. *калӓмкāр* «каләм эше», «каләм белән эшләүче» дигәннән: **каләм** бу очракта «очлы эш коралы, махсус без».

Рус. *коленкор* төрки телләр аша фарсычадан.

**КАЛБЫР** (ЗДС: 382) «большое решето (на току и др.)» ~ каз. (ҚТДС: 186) *қалбыр*, төр. *kalbur*, аз. *халбур, хәлбир* id. һ.б. гар. *ғирбāл* «зур иләк; өермә» сүзеннән, к. Будагов II: 21. Тат. телендә *гыйрбал* сүзе үзе дә кулланыла.

**КАЛГАЙ** «наместник правителя в провинции» (к. Атласи: 99), «нугай һәм Кырым ханнары катындагы морзаларга бирелгән югары титул» (к. Будагов II: 22), кр.-тат. *қалға* «уң кул вәзире», госм. *қалға* «гарнизон башлыгы», «хан яуга киткәч, аның урынына калучы» < монг. *қағылғай, қағалғай ~ қаганқай* «кече каган» дип аңлатыла. Velidi: 113; İA VI: 131–132. К. **Каган.**

Заманында Һ. Атласи һ.б. татар тарихчылары *қалгай* < «кала агае» дип тә аңлатканнар. *Хан урынына* **калгай** «каласы кеше» дип (интендант дип) аңлату да булган, к. Räsänen 1969: 226.

**КАЛГЫ-У** «вздремнуть, дремать» < гом. кыпч. *қалғы-,* к.-балк. *қалқы-*, кырг. *қаалғы-* id.; чаг. алт. *қал-* «үлеп китү», тат. диал. (ДС I: 74) **калый-** «һуш китү». *Калгы-у* < *қал-ық-* ← **қағал-ық-* булса кирәк.

**КАЛДАЗ, калдыз, калды** (миш., к. ТТДС I: 227) «двор; хлев» < морд. *кардаз, калдаз, калдо* id. Бу сүз нигезендә ясалган тат. (Оренбург, без теркәдек. – *Р.Ә.*) **калдыз инәсе** тәгъбиренә удм. *кильдисын, килцин, килдини* «балалау алиһәсе», *калдыкмуми, калдынимумас* «калды анасы» (*мума* «ана»)

бик охшаш. Арытабан манси телендә (Holmberg: 32–64; Kannisto 1958: 24–28, 121–123, 225, 254) *kaltes änki* «балалау алиһәсе» (*änki* – тат. диал. *әнкий, әнкәй* сүзеннән булса кирәк).

**КАЛДАЗЫН** себ. (к. Радлов. Образцы… IX: 208–209) «бес; домовой; гном» – «йорт иясе, шекә», урянхай (тува) әкиятендә *Калдазын* дигән кәрлә карт *Маңгыс* (к. **Мавыз**) дигән явыз рух белән көрәшә, к. Урманчеев 1984: 135. **Калдазын** сүзе югарыда китерелгән **калдаз** сүзенә һәр яктан бик охшаш, әмма тарихи җәһәттән караганда шикләнүләргә урын кала. Хант.-мансиләрдә *kaldaš ana* «биологик анага ярдәмче рух», ул күбәләк рәвешендә бишек тирәсендә очып йөри. Чаг. **Калдаз.**

Төньяк Башкортстанда **Калтасы** (зур авыл, район үзәге) топонимы да, ихтимал **калдазын** сүзе белән баглыдыр.

**КАЛДАУ [қа°лдаw]** «заброшенное поле» – **кал-у** фигыленнән шикелле. Ясалышы ачык түгел. Ихтимал, **каудан > каудал** сүзеннән метатезадыр. К. **Каудан.**

**КАЛДЫК** «остаток» ~ гом. кыпч. *қалдық,* уйг. *қалдуқ* id. < **қалындық* булса кирәк (ягъни **калын-у** фигыленнән). Һәрхәлдә, *кал-* тамырыннан, к. **Кал-у.**

**КАЛДЫРЧА** «скальница, блок ткацкого станка» ~ башк. *қалтырса* id., чув. *хултăрча > холтăрча* < болг. **һолтырча* > мар. *алдырцы, олдырчо*, удм. *колтреч* id. ← **калдыр* ~ **калтыр* «күтәрткеч тоташ тәгәрмәч»: андый сүзнең реальлеге төр. *kaldıraç* «күтәрткеч җайланма, калдырча, күтәргеч», *kaldırak* «күтәрткеч кран» ← *kaldır-* «күтәрү, күтәртү» сүзләреннән аңлашыла. Угыз телләрендә *қалдыр-у* «күтәрү, күтәртү» сүзе гом. төрки *қалқ-* (к. **Калык-у**) сүзенең йөкл. юн. (*калқтыр-*) булса кирәк. *Калдырак* нигезе турыдан-туры *калдыр-* фигыленнән ясалган, шуннан «кире сүз ясалыш» буенча ***калдыр** нигезе пәйда булган. Чаг. ш. ук себ. (Тумашева 1992: 117) **қалтырма** «күтәрмә, ишегалды баскычы».

Әйтергә кирәк, **калдырча** тәүдә көрене бер күтәреп, бер төшерә, «калдыра» торган шылдырма булган, шуннан соң гына җепне кабатураттыра торган җайланма мәгъ. алган.

Материалыбыздан күренгәнчә, **калдырча** сүзен «калтыр-колтыр килү» яисә **калтыра-у** сүзләреннән чыгып аңлату (мәс., Федотов II: 356) дөрес түгел кебек – ул халык этимологиясенчә. Хәер, башк. *қалтырса* «калтыравык үрдәк (кыргый үрдәк төре)» төрлечә уйларга урын калдыра.

**КАЛЕБ [қәлеп], калеп** «сердце, душа» < гар. *қалб* id. Шуннан *кальби* < гар. *қалбӣ* «йөрәккә, күңелгә бәйле».

**КАЛЕНДАРЬ** «календарь». Тат. теленә күптән рус теле аша кергән һәм **калиндар** дип әйтелә торган бу сүзне һаман русча язабыз, **калиндарлар** дип әйтәбез, әмма **календарьлар** (!) дип язабыз. Русчадан үзгәртмичә язганда да **календар** – исем, ә **календарь** – сыйфат булырга тиеш: мәс., *яңа ел календары,* ләкин *календарь ял* (отпуск).

Гомумән, бу сүз лат. теленнән килә. Тат. календары турында зур гына хезмәтне В. Беркутов бастырып чыгарды, к. «Мирас» 2004, № 4–12.

Дерив.: **календарьчы, календарьчылык.**

**КАЛҖА** «жирный кусок; творог из молозива» (и пр. «особенно питательная пища для больных и рожениц», к. Хайрутдинова 1993: 103) ~ башк. *қалйа,* нуг., госм. *қалйа*, каз., к.-калп. *қалжа*, кырг. *қалҗа* id., нуг. диал., к.-балк. *қалҗа* «итле токмач ашы» < фар. *қалйā* «итле аш». Гомумән, бу сүзнең чыгышы ачык түгел: ГТРС та, Özön дә аны гар. яисә фар. сүзе дип күрсәтмиләр. К. аз. *қалҗа* «баланың исән-аман тууына шөкер итеп ясалган сый, мәҗлес» дип аңлатыла. Räsänen 1969: 226.

**КАЛҖАЙ-У, калчай-у, калшай-у** «искривляться от рассыхания» ~ кырг. *қалҗай-* «коры һәм биек, буйчан булу; хәлсез буйчан булу». Чаг. **Калтай-у.**

**КАЛҖАР** «руда, каменоломня» ~ башк. (к. БҺҺ II: 26) *қалйар, қалыйар* id. Чаг. фар. *қал* «эреткеч учак», *қалчы* «тимер эретүче» – төрки телләрдән; чаг. монг. *ғал* «ут, учак». К. түбәндәгене.

**КАЛҖЫН** (Н. Арсланов), иске тат. **қалҗун** «острая шутка, насмешка, сатира» ~ кырг. *қалҗың*, каз., к.-калп. *қалжың* id., ш. ук «үртәвеч» < бор. монг. *ғалҗуун* > монг. *галзуун* «үртәвеч; которык» ← *галҗи-, галзи-* «үртәү, ярсыту» ← *ғал* «үрт, ут». К. ш. ук яз. монг. (ССТМЯ I: 138) *γalǯaγu, γalǯiγu* > хәз. монг. *галзуу* «котырган; которыну», тув. *қалча* «тиле, юләр», к.-калп., кырг. *қалҗақ* «сөйләнү, шаяру», каз. *қалжыңқуй* < фар. *қалҗыңгуй* «шаталак, күләмәчләр сөйләп йөрүче хатын-кыз», алт.

Будагов II: 25) *ҡалҗиур-*, *калјуур-* «котырыну»; алт. диал. *калйы-* «кызып китү» һ.б. монг. мифологиясендә *галзушын* < *γalǯučin* «мәсхәрәче, дуамал рух» (к. МНМ II: 174). Чаг. ш. ук рус. (Аникин: 161) *галзут* «рус белән бурят кушылгагы, метисы» < бур. *галзууд* «котырганнар» һ.б. Бу хакта бай әдәбият бар. К. **Кала-у, Калҗар, Калмык.**

**КАЛҖЫ-У** (Будагов II: 22) «распуститься, расклеиться, распаяться», башк. (БТДһ: 183) *ҡалйы-у* «уклоняться; затупляться». К. добр. *qalcıtaq,* кырг. *ҡалжоо-,* нуг. *ҡалуа-* «ашык уенында бәргеч ашыкны атып бәрү», «атып, тидерәлмәү» һ.б. К. Räsänen 1969: 225–226. Ихтимал, югарыдагы ике сүз белән гомогендыр.

**КАЛКАВЫЧ [ҡа°лҡаwы̆ч]** «поплавок», диал. **ҡалҡын, ҡалатҡы** (Тумашева 1992: 116) ~ башк. диал. (БҺҺ II: 130) *ҡалҡа*, мар. *калка*, чув. *хулха, хулкка, хулка* id. **Калкавыч** варианты көнб. кыпчакларда, к. ком. *ҡалҡувыч,* к.-балк. *ҡалҡыў̆чу* «калкавыч». *Калаткы*га параллель – алт. диал. (Баскаков 1966: 122) *калаткы*, каз. *ҡалтҡы* id. *Калка* варианты алт. *калка*, каз. диал. (ҠТДС: 186) *ҡалҡаҡ* < **ҡалҡаг* белән бердәй нигездән.

Барча вариантлар *ҡалҡ-, ҡалыҡ-* нигезеннән, к. **калык-у** тат. (ком.) вариантына ихтимал, монг. *халхавч* < *ҡалҡавч* «калкан» сүзенең контаминацион тәэсире бардыр (калкавыч калканга охшаш).

**КАЛКАН** «щит» < гом. төрки, бор. төрки *ҡалҡан, калкаӊ* id. ~ каз. *ҡалҡа* «япма», *ҡалҡан* «калкан», яз. монг., як. *халха,* маньч. *ҡалан, калка, калкан* «калкан, каланча; койма, читән; талта», як. *ҡалган* «ишек; ишек канаты», хак. диал. *каалка* «ян капка; ишекчек; ишек» > каз., кырг. *ҡалҡа* «япма, лапас; ишекле корылма» һ.б. Räsänen 1969: 227; ССТМЯ I: 367.

**Калка, калкан** сүзе абстракт «химая; сихер кайтару» мәгънәләрендә дә (каз., кырг., себ.) кулланылган һәм шул мәгънәдә рус сөйләшләренә дә (*калган*) кергән (Пекарский: 3271; Аникин: 242). Түбәндә *калкан* < **кагал-кан* «саклану, саклау чарасы» мәгъ. бор. төрки **ҡага-* «каплау, ябу, яклау» фигыленнән. **Калкан** сүзенә *халха монгол* «төп монгол» сүзе тоташа. К. **Кәлинкә.** К. Сафар ов: 56.

**КАЛКУ** «выпуклый; возвышающийся; высокий» – **калык-у** фигыленнән, к. аз. *галхыг* < **калкыг* «калку».

Дерив.: **калкулык; калкулан-у.**

**КАЛЛАП** «шут; шутник, балагур; профессиональный сказочник и потешник»; иск. (Троянский) «мошенник» < гар. *ҡаллāб* «әйләнүчән, үзгәрүчән; ялагай хадим-экиятче» ← *ҡлб* «әйләндерү, үзгәртү; әверелдерү; шигырьне һ.б. кирегә сөйләү», шуннан фар. *калб* > каз., ком., кырг., үзб. (ЎХШЛ: 155) *калп* «алдак; ялган; әверелдерү; юкны сөйләү (фольклор жанры – экиятнең бер төре, кырыгалдар экияте); язганны кирегә уку; метатеза, анаграмма», *ҡаллап* «каллап; алдакчы; ялган акча ясаучы» (чаг. тат. сөйл. *калыплау* «алдау»).

**Каллап** төрки хөкемдарның кәефен күтәрүче хадим булган, к. чув. (Федотов II: 308) *халлап* «ялагай ярлы», *халлапӑ* «көлдергеч экият» һ.б., к. **Калып.**

*Каллаб* сүзенең гар. *ҡуллаб* «алдакчы ялагай» варианты иске тат. (Троянский) *ҡуллап,* төр. *kullabi* «елгыр алдакчы, ялагай хезмәтче» сүзендә, арытабан рус. *холоп* ~ *хлап* «ялагай хезмәтче» сүзендә (к. Фасмер IV: 252) чагыла.

**КАЛЛӘН** (Ш. Маннур) «тихонько, осторожно» > удм. *каллен* id. ~ чув. *хуллен, хулен, хольан* < болг. **һалән* > мар. *олен, олэн* id. (к. Иванов, Тужаров: 146; Саваткова: 146) << гар. *каһилӓн* «ялкаударча; ашыкмыйча» ← *кāһил* «ялкау», к. **Каһил, Кайлән-ү.**

**КАЛМЫК** «калмык; название группы сибирских татар и нескольких башкирских родов» ~ башк. *ҡалмыҡ, ҡалмаҡ,* нуг., к.-балк., ком. *ҡалмуҡ,* каз. *ҡалмаҡ,* калм. *хальмг,* монг. *халимаг* «калмык (халкы)», рус. (Себердә 1607 елдан бирле билгеле) *калмак, колмак* «калмык», *колмаки белые* «телеутлар (алтайлыларның бер этнографик төркеме)», *колмаки чёрные* «җунгарлар һәм калмыклар» (к. Аникин: 240, 298).

Әбүлгази (хан һәм тарихчы, XVII г.) буенча, **калмык** дип татарлар мөселманлыкка кермичә калган төркиләрне атый башлаганнар. Ягъни **калмык** яисә **калмак** – *калу* сүзеннән. Тик бу этимология җентекле исбатлауга мохтаҗ. Һәрхәлдә **калмык** сүзе калмык теленнән килми. Хәз. рус этимологиясендә **калмык** сүзен *колимага, колымага* «күчмәнче арбасы, зур калама, шөкәтсез арба» сүзе белән баглыйлар (Фасмер II: 169–170, 291).

Икенче бер версия буенча, *калмык* < алт. *калйымак* ~ монг. *халимаг* «кызып китүчән, кызу холыклы» (чаг. тат. *калҗын*) сүзеннән, имеш. Безнеңчә, **калмык** сүзе диал. «ятим *калдырылган*» мәгъ. Шулай дип, мәс., Башкортстанның Борай районы

Калмык авылы кешеләре аңлаталар һәм тиешле хикәясен дә сөйлиләр. Чыннан да авыру-чирләрне, кимсетеп карауны, җитешсезлекне белдерүчән төрки *-мык* ~ *-мук* кушымчасы бар, к. **Боламык, Кызамык, Теремек**, диал. **Чыдамык** һ.б.

**Калмык, калмак** сүзләре Идел-Урал регионында топонимикада очраштыргалый.

**КАЛПАК I** (Будагов II: 21) «обложение, подать, дань» – дөресе «салым түләү урыны» булса кирәк < фар. *қалбгāћ* «үзәк, йөрәк (күч мәгъ.)»: *қалб* «йөрәк, калеб», *гāћ* «җыелу урыны». Шунысы кызык ки, Оренбург татарларын **каракалпак** дип атаганнар (Будагов), бу **каракалпак** халкы белән берничек тә баглы түгел.

**КАЛПАК II,** себ. (Тумашева 1992: 117) **қалбақ** «заглушка (самоварной трубы)», (ТТДС I: 189) «вид женского головного убора», «валяная шапка без наушников» > мар., удм., рус. *калпак, колпак* < гом. көнб. төрки *қалпақ,* төр. *kalpak*, аз. *ғалпағ* һ.б. «баш киеме» < фар. *кäллäпак* «баш каплагыч» (*кäллä* «баш», к. **Кәллә**, *пак* «кием, каплавыч»). Бу фарсы сүз төрки телләргә бик бор. заманнарда ук кергән, к. як. *халпаак* «бүрек», яз. монг. *xalbaang* «кызлар кия торган биек очлы бүрек». Бор. рус. (гом. слав., к. Фасмер II: 252) *клобук* «монахлар кия торган очлы бүрек»; хәз. рус. *колпак* «калпак бүрек» тур. Аникин: 299.

**Калпак ~ кäллäпак** сүзе төрки телләрдә берничә этимологик дублет биргән, мәс., Алтын Урда төрки телендә (Zajączkowski 1961: 323–342) *γalpaq* «бәбиләрнең беренче чәче», к. тат. **Калфак, Кәләбәк, Кәлпәк, Кәпәч, Тәлпәк.** К. ш. ук Будагов: II: 21; Doerfer III: 494–495; Федотов I: 218.

Дерив.: **калпаклы, калпаксыз; калпакла-у.**

**ҚАЛТА** «кушак, ремень с прикреплёнными кошельками» (к. Будагов II: 22), диал. (ТТДС I: 192, ТТДС II: 127) «вышитый кошелёк; карман; оборка», себ. (Тумашева 1992: 117) «кисет; карман», (Рамазанова 2001: 57) «варежки» ~ гом. кыпч., башк., алт. *қалта , халта* «калта, чунтай, дорба (ат җиме капчыгы)», каз. *қалта* «җылымның капчыгы – балык кереп җыела торган урыны», үзб., уйг., фар. *халта,* төркм. *ғалта* «калта, янчык; куык; посылка» < бор. фар. *халита* id. (дип исәпләнә). Бу сүзнең кайбер аерым вариантлары аңлатуга мохтаҗ: рус. *калита* «билбауга тагылган күн янчык, акча янчыгы» (ул каян килә?), мар., удм. *калта, калтак* «калта, кузак» (*-к* каян?) һ.б. Фасмер II: 168; Räsänen 1969: 227; Аникин: 240 (арытабангы әдәбият күрсәтелә).

Дерив.: **калталы, калтасыз.** К. **Калтаман, Калтан, Калчан.**

Безнеңчә, **калта** сүзе монг. телләреннән дә була ала, чаг. тунг. (ССТМЯ I: 460) *хали* «кисет».

**КАЛТАЙ-У** диал. «коробиться» < гом. кыпч., к. башк. (БТДҺ: 183) *қалтайыу,* каз., к.-калп. *қалтай-, қалтый-* «кәкрәеп кату» ← *қалта* «кәкре».

**КАЛТАК** иск., диал. (Dobr. II: 191) *qaltaq* «деревянная часть седла, остающаяся под накладкой», күч. «голый (о чём-либо, что обычно накрывается)» ~ каз., кырг. *қалтақ,* төр. *kaltak* id., күч. «ярамсак, теләсә кемгә бирелүчән хатын», чыгт. (Будагов II: 62) *қалтақ* «татарское седло из дерева» – «агач ияр», күч. «юньсез кеше; усал хатынның табан астында булган юаш, сүзсез ир». ЭСТЯ V: 236–237; Аникин: 240–241 (рус. *калтакá* «сакау ир» матдәсендә, бай әдәбият күрсәтелә).

**КАЛТАКАЙ** диал., (ТТДС I: 190) **қалдағай** «широкие лыжи без мехов» ~ башк. (БҺҺ II: 130; БТДҺ: 183) *қалтақай, қалтықай* (БТДҺ дөрес аңлатмаган: «мехлы чаңгы» диелә, хәлбуки элекке *гади чаңгы* мехлы булган – аның табанына уңай тарафын алга юнәлтеп сыер, болан һ.б. тиресен беркеткәннәр – ул тире тасмалары ырмау ролен үтәгән – артка шуышырга ирек бирмәгән) ~ як. *халтархай* «шома, шугак», *халтарый-* «шугаклау», *халтаң* «ялангач, киемсез». К. **Калтак, Калтаң.**

**КАЛТАМАН, картаман** (*угры картайса картаман була* диелә) «праздношатающийся бродяга, нищий; карманщик» – Максуди телендә *қалтаман* – сүгү сүзе; каз., тат. (Будагов II: 33, 66) *калтаман* «эшлексез»; «кесә карагы» ~ каз., к.-калп., кырг. *қарғаман* id., төркм. (ТДГДС: 48) *галтаман* «ярлы; сукбай», төр. *kaltaban* «жулик» фар. теленнән булса кирәк, к. **Калта**. Чаг. түбәндәгене.

**КАЛТАҢ** «беспокойный бездельник, праздношатающийся, нищий бродяга» (к. БТДҺ: 183) ~ к.-калп., кырг. *қалтақ, қалтаң* «калтырап торган, мәлҗерәгән кеше; юньсез, ләкин тиктормас бәндә»; чув. *калттак,* мар., удм. *калтак* «мескен; гарип; эшкә яраксыз кеше» сүзе дә бу рәткә карый булса кирәк; ләкин як. *халтаң* (к. **Калтакай**) «ялангач, юка», чыгт. (Будагов II: 62) *қалтағай* «түбән ярамсак».

**КАЛТАШ** (Тумашева 1992: 117) «большой котёл», шуннан рус. (Аникин: 241) *калташиха* id. – *каңыл ташт* «чуен тас» сүзеннән микән? К. **Каңылтыр. Калташиха** дигән зур сука төре дә билгеле (Н. Халиков китабында күп тапкыр искә алына).

**КАЛТЫР** – имитатив дрожи, дрожанию – гом. төрки характерда. К. түбәндәге сүз. Чаг. **Кылтыр**.

**КАЛТЫРА-У** «дрожать» – алт., гом. кыпч. *қалтыра-, қалтра-* (к. Радлов II: 260), угыз., монг., чыгт. *γaldira-, γaldıra-* id., *қалтыр* ← **қалт* тәкълиди сүзеннән (**калтыр-калтыр, калтыр-колтыр килү** һ.б.). К. тат. диал. **кәлтерә-ү** «калтырау», **кәлтерәк, калтырак** «калтыранучан (кеше)». Удм. *колтыр-колтыр, колтыртыны* «калтырдау» < тат.

Дерив.: **калтыран-у, калтыраш-у, калтырат-у; калтыравык, калтырак.**

**КАЛ-У** «оставаться, остаться» < гом. төрки *қал-, қаал-*, як. *каалы-*, *хаал-*, төркм. *ғаал-*, чув. *йул-* < *йол-* < болг. **йал-* < **киал <** *қиал-* id., кайбер телләрдә «үлү» мәгънәсе бар; Будагов II: 23–24; Räsänen 1969: 224; Федотов II: 483.

Дерив.: **кала, калдык; калдыр-у; калма.** Гомумән **кал-** төрки телләрдә иң актив кулланышта йөргән күпмәгънәле нигезләрнең берсе. К. **Калыш-у.**

**КАЛУШ,** диал. **галуш, галуша** «галоша» < рус. диал. *калош, калоши*. *Галоша* сүзе ит. *galoschio* < лат. *gallica* «галлар аякчуы» сүзеннән (Преображенский I: 286). Бүтәнчә аңлатманы к. Фасмер II: 389.

**КАЛЧАК** себ. (ЗДС: 384) «большое родимое (или другого происхождения) пятно, неестественная лысина на голове», (ЗДС: 381) **калы, кал** «красноватое (родимое) пятно» ~ чыгт. *қалйақ* «атның маңгаендагы сирәк йоннары», алт. диал. (Радлов II: 256) *калјақ, калҗақ* ~ бор. монг. (Поппе 1938: 289) *qalčaq* «кашка, маңгае ак», *qalčiγaj* «кырчынлы» һ.б. Бу сүзләрнең нигезен гар.-фар. *хал, хол* «зур миң» белән чагыштыралар. Ләкин сүзнең таралышы гарәп-фарсыныкыннан киңрәк, к. фин. (Räsänen 1969: 225) *kaljn* «таз».

Руслардагы атаклы *Колчак* дворян фамилиясенең безнең **калчак**тан килүе ихтимал. Һәрхәлдә ул фамилиянең төрки икәнлеге билгеле (рус. этимологик сүзлекләрдә **колчак** < төр. *қолчақ* «кечкенә кул» һ.б. фаразлар әйтелә, ләкин рус. *о* тат. беренче иҗектәге иренләшкән *а*°дан килә ала, моңа аналогияләр-мисаллар күп кенә).

**КАЛЧАН** «колчан» – төрки телләрдә бу сүз теркәлмәгән, тик рус. (көнч. слав.) *колчан* (> укр. *ковчан*) тат. теленнән дип исәпләнә. Башк. *қальян, қалта* (Бурангулов М. Сәсән аманаты. Өфө, 1995: 45, 75) «калчан, теркеш» шикле (М. Бурангулов үзе уйлап чыгармадымы икән?). *Калчан* сүзенең *калта*дан булуы тур. к. Добродомов И.Г. К этимологии слова *колчан* // Этимологические исследования по русскому языку. Вып. IX. Изд. МГУ, 1981: 70–89 (автор бу сүзне чув. теле белән бәйләргә тырыша). К. диал. (м.-кар., ЗДС: 270) **калча** «калта». Безнеңчә, әгәр **калчан калта** белән бәйле булса, фар. *халта-и-җәң* «сугыш калтасы» сүзеннән үзгәреп килеп чыга ала.

Рус. диал. *колчат* «калчан» тур. к. Аникин: 299 (автор бу форманы рус телендә килеп чыккан дип карый).

**КАЛЫ** (ЗДС: 384, «Аккүбәк» дастаны теленнән) «где; куда, как, если» бор. төрки (ДТС: 411, 413, 635) *qalï, qaktï, xalï* «ничек; әгәр», к. КБтә *Kimin erdami bolsa, ati jörir, qali bolmasa erdam, atsiz qarir* «Кемнең ирдәме булса аты-даны йөрер, кемнең ирдәме булмаса атсыз картаер». *Калы* сүзе бор. төрки әдәбиятында киң кулланылган, хәз. телләрдә сирәк очрый.

**КАЛЫК-У, калк-у** (**калка,** ләкин **калыкты**) «всплывать, всплыть; восходить; выходить наверх), диал. (Будагов II: 23, ДС I: 74) «вынырнуть, всплыть» < гом. кыпч., төр. *қалқ-*, *қалқы-*, аз. *галх-* id. тат. диал. (Тумашева 1992: 117) **калы-, калый-** «кыялау; күтәрелү» < гом. төрки, гом. монг. *қалы-*, тув., хак. *халы-* «калку, йөзү, кыялау, күтәрелү, сикерү» сүзенең интенсивлык дәрәҗәсе; к. бор. төрки (ДТС: 411–413) *qalï-* «очып китү, күтәрелү, йөгерү», *qalït-* «күтәртү», *qalïq* «күк; югары этаж»; к. ш. ук себ. тат. (Тумашева 1992: 117) **калтай-у** «күтәрелеп чыгу», **калтырма** «күтәрмә, ишегалды баскычы». Räsänen 1969: 227. К. **Калын.**

Дерив.: **калкын-у, калкыт-у**; диал. **калыкма**. К. **Калкавыч, Калку.**

**КАЛЫМ I**, диал. (ТТДС I: 190, 228; БҺҺ II: 131; Тумашева 1992: 117–118) **калын, калың** «калым, вено, выкуп за невесту» ~ чув. *хулăм* < *холăм* < болг. **һалым, һалың* > мар. *алны, олно* id. < гом. кыпч. *калым, калын, калың* (һәр төрки телдә дияр-

лек шул вариантлар бар) < бор. төрки (ДТС: 442, 675) *qalïŋ* id. < бор. кыт. *ka liän* ≈ *цзялян* id. (?); икенче версия буенча, бор. кыт. *ka lem* «бирнә сандыгы» сүзеннән (к. Федотов II: 354–355), монысы тагын да шиклерәк; үзб., таҗ. *қылың, қилиң* «калым» өченче версиягә этәрә. Будагов II: 23; Радлов II: 230; Räsänen 1969: 226; ЭСТЯ V: 240; Аникин: 243.

Дерив.: **калымлы, калымсыз.** Кайбер сүзлекләрдә **калым** һәм **калан** сүзләре бутала.

**КАЛЫМ II** диал. (Тумашева 1992: 117) «водоём со стоячей водой (после паводков или обильных дождей); болото; трясина» > удм. *калым* id. (к. Зверева: 110–116; Розова 1969) **кал-у** фигыленнән булса кирәк.

**КАЛЫН** «толстый (о плоских предметах)» < гом. төрки, бор. төрки *қалын, қалың* > чув. *хулăн, холăн*, аз. *ғалын,* як. *халың*, тув. *қылын* һ.б. «калын, юан; куе; ишле» ← бор. төрки *qal-, qalı-* «үсү, зураю, күтәрелү» (тәүдә бу сүз йон тур. әйтелгән). Радлов II: 240; Будагов II: 24–25; Пекарский: 3276; Федотов II: 355. Ясалышы ачык түгел.

Актив деривацияле: **калынай-у; калынлык.**

**КАЛЫП** «колодка; форма» > чув. *калăп* (күтелгән **хулăп* юк), мар., удм. *калып, халып,* болг. **һалып* > мар. *олып* < гом. төрки *қалып, қалб,* үзб., таҗ. *қолиб,* үзб. диал., к.-калп. *қэлип* һ.б. гар. *қāлиб* < грек. *χαλοπους* «агач аяк»: бу сүз баштан ук аякчу калыбын белдергән. Шул ук грек сүзенә **калибр** «утлы корал көпшәсенең диаметры» сүзе дә тоташа. (Преображенский I: 288; Фасмер II: 171; Kluge: 462); бу сүз «пуля кою калыбы» мәгъ. барлык себер телләренә таралган; рус. *калыпь, калибь, колыпь* һ.б. тур. к. Аникин: 243; Федотов I: 217.

**КАЛЫПЛА-У** диал. (трбс.) «обмануть (особенно – женщину, девушку), овладеть обманом» < **калпыла-у.** Чаг. каз. *қалпы* «ялган; ялагайлык» < гар. *қалб* id. К. **Каллап.**

**КАЛЫШ-У** «отставать; уступать кому, чему в чём-либо» < гом. кыпч. *қалыш-* id. < бор. (ДТС: 413) *qalïš-* «арттарак калу»; бу сүзнең борынгылыгы як. *хаалсыс-* id. (← *хаал-* «калу») мисалыннан да күренә.

**Калыш-у,** әлбәттә, **кал-у** фигыленең урт. юн., аерым мәгъ. алган; чаг. ш. ук **биреш-ү.**

**КАМ** «шаман» (это слово к XX веку в народе было забыто, у сибирских татар сохранилось только в дериватах) < алт., урта төрки, бор. төрки *qam, qaam*, хак., тув. *хам* id. (Räsänen 1969: 228; ДТС: 413–415) ~ чув. *йом, йум* «ырым, ырымлау». **Камнар** тур. тәүге мәгълүмат XIII г. П. Карпини һәм В. Рубрук (к. Плано Карпини, Вильгельм де Рубрук: 10, 93) язмаларында бирелә: «куманнар тәңрене *кам* дип атыйлар»; «төньяк илләренең төп хөкемдары... *Кон-хам* ... *хам* «күрәзә» дигән сүз» һ.б., чаг. себ. тат. (Тумашева 1992: 118, Радловтан) *камай-* «күрәзәләү» . *Кам* сүзен Рамстедт (Ramstedt 1949: 90) кор. *kam* «инспектор» сүзе белән чагыштыра; баштагы камнар хатын-кызлар булган (к. Малов 1912: 62). ЭСТЯ V: 240–242 (*кам-* «ыргу, кыялау» фигыле белән баглы диелә, к. як. *хамна-* «камлау; очыну»). Рус. диал. *кам, камлак, камлать* тур. к. Аникин: 244, 250. К. **Кама.**

**КАМА I** «выдра» ~ чув. *хăма* «кама; кондыз» < болг. *һама* > мар. *ама, ома, кома, кама*, удм. *кама* id. бор. төньяк кыпч. телендә килеп чыккан, тәүге формасы *кам-ау* < **кам-а-ғ* «камлау, ырымлау» булса кирәк; кама тиресе белән *камлаганнар*; к. себ. **камнау** (< *камлау*) «кама», чулым. *камноц*, хак. диал. *камнуус* < **камлагыч*, шор. *камнагы* < *камлагы*, алт. *камлаа, камдуу* < **камлығ* «кама» – бу җәнлек сихерле дип исәпләнгән (чөнки артка таба йөзә белә). Уйг. *қама* «кама» < тат. Räsänen 1969: 299; Федотов II: 323–324.

**КАМА II** диал. (Арсланов 1988: 80) «железный клин» ~ к.-балк., төр., гаг. *қама* «киң чөй; киң һәм озын хәнҗәр», добр. *qama* «хәнҗәр; мүк тыгу өчен яссы чөй; уенда бер пуан (очкó)» ~ фар., көрд., груз. (Будагов II: 25) *қāмā* «зур хәнҗәр». К. **Комачау.**

**КА́МА III** – река Кама < рус. < удм. теленнән (удм. *кам* «зур елга»). Татарлар Каманы *Агыйдел* һәм (Агыйделгә кушылганга кадәрге агымын) *Чулман* дип атаганнар. К. **Чулман.**

**КАМАКЫШ,** диал. (ТТДС I: 191; 228) **камаш,** «нёбо, твердое нёбо; свод печи» ~ башк. (БҺҺ II: 131; III: 104) *қамашау, қамағаш, қамашақ* id., чув. *кăмака,* мар. *комага* < *камага* > **камака* ~ алт. *кäмäгä,* шор. *кäбäгä,* каз. диал. *кемәгә* «мич, учак; тандыр; җиргә чокып ясалган мич» сүзеннән; бу сүзне Г. Рамстедт (Ramstedt 1949: 90) кор., яп. *kama* «чүлмәкче миче» белән чагыштыра.

Тат. *камакъыш* болг. теленнән, **камака-шы* < **камака-сы* формасыннан булса кирәк; алт. һ.б. палаталь вариантлар икенчел булырга да мөмкин. Гомумән, бу сүзнең тарихында ачыклыйсы моментлар күп.

**КАМАЛ** «окружение врага; осада», «облава» ~ чыгт., гом. кыпч., уйг. *камал*, үзб. *қамол* id., төр. *kamal* «кальга». К. **Кама-у, Каму.**

Дерив.: (диал.) **камаллы; камалла-у; камалчы.**

**КАМАУ [қaᵒmaw]** «почёт» < *қамғау*, к. тув. *қамға* – «яклау, явыз көчләрдән, сихерчедән саклау» ← *кам* «хәстәр» ~ монг. *хам* id.

**КАМА-У** «окружать (врага)», диал. (ДС III: 72; ТТДС I: 191) «подавлять; загонять в кучу», (ДС I: 75) «окружить вниманием, почитать» ~ кр.-тат. (Dobr. II: 192) *qamala-* «кама кадау; камау, бер почмакка кысрыклау; эт (көтүне уратып) өрү» ~ гом. кыпч., уйг., үзб. *қама-,* каз. (Будагов II: 409) *қама-* «халаекны җыю», *қамау* «кәртә-кура, ихата» ~ монг., бур. *кама-*, *хама-* «уратып алу, камау», чаг. ш. ук. төр. *kapa-,* чыгт. *каба-*, төркм. *габа-* «дошманны камау; кулга алу, тоту». Чаг. як. *хаам* «киртә, чик, чикләү».

Дерив.: **камал-у, камат-у, камалыш,** иске әд. **камак** «камал, камалыш». К. **Камал, Камуг, Комача-у.** Чаг. **Кама I, Камчы.**

**КАМАШ-У** «(временно) выходить из строя, перестать функционаровать» (*күз камашу* «ослепление от яркого света», *теш камашу* «набиваться – о зубной оскомине») ~ гом. кыпч., уйг., үзб., төр., гаг. *қамаш-*, аз. *гамаш-* id. к.-балк., куман., каз., уйг., чыгт., монг., бор. төрки (ДТС: 414) *qama-* «камашу; кителү, үтмәсләнү» сүзенең урт. юн.; к. ш. ук эвенк. *камни-* «кысылдыру, сыгу», бур. *хам-* «китеп алу».

Тат. сөйләшләрендәге (трбс.) **қамық-у** (*камыгу*) «камашу» ~ нуг., каз., кырг. *қамық-* «кыенсыну; җәберсенү», бор. **кам-* фигыленең интенсивлык формасы һәм шуннан чув. *йӑмӑх-* «(күз) ару, сукыраю» килеп чыккан; чув. *йӑмӑл-* «талчыгу» < **камыл-,* ягъни *кам-* фигыленең төш. юнәлешеннән. К. ш. ук мар. *йымаш-, йымык-* «камашу, камыгу».

Г. Рамстедт (Ramstedt 1949: 92) *кама-* фигылен кор. *kamgida-* «булдыралмау» сүзе белән чагыштыра. Räsänen 1969: 228; ЭСТЯ V: 242–243.

Дерив.: **камаштыр-у.**

**КАМӘРИЯ [кәмәрийә]** «лунный год (применяемый в религиозном календаре)» < гар. *қамӓрийӓ* id. – «айга бәйле» ← *қамӓр* «ай».

**КАМӘТ** «верхняя часть тела (человека); рост; туловище» < гар. *қāмӓт* id. Тимергалин: 225. Чаг. **Икамәт, Кыям.**

Махсус фразема: **камәт төшерү** «намазга бастыру догасы».

**КАМБАЛА** «рыба камбала» – рус этимологик сүзлекләрендә элек төр., тат. **калкан балык** сүзеннән дип аңлату очрый иде. Төрекләр чыннан да аны шулай атыйлар. Ләкин монда очраклы охшашлык кына: рус. *ка́мбала* вариантында карел. *kampala,* фин. *kampela* id. сүзеннән. Аникин: 245.

**КАМГАК,** диал. (Арсланов 1988: 126) **қамбақ** «перекати-поле (растение)» ~ гом. кыпч. *қамғақ,* монг. *камкак,* ком. *қаммақ,* каз. *қаңбақ,* бор. төрки (ДТС: 415) *qatyaq* id. < *қаңғак* бор. **каң-* «тәгәрәү» фигыленнән (к. *каңгы* һәм чаг. *тәгәрәй үләне* «камлак»). Кр.-тат. *қамғақ* «дөя үләне» диелә. Төркм., төр. *камак* < *қаммақ* < *қаңмақ* булса, бу сүздә *-мақ* кушымчалы вариант та күрергә мөмкин. ЭСТЯ V: 244–245. Рус. *канмал, канфул, хамхул* «камгаксыман үләннәр» монг. телләреннән, к. Аникин: 257: 302, 607. К. ш. ук **Каңгыл II.**

Дерив.: **камгакла-у** «камгак кебек тәгәрәү, өерелү».

**КАМЗУЛ** «камзол» > чув. *камсул,* мар. *камчол*, удм. *камзол, камзул* id. рус теленнән; рус. < ним. *Kamisol* < ит. *cammicinolo* «күлмәкчек», *camisia* «эчке күлмәк» сүзеннән, бу сүз исә **Камис** (к.) белән бердәй.

**КАМИЛ I** «совершенный, совершеннолетний» (более правильное написание – **кямил**) < гар. *кāмил* id. Тат. сөйләшләрендә (к. ЗДС: 271) **кямил** «бөтенләй, тәмам», Батырша хатында (XVIII г. уртасы) **кямиллә-ү** «башкару» (*чиру кешеләре пахутка барып, каравыл тормак эшене кямилләйләр*).

**КАМИЛ II** диал. (Г. Әпсәләмов) «камвольный» – рус яки ним. теленнән: рус. *камволь* < ним. *Kammwoll* «тарап алынган кәҗә мамыгы» (*Kamm* «тарак», *Woll* «мамык, йон»).

**КАМИС** «девичье платье, рубашка до колен (надевается на пару с шароварами **сирвәлә**); бе-

лый атлас для такой рубашки» < гар., фар. *қамиҫ* < грек. *καμιςου*, герм. *kamitja* (>> ним. *Hemd*) «кыска күлмәк, ирләр күлмәге», шуннан лат. *camisia* «эчке кием, күлмәк» (> фр. *camise*, инг. *chemise*) ахыр чиктә *кам//чам* «җитен» мәдәни тамырыннан. **Чәмчә** (к.) сүзе белән тамырдаш. К. Poucha: 47–48.

**Камис** белән **сирвәлә (сәрвал)** кию мөселман кызларына элек-электән тәкъдим ителгән, к. EI: 732–753 (*Libas* мәкаләсе).

**КАМКА I** «камка, шёлковая ткань с блестящими узорами, цветами» < гом. кыпч., алт. *камка*, кр.-тат. *кимха*, үзб., таҗ. *кимхоб*, уйг. *кимхап*, хак. *канфа,* монг. *ханфу* < кыт. *һаң-фоу* id. К. ш. ук як. *хампа* «Кытай атласы». Икенче бер версия буенча, фар. *katha, kincob, kimkha* < кыт. *kin qua* > *chin xwa* «алтын чәчәк» (A Survey… III: 2006). Рус. *камка, канфа* id. < бор. уйг., куман. *камкы*, рус. (Будагов II: 26) *анфа* турыдан-туры кытайчадан булырга мөмкин (төрле карашлар тур. к. Аникин: 249–250). К. **Камка II, Камчат.** Чув. *канихва* «камка» иске тат. *канфә* вариантыннан. Чаг. **Хәтфә.**

**КАМКА II: камка таракан** «божья коровка» ~ башк. *камфаратыр, камкакүрей* id. (БҺҺ II: 76–77) **камка I** сүзеннән.

**КАМСА-У,** иск. **кабса-у** «охватить в клещи (войско противника)» ~ госм. *камса-*, чыгт. *капса-* id. (Боровков 1963: 199). *Кама-у* һәм *кып-* тамырларының контаминациясеннән.

**КАМУГ, каму** иск. «все полностью, все без исключения» бор. уйг. теленнән, к. бор. төрки (ДТС: 414–415) *qatïγ, qataγ* ~ бор. монг. *qatuγ* «бөтенесе бергә; җәмәга» алт. *қамық* «масса» һ.б. формасына караганда, *камуг* «җыен, җыелыш» *камы-, қам-* «җыю» тамырыннан, һәм к. як. *хамый-, хомуй-* (~ эвенк. *қамый-*) «бергә җыю, өю», бор. монг. *qatи-* «бергә китереп өю» һ.б. Бу *кам-, каму* тамыры тур. төрле фикерләр әйтелгән: берәүләр аны ир. *katag* «күп» сүзе белән, икенчеләр **кама-у** (к.) ~ кор. *kamda* «уратып алу» сүзе белән чагыштыралар. Бор. төрки (ДТС: 414–416) *qataγan, qataγип, qatïγип, qatиγип* «бергәләшеп». Монг. телләрендә дә *қам ~ хам* тамыры бик продуктив. Поппе 1938: 291; ССТМЯ I: 371; ЭСТЯ V: 243–244. К. түбәндәгене.

**КАМУТАН** диал., иск. (Максуди телендә, XVI г.) «общество, общественная организация» ~ к.-балк. *хамудал,* алт. *комудал* «җәмәгать, җәмгыять; җәмәгать таләбе», госм. («Мөхәммәдия» китабында) *камудан,* тув. *хамытан* «җәмәгать» һ.б., алт. диал. («Маадай-Кара»: 73, 106 һ.б., берничә тапкыр) *комуда-* «зар, зарлану», *комудалы* «зарлы» ← *кому* «зар» (бу сүзләрдә *о* < *а* регрессив ассимиляция күренеше) < *қаму, камуг* «бөтенесе; җәмгыять, халык зары»; алт. (Будагов II: 93–94) *комыда-* «җәберсенү» ~ монг. *хомидаху* «кайгыру», *кумидал* «җәбер, золым» һ.б. Ошбу *камуда-, камудал* сүзләренең ясалышы аңлашылып бетми, чаг. чыгт. *қамту, камуту* «ханга каршы закон буенча бергәләшеп», КБтә *камыт-* «бергәләшеп эш этү» (*камы-, камудигән* фигыль булган микән?). Räsänen 1969: 229.

**КАМФАР** «камфара» к. **Канәфер.**

**КАМЧАТ** «вид ткани; вид пушного зверя» (к. мәкаль: *картлар сүзен отып ал, камчат күрсәң атып ал*) < рус. *камчатый, камчатный* «камкадан эшләнгән, камкасыман» сүзеннән, бу сүз үз чиратында **камка** < тат. *қамқа* (к.) нигезеннән. Җәнлек атамасы мәгъ. функция буенча күчерелгән: камка да, кыйммәтле мех та кием кырпуына кулланылган (**камчат бүрек** «матур кырпулы бүрек»).

**Камчат** сүзе тат. телендә күптәннән килсә кирәк – аның **қымшат** варианты да бар; уйг. **кәмчәт** id. татарчадан бугай.

Рус. *камчат, камчатка, камчатый* тур. Аникин: 252.

**КАМЧАУ I [қа$^{o}$мчаw]** (ТТДС I: 191), **камасау** (БТДҺ: 184), «гангрена; экзема; рожа (разные кожные болезни)» ~ чув. *хунчав* < *хончав* < **каңчаw* ~ төркм. *камчав, камчов, гамчав* «камчау; күз чепиләнү һ.б.ш.» < бор. төрки (ДТС: 415) *qatčïγи* > алт. *қамчуу, канчу, камча, камҗа* һ.б. id. (к. ЭСТЯ V: 246–247, гомумән материалы ярлы). Тат. **камчау, камачау үләне** (ТТДС I: 595) – камчау чирен шул үлән (ярут, тайтояк һ.б.) белән дәвалау нигезендә туган атама. Чир үзе якын кардәшләр җенси кушылудан (инцест) дип исәпләнгән.

*Камчаw* гомуми фонетик закончалык буенча < **қамчаг-у* яисә *қамча-гу* нигезеннән, к. бур. *хамшаг* «камчау, эпидемия», монг. *хамшиг* (> тув. *хамчык*) «үләт» ← **қам* тамырыннан, к. калм. *hат ~ гам* «маңка авыруы; мал үләте», бор. монг. *хата-* < *qata-* *кама-у* «кычулы булу, чирләү» һ.б. Чаг. **Канча-у**.

Рус. (XV г. билгеле) *камчуг, камачуга* «төрле чир, тырнак чирләре» тур. Аникин: 252 (бу бапта арытабангы әдәбият күрсәтелә).

*Камчау ~ камачау* бер яктан, **камаш-у** (к.), икенче яктан, **комачау** (к.) сүзе белән баглы булырга тиеш. Ләкин моны эзлекле рәвештә исбат итү кыен – баглавыч материал җитенкерәми. Чаг. **Каңчаш-у**.

**КАМЧЫ** «плеть, кнут» < гом. кыпч. *қамчы* (к. Радлов II: 493–494), чыгт., уйг. *қамчи* ~ тув. *кымчы*, хак. *хымчы*, як. (Пекарский: 1392), *кымнјы,* тув., кар., кырг. *қамчы* «шаман чыбыркысы» (кар. һ.б. *қамчы* «шаман, кам»), ком. *қамучу,* нуг. *қамышы*, нуг., каз., к.-калп. *қамшы,* таҗ., үзб. *қамчин* < яз. монг. *қамчин* id. ЭСТЯ V: 247–248. Рус. *камча, камчи, камчук* «камчы» тур. к. Аникин: 250–552. Гомумән – ачык түгел.

**Камчы** тәүдә ау коралы булган (аның белән ат өстендә куып сайгак, карсак, бүре, төлке аулаганнар) һәм шуннан бу сүзне бор. төрки (ДТС: 413–414) *qat-* «аяктан егу» сүзеннән чыгаралар. Ләкин *-чы* кушымчасы кешене белдерә һәм **камчы** сүзе **камчы чыбыркысы** тәгъбиреннән эллипсис була ала.

**КАМЫЛ** «стерня» > удм. *камъл* (Насибуллин: 118), чув. *хăмăл* id. < гом. кыпч. *қамыл* «камыл, камыш», шуннан ук башк. диал. *қамыл,* башк., тат. *қамыр* (*камыр чийә, камырлаwык, камырлык*) «дүләнә» (к. БҺҺ II: 132; ТТДС I: 595) < иск. фар. *каһи мыл* «ук сабы; эче куыш сабак», яисә *каһи мури* «корыган сабак», к. башк. диал. *қамырый* «каудан, корыган сабак», төркм. (ТДГДС: 109) *кемил* «дөге камылы».

*Камыл ~ камыр* ир. телләрдән бик бор. заманнарда ук алынган булса кирәк, шуннан **камыш** сүзе дә килә.

Дерив.: **камыллы, камылсыз; камыллык; камыллан-у.**

**КАМЫР,** иске тат. (Троянский I: 52) **хамыр** «тесто» ~ гом. кыпч. (куман.) *қамыр*, чыгт. һ.б. *хамыр* < гар. *ḫамӣр* «әчегән» сүзеннән, **хәмер** сүзе белән тамырдаш.

*Камыр батыр* ~ мар. *Ненчык батыр* ~ чув. *Чӳста паттăр* ~ як. *Тиэстэ боотур* экият образы игенчелеккә күчүгә пропаганда булып тора: камыр ашлары ашаган кеше көчле була янәсе.

**КАМЫТ, хамыт** «хомут» ~ чув. *хăмăт, хамăт* < болг. **һамыт* > мар. *амыт, омыт, омыта* ~ гом. кыпч. *камыт,* алт. *камыт* < монг. *хомууд* «камыт» бу сүзне башк. диал. *кум* «эчерге, ияр астына салына торган киез» < үзб., уйг., алт., кырг. *қом,* бур. *хом* «дөя ияре» сүзе белән бәйләргә мөмкинлек бирә. К. ш. ук фар. *хамут* «камыт, җигүле ат».

Шул ук вакытта *камыт* сүзенең барлык слав. телләрендә барлыгы, слав. телләреннән лит. һәм ним. телләренә кергәнлеге билгеле (Богородицкий В.В. Слово *хомут* в индоевропейских и урало-алтайских языках // ИОАИЭ, т. XI, вып. 2. Казань, 1893: 1–8), к. ним. *kummet*, венг., рум., слов. *ham* «камыт».

Тюркологиядә *камыт* сүзен русчадан дип күрсәтү гадәткә кергән, к. Сергеев Л.П. Изоглоссные явления русских лексических проникновений в чувашский язык // Уч. зап. ЧНИИЯЛИ, Чебоксары, 1966: 113–130. Ләкин мари теле материалы *камыт* сүзенең бор. болг. телендә үк булганлыгын күрсәтә. Болгарлар – элекке арбалы күчмәннәр – камытны руслардан үзләштерделәр микәнни? Федотов II: 325 (этимологик проблеманы җавапсыз калдыра).

Безнеңчә, **камыт** сүзе скифлардан калган сүз, к. ягн. *kata* «муен» (*katot* «муеннар») < бор. һинд-ир. **kata* «муен», санск. *katavanta* «муенса, камыт» (ЯТ: 270).

**КАМЫШ** «камыш; рогоз» ~ чув. *хăмăш, хумăш* < *хомăш* < болг. **һамыш* > мар. *амыж, амыш, омыш*, удм. (Насибуллин: 118) *камъж* id. < гом. төрки *камыш*, кар., уйг., бор. төрки (ДТС: 415–416) *qamiš*, нуг., каз., к.-калп. *камыс*, як. *хамыс*, төркм. *гамыш* һ.б. id. М. Рясянен буенча, бор. төрки, уйг. *кам-, кым-* «тирбәлеп, җилфердәп тору, кымшау» (уйг. *қамша-у*) сүзеннән (Räsänen 1969: 230). Безнеңчә, *камыш* сүзен *камыл* сүзеннән дип уйларга берни дә комачауламый. К. ш. ук уйг. *қомуч* «камыш» < бор. **қамулч* (беренче иҗектә *а* > *о* икенче иҗектәге *у* тәэсиреннән, мондый регрессив ассимиляция уйг. теленә хас): **-лч* > *-ш* төрки телләрдәге **-л* > *-ш* күчешенең башлангыч этабын чагылдыра. К. **Камыл.** ЭСТЯ V: 249–250. Рус. *камыш* (< төрки) тур. Фасмер II: 176.

Рус. сөйләшләрендәге *камыш* тур. к. Аникин: 252–253 (шунда ук әдәбият).

Дерив.: **камышлы, камышлык.**

**КАН** «кровь» < гом. төрки *қан*, бор. уйг. *қаан*, себ. тат. (Старчевский) *қаған* id., к. ш. ук як. *хаан-* ~ төркм. *гаан* ~ чув. *йун* < *йон* < **йан* < **кйан* «кан»; к. ш. ук эвенк. *һāң-* «канау» (ССТМЯ I: 372). Бик ихтимал, бор. *қāң-* «канау, яралану» фигыленнән *қāңан* (яисә *қāңгын*) «кан» килеп чыккандыр. Будагов II: 26–27; Мухамедова 1973: 112–113; ЭСТЯ V: 251; Федотов I: 486.

**Кан** сүзеннән күп гом. төрки нигезләр ясалган, к. **Кана-у, Кан-у, Канык-у;** диал. **Кансыра-у, Канчаш-у** һ.б.

**Кан көн** «среда» ~ чув. *юнкун,* мар. *вүргече*, удм. *вирнунал*, морд. М. *вяржи*, коми. *шӧрлун* – барысы да «кан + көн» структуралы «чәршәмбе» мәгъ. сүзләр (к. Федотов 1962: 247). Идел Болгарында бишкөнлек атнада бу терлек сую көне булган, дип уйлыйлар, чаг. фар. *чаһаршамбāи-сурх* «кызыл чәршәмбе». Болгардагы бишкөнлек атна системасы хәзәрләрдән алынган булса кирәк, хәзәрләр исә аны сугдлардан (болары бор. фарсылардан) алганнар. **Кан көн** мәгъ. сүзләр бор. Мисырда да булган.

**КАНА, канә** «где уж» (вводное слово с оттенком сожаления по поводу невозможности чего-либо) < иске уйг. *қанә, қәнә* id., төп. мәгъ. «кайда, канә» ~ бор. төрки (ДТС: 418–419) *qana, qanı, qanju, qanu, xaju* > төр. *hana, hanı* id. һ.б. ← бор. төрки *qan', qanju* «кай, кайсы» сүзеннән, к. шуннан ук башк. *қайныһы* < *qanjusu* «кайсы». К. **Кай, Кандый, Кани.**

**КАНАТ** «крыло» < гом. төрки *қанат,* төркм. *каанат,* аз. *гәнәт,* сары уйг. *кыйнат,* як. *кынат, кыньат* «канат» < бор. монг. *qana* «каурый, кыяк» сүзенең күп. формасы дип исәпләнә (Räsänen 1969: 230). Ләкин чаг. фар. *қанāт* «җилкән, тирмә канаты», гар. *җāнāх* < *гāнāх* «канат». Чув. *çунат* < *çонат* < болг. **җанат* «канат» та гадәти түгел (чув. *йунат* булырга тиеш иде). ЭСТЯ V: 252.

Дерив.: **канатлы, канатсыз; канатлан-у.**

**КАНАУ [қа°naw]** «канава» – рус. диал. *конов, канов* «канау» сүзеннән чагыштырмача яңа алынма, к. ш. ук чув. *канав*, мар. *канау* һ.б. Рус сүзе XVIII г. хөкүмәт авылларны төз урамлы, канаулы итеп төзеткән чорда таралган; рус теленә бу сүз грек теленнән кергән һәм *канал* сүзе белән тамырдаш. Фасмер II: 177.

**КАНА-У** «кровоточить» < гом. төрки *қана-*, *хана-* ~ чув. *юна-* < *йона-* id. *қан* (к.) сүзеннән, әлбәттә.

**КАНӘГАТЬ,** диал. һәм иск. **канигать** «доволен достигнутым; неприхотлив» – иске **канәгатьле** ~ **канигатьле** сүзеннән эллипсис, югыйсә гар. *қанā‘ат* «булганына ризалык, нәфессезлек» (исем), ә менә иске **канигъ** «канәгатьле» гарәпчәдә дә сыйфат.

Дерив.: **канәгатьсез; канәгатьлек; канәгатьлән-ү; канәгатьчел, канәгатьчелек.**

**КАНӘФЕР**, диал. (ТТДС I: 223; Тумашева 1992: 126) **қәләмпер, қәләмфер** «гвоздика» > чув. *калемпĕр*, мар. *каламбыр*, удм. *канафыр* id. ~ үзб. диал. (ЎХШЛ: 155), кырг. *калямпир* «һәртөрле хуш исле матдә» ~ рус. *кануфер, калуфер*, бор. рус. *калафуръ* һ.б. id. ахыр чиктә гар. *әл-кāфӯр* «камфара» > иске тат. *кафур* id. (ш. ук аклык символы). Бу сүз исә бор. һинд. *karpūras* сүзеннән (Срезневский II: 1181); ә бу, үз чиратында, австроазиат (кхмер һ.б.) телләреннән (Kluge: 464); **кәләмпер** варианты гар. *қарāнфул* вариантына кайтып кала, к. ш. ук ним. *Kampfer*, ит. *Canfora* > рус. *камфора, камфара* «хуш исле ак сумала». Бу сүзләр – бөтен дөньяга таралган мәдәни сүзләр мисалы. Фасмер II: 131; Федотов I: 217. Бүтән төрки телләрдә дә **канәфер** күп фонетик вариантларда очрый.

**КАНБАЛ** тар. (в Касимовском ханстве, Будагов II: 67) «воин во главе строя», чаг. фар. *ба қанбал* «тезем башында». Ихтимал, **Камбар** «хәзрәте Галинең корал йөртүчесе» исеменнәндер. Бу **Камбар** сүзенең «туйда хезмәтче» мәгъ. дә бар.

**КАНДА** иск., диал. «где; где уж» ~ гом. кыпч. *қанда,* угыз. (Мухамедова 1973: 113) *қанда, ханда* id. бор. төрки *qan'* «кай» сүзеннән урын-вакыт килеше. К. түбәндәгене.

**КАНДАЙ** диал., иске тат., себ. (Тумашева 1992: 118) **қандый, кантай** «какой» ~ башк., каз., к.-калп. һ.б. *қандай* id. бор. төрки *qan'* «кай, кайсы» сүзеннән. Ш. ук мәгъ. **каңгы** «кайсы, нинди» сүзе дә төрки телләрдә очрый. К. **Кани.**

**КАНДАЛА** «клоп» < гом. кыпч., үзб., төркм. *қандала,* кырг. *қантала,* хак. *хандала*, нуг. *қандалай*, ком. *қаннала*, даргин. *қанул,* к.-балк. *қандагай* id.; оригиналь вариантлар: чув. (Сергеев 1971: 138) *хăнкăла, хăмтла, хăнăкла, хăнăтла, хăнтăла, хăмăртла* һ.б. ~ мар. *умдыла, ундула*, морд. *кендал, келда*, манси. *kantel* ~ осет. *qāndil* «кандала». Бу мәдәни сүзнең чыгышы тур. юраулар гына булырга мөмкин. Безнеңчә, **кандала** фар.-таҗ. *гäндäги* «сасылык, әшәкелек», *гäндӣдан* «сасыту», *гäндā* «кандала», *гäнд, гäндä* «сасы» ← авест. *qanti* «сасы ис» һ.б. (к. Абаев I: 542) сүзләре белән баглы, чаг. тат. диал. **сасық** «кандала» (ир. телләрдән калькамы?). Як. *хаптагай, хаптанийа* «кандала» сүзенең

*кандала* сүзенә кардәшлеге шикле. Гар. *хӓнзӓлӓ* «кандала» һәр яктан сорау уята (ул төп гар. түгел). Räsänen 1969: 229; ЭСТЯ V: 253–254.

Дерив.: **кандалала-у; кандалалы, кандаласыз.**

**КАНДИ** «мёд с сахаром» к. **Кант, Кәнди.**

**КАНДИЛ, кәндил** «висячий подсвечник; люстра» < рус. диал. *кандель, кандило* < грек. *χανδηλα* > лат. *candela* «шәм». Чаг. рус. *канделябр* «люстраның бер төре» < фр. Гомумән, бу сүз киң таралган, к. гар. *ҡандӣл* «кандил» һ.б. (< грек.).

**КАНҖЫГА,** диал. (Тумашева 1992: 118) **канцыга** «торока (шнур, прикреплённый к седлу для привязывания вьюка, сумки и т.п)» ~ башк. *ҡанйыға*, кырг., госм. *ҡанжыға*, каз., к.-калп. *ҡанжыға*, чыгт. *ҡанжуға* < бор. төрки, монг. *γanǯurγaj* (> хәз. монг. *ганзега*) **кантар IV** (к.) белән тамырдаш; к. ш. ук алт. *кандьыга, кандьага, канйага*, аз. *ғанжыға* һ.б. «канҗыга, кантар». Räsänen 1969: 230–231; ЭСТЯ V: 254–255; ССТМЯ I: 139. Рус. *гандзагай* (< монг.) «канҗыга» тур. Аникин: 163.

**Канҗыга** сүзе төрки телләрдән күрше телләргә дә кергән.

**КАНЗА, канзы** (Ш. Маннур), диал. (Тумашева 1992: 118–119) **каңза, канца** «курительная трубка» ~ алт. *ҡанза,* хак. *хаңса*, як. *ғаңса, хамса* ~ монг. *ганза, ганс,* яз. монг. *γangsa(n)* id. < кыт. *ганьцзы* «төрепкә, челем», к. ш. ук эвенк. *ганча, ганса,* эвен. *ҡаңса* id. < монг.; маньч. *гуванцзы* «төрепкә; сыбызгы» < кыт. *гуанцзы* «төрепкә; сыбызгы» дип карала (ССТМЯ I: 139, 165). **Канза** сүзен тибет. *gaŋ-zag* id. сүзеннән дип фаразлау да бар; рус. *гамза, ганза, гонза* һ.б. «төрепкә» тур. Аникин: 162 (бай әдәбият һәм күп вариантлар күрсәтелә).

**КАНИ, кан** диал., (Махмутова: 246–247, к. ш. ук ЗДС: 272–273) **каны, кан'ы, качы < канчы < каничы** һ.б.ш. «ну-ка посмотрим, где оно, что оно (в риторических предложениях)» < чыгт., уйг., госм., бор. төрки (ДТС: 418) *qanı* «кайда, кани», к. ш. ук үзб., уйг., таҗ. *ҡәни*, төркм. *хани*, төр. *hani* id., госм. *ҡаңгы* «кайдагы».

**КАНТ, канд** «небеленый сахар» – «шикәр; агартылмаган (көрәнсу төстәге) шикәр» < фар., гар. *ҡанд* id. < һинд. *khandaka* id. (к. **Шикәр** матдәсен). Гар. теленнән бу сүз Европа телләренә дә үтеп кергән: ним. *Kandis*, инг. *candy*, фр. *sukre candi* һ.б., к. Kluge: 465; Тимергалин: 236. К. **Кәнди.** Бу сүзгә ит. *kandito* «шикәрле» сүзе аша **кондитер** сүзе тоташа.

**КАНТАМЫР** «стальной осёлок» (к. ТТДС I: 191) << бор. монг. *gaŋ tömür* «корыч, тимер; игәү» ← **каң** (к.); диал. **ҡантамыр** «иген сабагының балдагы» сүзе дә шул сүзләрдән булса кирәк (төптә «корыч балдак» мәгъ. булган).

**КАНТАР I**, диал. **кантыр** «глыба, ком» > удм., мар., чув. *кантар*, чув. *кӑнтар* id. ~ ком. *каңтар* id. бор. *ҡаңылтар* «шлак; эреп каткан металл кисәге» сүзеннән, шуннан ук тат. диал. (ЗДС: 287–289) **кәнтәр, кәлтәр, кәлүтәр** (< *кәүелтәр* < *каңылтар*) «кантар; кәс» ← бор. төрки *ҡаңта-* «маяу, металл эретү, чуен кою», к. себ. (Тумашева 1992: 118), **каңка-у**, алт. *каңна-, каңда-* «маяу – эретеп ябыштыру». К. **Кантар II, Канҗыга, Каңылтыр.**

**Кантар** сүзенең төрле фонетик вариантларда төрле мәгънәләр алуы татарларда һәм бор. (Алтайдагы) төркиләрдә металл коюның киң масштаб алганлыгын күрсәтә.

**КАНТАР II,** диал. **каңтар** компонент названий месяцев: *көз кантары* «октябрь – середина осени», *кыш кантары* «январь – середина зимы», *яз кантары* «апрель – середина весны» (к. *Кантар килми яз булмас; Кантарда карга адымыдай көн озаер,* Исәнбәт I: 435). Элек ел фасыллары кояш буенча төгәл исәпләнмәгәч, **кантар** хәз. мәзкүр айларга төгәл туры килми.

Гом. кыпч. **кантар II** сүзе **кантар III** (үлчәү нәйзәсенең уртада торуы мәгъ.) сүзеннән булса кирәк, к. Диваев 1895: 284–286. К. кырг. *ҡаңтар* «кантар; каприз, икеләнеп, бер тегеләй, бер болай авышу». Уртада *-ң-* авазы соңгы күренеш (ул **кантар III**тә дә күзәтелә). ЭСТЯ V: 261–262 (**кантар IV** белән чагыштырыла, безнеңчә, алай түгел).

**КАНТАР III** диал. «безмен, рычажные весы» ~ башк. *кантыр, кантр, кәнтер, кәнтр* «кантарның бер төре» (БҺҺ III: 77), нуг., ком. *каңтар*, төр. *кантар*, аз. *гантар* «бизмән; 125 кадаклык үлчәү берәмлеге» < гар. *ҡинṭāр* «авыр нәрсәләр өчен бизмән 44,928 кг» (ГТРС: 215) < грек. *χεντηναριον* id. **центнер** белән тамырдаш. К. Вашари: 97–101.

**Кантар** слав. телләрендә, бигрәк тә рус телендә, киң таралган: бор. рус. *кентарь* «1,5–10,5 пот» (Срезневский: 1206), *кантарь, кантырь, контарь* «бизмән» һ.б. к. Аникин: 257.

**КАНТАР IV** диал. «короткий повод» (Будагов II: 27), диал. *кантар* «киндерә» (Тумашева 1992: 146) – дөресе – **кантаргы,** чөнки гом. кыпч., уйг., чыгт. *қаңтар-*, аз. *гантар-* «йөгәнне ияргә атның башын борып бәйләп кую» (бу хәлдә ат кола яланда – бәйләрлек агач, багана һ.б. булмаганда да бер урында тора), чаг. ш. ук госм. *кантарма* «кантаргы», як. *хантарга* «тезген», калм. *хантр-* «йөгәнне ияргә беркетү» < бор. монг. *qantari-*, маньч. *кантара-* id. эвен. (ССТМЯ I: 139, 375) *канда-* «боланны бәйгә бәйләү» һ.б. Räsänen 1969: 231.

*Кантар-* < *каң тар-* бик бор. сүз, ул (һуннар телennәнме) ним. теленә дә үтеп кергән: *kandare* «кантаргы». *Кантаргы* сүзенең монг. телләре аша кергән формасы **канҗыга** (к.). Бу сүзләрнең тамыры (кырг.) *каң* < кыт. *хаң* «металл ярдәмендә беркетелгән урын» булса кирәк. К. **Каң, Каңылтыр, Кургаш.**

**КАНТУН** «кантон (административный район в Башкирии в XVIII–XIX веках и в Татарстане в 20-х годах XX века); начальник кантона» < рус. *кантон*; к. ш. ук тат., башк. *кантанис* «молодой человек, не знающий языка отца и матери» < рус. *кантонист* «учащийся военного училища из татар и башкир» (*кантанислар* ун-унике яшьтән һәрбер кантуннан билгеле санда алынып укыганнар). К. Фасмер II: 182.

Кантонистларның туган телләрен онытуын күргән рус язучы С.Т. Аксаков, барча башкорт балаларын яшьли ата-аналарыннан алып, русча укыту юлы белән руслаштырырга тәкъдим иткән. Нинди гуманист!

Рус. *кантон,* ним. *kanton* «рекрутларны җыю округы» һәм рус. *кантонист,* ним. *kantonist* «хәрби хезмәткә барырга тиешле егет» *кант* «почмак; кант» сүзеннән, к. Kluge: 467.

**КАН-У** «удовлетворяться; утолить жажду» < гом. кыпч., уйг., чыгт., алт., угыз. һ.б. *қан-, каны-* (к. Радлов II: 106) ~ бор. монг. (Поппе 1938: 291) *qana-, qanγa-* id. тәүдә «кан үчен алу (вендетта)» мәгънәсендә булган, к. ш. ук аз. *ган-, қаны-* «аңлау; аңлашу, килешү». Будагов II: 28; ЭСТЯ V: 251–252. К. **Кан, Канык-у.**

Дерив.: **кандыр-у** (төп формадан ешрак кулланыла).

**КАНУН** «закон, закономерность; гусли» (к. Ш. Бабич. «Канун тыңлаганда») < гар. *қāнӯн* id. (к. Будагов II: 28) – бөтен Шәрыктә билгеле сүз.

**Канун** сүзенең «закон» һәм «гөслә» дигән (беренче карашка үзара бәйләнешсез) мәгъ. төп чыганактан – грек теленнән килә: бу телдә *канон* (шуннан ук рус. *канон*) «юнәлткеч таяк; судья яисә дирижёр таягы; кагыйдә, закон», ш. ук «гөслә». Бу грек сүзе семит телләреннән алынган *kanna* «улак; зур торба – эче куыш бүрәнә» тамырыннан. Шуннан ук лат. *cannone* «пушка» (→ *канонада* «тупка тоту»), *canale* «канал», *canistrum* «чиләк, канистр» һ.б. сүзләр ясалган һәм Европада киң таралыш алган. К. Kluge: 466.

Шунысы кызык – тат. (трбс.) **кәннә** ~ чув. (Ашмарин) *канна* «дренаж канал, канау» грек-семит *канна* «агач торба, улак» сүзенә бик тә охшаш.

**КАНЧА-У** (ЗДС: 387) «болезнь с упорной сыпью»; чаг. **Камча-у, Каңчаш-у.**

**КАНЧЫК,** диал. **канцык, қанцық** «сука», редко «кошка» (к. Тумашева 1992: 118; Дмитриева 1981: 151), «хохотун» (Остроумов 1872: 84) ~ башк. диал. *кәнсек* «кәнтәй» < гом. төрки *қанчық, қанчуқ* һ.б. (Räsänen 1969: 230). Тат. **кунчык** (Бәетләр 1960: 201) id. < *қану-чық* бор. **кану* «эт» тамырыннан, к. **Кәнтәй.** ЭСТЯ V: 255–256 (күпсанлы параллельләр китерелә).

**КАНЫК-У** «злиться на кого-либо, долго мстить кому-либо», иск. «желать крови» < гом. төрки *қанық-* id. (Радлов II: 115) ~ чув. *йунӑх-* < *йонӑх-* id. (к. Ашмарин IV: 330–333) бор. **қан-, *қаны-* «кан теләү» фигыленең интенсивлык формасы, к. аз. *ганыг* «канга сусамыш». *Канық-* сүзенең иске тат. (Будагов II: 28), кырг. һ.б. «гадәтләнү» мәгънәсе икенче тамырдан, к. үзб. *қоник-* «тәмам канәгатьләнү, тәмам кану». К. **Кан-у.**

**КАНЯТ** диал., ш. ук **канәт** (ТТДС I: 229), **канат, қанат** (ЗДС: 272, 386) «парные гости в свадебном поезде», «милый друг, дружище» < бор. монг. *qaniat* «хәрби дуслар; ике хәрби дус» сүзеннән, бор. монг. *qani* > монг. *хани* (*хани-нөкүр*) «хәрби дус» сүзенең күп. формасы, к. ССТМЯ I: 373.

**Қанат** варианты халык аңында **канат** сүзенә (к.) нисбәтләнгән.

**КАҢ** диал. «припай; пайка» (**каңна-у** «паять, к. Тумашева 1992: 119) ~ кырг. *каң* id., тув., алт., хак. *каң* «кургаш, корыч, калай» < кыт. *каң* «корыч», *хань* «маяу, эретеп ябыштыру». Чаг. тат. диал. (ТТДС I: 191) **кантамыр** «игәү» < бор. монг.

*qaŋ tömür* «корыч, игәү тимере», төркм. (ТДГДС: 49) *каңсак̧* «тәгәрмәч тугымы».

Бор. төркиләр, билгеле, тимер-корыч эшләү белән атаклы булганнар һәм Кытайдан үзләштергән бу һөнәрләре бәрәкәтендә тарихта (VI–IX гг.) зур уңышларга ирешкәннәр; **каң** тамырыннан ясалган сүзләр төрки телләрдә бик күп булуы да шуның белән аңлатыла, к. **Кантар, Каңылтыр, Касмак, Кургаш**. ЭСТЯ V: 259.

**КАҢГА** (Тумашева 1992: 119) «деревянный остов седла» (Радлов II: 83; Будагов II: 28, 60), иск. «женское седло – дощатый квадрат, укрепляемый к спине лошади, на котором можно сидеть как угодно» – мәзкүр сүзлекләрдә тат. теленә нисбәт ителгән бу сүз хәз. сүзлекләрдә очрамый (Тумашева Радловтан алган), к. ләкин, мар. *ханга, ŏнга, ŏңа* < болг. **ћаңга* > чув. *хăма* «такта, куна», удм. (Кельмаков 1977: 55) *кана, каңа* «киштә, шкаф; тәре урыны (шүрлеге)» ~ куман. *каңа* «идән», ком., к.-балк. *к̧аңңа* «куна; такта», як. *хаңха* «йөк ияре», эвенк. *к̧ангк̧а* «балалар ияре», монг. *хаңхай* «йөк ияре» һ.б. К. Räsänen 1969: 232; ССТМЯ I: 374–375; ДСЯЯ: 279; Федотов II: 324.

**Каңга**, ихтимал, **каңгы, каңга** «арба» сүзе белән (к. түбәндә) бәйледер.

**КАҢГЫ I** иск., диал. (мәкальдә: *Кыз бала – каңгыда яткан ук* «девушка что стрела, лежащая в телеге») «широкая телега кочевника, куда могли ставиться даже небольшие юрты в неразобранном виде» ~ каз. *к̧аңгы, к̧аңы*, кырг., алт. *к̧аңа*, хак. *хаңаа,* уйг., бор. төрки (ДТС: 418) *qaŋγa*, угыз. *к̧аг-ны* (> төр. *kağnı*) «киң, яссы өсле, еш кына ябулы арба», госм. *каң,* чыгт., иске уйг. һ.б. *к̧аңк̧, к̧анык̧* «зур ике тәгәрмәчле биек арба», ихтимал, кыт. *хiăn* «ике тәгәрмәчле биек арба» сүзеннәндер (Joki 1952: 159). К. **Каңлы**. Räsänen 1969: 232.

«Угыз каган» дастанында *к̧аңгы* «арба» аның тәгәрмәче *каң-каң* итеп шыгырдавыннан дип аңлатыла. Соңыннан бу аңлатма халык этимологиясендә күп тапкыр кабатланган, к. Будагов II: 28.

**КАҢГЫ II** (ТТДС: I: 199) «беглец», (ЗДС: 387) «худой, худосочный» ~ кырг. *к̧аңгы* «аңгыраган», алт. *каңгы* «ачыгавыз». Чаг. **Каңгыр-у.**

**КАҢГЫЙ** «сказочная страна» (к. мәкаль: *Буз бала – хыялында Каңгыйдан кыз ала*) ~ алт., бор. монг. *каңгый, каңгай* «урманлы-таулы бай табигатьле җир» (к. Баскаков 1972: 219) < кыт. *хан хай* «каз дингезе» сүзеннән, хәз. Көнб. Монголия һәм шуңа чиктәш җирләрдә моннан ике мең еллар элек бик тә үсемлек-тереклеккә муллык булган, шунда ишле кабиләләр яшәгән. Соңрак, корылык башлангач, табигать муллыгы таксыган. Һуннарның көнбатышка юнәлүләрен дә шул вакыйга белән баглыйлар.

Хәз. Көньяк Себер фольклорында да *Каңгай, Ханхай* «баһадирлар иле». Хәз. *Хангай* сырты (Монголиядә) – күп күлле таулык. Монг. телендә бу сүзнең «томак; байрак» һ.б. мәгъ. бар. К. ш. ук **Үтәгән II.**

**КАҢГЫЛ I** «костлявый; скуластый; тощий» ~ мар. *каңга* «какча», кырг. *каңгыл* «арык ит», алт., тув. *каң* «как, коры». К. **Кәңгел.**

**КАҢГЫЛ II: каңгыл (каңгыллы) дала** шигъ. «степь с широким видом (открывающимся путникам с перевала)», күрәмсең, ***каңгыл** «дүңгәләк, өермә үлән» сүзеннән ~ төр. *kangal* «камгак, дүңгәләк; зур урама, бунд», каз. *к̧аңгалак̧* «механик ургыч-чапкычларның озын-озын калаклы әйләнгече», «орчыкбаш», **каңгалау, каңгалаклау** «кылдыйбылдый тәгәрәү яки әйләнү», тув. **каңмыл** ~ калм., бур., монг. *хамхуул* < яз. монг. *хатхаγul* «камгак, дүңгәләк » ~ кыт. *хуаң-ха?* Ләкин угыз., бор. төрки һ.б. *каң, каңгы* (к. **Каңгыр-у**) «арба» һ.б.ш. (к. Будагов II: 28). Рус. *канмал, конхул, хамхул* «камгак, каңгыл» тур. Аникин: 257, 607. К. **Каңгы.** Чаг. ш. ук *Даңгыл дала.*

**КАҢГЫЛДА-У, каңкылда-у** «гоготать (о гусях)» – типик имитатив фигыль, *каң-каң* тәкълиди сүзеннән. Гом. төрки сүз.

Дерив.: **каңгылдаш-у, каңгылдат-у.**

**КАҢГЫР-У** «шататься; скитаться; бродяжничать» ~ башк. *к̧аңгыр-* «исәрләнү, аңгыраю», каз. *к̧аңгыр-* «ятсыну; каңгыру», алт. *каңгыр-* «авыз ачып калу» һ.б. тат. диал. (эчк., әстр., к. ТТДС I: 199; Арсланов 1988: 82) **к̧аңгы-у** ~ башк., нуг., каз., к.-калп., ком. *к̧аңгы-* «каңгыру». Ихтимал, *каңгы* «юл арбасы», *каңгычы* «юл арбасында яшәүче» (*каңгы-р-* «каңгыда яшәү» ← бор. **каң* «әйләнү; тәгәрмәч» сүзе белән баглыдыр, к. тат. *баш каңгыру* «баш әйләнү», аз. *каңыр-* «әйләнеп карау» һәм калм. *хаңгр-* «өерелү; тәгәрәү». К. **Каңгы I.**

**КАҢКАЙ-У, кәңкәй-ү** «застывать при неестественном положении тела (особенно головы)» ~ кр.-тат., кырг., каз., к.-калп. һ.б. *к̧аңкай-, к̧аңкый-* «серәю, тырпаю» – **к̧аңк̧а, *к̧анк̧ы* нигезеннән.

Чаг. тат. диал. **кашкай-у** «каңкаю». *Каңкай-у, кашка-у* сүзләренең «кәпрәю, тәкәббер кылану» мәгъ. дә бар. Чаг. башк. диал. (БҺҺ III: 106) *қаңға* «карачкы элү өчен багана», «махсус чатлы багана».

**КАҢЛЫ** (**канлы** дип тә языла) «название нескольких башкирских, сибирско-татарских и множества тюркских родов и племён» – к. БРҺ 1996: 863. Безгә якын кр.-тат., нуг., каз., к.-калп., уйг. *каңлылар* элек-электән *каңгалы, каңгылы* «арбалы (кабилә)» дип аңлатыла. «Угызнамә»дә *каңлы,* В. Рубрукта *кангле*, П. Карпинидә *каңкат* (к. Карпини, Рубрук: 95, 101–102) – кыпчак кабиләсе атамалары. Кытай чыганакларындагы *кангюй* дигән төрки халык атамасы *қаңлыз* сүзен чагылдырса кирәк. К. **Каңгы I.** Госманлы Төркиядәге каңлыларның бер өлешен *чавдар татар* дип атаганнар, к. Karadağ H. Kangal yer adı ve *kangal köpeğinin* orijine üzerine görüşler // Milli folklor, № 56. Ankara 2002: 34–45. Гомуми мәгълүмат З. Вәлиди һ.б. тарихчылар хезмәтләрендә. ДТС: 419; ЭСТЯ V: 259–260 (материалы аз).

**КАҢЧАР,** диал. (Тумашева 1992: 118–119) **каңчыр, каңҗар** «переносица» ~ добр. *qaŋsar* «ат башының танауларыннан маңгаена кадәрге өлеше», тат., башк. *қаңшырық* «саңак», *қәнщерек* «йоткылык өсте», башк. (БҺҺ III: 105) *қаңшырық, қаншырық* «таңлай; аңкауның арты» үзб. диал. (Будагов II: 28) *қаңшар* «ат танавы, танаулар арасы», уйг. *қаңшар* «каңчар» < кырг. *қаңылжаар, кеңилҗәэр* «борын кимерчәге, борын каркасы» тат. **Киңертәк** (к.) сүзе белән бәйле булса кирәк. Чаг. ш. ук аз. *ганчыр* < *канчыр* «тире астында катып калган кан», як. *хааңы* «боз астындагы бушлык», *хааңсаар* «борын куышлыгы». Чаг. рус. *ганаши* «ат яңагы мускулы».

Бор. төркиләр терлекчелектә ит белән күп эш иткәннәр, шунлыктан аларда анатомик нечкәлекләр хәзергедән күбрәк булган. Без ул бор. тәфсилләрне белеп бетермибез.

**КАҢЧАШ-У** (Будагов II: 27) «вступать в кровосмесительную связь», «болезнь детей, рождённых от такой связи» ~ каз. *қаңсарсу* id. < *қаң чаршы-у*? Ачык түгел. Чаг. бор. төрки (ДТС: 419) *qaŋ* «ата; нәсел». К. **Канча-у.**

**КАҢЫЛТЫР** (Будагов II: 20), диал. **каңалтыр** «листовой металл; тонкая жесть» ~ башк. *қаңалтыр,* кырг. *қаңылтыр* «калай; тимер кисәге, ялтырка», нуг. *қаңылтыр* «каткан балчыклы; кантарлы», каз. (Катаринский) *қаңылтар* «юка тире, юка калай», к.-калп. *қаңылтыр*, уйг. *қаңалтир* «калай кисәге, калай савыт», үзб. диал. (ЎХШЛ: 155) *қаңылтыр* «тимер кисәге», к.-калп. *қаңылтақ* «юка калай»» һ.б. бор. төрки **қаңылт-* «металл эретү» (шуның бер төре) сүзеннән. Күрәсең, *каңылт-у* ысулы белән калай ясаганнар, ул барып чыкмаса, формасыз металл каткагына әверелгән. К. **Кантар I, Каң, Кургаш.**

**КАП I** – подражание хватанию ртом, закрыванию рта и т. п. – «хап», «хоп». Чаг. **Кап-у, Кып I.**

Дерив.: **кап-коп (кап та коп)** (мәс., ашау).

**КАП II** «вместилище, сосуд, футляр; куль (рогожный); коробка», диал. «стручок» < гом. кыпч. *қап,* угыз. *ғап,* тув., хак. *хап*, чув. *хап* (< тат.) һ.б. < бор. төрки (ДТС: 399–400) *qab, qa* > як. *хап, хаа* id., төрле төрки телләрдә үзенчәлекле мәгъ. алган (к. Будагов II: 1–2; ЭСТЯ V: 266–267), бик ихтимал ки, *кап-у* «ябу» фигыле белән бәйледер. Räsänen 1969: 233; Федотов II: 310; Аникин: 258.

**Кап** һәм аның дериватлары күп күрше телләргә кергән, к. мар. диал., *кап, каб*, рус. диал. *кап* «кап, капчык», фар. *қаб* «зур табак, кын һ.б.ш.» *Шырпы кабы* сүзендә диал. «кузак» мәгъ. чагыла.

**Кап** бик продуктив нигез: **каплы, капсыз;** к. **Кабак, Кабар-у, Капат-у, Капка, Капкач, Капла-у, Капу, Капчык, Кабык, Кабырчак** һ.б., к. Будагов II: 1–2.

**КАПАТ-У** иск. «арестовать» < госм. *қапат-*, аз. *гапат-* id. угыз. *қапа-, ғапа-* «каплау, өстән бикләү» фигыленең йөкл. юн., к. ш. ук ком., чыгт. *қапа-* ~ бор. монг. *qaba-* «бикләү» (Поппе 1938: 284) ← *қап* «савыт, каплагыч», к. **Кап.**

Дерив. (иске тат.): **капала-у** «кулга алу», **капалы** «төрмәдә» һ.б. төрекчәдән.

**КАПКА,** диал. **капҡак** «ворота» (Тумашева 1992: 119 һ.б.), «двор» > чув. *капка, хапха,* мар., удм. *қапқа* (к. ш. ук татарчадан ярымкалькалар: мар. *мардежкапка* ~ *җилкапка*; мар. *руш капка,* чув. *вырас капка* ~ *урыс капка*) < бор. төрки (ДТС: 420) *qapуa* «капка»; к. ш. ук уйг., кырг., үзб. (ЎХШЛ: 156) *қапқа* id. (> төркм. диал. *ғапға*), каз. *қақпа* id. Чыгт., кырг. телләрендә *капқа* «тарлавык; үткел» ~ к.-балк. *қапхақ* «кашлак, тау битләве». К. **Капкак, Капу.** Федотов II: 311.

Дерив.: **капкалы, капкасыз; капкалык**. К. түбәндәгене.

**КАПКАК** (ТТДС I: 192) «крышка; заслонка» < гом. кыпч., уйг. *қапқақ,* бор. төрки (ДТС: 420) *qapүaq* «капкач, дека; каплавыч» ~ монг. *хабхаг* id. һ.б. *қап-* (к. **Капу**) «ябу, томалау» сүзеннән; к. ш. ук угыз. *ғапағ, қапағ,* як. *хаппах* «капкак».

**КАПКАЧ** «крышка» > удм. *капкач, капкась,* мар. *капкась* < башк. *қапқас* < гом. кыпч. *қапқач* id. ← *қапықач* < *қапу-қач* яисә *қапқақ-қач.* К. ш. ук тат. диал. (БТДҺ: 186) **капкыч** «капкач» ← диал. **кап-** «ябу». К. **Кабак III, Капкак, Капу.**

**КАПКЫН,** диал. **капкан** «капкан» > чув. *кап-кӑн*, мар., удм. *капкан* < гом. төрки *қапқан*, ком. *қапғун*, хак. *хахпан*, монг. *хавка* id. *кап-* «эләктерү» сүзеннән, ясалышы буенча *капкын* сүзе (сыйфат) дөресрәк, *капкан* варианты икенчел булса кирәк. Федотов II: 226. Рус. *капкан* тур. Аникин: 258.

**КАПЛАН** «леопард» < гом. төрки, бор. төрки *қаплан*, төркм., аз. *гаплан*, кырг. *қабылаң* id. (русча «тигр» дип тәрҗемә ителүе дөрес түгел) – *кап-, капа-* фигыленнән булса кирәк. ЭСТЯ V: 269–270 (бай әдәбият күрсәтелә).

**КАПЛА-У** «закрывать, закрыть (от глаз), покрывать, покрыть, возместить расходы» > чув. *хопла-, хупла-* < гом. кыпч., төр., гаг. *қапла-* (каз. *қабта-, қапта-*), төркм., аз. *ғапла-* id. **Кап** сүзеннән; бу фигыльнең гом. кыпч. дериватларыннан *каплама* «йөзлек – кесә капкачы, чабу, борт», тат. диал. «бәлеш төре» (> мар., удм. *каплама* «чабу, борт») ~ төр. диал. *kapluta* id.

Дерив.: **каплан-у, каплаш-у, каплат-у** (бу сүзнең үзенчәлекле «аталандырту» мәгъ. дә бар); **каплагыч, каплавыч.**

**КАПСА-У** (Тумашева 1992: 119, иске терминологик сүзлекләрдә еш очрый) «окружать; закутать; осаживать, обхватить противника; заключать в себе» < гом. кыпч., чыгт., төр., уйг. *қапса-* < бор. төрки (ДТС: 421, 437) *qapsa-, qavsa-* > аз. *ғапса-* id.; к. ш. ук себ. **қапсау** «сүрү, мендәр тышлыгы» ← *кап-* (к. **Капу**) «каплау». Чаг. каз. *қапсыр* ~ монг. *хавсар* – «беркетү». Zajączkowski: 127.

Бу сүзгә бик охшаш гар. *қабḍ* «тотып алу, учмарлану» сүзе күп дериватлы *қбḍ* «тоту» тамырыннан. Төрки язмаларда бу гарәп сүзе дә очрый. К. **Кабза-у.**

**КАПТАК** (Будагов II: 3, 60) «должея; зарубка, выемка; паз, по которому скользит край доски в полке» ~ төр. диал. *капта-* «эләктерү» ← *кап-* (к. **Кап-у**) булса кирәк. Чаг. ш. ук монг. *хабтах-ан* «яссы», *хабтагай* «такта» (һ.б. күп сүзләр).

**КАПТАЛ** (ТТДС I: 192; Тумашева 1992: 119) «женский кафтан, нагрудник», (ЗДС: 388) «кафтан», себ. (Будагов II: 60) **қафдал** «толып» < гом. кыпч. *қаптал* «җилән, бишмәт, чикмән», «бик озын (тезгә кадәрге) ир-ат күлмәге» (андый күлмәкләр мишәрләрдә булган), башк., к.-калп. *қаптал* «иярнең, ыңгырчакның бер канаты», каз. (ҚТДС: 190–191) «өйнең, тирмәнең бер яны», кырг., уйг. *қаптал* «ян, битләү», үзб. (ЎХШЛ: 156) «янбаш», чыгт. (Будагов II: 2) «атның янтыгы», төркм. (ТДГДС: 49) *ғапдал* «кием», *қапдал* «өске кием» һ.б., к. ЭСТЯ V: 268–269.

Рус. *кафтан* «кыска бишмәт» сүзен төр., кр.-тат. *қафтан* id. сүзеннән, ә ул сүзне фар. *һафтан* > гар. *кивтан, куфтан* «җилән» сүзләреннән дип карау бар (Фасмер II: 212, ш. ук ним. *kaftan* тур. Kluge: 459), ләкин Г. Дёрфер бу фаразны кире кага (к. Аникин: 274–275). Татар этимологиясендә күптәннән *кафтан* < рус. *кафтан* < бор. төрки *qap ton* «кап тун», ягъни «ябынча» дип карала. К. кр.-тат. (Dobr. II: 173) *qabdal, qaptal, qaptan* «ике кат тукыма арасына мамык җәеп сырылган ат ябуы, ияр аслыгы». Чаг. ш. ук тат. (ДС I: 40–41) **бохаптан, былхаптан** «бишмәт» < **буй каптан? Каптан* > *каптал* күчеше, гомумән, аңлатыла ала (кайбер төрки шивәләрдә, мәс., хак., тат. сөйләшләрендә *-н* > *-л* күчеше күзәтелә). Сүзнең төп мәгъ. «калкан төре», «зур көбә».

**КАПТЫРГА** (Будагов II: 3), себ. тат. **каптырка** «зацеп; кисет, мешочек, который прицепляется к ремню, к седлу и т.п.; крючок» ~ башк. *қаптырқа,* кырг., алт. һ.б. *қаптырға, қаптырғы* id., ш. ук «каптырма, калган» ~ монг. *хабтурга* «аучы янчыгы». Рус. *каптурга, хаптурга* «аучы янчыгы» тур. Аникин: 259, 260 (шунда төрки параллельләр һәм әдәбият). К. **Каптырма.** ЭСТЯ V: 271–273.

**КАПТЫРМА,** диал. (ЗДС: 388) **каптыргыч, каптырмак, каптырмац** «крючок; застёжка платья или ремня; украшение одежды – широкая брошка и т.п.» > чув. *каптӑрма*, мар., удм. *каптырма* ~ гом. кыпч., алт. һ.б. *қаптырма* id. ← *каптыр-* (к. **Каптыр-у**). Федотов I: 227. Башк. *қаптырма* «каптырыла, эләктерелеп куела торган нәрсә, мәс., янчык» һ.б.

Дерив.: **каптырмалы, каптырмасыз; каптырмала-у.**

**КАПТЫР-У** «быстро схватить, поймать; ловить рыбу на крючок; зацепить; ловить на слове, остро ответить» > мар., удм. *каптыр-* id. < гом. кыпч., алт., уйг. һ.б. *қаптыр-* id. ← *кап-* (к. **Кап-у**).

Дерив.: **каптырыл-у, каптырын-у** (мәс., киенгәндә), **каптырыш-у, каптырт-у; каптыргы, каптыргыч.** К. **Каптырга, Каптырма.**

**КАПУ, капуг** кит. «врата (рая; дворца)» < чыгт.. төр., аз. *қапу, қапуғ,* бор. төрки (ДТС: 420–421) *qapuγ, qapïγ, qapaγ*, төр., үзб. (ЎХШЛ: 156), каз. *қапы,* аз. *ғапы*, иске сүзлекләрдә (Мухамедова 1973: 113; Zajączkowski III: 127) *қабуғ, қаабы* «капка, ишек» ← **қаап-* «ябу, каплау» фигыленнән, ул фигыль *қап* (к.) сүзенең коррелянты булса кирәк, к. ЭСТЯ V: 263–264. К. ш. ук Будагов II: 37–38 (төр. *kapı* сүзенең тарихи мәгънәләре аңлатыла, солтан капусы тасвирлана).

**Кап-** < **каап-* фигыле төрки телләрдә чув. *хуп-* < *хоп-*, кайбер чыгт. ядкәрләрендә *қап-*, төркм. (ТДГДС: 49) *ғап-* «каплау, капка (капкач) ябу» сүзләрендә сакланган. Бүтән төрки телләрдә ул бик кулланылышлы **кап-у** «кабу» сүзе белән омоним булгач, онытылган (чув. телендә *кабу – хып-,* шунлыктан ул *хуп-* «каплау» сүзенә омоним түгел, к. Федотов II: 358–359, 380).

**Капы** «капка» һәм **капу** «ябулык» сүзләре XIX г. татар (крш.) сөйләшләрендә дә теркәлгән (к. Будагов II: 1–2).

Дерив.: **капучы.**

**КАП-У (капты, каба)** «хватать ртом (зубами); попасться; клюнуть», диал. (Тумашева 1992: 113) «хватать руками, ловить, поймать» > мар., удм. *қап-* «тешләү, кабу; эләгү» < гом. кыпч., алт., чыгт. *қап-* < бор. төрки (ДТС: 420) *qap-*, хак., як. *хап-*, чув., тув. *хып-* id., төбендә имитатив булса кирәк, к. чув. (Ашмарин VI: 71–73) *кап-* «тиз генә тотып алу» тәкълите, рус. *хап* id. (шуннан *хапать, хабить, хавать*, к. Фасмер IV: 215), һинд-евр. (Абаев I: 623) **kap, kep* «кабу, эләктерү», индонез. *qapai* «кабу, тотып алу» һ.б. Будагов II: 3–4; ЭСТЯ V: 262–264; Федотов II: 380.

**Кап-** төрки телләрдә иң продуктив тамырларның берсе: **кабыш-у, каптыр-у;** к. **Кабала-у, Кабыз-у, Кабын-у, Кавыш-у, Капат-у, Капса-у, Каптыр-у I, Каптыр-у II, Капша-у** (һәм аларның икенчел дериватлары).

**КАПЧЫК**, диал. **капцык** «мешок» < гом. кыпч., госм. *қапчық* (> башк. *қапсық,* нуг., каз. *қапшық*), чыгт., уйг., бор. төрки (ДТС: 420–421) *qapčïq*, аз. *ғапчағ* «(тире) капчык», алт. *қапчық,* тув. *хапчық* «чунтай (күкәй капчыгы)» ← **қап**. Күрәсең, капчыклар бор. (күчмәнчелек шартларында) бик зур булганнар, шуннан гадирәге, кечерәге **кап-чык** дип кечерәйтү формасында аталган. **Капчык** сүзе күп күрше (мар., удм. һ.б.) телләргә кергән; рус. *капчуг, капшук* тур. Аникин: 260.

Дерив.: **капчыклы, капчыксыз** (төрле мәгъ.); **капчыклап.**

**КАПШАГАЙ** (Тумашева 1992: 119; ЗДС: 389) «тщеславный; проворный, хваткий; худой, но сильный». Монда ике сүз кушылмасы бар бугай. Бер яктан себ. (Будагов II: 3) *қабшай-* «мактану» ← **қабыш* «мактанчык». Икенче яктан каз. *қапсағай,* тув. *қапшағай,* алт. (Баскаков 1966: 127; Баскаков 1972: 219) *қапчағай, қапчығай, қапчай* «ябык һәм көчле; кәрәштә кысып тотучан, эләктерүчән», як. *хапсағай* «шәпле» һ.б. Чаг. бур. *хабшаахай* < монг. *хабчаахай* «кыскыч, кысла» ← бор. монг. *xabči-* ~ чыгт. (Будагов II: 2–3) *қапчы-,* үзб. *қапчи-,* эвенк. һ.б. тунг. (ССТМЯ I: 378–379) *капчи-* «кысу, тарайту, эләктереп кысу, кыстыру». Бор. монг. *xabčiγai* (> хәз. монг. *хабцгий*) >> кырг. *капчыгай,* уйг., үзб. *қапчиғай* ~ як. *хапчағай*) «кысык тарлавык; ике яклы текә ярлар» һ.б. (барча төрки телләрдә очрый). ЭСТЯ (V: 270) авторлары бу сүзне монг. *γabi* «аерылып тору» сүзеннән чыгаралар.

**КАПША-У** «щупать» > морд. *капша-* id. ← *кабыш-а-у*, к. гаг. *капыш* «тоту, тоткалау», тат. диал. (ДС I: 93–94) **кабашла-у, кабышла-у** ~ чув. *хыпашла-* id.; тат. диал. (Т. Госман) **капшарла-у** «капшау» һ.б. ← *қап-* (к. **Кап-у**). Чаг. **Капса-у**, ш. ук **Капшагай.** Гомумән, **капша-у** сүзендә төрле фигыльләрнең контаминациясе бар бугай.

Дерив.: **капшал-у, капшан-у, капшат-у; капшавыч, капшагыч.**

**КАПЫЛ, капылт**, диал. **капылтын** «вдруг, неожиданно» > чув. *хапӑлт,* удм. *гапыл*, мар. диал. *қапыл* ~ ком. *қапултундан,* к.-калп. *қәпилемде,* нуг. *қапилес, қапилестен,* каз., кырг. *қапылыстан*, кырг. *қапилеттен* id. гар. *ғāфил, ғафлӓт* «гафил, гамьсезлек» сүзеннән ясалып, тәкълиди сүзләр калыбына кертелгән.

**КАПЫР-У** (ТТДС I: 192) «хватать помногу, хапать» ← *қап-* (к. **Кап-у**). Ясалышы ачык түгел.

**КАР** «снег» < гом. төрки *қар*, гаг. *қаар*, төркм. *ғаар*, бор. төрки *qaγar* id. ~ чув. *йор* > *йур* (< болг. **йар* < **ԋиар* < **кыар*) id. К. **Карт, Кары-у.** К. Räsänen 1969: 235.

Дерив.: **карлы, карсыз; карлан-у.**

**КАРА** «чёрный; чернила» < гом. төрки *қара*, тув., хак., як. *хара*, чув. *хора* > *хура* «кара; явыз һ.б.» ~ гом. монг. *қара, хара*, гом. тунг.-маньч. *қарā* id. (ССТМЯ I: 379–380). Бу сүздән бик күп сүзләр ясалган һәм күрше телләргә дә кергән. Төрки-монг. *қара ~ хара* «кара» сүзен *карга* сүзе белән дә бәйлиләр (ССТМЯ I: 379–380), чаг. рус. *ворон* > *вороной*. *Кара* сүзе ярдәмендә ясалган фразеологизмнар исәпсез күп. Будагов II: 42–44; ДТС: 422–424.

Төр. *kara* «коры җир, кыраз» **кара җир** сүзеннән түгел, гар. *қāрра* «коры җир» сүзеннән (Redhouse: 601).

*Кара* сүзенең «өер; көтү» (к. тат. *кеше-кара, терлек-кара*) мәгъ. *кара төскә* баглы микән, әйтүе кыен. ДТС (422–424) бу сүзләрне аерым бирә. К. ш. ук Räsänen 1969: 235; Федотов II: 262; ССТМЯ I: 379–380; ЭСТЯ V: 286; Гарипова 1998: 139–141.

Дерив.: **каралы, карасыз; каракай, каралык; карала-у; каралан-у; карача́; кара́ча; карай-у, карасу.** К. **Карабай, Карагай, Каразы** «явызлык», **Каралты, Карамчык, Карамык, Карач, Карачкы, Карачман, Карачы** һ.б., ш. ук бик күп кушма сүзләрдә (**қарагач < кара агач** һ.б.ш.).

**КАРАБАИР** «карабаир (порода лошадей)». Сүзлекләрдә (берсеннән икенчесенә күчерелеп һәм русчадан алынып) *карабаир* язылышында бирелгән бу сүз асылда башк. *қарабайыр,* каз. *қара бәйір,* асылда төркм., төр. һ.б. *қарабәйгир* «махсус йөк аты токымы» сүзеннән булса кирәк. Бу сүздә *қара* өлеше «кара, авыр» (эш тур.), *бәйгир* ~ төр. *beygir* «йөк аты, йөк алашасы» (еш кына гомумән «алаша») < фар. *бāргӣр* «йөк күтәрүче»: *бāр* «йөк», *-гӣр* «алу, күтәрү» мәгъ. (фар. *гирифтäн, грифтäн* «алу, тоту, күтәрү» чаг. **Грифтар**). К. Будагов I: 222 (*баргир* бар, *бейгир* юк).

Шулай итеп, **карабаир** сүзе өч нигездән гыйбарәт: төрки *кара* һәм фар. *бар* вә *гир.* Карабаир (дөресрәк язылышы *карабәер*) атлар татарларда файдаланылды микән – ачык түгел. Башкортларда булгалаган, чөнки алар ярымкүчмә тормыш алып барганнар.

Төр. телендә *beygir* «карабаир» киң кулланыла һәм күч. мәгъ. дә ия, мәс., шахматта *ak beygir* «ак ат», *kara beygir* «кара ат».

**КАРАБАЙ (карабай тургай)** «чёрный воробей» ~ ком. *қарапай җымчык*, каз. *карабай* > рус. *каравайка* id. (Будагов II: 8) – **кара** сүзеннән: **кара** сүзе хайван, үсемлек, авыру, кавем, әйбер атамаларында, топонимикада һ.б. (кушма сүзләр составында) бик еш очрый; кош атамалары бабында к. тагын кырг. **карабай** «кара челән». Будагов II: 42–44.

**КАРАБАКЧАР, қарабақцай, қарабақсар, қарабақцы(р)** һ.б. (ЗДС: 390) «скворец, вид скворца» < *карабаркчар* «ана сыерчык»: *кара* «кара» + *бакчар* < *баркчар* «сыерчык һ.б. баркылдаучы кошларның анасы». К. ш. ук себ. (Будагов I: 232–233) **бағчар, бақчар** «сыерчык, ана сыерчык». Бу сүзләрдәге **-чар//-чәр** монг. телләрендә ана (инә, теше) затлыкны белдерүчән кушымча, **бақ < барқ** кайбер кошларның һәм бакаларның өн-авазларын белдерә торган тамыр сүз, шуннан **баркылда-у, баркылдак** һ.б. сүзләр ясала. К. **Баркылдак.**

**КАРАБАРАК** – имя племени на севере, с которым сражался легендарный Огузхан; один из современных башкирских родов. К. **Барак.**

Каз. (ҚТДС: 191) *қарабарақ* «саксавылсыман агач» сүзенең мәзкүр этнонимга нисбәте ачык түгел.

**КАРАБАШ** «черноголовка» – тат. һәм бүтән төрки телләрдә төрле этноним, топоним, зооним һәм фитонимнарда очрый торган сүз. Тат., башк., үзб. телләрендә «җикән» һәм (ЗДС: 390) «йөксез», «гаиләсез» һ.б. мәгъ. очрый. Иске тат., төр., аз. һ.б. **карабаш, гарабаш** «монах». Рус. *карабаш* «җикән төре» тур. Аникин: 260 (әдәбият китерелә).

**КАРАВАЙ [каравай]** «каравай (большой круглый подовый хлеб)» < рус.; рус сүзенең чыгышы ачык түгел һәм бу сүз тат. *кәвәрәй* (к. **Кәвәрә**) сүзеннән түгелме икән дигән фикер туа. Тат. сөйләшләрендә (ЗДС: 274) **караwай** «бәлешсыман камыр ашы», әлбәттә, русчадан.

**КАРАВАТ [караwат],** диал. **кәрәвәт** «кровать». Бу сүз гадәттә рус теленнән дип күрсәтелә, ләкин иске кыпч. сүзлекләрендә (Курышжанов 1970) үк *кәрәбәт*, гар., төр. *кäрäвäт* < грек. *καραβατ* id. (рус теленә грек теленнән шактый фонетик деформация кичереп, төрки телләргә деформациясез кергән), к. Räsänen 1969: 265. Һәрхәлдә хәз. тат. яңгырашында бу сүз, әлбәттә, русчадан (урта *к*). Чаг. төр. *kerevet, kerevit, karavide* «агач карават; сәке» грек сөйләшләреннән.

**КАРАВАШ [қа°раwаш], каравыш** тар. «фрейлина; рабыня знатной госпожи» < бор. кыпч., к. кар., к.-балк., кр.-тат. *қараваш,* куман. *karavaš,* төр. *karavaş,* төркм. *ғарабаш* id. ~ бор. төрки (ДТС: 422) *qarabaš* «кол хатын» (*baš* «хезмәтче хатын» мәгъ. булган, к. Боровков 1963: 93, 200). Будагов II: 48; Zajączkowski: 132; Redhouse: 605. Ихтимал, **караваш** һәм **каравыш** икесе ике сүздәндер. Һәрхәлдә *караваш* ул *кара баш* түгел! Мухамедова 1973: 113–114.

**КАРАВЫЛ [қа°раwы̆л]** «караул, караульный» ~ гом. төрки *қараwыл, қараwул, қарағул* (к. Будагов II: 48) ~ чув. *хурал* < *хорал* < болг. **хороол* > мар. (Иванов, Тужаров 1971: 148, Саваткова: 108) *орол, оролы* һ.б. монг. *қарагул* сүзеннән, ихтимал, монгол яуларына кадәр үк таралгандыр, к. ш. ук як. *харабыл* id. К. Гуломов А. Сўзлар хаётидан: коровул // Үзбек тили ва адабиёти. 1969, № 6: 58–60.

Төрки телләрдә бу сүз барча күрше телләргә таралган, аның таралышына рус. *караул* (к. Аникин: 265–266) да өлеш керткән. *Каравыл – кара-* фигыленә *-wыл* < *-гул* кушымчасы ялганып ясалган. Бу модельдә тагын күп хәрби-административ терминнар ясалган булган: куман сүзлегендә үк инде *бегеул, булгавул, чырмавул, токтавул* искә алына; тат. теле тарихында (**каравыл**дан тыш) тагын *ирәвел, багавыл, яртәвел, ясавыл* һ.б. билгеле. Будагов II: 48; Ахметьянов 1989: 148–149; Федотов II: 363–364; ЭСТЯ V: 290–291.

Дерив.: **каравыллы, каравылсыз; каравыллык; каравылла-у; каравылчы.**

**КАРАГАЙ** «сосна, вид сосны», диал. **каргай** > рус. диал. *каргай* һ.б. «тәбәнәк карагайлык» < гом. кыпч. *қарағай, қараңай* < монг. *қарагай* (*-гай* – монгол кушымчасы), к. ш. ук алт. *карай, каракай,* як. *харыйа* «нарат» (к. Räsänen 1969: 235). Кайбер галимнәр бу сүзнең тамыры **кара** түгел, ә бор. (ДТС: 426) *қары* (> чув. *хыр* «чыршы») диләр (к. Аникин: 261). ЭСТЯ V: 291–293.

**Карагай агачы** белән беррәттән **карагай** (*кара* + *ғай, қай* «кош») «кыр үрдәгенең бер төре» сүзе дә бар. К. **Карагат, Карагач.**

Дерив.: **карагайлы, карагайсыз; карагайлык.** *Карагай* ярдәмендә ясалган төрле атамалар тур. к. ЗДС: 390.

**КАРАГАТ** «чёрная смородина» (наряду с **кызылгат** «красная смородина») < гом. төрки (кайбер телләрдә юк) *қарағат,* аз. *ғарағат* id. **кара** һәм диал. **гат, кат** «җиләк» сүзеннән. К. башк. (БТДҺ: 88) *қарақат* «карагат», бор. төрки (ДТС: 432) *qat* ~ хак. *хат* «җиләк, җимеш».

**КАРАГАЧ** «лиственница» < гом. кыпч., үзб., уйг. һ.б. *қарағач* (нуг., каз., к.-калп. *қарағаш* id.) < *кара агач*? **Карагач** дип караманы һәм бүтән кайбер агачларны да атыйлар (к. рус. *карагач* тур. Аникин: 262–263).

**КАРАГРУҺ** «черная сотня» (организация монархистов начала XX века) – тат. теленең үзендә **кара** һәм **груһ** сүзләреннән ясалган.

**КАРАЗИР, каразирә** «дурман; черниха (растение)» ~ башк. *қарасира,* кар. *кара зирә* «әнис» (*зирә* < гар. *зäррä* «вак орлык»). Добр. *kara žire* – фәнни атамасы *Nigella Sativa,* «вак кына кара орлыгы күмәч өстенә сибелә торган үсемлек» диелә.

**КАРАЗЫ,** (Тумашева 1992: 120) **қараузы** «мрак; невежда», (БТДҺ: 188) **қараз** «злодей» ~ алт. (Будагов II: 45–46) *каразы* «мәет чыккан өйдә калган үлем рухы» ~ төр. *karayazi* «кара бәхет, кара язмыш» ← **кара** (к.). Ясалышы ачык түгел.

**КАРАЙ** диал. (к. Будагов II: 47) «смотря; в сторону», «около» – гом. кыпч. *қарай,* каз. *ғарай* id.; башк., каз. һ.б. *қарайлы* «карап, карата» һ.б. *кара-у* (к.) фигыленнән, әлбәттә, әмма ясалышы бик үк ачык түгел. Чаг. **карамый(ча)** ~ *карамастан,* киресе – **карап** һ.б. җентекләп тикшерүгә лаеклы сүзләр. К. ш. ук **карата.**

**КАРАК** «вор, разбойник» > чув. *хорах* > *хурах,* удм., мар. *карак* id., тат. диал., гом. төрки, бор. төрки (ДТС: 425) *qaraqcï* сүзеннән эллипсис; *қарақ* (хак., як. *харах*) үзе төптә «күз, караш» дигән сүз (чаг. тат. *елан карагы* «елан күзе» – бер төр җиләк; диал. *карагым* «җаным, күз карам» һәм *каракчы* «күзәтче, күзәтүче» мәгъ. булган – әлбәттә, **кара-у** сүзеннән), к. бор. монг. *qaraqcı* «күремче» (Поппе 1938: 293). Федотов II: 365–366; ЭСТЯ V: 294–295 (*карак* сүзенең беренчел мәгъ. «талау» диелә, безнеңчә, алай түгел). К. ш. ук Аникин: 260–261.

**КАРАКАЛ, караколак** «степная рысь (с чёрными ушами)» < гом. кыпч., үзб. һ.б. *қарақал* «кара какул» (к. **Какул**), ә *караколак,* төр. *karakulak* «кара колак», чаг. фар. *сийаһ гүш* «караколак» (*сийаһ* «кара», *гүш* «колак»).

**КАРАКАЛПАК** «каракалпак», у татар – «крестьянин, крепостной» (Будагов II: 21) – кара калпак (түбәтәй) киюдән. Татар түбәтәе гадәттә **кара.** Этник *каракалпак* атамасы тур. Фасмер II: 191.

**КАРА-КАРШЫ** «друг против друга» – *карама каршы* сүзеннән эллипсис.

**КАРАКИР** «караковый (о лошади)» – **кара** һәм **кир** сүзләреннән гыйбарәт. Бу сүз борынгыдан килә, к. фарсы (< төрки) *қара-кäһäр* «каракир».

**КАРАКОРЫМ** «Каракорум, столица империи Чингиз хана» элекке тат. тарихи әдәбиятта «кара корым» дип аңлатылган. Хәлбуки бу атамада **корым** сүзенең катнашы юк. Ике **Каракорум** бар: 1) Кытай белән Пакьстанны аерып торган зур (900 км озынлыктагы) тау сырты һәм шундагы бер үткел атамасы; **кара** «кара», **корум** – каз. *қорым,* кырг., монг., бор. төрки (Боровков: 215) *қорум* «эре ташлар, таш таулар, кыялар күп булган төбәк»; 2) Монголиядәге **Кара Корум** (асылда *Кара Курим ~ Хара Хурим*) Чыңгыз хан империясенең Монголиядәге башкаласы, *кара* «дәү; эш өе» (к. тат. *кара өй*) һәм *курим* «сарай, гыйбадәтханә» сүзләреннән тора. Сүзләр вә тәгъбирләр этимологиясендә бу бик гыйбрәтле очрак.

**КАРАКОШ,** диал. **қарағош** «орёл-могильник», «орёл на гербе России» ~ башк. *қарағош,* кырг., алт. һ.б. *қарақуш,* төр. *karakuş* «каракош, гербтагы бөркетсыман кош», күч. мәгъ. «деспот, залим»; аз. *ғарағуш* «каракош» төрле мәгъ., күп Кавказ телләренә алынган. Рус. *карагуш, карагуж, каракус* тур. Аникин: 263. Гар., фар. *қарақуш* «деспот», шуннан *қарақуши* «деспотик» һ.б. (*Қарақуши* дигән династия дә булган).

**Каракош** сүзе характерлы мәгънәләрендә фар. *сиёһмург* (*сиёһ* «кара», *мург* «кош») «сәмрәү, гербтагы кош» сүзе калькалаштырып ясалган булса кирәк. ЭСТЯ V: 24.

**КАРАКУЛ I** тар. «военная полиция» ~ төр. *karakol* id. *Кул ~ kol* монда «гаскәр бүлеге, фланг» булса кирәк. **Каракул** сүзен еш кына **Каравыл** сүзе белән бутыйлар. Хәлбуки болар төптән аерым-аерым сүзләр. *Қарақол* һәм *караwул* аерым сүзләр дип атаклы немес тюркологы В. Банг язган булган, к. İA VI: 288–289.

Башк. *Қарағол* исеме «кара кол» түгел, ә **каракул** сүзеннән булса кирәк.

***КАРАКУЛ II** «каракули, неразборчивый и неграмотный почерк» > рус. *каракули* id. (к. Фасмер IV: 192). *Кул > қол* сүзенә караганда татарчадан, ләкин тат. *кара кул* бик мөмкин булса да, андый тотрыклы тезмә сүз бүген кулланылмый.

**КАРАКУРА** «бурьян» ~ башк. *қарағура* «каракура; карабаш җикән», каз., к.-калп. *қара қора* «камыш кура» (кабарда. *қэрэқурэ*, абаз. *каракъвыра* «каракура» < төрки *қара қура* (к. **Кара** һәм **Кура, Курак**).

**КАРАКҮЛ** «каракуль» – Урта Азиядәге *Кара күл* исеменнән (шул тирәдәге махсус токымлы куйларның бәрән тиресе).

**КАРАЛДЫ, каралты** (себ., ЗДС: 391) «привидение: чучело» к. түбәндәгене.

**КАРАЛТЫ** «надворные постройки» > удм., мар. диал. *каралты, каралды* «каралты, йорт», себ. (Тумашева 1992: 120) **қаралты** «карачкы» < гом. кыпч., к. башк. *қаралды,* нуг., каз., к.-калп. *қаралты* «силуэт; еректан ачыксыз күренгән нәрсәләр; каралты», каз., к.-калп. *қаралды* «кирәк-ярак», «җиһазлар», төр. *karaltı, karaldu*, гаг. *қаралты, қарарты,* балк. *қарелди,* аз. *ғаралты*, төркм. (ТДГДС: 51) *ғаралтғы* «ерактан күренгән силуэт; карачкы», иске төр. (Будагов II: 44, 47) *қаралты* «ерактан начар күренгән нәрсә; көтү, өер; өрәк, иләс», к. ш. ук себ. (Дмитриева 1981: 151) *қаранды* «бина, корылма», үзб. (ЎХШЛ: 156) *қаратқы*, аз. (АДДС: 115) *ғаратғу* «каралты; силуэт, күләгә», тув. *каралдыр* «карасу» һ.б. – **кара-у** фигыле нигезенә эшхәрәкәтнең (котылгысыз) нәтиҗәсен белдерүчән *-лты//-лте, -нты//-нте* кушымчасы ялганып ясалган сүз. **Кара** сүзенең дә тәэсире булган.

Чув. *хуралтӑ < хоралтӑ* < болг. **һаралты* > мар. *аралте,* (Иванов, Тужаров: 17) *аралды* «каралты» варианты бу сүзнең борынгыдан килгәнлеген һәм болг. теленә кыпчакчадан кергәнлеген күрсәтә, чөнки *қара-* фигыле төп болг. телендә булмаган, ул кыпч. телләренә чагыштырмача соңрак монг. телләреннән кергән. Räsänen 1969: 236, 302 (чагыштырулар белән чикләнә), Федотов II: 364 (асылда тат. телчеләре әйткән фикерне – **каралты < кура алды** дигәнне кабатлый һәм **кор-у** сүзенә дә бәйләмәкче; бу фаразлар кирәксез һәм нигезсез).

«Силуэт ~ каралты» мәгъ. тәңгәллеге бор. төрки (ДТС: 84–85) *barq* сүзендә дә күзәтелә.

Дерив.: **каралтылы, каралтысыз.**

**КАРАЛЫК** «чернота» – гом. кыпч. *қаралық,* уйг. *қаралуғ* һ.б. ← **кара** (к.). Бу сүзнең металлургик мәгънәсе «корычлык» булган, к. Засенко А. Откуда сие: *харалужный* // Радуга, №1, 1973: 165–172.

**КАРАМА** «вяз» > удм. *куромо, корома,* чув. *хорама* > *хурама* id. < гом. кыпч., к. каз. (ҚТДС: 194), алт. *қарама* id., каз., к.-калп. үзб. (ЎХШЛ: 156) *қараман* «арба, чана карамасы», «каты карагач» ← **қарыма* ← **кар-, *кары-* (к. **Карыш-у**) «бәйләү (караманың яшь ботаклары агач детальләрне беркетү өчен кулланылып килгән)», чаг. мар. *шоло* «карама агачы; чана һ.б. карамасы», фин. *paju* id., рус. *вяз* id. (шуннан «вязать»). Räsänen 1969: 236; Федотов II: 264–265 (кирәкмәгән этимология китерә); ЭСТЯ V: 296 (материалы ярлы, *кара* сүзеннән чыгып аңлатыла – бу дөрес түгел); ДАУ I: 108.

Дерив.: **карамалы, карамасыз; карамалык** (төрле мәгъ.); **карамала-у.**

**КАРАМАК** только в притяжательной форме или в косвенных падежах (**карамакта, карамагында**), кит. «ведение, распоряжение; попечение» – чыгт. (әд.) телдә килеп чыккан; каз., кырг., уйг. һ.б. *қарамақ,* үзб. *қарамоқ, қорамоқ* id. ← *қара-* (к. **Кара-у**). Төр. телендә юк.

**Карамакчы** дигән грамматик форма, әлбәттә, бүтән сүз.

**КАРАМЧЫК** «тёмное пятно» ~ алт. *қарамтық,* төр. *karamtık* «кара нәрсә», башк. *қарасық,* чув. *хуранчăк* «карамчык», кар., ком. *қарамчық, қарамчых* «чүп үләне, карамык» һ.б. ← гом. кыпч. *қараң, қаран*, кырг. *қараан* «томанлы силуэт» ← **кара** (к.). Чаг. **Карачкы.**

**КАРАМЫК** «чёрная оспа», (БТДҺ: 188) «тиф», тат. диал. (м.-кар.) «почерневший орех без ядра», (ТТДС I: 230) «пасмурный, мрачный» > чув. *карамăк* ~ нуг., каз. *қарамық,* төр. *karatık* «карамык; кызамык» һ.б.

Бу сүзнең үсемлек мәгъ. киңрәк таралган, к. диал. (Арсланов 1992: 127; Тумашева 1992: 120), кар., кырг., каз., к.-калп., чыгт. *қарамық,* төркм. һ.б. угыз. *ғарамық,* уйг. *қаримуқ* < бор. төрки (ДТС: 425) *qaratıq* «бакра; эт җиләге», төр., кр.-тат. (Будагов II: 47) *қарамуқ* «кыргый кара чия», аз. (АДДС: 115) *ғарамух* «чәчкәле бер куак үсемлек», гаг. *карамук* «кара бөрлегән» һ.б. К. Zenker II: 696, 698. Бу сүз күрше телләргә дә алынган, к. манси. (Kannisto: 112) *karatax* «бер төр чүп үләне». Ком. *қарамуқ* «сугару канавы» мәгъ. «чүп үләне» мәгънәсеннән булса кирәк (канау читләрендә чүп үләне үсүчән). Мухамедова 1973: 114 (тәфсилле); ЭСТЯ V: 296–298 (авыру атамасы аерым бирелә).

**КАРАН I** диал. «незамерзающий зимой водный источник; проталина» **кара** сүзеннән булса кирәк (к. ЭСТЯ V: 298), к. башк. *қаран,* алт. *каранты* «каран». Чаг. рус. диал. *харасун* < монг., бур. *хара*[н] *усун* «кара су», «каран». к. Аникин: 611.

Чув. *хуран* < *хоран* «карамчык» ~ гом. кыпч. *қараң* «карамчык» икенче сүз.

Топонимикада **Каран** тур. Гарипова 1998: 381–382.

**КАРАН II** диал. «бесплодный (о женщине, о земле)» ~ к.-балк. *қаран* id., чаг. башк. *қара бидәү (биҙәү)* «бөтенләй бала тапмаган хатын». **Кара** сүзенә баглы.

**КАРАНДАШ,** диал. **кырандаш, кардәш қәләм, кәрендәш қәләм** «карандаш» ~ чув. *кăрандаш*, каз. *карындаш*, кырг. *қарандаш*, каз. диал. *карындаш таш,* башк. диал. *таш қәләм,* үзб. *тош қалам,* каз., к.-калп. *таскалам, таскалем,* төркм. *дааш калем*, нуг. *таш карындаш* «карандаш», асылда «грифель», төр. *kurşun kalem, kurşun daş* «кургашын каләм, карандаш». Рус. этимологиясендә аз. *қәләм даш* сүзеннән дип күрсәтелә (к. Колесников Н.П. К этимологии слова карандаш. Немет Т.Ю. Происхождение русского слова *карандаш;* ике мәкалә дә // «Лексикологический сборник», V. М., 1962: 105–114). Федотов (II: 257) та шул фикердәрәк. XX г. башында яшәгән татар лексикологы С. Җантурин (к. аныкы. Лөгать. Уфа: 275) тат. **кырандаш** < госм. *кыран даш* «вакланып прессланган таш» сүзеннән ди.

Безнеңчә, тат. *кырандаш,* искечә *коранташ* < бор. *қургал таш.* Монда *қургал* «кара кургаш» > «графит»: графит төсе белән каракургашка бик охшаш, шунлыктан аны кургашның бер төре дип уйлаганнар. Графит таякчык – грифель белән төрле өслекләргә б.э. кадәр үк яза белгәннәр. Бу фараз ним. *Bleistift* «карандаш», сүзмә-сүз «кургаш таякчык» сүзе белән исбатлана кебек (к. Kluge: 132). Әйтмәкче, каракургашның үзе белән дә махсус «кара тактага» язып йөргәннәр һәм китерелгән төр. сүзләре иске реальлекне чагылдыра.

**КАРАНУГАЙ** «татарин, переселившийся (в организованном порядке) из России в Южный Казахстан в XVIII–XIX веках» К. Будагов II: 295.

**Кара нугай** этник төркеме (хәз. Төньяк Кавказда) да бар. Ләкин ул бүтән шәй.

**КАРАҢГЫ,** (Дмитриева 1981: 152) **караңгый** «тёмный; темнота» < гом. төрки *караңгы* (хак. *хараағы* һ.б. вариантлар), урта төрки (СС) *караңгу*, аз. *гарангу*, бор. төрки (ДТС: 424) *qaraŋqu*, алт. *караҥуй* < бор. монг. *qaranγui* «карагысыз, күргесез» сүзеннән (*кара-у* фигыленнән) (Räsänen 1969: 236), к. хәз. монг. *гарангуу*, бур. *харангуй*. Икенче бер вариант буенча, монг. телендә *кара, хара* сүзеннән ясалган (Дондуков: 93). Монгол халыкларында *Хан Хараңгуй* «Караңгылык патшасы» – мифологик эпос герое (МНМ II: 577–578).

Дерив.: **караңгылык; караңгылы; караңгылан-у** һ.б.

**КАРАП I** диал. (Kecskemeti-Paasonen 1965: 25) «вид коршуна» ~ рус. диал. *карап* «тилгән» (Аникин: 265). Чаг. рус. *гриф* бөркет төре – грек. *γρυφ* id. сүзеннән.

**КАРАП II** «корабль» к. **Кәрап**.

**КАРАР** «решение; резолюция; решимость» < гар. *қарāр* id. *Крр* тамырыннан, шуннан ук **икърар.**

Дерив.: **карарлы, карарсыз; карарлан-у, карарла-у, карарлаш-у.**

**КАРАСАН** диал. (Тумашева 1992: 120) «сибирская язва», башк. *қараһан*, каз., кырг. *қарасан, қара сан* – сыерларның яман чире (гәүдәнең бер ягы – саны карая). Будагов II: 8. Ясалышы ачык түгел.

**КАРАТА** «в отношении; в адрес кого», ш. ук **каратып** id. ← **карат-у** ← **кара-у.** К. **Кара-у.** Тат. телендә ясалган булса кирәк.

**КАРАТАЙ** – ныне почти исчезнувшая группа татар в трёх небольших населённых пунктах у устья Камы, говорящая на своеобразном наречии с чертами мишарского диалекта, считаются отатарившейся мордвой – **кара тай** дип аңлату берничек тә нигезләнмәгән. *Каратай* дигән ыру атамасы нугайларда, казакларда һ.б. бар. К. Мордва-каратаи. Казань, 1991.

**КАРА-У** «смотреть, наблюдать; осмотреть; присмотреть, воспитывать младенцев», «пытаться» < гом. кыпч., уйг., алт. *қара-*, тув., хак. *кара-*, як. *харай-*, төркм. (ТДГДС: 51) *гара-* id. Угыз телләрендә сирәк очрый, чув. телендә юк һәм бу сүзне монг. телләреннән алынма дип карыйлар (Räsänen 1969: 235) к. монг. *хараа-* < *qaraa-* «карау, күзәтү» > гом. тунг. (ССТМЯ I: 380) *қара-, қарай-* id. Будагов II: 47; ЭСТЯ V: 288–289.

Дерив.: **карал-у, каран-у, караш-у, карат-у; кара** «игътибар ит!»; **караш, карама-у** (аерым мәгънәле). К. **Каравыл, Карай, Карак, Карамак, Карата.**

**КАРАЧ** «чёрная скотина» – **кара** сүзеннән < гом. кыпч. *қарач* «кара нәрсә» (төрле мәгъ. очрый, һәрхәлдә *кара* сүзеннән). К. **Карачá I, Карачман.**

**КАРАЧÁ I** «нечто чёрное; чёрный, бедный; чернь» ~ каз. *қараша,* кырг. *қарача* «кара эштә хезмәтче» һ.б. < **кара-ча** (исем). Төрки телләрдә **карача** төрле мәгъ. очрый. Мәс., кр.-тат. *қарача* «болан төре» (тат. *«Ары да килер карача, бире дә килер карача. Тал төбендә тонык су тондырып эчәр карача»* дигән табышмакта шул булса кирәк).

**КАРÁЧА II** «курная (изба)» < *кара-ча* (рәвеш, сыйфат). К. ш. ук *карáча* рус. «по-дилетантски».

**КАРАЧКЫ** «огородное пугало; пугало» < гом. кыпч. *қарачқы* (нуг., каз., к.-калп. *қарашқы*) id., алт. *карачкы,* хак. *харасхы* «кара тап; караңгылык, карамык», к. ш. ук үзб. (ЎХШЛ: 156) *қаратқы*, аз. (АДДС: 116) *гаратчу,* ком. *қаранчқы,* к.-балк. *қаранчқа, қаранчха* «силуэт, сөкәт», «карачкы». К. ш. ук **Карач.**

**КАРАЧМАН** «смуглый» ~ алт. *каразман,* башк. *қарасман, қарасмы* id. **Карач** нигезеннән булса кирәк.

**КАРАЧЫ** «карачи, один из четырёх выборщиков хана» (Фасмер II: 194) ~ уйг. *қарачу*. Казан һәм Кырым татар дәүләтләрендә *карачы* ~ каз. *қарашы* дип хан сайлау хокукы булган дүрт бөек асылзатның берсен атаганнар. Гадәттә, карачылар *аргын, барын, ширин* һәм *кыпчак* ыруларыннан вәкил буларак билгеләнгәннәр. Дәүләттә иң югары орган – карачылар киңәше булган. *Акыллы карачы кара җирдән каек йөртер* мәкале шуннан калган. Хан үлеп, ханзадәләр арасыннан хан сайларга җыелгач, хан буласы кешене дүрт почмаклы киезгә утыртканнар, күзен бәйләгәннәр һәм һәр карачы, киезнең бер почмагын тотып, бераз читтәрәк торган тәхеткә таба күтәреп алып барганнар. Әгәр

карачыларның берәрсе бу кандидатка каршы булса, ул үз почмагын төшереп җибәргән. Нәтиҗәдә претендент егылып киткән һәм хан бу юлы сайланмаган. Яңа хан тик барча *карачылар* бер фикердә булганда гына сайлана алган.

Күп төрки телләрдә *қарачы,* төркм. *гарачы* «кара халык», уйг. *қарачуқ* «кара халык вәкиле» дигән сүз. Бор. (көнб.) уйгур һәм хакас дәүләтләрендә *карачы* «хан янында кара халык вәкиле» мәгъ. бер титул булган. Шуннан Алтын Урдада *карачы* сүзе «Чыңгыз хан нәселеннән булмаган дәрәҗәле кеше» мәгъ. алган һәм Казан дәүләтендәге *карачы* да Алтын Урдадагы традицион функцияне үтәгән.

Карачылар Касыйм ханлыгында да булган, бу турыда В.В. Вельяминов-Зерновның «Исследование о Касимовских царях и царевичах» (СПб., 1864) дигән китабында күп мәгълүмат бирелә. К. ш. ук Рашид-ад-Дин. Сборник летописей. Т. I, ч. 2. М. – Л., 1952: 14.

Гомумиләштереп әйткәндә, *карачы* титулы һәм вазифасы безгә көнб. уйгур дәүләтчелегеннән (840–1236) мирас булып калган, һәм бу очраклы түгел: Алтын Урда шәһәрләрендә уйгурлар күп булган, алар дәүләтнең язу-сызу, конкрет идарә эшләрен йөрткәннәр.

Шуны да әйтик, төрле төрки һәм күрше телләрдә бу сүз бик төрле мәгънәле, мәс., төр. (YTS: 126) *karaçı* «чегән; яла ягучы; күзәтче, шпион; фалчы; мәхәббәт яулаучы», алт. *карачы* «чибәр, купшы (егет, кыз)», аз. *гарачы* «чегән; теләнче; тавышчан кеше; әләкче, доносчы», хак. (Бутанаев: 201–206) *харачы* «асылзатның хезмәтчесе, лакей; кара кол» һ.б.

Сүз ясалышына караганда (*-чы* аффиксы фигыль нигезенә турыдан-туры ялгану) бу бик бор. термин. **Карачы** сүзен *кара-у* фигыленнән дип аңлату да бар (Будагов II: 45). ЭСТЯ V: 300–301 (бик таркау аңлатма).

**КАРБЫЗ** «арбуз» > чув. *харпăс* < гом. кыпч. *қарбыз*, госм., кр.-тат. (Радлов II: 212) *қарпуз*, үзб. (ЎХШЛ: 157) *қармыз, хармыз* һ.б. id. < иске фар. *xarbuzak* «ишәк кыяры – карбыз». Рус. *арбуз* Касыйм татарлары теленнән, ә укр. *гарбуз* id. кр.-тат. теленнән булса кирәк.

**КАРГА** «ворона; грач» (**кара карга** «грач», **ала карга** «ворона») < гом. төрки *қарға* < *қарғай* (*кар* имитатив, каркылдау авазын белдерә, *-гай, -кай* (*-га, -ка*) күп кенә кош атамаларында күзәтелә: *карчыга, тургай, чүрәгәй* һ.б. «кош», чаг. чув. *кайак* id.), к. ш. ук чув. *курак* < *корак* ~ мар. *карак* «карга». Каргаларның атамасы барча телләрдә *қ, ғ* һәм *р* авазларын эченә ала, к. рус. *грач,* ним. *Krähe*, эстон. *kaaren*, инг. *crow*, лат. *corvus*, фар. *карокар*, әфг. *карғā*, гар. *ғурāб*, көрд. *qarıq* «козгын», *qarqarq, qıriq* «карга» һ.б. Ләкин рус. *карга* «карга» < тат., к. Аникин: 266. Чаг. ш. ук алт. *қарға-* «каркылдау». ЭСТЯ V: 303–304; Сафина 2006: 44–45.

**КАРГА-У** «проклинать» > удм. *қарга-*, чув. *харка-* < гом. төрки, бор. төрки (ДТС: 426) *қарға-, қаарга-*, як. *қыраа-* id. ~ бор. монг. *qarija-* «сүгенү» (Räsänen 1969: 237) ~ бор. монг. (Владимирцов: 210) *qarıγa-* «сүгү». Рясянен (Räsänen 1969: 237) *қарға-* нигезен себ. тат. *қарғы-* «йомыш кушу, әмер итү», монг. *qarija-* «сүгү, каргау, кискен әмер бирү» һәм фин. *kiroa-, kirvaa-* id., *qīrγa-* «(башлык, боерчы) ачулану» сүзләре белән чагыштыра. К. **Каргыш**; чаг. **Кару.** ЭСТЯ V: 304–305 (**қар-* «каргау» тамырыннан диелә).

Дерив.: **каргал-у, карган-у, каргаш-у, каргат-у; каргаш** (каргау күренеше, **каргыш** түгел).

**КАРГАША I** (Будагов II: 10), **қырқаша** (Тумашева 1992: 141) «ссора, сумятица, замешательство» ~ чыгт., кр.-тат. *қарғаша* id., төр., аз. *гарааша* «талашу, әрепләшү, хаос», кырг. *қарғыша* ~ монг. (Поппе 1938: 293) *qarγaša* «судлашу, судта дәгъва» һ.б.ш., чаг. каз. (ҚТДС: 195) *қарғаса* «әләктергеч тимер, аркылы-торкылы тимер»; фар. (Будагов I: 530) *хāрхāшā* «дошманлашу» төрки телләрдәндер. Чаг**. Каргыш**.

**КАРГАША II** себ. (ЗДС: 392) «сруб из тонких брёвен» ~ рус. диал. (Аникин: 267–268) *каргашак, каргазник, каргыз* «сазда үскән чибек, нәзек карагай, чыршы» (Аникин моны *карагай* сүзеннән чыгара).

**КАРГЫН** (ЗДС: 392) «куча земли, выкопанная роющими норы животными» – «өннәрдә яшәүче хайваннар казып чыгарган туфрак өеме» ~ каз. (ҚТДС: 195–196) *қарғын* «көчле яңгырдан соң ташып аккан су һәм казылмалар», *қарық* «буразнасыман арык; киртә функциясендә казылган ур» ~ төр. диал. *kargın* «өй алдында, йортта ясала торган балчык-җир урындык». Барысы да бор. **қарғ-* «казу» сүзеннән булса кирәк. Чаг. **Карла-у.**

**КАРГЫ-У** «прыгать от возбуждения (о животных)» ~ каз., к.-калп., кырг. *каргы-* id. Ачык түгел. Чаг. диал. *қарғы-у* «бурыч йөкләтү» (< өстенә менү?).

**КАРГЫШ** «проклятие» < гом. төрки *қарғыш*, нуг., каз., к.-калп. *қарғыс* id., бор. телдә үк *qarγïš* id. *qarγaš* сүзеннән аерыла (ДТС: 426), чаг. як. *харгыс*, монг. *харгис*, эвенк. *харги* «явыз, яман; явыз рух», госм. *қарғы*, уйг. *қарғи* «каргау; каргыш». Ничектер *каршы* сүзе белән баглы булса кирәк, к. як. *каргы*, үзб. *қарық* (ЎХШЛ: 159) «сай канал; комачау», бор. төрки *qarγu*, *qarγuj* (ДТС: 426) «чик буендагы күзәтчелек манарасы».

Ихтимал, сүзнең тамыры – бор. монг. *qar-* «дошман күрү» (Поппе 1938: 444) ~ камас. (Joki 1952: 165) *kargı-* «каргау».

Дерив.: **каргышлы, каргышсыз; каргышла-у; каргышлан-у.**

**КА́РДА [ка́рды̆]** «ка́рда, обширное загороженное место для скота» < рус. *ка́рда* < чув., морд. *ка́рда* < тат. *кәртә,* к. **Кәртә.** Бу сүз бор. тат. теленнән таралган дияргә мөмкин, чөнки тамыры палаталь яңгыраштa. Фасмер II: 196–197.

**КАРДӘШ [қәрдәш]** «родственник» < диал. **қәрендәш** «кардәш; хатын-кыз туган» ~ чув. *хурăнташ* < гом. төрки *қардаш* < *қарындаш* (нуг., каз., к.-калп. *қарындас*) «бер карыннан чыккан». Кыпч. телләре өчен гадәттә булмаган, гайре табигый (алгы рәт сузыклар белән килгән) каты **қ-** безгә уйгурчадан кергән, к. ш. ук **қәйнә, қәртинә.** К. Покровская: 38–41; Рамазанова 1991: 153 (һ.б.); Федотов II: 366.

Дерив.: **кардәшле, кардәшсез; кардәшлек; кардәшлән-ү; кардәшләрчә.**

**КАРЕ [қәрĕ]** «предплечье» (Тумашева 1992: 121) «локоть (чаще – как мера длины)» ~ башк. (БТДҺ: 187) *қара* «ун аршынлык берәмлек», чув. *хор* > *хур* «терсәк; озынлык үлчәме» ~ гом. кыпч., чыгт., үзб. диал. һ.б. *қары* «ике аршин» ~ бор. төрки (ДТС: 426) *qarï*, як. *хары*, тув. *кары* id. К. ш. ук монг. *гар, қар* «кул», к. **Карыш**. Тат. яңгыраш хива сөйләшләрендәге (Радлов II: 189) *қарі* яңгырашын хәтерләтә. Будагов II: 13; Федотов II: 360 (тат. сүзен белми). Тәфсилле мәкалә: Дыбо Л.В. К истории антропометрических терминов. СТ, № 1, 1989: 71–79.

**КАРИ** «чтец Корана» < гар. *қāрū'* id. (*Коръән* сүзе белән тамырдаш). **Карый** (к.) белән бутамаска.

**КАРИП** «близ, близок; около» < гар. *қарūб* id. К. ш. ук себ. **қәреп** «дус, якының» (Тумашева 1992: 126). К. **Әкрәбә, Корбәт.**

**КАРКАРА** «вид журавля с хохолком на голове», к. **Кәркәрәй.**

**КАРКЫЛДА-У, каргылда-у** «каркать» < гом. кыпч. *қарқылда-* id. ← *қарқыл-қарқыл* ← *қарқ* имитативыннан, чаг. чув. *карк, карăк* «карк» (карга тавышына имитатив).

**Каркылда-у**дан **карылда-у**ны аерырга кирәк: ул икенче авазны белдерә (карга гына түгел, тавык һәм этәч тә *карылдый*).

Дерив.: **каркылдаш-у, каркылда-у; каркылдавык, каркылдык.**

**КАРЛАУ [қаºрлаw],** диал. **карлак** (ДС II: 99), **карлач** «лопатка, мешалка; инструмент для очищения плуга» > чув. *карлав* ~ нуг., ком., к.-балк. *карлаw,* добр. *karlaw* id. Ачык түгел. Чаг. **Карма-у.** Федотов I: 224.

**КАРЛЫГАН** «смородина» > чув. *хорлахан* > *хурлăхан* id. Бүтән төрки телләрдә *қара қат*, *карагат, ғарағат* (к. **Карагат**). Тат. яңгыраш бор. төрки *qaragan* > себ. төрки, башк. (БТДҺ: 187) *қараған, қарағана* «акация сыман куак» (к. ш. ук башк. «эт муелы») < **карагал* сүзеннән үзгәргән һәм **карлыган** сүзе төптән (мәгънә җәһәтеннән дә, яңгыраш җәһәтеннән дә) дөрес түгел, ә диал. **карагат** – дөресрәк. К. рус. диал. *карагал, карагана* «карагана үсемлеге» (Аникин: 262). Räsänen 1969: 238. *Қарағaн, қарғана* тур. ЭСТЯ V: 293–294 (күп параллельләр китерелә).

*Карлыган* < *карагал* < *карагана* мәгъ. күчеше **караганa**ның Идел-Урал өлкәсендә, ә карлыганның Себердә электән киң билгеле булмавы белән аңлатыла.

Дерив.: **карлыганлы; карлыганлык; карлыганлан-у.**

**КАРЛЫГАЧ,** диал. **карлугач** «ласточка; стриж» < гом. кыпч. *қарлығач*, уйг. *қарлиғач* (> башк. *қарлығас,* нуг., каз., к.-калп., алт. *қарлығаш*), чыгт., төр. *karlugaç, karlaguç, karlanguç,* хак. *қарлағас*, үзб., уйг. *қалдырғач* id., як. (Пекарский: 3342) *хараңыччы, хараңаччық* «карлыгач; эре карлыгач (рус. “сорокопут”); карга» һ.б. Чаг. тув. *хараачығай*, чыгт. *харачыгай* «карлыгач» (>> тат. диал. – к. Остроумов 1992: 111 – *карачай* «ниндидер кош») ~ бур. *хараасгай,* монг. *харийачай*, тунг. *карачугай* «карлыгач, эре карлыгач» һ.б. (к. Räsänen 1969: 238). Гомумән, **қара** сүзеннән, ләкин төрле регионда төрлечә ясалган: тат., гом. кыпч. *қарлығач* < *қаралығач* сүзендә *-гач* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы бар булса

кирәк. Төр. диал. *kırlangıç,* бор. төрки (ДТС: 426) *qarγïlač* вариантлары бөтенләй бүтән тамырлардан (халык этимологиясенчә) ясалганнар: *карачигай* вариантында *-чигай* «кошчык» элементы күзәтелә. Радлов II: 195, 197. Рус. *карлыгаш* < алт. *қарлагаш* «карлыгач» тур. Аникин: 268. К. ш. ук ССТМЯ I: 379–380 (тунг.-маньч. һәм монг. телләрендә *кара* нигезендә ясалган карлыгач атамалары китерелә). Чаг. **Карчыга.**

**КАРЛЫК-У (карлыкты, карлыга), қарыл-у, қарык-у (қарыгу)** «хрипнуть» < гом. кыпч., алт., хак. *қарлық-*, хак. *харлық-, харық-, харла-*, алт. *қаргырла-* һ.б. «карлыгу; какыру» (к. Радлов II: 197) имитатив *қарқ* – ихтыярсыз тамак авазлары чыгару сүзеннән (чаг. рус. *харкать, гаркнуть* һ.б.ш.). Морфологик җәһәттән *карлык-* < *карыл-ык, карыл-* нигезенең интенсивлык формасы, димәк төп форма **қар-у* яки *қары-у.* Будагов (II: 8) бу сүзне *кар* сүзе белән аңлата (*кар ашап карлыгу*), ләкин бу сүз күзгә дә нисбәтләнә (*күз карыгу*).

**КАРМАК** «удочка, крючок» > мар. (Исанбаев 1978: 42), удм., чув. *кармак* < гом. кыпч., алт., тув. *қармақ,* төркм. (ТДГДС: 52) *гарвақ, гармақ, гарнақ* «кармак, сөкә», аз. *гармач* «кармак, ыргак» < бор. төрки (ДТС: 428) *qarmaq* «ыргак, багур» ← *қарма-* (к. **Карма-у**); к. ш. ук гаг. *қармақ* «эләктергеч, ыргак», алт. диал., шор., хак. (Радлов II: 213) *қарбақ* «учлам; көрәшә (рус. “жерлица”)», хак. *харбах* «учлам», төр. *karmık* «балык тоту өчен суга корылган читән», *kartuk* «зур ыргак». Рус., укр. *кармак* «зур кармак; балык тоту урыны» тур. к. Аникин: 269; чув. *кармак* «биектәге алма һ.б. өзеп алу өчен җәпләкәле таяк» тур. Федотов I: 229–230.

**КАРМАЛА-У** «ощупывать пятернёй (стараясь схватить)» **карма-у** (к.) сүзенең кабатлаулы ешлык формасы. Чаг. ш. ук бор. төрки (ДТС: 428) *qarta* «талау (күренеше)».

**КАРМАН I** «карман» – бу сүз (миш. диал.) үзебезнеке микән, русчадан алынма микән – әйтүе кыен, чөнки рус сүзе төрки телләрдән алынма булып исәпләнә, к. чув. *карман, хайман* «акча янчыгы; җип (хатыннар билбауга асып йөртә торган зур янчык)» ~ алт. *қарман, јан карман*, тув. *қармақ* «кесә». Чаг. **Карман II**.

**КАРМАН II, қәлмән, хәлмән** (ЗДС: 628) «надворные постройки» ~ төр., үзб., чыгт. (к. Будагов I: 511) *хирман, харман* > каз., кырг. *қырман*, *қарман* «ындыр (ток); амбар». Башкортстанда *Қарман* дигән авыллар бар. Бу сүз фар. теленнән килсә кирәк.

**КАРМАСАН** «знаменитая река в Башкортостане, параллельно с которой течёт столь же знаменитая **Чәрмәсән//Сәрмәсән**» – бу елгалар электән үк көйгә-җырга кергән (к. Г. Тукайның җырлар җыентыгы) һәм аларны халык үзара нисбәттә алган. Алар *карма-у* һәм *сәрмә-ү* (һәр икесе «балык тоту» мәгъ. дә кулланылган) сүзләреннән түгелме икән? Чаг. Башкортстанның Балтач районында **Таңатар** һәм **Таңсызар** янәшә авыл атамалары.

Башкорт фольклорында *Кармасан* һәм *Чәрмәсән* ниндидер Ялык ханның угыллары, имеш.

**КАРМА-У** «зацепить пятернёй; искать ощупью» < гом. кыпч. (Радлов II: 216), алт., чыгт., уйг. *қарма-*, алт. диал., шор., хак. диал. (Радлов II: 213) *қарба-* «кармау, эләктерү», як. *харбаа-* «кармау; тырмалап җыештыру; эт кебек йөзү» ~ иске монг. (Поппе 1938: 176, 294) *qarta-* «тотып алу, эләктерү, ябышу» һ.б., төр. (Будагов II: 12) *қару* «капшау» бор. төрки, бор. монг. **қар* «кул» сүзеннән булса кирәк, к. ш. ук бор. монг. *qar-* «өемгә өю» (чаг. **Каша-у**). К. ш. ук үзб. (ЎХШЛ: 157) *қармақ, кармав* «урып җыю», кырг. *қарма-* «уратып алу, каймалау; тоту». Будагов II: 11; Räsänen 1969: 238 (*қарма-* фигылен бор. **қар-* фигыленең интенсивлык формасы ди, ә **қар-* сүзен *каз-у* белән чагыштыра); ЭСТЯ V: 302–303. Дерив.: **кармал-у, карман-у, кармат-у.** К. **Кармак.**

**КАРНАША, карнаса** (ТРС 1931; ТТДС I: 194; ТТДС II: 130) «лоток», «кошница, корзина с верёвкой, которую носят на плече при сборе ягод и т.п.» (М. Гали) < **қарнача* булса кирәк, к. рус. диал. *карна, корна* «тобра», чув. (Ашмарин XI: 85–95) *кармак, карнак* «янчык» > мар. *кармак* id. К. ш. ук тат. (Троянский II: 89) **курна** «тас», литв. *karna* «юкә, шеле». Гомумән, ачык түгел.

**КАРПЫЧ** «жёсткая трава (малопригодная для сена)» ~ чув. *карпăч* < мар. диал. *картпуч, картпыч* «картайган үлән» сүзеннән (*пуч, пыч* «сабак»). Чаг. ш. ук башк. (БТДҺ: 187) *қапырт, қапырық, қапырыш* «карпыч».

**КАРСАК I**, диал. **каршак** «низкий ростом, невысокий» ~ башк. *қарһақ* id., чаг. чыгт. *қарс-* «басу, бастыру, тәбәнәкләтү» (к. Радлов II: 206). К. **Карсак II.**

**КАРСАК II** «корсак, степная лисица» (Vulpes corsac) ~ башк. *ҡарһаҡ* id. < гом. төрки *ҡарсаҡ* id., алт. диал. *ҡарсаҡ,* хак. *харсах* «җәнлек (кеш) тәпие» (к. ш. ук чув., мар. *карсак* «кыр куяны»), рус. *корсак, корсок, корсук* (к. Аникин: 304, шунда ук бай әдәбият күрсәтелә) ~ як. *кырса* ~ яз. монг. *kirsa*, монг. диал. *xjars, gjārs, girsa* «карсак, кырса» (Rona-Tas 1960: 7), рус. *харза* «көзәнсыман җәнлек (Себердә яши)». Л. Будагов буенча, *карсак* гади төлкедән икеләтә кечерәк, шунлыктан бу сүзне **карсак I** белән чагыштырырга ярый. Ләкин кайсы кайсыннан килеп чыккан? Федотов I: 231.

Даль сүзлегендә *корсак* рус сөйләшләрендә «кыргыз (казак)» мәгънәсендә килә, дип күрсәтелә.

**КАРТ** «старик; старый» > чув., мар., удм. *карт* «мәҗүси рухани» ~ гом. кыпч., госм., чыгт., алт. диал. *ҡарт* «карт» < бор. төрки **ҡарыт* «картаю, картайган шәй; күп кар кичергән» ← бор. төрки *qarı-* «күп кар (кыш) кичерү; картаю» сүзеннән (чаг. *яшә-ү* «(күп) яшеллек, үлән кичерү», мар. *ий* «яшь; боз, кар; ел»). К. **Картаң, Картый, Карчык, Карый, Кары-у.**

Дерив.: **картлык; картларча; картай-у; картаймыш.** Төрле сөйләшләрдә (Кавказдан алып Себергә кадәр) *карт* тамырыннан ясалган исәпсез күп сүзләр очрый (к. ЗДС: 393–395, анда барысы да түгел), **ҷарта** «дәвәтисенең исеме кушылган бала», шуңа ук эндәшү сүзе; **ҷартатай, ҷартәтәй, ҷартәти; ҷартбабай** (әтисенең әтисенең әтисе һ.б.), **ҷартанай, ҷартәнәй, ҷартәни, ҷартинәй, ҷартнә, ҷартнәй; ҷарткай, ҷартыкый; ҷартнәнәй** һәм **ҷартөннә** (әтисенең әнисенең әнисе һ.б.). Кайбер очракларда **ҷарт-** нигезендә *а* > *ә* пәйда була (к. ЗДС: 405): **ҷәртәни, ҷәртинә, ҷәртнә** һ.б. К. **Картатай, Картинәй** кебек кардәшлек терминнары тур. ш. ук БТДҺ: 190 (тәфсилле).

**КАРТА I [ка́рты̆]** «карта» < рус. < ит. (к. Фасмер II: 203); к. **Кәрт, Харита.**

**КАРТА II [ка°рта]** собственно **кырык карта** «сорок (множество) слоев», «сычуг; прямая кишка (лошади)», диал. «оборка» ~ чув. *хуртa* < *хорта* «бөрмә», *çӑрхурт* «йөз карта», тат. диал. **карына** ~ як. *харына, хана* «карта», к.-балк. *ҡарта* «кат-кат катлама» ~ гом. кыпч., төр. *ҡарта* «карта» һ.б. **карын** белән бәйле (*карна* > *карда* > *карта* булса кирәк). ЭСТЯ V: 316.

Дерив.: **карталан-у** (муен тур.).

**КАРТАМАН** «карманный вор» ~ кырг. *ҡартаман*, каз., к.-калп., чыгт. *ҡалтаман* id. *калта* сүзеннән. К. **Калтаман.**

**КАРТАҢ, картаңгы** (себ., ЗДС: 393) «преклонных лет; дряхлый, очень старый» ~ каз., кырг. *ҡартаң* «чынлап картайган, картайганлыгы сизелә башлаган». Ачык түгел.

**КАРТУФ, картуш, картуп, картупка, картук, карту, карток, картопка, картапка, картау** (ЗДС: 275–276) «картофель» ~ башк. *картуф* id. < рус. әлбәттә (рус. < фр. < ит. һәм тәүдә «җир алмасы» кебек мәгъ. булган, к. Kluge: 474–479). Ләкин китерелгән яңгырашларының күпчелеге тат. теленең үзендә, миш. сөйләшләрендә ясалган. Урта диалект вәкилләренә **бәрәңге** көнчыгыштан килгән – алар аны, ихтимал, руслардан да алдан белгәннәрдер. Шунлыктан **картуф** сүзен алмаганнар.

**КАРТЫЙ** (ТТДС I: 194; ТТДС II: 160) «бабушка, мать отца или матери» ~ добр. тат. *kartıy* id. (к. Akb: 8, 20, 195 һ.б.) < нуг. *карт айа* < **карт аҗа*. **Картый** сүзе нугай элементлары еш очраган төньяк Башкортстан тат. сөйләшләрендә таралган.

**КАРУ [ка°ры̆w]** (ЗДС: 394) «ответ-возражение; способность противостоять; сопротивление, отпор; возмещение, сатисфикация», (БТДҺ: 191) «причина» (чаще в связанных выражениях: *бер сүзеңә биш кару, кару алу, кару кайтару, каруга кару, аның каруы* һ.б.); диал. (ТТДС I: 195) **кару** «хәлкөч» актив кулланыла > мар. *кӓр*, *каро, кару* id. < гом. кыпч., чыгт. *ҡару, ҡарув,* тув. *харыы*, як. *хоруй* бор. **ҡарыӷу* id. ~ бур. *харуу,* монг. *харигу* ~ маньч. *кару* «хәл-куәт; каршылык, судта үз-үзеңне яклау һ.б.ш.», к. ш. ук шор., уйг. *ҡаруҡ,* тув. *харык*, хак. *харыг,* монг. *хари* «каршылык, җавап»; Котбидә *ҡарӷу* id. Хәз. каз. *ҡару* «сугыш коралы» мәгъ. активлаштырылган.

Бу сүзнең тат. *карау* ~ төр., төркм. *ҡарав* вариантлы икенчел, ләкин күптәннән килә, к. чув. *хорав* > *хурав* < болг. **һараw* > мар. *хоро* > *оро* «кискен каршылык». Бор. төрки телчеләр бу сүзне *ҡар, ҡары* «беләк; каре; көч» сүзе белән бәйләгәннәр Чаг. бор. монг. *xari-* «кайту». К. **Карымта, Каршы.** Будагов II: 12; Пекарский: 3513; ССТМЯ I: 381 (бик күп сүзләр китерелә); ЭСТЯ V: 289–290; Федотов II: 362–363.

Дерив.: **карулаш-у** (мар., удм. телләренә дә кергән), диал. **карулык.**

**КАРУН** «скряга» < гар. *Ḳārūn* – Коръәндә әйтелгәнчә, Муса пәйгамбәрнең дошманы, бик бай һәм бик саран кеше, Библиядә *Корей.* **Карун** сүзен бор. *Крез* патша исеме белән дә чагыштыралар. Будагов II: 12; МНМ I: 625.

**КАРЧА** иск. (Будагов II: 9) «ястреб (разновидность ястреба?)». Будагов моны монг. **ҡарчаа, *ҡарчага* сүзеннән кыскарып килеп чыккан димәкче, ләкин шунда ук чыгт. *карчә* «кечкенә лачын төре», алт. диал. (Баскаков 1966) *ҡарчаа* «карчыга». Чаг. **Карчыга.**

**КАРЧЫГА**, (ЗДС: 276) **карчыган,** себ. (Тумашева 1992: 121) **ҡарцыға** «ястреб» > мар. диал. *карцыга,* чув. *хорчка* > *хурчка* < гом. кыпч., башк. *ҡарсыға,* алт., уйг. *ҡарчыға, ҡарчиға,* к.-балк. *ҡартҗыга*, нуг., каз., к.-калп. *ҡаршыға*, төр. *karçuga, karçiga, kart çiga*, каз., хак., тув. *ҡартыға* һ.б. id. (ш. ук төрле ерткыч кош атамалары); гомумән, бу сүзнең вариантлары бик күп, к. ЭСТЯ V: 317–318 (ләкин анда да тулы түгел). Иске тат. **карчыгай** варианты уйг., чыгт. *ҡарчиғай* ~ монг. *харчагай* вариантыннан килә. Чаг. ш. ук **Каратыгай.**

Безнеңчә, **ҡарчыға** < *ҡарчығай* < *ҡартчығай* бор. **ҡараты чиғай* «ерткыч кош» сүзеннән: *караты* (алт. һ.б.) «ерткыч; явыз; үткен» + бор. төрки **чығай*, монг. *чигай* «кош». ЭСТЯ бүтән этимологияләр китерә, ләкин алар да юраулы. К. ш. ук Радлов II: 201; Пекарский: 3360; Федотов II: 237; Сафина 2006: 23–24.

**КАРЧЫК,** диал. **карцык** «старуха» ~ башк. *ҡарсыҡ,* id. > чув. *карчăк,* мар., удм. *карчык* id. < гом. кыпч. *ҡарчыҡ* id. < *ҡарый-чыҡ, ҡары-чыҡ,* к. кр.-тат. *ҡары*, төркм., аз. *ғары, ғарры* «әби, карчык» < **ҡарығ* ← *ҡары-* (к. **Кары-у**). **Карчык** сүзен **картчык** дип аңлау-аңлату да бар. Федотов II: 233.

Дерив.: **карчыклы, карчыксыз; карчыклык; карчыкларча.**

**КАРШУГА, каршуwа, каршыwа** (бөре, прм., ЗДС: 394) «ракушка, раковина особого (мелкого) вида, которая употреблялась для нарядов» < *каршы* (*капкачлы*) *ука: ука* дип элек хәз. **ука**ны гына түгел, камзулларга тезеп беркетелә торган ялтыравыклы кабырчакларны да атаганнар (алар соңрак кулланыла башлаган тәңкә ролен үтәгәннәр). Хәз. *укаң коелмас* тәгъбирендә шундый *каршугалар* күз алдында тотылган. Сүз уңаеннан искәртик – **сәдәф** сүзе дә түбәндә «кабырчык» дигән сүз. *Каршуга* удм. телендә дә очрый.

**КАРШЫ**, диал. (ДС I: 181) **карышы, каршыҡ, карышыҡ, ҡаршый** «против; то, что напротив; противник чего; упрямый; навстречу» > мар. *кáрше*, удм. *каршы* «кире, каршы» < гом. кыпч., госм. *ҡаршы* (нуг., каз., к.-калп. *ҡарсы*), уйг., үзб. *ҡарши* < бор. төрки (ДТС: 429) *qaršu* id., ш. ук «явыз дошман» > алт. *ҡаршу* id. Тат. вариантлар бик ачык күрсәткәнчә, **ҡаршы < ҡарышы <** **ҡарыш-ығ* «каршы» ← *ҡарыш-* «карышу, артка, кирегә тарту (юнәлү)» фигыленнән, ул фигыль исә бор. (к. ДТС: 428) *qar-* «оппозициядә булу» сүзенең «киңәйтелгән» формасы; чаг. тунг. (ССТМЯ I: 381) *ҡари* < *карығ* «дошман; ят кеше; үчегүче» ~ тув. *хары* «чит кеше». Чаг. ш. ук чув. *хирĕç-* < болг. **һыйрыш*// *һыйрыж*//*һыйрыҗ-* ~ төркет. *ҡарыш-* «карышу», *хирĕç* < болг. **һыйрыҗ* ~ төркет. *карышы* (болг. *ы* ~ төркет. *а*) «каршы». Федотов II: 350; Рамстедт 1957: 92 (каршы сүзен бор. монг. *qarıša* id. сүзеннән алынган ди).

**Каршы** сүзе тат. телендә артык күпмәгънәле, шунлыктан аның кулланылышында абсурд сүзтезмәләр килеп чыга (мәс., *каршы килү, каршы чыгу*). Татарча белеп сөйләшүчеләр тискәре мәгъ. *каршы килү, каршы чыгу,* дип, уңай мәгъ. *каршыга килү, каршыга чыгу* дип тутырып сөйлиләр.

Дерив.: **каршылык; каршыла-у, каршылан-у, каршылаш-у** (юн. формалары үзенчәлекле мәгъ. ия).

**КАРШЫЙ, ҡарши** тар. «столица степного государства (у монголов), ханский дворец» – бу сүз КБ, бор. төрки, чыгт. ядкәрләрендә, ш. ук иске монг. телендә очрый. Аның «тирмә кирәгәсе» мәгъ. дә бар, к. Räsänen 1969: 239.

Хәз. **Карши** Үзбәкстанда бер шәһәр. Бу сүзне Төркиядәге *Карс* ~ *Карш* шәһәре исеме белән, арытабан болгар кавеме ванандларның (алар Урта Иделдә дә булган) *карс* кабиләсе исеме белән чагыштыралар.

**КАРЫЗ**, диал. **карыж** «ссуда, финансовое обязательство» < гар. *ҡарḍ* «бурыч». **Хәреж** сүзеннән түгел.

**КАРЫЙ,** диал. (Тумашева 1992: 121) **ҡары** «старец, очень старый человек» < гом. кыпч., чыгт. *ҡарый* < бор. төрки **ҡарығығ* «картайган». К. **Кары-у.**

***КАРЫМ** «бастард; метис – человек, родившийся от смешанного брака татарина (татарки) или русского и аборигена Сибири» ~ рус. диал. (Аникин: 270) *карим, харим,* бур. *харим* id. (монг. сүзе диелә), к. каз. (ҚТДС: 196) *қарым* «чыгыш, нәсел» (метислар тур.?), *қарыма* «балык итен төеп, он кушып пешерелгән ашамлык» ← *қары-* «кару, аралаштыру, буташтыру», к. **Кары-у.**

Дерив.: себ. (Тумашева: 122) **карымчак, карымшак** «төпчек ир бала» диелә, безнеңчә, шикле, чөнки к. кр.-тат. *қарымчақ* «татар һәм грек яки яһүди кушылгагы» (боларны *крыймчак* дип тә атыйлар). Дөрес, рус. (Аникин: 270) *карым* «уылдык чәчәргә яше җитмәгән, яшь чөгә балыгы» сүзе бар һәм бу сүз дә татарчадан, тат. телендә әлегә теркәлмәгән сүздән килергә мөмкин. Ул тәкъдирдә тат. **карымчак** әлеге **карым** «бастард» сүзенә баглы микән, дигән сорау туа.

**КАРЫМСА** (ДС II: 100) «подбрюшник» ~ каз., к.-калп. *қарынса*, төркм. *гарынса* id. ~ **карын** сүзеннән (**қарын-са** «карын савыты»).

**КАРЫМТА** тар. «ответный угон скота» (*барымтага – карымта* мәкаль: «на угон – ответный угон») < гом. кыпч. *қарымта* id. *қар-у* «кискен каршылык бирү» сүзеннән, к. **Кару.**

**КАРЫН,** диал. (Тумашева 1992: 118, 122) **қарым** «внутренности ниже груди; желудок; матка» < гом. кыпч., алт., уйг., госм. һ.б. *қарын* ~ чув. *хырăм* id., тув. *хырын* «корсак; карындык», як. *харын* «ашказанның бер өлеше» һ.б. < бор. төрки (ДТС: 427) *qarïn* «корсак»; к. ш. ук як. *харба* «карын, корсак» ~ монг. *харбиң* «зур корсак», **казы** һәм **карта** сүзләре белән тамырдаш. Будагов II: 12; Räsänen 1969: 238; Федотов II: 382.

Дерив.: **карынлы; карынчык.** К. **Карымса, Кардәш, Карындык.**

**КАРЫНДЫК,** диал. **карынды, кандык** «перепонка; брюшина», иск. «бычий пузырь или грудобрюшная перепонка, используемая вместо стекла для окон; послед» > чув. *карăнтăк* id., *кантăк, харăнтăк* «тәрәзә пыяласы; тәрәзә», мар. *хандык, харындык*, удм. *кандык, карандык, карнык, кырындык* «тәрәзә пыяласы; карындык» < *карын-дык* < **қарынныұ* < *қарын-лық,* к. **Карын. Карандык** варианты халык этимологиясе буенча **каран-у**дан. Алт. һ.б. *кандык, кандыг* «сарана» сүзе дә шуннан булса кирәк (бу үсемлекнең суганы элпә эчендә була). Федотов II: 223.

**КАРЫНЧА: карынча догасы** (К. Нәҗми һ.б.) «религиозный текст, написанный очень мелким шрифтом (для ритуальных целей)» – букв. «муравьиный молитвенник» ~ к. төр. *karınca duası* id., к. төр., аз. (Будагов II: 52) *карынджа, харынджа,* төркм. (Мухамедова: 207) *гарынҗа, гарынҗақ, гарынчга,* бор. төрки (МК) *qarïnča, qarïncaq* «кырмыска», ихтимал, *qarın* «карын» сүзеннәндер (көньяктагы бер төр кырмыскаларның карыннарын югары күтәреп йөрүеннән микән?).

**КАРЫ-У** иск., диал. (ЗДС: 394) «стареть, постареть» – гом. төрки (ДТС: 426) *qarï-* id., *qarï-jaša-* (парлы сүз) «кару, картаю» – *кар* сүзеннән, ягъни «кар кичерү» (шуның шикелле *йаша-* ← бор. *йаш* «яшел, яшеллек») мәгъ. булган. Чаг. мар. *ий* «ел, яшь; боз», рус. *сколько лет* «ничә яшь» – асылда «ничә җәй» дигән сүз. К. тув. диал. *харла-, қарла-* «яшәү, карлар кичерү», (фәлән) *харлыг* «(фәлән) яшьле». К. **Карт, Карый.**

**КАРЫШ** «пядь (0,213 м)» < гом. кыпч., чыгт., тув., төр., гаг. *қарыш*, бор. төрки (ДТС: 428) *qarïš*, нуг., каз., к.-калп., хак. *қарыс*, хак. *харыш, харыс* id. Һичшиксез тат. диал. *қары, қара, каре,* як. *хары, хара*, бор. төрки *qarı* ~ тув. *қыры* «беләк; аршын; ике аршын (үлчәме)» ~ монг. *гар, қар*, маньч. *гала* «кул» сүзеннән, ләкин **қарыш** нигезе ничек ясалуы ачык түгел. Ихтимал, (үзб.) *қарич* «карыш» < **қарича* «кечкенә каре» сүзеннәндер, ә бәлки **қары-* «беләкләп үлчәү» фигыле булгандыр, шуннан **кары-ш.** Чаг. **Каре.**

Бор. төрки (ДТС I: 428) *qarïš* «пядь» (Даль буенча *пядь, пядень, пядка* «протяжение меж большого и указательного перстов..., четверть аршина»), 2007 елгы тат.-рус. сүзлектә **карыш** «пядь, вершок» диелгән. Будаговта (II: 13) төр., тат. *қарыш, қаруш,* кырг. (каз.) *қарыс* «аршынның дүрттән бере (1/4 аршын)» һәм бу үлчәм чыгт. *қары, қару* «архитекторларның аршыны, икеләтелгән аршын» белән чагыштырыла. Чыннан да **карыш** ул *карымак* «беләк белән үлчәү» сүзеннән була ала. Бу үлчәмне Искәндәр Зөлкарнәйн гамәлгә керткән имеш. Ул: «12000 **карыш** бер **агач** булсын», дигән. **Агач** үлчәме исә якынча 8 чакрым, ачык тигез далада зур агач еректан күренерлек ара. Гомумән, тарих дәвамында *карыш* һәм *кары* үлчәмнәре еш кына нигезле микъдарларыннан читләшә торган булганнар.

**КАРЫШЛАВЫК [қа$^{o}$ры̆шлаwы̆қ]** «пяденица (вид личинки)» ← **карышла-у** «карыш исәбенә кул белән үлчәү» – бөҗәкнең хәрәкәт рәвешеннән; ул бөҗәк кортын **марышлавык** (*марш* сүзеннән) дип тә атыйлар. К. Зимасов: 65.

**КАРЫШ-У I** «сопротивляться, упрямиться» > мар., удм. *қарш-, қарыш-* < гом. кыпч. *қарыш-* (нуг., каз., к.-калп. *қарыс-*), уйг. *қериш-* id. ~ чув. *хирĕҫ-* бор. төрки *қары-* (к. **Кару**) «каршы тора алу» фигыленнән. К. ш. ук як. *харыс-* «сөзешү, төкешү». К. ш. ук **Каршы.** Федотов II: 350.

Төрки сүзлекләрдә гадәттә бу **карыш-у** икенче **карыш-у** белән бутала, бергә бирелә. К. **Карышу II.**

**КАРЫШ-У II** диал. (ДС I: 72) «сводиться судорогой; переплетаться, вмешиваться» < гом. кыпч. *қарыш-* (нуг., каз., к.-калп. *қарыс-*) id., госм., уйг., тув., добр. (Dobr II: 220) *қарыш-* «борылгалау; төрле якка китү, аркылы-торкылы килү; чатлашу», ком. *қарыш-* «ишелеп, үрелеп бетү» ~ як. *харыс-* «аймылышу», төр. *karış-* «буталу, катлаулану» ← тат. диал. *кары-у* «үрү, ишү, буталдыру» ~ госм. *қары-*, төркм. *ғаар-* «буталу, болгалану» (монда озын сузык, ихтимал, икенчелдер) ~ бор. төрки (ДТС: 422) *qar-* «кату, бутау, катыштыру». Будагов II: 9–10; Мухамедова 1973: 113.

Бор. **кары**- фигыленнән *карыл-* «болгану» (к. Радлов II: 167, 175–178) һәм себ. тат. **қарым** > рус. диал. *карым* «метис, кушылгак» (к. Аникин: 270) сүзләре дә ясалган. Чаг. кр.-тат. *қырымчақ* < *қарымчақ* «яһүди-татар кушылгагы».

Дерив.: **карыштыр-у** «аралаштыру»; к. **Карама, Карым.**

**КАРЫЯ, кария** сөйл. «старая почтенная женщина». Бу сүз **карый** (к.) сүзен гарәпчәдән дип уйлап, шул псевдогарәпчә сүздән мөәннәс формасын ясаудан килә.

**КАРЬЯ [қәрйә]** «деревня, селение» – элекке әд. телдә актив кулланылган сүз – гар. *қарйä* «шәһәр, авыл, карья» сүзеннән. *Әл-Қарйäтäйн* – Мәккә белән Мәдинәнең бергә аталышы, к. Будагов II: 53.

**КАС** «зол (на кого-что)» > удм. *кас* id. < нуг., каз., к.-калп., кырг. *қас* id. < гар. *қасд* «ният; үч» (ГТРС: 204). К. **Каст.**

Дерив.: **каслы, каслык; каслан-у** (тат.-башк диалектологик сүзлекләрендә еш очрый).

**КАСА** (ТТДС II: 131) «коленкор; лучшее домашнее полотно» ~ кырг. *қаса, қаза* «иң яхшы; иң сортлы» << гар. *х̣āс̣с̣а* id. >> рус. *хаз* «тукыманың иң яхшысы, яхшы урыны» (шуннан *показать с хазового конца* «товарның иң яхшы өлешен күрсәтү», гомумән «нәрсәнең дә булса яхшы ягын купайту»). К. **Хас.**

**КАСАБӘ** «посёлок, городок» ~ башк. *қасаба* id. < гар. *қас̣абä* «кечерәк шәһәр, зур авыл, бистә» > төр. *kasaba* «провинция үзәге, провинциаль шәһәр, кала» (башк. варианты төрекчәдән күчерелгән). Будагов II: 57. К. **Кассап.**

**КАСАР** диал. (миш.) (к. **Әләңгәсәр**) «великан, человек огромного роста» ~ башк. (БТДҺ: 194) *қаһар* id. – ихтимал, бор. төрки халык – **хазар, хәзәр** сүзенең чагылышыдыр. Куәтле дәүләт кешесе күршеләре аңында әзмәвер булып күзаллана. К. ш. ук алт. *қазра-* «талау; явыз хөкемдар булу», *қазыр, қазар*, хак. *хазыр* «усал җанвар; коточкыч» (Будагов II: 16; Баскаков 1966: 121; Баскаков 1972: 217).

**КАСАРТКЫ** диал. (Тумашева 1992: 122), **казарткы** (ЗДС: 376), **қасыргы** (ТТДС II: 132) «буря, вихрь», «смерч» ~ тув. *казыргы,* төр. *kasırga,* бор. төрки (ДТС: 430) *qasïrqu* id. К. ш. ук тат. (ДС II: 101) **касырка** ~ ком. *қасыртқы* «укра (укралы хайваннар кая барырга белмичә дулап йөриләр)». Кр.-тат. *қасартқы* «борча; кандала». Күренгәнчә, сүзнең нигезе *казар-*, *касар-*, к. каз., к.-калп. *қасарт-* «ярсыту», *қасар-* «ярсу» ← **қас?* Чаг. югарыдагыны, ш. ук **кәзәр-ү**. Будагов II: 16 (тагын охшаш сүзләр күрсәтелә).

**КАСӘМ** «присяга» < гар. *қасäм* id.

Идиома: **касәм эчү** «ант итү». Чаг. **ант эчү.**

**КАСӘТ, касаwәт, казат** (м.-кар.) «милость (Бога); попечение (властей)», «стеснённость» ~ кр.-тат. *kaswet, kasıwet,* гаг., төр. *kaswät* id. < гар. *қасwäт* «кырыслык, усаллык; таләпчәнлек», к. ГТРС: 204; Будагов II: 56. К. **Казат.**

**КАСД, каст** иск. «цель, стремление; страсть (недобрая)» < гар. *қас̣д* id. Шуннан ук **касдан, кастан** «юри» – гар. теленнән (тат. телендә ясалмаган). Тат. **қас** (к.) һәм **касд** – этимологик дублетлар; аларның мәгъ. һ.б. аермалыры бар; **касд итү** тәгъбире бар, әмма **кас итү** – юк һ.б.

**КАСМАК,** диал. **касмык** «плёнка, налипшая к стенкам котла», диал. «плёнка на поверхности кипячёного молока; чешуя» ~ чув. *хысма*, төр. *kazmık*, ком. *қаснық*, каз., к.-калп., кырг. *қаснақ* ~ үзб., уйг., чыгт. (Радлов III: 359) *қасмақ* «каткан эрен» id., чаг. монг. *хусам* «касмак». Räsänen 1969: 158; Федотов II: 384–385.

Сүзнең тамыры гом. төрки **қас* «җыерчык» һәм **қас-* «бөрешү, җыерылу» булса кирәк, к. кр.-тат. *қас-* «бөрешү; казан төбенә утырту (казан төбендә кайнап беткән сөт бөрешә)». Шул ук тамырдан к. **Касык.** Чаг. бор. төрки (ДТС: 430–431) *qas, qasïγ, qasïq* «каты тире», «агач кайрысы», *qasuq* «бурдык, тире турсык». Монда ачыклыйсы моментлар бар. Будагов (II: 15) *қасмақ* сүзен *қазы-у* белән баглый.

Дерив.: **касмаклы, касмаксыз; касмаклан-у.**

**КАСНАК** – тат. телендә бу сүз әлегәчә теркәлмәгән, ләкин мар. *каснык* «верхний край брюк; очкур» һичшиксез татарчадан, к. үзб. (ЎХШЛ: 157) *қасноғ* «иләк һ.б. кысасы, рам», төр. *kasnak* «киң каеш, рам» һ.б. Ихтимал, **касык** (к.) сүзе белән тамырдаштыр; чаг. башк. *қаҫмау* «кием бөрмәсе; бөрмәләү өчен тасма». Чаг. ш. ук **Касык.**

**КАССАП** иск. «мясник; бойня» < гар. *қаṣṣāб* id. (һәр ике мәгънәдә, шуннан *касаба* «кассапханәләр (урнашкан төш)» – Шәрыктә шәһәр-кала читендәрәк урнашкан бистә, шуннан гомумән «бистә, посёлок» мәгъ. килеп чыккан.

**Кассап** сүзе белән укр. *кацап* < идиш. (Германия һәм Украина яһүдиләре телендә) *каццап* «рус; Украина калаларында ит белән сәүдә итүче урыс» сүзе игез. К. ним. *Katzoff* «итче, кассап» < көнб. иврит. *kazzow* < яһ. *qassav.* Kluge: 478.

Украиннарда *кацап* – кимсетү сүзе.

**КАСТА** «больной, хворый» к. **Хаста. Қаста** яңгырашы төрки телләрдә еш очрый.

Дерив.: **касталы; касталан-у.**

**КАСЫЙДӘ, касидә** «касыда, стихотворение из многих строф на одну рифму» < гар. *қаṣӣдä* id. К. **Хәситә.**

**КАСЫК** «пах, нижняя часть живота», диал. «мошонка», «лобок» ~ башк. (БТДҺ: 191) *қаҫалақ* «касык», ә *қаҫыҡ* «сидек куыгы» < гом. төрки, к. кр.-тат., гаг. *қаçық,* төр. *kasık*, төркм. *ғасық,* аз. *гасыг* «касык; тәннең тиресе җыерылган төше» < бор. төрки (ДТС: 430, 431) *qasïγ* «касык», *qasuq* «турсык» ← госм. (Радлов II: 347–350) *қас-* «бөрү, җыеру; бөрелү, җыерылу» ~ төр. *kas* «тәндәге кабарынкылык; мускул», *kas-* «бөрү», монг. *хас* «ботның эчке ягы». Бу сүзнең бор. төрки телләрдән килүен чув. *хыс, хысӑ* «касык» < болг. **хысыҥ, *хыйсыҥ* сүзе дәлилли. Räsänen 1969: 239; Федотов II: 383.

**Қас-** сүзенең монг. «тезгенне иярдәге махсус ыргакка эләктереп кую», тат. диал. **касык-у** «бөрелеп бәйләнү» һәм бор. төрки *qasuq, qasγuq* «ат тиресеннән эшләнгән бөрмәле янчык» мәгъ. этнографик җәһәттән кызыклы.

**КАТ I** «слой, этаж; ряд; раз, крат» > мар., удм. *кат* ~ чув. *хот* > *хут* id. гом. төрки *қат*, башк. диал. (БТДС: 191) *қат* «балитәк», тув. *каът* id. ш. ук «тышлык» (гомумән, мәгъ. бик күп, к. ЭСТЯ V: 335–336), як. *хат* «яңадан», көрд. *кат* «кием комплекты», бор. монг. (Поппе 1938: 211) *xat* «буй, кишәр». К. **Кат II.** Федотов II: 371–372.

**КАТ II** «то, что рядом» (*катында* «у, возле, рядом, с») < гом. кыпч., угыз., уйг. *қат* id. Этимологик характердагы сүзлекләрдә гадәттә **кат I** һәм **кат II** бер сүз итеп бирелә (к. Будагов II: 4; Räsänen 1969: 241). Һәр ике сүзнең *кават, кабат* вариантлары да очрый (к. **Кабат**). Шуңа да карамастан *қат* < *кабат* дип раслап булмый, чөнки бор. төрки текстларда *кабат* сүзе юк, ә **қат** бар. **Кат I** һәм **Кат II** сүзләреннән бик күп нигезләр ясала, к. **Катар, Катла-у, Катмар, Катнар-у, Катна-у** һ.б. Чаг. **Кат-у II**. Будагов II: 4–6.

**КАТА I** «тапки, коты; поршни» > чув., мар., удм. (һәр телдә диалекталь) *ката* id. < башк. *қата* «ката, күн чүәк». Кайбер телчеләр (к. Ашмарин VI: 156; Фасмер II: 354; Аникин: 307) тат. сүзен рус. *коты* сүзеннән дип язалар, ләкин к. уйг. *қата* «олтан», башк. диал. (БТДҺ: 191) *қата* «ката; тояк» ~ эвенк. һ.б. тунг. *һата, хата* «тояк асты тиресе» (ул олтанга әйбәт, к. ССТМЯ II: 318). Чаг. ш. ук себ. **кат-у** «кунычсыз аякчуны тиз генә киеп алу» (к. Рамазанова 2001: 64) ← **кат-у I** (к.) сүзенең аерым мәгънәсе. Кыт., яп. *γetá* «агач сандали» – очраклы охшашлыктыр.

**КАТА II** «весь, всю; непрерывно; сплошь» ~ чув. *хота, хута* ~ уйг., алт., шор. *қада*, хак. *хада* id. **Кат-у II** фигыленнән, к. Махмутова 1978: 226–227. Чаг. тат. диал. *катын* «ката» (һәр ике сүз – хәл фигыль формасыннан).

**КАТАГАН** иск. «пост, охраняемые ворота» < чыгт. *қатаған,* каз. (ҚТДС: 180) *қадаған,* төркм. *гадиган* «тыю; тоткарлау». К. **Катау.**

**КАТАЙ** «название одного из башкирских родов; неведомая страна с несметными богатствами» (к. мәкаль: *атай малы – Катай малы*) **Кытай** (к.) сүзе белән гомоген булса кирәк. М. Әхмәтҗанов 2002: 132–137.

**КАТАЛА-У, катайла-у** (ЗДС: 278) миш. «катиться, покатиться» (фольклор әсәрләрендә) < рус. Рус теленнән фигыль алынуның сирәк очрый торган мисалы, **каталат-у** «тәгәрәтү» формасында ешрак очрый (ихтимал, бу сүзнең таралуы йөкче булып эшләгән мишәрләр телендә кулланылуыннандыр – XIX–XX г. башларында Үзәк Россия шәһәрләрендә йөкчелек кәсебендә мишәрләр күп булган, бу хакта Россиядә сәяхәт иткән француз язучысы А. Дюма һәм рус язучысы П. Мельников-Печерский һ.б. язалар).

Добр. татарларында (Dobr. II: 232) *qatalaq* «йомгак; хайваннарда җиргә егылып аунау авыруы», *qatala-maq* «каталау» сүзләре дә русча нигездән булса кирәк, чөнки төрки телләрдә бу сүзләрнең тамырлары һәм параллельләре күренми. Румыниядә Россиядән китеп урнашкан мишәрләр күп.

Иске Казан тат. сөйләшендә **Кәтәчә ~ Катайсә** бәйрәме – Май чабу көннәрендә мәзәк-хозур өчен ат җигеп чаптыру билгеле булган; бу сүз, әлбәттә, рус. *кататься* тәгъбиреннән.

**КАТАҢГЫ** (Тумашева 1992: 123) «худощавый, но крепкий» гом. төрки планда киң таралган сүз: ком. *қатаңқы,* к.-балк. *қатаңғы*, кырг., уйг. *қатаң*, ног., каз., к.-калп. *қатаң, қатал* «кырыс; каты мөгамәләле», тув. *кадаң,* як. *хатаң* «чыныккан, чандыр, ләкин көчле» ~ эвенк. < монг. (ССТМЯ I: 383–384) *катан, хатаң, хатаан* «чыныккан, ныклы» һ.б. Арытабан – чыгт. (Будагов II: 4) *қатаңғур* «ябык, ләкин көчле», монг. *хатангир* «ябык, арык» >> аз. (АДДЛ: 121) *гатангаз* «каты, ныклы». Чаг. ш. ук Себердәге *Хатанга* елгасы – «каты агымлы».

Бу сүзләр **кат-у, каты** сүзләре белән тамырдаш булса кирәк.

**КАТАР** «ряд», диал. «снова, крат, рядом» (ДС I: 79), «слой, второслойный» (БҺҺ II: 138) ~ гом. кыпч., чыгт., госм. (Будагов II: 4), *қатар* «рәт, кат; талпа» аз. *гатар* «кәрван > поезд» гом. төрки *қат-* «рәттән кую» сүзеннән булса кирәк, чаг. себ. **қытра-у** «рәткә кую» (Тумашева 1992: 144), к. Räsänen 1969: 241. Радлов (II: 280) бу сүзне гар. *қатар* «берләшмә» (*қтр* «тамчылау; бер-бер артлы тезелү, теркәлү») сүзеннән ди. Ләкин к. алт. *катай*, тув., хак. *хатай* «катар». Чаг. **Катаргы, Кыйтар.**

**КАТАРГЫ** «паром на двух больших лодках» < бор. кыпч. (XIII г.) *қатарға* «кәрап, галера» ~ Әбү Хәййам сүзлегендә (Курышжанов: 159) *қатрыға*, төр. *кадырыга, кадырга, катырга* «хәрби каек», чаг. бор. рус. (күп сүзлекләрдә) *катарха, ка́торга, катарга* «галера, әсирләр чылбырланып ишкәк ишкән каек» (Фасмер II: 210; Порохова: 171). Төрки һәм көнч. слав. сүзләре бер-берсеннән алынмаган, ә параллель рәвештә грек. *χατεργοι* сүзеннән килә, дип уйлыйлар. К. Будагов II: 5.

**Катаргы** ~ рус. *ка́тарга* сүзеннән рус. *ка́торга* «авыр физик эш белән җәзалау урыны» сүзе килә, шуннан тат. **катр (катыр) китү** тәгъбире ясалган.

**Катаргы** фонетик формасында, ихтимал, **катар** «рәт, җәргә» сүзенең контаминацион тәэсире сизеләдер: *катаргы* ике яисә берничә көймә өстенә түшәмә җәеп ясалган.

**КАТАРЛА-У** «ставить в ряд» – **катар** сүзеннән, әлбәттә.

**КАТАУ [қаᵒtaw]** «небольшая крепость на границе» (к. мәкаль: *мал – кырау, баш – катау,* ягъни мөлкәт тиз бетүчән, ә тереклегең кальга кебек тора) < иске уйг., чыгт. *қатаң, қатағ* «киртә, барьер», хак. *хадағ* < бор. төрки (ДТС: 401) *qadaγ,* бор. монг. *xadaγa* «гөнаһ; тыю». К. «Угызнамә»дә *қадағла-, қатағла-* «чикне катау куеп саклау», к. ш. ук тув. *ката-* «көтү көтү, терлек саклау» > алт. *када-* «көтү; саклау», к. бор. монг. *xadaγa-la-* > хәз. монг. *хадгала-* «саклау, яшерү, асрау», *хит* «катау». Чаг. ш. ук чув. *хӳте* «койма, дивар». К. **Катаган.** Чаг. **Кутан.** Будагов II: 4 (бик аз әйтелә).

Башкортстандагы **Катау** елгасы шуның ярларында булган кирмән сүзеннән булса кирәк. Әмма **катау** дигән кабилә дә булган, имеш.

**КАТВӘЛ [қәтwәл], катмәл [қәтмәл]** (ЗДС: 406) «в первую очередь; первым делом; то, что надо» < гар. *хäддү-л-äwwäл* «беренче (әүвәлге) чиратта». К. **Хәт** һәм **әүвәл**.

**КА́ТГАН, катгы́ян** «решительно, категорически» к. **Катгый.**

**КАТГЫЙ** «решительный, категорический» < гар. *қаṭʻӣ* id. *қṭʻ* «кисү, өзү» тамырыннан (к. ГТРС: 205–206).

Дерив.: **катгыйлык; катгыйлан-у, катгыйлаш-у.**

**КАТИЛ** «убийца», **катилә** «женщина-убийца» < гар. *қāтил* id. *қтл* «үтерү» тамырыннан, шуннан ук **кател** «үтерү күренеше» (к. ГТРС: 206).

**КАТКАК** «затвердевшая, замёрзшая слякоть», «жёсткий» < гом. кыпч. *қатқақ* id. (яки якын мәгъ.) ← **кат-у II** сүзеннән; к. ш. ук диал. *қатқыл, қатқын* id. (к. БТДҺ: 192).

**КАТКЫЧ** «крутило для сучения ниток» > мар. *каткыч* id. (Исанбаев 1978: 43) – **Кат-у II** фигыленнән.

**КАТЛА-У** «складывать, загибать, сложить (один на другой)», чув. *хотла-* > *хутла-* < гом. кыпч. *катла-* (каз., кырг., башк. диал. *қатта-*), аз. *ғатла-* id. **кат I** сүзеннән.

**Катла-** бик продуктив нигез: тат., башк. **катлау** (исем, мәс., *тау катлавы*); гом. кыпч. **катлама** (> мар., удм. диал. *катлама*), кырг., каз., башк. диал. *қаттама*, төркм., аз. *ғатлама* «слоёный пирог»); диал. **катлач** «катланган хәлдә» һ.б. К. ЗДС: 397–398; Dobr. II: 235.

**КАТМАР** «складка; складчатый, махровый» > чув. *катмар* «кантар; һәйбәтле, кыяфәтле» < гом. кыпч. *қатмар* (> нуг., каз., к.-калп. *қатпар*) «катмар», башк. (БТДҺ: 192) *қатмар* «(җыерчыкланып торган) тау сырты», төр. *katmer* «катлама (ашамлык)»; бу соңгы сүзгә караганда, *катмар* < *катмәр* < **кат-мәр: мәр* «кат» мәгъ. (алынма?) сүз булса кирәк. Госм. *катмер, катмäр* «күпьяфраклы, күп лепелдәкле» сүзенә караганда? *катмәр* < фар. (төрки + фар.) *қат бäрг* «катлаулы яфрак» сүзеннән булуы ихтимал, к. кырг. *қатмар* «бергә». Һәрхәлдә *катмар* сүзенең тамыры билгеле (**кат I**) булса да, ясалышы ачык-аян түгел. Чаг. **Катнар.** Будагов II: 59; Räsänen 1969: 241 (һәркайсында сүзнең фиксациясе генә).

Дерив.: **катмарлы, катмарсыз; катмарлан-у.** Бүтән кайбер төрки телләрдә (каз., төр.) *қатмар* сүзе бик продуктив нигез.

**КАТНАР** «подволока, чердак» ~ башк. (БТДҺ: 192) *қатмар, қатмау* **катна- ~ катма-** фигыленнән ясалган, әмма ясалышы ачык түгел. **Кат нар** дигән фараз да бар. К. **Нар.**

**КАТНА-У** «строчить; наложить новый слой», иск. «ходить туда и обратно; посещать друг-друга» < гом. кыпч. *қатна-*, төркм., аз. *ғатна-* id., бор. төрки (ДТС: 436) *qatna-* «кабатлау»; бу сүзнең формалашуында ике тамыр контаминациясе сизелә; бор. төрки *qat-* (к. **Кат-у II**) һәм бор. төрки (ДТС: 403) *qad-* «тәртипсез хәрәкәтләнү, кайнашу». ЭСТЯ V: 337–338.

**Катна-** тат. телендә бик продуктив нигез, шуннан **катнаш, катнаш-у** һәм шулардан икенчел дериватлар килә.

**КАТРАН** «смола» ~ нуг. *қатыран* «озокерит, тау сумаласы», «деготь», төр. *katran* < гар. *қаṭрāн* id., ш. ук «нефть, гудрон». *Катран тамыр* – дарулы үсемлек төре (кырг. *қатраң, қатыраң* дип кенә атала).

**КАТРӘ [қәтрә]** «капля», күч. «чуточку» < гар. *қаṭрä* id.

**КАТУ** «колики; (резкое) стеснение дыхания; грыжа» > мар. диал. *кату* id. ~ калм. *хатха* «кадау, кату алу»; (**эч кату** сүзе белән түгел, **када-у** сүзе белән баглы шикелле). Чаг. ш. ук себ. (Тумашева 1992: 123) **қат** «каты шеш» ~ ком. *қатыв* «сөял, шеш». Монда өч төрле мәгънә контаминациясе күзәтелә.

**КАТ-У I** «прибавить (слой), примешивать; насаживать, насадить; сучить (нитки), заправлять чем-либо; обращаться (со словом)»; себ. (Тумашева 1992: 123) «накинуть одежду; навесить украшения» < гом. кыпч. *қат-*, угыз. *ғат-*, як., хак. диал. *хат-* < бор. төрки (ДТС: 432) *qat-* id., чув. *хот-* > *хут-* «мич ягу; җепне агартырга көлгә кую» һ.б., һичшиксез **кат I** сүзенең фигыль коррелянты. Тат., башк. **кат-** нигезе бәйле тезмәләрдә генә кулланыла (*җеп кату, йөгән кату, катык кату, сүз кату*). Ләкин аның дериватлары шактый күп, к. **Каткыч**, диал., себ. (Тумашева 1992: 123) **катма** «җеп кату өчен махсус зур орчык», (ЗДС: 398) **катмыш** «йөзек төре»; юн. формалары **катыл-у, каттыр-у** диал. сөйләмдә очрый. К. **Катыш-у.** Чаг. **Катар, Катаргы, Катык.** Будагов II: 5–6 (**Кату II** белән бергә бирә); ЭСТЯ V: 336–337.

М. Федотов (II: 372) чув. *хот-* > *хут-* сүзен **кала-у** (к.) сүзеннән чыгара (имеш, **калт-* нигезеннән), ләкин бу бик шикле.

**КАТ-У II** «твердеть; засыхать; замерзать; грубеть; загрязняться; (диал.) крепнуть телом» < гом. кыпч., уйг. һ.б. *қат-*, тув. *қаът-*, аз., төркм. *ғат-*, чув. *хыт-* < бор. төрки (ДТС: 432) *qat-* id. **qaγ* тамырыннан (к. **Кау**) булса кирәк; к. ш. ук бор. монг. *xata-*, эвенк. (ССТМЯ I: 383–384) *ката-,* монг. *кагат-* «кату, кибү». Федотов II: 385–386.

**Кат-** иң продуктив нигезләрнең берсе, к. **Каткак, Каты, Катыр-у,** диал. **каткын** «каты» ~ башк. (БТДҺ: 192) *қатқыл.*

**КАТУТ** (ТТДС I: 163) «липучка (растение)» – ябышкак үлән, вак сырлан – **каты ут** дип аңлатырга сүзнең мәгънәсе комачаулый (сырлан бер дә «каты» түгел).

**КАТЫ**, диал. (Тумашева 1992: 123) **катты, кату** «твёрдый; жёсткий; суровый» < гом. кыпч., уйг., угыз. һ.б. *қаты*, үзб. диал. *қаттығ, қаттиғ* < бор. төрки (ДТС: 433) *qatïγ* id. ← *қат-у*, әлбәттә. Тат. диал., кырг., куман. **қатты** < *қаттығ* варианты бор. төрки (ДТС: 433, 434) *qatïγdï, qatïγtï* «каты; көчле» сүзеннән килә. Чув. *хытă* «каты» болг. **һыйты* сүзеннән булса кирәк. Федотов II: 385–386; ЭСТЯ V: 334–335.

Дерив.: **катылык, каты** сүзенең исем мәгънәсеннән **катылы, катысыз; катылан-у.**

**КАТЫК** «катык; простокваша» < гом. кыпч. *қатық,* үзб. *қотиқ,* аз. *ғатығ,* төркм. *ғатық* id. ком. *қатық* «тәмләткеч», бор. төрки (ДТС: 435) *qatïq* «тәмләткеч; серкә; соус», тув. *кадыг* «бутка», гаг. *катык* «икмәктән башка ашамлыклар», к.-балк. *қатық* «кукуруз көлчә» һ.б. **кат-у I** «кушу, өстәү, катыштыру» сүзеннән. ЭСТЯ V: 338–339.

**КАТЫР** «каторга». Рус *каторга* сүзен **катор* сүзенең юн. килеше дип аңлаудандыр. К. **Катыргы.**

Дерив.: **катыр китү** «каторгага җибәрелү».

**КАТЫРГАН** «софора (растение)» < бор. төрки (ДТС: 435) *qatïrγan*, уйг. (Будагов II: 8) *қадырқан* id. ~ тув., алт. *казылган, казырган*, рус. диал. *казырган* «сары карагат» (гомумән, төрлечә аңлатыла, к. Аникин: 236). К. ш. ук чув. *катăркас* «дүләнә; баялыч», *катăркан* «кычу чире» («катырган белән дәвалана торган авыру»?).

**КАТЫРГЫ** «картон», иск. (Будагов II: 5–6) «клеёнка» ~ диал., каз. **қатырма** «иң тупас, каты киндер» – тирмәне эчләү өчен кулланыла. Әлбәттә, барысы да **катыр-у ← каты** нигезләреннән ясалганнар. К. ш. ук (ЗДС: 400) *катырма, катырмак* «каты өслекле, ләкин эче йомшак ашамлык, кәтермәч» һ.б.

**КАТЫР-У** «сделать твёрдым, жёстким, заморозить, затвердеть» < гом. кыпч., уйг. һ.б. *қатыр-* id. Бу нигез ике юл белән ясала ала: 1) *қатыр-* < *қаттыр-* ← **кат-у II** (аның йөкл. юн.), 2) *қатыр-* < *қаты-р-* «каты булып китү» (сыйфаттан ясалган фигыль).

Дерив.: **катырыл-у, катырын-у, катырыш-у, катырт-у; катырка; катыргыч, катырткыч; катырма; катырмач** (к. **Кәтермәч**), себ. (Тумашева 1992: 124) **катырац, катрац** «нык таза; каты».

**КАТЫШ** «вперемежку с» > чув. *хотăш* > *хутăш* id. < гом. кыпч. *қатыш* (нуг., каз., к.-калп. *қатыс*) id.; бу сүзнең үзгә мәгъ. дә бар: тат., башк. диал., кырг. *қатыш* «катнашлык, дәхел», төр. *katış* «катнашма; ашы, өстәмә», *katışıg* (~ аз. *ғатышығ,* төркм. *ғатышык*) «катыш, аралаш», әлбәттә, **кат-у I** фигыленнән, ләкин мәгънәви үсеше, эчке мантыйгы аңлашылып бетми: гомуми грамматик кагыйдә буенча **катыш** – «кату шөгыле». Гомуми көтелгән мәгънәгә угыз телләрендәгечә **қатышық** варианты тәңгәл һәм, ихтимал, кыпч. **қатыш** шуннан кыскартылып алынгандыр.

**КАТЫШ-У** «смешиваться, соединяться; общаться; вмешиваться» ← **кат-у**; бу сүз дә гом. кыпч. характерда, чув. *хотăш-* > *хутăш-* тат. теленнән булса кирәк. Федотов II: 373–374.

Дерив.: **катыштыр-у** (күпмәгънәле сүз); **катышлы** һ.б.

**КАУ I [қа°w]** «трут, гриб-трутовик, чага», (ТТДС I: 197) «засохшая трава, особенно прошлогодняя», (ДС I: 81; Тумашева 1992: 124) «осот; стерня», (БТДҺ: 193) «шерсть-линька» < гом. кыпч. *қаw* (*қав* дип тә языла) < бор. төрки (ДТС: 436) *qav, qavaγu* > төр. һ.б. угыз. (ЭСТЯ V: 169–180) *kav, qav* ~ тув. *қағ, хағ,* хак. (Радлов II: 448, 455) *қабо, қабу,* як. *қыа* «кау (кипкән үлән, гөмбә һ.б.)», к. ш. ук кырг. *қоо* «иңкүлектә үскән биек үлән, кура; киртә, кәртә» ~ каз. диал. (ҚТДС: 199) *қау* «киртә, капка».

ЭСТЯ һ.б. сүзлекләр *каw* сүзен *ку* белән бергәлектә карыйлар, ләкин, безнеңчә, бу сүзләрнең күпьяклы мәгънә тәңгәллекләре белән беррәттән

тирәннән килгән аермалары да бар. Гомумән, *қaw* < *қақ, қаг* тамыры монг. *гаң-, каң-*, кор., кыт. *каң* «кибү; кипкән, корыган» сүзе белән баглы булса кирәк. К. **Как**.

Элекке дала тармышында кипкән, корыган үлән үсемлек сабаклары күптөрле кулланыш тапкан, шунлыктан бу *қaw* тамыры төрки һәм монг. телләрендә иң продуктив нигезләрнең берсе. Ахметьянов 1989: 30–32.

Дерив.: **каулы, каусыз** (мәс., ут кабызу); **каулык.** К. **Кавай, Кавак, Кава-у, Кавыз, Кавык, Кавыл, Кавыр, Кавырсын, Каугал, Каудан, Каудар, Кауза-у, Каука, Каулак, Каулан, Каура, Кауры, Каурый, Кауша-у, Курай.** Башк. *қауа-у, қауқа-у, қауса-у* һ.б. дериватлары бар.

***КАУ- II [қа°w]** «засохнуть» – **кау** (к. югарыда) сүзенең фигыль коррелянты булган: к. башк. (БТДҺ: 193) *қауай, қауғак* < *қау-гақ* «түземсез; сүз һ.б. күтәрмәүчән; гаугачыл».

**КАУГА I [қа°wға]** диал. «общее волнение» ~ башк. *кәүгә,* төр. *kavga* id., к. **Гауга.**

**КАУГА II [қа°wға]** «колодезное ведро (с длинным колом)», иск. «барабан» ~ башк., нуг., каз., к.-калп. *қауға* «үгез тиресеннән эшләнгән бадья, кое чиләге» < бор. төрки (ДТС: 461) *qovya, qova* > чыгт. *кога*, алт. диал. *қого*, госм., төр. *kova, kovan* «чиләк; цилиндр; умарта», кр.-тат. *қопқа* «кое чиләге» ~ калм. *хowa* < бор. монг. *qobuγa* «кауга; чиләк» (к. Ramstedt 1949: 191; Räsänen 1969: 273), к. ш. ук сол. *ховоо*, нан. *ҳобо(н)* «чүп чиләге» < яз. монг. *xobuγa* (ССТМЯ II: 467). *Қауға ~ қога ~ қов* дип дәлү (сукояр) аен һәм йолдызлыгын да атаганнар, к. Будагов II: 85; Мухамедова 1973: 49.

**КАУГАЛ [қа°wғал], қауғалы** (ЗДС: 400–401) «кустарник», күрәсең (к. **Каудан**) «сухой, прошлогодний, засохший» ~ башк. *қауған* «язын яндырыла торган былтыргы үлән», чув. *хавхал, халхав* «янгын, үртәү» < монг. *қоогал, хоогал* «былтыргы үләнне яндыру», *коо* «кау» һәм *гал* «ут» сүзләреннән гыйбарәт. Төр., гаг. *кагал* «дала» асылда *каугал* булса кирәк. К. **Кауга, Каудан**.

**КАУДАН [қа°wдан],** диал. (ЗДС: 401) **каузан,** себ. тат. (к. Будагов II: 29) **каудақ** «прошлогодняя трава; сухой бурьян для топки, шерсть-линька» и т.п., **каутан** (ДС I: 81; Тумашева 1992: 124), «оставленная после линьки кожица змеи, перхоть на голове», **каудын** (Н. Исәнбәт) «покрытый высокой (сухой) травой» > мар., удм. *каудан*, чув. *хавтан* «каудан» (чув. *халдан* «абага; биек үлән») ~ башк. *қауҙа, қауҙан*, нуг., кр.-тат., ком. *қавдан* (нуг., каз. ш. ук *қавмақ*), к.-балк., каз., к.-калп. *қаудан* «корыган үлән», морд. *гавдан,* аз. (АДДЛ: 105) *ғағдан* «коры печән», як. *хагдан, халдан* «корыган үлән» (*халдан* < *қағалдан* < *қауғалдан,* к. **Каугал**) һ.б. (төрки телләрдә күп параллель сүзләр табарга мөмкин) монг. телләреннән, к. яз. монг. *хагда*, бур. *һагда*, калм. *хагд* «коры үлән», халха монг. *гаңда-* «корып кибү (үлән тур.)», иске монг. *гаң-,* кор. *каŋ-* «кибү, кору». *Кагда-, кагуан* > *һагдан* > *сагдан* сүзләре эвенк., эвен сөйләшләрендә «кору, картаю» мәгъ. алганнар. ССТМЯ II: 457; Номинханов: 294. Рус. диал. *хагда* «каудан» (< монг.) тур. Аникин: 601; Räsänen 1969: 220.

Дерив.: **кауданчылык** «дошманлык; кызулык». К. түбәндәгене.

**КАУДАР [қа°wдар], каудыр** «вспыльчивый, горячий» ~ башк. *қауҙыр* id. > мар. *каудыр* id. ~ каз. *қаудар* «корыган, кипкән үлән; каудар» < монг. *хагдар* «каудан», бур. *хагдар-* > як. *хагдарый-* «корып кибү» һ.б. (күп төрки монг. телләрендә параллельләре табыла). Рус. (Аникин: 615) *хаузар* «үткен кыяклы үлән төре (вострец)» < бур. К. **Кау, Каугал, Каудан.**

**КАУДЫ [қа°wды̆]** иск. (И. Хәлфин) «некая птица» ~ башк. (БТДҺ: 194) *қауҙы, қаулан* «ләкләк» – *каудан, каулан кошы* дигәннән булса кирәк. Ягъни – дүдәк.

**КАУЗА-У [қа°wза-]** диал., башк. (БТДҺ: 193) «превратить в труху, измельчать» < *кавыз-а-,* к. **Кавыз II.**

**КАУЗЫ [қа°wзы̆]** «колокольчик (на шее лошади)» ~ алт. *козо, кооза, коозы* id. < кыт. *коң цзы* id.

**КАУКА [қа°wқа]** «шерсть-линька; шелуха» ~ башк. диал. *қауқа-* «кавакланып коелу» (БҺҺ II: 141) *кавык* нигезеннән: *кавык-а-* булса кирәк. Һәрхәлдә **кау** тамырыннан, к. **Кавык, Кау.**

**КАУЛАК [қа°wлақ]** (Тумашева: 124) «одуванчик; пух тополя, одуванчика», себ. (ЗДС: 401) «разная высокая трава», күч. «новое поколение», к. **Каудар, Каулан.** Төр. *kavlak* «кабыгы суелган» ← *kavla-* «кабыгын сую».

**Каулак** дип ата-бабаларның данын дәвам иттермәгән буынны атаганнар.

**КАУЛАН [қа$^{о}$wлан]** «высокая трава» (к. Исәнбәт II: 545) ~ себ. тат., башк. (БТДҺ: 194) *қаулан* «кавыл»; бу сүз Ә. Бируни тарафыннан X г. ук теркәлгән: *қаулан* «алтынсу чәчәкле биек үлән» (к. Бируни III: 263) – андыз булса кирәк ← бор. *каула-* «каугa әверелү» сүзеннән, к. каз. *қаула-* «каплап, биек булып үсү (үлән тур.)» К. **Кау, Каудан.**

**КАУЛА-У [қа$^{о}$wла-]** «гнать, подгонять» – беренче карашка **куала-у**ның варианты шикелле күренгән бу сүз бүтән мәгълүматлар яктылыгында мөстәкыйль, аерым бер лексема булып шәйләнә, к. ком *қавла-* «рухландыру, кычкырып куәтләү» (мәс., көрәшчеләрне, ярышучыларны)» – *қау* «үрт» сүзеннән булса кирәк, к. Ә. Ясәвидә (XII г.) «*Газазилне Ходаем үзе **каулар***», ягъни «дәһшәтле рәвештә куып җибәрер», уйг. *қоғла-* «каулау» ← *қоғ* «кау». Гомумән, **каула-у** һәм **куала-у** икесе ике тамырдан, ләкин контаминацияләнгәннәр. Моны А. Будагов та сизенгән (к. аныкы II: 97), тик ул «монда ике тамыр» дими.

**КАУРА [қа$^{о}$wра]** «бурьян; высокая сухая трава» ~ кр.-тат. *qawraq* id., к.-балк. *қаура;* үзб. *қовраң,* төр. *kavrak* һ.б. «учакка ягыла торган коры биек үлән». К. түбәндәгене.

**КАУРА-У [қа$^{о}$wра-]** «сильно сохнуть, засыхать (только о травах, сене, листьях)» – гом. кыпч. *қаура-* id. *Қаура-* ← **қау** (к.) сүзеннән.

Төр. *kavra-* «уйлап алу; төп мәсьәләне тотып алу; аңлау һ.б.» һәм *kavru-* «катып кибү» аерымланалар.

**КАУРЫ [қа$^{о}$wры̆]** (ТТДС I: 235) «сухие остатки, кострика льна, конопли», «сильно засохший (о стеблях трав)», шуннан тат. диал. (миш.) **каура-у**, к.-балк., ком. *қаура-* «кибү, кору; корып җиңеләю»; к. ш. ук к.-балк. *қаураң* ~ мар. (< тат.) *кагура, каура* «кауры, мурт». *Кау* тамырыннан, әлбәттә. Ихтимал, *кауры* < **кауырыг* ← *кау-ыр-* «каугa әверелү», әмма мәзкүр сүзләр бүтәнчәрәк тә ясалырга мөмкин. К. **Каура-у.**

**КАУРЫЙ [қа$^{о}$wры̆й],** диал. **кауры** «перо птицы» ~ диал. (ДС: 71; ДС III: 68; ш. ук Радлов II: 52) **қаwыр, қаwыргый, қаwырсын** «каурый, кавырсын, канат» (бу мәгъ. еш кына буталалар); **каwрый < каwырғый <** **қаwырғай, *қаwырқай* булса кирәк, һәрхәлдә **каwыр** нигезеннән.

**Каурый** хәз. тат., башк. телләрендә генә очрый, ләкин элек киң таралган булган, к. кабарда. *кабзий* «каурый» – бор. кыпч. шиваләреннән (*кабзий* << *қаwызгый* булса кирәк, к. ш. ук башк. (БТДҺ: 194) *қауҫа* < *қауҙа* «кауры, каура»; бу сүзләрдә *-р-* > *-з-* күчеше чагыла).

**Каурый** нигезе тат. диал. (Тумашева 1992: 124) **қаурый** «курай» сүзе белән бердәй булган булуы да бик ихтимал. К. **Кау, Кауры, Кавырсын** һ.б.

Гомумән караганда, ***каwыр- < * қаw-ғыр-** «кау булып кибү» фигыле булган булса кирәк, шуннан **каwыр-ығ** «кипкән үлән сабагы» мәгънәсеннән тармаклы чемгә охшаш нәрсә – каурый мәгъ. килеп чыккан.

Тотрыклы сүзтезмә: **каурый каләм** – элек карага манып алып язу язар өчен кулланыла торган кавырсын, күч. мәгъ. язу куәсе, эчтәлекле язма; **каурый каләм эзеннән** – эчтәлекле хат, шикаять буенча.

**КАУША [қа$^{о}$wша],** диал. **кәүшә** (ДС II: 102) «мельничный ковш; мельничный лоток» ~ чув. *кавшă* id. хәз. яңгырашында рус теленнән булса кирәк: рус. *ковш*, диал. *ковша* (> лит. *kaušis,* эстон. *kaus*, фин. *kauha* һ.б.) «кауша, чүмеч», ләкин рус сүзе үзе төрки телләрдән, к. бор. төрки (ДТС: 452–453) *tegirmen qoγuši,* каз. *қауашақ* «тартма». Рус. *ковш* «кауша» < иске төрки («Хөсрәү вә Ширин» телендә) *қōш* < бор. төрки *qoγuš* «су улагы; тупас күн, каткан тире; кавырсын хәленә җиткереп куырылган тире» (к. **Куяк**): су саклау, су агызу әйберләре шуннан эшләнгән.

**КАУШАК [қа$^{о}$wшақ]** диал. «слабонервный; быстро теряющий контроль над собой» > чув. *хавшак* «мәлҗерәгән (кеше), бик картайган» ~ мар. *кавыжа* id. ~ төр. *kağşak, kağşar* «какшаган, какшак» < бор. төрки *qoγšaq* id. К. **Кауша-у.**

Дерив. (ЗДС: 401): **қаушақлан-у** «яргаланып кубу».

**КАУШАР-У [қа$^{о}$wшар-]** «прицепить друг к другу (руки)» – гом. кыпч., ног., каз., к.-калп. *қаусар-* id. **кавыш-у** сүзенең (к.) йөкл. юн.

**КАУША-У [қа$^{о}$wша-]** «оробеть; растеряться, паниковать», иск. (Троянский II: 124) «шататься (туры һәм күч.)», диал. (Радлов II: 54) «распадаться, разломаться» > чув. *хавша-* «кибегү; зәгыйфьләнү,

каушау» ~ ком., к.-балк., чыгт. *қауша-*, нуг., каз., к.-калп. *қауса-*, кырг. *кооша-,* төркм. *ғовша-* һ.б. < бор. төрки (МК) *qoγša-*, госм. *qaγša-* «хәлсезләнү; рәтсезләнү; таркалу» > тув. *қағжа-* «кибегү, челегү, кайшалу» ~ монг. *хагса-* «кибегү» >> тат. һ.б. *какша-у*. Чаг. тат. диал. **какша-у** «хәлсезләнү», каз. *қақса-* «кайгыру, зарлану; каушау», үзб. *қақша-* «калтырау». Шулай итеп *қауша-* < *қағша-* > *қақша-* күчешләре ачык-аян, тамыры **қақ, қағ** ~ **қау,** әмма төп сүзнең ясалышы ачык түгел. К. **Как, Какша-у.** Будагов II: 29; Федотов II: 304–305.

Дерив.: **каушат-у** < бор. төрки (ДТС: 452) *qoγšat-*. К. **Каушак.**

**КАФ: Каф тавы** фольк. «гора Каф» фар. *кӯһи қаф* id. тезмәсеннән калька. Гомумән, бу сүзне ир. телләрдән таралган дип уйлыйлар. Бор. ислам географиясендә «Каф – коры җирләрне һәр яктан уратып алган тау сырты» булган. **Каф** сүзе **Кавказ** сүзенең нигезендә ята. Төгәл генә этимологиясе юк. Будагов II: 18; МНМ I: 50.

**КАФИЯ [каºфийә]** «рифма» < гар. *қāфийă* id. *қфw* «эздән бару» тамырыннан. **Кифая** белән бутамаска.

Дерив.: **кафияле, кафиясез; кафиялә-ү.**

**КАФТАН** «кафтан» – русча (*к* белән) дә, татарча (*қ* белән) дә әйтелә; XIII–XIV г. сүзлекләрендә (Поппе 1938: 286) *qaftan* id. Рус һәм венг. этимологик сүзлекләрдә бу сүзне фар. *һафтан* сүзеннән дип күрсәтәләр, ләкин фар. сүзе үзе төрки *қап тон* (парлы) сүзеннән килә, к. **Каптал.** Будагов II: 2; Аникин: 274.

**Кафтан** бор. төрки *қап тон* «плащ» сүзеннән дә килергә мөмкин, к. алт. (Баскаков 1966: 126) *кептең* «кафтан». К. **Кип.**

**КАХА, кахай** (ЗДС: 401) «старший брат» ~ нуг., каз. (ҚТДС: 184) *қақа* id., ш. ук «ата». Бор. төрки (ДТС: 419) *qaŋ* «ата», *qaŋdač* «бертуган агаэне, абыйлы-энеле», *qaŋsïq* «үги». Ниндидер бор. кушма сүздән үзгәреп килеп чыккан булса кирәк (чөнки яңгырашы сәеррәк).

**КАҺАРМАН** «герой (произведения); герой (вообще)» < фар. *қаһрамāн, қаһремāн* «хөкемдар; җиңүче, каһарман». К. ш. ук тат. **каһармани** < фар. *каһармāнӣ.*

Фар. *каһарман* гар. *қāһир* «җиңүче» сүзеннән ясалган булса кирәк. К. **Каһәр.**

**КАҺӘР** «проклятие; жестокость, жестокое обращение» < гар. *қаһр* id.

Дерив.: **каһәрле, каһәрсез; каһәрлә-ү, каһәрлән-ү** («сүгенү» мәгъ. дә бар): **каһәрнамә** (Гиганова рус. «заклинание»).

**КАҺВӘ** кит. «кофе» ~ төр. *kahve* < гар. *қаһwă* id., үсемлек төре; гар. сүзе исә хамит (Хәбәшстан) телләреннән алынган. Гар. *қаһwә* сүзе фр. телендә *кафé* булып әверелгән, ә нидерланд телендә *кóфе* дип әйтелгән. Рус теленә һәр ике шул сүз – *кафé* һәм *кóфе* аерымрак мәгънәләрдә алынганнар. Будагов I: 100–101; Kluge: 459.

Тат. теленә төр. **каһвәханә** сүзе дә (элегрәк) кереп калган.

**КАҺКАҺӘ** «издевательский смех, хохот» < гар. *қаһқаһă* id., к. Dobr. II: 180. Гомумән, күренеп тора, тәкълиди сүз.

**КАЧ** «сколько» < төр. *kaç* id. ~ каз. *қат* id. бор. *қа* «кай, нинди; ничә» сүзеннән. К. Будагов II: 6. Чаг. **Качан.**

**КАЧАГАН** «склонный убежать (преимущественно о скотине)» ← **кач-у** (к.); кайбер төрки телләрдә (мәс., ком., чув.) *-аган//-әгән* фигыльдән регуляр сыйфат ясагыч кушымча. Чаг. ш. ук **тибәгән.** Рус. диал. *качаган, качеган* (< төрки) тур. Аникин: 275.

**КАЧАК** «беженец» < гом. кыпч., аз.. чыгт., госм. һ.б. *қачақ* (> нуг., каз., к.-калп. *қашақ*) id. ← *кач-у*. Чаг. ш. ук фар. *қачақ* «контрабандист».

**КАЧАН, кацан** миш., себ., иск. кит. «когда; когда же», употребляется и как союзное слово «когда» – *кайчан* сүзеннән кыскарган шикелле, ләкин к. **Кач.**

**КАЧАР** (ЗДС: 402) «годовалая тёлка» ~ төркм., госм. *қаҗар*, каз. *қашар*, тув., алт. диал. *қазыра, қазра*, хак. *хазыра*, яз. монг. *xasiraγ* «икенче-өченче яшьтәге бозау» һ.б. (монг. телләрендә параллельләре күп). Бу сүзнең төрлечә чагылышлары рус (Себер) сөйләшләрендә күп икән: *казра, качарак, качарик, кочерик, коширик* һ.б. (Аникин: 235, 275–277, 617, тик бу автор төркм., төр. сүзләрен һәм тат. сүзен дә белми).

**КАЧКЫ, қачқын** «беглый; дезертир» ~ гом. кыпч. *қачқы, қачқын* (> нуг., каз., к.-калп. *қашқы,*

*қашқын*) ← **кач-у**. Рус. диал. *кочка* «качкы» тур. Фасмер II: 359.

**КАЧ-У** «убегать, убежать; избегать, удаляться; не вернуться домой, чтобы совокупляться (о скотине)», эвф. «совокупляться» < гом. кыпч. *қач-* (> башк. *қас-ыу,* нуг., каз., к.-калп., тув. *қаш-* > хак. *хас-*) id. < **қаач-* < **қағач-*, к. тув. диал. *қа'ш*, бор. монг. (Поппе 1938: 286) *qaγača-* «аерылу». Будагов II: 6–7; ЭСТЯ V: 340–342.

Дерив.: **качыл-у** (качырга туры килү), **качын-у** (Ф. Әмирхан телендә), **качыр-у**, **качыш-у; качыш** (шуннан **качышлы** – уен атамасы); к. **Качаган, Качак, Качкы, Качык-у.**

**КАЧЫК-У (качыкты, качыгу)** сирәк «стремиться, норовиться убегать» – **кач-у** сүзенең интенсивлык формасы.

**Качыгу көче** рус. «центробежная сила» – неол.

**КАЧЫР** «мул» < гом. кыпч. *қачыр* (нуг., каз., к.-калп. *қашыр*, башк. *қасыр*), уйг. *қачир*, үзб. *хачир* < бор. монг. *qačir* < бор. төрки (ДТС: 405) *qatïr* < *qaγatïr* id. ← *qat-* «кушу, кату» (Рамстедт 1957: 86), к. ком., гаг., госм. һ.б. *қатыр,* төркм., аз. *ғатыр* id. һ.б. Күрәсең, качыр терлеген гомумән яхшы белмәгән кыпчаклар бу төрки сүзне монголлардан ишеткәннәр. Төрки *қатыр* сүзе һунн телендә Кытай чыганакларында б.э. кадәр үк искә алына. *Катыр* > *качыр* күп телләргә таралган; рус. диал. *катырь* «качыр». Аникин: 273–274; ЭСТЯ V: 340–342 (сүзнең ир. телләрдән булу ихтималы әйтелә).

**КАШ I** «бровь», «бровка, округлый крутой холм, крутая возвышенность; лука седла» < гом. кыпч. *қаш* (> нуг., каз., к.-калп. *қас*), төркм. *қааш,* як. *хаас* < бор. гом. төрки **қāлч* id., к. мар. (< болг.) *хал* ~ монг. *хал* < бор. монг. *qal* «каш», чув. *харш* id. Тат., башк. һ.б. **күз кашы** ~ удм. *шинкаш*, мар. *синзахал* тәгъбиреннән чыгып, *каш* сүзенең төп мәгънәсе тән әгъзасына карамаган дип уйларга мөмкин. Һәрхәлдә гом. төрки *қаш* ~ хак. *хас* ~ угыз. *ғаш* сүзенең «маңгай, ян» мәгъ. дә нык сизелә. Räsänen 1969: 240; ЭСТЯ V: 343–345 (*ш* > *л* дигән ялгыш караштан чыгып, бу китап авторлары мар. *хал* сүзен чув. теленнән дип кенә күрсәтәләр). Гарипова 1998: 95–97 (тәфсилле).

Дерив.: **кашлы, кашсыз; кашлык** (биек булмаган текә үрлек). К. **Кашага, Кашак, Кашка, Кашлак.**

**КАШ II** «драгоценный камень-печатка в кольце», диал. (ДС III: 78) «перламутр, пуговица» < гом. төрки *қаш*, төркм. *қааш* id., бор. төрки (ДТС: 431) *qaš* «минерал нефрит», к. ш. ук нуг. *қас*, тув. *хаш*, монг. *хас* һ.б. «йөзек һ.б. кашы». Фонетик җәһәттән һәр телдә **каш I** белән бердәй, ләкин **каш II** сүзенең бик үзенчәлекле мәгънәсе аны аерым сүз дип карарга мәҗбүр итә һәм барча этимологлар да бу **каш II** ны аерым сүз итеп карыйлар. **Каш I** күрше телләргә дә алынган, шундый алынмалардан удм. *кӓч* игътибарга лаек. К. Будагов II: 15; ЭСТЯ V: 345–346; Тимергалин: 234.

Дерив.: **кашлы, кашсыз** (йөзек тур.).

**КАША** (әстр., ЗДС: 403) «забор, ограда» ~ каз. *қаша* id. Чаг. кырг. *қашаа,* уйг. *қаша,* шор. *қажа,* хак. диал. *қазаа,* як. *хасаа* «читән; киртәләнгән мәйдан», тув. *қажа, қаза* «йорт, абзар» ~ монг. *qasiγa* «читән киртә» һ.б., к. Räsänen 1969: 240 (тат. сүзен күрсәтми). К. **Кашага.**

Дерив.: **кашала-у.**

**КАШАВАЙ** «кошевые сани» к. **Кәшәү, Куш**.

**КАШАГА** «бордюр; верх наличника окон и дверей и т.п. отверстий; верхняя занавеска», себ. «сруб под печь; обрамление; перекладина, спинка стула» (к. ТТДС I: 198; Тумашева 1992: 151) > чув. *хашака, хавшака* «рам, кәрниз, янак» ~ башк. (БҺҺ II: 141) *қашаға* «фриз, кәрниз; рам, матча; фундамент» , үзб. *қашаға* «куак киртә», каз. диал. (ҚТДС: 201) *қаша* «койма, читән, кура», *қашаға* «чыбылдык» һ.б. *-ға* аффиксына караганда, монг. телләреннән алынма, ЭСТЯ (V: 346–347) авторлары бу сүзләрне кырг. *қашаа,* тув. *кажаа,* хак. *казаа*, як. *хасаа* < монг., бур. *хашаан* «йорт; кура; читән; лапас», төр. *kaşa* «абзар», арытабан төр. *kasu*, бор. төрки (ДТС: 430) *qasï* «читән абзар» сүзләре белән бергә бирәләр; чаг. ш. ук уйг. *қаша-*, яз. монг. *xaši-*, маньч. *хаша-* «киртәләү, каплау, яклау» һ.б. (бу фигыльнең дериватлары бик күп). Joki 1955: 174; ССТМЯ I: 463.

Дерив.: **кашагалы, кашагасыз; кашагалык; кашагала-у.** К. **Кашак.**

**КАШАК I** «опушка (леса)». Күрсәтелгән мәгъ. тат. телендә генә булса кирәк. Мәгънәсе буенча **кашага** сүзенә тап килә. Чаг. ш. ук бор. төрки (ДТС: 431) *qašaq* «кылган төре». Чув. *хуша* ~ *қаша* «аралык». К. **Каша.**

**КАШАК II, кашаң** (себ., ЗДС: 403) «одноглазый; с прищуренным одним глазом – с уничижителным или злым взглядом», ш. ук **кашай-у** «посмотреть со злостью». Чаг. каз. *қасаң* «каты; кырыс; явыз, кызганусыз», «нык каткан калын тире» ~ *қасар* «усал»; чыгт. *қашаң* «ябык, ямьсез, усал карашлы» ~ монг. *qašaŋ* «авыр хәрәкәтле (һәм аз сүзле)». Будагов II: 15; Räsänen 1969: 240 (аз. *kašaŋ* «нәфис һәм иплe – хатын-кыз тур.» сүзен дә китерә).

**КАШАН, қаша, қажан** (ЗДС: 374, 403) «ограда из камыша, хлев» и т.п. ~ каз. (ҚТДС: 201) *қаша* «биек койма яки зәмәт (балчык койма) белән уратылган урын, кура» ~ рус. (Аникин: 277, 616) *кашан* «абзар; арба сыярлык ишек; шундый ишеге булган лапас» һ.б.ш., *хашан* «кәртәләнгән бүлмчек; җылытыла торган абзар» < бур. *хашаа(н)* «киртә, кәртә» ← *хаши* – «кәртәләп алу». К. ш. ук тув. *қажа*, монг., маньч. *хаша*, бор. төрки *qasï* «кәртәләнгән урын; читән абзар» һ.б.ш. **Кашага** (к.) белән тамырдаш булса кирәк.

Идел Болгары, Казан дәүләтләрендәге **Кашан** шәһәре исеме, ихтимал, мәзкүр **қашан** сүзеннәндер.

**КАШАП** (ЗДС: 403) «деревянный башмак» < гар. *ҳашäб* id. К. **Хәшәп**.

**КАШАУ [қа°шаw]** «скребок, скребница для чистки лошади» > чув. *хашав, кашав* id. ~ каз., к.-калп. *кашау* (< тат.? **касау* булырга тиеш иде); кр.-тат. *қашага,* чыгт., бор. кыпч. (Курышжанов: 160) *қашағу*, госм. *қашағы*, куман. *қашрау* «кашау» (к. Радлов II: 389, 390, 396), төркм. *гашав*, аз. *гашов*, төр., урта төрки *қашақ,* як. *кысыах, кыһыах* «кашау», *кыһый-* ~ авар. (< төрки) *хаша-* «кыру, кыргычлау» (атны); чаг. ш. ук себ. (ДС I: 81) *кацау, качау* «өтерге» ~ нуг., каз. диал. *қашау* id., бур. *хосо-* «кыргычлау».

Чаг. мар. *кашар, кашаргы* «очлы таяк», *кашарт-* «очлау» (төрки телләрдән, әлбәттә), чаг. ш. ук **Кашы-у.**

Сүзнең тамыры **қаша-* «кыргычлау» булырга тиеш, ләкин монда контаминацион тамырлар да бар булса кирәк. К. Räsänen 1969: 240.

**КАШБАУ [қа°шбаw],** диал. (к. Будагов II: 16) **қашмаw** «налобная повязка; женский головной убор с налобными украшениями» > мар., удм., морд. *кашпав, кашпау,* чув. *хушпу* < *хошпу* < болг. **һашпу, *һашбу* > мар. (Исанбаев 1978: 33; Саваткова: 111) *ошпу, öшпÿ* ~ башк. *қашмау,* каз. *қашпау* һ.б. id. Төрле фонетик вариантлар төрлечә ясалган булса кирәк: **кашбаw** < (кар.) *қашбағ* (к. **Бау**); **кашмаw** кушма сүзендә кыт. *маw* «хатын-кыз бүреге» сүзен күрәләр; **кашпаw** дигәне < **қашпағ* (*қаш* + фар. *пак* ~ *паг*) «каш (маңгай) киеме» дип тәгърифләнә ала. К. ш. ук аз. (АДДС: 124) *гашбәнд* «кашбау (*қаш* + фар. *бäнд* «бәйләвеч»). Тимергалин: 234.

**КАШКА I** «с белым пятном на лбу (преимущественно о лошадях); белое пятно на лбу (животных)», диал. **қашкар** «то же (о собаке)» > удм. мар. *кашка*, чув. *хошка* > *хушка* < гом. кыпч. *қашқа* (нуг., каз., к.-калп., алт. *қасқа,* хак. *хасха*), төр. *kaşka, kaşga,* аз. *гашга,* бор. төрки (ДТС: 431) *qašγa* «кашка»; кайбер телләрдә (каз. һ.б.) «пеләш, таз» ~ чув. *какша* > *кокша* > *кукша* (к. Räsänen 1969: 241) id. тат. сөйләшләреннән булса кирәк; чув., удм. диал. *качко, кäчко* «кашка» бор. төрки **қалчқа* id. булырга тиеш, чаг. бор. төрки, монг. *qalčaq, qalčiγaj* > як. *халчағай* «пеләш» һ.б. *Кашка* < *қалчқа* сүзенең фигыль нигезе **калч-* < **калчы-* «кашлану (?)», к. иске монг. *qalǯan* (> алт. *қалдьан-* һ.б.), бур. (> рус.) *халзан* «кашка»; алт. *қалтар*, бур. *халтар* (> рус. *халтарый*) «ак томшыклы ат». Бөтен бу сүзләрнең тамыры бор. төрки > монг. **қал* «ак тап» (к. ЭСТЯ V: 350–351), безнеңчә, кырг. *қал-* ~ фар. *хал* «миң, ак каш» (сирәк кенә тумыштан чал кашлы кешеләр була) белән бердәй. Чаг. ш. ук **Каш.** Аникин: 604; ССТМЯ I: 366.

Дерив.: **кашкалы; Алланың кашка тәкәсе** рус. «козёл отпущения» – Тәңрегә кашка тәкә (ш. ук ат һ.б.) корбан итү яисә аңа табыну гадәтеннән килә (мондый йола дөньядагы күп халыкларда очрый, мәс., бор. Мисырда кашка үгез **Апис**ка табынганнар). К. **Кашкалак.**

**КАШКА II** фольк. «самоотверженный воин» ~ башк. id., хак. *хасха, хашқа* «элитар ыруг; аксөяк; рыцарь»; кырг., үзб. *қашқа* «аерылып торган зат» (бәлки **кашка I** дәндер), бор. төрки (ДТС: 431) *qašïγ* «мәһабәт кыяфәтле». Бутанаев 1990: 22–25, 56–58 (**кашка I** белән бердәй булмаска тиеш ди, без дә Бутанаев фикерендәбез).

Төрки телләрдә кире-тискәре мәгъ. *қашқа*лар да очрый: нуг., каз., к.-калп. *қасқа* «мескенкәй»; аз. (АДДЛ: 124) *гашга* «кире, хәясыз, оятсыз» (бәлки этнонимнандыр), шор. *хашха* «явыз рух» һ.б.

**КАШКА III –** один из родов, племя у башкир. Бу исемдәге этнонимнар төрки халыкларда төрле

җирләрдә очрый: каз., кырг. *қашқа (җиде қашқа),* хак. *хашха,* як. *қасқа* һ.б. – ыруг-кабилә атамалары. К. Камалов, Камалова: 121–126. Чаг. түбәндәгене.

**КАШКАЙ –** одно из тюркоязычных племён Ирана. Ихтимал, фар. *қашқаи* «кашкалы» сүзеннәндер. Безгә ирешкән мәгълүматлар буенча, *қашқайлар* төбендә кыпч. телле, ләкин күрше угыз кабиләләре тәэсирендә угызлаша башлаганнар.

Кашкайлар күпсанлы һәм сугышчан халык дип исәпләнә икән. Чаг. **Кашка II, Кашка III.**

**КАШКАЛАК, кашкалдак** «лысуха (плавающая птица, относящаяся, однако, к куриным)» < гом. кыпч. сүз, к. нуг. *қасқалақ,* каз., к.-калп. *қасқалдақ,* бор. төрки (ДТС: 431), кырг., уйг. *қашқалдақ,* чыгт. *қашқалдағ* һ.б. (к. ЭСТЯ V: 351–352) id. Күп күрше телләргә алынган (к. Аникин: 271). Һичшиксез **кашка** сүзе белән баглы (*кашкалы дағ?*).

**КАШКАРЫЙ** «астра (растение)» < иске тат. *кашгарый гөл* «Кашгар гөле»: *қашгарый* гар. Кашгарныкы, Кашгарга бәйләнешле (**Кашгар** – Кытайның Циньцзян провинциясендәге бер өлкә һәм шәһәр исеме), чаг. каз. (ҚТАС: 408) *қашқар шәйек* «кашгар чәйнеге; комган», уйг. *қәшқәри* «йөземнең Кашгарда үстерелә торган сорты» һ.б. Кашкарый гөле Кытайдан таралган.

**КАШКИ** «о, если бы» – **кяшки** сүзенең дөрес түгел язылышы.

**КАШКЫР**, себ. тат. **қарышқыр** «волк» > чув. *кашкăр* < гом. кыпч., к. кырг., башк. *қарышқыр,* нуг., каз., к.-калп. *қасқыр, карысқыр,* к. ш. ук (Радлов II: 212) *қаршқур,* төр. (DS: 2680) *kaşkır,* үзб. *қашқир,* үзб. диал. (ЎХШЛ: 157) *қаршъқул* < *қарыш қурт* «усал бүре» дип аңлатыла (чаг. башк. *қарысқы, қарычқы* «бүре»), мондый аңлату тат. филологларында да очрый. Бүтән фаразлар тур. к. ЭСТЯ V: 352–353; Федотов I: 243. Рус. *кашкыр, каскыр* тур. Аникин: 271.

**КАШЛАК** «пригорок», собственно «место с пригорками», диал. **кашлык** id. **Каш I** сүзеннән (сүзьясалыш моделе җәһәтеннән к. **Тозлак**).

**КАШШАК, хашшақ** (ЗДС: 403, 699) «нищий; негодяй» < уйг., үзб. *қашшақ,* үзб. *қошшоқ* «мескен ярлы» гар. *қашшāш* «калдыкларны җыю, себерү», *қашшāш* «урам себерүче» һ.б. сүзеннән үзгәргән (төркиләштерелгән булса кирәк). Кашшашлар махсус минималь ихтыяҗлар белән генә яшәгәннәр.

Бу сүзне **Кашак II** (к.) сүзеннән аерырга кирәк.

**КАШЫК** «ложка» > чув. *кашăк* id. < гом. кыпч., уйг., угыз. *кашук, қашык* (нуг., каз., к.-калп. *қасық*) id., чув. *хошăк* > *хушăк* «калак» – икенчел мәгънә. Һичшиксез *калак* сүзе белән тамырдаш – бор. **қалчығ* формасыннан; чаг. тат. диал. *кашык* ~ алт. диал. *кажык* «аяк табаны сөяге; киль»; чаг. бор. монг. *qalbaγa, γalbaγa, γalbuγa* > хәз. монг. *халбага* «кашык; калак», *халбай-* «киң булу» һ.б. Räsänen 1969: 241; ЭСТЯ V: 353–354; ССТМЯ II: 365; Федотов II: 243. Рус. диал. *кашик, кавшик* «чүлпы, кипкер» тур. Аникин: 231, 277.

**КАШЫНДА** (ш. ук **кашына, кашыннан**) «у, при» < **каршында** сүзеннән бор. кыскартылма була ала; ләкин кайбер телчеләр бу аңлатма белән канәгать түгел – алар **каш** сүзенең аерым мәгънәсеннән дип исәплиләр. К. үзб. *кошида,* уйг. *қашида.*

**КАШЫ-У** «чесать, чесаться; скрести» < гом. кыпч., аз., төр. һ.б. *қашы-,* үзб. *қаши-*, төркм., госм. *қаша-*, әр.-кыпч. *харша-* < бор. төрки **қалчы-* «тазны тырнау?» сүзеннән булса кирәк (Поппе 1925: 42), чаг. тат. (ТТДС I: 190, 199) **калҗа-, каҗа-** «тире чистарту (тиречеләр-күнчеләр телендә)». Радлов II: 392–396; Räsänen 1969: 240; ЭСТЯ V: 347–348. Чаг. **Кашау.** Чув. *хыç-* «кашу» тур. Федотов II: 384 (*кашы- ~ качы-* нигезләрен чагыштыра).

Дерив.: **кашын-у, кашыт-у.**

**КАЮ I [қаºйу, қаºйыw]** иск. «какой, который» < бор. төрки (ДТС: 408–409) *qaju* (ш. ук *qajuda, qajudïn, qajun, qajunï, qajuqa*) «кайсы, кайсы ки, нинди». Бу сүз элекке тат. әд. телендә киң кулланылган. К. ш. ук **Кани.**

**КАЮ II [қаºй-у]** к. **Кайы-у** (*Каю кайыйлар*).

**КАЯ [қаºйа]** «куда; *модальное слово* где тут; где уж» < гом. төрки *қайга.* К. **Кай.**

**КАЯЗ [қаºйаз]** «усач (рыба)» ~ үзб., каз., к.-калп. *қайаз* id.

**КАЯУ [қаºйаw]** «жало» (к. ТРС: 1966) ачык түгел; чаг. башк. *қайау* «бидәр, бизәк» (БҺҺ II: 127), ком. *қаяв* «яры, элпә». К. ш. ук тат. диал. **каяу** ~

чув. *каю* «яңа шытым», каз. *қаяу* «тәндәге киселгән төш, яра; күңел ярасы; дефект».

**КӘ + тартык аваз** комплексы тат. һәм. башк. телләрендә күп кенә очракларда **ки + тартык аваз** комплексы белән (һәм киресенчә) алмаштырыла, мәс., *кәбән ~ кибән, кәрәк ~ кирәк, кәртә ~ киртә* һ.б. кайбер очракларда мондый тәңгәллекле сүзләр мәгънәләре, валентлыклары, деривацияләре белән дә аерылып торалар. Шуның өчен без андый пардашларны аерым-аерым алабыз.

**КӘБАП** «жаркое, шашлык; кебаб» < гар. *кäбāб* id. (к. Будагов II: 111) *кбб* «пешерү, кыздыру» тамырыннан.

**КӘБӘК** «мякина» < уйг. *кәбәк,* бор. төрки *кäпäк* id. К. **Кибәк.**

**КӘБӘМ** «мой дорогой», **қәбәй** «дружище (мой)» (к. ДС III: 96–97; ТТДС I: 266) ~ чув. *кепе* «язмыш алиһәсе» ~ мар. *кава юмо* (*юмо* «тәңре»), удм. *каба инмар* (*инмар* «тәңре») < болг. **кәбә* < гар. *кä'бä* (к. **Кәгъбә**) сүзеннән дип исәпләнә, к. Федотов I: 267 (М.Р. Федотов тат. сүзен искә алмый).

**КӘБӘН** «стог (большой)» ~ куман. *käbän,* ком., к.-балк., кр.-тат. *кебен* һ.б. Барча күрше телләргә кергән: чув., мар. *капан, кабан* (мар. ш. ук *кäбäн*), удм. *кабан,* рус. диал. *кабан* id. Угор телләрендә башлыча *kepän,* венг. *kepe* id. Räsänen 1969: 254. К. **Кибән.** Кайбер телчеләр **кәбән** яңгырашы башкортча дип язалар. Бу дөрес түгел: ул вариант төрле тат. сөйләшләрендә очрый.

**КӘБӘНӘК** («Җәмигъ әл-хикәят» телендә) «плащ-дождевик; веко (глаз)» < гом. кыпч., к. башк. (БТДҺ: 168) *қәбәнәқ, кәбәнәк,* кырг., каз., төркм. *кебенек*, үзб. *кебәнәк, кәбәнәк, кәпәнәк*, төр. *kepenek*, к.-балк. *гебенек*, тув. *хевенек* һ.б. (ЭСТЯ V: 48–49) «җиңсез киез халат» ← төр., госм. *кäбä* «каплавыч; киез чапрак һ.б.ш.» диелә, безнеңчә, *кәп//кип* тамырыннан, к. **Кәп.** Чаг. **Кибән ~ Кәбән.**

*Кәбәнәк ~ кәбәнәк* сүзе күрше (ир., монг. һ.б.) телләргә дә үтеп кергән, к. монг. *kebeneg,* фар. *кäпäнäк*, осет. *geben, gebenek* «иң гади плащ». Рус. *кебеняк, тебеняк* (< төрки) «кәбәнәк» тур. Фасмер II: 220.

**КӘБӘРӘ,** (ЗДС: 282–283) **кәвәр, кәвәрә** «общая, необработанная форма; заготовка», **кәвәрә-ү** «камыр әвәләү» һ.б. к. **Кипрән.**

**Кәбәрәсе килгән** «инде әзер диярлек (әйбер тур.)», «теләсәң, бүгеннән кияүгә бир (кыз тур.)».

**КӘБӘРТКЕ** (ТТДС I: 266$ ТТДС II: 192; БҺҺ II: 126) **кәбәркә, кәбәрткә, кәбертке, кәбәртмә,** ш. ук (без теркәдек. – *Р.Ә.*) **кибертке** «настил» ***кәбәрт- ~ *кибәрт-** «киптер-ү» (фиксациясе юк) фигыленнән, к. каз. (ҚТДС: 149) *кебіртең* «коргаклаган» ← *кебірт* – «киптерү»; кырг. *кебек* «кибеп яргаланган», *керерси-* «коргаксу». Чаг. **Кип-ү.**

Сөйләшләрдә **кәбәртке** төрле аерым мәгъ. йөри: «мич белән эргә (стена) арасы һәм шунда ясалган (утын киптергеч) сәндерә», «гомумән сәндерә; сәке», «киштә, корыт киптерү өчен түшәмә» һ.б.ш. Гомумиләштереп әйткәндә, **кәбәртке ~ кибәртке** «нәрсәне дә булса җәеп киптерү өчен таскак, түшәмә», ихтимал, кирпеч яндыруга карагандыр. **Кәбәртке** тур. этимологик әдәбиятта берни әйтелмәгән.

**КӘБЕН**, (Будагов II: 108, ДС III: 96) **кибен, кибын** (ТТДС II: 169) «церемония бракосочетания» > мар. *кäвин* id. < фар. *кабин* id., төп. мәгънәсендә – туйда кулланыла торган тәңкәләр, аларны кәләшнең башына койганнар (шуннан *кәбен кою* «никахлау») һәм килешү-ярәшү билгесе итеп бер тәңкәне урталай кискәннәр (шуннан – *кәбен кисү*). Redhouse: 629.

**КӘБЕСТӘ** «капуста» ~ чув. *купăста* < *копыста*, мар. *капшта, кавышта,* удм. диал. *кубыста, кобыстан*, морд. М. *капста* ~ миш. **капыста, кәпестә, капста** (бу вариант хәтта диалекталь сүзлекләргә дә кертелми, диалектологлар аның рус сүзе икәнлегенә шул кадәр ышаналар), рус. *капуста*, ит. *cappuccio* «башчык, кәбестә башы» сүзеннән дип исәпләнелә (Преображенский I: 295), ләкин монда шикләнерлек моментлар бар икән (Фасмер I: 295), чаг. кабарда. *кәбыстә* «кәбестә». Төрки телләргә *кәбестә* турыдан-туры лат. яки ит. диалектларыннан да килергә мөмкин, к. тат. диал. (Тумашева 1992: 113), ком. **қабыста** «кәбестә» (*қ- !*). С.А. Максимов (ДАУ I: 105–109) буенча, *кәбестә* һ.б. ит. *komposita* «катлаулы» сүзеннән.

**КӘБИСӘ (кәбисә ел)** «високосный (год)» < гар. *кäбūсä* id. Тимергалин: 235.

**КӘВЕР [кәwĕр], кәwир,** миш. **каwир,** (ЗДС: 295) **кеwәр** «коврик» ~ башк. (БҺҺ II: 109, 125) *кәүер* id. < рус. *ковёр* (< бор. рус. *кóвьръ*); чув. *кавир* «кәвер» татарчадан булуы ихтимал. Рус сүзе

үзе бор. төрки телләрдән («бор. чув. теленнән», ди Фасмер II: 270–271). Башк. (БҺҺ III: 89) *күбер* «чүпрәк палас» сүзе дә русчадан булса кирәк. Бор. төрки **кэwбирг* булган кебек, к. **Киез.** Федотов I: 209–210; Аникин: 294–295.

**КӘВЕШ [кәwӗш]** «кожаные туфли, башмачки» > мар. *кäуш* id. чыгт., үзб. *кәвуш, кавуш,* үзб. диал. *кабиш*, уйг. *кәпиш* ~ фар. *кафш, кäфш* id. Бу сүзнең *-ч* варианты – себ. (Тумашева 1992: 92, 96) **кәбец, кәүц** ~ кырг. *кебич, кепич, кепүч* сугд. (к. ЯТ: 268) *krč* «кәвеш» сүзеннән булса кирәк. Бор. ир. телләрдә **кāбиш, кāбич* «алтын башмак» мәгъ. булган һәм аны хан кызлары – кәникәләр кигән. Гомумән, бу сүз күп телләргә таралган, к. Kannisto: 127.

**КӘГАЗЬ [кәғәз]** «бумага; официальный документ; бумажный» > мар., удм. *кагаз* id.; тат. диал. **қыйаға з** > чув. диал. *киакас*; тат. диал. (ЗДС: 240) **җәғаз, йәғаз** > удм. диал. *ягаз* id.; ком., аз., төркм., иске тат. **қағыз** > башк. диал. *қағыҙ* id. ~ каз., к.-калп. *қағаз, қағыз* < фар. *кағаз* ~ гар. *кағад* дип исәпләнә. Гомумән, бу сүзнең вариантлары исәпсез күп, бор. төрки шивәләрдә үк (ДТС: 294, 405) *qaγaz, qaxïd, kägädä* һ.б.; *-т, -д* вариантлары киң таралган: уйг., алт. (Баскаков 1966: 121; 1972: 216) *қағат*, нуг., к.-балк., куман., госм. *қағыт*, кар. *кагыт*, *кяхад*, гаг. *киат*, морд. М. *кягод* (бор. төрки телләрдән) һ.б. Үзенчәлекле вариантлар Кавказ телләрендә күп (мәс., осет. *даххат,* груз. *кагалди, кагарди* һ.б.).

Бор. монг. *čaγalsun* > алт. *чаазын* «кәгазь» сүзен гом. монг., тунг. *чаға*[н] «ак» сүзе белән бәйлиләр (ССТМЯ II: 380–382).

*Кәгазь* сүзе гарәпчәдән таралган дигән фикергә күпләр шикләнеп карый, чөнки гарәпләр кәгазьне Кытайдан 751 елда гына үзләштергәннәр. А. фон Габен (к. аның Культура письма и печатания у древних тюрков // Зарубежная тюркология. М., 1986: 159–160) буенча, *кәгазь* сүзе кыт. *ки, кик, к'ак* «тут агачы» сүзе нигезендә ясалган. К. ш. ук Pokora T. Das alteste Papier der Welt und seine Probleme // Das Altertum. II. Berlin, 1985: 113–118; Тимергалин: 236–237.

**КӘГӘ-Ү** (ЗДС: 93) «гневно угрожать» ~ уйг. *кәкә-* id. ← *кәк, кик* «үч, усаллык, явызлану». К. **Кик.**

**КӘГЕТ** диал. «мелкая сорожка (рыба)» ~ башк. *кәгет* id. (БҺҺ II: 120).

**КӘГЪБӘ** «Кааба: (любой) предмет поклонения» (эллипсис от выражения «күңел кәгъбәсе») < гар. *кä'бä* «Кәгъбә; куб» (*куб* сүзе үзе гар. *ку'ӯб* «кәгъбәләр, кәгъбәне тәшкил иткән яссылыклар» сүзеннән килә). *Кәгъбә* һәм *куб* сүзләренең тамыры *к'б* бор. Мисыр теленнән килә дип исәплиләр. Тимергалин: 237.

**Кәгъбәтулла** – «Алланың кәгъбәсе» дигән сүз.

**КӘЕФ [кәйӗф]**, диал. (ДС I: 88) **киф** «настроение» < гар. *кäйф* id. ← *кйф* «формалаштыру, җайлау» тамырыннан. К. ш. ук иске әд. **кәйфия, кәйфият** «форма» (к. ТГРС: 222), «кәефләндергеч шартлар; яшәү рәвеше» (Будагов II: 178).

Дерив.: **кәефле, кәефсез; кәефлән-ү** һ.б.

**КӘҖ** «кривой; неверный; неспособный, не к месту» < фар. *кäҗ, кäж* < бор. ир. *kž* id. (Абаев I: 624). Бу сүздән **кәҗә** < фар. *кäҗи* «бөккән» сүзе ясалган, ләкин аны **кәҗә** ~ *тәкә* белән контаминациялиләр, к. ЗДС: 283.

**КӘҖӘ,** диал. **кәзә,** себ. тат. **кәцә, кәчә** «коза» ~ башк. *кәзә*, чув. *качак, качака* (к. Ашмарин VI: 168–175), мар. *каза*, *кäзä,* удм. *кеч* < төр., төркм., үзб. диал. *гечи, кäчи* ~ венг. *kecske* id. һ.б. тат. диал. (Тумашева 1992: 62) **ичке, ицке, ицкә** ~ гом. төрки *эчки* < бор. төрки (ДТС: 162) *ečkü* id. белән чагыштырыла (ләкин Аникин бу чагыштыруны кире кага). К. ЭСТЯ III: 34–36.

Рус. *коза* < гом. слав. *koza* һинд-евр. сүзе дип исәпләнә (Фасмер II: 277–278). Ләкин тат. диал. (ЗДС: 284) **кәҗи** «кәҗә»; **кәҗ-кәҗ** – кәҗәне чакыру ымлыгы, **көҗҗә** – кәҗәне куу ымлыгы ниндидер бор. җирле вариант тур. сөйли. Ихтимал, бор. *кэҗэ ~ кәҗә < *күәҗә > көҗҗә* бор. һинд-ир. телләреннән таралгандыр. Ләкин, нишләп төркиләр – һәртөрле кәҗәләрне күп күргән кавемнәр, бу хайван атамасын Европа халыкларыннан үзләштерерләр икән? Һәрхәлдә тат. **кәҗә** рус теленнән алынмаган. Мухамедова 1973: 122–123.

**Кәҗә сакалы, кәҗәсакал** төрле җирдә төрле үсемлекләр атамасы, рус. «козлобородник», «кашка», «шиповник», «пастернак» (к. ЗДС: 283). Шуңа охшаш атамалар борыннан бирле күп телләрдә очрый, к. төр. *keçisakalı, teke sakalı, erkeç sakalı* ~ лат. фәнни атамасы *tragopogon* (грек. «тәкә сакалы» мәгъ.) «пәрәгән чәчәге».

**КӘҖЕ** (ЗДС: 284) «худенький», шуннан **кәҗек-ү, кәҗе-ү** (ЗДС: 284, 285) «ухудшаться» ← *кәй*

(ихтимал, ***кәй-че-** фигыле булгандыр; гомумән **кәй** тамырыннан тат. телендә күп сүзләр ясалып, әд. телгә кертелмәгән).

**КӘҖҮЛ** «выделенная козья шкура» < рус. *козёл* (төптә «кәҗә тәкәсе») id. К. ш. ук башк. (БҺҺ II: 99–113) *канзул, кузыл, кузул*, чув. *качăл* id.

**КӘЗ I** иск. (ТТАС II: 249) «аршин» ~ уйг. *кәз,* кырг. *кез* < фар. *гэз, гäз, газ* «аршин; өч фут (1¼ аршын)», к. Будагов II: 126. Ценкер (Zenker: 748) бу сүзне бор. гом. төрки *кэз* «ук таягы» сүзеннән ди, әмма төрек теленең аңлатмалы сүзлегендә *gez* «кәз; үк кизе» сүзенең «асылы фарсыча» диелә (TS: 419). Безнеңчә – төп төрки сүз. К. **Киз.**

**КӘЗ II: кәз-кәз басу (йөрү, атлау)** «размеренно и быстро шагать»; чаг. каз. *қаз-қаз басу* id. **Каз** сүзеннәнме? Чаг **киз-киз.**

**КӘЗӘКИ, кәзәкин** «казакин, вид полукафтана» ~ каз. *кәзәкей, кәжекей* «камзул» < рус. *казак, казаки, казакин* < иске тат. < фар. *казакый, казакыйн* «казак (гаскәри, солдат) киеме», ди К. Дмитриев (1962: 535), к. иске тат. (Фукс 1844: 287) *қазақ,* төр. *kazak* «жилет; кыска җиңле камзул». **Казакин** сүзе (җирле фонетик вариантларда) ним., фр., ит. телләрендә дә очрый (төр. теленнән таралган булса кирәк).

**Кәзәкин** сүзенең бүтән чыганагы да булуы (контаминация) ихтимал, к. иске фар. (к. Очерки истории культуры средневекового Ирана: 224) *қазāганд* «яугир фуфайкасы».

Шунысы кызыклы, бу «казак киеме» казакларның үзләренә (к. ҚТДС: 244) *кәжекей, кәзекей* яңгырашында кайткан.

**КӘЗӘЛЕК I** (ЗДС: 284), иске әд. **кәзалик** «и так далее, и тому подобное; паче чаяния; вдруг» < төр. *kezalik, keza* < гар. *кäẕā* (*кä* «нәкъ үзе; кебек, шикелле», *ẕā, ẕāлик* «шул). К. ш. ук иске әд. *һәкяза* «һәм башкалар» < гар. *һакäẕā* «менә шуның кебекләр».

**КӘЗӘЛЕК II, кәҗәлек, кәҗәнлек, кәзәллек** (ЗДС: 284) «маленькая комната в сенях или под полом сеней» – **кәҗә** (к.) сүзеннән, ләкин **кәзәнке** сүзе тәэсирендә халык этимологиясе буенча ясалган (кәҗә бәтиләре тотыла торган урын, дип уйланылган). Кызыклы мисал. Татарның «үз сүзе».

**КӘЗӘНКЕ**, диал. **кәзәнкә, каз′ун′ка, кәзүңкә, кизәңке** һ.б. «голбец, запечек» (ТТДС I: 226, 267; ЗДС: 304–305) ~ удм. диал. (Кельмаков 1977: 54) *каз'онка* «небольшие полати за печкой», мар. *казаньга*, чув. диал. *кесеҫке*, башк. диал. (БҺҺ II: 99, 121) *казанка, кәзәңке, кәҗинкә, кәзүнкә* «кәзәнке» < рус. диал. *казёнка* id. **казна** сүзеннән ясалган (**казна** исә төрки-тат.).

**КӘЗБЕРӘ** «каперсы (растение)» < рус. диал., иске рус. *каперзы, каперцы* сүзеннән булса кирәк (*кезберә* < *кәберзә*). Чыгышы белән грек сүзе.

**КӘЗЛЕК** «небольшой кинжал, стилет» < бор. төрки *käzlik* > фар. *gazlik,* гар. *кäзлик* id. ~ каз., к.-балк. *кезлик*, алт., тув. *кестик* «ук **киз**ен (к. **Кәз, Киз**) киртү өчен махсус пәке», аңа мистик әһәмият биргәннәр – ул мәргәнлек иңдерә дип уйлаганнар. Кайнешкә «җизни пәкесе» – кәзлек бирү шуның белән аңлатыла. Doerfer IV: 3–4. Тат. «Бүз егет» дастанында шундый пәке тасвирлана.

**КӘЙ, кәйе, кәйә** (ТТДС I: 267; БТДҺ: 169–170) «плохой, неважный; запоздалый (о хлебах); отава (трава, выросшая на поле жатвы или на лугу после выкоса)» ~ мар. (Саваткова: 51) *кӓй, кай,* чув. (Ашмарин VI: 5–10) *кай* «арт як, арткы; тискәре; начар, кәй; көнбатыш» < бор. төрки (ДТС: 292–303) *kej, keδ, ked, ket, kes* «арт; азак; нигез; көчле, тернәкле; шәп; бик тә». **Кәй** сүзе тат.-башк. сөйләшләрендә киң таралган булса да, тат. әд. теленә үтеп кермәгән диярлек (ул тик XVI г. шагыйре Максудидә һәм Г. Кандалыйда очраштыргалый: *эшләрем булды кәй генә…*), чөнки традицион әд. яз. телдә һәм бүтән кыпч. һ.б. төрки телләрдә ул бик сирәк очрый. Бары тик чув. телендә генә бу сүз актив һәм анда *кай* «артта калган, начар» сүзеннән юн. килеш формасы *кайа* «артка, соңгы; яшьрәк; арзанрак» сүзе – шуннан мар. (Иванов, Тужаров: 76; Исанбаев 1978: 18; Саваткова: 51) *кӓйа* «кәлшә», *кӓйе* «начар үскән иген» – аерымлана. К. ш. ук чув. *кайаш* < **кәйәсе* «калдык; ашлыкның начар, китек һ.б.ш. бөртеклесе».

Идел-Урал регионыннан тыш, *кәй ~ кәд ~ кәз* сүзенең инструменталь килеш формасы – тат. (Тумашева 1992: 93) **кәйен** < уйг. *кәйин*, каз., к.-калп., үзб. *кейин,* иске төрки, чыгт. *кәдин*, алт. диал. *кэзин*, хак. *кизĕн* «соңгы, соңыннан; көнбатыш» киң кулланыла, к. ЭСТЯ V: 23 (тат. **кәй, кәйен** сүзләре искә дә алынмый). Монг. *gädä* «артка» төрки *kädä* id. сүзеннән бугай. Чаг. **Кит: киткә китү.**

Тат. һәм башк. телләрендә *кәй* сүзенең фигыль коррелянты *кәй-ү* «артта калу» да булган, шуннан тат. диал. **кәйек-ү,** башк. *кәйек* «коелган ашлык шытымы», *кәйе-ү* «начарлану; маемлау (ашаганың кире килү)» сүзе ясалган (*кәй-ү*нең интенсивлык дәрәҗәсе). К. ш. ук Räsänen 1969: 246; Федотов II: 211.

Бу авторлар чув. *кай* сүзен дә «ниндидер» (тат. теле искә алынмый) төрки телдән алынма дип икърар итә. Күрелгәнчә, **кәй** һәм **кәй-ү** (к. ЗДС: 285) «начарлану», **кәйек** һәм **кәйек-ү** сүзләре тат. телендә генә киң тамырдашлар системасын тәшкил итәләр. Бу факт һәм мәзкүр сүзләрнең игенчелек терминологиясенә каравы татарларның бабалары Идел-Урал регионына болгарлардан элек үк килеп утрак игенчелек белән шөгыльләнә башлавына дәлил.

Дерив.: **кәйлек; кәйлән-ү,** диал. **кәйәр-ү, кәйек-ү, кәйе-ү** һ.б.ш., к. ЗДС: 285. К. **Кәҗе, Киен, Кире.**

**КӘЙЛӘ** «кайло, кирка» > удм. диал., мар. диал. *кäйла* «китмән» ~ каз. *қайла* «казыгыч», бор. тат. (Мөхәммәдьярда) *хәел* «кәйлә». Төрки сүз булса кирәк, рус. *кайло* (-*ло* халык этимологиясе буенча), *кайла* < тат.

**КӘЙПЕР, кәпер** (ЗДС: 290) «маленькая полукруглая стамеска; маленький совок» < фар. (Будагов II: 172) *кейпур* «махсус киң сөңге яки ук башагы» > рус. *кибирчатая стрела, кибирь* «киң һәм тишекле ук (очканда сызгыра)». Тарихта атаклы «сызгыра торган уклар» шулдыр. Рус сүзе тур. к. Аникин: 286 (бу автор сүзнең этимологиясен белмәгән). К. ш. ук алт. (Будагов I: 31) *кайбур* «ук очы; җәенке очлы ук»; күч. мәгъ. «чуртан».

**КӘЙТӘН** «декоративный шнур, гайтан» < төр. *gaytan, kaytan* < грек. *γαϊτανι*, лат. *gaitanum* id. *Cajeta* шәһәре исеменнән дип уйланыла (Преображенский I: 116); рус. *гайтан* төр. теленнән булса кирәк, төрле фаразлар тур. к. Фасмер I: 384; П.В. Ернштедтның «О греческом предшественнике слова гайтан // Акад. Виноградову к его шестидесятилетию» (М., 1956: 131–136) мәкаләсендә *гайтан* лат. *gaditane* «Гадес шәһәреннән» диелә.

**КӘКӘЙ, кәкәч, кәк** «нечто грязное, кака» ~ мар., чув. *какка* id. **мәмәй, мәмәч**кә каршы куела. Чаг. бор. төрки (ДТС: 422) *qaqač*, рус., укр. *как, какай*, төр. *kaka* «нәҗес, тизәк» һ.б. күп телләрдә бар. Фасмер II: 162–163; Федотов II: 213; Аникин: 237.

**КӘКЕЛ, кәгәл, кәкәл ~ кикел** (ТТДС I: 227; Тумашева: 93; БТДҺ: 142), миш. **кякюл,** добр. (ш. ук миш. булса кирәк) *kyakyül* «пучок волос, оставляемый нетронутым на макушке у мужчин – хохол, оселёдок», а также «чёлка лошади; кисть на шапке» һ.б. ~ нуг., каз., к.-калп. *кекил,* аз. (АДДЛ: 254–255) *кәкил,* к.-балк. *кекел,* кырг. *көкүл* һәм *кaкыл,* төр. *kâkül,* уйг. *көкүлә,* үзб. *қоқил* һәм *қоқул* ~ як. *көгүл, көгүл,* монг. *kökül, гөхәл, хөхөл* (>> рус. *хохол*), тунг. *кэкэл,* маньч. *кукулу* id. һ.б. фар. *kâkul, kâgul, каһкул* id. сүзеннән дип исәпләнә, к. Özön: 416. Ләкин **қакул** (к.) һәм *қ*га башланган бүтән вариантлар булуы бу сүзнең нәкъ фарсычадан таралуына шикләнергә мәҗбүр итә. К. ш. ук Räsänen 1969: 247.

**Кикел** вариантыннан *кикеләк* > *кикерик* «әтәчнең башында күпереп торган кызыл үсенте» сүзе килсә кирәк, к. **Кикрик.**

**КӘКЕЛДӘ-Ү, тәкелдә-ү** «бессмысленно поддакивать». Русчалатып «а как же, тәк-тәк» дип торудан булса кирәк, К. ш. ук рус. диал. *дак-дак, дык, дык-дык* һ.б. ш. ук мәгъ. К. **Дек.**

**КӘКРЕ, кәкере, кәкер** «кривой; крюк» ~ чув. *какăр, каккăр* id., ш. ук «мөгез», мар. *кагыр* «кәкре, кәкре урын», к. ш. ук тат. *кәкер, кәкрә* > удм. *кекер* «ярымайсыман күмәч» ~ иске уйг. *кәкрү* «кәкре», уйг. *кәңри*, кар. *кәгрә* id., госм. *кәкрәй-* «кәкрәю» һ.б. (гомумән бу сүз төрки телләрдә сирәк очрый) һ.б. ономопоэтик *кәк, қақ* «кәкре, кәкрелек» тамырыннан. Бу тамырдан тагы тат. диал. (ЗДС: 286) **кәкчек** «бөкрәйгән», **кәкәш** «кәкре», мар. *какак, кагак* «ыргак», *какляка* «бөгелгән, кәкре, хәйләкәр», госм. *кäкä,* бор. монг. *үаүа* «ыргак» ~ чув. *кукăр* «кәкре» һ.б. ясалганнар. Räsänen 1969: 248.

Китерелгән һ.б.ш. лексик материалны төзек системага салу кыен. Ихтимал, *кәкер* – исем (к. диал. **кәкерчек** «чәкүшкә»), ә *кәкере* > *кәкре* сыйфат (< **кәкир-иг* ?) булуы шәйләнәдер. Федотов I: 303. К. **Кәкерә.**

**КӘКЕРӘ, кәкрә** (ЗДС: 286–287) «обувь с изогнутым кверху носом; старая обувь», **кәкерәч, кәкереч** «что-либо изогнутое; крюк», **кәкермәч, кәкермәц** «что-либо сильно изогнутое» (**-мач//-мәч** аффиксы ярдәмендә ясалган, чаг. **тәгәрмәч**). Бу сүзләрнең охшашлары мар., чув. телләрендә табыла. Рясянен (Räsänen 1969: 248) бу сүзгә фин. *käyrä,* карел. *kägrä* «кәкре» параллелен китерә. К. түбәндәгеләрне.

**КӘКЕРИ** (ТТДС I: 267) «кривой пирог (сваренный в воде)» ← **кәкер.** К. **Кәкре.**

Дерив.: **кәкери-чөкери, кәкер-чөкер** (ТТДС I: 249) «остатки еды, хлеба и т.п.» (которые давали жениху для испытания), к. **Чөкер.**

**КӘКЕРЧЕК, кәкерчәк** «деталь с изогнутой головкой; чека, чекушка» ~ башк. *кәкерсәк* «зигзаг, Z хәрефен хәтерләткән нәрсә» һ.б. Тат., башк. **кәкрешкә** «торба бөгелеше, фитинг»; күч. «бөкре; бөкре кеше» һ.б., чув. *кукăр, куккăр* «кәкре нәрсә, кәкрешкә» һ.б.ш. нигездән ясалган сүзләр. Гом. төрки параллельләре табылмый. К. югарыдагыларны.

**КӘКИ, кәкәй** (ЗДС: 285) «мясо; жареное мясо, котлета» ~ чув. *какай, каккай*, мар. *кага, кагай, кӓгӓй* id. ~ монг., бур. *гахай*, яз. монг. *γaхai,* тув. *қағай* «дуңгыз, чучка; дуңгыз ите», рус. диал. (Аникин: 164, 174) *гахай, гухай* «дуңгыз, чучка» (күбесенчә сүгенү сүзе) ниндидер бор. чыганактан. Чаг. **Кәкәй.** Федотов II: 213.

**КӘККҮК**, диал. **күке,** (ДС III: 89) **кукы,** (м.-кар.) **куку**, (ДС I: 97) **кукук, куккук** «кукушка» ~ чув. *кукку, куккук*, мар., морд. *куку*, мар. *кукӧ* һ.б. id. – барча телләрдә диярлек бу кошның характерлы авазына тәкълидән ясала торган сүз, к. Абаев I: 104. Бу сүзнең себ. **кәwек** варианты алт., хак. телләрендә дә очрый. ССТМЯ I: 426.

**Кәк-күк** имитатив буларак та кулланыла.

**КӘКЛЕК** «жареный цыплёнок» к. **Киклек.**

**КӘКРЕШКӘ** «сгиб трубы, фитинг; деревянный крюк» ~ чув. *какрашка, кукрашка* id. К. **Кәкерчек.**

**КӘКТӘ** (Будагов II: 131; Тумашева 1992: 93) «меховые носки, обычно из собачьей шкуры» ~ рус. *кяхта* «тире ыштыр» – Монголия чигендәге **Кяхта** каласы исеменнән. Бу топоним исә монг. *хиагтай* «кыяклы» сүзеннән, к. Аникин: 346 (тиешле әдәбият китерелә). К. **Кыяк.**

Тат. сәүдәгәрләре Себердә шактый актив булганнар. Әлеге сүз аларның теленнән таралган.

**КӘК-Ү, как-у** (ЗДС: 266) «немножко выпить спиртное» – *кагу* сүзеннән булса кирәк. К. **Как-у.**

**КӘЛӘВӘ, талкыш кәләвә** «коржик; халва» ~ үзб. *калава*, осет. *kölwa* һ.б. id., к. **Хәлвә.** Абаев I: 625.

**КӘЛӘКӘЙ** диал. (Ә. Фәйзи) «недотёпа (в сатире на плохого литератора)», «с трудом говорящий» ~ алт. *келегей*, яз. монг. *kelegei* > як. *кэлэгэй* id. Ихтимал, монг. *кэлэгүй* «телсез» сүзеннәндер. Räsänen 1969: 248. Рус. *калыгей, кылыгей* «сакау» тур. Аникин: 342.

**КӘЛАМ** «словеса», **кәләм** «словечко, обращение», **кәлимә** «одно слово, выражение»; **Кәлямулла** «слово божье, Коран» – бу тамырдаш гар. сүзләр (← *клм* «сөйләү, әйтү»дән) элекке әд. яз. телдә генә түгел, фольклорда да киң кулланылган, мәс., хат башында «Сәлам, сәлам соңында кәлам» дип язганнар.

Рус. *галиматья* «кеше ышанмастай сүз-хәбәрләр» < гар. *кӓлимāт* «юк-бар сүз» дигән фикер бар, к. Фасмер II: 386–387.

К. ш. ук **Кәлимә.**

**КӘЛӘ-МӘЛӘ, кәллә-мәллә: кәлә-мәлә сөйләшү** (Н. Исәнбәт) «говорить между собой так, что постороннему непонятно, хотя слова вроде знакомые» – «аңлашылмаган телдә яисә әңгәмәдәшләр үзләре генә аңлаган мәгънәләрдәге сүзләр ярдәмендә чит кеше алдында сөйләшү». Бу сүз болг. теленнән калган булса кирәк, к. чув. *кайла-майла калаҫма* «артлы-аллы сөйләшү», ягъни «мәсьәләнең төрле ягын карап фикерләшү» – монда *кайла* «арттан», *майла* «алдан». Чаг. тат. сөйл. **килделе-киттеле** (сөйләшү) «аныксыз, төгәллексез, эзлексез».

Монда тат. диал. **кәлә-ү** ~ чув. *кала-* «сөйләү, әйтү» белән охшашлык контаминацион характерда.

Рус. *каля-маля, калякать, каляки* (к. Даль) сүзләре дә болгар һәм чуваш теленнән алынган нигезләрдән ясалганнар (*каля* < *кайла* бер сүз, *калякать* фигыленең нигезе исә бөтенләй икенче сүз).

Карап-тыңлап торучылар аңламаган телдә ике (үз һәм чит) кеше сөйләшүен соңыннан аңлатуга корылган анекдотлар Шәрыктә күптән популяр, бигрәк тә Хуҗа Насретдин турындагылар.

**КӘЛӘП** диал. «моток ниток в ткачестве» (к. **Киләп**) ~ гом. кыпч. *келеп* [*кәләп*] id. < фар., төр. *keleb* (госм., аз. *кӓлӓп*) < фар. *кӓлӓбӓ.* Бу сүз төрки һ.б. күрше телләрдә киң таралган, к. башк. *кәләп* id., (БТДҺ: 172) *кәләбә* «дебеткә катланган җеп», чыгт. *kelebe* «әвернә», кр.-тат. *kelebe* «кое чыгыры (< чыгырга уралган аркан)», хәз. таҗ. *калоба,* ягн. (ЯТ: 272) *kilopa* «киләп, урама» һ.б. Räsänen 1969: 249.

**КӘЛӘПҮШ** «тюбетейка, ермолка» > чув. (Сергеев 1968: 30) *келеннуç, келептуç* id. < фар.-таҗ. *кӓллӓпуш* «баш каплавычы» сүзеннән (*кӓллӓ* «баш», к. **Кәллә,** *-пуш* «каплавыч» мәгъ., чаг. төр. *serpuş* «кәләпүш» – *ser* «баш» (ш. ук фарсычадан).

Дерив.: **кәләпүшле, кәләпүшсез; кәләпүшлек; кәләпүшче.**

**КӘЛӘЧЕ** («Җәмигъ әл-хикәят» телендә) «словечко; беседа, разговор» < чыгт., урта төрки (к. Боровков 1963: 170) *кӓлӓчі*, бор. төрки (ДТС: 296) *kälӓčü* > кырг. *келече,* төркм. *кележи, гележи* id. Тат. сүзе, иске тат. *кәлә-ү* < бор. төрки *кәлә-* > чув., мар. *кала-* «сөйләү» сүзеннән, тик ясалышы аңлашылмый. Бор. уйг. һәм монг., тунг. телләрендә *кәлә-* «сөйләү» белән беррәттән *кәлә*$^{н}$ «сүз» сүзе дә булган (к. ССТМЯ II: 447), шуннан **кәләчүк* ~ **кәләчик* «сүзчек» сүзе ясала ала, ләкин нишләп ауслаут *-к* югалган соң?

Кр.-тат., к.-балк. *келечи*, ком. *гэлэчи* ~ бор. монг. *keleči* «илче, аңлатучы; башкода» мәгъ. кулланыла, ул *кәлә-* ~ ком. *гелеш-* «кыз ярәшү» сүзеннән һәм бу хәл аңлаешлырак – бор. төрки телләрдә *-чы//-чи* аффиксы фигыль нигезенә дә ялгана алган һәм, өстәвенә, элеге *кәлә*$^{н}$ «сүз» нигезеннән дә *кәләнчи* сүзе бик җиңел ясала. Чаг. хәз. монг. *хэл* «тел; сөйләү» → *хэллэ-, хэлэ-* «сөйләү, аңлату», бур. *хэлэшэ* – «хәбәр итү». К. ш. ук иске тат. (Будагов II: 133) *кәләгүче*, бор. төрки (ДТС: 296) *kelemeči*, уйг. *кәләмәчи* «тылмач, комментатор».

Мәзкүр сүзләр рус теленә дә кергән: *киличеи, киличии* «илче, кәләче» (1362 елда теркәлгән, к. Фасмер II: 232), рус. сөйл. *калякать* «начар аңлашып, юк-барны сөйләү» < чув. *кала-* «сөйләү». К. **Кәләш, Кел.** ЭСТЯ V: 32–33 (**келечи** матдәсе; тат. теле материалы файдаланылмаган диярлек). Федотов I: 214–215 (*кала-* матдәсе, тат. сүзләрен бөтенләй искә алмый).

**КӘЛӘШ** «невеста; молодая жена» > мар. *кӓлӓш* id. **кәләшле, *кәләшүле* «сговорённая» сүзеннән (рус сүзенең семантик структурасына игътибар!) эллипсис, иске тат. *кәләш-ү* «сөйләшү, кодалау» фигыленнән. К. кар. *келяшмяк, келяштирмяк* «ярәшмәк, ярәштермәк», *келяшмиш* (ком. *гелешмиш*) «кәләш», чув. *калаçтар-* «кодалау, ярәшү» (<**кәләш-тәр-*), ком. *геле-, гелеш-*, к.-балк. *келе-, келеш-* «сөйләшү, ярәшү» (к. **Кәләче**). Räsänen 1969: 249 (аз әйтелә). *Кэлэ-, хэлэ-* «сөйләү» сүзенең «кыз сорату, ярәшү» мәгъ. монг., тунг.-маньч. һәм фин-угор телләрендә дә бар (к. **Кел**).

К. ш. ук морд. *кяляцямс* «димләү; күндерү» < миш. **кәләч-* id. Төр. *keleş* «матур, гүзәл» (кыпч. телләреннән).

**КӘЛҖЕМӘ** «пюре; лепёшки из картошки (ДС II: 123; БҺҺ II: 122); перезимовавший в поле картофель (чем питались в голодные годы)» > мар. *кӓлзмӓ* id. (Исанбаев 1978: 38) – **Кәрчемә** (к.) сүзеннән үзгәреп килеп чыккан.

**КӘЛҖЫГЫР**, диал. **кәлҗигыр** (БҺҺ II: 122–123), **көнҗыгыр** (ТТДС I: 276) «вид ящерицы – воплощение банного духа» (потому что часто встречается в банях) – бор. төрки *kelär* «кәлтә» (ДТС: 296) белән бәйле булса кирәк, к. төркм. *келпесе*, бор. кыпч. (Курышжанов: 141) *келер ~ келез*, *келес*, аз. (АДДЛ: 255), төр. *keler, kiler* – кәлтә төрләре, үзб. (ЎХШЛ: 140) *кәлтәкәләс*, госм. *kärtänkälär* һ.б. ~ калм. *gölwrgə* һ.б. (вариантлары күп) id. Räsänen 1969: 257–259. К. **Кәлтә.**

**КӘЛИ** диал. (прм.) «провал в болоте» (ТТДС I: 268) < рус. диал. (Урал) *киляй* «зур баткыллы саз» < манси *келыг* id.; себ. рус. диал. *каля* «урманда баткылык» < хант. *хале* id. К. Аникин: 244, 281. Тат. сүзе турыдан-туры фин-угор телләреннән дә килергә мөмкин.

**КӘЛИГӘ, кәләгә** (Тумашева 1992: 142), **кал'ага** (< удм. *кал'ага*) «брюква» < рус. диал. *калега, калига, каликка* id. < эстон. *kaalik* id. Фасмер II: 167.

**КӘЛИМӘ** «слово» < гар. *кӓлӣмӓ* id.

**КӘЛИНКӘ** «калитка» (ТТДС I: 268) ~ чув. (Сергеев 1971: 71), *калинкке, каленкке* id. < рус. *калитка* яисә рус. диал. *калинка* сүзеннән, рус. сүзе бор. төрки («Угызнамә»дә) *қалиқа* «капка» < бор. монг. **qaγalinqaj* id. сүзеннән (асылда **калкан** белән бердәй): чаг. хак. диал. *қаалқа* «кәлинкә», алт, (Баскаков 1965: 204) *калыткы* «капка» һ.б. Шулай итеп, **кәлинкә** «безнең сүз».

**КӘЛИТ,** диал. (ЗДС: 300 һ.б.) **керит, керт** «висячий замок» ~ кр.-тат., каз. *келит,* чыгт., үзб. *кәлит,* СС *kilit,* к.-балк. *кирит* id. Кайбер төрки шивәләрдә *килит* «йозак», *кирит* «ачкыч» (күрәсең, *кир-* «керү» сүзенә нисбәтләнгән). Бу сүзләр фар., гар. *килид* сүзе аша яисә бор. Урта Азия греклары теленнән грек. *klets, kleiδion* «йозак» сүзеннән киләләр. Будагов II: 134–135; Räsänen 1969: 271.

**КӘЛКЕТ-Ү, калкыт-у** (прм., лмб., ЗДС: 269, 287–288) «качать (колыбель) сверху вниз» ← **кәлке-* «астан өскә селкенү, тулкыну». К. (шунда ук) **кәлкетмә** «калкавыч», эстр. һ.б. *калкүн* «таган, сикертмә». *Калк-у, калык-у* (к.) сүзе белән бәйләнышы шикле, чөнки к. бор. төрки (ДТС: 296) *kelgin, kelkin* «дулкын, дулкынлану». Аерым нигез бугай.

**КӘЛЛӘ**, диал. **киллә** «голова», (ТТДС I: 268) «тюбетейка» ~ каз., кырг. *келде, кәлдә,* диал. *кәллә* ~ үзб. *кәллә, калла,* төр. *kelle* «баш, баш түбәсе», гаг. *келлä* «баш сөяге» ~ фар. *калле, кäлле* «баш». Шәрык телләрендә еш кына очрый. Төп чыгышы безгә мәгълүм түгел. К. **Кәләпүш, Кәлпәк, Кәпәч.**

**КӘЛПӘК** «женская тюбетейка» < фар. *кäллепак* «баш киеме» К. **Калфак, Калпак, Кәпәч.**

**КӘЛТӘ**, диал. **кәлтә йылан, кәлтә кисәртке** (к. Радлов II: 1121) «ящерица» ~ төр. *kelten, keltenkeler* (< *kelten keler*), үзб. *кәлтә, кәлтәкесак,* (ЎХШЛ: 140) *кәлтикәлас, кәлтәкәләс* һ.б. id. Бу сүзләрдә (ш. ук тат. диал.) *кәлтә* «кыска, китек», икенче компонент *кәләр > кәләз > кәләс* «кәлтә, сөйрәлүче хайван» мәгъ. сүз. К. ш. ук башк. *кәлтәкәй* «кәлтә» < *кәлтә қай*: *қай* < угыз телләрендә *қайы* «елан».

**Кәлтә** «кыска», башк. «кырт җимерелгән яр» ~ каз., кырг., уйг. *келте, кәлтә,* чыгт. *кäлтä* > фар., көрд. *кäлтä* «кырт киселгән; көтек» *кäлт-* «кырт кисү, китеп алу» фигыленнән (хәл фигыль яисә бор. **кәлтәг* формасыннан), к. ш. ук монг. *хэлт* «ярты, кисек, китек», эвенк. һ.б. тунг. *калта* «ярылу, кыркылу, кителү, киселү», *калта* «ярты, өзек» (к. **Кит-ү II**). Мар. диал. *кäлтä* «кәлтә» < тат. К. **Кәлтәү.** Будагов II: 133–134; Räsänen 1969: 249; Федотов I: 218; ЭСТЯ V: 34 (чув. *калта* «кәлтә» татарчадан диелә, ләкин *кәлтә* «кыска» сүзе фар. теленә нисбәт ителә). К. **Кәлҗыгыр.**

**КӘЛТӘҮ** диал., (ТТДС I: 268, 269; БҺҺ II: 123) **кәлтәр, кәлтер, кәлүтәр** «дёрн, кусок дернины; торфяной кирпич» > мар. (Исанбаев 1978: 26) *кäлтäу* «торф» ← **кәлт-* «китеп алу» сүзеннән, к. **Кәлтә. Кәлүтәр** варианты **кәлтүәр* < **кәлтәwер* вариантыннан булса кирәк (чаг. **Янтавыр**).

**КӘЛЧӘК** «чехонь; сорога, плотва» ~ чув. *кăлчак* «подлешник» диелә, мар. *кыльчак,* коми. *келчи*, лив. *koltak* (КЭСК: 121) «кәлчәк» ~ тунг.-маньч. *кэлтэгэ, кэлтэкэ*, яз. монг. *keltege* «кәрәкә» (ССТМЯ I: 447). Кайбер балык атамаларының киң таралуы аларның сәүдә яисә запас шәй булуы белән аңлатыла.

**КӘЛШӘ** «всходы; отава; рассада; несозревшие хлеба; зелёный стебель злаков; хлеба, скошенные (для корма скоту) в зелёном виде; с коротким стеблем (о сортах злаков)» (ТТДС I: 268–269) ~ иске тат. **кальша** «курпы» (к. Будагов II: 22), башк. *кәлсә* «кылган; чирәм», чув. *калча*, удм. *кальча* «шытым, уҗым; камыл, яшь сабак», удм. *кальча сэзы* «өлгермәгән солы» мисаллары төп вариант **кәлчә** булганлыгын күрсәтә. Н. Поппе бу Идел-Урал регионы сүзен госм. *kölčä* «чүп үлән» белән чагыштыра (к. UAJ VI, 1927: 165), ләкин араларның ераклыгы һәм мәгънәләрнең дә бигүк тәңгәлләшмәве бу версияне кире кагарга мәҗбүр итә. Безнеңчә, *кәлчә* < *кәлтә* «кыска, киселгән» (чаг. себ. **кәлцә** «кәлтә», к. Тумашева 1992: 94) була ала. Ләкин бу версия дә *кәлшә* сүзенең барлык мәгъ. аңлатып бетерми. Ихтимал ки, *кәлчә* < **кәйелчә,* ягъни **кәйел* < *кәйен* «соңыннан үсеп чыккан» сүзеннәндер, к. **Кәй, Кәнеҗ, Кинҗә.**

**КӘМ** диал. «меньше; меньший, незначительный» ~ башк. id., к. **Ким.**

Дерив.: **кәмәй-ү** (**ким** вариантында моның тәңгәле юк); **кәмәйт-ү; кәме-ү; кәмсен-ү, кәмсет-ү** һ.б. (нишләптер тат. диал. сүзлекләрдә күрсәтелмиләр). Рясянен як. *кэмсин-* «үкенү» сүзен аерым матдә итеп аңлата, һәм монг. *gemsi-* «үзен гаепле итеп карау» ← *gem* «авыру» ди. Räsänen 1969: 250.

**КӘМАНЧА** «гитара, скрипка (восточного типа)» < төр. *kemançe* id. *keman* (фар. *keman*) «җәя, кылкубыз» сүзеннән, к. Будагов II: 136; Redhouse: 625. К. ш. ук уйг. *кәманчә* «сызма», добр. тат. *getane* id.

**КӘМӘ,** диал. **кәмәшәй** ~ **кәмәчәй** «небольшая лодка» (**кәмә** сүзе **кимә** вариантыннан мәгънәсе белән дә аерымлана) ~ гом. кыпч. *кеме* [*кэмэ*], алт. *кебе, kebe, keme,* тув., монг. *хеме* [*хэмэ*] «кәмә; кимә», үзенчәлекле вариантлар: бор. төрки (Боровков: 17) *кäми,* төр. *gemi,* төркм. (Мухамедова 1973: 121) *гәәми, кәәме* «кәрап».

Алт. һ.б. кайбер телләрдә *кеме* белән рәттән *гебе, геме, кеме, кебе, кибе, кӧбӧ, кемеге, кӧбӧгӧ* «мич» сүзе бирелә. Бу очраклы түгел – бор. мичнең бер төре кәмәдән ясалган, к. **Кәмәгәч, Кимә, Кимәшә, Көймә, Комага.** Räsänen 1969: 250.

Икенче яктан **кәмәчә ~ кимәчә,** башк. *кәмәшәү ~ кимәшәү* дип атта, дөядә барган балалар өчен улаксыман озынча бишекне дә атаганнар. Шулай итеп, тат.-башк. даирәсендә бер тамырдан алты этимологик дублет бар.

*Кәмә ~ кимә ~ көймә* сүзенең дериватлары, янгырашлары күп һәм мәгънә спектры киң булуга карамастан, этимологиясе әле һаман томанлы. Тикшеренүчеләр *кәмә ~ кимә, кәмәчә ~ кимәчә* сүзләренең уртак нигездән икәнлегенә инанган хәлдә, кайсы мәгънә – суда йөзү транспортымы, әллә зур учакмы – беренчел булуы мәсьәләсендә төрлечә уйлыйлар. Хикмәт шунда: элек көймәләрне юан агач кәүсәләрен бер тарафыннан әкренләп яндыру ысулы белән ясаганнар. Агач кәүсәсен вертикаль хәлендә үк янтыктан яндырып, соңрак кына өстән һәм астан кистергәннәр. Янып утырган кәүсә күмәч пешерергә мич ролен дә үти алган. К. түбәндәгене.

**КӘМӘГӘЧ, кимәгә, күмегәч** (ЗДС: 288, 310, 353) «малая камера татарской печи; тандыр» ~ кырг. *кемеге*, алт. *кебе*, *кебеге,* хак. *кимеге* «ачык җиргә, тышка куелган һәм еш кына балчык белән сыланган кимәдән гыйбарәт мич төре» ← *кеме* «кимә», к. Потапов 1953: 157; Räsänen 1969: 250.

Бу сүзнең *кәмәгә* варианты да булган, к. **Комага**. Гомумән, татарларның аерым этник группаларында мичләр төрлечә ясалган. К. **Кәмә.**

**КӘМӘР I** «украшенный пояс (военного чина, жениха, невесты)» > чув. диал. *кемер* < төр. < фар. *камар, кәмәр* «билбау, билдәк, билдәмә; җәя; гөмбәз; диадема; акведук; бию төре» < авест. *katara*, санск. *katar* id. Platts: 848; Будагов II: 137. К. **Кимәшә.**

**КӘМӘР II,** диал. **кимәр** «подмытый водой (так, что образован свод) берег реки» ~ каз., кырг. *кемер* «текә яр, кәмәр; калкулыкның текә янтыгы», кр.-тат. (Dobr. II: 265) *kemer* «биек-биек түмгәкле җир». Бу сүзне Юдахин, Будаговка нигезләнеп, фар. сүзе ди (чынлап та, фар. телендә *кäмäр* «áрка; дуга»). К. ш. ук төр. *kemer* «бөкрелек; уелты»; «áрканың түгәрәк өсте». Госм., аз. *kämär* «кәмәр» сүзен Рясянен грек. *καμαρα* «бөкре, бөкрелек» сүзеннән дип карый. Будагов II: 137; Räsänen 1969: 251.

Шунысы кызыклы ки, барча сүзлекләрдә диярлек **кәмәр I** һәм **кәмәр II** берләштерелеп, бер матдәдә бирелә. Без, монда ике сүз бардыр, дибез.

**КӘМӘШ** (Г. Толымбай) «нечто – подобие чего-либо» < болг. **кәмәше* < **кәбәсе* > чув. *капаш [кабаш]* «кәмәш; тышкы күренеш» ← *кап* < болг. **кәп* «форма»? к. **Кебек, Кип. Кәмәш** сүзе Тау ягында гына таралган һәм ул чув. теленнән алынма булырга да мөмкин. Федотов I: 225.

Чаг. ш. ук гар. *кäма äш-шäй* «әйбернең охшашы».

**КӘМЕР** (ТТДС II: 195; БТДҺ: 172) «порошок-отбеливатель холста» < иске тат. *кәбер, кәпер* < гар. *кафур* «камфара». Гомумән, бу сүз бор. һинд телләрдән, к. Фасмер II: 176.

**КӘМИТ** «представление, шуточный спектакль; чудак, клоун» ~ чув., удм. *камит,* мар. *кäмет* < рус. диал. *камидь, камедь* < пол. *komedia* < лат. *comoedia* < грек. *κυμψδια* «комедия» (Фасмер II: 306). Федотов II: 220.

**КӘМШӘЙ-Ү** «сдавливаться, скоситься» (ТТДС I: 269), «чувствовать себя малым» (ТРС 1931: 162), соңгы аңлатма дөрес түгел, к. себ. (Тумашева 1992: 94) **кәмшәй-** «авызны кыйшайту» < *кәмешәй-:* себ. *кәмеш, кәмшек* «кыйшый, изелгән; кимерек» ← **кәм-, *кәб-* «кимерү; ашалу» фигыленнән. Чаг. як. *кэбий-* «кимерү», *кэбилин-* «кимерелү; бозылу, ашалу, ямьшәю». К. **Кимер-ү, Кимшек, Көйшә-ү.**

**КӘН** диал. (к. Тумашева 1992: 94) «много, масса» < фар. *к'āн* > тат. кит. *кян* «рудник; залежь», к. ш. ук төркм. *кән*, үзб. диал. *кан* «күп; бик, гаять, шактый», к. Будагов II: 110; ЎХШЛ: 138.

**КӘНАР** кит. «берег, побережье» < фар. *кäнāр* id. К. ш. ук диал. **кәнәрә** «кое, шахталарның янтык (стена) ныгытмасы».

**КӘНӘ I** «клещевина, касторная трава» – **кәнә үләне** тәгъбиреннән эллипсис, к. чув. *кана,* каз. *кене,* бор. төрки (Räsänen 1969: 251) *känä,* чыгт. *kännä,* госм. *gene,* төр. *kene* < фар. *кана* «талпан, кандала», чаг. **кандала үләне (уты)** кандалага каршы төрле үләннәр атамасы, к. ТТДС I: 595; Будагов I: 140; Steuerwald: 515. Чаг. **Кәннә.**

**КӘНӘ II, кәна** иск., әд. (Тукай һ.б.) «ещё; к тому же; а также» < бор. төрки («Угызнамә») *kenä* «менә; кәнә»; урта төрки әдәбиятта еш очрый, госм. *гәнә*, төр. *gene*, иске аз. *йәнә* ~ фар. *кепä*. Будагов I: 140; ДТС: 298. Бу сүз ним. *ganz* «бөтенләй» сүзе белән тамырдаш, к. Kluge: 330.

**КӘНӘФИ** «канапе, мягкая мебель, мягкое кресло» < төр. *kenefil, kenepil* id. > аз. *гәнәпә* id.; төр. теленә бу лат. (< грек.) *conopeum, conopium* «чыбылдыклы ятак» сүзеннән (к. Фасмер II: 177); себ. тат. (Тумашева 1992: 105) **кәнәпил, кунапил** id. << лат. *conopium*, ләкин каян бу сүз Себергә ирешкән? Гомумән, лат. сүзе «чебенлек» мәгъ., грек. *konops* «черки, чебен» сүзеннән, к. Kluge: 464–465.

Рус. *канапе́* «кәнәфи» фр. *kanapé* < төр. *kenepil* булса кирәк.

**КӘНӘШ** миш. (ЗДС: 289) «жеребёнок», **кәнәш-кәнәш, кенәш-кенәш** – междометие подзывания жеребёнка < рус. *коняш* id.

**КӘНДИ,** диал. **кандика** (Ахмаров: 21), **қәнди** «чашечка (к. Будагов II: 66); двойная чашка» ~ башк. (к. БҺҺ III: 98) *кәндей* «тилбәрән (мәк һ.б.) орлыгының тартмачыгы» һ.б. > чув. *канти* «кәнди» < фар. *қанди* «шикәрле, шикәрнеке, шикәр савыты» ← *қәнд* > себ. тат. **қәнт** «шикәр» сүзеннән. К. ш. ук умартачылыкта **қанди** «бал кортларына кирәккәндә куела торган ширбәт». К. **Кант.**

**КӘНЕҖ, гәнеҗ** «сокровище; шкатулка с драгоценностями; юный, молодой» < фар. *кäнҗ* id. гар. *кäнҗ* «хәзинә» сүзеннән дип исәпләнә (ТГРС: 224).

**КӘНИЗ** тар. «девушка, барышня на выданье»; «девушка на продажу» төр. < фар. *кäниз* id., к. **Кәнизәк.**

**КӘНИЗӘК**, диал. **кәнизә,** себ. **канисәк** (к. Тумашева 1992: 118) «рабыня-наложница; прислуга знатной женщины» ~ башк. *кәнизә* id. < фар. *кäнизäк, кәнизәк* «кызыкай, кызчык» ~ сугд. *kncyk* «кыз» – фар. *кäниз* (< бор. фар. *kanis*, авест. *kainyā*, санск. *kanya*) «кыз бала» сүзенең кечерәйтү-иркәләү формасы.

**КӘНИКӘ** «принцесса» (к. Радлов. Образцы… IV: 130–132) > диал. **тәнәкә** «младшая принцесса» (Х. Туфан) ~ кырг. *каныкей* id. < монг. *ханкэн, ханкеүн* «хан кызы». к. ш. ук иске тат. **ханәкә, ханикә, ханкәй** (Будагов I: 527–528) «хан затыннан булган хатын-кыз» (бу сүз фольклорда еш очрый, к. «Ханәкә туташ бәете»). К. **Ханәкә I**.

**КӘНИТИЛ** разг. «возня; недопонимание друг друга», диал. (ЗДС: 289) **кәнәтил** «канитель, золотистые и серебристые нитки для вышивания, а также вышивка, узоры из канители». Рус телендә дә *канитель* (< фр.) төп мәгъ. түгел, ә күч. «буталчыклык, аңлашмаучылык» мәгъ. кулланыла, шул мәгъ. тат. телендә киң таралган.

Дерив.: **кәнитилле** (эш, хәл, шөгыль); **кәнитилләү** (бизәү), **кәнитилләнү** «маташу».

**КӘННӘ** (Башкортстан) «дренажный канал, дренажная канава» ~ чув. *канна* id. (чув. телендә киңрәк билгеле) халыкара киң таралган, к. бер яктан гар. *кäннäт* «кәннә, камышлык» > лат. *canna,* грек. *kanna* «канау; көпшә; камышлык», икенче яктан ит. *canale* «көпшә, канау, су агымы» >> рус. *канал* һ.б. (күп телләрдә таралган), төп чыганагы бор. Мисыр теле диләр, Шул ук сүзгә *канон* «пушка; туп», *канонада* «күп туплардан ату» сүзе тоташа. К. Kluge: 464, 466.

**КӘНСӘ** «канцелярия, правление, административное учреждение» < **кәнсәләр (< канцелярия)** сүзен халыкча аңлаудан килеп чыккан. **Кәнсә** сүзе шактый киң таралган (к. Гайнетдинов М. XVIII йөздә татар яңарыш хәрәкәте. КУ, 1992, № 7–8) һәм хәтта кардәш вә күрше телләргә дә таралган: үзб. *кенгса* «контора» (ҮХШЛ: 145). Тимергалин: 239.

Рус. *канцелярия* < лат. *cancellarius* «рәшәткә, барьер» сүзеннән.

**КӘНТ, кәнде, кәндә** диал. «точь-в-точь» ~ төр., аз., төркм. *кенди, кенды, кәндү, кәндүси* (> к.-балк. *кенси, кеси*) «үзе» ~ як. *кини, киэнэ* «ул, шул, үзе», *киэнэ* «аныкы; аның; үзенеке», бор. төрки *кәнт, кинт* «үзәк» сүзеннән (шуннан ук к. **Кендек**), к. Убрятова: 279–292. Räsänen 1969: 252 (бор. монг. *gendün* белән чагыштыра).

Тат., башк. (ТТДС I: 268; БТДҺ: 172–173) **кәлдә, кәллә, кәлле** «кәнт, нәкъ» < *кәнтләй*. Чаг. төр. *kendigelen* «кинәт (үзе килгән)», *kendilik* «үзенчәлек» һ.б.

Фар.-таҗ. *канд, кэнд* «үзгенәсе» төрки телләрдән булса кирәк.

**КӘНТӘЙ** «сука» < бор. **кәнтәг* булса кирәк, к. каз., кырг. *канден, кандель, кандек* «кечкенә гәүдәле эт токымы» – ***кән****//кан* «эт» тамырыннан (к. ЭСТЯ V: 255–256), к. бор. монг. *gani, kani* «эт», *kačikan* «көчек»; к. тат. диал. (ТТДС I: 270) **кәнчек, кәнчәй,** башк. *кәнсек, кәнсәй, кансай* «кәнтәй» < *кәни-чәг//қаничағ* id.

*Кани*, **кану* эт тамыры барча Себер телләрендә очрый: корел., нивх. *кан, кани*, хант.-манси *канак*

«эт» һ.б. һәм бу тамыр сүзне һинд-евр. **keuon* «эт, бүре» (шуннан авест. *kuon* «эт», лат. *kuno* «кәнтәй», *canis* «эт», кельт. *kunos*, ним. *Hund* «эт» һ.б., к. Георгиев: 47) сүзе белән чагыштыралар.

Дерив.: **кәнтәйлек, кәнтәйлән-ү** (һәр икесе күч. мәгъ.).

**КӘҢГЕЛ, кәңлек** (ЗДС: 289) «откровенный, добродушный, бесхитростный» ~ алт. *кäңкил* «акыллы шаян». Бу бараба диалекты сүзе, ш. ук уйг. теленә хас булган *кәң* «киң» нигезеннән булса кирәк. Чаг. ш. ук каз. *кәңкел, кеңкіл* «өзек-өзек көлеш», *кеңкілдәу* «өзек-өзек (ямьсез) авазлар белән көлү, көлешү», *кеңкелес* «ахмак шаян». Һәрхәлдә **кәңгел** һәм **кәңгелде** (к.) нигездәш сүзләр дип уйланыла. Башк. (БҺҺ II: 123) *кәңгелдә-ү* «тинтерәү (тинтәкләнү)»? Гомумән, ачык түгел.

**КӘҢГЕЛДЕ** (ЗДС: 289) «вершина, пригорка, где не держится снег». Ихтимал, югарыдагы сүз белән тамырдаштыр. Чаг. ш. ук. **Каңгыл, Кәңгер.**

**КӘҢГЕР** (ЗДС: 289) «высокомерие», **кәңгерле** «высокомерный», **кәңкерәй-ү** «важничать». Ихтимал, төр. («Мөхәммәдия»дә), фар. *кәңгәрә, кәңгирә* «кирмән башнясы» сүзе белән баглыдыр. Чаг. к.-балк. *кеңер-* «үз күңелең басылсын өчен мактану, бүтәннәрне хурлау».

**КӘҢКӘЙ-Ү** (ЗДС: 289) «свалиться набок (о стоге, о домике, о сидящем человеке)» ← **кәңкә* «кыйшайган»? Чаг. чув. *каңк-* «кәкерәеп кату», каз. *кеңки-* «тырпаю, күренергә тырышып утыру», кырг. *кеңги-, кеңгире-* «аптыраштa калу; кыйшаеп утыру», як. *ханкый-* «бер тарафка нык авышу; кәңкәю» һ.б. формасына караганда ниндирер *кәңк, кәңкә* (?) сүзеннән.

Дерив.: **кәңкәеш-ү, кәңкәйт-ү.**

**КӘҢКЕ, кәңки** гади «коньки (для катания)» < рус. *коньки* id., асылда атчыклар (кәңкеләрнең баш өлешендә ат башы сыман фигура ясап куйганнар).

Дерив.: **кәңкиче.** Гомумән бу сүз яз. телдәге *тимераяк* сүзеннән һәр җәһәттән отышлырак.

**КӘҢШЕРЕК** (себ., ЗДС: 289) «твёрдое нёбо; носоглотка» ~ каз. (Будагов II: 411) *кәңсерік* «ноздри у лошади», хәз. каз. сүзлегендә *кеңсірік* «борын кимерчәге; борын куышы». Чаг. **Киңертәк.** Чаг. ш. ук кр.-тат. (Dobr. II: 268) *keñiz,* төр. *geniz* «кәңшерек».

**КӘП I** (себ., ЗДС: 289) «слово; беседа, разговор» < фар. *гäп,* к. **Гәп.**

Дерив.: **кәплән-ү** «төштә, йокыда саташып сөйләнү», **кәплә-ү** «сөйләшү», **кәпләш-ү ~ йәпләш-ү** (ЗДС: 290) «сөйләшү», «(нарасый бала тур.) сөйләшә башлау», **кәпце, кәпцән** «сүзчән» һ.б. К. **Кәпкер.**

**КӘП II** диал. «вместилище; оболочка» ~ кырг. *кеп (кәп)* «форма; маска; кием». Дерив. (ЗДС: 291) **кәпцек** «мешочек». Күп сөйләшләрдә **кәплә-ү, киплә-ү** «тышлау, япкалау, формасына китерү» һ.б.

Бу *кәп ~ кап* тамыр сүзе тат. һәм. гом. төрки лексикада күп тапкырлар очрый һәм гомумән күп телләргә таралган халыкара сүз булса кирәк. К. **Кәбәк ~ кибәк, Кәбән ~ кибән, кәбәнәк ~ кәпәнәк, кәбәрә ~ кәвәрә, кәперән ~ кипрән, кәпәрен-ү, кәпер, кәпле** һ.б.

**КӘПӘЙ, кәппәй** диал. «пустой хвастун» ~ каз. *кеппей.* **Кәп II** тамырыннан булса кирәк.

**КӘПӘР-Ү, кәпәй-ү** (ЗДС: 289) «рисоваться; возгордиться» ~ башк. *кәпәй-* «тәкәбберләнү; кабарыну», чув. *капай-*, *каппай* «мактану» һ.б. бор. *кәп* «(тышкы) форма» сүзеннән. К. ш. ук башк. *кәпәй* ~ чув. *каппай* «мактанчык». К. **Кәп, Кип, Кәпер.**

**КӘПӘЧ** «шапочка; головной убор простейшей формы» > чув. *кеппеç,* башк. *кәпәс* id.; тат. (бигрәк тә себ.) сөйләшләрендә вариантлары күп: **кәбәц, кибәц, кэбэц, кәпәц, кәүәц** (к. Тумашева 1992: 92, 94) < *каләбәц, киләбәц* (Радлов II: 1116; Радлов, Образцы… IV: 286) «кәпәч; хатын-кыз бүреге» ~ искечә *каләбаш*, башк. *каләбәш* (БТДҺ: 172) id. *каләпүш < калләпуш* сүзенең «бозылган» (дөресрәге тат.-башк. вокализмы законнарына буйсындырылган) варианты булса кирәк. Ләкин төр. *kepez* «яр буендагы кыя, текә һәм биек тау; каләш бүреге; әтәч кикриге» һ.б.ш. (Redhouse: 639) икенче төрлерәк аңлатмага да юл куя (< **калләпәз**?, к. фар. диал. *базäк* «җилфердәк; баш киеменә беркетелгән каурый»). К. ш. ук куман. *kepes,* бор. төрки (Räsänen 1969: 254) *käbäc, käbäš* «бүрек».

**КӘПЕР, кәпәр** диал. «вздутый, дутый; пустая оболочка; хвастунишка и т.п.» ~ башк. (БТДҺ: 173) *кәперек* id. > чув. *капăр, капăркка* «купай, көяз, мактанчык» ~ мар. *кавыр* id.; гом. төрки сүз булган, к. алт. *кэбэр, кебер, кебир,* тув. *кевер, кевир* «образ, сурәт, форма, күренеш, кыяфәт» ← *кәп* «форма»

(к. **Кип**). Чаг. ш. ук кырг. *кебек* «бүлтәеп каткан ләм». К. **Кибер II.**

**Кәпер** сүзенең үзеннән активрак деривааты **кәпәрәй-ү > кәпрәй-ү** «шәпләнү, мактану, масаю».

**Кәпер** (исем) белән беррәттән диалекталь сөйләмдә **кәпер-ү, кәпәр-ү** фигыле дә очрый, шуннан актив форма **кәперен-ү, кәпәрен-ү** эд. телгә дә кергән. К. ш. ук **Кәперән, Кәпле, Кипрән.**

**КӘПЕРӘН, кәпрән** «оболочка, наволочка» к. **Кипрән.**

**КӘПИК** сөйл. «копейка» рус теленнән булса кирәк, ләкин к. ком., к.-балк. *кэпэк, кепек*. Аксак Тимер заманында Урта Азиядә *көпэки* «вак акча» сүзе булган (Будагов II: 112). Рус. *копейка* тур. Фасмер II: 317–318 (*копьё* «сөңге» сүзеннән ди; төр. һ.б. *көпäги* һәм рус. *копейка* – очраклы охшашлык кына ди).

**КӘПКЕР** (себ., ЗДС: 290) «словоохотливый»: ике төрле (әмма бер үк тамырдан чыгып) аңлатыла: 1) фар. *гäпгир* «сүз алучан» дигәннән һәм, 2) себ. тат. *-гер*//*-кер* кушымчасы ярдәмендә ясалган *гәпкер* «сүзчән» (к. **Гәп**) сүзеннән.

**КӘПЛӘ-Ү, кипла-ү** (ТТДС I: 247; Тумашева 1992: 95, 99; БҺҺ II: 124) «облицовать; тесно облегать» < гом. кыпч., к. нуг., к.-калп. *кепле-,* каз., кырг. *кепте-* «сүрүгә, кипрәнгә тыгызлап тыгу» ← *кәп*//*кип*, к. **Кип, Кәпсәл-ү.**

**КӘПЛЕ, кәплү** (Тумашева 1992: 95) «наряженный, щеголеватый; в военной и т.п. форме» ~ кырг. *кептүү,* тув. *хэптиг* «зифа; кыяфәтле; купшы» һ.б. ← **кәп//кип**. К. **Кәптәр, Кип.**

Дерив.: **кәплән-ү < кәплелән-ү.**

**КӘПСӘЛ-Ү, кипсәл-ү** (БТДҺ: 173), **кәпшәл-ү** «оставаться в тесноте, в щели и т.п.» ← ***кәпсә-, *кипсә-** ← бор. **кäбиз* «тар форма, тыгызлык» булса кирәк. К. **Кип.**

**КӘПТӘР I** «военная, официальная, парадная форма одежды», шуннан активрак кулланылган дериваты (без теркәдек. – *Р.Ә.*) **кәптәрлә-ү** «доводить до формы, кондиции». Монг. *хэбтэр, кэбтэр* «тиешле форма» **кәп//кип** тамырыннан монг. телендә ясалган булса кирәк.

**КӘПТӘР II** диал. (Тумашева 1992: 95 һ.б.) «голубь» < фар. *кäбӯтäр* id. *кäбуд* «күк» сүзеннән (төптә киресенчә булмаса) > төр. *kebuter* «күгәрчен». Татарларда күгәрчен уйнату киң таралган булган (К. Насыйри бу шөгыльне бушка вакыт уздыру дип махсус язып чыккан), шуннан яшьләрдә **кәптәр** сүзен **кәп** дип кенә кыскартып атау (к. Тумашева 1992: 95) килеп чыккан.

**КӘПЧӘЛЛӘ** (себ., ЗДС: 290) «гвоздодёр» дип аңлатылган, ләкин чынлыкта кр.-тат., төр. *kepçekelle* «эрегән металл белән эш итү (мәс., эретмәнең составын контрольләү) өчен файдаланыла торган озын саплы чүмеч» сүзеннән булса кирәк. Бу сүздә **кәпчә** ~ кр.-тат., төр. *kepçe* «озын саплы тирән чүмеч», **-эллә** < *кәллә* (к. **Кәләпүш**) ~ төр. *kelle* «баш».

**Кәпчә** сүзе (себ. тат. сөйләшләрендә бар бугай) – уйг., үзб., төркм. *кәпчә, капча* һ.б. – тагын «vulva, һәркем түләүсез файдалана ала торган (кол, әрсез, мескен) хатын» мәгъ. – фар. телендә яисә Якын Шәрык төрки телләрендә гар. *кäлб* «эт; кәнтәй; эт авызы» сүзеннән, аңа мәзкүр телләрдә киң кулланышлы *-ча*//*-чә* кушымчасы ялганып ясалган: *кäлбчä* «кечкенә эт, кәнтәйчек»

**КӘР** «забота, дело» ~ башк. «көч; мөмкинлек» < фар. *к'āр* «эш».

Дерив.: **кәрсез** «эшсез, ялкау» (~ мар. диал. *кäрдыме* id. татарчадан ярымкалька), башк. *кәрһеҙ* «ярдәмсез, көчсез». К. **Кяр.**

**КӘРАП**, диал. (к. ТХИ: Әкиятләр I: 262) **кәрәп,** (Радлов, Образцы… IV: 204) **кирәп** «корабль», бор. тат. *хараб* «кимә» (Максудидә *Гизәр икән, күрде анда бер хараб, Ул харабта ултырыр түкмәккә аб [суын түгәргә]*) < чыгт. һ.б. иске эд. телдә *кäраб,* фар. *геряб*, гар. диал. *җерэб* id.; к. ш. ук гар. *кäраб, ғураб* id.; алт. *кäрäп*, монг. *кэрэм* «каек». Бор. заманнарда ук грек теленнән таралган (грек. *karabos* «гади палубалы кимә»). Рус. *корабль* (> тат. сөйл. *карабел*) сүзе турыдан-туры грекчадан, төрки сүзләргә бинисбәтән алынган. К. **Кораб.**

**КӘРӘ, кәрәү** диал. (ТТДС: 27) «сбор средств на проведение праздника сабантуй (мальчиками и девочками)», (ЗДС: 290) «ряженый на праздник (для сбора средств)» ~ каз. *кере* «тулы дистанция, иң зур дистанция (ат чабыштырганда, йөгерешчеләр йөгергәндә һ.б.)».

Ачык түгел. Чаг. каз. (ҚТДС: 154–155) **кереши** < *керечи* «зур (20–30 километрлап) дистанциягә чабышкан атларның йөгерешен (көрчеккә барып жи-

түен, юлда хәрәмләшүләр булмавын һ.б.) тикшереп торучы (шуларның берсе), кайсы ат алдан килүен еpayтан (махсус каланчадан, сыргавылдан) күреп, финишта көтеп торучыларга хәбәр итүче малай». Безнеңчә, сүзнең төбендә нәкъ шул малай атамасы ятарга мөмкин, к. төр. *kerübi* «бәйрәмдә фәрештә булып киенеп, туйда кәләшнең озын арт итәген күтәреп йөрүче бала (малай яисә кызчык һәм малай икәүләп)» < гар. *кәруби, кәруб* ← яһ. *kerub* «шатлыклы хәбәр бирүче, шат җырлаучы фәрештә» (шуннан күп. *kerubim* > грек. *χερουβιμ* > рус. *херувим* «бергәләп җырлаучы фәрештә; фәрештә булып киенгән бала – ул җиңүдән хәбәр китерә»).

**КӘРӘВӘТ, кәрвәт [кәрwәт]** диал. «кроватик, тахта для постельных принадлежностей» – бу сүз **караваt**тан үзгә буларак турыдан-туры кр.-тат., төр. *kerevet, kärävät* id. сүзеннән. К. **Караваt.**

**КӘРӘЗ** «соты» ~ чув. *карас*, мар. *карас, кäрäз, кäрäш*, морд. *кяряст* (Егоров: 114), удм. *карас* id. бор. балтыйк телләреннән, к. латыш. *karis* «кәрәз». К. ш. ук Федотов I: 229.

**КӘРӘКӘ** «карась» > чув., мар., удм. *карака* id. венг. *karika* «густера»; чаг. башк. *кәрәкә* «елганың сазламык тамагы» (кәрәкәнең яраткан урыны, к. Башҡорт диалектологияһы, Өфө, 1963: 182). Рус. *карась* < *кәрәкә* тур. к. Коломиец: 127.

**КӘРӘМӘТ** «чудо святых людей в отличие от *могҗиза* – чуда пророков; чудесное свойство» < гар. *кäрамäт* id., гомумән – «изгелек, юмартлык», к. ТГДС: 224; Тимергалин: 239–240. К. **Кирәмәт.**

**КӘРБӘЗ** «франтоватый; спесивый» ~ башк. *кирбәз*, кырг. *кербез,* үзб. (ЎХШЛ: 145) *керваз*, нуг., каз., к.-калп. *кербаз* < фар. (Будагов II: 121) *кәүрбаз, кәүрбаз, горбаз, җорбаз* «шарлатан, елгыр; күпне күргән, кыршылган» – *кәүр* «кыяфәт, кыланыш» һәм *bāz* «уен, уенчы» сүзләреннән гыйбарәт.

Дерив.: **кәрбәзлек.**

**КӘРБӘН** (Ш. Маннур) «весомый, увесистый; крепкий, зажиточный» ~ чув. *кервен, кеврен* id. < фар. *геранбäһа, геранбäр* «авырлыклы, салмак» < *геран* «авырлык» һәм *бäһа* «бәя» яисә *бäр, бар* «йөкләүче» сүзләреннән.

**КӘРВАН** «караван» ~ гом. кыпч. *кәрүан*, чыгт., төр., аз. *кäрван* һ.б. (к. Räsänen 1969: 257) < фар., гар. *kārwān* id. Иске рус. *карван* кыпч. телләреннән, ә *караван* – Көнб. Европа телләреннән булса кирәк, Фасмер II: 190; Тимергалин: 240.

Бу сүз фар. *карбан* яңгырашында тәүләп Фирдәүсидә (X г.) күренә; соңыннан аның халык этимологиясенчә төрле яңгырашлары пәйда булган; *караван* дип киңәйтелеше гарәпчәдән таралган; иң бор. нигезе пәһл. *kārpānde* «хәрби йөреш җыены» дип уйлыйлар, һәрхәлдә тамыры бор. ир. *kar, kara* «армия; кушын (өйрәтелмәгән армия)». К. EI IV: 676–679.

Дерив.: **кәрвансарай** «кәрван тукталышы урыны»; шул исемдә топонимнар бар.

**КӘ́РЕС, кә́реш** (Тумашева 1992: 193; ЗДС: 291; БҺҺ II: 124), **ҡарыс** (ЗДС: 395) «гарус; гарусная нитка; кашемир; толстый тёплый платок» ~ чув. *карăс,* мар. *карыз* һ.б. (киң таралган) < рус. *гарус* id. < ним. Төньяк Франциядәге *Harras* дигән шәһәр исеменнән. Фасмер I: 395.

**КӘРЕШ** (ЗДС: 291) «стерлядь» < рус. *хариус, хайруз, зарез* < фин. *harjus* «чөгәсыман балык төре» сүзеннән булса кирәк. Тат. **ҡәреш** дип әйтелүе рус. каты *х-* белән әйтелүен чагылдыра бугай. Фасмер IV: 224.

Рус. диал. *карыш* id. татарчадан кире алынма булса кирәк, әмма Аникин (: 270–271) бу сүзне хант. *kari, käri, köri* «чөгә» сүзеннән димәкче.

**КӘРЕШКӘ, кәрәшкә** (ЛС: 12; ЗДС: 291) «вика, мышиный горошек (растение)» ~ чув. *кĕрешке, керĕшке*, удм. диал., мар. диал. *кäрешкä*, башк. *кәрешкә, кәршикә* «тычкан борчагы». Н.Б. Борһанова буенча (Вопросы лексикологии и лексикографии татарского языка. Казань, 1976: 138), рус. *горошек*, *горошка, горошки* сүзеннән. Чаг. себ. (Тумашева 1992: 95) **кәреш** «кара әрем».

**КӘРЗИН** «корзина» < рус., рус. *корзать* «вак чыбык әзерләү һәм кәрзин үрү» фигыленнән (*корза → корз-ина*).

**КӘРИ** «противодействие, отвращение» < гар. *кäрūһ* «җирәндергеч, нәфрәт тудыргыч» ← *крһ* «каршылык күрсәтү; җирәндерү».

**КӘРКӘДӘН** «носорог» ~ кар. *гэргэдэн, кариедень, гаргардан,* төр. *gergeden, gergedan* < фар., гар. *кäркäдäн* < санск. *khadgadanta* «кылычтеш» – кәркәдән. **Кәркәдән** сүзеннән төрле юллар белән үзгәреп (грек теле аша) рус. *крокодил* > тат. сөйл.

**каркадил** сүзе дә килә (тат. сүзе рус. диал. *коркодил*дан, к. Фасмер II: 380).

Иран телләрендә бик иртә *кәркәдан* сүзеннән кыскартылган *кәрк* варианты (> уйг. *кәрк*) килеп чыккан К. **Кир.**

**КӘРКӘРӘЙ, кәкәрәй** (ЗДС: 286) «длинное цветное хвостовое перо у петухов; хохолок у птиц; вид птицы с хохолком» ~ төр. *karkara (telliturna* «тәлле торна» дип тә атала) «түбәсендә таҗы булган торнасыман кош» (ним. *Jungfernkranich* «кәләш торна» диелә). Бабур (Будагов II: 50) *каркара* дигән кошны өке, тавис, челән кебек бүрекле кошлар рәтендә искә ала. Сүз төзелешенә караганда, бу зооним гарәп теленнән килә. К. ш. ук чыгт., каз., кырг. (Räsänen 1969: 238) *karkara,* телеут. *karkıra* «торна кебек кошлар» < монг. *qarqara* «көлсу төстәге торна» (сүзнең монг. булуы шикле).

Кәркәрәйне элек егетләр баш киеменә ярсызлык-буйдаклык билгесе итеп тагып йөрткәннәр. Бу гадәт Европада киң таралган һәм бездә дә билгеле булган. Кәркәрәй биреп вәгъдәсендә тормаган егет турында бер башкорт җыры да бар:

*Кәркәрәең бирдең дә,*
*Касып киттең кош кеүек...*

Кәттә егетләрдә **кәркәрәй** – бизәнгеч, көмеш кыстыргычлы, кыйммәтле әйбер булган.

**КӘРКЕШ** (ТТДС II: 196) «шнурок лаптя» – морд. телләреннән булса кирәк, к. морд. *карь* «чабата», *карькс* «киндерә», *каркс* «бау, билбау».

**КӘРЛӘ** «карлик; карликовый» > мар. *кäрлä*, чув. *керле* id. < рус. сөйл., иске рус. *карла* «кәрлә кеше, лилипут» < ним. *Kerl, Kerle* «кешекәй, егеткәй». Тимергалин: 241.

**КӘРЛӘЧ** «карликовый» (о растении) – **кәрлә** сүзеннән тат. теленең үзендә ясалган.

**КӘРПӘТӘН** иск. «клещи для выдёргивания гвоздей», а также у лекарей – «для выдёргивания зубов» ~ кр.-тат. *kerpetan, kerpeten, kelpeten* id. < фар. *кäлбидäһан* id., сүзмә-сүз «эт авызы» ~ гар. *кäлбäтäйн* id., сүзмә-сүз «ике эт». Чаг. тат. *каргаборын,* рус. *клещи* (сүзмә-сүз «талпаннар») – кадак алгыч корал атамалары. Чаг. ш. ук **Кәпчә.**

**КӘРРӘ** кит. «раз, -жды» < гар. *кäрра* id. К. Будагов II: 125–126. Бу сүзнең сөйләшләрдә *кәрә, кәрән, кәрәм* (~ нуг. *кэрэ,* ком. *кэрэн*) вариантлары бар, к. Арсланов 1976: 70; Арсланов 1986: 51.

**КӘРТ** «игральная карта» > чув. *керт*, мар. *кäрт*, мар., удм. *карт* (Насибуллин: 118) < рус. *ка́рты*, *карта* < ним. *Karte* «кәрт, ка́рта» < фр. *quarte* «дүртпочмак» сүзеннән диелә (Фасмер II: 203). Чаг. ләкин **Харита.**

**КӘРТӘ** «двор, ограждение; рамки» (к. **кәртәгә керү** «входить в рамки чего-либо», диал. (в Башкортостане как в тат., так и в башк. печати) «жердь, жердина» в отличие от **киртә** «ограда» ~ чув. *карта*, мар. *кäртä* > *карта*, удм., манси. *карта́,* каз. (ҚТДС: 156) *керте* id. – бор. тат. теленнән таралган булса кирәк. Чаг. **Калдаз**.

**Кәртә ~ киртә** вариантлары бор. ***кәртә,** к. төр. *kerte* «кирт, төрле үлчәү аләтләрендә – санлы сызык; кәртә; киртә, кечкенә арык» яңгырашыннан килә һәм мондый вариантлар булу – тат. теленең үзенчәлеге. Бу факт (*кәй* сүзе кебек, к. югарыда) татарларның бор. бабалары төркиләрдән беренче булып урта пояста утрак тормышка күчкәнлегенә һәм болгарлардан элек үк Урта Идел регионында яши башлаганлыгына дәлил (к. ш. ук **Басу**). Räsänen 1969: 293; Федотов I: 232–233.

Рус., морд., коми. һ.б. *карда* (> тат. сөйл. *ка́рда*) чув. теленнән таралган (к. Фасмер II: 196–197), каз. (ҚТДС: 156) *керте, кертелеу* «кәртә, кәртәләү» татарчадан (төньяк Казакстаннан).

**Кәртә < кәртә > киртә** сүзенең чыгышы ачык түгел, чөнки күп телләрдә охшаш сүзләр күп. Ихтимал, бу сүз кимәкләр телендә булгандыр. М. Рясянен бу сүзне *кирт- < кәрт-* (к. **Кирт-ү**) фигыленнән димәкче. Ш. ук вакытта к. фар. *кäрдә, кäртә* «түтәл, эшкәртелгән җир, кишәрлек»; Евразиядәге күп телләрдә **kert, *kerd* «киртәләнеп алынган урын» сүзе очрый, к. Абаев I: 586. К. **Киртә.**

Дерив.: **кәртәле, кәртәсез; кәртәлек, кәртәлә-ү** (шуннан **кәртәлән-ү**).

**КӘРТЕМӘЧ** (ЗДС: 292) «прямоугольная фигура в узорной ткани». Бу сүзне төрлечә чагыштырып була, мәс., **кәрмец** «кирпеч», **кәтермәч** һ.б.

**КӘРТЕЧКӘ** сөйл. «фотокарточка» < рус. *карточка* id. – *карта* сүзенең кечерәйтү формасы. Башк. *кәртескә* id.

**КӘРЧӘ: кәрчә-мәрчә** (Г. Толымбай) «харчи, дорожное продовольствие, деньги на еду» ~ мар.

*кäрчä-мäрчä*, рус. *харчи-марчи* id. *мгә* башланган тагылмалы парлы сүз: төп сүз *хәрчә* < гар. *ḫарā-җä, ḫарāҗäт, ḫарҗ* «чыгымнар, хәраҗәт» (к. **Хәраҗәт**). К. **Кырчыма.** Рус. *харч, харчи* тур. к. Аникин: 613.

**КӘРЧЕМӘ**, диал. **керчемә, көрцемә** «варёный мёд» (ТРС 1931), «кислушка; брага» (ТТДС I: 239, 271) «самогон» (Тумашева 1992: 103), «состав для закисления кожи» > чув. *кăрчама, карчăма* ~ кырг. *киричме* «буза» **кәрче-ү** фигыленнән.

**КӘРЧЕ-Ү**, диал. **кәрсе** «перекисать; закисать; превращаться в спирт» ~ башк. *кәрсе* id. < **эки эгәрчи-* «ике тапкыр әчү» ← бор. монг. *ayarči-* монг., бор. төрки *эгәрчи-//агарчы-* «агу, әчү» сүзеннән (*ачы//әче* параллельлеге бик борынгылыктан килә). К. монг. *харза* < *ҡарца* «дүрт тапкыр куылган аракы», *арза* < *арца* «өч тапкыр куылган аракы (самогон)».

**КӘРШЕ** «тонкая замша, лучший сафьян» (к. ТХИ: Кыска җырлар 1976: 294), ихтимал, *кәрчегән,* **кәрчемә**дә эшкәртелгән тиредән ясалган күн (к. **Кәрче-ү**). Чаг. ш. ук рус. *харсук* «иң яхшы замшага китә торган болан тиресе» (Аникин: 613).

**КӘС I,** диал. **кәз** «дёрн; дернина (кусок дёрна, используемый для сложения стены); целина; борозда, ком вспаханной земли», диал. *кәс* «кизәк, торф кирпече, уалучан; таркау, ш. ук кеше тур.» ~ башк. *кәс, кәрс, кәрҫ*, удм. *кäрш*, мар. *кäш*, *каш* «кәс» – Идел-Урал регионына хас агротехник термин. Чаг. чув. *кас, касă* «буразна; җир кишәре, яңа эшкәртелгән җир». каз. (ҚТДС: 143, 146) *кас, кәс* «кәс» татарчадан булса кирәк. К. **Кизәк.**

**КӘС II** (ЗДС: 292–293) «тихий сумасшедший» ~ төр. *kes* «сүзсез тиле, сүзсез калмыш». Чаг. гар. *кäзз* «столбняк», *кäззä* «теш кысып тору»?

Дерив.: (Тумашева 1992: 93, 96) **кәзәр-ү** (< **кәсәр-ү**) «тилерү».

**КӘСАФӘТ** «скрытое отрицательное воздействие; нехорошие последствия; наваждение» < гар. *кäҫафäт, кäсафäт* «кояш тотылу; караңгылану; йогыш, заразы» (гар. телендә мәгънәләре үзара якын ике сүз, к. ТГРС: 226). Төрки телләрдә еш очрый.

**КӘСӘБӘ** «предприятие; промысел» < гар. *кäсäбä* id. *ксб* тамырыннан, к. **Кәсеп.**

Дерив.: **кәсәбәче, кәсәбәчелек.**

**КӘСӘРТКЕ** «вид ящериц» к. **Кисәртке**.

**КӘСЕП** «промысел, производительное занятие, ремесло» > чув. *кесĕп*, мар. *кäсып* id. < гар. *кäсб* «һөнәрчелек; вак сәүдә» ← *ксб* «һөнәрле булу».

Дерив.: **кәсепле, кәсепсез; кәсеплән-ү; кәсепче, кәсепчелек; кәсептәш** һ.б. К. **Кәсәбә.**

**КӘСЕР** иск. «математическая дробь; остаток от деления» < гар. *кäср* id.

Дерив.: **кәсерле, кәсерсез** (мәс., бүленү).

**КӘСТӘНӘ** «каштан, каштаны; каштановый» < төр. *kestane* id. (характерлы көрән төстәге һәм утта куырып ашала торган эре чикләвек). Рус. *каштан, каштаны* ним. *Kastanie* id. сүзеннән булса кирәк (ним. *-st-* *-шт-* дип укыла), ним. сүзе исә < төр. Шуннан ук бу җимеш атамасы барча Европа телләренә таралган. Моңа төрекләрнең хәрби атларга кәстәнә ашатуы сәбәп булган диләр. Төр. теленә *kestane* сүзе Якын Шәрык телләреннән килә, к. әрм. *кäст,* гар. *кäстäл* һ.б. «кәстәнә». Төп чыганагы билгесез.

**Кәстәнә** < *кастана* сүзеннән рус. *кастаньета* << исп. *castanieta* «музыкаль шакылдавык» – төп мәгъ. «кәстәнәчек» сүзе килә. К. Kluge: 475; Фасмер II: 215.

**КӘТАВЫЛ [кәтаwы̆л], кәтәүел** тар. «комендант города, (в особенности) крепости» < чыгт. *кäтаул* һ.б. (иске яз. төрки телләрдән) id. < монг. *гэтэгул, гэтэгүл* «сагалап торучы; шпион, күзәтче; төнге сакчыларның башлыгы» ← *гэтэ-* «сагалап тору». Räsänen 1969: 259.

Төрки халыкларда *кәтәwел* дигән кавем-кабиләләр бар.

**КӘТӘН** диал., **кәтәнә, кәтәнәк** (ЗДС: 293; Рамазанова 2013: 170), **кәртләкә** (к. югарыда) «замухрышка, малорослый человек» ~ башк. *кәтәбәк, кәтәл, кәтмәк, кәтмек* id., чув. *картлака* «кителгән, киртелгән» (кеше, үсемлек һ.б.). К. **Кәтмәр.**

Әкиятләрдәге **Кәтән (Кәтән Иванович)** «бәләкәй генә елгыр кеше», «әкияти елгыр песи» бүтән тамырдан (рус. диал. *котян?*) булса кирәк. Гомумән, китерелгән сүзләр төрле тамырлардан, ләкин сөйләүчеләр аңында ничектер бердәй күренәләр.

**КӘТӘРМӘЧ**, **кәтер, кәтеркә, кәтерки, кәтермәк** ~ **кәтермәч** – разные виды печёных изделий (описание в ЗДС: 293), «обычно рыхлые, но сухие

лепёшки» ~ башк. *кәтермәс* id. **Кәтермәч**не **катырмач** (к. югарыда) сүзеннән дип уйлау табигый, ләкин палатализация сәбәпләре аңлашылып бетми. Бүтән вариантларның ясалышы да әллә ни сораулар уятмый: *-мач//-мәч, -ка//-кә, -мак//-мәк* ашамлык атамалары ясалышында актив кулланылышлы кушымчалар. Мәс., *-мач//-мәч пәрәмәч, токмач, умач* һ.б. сүзләрдә күренә.

**КӘТМӘР** диал. (ТТДС I: 271) «шутник; шустрый», (ЗДС: 294, 301) **кәтүмә, кетеки, кетмер** «малорослый подвижный (человек)» ~ башк. (БҺҺ II: 103) *кетмер* «өлгер, елгыр», чув. *катимар* «көяз; кыяфәтле». Ачык түгел. Чаг. **Кәтән.**

**КӘТТӘ** «самый большой (из группы); замечательный», диал. «кавалер, любимый (девушки); красивый; горделивый» (к. ДС I: 113; ДС III: 99; ТТДС I: 271; БҺҺ II: 125) ~ каз., кырг., уйг. *кәттә, кэттэ,* үзб., таҗ. *катта* «зур, иң зур; асылзат» << һинд. *kattä (< gattha)* «көчле; кыяфәтле; сылу; төгәл; көяз (хис)».

Чув. *каччă*, мар. *катчы, кăцы, кацы* «йөргән егетең; егет», (Иванов, Тужаров: 79) *кăцы* id. < *кәттә*? Чаг. ш. ук манси. *кащ, кас* «энекәш». М.Р. Федотов буенча, чув. *каччă* мари теленнән (Федотов 1990: 302).

**КӘТТӘҖИ**, диал. (ЗДС: 279, 294) **каттачи кәртәҗи, кәттәчи, ҡатташи** «женская шапочка» (которая была в моде у татарок в конце XIX – начале XX века) фр. теленнән (рус теле аша) килә, к. фр. > инг. *coattage* «каурыйлы йон кәпәч».

**КӘТҮК** «катушка ниток»; күч. «юркий мальчик небольшого роста» < рус. сөйл. *каток, катук* id. (шуннан – *катушка* id.).

Дерив.: **кәтүкле** «кәтүккә уратылган», **кәтүксез.**

**КӘҮСӘ [кәwсә]** «ствол дерева», (ТТДС II: 198) «туша» ~ төр. *kevse* id. Ачык түгел. Чаг. чув. диал. *кĕвсе, кепсе* «күсәк; ахмак», кабарда. (< төрки) *күпсэ* «сабак, кәүсә». Чаг. **Гәүдә**.

Дерив.: **кәүсәле.**

**КӘФЕН** «саван» < гар. *кăфăн* id. Рус. *саван* белән тамырдаш булса кирәк – бор. семит телләреннән, к. Фасмер III: 542.

Дерив.: **кәфенле, кәфенсез; кәфенлек; кәфенлә-ү.**

**КӘХӘЛ** (Н. Исәнбәт) < **кәһәл < кяһил** (Г. Утыз-Имәни, Г. Кандалый, БТДҺ: 135) «лентяй, бездельник» ~ чув. *кахăл,* удм. *какал*, мар. *какыл* id. < фар. *kāhил* id. К. **Кайлән-ү, Каллән.** Федотов II: 241.

**КӘЧКИ** диал. (ДС III: 241) «коза» к. **Кәҗә.**

**КӘЧӘК, кас'ак, кучак** (ЗДС: 277; 294, 432) «косяк окна». Русчадан.

**КӘШ** кит. «состоит из (о предметах, имеющих составные части)» < иске фар. *к'аш, кэшт, кäште* id. Чаг. ш. ук бор. төрки *keš, käš* «корал-ярак, ук савыты; калчан; комплект». К. **Кяшки, Теркеш.**

**КӘШӘ I** «перхоть; облупленные части кожи» < бор. төрки *кäсä, кечä* «волосок на поверхности фруктов» (МК III: 220) яки к. фар. *кяһче* id. ← *кяһ* «салам».

Дерив.: **кәшәле, кәшәлән-ү.**

**КӘШӘ II** (ТТДС I: 272), **кәшәкә, кәшләкә** (к. ТТДС I: 272) «клюшка; игра с клюшками» – ачык түгел. Чаг. көрд. *кäшо* «кәшәкә (таяк)», *кäшокäш* «кәшәкә (уен)». К. түбәндәгене.

**КӘШӘКӘШ** «возня; несерьёзные споры; игры детей – куча мала» ~ госм. *кäшäкäш* < фар. *kaša-kaš* id. Räsänen 1969: 258.

**КӘШӘНӘ** «ограда могилы» (первоначально кирпичная), диал. «гробница» ~ гом. кыпч. *кэшэнэ* (к. Räsänen 1969: 258) < фар. *кашанэ* id. «Кяш шәһәреннән килгән керамика» сүзеннән, к. Abrahamowicz Z. Käšäne in türkischen und slavischen Sprachen und in der Toponymik des Dešti-Qıpcaq // UAJ, 1965, v. 36, s. 3–4.

**Кәшәнә** сүзе күп телләргә таралган, хәтта рус телендә дә *кешень* «кәшәнә» (Абаев I: 594), к. ш. ук рус. *кашин* «ялтыратылган ак керамика». *Кишинёв* шәһәренең исеме дә шуннан диләр.

Дерив.: **кәшәнәле, кәшәнәсез; кәшәнәлә-ү.**

**КӘШӘҢКӘ** диал. (ТТДС II: 198), **кәшәнә** «соплодие (орехов)» к. **Кишәңке.** Чаг. диал. (ТТДС II: 197) **кәсәңкә** «кәс, кантар».

**КӘШӘҮ, кашау, кашаwай** (ЗДС: 295; башк.) «кошевые (сани)» ~ каз. (ҚТДС: 148) *кәшебой* id. рус. *кошевой (экипаж)*, *кошевые (сани)* сүзеннән. Рус сүзе исә *кош* < бор. төрки *кӧш* «күш, күлә-

гәлек» булса кирәк. Рус сүзе куман., бор. төрки (ДТС: 319) *köšigä* «күләгә» сүзеннән турыдан-туры да алына ала, шуннан рус *кошёва* «күш» килсә кирәк. К. **Күш**.

Рус., укр. *кошевой* (атаман) сүзе рус диал., укр. *кош* < гом. төрки *қош, қоош* «куыш» сүзеннән. К. **Куыш**. Аникин: 309.

**КӘШКӘЙ-Ү** «изгибаться, загибаться», ачык түгел, к. чув. *кашкалан-* «кәшкәю».

Дерив.: **кәшкәләнчек** «чормавык (үсемлек)».

**КӘШТӘ** (ЗДС: 295) «полка (к. **Киштә**)», «доска, жердь, на которой навешивается колыбель для покачивания» ~ уйг. *кеште* «чигелгән бизәк; бизәкле-бидәрле такта» < фар. *кäште* «чигелгән; бизәкләнгән». Чаг. иске тат. (Будагов II: 177) *киштәмәк* «чигү».

Татарларның бәбиләрне яратуын белдергән сүзләрнең берсе.

**КӘШТӘК** (ЗДС: 295) «волан, лента красивой ткани по низу платья» к. **Кештәк.**

**КВАРТИР** «квартира» < рус. < фр., асылда «дүртпочмак, дүрткел; дүрттән бер» дигән сүз. **Квартир** сүзен **фатир** белән алмаштыруда әллә ни мәгънә юк. Фасмер II: 217.

**КЕБЕК**, иск., кит. **кеби** «как, подобно, вроде, наподобие» – в диалектах и говорах тат. языка множество вариантов: **күĕк, күк** (часто встречается как лексический дублет и в литературном языке), **күбĕк, күwĕк** (Садыкова 1985: 95), **кәбәк** (Дмитриева 1981: 158; Махмутова 1978: 222) ~ башк. *кебек, кеүек, күбей* (Максютова 1963: 109) < бор. кыпч.; к.-балк.; кар. *кибик, кибиг,* уйг. *кәбиг* > *кәби* ~ куман., госм. *киби,* төркм. *гиби*, ком. *йимик,* төркм. диал. (Мухамедова 1973: 123) *кимин, кими-ин,* бор. төрки М. Кашгари сүзлегендә (ДТС: 290) *kebi* id.

Метатезалы варианты да очрый: төр. диал. *bigi, begi* ~ чув. *пек, пак, паки.* Бу сүз һичшиксез бор. *кэп* «фигура, форма» сүзеннән килә, (к. **Кип**), к. ш. ук алт. *кэбэрлү,* тув. *кэбэрлиг* «кебек, шикелле». Ләкин ясалышының семантик һәм морфологик юллары бигүк ачык түгел. Räsänen 1969: 244; ЭСТЯ V: 15–16; Федотов I: 412.

**КЕЗ** диал. (Будагов II: 126) «впадина между двумя горами» ~ каз. (ҚТДС: 150) *кез,* кырг. *кезен* «дөянең ике өркәче арасы; ике калкулык арасы». **Киз** (к.) сүзенең метафорик мәгънәсе булса кирәк.

**КЕЛ** диал. (*келен белү* «знать заговор против чего») «языческое моление», **кел итү** «сватовство, уговаривание девушки» (ЗДС: 2972 > чув. *кĕл, кĕлĕ* «молитва (в церкви)» (*кĕлле-* «молиться») < бор. төрки *кил*, монг. *кил, хил,* удм. *кил,* морд. *кель*, фин. *kiel* «тел» һ.б. Төрки-монг. һәм фин-угор телләрендә таралган сүздән, шуннан ук **тел < тил** (к.). Гомумән *кел* < **кил* варианты төрки телләргә хас түгел – ул миш. диалектында һәм чув. телендә генә (бик сирәк) очрый, ләкин аның дериватлары (бигрәк тә тат. телендә) шактый һәм алар Себер төрки телләрендә дә табыла (к. **Кәлә-ү**).

Миш. **кели** «тели» сүзе белән ***кәл** (к. **Кәлә-ү**) тамыры гомумән бердәй булса кирәк, ләкин бу вариантлар Идел-Урал регионында пәйда булмаган – алар читтән һәм борынгыдан килә.

**Кел** тамырының дериватларына тат. **кел**ә**, келәвез, келәнче, келәү, келәч** сүзләре керә; шунысы кызык ки, алар күрше телләргә (шул хисаптан рус теленә) үтеп кергәннәр. Бу факт *кел* тамыр дериватларының элек киң кулланылуын күрсәтә. К. **Кәләш**. Тюркологиядә нишләптер **кел** тамырына игътибар ителмәгән.

**КЕЛӘ I**, диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) **келәү**, диал. (ТТДС II: 165) **келәй, келәп** «щеколда, крючок двери; запор, задвижка» ~ башк. (БТДҺ: 137) *келәй* «күгән» > чув. *кĕле* id. Идел-Урал региональ сүзе, тат. диал. *кĕл* < *кил* «тел (тел сыман деталь)» сүзеннән, к. мар. *кĕл, кыль* «тоташтыргыч (скоба); тел». Тәүдә **«киллäгү > килләwү** булса, бүтән фонетик вариантлар шуннан чыгып җиңел аңлатыла. Рус. *кляп* «тыгын» сүзе үзе төрки телләрдән алынма булса кирәк (аның этимологиясе томанлы, ди Фасмер II: 260). М.Р. Федотовның (I: 271) **келә** сүзен фар. *килит* «йозак» сүзеннән диюе фонетик җәһәттән акланмый. Төр. *kle* «ачкыч» тат. теленнән түгелме икән?

Дерив.: **келәле, келәсез; келәлә-ү.**

**КЕЛӘ II** (ТТДС I: 236) «каблук; пятка» ~ чув. *кĕлĕ*, *кĕле* id. (к. Ашмарин VII: 236) – тат. **күбәлек** (к.) сүзеннән булуы ихтимал. Федотов (I: 270) осет. *к'еле* «үкчә, көбеләә» сүзе белән чагыштыра, ләкин, безнеңчә, монда очраклы охшашлык кына.

**КЕЛӘВЕЗ [кĕләwĕз]** «кляуза, ябеда» < миш., чув. яки болг. **кĕләwĕҫ* < тат. *келәwеч* «әләкче,

теләнче» булса кирәк, к. мар. *келäпсě* «теләнче» (-*н*- түгел, -*п*-). каз. (ҚТДС: 151) *келауыздык* «ялган сүз» этимологиягә берни дә бирми.

**Келәвез** сүзен бик теләп рус теленнән алынма диючеләр бар. Ләкин рус сүзенең үзенең этимологиясе ачык түгел (к. Фасмер IV: 260). Лат. *clausula* «клаузула, суд карарында искәрмә» сүзе белән чагыштыру мәгънәви җәһәттән бик аксый. Гомумән, *келәwez*нең төрки сүз булуы бик ихтимал. Чаг. рус. *клевета* – ш. ук этимологиясе томанлы сүз ← *кěл-әү?* К. **Келә-ү.**

**КЕЛӘЙ** «клей» < рус., гом. слав. сүзе (Фасмер II: 246).

Дерив.: **келәйле, келәйсез; келәйлә-ү.**

**КЕЛӘЙМӘ** «клеймо, тавро» < рус. < герм. алынмасы (Фасмер II: 246).

**КЕЛӘМ** «ковёр, коврик» ~ башк. *келем*, фар. *гилем, килим* id., добр. *kĭlĭm* «бик калын тукыма»; төрки телләрдә төрле фонетик вариантларда очрый: чыгт. (Радлов II: 248) *кäлин*, төр., гом. кыпч. *килим* һ.б. > рус. *килим* (Аникин: 288); к. ш. ук хак. *кěлěң* ~ тув. *хилиң* ~ монг. *хилэн*, бур. *хилең, хилэң* «бәрхет, плис» < Ирандагы *Гилäн* өлкәсеннән. Бу сүз төркиләрдә тавар атамасы буларак киң таралган, соңыннан фар. теленә әйләнеп кайткан, ди Doerfer IV: 4–7. К. ш. ук Räsänen 1969: 270.

**КЕЛӘП** «кляп» – гадәттә ручадан дип уйланыла, ләкин сүзнең яңгырашы ук моңа шик тудыра. Фасмер (II: 260) *кляп* сүзенә төрле охшаш сүзләр китерә дә азакта «тёмное слово» ди. К. төр. (Будагов II: 133) *кiлпэ* «тышау», *келепчэ* «кечкенә келәп» < фар. *келебче* id. < *келеб* «киләп; төргәк».

**КЕЛӘТ** «закром для хлеба; летний домик» (без печки, с одним окном)» < рус. *клеть* id. (рус сүзе тур. Преображенский I: 318; Фасмер II: 249). Чув. *кěлет*, мар. *кěлäт, клат* id. тат. теленнән булса кирәк (рус. > тат. > чув., мар.).

**КЕЛӘҮ [kĕləw]** (к. Баязитова 1995: 22–26, 38–40) «языческое моление, жертвенник» (о разных значениях этого слова см. Матвеев 1910) > чув. *кěл, кěлев* id. К. түбәндәгене.

**КЕЛӘ-Ү** диал. (миш., к. ТТДС I: 236–237) «желать, хотеть; молиться, просить» > чув. *кěле-* «келәү, теләү, теләнчеләү», мар. т.-кб. *кěле-* «кирәк булу» (Иванов, Тужаров: 107) – ягъни мари телендә бу күчемсез фигыль; миш. диалектында да *баргым кели* кебек тезмәләрдә **келәү** – күчемсез. Бу фигыльнең параллельләре күп түгел: аеруча хак. *кěлэ-* «теләү, үтенү, (кем турында) борчылу», кар., алт. *килэ-* «теләү; сорау; борчылу, хәстәрлек күрсәтү, игътибар иттерү (әләкләү)» ~ монг. *хэллэх* «сөйләү; зарлану» ← *хэл* ~ тат. *кěл* < *кил* «тел» сүзеннән. К. **Кел, Телмәр**.

**Келә-ү** фигыленең дериватлары күп кенә, иң билгелесе **келән-ү, келәнче** > мар., чув. *келэн-, кěленçě*, хак. *кěленҗěк* «теләнче» (шуннан рус. *клянчить*), кар. *килэн-* «теләнү», *килэнчи* «теләнче». Чув. телендә тат. телендә кулланылмый торган *кěлеш-* «сатулашу», ә кар. телендә *клэк* «теләк» сүзләре сакланган, морд. *кле* «сөйлиләр, диләр» (< миш.). К. ш. ук К. Menges 1972: 319–320; Федотов I: 270–271.

**КЕЛӘЧ** «хлястик, языкообразная деталь» ~ удм. *киляч* id. *Кел* (к.) сүзеннән. Рус сүзенең дә татарчадан булуы ихтимал.

**КЕЛӘШЧӘ** «клещи (как инструмент)» < рус. *клещи – клещ* «талпан» сүзеннән. Чув. *кěлешче, кěлешше* id. < тат. булса кирәк.

**КЕЛИНДЕР**, диал. **келиндрик** (ТТДС I: 236), **керәндил** (трбс.) < рус. *крендель* < ним. *Kringel* «түгәрәк». Чаг. чув. *кěлинтěр* < тат.? Ним. сүзе *ринг* «көрәш түгәрәге» белән гомоген һәм бор. *һрингур* «түгәрәк» сүзеннән килә. Бу сүз авар теленнән алынган һәм **күрән** (к.) + **кор** (к.) сүзеннән дигән фараз бар.

**КЕЛПЕ-Ү** «засиять, засверкать; быть сияющим (о комнате, доме, дворе)», диал. (ТТДС I: 236, 275) **келпә-ү, көлпе-ү** «сиять, светиться», (Ф. Хөсни) «светиться счастьем, радостью» ~ башк. (БҺҺ II: 117) *күлбе-* «җәйрәү; киңәеп китү», нуг. *күлпи-* «балкып китү», нуг. *күлпилде-* «тигезсез ялкынлану», кырг. *күлпөң* «балкыш», *көлпү-* «зур һәм матур булып йөрү». Веляр вариант ком. *кулбу-, кулбур-*, кырг. *кулбур-, кулпур,* каз. *кулпыр-* «тигезсез яну; төрле төстә балку». Чаг. ш. ук як. *килбэй-* «ялтырау», *килбиэң* «балкыш». Тат. диал. **гөлпе-ү,** башк. (БҺҺ II: 65) **гөлбә-ү** «купшы, матур булып йөрү» халык этимологиясендә **гөл** сүзенә нисбәтләнгән булса кирәк. Безнеңчә, сүзнең нигезе – **күлп* ~ **kұлп* тәкълиди тамыры. Шуның белән бергә төрки телләрдә шул ук мәгъ. *кил-* тамыры да бар: алт., як. *килэң* «ялтырау, келпү», *килэй-, килбэй* «ялтырау,

келпү» ~ эвенк. *килули* «ялтыр», *килумча-* «ялтырау» һ.б. (к. ССТМЯ I: 394).

БТДҺ (150, 161) **көлбә-ү, күлбе-ү** сүзен «киңәю, җәйрәү» дип аңлата.

**КЕЛТ** – имитатив резким движениям небольших предметов, частей механизмов ~ чув. *кĕлт* id.

Дерив.: **келт-келт** (сәгать йөргүе тур.), **келтер-келтер; келтерә-ү, келтердә-ү.**

**КЕМ** «кто» < гом. төрки *ким* ~ чув. *кам* < **кәм* ~ иске тат., башк. диал., алт., бор. төрки *кäм* (к. Радлов II: 1416) ~ монг. *кем, хэм, кен* id. Үзб. диал. *кум, кым,* тув. *кум, кым* вариантлары икенчел, әлбәттә. Чаг. һинд-ир. *ka, kam, ki, kom* (к. Абаев I: 595), санск. *kim* «кем, кайсы, ничек, нинди» – ностратик сүзләрнең берсе. К. **Ки**. Будагов II: 181; ЭСТЯ V: 67–68; Федотов II: 219–220.

Дерив.: **кемлек.**

**КЕМӘЙ** (ТТДС II: 165)**, көмәй** диал. (Н. Исәнбәт; без теркәдек. – *Р.Ә.*) «предводительница девичника; одна из двенадцати подруг, сговорившихся участвовать в свадьбе друг друга» (к. **Тиңгенәй**) < кыт. *күң мэй* «кома кыз, бүлмә кызы» (*күң* «хатын-кыз бүлмәсе», *мэй* «сеңел, ахирәт») сүзеннән булса кирәк; кемәйләр, тиңгенәйләр оештыру гадәте Кытайда булган. К. ш. ук тув. *кымый* «кәләш яки өйләнүче егет» (к. Сат 1981: 44). к. **Көмәй**.

**КЕМЕРКҮМӘЧ** (Троянский II: 187) «булка, булочка» – диал. *кемер* «бәләкәй буйлы; соңгы бала, кинҗә» ~ тув. *кеймер, хеймер* «иң соңгы бала» ← *кәй* (к.); *кемеркүмәч* камыр калдыгыннан пешерелә. Чаг. **Кетмер, Киен.**

**КЕМРЕК, көмрек** тар. (Троянский II: 187) «пошлина» ~ кар., кр.-тат., госм. *гөмрук* id. < грек. *коμερκη* id.

Дерив.: **көмрекханә** «тамгаханә».

**КЕМСӘ** иск., кит., диал. «не́кто, некий человек» < иске тат. әд., диал. *кемирсә* < бор. төрки (ДТС: 307) *kim ersä* «кем булса (шул)», уйг. *кимәрсә* «кемсә, нәрсә», әрм.-кыпч. *kimesä,* кар. *күмсә, күмәрси, күмәри* «кемсә; кемдер; кайбер кеше». К. **Кемсәнә.**

**КЕМСӘНӘ** «некий человек; один человек, любой (а кто – не имеет значения)» < бор. уйг. *kimsene* < *kim ersä nä* «кем булса ни, кем дә булса берәү», чаг. **Кемсә.**

**КЕН** «ладан» к. **Күнлек**.

**КЕНӘ//КЫНА, генә//гына**, диал. (трбс. һ.б.) **кенәк//кынак, генәк//гынак** – частица ограничительно-ласкательная – к. **Гына.**

**КЕНӘГӘ** «конторская книга», диал. (крш.) «книга вообще» ~ чув. *кĕнеке*, мар., удм. *кĕнäгä, кнäгä* < рус. *книга* (?) < бор. слав. *kъniga* < бор. төрки **küinig* > болг. **küiniv* > венг. *könyü, könyv* «китап» һәм морд. *конёв* «кәгазь», осет. *kiunugə* «кәгазь; китап» (Фасмер II: 262–263); к. бор. төрки *kuin, kujn bitig* «язулы озын кәгазь, төргәк» < кыт. *kuoen* id. (ДТС: 322); бор. төрки яз. телдән монг., бур. *киник, кūниги* «китап; язу», хак. *киңде, кииңде* (к. Диалекты хакасского языка: 22) «кәгазь» сүзләре килә. К. ш. ук AMES 1970: 614 (кыт. *k'üen* сүзен шумер. *киникки* «мөһер» сүзеннән чыгара). Федотов I: 273–274.

**КЕНӘЗ** «князь» ~ башк. (БТДҺ: 138) *кенәҙ* «нәзберек, талымчан» – рус. *князь* сүзеннән, шуннан ук уйг. *кинәз*, төр. *keniz* һ.б. (рус тарихына караган хезмәтләрдә), иске тат. (Будагов I: 138) **кенәз, кенәзләр** – XVI–XVIII гг. Россия чикләрендәге «ныгытылган линия» – «кенәз кальгалары». XX г. башларына кадәр руслар татарларны «князь» дип атаганнар – бу факт төрлечә аңлатыла.

Рус. *князь*, иске рус. *кнезь* < герм. *könig* «король» сүзеннән (чаг. рус. *княгиня* «кенәз хатыны» ~ ним. *Königin* «королева»); шунысы кызыклы, герм. *könig* сүзен һунн **киāң* (к. **Киң II**) «киңәшче» (патшаның киңәшчесе һ.б.) сүзеннән дә чыгаралар; гомумән бу герм. сүзенең этимологиясе томанлы (к. Kluge: 519–570); кайбер слав. телләрендә *князь* сүзенең тарихи тәңгәллекләре «рухани» мәгънәсендә (мәс., пол. *ксендз* «поп»).

Дерив.: **кенәзлек** (төрле мәгъ.).

**КЕНӘРИ** «канарейка; красавица» (к. Асылъяр, кенәри… көе һәм җыры бар) < рус. сөйл. *кенари, кинари* «кенәриләр» сүзеннән. Рус. әд. *канарейка* икенче төрле ясалган. Һәр ике рус варианты фр. *canari* сүзеннән, фр. сүзе исә **Канар** (утраулары) топонимына тоташа. Фасмер II: 177–178; Kluge: 465.

**КЕНДЕК,** диал. (Рамазанова 2013: 98–99) **кентек** «пуп, пупок; сердечник (деталь различных устройств)» > чув. *кĕндĕк,* мар. *кендек, кындык,* удм. *киндик, киндикчӧг* id., рус. (к. Дмитриев 1962: 537) *киндяк* «арба кендеге (шкворень)» <

гом. кыпч., уйг., үзб., алт. *киндик,* ком. *гинник*, тув. *хиндик* һ.б. «кендек» < бор. төрки (ДТС: 308) *kindik* id. ← **киин*, к. алт. *кин,* тув. *хин*, хак. *кĕн*, як., төркм. *киин* id., чаг. ш. ук тув. *хирин* «кендек». Тамыр **киинт* булырга да мөмкин (ягъни *кендек* < *киндик* < *киин-дик* түгел, ә *киинт-ик* < *киинт-иг* була ала). Әрм.-кыпч. *kindik* «буыннар теземендә урын; нәсел буыны» мәгъ. кызыклы. **Кендек** сүзен *кәнт* (к.) «үзе, кәнт» сүзе белән чагыштыралар. К. ш. ук монг. *күйи* «кендек», мар. *кĕлĕмде* ~ венг. *köldök* «кендек» (< болг.). ЭСТЯ V: 68–69 (*киин* тамыры *кин* «кен» белән дә чагыштырыла). Федотов I: 274; Eren: 167 (тәфсилле); Аникин: 458.

Дерив.: **кендекче (әби);** (ДС III: 80) **кендекәй** «кендекче».

**КЕР** «грязь; бельё, подлежащее стирке» < гом. кыпч., үзб., уйг., чыгт., госм., як. *кир*, тув. *хир*, үзб. диал. *киир*, хак. *кĕр* ~ үзб. диал. *кирэ* ~ бур. *хирэ,* эвенк. *кир* < бор. монг. *gkir* (к. ССТМЯ I: 398) «кер; керле»; **кир-** < *киир-* керләнү, пычрану фигыле дә булган булса кирәк, к. каз. *kirik-* < бор. төрки (ДТС: 309) *kirik-* ~ тув. *хирик-* «керләнү» (**хир-* < **кир-* фигыленең интенсивлык формасы).

Тирән тамырлары ачык түгел; чаг. фар. *гир,* ягн. (< сугд.) *γirek, γıreg* «кер, балчык, тузан» (к. ЯТ: 258). К. ш. ук **Кerәч**. ЭСТЯ V: 69–70; Федотов II: 298 (чув. *кирĕк* «кер, былчырак» тур.).

Тат. **кер (элү)** «юылган кием-салым (элү)» абсурд мәгънәгә ия (юылганы да, юылмаганы да **кер**!). Монда ниндидер этимологик хикмәт булырга тиеш. Ихтимал, **кер элү** дигәндә чынлыкта диал. **керги** << монг. *киргүй* «керсез (нәрсә)» элү тур. әйтеләдер. Шундый ук хәл **чүплә-ү** дә бар.

Дерив.: **керле, керсез; керлән-ү;** диал. (ТТДС I: 239) **керек** «кер, былчырак».

**КЕРӘК** (ЗДС: 299) «вид диких уток» < рус. *кряк* id., асылда тәкълиди сүз – «барк». Рус. *кря-кря* – тат. **барк-барк.** Кайбер тәкълиди сүзләрнең гаҗәп дәрәҗәдә охшашмавына мисал.

**КЕРӘН** «хрен» ~ чув. *хĕрен* < болг. **һерән* > мар. *кĕрӓн, ĕрӓн* (Саваткова: 226), удм. *кирен, кирень* id. Рус. *хрен* болг. теленнән, к. Добродомов 1974: 106–116. Тат. *керән* болг. *һерән*нән түгел, киресенчә, болг. сүз борынгы тат. **кыйран* сүзеннән булырга тиеш (фонетик закончалыклар шуны күрсәтә).

**КЕРӘЧ** «керамическое изделие» (преимущественно «черепица», «пуговица» и т.п., но не сосуд), «извёстка» (ДС II: 112) ~ кар. *кирэц, керэч, кирач, крэч*, гаг., ком., кр.-тат. *киреч,* төр. *kireç* «известь, акбур; бур» (шуннан *Керчь* ярымутравының атамасы килә) ~ фар. *гирэч, гэрэч* – Шәрык телләрендә таралган *kir ~ gir* «балчык, известь» сүзеннән булса кирәк (Абаев I: 653). Радлов I: 1092; ЭСТЯ V: 70–71.

**КЕРӘШӘ,** диал. **көрәшчә** (Г. Бәширов), **керәч** (ТТДС I: 239), **керәүшә** (ЗДС: 299) «стриж береговой» < чув. *кĕреçе* «көрәк, ишкәк; ике япьле сәнәккә охшаш балык тоту коралы» < бор. **көрәгчә* < **күрэгчәг* > монг. *хүрзэ* < бор. монг. *kürǯe* «көрәк» (Поппе 1938: 230), к. мар. *куреж* (бор. болг. теленнәндер) «сөлчә (балык тоту сөңгесе)», *курежан кайык* «сөлчә кошы» – «керәшә». К. **Көрәк, Көрәч.**

**КЕРӘШЕН** «крещёный татарин, кряшен» ~ чув. *кĕрешĕн,* мар. *крӓшĕн, кĕрашĕн* id., чув. *кĕресчĕн* «крещёный чуваш», һичшиксез, рус. *крещён* сүзеннән (Никольский 1920: 214–216; Мухаметшин 1977; Баязитова 1986). М. Глухов (Судьба гвардейцев Сеюмбеки. Казань, 1993) *керәшен* сүзен бүтәнчәрәк аңлатмакчы, ләкин аның фикер һәм фактлары ышандырмый.

**КЕРГИ** диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «выстиранное; подлежащее стирке» к. **Кер**.

**КЕРДЕШ, кердәш,** (ЗДС: 329) **көрдәш** «приёмыш, человек (в общине) со стороны», «примак» ~ башк. *керҙәш* id. < бор. төрки **kirdäš* «өйдәш» ← *kir ~ kil* «өй, гаилә» сүзеннән булса кирәк, к. тат. диал. (кас.) *килдеш, килдәш* «кердеш» ~ чув. *килтеш* «өйдәш», *кил* «өй, йорт» ~ госм. *гил* «гаилә; почмак», бор. хәзәр. *кил, кәл* «үкәк (нгытманың почмактагы башнясы)» һ.б., к. **Киләк. Кердеш** яңгырашында **керү** сүзенең, **көрдәш** дигәндә **кәрдәш-ү** контаминацион тәэсире сизелә. К. Räsänen 1969: 270.

**КЕРЕНДЕР-Ү** диал. «жестоко наказать», к. диал. (Тумашева 1992: 97) **кер-ү** «кыйнау». Чаг. ком. *кириндирмек* «чукындыру» ← *киринмек* «чукыну» (суга кереп чукынудан – христиан диненә керүдән булса кирәк). Чаг. **Гөр-ү.**

**КЕРЕШ I** «тетива; жила» < гом. кыпч., тув. *кириш* (нуг., каз., к.-калп. *кирис*), бор. төрки (ДТС: 309; Поппе 1938: 219) *kiriš*, хак. *киреш,* себ. (Ту-

машева 1992: 142), алт. *кырыш*, хак. *кырыс,* чув. *хирлӳ* id., к. ш. ук кырг. *кирич* «кереш», төр., гаг. *кириш* «өрлек, аркылач». М. Рясянен (Räsänen 1969: 272) буенча, *кириш* < **кирил* һәм чув. *хирлу* < **kiriläk*. Федотов I: 350; ЭСТЯ V: 71–72.

**КЕРЕШ II** «введение (в произведение)» – русчадан калька булса кирәк; әлбәттә **кер-ү** сүзеннән. Революциягә кадәрге әдәбиятта **мөкаддимә** сүзе кулланылган.

**КЕРЕШ-Ү** «входить друг в друга (друг к другу); приниматься за дело (входить в подробности дела)» > чув. *кĕрĕш-*, мар. *кĕрĕш*, *кырыш*, удм. *кереш-, кырыш-* «яллану; эшкә керешү» < гом. кыпч., үзб., тув. һ.б. *кириш-*, төркм. *гириш-*, төр. *giriş-* id. **Кер-ү** сүзеннән.

Икенче бер фараз да игътибарга лаек: гом. төрки *кириш-* «керешү» бор. *кир-* «башкару» сүзенең урт. юн. К. **Күр-ү II.**

**КЕРКӘ,** диал. (ЗДС: 329) **көркә** «форель; пескарь»; «малорослый» (Остроумов 1892) ~ чув. *кĕркке,* гом. кыпч. *киркә* id.

**КЕРМЕК** «облепиха (растение)», «жёлтый корень» (Statice tatarica) ~ кырг. *кермек,* каз. *кермәк* >> рус. *кермяк, кармяк*, укр. *кермак* id. Фасмер II: 225. Чаг. фар. *харбӓк* «аксыргак» – *харб* «энә, тикән» сүзеннән (ЛТ I: 184), к. ш. ук рус. диал. *хермык* «аксыргак». К. **Кәрмәк.**

**КЕРНӘ** диал. «берлога» (Ахмаров 1903: 24), **гернә** «тамак (пасть)» (ТТДС I: 117); чаг. тат. **ач кернә,** башк. *әскернә, әскернәй, аскырный* «гуҗ» (БҺҺ II: 324). Чаг. фар. *гиранэ* «мич авызы».

**КЕРОСИН,** сөйл. **керәчин, керәчен, керәсин, крачин** «керосин» < рус. (төбендә грек. *χηρος* «балавыз» сүзе).

**КЕРПЕ** «ёж» < гом. кыпч. *кирпи*, уйг. *кирпә* ~ чув. *гĕрĕп* id. К. Насыйри (ЛТ I: 181) бу сүзне фар. *харпушт, харпүштәк* «керпе (энәле тире)» сүзе белән чагыштыра. К. **Керфек.** Чаг. башк. диал. *керпек* «чәнечке», «борындык (агач авызлык)» (БТДҺ: 139). ЭСТЯ V: 72–73.

**КЕР-Ү** «входить, двигаться внутрь» ~ чув. *кĕр-,* хак. *кір-,* гом. төрки *кир-* (угыз. *гир-,* як. *киир-*) «керү, җитү» ~ монг. *күр-* «җитү». К. **Кергелек, Кереш-ү.** Будагов II: 174–175; Федотов I: 276–277; ЭСТЯ V: 47–49.

Дерив.: **кергез-ү, кердер-ү, керт-ү** ~ **керет-ү; керттер-ү** (бу йөкл. формаларының һәркайсы аерымланган мәгъ. ия), **керел-ү, кереш-ү, кертел-ү; керә-керешкә; кергәлә-ү, кереештер-ү; кергеле, кергесез; кергелек; кереш** (шуннан **керешле, керешле-чыгышлы; керешли**); **керем, кертем** һ.б. Сөйләшләрдә **керт-ү** сүзенең **керет-ү** варианты бар. Әд. **кереш** «мөкаддимә» рус теленнән калька булса кирәк, к. **Кереш.**

**Кер-ү** сүзенең аерым мәгънәләре (ш. ук формалары) аңлатмага мохтаҗ, мәс., **җеп керү** ~ **керешү, керет-ү** «юындыру». Алар аерым сүзләр һәм аерым тамырдан түгелме икән?

**КЕРФЕК,** диал. **керпек** «ресница» < гом. төрки *кирпик*, хак. *кĕрбĕк*, алт. *кербех, кирбик*, тув. *кирбик*, чув. диал. *хăрпăк* id., башк. *керпек* id., ш. ук «бөрмә» (к. БТДҺ: 139). Чаг. аз. диал. *гырп* < фар. *харб* «кылчык, тикән». Тат. вариант бор. уйг. диалектларыннан (*п* > *ф*). Ихтимал ки, бу сүздә ике нигез контаминациясе бардыр, чаг. тат. диал. **керпе-ү** «күзләрне челт-челт йомгалау» < **келпе-ү** (к. **Келпе-ү**). ЭСТЯ V: 74–75; Федотов II: 333–334 (*керпек ~ кырпу* димәкче).

**КЕРШӘН** «белила, крем для лица», себ. *күршән* (? к. Будагов II: 123) id. ~ бор. төрки (ДТС: 309) *kiršän*, төр. *kıršan*, *kirišan*, әрм.-кыпч. *кыршан* id., кар. *кирсэн* «акшар», аз. *киршан* «пудра», *киршән* «майлы күкерт – мәлхәм (мазь) төре». Чаг. фар. *гиришӓңги* «бизәү балчыгы, акшар» (*гир* «балчык», *шӓңги* «кыланчыклык, бизәнү-төзәнү»). К. **Керәч.** ЭСТЯ V: 75.

**КЕСӘ** «карман» > чув. *кĕссе* < гом. кыпч., төркм. *кисе, кисә*, кар. *кэсэ*, госм. *кӓсӓ,* үзб. *кийсә, късmә* (ЎХШЛ: 146), үзб. *кисса*, бор. төрки (ДТС: 310) *kisä* «кесә, янчык, кисет» < гар. *кис, кисӓ, кисӓт* «янчык» < грек. *κιστῑς* «пакет, букча, янчык» (шуннан **киста** «эчтәге авырулы бүлтәймә»). Күп телләргә таралган сүз. Удм. *кис, кисы* «кесә», мар. *кисӓ* «икмәк янчыгы», *кĕшан, күсен*, чув. *кăсийе* (к. **Кесия**) «кесә» – татарчадан түгел, бүтән чыганактан (к. Федотов I: 285). **Кесә** сүзе тур. әдәбият ишле, к. Zenker: 785; Абаев I: 613; Аникин: 292 (шунда ук әдәбият күрсәтелә). К. **Кисет.**

**КЕСӘБИКӘ** (ЛТ: 163; ДС I: 84) «кацавейка (кесәле камзул)», иск. **күсәбикә** id. (к. Радлов II:

1501). Халык этимологиясе буенча рус. *кацавейка* (< ним., к. Фасмер II: 212–213) *кесә* сүзенә нисбәт ителгән.

**КЕСӘЛ** «кисель» < рус. (*кис* «әче» тамырыннан, к. Фасмер II: 239).

**КЕСИЯ** «вид синиц» (к. ТТДС I: 240) ~ мар. *кӗсиа, кисӓ, кӗса,* удм. (Насибуллин: 119) *киса,* чув. *кӑсӑя* id. < чув. *кӑсийӑ, кӑсийе, кӗсӗйе* «кесә» (Ашмарин VII: 189), к. чув. *кӗсье* «карак, кесә карагы»: песнәкләрнең ит урлавыннан.

**КЕТӘК,** диал. (Тумашева 1992: 96) **китәк**, **кәтәк** «клетушка (для кур, для молодняка скота)» ~ каз. (ҚТДС: 157) *кетек, кетiк,* к.-калп., төркм. *кетег,* чыгт. *кӓтӓк* < фар. *кадак, катак* id., ш. ук «кечкенә өй» ← *кад, када* «өй, йорт» сүзеннән (к. Platts II: 820). Будагов II: 113; Räsänen 1969: 259.

Шуңа охшаш сүзләр күп телләрдә очрый: мар. *куды, кудо* «шалаш», морд. *куд, кудо* «өй», рус. *котух* «кетәк» ~ словен. *kotec,* серб. *котац*, чех. *kot, kotak*, белорус. *котих* «кетәк, кечкенә абзар һ.б.ш.» (Даль; Преображенский I: 370).

**КЕТКЕЛДӘ-Ү** «хихикать (по-стариковски, сдержанно)» – *кет*//*кыт*//*кат* көлүгә тәкълит сүзеннән (*кет-кет көлү*), к. ш. ук диал. **каткыр-у** «кычкырып көлү» (Тумашева 1992: 123), алт. *каткы* «көлеш» һ.б.

**КЕЧАТНА, кечәтнә** диал. «четверг» < *кече атна* id., к. башк. *кесаҙна*, тат. диал. **кеце йома** ~ башк. *кесе йома* id. (ТТДС I: 240–241; БРҺ 1996: 267) ~ чув. *кӗҫнерни*, мар. *изарня* «кече атна», ягъни **атна көн**нең кечесе. Чаг. **Атнакич**. К. **Атна, Кече.**

**КЕЧЕ,** диал. **кеце** «младший, меньший», диал. «небольшой». Сөйләшләрдә бу сүзнең утыздан артык варианты һәм паронимы бар: **кечек, кецек, кецегә, кецегәц, кечкә, кечкәй, кецкәй, кескәй, кечкен, кестен, кечкентәй, кечкентүк, кечү, кечнә, кечри, кечтек** һ.б. (к. ЗДС: 301–303; Dobr. II: 313–314). Күрше һәм кардәш телләрдә дә шундый хәл. Төп форма гом. кыпч., алт., госм., иске яз. төрки *кичи* (> нуг., каз., к.-калп. *киши*), башк. *кесе,* ком. *киччи,* к.-балк. *гитче,* хак. *кiчiг,* бор. төрки (ДТС: 306) *kičig, kičüg* id. һ.б. (к. Будагов II: 174). К. ш. ук себ. (Тумашева 1992: 100) **кичү**, кырг. *кичүү,* алт. *күүчүү*, хак. диал. *кӗзәк*, госм. *күчүк* «кече, кечкенә» ~ монг. *күчүк, кичик,* бор. монг. *hičüken, hičügüken* > эвен. (ССТМЯ I: 421) *кӧчукэн, кучукэн, кучиккэн* «кечкенә». Кайбер төрки телләрдә (тув., як.) ышандырырлык параллельләре юк. Мар. *изи* «кече» төбендә фин-угор сүзе дип исәпләнә.

Сүзнең этимологиясе бәхәсле. М. Рясянен (Räsänen 1969: 269) *кече ~ күчүк* сүзен гом. төрки, монг. *күчүк* «көчек» сүзе белән тәңгәлләштерә (**көчек** исә халыкара яисә ономопоэтик сүз). Безнеңчә, *кече < кичиг* < бор. **кейинчиг* «иң соңгысы», ягъни бор. *kejin, kedin* «соңыннан, соңгы» сүзеннән була ала (*көчек* мәгънәсендәге сүздән гомумән **кече** мәгъ. сүз килеп чыгарга тиеш түгел). К. **Кечерәй-ү, Кечкенә, Киен.** Чаг. **Кинҗә**.

Дерив.: **кечелек, кечелекле; кечелән-ү, кечерәй-ү**.

**КЕЧЕК** кит., диал. «небольшой, малый» < чыгт., уйг. *кичик* id. К. **Кече, Кечкенә.**

**КЕЧЕРӘЙ-Ү** «уменьшаться» – **кече** сүзеннән гайре регуляр ясалма; *кече-р-ү* фигыле дә бар (к. миш. **кецерү**, диал. **кечери** «кечкенә» < *кечерей* < **кечерег*), шуннан паронимик *кечерәй-ү* ясалган. К. ЗДС.

**КЕЧКЕНӘ**, диал. **кецкенә** «маленький, малюсенький», себ. (Тумашева 1992: 97) **кецегә** «олан» ~ гом. кыпч., бор. кыпч. *кичкинэ* < *кичик кинэ* id., к. ш. ук башк. *кескенә,* каз., к.-калп. *кишкинэ*, кырг. *кичинекей, кичкинекей*, үзб. *кичкена* id., чаг. төр. *küçücük*, алт. диал. *кичэнэк, кичэгэч,* хак. *кӗчиҗэк* һ.б. «кечкенә». К. **Кече.**

**КЕШ** «соболь», диал. **кешмал** «вид выдры» (ДС I: 84) < гом. төрки *киш*, бор. төрки *kiš* (ДТС: 310), як. *кис* «кеш». Чаг. шумер. *kiši* «бер җәнлек». ЭСТЯ V: 77–78.

**КЕШӘН**, диал. **көшән** «путы (лошади)» < гом. төрки *кишэн* (> нуг., каз., к.-калп. *кисэн*), уйг. *кижэн*, алт. *кижэн*, хак. *кизэн, кизӓн* id. < бор. төрки *kišän* id. ← *kišä-* «кешәнләү» ~ хак. *кузэ-* id. КБтә *Ажун фәйләсуфи, нәңи болмаса, нәгә тилдәм эрсә, кишәди тилиг,* ягъни «Бөтен дөньяга билгеле философ та, байлыгы булмаса, ничек кенә телдәр булса да, телен тыяр». Иске **кишән** сүзенең гомумән «богау» мәгъ. дә булган, к. Ясәвидә (30 хикмәт) *Бәхилләрнең муйнында [кыямәттә] утлыг зынҗыр-кишан бар.* К. ш. ук каз., к.-калп. (ҚТДС: 171) *күшен* «камыт». Joki (1935: 184) төр. *күйл,* төркм. *гүйл-, гүлү-* ~ монг. *кули* «бәйләү» белән баглы

дип карый. Чаг. **Күшә.** К. **Көлтә.** ЭСТЯ III: 95–96. Дерив.: **кешәнле, кешәнсез; кешәнлә-ү.**

**КЕШЕ** «человек; чужой; посторонний» < гом. төрки *киши* (Радлов II: 1392) > нуг., каз., к.-калп. *киси, кĕсĕ,* алт. диал., як. *киси ~ киһи* < бор. төрки (ДТС: 310) *kiši* «кеше; хатын, килен; теше», *kis* «хатын, зәүҗә», к. ш. ук угыз. *гиши*, алт., тув. *кижи,* хак. *кĕзĕ* id. Бор. төрки *kiši* «кеше; хатын» һәм *kisi* «хатын, зәүҗә» икесе ике аерым сүз, дигән фикер дә бар. Чаг. санск. *kisi* «кеше»; икенче тарафтан к. кыт. *кэ жэн'* «кеше; кунак кеше», *кэ* «кунак»; тат. *кеше* кытайча *жэн'* шикелле адәми зат билгесе булып килә: *ана кеше, кыз кеше, кода кеше* һ.б. ЭСТЯ V: 78–79.

**КЕШЕЛЕК** «одежда (и т.п.) на выход» < *кешелек* «кунаклык» ~ үзб., уйг. *кишилик* id.

**КЕШНӘ-Ү** «ржать (о лошади)» < диал. (трбс.) **кешеннә-ү, көшеннә-ү** < *кешенлә-ү, көшенлә-ү, көшнә-ү* < бор. төрки **кишинлә-* > гом. кыпч. *кишнэ-* (нуг., каз., к.-калп. *киснэ-*) к. ш. ук кырг. *кишине-, кишене-*, чув. *кĕçен-*, *киште-* > хак. *кисте-* id., як. *кистээ-* «кешнәү; коркылдау». Төр. *kişnemek* һәм *kişirmek* «кешнәү» ← *kiş* «көш, кит!» Тат. диал. вариантлар бор. (бүтән телләрдә онытылган) нигез вариантны чагылдырамы, яисә, халык этимологиясенчә, *-нә*гә беткән фигыльләр калыбына салынганмы? Һәрхәлдә сүзнең тамыры *киш ~ күш.* ЭСТЯ V: 79–80; Федотов I: 285–286. Чаг. **Көстән-ү.**

**КЕШТӘК,** диал. **кәштәк** (ДС III: 99) «ластовица; мотня» > чув. *кĕштăк,* мар., удм. *кĕштăк, кыштак* < фар. *хиштак* «кештәк; ярым кирпеч» ← *хишт* «кирпеч»; шунысы кызык ки, *хиштак* < *һиштак* дериваты хәтсез заманнардан бирле килә: пәһл. *khastak* < авест. *istya* ~ санск. *ishtakă* «кештәк, кирпеч кисәге» (Platts: 490). Федотов I: 289.

**КИ** «что» (*относительное местоимение*) < фар. *ки* < бор. фар. *ке* ~ сугд. *ky* (ЯТ: 272); бу теркәгеч яз. әд. телдән диал. лексикага да кергән һәм хәтта удм. теленә дә *ке* рәвешендә алынган. Төрки-татар текстларында *ки* еш кына үзенең төрки тәрҗемәсе **кем** белән алмаштырыла (мәс., *та ки = та кем*).

**КИБӘК**, диал. **кәбәк** «мякина, отруби» > чув. *кипек* «кибәк, орлык тышчысы; кау, кавак» (к. Ашмарин VI: 225), мар. (Исанбаев 1978: 38) *кибăк, кăбăк* id. < гом. кыпч., башк. *кәбәк,* уйг., чыгт., госм. һ.б. *кэбэк, кăбăк* ~ монг. *кебег* (Räsänen 1969: 254), *хэбиг, хэбэг, хивэх* id., һичшиксез, бор. гом. төрки *käp//kep* «тышча, кабык» тамыр сүзеннән (к. Егоров 1964: 113), фар., көрд. *капăк* «кибәк, чүп, йомычка», *кибәк ~ кәбәк* сүзе белән гомоген. К. ш. ук чув. *кипенкĕ* < тат. **кибәнкĕ* «кибәк, ташландык тышча». К. **Кип.** Федотов I: 296.

**КИБӘН**, диал. **кәбән** «стог» < гом. кыпч. *кэбэн, кәбән* (> башк. *кәбән,* к.-балк., ком. *гэбэн*) > чув. *капан*, мар., удм. *кабан*, манси. *кепăн*, венг. *kepe*, морд. *капаня* (к. Егоров 1964: 89), чаг. ш. ук морд. *капа* id. Чаг. кырг. *кепе*, уйг. *кепә* «шалаш». **Кибән, кәбән** төбендә «өстән ябулы өем» мәгъ. булган булса кирәк (кибәннең эче куыш була). Себ. тат. **кәмәл, кимәл** «кибән» – халык этимологиясе буенча *кәмәл ~ кимәл* сүзе (к. **Кимәл**) белән буташтыру. Таҗ. диал. *каппа* «шалаш», һинд. *kabandh* «зур мичкә; өем, өркәч» сүзләрендә дә очраклы охшашлык кына булса кирәк. Ләкин як. *кāбис-* «кибән салу» (Пекарский: 1059) очраклы түгел – ул *кибән* сүзенең тамыры *кәп//кип* булуын күрсәтә, каз. (ҚТДС: 170) *қабан* «кибән» – кибәнне кабанга охшатудан. К. **Кип, Кипен II.**

Рус. диал. *кабан* «әрдәнә; кибән» тур. Аникин: 229; Räsänen 1969: 254; Федотов I: 223.

Дерив.: **кибәнле, кибәнсез; кибәнлек; кибәнлә-ү.**

**КИБӘТ** «одежда младенца», хәз. «конверт» ← *кип* (к.). К. **Тибәт.**

**КИБЕР I** (ДС III: 81, иске әд. телдә еш очрый) «гордыня; гордый» < гар. *кибр* id. ← *кбр* «зур булу», шуннан ук к. **Тәкәббер.**

Дерив.: (иске әд. телдә): **киберле** (кеше); **киберлек; киберлән-ү.**

**КИБЕР II** (БТДҺ: 141) «очлы бүрек» < **ки́вер** id. (к. **Кип**). Рус. (Европа) телләреннән урап кайткан сүз.

**КИБЕТ,** диал. **кибит** «лавка, небольшой магазин» > чув. *кипĕт, типĕт*, мар. *кевыт* id., удм. *кебит* «тимерлек; кибет» < бор. төрки *kebit* «кибет» < сугд. *қруб* «кибет» (к. Räsänen 1969: 244), к. ш. ук урта төрки, куман. *кэбит, кăбит*, бор. уйг. *кăбүт* «кибет» ~ гар. *қуббăт* «чатыр; гөмбәз» >> рус. *кибита, кибитка* «тирмә, арба өстендәге торак» (к. ш. ук Аникин: 286). Күрәсең, **кибет** тәүдә арба-чана өстендә йөргән. Будагов II: 172.

**КИБИ [кибĕй]**, **кыйбый** диал. (ТТДС I: 215, 242; ЗДС: 437) «место скачек лошадей»; «сбор средств на проведение сабантуя» < нуг. *кӧй буйы* яисә *кӧй-буй* id.: нуг., кр.-тат., төр. *кӧй* «авыл», *буй, бой* «җәмәга, кабилә».

**КИГӘВЕН [кигәwĕн],** диал. **күгәwен,** себ. **кәгәүн, кәгәwен** «овод; слепень» < бор. төрки *kökägün* id. (МК, к. DLT II: 287) > кырг. *кӧӧгӧн, кӧгӧӧн,* алт. *кӧгүүн*, уйг. *кӧкүйүн*, ком. *гёгевюл*, як. *күҥүгэс* һ.б. (к. Räsänen 1969: 287) *кӧк* «күк, яшел» сүзеннән. Чаг. **Кигәвеч, Күгәл.** ЭСТЯ III: 55–56 (бер төр. телендә генә сигез вариант күрсәтелә).

**КИГӘВЕЧ [кигәwĕч], кәгәвец** «вид дикой утки (селезня)», (ДС I: 85) «кулик» (ЗДС: 283) ← **кигә-ү, кәгә-ү** «янау»?

**КИГӘН-Ү, кигә-ү, кәгә-ү** (Тумашева 1992: 98; ЗДС: 283), **киңгәй-** (Будагов II: 178) «угрожать» ~ кырг. *кеген-*, *кегеш-*, алт. *кекең-*, каз. (ҚТДС: 149) *кегежден-у* «ачуланып янау» ← * *кэк* «үч, ачу». К. **Кик.**

**КИГЕРМӘК,** диал. **кирмәк, кәрмәк** «бурый; бурый слой коры (березы) под слоем бересты» ~ башк. *кигермәк, кигерләк* id. – **киңертәк** белән тамырдаш булса кирәк (төсләре буенча охшашлык). К. Тумашева 1992: 96, 98–99; БТДҺ: 141.

**КИГЕРТӘК, кикертәк** (ЗДС: 303, 309) «трахея» к. **Киңертәк**.

**КИГИ [кигĕй],** диал. **кәгәй** (Тумашева 1992: 92) «спица колеса» ~ нуг., к.-балк., төркм. *кегей [кэгэй]*, кр.-тат. *кäгäй*, каз. *кегәй,* ком. *гегей*, *когай* (!) ~ монг. *хигээс*, диал. *хүхүсүн, күгүсүн,* яз. монг. *kigeüsün*, калм. *киг* id. Чыгышы ачык түгел (кытайчадан дигән фикер бар). Чаг. диал. *киги* «кеше тырнагы» (ТТДС I: 243). ЭСТЯ V: 17.

**КИЕЗ [кийĕз]** «войлок, кошма; ковёр» ~ башк. диал. *көйөз* (БҺҺ II: 109) ~ нуг., кырг., иске кыпч. *кийиз, кииз*, каз., үзб., уйг. *кигиз*, алт. *кийис* id., алт., монг. *кебис* «келәм», бор. монг. *kibez* «мамык», бор. төрки (МК) *kiδiz, kiwiz* «киез; киҗе», *küvüz* «киез; мамык» (к. DLT I: 366; DLT III: 164; ДТС: 306, 311, 331), тув. *кидис* «киез» ~ маньч. *кэбису* «киез, келәм», бур. *хибэс* «келәм» һ.б.; чаг. кыт. *цзи* < **кей* «келәм», *цзибӣнь* < **кейбир* «Кашмир; келәм» (ССТМЯ I: 444).

Интервокаль *й ~ ҙ ~ w ~ б* чиратлашу бүтән кайбер гом. төрки тамыр сүзләрдә дә күзәтелә (к. **Ияр**). Рус. *ковёр* < бор. төрки **ковур* < ***кавур*** < *кәйбур* булса кирәк, к. **Кәвер.**

**Киез итек** тур. к. **Кизтек**. Räsänen 1969: 112; Федотов I: 287; ЭСТЯ V: 83–84 (**киез** һәм **кәвир** сүзләрен чагыштыруга каршы).

**КИЕК [кийĕк],** диал. **кэйек, кәйик, көйөк** «дичь (дикие животные, мясо которых употребляется в пищу)», диал. «молодой лось, олень» (Тумашева 1992: 97–98) ~ башк. *көйөк* id., чув. *кайăк* «җәнлек-җанвар, хайван», *кайăк-кăш* «киек-кош», мар. *кӗйӗк, кайык, кек* «киек», удм. *койык* «пошый» < гом. төрки, бор. төрки *kejik, keδik, kedik* «болан; киек; кыргый (җәнлек)» (к. ДТС: 294–295) ← бор. төрки *кей, кäй* «киек кош», чаг. тунг. *қай* «аккош» ~ саянсамоед. *кай* < *кăйăк* < *кăй-ăк* «кош». К. Федотов I: 212–213.

Төркиләрнең бор. ватаны Хангайда заманында киек кошлар гаять күп булган: *Хангай ~ Қангай* кыт. *каң хай* «каз диңгезе» сүзеннән.

**Көйөк** варианты үзгә: ул **көй** < *кӧд* «ирекккә җибәрелгән терлек» сүзеннән, к. **Көй II.**

**КИЕККАЗ [кийĕкқаз]: Киекказ юлы** «млечный путь» – *кош юлы, салам юлы,* төрки телләрдә *Кар юлы, Тәңре юлы, Тәңре җәясе, Тәңре коры* (билбавы), *Хаҗилар юлы, Саман юлы* ~ фар. *кеһкешан* «салам ташу юлы» дип тә атала. Русча атамасы Европа телләре аналогы.

**КИЕМ [кийĕм]** «одежда» < гом. кыпч. *кийим* < бор. төрки (ДТС: 294) *kejim* < *keδim, kedim* < ← *kej-, keδ-* һ.б. «кию», к. **Кий-ү.**

Дерив.: **киемле, киемсез; киемлек; киемлән-ү** (үзенә яхшы кием булдыру).

**КИЕН [кийĕн],** (ТТДС II: 170) **кийен**, себ. (Тумашева 1992: 93) **кәйен** «потом, после этого, затем» ~ башк. (БТДҺ: 170) *кейен, кәйен,* каз., уйг., үзб. һ.б. *кейин, кәйин* id. – **кәй** (к.) сүзенең инструменталь килешеннән, чаг. чув. *кай → кайăн* «соң, соңыннан», иске тат. **кәзин** id. ~ бор. төрки (ДТС: 294) *keδin, kedin, kejin, ken, kin* «артка, арттан».

**КИЕР-Ү [кийĕр-],** диал. **кир-ү** «распяливать; напрягать» ~ башк. диал. *кир-у* id. < бор. тат. **киир-?* Һәрхәлдә бу сүзнең (ике сузыклы фонетик формада тик тат. телендә генә) гом. төрки эквиваленты *кэр-, кäр-* > чув. *кар-* id., к. ш. ук тув. *хер-*

*[хәр-]*, мар. диал. *кäр* > чув. *кар* «киеренке, киерелгән, чыйрак эрләнгән (ишелгән)». Гомумән, мар. һәм чув. теләрендә *кäр* > *кар* тамырыннан бик күп сүзләр ясалган (Иванов, Тужаров: 77–78; Саваткова: 52; Ашмарин VI: 85–86, 92–93) һәм алар болг. теленнән киләләр. К. **Кирәгә, Кирәм, Кырандас.** Будагов II: 175; Федотов I: 228; ЭСТЯ III: 23–24 (**киер-ү** сүзен тат. диал. **киер-ү** «кидерү» белән бердәй дип бара, ягъни сүзнең тамыры *ки-* < *кеδ-*, имеш).

Дерив.: **киерел-ү; киеренке; киерге.**

**КИЕТ [кийёт]** диал. (ТТДС I: 244) «одежда, которая дарится невестой жениху» (бор. гадәтчә бөтен киемне һәм корал-яракны кияүгә кыз-кәләш бүләк иткән) ~ башк. *кийет* id.< гом. кыпч. *кийит* id., үзб. *кийит* < бор. төрки (ДТС: 294, 305) *kejit, keδit, kezit* «бүләк итеп бирелгән кием» ← *kej-, keδ-* «кию». Татарларда элек **киет keләү** (*киет келәмеш*) дип Нәүрүз бәйрәмен атаганнар булса кирәк (к. Будагов II: 183). К. ш. ук Ногайцы 1998: 165.

Дерив.: **киетле, киетсез; киетлек.**

**КИҖЕ,** диал. **кизе** (к. ТТДС I: 243, 250) «разновидность грубого шёлка», «(шёлковые) привозные нитки» ~ башк. *кизе* id. > мар. *кэзэ*, удм. *кизьы* «клетчатая или полосатая красная ткань домашнего производства» > чув. *киç, киçе* «хлопчатобумажная пряжа; ткань с узорами», бор. рус. *кеджа, кежь*, рус. диал. (Аникин: 280) *кеж, кежь, кешь, кежа* < фар. *кäҗ, кäж* «чи (эшкәртелмәгән) ефәк», *кäҗи, кäжи* «чи ефәктән эрләнгән яисә тукылган»; к. ш. ук ком. *кежи* «ефәк корты; чи ефәк» һ.б. Бу сүзгә ахыр чиктә рус. *газ* < ним. *Gaze* «бик юка тукыма төре» кайтып кала, к. Kluge: 334 (бор. гарәп, Шәрык сүзе ди).

Идел-Урал телләрендә тат. **кижеле**, башк. *кезеле*, мар. *кэзыла* «кызыл шакмаклы тукыма» сүзе киң таралган.

**КИЖЕ-КӨРЧИН** «готовая пряжа» < *кижҗе* һәм *көрчин* < *гарусин,* к. **Кәрес.**

**КИЗ I**, диал. **кис** «древко, стержень стрелы», күч. «балка» (Тумашева 1992: 135) ~ башк. *киҙе, киҙәү* «ук сүреге (таякчыгы); ук сүрегенең төбенә аны җәя керешенә кую өчен ясалган кирт» ~ каз. *кез [кәз]* «ук сүреге (таягы); киртле ук таягы», төр. *giz* «ук сүреге төбенә ясалган кирт», иске уйг. *gez, kez* «ук ясау өчен таякчык; аршын» ~ *кäз* «аршын» (чөнки ук таягы бер аршын озынлыгында була, к. Zenker: 748), к.-балк., каз., кырг. *кез [кәз]* «кирт; ике тау арасында иңкүлек», хак. *кис* < алт., тув. *кес* < бор. төрки (МК) *kez* «укның төп ягы», *kezlä-, kezgär-* (< кырг. *кезгер-*) «укны керешкә җайлап кую» ~ гаг. *кеез [кәэз]* «мәрәү (прицел)» һ.б., чаг. ш. ук мар. *йангеж, йоңеж* «җәя» < бор. тат. *йан-кэз* «җәя һәм ук» > чув. *Янккас* «әкият батыры исеме». К. ш. ук хак. *кис,* алт., тув. *кес* «киз».

Кадим тормышта **киз ук** һәм **җәя** гаять зур әһәмияткә ия булган һәм бу сүзләр көндәлек телдән төшмәгән; шул шартларда *киз* < *кэз* < *кәз* тамырыннан бик күп сүзләр ясалуы гаҗәп түгел. К. **Кәз, Кәзлек, Киз II, Кизә, Кизәк II, Кизә-ү, Кизү.** К. Будагов II: 176; Räsänen 1969: 260; Redhouse: 398–399; ЭСТЯ V: 20–21.

**КИЗ II** «раз» ~ төр. *kez* id., к. **Гиз II.**

Дерив.: **киз-киз** «еш-еш; вакыт-вакыт».

**КИЗӘ,** Гигановта **кися** «поперёк», диал. **кисә** (Тумашева 1992: 100) «диаметр; прямая линия, соединяющая две точки; коньковый брус; длина или ширина» (**кисәбаш** «кишәрлек иңе», **кисәләй** «аркылыга», **кисәлек** «иң») – **киз** «ук төбендәге аркылы кирт» сүзеннән булса кирәк (төп мәгъ. «диаметр»). Чаг. каз. (ҚТДС: 150) **кез** «дөянең ике өркәченең тоташу урыны», төр. *keser* «кизә». К. **Киз I.**

**КИЗӘГӘ** диал. (ЗДС: 305) «зигзаг; ферма; лестница, стремянка», башк. *киҙәгә, киҙәгәй* «ряд зубов, десны» к. **Кирәгә.**

**КИЗӘК I** «кизяк; кирпичи из торфа, навоза (на топливо)», диал. (ДС III: 81; ТТДС I: 266; ТТДС II: 169; ЗДС: 284) **кәҗәк, кәзәк, кизек** id. > морд. М. *кизик*, рус. *казик, кизик, кизяк, кизёк*, чув. *кисек* id., к. алт., уйг., чыгт., бор. төрки *käзäк* «өлеш, өлте, кисәк, бүлемтек» (к. Радлов II: 1172–1174) һ.б. *киз* ~ *кәз* тамырыннан, к. тат. диал. (ДС III: 81; ТТДС I: 243) **кизәр-ү** «өлтеләргә бүлгәләнү; кибеп, катып яргалану». Бу фигыльдән күренгәнчә, **киз** сыйфат мәгъ. дә ия булган, ихтимал, аның фигыль мәгъ. дә булгандыр (**кэз-е* «тигез кисәкләргә бүлгәләнү»), к. к.-балк. *тезгек [тэзгэк]* < *кэзгэк* «кизәк». **Тизәк** яңгырашы икенчел. К. **Кизәки.**

Рус. диал. *кизяк, кизик* тур. к. Фасмер II: 231; ЭСТЯ V: 22; Аникин: 288 (Фасмер да, Аникин да тат. **кизәк** сүзен белмиләр). К. **Кәс, Тизәк.**

**КИЗӘК II** (к. мәкаль: *Үлем – кизәк, дау – кунак,* Исәнбәт II: 870) «очередь удара в поединке богатырей; очередь, поветрие, эпидемия», каз., кырг. *кезек,*

уйг. *гезәк,* төркм. *гезек* «тапкыр, мәртәбә», хак. *кизӗм*, алт. *кезим*, монг. *кидзик, киджик*, каз. *кезбә* id. һ.б. *киз* < *кәз* «җәя керешенә ук кую» сүзеннән (Будагов II: 176–177), к. кырг. *кез* «момент (керешкә ук кую моменты), кизәк ату-бәрү чираты (бергәбер көрәштә һәм уенда)». К. **Киз, Кизү, Кисәк II.**

**КИЗӘКИ, кәзеки** (ЗДС: 284, 305) «кизяк в форме кирпичей». Бу сүз рус. *кизякид*әнме, әллә кечерәйтү формасымы, әллә фарсычаданмы – әйтүе кыен. К. **Кизәк I.**

**КИЗӘН-Ү** «замахиваться» – **кизә-ү** сүзенең кайт. юн. (к. мәкаль: *Кизәнгән яуның (дошманның) күзеннән саклан*, Исәнбәт III: 384), к. хак. *кизен-* «куркыту; кизәнү», кырг., алт. *кәзән-* id., тув. *кезен-* «(ук) төзәү, прицелга алу» һ.б. К. **Киз, Кизә-ү.**

Дерив.: **кизәнеш-ү; кизәндер-ү.**

**КИЗӘР-Ү** (ЗДС: 305, миш.) «растрескаться (о земле в пору засухи)» ← **киз* – **кәз, кәс** (к.) сүзенең **-и-**ле вариантыннан (**киз*дән) булса кирәк. К. **Кизәк I, Кизәки.**

**КИЗӘ-Ү I** «прицеливаться; замахиваться» (Г. Толымбай), диал. «вдевать утковую нить в челнок» ~ башк. *кизәү* «укны керешкә кую» (диал. **күзә-ү** id. дөрес түгел – халык этимологиясе буенча **күзгә** нисбәт ителгән). Төбендә **кизә-ү – «кизне** (к. **Киз**) керешкә куеп, ук атарга әзерләнү» дигәннән, к. каз. *кезе* «корал (ук) төзәү», башк. (Катаринский) *кизә-* «ук таягының төбенә киз киртү» ~ тув. *кезе-* id.; кырг. *кезе-* «(взять оружие на изготовку) коралны атарга әзерләү», тат. диал., башк. **кизәү, киҙәү** «ук таягы төбендәге кирт, киз» һ.б. Шулай итеп, мәгъ. үсеше: *киз* «ук төбендәге махсус кирт» → *киз-ә* «шул киртне керешкә кую > атарга әзерләнү > янау > сугарга әзерләнү, кул күтәрү», соңгы мәгънә ук-җәя тормышта очрамый башлагач активлашкан. К. **Киз, Кизән-ү.** Räsänen 1969: 260 (бик аз мәгълүмат).

Дерив.: (иске тат.) **кизәк, кизәчәк** «батыр сугышчы – төз атучы»; **кизәгән** «мәргән».

**КИЗӘ-Ү II** диал., к. **Күзә-ү I** «очистить крупу от мякины».

**КИЗГЕН** иск., кит. «бродячий (торговец, цирк)» ← *киз-ү*; чаг. ш. ук чув. *каскӑн* «тиктормас, тынычсыз», кырг. *кезгин* id. К. **Гиз-ү, Киздер-ү.** Төр. *gezegen* «планета» – неол.

**КИЗДЕР-Ү** «водить (на прогулку); руководить» (Ш. Маннур), диал. «ходить перед родами (о женщинах)» – диал. **киз-ү** «төрле җирдә йөрү, гизү» сүзеннән, к. **гиз-ү** < *киз-ү* ~ яз. монг. *kerü-* «кыдыру, сәяхәт итү» (*р* ~ *з*).

Тат. диал. (Ставрополь, без теркәдек. – *Р.Ә.*) **җан киздерү** «бала табу алдыннан бераз атлау, йөрү», ихтимал, мәҗүси ышанулар белән бәйледер.

**КИЗЛӘҮ [кизләw]** «скрытый (к. *кизләү мәчет* «скрытая мечеть», Бәетләр 1960: 200); маленький крытый колодец (в низине, где вода близка к поверхности)» – төбендә «ябулы, яшерен кое» дигәннән, к. иске тат., башк. *кизлә-ү, гизлә-ү* «яшерү» ~ үзб. диал. *кизлә-*, кр.-тат., кар. *кизлэ-*, төр., төркм. *гизлә-,* як. *кистээ-* «яшерү», үзб. *кизлик* «яшерен», төр. диал. *гизчи* «җасус, шпион» – фар. (?) *киз* «сумка; мисек савыты» сүзеннән, ди ЭСТЯ III: 43. Чаг. фар. *гиз* «яшерен».

**КИЗЛЕ I** диал. «скрытый» ← **киз* «яшерен». К. **Кизләү.**

**КИЗЛЕ II** диал. «периодический», чаг. *киз-киз* «вакыт-вакыт» – диал. *киз, кәз*, иске тат. *гиз* (к. *һәргиз*) «момент» сүзеннән. Чаг. **Киз I.**

**КИЗРӘН-Ү** диал. (ТТДС I: 248) «содрогаться, дрожать» > чув. *кисрен-* id., удм. *кисыраны-* «бөрешү; җыерылу; оялу»; мар. *киж-* «өшү, туңу» < тат. *киз-* (?). Чаг. бор. төрки (ДТС: 305) *kezik* «бизгәк» – бәлки, *кизү* «чират, эпидемия» сүзенә тоташадыр. Федотов I: 299 (бик кыска – фиксация генә бирелә). Чаг**. Кәс II**.

**КИЗТЕК** «валенки» > чув. *киçтӗк* id. < **киез итек**; чаг. диал. *кизката* «кыска пима» < *киез ката* (ТТДС I: 243).

**КИЗҮ [кизӗw]** иск. «дежурство; дежурный (в медресе)», диал. (ЗДС: 305–306) «дежурство», (ДС I: 26) «эпидемия (болезнь по очереди)» > мар. *кезү чер* «эпидемия» ~ гом. кыпч. *кезү, кезүв,* куман. *keziv*, кырг., алт. *кезүү* «чират; чират чир» < бор. төрки **кезег, *кезиг* id. > удм. *кезег* «малярия», каз. *кезек* «чират», *кезик* «тиф», кырг. *кезек, кезик*, уйг. *кәзик*, угыз. *гезик* «чират; кизү» (ш. ук «гизү») һ.б. Рясянен бу сүзләр рәтендә брб. **кыжык** ~ монг. *kišig* «эпидемия; түләмә» сүзен дә карамакчы. Чув. (Ашмарин VI: 130–131) *касу, касо* «чират; табун; көтү чираты» белән абаз. (һ.б. Төньяк Кавказ)

*к'азу* «чират» гомоген микән – әйтүе кыен. Барча бу сүзләр бор. төрки *kez-, käz-* «күчү, күчеп йөрү» (к. **Гиз-ү**) белән дә, бор. *кәз//кәз* «киз; ук ату; ук атып дежур (гөрләүче) билгеләү» сүзе белән баглы була ала. К. **Кизәк II.** Räsänen 1969: 260.

*Кизү ~ кизәк ~ кәзәк* сүзе белән бор. монг. *кәшик//кэсик//кэсэк//кэзик//кэзэк* (төрле язылышларда, к. Бартольд I, 1963: 447–449) «дежурда торган хан гвардиясе» сүзе тамырдаш бугай: **кишек** яңгырашында бу сүз иске тат. чыганакларда да очрый.

**КИЙ-Ү (кию) [кĕйĕw]** «надевать, одевать, одеваться» < гом. кыпч., алт., уйг. *кий-,* төр. *giy-* (ком. *кей-, гей-*), хак. *кис-* (< *киз-*), *кес-* (< *кез-*), бор. төрки (ДТС: 303) *kej-, keδ-, ked-, ket-* > тув. *кет* id. < бор. гом. төрки **ker* (?), чаг. мар. *кäр-, кар-*, чув. *кар-* «тартып сыйдыру». К. **Киер-ү.** Будагов II: 181–182; ЭСТЯ III: 12–14, 23–24.

Дерив.: **киел-ү, киен-ү, кидер-ү** (ш. ук **кигез-ү**); **кигеч; кидергеч;** (ТТДС II: 170) **киенчек** «кешелеккә дигән кием». К. **Кием.**

**КИК** (ЗДС: 308) «мстительность; враждебность; злоба» ~ чув., як. *кик*, гом. төрки *кек [кәк]* < бор. төрки (ДТС: 294) *кек* id. К. ш. ук (ЗДС: 286) **кәк, кәкцек** «тәкәббер» диелә. Бор. төрки бу сүз деривацияле: *kek kör-* «нужа күрү», *kekčür-, keknä-, kekräs, kektäš-* «дошманлашу, ачуланышу һ.б.ш.» Räsänen 1969: 247–248 (күп мисал). Федотов I: 291. К. **Кәгә-ү, Кигәй-ү**.

**КИКЕЛ** диал. (Рамазанова 2013: 26) «чёлка (лошади), гребешок (петуха)» ~ башк. *кикел,* нуг., каз., к.-калп., кырг. *кекил,* уйг. *кәкел* id. К. **Какул, Кәкел, Кикерик.**

**КИКЕРЕК** «отрыжка» к. **Кикер-ү.** Чаг. **Какырык.**

**КИКЕР-Ү** «рыгать» < гом. кыпч. *кекир-*, хак. *кигир-*, төркм. *гәгир-*, госм. *гегир-*, аз. *гәйер-, гәйир-*, чув. *какăр-* һ.б.ш. id. (к. Егоров 1964: 86) < *кәк-кир-, кәк-кир-* «кәк дип кычкыру» сүзеннән: **-кир-//-кыр-** ымлыклардан фигыль ясагыч кушымча (к. *а-кыр-, ба-кыр-* һ.б.). Räsänen 1969: 248 (бик күп шикле параллельләр китерә); ЭСТЯ III: 37.

**КИКЛЕК, кәклек** «горная куропатка» ~ уйг. *кәкәлик,* каз., үзб., кырг., уйг., төр. һ.б. *кеклик, кекилик,* бор. төрки (ДТС: 294) *keklik, kekalik* id., безнеңчә, «кәки итеп пешерергә әйбәт (кыр тавыгы)». Бу сүз киң таралган, к. рус. *кеклик,* фар. *кеглик* һ.б. Räsänen 1969: 248 (безнеңчә түгел). К. **Кәки.**

**КИКРИК,** диал. **кикерик,** (ДС I: 85) **кикрүк** «гребешок петуха» ~ башк. диал. (БТДҺ: 142) *кикел, кикелек, кикерек* id. > чув. *кикирик* «кикерик; озын каурый», мар. (Саваткова: 53) *кекерек, кекырек,* удм. (Насибуллин: 125) *кэкьрэк* id. < тат. диал. *кикеллек,* каз. диал. *кәкәләк* id. *кикел, кәкәл* сүзеннән (*л* > *р*), к. **Какул, Кикел.**

**КИКСӘ** диал., иск. «дряхлый» ~ үзб. *кекса* id., каз., к.-калп., кырг. *кексә* «карт; хәйләкәр», каз., кырг. *кекчил* «үпкәчел, үчегүчән» ~ төркм. (ТДГДС: 55) *гекшиллә-* «картаю»; к. чув. *кив, кивĕ* «иске; карт» < бор. тат. *киw* < *киг* < *кик* «үчегүчән» сүзеннән булса кирәк, ягъни картайган кешеләрнең үпкәчел булып китүеннән. К. **Кик.**

**КИЛӘК** «омшаник (в лесу); поляна, где располагаются ульи» ~ чув. *кил, килĕ* «өй, йорт, гаилә» ~ бор. төрки (хәзәр) *кел* «арба өстендәге тирмә». (Хәзәрләрнең атаклы *Саркел* ныгытмасын шул замандагы авторлар беравыздан «ак өй» мәгънәсендә дип аңлаталар, бу аңлатма чув. *шурă (<*сары) кил* «ак өй» сүзенә бик туры килә.) Икенче яктан к. төр. *gil, kil* «почмак, өй почмагы» (чаг. тат. *торыр почмагың* «яшәр җирең») > тат. *-кел* (**өчкел** «өчпочмак», **дүрткел** «дүртпочмак» һ.б.).

**Киләк** сүзен русча *ко́лок* «басу уртасындагы урманчык, куаклык» сүзенә нисбәтләү мәгънә ягыннан да (**киләк** һәрвакыт умарта белән бәйләнештә килә, ә рус сүзендә андый бәйлелек юк), фонетик җәһәттән дә (*ко́лок* татарча **кулык** булыр иде) аксый.

**КИЛӘН-Ү** «наслаждаться жизнью» (Г. Толымбай, ТТДС I: 245) > чув. *килен-*, мар. *килан-* id. *кинәл-ү, кинән-ү* сүзләреннән метатеза, к. **Кинән-ү**. Федотов I: 293.

**КИЛӘП** мера измерения ниток – «моток пряжи, мотня (не клубок)», тат. (ЗДС: 309) «мера длины – сажень» (?), к. **терсәк. Киләп** тат. телендә *э* > *и* күчеше нәтиҗәсендә килеп чыккан. К. **Кәләп.**

Элек **киләп агачы, киләп тактасы** була торган иде. Дерив.: **киләпле; киләплә-ү, киләпкә салу** һ.б. тәгъбирләр бар. Будагов II: 132 (бик аз).

**КИЛБӘТ**, диал. **килбат** «фигура; осанка; (впечатляющая) внешность; образ», диал. (ТТДС I: 245)

«арматура (кирпичных сооружений)» > чув. *кил-пет* < гом. кыпч. *кэлбэт*, к. кырг., к.-калп. *келбет*, каз. *келбит*, ком. *келпет* id., к.-балк. *келбет* «матур кыяфәтле»; нуг. *келбак, келбӓк* >> чув. диал. *килпек* «килбәт» варианты да бар. Гадәттә *килбәт* ~ госм. *kalbüd* сүзен бор. төрки (ДТС: 289) *kälbüd* «сүрү, кипрән» ~ фар. < гар. *кӓлбуд, кӓлбод* «форма, калып; гәүдә» сүзеннән дип тәгъбрифлиләр, к. Будагов II: 110, 133; Федотов I: 292–293; Özön: 417.

Дерив.: **килбәтле, килбәтсез.**

**КИЛЕ**, диал. **кейле, көйле** (Тумашева 1992: 98) «ступа», в некоторых говорах «пест» > чув. *килӗ, кил, килли* (Ашмарин VI: 214–216) < гом. кыпч. *кели*, як. *кӓлii* (Пекарский: 999, 1020, 1037), куман. *кӓли*, каз. *килә,* үзб. диал. *кәллә* >> венг. *kolyü* id. Joki 1952: 134; Räsänen 1969: 249; Федотов I: 293. К. **Кисап.**

**КИЛЕН** «сноха; невестка» < гом. төрки *кэлин, кӓлин*, угыз. *гэлин* id. Бу сүзне *кил-ү* сүзеннән дип аңлату киң таралган (к. Покровская: 63–64), ләкин бу уйдырма гына – чынлыкта бу сүз бор. дуаль кардәшлек заманнарыннан калган халыкара тамырдан килә, к. (ССТМЯ I: 446) тунг.-маньч. *кэли, кэлин* «бажа; абсын», удм. *кали*, морд. М. *кел*, морд. Э. *кийало*, коми. (КЭСК: 220) *кев, кел* << гом. урал. *kälü* «килен», чув. *кин, кинемай* «килен; җиңги» бор. тат. теленнән булса кирәк, *килӗнтеш* «килендәш» тәгаен тат. теленнән (ул нәкъ татарча әйтелә дә).

**Килен** сүзенең деривациясе тур. к. Рамазанова 1991: 88–90; Будагов II: 135–136; Räsänen 1969: 250 (фин. *käly* «килен» сүзен китерә); Федотов I: 295–296; ЭСТЯ III: 16–18 (**килен** һәм **кәләш** сүзләре гомоген дигән иске фикерне кабатлый, безнеңчә, бу дөрес түгел).

**КИЛЕНЧӘК** «молодая, молодица, молодуха (невестка, еще не рожавшая детей)» ~ гом. кыпч. *келинчэк* ~ төр. *gelincek* id. К. **Килен.** Будагов II: 135; ЭСТЯ III: 18. Төр. *gelincek* «киленчәк» сүзеннән **Геленджик** дигән шәһәр исеме килә (Кавказның Кара диңгез ярында). Төр. *gelincek* дип төрле матур үсемлек һәм хайваннарны да атыйлар.

**КИЛЕШ I** «падеж (грамматический)» – букв. «приход», XX г. башларында тат. телендә телчеләр тарафыннан ясалган һәм кайбер кардәш төрки телләргә дә таралган (башк. *килеш,* уйг. *келиш*, үзб. *келишик* һ.б.). К. **Кил-ү.**

**КИЛЕШ II** «облик; внешнее поведение» > удм. *кельыш* < гом. кыпч. *келиш* id. К. ш. ук *килеш, килештән* «в виде» (*исерек килеш* «в пьяном виде»); тат. телендә **килешле** (> удм. *кельышлы*) «буй-сынга матур», **килешсез** (~ чув. *килӗшсӗр*, мар. к. *келшедыме*) «килбәтсез» сүзләре киң кулланыла. К. **Кил-ү.**

**КИЛЕШ-Ү** «ладить между собой; соглашаться, быть к лицу» (**килешү** «соглашение») > мар. *келыш-* (*келшаш*), удм. *кельш-* (*кельшыны*), чув. *килӗш-* < гом. кыпч. *келиш-* (нуг., каз., к.-калп. *келис-*), ком., аз., төр. *гелиш-, гәлиш-*, хак. *килӗс-* «килешү; кодалау, ярәшү». К. ш. ук тат. *килгән* «килешкән». К. **Кил-ү.** Федотов I: 293. Төр. һ.б. угыз диалектларында «килешү» мәгъ. *барыш* сүзе кулланыла.

**КИЛЕШТЕР-Ү** «примирить, согласовать, увязывать; делать складно, хорошо; уподобляться, рисоваться» > чув. *килӗштер-*, мар. *келыштар-* id. **килеш-ү** фигыленең йөкл. юнәлешеннән.

**КИЛКЕ: килкен, килкенни** (ЗДС: 310) «некоторое время» ~ башк. *бер килке* id. < монг., к. хәз. монг. *хэлхээ* «бәйләм; чылбыр бөжрасы, вакыт аралыгы».

**КИЛТӘ** «конец недотканной пряжи, концы ниток основы» > чув. *килте, кӗлт* id. гом. төрки *кэлтэ* «кыскартылган, көтек» сүзеннән, к. каз. диал. *келдек, келтек* «башы киселгән үсемлек, агач һ.б.». К. **Кәлтә, Китәр-ү.**

**КИЛ-Ү** «приходить, подходить» > чув. *кил-* < гом. төрки *кэл-* id. – **кит-ү** < *кэт-* сүзе белән тамырдаш булса кирәк; фин-угор, юкагир., эскимос. телләрендә дә очрый (К. Bonnerja 1971). Будагов II: 179–180; Räsänen 1969: 248; ЭСТЯ III: 14–16.

**Кил-ү** фигыле тат.телендә гаҗәп күп функцияле: ул составлы фигыльләр (*гөр килү* һ.б.ш.) ясау өчен дә, һәртөрле актионсарт һәм модаль ярдәмлек фигыль буларак та кулланыла, шунлыктан булса кирәк, аның дериватлары (к. **Килеш, Килеш-ү**) төп мәгънәдән ерак китә. К. **Китер-ү.**

**КИМ I,** диал. **кәм** «меньше кого-чего; мало, маловато; ущербный, лишённый достоинств, обычных прав» (к. мәкаль: *Килен кеше – ким кеше*) ~ башк., добр. *кem* ~ мар. *кӓм* > *кам*, чув. *кам,* удм. *кэм* id. < гом. төрки *кәм, кэм*, угыз. *гэм* id. ~ монг. *гэм* «зыян, кимсенү», бур. *гэм* «гаеп, зыян, җина-

ять» ~ тув. *кем* id. Кайбер тикшеренүчеләр төрки сүзләр белән монг. сүзләре арасында билгеле мәгънәви аермадан чыгып, аларны аерым-аерым этимологик тамырларга нисбәт итәләр (бу тур. к. ЭСТЯ V: 34–35). Безнеңчә, һәр очракта *гәм* < *кәм* < фар. *кäм, кам,* пәһл. *kem, kim*, авест. *kamna* «кимчелек, җитешсезлек; кечкенә, кимрәк» (к. Platts II: 846). К. ш. ук Будагов II: 136, Räsänen 1969: 250; Dobr. II.

**Ким ~ кәм** бик продуктив нигез: **кимлек; кимлә-ү** (тат. диал. **кәмлә-ү**); **кимчел, кимчелек**; тат. диал. **кимсез** «кимчелексез»; башк. (БТДҺ: 143) **кимҗә-ү ~ кимйә-ү** «йончу», **кимеш** «кимчелек» (**киму** фигыленнән булса кирәк), к. **Киме-ү, Кимпер, Кимсе-ү, Кимтек, Кимтер.**

**КИМ II** диал. «должный уровень» (**кимен куйма-у** «держать марку, быть на должном уровне, не отступать от достигнутого») < уйг., алт. (Радлов II: 1203) *кем, кäм*, кар., як. һ.б. *кем ~ кэм* «чама, үлчәм; вакыт, момент; порция» ~ тув., иске монг. *кем, кэм* «чама, пропорция; җир өлеше, җирәбә; ук атканда төзәү өчен кулланылган вертикаль шкала». К. ш. ук удм., хант., манси. *кем* «чара, мөмкинлек; чама; таман»; башк. **ким-ким, кимгел-кимгел** «вакыт-вакыт» ~ эвенк. *кэмэй* > як. *кээмэй* «үлчәм, үлчәгеч», маньч. *кэмнэ-* < бор. монг., бор. төрки *kemne-* «үлчәү» (к. ССТМЯ I: 448). Хәз. монг. *хэм* «чама, үлчәм» бик продуктив нигез. Чаг. **Кимәл.** Räsänen 1969: 250.

**КИМӘ** «лодка» к. **Кәмә, Көймә.**

**КИМӘК** «кимяк, кимак» – название древнего народа, жившего в VIII–X веках в среднем течении реки Иртыш, звучание восстановлено по письменным памятникам, написанным на арабском и персидском языках (напр., М. Кашгари), а также по русским летописям. Кимяки считаются предками татар.

Бу сүз хәз. төрки телләрдә сакланмаган (Т. Гарипов **кимак мае** сүзендә **кимәк** сүзен күрмәкче, ләкин бу сүз икенче мәгъ. – миш. әйтелештәге **коймак мае** булса кирәк). Кайбер галимнәр хәз. татарлар кимәкләрдән килә дип карыйлар.

**Кимәк** дәүләте турында фрагментар мәгълүматлар гына калган. Бу дәүләттә (федерациядә) төп урынны **татар** дигән кабилә тоткан. Кимәк дәүләтенең килеп чыгу вакыты тур. фикерләр бик төрле: археологлар Р. Фәхретдинов (1995: 43–44), Н. Мәҗитов (к. Кимяки // Башкортостан. Краткая энциклопедия. – Уфа, 1996: 334) ул дәүләтне VIII г. ахыры – IX башында, күктүрк дәүләтен уйгурлар җимергәч качаклар килеп оештырган дип карый; Л. Гумилев (2002: 223–229) һәм Татар энциклопедиясе (1999 ел басмасы) X г. оешкан дип баралар. Безнеңчә, кимәк дәүләте 840–848 елларда барлыкка килә: уйгурларга союздаш татарлар нәкъ шул чорда көнбатышка качып китәләр. X–XII гг. **кимәк** көчле бер дәүләт атамасы булып кала; 1183 елда кимәкләр Идел Болгары дәүләтен, рус елъязмаларында әйтелгәнчә, «яулап алалар» (яисә талап кайтып китәләр). Кимәкләр кыпчак-татарлар һәм болгарлар белән аралашып торган булсалар да, **кимәк** сүзе дә, кимәк федерациясенә кергән кабилә атамалары да хәз. төрки телләрдә сакланмаган. **Кимәк** сүзен еш кына (шулай ук сакланмаган) **йәмәк ~ имәк** кабиләсе атамасы белән нисбәттә карыйлар: берәүләр **кимәк > йәмәк** дисә, икенчеләр **ике йәмәк > кимәк** дип фаразлый. Ихтимал, **кимәк ~ йәмәк** безгә бик таныш сүзләрдәндер, тик без аларны таный белмибездер.

**КИМӘЛ** диал. «уровень», әд. телдә техник әдәбиятта кулланыла; башк. әд. сүз, тат. диал. (ТТДС I: 269, А. Гыйләҗев телендә һ.б.) **кәмәл** «должная высота плотины», башк. (Катаринский) «ватерлиния; отмеченное место в посуде, до какого должен доходить уровень воды» ~ чув. *камал ~ *кәмәл* «мера жизни» (*камалсăр вилĕм* «вакытсыз үлем»). Бу сүзне без Идел-Урал төрки телләрендә генә күрәбез. **Ким II** сүзе белән тамырдаш булса кирәк (ихтимал, **кимәл** << *кэмгэл*).

**КИМӘШӘ, кимәчә, кимешек** диал. (ЗДС: 311) «вид чепчика; женский головной убор» (с перьями?, к. **Кимәшәбаш** – к. ДС III: 241 – «одуванчик») ~ каз. *киймешик*, к.-калп. *киймешек* «чепчик» (к. Будагов II: 181), башк. (БТДҺ: 143) **кимәсә** «гади көндәлек күлмәк» – «билбаулы халат», себ. (Тумашева 1992: 94, 98) **кәмәцә, кимәцә** «чәберчек» (бу кошның башындагы таҗына карап аталган булса кирәк) < **кәмәрчә** «кечкенә кәмәр (диадема)», к. башк. (БТДҺ: 172) *кәмәсук, кәмәрсек* < *кәмәрчек* «чәберчек, сиртмәкойрык». К. **Кәмәр.**

**КИМЕК**, себ. (ЗДС: 288) **кәмүк** «губчатое костное вещество (которое можно грызть)» < гом. кыпч. *кэмик*, каз. *кәмек*, уйг., үзб. (ЎХШЛ: 140) *кәмик, кӧмик, кӧмук* id., төр. *kemik* «сөяк», алт. (Будагов I: 137) *кеемік* «кимерчәк» ← бор. төрки *кәм-* «кимерү» сүзеннән, к. бор. монг. (Поппе 1938: 215)

*kemilebe, kemigi* ~ чыгт. *kemükni sordı* (суырды), як. *кэбий-* «кимекләү», эвенк. (ССТМЯ I: 388) *кэми* «мамонт сөяге» (күрәсең, ул кимерергә яраган), бор. төрки (ДТС: 297, 304) *kem-, kev-* «шыеру, кимерү» ~ госм. *геб-, гев-* «көйшәү, кимерү». Чаг. тохар. *kam, keme* «теш». ЭСТЯ V: 36–38. К. **Кимшек.**

Дерив.: **кимекле, кимексез, кимеклә-ү** «суырып кимерү».

**КИМЕР-Ү** «грызть» < гом. кыпч. *кэмир-*, чыгт., уйг. *кэмүр-*, угыз. *гэмир-* id. < *кэмгир-, кэмгүр-,* ягъни **кэм-** «кимерү» сүзенең йөкл. юнәлешеннән. К. **Кимек, Кимерчәк.** Räsänen 1969: 251; ЭСТЯ III: 19–20.

**КИМЕРҮЧЕ** «грызун» – тат. теленең үзендә рус. *грызун* сүзеннән калька итеп ясалган.

**КИМЕРЧӘК** «хрящ; часть кости, которую можно грызть» ~ башк. *кимерҫәк,* башк. диал. (БТДҺ: 143) *кимерсәк,* чув. *кимĕрчек* < гом. төрки (Радлов II: 1209–1210) *кимерчек, кӓмирчӓк* id., алт. *кемирчек* «кимерүче; кимерчәк». *Кимер-чәк* сүзе **кимер** дигән исем булганлыгына ишарәли шикелле, к. башк. (БТДҺ: 143) *кимер* «кып-кызыл (ит төсе?)».

К. **Кимек, Кимер-ү.** Федотов I: 252; ЭСТЯ III: 19–20.

**КИМЕ-Ү**, диал. **кәме-ү** «уменьшаться, уменьшиться; убавляться, убавиться» > чув. *кем-, ким-*, мар. *кӓмӓш, кемĕ-* (*кемиш*), удм. *кэмъ-* (*кэмънъ*) id. < гом. кыпч., алт. һ.б. *кэми-* ← *кэм* (к. **Ким**); тат. сөйл. **кимек-ү** «кими төшү, прогрессив кимү» сүзе очрый. К. түбәндәгеләрне.

**КИМПЕР** «старушка (из казахов)» < каз., кырг. һ.б. *кэмпир*, үзб., уйг. *кәмпир* «карчык» < фар. *кӓмпир, кампир* id., «кечкенә карт» (*кӓм* «кечкенә», *пир* «карт; остаз»). Чаг. **карчык < картчык.**

**КИМСЕ-Ү** диал. «стать, становиться малоценным» (шуннан әд. **кимсе-н-ү**, **кимсе-т-ү**) < гом. кыпч., к. гом. кыпч., уйг. *кэмсин-* һәм *кэмсит-*; чаг. бор. монг. *gemsi-* (хәз. монг. *гэмши-*) «үкенү, тәүбә итү». К. **Ким.** Räsänen 1969: 250.

**КИМТЕК** (Гиганов) «ущерб, изъян» ~ уйг. *кэмтүк* «җиткелексез» – *кэм* (к. **Ким**) сүзеннән шикелле, ләкин к. кырг. *кемтик* «кителгән төш», бор. төрки (ДТС: 297) *kemdük* «җимерелгән» ← *kem-* «кимерү» (?). Чаг. **Кәмшәй-ү, Кимтер.**

**КИМТЕР, кимтәр** диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «ущербность, ущербный, бесправный, нижайший» ~ фар. *кӓмтӓр* «кимрәк, кечерәк; мескен; икенче дәрәҗәдәге (кеше)». Элекке хатларда хат язучы үзен махсус кимсетеп *кимтәрегез ~ кәмтәрегез* дип яза торган булган.

**КИМШЕК ~ кишмек, кәмшек ~ кәшмек** «плюсна, гнездо орехов» < **кимеш-ек ~ *кәмешек* «ташландык» ← бор. төрки (Наджип 1989: 211–212; ДТС: 294, гомумән, күп чыганакларда очрый) *кӓмиш-* «ташлау, төшерү, ыргыту» ~ як. *кэбис-* id. К. ш. ук диал. (ТТДС II: 195, 198) **кәмшек ~ кимшек** «тешсез (тешләре төшкән) авыз».

Дерив.: **кимшеклә-ү ~ кишмеклә-ү** «чикләвекне оясыннан чыгару, чистарту». К. **Кәмшәй-ү.**

**КИНАЯ [кинайә]** «тонкий намёк (особенно в художественной речи); метафора, метонимия с подоплёкой» < гар. *кинāйӓ, кинāйӓт* id. Будагов I: 137.

Дерив.: **кинаяле, кинаясез; кинаялә-ү.**

**КИНӘ**, (ТТДС I: 238) **кенә**, иск. (Акмулла һ.б.) **кен, кене, кин** «затаённая враждебность, мстительность; злопамятность» ~ башк. (БТДҺ: 138) *кенәм* id. > мар. *кĕнӓ, кына* id. < фар. *кин, кина* «кинә, ганвә» ~ сугд. *ken, kyn* < бор. ир. *kaina*, авест. *kaena* һ.б. id., һинд-евр. сүзе, шуннан ук рус. *каять* «үкендерү; үч алу» һәм *цена* «бәя, хак» – төбендә «үч бәясе, җинаять өчен түләү, сатисфикация». Абаев I: 296; Фасмер II: 216. Чаг. як. *киӊ* «усаллык».

Дерив.: **кинәле, кинәсез; кинәчел, кинәлә-ү.**

**КИНӘН** (Тумашева 1992: 99) «свободный; без забот» ~ каз. (ҚТДС: 153) *кенен* id. ~ як. (Пекарский: 1020) *кӓнi, кӓнӓн* «гамьсез һәм эчкерсез» ~ бур. *гэнэн* < *гэнэхэн* «садә; дуамал», бор. монг. *genen* ~ чыгт. *kenen* «гамьсез» (к. Поппе 1938: 170) >> хак. *кинэн* «гамьсезлектән чыккан бәла», тув. *кенен, кенет* «беркатлы, наив» һ.б. ← **кэн-*, к. **Кинән-ү, Кинәт.**

**КИНӘН-Ү,** диал. (ДС I: 89; ДС III: 83 һ.б.) **кинәл-ү, килән-ү, киңән-ү** «наслаждаться достигнутым, чувствовать удовлетворение (от осуществления чаяний)» < гом. кыпч. *кэнэн-, кэнэл-* id. ← (каз.) *кэнӓ-* «канәгать булу» фигыленең кайт. һәм төш. юнәлешләреннән (тат. диал. *килән-* < *кинәл-* метатеза, *киңән-* халык этимологиясендә **киң** сү-

зенә нисбәтләүдән), к. ш. ук чув. *кан-* < **кән-* «тынычлану, тынычлык; кинәнү; ял итү» – болг. теленнән, *килен-, кинел-* «кинәнү» – татарчадан. К. **Кинән, Кинәт.** Чув. *кан-* «кинәнү, ял итү, тынычлану» сүзенең этимологиясен М.Р. Федотов (I: 212) **җан-у** (к.) фигыленнән эзли, ләкин бу бик шикле. **Кинәл-ү**, ихтимал, тув. *хенер* – «кинәт эшләнү, булу» белән бердәйдер.

Дерив.: **кинәнеш-ү, кинәндер-ү** (шуннан – **кинәндергеч** һ.б.); **кинәнеч**.

**КИНӘТ**, диал., сөйл. **кинәтен, кинәттән** «внезапно, вдруг» > чув. *кинет* id., мар. *кенета, кэнэтэ*, удм. (Насибуллин: 125) *кэната* ~ кар. *кэнэтэ, кенэтэ, кенятэ*, чыгт., куман. *kenete* < бор. монг. *genete, genedte* id.; к. ш. ук төркм., нуг., каз., к.-калп. *кенетен*, алт. *кенетийин*, хак. *кинэтĕн*, тув. *кенертен* ~ хәз. монг., бур. *гэнэт, гэнтэд* > эвенк. *гэнэтэ* «кинәт» һ.б. бор. төрки ***кән** «тынычлану хәле, кинәнеч; гамьсезлек» тамырыннан (к. **Кинән, Кинән-ү**), шуннан монг. телләрендә **кэнэд* > *гэнэд* «гамьсезлек» сүзе ясалган, шуннан төрки *кэнэдтэ* «гамьсез генә булганда» сүзе ясалган булса кирәк. Räsänen 1969: 252; ССТМЯ I: 180; ЭСТЯ V: 41–43 (бу хезмәтләрдә материал күп, ләкин тат., башк. *кинән-ү*, чув. *кан-* < *кән-* сүзләре искә дә алынмый).

**КИНДЕР** «ткань из конопляных ниток; конопля» ~ хак. *киндĕр* < гом. төрки *кэндир, кэндүр* id. (Räsänen 1969: 252) ~ венг. *kender* «киндераш» < болг. **кӑндӑр* > чув. *кантӑр, кантăр*, таҗ. *кандир* «киндер, киндераш» < бор. төрки (ДТС: 298) *kendir* «киндераш» **ken teri* «тукылган тире» (?); сүзнең *ken* өлеше халыкара тамырдан, к. төр. *kenevir*, мар. *кынья, кыне, кине*, удм. *кенем [кэнэм]*, морд. *кант*, коми. *кентус*, фар. *кана, канап*, бор. слав. *коноль, конопель*, ним. *Hanf*, эстон. *kanip*, фин. *hampрu* << шумер. *kunibu* «киндер, киндераш» (к. Абаев I: 513); рус. *кендырь* «киндераш» тур. Аникин: 282 (шунда ук әдәбият). К. **Киндерә.** ЭСТЯ V: 39–41.

Себ. (ЗДС: 311–312) **киндер** «кычыткан» элек киндераш урынына кычыткан файдаланудан.

**КИНДЕРАШ** «конопля» < *киндер ашы* (**ашы** монда «сабак», к. **Ашы**).

**КИНДЕРӘ** «шнур (из конопли)» ~ мар. *кӓндрӓ, кандра,* чув. *кантра* id. < бор. **кэндирәк* id., чаг. төр., төркм. *кендирик* «эскәтер», бор. төрки *кендүрүк* «зур эскәтер» (Мухамедова 1973: 121), төркм. *кендир*, аз. *кэндир* «киндерә». Чув. *кантăр, кантăра* сүзләре тур. Федотов I: 223–224. Тат. сөйләшләрендә дә **кәндер, кәндерә** сүзләре булган булса кирәк.

**КИНҖӘ**, диал. **кинцә, кинцәтәй** (Тумашева 1992: 99), **кинчәтәй** (ДС I: 87) «самый младший сын; последний ребенок», ш. ук (ЗДС: 312) **кинжә, кинҗә, кинцә** «младший», «единственный» ~ башк. *кинйә, кинжә, кинйәкәү, кинйәтәй* (БТДҺ: 144), ком., кырг., *кенҗе*, нуг., каз., к.-калп. *кенже* id., чыгт. *кенҗӓ* «иң кече кыз», ком. *генҗе*, үзб. (ЎХШЛ: 65) *генҗа, гәнҗә, кенҗа* «иң кече бала, төпчек» һ.б. этимологик хезмәтләрдә бор. монг. *kenǯe* «соң туган» сүзеннән дип күрсәтелә (к. ЭСТЯ III: 20–21). Ләкин бу нәтиҗә дөрес һәм тулы түгел. Монг. сүзе үзе төрки *кэйинчэ* «соңгы (бала)» сүзеннән килә, төрки сүз исә *кэйин* ~ бор. төрки *kejin, kedin, kezin* «арттан, соңыннан» сүзеннән ясалган (к. **Кәй**), к. каз. *кейінжі* «кинҗә» («последний, запоздалый, младший», к. Аманжолов: 383), алт. *кейин* «соңгылык, плацента» (к. Тощакова 1978). **Кинҗә** < *киенчә* дип Будагов та (II: 182) раслый.

**Кинҗә** сүзе белән тат. диал. (эчк., шрл.) **кинзә, кинзәтәй** «ялгыз, сыңар; төпчек (терлек баласы)», **кинчә, кинцә** «уҗым, көзен шыткан үлән һ.б.», **кинчәлек** «такыр басу, көзге үлән үскән басу» (ТТДС I: 246) сүзләре тамырдаш, к. к.-балк. *ханс, ханза* «шытым, уҗым», тув. *хенче* «көзен туган», *хенче сиген* «кинҗә җикән» – «курпы», таҗ., ягн. *kenǯa, kanja* «гадәттәгедән соң туган (терлек баласы)» ~ бор. монг. *kenǯe* «соң туган, зәгыйфь» ~ мар. Т. *кенза* «ашамый торган (бала)», бур. *хэнзэ* «курпы үлән; көзге тума» һ.б. Уйг. *кәнҗи* «кинҗә, соң өлгерүчән» сүзе фар. *кӓнҗи, гӓнҗи* id. сүзеннән һәм фар. *генҗ, кенҗ* < төр., гаг., кр.-тат., кар. *гэнч* «яшь» ~ бор. төрки (ДТС: 298) *kenč* «бала» сүзеннән килә, ә бу сүз шул ук *кэнҗэ* нигезеннән үзгәргән. Дөрес, ир. телләрдә дә шуңа охшаш сүзләр бар (к. **Кәниз, Кәнизәк**), ләкин алар төркимонг. телләрендәге *кэнҗэ* сүзе рефлексларына кереп бетмиләр. Чаг. **Кече.** Гомумән, монда төрле сүзләр контаминациясе бар бугай.

**КИҢ I,** себ. (Тумашева 1992: 95) **кәң** «широкий; широко» < гом. төрки (Радлов II: 1067) *кӓң, кэң*, госм., кр.-тат. *гӓң*, ком. *гең*, төркм. *гииң* ~ як. *киэң*, бор. чыгт. *kӓing* id.; монг. *кэң, гэң* төрки телләрдән. Бу сүзнең чув. һәм мар. телләрендә юклыгы игътибарга лаек. Бор. төрки (ДТС: 299) *keŋä-, keŋi-* «киңәю» ~ төркм. *гиң-* id. Аз. *кениш,* госм.

*гäниш* «киң» сүзләренең ясалышы безгә ачык түгел. Räsänen 1969: 253; ЭСТЯ III: 46–47.

**КИҢ II** иск. (в эпосе татар, башкир) «название высокого чина в Золотой Орде, у ногайцев, у крымских татар». «Идегәй»дә *Киң Җанбай* Туктамыш ханның «премьер-министры», иске Кырым ханлыгы документларында (Будагов II: 22) *қалғäй, ураддин* һәм *киңбуй* – ханнан кала өч югары чин. *Киңбуй* дигәндә *буй* «кабилә» булса кирәк. Тарихчы Әзһәр Мөхәммәдиев бу *киң* сүзен герм. телләрендәге *киң* «король» сүзе белән чагыштыра. К. **Буй II, Киңәшү.**

Дерив.: **киңлек; киңчә; киңәй-ү** (һәм аның юн. формалары).

**КИҢӘШ**, диал. (Тумашева 1992: 95) **кәңәш** «совет» ~ башк. *кәңәш* id. > чув. *канаш*, мар. диал. *кäңäш, каңаш*, удм., манси. *кенеш, кеңеш* < гом. кыпч. *кэңэш, кäңäш* < бор. төрки (ДТС: 298–299) *keŋäš, keŋiš* > угыз. *геңәш, гәңәш* id. *keŋä-* «киңәш бирү» фигыленнән ясалган исем (к. алт. диал. *кеңеш-, кäңäш-* «тыныч кына аңлату»), бу фигыль исә *кэң* тамырыннан, к. **Киңәш-ү. Киңәш** < *кэңэш* > *кәңәш* сүзләре төрки телләрдән күп күрше телләргә кергән (мәс., абаз. *к'аңаш* «киңәш»). Räsänen 1969: 253; Федотов I: 222–223; ЭСТЯ III: 21–23.

Дерив.: **киңәшләш-ү; киңәшче, киңәштәш.**

**КИҢӘШ-Ү,** диал. **кәңәш-ү** «советоваться» ~ башк. *кәңәш-* id. < гом. төрки *кэңäш-* < бор. төрки *keŋäš-* id. бор. *keŋä-* «киңәш бирү» фигыленең урт. юн. (бүтән юн. сакланмаган диярлек), фигыль исә **кэәң* исем сүзеннән, к. ком. *геңлеш- [гэң-лэ-ш-]* «киңәшү». ***Кэәң** сүзенең рефлексларын «Идегәй» дастанындагы **Киң Җанбай** («киңәшче Җанбай»), «Алтаин Саин Сүмә» дастанындагы **киәң** «патша, хөкемдар, баш вәзир», Ибне Фадлан теркәп калдырган бәҗәнәк титулы **күзәркин** < *күзәр киң* «күзәтүче хөкемдар», Кырымда булган (к. Будагов II: 22) **кәңбуй** титулларында күрергә мөмкин. Тарихчы Ә. Мөхәммәди раславынча, бор. ирани хәрефләр белән язылган һәм Идел-Урал регионында табылган язуларда *киң, кәиң* «король» сүзе укыла икән (к. ш. ук **Кенәз**). Бор. **кииң, *кэәң* сүзен маньч. *киң* < бор. кыт. *киң* «вәзир, канцлер» (к. ССТМЯ I: 395) сүзе белән чагыштырырга мөмкин, к. ш. ук вьет. *küeŋ* «король», бор. төрки-һунн. *кэң* «юрау, киңәш барабаны» (к. Фасеев 1978: 124–136). К. **Киңкерә.** Räsänen 1969: 253; Федотов I: 223. К. **Киңәш.**

**КИҢЕРТӘК,** (ДС I: 85) **кигертәк**, (трбс., без теркәдек. – *Р.Ә.*) **кикерәк, кикерек** «трахея; гортань» – тат. һәм башк. сөйләшләрендә гадәттән тыш күп вариантлы сүз, к. (Тумашева 1992: 93–98, БТДһ: 144, 173) **кәгелдерек, кәгилдерәк, кәңирдәк, кәүертәк, кикертәк; кәңәрҙәк, киңерҙәк, киңәрҙәк, киңәрҙәй, кигерләй, кигәл ~ кигәр** ~ каз., кырг. *кеңиртэк, кегирдек,* нуг. *кегирдевик*, уйг., чыгт. һ.б. *кэкиртэк, кәкиртәк*, үзб. *хэкиртәк* id. үзб. диал. (ЎХШЛ: 141) *кәңирчәк* «борын кимерчәге» ← башк. һ.б. (БТДһ: 141) *кәңәр, кигәр* < бор. төрки **кэңир* >> төр. *geniz* «борын-тамак юлы, шул юлдагы кимерчәкле органнар». Бу сүзнең веляр варианты да бар булса кирәк, к. себ. (Тумашева 1992: 133) **қуғыртак**, иске чыгт. (Поппе 1938: 297) *qanarıq*, бор. төрки (ДТС: 419) *qaŋraq* «бугаз», алт. *каңдай, каңдық* > рус. (Фасмер II: 157) *кондык* > *кадык* «бугаз төере».

**КИҢКӘ** (ДС I: 89; Тумашева 1992: 99; Валеев 1993: 85) «высокие галоши» < рус. диал. *ке́ньги, ке́нги* «кыска пима» < фин. *kenkä*, карел. *keŋgä*, эстон. *keng, king* «башмак», к. Фасмер II: 223; Аникин: 283.

**КИҢКЕРӘ** иск. (Котби телендә) «охотничий барабан» < яз. монг. *kenggerge*[n] (хәз. монг. *хэнгэрэг*) «барабан», бор. монг., төрки *кэң* id. К. ССТМЯ I: 450–451. Бу сүзне арытабан маньч. *киң* < бор. кыт. *киң* > кыт. *цин* «таш барабан, литофон» сүзе белән чагыштырырга мөмкин. ССТМЯ I: 395. К. ш. ук **Киңәш.**

**КИП** (ЗДС: 306, 312) «внешность; вид» (к. «Мөхәммәдия»дә: *тышы-кибе, эче дәхи ула саф*), (Тумашева 1992: 98–99) **киип** «одежда» ~ башк. *кип* «калып (икмәк, кирпеч өчен)» – төрки телләрдә исәпсез күп дериватлар биргән тамырлардан, к. хак. *кип* «күлмәк», алт., каз., к.-калп., кырг., уйг. *кеп, кэп*, тув. *хэп* «форма, кием; кыяфәт, маска, савыт, сумка, сөкәт, ярылмаган тире», як. *киәп, киэп* «форма; образ», төркм. *гәп* «карачкы» < төр., бор. төрки (ДТС: 299) *kip, kep* «форма», күп кенә чыганакларда *kär* дип бирелә. Бор. Идел-Урал регионында *кäп* яңгырашы киң таралган булган, к. мар. *кäп, кап* ~ чув. *кап* «тән, гәүдә, кыяфәт; күләм, зурлык», чув. *кап* «кебек» (чув. *пек* «кебек» сүзе дә *кеп* яңгырашыннан метатеза); бор. монг., калм. *кеб,* монг., бур. *хэб* «форма, модель, образец, фасон, фигура, вид» (Номинханов 1975: 256), эвенк. *кёп* «трафарет, форма, үрнәк» (ССТМЯ I: 388) –

төрки теллəрдəн. Бор. төркилектə *кäп* «санəм, пот, сын, тораташ» мəгъ. булган, шуннан рус. *капище* «мəҗүси гыйбадəтханə» сүзе килə (Фасмер II: 185).

**Кип ~ кэп** сүзенең дериватларыннан тат. телендə к. **Кəбəрə, Кэпəй-ү, Кэпəр ~ Кэпер, Кəбен ~ Кипен, Кэпрəн ~ Кипрəн, Кəбəк ~ Кибəк, Кəбəн ~ Кибəн, Кэплə-ү, Кəмəш, Кипкəр, Кебек** һ.б. К. түбəндəгелəрне. Будагов II: 151; Räsänen 1969: 253; ЭСТЯ V: 44–45; Федотов I: 224–225.

**Кап//кэп** «кием, савыт» кебек сүзлəр бик күп теллəрдə очрый.

**КИПЕН I** (ТТДС I: 247) «заварка, сухой чай» < рус. диал. *кипень* «шама; чəй».

**КИПЕН II** (Balint: 56; ЗДС: 312) «исправная (любая, хоть старая) одежда», диал. **кəбен, кибен** «наволочка подушки; подушка; лицо, маска; саван» (Тумашева 1992: 98; ТТДС I: 247; ТТДС II: 172) – **кəфен** сүзеннəн түгел («мендəр тышлыгы < кəфен» мөмкин түгел!), ə **кип** тамырыннан, чаг. тат. диал. **кибен** «кибəн (ябулы чүмəлə!)» (БҺҺ II: 80), к.-балк. *кебин* «кəфен; кипрəн, сүрү».

**КИПКƏР** «сушеница (растение)» – һəрвакыт кипкəн шикелле күренгəч, шулай аталган. Ясалышы ачык түгел. Ихтимал *кипкə-* дигəн фигыль бардыр.

**КИПКЕР,** диал. (ЗДС: 290) **кэпер, кэпкер, кэпкир,** (Будагов II: 112) **кебiиръ** «шумовка, дуршлаг», «пончики, испекаемые в дуршлаге» ~ каз. (ҚТДС: 143, 144, 150, 153) *какбiр, кəкбiр, кəкбар, кекпiр, кепкiр,* уйг. *кəпкүр,* кырг. *кепкир, кепкүр,* төркм. *кепгир* «тишекле чүмеч» < фар. *кäфгир, кäфкгир* «кипкер, тишекле чүмеч», сүзмə-сүз «күбек алгыч» (*кäфк* «күбек», *гир* ← *гирифтан* «алу»). Иске əд. телебездə нəкъ фарс. əйтелгəн *кəфкегир* «мəрхүмне искə алу кичəлəрендə так санда пешерелə торган кечкенə кабартма» сүзе **кипкер**дə пешерелгəне өчен шулай аталган.

**Кэпкер** вариантын **Кэпкер** «сүзчəн» (к.) сүзе белəн бутамаска.

**КИПРƏН,** диал. **киперəн, кэпрəн** (Троянский; Будагов II: 172; ТТДС I: 247; Тумашева 1992: 95, 99), себ. **кибрəн** «наволочка; оболочка; нижнее покрытие одежды» ~ башк. *кэпрəн, кэперəн,* нуг., каз., к.-калп. *кепирəн* «мендəр тышы; мендəр; ястык, түшəк» < **кепирäң* > * *кепирäй* > тат. **кəбəрə** (Ф. Бурнаш), **кəбəре, кəвəрə** «тупас форма; үзеннəн нəрсəдер ясау өчен камыр əвəлəмəсе; уклау, үзеннəн нəрсəдер ясау өчен агач кисəге һ.б.» (ДС III: 97; ТТДС I: 266) ~ үзб. (ЎХШЛ: 138) *кəвəрə* «гəүдə», төркм. *ковере* «əле яндырылмаган чүлмəк; чүлмəк яндыру миче», аз. *гавара* «буйсын, тышкы кыяфəт, форма» ← (кырг.) *кебер* «кабарынкы, күпкəн», алт. (Баскаков 1972: 221) *кебер* «сын, рəсем, минəз», *кеберы, кеберли, кеберлү, кепти* «төсле, кебек». К. ш. ук кырг. *кебете, кеберте* «форма, кыяфəт, төс», башк. (БТДҺ: 141) *киберһеҙ* «шыксыз; тыңлаусыз; ямьсез; кыяфəтсез (чəрексез, түземсез)», *кибəҙə* «озын чилəк, гөбе», «фанер (тышлык такта), кызау, тартма» < **кибəрə* һ.б. һичшиксез **кип** тамырыннан, к. ш. ук **Кипен II.**

*Кибəрə ~ кəбəрə* нигезе хəз. төрки теллəрдə сирəк очрый, лəкин иске теллəрдə ул еш кулланылган. Рус телендəге *кúвер* «парлак, биек баш киеме, төрек солдатларының каурыйлы биек бүреге», *коврига, каравай* < *каварай* (~ *кəвəрə* «камыр əвəлəмəсе», к. **Кəвəрə**) сүзлəре төрки теллəрдəн булырга тиеш (бу сүзлəрнең слав. яисə һинд-евр. теллəрендə канəгатьлəндерерлек этимологиясе юк).

**КИП-Ү (кипте, кибə)** «сохнуть, подсыхать» < гом. кыпч. *кеп-, кэп-*, үзб. (ЎХШЛ: 138, 142) *кəп-, кəви-,* ком. *кеби-* id. < бор. төрки (ДТС: 300) *kepi-*, (Räsänen 1969: 253) *käbi-* «өстəн кибү, кипкəн өслек пəйда булу», ихтимал, *кеп, кэп* «форма» сүзе белəн баглыдыр (к. **Кип**). Чув. *тип-* «кибү» < тат. (*к-* > *т-,* чаг. ш. ук үзб. диал. (ЎХШЛ: 250) *тəпсəй-* «кибү»). Федотов II: 233–234.

Дерив.**: кибек-ү; кибен-ү, киптер-ү** (шуннан **киптергеч** һ.б. сүзлəр); диал. **кибеш-ү.** К. **Кəбəрткe, Кипшен-ү.**

**КИПШЕН-Ү** диал. «высыхать, подсыхать» ~ башк. id. – **кипше-ү** сүзенең кайт. юн.

**Кипше- < кибеш-е-,** ягъни **кибеш* «кипкəн» сүзеннəн ясалма, шуннан ук **кибеш-ер-ү > кипшер-ү.**

**КИПШЕТ-Ү** «подсыхать (о почве после дождя, весенних паводков и т.п.)» – **кипше-ү** (к. **Кипшен-ү**) фигыленең йөкл. юн., затланышсыз мəгънəдə кулланылудан (чаг. **җепшет-ү, йончыт-у, ялкыт-у**).

**КИР I** «мухортый; игреневый, саврасый» < гом. төрки *кəр* id. (тəр., тув. *кыр*, як. *кэрэ, кäрä* «бурыл, чаптар», *кэрэмэс* «күгелҗем»). Еш кына (хəтта филологлар да) җырларда очрый торган (*Салават*

*батыр ир иде, Менгән аты кир иде…*) **кир** сүзен **кире** дип аңлыйлар. Хәлбуки **кир** төрки телләрдә киң таралган «аксыл туры» мәгънәсендәге сүз һәм аның бик кызыклы тарихы бар.

Бор. төрки *кәәр* (~ фар. *кәһәр*), монг. *кэгэр* «кир» төптә «мамонт, фил (сөяге)» һәм, гомумән, «әзмәвер, гигант» дигән сүз булган. *Кир* – «мамонт төсендәге» дигән сүз. Бор. Урта Идел төрки телләрендәге **кәр** «кир» сүзеннән рус. *карий* «коңгырт» сүзе килеп чыккан (Добродомов И.Г. Карий // Русский язык в школе, № 4, 1970). Төрки (бигрәк тә Себер төркиләрендә) мифологиядә *кәр кош* «гигант кош (рух кошы, сәмруг, ганка)», *кәр йылан* «гигант елан» *кәр балык* «кит» һ.б. (Новиков 1999).

**Кир** < *кәһәр* сүзен һинд-ир. телләрендәге *кәәрк* «кәркәдән, мөгезборын» сүзеннән килеп чыккан дип уйлыйлар. **Кәркәдән, кәркәдан** сүзе үзе бор. ир. *кәркән дан* «су сыеры» дигәннән яисә *khadga denu* «күлдәге тана» сүзеннән килә (к. Räsänen 1969: 256). Чаг. үзб. диал., уйг. *кәрк* «кәркәдән». Себ. татарларында **киртеш** дип Себердә еш табылган мамонт сөяген атыйлар һәм бу сүз, әлбәттә, **кир теше** дигәннән.

**Кир** сүзен эвенк. < яз. монг. *karetmun* «тиен» белән дә бәйлиләр (ССТМЯ I: 454; Аникин: 283–284). К. ш. ук ЭСТЯ V: 64–65 (материалы ярлы, әдәбият күрсәтелә). Безнеңчә, бу – шикле.

**Кәркәдән**не мамонт белән бутауның (алмаштыруның) тарихи нигезе бар: һәр ике хайванның сөяге (берсенең азаву, икенчесенең борын өстенә үсә торган мөгезе) сәүдә әйбере булган. Кәркәдәнне үз күзләре белән күрмәгән Себер халыклары кыйммәтле дару итеп сатылган кәркәдән сөяген үзенчәлекле мамонт сөяге дип уйлаганнар, ә кәркәдән турыдагы сөйләкләрне мамонтка нисбәт иткәннәр.

**КИР II** иск. «корчага, большой керамический сосуд» – шуннан **балакир** < *бала (кечкенә) кир* «балчык комган». Чаг төркм. (ТДГДС: 143) *киртаңңыр* «ләгән» < *кир таңгыр.* Ачык. түгел. К. **Киршән.**

**КИРАЗ, кирәз,** (Гиганов сүзлегендә **кирясъ**) «черешня» ~ кр.-тат. *karaz, qıras,* (Räsänen 1969: 255) *käraz,* төр. (Будагов I: 112) *кирас, kiraz* «татлы чия» (русчада да бар ди), куман. *kiräs* id. < лат. *cerasinum* < грек. *kerasijon* id., Kluge: 490. Рус. *черешня,* ним. *kirsche, kerse* шул ук нигездән.

**КИРӘ** (брб.) «вид пилы» (к. Räsänen 1969: 255), хәз. әйтелештә **герә, керә** диал. (Тумашева 1992: 96) «подпилок» ~ алт. *kärä, кэрэ* id. < гом. алт. **ki-rige*; тәфсилле этимологиясен к. Цинциус 1984: 92. Рясянен буенча, бу сүз тунг. телләрендә дә бар.

**КИРӘБӘЙ, кирбәй** диал., **кируба** кит. («Мөхәммәдия»дә) «самое сильное и большое из созданий Бога, ангел, который может охватить всю землю, покрыть крыльями все небо» – рус. *херувим* «иң көчле фәрештә» белән бер. Гомумән яһүди теленнән таралган.

Элек бездә **Кирәбәй** дигән кеше исеме таралган булган һәм аны руслар да балаларына кушканнар, к. Лермонтов поэмасында **Кирибеевич.**

Дерив.: **кирбәйлән-ү** (*кирбәйләнеп утыру*) «бөтен сәкене тутырып (итәкләрен җәеп) утыру», ш. ук (ЗДС: 313) **кирбәй-ү** «бик шәпле кыяфәттә утыру, басып тору».

**КИРӘГӘ** «обрешётка, каркас юрты, сетка из палок (унин)» < гом. кыпч. *кэрэгэ, кэрэгэй* id., күч. «зигзаг», чыгт., сарт., алт. *кэрэгэ, kärägä,* уйг., бор. төрки (МК) *keräkü, käräku* id. к. ш. ук төр. *kerake* (фар. теле аша булса кирәк) «кирәгә», төрле аз., төр. сөйләшләрендә «балаган, балчык өй» ← гом. төрки *кәр-* тат. диал. (Тумашева 1992: 96) **кәр-** «киерү» сүзеннән бугай. К. ш. ук бур. *хэрэ* «чатлаштыру». Чаг. **Кизәгә, Кирге.**

**Кирәгә** тур. күп язылган, ләкин төгәл генә этимологиясе юк.

ДТС: 300–301; Будагов II: 121; Räsänen 1969: 255; ЭСТЯ III: 24–25 (төркм. *гереге* «кирәгә» тур.).

Дерив.: **кирәгәле, кирәгәсез; кирәгәлә-ү.**

**КИРӘЙ I** иск., диал. **кәри** «извоз (промысел – перевозка грузов); аренда, плата за услуги» ~ нуг., кар., кырг., гаг. *кирэ, кира*, к.-калп. *кирей*, төр. *кира* id. < фар. < гар. *кирā'* id. Zenker: 742; Будагов II: 119. Гигановта: заклад – **керю.**

**КИРӘЙ II** – название одного из башкирских родов (монг. *кирэйит* «каргалар») – бүтән төрки халыкларда да еш очрый торган этноним һәм кеше исеме (татарда да булган). *Кирәйләр* – «кара татарларның» бер ыругы. Алар XI г. христианлыкны (несториан мәзһәбен) кабул иткәннәр, аларның *Сар Маркус* дигән ханы («Заятүләк» дастанындагы *Сары Мыркас*) миссионерлык белән актив шөгыльләнгән. К. Velidi; Гумилёв 1994: 167–170, 227.

XVI г. Казан асылзаты **Кирәй** исеменнән атаклы рус дворян фамилиясе – *Киреевлар* килә. Чаг. **Гәрәй.**

**КИРӘК I**, диал. **кәрәк** «надо, нужно; то, что нужно», «хоть (*кирәк кем* хоть бы кто)» ~ башк. *кәрәк* id. > чув. *кирек* (в значении модального слова и союза), мар., удм. *керек* < гом. төрки *кэрэк, кэрӓк* id. ← бор. төрки *kärgä-, kergä-* «ярашу; җитү, җитешмәү» (Räsänen 1969: 256), к. **Кирәк-ү.** *Кирәк ~ кәрәк ~* яз. монг. *kereg,* як. *käräk* «мәҗүси дини гамәл» мәгъ. дә кулланылган, к. Аникин: 343–344.

Чув. *кирлĕ, кирелӗ, киревлĕ* «кирәк» ~ мар. *керал, кералĕ* < бор. тат. *кирәwле (< кэрэwли < кэрэгли*) булса кирәк; гомумән, *кирәк* сүзе сыйфат мәгъ. *кирәкле* сүзеннән килеп чыккан; исем мәгъ. *кирәк* < бор. *kergäk*. К. **Кирәк II, Кирәк-ү.** Будагов II: 119–120; Räsänen 1969: 256; ДТС: 300–301; Федотов I: 299; ЭСТЯ III: 25–27.

Дерив.: **кирәкле, кирәксез; кирәклә-ү, кирәклек; кирәгәй-ү; кирәксен-ү** һ.б.

**КИРӘК II** диал. «предел» ~ башк. *кирәк* «ят яклар; бигәнәй» (БҺҺ II: 106) < бор. төрки *kergäk* «оч, кырый, чит» (*kergäk bol* «үлү; бетү», *kergäksiz* «очсыз-кырыйсыз», к. ДТС: 300–301), як. *кэрэх* «явыз рухларга корбан», *кэрэдэх* «биленке, бигәнәй, сукбай»; чаг. ш. ук нан. *хэргэ*[н] «яс тоту вакыты (мөддәте)», маньч. *хэргэн* «чик сызык; сызыкча, хәреф; язу» (ССТМЯ I: 482). К. **Кирәк-ү, Киргәк.**

**КИРӘК-Ү (кирәгү)**, диал. **кәрәк-ү** «стать, становиться нужным» < гом. төрки *кэрэк-* < *кэргэк-* id. ← *кэргӓ-* «җитешмәү, җитмәү» («җитми > кирәк»), ләкин шуннан ары этимология куе томанда кала. А. Йоки *kerge-* < монг. *kerege-* «аркылы-торкылы бәйләү» дип бара (Joki 1952: 177), ул чагында **кирәк-ү** фигыле **кирәгә** белән тамырдаш булып чыга!

**КИРӘМ I** иск. «землянка в лесу (для охотников, лесозаготовителей и т.п.)» < бор. төрки *keräm* id. (ДТС: 300) ~ монг. *кэрэм* «кирмән». К. **Кирмән, Киртә.**

**КИРӘМ II** диал. «верёвочная лестница (охотников, бортников)» ~ башк. *кирәм, кирам, кәрәм* (к. БҺҺ II: 124; БҺҺ III: 99), иске тат. *хәрәм* «шнур, скань (проволочный узор в ювелирном деле)» ~ мар. *керéм* «шнур, аркан» (Иванов, Тужаров: 81), «бау, элекке җир үлчәү бәрәмлеге (Саваткова: 54), рус. диал. *кирень, керень, кирюн* «махсус бау, кирәм» (Полякова: 67–68). Ачык түгел. Тат., башк. **кир-ү, киер-ү** сүзеннән дип раслау (М. Рясянен) *кирам, кирюн* кебек вариантлар яңгырашын аңлатмый. К. ш. ук Фасмер II: 237.

**КИРӘМӘЙ** «упрямый, упрямец» (ТТДС I: 248) ~ башк. (БҺҺ I: 192) *киҙәм* id. – **кире** сүзеннән булса кирәк. Чаг. башк. *кирем* «каршылык, үҗәтлек».

**КИРӘМӘТ**, диал. (Тумашева 1992: 99) **кәрәмәт** «чудо, чудеса» ~ башк. (БТДҺ: 145) *карамат* id. < тат. кит. *кәрәмәт* «шәрәф, (әүлияда булган) абруй, могҗиза; киң күңеллелек» < гар. *кӓрамӓт* id. ← *крм* «юмарт, киң күңелле, игелекле булу» > гом. кыпч. *кэрэмэт*, үзб. *каромат* id., ком. *карамат, керемет* «тылсымлы көч», к.-балк. *керамат* «оҗмах» һ.б. К. ш. ук исемнәр: **Кәрәм, Кәрим, Кәримә, Кирам** һ.б.

Бу сүз Идел-Урал регионында үзенчәлекле «изге зат; изге затның могҗизалы, тылсымлы кабере» мәгъ. алган, к. тат. диал. **кирәмәт** «мәҗүси каберлек», «яланда ялгыз үскән карама агачы – караманың вак яфраклы төре (аны фаҗигале үлем белән үлгән кеше каберенә утырткannar)» (к. Мөдәррис Ш. Яшел тасма: 17), чув., мар., удм. *керемет* (> рус. *кереметь*) «мәҗүси табыну урыны булган агачлык; корбан таләп иткән явыз рух һ.б.ш.»; крш. тат. **кирәмәт** «үзендә рух яшәгән әйбер» тур. зур әдәбият бар. Софийский: 69–76; Коблов 1910: 457–459; Матвеев 1910; Смирнов 1889: 220–221; Золотарев 1964: 258–260; Владыкин В.Е. Культ кереметі у удмуртов // Вопросы советского финно-угроведения. Саранск, 1972: 75–77; Hämälainen A. Das kultische Wachsfeuer der Mordwinen und Tscheremissen // JSFou XLVIII. Helsinki 1936–37: 1–158 һ.б.; Ахметьянов 1981: 31–33; Федотов I: 297.

Дерив.: **кирәмәтле; кирәмәтлек.**

**КИРӘП** себ. «корабль» < грек., к. **Кәрап**.

**КИРГӘК**, диал. **кирәк** «чужбина; чужой», **киргәк** «отчуждённый; нелюдимый» ~ башк. диал. (БТДҺ: 145) *кирәк* id., ш. ук башк. *кирә ҡ҄ӧрт* «аерылган күчкә куныр урын эзләгән бал корты», *кирәлә-ү* «аерылган күчкә куныргa урын эзләү».

Морфологик составыннан чыгып, **киргәк** сүзе ***кир-** фигыленнән дип әйтергә мөмкин, ул фигыль исә **гиз-ү** (к.) белән чагыштырыла ала. К. **Кирәк II.**

**КИРЕ** «обратно; назад; упрямый, непослушный», диал. «после, за, повторно; снова» > мар., удм. *керы* «үҗәт» < гом. кыпч. *кэри*, ком., угыз. *гэри* < бор. төрки (Радлов II: 1095; ДТС: 302) *käri, keri, kerü* «назад; обратно»; борынгырак яңгырашы себ. (Тумашева 1992: 93) **кәйрĕ, кәйри** «яңадан» булса кирәк һәм бу сүз **кәй** (к.) тамырыннан ясалган дип

уйларга нигез бар. Будагов II: 175–176; ЭСТЯ III: 27–28 (Э.В. Севортян себ. тат. сүзен игътибарга алмаган, шунлыктан кыюсызлык күрсәтә).

Дерив.: **кирегә, киредән** «кабаттан»; **киреле > кирле; кирелек; кирелә-ү, кирелән-ү.**

**КИРКӘ,** себ. (Тумашева 1992: 95) **кәрге < кәрке** «кирка» < **кирткә, киртке* id., **кирт-ү** фигыленнән; к. уйг. *кәкә, кәки, кәрткә, кәртки* id., ш. ук «аркылы балта», аз. *кәрки, кәртки* «киртке». Рус. *кирка* < тат.

**КИРМӘН** «крепость» ~ кар. *кирмэн, кармен*, чув. *кермен, карман*, мар. *кäрмäн > карман* «крепость; дворец, чертог» < куман., чыгт. *кäрмäн*, төр., иске кыпч. *кермен, кэрмэн* id. < бор. монг. *kerte*$^{n}$ id. (Poucha: 99), иске тат. *Ханкирмән* – Касыйм (Касимов) шәһәре (чөнки анда XVII г. азагына кадәр татар ханнары токымы яшәгән); рус чыганакларында бу шәһәр *Городец* дип атала, бу русча атама үзе **Кирмән** сүзенең тәрҗемәсе булса кирәк. Чаг. мар. *Угарман* «Яңа Кирмән» – Түбән Новгород, *Ошкермен* «Ак кирмән» id.

Гомумән, *кирмән ~ кәрмән* сүзе хәз. төрки телләрдә сирәк очрый һәм аның башлыча Идел-Урал регионында саклануы игътибарга лаек.

Лингвистик әдәбиятта рус. *кремль* сүзенең **кирмәл* < **кирмән* (*-н > -л* бик мөмкин, чаг. *каптал < каптан, мал- < ман-, тәбәлдерек < табандырык* һ.б.ш.) мәсьәләсе күп тапкырлар күтәрелгән. Рус. этимологлары, Фасмер (II: 224), Дёрфер (Doerfer, 4: 300–302) бу гипотезаны кире кагалар, ләкин **кремль** сүзенең бүтән этимологияләре дә ышандырырлык түгел. Шуңа күрә, *кремль < кéрмәл* фаразы үз көчендә кала (өстәвенә рус сүзе Алтын Урда чорында гына теркәлә һәм, гомумән, Алтын Урда монголлары теленнән булса кирәк).

Монг. *кэрмэн, кэрэмэн ~ кэрэмэл* (?) һичшиксез бор. монг. *kerem* (хәз. монг. *хэрэм*) «кирмән дивары; кирмән, ныгытма» сүзе белән (к. **Кирәм II**) бәйле, к. иске рус. *керемень* «кирмән» (Фасмер II: 224); сүзнең тамыры *кэр-, кэрэ-* «киртәләү, коймалау», чаг. **Кәртә, Киртә**. К. ССТМЯ I: 482–483. Фар. *кермен* «кальга» (сирәк кулланыла) монголчадан. Федотов I: 230; Тимергалин: 263–264.

**КИРПЕЧ**, миш. (ДС II: 125) **кәрпец,** себ. (Тумашева: 96; ЗДС: 319), **кәрмец ~ кирмец, кирбиц** «кирпич» ~ башк. *кирбес* (диал. *кирбез, кирбеч*) id. Чув. *кирпĕч, кирпич*, мар. *кервыч, кермыч, кĕрпыц,* удм. (Насибуллин: 125) *кърпич, кэрмич* id. төрле тат. сөйләшләреннән. Төп тат. варианты бор. төрки (ДТС: 301), төр., төркм. *kärpič, kerpič* «кирпеч; туңка» сүзенең дәвамы (иң киң таралган фонетик вариантыннан); рус. *кирпич* татарчадан (э > *и*). Бүтән вариантлар: үзб. (ЎХШЛ: 142) *кәрбич, кәрвич*, куман. (Радлов II: 1107) *кäрпäц,* бор. кыпч. (Räsänen 1969: 256) *kärpüč,* (Боровков: 180) *кäрпäч* һ.б. Күп телләрдә һәм вариантларда очравына карамастан, сүзнең чыгышы-ясалышы һаман ачыкланмаган (төрле фаразлар гына бар). Фасмер II: 238; Федотов I: 299.

**Кирпеч** төрки телләрдән һәм рус теле аша Евразиядәге күп телләргә таралган. Рус. *кирпич* (кайбер очракларда) «акча функциясендә такта чәй» тур. Аникин: 291. Укр. *кирпич* «кизәк» мәгъ. генә кулланыла. Каз. *кірпіш* рус теленнән алынган бугай (Урта Азия телләрендә «кирпеч» мәгъ. ешрак фар. *гишт* сүзе кулланылучан). Чаг. **Кәртемәч.**

Рясянен, **кирпеч** сүзе *керамик, керамит* сүзләре белән баглы бугай, ди. Арытабан шул ук тамырдан *чирәп* килә.

**КИРТ** «рез, насечка, зарубка» ~ чув. *карт < кäрт*, хак. *кирт* < гом. төрки *керт [кэрт]* id. (кайбер төрки телләрдә очрамый), к. **Кирт-ү. Кирт** сүзеннән **киртлә-ү** фигыле ясалган. Фар., көрд. *kert* «кирт» төрки телләрдән. Федотов I: 231; ЭСТЯ V: 54–55. К. ш. ук **Киркә.**

**КИРТӘ** «ограда; препятствие», **кәртә** «ограждение, двор; жердь (для ограды)» ~ чув. *карта [карда]* < мар. *карта < кäртä* < тат. **кәртә** < бор. **кэртэ > киртә*, к. ш. ук удм. диал. *кäртä*, коми., манси. һ.б. *карта*, манси. *карда* һ.б. «кәртә». К. ш. ук каз. (ҚТДС: 156) *керте* «кәртә-кура, читән; арбачана» < тат. **киртә < *кәртэ.** Хәз. һәм бор. төрки телләрдә юк, шуңа күрә аның этимологиясе бәхәсле. М. Рясянен (Будагов буенча) бу сүзне **кирт, кирт-ү** сүзләре белән бәйли (Räsänen 1969: 257), чаг. чув. *карта* «киртә, кәртә», *карт-* «киртү» ~ төр. *kerte* «чик; кирт; участок», *kert-* «киртү, чиген билгеләү». Икенче җәһәттән *kert* яңгырашындагы сүзләрнең халыкара киң таралуына игътибар итәләр: к. осет. *кäрт*, чеч. *керт* «кәртә (ограда, двор)», литв. *gardas* «лапас», гот. *garda* «карда, кәртә», морд. *гардас* «йорт, кәртә-кура», венг. *kert* «кәртәләнгән урын, бакча» һ.б. (Абаев I: 515, 524, 586; Joki 1973: 270, бик күп мисаллар китерелә), фин. *kartano* «кәртә-кура» (к. КЭСК: 117–118) һ.б., шул сүзләрнең берсе бор. төрки теленә кереп, фигыль мәгънәсен алган булса, фигыльдән *кәрт-ә < кэрт-э*

> *киртә* ясала ала. Чаг. ш. ук **Киртәк.** К. **Кәртә.** Федотов I: 231–232.

Дерив.: **киртәлә-ү, киртәле, киртәсез.**

**КИРТӘК** тар. «брачный терем; шатёр для новобрачных» ~ куман. *kärtäk* «бүлмә», кар. *кэртэк,* төр. *gerdek*, төркм. диал. (ТДГДС: 55), аз. (Будагов II: 122) *гердек* < фар. *гäрдäк* «түгәрәк тирмә; киртәк; түгәрәкчек» ← *гäрд* «әйләнә, түгәрәк». Фарсыча этимон ышандырырлык булса да, **киртәк ~ кәртик** шул ук *киртә ~ кәртә* түгелме икән, дигән фикер туа, к. себ. (Тумашева 1992: 98) *кирт-ү, кийерт-ү, кәрт-ү* «бура бурау» → *киртәк, кәртәк* «бура»?

**КИРТЕК** «зарубка, засечка, надрез, метка; зазубрина» < гом. төрки *кертик (кэртик, кäртик)*, хак. *киртік* id. һ.б. *кирт-* фигыленнән. Күптән теркәлгән сүз: бор. төрки *kertük, kertik* id. (ДТС: 302).

**КИРТЕН-Ү** диал., иск. «зарекаться, горячо утверждать» ~ хак. *киртін-*, алт. *кертин-* < бор. төрки *kertün* «ышандыру, раслау, дөресләү», (ДТС: 301) *kertgün-, kertkün-, kertkin-* «инану» һ.б. ← **Кирт-ү** (к.), **Кирчәк.**

**КИРТЛӘЧ** «зубчатый» > башк. *киртләс* ~ чув. *картлаç* id. Идел-Урал региональ сүзе булса кирәк. Әлбәттә, **кирт-ү** фигыленнән.

**КИРТМӘ I**, **кәртмә** (ЗДС: 292, 314) «срубное сооружение; небольшой сруб, охотничий домик в лесу», «зарубка» диал., башк. (Тумашева 1992: 96, 99; БТДҺ: 145) «забор из плах (из расколотых надвое брёвен: прежде, когда распиливать бревна на доски, было трудно и дорого, нередко обходились плахами)» ~ алт. *кäртмä, кертпе,* рус. (төрки телләрдән, к. Аникин: 224) *керма, кортма, кртма, кыртма* «төрле максатларда ясалган бура» ← *кирт-ү,* (ЗДС: 292) **кәрт-ү** «бурау һ.б. ← гом. төрки *кирт-, кэрт-, кәрт-* «киртү».

Бу махсус мәгъ. сүздән тыш, төрки телләрдә тат., башк. диал. *киртмә ~ кәртмә* «баскыч; басма» һ.б.ш. сүзләр регуляр рәвештә ясалып тора. Чаг. **Киртләч.**

**Киртмә** сүзенең ихтимал булган *киртмән* вариантыннан **кирмән** (к.) сүзе дә килмиме икән фикер туа (гадәттә **кирмән** сүзен монг. теленнән диләр).

Дерив.: **киртмәлә-ү, киртмәле.**

**КИРТМӘ II** (ЗДС: 314) «закваска для теста (специально оставленная часть теста); маленький хлебец (из остатков теста)» **гердә** id. (к.) сүзе белән тамырдаш булса кирәк.

**КИРТМӘ III** (әстр., ЗДС: 314) «груша» ~ к.-балк., ком. *кертме* id. Кавказ телләреннән булса кирәк.

**КИРТ-Ү,** диал. (Тумашева 1992: 98, 100) **кәрт-ү, кийерт-ү, кирет-ү** «надрезать, насекать, делать метку, зарубку», диал. «срубить сруб» < гом. төрки *керт- (кэрт-, кäрт-)* < **кээрт-*, монг. *хэрчих*. Чув. *карт-* id. (чув. *карт* – кискен кисү хәрәкәте «кырт» белән чагыштырыла (к. Ашмарин VI: 105–117), чыннан да, барлык телләрдә *крт* кисү, киртү һ.б.ш. белдерә, к. һинд-евр. *kert* «кисү», индонез. *kerat* «кисәк», *kerut* «кимерү» һ.б.ш. Дериватлары ишле: **киртел-ү, киртеш-ү, кирттер-ү, киртен-ү,** к. **Киркә, Кирт, Киртек, Киртләч, Киртмә I, Кирчәк, Киршән.**

**КИРЧӘК,** диал. (Тумашева 1992: 96) **кәрчәк, кәрцәк, кәрсәй** «правда; правдивость, суть», крш. **кярцяк** «искренний» < көнб. кыпч. (кар., кр.-тат. һ.б.) *кэрчэк* id. ~ төркм. *гәрчәк, гәрҗәк* (к. ЭСТЯ III: 28–30), төр. *gerçek* «дөрес; дөреслек» < бор. төрки *кэрт-чэк* id. *кэрт* «кирт» сүзеннән: дөреслек, тугрылык, ант, шартнамә билгесе итеп нәрсәне дә булса киртеп, билге кую гадәтеннән (чаг. *колагыңа киртеп куй, колакка киртү* «онытмаска хәтергә алып кую», к. Н. Исәнбәт, Фраз. сүзлек I: 392–393; *колак тешләтү* шул тарыздын), элекке заманнарда **җир киртү** – җир белән ант итү булган: «Угыз егетнең үпкәсе кабарды, кылычын чыгарды, җиргә сукты – *киртте*, әйтте ки: – Җир кеби *киртеләем,* туфрак кебек суырылаем, кылычыма туралаем, угыма чәнчеләем… бу киртәккә керер булсам, – диде» (Dede Korkut kitabı I, Ankara 1989: 193); к. кырг. һ.б. *керт* «колак тешләтү»; манси. (Kannisto 1912: 131) *керт, kert* < куман. *кäрти*, кар., к.-балк. *керти* «дөреслек, чынлык», к. ш. ук як. *кирдик, кырдьык* «чынлык, хакыйкать» ~ бор. төрки (ДТС: 302) *kertük, kertü* «дөреслек».

Бу сүзнең *-t* сыз варианты мари телендә сакланган: мар. диал. *кир, кир ок, кере, кер ок* «чын, чынлык, чыннан ук» (к. Иванов, Тужаров: 81, Саваткова: 56) ~ гаг. *кер* «хакыйкать», мар. әд. *кере* «чынлык» ~ тув. *кереэ* «шартнамә», эвенк. *гэрэчи* «гүаһ» < як. *кэрэси, кэрэһи* «гүаһлык, таныклык», *кэрэсик [кäрäсік]* «гүаһ, танык, шаһит», бор. монг. *gerči* id. (к. ССТМЯ I: 182). К. ЭСТЯ III: 28–30. К. **Кирчегәй.**

**КИРЧЕГӘЙ** (А. Гыйләҗев), диал. **кирчегә, кирчәгәй** «секрет ремесла; каприз; заковыка» < бор. монг. *kerčigei* «кырыс чынбарлык; кырыс, усал» сүзеннән *kerči-* < **kerti-* «дөреслек таләп итү» фигыленнән, *kert* «дөреслек, ант һ.б.». К. **Кирчәк.**

**КИРШӘН,** себ. (Дмитриева 1981: 159–160) **кәршән** «корыто; большая деревянная чаша» ~ башк. (БҺҺ III: 99), үзб. диал., уйг. *кәрсән* > манси. (Kannisto 1912: 131) *kersen, kärsän* id. < гом. кыпч., к. нуг., ком. *кершен*, каз., к.-калп., төркм., төр. *кәрсән*, үзб., төр. диал. *карсан*, аз. (АДДС: 259) *кәрсән* «камыр изү тагарагы», төркм. «гомумән агач табак», үзб. диал. *кәрсән* һ.б. id. (к. Redhouse: 641; Räsänen 1969: 257; ЭСТЯ V: 53) фар. теленнән алынма дип исәпләнә, ләкин фар. *карсан* «камыр табагы» сүзенең үзенең чыгышы ачык түгел. Анары, чаг. **Кир II, Кирт-ү.**

**КИСАП** «пест» < **киле сап**, к. каз. *келсап*, нуг., к.-калп. *кели сап*, кар. *кели сабы* id.; чув. *кисеп* «кисап» < тат. (Егоров 1964: 114); к. **Киле.**

**КИСӘК I** «кусок» < гом. кыпч. *кэсэк* id. **кэс-** «кисү» сүзеннән, әлбәттә.

**КИСӘК II, кизәк** (ЗДС: 305, 314–315) «внезапно, вдруг; иногда, изредка» (мишәрчәрәк) **кизцәк* ~ **кизчәк* сүзеннән булса кирәк, к. **Киз II** (момент). Чаг. **Иртәнчәк**. К. **Кизәк II.**

**КИСӘРТКЕ,** диал. (ЗДС: 293, 305, 315 һ.б.) **кәсәртке, кизәтке, кисеркә,** себ. (Тумашева 1992: 93) **кәзәлткү** «ящерица, мелкий вид ящериц» ~ башк. *кәсәртке,* нуг. *кесертки,* кар. *кэсэртки, кесиртки, касарткы,* каз. *кесартки*, к.-калп. *кесиртки,* чыгт. *кäсäрткä*, бор. кыпч. *käsältkü, käsältki,* к.-балк. *кеселекке,* ком. *гесертки* һ.б. бор. төрки (Боровков 1963: 173 һ.б.) *кäсäт-* «өзгәләү», *кäсіл-, кäсул-* «өзелү» һ.б.ш. сүзеннән булса кирәк (кәлтәләрнең үз койрыкларын өзеп качу гадәтеннән), чаг. себ. (Тумашева 1992: 96, брб.) **кәсләнчүк** < уйг. *кәсләнчүк,* бор. төрки (ДТС: 303) *keslančü* ~ чыгт. *кäслäн* «кәлтә; елансыман кәлтә (полоз)»; кырг. *кескек, кескелдирик* «кәлтә». Чаг. **Кәлтә.** К. Будагов II: 127; Zajączkowski 1961: 94

**КИСӘТ-Ү** «строго предупредить; наказывать заранее, пугать», себ. (Тумашева 1992: 96) **кәсәт-ү** «приказывать» ~ уйг. *кәсәтку* «тыю», тув. *кезет-* «җәзалау, кисәтү; өйрәтү» ← *кезе-* «куркытылган булу», як. *кэһэй-, кэсэй-* «җәзасын күрү, сабак алу», *кэсэт-* «җәзалау, иманын укыту, үкендерү» ~ бур. *хэһээ-*, монг. *кэсээ-* < бор. монг. *kesege-* id. > эвенк. *кэсэ* «азап», нан. *кэсэ-* «үкенү» (к. ССТМЯ I: 455) ← як. *кэс* «тыюлы, намуслы; көмәнле» – бор. җенси дисциплина белән бәйле.

**КИСӘҮ [кисәw],** диал. (Тумашева: 92) **кисәү, кизәү** «кочерга» – диал. **кисәү агачы** тәгъбиреннән эллипсис < башк. (БТДҺ: 175) *кәсәү* id., нуг., каз., к.-калп., ком. *кесев [кэсэw],* бор. кыпч. (ИМ) *küsägü,* бор. төрки *közegü,* (ДТС: 321) *közägü* > куман. *kösov* ~ нуг., каз. *köсеw*, кырг. *көсөө, көзөө,* уйг. *көсөй, көсәй* id. ш. ук «ут кыскычы» һ.б., тат. диал., башк. *күзә-ү, күҙә-ү* «учакны рәтләп тору» ← *күз* < *көз* < *қоз* «утлы күмер» сүзеннән. К. ш. ук төркм. *кесеви* «кисәү», кар. *күсэв, кисэв, кöсöв, кöсүв, кöсэв, кюсев* «факел», ком. *кесев* «кисәүбаш» ~ алт. *кöсöк* «кисәү», тув. *кезек* «кисәүбаш» һ.б. Joki 1952: 202; Räsänen 1969: 293; Мухамедова 1973: 122 (тагын мисаллар китерә). Гомумән, **кисәү** һәм **күсәк** бер нигездән. К. **Күз II, Күзә-ү, Күсәк.** Чаг. **Кучарка.**

**КИСКӘ,** диал. **кискәк** (ТТДС I: 248) «колода, чурбан, плаха» > удм. *кеска* «тик ятучы» < бор. болг. (?) **кэскэ* > **кәскә* > мар. (Иванов, Тужаров: 79) *кäшкä* «кискә» ~ чув. *каска* id. Тат. диал.. башк. *кискә* «лапы, киселгән ботаклар» (БҺҺ III: 82) яңа ясалма. Болар барысы да, әлбәттә, **кисү** фигыленнән.

**КИСКЕН** «резкий, острый» < гом. төрки *кэскин* id. ← *кэс-*, к. **Кис-ү**.

**КИСМӘК** «кадушка» > удм. *кесмек* «тырыс», чув. *касмак, касмăк* < бор. **кэсмэк*, к. кырг., каз. *кеспек* id. *кис-ү* фигыленнән (*кисеп* уеп ясалган савыт). Федотов I: 236; ЭСТЯ V: 59.

**КИСТӘН,** диал. (ЗДС: 316) **кистан** «кистень, палка или шнур с железной головкой» > чув. *кистен,* мар., удм. *кестен* «кистән; бизмән таягының башы»; рус. *кистень* < тат. (Фасмер II: 240) ~ чыгт. (Будагов II: 177) *кистан*, фар. *кäстäн* id. Федотов I: 299; ЭСТЯ V: 58 (чыгт. *кескен* id. төп форма итеп китерелә, ләкин, безнеңчә, бу шикле).

**КИСТӘ-Ү** (Будагов II: 177) «вышивать (шёлком)» ~ кырг. *кеште-* id. ~ кырг. *кеште*, уйг., үзб.

*кәштә*, каз., к.-калп. *кесте* «чигеш»; чаг. фар. *кäшидан* «чигү» ~ *кäшида* «чигелгән; чигеш». ЭСТЯ V: 61. К. **Кәштә.**

**КИС-Ү I** «резать» < гом. төрки *кәс-*, уйг., угыз. *кәс-* >> чув. *кас-* id.; М.Р. Федотов (I: 233–235) бу сүз белән тат. **кәс** < *кәз* «чирәм кирпеч» сүзен бәйли, ләкин, безнеңчә, бор. кыпч. фараз өстәмә дәлилләр сорый, Räsänen 1969: 257; ЭСТЯ V: 55–57.

**Кис-** бик продуктив нигез: **кисел-ү, кистер-ү, кисеш-ү** (бу юн. формалары аерым мәгъ. ия), **кисәк, кисек, кисем, кисенте.** К. **Кискә, Кискен, Кисмәк.**

**КИС-Ү II** «выражаться особенно явственно» (употребляется только предпозитивными прилагательными: *кара кискән ~ киселгән* «отроду чернявый», *туң кискән ~ киселгән* «совершенно тупой, безнадежно туп» и др.) – **кис-ү I** белән баглы булса кирәк.

**КИТ I** «кит, касатка» < рус. < грек. К. **Хут.**

**КИТ II** сөйл. «задняя сторона» (к. мәкаль: *Дөнья бер битен, бер китен күрсәтә*). Бор. төрки *ket* (к. **Кәй**) ~ монг. *гэд* id. Фразема: **киткә китү** «артка китү».

Дерив.: **китен** «артка», **китенлә-ү** «сүздән баш тарту».

**КИТАП** «книга» < гар. *китāб* id. ← *ктб* «язу» тамырыннан, шуннан ук **мәктәп, мәктүп, көтеп** (к. **Көтепханә**), **кятип.** Иске тат. **китабәт** «һәртөрле язулар, документация һ.б.». Будагов II: 113.

Дерив.: **китаплы, китапсыз; китаплык, китапчы, китапчылык; китáпча; китапчык; китаби** (неол.).

**КИТӘН**, диал. **кетән, кәтән** «сорт холста с основой из фабричной, покупной, а уток из домотканной пряжи» ~ чув. *катам* id., *катан* «коленкор» (к. Ашмарин VI: 157) << мар. *кäтäн, кәтән, кытан* (Исанбаев 1978 33; Саваткова: 70) «китән» < гом. көнб. кыпч. *кәтән*, кар. *кетянь, кетэн, кәтән,* ком. *гэтэн,* куман., кр.-тат., госм. *кäтäн*, алт., тув. *кеден (кäдäн)*, бор. төрки *küdän* «мамык тукыма» (Räsänen 1969: 259), иске тат. (Будагов I: 114) *кәтүн* «мамык тукымадан тегелгән җилән» < гар. *кäттāн,* фар. *кäттāн, кäтан* «китән; җитен» ~ санск. *kettānā,* ассириячә *kitinnu* һ.б. «җитен; мамык» бик күп телләргә (бөтен дөньяга таралган сүз, к. Абаев I: 595), ахыр чиктә шумер *gad* «тукыма, киндер» сүзенә кайтып калса кирәк (семит телләре аша таралган). Шул ук тамырдан рус. *коттон* (тукыма төре, инглизчәдән) һәм *хитон* «каты җилән» (грекчадан) сүзләре килә. **Җитен** сүзе дә бор. болг. телендә *китен* яңгырашыннан (ә бу яңгыраш исә нииндидер Шәрык теленнән) килеп чыккан (*к-* > *й-* > *җ-* болг. теле билгесе) һәм **китән** сүзе белән тигез. К. **Җитен.**

**КИТӘР-Ү** «удалять, устранить» > чув. диал. *катер-*, кар. *кетәр-*, ком. *гетер-*, төркм., төр. *гидер-* id. Бор. төрки *ketär-* «китәрү» сүзен гадәттә *ket-* «китү» сүзенең йөкл. юн. дип карыйлар (к. ДТС: 303), ләкин тат. *китәр-ү*, нуг. *кетер-ү* башлыча «чәч, сакал кыру»га карый, шуңа күрә, *китәр-* < *килтәрт (keter- < kelter-)* «кыскарту» (к. **Кәлтә**) булырга мөмкин. К. **Килтә.** ЭСТЯ III: 39 (*кит-ү* сүзеннән дип карый).

**КИТЕР-Ү** «привести, приводить» < тат. диал., башк. *килтер-ү* ← *кил-ү* (шуның йөкл. юн.). ЭСТЯ III: 31–32 (Э.В. Севортян *китер-* һәм *килтер-*, гом. төрки *кэтүр-* һәм *кэлтүр-* һ.б.ш. парлар арасында мәгънә аермалыклары таба).

Дерив.: **китерел-ү, китереш-ү; китерт-ү.**

**КИТМӘН** диал. «кетмень, мотыга» ~ башк. *кәтмән* id. < гом. кыпч., чыгт. бор. монг. *ketmen, ketmān* (Будагов II: 173; Поппе 1938: 405; ДТС: 304), уйг. *кәтмән* >> мар. *катман*; борынгырак вариант тат. сөйләшләрендә: **киртмән, кертмән** (Арсланов 1976: 61; Арсланов 1988: 85) ← **кирт-ү** фигыленнән, к. ш. ук төркм. (Мухамедова 1973: 132) *кәәтмен,* аз. *гәтмән,* чув., мар. *катмак* «китмән» һ.б. Räsänen 1969: 259. К. **Кит-ү II.**

Дерив.: **китмәнлә-ү, китмәнче.**

**КИТРА** (ЗДС: 317) «мягкие валенки» < рус. диал. *кветра* < *хветра* < *фетр.*

**КИТ-Ү I** «уходить, отправиться» (употребляется в качестве глагола-модификатора) < гом. төрки *кэт-,* уйг. *кәт-*, төр. *git-* id. **Кил-ү** белән тамырдаш булса кирәк (*ки-л-, ки-т-*); Будагов II: 173; Räsänen 1969: 258; ЭСТЯ III: 19–50. К. **Китәр-ү.**

**КИТ-Ү II,** диал. **кәт-ү** (к. Тумашева 1992: 93 – **кәдик** «китек»; ТТДС II: 198) «отломить (острым орудием)», диал. «отколоть» >> мар. *кäт-, кат-*, чув. *кат-* < гом. кыпч., уйг. *кэт-, кәт-* < **кәлт-,*

*кäлт-* id., чаг. як. *кэлтэй* «кителү, яньчелү», алт., як., бор. монг. (Поппе 1938: 215) *кэлтэгэй* «китек», эвенк. *кэлтэ-*, яз. монг. *keltele-* «китү (отломить, откалывать)» (к. ССТМЯ I: 447). Бу тамыр *кэрт* (к. **Кирт-ү**) белән гомоген.

**Кит-ү** фигыленең киң таралган дериватлары – тат., башк. **китек**, (ТТДС II: 196) **кәтек** ~ удм. *кетык*, мар. *кäтык > катык*, чув. *катăк* < гом. чыгт. *кэтик,* бор. чыгт. *ketük* «кителгән; кителгән төш» (к. Поппе 1938: 215) һ.б. Федотов I: 238; ЭСТЯ III: 30–31 (этимология сай).

**КИФАЯ [кифайә]** «достаточно, самодостаточно» < гар. *кифāйā* id. ГТРС: 231.

**КИЧ** «вечер; вечером» ~ башк. *кис* ~ чув. *каç,* мар. *кас'* < *кāс'* < болг. **кэҗ* id. ~ гом. кыпч. *кэч* id. ~ угыз *гэч, гәәч, гäҗ*, уйг. *кәч* «соң; соңарган» (ЭСТЯ III: 50–52); иске уйг. *кич-, кәч-* «соңару» мәгъ. булган, шуннан кыпч., алт. *кэчик-* > тат. *кичек-ү* фигыле. К. ш. ук бор. төрки *keč* «соң, озак», *keč-* «соңару, соңга калу» (ДТС: 290–291). К. **Кичә, Кичек-ү.** Федотов I: 237–238; ЭСТЯ III: 50–52; ЭСТЯ V: 59.

Дерив.: **кичен; кичкелек** «кичке аш»; **кичле; кичлә-ү** һ.б.

**КИЧӘ** «вечер, вечерняя встреча людей, званый вечер и т.п.», кит. «ночь» и (через фразему *кичәгенәк* < *кичә генәк*) «вчера» ~ башк. *кисә* id. < уйг., урта төрки *кичэ, кичä*, куман., кар., уйг., бор. төрки *кäчä,* ком., к.-балк. *гэчэ*, төркм. *гиҗә*, як. *киэсэ* ~ *киэһэ* һ.б. «кич, төн». Бу сүз бор. бер мәдәни үзәктән таралган, шунлыктан аның фонетик һәм мәгънәви эзлексезлеге күзәтелә. Морфологик җәһәттән дә **кичә** билгеле бер модельгә карамый. Ихтимал, себ. тат. (Тумашева 1992: 100) **кичәү** «соң» (< **кич-ә-гү**) иң тәүге форманы чагылдырадыр (Räsänen 1969: 245). ЭСТЯ III: 40–41. К. **Кич-ү.**

«Үткән көнне» мәгъ. **кичәгенәк** (диал. **кичәген, кичәwен**) киң таралган (һәм бу вариант дөресрәк тә).

**КИЧЕК-Ү (кичекте, кичегә)** «опоздать» ~ башк. *кисек-ү* id., башк. диал. (БТДҺ: 146) «кич җитү» – ***кич-ү** «кич (соң) булу» фигыленең интенсивлык формасы.

Дерив.: **кичегел-ү, кичектер-ү.**

**КИЧЕН-Ү** «как-то жить, просуществовать (с трудом)» ~ башк. *кисен-ү* id. < гом. кыпч. *кэчин-* id. **кич-ү** «үтү, узу» фигыленең кайт. юн.

**КИЧЕР-Ү** «перевозить (на лодке); пережить, переживать; простить, прощать; миновать (трудную пору)» ~ башк. *кисер-еү* id. – **кич-ү** (к.) фигыленең «дөрес булмаган» йөкл. юн. < гом. кыпч., уйг. *кэчир-, кәчир-* id. К. бор. төрки (ДТС: 292) *kečür-* «кичерү» (төрле мәгъ.). Чув. *каçăр-* < бор. төрки **кэчĕр-* булса кирәк (*-и-* > *-ĕ-* > *-ă-*). Мәгънәсе – фар. *гүзаштан* фигыленнән калька.

Дерив.: **кичерел-ү, кичерен-ү, кичереш-ү, кичерт-ү.**

**КИ́ЧКЫРЫН,** диал. **кицкŏрŏн** «под вечер» < гом. кыпч., к. башк. *кисҡŏрŏн,* кар. *кечҡырын,* кырг., уйг. *кечҡурун, кәчҡурун,* нуг., каз., к.-калп. *кешкурун* id., к. тат. диал. *кичке кŏрŏн* (ТТДС I: 249–250) «кичке җыелып алу»; чаг. чыгт. *төрт ҡур (курун)* – тәүлекнең дүрт вакыты (к. **Корын**). Бүтән *өч корын* онытылган.

**КИЧҮ [кичӗw]** «брод» ~ бор. төрки (ДТС: 292) *kečig, kečüg* id. һ.б. – **кич-ү** сүзенең исемләшкән формасы.

**КИЧ-Ү**, миш., себ. (Тумашева 1992: 100) **киц-ү**, брб. **кәц-ү** «переходить; проходить» ~ башк. *кис-,* кр.-тат. (Dobr.: 68–70, 72–74, 257) *geç-, geş-, keç-* id., кр.-тат. сүзлегендә 27 мәгъ. күрсәтелә < гом. кыпч. *кеч-, кэч-* (> нуг., каз., к.-калп. *кеш-*), уйг. *кәч-,* угыз. *гэч-* ~ чув. *каç-,* бор. төрки (ДТС: 290–291) *keč-* «(төрле мәгъ.) кичү, үтү» > угыз. *гэч-,* як. *киэс-, киэһ-* id. һ.б. Будагов II: 115–116; ЭСТЯ III: 32–33; Федотов I: 237.

Дерив.: **кичер-ү,** сирәкләп **кичтер-ү, кичел-ү, кичеш-ү;** нык үзенчәлекле мәгъ. **кичек-ү** (бу сүз **кич-ү** һәм **кич** «ахшам» сүзләренең гомогенлыгын күрсәтә шикелле), **кичен-ү** (к. аерым матдәләр). К. **Кичү.**

**КИШӘҢКЕ** (ЗДС: 318) «полоса земли» к. **Кишәр.**

**КИШӘР** «полоса; участок земли» (чаще в форме **кишәрлек**) – бу сүзнең ышандырырлык параллеле мар. телендә генә: *кäжäр, кäшар* «сөрелгән, ләкин чәчеленмәгән җир; урманның аерымланган тоташ өлеше» (Саваткова: 51), к. ш. ук чув. *каçалăк* «кишәрлек» (Ашмарин VI: 146) – ләкин бу сүз чув. *каç-* «кичү, үтү» сүзеннән бугай.

Мар. сүзе *кäж* «көз, кәс» (к. **Кәс**) сүзенә мөнәсәбәтле булса кирәк. Гомумән, **кишәр** сүзенең этимологиясе ачык түгел. Хәлбуки игенчелек термины

буларак, бу сүз тарих өчен бик әһәмиятле. Шунлыктан, уйлануга мәгълүмат итеп: як. *кäңiгiр* (Пекарский I: 1071), *кэчэӊэр* (диал.) «тигез рәт, тезем», *кэчигирээ-* «тигез рәт булып урнашу», *кäчäрä, кäчiрä* «бер көс, көстәге үзара тип-тиң балыклар (гадәттә – кәрәкә)» > эвенк. *качаргэ* id. (ССТМЯ I: 385).

**КИШВӘР [кишwәр]** иск. «климатический пояс, географическая область» < фар. *кишвар* «кишвәр; өлкә, регион, ил».

**КИШЕР** «морковь» > мар., удм. *кешыр,* (ДАУ I: 125) *кэшыр, кэчыр, кишыр, кешер* < гом. кыпч. *кэшир*, төркм., чыгт., уйг. *кәшир* > үзб. *кашир* id., бор. төрки (ДТС: 303) *kešür* «редис», иске угыз. (Мухамедова 1973: 123) *käšvär* ~ төркм. *кәәшир* һ.б. (күп телләрдә очрый) «кишер» < фар. диал. *кэwзäр, кэзwäр* ~ фар. *гэзэр* > гар. *җäзäр* «кишер». Бор. рус. (Срезневский II: 1211) *кичири* һәм *кезер* төрки телләрдән. Кайбер төрки телләрдә кишер *сәртәк* дип атала, анысы да фарсыча (к. **Сәртәк**).

**КИШМЕК, кәшмек < кимшек, кәмшек** «шелуха орехов; плюсна, гнездо орехов», ихтимал, **кимешек ~ кәмешек** id. иске тат. **кимеш- ~ кәмеш-* < уйг. *кәмиш-*, чыгт. (Боровков 1963: 171; Наджип 1989: 211–212) *кäмиш-* ~ як. *кэбис-* «ыргыту, ташлау» сүзеннән ясалгадыр. **Кишәңке** (к.) формасы ***кимшәңке** (һ.б.ш.) яңгырашыннан ясала ала. Гомумән, ачык түгел.

Дерив.: **кишмеклә-ү.**

**КИШТӘ I** «полка, стеллаж», (ТТДС I: 250) «наклонный жердь, маяк», (ТТДС II: 198) «балка под потолком», (ЗДС: 318) «наклонный шест, жердь для подвешивания люльки (вместо пружины для покачивания)» и т.п., более широкий спектр значений и более широкое географическое распространение имеет вариант на *ә ~ а:* тат. диал. (ЗДС: 295, 318), башк. **кәштә** «полка; полати, настил; матица; покос, полоса» ~ мар. *кäштä, кашта* «киштә; матча», (Иванов, Тужаров: 79; Саваткова: 52) «озынга сузылган болыт кисәкләре, ш. ук кошлар, җирдә – гөмбәләр төркеме», гомумән – «сузынкы төркем», чув. *кашта* «киштә, аркылы агач, аркылаш, шикмә», удм. (Насибуллин: 119) *кашта* «киштә, сәрдек». Гомуми закончалыклар буенча бор. төрки **кәштә* сүзеннән, ләкин андый сүз табылмый. Ихтимал, фар. *кäштэ* «буй-буй, буйлык; чигелгән, тарттырылган» (*кашидан* «тарту; чигү; сузу»)) сүзеннәндер. Сүзнең гом. төрки параллельләре юклыгын Рясянен да билгели.

Дерив.: **кәштәле ~ киштәле, киштәсез;** мар. *каштала-* «чулпы (тишекле чүмеч) белән сөзеп алу» (*кашта* «рәшәткә, сөзгеч» сүзе булган); чув. *кашталан-* «(болытлар) рәт-рәт сузылу»: бәлки тат. сөйләшләрендә дә *кәштәлән-ү* сүзе бардыр. Бүтән төрки телләрдә бу сүзнең күренмәве дә гаҗәбрәк. Räsänen 1969: 258; Федотов I: 245 (аз гына әйтелә).

**КИШТӘ II** (ЗДС: 318) «веха, маяк». Мөгаен **киштә I** белән бердер, ләкин мәгънәви мөнәсәбәтләр аңлашылмый.

**КИШТЕБАН** тар. «комендант перевоза, паромов; смотритель водных путей в Казанском государстве» < фар. *кäштибан* «кәрап иясе, кәрапчы; матрос, лоцман, капитан» (*кäшти* «кәрап», *-бан* «караучы, багучы»).

**КИЮ** к. **Кий-ү.**

**КИЯ [кийә]**, **киялек** (ТТДС II: 170 һ.б.) «дух возмездия, дух-защитник» (*һәр нәрсәнең иясе һәм киясе бар* – у каждого сущего есть «хозяин» и дух-защитник, дух-мститель за нанесенную обиду») ~ башк. *кийә, гийә,* үзб. диал. *къйә, кийә* (ЎХШЛ: 146), нуг., каз., к.-калп. *кие [кийэ]* id., кырг. *кээ* «кару; үч, кия», алт. *кееге, кегее* «кот, ямь, фәрештә», *кеен* «матур, сылу», кабарда. (< төрки) *гие* «табалау, шелтә», чаг. бор. монг. *kia* «хан сакчысы; баһадир сакчы» (к. Очерки истории культуры Средневекового Ирана: 237).

Дерив.: диал. (ТТДС: 244) **кийәлән-ү** «кадерен белмәү; зурдан кубу», **кийәле** (ЗДС: 306) «претензияле; бәлале» ~ каз., к.-калп. (Будагов II: 183) *кийели* «изге, кагылгысыз», (Катаринский буенча) каз. *кейели қус* «аккош»; кара татар (алт. диал.) *кеегелү, кеен* «матур, зифа», *Кеен-Чокур* «Киян чуар» – ат исеме һ.б.

**КИЯНКЕ** (к. Будагов II: 183) «бесплодная» ~ башк. (БТДҺ: 136) *кейәнке* «тәрбиясез кыланчык кыз» ~ кырг. *кээнки, кээнги* «бидәү, бала тапмый торган», үзб. (ЎХШЛ: 145) *кийәнки* «ирония; кыек сүз (буш сүз?)». Чаг. монг. *кöкенгүй, кöкейгүй* «бала тапмый торган» ← *кöкен, кöкей* «бала, бәби». **Кыянкы** сүзе тыштан гына охшаш.

**КИЯҮ [кĕйәw],** себ. (Дмитриева 1981: 163; ЗДС: 323) **көйәү, күйäw** «зять; молодой муж», «жених»

> удм. диал., мар. диал. (Исанбаев 1978: 9) *кийäү* < гом. кыпч. *кийэw, кийеw*, кырг. *күйөө,* бор. ядкәрләрдә (Боровков 1963: 187; Мухамедова 1973: 129) *күйәгү, küδägü ~ küzägü* < бор. төрки **küräkün*, к. аз. *күрәкән,* төр. диал. *köreke, köreken*, төркм. диал. (ТДГДС: 117) *кöрöк, кööрöк*, (Мухамедова) *кööрекен* һ.б. id., бор. монг. *kürikän* (бу сүзнең вариантлары төрлечә һәм күп) «кияү», гадәттә (М. Рясянен һ.б.) бор. монг. *kür degün, kur degün* «кызыма дус энем» сүзеннән дип карала; *-r-* варианты чув. телендә дә саклана: *кĕрү [кәрĕw]* < **кәрәw* < **күрәгү*. Угыз телләрендә закончалыклы рәвештә *гийев*, төр. *güvegü, güvey*. Башк. *көҙөй, күҙәй, күдәй* ыру атамасы бор. төрки (ДТС: 324) *küδägü, küdägü* «кияү» сүзеннән килүе бик ихтимал. Будагов II: 170; Покровская: 60–63; Räsänen 1969: 306; Федотов I: 283; ЭСТЯ III: 43–45; Рамазанова 1991: 90–91.

Дерив.: **кияүле, кияүсез; кияүлә-ү** (*кияүләп йөрү* «ярәшелгән кыз янына килеп йөрү»).

**КЛИТ** иск. (Бәетләр 1960: 147) «клеть в шахте» < рус. Рус. *клеть* тур. к. **Келәт.**

**КОБА I, куа** «тёмно-жёлтый, светло-коричневый», **куба** «бледный, бурый» (Троянский II: 58), **кŏба** «буланый» (Троянский II: 63) ~ чув. *хăва [хŏва]* < болг. **һоwа* > мар. *ува* «кара көрән» < гом. кыпч., алт. *ҡуба, ҡува, ҡуа*, хак. *хува* – һәртөрле корыган үлән төсләре; бу сүз күп вариантлары белән **ку** һәм **куа** сүзләре белән тоташа, һәрхәлдә бер үк сүзнең вариантларыннан берсе итеп карала ала. Ләкин к. ш. ук яз. монг., маньч. *хуба* «гәрәбә; гәрәбә төсендәге» > хәз. монг., бур. *хуба, хубан* «коба» (рус. «светло-жёлтый» диелгән), К. Räsänen 1969: 295; ЭСТЯ VI: 94–96 (һәр ике сүзлектә күп материал). Чаг. **Кола.**

**КОБА II** иск., диал. (к. Тумашева 1992: 132) **ҡуба** «ворота, столбы ворот», шуннан **коба жыры** ~ башк. *коба йыр* – кодаларның кунак булып килгәндә йорт хуҗасына мактау җыры (кода коданың өй-йортларын, капкасын, киемен, затыннәселен мактаган; бу җыр эпоска охшап киткән); Г. Ибраһимов язганча, башкортларда өйнең киртәсе-коймасы булмаса да, капкасы булырга тиеш булган; күп төрки халыкларда капка һәм капка янындагы ат бәйләү баганалары – поэтизация объекты. К. бор. монг. (Поппе 1938: 299) *qobaɣı* – чыгт. *qobuɣa* «текә утыртылган кәртәлек». К. **Кобага.**

Типик *коба җыры*на мисал (к. Дмитриева 1981: 74):

*Ат бәйләдем ҡобағызға,*
*Чаң бәйләдем дуғағызға;*
*Ҡарап торам исем китеп*
*Алтын уҡалы яҡағызға...*

**КОБАГА** «боковая доска (лодки и т.п.); водосточный желоб; (БҺҺ II: 111) карниз» ~ ком. *ҡобаға* «чана шуарга улак»; чаг. башк. (к. БТДҺ: 195) *ҡобаға* «шпатель, штукатурканы тигезләү коралы», гом. тунг. (ССТМЯ I: 421) *куба-* «(тактаны һ.б.) ышкалау». Ясалышы буенча (*-ға* < *-ғай*) *ҡŏбаға* < *ҡубаға(й)* монг. сүзе. К. **Коба II.**

**КОБАУ [ҡŏбаw]**, себ. (Тумашева 1992: 79) **кубак** «болотистое озеро, озеро посреди болот» ~ иске тат., каз. (Будагов II: 69) *ҡоба*, каз. *ҡобу, ҡопа* «корыган күл», аз. (АДДЛ: 144) *гобу, гобый* «субасар иңкүлек, сазламык күл яки елга», алт. *кобы* «кобау; чокыр, өңгер; өн»; к. ш. ук башк. (БТДҺ: 195) *ҡобау* «ана бал корты оясы». Чаг. **Купкы.** Рус. *кубак* «сазламыклы күл» (< тат.) тур. Аникин: 311.

Башкортстанда **Кобау** дигән авыллар һәм кабилә атамасы бар. Болар бүтән сүз булса кирәк.

**КОДА** «сват» > удм. диал. *кыдо, къдо, кудо, кўдо*, мар. диал. *куда* (*башкуда* «сваха» < тат. *башкода* «головной сват»), чув. *хăта [хŏда]* < гом. кыпч., үзб., алт. *ҡуда* «кода», тув. *куда* «кода; туй» < бор. монг. *quda* «кода; бәя» ~ гом. тунг.-маньч. *хода, худа* «сату-алу, сәүдә; эш хакы; кәләш хакы» (бу мәгъ. татарча һ.б. **кодала-у** фигыле мәгъ. чагыла). Бу сүз дуаль кодалашу заманнарында таралган.

*Кода* сүзенең монг. телләреннән алынганлыгын *кодагый* һәм *кодача* сүзләре дәлилли: алар монг. сүзьясалыш модельләренчә ясалганнар.

Кайбер төрки телләрдә *кода* сүзе юк яки сирәк очрый (угыз телләре, к.-балк. һ.б.), *кодагый* һәм *кодача* аннан да сирәгрәк. Ләкин як. телендә *ходогой* бар, ә **ходо* < *ҡуда* үзе юк, «кода» мәгъ. як. *тунер* (~ төр. *dünür*) сүзе кулланыла. К. Будагов II: 40–41; Покровская: 75; Рамазанова 1992: 122–126; Räsänen 1969: 296; ЭСТЯ VI: 102–103; Федотов II: 336.

Дерив.: **кодалык; кодалаш-у.**

**КОДАГЫЙ** «сва́тья» < гом. кыпч., үзб., алт. *ҡудағый, ҡудағай* (каз. әд. *ҡŏдағый*) id. < бор. монг. **qudaɣuі* id., *-ɣuj* хатын-кызларны белдерә торган кушымча, к. хәз. монг. *худугуй* «кодагый, кодача». К. **Кода.**

**КОДАЧА** «свояченица (младше говорящего)» < гом. кыпч., үзб. *қудача* (нуг., каз., к.-калп. *қудаша, қŏдаша*) < монг. *qudačar* id., *-čar* яшь хатын-кызны белдерә торган кушымча (к. **Бүләчәр, Җиянчәр**); **кŏдача** һич кенә дә «кечкенә кода» түгел. К. **Кода.**

**КОДРӘТ [қөдрәт]** «безграничная сила; божья десница» < гар. *қудрат* id. *қдр* тамырыннан, шуннан ук **Кадәр, Кадер, Микъдар, Тәкъдир.**

**КОЕ [қŏйŏ]** «колодец» ~ башк. *қойо* id. > удм., мар. *куйы, кыйы,* чув. *хӑйӑ* id. Җирле халыкның мәдәни дәрәҗәсенә, яшәү рәвешенә, җир-су, климат шартларына күрә коелар бик төрлечә була: яңгырлы, дымлы якларда өсте бераз капланган чокырча да кое, коры якларда янтыклары ныгытылган тирән чокыр, хәтта мәгарә кебек ясалган корылмалар да кое. Икенче яктан, татар халкы бик төрле төрки кавемнәрдән оешкан. Шул факторлар кое атамаларының төрлелегенә сәбәпче булган, к. диал. (ЗДС: 364, 407, 418, 422, 431, 438) **кŏйŏ, кыйы, қодоқ, қозоқ, қотоқ, кутук, куйун,** брб., чулым. **куйуӊ** «кое; бәке; су улагы» (чаг. рус. *колодец* «кое», асылда «улак»), башк. (БТДҺ: 196–197) *қыйу, қуйу* «бәке», *қŏдық, қŏзық, қŏтық,* себ. (к. ДС I: 90, 94, 110) *қŏйŏқ* «кое», *қŏтŏқ, қŏҙŏк, қŏдŏқ* «бәке» ~ кар., кр.-тат. *қуйу, қуйув,* гом. кыпч., уйг., чыгт., алт. *қудуқ,* бор. кыпч. *қуйуқ,* куман., кар., госм. *қуну, қуньу,* алт. *қутуқ,* уйг. диал. *қоды,* чыгт. *қоҙы* ~ кар. *қуйу, қуйув* «кое»; удм. телендә *қъйгу, кыйгу* варианты бар (Кельмаков 1977: 32) < бор. **қуйуӊу* > себ. (брб.), чулым. *куйуӊ* «бәке; кое» ~ монг. *худуғ, худағ* «кое; даладагы чишмә», бор. монг. *xuddux,* тунг. *худуғ* «кое, чишмә». Күрше телләрдә төрки-монголларның үзләрендә сакланмаган вариантлар да очрый: удм. (Кельмаков 1977: 32) *қыйгу,* венгр. *хут* «кое». Бор. төрки ядкәрләр оригиналь түгел: (ДТС: 464) *qиδuγ, quduγ* «кое». **Кое** сүзе нуг. *қуйы* кебек, ләкин к. бор. (ДТС: 440, 463) *quduγ ~ qedıγ, qıδıγ* «яр буе», «кырый»? Чаг. **Койты.** Gombosz: 144; Räsänen 1969: 297; ЭСТЯ VI: 119–120 (без китермәгән мисаллар бар); Гарипова 1998: 97–98; ДАУ I: 183–189. Төрки мифологиядә **кое анасы** образы булган, к. Dobr. II: 344. Аңарга дип юлчылар тәңкәләр ташлаганнар. Татарларда чишмәләргә тәңкә, йөзек салу шул далаларда яшәгән ата-бабадан калган (к. *Җидегән чишмә* җыры).

**КОЕЛ-У [қŏйŏл-],** миш. **кыйыл-у** «рассыпаться, сыпаться; осыпаться, падать, литься, течь; вывалиться; изготавливаться литьем» – тат. телендә күп мәгънә алган һәм киң кулланылышлы бу сүз **Кой-у** (к.) фигыленең төш. юн. генә.

Дерив.: **коелдык, коелма; коелдыр-у, коелыш-у;** диал. **қойлоқ** «су агып төшә торган торба», **қойлоқ-у → койлокма** һ.б. тат. теленең үзендә ясалган сүзләр.

**КОЕМ [қŏйŏм]** «литьё, литейное дело» ~ бор. төрки (МК, ДТС: 464) *qujma* id., әлбәттә, *кой-* < *quj-* нигезеннән. Бу сүзнең металл эшенә кагылышлы булуы характерлы. К. **Кой-у.**

Дерив.: **коемчы, коемчылык.**

**КОЕН [кŏйŏн]** «ливень; вихрь; ураган», диал. **кŏйŏлŏк** «водоворот» (к. ТТДС I: 200) ~ башк. *қуйун, қŏйŏн, қŏйŏм* id., нуг., каз., к.-калп. *қуйын,* кырг., чыгт., уйг., урта төрки *қуйун,* хак. *хуйун,* алт. *қуун* «коен; пәри» < монг. *қуйун, хуйун* ← бор. монг. *quj* «өермә; бөтерелү» (к. Räsänen 1969: 297), монг. *хуйла-* «өерелү, өермәләү». К. **Койрык.** Чаг. **Койгырыш.** ЭСТЯ VI: 117–119.

**КОЕШКАН [қŏйŏшқан]** «подхвостник (часть сбруи)» ~ башк. *қойошқаӊ, қойосқан* «эшлия каешы» (?) < гом. кыпч. *куйышкан* «койрык асты бавы» (куман. *coyskan, kojšnak*, нуг., каз., к.-калп. *қуйысқан*, кырг. *қуйушқан*), кр.-тат., ком., шор. *қуушқан*, госм. *қойашқан*, хак. *хосхун, қоскун* ~ бор. монг. *qudusqa* < *quduzga*[n] id. ~ *qudruq – qudur-uq* «койрык» белән нигездәш (к. Räsänen 1969: 297: *r* > *z*). Сүзнең *қуйылған* варианты да бар, к. нуг. (Dobr. II: 394) *ийэр бавын бик тартып, куйылганын кыскартып... атына сэкереп менгэн, ди* (Бүзьегет). Гомумән, бу сүзнең вариантлары аеруча күп.

К. бор. төрки *qudurγun* «коешкан» ~ тув. *қудурга*, як. *қудурган*, эвенк. монг. *кудурга, худурган, худраға* «коешкан» һ.б. (МК, ДТС: 464); ССТМЯ I: 423–424; ЭСТЯ VI: 116–117 (*қуйруқ* матдәсе эчендә), 182–183 (*қушгун ~ қушқан ~ қоішнақ* матдәсендә).

**КОЗАВЫЗ [қозаwы̆з]** «хвощ полевой» (ЗДС: 319; Иванов 1990: 118) < удм. (ДАУ II: 110–127) *казаузы, козавыз, кызавыз* «чыршының ата чәчәге», сүзмә-сүз «чыршы җиләге».

***КОЗАК,** себ. **қосақ** «туку ыстаны» ~ к.-калп. *қозақ* «туку урдыны (ыстаны)», үзб. диал. (ЎХШЛ: 163) *қозақ , қузақ* «туку кярханәсе». Чаг. уйг. *қузуқ* «караваt». Бу сүзне *козау* сүзе белән дә, *кузақ* сүзе белән дә чагыштыралар. Будагов II: 80

(Вамберидан алып билгесез чыганакта гарәп хәрефләре белән язылган *ķозаķчы ~ ķузаķчы* «тукучы» сүзен китерә).

**КОЗАУ [ķŏзаw]** диал., **кызаw** (ДС I: 103; ДС II: 108) «лукошко; желоб у жерновов; кузовок» > чув. *кусав, косав* «козау» ~ башк. *ķызаw* id., төр. *kizak* «чана; улак; стапель (кәраплар ясау урыны)»; рус. *кузов* «козау, улак» һичшиксез тат. теленнән (Фасмер II: 402; Шанский: 225). Чаг. ш. ук башк. *куӡы* «тубал» ~ фар. *кӯза* «чүмеч» < авест. *khawza*, санск. *kūza* «зур табак; кыны һ.б.ш.» (Platts II: 785). Räsänen 1969: 312.

**КОЗГЫН [ķŏзғŏн],** диал. **кузгын** (Остроумов 1876: 93) «ворон» ~ нуг., каз., к.-калп. *ķузғын*, кырг., к.-балк., госм., чыгт. һ.б. *ķузғун,* алт., тув. *ķусķун,* хак. *хусхун* «козгын; кара карга» ~ рус., укр. *коркун* (шуннан ук, ихтимал, *коршун,* к. Фасмер II: 342) id. < бор. төрки **qorq-γun* – бор. төрки *qun//kün, γun//gün* кушымчасы белән *ķорķ* тәкълиди сүзеннән (чаг. бор. төрки *kögerckün* «күгәрчен»). Чаг. **Коз-у.**

Торна һәм карга-козгыннар атамасы тәкълиди сүзләрдән ясалучан (к. Гамкрелидзе, Иванов: 540): бор. һинд. *karata*, грек. *χορος* «козгын», лат. *corkus* «козгын», *cornix* «ала карга», ним. *Krähe* «карга», яп. *карасу*, мар. *курныж*, удм. *кыринж*, фин. *korppi*, нен. *карна, харна, харигэс*, бур. *хирээ*, эвен. *кэре* һ.б. «козгын». ЭСТЯ VI: 107–108.

**КОЗ-У, козы-у** (ЗДС: 408) «урвать, сорвать, вырывать». Бүтән төрки телләрдә параллельләрен тапмадык. Бу сүз **козгын** ~ гом. төрки *ķузғун* сүзен белдерә шикелле: *ķузғун* «(томшыгы белән) эләктереп тартучан (кош)», чаг. *баскын, узгын, үткен, чапкын, яткын* һ.б.

Шул *куз-* тамырыннан *кузык* < *козык* «өзеп алынган (чикләвек)» сүзе дә килә бугай. К. түбәндәгене.

**КОЗЫК [ķŏзŏķ],** диал. **kŏcŏķ** (Тумашева 1992: 126, 129) «орех» к. **Кузы.**

**КОЙГАШ** (себ., ЗДС: 408) «подруга» < *ķуйғаш.* К. **Куйгаш.**

**КОЙГЫРЫШ [ķойғорош]** (Мухамедова 1972: 189; Тимергалин: 252), кыйгырыш (ЗДС: 364) «птица счастья (которая вылетает из промежутка между двумя новорожденными жеребятами-близнецами» ~ чув. *куйкăрăш* id., морд. *куйгорож* «шекә; елан-кош» (*куй* «елан», *корож* «ябалак» дип аңлатыла): ләкин морд. сүзе халык этимологиясе буенча гына аңлатылмыймы икән? К. тат., башк. (ЗДС: 408, 409; БҺҺ III: 111–112) **кыйғороч, койғорош** «ике йөзле ялагай», «кыланчык», кас. *'ойгорош* «ләтчә», *койгорошлан-у* «кыланчыклану». Чаг. алт. (тел.) *ķуйғур-* «шатланып бөтерелү, рухланып кылану – башлыча шаман тур.». Чаг. **Коен.** Гомумән, ачык түгел.

Урта диал. (ЗДС: 436) **кыйғырышлан-у** «рухлану».

**КОЙКА [ķŏйķа]** «студень; опалённая кожа головы козла, барана (которая считается деликатесом)» ~ башк. диал. (БТДҺ: 196) *ķойка* «ярлы, фәкыйрь» – күрәсең, пешерелгән тире генә ашап торучы ~ каз. *ķŏйķа*, нуг., каз., кырг., алт., бор. төрки *ķуйķа*, як. *куйаха, куньаха* «йоны көйдерелгән тире», алт. диал. (тел.) *куйуķа* «койка; баш тиресе», *куйах*, *ķунйах* «кыяу, калын тиредән эшләнгән броня». К. ш. ук бор. монг. *qujiqa,* тунг. *куйика* id. Элекке заманда тирене махсус алымнар белән кыздырып хәз. пластмассага охшаш хәлгә китергәннәр һәм шуннан калканнар, тулкалар (шлем) һ.б. әйберләр ясаганнар. К. **Кыяу.** ЭСТЯ VI: 111–112 (*куяк* матдәсе, күп материал китерелә, ләкин *койка* һәм *кыяу* белән чагыштыру юк).

**КОЙЛЫК [ķойлоķ], койлокма, ķойолыķ** (ЗДС: 408) «водопад, место быстрого течения воды; специальное устройство – желоб по течению воды в реке (для сохранения русла без изменений в некоторых случаях)» ← *ķойлоķ-у* «течь, протекать очень быстро, с угрозой размыва берегов и т.п.» – **ķой-** фигыленең интенсивлык формасы (чаг. *йоту → йотлыгу, карыу → карлыгу, өзү → өзлегү* һ.б.ш.)

**КОЙМА**, диал. (ЗДС: 334) **куйма** «забор; ограда» ~ чув. *хуме, хумме* id., каз. (ĶТДС: 211, 212) *куйма, куйым* «койма; койма кою өчен ясалган балчык болгатмасы», гом. кыпч., бор. төрки *quita* «коеп ясалган нәрсә». Удм., мар. (Насибуллин: 121; Исанбаев 1978: 30, 40) *кульма* «койма» тат. диал. **койылма** *(киртә)* сүзеннән. К. **Кой-у**. Räsänen 1969: 297 (арба-чана *көймәсе* белән баглый).

Койманың тат. мәгънәсе «такталардан ясалган киртә» Идел-Урал регионында гына һәм бу сүз бирәдәге төркиләрнең урмансыз яклардан килгәнлегенә дәлил, чөнки **кőйма** тәүдә «ике кыса арасына сыек балчык *коеп* ясалган киртә» булган (*койма кою* тәгъбире дә шуннан килә). Андый киртә

яңгырсыз климатта гына озак тора ала. Күчмәннәр тырышып койма коймыйлар. Ниһаять, **койма** сүзе тат. теленең чув.-болг. теленә нисбәтән беренчелеген дә күрсәтә: чув. *хӳмә* < *қуйма* (һәм *хӳ-* < *қуй-*) татарчадан, фонетик законнар буенча киресенчә була алмый. Чаг. ш. ук удм. диал. *кӧй* «койма». К. **Коймак, Кой-у.**

**КОЙМАК,** миш. **кыймак, кимак** «оладья, блин» > мар., удм. *кульмак*, удм. *кыймак*, чув. (Сергеев 1968: 27, 34) *куймак, кыймак*, рус. диал. *куймак* < гом. кыпч., уйг., чыгт. *қуймақ* ~ монг. *хуймаг* «коймак», ком., үзб. диал. *қуймақ* «тәбә», кар. *куймақ* «мәҗүси кою (утка корбан итеп учакка ашамлык агызу)»; **коймак** сүзенең киң таралуына аның мәҗүси йолага бәйле булуы сәбәп (*коймак* < *куймак*ның төп мәгънәсе – йола атамасы). К. **Кой-у.** ЭСТЯ VI: 113–114 (күп материал китерелә).

Дерив.: **коймаклы; коймаклык** (он һ.б.).

**КОЙМЫЛ-У, коймыр-у** (ЗДС: 408–409) «быть весёлым и гордым», **койымлаш-у** «кунаклашу, күңел ачу» ← **қойымла-у** «шатландыру», (ЗДС: 422) **куйму** «шатлык», **куймыр-у** «шат булу». Чаг. башк. *ҡуймыр күҙ* «шатлыклы коңгырт күз», ком. *қуймур* «кокетка, күз уйнатучан (кыз)», кырг. *қоймолжу-* «майлы күз белән сөеп карау», як. *куйбаңнаа-, куймаңнаа-* «койрык болгау (эт тур.)». Күрәсең, гом. төрки сүз. Чаг. ш. ук бур. *хойболзо-* «ярамсаклану». Чаг. **Кыйлан-у.**

**КОЙРЫК [қо̆йро̆қ],** диал. (ТТДС II: 182) **қо̆йо̆рық, ко̆рек, куурук** «хвост; охвостье» < гом. кыпч. *қуйрық,* башк. диал. (БТДҺ: 196) *қо̆ҙро̆қ,* кырг., алт., уйг. *қуйруқ,* чыгт., үзб. диал. *қуйруғ,* шор., хак. *кузуруқ,* тув. *қудуруқ,* як. *қутуруқ,* бор. төрки (ДТС: 463) *qudruq, quduruq* id., безнеңчә, бор. төрки **куд-, *қуду-* «бөтерелү, болгану» сүзеннән (эт, дуңгыз һ.б. хайваннарның хәрәкәтчән койрыгына карап әйтелгән), к. аз. (АДДЛ: 192) *гуiрул-* «боргалану», бур. *годи- (<*қоди-)* «болгану, бөтерелү», *годируу* «боргаланучан (койрык)». Койрыкны «бөтерелчек» дип исемләү төрки-монг. телләрендә (тәүдә «хатыннар телендә») тән әгъзалары атамаларын фигыльләрдән ясау традициясенә бик туры килә (к. **Бармак, Колак** һ.б.). Бор. *қуд-, қуй-* (к. **Коен**) «бөтерелү» фигыленнән «койрык-бөтерчек» мәгъ. берничә пароним ясала алган, мәс., **қуй-уқ, *қуй-гақ* һ.б. (күп кенә сүзләр була ала), шундый паронимнарга **коешкан** (к.), **комыч** (к.) сүзләре тоташа. *Ко̆йрык << куҙуруқ* асылда **қур-дуруқ* «койрыклык» сүзеннән, бу фаразга хак. диал. *хузурға* «койрык» ~ бор. монг. *qudurγa(n)* «коешкан» сүзләре дәлил өсти (чаг. *йодрык* < *йумдурук* ~ монг. *нидурга*[н]). ЭСТЯ VI: 114–117 (бай әдәбият; аңлатма безнеңчә түгел).

Чув. *хӳрӗ* «койрык» < болг. **һуйры* < *қуйруғ* булса кирәк, к. Федотов II: 377 (аңлатма безнекечә).

Иске төрки *кудрук* > *қурдуқ* вариантыннан рус. *курдюк* «куйларның май җыелган арты, көрдек» сүзе килә, к. Аникин: 313, 327. Шуннан – тат. **көрдек** id. (тик монда кайбер сораулар кала). Чаг. ш. ук **котыр-у.**

Дерив.: **койрыклы, койрыксыз; койрыкчы** (кимәдә); **койрыклык; койрыклан-у.**

**КОЙТЫ [қо̆йто̆],** диал. (ТТДС I: 200, 251, 281; Тумашева 1992: 127) **қыйты, кыйты** «плохо, неважно» ~ башк. *ко̆йто̆* id. > чув. *кăйттă* id. ~ кр.-тат., добр. *quytu, quytı* «ышык җир; аулак», «җилсез-яңгырсыз һәм бик эссе булмаган тыныч һавалар, әйбәт (!) һава»; ачык далада көтүчеләр һәм терлекләр дә *койты* (чокыр-чакырлы) җирләргә, балкыларга төшеп ял иткәннәр. Безнең якларда *койты* җирләр әйбәткә саналмаган. К. ш. ук гаг. *куйту,*төр. *kuytu* «күләгәле түбән җир, тирән тарлавык; эчке як» < бор. монг. *qojtu* > монг. *хойту,* бур. *хойто* «арт як; төньяк; түбән; моннан соңгы». Каз., к.-калп. *қуйту* «тәбәнәк буйлы; ялагай; мут» һ.б. да монг. телләреннән таралган (*-ту* аффиксы). Сүзнең нигезе – тат. диал. *қуйы* «яр асты» (еш кына **кое** белән бутала), үзб. *қуйи* < бор. төрки (ДТС: 452–453) *qoji̇, qoδi̇, qodi̇, qozi̇* «түбән; түбәндәге»; к. ш. ук алт., тув. *қуй* «баз, өңгер». Охшаш сүзләр күп телләрдә бар. К. **Куе II.**

Дерив.: **кыйтылан-у, кыйтыр-у**.

**КОЙ-У** «лить; лить плавленый металл и т.п. в форму; рассыпать» < гом. кыпч., чыгт., уйг., госм. *қуй-* (~ чув. *хӳр-, хор-*) < бор. төрки (ДТС: 463–464) *qud-, qud-, quj-* > сары уйг. *quz-, qoz-*, хак. *хус-, қус-*, тув., як. *қут-* id. к. Räsänen 1969: 296; ЭСТЯ VI: 109–111; Федотов II: 361.

*Ко̆й-* < *куй-* сүзеннән күп кенә яңа нигезләр ясалган, к. **Коем, Койма, Коймак.** Кайбер телчеләр **кое** сүзен дә **кой-у** белән баглыйлар, без аларга кушылмыйбыз. Тат. регуляр дерив.: **коел-у, коен-у, коеш-у, койдыр-у; койма** (яңгыр), **койгын** (яңгыр төре).

**КОЛ** «раб; работник» < гом. төрки *қул* id.; бу сүз тур. фикерләр күп. Л.Н. Гумилев (1974: 28–29)

төрки *қул* сүзен кыт. *цзелу* – бер кабилә исеме сүзе белән тәңгәлләштерә; ләкин *цзелу – цзе* «иптәш, дус-иш» һәм *лу* «һунн» сүзләреннән тора; як. *кулут* (< монг. *қулут* «коллар») – туйда кәләш анның аркасына басып атка менә торган кеше (к. Нюргун Боотур. Якутск 1975: 429). Кайбер телләрдә *кул* «солдат; яничәри» (Steuerwald: 562) һәм бу мәгънә иң бор. булса кирәк. Башкортлар XVII–XIX гг. үз җирләренә килеп утырган игенчеләрне *қол* дип атаганнар, к. Будагов II: 88–89.

**Кол** һәм **кул** сүзләрен тәңгәлләштерү фонетик җәһәттән акланмый. ЭСТЯ VI: 120–121. Бор. рус. *кулъ* «кол» тур. Аникин: 320.

Дерив.: **коллы, колсыз; коллык.**

**КОЛА I** «саврасый; буланый» ~ чув. *хӑла*, мар. Т. (Саваткова: 182) *хыла,* удм. (Насибуллин: 123) *къло, куло, кулӧ* < гом. төрки, иске монг. *қула*, хәз. монг. *хул*, бур. *хула, хулан* id., гом. төрки *кулан*, яз. монг. *хулан*, хәз. монг. *хул, хулан* «колан, Үзәк Азия кыргый аты» (ул һәрвакытта кола төстә була). Шулай итеп, ат төсмере һәм берничә хайванның атамасы уртак төс буенча аталган. К. **Кола II, Колан, Солаң.** Räsänen 1969: 299; ЭСТЯ VI: 121–122; Федотов II: 320–321.

Атларны бик яхшылап төрен-төргә аерган монг. телендә *хула* «үзе ачык соры һәм койрыгыялы кара» ат.

**КОЛА II: кола ялан** «совершенно голая степь (равнина)» ~ кр.-тат. (Dobr. II: 326) *kolan ~ kulan çöl* id., үзб. *қула туз (тұз),* к.-балк. *кула тюз* «кола ялан» – **кола I** белән бердәй һәм «*ку* төсендәге» дигәннән булса кирәк, к. тув. *кувала* «кола ат» (< *ку ала*?), к. абаз. (< төрки) *къвлан* «чуар (ат)».

Бор. чыгт., бор. монг. *qola kēr* «ерак дала» (к. Поппе 1938: 300) сүзе дә шуңа мөнәсәбәтле. К. Joki 1952: 188, Räsänen 1969: 298, ССТМЯ I: 428.

**КОЛАВЫЗ [кŏлаwы̆з]** «проводник в дороге» к. **Кулавыз.**

**КОЛАК** «ухо; слух», күрәсең күч. «ушко (котла); первые парные листья некоторых растений и т.п.» (много значений, к. Рамазанова 2013: 55–62) < гом. кыпч. *қулақ* < бор. төрки (ДТС: 465) *qulγaq, qulqaq, qulxaq* id. > чув. *хӑлха* id. ~ як. *құлгах* id., бор. **қул-* «ишетү» фигыленнән бугай. Чаг. мар. *колаш*, морд. *кулемс* «ишетү», *куля* «хәбәр», фин. *kuulo*, манси. *хол* «ишетү, ишетү куәсе», һинд-евр. *kleu* id. һ.б. халыкара тамырга охшый. К. **Колакай.** Будагов II: 89–90; Räsänen 1969: 298; ЭСТЯ VI: 124–127; Федотов II: 322. Бу авторларның берсе дә безнеңчә аңлатмаган.

Дерив.: **колаклы, колаксыз; колакча; колаклан-у** (үсемлекләр тур.); к. **Колакса, Колакчын.**

**КОЛАКАЙ** (ТТДС I: 201; БТДҺ: 197) «глухой» ~ гом. кыпч. *қулақай* < монг. **қулақгуй* «колаксыз» сүзеннән; мар. *клукой, кулукой, кулакай*, удм. *кылакай* сүзләрендә рус. *глухой* сүзенең контаминацион тәэсире сизелә.

**КОЛАКЛЫ, кылаклы** (ТТДС I: 261) «величиной с …, одного рода; одного поколения с …» – чаг. бор. төрки (ДТС: 454) *qolu* «вакыт үлчәме – 10 секунд; микъдар».

**КОЛАКСА** «выступ балки за стену снаружи; разновидность серёжек; часть женской шапочки, прикрывающей уши» ~ башк. (БТДҺ: 197) *қолақһа* id. ← **колак. Колакса** кызлар кәпәченә өстәмә рәвештә беркетелгән, бүрәнә колакчасы шуңа охшатылган булса кирәк.

**КОЛАКЧЫН** «шапка-ушанка» ~ башк. *қӧлақсын,* каз. *құлақшын* id. ← **қолақ < кулак,** әлбәттә. Ясалышы ачык түгел.

**КОЛАН** «кулан, степная дикая лошадь (вернее – осёл, онагр)» < гом. төрки *қулан*, монг. *кулан, хулан* id. – **кола** (к.) сүзе белән баглы. Räsänen 1969: 298; ЭСТЯ VI: 127–128. Рус. диал. *хулан* «колан» тур. Аникин: 626.

**Кулан** сүзе күп күрше телләргә үтеп кергән.

**КОЛАНЫК,** диал. (ЗДС: 424) **құлануқ** «колонок, жёлтый хорёк» ~ башк. (БТДҺ: 168, 211) *қылануқ, қыламық* id. **Кланук** варианты – рус сүзеннән кире алынма булган тат. сүзе, төбендә монг. телләре аша тунг. телләреннән таралган. Аларда (ССТМЯ II: 109, 332) *колоңго* < *холоңго* < *һолонго* < *солоңго* (*с* > *һ,* башк. телендәге шикелле, аларда да бар) «сары ас, коланык; салават күпере» > бур. *хологюна,* монг. *кулгуна* «коланык», төп мәгънә «салават күпере» булган, к. тат. **солаңгыр**. Мәгънәви җәһәттән салават күпере аркасын күтәреп торган озын торыклы сары аска охшатылган (монда, ихтимал, бер мифология бардыр).

Рус. *колон, колонок* һәм рус диал. *солонгой* «көзән» тур. Аникин: 288–289, 503. Чаг. ш. ук. **Кулунчак.**

**КОЛАҢСА,** себ. (ЗДС: 411) **қолаңза** «дурно пахнущая опухоль, мозоль» ~ нуг., каз., к.-калп. *қолаңса* «сасы тир исе», як. *колоңсо* «култык исе», маньч. (ССТМЯ I: 408) *колаңсу, колоңсо, колоңсу* ~ яз. монг. *xoloŋso* «тир; тир исе», кырг. *колоңсо,* башк. *қолаңса* «сасы кутыр (бигрәк тә атның алгы аягының эчке ягында)» һ.б. Бик тар мәгънәле бу сүзнең фонетик җәһәттән үзгәрмичә диярлек шулай киң таралыш алуы гаҗәбрәк тә. Ихтимал, монг. теленнәндер, к. Räsänen 1969: 277–278.

Чаг. ш. ук себ. (туб., к. Будагов II: 63) **кылгуна** «махау» (Будагов **кылгунә** «чарасыз, дәвалагысыз» дип аңлатмакчы).

**КОЛАТЫ I** – название племени – к. **Кулаты.**

**КОЛАТЫ II** (Тумашева: 127) «разновидность орла» к. **Кулаты.**

**КОЛА-У I, қол-у** диал. (м.-кар.), иск. «просить девушку в жёны для сына, младшего брата и т.п.», «просить у начальства повышение» ~ чыгт. (Будагов II: 92) *қула-, кул-* «үтенү, гафу үтенү, рөхсәт сорау; кәләш сорату һ.б.ш.», кар., куман., уйг. һ.б. *қōл-* «сорау, үтенү», бор. төрки *qoldačı* (> венг. *koldus*) «хәерче, теләнче». Räsänen 1969: 277. К. **Колыш.**

Себ. (ЗДС: 411) **қоллоқ** «үзеңә эшләүчеләрдән үтенү, әйбәтрәк эшләргә өндәү», асылда **қолулықтыр**. Чаг. ш. ук **Колау II.**

**КОЛА-У II** «падать (с лошади), свалиться» (Арсланов 1988: 83), «тянуться за чем-либо» (Тумашева 1992: 127) ~ нуг., кр.-тат., каз., к.-калп., кырг., чыгт. *қула-* «тәгәрәп төшү», алт. «нәрсәнең дә булса өстеннән сикерү» ~ монг. *гула-* «авып төшү». ЗДСта себ. **қолау**ның «үрелү, тартылу» мәгъ. күрсәтелә, шундый ук мәгъ. чыгт. (Будагов II: 90) *қуламақ* сүзендә дә бар. Ихтимал, бу фигыль *қу-ла-* дип таркатыладыр (к. **Ку** «бушлык»). Räsänen 1969: 298; ЭСТЯ VI: 122–123.

Дерив.: **колат-у** «бәреп төшерү», башк. телендә актив кулланыла; диал. **колаткы** «текә, биек ярлау», «текә борылыш».

**КОЛАЧ** «размах рук; обхват, охват» ~ башк. *қолас* id. < гом. төрки *кулач* (> нуг., каз., к.-калп. *қулаш,* каз. *қолаш*) > чув. *хăлач* id., ш. ук. «сажин», төр. (Steuerwald: 562) «1,83 метрлы үлчәү берәмлеге», көрд. *kulaç* «кул яссуы» гына. Төр. диал. (DS VIII: 2907) *kolanç* «колач» бу сүзнең фигыльдән ясалганлыгын күрсәтә шикелле. *Кул* < *қол* сүзе белән турыдан-туры багланмый (фонетик закончалыкларга хилафлык килеп чыга), ләкин к. төр. *kol acısı* «ике кул арасы». ЭСТЯ VI: 129–131; Федотов II: 321.

Дерив.: **колачлы, колачсыз** (еш кына абстракт мәгънәләрдә); **колачлык; колачла-у, колачлан-у, колачлат-у.**

**КОЛАША**, диал. (Остроумов) **кулаш, колаш** «широкий желоб (из досок); корыто для сушки зерна» или (БТДҺ: 197) «для соления мяса», (ДС I: 91) «ночёвка» > удм. *кулаша* «улак», башк. диал. (к. БТДҺ: 203) *қулаша* «эркет саркыту өчен савыт – кабык әрҗә һ.б.» ~ төркм. (Будагов I: 89) *қулас* «суда йөзәр өчен улак». А. Троянский буенча, тат. *қолаша, қулаша* ← **колак** («колаклы савыт», чаг. рус. *ушат*). Чув. *хăлача* «колаша» < тат.

**КОЛГА** «шест, жердь» > мар. *қулга*, удм. *кулго* id., башк. *қолға* «колга», (Авижанская: 21) «каба». Диал. *қолға* (к. **Колгалан-у**) «сабакча, чем» белән бердәйлеге бик шикле. Будагов II: 91.

**Қолга** сүзенә охшаш сүзләр слав. (к. бор. рус. *халуга* «читән, киртә, чыбык») һәм фин-угор (к. фин. *kolkka* «колга») телләрендә бар.

Дерив.: **колгалы, колгасыз, колгалык.**

**КОЛГАЛАН-У,** диал. **кылгалан-у** «выпустить стебель (о злаках)», «выпустить первые парные листья (о всходах злаковых)» – бу фигыль (тат. телендә генә) төрле сүзләрдән килеп чыккан булса кирәк; беренчедән – себ. (Räsänen 1969: 298) **kulγa, колга** «уҗым», алт. *қулға, қылға* «сабак» < бор. төрки (ДТС: 455) *qoluŋa* «үсенте» > хак. *хулга* «иген шытымы» һ.б. сүзеннән (Хакасия – төрки игенчелекнең бор. учакларыннан); икенчедән – **кылка, кылкан** «башак кылчыгы» (к. **Кылган**), өченчедән – бор. төрки **қолғақ* > чув. *хăлха* «колак, беренче парлы кыякларның берсе» (чаг. тат. сөйл. **колаклану** «беренче пар яфрак-кыяк чыгару»). Чаг. ш. ук **Колга, Кулга.**

**КОЛГАСАР** «долговязый» – тат. телендә генә очрый торган бу сүз сәер тәэсир калдыра: *-сар* кушымчасы гадәттә берәр төрле үсемлек күпләп үскән урынны белдерә торган сүзләр ясый, андый сүзләр адәми затны белдерми (**көлемсәр** очрагы *көл-емсә-р* рәвешендә таркатыла). **Колгасар** сүзе *қолға* сүзен бор. тат. **кӧлка, кӧлга* «колак (үсемлек яфрагы, гомумән чыгынты)» ~ чув. *хăлха* id. сүзенә нисбәтләүгә дә киртә булып тора.

**КОЛМАК**, диал. **қоламақ, қоламық, қŏмалақ, кумалак** (ДС I: 98), **кумнак** (Радлов II: 1050), **комнак** (ТТДС I: 251) «хмель» ~ башк. *қŏмалақ* id. ~ чув. *хумла, хăмла* < болг. *һумла, һŏмла* > мар., удм. *умъла, умла*, *ымыла* (к. Саваткова: 221; Насибуллин: 142), венг. *humala, komlo* id. – бик күп телләргә таралган мәдәни сүз: рус. *хмель* < бор. слав. *хьмель* < грек. *хоомели*, лат. *humulus*, бор. герм. *humeli* (хәз. ним. *kummel*) id. << шумераккад. *humel, hml* «сыра». К. ш. ук эвенк. *коланак*, *кōлнок* «шәрап». К. Егоров 1964: 202; Абаев I: 649; Фасмер IV: 249–250; Räsänen 1969: 299; Kluge: 546.

Рясянен, безнеңчә, мәзәк рәвештә, *колмак* ~ *комлак* сүзенең бор. аңлатмасын китерә: әгәр бу үсемлекне кәрапка алсаң, диңгез дулкынлана – **комлана** башлый, шуңа күрә аны **комлак** «дулкынлаткыч, хәтта давыл чыгаргыч» дип атаганнар, имеш. К. **Ком II.**

Һәрхәлдә **қомлақ, комалак** варианты халык этимологиясендә **комла-у, комала-у** «дулкынлату, чайкалдыру» сүзеннән дип аңланылуы бардыр инде. Ләкин исерткеч атамалары типологик рәвештә күп халыкларга тарала, ә **ком** «дулкын» сүзе андыйлардан түгел.

**КОЛЫН [қŏлŏн],** диал. **колом, колокай, көлкәй, көлөкәй, көлек, көләш, көнәш** һ.б. (ТТДС I: 274; БТДҺ: 197) «жеребёнок» < гом. төрки *қулун* (угыз. *ғулун*) ~ тат. диал. (ДС I: 92; Тумашева 1961: 152) **қонқақ, қонақа концақ,** чув. *хăм* ~ монг. *хула, хулу*, гаг. *кули, кулум*, хак. *хулун* id. һ.б. – чыгышы һәм ясалышы бик үк ачык түгел; **кŏлан** сүзе белән чагыштыру семантик законнарга хилаф, аккад. *kudunu* «качыр, мул» сүзен тәңгәлләү дә (Joki 1952: 208–209) шик уята.

**Колын** сүзенең тамыры *кŏл* < *қул*, к. югарыдагы мисаллар һәм к. каз. *қулуқ тай* «колын», эвен. *кулуня, хули* «бәби». Колынны *бәббә* дип атау татар-башкортларда да очрый. Палаталь вариантлар (*көлкәй* һ.б.) иркәләү-ярату варианты буларак, **көлек** «эш аты» сүзе белән чагыштыру нигезендә ясалган. ЭСТЯ VI: 132–133; Аникин: 319 (әдәбият күрсәтелә); Федотов I: 323–324.

Дерив.: тат., башк. **қŏлŏнчақ** ~ кырг. *кулунчак*, нуг., каз. *қулыншақ* һ.б. (киң таралган); **колынла-у** (**көлөнлә-ү** һ.б.).

**КОЛЫП [кŏлŏп]** диал. (ЗДС: 412) «вид замка́ (большого); замок пушки» < фар. *қулф* id. К. **Кылып.**

**КОЛЫШ [кŏлŏш]** иск. «прошение; договор». К. **Кулыш.** Башкортстанда **Колыш** дигән авыллар бар.

**КОМ I** «песок; накипь» < гом. төрки *қум*, кырг., алт., шор. *қумақ* >> венг. *homok* иске монг. *qumaqi* id. К. **Ком II**, **Комак, Комаяк.** ЭСТЯ VI: 133–134.

Дерив.: **комлы, комсыз; комлык, комлак; комлан-у; комсыл,** диал. **комык-у, комшак** һ.б., к. ЗДС: 413.

**КОМ II** диал. (ТТДС I: 202) «волна, волнение» ~ чув. *хум*, мар. *ом* < бор. төрки (ДТС: 465) *qum,* чыгт. *қоом*, төркм. диал. (Мухамедова 1973: 116) *ғоом* id. **Ком I** һәм **Ком II** төрки телләрдә фонетик җәһәттән дә аерыла. Räsänen 1969: 299.

Дерив.: **комла-у, комлан-у** (к. популяр җырда: *Агыйделләр дулкынлана, Дулкынлана – комлана*).

**КОМА** иск. «наложница» < чыгт., куман., госм. *қума.* Фар. сүзе булса кирәк, к. Будагов II: 64; ЭСТЯ VI: 134–135.

**КОМАГА** (урта **к** һәм **г**) миш. диал. «свод печи; большая камера печи» < чув. *кăмака* < тат. **кемәгә* (к. **Кәмәгә**) «мич». К. ш. ук мар. (Иванов, Тужаров: 71; Саваткова: 472) *конга, канга, камака, канка* «мич» < чув.

**КОМАГАЙ I** «жадный до денег, взяточник; ненасытный» ~ каз. *қомағай* «убыр» < монг., бур. *хомхой, хумхай* «кышын үлгән эт өрәге» (к. Хангалов II: 127), «комагай; ялагай». **Комсыз** сүзе белән бер тамырдан.

**КОМАГАЙ II** (БТДҺ: 198) «нёбо» – монг. телләреннән булса кирәк. (*-гай* кушымчасы). Чаг. **Камакыш**.

**КОМАЙ I: комай үләне** «манник (растение)» (ТТДС I: 272) – чаг. каз. (ҚТДС: 214) *қумай* id., *кумай* «бурзай эт; әйбәт холыклы ат», кырг., каз. *қумайық* «каракоштан туган мифик эт» (аны *италаказ* дигән мифик кош чыгара), ихтимал, **Һомай** сүзеннәндер. К. Рапопорт: 58–71.

Гомумән, *қомай* дигән берничә омоним сүз бар, к. БТДҺ: 198. К. түбәндәгене.

**КОМАЙ II** (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «некрасивый (о ребёнке)» ~ башк. *қомай* id., кырг., алт. *қоо-*

*май* «ят; яраксыз», хак. *хомай,* тув. диал. *хуумай* «бәхетсез», як. *қуомай* «хөрти, бик шәп түгел» < монг. *хитхä* «бозылган, бозык, ямьсез». Räsänen 1969: 279.

**КОМАК**, диал. **комык** «крыса-песчанка; крыса (вообще)» > чув. (Сергеев 1968: 27) *кăмак, кумак*, удм., мар. (Иванов, Тужаров: 89) *комак, кöмöк* «күсе; әрлән» – **ком** (к.) нигезеннән, к. себ. (Тумашева 1992: 133) **комак** < гом. төрки (Радлов II: 1044 һ.б.) *қумақ,* төркм. *ғумақ* ~ монг. *хумаг* «комлык», к. ЭСТЯ VI: 134 (**комак** – җәнлек искә алынмый). Чаг. рус. *хомяк.*

**КОМАЛАК** «шарик», «козий катышек»: **тугыз комалак** «вид игры с девятью шариками» ~ чув. *кăмала* < гом. кыпч. *қумалақ,* уйг. *қумулақ* ~ бор. монг. *qotuɣal* > калм. *xotɣal* id. > чыгт. *кумал* id., *комалак* < *комал-ак* яисә *комугал*дан метатезамы – әйтүе кыен. К. ш. ук тув. *ком* «корыт шары», аз. *қолама-* «өемгә өю». Чаг. рус. *ком* – ономапоэтик сүз? ЭСТЯ VI: 135–136. Чаг. **Колмак**.

**КОМАЛА-У** (Н. Исәнбәт, Фраз. сүзл., II: 57) «заговаривать, портить заговором» ~ мар. (Саваткова: 68) *кымала* «молиться; умолять». Ачык түгел. Ихтимал, **комалак** (к.) сүзе белән баглыдыр.

**КОМАН, куман** тар. «куманы, команы; половцы; куны» – древняя народность, жившая в Восточной Европе с начала XI столетия. Сүзнең төп мәгъ. «ком төсендәге чәчле, сарычын чәчле (к. **Сарычын II**)» булса кирәк, к. рус. *половцы, половец* иске рус. *половый* «салам төсле саргылт» сүзеннән, ш. ук ним. *Falben* «команнар» ← *falbe* «саргылт, кола», әрм. һ.б. чыганакларда да «сарылар» – куманнар. З. Вәлиди (Velidi: 163) бу атаманы куманнарның чыннан да саргылт чәчле булуыннан дип раслый, әмма кайберәүләр куманнарның «сарылыгы» шартлы мәгънәдә дип баралар. Хәлбуки саргылт чәчле төркиләр ара-тирә бор. заманнардан бирле булган. Мишәрләрнең бор. куманнардан килүе тур. фараз да ышандырырлык. Чаг. ш. ук **Куандык.**

Куманнар кыпчакларның бер өлеше яисә кыпчаклаштырылган бер ят халыктан булганнар. **Куманнар** – «половцы» тур. әдәбият бик ишле. К. История татар II: 459–504; ТЭ V: 296.

**КОМАР** «азартная игра; страсть (в игре, в деятельности)» ~ гом. мөселман төрки *қумар*, кр.-тат. *хумар*, үзб., таҗ. *химар, қимар*, гар. *қумар, қимар* id. Чаг. ш. ук чув. *хăмар* «ачу, ярсыну». к. Zenker: 708; Räsänen 1969: 300 һ.б.

Дерив.: **комарлы** (уен); **комарлан-у.**

**КОМАРТКЫ** «наследие; литературный и т.п. памятник» ~ ком. *қумартқы* «васыять, васыятьнамә», хак. *хумартха* «әманәт», бор. төрки, СС *qumartqu* «васыять, тәүсыя» – **кумарт-* фигыленнән, к. бор. төрки (ДТС: 465–466, 638) *qumaru, xumaru* «мирас; улҗада хан өлеше», төр. *kumaru* «догалык» ~ себ. (Будагов II: 411) **қумарқым** «тылсымлы әйбер, әмәйлек»; чыгт. (Будагов II: 65) *қомурқа* «камау түгәрәге», *қомур-* ~ аз. (АДДЛ: 148) *ғомар-* «камау; һәр яктан яклау» ← **қом* ~ **ғом* «саклана-яклана, яшерелә торган (нәрсә)» сыйфат-исем тамырыннан булса кирәк. Чаг. уйг. *қомар-* «казып чыгару», *қомарт-* «казып чыгарту». Чаг. **Комырык.** Гомумән – ачык түгел. ЭСТЯ VI: 138.

Келт. (ирланд.) *komarbe* «комарткы» сүзе белән охшашлык – очраклы.

**КОМАЧ** тар. «ткань красного цвета» ~ чув. *хăмаç*, мар. Т. (Саваткова: 182) *хымац,* рус. *кумач* id. ~ иске тат., төр., кр.-тат., болг., гар., фар. һ.б. *қумаш* «тукыма тавар; тукымалар», кар., хак. һ.б. *қумас*, иске рус. *кимак* һ.б. киң таралган мәдәни сүз, ахыр чиктә бор. Мисыр. *кмйт* «тукыма төре» сүзеннән (Toivonen: 336). Федотов II: 324. Рус. *куман* ~ *кумач* тур. Аникин: 321 (бик күп әдәбият).

**КОМАЧАУ** «препятствие, помеха», миш. (к. Räsänen 1969: 299) **кумачан** «беспокойство, препятствие» ~ чув. *кумачав*, мар. *кумача* «һәртөрле кыенлыклар». Тат. сөйл. *комача-* «комачаулау» сүзен дә ишеткәнем бар: *ул миңа комачады* диләр. Ләкин бу сүзнең тарихы сәеррәк, чөнки бүтән Урал-Алтай телләрендә сүз нигезендә *о ~ у ~ ŏ* авазлары урынына һәрдаим *-а-* килә: тат. диал. **қамачау,** башк. (БТДҺ: 184; БҺҺ III: 207) *қамасау, қамашау* «комачау», каз. *қамажау* < *қамажқау* «камалыш, камау (исем)». Бездән ерак яшәүче эвенклар телендә (ССТМЯ I: 369) *камавча-* «бозауга имәргә бирмәү, комачаулау», *камавчага* < *камавчаа* «бозау авызлы» һ.б. Башк. *камашау* «камчау» «рожа, экзема, тимрәү» һәм кр.-тат. *камача* «блокада» сүзләренә караганда, сүзнең нигезе *кама-у* фигыленә якын. Ләкин **-ча, -чау** нәрсәне белдерә һәм каян килгән – шунысы томанлы. Чаг. **Камчау.**

Дерив.: **комачаулы, комачаусыз; комачаула-у.**

**КОМАЯК** «песчаная почва; песчаный пляж» < *комай-ак* (**ком аяк** түгел), к. кырг. *қумай*, үзб. *қумой* «комлык, комлы җир»; **комайак** сүзендә иркәләү-кечерәйтү модальлеге сизелә, чаг. **жылыкай.**

**КОМГАН,** (ЗДС: 142) **қомқан, қамқан** «ритуальный рукомойник, кумган; металлический чайник» > чув. *кăмкан*, удм. *кунган*, мар. *кулган*, хант., манси. *хомхан* ~ гом. төрки (Радлов II: 1049) *қумған,* бор. төрки (Поппе 1938: 307; ДТС: 466) *qumγan, qumqan*, яз. монг. *qumaγan* ~ башк. (БТДҺ: 198) *қумаған* «комган, су тәгәче», төрки телләрдән тыш күп телләрдә очрый: Кавказ телләрендә (Абаев I: 651) *гогон, гулгун, гунгуме*, рус. *кумган, кунган, кулган* «комган», маньч. *хумган* «буддистларның изге савыты» һ.б., тат., гом. төрки *хум* (к.) сүзе белән баглы булырга мөмкин. Федотов I: 252; Аникин: 322; Тимергалин: 253.

**КОМСАР-У** (ЗДС: 413) «мрачно смотреть; жадничать» ниндидер *комыс* тамырыннан, к. монг. *хомс* «юксыллык». К. түбәндәгене.

**КОМСУК** (Гиганов), **қомсық** (Тумашева: 128) «жадный, алчный» ~ башк. *қомһоқ* id. *Қомсы-* фигыленнән бугай, бу фигыль исә ***ком** тамырыннан, к. диал. (ЗДС: 412–413) *қомкүз* «ачкүз, комсык, комсыз». Икенче яктан, **қомсық** < **қомысық** булса, сүзнең нигезе **комыс,** к. югарыдагыны. Ләкин тамыры шул ук *қом* < *қум* булырга тиеш.

**КОМСЫЗ [қŏмсŏз]** «жадный» ~ башк. *қомһоҙ* id. – ачык түгел, чаг. башк. (БТДҺ: 198) *қом, қон,* алт. (Радлов II: 667) *қом, қум* «иганә, бөтен җәмәгагә төшкән түләү – салымнарны үтәү өчен үзенә салым салынмаган кешенең дә өлеш кертүе», шуннан *қумсуз* ~ *қумсыз* «җәмәгать кассасына берни дә бирмәүчән» сүзе ясала ала. Ләкин **комсыз** сүзенең бор. *қомыс* (к. **Комсар-у**) нигезеннән дә ясалуы ихтимал. Чаг. **консыз.** Монда төрле контаминацияләр бар бугай.

Дерив.: **комсызлан-у, комсызлык.**

**КОМСЫЛ [қŏмсŏл], комсу** «супесчаный», ш. ук **комташ** «песчаник» **ком** сүзе нигезендә тат. теленең үзендә ясалганнар бугай. Монда рус терминологиясенең тәэсире сизелә.

**КОМЫК [қŏмŏк]** «кумык; кумыки» –сүзнең этимологиясе бәхәсле; безнеңчә, бор. атаклы идарәче *Гази (Кази) Қумуқ* исеменнән. Комыклар үзләрен, бор. төркиләрдән үк киләбез, дип язгалыйлар, ләкин комык теле – иң типик кыпч. теле, тат. теленә бик якын. XIX г. рус язучыларының комыкларны **татар** дип атаулары юкка түгел. XX г. башларында комыклар тат. әд. телен үз итмәкче булганнар. Velidi: 161, 459 (комыклар бик бор. халык дип бара, бор. *кумох* дигән халык белән тиңләштерә). Фасмер II: 416 (*куман* сүзе белән чагыштыра).

**КОМЫРЫК [қŏмŏры̆к],** диал. (ТТДС I: 202; ЗДС: 419) **қоморок** «глухой речной залив; подводная выемка», күч. «закуток, закоулок; уединённое место» ~ башк. (БТДҺ: 193) *қоморок* id. ← себ. (Старчевский) *қумур-* «суга чумдыру, чумдырып яшерү», чаг. каз. (Будагов II: 93) *қумалдуруқ* «биек барханнар арасында – җилдән, бураннан ышыкта кышлау урыны»; төр. *kumul* «дюна, бархан».

Дерив.: **қомырыклан-у** «яшеренеп яту».

**КОМЫЧ [қŏмŏч]** «крестец; репица, копчик» > чув. *кăмăч* «кузна төре» < ком. *қуймуч,* нуг. *қуймыш* «комыч», к.-калп. *қуйымшақ,* кырг. *қуймулчақ* «комыч сөяге» – **коешкан, койрык** сүзләре белән тамырдаш булса кирәк (*кŏмŏч* < **куймулч* ?).

**КОН [қŏн]** (к. ДС III: 85, ТТДС I: 203, 251) «честный облик (лицо)» ~ башк. *қŏн* «үч» (*қŏнсŏ* «үч алучы», *қонсал* «үчегүчән»), каз. *кŏн*, кырг., к.-калп. *қун* «хак, бәя; вира, канга кан түләү» (*қунсыз* «арзан; үче алынмаган») < фар. *хун* < авест. *vohun* «кан; кан үче» >> сугд. *γwrn [*γuran < γunra]* >> башк., каз. *қŏнар* «юнь, рәт, мәгънә, дәрт». Элек (фарсыларда һәм төркиләрдә) *кун* < *хун* дип кәләшкә «кызлык каны» өчен аерым түләүне дә атаганнар (шуннан ук бор. рус. *кунное* «кызлык өчен аерым бүләк»).

Дерив.: **консыз** (ш. ук **конарсыз,** к. ЗДС: 423).

**КОНАҖЫН** иск. «трёхлетняя корова; нетель», диал. (Тумашева 1992: 134) **кунацын** id. < яз. монг. *γunaǯin*, бор. монг. *qunaǯin* > башк. *қонайын,* каз., кырг. *қунаҗын*, үзб. *ғунажын*, төркм. *ғулаҗын* һ.б. К. **Конан.** Рус. диал. *гунаджина, гунак* «конаҗын» тур. к. Аникин: 171–172.

**КОНАН** «трёхлетняя лошадь (реже – корова)» < бор. монг. *кунан*, хәз. монг., бур. һ.б. *гунан, гунун* төрки телләрдә дә киң таралган сүз (Номинханов 1975: 228–229): нуг., каз., к.-калп., кырг. *қунан*, уйг., үзб., төркм. *ғунан* һ.б. монг. *гурбан* «өч» сүзеннән ясалган. Рус. диал. *кунан, гунан, уй*

*кунан* «өч яшьлек ат яисә сыер заты» тур. к. Аникин: 323, 581. К. **Конаҗын.** ЭСТЯ VI: 142–144.

**КОНДЫЗ [қŏндŏз]** «бобр, бобёр», «бобровая струя – парфюмерное вещество» (к. киң таралган такмаза: *Күктә, күктә нилəр бар? Чуар-ала кошлар бар. Канатында нилəр бар? Кондыз белəн җофар бар*) < гом. кыпч. *қундуз* (себ. тат. *қундус*), «кондыз (җəнлек)», алт. *кундус*, төркм. *гундуз* «кама», бор. төрки (МК) *qunduz, quntuz* «су эте», «кондыз», күрше теллəрдə бөтенлəй икенче фонетик вариант: чув. *хăнтăр* < болг. **ҕŏндŏр* > мар. *умдыр, ындыр* (Саваткова: 222), удм. *удор, ундор*, *кундыр*, манси. *хонтел* «кондыз» (к. Räsänen 1969: 301).

Кондызлар Евразиянең урман һəм урман-дала зоналарында, бигүк салкын булмаган елгаларда яшилəр. Кондыз тиресе һəм кондыз мисеге бор. заманнардан бирле сəүдə əйбере булган һəм шунлыктан бу сүз гар., фар. теллəренə дə кергəн: гар. *қундуз, қундус* «кондыз», фар. *қундуз* «кама, кеш, кондыз; бүрек каймасы, кайма» (мəгъ. күчешлəре җəһəтеннəн к. **Камчат**). *Кондыз* сүзен гар. теленнəн дию (Егоров 1964: 293) дөрес түгел.

**Кондыз** бор. төрки **куңтургу*, безнеңчə, *куң* (> *кŏң*) «ис, хуш ис» сүзеннəн ясалган (чаг. *андыз, балдыз, йолдыз, көндез*). **Кондыз** сүзе бор. төркилек оешкан өлкəдə кондызлар яшəгəнлеген белдерə. Шуның кебек, бор. ирани алиһə Анахитага багышланган язмаларда Воурукаша (Каспий) диңгезе һəм Раха (Идел) елгасы буйларында яшəгəн кондызлар искə алына һəм бу факт бор. һинд-ари кавеменең Каспий бассейнында, Идел-Җаек буйларында яшəгəнлеген дəлилли (Гиршман. Иран и миграции индо-арийцев // Этнические проблемы истории Центральной Азии в древности. М., 1981: 140–144).

Урта Азиядəге төрки **кондыз (кундуз)** кабилəсе (һəм шəһəр исеме) ул кабилə кешелəренең кондызлы, камалы бүреклəре буенча бирелгəн булса кирəк (чаг. **Каракалпак, Хахул**). Чаг. **Кондырлы.** ЭСТЯ VI: 146–147; Федотов II: 329.

**КОНДЫРАК** диал. к. **Кындырак.**

**КОНДЫРЛЫ: кондырлы кодача** «чопорная женщина» ~ себ. (ЗДС: 412) **колторло** «щеголеватый»? Ихтимал, **Кондырлы** дигəн авыл исеменнəндер; бу авыл исə болг. *қŏндŏр//ҕŏндŏр* «кондыз» сүзеннəн. Идел-Урал регионында тагын *Кондырча* дигəн авыл һəм елга атамалары бар. К. **Кондыз.** Чаг. ш. ук **Кундыр.**

**КОНТЫШ [қŏнтŏш]** иск. «рубище; кафтан с откидными рукавами» – сүзнең «җəрбəк» («рубище») мəгънəсе ироник характерда булса кирəк, югыйсə кр.-тат., төр. *контош, кунтуш* (> рус., укр., *кунтуш*) бик мул чигүле һəм җиңнəре артка ташламалы өске кием»не белдерə һəм бор. ир. (Мидия) *χανδος* (грекча язылышта) «өске кием» сүзеннəн килə (Фасмер II: 418).

М. Рясянен буенча, госм. *kontŏš* «Төркиядə чик сакчысы булып хезмəт иткəн ттарларның форма кием» һəм ул венг. теленнəн алынган сүз, к. Räsänen 1969: 279. Штайервальд (Steuerwald: 548) **контош** «кырымтатар кенəзлəренең мул чигүле кием», ди.

**КОНЫ [қŏнŏ]** «росомаха», диал. **қыны** «рысь; куница» (ТТДС I: 203, 218) ~ башк. *қŏнŏ* «кондыз», себ., хак., шор. *куну, хуну*, хак. диал. *куна,* камаси. *kŏnu*, кетт. *kuone* «коны», шор. *кунучак* id., кырг. *қуну* «коны; йомшак йонлы кыйммəтле тире; йомшак йонлы ат токымы» – шуннан ук рус. *куна, куница* «сусар» (к. Joki 1952: 192). Räsänen 1969: 300 (уйг., урта төрки *qun-* «урлап качу» сүзеннəн ди).

Бор. русларда һəм украиннарда *куна* «сусар» (**тиен** шикелле) «акча» мəгъ. йөргəн һəм бер дирһəмгə тиң исəплəнгəн (к. Фасмер II: 417); металл акчаларның бер ягына көзəн рəсеме сугылган (чаг. – Уфа гербындагы сусар).

**Коны** сүзе **кондыз** белəн тамырдаш булырга мөмкин.

**КОҢГЫРАТ [қŏңғŏрат]** – старое название г. Уфа, а также как имя родоначальника (к. Əхмəтҗанов 2002: 91–104) – төркилəшеп, төрле якларга таралган **куңгурат** (к.-калп. *күңгырат*) дигəн монг. кабилəсе исеменнəн. К. Дрон И.В. Комрат – этнотопоним тюркского происхождения // СТ, № 1, 1981: 54–59.

**КОҢГЫЗ [қŏңғŏз],** диал. (злт.) **қŏңғŏр** «жук» ~ башк. *қуңгыҙ*, каз. *қоңыз*, уйг., кырг. *қоңуз, куңуз, коңгаз,* чыгт., бор. төрки (Räsänen 1969: 281; ДТС: 456) *qoŋuz, qonuz* > алт. *коңос, комыс, коос* «коңгыз» ~ монг. *ғуур* «нөр; бөҗəк курчагы»; бор. монг. (Поппе 1938: 157) *qonquzuk* ~ чыгт. *qonquz* ~ як. *хомурдуос* «коңгыз», к. чув. *хăмăр* «бал корты; бөҗəк». Гар. *хунғус* «коңгыз» төрки теллəрдəн булса кирəк. ЭСТЯ VI: 61–62.

**Коңгыз** сүзен *коңгыр(т)* сүзе белəн тəңгəллəштерергə мөмкин. Икенче яктан к. алт. *коңыз, комыс* «кубыз» (кайбер коңгызлар кубыз авазлары чыгаралар).

**КОҢГЫР [қо̄ңғо̄р], коңгырт,** себ. (Тумашева 1992: 128, 155) **куңыр** «коричневый, красно-рыжий» < гом. кыпч., алт., уйг., угыз. *қоңур* (башк. (БТДҺ: 153) *көңгөр, көңгөрт,* нуг., каз., к.-калп. *қоңыр, қоңғыр* һ.б. вариантлар шактый) «коңгыр», як. *хоңор* «ачык сары (ат төсе тур.)» < бор. төрки (ДТС: 456) *qoŋur* «көрән; җирән» һ.б.ш. барча төрки, монг. һәм тунг.-маньч. телләрендә очрый (Пекарский: 3489, Räsänen 1969: 280–281, ССТМЯ I: 411; ЭСТЯ VI: 62–65). Чув. *хăмăр* ~ башк. *қумыр,* гаг. *қомур* «коңгыр» чув. *хăмăр* һәм як. *хомурдуос* «коңгыз» сүзе белән баглы шикелле; алт. диал. *қоор* (> хак. *хоор*) «кара коңгыр» рус. *коурый, каурый, каурка* «елтыр кара (ат)» сүзләренең чыганагы булып исәпләнә (к. Аникин: 274). Сүзнең тамыры **коң* > **куң*; чаг. тат. диал. (ТТАС II) *күн сакал* «җирән сакал», башк. (БТДҺ: 163) *күн туфрак* «кызгылт туфрак». Төрки *қоңғыр* ~ *қоңур* күп күрше телләргә кергән, к. рус. *кангор, конгор* «соры кыргый каз», ш. ук «койгыз», *хонгор* «бурлы җирән ат» һ.б. К. Аникин: 25, 621.

**КОҢГЫРА-У** «глухо звенеть» к. **Кыңгырау.**

**КОҢКА** «музыкант-певец» к. **Куңка.**

**КОПЫ: копы бүрек** «простая глубокая шапка без наушников» < фар. *хуби* «көяз»: колакчынсыз бүрек киеп йөрү – көязлек галәмәте дип исәпләнгән.

**КОР I, қур, қор** (ЗДС: 415, 427; БТДҺ: 203) «пояс; круг сверстников; хоровод; круг играющих» < гом. төрки (Радлов II: 916; ДТС: 167 һ.б.), чыгт. *қур* «билбау; яшьтәш; (билгә тагылган) корал; дивар, койма; вакыт, чор», бор. уйг. *quur*, бор. төрки *qur* «билбау; чин (бу мәгъ. «билбау, кәмәр, каеш» мәгънәсенә бәйле: билбау чинга, дәрәҗәгә карап төрлечә булган), чират, тезем». Гомумән **kur* ~ **kor* күп телләрдә очрый; грек. *хор* «хор, уен түгәрәге», гар. *кур* «шар, түгәрәк». Чаг. шумер. *кур, гур* «түгәрәк кирмән». Г. Рамстедт төрки-монг. *қур* ~ *күр* сүзен кор. *korii* «кыршау» сүзе белән дә чагыштыра.

Бу сүз элекке дәверләрдә бик еш кулланылган һәм бик актуаль булган, шунлыктан аның дериватлары да күп: к. **Бастаңгыр, Җәйгор, Корак, Кордаш, Коршау, Корын, Курпы, Курчалау, Курчы, Кучты, Кушак.** К. Будагов II: 73; Räsänen 1969: 301–302 (тәфсилле); Gombosz: 128; Боровков 1963: 217; ЭСТЯ VI: 152–154.

Дерив.: **кор җәргә** (КБ) рус. «круг воинов – охранников монарха при походах, выездах и т.п.»

**КОР II** «тетерев» ~ каз., үзб., уйг. диал. *қур* id. ~ бор. монг. *qora, qoru,* тунг. *һороки* «боҗыр, суер һ.б.ш. кош», хәз. монг. *хур*, *қур*, бур. *хура* id. ЭСТЯ VI: 155.

**КОРАБ** «корабль». Бу сүзне революциядән соңгы матбугат телендә русчага охшатып, русчадан дип белеп шулай яза башладылар, хәлбуки революциягә кадәрге тат. яз. әдәбиятта бу сүз (к. Будагов II: 119) كراب = *кәраб* дип язылган. Бу сүз русчадан алынмаган һәм аны *кораб* дип язу (моны ничек укырга икән?), русча әйтмешли, «безобразие». К. **Кәрап.**

**КОРАК, қордақ, кораклы, корлы** (ТТДС I: 203, 252, Тумашева 1963: 152–153) «сверстник» ~ башк. (БТДҺ: 199) *қорақлаш* id. ← **қор I.** К. **Кордаш.**

**КОРАЛ** «оружие» > удм., мар. *корал, курал, кӱрал* (Алатырев 1976: 27) ~ чув. *хăрал*, *кăрал* < гом. кыпч., үзб., уйг. *қурал,* төркм. *ғурал* id. Ком., нуг. телләрендә «музыкаль инструмент», иске тат. (Будагов II: 47) *қурал* «дирбия, тирге һ.б.», кар., кр.-тат., төр. диал. *kuran* «корал», төр. *kural* «кагыйдә; тәртип». Күп кенә төрки телләрдә бу сүз юк. *Қурал* сүзенең ике мәгъ. ике чыганак тамырдан: 1) бор. *қорға-у* < *қурға-у* «саклау, курчалау», 2) *қор-у* < *қур-* «кору, төзү, тезү, төзеклеккә китерү». Будагов II: 73; Räsänen 1969: 302; Федотов I: 257; ЭСТЯ VI: 158–159. К. **Курга-у.**

Дерив.: **кораллы, коралсыз; кораллан-у.**

**КОРАЛАЙ** «разновидность диких коз; дикий козлёнок» (**коралай ае** «22 апрель – 22 май») < гом. кыпч. *қуралай* < **qurγalan* id. ~ яз. монг. *quriγan, quraγan* id. бор. төрки **qurï* «коралай» > гом. төрки *quzı, qozı* «куй бәрәне» (*r* > *z*). К. Будагов II: 74; ЭСТЯ VI: 159–161.

Рус. *куран, курган, кураган, хураган* «коралай, кузый» (монгол телләреннән) тур. Аникин: 325–326, 627. К. **Кузый.**

**КОРАМА**, диал. **корамыш** «сборный, лоскутный; сшитый из разных кусков» < гом. кыпч., үзб., уйг. *қурама, қурамаш*, уйг. *қуралма* id. *қура-* «корау» фигыленнән. К. түбәндәгене.

Урта Азия халыкларында, кыпчакларда һ.б. *корама* (юрган, кием һ.б.) явыз рухлардан, сихердән

саклый дип исәпләнгән (к. Таджики Каратегина и Дарваза. Душанбе, 1970: 203–225).

**КОРА-У** диал. (Тумашева 1992: 129) «составлять (из лоскутьев); составлять, соединять (вообще)» < гом. кыпч., үзб., уйг. *қура-*, хак. *хура-,* төркм. *ғура-* id. ~ иске монг. *quri-ja* id. ~ бор. төрки *quvra* «җыелу», *quvraγ* «(изге) җыен». М. Рясянен (Räsänen 1969: 302) бу сүзләрне фин. *kuro-* «кишәрләрдән җыю» сүзе белән чагыштыра. Г. Рамстедт исә *кор* < *кур* «түгәрәк» сүзеннән чыгара. К. ш. ук ЭСТЯ VI: 157–158. Чаг. **Кор-у.**

**КОРБАН** «жертва; жертвоприношение; (**корбан балык**) лещ» > чув. *кăрпан* (татарчага бик охшаш әйтелә), *хăрпан,* удм. *курбон* «корбан; корбанлык өрәге» < гом. мөселман. *қурбан* < гар. *қурбāн* «корбан; Аллага якынаю (чарасы)» сүзеннән, *крб* «якынлашу, якын, якынлык» тамырыннан (шуннан ук иске тат. **қариб** «якын; якынлашкан», **әкърәбә** «якыннар, дус-иш»). Räsänen 1969: 302.

**Корбан** сүзенең тат. диал. **корман** > удм. *курман, корман,* мар. *хорман* > *орман* ~ каз., к.-балк. һ.б. *қурман, қурмал* варианты да киң таралган. Шуннан **корман айы > корманай** шәмсия айларының берсе (октябрь), ә **корбан бәйрәме** камәрия ае буенча үткәрелә.

**Корбан балыгы** каны түгелмәгәнлеге өчен «корбан ителгән».

Дерив.: **корбанлык.**

**КОРБӘТ,** тар. (Velidi: 203) **қурбăт** «хөкемдарның дусты, яшерен киңәшчеләре» < гар. *қурбăт* id., к. **Кариб.**

**КОРГА I** (Балинт: 60) «голбец, летний ледник» ~ каз., чыгт. *қорға* id. Рясянен буенча (Räsänen 1969: 283), **қурган** (к.) сүзе белән игез яки нигездәш.

**КОРГА II, корага** иск. (Г. Ибраһимов һ.б.) «военный жребий, билет при наборе солдат в царскую армию» – «хәрби жирәбә, шобага, билет (ак билет, кызыл билет булган)» ~ төр., фар. *қур'а* (*курга* дип язылган) «сайлау шары; солдатка алыну жирәбәсе; солдатка алынырлык яшь» < гар. *қур'а* «шобага; лотерея шары» ← *қр'* «шакылдау, шалтырау». Будагов II: 49.

**Корга** системасы армиядә егерме биш ел хезмәт иткән хәрбиләрне пенсиягә җибәргәндә дә кулланылган, ягъни алар хезмәт мөддәте җиткәч тә бер юлы җибәрелмәгән. **Кура** сүзе Төркиядә «хәрби пенсия; пенсия урынына бирелгән җир кишәре; хәрби пенсионер» мәгъ. алган. **Корга** системасы Казан дәүләтендә дә булган бугай.

**КОРГАК I** (себ., ЗДС: 415) «твёрдое нёбо; челюсти» ~ алт., шор. *қурғақ* «урт ите»; хак. *хургах* id. һ.б. Сәер сүз. К. Räsänen 1969: 303 (кайбер фаразлар китерә).

**КОРГАК II** «сухой, засохший; засушливый» < гом. кыпч., уйг., алт., хак. һ.б. (Радлов II: 940) *қурғақ,* добр. *qurgaq,* төр. *kurak* < бор. төрки (ДТС: 467–470) *qurγaq* id. < *qurγa-* «кору, коргаксу» ← **қуру-ғақ* яисә **қуруғ-ақ* id. ← *quru-* «кору». Бор. телдә бу нигездән ясалган сүзләр хәзергедән күбрәк. К. **Коры-у.**

Дерив.: **коргакла-у; коргаклык.** К. түбәндәгене.

**КОРГАКСЫ-У** «засыхать, рассыхаться; испортиться: растрескиваться от засухи (о земле)», күч. «впасть в нужду» ~ гом. кыпч. *қурғақсы-* «корый башлау; корыга охшау» ← **қорғақ.** К. югарыдагыны.

**КОРГАН** «укрепление» к. **Курган.**

**КОРГЫЛДА-У, коркылда-у** «квохтать, клохтать»?, «глухо каркать (о вóронах)» – **қорық** *(корык-корык)* тәкълиди сүзеннән. Чаг. диал. **корык тавык** ~ төр. *gurk* id.

Сүзлекләрдә **коргылда-у**ны «квохтать» дип аңлату шик уята. В. Даль буенча, *квоктать, квохтать, клохтать* «особым криком проситься на яйца и сзывать цыплять». **Коргылда-у** исә, безнеңчә, *қоррығ* дип сузып, аптыраган шикелле аваз чыгару. Русча *квохтать* сүзенең тат. дөресе *кыртлау* була. Татарча тавыклар *коргылдый, кургылдый, куррылдый, кыртлый, кытаклый, кытный, көртли* һ.б. Гомумән, тавыкның дүрт төрле төп авазы – паникага бирелгәндәге, чебигә утырасы килгәндәге, дусларны-чебиләрне ашарга чакыргандагы һәм аптырап торгандагы озын авазы була. Соңгысына *коргылдау* бап килә.

**КОРГЫН [қŏрғŏн]** диал. (ДС I: 93; Тумашева 1992: 129) «предплечье; кость крыла, к которой прикреплены маховые перья» ~ алт. *қурқун, қорқун*, хак. *хурхун* id., **кор-у** фигыленнән булса кирәк: **коргын**га каурыйлар тезелеп тора, *корыла*.

**КОРДАШ** «сверстник, человек одного поколения с кем-либо» < гом. кыпч. *қурдаш* (нуг., каз., к.-калп. *құрдас*) id. *қур* «түгәрәк; яшьтәш кешеләрнең җыены» сүзеннән: бу сүз үзе генә дә «кордаш» мәгъ. кулланыла: *Айдар ханның коры (чордашы) Печән хан ирде* (Т. Ялчыгол). К. **Кор I.** Д.Б. Рамазанова. Слова со значением «ровесник, друг» в татарских говорах // Проблемы функционирования... Казань, 1998: 53–61.

**КОРКА, курка, корга** диал. «ковшик» (Остроумов 1976: 91; ТТДС I: 257) ~ чув. *корка, курка* id. Чаг. рус. диал. *корец* id.

**КОРКЫТ [қŏрқŏт]: Коркыт ата, Коркыт баба, Коркод** (к. Әхмәтҗанов 2009: 157–163) «древний легендарный певец, бард и патриарх-вождь, святой, почти пророк у огузских народов, а также у казахов, башкир, у отдельных групп татар» ~ башк. (Народное творчество башкир: 34–35) *қорқот, кузкурт, кормкут* id. X–XII гг.дан аның тарихи прототибы – реаль шәхес булганлыгы тур. язмалар калган: Византия императоры Константин Порфироген бәҗәнәкләр Идел һәм Җаек буйларында яшәгәндә аларның башчысы **Куркута** булган дип хәбәр итә (X г.), XII г. Гыймадетдин Исфаһани төрекмән кабиләсе гузларның әмире *Коркуд* булган ди (к. Короглы Х. Шаман, полководец, озан // СТ № 4, 1989: 48–62). **Коркыт** исеменең югарыда китерелгән башкорт вариантлары бүтән беркайда да очрамый, бигрәк тә *кузкурт ~ куркурт* (?) варианты кызыклы: исем составында, димәк, *корт* ~ **курт** «бүре» сүзе булган. К. Bazin L. Le nom propre d'homme Qorqut < qor qut // UAJ, 36, 1964: 278–283. Атаклы «Коркыт дәдә китабы» – угыз дастаннары җыентыгы тур. зур әдәбият бар. МНМ II: 5.

**Коркыт ата** исеме тат. мәкальләрендә очрый. Мәшһүр татар драматургы, шагыйрь Ф. Бурнаш Коркыт турында бер поэма язган: анда Коркыт үлемнән качып сәяхәт итеп йөри, ләкин кая гына барса да, алдына кабер килеп чыга. Шундыйрак легенда караимнарда да бар.

2000 елда Бакуда уздырылган «Тәңречелек» дип исемләнгән бер конференция материалларында Коркытның тәфсилле биографиясе бирелә: ул, имеш, 203 елда Дербентта туган, унөч яшеннән Алтайга шаманнар мәктәбенә укырга җибәрелгән, 220 елда **дәдә** «укытучы, мөгаллим» чинын алып, хәз. Монголия һәм Тибет өлкәләрендә сәяхәт иткән, тәңречелекне өйрәнгән, аннары Һиндстанда, Иранда, Гыйракта төрле диннәр белән танышып, туган якларына кайткан һәм өр-яңа *Коркыт динен* нигезләгән. Һәм *коркыт* сүзе илнең дин башлыгы мәгъ. кулланыла башлаган. Зәки Вәлиди дә, **Коркут** ул бор. төрки дәүләтләрендә «вәзир» мәгъ. дигән сүз булган яки бер вәзир булган, шуннан соңгы *коркыт* < *коркут* титул да, кеше исеме дә булган, дип язган. К. İA VI: 860–866.

Казакстанда Коркытның мәһабәт мавзолеен ясап куйганнар. Шуңа барып дога кылалар.

**КОРМАН** (**корман, қŏрман,** к. ЗДС: 321, 415) «название различных языческих увеселений, обрядов, жертвоприношений» ~ мар. *орман, урман* < болг. **ҕŏрман* id. һ.б. Ислам, мөселманлык белән таралган дини-мифологик төшенчәләрнең мәҗүсилек һәм христианлык регионнарына үтеп керүе – типологик күренеш. Бу очракта да *корман* < гар. *қурба̄н* (к. **Корбан**), әлбәттә. К. МНМ II: 540–541 һ.б.

Төрле чыганакларда **ай** сүзе ялганып **Корманай** дигән кеше исеме ясалганлыгы күренә.

**КОРМЫШ I, кырмыш** «дикая пчела; шмель» (ТТДС I: 263). Ачык түгел.

**КОРМЫШ II, кырмыж, қораңгыш** (к. ТТДС I: 203, ТТДС II: 149), (БТДҺ: 200, 206) **кормош, коромос, курмыш** «скряга». **Кормыш I** очрагы шикелле, бу сүзнең дә ихтимал тамырдашлары күп, ләкин конкретлаштырырлык материал юк. Чаг. **Кырмыш.**

**КОРСАК** «живот, брюхо; бремя» < гом. төрки *қурсақ* id., ш. ук (алт.) «ашказаны; азык, ризык» (Радлов II: 957) < бор. төрки (ДТС: 470) *quγursaq* ~ *quruγsaq,* бор. уйг. *qorsqaq* «корсак». Үзенчәлекле мәгънәләр: төр. *kursaq* «һава капчыгы», хак. *хурсаг,* як. *куртах* «ашказаны; бүтәкә». Сүздә *-сак* элементы шәйләнә (чаг. **Бавырсак**). Будагов II: 76; Räsänen 1969: 303; ЭСТЯ VI: 164–166.

**КОРТ I** «червь, червяк; личинка» < гом. кыпч. *қурт* id. ~ тув. *хораган* «ефәк; ефәк корты», як., монг. *хорохой* «бөҗәк, кигәвен; корчангы» < бор. монг. *qoraγai* id., к. ш. ук уйг. *қурут* «корт». Ихтимал, сүзнең төп мәгъ. «ашаучы» булгандыр. К. **Корт II.** Чаг. **Кортка**. К. Будагов II: 74; Räsänen 1969: 303–304; ЭСТЯ VI: 167–168.

**КОРТ II** иск. «волк» < госм., аз., чыгт. *қурт*, иске угыз. *гурд* > төркм. *гуурт* «бүре» (Мухаме-

дова 1973: 117) < бор. төрки ******қуурт* < ******қуурут* id., **корт < курт I** сүзеннән (табу) дип уйланыла (Севортян һ.б.). Кайбер телләрдә бүрене «бөҗәк» дип тә атыйлар.

Чаг. ш. ук фар. *хурдан* «ашау», *хурак, хуррак* «ашамлык».

**КОРТКА** «старушка, оставшаяся без мужа» < гом. кыпч. *қуртқа* (к.-балк., ком. *қуртха*) «карчык» < бор. төрки (ДТС: 469) *qurta, qurtqa* id.; бу сүзнең тат. диал. **қŏртқайак,** алт. *курткайак,* хак. *хуртуйах, хурайак,* шор. *қуртуйақ,* тув. *куруйак,* каз., кырг. диал. *куружақ* «карчык» варианты киң таралган. Канәгатьләндерерлек этимологиясе юк. Чаг. *карт*-**коры.** Räsänen 1969: 304; ЭСТЯ VI: 168–169.

Кр.-тат. *qurtqačıq,* нуг. *qurtqašıq* «салават күпере» ~ каз. *қуртқа коры* id. тур. бер гүзәл риваять бар. Ул риваять буенча, *қортқа* < *қуртқа* «кәҗә-сарыкларның химаяче рухы», аның аллы-гөлле бәтибәрәннәре бар икән. Шулар болытларга менгәч, салават күпере пәйда була, ди.

**КОРТКЫЧ [қŏртқŏч],** диал. **қорытқыч** «вредитель» ~ башк. *қоротқос* id. ← тат. *қорыт-,* башк. *қорот-* гом. кыпч. *қурут-* «корыту; бетерү, юк итү (*агачны корытудан*)» фигыленнән (*коры-у* фигыленең йөкл. юн.) тат. телендә ясалган сүз. Ихтимал, рус. *вредитель* сүзеннән калька итеп ясалгандыр.

**КОР-У**, диал. **қора-у** «ставить, воздвигать, строить; устраивать; составить; заряжать», диал. «запрягать» < гом. төрки (Будагов II: 77; Радлов II: 919) *кур-* id., *қŏр* < *қур* «түгәрәк» сүзеннән фигыль корреляты булса кирәк (тәүдә «түгәрәкләп тезү, түгәрәкләп утыру» мәгъ. булган), к. бор. төрки *qur-* «тирмә һ.б.ш. кору; хәрби теземгә тезү; керешне җәягә тарттырып кую». К. **Кора-у, Корга-у.** Будагов II: 77–78; Räsänen 1969: 302; ЭСТЯ VI: 156–157.

**Кор-у** сүзеннән төрки телләрдә дә, тат. телендә дә күп кенә сүзләр ясалган: **корыл-у, кордыр-у** һ.б. К. **коргыч** «чыбылдык, чаршау», **корма** «куыш», к. ш. ук **Корал, Коргын** «канат сөяге», **Корылтай**.

**КОРЧАҢГЫ,** диал. **курчаң** (к. Радлов II: 953) «чесотка», диал. «короста, парша; шелудивый» > чув. *кăрчанкă*, удм. (Насибуллин: 123) *куршангы,* мар. (Исанбаев 1978: 18) *курчанге* id., удм. *курт-чаньги* «сифилис» < гом. кыпч. *қурчаңғы* (каз. *қыршаңқы*, кырг. *қырчаңғы*, нуг. *қуршаңғы*), уйг. *қирчанғу*, үзб. *қирчоңғи* «корчаңгы» *қорчан-* < *қурчан-* «кашыну (терлек тур.)» фигыленнән, фигыльнең төп юн. ******қурча-,* ******қурчы-*, к. тат. диал. **қорчы-у,** башк. диал. *қорсо-* (ТТДС I: 205; БҺҺ II: 145) «кычын-у» ~ госм. *курҗа-* «тырнашу» ~ бор. монг. *qorči-ji* «бетләү, кортлау» һ.б. Ихтимал, *корт* сүзе белән тамырдаштыр. Будагов II: 75; Räsänen 1969: 266; Федотов I: 260.

**КОРШАУ [қŏршаw], кыршау** «обруч; обод, ободок», диал. (ТТДС I: 264; БТДҺ: 200–201) «обшивка подола» < гом. кыпч., к. кар. *қуршов,* каз. *қŏршау*, ком. *қыршав* «коршау, билбау», төркм. *қуршав* (< кыпч.), нуг., каз. *қурсав* һ.б. < бор. төрки (ДТС: 468) *quršaγ* id.; тат., башк. телләрендә **корша-у, кырша-у** (к.) «әйләнәли беркетү, ныгыту, кыршаулау», (БТДҺ: 201) «бергә җыю» фигыле дә бар һәм **коршау** сүзе (исем) шуннан да, бүтән төрки телләргә бинисбәтән, килеп чыга алыр иде. К. ш. ук **кушак ← куша-у.**

Күп кенә төрки телләрдә **куршаw < куршағ** белән беррәттән шул ук мәгъ. *курчаw* > кырг. *курчоо, кырчоо* «коршау, тирмәне тыштан кысалап торган бау» ~ хак. *хурчаг, қурчаг* «коршау» ~ себ. (Тумашева 1992: 129) **қоршақ** «коршау; билбау» сүзе дә актив кулланыла.

Барлык бу сүзләрнең тамыры *қŏр* < *қур* «түгәрәк; алка; билбау» к. **Кор.** Будагов II: 75; ЭСТЯ VI: 150–152 (*қуршаw* < *қуршаг* һәм *қурчаw* < *қурчаг* нигезләре аерым карала, гомумән, шактый буталчык).

Дерив.: **коршаулы, коршаусыз; коршаула-у.**

**КОРША-У** «натянуть обруч; опоясывать», диал. (ДС I: 93; ТТДС I: 205) «окружать; огородить» < гом. кыпч. *қурша-*, тув. *куржа-* < бор. төрки (МК) *qurša-* «уратып алу, коршау» (*-ш-* варианты борынгылыктан килә) < бор. гом. төрки *қурча-* id. К. **Коршау, Кушак.**

**КОРЫ [қŏрŏ]**, диал. (ЗДС: 317, 318) **қороқ, корык** «сухой; сухо»; күч. «только лишь, всего; без ничего» < гом. кыпч. *қуры, қуру,* гом. төрки *қуру*, *куруг* < бор. төрки *қуру-г* «корыган». Тат. диал. (ТТДС I: 204, 252) **қŏрŏқ** «буш», **кŏрык** «кисенте ботаклар, лапы» **коры-у** фигыленнән. К. ш. ук чув. *хăр, хăрă* «коры (төрле мәгъ.)»». Будагов II: 78–79; Räsänen 1969: 266; Федотов II: 331.

**КОРЫК [қŏрŏқ]** «укрюк (длинная палка с петлёй в конце для поимки животного, скота из стада)» ~ башк. *қŏрŏқ* < гом. кыпч. *қурық, қуруқ* (ком. *курух*), уйг. *қоруқ, қуруқ* id. күп күрше телләргә кергән, к. венг. *hurok,* кабарда. *гурыгъ* «корык». Барлык

этимологлар *корык* < *ŏкырык* < *окуруқ* > себ. тат. **укрук, ŏқрык** id. (к. Тумашева 1992: 162) дип карыйлар, к. тув., алт. *урук, уурук*, хак. диал. *урух* «элмәкле колга; аркан» < (як.) *оғуруқ* «корык» ← *оғур*, эвенк. *окурга*, бор. монг. *ugūrga* «корык» ← бор. төрки, бор. монг. *oku-* «челтәр белән кош тоту» (Poppe H. On some mongolian loan words in evenki // UAJ, XVI, №2, 1972: 95–96). Будагов II: 52–53 (төрле тарихи мәгъ. бәян ителә). Räsänen 1969: 516, ЭСТЯ I: 585–586. К. ш. ук **Аркан.**

Рус. *укрюк* < төрки **үкүрүк* < *уқуруқ* тур. Аникин: 581, 592.

**КОРЫЛТАЙ [кŏрŏлтай]** тар. «государственное собрание» ~ башк. *кŏрŏлтай,* нуг., каз. *құрылтай*, гом. төрки *қурултай*, аз., төркм. *ғурултай* id. < бор. монг. *хурултай, хурилтай* «тантаналы рухани бәйрәм төсендә» дигән сүздән Чыңгыз яулары чорында таралган булса кирәк (к. Номинханов 1975: 110–112). Сүзнең нигезе монг. *хурал, хурил* «җыен; зур дини бәйрәм; парламент» – хәз. көндә дә Монголиядә, Тувада һ.б. кулланыла торган сүз *қор-* < *кур-* «кору, төзү, тезү» тамырыннан дип уйланыла, к. Аникин: 375–376, 627.

**КОРЫМ I [қŏрŏм]** «сажа» ~ чув. *хăрăм*, башк. *қором* < гом. төрки *қурум* (хак. *хурум*), хак. диал. *хурун* < бор. төрки *qurun* «корым, көек», эвенк. *куруң* «көек», *курунук* «корым» (к. ССТМЯ I: 438), к. Радлов II: 936, Räsänen 1969: 304). Чаг. маньч. *қуваргана* > *қургана* «корымлану, каралу», *курча* «корым, көек, юшкын, кара күмер» һ.б. К. ЭСТЯ VI: 169.

**Корым** сүзенең бор. төрки *qorum* (ДТС: 460) > тув., алт. *қорум, хорум* «ишелгән ташлы тау битләве» сүзе белән бәйләнеше шикле. Әмма бу **қорум** < **қором**га тат. **кŏм-кŏрыч** < *қŏрŏм корыч* (ТТДС I: 204) «таркау, җимерек-ватык» сүзе тоташуы мөмкин.

Тат. тарихи әдәбиятында өченче бер **корым** – **Кара Корым** шәһәре – Чыңгыз империясенең тәүге башкаласы атамасы да очрый. Беренче карашка бик «аңлаешлы» күренгән бу атаманың **корым**га катнашы юк: монда *корым* < монг. *хурим, қурим* «зур гыйбадәтханә; хан сарае» сүзеннән. Бу сүз белән тат. диал. (миш.) **курмыйш** < *курим йеш* «авылның (мәҗүси) гыйбадәтханә һәм идарәханә урнашкан очы» сүзе баглы (*йеш* «парк»). К. **Каракорым.**

Дерив.: **корымлы, корымсыз; корымла-у; корымлан-у.**

**КОРЫМ II [қŏрŏм]** диал. (ТТДС I: 204) «охотничье сооружение; расставленные сети» – әлбәттә, **кор-у** фигыленнән.

**КОРЫН I [кŏрŏн]** диал. «сходка, встреча членов общины (односельчан) в определённое время суток» – к. чыгт. *тӧрт кур (курун)* «тәүлекнең дүрт вакыты», иске уйг. (Zenker: 713, 716; ДТС: 467)*korun, koron* «билгеле вакыт», алт. *кором* «соңыннан, бераздан» < бор. монг. *qorım, qurım* «бәйрәм җыены; бәйрәм табыны; кордашларның бергә җыелуы» (Poucha: 179), яз. монг. *xurim* «бәйрәм, табын; туй» >> хәз. монг. *хурим*, як. *қурум*, эвенк. (ССТМЯ I: 437) *курим, курум*, эвен. *курам* id. , рус. диал. (Аникин: 329) *курим* «свадебный пир, девичник» . Чаг. ш. ук тат. диал. (ТТДС I: 204) *қŏрŏм сөртү* (дөресе – **сөрү**) «кунаклашу, кунакка барышу» . **Кор I** (к.) сүзеннән (аның инструменталь килеш формасы исемләшкән). К. **Кичкырын.**

Монг. *хурим* < *курим кор-у* < *кур-* сүзе белән бәйле булса кирәк. К. **Корым I.**

**КОРЫН II [кŏрŏн]** иск. «век, эпоха» > мар. *курым* «гасыр» < гар. *қурӯн* «гасырлар, еллар» һ.б.ш. ← *қарн* «мөгез; мөгездәге еллык сырлар». Чаг. *Зөлкарнәй* «ике мөгез иясе» – Македонияле Искәндәр (Александр Македонский)ның кушаматы. *Қарн* тамыры ностратик характерда (чаг. ним. *Horn* «мөгез» һ.б.)

Дерив.; элекке терминологиядә **коруне әүла** «борынгы заман», **коруне вуста** «урта гасырлар».

**КОРЫСКА** [**қŏрŏсқа**] диал. (Тумашева 1992: 129) «мерлушка» ~ алт. *қурусқа,* хак. *хурусха* < монг. (Будагов II: 79) *хурисху* «илтер» бор. төрки > монг. *хуригас* «яшь кенә бәрән; кузый» сүзеннән, к. рус. диал. *курегашка* «бер атнадан алты атнага кадәрге бәрән» < монг. (Аникин: 327).

**КОРЫТ [қŏрŏт],** диал. **қŏрт** «курут, сушёный сыр» < гом. төрки *қурут* id. ~ бор. ядкәрләрдә *грут, грунт* (В. Рубрук) – төрки-монг. күчмәннәрнең төп азыгы, к. гом. кыпч. *қурт*, төркм. һ.б. угыз *қурут, ғурут*, хак. *хурут*, алт. диал. *қурғут* id. һ.б. (ЭСТЯ VI: 156–167), к. ш. ук яз. монг. *xurud*, хәз. монг. *хурууд* < *қуруғуд* «эремчек, сыр». Гомумән, монг. телләрендә ясалган булса кирәк. Бу сүзне гадәттә *коры-у* фигыленнән дип карыйлар («корытып киптерелгән эремчек»), к. Räsänen 1969: 304; Аникин: 332–334, 629 (шунда ук бай әдәбият күрсәтелә). Ләкин, безнеңчә, бу сүз бор. төрки *қур* «за-

пас азык» сүзеннән, к. як. *курула-, курут-* «запас калдыру». Чаг. рус. *курсун, корсун, коршуны* «эремчеккә җиләк-җимеш болгатып ясалган һәм кышлыкка киптерелгән күмәч-тәмәч» ~ бур. *хурһан*, калм. *хурен* < бор. монг. (Ramstedt 1935: 199) **xurisun* id. ССТМЯ I: 438.

**КОРЫ-У [қŏрŏ-]**, диал. **қор-** «сохнуть, высыхать (о деревьях); захиреть; обезвоживаться; пересыхать; вымирать (о роде)» < гом. төрки *қуру-, қуwру-* (кыпч. *қыwры-*), як. *куур-*, тув. *қурға-* (икенчел булса кирәк) < бор. ** қу-ра* id. *қу* «коры, кипкән» сүзеннән ясалган булырга тиеш, чаг. бор. монг. *qoqira-* «кору». К. **Коргаксы-у, Коры, Корыш-у.** ЭСТЯ VI: 154–155 (төп форма *қур* дип карала); Федотов II: 331. Чаг. **Каура-у.**

Дерив.: **корыш-у; корыт-у, корткыч < корыткыч** һ.б.

**КОРЫЧ [қŏрŏч],** себ. **куруч** «сталь» ~ чув. *хорçă, хурçă, хурăç* < болг. **һурыч* > мар. *хурыс', урас', урс'о* «корыч; сыра көче» < бор. төрки (ДТС: 467) *qurč temür* «үткер тимер; корыч» (*qurč* «чыдам, ныклы») сүзеннән эллипсис; к. себ., кар., куман. *қурц,* уйг. *қуруч* (> каз. *қуруш, қурыш*) «корыч» ~ үзб. *қурч* «точ; бронза; саллы», кырг. *қурч* «корыч; үткер, кайнар, темпераментлы», алт. *қурч* «үткер, кискен, чая», госм., төр. *kurç* «корыч; үткер», калм. *хурц* «үткер» < бор. монг. (Поппе 1938: 311) *qurča* «җете, үткер», чаг. маньч. *курчала-* «корымлау, тимерне корымда чыныктыру» (*курча* «корым»), *куварчана-* «каралу, корымлану». Шулай итеп, ахыр чиктә **корыч** сүзе бор. төрки (?) **қуварча* «корым» сүзеннән булып чыга (әйтергә кирәк, корыч ул – үзендә карбон күбрәк булган тимер). Тимергалин: 256–257.

**КОРЫЧАГАЧ [қŏрŏчаᵒғач]** «ясень» < *көреч агач* ~ ком. *гүйрүч*, чув. *кавăрăç*, *кавăрç* id. ~ венг. *körisfa* (*fa* «агач») id. тат. диал. (Тумашева 1992: 102, 110) *көрөц, қүрүч, күрүц* «дөге» < бор. төрки > фар. *гурунч, гүринч* «хөрмә талы; дөге» сүзеннән (*көреч агачы* сабаклары дөгенекенә охшаш). **Корыч агач** дию халык этимологиясеннән.

*Көреч, гөреч < күрүч, гүрүч* «дөге» күп төрки телләрдә очрый: к. каз. *күрүш,* кырг. *күрүч*, бор. төрки *kürüč, gürüč* «дөге; пылау» (ДТС: 195, 329).

**КОРЫШ-У [қŏрŏш-]** «сохнуть (от старости), уменьшаться (в объёме), сжиматься» < гом. кыпч. *қуруш-* id. **коры-у** фигыленнән.

**КОС-У** «блевать; появиться (о колосьях)» ~ чув. *хăс-* id. < гом. төрки *қус-* id. (Радлов II: 1012; Räsänen 1969: 304), бор. төрки (ДТС: 475) *quz-* id. Кайбер сүзлекләр «косу» һәм «башак чыгару ~ косу»ны *qus- I* һәм *qus- II* рәвешендә бирәләр (ДТС: 470). **Косык** < бор. *qusuq* сүзе дә гом. төрки характерга ия. Будагов I: 81; Федотов II: 334–335.

**КОСУР** (М. Гафури һ.б.) «вина, провинность; недостаток усердия, внимания и т.п.» < гар. *қусӯр* «җитешсезлек» ← *қср* «җитешсез булу»; нишләптер бу сүз башк. телендә киң таралган: *қоçор ~ қоһор, қөһөр* «начар нәтиҗә» (к. БТДҺ: 201).

**КОТ** «дух нормального состояния и счастья; присутствие духа и одухотворенности, красоты и т.п.» ~ чув. *хăт,* удм. *кыт, кут*, мар. *кут* id. < гом. төрки *қут* < бор. төрки *qut, qawut* «фазыйләт, бөеклек» (ДТСта *qut II* «бәхет» аерым сүз итеп бирелә), чаг. ш. ук алт. *коот* «юаныч». Кетт телендә *kyut, kūt* «шаманның ярдәмче рухы» (Donner K. Ethnological notes about the Jenisey-ostjaks // MSFOu LXVI, H. 1933), кор. *qut* «магия» ~ төрки *қут* (к. Ramstedt 1949: 132). Кыргызларда *кут* «җиде сәдәп яисә кургаш курчактан гыйбарәт фетиш (аны кеше үзе белән йөртә)», бор. монг. *gutug, γutuγ, qutuq* > хәз. монг. *хутух, хутаг* «кот, бәхет» > эвенк. *куту, коту, кута* id., маньч. *хутури* «бәхет, мач». Безнеңчә, тат. диал. **кортла-у** «котлау», *кортыл-* < чыгт. *қуртул-* «котылу» сүзләрендәге *қорт* тамыры бор. яңгырашны чагылдыра һәм бор. яңгыраш **қағурт* < **қаңурт* «кургаш җан» (к. **Каң** һәм **Үрт**).

**Кот** курчакларны кургаштан койганнар ич. Хәер, бу безнең фараз гына. Бу фараз файдасына түбәндәгеләр дә «су коя».

**Кот** сүзенә һәр җәһәттән – үзенең яңгырашы, мәгънәләре, фраземалары белән – мар. *орт, öрт,* коми. *орт, урт,* удм. *урт* «кот, җан» охшаш. Бу сүз болг. (яисә бүтән бер бор. төрки) **һорт ~ һурт < *хурт < қурт* «кот» сүзеннән булуы бик ихтимал.

**Кот < кут** сүзе (әлбәттә) тунг.-маньч. һәм монг. телләрендә дә киң таралган. Монг. *хутухта, кутухта, хутагта* «монгол буддистларының рәсми башлыгы» (католиклардагы папа шикелле) ← бор. монг. *xutuγtu, qutuγtu* «котлы» id. ← *qutuγ* «кот» (к. Аникин: 37). Чаг. бор. төрки, гом. төрки **котлы, кутлу, кутлуг** – монарх титулы (үзенә **кот** бирелгән кеше мәгъ.), *idi qut, idi qurt* (ДТС: 469) «кенәз».

**Кот** сүзе тур. әдәбият бик ишле, к. Bombaci A. Qutluγ bolsun // UAJ, 36 (1965) – UAJ, 38 (1966); Paasonen H. Uber die ursprunglichen Seelevorstellungen bei den finnisch-ugrischen Völker und die Benennungen der Seele in ihren Sprachen // JSFOu XXVI. 1909: 1–27; Rahmeti-Arat R. Der Herrscher titel Ïduq-qut // UAJ, 35, B. 1964; Donuk: 77–88; Федотов II: 335–336; ССТМЯ I: 440.

К. **Коткар-у, Котла-у; Котыл-у; Котыйчык; Курчак** һ.б. сүзләрдә дә *кут* тамыры бар дип фараз ителә.

**КОТАЙ-У** «делаться счастливым, красивым» < гом. кыпч. *кутай-* < уйг. *кутад-* < бор. төрки *qutaδ-* id. **кот < qut** сүзеннән. К. югарыдагыны.

Дерив.: **котайт-у → котайткыч.**

**КОТАНАЙ** (Г. Газиз) «идол в виде худой старушки» ~ башк. *ҡотан* «убырлы карчык». Тат. **Котан батыр** – комик герой, икенче бер сүз. Күп төрки телләрдә (каз., к.-калп., алт. һ.б.) *кутанай* «химаяче рух; юньле кыяфәт, котлылык». ***Кот анай** булса да гаҗәп түгел, әмма андый сүзтезмә үзе теркәлмәгән.

**КОТКАР-У,** диал. **котказ-** «спасать» ~ чув. *хӑтар* < болг. *һŏтар-* > мар. *ытар-, утар-* id. < госм., аз., кр.-тат. һ.б. угыз., чыгт. *кутар-*, аз. *ғуртар-* ~ гом. кыпч. *кутҡар-*, ком. *кутғар-*, уйг., үзб. *кутҡаз-* < бор. **куртғар-* һичшиксез *курт* «кот» сүзеннән: *аткар-, җилгәр-, сугар-* моделендә ясалган, я **кот- < кут-** фигыленнән, к. **Котыл-у.** Räsänen 1969: 304; Федотов II: 336–337.

**КОТКЫ [ҡŏтҡŏ]** «агитация; подстрекательство; натравливание» ~ нуг. *кутҡы*, кырг., үзб. *кутҡу* «коткы; болгату, талау» – тат. диал. (ТТДС II: 178) *ҡот-у* < **кут-* «ярсыну, котыру» к. бор. монг. *qutqiči* «болгаучы» (Поппе 1938: 351)», яз. монг. *хидхи*, монг. *хутга-,* бур. *худха-*, эвенк. *кутку-*, нан. *котко-, хотоха* «болгату, бутау» (ССТМЯ I: 440). Бу сүзләрнең тамыры тат. телендә (**ҡот-у* «болгату») булып чыга. К. **Коен, Котыр-у.** Чаг. **Койрык.**

**КОТЛАУ [ҡŏтлаw]** «поздравление» к. түбәндәгене.

**КОТЛА-У** «поздравлять» ~ чув. *хӑтла-* < гом. кыпч. *кутла-* (к.-калп., кырг. *кутта-* һ.б.) id. К. ш. ук **котлык** < гом. кыпч. *кутлуҡ* «бәхетлелек» (кырг. *куттуҡ*) < бор. төрки *qutluγ* «котлы» һ.б. *qut* «кот, бәхет» сүзеннән (**котла-у** «кот бирү»).

Өйдән чыгып китүчегә: *Сиңа юл котлык, миңа өй котлык* дигәннәр (бу әйтем «тизрәк чыгып кит» мәгъ. дә әйтелгән). Элек юлда туган балага **Юлкотлык, Котлыюлай** дип исем кушканнар.

**КОТЫЙ [ҡŏтŏй]**, диал. **ҡŏтŏҡ** «коробочка, круглая деревянная кружка с крышкой (для хранения непищевых предметов)» ~ башк. *ҡŏтŏҡ,* каз. *ҡŏты*, нуг., к.-калп. *ҡуты, ҡутыҡ,* ком. *ҡутуҡ,* үзб. *ҡутти*, алт. *котты*, кырг., госм., гаг., кр.-тат. *ҡуту* id. (кайбер телләрдә «дары савыты»), аз., төркм. *ғуты*, як. *кытыйа* id., ләкин борынгырак яңгыраш тат. сөйләшләрендә: **кŏтŏл** (ТТДС 1992: 176) < *кŏтŏр* «кузак; мөгез савыты» < бор. төрки (ДТС: 474–475) *qutur, qutuz* «болан; як» сүзеннән булса кирәк. **Котый**, димәк, «як мөгезеннән эшләнгән савыт» булган. Бор. ядкәрләрдә, төркиләр (кыргызлар) **хуту** дигән мөгез белән сәүдә итәләр, дип языла (мәс., Гардизи). К. түбәндәгене.

Тат. телендә кечерәйтү формасы – **котыйчык, котырчык** ~ төр. *kuticik* һ.б. киң таралган. К. **Кутаз.**

**КОТЫЛ [ҡŏтŏл]** (ТТДС II: 176–177) «рожок, кривой стручок», **ҡотылчык** (ДС III: 88) «высокий небольшой круглый сосуд». Бу сүзне **котый** (к.) сүзенең варианты дип исәпләп, «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге»нә кертмәгәннәр. Ләкин фонетик җәһәттән монда уйланырга урын бар.

**КОТЫЛ-У [кŏтŏл-]** «спасаться» < гом. кыпч. *кутул-, куртул-, кутрул-* (к. Егоров 1964: 295–296) < бор. төрки *qutul-, qurtul-, qutrul-* (ДТС: 466, 473–474) – *кот* < *qut* сүзеннән, ихтимал, аның фигыль коррелянты **qut-* < *qurt-* «котка ия булу» сүзеннәндер. К. **Коткар-у.**

**КОТЫП [кŏтŏп]** «(Северный) полюс», «светоч святости, святой высшего разряда» (к. бу хакта Будагов II: 58–59) < гар. *кутб* id.

**КОТЫР-У [кŏтŏр-]** «взбеситься, бушевать; беситься», диал. «разгневаться», себ. «бежать, мчаться, метаться» > чув. *кӑтӑр-, хӑтӑр-* < болг. **һŏтŏр-* > мар. *ытыр-* id. < гом. кыпч., уйг., үзб. *кутур-*, алт. диал., госм. *кудур-* id. Чаг. як. *кутур-* «шаман җыр-тулгауларын башкару» (*кутуруҡ* «шаман җыры, котырыгы») ~ тув. *кудуур-* «кайгыру»,

бур. *годоор-* «тынычсызланып чабышу». Чаг. **Коен, Койрык, Коткы.** Радлов II: 1003; Федотов I: 263. Räsänen 1969: 305 (тел. *kut-* «хәлең беткәнче чабу» сүзен китерә).

Төр. *kudur* «котырган, котырынкы» < бор. **қутурғ* < *қутурғу* булса кирәк. Чаг. чыгт. *қутуз,* госм. *қудуз* һ.б. «бик усал кыргый үгез төре» (*-рғ* > *-з*). Чаг. **Котый, Кутаз.**

Дерив.: **котырын-у, котырыш-у, котырт-у; котырык.**

**КОТЫРТ-У [kŏтŏрт-]** «подстрекать, подзуживать» > чув. *кăтăрт-,* мар., удм. *кутырт-* id. < гом. кыпч. *қутырт-, қутурт-* id. *қоттыр-* < *қуттур-* фигыленең йөкл. юн.; мар. *ытырт-* «котырту» < болг. **һŏтŏрт-* < бор. төрки *қŏтŏрт-* id. Бу **котыр- < коттыр-** исә *кот-* (к. **Коткы**) фигыленең йөкл. юн.

**КОЧА** (әстр., ЗДС: 418) «кучкар, сарык тәкәсе» < калм. *хуцa* id. ~ алт. *қуча,* яз. монг. *quča*$^{n}$ id. һ.б. «кучкар». Барча себ. төрки, монг., тунг. телләрендә, барча себ. рус сөйләшләрендә очрый, к. Аникин: 174, 308, 338, 630 (бик күп әдәбият). К. **Кучкар.**

Әйтергә кирәк, бу *кŏча* Себер якларындагы *қоча* белән бер изолиния тәшкил итми (гом. төрки *о* белән әйтелә).

**КОЧАК** «объятие; охапка» < гом. төрки *қучақ* (> башк. *қŏсақ,* каз. *қошақ,* нуг., к.-калп. *қушақ*) id. ← *коч-* < *куч-* (к. **Коч-у**).

Дерив.: **кочакла-у; кочак-кочак.**

**КОЧ-У** «объять, обнимать» < гом. төрки *қуч-* (> башк. *қŏс-,* каз. *қŏш-*, нуг., к.-калп. *қуш-*) id. ~ бор. төрки *quč-* ~ яз. монг. *quči-* «кочу, чолгау, каплау» (Поппе 1938: 307).

Дерив.: **кочыш-у, кочтыр-у.** К. **Кочак.**

**КОШ** «птица», тар. «ловчая птица, сокол» < тат. диал. (м.-кар.) **қŏғŏш** ~ гом. төрки *қуш* (> каз. *қŏс-,* нуг., каз. *қус,* хак. *хус*), *қууш* id. < *қуғуш* ~ иске уйг. («Угызнамә»дә) *қуғаш*; бу сүз алт. *ку, куу* < бор. төрки *quγu* «аккош» (ДТС: 464) сүзе белән баглы. Кайбер төрки телләрдә (чув., як.) *кŏш* < *куш* сүзе (һәрхәлдә төп мәгъ.) юк һәм бу факт *қуш* сүзенең чагыштырмача соңрак таралганлыгын күрсәтә. Будагов II: 81–82; Радлов II: 1022; ЭСТЯ VI: 180–181 (мәгълүматлыгы тулы түгел).

Дерив.: **кошчы** (~ бор. төрки *кушчи, кушчы* «ау кошы белгече» (рус. «сокольничий» мәгъ. дә бар»); **кошчылык.**

**КОШТАБАК** «глубокая чаша» (к. ЗДС: 419) < кош табак? **Кош** монда бор. кыпч., чыгт. («Хөсрәү вә Ширин» һ.б.) *қоош, қууш* «эчемлек эчү савыты» сүзеннән (к. Будагов II: 82) булуы ихтимал. Ш. ук **кушт табак** «ит табагы» сүзеннән дә була ала, к. **Көшт, Кушт.** Төрле вариантлар тур. к. Хайрутдинова 2000: 41.

**КОЯШ** «солнце» < гом. төрки *қуйаш* id. (ләкин бу сүз кыпч. һәм угыз телләрендә сирәк очрый) < бор. төрки *qujaš* ~ як. *куйаас, куньаас* «эссе» ~ чув. *хĕвел* «кояш» < бор. төрки *qıval* id. М. Кашгари бор. текстта *qıznıŋ ... burnı qıval* дигәнне «борыны төз» дип аңлаткан, ләкин контексттан күренгәнчә, *burnı qıval* «алды кояш» дигән сүз. К. бор. төрки *burun* «алгы як, ал» (к. ДТС: 126); башк. диал. *кыуал* «тирмәнең түбә ачыклыгы» ~ венг. *hajnal* «таң», хант. *куныл* «эссе». **Кояш** сүзен *көнәш* (к.) сүзеннән дип аңлату исә фонетик җәһәттән нигезләүгә мохтаҗ. ЭСТЯ VI: 122–123.

Дерив.: **кояшлы, кояшсыз; кояшлан-у.**

**КӨБӘ** «кольчуга, панцирь» ~ чув. *кĕпе [көбә]* «күлмәк; конверт» ~ нуг. *күбэ*, к.-балк. *кюбе*, ком. *гюбе,* кырг. *күбө*, кр.-тат., төркм. *күве* «күбә», алт. диал. *күбе* «гайка; җигемлектә – алка, дүңгәләк» (**көбә** – аерым алкалардан тезелә), гаг., төр. *küpe* «колак алкасы, сырга» ~ гар. *күббӓ* «алка» (төрки телләрдән булса кирәк), к. яз. монг. *kȫhe* < **köböhe* «көбә» (к. Поппе 1938: 220), чыгт. *күпэ, күбә* «шайман» (Будагов II: 142). К. ш. ук **Көпе.** Федотов I: 275 (**көбә** сүзен *кәбәнәк* һәм *күбәк* сүзләре белән бәйли, ләкин семантик җәһәттән бу чагыштырулар бик шикле). Сафаров: 44; ЭСТЯ VI: 129–130 (без китермәгән мисаллар күп).

**КӨБӘК** «ствол (ружья)», вообще (ЗДС: 322) предметы из полого ствола дерева: «ведёрко», «труба колодца, источника», «полый конец цепа» и т.п. к. **Күбәк.**

**КӨБӘЛӘ** «мелкий кузнечик; кобылка» – рус. *кобыла* id. сүзеннән булса кирәк. Бу сүз исә, ихтимал, **күбәләк** (к.) сүзе белән баглыдыр (рус. *кобыла* «бия» тәүдә «чикерткә» мәгъ. булган булса кирәк, һәрхәлдә бу рус сүзенең ышандырырлык этимологиясе юк).

**КӨБЕРГӘЕЛ [көбөргәйĕл]** «жаба; черепаха» < **көбөрткәйле*, к. башк. (БТДҺ: 73, 148) *гөбөргәйел, көбөргәйел,* нуг., к.-калп. *күбирткейли (бака)*

«талпан; гөберле бака; ташбака», каз., кырг. *күбүргөлүү бақа* «ташбака, гөберле бака», кырг. *күбүргө* «селкенчәк, тетрәвек саз» – асылда «тире капчыклардан тезелгән күпер», гом. кыпч. *күбүркэй, күбүркә* «йөзмә күпер салу өчен файдаланылган тире капчык» (к. **Күпер**) сүзеннән (чаг. тат. **гөберкә** «гөберле бака тәнендә аерым-аерым торган мүкләч бизләр; шәлдәге кабарынкылыклар – бизәк күпермәләре»), к.-балк. *кюбюр [күбүр]* «сандык, тире сандык». Төр. (Будагов I: 141–142) *köпүрлү бэга* «гөберле бака».

Бу мәгъ. кучешләрендә кулланылган метафоралар: кырг. телендә «селкенчәк саз < йөзмә күпер сыман (саз)», тат. телендә «күпертеп эшләнгән (шәл бизәге) < рәттән тезелгән үзара тигез тире капчыклар (сыман)»; кырг. телендәге *күбүр* «боз боткасы, су өстен каплап йөзгән вак бозлар < тире капчыклардан торган йөзмә күпер» һ.б. бик аңлашыла (заманында алар һәркемгә таныш булган әйберләрне белдергәннәр).

Ташбака төрки телләрдә еш кына «савытлы бака» мәгънәсендәрәк булган сүзләр белән белдерелгән: ком. *қапқачлыбақа, тақалыбақа* (*тақа* «чүлмәк; баш сөяге»), каз., үзб. *қурбақа,* гаг. *курбаа,* төр. *kurbağa* «ташбака, гөберле бака» < *кувурбака* (*кувур* < *кубур* «кубыр, кобура»); венг. *teknösbeka* «ташбака»: *teknö* «ялгаш, тигәнә», *beka* «бака» һ.б. Чаг. ш. ук **Ташбака.**

**КӨГЕЛТЕ [көгөлтĕ], көйөлте** диал. (ДС I: 114) «кулик», чаг. ш. ук **көйөлтке** «куропатка». Үзгә язылышларда **көгөлде, көгөндә, көйөлткө** (Тумашева 1992: 101) ~ башк. (БТДҺ: 149) *көйөлгө* «кулик», *көйөлдөр* «зур шөлди» – *көй* ~ *көг* «көй, көйләү» сүзеннән булырга тиеш (бу кошларның еш кына сайрап йөрүеннән). Чаг. **Көелте, Көйгәнәк.**

**КӨДЕРӘЙ-Ү** «ощетиниться; грозить (не имея сил, чтобы осуществить угрозу)» ~ башк. *көҙөрәй-* id., тат. диал. (Остроумов 1892) **гөдөрәй-** «кабарыну (күркә тур.)» ~ каз. *күдірей-, күжірей-* «аркасын кәкрәйтү» (мәс., мәче тур.) ← *күдіре* «көчле, гайрәтле», *күдір-күдір* «түмгәкле». Чаг. як. диал. (ДСЯЯ: 133–134) *күтүр* «дәһшәтле; явыз, усал» ~ яз. монг. *küder* > бур., монг. *хүдэр* «юан, массив, көчле».

**КӨДРӘ** «кудрявый» ~ чув. *кăтра*, мар. *кудыр* һ.б. id. Русчадан булса кирәк. К. Федотов I: 264. Чаг. **бөдрә.**

**КӨЕЛТЕ** – жалобный (кажущийся жалобным) крик некоторых птиц – **көй-ү** «яну, кумергә әйләнү; кайгыру» сүзенә нисбәт ителә, **көелте** дип кайбер ерткыч кошларны атыйлар.

**КӨЗ** «осень» < гом. төрки *куз* ~ чув. *кĕр, кĕркунне* «көз, көз көне» < бор. төрки **kǖrg*, к. төр. *güz*, төркм. *гүйз, күйз* id. Räsänen 1969: 312, ЭСТЯ III: 94–95. Чаг. ш. ук төр. *güzei, küzei* «тауның күләгәле ягы; төньяк», венг. *köd* «томан; көз», удм. *гӧр* «зыкы, кырау» < төрки ? Федотов I: 277; ЭСТЯ VI: 130.

Дерив.: **көзле (язлы-көзле); көзсез** «көз житмичә»; **көзләү; көзлек** (күп мәгъ., «көзен чәчелгән, уҗым» мәгъ. бар) һ.б. К. **Көзләч.**

**КӨЗӘН I** (**сасы көзән** «вонючий **көзән**») «хорёк; лисица» < гом. кыпч. *күзэн, күзән,* уйг. *күзән,* бор. төрки (МК) *küzün* id. ~ тат. диал. (т.я.) **күрә,** (әстр., к. ЗДС: 329) **көрәнәй** ~ монг., маньч. *күрэнэ* ~ венг. *goreny* «көзән». Барлык этимологлар бу сүзне **көрән** төс белән баглы табалар (к. ССТМЯ I: 437). К. **Көзән II.** ЭСТЯ VI: 86–87; Аникин: 331 (рус. *курна* < монг. *хүрнэ* «кара көзән төре» тур. бай әдәбият күрсәтелә).

**КӨЗӘН II** (**көзән җыер-у** «стягивание **көзән**») «судорога; паралич» > удм. *кузен* id., чув. *кĕсен* «кутырлау», мар. *кĕсäн, кусен* «сеңер», *кусен шупшмаш* «сеңер тарту – көзән җыеру». Мар. сүзе тат. теленнән булса, бу – халык этимологиясе буенча мәгънә үзгәреше. Тат. **көзән** исә **көзән I** сүзеннән: сасы көзәннең сыекчасыннан сеңер тарта, тән кутырлана һ.б. Көнч. Азия халыкларында көзән хикмәтле хайван дип исәпләнә, к. Сидихменов 2000: 68.

**КӨЗГЕ [көзгө]** «зеркало» > чув. *кĕскĕ*, мар. *күзгӧ,* удм. *күзгĕ, кызгы* id. < гом. кыпч. *күзгү, күзги* id. < бор. төрки (ДТС: 321) *közgü, közŋü, közüŋü* «көзге» ← *közün-* «чагылу», к. «Мөхәммәдия»дә *Сән ул күзгүнүң ичиндә [эчендә] күзүнгән рухи әгъзамсың.* Бор. төрки **köz-* «күрү, карау» (к. бор. төрки *közgär-* «күрсәтү», к. **Күрсәт-ү**) сүзеннән, ягъни **көзүнгү* «күренге, күренгеч, үз-үзеңне карагыч» дигәннән, чаг. хак. *кӧрендес* «көзге». К. ш. ук алт. диал. *кӱзӓңӓ* ~ як. *куһӓңӓ* «көзге». Гомумән, *көзүн-* < **көргүн-,* ягъни *көр-* «күрү» сүзенең **көрүк-* «күрергә тырышу» формасыннан. ЭСТЯ VI: 132–133.

Дерив.: **көзгеле, көзгесез; көзгедәге, көзгедәгечә, көзгесыман** һ.б. хәз. фәнни терминологиядә кулланыла.

**КӨЗЛӘЧ, көзләwеч** (ЗДС: 323) «животное (овца, коза) осеннего окота» диелгән. Күрәсең **көзлә-ү** «көзен бәрәнләү-бәтиләү» сүзе булган. Яисә **көзлә-ү** «көзен билгеле бер урында (көтүлектә) тору» сүзе булган (к. каз. *күзде-* id.) һәм көзләүдә туган бәрән-бәти дә **көзләү** (бәтие) дип аталырга мөмкин. **Көзләвеч** сүзе исә структурасы буенча бәрән-бәтигә түге, сарык-кәҗәнең үзләренә карый: «гадәттә көзен бәрәнли-бәтили торган».

Миш. сөйләшләрендә **йәйләц, йәйләwец** сүзе бар. Ихтимал, **кышлач, кышлавыч** сүзе дә бардыр.

**КӨЙ I** диал. (миш., себ.) **кү, күй** «мотив, мелодия; лад; настроение» ~ чув. *кӗвӗ* < гом. кыпч., уйг. *күй* id. кырг., алт. *куу, күй* (бераз аермалы мәгъ.) < бор. төрки *kȫg* «мелодия» < бор. кыт. *khyog* > кыт. *цюй* «музыкаль инструмент; көй» (к. ДТС: 311), к. ш. ук тув. *хөг,* хак., монг. *көг* «шатлык; көй». Кайбер тикшеренүчеләр *көй* һәм *ку* кытайча ике сүздән килеп чыккан һәм бор. *ку, күй* «дан, данлау» < кыт. *kö* сүзеннән диләр (Рамстедт), шуннан бор. төрки *külüg* «данлы» > кырг., алт., тув. *кулук* «герой», хак. *кулук* «хикмәт иясе» һ.б. (гомумән, бу сүзләрнең мәгъ. һәм вариантлары күп, к. Räsänen 1969: 286, 306–307, Номинханов 1975: 174 һ.б.). Идел-Урал регионында миш. *ку, kew* һәм чув. *кӗв, кӗвӗ* вариантларының гомогенлыгы күзгә ташлана; *көй* сүзенең барлык мәгъ. һәм кулланылышлары чув. *ҫем* ~ мар. *с'ем*, удм. *сям* сүзендә кабатлана (калькалаштырыла), бу сүз бор. тат. *җәм* сүзеннән килә. Димәк, болг. телендә «көй» мәгъ. *җәм* сүзе кулланылган, ә *кӗв* сүзен чувашлар кыпч.-тат. теленнән алганнар. К. **Ямь.**

Дерив.: **көйле, көйсез; көйлә-ү, көйлән-ү.**

**КӨЙ II: көй каз** (ДС II: 127) «гусь, гуси, гуляющие на свободе без особого присмотра (осенью)» < бор. төрки (ДТС: 312) *kög* «ирекккә җибәрелгән терлек», *kök* «иркендәге, азат, ирекле». Шуннан бор. *кӧк түрк* «**күктүрк**» этнонимик тәгъбире килә: «азат һәм көчле» дигән сүз булып чыга. Чаг. **Киек.**

**КӨЙГӘНӘК** «вид ястреба», тат. диал., башк. **көйгәләк** id., тат. диал. **көйәнәк, көйгәнәк** «бүзтургай, бүзтилгән (рус. “пустельга”)» ~ каз., чыгт. (Будагов II: 170) *күйкәнәк* (гарәп шрифтында төр. «муймул дидекләре куша дерләр», *көйкенек,* каз. (Катаринскийда) *кӱйкӧнтӓй,* хәз. языльшта *күйкентай,* диал. *күйкәннәй* «тычкан карчыгасы», чыгт. *күйкӓнӓк* «тычкан карчыгасы», төр. *күйкӓнӓк* «карчыга», алт. диал. *күйкӓнӓк* «дүдәк», хак. *көйкенек* «сапсан», кр.-тат. *күйгӓнӓк* «лачын төре» ~ кырг. *күйкө* id. һ.б. **көй-ү** һәм **көй** сүзләре нигезендә ясалганнар (мәзкүр кошларның характерлы авазларына имитативлардан), к. тат. диал. (ЗДС: 324) **көйәләк, көйәрәк, көйгәк, көйгән, көйгәнәк** «борчылучан, темпераментлы, усал». Kannisto, 121; Räsänen 1969: 307. Чаг. **Көелте.** ЭСТЯ VI: 133–135 (үзара аз охшашкан күп сүзләр рәтендә китерелә).

**КӨЙЗӘ-Ү** «слегка толочь в ступе для вышелушивания зерна; вообще – очищать от остьев, остатков мякины, шелухи (зерно, крупу)» ~ диал. **кизә-ү, күзә-ү** (ТТДС I: 243, 281). К. ш. ук башк. *көйҙә-ү* id. (БТДҺ: 149). Ачык түгел.

**КӨЙМӘ I** «большая лодка, судно, корабль» – дөресрәге **киймә,** гом. диал. (күп төбәкләрдә), башк. *кәмә*, тат. **кимә** < хак. *кимэ,* гом. төрки *кэмӓ, кӓмӓ,* уйг. *кәми, кими* >> төр., төркм. *gemi*, төркм. *гәәми, кәәме* (к. Räsänen 1969: 251; Мухамедова 1973: 120–121; ЭСТЯ III: 37–39). Төрки телләрдән күп күрше телләргә кергән, к. ЭСТЯ VI: 36. Тат. **кәмә ~ кимә** закончалыклы күренеш. Бу сүз бор. төрки *kӓm*, тув., хак. *кэм, хэм*, бур. *хэм* «Енисей; зур елга, Идел» сүзе белән баглы булса кирәк («зур елга каегы»). К. **Кимәгәч.**

Тат. әд. телендә карарлашкан **көймә** формасы **көймәле каек** тәгъбире тәэсирендә барлыкка килгән. **Көймә** ул *көймәле кимә!* К. **Көймә II.**

**КӨЙМӘ II,** диал. (ЗДС: 324, 352–353) **күмә** «маленький шатёр, кров; покрывало; тележка с крышей для младенца» ~ нуг., каз. *күймэ* «крыша телеги» ~ тат. диал. **көрмә** > чув. *кӗрме* id. К. ш. ук кабарда. *гөймэ* «түбәле арба» һ.б. *көймә* < *көрмә* (*күймэ* < *күрмэ*) булса, сүзнең тамыры **күри-* < **кули-* < **kölü-* «күләгәләү» (к. ДТС: 314), чаг. калм. *күмаh* < *кулмh* «арба көймәсе». К. **Көрмә, Күмәгәй.**

**КӨЙРӘ-Ү I,** диал. **көйөрә-ү** «тлеть», (ДС I: 114; Тумашева 1992: 101) «разрушаться от пребывания в жаре»; «поджариваться». Төрки телләрдә *күйрэ-* татарчадагы мәгъ. сирәк очрый һәм гомумән күп телләрдә юк, булганда да икенчерәк мәгъ., к. себ. (Радлов II: 1413) *күйрэ-* «картаеп мәлҗерәү», кырг. *күйрө-* «җимерелү, кыйралу», нуг. *күйревиш* (< *күйрэwич*) «вак куак, чытыр».

**Көйрә-** < *көй-рә-* < *көгрә-* (як.) *-ра//-рә* компоненты ярдәмендә бор. *kög-* «көю» фигыленнән ясалган (чаг. *аз-* > *асра-*, *җәй-* > *җәйрә-*, *кый-* > *кыйра-*

һ.б.), к. аз. (Радлов II: 1524) *күврә-* «картаеп какшау» ~ чув. *каврай-* «көйрәү, җимерелү, таркалу».

Дерив.: **көйрәл-ү, көйрәт-ү**; үзенчәлекле дериваты – диал. **көйрәк** «бераз көйдерелгән (камыр ашы һ.б.)», к. ДС I: 114; Тумашева 1992: 101. К. **Көй-ү.** ЭСТЯ III: 7.

**КӨЙРӘ-Ү II** (ЗДС: 325) «жаждать, испытывать жажду» – ихтимал *көйөрә-ү*. Чаг. алт. *кӱӱре-* «азаплану, көю» һ.б.

**КӨЙРӘ-Ү III, күрә-ү** (ЗДС: 324–325, 356) «стать тонким от усыхания – о покосах сена» – **көйрә-ү I** белән бердәй түгел бугай. Чаг. бор. төрки (ДТС: 304) *kevirä-, kevrä-* «зәгыйфьләнү, кибү», *küvrä-* «кибеп кату» (чаг. **Көрән**). Тат. (ЗДС: 324) **көйрәк** ~ бор. төрки *kevräk* «зәгыйфьләнгән, нечкәргән; юкарган (үлән-печән тур.)». К. ш. ук бор. төрки (ДТС: 30) *küvrä* «скелет, кипкән калдык». Чаг. **Кура-у.** Будагов II: 170 (бик аз язылган).

Дерив.: **көерек, көйрек** «нык кипкән (печән тур.)».

**Көйрә- II** һәм **көйрә- III** тә **көй-ү** белән тамырдаш, ләкин төрлечәрәк ясалганнар.

**КӨЙ-Ү,** диал. **кү-ү, кеw-ү** (ДС I: 118 һ.б.) «подгорать, тлеть», күч. «горевать» (*горе ← горевать* мәгъ. күчеше тур. к. Фасмер I: 440) < гом. кыпч. *күй-* < гом. төрки *кöй-* ~ угыз. *гöй-* id., уйг. диал. *кöй-*, кар. *киw-* < бор. төрки *köj-* < **kög-* «яну» (чаг. бор. монг. *kögji-* «яну, янып китү»). К. **Көйрә-ү, Көя, Күмер.**

Дерив.: **көел-ү, көен-ү, көеш-ү, көйдер-ү;** үзенчәлекле дериватлары: **көек-ү (көегү)** «чамадан артык көю (ашамлык тур.)»; **көек [көйөк]** «урман янган урын, янык» (бу сүздә **көй-ү** «яну» мәгъ. сакланган), «кайгы», **көенке** «куе кызыл төс» (ТТДС I: 274), **көялән-ү** «кайгырып борчылу» һ.б.

**КӨЙШӘ-Ү** «жевать жвачку» к. **Күшә-ү.**

**КӨЛ** «зола» > чув. *кĕл* < гом. төрки *кул* (> тув., хак. *хул*) id. Барча телләрдә дә «көл» мәгъ. сүзләр – иң борынгылардан, чаг. (ССТМЯ II: 347) эвенк. *һулэптэн,* эвен. *һултэн*, маньч. *фулэнги* «көл». ЭСТЯ VI: 137–138.

Дерив.: **көлле, көлсез; көллек; көллән-ү; көлсу, көлсыман** (туфрак). К. **Көлчә.**

**КӨЛӘПӘРӘ**, диал. **көрәпәлә** «шлем с пелериной, капюшон» ~ башк. (БҺҺ III: 83) *колапара* «сарык тиресеннән тегелгән һәм иңнәрне дә ябып торган баш киеме», каз. *күләпара* «киң колакчынлы хатын-кыз бүреге» (к. Будагов II: 133) < фар. *күлаһибәррә* «канатлы очлы бүрек»: *күлаһ* (> иске тат. *куляһ, көлаһ* – «нәкышбәндиләрнең рухани дәрәҗәгә күрә төрлечә тегелгән очлы бүреге», уйг. *кула,* кырг. *күлö* «дәрвишләрнең чуар бүреге», төр. *külah*, гаг. *кулаф* «дәрвишләрнең очлы бүреге; манара башы; шлем» һ.б.) һәм *бәррә* «бәрән (тиресе)». Димәк, **кәләпәрә** «мехлы көлаһ».

**КӨЛӘЧ** «с лучезарным лицом, весело улыбающийся» < диал. (ДС I: 115) **көләгәч,** (Тумашева 1992: 101) **көләгәц,** кр.-тат. *күлегеч* id. – бор. төрки сүз, к. як. (Пекарский II: 1289) *күлүгäс* id. – *күлә-* «көлеп тору» фигыленнән. К. **Көл-ү.**

**КӨЛЕМСӘР** «смешливый; улыбчивый» – **көләмсәр** яңгырашыннан булса кирәк: *көлә-мсәр-*; *-мсар//-мсәр* аффиксы төрки һәм монг. телләрендә еш очрый. Чаг. ш. ук **көлемсерә-** < гом. төрки *күлүмсүрә-* «бераз көлгәндәй итү» (к. ЭСТЯ III: 99–100). К. **Көл-ү.**

**КӨЛЗЕМ** иск. «Красное море; сказочный город чертей; одна из могущественных джиннов женского пола» – хәз. Сүәеш порты тирәсендәрәк урнашкан бор. грек-рим порты *Clysma* сүзеннән. Грекча бу сүз «юыну улагы» мәгъ. һәм шулай дип озын вә тар Сүәеш каналын һәм Кызыл диңгезне дә атаганнар.

Әлеге грек сүзенә хәз. медицина термины – **клизма** сүзе дә, *Өммегөлсем → Гөлсем* («диңгез анасы», «чибәр җен кызы») сүзе дә тоташа. Кеше исеме буларак бу сүз Мөхәммәт пәйгамбәрнең кызларының берсе шулай (*Уммукулсум* дип) аталганлыктан активлашкан. **Гөлсем** яңгырашы үзе фар. теленнән килә һәм ул фар. *гули сунб* «тояк гөле» сүзенә охшатылган (шундый гөл бар).

**КӨЛКӘЙ, көлеки** «уже подросший жеребёнок». Бу сүзнең вариантлары бик күп, к. (ЗДС: 156, 325–326, 365, 411) **гөлкәй, колкай, көлекәй, көлөңкәй, кыликай, колокай.** Соңгы вариант *колынкай* сүзеннән шикелле. Ләкин палаталь вариантлар бөтән нигездән булса кирәк, к. **Күлек**. Чаг. **Гөлген, Көнәш.**

**КӨЛТӘ** «сноп» > чув. *кĕлте [көлтэ]*, мар. *кĕлтä*, удм. *культо*, коми. *кольта, култа* id. (бу сүз тат. телләренең X г. ук Идел-Урал регионында

яшәгәнлеген раслый, чөнки коми халкының бабалары шул гасырда төньякка күченгәннәр) < гом. кыпч., уйг., үзб. диал. (ЎХШЛ: 151) *күлтә* «көлтә, бәйләм, дәстә» ~ төркм. *күлтер* «бау төргәге», төр. *külte* «бәйләм, төргәк, букет» (Мухамедова 1973: 130) һ.б. гом. төрки *кул-*, алт. диал. *күлү-*, төркм. *гүйл-* бор. монг. *küli-* < *küjli-* «бәйләү, бәйләп кую, көшәнләү» (к. ЭСТЯ III: 95–96) фигыленнән, к. **Кешән.** Федотов I: 272–273; ЭСТЯ VI: 139–140.

Дерив.: **көлтәле; көлтәлә-ү**.

**КӨЛ-Ү** «смеяться» ~ чув. *кул-* < *кол-* < гом. төрки (Будагов II: 161), бор. төрки (ДТС: 325) *kül* > угыз. *гүл-* id., *күлә-* id. варианты да бар (ЭСТЯ III: 98–100). К. **Көләмәч, Көләч, Көлемсәр.** Чув. *кул-* < *кол-* гом. фонетик закончалыкларга буйсынмый торган сәер яңгыраш. Федотов I: 305.

Дерив.: **көлен-ү** «көлкегә калдырылу»; **көлеш-ү; көлдер-ү, көлдергеч; көлке** (бу үзе продуктив нигез) һ.б., к. Будагов II: 161; ЗДС: 325–326.

**КӨЛЧӘ** «лепёшка (тонкая)» > чув. *кĕлче (көлҗә)*, удм. *колжо* < гом. кыпч., төркм. *күлчә* (> нуг., каз., к.-калп. *күлше*), уйг. *күлчә,* кырг. *күлчө,* үзб. *кулча, күлчә* > калм. *kültsü* id. Бу сүз «көлдә пешерелгән тәбикмәк» дип аңлатыла, ләкин бу – халык этимологиясе булса кирәк, чөнки тат. диал. (ТТДС I: 274) **көләчә,** башк. *көләсә* варианты һәм кырг. *күл азык* «юл азыгы» бар. Рамстедт рус. *кулич* сүзен дә шуннан чыгара (Ramstedt 1935). ЭСТЯ VI: 140–141.

**КӨМӘЙ** (ДС II: 127) «подруга», диал. **кемәй** «организатор девичника» (к. Исәнбәт Н. Аулак өй // КУ, № 5, 1971: 128) << кыт. *күң-мәй* «кома (җария) + сеңел – күңнәрнең башлыгы» сүзеннән булса кирәк, к. **Күң.** К. **Кемәй.**

**КӨМӘН** «беременность» < фар. *гөман* «фараз; гөман; көмән» сүзеннән (көмәнле булуны читләтеп әйтүдән)». К. ш. ук кырг. *кумөн* id. Тат. (ТРС 1931: 112) **гүбән** «корсак», госм. *гүбӓ* «корсак; көмән» сүзенең **көмән**гә кагылышы шикле. К. **Гөман.**

Дерив.: **көмәнле** (диал. **гөмәнле**).

**КӨМБӘ, көппә** (себ., ЗДС: 327) «вид гриба» ~ каз. (ҚТДС: 165) *көмбелек,* төркм. *көмелек* id. К. **Гөмбә.**

**КӨМЕРЕ [көмөрĕ]** «горбатый (который горбатится)», «горб» – о лошади и пр. ~ башк. *көмөҙ, көмөрө, көмөрөй*, кырг. *кӧмӧрӧ, кӧмкӧрӧ* «бөкре; йөзтүбән, бөк (ашык уенында ашыкның торышы тур.)». Башк. *көмөҙ* «бөкрәйгән» *көмөрө* белән бердәй булса, **көмере** чув. яки монг. телләреннән булып чыга (бор. *-р* сакланган вариант). Диал. **көмере күпер** «(Кытайдагычарак ясалган) бөкре күпер» сүзе дә бу нигезнең көнчыгыштан килгәнлеген күрсәтә бугай. К. ЭСТЯ III: 100 (*гүбүр* тур.).

Дерив.: **көмерәй-ү** «бөкрәю».

**КӨМЕШ [көмөш]** «серебро; серебряная монета» < гом. төрки *күмүш*, угыз. *гүмүш* (к. Радлов II: 1527–1528) > каз. *күмĕс* (нуг., к.-калп. *күмĕс, күмис*) һ.б. ~ чув. *кĕмĕл* < бор. гом. төрки *күмүлч* id. бор. кыт. *киэм-лйеү* «алтын-көмеш» сүзеннән дип карала; к. як. *кыһыл күмүс* «кызыл көмеш» – «алтын», ә *үрүң күмүс* «ак көмеш» – «көмеш», шуңа параллель бур. *саган мөнгэн* (*саган* «ак», *мүнгэн* «көмеш») ~ эвенк. *багдарин мэңүн* (*багдарин* «ак», *мэңүн* «көмеш») «көмеш»; эвенк. *кӧмүс* «алтын»; кор. *kim* «алтын». К. **Көмсән.** Räsänen 1969: 308; Федотов I: 273; ЭСТЯ VI: 142. Рус. *кумюс* «көмеш» тур. Аникин: 323.

Дерив.: **көмешле; көмешлә-ү, көмешлән-ү; көмешче.** Чаг. түбәндәгене.

**КӨМСӘН, кемсән, кумзан** (Гиганов; Будагов II: 181; Тумашева 1992: 97, 104, 108), «листовое золото, золочёная кожа» ~ чыгт. *кимсэн, кимсэнд* «алтынлы күн», уйг. *кимсән* «сары сәхтиян» < кыт. (ДТС: 307) *kim siaen* «алтын җеп».

**КӨН I** «день; солнце» (к. **көнчыгыш** «восток», **көнбатыш** «запад») < гом. төрки *күн* < *күүн* > төркм., төр. *гүн* һ.б., безнеңчә, гом. тунг. (күп фонетик вариантлары белән) *гēвун* «таң» (ССТМЯ I: 145) белән чагыштырылырга тиеш. Чув. *кон* > *кун* «көн» үзенчәлекле үзгәрешләр кичергән сүз (һәм борынгылыкны чагылдырмый).

Тат. *көн күр-ү* ~ чув. *кун кур-*, хак. *күн кӧр-*, як. *күнү кӧр-* «нормаль яшәү» фар. *руз дидан* id. тәгъбиреннән бор. калька булса кирәк. *Көн күр-* нигезендә **көнкүреш** һ.б. сүзләр ясалган, к. Будагов II: 164–165.

*Көн* < *күн* һәм *төн* < *түн* сүзләренең охшашлыгы аңлы рәвештә (шаманнар тарафыннан) хасил ителгән булса кирәк; чаг. бор. кыт. *хунь-тунь* «беренчел галәм» – галимнәр фикеренчә, тәүге «күк-җир (җир-күк)» яисә «су (диңгез) һәм күк» мәгънәсендәге тәгъбирдән килә; ул вакытта, ихтимал, *күн* «көн» – «күк», ә *түн* «төн» «төпсез диңгез, су»

(к. **Диңгез**) мәгъ. булган. Күп кенә бор. кыт. һәм бор. төрки сүзләрнең тамырдашлыгы шиксез. Федотов I: 306–307; ЭСТЯ III: 100–102.

Дерив.: **көнлек, көнлекче; көммә-көн** (ТТДС II: 200) < чыгт. *күн-бәкүн-* «көн сөен». К. **Көндәлек**, **Көндез.**

**КӨН II: ил-көн** «население» ~ уйг., хак. диал. һ.б. (Радлов II: 1435) *әл-күн* «халык; җәмәга; авыл»: **әл** «ил», **күн** «халык», кыпчак-куманнарның үзатамасы – шуннан венг., рус. *кун* «кыпчак-куман»; к. ш. ук бор. төрки *kün-qadaš* «кавем-кардәш», *el-kün* «халык, кешеләр» («Кутадгу билик»тә һәм «Угызнамә»дә), к. ДТС: 321. Димәк, бор. төрки *kün* «халык, кавем, җәмәга» мәгъ. сүз булган (к. Гумилёв. Древние тюрки: 60). Аерым *кун ~ күн* төрки кавеме тур. Velidi: 144–146, 156–160 һ.б.

**КӨНӘГЕН** «позавчера» < иске тат. *көнә көн:* **көнә** < фар. *күһнä* «иске, үткән, узган». Чаг. каз. *көне* «иске, борынгы», кырг. *көөнө* «иске» (*көөнө жыл* «узган ел»), *күнө* «борынгы» һ.б. К. **Төнә.**

**КӨНӘР** диал. «чёрная зависть» ~ к. башк. *көнәрке* «туймас», *көнәрке-ү* «барысын да үзеңә алырга тырышу, бүтәннәрнең уңышына эч пошу», *көнәркәш* «көндәш», *көнәркәт* «хөсетчән, көнләшүчән», себ. **күнәргәш-ү** «кешенең уңышыннан көнләшү». Тамыры – *күн-* (себ. тат.) «көнләшү (кеше уңышыннан), кызгану», ясалышы ачык түгел.

**КӨНӘШ I, колнәш, колекей, колкәй, коләкәй, колөн, колөңкәй** (ЗДС: 325–326) «жеребёнок» ~ шор., алт. *kунаш, kуначак* һ.б. id. Бу сүзнең тамыры – **кул* сүзе *колын* сүзенең тамырыннан үзгә, ләкин монда паронимик аттракция пәйда булып, нәтиҗәдә бик күп вариантлар килеп чыккан. К. **Колын.**

**КӨНӘШ II** «сухая жара» < бор. төрки (ДТС: 326) *künäš* «кояш; кояш эссесе», к. ш. ук кр.-тат. һ.б. *кунäш*, чыгт. *күнәс*, төркм., төр. *гүнеш*, аз. *гүнәш* ~ як. *куньаас* id. *күн* «көн» сүзеннән, ясалышы ачык түгел. **Кояш** белән контаминация. Будагов II: 165–166; Мухамедова 1973: 131; ЭСТЯ III: 103–104; Иванов 1993: 224–225.

**КӨНБАГЫШ** «подсолнечник» > удм. *кумбагыш* – букв. «смотрящий на солнце» тат. теленең үзендә ясалган (гомумән, бу үсемлек Көнч. Европага XVII г. гына таралган), к. вариантлары: **айбагар, айбагыш, гөмбагар, гөмбакты, көнайланма, көнәләнгеч** һ.б. ~ чув. *хĕвел çаврăнăш* «кояш әйләнеш», мар. *кечывуй* «кояшбаш», *кечыгалпак* «кояш калпак» һ.б. К. ДС I: 115; ДС II: 73; ДС III: 248; ТТДС I: 26–27, 121–122; Саваткова: 54.

**КӨНГЕРӘ** «кенгуру» – тат. телендә XX г. башларында рус теленнән алынып үзләштерелгән, рус сүзе < инг. < Австралиянең җирле телләреннән.

**КӨНДӘЛЕК** «ежедневный; дневник» ~ төр. *kündelik* id. Бу яңа сүз төр. теленнән таралган булса кирәк (бүтән әд. төрки телләрдә дә очрый).

**КӨНДӘШ** «соперница, одна из жен (при нескольких жёнах)», яңа мәгъ. «соперник (в деле, игре и т.п.)» < гом. кыпч. **күндәш* (> нуг., каз., к.-калп. *күндэс, күндәс*), уйг., үзб. диал. *күндәш,* кырг. *күндөш*, төр. *gündeš, gündaš* id. тамыры *көн* < *күн* < *күнү* (?) сүзен кыт. *küәn* «хатыннар бүлмәсе» сүзеннән дип уйлыйлар (Çagatay 1961: 23): чув. *күй* «туй бүлмәсе» сүзе дә шул ук кыт. сүзеннән булса кирәк һәм бу факт әлеге кыт. сүзенең бор. төркиләргә яхшы таныш булганлыгын күрсәтә (к. **Күләп**).

**Көндәш** сүзенең **көнлә-ү, көнче** сүзләренә тамырдашлыгы, беренче карашка «күзгә ташланып торса» да, төпченеп караганда шактый бәхәсле булып чыга, к. **Көнлә-ү, Көнче.**

**КӨНДЕЗ [көндөз], көндезен** «днём» < гом. төрки *күндүз*, алт., хак. диал. *күндүс*, тув. *хүндүс*, төркм. *гүндиз* һ.б. «көндез», хак. *көндес* «көндез; көн артыннан көн; тауның кояшка караган ягы» ~ чув. *кăнтăр [кŏндŏр]* «көндез; төшлек; көньяк» ~ бор. төрки **kündüri* id. К. ш. ук кырг. *күндүң* «кояш нуры» ~ к.-балк. *кюнню́м* «көнгә караган кашлак», як. (Пекарский I: 1297, 1299) *күндäл, күндүл* «ялтырак, балкышлы». Бу бор. сүз (*r ~ z*) *андыз, балдыз, кондыз* һ.б. моделендә ясалган булырга тиеш: *-дыз*//*-дез* морфемасының асылы әлегәчә ачыкланмаган, бик ихтимал, ул тәүдә *-ныз//-низ* яңгырашында булгандыр (*-нн-* > *-нд-* диссимиляция булган), к. ком. *гүннүз* «көндез», чаг. тат. диал. (крш.) **кенне-** < *көннө-* «яктырып китү, балку» (ТТДС I: 238).

Чув. *кăнтăр [кŏндŏр]* < болг. **көндөр* яңгырашыннан. Räsänen 1969: 264; Федотов I: 255; ЭСТЯ III: 102–103.

Дерив.: **көндезге, көндезгелек.**

**КӨНҖӘЛӘ**, диал. (ДС II: 75) **гөнҗәлә** «кудель, прядево; очёски» ~ башк. (БҺҺ II: 110) *көнйәлә* «каба; чыгырык; көнҗәлә», чув. *кĕнчеле, кăн-*

*чала*, мар. *кынзала, кунчыла* һ.б. (күп вариантлар), удм. (Насибуллин: 123) *кунзёла* < бор. рус. *кунделя* (яз. рус. кѫдѣль) ~ укр. *кундель* һ.б.; бу сүз артык киң таралмаган (тагы Д. болг. һәм чех телләрендә, к. ш. ук фин. *kuontalo* «көнҗәлә») славян сүзе дип карала (Фасмер II: 399), ләкин чыгышы-ясалышы ачык түгел. Федотов I: 274–275.

**КӨНЛӘ-Ү**, диал. (ТТДС I: 375), **көнөлә-ү, кенелә-ү** «приревновать, быть ревнивым» < себ., уйг., куман. *күнүлә-, күнәлә-* id. ← себ. (Тумашева 1992: 108–109), алт. диал. *күнү* «көнләү күренеше», *күнү-* «көнләү» ~ алт. (к. Радлов II: 1419–1441) *күин-* «көнләү» ← алт., кырг. *күй-* «гашыйк булу»; к. ш. ук бор. *küni, künü*, як. *күнүү*, төр. *гүнү*, алт. *күнä, күне* «көнләү (күренеше)», ш. ук «көнчелек, көнләшү» һ.б.; бу сүзне кырг. *күнү* «бер ирнең ике (өч һ.б.) хатыннарының берсе», бор. төрки (ДТС: 327) *küni* «яндаш хатын, кома» сүзе белән баглыйлар (Räsänen 1969: 309). Икенче бер урында (Op. sit.: 307) **көннәш-ү**не **көен-ү** белән баглый. К. ш. ук **Көндәш.** Чув. *кĕвеç-* «көнләү» сүзнең этимологиясен тагын да катлауландырып җибәрә. К. **Көнәр, Көндәш**, **Көнче.** ЭСТЯ III: 104–105; Федотов I: 269 (чув. яңгырашын аңлата алмаган).

Дерив.: **көнләш-ү** (**көнлә-ү** сүзенең урт. юн. аерым мәгъ. алган).

**КӨНЧЕ [көнчө],** диал. (ТТДС I: 275) **көнөчĕ, көнөчәк, көнцән** «ревнивец; ревнующий» ← диал. **көне, көнө,** кр.-тат. *күн* «көнләү күренеше», к. югарыдагыны. К. **Көндәш, Көнлә-ү.**

Дерив.: **көнчелек, көнчелә-ү.**

**КӨНЬЯК [көнйак]** «юг; южный» < *көн ягы* ~ гом. кыпч. *күн йагы, күнйак* id. Кайбер төрки телләрдә бүтәнчә: кырг. *күней,* төр. *güney* «көньяк» яки гар. *җәнүб* активлаштырылган.

**КӨҢ**, себ. (Гиганов) **күн кыс**, (ЗДС: 354) **күнцүк** «рабыня-наложница» < гом. кыпч., чыгт. *күң*, бор. төрки (ДТС: 323 һ.б.) *küŋ* id., чаг. ш. ук төркм. *гүң* «әнисе фарсы булган төрекмән», үзб. *гунг* «саңгырау, чукрак». Будагов II: 158–160; Räsänen 1969: 142; ЭСТЯ VI: 142.

**КӨҢГҮРӘ, күңгүрә** (К. Насыйри) «зубец крепостных стен, а также царского венца; крепостная стена с башнями» ~ төр. (Özön: 451) *küngüre, künküre* «гөмбәзнең иң биек төше; тамыр, үзәк». Штойервальд буенча, «кальга диварының башнясы». Барча чыганакларда фар. сүзе диелә. А. Тимергалин (: 239) фарсыча хәрәкәсез язылыштан чыгып **кәңрә** дигән сүз «ясый». Хәлбуки андый әйтелеш булмагандыр.

**КӨҢСЕ-Ү**, (ТТДС I: 288) **күңсе-ү** «быть с душком; начинать пахнуть дурно» < гом. кыпч., к. башк. (БТДҺ: 164) *күңе-ү, күңне-ү, күмһе-ү,* каз., алт., хак. *қуңсы-,* себ. **қуңырсы-** < гом. кыпч., к. каз. **қоңырсы-,** кырг. *қоңурсу-*, төркм. *қоңурса-* id. һ.б. тат. **коңы, күңу** (**исе-коңысы, исе-куңусы** > **исекосы** парлы сүзендә, к. ЛТ I: 74; ТТДС I: 251) < башк. **қуңы** < (каз.) *қоңы* «ис» ← каз., кырг. *қуң, қоң* «анус, сасы ис; тән исе» ~ төр. *koku* «ис, исе», бор. төрки (ДТС: 457) *qoqu-* > себ. (Гиганов) **куқы-у** «исләнү; янык исе килү һ.б.» Гомумән, *қуң* ~ *қоң* ~ *қоқ* тамыры һәм аның дериватлары бик күп, к. Räsänen 1969: 276; ЭСТЯ VI: 33–34, 65–66 (тат.-башк. сүзләре китерелмәгән).

**КӨП** диал. (трбс.) «(выпуклая) крышка; доска-обшивка (которая накладывается на зазоры, щели)» ~ башк. (БТДҺ: 153) *көп* «кузак, кузакның бер ягы» – ихтимал, (ЭСТЯ VI: 143) уйг., угыз. һ.б. *күп*, бор. төрки (ДТС: 328) *küp* «купы; күкшен» сүзеннән киләдер. К. **Купы.** Чаг. түбәндәгене.

Дерив.: **көплә-ү** (→ **көплән-ү, көпләш-ү, көпләт-ү**); башк. (БТДҺ: 153) *көплө* «бал белән тутырылып сыланган (күзәнәк)», *көптә* «каплау материалы».

**КӨПЕ [көпө]** (ЗДС: 328) «стёганое пальто; стеганые штаны» < гом. кыпч., к. башк. (БТДҺ: 153) *көпей, көпәләй,* каз. *күпі, көппө, күмө,* (ҚТДС: 173) *күмпей,* кырг., үзб. диал. *күпү* «калын сырылган өс киеме» < бор. төрки (ДТС: 328) *küpik* «сырылган кием, сырма» һ.б. Чаг. ш. ук төркм. *гүпби* ~ башк. *күпмә* «сырма; фуфайка» һ.б. Тат. диал. (ТТДС I: 278) **көп-,** башк. (БҺҺ III: 89; БТДҺ: 148) *көбө-,* себ. (Гиганов) **күбе-ү** «ике тукыма арасына берәр нәрсә калдырып сыру» фигыленнән. Интервокаль *-п-* ***көппе** яңгырашына ишарәли. К. ш. ук каз., кырг. (Будагов II) *көппө* «калын киез бишмәт» > чыгт. *күпә* «шайман». ЭСТЯ V: 144–145 (күп сүзле, ләкин төрле сүзләр буталган аңлатма). К. **Күп-ү.**

**КӨПКӘ** (Будагов II: 112; БТДҺ: 153), себ. **күпкә, кӧпкә** (к. Тумашева 1992: 102) «закут, хлев для молодняка; землянка» > манси. (Kannisto 1912: 135) *körkə* < гом. кыпч., к. кырг. *күпкө, көпкө* «кәбәртке, тирмә эчендә сул якта яшь бәрәннәр һәм

бәтиләр урыны», алт. *кұпкӓ* «вак мал өчен зимләнке» < **күрүпкә*, к. хак. (Бутанаев 1990: 102) *күрүп* «кош-корт зимләнкесе». Чаг. к.-балк. *кюрке* «өн, оя», башк. (БТДҺ: 154) *көркә* «көпкә, зимләнке»; к.-балк. *гюрбе* «келәт; алачык» – барысы да ***күр** (к. **Көрә-ү**) тамырыннан булса кирәк.

Игътибарга лаек: башк. *көпкә* < **көрөпкә* > *көркә.*

**КӨПЧӘК,** диал. **күпчәк** «труба, шланг; вал (из полого бревна); ступица колеса; колесо без спиц» > чув. *кӳпчек, кĕпчек* «көпчәк; иярнең арт терәге», хант. (Kannisto) *tирčäx* «көпчәк» < гом. кыпч., к. башк. *көпсәк,* кар. *кипчэк, кипцэк, күпчэк, кұпчақ,* кр.-тат. *кӧпчэк*, к.-балк. *арбакӧпчэк*, кырг. *күпчөк*, нуг., каз., к.-калп. *күпшек, кұпшӓк* «тоташ тәгәрмәч», төркм. (ТДГДС: 118) *күпҗек* id. ← *күп, күбү* «тамырыннан», к. **Күбәк.** Кайбер телләрдә (чув., төркм.) **күпчек** белән контаминациягә кергән (бу сүз исә бөтенләй бүтән тамырдан).

Диал. **күпчәкле, көпчәксез** (мәс., арба). К. **Көпшә, Көпшәк.**

**КӨПШӘ** «полый стебель; ствол (ружья)», диал. «ступица колеса» ~ чув. *кĕҫҫе* «көпшә; көпчәк; күбәк» < бор. **күпчәг (> көпчәк)* сүзеннән, ихтимал, болг. теленнәндер (чөнки яңгыраш тат.-башк. даирәсеннән тыш күренми). Чаг. бор. төрки (МК) *küviž* «куыш кәүсә» (ДТС: 330). К. **Кәүсә, Көпчәк.** Федотов I: 276.

**КӨПШӘК I** «рыхлый, пористый», «дряблый», диал. (ДС II: 118; ЗДС: 342, 355) **күпшәк, күбешәк, күбешек** «вспученный; рыхлый», **күбешкәк** «склонный вспучиваться» ← **күбеш-ү** «күбеп кабарып чыгу» ← **күп-ү** (к.). Аналогик ясалыш модельләре барча төрки телләрдә бар бугай, мәс., чув. (Ашмарин VI: 160–164) *кăпшак, кăпăшка* ← *кăпăш* ← *кăп-* «көпшәк ← күбеш- ← күп-ү»; кырг. *көпшөк [кӧпшӧк],* хак. *кӧпсек* «кабарынкы, йомшак, көпшәк». К. ш. ук бор. төрки (ДТС: 304, 331) *kevšäk, küvšäk* «йомшак, зәгыйфь» ← *kev-, küv-* «йомшару, зәгыйфьләнү». Räsänen 1969: 291; Федотов I: 256.

Дерив.: **көпшәклек; күпшәклән-ү** һ.б. Чаг. (сүзьясалыш буенча аналогы) **Йомшак.**

**КӨПШӘК II, күпшәк** (ЗДС: 329, 355) «белый, мягкий; пористый (о хлебе); белый, мягкий, пористый хлеб» – чаг. **күпшәк,** (ЗДС: 342) **күбешкәк** «күбә, күбенә, күбешә торган», арытабан к. **Күпце-ү, Күпче-ү** һәм **Күпше-ү, Күпшен-ү** «күбенү», **Күпшек** «эремчек» һ.б. Барча төрки телләрдә диярлек параллельләре бар. К. югарыдагыны.

**КӨР** «упитанный (о скотине); полный сил, бодрый (о человеке)», иск. «надменный; грозный; могучий, внушающий ужас» ~ башк. (БТДҺ: 254) *көрөк, көрсә* (< *көрчә*), чув. *кĕр* id. < гом. кыпч. *күр*, төр., төркм. *гүр*, тув. *хүр* ~ монг. *гӧр, гор* «көчле, көр, юан, бай, хәйләкәр һ.б.» (бик күп мәгънәле сүз), к. Räsänen 1969: 310, ЭСТЯ III: 106 (Э.В. Севортян фикеренчә, *гөрлә-ү* «шаулау; данда булу» сүзе дә шуннан). Федотов I: 277–278. К. **Көрә**.

Дерив.: **көрлек, көрәй-ү;** диал. **көрле (барлыкөрле).**

**КӨРӘ, көрө** (ТТДС: 276) «бодрый; упитанный» ~ чув. *кĕрĕ* id. Тат. сүзе (т. я.) чув. сөйләшләреннән бугай, ләкин к. төр. дә *güre, gürbüz* «көр, көчле вә кыргый; өйрәтелмәгән тай, кыргый» фарсычадан алынма шикелле, к. фар. *гур, гүр* – кыргый ишәк төре һәм гайрәтлелек, кыргый елгырлык символы. Элекке тат. әд. телендәге *көр арыслан* идиомасы да шул мәгъ. К. төркм. *гүр тоқай* «куе үләнле тугай». Монда тикшеренәсе бар (*арыслан* – түбәндә «кыргый җәнлек» мәгъ.)

**КӨРӘГӘ** «кадка для кумыса (деревянная), круговой ковш» > мар. *кӧрӓгӓ* «сыра өчен агач кәсә, тигәч», чыгт., кр.-тат. *кӧрӓгӓ, киргӓ, кӧргӓ* «эчемлек савытлары куела торган урындык», нуг. *күрәгәчи* «сакый, көрәгәче», куман., уйг., алт., чыгт., госм. *küräk* «озынча урындык» > манси. *keerx* (к. Kannisto 1912: 128), чув. *кĕреке* «эчке мәҗлесендә шәрәфле урын», алт. диал. *күргү* «зур туз тәгәч» һ.б. бор. *kür* «түгәрәк» тамырыннан булса кирәк. М. Рясянен (1969: 311) **қорка** (к.) белән чагыштыра. Будагов II: 149; Федотов I: 278.

**КӨРӘК** «лопата» > удм. *курак* < гом. төрки *күрәк* (кырг. *күрөк*, үзб. *курак*, тув. *хүүрәк*) < бор. *kürgek* (ДТС: 328) «көрәк, ишкәк»; күп кенә телләрдә *-чәк* паронимы бар: хак. *күрчәк,* як. *күрдьэх*, бор. монг. *kürǯek, kürǯe* (Поппе 1938: 230) >> чув. *кĕреҫе* «көрәк; балык аулау сөңгесе, салдау», к. **Керәшә, Көрә-ү, Көрәч.** Будагов II: 149; Федотов I: 280 (әдәбият китерелә).

Дерив.: **көрәкле, көрәксез; көрәклә-ү.**

**КӨРӘН** «бурый, цвета засохших камышей», диал. (Тумашева: 109–110; ЗДС: 304, 330–331) «коричневый», «о чернилах – фиолетовый», (Будагов

II: 120) *кӳрең* «бурый, саврасый» > чув. *кĕрен*, мар. (Саваткова: 73 һ.б.) *кĕран, көрән, кӳрән,* удм. *курень, курен* «көрән», *кырен* «шәмәхә» < гом. кыпч., алт. *күрән, күрен,* уйг. *күрәң*, ком. *гюрен*, тув. *хүрең,* бор. монг. *küreŋ* – хәз. монг. *хүрэн*, бур. *хүрин, хүрүң*, тунг. *курин, күрэн* һ.б. «көрән; көрәнгә якын төсмерләр». Кайбер телләрдә аеруча ат тур. (бор. заманнарда көрән, җирән һәм туры атлар яхшырак дип исәпләнгән): кр.-тат. (Dobr. II: 403) *küren* «кофе төсендәге, куе сары, туры (ат тур.)» диелгән, аз. диал. *күрән* «җирән», як. *күрäң, күрүң* «кара җирән» һ.б. Сүзнең тамыры**күр-,* к. тув. *хүргүл* «көрән», бор. монг. *küregčin* «көрән терлек», ком. *гӧзен* «көрән» < **кӧргэн* (*-рг-* > *-з-*). Гипотетик *күр* тамырын *көз* < *күз* белән чагыштыралар (дала **көзен** көрән төскә керә). Чаг. **Көз, Көзән, Күрән, Күрә-ү.** Räsänen 1969: 310; Федотов I: 278–279; ЭСТЯ V: 146–147; ССТМЯ I: 437.

Дерив.: **көрәнсу; көрәнлек; көрәнәй-ү** һ.б. **Көрән** сүзенең көтелмәгәндә «шәмәхә» мәгънәсен алуы шуның белән аңлатыла: элек – XX г. башларына кадәр – язу карасын имән чикләвеге кабыгын төнәтеп ясаганнар һәм ул «көрән» төстә булган. Шундый язу каралары шәмәхә төскә алмаштырылгач та, атамалары искечә калган һәм **көрән** сүзе шәмәхә төсне белдерә башлаган. Хәлбуки чын көрән төс шәмәхә төстән кискен рәвештә аерыла.

**КӨРӘНТЕ,** диал. **көрәнде** «нечто сгребённое; свалка; почва из выкопанной ямы, котловина и т.п.» **көрә-ү (көрән-ү)** фигыленнән. **Көрәнте** сүзенең «чолан, веранда» мәгъ. дә бар (ТТДС I: 276), ләкин ул соңыннан килеп чыккан, икенчел (тәүдә – «кухня чүбе, ашамлык әзерләү калдыклары өчен кызау, тартма булган урын»).

**Көрәнте** сүзе белән **көренте** (к.) арасында турыдан-туры бәйләныш юк.

**КӨРӘПӘЛӘ** диал. «войлочная шляпа с широкими краями» – **көләпәрә** (к.) сүзеннән метатеза.

**КӨРӘ-Ү** «гребать, сгребать»; «грести веслом» (Троянский II: 156) < гом. төрки *күрә-*, тув. *хүүрэ-*, угыз. *күрү-*, бор. төрки *küri-* id. (Räsänen 1969: 310). Тамыры **күүр* «читкә этәреләсе нәрсә, чүп». Бу фигыль бик продуктив нигез, к. **Керәшә, Көпкә, Көрәк, Көрәнте, Көрәч, Көрт, Көсмән.** ЭСТЯ V: 150–152.

**КӨРӘЧ** «двурогие вилы, рожон; приспособление для натягивания шкур мелких животных (белок и т.п.)» ~ мар. *куреж* «балык аулау сәнәге» < болг. **көрәҗә, *күрәҗә*, к. **Керәшә, Көрә-ү.** Асылда – «көрәкчә».

**КӨРӘШ** «борьба» – **көрәш-ү** сүзе белән нисбәтле, ләкин турыдан-туры бу фигыльдән килеп чыкмый, уйг. *күрәш,* кар., алт., нуг., каз. *күрэс,* төркм., төр., гаг. *гүрэш*, тув. *хүрэш*, төр. диал. *güleş*, аз. *гүләш* һ.б. бор. *күр-* «бәйләү» (к. **Көрмә-ү**) сүзеннән, к. Э. Фозилов (Үзб. *кураш* // Ўзбек тили ва адабиёти масалалари. № 3, 1960: 57) к.-калп., үзб. диал. *кур*, уйг. *кур* «билбау» сүзеннән чыгара (төрки көрәштә көрәшчеләр махсус билбау кулланалар), Э.В. Севортян да шул фикерне яклый. Рясянен **көр** сүзеннән ди.

**Көрәш** сүзе абстракт мәгънәдә тат. телендә XX г. гына кулланыла башлаган (элегрәк шул мәгънәдә, мәс., Г. Исхакый телендә, **тартыш** сүзе кулланылган, аңарчы гарәпчә **мөҗадәлә** кулланыла). К. **Көрәш-ү, Көрдәш-ү.** Räsänen 1969: 310; Федотов I: 280; ЭСТЯ III: 80–81.

**КӨРӘШ-Ү** «бороться» < гом. кыпч. *күрэш-, күрәш-,* уйг. *күрәш-*, бор. төрки, уйг. *күрә-* «билбаулау; көрәшү» фигыленең урт. юн.; бу фигыль исә *күр* «билбау; бәй» (ихтимал, *қур* «түгәрәк» белән дә бердәйдер) сүзеннән. К. як. *күрэх, күрэс* «көрәш; азарт», *күрүс-* «көрәшү», чаг. иске тат. (Максуди) **қуршаг (кушак) тоту** «көрәшү». ЭСТЯ III: 79–81. К. ш. ук **Көрмә-ү, Көрмәшү.**

**КӨРДӘШ-Ү** «конаться (в игре); составлять команду играющих» ~ мар. *кургүлäш-* id. бор. *көр* < *күр* «уен түгәрәге» сүзеннән. К. ш. ук **Гөрлә-ү II.**

**КӨРЕ [көрө]** «нитченка» ~ чув. *кĕр* «көре», *кĕрĕ* «көре; тукымачылык; көре» ~ алт. *күзүг,* кырг. *күзүк, күзүү*, бор. төрки (ДТС: 331) *küzäk* «тукучы коралы» тат. сүзен чув. теленнән дип раслау (Räsänen 1969: 312) дөреслеккә туры килми, чөнки каз. *күрү* «көре» һәм башк. *көрөҫ* < *көрөч* вариантлы да аңлатуга мохтаҗ. Бу болг. сүзе (*-р- !*) кыпч. телләрендә бор. заманнарда (XIII г. кадәр) таралган булса кирәк. Чаг. ш. ук каз. диал. *күреңкі* «бауга беркетеп тезелгән нәрсәләр төргәге» (ҚТДС: 175). к. **Көрмә-ү.** Федотов I: 278.

**КӨРЕНДЕ [көрөндĕ]** «волнистая поверхность льда или снега» ~ кырг. *күрӧндү* «кышын (җылылык өчен) тирмә тирәли өелгән кар» (Радлов II: 1453), безнеңчә, бор. **күрү-* «көрәү» сүзеннән

(*күрә*нең вариантыннан), шуның өчен **көренде** ул **көрәнте** түгел.

**КӨРЕЧ [көрөч],** (ЗДС: 357) **күрец, күреч** «ясень», диал. «рис» < гом. кыпч. к. к.-балк. *күрүч, күйрүч*, ком. *гүйрүч,* аз. *гөйрүш*, төр. (DS VIII: 305) *küvrüç* ~ чув. *кавăрăç, каврăç* id.; к. ш. ук венг. *kö-ris*, осет. *kärz* (төрки теллəрдəн) id. Безнеңчә, бу сүз төрки, фар. *гурунч* «дөге» сүзе белән бердәй. К. **Корычагач.** ЭСТЯ V: 152 (этимология безнеңчә түгел).

**КӨРҖӘ (таз көрҗә)** «шельмец, хитрец» << бор. монг. *körǯü* id. ← *kör-* «тулгану; боргалану»; к. ш. ук тув. *хөржү-* «гаебен танып, хәйләләп котылу», *хөрле-* «хәйләләү».

Дерив.: (ТТДС II: 202) **көҗәлә-ү < көрҗәлә-ү** «юмалау».

**КӨРМӘ** «зонт, покрышка из холста для кашни; задник саней (к которым прислоняются спиной)» > чув. *кĕрме,* мар. *кĕрмä* id. < *көремә* < *күрүме* ← **көре-* < **күрү-* «күләгәләү» (< бор. төрки *kölü-* id.?) Чаг. алт., каз. *күрме*, яз. монг. *kürme*, бур. *хүрмэ*, маньч. *күрүмэ* «иң өске, тун өстеннән киелә торган кием; бөркәү» (к. ССТМЯ I: 437).

**КӨРМӘК** «калмыцкий узел» ← **Көрмә-ү** (к.).

Дерив.: **көрмәклә-ү, көрмәкләш-ү** (мәгънәләре үзенчәлекле).

**КӨРМӘ-Ү**, себ. (Радлов II: 1464) **күрмә-ү** «завязывать двойным узлом» < гом. кыпч., алт., чыгт. *күрмэ-,* кырг. *күрмө-* id. ← бор. **күрэ-* «бәйләү, төенләү» сүзенең интенсивлык формасы, к. яз. монг. *güre-*, бур. *гүрэ-* «ишү, ишелдерү, үрү, бәйләү». Räsänen 1969: 310; ЭСТЯ V: 148.

Дерив.: **көрмәл-ү** (тел тур. «катлану; авыр хәрәкәтләнү»). Чаг. **Көрәш-ү.**

**КӨРПӘ I**, диал. **көрпәк** «крупа; мелкий и плотный (о снежинках)» ~ башк. *көрпәк* id. > удм., мар. *кĕрпе, кырпа*, чув. *кĕрпе* id. < гом. кыпч. *күрпэ* ~ бур. *хүрпэк*, монг. *күрпээ* id. Чаг. ш. ук каз. *күрпе* (ҚТДС: 176), *курпĕ*, венг. *korpa* «кибәк».

Рус. *крупа*, гом. слав. *kroupa* (Фасмер II: 386) «көрпә» сүзе белән охшашлык очраклы түгелдер.

**КӨРПӘ II,** диал. (Тумашева 1992: 111; БТДҺ: 165) **күрпә** «мягкое и тёплое качественное одеяло» < чыгт., үзб. *күрпә, курпа* «дөя йоны катылган юрган», каз., ком. *көрпэ* «эчек, мех; эчек юрган», кр.-тат., төркм., уйг. һ.б. *көрпе,* бор. төрки *күрпә* «яңа туган бәрән», хак. *күрпе*, кырг. *күрпөң* «көзен яисә кышын туган бәрән» (нәкъ шуларның йоны йомшак һәм җылы була). Ихтимал, *көз* < *күз* < **күр* сүзе белән тамырдаштыр. Федотов I: 282; ЭСТЯ V: 116–118 (бай материал). Рус *курпей* «бәрән тиресе» < төрки *kürpä* «яңа туган бәрән» һ.б. тур. Аникин: 332.

**Көрпә <** *күрпә* сүзе күп телләрдә (алт., кырг., төр., уйг., монг.) *күрмә, күрмэ, күүрмэ* «көрпә куртка» сүзе белән (к. **Көрмә**) бердәйме – әйтүе кыен.

**КӨРСЕН-Ү [көрсөн-]** «воздыхать, переживать; сожалеть о случившемся» < гом. кыпч., к. башк. *көрһөн-,* нуг., каз. *күрсин-*, кырг. *күрсүн-* «аһ итү, көрсенү» (к. Радлов II: 1463) ~ иске тат. (Гиганов) *күрүстүн-, көрөстен-* id. ← **күр* < *күүр* «авыр кичереш» тамырыннан. Чаг. себ., каз. (Будагов II: 159–160) *күңрән-, көңрен-* «зарлану; елау», бур. *хөөрхэй* мескенкәй», *хөөрхы* «көрсенерлек»; чаг. ш. ук чув. *күрен-*, мар. *кӧрäн-* «җәберсенү; ялвару». Чаг. **Көсә-ү.**

Дерив.: **көрсендер-ү.**

**КӨРСИ** кит., юг. «сидение; престол» < фар. *курси* «урындык» < гар. *курсӣ* «урындык; кафедра; тәхет» > төр. *kürsü* «трибуна; кафедра».

**КӨРТ,** диал. **көрөт** «сугроб» ~ чув. *кĕрт [көрт]*, мар. *кĕрт, кӱрт,* удм. *кĕрт*, *курт* «көрт; туңкар» < уйг. диал., шор., алт. *күрт*, тув. *хөр*, бур. *хүр* «көрт». Бу сүзнең паронимы тат. диал. (ДС I: 116) **көртөк, көртек** ~ нуг., каз. *күртик*, кырг. *күртүк, күрткү*, хак. *көртĕк*, алт., тув. *көртүк* «көрт». ЭСТЯ V: 149–150.

**Көрт** < *күрт* < *күрүт* «көрәлә торган нәрсә» сүзеннән, **көртек** < **күрүтүк*. К. **Көрә-ү, Көртлек.**

**КӨРТЛЕК [көртлөк]** «тетерев» – *көрт* астында кышлаучанлыгыннан шулай аталган; чаг. алт. *күртүк* «көрт, көртлек», тув. *күртү*, алт. диал. *күртä* «көртлек».

**КӨРТМӘЛЕ,** диал. (ТТДС II: 201) **көртмәлек** «клюква; черника» > чув. *кĕтмел*, мар. *кытмäл* id. < удм. *курытмольы* «әче җиләк» (*курыт* «әче», *мольы*, *мульы* «җиләк»). **Көртмәлек** формасы халык этимологиясе нәтиҗәсе. Федотов I: 289 (этимологиясе шул ук, ләкин киңрәк бирелә).

**КӨРЧЕК [көрчөк],** (ЗДС: 300–301) **керчек** «финиш, тупик; кол, камень, яма и т.п., обознача-

ющая конец маршрута, дистанции и т.п.» ~ башк. *көрсөк* id. < яз. монг. *kürcük* «чик, көрчек» ← *kür-, kürči-* «барып җитү» (к. Поппе 1941: 81–134). Ком. *курчук* «нигез; нигез ташы» сүзе дә шуннан булса кирәк.

**КӨРШӘК,** диал. **гүршик** (к. ДС III: 50) «горшок» – рус. теленнән (рус. *горшок* < *горншок* – *горн* «чүлмәк яндыру миче» сүзеннән), к. ш. ук чув. *куршук,* мар. *коршок,* удм. *горшок* «көршәк».

**КӨС** «стая мальков рыб или головастиков (рыба-наживка)» ~ башк. *көҫ, көҫөй, көҫкө, көстей*, тат. диал. **көсәк** «косяк». Рус теленнән дисәң, рус. **косяк** сүзенең үзенең чыгышы ачык түгел.

**КӨСӘ-Ү**, диал. **көстә-ү** (ш. ук. **көсән-ү, көстән-ү**) «пожелать; жаждать (чего); переживать» ~ башк. *ҡөҫә-ү,* чув. *кӳште-* < гом. кыпч. *күсә-* < бор. төрки (ДТС: 329) *küsä-,* төркм. *күйсе-,* яз. монг. *küse-* id. Кар. *кӧстун-, күстүн-* < *кӧрстүн-* «көсәнү» сүзләренә караганда **көрсен-ү** (к.) белән тамырдаш. К. ш. ук нуг. *күс* «теләк», кр.-тат., төр. *küs* «ачулы», кар., ком., госм. *күс-,* бор. төрки (ДТС: 329) *küs-* «ачулану, җәберсенү». Räsänen 1969: 393.

**Көсә-** белән **көстә-** вариантлары арасындагы нисбәт ачык түгел. ЭСТЯ V: 135 (*көстә-* < *күрстә-* варианты искә алынмый). К. **Көстән-ү.**

**КӨСМӘН** «весло (парное)» ~ чув., мар., ком. *кӳсмен* < чулым. *күрсмән* ~ тат. диал. (Тумашева 1992: 102) **көрөсмән** id. бор. «ишкәкче» мәгъ. булган булса кирәк. Тамыры – **кур-, курә-* «ишкәк ишү» (к. **Көрә-ү**).

**КӨСМӘР,** диал. (Тумашева 1992: 105) **кӧсмәр** «вид грызуна (крот, крыса)». Чаг. **Күсе.**

**КӨСТӘН-Ү, кестен-ү** (ЗДС: 301) «не желать, затрудняться, делать неохотно, выражать неохоту» (әд. телдә элек киң кулланылган), Ихтимал, бор. *küsüt* «ачу, үпкә» сүзе булгандыр, к. нуг. *күсет-* «көсәтү» һ.б. К. **Көсә-ү.**

**КӨТӘ** (Тумашева 1992: 137) «кочка в озере, образовавшаяся вокруг стеблей камыша» ~ як. < эвенк. *кута* id. ЭСТЯ V: 154 (**күтер** сүзе белән буталган).

**КӨТЕК [көтөк]** «куцый, слишком короткий; недостаточный» ~ чув. *кĕтĕк*, мар. (Иванов, Тужаров: 105; Саваткова: 74) *көтөк, кĕтĕк*, *кучык* id. ~ каз., төркм. *күтек*, аз. *кӧзәк*, төр. *kütük, güdük* id. Чаг. як. *кӧтӧк* «арык, ябык». Чаг. рус. *куцый,* серб. *кусов* «койрыгы киселгән (ит)». Федотов I: 289; ЭСТЯ V: 154 (төр., аз. *кут, куд* «кыска һәм тупа» сүзе белән чагыштырыла).

**КӨТЕМ** диал. «стадо; пастьба» > мар. диал. *кӱтым* id. Бәрәңге сөйләшендә кулланылучан бу сүзне әдәбиләштерәсе иде.

**КӨТҮ [көтөw]** «стадо; пастьба» > чув. *кĕтү*, мар. *кутү, кутӧ, кытӧ*, удм. диал. *кыту*, удм. *кутьы* id. < гом. кыпч. *күтү* (куман. *kütöv*, кырг. *күтүү*) id. **Көтүче** (> мар. *кутүчӧ,* удм. *кутычи*, чув. *кетүç*) сүзе дә гом. кыпч. характерга ия (к. ш. ук алт. *күдүчи* «көтүче»). **Көтүлек** (> удм. *кутьылык* һ.б.) тат.-башк. даирәсендә килеп чыккан булса кирәк. К. **Көт-ү.**

**КӨТ-Ү** «ждать, ожидать; пасти» > чув. *кĕт-*, мар. *кут-* < гом. кыпч., уйг. *кут-*, төр. *güt-*, төркм. *гут-, гүйт-* һ.б. id. (ЭСТЯ III: 107–108). Кайбер телләрдә «тәрбияләү; карау, саклау» мәгъ. ия, к. себ. **күүт-** id. (*ҡапҡа кӯтуци* «привратник», к. Радлов. Материалы IV: 367).

*Көт-* < *күүт-* катлаулы семантик һәм морфологик структурага ия һәм шунлыктан бу сүз астында ике яки хәтта өч бор. сүз бар дип уйлыйлар. «Көтү көтү» мәгъ. *күүт-* бор. *күү-* (*kǖ-,* к. ДТС: 322) «саклау, күзәтү» фигыленең йөкл. юнәлешеннән гыйбарәт. Бу бор. *күү-* исә (кырг.) *күй-* < **küδ-* (аз., төр) *küd-* яңгырашларыннан булса кирәк. *Күүт-* «көтү» фигыленнән тыш. бор. *küt* < *küüt* «көтү, көтем» исем сүзе дә булган (к. ДТС: 330). Шуннан **küwĕt* «көтү, өер» ясала алган.

«Көтеп тору» мәгъ. *кут-, күүт-* бор. **култ-* сүзеннән булырга тиеш, к. бор. монг. *küličimi* «көтеп тору». К. Räsänen 1969: 306, 312; Федотов I: 288; ЭСТЯ III: 107–108.

Дерив.: **көтел-ү, көтеш-ү, көттер-ү.**

**КӨЧ** «сила», (ДС I: 116–117) «трудно, трудность» < гом. кыпч. *куч* (> башк. *көс,* нуг., каз., к.-калп. *куш*), угыз. *гуч*, төркм. *гүйч* id. ~ яз. монг. *küčin, küčün* «көч-куәт, хезмәт»; к. ш. ук эвенк. һ.б. тунг. *куси-, куǯі-, кути-* «сугышу» – бу сүзләрне Г. Рамстедт (1957: 12) тунг. *гутин* ~ монг. *гучин* «утыз» сүзе белән чагыштыра: бор. төрки-монг. кабиләләрендә сугышчылар утызлы төркемнәргә бүленгән булган. Будагов II: 145–146; ЭСТЯ III: 96–98.

Дерив.: **көчле, көчсез; көчәй-ү (→ көчәеш-ү, көчәйт-ү); көчлек;** к. **Көчән-ү (← *көчә-ү ?); Көчергән-ү.**

**КӨЧӘЛӘ** (Будагов II: 146) «кучеля, кучеляба, аконит (растение с сильно ядовитыми плодами)» ~ кырг., үзб. *қучала* > каз. *қушала,* к.-калп. *күшәлә* id. фар. теленнән дип исәпләнә. Рус. *кучелеба, кучеля, кольчиба*, бор. рус. *кицилибуга* ~ бор. тат. *kuczylabuka* һ.б. (күп телләрдә бар) тур. Аникин: 339 (бик тәфсилле).

**КӨЧӘН-Ү** «напрягаться, тужиться» < гом. кыпч. *күчән-* (закончалыклы фонетик вариантлары белән) id. ← *қучә-* «көч куллану». Чаг. каз. (ҚТДС: 176) *күшең* < *күчең* «көчле».

Дерив.: **көчәнеш,** диал. (ТТДС II: 202) **көчәндек, көчәнке.**

**КӨЧЕГӘН [көчөгән]** (Бәетләр 1960: 30) «подорлик», себ. (Тумашева 1992: 137) **көцөгән** «орёл; беркут» > мар. кч. *кусугäн* id. < гом. кыпч., к. башк. (БТДҺ: 156) *көсөгән, көсәгән,* кырг. *күчүгөн*, алт. *күчүгäн*, каз., к.-калп. *күшүгөн*, *күшиген* ~ төр. *gücügen, guceğen*, алт. диал. *күчүгүгэн* < **күчәwгэн* «бөркет һ.б.ш. ерткыч кошлар» – монг. телләреннән булса кирәк, к. кырг. *күчүгүт, күчүбүт* «көчегән» – **күчүгэн** сүзенең монг. күп. формасы. Räsänen 1969: 306; ЭСТЯ V: 130 (боларда материал безнекеннән ярлырак).

**КӨЧЕК [көчөк],** диал. **көцек, кӧчык, кӧчӧк** «щенок» ~ башк. *көсөк*, чув. *кӑчӑк,* мар. *кычык* «эт; көчек» ~ уйг., үзб. *күчүк* «эт, көчек», алт., к.-балк., кырг. *күчүк* «эт; бүре баласы», каз. *күшик*, нуг., к.-калп. *күшүк* «эт», угыз телләрендә һәм ком. *гүчүк, гүҗүк* һ.б. «көчек» (к. ЭСТЯ III: 92–93). Э.В. Севортян буенча, сүзнең тамыры **күч, *күчи* «эт», бу алт. *күчегеш*, хак. *күчүгеш* (~ себ. тат. **көцөгәц**) «көчек» сүзеннән күренә (*күчү-гэч*). Кр.-тат. *küçü* «көчек», *küçü-küçü* «көчекне чакыру ымлыгы» ~ рум. *kutu-kutu* id.

*Күч, күчи* тамыры киң таралган *күти* тамырыннан, к. бор. гом. ир. *küti*, коми. *кути, кутян, кутю, кочи* < бор. перм. *кисэ* (к. КЭСК: 147), венг. *kutya*, рус. *кутя, кутёнок, кутёк* «көчек, эт»; шуларга охшаш күп кенә бүтән сүзләр Г.Е. Корниловның «Названия для канис в чувашском языке» (1970: 185–186) мәкаләсендә китерелә. К. ш. ук Фасмер II: 433–434; ССТМЯ I: 385 (эвенк. һ.б. *качикан, качи, кэчи* «көчек» тур.). Чаг. **Кече.**

**КӨЧЕРГӘН-Ү [көчөргән-], көчәргән-ү** «напрягаться» ~ башк. *көсөргән-* id. – **көчергә-* фигыленең кайт. юн., к. алт. *күчүркэ-*, як. *күсүркэ-* «көч белән мактану; көч куллану», яз. монг. *kücürke-* «көчләү» (*-ырка//-иркэ* кушымчасы ярдәмендә *көч* < *күч* сүзеннән ясалган; чаг. тат. диал. *алпырка-* «алып булып кылану»).

Дерив.: **көчергәнеш** «киеренкелек» һ.б. регуляр формалар.

**КӨШ, көш-шә** – междометие, которым отгоняют птиц, мух и т.п. ~ рус. *кыш*. Халыкара сүз булса кирәк.

**КӨШБӘТ** диал. «чин, нормальное поведение». Ачык түгел.

Дерив.: **көшбәтсез** ~ башк. *көшбәтьеҙ* «җыйнаксыз; шыксыз».

Без түбәндәге фаразны хөкемгә куябыз. **Көшбәт** < төр. *köşebent* < фар. *кушбäнд* «хәрбиләрнең чинын белдергеч – күкрәккә кыеклатып алына торган укалы киң каеш һәм шундый ук бил каешы» сүзеннән булган тәкъдирдә *көшбәтсез* «җәза чарасы буларак амунициясе салдырылган (хәрби һ.б.)» була. **Көшбәт** сүзе Башкортстанда (трбс. һ.б.) билгеле, нәкъ менә башкортлар үзләренең милли хәрби формаларын XIX г. кадәр саклаганнар һәм аларның хәрби терминологиясендә фар. сүзләре булган.

**КӨШЕЛ I [көшөл]** «ворох зерна на току» ~ мар. *күшүл, кӗшӗл, кышыл* > чув. *кӑшӑл* «коршау, түгәрәк кыса (мәс., иләкнеке); көшел; кибәк өеме», к. ш. ук чув. *кӑшӑлла-* «коршау кидерү; өем өю», *кӑшӑллан-* «түгәрәк ясап басу (уенда)» һ.б. Чув. һәм мар. материалларыннан күренгәнчә, сүзнең төп мәгънәсе «түгәрәк кыса, кабык коршау» һәм бу хәл *көшел* сүзен рус. *кошуля* (ш. ук *кошь, кошьница*) «ашлык савыты; көлтә ташу өчен читән кырандас» сүзе белән (гом. слав. тамыры) тәңгәлләргә комачаулый. Чаг. удм. *кусул* «киртә карамасы, дүңгәләк», *куасаль* «бөгел, бөгелеш», **кус-* «бөгү». Гомумән, *көшел-* фин-угор телләреннән булса кирәк (Räsänen 1969: 312). Р.М. Федотов (I: 265–266) моңа каршы, ләкин без аңа кушылмыйбыз.

**КӨШЕЛ II [көшөл]** «водяная крыса; крот» (к. ДС III: 101; БҺҺ III: 88–89) < гом. кыпч. (кр.-тат.) *күшүл*, алт., каз., госм. *күжүл* «күсе», алт. диал., хак. *күзүл* «сукыр тычкан» ~ калм. *күшл, күшел* id. һичшиксез **күсе** белән тәңгәл. Ихтимал, *көшел* <

*кусур*, к. як. *кутэр* «көшел» < *кусэр* (як. телендә еш кына *с* > *т*). ЭСТЯ V: 155–157.

**КӨШКЕЛ [көшкөл]** (Г. Бәширов), диал. (ТТДС I: 277) **көшкә, көшке, көшкө**, (Кандалый 1988: 387) **күшки,** (Ф. Әмирхан I: 38) **көшлек** «избалованный; кокетливый; предерзкий» ~ башк. (БТДҺ: 156) *көшкө, көшкән* id. Сүзнең деривациясе киң: тат. **көшкеллән-ү,** башк. *көшкәндә-ү, көшәндә-ү, көшкәннә-ү* «кыланчыклану, назлану, юхалану» һ.б. Ачык түгел.

**КӨШТ, күш** (ЗДС: 332, 362) «мясо», фар. *гушт* «ит» сүзеннән. Урта Азия төрки телләрендә киң кулланыла. К. **Күшт.**

**КӨШТӘН** (Радлов II: 605) «ходатай, адвокат, защитник» < рус. *коштан* id., бу сүз исә төрки телләрдән, к. **Куштан.**

**КӨЮ** к. **көй-ү.**

**КӨЯ I [көйә]** «моль» > мар. кч. *кийе*, удм. *кей, кийэ*, морд. Э. *ки* (к. Исанбаев 1978: 119) ~ чув. *кĕве*, тат. диал. (брб., миш.) **күә, кеwе** ~ гом. кыпч., алт. *күйе,* уйг. *күйә* (> үзб. *куйа*), төркм., ком. *гөйә, гүйә*, кырг. *күйө, күбө* ~ төр. *güve*, хак. *күү* «көя» < бор. төрки *kǖje* id., кайбер телләрдә бүтән зарарлы бөҗәкләрне, нөреләрне белдерә; к. ш. ук эвенк. *куйур*, як. *көйүр* ~ бур. *хүйр*, монг. *гүүр* id. Бу сүзне гадәттә *көй-ү* сүзеннән чыгаралар. Чөнки күп кенә телләрдә (уйг., нуг., каз., к.-калп.) *күйе* «корым, көйгән төш», ләкин М. Рясянен (Räsänen 1969: 297) бу сүзне Урал-Алтай уртак сүзләр җөмләсенә кертә (к. фин. *koi* «көя»). Чаг. ш. ук **Көя II,** мар. *көгер* «пешкән, көйгән төш», *кӧгершӗ* «көя». ЭСТЯ III: 94; Федотов I: 268–269; ССТМЯ I: 424–425 (эвенк. һ.б. *куйи-* «кигәвен корты үсү» сүзе белән чагыштыра).

**КӨЯ II [көйә]** «сажа», диал. (Радлов II: 1422) *күӧ* < гом. кыпч., төркм., уйг. *күйе* ← *күй-* «көю» сүзеннән булса кирәк. ЭСТЯ V: 133.

**КӨЯЗ [көйәз]** «щеголеватый, франтоватый и манерный в своём поведении», себ. (ЗДС: 323) **көйәс** «праздничный» ~ нуг., каз. *күйэз*, кырг. диал. *күйөз* id. Бу сүзнең миш.-угыз линиясе (*-й* урынына *-w*) ешрак очрый: тат. диал. (ТТДС II: 203) **күwәз, кеwәз** «көяз» ~ уйг. диал. *күбәс, кәвәз, кәбәз*, куман. *kövezlü,* бор. төрки (ДТС: 304, 330) *küväz, keviz* «горур, үз-үзенә ышанган; көяз» ~ каз. диал. (Аманжолов: 386) *күәр,* калм. *köör,* яз. монг. *köger* «тәкәббер» һ.б. Räsänen 1969: 244. К. ш. ук **Күән-ү.**

Дерив.: **көязлек; көязлән-ү.**

**КӨЯЛӘН-Ү [көйәлән-]**, диал. **күлән-ү** «беспокоиться, тревожиться, тужить, переживать» ~ чув. *кулян-, колян-* id. – һичшиксез *көй-ү* сүзеннән, ләкин ясалышы бик үк ачык түгел. Чаг. ш. ук диал. (ТТДС I: 305–306) **көйгәнәк, көйәнәк, көйәрәк** «борчылучан, артык пошынучан». К. **Көйгәнәк.** Федотов I: 305–306.

**КӨЯНТӘ [көйәнтә]**, миш. (ДС II: 79; ЗДС: 289, 343) **кевәндә, кәнтә, күwән** «коромысло; палка, которой помешивают мытье» ~ чув. *кĕвенке* < гом. кыпч., к. кр.-тат., нуг. *күйэн,* каз. *күйеңте, көйәнте* id. Федотов I: 268.

Дерив.: **көянтәле** (төрле мәгъ.), **көянтәсез; көянтәлә-ү; көянтәлек;** идиомалар: **көянтә йолдызлыгы** «орион» (күп телләргә характерлы, к. мар. *вӱдвара* «көянтә», *вӱдвара шӱдыр* «орион»); **көянтәле маржа** «энә карагы (бөҗәк)» = **маржа көянтәсе** id.; энә карагын «көянтә» дип атау рус. *коромысло,* лат. (фәнни термин буларак) *libella* сүзләрендә дә чагыла (*labella* төп мәгъ. «үлчәү көянтәсе»).

**КРЕСТЬЯН** «крестьянин» < иске рус. *крестьяне* сүзеннән (XVIII г. кергән). Асылда *христиан* сүзеннән.

**КУ I [кыw]** (ДС I: 95; Тумашева 1992: 131–143) «трут (для разжигания огня); засохшая (в особенности прошлогодняя) трава» – имеет множество вторичных и метафорических значений – төрки телләрдә бу, мөгаен, иң бай деривацияле тамырдыр, к. башк. *ҡыу* «коры, корыган, кипкән, җиңел холыклы; каудар», тат. сөйләшләрендә «кипкән, коры; саргайган; аксыл-сары, майсыз (аш), хәйләкәр; үтә дә, бик тә» һ.б. < гом. кыпч., алт. *ҡу, кув, ҡуу*, хак., тув. *хуу*, аз., төр. *коw*, *гов*, гаг. *коф* «ку; мамык» (мамык үскән җирләрдә ку урынына мамык кулланылган)», як. *кыа* ~ яз. монг. *хии* һ.б. «ку»; к. ш. ук чув. *ăвă, у* < болг. **ћуи* «ку», чув. *хăва* «чыра».

Мәгъ. һәм яңгыраш охшашлыгыннан чыгып, **ку** һәм **қау** (к.) сүзләрен гомоген дип карарга кирәк, ләкин монда үсеш линияләрен билгеләү кыен; госм. (Радлов II: 455–462) *ҡаw, ҡав* ~ бор. төрки (ДТС: 436) *qav* «ку, кау» белән бергә бор. төрки (ДТС: 436) *qavaγi* ~ башк. *ҡыуау* «ку» формасы да бар.

Кайбер телчеләр *ку* беренчел дип тә карыйлар: бор. һәм гом. төрки *quw* «коры» < бор. кыт. *qu, q'u* «кору, кибү» (Баскаков 1987: 73). К. ш. ук **Коба.** ЭСТЯ V: 98–99 (әдәбият күрсәтелә). Федотов I: 79–80.

Дерив.: **куар-у; кулык** (гөмбә); башк. (БТДҺ: 297) *қыуғыл* «аксыл сары».

**КУ II** диал. «бесплодная; холостяк» (Арсланов 1988: 83), миш. (ТТДС I: 254) *кубаш, ку баш* «баласыз хатын» ~ каз. *қу бас* id., *қу* «коры, кипкән; гыйшык дәрте беткән; эчтәлексез», *қу ауыз* «юкны, кирәкмәгәнне сөйләүчән» ~ төр. *kov, koğ* «буш» һ.б. Хак. *хуу иней* «Әрликнең – җир асты патшасының хатыны» – еш очрый торган фольклор персонажы; гомумән – «ырудан калган хатын-кыз; әби». К. **Ку I, Куык.**

**КУ III** (Арсланов 1988: 83), себ. (ЗДС: 431) **қуу,** м.-кар. **қуғу** «лебедь» ~ добр., кр.-тат. *қуу,* чыгт., кар. *қуғу*, кырг., алт., уйг., госм. *қоғу*, хәз. төр. *kuğu,* кыпч. телләрендә, ш. ук тув. *қуу*, хак. *хуу* id. Чаг. **акку,** кырг. *уққу* «аккош» һәм *қу* (к. **Куар-у**) «ак», **Куас.** Ихтимал, кыт. теле даирәсеннәндер. К. **Куа I, II.** Будагов II: 67 (бик аз гына язылган). Räsänen 1969: 275 (**кугый** сүзе белән чагыштыра).

**КУА I** «бурый, темнокрасный» > мар. *кува, хыва, ува* < болг. **һуа* «куа». К. **Коба.**

**КУА II** диал. «сказочная красавица» (к. *Тәбәнә куа, Тәбәнә куга,* к. ТХИ: Дастаннар 1984: 132–133) < бор. төрки (ДТС: 638) *хиа* «чәчәк; гүзәл» < кыт. *xwa, хиа* id. Бу кыт. сүзе Себер телләрендә (төркиләрдә генә түгел) еш очрый: алт. *куву*, тув. *хува*, як. *куо* ~ монг. *гуа, куа* «әкияти гүзәл». Чаг. **Куас.**

**КУАК** «куст» > мар. кч. (Исанбаев 1978: 23) *куак*, удм. (Атаманов: 68–75) *куак* < гом. кыпч., к. башк. *қыуақ,* нуг., каз., чыгт. *қуақ, қувақ* «куак; чикләвеклек» (к. Радлов II: 1040) ~ мар. *уа* < болг. **һуа* > чув. *хӑва* «тал, таллык; әрәмәлек; көтүлек», к. тув. *хаак* «таллык; тал». Räsänen 1969: 215.

Дерив.: **куаклы, куаксыз; куаклык.**

**КУАН** «жаркая и сухая погода» ~ башк. *қыуан,* (БТДҺ: 217) *қыуансыҡ,* каз. *қуаң* id. – *қу* «коры» сүзе белән гомоген булырга тиеш. Себ. (ЗДС: 406) **коан, коаң** «нажагай, яңгырсыз яшен». Чаг. **Куар-у.**

**КУАНДЫК** «название реки и племени на Южном Урале, в Башкортостане» (БРС 1996: 856) – бу сүз бер дә «куану»дан түгел, ә бор. төрки этнонимнан килә, к. алт. (Баскаков 1972: 6) *куманды, кубанды, кубандык, кувандыг, кувандых, кумандык, куванты* – алтай халкы составына кергән кавемнәрнең берсе. Кумандыларның теле уйгурчадан килә. Кумандылар күп кенә ыруларга бүленәләр: *тазлар, татарлар, тиләйләр* һ.б. (болары бүтән төркиләрдә дә бар, калганнарының төбе-тамыры безгә ачык түгел). Ләкин хәз. куандыкларның төп өлеше төркиләшкән кетт халкыннан килә дигән фикер бар.

**Куандык**лар хәз. көндә төньяк-көнч. Башкортстанда да яши (һәрхәлдә – теркәлгәннәр). Алар Алтай тарафларыннан килгән булса кирәк. Ихтимал ки, аларның бабалары **куман** ~ команнар белән нәселдәштер (*куманды* асылда *куманлы, куманлык* дигән сүз).

**КУАН-У** «(бурно) радоваться» > мар. Т. *куан-* id., удм. *куан-* «канәгать булу; соклану; ышану, куану» ~ мар. *уан-* «өметләнү; ышану» < болг. **һуан-* > чув. *хӑван-* «куану» < гом. кыпч. *қуан-, қуван-*, башк. *қыуан-ыу,* алт., уйг., кырг. *қубан-* (кырг. *коон-* варианты да бар), төр. *kıvan-* «горурлану; куану» бор. **қуа-* «шатлык кичерү, шатлыкта булу» фигыленең кайт. юн.; сүзнең тамыры – тат. **куw** (Гиганов сүзлегендә *кувъ*), каз. *қув*, уйг. диал. *қвы* «җыну шатлыгы, сөенеч», төркм., алт. *қубуй* «шатлык; матурлык», *гову, говы* «әйбәт, шат, шатлыклы»; бу сүзне бор. төрки (ДТС: 472, 475) *qut-quv, qut-qïv* «куаныч, шатлык» сүзенең икенче компоненты белән тиңләргә ярый; чаг. ш. ук тув. монг. *хоғ* < *қоғ* «чам (к. **Чәм**) тамашасының азаккы – җыну, куану өлеше, апофеозы». К. **Куат.** Чаг. **Купшы.**

**Куан-у** фигыленең үзеннән бигрәк аның дериваты – **куаныч,** кр.-тат. *қуваныч,* кырг. *қубаныч,* төр. *kıvanç* һ.б. «куану хәле, горурлык» киңрәк таралган. К. Будагов I: 68; ЭСТЯ VI: 100 (сүзнең тамыры бор. монг. *qubi* «бәхет, өлеш» дигән фикер әйтелә, бу сүз тур. ш. ук ССТМЯ I: 403); Федотов II: 316 (бик аз).

Дерив.: **куаныш-у, куандыр-у** (→ **куандыргыч**).

**КУАР-У** «побледнеть, поседеть, поблекнуть» ~ кар., каз., к.-калп. *қуар-, қувар-*, кырг. *қубар-* < бор. төрки (ДТС: 475) *quvar-, quvur-* id. һ.б. *қу* «аксыл сары» сүзеннән.

**КУАС, куаш** (Тумашева 1992: 132, 136; ЗДС: 420) «украшенный; убранство» ~ кырг. *қооз,* алт. (Баскаков 1972: 224) *қоос*, хак. *хоос,* алт., хак. диал. *қубаз* «матур». Чаг. маньч. (ССТМЯ I: 422) *кува-*

*са* «мактану» ← кыт. *kӯa* «мактану», *kӯацзы* «мактаныч». Räsänen 1969: 295 (*куас*ны бор. фар. *xᵛašš* «хуш, әйбәт» сүзенә баглый).

**КУАТ** «сила; радость» ~ башк. (БТДҺ: 217) *кыуат,* алт. *кубат*, алт. диал. *ҡоот* «шатлык, кәеф» – **куан-у** (к.) белән тамырдаш булса кирәк. **Куәт** (к.) сүзеннән булуы бик шикле. Ләкин М. Федотов (II: 316–318) *хăват* «көч-куәт» сүзенең **куәт** белән бердәйлеген алга сөрә.

**КУӘ** «способность, дар» (мәс., *каләм куәсе* «способность писать хорошие произведения» < гар. *ҡуwä* id. К. **Куәт.**

**КУӘТ** «мощь, сила; крепость (напитков)» > мар., удм. *куат* id.; мар. диал. (Саваткова: 64, 174) *уат* < болг. **һуат* > чув. *хăват* id. < гар. *ҡуwwät* id. (*куә* сүзендә *-w-* тәшдитсез) id. Будагов II: 70. Монда **куат** (к.) сүзенең тәэсире бар бугай.

**Куәт** сүзенең дериватлары **куәтле** «көчле» һәм **куәтлә-ү** «ярдәм итү; көчен арттыру» сүзләре дә күрше фин-угор телләренә кергән. Федотов II: 316–317.

**КУБА: куба тал, купа тал** (ТРС 1966: 298) «вид ивы» – Н. Исәнбәт (Мәкальләр I: 527) **кубал тал** дип яза. Ачык түгел. **Куба тал** «коба тал» дип аңлату (БТДҺ: 201) безне канәгатьләндерми.

**КУБАГАЙ** «густо-синий, тёмно-синий, кубовый» (ТТДС I: 206) ~ иске тат., алт. диал. *ҡубалаҡ* «зәңгәр, күксел» (к. Радлов I: 1035). Ачык түгел. Русча *кубовый* «кубагай» сүзе үзе дә аңлатылмый.

**КУБАЛАК** «легко снимающийся, незакреплённый (о крышке и т.п.); облупленный; шелудивый; шелущащийся» – **кубала-у** фигыленнән.

**КУБАЛА-У** «облупляться, облупиться; шелушиться» – **куп-у** фигыленең интенсивлык, күптапкырлык дәрәҗәсеннән. К. **Кубар-у, Куп-у.**

**КУБАР-У** «срывать, отрывать, поднять с места; возбуждать» < гом. кыпч. *ҡобар-*, угыз телләрендә *ҡопар-* < бор. төрки *qopar-, qopïr-* «урыннан күтәрү», уйг. *ҡомар-* «кубару, куптару, актару» *ҡуп-* < *ҡоп-* сүзенең йөкл. юн. дип аңлатыла (ДТС: 457). К. **Куптар-у, Куп-у.**

**КУБЫЗ,** диал. **кумыз** «варган», иск. «гитара, мандолина», «вообще музыкальный инструмент; музыка» (*Кыз, кубыз, кымыз – шайтанга өч кулавыз* «разгульная девка, музыка и хмельное – три проводника чёрта» дигән мәкаль бар > чув. *купăс* «кубыз; гармун», мар. (Исанбаев 1978: 45) *кóвыж, комыж* «иң гади скрипка», удм. (Насибуллин: 119) *кубыз* «сыбызгы; скрипка», *кобъз* «түтек (дуда)» < гом. төрки *кубуз, кобуз* (башк. *ҡумыз,* нуг., каз. *ҡобыз*) < бор. төрки (ДТС: 451) *qobuz* «кыллы музыка коралы», шуннан **qobza-** (< *qobuz-a-*) «музыка коралында уйнау» > иске тат. **кубса-, кыбса-** id. (к. «Әдәби мирас», № 4, 1997: 26), куман. *kopsa-* «музыка коралында уйнау; мактап җырлау», рус., укр. *кобза-* «кыллы музыка коралында уйнап җырлау», *кобза* «кубыз», *кобзарь* «чичән, бард». Рус. *комуз* «озын муенлы гитара» каз., кырг. *комуз* id. сүзеннән, к. ш. ук алт. *комыс* «гармун», *камус* «кубыз» ~ *комургай, кобрак, кообрак,* хак. *хобрах* «курай, түтек» ~ монг. *хуур*, иске монг. *xuγur* (> эвенк. *кӯр*) «балалайка» (к. ССТМЯ I: 434–435) < бор. кыт. *xien kur* «кыллы курай» сүзеннән дип исәпләнелә. Һәрхәлдә *кубыз* < *кобыз* < *кобуз* < **кōбург* үзгәрешләре бәхәссез, монг. яңгырашлары үзгәрәк чыганактан булырга мөмкин.

К. Räsänen 1969: 281; Галайская: 328–350; Федотов I: 309–310 (тәфсилле).

**КУБЫЛГЫ** «переливающийся (о цвете тканей, крыльев насекомых и т.п., а также о голосе певца)» ~ иске уйг. («Угызнамә» телендә) *ҡуғылғы* id. ← гом. кыпч. (нуг., к.-калп.) *ҡубыл-,* (кырг., алт.) *кубул-* «үзгәрү, әверелү» фигыленнән, к. ш. ук як. *кубулуй-*, хак. *хубул-*, тув. *хувул-, хуул-* «икенчеләнү, башкару» һ.б. ← бор. монг. *qubiγul-* «алмаштыру; әверелдерү; алдаштыру» һ.б. (к. ЭСТЯ VI: 96–98, тат., башк. сүзләре искә алынмый). Чаг. кыт. *хуа* «әверелү, үсү; мәгърифәт» – монг. сүзе шул нигездән килгәндер. К. **Кубылҗы-у, Кубылма.**

**КУБЫЛҖЫ-У** «переливаться (цветами, голосом)» < гом. кыпч., к. башк. (БТДҺ: 207) *кыбылйы-у,* кырг. *ҡубулҗы-,* каз. *ҡőбылҗы-* id. < **ҡубулчы-* ← *кубул-* «үзгәрү һ.б.», к. **Кубылгы, Кубылма.**

**КУБЫЛМА**, себ. (Будагов I: 68) **куплума** «одновременно двухцветный (о тканях, о перьях птиц)» ~ нуг. *ҡубылама* id. ← **кубыл-* «үзгәрү һ.б.» (к. **Кубылгы**). Л. Будагов (II: 68–69) бу *кубыл-* фигылен **куп-у** «кубу, кубалаклау» сүзе белән баглый. К. ш. ук Räsänen 1969: 295.

Дерив.: **кубылмалы** («Идегәй» дастанында *Кубылмалы күк Идел…*).

**КУБЫР** диал. «небольшая верша, сачок» (Татарстанның Мөслим районында без теркәдек. – *Р.Ә.*) ~ башк. *ҡубыр,* (БТДҺ: 201) *ҡубар* id., кр.-тат., чыгт. (Будагов II: 38, 272) *ҡубур* «комган», *ҡопур* «капкачлы агач купы», нуг., ком. *ҡубыр*, кырг. *ҡабур, ҡабыр*, госм. *ҡавур, ҡавураҡ* һ.б. «футляр, кумта» > рус. (Фасмер II: 269) *кобура* «утлы корал өчен күн савыт», к. ш. ук каз. *ҡөбыр* «торба», төр. *kubur* «торбасыман савыт; сууткәргеч; пистолет төре» һ.б.; бу сүздән кечерәйтүле нигез – **кабырчак** (к.). Радлов II: 654, 660; ЭСТЯ VI: 71–72.

**КУГА** (Тумашева 1992: 132) «озёрный камыш (осенью, засохший)», **ҡуғы** (себ., ЗДС: 421) «болотистая низменность с ельником» ~ чув. *кука* «саз үсемлеге» (ди Ашмарин, VI: 258) < гом. кыпч., к. башк. (БТДҺ: 2001) *ҡуға,* (БТДҺ: 217) *ҡыуға,* кар., каз., кырг., алт. *ҡоға*, үзб. *ҡўға,* төр. диал. *qoγa, koka, kova* һ.б. (к. ЭСТЯ VI: 10–12, **купа** «кобау, купкы» сүзе белән гомоген дип карала, безнеңчә, бу бик шикле), асылда **кау, ку** сүзләре белән тамырдаш булса кирәк. Чаг. кыт. *ху, хуа* «күл чәчәге, бамбук». Рус. *куга* (< төрки) тур. к. Аникин: 311–312 (бай әдәбият күрсәтелә). Манси *кока* < бор. төрки (*qawqa*) тур. к. Kannisto 1912: 103.

**КУГЫЗ**, себ. (Тумашева 1992: 131, 132) **ҡоғус, ҡуғыс** «пустой; пустота; выемка», «пещера; пустое помещение» ~ башк. (БТДҺ: 217) *ҡыуғыҙ* «яр читеннән өңелеп төшеп киткән чокыр», кырг. *ҡуз* «тирән ерынты», як. *куоһаа-* (< *куосаа-*) «яр астын юылдыру, өңгерләү (мәс., ташкын тур.)». Чаг. төр. *koğuz, kokuz, kovuz* < бор. төрки (ДТС: 457; Clauson: 614) *qoquz* «буш; эчтәлексез», тув. *хоозун* «буш; эчтәлексез», себ. **ҡуғыр,** бор. төрки *qoqur* һ.б.ш. (инде күрсәтелгән сүзлекләрдә) «буш» шул ук **кугыз** микән – юраулы. Гомумән, бу сүзләр гом. төрки *ҡу* ~ *ҡоғ* «буш» тамырыннан булса кирәк, к. **Ку II.** Чаг. **Кавыз.**

**КУГЫЙ** (Тумашева 1992: 132) «гагара» ~ як. *ҡуоғас* (< *ҡуағач* булса кирәк), ульч. (ССТМЯ I: 405) *коколду* id. «кукылдык» кебек; лат. атамасы *Gavia* – характерлы *ҡуо-ҡуо* «каңгылдау, куңгылдау» авазларына карап бирелгән атама. Räsänen 1969: 276. К. Фасмер I: 380. Чаг. ш. ук **Тиресаяк.**

**КУГЫН** «гонец, вестник; погоня; изгнание массой», диал. «моль (транспортировка брёвен самоходом по малым рекам под наблюдением погонщиков)» < гом. кыпч. *ҡуғын, ҡуғун,* кырг. *ҡууғун,* ком. *ҡувун,* төр. *koğun* һ.б. «күпләп куалау; куыла торган масса» (һәр телдә диярлек диффуз мәгънәле). **Ку-у** сүзеннән, әлбәттә.

Дерив.: **кугынчы.** Чаг. төр. *koğuncı* «куалаучы».

**КУГЫШ,** себ. (ЗДС: 406) **ҡōғус** «спинной хребет» < бор. төрки (ДТС: 456) *qoγuš* «аерым өлешләрдән торган су торбасы», төр. диал. (YTS: 142) *koguş* «ук ату өчен улак, көпшә» (гадәттә балалар уенчыгы, ләкин элекке тиенчеләр дә җәнлекнең күзенә генә тидерерлек төзлек кирәк булганда кугыш кулланганнар). Чаг. **Куыш.** Räsänen 1969: 275 (бу сүзне монг. *qobul* сүзе белән чагыштыра, ягъни *б ~ w ~ г, л ~ ш* күчешләренә таяна).

**КУДАШ, кодаш** – название ряда деревень и знаменитая дворянская фамилия; отсюда русский дворянский род **Кудашевы.** Н.А. Баскаков буенча, төр. һ.б. төрки *qundaş* «бишектәш, бер атадан, төрле анадан туган (бала, балалар)», к. Баскаков 1979: 30. Ләкин монда төрлечә уйларга урын бар. К. бор. төрки (ДТС: 9) *adaš-qoldaš, adaš-qudaš, adaš-qadaš* «дус-иш». Кыскасы, әгәр **кудаш** сүзендә *-даш* билгеле уртаклык аффиксы дип куйсак, төрле фаразларга урын киң, ләкин монда сүз төзелешенең бөтенләй бүтән булуы да ихтимал.

**КУЕ I [ҡуйы̆]** «густой; частый (о растительности, о лесе); мутный (о воде)» < гом. кыпч. *ҡойы, ҡойу* < уйг., алт. *ҡойуғ* һ.б. id. > төр. *goyu*, як. *хойуу* id. (барча төрки телләрдә, к. ЭСТЯ VI: 32–33) ← (к.-калп.) *ҡойы-* < *ҡойу-* «куе булу, куеру» фигыленнән; ул фигыль исә **ҡой* исеменнән ясалган шикелле.

**Куйы** бик продуктив нигез: **куелык; куер-у** һ.б. К. **Куерык.**

**КУЕ II [ҡуйы̆], ҡуи** иск., кит. (в словах **куеда, куедагы**) «низ; то, что (следует) внизу, ниже, нижеследующий» < чыгт. (Будагов II: 100) *ҡойы, ҡойу, ҡоян* «түбән төш, ас; түбәнге, түбәнгә» (Будагов күп мисаллар китерә һәм тат. «Кыйссас-үләнбия» телен «башкортча» ди). Сүзнең тамырлары тур. к. **Койты.**

Дерив.: **ҡуичылык** «түбәнчелек, буйсыну», **ҡуи салмак** «түбәнәйтү, кимсетү». **Ҡуи** һәм аның дериватлары каз., үзб., уйг. һ.б. төрки телләрдә ешрак, киңрәк кулланыла.

**КУЕН [ҡуйы̆н]** «пазуха; грудь (в некоторых выражениях)» < гом. төрки *ҡойун* ~ аз., төр. диал.

*гойун*, як. *хойньо, хойн, хōй* ~ бор. төрки *qojun, qojın, qoj, qon* id. (ДТС: 453) ~ чув. *ху, хĕв, хүм* < болг. **қŏw, қowyм* < ** қowyң*; фонетик реконструкция буенча, бу сүзнең тамыры **кōң* ~ мар. (Рясянен 1955: 179) *коңла, коңгыла* «умрау асты», чаг. фин. *kainalo* «култык», чаг. ш. ук гаг. *қойну* «куен». Чаг. *култык* < **коңултуқ*. **Куен** сүзенең күп кенә вариантлары *куй* сүзенекенә тәңгәл, шунлыктан **куен** ул киемнең *куй* тиресеннән эшләнгән өлеше диючеләр бар (Потапов 1969: 206–207). Гомумән, фин-угор сүзләре белән чагыштыру да, *куй* сүзе белән тәңгәлләштерү дә исбатланмаган фаразлар гына. ЭСТЯ VI: 26–27.

**КУЕРЫК [қуйы̆ры̆қ]** «мутный, взбаламученный (о воде)», «гуща» **– куер-у** фигыленнән үзенчәлекле дериват. К. ш. ук **куерткы**; (мәсьәләне) **куерту**; **куертма** һ.б.

Дерив.: **куерыклы, куерыксыз; куерыклану.**

**КУҖЫ-У (кужу)** «быстро размножаться; разгораться; расширяться (о рое)», (ТТДС I: 213) «раззадориться». К. **Кузгы-у**.

**КУҖЫЛЫ** «лесной муравей» < удм. *кузьыли* ~ коми. *кодзувкот, кодзыль*, фин. *kusiainen* һ.б. id. КЭСК: 126.

**КУЗ**, диал. **кус** «горящие уголья» < чыгт., бор. төрки, каз. һ.б. *қōз* > алт. *қос,* хак. *қоос* id. (к. Баскаков 1966: 179) ~ госм. һ.б. *қор* id. К. **Кур, Күзә-ү.** Будагов II: 79; Räsänen 1969: 285.

**КУЗА** (ТТДС I: 254) «металлическое украшение на одежде и обуви», (ЗДС: 421) «медный кувшин», диал. **кузай** «бусы; шлафрок; брыли» ~ башк. *қуза* «киемдә кургаш бидәр» (*қузалау* «кургаштан бизәк төшерү», к. БҺҺ II: 147), *қуҙа* «ромб формасындагы сырга», каз. (ҚТДС: 203) *қозалы сырға* «кыйбатлы сырга», алт. *қоза, қозо, кооза* «калай шөлдер», бор. төрки (ДТС: 462) *qoza čečak* «ак лотос» (ритуаль бизәк) = санск. *māndāraka*. Гомумән, **куза, кузай,** төр. (Redhouse: 677) *koza, kozar* «борчак төре; бөртек, бөрчек» белән баглы һәм бор. шаман киеменең бер төрле бизәген белдергән. Чаг. ш. ук **Кузалак, Кузыр.**

**КУЗАК** «стручок (бобовых)» ~ башк. *қуҙақ* id., ш. ук «борчак бөртеге» > чув. *кусак* «мәк башы» ~ госм. *қозақ* «нарат күркәсе; бүк чикләвеге» (Радлов II: 629; Steuerwald 4: 554). Барча сүзлекләр бу сүзне **кузы** сүзе белән тамырдаш дип карый. К. **Кузы.**

**КУЗАЛАК I** «двуколка, ро́спуск, двухколёсная тележка» ~ нуг. *қодалақ,* нуг., ком. *қозалақ, қудалақ* > тат. диал. (Арсланов 1988: 82; Dobr. II: 393) **қŏзалақ,** *qodalaq* id. тат. **куз-, *кузала-* «тәгәрәп бару» сүзеннән, к. чув. *кус-* (< *қуз-*), *кōс-* (< *қōз-*) «тәгәрәп бару; йөгерү; качу (ана хайваннар тур.)», *кускала-* «әйләнеп тору», *кускăч* (< *кузгыч* «әйләнгеч, тәгәрмәч», к. Ашмарин VII: 15–17), ш. ук *косатран* (< *куза торган*), *косаткан, костарчăк* «тәгәрмәч», мар. (Иванов, Тужаров: 94–95, Саваткова: 67) *кŏдала-, кузала-, кыдала-* «чабып бару, йөгерү, тәгәрәп бару». Барлык мәгълүматлар бу сүзләрнең дә тат. телендә булганлыгын һәм аларның тамыры *куҙ-* (ягъни башкортчарак) булганлыгын күрсәтә, ләкин ни татарча, ни башкортча сүзлекләрдә ошбу сүзләр теркәлмәгән. Чаг. тик каз. *қудала-* «калышмастан куалау»; (ҚТДС: 280) *қауза-* «каулау, куу».

Тат. диал. **кулазак** (ДС II: 113), **куладан** (ТТДС I: 209) *кузалак, *куҙалан* формаларыннан метатеза булса кирәк. Нуг. һәм ком. телләрендәге сүзләр Урта Идел регионыннан булырга да мөмкин: **куз-* < **коз-* тамырының иң бай деривациясе чув. һәм мар. телләрендә.

*Кузалак* < *козалак* сүзе белән, ихтимал, госм. *қозалақ, қозақ* «бүк чикләвеге; түгәрәк мөһер, балавыз; мөһер өстенә (аны саклау өчен) беркетелгән алтын яки көмеш каплама, конус» сүзе тәңгәлдер. **Куз-** тамырын ш. ук калм. *кууц-* «йөгерү, тәгәрәү» сүзе белән чагыштырырга мөмкин.

Чув. *кустарма* < *костарма, кустармач* (чаг. *тәгәр-мәч*!), *костарак, костарчă, кăстăркăч* «тәгәрмәч» тур. сөйләгәндә М.Р. Федотов тат. *кузалак* сүзен искә алмый, С.Н. Муратовның тунг.-маньч. *кус* «тиз» тамыры белән чагыштыруын китерә (Федотов I: 313). Бу чагыштыру, безнеңчә, шиклерәк.

Урта Идел һәм Төньяк Кавказ телләреннән тыш, мәзкүр сүз аз. (АДДЛ I: 391) *газалаг* «элекке Апшеронда (Баку тирәләрендә) билгеле булган ике тәгәрмәчле пассажир арбасы» билгеле. Төр. *kozalak* «ябулы бәбиләр арбасы».

**КУЗАЛАК II, қŏзалақ** (Dobr. II: 345) «шишка ёлки, сосны и т.п.», «кукла (из шишек)» ~ госм. *қозақ, қозалақ,* төр. *koza* «бүк чикләвеге; ылыслы агачлар күркәсе», «шуларга охшатып ясаган кара савыты капкачы», ш. ук «шундый (еш кына алтыннан, көмештән ясалган) мөһер, пичәт». Чаг.

алт. *қозо* «каузы, кечкенә кыңгырау». Чаг. ш. ук себ. тат. (ЗДС: 421) **қуза** «бакыр күкшен» (кузалак формасындамы?). К. **Кузы.** Бу сүзләрдә төрле контаминацияләр дә булырга мөмкин. К. Будагов II: 80; Радлов II: 629; Redhouse: 677.

**КУЗГАЛАК,** миш. диал. (ЗДС: 334, 421, 430) **кузгалдак, кузгулдак, кузгылдак,** урта диал. **қузганақ,** себ. **қусқалақ** «щавель» > чув. *кускалак*, мар. *козгалык*, морд. *козгалав,* удм. (ДАУ II: 174–193, бик тәфсилле) *кузкалак, кучкылак* һ.б. (дистәләгән вариант) ~ нуг., каз., к.-калп. һ.б. кыпч. *қозғалақ* < к.-балк., кырг. *қозуқулақ,* ком., уйг. *қозу қулақ*, аз. *қузуғулағы*, төр. *kuzukulağı*, төркм. *gozugulagı* һ.б. барысы да асылда «кузы (бәрән) колагы» дигәннән метафорик атама. Бу атама күп кардәш вә күрше телләрдә калькалаштырыла: удм. (Алатырев 1967: 44–45; Насибуллин: 122) *кузым турын* «кузый үләне – кузгалак», к.-балк. (Отаров 1987: 38) *қозу қулагы* ≈ бур. *хурьгэн шэхэн* id. Чаг. ш. ук үзб. *отқулоқ* «ат колагы – кузгалак», тув. *инек қулақ* «инәк (сыер) колагы – кузгалак», төр. диал., уйг. *тәкә қулақ* «тәкә колагы – кузгалак» һ.б. Радлов II: 633, 1021; Алпаров 1945: 170, 177.

**КУЗГАЛ-У** «сдвинуться с места; восстать» – **кузга-у** фигыленнән. Бу сүзнең бур. *хубисхал* < *хүбизгал* «күтәрелү, революция» сүзенә охшашлыгы күзгә ташлана һәм *кузга-у* < **кубызга* ← *куй-у* (к. **Куп-у**) түгелме икән, дигән фикергә китерә. Ләкин бу исбат ителмәгән. К. **Кузгалыш.**

**КУЗГАЛЫШ** «восстание; революционное движение» – **кузгал-у** сүзеннән тат. теленең үзендә килеп чыккан.

**КУЗГАТУ** «сдвинуть с места» – **кузга-у** фигыленең йөкл. юн. буларак та, **кузгалт-у** формасыннан да килеп чыга ала.

**КУЗГА-У** диал., (Тумашева 1992: 136) **қусқа-у** «сдвинуть; беспокоить» > чув. *хускав* «хәрәкәт» нуг., каз., к.-калп. *қозға-*, кырг. *қозго-*, алт. *қосқа-, қосқо-* id. кар., чыгт. һ.б. < бор. төрки *qozγa-* ~ иске монг. *qorγa-* id. (к. Поппе 1938: 199). Räsänen 1969: 285.

Тат. телендә **кузга-у** үзе диалекталь сөйләмдә генә; гомумхалык телендә аның төш. һәм йөкл. юн. **кузгал-** һәм **кузгат-** ешрак кулланыла (*қозғал-* һәм *қозғат-* барча кыпч. һәм уйг. телләрендә дә актив). К. ш. ук тат. әд. **кузгалыш, кузгалан** ~ үзб. *кўзғалан,* уйг. *қозғалан* «баш күтәрү, фетнә, революция». К. **Кузгы-у.** Будагов II: 80; ЭСТЯ VI: 21–22; Федотов II: 370.

**КУЗГЫ-У, кужгы-у, куж-у** (ТТДС I: 213) диал. «усиливаться (о процессах); возбуждаться; раздражаться» ~ башк. *қужы-у, қузы-у,* (БТДҺ: 202) *кужғы-у, кузгы-у* id. *Кузгы-у, кужғы-у* <* *кузык-у, *кужҗык-у* булса кирәк (ягъни *козы-*, *кожы-* нигезенең интенсивлык формасы). Нигезе – гом. кыпч. (кр.-тат., к.-балк., кырг. һ.б.) *қозу-*, каз. *қозы-* «ярсу, ярсыну», ш. ук. «ярсыту» ~ төр. диал. *kooz-*, *koz-* id. төркм. > каз. (ҚТДС: 58) *ғооз* «шаян; тынгысыз (бала)». Чаг. **Кузга-у.**

Дерив.: **кужгыту** «ярсыту (мәс., бал кортларын туздырып)» – төп фигыльдән ешрак кулланыла; **куздыр-у** (ЗДС: 421) «котырту».

**КУЗЛА** «козлы» < рус. (*козёл* «кәҗә тәкәсе» сүзенең күп. формасыннан; чаг. тат. **кәҗә** «кәкре аяклы урындык һәм утын кисү җайланмасы»).

**КУЗНА,** диал. (ДС III: 49) **гузника** «игра в альчики; ко́зонки» ~ чув. *кусна*, мар. *козно-лу*, удм. *козлок*, *козан* «кузна (ашык) сөяге, чәмәй, шәмәй; ашык – кузна уены» < рус. *ко́зны, козонки́, козло́к* һ.б. id., ләкин бу сүзләр үзләре төрки телләрдән, к. **Кузый.**

**КУЗ-У** (ЗДС: 422, төньяк Татарстан) «вставать со сна; задвигаться» ~ мар. *кодала-, кыдала-* «чабып китү, тәгәрәү», *кудалтыр-* «тәгәрәтү», чув. (Сергеев 1968: 33, 35) *кос-, кус-* «тәгәрәп килү», *косатран, костарак, кускăç* «тәгәрмәч». Бор. бер югалган сүздән булса кирәк, к. **Кузалак I.**

**КУЗЫ,** (Будагов II: 80) **қозуқ = қузық** «грецкий орех; кокон (шелковичного червя)» < гом. кыпч., к. каз., к.-калп. *қозы,* үзб., уйг. *қузы, қозы* ~ гаг. *қоза*, каз. диал. < төркм. (ҚТДС: 58) *ғоза*, к.-калп. *ғоз,* аз. *ғоз*, гом. төрки (Радлов II: 629), куман., госм., чыгт. *қоз,* төр. *koza* id. Тат. (Тумашева 1992: 126, 129) **қŏз-, козы-** «чикләвекне өзеп алу» – уникаль фигыль. Бу фигыль себ. **қузық, қŏзŏқ, қŏзык, қŏсŏқ,** иске тат. **қŏзуқ** < алт. *қузуқ,* хак. *хузук* һ.б. (ЭСТЯ VI: 23–24) «кедр чикләвеге», төркм. *хозы* «чыршы күркәсе» сүзенең «өзеп алынгыч» мәгънәсеннән килеп чыкканлыгын күрсәтә шикелле. ЭСТЯ авторлары *кузы, қоз* формаларын, нишләптер, китермиләр. К. ш. ук **Кузак.** Будагов II: 80.

Дерив.: **кузла-у, кузыла-у** «җиләк-җимешкә ябышып үсентеләр үсү» (ихтимал, **кузый** сүзенә карыйдыр).

**КУЗЫЙ,** (ДС I: 97; ДС III: 84) **козе, кузы,** себ. (Тумашева 1992: 136) **қусы, кусы бала** «ягнёнок (самка)» < гом. кыпч., к. нуг., каз., к.-калп. *қозы*, чыгт., куман. (к. Радлов II: 630, 632), ком., к.-балк., кырг. *қозу*, алт. *қозо,* кырг. диал. *қоозу*, кырг. *қозуға, қозуғғана,* гаг. *қузу*, төр. *kuzu,* уйг., чыгт. *қоза,* (Боровков 1963: 210) *qoбı* id. ~ яз. монг. *xuriyan, xurayan* «кузый»; иске монг. *qurayan* – чыгт. *qozı* «кузый» (к. Поппе 1938: 111), хәз. монг. *гур* id.; к. ш. ук бур. *хурьган* «кузый», бур. *хурай*, монг. *гуран*, монг. *хурань* «кыр кәҗәсе, сайгак» (шуннан рус. *горал* «Үзәк Азиядә яши торган тау кәҗәсе төре»). Бор. төрки (ДТС: 462) *qodï, qoδï, qojï, qozï* «кузый» һәм «түбән, тәбәнәк» мәгъ. бергә бирелә. Шунда ук китерелгән *qozqï ~ qodqï ~ qoδqï ~ qosqï ~ qotqï* (чаг. **Куйы**) «түбән, тәбәнәк» сүзе дә **кузы** сүзенә кардәш булуы ихтимал. Сарык, куй бәрәннәре гадәттә яшеренебрәк яталар. К. ш. ук **Коралай, Куран, Ташкуран.**

Рус. *курган, хурган* «кузый» тур. Аникин: 325, 326, 627–628 (шунда ук әдәбият).

Төрки *қозу → қозуғанақ* «кузый» сүзенә, безнеңчә, рус. *ко́зон, козан, козанак, козунак, козень, козён, ко́зна, козлак* «кузна, ашык» сүзе тоташа. В.А. Меркулова (Заметки по истории и этимологии слов // Этимология 1968. М., 1971: 81–83) бу сүзләрне төп рус *звено, позвонок* сүзләре белән чагыштыра. Тик монда фактларны «колагыннан тартып китерү» күренеп тора. К. **Күз: күзе ярыган.**

Дерив.: **кузыла-у** «бәрәнләү»; бор. төрки (ДТС: 462) *qozï julduzï* – бөреҗ йолдызлыкларының берсе. К. **Кузгалак.**

**КУЗЫЙ КҮРПӘЧ (Күрпәц), Кузый Күрпә** – герой одноимённого эпоса кыпчакских и южносибирских тюркских народов ~ башк. *Кузы Күрпәс,* каз. *Козы Көрпеш, Козы Көрпе* һ.б., безнеңчә, беренче сүз **Кузый** «бәрән» сүзе белән бердәй, икенче сүз исә алт. *Кӧрбӧс < Кӧрмӧс* < ир. *Хормуста, Хормуз* < бор. ир. *Аһура Мазда* (*Аһура* ~ һинд. *Асура* «игелекле») «игелекле алиһә» сүзеннән (бу сүзнең вариантлары Көньяк Себер телләрендә киң таралган һәм җирле фольклорда еш очрый). Безнең бу фаразыбыз түбәндәгечә нигезләнә: **Кузый-Күрпә (күрпәч)** дигәндә бу синоним сүзләрдән гыйбарәт парлы сүз, стилистик җәһәттән иркәләү-кечерәйтү сүзе һәм эсәрнең эчтәлегенә ярашмый. Һәм монда Кузый Күрмәз – Кузый рәвешенә кереп йөрүче **Хормузд <** Аһура Мазда тур. сүз барган булган. Хикмәт шунда: борынгыдан килгән мифологема буенча, Аһура Мазда дөньяга зәгыйфь бәрән, чирләшкә, маңка малай булып туып, кешеләрнең күңел-вөҗданнарын сынарга мөмкин. Әлеге дастанда бер тапкыр (ярәшелгән кызы Баян сылуга күренер өчен) герой *алтын баеркалы кузый*га әверелә, ягъни асылда ул кузый булып туган Аһура Мазда. К. ш. ук **Айзар-Байзар, Күрүмәз.**

**КУЗЫР** (Радлов II: 1019) «козырь, сильная масть в данном туре игры», диал. (к. җыр атамасы *Кузырлыкай чана,* к. Тарихи һәм лирик җырлар. Казан, 1988: 222) «верх, козырёк экипажа, саней» ~ рус. *козырь* (Фасмер II: 279) «төсе көчле кәрт атамасы; бастырмалы яка; тышкы ишек өстендәге япма, кыекчык, көймәле чана, чана көймәсе» (шуннан рус. *козырёк* «баш киемендә күләгәлек»). Рус. һәм тат. сүзләренең этимологик бердәйлеге шиксез, ләкин тат. сүзе русчадан дип әйтеп буламы? К. башк. (БҺҺ I: 137; БҺҺ II: 147) *кузыр, куҙыр* «керосин лампасының куыгы утыртыла торган рәшәткә; бизәк», (Миржанова 1981: 230) «әкәм-төкәм яисә тәкә мөгезе шикелле бизәк», (БТДҺ: 157) «бидәр, бизәк», «эре кеше» – нәкъ шул мәгънәләр **куза** (к.) сүзендә дә бар; к. ш. ук төр. *koz*, гаг. *қооз* «кузыр (кәрт); әкәм-төкәм кабырчыгы» (күрәсең, шуннан «экипаж көймәсе» мәгъ. килеп чыккан).

Шулай итеп, рус. *козырь* төрки телләрдән булып чыга, тик бу сүзнең ясалышы ачык түгел: **kōз йәр* «ышык җир» булуы ихтимал (**кузыр кәрт** «ышыклык бирә торган масть»!). Әмма хәзергә кәрт уенындагы **кузыр** барча сүзлекләрдә русчадан дип күрсәтелә. К. **Күзер.** Чаг. **Кузалак.**

Дерив.: **кузырлы, кузырсыз; кузырла-у** (мәс., арбаны).

**КУЙ (куй сарык),** себ. (к. Рамазанова 2001: 87 – *куйын тирчәге ~ тиресе* сүзендә) **куйын** «курдючная овца; овца (вообще)» < гом. кыпч. *қой*, хак. *хой*, төр., гаг. *койун*, аз., төркм. *ғойун* < бор. төрки (ДТС: 452–455) *qoj, qojun, qojïn, qon* ~ бор. монг. *xonin*, тунг. (уд. һ.б., к. ССТМЯ I: 410) *хуани* ~ самод. телләрендә (Räsänen 1969: 279) *koj, konnir* id. К. Новикова (1984: 190–196) буенча, архетип *kuvanin*, к. чжуан. (Көньяк Кытай) *huoni* «куй, сарык». Шулай итеп, **куй** < *қой* сүзе бөтен Көнч. һәм Үзәк Азиядә таралган, төрки телләрдә иң бор. сүзләрнең берсе. К. ш. ук Будагов II: 97 (әйбәт аңлатылган); Номинханов 1975: 206; ЭСТЯ VI: 24–26.

Дерив.: **куйчы, куйчылык; куй елы** төрки мөҗәлдә сигезенче ел, ир-ат өчен бәхетсез, хатын-кыз өчен бәхетле ел исәпләнә.

**КУЙГАШ** (Тумашева 1992: 132) «средняя сестра мужа» < себ. (ЗДС: 420, 422) **қуағач, қуwас** «красавица, красавец» (особенно при обращении невестки к младшим братьям и сёстрам мужа) < *қуағач* (**-гач** – иркәләү кушымчасы, чаг. *кайнигәч* һ.б.) ← *қуа* < кыт. *хуа* «чәчәк; гүзәл, чибәр кыз». К. **Тәбәнә куга.** Чаг. урта диалектта *матур (чибәр) җиңги (апа)* «уртанчы җиңги (апа һ.б.ш.)». К. **Койгаш.**

**КУЙМУ** (Тумашева 1992: 132) «радость; приподнятое настроение» (особенно – «желание предаваться плотским утехам») ← кыт. *хуу* «шатлык, шат кәеф»?

Дерив.: (брб., ЗДС: 408) **коймылу < куймылыг** «шат һәм масайган», **коймыр-у, куймыр-у** «шатлану; күндерү, аздыру». Чаг. ком. *куймур* «кыланчык кыз».

**КУЙТЫР** «овчина», гадәттә *қой тәри > куй тире* сүзеннән диләр, к. Будагов II: 97.

**КУЙ-У** «ставить, поставить; оставить» < гом. кыпч. *қой-* (к. Радлов II: 501) < бор. төрки (Боровков 1963: 210; ДТС: 451–461) *qoj- < qoδ-, qod-, qot-* id. > чув. *хор-, хур-* id. *Қун- < қон-* сүзе белән чагыштырыла (к. **Кун-у**), ягъни бор. * *қо-* тамырыннан (**ко-р-* һәм **қо-н-* шул фигыльнең төрле юн.). Будагов II: 99; ЭСТЯ VI: 27–28.

Кайбер сүзлекләрдә *куй-* «урнаштыру» һәм *куй-* «калдыру» (ш. ук «җирләү, кабергә күмү») ике аерым сүз итеп бирелә.

Дерив.: **куел-у, куеш-у, куйдыру; куй** (ымлык мәгъ.).

**КУК, кукы** диал. «гордый, важный, спесивый» → себ. **күке-ү, қуқы-у** «возгордиться» (к. ДС I: 120, Тумашева 1992: 107) ~ каз., к.-калп. *қоқи-* id. күп телләрдә очрый торган *қоқ* «әтәч» сүзеннән булса кирәк, к. кар. *қогут*, гаг. *қоқош*, рус. *ко́кош,* укр. *кокош*, фин. *kukko,* ит. *cocco*, фр. *coq*, инг. *cock* «әтәч; кук, кәттә, беренчелек, беренчелек дәгъвасында булучы». К. **Кукыр.**

**КУКАМАЙ** «Баба-Яга» ~ удм. *гугама*, удм. диал. (бисермән) *кукамай* id., чаг. чув. *кукамай*, мар. *кугу амай* «дәү әни» – «әби, түти» (к. КЭСК: 81). Чув. сүзе мари теленнән булса, аны *кӑк амай* «тамыр анай» дип аңлатуның кирәге юк. Тат., мар. **кукамай** ниндидер гыйбарәдән эллипсис, к. тат. (ЗДС: 335, 423) *кукамай сакчысы* «ямьсез кеше», *қуқмай* «мәзәкче». Чаг. ш. ук тув. **қоңгувай, қоңгумай* ~ монг. *хохимой* «чам мистериясендә бер персонаж». Федотов I: 302 (чув. *кукамай кук < кӧк* «тамыр; нәсел» сүзеннән ди).

**КУКША [кукша** (*қ* түгел)**]** миш. (ТТДС I: 255) «плешивый, лысый» < чув. *кукша < кокша* ~ мар. *кокша ~ какша* id. гом. төрки *кашка* сүзеннән метатеза булса кирәк. К. Федотов I: 304 (тәфсилле аңлатма бирелә).

**КУКЫ I** (ТТДС I: 598) «свербига», (ЗДС: 335, 423) **кукы, қуқы** «кычыткан» ~ чув. *кука* «куга, җикән», тат. диал. (ТТДС I: 208–209) **кука җиләге** «аю баланы, карга миләше».

**КУКЫ II** (ЗДС: 319), **кокы** «кукушка» – миш. сөйләшләрендә һәм күрше фин-угор халыкларында киң таралган вариантлар (к. **Кәккүк**). Шулар нигезендә бик күп үсемлек атамалары ясалган һәм **Кукы I,** ихтимал, шуларның берседер, к. удм. *кукы* «кәккүк, күке», *кукы ката* «кәккүк катасы» – рус. «венерин башмачок», *кукыгумы* «күкебаш» һ.б.

**КУКЫЛ, күкел** диал. (ТТДС I: 255–256, 280) «пирог, пирожок; род пельменя – пирог, который варят в котле (а не пекут)» ~ чув. *кукӑл, куккӑль, кукли*, мар. *когыль, кагыль, когыльо*, удм. *когыли* id. Т.Н. Тепляшина (О происхождении марийского слова *когыльо* «пирог» // Вопросы марийского языкознания, III, Йошкар-Ола, 1973: 56–58) бу сүзне перм. (удм., коми) *кока нянь* яисә *кок ли* «суда пешерелгән келиндер» сүзеннән чыгара. Тат. сүзе үзе удмуртчадан түгел, ә мари яисә чувашчадан булса кирәк. Һәрхәлдә бу сүз фин-угор телләреннән булырга тиеш, к. эстон. *күел,* лив. *кукил, куккил* «кечкенә ипи». Әмма, чаг. ш. ук рус. *кугель, гу́гель* «еврейское изделие из теста» (Фасмер II: 398), аз. *гөгәл* «кабартма» һ.б.

**КУКЫЛДЫК, күкелдек** (ТТДС II: 180, 204) «нечто дорогое» – **күкердәк* «ими, күкрәк» сүзеннән булса кирәк, к. кас. тат. **күкелдәш** ~ үзб. *кукилдош* «сөттәш (бер имине имгән) кардәш», ягъни бер дая имезеп үстергән кешеләрнең берсе. К. **Күкрәк.**

**КУКЫР** «хвастун; хвастливый» ~ үзб. (ЎХШЛ: 163) *қоқыр, қӯкир* id. бу сүзнең дериваты **кукы-**

**рай-** < гом. кыпч. *қоқырай-, қоқурай-* киңрәк таралган. Тамыры – **кук** (к.). Чаг. төр. *kokodoz* «нахал мактанчык».

**КУЛ I** «рука» < гом. төрки *қол* id., хак., тув., як. *хол* «кул; атның алгы аягы», чув. *хул* «кулның беләзектән иңбашка кадәрге өлеше», бор. монг. *kol* «алгы аяк» (Поппе 1938: 292), хәз. монг. *көл*, бур. *хүл* «тәпи» (хәер бу сүз бүтән тамырдан да булырга мөмкин). *Қол* сүзе кайбер төрки телләрдә пассив лексик фондка карый, «кул» мәгъ. угыз телләрендә башлыча *әл, эл,* чув. *ал* кулланыла. Будагов II: 86–88; Räsänen 1969: 217.

*Кул*га тамырдаш бор. сүзләр сирәк (юк), әмма яңа заманда бу нигездән күп кенә сүзләр ясалган, к. **Колач, Кулак, Куллан-у, Кулса**. ЭСТЯ VI: 37–43.

**Кул куй-у** тәгъбире сәвәтсез заманнарда документка, истәлеккә, хатка һ.б. карага буяп кул, бармак эзе калдырудан, чаг. хак. *хол пас-* «кул басу» – «кул кую».

Дерив.: **куллы, кулсыз; кулдаш;** кушма сүзләргә: **Кулалмаш, Кулбаш, Кулкап** (к.) һ.б., к. Рамазанова, 2013: 106–112 (**кул** сүзенең дериватлары өч таблицада бирелә).

**КУЛ II** «неширокая долина (без значительной реки)» < гом. төрки *қол, қōл (коол)*, төркм. *ғоол*, тув., монг. *ҳол* id., (ә *гол* «кул (әгъза)»); **кул I** һәм **кул II** һичшиксез тамырдан икесе ике сүз, **қоол** «үзән» тән әгъзасы исеменнән түгел (Мухамедова 1973: 116), М. Бабур тән әгъзасы – кулны *қол,* дип, ә хәрби колонна – кулны *ғол* дип аерып язган (к. Будагов II: 86–88), к. монг. *гол* < бор. монг. *γool, γoul* «үзән, үзәк, урта, күчәр; колонна» (чаг. тат. *Сул кул урар, уң кул турар, урта кул ук атар*, мәкаль); «гаскәрнең төп өлеше» мәгъ. бу сүз фар. теленә дә кергән (Doerfer I: 438–440). К. ш. ук маньч. *голо* «үзәк, сүрек, асыл, аеш, үзән, төп юл, ике елга арасы» ~ кор. *qol* «үзән» (ССТМЯ I: 160). К. **Кулат.**

Гомумән, бу *кул < кол < қоол* тур. әдәбият ишле, к. Константинова 1969 һ.б.

Рус. *средней руки* тәгъбире татарчадан калька булса кирәк: төрки-монгол хәрби тактикасында гаскәр өч кулга бүленгән, *урта кулга* картрак сугышчылар куелган (бу кул оборона тоткан), шуннан *урта кул* «бик ук әйбәт тә, начар да түгел» гыйбарәсе килә; руслар *кул* «колонна» сүзен *кул* «рука» дип аңлаганнар. ЭСТЯ VI: 43–46; Федотов II: 353 (**Кул I** һәм **кул II** сүзләрен бер дип карый); Гарипова 1998: 126–127 (шулай ук **кул I** һәм **кул II** сүзләрен бердәй дип бара.

**КУЛА** (Будагов II: 8) «зелёная медь», (ДС II: 113; ТТДС I: 256) «сорт сплава меди; вообще сплав» (к. фольк. *Әтекәй, абзарың – каладыр, Өйнең кырыйлчасы куладыр, Кула да гына түгел, көмеш булсын, Барысы да бездин каладыр;* Әлвидаг җыры), миш. «плоскодонный котёл» (безнең язмалардан. – *Р.Ә.*) < гом. төрки *қола* id., к. башк. (БҺҺ II: 143) *қула, қŏла* «калай казан», уйг. *қула* «каракургаш», нуг. *қола* «аккургаш», к.-калп. *қола* «точ, бронза», алт. *қоло* «кула казан», кырг., алт., тув. һ.б. *қола, қоло* «җиз», алт. диал. *куулы*, төркм. (Мухамедова 1973: 83) *ғола, ғоола* «яшел бакыр; металл эретмә» ~ монг. *гууль* < иске монг. *γooli, γaulin* < тибет. *гӯлиң* «бакырлы эретмә». К. Радлов II: 585; Joki 1952: 188; Тенишев 1976: 200; ССТМЯ I: 159. Чаг. ш. ук төркм. (ТДГДС: 114) *қола* «метис»; ЭСТЯ VI: 46.

Матур әдәбиятта *кула* сүзен **калай** белән бутап аңлату очрый. Бу сүзләрне гомоген дип уйларга нигез юк.

**КУЛАВЫЗ [қулаwы̆з], кылавыз, колавыз** «проводник; учитель, наставник», иске тат., төр. (Будагов II: 61) **кылагуз** «вожатый; лоцман, фланкер, часовой» ~ чыгт. (Нәваида) *qolauz* «каравылчы; башак косу», бор. ядкәрләрдә (ДТС: 464–465) *kolaγuz, kolabuz, kolavuz*, госм. *қулағуз* «кулавыз, белешмәлек; яучы, димче»; бу сүзнең (*-z* вариантында) иң тәүге теркәлеше (Clauson 1972: 617–618) Ибне Фазланда – *kulāwız* «юламан», хәз. төр. *kılavuz* «инструкция, белешмәлек» > венг. *kalauz* «вагон һ.б. озатучы»; бор. *-r* варианты да билгеле: бор. болг. *qolovp, kolovur*, грек. язылышта *χολόβρος* «кулавыз; Дунай Болгар дәүләтендә югары чин», аварларда *bo-kolabur* (582 елда теркәлгән) «рухани башлык; баш рухани» (Pritsak 1955: 46; Räsänen 1969: 277; Donuk: 29). Чаг. як. *холобур* «үрнәк» ~ эвенк. *коловур* «үрнәк, өлге» (ССТМЯ I: 408).

Бу бик бор. (иң тәүләп теркәлгән төрки) сүзләрнең берсе һәм бу кызыклы сүзнең этимологиясе табышмаклы. Ә. Нәваидагы кулланышка караганда, бор. **колагур* – «юлчылар өчен аулак җирләрдә салынган һәм түбәсеннән озын колга чыгып торган торак» булмадымы икән? Әйтмәкче, гарәпләрдә шундый бер торак *кулайс* дип аталган (Нәһҗел-фәрадис. Казан, 2002: 51). Гомумән, бу сүз Шәрык телләрендә киң таралган, к. көрд. *qelawiz*, «тәнсакчы, кучты», *qilawız* «кулавыз» һ.б.

Рясянен (Räsänen 1969: 277) бу сүз – госм. *qol aγası* («*кул* – гаскәр бүлеге – *агасы*») дигән фикерне китерә, ләкин бор. язылышлар моны расламый. Чаг. бор. төрки (ДТС: 454–455) *qol-* «сорау, сораштыру; теләү». К. **Калавыз, Колавыз, Колыш.**

**КУЛАГАЙ** «взяточник» < иске монг. *xulaγaj* «карак, караклык» > хәз. монг. *хулгай* id., монг. диал. *кулакай* id., яз. монг. *xulaγu-* «урлау, караклык итү» > тунг. *хулаха-* id., чжуан. *hu-lâh-hâi* «юлбасар» һ.б. ССТМЯ I: 476.

**Кулагай** сүзе төрки телләрдән тат.-башк. даирәсендә генә очрый. «Ришвәтче» мәгънәсе *кул* сүзе тәэсирендә барлыкка килгән.

**КУЛАЗАК, куладан** диал. (ДС II: 113) «телега, которую при необходимости можно повалить для разгрузки» (аудара торган арба) **кузалак** (к.) сүзеннән метатеза.

**КУЛАЙ,** диал. **қулайлы** «удобно; удобный, подходящий» ~ башк. *ҡулайлы* id. < гом. төрки *қолай* (Себер төркиләрендә сирәк очрый) id., күрше телләргә дә кергән (манси. *қӧлай* «кызыктыргыч; җиңел» һ.б. к. Räsänen 1969: 277). Аерым мәгънәләр: нуг., каз. *қолай* «әхвәл, хәл», гос., к.-балк. *қолай* «яхшырак; җитешлек; мөлаем», аерым формалар: каз. *қолапай*, каз. диал. *қолағай*. Сүзнең этимологиясе бәхәсле: берәүләр (Рамстедт һ.б.) *кол ай, колу ай* «кулы яхшы» сүзеннән диләр, икенчеләр *кол (кул) айы* «кул асты» (*ай* «ас»), яисә *кул уңай-ы* (< *кол оңай-у*) сүзеннән диләр, чаг. тат. *кул* «кулай» (к. ТТАС II: 187). Иске кыпч. *қоолай* < чыгт. *хоһлаӣу* «теләп» (фар. *хоһ* «теләк, мәел») сүзеннән дә булуы мөмкин, к. үзб. *хоһла-* «теләү; ярату». Будагов II: 91; ЭСТЯ VI: 46–47 (төп этимологик фикер – *кул* < *кол* сүзеннән).

Дерив.: **кулайлы** (!); **кулайлык; кулайлан-у, кулайлаш-у.**

**КУЛАК [кулак]** «богатый крестьянин, держащий наёмных работников; кулак» < рус., төп мәгънәсе «йодрык», әмма рус сүзе үзе төрки телләрдән. Ләкин төрки телләрдә бу сүзнең канәгатьләндерерлек архетибы табылмый. Безнеңчә, *кулак* < бор. тат. (*ō* > *у*) *қоллақ, қуллақ* «кул белән эш итүче», *кулла-* нигезеннән, к. үзб. *ҡўлла-*, чыгт. *қолла-* «кул белән эш итү; култыклау», ком. *қолла-* «куллану», к.-балк. *қолла-* «үзләштерү», кр.-тат. *қолла-* «җаен эзләү, җаен табу» – шуннан **қоллак* «кулына эләктергеч, йомдыргыч»? Дальдә рус. *кулобой* «сугышкак, сугышырга яратучы; кул күтәрергә яратучы унтер-офицер». Будагов II: 87–88.

**КУЛАН,** диал. (себ.) **қулақ,** (ЗДС: 410) **қолақ** «киндерә – оборки верёвки лаптей», шуннан *чабата колагы ~ колаксасы* «чабатаның киндерә үткәрү өчен ясалган ян тишекләре», ш. ук «ияр бавы» ~ кр.-тат. (Dobr. II: 326) *qulan, qolaŋ,* куман., төр. *kolaŋ* «бик киң ияр тасмасы (корсактан уратып үткәрелә)», төр. *kolan* «һәртөрле ныклы киң каеш, шкив; ат менү дирбиясендәге махсус киң каеш; атына торган таган каешы, бигрәк тә аның утыргычы», күчмән кабиләләрдә – «тирмәне астан-өстән тотып тора торган киң тасма», алт. *қолоң,* шор. *qolaγ, xolaγ, холлаг,* койбал. *қоллаг, қоллақ,* як. *холун* «ияр каешы», Рясянен буенча, монг. *qolaŋ, olaŋ* «ияр каешы (шуның бер төре)» ~ кор. *koraŋ* «каеш богау» сүзләре белән тамырдаш. Алай булса бу бик бор. сүз булып чыга һәм бераз гаҗәбрәк тә.

Räsänen 1969: 227 (тагын кайбер мисаллар китерә; аның себ. тат. сөйләшләреннән алган сүзләре хәз. безнең диал. сүзлекләрдә юк). Хәер, бу сүз хәз. һәр җирдә сирәк очрый бугай (ул **колан** белән тәбендә бердәй булыра, ә коланнарның бор. төре зебра шикелле «каешлы» булганлыгы билгеле).

**КУЛАНАЙ** иск. (Җ. Вәлиди) «вид обложения, налог с нерусских народов Среднего Поволжья» ~ чув., мар. *кknown* id. Элекке этнографик әдәбиятта рус. *головной, поголовный* сүзеннән дип аңлатылып килгән. Ләкин соңрак **кулыш-култка** (к.) белән баглап аңлатыла башлады. Җентекләп тикшерүгә мохтаҗ сүз.

**КУЛАТ: кул-кулат** (ЗДС: 425, **кулкулат** дип язылган) «сильно овражистая местность, буераки-овраги» ~ башк. *ҡул-ҡулат, ҡул-ҡылап* (дөрес язылмаган бугай) id. Беренче компонент *кул* тур. к. **Кул II. Кулат** – киң таралган алтаистик сүзләрнең берсе, к. башк. (БҺҺ II: 147) *ҡулат* «тирән һәм тар үзән», кырг. *қолот* «озын үзәнлек, буйрак», як. *колағай, курологай, холлогой* «озын һәм текә ярлаулы тар үзән», маньч. (ССТМЯ I: 406) *қолоү, холо* «тигез тар үзән; колаша». **Кул II** белән тамырдаш булса кирәк: бор. **қолат, *қолут – қол* «кул (тар тирән үзән)» сүзенең монг. күп. формасы. Гомумән, бу сүзнең охшашлары тунг.-маньч. телләрендә күп.

**КУЛАТА** диал. «сани со сплошным дном (доска, употребляемая как сани)» < рус. *колода* id. Чаг.

ш. ук диал. **кулатка** «аякчу күтәртмәсе» < рус. *колодка* id.

**КУЛАТЫ, кулады, колаты** (Тумашева 1992: 127) «вид коршуна», (ЗДС: 411) «разновидность орла, беркута» ~ чув. *хăлат,* (Сергеев 1968: 79) *хăлатă*, *хăлаш* «козгын», каз. (ҚТДС: 212) *қуладын, қōладын жапалак* «мүктәргедән зуррак ябалак шикелле кош», кырг. *қулаады, қулаалы* «сарыча; козгын», шор. *қулады* «карчыга» һ.б. < бор. монг. *quladu* «саз карчыгасы». Räsänen 1969: 298; Федотов I: 321–322. Бу бик бор. сүз булса кирәк, к. венг. *holló* «козгын». Башк. кавеме **колаты** атамасы да шул кош исеменнән бугай (һәр кавемнең *кошы,*ораны, тамгасы булган).

**КУЛГА** себ. (Будагов II: 91) «озимь, озимые» ~ бор. төрки (ДТС: 454–455) *qolŋa, qoluŋa* «үрген, бәбәк» (дөге үрентесе булса кирәк). Чаг. **Кулка II.**

**КУЛГУНА** себ. (Будагов II: 63) «проказа», «беда, несчастье» ~ каз. (ҚТДС: 221) *қулғана, қылқуна,* хәз. каз. *қулғана* «яман шеш», *қылғыма* «тамак авыруы, кылтамак (авыру ашый алмый)». Бу авыруны *қылгу нә* «нишләмәк кирәк?» дип аңлатканнар.

**КУЛГУР, көлгер** (Тумашева 1992: 101, 133) «хитрец, плут», «козни, кривда, ложь» ~ алт. *қулғыр, қулуғыр*, тув. *кулугур* id., ш. ук «каһәр суккыры». Чаг. бор. төрки (ДТС: 454) *qolγuči* «хәерче», *qol qolγur* «сорану, теләнү». Будагов II: 91.

**КУЛКА I** «главная артерия от лёгких к сердцу» ~ каз. *қолқа, қулқа,* алт., шор. *қолқа, қолға* id. Иске тат. (Будагов I: 91) *қулқа-бawыр* «үпкә-бавыр». Räsänen 1969: 278.

**КУЛКА II, қулқы** себ. (ЗДС: 336–337, 424–425) «небольшой лес, густой кустарник», «высокие камыши», **кулка** (миш.) «поляна, поросшая высокой травой и молодыми деревьями», **қулға** (себ.) «лесок в поляне» ~ тув. *кулузун,* як. *қулусун* < яз. монг. *xulusu(n),* хәз. бур. *хулһа(н)* ~ бор. төрки (ДТС: 471) *qušγun* «терлек ашый торган камыш төре; рәваҗ». Монг. телләреннән рус. (Аникин: 319–320) *колусун, кулусун* «камыш төре» һ.б. (Аникин бик күп әдәбият күрсәтә, рус. *колок* «кечкенә урман» сүзен искә алмый). Чаг. **Кулга.**

**КУЛЛАГАЧ** «крест, икона на поле» < **куллы агач.** Элек рус авылларында басу капкасы янында матурлап (еш кына өсте ябулы) тәреләр куела торган булган.

**КУЛЛАМА** «салма из лошадиного мяса» – кул белән ашалганга күрә шулай әйтелгән, диләр (Радлов II: 985).

**КУЛЛАН-У** «применять; употреблять» > нуг., кар., төр., гаг. *kullan-* id. < гом. кыпч. *қоллан-*, уйг. *қоллун-*, кырг. *қолдон-*, каз. *қолдан-* id. ← уйг. *қолла-, қолли-*, кырг. *қолдо-,* каз. *қолда-* «яклау, куәтләү», к.-калп. *қолла-* «химаяче булу», тув. *қолда-* «баш булу»; к. як. *холлоох* «уңган, эшчән; кулланышлы». **Кул II** сүзеннән булса кирәк. К. **Кулак.**

**КУЛПЫ** диал. (әстр., без теркәдек. – *Р.Ә.*) «колпик (вид птицы, обычно неподвижно стоящей на длинных ногах в мелкой воде и качающейся в лад с камышами, когда дует ветер)». Чаг. карагаш. (Арсланов 1992: 130) *кōлпы,* каз. *қулпы* «кабер өстенә куелган (фигуралы) таш», башк. *қолпа таш* «кабер өстендәге стела» (**қолпа** үзе «авторитет» диелә).

Рус. *колпик* сүзен төрки телләрдән димиләр (к. Фасмер II: 207), ләкин ул сүзнең ышандырырлык этимологиясе дә юк.

**КУЛТЫК** «подмышка; залив» < нуг., каз., к.-калп. *қолтық,* хак. *холтых*, гом. төрки *қолтуқ* бор. төрки (ДТС: 454) *qoltıq, qoltuq* id. (Радлов II: 987) < бор. **коңул-тук, қоңул-туғ,* к. удм. *куңул, кунул* «култык» (бор. төрки телләрдән), к. камас. *kuŋgyl*, тув. *qoŋγul*, алт. *куңкул*, кырг. *қоңул* «уелып кергән бушлык, куышлык; өңгел, өңгер» (Joki 1952: 211) ~ яз. монг. *xongxiγur* ← *xongxui-* (хәз. монг. *хонхой-*) «уелып керү, уем» ← бор. **xong* ~ маньч. *kōŋa* «куыш» (ССТМЯ I: 411). *Култук* < *қолтуқ* сүзе географик мәгъ. күп күрше телләргә (фар., гар. һ.б.) кергән, к. Гарипова 1998: 127–128.

Рус. *култук* «елга-күл култыгы» тур. к. Аникин: 318. К. ш. ук Мурзаев 1984: 312–313; Räsänen 1969: 351 һ.б. *Култык* < *кулны тык* дип аңлату – мәзәк дәрәҗәсендә.

**КУЛТЫР** (Тумашева 1992: 133) «пустословхитрец» ~ алт. (Будагов II: 91) *қултур* id., каз. (ҚТДС: 213) *қултуғыр* «ялкау», *қултырaң* «хәйлә», як. *култугур* «бик кыска борынлы» ← *қултой-* «кыска һәм тупа булу», башк. (БТДҺ: 204) *қултый* «чулак», эвенк. (ССТМЯ I: 429) *култумак, култумат* «мүкләк». К. ш. ук хак. *холтырых* «кештәк»,

мар. (Саваткова: 181–182) *холдыр, холдымак* «буш сүз, ялган хәбәр» (татарчадан булса кирәк, к. Рорре 1927:165). К. түбәндәгене.

**КУЛТЫРАК** (ТТДС I: 256) «нездоровая рука, культя; однорукий». К. югарыдагыны, ш. ук. рус. (төрки телләрдән булса кирәк) *культя, культяк, культяпка* «кисек кул». К. **Култырмач**.

**КУЛТЫРМАЧ** «украшение к платью в виде погона; оборка в начале рукавов» > удм. *колтырмач*, чув. *хултăрма, хултăрмач* id. < чыгт. *колтурмач,* аз. *қолтурмаҗ* «киелми торган озын җиң (еш кына аркага кайтарыла һәм ике шундый җиң очы бергә беркетелә)» ← *қолтур* «култыр», к. ш. ук кырг. *қолтурмач* «балалар йөртү өчен кулланыла торган иярдәге як-як тоткалар, кечкенә бәләсәләр».

Күрәсең *қолтур ~ қолту* тамыр сүзе бик борынгы. Аның чыгышын-ясалышын төгәл билгеләү дә кыен. К. ЭСТЯ VI: 41, 43.

**КУЛУГУР** диал. (миш.), себ. (ЗДС: 424) **қулгур,** «неразговорчивый человек; грубиян» к. **Кулгур.**

**КУЛУНЧАК** (себ.) «колонок, зверёк с красивым телосложением и окраской» ~ сагай. *қулунағач, қулуноқ, қулунғач* «коланык» *колон ~ солон* нигезеннән. К. **Коланык.**

**Кулунчак** ~ *колынчак*ларның гәүдәләрендә тигез аралыклы буй-буй «тасмалар» була, шуңа охшатып булса кирәк, артык озын туку кылычын (мәс., тастымал тукыганда) кыскарту өчен аңа параллель бәйләнгән тасмачыкларны **колынчак** дип атыйлар. К. ЗДС: 411.

**КУЛЫШ-КУЛТКА** «вид налога, побора в Казанском ханстве» – бор. *qol-* «сорау, үтенү» һәм *qolt-* «сорату» (ДТС: 454) сүзләреннән ясалмалар, к. кар. *колтка* «сорау, үтенү; ялвару». *Қол-* «сорау, үтенү, ялвару» тур. ЭСТЯ VI: 36–37. К. **Кола-у.**

**КУМ** диал. «толстый подседельник из кошмы» ~ башк. *қум* id., каз., кырг., уйг., алт. *қом,* тув., бур. *хом* «дөя ияре», Будагов (II: 92) каз. *қум, қом* «нагорбник, свернутый из кошмы для двугорбого верблюда» (ничек, нинди икәнлеген белмибез). Räsänen 1969: 278. К. түбәндәгене.

**КУМАК** диал. «узелок; горсть» < рус. *комóк* (? к. ТТДС I: 256). Чаг. ш. ук башк. *қум* < гом. төрки, монг. *қом* «ияр астына салына торган киез», шуннан *қомақ* «ияргә тагылган төенчек».

**КУМНА, кулма, кулмыт, кумыт** (ЗДС: 337) «комната; квартира в многоэтажном доме» – русча *комната* сүзен *кумна-да* дип аңлаудан килеп чыккан сүз. Бу сүз 1930 нчы елларда күп «кара халык» шәһәрләргә күченә башлагач пәйда булган.

Рус. *комната* ахыр чиктә лат. теленнән. К. Фасмер II: 204.

**КУМТА, кумты** «шкатулка; ящик, коробка» (ДС I: 98; ТТДС I: 209–210), **кунта** id. (Тумашева 1992: 134) ~ чув. *кунтă*, морд. *кундо,* мар. *комдо, комды* ~ тув. *қомду* «кумта, кәрзин», алт. диал. *коомди, коомдо*, хак. диал. *қомда* «әрҗә; табут» ~ каз. *қобди* «чемодан», монг. *кобда, кобду* «теркеш, калчан» ~ коми. *конте*, фин. *kontti* «туз әрҗә»; к. ш. ук тунг. *коптаган, кумтан* (һ.б.) «капкачлы кәрзин; капкач» (ССТМЯ I: 409). К. Егоров 1964: 118; Räsänen 1969: 279.

Бу бик бор. Урал-Алтай сүзе. Шундый сүзләрдән к. ш. ук **Күбәк.** Räsänen 1969: 279; Федотов I: 308.

**КУМЫШКА** «самогон» ~ чув. *кумăшка*, удм. *кумышка, кумыска,* мар. *кумышка, комышка, кумыш, комыш* «әче бал», рус. *кумысика, кумыска* сүзеннән, *кумыс* «кымыз» нигезеннән; к. ш. ук тат. диал. **көмешкә** id. < *комышка* < *кумышка*. К. Аникин: 323. Чаг. ш. ук чув. *кăмăска* «әчегән, күпчегән; күгәрек».

**КУНА I (куна тактасы)** «кухонная доска», диал. (ДС I: 98–99) (**кунаяк**) «кухня», диал. «столик в саду» (*Бакчабызда биш куна, Очып килеп кош куна...,* җыр), «шкаф; этажерка» (Тумашева 1992: 133) ~ добр. тат. (Akb) *kona* «өстәл», кр.-тат. *қона* «зур түгәрәк өстәл», кар. *қона* «уша, эскәмья», тат. диал. (Астраханские татары. Казан, 1992: 69) *кумна, куна* «сандал (гадәт буенча җир идәндә утыра торган вакытта *куз* күмерле чокыр өстенә куелган тәбәнәк өстәл – елның суык чорында гаилә әгъзалары аякларын шул өстәл астына тыгып җылытып утыралар)» ~ осет. *қоңа* «кече учак». **Куна** сүзе үзенең төрле мәгънәләре белән ир. (к. ЭСИЯ 3: 491–493) *xvana* «аш өстәле һ.б.ш.» сүзенә бик охшаш, ләкин ул сүзнең тат. теленә каян кергәнлеге ачык түгел (фар. *хуан, хон* «аш куелган өстәл», ә *хуана* сүзе юк бугай).

**КУНА II** «молодая поросль вокруг пня; отава» (ДС I: 98; ТТДС I: 257) ~ чув. *хунав, кунав* (< тат.

*кунау?*), *хонав, хона, хоно* (к. Сергеев 1971: 142) id., *куна-, хуна-* «үрчү, үргү, курпылау» (хәзер сирәк очрый) фигыленнән.

Бу сүзнең тарихы катлаулы: тат. (т.я., мишәрләр белән чувашлар аралашып яшәгән җирләрдә) *куна* чув. теленнән, ә чув. сүзе үзе бор. татарчадан булса кирәк, к. мар. (к. Гордеев I: 107) *ана, хана* «куна, курпы, үсенте», *ана-, хана-* «курпылау» < болг. **һана-* < тат. **қана-* id., чаг. бор. төрки (Бабур телендә) *қан-* «күпләп, шәп үсү» (Радлов II: 107). Шулай итеп, *куна* < чув. *хуна* < *хона* < *хана* << бор. тат. **қанау* «курпылау, курпы» (чув. *хунав, хонав* вариантлары тат. теленнән алынмалык билгесенә ия), **қана-* «курпылау».

Бу **кана* фигылен монг. *кана//кэнэ, гана//гэнэ* «җиләк, чәчәк; үсемлек» (үсемлек атамалары ясалышында киң кулланыла) морфемасы белән чагыштырырга мөмкин.

**КУНАЙ** (ТТДС I: 209; БТДҺ: 204) «гордый; неразговорчивый» – ачык түгел. Ихтимал, фар. *гунаи* «үзенә бер төрле, үзенчәлекле» сүзеннәндер.

**КУНАК** «гость» (с рядом переносных значений, в т.ч. «оспа») ~ чув. *хăна [хŏна]* < болг. *һŏна, һуна* > мар. *уна, уно*, удм. *куно, кыно, къно, куна, кұна* (Насибуллин: 71) < гом. төрки *қонақ* «кунак, кунакханә; гаилә; куныш; тәүлек» ~ алт., кырг. *қоноқ* «кунак; кичке аш – *кун-у* сүзеннән. Будагов II: 93–94; ЭСТЯ VI: 56–57.

**Кунак** сүзе төрки теллардән барча (йөзгә якын) күрше телләргә (шул исәптән гар. теленә дә) кергән. Рус. *кунак* «кунак, дус» татарчадан (*о* > *у*), ә *конак* «кенәз йорты; кунакханә» төр. теленнән (Д. болг., серб телләре аша) килә (к. Фасмер II: 307, 417).

**КУНАКЛА-У** «осесть на ночь (о куриных)» – **кунак** сүзенең «куныш, куну урыны» мәгънәсеннән. К. **Кунача.**

**КУНАЛГЫ, куналка** тар. «обязанность содержать правительственных чиновников» (с XIII века), соңыннан «постоялый двор». Чаг. иске рус *постой* – «хөкүмәт әһелләренең төбәктә бушлай яшәү хокукы». Башкортстанда куналкалар хәзер дә (калалардан ерак авылларда) очрый. Чаг. **Сусун.** Velidi: 302. К. түбәндәгене.

**КУНА-У** диал. (Тумашева 1992: 134) «отдыхать (после тяжелого пути, труда); наслаждаться отдыхом» ~ каз. *қуна-* id., ш. ук «көчәю». Чаг. кырг. *қуна* «рәхәтлек». **Кун-у** белән тамырдаш булуы ихтимал. К. югарыдагыны.

**КУНАЧА** «насест» < диал. **кунакча** ← *кунак, куньк*, к. каз. к.-калп. *қонак* «кунача». Чаг. **Кунгак.**

**КУНГАК** «леток улья», **кун-у** сүзеннән тат. теленең үзендә ясалган.

**КУНДАК** (Тумашева 1992: 134 һ.б.) «ложе, постель; ложе ружья; приклад; люлька в виде корыта», иск. **қондақ** («Зая Түләк») «вид гуслей – музыкальный инструмент» < гом. кыпч. сүз, к. каз. *қундақ* «оя», к.-калп., кырг., төркм., госм. *қундақ, қумдақ,* ком. *қуннақ,* чыгт., үзб., уйг. *қондақ* «кундак; бәбиләр өчен тагараксыман ятак; биләүсә», аз. *ғондақ* «кундак; бәби» һ.б. фар. һәм көрд телләренә дә үтеп кергән. **Кундак** күчмә тормышка бик җайланган бишек: аңа бәбине өстән бәйләп салып теләсәң нинди торышта – вертикаль, авыш, горизонталь һ.б. – куеп торып була. Сүзнең тамыры бор. төрки *qoŋ- ~ qoj-* «кую» булса кирәк, к. **Куй-у, Кун-у.** Будагов II: 95; Ramstedt 1935: 197; Räsänen 1969: 279; ЭСТЯ VI: 144–146.

**КУНДЫР, кунтыр** (ЗДС: 428) «меховая манжета рукавов». Чаг. **Кондыз, Куйтыр.**

**КУН-У** «сесть с лёта (о птицах); оседать; провести ночь (по дальней дороге)» < гом. төрки *қон-* (тув. як. *хон-*) id. чыгт., госм., кр.-тат. *қо-* «кую; куеп китү» (> чув. *ху-, хыв-* «кую, салу») фигыленең кайт. юн., М. Рясянен буенча (Räsänen 1969: 273), **куй-у** сүзе белән тамырдаш. К. төр. *қон-* «әйберләреңне урнаштыру». Будагов II: 94–96; ЭСТЯ VI: 55–56.

**Кун-у** сүзеннән бик күп яңа нигезләр ясалган, к. **Кунак, Кунача,** ш. ук гом. төрки характердагы **Куньк, Куныш**, тат. теленең үзендә ясалган **кундыр-у** (сугу), **кунмалы** һ.б., диал. **куньлгы** «кырда төн уздыру урыны (олаучылар телендә)». **Куналгы** исә икенче сүз.

**КУНЦАК** себ. (ЗДС: 426) «ягнёнок (маленький)». Бу сүз тамырында *қуй* < **қон'* сүзенең бор. азагы сакланган, к. **Куй.** Бор. төрки **қончақ* «булган». Һәм, ихтимал, бор. куман-кыпчак ханы **Кончак** исеме «кунцак, куй бәрәне» мәгънәсендә бирелгән булгандыр. Хәер, монда бүтән фаразларга да урын кала.

**КУНЧЫК**, **кунцык** (Ф. Хөсни) «собачка; пёс, пёсик» ← бор. тат. (?) *кун* «эт» сүзеннән, бу сүз һинд-евр. **keuon, *kuon* «эт, бүре» сүзен хәтерләтә һәм тохар. (к. Kluge: 427) *ku, kun* «эт» сүзеннән килсә кирәк. Миш. сөйләшләрендә очрый торган бу сүз бүтән төрки телләрдә юк шикелле. Чаг. **Канчык.**

**КУНШЫ, куныш, куңчы** (ЗДС: 338, 426) «сосед» ~ бор. төрки (ДТС: 455) *qonšï*, төр. *komşu,* үзб. һ.б. *қўшни* id. **Күрше** сүзе белән бердәй түгел (аваз күчешләре үзгә). Ихтимал, бор. төрки *qonšï* «бодисатва исеме» белән тәңгәлдер: *Үзеңне яхшы дип белсәң, куншыңны фәрештә дип бел,* дигән мәкаль бар. Бор. төрки *qonšï, quanšï* (< кыт.) – фәрештәләрнең бер төре > кор. *конжу* «ханәкә, принцесса». Төрки сүз кор. теле аша алынган булса кирәк. Кыт. сүзе исә бор. һинд. *бодисатва* «игелек итү юлында кямиллеккә ирешкән фәрештә» сүзеннән тәрҗемә ителгән. К. МНМ I: 181.

Добруҗа сүзлегендә (Dobr. II: 330, 334) *komşı, koŋşı, konu-komsı, kom-qomşı* «konuwşı» – *кунучы* сүзеннән дип тәгърифләнә. Ләкин сүзнең **кончы** (*-ч-*) варианты юк һәм *-ŋ-, -т-* белән әйтелгән вариантлар да аңлатылмый. Мәгънә җәһәте дә аксый. Чаг. **Кушны.**

**КУНЫЧ,** диал. **куныц,** (ТТДС I: 210) **қунчы** «голенище», (ЗДС: 426) **қуныц** «болотные сапоги», **кунчы** «чулок» > удм. диал. *кунись,* удм. *кунчи,* чув. (Сергеев 1971: 81–82) *кунча, кунчӑ* < гом. кыпч., алт. *қоныч, қонч* (> башк. *қуныс, қуңыс, қуңғыс,* нуг., каз., к.-калп. *қоныш*, ком. *хонч*), уйг. *қонч, қонҗи, қонҗа,* гаг. *қонч,* төр. *konc*, төркм. *ғонч*, аз. *ғунчу*, тув. *хончу*, алт. диал. (Баскаков 1972: 224) *қоньди* һ.б. «куныч; чалбар балагының аскы әдебе». Мар. Т. (Саваткова: 60) *конзы, комзы* «куныч» чув. яисә болг. сөйләшләреннән. Федотов I: 308; ЭСТЯ VI: 57–58 (биредә күрсәтелмәгән бүтән күп кенә параллельләр китерелә, ләкин алар этимонны ачыкламыйлар; ниндидер төрки булмаган телдән алынма дигән фикер әйтелә).

Безнеңчә, сүзнең этимологиясен башк. *қуңғыс* < *қуңғыч* варианты ачыклый, к. себ. (Рамазанова 2001: 68 һ.б.) **ғуц, қуц** < *қуныц* «бияләй яки җиң беләзеге» – элекке лачынчыларда ау кошы (лачын, бөркет һ.б.) *қунғыч* < *конгуч* «килеп куна торган җайланма, урын, әсбап (ау кошының үткен тырнагыннан саклану өчен аеруча калын итеп эшләнгән беләзек)» булып чыга.

Дерив.: **кунычлы, кунычсыз; кунычла-у; кунычлык.**

**КУҢГЫЛДАК**, себ. (Тумашева 1992: 140) **қыңгылдак** «облезлый (о животных)» ~ башк. (БТДҺ: 204) *қуңалтай, қуңғылтақ, қуңқылтақ,* кырг. *қоңултақ,* каз. *қоңылтақ* «оексыз (киелә торган)», *қуңылты* «ялангач» → *қуңалты айақ* > *қуңалтайақ* ~ каз. *қоңылтайақ,* үзб. (ЎХШЛ: 163) *қоңғолтайақ* «ояксыз киелә торган». Бу сүзләрнең фигыль нигезе (башк.) **куна-у** < *куңга-у* «йоны коелу» булса кирәк. Чаг. **Калтакай.**

**КУҢГЫРА I** (к. Мухаметшин: 149) «выдолбленное из бревна корыто, колода (обычно с незакрытыми концами)», себ. (Будагов II: 86) **қоңарақ** «сковорода» ~ чув. *кункӑра* «куңгыра», удм. *кокора* id., мар. (Саваткова: 60, 62) *конгыла* «култык», *кӧнгыра* «ындырда кулланыла торган агач тарткы», чаг. ш. ук як. *коонкура* «асты ашалган, өңгерле боз; боз астындагы куышлык», калм. (Ramstedt 1935: 185–186) *хonuur, qonqurqai* «җир казып ясалган түгәрәк оя, хуҗалык чокыры (чүп өчен түгел)» >> рус. *конура* «эт оясы» (Г. Рамстедт фикере, рус этимологик сүзлекләрендә бу фикер яклану тапмый).

Ихтимал, **куңгыра** сүзе белән себ. (Тумашева 1992: 134) **куңгырала, куңгыралай** «хариус, бәрде балыгы» сүзе («су асты чокырларын яратучы балык»?) гомогендыр. Ш. ук себ. **куңырайыу** «яра төзәлү» («аның урынына чокыр калу?»). Гомумән, төрки-монг. телләрендә *куңгыр* < *коңгур* дигән омонимик нигезнең мәгънәләре төрле һәм бу хәл этимологияне читенләштерә. К. түбәндәгене.

**КУҢГЫРА II,** (Тумашева, 134) **куңғырый** «курай, флейта» ~ тув. *хоңура* «җиз торбачык, җиз курай». **Қаң** ~ *қоң* ~ *қуң* тәкълиди сүзенең исәпсез күп дериватларының берсе, турыдан-туры **курай** белән баглы түгелдер. Чаг. ш. ук башк. (БТДҺ: 204) *қуңғырҙай, қуңғырҙақ* «үпкәгә һава юлы, трахея».

**КУҢКА, коңка** (русча «Кузы-Курпяч» дастанына керештә) тар. «официальный придворный, музыкант, арфист» << бор. уйг. *kungkav, kunhan kunku* < кыт. *k'onghevu* «арфа», к. Caferoglu A. Eski uygur türkçesi sözlügü, 1993: 123. «Башкортстан энциклопедиясе» (Уфа, 1996) *Кункас сэсэн* дигән аерым шәхесне күрсәтә, ләкин бу *куңкачы чәчән* дигәннән һәм гомумән уртаклык исем. К. ш. ук Räsänen 1969: 301.

**КУПА: купа тал** «дряблая ива» (ТРС 1966: 298) – аңлатмасы шикле, безнеңчә, **купа талы** «сазламык талы, елга утравы талы», к. башк. *купа* «саз җикәне;

күтер» (БҺҺ II: 149), *купы* «бәләкәй генә утрау» (БҺҺ III: 119; БТДҺ: 204–205) ~ себ. *ҡубаҡ* «сазлык, былчырак; сазлык утравы» (Тумашева 1992: 132) ~ мар. *куп, купан* «сазламык», каз. *копа куе* «камыш үскән күл» (Радлов II: 652), кырг. *копо* «яр буендагы камыш», к. ш. ук рус. *купина* «көлтә; куе ябалдашлы куак; елга утравы» (гом. слав. параллельләре бар, к. Фасмер II: 420). Күрәсең, киң таралган интернациональ тамырдан. К. **Купкы.** К. **Куба тал.**

**КУПАЙ**, (ДС I: 115) **ҡупый, ҡупыҡ, ҡубый** «хвастливый; тщеславный», себ. (Тумашева 1992: 126) **ҡобый** «щегольство» ~ башк. (БТДҺ: 205) *ҡупыҡ, купым, купырыҡ* (← **купыр-*), кр.-тат. (Dobr. II: 335–336) *qopau,* нуг. *ҡопар* «мактанчык, купай». Чаг. фар. *хоби, хуби* «купшылык, көязлек» ← *хоб, хуб* «яхшы, шәп» (к. **Хуп**), к. төр. *hobi* «купшылык һ.б.». Рус. *хупавый, хупавъ* «купай, шәп, шәпле», укр. *хупавий*, Д. болг. *хубав* «купшы, көяз» төр. теленнән таралган булса кирәк. К. **Куптарай, Купшы.** Фасмер II: 420 (ачык түгел ди). Монг. **купый** «баш министр» сүзенең катнашы юктыр, мөгаен.

Дерив.: **купайлык**. К. **Купай-у.**

**КУПАЙ-У** «надуться от чванства; чрезмерно возгордиться» ~ каз., добр. тат. (Akb: 216) *kopay-* id. ← *kop* «мактанчык». Бу сүз исә фарсычадан булса кирәк, к. югарыдагыны.

Дерив.: **купаеш-у; купайт-у** «күптерү, арттырып мактау һ.б.ш.».

**Купай** һәм **купай-у** сүзләренең формалашуында ономопоэтик *ҡоп ~ ҡоҡ* «кабарынкы; горур» сүзенең тәэсире бар.

**КУПКЫ** диал. (Тумашева 1992: 134) «топь, топкое место, ямина в болоте» ~ удм. *гоп* «(саздагы) чокыр», коми. *гӧп* «(саздагы) күл, күлчек», карел. *kuplo, kuplu* «купкы», фин. *kuoppa* «чокыр», венг. *kupa* «ерынты» һ.б. **Купа** (к.) «саздагы утрау» булса, **купкы** «саздагы күл». Чаг. **Кобау, Купа.**

**КУПТАРАЙ** «горделивый, общительный хвастун; любитель показухи» < иске **хуптарай** «артык яхшы, яхшатланучан, яхшылыгы белән мактанучан» **хуп** сүзенең диал. артыклык дәрәҗәсе (*-тарай//тәрәй* кушымчасы). Ш. ук вакытта диал. **куптар-у** «кубару, актару» сүзеннән дә ясала ала.

Дерив.: **куптарайлык, куптарайлан-у.**

**КУПСА-У** («Заятүләк» дастанында) «играть на кобзе» < *копуз-а-*. К. **Кубыз.** Чаг. рус., укр. *кобзарь* «халык җырчысы» ← *кобза-* «кубызда (кыллы музыкаль инструментта) уйнау» – төрки телләрдән.

**КУПТАШКА** «рассоха, вид плуга в начале XX века» (Н. Халиков 1981: 61) < чув. *купташка* id., ш. ук «төпсә, тумар, түмәр», *купчашка* «кәтүк, шүре» – *купта, копта, коптака* «купташка, тәрән сабы» (Ашмарин VII: 100) ← мар. *копа, копка, коптак* «уч; калак; ярымтүгәрәк өтерге» (Упымарий: 74). Шулай итеп бу сүз мари тамыры нигезендә чуваш телендә ясалып, татар һәм рус игенчеләре арасында киң таралыш тапкан. К. ш. ук **Каба.**

**КУП-У [кубу]** «отлупиться, отрываться; расклеиться, подниматься (разом)» (о значениях этого слова хорошо написано у Будагова, II: 68–69) ~ чув. *хӑп-* < гом. төрки *ҡоп-* id. (Радлов II: 650; Räsänen 1969: 281), элек бу сүз **ят-у**ның антонимы булган (к. «Диване хикмәт»тә: *Йөрсә-торса, ятса-купса мине яд итәр*). Бор. күчмә тормышта *куп-* < *коп-* иң актуаль сүзләрнең берсе булган – ул күченергә кузгалуны белдергән һәм шунлыктан бу сүзнең дериватлары да күп булырга тиеш. Федотов II: 330–331 (тәфсилле).

**Куб-у** фигыленең турыдан-туры гом. төрки дериватлары *ҡубар-у* < *ҡобар-, ҡопар-* һәм *ҡуптар-у* < *ҡоптар-* икесе дә – йөкл. юнәлешенең лексикалашкан формалары. Тат. **ҡубын-у** «күченү» (ТТДС I: 206) – кайт. юн. формасы. Себ. **купкын** «өрәк» (Тумашева 1992: 134) – үзенчәлекле ясалма. Алт., кырг. һ.б. *ҡубул-* «әверелү» (к. **Кубылгы**) сүзе дә *ҡуп-, ҡоп-* сүзе белән тамырдаш булуы ихтимал (к. *ахирәттә куп-у* «икенче кыяфәткә килү?»). Ләкин моның исбаты юк. К. ш. ук **Кузга-у, Купшы-у.**

**КУПЧЫР, копчыр** тар. «налог с количества скота» < монг. *ҡобчур, ҡыйбчур, ҡубжур*. Урта гасырларда төрле язмаларда *гупчур, хабчур* һ.б., бор. уйг. (ДТС: 462) *qubčïr* (> рус. *купчир*) «терлекчелектән алынган салым (иң җиңеле – йөз баш терлектән берсен алу булган)». К. хәз. монг. *говчуур* «ятьмә, җылым» ← *говчих* «балык тоту; салым җыю». Будагов II: 68; Аникин: 172.

**КУПШАК** «вспученный; отваливающийся» ← **купшы-у**, чаг. **Кубачак, Көпшәк.**

**КУПШАНГЫ** «мокрица; тысяченожка», диал. «жук; таракан; солдатики» (? к. БҺҺ III: 118), диал. **капшангы** «жук; червяк» (ДС I: 77) ~ чув.

*купшанкă, кăпшанак̦, кăпшанкă, копшанкă* «купшангы; купшы» (Сергеев 1971: 75; чув. «купшы» мәгънәсе халык этимологиясе буенча гына килеп чыккан), мар. *ковшангы, капшангы, кавшангы* «купшангы; коңгыз, һәртөрле корт» (Иванов, Тужаров: 73; Саваткова: 48), удм. *копшангъ* «коңгыз» (Насибуллин: 120). Чаг рус. диал. *капшак, ковшак, кавсяк* «кыргаяк, купшангы һ.б.ш. балык җиме» (Даль), рус. әд. *кивсяк* «бөҗәк төре» – Идел-Урал региональ сүзе. Чыгышы анык билгеле түгел, чаг. чув. диал. *хупшанкă* «ябылган, каплаулы, ябулы, футлярлы» ← *хуп-* «ябу, каплау» (< бор. гом. төрки **к̦ап-*).

**КУПШЫ** «франт, щёголь; щегольской» > чув. *купшă,* мар. *копшо,* удм. (Насибуллин 1978: 120) *копшъ*, себ. (Гиганов; Тумашева: 134) *купшу, купшув* «мактанчык» – бу сүз тат. телендә төрле тамырлы сүзләрнең контаминациясе булып килеп чыккан, к. бер яктан алт. *к̦опчы,* хак. *хопчы* «алдакчы, мактанчык» ~ монг. *к̦обчихан* «купшы», «купшылык» – алт. *к̦оп*, хак., тув. *хоп*, як. *хоп, хобу, хобуу* «әләк, яла» < монг. *к̦об, хоб* «әләкләү, ярамсаклану» (к. Räsänen 1969: 281), *хобчин* «әләкче» > бур. *хобшо(н)* «әләкче, ялачы», икенче яктан иске тат. (Троянский II: 63) **купыз** «купшы». *Купшы* < *купчы* сүзенең мәгънәви үзгәреше (әләкче > мактанчык > купшы) бүтән охшаш сүзләр (мәс., *купай, купык* һ.б.ш.) тәэсирендә барган.

Дерив.: **купшылык; купшылан-у, купшыландыр-у** (киемне).

**КУПШЫ-У** «вспучиваться (о льде на реке весной); отваливаться; разволноваться, терять спокойствие (о человеке)» < бор. **к̦упчы-* id. к. каз. *к̦опсы-*, кырг. *к̦опшо-*, ком. *к̦опчу-* «кубалаклау» (кыргызча көчемле мәгънәдә – «купшыту») ← *к̦уп-* < *к̦оп-* фигыленең интенсивлык формасы (*-чы//-че* кушымчасы; чаг. *арчы-, борчы-, кырчы-* һ.б.ш.); *ч* > *ш* күчеше бу сүзнең тат. теленең нугай компонентыннан килгәнлеген күрсәтә. К. **Купшак.**

**КУПЫ** «неглубокая чаша, ковшик (без ручки)» ~ чув. *куп* «дегет кудыртканда агып чыккан дегет өчен савыт» (Сергеев 1968: 35), удм. *кобы* «чүмеч», венг., госм. *купа*, ит. *cupa*, лат. *cupa, cuppa*, һинд. *куппа*, фин. *kuppi* «купы», көрд. *kûp* «хум, цистерна», индонез. *kopi, kupi* «банка, пыяла савыт» һ.б. Күрәсең, интернациональ сүз. Бу фонда бор. уйг. *qupïŋ* ~ монг. *quubiŋ* < бор. кыт. *γuo bieng* «ваза» белән чагыштыруның да әһәмияте югала.

**КУПЫНА** (ЗДС: 338) «копна» – русчадан дип күрсәтелә. Ләкин бу сүз һәр яктан (фонетик, морфологик һ.б. җәһәтләрдән) караганда да тат. һәм төрки телләрнең үзләрендә дә ясала алыр иде, к. каз. *к̦опын*, бор. төрки (ДТС: 457) *qopïn* «өем; өер» һ.б. ~ һинд-евр. *kop* id. К. **Күбә.**

**КУР** «уголь для сохранения огня», диал. (ЗДС: 338, 427) «закваска (*камыр курына күрә,* мәкаль)», *к'ур* «тесто» ~ башк. «калдык, сөземтә; түпрә» < гом. төрки *к̦ор, к̦ōр*, үзб., таҗ. *кўр*, бор. төрки, гаг. *к̦оор*, төркм. *гор, гоор* «кур; куз; ачыткы; запас, нәселлек» (башк. *к̦ур мал* «нәселгә калдырылган терлек»), як. *к̦ур* «үткән елгы», *к̦уруй-* «киләчәккә (киләсе елга) калдыру», бор. төрки (ДТС: 458) *qor* «катык оеткысы» ~ чув. *коар, кăвар* «күз күмер» id. В.Е. Егоров (1964: 97) бу сүзне һуннарның яшен тәңресе *Хвар* һәм арытабан бор. ир. *hvar* «кояш; ут» сүзе белән чагыштыра. Мәгънәви һәм фонетик үсеш: *hvar* > *к̦оор* > *к̦ор* «көлгә күмелгән куз» > «запас башлангыч (ачыткы; нәселгә куелган терлек)» бик аңлашыла. Шуннан ук – *к̦оз* > *к̦уз* (*-р* > *-з*).

**Кур** продуктив сүзьясагыч нигез, к. тат. диал. **куwырлык,** башк. диал. *курҙы* «үрчемлек» ~ себ. тат. **к̦урлы** «әче (камыр)», **к̦урлык̦** «ачыткылык» һ.б. Будагов II: 72; ТТДС I: 211; Тумашева 1992: 134; БТДҺ: 205, к. Мухамедова 1973: 116; ЭСТЯ VI: 72–73. К. **Курҗы-у.**

**КУРА I** миш. (ЗДС: 338) «жердинка, жёрдочка (в доме); ограда из жердей»; **к̦ура** диал. (к. ш. ук **к̦урай**) «(сухой) стебель высоких трав или мелких кустов», (Остроумов 1872: 94) «рябинник – растение в высоких хлебах», (К. Насыйри буенча, к. ЛТ II: 46) «вак агач, эре үлән» > удм. (Тараканов: 91) *куро* «каты салам», мар. (Саваткова: 108) *ора* «салам; терлеккә ашарга яраксыз каты үлән» ~ каз. *к̦ора,* (К̦ТДС: 206) *к̦орагаш* «озын, юан таяк». Бүтән төрки телләрдә сирәк очрый күрәсең, к. СС *kuura* «чүп үлән», венг. *koro* «коры сабак» һ.б. **Курай** (к.) белән бердәй булса кирәк, к. гаг. *к̦орай* «каракура, чыбык-чабык». К. түбәндәгене.

**КУРА II** (ЗДС: 327–328, тәфсилле; к. ш. ук Тумашева 1992: 135; БҺҺ II: 149) «двор, усадьба; ограда; сарай, огороженная площадка во дворе для различных целей» ~ кр.-тат. (Dobr. II: 337) *kora* «киртәләнгән мәйданчык, бакча; камыш киртә» ~ үзб. *к̦ўра* «читән, текмә; киртәлек материал», нуг., каз., к.-калп., чыгт., уйг. *к̦ора*, алт., кырг. *к̦оро, ко-*

*роо* «кура, кәртә; утар; сарык көтүе». **Кура I** белән бердәй (далаларда киртәлек материал – кура). Будагов II: 73; Радлов II: 550; ЭСТЯ VI: 75–76.

Әд. телдә **кура** сүзе башлыча *киртә (кәртә)-кура* дигәндә кулланыла; добр. телендә деривациясе киң: *qoralata, qoralataq, qoralı* һ.б.

**КУРАЙ** «вид флейты, курай», диал. «растение с полым стеблем» ~ нуг., каз., к.-калп. *қурай,* кырг. *қуурай* id. ~ себ. **қаурай** «курай (музыкаль аләт)» ~ к.-балк. *қаурай* «коры камыш» < бор. монг. *qaγurai* > хәз. монг. *хуурай* «коры сабак» ← *қаɣу-ра-* «кору, кибү» фигыленнән, к. **Как**. К. ш. ук уйг., гаг. *қорай,* алт. *қоңурай* «каракура; көпшә». *Курай* – уен коралы мәгъ. рус теле аша күп телләргә таралган; рус. диал. *курай* «чатырчәчәкле үсемлек» тур. к. Аникин: 325. К. **Кура I–II, Кура-у I.**

**КУРАН** (Старчевский) «козуля, косуля» ~ кырг., алт. *қуран, қураған* id., тув., хак. *хураган* «бәрән, бәти» ~ яз. монг. *γura, γuran* < бур. *гуран*, монг. *гур* «кыр кәҗәсенең (кәҗә, болан шикелле хайваннарның) тәкәсе» ~ эвенк. *гууран*, маньч. *ɣуран*, нан. *горан, горал* id., як. *хорой* «яшь болан» > рус. *хора* «печелмәгән сарык тәкәсе», нен. *һоора, хоора* «болан үгезе» һ.б., к. **Коралай, Кузый.**

Бу сүз рус телендә *горал* «себер тау кәҗәсе» сүзендә дә чагыла (тунг. телләреннән кергән булса кирәк).

*Куран* «кәҗә яки болансыман хайван» гомумән Евразиядә күп телләрдә очрый. Пекарский: 3507; Фасмер IV: 262, 264; ССТМЯ I: 173. Рус. диал. *кураган, курагашка, хураган* «бәрән, бәти» тур. Аникин: 325 (шунда бу сүз хакында күпсанлы әдәбият күрсәтелә).

*Куран, коран* элек шактый продуктив нигез булган: себ. **куран айы** «ноябрь» – бу айда куранга ауга йөргәннәр; к. ш. ук **Ташкуран.**

**КУРА-У I** диал. (Тумашева 1992: 135) «пересыхать; засыхать» ~ нуг., каз., к.-калп. *қура-*, кырг. *қуура-* id. < бор. монг. **қагура-* id. К. **Курай.** Чаг. **Каура-у.**

**Кура-** нигезеннән тат. диал., гом. кыпч. **курақ** «кипкән үлән сабагы, чикләвек кәшәнкесе» һ.б.ш. ясалган.

**КУРА-У II** иск. «защищать, охранять, оборонять» ~ каз., кырг. *қоры-,* к.-балк. *қора-,* төркм. *ɣора-,* төр., кр.-тат. (Dobr. II: 338, 340) *qorı-, qoru-* (рәсми язылышта *korı-, koru-*), к.-балк., алт. *қору-* һ.б. < бор. төрки (ДТС: 458, 460) *qorï-, qoru-* id.; тат. дөресе *куры-у* булырга тиеш.

Бу фигыльдән төрки телләрдә бик күп сүзләр ясалган, к. **Курган, Курга-у, Курк-у, Курчала-у,** (болардан арытабангы ясалышлар), ихтимал, **курыл-у** «бөршәю».

**Кура-** фигыленең *қур ~ қор* ностратик тамырыннан булуы күзаллана, чаг. лат. *cūra* «хәстәр» (шуннан хәз. Европа телләрендә бихисап терминнар килә).

**КУРАЧ** «щупленький; недорослый; кургузый (об одежде)» ~ каз. *қораш*, башк. *қураныс* < *қураныч* «арык, ябык; ач (башак тур.)»; к.-балк. *қоранч* «кечерәйгән» ← бор. төрки (ДТС: 458) *qoran-* «кечерәю, чибекләнү» ← *qora-* «ябыгу, чебегү; югалтуларга дучар булу» ← *qor* «зыян». Хәз. алт., к.-балк. *қора-* кырг. *қоро-,* хак. *хора-* «кечерәю, чебегү» ~ монг. *хоро-*, *хору-*, калм. *xora-* id. ← *xor* «кечкенә нәрсә, нәрсәнең дә булса кечкенәсе». Киң таралган тамыр: алт. *қураны* «арыкланган, курач», көрд. *qor* «курач, мәлҗерәгән» (бу нигездән *қорач* < **қорɣач* булырга мөмкин, *-ɣач* кечерәйтү кушымчасы) һ.б.

Төр. *kurgaz* ~ рус. *кургуз-ый* сүзләренең *курач* сүзенә мөнәсәбәте ачык түгел. Гомумән, төрки телләрдә *қор, қур* дигән тамырлар күп.

Дерив.: **курачлык; курачлан-у.**

**КУРГАВЫЛ [қурғаwы̂л]** тар. «охранник; охрана» ← к. **Курга-у**. К. ш. ук **Кыргавыл.**

**КУРГАН,** (Н. Исәнбәт телендә) **қорған** «курган; среднеазиатская крепость с глиняными стенами» < гом. кыпч., чыгт., уйг., төркм. һ.б. *қорған*, кырг. *қорɣон*, госм. *қурган* < бор. төрки, бор. монг. *qorïγan* id., к. бор. төрки *qorïγ* «сакланыла торган җир; биләмә» ← (ДТС: 458–460) *qorï-* «яклау, саклау» ~ ком., уйг. *қору-, қора-*, алт. (Баскаков 1972: 224–225) *коры-* «яклау, саклау» (к. **Курга-у, Курк-у, Курчала-у**). К. ш. ук тунг. *қориган* «киртә; бура ныгытма» гом. алтай сүзе, к. ССТМЯ I: 415 (бик күп материал күрсәтелә).

**Курган** < *қорған* сүзе төрки телләрдән бик күп күрше телләргә кергән. Räsänen 1969: 282; Фасмер II: 424; Аникин: 326; Сафаров: 40; Тимергалин: 266.

**КУРГА-У** «защищать, охранять (со всех сторон)» < гом. төрки (хәз. каз., чыгт.), *қорɣа-*, кырг. *қорɣо-* < бор. төрки **қоруɣа-* id. бор. төрки *qorïγ, qoruγ* > уйг. *қоруқ* һ.б. «яклау, саклау чарасы»

сүзеннән ясалган (*қорға-* < *қоруға-*), каз., кырг. *қорға-* тулы парадигмасы белән килә. К. **Кура-у, Курган.** Будагов II: 77–78.

**Курга-у** сүзенең киң кулланышлы дериваты **кургавыл, кургавыч, кургавыш** «шәхси сак, шәхси каравыл». К. **Кыргавыл.**

**КУРГАШ, кургашын** «паяльный материал»: **аккургаш** «олово», **каракургаш** «свинец», «оловянный; свинцовый» < гом. төрки *қорғашын, қорғашун*, чыгт. *qorqašun*, алт. *қорғолдьын*, хак. *хоргамчыл*, кырг. *қорғалдин* < монг. *горгальчин,* бор. монг. *qorγaršun* (Поппе 1938: 303), яз. монг. *xorγulǯin*, як. *хорголдьун* һ.б. Чаг. бор. монг., себ. тат. *qaŋпа-* < бор. төрки *qaŋla-* «каңлау, кургаш эретеп ямау» себ. тат., кырг., алт. *қаң* < кыт. *каң* «эретеп ябыштыру өчен металл» тамырыннан (Радлов II: 80; Joki 1952: 160). Димәк, *қорғар + чун* < монг. *γaŋnaγur* «эретеп ябыштыргыч» + **ǯun* «металл» (?). Нуг., каз. *қорғай*, гаг., төр. *kuršun* һ.б. «кургаш» икенчел ясалмалар. ЭСТЯ VI: 172–175 (бу сүзнең этимологиясе буталчык һәм билгесез булуы икърар ителә, бай әдәбият китерелә). Кургаш атамасы гадәттә бик еракларга тарала, к. **Калай,** мар. *улна, вулно* «кургаш» (*ош волно* «аккургаш», *шум волно* «каракургаш») << шумер. *alna* «каракургаш» (Гордеев II: 165).

**КУРГЫ I** «горн в кузнице» (Г. Ибраһимов), ачык түгел, чаг. эвен. *хорхо* id. **Кургы II** һәм **кургаш** белән бәйле булса кирәк. Чаг. тат. диал. **курға-, кургы-,** каз. *қорыт-* «эретеп ябыштыру».

**КУРГЫ II** диал. (Башкортстан, Миякә, без теркәдек. – *Р.Ә.*) «пряжка у пояса» << монг. *горхи,* бур. *горьё* < яз. монг. *γorki* «аел, божра; бил каешының каешчыгы» ~ эвенк., маньч. (ССТМЯ I: 161) *ғорғи, ғурғи,* кор. *кори* «божра». Чаг. төр. *kurgu* «ачкыч».

**КУРҖЫН,** себ. (Тумашева 1992: 110, 135) **курцын, күрцён** «переметная сума; саквояж» ~ башк. *қурйын,* кырг. *қоржун*, уйг. *хоржун* һ.б. фар. *куржин* ~ көрд. *хөрҗ* id. Рус. диал. *курджун, курджул* тур. к. Аникин: 327 (чыгышы – этимологиясе ачык түгел ди).

**КУРҖЫ-У,** диал. **курза-у** «кваситься, скисать» ~ башк. *қурза-* id. < ***курчы-у** (*-р-* авазы янында *-ч* > *-җ*), ихтимал *кур* (к.) сүзенең фигыль коррелянты булгандыр, шуннан *құр-чы-* «әчи төшү» ясала алган. Чаг. монг. *арачан-курачан* «әчегән сөттән ясалган исерткеч» һ.б.

Дерив.: тат. (ЗДС: 428) **куржау, қуржым**, башк. (БТДҺ: 305) *қуржын, қуржа, қурйын* «түпрә; чүпрә; утырма, юшкын» ~ хак. *хордың, қордың* «чүпрә» (к. ЭСТЯ VI: 73).

**КУРКАК** «трус; трусливый» < гом. кыпч. *қорқақ* < *қоруқ-қақ* id.

**КУРКАЧ** «боязливый, робкий» ~ ком. *қорқач* id. **Курык-у** сүзеннән, ясалышы ачык түгел.

**КУРКУ** «страх» < **курыку** (к. **Курык-у** сүзенең исемләшкән формасы). Төр. *qurku* курку (исем)» < кр.-тат.

Дерив.: **куркулы, куркусыз; куркулык** (авыру курыккан нәрсәне белү өчен кургаш эретеп суга салу); **куркылык < курыккылык** «карачкы төре».

**КУРМАЧ** «жареное зерно» к. **Куырмач.**

**КУРМЫЙШ** (ТТДС I: 258) «околоток, конец улицы; отдельная группа домов» < рус. диал. *курмыш* id. ~ морд. *курмыш* «авыл, авылчык». Бу сүз төрки телләрдән булса кирәк, к. бор. уйг. *қорум* «нығытылган йорт» (шуннан **Кара Корум** бор. уйг. дәүләтенең, соңрак монгол ханнарының пайтәхете). К. **Курмыш** – Сора (Сура) елгасының Иделгә койган төшендәге калачык, аны Олуг Мөхәммәт хан үзенең пайтәхете ясамакчы булган.

**КУРПЫ,** диал. (ДС I: 100) **курвы** «отава – трава, росшая после косовицы; ростки, побеги вокруг пня спиленного дерева» ~ башк. (БТДҺ: 205) *қурбы* id. > чув. *курпă*, мар. *корпо* ~ алт. *қорбо,* хак. *хорбы, хурбы* «курпы», башк. *қорбо* «табындаш; кордаш» (к. БҺҺ II: 145), кырг. *құрбу* «яшьтәш; яшьтәшләр төркеме» ← гом. төрки, төркм. *қор*, төр. диал. *qor* һ.б., уйг. бор. төрки (ДТС: 467) *qur* «рәт, тезем; чин, иерархия; әйләнә, түгәрәк» сүзеннән. К. **Кордаш, Кырпу.**

Дерив.: **курпыла-у.** Башк. (к. БТДҺ: 206) *курпы-у* «курпылау» сүзенә караганда *кур-* < *қор-* дигән фигыль дә булган, шуннан (билгеле *-пы//-пу* кушымчасы ялганып) *корпы-* фигыле ясалган, ул фигыльдән **қорпуғ* исеме ясалган булса кирәк.

**КУРТАЙ** (ЗДС: 339, русчадан дип әйтелә) «гордый; удалой» ~ алт. *кортонь*, тув., як. *хордоң* ~ монг.

*хурдуң* id. Русчадан дияргә монда фонетик закончалыклар комачаулый.

**КУРЧАК,** себ., миш. **курцак** «кукла; куколка, кокон насекомых» > мар., удм. *курчак*, мар. диал. (Иванов, Тужаров: 92) *курцак* id. < гом. кыпч. (ләкин кайбер телләрдә теркәлмәгән) сүз, к. башк. *ҡурсаҡ,* нуг. *ҡоршаҡ,* ком. *ҡурчаҡ,* кырг. *ҡуурчаҡ,* төркм. *ҡурҗаҡ* «курчак», чыгт. (Радлов II: 577, 899 һ.б.) *ҡуғурчаҡ, ҡаурҗаҡ, ҡорчаҡ* «һәйкәл; сын; кыяфәт» һ.б. < уйг. *ҡуғурчаҡ,* үзб. *ҡуғирчаҡ,* чыгт. (Котби һ.б., Zajączkowski 1961: 136–137) *qavurčaq, qawurčaq* «элекке күләгә театрында фигура-марионетка» < чыгт. **qavur-čaq* (*-чаҡ* – кечерәйткеч кушымча); бор. фонетик вариантлар себ. сөйләшләрендә (к. Тумашева 1992: 131, 135; Дмитриева 1981: 28, 119, 154, 156): **ҡōңырчаҡ, кōңурцак** «курчак, пот, курчак итеп ясалган мәҗүси санәм» (алар тур. төрле сөйләкләр йөри – аерым кешеләр ул курчакларга бүгенгә кадәр табыналар, имеш). Себ. тат. материалы бор. нигез **ҡаңур* булганлыгын күрсәтә шикелле, бу гипотетик сүзне **ҡаң* (к.) «кургаш» сүзеннән дип фаразларга мөмкин: кургашлардан санәм, пот кою төрки халыкларда күптән билгеле (к. **Кот**). Гомумән, **курчак** < *куурчак* < **каңурчак* сүзе мәҗүсилек белән баглы. Элекке (XIX г.) тат. **курчак туе** ясау (к. Г. Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрен) мәҗүсилек калдыгы булган. ЭСТЯ VI: 161–163 (гомуми фаразлар гына китерелә). Räsänen 1969: 220 (бөтенләй үзгәчә аңлата: монг. *qaurtag* «алдаткыч» белән баглый).

Дерив.: **курчаклы** (уен исеме буларак та билгеле), **курчаксыз; курчаклык; курчак-курчак** (уен).

**КУРЧАЛА-У** «защищать, опекать, окружая со всех сторон» < гом. кыпч., к. башк. *ҡурсала-у* нуг. *ҡорсала-, ҡоршала-*, каз., к.-калп. *ҡоршала-* «курчалау, яклау; төрле яктан киртәләү» – ***курчы-у** (> башк. (БТДҺ: 206) *ҡурсы-у*) ~ кырг. *ҡурча-*, хак. *хурча-* «урап алу» (чаг. **Корша-у, Кушак** һ.б.ш.).

**Курчала-** ш. ук **курчы** «тирәли яклаучы» сүзеннән дә була ала, к. үзб. (ЎХШЛ: 164) *ҡорчыла-* «саклау, саклап тору» ← **ҡорчы* «тирәли саклаучы» (к. **Кучты**). Һәрхәлдә сүзнең тамыры **кур** ~ *ҡōр* (к. **Кор)** булса кирәк.

**КУРЫК-У (курыкты, курку)** «пугаться, бояться» < гом. кыпч., уйг., госм. *ҡорҡ-,* каз., алт., чыгт., хак. *ҡоруҡ-*, бор. төрки (ДТС: 459–460) *qorq-, qorqu-, qoruq-* id., ш. ук «оялу» < гом. кыпч. (тат., башк. даирәсендә юк) *коры-, ҡору-*, төр. *koru-*, бор. төрки (ДТС: 458, 460) *qorï-, qoru-,* яз. монг., маньч. (ССТМЯ I: 415), алт. диал. (Баскаков 1972: 224) *ҡоры-, ҡоory-* «яклау; саклау; тирәләү; тыю» ~ тув. *хору* «тыю; куркыну, яшеренү (кош-корт тур.)» һ.б. сүзенең интенсивлык формасы (*-к* кушымчасы ярдәмендә ясала, чаг. *йол-у → йолҡ-у, көй-ү → көек-ү, тал-у → талыҡ-у* һ.б.). Алт. мисалында сүз нигезендә озын сузык сүз тамыры **коо-* дигән фаразга урын калдыра (*-ра* дигән фигыль ясагыч кушымча билгеле). Гом. кыпч. *ҡоры-, ҡору-* чув. телендә *хăра- (хăрав)* «курку, шүрләү» яңгырашында чагыла. Тат. **куры-у* сүзе, *куру* < *куыр-у* фигыленә омоним булгач, онытылган.

Кыпч. һ.б. төрки телләрдә *коры-, кору-* фигыленең юнәлешләре *корын-, корун-* «саклау, үз-үзен яклау; оялып йөзен яшерү», *корыт-, корут-* «яклар-га кушу, яклату, саклату» сүзләре билгеле. К. ш. ук төр. *koru*, к.-балк. *ҡоруў* < бор. төрки (ДТС: 460) *qoruγ* «саклау, яклану эше, каравылчылык». ЭСТЯ VI: 79–80; Федотов II: 331–332 (бик ярлы; удм. *курданы-* «куркыну» тат. теленнән диелә; *өрек-ү* ~ монг. *ürege-* id. сүзе белән ялгыш чагыштырыла). Чаг. **Кура-у.**

Дерив.: **куркын-у, куркыш-у, куркыт-у; куркулык; куркыш; куркылык, куркыныч;** к. **Куркак, Куркач,**

**КУРЫПСА** (С. Хәким) «корьё для плетения лаптей, коробов, лукошек и т.п.» – ачык түгел. Шуңа охшаш сүзләр төрки һәм монг. телләрендә очрый, ләкин бүтәнчәрәк мәгънәләрдә (мәс., бур. *хургабша* «уймак»). Чаг. каз. *ҡорап* «әрҗә, тартма». К. **Курыс.**

**КУРЫС,** диал. **куры** (ДС I: 101) «луб, кора липы, снятая целиком, корьё» (*курыс төшерү* «снять кору липы целиком для дальнейшей обработки»), диал. «лыко» ~ башк. *ҡурыҫ, ҡурыз* «шелле, кабык», чув. *курăс, корăс* «салабаш» (к. Ашмарин VII: 6), мар. *корш* «каеры сыдырылмаган шеле», *курыс* «шеле» – барысы да удм. теленнән, к. удм. *кур* «кабык» (коми. *кырсь*, фин. *kuori*, эстон. *koor* һ.б. id., рус. *кора, корьё* «курыс»), *курьёс* «курыс, кабыклар», *курыз* «(агачның) кабыгы». Räsänen 1969: 269; Федотов I: 312 (һич урынсызга *курыс* сүзен *козау* белән бәйли).

**КУС** «щавель конский» (Иванова: 192) – ачык түгел. Ихтимал, **кузы үләне** (к. **Кузый**) сүзеннән эллипсистыр. Чаг. ш. ук диал. (ЗДС: 339) **кус** «куак», «курпы» (русчадан диелгән).

**КУСАР** «большой, длинный нож, косарь» ~ чув. *кусар*, мар. (Иванов, Тужаров: 87, Саваткова: 87) *косар, косор* id., гаг. *косор* «бакчачы пычагы» < рус. *косарь* (?); рус. *коса* «чалгы» һәм *косарь* «чалгы пычак (иске чалгыдан ясалган пычак)» сүзләренең этимологиясе ачык түгел (*косить* «печән чабу» үзе *коса* сүзеннән). Чаг. ш. ук гар. *ҡусар* «кыска кылыч». Федотов I: 313.

**КУСИЛА** (ЗДС: 340) «косуля, вид старинного (XIX век) металлического плуга» < рус. әлбәттә.

**КУСТАРТКЫЧ** (Тумашева: 136) «кочерга» < *ҡуз тартҡыч*. К. **Куз.**

**КУСЫЛ** (ЗДС: 340) «специальная завязка для парных столбов при построении плетня, заранее приготовленная» – тат. *карама, карыма* дип атала, ләкин алдан әзерләнми. **Кусыл** сүзе удмуртчадан булса кирәк, анда *кузыли* id. (ш. ук «карама агачы»).

**КУТАЗ,** (ТТДС I: 211) **кутас** «жестяной колокольчик, который навешивается на шее у скотины, чтобы легко найти её в лесистой местности» > мар. (Иванов, Тужаров: 93) *кутас* id., каз. *ҡодас* «купшы» ~ төр. *kutaz, kutas* «бүрек, чалма һ.б. түбәсенә беркетелгән каурый, чук; ат муенына тагылган бизәнчек», госм., фар. *кутаз, ҡутас* «Тибет ягы: як койрыгы», бор. угызларда (Гордлевский I: 82–83) *ҡутас* «мәргән аучыга бирелгән бүләк – як койрыгы», ш. ук «бизәнчек төре», бор. төрки (ДТС: 463, 474–475) *qudaz, quduz, qutuz* < *qutur* «асыл болан», ш. ук «як». Бабурда (Будагов II: 70) *котас* «тау үгезе». Төрки телләрдән бу лексема күп күрше телләргә кергән, к. рус. (Фасмер II: 433; Аникин: 335) *кутаз, кутас* «чуклы шнур, аксельбант; асылма кыңгырау», (Баскаков 1971: 96–97) *кутуз, кутайс* «койрыктан ясалган бизәк»; осет. (Абаев II: 334–335) *кутаз* «кутаз, кыңгырау»; гар. *ҡутас* «диңгез аты чәчләреннән ясала торган бант» (< төр.) һ.б. Сүзнең фонетик үсеше: *ҡутур, ҡутор > кутаз* мәгънәви үсеше: «як үгезе > батырга бирелә торган бүләк чук (як койрыгы һ.б.) > хайван муенына тагылган чук, бизәнчек > кутаз, кыңгырау». **Кутаз, кутуз** сүзеннән рус. **Кутузов** фамилиясе килә, диләр (Н.А. Баскаков; икенче версия буенча, бу фамилия *Котдус* исеменнән). ЭСТЯ VI: 81–82 (күп материал һәм әдәбият).

**Кутаз** сүзенең чув. *хутаҫ* «кот савыты» сүзенә бәйләнышы, ә **кутур*ның *кут* «кот» сүзенә мөнәсәбәте ачык түгел. К. **Котый.**

**КУТАН I** диал. (к. мәкаль: *Кутанда кучкар булмаса, кутырлы кәҗә баш булыр*) «ограждённый глиняным забором двор, карда в степи» < каз., уйг., чыгт. *ҡотан*, к.-балк. *ҡодан*, тунг., кырг. *ҡотон*, уйг. *ҡотоң, ҡатаң*, як., тув., монг. *хотон, хото, хот* «кутан, ныгытма, ныгытылган йорт» – бик бор. сүз, к. кор. *kot* «мәйдан, урын», айну. *kotan* «авыл»; чаг. чув. *хӳте* «кәртә, киртә», *хӳтер-* «киртәләү», *хӳтеле-* «яклау»; рус. диал. *хатон, хотон* «сыер абзары» (монгол телләреннән, к. Аникин: 623); к. ш. ук Будагов II: 70; Радлов II: 602; Номинханов 1975: 234; ССТМЯ I: 418–419; ЭСТЯ VI: 83–84; Räsänen 1969: 284 (фин. *kota* «куыш, алачык» сүзен дә терки).

**КУТАН II,** диал. **котан** (Арсланов 1988: 83) «стерх; цапля»; «игра в аисты» (Г. Ахмаров) ~ чыгт. (Бабур) *кӧк ҡутан* «челән» (к. Будагов II: 70), тунг., як. *ҡутан* «челән», *ҡутаң* «күлдә йөзә торган торф утрау (кутаннар шунда оялый)». Räsänen 1969: 284 (тагын берничә телдән параллельләр күрсәтә).

**КУТАР-У** (ЗДС: 430–431) «перекладывать, перемещать, поднимать с места» < гом. төрки *ҡотар-*, кырг. *ҡотор-,* алт. *ҡодор-* id., бор. төрки (ДТС: 461) *qotar-, qotur-* id. ~ як. *хотор-* «аш бүлү; күчерү», үзб. *ҡӯтар-* «күчереп утырту», каз. (ҠТДС: 208) *ҡотару* «аудару; тәрҗемә итү; күчерү», алт. диал. *котор-, кодор-* «сүтү, җимерү, аудару», кр.-тат., төр. (Будагов II: 70) *kotar-, koutar-* «күчереп төяү; көрәкләү, көрәү; аш бүлү» һ.б., һәркайда **актару** белән контаминацияләнә, ләкин *актару* белән тамырдаш түгел. **Куптару** белән тамырдашлыгы да шикле. ЭСТЯ VI: 85–86.

Дерив.: **кутарыл-у, кутарт-у.** Диал. (ЗДС: 431) **кутарын-у** «чишенү» *кутар-* нигезеннән микән – әйтүе кыен, һәрхәлдә алт. *котор-* «сүтү» фигыле дә бар.

**КУТКУЗЫ** (ЗДС: 431) «разноцветные оборки лаптей; нарядная обувь марийского типа» < мар. *кудкозы* id.

**КУТЫР I** «короста, струп; парша» > чув. *кутăр*, мар. *котыр* id. < гом. төрки *ҡотур*, төркм., аз. *готур* id., алт., тув. *кодур* «кутыр, кычу; шадра», чыгт. *котур-* «кутырлау» (к. Радлов II: 609) ниндидер **кот* тамырыннан. Чаг. тув. *ходуй-* «тырпаеп тору», монг. *ходугур* «тырпа». Федотов I: 317 (гаҗәеп рәвештә тат. һәм гом. төрки параллельләрен бөтенләй белми); Будагов II: 70–71; ЭСТЯ VI: 86–87.

**КУТЫР II** диал. «хутор» (ТТДС I: 212; БҺҺ II: 119), «окольный; окрестность» (ЗДС: 349) ~ чув. *ҫуттăр* id. (Сергеев 1978: 36) < рус. *хутор*, диләр, ләкин бу рус сүзенең канәгатьләндерерлек этимологиясе юк; чаг. удм. *котыр* «тирә-юнь, түгәрәк»; иске тат. **кŏтур,** төр. *kutur* «диаметр; тирәлек» < гар. *ḳутр* «диаметр; әйләнә-тирә» < лат. *quadra* «дүрт тараф, дүрткел, квадрат».

**КУ-У** «гнать; преследовать» < гом. төрки *ḳу-, ḳуw-, ḳов-, ḳоғ-* (к. Радлов I: 813), башк. *ḳыу-ыу,* чув. *ху-, хăв-,* хак. *хоғ-* id. Чыгт. *ḳоғ-, ḳуғ-*, вариантлары иске тат. *ḳуғ-* рәвешендә чагыла (Н. Думави, «Мәхбүс»). Чаг. ир. **kū, *kav-* «кычкыру, акыру» (Абаев I: 591).

**Ку-у** фигыленең кабатлаулы дәрәҗәсе *куала-* ~ чув. *хăвала-*, алт., кырг. *ḳубала-* киң таралган. К. ш. ук к. **Ҡаула-у**. Будагов II: 97; Räsänen: 275; ЭСТЯ VI: 9–10; Федотов II: 315–316.

Дерив.: **куыл-у, куыш-у, кудыр-у.**

**КУФАЙКЫ, куфайка, куфай** диал. «фуфайка» > удм. диал. (Насибуллин: 121) *купайка,* мар. диал. (Саваткова: 179) *куфайкы,* чув. *хухайка, хухвайка* < рус. диал. *куфайка, хвуфайка* < *фуфайка* (бу сүзнең чыгышы ачык түгел, әмма ул шиксез рус сүзе: *-ка*).

**КУЧАРКА, кучарга, куцарка, күчәркә, күчәргә** диал. (миш., Һ. Такташ һ.б.; ЗДС: 340, 341, 361) «кочерга» – рус. теленнән булса кирәк, рус телендә исә төрки алынма булырга тиеш. К. **Күчәр.**

**КУЧАТ [кучат]** диал. «петух» < рус. «кочет» id. (түбәндә, ихтимал, төрки сүздер). К. **Таңкучат.**

**КУЧКАР I,** себ., миш. **куцкар**, себ. (ЗДС: 418–419, 432) **ḳŏцкар, ḳŏчḳŏр, коча** «баран-производитель; бойцовый баран-чемпион» < гом. кыпч., чыгт., уйг. *ḳочḳар* (> башк. *ḳусḳар,* нуг., каз., к.-калп., тув. *ḳошḳар*), кырг., алт. *ḳочḳор* (> хак. *хосхор*), кар., к.-балк., гаг. *ḳочхар*, төркм., госм. *ғочғар* < бор. төрки (ДТС: 451) *qočqar, qočiŋar* id. ← тат. диал. (ЗДС: 432) **коча, куч,** кар., гаг., чыгт., госм. *ḳоч* < бор. төрки *qoč* ~ аз., төркм. *ғоч* ~ калм. *хуц, хуцу*, бур. *хуца*, кырг., алт., монг. *ḳуча* «(печтерелмәгән) сарык тәкә се», күч. «дәртле егет, көрәшче». Себер төркиләрендә (к. Сатлаев Ф.А. Старинный обряд испрашивания плодородия у кумандинцев // Религиозные представления и обряды народов Сибири. Л., 1971: 130–141) *коч, коча, хоч, хоча* «шәһвәт һәм



үрчүчәнлек тәңресе». Бу тәңре бор. археологик ядкәрләрдә кат-кат мөгезле кучкар рәвешендә табыла. Ирани культларда да падишаһлык рухы – коты *hvarna, hvarr* > фар. *фарр* «уңыш, бәрәкәт, үрчү һәм дан рухы» сарык тәкәсе, кучкар рәвешендә сурәтләнгән (к. МНМ I: 557) һәм **кучкар** сүзенең – **ҡар** өлеше шул *hvar* сүзеннән килергә мөмкин. К. **Кучкар II, Кuччак.** ЭСТЯ VI: 87–89 (**коч** матдәсендә). Торма Й. Этимология одного бродячего слова венгерского происхождения в башкирском языке // Tatarische etimologische Studien. Szeged, 1988: 232–238 (мәкаләд **күчәр** сүзенә багышланган, ләкин **кучкар** сүзенә дә зур урын бирелгән: венг. *kos* «кучкар»). Аникин: 308, 338–339 (рус. *кочкор* һәм *куцан* «кучкар» тур.; күп материал һәм әдәбият).

**КУЧКАР II** «улитка, раковина улитки» – **кучкар I** сүзеннән («чөнки аның тәкә мөгезе кебек уралган кечкенә кабырчыклары була»; к. Алпаров Г. Дөнья эчендә дөньялар // «Шура», № 2, 1922: 38–39).

**КУЧКАР III** «полка у печки; светильник с лучиной» – к. **Кучкар I,** чыра кыстыру өчен тәкә чирәбен бәхеткә дип мичкә беркетеп кую гадәтеннән (*тәкә башы* кыз бирү – кодалау гадәтендә дә бәхет билгесе).

**КУЧКЫЛ** «тёмно-красный, тёмно-красный оттенок» << кырг. *ḳочкул*, каз., к.-калп. *ḳошḳыл* id. *күч* < *коч* < *кош* тамырыннан (*-кыл* – аффикс). Аръягы билгесез.

**КУЧТЫ** диал., тар. «молодой друг; оруженосец», при обращении к молодым **кучтым** «дружище; дружок» ~ башк. *ḳусты* «туган; батрак; ярдәмче», нуг. диал. *ḳоччы*, нуг. *ḳошшы,* к.-калп. *ḳосты* «юлдагы хезмәтче; дәрәҗәле кешенең яраны», каз. *ḳосты* «юлчы; юлга алган хезмәтче (егет), дая (хатын), нөгәр», кырг. *ḳошчу* «озатып баручы; батырның ат караучысы» һ.б. гадәттә гом. кыпч. *ḳош* «юлдагы куыш» яки *ḳош* «куш, иптәшлек итүче» (чаг. тат. диал. **кушлык** «төп персонажга юлдашлыкка калган кеше») сүзеннән дип карала.

Ләкин к. Урта Азия һәм Иран төркиләрендә (Будагов II: 73–74) *қорчы, қурчи* (*қур* «корал») «кучты, батырның корал йөртүчесе» ~ монг. *қурчут* id. Фонетик җәһәттән *кучты* < *куччы* мөмкин булса да, *кучты* < *курчуты* id. ышанычлырак. Өстәвенә башк. *кусырсы* < *курчысы* «тәнсакчы» сүзе дә бар, к. **Курчала-у.** Монда, гомумән, төрле тамырлар контаминациясе бар бугай. Чаг. **Кушчы.**

Кайбер мәгълүматларга караганда, рус. диал. (Көньяк Себер) *кыштым* «буйсынган халык, хезмәтчеләр» сүзе дә тат. (себ. тат.?) теленнән килә икән, к. Аникин: 345. Бәлки бу сүз **кучтым** дигәннән киләдер?

**КУЧЧАК, куццак** (ДС I: 102) «баран; горячий борец» < гом. кыпч., к. ком., үзб. һ.б. *қоччақ* (> нуг., каз., к.-калп. *қошшақ*), төркм. *қочақ, ғочақ, ғоччақ,* төр. диал. *koçag* һ.б. «кучкар; шәп егет, герой; фидакяр», безнеңчә, **куч-чак** < *қоч-чақ,* ягъни *қоч* (к. **Кучкар**) сүзенең иркәләү-кечерәйтү формасы. Räsänen 1969: 296; ЭСТЯ VI: 89–90.

**КУШ I** (Тумашева 1992: 137) «шалаш; куыш» < гом. кыпч., иске чыгт. һ.б. *қош* «чатырлар теземе, чатыр; гаскәри чатыр, гаскәр лагере», кырг. *қош* «каравылчы һ.б.ш. тирмәсе, еш кына буш тора торган торак» ~ монг. *хош* «вакытлы торак» һ.б. >> рус. *кош* «ирәк (стан)», бор. рус. *кошь* «олау; хәрби лагерь» һ.б. (к. Аникин: 309). Хәз. тат. *куыш* < *қоғуш* ~ (себ.) *қо̄ғус, қо̄ғуз* турыдантуры *қуш* < *қош* белән баглы түгел. Чаг. **Кушын, Күшен.**

**Қуш** < **қош** тур. зур әдәбият бар. Doerfer III: 363–363.

**КУШ II** «двойной; парный», диал. (ТТДС I: 212) «супруг или супруга; нечто дополняющее» – тат. телендә шактый актив кулланылса да, бу сүз чув., мар., удм. телләрендә юк. Бу хәл тат. теленә дә сүзнең соңрак кергәнлеген күрсәтә. Гом. төрки *қош, қо̄ш,* төркм., аз. *ғош*, нуг., каз., к.-калп. *қос*, бор. монг. *qoc* > бур., як. *хос* бик күп мәгънәле сүз: «бергәлектәге, пар; сабан һәм үгез; лагерь; аерым торлак; шалаш, куыш; көтү; бер атлык йөк» (Радлов) – бу мәгънәләрнең уртак семемадан килгәнлеген нигезләү тәҗрибәсен Л. Будагов (II: 82–84) бирә. *Ко̄ш* «куыш, чатыр > лагерь» сүзенең **куш** белән бердәйлеге бик шикле. Әмма, **куш** һәм **куш-у** сүзләре һичшиксез уртак тамырдан. Бу тамырны Н.Н. Поппе монг. *холбу-* < **qolbu-* «кушу» белән чагыштыра (к. аның Монгольские числительные // Языковедческие проблемы по числительным. Л., 1927: 97–110).

**Куш** тамыры төрки телләрдә иң продуктивларның берсе: ул кушма сүзләр ясалуда киң кулланыла (мәс., тат. **кушаяк, кушбаш, кушбугаз, кушбуын, кушканат, кушколак, кушкөбәк, кушарлык, кuштояк, кушуч, кушъяулык,** к. ТТАС II), к. **Кушай, Кушарла-у, Кушарай, Кушуч, Кушчы, Кушыр-у.** К. **Куш-у.**

**КУШАЙ** диал. «двойник; нечто дополняющее»; чаг. үзб. *кўша*, кырг. *кошо*, аз. *гоша*, чыгт., госм., төркм., бор. төрки *qoša* «кушай; пар; куш», (ДТС: 460) *qošayu*, бур. *хошоо* «куш».

**КУШАК** «кушак, широкий пояс (ямщиков)» ~ иске тат., диал. **қоршақ** «кыршау; билбау, кушак», иске тат., диал. **куша-у** (ешрак кулланылыштагысы **кушан-у** «кушак бәйләү»; *кылыч кушану* «сугышка әзерләнү») < бор. яз. тат., гом. кыпч. *қурша-у* «урату, коршау» сүзеннән (*кушак, куша-у, кушан-у* сүзләрендә гом. өрки *-у-* саклануы аларның китап теленнән алынганлыгын күрсәтә), *кур* «билбау; түгәрәк; божра; түгәрәк табын» тамырыннан, к. **Корша-у** (*кушак* асылда **коршау** белән бердәй). Рус. *кушак* < тат. (Дмитриев 1962: 540). К. ш. ук Аникин: 340. Сөйләшләрдәге (ЗДС: 429) **курцан-у, курчан-у** «бил буу» борынгырак яңгырашта.

**КУШАМАТ** «прозвище» – гадәттә *кушым ат* сүзеннән дип аңлатыла, ягъни «өстәмә исем» була. Әмма бу – халык этимологиясе генә. **Кушамат** исә – икенче бер сүз. Себердә һәм башкортларда туйда **кушамат** «урынбасар, төп персонажларның ярдәмчесе»: **кушамат егет** – «кияү егете», **кушамат ата** «кыямәтлек ата» һ.б. (к. Башҡорт халыҡ ижады I. 1995: 539), к. каз. *кушемет,* кырг. *кошомат* «комплимент; хөрмәт, шан-шәрәф» < фар. *хош а̄мад(ед)* «хуш килдегез, хуш киләсез» – хөрмәтле кунакларга мөрәҗәгать сүз (**хуш килдегез** тәгъбире дә шуннан калька булса кирәк). Дәрәҗәле, хөрмәтле кешене исемләп әйтмәү, читләтеп атау фарсы мәдәниятендә этик норма булган, к. **Ишан.** Башк. *қушамат қыҙ* «көрәштә беренче батырга тәгаенләнгән кыз» тур. к. Бурангулов М. Сәсән аманаты. Өфө, 1995: 220–227. К. **Хушамәт.**

**КУШАРАЙ** «двойной плод (овощей и фруктов); сросшийся» < бор. *қош уруғ* (*уруғ* «орлык», к. **Орлык**). К. табышмак: *мөгезе урактай, кушарае шактай* (сарык тәкәсе, кучкар тур.)

**КУШАРЛА-У** «соединить (две части)» – иске тат. **куша-у* сүзеннән (*куша-р-ла-*), чаг. *ботау ~ ботарлау, бөгү ~ бөгәрләү.*

**КУШАЯК** «малый тушканчик» ~ кырг. *қошайақ,* каз. *қосайақ* id. < *қуш (қош) айақ* (кушаяклар арт аякларында торып сикерә-сикерә хәрәкәтләнәләр; к. ш. ук тат. *кушаяклап сикерү* ике аякны рәттән бергә куеп сикерү).

**КУШБАШ** «голавль» > удм. *кушбаш* id. < *куш баш* (бу балыкның баш формасына карап). Чаг. ш. ук башк. *қуштай* «кушбаш» (БТДҺ: 207).

**КУШМА** «небольшой плот (употребляемый как плавучее средство)» – *кушма* «кушылган; бергә беркетелгән» (к. **Куш-у**) сүзеннән субстантивация. Рус. *кошма* «сал, салчык» (< тат.) тур. Аникин: 309–310.

**КУШМАН** диал. (глз.) «репа, редька» ~ чув. *кушман, кăшман* «чөгендер», *кăшми, кушăм, кушăм* (Ашмарин VII: 62) «турнепс; шалкан, әче торма», морд. *кшумань,* мар. *ушман* «турнепс, гәрәнке, бүкән шалкан», *качушман* «ачы гәрәнке, ачы торма», *үшмэн* торма» (Саваткова: 177; Иванов, Тужаров: 75, 294). КЭСК коми. *кушман* сүзен чув. теленнән дип күрсәтә, әмма к. манси. *kas's'әt, koštәŋ, xōstan* «суганчыл үсемлек», коми. *komiz,* удм. *kutiz* «суган», венг. *hagyta* «сарымсак» (к. Редеи К., Рона-Таш А. Об одном агрокультурном термине в языках Среднего Поволжья // Turcologica к семидесятилетию акад. А.Н. Кононова. Л., 1976: 142–145). Шулай итеп, *кушман* Идел-Урал регионында таралган угор сүзе булып чыга. М.Р. Федотов (I: 267) бу сүзне бер нигезсез «чуваш сүзе» ди.

**КУШНЫ** диал. «сосед; ближайшие люди (кроме семьи)» ~ башк., каз. *қушна,* каз. *қошына,* чыгт., иске төрки (к. Räsänen 1969: 283) *qošna, qošny* «күрше; кучты», чаг. монг. *хошуун* «бер авылдан, бер тирәдән җыелган хәрби берләшмә, кушын»? Чаг. **Куншы.**

**КУШТАБАК**, диал. **коштабак** «деревянная чаша с крышкой» < бор. кыпч. *кōш* (> рус. *ковш*) «агач табак; кясә» (Zajączkowski: 141) + *табак*? **Куш табак** дип тә аңларга мөмкин (чөнки капкачы – бер табак).

**КУШТАЙ** (Тумашева 1992: 137) «в добром здравии; благополучный» < фар. *хуш таби'* яки *хуш тали'* «холкы белән бәхетле; бәхетле йолдызлык астында туган».

**КУШТАН** «угодливый; радушный», иск. «фискал, человек, близкий к начальству; сват; посредник между (русской) администрацией и простыми крестьянами; староста (у нерусских народов Поволжья)» ~ «Идегәй» дастанында *қуштан кош* – «тәхет аркалыгына төшерелгән кош – һомай кош рәсеме» (*Ал тәхетнең аркасы – Алтын йыгач, куштан кош Сайрап телгә килгәндә...*); тәхет аркалыгына шундый герб төшерү Иран шаһлары гадәте булган. К. Насыйри *куштан* «адвокат» дип аңлата һәм бу сүзне фар. *қәст* «мөддәт; дөреслек», *қәстбан* «дөреслекне тикшерүче» сүзләре белән бәйли (ЛТ II), безнеңчә, бу сүз фарс. *хош даһан* «хуш авыз» (чаг. **Хушаваз**), ягъни «татлы телле» дигән сүздән, чөнки кр.-тат. һ.б. **қуштан** «мәрәкәче, шаталак; тапкыр сүзле» (к. Будагов II: 83). Фар. сүзе монг. яуларына кадәр кыпч. телләренә кергән һәм Алтын Урда һәм Казан дәүләте чорларында административ мәгънә – «хөкүмәт агенты, гаскәр җыючы һәм хөкүмәт файдасына үгетләүче» (к. *Түрә куштансыз булмас; куштанга ышанма, кушканга ышан; кем боерса – шул солтан, кем йөгерсә, шул – куштан; начар арба юл бозар, начар куштан ил бозар* һ.б.ш. мәкальләр шуны күрсәтә, к. Исәнбәт Н. Мәкальләр III: 75, 338–339, 656), *куштан итәк* – бизәкле итәк куштаннарның махсус формасы булганлыгын күрсәтсә кирәк (кием өлешләре буларак **куштан** тур. к. ЗДС: 433).

**Куштан** сүзе тат. теленнән күрше телләргә кереп киң таралган, к. чув. *куштан, коштан, каштан* «холыксыз; усал; ил козгыны; купшы; китмән» (? к. Ашмарин VII: 64), мар. *коштан* «усал, елгыр; холыксыз», удм. *куштон* «купшы, көяз; тәкәббер», рус. *коштан, коштанник, каштан* «ил козгыны; усал; елгыр, гайяр; җыелышларда актив катнашучы; әләкче; халык адвокаты; купшы, көяз һ.б.» (СРНГ 25: 15–156, авторлар фикеренчә бу сүз русча *кошт* «иске администраторларга һ.б. бирелгән акча» сүзеннән). Тат. диал. *каштан* (ТТДС I: 235) «күрекле» рус теленнән кире алынма.

**Куштан** сүзе тур. әдәбият ишле, бигрәк тә чуваш *коштан*нары тур. к. Кузнецов 1957 (344 сәхифә!); Скворцов 1976: 73–100 (автор фикеренчә, *коштан, каштан* монг. *кашиктан* «ханның шәхси гвардиясе» сүзеннән, ләкин монг. сүзе асылда *кәшиктэн,* ягъни палаталь вокализмлы, ә **куштан** сүзенең андый варианты юк). К. ш. ук Аникин: 310;

Федотов I: 310; Ахметьянов 1981: 85–86; Тимергалин: 267–268.

**КУШ-У I** «поручить» к. **Куш-у II.**

**КУШ-У II** «1) сложить; прибавлять, добавлять; 2) поручать, приказывать (во всех основных тюркских словарях эти значения даются вместе, хотя промежуточных значений недостаточно)» – арадаш мәгънә булып «булганына өстәү» тора: *эшкә кушты → эш кушты* яки *сүз кушу → әмер (боерык) кушу* һ.б., к. чув. *хуш-,* удм. *куш-, кос-*, мар. *уш-* < гом. төрки *қош-* (нуг., каз., к.-калп. *қос-*), аз. *ғош-* «кушу; җигү; иярү; җитү; нәрсәнең булса артыннан йөрү; сыгыт әйтү», бор. төрки (ДТС: 460) *qoš-* «кушу, өстәү; парын-сыңарын сайлау; ат бәйләү; бозауны һ.б. имезү», төр. *koš-* «артыннан йөгерү; куу; гомумән йөгерү; шарт кую» – гомумән, бу сүзнең мәгъ. төсмерләре гаҗәеп дәрәҗәдә күп һәм катлаулы; фигыль грамматик мәгънәсе, шиксез, *куш* исем-сыйфат мәгънәсе белән бәйле (к. **Куш**).

**Куш-** бик продуктив нигез: **кушыл-у, кушыш-у; куштыр-у;** к. **Кушма, Кушык, Кушылдык, Кушым, Кушымта, Кушымча; Кушын, Кушынты, Кушыр-у.** К. Räsänen 1969: 283; Федотов II: 375; ЭСТЯ VI: 90–94.

**КУШЧЫ** тар. «слуга, сопровождающий в пути; стремянный» («Исмәгыйль ага сәяхәте» әсәрендә) < чыгт. *кошчы*, үзб. *кўшчи,* кырг. *кошчу*, каз. *косшы* (к. Будагов II: 83) id. *қош* «курҗын, ат йөге» яки *кош* «юл тирмәсе» сүзеннән. Чаг. ш. ук *Бер кушчыга мең башчы*, мәкаль.

Моннан тыш, төрки телләрдә икенче **кошчы** «сабанчы», ягъни «куш үгез белән сабан сөрүче» сүзе дә бар. Чаг. **Кучты.**

**КУШЫК** «строфа песни; рифмованный речитатив» ~ гом. кыпч., к. каз. *қошық,* кырг. *қошоқ,* үзб. *қўшуқ,* госм., чыгт. (Будагов II: 84) *қошуқ* < бор. төрки (ДТС: 460) *qošuγ* > төркм. *қошуг,* төркм. диал. (ТДГДС: 114) *ғошғы* «шигырь, поэма», чыгт. «икәүләп җырлау», чаг. ш. ук тув. *кожамык, кожумак, кожаң* «такмак». Бу сүзләрнең тамыры *қош-* «кушу» (һәм *кушык* < *кошық, кошуқ* «кушылган, береккән һ.б.ш.»), ләкин аның «поэтик» мәгънәсе бор. заманнарда ук аерымланган, к. тат. (ТТДС I: 259) **куш-у** «шигырь, җыр чыгару» < гом. кыпч. *қош-*, бор. төрки *qoš-* id., як. *хоһоон* (< **кошаган*) «җыр; кушык; сүз кушу» ← *хоһуй-* < *хошуй-* «мактап җырлау». Чаг. **Кушымта.**

**КУШЫЛДЫК** «приток (реки)» ← **кушыл-у**, чаг. *белдек, калдык* һ.б. (*-дык//-дек, -тык//-тек* аффиксы).

**КУШЫМ** «добавка; привитие», «приток реки» ← **куш-у** (к.). Төрки телләрдә *қошум* «кушымча; кушылдык һ.б.» мәгънәләрдә. К. **Кушымча.**

**КУШЫМАТ** «прозвище» < *кушым ат* (к. **Кушым** һәм **Ат II**). **Кушамат** (к.) исә бөтенләй бүтән сүз.

**КУШЫМТА** «добавка; припев» < гом. кыпч., к. нуг., каз. *қосымта*, кырг. *қошумта* id. *қош-* «кушу» сүзенә *-мта* кушымчасы ялганып ясалган (ягъни **кушым** нигезеннән түгел).

**КУШЫМЧА** «аффикс, суффикс» < гом. кыпч. *қошымча,* кырг. *қошумча* (> нуг., каз. *қосымша*), уйг., үзб. *қошумчә* «кушымча; туй термины – бирнә яки калым составына кардәш-ыруның кертеме, өстәмәсе» ← *куш-* < *қош-*, к. **Куш-у.**

**КУШЫМЫК** «сросшийся» – дөресрәге **кушмык** яки **кушынмак** (*-мык* < *-мук* һәртөрле авыру атамасын ясагыч кушымча).

**КУШЫН** тар. «ополчение» < чыгт., уйг. *қошун*, кырг. *қошуун,* каз., к.-калп. *қосын,* төр. *košun*, аз. *ғошун* һ.б. id. монг. сүзе булса кирәк: тув. *кожун,* бур. *хошшун* (> рус. *хошун*) ← яз. монг. *xosiγun* «район, волость; хәрби берәмлек». Doerfer III: 282; Аникин: 634. Монг. дәүләтләрендә хәрби бүлек һәм административ берәмлекләрнең бердәй аталуы – билгеле факт.

**Кушын** сүзенә мәгънәдәш **күшен** сүзе дә бар. Асылда бу сүз **куш** «саклану чарасы» (к. **Куш**) тамырыннан һәм аръергардны белдергән.

**КУШЫНТЫ** «примесь» ← **куш-у** (к.) сүзеннән закончалыклы ясалма (*-нты* кирәксез, артык һ.б.ш. компонент атамаларын ясагыч кушымча). Уйг. *қошунди*, төр. *koşuntu* «ярдәмче; ярдәмлек; тирәлек» мәгъ. дә кулланыла.

**КУШЫР-У** «скрестить руки» ~ кырг. *куушур-* (> нуг., каз. *қусыр-*) < уйг. *қавуш-ур* id. к. **Кавыш-у. Куш-у**дан түгел (югыйсә, мәс., кырг. *кош-ур* булыр иде), к. **Кап-у.**

**КУЫК** «пузырь» < гом. кыпч. *қуwық, қуwуқ,* як. *хабах* «сидек куыгы» < төр. *kavuk*, уйг., чыгт.

*қаwуқ,* бор. төрки *qavuq, qawïq* id. (МК; ДТС: 406, 438), аз. *ғовуғ* «куык»; ком., бор. төрки ш. ук «(мендәр эченә салына торган) кибәк; мамык; кабырчык» ахыр чиктә *кау* (к.) сүзеннән булса кирәк. К. ш. ук госм. *қоғуқ,* төр. *kovuk,* үзб. *ковоқ, кавақ* > фар. *кавак* «буш, куык; куыш; мурт, күпшәк». К. **Куыл.**

Кырг. *қооқ* < *қаwуқ* «җинаятьчеләрнең, әсирләрнең башларына кидерелә торган һәм дөянең чи тиресеннән эшләнгән бүрек – ул кибә-кибә кешенең баш сөяген деформацияләп, бәндәне амнезиягә китергән, бәбиләр кебек күндәм-ихтыярсыз итә торган булган (чаг. тат. диал., алт. һ.б. *ку баш* «аңсыз, хәтерсез»). Чаг. ш. ук **Куыш.**

**КУЫЛ** (Тумашева 1992: 137) «укромный угол, полость, дупло» ~ чув. *хăвăл*. К. **Куыш.**

**КУЫРДАК,** (ЗДС: 420, 428) **қуwырҗақ, қуwырдық, қуwырҗық,** себ. **қуwыртық** «мелко нарезанное и жареное мясо; шкварки» ~ нуг., каз. *қуырдақ*, кырг. *қуурдақ,* төр. *kavurdak* һ.б. (барча төрки телләрдә бар) «майда кыздырылган ит» (бу тур. к. Будагов II: 29) ← гом. төрки, бор. төрки *qawur-, qaγur-,* монг. *хаγur-* «куыру». ЭСТЯ V: 177. Рус. (< төрки) *кавардак, ковардак, ковордак* һ.б. куырдак төрләре тур. Аникин: 230. К. **Куыр-у.**

**КУЫРМАЧ, курмач,** диал. (Хайрутдинова 1993: 104) **куырма, куырган** «жареное зерно; шкварки; кавардак» > рус. *курмач* id. < гом. кыпч., алт. чыгт. *куурмач* id. – *куыр-у* фигыленнән ашамлык атамаларын ясый торган *-мач//-мәч* аффиксы ярдәмендә ясалган, к. госм. *kavurtač*, үзб. *кавурмач*, бор. төрки (МК) *қағурмач* id. (к. Гуломов А. Сўзлар хаётидан // Ўзбек тили ва адабиёти, № 6, 1996, бик күп әдәбият һәм параллельләр китерелә). Аникин: 330 (арытабангы бай әдәбият бирелә).

**КУЫР-У**, диал. (ЗДС: 371) **қаwыр-у** «жарить на сковороде; спереть дыхание (о морозе)» < каз. *қуыр-*, гом. төрки, бор. төрки, чыгт. *qawur-, qawır-* id. (к. Räsänen 1969: 220) ~ башк. *қыуыр-,* уйг. *қағур-*, яз. төрки *qoγur-*, кырг., алт. *куур-*, монг. *хуур-*, бор. монг. *qaγur-* (Поппе 1938: 297) id. К. ш. ук тув. *қаар-, хаар-* id. Ихтимал, *кау* < *қағ* сүзе белән бәйледер. К. **Курыл-у.**

Дерив.: **куырыл-у;** к. **Куырдак, Куырмач.**

**КУЫРЫЛ-У** «исхудать; сморщиться; хиреть» ← **куыр-у.** Федотов II: 317 (тат. сүзен искә алмый).

**КУЫШ I, қуwыш** (себ., к. Тумашева 1992: 154; ЗДС: 421) «открытое место в лесу, поляна». Ачык түгел.

**КУЫШ II**, диал. **күүш** «дупло; пустота, полость в теле чего-либо; шалаш; полый» ~ кар. *ковуш, кувуш* «куыш, буш; бокал», ком. *қувуш*, куман. *қовуш*, үзб. диал. (ЎХШЛ: 165) *қувуш* «куыш, уем», нуг., каз., к.-калп. *куыс, қувус* «куыш» һ.б. < бор. төрки *qoγuš* «сууткәргеч (торба яисә улак)» ~ чув. *хӳше, хушă, хуш* «куыш, шалаш».

**Куыш** сүзенә элгәр булырдай тагын өч сүз бар: 1) себ. тат. (ДС I: 96) *кугыҙ, қōгус[1], кугыс* «куыш, куышлык» (*қōгус[2]* «арка үзәге, умыртка», чаг. *qoγuš* «торба»); 2) иске тат. *куш, күш* < гом. кыпч. *қош* «арбада (каңгыда) йөртелә торган җиңел тирмә; көтүче куышы; хәрби тирмә, чатыр; хәрби лагерь» (> рус., укр. *кош*) ~ монг. *кош*; 3) чув. *хăвăл* < **кыwыл* «куыш», себ. тат. *қуыл* «почмак, ярык; агач куышы» (к. **Куыл**) ~ хак. *хоол*, тув. *коңгул* ~ монг. *qobul*, калм. *xowl* (Räsänen 1969: 275) «куыш, куышлык». Болар барысы да бер нигездәнме, аныcын кистереп әйтеп булмый. Һәрхәлдә **куыш**ның тамыры – гом. алт. *коң* «уем, куышлык» (онопоэтик сүз) булса кирәк, ясалышы бигүк ачык түгел (к. *култык* < *куңылтык*). К. **Куык, Күш.**

Бор. *кош, коуш* «агач чүмеч» сүзеннән рус. *ковш* сүзе килә (ләкин бу версияне рус телчеләре кире кага). Рус. *кош* «ирәк, утар, күчмәннәр авылы» тур. Аникин: 309. К. ш. ук Федотов II: 376.

Дерив.: **куышлы, куышсыз; куышлык; куышлан-у.**

**КУЮ** к. **Куй-у**.

**КУЯК [қуйақ]** (Тумашева 1992: 132) «латы» < гом. төрки *қуйақ* id.; к. **Кыяу**. ЭСТЯ VI: 111–112.

**КУЯН [қуйан]** «заяц» < гом. кыпч., урта төрки *қойан*, алт., шор. *қозан, ходан* һ.б.ш. хак. *хозан, хōзан*, як. *хотон-ох*, алт. диал. *кöйöн* id.; тув. *қодан* «куян, көтү, табун, табыр» (? куяннар көтүләре белән йөрмиләр, монда ике сүз булса кирәк), *қойғун* «куян; куркак» ← *хой-, кой-* < *qor-* «курку» сүзеннән, ди Räsänen 1969: 278). Ни өчендер бор. төрки сүзлектә *куян*га охшаш сүз юк. Чув. *хоран, хуран* «куян» тур. к. Корнилов 1971: 29–36. Чув. *хоран* < **хораган* «курка торган» булуы бик ихтимал, әмма семантик җәһәттән бу версия безне бигүк канәгатьләндерми: куркак җанварлар бер куян гына түгел!

Рус. диал. *койон, куян* тур. Аникин: 341 (шунда ук – әдәбият). Федотов I: 319; ЭСТЯ VI: 29–30.

**КҮ** (ЗДС: 343) «слава» – «аваз, тавыш; дан» (**кү** ~ **көй** сүзе белән бердәй дип карала, ләкин бу дөрес түгел) ~ бор. төрки (ДТС: 322) *kü, kǖ* «атчап, дан». Räsänen 1969: 306. К. түбәндәгене.

**КҮӘН-Ү** диал., иск. «почувствовать гордость, удовлетворение» (сөйләүчеләр аңында **куан-у** белән бутала) < чыгт. (к. Будагов II: 168–169) *күwән-*, төр. *güven,* бор. төрки (ДТС: 304–305, 330) *kewän-, kevin-, küvän-* «үз-үзенә ышану; горур булу, мактану». Иске угыз, төркм. (Мухамедова 1973: 84) *гүwән-, гүвен-* «мактану». ***Кү-** яисә ***күә-** фигыленнән булса кирәк.

Тагы бер тапкыр әйтик, **күәнү** ул *куану* түгел!

**КҮӘС, күәс чиләге** (Хайрутдинова 2000: 12) «квашня (сосуд)» – диал. **кыwас, куwас, куwашна, күәшнә** (Троянский II), **кеwәшнә** (Остроумов) һ.б. ~ чув. *кӑвас* id., мар. *куашна* «тесто» < рус., әлбәттә.

**КҮБӘ** «копна, копёнка» ~ кр.-тат. (Dobr. II: 402) *küpen* «кибән», чув., рус. *купа, копа*, рус. диал. *копень* һ.б. – бер яктан каз. (ҠТДС: 159–160) *кöбе,* нуг. *күпен*, хак. *кӧпэн*, тув. *хөпээн* ~ бур. *гүбөөн* «өем, күбә», икенче яктан эстон. *kubo, koop*, фин. *kupo, kuuppo* id. белән баглы булала. Чаг. ш. ук фар., төр. *küme* «өем, өер; күбә», к. **Күп**. Бу сүзнең *-на//-нэ* белән киңәйтелгән варианты тат. (ТТДС I: 257) **купына** ~ рус. *копна* < *копъна*, морд. *копуня*, каз. (ҠТДС: 175) *күпэнә* «күбә» ш. ук рус-слав. даирәсендә дә, төрки телләрдә дә (**күп-* «җыю» фигыленнән) килеп чыгарга мөмкин. Гомумән, **күбә**, күрәсең ностратик тамырларның берсе, к. Фасмер II: 418–419; Kluge: 396; Федотов I: 308–309 (арытабангы әдәбият күрсәтелә); ЭСТЯ VI: 80–81.

Дерив.: **күбәле; күбәлек; күбәлә-ү.**

**КҮБӘГӘЙ** «повышенный край круглого перемяча и т.п.» ~ кырг. *көбөө* «кием кырыеның калкып торганы, кырпу һ.б.», монг. *гүвээ* «валик», *хөве* «нинди дә булса яссылыкның кабарынкы чите». К. каз. (ҠТДС: 160) *көбелеү* «су җыелсын өчен яссылык тирәли туфрак өю». Чаг. **Күбәлек, Күбәтә.**

**КҮБӘК I** иск. «пуп, пупок (в особенности младенца)» ~ чув. *кӑвапа* < бор. төрки *kööbek* ~ төркм. *гөөвек,* төр. *göbek* id. Мухамедова 1973: 124. К. **Аккүбәк.** К. түбәндәгене.

**КҮБӘК II**, диал. **көбәк** «ствол ружья; деревянная труба (специально высверленная) для различных целей; било цепа (для крепости привязки оно наполовину высверливается трубкой, туда вводится ременной узел)» – асылда *күп** «куыш агач» сүзеннән кечерәйткеч форма (деминутив), к. себ. (Тумашева 1992: 100) *көбәк* «агач чиләк, кәстрүл, кое бурасы», башк. *көбәк* «күбәк; самавыр торбасы», *көбөсәк* «агач купы» ← *көбө* «озын (биек) чиләк, майязгыч» (к. **Гөбе, Көбе**) ~ каз. *күбби*, алт., кырг. *күп*, үзб., таҗ. *гуппи*, үзб. диал. *күпи* «гөбе», аз. (АДДЛ: 275) *күпи* «шүре, камыш, көпшә» ~ удм. *гумы*, фин. *kääti*, саам. *габме* «күбәк, көпшә» (В.И. Алатырев чагыштыруы) һ.б. (охшаш сүзләр һинд-ир. телләрендә дә очрый) – бор. (фин-угор?) **köbbä* «эче куыш кәүсә» сүзеннән; бор. тормышта үзәге куыш (уелган) агач күп нәрсәгә кулланылган – аннан һәртөрле торбалар, савытлар, шүреләр, тәгәрмәчләр ясаганнар, к. **Кәүсә, Көпчәк, Көпшә.**

Тат. диал. (Тумашева 1992: 92) **кәбәк** «күбәк» болг. **күәбәк (ö > үә)* яңгырашыннан. Чаг. ш. ук *кәүсә* < **күәвсә*. Төр. *göbek* «көпчәк; кендек; үзәк» (> чув. *кӑвапа* < болг. **күәбәг* id.) сүзе дә *күбәк* сүзенә иш булса кирәк («*кендек бавы*» > «торба»), к. ЭСТЯ III: 52.

Башк. *күбәмә* «юкәнең тоташ салдырылган кабыгы» элек **күбә* дигән фигыль («торбалау, торба ясау») булганлыгын күрсәтә шикелле.

**КҮБӘЛӘК** «бабочка» < гом. кыпч., к. нуг. *күпелек,* к.-балк. *гөбелекке*, куман. (Радлов II: 1315) *кöбäлäк*, алт., кырг. *көбөлөк, көпөлөк* ~ к.-калп., төр., төркм. *gübelek, göbelek* һ.б. id. беренче иҗектә *ә ~ э* булган вариант киң таралган: төр., төркм. *kebelek ~ kelebek*, куман., бор. чыгт. (Боровков 1963: 168) *кäбäлäк*, уйг. диал. *кәпәләк* һ.б., к. ш. ук бор. төрки (Räsänen 1969: 290) *köbäli* «күбәләк»; боларга охшаш сүзләр бүтән телләрдә дә очрый: осет. *гәләбу, гәбәлү* «күбәләк»; рус. *кобылка* «саранча; чикерткә»; удм. *кöбöле* «май коңгызы». Будагов II: 141; ЭСТЯ V: 13–15 (бик күп һәм артык төрле мисаллар китерелә). Гомумән – ачык түгел.

**КҮБӘЛЕК** (ЛТ II: 69) «стелька (с приподнятыми краями); каблук» ← (Тумашева 1992: 205) **күбә** «колыбель, люлька в виде корыта; боковые доски колыбели» ~ каз. (Катаринский) *кöбе* «кырый; җөй; кырые күтәренке яссылык», кырг., алт. *кöбö, кöбöö* ~ яз. монг. *köbüge* (> бур. *көбөө,* калм. *кöwее*) «кайма, кырпу; күбә» ~ эвенк. *кувэ, куво* «куныч кайтармасы» һ.б.; бу сүзләрнең фигыль коррелянты

тат. диал., башк. (Радлов II: 1519; ТТДС I: 278; БТДҺ: 148) **күбе-ү, көбө-ү** < бор. төрки (ДТС: 311) *köbi-, kübi-* «калын сыру, калын материяне (тирене һ.б.) тегү», себ. «итек тегү» ~ төркм. (к. ЭСТЯ V: 111) *кöпе-*, төр. *körü-, göbü-* «калын сыру», алт. диал. *күбүр-* «тирәли сыру». Ramstedt 1935: 242; Räsänen 1969: 285; ССТМЯ I: 143. К. **Күбәгәй.**

Рус. *каблук* < төрки *köbülük* булса кирәк, к. монг. *гүвээ* «тау теземе; кырый мендәр (рус. “валик”)».

**КҮБӘТӘ** «деревянная чашка» (ТТДС I: 278; БҺҺ II: 114), диал. **күәтә, күбәтәй** id. < монг. *кöбүтәй, кöбүүнтәй* «корсаклы», к. чыгт. *kör, körü* «чите кабарынкы савыт» < монг. *кöвöö* id., к. **Күбә.** Чаг. **Чүгәтә < Чүгәтәй.**

**КҮБЕК** «пена» < гом. кыпч., уйг,. алт. *кöбүк*, чыгт., угыз. *кöпүк*, тув. *кöвүк* id. ← *кöп-* «күбү» фигыленнән; чув. *кăпăк* тат. сөйләшләреннән булса кирәк (миш. диалектында гиперсынылыш *ö* > *ү* > *ө* күзәтелә һәм **көбөк** яңгырашы була ала); к. ш. ук тат. диал., башк. диал. (Арсланов 1988: 86; БТДҺ: 164) **күперек** «күбек». Кайбер телләрдә (аз. һ.б.) *кöп* «күбек».

Бор. монг. (Поппе 1938: 220) *kögesün* «күбек» < **köbüge-sün* булырга тиеш. К. **Күп-ү.** Федотов I: 255–256.

Дерив.: **күбекле, күбексез; күбеклән-ү.**

**КҮБЕН-Ү** «переедать, страдать от переедания», күч. «завидовать, злословить от зависти» ← **күп-ү** (к.).

Дерив.: **күбенеш-ү, күбендер-ү.**

**КҮБЕР-Ү,** (Будагов II: 142) себ. **кӱбӱрмек, кӱбӱрӱнмек,** казан тат. **кӱбренмек** «журить» ~ төр. *кӱфремек* id. диелә һәм **көфер** сүзенә нисбәтләнә. Штойервальд сүзлегендә *küfretmek* < *küfür etmek* «сүгенү, каргану; сүгү», ләкин *köpürmek* «ярсып ачулану» сүзе дә бар («күперү»гә нисбәтләнә). ЗДС (: 343) **күбүрүнцәк** «бәйләнчек» сүзен генә бирә.

**КҮБҮ** к. **Күп-ү.**

**КҮВӘРИК, күwәрик** (ЗДС: 343) «бурундук, вид бурундука» ~ алт. (Баскаков 1966: 128) *кöрүк* «борындык». Ачык түгел.

**КҮВӘЧ [күwәч], күwәц** (ЗДС: 343), брб. (Радлов II: 1417) **күйәҗ** (*кӱјӓǯ* дип язылган) «кувшин» ~ НФтә *күвәҗ,* бор. угыз (Мухамедова 1973: 129) *күвеч,* төр. *güveč* «көршәк», «чүп чүлмәге», алт. *кööш* «көршәк». Бор. төрки **kögäč* булырга тиеш. **Күәс чиләге** белән чагыштыру проблематикалы. Чаг. ш. ук төр. *küvet* «һәртөрле әрсез савыт: кер юу һәм юыну тасы, ванна һ.б.ш.»

**КҮВЕР-Ү [күwĕр-]** иск. «совершить, сделать». Иске яз. телдә һәрчак кулланылган, ләкин язылышта чагылдырылмаган, бары тик шигырь үлчәменнән генә беленә, мәс., Максудидә *Басра эчрә хур күwерден сән мәни* диелгән. К. **Күр-ү II.**

**КҮГӘВЕН [күгәwĕн]** «синяя муха; овод», себ. (Тумашева 1992: 106, 91) **күгәүен, күгүөн, көгүүн, кәгәүен** «овод» < гом. кыпч., к. кырг., алт. *кöгүүн* id. < бор. төрки (ДТС: 313) *kökägün* «(күк) чебен» ~ аз. *гöгöүн*, төркм. *гöгейин*, төр. *göveğen, göveğin* һ.б. ← *күк* < *кöк* (к. **Күк II**). Бу сүзнең вариантлары бик күп, к. ЭСТЯ III: 55–56. К. **Кигәвен; Күгәл.**

**КҮГӘЛ** «селезень», диал. (ЗДС: 343) «утка (вообще)», (Тумашева 1992: 105–106) «вид диких уток, утка-зеленоголовка» < себ. (Дмитриева 1981: 160) *кöгäл* «үрдәк» ~ алт., кырг. һ.б. *кöгöл* >> госм., төр. (Bozqaplan: 62) *gögel, gövel* > Д. болг., укр., рус. *гоголь* > «ата үрдәк; кыр үрдәге төре» ~ каз. *кöгӭэл* «җете яшел» < бор. **кöкэгүл* булса кирәк (*кöкэ* «күк, яшел», *-гүл* төс атамалары ясагыч кушымча), шуннан ук **күгәвен < *күгәвел** дә булала. Räsänen 1969: 287; Федотов I: 246 (чув. *кăвакал* < болг. *күәгәл* < *кööгэл* «үрдәк»).

Рус. *гоголь* тур. Аникин: 167 (рус этимологлары бу сүзнең төрки телдән алынганлыгын инкяр итмәкче, ләкин аларның фикерләре нигезсез).

**КҮГӘМӘЙ, күгәмә, күгемә** (ЗДС: 343) «черника», «тёрн», «голубика» – Себердә, Уралда һ.б. төбәкләрдә таралган сүзләр – тат. (төрки) *күк* һәм фин-угор *маль* «җиләк» сүзләре нигезендә ясалганнар. Чаг. **Күкмал.**

**КҮГӘН I,** диал. **күңән** һ.б. (Будагов II: 158) иск. «верёвка, к которой привязывают барашков – она имеет петли с пуговками, обхватывающие шеи животных», (Радлов II: 1426) «крюк, на который сажаются дверные петли (ось на кронштейне, на которую надевается трубчатая железная полоска, прибиваемая рядом гвоздей, шурупов к дверям)», вообще «крепление двери к косяку», «шарнир», «дверной крючок» > мар. *кöган* «каплавычлы

тимер тотка (рус. “скоба с накладкой”)», *кӧгӧн* «йозак, бик», удм. *кӧгӓн* «күгән» ~ чув. *кӑкан* (*кӧган* < **көгән*) «чиләк һ.б.ш. колагы, чабата колакчасы» < гом. кыпч. *кӧгән*, к. башк. (БТДҺ: 158) *күгәнәк,* каз., к.-калп. *күген, кӧген,* кырг. *кӧгӧн*, үзб. (ЎХШЛ: 148 һ.б.) *кӧгән*, сары уйг. *кӧкен, кӧкән*, к.-калп. < төркм. *гүвен, гүwән* < бор. төрки (М. Кашгари һ.б. чыганаклар буенча) *kӧken* ~ бор. монг. *kӧgene* һ.б. «күгән». Озак гасырлар буенча төрки-монг. халыклары тормыш, көнкүрешенә иң характерлы, иң гадәти-таныш нәрсәләрнең берсе – «терлекне бәйләп кую өчен казыкка бәйләнгән озын бау, аркан; элмәкле бау», бигрәк тә – «күчерелмәле казыкның үзе» – бор. төрки *kӧk* (> чув. *кӑк*) «казык, чөй, тамыр» сүзеннән; бу тамырдан *kӧk-ӥ-* «күчерелмәле казыкка бәйләү» фигыле (> чув. *кӑка-, кӑкар-* id., як. *кӧхӧ* «чөй»), шуннан **kӧkӓgӓn* «күгән» сүзе ясалган: бәйдәге терлек казыгы тирәсендә әйләнгән шикелле, ишек тә күгән тирәсендә әйләнә. К. **Күгән II, Күклә-ү.** Федотов I: 248–249; Räsänen 1969: 287; ЭСТЯ V: 93–94.

Дерив.: **күгәнле, күгәнсез; күгәнлә-ү.**

**КҮГӘН II** «тёрн; колючка на стебле растения; терновник, чемерица» ~ удм. *кекон, кэкон*, мар. *кекен*, чув. *кикен* ~ кр.-тат. *кӧгем,* госм., гаг. *кӧқӓн, кӧкән* «үсенте; мыекча, тикән», төр. *kӧkӱn* «җиләк куагы; туган як» ← *kӧk* «тамыр». Монда ике нигез контаминациясе булырга мөмкин. Һәрхәлдә «тикән» мәгънәсе **күгән I** дән (аның «казык» мәгънәсеннән) булса кирәк. К. ш. ук як. *кӧгӧ* «ыргак; кармак» ~ монг. *хӧхӧ, кӧхӧ* «ыргак; казык». Федотов I: 291, 319–320.

**КҮГӘРЕК** «плесень» ← *күгәр-* < гом. төрки *кӧгәр-* < бор. төрки, гом. төрки *кӧк* «күк; яшькелт».

**КҮГӘРЧЕН**, диал. **күгәлцин, күгерцен** һ.б. күп вариантлар (к. ЗДС: 343–344) «голубь» > башк. *күгәрсен,* чув. диал. *кӳкерчен*, мар. *кӧгӧрчен, кӧгӓрчын* ~ чув. (болг.) *кӑвакарчӑн, коакарчан* һ.б. id. < гом. кыпч., к. нуг., каз. *кӧгершин,* к.-балк. *кӧгүрчүн,* кырг. *кӧгүрчкен* id. – бу вариант бор. вариантка иң якыны, к. бор. төрки (ДТС: 313) *kӧkӧrčkun, kokorčkӓn*, бор. монг. (Владимирцов: 225) *kӧgӱrǯirgene, kӧgulǯirgene* > хәз. монг. *хӧгүлзиргэн* «күгәрчен», к. ш. ук угыз. (төр.) *gӧverçin* һ.б.; чув. (Сергеев 1971: 74) *коакарччӑ*, мар. (Иванов, Тужаров: 102) *күгерцы,* удм. *гӧгӧрчи* «күгәрчен» бор. чыгт. (Поппе 1938: 224) *kӧgӧrçi* вариантын хәтерләтә. К. ш. ук венг. (Gombocs: 102–103) *kokorcs, kokorchun* «күгәрчен» һ.б. (күп күрше телләрдә очрый). ЭСТЯ V: 57–59.

Барча китерелгән формалардан иң борынгырагы – бор. монголчасы. Бу сүз, әлбәттә, *күк* < *kӧk* сүзеннән, ләкин сүзнең ясалышы томанлы. Семантик җәһәттән к. рус. *голубь ~ голубой*, фар. *кабутар* «күгәрчен» – *кабуд* «күк, зәңгәр», осет. *әхсинәг* «күгәрчен» – *әхсин* «куе зәңгәр» һ.б. Сафина 2006: 36–37.

**КҮГЕЗМӘК, күгезмөк, күгесмәк, күксемәк** (Тумашева: 106; ЗДС: 343–344, 348) «стёганый жилет; меховая душегрейка», иск. «шлея, совокупность ремней, которые надеваются на рабочую лошадь» < бор. төрки (ДТС: 313) *kӧkӱzmӓk* «күн куртка, күн камзул төре». К. **Күлмәк.**

**КҮГЕЛ, күгеләк (< күк йеләк), күкмаль (< күк маль)** «черника», **күгемәй, күгүмәй** «слива» (к. ЗДС: 343, 344, 348) – бу җиләк исемнәре Татарстанның һәм Башкортстанның төньяк районнарында һәм төньяк күрше өлкәләрдә таралганнар. *Маль ~ мәй* фин-угор телләрендә «җиләк».

**КҮГЕРТ, кӧгӧрт, күкерт, күкүрт** (ЗДС: 322, 343, 348) «гром, гром и молния», себ. сөйләшләрендә саңгыраулашкан анлаутлы бу сүзләр **гүгерт* < *гүргүрт* < *гӧргӧрт* яңгырашыннан килә бугай. Ясалыш моделе ачык, чаг. *гөлдерт, гөрт,* ш. ук *гөр-гөр, гөрелдә-ү* һ.б. Тик бүтән төрки телләрдә мәзкүр сүзләрнең охшашларын тапмадык. Чаг. *күкрә-ү* < *күркүрә-ү.*

**КҮДӘЗ, күдәс, күтәс** (Тумашева 1992: 106, 112) «ребёнок, малыш, который передвигается сидя» ← *күдә-, кӧдә-* «утырып шуышу (сабый бала тур.)». Чаг. ш. ук каз. (ҚТДС: 160) *кӧдек,* төркм. *гөдәк*, үзб. *гӯдак* ~ фар. *гудак* «утырып шуыша торган бәби; бер яшьлек бәби». **Күт** сүзеннән түгел бугай. Сүзлекләрдә фар. сүзе дип бирелә, ләкин тат. сүзләре моны расламый. К. **Күзәлә.**

**КҮҖӘ** «каша из цельных зёрен (нового урожая, ритуальная)» ~ башк. (БТДҺ: 161) *күзә* id., (БҺҺ II: 115) «ячменный суп», себ. (Тумашева 1992: 112), по В.В. Радлову «плов из очищенных зёрен ячменя» ~ каз., к.-калп. *кӧже, кӧжçе*, кырг. *кӧжçӧ,* уйг. *кӧжçә*, тув. *кӧжэ*, бор. чыгт. *kӧče, gӧӂӓ*, госм. *гүчэ* «күҗә (чөгердән, ш. ук арпадан, бодайдан һ.б.)» (к. Поппе 1938: 307; Төхфәт… 1979: 289), алт. *кӧчӧ, кочо*, монг. *кӧзӧ* «арпа өйрәсе; көмән»

һ.б. Күп күрше телләргә кергән, к. манси *kütsä* «арпа буткасы» (Kannisto 1912: 134) һ.б. K. Räsänen 1969: 286; ЭСТЯ V: 84–85 (бай материал китерелә).

**Күҗә** – күп телләрдә ритуаль ризык; Нәүрүз бәйрәмендә **күҗә**не җиде төрле ашлыктан пешергәннәр (бу хакта бай этнографик әдәбият бар). Түбәндә бу сүз кыт. *ку цзу* > уйг. диал. *кудза* «тары сорты» сүзеннән килсә кирәк (кытайларда да яңа уңыш яисә яңа ел буткасы пешерелә).

**КҮЗ I** «глаз (төрле күч. мәгъ. белән)» < гом. кыпч., алт., уйг. һ.б. *көз*, угыз. *гөз* < (безнеңчә) **көрҗ* < **көрг*, к. чув. *куç* < *курҗ* < **көрҗ*, Г. Рамстедт (1957: 132) фаразынча, **кө-* тамырыннан, шуннан *көр-* > *күр-ү* (к.); *күз-* < *көз-* дигән фигыль дә бар (ЭСТЯ III: 77–79).

**Күз** сүзе белән ясалган бик күп идиомаларның кайберләре этимологик аңлатмага мохтаҗ. **Күз ату, күз ташлау**, ихтимал, фар. *чәшм әндахтан* тәгъбиреннән калькадыр. **Күз кешесе** – кешенең күзенә караганда анда үзеңнең чагылышыңны күрүдән. **Күзе яры-у** «корсактагы бәбинең күзе ачылу – бәби туарга якынлашу»: *яры-у* монда «яктыру» (чаг. хак. *харачы чары-* id.). К. ш. ук Будагов II: 152–154; Федотов I: 310–311; 314–315.

**Күз** сүзе тат. телендә иң күп дериватлы нигездер, мөгаен, к. тамыры **күз** үзе генә булган ясалышлар: **күз-күз**; **күзгә-күз**; **күзмәкүз** (бөҗәк); **күзәләмә** (өеп һәм иң өстенә чокырчык ясап), **күзәлә-ү**; **күзәнәк, күзәт-ү, күзә-ү, күзлә-ү I** (энә күзенә җеп кидерү); **күзлә-ү II; күзле, күзлек** һәм **күзелдерек** (рус. «шоры»); **күзләвек; күзсез; күзчел** «күз тидерүчән (субъект)» һәм **күзек-ү** «күз тию»; төп компонент **күз** булган парлы һәм кушма сүзләр: **күзәен**, **күзәфә**, диал. **күзәрәт, күзикмәк, күзкабак** (балык төре), **күзкөзге, күзлут, күзмәләк** («күз кешесе» – имеш кешене яклаучы фәрештә); ш. ук **аккүз, каракүз, тозкүз; күз-колак** һ.б. Күбесе тагын тармаклана. Бор. төрки телләрдә дә (к. ДТС: 320–321) бу сүз бай дериватлы булган. К. Рамазанова 2013: 33–50 (**күз** сүзенең төрле мәгънәләрен, **күз** тамырыннан үсеп чыккан дериватларны өч «дәрәҗәле»-этажлы корылма итеп күрсәтә, компонентында **күз** булган алтмышка якын кушма сүз һәм фразеологизмнарны китерә; әмма әле төрки телләрдә *көз* тамырыннан ясалган нигез вә сүзтезмәләрнең шактый өлеше тат. телендә дә теркәлмәгән – тагы бардыр).

**КҮЗ II** (ТТДС I: 279; БТДһ: 159, 161) «горящий уголёк» ~ урта төрки, төркм. (Мухамедова 1973: 124) *көөз*, төр. *köz*, хак., тув., алт. *көс* id., безнеңчә, *қуз* < *қоз* сүзеннән палатальләшкән. Чаг. **Күзә-ү.** ЭСТЯ V: 85 (бүтән фаразлар китерелә).

**КҮЗӘ, күзәй** «керамический сосуд (тарелка)», себ. (Тумашева 1992: 111) **күсә** «металлический чайник» ~ каз. (ҚТДС: 170) *күдәй, күзә* «күзә», кырг. *көзө*, үзб. *кўза*, диал. *көзә*, уйг. *коза, көзә* «зур чүлмәк», төр., фар. *küze*, төркм. *күйзе*, к.-калп. < төркм. *гүзе* «(керамик) купы» ~ бор. кыпч. (МК) *közüj*, бор. чыгт. (Боровков 1963: 182) *közä* «күкшин». С. Аманжолов (1959: 386) бу сүзне кыт. теленә, К. Юдахин ир. телләргә нисбәт итә. Чаг. бор. төрки (ДТС: 331) *küδäč, küzäč, küzüč* «күзә, көршәк». К. ш. ук Будагов II: 155; Özön: 179 (гарәпчәдән ди).

Дерив.: иск. **күзәгәр** «чүлмәкче, керамист».

**КҮЗӘЕН [күзәйён]**, ш. ук (ЗДС: 369, 409) **кусайтын, күсайтын, кусыңайтын** «свидание; знакомство с новым лицом; вечер в честь гостя – нового лица», **күс айтын, күз айтун** – «поздравление по поводу возвращения из дальней дороги», Әстерханда (Арсланов 1976: 66), **күзәйен булу, күзәйенгә бару (керү)** «пойти в дом, куда приехали гости» ~ кар. *көзүң айдын болсун = күзең айдын булсын* – тәбрик вә рәхмәт сүзе ~ иске төр., аз. *гөзүң айдын олсун* id., Чаг. ш. ук тат. диал. **күз айны-у** ~ «Угызнамә» телендә *көзи айнып, бала тапты* «күз яктырып китү» һ.б. Күрәсең, монда ике тәгъбир үзара алмаштырылган: 1) күз *айдын* булу, 2) күз *айнык* булу. К. кырг. *көргендиң көзү айнайт* «күргәннең күзе зурая (гаҗәпләнүдән)», хәз. төр. *göz aydına gitmek* «(кемне) тәбрикләргә бару», *gözünüz aydın!* «мәрхәба, хуш килдең!». Бик киң территорияләрдә очравына караганда, болар – бик бор. сүзләр (*күзәйен* < *күз айын* < *күз айдын*) – мөселманлыкка кадәрге тәбрик сүзләре.

**Кусайтын цырагы (чырагы)** – рус. «лучина, которую при отъезде дорогого человека прячут где-нибудь, чтобы зажечь при его возвращении» диелә. Будагов II: 153; Dobr. II: 368–389.

**КҮЗӘЛӘ, күдәлә** (ЗДС: 344) «подгузник», чаг. (шунда ук) **күдәз** «утырып шуыша башлаган бала» ~ бор. төрки (ДТС: 24) *küdäz-, küδäz-* «күзәтеп саклау» ← *küd-, küδ-, küs-* «бала багу; саклау, каравыллау; көтү көтү». К. **Күдәз**.

**Күзәлә** сүзенең ясалышы ачык түгел.

**КҮЗӘНӘК,** (БТДһ: 156–160) **күзгәнәк, күзгәнәс** «ячейка в сотах; клетка (тела); почки в

картофелине; маленький колодец» < каз. *көзэнэк, көзелек* «кирәгә челтәренең бер күзе; кечкенә күзә», кырг. *көзөнөк* «тишек», алт. *көзөнөк, көзүнөк* «тәрәзәчек, тәрәзә», уйг. *көзнәк* id.; төр. *gözene, göze* «балавыз күзәнәге», *gözenek* «челтәр күзе, тишек (күп тишекләрнең берсе)», бор. төрки (ДТС: 321) *közünük* «тәрәзә (булса кирәк)», *köznäk* «чагылыш» һ.б. *күз* < *köz* > *göz* сүзеннән «беришле күп нәрсәләрнең берсе» мәгънәсен бирә торган *-(ы)нак*// *-(е)нәк* кушымчасы ялганып ясалган. Будагов II: 155; ЭСТЯ III: 60–63.

**КҮЗӘРӘТ** диал. «осуждающий, ненавидящий или алчный взгляд» < *күз-гарәт* (*гарәт* «талаучыл кыланыш», к. **гаеп-гарәт**). Чаг. (ЗДС: 345) *күзәрәкче* «кемнең күзе тигәнен юраучы».

**КҮЗӘРБАН** тар. «смотритель дорог, мостов и переправ в Казанском государстве» (в ярлыке хана Сахибгирея, середина XVI века) < фар. *gӧẓārbān* id. *gӧẓār* «юл, үткел; урам; басма, күпер» + *bān* «карауччы». К. каз. диал. (ҚТДС: 17) *күзер* «боз өстеннәнге юл, боз күпер».

**КҮЗӘТ** «дозор; ночное (охрана лошадей ночью)» < гом. төрки *көзәт, көзэт,* уйг. *күзәт*, нуг., каз. *күзөт*, к.-калп. *күзэт* (*ӧ* > *ү* очраклары тат. теленнән түгелме икән?), ком. *гүзәт*, төр., төркм. *gözet, гөзәт* id. К. **Күзәт-ү.**

**КҮЗӘТ-Ү** «наблюдать» < гом. төрки *көзәт-* (угыз. *гөзәт-*) id. урта төрки *küzät-* «саклау, абрау», тат. диал. (к. **Күзәт**), башк. *күзә-ү* «төзә-ү; (чыбыркы сабы белән) төртеп күрсәтү» фигыленең йөкл. юнәлешеннән (мәгънәсе үзгәребрәк) килеп чыккан, әлбәттә. *Күз* < *көз* тамырыннан. К. ш. ук тат. диал. **күзәлә-ү** «күзәтү» (*Җомагыл ... әледән-әле Гөлсемне күзәли.* Ф. Сәйфи-Казанлы). ЭСТЯ III: 64–65.

**КҮЗӘ-Ү I** «помешивать огонь в костре, очаге, шуровать, не давать огню распространяться; подправлять», (ДС III: 102) «толочь белье», «очищать зерно от кожуры в ступке», далее (ТТДС I: 204) **көйзә-ү, көзә-ү** «подрезать ость, хвосты у лошадей» ~ гом. кыпч., к. башк. *күйҙә-, күҙә-,* каз. *көзе-,* кырг. *көзө-*, үзб. (ЎХШЛ: 148–149) *көөзә-* «ашлык күзәү», *күйзә-ү* «гомумән чистарту», төркм. *көвзе-* «күзәү»; тат. диал. (ДС II: 105) **күзәү** «киле», (ДС III: 66) **йезлә-ү** «киледә төю». Күпчелек очракларда бу фигыль ашлыкка нисбәтле, ләкин бу мәгъ. «киле-кисап белән эшләү» булганлыгы да ачык күренә; «кисап» мәгъ. **кисәү ~ күсәк** мәгъ. килеп чыга ала, шул фаразлардан чыгып без «учак күзәүне» дә «ашлык күзәү» белән берләштереп карыйбыз. ЭСТЯ V: 81 (бүтән фаразлар китерелә).

**КҮЗӘ-Ү II** «продеть нитку в ушко иголки» ~ башк. (БТДҺ: 160) *күзәлә-* id. әлбәттә **күз** сүзеннән (аның «якты тишек» мәгънәсеннән). К. ш. ук себ. (ЗДС: 359) **күсә-ү** «мылтык һ.б. төзәү» ~ каз. *көсе-, көзе-* «күрсәтү, төзәү; күзәтү». Чаг. **Күзәт-ү.**

**КҮЗӘФӘ** (ДС I: 119; ТТДС I: 280), **күзәбә** (ЗДС: 345) «то, что перед глазами; на виду; о́чно» ~ (Ф. Әмирхан телендә) **күз әфәсе** id., иске тат. (Троянский II: 166) **күз әбедән (< әфәдән)** «карар күзгә (на взгляд)» – **күз** (к.) һәм **әфә** < гар. *ʻаффӑ* «ачык, эчкерсез» сүзләреннән гыйбарәт.

Дерив.: **күзәфәле** «кара-каршы килеп; йөреп (уку)», **күзәфәсез** «читтән торып (уку; хөкем итү һ.б.)», **күзәфәлә-ү** «күз алдына китерү».

**КҮЗЕК-Ү (күзекте, күзегү)** «подвергнуться сглазу» ~ чув. *куҫӑх-* ~ гом. кыпч. *көзик-, көзүк-*, угыз. *гөзүк-* id. бор. **күз- < köz-** «карау, күзләү» фигыленең интенсивлык дәрәҗәсеннән (тәүдә *күзегүдән авыру* тәгъбире булган, шуннан кыскарып, мәгънәсе үзгәрә төшкән). Чаг. бор. төрки (ДТС: 321) *közün-* «күренү» ← *köz-* «күрү».

**КҮЗЕЛДЕРЕК** «наглазник, шоры» < гом. кыпч., к. бор. төрки (ДТС: 321) *közüldürük* id.: < *köz-ü-ldürük* (к. тат. *-лдырык* билгеле кушымча, к. **Сакалдырык, Тәбәлдерек** һ.б.); чаг. тат. диал. **күзелдерек** ~ каз. *көзелдерек* «буткада май чокыры».

Дерив.: **күзелдерекле, күзелдерексез; күзелдереклә-ү.**

***КҮЗЕР, күзүр**, (брб. XIX г.) **көзүр** (к. Kannisto 1912: 133) «игра в карты; козырь», хәз. себ. (Тумашева 1992: 106) **күзүр** «сарай» (биек түбәле корылма). **Кузыр** (к.) сүзенең мәгънәләре яктылыгында «кәрт» һәм «сарай» мәгънәләренең уртак чыгышы гаҗәпләндерми, к. әстр. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) *көзәр*, к.-балк. *көзүр*, каз., алт. *көзөр,* калм. *көзр* «кәрт; кәрт уены». М. Фасмерның (II: 279) бу сүзләрне рус теленнән дип раславы шик уята, рус. *козырь* сүзе үзе төрки телләрдән алынган.

Кәрт уены гомумән Кытайда килеп чыккан һәм Европада – тәүдә Австриядә – XVII г. гына таралган. Европага бу уен төрекләрдән кергән булыр-

га да мөмкин. Төрки телләрдә *қозур һәм *көзүр* вариантларының булуы аларның элекке кушма сүздән килеп чыкканлыгын һәм **қоз < қооз** компонентына палаталь яңгырашлы сүз кушылганлыгын күрсәтә шикелле (нәкъ шундый очракларда кушма сүзләрдән палаталь һәм веляр вариантлы филиацияләр килеп чыгучан). Төрки телләрдә кәрт уены терминологиясе бай.

**КҮЗИКМӘК** «лепёшка, вид лепёшки»: **күз I** (бу очракта «тишек») яисә **күз II** «утлы күмер» + **икмәк.** Тәбикмәкне тишекләр белән бизәү гадәте бар.

**КҮЗКӨЗГЕ** диал. «девичье зеркальце, носимое в кармане» > чув. *кӳскӗскӗ* id., шуннан ярымкалька удм. *синкузги* id.

**КҮЗЛЕК** «очки» (**күзлек** – сыйфат мәгъ. дә бар) > мар., удм. *кӧзлык* ~ чув. *куҫлăх* < гом. кыпч. *көзлик, көзлүк,* угыз. *гөзлүк* id., әлбәттә **күз** сүзеннән.

Дерив.: **күзлекле, күзлексез; күзлекчән; күзлекче.**

**КҮЗ-КОЛАК** «наблюдатель; свидетель» к. **Күз** һәм **Колак.** Чаг. удм. *синпель* id. (*син* «күз», *пель* «колак»).

**КҮЗМӘКҮЗ** «божья коровка (насекомое)» ~ диал. *күчмәкүч, күцсәкүц,* башк. *күс, күсапай, күсӗлӗкүс, күсӗмбей, күсӗмкүс, күсмәнкүс, күсмәкүс, күсәргән* һ.б. id. (БҺҺ II: 119; БТДҺ: 165–166) – балаларча сүз ясау моделе, чаг. ш. ук чув. *вăсă-вăс* id. Сүзнең чыгыш нигезе *күз* (бөҗәкнең аркасында түгәрәк нокталар булудан).

**КҮЗМӘ-КҮЗ** «с глазу на глаз; наедине вдвоём» < иске *күз-бә-күз*; чаг. **башма-баш.**

**КҮЗҮР, көзөр** (Тумашева 1992: 106) «сарай, навес». **Кузыр** (к.) сүзеннән палатальләшкән. К. **Күзер.**

**КҮК I** «небо; синий, сивый (о лошади), небесного цвета», диал. «зеленоватый, зелёный» < гом. төрки, бор. төрки *көк* id. (шунысы игътибарга лаек ки, ДТС *көк* дигән 11 омоним сүз бирә, хәлбуки *күк* һәм *күк* (зәңгәрсу) икесе ике тамырдан түгелдер инде) < бор. *kȫk* (угыз. *гөөк*) «күк» > чув. *кăвак* «зәңгәрсу» ~ монг. *кӧкӧ, кӧке* > бур. *хүхэ* «күк». Төрки телләрдә күп мәгънәләргә ия булган һәм күп дериватлар биргән тамырлардан, к. Номинханов 1975: 224; ЭСТЯ III: 66–68. Төрки телләрдән күрше телләргә дә кергән, к. венг. *kek* «күк». К. **Күгәвен, Күгәл, Күгәмәй, Күгәр, Күгәрчен, Күкәнәш, Күкбүре, Күмгәк, Күкнар, Күкфарыз** һ.б. К. ш. ук Будагов II: 157–158; Räsänen 1969: 287; Федотов I: 246.

**Күк <** *көк* сүзенең төрле дериватлары төрки телләрдә бихисап. Иң беренче чиратта һәртөрле чагыштыру, зурайту-кечерәйтү формалары күплеге күзгә ташлана: **күгелҗем** ~ *күгелчем ~ күгелсем; күгелтер, күгелтермә; күксел ~ күкчел ~ күкшел* (шуннан **күкшел, күкшә** – кош атамасы килсә кирәк) һ.б.; аннары беренче чиратта ясала торган сыйфатлар һәм исемнәр: *күкле, күклек* һ.б.; фигыльләр: **күгәр-ү, күклән-ү, күклә-ү**ләрдән башлап барча югарыда китерелгән зурайту-кечерәйтү формаларыннан яңа фигыльләр (алардан тагын яңа сүзләр) ясала килә. **Күк-** компоненты белән ясалган кушма сүзләр дә бихисап: сыйфатлар **күк-ала, күкбүз;** исемнәр (еш кына ялгызлык исемнәр) **Күк диңгез** «Каспий диңгезе», **Күкбүре** «мәшһүр эпик-әкият персонажы», себ. **күк аяк** «төлке төрчәсе», **күк ял** «карт бүре», ш. ук – әкият персонажы; **күк** компоненты белән ясалган кош атамалары, үсемлек атамалары: **күкбашак, күкҗиләк, күккүз, күксабак, күктамыр; күктал, күктирәк** һ.б. Бүтән төрки телләрдә дә алар санап бетергесез. ЗДС: 343–344, 346–349.

**КҮК II** себ. «корневище (трав); соска молочных желез; кол; булавка» ~ чув. *кăк* (< *кәк* < *көк*), кр.-тат., уйг., аз., төр. *kök* id. Бу тамыр сүз (иң бор. реконструкцияләнгән варианты **көңк*) төрки телләрдә иң беренчел һәм иң продуктивлардан, к. **Күгән, Күкелдәш, Күкләм, Күкләү I, II, Күксагыз, Күксәү, Күкрәк, Күкшәнәк, Күлмәк, Күмелдерек, Күңел.** Räsänen 1969: 287; Федотов I: 248 (тат. сүзен белми); ЭСТЯ V: 91–92 (тат. сүзе кителми).

**КҮК III** иск. «род» < төр., бор. төрки (ДТС: 312) *kök* id. (*kök* «тамыр» матдәсендә). Чаг. **Күкә.**

**КҮКӘ I, күкүцәк** (Тумашева 1992: 106; ЗДС: 347) «младший брат или сестра»; «любой родственник младше говорящего». Чаг. бор. төрки (МК һ.б.), гом. угыз *kök* «нәсел, ыру, чыгыш», төр. *kökän, köken, kökün* «бер төп үсемлек, уртак тамыр; нәсел, нәселдәш; ватан». Конкрет әйберлек мәгъ. чаг. **Күгән.** К. **Күк I, Күк II, Күкелдәш.**

**КҮКӘ II** «penis маленького мальчика». Ихтимал, югарыдагы сүзләр белән баглыдыр. Төрки телләрдә *penis*ны – *тамыр* дип атау очрый. Чаг. ш. ук **Күкәй.**

**КҮКӘЙ** «яйцо» ~ удм. *кукей*, коми. *кольк,* карел. *kalkku*; икенче яктан сирәк кенә төрки телләрдә дә очрый: хак. *кока,* кырг. *күкей* һ.б.; интернациональ сүзләрдән, к. рус. диал. *кока*, пол. *koko*, фр. *coco*, лезг. *кака* id. һ.б. (к. Абаев I: 505).

**КҮКӘНӘШ** «вид птицы наподобие синицы» – **күк** сүзеннән. Ясалышы ачык түгел.

**КҮКӘР, күңкәр** «столяр; плотник, наладчик», диал. (Остроумов 1876: 93) **кукар** «плотник» > мар. (Исанбаев 1978: 15) *кукарин* «ялланган һөнәрче»; чаг. бор. чыгт. *кӧнкäр-*, бор. төрки *köngär-, kändgär-, köndgür* – «ремонтлау, төзәтү, җайга салу», (Боровков 1963: 184) *кӧнкäр-* «төзәтү». **Күкәр** < ***күкәрче** (эллипсис) булса кирәк. Сүзнең тамыры тат. диал. **күн-** < бор. төрки *kön-* «тураю; төзәлү; дөрес юлга керү». К. **Күн-ү.**

**КҮКБАР: күкбар тарту** (Н. Арсланов телендә) «скачки с козлом, козлодранка» (у народов Казахстана и Средней Азии)». К. каз., кырг. һ.б. *көкбөрү тарту* «күк бүре тарту» сүзеннән: **Күк Бүре** төрки халыкларның бор. тотемы, шуңа бәйле багланышта күп кенә гадәт-йолалар булган. Бу хакта күп язылган. **Күкбар** дигәне бәлки «күк барыс» мәгъ. сүздәндер (**барыс** та төрки халыкларда изге-легендар хайван). К. түбәндәгене.

**КҮКБҮРЕ, күкалп (күгалып), күктүрк** – мифический предок тюрков – төрки халыкларның мифик атасы. **Күк бүре** образы төрки халыкларда (татарларда – Касыйм ханлыгы тарихында) Угыз хан тур. әсәрләрдә – Угызнамәләрдә еш очрый. *Өй артында дүрт бүре, Дүртесе дә күк бүре* дигән такмак-табышмактагы тәгъбир чал борынгылыктан килә. Легендага күрә, Угыз ханның гаскәрләрен шанлы яуларга *Күк бүре* ияртеп барган. Күк бүре – *Көк бөрү* белән берләштән *Буз (бөз, боз) бүре,* шуннан рус фольклорындагы *босой волк* (шуның тәрҗемәсе – серый волк), аннары угызлардагы *боз қурт* (*қурт* «бүре») тәгъбирләре кулланылган. К. Будагов I: 754; Фасмер I: 199.

**КҮКЕ, кәккүк** һ.б., диал. ш. ук (ЗДС: 365 һ.б.) **коко, күкү, күкүк, кукы, кыкы, кәүгана, кәүк** id. (гомумән бер тат. телендә генә дә күп вариантлар очрый) «кукушка» – барлык телләрдә охшаш булган атама – бу кошның бик ачык ишетелгән тавышыннан – *күкелдәвеннән*. **Күке** вариантына параллельләр: рус., чув., мар. *куку,* яз. монг. *kökü-ge, kökei*, эвенк. *кукку, кукук* һ.б. ССТМЯ I: 426. К. **Кәккүк.**

**КҮКЕЛДӘШ** иск. (Касыйм ханлыгы документларында) «молочный брат, молочная сестра» ~ үзб. һ.б. *кокилдаш* id. бор. *күкел* «ана күкрәге» ← *күк* «ими» сүзеннән. Бор. төрки, чыгт. (Боровков 1963: 182–183) *кӧкун*, яз. монг. (Поппе 1938: 220) *kö-ken* «ими, имчәк» ← *көк* «күкрәк». К. **Күк II.** Чаг. **Имелдәш.**

**КҮКЕРТ** «сера» ~ башк. *көкөрт,* чув. *кӳкӗрт, кӗкӗрт,* каз. *күкӗрт, кәӳӗрт,* к.-калп. *күкир*, нуг. *кӧкирт*, кырг., төркм., госм. *күкүрт,* аз. *күкүрд* ~ үзб. *гугирд*, фар. *гогирд*, *гугäрд* «күкерт, шырпы» гар. (> төр.) *кибрит* «күкерт» сүзе белән чагыштырыла (һәм шуннан килә дип тә тәгърифләнә). Безнеңчә, бу сүз тат. диал. **Күгерт** (к.) сүзе белән бердәй – бор. күкертле шырпы каты гына шартлап янып киткән һәм бу күренеш күкрәүгә-яшенгә охшатылган. **Кибрит** сүзе белән охшашлык – очраклы (яисә ул контаминацион тәэсир ясаган).

**Күкерт** сүзе төрки телләрдән күп күрше телләргә таралган, фар. *гүнгүрт,* к. калм. *күкр, күкүр* ~ монг. *хүхэр,* яз. монг. *хурку* «ут кабызгыч күкерт» → *хуркудэ-* «ут кабызып җибәрү» (ССТМЯ I: 478). К. ш. ук Егоров: 122; Номинханов 1975: 258; Räsänen 1969: 307; Федотов I: 320.

**КҮКЕС, күгес (күксе)** иск., кит. «грудь; сердце», себ. (Тумашева 1992: 104), алт. *кӧгүс,* уйг. *кӧкүз, кӧгүз,* куман., чыгт. *кӧгүс*, кр.-тат. *гӧкүс,* төр. (угыз). *гӧкүс, гӧгүз, гӧвүз,* төркм. *гӧвүс* һ.б. < бор. төрки *köküz* «күкрәк» < *kökür* (к. **Күкрәк**) ← *көк* (к. **Күк II**). К. **Күксә, Күксә-ү, Күкрәк**. К. ш. ук **Күкелдәш.** Räsänen 1969: 288 (тәфсилле).

**КҮКЛӘМ I** «пастбище для молодняка; первый выход на пастбище» ← **күклә-** «күгәнгә (казыклы бауга) бәйләп кую» (к. **Күк II**). К. ш. ук к.-калп. *кӧклем*, кырг. *кӧктӧӧ* «язгы көтүлек» ← *кӧктӧ-* «терлекне язгы яшеллеккә чыгару», каз., тув. *көкте-* «яшь үләндә утлау» һ.б. К. **Күк I, Күклә-ү II.**

Монда төрле тамырдан чыккан сүзләр берләшә. К. ш. ук чув. *кăкар-* < **кӧгәр-* «казыкка бәйләп утлату» (ихтимал, *кӧккäр-* сүзе булгандыр, чаг. **Сугар-у**).

**КҮКЛӘМ II** «ранняя весна» > гом. кыпч. *көклем,* уйг. *көкләм,* үзб. *кўклам*, кырг. *көктөм* һ.б. id. Гом. кыпч. *көкле-,* уйг. *көклә-,* каз. *көкте-* «яшелләнү, яшәрү» ← *көк* «күк; яшел», к. **Күк I**, **Күкләм I.**

**КҮКЛӘ-Ү I** «шить крупными стежками; пришпилить, приколоть булавками; ставить скот на привязь в поле» ~ башк. *күктә-ү* id. < уйг. *көклә-,* гом. кыпч., чыгт. *көклä-* «кадаклау, күкләү; төпләү», каз., алт., тув. *көкте-,* кырг. *көктө-* «күкләү; эләктереп кую; типчү; ямау» ← каз., кырг., алт., чыгт., төр. һ.б. *көк* «казык; тамыр; без, энә», к. **Күк II.** Будагов II: 158–159; ЭСТЯ VI: 91–92.

Дерив.: (ЗДС: 348) **күкләү, күкләк** «бәбиләр утырту өчен тупас сырылган аслык (элек иске-мосхыдан эшләнгән)», к. **Иске II.**

**КҮКЛӘ-Ү II** «красить в тёмно-синий цвет», ш. ук **күкле** «зәңгәрсу һ.б.» Кыпч. телләрендә очрый торган сүзләр. Чаг. к.-калп. *көкле-* «яшәрү, яшелләнү», *көкли* «күкле» һ.б.

**КҮКЛӘ-Ү III** «корчевать (лес, сад)» > мар. *кукла-* < гом. төрки *көкле-, көклә-,* төр. *köklemek* id. ← *көк* «тамыр». К. чув. *кăкла-* «күкләү, төпләү» ← *кăк* «тамыр; төп». К. **Күк II.** Федотов I: 248–249.

**КҮКМАЛ** (прм., ЗДС: 348) «голубика» < удм., коми. *кукмал* id. (*мал* «җиләк»).

**КҮКМУНЦАК** себ. (ЗДС: 348) «бисер, камешек голубого цвета». Бу кыйммәтле ташны зәңгәр күзле кешенең күзе тимәсен дип сабыйларның баш киеменә беркетә торган булганнар. **Күк** һәм **мунчак** сүзләреннән гыйбарәт, асылда лазурит булса кирәк. Чаг. добр. (Dobr. II: 350) *kökmoşaq* «мави (зәңгәр) мунчак, назир бунчугы»; «пәйгамбәр чәчәге (Centaurea cyanus)». Гомумән, *күкмунчак ташы* – сихерле таш, аның тур. хикмәтле сөйләкләр бар.

**КҮКНАР** «(опийный) мак; ещё не созревшие синеватого цвета коробки мака» < каз., үзб. *көкнар, köknar,* төркм. *гөкнар* id. Асылда кр.-тат., төр. һ.б. *köknar* «үзенчәлекле яшел төстәге ылыслы агач», ылыслары кыска була, лат. фәнни атамасы *Abies. Күкнар* < *көкнар* төрки телләрдә ясалган сүз (*күкарат?*) булса кирәк (**күк** тамырыннан). ҚТДС: 163.

**КҮКРӘК,** диал. **күкерәк, күгерәк** «грудь; женская грудь» (ДС III: 103) «нагрудник» > удм., мар. *кӧкрäк* id. < *көкирәк* (нуг. *көкирек*, төркм. *күкүрек* һ.б. төрле язылышларда) «күкрәк» < *көкүр-әк,* ягъни бор. *көкүр* сүзенең иркәләү-кечерәйтү формасы. К. бор. төрки *kökür, kökır* (> мар. *кӧкыр,* чув. *кăкăр* < **көгөр* ~ калм. *көкүр)* ими, имчәк», ш. ук. «күңел», к. себ. *күкрән-ү* «күңелсезләнү, көрсенү», ягъни **күңел** сүзенең «күкрәк» мәгъ. булган кебек, *күкрәк, күкер* сүзләренең дә «күңел» мәгъ. булган.

Бор. *kökür* нигезеннән киң таралган (бор. төрки һ.б.) *köküz* «күкрәк» сүзе килә, к. **Күкес**. Боларның тамыры исә бор. төрки *көк* ~ бор. монг. *kök, kökü* (хәз. монг. *хөх*) «хатын-кыз күкрәге; үзәк; тамыр» бик күп сүзләрдә чагыла. К. **Күк II, Күгән, Күңел**. Будагов II: 159; Räsänen 1969: 288; Федотов I: 249; ЭСТЯ III: 54–55; Колесникова 1971; ССТМЯ I: 255.

Дерив. киң түгел. К. түбәндәгеләрне.

**КҮКРӘКЧЕН, күкрәкчән** тар. «часть лат, защищающая грудь» ← **күкрәк**, әлбәттә; ясалышы бигүк ачык түгел.

**КҮКРӘКЧӘ** «женский нагрудник (иногда с карманами для отдельных грудей)» – **күкрәк** сүзенең «күкрәк ябуы» мәгънәсеннән (дөресрәге – **күкрәксә**).

**КҮКРӘ-Ү** «греметь» < гом. төрки, алт., уйг. *күркүрә-* id. *күр-күр* «гөр-гөр, гөрелдәү авазы» тәкълиди сүзеннән; к. яз. монг. *kürkire-,* чыгт. *kükre-* «күкрәү» (Поппе 1938: 230).

Дерив.: **күкрән-ү, күкрәт-ү.** Себ. (Тумашева 1992: 107) **күкрәк** «күгерт», **күкрәвек.**

**КҮКСАГЫЗ** «коксагыз (культурное растение, из корней которого в 30–40 гг. XX века в России извлекали каучук)» < төркм. *көксагыз* < *көкү сагыз* «тамыры сагызлы» сүзеннән. К. **Күк II.**

**КҮКСӘ** (ЗДС: 348) «грудная клетка». Бу сүздә бор. тамыр сүз *күк* < *көк* (к. **Күк II**) ачык шәйләнә. К. **Күкес, Күксә-ү.**

**КҮКСӘ-Ү,** (Тумашева 1992: 107) **көксән-ү** «болеть кашлем, туберкулезом и т.п.» ~ башк. *күкһәү,* (БТДҺ: 162) *күкһе-ү* < *күксе-ү* «ютәлле авыру; сызлаулы», кырг. *көксөө* «ютәлле карт; гомумән карт кеше» һ.б. < **көкүз-ә-* id. *көкүз* «күкрәк» сүзеннән; чаг. хак., алт., тув. *көксе-, коксө-* «ачулану, тиргәү; үпкәләү; бик теләү». Иске тат. **күксә-ү** «сугышчының күкрәгенә шайман кидерү».

**Күксәү** сүзе яктылыгында рус. *коклюш* «бума ютәл» сүзе дә төрки телләрдән дигән фикер туа (бәлки **кöкле-* «күксәү» сүзе булгандыр).

ЭСТЯ (V: 94–95) авторлары к.-калп. *кöксав* «күксәү (авыруы)», хак. һ.б. *кöксе-* «сүгү, сүгенү» сүзләрен аерым нигезләр дип аңлаталар: «ютәл авыруы» мәгъ. *кöк* «күк, күксел, зәңгәр» сүзеннән дип исәплиләр һәм дәлил итеп уйг. *кöк йүтәл*, нуг. *кöк йүтел*, каз. *кöк жүтүл* «күк ютәл, күксәү» сүзен китерәләр. Ләкин бу тәгъбирләрдә *кöк* «күк, зәңгәр» түгел, ә «күкрәк» булуы да мөмкин, к. **Күк II.**

Гомумән, ЭСТЯ V авторларын да аңларга мөмкин. Шунысы бар: **күк** (I, II һ.б.) тамырыннан ясалган сүзләрдә яңгыраш чикләре дә, мәгънә чикләре дә аерым-аерым билгеләнмәгән, берсе икенчесенә күчә ала.

**КҮКФАРЫЗ** «купорос» < рус. (халык этимологиясе буенча, **күк** сүзенә нисбәт ителгән, чөнки купорос яшелле-күкле була).

**КҮКЧӘК, кöкчәк** (ЗДС: 325) «молодая трава». Чаг. төр., аз. *кöкчәк* «матур, гүзәл», чаг. **Күкләм I.**

**КҮКШӘ** «сойка» ~ рус. *кукша*, *кукса* «төрле урман кошлары атамалары» < карел. *kuukšo* id. (Аникин: 316; Фасмер II: 408); ләкин к. тат. диал. *кукша* (ТТДС I: 255) < чув. *кукша* < *кокша* < *кашка* «кашка, пеләш; күкшә» (күкшәнең башында кашкасы бар) > мар. *кокша* «кашка». Чаг. ш. ук эвенк. *кукӭкӣ* һ.б. тунг. «күкшә» (ССТМЯ I: 427). Чаг. морд. Э. *каль сезьган* = *кәл* (пеләш) *саескан* «күкшә».

**КҮКШӘНӘК,** себ. (Тумашева 1992: 104) *кöкшүнәк* «старуха» ~ кырг. *кöкшүн* «карт кеше», алт. (к. Будагов II: 159) *кöкшöн* «бабай, баба, җәт». *Кöк* ~ *күк* «тамыр» сүзеннән кебек, ләкин к. каз., к.-калп. *кöкши* ~ *кöкчи* «тирмәне яңадан җыючы тәҗрибәле карт яки карчык» ← «күкче».

**КҮКШЕЛ** «синеватый» < кр.-тат. *kökşil,* нуг., каз. *кöкшүл, кöкшил* (к. тат. *күксел,* к.-балк. *кёксюл* id., *с* > *ш* очраклы, нуг.-каз. даирәсенә хас) ~ төр. *gökçe, gokçül* id. һ.б.

**КҮКШЕН, күкшел** һ.б. (вариантлар күп) (ТТДС I: 281; Хайрутдинова 2000: 37) диал. «кувшин» ~ чув. *кăкшăм* < бор. кыпч. *күгучын* < *кукучин* «кәккүк; кәккүксыман савыт» сүзеннән, к.



төр. диал. *göğüт* «күке; күкесыман савыт»; тат. телендә дә *күкшен* «күке, кәккүк» сүзе бар (к. себ. җырында *Күрүмәз иле – күк чәчкә, Күләп йергә чыгыпсың; **Күкшен** баласы бертуган – Күрүшмәс йергә барыпсың,* ягъни «Хормузд илендәге күк чәчкә, Гүләп җиргә чыккансың; Күке балалары бар да бертуган, Шулар кебек, күрешмәс җиргә киткәнсең», к. З. Вәлиди. Җырларыбыз хакында // Шура, № 19, 1911: 11); чаг. ш. ук к.-балк. *қошун*, ком. *қожин*, осет. диал. *госин*, кабарда. *кхъуэшын*, адыгей *қошын* (Отаров 1987: 70) < бор. кыпч. *куушын* < *куучын* < *кугучын* «күке» (*-чын*//*-чен* – кош атамалары ясагыч кушымча, к. Bozkaplan. Türkiye türkçesi ağızlarında kuş isimleri // Türk dili araştırmaları yıllığı. Ankara, 1992: 73–79). Рус. *кувшин, кукшин* төрки телләрдән.

Төрки мифологиядә *күке* < *күкү* (ат башындай алтын күке) «байтирәк (к.) башында утырып, дөньяда ни бар – барысын да белеп торучы кош» ~ хак. *кöкчін иней* – «барсын белүче кубылгы карчык», *кööк* ~ алт. *күүк* «күке».

**КҮЛ** «озеро» < гом. төрки, бор. төрки *кöл* (угыз. *гöл,* тув. *хöл*) «күл, елга тармагы; сазлык» (Радлов II: 1267) ~ бор. монг. *köl* «сулык; күл» (Поппе 1938: 184). Чаг. бор. һинд. *kulyā* «елга; канау, канал». **Кул II** сүзе белән чагыштырылмый. К. **Күлләвек**. Räsänen 1969: 288; Федотов I: 321; ЭСТЯ V: 95–96; Гарипова 1998: 99–101.

**Күл** нигезеннән сөйләшләрдә (ЗДС: 350) сәер ясалышлы сүзләр барлыкка килгән: **күләwәт** «сазлык эчендәге күл»; **күлтәм** «елганың ике борылыш арасы – турыга аккан өлеше». К. **Күләвек.**

**КҮЛӘ,** (ЗДС: 350) **күли** «куль; рогожий мешок», русчадан шикелле, < рус., укр., белорус. *куль,* пол. *kul,* латыш. *kule* һ.б. (Фасмер II: 412) «күлә, тупа тукымадан тегелгән капчык», ш. ук җылымның, мурданың «капсыман өлеше». Бу сүзләрнең чыгышын гадәттә һинд.-евр. (лат. һ.б.) телләреннән эзлиләр, ләкин бик үк ышандырырлык этимоны юк. Тат. һ.б. төрки телләргә игътибар ителми. Ләкин к. бор. төрки *köl-, kööl-* «ат аркасына йөк йөкләү», *köl* «ат йөге» (хәз. монг., тув. *көл, хөл* «ат йөге; йөк аты» һ.б., к. **Күлек**), тат. диал. (ЗДС: 349) **күләк** «кап». Ясәвидә *Үзен шәйх әйләй-ү, кул-ү-*

*бары хали,* ягъни «үзен шәех дип күрсәтә, ләкин күле һәм бары (белем) йөге буш» (фар. *bār* «йөк»). Шул **күл-ү-бар** сүзеннән каз., кырг. *көлбар* «курҗын» сүзе килә. Төрле күләләр белән эш итү күчмән төрки-монголларга аеруча хас булган. К. **Күли.**

**Күләвәт: күләwәт** (ЗДС: 349) «сазлы күл өстендә ачык урын». **Күл** сүзеннәндер, мөгаен. Ясалышы аңлашылмый.

**КҮЛӘГӘ** «тень», диал. **күләңкә, күләткә** id.; Бу өч синоним параллель рәвештә бор. тат. *күлә-* < бор. төрки (Радлов II: 1270; ДТС: 314) *kölü* > алт. *кӧлӧ-, кӧлä-* (һ.б. телләрдә) «күләгәләү; ышыклау; яшерү» фигыленнән түбәндәгечә ясалганнар.

**Күләгә** < гом. төрки *кӧлäгä*, бор. төрки *kölige*, кырг. *көлөкө*, ихтимал, тув. *хөлеге,* угыз. *gölge* һ.б. id. монголчадан бугай. Ләкин к. к.-балк. *кёлекке,* хак. диал. *кӧлäк,* як. *кулук* id. Тат. диал. (ЗДС: 349) **күләгәткә, күләйткә** яңарак барлыкка килгән булса кирәк.

**Күләңкә, күләңке** ~ каз., уйг. *көлеңки, көләңкә* ← себ. (Тумашева: 107) *күлән-*, уйг. *көлән-* [*кӧлäн-*], хак. диал. *кӧлән-* «яшеренү, ышыклану» ← *кӧлә-* һ.б (төрле язылышта очрый).

**Күләткә** «күләгә; күләгә бирүчән» ← *күләт-ү* < *кӧлäт-,* алт., тув. *кӧлӧт-* «күләгә бирү». Бу сүзнең үзенчәлекле мәгъ. бар: себ. (ЗДС: 325) **кө̄ләтке** «зонтик», **кө̄ләт-ү** «күләгәгә кую».

**Күләгә, күләнкә, күләткә** сүзләре күп күрше телләргә дә кергән: чув. *кулетке, кĕлетке* «гәүдә; кыяфәт», удм. диал., мар. диал. *кӧлäгä* «күләгә, ышык» һ.б.

**Күлә- < кӧлä-** фигыле **кӧ* «түбә; калкан» сүзеннән дигән фараз бар. К. Räsänen 1969: 288–289; ЭСТЯ V: 96–97.

Дерив.: **күләгәле, күләгәсез; күләгәлек; күләгәлә-ү.**

**КҮЛӘМ** «объём; размер, масштаб» < уйг. *көләм, күләм*, кырг. *кӧлӧм*, хак., нуг., каз., к.-калп. *көләм* < *кӧлләм* id., к. тув., монг. *хөл* < *кӧл* «ат аягы; ат йөге; терлек саны; состав», *кӧллә-* «терлек санын, составны һ.б. билгеләү». К. ш. ук чув. *кулем* «тышкы кыяфәт, форма», *кулемлĕ* «кыяфәтле» ~ тат. **күләмле,** уйг. *көләмлик,* кырг. *кӧлӧмдик,* хак. *кӧлемдиг* «күләмле; көмәнле». **Күләм** сүзе бор. төрки сәүдә заманнарында формалашкан. К. **Күлек, Күлем.** ЭСТЯ V: 98.

**КҮЛӘН: күрше-күлән** парлы сүзенең икенче синоним компоненты ~ чув. *кулем, кулĕн* id. ← кыт. *күй* «туй бүлмәсе»: тат. туенда кайбер актлар күрше өендә үткәрелгән.

**КҮЛӘН-Ү** (ДС I: 120; ДС III: 102–103) «собираться на работу», «поесть на поле (во время работы)» ← **күллә-нү** «җигелү; ат җигеп алу» сүзеннән булса кирәк, к. тув., бур. *хүллә-*, монг. *хөллө-* «җигү». К. ш. ук **Күлек, Күлем.**

**КҮЛЕК** (М. Гафури телендә; ТТДС II: 205; БТДҺ: 163 һ.б.) «упряжная лошадь; тягловое животное» ~ каз. *көлік*, нуг., к.-калп., үзб. диал. *көлик,* үзб. *кӧлук* < бор. төрки (ДТС: 314) *kölük* > төркм. *гөлүк, гөөлүк*, төр. *gölük* id. ← бор. төрки *köl-, kȫl-* > чув. *кӳл-* «җигү». Бу сүзләрнең фономорфологик һәм мәгънәви-семантик вариантлары хәтсез: алт., як. *кӧлкӧ, кӧлӧ,* тув. *хөлге* «йөк аты (ишәге, качыры); кәрван аты; арба төре», бор. уйг. *kölüŋü* (тат. **күлеңге* булыр иде, чаг. *менге*) «күлек; ерак юл арбасы» (шуннан – рус. *колымага*), хәз. як. *кӧлүй-* «җигелү»; монг. телләрендә *хөл* «юл аты; олау, кәрван; ерактан килгән кунаклар, мөсафирлар; кәрап, палуба; шахмат тактасы» (соңгы мәгънәләр бор. монг. *kölü* «гаять зур тигез өслекле, дистәләрчә үгезләр, атлар җигелгән арба» сүзеннән – тарих китапларында андый арбаларның рәсемнәре сакланган); Көньяк Себер төркиләрендә *кӧл* id.; тув. *ат-хөл* синонимик парлы сүз «һәртөрле атлар» мәгъ.

Кайбер телләрдә мәзкүр сүз гомумән «ат» мәгъ. дә очрый: каз. *кулук* «чапкыр ат» ~ бур. *хүләг,* маньч. *кулук* «аргамак» (ССТМЯ I: 429); к. ш. ук бор. төрки (Зәмәхшәри) *кулук* «ишәк көтүе», хак. *кӧлгек* «мичәүләп җигү», монг. *хөлөг* «һәртөрле кәрван; көймә». Тат., башк. диал. *көлкәй, көлөк, көлекәй* «колынкай» бор. *кӧлук* сүзенең үзенчәлекле чагылышы булса кирәк.

**Күлек** сүзе тур. күп язылган, к. Räsänen 1969: 289; Курышжанов 1970; Мухамедова 1973: 130; Karamanoglu A.F. Über kölük und külük // UAJ, 48. 1976: 124–126; ЭСТЯ III: 69–70; ЭСТЯ V: 98.һ.б. К. **Күләм, Күлем, Күтәр-ү.**

**КҮЛЕМ**, диал. (ДС I: 120) **күләм** «отдых, передышка на поле (во время пахоты)» – собственно «запряжка» – чтобы лошади отдыхали, их на время распрягали ~ чув. *кулĕм* id. > мар. *кӧлым* «күлем», удм. *кӧльым* «период», чув. *кул-* ~ бор. тат. **кул-* < бор. төрки *köl-* «җигү, йөкләү» > хак. *кӧл-, хөл-* id. Бу сүзнең исем коррелянты да бар: тув., монг. *хөл* «юл аты; олау; кәрван; ерактан килгән кунаклар;

шахмат тактасы (өстенә куыш куелган олау арбасы, каңгы); кәрап». К. ш. ук тув. *хөлгэ* «түрә аты», бор. чыгт., монг. *köle* «шәп ат»; шор., як. *көлүй-* «җигү» һ.б. К. **Күләм, Күлән-ү, Күлек.**

**КҮЛИ** (ЗДС: 350) «куль, кулёк, сумочка». К. **Күлә.** К. ш. ук (ЗДС: 351) **күлүк** «мунчала кап» < рус. диал. *кулёк* id.

**КҮЛЛӘ: күллә тун** (себ., ЗДС: 350) «стёганое одеяло» (юрган) **хөллә** (к.) сүзе белән бердәй диелгән. Ләкин монда яңгыраш җәһәтеннән дә, мәгънә җәһәтеннән дә шикләнерлек урын бар.

**КҮЛЛӘВЕК [күлләwĕк], күлдәвек, күләвек** «лужа» тат. телендә **күл** нигезеннән ясалган, чаг. *баз → базлавык, боз → бозлавык* (димәк *-лавык* сүзьясагыч элемент). К. башк. *күләү* «күләвек».

**КҮЛМӘК** «рубаха, рубашка; платье», диал. (ЗДС: 324, 326, 328, 344, 346, 348, 351, 354) **көйләк, көйлөк, көңләк, көңнәк, көнәк, күли, ’үли’ < күлик, күлмик, күңнәк,** (ТТДС I: 381–282) **күләк, күләкәй** ~ башк. *көлмәк, күйләк, күлдәк* һ.б., каз., нуг. *көйлек,* куман. *köüläk*, кар. *kölmek,* төр. *gömlek*, аз. *көйнәк,* чыгт. *könlek*, тув. *хөйлек,* хак. диал. *күгнәк* һ.б. id. (к. Räsänen 1969: 290–291), кр.-тат. *kölekse, kölmekse* «күлмәк, аның төрле төрләре» һ.б. Чаг. ш. ук себ. (ЗДС: 348) **күксемәк** «тире җилән», (Тумашева 1992: 106) **күгесмәк** < бор. төрки (ДТС: 313) *kökuzmek,* бор. уйг. *kögüspek* «күн куртка; күн камзул төре һ.б.ш.». Сүзнең нигезе *köŋül ~ köŋür ~ köŋüz* «күкрәк», ягъни күлмәк тәүдә күкрәк киемен белдергән (к. **Күңел** һәм **Күкрәк, Күксә-ү**). Чаг. тат., башк. *күмелдерек < күңелдерек* ~ төр. *kömüldürük* «җигүле атның күкрәк асты»; як. *күҥкүләки* «күн куртка» > рус. *кухлянка*.

*Күлмәк* сүзен бор. төрки **köŋläki* «күн кием» сүзеннән дә чыгаралар (ССТМЯ I: 433). ЭСТЯ V: 89–90 (бездә китерелмәгән күп вариантлар бар, аңлатма безнеңчә). Чаг. **Күгезмәк, Күли.** Тат. күлмәге төрләре тур. (ЗДС: 350–351) диалектологлар бик тәфсилләп язганнар. Анда бай фразеологик терминология дә китерелә.

Дерив.: **күлмәкле, күлмәксез; күлмәклек; күлмәкчән.**

**КҮЛТӘМ** себ. (ЗДС: 351) «участок течения реки между её двумя поворотами» – *күндәл* сүзеннән булса кирәк, к. **Күндәл.** Ягъни **күл** сүзе тәэсирендә бөтенләй бүтән сүз үзгәртелгән.

**КҮЛТИЛӘ-Ү** (Төньяк Башкортстанда шактый киң таралган. – *Р.Ә.*) «культивировать», **күлтиләү** «культивация» – русчадан тат. сөйләшләрендә ясалган ярымкалька.

**КҮЛҮК** себ. (ЗДС: 351) «славный; богатырский; богатырь» < алт. *күлүк* «баһадир; эпик герой» (барча Көньяк Себер телләрендә очрый) ← **күү** «дан» һ.б. Räsänen 1969: 306.

Чаг. тат. **көлек** «колын» (булачак баһадир аты).

**КҮЛЧӘ** «кольцо для привязывания к чему-либо», **күлцәр** «обод, ободок» (ЗДС: 351, беренче сүзне рус. *кольцо* сүзеннән дип күрсәтелгән). Ләкин шуңа охшаш сүзләр төрки, гар., фар. телләрендә дә очрый. К. бор. төрки уйг. *күл-* «бәйләү, баглау» (к. **Көлчә**), госм. (Räsänen 1969: 308) *külüǯä* «кояш тирәли түгәрәк, түгәрәк таба, түгәрәк ипи, көлчә». Гомумән, **kul, *kol* «түгәрәк нәрсә» күп телләрдә очрый торган тамыр сүз.

**КҮМӘГӘЙ** «полость рта; твёрдое нёбо; пищевод (животных)» ~ башк. (БТДҺ: 151, 161) *көмәгәй, көмәк, күмәгә* id. < гом. кыпч. *kömekей*, кырг. *көмөгөй*, чыгт. (Будагов II: 164) *кӧмегей* id. ~ як. *көмөгөй, көмөгөй, күөмэй* ~ тунг. (сол., к. ССТМЯ I: 408) *коомуге* «бугазның өске өлеше, ияк асты» – монг. сүзе булса кирәк.

**КҮМӘК** «коллектив; коллективом, коллективно, сообща» < уйг. *көмәк*, гом. кыпч., үзб., төркм. *көмек* «ярдәм», госм., чыгт. (Радлов II: 1320) *көмäг* «яурын; тыл; ярдәмче гаскәр», төр. *küme, kümek* «группа, команда», бор. чыгт. (Поппе 1938: 405) *kümek* «талпа»; як. *көмө* «ярдәм» ~ бор. төрки (ДТС: 322) *kümäk* «сак, сакчылык» ← *кү-, күй-* «арттан карап, саклап, күзәтеп тору». Шулай итеп, төбендә *күмәк* «тыл; оборона, ополчение» булып чыга. Будагов II: 163; Räsänen 1969: 289; ЭСТЯ V: 98–99 (нигезсез рәвештә **күмәк** сүзен **өмә** белән чагыштыру алга сөрелә).

Дерив.: **күмәкләп, күмәкләшеп;** диал. **күмәкче** «ярдәмче».

**КҮМӘРТӘ** «оптом, во множестве; сразу», «общий» ~ башк. (БҺҺ II: 117; БТДҺ: 163) *күмәртей* id. ~ чув. *кӳмĕртен, кӳмертен* «күмәртә», *кӳмерте, кӳмеркке* «күләм, гәүдә, бәдән; өем күплек» << уйг. *көмүртә* «умыртып, умырып» ← *көмүрт-* «күмдереп, аударып» ← *көм-* «күмү» (?). Бу аңлатмабызда семантик кыенлыклар бар, ихтимал, уйг.

*кӧмүрт-* фигыле **күмәк** (к.) сүзе белән баглыдыр. Чаг. ш. ук себ. (Тумашева 1992: 108) **күмәртәк** «пачка». Башк. диал. (БТДҺ: 158) *күбәртәләп* – халык этимологиясенчә **күп** сүзеннән.

Чув. *күмерекке* сүзен бор. рус. *коумиръ* «кумир», осет. *gumeri* «пот, санәм» сүзләре һәм боларны *киммер* (халкы) этнонимы белән чагыштырулар (к. Български език, № 7, 1957 һ.б.) дөрес түгел. Федотов I: 322.

Дерив.: **күмәртәлә-ү; күмәртәле.**

**КҮМӘЧ**, диал. **күмәц,** (к. Хайрутдинова 1993: 17–19; ЗДС: 352–353) **күмич, күмәгәч** «булочка, колобок, (белый) хлебец», «пресная лепёшка», «ритуальная и обрядовая лепёшка» (с разнообразными значениями, к. Хайрутдинова op.cit., Будагов II: 162–163) > чув. диал. *күммеч*, мар. (Исанбаев 1978: 36) *комеч, кӧмеч, кӧмӓч*, удм. (Насибуллин: 121) *кӧмеч* «күмәч; ак (киң мәгъ.) < гом. кыпч., чыгт., уйг. һ.б. (к. Радлов II: 1320) *кӧмеч* (> нуг., каз., к.-калп. *кӧмеш*), башк. *күмәҫ,* кырг. *кӧмӧч* < бор. төрки (ДТС: 314) *kӧmӓč* «көлдә пешерелгән тәбикмәк; күмәч» (әлбәттә, бу сүзнең камырдан пешерелгән ашамлыкларның исәпсез күп төрләрен белдерүе табигый, башк. сөйләшләрендә хәтта шакмак салманы да *күмәс* диләр, к. БТДҺ: 163). Бу сүзне элек-электән (М. Кашгаридан башлап) **күм-ү** («кайнар көлгә күмеп пешерү») сүзеннән дип аңлаталар, ягъни асылда **күммәч** < *кӧм-мӓч* (*-мач//-мәч* – ашамлык атамаларын ясагыч кушымча). Тат. этимологиясендә **күмәч** < *күммә аш* дип аңлату фонетик закончалыкларга хилаф. К. **Күмгәч, Күмпәч.** ЭСТЯ V: 100–101 (төркм. *гӧмәч* сүзе тур.).

**КҮМГӘК** диал. (Ф. Сәйфи-Казанлы; трбс.) «синий посиневший; сизый» ~ төр. *gӧmgӧk* «сизый» – **күк** тамырыннан булырга тиеш, мәс., **күг-ем-гәк, *күг-гәк* һ.б. Артыклык дәрәҗәсе: **күп-күмгәк.**

**КҮМГӘЧ** (себ., ЗДС: 353) «котёл, место котла, пристроенное к печи» < *күммәгәч* ← *күммә казан.* Чаг. каз. *кӧмбе қазан* «ябулы таба; күммә казан». Элекке *кече учак* аерым булган, мичкә ялганмаган. Чаг. **Күмпәч.**

**КҮМЕЛДЕРЕК,** диал. (Тумашева 1992: 108) **күмелтерек, күмелтек** «нагрудник (лошади)» < гом. кыпч. (гәрчә сүзлекләрдә сирәк очрый) *кӧмүлдүрүк, кӧмилдирик,* кырг. *кӧмӧлдүрүк,* башк. (БТДҺ: 151) *кәмәлдәрәк,* < бор. төрки (ДТС: 314) *kӧtüldürük* > угыз. (төркм. һ.б.) *гӧмүлдүрүк* id. ш. ук «камыт» ← *кӧмүл* (~ чув. *кӑмӑл*) < *кӧңүл* «күкрәк» сүзеннән. К. **Күлмәк, Күңел** һ.б.ш. Будагов II: 137; ЭСТЯ III: 71–72.

**КҮМЕР** «уголь» < гом. кыпч. *кӧмир*, алт., уйг. һ.б. *кӧмүр*, уйг. диал. *кӧмәр*, хак. *кӧмӗр*, кайбер угыз шивәләрендә *гӧмүр-* һ.б. id., күпчелек этимологлар фикеренчә, *күм-* < *кӧм-* «күмү» фигыленнән (запас күмерне, кузны көлгә, туфракка күмеп әзерлиләр); ләкин икенче фараз – *күмер* < *кӧмүр* < **кӧймүр* ← *кӧй-* «көю» сүзеннән дип карау да нигезсез түгел, к. ЭСТЯ V: 102–103. Чув. *кӑмрӑк, кӑммӑрӑк, кӑммӑри* «күмер» тур. Федотов I: 253.

Дерив.: **күмерле, күмерсез; күмерлек** (төрле мәгъ.); **күмерлән-ү; күмерче, күмерчелек.**

**КҮМПӘЧ** (әстр., ЗДС: 353) «булочка, колобок», чаг. каз. *кӧмбеш* «зур күмәч, күпертмә пешерә торган таба һәм шунда пешерелгән күпертмә, кабартма». **Күм-ү** сүзеннән, ләкин ясалышы бигүк ачык түгел. **Күммәч** сүзеннән шикелле (каз. *-мм-* > *-мб-* күчеше еш очрый). К. **Күмәч, Күмгәч.**

**КҮМ-Ү** «закопать, хоронить, оставить под наваленной массой» < гом. кыпч. *кӧм-*, угыз. *гӧм-*, тув. *хӧме-* id. Бу сүзнең исем коррелянты да бар: төр. *gӧт* «күмелгән запас». ЭСТЯ III: 70–71. Чаг. **Күмәртә**.

Дерив.: **күмел-ү, күмеш-ү, күмдер-ү**; к. **Күмәч.**

**КҮН I** «выделанная кожа» < гом. кыпч. *кӧн* < бор. төрки *кӧӧн*, угыз. *гӧӧн* ~ тув. *хӧм*, монг. *кӧм*, алт. диал. *кӧң* id. Räsänen 1969: 290; ЭСТЯ III: 72–73. К. **Күнәк, Күнчек.**

**КҮН II: күн як** «орёл в монете; гербовая сторона монеты» – рус. *куна* «акча берәмлеге, аның коны төшерелгән ягы» сүзе белән чагыштырыла (к. **иләк як** ~ рус. *решка* «иләк»). Чаг. ш. ук кыт. *хонь* «язу, иероглифлар».

**КҮНӘ: күнә суы** иск. «ртуть» ~ куман. *кӧнӓсү* (Радлов II: 1243), уйг., нуг. *кӧнӓ сув*, бор. төрки (ДТС: 314) *kӧnä suvï*, иске уйг. *kӧnüg (su)* >> венг. *keneso* (Кавказ телләренә дә күчкән) < кыт. *küni* «көмеш» һәм *су* сүзләреннән, чаг. фар. *симаб* – «көмеш су» – «терекөмеш, күнә суы», тув. *мӧнгун су* «көмеш су» – «терекөмеш» (*мӧнгун* «көмеш»).

**КҮНӘК** «кожаное ведро; кожаная посуда» < гом. төрки (Радлов II: 1242–1243) *кӧнӓк, кӧнэк*,

алт., кырг. *кӧнӧк* ~ госм., төр. *köynük*, башк. *гөйнүк* (?, к. Räsänen 1969: 290), бор. төрки *könäk* «савыт» (ДТС: 315), бор. монг. *köneg, könüg* «күнәк» һ.б. һичшиксез *күн* < *кӧн* сүзеннән. Госм., төр. *köynük* яңгырашы *күн* сүзенең борынгырак бер яңгырашы *кӧйн* икәнлеген белдерә. ЭСТЯ V: 104–105.

**Күнәк** сүзе күп күрше телләргә кергән, к. яз. монг. *könäg*, *könüg* «күнәк», рус. *кунук, кунучок* «чиләк» тур. к. Аникин: 324 (шунда ук әдәбият китерелә). Хайрутдинова 2000: 33.

**КҮНДӘЛ, күлдәм** (Тумашева: 108), **күлтәм** (ЗДС: 351) «расстояние между двумя поворотами реки», вернее (что не сказано) «прямая линия между определенными точками» < монг. *күнидэл, кѳнидэл, кѳнидэлэң, хѳндлѳң, xöndlöŋ* «ара үлчәгәндә мөмкин кадәр туры-төз булып сузылырга тиешле аркан, киндерә»: *күни* «туры, төз», *дэл, дэлэң* «ат ялыннан яки койрык кылыннан үрелгән бау» (к. **Тәл**). Бу монг. сүзе төрки телләрдә киң таралган: кр.-тат., к.-балк. *köndelen,* нуг. *кӧнденен,* үзб. *кундаланг* «туры, аркылы ара», к. Dobr. II: 352. Чаг. ш. ук каз. *күнделе-* «терлекнең аякларын чапрыш тышаулау» ← чыгт. (Будагов II: 139–140) *кӳндэ, кӳнде* «тышау, аяк богавы» (фарсычадан диелә).

Дерив.: **күндәллә-ү, күндәлләп үлчәү** «ике нокта (мәс., агач, яр) арасын аеручa төгәл үлчәү». Безнеңчә, бу **күндәл, күндәләң** сүзләре активлаштырылырга да лаек, мәс., «диаметр» мәгъ.

**Күни** тамыры **күндәм** сүзендә дә бар, к. түбәндәгене.

**КҮНДӘМ** «покладистый, послушный» > мар. *кӧндӓм* id. < бор. төрки *кӧндӓм* id. ← *күн-* < *кӧн-*, к. **Күн-ү.** Ясалышы буенча к **бердәм, елдам, үктәм.**

Дерив.: **күндәмлек; күндәмлән-ү.** Чаг. югарыдагыны.

**КҮНДЕР-Ү** «послать, посылать (прямо)» < гом. кыпч., к. куман., кар. *кӧндәр-*, төр., төркм. *гӧндәр-*, төр. *göndür-* һ.б. (ЭСТЯ III: 73–74) «җибәрү, юнәлтү; күндерү, озату; туры юл күрсәтү, юлбашчылык итү»; чаг. чув. *кунтар-* «эрләнгән җепне тигезләү, шомарту» ~ як. *кӧннӧр-* «турайту», төзәйтү» ← *күн-* < *кӧн-* (к. **Күн-ү**) сүзенең аерым мәгънә алган йөкл. юн. Мухамедова 1973: 127.

Дерив.: **күндерел-ү.**

**КҮНЕ, күни** «прямой, верный (о дороге, пути)» ~ чув. *кӳнӗ* – иске тат. әд. теленнән, к. гом. кыпч. *кӧни, кӧнү,* уйг., чыгт. *кӧнү,* хак. *кӧнӗ,* бор. төрки (КБ) *köni* id. ← тат., башк. *күн-* «күнү», асылда «тураю; туры бару», алт., як. *кӧнӧ*, тув. *хӧнү,* монг. *köni, хѳнү* id. < бор. төрки **кӧнүг* id. ← *күн-* < *кӧн-* (к. **Күн-ү**). К. ш. ук угыз. (Мухамедова 1973: 84) *гӧни* «туры, төз». ЭСТЯ III: 74–75; Федотов I: 307.

Дерив.: (дини стильдә) **күнилек; күнилән-ү, күниләш-ү.**

**КҮНЕК-Ү (күнекте, күнегү)** «привыкать; упражняться», себ. (Тумашева 1992: 109) **күнүк-ү** «выжидать, терпеть» < гом. кыпч. *кӧник-*, кырг., уйг. *кӧнүк-* «күнегү; дөрес юлга керү» һ.б. ← **күн-ү** (к.) фигыленең интенсивлык дәрәҗәсе; к. ш. ук чув. *хăнăх-* id.

Дерив.: **күнегел-ү, күнегеш-ү, күнектер-ү; күнекмә.**

**КҮНЛЕК,** (Тумашева 1992: 109) **күнлүк** «ладан» < чыгт. *күнлүк* ~ төр. *гүнлүк* id. ← иске тат. *күн, кен* < бор. төрки (ДТС: 307, 327) *kün jïpar* ~ *jıpar kün* «күнлек» ~ алт., иске кыпч. *киин, кин* id. Тув. *хин* «кендек; кабарга (бизләреннән хуш исле сыекча алына торган болан төре)» сүзенә карагандa *күн* ~ *кин* **кендек** сүзе белән тамырдаш: кабарганың әлеге сыекчасы кендеге тирәсенә җыела; чаг. рус. диал. *пупина* «кабарганың мускус янчыгы (аны тере хайваннан кисеп алалар икән)», **күн** һәм **кен** вариантларының килеп чыгышы түбәндәге формула белән аңлатыла ала: *күн* < *күwӗн* < *kӧwин* < **kӧгин* > *кӧйин* > *киин* > *кин* > *кӗн*, к. Аникин: 230, 458; Будагов II: 167; Zajączkowski: 98 (мәгълүматлары тулы түгел). К. **Кендек.**

**КҮНТЕ, күнтәй, күнтәк** иск. «судья низшего ранга; знаток обычаев и обрядов; понятой; свидетель на свадьбе» (к. мәкальләр: *Куйны күнтәк (~ күнтәй) бозар, туйны тинтәк бозар*, Исәнбәт III: 348 – *бозу* биредә «пешерелгән куйны бор. кагыйдәләр буенча кунакларның дәрәҗәсенә карап өләшергә бүлгәләү»; *Күнте чанасын күндерү* «туй мәшәкатьләрен төгәлләп тәмам итү – туй шаһитлары утырган чананы озату» – ул чана (арба) иң соңыннан җибәрелгән). Бу сүз, мәҗүси йола-гадәтләр калдыгы дип саналып, ислам әһелләре тарафыннан кулланыштан төшерелгән булса кирәк, югыйсә ул күрше телләрдә тат. теленнән алынып сакланып килгән: чув. *кӳнтеле-, кӗнтеле-* (< тат. **күнтәйлә-ү**) «шаһитлык итү», иске чув. (1836 елда теркәлгән) *кюнделеген, кундэлэгэнь* «шаһит, гуаһ; шаһитлык итүче» > хәз. чув. *кӳнтелен* id. ~ удм. (Та-

раканов: 90) *канделем, кангелем* id.; башк. (М. Гафури мемуарларында) *күнтәй авылы* «ишан яшәгән авыл». Идел-Урал регионыннан тыш: кырг. *кундө* «староста, старшина», алт. *кӱндӱ*, тув. *хүндү* «кунак итү; түрә», чыгт. *күндүк* «хөрмәт, игътибар, кунакларны кагыйдә буенча хезмәтләндерү» ~ бор. монг. *kündü* «югары дәрәҗә, әһәмиятле пост; түрәлек, түрә», авар. (VII г.) *kündü* «гамәлдар, чиновник» < кыт. *күң тай* «сарай агасы (гофмейстер)», к. Ramstedt 1951: 59–82. *Күнду, кунду* титулы хәз. як., монг. һәм тунг.-маньч. телләрендә дә очрый (ССТМЯ I: 432).

Чув. *хунтă* «ярдәм; кемнең дә булса абруйлы химаячесе» (*хунтăла-* «яклау») сүзе **күнте** сүзенә бик охшаш, ләкин фонетик җәһәттән аны **күнтĕ** нигезенә кайтару читен: *хунтă* < *хонтă* < **қанды* булырга тиеш. Шунлыктан *хунтă* сүзен М. Федотов (I: 322–323) *күнтеле-* матдәсен караганда искә дә алмый.

**КҮН-Ү** «согласиться, соглашаться» < гом. кыпч. *көн-* ~ угыз. *гөн-* < бор. төрки (ДТС: 314–315) *kön-* «тураю; төзәю; дөрес юлга керү; күнү» >> чув. *кăн-, кун-* < *кон-* «тураю, төзәю; аяк сузу, үлү». Чув. диал. *хăн-* «төнү, әчелеге бетү». Төбендә ниндидер **кү-* < *көө-* фигыленең кайт. юн. булса кирәк. Будагов II: 168; Räsänen 1969: 290; Федотов I: 254; ЭСТЯ III: 73–75.

Дерив.: **күнел-ү, күнеш-ү, күндер-ү,** диал. (ЗДС: 353) **күнем** «конфликтсызлык»; к. **Күндәм, Күндер-ү, Күне, Күнек-ү.**

**Күндер-ү** нигезенең гади сөйләмдәге йөкл. юн. «күнәргә ярдәм итү, үтенү, мәҗбүр итү» мәгънәсеннән тыш, «юнәлтү» мәгъ. дә (к. яз. әд. стильдәге *сәлам күндерү*) бар. Шуннан һ.б. бүтән очраклардан чыгып, *көн-* һәм *йөн* (к. **Юнь**) уртак нигездән дип тә уйлыйлар.

**КҮНЧЕК**, (ТТДС I: 281) **күнчәк** «обшивка прореза рубахи; внутренний карман; сумочка, портмоне» > чув. *кунчĕк, кунчек* id. < бор. төрки (ДТС: 327) *künčük, künčäk* «яка; куен», чыгт. (Боровков 1963: 178, 189) *künčäk, künčük* «кесә», ш. ук кайбер кырг., төркм., төр. сөйләшләрендә «куза (бизәк өчен киемгә беркетелгән калай)».

ЭСТЯ (V: 105, 106) **күнчәк** сүзен тат. (**күлмәк-күнчек** дигәндәге) **күнчек** «чалбар» ~ кырг., к.-балк. *көнчәк*, куман. *conček*, төр. *köncek, kömçek, gönçek* «чалбар, эчке күлмәк, майка» сүзеннән аерым һәм бүтән тамырдан дип карый: беренчесе ниндидер **көн* «куен сүзеннән», икенчесе **күн < көн** (к. **Күн**) сүзеннән, имеш. Без М. Рясянен (Räsänen 1969: 290) фикерендә калабыз: һәр ике мәгънә юнәлешләре **күн** мәгънәсеннән, чөнки барча мәзкүр әйберләр тәүдә күннән эшләнгән.

**КҮҢ I** к. **Көң.**

**КҮҢ II** (БТДҺ: 164) «трясина» ~ себ. (Тумашева 1992: 104), алт. **кӧң** «тундра». Будагов II: 159.

**КҮҢЕЛ**, диал. **көңөл > кеңел,** себ. (ЗДС: 328) **кӧңүн** «душа, душевная субстанция; настроение, желание, любовь» ~ чув. *кăмăл* «характер, мәел, кәеф», мар. *кумыл, кымыл* «кәеф; илһам, теләк, мәел» < бор. кыпч., як., уйг., бор. төрки *көңүл* (СС *congul*), алт. *кӧңил*, башк. *күңел, көңөл,* үзб., чыгт. *күнгул*, төр. диал. *göŋül*, төр. *gönül* id., Себ. төрки телләрендә ш. ук «юаткыч, юатучы» (алт. *кӧңӗл кан* «мескеннәрне юатып йөрүче изге рух», к. Катанов 1888: 50). Күп төрки телләрдә бу сүз фонетик җәһәттән нык үзгәрә, к. каз., к.-калп. *kewил,* кар. *кӧлун*, аз. *койул*, төркм. *гөвил, гөwил, гөвүн,* тув. *хөөн,* алт. *кӱүн* һ.б. һәм бу хәл мәзкүр телләрдә бу сүзнең алынма булуын сөйли: к. ш. ук эвенк. *куңул* «ихтыяр, теләк» (ССТМЯ I: 434). Э.В. Севортян (ЭСТЯ III: 75–77) бор. *көң-* > төркм. *гөң-*, төр. *göv-* «көтеп тору, түзү» фигыленнән ди. Безнеңчә, бу сүз бор. *кӱң, күк* (к. **Күк III**) «ана күкрәге, күкрәк; тамыр; казык; кендек» сүзеннән турыдантуры ясалган: *күң-кил* (*-кыл, -кил* сыйфат һәм исем ясагыч кушымча) тәүдә ана күкрәген белдергән, аннары гомумән хатын-кыз күкрәген һәм теләген һ.б. белдерә башлаган; бу фикер **күңел ачу, күңелен алу, күңел бирү, күңелен күрү, күңелеңне киң тоту** «күкрәк киемен киң ясау», **күңелсезгә** «күкрәксезгә» **күлмәк кидермиләр, күңелдән ары, күттән бире** һ.б.ш. кебек фразеологизмнардан да күренә – алардагы **күңел** тәүдә конкрет мәгъ. аңлашылган. К. **Күк II; Күкрәк; Күмелдерек; Күлмәк, Күңелчәк.** Räsänen 1969: 291; Будагов II: 166–167; Федотов I: 251–252.

Дерив.: **күңелле, күңелсез; күңеллек** (бүләк тур.). Диал. (ЗДС: 328) **көңүллән-ү** «уйлану», (Старчевский) **кюньюлляймен** «телим». Чаг. **Көрсен-ү.**

**КҮҢЕЛЧӘК, күңелчән** «весёлый; открытый» ~ мар. (Саваткова: 69) *кумылзак, кумылчык* id. ← **күңел** (к.) тат. телендә ясалган булса кирәк.

**КҮҢСЕ-Ү,** диал. **куңсы-у, коңсы-у** «дурно пахнуть; провонять» – тат. *коңы* (ЛТ: 74) ~ каз. *куңу*,

төр. *koku* «ис; начар ис», *koku-* «ислəнү», кырг. *көң, кок* «тизəк, пычрак», *күңкү-* «күңсү»; бор. төрки *qoq* «тузан», *qoq-* «көегү, көек исе чыгару» (ДТС: 314); алт. > рус. *куку яман* «исе яман» – тау кəҗəлəренең бер төре. Тат. **исе-косы < исе-коңысы.**

**КҮП I** «много; очень» < гом. төрки *kön*, тув. *көбей*, нуг., уйг. *қоп*, бор. төрки (ДТС: 317 һ.б.) *kör, qор* «барысы да; күп; гаять»; чаг. ком. *гюп,* кабарда. *гуп* «төркем, өер» ~ рус. диал. *куп, купа, коп* «бөтен группа; өем» – безнеңчə, ономопоэтик сүз. Будагов II: 141; Räsänen 1969: 291; ЭСТЯ V: 107–108. Чаг. **Күп II.**

Дерив.: **күплек, күплə-ү; күптəн; күпчелек.** Диал. сөйлəмдə еш кына **күбе** «күпчелеге», ш. ук **күбəр, күбəрлəп** «күплəп», **күбəү** «күп зат, зур төркем» кебек ясалмалар да очрый. Грамматикада **күплек,** рус. «множественное число» кебек үк, бигүк уңышлы түгел.

**КҮП II** диал. (Akb) «кожаный мешок (для сохранения зерна, воды)» < төр. *küp* id., алт., каз. *күп* «төрле сыеклыклар саклана торган капчык, гадəттə тиредəн эшлəнгəн» ~ калм. *küp* «толык, толыкман». Гомумəн, күп чыганакларда очрый: Малов (1969: 397) *kup,* бор. төрки (ДТС: 328) *küp* «зур балчык чүлмəк». ҠТДС: 174–175; Аникин: 374 («агач чилəк» мəгъ., бу сүз ир. теллəреннəн дигəн фикер һəм əдəбият күрсəтелə).

**КҮПЕК, көпəк: күпəк балык** «тюлень; афалина» ← каз., төркм. һ.б. *көпек*, үзб. *куппак,* госм. *кöпäк* «эт, ау эте». Нұрмағамбетов: 64–65; ЭСТЯ V: 11–112. Рус. *собака* «эт» сүзе белəн тамырдаш дип исəплəнелə, к. Фасмер III: 303.

**КҮПЕР,** себ. **күбер,** диал. (ЗДС: 313, 328, 342, 353–355) **кипрү, көпере, көпрү, күбер, күмрəү, күперəк, күпре** «мост; настил» ~ чув. *кĕпер*, мар. *кувäр, кувар* id. ~ нуг., каз., к.-балк. *көпүр*, хак. *кöбүр, кöбĕр*, алт. *кöмүр, кумур,* кырг. *кöмүрүк, кöпүрöö,* хак. *күбүрткä, кöбĕрткĕ*, аз. *көрпү,* тув. *көвүрүг* ~ бор. төрки (ДТС: 317) *köprük,* үзб. *куприк,* госм., чыгт. *кöпрү*, як. *күргä, күрбä* һ.б. (к. Räsänen 1969: 292) ~ яз. монг. (Поппе 1938: 231) *köwürge,* хəз. монг. *хөөрөг* «төңгер, барабан, күрек; күпер» һ.б. бор. **кöпүр, кöппүр, *кöпкүр* «елгалар аша чыкканда эченə салам һ.б. тутырып, йөзмə күпер ясала торган тире капчык» сүзеннəн (андый капчыклар тур. Ибне Фазлан бик тəфсилле яза), к.-балк. *кюбюр* «сандык; күперчек; кичү», алт., хак. диал. *кöгäр* «тире капчык, турсык», уйг. (хəтта) *күп* «тире капчык», бор. төрки (Мухамедова 1973: 124) *көбүрчүк* «сандык». Чаг. ш. ук хак. *кöбĕр* «күрек», төркм., аз. *кöпүрчəк* «куык»: бу сүз дə **күпер** сүзенең тамыры *күп-* (к. **Күп-ү**) икəнлеген күрсəтə. К. **Күпер-ү, Күрек II, Күрүк.** Чаг. **Гөберкə, Көбергəел.**

**Күпер** сүзен бор. грек. *γεφυρά* «дамба» сүзеннəн дип бару (Рясянен) дөрес түгел. Лəкин мар. *кувäр* < төрки **күбəр* сүзе фонетик җəһəттəн аңлатуга мохтаҗ. Федотов I: 275–276 (шунда ук без күрсəтмəгəн параллельлəр).

Дерив.: **күперле, күперсез; күперчек; күперлек, күперлəн-ү**. Федотов I: 275–276; Иванов 1993: 133–135; ЭСТЯ VI: 112–114.

**КҮПЕР-Ү** «вспучиваться, подниматься (о поверхности чего-либо); пениться» < каз., кырг., госм. һ.б. *кöпүр-,* алт., хак. *кöбүр-* «күбеклəнү, күперү», як. *кöппэй-* id. бор. **кöппэ* «күперенке» сүзеннəн (интервокаль позициядə *-п-* саклануы бор. вариантта ике тартык булу галəмəте). Чаг. ш. ук хак. *күбүр* «күперенке, көпшəк, йомшак, мамыклы», *күбүр-* «эчтəн черү (агач тур.)». *Күп-ү* сүзе белəн тамырдаш. К. **Күп-ү.**

Дерив.: **күперел-ү, күперен-ү, күпереш-ү, күперт-ү; күперенке; күпертмə** (ашамлык төре), диал. **күперек.**

**КҮП-Ү I** (ЗДС: 342–343) «стегать с ватой» к. **Көпе, Көбə.**

Дерив.: **күбек** «күперткеле шəл», **күбемə** «сырылган чалбар».

**КҮП-Ү II (күбү, күпте)** «вспучиваться, вспухать, вздуматься» < гом. төрки *кöп-,* як. *көбөө-* id., чув. *куп-* «күбү» белəн рəттəн аның исем коррелянты *куп, купĕ* «күпкəн корсак» та бар (Ашмарин VI: 76–77). *Күп* < *кöп* иң продуктив нигезлəрнең берсе, шуннан к. **Күбек, Күбен-ү, Күпер, Күпер-ү, Күптермə, Күпче-ү, Күпше-ү, Күрек, Күрүк.** ЭСТЯ V: 109–111.

Дерив.: **күбен-ү, күбеш-ү, күптер-ү.**

**КҮПТЕРМƏ, күптермəч, күптертмə** «лепёшка на яйцах» ~ чув. *куптĕрме* id. **күптер-** сүзеннəн, əлбəттə.

**КҮПЧЕК**,башк. **күпсек** «маленькая подушка», мар. *купчык, көпцөк*, чув. *купчĕк* < гом. кыпч. *кöпчəк, кöпчүк* (нуг., каз., к.-калп. *кöпшĕк, кöпшəк,*

*көпшүк*), каз. (ҚТДС: 165) *көпшік* «ястык», (Будагов II: 142) *кӳпшек* «арба ястыгы», калм. *кепциг* «күпчек; ияр мендәрчеге» < *көпү-чәк, көпү-чүк,* ягъни «кечкенә көпе» (эченә мамык куеп сырылган һәртөрле әйбер) сүзеннән булса кирәк. К. **Көбә, Көпе.** Будагов II: 142; Федотов I: 324 (**көпшәк** сүзе белән бәйли һәм бу, безнеңчә, дөрес түгел).

**КҮПЧЕ-Ү,** диал. **күпце-ү** «разбухать; перекисать» ~ башк. *күпсе-ү,* чув. *кӳпче-* id. **күп-ү** фигыленең интенсивлык формасы (*-чы* кушымчасы). К. түбәндәгене.

**КҮПШЕ-Ү** диал. «вздуваться, образуя воздушные газовые камеры в толще замеси и т.п.» < **күбеш-ү – күп-ү** «күбү» фигыленең интенсивлык формасы.

Дерив.: **күпшен-ү, күпшет-ү;** диал. (ЗДС: 342, 355) **күпшәк** «ак күмәч, ак күмәч камыры», «таркау, хәтерсез»; себ. **күпце-ү; күпцек** «эремчек; әчегәндә кабарып чыга торган (ашамлык измәсе)» һ.б.; төп нигез **күбеш-ү** сүзеннән **күбеш,** *күбешкәк* «күпшәк, көпшәк», *күпшәк* < *күбеш-әк* > *көпшәк* ~ чув. *кăпшак* һ.б. К. **Көпшәк.**

**КҮРӘ I** «близоруко; близорукий» ~ башк. *гүрә* id. < фар. *кӯррӓ* «сукырларча», *кӯр, кӯри* «сукыр; сукырлык» сүзеннән (> төр. *kör,* гаг. *көөр* «сукыр»).

**КҮРӘ II** послелог «из-за, ввиду, по причине; сообразно, по» > мар. *кӧрӓ,* удм. *куре, кура*, чув. *кура* < гом. кыпч. *көрә*, кырг. *көрө*, чыгт. *көрӓ*, уйг. бор. төрки *körü* id. (ДТС: 319) ← *kör-* «күрү». Чаг. рус. *смотря, ввиду* һ.б.ш.

**КҮРӘГӘ** «курага, сушёный урюк» ~ кр.-тат. *körĭk,* төр. *körügä, körük* «курага». К. **Күрә-ү.**

**КҮРӘЗӘ** «ясновидец; гадальщик, гадальщица» ~ башк. *күрәҙә* id. > мар. кч. *кӧрӓзӓ* id. тат.-башк. сүзе. Ясалышы ачык түгел, ихтимал: гар. *күррāсӓ* «китапчык, рисалә» сүзенең халык этимологиясенчә (*күр-ү* белән бәйләп) үзгәрүеннәндер (тик ул тәкъдирдә дә *-з-* аңлашылмый).

**КҮРӘМӘТ: күрәмәт күрү** «видеть виды» – тат. телендә ясалган сүз.

**КҮРӘН I,** себ. **күрәң** «осока», (ДС I: 122; ЗДС: 356) «камыш; тростник» > чув. (Ашмарин VII: 83) *кӳрэн, кӧрэн* «күрән» < гом. кыпч. **көрәң* id. ~ хак. *көрәң*, алт. *кӧрӧн, кӱрӧн* «күрән, камыш», алт. диал. (куманды) *күүрәң* «әрем», як. *хороҥ* «кура, каты сабаклы үлән», башк. *курень* (?) «саздагы түмгәк, саздагы утраучык» (к. Будагов II: 148; бу авторның «башкортча» мисаллары башк. теле фонетикасына туры килмәүчән) ~ монг. *хүрмэл* «күрән» һ.б.

**Күрән, күрәң** сүзен як. *күрүө, күрӓ* ~ бур. *күрэ, хүрэ* > эвенк. һ.б. (ССТМЯ I: 436) *куре* «кәртә, терлек тоту өчен читән белән уратылган туплау» ~ ком. *гёзэн, гёрэн* «ат көтүе өчен кәртә; түгәрәк, әйләнә» ~ иске уйг. *күрийән* < яз. монг. *kürijen* «киртә, кәртә, ирәк (стан), лагерь» сүзе белән бәйләргә мөмкин; шул ук сүзгә рус., укр. *курень* «казаклар авылы; вакытлы хәрби лагерь» тоташа. «*Күрән* сүзенең мәгънәсе түгәрәк, боҗра, – дип язган XIV г. башында Рәшидетдин, – кайчан ки берәр кабилә берәр җиргә килеп түгәрәкләнеп утырса һәм иң өлкән зат ул түгәрәкнең үзәге кебек торса, бу *күрән* дип атала…» (Җәмигъ әт-тәварих 1836: 94–95). «Камыш > читән, текмә > кәртә, лагерь» семантик күчешләре типологик характерга ия, шунлыктан рус. *курень* сүзен **күрән** белән баглауны хәзер дә кире какмыйлар (Мурзаев 1984: 317–318), к. ш. ук чыгт. *күрән* «лагерь, талпа; отряд, корпус, 1000 тирмәлек күчмәннәр группасы» (к. Будагов II: 124). К. ш. ук **Көрән.**

Рус. *курень* сүзенең «күрән» мәгънәсе дә бар; гомумән, бу сүз тур. әдәбият ишле, к. Будагов II: 124; Аникин: 328; ЭСТЯ V: 147–148 (материалы ярлы).

**КҮРӘН II** (ЗДС: 356) «хлев». «Күрәннән ясалган корылма» мәгънәсеннән булса кирәк. Будагов (II: 124) буенча, бу сүз Әстерхан өлкәсендә татарларда да, русларда да «пекарня» мәгъ. очрый икән.

**КҮРӘҢ** (брб., ЗДС: 356) «коричневый; цвета засохших осенью осок и др. высоких трав». ЗДСта рәттән бирелгән **күрән** «үлән төре», **күрән** «камыш яндаулы абзар» сүзләре белән гомоген. К. **Көрән.**

К. бор. төрки (ДТС: 304) *küvrä-* «кибеп кату, көйрәү (үләннәр тур.)»; к. түбәндәгене.

**КҮРӘ-Ү** (брб., ЗДС: 356) «засыхать (о траве, особенно о сене)» < гом. кыпч. *көрә-, көре-,* угыз. (төр. һ.б.) *köre-, göre-* «уменьшаться, утончаться от засыхания». Чаг. бор. төрки (ДТС: 304, 330–331) *kevrä-* «зәгыйфьләнү; нечкәрү; юкару (үлән тур.)», төр. (Будагов II: 148) *кеврек* «кипкән (үлән)» һ.б. К. **Күрәгә, Күрән.**

**КҮРГӘЗ-Ү** (в отличие от **күрсәт-ү**) «особо показать, показать с шиком (на свадьбе)», к. **Күрендер-ү.** Чаг. бор. төрки (ДТС: 317) *körgaд-* «матураю» һ.б.

Дерив.: **күргәзмә** – бу терминны XX г. башында бик белеп керткәннәр. Тәүдә ул туй терминологиясенә караган.

**КҮРГЕН** (ЗДС: 356–357) «смотрины невесты», **күргелек, күремлек, күремнек, күрендерү, күренеш, күренте, күрентелек** һ.б. «знакомство с невестой», **күреш** (ЗДС: 356–357) «знакомство невесты с соседями» һ.б. ~ кырг., алт. (Будагов II: 412) *көрүмдүк,* төр. *görümlük, güzgörümlüğü, göstergi* һ.б, бор. төрки *körgülük* «кәләш ире өенә тәүләп кергәндә иренең кардәшләре бирә торган бүләк». **Күремдек, күрендек** ~ каз., кырг. һ.б. *көрүмдүк, көрүндүк* дип яңа туган бәбине күрергә, танышырга – «бәби туена» алып киленә торган бүләкләрне дә атыйлар. Болар барча төрки телләрдә бик бай булган туй терминологиясеннән үрнәкләр генә. Монда һәртөрле мәгънәви нечкәлекләр күзәтелә. Барысының да тамыры *көр-,* бор. төрки *kör-* ~ угыз. *гөр-* «күрү». К. ш. ук Будагов II: 151; ДТС: 319.

**КҮРЕК I** «красота, вид» < гом. төрки *көрк,* бор. төрки (ДТС: 317–318) *körk, körük* «образ», уйг. *көрүк* «күзәен, смотр», төр. һ.б. *körek* «күрек» һ.б. *күр-* < *көр-* тамырыннан. К. **Күркәм.** ЭСТЯ III: 81–82; ЭСТЯ V: 116.

Дерив.: **күрекле, күрексез**; диал. **күркәй-ү** (→ **күркәйт-ү** ешрак кулланыла) һ.б.

**КҮРЕК II** «кузнечные и пр. воздуходувные меха»; «мех, обработанная шкура с хорошей шерстью»; диал. «шуба» – бу өч сүз асылда бер үк нигездән киләләр; к. түбәндәгеләрне.

I. Мар., удм. (< тат.) *көрык, курик* ~ добр. *körik,* нуг., каз. *көрик,* к.-балк., ком., алт., госм., гаг. *көрүк,* бор. төрки (ДТС: 318), төр. *körük,* тув. *хөрүк,* алт. *көбрүк, көбүрүк,* монг. *хөөрөг* «тимерче күреге».

II. Чув. *кĕрĕк [көрөк]* «тун; мех» ~ аз., чыгт., калм. һ.б. *көрк, көрүк* «миш (мех), эшкәртелгән йонлач тире».

III. Уйг. *көрүк, көпүрүк* ~ монг. *көгерге* «күрек (II); күпер».

IV. Бор. төрки (ДТС: 331) *kövrüq* «барабан (тоташ тиредән эшләнгәне)».

Бу сүзләрнең уртак нигезе *көбүр ~ көвүр ~ көгүр* «күпер» (к. **Күпер**) сүзендә дә ачык чагыла. Чаг. рус. *мех* «күрек тун» һәм *меха* «тимерче күреге». Бу чагыштырулар ышандыру көченә ия булсалар да, монда бүтән тамырлар кушылмадымы икән, дигән фикергә дә урын кала. К. уйг. (Радлов II: 1252) *көрү-* «күрек эшләтү, өрдерү», «дөрләп янып китү» ~ төркм. *көөре-* «янып китү; көйрәү». Бор. төрки (ДТС: 318, 329) *körük* «күрек; горн», ә *kürk* «мехлы кием, күрек», ягъни бор. язылышлар аерымланган. Семантик җәһәттән **күрек** «көйрәткеч» мәгънәсенә бик тә бап килә. Җентекләбрәк тикшерүне яшьләргә калдырабыз. К. ЭСТЯ V: 148–149; Мухамедова 1973: 129.

Инг. *quiver,* ним. *köcher* «садак, ук янчыгы; калчан» сүзләре дә бор. төрки (һунн) *күгүр, күкүр* «тире янчык» сүзеннән килә икән, к. Kluge: 507.

**КҮРЕМ I** «менструация» < *кувĕрĕм* «башкарылыш, үтәлеш» сүзеннән булса кирәк, чаг. чув. *йун кур-* «кан булу» – күрем. Ләкин к. аз. *гөрмәк* «күрү, күрем». К. **Күрем II.**

**КҮРЕМ II** «гадание; ясновидение» < кар., хак. (сагай) *көрүм* «күренеш; өрәк; саташу, булмаганны күрү»; төр. *görüm,* бор. төрки (ДТС: 319) *körüm* «караш, күреш; тамаша»; *körümci* > тат. **күремче** «күрәзәче».

**КҮРЕНЕК** «достойный вид, видность» < гом. кыпч. *көрүник, көрүнүк, көрүндүк* id. ← *көрүн-,* әлбәттә. Гомумән барча төрки халыкларда да *körün-dük* ~ як. *көрүнньүк* туй йоласы – «кәләшне күрсәтү, кәләшнең халыкка күренүе». К. **Күрген, Күр-ү**.

**КҮРЕНЕШ** «явление; торжественный выход», в терминологии «часть спектакля – акт, сцена», в свадебных обрядах – «первое после свадьбы приход-приглашение в гости брачующихся сторон» (к. ЗДС: 357). **Күренеш** < **көрүнүш** урта гасырларда яңа сайланган монархның яки түрәнең халыкны ялан-кырга чыгарып сыйлаганын белдергән (к. **Шыйлык**). Туй мәрасимендәге **күренеш** шуннан күчермә (туйда кыз ягы – хан ягы, кияү ягы – тархан ягы). Velidi: 64; Будагов II: 151 (чыгт. *көрүнүш* мәрасименең тасвирламасы бирелә).

**Күренеш** мәрасиме Пакьстан, фар., монг., кыт. халыкларында да үзара охшаш. Мәзкүр сүз үзе дә күп телләрдә очрый. К. **Күр-ү**.

**КҮРКӘ**, диал. **корка** (ДС II: 119), **кырка** (ЗДС: 368) «индюк» > мар., удм. *куркä, курак,* чув. *кăркка* < рус. диал. *курка* «күркә» сүзеннән бул-

са кирәк. Үзб. *курка,* каз. *күркэ* һ.б. «күркә» татарчадан (**күркә** асрау Америкадан тәүдә Европага, аннары Россиягә таралган, Россия төркиләреннән беренче булып күркәне татарлар асрый башлаган). **Күркә** сүзе тат. *курык тавык* «чеби чыгарырга җыенган тавык» (ДС I: 100–101) сүзе тәэсирендә нығып калган булырга мөмкин. К. Егоров 1964: 100.

**КҮРКӘМ** «видный, красивый на вид» ~ нуг., каз., чыгт. *көркäм,* кырг. *көркөм* id. *күрек* «матурлык» нигезеннән (*күрек-ә-м*), к. иске тат. **күркәй-ү** «матурлану», бор. чыгт., уйг. *көркäт-* «матур итеп күрсәтү» < бор. төрки (ДТС: 318) *көркäδ-* «матураю» һ.б. ЭСТЯ III: 80–82.

Дерив.: **күркәмлек, күркәмлән-ү.**

**КҮРМӘ** диал. (к. Радлов, Образцы… IV: 204) «корма, хвостовое весло» (*йигит ... кирәбе бүткәч үк мал тийәтĕптĕ, кĕшĕ йаллапты – кайсы күрсмәнгә, кайсы күрмөгө*) ← *күр-, күрә-* «ишү, көрәү» фигыленнән (к. **Көсмән**). Рус. (болг. Д.) *кормá* «көймәнең койрык тарафы» төрки телләрдән булып чыга!

**КҮРПӘ** диал. (к. ш. ук БТДҺ: 165) «шуба из шкуры ягнёнка», себ. (Тумашева 1992: 105) *көрбө* «мерлушка» < гом. кыпч. *көрпэ, күрпэ,* госм. *көрпä* «яшь бәрән; яшь бәрән тиресе» һ.б. к. ЭСТЯ V: 116–118. Рус. *курпей, курпек, курпя* «күрпә; яшь бәрән» тур. Аникин: 332 (шунда ук арытабангы әдәбият): шунысы игътибарга лаек ки, рус телендә бу сүзнең төрки телләрнең үзләрендә сакланмаган морфологик вариантлары күренә. К. **Көрпә II, Кузый Күрпәч.**

**КҮРСӘТ-Ү** «показывать, указывать» – неправильная форма понудительного залога от **күр-ү** (наряду с **күргәз-ү** и регулярно-правильной формой **күр-дер-ү**) ← бор. (МК) *körse-* «күрергә теләү» сүзенең нормаль формасы *körset-* сүзеннән яисә төр. *köster-* > иске тат. **күстәр-** сүзеннән (метатеза), бу төр. сүзе бор. *köz-* «күрү» сүзеннән угызча регуляр ясалышлы йөкл. юн. ЭСТЯ III: 83–84.

**Күрсәт-ү** һәм **күргәз-ү** тат. телендә актив сүзьясагыч нигезләр: **күрсәткеч, күрсәтмә,** (күп төрки телләрдә бар) **күрсәтүле; күргәзмә, күргәзүле** һ.б. **Күрдер-ү** «күрергә мөмкинлек бирү» сирәк кулланыла. Ниһаять, шуңа якын мәгъ. **күркәйт-ү** (Г. Кандалый) сүзе дә бар. К. **Күр-ү.**

**КҮРТӘ,** диал. (Тумашева 1961: 137; ТТДС I: 276) **көртә, көрти,** (ЗДС: 702) **хөрти, хертә** «утеплённый женский камзол, безрукавка» ~ башк. (БҺҺ III: 87) *көртөй,* уйг. *күртә,* үзб. *курта*, каз., к.-калп., кырг. *күрте*, төр. *kürte,* (Будагов II: 127) *көрте* «өске күлмәк; мамыклап сырылган кыска (җиңсез) чапан» һ.б. < фар. *kurtak*, сугд. *kwrδ'k, kwrty* «күлмәк төре»; фар. теленнән күп телләргә таралган (Абаев I: 609). Рус. диал. *курта, куртак* тур. к. Аникин: 333 (тат. сүзе искә алынмаган).

*Күртә* элекке шәкертләрнең «форма киеме» булган.

**КҮРҮ** иск. (Котбидә) «музыкально-сигнальный инструмент – большая морская раковина» < монг. *күрү, хүр, моринхүр* id.

**КҮР-Ү I** «видеть; смотреть» < гом. төрки *көр-,* угыз. *гөр-* id. барча төрки телләрдә бар һәм аннан **күз** < *көз* исем сүзе дә килеп чыккан. *Көр-* фигыленең *көз-* варианты да билгеле (к. **Күз**). Барча юн. формалары – **күрел-ү, күрен-ү, күреш-ү** – актив, ә йөкл. юнәлешенең берничә формасы бар: нормаль **күрдер-ү,** аннары **күргәз-ү, күрсәт-ү, күстәр-ү** һ.б. ЭСТЯ III: 77–79.

Бор. телләрдә үк (ДТС: 317–319) *körgü, körü ~ körä, körkäδ-, körk, körüg, körsä-, körük, körüm, körüš* «күрге, күрә, күркәю, күрсәү, күрек, күрем, күреш һ.б.» һәм аларның дериватлары теркәлгән. Хәз. төрки телләрдә **күр-** ~ **көр-** нигезенең дериватлары бихисап. К. түбәндәрәк.

**Күр** тамыры тат. телендә дә иң продуктив сүзьясагыч нигезләрнең берсе, к. **Күрә I, Күрәзә, Күрген, Күрек, Күренеш, Күркәм, Күрсәт-ү, Күрше. Күр-** фигыленең юн. формалары да (бигрәк тә **күрен-ү, күреш-ү**), аерым мәгънәләр алып, сүзьясагыч нигез буларак киң кулланылалар (мәс., **күренек** «карарлык кыяфәт, төс-буй», шуннан **күренекле** «танылган, атаклы»; **күрендер-ү** «кәләш күрсәтү» ← **күрен-ү** һ.б.). К. **Күрем I, II** (бу сүзләрдә бүтән тамырлар тәэсире бар).

**КҮР-Ү II** (**чара күрү, килә күр** кебек тәгъбирләрдә) «выполнить, исполнить, совершить, вести (дело), проводить (в жизнь)» ~ чув. *кӳр-* «китерү; ташу; куллану» < иске тат. *күwĕр-* < чыгт. (Радлов II: 1402; Боровков 1963: 177–178) *киwир-, киwүр-* < бор. төрки (ДТС: 306) *kigür-* < уйг., иске тат. («Нәһҗел-фәрадис»тә) *киргүр-* «китерү; башкару» ← бор. төрки **kir-* «эшләү». Егоров 1964: 124.

Тат. *күр-*, ихтимал, халык (сөйләм) телендә *күwĕр-* дип тә әйтеләдер, аны әд. телгә шул вариантта алырга кирәк. «Мөхәммәдия» телендә *иман күwүр-* «дин тоту». К. **Күвер-ү.**

**КҮРҮК** «дымарь (у пчеловодов)» < рус. диал. *курюк* < иске тат. *күрек,* к. **Күрек II.**

**КҮРҮМӘЗ** (Җ. Вәлиди язып алган себ. тат. җырында: *Күрүмәз иле күк чәчкә...*) «Хормузд, божество, дающее дожди» ~ алт. һ.б. Себер халыкларында *көрүмес, көрмөс* id., к. МНМ II: 595–596. К. ш. ук **Айзар-байзар, Кузый Күрпәч.**

К. Вәлиди Җ. Җырларымыз хакында // Шура 1911, № 19; Будагов II: 151–152.

**КҮРШЕ,** диал. **күреш** «сосед», чув. *кӳрӗш* > мар., удм. *кöршы, кöрыш* id. ~ каз. *көрши* id. (< тат., чөнки төп каз. *көрси*), алт. *көрүш* ~ бур. *хүршэ* «күрше»; сүзнең таралыш географиясе аның бор. төрки-монгол даирәсеннән килгәнлеген күрсәтә; этимоны *күреш-ек* < **көрүшүг* «күрешеп торучы» сүзеннән булса кирәк. Күп төрки телләрдә «күрше» мәгъ. *қушны* (иске тат.) < *қошну ~ коншу* кулланыла. Федотов I: 324; ЭСТЯ V: 118–119.

**КҮРШЕ-КҮЛӘН** «соседи» – **күрше + күлән** < *күйлән* ← чув. *кӳй*, бор. төрки *куй* (к. Радлов II: 887) «хатын-кыз бүлмәсе; кыз тирмәсе» < кыт. Элекке төркиләрдә җиткән кызлар аерым тирмәдә яшәгәннәр. К. **Күлән, Тирмә.**

**КҮСӘ** «мужчина без бороды и усов; неполноценный человек (мужчина)» ~ чув. *кӗвсэ, кӳсэ*, мар. *кӱсӓ* < гом. көнб. төрки *көсә*, кырг. *көсөө*, бор. төрки, бор. монг. *köse* (Поппе 1938: 224) < фар. *köse, kösen* id. < бор. *күшӑн, кушан* – б.э. беренче гасырында Урта Азия һәм Әфганстанда империя корган монголоид халык атамасыннан. Федотов I: 325 (гар. сүзе дип карый).

**КҮСӘК** «дубина, дубинка, рычаг» > чув. *кӳсек*, мар. *кӱсек, кӱсӓк*, удм. *кöсег* «каергы, рычаг» < гом. төрки, к. алт. *көсөк*, төр. диал. (DS VIII: 2971) *kösek* һ.б. «күсәк; кисәү» < бор. төрки (ДТС: 321) *közägü* «кисәү, кучарка» ← *közä-* «күзәү, кисәү белән болгату» ~ нуг., каз., к.-калп., төркм. *көсе-* id.; к. үзб. (ЎХШЛ: 149) *кӧсаң, кӧсагу,* төр. *köseği,* кырг. *көсөө, көзөө*, нуг. *көсев* «кисәү», кар. *күсев, кесев, көсев* «күсәк; кисәү». Шулай итеп, **кисәү** һәм **күсәк** сүзләре үзара төрлечә тоташа. Бу гаҗәп түгел, әмма *з ~ с* тәңгәллеге гом. төрки планда гайре табигый хәл – монда ике тамыр контаминациясе булса кирәк. Joki 1952: 202; Räsänen 1969: 293; ЭСТЯ V: 119–121 (күп материал китерелә, тәфсилле); Федотов I: 327.

Дерив.: **күсәкле, күсәксез; күсәкләү.**

**КҮСӘМ: Күсәм агай** – юмористический герой в сказках. Каз., төр. *kösem, kösemen* «көтү башында йөри торган тәкә» ← *kös, köse* «көтү». Будагов II: 156.

**КҮСЕ,** диал. (ДС I: 116) **көсмәр,** (Радлов III: 1501–1513) **күске, күшмәр** «крыса», диал. «крот» << төр. диал. *köskü* «сукыр тычкан», бор. төрки (ДТС: 329) *küskü* «тычкан» ~ башк. (БТДҺ: 166) *күсә* «су тычканы», хак., алт., тув. *күске*, як. *кутуях* «күсе», *кутэрь* «көшел»; бор. төрки (ДТС: 319, 329) *kösürgä, kösürgän, küsürgä, küsürgen* «сукыр тычкан» ~ алт. диал. *күскэҗәк, күскүжәк, күскүчәк* «тычкан» һ.б. Чаг. фар. *гэрзү, герзү* «тычкан» >> рус. *крыса* (?). *Күсе* < **көсгү* < **күсгүр, күскүр* > *күсүр* > *көшел* булса кирәк; ЭСТЯ (V: 122–123) буенча *күсгүр* < бор. төрки *көзүкүр* «күзе сукыр» булырга мөмкин (ягъни мәзкүр сүзләрнең чыганак мәгънәсе «сукыр тычкан» була). Кызыклы фараз! К. **Күрә I.**

**КҮСТӘК, көстәк** диал. «тяжёлые деревянные путы (для лошадей)» ~ каз. (ҚТДС: 167) *көстек* id., төркм., төр., урта төрки (әт-Төхфәт... 40) *köstek* «тышау; сәгать чылбыры; обойма; тимер юл тормозы» ← **köstä-* «ныгытып бәйләү»? К. ш. ук төркм. (Мухамедова 1973: 128) *көсдек, көссек* «озын тышау, бәй», төр. *kössek* «богау» һ.б. Чаг. тат. диал. (ЗДС: 331) **көстөми** < **көстәмәк* «шпал кадагы; обойма». Будагов I: 155.

**КҮСТӘР-Ү** иск. «показать» < төр. *köster-* < бор. *közdär-* id. *koz-* «күрү» сүзенең йөкл. юн. (Будагов II: 155).

**КҮТ** «задница» ~ чув. *кӳт, кут* < гом. төрки *köt,* угыз. *göt* id. Федотов I: 316–317 (урынсызга гом. төрки **кэд** – к. **Кәй** – «арт» сүзе белән чагыштыра).

**КҮТӘН** «задний проход, прямая кишка» ~ чув. *кутан, кутана,* мар. *кӱтан, кӱтӓн* «күт» (Иванов, Тужаров: 99), морд. Э. *котян* id. < гом. төрки *kötän*, алт. диал. *көдэн* һ.б. *күт* < *köt* сүзеннән, әлбәттә. Ясалышы ачык түгел.

**КҮТӘМӘ** «вид мелкой рыбы» ~ башк. *күтәмә* «зәңгелә балыгы» ~ чув. *кутеме [кӳдэмэ]* «хариус, бәрде», *кутан* «ташбаш», мар. *кодама, котама, ка-*

*тама* id., рус. *куте́ма, кутерма́* «форель, керкә» – фин-угор телләреннән. СРНГ, вып. 16: 167.

**КҮТӘРӘМ: күтәрәмгә калу** «истощиться до того, что не иметь сил стоять на ногах (о скотине)» К. чув. *кӳтерем [күтэрэм]* id., мар. *кӧтрем* «нерасторопный, медлительный; капризный» (Иванов, Тужаров: 89) ~ нуг. *кӧтерем,* кырг. *кӧтӧром, кӧтӧрүм* «күтәрәм, бик йончыган», төр. *kötürüm* «яраланган, нык алҗыган» һ.б. < **күтәрем,** к. **Күтәр-ү.**

**КҮТӘРЕНКЕ** «приподнятый; возвышенный; завышенный» **күтәрен-ү** фигыленең төп мәгънәсеннән («үз-үзеңне күтәрү») мәзкүр рус. сүзләре тәэсирендә тат. телендә барлыкка килгән булса кирәк.

**КҮТӘРМӘ** «крыльцо; ступени крыльца; передок телеги; деревянный каблук; подставка; рычаг; фрамуга (окно, окошко, поднимающееся снизу вверх)» – барысы да **күтәр-ү** фигыленнән, әлбәттә, тик аларның мәгъ. үзенчәлекләре тарихи аңлатмага мохтаҗ. 1) иске тат. *күтәрмә* ~ нуг. *кӧтерме* «каңгыга (киң тигез мәйданлы арбага) куела торган җиңел тирмәчек (аны *күтәреп* утырткannар)», шуннан «болдыр» мәгъ. килеп чыккан; 2) бор. тат. *күтәрмә* < *кӧтәрмә* һ.б. «хан сайлаганда хан утыртыла торган киез»; 3) ерак арага ат ярышларында – бәйгедә арыган атларны озын тасма белән ике яктан корсагыннан уратып күтәрү, бу шөгыль бик көчле һай-һулар белән башкарылганлыктан, *күтәрмә* > рус. *кутерьма* гомумән шау-шулы күренешне белдергән (к. Будагов I: 241, II: 143; Сборник материалов, относящихся к Золотой Орде: 172, 302). Аникин: 336; Velidi: 112 (элекке мәдрәсәләрдә дә «казый»ны сайлаганда дүрткел киезгә утыртып күтәрү һәм бу гадәт хан сайлаудан күчермә булу тур.).

**КҮТӘРМИС** (ЗДС: 357) «работник периода ликбеза в 20-е гг. XX века» < рус. *культармеец* булса кирәк.

**КҮТӘРТМӘ, күтәрмә** «деревянная колодка, прикрепляемая к подошве обуви (особенно весной), чтобы не размочить ноги» > мар., удм. *кӧтермя, кутӓрмӓ* id. **күтәрт-ү** фигыленнән.

**КҮТӘРТ-Ү** «заставить взять лишние карты (в игре)» – **күтәр-ү** фигыленең йөкл. юн.

**КҮТӘР-Ү** «поднимать» < диал. *күлтәр-* (к. Ахатов 1980: 64), бор. тат. (НФ) *күлтүр-* ~ к.-балк. *кёлтюр-* id. Шунысы игътибарга лаеклы, *-л*-ле вариантлар тат. һәм к.-балк. телләрендә генә сакланган, күпчелек төрки телләрдә (Радлов II: 1276–1280) *котӓр-, котүр-*, бор. төрки (Поппе 1938: 186; ДТС: 320) *kötür-*, алт. *кӧдүр-*, хак. *кӧдĕр-* «күтәрү», к. ш. ук үзб. *кӧтәр-, котар-* «күчерү», аз. *гӧтүр-* «озату» һ.б. Сүзнең тамыры бор. төрки **köl* «атка (аркасына) йөкләтү» – шуннан **költär-* «йөкләтү»! А. Гуломов (Сузлар хаётидан: *кутар-* // Ўзбек тили ва адабиёти, № 6, 1969: 61) бу сүзне бор *köt-* «күтәрелү» сүзеннән димәкче (к. бор. төрки *köti-* «күтәрелү», *kötki* «үр, күтәрелеш»), тик ул сүз дә **költir-* кебек сүздән булса кирәк. *Költer-* фигыленең бор. бер формасы *köler-* «шешенү, тутырылу, йөкләнү, тутыру, йөкләү, тулышу» (Clauson: 719–720); шуннан ук чув. *кӑлар-* < **көләр-* «тартып чыгару; чыгару».

**Күтәр-** продуктив нигез, к. **Күтәрәм, Күтәрмә, Күтәренке,** ш. ук аерым үзенчәлекле мәгъ. алган регуляр ясалмалар: **күтәргеч, күтәрем** (бер кеше күтәрерлек), **күтәрен-ү, күтәренке, күтәрт-ү** һ.б. к. Будагов II: 143–144. ЭСТЯ III: 86–88 (этимоны безнеңчә түгел).

**КҮТӘЧ,** диал. **күтәс** «чрезмерно угодливый; старающийся свою вину загладить угодливостью» ~ башк. *күтәс* id. – **күт** сүзеннән булса кирәк. Чаг. **Күтенлә-ү.**

**КҮТЕНЛӘ-Ү** «отказаться от уговора, обещания, пойти на попятную» – *күт* сүзенең «арт як» мәгънәсеннән; тәүдә *китенлә-ү* (*китен* «соңыннан», к. **Кәй**) булган, соңыннан экспрессивлыкны көчәйтү өчен *күт* сүзенә нисбәтләнгән (*күт* сүзе һәртөрле хурлау, сүгенүләрдә кулланыла, **күтен** нигезе килеп чыгу шуның белән аңлатыла).

**КҮТЕР, күтергәк** диал. (Тумашева 1992: 112; ТТДС I: 286; БТДҺ: 166) «трясина; торфяник; островок или полуостров, образовавшийся из плавня» ~ башк. *күтӗр* «газ чыгарып, күбекләнеп торган саз; саз уртасындагы күл; саз үләне (төрле үлән)» – тарихи яктан бик кызыклы сүз. Аның кызыклыгы шунда – ул барлык төрки телләрдә, монгол һәм тунг.-маньч. телләрендә, аннары фин-угор телләрендә киң таралган. Төптә ул тозлакны (тозлы сулы сазламык җирне) белдергән: чув. *кутӗр (кӳдӗр)* «саз» ~ удм. *гудыр* «ләм», эвенк. *куду*, монг. *куҗир, кудыр* «тозлы саз, тозлы дала» һ.б. (йөзләп

мисал китерергә мөмкин). К. Räsänen 1969: 296; ССТМЯ I: 423; ЭСТЯ V: 154 (материалы аз). Рус. *кужир, куджур* «тозлак; тозлакта үсә торган үлән төре» < монг., тув. турында Аникин: 312.

**Күтер** сүзенең болай киң таралышы (башка шундый сүзләр белән бергәлектә) атаклы Урал-Алтай телләре (аларның борын-борынгы бер телдән килеп чыгуы) гипотезасына нигез булып тора (әлбәттә, бер бу сүз генә түгел).

Дерив.: тат. **күтергәк,** башк. *күтерҙек* < *күтерлек* «күтер».

**КҮФИ: күфи хаты** – способ, стиль написания арабских букв – *Күфә* шәһәре исеменнән.

**КҮЧ I** «группа кочевников (на марше), свадебный поезд; рой», иск. «один переход» ~ башк. *күс,* чув. *куç* < гом. кыпч. *кӧч* (к. Будагов II: 144–145), угыз. *гӧч-,* хак., як. *кӧс*, нуг., каз. *кӧш* id.

**Күч** «күчеп барган төркем; туй процессиясе» һәм *күч-ү* фигыле төрки телләргә хас булган (һәм инг. телендә дә еш күзәтелгән) фигыль-исем синкретизмы дигән күренешкә мисал, к. гом. кыпч., уйг. *кӧч-*, угыз. *гӧч-*, нуг., каз., к.-калп. *кӧш-* «күчү, күченү».

*Күч* сүзенең кайбер төрки телләрдә «гаилә; хатын» мәгъ. бар (*умарта күче* тәгъбирендә шул мәгъ. чагылырга мөмкин). Шуннан чыгып, кайбер тикшеренүчеләр бу сүзне сугд телендәге *kwč* «авыз» (ягъни «ашаучы, тамак») сүзеннән дип уйлыйлар. Ләкин *күч* сүзенең төп мәгъ. «гаилә» түгел кебек. *Күч* сүзенең «бер көнлек юл (гадәттә тигез җирдә 27 чакрым)» мәгънәсе дә булган. Татар (утрак игенчеләр теле) өчен бу мәгънә характерлы түгел.

**Күч** һәм **күч-** (< гом. төрки *кӧч-* > удм. *кӧч-*) бик продуктив нигезләр: **күчем, күчел-ү, күчен-ү, күчеш-ү; күчек-ү, күчемле, күчеш, күчкен, күчмә, күчмән, күчмәнче** һ.б. сүзләр ясалган. Төрки телләрдән бу сүзләр күп күрше телләргә үтеп кергәннәр. Русча *кочевать, кочевой* һ.б. хакында к. Аракин: 32–33 (рус. *кочь* XII г. ук теркәлгән); Аникин: 308. К. ш. ук ЭСТЯ III: 88–90; Федотов I: 315–316. К. **Күчәт, Күчер-ү.**

**КҮЧ II, күчә** (ТТДС II: 210), (ЗДС: 340) **куча́** диал. «куча» < рус. булса кирәк.

**КҮЧӘ** иск., диал. «маленькая деревня; улица» ~ башк. *күшә* «урам» < каз. *кӧже* < *кӧҗә* < *кӧчә* > *күчә* «урам; тыкрык», Урта Азиядә һәм Казакстанда киң кулланышлы сүз. Ул *кӧйчә* «кечкенә, тар урам» сүзеннән таралган. Сүзнең тамыры *кӧй, кой* «авыл, торлак; күршеләр бергәлеге» күп телләрдә, шул хисаптан тат. сөйләшләрендә дә очрый. Казан арты сөйләшләрендәге *киби йөрү* «урам буйлап сабантуйга бүләк җыю» *кӧй буе йөрү* дигәннән килә.

*Кӧй* «авыл, торлак» сүзе бор. кыт. теленнән алынган булса кирәк (хәз. кыт. сөйләшләрендә *цзе* «авыл, урам» < борынгыча **кийәй* «урам»).

Ойконим номенклатурасы (*авыл, шәһәр* һ.б.ш. сүзләр) барлык телләрдә дә икенчел, ягъни күч. мәгънәдәге сүз (рус., мәс., *село* «сала, зур авыл» төптә «утырыш, утыру урыны», ә *деревня* «бәләкәй авыл» төптә «агачлык» һ.б.) яисә алынма (мәс., *сала* < *село, пучинкә* < *поселок* яисә *починка* «яңа авыл»). К. Будагов I: 147, 170; ССТМЯ I: 404.

**КҮЧӘН** «кочан» ~ башк. *күсән,* чув. *кучăн, кучăк*, мар. *кӧчăн, кӧцӧн*, удм. *кӧчӧн* id. – Идел-Урал регионына хас сүз. *Күчән* «кәбестә башы һәм кәбестә башының үзәге» сүзен бик җиңел генә русча *кочан* сүзеннән дип аңлатырга була. Ләкин рус сүзе үзе һинд-евр. телләре җирлегендә аңлатылмый. *Кочан*ның русча тагын *кочень* һәм *кочерь* (шуннан *кочерёжка*) формалары бар. *Кочерёжка*ның турыдан-туры морфологик нигезе *кочерга,* ләкин бу сүз кисәү агачын белдерә; рус сөйләшләрендә *кочерга* дип өй кәрнизен тотып тора торган кәкре казыкларны да атыйлар.

Венг. һәм барлык Балкан телләрендә *кочан* «чәчәк сабы һәм яфрак чеме, сабакчасы» < төр. *koçan* id. (к. Gombocs: 97); төр. *koçan olmak* ~ рус. *кочене̇ть* «күшегү, суыктан, өшүдән буыннар, бармаклар *күчәнләнү*» Башк. сөйләшләрендә (БТДҺ: 166) *күсәр* «күчән». Рус. *окочуриться* «агач булып кату, үлү», рус. диал. *кочерь* «кәүсә, күчән».

Барлык бу һәм бүтән фактлар *күчән* һәм *күчәр* сүзләренең төрки тамырдашлыгын күрсәтәләр. Рус телчеләренең дә күпчелеге *кочень, кочан* һәм *кочерь (кочерга)* төрки телләрдән дип аңлаталар. К. **Күчәр, Кучарка.**

**КҮЧӘР,** диал. **күсәл** (Җ. Вәлиди) «ось», диал. «колесница, двуколка» > удм., мар. *кӧчер* «күчәр» ~ кр.-тат., кар. *кӧчäр* id. (Радлов II: 1289), нуг., каз., к.-калп. *кӧшәр, кӧшәр*, үзб. диал. (ЎХШЛ: 149) *кӧчәр* «күчәр» ~ калм. *kösür* «арба күкрәге» < *kösigür* «агач кисәге, тумран» (монг. *kösi* «агач; агач үзәге»), к. Ramstedt 1935: 241 (Г. Рамстедт монг. *коси* төрки *кисәү//күсәү* белән чагыштыра). Ләкин монда мәгъ. бәйләнешләрендә аңлашылмаучылык кала: *күчән* белән *күчәр* охшаш – анысы аңлашыла,

ә менә кисәү агачы нишләп күчәргә, яки киресенчә әверелергә мөмкин? *Кисәү//күсәү* сүзенең бирелдә катнашы юк.

Монда табышмакның җөмен-җавабын морд. сөйләшләрендәге *кӧцькергань* һәм мар. диалектларындагы *коцькарга* «кисәү агачы» сүзе ачып бирә: төбендә *күчкәргә* < *күкчәргә* монг. *кӧкчүргә* «төп тамыр» дигән сүздән: аның тамыры *кӧк* < гом. төрки *кӧк* «тамыр; ими үзәге» (шуннан ук *күчән, күкрәк, күңел* һ.б. бик күп сүзләр, к. югарыда). Монг. *кӧкчэр, күкчәр* «үзәк тамыр, тамыр үзәге», шулай ук «арба кендеге» (тат. *күкрәге* дип тә сөйлиләр: *күкрәк* монда «ими тамыры кебек нәрсә» мәгънәсендә). Арба кендеге күгәнгә охшаш – бер башы кискен кәкре таяк. Нәкъ шундый таяк – кисәү агачы да (ягъни – *кучарка*). *Күкчәр*дән *күчәр* сүзе килеп чыккан: ул башта арба кендеген, соңыннан күчәрнең үзен белдерә (*-чәр* монг. кечерәйтү кушымчасы).

*Күчән* исә *күчәр* сүзенең морфологик варианты – паронимы (бор. формасы) *кӧкчәң* > *кӧкчүк* >> монг. *кӧси* (*kösi*) «үзагач».

Элек бездә *күчәр* < *köčür* дип ике тәгәрмәчле арбаны һәм алдарбаны атаганнар (ТТДС I: 287). Шуннан (болг. теленнән) бу сүз венг. теленә *куче* рәвешендә кергән (соңгы *-р* төшеп калган) булса кирәк. Икенче яктан венг. *kocsi* «арба; вагон» төр. *koçu* «ике тәгәрмәчле арба» сүзеннән дә булырга мөмкин (киресенчә булмаса).

Кайбер этимологлар *күчәр* сүзеннән *кучер* сүзе килеп чыккан дип уйлыйлар. *Кучер* һәм *күчәр* сүзләре арасында тарихи бәйләнеш чыннан да бар, ләкин турыдан-туры түгел.

Әлеге венг. сүзе *kocsi [куче]* «алдарба» ним. теленә барып эләккән. Ним. *Kutsche [куче]* «алдарба, элекке экипажларда – файтуннарда ат куучы урыны». Шуннан нимес сүз ясалышы кушымчасы *-р* ярдәмендә *кучер* «ат тотучы» сүзе ясалган. К. Тóрма Й. Этимология одного бродячего слова венгерского происхождения в башкирском языке // Tatarische etymologische Studien II. Szeged, 1988: 231–266.

Хәер, бу этимологияне гадиләштереп караучылар да бар: *кучер* турыдан-туры *күчәр*дән дип. Ләкин мондый аңлатманың тарихи нигезе күренми: кайчан немесләр татарлар белән шулкадәр тыгыз аралашканнар да, татар теленнән шундый сүзләр ала башлаганнар? Ә бит *күчәр* татарча гына шулай яңгырый, бүтән төрки телләрдә *кӧчәр* (умлаутлы *ӧ* белән әйтелә). К. Фасмер II: 356–357; ЭСТЯ V: 125. Ниһаять, **күчәр**не **күч-ү** сүзеннән чыгып аңлату очрый, тик бу аңлатма бөтенләй дәлилсез-нигезсез.

**КҮЧӘТ** «рассада» ~ уйг. *күчәт* id. ← **күч-ү** (к.).

**КҮЧЕР-Ү** «переместить, перемещать», «списать, переписать» – гом. кыпч. *кӧчүр-* (башк. *күсер-*, нуг., каз., к.-калп. *кӧшир-*) id. *күч-* < *кӧч-* фигыленең (к. **Күч-ү**) «дөрес түгел» йөкл. юн. (*күчтер-* > *күччер-* > *күчер-* кебек күчешләр бүтән телләрдә дә бар). К. **Күч-ү**.

Дерив.: **күчерел-ү, күчерен-ү, күчереш-ү, күчерт-ү; күчерге; күчергеч; күчерек, күчермә.**

**КҮЧТӘНӘЧ**, диал. (ЗДС: 361) **күчтинәч** «гостинец» < рус. Чув. *кучченес* (Ашмарин VI: 56), мар. *кӧстӓнӓс* (Исанбаев 1978: 35), *кӧстенец* (Саваткова: 61), удм. диал. *кустэнэс* id. татарчадан, мар. *костенеч, коснес* турыдан-туры русчадан. К. **Күчти.**

**КҮЧТӘРКӘ** (ЗДС: 361) «костёрка, сковорода с ножками» < рус.

**КҮЧТИ** (ЗДС: 361) «пышка, булочка и т.п. испечённое мучное изделие». Бу сүз **күчтинәч** (к. **Күчтәнәч**) сүзеннән кыскарган бугай. Ләкин ул тат. телендә ясалган, шунлыктан рус теленнән алынма дип исәпләнми.

**КҮЧ-Ү** «переместиться; кочевать» < гом. кыпч. *кӧч-*, башк. *күс-*, нуг., каз. *кѳш- [köš]* һ.б. id. К. **Күч I, Күчер-ү.** Räsänen 1989: 285–286.

**КҮШ** «крыша над сиденьем экипажа» (Г. Газиз), иск. «повозка, кибитка коляски» (к. Будагов I: 156) ~ рус. *кош* «экипаж с крытым сиденьем» < гом. төрки *қош, кӧш* «куыш; куышлы арба» сүзеннән булса кирәк (к. ш. ук рус. *кошевой экипаж, кошева, кошёвка* > тат. сөйл. *кашавай чана*). Тат. *күш*, хәер, *күшек* сүзеннән дә булырга мөмкин (к. **Күшек**), к. *Күшле чана* «көймәле чана». Әдәбиятта **куыш** һәм **күш** буталып килә.

**КҮШӘ,** диал. **күшәй** (без теркәдек. – *Р.Ә.*), «навой, нитки для основы тканья, связанные наподобие звеньев цепи для компактности и – чтобы не спутались – в таком виде звенья надеваются на столбик» ~ башк. диал. *күшәк* id. Тат. **күшә баганасы** ~ башк. (БТДҺ: 167) *күшә* «юан киндер бау» < бор. төрки **кӧшӓгӓ* «толым» булса кирәк, к. тув. *кӧжээ, кӧжэгэ (< кӧшэгэ)* > хак. *кӧзӓ, кӧзэ* «кызлар какулы; какуллы кешеләрне сурәтләгән сынташ, балбал» (к. Сат 1984: 187–198; Грач: 94).

Тат. диал. **күшә** «үлән төре, көпшә» (ТТАС II: 317) сүзенең **күшә**гә мөнәсәбәте ачык түгел.

**КҮШӘГӘ,** диал. (ЗДС: 344) **күжәгә** «занавеска, покрывало; лёгкий полог», (Будагов I: 15) *кӧжӧгү* «занавес; куриная слепота», (ДС III: 105) **күшәге** «халат, верхняя длинная лёгкая одежда» ~ кырг. *кӧшӧгӧ*, уйг. *кӧшәгә, кӧшигә, кӧшүкә*, үзб. (ЎХШЛ: 149) *кӧшәгәнә, кӧшәңгә, гушанга,* алт. *кӧжӧгӧ*, тув. *кӧжэгэ* > хак. *кӧзэгэ* һ.б. бор. монг. (Поппе 1938: 157) *kӧšige* «пәрдә». Сүзнең ясагыч нигезе төрки булса кирәк, к. бор. төрки (ДТС: 319) *kӧši-* «каплау, күләгәләү» → *kӧšigä* «пәрдә», *kӧšätri* «ябулык» һ.б. Бу тамыр фигыль үзе мөгаен *kӧš* ~ *kӧl* «аслык, ябулык, түбә» дигән тамырдандыр. К. **Күш, Күшән-ү.** Чаг. **Күшмә.**

Мәзкүр *kӧši-* тамырын бор. *koli-* (к. **Күләгә**) «җиңелчә каплау, ябу» белән чагыштыралар. Räsänen 1969: 294; Номинханов 1975: 141; ЭСТЯ V: 128.

**КҮШӘН-Ү I** диал. «прикрываться; убежать от взоров (о девушках)» ~ алт., кырг. *кӧжӧн-* «күшәнү, качу» (*кӧжӧн* «качу урыны») < бор. төрки (ДТС: 319) *kӧšun-* «кояштан каплану» ← *kӧš-*. К. **Күшәгә**.

**КҮШӘН-Ү II** «всё время что-то жевать (о человеке)» ← **Күшә-ү**.

**КҮШӘ-Ү,** диал. **көйшә-ү** һәм себ. (к. Тумашева I: 96) **кәүшән-ү** ← **кәүшә-ү** «жевать, пережёвывать (о жвачных)». Ике вариант ике тарафтан килә: *күшә-* < *күйшә-* < **кӧгшә-* кыпч.-уйг. линиясе (к. кыпч. *күйше-, күйшә-,* кырг. *күйшӧ-*, аз. *гӧйшә-*) һәм чыгт., үзб. һ.б. (к. Поппе 1938: 212) *käwšä-, kevše-*, төр. *gevše-* id. Бу төрле вариантларның нигезләре үк ике вариантлы: 1) **кәйүш*, 2) **кәwүш* (*-й* ~ *-w* тәңгәллеге тат. телендә тагы *сөй-* ~ *сәү-*, *өйрә* ~ *үрә* < *үwрә* һ.б. очракларда күзәтелә), шулардан *кәйүш-ә-* һәм *кәwүш-ә-* фигыльләре ясалган. Әлеге нигезләр исә үзләре бор. төрки (ДТС: 304) *kev-* > госм. *гäв-, кäв-,* төркм. *гев-,* бор. монг. *kebi-* > як. (Пекарский: 999) *кäбіі-* «чәйнәү, көйшәү» (бур. *хибэ-* id.) фигыленнән, ул фигыль, тагын килеп, бор. **кәб* (эвен. *кэбэ*) «яңак, урт» сүзеннән, шуннан **кәблä-* > чув. *кавле-* (> морд. *кавля-*) «көйшәү, уртлау». Räsänen 1969: 244; ЭСТЯ III: 5–7.

**Көйшә-** ~ **күшә-** нигезенең тамыры бор. төрки (ДТС: 304) *kev-* «кимерү» булса, ул һинд-евр. **gev-* «көйшәү, чәйнәү» сүзе белән (к. Kluge: 479, 486–487) бердәй булуы ихтимал. Ул тамырга ним. *Kieme, Kimme* «урт, яңак; саңак» сүзе дә тоташа һәм *ким-, кәм* < гом. төрки *kät-, ket* нигезе дә (к. **Кимек, Кимер-ү, Кимшекләү-ү**) гомоген булуы ихтимал. Гомумән, монда ностратик тамырларның берсе булуы мөмкин.

Бор. ностратик *gev-* тамырыннан рус. *жев-ать* ~ фар. *җäв- (җäвидин)* «ашау, чәйнәү, күшәү» сүзе дә килә, дип язалар. Фар. сүзенә гом. төрки *йэ-* «җию, ашау» тоташса да гаҗәп түгел (к. **Җи-ү**). Әмма шунысы бар: китерелгән тамырлар барысы да бер иҗекле тамырлар, аларда охшашлыклар һәрчак очраклы була ала.

**КҮШЕК** «бойница; ниша», иск. «уголок (с крышей над головой)» ~ госм., фар. һ.б. Шәрык телләрендә *кӧшк, гӧшк* «матур павильон», төркм. «сарай», шуннан ук (бор. куман теле аркылымы) рус. *киоск* сүзе килә. к. Будагов II: 156. Абаев (I: 642) бу сүзне бор. ир. *gӧšäk* «почмак, күшек» сүзеннән ди, ләкин чаг. монг. *хөшиг* «күшәгә, пәрдә», к. **Күшәгә.**

**КҮШЕК-Ү (күшегү, күшекте)** «коченеть от холода, озябнуть» – бу интенсивлык формасында тат. телендә генә, төп фигыль – **күш-ү** (к. шуннан юн. формалары (ЗДС: 362) **күштер-ү**, трбс. сөйләшендә (без теркәдек. – *Р.Ә.*) **күшен-ү**) ~ кырг. *кӧшү-*, тув. *кӧжү-,* як. *кӧсүй-, кӧһүй-* «күшегү», «тынып калу» ~ яз. монг. *gӧši* id. *Kӧš-* тамыры монг. *кӧлдэ-* > тунг. *кулдэ-* «күшегү, өшү» белән чагыштырыла. Ramstedt 1935: 241; Räsänen 1969: 294; ЭСТЯ V: 127.

Дерив.: **күшегел-ү, күшегеш-ү, күшектер-ү.**

**КҮШЕН** тар. «войсковое подразделение» к. **Кушын.**

**КҮШИЛ** «кошель, плетёная из лыка корзина, котомка» < рус. (ЛТ I: 242) ~ чув. *кушел, кушелкке* (< *кошелёк*) id.

**КҮШКЕ** (Г. Кандалый; БТДҺ: 167) «вид плётки, нагайки» < рус. сөйл. *кошки, кошка* id. Даль буенча, «песи койрыгы шикелле яисә тармаклы камчы».

**КҮШМӘ** (Тумашева 1992: 117) «сшитая из лоскутьев (об одеяле)» < алт. *кӧшме* id. Бу сүз рус. *кошма* сүзенең этимоны булса кирәк (рус сүзенең ышанычлы аңлатмасы юк, к. Фасмер II: 361). Чаг. **Күшәгә.**

Тат. сөйләшләрендәге **кашма** «киез палас» сүзе рус сөйләшләреннән алынган.

**КҮШТ** иск., себ. (Тумашева 1992: 105, 112) **көш, күш** «мясо; мясное блюдо» < фар. *гөшт, күшт* id. (бу сүз күп төрки телләргә кергән).

**КЫБЫР:** диал. (ЗДС: 434) **кыбыр-кыбыр,** ш. ук **кыпыр-кыпыр –** имитатив о медлительных и мелких движениях: **кыбыр-кыбыр килү** «суетливо, но не очень интенсивно шевелиться», **кыбырда-у** «помаленьку двигаться» (*қыбырдаған қыр ашқан* «дорогу одолевает идущий»), **кыбырсы-у** «делать беспорядочные мелкие движения от волнения, от желания высказаться или уйти и т.п.» – гом. кыпч. *қыбыр,* төр. *kıpır* id., чув. *кӑпӑр: кӑпӑр-кӑпӑр* «ашык-пошык», *кӑпӑрта-* «шакылдау» һ.б. Чаг. **Кыймыл, Кымыр, Кым, Кып I.**

**КЫДРАЧ** «горячий нравом; драчливый» ~ башк. *қыҙрас* id. Чаг. **Кыҗра-у.**

**КЫДЫР-У** (ТТДС I: 213) «сделать всё, чтобы найти; скитаться» ~ башк. *қыҙыр-у* «каңгырап йөрү, ил гизү; йөреп чыгу» (*қыҙырып эҙлә-ү* «мөмкин булган бөтен җирдән эзләү»), < гом. кыпч. *қыдыр-* id., үзб. (ЎХШЛ: 160) *қъдър-* «кунакка йөрү», төркм., төр. диал. *қыдыр-* «эзләү; кодалау», төркм. (ТДГДС: 70, 119) *ғыдыр-, қыдыр-* «бара бирү», «яшәп яту», каз. диал. (Будагов II: 42) *қыдырт-* «кунакларга аш өләшү» һ.б., к. Будагов II: 103; ЭСТЯ VI: 185. Ачык түгел.

**КЫЕ [қы̆йы̆]** диал. «край, кайма» – гом. кыпч., башк. (БТДҺ: 210, *қыйла-у* сүзендә), госм. һ.б. *қый, қыйы* «яр, кырый» < бор. төрки (ДТС: 440) *qïδïγ* id. ЭСТЯ VI: 196–197, 203–204.

**КЫЕК [қы̆йы̆к]** «косой, наклонный; скат крыши; крыша (дома)», диал., башк. (БТДҺ: 210) «лоскут, отрезок, ломтик; косоглазый; косынка; ластовица» > чув. *кӑйӑк* id., удм. диал., мар. диал. *кыйык* «түбә, кыек» < гом. кыпч., уйг. *қыйиқ* «кыеп алынган, авыш киселгән (нәрсә); кыенты» < бор. төрки (ДТС: 441) *qïjïq* «кыек» һ.б. ← *qïj-*, к. **Кый-у I,** төрки телләрдә *кый* үзе генә дә «кыек, кыеш» мәгъ. очрый. Будагов II: 103; ЭСТЯ VI: 199–200.

Дерив.: **кыеклы, кыексыз.**

**КЫЕКЧА [қы̆йы̆кча]** «косынка (треугольный платок); лапша и т.п. в виде треугольника» ~ башк. (БТДҺ: 210) *қыйыҡса* id., кырг. *кыйыкча* «кыек киселгән (нәрсә)». Яулык төре мәгъ. русчадан калька булса кирәк. Әлбәттә, **кый-у I** фигыленнән.

**КЫЕН [қы̆йы̆н]** «трудно, трудный», «трудности; побои» (к. мәкаль: *Ат кыен белән бармас, сыең белән барыр* ≈ «погоняй коня не кнутом, а овсом»), к. ш. ук иске тат. (Троянский II: 138) **кыйынлы** «кыен, авыр» ← гом. кыпч. *қыйын, қыйн*, төркм. *қыйын, қыын*, тув. *хыйын,* хак. *хыйал* «кыенлык; җәза», кырг. *қыйын* «авырлыклы, авырлыклар җиңеп эшләгән (эшләүчән); елгыр; афәрин», к.-балк. *қыйын* «хезмәт» (шуннан *социалистик қыйын геройы!*) һ.б. гадәттә **кый-у** («җәзалау» мәгъ.?) сүзеннән дип уйланыла, к. ЭСТЯ VI: 218–219, ләкин бу фараз өстәмә дәлилләргә мохтаҗ. Чув. *хӗн* ~ венг. *kín* «кыен» бу сүзнең бик борынгылыгына шаһитлык итә. Федотов II: 342.

Дерив.: **кыенлык; кыенчылык**; к. **Кыйна-у.**

**КЫЕР [қы̆йы̆р]** диал. «не свой, чужой, посторонний» – бу сүз үзе генә сирәк кулланылса да, аның дериватлары шактый: **кыерчык** «ипинең каты пешкән өлеше», диал. **кыерла-у** «нәрсәнең дә булса кырыен тигезләү, тырпаеп торган өлешләрен һ.б. алу» (к. ТТДС I: 215–216) һәм (бигрәк тә еш кулланылганы) **кыерсы-н-у** «үзеңне чит дип хис итү», **кыерсы-т-у** «кемне дә булса читләтү, хокуксыз калдыру» (боларның төп юнәлеше **кыерсы-у* очрамый) ~ кар., к.-калп., кырг. *кыйыр* «ерак кырый», *кыйыр туган* «ерак туган», кырг. *кыйырчык* «оныкның оныгы, нәбирәнең баласы», *кыйырлуу* «күп токымлы» (кыйыр һәм кыйырчыкларын күргән).

Бу сүзнең этимологиясе бигүк ачык түгел: **кырый** сүзеннән метатеза дип үк әйтеп булмый. Чаг. себ. **кыяри** «читтән килгән, чит ил кешесе, бигәнәй» (к. Будагов II: 101) < гар. *ғайри* «бүтән, чит».

**КЫЕШ [қы̆йы̆ш]** «кривой, косой, наклонный, заваленный набок» < гом. кыпч. *қыйыш*, каз., к.-калп. *қыйыс* id. (шуннан: *кыйшык* < *кыйышык* < *кыйыш-ык, кыйшай-у* < *кыйыш-ай-у*) – *қый-* фигыленнән. К. **Кыйшаң, Кыйшык.** Будагов II: 103.

Дерив.: **кыешлы; кыешлык; кыешай-у > кыйшай-у,** диал. **кыйша-у.**

**КЫЕШ-У [қы̆йы̆ш-]** (ТТДС I: 216; БТДҺ: 211) «возиться, (безуспешно) стараться; упорствовать, стоять на своём; ссориться» ~ ком., к.-балк., кырг. *қыйыш-*, каз., к.-калп. *қыйыс-* «җайлау, рәтләү, чыгынтыны уентыга туры китерү» ← *қый-* id. (шул ук телләрдә «кыек кисү»), тат. (ТТДС I: 214) **қыйалаш-у** «каршы әйтешү; ачуланышу», (БТДҺ II: 309) **қыйал-ыу** «маташу». Бу сүзләр ахыр чиктә **қый-** «кыеклап китү, хәрәкәтләнү, язлыгу»

тамырыннан булса кирәк, тик аларның ясалышында эчке логиканы эзлекләп бару читен. Чаг. диал. **кыйа кит-ү** «ялгыш китү, язлыгу».

Дерив.: **кыештыр-у** «маташтыру».

**КЫҖРА-У, кыҗыра-у** «скрипеть зубами (от злости, ярости); яростно хотеть; грозно вопрошать» ~ к.-балк., ком. *қыжҗыра-*, каз. *қыжырай-* id. *қыжҗыр* тәкълиди сүзеннән, к. кырг. *қыжҗыр* «ярсыну» ~ к.-калп. *қыжыр* «ачу», чув. *кӑчӑр, кӑчӑрт, кӑчӑр-кӑчӑр* – теш шыгырдатуга тәкълит. Чаг. ш. ук себ. **кыцыр-у, кыҗыр-у** «явызларча шатлану», каз. (Будагов II: 102) *қыжырда-* «кычыттырып авырту», хәз. сүзлектә ш. ук «ачуланып-ярсынып йөрү», кырг. *қыжҗын-* «явызлану», *қыжҗыр* «ярсыну, ачудан котыру хәле» һ.б., каз. *кижил* id. һ.б., тунг.-маньч. (ССТМЯ I: 385–386) *качир* «кыҗыр».

Бу сүзләр арасында мөнәсәбәтләр катлаулы: *кыҗыр-а-* фигыле **кыҗыр** дигән исем-сыйфаттан ясалган, ул сүз исә **кыҗыр** имитативыннан исемләшкән (сыйфатлашкан) дип уйларга мөмкин. **Кыҗыр-** фигыле исә **кыҗы** нигезеннән; ул нигез исә я мөстәкыйль тәкълиди сүз, я *кыҗыр* тәкълиди сүзеннән *-р* төшеп калып килеп чыккан. К. як. *хадьырый-* «кимереп өзгәләү» ← *хадьый-* «тешләп өзү; комсызланып ашау». К. түбәндәгене.

**ҚЫҖЫ-У** диал. (**қыз-у** белән бутала) «возбуждаться идеей, очень хотеть что-либо сделать («построить, соорудить» «поступить в учебное заведение», а также «наказать кого-либо»)» ~ як. *қыжҗы-, қыдьы-* id. (бүтән төрки телләрдә дә булырга тиеш) ← *қыжҗ* «тавышланып мыж килү» тәкълиди сүзеннән, к. каз., кырг. *қыж, қыжҗ,* кырг. *қыжҗы-қужҗы, қужҗ* «тавышлану, тавышланып авырту, үзәк көю» һ.б. Чаг. **әҗе-гөҗе.**

**КЫЗ** «девушка, девица; дочка, дочь» < гом. төрки *қыз, қыыз,* хак. *хыс*, угыз. *ғыз* ~ чув. *хӗр* < болг. **қыр* < бор. гом. төрки **қы̄рғ*; сүзнең этимологиясе өчен тат. теле материалы әһәмиятле: кас. **’ŏз** < *кŏз* «кыз» (ДС III: 121), себ. **қысақ, қызақ** «ахирәт; җария, каравыш» (Тумашева 1992: 142), *қыргын* «хатын-кыз» (ДС I: 106). К. ш. ук төркм. *қыыз* ~ як. *кыыс* «кыз». Бор. төрки (ДТС: 449–450) *qïz, qïzγaq* «кыз», *qïz* «кыйммәтле, сирәк; кыйбат бәяле»; *-ғақ* кушымчасы гадәттә фигыльләргә ялгангач, бор. төрки **qïz-* дигән фигыль дә булган, дип уйларга мөмкин (*кыргын, кыркын* формасы да шул фикергә китерә). Күп кенә төрки телләрдә *қырнақ* «кол кыз, әсир алынган кыз» сүзе очрый. Без бу сүзне *қыз ~ қыр* сүзеннән аерырга җитәрлек сәбәпләр күрмибез (к. ш. ук Clauson: 680).

Гомумән, *кыз* сүзе тәүдә нәсел-нәсәп терминологиясенә карамаган, ул кыйммәтле нәмәрсә, энҗе-җәүһәр, алтын-көмеш кебегрәк мәгънәдә булган булса кирәк. «Төркиләрдә, – диелә бер борынгы кытай тарихи язмасында, – принцесса *тсӣн кыр* дип атала, сүзмә-сүз тәрҗемәләгәндә бу «мең алтын» дигән сүз» (Liu Mau-tsai 1958: 44). Чаг. тат. туй җырларында: «безнең апа мең алтын».

Бор. *кыз* «алтын» сүзе белән **кыз* «кызыл» (чаг.: *кызару*) һәм *кызу* «кызыл төскә керү» сүзләре дә баглы булса кирәк. Тик кайсы мәгъ. беренчел икәнлеге генә бөтенләй үк ачык түгел. Аз. *ғызыл* «алтын». Räsänen 1969: 269; ЭСТЯ VI: 240.

Дерив.: **кызый; кызларча; кызлы, кызсыз; кызлык. Кызбикә** «җиткән кызларны карап-күзәтеп торучы хадимә»; **кызтәкә** «кызлар янындарак йөрүчән малай, егет». Туйда **кызалдычы, кызаш** һ.б. тур. Баязитова 2006: 34, 64.

**КЫЗА, кызан** «ястреб-мышелов», **козан** (ТТДС I: 194) «коршун» ~ чув. *хӗре, хӗрен* id. Ихтимал, бор. төрки **qoran* id. К. **Козгын, Коргын** < бор. төрки **qoran* id.

**КЫЗАЛАК** «вид тюльпанов» ~ башк. диал., каз. *қызалақ, қызғалдақ* id. *кызыл* сүзе белән тамырдаш булса кирәк; бу сүзнең башк. «*қызчық»* мәгънәсе – күчерелмә. Чаг. ш. ук аз. *ғызараг* «кызалак».

**КЫЗАМЫК** «корь» > чув. *кӑсамак*, мар. *кызамык, кыжамык*, удм. *кызамык* < гом. көнб. төрки *қызамық,* төркм. аз. *ғызамык,* ком. *қызамуқ* id. *кыз* «кызыл» тамырына чир-хасталык атамаларын ясагыч *-амык* кушымчасы ялганып ясалган. Төп чув. *хӗрлехен* «кызамык» < болг. *һырлыган* (< **кырлыган*) > мар. *ырлыган, ерлегӓн* id. ← бор. төрки **кыр* «кызыл, кызыллык». Федотов I: 261; ЭСТЯ VI: 192–193. Чув. сүзе, ихтимал, **кызамык**ны **кырлыган** белән дәвалаганнандыр.

**КЫЗАР-У** «покраснеть, краснеть» < гом. көнб. төрки *қызар-,* угыз. *ғызар-* id. бор. **қыз* «кызыл» тамырыннан.

Дериватлары бар: **кызарыл-у, кызарын-у, кызарыш-у, кызарт-у;** тат. **кызарткы** «мичтәге утлы күмер» (ДС III: 93), **кызартма** – күмәч төре һ.б.

**КЫЗГАН-У I** «жалеть; скупиться» > мар., удм. диал. *кызган-* < гом. кыпч. *қызған-*, алт., гаг. *кыс-*

*кан-*, төркм., аз. *ғысған-*, бор. төрки (ДТС: 447) *qïsγan-* ← бор. **қысға-* < *қызсық-а-* «саран булып китү» ← **қызсық* «саран» ← *қызсы-* «саранлану» ← бор. төрки (ДТС: 450) *qïz* «саран» ~ «кыйммәт», «сирәк очрый торган». Шуннан **qïzïγ* (чаг. **кызык-у**) → **qïzïγa-* > **qïzïγa-* «кыйммәт дип исәпләү». Бу фигыльдән бор. төрки *qïzγaq* «саран» һ.б. сүзләр ясалган. К. Dobr. II: 305–308. Шулай итеп, *кызган-у* сүзе күп кенә морфологик ясалышлар һәм семантик үзгәрешләр нәтиҗәсе. К. **Кыз.** К. ш. ук бор. төрки *qïsïrqan-* < **қызсырқа-н-* «кызгану, саранлану» (ДТС: 448).

Дерив.: **кызганчык.**

**КЫЗГАН-У II** «жалеть, пожалеть, сопереживать» – русчадан калька нәтиҗәсе яисә, дөресрәге, **кызган-у** сүзенең «ярдәм итү теләгендә булу, берәүнең хәленә керү, аяну» версиясе икенче бер чыганактан булса кирәк: **қызға-* «әсәрләнү > жәлләү хисе кичерү» ← *қыз-* «кызу, көчле хис кичерү», к. чув. *хĕрхен-* < болг. **һерғән-* < **қырған-* «жәлләү» (чув. сүзенең *хĕрхен-* «саранлану» мәгъ. юк). К. **Кызганыч, Кызгын.** Федотов II: 346–347.

Дерив.: **кызганыш-у, кызгандыр-у.**

**КЫЗГАНЫЧ** «жаль; достойный жалости, сожаления» – **кызган-у II** сүзеннән. Гаг. *кысканч*, алт. *кыысканчак* «саран» **кызган-у I** дән.

**КЫЗГЫН** «горячо, интенсивно» < уйг. *қызғын, қизғин* id. *кыз-у* фигыленнән, әлбәттә. Диал. (ЗДС: 448) **қысған** «кызмача», **қысғыр** «кызу канлы» кире мәгънәгә ияләр.

**КЫЗМАЧА** «навеселе, слегка пьян» **кыз-у** сүзеннән тат. теленең үзендә ясалган булса кирәк.

**КЫЗУ** «горячо; горячий, жаркий; быстрый» > мар. (Исанбаев 1978: 11) *кызу,* удм. (Насибуллин: 124) *къжу* id. тат. телендә ясалган сүз; чув. *хĕру* татарчага аналогия. *Кыз-* ~ *хĕр-* «кызу» фигыленнән.

**КЫЗ-У** «накалиться > горячиться, возбуждаться, завидовать > убыстриться» < гом. төрки *қыз,* тув. *кыс-*, як. *кыыс-* id. ~ чув. *хĕр-* (бүтән күпчелек төрки телләрдән үзгә буларак, моның йөкл. юн. *хĕрт-*, *хĕрĕт-* «кыздыру») < болг. **һĕрĕ-* > мар. *хĕр-, ĕр-* «кызу, җылыну; иген кызу». К. ш. ук үзб., уйг. *қизи-, қызы-, қызый-* «кызу; кызару» < бор. гом. төрки *қыыз-ы-* (йөкл. юн. *қызыт-*), ягъни бу сүз бор. **қыыз* < **қыырг* исеменнән ясалган фигыль булып чыга. Бу исемне **кызыл** сүзенең тамыры белән бердәй дип карарга кирәк. К. **Кызык, Кызык-у, Кызыл, Кызын-у.** Будагов II: 55; Федотов II: 343; ЭСТЯ VI: 187–190.

Дерив.: **кызын-у, кызыш-у, кыздыр-у; кызгын; кызмача.**

**КЫЗЫК** «интересный; забавный; занимательный; забава; занимательность; интерес» > чув. *кăсăк*, мар. *кызык, кыжык,* удм. диал. *қызық* < гом. көнб. төрки *қызық* id., алт., каз. ш. ук «кызган, җылы, кайнар» (к. Радлов II: 824) – **кыз-у** фигыленнән. Федотов I: 261.

Дерив.: **кызыклы, кызыксыз; кызыклык; кызыксын-у; кызыкчы** (бу сүзләр еш кулланылып өстәмә мәгъләләр алганнар).

**КЫЗЫК-У (кызыкты, кызыгу)** «завидовать; считать интересным и желанным» < гом. кыпч., төркм. *қызық-,* үзб., уйг. *қизиқ-* id., ш. ук каз., алт., уйг. диал. (Радлов II: 824) *қызық-* «янып китү; кызару; кәефләнү» – **кыз-у** (к.) фигыленең интенсивлык дәрәҗәсе (*-қ, -к* аффиксы): ЭСТЯ VI: 189.

Дерив.: **кызыгыш-у, кызыктыр-у (→ кызыктыргыч).**

**КЫЗЫЛ** «красный» < гом. кыпч. *қызыл* < *қызғыл* id. (*-ғыл* төс атамаларын ясагыч кушымча) ← **қыз* тамырыннан, к. *кыз-ар-у* «кызыллану, кызыл булып китү»; *кызгылт* «бераз кызылрак» < *кызгылт* id., к. ш. ук төр. диал. *γızıl*, үзб. уйг. *қизил*, хак. *хызыл*, як. *кыһыл* < *кысыл* һ.б. id. *қыз* < **қыырг* тамырыннан (тәүдә төснеме яисә температураны белдергәне беленми), к. **Кыз-у, Кызык, Кызык-у, Кызын-у.** Чаг. чув. *хĕрлĕ*, *хĕрĕл* «кызыл», *хĕрел-* «кызару»; бор. төрки *qïzγu* ~ *qïrγu* «алсу» (ДТС: 446–448). Будагов II: 55–56; Федотов II: 343–344; ЭСТЯ VI: 194–196.

**Кызыл** сүзе күп кенә кушма сүзләр составында килә: **кызылканат, кызылкүз** (балык атамалары), **кызылтүш** (кош атамасы) һ.б. Рус. *кызыл, кизил* дигән үсемлекләр тур. Фасмер II: 230; Аникин: 235, 288.

Дерив.: **кызыллы; кызыллык; кызыллан-у, кызылла-у; кызылча** (авыру исеме) һ.б.

**КЫЗЫЛБАШ** (Г. Камал) «перс, персы; Иран» < чыгт., төр. *қызылбаш* – төрки телдә сөйләшүче һәм Иранда яшәүче шигый яисә христиан: шулардан җыелган җәмәгать унике тасмалы кызыл чалма киеп йөргән. Шигыйлык билгесе булган бу баш

киемен XV г. Хәйдәр дигән бер шаһзадә хәрби формага кертә. Будагов II: 55. Рус. *кизильбаш, кизылбаш* һ.б. тур. Фасмер II: 230–231.

**КЫЗЫН-У** «загорать; греться (у огня)» – **кыз-у** сүзенең (элекке «җылыну, кызару» мәгънәсеннән) кайт. юн. формасы.

**КЫЗЫРГАН-У** (Akb) «скаредничать» (бу сүз **кызган-у** «аяу, җәлләү» сүзеннән аерымлана) ~ төр. *kızırgantmak* «кыйбат дип исәпләү» ← *kız* «югары бәя, кыйммәтлек» (*kızlı* «бәяле, бaһалы»). Сөйләшләрдә ш. ук кырг. һ.б. төрки телләрдә *қызырқан-* «кызып китү, ярсыну» сүзе дә бар, тик ул, ихтимал, бүтән нигездәндер. К. ш. ук аз. (АДДЛ: 133) *гызыргаммах, гызыргаламмах* «кызыргану» һәм икенче *гызыргаламмах* «аркалану» һ.б.

**КЫЙ I,** диал. (ТТДС II: 146, кас.) **’ӧй < қӧй** «остатки навоза; сухой навоз; мусор» ~ башк. (БТДҺ: 209) *қый* id., ш. ук «чүп-чар; вак-төяк эш» < гом. кыпч. *қый* «кизәк; чүп; хәрабә» < бор. төрки (ДТС: 440) *qïy* ~ төр. диал., аз. *қы, қыы, кыһ, қығы, қықы* һ.б., к. ш. ук үзб., уйг. *қиқ,* кырг. *қық,* бор. төрки *қыйғ,* төркм. диал. (Мухамедова 1973: 117) *ғыйқ,* як. *қыы* «кый» һ.б. ЭСТЯ VI: 184–185 (шунда ук әдәбият), к. ш. ук рус. диал. (Аникин: 617) *хий* < бур. *хии* «кипкән тирес» < төрки *қый*; төр. (Redhouse: 649) *kıkır* «коры һәм кипкән». К. түбәндәгене.

**КЫЙ II** «дикорастущее растение, сорняк», употребляется как второй компонент сложных наименований растений: **ачыкый, баллыкый** һ.б. (к. ТТДС I: 590). **Кый I** сүзе белән гомоген булса кирәк (тәүдә «абзар, туплау, табыр урынында үскән үлән» булгандыр). **Кый II** сүзе хәзер «тоташ каплаган» мәгъ. дә кулланыла. Сөйл. **кый** – гомумән «кыргый», мәс., себ. **кый каз** «кыр казы».

Дерив.: **кыйлы, кыйсыз; кыйлык.**

**КЫЙ III** диал. «дикий крик», (БТДҺ: 209) «перебранка, ссора» к. **Кыйгыр-у, Кый-ку.**

**КЫЙ IV** диал. «ведь, же» – циркумурал (к. Садыкова 1985: 99; Хайрутдинова 1985: 100–101; Тумашева 1992: 131–132) башк. һәм тат. сөйләшләрендә *қый, қӧй, қуй, ғуйын, қойын* «ич, бит, ләбаса» кисәкчәсе, кайберәүләр уйлаганча, *куй-* фигыленнән (*куй инде син аны!)* түгел. К. каз. *ғой, қой, кӧ, кё,* кырг. *қо, кё, ғо, кү, гү,* үзб. *кү,* уйг. *гё, гү,* монг. *кү* «бу, шул, бит», чув. *ку, кү* «бу» (*кунда* «монда»), тунг. телләрендә *кэ, гэ* «менә, ну, шулай» (*кэ, кэ* «менә, менә!»), кор. телендә *ki* «бу, ошбу» һ.б. Кырг. ул җөмлә башында да әйтелә: *кой бай болсун, кой жарлы болсун...* Будагов II: 99; Федотов I: 300–302 (тат. сүзен искә алмый). ССТМЯ I: 176, 442.

**КЫЙБАТ** «дóрого; дорогостоящий» > мар., удм. *кыйбат,* чув. *хӑйпат* ~ кар., кырг. һ.б. *қыйбат*, нуг., каз., к.-калп., кырг. *қымбат* < гар. *қиммӓт* id. сүзеннән, к. **Кыйммәт.**

**КЫЙБЛА** «кибла, сторона, направление на Мекку» < гар. *қиблӓ* id. *қбл* «кабул итү, очрау, килешү» тамырыннан, шуннан ук к. **Кабалә, Кабул, Мәкъбүл.** Тимергалин: 274 (тәфсилле).

**КЫЙГАК** – подражание звонкому однократному крику гусей. Казлар күптөрле тавыш-авазлар ярдәмендә аралашалар, хәбәрләшәләр һәм аларның ул авазлары тат. телендә тиешле чагылыш таба. Добр. сүзлегендә *qıy-yaq* (ике сүздән гыйбарәт) итеп күрсәтелгән, ягъни: *қый, қыйқ* һәм *ғақ, қаңқ.* Беренчесенннән *қыйқ-қыйқ, қыйғыл-қыйғыл, қыйғылда-у, қыйғылдаш-у* һ.б., ш. ук *ғайғылдаш-у,* икенчесеннән *қаң-қаң, қаңқ-қаңқ, қаңғылда-у, қаңғылдаш-у* һ.б. ясалган. Бу сүзләрнең параллельләре татарларга күрше башк., чув. һәм фин-угор телләрендә табыла.

**Кыйгак** һәм аның дериватлары (**кыйгак-кыйгак, кыйгакла-у**) иң кулланышлысы бугай. Ә гомумән тат. телендә бу бапта кырык-иллегә якын сүз ясала ала. Элекке күчмән төркиләрдә (каз., кырг. һ.б.) мондый сүзләр азрак, чөнки каз күчмә тормышка бигүк яраклы терлек түгел.

**КЫЙГАЧ,** (ЗДС: 437) **кыйқач** «изогнутый (о бровях)», «косой, наклонный; наискось» < гом. кыпч., уйг., госм. *қыйғач*, башк. *қыйғас,* нуг., каз., к.-калп. *қыйғаш*, гаг. *кыйнаш* id., аз. (АДДЛ: 133) *гыйгач* «кыек яулык, өчпочмак» – иркәләү аффиксы *-гач* ярдәмендә *кый-* тамырыннан ясалган (**кыек-кач?*). Чаг. алт. *кыйгас* «көйсез, холыксыз». Күрше телләргә дә кергән, к. калм. *кигас* «кыек».

**КЫЙГЫЗ,** себ. (Тумашева 1992: 138) **кыйгыц, кыйгац** «ложка из бересты» (которую жених дарит невесте) ~ алт. *кыйгаш* id., башк. (БТДҺ: 209) *қыйғыз, қыйғаз, қыйғас* «эре каурый» (ул да

кәләшкә бүләк ителгән). Ихтимал, *қый қаз* «аккош» сүзеннәндер.

Баш киеменә каурый тагып йөрү элекке Европада ярсызлык билгесе булган. Яр, кәләш тапкач, егет каурыен кәләшенә бүләк иткән, кәләш аны баш киеменә тагып, яры барлыгын белдергән. К. ш. ук **Өке.**

**КЫЙГЫР,** диал. **кыргый** (ДС I: 106) «ястреб-перепелятник, чеглок», күч. «крайне хваткий, ловкий человек, жиган» > чув. *кăйкăр*, каз., кырг., алт. *қыйғыр*, госм. *қырғай*, чув. *хĕрхи, хĕрху*, мар. *кыргивараш* ~ уйг. *қорғуй, қурғуй*, куман. *korγuj*, урта төрки *қырғы, қуруғы, қарқуй* (> тат. диал. **каргы,** к. Исәнбәт I: 608) id., бор. төрки *γurγuj* «иң кечкенә лачын төре» (Räsänen 1969: 266) ~ яз. монг. *qïrγui* (Поппе 1938: 406) id.; бу сүз слав. телләренә дә киң таралган: болг. Д., серб., иске слав. *крагуй*, чех. *krahujec*, слов. *korgujь*, пол. *krogulec* һ.б. (Булаховский: 153–197). Кош атамалары ясагыч *-гай, -гуй* кушымчасына караганда, һичшиксез төрки-монгол сүзе: **кыйгыр** < *кыргый* < *кыргуй*. **Кыйгыр-у** сүзенә катнашы юк. Федотов I: 248; ЭСТЯ VI: 232–235 (бик тәфсилле).

**КЫЙГЫР-У** «пронзительно кричать; кликать (о птицах)» < гом. кыпч., алт., тув. *қыйғыр-, қыйқыр-*, бор. төрки *қыйғур-, қықыр-* (Боровков 1963: 306, 207) *қый* «кычкырык» сүзеннән, әлбәттә, әмма ничек ясалуы бәхәслерәк: *қый-ғы-р-* (*қыйғы* исеменнәнме, к. тув. *кыйгы* «кычкырык, чакыру»), яисә *қый-ғыр*-мы (*-қыр* тәкълиди сүзләрдән аваз салуларны белдерүчән фигыль ясагыч кушымча)? К. ш. ук аз. *гыйла-, гыйхыр-* «кыйгыру» (АДДЛ: 134). К. **Кый-ку.**

**КЫЙ-КУ,** диал. (Тумашева 1992: 138) **кыйгу, кыйгыл** «тревожные крики; возгласы; шум-гам» – *кый* һәм *ку* (икесе дә билгеле тәкълиди сүзләр) тамырларыннан гыйбарәт, к. каз., кырг. *кый-ку, кыйгу*, башк., к.-калп. *қый-қыў* id., алт. (Баскаков 1972: 230) *қый, қыйық* «кычкырык», тув. *кый* «эндәшү», *кыйгыр-* «чакыру, өндәү» (*кыйгырыг* «лозунг»), як. *кый-хай* «шау-шу, кый-ку».

**КЫЙЛАН-У,** диал. **кôйлан-у** «кривляться; подражать» ~ мар. *кайлан-, айлан-, ойлан-* id. Чаг. тув. *хайлан-* «ачуланып мыгырдау». Икенче яктан к. госм. (Будагов I: 539) *хуйлан-, хôйлан-* «кешегә (бүтәннәргә) охшатыну яисә үчекләү» ← *хуй, хōй* «(начар) кыланыш». Хәз. төр. *hu, huy* «табигать, гадәт; начар кыланыш» < фар. *ху* id., *хуи* «характер күрсәтүчәнлек, үзсүзлелек». Өченче яктан к. **Кылан-у.** К. **Кыйлы II.**

**КЫЙЛ-У** «сделать, содеять» < уйг. *қил-* id. К. **Кыл-у.**

**КЫЙЛЫ I, кыйла, хыйлы** диал. (Тумашева 1992: 138; ЗДС: 102, 437, 704) «довольно, значительно» < фар. *х̣әйлū* > төр. *hayli* id. >> иске тат. (Батырша телендә) *хиле* id.: ахыр чиктә гар. *х̣айл* «талпа, өер» сүзеннән. К. ш. ук ног., каз., к.-калп., кырг. *кыйлы*, ног., үзб. диал. *хыйлы* «байтак, күп кенә, шактый».

**КЫЙЛЫ II: бер кыйлы**, себ. (Тумашева 1992: 138) **пер ғыйлы** «уравновешенный, с ровным, предсказуемым характером» < *қôйлы* < иске тат. *хôйлы* «характерлы, холыклы» ← **хôй** < иске фар. *хой, хуй, хуи* «үзенчәлек, характер» ← *ху(д)* «үзе»; шуннан төр. *huylu* «холыксыз; нindидер бер сыйфатка ия» һ.б. → к. **Кыйлан-у**; фар. *хой, хуй* «холык, кыланыш» күп төрки телләрдә бар.

**КЫЙЛЬ** иск. «статья, параграф; абзац, пассаж» < гар. *қūл'* id. Ш. ук *кыйль вә каль* «нечкәләп, төптөгәл итеп әйткәндә» гар. «мәкалә вә аңлатмасы» дигән тәгъбирдән.

**КЫЙМА** (БТДһ: 210) «толстая кишка» ~ ног., каз., к.-балк. *қыйма, кима,* хак. *хыйма* «казылык», кырг. *қыйма*, уйг. *қима* «фарш, тапалган ит», аз. (АДДЛ: 131) *гийма, гыйма* << бор. (ДТС: 407, 442) *qajïta, qïjta* «фарш, вермишель һ.б.ш.» ← **кый-** (к. **Кый-у**) «кисү; турау; фарш ясау» (бу мәгъ. уйг. һәм төр. телләрендә бар).

**КЫЙММӘТ** «цена; ценно, дорого» < гар. *қиммāт* «бәя, хак» *қийāм* «тору, басу» тамырыннан. Бу тамырдан ясалган бик күп гар. сүзләре төрки һ.б. телләргә үтеп кергән, мәс., тат. кит. телдә **истикамәт, икамәт, камәт, кыямәт** һ.б. К. **Кыйбат.**

Дерив.: **кыйммәтле, кыйммәтсез** һ.б.; **кыйммәтлек** рус. «ценность» мәгъ. һ.б.

***КЫЙМЫК** «(одно) мелкое движение» – шуннан (Тумашева 1992: 138) **кыймыкла-у** «бер кыймылдап кую»; алт. *кыймык.* К. **Кым.**

**КЫЙМЫЛ: кыймыл-кыймыл,** (ЗДС: 437) **кыймыл-камыл, кымыл-кымыл** – имитация

постоянному шевелению, мелким движениям отдельными частями тела ~ гом. кыпч. *қыймыл, қыймыл-қыймыл, қымыл-қымыл,* уйг., үзб. *қимыл-қимыл, қимил-қимил,* төр. *kıml,* аз. *гымыл,* төркм. *ғымыл* id. һ.б. ← *қым* (к.). Чаг. к.-калп., кырг. *қыймыл,* каз. *қимыл,* үзб., уйг. *қимил,* аз. *гымыл* «хәрәкәт».

Дерив.: гом. кыпч. **кыймылда-у; кыймылдык.** Чаг. төр. *kımıltı* «бер вак хәрәкәт». К. **Кымыр.**

**КЫЙНА-У** «бить, покалачивать (человека, животного)», диал. «беспокоить; наказывать» < гом. кыпч. *қыйна-*, уйг. *қина-*, төр., аз. *кына-*, төркм. *ғына-* < бор. төрки (ДТС: 444) *qïna-* «кыйнау, җәзалау; җәзалап таныту, икърар иттерү» ~ чув. *хĕне-* id. һ.б. тат. **кыен** (к.) ~ төр. *kın*, бор. төрки *qın, qıjın* >> чув. *хĕн* «җәза; газап; азап» сүзеннән: *кыйна-* < *кыйын-а-*. Бу сүз үз чиратында (к. Будагов II: 105–106) *қый-* ~ бор. төрки **qïz-, *qïr-* (к. ДТС: 441, *qïjïn-qïjït, qïjïn-qïzgut, qïjïn-qïrqïn* «җәзалаулар», *qïjïnlïq* «җәза урыны») тамырыннан. Чаг. ш. ук тув. *хына-* «тикшерү, контрольләү, ревизияләү». Räsänen 1969: 264; Федотов II: 343.

Дерив.: **кыйнал-у, кыйнат-у, кыйнаш-у; кыйнаш** (**орыш-кыйнаш** парлы сүзендә). Чаг. **Кыны-у.**

**КЫЙПАН** диал. «бегающий (о глазах); с бегающими глазами (о человеке)» ~ башк. диал. *қыйпан, қыйпаң* «кыланчык кыз»; к. ш. ук тат. диал., башк. диал. (БТДҺ: 210) **қыйпаң қара-у** «кырын карау» һ.б. – *кыйпы-* фигыленнән. К. **Кайпан.**

**КЫЙПТЫЙ, кыйбтый** «копт, копты; коптский» – Мисырның төп, асыл халкы атамасы (рус. *Египет* сүзе белән тамырдаш). Бу сүз безгә гарәпчәдән кергән. Кыптыйлар Мисырда хәзер дә яшиләр, әмма мисрилардан аерылып торалар.

**КЫЙПЫЛ-У** «отколоться, отщепиться; рикошетировать» – к. **Кыйпы-у. Кыйпыл** дигән исем дә бар, шуннан киң таралган **кыйпылчык** сүзе килә.

**КЫЙПЫ-У** «отколоть, отщепить» ~ к.-балк. *қыйпа-* id., төр. *kaypı-* «тайпылу», кырг. *кыйпы* «хәйлә (котылу өчен)», каз. *қыйпақ, қыйпаң* «назлану; эштән качу өчен хәйләләү» – *қыйпы-* фигыленең күч. мәгънәләреннән; *қый-пы-* билгеле модель буенча (*-пы* кушымчасы) **кый-у** фигыленнән ясалган.

**Кыйпы** продуктив сүзьясагыч нигез, шуннан **кыйпык** (ДС III: 93), **кыйпыл-у, кыйпылчык** сүзләре ясала. К. **Кайпан, Кыйпан.**

**КЫЙРА** диал. (Тумашева 1992: 138) «ленивый» << фар. *х̣ӣрӑ* «нахал».

**КЫЙРАТ** иск. «карат (единица измерения драгоценных камней)» < гар. *қӣрāṭ* id. < грек. *χερατιου* id., асылда «вак борчак».

**КЫЙРА-У** сирәк «лежать в развалинах; рушиться, гибнуть» ~ гом. кыпч. *қыйра-* id. Бу фигыльнең юн. формалары тат. телендә активрак кулланыла: **кыйрал-у, кыйрат-у.** Räsänen 1969: 262.

*Кыйра-* фигыле *-ра* кушымчасы ярдәмендә *кый* «тирес, тиреслек; хәрабә» сүзеннән ясалган (чаг. *җәй – җәйрә-, көй – көйрә-, сай – сайра-, төй – төйрә-, уй – уйра-* һ.б.). Ш. ук (кр.-тат.) *qıyır* «ватык-сүтек» сүзеннән дә була ала.

**КЫЙССА** «рассказ, повествование; поэма» (к. *Кыйссас-үл-әнбия* «повествование о пророках» – название многих книг) < гар. *қиṣṣа* id., бор. гар. *қасса, қасс* «ни булганны мәхкәмәдә сөйләү; аклану» < лат. *casus* «судка бирерлек очрак, казус» сүзеннән (гомумән *cas* «очрак» *cadere* «төшү, егылу» фигыленнән ясалма). Бу сүз Рим империясе чорында гарәпләрнең суды римлеләрчә булуыннан килә. Шуңа тамырдаш *каденция* «шигырь яки җыр азагы, берәр эшне тәмамлау документациясе», ш. ук *каскад* «бер-бер артлы егылу, төшү».

**КЫЙТГА** «континент, материк»; иск. «часть целого; отрывок; строфа» < гар. *қиṭ‘а* id. *қṭ‘* «кисү» тамырыннан (шуннан ук *катгый* «каршы килә алмаслык»), к. Будагов II: 59.

**КЫЙТЫК** (ЗДС: 438) «осколок», (ТТАС II: 218) «оскомина в душе», ләкин чынлыкта сөйл. телендә бу күп мәгъ. сүз: «холыксыз, үпкәләүчән», «ялгыш кыелган төш (мәс., бура бүрәнәсендә һ.б.)» ~ нуг., кырг. *қыйтық,* каз. *қитық* башлыча «үпкәләүчән»; «комачау» һ.б. ← *қый-* (к. **Кый-у I**) нигезеннән. Бу нигездән тагын **кыйпык, қыйынты, қыйынтық, қыйылтық** «кыеп, кыеклап кисепярып ясалган (пәйда булган) нәрсә» сүзләре дә төрки телләрдә очрый. Чаг. **Кыек, Кыеш.**

Бу сүзгә рус. диал. (Аникин: 293) *китык* < як. *қитық* «бер кыеклы шалаш, куыш, корылма» сүзе тоташа бугай (Аникин алай дими).

**КЫЙ-У I (кыю)** «резать одним взмахом; резать наискось», себ. (Тумашева 1992: 138) «юл кую,

чигәрелү» < гом. төрки *ҡый-* id. ~ чыгт., уйг. диал. *ҡый-* «тупчу, типчү, каю», урта төрки *ҡый-* «кыяклау, бер читкә китү, юлдан сабу», як. *кый-* «харап итү». **Кый** – бик продуктив сүзьясагыч нигез: **кыйдыру, кыелу** юн. формалары актив кулланыла. **Кыек** һәм **кыеш** (шуннан *кыешык* < *кыйшык*) сүзләре *кый-* «диагональ буенча кисү» фигыленнән ясалганнар. Шуннан ук **кыйпылу (кый-пы-л-у); кыйгач** (болар гом. төрки сүзләр), тат. диал. **кыйынты**, башк. (БТДҺ: 200–211) *ҡыйпыс* < *ҡыйпыч* «кыйпылган»; тат. диал. **кыйтык, кыйындык, кыйынтык** «кыенты». Сөйләшләрдә **кыялау** «кыек траектория буенча очу» фигыле актив кулланыла. Моның нигезе **кыя** – *кый* сүзенең хәл фигыль формасы. К. ш. ук башк. (БТДҺ: 209) *ҡыйалаҡ, ҡыйғалаҡ* «юл чалуы», *ҡыйғала-у* «юл кыеклыгында таю». Бу сүзләрнең бүтән төрки телләрдә күпсанлы параллельләре бар.

Мәзкүр сүзләрнең үзара бәйләнеше бәхәс тудырмый. Болардан тыш *кый* тамырына кайбер бүтән – шул тамырдан икәнлеге күренеп тормаган сүзләр дә кайтып кала булса кирәк. К. **Кый-у II, Кыйтык, Кыю I, Кыяк.** Будагов II: 105; Räsänen 1969: 261; ЭСТЯ VI: 200–201; Федотов II: 318 (тат., башк. сүзләрен искә алмый).

**КЫЙ-У II (кыю)** «осмелиться, дерзать» (активен фразеологизм *кыючылык иту*) иске уйг. *ҡый-* «кагыйдәдән чыгу, бер як читкә китү; юл сабу» фигыленнән. **Кый-у I** белән бердәй. **Кыю** «батыр йөрәкле» – бу фигыльнең адъективлашу формасы. Федотов II: 318.

Гомумән **кый-у** амбивалент, төрле абстракт мәгънәләргә бара торган сүз. Чаг. **Кыйы-у.**

**КЫЙШАЙ-У** «скривиться» < гом. кыпч. *ҡыйшай-* < *ҡыйыш-ай-* id. К. **Кыеш.**

**КЫЙШАН** диал. «кривой (в абстрактном значении); кривляка; кокетка; тот, кто нарушает правила поведения, расчитывая на любовь и уступчивое, прощающее отношение других» (к. Тумашева 1992: 138) ~ кырг. *ҡыйшаҡ, ҡыйшаң*, каз., к.-калп. *ҡыйсаң* id. – бу нигездән ясалган тат., башк. **кыйшанла-у** ~ каз. *ҡыйсаңла-*, кырг. *ҡыйшаңда-,* каз. *ҡыйсаңда-*, тув. *хыйыжаңна-* «кыланчыклану; боргалану – сүзеннән кайту һ.б.» киңрәк кулланыла. К. Будагов II: 103.

**Кыйшаң** < диал. **кыйшаңкы** формасыннан, *кыйша-* < *кыййыш-а-* «кыйшык, кыеш булып китү, кыйшаю» сүзеннән. К. **Кыйшык.**

**КЫЙШЫК** «кривой (чаще о частях тела)» < гом. кыпч. *ҡыйшыҡ* < *ҡыйыш-ыҡ* (нуг., каз., к.-калп. *ҡисыҡ, ҡыйсыҡ*) id. К. **Кыеш.**

**КЫЛ** «конский волос; шерстинка»; күч. «струна» > чув. *хӗлӗ, хӗлӗк* ~ мар. *кыл, кӗл, ӗльык* < гом. төрки *ҡы̄л* (к. Радлов II: 764), угыз. *гыл* ~ монг. *хил,* яз. монг. *kilyasun*, хәз. монг. *хялгасун* < бор. *qılqasun*, к. эвенк. ССТМЯ I: 392) *килағаһун* < *ҡылага-сун* «кыл».

*Кы̄л* < **кыла* булса кирәк; к. себ. (брб.) **кылаң** «кыл» ~ бор. төрки *qılayı* > *кылау* «кылчык, мыекча». К. **Кылау, Кылган, Кылка.** Федотов II: 342.

**КЫЛАВЫН [ҡы̆лаwы̆н]** «сетка, ткань из конского волоса» > чув. *кӑлавӑн* id. **кыл** сүзеннән, ясалышы ачык түгел.

**КЫЛАН, ҡила, кула** (к. Будагов II: 21) тар. «вид подати (в Казанском ханстве), оброк» ~ алт., аз. *ҡалан*, бор. төрки (ДТС: 410) *qalan* id. Бу сүзне бик теләп **калым** (к.) сүзе белән чагыштыралар, ләкин, безнеңчә, шикләнер урын да бар.

**КЫЛАН-У,** иск., диал. **кыйлан-у** «рисоваться, кривляться, играть надуманную роль, притворяться; подражать (в поведении); вести себя (определённым образом)» – бу очракта ике сүз контаминациясе күзәтелсә кирәк: **кыйлану** «охшарга тырышу; боргалану» аерым сүз булган (*кый* < *кай* яисә *кой* < *хой* тамырыннан, к. мар. Т. *кайлан-* «кылану» ди Саваткова: 46, к. ш. ук чув. *айлан* < мар. *айлан-, ойлан-* < болг. **һайлан-* id.), *кылан-* исә гом. төрки *ҡылын-* «үзеңне тоту, нидер башкару, нәрсәдер эшләү» (к. Радлов II: 773) сүзенең чагылышы, ләкин аның төп мәгънәсенә *кыйлан-у* < *кайлан-у* фигыленең мәгънәсе өстәлгән һәм йөкләнгән; бу процесска иске тат. *ҡыйл-у* < уйг. *ҡил-у* «кылу» этәргеч булган.

**Кылан-** продуктив нигез, шуннан **кыланчык, кыланыш**. К. **Кыл-у.**

**КЫЛАУ I [ҡы̆лаw]** «заусеница; жальце; пупырь на языке скота, болячка (от занозы), катаракта (от прободения глазного яблока занозой и т.п.)» ~ башк. *ҡылы,* нуг., ком., каз., к.-калп. *ҡылау*, кырг. *кылоо,* як. *кылааң* «кылау», төркм. *гылав* «пәке һ.б.ш.ның иң үткер төше», госм., чыгт. *ҡылау* «шырпы, кылчык» һ.б. **кы-ла-* «очлаю, үткерләнү» сүзеннән. К. **Кыл.** ЭСТЯ VI: 207–208.

**КЫЛАУ II [қы̆лаw]** «дужка ведра» к. **Кылдау, Кылып.**

**КЫЛАФ** – имя эпического героя (в сказке, лежащей в основе всемирно известной оперы «Принцесса Турандот») < фар. *гилāф* «кылыч кыны» > кр.-тат., госм. *қылыф* id. Будагов II: 63.

Чаг. тат. диал. **кылап** «булдыклы һәм өлгер егет».

**КЫЛБЫР I: кылбыр таш** (ТТДС I: 216) «камень для мостовой; изразец» ~ төр. (Будагов II: 21) *қалбур*, аз. *халбур* «зур иләк, таш иләге; кыса; таштан һ.б. бизәкләр ясау эше», төркм. (ТДГДС: 48) *ғалвыыр* «ашлык иләге» < гар. *ғирбāл* «иләк; иләктән үткән нәрсә (нәфис, сыйфатлы һ.б.)». **Кылбыр** < *калбыр* дип һәрбер сәнгать әсәрен атаганнар. Удм. *кылбур* «шигырь» (*кылбурчи* «шагыйрь») сүзе дә тат. **кылбыр** сүзе тәэсирендә булуы ихтимал (гомумән исә бу сүз удм. теленең үзендә ясалган).

Дерив.: **кылбырчы** «таш тезүче, таш бизәкләр остасы».

**КЫЛБЫР II** – имитатив качению, вращению со стуком (**кылбырт** об однократном стуке колеса с отзвуком, **кылбыр-кылбыр** о неравном вращении громоздкого колеса со стуком). Чаг. **Кылтыр.**

Дерив.: **кылбырда-у** «шома гына әйләнмәү (зур тәгәрмәч тур.); тигез генә типмәү (йөрәк тур.)», **кылбырдат-у.**

**КЫЛГАН** «ковыль» > чув. *кăлкан*, мар. *кылгын, кылган* < гом. кыпч., к. нуг., к.-балк., ком., алт. *қылған*, каз., к.-калп., кырг. *қылқан* id. ← *қыл* (Räsänen 1969: 263), *қыл қана* «кыл үлән» булса кирәк (к. **Кана-у II**); себ. (Тумашева 1992: 139), төркм. *қылғанақ* – аерым үлән төре («императа»); к. ш. ук монг. *хялгана* «кылган», бур. *хилгана* «йонча», аз. (АДДЛ: 134) *ғылғына* «чәнечкеле үлән». ЭСТЯ VI: 208; Федотов II: 250. Рус. *калгана, келогана, хилагана* «кылган; йонча» тур. Аникин: 239, 281, 617.

**КЫЛДАУ [қы̆лдаw]** «дужка ведра» < башк., каз. *қылдау* «кыллау» сүзеннән булса кирәк, к. мар. *кыл* «кыл, кылдау; бәй», *кылда-* «бәйләү» (< тат. диал.), алт. *кылдьы, кылйы* «кылдау», хак. *хылчы* id. һ.б. К. **Кылы.**

**КЫЛКА I** «остистый; ворсистый» ~ хак. *хылға* «кылчыклар», алт. *кылга* «башакланмаганчы кыяклы үсемлек» – *кыл* сүзе белән тамырдаш. К. **Кылчык.**

**КЫЛКА II, колка** диал. «мохнатый; оборванный». **Кылка** (ЗДС: 440) «кикрик». Ачык түгел.

Дерив.: **кылкалан-у** «сәләмәләнү».

**КЫЛКУБЫЗ** «скрипка, думбыра» **кыл + кубыз.** К. **Кубыз.**

**КЫЛКЫН-У, қылғын-у** (Тумашева 1992: 139) диал. «судорожно глотать воздух; задыхаться» ~ башк. *қылқын-у, қылқылда-у – қылқ* тәкълиди сүзеннән. К. ш. ук диал. (ЗДС: 411) **қолқон-у** «тончыгу; йотлыгу»; «ашыгып эчү» ← **қолқа-у, қолтқа-у** «су эчкәндә яки сулыш алганда бугаз төерен селкетү» һ.б. – барысы да *қолт-қолт ~ ғолт-ғолт* – тавышланып эчү, йоту авазларына тәкълит сүзеннән.

Чаг. рус. *глотать* «белендереп йоту» ← *глот* «колт». Күрәсең, монда халыкара тәкълиди тамыр.

**КЫЛТ: кылт итү** «действовать, совершаться внезапно» – тәкълиди сүз. Шуннан Идел-Урал телләрендә берничә нигез сүз ясалган:

**кылтай-у** «вдруг обижаться, обидеться; неожиданно проявлять характер; вдруг возгордиться; вести себя непредсказуемо» < *кылт-ай-*; к. ш. ук башк. *қылтый* «кылтаючан»;

**кылтык** (ДС III: 94) ~ чув. *кăлтăк* «неожиданный казус, причина» < *кылт-ык*;

**кылтым** (ДС I: 104) «своенравный, с нравом»;

**кылтымби, кылтымбикә** «склонный к высокомерию; чванливый, спесивый». К. ш. ук диал. **кылтайт-** «аз гына ачып кую», **кылталык** «автоматик рәвештә ачылып-ябылып торучан капкач, пешкән һ.б.ш.» (к. ДС III: 94). К. **Кылтыр.** Федотов I: 250.

**КЫЛТАМАК** «привередливый» < гом. кыпч. *қылтамақ*, уйг. *қилтамақ* id. < **қил** (кыл кебек нечкә) + **тамак.**

**КЫЛТЫР** – имитатив стукам при вращении небольших колёс и падении механизмов ~ чув. *кăлтăр* (с многочисленными производными) ← **кылт** (к.). Чаг. **Кылбыр, Келтер**.

Дерив.: **кылтырт** (бер тапкыр гына кылтырау авазына тәкълит); **кылтыр-кылтыр; кылтыра-у, кылтырда-у**; **кылтырдык, кылтырдавык,** диал. **кылтырмач** һ.б.

**КЫЛ-У** «делать, сделать; содеять» < гом. төрки *кыл-* (угыз. *гыл-*) id. > уйг., чыгт., үзб. *қил-, қыйл-* (> иске тат. дини стильдә **кыйл-** < уйг.) «кылу; ясау, эшләү» – бор. гом. төрки *кы-* фигыленең төш. юн. (к. Рамстедт: 150), чаг. як. *гын-, кын-* «әзер булу; әверелдерү» – шул ук *кы-* фигыленең кайт. юн. һәм шуннан иске тат. һ.б. әд. телләрдәге боерык фигыль кушымчасы *-гыл//-гын* килә (бу кушымча *дигел//диген* «дип әйт» сүзендә саклана). Тат. телендә *кыл-* сүзе китаби аһәңгә ия һәм, гомумән, чагыштырмача соңрак кергән булса кирәк – ул, мәс., чув. телендә юк. Будагов II: 104; ДТС: 442–444; ЭСТЯ VI: 211–212.

Дерив.: **кылын-у, кылыш-у, кылдыр-у; кылмыш;** башк. *қылым* «фигыль». К. **Кылык.**

**КЫЛЧАК,** (Pallas) **kyltschak** «чехонь» < *кылычак ← кылыч*, к. каз. *қылыш (балык), қлыш, қлыч*, аз. *гылынч балык* id., ягъни «кылыч кебек балык», к. Линдберг: 177.

**КЫЛЧЫК** «ость, усик злаков; мелкие кости рыб» > мар. *кылчык*, чув. *хăлчăк* < болг. **һылчык* > мар. Б. *ылчык* > мар. Т. *ĕлцĕк* id. (к. Саваткова: 225); болг. теленә бу сүз кыпч. телләреннән (бор. татарчадан) кергән, к. бор. кыпч., госм. *қылчық* (> нуг., каз., к.-калп. *қылшық*), төркм., аз. *гылчық*, үзб. *қилчиқ, қилтиқ*, уйг. *қилчиқ, қилтириқ* < бор. төрки (ДТС: 441–442) *qïltïrïq, qïldruq, qïltïq* «кылчык; кәшә (баш кавагы)» – **кыл** (к.) сүзеннән, әлбәттә. Чув. телендә *хăлчăк* «кылчык», әмма *кыл → хĕл,* ягъни бу сүзләрнең этимологик нисбәтлелеге сизелми һәм болг. телендә дә шулай булган булса кирәк. Räsänen 1969: 262; Федотов II: 323. Рус. диал. *кылик* «гөлҗимеш, гөләп», *кылка* һәм *кылчык* тур. Аникин: 342 (тат. сүзләре күрсәтелми).

Дерив.: **кылчыклы, кылчыксыз.**

**КЫЛЫ** (Тумашева 1992: 139) «ручка котла, ведра» и т.п. ~ алт., башк. *қылы* «кылы; ике сулыкны тоташтырган елгачык», башк. (БТДҺ: 212) *қылымық* «язгы агым булган иңкел; сазламык» ~ кырг. *кылды*, алт., як. *қылдьы, қылҗы*, хак. *кылҗы, кылчы, хылчы* «кылы». ЭСТЯ (VI: 209–211) **кылы** сүзенең варианты итеп *кыл* һәм (ТТДС I: 201–202) *қ̌олау, қ̌олу* «кылдау» сүзләре китерелә, ләкин болар бүтән тамырдан.

**КЫЛЫЙ** «косоглазый, косой» < гом. кыпч. *қылый*, алт. *қылыр*, як. *кылар*, бур. *хилар*, эвенк. *келар, килар* id. Шуның белән бергә тат. диал. **кылай-,** кырг. *қылый-*, бур. *хилай-*, монг. *хялай-* < яз. монг. *kilui-* «кылаю, кылый карау»; тунг.-маньч. телләрендә бу сүзнең күптөрле вариацияләре китерелә (к. ССТМЯ I: 387). Бик бор. тасвирлы-тәкълиди тамырдан. Ихтимал, *кый-у* фигыле белән баглыдар, ләкин моны исбатлавы кыен.

**КЫЛЫК** «нрав; характер; поступок; действие» > мар., удм. *кылык*, чув. *хăлăх* < гом. төрки, бор. төрки (ДТС: 444) *qïlïq* id. Идел-Урал телләрендә кайбер мәгънәләре **холык** сүзе тәэсирендә формалашкан. Бүтән кайбер кыпч. телләрендә (нуг., ком., к.-калп.) *қылық* «кыланчыклык» мәгъ. дә ия. Радлов II: 770–773; Тыбыкова: 117; ЭСТЯ V: 211–212.

**КЫЛЫП, колып** (Тумашева 1992: 139) «дужка ведра; ушко котла, к которой привешивается дужка; спинной плавник рыбы» ~ чув. *хăлăп* «тотка, сап, кулса, кылдау» < фар. *қулп*, төр. *kulp* id. ш. ук «тәңкә колакчасы (чулпыга тезү өчен)» < гар. *қулб* «ишек тоткасы; ишек биге; йозак; пушка йозагы». К. ш. ук себ. (Тумашева, Op. cit.) *қылап* «кием элгече» – әлеге гар. сүзенең икенче бер формасыннан булса кирәк.

**КЫЛЫЧ** «сабля, меч; шпага; мечевидная планка при ткании кулей; бердо», себ. тат. «челнок» (к. Будагов II: 62). Шулай итеп, *кылыч* төрле туку коралларын да белдерә (чаг. ш. ук калм. *улди* «туку кылычы; сугыш кылычы», к. Эрдниев 1971: 97); бу хәл сүзнең беренчел мәгъ. дә сугыш коралы түгел, ә туку коралы түгелме икән, дигән фикергә китерә, к. ш. ук аз. *гылынч, кылынч* «кылыч» – *гыл-, кыл-* «кылу, эшләү, ясау, туку (?)» фигыленнән. Тат. һ.б. (гом. төрки) **кылыч,** башк. *қылыс*, нуг., каз., к.-калп. *қылыш,* бор. төрки *qïlïč* (ДТС: 442) ~ алт. диал. *каläш, калэс*, камас. *калыш* «кылыч» (Joki 1952: 154), к. ш. ук як. (Пекарский I: 1389) *кылыс* «кылыч, пычак; күрән; кереш» һ.б.

Болг. телендә бу сүз нык үзгәргән булган, к. чув. *хĕҫ* < болг. **һĕҗ* > мари. *ис', хис'* (Иванов, Тужаров: 54, Саваткова: 36), удм., коми. *кис, ис'* (Насибуллин: 117) «кылыч» (һәр ике мәгънәдә). Будагов II: 62; ЭСТЯ VI: 212 (юраулы этимологияләр китерелә һәм алар безнекенчә түгел). Федотов II: 348 (кирәксезгә ике нигез аера).

**Кылыч** сүзен бор. монг. *kilaqu, kilagu* «кылыч йөзе» белән чагыштыру морфологик җәһәттән нигезләнмәгән. К. **Кылчак.**

**КЫМ, кыйм** – имитатив лёгкому движению: **кым итү** «слегка двигаться (например, о листьях и ветвях)» ~ гом. кыпч. *қым,* чыгт. (Räsänen 1969: 263) *қим* id. Исем мәгъ. **кым** (ЗДС: 441–442) «ният, уй, теләк» ~ добр. (кр.-тат.) *qım* «күзләрне йомып алу», каз., кырг. *қым* «эчке рухи хәрәкәт» (күңел – шатлыктан яки кайгыдан – *кым этти* диелә), к. ш. ук төр. *kım-kım* «вак хәрәкәтләр; кыбырдау», к.-балк. *қым, қымп* – сүз әйтергә теләп ирен кыймылдату тур. тәкълиди сүз. Фигыль мәгъ. алт., кр.-тат. *кым-мак* «канатларны җыю (кошлар тур.)», күч. «үз ягына аудару», аз. (АДДЛ: 136–137) *ғым-* «күз ачып йому», *ғымы-* «ычкыну, чабу». Чаг. як. *хамна-*, *хамса-* «кымлау; кымшау». Будагов II: 104. Чаг. бор. төрки (ДТС: 413–416) *qam-* «этәреп кую, шуыштыру», *qamït-* «аз гына хәрәкәтләндерү», *qamtur-* «аудару» һ.б.

Дерив.: себ. (Тумашева 1992: 138–140) **қымла-у** (чаг. төр. *kımlan-* «читкәрәк китү») «кымрау, аз гына кыймылдау». **Кым ~ кыйм** тамырыннан бик күп сүзләр ясалган, к. **Кыймыл, Кымран, Кымра-у, Кымтырык, Кымша-у, Кымыз, Кымыр, Кымырҗы-у, Кымыт-у (Кымты-у), Кырмыска.** Чаг. ш. ук **Кып I, Кыбыр.**

**КЫМ-КУАТ** диал. «множество движений людей без особого шума» ~ каз., кырг. *қым-қуут* «шау-шу, ыгы-зыгы» ~ башк. (БТДһ: 212) *қымғыуат* id.

**Куат**~**куыт** монда «шатлык ыгы-зыгысы» булса кирәк, к. **Куат.**

**КЫМРАН** иск. «молочный квас; верблюжье молоко особого типа»: иске тат. телендә (XIX г.) һәм каз., кырг. *қымыран, қымран* «сөт куасы, ясалма кымыз; куертып кайнатылган сөт» мәгъ. очрый (к. Радлов II: 854; Будагов II: 64). Кайбер бүтән төрки телләрдә бу сүз шул ук мәгънәдә, шулай ук «дөя кымызы (дөя сөтеннән ясалган кымыз)» мәгъ. теркәлгән (ЎХШЛ: 160–161). К. ш. ук тув. *хымыраан* «чәй шамасы», монг. *кимур* «кымран».

*Кымран, кумран* сүзен М. Рясянен хаклы рәвештә *кымыз* < *кумыз* сүзе белән баглый (*р* > *з* күчеше). К. **Кым, Кымра-у, Кымыз.**

**КЫМРА-У, кыймра-у** диал. «(беспрестанно) шевелиться; кишеть» ~ алт. *кыймыра-*, хак. *хыймыра-* id. < *кыйм-ы-ра-* яисә *кыймыр-а-, кым//кыйм* «вак хәрәкәт» фигыленнән. Чаг. ш. ук (Тумашева 1992: 138–140) **қымла-у** «кымрау». К. **Кым, Кырмыска.** К. түбәндәгене.

**КЫМТЫРЫК, қымтық** диал. «подвижные губы лошади, оленя, а также рыбы и т.п.» – сүз ясалыш моделе буенча **кымтыр-ык** (ихтимал, *кымылтырык*) id.: *кым-* «вак хәрәкәтләр ясау» + *-тырык* – орган һәм җайланма атамаларын ясагыч кушымча (чаг. *койрык* < *куйдурук*). Ихтимал, **кымтыр-у** фигыле бардыр. К. түбәндәгене.

Дерив.: **кымтырыкла-у** «иреннәр белән кабу», «ялмау».

**КЫМТЫ-У, қымды-у** (к. Будагов II: 64), **кымыт-у** «подоткнуть, подтыкать; поджать, сжимать, закусить (губы)», күч. «скредничать, давать (должное) по-маленьку; присваивать по-маленьку, грести под себя» < гом. кыпч. *қымты-,* нуг. *қымдыр-* id., нуг., к.-калп. *қымты-* ирен тур., ә *қымта-* «чабуларны, итәкләрне җыю», үзб. (ЎХШЛ: 161) *қымты-* «мөлкәтне нык саклау», бор. төрки (ДТС: 444) *qamït-, qïmït-* «кузгалту» > як. *кыбыт-* «кымыту» ← кр.-тат., башк. (БТДһ: 212), к.-балк., алт. (Баскаков 1972: 230) *қым-, қымы-*, кырг. *қымыр-* «аска, эчкә тыгу, тыккалану», як. (Пекарский: 1361, 1403–1404) *қып-, қыбы-* (→ *қыбын-*) «кымыту». Күрәсең, **қым** (к.) тамырыннан. Чаг. **қымтырык**; монг. *хамхи-* «кымыту», эвен. *камта-* id.

Дерив.: **кымтын-у, кымытын-у.**

**КЫМША-У,** диал. (ТТДС I: 218) **қымшы-у** «сдвинуться; сдвинуть (слегка)» < гом. кыпч. (булса кирәк) **қымша-*, к. каз., к.-калп. *қымсы-у,* төркм. (ТДГДС: 71) *ғымшы-* «кымшау», аз. (АДДЛ: 136) *ғымыш-* «көлемсерәү, иреннәрне көлүгә таба кыймылдату», як. *хамсаа-, хамсан-* «кымшану» < бор. төрки (ДТС: 414–418) *qamša-, qïmša-* «кымшау» һ.б. **қым** (к.) тамырыннан.

Дерив.: **кымшан-у, кымшат-у;** диал. **қымшық** «кыбырсык».

**КЫМЫЗ** «кумыс, напиток из кобыльего молока» ~ иске тат., башк. (БҺҺ II: 144) *кумыз, қǒмǒз,* алт., хак. *кумыс* < бор. төрки (ДТС: 444) *qumuz, qïmïz* id.; төрки телләрнең күпчелегендә бу сүз иренләшүен югалткан, к. урта төрки, каз. һ.б. *қымыз*, аз., гаг. *гымыз*, хак., тув., як. *хымыс* «кымыз» һ.б. ЭСТЯ VI: 214–216.

Кайбер телчеләр *кымыз* гар. *ҳāмиḍ* «сөт кислотасы (төрки телләрдә дә очрый) сүзеннән дип аңлатып килделәр. Гар. сүзе безнең төрки сүзгә мәгънәсе җәһәтеннән дә, яңгырашы белән дә охшаш булса да, бу очракта әлеге ике сүз үзара баглы түгел. Кытай чыганаклары шаһитлык иткәнчә, кы-

мызны төркиләр безнең эрага кадәр үк белгәннәр һәм яратып эчкәннәр. Моны аларга гарәптән өйрәнәсе калмаган.

М. Рясянен буенча, *кымыран* һәм *кымыз* сүзләре гом. төрки *кымы-, кымыр-, кымырҗы-* «аз гына әчү, ачыту, йомшак кына, әмма тиз-тиз хәрәкәтләнү» фигыле белән баглы. Бу сүзләрнең тамыры – *кым, кыйм* «вак хәрәкәт (кайбер төрки телләрдә механик хәрәкәт); болгату, катнаштыру» сүзеннән (шуннан аз. *гымыз* «язу карасы») ди (Räsänen 1969: 264), ләкин сүзнең тамыры **кум** (к. **Кымызлык**) бу фаразга шик кертә.

*Кымыз* ~ *кумыс* сүзе рус сөйләшләрендә бик киң таралганлыктан, мар., удм. *кумыч, кумыз*, чув. *хăмăс* «кымыз» сүзен татарчадан дип раслап булмый. К. **Көмешкә, Кым, Кымран, Кымызлык, Кымырҗы-у**.

Рус. диал. *кумыс* «әйрән», *кумыз* «кымыз» һ.б. тур. Аникин: 322.

Дерив.: **кымызчы; кымызчылык.**

**КЫМЫЗЛЫК,** «кислица; сурепка», «любое растение с кислым вкусом стебля» (к. ДС II: 119) > чув. *кăмăслăх*, мар., удм. *кымызлык* id. < гом. кыпч. *қымызлық* (> башк. (Будагов II: 65) *қӧмӧзлық,* каз., кырг. *қымыздық*) id., төбендә – «кымыз урынына; кымыз тәмен хәтерләтә торган үсемлек» мәгъ. **кымыз** сүзеннән ясалган, к. тат., башк. (БҺҺ II: 155) *қымыҙ* «какы». **Кымыҙлык** сүзенең нигезе классик **кымыз** түгел, ә гомуми «әче нәрсә, катык» мәгъ. сүз булырга да мөмкин, бу сүзнең тамыры **кум* исә **комлак ~ колмак** (к.) белән баглы булуы ихтимал.

Дерив.: **кымызлыклы; кымызлыклык.**

**КЫМЫР, кымыр-кымыр** (ТТДС I: 218) – имитация мелким движениям многих насекомых – гом. кыпч. сүзе булырга тиеш (сүзлекләрдә имитативлар аз бирелә); үзб. *қимир, қимир-қимир* id. **Кым** (к.) тамырыннан, к. **Кымырҗы-у.**

Дерив.: **кымырда-у** ~ нуг., башк. *қымырла-у,* үзб., уйг. *қимирла-у.*

**КЫМЫРҖЫ-У** «двигаться по коже человека (о насекомом); вызывать зуд, жжение» (Будагов II: 65) «першить, мозжеть», «закисать, выпуская пену (с легкими звуками)», себ. (Тумашева 1992: 140) **кымырцы-у** «егозить; быть не в состоянии терпеть (зуд и т.п.)» ~ башк. *қымырйы-у* «тамак төбе кычыту» < **кымырчы-у;** күрәсең, ***кымыр-** дигән фигыль нигезе дә булган, шуннан *-чы* интенсивлык кушымчасы ярдәмендә **кымыр-чы-** нигезе ясалган; бу **кымыр-** исә **қым-, қымы-** «вак хәрәкәтләр ясау» (к. **Кымты-у**) фигыленнән, шуннан ук (турыдан-туры) башк. *қыймйы-у* < **кымҗы-у* < **кымчы-у* «кымырҗу», к. **Кым, Кымыр.**

Дерив.: **кымырҗыт-у** (затланышсыз мәгъ. кулланыла), **кымырҗыткыч.**

**КЫМЫРЫК,** (ТТДС I: 598) **кумырык** «бузина; акация мелкая» ~ үзб. (ЎХШЛ: 161) *қымрық* < *кымырық* «кәкре-бөкре», себ. (Тумашева 1992: 140) **кымыр агац** «кыеш (кымыр агачы кебек)». Чаг. уйг. *қому-, қуму-* «кубып чыгу; актарылу, куптарылу», *қомур-, қумур-* «актару, куптару».

**КЫН, кыны** «ножны», диал. (Радлов I: 724) «стручок» < гом. кыпч., уйг., угыз. *қын*, як., төркм. *қыын*, аз. *гын*, бор. төрки (ДТС: 444) *qïn* id. чув. *йĕнĕ, йăнă* < **һйын, *қйын* «кын; өн», к. себ. тат., аз. (Будагов II: 105) *қыйын* «кын; кузак» ~ бор. монг. *qui, qunі, quŋi* id. Räsänen 1969: 172, 264; Федотов I: 195–196 (нигезсез рәвештә **өн** сүзе белән чагыштыра).

Каз., кырг. *қынап* «кыны» фар. *гилāф* id. сүзеннән килә һәм **кын** сүзенә баглы түгел. Чаг. **Кылаф.**

Дерив.: **кынлы, кынсыз.**

**КЫНА** «хна; хинна; бальзамин» > мар. *кына, кенä* (*кенä шуды* ≈ *кына гөле*), удм. *кына* id. < гом. көнб. төрки (Будагов II: 105) *қына* «краска из бирючины, хина» < фар. *хäнā* < гар. *хиннā'* id. (*хна* «кына төсенә керү» тамырыннан) күп телләргә таралган.

Дерив.: **кыналы** «кынага буялган», **кынала-у.**

**КЫНДЫРАК, кӧндӧрақ** «костёр, полевица (трава); место с жёсткими злаками», *кӧндрак* (ТТДС I: 203) «телячий выгон; моховидная короткая трава», себ. (Тумашева 1992: 128) **қӧнтырақ** «мягкая трава, сгнившая осенью» ~ башк. (БТДҺ: 199) *қӧндӧрақ* «тозлак», «ач, җиме йомшак (башак тур.)», *қӧндӧрӧқ* «игеннең үтә куе булып үскән җире», чув. (Сергеев 1968: 28) *кӧнтăрақ* «мүк сыман үлән» (< тат.), рус. диал. *кундрак* «кипкән сазлыктан кисеп алынган кәс», аз. *гындырга* «нечкә сабаклы куе үлән; чуалган нәрсә (үлән, җеп һ.б.)» < монг. *хонин туураг* (бор. монг. *қонин туғурағ)* «куй тозлагы»; шуннан ук тат. диал. (әстр.) *кӧндӧраw* «түмгәкле болын; Идел дельтасындагы болыннар», шуннан **Кондорау татарлары** – Әстерхан яклaрыннан Оренбург өлкәсенә күчеп килгән татарлар (к. Садыкова, 1985). Аникин (: 323); рус. телчеләре

бу сүзне (кирәксезгә) **тундра** сүзе белән дә чагыштыралар. К. **Куй, Кынҗырак.**

**КЫНҖЫРАК,** (ТТДС I: 203, 218; БТДҺ: 199) **ҡŏнжырыйҡ, ҡŏнжŏрыйҡ** «поршни; обувь из шкуры с холщовым вéрхом» ~ башк. *ҡынйыраҡ,* башк. диал. (БҺҺ III: 113) *кинйыраҡ* id. > мар., удм. *канйырак, кынйырак* id. < иске кыпч. **кӧн (күн) чарыҡ* (к. **Чарык**), к. нуг. (Ногайцы: 124) *кӧн шарык* «күн чарык».

Кр.-тат. һәм төр. телләрендәге *kondıra, kundura* «җиңел аякчу, ката, гади батинка» сүзен грек теленнән алынган диләр, к. Dobr. II: 331–332, 378. Ягъни ул **кынҗырак** сүзенә кардәш түгел.



Кынҗырак калыбы.
Аралыклар җиңел булсын өчен калдырыла.

**КЫҢГЫР I** «кривой; неправедный, не правый» < гом. кыпч. *ҡыңыр, ҡыңғыр* < бор. төрки (ДТС: 445) *qïŋïr* «кыңгыр; явыз» ← *qïŋ* (шунда ук) > уйг. *ҡың* «кылый; кыек». Чаг. **Кыек.** ЭСТЯ VI: 220–221.

Дерив.: **кыңгырай-у** (һәм юнәлешләре), **кыңгырлык.**

**КЫҢГЫР II: кыңгыр-кыңгыр, кыңгыр-каңгыр, каңгыр-ҡŏнгŏр** һ.б. – имитатив звукам колоколов и т.п. – барча алтай телләрендә таралган сүз, **кың** тамырыннан, к. монг. *хэн-хэн*, як. *хоң-хоң*, тунг. (ССТМЯ I: 411, 451) *коң-коң* «куыш агачка бәрү авазына тәкълит». К. **Кыңгыра-у.**

**КЫҢГЫРАВЫК [ҡы̆ңғы̆раwы̆ҡ]** «погремушка (ш. ук үлән исеме)» ← **кыңғыра-у** (к.).

**КЫҢГЫРАУ [ҡы̆ңғы̆раwы̆ҡ],** диал. (трбс.) **ҡŏңғŏраw** «колокольчик» > чув. *хăнкăрав, хăнкрав* < гом. кыпч. *ҡунғураw, коңғураw,* башк. *ҡоңғораw,* нуг., каз., к.-калп. *ҡоңыраў, ҡоңраў,* үзб. *ҡиңғирав,* уйг. *ҡоңғираҡ, ҡоңғураҡ* һ.б. < бор. төрки (ДТС: 456) *qoŋraγu* > алт. *ҡоңара, ҡоңруу*, тув. *ҡоңға, ҡоңшулуур* id. (гомумән бу сүзнең фонетик вариантлары исәпсез күп); к. ш. ук башк. (БТДҺ: 185) *каңгырау* ~ чув. *канкрав.* Räsänen 1969: 280; Номинханов 1975: 174; Федотов II: 329. К. **Кыңгыра-у.**

Дерив.: **кыңгыраулы, кыңгыраусыз; кыңгыраучык.**

**КЫҢГЫРА-У** диал. (трбс., себ. к. Будагов II: 86) «звенеть (о колокольчике)». Ясалышы буенча *кыңгыра-* < *кŏңгыра-* < *куңгыра-* нигезе тат. ***коңгыр (каңгыр-коңгыр** нигезе, һәрхәлдә, бар) ~ чув. (Ашмарин XVI: 339) *хăнкăр-ханкăр* (кыңгырау авазы) имитативыннан (к. ш. ук кырг. *ҡыңғыр* id.); к. каз. *ҡоңра-,* башк. ( БТДҺ: 213), кырг., тув. *ҡыңғыра-* «кыңгырау; дөмбердәтү (бренчать)» ~ бор. төрки (ДТС: 456) *qoŋra-* «(яшүсмернең тавышы) гөрелди башлау» < **ҡоңғура-* id. Гомумән, күп төрки телләрдә бар.

*Коңгура-* фигыль нигезе үзе бор. алтай *коңкы-, коңку-, коңка-* «шалтырау; яңгырау һ.б.ш.» фигыленең *-ра* морфемасына «киңәйтелгән» варианты да була ала, к. алт. *коңко, кың-кың, коңо*, тув. *коңга* ~ монг. *коңка*, бур., калм. *хонхо*, яз. монг. *хоŋхо* «кыңгырау» ← каз., к.-калп. *кың-кың,* як., бур., монг. *хоң, хон (хон-хон)* – кыңгырау тавышына тәкълит (~ тат. *ҡаң-кŏң*) (к. Пекарский: 3486, 3492). Алт. *коңыр-, коңгыр-*, яз. монг. *xongγina* «кыңгырау, шалтырау, яңгырау» шул *хоң ~ коң* тамырыннан, әлбәттә. Тунг.-маньч. телләрендә (к. ССТМЯ II: 373–374, 395–396, 410, 450–451) *каң, кең, коң, кэң* – яңгырау авазына тәкълитләр – исәпсез күп дериватлар биргән тамырлар. Мондый тамырлар кытай-тибет телләрендә дә билгеле һәм продуктив, к. бор. төрки (ДТС: 456, 466) *qoŋqïu, quŋqau* < кыт. *khoŋхәи* «музыка уен коралы төре» һ.б. К. **Кыңгыр II, Кыңза-у.**

Дерив.: **кыңгырат-у,** к. **кыңгыравык.**

**КЫҢЗА-У** (Тумашева 1992: 140) «визжать (о щенке)» < **кыңса-у;** кайбер төрки телләрдә (уйг., үзб.) **кың-, хың-** ризасызлыкны белдерүчән ымлык һәм бу ымлык **кың** тәкълиди сүзеннән аерым карала, чөнки ул кеше авазына карый (чаг. *һмм*). Чаг. к.-калп. *ҡыңҡ,* к.-балк. *ҡымп*, үзб. *ғыйң, ғиң* ризасызлык авазы тур. әйтелә торган сүз, к.-калп. *ҡыңҡылда-у* «капризлану» (тат. телендә дә **кыңгылда-у** бар, тик фиксацияләнмәгән генә), **кыңкылды(к)** «капризлы» һ.б.

**КЫП I –** подражание не быстрой, но крепкой хватке, движению. Гом. төрки характерда: кырг., каз. һ.б. *ҡып* id.

**КЫП II** диал. (Тумашева 1992: 140, неточно) «дополнительный слой материи, ткани в одежде; утепление; слой хлопка, шерсти и т.п. для утепления» < фар. *хаб,* $x^w$*āб* id. (гарәпчәдән булса кирәк). К. **Кыптыр, Кыса.**

**КЫПСУЫР** «клещи, зажим» < диал. **кыпчуыр, кыпцуыр** (Тумашева 1992: 140), **қыпсуwыр, қыпцуwыр** (ЗДС: 442) > башк. *қыпсыуыр* < монг. *хавчаар, кабчуур* < бор. монг.; (к. Поппе 1938: 444) *qabčiγur* «кайчы, эскәнҗә, кыстыргыч» ← *qabči-* «кыстыру» > тат. диал. **кыпчы-у, кыпцы-у** «келәшчә белән тарту (тартып чыгару)», **кыпчыр-у** «кысу» ~ гом. кыпч., алт. һ.б. *қыпты-*, шор. *капты-* id.; як. *кыптый*, алт. *қыпта*, хак., тув. *хыпты* «кайчы, кыстыргыч» һ.б. Бу сүзне бор. кыт. *kăp, kiap* «кыстыру, кыстырып кысу» сүзе белән чагыштыралар (Joki 1952: 161). Тат. **кыпсуыр** яңгырашы халык этимологиясен (*кып* һәм *суыр-*) чагылдыра.

**КЫПТЫР: кыптыр тун** «вид шубы (из невыделанных шкур)» – гадәттә, кыштырдауны белдерә торган **кыптыр** тәкълиди сүзе белән бәйлиләр (к. ТТАС II: 223; БРС 1996: 394). Безнеңчә, бу халык этимологиясе: *кыптыр* < фар. $x^{w}$*ābdār* «ике тукыма арасында мамык куеп сырылган» дигән сүздән булуы ихтимал.

**КЫПЧАК** «кыпчак, кипчак» ~ гом. кыпч., алт. һ.б. *қыпчақ* id., бор. төрки (ДТС: 445, 449) *qïpčaq, qïfčaq, qïvcaq, qïvčaq-qobï* «кыпчак; мескен, ярлы, бәхетсез» – З. Вәлиди (к. аныкы. Әҫәрҙәр. Өфө, 1996: 35) буенча, бор. төрки *қубы* < *қобы* ~ бор. монг. *γobi*, монг. *гоби* (> каз. *ғобы*) «коры дала, чүл; Гоби чүллеге» сүзе белән баглы. *Кыпчак* < *кубий-чақ: -чак* – кечерәйтү-иркәләү кушымчасы (**кыпчак**, димәк, «ярлы мескенкәй»). КБтә *қывчақ* «мескен; ярлы», ш. ук «кыргый» мәгъ. күп тапкыр искә алына, *қыв, қывы* «буш, ку» сүзе дә еш очрый. Ләкин Европа галимнәре **кыпчак** сүзенең «этимологиясе билгесез» дип язалар.

Мифологик-фольклористик аңлатмаларда (к. Будагов II: 36–37, «Угызнамә» һ.б.) **кыпчак** сүзе *кубырчак, кабырчык* «эче куыш нәрсә, куышлы агач, тупас ясалган кимә» сүзеннән диелә. Алт. *қыбы* «хәйләкәр» → *қыбычақ* «елгыр».

**Қыпчақ ~ қыпсақ ~ қыпшақ** алт., башк., нуг., каз., к.-калп., үзб. һ.б. халыкларда аерым бер кабилә яисә ыруг атамасы. Башкортларда *қыпсақларның* егермеләп ыруы (мәс., *қара қыпсақ, қарағай қыпсақ, сарыш қыпсақ* һ.б.ш.) аерымлана, казакларда, алтайлыларда да шул ук хәл. Әмма аерым кыпчак халкы юк. Татарларда *кыпчак* сүзе хәтсез заманнардан бирле билгеле (Алтын Урда әд. ядкәрләрендә очрый).

Хәз. *кыпчак телләре* төшенчәсе соңрак пәйда булган. Бу телләрнең төп билгес – иҗек азагында яңгыраулы тартыклар *б, ғ, г, д* килә алмау, ул авазларның икенче төр авазга күчә килүе. Мондый күренеш бүтән төрки телләрдә дә очрый, ләкин кыпчакларда эзлекле рәвештә килә. Ш. ук *-ган* кушымчасының киң кулланылуы да кыпчаклык билгесе. Гомумән, кыпчак телләре уйгур группасы телләреннән килеп чыкканнар.

**Кыпчак** сүзе һәм кыпчаклар тур. күп язылган. К. Marquart 1914; Кузеев 1974; Velidi; Kırzıoğlu 1992; Ögel 1993; İnan 1998: 1–68; Кляшторный С. Кимаки, кыпчаки и половцы // История татар I: 328–346 (кыпчакларны турыдан-туры элгәре бор. **сир** халкы дип яза). К. ш. ук **Куман, Коман.**

**Кыпчак** сүзе (башк. *қыпсақ,* каз. *қыпшақ*) күп кабилә, ыруг атамаларында очрый. **Кыпчакый** дигән тәхәллүс һәм **кыпчакый** дигән терминологик сыйфат бар, мәс., *қыпчақый ат токымы.* Күрше телләрдә дә *қыпчақ* һәм модификацияләре еш кулланыла.

**КЫПЧЫ-У,** диал. (Тумашева 1992: 140) **кыпцы-у** «зашить между двумя слоями ткани»; күч. «упрятать; стащить, украсть», «зацепить за края и вытащить» ~ башк. *қыпсы-* id. – бор. *қып-* «кабып алу, эләктерү, эләктертү» фигыленең дәвамлы интенсивлык формасыннан (к. **Кыпсуыр**). К. башк. (БТДҺ: 213) *қыпсыу* «әдеп, кырпу», *қыпсық* «кысык күзле».

**КЫР** «поле – все то, что за населённым пунктом», диал. «то, что рядом; грань», в терминологии «поле»; в изафетных сочетаниях «дикий» > удм. *кыр* id. ~ чув. *хир* < болг. **һыйр* > мар. *ир* id. (Идел-Урал телләрендә бу сүзнең мәгънәләре охшаш) < гом. төрки *қыр* (уйг. *қир, қыр, хыр*) «кырый; сырт; кыраз, таулы дала, кыр; кешесез җирләр» > Д. болг. *кър* id. (гомумән бу сүз күп күрше телләргә күчкән). Төрки *қыр,* яз. монг. *kira* ~ эвенк. (тунг.) *кира, қира* һ.б. (күп вариантлар, к. ССТМЯ I: 397) «кыр; кырый» сүзе белән тамырдаш; чаг. ш. ук коми. *кыр* «калкулык, сырт, текә яр», мар. *курук, кырык* «таулык», эстон. *kurak* «калкулык» < бор. фин-угор *kur* «калкулык»; икенче яктан сугд. *kĕrăn*, авест. *karana* «як юнәлеш; кыр, яр»; шумер. *kiru* «тау». Будагов II: 42; Радлов II: 734; Мурзаев 1984: 327–328; ЭСТЯ VI: 225–227; Федотов II: 249–350 (бик кыска).

Тат., башк. *қыр* бик продуктив тамыр, к. **Кыра, Кырагай, Кыраз, Кырач, Кыргак, Кыргый, Кырлан, Кырлык, Кыртыш, Кырый, Кырын.**

**КЫРА I** диал. (Тумашева 1992: 141) «поле, пашня» ~ алт., кырг. *қыра,* хак. *хыра* (к. Будагов II: 42 һ.б.), уйг. *қира* < бор. төрки (ДТС: 445) *qïra* id., башк. *қыр* «тау сырты» (БТДҺ: 213), тув. *хыра* «тирәч; кайма» ~ монг. *кира* «дамба». **Кыра**ның «басу» мәгънәсе дөге үстерү шартларыннан килеп чыккан. **Кыр** сүзе белән бәйле һәм, ихтимал, шуның бор. яңгырашыдыр. К. **Кыраз.**

**КЫРА II: кыра җил** «северный холодный ветер» – алт. *қыра йэл,* госм., төр. *кыра* (*кира*) *йэл* «төньяк-көнбатыштан искән җил», *йылдыз кира йэл* «төньяк, төньяк-көнбатыш җиле» (*йылдыз* монда «котып йолдызы»). Кайбер сүзлекләрдә *кира җил* дип кенә кителә. Ихтимал *кира* монда фар. күпмәгънәле *хӣрä* > иске тат. *хирә, хира* «начар, әшәке, салкын, тискәре» сүзеннәндер. Будагов I: 44; Будагов II: 361; Steuerwald: 1028.

**КЫРАГАЙ** «дикий; диковатый; неприветливый» < бор. монг. *qairaγui* «мәрхәмәтсез» сүзеннән; *кыргый* сүзе белән контаминацияләнгән; сүзнең тамыры бор. монг. *xaira* < *qaira* «мәрхәмәт, йомшак мөгамәлә, кызгану» мәгъ. себ. төрки, монг., тунг.-маньч. телләрендә киң таралган сүз (чаг. алт. *кайракан* «мәрхәмәт тәңресе»), к. ССТМЯ I: 362. К. алт. *кыракай* < *қайрақуй* «талашчан, кырыс» (Баскаков 1972: 230). Каз., к.-калп. *қырығы*, кырг. *қыраақы* ~ эвенк. *кирага* «үтә сак; алдан күрүчән» сүзе дә *кайра* тамырыннан булса кирәк, бу тамыр кыт. *āй* < бор. кыт. *hai, xai* «кайгыру; гамь» сүзе белән чагыштырыла.

**КЫРАЗ** диал. «суша» (сазлык уртасында) ~ башк. *қыраз* «сыртлавык (озын коры җир яисә кар өеме)», алт. диал. (черневые татары – кара татар этник группасында, к. Баскаков 1966: 96) *кыразы, кырас* «басу», «сазлыкта корырак урын» – **кыр** сүзеннән (к. уйг. *қир*, монг. *кира* «дамба»). Ясалышы ачык түгел. Чаг. **Кырач.**

**КЫРАН: кыран таш** «слюда». Ачык түгел. Чаг. ш. ук *кыран да булмас* берни дә булмас, башк. *қыран-һәләкәт* «кырылыш» (?), төр. *kıran* «эпизоотия, кыргын».

**КЫРАНДАС, кырантас, карандас, кәрандас, кәрәндәс, кәрендәс** (ДС III: 94–95; ТТДС I: 270; ЗДС: 291) «повозка с плетёным кузовом» ~ башк. (БТДҺ: 168) *кырандас* «тарантас, кырандас козавы» ~ чув. (Сергеев 1971: 49) *кăрăнташ,* мар. *карандас, кäрäндäш*, морд. М. *крандаз* «тарантас» (~ коми. *карандыс* «ушат, кадка»?) – урта *к-* авазына караганда, рус теленнән, к. рус. диал. (Вятка) *карандас*, ләкин рус телендә *карандас, тарантас* сүзләренең юньле этимологиясе юк («шәрык сүзе булса кирәк», ди М. Фасмер IV: 23). Безнеңчә, бу сүз мари теленнән, к. мар. *кӗрäн* «кабыктан ясалган», к. мар. *кӗрäнтир* «кәшәү, кабык козаулы чана» (*тир* «чана»), к. Саваткова: 73. Мариларның яхшы арба-чаналар белән мавыгуы, «арба-чана бәйрәмнәре» уздырулары тур. тарихи истәлекләр бар. *Тарантас* < *карантас* рус телендә үзгәртелгән.

**КЫРАУ [қы̆раw]** «иней, пороша» < гом. кыпч. *қыраw,* кырг. *қыроо*, алт. *кураа, куруу*, як. *кырыа* < бор. төрки, уйг., госм. *қырағу,* бор. монг. *kıraγu* (к. Räsänen 1969: 265) id.; вариантлары күп. Чаг. алт. (Вербицкий) *қырар-* «чәч агару».

*Қыраw* < *qıraγu* сүзен, безнеңчә, *кар* һәм *кырпак* сүзләреннән аерырга ярамас: бор. *qār* < *qaγar* > *qıγar* (бор. тамырларда *а* ~ *ы*) сүзеннән **qıγra-* < *qıγar-a-* фигыле, шуннан исә *qıγara-γu* > *qıγraγu* исеме ясала ала. ЭСТЯ VI: 230–231. К. **Кырпак.**

**КЫРАЧ** «каменистый склон; неплодородная каменистая земля», «скудный, сухой, неплодородный (о земле)» ~ башк. диал. *қырас,* чув. *кăрач, кăрачă,* төр. *kıraç* > фар., көрд. *qırac* «үсемлексез ташлы җир (гадәттә ярлау, текәлек)»; **кыра** сүзеннән булса кирәк; к. кырг. *кыраң, кыранч* «калкулык, кашлак, кыраз», каз. *қырат* «плато, тау башындагы тигезрәк җир». Федотов I: 257. Чаг. себ. (Гиганов) **қарач** (ялгыш язылгандыр) «суша» диелгән.

**КЫРАША** (Г. Мөхәммәтшин) «вид небольшого болотного карася» ~ госм. *қарасы* id.; чув. *кăрăш, кăртăш* «шыртлака». Федотов I: 261 (тат. диал. **кыртыш** «шыртлака» сүзен дә китерә).

**КЫРГА** диал. «жребий» к. **Корга.**

**КЫРГАВЫЛ [қы̆рғаwы̆л], коргаwыл** «фазан» (к. мәкаль: *Кызымның кызы – кыргавыл*) <



гом. кыпч., чыгт., госм. *қырғаwыл, қырғаwул*, госм. *қирқавул*, аз. *ғырғавул*, монг. *гургуул*, калм. *һорһл* < *горгуул* < иске монг. *qırγaγul* h.б. (Räsänen 1969: 266, Номинханов 1975: 193). Төрки телләргә бу сүз, безнеңчә, кыпчаклар-

дан таралган һәм *қурғawыл* «паж, хатын-кыз күчтысы, фрейлина» сүзеннән, **курга-у** «саклап йөрү» нигезеннән. ЭСТЯ VI: 232. К. **Курга-у.** Рус. *каргаул* «фазан» тур. Аникин: 267; этимологиясен белми.

**КЫРГАК** диал. «побережье (реки)» – үзб. *қирғоқ* id., кырг. *қырғақ,* бор. төрки (ДТС: 445) *qïrγaγ* «кайма» – *кыр* сүзеннән, ясалышы ачык түгел. К. ЭСТЯ VI: 242–244.

**КЫРГАЯК [қы̆рғайақ]** «мокрица; сороконожка» > чув. *кăркаяк* (Сергеев 1968: 88), мар., удм. *кыргайак* < гом. кыпч. *қырғайақ, қырқайақ,* төр. *kırkayak* id. < *қырық айақ*; рус. *сороконожка* сүзенә охшашлыгы игътибарга лаек.

**КЫРГУЙ** «копчик; перепелятник» < уйг. *қурғуй,* төр. (Будагов II: 50) *қырғы, қырқы, қырғу* > фар. *қирғӯй* id.

**КЫРГЫЗ** «киргиз», «один из башкирских родов» (а также название родов и племён ряда тюркских народов), иск. «казах» (вслед за татарами и русские до 30-х годов XX века казахов называли *киргиз*ами, а киргизов *кара-киргиз*ами); казакларны кыргыз дип атау аларны *казак кыргыз* яки *кыр казагы* дип атаудан (ягъни *казах* ~ *қазақ* сүзенең тәүдә этноним булмавыннан, ә *кыргыз* сүзенең борынгыдан төрки этноним булуыннан) килә; чув. *кăркăс* (< тат.) «елгыр; үзсүзле» ~ **кырыс**, төр. сөйләшләрендә *кыргыз* «ирдәүкә, ир-ат кебек кыланучан хатын-кыз» – шактый үзенчәлекле мәгънәләр.

*Кыргыз* этнонимының этимологиясе катлаулы. Аны 1) *кыр кыз* «тау кызы»; 2) *кырык кыз* «кырык кыз, бер ирдән туган балалар токымы» (бу турыда төрле легендалар бар); 3) *кыргы угуз* «кызыл (җирән) угыз» (бор. төрки телдә *кыргы* «кызыл, җирән», ә Енисей кыргызларының җирән булуы билгеле; *угуз* < *угур* «токым, халык» мәгънәсендә булган); 4) *кыр күн* яисә *кырык кун: күн/кун* > *көн* борынгыча «халык» (тат. *ил-көн* сүзендә сакланган), һәм, ниһаять, 5) **кыргыз** < бор. төрки *qïrqïz* (ДТС: 445) – *кыркун* сүзенең күп. формасы дип исәпләнелә (Зуев: 11, 19–20), бу сүз исә кыт. чыганакларында *гяньгунь* рәвешендәрәк б.э.к. II г. ук теркәлгән (*гяньгунь* = *kien-kuen* = *кыркун* тәңгәллеге бу хакта язган барча авторлар тарафыннан раслана), ләкин ул чакта бу сүз бүгенге кыргызларның турыдан-туры бабаларын белдермәгән, ә җирән чәчле, ак йөзле бер халыкны белдергән, шуннан чыгып бор. *кыргыз* сүзенең тамыры, тагын килеп *қырғ* «кызыл» дип уйлыйлар – *кыргыз* «кызыллар» дигән сүз булып чыга. Мари этимологы Ф.И. Гордеев мар. *хĕрäш* «сары чәчле (кеше)» (к. Саваткова: 182) сүзеннән чыгып булса кирәк, *кыргыз* сүзен *кырык ас* яисә *кырк-аз* «таулы ас» яисә «таулылар» сүзеннән ди (к. аныкы 1968: 10–30). Гомумән, **кыргыз** сүзенең чыгышы тур. әдәбият ишле. Рус әдәбиятында *кыргыз* сүзен *кыр гиз* дип аңлату (Фасмер II: 237) элекке язмаларда **қыр киз** (قرکز) дип язылуга нигезләнгән, ләкин монда орфографик хата гына булса кирәк. К. ш. ук Л.Р. Кызласовның **кыргыз** һәм **хакас** сүзләрен тәңгәлләштерүе дә (к. аныкы: Взаимоотношения терминов *хакас* и *киргиз* в письменных источниках VI–X веков // Народы Азии и Африки. № 4, 1968: 88–97) ышандырып бетерми. Рус. *киргиз* тур. Аникин: 290–291 (бик кыска).

**КЫРГЫЙ** «дикий; дикарь» ~ к.-калп. *қырғы* id. Тат. телендә бу сүз **кырагай** (к.) сүзеннән кыскарган булса кирәк, әмма мөстәкыйль-аерым сүз дә була ала. Бүтән төрки телләрдә күренми (**кыргый** «кыйгыр» еш очрый).

Дерив.: **кыргыйлык; кыргыйлаш-у; кыргыйларча.**

**КЫРГЫН** «резня» ~ гом. көнб. төрки *қырғын* id. **кыр-у** сүзеннән, әлбәттә. Диал. *қырғынныҡ* «агач курпысы» (ДС I: 107) сүзе игътибарга лаек.

**КЫРГЫЧ** «скребница, скобель» ~ чув. *хыркăç* id. Бу сүз регуляр сүз ясалышына караса да, борынгылыгы белән кызыклы, к. бор. чыгт. *qïrγuči* ~ бор. монг. *qirγaqçi* id. (Поппе 1938: 440). Урта төрки телләрдә «кырып чистарту һ.б.ш.» мәгънәдә *қырға-, қырғы-* сүзе кулланылган һәм **кыргагыч** дигән сүз дә булган.

**КЫРДАУ [қы̆рдаw],** диал. **қыртам** (Тумашева 1992: 141) «ряд покосов; ряд гряд, плоскогорье» ~ башк. *қырҙау, қырдал* id., кырг., як. *кырдал* «кырлач; яшәргә уңайлы җир» – монгол сүзе, әмма төрки *кыр* тамырыннан. К. **Кырлач.**

**КЫРКА** «резко, наотрез» – *кырку (кырык-у)* фигыленнән (хәл фигыль формасы).

**КЫРКАН** «кипрей, иван-чай» (к. Иванова: 52) – *кыр кан үләне* сүзеннән (*кан үлән* «меңьяфрак, ярмабаш»). Кабаттаркалыш.

**КЫРКУ** «прогорклый; пересоленный», «резкий, крутой» ~ башк. *ҡырҡыу* id. > мар. *курку,* чув. *хӗрху* id. (чув. варианты бу сүзнең борынгылыгына һәм татар теленең чагыштырмача борынгылыгына дәлил) – **кырык-у** фигыленең сыйфатлашкан исем фигыль формасы.

**КЫРКЫН I: кыз-кыркын** дигәндә, диал. **қырғын** (ДС I: 106) ~ чув. *хăрхăм* «хатын кеше; яшь килен» < уйг. *қырқын* id., урта төрки *қырқын* «кәнизәк, кол хатын», чыгт. *қыр қын* «кара кол хатын», төркм. *гыыргын* «кол кыз» һ.б. бор. төрки *qïrqïn* (МК, ДТС: 446) **кыр кун* «һун кызы» дип тә **кыр күң* «кол кыз» дип тә аңлатыла, к. Егоров 1964: 294; Räsänen 1969: 267; ЭСТЯ VI: 237.

**КЫРКЫН II**, диал. **кыркылык** «ножницы для стрижки овец» ~ госм. *кыркы, кыркын*, аз. (АДДЛ: 142) *гырхын, гырхылық* id. *кырык-кын* һәм *кырык-кы, кырык-кы-лык* сүзләреннән. Угыз телләре күрсәткәнчә, **кыркын** һәм **кыркылык** бор. гом. төрки сүзләр. К. **Кырык-у.**

**КЫРКЫН III**, диал. (Тумашева 1992: 142) **кыршын** «крайне скупой; скудный» ~ башк. *ҡырҡын* «үләнен терлек ашап бетергән җир» (БТДҺ: 214). К. **Кыркын II.**

**КЫРЛА** диал. «крестец, стог четырёхугольной формы (без теркәдек. – *Р.Ә.*)» ~ башк. *ҡырла* «алты көлтәдән торган сослан» (БТДҺ: 214). Чаг. **Кырлык II.**

**КЫРЛАЙ** «коробейник» > чув. *кăрлай* id. ~ нуг. *құрдашы* < *құрдачы,* кар. *кыржҗы* id. **Кыр** сүзеннән дип әйтеп булмый. Алынма тамырдан булса кирәк, чаг. фар. *хордэчи, хордэфоруш* «кырлай» (*кырлай* < **курдлайычы* ?).

**КЫРЛАН** «возвышенность посреди болот» (чаще обрабатываемая, к. мәкаль: *Кырлан җирне саз йотмас*) ~ алт., тув. *қырлан*, хак. *хырлаң* һ.б. «калкулык» ← *кыр* (к. **Кыр**). Рус. диал. *кирлан* тур. Аникин: 291. Чаг. **Кыраз, Кырлач.**

**Кырлан ае** диал. шул ук **кырлач ае**.

**КЫРЛАЧ** (Радлов II: 754; К. Насыйриның 1879 елгы календаре; ДС I: 107) в названиях двух месяцев зимы: **олы (агам) кырлач** «январь» (варианты: «ноябрь», «декабрь») и **кече (энем) кырлач** «февраль» (вариант: «декабрь») ~ чув. *мăн кăрлач* һәм *кӗҫӗн кăрлач* id. id. ~ кар., алт. *улу қырлаш* һәм *кичи қырлаш*, хак. *улуг кырлас* һәм *кичиг хырлас* id. id. Тат. *кырлач*, башк. *ҡырлас* «тау сырты», себ. (Тумашева 1992: 141) *қырлаҵ* «сазлыклар, вак сулыклар арасындагы (озынча) калкулык» һәм А.П. Дульзон буенча (к. анык: 1950: 60), **кырлач айы** «таулыкларга, сазлыклар арасындагы калкулыкларга чыгып, болан аулау ае» икән, к. кырг., алт. *қырла-* «тауларга китү». *Кырлач* белән беррәттән тат. (Тумашева 1992: 141) **қырланчық,** тув., чулым. (Радлов II: 17) *қырлаң*, хак. *хырлаң* «биек үк булмаган тау сырты». *Қырлач* һәм *қырлан, қырлаң* сүзләренең уртак тамырын башк. *ҡыра* «калкулыклар теземе» сүзендә күрергә мөмкин, к. **Кыр.** Сбоев: 45; Романов 1960: 240–241; Беркутов: 24; Федотов I: 258–259; ЭСТЯ VI: 237–238.

**КЫРЛЫГАН**, (ТТДС I: 598) **қырлығ үләне** «вид таволги; клоповник (растение)» ~ чув. *хӗрлехен* id. – бор. *қырлы қана* «кызыл үлән» сүзеннән булса кирәк, к. ЭСТЯ VI: 258–259.

**КЫРЛЫГАЧ** «чистяк весенний (растение)» (к. Иванова: 192) – ***кырлыккач** сүзеннән булса кирәк.

**КЫРЛЫК I** (ТТДС I: 598; Халиков 1981: 37) «дикая гречиха, гречиха вообще» ~ башк. (БРС 1996) *ҡырлыҡ* «кырлык», «чүп үләннәрнең орлыклары (сугылган иген арасында)» > мар. (Исанбаев 1978: 24) *кырлык* id. (соңгы мәгънәдә) – күпләр уйлаганча **кыр** сүзеннән түгел, **кара орлык** дигәннән (**қар'ŏрлŏқ** дигән варианты да бар).

Төрки телләрдә *қырлық* дигән тагын берничә үлән атамасы бар, аларның кайберләре чыннан да **кыр** сүзеннән булырга мөмкин, к. ЭСТЯ VI: 238–239.

Рус. *кирлик, керлык, кырлык, курлук, курлак, карлык* «кырлык, песи тарысы, меңьяфрак һ.б.» тув. Аникин: 284, 330 (бу сүзләрнең барысын да татарчадан чыгара, ләкин аларның кайберләрен фонетик җәһәттән аңлатасы иде).

**КЫРЛЫК II** «суслон из шести снопов» – данное определение, видимо, неверно, потому что в детальном исследовании Н.А. Халикова (1981: 77–78) дано другое пояснение: **қырлық** в Оренбургской и Уфимской губерниях – это «крестец», «четырехугольная кладь» (а не суслон) – бу сүз **дүрт қырлық** тәгъбиреннән эллипсис булса кирәк, чөнки шундый өем **дүрт миеш (мөеш)** дип тә аталган

(Халиков, Op. cit.). **Кырлык**та көлтәләр саны алты гына түгел, 50–60 данә булган.

**Қырлық** сүзен «*кырга* калдырыла торган, басулык» дип фаразлау дөрес булмас, чөнки нәкъ бу сүз таралган якларда **кыр** сүзе «басу, ялан» мәгъ. кулланылмый, ә «ян, почмак» мәгъ. кулланыла. К. ш. ук **Кырла.**

**КЫРЛЫКУГА** «сусак зонтичный» (Иванова: 154) < **қырлы қуга.** К. **Куга**. Гомумән, **кырлы** сүзе күп кенә үсемлек атамаларында очрый: **кырлыкакы, кырлакурай** һ.б.

**КЫРМА** «точеный; подстриженный и выбритый по краям; трахома» һ.б. *кыр-у* фигыленнән регуляр ясалма, күп мәгънәләр алган; к. ш. ук себ. **қырмаяқ** < *қырма аяқ* «агачтан кыру аләтендә ясалган агач купы (аяк)» күп телләрдә бар һәм борынгыдан килә, бор. төрки *qïrma* «кырып ясалган» (ДТС: 446), башк. *қырма бүрек* «кырпулы бүрек» һ.б.ш.

**КЫРМАВЫК [қы̆рмаwы̆қ]** «вид растения (с липкими усиками); репейник» – *кармавык* вариантыннан, **карма-у** фигыленнән булса кирәк.

**КЫРМАЗИН** «кармазин; вид красной ткани» к. **Кырмызы.**

**КЫРМЫЗЫ, кырмазы** «густо-красный; краснуха (болезнь); амарант» ~ гом. көнб. төрки *қырмызы, қырмызый*, аз. *ғырмызы* << гар. *қирмизӣ* id., *қирмиз, қирмаз* «үзеннән буяу ясала торган бертөрле корт» < санск. *krimiǯa* id. ← бор. һинд. *krmih* «корт» (Räsänen 1969: 267).

Шул ук гар. сүзенең икенче дәвамы – тат. *кырмазин*, чув. *кӑрмачин*, мар. *кырмазин*, рус. *кармазин* «тыгыз кызыл комач» (рус теленә пол. һәм ним. телләре аша кергән дип исәпләнелә, к. Фасмер II: 201). Фар. һәм төр. *kırmız* «җете кызыл буяу» һәм *kırmızı* «кызыл» икесе ике сүз булып йөри. **Кырмызы** сүзенең бер чагылышы – рус. *кармин* «җете кызыл буяу» < фр. *karmin* < *karmis minium* «кечкенә кырмыз корты» (ул җете кызыл төстә була). Тат. диал. **кергезин** «тукыма төре» рус. диалектларыннан булса кирәк.

Мәзкүр бор. һинд. *krmih* «кызыл корт» сүзе белән рус. *червь* «корт» сүзе тамырдаш, шуннан исә *червонный, червлённый* «алсу кызыл» сүзләре дә килә. Гомумән, барлык бу сүзләрне белдергән предметлар – бор. сәүдә әйберләре. К. Platts II: 790; Срезневский III: 1197, 1557–1558; Крачковский I: 354, Абаев I: 39; ЯТ: 257.

**КЫРМЫСКА**, диал. (ДС I: 105; Тумашева 1992: 140; ТТДС I: 217, 262–263) **қырмычқа, қымрысқа, қымырысқа, кымырыцка** «муравей» < гом. кыпч., к. башк. (БТДҺ: 212, 214) *қымырҫқа, қымыртқа, қырмықса,* кр.-тат., добр. *қырмырсқа,* нуг. *қымырсқа* каз. *қӧмырсқа*, кырг. *қумурсқа*, алт. *қумурсқа, қомурсқа*, бор. чыгт. (Поппе 1938: 406) *qomursaqa,* бор. төрки (ДТС: 466) *qumursaγa* > уйг. *қумурсха*, бор. кыпч. (Räsänen 1969: 300) *kumursaka* > кар. *қумырсақ, кымырсак* id., к. ш. ук хак. *хымысха*, тув. *қымысқайақ,* төркм. (ТДГДС: 466) *ғымырсға* – фонетик нык үзгәргән вариантлар. Шор. *қымырташ*, як. (Пекарский II: 1394) *қымырдағас* «кырмыска» – «кымырдагыч» дигән варианттан чыгып, сүзнең нигезе **кымыр ← кым** (к.) тәкълиди сүзе дип уйларга мөмкин. Ләкин *қомур ~ қумур ~ қумыр* яңгырашлары бу фаразны шик астына куя. М. Рясянен башта сүзнең тамыры **қом < қум** («каты минералларның бөртекләре») дип язган иде, ләкин этимологик сүзлегендә бу фикерен кабатламый. Һәрхәлдә тат. **кырмыска < қымрысқа** (метатеза).

Иске тат. **карынча, қәренчә** ~ кр.-тат., госм. *қарынҗа* < чыгт. (Радлов II: 174, 181, 185) *қарынчқа, қарынҗға*, аз. *қарышқа, ғарышға*, төркм. (Мухамедова 1973: 115) *ғарынҗа, ғарынчға*, фар. (төрки телләрдән) *қарышҗақ* < бор. төрки (ДТС: 427) *qarïnča, qarïnčaq* һ.б. «кырмыска» *-чка ~ -ска < -чака ~ -сака* кушымчасы буенча *кымырычка ~ кымырыска* вариантына охшаш, ләкин аның тамыры *қар* – үзгә булса кирәк.

**Кырмысқа < кымрыска** (һ.б. вариантлары белән) нигезе кайбер төрки телләрдә (чув., үзб.) юк яисә диалекталь сөйләмдә генә очрый. Чаг. **Карынча догасы.**

**КЫРМЫШ** (ЗДС: 445) «скупой; скопидом» к. **Кормыш II.**

**КЫРНАК** («Кыйссаи Җөмҗөмә» әсәрендә һ.б.ш.) «рабыня (как трофей)» < кырг. *қырнақ,* төркм. *ғырнақ* < бор. төрки (ДТС: 446) *qïrnaq* бор. **қырғ-нақ* «кызларның берсе» сүзеннән (*-нак* «күпләрнең берсе» сememасын белдергән кушымча).

**КЫРПАК**, диал. **қырпық** «осенний мелкий твёрдый снег, снежинка; осенняя пороша, тонкий

снег» > мар. *кырпак* (*кырпак лум*) id., чув. *кăрпăк* < гом. кыпч., төркм. *қырпақ, қырбақ,* үзб. (ЎХШЛ: 102) *қырпақ, қырпық* «юка кар», як. *кыырпах* «каты кар бөртеге», *кыырмах* «көзге беренче кар», *кырпай* «кырпак», хак. *хырбых* ~ яз. монг. *qirtaγ* > хәз. монг. *хярмаг* «кырпак»; чаг. ш. ук башк. (БТДҺ: 214) *қырпық, қырайақ* «беренче юка кар» – **кар** һәм *кырау* сүзләре белән бәйле (*каарпы- ~ кыырпы-* «кар явып тору» фигыленнән булса кирәк). К. Räsänen 1969: 261; Номинханов 1975: 280–281; ЭСТЯ VI: 241.

**КЫРПУ,** диал. **кырпук, кырпа** «опушка, околыш, оторочка» ~ башк. *қырпай,* чув. *хăрпу* < гом. кыпч. *қырпу,* хак. *хырбыг* id., як. *курбӯ* «билбау» – *кур* «билбау, кыршау» белән бәйле. Чаг. **Курпы.**

**КЫРПЫ** «белуга (рыба)» (Радлов II: 1464) ~ кырг. (Будагов II: 75) *қуртпа,* калм. *хорба, хорбе* id. (бу тат. һәм калм. сүзен тәүләп В. Паллас XVIII г. фиксацияләгән, к. Линдберг, Герд 1972: 67). Калмыклар бу сүзне татарлардан алган булса кирәк.

**КЫРСА** «сибирский мех; песец» ~ алт. *кырса* «кәнтәй», кырг. *кырса* «төлке, карсак», тув. *кырза* «көзән», як. *кырса* «кырса, ак төлке» ~ рус. *харзá* «көзәнсыман җәнлек төре» < монг. *хярса, хярза* id., яз. монг. *kirsa* «карсак төлке», к. ш. ук эвенк., эвен. *кирса, кырса* «кырса», маньч. *кирса ~ хирса ~ хирһо* «карсак төлке» (ССТМЯ I: 399).

**КЫРСЫЗ,** (ДС: 107; Тумашева 1992: 141) **қырсыс** «лжец; мошенник» ~ добр. (Akb: 245) *kırsız* «карак, угры», нуг. *қырсыз* «карак; талаучы, юлбасар» ~ аз. (АДДЛ: 414) *хырсыз* «көчле явыз, көчләүче; җаһил, надан», төр. *hırsız* «карак, жулик, бандит». Добр. сүзлегендә *qırsız* гар.-төрки *хайрсыз* сүзеннән дип аңлатылган, ягъни тат. **хәерсез** сүзенең дублеты булып чыга. Ләкин добр. тат. *kırsla-* «урлау», каз., к.-калп., кырг. *қырсық* «афәт, каза; комачаулау», к.-калп. *қырсық-у* (*қырсығу*) «явызларча шәпләнү, явызлыклары белән мактану» ~ башк. (БТДҺ: 214) *қырҫын-ыу* «янау» һ.б. Башк. һәм каз. фигыльләре ***қырсы-** «кырыслану, явызлану» дигән фигыльнең төрле (закончалыклы) формалары. К. **Кырыс.**

Рясянен (Räsänen 1969: 159) бу сүзне фар.-гар. *ʻird* (*ғырд*) «намус» нигезенә нисбәтли: *ғырдсыз* «намуссыз» ди.

**КЫРТ: кырт кисү** «сказать и отрезать < отрезать одним взмахом», к. ш. ук **кырт чабу** – только в собственном значении. Тәкълиди *кырт* сүзеннән гом. төрки характердагы тамыр; к. чув. *кăрт* «киртү», як. *кэрт-* «кисү», *қырт-* «кырку» һ.б. Диал. (Будагов II: 102) *кырт* «кискен, дуамал, текә» (шуннан *қыртай-у* «кылтаю»). Чаг. **Кыр-у**.

**КЫРТАЙ, кыртый** (Һ. Вәлиев) «заяц (иносказательно)» < *кыр тае* «кыргый тай», чаг. ш. ук тат. диал. **миран** «куян» < монг. *морэн* «ат, тай», тат. сөйл. **кыртәкәсе, кыртәкә** «куян» һ.б. Аю, куян, төлке һәм бүрене төрлечә читләтеп атау гадәте күп халыкларда бар.

**КЫРТАЛАШ-У** «упорствовать» (к. ТТДС I: 220; БТДҺ: 215) < *кыр талаш-у*. Монда *қыр* сүзенең мәгъ. аңлашылып бетми.

**КЫРТЫШ** (Радлов II: 757–758; ДС I: 106–108) «палёная шкура свиньи (у крещёных татар); внешний слой дерева; целина; горбыль и т.п. (вообще – корка, верхний слой)» > чув. диал. *кăртăш* id. (ш. ук «шыртлака – балык төре») < гом. кыпч., төркм., алт., тув. *қыртыш*, нуг., каз., к.-калп. *қыртыс*, хак. *хыртыс*, як. *қырыс*, уйг. *қырдыш* id. Бу сүзне *кыр-тыш* дип аңлату ничектер ышандырып бетерми; дөресрәге *кырытыш* «кырыла, кырдырыла торган өлеш» дигәннән, **кыр-у** фигыленнән булса кирәк, чаг. чув. диал. *хăртăк* «йомычка, кыртыш».

**КЫР-У** «скоблить; разбить (всё подряд); стричь (волосы); истреблять» < гом. төрки (Радлов II: 734–735) *қыр-* id., уйг. *қир-*, чув. *хыр [хыйр-]* < болг. **һыйр-* > мар. *ир-* id. Будагов II: 51–52; Федотов II: 381–382.

Бу күпмәгънәле сүзнең кайбер төрки телләрдә аерым мәгънәләре активлашкан, мәс., төр. *kır-* күбесенчә «вату, бетерү» мәгъ. кулланыла.

Дерив.: **кырыл-у, кырын-у, кырыш-у, кырдыр-у; кырма** (сакал); **кырынты (кырынтык, кырындык)**. К. **Кыргын**, **Кыргыч, Кырку, Кырма, Кырт, Кырчы-у, Кырчын, Кыршы-у, Кырык-у.**

**КЫРЧЫ-У** (ТТДС I: 264) «чистить твёрдым орудием с трудом; корчевать» ~ башк. (БҺҺ II: 157–158) *қырсы-* id. – **кыр-у** фыгыленең интенсивлык формаларының берсе (*-чы//-че* аффиксы); чаг. як. *кырчый-* «юну». К. **Кырчын, Кыршы-у.**

**КЫРЧЫМА,** (Akb: 6) **kırcıma [кыржыма]** «корчма, общественная столовая» < төр. *harcata* id., асылда рус. *харчи,* гом. слав. (Фасмер II: 342) *корчма, кръчма* «ашау-эчү урыны» сүзе белән бердәй. Бу сүз гар. *харҗ* «акчаны әрәм итү» (к. **Хәраҗәт**) сүзе белән тамырдаш. Хайрутдинова 1993: 120; Аникин: 613 (арытабангы әдәбият күрсәтелә).

**КЫРЧЫН** «стригущий лишай» < **қырчы-ғын* формасыннан *қырчы-* фигыль нигезеннән. ЭСТЯ VI: 245–246. Будагов (II: 49) бу сүзне **корчаңгы** белән чагыштыра.

**КЫРШАУ [кы̆ршаw]** «обруч» < диал. **қоршау** ← **корша-** фигыль нигезеннән (к. **Корша-у**), яз. әд. телдә **коршау** «камалыш» (коршауда калу) һәм **кыршау** «чәмбәр» сүзләрен аерырга мөмкин.

**КЫРШЫ-У** «снять шерсть; измызгать (по краям), притупить лезвие щербинами» < *кырчы-* сүзеннән (нугай компоненты тәэсире) булса кирәк; ләкин к. аз. диал. *корш* «тупа, кыршылган балта безе», *коршал-* «тупару; үтмәсләнү», бур. *хэршэ* «турау; киртләчләү» (мондый сүзләрнең тат. *кыршы-* сүзенә тәэсире булырга мөмкин).

*Кыршы-* шактый продуктив сүзьясагыч нигез, к. **кыршылган** «(кыек эшләрдә) тәҗрибәле, кыркылган», **кыршыл-у** «йонлач әйбернең кырыйларында йоны коелып, күне күренү; тупару», диал. **кыршык** – кыршылган.

**КЫРЫЙ** «край, краешек; берег; граница; который с краю» < гом. кыпч. *қырый,* к. ком. *қырый* < (чыгт. һ.б.) *қырың, қырығ,* хак. *хырығ,* иске тат. (НФ телендә) *қыраг* ~ аз. *ғыраг* id., к. ш. ук чув. *хĕрĕ* < болг. **һыры* ~ як. *қырыы* «кырый» (барлык мәгънәләрендә), **кыр** сүзеннән, әлбәттә, әмма ничек ясалганлыгы бигүк аңлашылып бетми. Чаг. бор. төрки (ДТС: 440, 463) *qïdïγ, qïδïγ, quduγ* «кырый» ~ *qïδït-* «каймалау» ← **qïdï-*. ЭСТЯ VI: 242–244 (күп параллельләр китерелә, тәфсилле). Чаг. **Кыргак, Кыяк?**

**КЫРЫК** «сорок» < гом. кыпч. *қырық* (*қырқ*) күп кенә телләрдә (чыгт., госм. һ.б.) *қырқ,* уйг. *қирқ,* хак. *хырых,* чув. *хĕрĕх* < болг. *хрх* id. Бу сүзнең этимологиясе тур. төрле фаразлар гына бар, шуларның берсе – урта төрки *қырық* < *қырығ* «кырыйдагы; кырый» сүзе белән чагыштыру (Л. Җәләй, Р. Әхмәтьянов), икенче бер юрама – рус *сорок* сүзен төрки *кырык*ка нисбәт итү.

Себ. төрки телләрендә (алт., тув. һ.б.) **кырык** сүзе урынына *дөртен, дортун* «дүрт ун» сүзе кулланыла; чаг. бор. ир. *čatvārinsat* «кырык» – «йөзгә таба дүрт (ун)» (Абаев I: 323) ЭСТЯ VI: 235–236 (төркм. һ.б. *қырқ* сүзен *қыр-* «вату, җимерү» фигыле белән баглау алга сөрелә). Федотов II: 344–346 (тәфсилле).

Дерив. – (саннар өчен) регуляр.

**КЫРЫК-У** (**кырку, кырыкты**) «отрезать; стричь» < гом. кыпч. *қырқ-* < *қырық-* id. *қыр-* сүзенең интенсивлык дәрәҗәсе (*-қ* аффиксы), чаг. ш. ук як. *кырк-, кырт-* id. һәм «кыру»; яз. монг. *kirγa-, kirk-* «терлек йонын кырку» һ.б. к. Räsänen 1969: 266. **Кырык-у** фигыленең гайре регуляр төрләнеше *-к* аффиксына беткән бер төркем сүзләргә хас (к. **Курык-у, Өрек-ү**). ЭСТЯ VI: 236–237.

Дерив.: **кыркыл-у**; диал., башк. **қырқынты** (кыркып ташланган нәмәрсә); к. **Кырыкмыш.**

**КЫРЫКМЫШ: кырыкмыш тай** «жеребёнок-стригунок» > чув. *кăртмыш* > тат. диал. *киртмыш* (ТТДС I: 263); чаг. ш. ук *кыркымыш* «кырыкмыш; мактанчык, куптарай» (ТТДС I: 219). Бу сүз бер яше тулган колыннарның койрык һәм ялларын кырку гадәтеннән килә. Федотов I: 260 (тат.-башк. параллельләрен белми).

**КЫРЫМ** «Крым» – бор. төрки *қырым* «сугару каналы, урай (окоп һәм вал)» сүзеннән килә: Кырым ярымутравының кыйтга белән тоташкан муентыгына бор. заманнарда ук тирән урай казыганнар (русча ул урай *перекоп* дип атала). К. Фасмер II: 389; Будагов II: 51; Радлов II: 745.

**Кырым** сүзенең бу этимологиясе төрле бәхәсләргә дучар булган, ләкин мәзкүр иске этимология безнеңчә дә дөрес, к. тат. диал. **қырым** «түтәл арасы» (без теркәдек. – *Р.Ә.*), удм. *уркырем* «озын ерынты» < *ур-кырым* (синоним парлы сүз), бор. чыгт. (Боровков 1963: 209) *қырым* «ур». К. **Кырымзау.**

**КЫРЫМЗАУ,** диал. **кырым чирүе** «прусак, солдатик; красный таракан; множество» (ТТДС I: 264, 481) < *кырым явы:* камканы дошман гаскәре белән чагыштырудан, к. ш. ук тат. диал. **пайлак** < *поляк (гаскәре),* **саксун** < *саксон (гаскәре)* «камка», рус. *прусак* «Пруссия кешесе» id.; *Кырымзау* < *Кырымҗау* сүзе XV г. азагы – XVI г. башларында Кырым ханлыгы гаскәрләренең (алар

кызыл җиләнле булганнар) Казанга килеп йөрүеннән; кырымлыларның Казан дәүләтенә тыкшынулары ахыр чиктә яхшы нәтиҗә бирмәгән. Аларны тараканга охшатуда, бәлки, шул хакыйкать тә чагыладыр.

**КЫРЫН** «косо, боком; упрямый» (**кырын карау** «смотреть косо, неодобрительно») – *кыр* сүзенең инструменталь килеше; кайбер үзгә кыпчак телләрендә дә (нуг., каз., к.-калп.) очрый.

Дерив.: **кырынлык; кырынай-у, кырынлан-у, кырынлаш-у;** диал. **кырынтын** (к. БТДҺ: 215).

**КЫРЫС** «суровый; строгий; крутой; необщительный», диал. (ДС I: 108) «дикий», себ. (Тумашева 1992: 142) «неудачный; недостаточный; скудный» > чув. *кăрăс* id., *кăрсака* «кызып китүчән» < гом. кыпч., к. башк. *ҡырыҫ, ҡырҫ,* нуг. *кырыс* «кырыс, усал», ком. *къырс* «бәйләнчек», к.-балк. *къырс* «комсыз» һ.б., шул нигездән добр. тат. (Akb: 19) *kırsla-* «урлау, талау», башк. (БТДҺ: 214–215) *ҡырҫай-ыу* «күз кырые белән усал карау» һ.б. К. **Кырсыз.**

Бу **қырыс ~ қырс** сүзенең чыгышы ачык түгел; **қыр-у** сүзеннән чыгару (Федотов II: 258) бик тә шикле. **Хирыс** (к.) сүзе белән чагыштыру тур. да шуны әйтергә кирәк. К. **Кыргыз.**

Дерив.: **кырыслык; кырыслан-у.**

**КЫРЫЧ: кым-кырыч**, диал. (ТТДС I: 202–204) **кŏм-кŏрыч < кŏрŏм-кырыч** «совершенно разбитый, разгромленный; беспорядочный; смутный». Ачык түгел. Ихтимал, **корым-корыч** парлы сүздер (ягъни **корым** һәм **корыч** – синонимнардыр, чаг. як. *курум* ~ монг. *хурим* «туй; туй ыгызыгысы»).

**КЫСА,** диал. **қысса** «рамка; футляр; верхняя часть платья; кофта; сруб», иск. тат. (Будагов I: 57) «рама, рассадник, парник, грядка» ~ башк. (БҺҺ II: 158) *ҡыҫа* «талкы». К. Насыйри буенча, *қыwса* < *қыбса* < *кыпса* (ЛТ II: 44), к. себ. **қып,** алт. *кып, коп* «катлам, кештәк, тукыма кисәге; тышлык» (Тумашева 1992: 140). Түбәндә *кып* «тышлык» түгел, аның киресе «эчлек» – ягъни җылылык өчен ике тукыма арасына куела торган кештәк (тукыма, мамык, тире) булган, шуннан күлмәкнең эчлек белән җылытылган өлеше, шулай ук туракның ике кыса арасына сыек балчык коеп ясалган дивары (шуннан «бура» мәгънәсе) һ.б. килә.

**Кыса** < *кыбса* икәнлеге Троянский сүзлегендә үк белдерелә. *Кыбса* > *кыса* күчеше (халык аңлавынча) *кыс-у* сүзе тәэсирендә килеп чыккан.

**КЫСАН** «узкий» – төр. *kısan* «кыса торган», ләкин тат. сүзе бу сүздән түгелдер, к. каз. *қысаң* «кысан».

**КЫСКА**, диал. **қысқақ** «короткий, краткий» ~ чув. *кĕске* < гом. кыпч. *қысқа* (куман., ком. *қысға*), уйг., үзб. *қисқа*, хак. *хысха*, төркм. *ғысға*, бор. төрки *qïsqa, qïsqan, qïsγa* (Поппе 1935: 425; ДТС: 447) һ.б. – логик җәһәттән иң бор. форма тат. **қысқақ** < **қысғағ* (*-қақ* аффиксы). **Кыс-у** фигыленнән, әлбәттә (к. Егоров 1964: 109). Чаг. ш. ук төр. *kısa* «кыска».

**КЫСКЫЧ**, диал. **кыскыц, кыскац, кыскач** (Тумашева 1992: 142) «шипцы; клешни» > мар. *кыскыс',* чув. *хескĕç* ~ кар., ком. *қысқыч,* нуг. *қысқыш* «күмер кыскычы», кырг. (тат. диал.) *қысқыч* «кысла»; төрки телләрнең күпчелегендә *қысқач* (> удм. *кискач*), к.-балк. *қысғач*, алт., каз. *қысқаш,* аз. *ғысғач*, гаг., төр. *kısaç, kıskaç* «кыскач»; кайбер телләрдә *кыскыч* һәм *кыскач* ике аерым сүз (мәс., ком. *қысғач* «эскәнҗә, кыстыргыч», *қысқыч* «кысла кыскычы»); иске тат. **қысқач** «кысла» һ.б., әлбәттә, **кыс-у** фигыленнән.

**КЫСЛА** «рак», диал. «щипцы» (БТДҺ II: 215, гәй.) > мар. диал. *кысла* id., башк. диал. *кысна* (БҺҺ II: 158), башк. *ҡыҫала* id. **Кыс-у** фигыленнән, ясалышы ачык түгел. Чаг. югарыдагыны.

**КЫСЛАҢКЫ** (ТТДС I: 221; ТТДС II: 151) «залежная земля»; «неягнившаяся ярка» ~ башк. (БТДҺ: 216) *ҡыслаңҡы, ҡыҫлан, ҡыҫлам* «калдау, яткын җир» < тат. **кысраңкы** id. ← *кысра-у, кысыра-у* «кысыр калу». К. **Кысыр, Кысрак.**

**КЫСМЫР** «скупой», «чрезмерно бережливый» ~ бор. кыпч. *кысмар* «комсыз», **кыс-у** фигыленнән булса кирәк; чаг. себ. *кысмыр* < *кызмыр* «кызып китүчән» (Тумашева 1992: 142).

**КЫСРАК, кысырак** «неожеребившаяся *или* бесплодная кобыла» ~ чув. *хисре* «бия», гом. көнб. төрки *қысрак,* аз. *ғысраг* id., каз., гаг. *қысырақ* «кысрак; колынсыз», *қысыра-у* «кысыр калу»; **кысыр** сүзеннән, әлбәттә. Щербак 1961: 90; Räsänen 1969: 268; Федотов I: 285 (тат. сүзен искә алмый).

**КЫСРЫК** «узкий, тесный» (Г. Толымбай һ.б.) < *қысыр-ық* id., к. иске тат. **қысыр-у** «кысык итү» (к. Радлов II: 806). К. ш. ук бор. төрки (ДТС: 448) *qïsur-* «кыскарту» һ.б. Бу фигыль исә *қыс-ғыр-* формасыннан булса кирәк.

**Кысрык** сүзенең үзеннән бигрәк **кысрыкла-у** дериваты киңрәк кулланыла. К. **Кыста-у, Кыс-у.**

**КЫСТА-У** «торопить; настаивать; принуждать уговорами» ~ чув. *хисте-* ~ мар. *иста-* < гом. көнб. төрки, алт. *қыста-* id., ш. ук «басым ясау, мәҗбүр итү» – төп мәгъ. «итәкне (һ.б.) кыстыру» алт. сөйләшләрендә; ком. *қысла-* «кыстау» икенчел булса кирәк; *кыста-* < *кысыт-а-* бор. **қысыт* «кысу хәле» – к. төр. *kısıt* «мөстәкыйльлектән мәхрүм итү, каты кул астына алу» – сүзеннән ясалган фигыль, чаг. ш. ук тат. һ.б. **кыстала-у** < **қысытла-у* «ашыктыру», **кысталан-у, кыстал-у** «ашыгырга мәҗбүр булу», **кысталан, кысталаң** «ашыгыч» (Тумашева 1992: 142). Гомумән **кыста-у** фигыленең дериватлары ишле: госм. *қыстақ* «көчлек, авырлык», ком. *қыставыл* «махсус кыстаучы, лобби» һ.б. К. **Кыс-у.** Федотов II: 351.

**КЫСТЫБЫЙ** «род пирогов» < диал. (Хайрутдинова 1993: 56–57) **кыстымбый, кыстымбай, кыстырымбай** > чув. *кăстăмпи,* мар. *кыстывий,* удм. *кыстыбей* id. **Кыс-у** сүзеннән, ясалышы аңлашылмый. Ихтимал, **бый ~ бай** морфемасы **бай** «өлеш» сүзеннәндер.

**КЫС-У** «жать, давить, сжимать; принуждать; ограничивать; угнетать» > мар. *кыс-*, ш. ук *иш-* ~ чув. *хĕс-* < гом. төрки *қыс-,* бор. төрки (ДТС: 447) *qïs-* id. бик продуктив төрки тамырларның берсе, к. **Кысан, Кыска, Кыскыч, Кысла, Кысмыр, Кысрын, Кыста-у, Кыстыбый, Кысык, Кысынкы.** Будагов II: 56, 57; ЭСТЯ VI: 246–248; Федотов II: 347–348.

**КЫСЫК** «тесный, узкий» ~ чув. *хĕсĕк* < гом. кыпч. *қысық* < бор. төрки (ДТС: 447) *qïsïγ* id. *қыс-у* фигыленнән.

**КЫСЫНКЫ** «трудный, неудобный» – **кыс-у** фигыленнән гомумән регуляр ясалма.

**КЫСЫР** «бесплодный; яловый» ~ чув. *хĕсĕр* < болг. **һисĕр* > мар., удм. *исыр* id. < гом. көнб. төрки *қысыр*, уйг., үзб. *қисир*, аз. *ғысыр*, тув. *кызыр*, як. *қытарах, қызырақ, қысрақ* «кысыр; үләнсез-үсемлексез (җир)» (Пекарский: 1443) < бор. болг. **йыксыр* < **йӧксыр* «нәселсез, токымсыз» сүзеннән безнең эра башларында ук бүтән төрки телләргә таралган булса кирәк, к. мар. *йыхсыр* (*йых-сыр* «йыксыз») «нәселсез», *йых* «ыру, токым» < чув. *йăх*, тат. диал. **йық, җық,** башк. *йĕк, йық* «ыру, зат». Чаг. калм. *хусрң* < *хусуруң* ~ халха монг. *хусран* «кысыр», бор. монг. (Поппе 1938: 312) *qusran* «кысыр», монг. *хусра-* «кысыр калу» < бор. төрки **қусур-а*. К. Номинханов 1975: 244–245. **Кысыр** сүзен бор. монг. *keguser* (> хәз. монг. *хүүсэр*) «баласыз» сүзеннән дип раслау (Егоров 1964: 300) ышандырмый, ләкин без тәкъдим иткән *кысыр ~ хусран* тәңгәлләштерүендә дә проблемалар юк түгел. Чаг. **Йок.**

**Кысыр** сүзеннән *кысра-* «кысыр калу» фигыле, шуннан **кысрак** (к.) һәм тат. **кысланкы < кысранкы** «бер елга кысыр калган (кала торган); ял итсен дип калдырылган (җир)» сүзе ясалган. ЭСТЯ VI: 249–252. Рус. *хусуранка* «кысыр көе саудыручан» тур. Аникин: 629.

**КЫТАЙ** «Китай; китаец; китайский» ~ башк. *қытай* id. ш. ук «янтарь, ожерелье» (БҺҺ II: 159), чув. *кăтай* «тасма өчен ак ефәк тукыма» һ.б. гом. төрки *қытай, хытай, хитай* < бор. төрки (ДТС: 449) *qïtaj, xïtaj* id. сүзеннән, бу сүз исә бор. төрки *qïtaŋ* «кидань (халкы) – берара Төньяк Кытайда хакимлек иткән маньчжур кабиләсе» сүзеннән. **Кытай** сүзенә **катай** – башк. кабиләләренең берсенең атамасы килә, бу вариант бор. монг. *qataj, qıtañ* (> хант. *xatañ*, манси *qatañ* «татар») вариантына тоташа, к. ш. ук госм. *хатай* «ефәк» (к. Räsänen 1969: 268). К. **Кытат.** Рус. *Китай* «Кытай» тур. Аникин: 292–293 (шунда ук *китайка* «кытай ефәге» тур.).

**КЫТАТ** «китайка; тёмно-зелёный шёлк» (Троянский II: 105; ДС II: 12) > удм., мар. *кытат* «гади тупас тавар тукыма» (Насибуллин: 125; Исанбаев 1978: 33), чув. *кăтат* «клеёнка» (Ашмарин VII: 194, 196) < алт., тув. *кыдат* «Кытай, кытай; кәрт уены, валет», кырг. *қытат* «тушь, кара буяу» – бор. төрки, бор. монг. *кыдань* «Кытай; кидань» сүзенең күп. формасыннан; гади ефәк, тушь һәм кәрт уены – барысы да Кытайдан килгән. К. ш. ук Räsänen 1969: 268; Федотов I: 263.

**КЫТКЫЛДА-У, кыткытлау, кытакла-у** «кудахтать» – әлбәттә, тәкълиди тамырдан (*кыт-кыт* тавыклар авазына тәкълит). Чаг. **Коргылда-у.**

**КЫТЛЫК** «дефицит, нехватка» ~ себ. **қә’этцелек,** диал. **кыйхытлык** (Н. Думави) ~ чув. *кахăтлăх, хытлăх, хăтлăх* «ачлык, кризис» (Ашмарин VI: 177) < бор. чыгт. *qahtlıq* «ачлыкка дучар» (Поппе 1938: 276), төр. *kıt, kıtlık* «кытлык» һ.б. бор. чыгт. *qaht* < гар. *қахṭ* «корылык» сүзеннән. Шуннан ук гом. кыпч., гаг. (ҚТДС: 225), үзб. диал. (ЎХШЛ: 162) *қыт* «саран, ач; җитешсез», кырг. *қаат* «корылык». К. **Хыйтлан-у.**

**КЫТРА,** иск. **кыйтра**, **кытралаб**, диал. (Тумашева 1961: 154) **кŏтŏра** «рядом» – гом. көнб. төрки, иске тат. **қыйтар** < гар. *қиṭāр* «рәт, сафка тезелү, җәргә» сүзеннән (гар. *қиṭран* «рәттән»). К. ш. ук **Катар.**

**КЫТЫК, кетек, қыцык** (Тумашева 1992: 143) «щекотка; щекотливость» ~ чув. *кăтăк, кăчăк* < гом. кыпч. *қытық,* нуг. *қутық,* аз. *ғыдығ,* төркм. *ғыҗық* id. бор. **қыт-* фигыленнән, **кычы-у** белән тамырдаш булса кирәк. Федотов I: 263.

Дерив.: **кытыклы, кытыксыз; кытыкла-у, кытыклан-у.**

**КЫТЫР** «щербинка, неровность на поверхности, морщина» (Будагов II: 58) ~ каз. һ.б. *қытыр* «тигезсез өслеккә ышкылу тавышы» (*кытырт итү, кытырдау* һ.б.) – тәкълиди сүз; шуннан ук **кытыршы** «шероховатый» < **кытырчық,* чаг. чув. *кăтрашка* «кытыршы», як. *хытыр-* «кытыршы булу».

Дерив.: **кытырлы, кытырсыз; кытырлан-у.**

**КЫЧ** диал. «зад; пышный зад женщины», «задняя часть, корма, задок» ~ чув. *хыç,* төр., аз. *қыч, ғыч* id., к. бор. төрки *qïčïn* «арттан» (ДТС: 440); ЭСТЯ VI: 252–253.

**КЫЧКЫЛ** (ЗДС: 450) «кислый, горький» ~ гом. кыпч. *қычқыл,* каз. *қышқыл* id., ш. ук терминологиядә «кислота» мәгъ. кулланыла. К. **Кычы.**

**КЫЧКЫР-У,** диал. **кыцкыр-,** себ. **қыцқыр-** «кричать» ~ башк. *қысқыр-* id. > мар., удм. *кычкыр-*, мар. т.-кб. (Иванов, Тужаров: 109) *кĕцкĕр-* < гом. кыпч. *қычқыр-*, нуг., каз., к.-калп., уйг., тув. *қышқыр-* > чув. *кăшкăр-* id., ш. ук «чакыру», аз. *ғычғыр-* id. бор. **қычқы > хысхы* «кычкырык» сүзеннән, к. ш. ук тат. диал. **кыцы-у** «шелтәләү»; бу мәгънәдә төрки телләрдә охшаш сүзләр күп: тат. диал. (ТТДС I: 222), алт., ком., к.-балк. *қычыр-* «кычкыру, чакыру», көчле һ.б. авазларны белдерә торган фигыль ясагыч *-кыр//-кер* аффиксы ярдәмендә *қый, қыйчык* кебек нигезләрдән ясалган, чаг. **Кыйгыр-у** (к.). Будагов II: 40; Федотов I: 261.

Дерив.: **кычкырт-у, кычкырыш-у; кычкырын-у; кычкырык, кычкырыш,** диал. **қычқыртқыч,** (ЗДС: 371) **қычқырчық** һ.б.

**Кычкыр-у** *-кыр* < *-кы+р-* аффиксына беткән фигыльләр рәтендә тора, к. *ажгыр-у, ыжгыр-у, акыр-у, бакыр-у, җикер-ү, йөткер-ү, какыр-у, кикер-ү, өскер-ү, өфер-ү (өфкер-ү), пошкыр-у, сеңгер-ү, сызгыр-у, төкер-ү, үкер-ү, уфыр-у (уфкыр-у), чажгыр-у, чакыр-у, чөңгер-ү* һ.б.

**КЫЧУ** «зуд, чесотка» – **кычы-у** фигыленнән исемләшкән.

**КЫЧЫ**, диал. (ЗДС: 420, 450–451) **қочо, кыцы,** (Тумашева 1992: 144) **қыча** «глиста» ~ чув. *кучă*, мар. *кучы* ~ төр. *kısı*, тув. *кыжа* id., к бор. төрки *qïčï* «горчица» (МК, ДТС: 440), *qïčïla-* «кытыклау». **Кытык** һәм **кычы-у** сүзләре белән тамырдаш.

**КЫЧЫ-У**, диал. **кече-ү, кеце-ү** «чесаться» > чув. *кĕçĕ-* < гом. кыпч. *қычы-*, уйг., үзб. *қичи-*, нуг., каз. *қышы-* ~ угыз. *гиҗе-, гиҗи-* һ.б. id., бу фигыльнең йөкл. юн. *кычыт-у (кечет-ү)* активрак. ЭСТЯ VI: 186–187. Безнеңчә, **кычы-у** < бор. *қытчы-* id. *қыт-* «тынычсызлау» тамырыннан. К. **Кытык.** Будагов II: 40; ЭСТЯ III: 41–43; ЭСТЯ VI: 186–187.

**КЫЧЫТКАН,** диал. **кычырткан, кечерткән, кечеркән** «крапива» < гом. кыпч. *қычытқан* (ком. *ғычытган*, нуг. *қышытқан*), башк. *кесерткән,* кар. *кичиткән, кециткянь* id. (палаталь вариант күптәннән килә! – диал. *кечер-ү, кечерт-ү* «ачы кычыттыру» < **қычыр-у* сүзеннән, **кычы-у** белән тамырдаш. Чаг. алт. диал. *кычкыл,* каз. *қышқыл* «кислота». *Кычырткан* нигезе я *кычырткын, кычырткыл*, я (монг. *-кал* кушымчасы белән) *кычырткал,* я монг. **кычырткана* (*-кана* үсемлек атамалары ясагыч) формасыннан килә.

**КЫШ** «зима» ~ чув. *хĕл* < болг. **хыл* ~ гом. төрки *қыш* (нуг., каз., к.-калп. *қыс*) id. Продуктив сүзьясагыч нигез, шуннан **кышлау** «кышлый торган, кышлаган (гөл, терлек); кышын да туңмый

торган (чишмә), кышлак», **кышлак** «кышлау урыны» һәм күп кенә регуляр ясалмалар (**кышла-** «кыш үткәрү», **кышлык** «кышка җитәрлек яисә кышка тәгаенләнгән») һ.б.

*Кыш* ~ **кыл* сүзенең тамыр бағланышлары юраулы. ЭСТЯ VI: 253; Федотов II: 341–342.

Дерив.: **кышлык; кышлыклы** «суыкка чыдам».

**КЫЮ I** «смелый» к. **Кый-у II.**

**КЫЮ II** диал. (ТТДС I: 215) «отделка по подолу, руковам и т.п.» ~ чув. *хăю*, кырг. *қыю*, үзб. диал. (ЎХШЛ: 160) *қыйав, қыйаw*, каз., к.-калп. (ҚТДС: 226) id. *кыйу* белән бердәй булса кирәк. Чаг. ш. ук хак. *хын-* < *кың-* «теләү; кыйу».

**КЫЯ [қы̆йа],** диал. **қайа** «скала» < гом. төрки *қайа*, башк. *қайа,* хак., тув. *хайа* ~ монг., маньч. *хада*, тунг. *қадар* id. (ССТМЯ I: 360). Рус. диал. *кадырь* «текә ярлау» < эвенк. *қодар* тур. Аникин: 232.

Дерив.: **кыялы; кыялык.**

**КЫЯК [қы̆йак]** «лист злаков; осока» > чув. *хăйах*, мар. *хыйак, кийак* (Саваткова: 182) < тат. диал. (Тумашева 1992: 137), башк. (БТДҺ: 209), алт., кырг. *қыйғақ* «кыяк, кисүчән-кыючан яфрак» > гом. кыпч. *қыйақ,* үзб. *қийоқ,* яз. монг. *kijaγ* һ.б. id. К. **Кый-у.** К. Räsänen 1969: 262; Федотов II: 339. Күп телләргә кергән. Doerfer III: 566; Аникин: 346.

Дерив.: **кыяклы** – ботаник термин.

**КЫЯКЛА-У [қы̆йақла-]** «уходить от общего дела, отказываться, увильнуть» – *кыяк* сүзеннән булса кирәк, к. **кыяк тешлә-ү** ~ рус. «лечь на дно» – «тавышсыз-тынсыз качып яту», тәүдә «камыш көпшәсе аша сулап, су астында яту», дип аңлатыла (Н. Исәнбәт): *кыяк* сүзенең «камыш» мәгъ. дә бар.

**КЫЯЛА-У [қы̆йала-]** «скользить по воздуху (о плоских предметах)» – *кыйа* «кыеклап» сүзеннән булса кирәк. Чаг. ш. ук алт., төр. *kay-* (*қай-*) «кыялау; таудан шуып төшү»; башк. *қыйалақ, қыйғалақ* «кыеклап», тат. диал. **кыялач, кыялаш** id. (БҺҺ II: 153; ТТДС I: 214). Себ. (Тумашева 1992: 117) **кадый-у** «кыялау» – контаминацион компонент, икенче бер тамырдан.

**КЫЯМ [қы̆йам]** «стояние; часть намаза, совершаемая стоя; восстание, бунт» < гар. *қийāм* id. *қwм* «басу, тору, күтәрелү» тамырыннан.

**КЫЯМӘТ [қы̆йамәт]** «светопреставление» < гар. *қийāмāт* id. «(кубарылып) торып басу», *қwм* «басып тору» тамырыннан, шуннан ук **Кавем, Кыйммәт. Кыямәт** сүзеннән туй терминнары *кыямәтлек* > чув. *хайаматлăх*, мар. *киамäтлĕк* «кыямәтче (өйләнешүчеләрне кыямәттә якларга алынучы)» сүзләре ясалган. Чаг. ш. ук удм. *киамат төрä, киамат саус* мәетне искә алу мәрасимендә кешеләр белән бергә ашый торган күзгә күренмәс затлар («кыямәт түрә», «кыямәт чавыш»). Федотов II: 320.

**КЫЯН [қы̆йан],** диал. (ЗДС: 408, 432) **қойан** «соль на суставах», **қуйаң** «радикулит; ревматизм» < чыгт. (Бабур телендә, к. Будагов III: 98) *қуйан* «кабырга тамыры; кабыргага тоз утырып, нык сулкылдау», кр.-тат. диал. *quyan* «невралгия», к.-калп., чыгт. һ.б. *qujaŋ* < монг. *xujaŋ* «төрле сөяк авырулары» > рус. диал. (Аникин: 341, 626) *куян, хуин* «төрле тән-сөяк авырулары». Арытабан ачык түгел.

**КЫЯҢКЫ [қы̆йаңқы̆],** (ЗДС: 437) **қыйанқы** «дикий, злой» ~ башк. *қыйалқы,* каз. *қияңқы* «тинтәк, тупас сүзле», нуг. *қыяңқы* «саран», уйг. *қианқу* «шалапай» ~ башк. *қыйан* «мәгънәсез; тозсыз (сүз)», каз. *қиан*, алт., тув. *қыян* «кыек, кыңгыр; кыланчык, акылсыз хәйләкәр». Монг. сүзе булса кирәк. Чаг. **Киянке** (ләкин бу сүз тамырда икенче булса кирәк).

**КЫЯР [қы̆йар]** «огурец» > чув. *хăйар*, удм., мар. (ДАУ I: 128) *кыяр, кияр, хыяр*, *куйар* һ.б., морд. М. *куйар* < гом. кыпч. *қыйар*, ком. *хыйар*, госм. *хийар* << гар. *ẖийāр* < фар. *ẖийāр* < һинд. *xūra* id. (Platts: 497); икенче версия буенча, гар. *ẖийāр* фарсычадан түгел (киресенчә), грек. *αγγουριον* «кечкенә кавын; яшел көенчә ашала торган» сүзеннән (шуннан ук рус. *огур* → *огурец*). Федотов II: 339.

**КЫЯРИ [қы̆йари]** диал. «чужак» к. **Кыер.**

**КЫЯУ [қы̆йаw]** «опалубка, стенки колодца, сделанные из прутьев» (к. ТТДС I: 260) < иске тат., башк. **қойаw, қуйаw* «тирене кирчегәгә тарттырып эшләнгән шайман» сүзеннән (бу сүз рус. *куявник* = *панцырник* «кыяу кигән сугышчы» сүзеннән мәгълүм, к. Материалы по истории Башкирии:

193–194, 197, 234) < бор. төрки *qujaγ* > тат. диал. (Тумашева 1992: 132), гом. кыпч. *қуйақ,* хак. *хуйах* (< монг. *қуйағ*), як., алт. диал. *куньях* «кыяу; койка» сүзеннән: хикмәт шунда: *кыяу* ясар өчен үгез һ.б. тиреләрен кызу температурада махсус эшкәрткәннәр – шунда алар я койкага, я пластмассага охшаш каты материалга әверелгән. К. ш. ук кырг., тат. **кыяк** (Идегәй 1978: 151) «кыяу», тув. *ала хуйақ* «шаман туны», чув. *хăяв* «беркемне дә танымау; ләгънәтләү хәле» һ.б. **Кыяу** тур әдәбият ишле, к. Räsänen 1969: 301, ЭСТЯ VI: 424, Аникин: 341 һ.б. К. **Койка.**

**КЫЯФӘТ [қы̆йафәт]** «внешний вид» < гар. *қийāфäт* id.

Дерив.: **кыяфәтле, кыяфәтсез; кыяфәтлән-ү.**

**КЯН** «рудник» < фар. *к'āн* id.; к. ш. ук **Кән.**

**КЯФЕР,** диал. **кафер, киафер** «поганый, неверный, иноверец» > удм. *тяфыр* «җен-шайтан» < гар. *кāфир* id. *кфр* «әшәкелек; явыз рух» тамырыннан, шуннан ук **көфер** «ямьсез гөнаһ» (*Бер-берең*ә *төкереш – көфер эш,* мәкаль).

**КЯР, кәр** «дело, деятельность; воздействие, действие лекарства» < фар. *к'āр* id. иске әд. телдә киң кулланылган һәм бик күп кушма сүзләр составына кергән, к. Будагов II: 108; Özön: 420.

**КЯСӘ** (**касә** дип тә язылa) «небольшая, но глубокая чаша, чашка» < фар. *к'āсә* id. Киң таралган халыкара сүз. Özön: 423; Kluge: 470 (бор. Ассирия *kasu* id. сүзеннән ди).

**КЯШКИ** «о если бы» < фар. *к'āшкū* id. Будагов I: 109.

# Л

**Л** авазы гомумән төрки телләрдә сүз башында килмәгән, хәз. төрки телләрдә ул гадәттә алынмаларда, күпсанлы тәкълиди сүзләрдә һәм шуларның дериватларында очрый. Ә тәкълиди сүзләр элекке әд. телләрдә аз кулланылган һәм сүзлекләргә дә сирәк кертелгән. Җанлы сөйләм телләрендә алар, ихтимал, хәз. кебек үк шактый күп булгандыр. **Л** авазына башланган сүзләрдә фин-угор алынмалары еш очравы да күзгә ташлана.

**ЛА, лә I** – частица с модальным значением, выражает лёгкое раздражение в связи с содержанием своего сообщения: *беләм лә ул* «знать-то знаю (но что толку)», *юк ла* «да нет же» ~ нуг. *ла//де* id., чыгт. (Радлов II: 725) *ла* «кызганыч ки», алт. (күп фонетик позицион вариантлары белән) *ла, на* «һәм, тагы; тик», тув., хак. *-ла* (сызыкча аша языла) «тик; бөтенләй, тач, нәкъ», уйг. *ла (лә)* «бары тик» һ.б.

Башк., алт., хак. *ла//лә* тат. *да//дә* («һәм») мәгъ. дә кулланыла; башк. *осто ла китте* «очты да китте» һ.б.ш., шул ук вакытта башк. *ла, лә* тат. **ла, лә** мәгъ. дә килә.

**ЛА, лә II –** асемантическая морфема, употребляющаяся для преодоления «зияния» – восполнения недостающего слога в песнях – **Ла I**дән килеп чыккан булса кирәк. К. ш. ук **Лай. Ла II** мәгъ. **да//дә, та//тә, гына//генә, кына//кенә** кисәкчәләре дә һәм, хәтта, берничәсе берьюлы да кулланыла ала, к. җырда: *Кара ла гына урман, караңгы төн…* һ.б.

**ЛАБАЗ** «лабаз» – гом. кыпч. *лабаз* id. Бу сүзне тәгаен рус теленнән дип әйтеп булмый. К. **Лапас.**

Дерив.: **лабазник** – элекке «саллы товарлар (агач, балык һ.б.) белән эш итүче сәүдәгәр», бусы инде, әлбәттә, русчадан. Гомумән «тупас кыланышлы һәм үз-үзенә ышанган, үзенчә тәкәббер кеше» мәгъ. кулланылган.

**ЛАБАСА, ләбаса** (диал. **ласа//ләса**) «ведь, же, ясно, конечно же» > чув. (Сергеев 1968: 37) *лапасса*, удм., мар. *лабаса, лаваса* id. ике аерым кисәкчәдән гыйбарәт: 1) **ла//лә** һәм 2) **баса//бәсә.** Икенче компонент мөстәкыйль рәвештә себ. сөйләшләрендә (ТТДС I: 70; Тумашева: 171) **паса//пәсә,** нуг., кырг., уйг., алт. *баса,* тув. *база,* хак. *паза* һ.б. «әйе, шулай, әлбәттә» мәгъ. кулланыла. Бу сүз дүрт төрлечә: *бас-у* фигыленең хәл формасы дип (Joki 1952: 84), бор. төрки *basa* «соңыннан, шуннан соң» сүзеннән (ә бу сүз фар. *баз* «тагы» сүзеннән, к. Малов I: 369) дип һәм гар. *la basa* «кызганычка каршы, бернишләп булмый» тәгъбиреннән дип (Räsänen 1969: 313), яки саф төрки *ла баксаң* дигәннән дип (Максуди: 42) аңлатыла. К. ш. ук Будагов II: 184, 185; ДТС: 85.

**ЛАБЫНДЫЗ** диал. (ЗДС: 451) «осенний дождь со снегом и льдом». Тау ягы сөйләшендә сакланган бу сүз иске *лай-мондыз* дигән парлы сүзнең кыскартылышы. К. **Лай I** һәм **Мондыз.**

**ЛАБЫР** – подражание глубокой грязи и громкому пустословию ~ чув. *лапăр*; к. ш. ук **лыбыр, лагыр, лыгыр** – охшаш мәгънәле сүзләр, алар Идел-Урал лингвистик регионында киң кулланылалар. К. ш. ук үзб. (ЎХШЛ: 117) *лабыр* «лыгырдык».

Дерив.: **лабыра > лабра** «бик сыек былчырак» ~ мар. *лабра* һ.б. id.; **лабырда-у** «лыгырдау»; Räsänen 1969: 313. К. **Лапыр-лопыр.**

**ЛАГУН [лагун]** «ведро, кадка для дёгтя; лагун» ~ чув. *лакăм* id. < рус. (к. Фасмер II: 446; Федотов I: 328), рус. < грек. К. **Лакан, Ләгән**. Бор. төрки *laγun* (МК, ДТС: 332) «агач тустаган» Бактрия грек теленнән.

**ЛАГЫ** диал. (себ., ЗДС: 452) «глубокий проток» к. **Лакан.**

**ЛАЕК [ла°йык]** «достойный; достойно» < гар. *лā'иķ* «ярашлы; уңышлы» *лйķ* «ярашлы булу» тамырыннан.

**Лайыķ** сүзе төрки телләрдә киң таралган һәм төрле мәгънәләр алган, к. чув. *лайăх* «яхшы, шәп; мөмкин; нибуч», мар. *лайыķ* «тыныч кына», төр. *lâik* «таман» һ.б., к. Будагов II: 187 (*лаиķ* сүзенең элекке тат. дериватлары китерелә). К. ш. ук **Лаякать.**

Дерив.: **лаеклы, лаексыз; лаеклык** һ.б.

**ЛАЕШ [лаºйы̆ш]: лаеш шулпасы** «нужда, мытарства» – Лаеш каласында элек лашманнарның җыелу пункты булган. **Лаеш** топонимының этимологиясе безгә төгәл мәгълүм түгел.

**ЛАЙ I,** диал. **ылай** «жидкая глина; слизь» < гом. көнб. төрки *лай, ылай* id. < фар. *лāй* > үзб., таҗ. *лой* «былчырак, буялган пычрак; буялган катлам; штукатура», *лойчи, лайчы* «штукатур».

К. ш. ук **Лайка, Лайла, Лайма, Ләм.** Будагов II: 187.

**Лай** сүзе онопоэтик характерда һәм шунлыктан шуңа охшаш сүзләр бөтен дөньяга хас, к. мар. диал. *лай* «каймак», индонез. *луй* «былчырак; косык».

**ЛАЙ II, ләй** – припев к песням; *лай-лай* id. («без җырлыйбыз» мәгъ.) – чаг. уйг. *лай-лай* – көлтә суктырганда җырлана торган җыр.

**ЛАЙКА** диал. «муть, тина» ~ үзб., таҗ. *лойқа* id. < фар. *лāйгāһ* «лайлы урын».

**ЛАЙЛА, лайлак** «слизь» тат. теленең үзендә *лай* сүзеннән ясалган (Троянский), чаг. **тозлак.**

**ЛАЙМА** «вымазанный жидкой глиной» – төрки телләрдә *лай* нигезеннән ясалган (к. сөйл. *лаймалай* «бөтенләй былчыранган»), к. чув. *лайма* «лай, лайла», *лаймака* «лайлалы» ( VIII: 100).

**ЛАК** «лак, лакированная поверхность» – рус теленнән булса кирәк (урта *к*), рус теленә – фар. яисә ним. теленнән, ним. теленә – ит. *lacca* < гар. *ләкк* сүзеннән; ахыр чиктә Һиндстан телләрендәне *läkhä* < бор. һинд. *läksä* «бер төр үсемлек сумаласы – кызыл төстә була» сүзеннән, *raj (раҗ)* «кызыл» тамырыннан (Kluge: 552).

Бу сүзнең турыдан-туры Һиндстан телләреннән кергән варианты иске тат. **ләкә** «махсус кызыл билге, тап» < фар. *лäкä* id.

Дерив.: **лаклы, лаксыз; лакла-у.**

**ЛАКАБЫЙ** (БТДҺ: 219), **лақаплы** (ТТДС I: 289, эчк.) «анекдотичный, забавный, остроcловный; остроумный (ответ)» ← диал. **лакап,** себ. (Тумашева 1992: 144) **лағап** «пословица, поговорка; сатирическая частушка» ~ каз. *лақап* «ялган хәбәр, гайбәт, усал сүз», ләкин кырг. *лақап, ылақап* «акыллы сүз, мәкаль һ.б.» – гар. *лäқаб* (к. **Ләкаб**) «кушамат; титул» сүзеннән киләләр (тик гар. теленең үзендә бу сүзнең үткерлек, усаллык мәгънәлеге юк): **лақабый** << гар. *лäқабū* «ләкабка баглы; ләкабсыман» – әдәби жанр төре.

**ЛАКАН** «лохань» > мар. *лакан*, удм. *лакан, локан* id. – гадәттә рус теленнән дип исәпләнелә, ләкин тат. әйтелешле *-қ-* бу версияне шик астына куя, к. фар., гар. *лäққāн* (!) id. Рус. *лохань* үзе төрки телләрдән булырга мөмкин (Фасмер II: 524).

Гар. сүзе арамей. *laqna*, ассир. *lahanni* «лакан» < шумер. *lahan gidda* «озынча савыт» сүзеннән дип карала. Ләкин күп кенә телләрдә очрый торган (интернациональ-мәдәни) *лак ~ лах* тамыры төптән үк «су савыты, сулык, сулы чокыр» сүзен белдерә, к. тат. (Тумашева 1992: 144) **лағы** «күлдән чыккан елга», төр. *lak* «ясалма күлчек», бор. слав. *локы* «лакан», ним. *Lache* «күлләвек», бор. инг. *laci* «чишмә, елгачык, буа», лат. *lacuna* «күл, буачык; чокыр» (шуннан рус. *лагуна* һәм *лакуна* «өзеклек, текстның югалуы» сүзләре дә килә), грек. *λαχχος* «сулы чокыр, бассейн» һ.б. ← һинд-евр. **laqua* «күлчек, күлләвек» тамырыннан исәпләнелә, к. Kluge: 552–554. К. ш. ук **Лагун, Ләгән;** чув. *лакăм, лакчак, лакчăк* ~ мар. *лакса, лаксак, лаке* ~ фин. *laakso* һ.б. «сулы чокыр», к. Федотов I: 328.

Ихтимал ки, һинд-евр. сүзе үзе шумер теленнән яисә борынгырак уртак чыганактан алынгандыр.

**ЛАКЫ** (тат. диал., БТДҺ: 219) «вьюн (рыба)» ~ каз. *лақа* «шамбы; җәен», үзб. *лаққа,* төркм. *лақға* id. К. гом. тунг.-маньч. *лақа* «этләй», *лаха* «җәен» ~ яз. монг. *laxa* id. чаг. **Лагы.** Шуңа охшаш рус диал. (Аникин: 359) *лоха* ~ фин. *lohi* «сөләйман балыгы» сүзе дә бар. Гомумән, балык атамалары *л-* авазына башланучан бугай.

**ЛАКЫЛДА-У, лакырда-у** «громко болтать; нести чепуху» – к. **Лыгыр, лагыр.** Гом. төрки планда *лакыл ~ лакыр* нигезе ешрак очрый, к. ком. *лакыр,* кр.-тат., төр. һ.б. *lakırdı* «лыкылдау, лыгырдау» (ләкин әд. телдә «әңгәмә» мәгъ. еш кына кулланыла), каз., к.-калп. *лақырла-у* «шаулау», кырг. – «кычкырып мактану», уйг. *лақилда-* «селкенү, дерелдәү (мәс., юлдагы арба тур.); лагырдау» һ.б. Чаг. иске тат. *лақлақа* «быгырдау; лыгырдау». **Ла-, лы-** иҗекләренә башланган нигезләр типологик рәвештә күп телләрдә лыгырдауны белдерә: тат., башк. *ла-ла, ла-ла-ла*, диал. *лаң-лаң* күп һәм мәгънәсез сөйләүгә тәкълит (рус, фр., ним. һ.б. телләрдә шул ук), ним. (Kluge: 554, 584) *lallen, lullen* «бытылдау (бәбиләр тур.), бишек

җыры җырлау», лат. *lallare* «мыгырдау» һ.б. Тат. телендә бу китапка кертелмәгән шактый шундый сүзләр очрый: **Лабыр-лабыр, лабырда-у, лаңгылда-у** һ.б.

Бу сүзләрнең деривациясе дә регуляр характерда: **лакылдаш-у, лакылдат-у; лакылдык** һ.б.

**ЛАЛӘ** кит. «тюльпан» < фар. *lālä* «якты, нурлы, алсу; тюльпан» < гар. *лä'л* «ләгыль, ал, кызыл; рубин» сүзеннән, к. **Ләгыль, Ләлә.** Будагов II: 186.

**ЛАМПЫ** «лампа» ~ башк. диал. (БТДҺ: 219) *ламбы*, төр. *lambı*, рус. *лампа* < ним., фр. *lampe* ← лат. *lampa-da* «яктыртылыш» (> рус. *лампада* «чиркәү шәме») ← грек. *lampas* «факел» (Kluge: 552). Тат. теленә *лампы* төрекчәдән дә килергә мөмкин: рус телендә бу сүз XVIII г. гына таралган, төр. телендә исә күптәннән билгеле.

**ЛАНЧАК** диал. «дитя, детёныш» < *оланчак* (ТТДС I: 289, 326) «олан» сүзеннән кебек, әмма *оланшак* яңгырашы < *олан-ушак* парлы сүзеннән: *олан* «яшь бала», *ушаķ* ~ төр., аз. *ушағ* «кечкенә бала» < *уғчаķ, угылчаķ* һ.б. бор. гом. төрки *оγ, oq* «токым, ыру» сүзеннән. Икенче яктан, к. **Ошак.**

Рус. *лончак* «тай» сүзе дә татарчадан булса кирәк (рус телчеләре бу версияне кире кагалар).

**ЛАП I, лапа́** (ТТДС I: 289; Тумашева 1992: 144) «плоский, пологий; ровная низина; низкий; уплющенный» ~ чув. *лап, лапă* ~ мар., удм. *лап, лаб*, морд. М. *лапш* ~ венг. *lapas*, фин. *lapea* «лап, яссы» һ.б. беренче карашка фин-угор алынмасы кебек; к. ш. ук мар. *лаптак, лапчак, лапчака* һ.б. (бик күп вариантлар), ләкин к. уйг., к.-балк. *лапча*, як. *лапчыķа* «тәбәнәк-түбән», эвенк. (ССТМЯ I: 493) *лапака* «түбәнлек, уйсулык» һ.б. – гом. урал-алтай тамырларының берсе булса кирәк.

Гомумән, бу сүзләр онопоэтик *лапп* тамырыннан килә, чаг. **Лап II.** КЭСК: 157; Федотов I: 329–330 (материалы бай).

Дерив.: **лаплык,** диал. **лапалык**; **лап** тамырыннан тагын бик күп яңа тамырлар ясалган: **Лапай-у, Лапак, Лапакай, Лапы, Ләпәй-ү, Ләпәш, Ләпкә, Ләпшек** һ.б.ш.

**ЛАП II** – «имитатив удару сравнительно мягким предметом по твёрдой плоской поверхности: шлёп, шмяк, хлоп; топ» ~ чув., мар. *лап, лоп*, кырг., уйг., як. *лап* id., нуг., каз., к.-калп. телләрендә **лап** ялкын талпынышын белдерә. Чаг. **Лып.**

Дерив.: **лап-лап; лап-лып;** к. **Лапылда-у, Лап-лоп.**

**ЛАПА** (ТТДС I: 290), **лапак** (БТДҺ: 220) «(снег) хлопьями»; чаг. **Лапы.**

Дерив.: **лапа-лапа** «ябалак-ябалак (кар тур.)».

**ЛАПАЙ-У** «усесться широким задом; быть невысоким и иметь широкое основание (о стогах)» диал. (к. ТТДС I: 289) «уплощаться, деформироваться (о ведре)» ← тат. диал., чув. **лапа́** «тәбәнәк һәм киң» тәкълиди сүзеннән; гаҗәеп рәвештә бик киң таралган фигыль: мар. *лапай-* «лап итеп (былчыракка) төшү», удм. *лапег* «тәбәнәк, лапа», *лапега-* «лапаю», як. (Пекарский: 1467) *лаппай-* «юан һәм кыска булу» һ.б. Мар., чув. *лапай-*, *лаппай-* «җыйнаксыз, шапшак булу», мар. *лапай* «шапшак». К. **Лап I.**

**ЛАПАК** диал. «невысокая гора с плоским верхом; небольшое (обозримое) плато» ~ башк. (БТДҺ: 220) *лапаķ* id., к. **Лапакай.** Чаг. тат. диал., удм. (ТТДС II: 211) *лапа́* «сөзәк». К. **Лап I.**

**ЛАПАКАЙ** «невысокий, но толстый, приземистый» < **лапак-кай:** тат., башк. **лапак, ләпәк**, удм. *лапак, лапег* «тәбәнәк-киңчә», мар. *лапата* «түбән җир», *лапка* «тәбәнәк» һ.б. **Лапакай** сүзе еш кына юантык кызларга карата кулланыла – **кай** иркәләү кушымчасы шуның белән аңлатыла. Гомумән бу сүзнең паронимнары бик күп, мәс., башк. (БТДҺ: 220, 224–225) *лапалдаш, лапанташ, лапаш, ләпәшә, ләпәш, ләпәшкә, ләпәк, ләпәкәй, ләпәндәш* һ.б., тат., мар., чув. сөйләшләрендә дә шул ук хәл. К. **Лап I.**

**ЛАПАС** «хозяйственное сооружение с плоской крышей; часть хлева, амбара и т.п. с плоской крышей (на крышу обычно кладутся сено, солома, всякая древесина невысокого качества)» ~ мар. *лепас,* (Сепеев: 82) *леваш* id. ← *левет-* «ябу» id., бор. мар. **лап-* «башаклар белән ябу» сүзеннән булса кирәк; к. ш. ук удм. *лапас, лабас* «лапас»; рус. *лабаз, лобаз, ла́вас, лобо́з, лапас* < коми. *лобос* «шалаш, балаган» диелә (Фасмер II: 442–445), яки конкрет әйтелми, перм. телләрендәге материал белән чагыштырыла гына (Матвеев А.К. Заимствования из пермских языков в русских говорах Северного и Среднего Урала // Acta Linguistica (Budapest), t. XIV, 1964: 298). Чув. *лапас* < *лопас* тат. теленнән

алынмага охшаган (*а* > *о* > *у*). Безнеңчә, төп чыганак – бор. мари теле, чөнки бу телдә генә *леп-* < *лап-* морфемасы фигыль мәгъ. дә ия.

**Лапас** сүзе, ераклашып, башк. диал. (БТДҺ: 222, 225) *лапаҫ, лапыш, ләпәш, ләпәшкә* «тәбәнәк (өй һ.б.ш. тур.)» сүзенә тамырдаш. К. каз., кырг. *лапас* «лапас» < тат. булса кирәк.

*Лапас* сүзенең этимологиясендә иң чатаклы төш – рус һәм удм. *лабаз* вариантындагы *-з* авазы: удм. сүзе русчаданмы, әллә рус сүзе удмурт теленнәнме? Урал-Себер фин-угор телләреннән тик удмуртчада гына *-з-* авазы актив кулланылуын искә алсак, бу сүзнең рус теленә перм. телләреннән керүе ышандырырлык, ләкин рус телендә дә *-с* > *-з* күренеше күзәтелә.

А.Е. Аникин *лаба́з* сүзе тур. күпсүзле матдәсендә бу нигез ниндидер бор. бер фин-угор теленнән дигән фикерне куәтли (Аникин: 346–347). Ләкин ул тат.-башк. һәм чув. материалы белән бөтенләй санашмый (бер генә сүзне дә күрсәтми). Хәлбуки тат., башк. *лапас* рус теленнән алынмаган (диалекталь *лабаз* «яссы түбәле озын амбар»ны исәпкә алмаганда), әлбәттә. Аннары **лапас** сүзенең бор. тат. телендә ясалу ихтималы да юк түгел, к. диал. (миш.) *лапаш, ләпәш* «лапас», морд. М. *лапаз* «ябу, күш» < тат. (ирекле тезмә) *лап асты* < *лапы асты (!)* > чув. *лап аслăк* «баганалар өстенә куелган сайгау, түшәмә» (к. Ашмаринnfnfһ VIII: 22–23). Миш.-себ. сөйләшләрендә *лап асты* > *лапаң* > *лапаз* (*-ц* > *-з*) мөмкин булган хәл. Һәрхәлдә **лапас** сүзе *лап* тамыры белән бәйләнгән. К. түбәндәгене.

**ЛАПШАЙ-У** «оседать (о стогах, о строениях)», **ләпшәй-ү** «уплощаться (о мелких предметах)» ← диал. *лапыш* ~ чув. *лапаш, лапашка, лапша*, удм. *лапшо, лапышлак* «тәбәнәк, түбән, лап» (*-ш* морфемасы белән киңәйтелгән **лап**) нигезеннән. Идел-Урал телләрендә бу нигездән тагын бик күп сүзләр ясалган (биредә барысын да китерергә мөмкин түгел).

**ЛАПШЫК**, диал. **ласпык, ласбык** (ТТДС I: 290) «растрёпанный» ~ чув. *лапска, лапсака* «учарлы, киң ябалдашлы (һәм ботаклары түбәнгә асылынган)», мар. *лапцака* «ямьшек», чув. *лапсăр-* ~ төркм. *лапшырда-у,* чув. *лапсăркка* «лапакай» һ.б. К. **Лапай-у, Лапшай-у.**

**ЛАПЫ́** «низшие ветки деревьев; хворост; сучья деревьев, которые слагаются в кучу во время лесоразработок» – рус. диал. *ла́пы* id.; *ла́па* «тәпи» сүзеннән дип уйларга мөмкин, ләкин к. мар. *лабы,* башк. (к. БТДҺ: 220) *лапы* «чүп-чар, калдык; бәс, лапа кар; аяк баскысыз куе үсентеле куаклык, сазлык; лапы», удм. *лабырес* «лапылы, киң ябалдашлы», як. *лабаа* «ботак, лапы» ~ эвенк. *лава* «күп ботаклы, учарлы», *лапара, лапку, латара* «ботаклар», хәтта Ибне Мүһәнна сүзлегендә дә *labä* «яфрак(лар)».

**ЛАПЫР-ЛОПЫР, лапыр-лыпыр** «имитатив хлюпанию» ~ төркм. *лапыр-лапыр* id.; к. ш. ук **лапра, лабра** ~ чув., мар. *лапра, лавыра, любыра*, чув. *лапăркка, лапăрка* (күп вариантлар) «ерып чыккысыз былчырак» һ.б. Чаг. **Лап II.**

**ЛАФ** «похвальба, самовосхваление» < фар. *lāф* (үзб., таҗ. *лоф*) << бор. фар. *laf* id. (Platts III: 945); *лаф ор-у* тәгъбире борынгыдан килә: бор. монг. *lāf deletbe* ~ чыгт. *laf urdï* id. (Поппе 1938: 232).

**ЛАФКЫ, лафка** (Будагов II: 186), **лаука** (ТТДС I: 291) «лавка, магазинчик» < рус. *лавка* ← *лава* «эскәмья, ләүкә». К. **Ләүкә.**

**ЛАЧ, лачт** – имитатив удару жидким предметом в твёрдое (о смачном плевке на пол, о падении в жидкую грязь) ~ чув. *лач* id. к. ш. ук **Ләч, Ләчт.** Чаг. **Лаштырда-у.**

Дерив.: **лач-лач; лачкыл-лачкыл; лачкылда-у; лачтыр-лачтыр, лачтырда-у** һ.б. К. **Лач-лоч, Лачма.** Бу сүзләр башк. *лас-* (*лас-лас, ласкылда-у* һ.б.) нигезендә дә очрый һәм бу хәл аларның тат. теленнән икәнлеген күрсәтә (чөнки мондый имитативларга *-ч* авазы хас, *-с* түгел).

**ЛАЧИНКА, лачинкә, лачинкы, лачиңка** (ЗДС: 455) «носилка, носилки» ~ башк. (БТДҺ: 221) **ласинка, лащинка** ~ мар. *лачинка,* чув. (Сергеев 1978: 39) *лочинкка* id. һ.б. < рус., әлбәттә. Бу сүз XX г. 20–30 нчы елларында Идел-Урал регионы халыклары вәкилләре күпләп җир-торф эшләренә җәлеп ителгәч таралыш алган.

**ЛАЧКА** «непропечённый (о хлебе)» ~ чув., мар. *лачка* «артык төче», к. **Ләч.** Чаг. **Тачка.**

**ЛАЧ-ЛОЧ** – имитатив шлёпанию (шагов по грязи, жиже), а также чавканию; «хлюп-хлюп». **Лач** имитативы нигезендә ясалган.

**ЛАЧМА** «совершенно (мокрый)» – **лач** имитативы нигезендә ясалган сыйфат.

**ЛАЧТЫК** (ТТДС I: 291) «сатин» < рус. *ластик* «эчлек тукыма (еш кына йонлач, өрпәк яисә ике катлы була)» ← иске рус. *ласт* id., к. **Ләчтит.** Башк. (БТДҺ: 221) *лаҫтай-ыу* «җәелү; өрпәю» ← тат. **лачты* сүзеннән булса кирәк, к. кырг. *ылас* «лачтык». Рус. *лачтик* ~ *эластик* фр. *elastique* < лат. *elasticus* «тартылучан, тартучан» ← грек. *elaunein* «тарту, куу, этәрү». *Ласт* формасы ним. *elaste* «лачтык» вариантыннан.

**ЛАЧЫН** «сокол» (**лачыным** «соколик мой») ~ башк. *ыласын*, чув. *лаччӑн, лачӑм* > мар. *лачым*, гом. төрки *лачын*, уйг., чыгт. *лачин*, үзб. *лочин*, нуг., каз., к.-калп. *лашын*, кырг. *ылаачын*, к.-балк. *илячын* id., *-чың* кушымчасы ярдәмендә ясалган кош атамалары (к. *әберчен, күгәрчен*, к. Bozqaplan: 67–68) рәтеннән булса кирәк, к. монг. *алагшан, алагшин* < төрки **алағчын* «чуар шоңкар, лачын». К. ш. ук яз. монг. *пačin*, монг. *нач, начин*, бур. *нашан* «шоңкар» ~ кор. *начжэн* «латин; шоңкар» һәм удм. *латинка* «лачын». Бу мәгълүматлар *лачын* сүзен «латин (кошы)» сүзеннән, дигән фаразга китерәләр (ССТМЯ I: 587). Ләкин моны раслар-лык тарихи мәгълүматлар билгеле түгел (Doerfer 1975: 11–14).

**Лачын** сүзе төрки-монг. телләреннән күп телләргә таралган: Кавказ телләрендә *лачен, лёчи*, фар. *лачын* һ.б. Рус. диал. *лашин* «чагалак» тур. к. Аникин: 354; Федотов I: 332. Сафина 2006: 29–31.

**ЛАШМАН, лашманчы** «человек, привлечённый к заготовке корабельного леса в XVIII–XIX вв., преимущественно из народностей Поволжья» ~ чув. *лашман* «лашман; көчле, ләкин авыр хәрәкәтле; юан; кара таракан (чаг. **Кырымзау**), кар ергыч җайланма (өчпочмак рәвешендә була)», мар. *лашман тадар, лашман эдем* «килбәтсез, ләкин көчле кеше», удм. *лашман* «бик көчле кеше», башк. диал. (БТДҺ: 220–221) *лашман* «килбәтсез; бәла, мәшәкать; авыр кузгалучан», рус. *лашман* «үзен сакал-мыек баскан кеше» (И.Г. Добродомов мәгълүматлары) һ.б. Бу сүзне рус. *лоцман* сүзеннән дә, ним. *laschetamann* «кисәсе агачларга тамга (ним. *Lasche*) салучы» сүзеннән дә чыгып аңлатып карыйлар. Ләкин иске тат. **лашман** «атлы гаскәри» (Будагов I: 186) сүзнең этимологиясен бөтенләй икенче яктан яктырта: *лашман* < иске фар. *лашбӓнд* «таран, кирмән, кальга капкаларын җимерә торган авыр бүрәнә яисә бүрәнәләр бәйләме» сүзеннән; **лашман** дип татарлар дошман җәргәләрен ера торган авыр коралланган кыяулы атлы сугышчыны да атаганнар (фар. *лаш* «авыр бүрәнә, кискә; мәет; ганимәт, улҗа») булса кирәк, к. аз. (АДДЛ: 286) *лаш* «арыш (сыңар тәртә); балка». Ниһаять, *Лаеш* топонимы белән баглап аңлату да бар (лашманнар Лаешка җыела торган булганнар). Бу фаразлар дөрес булмаган тәкъдирдә дә тарихи детальләрне искә төшерү белән кызыклы. Гомумән, **лашман** сүзе тур. күп сөйләнелгән һәм язылган.

**ЛАЯКАТЬ [лайәкәт]** «конформизм; верноподданичество» ~ башк. диал. (БТДҺ: 224) *ләйәкәт* (*ләйәкәтле*) «ышанычлы», < гар. *лā'иқат, лийāқат* id. К. **Лаек.**

**ЛАЯКЫЛ** «пьяный в стельку» < гар. *лā йа'қул* «акылдан язган» сүзеннән, *гакыл* > *акыл* белән тамырдаш.

**ЛӘБЛӘБИ** иск., **ләпләп, ләпләбә, ләпләбел** (Тумашева 1992: 145; ЗДС: 458–459) «красная свёкла» ~ аз. *ләбләби*, үзб. *лаблаби, лавлаги* id., төр. *leblebi* «борчак төре» ← фар. *лӓби, лӓбүи* «пешереп ашала торган яшелчә» сүзеннән. Башк. *ләпләмә* «җирдә туңган бәрәңге» (БТДҺ: 225) < *ләбләбә.* К. ш. ук (ТТДС II: 216) **ләүләви** «пешерелгән кызыл чөгендер».

**ЛӘББӘЙКӘ** «браво (с ироническим оттенком)», «приказывайте; слушаюсь» < гар. *лӓббӓйкӓ* «менә мин синең алдыңда» – Мәккәдә хаҗ вакытында дога буларак әйтелә торган сүз. ГТРС: 240 (бу сүзнең элекке мәгъ. генә күрсәтелә).

**ЛӘВӘШ** «мягкая лепёшка, леваш, лаваш; ритуальная жертвенная лепёшка» ~ *ләүеш, ләүәш, ләүешләмә* «бөгешнең бер төре» (к. ЗДС: 456; БҺҺ II: 165), иске тат. *lawaш* «род плоских пирожков» (Будагов II: 192) ~ мар. *лапаш* «катыкка сибелгән талкан» (Исанбаев 1978: 35) < чыгт., аз., төр., үзб. *лаваш, lawaш* << ком. *эливаш* «хәтем ашы», бор. уйг. *liv aši, livi aši* «хәтем ашы», *liv aš* «корбанлык аш» (ДТС: 333); *liv* сүзен берәүләр гар. *lif* «сый» сүзеннән, икенчеләр кыт. *li, li: jü* «ашлык» сүзеннән (Clauson: 762) диләр. **Аш** сүзе үзе «ритуаль сый» (тат. телендә хәзер дә шул мәгънәсе бар). Рус. сөйл. (к. Даль һ.б. чыганаклар) *лева, леваха, леваша* «ләвәш», *левашник* «ләвәшче», *левашня* «ләвәш пешерү урыны» сүзләре халык этимологиясе

буенча *леваш* дигәндә рус иркәләү-кечерәйтү кушымчасы *-аш* бар дип аңлатылганнан (чаг. рус. *Дуня, Дуняша → Дуняш, мама → мамаша* «әнкәй» һ.б.ш.) пәйда булганнар.

**Ләвәш ~ лаваш** рус һәм Кавказ телләре аша күп телләргә таралган сүз.

**ЛӘГӘН,** иске тат. **ләгүн** (Будагов II: 191) «медное ведёрко с ушками» ~ үзб. (ЎХШЛ: 167, 170) *лаган, ләгән, лагану*, уйг. *ләгән*, кырг., каз. диал. *лэгэн, ләгөн*, к.-калп. *ләген* һ.б., иске рус. *легин* < фар. *лäгäн, лäгäнд* «ләгән; поднос», **лагун** һәм **лакан** сүзләре (ахыр чиктә барсы да грек-лат. даирәсеннән) белән кардәш. Фасмер II: 473.

**ЛӘГЫЙНЬ [ләғин]** «проклятый» < гар. *лäʻūн* «ләгънәтләнгән». К. **Ләгънәт, Мәлгунь.**

**ЛӘГЫЛЬ** «лал, шпинель; рубин» < гар. *лäʻл* > чыгт., бор. кыпч., кр.-тат., төр. һ.б. *лал* id. сүзеннән. Чыгышы ачык түгел – бик бор. сүз һәм күп телләрдә очрый. К. **Ал, Лалә.**

**ЛӘГЪНӘТ** «проклятие» < гар. *лäʻнäт* id. *лʻн* «ләгънәтләү» тамырыннан. К. **Ләгыйнь, Мәлгунь, Нәгъләт.**

**ЛӘЗЗӘТ** «наслаждение» < гар. *лäẕẕäт* id. *лẕẕ* «татлы булу» тамырыннан, шуннан ук иске тат. *ләзиз* < гар. *лäẕūẕ* «бик татлы».

Дерив.: **ләззәтле, ләззәтсез; ләззәтлән-ү.**

**ЛӘЙСӘН** «первый весенний дождь (капли которого якобы превращаются в жемчуга)». Гомумән, бу сүз **ләйсән яңгыры** дигән тәгъбирдән эллипсис. **Ләйсән** исә *сәйлән* «вак энҗе» (рус. *бисер*) сүзеннән метатеза, к. башк. сөйләшләрендә (БТДҺ: 292) *сәйлән* «ләйсән; сәйлән». Халыкта шундый мифологема бар: имеш, ләйсән яңгыры тамчылары суга төшкәч, сәйләнгә әверелә. Бу сөйләк, күрәсең, язгы яңгырларның киләсе уңыш өчен әһәмиятле булуының чагылышы.

**Сәйлән** сүзе үзе иске төрки һәм төр. *seylan taşı* «гранатсыман бизәнгеч таш, алмандин» сүзеннән, *seylan* сүзе исә – Цейлон (утравы), гар. теленнән таралган атама. Шушы мәгълүматлардан чыгып, **ләйсән** сүзе **сәйлән**нән үзгәреп килеп чыккан дип уйларга мөмкин. Ләкин этимология шуның белән тәмамланмый икән. **Ләйсән** сүзенең икенче тамыры да бар – ул **нисан** «апрель» – фар. теленнән, фар. теленә исә Сурия яз. теленнән килә. Фар. *әбри нисан* «нисан болыты» елның уңышлы киләчәгенең галәмәте һәм, гомумән, бәрәкәтле, өметле билгеләр мәгъ.

**Сәйлән** (Цейлон) утравының атамасы Һиндстан телләрендәге *сангала, сингала* < *сайнгала* > *сайнал* дигәннән һәм шуннан ук хәз. Цейлон республикасының төп халкы – **сингал**лар атамасы да килә. Цейлон утравын һәм аны континенттан аерып торган бугаз гар. (һәм тат. да) **Сәрәндип** бугазы дип атала. Бу сүз дә **Сәйлән > Сәрән** сүзеннән (*-дип* – һинд. *двипа* «утрау» дигән сүз), ягъни бу очракта *л* > *р* күчеше (күп телләрдә очрый торган күчеш) күзәтелә.

Русча *Цейлон* вариантына килгәндә, ул инг. *Ceylon* дигән язылыштан килә, инг. язылыш, үз чиратында, португалчадан. Әлбәттә, бу сүз дә шул ук һинд. *сәйнал ~ сәйлан ~ сәйран* сүзеннән. Сүзнең тамыры төгәл билгеле түгел – бор. Һиндстан телләреннән булса кирәк. К. **Сәйлән.**

**ЛӘКАБ [ләкъәп], ләкап** «прозвище; титул, звание» < гар. *лäқаб* id. К. **Лакабый.**

**ЛӘКИН,** диал. **ликин** «но, однако» < гом. көнб. төрки (чув. юк) < гар. *лäкин* < гар. *лäкиннä* id. Бу сүз иске төрки телендә *лик* яңгырашында да кулланыла – гар. *ликн* вариантыннан; тамыры – гар. *лкн* «тотлыгу».

**ЛӘКЛӘК** «аист» < бор. кыпч. (яз. ядкәрләрендә) *лäклäк*, фар. *лаклак, лақлақ, лаглаг, лақлақа* < гар. *лақлақа* «кайгыру, кайгырып кычкыру; ләкләк» сүзеннән; рус. *леклек* төрки телләрдән; грек. *λελεχι* «ләкләк» сүзе дә гарәпчәдән булса кирәк; к. ш. ук госм., аз., кр.-тат. *ләйләк*, үзб. *лайлак, лайлақ* < бор. төрки, уйг. *лäглäк* ~ таҗ. *лаглак* id. (Räsänen 1969: 316). Гомумән, күп телләрдә очрый.

Уйг. *ләгләк* яз килү билгесе буларак карала; *ләгләк кар* «ябалак кар» ≈ тат. *карга кары.*

**ЛӘКШӘ,** диал. **лақша, ләкчә** (ТТДС I: 289, 294) «вермишель, мелко нарезанная лапша, которую готовит невеста в первый день прибытия в дом мужа» (тәүге теркәлеше Троянский сүзлегендә) ~ нуг., каз. *ылакса, улакса,* уйг. *лақша* >> рус. *лапша,* рус. диал. (Фасмер II: 460) *локша, лохша*, укр. *лапша, лакша, лакшина* < бор. төрки (ДТС: 332–333) *laqš, laqša* «бодай оны; токмач» ~ индонез. *laksa* «Кытай токмачы», күрәсең, Кытай-Тибет телләреннән, әмма безгә конкрет чыганагы билгеле түгел.

Бу сүзнең Идел-Урал телләрендә икенче бер кызыклы дәвамы бар: чув. *йашка*, удм., мар. *йашка, йашга* < мар. диал. *ляшка, ляшкä, лашка,* удм. (Насибуллин: 126) *лашка* < *лакша* (метатеза) «килен токмачы; туй ашы» ~ лак. (к. Джидалаев Н.С. О диахронии тюрко-дагестанских языковых контактов // СТ, № 3, 1970: 106) *йахша* «ләкшә». **Йашка** «аш» сүзе чувашлар белән янәшә яшәгән татарлар телендә дә очрый. Ахметьянов 1981: 87; Федотов I: 337.

**ЛӘЛӘ** «лилия» – бу сүз **лалә** (к.) сүзенең халык этимологиясенчә аңлануыннан һәм рус сүзе тәэсирендә килеп чыккан.

**ЛӘМ**, диал. (Тумашева 1992: 144–145, 157) **лам, лем, нам** «ил; жидкая глина; тина» ~ башк. *ләм* id.; тат. диал. **ләмәк** «былчырак» (ДС III: 108) ~ к.-калп. *ләм,* уйг. *нәм* (> үзб. *нам*) «юешлек, дым» < фар. *нäм* id. Гомумән, **ләм** сүзен шартлы рәвештә генә фар. алынмасы дип була, чөнки *ләм* ~ *лум* – киң таралган тәкълиди тамыр, к. мар. *лум* «өйрә, шулпа», удм. *лем* «җилем», *лым* «шулпа», чув. *лăм* «дым», мар. *лүм* «кар» ~ фин. *lima* «ләм», ним. *Lehm* «ләм, сыек балчык», *Leim* «җилем» һ.б. Чаг. ш. ук **Ләпек.**

**ЛӘМ-МИМ** «ни слова» ~ каз., к.-калп. *ләм-мим,* уйг., үзб. *лам-мим* id. – гар. хәреф исемнәре: *лям* «л» авазын белдерә һәм шул ук вакытта «юк, түгел», *мим* «м» авазын белдерә һәм шул ук вакытта «кечкенә авыз»; шулай итеп гар. *лям мим* «авыз да ачмау» мәгъ. фразеологизм килеп чыга.

**Ләм-мим** сүзе шәкертләр теленнән таралган.

**ЛӘҢ (ләң-ләң) –** подражание тявканию собачки, шуннан **ләңгелдә-ү** «тявкать» **ләңгелдек** «тявкун, шавка» – тат. телендә килеп чыккан. К. ш. ук як. *ньаң (ньаң-ньаң)* «ләң (ләң-ләң)». К. **Ләңкә.**

**ЛӘҢГӘЗ,** диал. **ләнгәч, ләнгәц, лянгыз** (Радлов III: 745; Остроумов 1876: 100; ТТДС I: 294) «тазик; кечкенә чиләк (туздан ясалган)» > чув. *ленкес* ~ удм. *лянэс*, мар. *лäнгыш, лӧныш* id. коми. *lapes* «чиләк», рус. *лянга* «капкачлы туз кумта», *лянган, лянгус* «туз чиләк», *лянгыс* «чиләк төре» (СРНГ, 17, 1981: 277) һ.б.ш. Агачтан, туздан, кайрыдан ясала торган савытларны, сыешлыкларны белдергән сүзләр гомуми фикер буенча пермь телләреннән, ул телләрдә исә *ляб, л'ап* «үзәге черек (яки куыш) кәүсә» сүзеннән (шундый агачтан һәртөрле әйберләр ясалганнар, чаг. **Күбәк**). Фасмер II: 552; Федотов I: 336–337; Аникин: 362; КЭСК: 166.

**ЛӘҢГӘР** әд. (Будагов II: 191) һәм диал. (Тумашева 1992: 145) «якорь; поплавок; балка, к которой привязаны шнурки с удочками» – елгага аркылы салынып, үзенә күп кармаклар бәйләнгән кәртәлек тур. сүз бара булса кирәк, к. чув. *ленкер* «өрлек, аркылагач» < фар. *лäнгäр* «ләңгәр; калкавыч», ш. ук «җанбаз (арканда йөрүче акробат) кулындагы авыр озын колга (ул җанбазга тигезлек сакларга ярдәм итә)». XI г. төрки телендә бу сүз «шпора» мәгъ. булган («якорь > шпора» мәгъ. күчеше аңлашылып тора – тышкы охшашлык бар). К. Ясәвидә:

*Рузы (рөхсәт) – Газазилне тотып меңдем,*
*Ләңгәр тегеп (кадап), билен басып янечтем менә!*

Гадәттә киң таралган *ләңгәр* сүзен ит. *l'ancora* «ләңгәр, якорь» сүзенә нисбәт итәләр, к. Räsänen 1969: 316. Ит. телендә *l' (le, la)* артикль, *ankora* өлеше Европа телләрендә киң таралган (к. Kluge: 46.) ним. *Anker* > рус. *анкер*, ш. ук *якорь* < лат. *ancora* һ.б. «ләңгәр; кармак». Ләкин *ләңгәр* сүзе Шәрык телләрендә (бор. төрки, фар., төр. һ.б.) киң таралуы гар. **äл-äнгäр* ← лат. (әлеге) *ancora* сүзеннән килүе ихтимал. К. ш. ук Аникин: 351–352 (*лангар* «җылым калкавычы», аннары рус. *лонгар, лангаръ, енгарь, янгарь,* хант. *läŋkär* һ.б. id. тур.; әдәбият күрсәтелә).

Гомумән, сүз башындагы *л-* ит. *l'* дәнме, әллә гар. *äl*-дәнме дигән сорау туа.

**ЛӘҢКӘ** «собачка, собака мелкой породы» – *ләң-ләң өрү, ләңгелдә-* сүзләре тәэсирендә тат. телендә ясалган, тәкълиди тамырдан.

**ЛӘП** – подражание слабому удару твёрдого по мягкому (более слабый удар или звук, чем **лап**); «ляп; шлёп» ~ чув. *леп* id. Башк. диал. *ләп* «кечкенә җәнлекләрнең кардагы эзе» (БТДҺ: 224) сүзе дә *ләп* тәкълиди сүзенә кардәш булса кирәк. к. ш. ук уйг., кырг. *ләп, ләп-ләп* «күбәләк канат кагуына тәкълит, леп-леп»; охшаш сүзләр фин-угор телләрендә дә бар, к. удм. *ляб* «зәгыйфь, тын, тыныч», рус. *ляп* «әйтеп ташлау». К. **Ләпәк II. Ләпек, Ләпелдә-ү.**

Дерив.: **ләпелдә-ү, ләпкелдә-ү; лепелдек** һ.б. ЗДС: 458–459.

**ЛӘПӘК I** «мошка, мошкара» ~ башк. (БТДҺ: 225) *ләпәк, лепек, ләпән, ләпәҫ, ләпкә* «ләпәк, сукыр чебен» фин-угор телләреннән, к. мар. *лымэ, лыбэ*

«ләпәк», *лепене, лыбе, лыве*, удм. *нымы*, коми. *ном* id., ш. ук «(кечкенә) күбәләк»; чув. *лĕпĕ, лĕпĕш* «(кечкенә) күбәләк», *лĕпĕç* «күбәләк очышы» һ.б. (Ашмарин VIII: 138–140) мар. субстратыннан. КЭСК: 193; Федотов I: 337 (чув. *лĕпĕ* сүзенә без китермәгән фин-угор параллельләр китерә).

**ЛӘПӘК II** диал., ш. ук **ләпән, ләпәшә, ләпәшкә, ләпкә** һ.б. (ТТДС I: 295; БТДҺ: 224–225) «низенький, приземистый» < *лапак* id. К. **Лап, Лапай-у, Лапакай, Тәбәнәк.**

**ЛӘПЕК** «слякоть; жижа; вязкая глина для замазывания щелей» ~ мар. *ляпы* «кесәл», *ляпӓш* «боламык» – **ләп** тәкълиди тамырыннан. Чаг. рус. *ляпать* «сыек балчык белән сылау» һ.б.

**ЛӘПЕШ** диал. «мокрый снег под ногами» ~ мар., чув. *лапӓш, лепĕш* һ.б.ш. id. Идел-Урал сүзе.

Дерив.: **ләпешек, ләпшек** «көпшәк»; **ләпшәй-ү** «формасын югалту (башта – су сеңдерүдән)» һ.б. сөйләшләрдә охшаш сүзләр күп табыла.

**ЛӘТАФӘТ** кит. «изящество; красота, соединения с мягким нравом и умом», **ләтыйф** «любезный, милый и умный», **ләтыйфә** «любезная, милая и умная» (гади сөйләмдәге **латыйп, латыйфа** – кеше исемнәре дә – шуннан) < гар. *лӓṭӣф, лӓṭӣфӓ* id. ← *лṭф* «игелекле һәм кеше хәленә сизгер булу» тамырыннан. Шул ук тамырдан ясалган бүтән әд. сүзләр дә бар. Шуларның берсе *латыйфӓ* > **латифә** «йомшак көлке, анекдот» барча төрки әд. телләрдә кулланыла. Мәс., *Хуҗа Насретдин латифәләре* диелә (шул исемдәге китаплар чыгарылган һәм нәшер ителә).

Дерив.: **ләтафәт былбылы** «үткен, тапкыр сүзле шагыйрь», аеруча «сүзгә оста гүзәл, актриса», гар. телендә ясалган.

**ЛӘТЕ** (Тумашева 1992: 145) «осадок масла, керосина», күч. себ. тат. (к. Будагов II: 187) **ләт** «непроданный и безнадёжно устарелый товар». Чаг. түбәндәгене.

**ЛӘТТӘ** иск. «специальная подушечка для стирания написанного в медресе» < чыгт., бор. төрки (к. Räsänen 1969: 315) *latta* «чүпрәк; тукыма кисәге; постык»; хәз. кырг., уйг. *лата* гына диелә. Чаг. ш. ук куман. *ласт [last]* «сүс, ефәк калдыгы, ефәк чүпрәк» һ.б. Гомумән, *латта, ләттә* «чүпрәк» фар. теле даирәсендә дә киң таралган.

**ЛӘТЧӘ,** диал. **йәтчә,** (ЗДС: 459) **лачча, ләшшә** «ласка (зверёк); маленькая злая женщина» ~ башк. *ләтсә, йәтсә* id. < рус. *ласица* ~ гом. слав. *ласица, ласка, ласа* (Фасмер II: 461); шунысы кызык: Троянский сүзлегендә *алтча* «ләтчә» (Троянский I: 62).

**ЛӘҮ [ләw]** «дракон» << уйг. *ләү* < бор. төрки, фар. *lu, lü, lüj* < кыт. *lūŋ* id. (ДТС: 334) > бур. *луу*, бор. монг. *luu* id. **Ләү** бор. төрки уникеellлык циклда бер ел, аннары ай һәм чак (ике сәгатьлек берәмлек) атамасы. *Ләү ае* «яңгырлы-буранлы була», шуннан башк. диал. *ләүән ае* «март». Кыт. *лун, луоң* < тибет. *klu* «аждаһа» тур. шактый зур әдәбият бар. Мәс., Doerfer 1975 IV: 15–17. Яхонтов С.Е. Начальные **l** и **r** в древнекитайском языке // Востоковедение 2. Л., 1976: 78–87; МНМ II: 73–74; 77–78. К. **Шүлгән.**

**ЛӘҮКӘ [ләwкә],** диал. **эләүкә** «полок в бане» ~ чув. *лапкаçи*, мар. *лапка* id. < рус. диал. *лавка* id. (к. ш. ук **Лафкы**); удм. *лапча* id. < рус. *лавица.*

**ЛӘҮЛӘ-Ү [ләwлә-]** «полыхать» ~ каз. *лаула-у* id., к. Нәваи телендә *лаw* «ялкын теле» (Боровков 1961: сүзлек) < **Ләү** (?).

**ЛӘХЕТ** «подбой в могиле (по мусульманскому обычаю)» < гар. *ләхд* id. > каз. (ҚТДС: 227), нуг. *лахат,* к.-калп. *ләхәт.*

**ЛӘЧ** (ЗДС: 459) «непропечёный, сыроватый (о хлебе); мокрый насквозь» ~ башк. *ләс* id. ~ диал. *ләчкә, лачка, тачка*, мар. (Иванов, Тужаров: 113) *ляцкӓ, лачка*; чаг. *лач, лыч* – бик нык җебү, сулану (киемнәр) тур.; каз., к.-калп. *ылас* «лач». Гомумән, күп вариантлы: **ләчләтә, ләчтекә, ләчкелдәгән** һ.б. К. **Лач, Лачка, Тачка.**

**ЛӘЧТИТ: ләчтит сату** «болтать; нести чепуху; судачить без толку» – букв. «продавать ластики», к. ш. ук башк. (БТДҺ: 225) *ләстит сәйнә-ү* «юкбар сүз сөйләү» – букв. «жевать ластики (резиновую жвачку)», *ләстит* «буш сүз» << рус. **ластик** (XIX гасырда таралган сүз) < фр. *elastique* «эластик» – ахыр чиктә грек сүзе, к. Фасмер IV: 517. К. **Лачтык.**

**ЛӘШКӘР** тар. «многочисленное войско; ополчение» < гар. *äл-ʻаскӓр* сүзеннән фар. телендә кыскарган, к. **Гаскәр.** Будагов I: 188–189.

**ЛӘЮСАН** («Мөхәммәдия» телендә һ.б.) «некое животное, которое несёт на рогах землю; бык, на котором держится земля» < бор. яһ. *liwjathan* ≈ *лиwйаçан* > рус. (ним., фр. телләре аша) *левиафан* – мифик хайван, кайбер сөйләкләрдә – «коточкыч зур кеше».

**ЛЕП, леп-леп** – имитатив мягкому, тёплому воздействию (воды), мягкому удару (сердца), взмаху крыльев бабочки ~ чув. *лĕп*, мар. *леп, леп-леп, луп* – гом. фин-угор, гом. төрки характердагы сүз, к. кырг. *лэп-лэп*, уйг. *лип-лип* id. һ.б. болар төрки һәм фин-угор телләренә аеруча хас булган тамырдан.

Чаг. **Лып.** К. **Лепелдәк, Лепелдә-ү, Лепер.**

**ЛЕПЕЛДӘК** «лепесток; крыло бабочки; нечто порхающее; мелкая бабочка с мохнатыми крылышками» ← **лепелдә-ү** (к.).

**ЛЕПЕЛДӘ-Ү, лепкелдә-ү** «мягко хлопать на ветру (о лепестках), махать крылышками (о бабочке); мягко биться (о сердце)» ← *леп* (к.); шуны әйтергә кирәк, **ләп//леп//лип** тәкълиди сүзе күп һәм төрле телләрдә очрый, чаг. рус. *лепет*, ир. *lapak, lapka* «лепелдәү; пульс; чишмә» һ.б. Фасмер II: 483–484.

**ЛЕПЕР** – имитатив шелесту; очень негромкому журчанию, кипению и т.п. ← **леп** (к.).

Дерив.: **лепер-лепер; лепердә-ү.**

**ЛЕПКӘ**, иск. (Троянский I: 66) **әлфкә**, диал. (Радлов III: 767) **лүпкә** «родничок, венец (младенца)» ~ башк. (БТДҺ: 221, 225) *лепке, ләпкә* ~ мар. *лĕп, лĕпкӓ, лэпкӓ, лĕплү* (*лу* «сөяк, кимерчәк»), чув. *лĕпке* id. М. Рясянен фикеренчә (Räsänen 1969: 94), фин-угор (мари) теленнән таралган. Безнеңчә дә, түбәндә мар. *лыпке* > чув. *лăпка* «тын; йомшак; нәфис» сүзе белән бердәй – **лепкә** – бәбинең иң нәфис, аяулы төше. Тат., чув., башк. телләренә бу сүз фин-угор субстраттан калган. К. ш. ук Федотов I: 338. К. **Леп.**

**ЛИВА** тар. «знамя; герб» < гар. *лиwā'* id.; к. ш. ук иске тат. **мири лиwә, мир әлwиә** «губернатор» < гар. *āмир ăл-лиwā'* «генерал-губернатор; флагман; адмирал» >> **адмирал.** Будагов II: 191–192.

**ЛИМОН, лимун** «лимон» < рус. *лимон* < ним., фр. *lemon,* ит. *limone* < фар.-төр. *лимун* < гар. *лăймӯн, лăмӯн* – ахыр чиктә Һиндстан телләреннән, к. Фасмер II: 497. Тат. **лимун** турыдан-туры фарсычадан булуы да ихтимал.

**ЛИШАЙ** «лишай (кожная болезнь)» < рус. (гом. слав. сүзе).

**ЛИШУН** тар. «лишённый права быть избирателем и избираемым – о выходцах из эксплуататорских классов в 20–30-х гг. XX века в СССР» – рус. *лишён прав* сүзеннән кыскартылып үзләштерелгән.

**ЛУМ** «лом» < рус., әлбәттә.

**ЛЫБЫ** (Остроумов 1876: 100; ТТДС I: 292) «корзина из лыка» ~ чув. *лăпă* «печән төяп күтәрү өчен юкә җайланма (бик эре күзәнәкле кәрзин); бау челтәр» < мар. *лупо* «лыбы», *лыве, лĕвĕ* «кайнатып йомшартылган каез». Федотов I: 335 (кирәксезгә рус. *липа* «юкә» сүзен искә ала).

**ЛЫБЫР, лабыр** – имитатив состоянию и звукам от жижи, а также косноязычному бормотанию.

Дерив.: **лыбыр-лыбыр; лыбыр-лабыр; лыбырда-у; лабырда-у**; к. **Лабыр.**

**ЛЫГЫР, лагыр** – имитатив болтовне ~ чув. *лакăр* «быгырдау»; гом. төрки характерга ия; чаг. **Лык, Лыкы-лыкы.**

Дерив.: **лыгыр-лыгыр, лыгыр-лагыр** һ.б.ш. **лыгырдау, лагырдау, лыгырдык, лагырдык**; чаг. кр.-тат., к.-балк., төр. *лакырды* «лыгырдау; буш сүзләр». Идиома: **лыгыр сату** (к. ДС III: 107); Федотов I: 334 (бик аз әйтелә).

**ЛЫК** – имитатив переполненности, а также громкому редкому бульканию, **лык булганчы** «до отвала» ~ чув. (Ашмарин VIII: 10) *лăкă, лăк* ~ гом. кыпч. *лык,* үзб., уйг. *лиқ* «лык», ш. ук – кайнауга тәкълит. Федотов I: 333.

Дерив.: **лык-лык.** К. **Лыкы-лыкы, Лыкырым.**

**ЛЫКЫ-ЛЫКЫ** – имитатив болтовне ~ чув. *лăкă-лăкă* – чайкалуга имитатив. К. **Лыгыр.**

Дерив.: **лыкылда-у; лыкырда-у** һ.б. Федотов I: 334.

**ЛЫКЫРЫМ, лыгырым, лыгрым** – имитатив переполненности ← **лык.**

**ЛЫП I,** диал. **леп** – имитатив тихому состоянию; **лып булды** «утих, затих (чаще о разбушевавшемся человеке)», **лып кына** «тихонько» ~ чув. *лăп* «тыныч-зәгыйфь», мар. *лып, лыпке* id. (→ *лыплан-* «тынычлану», *лыпландар-* «бастыру, тынычлау, тындыру»), фин-угор сүзе булса кирәк, к. **Леп, Лепкә.**

**ЛЫП II –** имитатив падению плашмя; **лып итеп утырды** «уселся (широким) задом» ~ чув. *лăп* id. ~ мар. *лыпша-* «шапылдату; кагыну (кошлар тур.) һ.б.

**ЛЫШ, лыш-лыш –** подражание шмыганию носом: «шмыг»; шуннан *лышык-лышык (елау), лышкылда-у, лыштырдау* (*лыш-лыш* килеп нидер эшләү) һ.б.

Тат. сөйләшләрендә тагын **лыштырда-у, лыстырда-у, лычырда-у, лычтырда-у** һ.б. тәкълиди сүзләр дә очрый.

**ЛЯШӘЙ** иск. (М. Гафури һ.б.) «ничто; ничего не значит» < гар. *лā шăй* «шәй түгел; берни түгел»; иске әд. телдә (бигрәк тә шәкертләр телендә) киң таралган булган (хәз. *ничава* мәгъ.).

## ЭЧТӘЛЕК

Сүз башы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
Сүзлек мәкаләсенең төзелеше . . . . . . . . . . 7
Этимология турында . . . . . . . . . . . . . . 11
Сүзлеккә кереш . . . . . . . . . . . . . . . . . 38
Библиография . . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
Шартлы кыскартмалар . . . . . . . . . . . . . 65
Сүзлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68

Справочное издание

**Ахметьянов** Рифкать Газизянович

**ЭТИМОЛОГИЧЕСКИЙ СЛОВАРЬ
ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА**

**В двух томах**

**Том I (А–Л)**

Казань. Издательство «Магариф — Вакыт». 2015

Белешмә басма

**Әхмәтьянов** Рифкать Газизҗан улы

**ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ
ЭТИМОЛОГИК СҮЗЛЕГЕ**

**Ике томда**

**I том (А–Л)**

Редакторы
Бизәлеш редакторы
Компьютерда биткә салучы *Н.Т. Абдуллина*
Корректоры

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 10.04.2015.
Форматы 84 x 108 1/16. Офсет кәгазе. «Times New Roman» гарнитурасы.
Шартлы басма табагы 34,0. Тиражы 1000 д. Заказ

«Мәгариф – Вакыт» нәшрияты
E-mail: valeevmx@mail.ru
http://magarif-vakyt.ru

Отпечатано в полном соответствии с качеством предоставленного
электронного оригинал-макета в типографии филиала ОАО «ТАТМЕДИА»
«Пик «Идел-Пресс».
420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2.
E-mail: idelpress@mail.ru